ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

## II том
## Г–Й

Казан • 2016

УДК 811.512.145'374.3
ББК 81.2Тат-4
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

«2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

*Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы законнары белән саклана (РФ ГК, 4 өлеш). Китапны тулысы белән яки өлешчә, төрле, шул исәптән, электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки яздырып алу, сурәтен төшерү авторлык хокукына ия юридик затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела*

**Проект җитәкчесе –** А.Ә. Тимерханов

**Төзүче авторлар:**

И.И. Сабитова, Ф.И. Таһирова, А.М. Сәгыйтова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Г. Саберова, Л.Ш. Шәмсетдинова, Г.Р. Сәмирханова, Э.И. Сафина

**Фәнни редакторлар:**

Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова

**Бәяләүчеләр:**

*Д.Б. Рамазанова*, филология фәннәре докторы, профессор (ТӘһСИ);
*Казан (Идел буе) федераль университеты Лев Толстой исем. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар тел белеме кафедрасы*
(мөдире – Г.Р. Галиуллина, филология фәннәре докторы, доцент)

**Т 23 Татар теленең аңлатмалы сүзлеге:** II том: Г – Й. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 748 б.
ISBN 978-5-93091-205-0

II томда барлыгы 11 меңгә якын сүз һәм 2300 дән артык фразеологик берәмлек теркәлде. Төп фигыль оясында мәгънә төсмерләренә ия булган тезмә фигыльләр дә исәпкә алынды. Сүзлек хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасы һәм фразеологиясеннән, төрле фән һәм хуҗалык тармакларына караган термин, атамалардан гыйбарәт. Анда соңгы вакытта татар теленең үз мөмкинлекләре исәбенә ясалып, кулланышка кереп киткән неологизмнар, кабат торгызылган сүзләр, телне баетырдай диалектизмнар, алынмалар да чагылыш тапты.

**ISBN 978-5-93091-205-0**
© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2016

## СҮЗ БАШЫ

Татар теленең күп томлык фундаменталь аңлатмалы сүзлеге лексикография бүлегендә әзерләнә. Аның I томы (Казан, 2015, 712 б.) А – В хәрефләренә башланган сүзләрне эченә алды. II томга Г – Й хәрефләренә башланган сүзләр кертелде. Сүзлеккә кагылышлы белешмә материаллар I томда бирелде.

Проектның гомуми координаторы һәм җитәкчесе – А.Ә. Тимерханов.

Сүзлекнең II томын төзүдә түбәндәге хезмәткәрләр катнашты: **Г хәрефе:** Ф.И. Таһирова; **Д хәрефе:** А.Ф. Гайнетдинова; **Е, Ж, Й хәрефләре**: А.М. Сәгыйтова; **Җ хәрефе**: Г.Г. Саберова, Э.И. Сафина, Г.Р. Сәмирханова; **З хәрефе:** Л.Ш. Шәмсетдинова; **И хәрефе:** И.И. Сабитова.

II томны түбәндәге хезмәткәрләр редакцияләде: Г.Г. Саберова – Г, Д, Җ, З хәрефләрен; Ф.И. Таһирова – И, Й хәрефләрен; Ф.Ф. Гаффарова – тулысынча.

Е, Ж, Җ, З, Й хәрефләренә тезмә фигыльләр өстәп төзүче, томны алфавитка салу һәм басмага әзерләү эшләрен башкаручы – Ф.Ф. Гаффарова. Томны техник редакцияләү һәм нәшриятка әзерләүдә Я.М. Абдулкадыйрова һәм Р.Т. Сәфәров катнаштылар.

Авторларның исемнәрен күрсәтү тәртибе аларның сүзлек төзүгә керткән өлешләрен исәпкә алып билгеләнде.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*а.* – алмашлык
*авиа.* – авиация
*агроэкол.* – агроэкология
*анат.* – анатомия
*артык.* – артыклык (дәрәҗәсе)
*археол.* – археология
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономия
*а. х.* – авыл хуҗалыгы
*әд.* – әдәбият термины
*әрл.* – әрләү
*баш. кил.* – баш килеш
*бәйл.* – бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*берл.* – берлек сан
*биол.* – биология
*биохим.* – биохимия
*б-сез.* – билгесезлек
*бор.* – борынгы (сүз)
*бот.* – ботаника
*бүл. саны* – бүлем саны
*вет.* – ветеринария
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*геол.* – геология
*геом* – геометрия
*грам.* – грамматика
*дәр.* – дәрәҗә
*диал.* – диалекталь сүз
*дини* – дини сүз
*диңгез.* – диңгезчелек термины
*жарг.* – жаргон
*җый. и.* – җыйма исем
*җыр* – халык җыры
*зоол.* – зоология
*з.-сыз* – затланышсыз (фигыль)
*и.* – исем
*икът.* – икътисад
*информ.* – информатика
*ирк.* – иркәләү сүзе
*ирон.* – ироник мәгънәдә
*иск.* – искергән сүз
*иял. кил.* – иялек килеше
*иярт.* – ияртем
*иҗт.* – иҗтимагый
*йөкл. юн.* – йөкләтү юнәлеше
*к.* – кара
*кбт. форм.* – кабатлаулы формада
*кайт. юн.* – кайтым юнәлеше
*карг.* – каргау (каргыш) сүзе
*кер. сүз* – кереш сүз
*кеч.* – кечерәйтү
*килеш* – килеш (формасында)
*ким.* – кимлек дәрәҗәсе
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кино* – кинематография
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*комп.* – компьютер
*көч.* – көчәйтү
*кулин.* – кулинария термины
*күпл.* – күплек санда
*күрс.* – күрсәтү
*куч.* – күчерелмә мәгънәдә
*лингв.* – лингвистика
*лог.* – логика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус термин
*мәгъ.* – мәгънәдә, мәгънәсендә
*мәс.* – мәсәлән
*мед.* – медицина
*метеор.* – метеорология
*микробиол.* – микробиология
*минер.* – минералогия
*миф.* – мифология
*мод. сүз* – модаль сүз
*мод.ф.* – модаль фигыль
*мөн.* – мөнәсәбәтлек (сүз)
*муз.* – музыка
*мыск.* – мыскыллау сүзе
*неол.* – неологизм
*нәфр.* – нәфрәтләнү
*пед.* – педагогика
*психол.* – психология
*радио* – радиотехника
*рәв.* – рәвеш
*рәсм.* – рәсми
*ритор.* – риторик
*с.* – сыйфат
*сан* – сан

*сәнг.* – сәнгать
*сәяси* – сәяси термин
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләм телендә
*спорт* – физкультура һәм спорт
*сын.* – сынлы (сәнгать)
*тар.* – тарихи
*тарт. форм.* – тартымлы формада
*тасв.* – тасвири сәнгать
*тәрт. саны* – тәртип саны
*театр* – театр сәнгатенә караган сүз
*терк.* – теркәгеч
*тех.* – техника термины
*типогр.* – типография термины
*тирг.* – тиргәү сүзе
*төзел.* – төзелеш термины
*төш. кил.* – төшем килеше
*төш. юн.* – төшем (юнәлеше)
*туп.* – тупас сүз
*урт. юн.* – уртаклык (юнәлеше)
*у.-вак. кил.* – урын-вакыт килеше
*ф.* – фигыль
*фарм.* – фармацевтика
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*филос.* – философия
*финанс.* – финанслар
*фольк.* – фольклор
*форм.* – формасында
*фото.* – фотография
*функ.* – функция
*хим.* – химия
*хуплм.* – хупламау
*хупл.* – хуплау
*хурл.* – хурлау
*хәб. функ.* – хәбәр функциясендә
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хәрби* – хәрби сүз
*чаг.* – чагыштыру
*чыг. кил.* – чыгыш килеше
*шаярт.* – шаярту сүзе
*шелт.* – шелтәләү сүзе
*шигъ.* – шигъри сөйләмдә
*шөб.* – шөбһәләнү
*ы.* – ымлык
*эвф.* – эвфемизм
*энд.* – эндәш сүз
*электро.* – электротехника
*эпис.* – эпистоляр стиль
*этн.* – этнография
*юг.* – югары стиль
*юкл.* – юклык
*юн.* – юнәлеш
*юн. кил.* – юнәлеш килеше
*юр.* – юридик термин
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

**Чыганак телләрнең кыскартылмалары**

*алб.* – албан теле
*амхар* – амхар теле
*әрм.* – әрмән теле
*баконго* – баконго теле
*бурят* – бурят теле
*венг.* – венгр теле
*гар.* – гарәп теле
*голл.* – голланд теле
*гр.* – грек теле
*груз.* – грузин теле
*ингл.* – инглиз теле
*исланд* – исланд теле
*исп.* – испан теле
*ит.* – итальян теле
*кельт* – кельт теле
*кечуа* – кечуа индеецлары теле
*коми* – коми теле
*кыт.* – кытай теле
*лат.* – латин теле
*литв.* – литва теле
*малая* – малая теле
*мар.* – мари теле
*монг.* – монгол теле
*мордв.* – мордва теле
*нем.* – немец теле
*пол.* – поляк теле
*португ.* – португал теле
*румын* – румын теле
*рус* – рус теле
*саам* – саам теле
*санскр.* – санскрит теле
*сканд.*– скандинав телләре
*слав.* – славян телләре
*тамил* – тамил теле
*тат.* – татар теле
*төрек* – төрек теле
*төрки* – борынгы төрки сүз
*тунг.* – тунгус теле
*тупи* – тупи теле
*удм.* – удмурт теле
*уйг.* – уйгур теле
*укр.* – украин теле
*үзб.* – үзбәк теле
*фар.* – фарсы теле
*фин* – фин теле
*фин-угор* – фин-угор телләре
*фр.* – француз теле
*һинд.* – һинди теле
*чех.* – чех теле
*эст.* – эстон теле
*як.*– якут теле
*яп.* – япон теле
*яһүд* – яһүд теле

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Аа** | **Дд** | **Зз** | **Мм** | **Пп** | **Үү** | **Чч** | **ь** |
| **Әә** | **Ее** | **Ии** | **Нн** | **Рр** | **Фф** | **Шш** | **Ээ** |
| **Бб** | **Ёё** | **Йй** | **ң** | **Сс** | **Хх** | **Щщ** | **Юю** |
| **Вв** | **Жж** | **Кк** | **Оо** | **Тт** | **Һһ** | **ъ** | **Яя** |
| **Гг** | **Җҗ** | **Лл** | **Өө** | **Уу** | **Цц** | **Ыы** | |

# Г

**ГА** *и. рус сөйл. иск. Гектар* сүзеннән кыскартылма. *Сабаныгыз ничә га?* Т.Гыйззәт

**ГАБА** *и. гар. иск.* Плащка охшаш йон өс киеме. *Габа кияр, үз-үзен суфи белер.* М.Колый

**ГАБАРДИН** *и. фр.* **1.** Пальто яки костюм тегү өчен кулланыла торган, йон, ярым йон яки киҗе-мамык тукыма төре. *Матбугатта габардин, коверкот, бостон, диагональ, шевиот, драп, бәрхет ише чын табигый тукымаларны китте яманлау, китте яманлау!* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Ул киемнәр! Габардин костюм, затлы күлмәк, затлы галстук, запонкалар.* М.Мәһдиев. *Тавил теге яктан хром пальто, велюр эшләпә киеп чыкты. Кулында хуҗабикәнең карасу-күк төстәге габардин пальтосы иде.* Х.Камалов. --- *туза белмәс габардин һәм бостон костюмнар, киң каптыргычлар һәм галстук булавкалары... Болар игътибарлы кешегә кием хуҗаларының язмышы турында бик күп нәрсәләр сөйли иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГАБАРИТ** *и. фр. махс.* **1.** 1) Машина, күпер, бина, вагон кебекләрнең тышкы чик сызыгы. *Вагоннарның габариты өч тапкырга артачак.* М.Хәсәнов. *Вертолётның габарит утлары сүнгән, чөнки аларның дошман өчен бер дигән мишень булып куюы ихтимал.* З.Мәхмүди. *Тавыш һәм ут индикациясе, габарит утлары һәм транспорт фаралары, пыяла чистарткыч һәм электро-гидробүлгеч эшләми.* Урып җыю машиналары

2) Гомумән нинди дә булса объектның зурлыгы, күләме. *Аннан, Сафия белән мин мәҗлесләргә ни-ни. Аның габариты не позволяет. Слишком тазарды.* Н.Гыйматдинова. *Йөкнең габаритлары документларда күрсәтелергә тиеш*

3) Поездлар иркен үтеп йөри алсын өчен, тимер юл тирәсендә корылмалар төзергә яки әйберләр куярга рөхсәт ителми торган аралык. *Тимер юл буенда төзелеш алып барганда, габаритларны истә тотарга кирәк*

4) Әйбернең үз зурлыгындагы моделе. *Иң әүвәл фанердан габаритлар ясап карадылар*

**2.** *с. мәгъ.* Объектның габаритларын (*1, 2 мәгъ.*) билгели торган, габаритларын (*1, 2 мәгъ.*) күрсәтә торган. *Габарит сигналлар алда – ак, артта кызыл төстә була.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Габарит капка*

**ГАБАРИТЛЫ** *с.* 1) Үзеннән алда килгән сүзләрдә белдерелгән күләмдәге. *Авылның инде ябылган иске зиратында зур габаритлы дистәләрчә кыргый ташлардан куелган ләүхәләр бар.* М.Әхмәтҗанов. *1938 елда Германиядән кайтарылган шактый зур габаритлы ангар эксплуатациягә тапшырыла.* Р.Ибраһимов. *Күкрәк, куна такта кебек, киң габаритлы күренә.* М.Галиев

2) Зур күләмле. *Габаритлы йөкләрне ачык һавада саклау*

**ГАБӘС** *и. гар. иск.* 1) Уен

2) Файдасыз эш, буш нәрсә, юк нәрсә. *Әмма исраф шулдыр ки, габәс вә намәшругъ урынга хәреҗ итү...* К.Насыйри. *Габәс үткәрмәгәйлем маһ вә сали. Тәрәккъый идәлем, идеб тәгали.* Г.Тукай

**ГАБДИЯТ** *и. гар. иск.* 1) Коллык

2) Бәндәлек, табынучанлык. *Булды заһир, белмәделәр җир йөзе мөнкирләре: Монда габдият, гыйбадәтнең илаһи серләре.* Г.Тукай

**ГАБЕД** *и. гар. иск.* 1) Кол. *Әфәндем хәзрәтенә гаҗизанә Бу тәкъдим итдегем шу бер фәсанә Тәлид килек габед гаҗизедер, Хосуле хирси фикер начизедер.* Дәрдемәнд. *XVI–XVII гасырда татар алпавытлары кулындагы татар крестьяннары мөселман шәригатендәге «габед – кол» хокукында булып, аларны саваплык өчен азат итәргә яисә васыять итеп калдырырга була...* Г.Гобәйдуллин

2) *дини* Бәндә, кеше. *Хәтта тәкълид без габедләргә гыйбадәттер дидем.* Ш.Бабич

**ГАБИ** *с. гар. иск.* Аңгыра, зиһенсез, акылсыз. *Дәресе вә сүзе бик әсәрле иде. Тып-томал габи булмаган шәкерт аның дәресеннән һичбер истифадә кылмый калмас иде.* К.Насыйри. *Һәнүз кәлмеш җиһанә бер сабыйдыр, Әдибләр дөркисендә бер габидер.* Дәрдемәнд

**ГАБИД** *и. гар. иск.* 1) Гыйбадәт кылучы кеше, гыйбадәттәге кеше // гомумән, Аллага табынучы, диндар кеше. *Бер кичәдә бер гүзәл хатын мәгарәгә килеп, мине мәгарәңә керт дип, габидтән риҗа итте, ләкин габид илтифат итмәде, һаман гыйбадәте белән мәшгуль булды.* К.Насыйри. *Кәбәш шаһы ун елдан соң бер габидне күрмеш. Бу габид шаһга сөйләмеш.* Ф.Халиди. *Габид булгач, кирәк булмас дөнья малы, Кайгылардан, хәсрәтләрдән күңел хали...* Г.Харис

2) Буйсынып яшәүче, кол

**ГАБИДӘ** *и. гар. иск.* Габид хатынкыз. *Бер көн Сөләйман галәйһиссәлам --- шәһәр янында булган ике зур әһрашны күреп һәм ташдан үскән габидә башыны күреп --- сөаль кылмыш ---.* Ф.Халиди

**ГАБИДЛЕК** *и.* Табыну, гыйбадәт кебек эш-гамәлләр. *Караңгы бер мәгарәңне йортың итеп, Габидлеккә, заһидлеккә башыңны сал.* Г.Харис

**ГАБИЛЕК** *и. иск.* Аңгыралык, зиһенсезлек. *Гаҗәп түгел сабый итә сабыйлык, гаҗәптер әмма галәмдә габилек.* Дәрдемәнд

**ГАБТА ИТҮ** *ф. иск.* Кызыгу, көнләшү. *Ганганә мәдәниятләре нык булган милләтләрдәге габта ителерлек бик күп хәлләрдән берсе.* Ф.Әмирхан

**ГАБТА́ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **габта итү**. *Аларның хәлен габта кыла.* М.Гафури

**ГАВА́Й ГИТАРАСЫ** *и.* Махсус пластинка-плектр белән чиртеп уйнала торган алты кыллы гитара. *Шуннан соң Фирая диван өстендә яткан гавай гитарасын эләктереп ала да, ярсып: – Юк, алай сукмыйлар аны, менә болай сугалар! – дип, куплетчының нәкъ баш түбәсенә китереп тондыра ки, хатын кулында гитараның бары озын сабы гына торып кала.* Ә.Еники. *Сак кына, кыюсыз гына булса да, гавай гитарасының гөнаһлы авазы да, хәтер шикелле булып, каяндыр килә.* Ә.Баян

**ГАВАМ** *и. гар.* 1) Халык, халык массасы. *Иптәшләреннән аерылу гавамнан аерылу түгел.* Г.Коләхмәтов. *Мәчетләрдә гавам аңларлык татарча вәгазьләр сөйләнсә иде.* Ш.Маннур. *Мәсәлән, гавамнан берәү җырлый: «Сандугачлар су ташый, кайда икән су башы».* Х.Ярми

2) Түбән катлау кешеләре; изелгән халык. *Ә гавам шул коллыкка эләкмәс өчен, эләккәч – азат булыр өчен көрәшә.* Г.Коләхмәтов. *Бу әсәрдә мөгаллимнәрнең әхлак вә кыяфәтләре, анларның үзләре белгән аз мәгълүматлары илә бик зур эшләр күрсәтергә иҗтиһадлары, анларның гавам илә бу хакта көрәшүләре --- тасвир ителмештер.* Г.Камал. *--- соңгы инкыйлабка кадәр Төркиянең зыялы сыйныфы илә гавам (эшче вә крестьян сыйныфлары) арасында өлфәт вә мәгашәрәт юк дип әйтерлек иде.* С.Рахманколый

3) Надан халык. *– Гавам гайбәтен җыеп йөрергәме?! – дип бик гаҗәпләнде Рәшидә.* М.Маликова. *Гавам үтә надан һәм аңсыз, төрле эт җаннар коткысына колак салып, бушбугазлар корбанына әйләнүе дә ихтимал.* Т.Әйди

**ГАВАМИ** *с. гар.* Халыкчан, гади халыкка, массага якын, шуңа караган. *Минем телем – ... Гавами ул, Бик гади ул.* Р.Фәйзуллин. *--- шагыйрь [Равил Фәйзуллин], аеруча җитмешенче еллар ахырыннан башлап, иң гавами дип аталырлык шигырьләрендә дә барыбер нинди дә булса шәхесне күз алдында тота ---.* Н.Гамбәр. *Гавами тел булырак, төрки телнең никадәр тотрыклы икәненә тагын бер гыйбрәтле мисал бу.* М.Галиев

**ГАВАМИЛӘШТЕРҮ** *ф. иск.* Гадиләштерү, халыкчанлык сыйфаты бирү, халыкка якынайту. *--- «народниклык» дип, руслар гавам мәнфәгатен алга куючы, фәнне, сәнгатьне гавамиләштерергә хезмәт итүче бер фирка һәм мәсләккә әйтәләр.* Җ.Вәлиди

**Гавамиләштерә бару** Торган саен ныграк гавамиләштерү

**Гавамиләштерә башлау** Гавамиләштерү юлына басу

**Гавамиләштерә килү** Электән, системалы гавамиләштерү

**Гавамиләштерә төшү** Бераз гавамиләштерү

**Гавамиләштереп бетерү** Артык гадиләштерү, ялган халыкчанлык төсмере бирү

**Гавамиләштереп җибәрү** Бераз гавамиләштерү, халыкчанлык төсмере бирү

**ГАВАМИЛЕК** *и. иск.* Халыкчанлык, гадилек. *--- бунтларның асыл табигатендә, рухани төзелешләрендә шундый бер гавамилек бар.* Җ.Валиди. *Иштә бигрәк ушбу ике хасыяте өчен халыкның аңлы кыйсьме аны бөтен заһри гадилегенә, гавамилегенә карамыйча, әдип дип таный вә аның сәҗгысыз, кафиясез асәрене «шигырь» диеп атый.* Җ.Вәлиди

**ГАВАМИЯТ** *и. гар. иск.* Гади халык, гавам; кара халык, түбән катлам. *--- татарның мәдәни вә иҗтимагый хәяты мәсләкне алай гавамият кеби аерым фикерләргә тәхәссыс кылырга мөсагыйд түгел.* Җ.Вәлиди

**ГАВА́МЧА** *рәв.* **1.** Гади халык телендәгечә, халык массасы сөйләшкәнчә. *Әйа, дустлар, якын дустлар! Гаҗәиб нинди дустлар сез? Гавамча әйтәм инде: дуст түгел, бәлки, ...лар сез.* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* Халыкчан, халыкка якын. *--- [Г.Тукайның] Тел-өслүбе, ниһаять, «Шүрәле», «Су анасы» шикелле матур, садә һәм гавамча (халыкчан) табигый тел илә язылган әкиятләр бирә алырлык мәртәбәдә тәкямел итте (камилләште).* Г.Ибраһимов

**ГАВА́МЧАЛЫК** *и.* Гавамга хас үзенчәлекләр (гадәттә телдә); халыкчанлык

**ГА́ВАНЬ** *и. голл.* Су буенда төрле суднолар килеп туктау, аларны төзәтү яки кышлату өчен хезмәт итә торган, көчле җилдән, агымнардан, дулкыннардан ышыкланган урын. *Бер-берсеннән бик нык аерылып торган ике географик зонага бүленгәнгә, аның дала өлешендә күчмәләр яшәгән, ә диңгезгә якын таулы көньяк районнарда авыллар, борынгы калалар гөрләгән, гаваньнарда йөзләгән кораблар чайкалган.* Ш.Солтан. *--- хәзер Олы күлләрдәге 400 порт һәм гавань арасында күл флотындагы меңләгән судно, баркаслар, катерлар, моторлы көймәләр туктаусыз йөреп торалар ---.* А.Муранов. *Уңайлы диңгез гаваньнарының күп булуы Византиядә диңгез сәяхәтенә уңайлы шартлар тудыра.* Урта гасырлар тарихы

**ГАВЕР** *и. гар. иск.* Кяфер, мәҗүси, мөшрик; *к.ш.ук.* **гәвер**. *Гавер аткан утчагыр Күкрәгенә батмаган, «Утчагыр алмас батыр» дип, Даны йортка таралган...* Дастан. *Бу Йосынчы гаверне Адәм заты чапмак юк!* Дастан

**ГАВИАЛ** *и. һинд. зоол.* Крокодиллар отрядыннан, Һиндстан елгаларында яши торган, тар һәм озын авызлы җир-су хайваны. *Һиндстанда яши торган гавиал крокодилы балык белән генә туклана.* Кызыклы ихтиология. *Гавиал, нигездә, балыклар һәм бакалар белән туклана, кайбер вакытларда кошлар, еланнар яисә имезүче хайваннарны да эләктерергә мөмкин.* Хайваннар дөньясы

**ГА-ГА** *иярт.* Каз каңгылдаган тавышны белдерә. *Савыты ватык; Ата каз килде яныма: – Га-га-га! – дип муенын суза, мине юатып.* Г.Сәгыйров

**ГА́ГА** *и. рус зоол.* Казсыманнар отрядының үрдәкләр ыруына караган, котып диңгезләре буенда яши, яхшы йөзә һәм тирән чума торган, зур башлы, кыска муенлы, кыйммәтле мамыгы промысел объекты булган кош. *Кыялар арасында ул гаҗәеп матур ике гага кошы күрде.* Г.Әпсәләмов. *Аларның [папанинчыларның] гага мамыгы ту-*

*тырып ясаган палаткалары, радиолары, патефоннары, примуслары, кырык өч төрле ашау-эчү әйбере була.* Робинзон эзләреннән. *Бу отрядка суда йөзүче кошлар, мәсәлән, казлар, аккошлар, үрдәкләр, гагалар керә.* Биология. Хайваннар

**ГАГА́РА** *и. рус зоол.* Гагарасыманнар семьялыгына караган, үткен томшыклы, карсаграк гәүдәле, гадәттә, ике йомырка салып, ата һәм ана кошлар чиратлашып басып бала чыгара торган диңгез кошы. *Гагара, чемга, крохаль дигән кошлар балыкларны суга шактый тирәнгә чумып тоталар.* Кызыклы ихтиология. *Күптөрле меңнәрчә кошлар: акчарлаклар, кайралар, чистиклар, давыл кошлары, гагаралар, бакланнар, шөлдиләр боз араларында һәм елгаларда туенып йөриләр.* Дөньяда ниләр бар. *Республикабызда тарихи дәвердә юкка чыккан хайван төрләре: кеш, комагай, төньяк боланы, кечкенә чыелдык, кара күсе, кызыл бүксәле гагара, гади агач бакасы, Каспий миногасы ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ГАГА́РАСЫМАННАР** *и. күпл.* Зур гәүдәле, куе тыгыз каурыйлы, җирдә авырлык белән шуышып йөри торган, йөзәргә һәм чумарга оста җайлашкан, Европа һәм Американың төньяк елгакүлләрендә таралган су кошларының берничә генә төреннән гыйбарәт семьялык атамасы. *Татарстанда очрый торган кошлар отрядларының төр составы: чомгасыманнар, гагарасыманнар, пеликансыманнар ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ГАГА́РКА** *и. рус зоол.* Чистиксыманнар семьялыгыннан, Атлантиканың урта һәм төньяк ярлары буенда таралган, гади үрдәк зурлыгындагы, вак балык һәм кыслалар белән туклана торган диңгез кошы (үз ыруының бердәнбер вәкиле). *Кайчандыр Лабрадор ярымутравында яшәгән канатсыз кошлар – гагаркалар – кешеләрнең эзәрлекләвеннән качып, Фарер утрауларына күчкәннәр.* Р.Әхмәтҗан. *Кеше тарафыннан юкка чыгарылган хайваннарның иң билгелеләренә су сыеры, кыргый ат тарпан, квагга зебрасы, илгизәр күгәрчен, дронт, канатсыз гагарка керә.* Табигать белеме

**ГАГАТ** *и. гр.* Ташкүмернең битумнарга бай булган аерым тупланмалар, кисәкләр һ.б.ш. формасында комлы, балчыклы яки карбонатлы токымнарында очрый, башлыча бизәнү әйберләре ясау өчен кулланыла торган тыгыз, ялтыравык төре

**ГАГАУЗ** *и.* Башлыча Молдова, шулай ук Румыния, Болгария, Украина территорияләрендә яши, төрки телләрнең берсендә сөйләшә торган халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Әллә ниләр такылдый. Тик сүзләрен һич аңлап булмый. Әллә кырым татарлары телендә, әллә гагауз телендә, әллә караим телендә сөйли.* С.Поварисов. *Гагауз... Җир йөзендә мондый милләт барлыгын белми идем мин. Полк штабында гагауз вәкиле Исмәгыйль Чадырлы белән сөйләшеп утырам.* М.Юныс. *Монда шулай ук этник төрек булмаган төркиләр – төрекмәннәр, --- гагаузлар, татарлар һ.б. бар.* Н.Фәттах

**ГАГАУ́ЗЧА** *рәв.* **1.** Гагауз телендә. *Хатыны – украин кызы Пелагея – Бишалмага килен булып төшкәч, гагаузча өйрәнеп алган – балалары инде гагаузча һәм урысча гына сиптерә.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* 1) Гагауз телендә язылган, башкарылган. *Кунак, дәрәҗәле исеменә көч китермәстән, төрекчә һәм гагаузча җырлар җырлап бирде.* Т.Әйди

2) Гомумән, гагауз теле, культурасы, халкы белән бәйле, шуңа караган

**ГАГЫЛДА́У** *ф.* 1) Каңгылдау, гайгылдау. *Оядагы каз, ягымлы гагылдап, «га-га» дип, үзенең әле йомырка эчендәге бәпкәләрен иркәли.* Г.Сабитов

2) *куч.* Ихахайлап көлү, гайгылдау. *Тик монда --- бу юлы тын кысылып кына калмый, солдатлар, нигәдер, гагылдап көләләр иде.* М.Мәһдиев

**Гагылдап җибәрү** Кинәт гагылдый башлау, гагылдарга керешү

**Гагылдап тору** Бертуктаусыз, гел, әледән-әле яки хәзерге вакытта гагылдау

**Гагылдый башлау** *к.* **гагылдап җибәрү**

**ГАГЫЛДАШУ** *ф.* 1) Каңгылдашкан, берьюлы күпләп гагылдаган тавышлар чыгару (казлар турында)

2) *сөйл.* Барысы бердән күмәкләп, ихахайлап көлү

**Гагылдаша башлау** *к.* **гагылдашып җибәрү**

**Гагылдашып җибәрү** Берьюлы күпләп гагылдашырга тотыну

**Гагылдашып тору** 1) Бертуктаусыз, даими, әледән-әле гагылдашу

2) Әле, хәзерге вакытта гагылдашу

**Гагылдашып яту** Шактый вакыт гагылдашу

**ГАД** *и. гар. иск.* Сан, исәп. *Могҗизатыңа сәнең булынмады һич хәд вә гад.* Г.Тайсугани

**ГАДАВӘТ** *и. гар. иск.* Дошманлык, ачу саклау; нәфрәт, күралмау. *Начар вә килешмәгән каләм ата вә анасын рәнҗетүче бала кебектер. Вә һәм богыз вә гадавәт итүче карендәш кебектер димешләрдер.* К.Насыйри. *Җәһаләт сәбәпле гадавәтдер.* З.Һади. *Искедән бирле күңелемездә сакланып килгән яшерен вә тирән гадавәтемез мең кат артты.* Г.Кәрам

**ГАДАЛӘТ** *и. гар. иск.* Гаделлек, дөреслек, хаклык. *«Җәбер-золым бетсен, гадаләт, хаклык телибез!» – дип, Думага членнар җибәреп, тамаклары ярылганчы кычкыралар.* Ш.Мөхәммәдев. *Әйтмәс җирдән, Аллам, әйтәм инде: Шул да булды микән гадаләт?!* Р.Рәмиев. *Эшче тели гадаләт, тигезсезлек – яман ат!* Ш.Бабич

**ГАДАЛӘТЛЕ** *с. иск.* **1.** Гадел. *Бабайны --- гадаләтле табигате өчен яраталар.* Г.Тукай

**2.** *рәв. мәгъ.* Намуслы рәвештә, гаделлеккә туры китереп. *Гадаләтле яшәү өчен, җирдә бирелгәнме һәммә мөмкинлек?* М.Галиев

**ГАДАЛӘТПӘРВӘР** *с. гар.-фар. иск.* Дөреслек, гаделлек сөюче, гадел. *Бу зат гадаләтпәрвәр мөхәррирләрдәндер.* Ф.Әмирхан

**ГАДАЛӘТПӘРВӘРЛЕК** *и.* Гадаләтпәрвәр булу; кешедәге гадаләтпәрвәрлек сыйфатлары

**ГАДАЛӘТСЕЗЛЕК** *и. иск.* Гаделсезлек, хаксызлык, дөреслекне бозу күренеше

**ГАДАЛӘТСЕЗЛЕ́К КЫЛУ** *ф.* Гаделсезлек күрсәтү, гаделсез кылану, дөреслекне бозу. *Гаяз әфәнденең әсәрләре хакында бу кадәр гадаләтсезлек кылырга шактый батырчылык кирәк.* Ш.Әхмәдиев

**ГАДАЛӘ́ТЧӘ** *рәв. иск.* Дөрес, гадел итеп, гаделлек нигезендә

**ГАДӘД** *и. гар. иск.* 1) Сан. *Сәтрәсез ханымнарның гадәде арта.* Ф.Әмирхан. *Безнең татарлар арасында аларның гадәде бик күп буладыр.* М.Гафури

2) Данә, нөсхә, номер һ.б.ш. *Әмма җылылыкның микъдары бөтенләй, мөгаен, гадәд белән тәгаен ителә алмыйдыр.* Ф.Әмирхан

**ГАДӘДЛЕ** *с. иск.* Алда килгән сүздә белдерелгән санлы, шул сандагы. *Икенче Дума рәисе Головин бу Думада аз гына гадәдле кадетлар арасында --- гына утырачактыр.* Ф.Әмирхан

**ГАДӘМ** *и. гар. иск.* Юк булу, юклык, булмау. *Вөҗүденә караганда, гадәме яхшы.* Мәкаль. *Ул калын ил кем гадәмдән сил булып килмәктәдер...* Дәрдемәнд. *Әсәрнең ялгыз бер косуры вар исә ул да имля җәһәтеннән гадәм интизамыдыр.* Г.Кәрам

**ГАДӘТ** *и. гар.* 1) Аерым халыкка, катламга яки тарихи чорга хас, аның традициясенә әйләнгән кагыйдә, закон, йола. *Сыйныфының гадәте буенча атасы аны укытты.* Ш.Камал. *Борынгыдан килә торган гадәт буенча Тимери йортында язгы чәчүнең беренче көнен быел да бәйрәм шикелле көтеп алдылар.* Г.Бәширов. *--- безнең халыкта шундый гадәт бар: кем дә кем баланың тешен беренче булып күрә, шул кеше [балага] бүләк ала.* Ф.Яруллин

2) Кеше характерындагы үзенчәлек; еш кабатланып күнегелгән, өйрәнелгән эш-гамәл. *Шәрифҗанның сабын күпертә-күпертә ун минут сөйли торган гадәте бар.* К.Нәҗми. *Гали абзыйның эреләнә, кыстата торган гадәте юк иде.* Г.Әпсәләмов. *Начар гадәтне ташлау бик җиңел түгел икән шул.* О.Ханнанов

**ГА́ДӘТӘН** *рәв. гар. иск.* Гадәт буенча, һәрвакыттагыча. *Балалар якты дөньяга килгәндә, гадәтән, бер бәхетлелек диңгезе булып киләләр.* Г.Тукай. *Беренче пәрдә бик шагыйранә, гадәтән гашыйканә.* Г.Кәрам

**ГАДӘТЕ́НЧӘ** *рәв.* 1) Йола, гадәт, традиция буенча. *Кыз, --- иске мирза гадәтенчә, бик күп русча тыгып сөйләп бирде...* Г.Ибраһимов

2) Һәрвакыттагы кебек, ияләшкәнчә, өйрәнелгәнчә. *Хәят гадәтенчә комод тартмаларын актарып ташлады да йөз кат күргән нәрсәләрен йөз дә беренче кат күздән үткәреп чыкмакчы булды.* Ф.Әмирхан. *Ә Фирүзә гадәтенчә читтә утыра, уенга катнашмый, күзе юлда, уе юлда.* А.Гыйләҗев. *Мин сине гадәтеңчә шаяртасың дип уйлаган идем!* Р.Хәмид

**ГАДӘТИ** *с. гар.* 1) Гел булып, кабатланып торган; гадәткә кереп киткән, гадәттәге. *Тагын гадәти эшләребезгә тотындык.* Ф.Яруллин. *Көнбатышта әсирлеккә төшү – гадәти бер хәл, әсирләрне кешечә кайгырту хакында халыкара килешүләр бар.* Г.Әйди. *Хәзер агынтыларның бер өлеше – гадәти юлдан, икенче өлеше Кабанга ага.* Р.Мостафин

2) Башкалардан аерылып тормаган; һәрвакыттагы кебек; *к.* **гади 1.** (*1 мәгъ.*). *Бүген Язкилдедә гадәти көн. Гадәти иртә.* А.Гыйләҗев. *Юк, акылдан шашкан кешегә охшамаган ул, гадәти бер мавыгучан кеше.* Р.Мөхәммәдиев. *--- юлның ике ягында шаулап үскән әлеге зур урманнар күп очракта сазда утыралар, вакыт-вакыт җәйрәп яткан киң болыннар да --- гадәти сазлавыктан гыйбарәт.* М.Госман

3) Еш әйтелә, кабатлана торган, аерым эмоцияләрне белдерми торган. *Ләкин кадерле, иң кадерле сүзләр дә иң гадәти саубуллашу сүзләре булып чыкты.* Н.Фәттах. *Ул кыз минем татлы кичерешләремне үзенең гадәти игътибарсызлыгы белән рәнҗетеп пыран-заран китерер кебек.* А.Расих

4) Нормага туры килгән, күләме, сыйфаты һ.б. ягы белән башкалардан аерылып тормаган. *Тегеләй үзе гадәти бәләкәй пристаньнар төсле түгел түгелен.* Ш.Камал. *Мин, яшьлегемне сагынып, картларча бер елап алырга җыенып, шул чиркәү янында басып торам... Гадәти бер авыл чиркәве.* М.Мәһдиев. *Әйе, гадәти биш катлы, дүрт подъездлы, алтмыш дүртәр квартиралы йортлар иде болар.* М.Маликова

**ГАДӘТИЛӘНҮ** *ф.* Гадәтигә әйләнү, гадәти булып китү. *Шушылай гадәтиләнеп һәм гадәтләнеп киткән көннәрнең берсендә көтелмәгән хәл булды.* Ф.Яхин

**Гадәтиләнеп китү** Әкренләп гадәтиләнү

**ГАДӘТИЛЕК** *и.* Гадәти булу, бернинди яңа, гадәттән тыш, искитәрлек ягы белән аерылып тормау. *Гадәтилек сарган уйларыңны, Юлларыңны сарган, елларыңны... Мәңге шулай булыр, димсең, эшләр, – Үзгәрешләр көтәм, үзгәрешләр...* Г.Моратов. *Ләкин көндәлек тормышның сикәлтәләрсез агышында гадәтилектән тискәре якка тайпылыш бар, һәм шул тайпылышның табигатендә комедиялелек ята.* Казан утлары

**ГАДӘ́Т ИТҮ** *ф.* Гадәтләнү, гадәткә кертү, традициягә әйләндерү. *Ил җаны күк сизгер, кайнар йөрәк, Җиңеп кырыс, салкын сынауны, Туган-үскән иле шикелле ул Гадәт иткән чыдау, сынмауны.* Х.Туфан

**ГАДӘТ-ЙОЛА** *җый. и.* Гореф-гадәт, халыкның барлык традицияләре, йолалары, ритуаллары. *Халкыбызның изге гадәт-йолаларны югалта баруы драматургларны гаять борчый.* Казан утлары. *Кеше – һәртөрле азыкны ашый торган зат. Ул теләсә нинди ризыкка җайлаша ала, аңа гадәт-йолалар гына комачауларга мөмкин.* Кызыклы физиология

**ГАДӘТ-ЙОЛАСЫЗЛЫК** *и.* Буыннан-буынга килгән гадәтләрнең үтәлмәве, юкка чыгуы, традицияләр бозылу күренеше. *Киләчәктә дә юлыгыздан тайпылмагыз, бөтен дөньяны кочаклап килүче глобализм, милләтсезлек, тәрбиясезлек, гадәт-йоласызлык диңгезендә дөрес юл күрсәтүче маяк булып калыгыз.* Казан утлары

**ГАДӘТ-КЫЛАНМЫШ** *җый. и. к.* **гадәт-холык.** *Алар кешеләрнең гадәт-кыланмышларын үтәли күрәләр.* Н.Сладков

**ГАДӘТЛӘНГӘН** *с.* 1) Өйрәнелгән, күнегелгән, гадәти. *Ә егетләр, дөньяла-*

*рын онытып, гадәтләнгән солдат эшен йөгерә-йөгерә эшли башлады.* И.Гази. *Кабинет ишеге алдында туктап, гадәтләнгән бер хәрәкәт белән, кесәсеннән ачкыч чыгарды...* Н.Фәттах. *Аның тышкы кабыгы гадәтләнгән юл буйлап эшкә барды, иреннәр, күнегелгәнчә елмаеп, лабораториядәге кызларга сәлам бирде, куллар таныш эшне башкарды.* М.Маликова

2) Билгеле бер гадәте булган, нинди дә булса гадәткә ия булган. *Кистереп сөйләшергә гадәтләнгән егет авыл ирләре кебек бераз дуамал, бераз дорфа иде.* Н.Гыйматдинова. *Кырда төлке күреп гадәтләнгән малларның исе китмәде.* А.Гыйләҗев. *Елмаерга гадәтләнмәгән йончу йөзле Салих тормыштан җавап эзләми, гел сорау бирергә ярата иде.* М.Галиев

**ГАДӘТЛӘНГӘ́НЧӘ** *рәв.* Гадәтендә булган рәвешле, гадәте нигезендә, ияләшкән рәвештә. *Аларның аяк атлаулары, гадәтләнгәнчә, җитез, гәүдәләре төз.* Р.Кәрами

**ГАДӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* Билгеле шөгыльгә, эшкә өйрәтү, күнектерү, аны гадәткә әйләндерү, гадәт тәрбияләү. *Икмәкне бала кулына җайлаштырып, кечкенә кисәкләргә бүлеп бирү. Ипине ташламаска, ашаганнан соң, савытка ипләп кенә салып куярга гадәтләндерү.* К.Закирова, Р.Низамов. *Шуңа күрә балаларны эшкә гадәтләндереп үстерергә кирәк.* Татар милли педагогикасы

**Гадәтләндерә бару** Торган саен ныграк гадәтләндерү

**Гадәтләндерә башлау** Гадәтләндерергә керешү; гадәтләнүгә китерү. *Хәтта бер генә мәртәбә эшләнгән хата да зур зарар китерә, чөнки ул хатаны тәкрарларга гадәтләндерә башлый.* М.Корбангалиев

**Гадәтләндерә килү** Электән үк, эзлекле рәвештә гадәтләндерү

**Гадәтләндерә төшү** Бераз гадәтләндерү; тагын да ныграк итеп гадәт тәрбияләү

**Гадәтләндереп җибәрү** Акрынлап берәүдә гадәт барлыкка китерү, ияләндерү, гадәт йоктыру

**Гадәтләндереп җиткерү** Тәмам гадәтләндерү

**ГАДӘТЛӘНҮ** *ф.* Үзенә гадәт итеп алу, күнегеп, өйрәнеп китү. *Ул мулласының кызуына, урынсыз тиргәвенә... күнгән, гадәтләнгән иде.* Г.Ибраһимов. --- *йокы алдыннан берәр физик эш эшләп кирәргә гадәтләнде: кар көрәде, утын ярды яки чаңгыда йөрде.* Г.Гобәй. *Тора-бара сәгатькә ул җанлы әйбергә караган сыман карарга гадәтләнде.* Р.Вәлиев

**Гадәтләнә бару** Торган саен ныграк гадәтләнү

**Гадәтләнә башлау** Нинди дә булса яңа гадәт барлыкка килгәне күренү. *Башкалар төсле гамьсез, шат була алмыйм, күп нәрсә белән кызыксынмыйм да, күбрәк ялгыз буласым килә, ялгызым гына уйланып йөрергә гадәтләнә башладым.* Ә.Еники. --- *яшь атны җан тире чыкканчы чаптыралар, шуннан хайван сабырлана, башындагы йөгән һәм өстендәге ияргә ияләшә, гадәтләнә башлый, дуламый, чыгымламый.* М.Хәбибуллин

**Гадәтләнә төшү** Бераз гадәтләнү; гадәткә ныграк керү

**Гадәтләнеп бетү** Күнегеп, өйрәнеп бетү, тәмам гадәтләнү. *Мондый соңга калып кайтуларга гадәтләнеп беткән озын буйлы чандыр хатын, бер генә сүз дә дәшмичә, йокылы күзләрен уауа, мич алдына барды.* М.Әмир. *Халык алдында чыгышлар ясый торгач, ул халәткә гадәтләнеп беткәнбез, сөйләшү һичбер тартынусыз, гади, ихлас, кызыклы булды.* Г.Ахунов

**Гадәтләнеп җитү** Тәмам күнегеп, гадәт итеп алу. --- *өр-яңа тар чалбары аякларының төзлеген, матурлыгын күрсәтүне үзе бик ошатса да, ул әле чалбар кияргә гадәтләнеп җитмәгән ---.* Г.Бәширов. --- *өй буйларында аллы-гөлле чәчәкләр үстереп, ихаталарны гөлбакчага әверелдерергә вакыт та, мөмкинлек тә бар. Тик моңа кешеләр күнегеп, гадәтләнеп җитмәгәннәр әле.* Р.Батулла

**Гадәтләнеп калу** Билгеле вакыйгадан соң яки шартлар алмашынганнан соң гадәт алып калу, гадәтләнеп китү

**Гадәтләнеп килү** Гадәткә хәзер генә өйрәнә, күнегә башлау, акрынлап гадәтләнү. *Илбарыс баһадир бу кешегә гадәтләнеп килә иде инде.* М.Хәбибуллин. *«Укучы» дигәннән, инде без укучы исеменнән үзебезнең сүзне әйтергә гадәтләнеп киләбез бугай.* М.Вәлиев. *Үзен дөньяның кендеге итеп хис итәргә гадәтләнеп килгән Генераль секретарь хаста кешенең канәгатьсезлегенә кулын гына селтәсә, калган икесе сагаерга мәҗбүр була.* Р.Мөхәммәдиев

**Гадәтләнеп китү** Ияләшү, гадәт буларак үзләштерү, гадәткә әйләндерү. --- *соңгы вакытта ялгызы калган чакларда: «Кемгә сөйлим серләремне, Йөрәгем ялкын кебек...» – дигән җырның сүзләрен күңеленнән генә кабатлап, көен көйләргә гадәтләнеп китте.* Ш.Янбаев. *Таһир элек-электән үк, аның [тауның] салкын шома ташларына сөялеп, таң атуын күзәтергә гадәтләнеп китте.* Г.Мөхәммәтшин. *Бүген генә түгел, соңгы вакытларда ул шулайрак сөйләшергә гадәтләнеп китте, шунлыктан игътибар итмәскә дә мөмкин иде.* Ф.Яхин

**ГАДӘТЛЕ** *с.* 1) Билгеле гадәте булган. *Кызлар үзләре дә теге гаҗәп гадәтле егетләрнең йөзләренә атып бәрделәр.* Ф.Әмирхан. *Үзе болай карт булса да Тәртипле һәм әдәпле ул. Алтмыш яшен сугып екты – Шундый начар гадәтле ул!* Р.Миңнуллин. *Юктан да кинәт үзлегеннән кабынып китә торган гадәтле Аяз ага чын-чынлап туарылмасын тагын дип, мин аны тынычландырырга ашыгам ---.* М.Галиев

2) Тәртипле, әдәпле, тәрбияле. *Үзе күркәм гадәтле, Үзе шундый әдәпле, Көнләп түгел, сәгатьләп Арта бара сәләте.* Г.Афзал. *Ә өйләрдә чынаяклар, әйдә, ватыла торсын, өйләр гадәтле булсын, тату-әдәпле булсын.* К.Латыйп

**ГАДӘТЛЕЛЕК** *и.* Гадәтле (*2 мәгъ.*) булу, тәрбиялелек, әйбәт тәрбия

**ГАДӘТСЕЗ** *с. сөйл.* **1.** Тәртипсез, әдәпсез, тәрбиясез. *Бик сирәк, кирәгеннән артык азынып колхоз уҗымына кергән яисә көтүдән качарга чамалаган гадәтсез сыерларның сыртларын кашып алыр өчен генә кулына ала иде чыбыркыны Җиһанша бабай.* Т.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ. тирг.* Тәрбиясез кеше. *Кабартма хәтле иреннәрен чапылдатып*

*ашавы гына җитмәгән, олылар сүзенә борын тыгып көлеп утыра. Гадәтсез!* Н.Гыйматдинова. *Гадәтсез марҗа! Кашын-күзен җимереп кычкырудан бүтәнне белмәс шул!* М.Маликова. *Шунда ук күрәчәкләр, һәммәсе көләчәкләр, Әдәпсез, диячәкләр, Гадәтсез, диячәкләр*... Р.Миңнуллин

**3.** *рәв. мәгъ.* Тәртип бозып, әдәпсез, тәрбиясез рәвештә. *Кыз тыйнак булса, егет җыйнак була; кыз әдәпсез булса, егет гадәтсез була.* Мәкаль

**ГАДӘТСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Әдәпсез кылану, тәртипсезләнү, тәрбиясезлек күрсәтү

**Гадәтсезләнә бару** Торган саен ныграк гадәтсезләнү

**Гадәтсезләнә башлау** Гадәтләрне бозыла башлау, гадәтсезлеккә йөз тоту

**Гадәтсезләнә төшү** Бераз гадәтсезрәк кылану

**Гадәтсезләнеп бетү** Тәмам азу, чиктән тыш гадәтсезләнү

**Гадәтсезләнеп җитү** *к.* **гадәтсезләнеп бетү**

**Гадәтсезләнеп йөрү** Соңгы вакытларда еш кына гадәтсезлек күрсәтү

**Гадәтсезләнеп китү** Билгеле бер моменттан алып гадәтсезләнү

**ГАДӘТСЕЗЛЕК** *и.* Әдәпсез кыланыш, тәртипсезлек, тәрбиясезлек. *Мин куркып калдым: егерме яшьтә исерек кеше буламыни?! Бу нинди гадәтсезлек?* М.Мәһдиев. *Заманында «остазым», «өйрәтүчем» дип, чын күңелемнән атап йөрткән кешемне хәзер айлар буе күрмим, моны бер дә гадәтсезлеккә санамыйм. Ни булды безгә?* А.Гыйләҗев. *Әбиләр – аяк өсте, егетләр утырып кайта. Авылга да, җәелеп түргә утырып, Шәһәр гадәтсезлеге кайта.* Ш.Галиев

**ГАДӘТТӘ** *рәв.* **1.** 1) Һәрвакыт. *Гадәттә зилзилә алдыннан дөнья оеп, изрәп тора*... Н.Гыйматдинова. *Калкан гадәттә иң каты корычтан эшләнә.* Ф.Яруллин

2) Күпчелек очракта, еш кына. *Өйдән чыгып китү белән, Габделхәй гадәттә көндәлек тормыш мәшәкатьләре турында уйламаска тырыша иде.* Н.Фәттах

**2.** *кер. сүз функ.* Һәрвакыттагыча, кагыйдә буларак. *Вәли абзый каршы килмәде, чөнки колхозга килгән олы кешеләрне, гадәттә, Галләмгали агайга фатир төшерәләр иде.* М.Мәһдиев. *Алда саналган сыйфатлары булган кешенең шәхси хәяты гаять катлаулы, кыен һәм, гадәттә, фаҗига белән тәмамлана ---.* Р.Батулла

**ГАДӘТТӘГЕ** *с.* **1.** 1) Һәрвакытта була торган. *--- гадәттәге ышанмаучанлык чаткысы аның миеннән йөгерде.* Г.Ибраһимов. *Менә хәзер беренче башлап килеп кергәндә була торган гадәттәге таркалудан соң, --- кызыксынып карый алды.* Ә.Еники. *Гадәттәге ягымлы чибәр йөзе сүрәнләнеп калган, аяк атлаулары да бик нык салмакланган.* Х.Камалов

2) Гадәти, гади. *Бу киенү гадәттәге киенү түгел иде.* М.Гафури. *Әсәрдә гадәттәге вакыйгалар дәвам итә.* Г.Нигъмәти. *Мин туып үскән Яңасала – элекке Казан губернасының зур шәһәрләрдән шактый ук ерак торган гадәттәге бер татар авылы инде ул.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса күнегелгән күләме, көчлелеге, тизлеге һ.б.ш. *Һава саф, алдыбыздан офык манзарасы гадәттәгедән ерак вә матур күренә иде.* Ш.Камал. *Йөрәге гадәттәгегә караганда ешрак, катырак тибә башлый.* А.Шамов

**ГАДӘТТӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* **1.** Гадәте буенча, гадәтләнгәнчә. *Кызса да гадәттәгечә сәүдәләр, Әллә ник бүген күңелсездер базар.* Г.Тукай. *Ул гадәттәгечә күңелле, шат кыяфәттә иде.* Ш.Камал. --- *Кәримә йомшак, ягымлы тавышы белән, гадәттәгечә каушабрак сөйләргә кереште*... Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* Һәрвакыттагы кебек, һәрвакыттагы шикелле. *Сәгатьтән артыкка сузылган һава һөҗүме бу юлы гадәттәгечә генә түгел иде.* Т.Әйди

**3.** *кер. сүз функ.* Һәрвакыттагыча. *Картның хикәясендә, гадәттәгечә, барлык нечкәлекләренә кадәр түкмичәчми сөйләү һәм ярыйсы гына күпертү өлеше дә булмады түгел.* Г.Минский. *Әкрен генә [баян] уйный башладым. Гадәттәгечә, салмак көйләрдән башлап, кыскарак көйләргә, аннары бию көйләренә, соңрак мажор ладка, тантаналы моңнарга тоташканымны Сафуан абый сикереп торгач аңладым.* Ә.Баян. *Җыелыш бетте, Вәли абзый райком секретарен үзенә чәйгә чакырган иде, гадәттәгечә, арага Галләмгали агай керде.* М.Мәһдиев

**ГАДӘТТӘ́Н ТЫШ** *с.* **1.** 1) Гадәти булмаган, сирәк очрый торган. *Бу дәкыйкадә миңа боларның сөйли торган сүзләре бик гаҗәеп вә гадәттән тыш сүзләр шикелле --- тоелды.* Ф.Әмирхан. *Кичәге көн ел кебек озын булды, чөнки гадәттән тыш вакыйгаларга бик бай иде ул.* А.Гыйләҗев

2) Әһәмияте, көче, тәэсире белән аерылып торган. *Бу арада аның хыялында --- гел зур, гел гадәттән тыш олуг булган эшләр генә йөри иде.* Г.Ибраһимов. *Гадәттән тыш вакыйга булып та тоела торгандыр, әмма патруль өчен тыныч көннәрнең гади күренешләре генә болар.* Г.Минский

3) Гамәлдәге тәртип-кагыйдәләрдән тыш, законнан читкә чыгып, махсус башкарыла торган; ашыгыч. *Болар – гадәттән тыш җәза белән үтерелгәннәр*... А.Шамов

**2.** *кис. функ.* Сыйфат һәм рәвеш янында: бик, нык, аеруча, артык, гаять дәрәҗәдә, чиксез. *Унсигезенче елның язы --- гадәттән тыш яңгырлы булды.* Ш.Усманов. *Бу куркыныч аларга гадәттән тыш сак булырга куша иде.* Ә.Еники

**ГАДӘТ-ХОЛЫК** *җый. и.* Характер, табигать, үз-үзеңне тотыш-кыланыш. *Председатель, Хәйретдин агайның гадәт-холкын тирәнтен белмәсә, бәлки, карулашып та маташыр иде, белгәнгә күрә, озын сүзсез ризалашты*... А.Гыйләҗев. *Кеше тормышта шәхси гадәт-холкына бәрабәр хәрәкәт итә, киресенчә булса, ул үз-үзен көчләүгә кайтып кала.* Ф.Галиуллин

**ГАДӘ́ТЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Гадәти, һәрвакытта булганча; көндәгечә. *Көн уртасы шәһәрдә Гадәтчә шау-шу, тавыш*... Г.Тукай. *Аның кайбер җырләрендә корылык була икән, башка бик күп җырләрендә яңгырлар булып, иген гадәтчә уңучан була.* Ш.Камал

2) Йола, гореф-гадәт буенча, урнашкан таләпләргә туры китереп, элеккечә.

*Мосафир, ишек төбендә туктап, гадәтчә сәлам бирде.* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* 1) Гадәттәге, гел була торган. *Атна кичләрендә була торган гадәтчә җыр кичләре... Габдулла һәм аның иптәшләренең төрле яңалык кертүләре белән кызыклана барды.* Ә.Фәйзи. *«Козгыннар оясындагылар» «бәйрәмнән» соң гадәтчә тонык, күңелсез кыяфәттә урыннарыннан торган чагында, су ташучы украинец Мәрьямнең буага батып үлгәнлеген хәбәр бирде.* Ш.Камал

2) Еш очрый торган, гади, гадәти. *Биек ак яка аның озынчарак кына муенына бик килешә, хәтта аның өстендәге гадәтчә пиджагын да әллә ничек матурлатып, артыграк йогышландырып җибәрә иде.* Ф.Әмирхан

**3.** *кер. сүз* Һәрвакыттагыча, гадәттәгечә. *Рәис аңа, гадәтчә, тик дөресне генә сөйләргә тиешлеген хәтерләтте.* Г.Ибраһимов

**ГАДДАР** *и. гар. иск.* 1) Хыянәтче, каин, сатлык җан. *Гаддар дошманның әленә (кулына) тотып вирде.* М.Акъегет

2) Җәберләүче, кыерсытучы, залим. *Һәр кеше мокыйр икән үз хәленә, Уграды гаддар дөнья аленә.* М.Әмин

**ГАДЕЛ** *с. гар.* **1.** 1) Дөреслекне яклый торган, хак. *Гадел кеше, дияр аны, крестьян кайгысын аңлый торган кеше.* К.Нәҗми. *Хәлифә Һарун Рәшид турында тарихчылар вә шагыйрьләр «гаять гадел хөкемдар иде» дип язып калдырганнар.* Р.Батулла. *Җинаятьне тизрәк ачып, җинаятьчене тизрәк гадел хөкемгә тартырга кирәк.* М.Ханнанов

2) Хыянәтсез, тугрылыклы, намуслы. *Һәр солдатның гадел вөҗданында Ватанына биргән анты бар.* Ф.Кәрим. *Безнең әнинең теле үткен булса да, гадел кеше ул.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Дөрес итеп, алдаусыз. *Син, күзең ачып, яхшы, гадел хисап кыл: хәзер күз алдында ике сумны артык бирергә торасың.* Ш.Мөхәммәдев. *--- бу мәсьәлә, минемчә, бездә гадел хәл кылынган...* М.Госман. *Яшь бригадир кайчакларын бик коры тотса да, урынсызга орышмый, тормышның вак-төягендә дә гадел булырга тырыша иде.* Г.Бәширов

2) Намуслы булып, намуслы рәвештә. *Намуслы, гадел яшәгән берәүне тап! Гадел яшәр өчен, син дәрәҗәгә омтылдыңмы?* А.Гыйләҗев. *Егерме ел буена намуслы булырга, гадел һәм туры булырга өйрәтте ул мине.* Р.Ишморат

**3.** *хәб. функ.* Хак, дөрес. *Ә.Ерикәйгә, инде әдәбиятта ныклы урын алгач та, «альбом шагыйре» дип карауччылар байтак булды. Әлбәттә, аның барлык иҗатына да мондый бәя бирү гадел булмас.* Ф.Галимуллин. *Моның өчен бер Уразаевны гына гаепләсәк, гадел булмас иде.* Х.Камалов

**4.** *и. мәгъ.* Хыянәтсез, тугрылыклы, намуслы кеше. *Җан өрүче ата-ана зур бурычлы – Һәрчак газиз баласына алар терәк. Гаделне күреп үскән гадел булыр, Саклый алса ата-ана олы йөрәк.* Иделбикә. *Ришвәт халыкның дәүләткә булган ышанычын югалта, гаделне кимсетә, яманга юл ача.* Казан утлары

**ГАДЕЛЛЕК** *и.* 1) Дөреслек, хаклык; хакыйкать. *Гел гаделлек җиңәргә тиеш дип, башыңа сеңдергәнсең.* Ф.Яруллин. *--- шәкертләр мирасына карата да без фәнни эзлеклелек, тарихи гаделлек принцибы белән гамәл итәргә тиешбез.* М.Госман. *Ә әхлак бары гаделлек белән генә нык була, гаделлек аша гына чыныга! Гаделлеккә хилафлык кылсә, әхлак та какшый.* Х.Камалов

2) Гадел булу сыйфаты, дөреслекне яклаучанлык. *Тормышта кешеләрнең яхшылыгын, гаделлеген аз күрмәдек.* Э.Касыймов. *Гаделлеге мәгълүм кеше буларак, ышаналар аңа, иярәләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Мин ул чакта әле судларның гаделлегенә әзме-күпме ышана идем.* Ф.Яруллин

**ГАДЕЛЛЕКЛЕ** *с. к.* **гадел**. *Гаделлекле каралар патша белән бәрабәр.* Мәкаль

**ГАДЕЛЛЕКСЕЗ** *с. к.* **гаделсез**. *Гаделлексез түрәләр эт-бүрегә бәрабәр.* Мәкаль

**ГАДЕЛСЕЗ** *с.* **1.** Хаксыз; гаделлек таләпләренә туры килми торган; гадел булмаган. *Гаделсез эшләрне хәзер бер җәзасыз гына, яшерен генә эшли алмыйсың.* Х.Камалов. *--- йә Фроловтан зарланалар, йә Уразаевның кырыслыгыннан кимсенеп, ул гаделсез дип җылыйлар иде.* Х.Камалов. *Ташлыйлар туфрак кабергә. Ә мин... мин үксим, үксим... Нигә шундый мәрхәмәтсез, Шундый гаделсез Күк син?* Р.Зәйдулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Хаксыз рәвештә, гаделлек сакламыйча. *Язмыш сезгә ни өчендер Гел гаделсез була килде.* Ф.Яруллин. *--- тормыш акыллы вә талантлыларга һәрчак шундый гаделсез булган...* Р.Мирхәйдәров. *Хан тарафыннан сине гаделсез кимсетелгән, җәберләнгән кеше дип таныдым.* Т.Насыйбуллин

**ГАДЕЛСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Гаделсезгә әйләнү, гаделсезлек күрсәтү

**Гаделсезләнә бару** Торган саен ныграк гаделсезләнү

**Гаделсезләнә төшү** Тагын да ныграк гаделсезләнү

**Гаделсезләнеп бетү** Тәмам, бик нык гаделсезләнү

**Гаделсезләнеп китү** Әкренләп гаделсезләнү

**ГАДЕЛСЕЗЛЕК** *и.* Гаделлекне сакламау, дөреслекне бозу күренеше, хаксызлык. *Аның шулай буйсынучантыныч тавыш белән җавап бирүе, әз генә дә бу гаделсезлеккә каршылык күрсәтергә тырышмавы Габделхәйнең кайнарлыгын сүрелдерә төште.* Н.Фәттах. *Шул сөйләшүдән соң ул, дөньядагы гаделсезлеккә эченнән рәнҗеп, елыйелый авылга кайтып китте.* М.Ханнанов. *Болай дип уйладым: гаделсезлекләр, тормыш сынауларыннан чиста рух белән чыга алу – кешенең иң зур бәхетедер.* М.Мәһдиев

**ГАДИ** *с. гар.* **1.** 1) Башкалар кебек үк, аермасы, өстенлеге булмаган. *Анда минем мөдирлектән алынып, гади тәрбияче итеп күчерелүем турында язылган иде.* Э.Касыймов. *Броневиктан өстенә гади солдат шинеле, башына соры папаха кигән коңгырт мыеклы бер командир килеп чыкты.* Г.Бәширов. *Беләм: минем баш очыма берәү дә йолдыз кадамас, --- гомергә гади кеше булып калдым.* А.Гыйләҗев

2) Еш очрый торган, игътибарны җәлеп итми торган. *Яшел болынлыкны*

*аерып, борыла-сырыла сузылып киткән яп-якты киң суның янындагы тигезлеккә утырган гади авыл.* М.Гафури. *Гади мехны асыл мехка әйләндерүчеләрнең берсе булып, зур исем казанды.* Р.Ишморат

3) Гадәти, көндәлек, гадәттәге. *Яңа җәйләүдә элекке гади көндәлек тормыш башланды.* Г.Ибраһимов. *Без аларның көндәлек гади эшкә бирелгән вакытларындагы тормышын күрмибез.* Г.Нигъмәти. *Киемнәре гади генә, ләкин килешле.* М.Фәйзи

4) Составы, төзелеше ягыннан катлаулы булмаган, структурасы элементар булган. *Операга нигез итеп алынган сюжет бик гади.* М.Җәлил

5) Эшләнеше, сыйфаты ягыннан уртача яки примитив булган. *Өстәлдәге лампа өстенә, кружка куеп чәй җылытыр өчен, гади калай түгәрәкләр беркетелгән...* Ә.Фәйзи

6) Җиңел башкарыла, чишелә, аңлашыла торган. *Гөлсем апа әйтерсең бик гади мәсьәләне хәл итә иде...* Г.Гобәй. *--- безгә биргән гади сораулары кайбер вакыт мине генә түгел, Газяны да аптырауда калдырырлык булалар...* М.Әмир. *Гади тел белән түгел, бик образлы, кинаяле тел белән сөйләшә ул.* Җ.Фәйзи

7) Хәйләсез, эчкерсез. *--- сәке әйләнәсендә түгәрәкләнеп утырган бу эчкерсез гади кешеләрнең күңелләрендә кинәт туган шатлык һәм тупас йөрәкләрне дә йомшартырлык гаҗәеп бер җылылык бар иде.* А.Шамов. *Баланың чын күңелдән әйткән бу гади сүзләре тетрәтеп җибәрде.* Г.Бәширов

8) Тыйнак, үзен башкалардан өстен тотмый торган. *Командующийның шундый ачык чырайлы гади кеше булуы Пахомовны рәхәтләндереп җибәрде.* Г.Бәширов. *Менә нинди кешеләр арасына эләккән ул! Чын батырлар, ә нинди гадиләр, тыйнаклар.* М.Ханнанов

9) Түбән катламга, халыкка караган. *Безләр икемез дә бертугма кардәшләремез, Аслан без гадиләрмез.* Ф.Халиди. *Иң гади нижний чиннардан торган гарнизон кайда?* К.Нәҗми. *--- чем кара чәч өстенә беркетелгән зур бантигы да аның гади крестьян кызы гына түгел икәнен әйтеп тора иде.* М.Әмир

10) *бот.* Ботаник терминнар составында үсемлекнең төр классификациясендәге урынын билгели торган сүз. *Сусаклагычлар төзегәндә, тугай болыннары су астында калу сәбәпле, биек сабаклы кыяклы үләннәр – гади сарут, хуш исле зубр кыягы, болын канәфере – бик сирәк очрый башлады.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

11) *мат.* Ваклаучы һәм санаучыдан торган; *русчасы*: **обыкновенная**. *Әгәр гади вакланманың санаучысын квадратка күтәреп, ваклаучысын 1 гә киметсәк, 2 гә тигез булган вакланма килеп чыга.* Алгебра

12) *мат.* Бергә һәм үз-үзенә генә бүленә торган; *русчасы*: **простые**. *Гади саннарны ятлау*

13) *лингв.* Бер предикатлы. *Гади җөмлә синтаксисы*

14) *лингв.* Телнең язма стиленә хас булмаган, бары тик халык арасында кулланыла торган. *Территориаль диалектлардан кала, гомумхалык теленә гади сөйләм, иҗтимагый диалектлар, жаргон, арго һ.б. керә.* Ф.Сафиуллина

15) *лингв.* Бер генә сүздән, тамырдан, нигездән торган. *Гади хәбәр белән мисал китерү. Гади сүз*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Башкалардан аерылып тормыйча, һәркем кебек. *Тәүфикъ абзый Вахитов белән танышу менә шулай бик гади башланып китте.* М.Госман. *Таныш абый түгел. Гади генә киенгән.* Г.Нәбиуллин. *Беләм: минем баш очыма берәү дә йолдыз кадамас, мин бик гади яшәдем ---.* А.Гыйләҗев

2) Тыйнак, кыланмыйча. *Каушау сиздермәде, гади, тыныч кына тотты үзен.* Ә.Еники. *Сестра да аның сәбәпсезгә оялганын сизә, гаҗәпләнә һәм үзен аның белән гадирәк тотарга тырыша иде.* А.Шамов. *Язасың гади, халыкчан, һәр көйнең тәмен белеп. Моң, сагыш, сөю җырларың күңелне ала телеп.* И.Әширов

**3.** *хәб. функ.* Катлаулы түгел, уйлап торырлыгы да юк. – *Ә монысы бик гади инде аның, – диде Фуат.* М.Мәһдиев

◊ **Гади күз белән** 1) Оптик приборлар ярдәменнән башка. *Гади күз белән караганда, бу таш валчыгының төсен белүе дә кыен.* А.Әхмәт; 2) Гадәти бер нәрсә дип, артык игътибар итмичә, ис китмичә. *Ул башка авырлыкларга да гади күз белән карый башлаган иде.* Г.Ибраһимов

**ГАДИД** *с. гар. иск.* **1.** Күпсанлы, күп. *Мәүлямез әмсалене итсен гадид, Таки улсын бәхтияр гасры җәдид.* Г.Тукай

**2.** *и. мәгъ.* Сан, микъдар. *к.ш.ук.* **гадәд**

**ГАДИЛӘНДЕРҮ** *ф. к.* **гадиләштерү**

**Гадиләндерә төшү** Бераз гадиләндерү

**Гадиләндереп бетерү** Тәмам гадиләндерү

**Гадиләндереп җибәрү** Артык гадиләндерү

**ГАДИЛӘНҮ** *ф.* 1) *к.* **гадиләшү**. *Шигырь әкрен генә катлаулана, сине уйланырга, шикләнергә, көрсенергә мәҗбүр итә. Аннары шулай ук әкрен генә ачыклана, гадиләнә.* Р.Харис

2) Гади кыяфәткә керү; гади булып күренә башлау

**Гадиләнә бару** Торган саен гадиләшү, акрынлап гадилеккә таба үзгәрү

**Гадиләнә башлау** Гадилеккә таба үзгәреш барлыкка килү

**Гадиләнә төшү** Бераз гадиләнү, тагын да гадиләнү. *Киләчәк бүгенгегә әйләнгәч, ни өчендер, тылсымын югалта, бераз тоныклана, гадиләнә төшә.* М.Юныс

**Гадиләнеп бетү** Бик гади хәлгә килү

**Гадиләнеп калу** Берәр нәрсәдән соң гап-гади булып күренү; гади хәлгә керү. *Хәбибнең ялтыравыклы туфли, модный кримплен чалбары янында Маратның киемнәре тагы да гадиләнеп калды.* М.Мәһдиев. *Тирә-як кинәт тынычланып, гадиләнеп калды.* А.Гыйләҗев. *Янымда утырган кешене олылау, хөрмәтләү хисе кинәт кенә юкка чыкты. Минем күз алдында ул кечерәеп, гадиләнеп калды.* Н.Фәттах

**Гадиләнеп киту** Артык гади булу, артык гади кылану. *Дөрес, артык гадиләнеп киткән чагы да була. «Гадилектә – матурлык» дигән гыйба-*

*рәгә бигүк туры килеп бетмәсә, Галимҗан аны төзәтә.* С.Поварисов

**ГАДИЛӘШТЕРЕЛҮ** *ф. к.* **гадиләштерү**. *Рәсемле, гадиләштерелгән хикәяләрдә тарихны күрсәтү, әдәбият һәм сәнгатьнең күренекле эшлеклеләренә багышланган мавыктыргыч китаплар, Урта гасырның бөек ядкарьләрен гади тел белән шәрехләгән әсбаплар бездә дә бик нык сорала.* Р.Вәлиев. *Киләчәк сайлаулар гадиләштерелә.* Безнең гәҗит

**ГАДИЛӘШТЕРҮ** *ф.* Артык беркатлы, примитив хәлгә китерү. *– Юк, алай ук туп-туры әйтмиләр, – диде Якуб, мәсьәләне артык гадиләштергәнен сизеп…* И.Гази. *Белгән атлы булсак та, бик гадиләштереп, әйтер идем, примитивлаштырып күрергә, аңлатырга омтылабыз.* Р.Мөхәммәдиев. *Хакыйкатьне гадиләштереп аңлатырга теләүчеләр тәнкыйтьчене яратмаган нәрсәләре турында язучы кешегә тиңлиләр.* Р.Нуруллина

**Гадиләштерә бару** Торган саен гадирәк итү, гадидән гади хәлгә китерү

**Гадиләштерә башлау** Гадиләштерүгә йөз тоту

**Гадиләштерә төшү** Гадирәк итү, бераз гадирәк хәлгә китерү

**Гадиләштереп бетерү** Бөтенләй примитив хәлгә китерү

**Гадиләштереп җибәрү** Кирәгеннән артык гади итү. *Туктачы, әби, болай үтә дә гадиләштереп җибәрмә син! Нигә фермада эшләргә тиеш, ди, мин?!* М.Хуҗин

**ГАДИЛӘШҮ** *ф.* Уңай, җиңел, гади нәрсәгә, хәлгә әйләнү; катлаулылыгын югалту. *Бу алымны грамматик гадиләшү процессы нәтиҗәсендә томанланган мәгънәне яңадан ачыклау… дип аңлатырга мөмкин.* Л.Җәләй. *Элегрәк очраклы күренгән танышлыклары үскәннән-үсә барды һәм үскән саен гадиләште.* Г.Минский

**Гадиләшә бару** Һаман гадиләшү, торган саен гадирәк булу. *Зиһен тупаслана, акыл кими, киләчәк абстракт төшенчә түгел, ул конкретлаша бара, хәтта «үлем» дигән нәрсә дә аңлаешсыз бер төшенчәдән гадиләшә барып, без аңа ияләшә башлыйбыз.* Т.Миңнуллин. *Шигърияттә кызык кына бер үзенчәлек яши: хисләр тирәнәйгән, җитдиләнгән саен, сүзләр ничектер гадиләшә, кешелеклерәк була бара.* М.Вәлиев

**Гадиләшә башлау** Гадиләшү сизелү, гадирәк булып китү

**Гадиләшә төшү** Бераз, берникадәр гадиләшү. *Гөлниса бераз гадиләшә төште.* М.Әмир

**Гадиләшеп бетү** Тәмам, бик нык гадиләшү

**Гадиләшеп калу** Билгеле очрактан соң гади, гадирәк хәлгә килү

**Гадиләшеп килү** Гадилеге күренә башлау, бераз гадиләшү

**Гадиләшеп китү** Кинәт гадиләшү, ап-ачык булып аңлашылу. *Атасы белән сөйләшкән кичтән соң бу нәрсә [ярлы кызы Рәүфәгә өйләнү мәсьәләсе] аның карашында ничектер гадиләшеп китте.* А.Шамов. *Шуннан соң инде эш шундый кызып, гадиләшеп китте, әйтерсең лә мин шул ут эчендә туып үскәнмен, һәм башка төрле, нииндидер тыныч дөнья бөтенләй юк!* С.Баттал

**ГАДИЛЕК** *и.* 1) Аңлаешлылык, ачыклык, катлаулы булмау. *Безнең фикеребезчә, төрки тел 2 мең ел элек үк диярлек грамматик төзелеш ягыннан камиллеккә, грамматик формаларның, фонетикасының, морфологиясенең гадилегенә ирешкән.* Ә.Кәримуллин. *Тик гадилек мөнбәре биек-биек болытлардан да, йолдызлардан да, күкләрдән дә биегрәк!* Н.Гыйматдинова. *Форма белән эчтәлек бердәмлеге ракета сыман. Формасы – камил гадилек, эчтәлеге – гади камиллек.* Ш.Галиев

2) Структурасы, составы, эшләнеше буенча элементар булу. --- *шул ук вакытта ул әйберләрнең барысында да рәхәтләндергеч гадилек бар иде…* А.Шамов

3) Үз-үзен тотышындагы табигыйлык, ачык йөзлелек. *Аның кыюлыгымы, әллә гадилегеме, нәрсәдер, башка кызылармеецларга да җан кертеп җибәрде.* А.Шамов. *Бу «тузга язмаган» сүз танышу процессына гадилек, җиңеллек төсе бирә.* М.Госман. --- *аның акыллы күз карашында, кешегә булган җылы мөнәсәбәтендә, гадилегендә, Газинурның беренче әйдәүчесе, беренче укытучысы Гали абзыйга охшаган сыйфатлары күп.* Г.Әпсәләмов

4) Кешеләр белән мөнәсәбәттәге эчкерсезлек, беркатлылык. *Әмма акыллы, әдәпле бала булгандыр инде, бер дә ятсынып тормыйча, безгә якынлашты, самими бер гадилек белән бөтен булган нәрсәләрен күрсәтергә тотынды.* Ә.Еники. *Минем кебек чын йөрәктән Шәмсияне бер кеше дә ярата алмас, үз итмәс иде. Ләкин ул минем беркатлылыгымның, гадилегемнең кадерен белми, ахры…* М.Ханнанов. *Галимҗанның бу кадәр гадилегенә аптырый Гөлсем ханым.* С.Поварисов

4) Халыкчанлык. *Каян килде бу безнең балаларга ата-ананың кара эшеннән йөз чөерү?! Гадилектән хурлану каян килде?* А.Гыйләҗев

**ГА́Д КЫЛУ** *ф.* … дип санау, … дип белү, … дигән фикердә булу

**ГА́Д КЫЛЫНУ** *ф.* … дип саналу, … дип исәпләнү. *Бу елда уен булды бомба атмак, Зур сәгадәт гад кылынды үлеп ятмак.* М.Гафури

**ГАДНӘН** *с. гар. иск.* Күпсанлы. *Тирә-ягы гаднән гөл диңгезе: Шул диңгездә эшли – йөзә ул.* Һ.Такташ

**ГА́Д УЛЫНУ** *ф. к.* **гад кылыну**. *Укымышлы гад улынан шәкертләр.* М.Акъегет

**ГАДҮ** *и. гар. иск.* 1) Дошман. *Гадүләр һәр тарафдин күп.* Г.Чокрый

2) Яу

**ГАЕП** *и. гар.* **1.** 1) Кабул ителгән гомуми традицияләргә, кагыйдәләргә җавап бирми торган, аларны бозган гамәл; *русчасы*: **проступок**. *Хәлим ага алдында эшләгән гаебемнән оялып, бер читтә мин басып торам, ә түтәл буласы җирдәге әрәмәлектә ике шешәнең калай бөкесе дача коямына ялтырап җем-җем итә иде.* М.Мәһдиев. *Посып кына утырмый, гаебең бар төсле, эзеңә баса-баса килеп, күзен чекерәйтә.* Н.Гыйматдинова. *Үз гаебемне үзем йолмыйча кеше күзенә күренә алмыйм дип, Чапбаев һаман бер нәрсәне кабатлый иде.* Х.Камалов

2) Дини кануннарны, кагыйдәләрне бозган гамәл, гөнаһ. *Сал үзең син тугры юлга, ярлыка гаебен, рәхим!*

Һ.Такташ. *Хәер, безнең барыбызда да гаеп бар әзрәк.* А.Алиш

3) Җинаять. *Әй бала, бала. Себер китәрлек нинди генә гаепләрең булды соң.* Т.Гыйззәт. *Гап-гади тарих укытучысының «халыклар атасы» каршында нинди гаебе булгандыр, Алла белсен.* Ф.Яруллин. *Әгәр егет ышанычны аклый алса, сугышуда катнашканы өчен гаеп җәзасын шартлы рәвештә генә билгеләргә мөмкин булыр ---.* М.Ханнанов

4) Ярамаган эш, җинаять һ.б.ш. өчен җаваплылык. *Поварның бөтен гаепне Хәлим өстенә аударуы мөмкин.* Г.Гобәй. *Җанымны саклап калу өчен, юк гаепне өстемә алырга мәҗбүр булдым.* Т.Гыйззәт. *Гаебем булмаса да түзәрмен, өстемә алырмын, тик миңа әллә нинди бүтән бәла якмагыз ---.* М.Ханнанов

5) Кимчелек, җитешмәгән як. *Алайса фатирының гаебе бар инде.* Г.Нәбиуллин. *--- әйтерсең Сәхинең кем икәнен белмәү – зур кимчелек, зур гаеп.* Ф.Яруллин. *Яратмыйм шул журналист халкын, җенем сөйми. Кешедән гаеп эзләргә генә торалар.* Р.Вәлиев

6) Шелтә, гаепләү. *Болар – абзагызның мескен башына төшкән гаепләр.* Г.Нәбиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Тыелган, ярамый торган, оят. *Татарка булу гаеп эшмени?* Ф.Әмирхан. *Ничек ул гаеп җире юк? Кычкырса ни булган? Гаеп эш түгелдер ич?* Г.Нәбиуллин. *Бер уйласаң, бер дә гаеп нәрсәләр юк инде монда.* Ф.Баттал

**3.** *хәб. функ.* Оят, гарьлек. *Кыз булган өйгә яучы килүе гаеп түгел.* М.Гафури. *Дөрес, башка килгән уйны тизрәк кәгазьгә теркәү гаеп түгел.* М.Җәлил

◊ **Гаеп ташлау** Җитди ялгышта, кимчелектә, гөнаһта гаепләү. *Бик зур гаеп ташланды бүген Бикашинга һәм шундый олы хис белән ташланды ки, моның нииндидер астыртын ният белән эшләнгәненә ышанып та булмый иде.* М.Маликова. *Ихтыярның шулай җиңел генә гаеп ташлавы күңеленә кагылды, ахрысы, теге таза бәдәнле агай төксе генә сүз кыстырды: «Читтән килеп өйрәтеп йөрергә барыбыз да оста».* Р.Вәлиев

**ГАЕП-ГАЙБӘТ** *җый. и. гар. к.* **гаеп-кыек**. *Гаеп-гайбәтләре, үпкәләре, үзеңнән соңгыларга, бары тик тимер-томырга әверелеп, орден-дәрәҗәләре кала.* Н.Гариф

**ГАЕ́П ИТҮ** *ф.* Гаепкә санау, гаеп дип кабул итү, гаепләү; өнәп бетермәү, ошатмау. *Булмас инде, булмас, гаеп итмә.* Р.Вәлиев. *--- күңел кичерә алмый бит теге этлегеңне. Гаеп итмә инде син мине, яме, агай.* В.Нуруллин

**ГАЕП-КЫЕК** *җый. и.* Һәртөрле хаталар һәм кимчелекләр. *Гаеп-кыектан булмасын, бу осталарны бездән чыгар, Зөлфәт.* А.Гыйләҗев. *Әгәр якыннанрак белгән булса, гаеп-кыегын табар, Тәбриянең күңелен сүрелдерергә тырышыр иде дә, булмады шул.* М.Маликова. *Сокланууларын эчкә яшереп, тизрәк гаеп-кыегын табарга тырышулары өскә калкып чыга.* М.Галиев

**ГАЕПЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **гаепләү 1**. (*3 мәгъ.*). *Гаепләнгән шәкертләрне берәм-берәм чакырып сорарга теләделәр.* Г.Ибраһимов

2) *юр.* Җинаять кылуда гаепле дип күрсәтелү. *Теге вакытта гаепләнүе дә, кулга алынуы да тирән бер аңлашылмау гына булды.* Г.Ибраһимов. *Алар зур суммада акча үзләштерүдә, мех әйберләре белән спекуляциядә гаепләнәләр.* М.Ханнанов. *Әнә, аңлаган кешегә аңларлык итеп: «Әлеге җинаятьтә, ягъни кеше үтерүдә гаепләнәсез», – дип, ачыктан-ачык әйттеләр.* М.Хәсәнов

3) *юр.* Җинаятьче дип табылу, гаебе раслану, юридик җаваплылыкка тартылу. *Аның иясе Нурый карак, кеше суюда гаепләнеп, гомерлек каторгагамы, Себергәме озатылган.* Г.Ибраһимов. *Әти Рөстәмнең үлүендә гаепләнеп ябылган ---.* Һ.Такташ

**Гаепләнеп алу** Кыска гына вакыт гаепле саналу

**Гаепләнеп йөрү** Берара гаеп астында тоту, гаепле саналу. *Гаепләнеп йөрүен уйларга керешә.* М.Гафури

**ГАЕПЛӘНҮЧЕ** *и. юр.* Җинаять эшләүдә гаепле дип саналган, гаепле дип күрсәтелгән кеше; *русчасы*: **обвиняемый**. *Хөкем әгъзалары да, гаепләнүче белән яклаучы да, рәис үзе дә, төрле яктан килеп, Әхмәт Уразовны тарткалап карадылар.* Г.Ибраһимов. *Аннан төрле белешмәләрне, гаепләнүчеләр һәм шаһитлар исемлеген күтәреп, прокурор бүлмәсенә юнәлде: эшне раслатып, судка җибәрергә кирәк иде.* Х.Вәлиәхмәтов. *Гаепләнүчеләр күрсәткән урында күпме генә эзләмәсеннәр, тикшерүчеләр дә, Шумбутский үзе дә гильзаларны таба алмадылар.* М.Насыйбуллин

**ГАЕПЛӘ́Ү** *ф.* 1) Гаепле санау, гаеп эш эшләгән дип табу. *Бу эштә мин сезне гаепләмим, сезне алдаганнар, кемнәрдер өйрәтеп җибәргәннәр.* Т.Гыйззәт. *Аларны моның өчен гаепләп тә булмый.* Ф.Яруллин

2) *юр.* Җинаятьче дип күрсәтү, гаебен судта тикшерү. *Колчакчылар бабайны Уразманов имениесен Советка алуда, ярлылар комитетында эшләүдә, Таштүбә Садыйкның яшергән игенен табып бүлүдә гаепләп кулга алганнар.* Г.Гобәй. *Белеп торам: мине гаепләрләр, булмаган гаепләрне тагарлар, төрмәгә озатырлар мине…* М.Әмир. *Спекуляциядә гаеплисез икән, гаепләгез.* М.Ханнанов

3) Яманлау, гаеп итеп сөйләү. *Ә халкыңны томаналыкта, наданлыкта гаепләсәләр, җан әрни.* Ф.Яруллин. *Син, Фәрзетдин энем, гаепләмә инде, еш кереп булмый яныңа, вакыт, вакыт җитми…* Г.Кашапов. *Кайсын гаепләргә белми торам менә: Әллә көзге, әллә авыз чалшайган…* Л.Лерон

4) Шелтәләү, әрләү. *Җамалый агай, Галимә абыстай, сез картлар, --- сез, бәлки, ачуланырсыз да, гаепләрсез дә ---.* Һ.Такташ. *Сөмбелне дә гаепләмим мин. Аның – үз фәлсәфәсе, минем – үземнеке.* Р.Вәлиев. *Үземне «паника куптарасың» дип кисәттеләр. Коткы таратуда гаепләделәр!* М.Маликова

**Гаепләп алу** Кыска бер вакыт аралыгында гаепле дип санау, бераз вакыт гаепләү

**Гаепләп ату** Уйлап тормастан, нигезсез гаепләү, гаепләп ташлау. *--- атай кече, мин зур диган кебек, «халык әле мине аңлар дәрәҗәгә җитмәгән» дип, үзеннән әүвәл халыкны гаепләп атмаса, ул яшь каләмнән әдип чыгар.* Х.Сарьян

**Гаепләп бару** Эзлекле рәвештә, гел гаепләү. *Әгәр дә без әле идеология томаныннан арынабыз икән, нигә әле милли тойгыны милләтчелеккә әйләндерергә ашыгабыз һәм гаепләп барабыз?* Н.Нәҗми. *Дөньяны гаепләп барма, гаепне башта үзеңнән эзлә. Кешеләрне яманлап барма, башта үзеңә бак.* Г.Хөсәенов

**Гаепләп бетерү** Бөтен гаепне аудару, тулысынча гаепле санау. *Гөлсинәне дә гаепләп бетереп булмый инде.* Г.Каюмов

**Гаепләп йөрү** 1) Һәр кешегә, һәр җирдә гаепле санап, яманлап сөйләү. *Биш-алты мәкаләңне басмаганнар да, бөтен дөньяны гаепләп син йөрисең.* Р.Батулла

2) Озак вакытлардан бирле гаепле дип санау. *Атаның үз-үзен нинди дә булса фикергә килә алмауда гаепләп йөргән көннәре.* Р.Мөхәммәдиев

**Гаепләп калдыру** Гаеплегә чыгару, гаепле дип күрсәтү. *Ике арада бәхәс килеп чыккан саен, Галия менә шул сүзен китереп кыстыра һәм Билалны гаепләп калдырырга тырыша.* М.Вәли-Барҗылы

**Гаепләп калу** Берәр очрашу, мәҗлес яки кешенең кимчелеген табып, аннан ризасыз булу, канәгатьләнмәү, гаеп итү. *– Ярый, туганнар, минем төшәр чак та җитә, – дип башлады бригадир Ибрай: – Гаепләп калмагыз.* Р.Вәлиев

**Гаепләп карау** Гаепләргә тырышу. *Йә, гаепләп кара тагын бер!* А.Гыйләҗев

**Гаепләп килү** Күптәннән бирле, электән, даими рәвештә гаепләү. *Күп дистә еллар инде менә тәнкыйтьчеләрне үз вазифаларын тиешенчә үтәмәүдә, тәнкыйтьне артта калуда гаепләп киләләр.* И.Нуруллин

**Гаепләп кую** Әледән-әле, бик сирәк кенә яки көтмәгәндә гаепләү. *Хәзер, искә төшкәндә, кияүнең хәленә кереп карарга тырыша, аның кочагында чүпрәк курчак булдым бугай дип, үзен гаепләп тә куя.* М.Маликова. *Башта шагыйрьне күзенә күренгән һәр күренештән шигырь ясарга тырышуында, ясалмалылыкта гаепләп куясың.* Р.Миңнуллин

**Гаепләп ташлау** Уйламый-нитми гаеп итү, гаепләү ягын гына карау. *– Мәхәббәткә милләтнең катнашы бармыни? – Бетте, бетте. Югыйсә син мине хәзер милләтчелектә гаепләп ташлавың мөмкин.* Р.Вәлиев. *Җегетнең түбәтәй асты бөтенләй үк буш түгел. Дәрдемәнд сүзләре аша безне аңгыралыкта гаепләп ташлады әнә.* Ф.Сафин

**Гаепләп тору** Һәрвакыт гаеп табарга тырышу, гел гаепкә санау, гаеп эзләү. *Солы печеньесыннан авыз иттеләр, чапылдыймы авыз, юкмы, карап, гаепләп торган кеше юк, рәхәт!* А.Гыйләҗев. *Кеше гаепләп торасы юк, үзем гаепле...* К.Кәримов. *Син нәрсә, ир-ат башың белән егетләрне гаепләп торасың?* Җ.Дәрзаман

**Гаепләп утыру** *к.* **гаепләп тору**. *Ә абыстай монда бер көннәрне Мәкәрҗә өстендә, абзый өйдә юк вакытта, Нәгыймә әби чүлмәк салырга килгән чакта, абзыйны гаепләп утырды: «Аның баласы булмый», – диде.* Г.Камал. *Чыкмаска кирәк булган. Шуңа күрә үзе гаепле. Рәмзилне, Рөстәмне гаепләп кенә утырмаска иде.* З.Дәүләтов

**Гаепләп чыгу** Гаепле дип игълан итү, гаеп ташлау. *Габделкадыйр бабай утыргач, Гомәр, сүз алып, Гыймади абзыйны масаюда гаепләп чыкты.* И.Гази. *Бу «усал телле» китап күпсанлы мисаллар ярдәмендә совет чынбарлыгын һәм Сталинның җинаятьчел режимын гаепләп чыга.* А.Тимергалин

**Гаепли бару** Һәрберсен, булган берсен гаепләү

**Гаепли башлау** Гаепләргә керешү, гаепләүгә күчү. *Гаяз Исхакыйны һәм аның көрәштәшләрен пычрату максатында, аларны бер нигезсез төрле җинаятьләрдә гаепли башлыйлар.* М.Сәхапов. *Монда тагы хәлле кешеләрне советка каршы коткыда гаепли башладылар, тагы кыйнаулар, кулга алулар китте.* Ф.Бәйрәмова

**Гаепли төшү** Бераз гаепләү

**ГАЕПЛӘҮЛЕ** *с.* Гаепләү, шелтә белдергән, гаеп ташлаган. --- *үзен, мыскыллы, гаепләүле, кызганулы карашларны ерып, мәсхәрә юлы белән баргандай хис итә.* М.Маликова

**ГАЕПЛӘҮЧӘН** *с. к.* **гаепчән**

**ГАЕПЛӘҮЧЕ** *и. юр.* Судта җаваплы якны җинаять эшләүдә гаепләп чыгучы. *Дәүләт исеменнән гаепләүче сүзенең актыгына җитте.* Г.Ибраһимов. *Секретарь гаепләүче һәм яклаучының, җаваплы тылмачның килгәнлекләрен белеште...* Г.Ибраһимов. *Судта җәмәгать гаепләүчесе буларак катнашырга теләүчеләр күп иде.* Х.Вәлиәхмәтов

**ГАЕПЛӘШ** *и.* Бер-береңне гаепләшү күренеше. *Сабан туенда нинди генә кычтәнәч бирсәләр дә, гаепләштән, үпкәләштән булмый.* Г.Бәширов. *Балалар уенда кызып, үзсүзләнәнеп, авырттыру, интектерүгә кадәр җитәләр. Гаепләш юк, яңадан бергә тату гына уйнап китәсең.* Ш.Галиев. *Шуңа күрә мин турысын әйтәм... Гаепләштән түгел: мин – бүтән!* Зөлфәт

◊ **Гаепләштән булмасын** «Гаеп итмәгез» мәгънәсендә. *Гражданин начальник, зинһар, мине дөрес аңлагыз, гаепләштән булмасын.* М.Насыйбуллин. *Гаепләштән булмасын, китик инде. Зур рәхмәт. Юлчының юлда булганы яхшы.* З.Зәйнуллин

**ГАЕПЛЕ** *с.* **1.** 1) Гаебе булган, ярамаган эш эшләгән; *русчасы:* **виноватый**. *Әйләнеп карасам, теге гаепле малай Шаһбаз да минем арттан чаба.* Г.Ибраһимов. *Зур гаепле бәндә төсле тотлыгам.* М.Гафури

2) *юр.* Җинаять кылган, җинаятьтә тотылган; *русчасы*: **виновный**. *Бүген гаепле кешеләрне кулга алу башланды.* Т.Гыйззәт. *Икенче фәрманыгыз кичекми үтәлде, гаепле кешеләр китерелде.* А.Алиш. *Нәрсә дип, син әллә нинди юк гөнаһларны үз өстеңә аласың, төп гаепле кешеләрне коткарасың?* М.Ханнанов

3) Берәр эшнең, хәлнең тискәре нәтиҗәләре өчен җаваплы. *Моңа гаепле кеше – Гайни!* Г.Камал. *Анализ мәгълүматлары расланууга да карамастан, гаепле кешеләрне ачыклау мөмкин булып чыкмаган.* Р.Мостафин. *Кеше – табигате белән кимчелекле ул. Аңа ул үзе гаепле булмаска да мөмкин.* Х.Камалов

4) Ярамаган, тыелган, ямьсез, килешмәгән. *Үзләренең нинди гаепле эш*

*эшләргә җыелган икәнлекләрен һаман аңлап җитмиләр иде.* Ф.Әмирхан

**2.** *и. мәгъ. юр.* Хөкемгә тартылган, җинаятьтә тотылган кеше. *Насыйп иптәш, алайса, син иртәгә чаклы монда калырсың, тикшер, гаепләрне яп.* Г.Ибраһимов. *Санитария нормаларын тупас бозу бер ай эчендә төзәтелгән. Гаепләләр каты җәзага тартылган.* Р.Мостафин. *Онытырга тырышырлар. Гаепләләр, җинаятьчеләр онытырга тырышыр!* Р.Батулла

**3.** *хәб. с. функ.* 1) Берәр ярамаган эш-гамәлнең тискәре нәтиҗәсе өчен җаваплы. *Улым! Дошманнарыбыздан үч ала алмавым өчен, мин синең алда бик гаепле.* Ф.Яруллин. *--- улымның үлүендә турыдан-туры сез гаепле ---.* Ф.Яруллин. *– Барысына да син гаепле ---. Шулай диде дә Зәлия еламсырап стенага сөялде.* Р.Вәлиев

2) Сәбәпче, этәргеч. *Барына да тынычлану турындагы черек фәлсәфәң гаепле.* Р.Ишморат. *Асяны күрми калу бигрәк күңелен телгәли иде. Барсына да шул кыюсызлыгы, мокытлыгы гаепле.* Х.Камалов. *Бу юлы да беркемне гаепләп булмый: сугыш гаепле, Гитлер гаепле.* Г.Гомәр

**4.** *рәв. мәгъ.* Гаебе булган төсле. *Җылкычының йөзендә, сүзендә үзен гаепле сизү күренә иде.* Г.Ибраһимов. *Дошманның Минскига килүендә ул үзен гаепле итеп сизә.* И.Гази. *Тузан басылган иде, кабина тәрәзәсе аркылы Хәбибнең ярым гаепле елмайган йөзе генә күренде...* М.Мәһдиев

◊ **Гаепләләр урындыгында утыру** Хөкемгә тартылу

**ГАЕПЛЕЛЕК** *и.* Гаепле, җаваплы булу. *– Эш гаеплелектә түгел, – диде Якуб, кешеләргә кабынып китәргә ирек бирмичә.* И.Гази. *Гаеплелек тойгысы, бигрәк тә Ирекне рәнҗетүе, аның гәүдәсенә бөтен авырлыгы белән басты.* Ф.Садриев

**ГАЕПСЕЗ** *с.* **1.** 1) Гаебе булмаган. *Ул кара җан аркасында бер гаепсез кешенең башын ашаулары мөмкин иде бит.* Г.Әпсәләмов. *– Гайбәт кенә икән, юкка гына бер гаепсез кешене талкыйбыз икән, – диделәр идарәдәгеләр.* Н.Гыйматдинова. *Әйттем бит инде, гаепсез булсам да, спекуляция өчен җавап тотармын.* М.Ханнанов

2) *күч.* Кимчелексез, җитешсезлекләре, деффекты булмаган. *Гаепсез аш эзләмә – ач калырсың, Гаепсез дус эзләмә – так калырсың.* Мәкаль. *Гаепсез дус эзләгән дуссыз калган.* Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* Гаебе булмыйча, гаебе булмаган хәлдә. *Мин беркайчан да үземне гаепсез дип санамадым.* Ә.Салах. *Бер атна эчендә Равил абый әтисе һәм аның белән гаепсез һәлак булганнарның эшеннән бөтен мәгълүматны сыгып ала. Кайбер фоторәсемнәрне дә үзендә калдыра.* Д.Гыйсметдинов

**3.** *и. мәгъ.* Гаебе булмаган кеше. *Кача, димәк, гаебе бар, Гаепсез нигә качсын?!* Ф.Яруллин

**ГАЕПСЕЗГӘ** *рәв.* 1) Хаксыз рәвештә, нахакка. *Бернинди гаепсезгә кешене батырып үтер, икенче берәүне тотып камчыла, имеш!* Г.Гобәй. *Аңа гаепсезгә кыелган җаннарның каргышы төшкәндер, күрәсең.* С.Шәмси. *«Теләнеп йөрмәм, төрмәгә кермәм, дип ант эчмә» дигән сүз. Саный китсәң, монда ярты халык гаепсезгә утыра.* М.Маликова

2) Урынсыз(га), кирәкмәгәнгә. *Бер сәбәпсез, бер гаепсезгә рәнҗеде аңа Вәзилә.* А.Гыйләҗев. *Чыраена гаепсезгә кимсетелү чалымнары чыккан: борын салынган, иреннәр кысылган, күзләрендә ихлас борчылу.* Х.Камалов

**ГАЕПСЕЗДӘН** *рәв.* Гаепсез килеш, гаебе булмаган көенчә. *--- минем иҗат юлымда борылыш ясаган героинялар: Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә – Сәрби, А.Островскийның «Гаепсездән гаепләләр»ендә – Кручинина, А.Гыйләҗевнең «Яланаяклы кыз»ында – Әлфинур ---.* Ватаным Татарстан

**ГАЕПСЕЗЛЕК** *и.* Гаебе булмау. *Минем гаепсезлек тиз арада исбат ителсә дә, мотоциклым милиция идарәсеннән эзсез-хәбәрсез юкка чыкты.* Ватаным Татарстан. *Казан хокук яклау үзәге җитәкчесе Игорь Шолохов егетнең гаепсезлеген раслый.* Безнең гәҗит

**ГАЕПЧӘН** *с.* Һәрвакыт гаеп итә торган, гаепләү гадәте булган. *Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен. Бик үпкәчән, бик гаепчән кеше.* Г.Камал. *Мактанчык кына, гаепчән генә нәрсә Маһруй, тик сөйләп, көлеп йөрер инде.* Ф.Әмирхан

**ГАЕТ** *и. гар.* Мөселманнарның ел әйләнәсендә билгеләп үтелә торган иң зур ике дини бәйрәменең берсе; бәйрәм. *Авылдыйн без чыгып киттек гайне, гает көнендә.* Бәет. *Нур балкытып, җырлап килгән изге гает ---.* Ш.Бабич. *Сәгать унбердә, гает котлап, Гали бәкләргә бардык.* А.Расих

**ГАЕ́Т ИТҮ** *ф.* Гаетне бәйрәм итү. *Йөрмәсен инде фәкыйрьләр әлсерәп, хәлдән таеп! Бертигез тотсын руза һәм бертигез итсен гает.* Ш.Бабич

**ГАЕ́Т НАМАЗЫ** *и. гар.-фар.* Гает көнне, гадәттә мәчеттә, барлык мөселманнар белән берлектә укыла торган намаз. *Аның каенагалары Мортаза белән Җәббар, әйбәтләп, гаеткә барып, рәхәтләнеп гает намазы укыдылар.* Ш.Камал. *Безгә, гает намазыннан соң, кунаклар килә.* А.Расих

**ГАҖАИБ** *и. гар. к.* **гаҗаип**. *1897 елда Т.Яхинның «Сабый вә сабиялар өчен мәгуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗаиб булган гыйбрәтләр» исеме астында 112 бит күләмендә бер җыентыгы дөнья күрә.* Х.Ярми

**ГАҖАИБАТ** *и. гар. иск.* Гаҗәп нәрсәләр, гаҗәп хәлләр. *Башы кызып, хыялда теге төштә күргән гаҗәибаты, томан эчендәге гәүдәләр шикелле, буталып йөзәләр.* Г.Ибраһимов

**ГАҖАИП** *и. гар. иск. кит.* **1.** Гаҗәп нәрсә; искиткеч, кызык, сәер хәл, сирәк күренеш

**2.** *с. мәгъ.* Искиткеч, сәер, гаҗәп. *--- җимеш агачлары вә гөлләре илә гаять тә шәп вә нәфис гаҗәиб булганга күрә, Кәрдән Кешан кызыгып бакчаның һәрбер ягына барып карап йөрде.* Дастан

**3.** *кер. сүз функ. к.* **гаҗәбә**. *Агып, күздән югалып, була чагы, гаҗәп, кая китә соң бу, гаҗаип?* Г.Тукай

**ГАҖӘБӘ** *ы. гар.* 1) «Менә гаҗәп! Ни гаҗәп! Менә!» мәгънәсен белдерә. *Каһарман: «Гаҗәбә!.. Монда язылган каһарман мин микән? Яки башка бер Каһарман исемле кеше микән?» – дип уйга калды.* Дастан

2) «...-мыни?, ...-микәнни?, … түгелме икән?» мәгънәсен белдерә. --- *белмәгән бер такым асламчы хатыннар, кибетче малайлар вә илхләрдән җыелган бер җыентык белән генә театр уйнауның мөмкин булмаганлыгын, гаҗәбә, Кудашев белми микәнни?* Г.Исхакый

**ГАҖӘЕП** *с. гар.* **1.** 1) Сокландыргыч, искиткеч матур, бик әйбәт. *Ул хәзер генә аңлады: буа, почта һәм мәгърур һәйкәл салыныр өчен, гаҗәеп бер урын икән ич!* А.Гыйләҗев. *Безнең ил ул – гаҗәеп ил: Дөньясында бердәнбер!* Л.Лерон

2) Сәер, кызыклы, көтелмәгән, шаккаткыч. *Берничә минуттан бу гаҗәеп хәл булган җиргә чабып килеп җиттем.* Р.Мостафин. *Дөньяда «телепатия», «магнетизм» дигән гаҗәеп күренешләр бар.* Г.Мөхәммәтшин. *Тамакка гаҗәеп бер нәрсә килеп утырды. Ни йотып, ни кире чыгарып булмый.* Г.Нәбиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик, гаять дәрәҗәдә, искиткеч. *Анда һава гаҗәеп саф, ымсыз тынлык.* Б.Камалов. *Староста гаҗәеп чибәр, һәркем белән күгәрчендәй гөрләп сөйләшә, үзе көләч, үзе итагатьле, җаныңа үтеп керә.* Ф.Садриев

**ГАҖӘЕПЛЕК** *и. сир.* Сокландыргыч үзлек, искиткеч яхшы, матур булу сыйфаты. *Хикәяләүче каләме бик озаклап шәһәр турында сөйли, аның гаҗәеплеге «бу җирдә фәрештәләр торалардыр», «моны кеше ясамагандыр, фәрештәләр булышкандыр» кебек гыйбарәләр ярдәмендә ныгытыла.* Д.Заһидуллина

**ГАҖӘМ** *җый. и. гар.* Ирак халкы, фарсылар. *Гаҗәм лисанында Дәһханәнең мәгънәсе үк «йорт» дигәндер.* Ф.Халиди

**ГАҖӘП** *с. гар.* **1.** 1) Искиткеч, шаккаткыч, сәер, аптырарлык. --- *фәнни иктираглар, гаҗәп вакыйгалар, төрле мәсьәләләрдәге, бигрәк тә һәйәт һәм тарих фәннәрендәге рус галимнәренең фикерләре [әнә шул кәгазьләргә] – һәммәсе дә кергәннәр…* Г.Гобәйдуллин

2) *к.* **гаҗәеп**. *Хезмәт ияләре өчен гаҗәп һәм сихри ял почмагы булачак ул, Гарәфи туган!..* Ф.Баттал

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик, искиткеч дәрәҗәдә. *Гаҗәп шифалы нәрсә бу, моның аркасында безнең бер патшабызның кызы яман зәхмәттән котылган…* Г.Гобәйдуллин. *Солы печеньесы гаҗәп тәмле икән.* А.Гыйләҗев. *Гаилә гаҗәп ярлы иде. Бүлмәдә зур мич һәм сәкедән башка берни юк.* Х.Камалов

**3.** *и. мәгъ.* Сәер хәл; гаҗәпләнерлек нәрсә; искиткеч, аптырарлык хәл. *Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар ---.* Г.Тукай. *Һәм иң гаҗәбе: үз хәлен аңлау да, кайгыру да юк иде шикелле бу зур гына авызлы озын-чандыр егеттә.* Ә.Еники. *Ләкин иң гаҗәбен автор новеллалардагы кебек ахыргы сәхифәгә калдыра.* Ф.Галимуллин

**4.** *хәб. с. функ.* Сәер, искитәрлек вазгыять. *Бу юлы ни үзе, ни хәбәре – гаҗәп! Теләсәң ни уйла!* Ә.Еники. *Гаҗәп бит ---, Морат мине өзелеп сөя, газаплана… Мин аннан качам.* И.Салахов. *Бу минем башыма сыймый! Гаҗәп, гаҗәп...* Г.Тавлин

**5. гаҗәпкә** *кер. сүз функ.* Көтмәгәндә, уйламаганда; көтелмәгәнчә, сәер рәвештә. *Гаҗәпкә, Андрейны өнәмәүче бер абруйлы галим генә аны яклап чыкты, аспирант үзенең ялгышын тирән таныды, диде.* Х.Камалов

◊ **Гаҗәпкә калдыру** Гаҗәпләндерү, хәйран калдыру, шаккатыру. *Эшлисе эшләр эшләнеп беткәч, Иван Лотяну үзенең гадәти булмаган чыгышы белән гаҗәпкә калдырды.* Я.Шәфыйков. **Гаҗәпкә калу** Гаҗәпләнү, ис китү, хәйран калу, шаккату. *Әмма соңыннан бер хикәядә ул нәкъ шуңа охшаш вакыйганы укып гаҗәпкә калды.* Г.Тавлин. *Хәзер шәһәр исемнәрен шундый җиңеллек белән алыштыралар: гаҗәпкә каласың.* М.Мәһдиев. *– Нигә шундый сүзләр сөйли икән бу? – дип, Ася эчтән гаҗәпкә калып карап тора.* Х.Камалов

**ГАҖӘПЛӘНДЕРЕРЛЕК** *с.* Бик сәер, шаккатыргыч, гаҗәпкә калдырырлык. --- *ул бөтен кешене гаҗәпләндерерлек бер эш кылган: атка атланган иде ---.* Г.Гобәйдуллин

**ГАҖӘПЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Таң калдыру, хәйран калдыру, искиткеч нәрсә белән шаккатыру. *Ул Сафияне портреты белән чагыштыра, бу чагыштыру аны ни сәбәптәндер гаҗәпләндерә иде.* М.Маликова

2) Аптырашта калдыру, көтелмәгәнлеге белән нык тәэсир итү. *Анналары аны шунысы гаҗәпләндерде: күз күреме җиткән бер генә җирдә дә ул трактор күрмәде.* Н.Фәттах. *Шунысы гаҗәпләндерде: куаклар арасында җәнлек-мазар, кош-корт, хәтта бөҗәкләр дә очрамады.* М.Маликова

**Гаҗәпләндерә бару** Даими, бөтен барышы дәвамында гаҗәпләндерү. *Хакас даласы безне үзенең көтелмәгән яңалыклары белән гаҗәпләндерә барды.* Г.Сабитов

**Гаҗәпләндерә башлау** Гаҗәп тоела башлау. *Бу әбинең сөйләгән әкиятләре мине бик гаҗәпләндерә башладылар әле.* Г.Камал

**Гаҗәпләндерә килү** Электән үк, шактый вакыт, әледән-әле гаҗәпләндерү. *Мине язучыдагы [М.Шабай] контрастлар һәрвакыт гаҗәпләндерә килде: тормышның караңгы, авыр якларын күпме күреп тә, үз әсәрләрендә кешенең гел уңай, якты сыйфатларын тасвирлый иде ул.* Р.Мостафин

**Гаҗәпләндерә төшү** Бераз гаҗәпләндерү

**Гаҗәпләндереп бетерү** Тәмам, бик нык гаҗәпләндерү

**Гаҗәпләндереп тору** Гел, әледән-әле яки даими рәвештә гаҗәпләндерү

**ГАҖӘПЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Берәр сәер, искиткеч, көтелмәгән нәрсәнең тәэсирендә булу; ис китү, таң калу, шаккату, хәйран калу; сәерсенү. *Бибинур карчыкның гаҗәпләнеп карап үткәне бар: көзнең соңгы көннәренә хәтле председатель кабинетының тәрәзәләре ябылмаган, сыланмаган булыр иде.* А.Гыйләҗев. *Тирә-юньдә утыручылар аңа гаҗәпләнделәр, тик бераздан, йә чит тел өйрәнүче студенттыр, йә азрак төшереп алгандыр дип уйлап, бөтенләй онытканнар, тамаша ләззәтенә чумдылар.* Р.Вәлиев. *Митяның татар музыкасын яратуына әле дә гаҗәпләнәм, чөнки мин русларның татар музыкасын шул дәрәҗәдә яратып тыңлаганын элек тә, соңыннан да күргәнем булмады.* А.Расих

2) Аптырау. *Дим аръягында куе әрәмәлек башлана, аны ярып үтсәң, тагын*

*Димгә килеп чыгасың... Тукта, нигә болай, Дим әллә икәүме дип гаҗәпләнергә мөмкин.* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ.* Ис китү, таң калу билгеләре. *Зал бермәлгә тынып калды кинәт, Гаҗәпләнү чыкты йөзләргә. Тел үлмәгән!* Ф.Яруллин

**Гаҗәпләнә бару** Торган саен ныграк гаҗәпләнү. *Мин ул сөйләгән саен гаҗәпләнә бара идем.* Гали Рәхим. *«Менә сиңа мә, олан гына димәссең үзен. Фикер сөрешен генә кара син аның», – дип, торган саен гаҗәпләнә барды Ягкуб би.* М.Хәбибуллин. *– Яшәп тә карыйлар кешеләр, да-а! – дип, аның саен гаҗәпләнә барды Нурислам. – Бер үзенә – бер утрау.* Р.Вәлиев

**Гаҗәпләнә башлау** Бераз гаҗәпсенү барлыкка килү

**Гаҗәпләнә калу** Берәр тәэсирдән, хәбәрдән, кинәтлектән нык гаҗәпләнү. *--- аның минем белән никадәр тыйнак, кечелекле булып сөйләшүенә чын-чынлап гаҗәпләнә калдым...* Ә.Еники. *Кызкуыш туеннан соң, бераз гаҗәпләнә калып, баһадир уң кулы Ташбулаттан сорап куйды: «Син нигә берәүне дә кумадың?» – диде.* М.Хәбибуллин

**Гаҗәпләнә төшү** Бераз гаҗәпләнү. *Шулай да ул Миңсылуның сорашмавына бераз гаҗәпләнә төште.* Ә.Еники. *Җиһангир әтисенең уйчан халәтенә гаҗәпләнә төште. – Әти! Нәрсә бар анда?* Н.Хәсәнов. *Усманов, гаҗәпләнә төшеп, алдагы рәттә басып торган Әхмәтсафага бераз карап торды да елмаеп аңа каршы килде ---.* Ф.Сафин

**Гаҗәпләнеп алу** Бераз гаҗәпләнүен белдерү, аз гына гаҗәпләнү. *Ишектә Булат күренүгә ул бераз гаҗәпләнеп алды. – Мин сине болай тиз килерсең димәгән идем.* М.Вәлиев

**Гаҗәпләнеп йөрү** Күптәннән, шактый вакыт гаҗәп нәрсә дип карау, уйлау, сәер дип санау. *Ул вакытка кадәр мин бик гаҗәпләнеп йөри идем: Кәримов һәр Ходай бирмеш җәй башында костюм сатып ала иде. Кая куеп бетерә?* М.Мәһдиев. *Күпләр башы төрмәдән чыкмаган каракның шундый сөяркәсе булганга гаҗәпләнеп тә йөрде.* З.Мәхмүди

**Гаҗәпләнеп калу** Берәр көтелмәгән нәрсәдән соң гаҗәпләнү хисе барлыкка килү. *Элек урам буйлап җырлап йөри идек. Хәзер җырлап кара, исерек дип гаҗәпләнеп калырлар...* Р.Вәлиев. *Хәлимәне күргәч, ул гаҗәпләнеп калды, нидер сизенүдән йөзенә сагаю билгеләре чыкты.* Ф.Садриев

**Гаҗәпләнеп кую** Аерым бер күренешкә бераз сәерсенү, гаҗәпләнү белдерү. *Мин, өстәлләр арасыннан үтеп, капитан янына килдем. Мине күргәч, Курбатов гаҗәпләнеп куйды.* М.Юныс. *Иллеләп узган хатынның болай җитез хәрәкәтләнгәнен берәрсе күрсә, гаҗәпләнеп куяр иде...* М.Маликова. *Кайчак гаҗәпләнеп тә куясың: артист аларны сәхнәдә кабатланмас рәвештә калку итеп гәүдәләндерүгә ничек ирешкән?!* Казан утлары

**Гаҗәпләнеп тору** Бераз вакытка аптырабрак калу, сәерсенү. *Өчәүләшеп, шау-гөр килеп, өйгә кергәч, Маһруй, нәрсә булган боларга дип, бераз гаҗәпләнеп торды да, куанычын яшерә алмыйча, өстәл тирәли әйләнгәли башлады.* Р.Вәлиев. *Төшемдә берәү мин белмәгән бер термин әйткәч, гаҗәпләнеп торам: әллә ниләр белә бу иптәш.* Ш.Галиев

**ГАҖӘПЛӘНҮЛЕ** *с.* **1.** Гаҗәпләнү чагылган, гаҗәпләнүне белдергән. *Икенче конвертка караганда, егет йөзенә бераз гаҗәпләнүле кызыксыну төсе йөгерде.* К.Булатова. *Сөембикә, башын күтәреп, аңа гаҗәпләнүле караш ташлады.* Ф.Садриев

**2.** *хәб. функ.* Гаҗәпләнгән хәлдә, кыяфәттә. *Күз карашы балаларча саф, гаҗәпләнүле, әмма иреннәре кысылган, монысы инде балаларча түгел.* Г.Ахунов

**ГАҖӘПЛЕК** *и. сир.* Берәр күренешнең гаҗәп ягы, сәер үзенчәлеге. *Гаҗәплеге шунда: Термезның бик күп татары минем уенны яратып тыңлаган булып чыкты.* А.Расих

**ГАҖӘПСЕНҮ** *ф.* 1) Бераз, берникадәр гаҗәпләнү кичерү. *Суфия сискәнүле гаҗәпсенү табышы белән сорады.* К.Нәҗми. *Бераздан гына исенә килеп, тамаша көтеп торучыларга гаҗәпсенеп карады: көләсезме?* А.Гыйләҗев

2) Гомумән гаҗәпләнү, гаҗәп нәрсә дип карау, ис китү. *Күзләрен зур ачып, бик гаҗәпсенеп карап ала.* Х.Камалов. *Гаҗәпсенеп, хәйран нык шаккаттык: --- кайдан килә бездәге бу «сатлык»?..* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Таксист, әллә гаҗәпсенеп, әллә шикләнеп, Ярагановка борылды, аның киндердәй агарган йөзенә текәлде.* Казан утлары

**Гаҗәпсенә бару** Торган саен ныграк гаҗәпсенү

**Гаҗәпсенә башлау** Кинәт гаҗәпсенү уяну

**Гаҗәпсенә төшү** Бераз гаҗәпсенү; тагы да ныграк гаҗәпсенү. *Ринат: – Син нәрсә? – дип гаҗәпсенә төште. – Әз.* Н.Хәсәнов

**Гаҗәпсенеп бетү** Бик нык гаҗәпсенү. *Ул тау түбәсендә сазлык булуына гаҗәпсенеп бетә алмады.* Х.Камалов

**Гаҗәпсенеп калу** Гаҗәпсенүдән аптыраште булу. *Хозыр Ильяс кебек ап-ак сакаллы, өстенә ап-ак күлмәкыштан кигән Сәмигулла карт килә иде. Кешеләр бермәлгә гаҗәпсенеп калдылар.* Ф.Абдуллин. *Ул Тукайның үзүзен сәер тотышыннан, аңлашылып бетмәгән сүзләреннән тәмам гаҗәпсенеп, аптырап калган.* Т.Миңнуллин. *Әтисеннән бу сүзне ишетүгә, әнисе гаҗәпсенеп калды: «Йа Раббым, бу кеше дә юньгә килер икән!»* Г.Якупова

**Гаҗәпсенеп кую** Нәрсәдер гаҗәп тоелу, бер нәрсәгә сәерсенү уянып алу. *– Нинди талаш ул?! – дип, кытыклаunion көлә башлаган Сәфәргә Мәхмүт тә, Миләүшә дә гаҗәпсенеп куйдылар.* Ф.Баттал. *Бу юлы ул, сыңар колакчыны сынган күзлеген борын очында тотып, миңа карады да гаҗәпсенеп куйды: – Бәй, син печән өстендә тумадыңмыни?* Н.Әхмәдиев. *– Тукта, нигә исем китә әле шул урам ышпанасына? – дип гаҗәпсенеп куйды.* А.Гыймадиев

**Гаҗәпсенеп тору** Күпмедер вакыт гаҗәпсенү; хәзерге вакытта гаҗәпсенү. *Гаҗәпсенеп торасыздыр: Безнең тел каян килгән?* Ш.Галиев. *Ул, үзенең кайдалыгына төшенмәгәндәй, бераз гаҗәпсенеп торды, бүлмәгә сеңгән дару исен тойды.* Н.Хәсәнов. *Аның шулай кинәт үзгәрүенә сагаеп калган Егет Бабай бераз гаҗәпсенеп торды да,*

*бүлдермим инде моны дигәндәй, кабат эшкә тотынды.* М.Кәбиров

**Гаҗәпсенеп утыру** *к.* **гаҗәпсенеп тору**. *Ирек, көрәштән алып бәлешнең төбенә төшкәнгә кадәр, бер нәрсәгә гаҗәпсенеп утырды: әйтерсең лә Әхнәф белән Фәһимәне алыштырып куйганнар иде.* Ф.Садриев

**ГАҖӘП-ХӘЙРАН** *с. гар. к.* **гаҗәп**. *– Әй-һәй, түтиләр! Гаҗәп-хәйран түтиләр икәнсез...* Г.Мөхәммәтшин. *Гаҗәп-хәйран калырлык хәл: Корбангали тегүче хәтта шул ачлык ел кышында да --- айгырын исән-имин саклап калды.* Ф.Хөсни. *--- әгәр шуннан мин аның бу эштәге әшәке ролен ачсам, халык гаҗәп-хәйран калачак.* Ә.Еники

**ГАҖЕЗ** *и. гар. иск.* Гаҗизлек; көчсезлек. *Мәзкүр шагыйрьләр үз гаҗезләрен икърар итеп, --- каләмнәрен чүплеккә ташларлар иде.* Г.Тукай

**ГАҖИБ** *с. гар. иск.* Искиткеч, бик сәер, таң калдыргыч. *Һәм гаҗиб бер яктылыкта җир көмеш төсле тора: Анда – урман һәм дә таулар, монда кырлар яктыра.* С.Рәмиев. *Бу тайдан гаҗиб дәрәҗәдә сөйкемле һәм җанлы бер ат чыга.* Г.Ибраһимов

**ГАҖИЗ** *с. гар.* **1.** 1) Аптыраган, югалып калган, кыен хәлдә калган. *Кыз чарасыз гаҗиз төс белән, бәйләп алып баргандай, әкрен генә аңа иярде.* Х.Камалов

2) Куәтсез, хәлсез, зәгыйфь, мескен. *Шилов өметен җуя башлаган кебек кулын селтәде. Аның бу гаҗиз кыяфәте Сергейга шунда ук тәэсир итте.* Х.Камалов

**2.** *хәб. функ.* Аптыраштa булу, кыен хәлдә булу, чарасызлык кичерү. *Мөхәммәт акылы белән моны тоемласа да, шуны җимереп, ватып сындырырлык көч табудан гаҗиз.* З.Хөснияр. *Хәлне үзгәртергә Әсгать көчсез, гаҗиз.* Р.Хафизова. *Соңгы көннәрдә Ленизаның башыннан үткән хәлләрнең иң мөһимен белмәгәнгә күрә, Мидхәт югалып калган, ул хатынын аңлаудан гаҗиз иде.* М.Маликова

**3.** *и. мәгъ.* Мескен, бичара. *[Аны] Фәкыйрьләргә, гаҗизләргә ярдәмле, дип хыял кылсалар, [хата] булыр.* Ш.Мөхәммәдев

**ГАҖИ́ЗАНӘ** *рәв. гар.-фар. иск.* **1.** Аптырап, гаҗиз булып, гаҗизләнеп. *Менә мин иксез-чиксез тел дәрьясын күзаллап, гаҗизанә калып торам.* М.Галиев. *Алар бер-берсенә гаҗизанә карашып, катып калдылар.* С.Поварисов

**2.** *с. мәгъ.* Түбәнчелекле. *Гаҗизанә шагыйрең булмакка бардыр ниятем.* Г.Тукай

**ГАҖИ́З БУЛУ** *ф.* Интегү, аптырап бетү, ни эшләргә дә белмәү. *Ашаудан авырайган идеме, әллә йокы баса башлагангамы, Алып Бәргән атына атлана алмыйча гаҗиз булды.* Р.Батулла. *Рушан, эшсезлектән бөтенләй гаҗиз булып, тулай тораклагы караватында аунап ята иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГАҖИ́З ИТҮ** *ф.* Тынгысызлау, аптыратып бетерү, кыен хәлгә кую. *Балаларны әллә нинди укытулар белән диннән чыгарып бетерәсез дип, куалап чыгара идем. Инде хәзер болары килеп гаҗиз итә башладылар.* Г.Камал. *Рәхәт гомер тиз үтә. Нужалы көннәр генә озакка сузылып башыңны гаҗиз итә.* Ә.Атнабаев

**ГАҖИ́З КАЛУ** *ф. к.* **гаҗиз булу**. *Шагыйрь, инде нишләргә гаҗиз калгач, Булмас ахры, диде, бер-бер хәйлә кормый.* Г.Тукай. *Гигант сәгать йөри! – Гаҗиз калып тыңлыйм мин шуны.* Х.Әюп. *Галимҗан булган хәлне тиз-тиз генә сөйләп бирде. Хәсәнә абыстай исә бөтенләй гаҗиз калды.* С.Поварисов

**ГАҖИЗЛӘНДЕРҮ** *ф. к.* **гаҗиз итү**. *Мине башка көчсезлегем гаҗизләндерә: ничек итеп Ленаның йөрәгендә дә үз күңелемдәге танышу уты кабызырга ---?* М.Маликова

**Гаҗизләндереп бетерү** Тәмам гаҗизләндерү

**ГАҖИЗЛӘНҮ** *ф.* **1.** *к.* **гаҗиз булу**. *Без укытучыбызга нәрсә булганын белә алмый гаҗизләндек.* М.Мәһдиев. *Самохин элекке иптәше белән уртак тел таба алмавына гаҗизләнә.* Х.Камалов. *Эчемдә ут кайный, дөрләп янган учак кебек, шуның, ичмасам, бер очкынын да кәгазьгә төшерә алмыйча гаҗизләнәм.* М.Маликова

**2.** *и. мәгъ.* Гаҗиз булу халәте. *Минемчә, чын шигырь һәр төр иҗаттагы кебек, җанның максималь киеренке чагында, уй-фикерне әйтми, бүтәннәр белән бүлешми кала алмау халәтендә, Илаһи гаҗизләнү минутларында туа.* Р.Фәйзуллин

**Гаҗизләнә башлау** Гаҗизлек тою. *Әнисенең сүзне ваклап-саклап, иңәләп-җепләп, киеренке бабта алып баруыннан гаҗизләнә башлаган Зөлфия әле бу юлы да җавапны үзе бирергә булды.* Т.Галиуллин

**Гаҗизләнеп бетү** Тәмам гаҗиз булу

**Гаҗизләнеп йөрү** Аптырап, шактый вакыт нишләргә белми тору, чарасызлыктан интегү. *Төне буе саташып чыкты, әллә нинди төшләр күреп бетерде. Төшендә буранда адашып, гаҗизләнеп йөрде.* Р.Вәлиев

**Гаҗизләнеп калу** Билгеле бер сәбәптән, вакыйгадан соң кинәт гаҗизләнү. *[Зәйтүнә] --- читлектәге кош кебек, атылып-бәрелеп, дүрт стена арасында чапаланудан узмаячагын уйлап гаҗизләнеп кала һәм соңыннан бөтенесен бер нәрсәгә – үзенең бәхете юклыкка сылтап, язмышына үпкәләргә тотына иде.* Ф.Хөсни. *Әхәтнең беркайчан да болай ук гаҗизләнеп калганы юк иде әле.* З.Фәйзи

**Гаҗизләнеп тору** Күпмедер вакыт яки хәзер гаҗизләнү. *Көтүче абый шул искиткеч хәлгә гаҗизләнеп торган мәлдә, аннан да гаҗәбрәк хәл булып ала.* Ә.Баян

**ГАҖИЗЛЕК** *и.* **1.** 1) Аптыраш, аптыраганлык, чарасызлык халәте. *Сызлану, гаҗизлек, өмет чаткысы, шул ук вакытта өметенең акланмавыннан курку да чагыла иде аның күзләрендә.* М.Маликова. *Ирек гаҗизлектән берни әйтә алмады, томлыгып, әйтәсе сүзләре тамагына тыгылып калды...* Ф.Садриев. *Наҗия, битараф адәмнәргә рәнҗүен, гаҗизлеген ничек тә тышка чыгармаска тырышып, үзенекен тукый.* Сөембикә

2) Көчсезлек, зәгыйфьлек, булдыра алмау. *Гомәргә әнисенең бу гаҗизлегенә карау бик авыр иде.* Ә.Еники. *Бу минутта, бәлки, башка ана булса, еларга яки үзенең гаҗизлеген күрсәтеп мескенләнергә керешер иде.* А.Расих

**2.** *хәб. функ.* Чарасызлык хәлендә булу. *Кешенең бата башлавын белә*

*торып, аңа ярдәм кулыңны суза алмавың – нинди гаҗизлек!* Г.Бәширов

**ГАҖИЛ** *с. гар. иск.* Ашыгыч, кичектергесез

**ГА́ҖИЛӘН** *рәв. иск.* Ашыгыч рәвештә, бик тиз, кичекмәстән

**ГАЗ** I *и. фр.* 1) Аерым кисәкчекләре үзара тыгыз бәйләнмәү сәбәпле, бушлыкка, үзенең төп сыйфатын үзгәртмичә, тиз һәм җиңел тарала торган матдә. *Кояшның – бу кызу газлардан тора торган шарның – Җир шикелле үк үзенең атуы бардыр.* Ф.Әмирхан. *Динамитның газы – соры елан, сузылып йөри забой буенча.* Ш.Маннур. *Егермешәр метрлы газ аеру колонналарының тып-тын көнне дә колакларыңны ярырдай булып ажгыруына җил-давыллы буран котыруы өстәлә.* Р.Хисмәтуллин

2) Шул матдәнең көнкүрештә, хуҗалыкта ягулык буларак кулланыла торган төре, гадәттә: пропан. *Әнә теге нефть ялкыннары безнең яңа шәһәргә газ биреп торачаклар, өйләрне газ җылытачак.* А.Әхмәт. *Бу күлнең Оренбург газ эшкәртү заводы агынтыларыннан хасил булганлыгын белгәч исем китте.* Р.Мостафин. *Хатын, күңеленнән генә ыргә рәнҗи-рәнҗи, газ плитәсенә ут төртте, аш куйды.* Н.Гыйматдинова

3) Шул ягулыкта эшли торган көнкүреш-хуҗалык приборы. *Ашны газ пешерәчәк.* А.Әхмәт. *Болын хәтле квартира. Водопровод, электр, газ.* Ш.Хөсәенов. *Бәрәңге әрчеп, газга куйдым да: «Нишләп сөйләшмичә утыра бу?» – дип, җаным түзмичә, Илдар янына чыктым ---.* Э.Шәрифуллина

4) Автомашинада һәм мотоциклда янучан катнашманың двигатель цилиндрына килү күләмен үзгәртү җайланмасы, шуның аяк белән басу өчен куелган тәбәлдереге; акселератор. *Нурислам җиңел генә кайтыр юл уңаена борып куйды. – Киттекме, Шәмсенур? – диде дә, җавап көтеп тормастан, газ башмагына басты.* Т.Миңнуллин. *Шофёр егет ерылган авызын җәһәт кенә җыеп җитдиләнде. Аннары бөтен йөзенә гаепле төс чыгарды, нишлим инде дигәндәй, ике кулын тиң рульдән ычкындырып, як-якка җәйде дә газ педаленә шытырдатып басты.* Р.Вәлиев. *Тагын күз алдында һәрчак торганы: кечкенә генә машинасына утырып, тәрәзәдән як-ягына карана да, рульне тотып, газга баса: тәвәккәлләдек!* Р.Нуруллина

◊ **Газ бирү** 1) Нинди дә булса эшчәнлектә тырышлыкны, активлыкны, мөмкинлекләрне арттыру; 2) Тизрәк китеп бару. *Тузан басылган иде, --- шофёр да газ бирү ягын карады.* М.Мәһдиев. **Газга басу** Барлык мөмкинлекләрдән файдалану. **Газны бору** *к.* **газ бирү**

**ГАЗ** II *и. фр.* **1.** Үтә күренмәле ефәк тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Менә шул көй моңы астында аның әнисе үзгәрә: битендәге җыерчыклары бетә, өстендәге тупас күк халат урынына аксыл зәңгәр газ сыман киемнәр барлыкка килә ---.* М.Мәһдиев. *Бу очракта марля (газ) капчыкны тыгыз киндер тукыма кисәгенә яки 10 см киңлектәге бәзгә тегеп беркетергә кирәк.* Ә.Халидов

**ГАЗА** *и. гар. иск. к.* **газават**. *Ул ун ел эчендә 52 газа булды. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең әүвәлге сугышы Бәдер булды, актыгы Тәбүк сугышы булды.* К.Насыйри. *Менә халыкның шул тойгысы Тукайның хәятында бердәнбер таянычы, бердәнбер газасы иде.* Ф.Әмирхан

**ГАЗАВАТ** *и. гар.* Изге сугыш. *--- мәкерле әмир Бохара әһеле арасында: «Династлам бишегенә кяферләр ябырылды, мөселманнарны чукындырырга, үтерергә яу чыкты, барыгыз да изге сугышка кутәрелегез, газават!» – дип, купләр йөрәгенә дәһшәт салды, коткы таратты.* Т.Әйди. *Тарихтагы сугышларның күбесе --- халыкның «дин», «иман», «ватан» дигән нәрсәләр хакына сугышуны «газават» дип ышануы һәм шәһит китүне олы бәхет дип хисап итүе аркасында башлана ---.* Мирас

**ГАЗАЗИЛ** *и. гар.* **1.** 1) Дини мифологиядә: Иблиснең фәрештә вакыттагы исеме; җәннәттән куылган фәрештә. *Инде аны мәңгегә Иблис диләр, Газазил дип эндәшергә кушмыйлар.* Ш.Бабич. *Ул адашкан тугры юлдан, Дәргаһең табалмаган, Мәңгелек сөрген Газазил, Ул колыңны алдаган ---.* Һ.Такташ

2) *күч. сөйл.* Яман эшкә котыртучы, коткы таратучы. *Газазилнең соңгы мәһарәтләре эш иткән, шулар сүзе, әллә кемнәр вәгазе, фәләннәр хәйләсе түгел, Илаһиның үз әмере дә минем йөрәгемне тыңлата алмас иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Котыртып торучы, коткы тарата торган. *Газазил көчләр белән бил алышуга соңгы көчәнешен биреп, яшәү, терелү, аякка басу өчен тартышкан чирле үзе шәйләмәскә дә мөмкин.* Т.Галиуллин

**ГАЗАЛЬ** *и. гар. иск. к.* **газәл** II

**ГАЗАМӘТ** *и. гар.* 1) Бөеклек, олылык, мәһабәтлек

2) Горурлык; тәкәбберлек; үзен артык эре тоту үзлеге. *– Моннан соң янымда сөйкәлеп йөрмәвеңне телим… – диде дә, бик газамәт белән, утырган җиреннән торып китте.* Ш.Камал. *Фырт киенеп, билгеле бер газамәт белән йөрүе, кыяфәт-калебе аны бай кеше итеп күрсәтә.* С.Поварисов

**ГАЗАМӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Олы, бөек, мәһабәт. *Поляк милләте үз тарихының иң газамәтле сәхифәләреннән берсен уздыра.* Ф.Әмирхан. *Шул кыймаган мәктәп аңар бик газамәтле бер бина, бер сарай, бер мәркәз төсле тоела.* Ш.Камал

2) Эре кыланучан, тәкәббер

**2.** *рәв. мәгъ.* Өстен, тәкәббер, эре кыяфәт белән. *Илһаметдин аз гына түземлек-сабырлык игенә керде. Шулай да үзен газамәтле-өстен тотарга кирәклекне онытмады.* С.Поварисов

**ГАЗАМӘТЛЕЛЕК** *и. к.* **газамәт**

**ГАЗАП** *и. гар.* 1) Физик авырлык, җәза, җәфа. *Минем дөньяда калган бердәнбер дусымны басмачылар, авыр бер газап белән, ике ай элек Фирганәдә үтергәннәр.* Г.Ибраһимов. *Умыртка сөяге уртага сынып, Вова ике көн коточкыч газаплар кичергәч вафат була.* А.Расих. *Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача ---.* Ә.Еники

2) Изү, җәбер, золым. *Мин – төрек феодаллары җәбере астында газап*

*чигеп үлгән Анатолия крестьяны улы.* Ә.Фәйзи

3) Бик авыр рухи кичерешләр. *Бәлки, чыннан да, моңарда вөҗдан газабы кузгалгандыр?* Ә.Касыймов. *Гел газаптан гына торган нинди мәхәббәт инде ул?* Ф.Яруллин. *--- белсәң иде эшсез яшәүләрнең газабын, бер көн тотмыйча, мине алып кайтыр идең, мин монда белештем, пенсиягә чыккач та эшләргә рөхсәт итәләр икән ---.* М.Мәһдиев

4) Кыенлык, азап, мәшәкать. *Ул, Зыяга кыенлык булыр, ул газап күрер, авыр яшәр дип уйламый, ничектер, бу бер дә аның башына килми, һәм кайгысы да ул ноктада түгел.* Г.Ибраһимов. *Рәүфәнең гаризасы бик зур газаплардан соң гына каралды.* А.Шамов. *Бер теләктә кала һәрбер кеше: – Исән кичер сугыш газабын ---.* Г.Хуҗиев

**ГАЗАП-ҖӘФА** *җый. и. гар.* Һәртөрле кыенлыклар, мәшәкатьләр, азап. *Мең төрле газап-җәфалар чигеп булса да, уку, белем алу иң бөек максат итеп куелган.* А.Расих

**ГАЗА́П ИТҮ** *ф. иск.* Газаплау, җәфалау. *«Боларны гаять каты газап вә җәфалар илә газап итәргә кирәк», – диде.* Дастан

**ГАЗА́П КҮРҮ** *ф. к.* **газаплану**. *Никадәр газаплар күрдем... Берәр чиге бармы аның?* Г.Сабитов

**ГАЗА́П КЫЛУ** *ф. иск. к.* **газаплау**. *Бөтен көн безне газап кылды, төнлә белән хезмәтче һәм крестьяннарны, күлмәкләрен салдырып, идән астына ябарга һәм аякларыннан асып куярга кушты һәм азаплады.* Г.Гобәйдуллин

**ГАЗАПЛАНУ** *ф.* 1) *тош. юн. к.* **газаплау** (*1 мәгъ.*)

2) Җәфалану, интегү; азаплану, мәшәкатьләнү. *Алар иртә таңнан караңгы кичкә кадәр авыр эштә газапланалар.* Ф.Бурнаш. *Мин аларны бер үзәккә җыйный алмыйча газапланам.* Ш.Камал. *Кинәт шунда кара җимешме, өрекме тутырылган авыр капчыкларны зур үлчәүгә салып газапланган өлкән яшьтәге берәүне күрдем.* М.Мәһдиев

3) Авыртудан интегү, сызлану, җәфалану. *Сулыш ала алмый газаплана.* Ш.Камал. *Ниһаять, бик озын газапланганнан соң, --- уналтынчы сентябрь, егерме зөлкагъдә, чәршәмбе көн төнлә сәгать ун ярымда бала дөньяга килде.* А.Расих. *Кан эчендә бер көн газапланып ятты да җан бирде.* М.Мәһдиев

4) Авыр уйлар, кичерешләр тәэсирендә булу. *Ул, үзенең сорашуы, кызыксынуы белән, Рәүфәнең уяныр-уянмас яткан шикләрен уятып җибәрде һәм аңа борчылырга, газапланырга юл күрсәтте.* А.Шамов. *Шулай да үкенмим, газапланмыйм, үз бурычымны үтәдем бугай.* А.Гыйләҗев. *Алар да кайчан да булса бер шушындый сорау белән газапланачак.* Ф.Латыйпов

5) Бик нык тырышу. *Ләкин өлкәннәр алдында салкын канлылык сакларга тырышып газаплана.* Г.Ибраһимов. *Күп газаплана торгач, Нурулла аягына басты. Әмма кузгалып китү мөмкин түгел иде.* Г.Әпсәләмов

**Газаплана башлау** Беренче газаплар кичерү. «*Кичерәм» дип, күпме антлар бирелмәгән дисең! Юк, җиде төн уртасында хәтергә, төшкә кереп, куркып уянасың да тагын газаплана башлыйсың.* Ә.Баян. *--- тетрәткеч каза сиңа да тия, синең йөрәгеңне дә әрнетә башлый. Син дә сугыштан кайтмаган егетне кызганып газаплана башлыйсың.* М.Юныс

**Газаплана тору** Шактый вакыт бер нәрсә белән мәшгуль булу, мәшәкатьләнү, тырышу. *Газаплана торгач, Бикмуш бабай, Илсөярне күтәреп, көч-хәл белән су читенә чыгып басты.* Г.Гобәй. *Атны буйсындырмакчы булып газаплана торгач, Ләмиганың хәле тәмам бетте ---.* Рифә Рахман

**Газаплана төшү** Тагы да ныграк газаплану

**Газапланып бетү** Физик яки рухи газаптан тәмам алҗу, ару. *Кояш баюга якынлашканда, көндәге гадәт буенча, газапланып беткән әсирләрне --- таш зинданга бикләделәр.* Ш.Мөхәммәдев. *--- телефоннан сөйләшкәндә, кабельнең икенче очындагы кешенең йөзен күрергә тилмереп, газапланып бетәм.* М.Юныс

**Газапланып йөрү** Озак вакыт газаплану. *Катя инде төннәрен йоклый алмый, ә көндезен, аның хакында гына уйлап, газапланып йөри башлады.* И.Гази. *Гомерлеккә гашыйк булдым сиңа, Йөрәккә ут төрттең. Оныта алмый газапланып йөрдем Почти бер көн.* Ф.Яруллин. *Иң яхшысы – газапланып йөргәнче, барып, сәбәбен белү.* М.Маликова

**Газапланып килү** Электән үк, күптәннән газаплану. *Бу яшь бөртекләре, үкенеч сулышы булудан битәр, ничә еллар газапланып килеп тә үткәненә дөрес хөкем юлы табу шатлыгыннан иде булса кирәк.* Р.Сибат

**Газапланып тору** Хәзерге вакытта газаплану; һәрвакыт газапта булу. *Халык шулкадәр фәкыйрьлектә газапланып тора.* Г.Коләхмәтов

**Газапланып утыру** *к.* **газапланып тору**. *Нургали шулай газапланып утырган арада, өстәл янына хәзерләүләр министрлыгы район уполномоченныеның агенты Нәфикъ Шәйдуллин чыгып баскан иде инде.* Ә.Еники. *Шулай газапланып утыра торгач, сеансның яртысы бетте.* М.Мәһдиев

**Газапланып чыгу** Билгеле вакытны (тәүлек, көн һ.б.ш.) газапта үткәрү. *--- кич белән кулы бик нык сызлый башлап, төнлә төн буена йоклый алмыйча газапланып чыккан.* Ш.Камал. *Йөрәгем үзенекен тукыды: «Искәндәрне уйлап, төннәр буе йоклый алмый газапланып чыкканың бармы? Юк!»* Ф.Яруллин. *Күбәләгем! Син кайда югалып йөрисең? Мин төн буе сине көтеп газапланып чыктым!* Ә.Яһудин

**Газапланып яту** Шактый озак вакыт газаплану. *Берәү күңел ачканга, икенче берәү газапланып ятсын, имеш!..* М.Әмир. *--- күңеленә килгән иксез-чиксез сорауларына җавап таба алмыйча газапланып ята торгач, кинәт кенә баш миеннән бер якты уй йөгереп узды.* Р.Вәлиев

**ГАЗАПЛА́У** *ф.* **1.** 1) Җәзалау, физик газапка дучар итү. *Менә мөмкин булса да, мин, шул әкияттәге батыр кебек, әтине газаплаган явызлардан үчемне алсам!* Г.Ибраһимов. *Аларны шул хәтле газаплаганнар: соңыннан иң якын кешеләре дә таный алмаган.* Г.Әпсәләмов. *Ф.Осетринны бик каты*

*газаплыйлар, иптәшләренең кем булуын, аларның адресларын әйтүне таләп итәләр.* Р.Вәлиев

2) Җәфалау, интектерү. *Ник газаплыйлар болай күкләр мине гомрем буе?* Һ.Такташ. *Башта ул [мич] бик каты төтенләп газаплады, аннары аның көймәсе дөбердәп ишелеп төште.* А.Шамов

3) Җәберләү, рәнҗетү. *Нигә шундый сүзләр белән үзеңне дә, мине дә газаплыйсың, Хәмит?* Р.Ишморат. *Иҗат дәрте сүнмәгән фидакарь Ленарга эш бирмичә газапладылар. Югыйсә режиссёрлар болай да бармак белән генә санарлык бит инде.* И.Юзеев

4) Рухи, вөҗдан газабы китерү, газапка дучар итү. *--- мин түгел, ул үзе борчыла, аның борчылуы мине газаплый.* Ш.Камал. *Намуслы кеше шул инде, юк гаебе өчен дә үзен-үзе газаплый.* М.Маликова. *Врач дөрес әйтте, болай юк-бар нәрсә уйлап, үземне газапламаска кирәк.* Р.Вәлиев

5) Бимазалау, борчу, туйдырып бетерү. *Мин бер дә сөйли белмим, мине болай газапламагыз, мин эшли генә беләм ---.* М.Мәһдиев. *Газаплыйдыр сине көннәреңнең Бер-берсенә охшаш булуы.* Р.Мингалим

**2.** *и. мәгъ.* Газап китерә, газапка дучар итә торган эш-гамәл. *Менә шуның өчен фашистлар башта Ибраһим бабайны искиткеч авыр газаплау белән газаплап, соңыннан тере килеш җиргә күмгәннәр.* Г.Гобәй

**Газаплап бару** Озак вакыт дәвамында, даими рәвештә газаплау. *Һәрвакыт төзәлмәс тирән яра кебек газаплап барды.* Г.Ибраһимов

**Газаплап бетерү** Тәмам йөдәтү, хәлдән тайдырганчы газаплау. *Ватык [савым] аппаратның бер стаканын алып кайтып, өйдәге сыерны газаплап бетердем.* М.Хәсәнов. *Әгәр дә син йөргән урманны начар кешеләр таптап, сындырып, газаплап бетермәгән булсалар, ул әле, учлап-учлап, төрле-төрле җиләк-җимешләрен дә бирер.* Көч һәм рух тамырлары

**Газаплап йөрү** Озак вакыт дәвамында борчу, тынгылык бирми тору. *Искәндәрнең кинәт кенә уйлары ачылып киткәндәй булды, ул еллар буе җанын газаплап йөргән сорауларга, ниһаять, җавап табуын аңлап, «аһ» итте.* Р.Вәлиев

**Газаплап килү** Шактый вакыттан бирле борчып, тынгылык бирмәү. *Менә нәрсә мине шушы көнгә кадәр тыеп, борчып, газаплап килде...* Ә.Еники. *Ул, үзен ике ел буена газаплап килгән сагышының, ничектер, үзеннән-үзе бетә башлавын, йөрәгенең җиңеләя баруын тоеп, елмаеп куйды.* Г.Мөхәммәтшин

**Газаплап тору** Бертуктаусыз борчу, гел газап китерү. *Әгәр гомер буе күңел түреннән китми шулай газаплап торса, ничекләр түзәрсең!* А.Гыйләҗев. *Искәндәр кинәт кенә үзенең гәүдәсе җиңеләя башлаганны тойды, әйтерсең борчып, күңелен газаплап торган бар уйлары --- төшеп калганнар иде.* Р.Вәлиев. *Ниһаять, теләгенә иреште, ничә көннәр, атналар буе тынгы бирми газаплап торган шашкын теләк басылыр, күңеле тынычлап, рәхәтләнеп калыр...* Р.Габделхакова

**Газаплап чыгу** Билгеле вакыт дәвамында (көн, тәүлек һ.б.ш.) газаплау. *Төн буена газаплап чыккан авыр уйларны тел белән әйтеп бирүе ай-һай кыен иде.* Г.Бәширов

**Газаплый башлау** Газапка әйләнү; газапларга керешү. *Задачаларның баштаграклары тиз эшләнсәләр дә, бара торгач авырайдылар, озак-озак чыкмый газаплый башладылар.* Ф.Әмирхан. *Кондукторның очраклы гына әйткән бу сүзе кызның күңелен газаплый башлады: «Катя адашкан... Катя адашкан...».* И.Гази. *Ә берничә минуттан соң Белугинны яңадан йокы газаплый башлады, һәм ул, түзәр тәкате калмыйча: «Барыбер черем итеп алмый булмас», – дип уйлады.* Н.Фәттах

**Газаплый тору** Шактый вакыт дәвамында газаплау. *Шулай бер ай буена газаплый торгач, меңләгән хатын-кыз арасыннан йөзен сайлап алып, аерым ашата, аерым күнегүләр ясата башладылар.* Р.Сәгъди

**Газаплый төшү** Тагы да ныграк газаплау

**ГАЗАПЛАУЧЫ** *и.* **1.** Җәберләүче, изүче, газап китерүче зат. *Менә мине газаплаучыларның берсе – шушы.* М.Фәйзи. *Царизм рус булмаган халыкларның палачы һәм аларны газаплаучы иде.* М.Җәлил. *Туйга кадәр ир кадерен белүче, бала җанлы булып кыланган Зәмзәмия, бергә яши башлагач, ата белән кызны газаплаучыга әверелде.* Г.Вәлиева

**2.** *с. мәгъ.* Газапка дучар итә торган, борчу-мәшәкать китерә торган. *Нигә шундый җан газаплаучы кеше син, Хәйдәр!* Р.Ишморат. *Мондый хәлләр дә тулып ята: балаларын музыкант, рәссам итәм дип, сабыйларны газаплаучы ата-аналар дөньяга аек күз белән карамыйлар.* М.Әхмәтҗанов

**ГАЗАПЛЫ** *с.* 1) Газаплый, җәфалый торган, физик интектергеч. *Ходай, яраткан кешемә чир бирермен, дип әйткән ---. Тәңренең мәхәббәте шулай газаплы булырга тиеш микәнни?* Ф.Яруллин

2) Борчулы, авыр рухи кичерешләр китерә торган. *Шундый рәхәт, татлы уйлардан бүленеп, газаплы, борчулы дөньяга кайткaны өчен, Рифкатьнең җен ачулары чыкты ---.* Р.Вәлиев. *Онытаның шундый газаплы, авыр уйлар кичергәнен Айдаш карт сизенде, ахрысы, сүзне гел икенчегә борды.* Р.Батулла. *Аның газаплы кичерешләре Хәлимәнең бәгырен яшен уты шикелле көйдереп үтте.* Ф.Садриев

3) Куркыныч, кәефне җибәрә торган. *Ичмасам, бу газаплы төшләрнең сәбәбен белеп яшәр.* Н.Гыйматдинова

4) Мәшәкатьле, авыр, катлаулы, азаплы. *Аннан товар поездларында Себер тайгасына кадәр озын-озын газаплы юл башлана.* А.Расих. *Хәрефне күптән танып, укырга былтыр ук өйрәнгән булса да, язу кебек гаять тә газаплы юлдан әлегә чатан-чутанрак атлый шул.* Э.Касыймов. *Яшәүдән дә газаплырак шөгыль дөньясында табылмас иде.* Н.Гыйматдинова

**ГАЗАПЛЫЛЫК** *и.* Авырлык, читенлек

**ГАЗАП-МИХНӘТ** *җый. и. гар.* Төрле газаплар, авырлыклар, кыенлыклар. *Оныталар үткәннәрен, Газап-михнәт чиккәннәрен: Зур дөньяга кеп-кечкенә Өйдән чыгып киткәннәрен.*

Ф.Яруллин. *Житәр тормыш авырлыкларына муен сонып тору! Оят миңа газап-михнәтнең астында эрү, черү.* С.Сүнчәләй. *Газап-михнәтләрне, үзеңә нинди генә кыен шартларда да тешләрне кысып, якын-тирәдәгеләргә сиздермәскә тырышу хәерле.* Г.Тавлин

**ГАЗАП-МИХНӘТЛЕ** *с.* Төрле газап тулы. *Авыр орудиесе белән Днепрны кичә, газап-михнәтле сугыш мәшәкатьләрен үзе генә белә.* Т.Нәҗмиев

**ГАЗА́П ЧИГҮ** *ф. к.* **газаплану**. *Әй, дөньямны якты иткән җырым, синең өчен газап чиккән җырым ---.* Ш.Маннур. *Мин бирелә аның белән нинди газаплар чигүемне тулы итеп язмыйм.* А.Расих. *Әллә кемнәр торгынлык елларында чикләүләрдән газап чиккән, имеш!* А.Гыйләҗев

**ГАЗӘЛ** I *и. гар. әд.* 1) Якын һәм Урта Көнчыгыш халыкларының поэзиясендә (Гётедән башлап Европа поэзиясендә дә кулланыла) шигырь төзелешенең бер төре; шигырьнең беренче ике юлы рифмалашып, бу рифма ике юллы һәр куплетның азагында дәвам итә. *Газәл рәвешендә аның «Күңел йолдызы» исемендәге шигыре язылган.* Г.Нигъмәти. *[Һ.Такташ] Мәдхия, газәл, сигезьюллык кебек шәкелләрдән файдаланмады диярлек.* Ф.Галимуллин. *Бүгенге көндә --- шигъри әдәбиятыбыз --- эстрада җырлары мәйданына әйләнеп бара. Аларга сонет ни дә, газәл ни, такмак ни дә, поэма ни...* Л.Шагыйрьҗан

2) *иск.* Гыйшык-мәхәббәт темасына язылган шигырь, бәет; сөйгән кызга багышланган мәдхия. --- *милләтнең укымышлы кешеләре дә бик үк зур белемле булмаганлыктан, иске әдәби кыйссаларны, газәлләрне, касыйдәләрне, мәсәлләрне милләткә тиешенчә аңлатып бирүчеләр дә юк иде.* К.Гасрый. *Бүлектә әдәби төрләрнең генә түгел, ә мәдхия-мәрсия, газәл, касыйдә, мөнәҗәт, сәяхәтнамә кебек жанрларның тел үзенчәлекләре хакында да аерым күзәтүләрне күрәсе килә.* Х.Миңнегулов

**ГАЗӘЛ** II *и. гар. зоол.* Куышмөгезләләр ыруына караган, Африка, Урта, Үзәк һәм Көньяк Азиянең чүл, дала һәм урман-дала зоналарында яши торган, матур сынлы, йөгерек, партояклы хайван; кыр кәҗәсе. *Сахраларын дер селкетеп торган Яллы патша – үз урынында. Өрекмичә йөрсен газәлләр дә, – Төшәр тиздән алар юлына ---.* Р.Әхмәтҗан

**ГАЗӘМӘТ** *и. гар. к.* **газамәт**

**ГАЗӘМӘТЛЕ** *с.* 1) *к.* **газамәтле**. *Мин, әфәнделәр, бөтен төрек-татар милләте исеменнән газәмәтле чехсловак гаскәренә актык канымызгача ярдәм итәргә ант итәмен.* Г.Ибраһимов. *Горурлы, илтифатсыз, газәмәтле бер патша иде.* Ш.Камал. *Әйдәгез, газәмәтле, сихри, мәһабәт Көнчыгышка! Монда акыл, монда самимилек, монда мәһабәтлек.* М.Мәһдиев

**ГАЗГО́ЛЬДЕР** *и. ингл.* Газны кабул итү, саклау һәм газүткәргеч челтәргә җибәреп тору өчен махсус корылма. *Аэростатка кудыртылган гелий газгольдер ярдәмендә соңыннан баллоннарга кире суырттырыла, димәк, ул гелийны күп тапкырлар файдаланып була, һәм шуның белән бу комплекс башкаларыннан отышлы санала.* М.Низаметдинова

**ГАЗЕ́Л ИТҮ** *ф. к.* **газел кылу**. *Без Шаһ Галине алып килдек, Сафа Гәрәйне газел итеп Казаннан чыгарыгыз ---.* Р.Фәхреддин

**ГАЗЕ́Л КЫЛУ** *ф. иск. кит.* Мәхрүм итү; эштән алу, урыныннан төшерү, куу. *Патшалыктан Карганы газел дә кыйлмак булдылар.* М.Гафури. *Сән үзеңнең ихтиярың илә падишаһның әмерене көтмәгән өчен, сәне падишаһ, әлбәттә, бу тугърыда гафу кылмас, кател кылдырыр яки газел кылыр.* Ф.Халиди

**ГАЗЕЛЬ** *и. фр.* < *гар. зоол. к.* **газәл** II

**ГАЗЕТ** *и. сөйл. к.* **газета**. *Кайбер кызлар исә аңа башка сәбәпләр белән дә сылана: «Чит ил кешесе, американ, җитди газетта эшли, димәк, бай кеше...»* Р.Мирхәйдәров. *Газет мәкаләсен генә ул көнендә укып барырга кирәк. Ә сәнгать әсәренең тузганак гомере генә яшәмәвен онытмыйк без!* Ф.Зөлкарнәев

**ГАЗЕ́ТА** *и. ит.* Иҗтимагый, сәяси, икътисади тормыштагы һ.б. яңалыкларны яктыртып бара торган, зур форматлы кәгазьдә, атнасына бер яки берничә мәртәбә чыга торган вакытлы матбугат басмасы. *Булды заманнар, аның да газеталарда макталасы килгән чаклары булды.* А.Гыйләҗев. *Яшермәде, әйтте: газетада эшләгән җиреннән куылып, партиядән чыгарылган икән.* Э.Касыймов

**ГАЗЕТА-ЖУРНАЛ** *җый. и. ит.-фр.* Вакытлы матбугат, һәртөрле газеталар һәм журналлар. *Фәнияр китапларның, газета-журналларның ничек басылуларын сорашты.* Ф.Яруллин. *Әлеге китаптан өзекләр башта республикада чыга торган газета-журналларда басылган иде.* Р.Мостафин. *Газета-журнал битләре бүген-иртәгә корып юкка чыгачак елга исемнәре белән шыплап тулы.* В.Имамов

**ГАЗЕ́ТАЧА** *рәв. сөйл.* Язма стильдә, ясалма, коры, хиссез. *Газетача сөйләшү*

**ГАЗЕ́ТАЧЫ** *и.* 1) Газета редакциясендә эшләүче, журналист. *Җиһаншин үзенең әрсезлеге белән әдипләр, газетачылар, артистлар арасында чуалып йөрүче бер яшьрәк шәһәр бае иде.* С.Сүнчәләй. *Һай да рәхмәт полковникка! Һай да рәхмәт газетачыга! Өйрәттеләр бит хәйләгә!* А.Гыйләҗев

2) Газеталар сатучы кеше

**ГАЗЕ́ТАЧЫЛЫК** *и.* 1) Газета эше, журналистика. *1987 елдан ул янә Казанда газетачылык хезмәтендә: «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт» газеталарында, «Казан», «Мирас» журналларында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире...* Н.Гамбәр

2) Әдәбият яки сәнгать әсәрендә телнең стилистик фигураларга, образларга, хисләргә ярлылыгы, стильнең корылыгы, ясалмалылыгы. *Театрның гомумән эш методына карата төп әйтә торган сүз: «җанлы газетачылык», «курчак уены» методыннан арынып, психологик образлар бирүгә күчәргә, капиталь әйберләрне куюга күчәргә, сәхнәдә җанлы образлар тудырырга кирәк.* М.Җәлил

**ГАЗИ** *и. гар. дини* 1) Ислам дине өчен изге сугышта – газаватта катнашып, аеруча батырлыклар күрсәткән

кешегә бирелә торган шәрәфле исем. *Басып тараткан китаплар исемлегендә «Каһарман Катил», «Зәркум», «Салсал батыр», «Сайкалый», «Сәетбаттал гази», «Баһрам», «Фәттәхетдин», «Хоббихуҗа», «Сәйфелмөлек», «Мәликә» кебек дистәләгән фантастик әсәрләр күренә.* Россиядә беренче төрки-татар басмасы

2) Гомумән, сугыш герое, җиңүче. *Газиләре күп иде, меллалары чук иде.* Бәет. *Ул вакытта солдат егет кешенең ни өчен гази булырга, үзенә тиеш булмаган җиргә бәреп керергә теләгәнен белми иде әле.* Ә.Гадел. *Атаң Ибраһим хан унбер ел дәвамында Мәскәүгә каршы торды, җиңү артыннан җиңүгә иреште һәм «гази» исемен яулады.* Р.Баттал

**ГАЗИЗ** *с. гар.* **1.** 1) Кадерле, иң якын; бердәнбер. *Яз, газиз угълым: кара тактаны сыз акбур белән! Һәм кара күңлеңне ялт иттер сызып ак нур белән!* Г.Тукай. *Күрәмсең бу кабер ташын: Башын игән, рөкүгъ иткән! Басып җиргә газиз башын, Янә кемнәрне юк иткән.* Дәрдемәнд. *Минем өчен газиз җанын кыйдылар бичараның, бер гаепсезгә салкын гүргә тыктылар.* А.Гыйләҗев. *Туган илнең иң газиз, иң мәгънәле ноктасы ул чик баганасы.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Олылап, кадерләп, ихтирам белән. *Бик газиз булып, әти белән әни күз алдына килде.* Г.Бәширов. *Газиз булсын сиңа туган туфрак, Хәтта аның кара ташы да; Ташларны бит үзең шомартырсың, Эш коралым сиңа тапшырам...* Р.Гаташ. *Әни кебек газиз күреп, Туган тел дип җанатып, Яшик әле дөньясында Татар телен яратып.* Ф.Зарипова

**3.** *и. мәгъ.* 1) **газизләр** *күпл. дини* Пәйгамбәрләр. --- *хәзрәти Җөнәйд Бәгъдадыйдан сөаль кыйлдылар: «Шәех вә газизләр хикәятенең мөридләргә ни файдасы бардыр?» – диделәр ---.* К.Насыйри. *Нәзерем булсын: җиде атнада җиде газизләр рухына җиде ясин укып багышлармын.* Г.Камал

2) *куч. күпл.* Пәйгамбәрләргә тиңләрлек кешеләр, халыкның иң бөек кешеләре. *Шул газизләр язмышында Юләрбашлар уйнап ята.* Ф.Яруллин

3) *энд. сүз функ.* Якын, кадерле кешегә эндәшү сүзе. *И газизем, и атам, Каерылып, атны тартаек, Ана Иделгә кайтаек ---.* Дастан. *Ала кошларга бакмакча, Газизем, булма такмакчы ---.* Дәрдемәнд. *И газизем! Бөтенләй кечерәеп калгансың ич. Кайчандыр син миңа гаять зу-ур булып күренә идең.* Н.Әхмәдиев

**4.** *хәб. функ.* Кадерле булу. *Ни газизрәк – бу ватанмы? Ах, туган каумем газиз!* Дәрдемәнд. *Тик бергәүнең дә үләсе килми, һәркемгә җан газиз ---.* М.Маликова. *И балалар, балалар! Бала һәркемгә газиз, керпенең дә баласы йомшак, карга баласы да ак ---.* А.Гыйләҗев

**ГА́ЗИК** *и. рус сөйл.* ГАЗ машинасы, гадәттә, шуның кечкенә моделе. --- *колхоз тагы да эреләнәчәк, ике йөк машинасы, председательгә газик биреләчәк дигән хәбәрләр таралды ---.* М.Мәһдиев. *Колхозның газигы борынын безнең капкага төрткән дә тынып калган.* Р.Хафизова. *Әле генә выжлап барган газик чокыр-чакырлар белән телгәләнеп беткән юлга килеп керде ---.* Ф.Баттал

**ГАЗИМ** *с. гар.* 1) Алдан уйлап куючы, ниятләүче, исәп тотучы

2) Батырчылык итүче, кыюлык итүче

3) Баручы, юл тотучы. *Тәгассыблар, тәшәйехләр нә лазим? Улалым җөмләмез бер юла газим.* Г.Тукай

**ГАЗИМӘТ** *и. гар.* 1) Күңелдән уйлап кую, ният

2) Юлга чыгу, сәфәр. *Газимәт әйләде сүз гөразилә, Сәнең дәгәһыңа гаҗиз ниазилә, Сулар итмәзсәдер ки лотфе галә, Сәбавәт шәһденә йитмеш ниһалә.* Дәрдемәнд. *Бәс, вәли һәм бик хафа булып, --- бер сәгать тормый хаким илә видагълашып, Багдадка газимәт әйләде.* Ф.Халиди

**ГАЗИМӘ́Т КЫЛУ** *ф.* Ниятләү, ният итү. --- *халык рыйзык хасыйл итмәк өчен, Багдаддан кучмәгә газимәт кылдылар ---.* К.Насыйри

**ГАЗИРО́ВКА** *и. рус сөйл.* Эчү өчен махсус әзерләнгән, газландырылган (тәмләткечләр кушылган яки чиста) су. *Арада бар кайберләре: озын чәчләрен туздырып, цехтан цехка әрле-бирле газировка суы эзләп йөрүдән башлары чыкмый, эштә гамьнәре юк.* Н.Хәсәнов

**ГАЗИФИКА́ТОР** *и. рус* Җитештерү өлкәсендә һәм көнкүреш газ коммуникацияләре төзүче, кулланучыларга газ үткәрү белгече, газ кертүче

**ГАЗИФИКА́ЦИЯ** *и. рус* Газ коммуникацияләре төзү, газ үткәрү эше. *Татарстан Президенты каршындагы газификация буенча бюджеттан тыш фонд директоры Җәүдәт Мидхәтовичның улы – Ирек Миннәхмәтов иде.* Т.Нәҗмиев

**ГАЗИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Газификация үткәрү

**Газификацияләп бетерү** Тулысынча газификацияләү

**Газификацияләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр газификацияләү

**Газификацияли бару** Рәттән, бербер артлы газификацияләү

**Газификацияли башлау** Газификацияләргә керешү

**ГАЗЛАНДЫРУ** *ф. макс.* Газ белән туендыру, газ кушу

**Газландыра төшү** Бераз газландыру

**Газландырып тору** Бертуктаусыз газландыру, даими рәвештә газландыру

**ГАЗЛАНУ** *ф.* Газ белән туену, газның концентрациясе арту. *Стәрлетамак, Салават шәһәрләре һәм Уфаның Орджоникидзе һәм Калинин районнары халкы һаваның нык газлануына зарлана.* Кызыл таң

**Газлана бару** Торган саен ныграк газлану

**Газлана төшү** Тагы да газлану

**Газланып бетү** Тәмам, бик нык газлану

**ГАЗЛА́У** *ф. махс. к.* **газландыру**

**ГАЗЛАШТЫРУ** *ф.* Газ белән тәэмин итү өчен, коммуникацияләр салу, газ үткәрү. *Газлаштыру, юллар салу, Казанда метро төзү, Чулман аша күпер булдыру, моңа кадәр күрелмәгән күләмдә уңыш үстерү, КамАЗны аякка бастыру – саный китсәң, халкыбызның фидакарьлегенә исең китәрлек.* Ф.Галимуллин. *Әйтик, авыллар-*

*ны газлаштыру проблемасын алыйк.* Я.Шәфыйков

**ГАЗЛӘТ** *и. гар. иск.* Ялгызлык. *Бер пәйгамбәр яки бер дәрвиш кеби: газләт сөя.* Г.Тукай

**ГАЗЛЫ** *с.* 1) Составында газ булган, газга бай; газландырылган. *Казанлык тирәсендәге тауларда җылы һәм салкын, тозлы һәм төче, газлы, күкертле, тимерле чыганаклар күп.* А.Мурáнов. *Киң аллеяне ике яклап тезелеп киткән газлы су киосклары арасында, әлбәттә, эшли торганнары да юк түгел иде ---.* Ф.Хөсни. *Хәтта газлы су автоматларын сатып җибәрсә дә, уен автоматлары алырга җитмәячәк иде.* Р.Мирхәйдәров

2) Көнкүрештә: газ белән тәэмин ителгән, газ кертелгән. *Үзең олы гына эштә икәнсең, коммунист та диләр, сезгә теге яңа йортлардан – газлы-ванналы өйләрдән фатир бирмиләрмени соң?* А.Гыйләҗев. *Кем дә кем үзенең ванналы, туалетлы, балконлы, газлы җылы өен ташлап, сезнең тавык кетәгегезгә барсын инде?!* Р.Вәлиев

3) Зарарлы газлар белән пычранган. *Алар икәүләп зур бомба чокыры кырыена килделәр, ярыннан төшеп, җыелып торган газлы, каракучкыл суга текәлделәр...* Х.Камалов. – *Миңа сиңа мә! – диде Рәшит. – Үз Казаныңда яшисең, нигә дип сагынасың? Дегетле Зәе тансыкмы, әллә газлы һавасы?* Р.Фәйзуллин. *Төрмәдә утырганчы, газлы шахтада күмер тузаны эчендә эшләвең хәерле.* С.Зыялы

4) Газда эшли торган. *Редактор булгач, тәмәкенең дә ниндиен генә тартасың, ә! Әле газлы зажигалкаң да бардыр, ә?* Р.Батулла. *Берни аңламыйча, буш кул белән йөгереп килгән эшчеләрне күн курткалылар кастет, тимер ыргак, монтировка һәм газлы уенчыклар белән каршы алалар.* Т.Галиуллин

**ГАЗЛЫЛЫК** *и.* Составында газ булу. *Шулай ук 7 мәктәп өчен насослар сатып алып урнаштырдык, 11 учреждениедә җылыту җайланмаларын контрольдә тоту системасы, кайберләренә газ клапаннары, газлылык сигнализацияләре куйдык, төтен торбаларын җылытып изоляцияләдек.* Дуслык. *«Бөгелмәгаз» идарәсе барлык торак-эксплуатация оешмалары җитәкчеләренә, шәхси йортларда яшәүче затларга газ җиһазларының торышына, төтен юлларына күзәтүне көчәйтүне, газ хуҗалыгы хезмәткәрләренә һаваның газлылыгын тикшерү үткәрү өчен керү юлларын ачуыгызны сорап мөрәҗәгать итә.* Маяк

**ГАЗОГЕНЕРА́ТОР** *и. рус тех.* Каты яки сыек ягулыктан газ эшләп чыгара торган махсус җайланма. *Генераторщик Тарасов белән газогенератор янына киләбез.* Р.Ишморат. *Су пары газогенераторга астан бирелә һәм, шулай итеп, реакциягә керүче матдә – күмер белән су пары агымнары бер-беренә каршы хәрәкәт итәләр.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

**ГАЗОЙЛЬ** *и. ингл.* Нефть куу процессында керосин белән майлау материаллары арасында арадаш продукт буларак барлыкка килә торган, мотор, дизельләр өчен сыек минераль ягулыкның бер сорты; шулай ук крекинг өчен чимал

**ГАЗОЛИН** *и. гр.-лат.* Нефть куганда яки промышленность (нефть) газларын аерганда барлыкка килә торган, эчке янулы двигательләр өчен ягулык итеп файдаланыла торган сыек матдә

**ГАЗО́МЕТР** *и. гр. махс.* Лабораторияләрдә төрле газларны җыю, саклау һәм күләмен үлчәү өчен кулланыла торган савыт. *Газометрдагы кислород нормаль шартларда нинди күләм били?* Гомуми химия. *Пиролиз сумаласы кабул итү савытында, пирогаз газометрда җыела.* Нефть продуктлары пиролизы

**ГАЗОН** *и. фр.* Бакча, парк, бульвар һ.б.ш.ларда махсус чәчеп үстерелгән, тигез һәм кыска итеп кыркыла торган үлән белән капланган җир; шул җирдә чәчелгән үлән. *Хәтта газоннардагы чәчәкләр дә, агачларның яшеллеге дә моңсулык катнаш тынлык-нәүмизлек кичергән кебек күренәләр мондый көннәрдә.* Ф.Хөсни. *Газоннар, клумбалар, чәчәкләр, гүя төрле-төрле төстәге күбәләкләр ял итәргә төшкәннәр дә йокымсырап оеп калганнар.* И.Салахов. *Ул әйтә, шәһәрләрдә дә бер генә карыш җир дә әрәм ятмаска тиеш, газоннарга арыш чәчәргә кирәк, ә скверларда алмагачлар, чияләр үстерергә күптән вакыт, ди.* М.Маликова

**ГАЗОСВА́РКА** *и. рус тех.* Металларны газ ярдәмендә эретеп ябыштыру; шуның махсус аппараты

**ГАЗОСВА́РЩИК** *и. рус* Газосварка ысулы белән ябыштыру белгече, шул эш белән шөгыльләнүче эшче

**ГАЗРАИЛ** *и. гар.* 1) Ислам дине буенча: җан алучы фәрештә. *Җырлыйҗырлый үләрмен мин үлгәндә дә, Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә ---.* Г.Тукай. *Газраил кешенең җанын кызыл алма белән алдап чыгара да кешене үтерә.* И.Гази. *Газраил канаты астыннан аны кемнеңдер көчле кулы кисәк тартып алды, чокырга сөйрәп төшерде һәм бөтен гәүдәсе өстенә йомшак, авыр, мәрхәмәтле болыт булып капланды.* М.Маликова

2) *сөйл.* Бик усал, явыз кеше, газаплаучы. *Бу – минем җанымны түгел, малымны алачак газраил.* Г.Коләхмәтов. *Су! Бер йотым суны да кызганасызмы, газраилләр!* Х.Вахит. *Әченнән генә егетнең тетмәсен тетте кыз. Башкисәр, диде, газраил, диде...* Н.Гыйматдинова

3) Үтерүче, җан кыючы. --- *дөресен әйтәм: Гыйлаҗи белән Зариф бабай мәрхүмнәрнең газраиле мин түгел.* Г.Ибраһимов. *1916 елда язылган «Газраилләр» әсәре Такташның беренче шигыре булып санала.* Р.Батулла

**ГАЗСАКЛАГЫЧ** *и.* Газ саклау өчен махсус резервуар. --- *азотны газсаклагычтан корылмага күчерүче вентилятор --- хасил иткән басымны табарга.* Химия технологиясенең процесслары

**ГАЗСЫЗ** *с.* 1) Составында газ булмаган, газландырылмаган. *Безнең урамнарга, тøкеректән башлап, трамвай билетлары, туңдырма кәгазьләре, газлы, газсыз су, аракы, сыра шешәләре, целлофан пакетлар, конфет-печенье каплары һәм зур-зур тартмалар оча ---.* Б.Рәхимова

2) Көнкүрештә: газ белән тәэмин ителмәгән, газ кертелмәгән

**2.** *рәв. мәгъ.* Газ кулланмыйча. *Без үзебез, мәсәлән, өч ай – газсыз, биш ай ваннасыз яшәдек.* Ф.Яруллин. *Ялгыз башы газсыз, утсыз яшәп ятадыр дип, кем уйлаган аны?!* К.Кәримов. *Кагыйдә-законнарга карап торса, Әскәй дә, районның бүтән авыллары да газсыз утырыр иде.* Н.Әхмәдиев

**ГАЗСЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* Төрле объектларны, бинаны, кием һ.б.ш. агулы газлардан арындыру, дегазация ясау

**Газсызландыра бару** Бер-бер артлы, эзлекле рәвештә барлык объектларны газдан арындыру

**Газсызландырып бетерү** Тулысынча газдан арындыру, тулы дегазация ясау

**ГАЗСЫМАН** *с.* Газ хәлендәге. *Хәзерге заман заводына газсыман ягулык биреп торган газогенератор станциясенең чынлыкта ничек булганын сөйләп үтик.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр. *Друде һәм Г.Лоренц тарафыннан тәкъдим ителгән классик теориядә электр коргысын йөртә торган электроннарны бератомлы газсыман булган электрон газы рәвешендә тасвирлыйлар.* Физика

**ГАЗҮЛЧӘГЕЧ** *и. техн.* Газ торбалары аша үткән газның күләмен үлчәү приборы

**ГАЗҮТКӘРГЕЧ** *и. техн.* **1.** Газны ерак араларга торбалар аша күчерү өчен төзелгән махсус система. *Пенсионерларга, инвалидларга, яралы-гарип әфганчыларга, Чернобыль һәм җир тетрәү корбаннарына, җимерелгән шахталарда һәм газүткәргечләрдә зыян күрүчеләргә, качакларга, ятим балаларга – барысына да акча кирәк.* Р.Мирхәйдәров. *Михаил Николаевич чираттагы пунктны укыды: «Йөз дә ундүрт миллиметрлы торбадан эшләнгән газүткәргечне тәмамларга».* З.Дәүләтов. *Нефтьүткәргечләр һәм газүткәргечләр төзеп, аяк басмаган җирләр өстеннән очып үтеп, кеше хайваннар дөньясына --- бәреп керә.* Биология. Хайваннар

**2.** *с. мәгъ.* Газ тапшыру, газ үткәрү өчен хезмәт итә торган. *Гөнаһ шомлыгына, төнлә районда авария булган икән: бер иске йорт янынан, газүткәргеч торба салу өчен, канау казыган булганнар. Сәгать унда йортның бер як дивары шул чокырга ишелеп төшкән.* М.Маликова. *Шәмәрдәннән Сабага газүткәргеч траншеяны казу да колонна техникасы белән башкарылды.* Борынгы Калатау итәгендә

**ГАЗЧЫ** *и.* 1) Газ җитештерү өлкәсендә эшләүче. *Башта без йөри идек җир астында кайда нәрсә ятканын өйрәнеп, безнең арттан киләкксә төзүчеләр, нефтьчеләр, газчылар, атомчылар килә иде...* Ф.Бәйрәмова

2) *к.* **газификатор**. --- *кунаклар, алтын куллы газчылар тарафыннан иҗат ителгән кар-боз патшалыгын (аны сүз белән генә аңлатып бетереп булмый) карап, профессиональ сәнгать югарылыгындагы мондый корылманың зур шәһәрләрдә дә булмавын әйттеләр.* Г.Нәҗмиев. --- *штукатур-малярлар янына су, канализация, җылылык системасын үткәрү өчен – сантехниклар, газ һәм ут бирү өчен газчылар белән электриклар килә. Бу чакта йорт кырмыска оясын хәтерләтә: эшчеләр ыгы-зыгы килә.* Ә.Сафиуллин

**ГАЗЫБ** *и. гар.* Ачу; ачулану, кызып китү. *Газыб илә агзыннан утлар чәчәр.* Г.Тукай

**ГАЗЫЙ** *и. гар. к.* **гази**. *Ш.Мәрҗани Болгар чорында «Шәһәре Болгар газыйлары» һәм «Нәүрүз» бәетләренең булуы турында ачык итеп әйтә.* Х.Ярми. *Куркъмыйбыз дошманнан асла, Без – баһадир газыйлар ---.* С.Сүнчәләй

**ГАЗЫЙМ** *с. гар.* 1) Бөек (Аллаһының исемнәреннән берсе). *Бер-бер нәрсә эшләсеннәр, валлаһи газыйм, ярман каласыннан кайтырмын, шул егетне кеше итмәм!* Ф.Бурнаш. *Һәр кич саен, ишегемне ачып, Улым белән кызым каршы ала. Шул бәхеттән мәхрүм итмәсәң лә, Газзә вә җәлләһи газыйм Алла!* Ш.Җиһангирова

2) Чиксез зур. *Бу кичә диңгез өстендә йөреп, сабак булдыкда, диңгез буенда ерак түгел җирдә бер газыйм абад шәһәр --- күрделәр.* Ф.Халиди. *Ишәк әйтте: «Бак, углым, гафил булма, саклан, алданма, аның аргы ягында кыямәт дәһшәте вә бәлаи газыймы бардыр», – дип, баласына нәсыйхәт итте.* К.Насыйри

3) Югары дәрәҗәле, бик өлкән

4) Әһәмиятле, җитди

**ГАИБ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Күз алдыннан югала торган, күз алдында булмаган

2) Юкка чыккан; күзгә күренми торган, яшерен. *Әмма бер урында Г.Ибраһимов болай дип тә куя: «Бу хәзерге материалга карап әйтелә, әгәр бер гаиб хәзинә килеп чыкса да, татарның Казан ханлыгы, Алтын Урда заманындагы әдәбиятлары табылса, мәсьәлә, әлбәттә, үзгәрер иде».* Х.Миңнегулов

**2.** *хәб. функ.* Юк

**ГАИБАНӘ** *рәв. гар. иск.* Күрми торып, күз артында, читтән торып, үзе юкта

**ГАЙБ БУЛУ** *ф.* Юкка чыгу, юк булу. *Гаскәрнең каһарманнарның сугышуыннан хәбәрләре булмадыгыннан: «Каһарманнарымыз гаиб булды», – дип, Һушәң шаһка хәбәр бирделәр.* Дастан. *Ә кыз шул хәл гомердә булмаган төсле гаиб булды.* Г.Тукай

**ГАИБИ** *рәв. гар. иск.* Күрмәстән, күрми торып, читтән торып. --- *шушы гаиби, еракта танышлык илә бер нәүгъ мәхәббәт вә хөрмәт хасил итмешдем.* Й.Акчура

**ГАЙБ ИТҮ** *ф.* Югалту. *Шаһ Гали, бөтен Казан мөселманнарының күзеннән төшүеннән вә әманиятен гаиб иттекеннән мәэюсь булып, мәхәббәтләрен җәлеп итү өмете белән, великий кенәздән Тау ягының Казан дәүләтенә кире кайтарылуын сорап карый ---.* Р.Фәхреддин

**ГАИД** *с. гар. иск.* **1.** Берәр нәрсәгә караган, шуңа бәйләнешле, мөнәсәбәтле. *Мин мәкаләмнең башында иске татар әдәбиятына гаид бәгъзы мөлахәзәләремне язган идем.* Ф.Әмирхан. *Бу әсәрнең мөкаддимәсе тарихка вә башка дини иҗтимагый мәсьәләләргә гаид нәзары мәсьәлә хакында сөйли торган бер әсәрдер.* Г.Гобәйдуллин. *Уенчылар, гомумән, үзләренә гаид вазифаларында кимчелек күрсәтмәделәр.* Г.Камал

**2.** *хәб. функ.* Берәр нәрсәгә караган булу, шуңа бәйләнешле булу. *Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем.* Г.Тукай

**ГАИЛӘ** *и. гар.* 1) Ата-ана, ир-хатын һәм балалардан торган, бергә яшәүче кешеләр төркеме, өй җәмгате. *Хәбир – гаиләдәге алты баланың өлкәне, ә аның әнкәсе тирә-юньдә уңганлыгы, чисталыгы белән дан тоткан хатын булып чыкты.* М.Маликова. *Минем дөньяга килүем болай да авыр тормыш сөргән гаиләнең хәлен тагы да авырайта һәм аерата әниемә зур мәшәкатьләр өсти.* А.Расих. --- *картайган Мирзанур, чәй янында ишле гаиләсеннән зарланып, бала-чагасын сүгеп утырган иде ---.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Уртак эш, мәнфәгатьләр, фикер бердәмлеге һ.б.ш. белән бәйләнгән кешеләр коллективы. *Алар, туган булу өстенә, яшьлек елларында Югары Курсада бергә укытканнар, тату, дусларча бер гаиләдә яшәгәннәр.* А.Расих. *Монтажчылар бригадасы – бер уй, бер теләк, бер максат белән яши торган гаилә ул.* Г.Кашапов

◊ **Гаилә кору** Өйләнү яки кияүгә чыгу, гаилә төзү. *Тик минә өйләнгәч, гаилә корып җибәрү өчен, бер куыш кирәк.* А.Расих. *Гаилә кору бит ул ихахай-михахай гына түгел. Гаилә башлыгы, ягъни син, авыр йөк аты кебек ---.* Г.Ахунов

**ГАИЛӘЛЕ** *с.* Гаиләсе булган, өйләнгән яки кияүдәге (кеше). *Ул хәзер үзе генә түгел, хатынлы, гаиләле.* Х.Камалов. *Гаиләле яшьләр тиз аякка басалар. Аларга фатирны да тиз бирәләр.* Ә.Салах. *Кунаклар барсы да диярлек бер даирә кешеләренә охшаган: гаиләле яшь парлар.* С.Сабиров

**ГАИЛӘСЕЗ** *с.* **1.** Гаилә кормаган, гаиләсе булмаган. *Мин – гаиләсез студент.* Идел. --- *гаиләдәгеләр бала тапмый – мәшәкатеннән курка; гаиләсез хатын-кызның бала табарга хакы да, мөмкинлеге дә юк; ә булган балаларны рәтләп, кеше итеп үстерергә хәленнән килми.* Татарстан яшьләре

**2.** *рәв. мәгъ.* Гаиләсе белән бергә түгел, гаиләсеннән башка. *Аңа илдән гаиләсез генә чыгып китәргә рөхсәт бирелгән, кулына билет та тапшырылган, ләкин ул туган иленнән китүдән катгый баш тарта.* Кызыл таң. *Бу афәт аркасында күпләр машинасыз, фатирсыз, хәтта гаиләсез калды.* Кәеф ничек?

**3.** *и. мәгъ.* Гаилә кормаган кеше. *Ә менә сорашу нәтиҗәләре барысы өчен дә: байлар һәм ярлылар өчен дә, гаиләле һәм гаиләсезләр, ирләр һәм хатын-кызлар өчен дә чама белән бер үк төрле килеп чыккан бит!* Ватаным Татарстан

**ГАИЛӘСЕЗЛЕК** *и.* Гаиләсез булу хәле. *Тукайның үтә нечкә һәм чиста җаны дөньядагы начарлыкларга башкаларга караганда күбрәк игътибар бирергә мәҗбүр. (Монда – ятим балачак, милли-дини изелгәнлек, үпкә авыруы, гаиләсезлек һ.б.).* И.Вәлиулла

**ГАИЛӘЧЕЛ** *с.* Гаилә җанлы, гаиләсе өчен тырышучы, гаиләсен яратучы (кеше). *Гаиләчел. Намусын базарга чыгарып сатарга ризадыр, әмма гаиләсенә чебен дә кундырмас.* М.Хәбибуллин. *Ул [Р.Вәһапов] яхшы гаиләчел кеше иде.* Казан утлары

**ГАИП** *с. гар. иск.* **1.** 1) *к.* **гаиб 1.** (*1–2 мәгъ.*). *Гаип казна мөгайян тау тишегендә...* М.Гафури. *Портфельне ачулары булды, капитан Сәйдәшев кычкырып ук җибәрде: – Менә кайда икән гаип хәзинә, шайтан алгыры!* М.Насыйбуллин

2) *лингв. иск.* Өченче затка караган. *Гаип алмашлык. Гаип зат*

**2.** *хәб. функ.* Юк, юкка чыккан, югалган. *Һәм шул китүдән гаип: өенә кайтып җитми. Ни булган, берәр бәхетсезлеккә юлыкканмы, юлда-мазар үлеп калганмы? – белүче дә юк, күрүче дә...* Ә.Еники. *Аннан, сөйләп ни мәгънә?! Анасы да, баласы да гаип...* Н.Гыйматдинова

◊ **Гаиптән хәбәр** Хорафатлар буенча киләчәкне белү, булачак вакыйгалар турында кисәтү һ.б.ш. өчен илаһи көчләр тарафыннан җибәрелгән һәм кешеләр тарафыннан төрлечә юрала торган берәр галәмәт, билге, хәбәр

**ГАЙП БУЛУ** *ф.* Югалу, юк булу, юкка чыгу. *Бу халыклар кинәт кенә юкка чыкканнар, эзсез-нисез гаип булганнар, нәсел-буыннары да калмаган.* Ә.Кәримуллин. *Зөһрәбану исә кеше күзенә карамый, куркак явыз көчек кебек ләң-ләң өрә дә күздән гаип була ---.* А.Гыйләҗев. *Гаип булды ул, тирән упкынга төшеп киткәндәй булды.* Р.Фәизов

**ГАЙП ИТҮ** *ф.* Югалту; юкка чыгару. *«Нәфес» дигән бeлэм чирне, Гаип итте бик күп ирне: Урындагы абзыйларны, Тарихларда – казыйларны.* Р.Зәкуан

**ГАИТ** *бәйл. гар. иск. к.* **гаид**. *Сөйләячәгем унҗиде яшь тулып яңа унсигезгә чыккан заманыма гаит.* Г.Ибраһимов

**ГАЙБӘТ** *и. гар.* 1) Чынлыкка туры килмәгән яки чынлыкны бозып сөйләнгән сүзләр, имеш-мимеш. *Юкка уздырма көнеңне юк кына гайбәт белән ---.* Г.Камал. *Ифрат дәрәҗәдә гайбәтчеләр, аталары ак сакалы белән гайбәттән бушамый.* Ф.Әмирхан. *Башта аның Мостафасын кайберәүләр, чынлап та, Кажҗул Камалиның акылга җиңел Сәрвиназына өйләнә икән дип уйладылар – әллә гайбәт, әллә чын.* К.Нәҗми

2) Кемнең дә булса хатасын, кимчелекле ягын гаеп итеп сөйләнгән сүз. *Инде гайбәтләре дә чыга башлаган иде, ләкин, әйткәнемчә, Сабир абзый озакламый роман җепләрен ансат кына өзеп --- китеп тә барды...* Ә.Еники. *Ә Гөлнара – Наиләдән өч яшькә генә олы хатын – --- тәҗрибәле, көнче, үпкәләүчән һәм гайбәтләрне итәгенә җыя торган ут күзле хатын иде ---.* А.Гыйләҗев. --- *бу китап, басылып чыккач та, гайбәт сатудан ләззәт алган татарлар арасында бик күп сүзләргә, төрле гайбәтләргә сәбәп булган иде.* Ф.Туктаров

◊ **Гайбәт ашау** *к.* **гайбәт сату**. **Гайбәт итү** 1) *иск.* Гаепләп сөйләү, яманлау. *Фәрхәнә абыстай ниндидер бер гаиләне гайбәт итеп утыра иде.* Ф.Әмирхан; 2) Гайбәт сөйләү, юк-бар сүзләр, имеш-мимешләр сөйләү. **Гайбәт капчыгы** Гайбәтче кеше. *Гайбәт капчыкларының авызын бәйләп булырлык түгел, тулып ташыган.* М.Маликова. **Гайбәт сату** Кемне дә

булса яманлау, яманлап сөйләү, гайбәт сөйләү. *Хәзер минем гайбәтне сата башларлар дип көтсәм дә, минем турыда сүз башлаучылар булмады.* Г.Нәбиуллин. *Инде утыз җиде минут телефоннан гайбәт сата.* Ф.Баттал. *Син нәрсә! Без аны җирләп кенә кайттык... Гайбәтен сатарга!* М.Маликова. **Гайбәт чәйнәү** *к.* **гайбәт сату**. *Гайбәт чәйнәгәнче, сагыз чәйнә.* Мәкаль. **Гайбәт чүлмәге тулу** Төрле имеш-мимеш, гайбәт күп җыелу. *Гайбәт чүлмәкләре тула башлагач, әлеге дус дүрт хатын янә җебенергә җыеналар.* З.Хөснияр

**ГАЙБӘТЛӘ́Ү** *ф.* Гайбәт сөйләү, гаепләп, яманлап йөрү. *Күршем кереп чыгар иде, гайбәтләп-гайбәтләп чәй эчеп алыр идек. Ату монда бер торт ике атна утыра инде ---.* Н.Измайлова

**Гайбәтләп йөрү** Һәр җирдә, теләсә кайда гайбәтләү

**Гайбәтләп тору** Гел, әледән-әле яки хәзерге вакытта гайбәтләү

**Гайбәтли башлау** Гайбәтләргә керешү

**ГАЙБӘТЛЕ** *с.* 1) Гайбәткә нигезләнгән; гайбәтләр китереп чыгара торган

2) Гайбәт ителгән, аның турында күп гайбәт чыккан, гаепләп сөйләнгән. *Мәхәббәт күзсез була, ди, Ярату сүзсез була. --- Безнең мең күзле булды, Гайбәтле, сүзле булды!* Р.Фәйзуллин

**ГАЙБӘТСЕЗ** *с.* Гайбәт яратмый торган, гайбәт сөйләмәгән. *--- холыкхарактерлары белән дә киң күңелле, гайбәтсез, вак-төяккә егылып китүчеләрдән түгел...* И.Низамов

**ГАЙБӘТЧӘН** *с. к.* **гайбәтчел**. *Буржуем, байбәтчәм, үзең булдың гайбәтчән.* Г.Камал. *Шундый кысынкы гаиләләрнең балаларындагы төрле-төрле табигатькә бик тирес гөнаһларга чумуы, егетләрнең, егетлекләрен онытып, хатын-кыз табигате алып, вакчыл, гайбәтчән булулары – моңгарга җитәрлек дәлилдер.* Г.Исхакый. *Сусыз авыл халкы, киресенчә, вак холыклы, гайбәтчән, көнче була.* М.Мәһдиев

**ГАЙБӘТЧЕ** *и.* **1.** Гайбәт таратучы, сүз йөртүче, яла ягучы кеше. *Әлбәттә, Казанның бөтен гайбәтчесенә билет җитмәде, күбесенә клубта урын булмыйча, кайтып киттеләр.* С.Рәмиев. *Ишетеп йөрим: гайбәтчеләр сүз тарата, Зөһрәбану да гел яный, гел каргана.* А.Гыйләҗев. *Әмма гайбәтчеләрнең сүзендә тырнак очы кадәр дә дөреслек юк!..* Р.Хәмид

**2.** *с. мәгъ.* Гайбәт, юк-бар сүз таратучы. – *Анда гайбәтче карчык утыра, әйдә монда, – дип, келәткә таба тартты ---.* Г.Ибраһимов. *Болар өчәвесе дә татар әдәбиятында чагылган гайбәтче мещан хатыннарының классик образлары булып торалар.* М.Галәү. *Гайбәтче Миңлеҗамал карчык та Гөлбикәне яратты.* А.Гыйләҗев

**ГАЙБӘТЧЕЛ** *с.* Гаеп итә, гайбәт сөйли торган гадәте булган, гайбәт сөйләргә яратучан. *Беренче көннән соң йортның киленнәре, яман тел, гайбәтчел кимперләре алдында байбичә үземне хур кылды ---.* Г.Ибраһимов. *Өй эчендәге гайбәтчел асрауларны да, тирә-юньне сырып алган танышларны да, --- – берсен дә, берсен дә күрәсе килми.* К.Нәҗми. *Усал күзләрдән, гайбәтчел карашлардан саклау өчен, мин дә сине вакытлыча күңел төбенә салып куйдым ---.* Р.Низамиев

**ГАЙБӘТЧЕЛЕК** *и.* Гайбәт сөйләү гадәте, гайбәтче булу. *--- кешене ямьсез итеп күрсәтүче сыйфатлардан – икейөзлелек, гайбәтчелек, хөсетлек, мактанчыклык һәм башка бозык гамәлләрдән сакланырга кирәклеге гыйбрәтле хикәяләр үрнәгендә бәян ителә.* Ж.Зәйнуллин. *Гайбәтчелек гөнаһыннан арыну авыр түгел. Кеше бары тик, ихтыяр көчен җыеп, теленә хуҗа булырга тиеш.* Инсан һәм дин

**ГАЙБӘТЧЕЛЛЕК** *и.* Характердагы гайбәтчел булу үзлеге

**ГАЙБҮБӘТ** *и. гар. иск.* Югалу, юкка чыгу. *Кальбемә гайбүбәтең тагълар кадәр вирди кәдәр...* Г.Тукай

**ГАЙГЫЛДА́У** *ф.* 1) Калын көр тавыш белән, көчле кычкыру (казлар турында)

2) *куч.* Артык кычкырып, ихахайлап көлү

**Гайгылдап алу** Бераз гайгылдау

**Гайгылдап җибәрү** Кинәт гайгылдый башлау

**Гайгылдап кую** Бер тапкыр гайгылдаган тавыш чыгару

**Гайгылдап тору** Бертуктаусыз гайгылдау. *Әбделмән куписнең абзарында Гайгылдап торадыр казлары ---.* Җыр

**Гайгылдый башлау** Гайгылдарга тотыну

**ГАЙГЫЛДАШУ** *ф.* 1) Көчле тавышлар белән берьюлы күп казлар кычкыру

2)*куч.* Көлешү, кычкырышу, күп кеше берьюлы ихахайлап, кычкырып көлү

**Гайгылдаша башлау** Барысы берьюлы гайгылдарга керешү

**Гайгылдашып алу** Бераз гына, берара гайгылдашу

**Гайгылдашып тору** Хәзерге моментта яки бертуктаусыз гайгылдашу

**ГАЙГЫЛДЫК** *с.* 1) Гел гайгылдап торган. *Гайгылдык каз*

2) *куч.* Яңгыравык, көчле, көр. *Гайгылдык тавыш белән сөйләшү*

**ГАЙДАМАК** *и. төр. тар.* 1) XVIII гасырда поляк шляхтасына каршы баш күтәргән украин крестьяны. *«Сугышчылар түгел гайдамаклар, Юлбасарлар, имеш, караклар, Тарих өчен алар бер тап», имеш... Ялганлыйсыз, явыз җәлладлар!* М.Җәлил

2) 1917–1919 елларда гражданнар сугышы чорында Украина Үзәк Радасы гаскәрендә яки Петлюра һәм Скоропадский отрядларында хезмәт иткән сугышчы

**ГАЙДУК** *и. пол.* < *венгр тар.* 1) Көньяк славяннарда, молдаван, валах, венгрларда төрек хакимлегенә каршы баш күтәрүче; партизан. *Гайдукларның төп дошманы төрекләр булса да, алар ислам динен кабул иткән славяннарга карата да мәрхәмәтсезлек саклыйлар.* Урта гасырлар тарихы

2) Кайбер илләрдә XVIII–XIX йөзләрдә хуҗасының каретасын озатып баручы лакей

3) Атлы сугышчы, атлы гаскәр. *--- кичә төнлә белән гайдук җибәртеп алдырып, его превосходительство господин губернатор фон Брант әмер итте, падишаһымызның әмере шушы манифестны татарчага әйләндереп, бөтен мәчеттә, базарларда укыттыру икән ---.* Г.Гобәйдуллин

**ГА́ЙКА** *и. рус тех.* Винт, болт һ.б.ш. нәрсәләргә борып кертелә торган бер-

кетү детале. --- *без болт һәм гайкаларга сыр төшерә башладык.* Э.Касыймов. *Ул инде хәзер нинди гайкага нинди ачкыч кирәген, тракторның кайсы рычагын тарткач, кай якка борылуын --- белә.* Ф.Яруллин. *Закировны тентеделәр. Чалбар кесәсеннән бер гайка белән винтовка гильзасы чыкты.* М.Мәһдиев

◊ **Гайкасы йомшак** *сөйл.* Йомшак характерлы, көчсез кеше. **Гайкасын бору** Шелтәләү, ачулану; таләпчәнлекне арттыру, кырыслату. **Гайкасын кысу** *к.* **гайкасын бору**

**ГАЙМОРИТ** *и. мед. (инглиз анатомы Гаймор исеменнән)* Борын яны куышлыгы (Гаймор куышлыгы) сүрүсенең ялкынсынуы. *Алар [гөмбәләр] кешедә төрле авырулар (лишай, парша, дерматитлар) китереп чыгара, кайчак гайморит, үпкә авыруларына, агулануга сәбәпче була.* Л.Мәүлүдова. *Яшүсмерләрдә травматизм, аденоидлар, гайморит, дерматит, мигрень еш очрый.* Сәламәтлек нигезләре

**ГАЙН** *с. гар. иск.* **1.** Шундый ук, бер үк төрле, нәкъ шундый. *Ул инде ялгыз инсаниятнең бер кисәгенә, үзе илә гайн каннан, гайн диннән булган бер кыйсменә генә түгел, бөтен мәзлум --- ач-ялангач әксәриятенә хезмәт итмәк булды.* Й.Акчура

**2.** *рәв. мәгъ.* Бөтенләй, тулысынча, тәмам. *Гавам халкы башларын без каңгырттык, Вөҗүдемез гайне бер афәт булды!* М.Акмулла

**ГАЙНӘН** *рәв. гар. иск.* Нәкъ үзенчә, үзгәртмичә, ничек булса, шул көенчә, булганча. *Бу вакыйга шактыйга мөһим булганлыктан, бу урында аны гайнән күчерү мәгъкуль табылды ---.* Г.Гобәйдуллин. *Гыйрфан мулла ут кебек кызып тузынды да китте: – Соң, Алла колы, гайнән – «үзгәртмичә», «ничек булса, шул көенчә» дигән мәгънәне аңлата бит ул.* С.Поварисов

**ГАЙРӘТ** *и. гар.* 1) Көч, куәт, хәл, егәр. *Гайрәтем тәнемә сыймый башлады.* М.Әмир. *Куәт диңгез миндә, гайрәтем шул, Һич җиңелмәм кара көчләргә ---.* С.Кудаш. --- *шушы иске кием белән дә Җиһангир үзен чын патшаларча тота белә: сыны мәһабәт, кыяфәте горур, карашы салкын һәм мәгърур – бөтен рәвешеннән теләсә кемне баш идерерлек гайрәт бөркелә.* М.Маликова

2) Батырлык, кыюлык. *Мәскәү гаскәренең Казан янында тора башлавына биш атна булып, казанлылардан 10 меңнән артык җан хисабын һәлак итсәләр дә, казанлылар һаман да үзләренең гайрәтләренә кимчелек китермәделәр...* Р.Фәхреддин. *Властьның түбән белгән кешенең гайрәте, тәвәккәллеге нык арта.* М.Маликова

3) Тырышлык, чын күңелдән бирелгәнлек, дәрт. *Тик шундин соң шундый гайрәт аркасында, Мәктәпләр дә әкрен-әкрен алга китәр.* Г.Тукай. *Яңача эш башларга көч-куәт тә, гайрәт тә калмады.* А.Гыйләҗев. *Эшләнәсе эшләрне артка чигерергә күнеккәнбез. Ул арада вакыт үткән, гайрәт суынган була.* Р.Әхмәтҗанов

4) Ачу, ярсу. *Азамат ир Туктамыш, Гайрәтеннән бузарып, Киң Җанбайга аны әйтте...* Дастан. *Сугыш вакытында атасына ничә мәртәбә ислам динен гарыз кыйлды. Атасы кабул итмәде, мөселман булмады. Ахыры гайрәте килеп, атасын үтерде.* К.Насыйри

5) Исерткеч эчемлекнең куәте. *Егетләр маташкалаган арада, хәмер гайрәте канга күчәргә дә өлгермәде, кәеф барометры аязуны күрсәтә башлады.* Б.Камалов. *Сакчы бер чәркә төшергәч, куйды шешәгә карап: – Гайрәте хәйран икән, – ди, – бу, энем, нинди шәраб?* М.Саттаров

◊ **Гайрәт кайту** *к.* **гайрәт чигү**. *Кинәт Гайнанның гайрәте кайтты, хәзер инде әйтәсе фикеренең әһәмияте дә калмаган кебек тоелды.* Г.Бәширов. **Гайрәт керү** 1) Хәлләнеп, дәртләнеп китү. *Урманда соры болан күрдем. Шундый мәгърур! Шундый эре! Аның көчле сынын күргәч, күңелемә гайрәт керде.* Р.Фәйзуллин; 2) Исерә башлау, башка китү. **Гайрәтне кайтару** Сүрелдерү, күңелне кайтару, күңелне төшерү, теләкне бетерү. *Ахыр чиктә, Кирмән татарларының гайрәтен кайтармас өчен, аны, бик ихтимал, рухани ата-кайлар кулына тапшыралар...* М.Хәбибуллин. **Гайрәтне чигерү** *к.* **гайрәтне кайтару**. *Салиха апа карышса, ызгышса, улының гайрәтен генә чигерәсен аңлады.* М.Маликова. **Гайрәт ору** 1) Батырлык күрсәтү. *Кешенең көче үзенә ышануда. Күңелеңне нечкәртмә. Батыр бул, гайрәт ор!* Г.Кутуй; 2) Урынсыз шапырыну, үзен күрсәтү. *Ислам гаскәренә аңсыздан бу пәһлуан белән гаскәрнең килеп гайрәт оруын сахиб кыйран Каһарман күргәч, бу хурлыкка чыдап тора алмый, гаскәрне йөреп, мәйданга атылып чыкты...* Дастан. *Әгәр кызмачарак та булса, җилән чабуларын җилбәгәй җибәреп, бүреген күз өстенә төшереп, урамга сыймагандай шаулап, гайрәт орып, өенә кайта торган иде.* Ә.Еники. *Мәрфуга җиңги, гайрәт орып, урыныннан калкынды.* М.Шабай; 3) Кызып китеп тавышлану, ачулану, җикеренү. *Нидер калын тавыш сугып еккандай булды. Иргали башын күтәрде: «Кем болай гайрәт ора?»* И.Салахов. *Жорка исә бик җитди, күзләрен тасрайтып, аскы иренен тешләп, шулкадәр гайрәт ора: икебезне ике кулына эләктергән килеш, җилтерәтепме җилтерәтә.* А.Расих. **Гайрәт сүнү** *к.* **гайрәт чигү** (*2 мәгъ.*). *Изелә, һиммәте вә гайрәте сүнә, ваклана, ялкаулана, авырая вә рухаи үлә.* Г.Баттал. *Элеккеге сизгерлеге дә, ташып торган гайрәте дә сүнеп бара шикелле.* З.Хөснияр. **Гайрәт чәчү** *к.* **гайрәт ору**. *Гайрәт чәчә рәис: «Әллә үзең Татып кайтасыңмы кереп, ә?..»* Г.Сәгыйров. *Ул фетнәчеләрнең уллары хәзер Кызыл гаскәрдә хезмәт итә, ди. Яшь әтәчләр гайрәт чәчми калмас ---.* Т.Әйди. *Мәхәббәтне сатып алып булмый, дип, бушбугазлар гына гайрәт чәчә бит ул.* В.Имамов. **Гайрәт чигү** 1) Күңел кайту, бизү, тую. *Гайрәтем тәмам чиккән дөньяның әле мине тыныч сиендырыр почмагы шушымы?* А.Гыйләҗев. *Кибетче кызларга контроль ясап, вәгазь укып ерак китеп булмый. Аларның синнән гайрәте чигәчәк.* Г.Ахунов. *Бу сүздән ике ирнең дә гайрәте чиккән...* Н.Гыйматдинова; 2) Сүрелү, теләк бетү. *Мөхәррир, язылган әсәрләренең басыла алмавын күреп, язудан гайрәте чиккән кебек, бернәрсә дә язмый.* Ш.Мөхәммәтьяров. *Кыскасы, Казанда да, Троицкига кайткач та,*

*минем тырышлыкларымнан берни дә мантымады, минем скрипкадан тәмам гайрәтем чикте.* А.Расих

**ГАЙРӘ́Т ИТҮ** *ф. иск.* Тырышу. *Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син. Чын сөбатлә алга бардың, бакмый улга-суңга син.* Г.Тукай. *Йосыф мирза, бердән, кызы Сөен бикә белән нәбирәсе Үтәмеш Гәрәй ханны яклау вә, икенчедән, Казан мәмләкәтен ислях кылу теләге белән, солых өчен Иван хозурында күп гайрәт итте.* Р.Фәхреддин

**ГАЙРӘ́Т КҮРСӘТҮ** *ф.* 1) Тырышу. --- *ул йончу хәленә җитте. Әмма сер бирми, җебегәнен сиздерми, текә маңгаена чыккан тир бөртекләрен дә сөртеп алмый, үзенчә бер гайрәт күрсәтмәк була инде.* С.Поварисов

2) Батырлык күрсәтү. *Кырым түрәләреннән Кушак углан халыкны сугышка өндәр вә гайрәтләр күрсәтер иде...* Р.Фәхреддин

3) *күч.* Шапырыну, үзенә игътибар иттерү

**ГАЙРӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* Куәтләү, көч бирү, гайрәт кертү, дәртләндерү. --- *Ибраһим Галиев, карчык-акушерканы алдалап һәм аны җинаятькә гайрәтләндереп, әнә шулай сабый баланың гомерен өздерде.* З.Бигиев

**Гайрәтләндерә бару** Торган саен ныграк гайрәтләндерү. *«Зәм-зәм суы»ның пары барын да гайрәтләндерә-дәртләндерә бара, «арыслан тотарлык» дозаны күпләр инде күптән узып киткән, «регламент» дигәне отыры югала бара, табын янында бары Кәеф галиҗәнабләре...* Роберт Әхмәтҗан

**Гайрәтләндерә төшү** Бераз гайрәт өстәү, дәртләндереп җибәрү

**Гайрәтләндереп җибәрү** Күңелне күтәреп, куәтләп, дәрт, гайрәт керерлек итеп тәэсир итү. *Бу эш --- безне тергезеп һәм гайрәтләндереп җибәрде.* Ф.Әмирхан

**Гайрәтләндереп тору** 1) Бертуктаусыз гайрәтләндерү. *[Елкин] Һаман басып, гел алга атылып, башкаларны гайрәтләндереп торды.* Ш.Усманов

2) Әле, хәзер, сөйләп торганда кемне дә булса гайрәтләндерү, нindidер эшкә дәртләндерү

**ГАЙРӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) Көч керү, гайрәт (*1 мәгъ.*) иңү. *Сукырлар – кайчан да булса күрү, --- көчсезләр – гайрәтләнү, талантсызлар талантлары ачылу турында хыялланмасалар, тормышның никадәр яме ким булыр иде.* Ф.Яруллин

2) Батыраю, дәртләнү. *Анлар базарда очраган картның иярченнәре икән. Һәркаюсы коралланган, гайрәтләнеп баралар.* А.Таһиров. *– Кем курка, ди! Бәйлән генә, күзеңне чукыйм! – дип гайрәтләнде кыз ---.* Н.Гыйматдинова

3) Шапырыну, артык кызып китү. *Ул тагын кулын алга сузып, гайрәтләнеп, нидер кычкырды.* Ә.Еники. *Шәфигулла агай Рәхимов иптәшенең сүзләрен кызып-кызып, гайрәтләнеп-гайрәтләнеп, кат-кат әйтә-әйтә сөйләде.* Ф.Әмирхан

4) Кызып китү, кычкырыну, ачулану. *Инде шактый җир киткәч кенә, ул корыга лаф орып гайрәтләнергә тотынды.* М.Шабай. *– Якын барып карагыз безнең өйгә, күрмәгәнегезне күрсәтермен! – Рөстәм тәмам гайрәтләнгән иде.* Р.Хафизова

5) *күч.* Ярсу, дулкынлану. --- *очтагы паровоз, калын гына итеп кычкырта да, азрак гайрәтләнеп пошкырганнан соң, әкрен генә кузгалып китә.* Ә.Еники. --- *җилле көннәрдә --- дулкыннар, гайрәтләнеп, кыяташларга килеп-килеп бәреләләр, гүя аларны ишеп төшерергә телиләр.* А.Муранов

**Гайрәтләнә башлау** Гайрәтләнергә керешү

**Гайрәтләнә бару** Торган саен гайрәте арту. *Ул өйдә кирәк, аны бала тапкан саен гайрәтләнә генә барган хатыны көтә һәм... эш, эш, эш!..* Ә.Гаффар. *Ләкин артист Иван Сулейманович Кацман, үләсе урында, эчкән саен гайрәтләнә генә барды.* Р.Батулла. *Бүгенге дөньяның иң зур парадоксы: кеше һаман көчәя, гайрәтләнә бара, ә Җир гүя торган саен кечерәя, көчсезләнә.* Казан утлары

**Гайрәтләнә төшү** Бераз гайрәтләнү; тагын да ныграк гайрәтләнү. *Ул алдындагы әйберләрне берсен тегендә, берсен монда күчергәләп, акыл җыеп утырды-утырды да, гайрәтләнә төшеп: – Ярар, Мөхәммәтҗан, – диде.* Г.Бәширов

**Гайрәтләнеп алу** Бераз гайрәтләнү. --- *көчнең үзендә булуын күрсәтергә теләгән иде ул җизнәләренә. Шуңа күрә генә азрак гайрәтләнеп аласы килгән иде.* Г.Мөхәммәтшин. *Әле берни аңламаган ир, иңбашларын турайтып, кукраеп, гайрәтләнеп алды.* Т.Галиуллин

**Гайрәтләнеп җитү** Тулы гайрәт керү, тәмам гайрәтләнү. *Ә инде үсеп җиткәч, Йөрәкләнеп тә киткәч, Гайрәтләнеп тә җиткәч, Уйлаган ул беркөнне, Тыңламыйча беркемне, Азрак уйнап килергә ---.* Р.Миңнуллин

**Гайрәтләнеп йөрү** Артык батыраю, батырлыгын күрсәтергә тырышу. *Беренче мәртәбә тамчы тама башлау, урамда гөрләвекләр ага башлау, чыпчыкларның чыр-чу килеп гайрәтләнеп йөри башлаулары аңарга бер куаныч бирә ---.* Г.Гобәйдуллин

**Гайрәтләнеп китү** 1) Берәр тәэсирдән соң көч, гайрәт арту, дәрт керү. *Безнең ат айгырланып кешнәп җибәрде. Аңар каршы Урал кешнәп җавап биргәч, ул тагы гайрәтләнеп китте.* Г.Исхакый. *Ул, бер тутырып карап: «Житкән егет бит инде син!» – дисә, үсеп-зураеп, гайрәтләнеп киткәндәй буласың, үзеңне яхшы кеше итеп сизәсең.* М.Маликова

2) Артык кызып, мавыгып онытылу. --- *ятылаш сузылган көе генә сүз башлады әбекәй, аннары инде, гайрәтләнеп китеп, бүлмә эченә кергән сыман итте.* В.Имамов

**Гайрәтләнеп яту** Шактый озак вакыт гайрәтләнү. *Вилдан: – Без германнарны бүрек белән дә бәреп егабыз! – дип әтәчләнеп, җыр-такмак чыгарып, төрле көйләргә шул такмакны әйтеп гайрәтләнеп ятса да, Исхак аңа кушылмады.* А.Гыйләҗев

**ГАЙРӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Физик яктан нык, көчле, егәрле. *Безнең борынгы бабаларыбыз зур гәүдәле, пәһлеван кыяфәтле, гайрәтле алыплар булганнар.* Ф.Бәйрәмова. *Шундый ачулы, гайрәтле тавыш иде ул, күк күкримени?* Г.Якупова. *Безнең егетләр дә гайрәтле, киң күкрәкле (чөнки дүртесенең бер-*

*се дә тәмәке тартмый) – ашау гына җитми.* Р.Кәрами

2) Куәтле, кодрәтле, чәчәк ату чорында булган. *Төркиянең иң гайрәтле вә иң шөһрәтле солтаны Сөләйман Кануни, киңәшче муллалары вә пашалары сүзенә карап, казанлыларның җан бирергә яткан вакытларында --- тәнәззел итмәде.* Р.Фәсхеддин. *Ошбу чор өчен шактый гайрәтле булган хан көтмәгәндә 1463 елда вафат була.* М.Хәбибуллин

3) Батыр, кыю. --- *аның бер өстенлеге бар: ул җитезрәк, гайрәтлерәк һәм, карт поши никадәр генә көчле булса да, аңа бирешми, егетләрчә каршы тора иде.* В.Нуруллин. *Шуңа күрә аларны кулга алу операциясенә иң гайрәтле, иң кыю милиционерлар, спортчы егетләр билгеләнде.* Х.Вәлиәхмәтов

4) Дәртле, ялкынлы, ашкынып торган. --- *әмма гайрәтле егетнең тынгысыз күңеле сәхнәдә икенче-өченче булып калуга ризалашмады ---.* М.Маликова. *Әмма бу чор да мәңгелек түгел, алга таба шигъриятебезгә Мөдәррис – Зөлфәттән дә гайрәтлерәк пафос белән иҗат итүче яшь авторлар килсә дә, алар әллә ни зур уңышка ирешә алмады.* Р.Миңнуллин

5) *куч. сөйл.* Градусы көчле булган, куәтле. *Кигәне – килбәтле, ашаганы – ләззәтле, эчкәне гайрәтле булсын иде аның.* М.Әмир. *Гайрәтле урыс аракысы ашказанын рәхәт яндырып төшеп китте дә, аның ләззәтле ялкыны бөтен тәнгә таралды*. М.Кәбиров

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Көчле итеп, көчле булып. *Таки синнән рәнҗеп, күңелендә сиңа гадавәт тотмасын. Әмма углыңа гайрәтле күрен.* К.Насыйри. *Җирән айгыр, ишләрен сәламләгәндәй, гайрәтле генә пошкырып куйды.* Р.Низами. *Кемдер иртүк учак яккан. Ара якынайгач аңлашылды: Баштутай учагы икән шулай гайрәтле яна.* Р.Батулла

2) Дәртләнеп, дәртле итеп. --- *үзе язган «яшәсен тынычлык»ка да бик гайрәтле итеп җырлап бирә, баянга кушылып ---.* Г.Ахунов. *Күрше авторотаныкылар, бик моңлы, гайрәтле итеп, украин җырларын сузалар.* С.Шәрипов

2) Кыю рәвештә, батырларча. *Ләкин яңа мулла бик дәртле, гайрәтле вә бик тә иркен яши башлый.* Р.Батулла

**ГАЙРӘТЛЕЛЕК** *и.* Батырлык, кыюлык. --- *ике матур кара күз, көләргә дә, егъларга да әзер тетрәк иреннәр, гайрәтлелекне, тырышлыкны, хәтта беразда гыйнадчылыкны күрсәтә торган мөнтазам таррак маңлай.* Й.Акчура. *Татар гаиләсендә балада батырлык, тәвәккәллек, гайрәтлелек сыйфатлары бик кечкенәдән тәрбияләнгән.* Татар милли педагогикасы

**ГАЙРӘТСЕЗ** *с.* 1) Сүлпән, дәртсез; көчсез. *Ул «япун» дигәннәре бик аз икән, җитмәсә, бик бәләкәйләр, гайрәтсезләр, ди.* М.Галәү. *Теләге булып та гайрәтсез булса, бәндәдән син игелек көтмә.* Р.Батулла. *Бүген, Сабан туе көнне, сөйгән кызы алдында булдыксыз, көчсез, гайрәтсез булып күренсенме?* Д.Каюмова

2) *куч. сөйл.* Градусы, көче кимегән, айныган

**ГАЙРӘТСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Булган гайрәтен җую, сүлпәнләнү, дәртсезләнү

2) *куч. сөйл.* Градусы, көче, тәэсире кимү, айну

**ГАЙРӘТСЕЗЛЕК** *и.* Гайрәт булмау, сүлпәнлек, дәртсезлек. *Гайрәтсезлек вә башкаларга һәрбер эштә ихтыяҗ – һәммәсе коллыктан вә тәрбиянең җитешмәвеннән киләдер.* Г.Бубый

**ГА́ЙРЕ** *с. гар. иск.* **1.** Башка, бүтән төрле, үзгә. *Әгәр күңелләргә әсәрле сүз әйтмәк теләсәң, үз сүзеңне әйт, гайре шагыйрьләрнең сүзе булмасын ---.* К.Насыйри

**2.** *и. мәгъ.* Башка кеше, бүтән зат. *Без генә идек без, гайреләр ят иде, Бер җирдә идек даим, күңелләр шат иде.* Дәрдемәнд. --- *гайреләрдә булган хакыңны оныткайсән, гайренең синдә булган хакын хәтереңдә тоткайсән...* К.Насыйри. *Эштән гайресен күрми икән бу дип уйласагыз, ялгышасыз.* Сөембикә

**3.** *кис. функ. иск.* Үзеннән соң килгән сүзгә юклык мәгънәсе, инкярлау мәгънәсе бирә. *Менә кинәттән җасуслар, ашыгып килеп, ашчыларның гайре гади вакыйгасыннан хәбәр бирделәр.* Дастан. *Паркта башланган музыка тавышына урманның гайре мөнтәнаһи кошлары сайрап җавап бирделәр.* Ф.Әмирхан. *Гөлйөзем үзе дә сихерләнгән кебек гайре табигый хаәт кичерә иде.* Ф.Латыйфи

**4.** *бәйл.* Алда килгән сүзгә «шуннан башка», «шуннан тыш» мәгънәсен бирә. *Күктәге ак болытлардан гайре аны беркем дә күзләми иде.* Н.Гыйматдинова. *Кул сузымы кадәр җирдән гайре берни күренми...* З.Фәтхетдинов

**ГАЙЯР** *с. к.* **гаярь**. *Габдерәзак мулла бик гайяр, бай кеше һәм мулла кеше икән.* К.Насыйри. *Алтмышынчы еллар уртасында ук инде син татар шигъриятендә мәйдан тоткан шагыйрь, җәмгыятьнең игътибар үзәгендәге гайяр егет идең.* Р.Вәлиев

**ГАКАИД** *и. гар. иск.* Юл күрсәтүче. *Зәгыйфьләргә рәфикъ, сагъларга каид, Болардыр – музыйхы җөмлә гакаид.* Г.Тукай

**ГАКЕС** *и. гар. иск.* Капма-каршысы, киресе. *Эш моның гаксенә икәнен аңламаган халык гаепне Зәйнәп өстенә аударалар иде.* М.Гафури

**ГАКЕ́С ИТЕЛҮ** *ф.* Чагылдырылу. *Әдәбият тарихын өйрәнү анда гакес ителгән фикер вә идеология тарихын гына өйрәнүдән гыйбарәт икән дип уйланылмасын.* Г.Рәхим

**ГАКЕ́С ИТҮ** *ф.* Чагылдыру. *Моның [милли әдәбият бакчамыздан җыеп, яшь балаларымыз кулына шуның чәчәкләреннән ясалган бер чәчәк бәйләме] кирәклеге фикере аңлы мөгаллимнәремезнең башында эшләнеп чыгып, аннан милли гәзитәләремез сәхифәләренә дә гакес иткән иде.* Г.Тукай

**ГАКЛЫЙ** *с. гар. иск.* Акылга бәйләнешле, фикер йөртү, фикерләүгә караган; уйлап эшләнгән. *Менә шул хәлләр аның йөрәгендә анасына каршы үтә ялкынлы бер кызгану тойгысы уятмаган да, гакылый, салкын, ләкин ачык һәм яхшы мөхакәмәсе һәркемдә анасының сүзләрен илтифатсыз калдырмауны вөҗданый бер бурыч дип таныта иде.* Г.Ибраһимов

**ГАКРӘБ** *и. гар. иск.* 1) Чаян; *русчасы:* **скорпион**. *Белерсән: зәхмәнә чөн такәтең юк, Кулыңны сукмагыл гакрәб өненә.* С.Сараи

2) Зодиак тамгасы буенча 22 октябрьдан 22 ноябрьга кадәр вакыт аралыгы, ноябрь ае. *Ул вакыт тарих тугыз йөз алтмыш бердә ирде, якшәнбә көн, гакрәб 2 нче көне иде.* Ш.Мәрҗани. *«Гакрәб башында кар яуса, кырык көннән ятар», – дигән борынгылар.* К.Тәхау

3) Сәгать угы, теле

**ГА́КСЕНӘ** *рәв. гар.* Капма-каршы, киресенчә. *Әһле көффар улды анда гаять шат, Һәрбере гаксенә кыйлды игътимад ---.* М.Әмин. *--- кешеләрне идарә итүчеләр даимән тәҗрибәнең гаксенә хәрәкәт итә торган мәхлуклардыр.* Й.Акчура

**ГА́КСЕНЧӘ** *рәв. иск.* Киресенчә. *Бәгъзысы хан кызыны зиндандагы әсир алып качкан, бәгъзылары, моның гаксенчә, ягъни хан кызы әсирне алып качкан диләр иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Гәрчә Европада соң ятып, иртәгәсен көн уртасына кадәр йокламак гадәт булса да, шәрыкта, хосусан «ислам мәмләкәтендә», эшләр моның гаксенчәдер ---.* Ш.Мөхәммәдев

**ГАКЫД** *и. гар. иск.* 1) Ант итү, ышандыру. *Димешләр ки, үлгәннән соң тәүбә юк, гакыддан соң шарт юк.* Ф.Халиди. *Яңадан сугыш булса да, булмаса да, солых гакыд ителсә вә ителмәсә дә, Истанбулда тиздән тынычлыкларның булу ихтималы юктыр.* Г.Камал

2) Сүз бирешү, килешү. *Һәм бу кызы, дәхи, мән вирәм сәңа, – Гакыд кыл ---.* М.Әмин

**ГАКЫЙБӘТ** *и. гар. иск.* 1) Эшгамәлнең соңы, ахыры, нәтиҗәсе. *Эшче һәм авыл халкы ачтан кырылса да, инша алла, үзе өчен гакыйбәте хәерле булып, дөньядан имансыз үтәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Һәр катылыкның гакыйбәте шатлыктыр.* К.Насыйри. *Йосыф мирза балалары вә Сөен Бикә кардәшләренең гакыйбәтләре менә шулай булмыштыр.* Р.Фәхреддин

2) Ниһаять, ахырда, ахыр чиктә. *Тагы киңәш, тагы мәслихәт ясадылар, гакыйбәт, үлем җәзасын гомерлек хибескә алмаштырырга карар бирделәр.* Г.Тукай

**ГАКЫЙДӘ** *и. гар. иск.* Ышану, иман. *Аның үз гакыйдәләреннән башка, һичбер чик икърар итми торган каләме, аның --- рухи күәсе бу игътикадны чәнечкеле вә гаять ачы калыпка куеп, укучыларына тәкъдим итә.* Ф.Әмирхан

**ГАКЫЙКА** *и. гар. иск.* Баланың тугандагы чәче, беренче чәч

◊ **Гакыйка корбаны** Бала туу уңаеннан китерелә торган корбан. *Әмма ул гакыйка корбаны ир бала өчен ике куй, кыз бала өчен бер куй чалмак тиеш.* К.Насыйри

**ГАКЫЙЛӘ** *и. гар. иск.* Акыллы, зирәк хатын-кыз. *Әй дана, вай гакыйлә, дөньяга ышанма, нәфесеңә алданма. Ирләрдә аслан мөрәүвәт, мәрхәмәт, сәдакать юктыр.* Ф.Халиди

**ГАКЫЙЛЬ** *и. гар. иск.* Бик акыллы кеше. *Гакыйль исәң, нәфсеңә өймә, сакыйн! Мәкренә җаныңны якмагыл, сакыйн!* Г.Тукай

**ГАКЫЛ** *и. гар.* 1) Фикерләү сәләте; *русчасы:* **разум**. *Ләкин, югарыда әйтелгәнчә, гүзәллекне бәяләү фәкать кешегә, гакылга ия булган затларга гына хас.* К.Гыйззәтов. *Динозаврлар инде тарих сәхнәсенә гакылга ия кеше чыкканчы ук үлеп беткәннәр дип санаганда да, аларның галәмәт зур скелетларын борынгы бабаларыбызга очратырга туры килгәндер әле.* Р.Мостафин

2) *иск., кит.* Аң, зиһен, акыл; *русчасы:* **ум**. *«Инсан» дигән шәрәфле бер мәхлукта ул Бар дип белә хаким гакыл вә хөр гакыл.* Г.Тукай. *Кешенең гыйззәте гакыл белән вә әдәб белән, һөнәр беләндер ---.* Т.Яхин

3) Зирәклек, тапкырлык; тирән акыллылык; *русчасы:* **мудрость**. *Халкына күрә гакыл ияләре вә хәкимнәре дәхи бардыр.* К.Насыйри. *«Гакыл» дигәнең бәладән дә коткара, тамакны да туйдыра икән.* М.Кәрим

◊ **Гакылдан язу** *иск.* Акылдан язу, шашу, юләрләнү. *Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.* Г.Тукай. **Гакыл җыю** Фикер туплау, аңга килү. *Пәһлеван, гаять арып, эштән чыгып, Ун минут торды катып, гакълын җыеп.* Г.Тукай

**ГАКЫЛЛЫ** *с.* **1.** *к.* **акыллы**. *Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга, Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.* Г.Тукай. *Гакыллы булсак та, үзебез кеби кешедә кол булып, гомеребезне үткәрәбез.* Г.Коләхмәтов

**2.** *рәв. мәгъ.* Уйлап, зиһен белән. *Әүвәл заманда фарсы йортында гакыллы һәм дә тугры хөкем итүче Таһмасып исемле бер падишаһның бик баһадир Каһарман Катил исемендә бер углы бар иде.* Дастан

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Уйлый белү, уйларга сәләтле булу. *Шулай да табигать анабыз ифрат гакыллы шул.* Т.Галиуллин

**ГАКЫЛЛЫЛАНУ** *ф. иск.* Акыл, тәҗрибә туплау; үзен акыллы итеп күрсәтү. *--- хәйләкәрләнгән булып, алданып ята торган, гакыллыланган булып, ахмаклыкта кала торган --- сала мужиклары.* Ф.Әмирхан

**ГАКЫЛЛЫЛЫК** *и.* Акыллы, зиһенле булу. *Кечкенә вакытында аның йөзендә баһадирлык, гакыллылык һәм дә юмартлык галәмәтләре билгеле иде.* Дастан. *Аның гакыллылыгын, аның минем кәефем өчен ни дәрәҗәдә тырышуын әйтергә дә юк.* Г.Ибраһимов

**ГАКЫЛСЫЗ** *с. иск.* Ахмак, юләр. *Каһарман, ачуланып: «Әй гакылсыз, җүләр, синең падишаһың кем дә, син кем?»* Дастан. *Үземне килеп тоткан-нарын көтеп тораммы? Нигә мин бу кадәр гакылсыз?* Г.Камал

**ГАКЫЛСЫЗЛАНУ** *ф. иск.* Шашу, аек акылны җую. *Атам – контрреволюционер... Абыем – аның ярдәмчесе... Ә мин... Мин кем?.. (Кинәт аягына басып, гакылсызланып кычкыра).* К.Тинчурин

**ГАКЫЛСЫЗЛЫК** *и. иск.* Акылсызлык, ахмаклык. *Моннан гыйбрәт ал, угълым: текә башлы булу гакылсызлыктан килә.* Дәрдемәнд. *--- мондый диванаы театрга алып килгән кешенең гакылсызлыгына гына хәйран калалар иде.* Ф.Әмирхан. *--- «фән», дидек, «гыйлем», «мәдәният», дидек, боларның бөек куатенә шөбһә итү гакылсызлык саналды.* Г.Ибраһимов

**ГАКЫЛ-ТӘДБИР** *җый и. гар. иск.* Уйлап эш итүчәнлек, төплелек, алдан күрүчәнлек, акыллылык. *--- урынына вәли гаһед энесе Һимрасын тәхеткә*

*утыртып, бик тугрылык илән эш башкара, гакыл-тәдбир белән генә хөкем кыла башлады.* Дастан

**ГАКЫЛЫЙ** *с. гар. к.* **гаклый**

**ГАЛА-** *фр.* «Аеруча тантаналы, зур тамаша» мәгънәсен белдерә торган кушма сүз компоненты

**ГАЛАКОНЦЕРТ** *и. фр.-ит.* Зур, тантаналы, матур, бәйрәмчә концерт. *Ачык һавада, пальма куаклары арасында берьюлы йөзләгән халык ашапэчеп, агач башларында барган төсле музыкалы галаконцертны тамаша кылып утыралар.* Р.Ибраһимов. *Фестиваль лауреатларын бүләкләү тантанасы һәм галаконцерт Ялта шәһәренең «Юбилейный» концерт залында үтте.* Казан утлары. *Галаконцерт Төмән шәһәренең, Европа стандартларына туры китереп, егерме ел буе төзелгән мәхәббәт драма театры бинасында узды.* Сөембикә

**ГАЛА́КТИК** *с.* 1) Галактикага мөнәсәбәтле

2) Бик зур, глобаль, дөньякүләм. *Коллегалар идек. Анда да уртак тел таба алмыйбыз. Ә син адәм логикасы белән галактик табышмакларны чишәргә телисең.* А.Гыйләҗев. *Якында булсаң да, тәнеңнән аерып тора галактик ераклык!* Р.Фәйзуллин

**ГАЛА́КТИКА** *и. гр. астр.* 1) Кояш һәм аның барлык планеталарын, бик күп йолдызларны үз эченә алган йолдызлар системасы; Киек Каз юлы; *русчасы:* **млечный путь**. *Дәү дә бит һәрбер кояш, Киң дә бит Галактика. Гомерләр кыскармаса, Бүлмә дә ярап тора.* Х.Туфан. *Оча торган тәлинкәгә утырып Йөрсәләр дә монда ялтырап, Патриотлар әйтер авыз тутырып: – Безнең галактика яхшырак!..* Г.Афзал

2) **галактикалар** Галактика шикелле үк йолдызлардан, газлы, тузанлы томанлыклардан һәм таралган йолдызара матдәдән торган, төрле типтагы (спиральсыман, эллипссыман, пекуляр һ.б.) йолдызлар системасы. *Еракларда, галактикалардан Без бу җиргә бергә килдек ич ---.* Х.Туфан. *Яңа галактика табылган, ди... Гаҗәп хәбәр йөри...* Зөлфәт. *Кеше ерак йолдызлар һәм галактикалар серенә үтеп керә, җирнең иң тирән катлауларын тикшерә, атомны өйрәнә.* Химиянең киләчәге

**ГАЛА́НКА** *и. рус сөйл.* Зур мичә, учак асты булмаган, гадәттә, кафель, изразец, калай һ.б.ш. белән тышланган, зур булмаган мич. *Ул тураймакчы булып алга омтылды, әмма галанка миче кебек эссе гәүдәләр һәм кесәдән эләктергән күренмәс кул аңа беркая кымшанырга да ирек бирмәделәр.* Ф.Садриев. *Галанка мич белән ат абзары чаклы клубны ничек җылытмак кирәк?!* К.Кәримов

**ГАЛАНТ** *с. фр.* Гадәттән тыш игътибарлы, тәкәллефле, үзен культуралы тотучан, нәзакәтле

**ГАЛАНТЛЫК** *и.* Мөгамәләдәге, үз-үзен тотышындагы игътибарлылык, тактлылык, тәрбиялелек. – *Гомумән, кадерле Сухроб, Костаны идеальләштермәгез, аның үз-үзен тотышы, тышкы матурлыгы, Кавказ горурлыгы һәм галантлыгы артында төксе Ашоттан да явызрак кеше утыра, – дип, кинәт кенә әйтеп ташлады Япон.* Р.Мирхәйдәров

**ГАЛАНТЕРЕЙЧЫ** *и. иск.* Галантерея товарлары белән сату итүче сәүдәгәр

**ГАЛАНТЕРЕ́Я** *и. фр.* Сатудагы төрле вак-төяк киенү-бизәнү әйберләренең, аксессуарларның (мәс., төймә, запонка, тасма, галстук, перчатка, зонт) һ.б.ш. гомуми атамасы. *Менә азык-төлек кибетләре, галантерея сәүдәсе рәте...* М.Галәү. *Монда хуҗалык товарлары, кооперация сәүдәсе, ресторан, китап кибете, галантерея, гастроном, спорт-культура товарлары кибете урнашкан.* М.Мәһдиев. *Хәзер тәрәч балык, зубатка һәм акула балыкларының тиреләре галантерея промышленностенда бик киң кулланыла.* Кызыклы ихтиология

**ГАЛАХ** *и. гар. сөйл.* Сукбай, зимагур, брамат. *Туган якларына ачялангач, хәерче галах булып кайтып төшәсе килми (Сакмаровларның үз горурлыгы үзләренә җиткән), шахтада урнашып кала.* Т.Галиуллин. *Хәби хәзер безнең ише галах ягына карап төкерми дә.* В.Имамов. *Минем «судимость снята» дип яздырып алган справкамны ертты! Үтерәм бит мин сине моның өчен, галах!* Ш.Хөсәенов

**ГАЛАХЛЫК** *и. сөйл.* Йортсыз-җирсез, гаиләсез тормыш, зимагурлык, сукбайлык. *Йә, син күпмегә хәтле болай галахлыкта йөрергә уйлыйсың?* М.Мәһдиев

**ГАЛӘБӘ** *и. гар. иск.* 1) Җиңү, өстен чыгу. *Кырым чирүсе тәмам галәбә илә Рязань вилаятенә килеп керде.* Р.Фәхреддин. *Руслар ничаклы күп җиңелделәр, һичбер вакыт галәбә казана алмадылар.* Ә-З.Вәлиди

2) Өстенлек. *Татар бае Сафа, мукшының бер галәбәсенә барыннан ук эчтән янып, --- чабышкы атлар алгаласа да, --- алга чыгарлык мал таба алмый.* Г.Ибраһимов

3) Бөеклек, олылык. *Ул үзе [хәзрәт] гомер буенча шуңа тырышты, галәбәне шунда дип белде.* Г.Ибраһимов

**ГАЛӘБӘ́ ИТҮ** *ф.* Җиңүгә куану, тантана итү, үзен җиңүче итеп сизү. *Мәкаләнең бу җиренә җиткәч, мишәр әфәнде, галәбә иткән бер гаскәр башлыгының ифтикары белән бераз туктап, хазирунга карап та торды.* Ф.Әмирхан. *Галәбә иткән сыман көлеп куйды.* Ф.Әмирхан. *Гаяз әфәнденең соңгы әсәрләре --- яңа тормыш каһарманнары белән иске тормыш каһарманнары арасындагы талашны вә яңа дөнья кешеләренең галәбә итәчәген күрсәтү юлында язылады*р. К.Бәкер

**ГАЛӘБӘЛЕ** *с. иск. кит.* **1.** 1) Җиңүле, тантаналы

2) Өстен, югары. *Галәбәле рухның кылган гамәлләре, гадәттә, һәр заман өчен кадерле.* З.Мансуров

**2.** *рәв. мәгъ.* Җиңүле рәвештә, җиңү белән. *Гражданнар сугышын галәбәле тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә багышлана.* Ф.Әмирхан. *Аның тавышы һәммәсенекеннән куәтлерәк тә, галәбәлерәк тә ишетелә.* Г.Ибраһимов

**ГАЛӘБӘЛЕК** *с. иск. кит.* 1) Җиңү тантанасы; триумф. *Кымыз да булмагач, Уфада нәрсәгә ятыйм. Җитмәсә, аның «авыллыгы», тынлыгы, җәйсызлыгы минем әле хасил булмактагы европалылыгымны, культурный*

*шәһәр кешеселегемне, шау-шу ялатучылыгымны, галәбәлек, көрәш сөючелегемне үчекләгән кеби булды*. Г.Тукай

2) Ыгы-зыгы, шау-шу. *Бу галәбәлек арасында хосусый берәм-берәм кешеләрне тикшереп карап торырга имкян булмаса да, --- кызга һәркемнең күзе төшә иде.* Ф.Әмирхан

**ГАЛӘКА** *и. гар. иск.* Бәйләнеш, элемтә, мөнәсәбәт. *Минемчә, ул үз кадерене сизсен иде, Дөнья берлә галәкасен киссен иде ---.* Г.Тукай. *--- минем җаным белән музыка арасында шундый бер галәка бар ки, мин аны, ни генә дисәм дә, дөрес вә тулы итеп тәгъбир кыла алмаячакмын.* Г.Ибраһимов

**ГАЛӘЛГОМЬЯ** *рәв. гар. иск.* Сукырларча, күз йомып; аны-моны карап тормыйча. *Үтте бездән Инде дөнья Җан бирәбез Галәлгомья.* Г.Тукай. *Галәлгомья кылган гамәлләрне Хәтереңә син дә яза бар.* Казан утлары

**ГАЛӘЛКӘСРӘТ** *рәв. гар. иск.* Күбесенчә, күп очракта, күпләп. *--- бу китаплар бу мәмләкәтләрдә басма вә язмалары галәлкәсрәт табылдылар, гайре мәмләкәтләрдә бер дә күргәне һәм ишетелгәне юк.* Ш.Мәрҗани

**ГАЛӘЛХОСУС** *рәв. гар. иск.* 1) Бик, бигрәк, аерым рәвештә

2) *кер. сүз* Аеруча, бигрәк тә. *Галәлхосус, тәрҗемәсендә гыйбарәсе тигез вә ифадәсе каба вә татсыз дәгелдер.* Г.Кәрам

**ГАЛӘМ** I *и. гар.* 1) Материянең барлык формаларыннан гыйбарәт табигать, бөтен дөнья, җиһан, макрокосм. *Бу галәмдә бер атом да артмагач, Бу эшеңнең төп мәгънәсе ни соң, Матдә?!* Х.Туфан. *--- без дөньяның төзелешен, галәмне, аның законнарын бик тә аз, чыпчык борыны чаклы гына беләбез икән әле.* Р.Фәизов. *Бу гарасатларда исә галәм әйләнеше фасылларының мизгелләре.* Ф.Латыйфи

2) Космос. *Аңа ай-йолдызлары белән бөтен галәм кереп урнаша ала.* А.Гыйләҗев. *Юлларда тәгәрәүче гади тәгәрмәчтән алып галәмгә очучы ракетага кадәр бары да – кешенең хыял һәм акыл җимешләре.* Ф.Яруллин. *Сүнүче йолдызлар бар. Әмма нурлары галәмнең башка җисемнәренә шул исәптән Җиргә килеп торалар.* С.Поварисов

3) Җир йөзе, барлык тереклек. *Аның өчен дөнья – бер җәннәт, галәмнең бөтенесе уенчык һәм ләззәт иде.* Ш.Камал

4) Кешелек дөньясы, җирдә яшәүче барлык кешеләр. *Толстой шикелле бөтен галәмнең зур мөхәррирләреннән хисап ителгән затларның шул кыска-кыска кыйссалар язуга гомер сарыф иткәнлеген күз алдыбызга китерү җитәдер.* Ф.Әмирхан. *Куансын бар галәм һәм дә Куансын ул, куан син дә!* С.Рәмиев. *Кояш назлый көндез, төнлә – йолдыз, Галәм белми синдәй гүзәл җирне.* Н.Касыймов

5) *иск.* Халык, кешеләр. *Хакъ нурын сүндерә алмый мөганидләр, Күрә алмайлар галәмгә фашын аның!* М.Акмулла. *Ах, хур булдым галәм алдында! Кем сүзенә карап эш иттем?!* Н.Исәнбәт

6) *иск.* Билгеле бер даирә, катлам, төркем. *--- ул бу көнгә кадәр белмәгән дә, күрмәгән дә рус галәменә атыла.* С.Рәмиев. *Әй, хатыннар галәме! Сез Ник наданлык дәрьясы?* С.Рәмиев

7) Реаль чынбарлыкның яки кешенең рухи-эмоциональ тормышының бер өлкәсе. *Гаяз әфәнде әдәбият галәмендә үзенә аерым бер мәктәп корды да халыкны табигать яраткан юл илә тәрбия кылырга, аларны әүвәлге хата фикереннән айнытып, үзләрен танытырга тырышты.* Х.Кәримов. *Гаяз әфәнде укып бетү белән, --- идея галәмендә гизгән вә нигъмәте әһелиянең голувиятләренә хәйран калып уянган изге бәндәләр кебек уянды.* Г.Гыйсмәти

8) Тормыш, яшәү рәвеше, халәт. *Сез ач, мохтаҗ яшисез икән, сезне сәфаләт галәме сарган икән, революционерлар да хәзер төрмәләрдә ябылып яталар, каторгага озатылалар.* С.Сүнчәләй

**ГАЛӘМ** II *и. гар. иск.* 1) Әләм, байрак

2) Билге, галәмәт. *Киттем Ходайның гарьшенә, Унсигез мең галәме Артымда калды барсы да*. Ш.Бабич

**ГАЛӘМӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Берәр нәрсәне хәтерләтә, белдерә, ишарә итә торган үзенчәлек, билге, эз. *Аның чыраенда әз генә дә кызыксыну галәмәте сизелмәде.* Ф.Яруллин. *--- кыскасы, картаю галәмәте һәркемгә төрлечә, һәркемгә үзенчә генә килә.* А.Гыйләҗев. *Минем кылыч күтәрүем мәкер галәмәте булса, кичерерме моны Перун, Һәм Стрибог та кичерерме?..* Р.Харис. *Йөзгә тамчы да гаҗәпләнү галәмәте чыгарырга ярамый.* Н.Гыйматдинова

2) Үзенчәлекле хәл, күренеш, вакыйга. *«Үлем» атлы ачы галәмәт адәм балаларын тигезли.* Т.Галиуллин. *--- кабердән: «Чыгарыгыз!» – дигән тавыш ишетелә икән. --- Мулла, бу галәмәтне сихер эше дип аңлатып, каберне таптый-таптый күмәргә, баш казыгына миләш агачы куярга куша.* Т.Миңнуллин

3) *иск.* Тамга, билге. *Сезгә сөенеч булсын, мине сезгә Каһарман пәһлуан җибәрде, галәмәт өчен, менә йөзеген китердем ---.* Дастан. *Сүз башында җитәргә калган алты-җиде юл нәрсәне ул аяк өстендә килеш кенә күздән үткәрде, килеп туктаган урынына карандаш белән бер галәмәт ясады да хозяйка кызының гимназиядән кайтканын көтте.* Ф.Әмирхан. *Меңнәрчә халык, кызыл байрак күтәреп, җиңнәренә кайгы галәмәте бәйләп, аны каберенә кадәр озатачаклар.* Ш.Усманов

4) Гайре табигый хәл, сирәк күренеш. *Бәй, менә син агай, бусы нинди галәмәт була инде моның тагы: бер кар өере төрле яктан китерде дә кысты.* С.Поварисов

5) Могҗиза. *Юрауларга, им-томнарга, сихри галәмәтләргә ышанмыйм.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Гаҗәп, сәер; искиткеч. *Тик, кайткан чагында, галәмәт бер күренешкә хәйран булып тордык ---.* Э.Касыймов. *Менә сиңа бер галәмәт сүз, яр астыннан яу чыккан, дигәндәй.* Г.Якупова

**3.** *рәв. мәгъ.* Бик, артык, искитәрлек. *Ишектән керүгә, нәкъ каршыда тәбәнәк, киң авызлы галәмәт зур мич, стена буенда ак тактадан таза эшләнгән лар-әрҗәләр, мич кырында сөяп куйган озын саплы көрәк һәм пумалалар ---.* Ә.Еники. *--- берсе галәмәт*

*киң якалы пинжәктән, аска таба киңәеп киткән «клёш» балаклы чалбардан.* Р.Мирхәйдәров. *Төнге Ленинград юлларын шлагбаум кебек урталай бүлеп, тиздән атаклы Нева күперләренең галәмәт озын канатлары да иртәнгә тикле ике якка аерып куелыр.* Р.Вәлиев

**4.** *хәб. сүз мәгъ.* Искиткеч, аптырап калырлык. *Кыяфәтләр бер дә галәмәт: ул аркылы-торкылы каешлар, ул чырайдагы бөркетләр кыюлыгы!* Г.Ахунов. *Дәү әтиемнең мине сөннәткә утыртуын белеп алгач, әти җикеренде инде. Бер дә галәмәт.* Ә.Хәсәнов

**ГАЛӘМӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) Берәр мәзәк уйлап табу, сәер кылану, төрле әкәмәтләр китереп чыгару

2) Көлкегә калу, уңайсыз хәлгә калу

**Галәмәтләнә башлау** Галәмәтләнергә тотыну

**Галәмәтләнеп бетү** Нык галәмәтләнү. *Балалары школда сугыша, аталары урамда талаша торган иде. Ул җитмәсә аналары кунакта тиргәшә. Йа-а галәмәтләнеп бетә торганнар иде.* М.Фәйзи

**Галәмәтләнеп йөрү** Һәрвакыт, һәр җирдә галәмәтләнү

**Галәмәтләнеп китү** Кинәт галәмәтләнү

**ГАЛӘМДӘШ** *и.* Автор белән, сөйләүче белән бер галәмдә яшәүче кеше. *Галәмдәш – замандаш – илдәш – милләттәш – кардәш – кандаш – җандаш ---. Нәрсә әйтим?* Р.Фәйзуллин

**ГАЛӘМИ** *с. гар.* Зур, глобаль; бөтен галәмгә кагыла торган, галәмгә бәйле булган. --- *кыскалыкка омтылган саен, фикерләр дә тыгызлана төшә, шул рәвешле атом-төш хәленә китерелгән, галәми фикерне сыйдырган бер күзәнәкле (һич тә киная итеп кабул ителмәсен иде бу сүз!) шигырьләр дөньяга килә.* Р.Фәйзуллин. *Фәрештә юк дию галәми ялгандыр ---.* Р.Харис. *Европаны Чыңгыз ханның галәми масштабтагы ниятләре генә куркыткан, күрәсең.* Р.Хәкимов

**ГАЛӘМЧЕ** *и.* Космонавт, астронавт. *Шул көнне Инҗар: «Мин үзем галәмче булам, йолдызларга үзем барам!» – дип ант иткән иде.* Р.Батулла

**ГАЛӘХИДӘ** *рәв. гар. иск.* Аерым, үзенә бер; атаклап. *Таләбәләр хакында галәхидә бер рисалә.* З.Бигиев

**ГАЛДЫР-ГОЛДЫР** *иярт. к.* **голдыр-голдыр**

**ГАЛЕ́РА** *и. ит. тар.* XVIII йөзгә кадәр кулланылган зур, авыр, ишкәкле хәрби кораб төре. (Урта диңгездә ишкәкчеләр әсирләр, коллар, җинаятьчеләрдән җыелган; француз, испан, итальяннарда «каторга» мәгънәсендә кулланыла.) *Хәзерге заманныкы белән беррәттән, моннан бер-ике мең ел элекке галералар да бар.* М.Мәһдиев. *Шушы корабль 500 матросы һәм туплары булган төрек галерасына һөҗүм итә.* Кызыклар дөньясында. *Борынгы грек галерасы (җилкәнле судно) үзенең текә түше белән Урта диңгез суларын кисеп йөри икән.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

**ГАЛЕ́РЕЯ** *и. фр.* 1) Бинаның аерым өлешләрен тоташтырган яки бинаның эчке я тышкы периметры буенча үткән, түбәле озын тар коридор. *Галерея буйлап барганда, арадашчыны капка төбендә үк ап-ак киемле ниндидер арык карт тоткарлап калды ---.* Р.Мирхәйдәров. *Колонналы галереялар белән әйләндереп алынган кечкенә генә ишегалды монастрьның үзәге булып тора; шуннан чиркәүгә, ашханәгә һәм монах бүлмәсенә керү юллары була.* Урта гасырлар тарихы

2) Хәрби корылмаларда, тау яки җир асты эшләрендә җир асты юлы. *Кеше Египет пирамидалары янында кечкенә күренгән кебек, кырмыскалар да үз торалары алдында бик бәләкәйләр. Ояның эчке катларында йөрү юллары да, галереялары да бар.* Кызыклар дөньясында

3) Театрның иң югары ярусында урнашкан, иң арзан билетлы өлеше. *Алты йөз лир түләп, галерееяда утыручыларның өстендә кара смокинг, утыз меңле билет белән ложаларда утыручыларның иске свитер һәм таушалып беткән джинсыдан булулары аеруча хәтергә сеңеп калган.* М.Юныс

4) Сәнгать әсәрләреннән, гадәттә, картиналардан күргәзмә ясау өчен махсус бина яки шундый әсәрләрдән торган музей. *Чыннан да, Третьяковка картиналар галереясына барырга кирәк дип уйлыйм.* А.Расих. *Әлеге галереяга [Ватикан музее] 250 авторның 700 ләп рәсем һәм скульптура әсәрләре керә.* М.Мәһдиев. *Өчәүләп галерея буйлап һәйкәлләр арасыннан барабыз.* М.Юныс. *Татарстан Милли галереясында Казан фото клубы әгъзаларының «Барысы да хатын-кызлар турында» дип исемләнгән күргәзмәсе ачылды.* Мәдәни җомга

5) *күч.* Бер типтагы, охшаш сыйфатлы шәхесләр, образлар, геройлар һ.б.ш.дан торган бер рәт, бер төркем. *Яки менә «артык кешеләр» галереясы: Онегин, Печорин, Рудин, Лаврецкий, Обломов...* И.Нуруллин. *Ул тудырган портретлар галереясында кешеләр әйбәт күңелле, миһербанлы, мәгърур; хәтта бөтен кимчелекләре белән матурлар!* Н.Гамбәр. *Әмма Тукайда искелек тарафдарларының, дин әһелләренең конкрет образлары да – бөтен бер галерея.* Казан утлары

**ГАЛЕТ** *и. сөйл. к.* **галета**. *Ул «галет» дигәннәре сохари икән, Рушан аларны бик яратты.* Р.Мирхәйдәров

**ГАЛЕ́ТА** *и. фр.* 1) Төче камырдан пешерелгән, коры, озак саклана торган печенье төре. *Өстәл янына килеп утыргач, ул үз каршында язу һәм ашамлыклар: берничә галета, чикләвек, ипи кисәге күрде.* Г.Әпсәләмов

**ГАЛЁРКА** *и. рус сөйл.* Театрда иң өске ярус (*галерея* сүзеннән). --- *галёркада кычкырып утыручылар да бар иде.* Х.Камалов. *Купшы сәнгать сарайлары, алтын нәкышлы галёркалар, бәллүр тамчылары яшьнәп кабынган саллы люстралар, калын пәрдәләрнең диңгез дулкыныдай вәкарь белән генә ачылуы ---.* М.Гали. *Галёрка тулы шәкерт-студент. Ул монокльләр, ул бинокльләр ялт та йолт. Чышы-пышы киләләр ---.* Р.Батулла

**ГАЛИ** *с. гар. кит.* 1) Бөек, өстен, олы. *Барлык яхшы уйларыннан, гали максатларыннан яза.* Г.Баттал. *Далаларның моңлы балалары – гали җаннар, чәчән, акыннар---* Л.Лерон. *Немец фәлсәфәчесе Гегельнең шундый фикере бар: «Вак, әһәмиятсез идеянең*

*гали рәвештә күрсәтелә алуы мөмкин түгел».* Ф.Галиуллин

2) Югары дәрәҗәле, сыйфаты, әһәмияте, дәрәҗәсе ягыннан өстен. *Менә тиздән гали мәгълүматлы кешеләребез өлгерәчәк.* Г.Тукай. *Шундый куәтле, гали рухлы татар кызлары яңа тормышны бизиләр икән, һич тә күпсенмим, Тәңре бирсен генә.* Ш.Әхмәдиев

3) Югары. *Икенче гали фәрман булгач, ерткыч Юлбарыс атылып чыга ---.* С.Рәмиев. *Ниһаять, ул гали мәктәпне тәмам итеп чыккач, врач булып эшкә керешә.* Ш.Камал. --- *Фатыйма – чын мәгънәсе белән көчле һәм мәхәббәтне чынлап аңлый торган гали рухлы, идеяле мөгаллимәдер.* Ш.Әхмәдиев

**ГАЛИБ** *и. гар. иск.* **1.** Җиңүче, өстенлек алучы. *Һушәң шаһ ни эшли алачак, ник аның белән килешәсең, әлбәттә, сугыш, менә сиңа мин рөхсәт бирдем, сине аңа галиб кылдым, аны җиңәрсең ---.* Дастан. *Кем галиб булса, шул падишаһ булыр, тәҗрибә итәргә тиешле.* Р.Фәхреддин. *Бу дәфгада үзләренең болгарларга галиб киләчәкләренә тәмам ышаналар.* Г.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Өстенлекле, әһәмиятлерәк, көчлерәк

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Мөһим, өстен булу. *Дөрест, бунда сурәткә караганда фикер галиб. Ләкин бу фикерләр берсе дә, тар мантыйк калыбына салынып, суык кан илә мөхакәмә ителгән саф фикерләр түгел.* Җ.Вәлиди

**ГАЛИБАНӘ** *рәв. гар-фар. иск.* **1.** 1) Җиңүче булып, җиңү белән

2) Җиңүче кыяфәте белән, җиңүчеләрчә. --- *уннан артык егет аңа кушылып кычкырып-сызгырып, тирәякка галибанә карашларын чәчеп киләләр.* Ш.Усманов

3) Эре, тәкәббер кыяфәт белән, үзен өстен куеп

4) Горурлык белән, хозурлык белән. *Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата.* Г.Тукай. *Ә безнең халык яшәгән җирләрдә ачаган уйный. Шөбһәле дә, галибанә дә.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Хозурлы, соклангыч. *Бу – «сугышчы солдат хакыйкате» дигән бөек, галибанә бер хис, изге хис иде.* М.Мәһдиев. *Соңга таба Тукай шигырьләрен галибанә мөкиббәнлек белән укый башлагач, аның күңеле «моңлы», «дәртле» Казанга тартыла.* С.Поварисов

**ГАЛИҖӘНАП** *и. гар.* **1.** Бөек, мөхтәрәм. --- *галиҗәнап тарих, көчле ташулардан соң үзәкләрен үзгәрткән елгалар сыман, бөтенләй көтелмәгән якка борылып кереп китә.* С.Шәмси. *Галиҗәнап Вакыт исеменнән көз, көнләшеп, балкон ишегеннән сузылып эчкә бакты ---.* М.Әгъләм

**2.** *и. мәгъ.* Бөек кешене, зур дәрәҗәгә ия булган кешене атау яки аңа мөрәҗәгать итү сүзе. --- *бу ил халкының ахмаклыгы, үҗәтлеге адәм башына сыя торган булмады, галиҗәнап.* М.Маликова. *Полковник галиҗәнаплары, бөтен авыл халкы, без килгәнгә, зур шатлык кичерә.* С.Поварисов. *Хөрмәтле архитектор галиҗәнаплары? Без инде менә бер сәгатькә якын сезнең кабинетта утырабыз.* Р.Вәлиев

**ГАЛИҖӘНАПЛЫК** *и.* 1) Олы күңеллелек, олы җанлылык, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек. *Гаһетләрне җиренә җиткерү, хакларын ригая итүнең галиҗәнаплык икәнлегендә шөбһә юк.* Р.Фәхреддин. *Дөресен әйтергә кирәк, галиҗәнаплык күрсәтте үзе.* И.Нуруллин

2) Дәрәҗәгә ия булу, бөеклек

**ГАЛИЛЕК** *и.* Бөеклек, югары дәрәҗә, олылык. *Кайда галилек сиңа, хали икәнсез син һәнүз!* Г.Тукай. *Галилек бар идеме ул, Асылдук юк иде мәллә? Алайса, ник гали җанлы Яраттың соң мине, мәула?* С.Рәмиев

**ГАЛИМ** *с. гар.* **1.** 1) Аерым бер фән өлкәсендә югары квалификациясе булган. --- *шулкадәр галим, бөек затның мәктәп капкасы ачык булып торганда, бу манигъләрнең булуы бары минем бәхетсезлегемнән генә.* А.Расих

2) *иск.* Гыйлемле, укымышлы, бик күп белүче, тирән белемле. *Аның ике вәзире бар иде. Бере бик галим вә бере бик надан иде.* К.Насыйри. *Рус падишаһларының шул заманга кадәр булганнарының иң явызы һәм иң икътидарлы вә иң галиме шушы падишаһтыр.* Г.Гобәйдуллин. *Татар шәкерте яки татар сәүдәгәре эчендә бик надан, галимрәге, бик бае, бәхетлесе, бәхетсезе булырга мөмкин.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Фәнни эшчәнлек алып баручы кеше, фән белән шөгыльләнүче; билгеле бер фән өлкәсендә белгеч. *Надан исә үз китабын халык медицинасы тәҗрибәсенә таянып, Әбүгалисина кебек даһи галимнәрдән өйрәнеп иҗат иткән ---.* М.Госман. *Кайчандыр вуз баскычларын биек тау дип исәпләүче ябык студентлар, үзләре галим булып, вузларда укыта башлыйлар.* Ф.Яруллин. *Галимнәр әнә шундый хыялчан малайлардан чыга дип язалар бит.* Г.Нәбиуллин

**ГАЛИМӘ** *с. гар.* **1.** Белемле, мәгълүматлы, әзерлекле. *Укымышлы, акыллы галимә кыз иде, хәзер әнә шәех Колшәрифкә чыгып йөри икән.* М.Хәбибуллин. *Аспирантура бетергән галимә кызны тиз генә таба алмадымы, берничә ел авылга кайтмады Әсфән.* Ф.Яруллин

**2.** *и. мәгъ.* Галим хатын-кыз, хатын-кыз белгеч. *Галимә Урта Кабанда фәнгә мәгълүм булмаган яңа төр кысла табылуы турында сөйләде ---.* Р.Мостафин. *Соңгы егерме ел эчендә әдәбият-сәнгать тәнкыйтьчесе, галимә Йолдыз Нигъмәтуллинаның эзләнүләре игътибарга аеруча лаек.* Р.Батулла

**ГАЛИМ-ГОЛӘМӘ** *җый. и. гар.* Гыйлем ияләре, галимнәр, фән кешеләре. *И ул салмак җөмләләрне галимголәмә тембры белән генә, кычкырмыйча гына тезүләр.* М.Мәһдиев. --- *безнең галим-голәмәбез аптырап калды, мондый әсәрләрнең жанрын ничек атарга?* С.Хафизов. *Үз кандашы, галим-голәмәсе Аны саткан чакта ятларга, Бугаздагы ачы төер булып Ватанына кайтты татар да!* Л.Лерон

**ГАЛИМЛЕК** *и.* Галим булу, югары дәрәҗәдә белемле, эрудицияле булу. *Галимлеккә килгәндә, Җәмилә белән алышып булмый, аның укымаган-белмәгән китабы юктыр.* М.Хәбибуллин. *Кемгә байлык, кемгә саулык, Галимлек – үзе зур байлык.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ГАЛИМНӘ́РЧӘ** *рәв.* **1.** Фәнчә, фәндә, галимнәрдә кабул ителгәнчә;

галимнәр кебек, галимнәргә хас булганча. *Борынгы әдәбиятны, атаклы шәхесләребез мирасын чын галимнәрчә өйрәнгән шәхес ул ---.* Ш.Галиев. *Миңа ул нәтиҗә ошады, галимнәрчә фикер йөртелә иде, ләкин канәгать үк калмадым.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Галимнәргә хас булган. *Галимнәрчә төгәллек*

**ГАЛИП** *и. гар. иск. к.* **галиб**. *Чөнки сугыш көнендә, әгәр дошман галип килерлек булса, ничек итеп вә кайсы юлга качарга кирәк, аны фикер итеп, аннан соң сугышка тотыналар, бәхет белән башларын коткаралар.* К.Насыйри. *Хөррият илә истибдат һәмишә сугышмактадыр, белмим, кайсы галип булыр.* Ш.Мөхәммәдев

**ГАЛИПОТ** *и. фр.* Ылыслы агачларның каерысы җәрәхәтләнгәч агып чыга торган, составында су, канифоль һәм скипидар булган сагыз, сумала

**ГАЛИФЕ** *и.* (француз кавалерия генералы *Galliffet* фамилиясеннән) **1.** Үзенчәлекле тегелешле, балагы тар, тездән югары өлеше киңәеп киткән чалбар. *Шпорлы итекләрдән, кызыл галифедан, ак папахадан, папаханың бөтен буена, кыеклап, кызыл тасма тоткан.* Ә.Еники. *Галифе кесәсеннән зур кульяулык чыгарып, тирләгән маңгаен сөртте ---.* Н.Фәттах. *Галифе кесәсенә шактый керә икән бит ---.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тегелешле. *Хәрби киемнән: башында фуражка, өстендә гимнастёрка һәм галифе чалбар, аякларында ялтырап торган итек.* И.Салахов. *--- кара гимнастёркалы, галифе чалбарлы кеше җиргә сикереп төште дә батып яткан машина янына килде ---.* Г.Ахунов

**ГАЛИШАН** *с. гар.-фар. иск.* Бөек, бик зур дәрәҗәле; кадерле, мәртәбәле. *Бу кадәр зур, галишан милләт белән ник уйнадың?..* Г.Тукай

**ГАЛЛ** *и. лат. тар.* 1) Галлиядә – хәзерге Франция, Бельгия, Төньяк Италия җирләрендә яшәгән кельт кабиләләре кешесенә римлылар тарафыннан кушылган исем

2) *иск.* Француз. *Кемне әсир итә ят зурлык, Инглиз малы, галлар тылсымы, Шул бәндәгә мәңгелек хурлык.* Шиллер. *Палач кына ирешмәде бүген бәхеткә. Төн сезнеке, татарлар һәм галлар! Бәхетегез бүген, яһүдләр!* Р.Әхмәтҗан

**ГА́ЛЛА** *и. гр. бот.* Үсемлек тукымаларында төрле паразитлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән кутыр, үсенте. *Үзләренең аналарын ашый торган галла чебеннәренең личинкалары турында сөйләнде инде.* Кызыклы физиология. *Чынында исә болар чикләвек түгел, ә кабарынкы түгәрәкләр, яфрак тукымасының бозык үсентеләре – галлалары гына.* Робинзон эзләреннән

**ГАЛЛӘ** *и. гар. иск.* Керем, файда. *Һәр ки асле фигъраәтендән хикмәтә яр улмайә, Һәргиз аның галләсенә һич дәвакяр улмайә.* М.Акмулла

**ГА́ЛЛИЙ** *и. лат. хим.* Ga символы белән билгеләнгән, йомшак, тиз эрүчән, көмешсыман ак металл; ярымүткәргеч материаллар җитештерүдә, манометрлар, югары температураларга термометрлар ясауда терекөмеш урынына файдаланыла. *100 г кремний кристаллында 10 мкг фосфор һәм 15 мкг галлий катышмалары тигез таралган.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Узган гасырның җитмешенче, сиксәненче елларында галлий, скандий һәм германий элементлары ачылгач һәм аларның үзлекләре закон нигезендә нәкъ Д.И.Менделеев алдан ук әйткәнчә булып чыккач, периодик закон һәм аның авторы зур тантанага ирештеләр.* Химия фаш итә

**ГАЛЛИЦИЗМ** *и. лат. лингв.* Берәр телгә француз теленнән үтеп кергән сүз яки гыйбарә; француз теле үрнәгендә, шуңа охшатып төзелгән тәгъбир. *Галлицизмнар белән чуарланган сөйләм*

**ГАЛЛЮЦИНА́ЦИЯ** *и. лат.* Чынлыкта булмаган нәрсәләрне субъектив рәвештә бар дип санау һәм шуларны күрү, ишетү, сизүдән гыйбарәт авыру халәт. *Яңгура, куркып, кычкырып, стенага таба елышты. Өрәк юк булды. – Галлюцинация, – диде Яңгура, үз-үзенә.* Г.Әпсәләмов. *--- алдында басып торган гәүдәнең чынмы, галлюцинациями икәнлегенә төшенә алмыйча: «Мин чыннан да акылымнан язам икән», – дип уйлады Мәдинә ---.* Ш.Хөсәенов. *Барып чыктың, инде күз алдында галлюцинацияләр башланды, ял итәргә, туйганчы бер йокларга иде дип уйлап куйды ул.* Р.Мирхәйдәров

**ГАЛО-** *гр.* Кушма сүзләрнең беренче, «тоз» мәгънәсенә туры килә торган өлеше

**ГАЛОГЕННАР** *и. гр. күпл. хим.* Металлар белән кушылганда, тозлар бирә торган, зур гамәли әһәмияткә ия химик элементлар группасы (фтор, хлор, бром, йод, астат). *Ә галогеннар окисьларының (бусы инде җиденче группа) һәм инерт газларның кислородлы кушылмаларының үзлекләре охшаш булып чыкты.* Химиянең киләчәге. *Лантаноидлар – галогеннар белән, ә җылытканда, азот, күкерт, углерод, кремний, фосфор, водород белән тәэсир итешә ---.* Органик химия

**ГАЛОП** *и. фр.* XIX йөздә киң таралыш алган кызу ритмлы бал биюе

**ГАЛОФИТ** *и. гр. бот.* Тозлы туфракларда (диңгез ярларында, тозлакларда) үсә торган үсемлек. *Ел буена нибары 180 миллиметр явым-төшем булган бу чүлдә анда-санда галофитлардан гайре үлән дә үсми.* А.Муранов

**ГАЛОШ** *и. гр.* Юештә, пычракта аяк киеме өстеннән яки калын оек белән киелә торган резин аяк киеме. *Тирән-тирән баткан тояк эзләре, резина галош эзләре, кечкенә-кечкенә ялангач аяк эзләре җир өстен чуарлаганнар.* М.Әмир. *Кеше арасына чыкканда, аягыбызда лаклы галошлар булыр.* Ю.Әминов. *Адаштырган песи баласыдай, Айлар буе кайта. Кан... Яра... Автомобиль покрышкасыннан Галош ясап, җәяү кар яра.* Х.Әюп

**ГА́ЛСТУК** *и. нем.* Күлмәк якасына бәйләнә торган, башлыча ир-атларныкы саналган, гадәттә, тасмасыман формадагы, рәсми стильдәге кием атрибуты, аксессуары. *Каш астыннан гына Петлеванныйның аллы-гөлле галстугын җентеклибез.* Э.Касыймов. *--- зур рам эчендә ап-ак күлмәккә кара галстук таккан, яхшы пинжәк кигән тап-таза яшь бер кеше Камәр карчыкның өстәлендәге электрлы самавырына карап тора иде.* М.Мәһдиев

2) Төрле кешеләрнең бер сәяси оешма, спорт клубы, уку йорты, профессия һ.б.ш. вәкилләре булуын белдергән, билгеле төстәге яки формадагы муен яулыгы. --- *аның ике ягына ике яшүсмер килеп басты. Икесенең дә муенында кызыл галстук.* М.Мәһдиев

**ГАЛУ́ШКИ** *и. укр.* Украин, словак, чех һ.б. Көнчыгыш Европа халыкларында һәм өлешчә Кавказда суда пешкән камыр кисәкләреннән гыйбарәт милли ризык; чумар. *Кичке аш вакытында староста миңа үз «хәзинә»сеннән (аерым җамаяктан) өстәмә рәвештә бер өлеш баланда, бер өлеш галушки бирде.* И.Салахов

**ГАЛЬВАНИЗА́ЦИЯ** *и. нем.* Түбән көчәнешле һәм аз көчле даими электр тогын дәвалау максатларында куллану. *Алай да ак җәймә белән аралык бүлеп, контейнер белән кайткан гальванизация, соллюкс, кварц, УВЧ аппаратларын, яктылык ванналарын эшләтеп җибәрдем.* Сөембикә

**ГАЛЬВАНИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Гальванизация процедурасы ясау, гальванизация үткәрү

**ГАЛЬВА́НИК** *с.* Электролит һәм электродлар арасындагы химик реакция нәтиҗәсендә барлыкка килә торган; шул реакция нигезендә эшли торган. *Гальваник элементлар – анод һәм катод арасындагы ионнар хәрәкәте турында Рушад татарча ярды да салды.* М.Мәһдиев. *Электр машиналары, гальваник элементлар, аккумуляторлар, генераторлар һәм башкалар ток чишмәсе булалар.* Физика курсы

**ГАЛЬВАНО́МЕТР** *и. нем. физ.* Аз көчле электр тогын һәм көчәнешен яки электрның аз күләмнәрен үлчәү өчен үтә сизгер прибор. --- *ток чишмәсен чылбырдан өзәбез, ә аның урынына гальванометрын тоташтырабыз.* Физика курсы. *Гальванометр бик сизгер булганга, аңардагы әйләндерүче һәм тоткарлаучы көч моментларын һәрвакыт исәпкә алырга кирәк.* Даими ток законнары

**ГАЛЬВАНОПЛА́СТИКА** *и. рус* 1) Беренчел предметның төгәл копиясен ясарга мөмкинлек бирә торган, металлның билгеле форма өстендә куык катламы хасил итүдән гыйбарәт электрохимик процесс һәм шуның технологиясе. *Сүзлекчәдә металлар һәм аларның эретмәләре, оксидлар, нигезләр, кислоталар гына түгел, гальванопластика һәм гальваностегиянең технологик процесслары өчен С.Глаголев тәкъдим иткән башка матдәләр дә күрсәтелгән.* Фән һәм тел

2) Шундый ысул һәм технология белән ясалган эшләнмәләр

**ГАЛЬВАНОСКОП** *и. гр. физ.* Гальваник чылбырда электр тогының булу-булмавын һәм аның юнәлешен билгеләү өчен хезмәт итә торган гади прибор

**ГАЛЬЮН** *и. гол.* Диңгез яки елга судноларында туалет; бәдрәф. *Корабльдә ---, берәр җирдән комиссия килсә, иң элек гальюнны карый.* М.Мәһдиев. *Мин сине һаман гальюн тазартып йөри дип уйлый идем.* М.Юныс. --- *флот сүзләре күп кулланыла иде. Әйтик, камбуздан тыш әле поварны да «кок» дип кенә җибәрәләр, бәдрәф туалет түгел – гальюн, казарма – кубрик һәм башкалар.* Р.Кәрами

**ГАЛЯКА** *и. гар. к.* **галәка.** *Әгәр дә мөхәррир әфәнде кыз кыяфәтенең дәрәҗәсен интеллигент бер ир илә араларында галяка хасыйль булырлык итеп югарырак күтәргән булса, яхшырак булган булыр иде.* Г.Камал. *Редакцияләр Тукай иҗатына азмы-күпме галякасы булган кешеләрне заказ белән күмеп ташладылар.* М.Мәһдиев

**ГАМ** I *и. гар. иск.* Ел

**ГАМ** II *с. гар. иск.* **1.** Гомуми, теләсә кемгә караган, күмәк. *Азатлык, әй мөкатдәс гам азатлык! Мөбарәк ит нурыңла күңелебезне!* С.Рәмиев. *Сәүдәгәр сыйныфының шәхесендә без аның бөтен сыйныфына гам булган язмыш вә сыйфатларны табабыз.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Масса, кара халык. *Казанда бер фазыйль чыкды алмас булып, Хасидләре күбәйде гам-хас булып.* М.Акмулла

2) Халыкчанлык. --- *бер заманнар Толстой гаме саф вә инҗим хыял әхлакысы илә Гаязны тәсхир әйләсә дә, бу мәзһәбнең тагбикатендәге имкәнсезлек, мистицизмга бик артык бирелүе аңардан да тиз сугытты.* Й.Акчура. *Фәйзы хак һәр мөмкинә гам – шарт имәс Бәгъдад, Хәлеб ---.* М.Акмулла

**ГАМА** *и. гар. иск.* Сукырлык. *Ул картның халь-әхвален вә гамасыннан сөаль кылдылар.* К.Насыйри

**ГАМАШ** *и. фр.* Тәнгә сыланып торган балаклы, бәйләнгән яки трикотаж җылы ыштан. --- *бәйләгән нәрсәләре – йон оек, мамык шәл, гамаш, бияләй, джемпер.* Казан утлары

**ГАМАК** *и. фр.* Ятып ял итү өчен, баудан үреп яки тукымадан ясалган асылмалы ятак. *Кырыйда, гамаклар астында ук диярлек, целлофан җәеп, өстенә катыргы түшәлгән ятак та бар.* З.Фәйзи. *Шул максатлардан чыгып, ул көн саен үзенә ботак һәм яфраклардан яңа оя кора һәм аны гамак шикелле элеп тә куя.* Кызыклар дөньясыннан. *Бу әйберләрдән тыш, Робинзон «корабльдәге барлык өс киемнәрен, запас җилкән, гамак һәм берничә мендәр белән түшәкне дә» утравына күчерә.* Робинзон эзләреннән

**ГА́М ӘЙЛӘҮ** *ф. иск.* Уртаклашу, бүлешү. *Беземчөн зәхмәтен там әйләйән кем? Соңыннан рәхмәтен гам әйләйән кем?* Г.Тукай

**ГАМӘЛ** *и. гар.* 1) Эш, хәрәкәт. *Әйе, үсә төшкәч аңладым, әтиемә эштә, аның һәр гамәлендә эзлеклелек, түземлелек җитми иде.* А.Расих. *Минем гомерем буе кылган эшләрем, гамәлләрем арасында терсәкне тешләрдәй булып үкенерлекләре күп түгел.* М.Мәһдиев. *Шул минуттан ул үзенең кылган гамәлләренең сәбәп-нигезен аңламас хәлгә килде.* А.Гыйләҗев

2) Практика; чынбарлык, тормыш. *Өстәвенә ул [әни] мине ярата, бик ярата һәм аның миңа булган мәхәббәте сүздә генә түгел, гамәлдә дә бик нык чагыла.* А.Расих. *Хәтта хакимнәр дә шагыйрьләр белән исәпләшкән, дигән фикерен гамәлдә раслады.* М.Кәрим. *Сөйләү җиңел, язу ансат ул. Ә эш, гамәл бөтенләй икенче төрле.* Х.Камалов

3) Эшнең торышы, хәл, вазгыять, халәт. --- *үземне бер киң вә рәхәт гамәлдә хис иткәнемне, юлда барганда,*

*күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.* Г.Тукай

4) Эшчәнлек. --- «*Казакъ кызы*» – *язучының эстетик карашларында һәм әдиплек гамәлендә романтизм хакимлек иткән вакыт җимеше.* Ф.Галимуллин

5) *мат.* Математик хисаплауның төп ысулы, төре. *Һиндстан математигы һәм астрономы Арьябхата (VI гасыр башы) күп кенә математик гамәлләрне яза, П (Пи) санын зур төгәллек белән билгели.* Урта гасырлар тарихы

6) *дини* Шәригать буенча үтәлергә тиеш булган һәм үтәлгән теләсә кайсы эш. *Хаҗ гамәле*

7) Чара, мөмкинлек, әмәл, ысул

◊ **Гамәл дәфтәре** 1) *дини* Ике фәрештә тарафыннан кешенең һәр яхшы һәм яман эшләре (гамәлләре) теркәлә торган дәфтәр. --- *гамәл дәфтәрләрен үлчәүче мизан янында өммәтем өчен шәфкать һәм мәрхәмәт таләбендә булырмын.* Ф.Яхин; 2) *куч.* Вак-төяк эшләр, алу-бирүләр язылган блокнот, кесә дәфтәре. *Контора-да һәркайсыгызның гамәл дәфтәре язылып барыла ---.* К.Нәҗми. *Һәркайсыгызның гамәл дәфтәренә даими игътибар итәчәкмен.* Ф.Баттал. *Борһанов ишектән чыгып китүгә, ул әлеге гамәл дәфтәрен алды.* Г.Ахунов

**ГАМӘЛӘ** *и. гар. иск. кит.* Эшче, эшчеләр катламы вәкиле. *Рус народникларыры шикелле безнең татар «халыкчы»сы да бу авыл халкының гамәләгә әйләнүе белән тагы бер мөшкел мәсьәләгә барып терәлә.* Г.Газиз

**ГА́МӘЛӘН** *рәв. гар. иск.* Эш белән, эшләп күрсәтеп, эш өстендә. *Докторның һичбер сүзенә гамәлән һәм игътикадән карыша алмый иде.* Ф.Әмирхан

**ГАМӘЛГӘ́ АШУ** *ф.* Тормышка ашу, барып чыгу, үтәлү. *Ә җитәкче иптәш, үбешеп саубуллашып, машинага утырганда, инде ни хакта сүз барганны оныткан булгандыр, мөгаен. Чөнки әлеге нәрсәләр башка кутәрелмәде. Вәгъдәләр гамәлгә ашмады.* Т.Галиуллин. --- *Әдрән диңгезгә җиткәч кире борылырга мәҗбүр булган Бату ханның гамәлгә ашмый калган максаты миндә пыскып уянамы әллә?* М.Галиев

**ГАМӘЛГӘ́ АШЫРУ** *ф.* Башкару, үтәү, тормышка ашыру. *Әгәр шул проект гамәлгә ашырылса, ул дөньяда тиңе булмаган зур корылма булачак.* А.Муранов. *Приказлар, күрсәтмәләр, документлар, экипаж әгъзаларының чит ил паспортлары, таможня декларацияләре, эшләнеп бетмәгән эшләр, гамәлгә ашырасы фәрманнар, әллә нәрсәләр...* М.Юныс. --- *ниятен гамәлгә ашыра алмыйча калган чаклары байтак булды Ханифәнең.* В.Нуруллин

**ГАМӘЛГӘ́ КЕРТҮ** *ф.* Закон төсе бирү, әйләнешкә кертү. *Менә шуны үзебезнеке итеп гамәлгә кертү өчен, бер кочак документ әзерләп тапшырдык, шулай да ярты юлда туктап калмадык.* Р.Ибраһимов. *Егерменче елларда Г.Гали даими рәвештә пролетар әдәбиятының принципларын гамәлгә кертү өчен көрәшкән.* Р.Мостафин

**ГАМӘЛГӘ́ КЕРҮ** *ф.* Законлы көч алу, эшли башлау. *Ә ул Конституциянең төзелеп беткәнен, гамәлгә кергәнен күпме көтәргә мөмкин соң?!* Г.Ахунов

**ГАМӘЛГӘ́ КУЮ** *ф.* Тормышка ашыра башлау, тәкъдим итү. --- *Байчура докладының төп эчтәлеге бәян ителә. Анда яңалифне гамәлгә куюның гына түгел, гомумән, татар теленең торышы, бу өлкәдәге уңышлар һәм җитешсезлекләр хакында да сүз бара.* Х.Миңнегулов

**ГАМӘЛДӘ** *рәв.* Чынлыкта; практикада, тормышта. --- *гамәлдә милли идеологиянең һәрвакыт булганлыгын һәм бүген дә бар икәнлеген ассызыклап китәргә тиешбез.* И.Таһиров. *Сүздә «демократия», ә гамәлдә «сәяси демагогия» килеп чыга түгелме?* Роберт Әхмәтҗан

**ГАМӘЛДӘГЕ** *с.* 1) Кулланылышта булган, кулланылыштагы; яшәп килгән. *Гамәлдәге сүзлекләребездә теркәлмәгән, матбугат битләрендә дә бик сирәк очрый яки бөтенләй очратып булмый торган --- сүзләрне тәрҗемәченең табышы дип карарга мөмкин.* Г.Ахунов. *«Кеше» дигәнең һай ничек үзгәрә! Ул – гамәлдәге системаның үз баласы.* А.Хәсәнов

2) Хәзерге вакытта үз көчендә булган, эшләп килгән, закон көчен югалтмаган, гамәлдән чыгарылмаган. *Мондый хәлләрне район җитәкчеләренә фактларга нигезләп, гамәлдәге законнарга таянып, еш кына аңлатып бирергә туры килә ---.* Г.Бәширов. --- *гамәлдәге ипотека системасы гражданнарның күпчелеге өчен хыял гына булып тора.* Мәдәни җомга

**ГАМӘЛДӘ́ КАЛУ** *ф.* Үз көчендә калу, кулланылышта калу, закон көчен югалтмау

**ГАМӘЛДӘ́Н ЧЫГУ** *ф.* Закон көчен югалту, кулланылыштан алыну яки төшеп калу

**ГАМӘЛИ** *с. гар.* 1) Практик; файдалы. *Мәчене кеше, башлыча, гамәли максатта: йорт-җирне иң әшәке кимерүчеләр – тычкан һәм күседән саклау өчен кулга ияләштергән.* Кызыклар дөньясында. *Җирнең бу табигый иярчене өстендә кешеләр атмосфера булдырып азапланмас, гамәли яктан бу мөмкин эш түгел.* Кызыклар дөньясында

2) Кулланылыштагы, гамәлдәге. *Шулай ук сынлы сәнгатьнең гамәли төрләренә караган керамика, архитектурадан да шактый мәгълүмат алып, Казанга кайта.* М.Әмир. *Лариса – сәнгать белгече, Урта Азия халыкларының гамәли сәнгатен өйрәнә, дөресрәге, Шәрекъ керамикасы үрнәкләрен җыя иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГАМӘ́Л ИТҮ** *ф.* Эш итү; шөгыльләнү. --- *шәкертләр мирасына карата да без фәнни эзлеклелек, тарихи гаделлек принцибы белән гамәл итәргә тиешбез.* М.Госман. --- *иске дәвер мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнгәндә, без «Асарь» материалларыннан башка фактографик төгәл һәм фәнни эзлекле рәвештә гамәл итә алмаячакбыз.* М.Госманов

**ГАМӘЛИЯТ** *и. гар.* 1) Эш-гамәлләр, практик мәсьәләләр; эшнең практик ягы. *Бер дә бу хосуста бераз тәҗрибә күргән вә бу эшнең гамәлияте илә уграшкан кешеләрнең фикерләрен тыңлап карыйк.* Г.Баттал

**ГАМӘ́Л КЫЛУ** *ф.* Эшләр башкару, гамәл итү. *Нинди гаебем бар микән, мондый хөрмәтле язучының хәтерен калдырырлык нинди гамәл кылдым икән, Ходаем?!* Ф.Баттал

**ГАМӘЛЛЕ** *с.* 1) Билгеле гамәлләрдән торган, берничә гамәлдән торган. *Синең әгәр күп гамәлле Мәсьәләңне чишәлмәсәм, --- Хөкем синең гадел яман!* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Кулы эш белгән, шөгыле, кәсебе булган, эше булган

**ГАМӘЛСЕЗ** *с.* 1) Гамәлгә ашырылмаган, гамәлгә күчмичә, сүздә, теориядә генә калган. *Гамәлсез гыйлем – яңгырсыз болыт.* Мәкаль. *Инде болардан да гарык булган, бер гамәлсез фикер мәйданына күз ташлаучылар бөтенләй бетте.* Ә.Ханнанов. *Президент Рөстәм Хәмитов республика җитәкчелеге дилбегәсен кулына алганнан ук «халык турында хәстәрлек» дигән гамәлсез фразеологияне «кешеләр өчен эшләргә» дип конкретлаштырды.* Кызыл таң

2) Эшсез, шөгыльсез, эш башкармаган. *Хәрәкәтсез, гамәлсез, Ходайдан ялваручылардан, кулын баглап ялкау зарланучылардан да мескен кеше юк.* С.Максуди

**ГАМБӘР** *и. гар. иск.* 1) Тешле китлар асотрядының кашалотлар семьялыгына караган, Арктикадан тыш барлык океаннарда очрый, баш-аяклы моллюсклар яки балык белән туклана торган, бик зур башлы имезүче диңгез хайваны; кашалот

2) Әлеге хайванның ашкайнату трактында барлыкка килгән, парфюмериядә файдаланыла торган хуш исле матдә; *русчасы:* **амбра**. *Ирен – якут, теш – энҗе, мисле гәүһәр, Кара чәч иңнәрендә, аңкый гамбәр.* Котб. *Учакка Ягып алой белән гамбәр, бүлмәне Төтәттеләр хуш ис белән.* Фирдәүси

**ГАМБИТ** *и. фр.< ит. шахм.* Активрак һәм отышлырак позиция алып, тизрәк һөҗүмгә күчү өчен, берәр фигураны оттырудан гыйбарәт уен башы. *Малайлар һәм үсмер егетләр сөенештеләр, көләләр. – Ну, Сафуанов, молодец! – Ну, ферзь гамбиты шәп уйналды.* Г.Афзал. *Даут Сөнгатевич ферзь гамбитыннан башлады, шулаймы?* М.Галиев

**ГАМБУ́ЗИЯ** *и. лат. зоол.* Карптешлеләр семьялыгына караган, Төньяк Америкадан чыккан, кайбер илләрдә бизгәк озынборыны белән көрәшү өчен үрчетелә торган, балаларын тереләй тудыручы кечкенә балык. *Безнең илгә гамбузияне 1925 елда Италиядән малмриягә каршы көрәшү өчен алып кайталар.* Кызыклы ихтиология

**ГАМЕ́ТА** *и. гр.* Җенси күзәнәк. *Аталану алдыннан серкә көпшәсе эчендәге спермаген күзәнәк бүленә һәм ике гамета хасил итә.* Л.Мәүлүдова. *Бүленгәндә, алар да, нәкъ хатын-кыз гаметалары кебек, хромосомаларының яртысын югалталар ---.* Кызыклы физиология

**ГАМИ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Халыкка, массага караган. *Аның [М.Бигиевнең] гами әсәрләрендә мантыйктан бигрәк дәрт вә һәяҗан куәтле.* Җ.Вәлиди

2) Тупас, дорфа

3) Надан, томана, караңгы

**2.** *и. мәгъ.* Надан кеше, томана. *Күрмәде гами, табигый, буш куыклар атмагач.* Г.Тукай

**ГАМИЗ** *с. гар. к.* **гамыйз**

**ГАМИЛ** *и. гар. иск. кит.* 1) Эшләүче, хезмәт иясе. *Шигырь дөрест – нәсихәтне хамил булса, Иясе кадәри халь гамил булса ---.* М.Акмулла

2) Хәрәкәткә китерүче көч, төп фактор, сәбәп. *Сәетгалиев-Мансуров фиркасенең бу эштә бер дә шөбһәсез кабәхәт бер гамилләр икәнлекләрен мин бик яхшы беләидем.* Ф.Әмирхан. *Төркиянең Идел буе эшләренә Кырым аркылы катышуы өчен мондый бер гамил табылды да.* Г.Гобәйдуллин

3) Хаким; дәрәҗәле кеше. *Мөхәммәт бине Хәсәннең дусларыннан берәү бер җиргә гамил булды.* К.Насыйри

**ГА́ММА** I *и. гр.* 1) *муз.* Бер октава эчендә яңгырашларның эзлеклелеге. *Яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль ---. Менә шулай, ә авазлардан гамма хасил була.* Ә.Еники. *--- бер тыңласаң, бу көйнең гаммасына, аз гына соңга калып, дистәләгән трубаларның көмеш чыңы өстәлә ---.* М.Мәһдиев. *– Гамма соль мажор икәнен дә онытма, – дип, пианино янына килде һәм, клавишларга басып, көйнең башын уйнап та күрсәтте.* М.Галиев. *Пентатоник гамма. Хроматик гамма. Мажор гамма*

2) Ноталарны уйнарга өйрәнүчеләр өчен, эзлекле рәвештә күтәрелә яки төшә барган тавыш рәтләреннән гыйбарәт гади күнегү. *Менә Хәбир, наз тулы күзләрен Мәдинәгә текәгән килеш, сыңар кулы белән гамма уйнады.* Ш.Хөсәенов. *Шушы тынлыкны бозып, күрше бинада өйрәнчек пианистның гамма алган тавышы ишетелеп китте.* М.Юныс

3) Декоратив һәм сынлы сәнгатьтә художество әсәрен тудыру өчен кулланылган барлык төсләрнең эзлеклелеге, эзлекле бөтенлеге. *Күкчәчәк таҗындагы төсләр гаммасын, нечкә бороылышларны җиренә җиткереп сурәтли алырмы ул ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Соры, күрәнсу кызыл һәм зәңгәр төсләр үзара матур гаммага берләшкәннәр.* М.Юныс. *Гаҗәеп үзенчәлекле күрән соры гамма – юлбашчының сурәттәге образы характеристикасына туры килгән сабыр, җылы гамма да бизәп тора аны.* Казан утлары

4) *күч.* Бер төрлерәк, охшаш, әмма бер-береннән аерылып торган предметларның, күренешләрнең эзлекле галереясе. *Романтизм – шул ук чынбарлык, тик аның канатлысы, илһамлырагы, хискә баерагы, сәнгатьчә буяулар гаммасының күзгә ныграк ташлана торганрагы.* Ф.Галимуллин. *Буяулар гаммасы. Кичерешләр гаммасы*

**ГА́ММА** II *и. гр.* 1) Грек әлифбасында *Г γ* билгесе белән белдерелгән өченче хәреф

2) Кушма терминнарда матдәнең бер билгеле халәтен белдерә торган беренче компонент. *Гамма-тимер* (910–1400° арасындагы булган тимернең халәте)

3) Гамма-нурланыш белән бәйле терминнарда алкушымча. *Йолдызның гамма-нурланышы озон катламын ертса, Җиргә зыян килә.* С.Поварисов. *Шулай да химик бәйләнешләрне какшатуның бер ысулы – реакцион катнашмага радиоактив нурланыш, мәсә-*

*лән, гамма, рентген нурлары, нейтроннар агышы һ.б. белән тәэсир итү турында берничә сүз әйтеп китәргә кирәктер.* Химия фаш итә

**ГА́ММА-ГЛОБУЛИН** *и. к.* **гамма** II. Кан аксымнарының авыруга каршы торырлык тәнчекләре булган һәм кайбер йогышлы авыруларга каршы дару булarak кулланыла торган группасы. *Аны көне-сәгате белән Эзи больницасына салдылар, казанлылар тиешле күләмдә гамма-глобулин да, Сирия әрләненең бөереннән ясалган махсус дару да алып килгәннәр иде.* А.Гыйләҗев

**ГАММӘ** *и. гар. иск.* 1) Масса, халык; гади халык. *«Әяфе ләйләти вә ләйләти» китабы кеби укыгач, сөрур хасыйль була торган бер китап тәрҗемә итеп яки тәсниф кылып бирсәңез иде гаммәгә һәдияңез дию белеп, укып, Хак Тәгалә хәзрәтләре гарикы рәхмәт әйләсен дию догалар илә яд идәр идек ---.* Ф.Халиди. --- *ул – үзенең халкыбыз гаммәсенең рухына якын шигырьләре белән яшь әдәбиятыбызны гаммәбез белән бағландырган шагыйрь.* Ф.Әмирхан

2) Җәмгыятьнең, халыкның билгеле бер катлавы. *Әйе, безнең демократия гаммәбез алдында шушы бер генә юл.* Ф.Әмирхан. *Шамил Госмановның сугыш дәверендә эшче-крәстиян гаммәсе арасында зур бер дикъкать белән каралып, сөелеп, Россиянең төрле почмагында сәхнәдән төшми килгән «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адымнар»ы --- шундый әсәрләр җөмләсеннәндер.* Ф.Бурнаш

**ГАММӘВИ** *с. гар.* Гомуми, массакүләм, көчле. *Эрегән кар астыннан барлык урманның күпереп калыккан былтыргы яфраклар юрганын берьюлы хәрәкәткә китереп, шабырдатып һәм дөбердәтеп, арттан аларны ниндидер гаммәви гөрелте куып килә иде.* А.Хәлим

**ГАММӘЧЕЛЕК** *и. иск.* Халыкчанлык, киң массаларга аңлаешлы, якын булу сыйфаты. *Бу әдәби стиль (метод урынына әле «стиль» төшенчәсе кулланыла) «без»гә, коллективка өстенлек бирә, гаммәчелек, ачыклык, контрастлыкка омтыла.* Ф.Галимулин

**ГАМЫЙЗ** *с. гар. иск.* 1) Аңлаешсыз, мәгънәсе аңлашылмый торган. *И угыл, әгәр шагыйрь булып шигырь әйтмәк касд итсәң, җәһәт ит ки, шигырьдә сүзең рушан булсын, саклан ки гамыйз булмагай.* К.Насыйри

2) Ачык булмаган, яшерен

**ГАМЬ** *и. гар.* 1) Кайгы, хәсрәт; көенеч, борчу, сагыш. *Инде ул беркем өчен дә гамь йимәс һәм «аһ!» димәс.* Г.Тукай. *Ни гамь – бөлсәм? Әгәр үлсәм – ни ваем?* Дәрдемәнд. --- *беркемдә бер тамчы гамь юк, беркемдә бер тамчы усаллык юк, көн якты, күңел якты, йөзләр-чырайлар якты.* Ф.Хөсни

2) Билгеле эш, хәл, әйбер турында уйлау, кайгыртучанлык, эш кайгысы, хәстәр. *Качарга тиешле җәнлек кача. Яки куак артыннан безне күзәтә. Качасы килмәгәнне үз гамендә булыр.* Р.Батулла. *Көндезге гамен кичкә калдыра торган гадәте юк иде – арыган күз кабаклары йомылуга, йокы ишелеп кенә төште.* М.Галиев. *Уяндым да, бер шомлы гамь качырды йокыны. Гомер бер. Яшәлгән шактые керделе-чыктылы.* Р.Фәйзуллин

3) Игътибар, кызыксыну, күңел кую. *Юк гамең бернәрсәдән дә, барча эшләр ал да гөл ---.* Г.Тукай. --- *хакыйкатьне ачып салган фидакарь тарихчыларда ни гаме булсын аның?!* Л.Лерон

◊ **Гаме(ндә) дә юк** Уйлап та бирми, исендә дә юк, игътибар да итми. --- *ә малайның гамендә дә юк – ул, баксаң, юри генә түгел, ә чынлап торып йоклап киткән икән!* Ә.Еники

**ГАМЬКИН** *с. гар.-фар. иск.* Кайгылы, гамьле. *Ах, бу көннәр гамькин күңелләрне кисә, Үткән гомер бер-бер искә төшә имди.* Г.Тукай

**ГАМЬЛӘНҮ** 1) Кайгыру, борчылу. *Һ.Такташ исә халыкка кирәкле әйберләрне ничек йөрәккә үткәреп язу турында гамьләнә.* Ф.Галимуллин. --- *элегрәк дөнья күргән «Хыянәт»еннән соң, халык гаме белән гамьләнә, бүгенгенең тамырларын тирәннән эзли, офыкның аръягына да караш ташлый ала торган әдип дип, аңа өметебез арткан иде.* Р.Шәрәфиев

2) Кайгыртучанлык күрсәтү, берәр эш мәнфәгатен уйлау, хәстәрен күрү

**Гамьләнә башлау** Гамь керү. *Күрәсең, милли язмыш турында гамьләнә башлау өчен, ниндидер этәргеч кирәктер.* Р.Вәлиев

**Гамьләнә төшү** Бераз гамьләнү; тагын да гамьләнү

**ГАМЬЛЕ** *с.* 1) Кайгылы, хәсрәтле. *Аны Сөхрәб үлемнән азат кылды, Колы итте, гамьле күңелен шат кылды.* Шаһнамә. *Ямь күрәлмәм, гамьле хәлләр китмичә, яшь килмичә, Күз яшемне киптерерлек якты кояш чыкмыйча.* Ш.Бабич. *Минем дә гамьле уй, онытылып яшендәй атылды яшь чакка!* Р.Фәйзуллин

2) Уйлануучан, кайгыртучан. *Уйлы кеше – гамьле кеше ул, карт.* Н.Гыйматдинова

**ГАМЬЛЕЛЕК** *и.* Гамьле булу хәле. *Көнләшергә әзер торган Күңелнең гамьлелеге; «Син генә» дигән чакларның Самими гаделлеге.* М.Галиев

**ГАМЬСЕЗ** *с.* **1.** 1) Ваемсыз, төптән уйламаучан, һәрнәрсәгә җиңел караучан, бер нәрсәгә дә исе китми торган. *Бай, бай яши Казан халкы, шуңа бераз гамьсезрәк тә бугай, чөнки тик торганда, Мәскәү кенәзенә баш иеп тормас иде.* М.Хәбибуллин

2) Кайгы-хәсрәте, мәшәкате булмаган, борчусыз. *Чәчләре чем-кара, йөзе ап-ак, күзләреннән коньяк кояшының эссесе сирпелә, ә буй-сынында гамьсез иркәлек.* М.Маликова. --- *Гамьсез, мәнсез, денсез бөҗәкләргә Ачык ласа утлы тәрәзәң.* Х.Туфан

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ваемсызлык белән, уйлап тормыйча, битарафлык күрсәтеп, артык кызыксынмыйча. *Башына – командирлар фуражкасы, аягына ыштыр урап чабата кигән көймәче карт Хәмдиянең урнашуын гамьсез генә көтеп торды.* Н.Фәттах. --- *кабат бу хакта сүз куертмады, --- язын кешеләрнең кәефе кырыкка төрләнүе турында гамьсез генә бер-ике сүз әйтеп алды.* А.Гыйләҗев. *Әмма минем, никтер, бүтәннәр кебек гамьсез генә: «Урыны күптән шунда иде», – дип кабатлыйсым килмәде.* Р.Мостафин

2) Кайгысыз, борчусыз, рәхәтләнеп. *Гамьсез уйнап йөргән Маһитап кинәт тынды.* М.Әмир. *Сабан тургайлары*

*бертуктаусыз очып, чырылдап, биек якты күктә гамьсез талпындылар.* И.Салахов. *Океан ярында, мәшһүр Варадеро курортының назлы комында бер ваемсыз, гамьсез ятарга була.* М.Маликова

**3.** *и. мәгъ.* Борчусыз, кайгысыз кеше, җиңел уйлаучы кеше. *Онытырлар. Битарафлар, гамьсезләр онытыр!* Р.Батулла

**4.** *хәб. сүз* Борчусыз халәттә. *Хәзер ул гамьсез, җансыз, әмма сүнмәгән, сүрелмәгән...* Ә.Гаффар

**ГАМЬСЕЗ-БИТАРАФ** *с.* **1.** Бернәрсәгә дә исе китми торган, салкын кыяфәтле

**2.** *рәв. мәгъ.* Ис китмичә, салкын карап, борчылмыйча, үтә битараф рәвештә. --- *кашлары астыннан гамьсез-битараф кына карап тора иде.* Г.Ахунов

**ГАМЬСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Уяулыкны, саклыкны югалту, гамьсезлек күрсәтү. --- *әмма бер секунда да гамьсезләнергә ярамый.* Г.Нәбиуллин. *Килешми кыйбласыз яшәү, Килешми гамьсезләнү, Килешми кеше көлдерү, Килешми ямьсезләнү.* Ф.Яруллин. *Күз туйдымы – күңел гамьсезләнә...* Р.Харис

**Гамьсезләнә бару** Акрынлап гамьсезлеге арту. *Без гамьсезләнгәннән гамьсезләнә барабыз. Кемгә карата диген? Минә шушы җир-суларыбызга карата бит.* Ф.Яруллин

**Гамьсезләнә башлау** Гамьсезлек билгеләре барлыкка килү. *[Хәлим] Әләкче булсам булырмын, әти, катырак әйт, абый гамьсезләнә башлады.* Т.Миңнуллин. *Озак көтеп арудан гамьсезләнә башлаган гавам, кайнап, бер сулыштан тупланып өлгерде.* М.Галиев

**Гамьсезләнә төшү** Бераз гамьсезләнү; тагын да гамьсезләнү

**Гамьсезләнеп бетү** Бөтенләй гамьсезгә әйләнү

**Гамьсезләнеп калу** Берәр хәлдән соң гамьсезләнү. *Искәндәр абыең киткәннән соң, әллә нишләп бик гамьсезләнеп калды.* В.Нуруллин

**ГАМЬСЕЗЛЕК** *и.* 1) Ваемсызлык, игътибарсызлык, салкын мөнәсәбәт. *Гамьсезлек шул көнгә калдырды бугай Казан халкын.* М.Хәбибуллин. *Батырлык башлана, улым, --- Йөрәктәге гамьсезлекне, Мин-минлекне җиңүдән.* Ф.Яруллин. *Коткарасың хисне ямьсезлектән, Аламадан, изге мәхәббәт; Гамьсезлектән безне аралыйсың, Рәхмәт сиңа, рәхмәт, мең рәхмәт.* Х.Туфан

2) Борчусыз тормыш. *Бу турыда төпчек игезәкләр уйлый белми әле, балачакның бөек бәхете – гамьсезлек.* А.Гыйләҗев. *Йөзендә гамьсезлек, туклык, күңел тынычлыгы чагыла.* М.Маликова

**ГА́МЬ ЧИГҮ** *ф.* Кайгы күрү, кайгы-хәсрәт кичерү, көенү. *Ленин үлде --- Бу зыягътан кем генә гамь чикмәде!* С.Сүнчәләй. *Балалык чоры ул, җаныңны артык каты авырттыра торган сикәлтәләргә дучар итмәсә генә, хәтердә якты, нурлы, рәхәт, гамь чикми торган вакыт булып саклана.* А.Расих

**ГАНБӘР** *и. гар. к.* **гамбәр**. *Дәһханә Гирәб әнкәсе илә сәгать унбергә кадәр йоклап, йокыларындан торгач, ничә җарияләр Дәһхәнәнең сачыны гуд, ганбәр илә тарап, --- Даһханә ничә мең наз илә боргаланып, фәйтунга утырып, уен бакчасына китте.* Ф.Халиди

**ГАНВӘ** *и. гар.* 1) Җәбер

2) Үч саклау, үчлелек

**ГАНВӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Җәберләнү

2) Үч саклау, үч тоту

**ГАНВӘЛЕ** *с.* Үчле, үч саклаучан

**ГАНГАНӘ** *и. гар. иск.* 1) Сүзнең кешедән кешегә күчүе; традиция. *Башка милләтләрнең искедән килгән тарихлары һәм мәшһүр көннәре, аерым гореф-гадәтләре һәм ганганәләре булса, без олуг болгар һәм төрек кавеменең дә тарихы һәм мәшһүр көннәре, гореф-гадәтләре, тел-лөгатьләре һәм дә ганганәләре бар.* Р.Фәхреддин. *Ганганә көче буенча финнәр элекке урыннарын бирмәскә азапланалар.* Г.Ибраһимов. *Һәрвакытта һәр халык ганганәсендә булганы шикелле, бу ганганәдә анахронизм вә ялганнар бар, аларны алып ташлаганнан соң, шактый мәгълүмат кала.* Г.Гобәйдуллин

2) Сүзне кешедән кешегә күчерүчеләр. *Иван Грозный исә, мөселман ханнарының хәлләрен, табигатьләрен яхшы белгәнлектән, Казан мәмләкәтенең бетүгә йөз тотуы башка ханнар карашында шәм сүнү кадәр дә әһәмияте юк икәнен ганганәсе илә аңлады ---.* Р.Фәхреддин

**ГА́НГЛИЙ** *и. гр.* Нерв төене, нейроннар һәм аларның үсентеләре җыелмасы. --- *ганглий күз бәбәген киңәйтә торган мускулларны да иннервацияли.* Кызыклы физиология

**ГАНГРЕ́НА** *и. гр. мед.* Кан йөреше бозылу нәтиҗәсендә, тукыманың, әгъзаның, тәннең бер өлеше үлү, черү күренеше. *Егетнең ике аягында да гангрена көчәеп бара иде, шуңа йөзебите һәм тәне көннән-көн эри, бетәшә.* Х.Камалов. – *Мин Шабай бездән качты, дәваланырга теләми, ә анда бик җитди ялкынсыну процессы бара, гангренага әверелүе бар, – диләр.* Р.Мостафин. *Минёрларның яраларын карыйсы иде. --- берсенең аягында гангрена башлану куркынычы бар.* З.Фәтхетдинов

**ГА́НГСТЕР** *и. ингл.* Элек АКШта, соңрак – гомумән ярымлегаль, ярымҗинаятьчел эшмәкәрлек алып баручы бандит шайкасы әгъзасы, ялланып үтерү, талау, янау һ.б.ш. шөгыльләнүче бандит. *Чит ил фильмнарында гангстер, үтерүчеләрне уйнаган артистлар кебек, Гөмбә сүзләрен хиссез, тойгысыз, әмма өздереп, мәгънәләрен урынына куеп әйтә.* Т.Галиуллин. *Әле ул вакытта Мәскәү тормышына бик төшенеп җитмәгән американ хәбәрчесе бу гангстерларның үз «һөнәрләрен» яшермәүләренә, хәтта шуның белән горурлануларына бик гаҗәпләнгән дә иде.* Р.Мирхәйдәров. *Америка киноиндустриясе гангстерлар турында вестерн төшерүдән баш тартмый.* Татарстан яшьләре

**ГА́НГСТЕРЛЫК** *и.* Гангстер булу

**ГАНДӘЛИБ** *и. гар. иск. кит.* Сандугач, былбыл. *Күрүбән гандәлибаны, тамаша әйләдем сәйран.* Г.Тукай

**ГАНДБОЛ** *и. ингл. спорт* Озынча күн тупны кулдан кулга күчереп, каршы як капкасына кертергә тырышудан гыйбарәт командалы спорт уены. *Людмила Шубина гандбол буенча СССР җыелма командасы составында алтын медальләр яулый.* А.Гафиятов

**ГАНДБОЛЧЫ** *и.* Гандбол белән шөгыльләнүче спортчы һәм гомумән гондбол уйнаучы кеше. *Бүген ТР Министрлар Кабинетында Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов Россия гандболчылар берлеге вице-президенты Андрей Лавров белән очрашты.* С.Семёркин. *Узган ел Казанның «Динамо» волейбол командасы һөҗүмчесе Леся Махно танылган гандболчы Е.Евдокимовка кияүгә чыккан иде.* Шәһри Казан

**ГАНҖӘ** *и. фар. к.* **гонҗә**. *Зөфәрнең дүрт ягында да, тирбәлә-тирбәлә, ганҗә гөлләр хуш ис тарата.* А.Гыйләҗев

**ГАНИ** *с. гар. иск.* **1**. Бай, мал-мөлкәтле, дәүләтле

**2**. *и. мәгъ.* Бай кеше, мал иясе. *Ганиләр вар, гарибләр вар җиһанда.* Г.Утыз-Имәни. *Салих задә болгарлар да чагыр эчкәй, Күп ганилар хәрам эшкә хирыс булгай* ---. Г.Чокрый. *Тугъды, көн тугар кеби, бер сахибе һиммәт гани* ---. Г.Тукай

**ГАНИД** *с. гар. иск.* Үзсүзле, сүзен бирмәс, кире, тыңлаусыз, үҗәт

**ГАНИМӘТ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Трофей, сугышта кулга төшерелгән дошман малы, улҗа. --- *Иван Грозныйның ганимәт буларак акча кулга төшерүе турында бер генә чыганакта да әйтелмәгән.* Р.Мостафин

2) Көч куймыйча табылган мал, табыш. --- *империализмның экономик һәм политик асылы кечкенә бер төркем эре монополияләрнең миллиардларча табыш алуларыннан, артта калган илләрнең йөз миллионнарча халкының «җилкәсендә баруларыннан» һәм ганимәтне бүлү өчен үзара көрәшүләреннән гыйбарәт.* Политэкономия

3) *күч.* Уңыш, бәхет

**2**. *с. мәгъ.* Трофей сыйфатындагы, трофей саналган

**ГАНИМӘ́Т МАЛ** *и. тар. к.* **ганимәт** (*1 мәгъ.*). *Казан шәһәренә ут төрткәннән соң, эченә керергә мөмкин иде, шул форсатны кулдан ычкындырдык, инде бу ганимәт маллары белән монда нишләп торабыз, ни өчен туры Мәскәүгә кайтып китмибез?* Р.Фәхреддин. *Көрәшмәк куркыныч: күп хәлләре бар, Вәли, җиңгәч, ганимәт маллары бар.* Г.Тукай. --- *сугышны феодаллар игълан иткән. Иң элек ганимәт мал табу өчен алып барылган ул.* Р.Мостафин

**ГАНКА** *и. гар. миф.* 1) Каф тавы артында яши дип саналган мифик кош. *Йомыркасы ганка йомыркасы кадәрле була, ди.* Г.Газиз

2) *күч.* Ахмак, аңгыра кеше. *Әллә ничә йирдән кунаклар адресына «Ганка!» дигән сүз йибәрелде.* Г.Исхакый. *Кәримовлар Шакирҗаны унбиш төрле хат таный, Бу дөньяда табалмассың аның төсле ганканы.* Ш.Хәлиди

**ГАНТЕЛЬ** *и нем.* Мускулларны ныгыту күнегүләре ясаганда куллана торган махсус гер, кыска тоткыч белән тоташкан ике шар формасында коеп ясалган гимнастик әсбап. *Аннан, гантельләр сатып алып, көн саен гимнастика ясый башларга кирәк.* М.Мәһдиев. --- *мондый сикерүнең булу ихтималын кире какмыйлар. Шуның өстенә борынгыларның гантель тотып сикерүендә үзенә күрә бер техник сер булуы да бик мөһим бит әле.* Кызыклар дөньясында

**ГАҢ** *иярт. к.* **гаң-гаң**

**ГАҢ-ГАҢ** *иярт.* Каз, аккош кебек зур кошларның көчле итеп кычкырган тавышын белдерә. *Барыннан да бигрәк кук ата каз шаулый: «гаң-гаң-гаң!» кылә.* М.Мәһдиев. *Тук казларның, утырган җиреннән генә түшен биетеп, борын эченнән генә гаң-гаң килеп гәпләшүләре...* М.Гали

**ГАҢГЫЛДА́У** *ф.* Каз, аккош кебек зур кошларның калын көчле тавыш белән кычкыруы, каңгылдау, гайгылдау. *Нәрсә ул сыер каз янында? Дүрт аяклы мәхлук ул. Сыер бит ул хәтта гаңгылдый да белми.* Т.Миңнуллин. *Әйтик, казның атасы да, анасы да бер үк төсле гаңгылдый. Ә үрдәкләр? Менә фантазиягә урын кайда!* М.Мәһдиев

**Гаңгылдап тору** Бертуктаусыз гаңгылдау

**Гаңгылдый башлау** Гаңгылдарга керешү

**ГАҢГЫЛДАШУ** *ф.* Бик күп кош берьюлы гаңгылдау, гайгылдашу. *Тегермән буасында, эри башлаган яшел боз өстендә, дәрт кергән ана казлар гаңгылдаша булыр...* И.Гази

**Гаңгылдаша башлау** Гаңгылдашырга керешү. *Ти-ти-ти, дип, тавыкларны чакырырга тотынган идем, казлар гаңгылдаша башлады, абзардагы дуңгыз мыркылдарга кереште, эт тә, өреп, аларга кушылды.* Т.Миңнуллин

**Гаңгылдашып тору** Бердән бик күп кош бертуктаусыз гаңгылдау

**ГАҢГЫЛДЫК** *с.* Гел гаңгылдап торган. *Гаңгылдык казлар*

**ГА́Ң ИТҮ** *ф.* Гаңгылдау, гайгылдау, каңгылдау. *Аккош китә гаң итеп, исәнләшеп моң итеп.* М.Укмаси. --- *һәр йомырка саен ала каз «гаң» итеп кычкырып куя.* Ф.Сафин

**ГАОЛЯН** *и. кыт.* Кытай, Корея, Япония һ.б. илләрдә игелә, бөртеге ярмага, онга, спиртка эшкәртелә торган берьеллык кыяклы бөртек һәм азык культурасы; соргоның бер төре. *Куе гаоляннар астыннан: «Беткән каның, Тамырларың шиңгән, Сизәм, Галим, синең хәлеңне!» – Үзенә дип алган ак бинт белән Ул күкрәген бәйли Галимнең.* Ф.Кәрим

**ГАП-** кис. «Г» авазына башланган кайбер сыйфатларга ялганып һәм басымны да үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә (мәс., *гап-гади, гап-гадәти*)

**ГАПЫЛДА́У** *ф.* Шапылдау, кинәт көчле тавыш чыгарып, җиргә яки идәнгә төшү, аву. --- *өстәлдән әйберләр, гапылдап, палубага коелалар.* М.Юныс

**ГАР** *и. гар.* 1) Тау тишеге, тау куышлыгы, мәгарә. *Хәзрәтләр, менә бит әле, пәйгамбәрләремез, Мәккәдән Мәдинәгә киткәндә, гар тишегенә кергән.* Г.Исхакый

2) *күч.* Нык таяныч, сыену, качу урыны. *Җөмләмез аңа хезмәт кылур улса, Ул безләрә каты гардыр, дирләр имди.* Кол Гали

**ГАРАЖ** *и. фр.* Автомобильләрне, мотоциклларны һ.б. төр техниканы саклау, төзәтү өчен махсус бина. *Гаражның ачык капкасыннан бер-бер артлы машиналар чыга.* И.Салахов. *Кучеп, әз генә яшәп калдылар, Искәндәрне милиционер җитәкләп китерде: «Гараж*

*йозагына ачкыч ярат ып, велосипед урлап чыкканнар!»* А.Гыйләҗев. *Алмас машинасын гараждан алып чыккан, пыяласындагы тузаннарын сөртеп тора иде.* Н.Әхмәдиев

**ГАРАИБ** *и. гар. иск.* Гаҗәп нәрсә, сәер, чит-ят күренеш. *Тик сөйли күргән кеше анда гараибләр күбен ---.* Г.Тукай. *[Чүпрә Сафа] Форсат барында Мәкәрҗәнең гаҗаибләрен, гараибләрен тамаша кылырга булды.* К.Тинчурин

**ГАРАНТ** *и. фр.* Гарантияләүче, гарантия бирүче зат. *Инде шул чагында ук конституцион ирекләр һәм гарантлар турында сөйләшкәндә, демагоглыкта шомарып-каешланып беткән ---.* Р.Мирхәйдәров. *Россия Федерациясенең Президенты [дәүләт башлыгы, Россия Конституциясенең, шәхес хокукларының һәм ирегенең гаранты] ---.* Политология

**ГАРА́НТИЯ** *и. фр.* 1) Берәр эшнең башкарылуын, булуын, яки, киресенчә, булдырылмавын тәэмин итү, ителәчәгенә ышандыру, шуларның җаваплылыгын үз өстенә алу. *Моңардан да зур гарантиянең булуы мөмкин түгел.* Ә.Еники. *Син тагы плен төшмәссең дигән гарантия кая, ә?* Х.Камалов. *--- ул сөйләшүләр башлап җибәрә: «Хиндуванны сугышсыз тапшырган очракта, Тимер морза нинди гарантияләр бирә?» – дип сорый.* С.Шәмси

2) Сатып алынган товарның яки төзәтелгән әйбернең сыйфатлы булуына, билгеле вакытка кадәр хезмәт итәчәгенә ышандыру; ватылу, бозылу очрагында, түләүсез төзәтеп бирүне үз өстенә алу. *Гарантия срогы чыкканчы, тизрәк заводына җибәреп калыйм дип тә уйлап бетергән идем.* Р.Төхфәтуллин. *Машинаның гарантиясе бетмәгән иде әле, гаеп заводта булса, бушка да төзәттереп була иде.* М.Маликова

**ГАРА́НТИЯЛӘНҮ** *ф.* Гарантиясе булу, тәэмин ителгән булу. *Фронтовиклар берәм-берәм ОРСлы җирләргә – конкрет акча түли торган, махсус кибеттә май, ипи, колбаса, чәй гарантияләнгән урыннарга киттеләр.* М.Мәһдиев

**ГАРА́НТИЯЛӘҮ** *ф.* Гарантия бирү, гарантия белән ныгыту, ышандыру, ышанычлы итү. *Бәлки, күбрәк тә түли алырбыз, ләкин безнең куркынычсызлыкны гарантияли алырсызмы?* Р.Мирхәйдәров. *--- заманыбызның иң төп мәсьәләсе булып, төрле милли территорияләрдә яшәүче халыклар мәнфәгатен гарантияли торган дәүләтләр булдыру тора.* Р.Хәкимов. *Ләкин сайлаулар гына инсаннарның хокукларын һәм ирекләрен тулаем гарантияли алмый.* Кеше һәм дин

**ГАРА́НТИЯЛЕ** *с.* Гарантияләнгән, тәэмин ителгән, ышанычлы. *Гарантияле чакыру килми торып, сезгә Казаннан чыкмаска кирәк иде.* Казан утлары. *Дәүләт --- бер өлешенең кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган аз керемле гражданнарны гарантияле минимум белән тәэмин итми кала алмый.* Мәдәни җомга

**ГАРАСАТ** *и. гар.* 1) *дини* Ахирәттә барлык халык кубарылып җыелачак мәйдан, соңгы хөкем урыны; шул хәл булачак көн. *Тагын кемнәрдер кыйнады ишегалдында, һәм гарасат көнендәге кебек шау-шу башланды, гауга купты.* Ф.Баттал

2) Көчле давыл. *Әстерханнан Каспий диңгезе буенча Бакуга юнәлгәндә, давыл куба. Диңгез дулкыннары гарасатына күнекмәгән әдипләребезнең күбесе үзләрен начар хис итәләр.* Ф.Галимуллин. *Көчле буран купты. Кышкы гарасат шашынып җенләнде.* С.Поварисов

3) *күч.* Зур, фаҗигале, куркыныч вакыйгалар. *--- «Йосыф китабы» татарның «кара сакалы» кебек булган: кайда барса да, аңар иярә барган – утянгыннарны бергә кичереп, восстание гарасатларын күргән, бәхет эзләп, яки сөрелеп, «Себер дә киткән».* М.Госман. *--- Миләүшә образы (Т.Миңнуллин пьесасы «Хушыгыз!») – бу гасыр гарасатларын кичергән һәр иҗат кешесенең язмышы ул. Үзәк өзгеч.* К.Тимбикова. *Мондый лыгырдавыкларны бер-ике ай фронт гарасатында газап чиктерәсе иде!* Т.Әйди

4) *күч.* Көчле тавыш, шау-шу, ыгы-зыгы. *Дөнья тетрәтеп, һавага зәңгәр боз кисәкләре оча, су баганасы күтәрелә, бу гарасатка сискәнеп, авыл өстеннән каргалар, чәүкәләр өере очып китә, сыерлар кычкыра.* М.Мәһдиев. *--- нәкъ шул вакытта пластмасса бүрек кигән Эдик, Рустик, Чуртик, тагын әллә кем, тыбырдатып, «Ява»сын кабыза һәм, --- гарасат куптарып, урамны бер әйләнә.* М.Мәһдиев

◊ **Гарасат мәйданы** 1) *дини* Ахырзаманда барлык кеше җаннарының Аллаһ хөкеменә җыелу мәйданы, соңгы хөкем урыны, мәхшәр мәйданы; 2) Шау-шулы, тавыш-гаугалы урын

**ГАРАСАТЛЫ** *с.* Төрле куркыныч, фаҗигале вакыйгаларга бай, борчулы, тетрәнүле. *Киләчәккә карасак, Бер дә сабак алмасак, --- Гарасатлы бу дөньядан Нәрсә генә калачак?* Ф.Яруллин. *Дүрт картина да кешелекне көткән гарасатлы вакыйгалар алдыннан, әмма әле Россиядә дә тыныч заманнарда --- иҗат ителгән.* Р.Мирхәйдәров

**ГАРӘБИ** *с. гар. иск.* Гарәп теленә караган, гарәп теленнән үтеп кергән

**ГАРӘБИЯТ** *и. гар. иск.* Гарәп теле һәм әдәбияты. *Береаздан соң, әнием яңа тормышка ияләшә төшкәч, Зәйнулла бабайдан Гайшә апа белән берлектә гарәбияттан дәрес ала башлый.* А.Расих

**ГАРӘП** *и.* 1) Көнбатыш Азиядә һәм Төньяк Африкада яшәгән алжир, мисыр, йәмән, ливан, сурия, фәләстин һ.б.ш. халыкларның гомуми атамасы. *Гарәпләр, хәбәшләр, әниләрнең котларын алган күгелҗем кара йөзле негрлар очрый.* А.Расих. *--- гарәп теле белгечләрен исәпләмәгәндә, минем кордашлардан кем генә бу борынгы язуларны ерып чыга алыр иде икән?* Р.Мостафин. *Мванза – Танзаниянең иң зур порты. Негрлардан тыш, монда гарәпләр һәм индуслар яши.* А.Муранов

2) Шушы халыклардан бер кеше. *Гарәпнең сөйләшендә Суфия сабый чактан таныш аһәңнәр тоя.* С.Сөләйманова

**ГАРӘ́П АТЫ** *и.* Ат токымнары арасында яхшы конституциясе һәм тизлек сыйфатлары белән аерылып торган йөгерек ат токымы

**ГАРӘ́П ГРАФИКАСЫ** *и.* Татарларда, ислам дине белән кереп, XX гасыр башына кадәр гамәлдә булган графика,

дөньяда иң киң таралган язу системаларыннан берсе

**ГАРӘ́П ХӘРЕФЛӘРЕ** *и.* Гарәп графикасына караган хәрефләр, язу ишарәләре. *Гарәп хәрефләре төшерелгән бәләкәй көмеш тәңкәләр дә күрсәткән.* Р.Мостафин

**ГАРӘ́П ЦИФРЛАРЫ** *и.* Күренекле гарәп математигы Мөхәммәд бин Муса әл-Харәзми (787–850) тарафыннан тәкъдим ителгән, Европага Урта гасырларда гарәпләр аркылы үтеп кергән һәм гомуми кулланылышта урнашкан цифрлар, сан тамгалары (мәс., 1, 2, 3). *Харәзми яңа цифрларны Һиндстанныкы дип күрсәтсә дә, тәрҗемәче, ялгышып, аларны «гарәп цифрлары» дип атый, һәм бу хата гасырлар буе дәвам итә.* А.Тимергалин. *«Гарәп цифрлары» дип йөртелгән билгеләр гарәпләргә Һиндстаннан килгән.* Кызыклар дөньясында

**ГАРӘ́ПЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Гарәп телендә; гарәп хәрефләре белән. --- *аның күршесендәге икенче бер кибетнең алдына гарәпчә «Болгар көне» дип язып куелган.* Г.Гобәйдуллин

2) Гарәпләр рәвешле, гарәпләргә хас булганча

**2.** *с. мәгъ.* Гарәп халкына, гарәп теленә мөнәсәбәтле. *Калкулыкларның башына ак ташлар куелып, аларга урак ай һәм гарәпчә сүзләр уелган иде.* М.Маликова

**3.** *и. мәгъ.* 1) Гарәп теле. *Ә инде гарәпчәне укыган кешеләр үз телләрендә язылган китапларны, ягъни үзләренең төркичәсен «су кебек эчәргә» тиешләр.* М.Госман. *Искиткеч тәрбияле, русчасы гаҗәп, гарәпчәсе, төрекчәсе бар...* М.Мәһдиев. *Дәреслекләр булмаганга күрә, мөгаллимнәр гарәпчәдән яки русчадан тәрҗемә итеп файдалана иделәр.* Казан утлары

2) Гарәп телендә язылган текст. --- *менә бу гарәпчәне татарчага аударырга кирәк иде, минем баш җитми, Галимҗан аны «ә» дигәнче эшләп бирәчәк, дигән.* С.Поварисов

**ГАРӘПЧЕ** *и.* 1) Гарәп телен, әдәбиятын, мәдәниятен өйрәнүче галим, шул өлкә белгече

2) *тар.* XX гасырның егерменче елларында татар телен латин графикасына күчерүгә каршы, гарәп графикасын яклап чыгучы

**ГАРӘПЧЕЛЕК** *и.* 1) XX гасырның егерменче елларында «татар теле гарәп графикасы нигезендә калырга тиеш» дигән караш, латин графикасын кабул итүгә каршы юнәлеш

2) Татар теленә гарәп теле йогынтысы, гарәп элементлары. *Ул татар телен кирәкмәгән гарәпчелектән һәм фарсычылыктан чистартты, әдәбиятта татар теленең гражданлык хокукын ныгытты ---.* М.Токтамышев. *Революция, безнең мәктәпләрдән гарәп телен чыгарып, бездәге гарәпчелекнең чыганагын корытты*. Җ.Вәлиди

**ГАРӘ́П ШРИФТЫ** *и. к.* **гарәп графикасы**

**ГАРӘ́П ЯЗУЫ** *и. к.* **гарәп графикасы**

**ГАРӘФӘ** *и. гар. дини* Гает алды көне; бәйрәм алды көне. *Татар-мөселман баласы, хәзер гарәфә, кадер кичләрендә, әнисенең чабуына тотынып, мулла абзыйларга китап ишетергә, вәгазь тыңларга бара алмый.* Г.Исхакый. *Гарәфә киче иде бу, кичтән гаеткә барырга ниятләнеп яткан Сөләйманның иртән, нигәдер, зиратка аягы тартмады.* А.Гыйләҗев

**ГАРБ** *и. гар. иск. к.* **гареп**. *Айрган Шәрекъ вә Гарбкә кыйтгаларны, Кавыштырган үз өстендә аларны.* Дәрдемәнд

**ГАРБИ** *с. гар. иск.* **1.** Көнбатышка караган, Көнбатышка бәйле, Көнбатыштагы. --- *Дарданелл вә Босфор, Кырым ханлыгы вә Кавказның гарби җирләре Төркия кул астында булганлыктан, Кара диңгез аның күле мисләндә булып калды.* Г.Гобәйдуллин

**2.** *и. мәгъ.* Көнбатыш кешесе. *Ул адәм: «Син читтән килгән гарбиме әллә?» – диде.* Дастан

**ГАРГАРӘ** *и. гар. иск.* Җан биргәндә, бугаздан гырылдап чыккан тавыш, гыжылдау, соңгы сулыш; үлем алды. *Ни булса булды, шуннан соң гаргарә хәлендәге күгә дә, шәһәребезнең үткәненә дә, күптән таныш легендалар һәм риваятьләргә дә бүтән күз белән карый башладым.* Р.Мостафин

**ГАРДЕМАРИН** *и. фр. тар.* Революциягә кадәр Россиядә диңгез кадет корпусының югары сыйныф укучысы; 1860–1882 елларда рус флотында түбән бер чин. *Моны, чәчрәп чыгып, гардемарин Юсупов әйтте.* И.Низамов. *Исеңдәме, гардемарин, бер мәртәбә, синең хисаплавың буенча, пароход Краснодар шәһәре янында булырга тиеш иде.* М.Юныс

**ГАРДЕ́НИЯ** *и. лат. бот.* Мареначалар семьялыгына караган, ак яки сары чәчәк ата торган мәңге яшел куак үсемлекләр ыруы. *Людмила, бармакларын бөгеп, гөл исемнәрен атый: кроссандра, азалия, баухиния, монстера, бровалия, гардения...* Яңа тормыш. *Лимон, гардения, ясмин тирә-юньне ямьләндереп, һаваны сафландырып кына калмыйча, безгә көч-энергия дә бирә, иммунитетны да ныгыта*. Ватаным Татарстан

**ГАРДЕРОБ** *и. фр.* 1) Кием шкафы. *Эш киемнәре элә торган стена гардеробы да игътибардан читтә калмады...* Ф.Баттал. *Берүзенә өч бүлмә, кухнясы, гардеробы, кладовкасы бар.* Г.Нәбиуллин. *Яруллам миңа җылы мамык шәл бүләк иткән иде. Чоланда гардеробта эленеп тора ул.* Х.Ибраһим

2) Җәмәгать урыннарында өске киемне салып калдыру өчен махсус бүлмә. *Кинәт ул, корт чаккандай, утырган җиреннән капылт кына купты да, гардеробка барып, плащын, эшләпәсен алды.* Э.Касыймов. *Гардеробка таба атлаганда, үзе ирексездән Хәлимә турында уйлады.* Т.Әйди. *Карлен уңайсызланып кына гардеробка таба атлады.* Р.Мирхәйдәров

3) Бер кешенең барлык киемнәре. *Алай да кыйммәтле кием-салым артыннан кибетләргә чыгып йөгерергә ашыкмагыз әле, гардеробыгызны җентекләп тикшереп чыгыгыз.* И.Иксанова. *Миңа яшьтән үк кара төс килешә, гардеробымның 80% ын кара кием тәшкил итә.* Сөембикә

4) *театр.* Сәхнә киемнәре, костюмнар җыелмасы

**ГАРДЕРОБЧЫ** *и.* Гардеробта (*2 мәгъ.*) эшләүче. *Гардеробчы юан хатын алпан-тилпән килеп җитте дә*

*Мәрьямнең пальтосын аңа тоттырды: – Егеткәй, туташка киенергә ярдәм итегез!* М.Маликова. *«Лидо»да вахтёр һәм гардеробчы булып, сезнең ике саллы егетегез дежурда булсыннар* ---. Р.Мирхәйдәров

**ГАРДИН** *и.* 1) *к.* **гардина**. *Гардины да яңа иде бит... Эре чәчәкле тюль сайлаганда, --- иптәш Сәйдәшев бер-бер хатын-кыз белән киңәшмичә калмагандыр.* А.Тимергалин

2) *сөйл.* Тәрәзә пәрдәсе эленә торган махсус таяк. *Аның башына чорналган пәрдә гардины-ние белән дөбер-шатыр кубарылды да аска ишелде*. Н.Гамбәр

**ГАРДИ́НА** *и. нем.* Тәрәзәне тулысынча каплый торган зур пәрдә. *Тыгыз гардиналар яктылыкны үткәрми*

**ГАРЕБ** *и. гар. иск. к.* **гареп**. --- *бездән гаребтә булган җирләрдә яңа зур патшалыклар үсеп киләләр; боларны без «сакляб» яисә «рус» дибез.* Г.Гобәйдуллин

**ГАРЕБЧЕ** *и. иск.* Көнбатышчы, иҗтимагый үсештә Көнбатыш юлын якын күрүче, шул юлны сайлау ягында торучы кеше. *Мәрҗани хәзрәтләренең матбуг әсәрләрендә никадәр шәрыклык --- күренеп торса, шул ук кадәр, күрыкмыйча, шиддәтле рәвештә аның «гаребче» икәнен дә күрсәтә торган урыннары бар ---.* Г.Гобәйдуллин

**ГАРЕМ** *и. гар.* 1) Күпхатынлылык булган мөселман халыкларында хатыннар ягы, хатыннар бүлмәсе, бинасы; хәрәм. --- *галиҗәнап әмир мунчасына кергәч, стенадан чыгып торган арыслан авызларыннан агып торган су челтерәвен, гарем ягыннан кәс-кәс атлап кереп килүче берсеннән берсе назлы кызларның толымын сүткәндә ишелеп төшкән чәч шарлавыгы тавышын ишетерсең сыман.* М.Галиев

2) Бер ирнең барлык хатыннары; җарияләре. – Әй, *татар малай, синең гаремың бар идеме? – дип сорады кыз.* М.Әмирханов. *Ела, җир тырна, Император, хурлык баганасына сине; инде кәпрәймәссең, гарем тотам, әнә кәнизәкләрем бухгалтерия тулы дип шапырынмассың.* Р.Камалов

**ГАРЕП** *и. гар. иск.* Көнбатыш; көнбатыш ягы. --- *байның үз бүлмәсе шәрекъ белән гареп стилен буташтырып, стеналары келәмнәр белән капланган.* Ш.Усманов. *Телне гарәп һәм гареп тәэсиреннән бөтенләй коткарып, саф төрекчә язу фикерен алга сөрүче бер груһ бар ---.* Җ.Вәлиди. *Бактың исә шәрекъ әдәбияты (бигрәк тә шигърият) белән чагыштырсаң, гареп әдәбияты бала гына.* Т.Миңнуллин

**ГАРЕШ** *и. гар. дини* 1) Күк түбәсе, күкнең иң югары, Аллаһ тәхете урнашкан каты. *Шәһәр халкы – олысы-кечесе – шатлык тавышларын гарештән югары җибәрделәр.* Дастан. *Аңар күрә үземне бик түбән саныйм, Аның урны фәләкләрдә, гарештә, дим.* Г.Тукай. *Җан-күңелем гарешләргә ашып, Бәхет яшем күктән түгелде.* Р.Мөхияр

◊ **Гарше әгъзам** *к.* **гарше әгъля**. --- *Җәгъфәр аһ итә, аның белән бергә татар баласының аһлары да гарше әгъзамга күтәрелә.* Ф.Әмирхан. **Гарше әгъля** 1) Күкнең иң югары катлавы; 2) Биеклек, югарылык. **Гарше көрси** Күк тәхете. *Масайма син, Тәңрем, кодрәтеңә, Тартып алып нибар бәхтемне, Килер бер көн, ватар, көл итәрмен Гарше көрсең, сәмаң тәхтеңне.* С.Рәмиев

**ГАРЗ** I *и. гар. иск. к.* **гарыз**. *Бер дин уларак гарз итдеңез һәр искелекләрне ---.* Г.Тукай

**ГАРЗ** II *и. гар. иск.* Теләк, үтенеч, ялыну; арзу. *Ихтыяҗын гарз итеп килсә теләнче капкаңа, Каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама.* Г.Тукай

**ГАРИ** *с. гар. иск.* 1) Ялангач, шәрә

2) Ачык, каплаусыз

3) Үсемлексез, үсемлек үсми торган

4) Буш, җиһазсыз

5) Саф, чын, өстәмәсез, кушымтасыз. *Тугъры юлны тапты бу, тәфикъ имеш, ярый дисәм, – Лотфе хактан пакь икән, гари икәнсең син һәнүз!* Г.Тукай

6) Нәрсәдән дә булса коткарылган, азат ителгән

**ГАРИБ** I *с. гар. иск. к.* **гарип** I

**ГАРИБ** II *и. гар. иск. к.* **гарип** II. *Кәрдән Кешан: «Дөрест, читтән килгән бер гарибмен, һичкемне белмимен», – диде.* Дастан. *Гарибләр, шәмчырак күргәндә юлда, Дисеннәр: бер заман бар булган ул да...* Дәрдемәнд. *Җан тынычланды димә, булганга малда артыгың, Артык ул алганга намәгъмүм гарибләр актыгын.* Г.Тукай

**ГАРИБ** III *с. гар. иск. к.* **гарип** III. *Гариб моң бар өнендә җил-җиләснең, туган илләрдән искән җил димәссең.* Дәрдемәнд

**ГАРИБЕДДИЯР** *и. гар.* Эмигрант, үз иленнән аерылып, чит илдә яшәүче. *Ят җирләрдә гарибеддияр булып сәфәрдә йөргән кемсәнәләр.* К.Насыйри

**ГАРИЗА** *и. гар.* Язма формадагы үтенеч, нәрсә дә булса сорап язылган кәгазь, документ. *Ял бирүләрен сорап, гариза яздым да баш врачка кердем.* Ф.Яруллин. *Чапбаев кичә теге лейтенантка, алгы сызыкка җибәрүләрен сорап, гариза биргән икән.* Х.Камалов. *Гаризам игътибардан читтә калыр дип уйламыйм, җавап бирерсез дигән ышанычта калам.* Ф.Сафин

**ГАРИЗИ** *с. гар. иск.* Табигый, тумыштан килгән, инстинкт белән бәйле. *Гаризи акыл – гадәти кешеләр акылыдыр, алар эчәрен, утка янарын, суда батарын белер ---.* Гыйбрәтле хикәятләр

**ГАРИЗЫЙ** *с. гар. иск.* Очраклы. *Ләкин бу хәл – вакытлы гына килгән бер авыру кебек гаризый бер хәлдер.* Г.Тукай

**ГАРИП** I *с. гар.* **1.** 1) Зәгыйфь, физик житешсезлеге булган, берәр җире имгәнгән. *Галиәхмәт абзый, гарип иңбашы белән сул яккарак янтайган көе, саргылт мыекларын салындырып, тирләп-пешеп, түрдә өстәл янында аш ашап утыра.* Н.Фәттах

2) Көчсез, хәлсез. *Алла бар ул! Тик нигә соң кызгану юк аз гына? – Гарип колын хөкем иткән Мәхәббәт җәзасына ---.* Р.Акъегет

3) *күч.* Кимчелекле, төзек булмаган. *Такы-токы, гарип юллар Бары Рәсәйдә генә. «Евростандарт»ка керәләр Бары тик җәйгә генә.* Л.Шәех

**2.** *и. мәгъ.* Физик җитешсезлеге булган кеше, инвалид. *Янымнан, гарип инде бу бичара дигән сыман, кызганулы караш ташлап үтәләр.* М.Галиев. *Шул ялган тәрбия астында үскән балалар-*

*дан киләчәктә рухи гарипләр, буп-буш новаторлар, отчёт коллары чыкмавына кая гарантия?!* В.Имамов

**ГАРИП** II *и. гар. иск.* **1.** 1) Туган иленнән аерылып, читтә яшәүче, читтән килгән кеше, юлчы, мосафир

2) Ярлы, хәерче кеше, йортсыз-җирсез кеше. *Акча гарипкә тансык, ди. Минем бит үземнеке дә артып ашкан...* М.Хәсәнов

3) Мескен, бичара, кызганыч хәлдәге кеше. *Һәркемне иркәләүчеләр табылган кебек, сакал-мыеклар үсә башлагач, без гарипне дә баштан сыйпаучылар табылды.* Һ.Такташ

**2.** *с. мәгъ.* 1) Читтә йөрүче, мосафир. *Минем укып йөрүче шәкерт, гарип бер мосафир икәнемә тәмам ышандылар.* М.Гафури

2) Ярлы, хәерче

3) Мескен, бичара

**ГАРИП** III *с. гар. иск.* 1) Ят, чит, таныш булмаган. *Бу пәрдәдә Габдулланың Мөгаллимәгә каршы сөйләгән җөмләләре арасында безнең өчен шактый гарип ифадә вә кәлимәләр бар.* Г.Кәрам

2) Ят күренгән, сәер, гаҗәеп, серле. *Күктә яшен яшьни. Караңгылык җир йөзен чолгап ала. Шул гарип хәлдән куркып, Каһтаран Каһарман Катилне онытып, сарайга кереп һушсыз була ---.* Дастан. *Бөтен сахра гарип төсләр аладыр, Болыт төсле ала булып каладыр.* Г.Тукай

**ГАРИП-ГОРАБА** *җый. и. гар.* Гарипләр, гарип кешеләр. *Авыл читендәге, калку урындагы урман сыман зыяратта гарип-гораба, хәлсез ирләр, картлар кабер казып куйганнар иде.* Н.Фәттах. *Гарип-горабаны рәнҗетмәде, авызыннан өзеп, мохтаҗларга өлеш чыгарып яшәде.* Ф.Латыйфи. *Сугышка алынмаган гарип-гораба, тилемсәләр дә җитәрлек.* Р.Батулла

**ГАРИПЛӘНДЕРҮ** *ф.* Имгәтү, зәгыйфьләндерү, гарип калдыру. *Берәрсен гарипләндерә күрмә берүк, Рөстәм!* Ф.Яхин. *Әле кичә генә безнең белән бер фиркадә, бер кыйблага табынган фиркадәшләр бүген --- вәхшиләрчә изәргә, гарипләндерергә тотындылар ---.* И.Салахов

**Гарипләндереп бетерү** Тәмам гарип хәлгә китерү; барысын да гарип калдыру. *Газиз телем, без сине имгәтеп, гарипләндереп бетердек түгелме?* Р.Миңнуллин

**Гарипләндереп кую** Кинәт гарипләндерү; гарипләнгән хәлгә китерү

**Гарипләндереп ташлау** Бөтенләй, тәмам гарипләндерү. *--- башка җырчылар кебек, көйнең дөрес агылышын саклыйм дип, сүзләрне тегеләй дә, болай да гарипләндереп ташламый.* Г.Бәширов

**ГАРИПЛӘНҮ** *ф.* Зәгыйфьләнү, гарип булып калу, имгәнгән килеш калу. *Абзар ияләрен дә, мунча ияләрен дә кеше күрергә тиеш түгел. Кеше күзенә күренгән ия дә, ияне күргән кеше дә гарипләнә.* Р.Батулла. *Әнә җизнәң әйтә: кулны кисмәсәләр, гарипләнеп булса да төзәлә иде, ди.* Х.Камалов. *Сазлыклы урыннардагы боланнар һәм кыр кәҗәләре начар үсәләр, һәм аларның мөгезләре дә гарипләнгән төсле бөгелеп-сыгылып беткән.* Кызыклар дөньясында

**Гарипләнә бару** Торган саен ныграк гарипләнү

**Гарипләнә төшү** Бераз гарипләнү

**Гарипләнеп бетү** 1) Барысы да гарипләнү. *--- утызлап кеше бер-берсенең өстенә авып, машина астында гарипләнеп беткән булырлар иде.* Г.Ахунов

2) Тәмам, бик нык гарипләнү. *Бу көнләшеп тора инде, димә, Әрнеп торам, эчтән сызланып. Егермедә гарипләнеп беткән Йөрәгеңне күреп, кызганып.* Г.Ибушев

**Гарипләнеп калу** Авыру, авыр эш, яралану һ.б.ш. нәтиҗәсендә бөтенләйгә гарип хәлдә калу. *Берәр җире гарипләнеп калмаса гына ярый инде.* В.Нуруллин

**ГАРИПЛӘТҮ** *ф. к.* **гарипләндерү**. *Болай итеп куркытып укыту баланың аңын гарипләтмәсме, иманын качырмасмы?* А.Хәлим

**ГАРИПЛӘ́Ү** *ф.* Имгәтү, гарип калдыру, зәгыйфьләндерү. *Башка берәүне гарипләсәләр, җинаятьчене, тотып, төрмәгә утыртырлар иде. Ә монда бөтен газабы Тәслимәгә...* М.Маликова. *Битарафлыкның һәм рухи ярлылыкның зәгыйфь җимеше --- аның да вөҗданы өстендә оя кора бит. Алай гына да түгел, кешеләрдәге матурлыкка омтылуны, горурлыкны гарипли, изә, юкка чыгара.* А.Вергазов

**ГАРИПЛЕК** *и.* 1) Зәгыйфьлек, физик җитешсезлеге булу. *--- берәүләре гарипелеге аркасында бүтән эшкә ярамаган, икенчеләре исә хәер сорашуны үзләренә кәсеп итеп тә алганнар.* Ә.Еники. *Гомере буе гариплегенә рәнҗеп, язмышын каһәрләп яшәгән бу кешегә, йөрәге түзсен өчен, кан тамырларын шулай юан ясаганмы Ходай хәзрәтләре?* А.Гыйләҗев. *Гаҗәп бу ир-ат халкы: матур хатын-кыз өчен үләр, гарип калса да, гүзәлгә үрелә. Гариплекләрен уйламыйлар.* Х.Камалов

2) *күч.* Көчсезлек, сәләтсезлек, тиешле функцияләрен үти алмау. *А.М.Горький сәнгатьнең сатира һәм юмор жанры турында, социаль бозыклыкларның кулай сатирик формада җирәнгеч һәм көлке гариплектә күрсәтелергә тиешлеге турында әйтә.* Х.Ярми. *СССРның таркалуы нәкъ менә милли сәясәтнең гариплегеннән килеп чыкты.* Т.Миңнуллин. *Икейөзлелек, кода-кодагыйлык, рухи гариплекнең чынбарлык икәнлеген күрә торып та дәшмәдек, нидер көттек.* Р.Мөхәммәдиев

3) Кимчелек, җитешсезлек. *Шигырьләрдә байтак гариплекләр, ямьсез тәгъбирләр вә тәшбиһләр вә шаянлыклар очрый ки, бу язучысының файдасына хезмәт итми.* С.Сүнчәләй

**ГАРИФ** *и. гар. иск. кит.* Белүче, аңлаучы, акыл иясе

**ГАРИЯТ** *и. гар. иск.* Бурыч, әҗәт. *Синнән бер генә гарияте сораса, пигамбәргә дә син бер инә бирмәссең, диде.* К.Насыйри

**ГА́РК БУЛУ** *ф. иск. к.* **гарык булу**

**ГА́РК ИТҮ** *ф. иск.* Батыру. *Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гарк итмәде.* Г.Тукай

**ГА́РК КЫЛУ** *ф. иск. к.* **гарк итү**. *Тырыштырып гарк кылдым кызыл канга.* М.Гафури

**ГАРМОН** *и. к.* **гармун**. *Гармонының тартып уйна, Җиңел булсын җырларга.* Ш.Маннур

**ГАРМО́НИК** *с. гр.* **1.** Гармониягә нигезләнгән, гармония саклаган, матур, гармонияле, һәрьяктан килгән. *Сәламәтлек китү, картаю әнә шул гармоник берлекнең бозылуы, бер механизмның какшавы ул, гадиләштереп әйткәндә.* Г.Хөсәенов. *Алар да – инкыйлабый омтылышлар белән янган авторның идеалы. Ләкин шулай да аларны «гармоник кеше» дип әйтәсе килми.* Ф.Галимуллин. *Шарчыкның тигезләнеш торышы аша узгандагы тизлеген шулай ук механика тигезләмәләреннән табып, гармоник тирбәнеш формулалары биргән тизлек белән чагыштырып карарга.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

**2.** *рәв. мәгъ.* Гармония нигезендә, гармонияле рәвештә. *Эстетик зәвыклары үскән, сәнгатьнең төрле өлкәләреннән хәбәрдар, гармоник үскән шәхес, чын интернационалистлар тәрбияләүдә, китапның әһәмиятенә инанган белгечләр әзерләүдә --- махсус курслар нык ярдәм итә.* Казан утлары

**ГАРМО́НИЯ** *и. гр.* 1) Бербөтен нәрсәнең өлешләре үзара ярашу, туры килү; гомумән, үзара ярашлы, ятышлы, ямьле булу сыйфаты. *Ул чынбарлыктагы ямьсезлекләрне, кеше шәхесен кимсетүләрне иҗатында артык «күрмәмешкә салышты», аларны матурлык гармониясенә төреп бирергә тырышты.* Ф.Галимуллин. *Аның йөзенә нindидер сәер елмаю җәелде, күзләре, ничектер, йөз гармониясенә кушылмыйча, күз кабакларына буйсынырга теләмичә, тәннән аерылырга хокук дәгъвалаган кебек, каядыр еракка төбәлделәр.* Р.Вәлиев. *Аксак-туксак сүзләр тезмәсен озак укып булмый. Ул күңелгә дә, акылга да берни бирми, киресенчә, ачуны чыгарып, барлы-юклы гармонияңне генә җимерергә мөмкин.* Л.Шагыйрьҗан

2) Архитектурада һәм рәсем сәнгатендә сәнгать әсәренең барлык элементлары үзара килешеп, йогышып, бербөтен хасил итү

3) Музыка теориясенең аккордлар төзелешен һәм музыкаль процесста аларның үзара бәйләнешен өйрәнә торган тармагы. *Хәбир, мелодик сәләте булуга карамастан, форма белән логиканы тоймый, гармониядән аксый, контрапунктны аңламый.* Ш.Хөсәенов. *Минһаҗев дигән композиторны хәтерлисеңме? Бездә гармонияне укытып йөргән иде.* Р.Вәлиев

4) Музыкада берничә аһәңдәш тонның бердән яңгыравы. *– Мин [В.И.Виноградов, маршны] оркестрга салырмын, тик гармониясен төзәтми кала алмыйм, – дип, рояль яныннан кузгалды.* Җ.Фәйзи. *--- музыка өчен такт һәм гармониягә буйсыну ничек лазем булса, шигырь язучыга да вәзен һәм аһәңгә игътибар итү шулай ук тиеш.* Г.Рәхим

5) *лингв.* Авазларның үзара ярашып, бертөрлерәк, охшашрак яңгыравы. *Футуристлар әсәрләренең тышкы күренешләренә, төзелеш формасына, авазлар чиратлашуына, бигрәк тә тартык авазлар гармониясенә – аллитерациягә зур игътибар бирделәр.* Ф.Галимуллин. *Ирен гармониясе. Сузыклар гармониясе*

6) Бердәмлек, фикердәшлек, татулык. *Кешелек тулы Гармониягә ирешкәч кенә, чын Бәхеткә тап булачак.* Р.Сибат. *Җиргә без һәрберебез бурычлы. Менә кеше шул бурычны түләргә өйрәнгәч, Җирдә гармония булачак.* Р.Вәлиев. *--- без шатлык һәм кайгылар, бурыч һәм теләүләрдән торган җан гармониясен, --- рух һәм рухсызлык, яшәү һәм үлем гармониясен җуйдык.* Мирас

**ГАРМО́НИЯЛӘШТЕРҮ** *ф. муз.* 1) Көйне гармония кагыйдәләре нигезендә төзү, шул кагыйдәләргә туры китерү

2) Аерым бер көй нигезендә музыкаль әсәр тудыру, шул көйне камилләштерү. *--- 1936 елда мин бу җырны гармонияләштереп, Мәрьям Рахманкуловага биргән идем.* Җ.Фәйзи

**ГАРМО́НИЯЛӘШҮ** *ф.* Гармоник хәлгә килү, үзара ярашу, туры килү, гармония хасил итү

**ГАРМО́НИЯЛЕ** *с.* 1) Аһәңле, матур яңгырашлы. *Рөстәм Яхинның музыкасы төсмерләргә бай, һәр очракта да гармонияле, тигез агышлы, җанга кагыла торган.* Г.Ахунов

2) Һәрьяктан үзара ярашкан, гармониягә нигезләнгән, гармония, матурлык күренеп торган. *--- аларның [киләчәк буыннарның] гармонияле үсешен тәэмин итү турында һәрчак кайгыртып тору кирәк.* Р.Низами. *Аның [Р.Гаташның] лирик герое гүзәллеккә, гаделлеккә соклана, гармонияле тереклек тантанасы өчен җаната.* Х.Миңнегулов

**ГАРМО́НИЯЛЕЛЕК** *и.* Гармония таләпләренә туры килү, гармонияле булу, камиллек. *Кеше тормышының мәгънәсе һәм бәхете, идеалы һәм ихтыяҗы, матурлык һәм гармониялелек, иҗади хезмәт һәм ял төшенчәләре арасында сәламәтлек аерым урын алып торырга тиеш бит югыйсә.* Сәламәтлек нигезләре

**ГАРМО́НИЯСЕЗ** *с.* Гармониясе булмаган яки гармониясе бозылган. *Ләкин гармониясез мохиттә, җәмгыятьтә аерым бер кешенең тулысынча ачылып бетүе һәм тулы гармониягә ирешүе мөмкин түгел...* Р.Батулла

**ГАРМО́НИЯСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Гармониясе бозылу, гармониясен югалту

**Гармониясезләнә башлау** Гармониясезлек барлыкка килү

**Гармониясезләнеп бетү** Тәмам гармониясезгә әйләнү

**Гармониясезләнеп китү** Сизелерлек дәрәҗәдә гармониясезләнү

**ГАРМО́НИЯСЕЗЛЕК** *и.* Гармония булмау яки гармония җитмәү күренеше. *Элек тә, хәзер дә милләтебез җаны гармониясезлек халәтендә кала бирә.* Р.Сафин. *Югарыда күрсәтелгән сфераларның берсендә генә психологик үсеш тиешенчә булмаса да, мондый хәл «гармониясезлек»кә һәм уку эшенең киргәгеннән артык күбәюенә китерә.* М.Мәхмүтов

**ГАРМОНЧЫ** *и. к.* **гармунчы**. *Әй, гармончы, уйна гармоныңны, Биючеләр, якын килегез!* Ә.Ерикәй. *Бер гармончы лабаса, ә бит төрле йөрәкләрдә Төрле телләргә баса.* Р.Юныс

**ГАРМОНЬ** *и. нем.* < *гр. к.* **гармун**. *Ярты төн җитәрәк, капка төбендә генә булса кирәк, гармонь тавышы ишетелде.* Г.Бәширов. *Житмәсә шунда, ачу китереп, гармонь уйнарга, биергә тотындылар.* М.Әмир

**ГАРМОНЬЛЫ** *с. к.* **гармунлы**

**ГАРМОНЬЧЫ** *и. к.* **гармунчы.** *Гармоньчы дус, гармоньчы дус, Гармоньчы дус, кил әле.* Ш.Маннур. *Сез?! Сез шушы гармоньчы егетме?* Г.Әпсәләмов. *Автомашина якынайгач, алар юл буена киләләр, һәм гармоньчы туш уйнап җибәрә.* Дөньяда ниләр бар

**ГАРМУН** *и.* **1.** Күреге, ике якта клавиатурасы булган, тартып уйнала торган тынлы уен коралы. *Әйдә, гармун илә скрипканы парлап уйнагыз әле, без сугыш бәетен әйтәбез...* Ш.Мөхәммәдев. *Гармуннар уйнатып, утлар балкытып, егетләр, кызлар көймәләрдә төннәрен күңел ачалар иде.* Р.Мостафин. *Кинәт урамнан, тоник кына булып, гармун тавышы ишетелә.* А.Расих

**2**. *с. мәгъ. сөйл.* Гармонь күрегенә охшаган, еш сырлы итеп эшләнгән. *[Сафуан абзыйның] Гармун кунычлы хром итеге баскан саен шыгырдап китә.* М.Галиев

◊ **Гармунсыз биетү** Үзенекен итү, үзенчә эшләргә мәҗбүр итү, буйсындыру. *Әнә күршедәге Сарбаевның килене дә чибәр, кычыткан чыпчыгы кадәр генә. Шулай да ирен дә, кайнатасы белән кайнанасын да гармунсыз биетә.* Ж.Рәхимов

**ГАРМУНЛАНДЫРУ** *ф.* Җыерчыкландыру, формасын гармун күрегенә охшатып кую. *Аның өстендә үзе тегеп кигән өр-яңа җилән, башында фетр эшләпә, аякларында кунычлары гармунландырып сыдырылган читекләр.* Т.Мөбарәков

**ГАРМУНЛАНУ** *ф.* Гармун күрегенә охшаган сырлар төшү, нык бөгәрләнү. *Пәлтәсе, иңнәрен сытып, аска салынган, чалбар балаклары гармунланган...* А.Гыйләҗев

**Гармунланып бетү** Тәмам гармунлану

**Гармунланып тору** Гармунланган хәлдә булу. *Шул вакыт башына чигүле түбәтәй, аягына кунычлары гармунланып торган читекләр, өстенә бәрхет камзул белән киң чалбар киеп алган (әле баягынак кына татар халык биюен башкаручы) егет, сәхнәгә чыгып, Вәлидәгә бер бәйләм чәчәк тоттырды.* М.Хәсәнов

**ГАРМУНЛА́У** *ф.* Гармунга охшату, күрек формасына китерү. --- *вәкил --- тузан сарган күн итекләренең кунычын гармунлап аска төшерде дә шыгыр-шыгыр басып китте.* А.Гыйләҗев

**Гармунлап кую** Гармун күрегенә охшатып калдыру

**ГАРМУНЛЫ** *с.* 1) Гармуны булган. *Гармунлы абзый утыру белән тальянын тартып җибәрде, ә иптәше, кыңгыравын чылтыратып, аңа кушылды.* Татарстан яшьләре

2) Гармун көе белән бергә башкарылган; гармун уйналган. *Гармунлы, җырлы романтик авыл ул китапларда гына калды.* Татарстан яшьләре

**ГАРМУНЛЫК** *с.* Гармун ясарга яки гармун сатып алырга дип билгеләнгән, шуңа җитәрлек. *Шуннан соң ул, трактирларда биеп, гармунлык акча җыя башлый һәм, ниһаять, гармунлы була*. Р.Батулла

**ГАРМУНЧЫ** *и.* 1) Гармунда уйнау остасы. *Гармунчы, сыздырып, бию көе уйнап җибәрде.* М.Галәү. *Гармунчының кулы кулга йокмый, дәртле гармун телләренә йөгерек баса.* И.Ихсанов. *Бәлки әле, без Халисә белән озак биегән булыр идек, ләкин гармунчы шып итеп гармунын туктатты.* Ф.Яруллин

2) Гармуннар ясаучы, гармуннар ясау белән шөгыльләнүче оста. *Монда танылган сәгатьчеләр, танылган гармунчылар, драп, бостон, габардин белгечләре, велосипед, фотоаппарат осталары бар.* М.Мәһдиев

**ГАРМУНЧЫЛЫК** *и.* 1) Гармун уйнау осталыгы, гармунчы булу. *Һәм шушы хыял минем гармунчылыгымны икенче планга күчерде.* Р.Вәлиев

2) Гармун ясау эше, гармун ясау осталыгы

**ГАРНИЗОН** *и. фр.* 1) Торак пунктта яки аннан тышта даими яки вакытлыча урнашкан хәрби частьләр, учреждениеләр һ.б.ш. --- *Казан гарнизонында күтәрелгән бунт кан коюсыз, югалтусыз гына бастырыла, көйгә салына.* Р.Мөхәммәдиев. *Кировокан шәһәренә урнашкан хәрби гарнизон судына гариза кертеп бирдем.* Ф.Яруллин. – *Син монда, – диде аңа участковый Нәбиуллин, – гарнизон начальнигы. Смотри, бөтенесе өчен башың белән җавап бирәсең ---.* М.Мәһдиев

2) Оборона корылмасында (крепость һ.б.ш.) урнашкан хәрби частьлар. *Кечкенә генә бер гарнизон сугышчылары шул борынгы Орешекны, дошманга бирмичә, дүрт йөз туксан сигез көн саклап тордылар.* А.Муранов. *Империянең чикләрен саклар өчен, Юстиниан крепостьлар кора, аларга гарнизоннар урнаштыра, чикләргә юллар сала.* Урта гасырлар тарихы

**ГАРНИР** *и. фр.* Ит яки балык ризыклары янына өстәп бирелә торган яшелчә, макарон, ботка һ.б.ш. *Синең авызыңны күргәч, алган гарнирым да, куркудан, кашыкка сыланып, кире төшә.* Н.Әхмәдиев. *Котлет янына гарнир итеп, пешерелгән яисә кыздырылган бәрәңге яки бәрәңге боламыгы --- бирергә мөмкин.* Йорт эшләре

**ГАРНИРЛА́У** *ф.* 1) Төп ашамлыкка гарнир өстәү

2) Тәмләткечләр салу

**ГАРНИТУР** *и. нем. < фр.* Бер максатка хезмәт итә торган әйберләр җыелмасы, бер стильдә эшләнгән тулы комплект. *Әллә никадәр мәшәкатьләр белән, әллә кемнәргә «чәйлек» төртеп эләктереп калган чикләвек гарнитур: кием шкафы, сервант, карават, өстәл, тумбочка, көзге һәм креслолар.* Ш.Хөсәенов. *Бөтен темага сөйләшәләр... Кичәге хоккей, Киссенджерның Токиога килүе, кримплен, рижский гарнитур турында...* М.Мәһдиев. – *Менә монда румын гарнитуры, – диде ул, кубогы белән әрҗәләргә ишарәләп.* Ә.Гаффар

**ГА́РПИЯ** *и. гр.* 1) *миф.* Борынгы грек мифологиясендә кешеләрне урлый дип саналган, канатлы хатын-кыз кыяфәтендәге давыл иясе

2) *зоол.* Карчыга кошлар семьялыгыннан, Үзәк Американың тропик урманнарында, Филиппин һәм Яңа Гвинеядә яши, маймыл һәм төрле кошларны аулый торган, 1 м га кадәр зурлыктагы эре ерткыч кошлар ыругы

3) *зоол.* Һиндстанда һәм Малай архипелагында таралган ярканатлар ыругы

**ГАРПУН** *и. голл.* Диңгез хайваннары һәм эре балыклар аулаганда кулланыла торган, озын бауга беркетелгән, кулдан яки махсус агрегаттан атыла торган ыргаклы сөңге. *Кемдер акваланг белән чума, кайсыдыр берсе гарпун белән су астында балык чәнчеп үтереп йөри.* М.Мәһдиев. *Судак, налим, сиг балыклары да хәзергегә караганда бик күпкә эре булган. Аларны кешеләр, тюлень аулаган шикелле, гарпун белән атып тота торган булганнар.* А.Муранов. *Бервакыт кит аулаучылар китка гарпун аталар.* Кызыклы ихтиология

**ГАРПУНЧЫ** *и.* Гарпун белән коралланган аучы, гарпун атучы. *Каекларның берсендәге гарпунчы үзенең үткен коралын кашалотның аркасына кадый.* Кызыклар дөньясында

**ГАРСОН** *и. фр.* Франциядә һәм башка кайбер илләрдә кафе яки ресторан официанты. *Кофе әсбаплары куелган төпсә тотып, гарсон керде.* Р.Батулла

**ГАРУЗ** *и. гар.* 1) Гарәп әдәбиятында барлыкка килгән, соңрак фарсы-таҗик, төрки, хәтта Европа шигъриятенә үтеп кергән, озын, уртача озынлыктагы иҗекләрне аралаштырып, үзенчәлекле ритм тудырудан гыйбарәт шигырь теориясе. --- *иҗекләрнең зурлыгына да игътибар итү анда электәге гаруз ритмы элементларының саклану күренешләреннән итеп каралырга тиеш.* Г.Нигъмәти

2) Гомумән, шигырь төзелеше турындагы фән, метрика. *Беренчедән, остазы Мотыйгулла хәзрәт, үзе Мисырда укып кайткан кеше буларак, Габдуллага гаруз (шигырь төзелеше) дәресләрендә гарәп, фарсы, төрек шигырьләре кануннарын өйрәткән.* Ф.Галимуллин

3) Гаруз (*1 мәгъ.*) теориясенә нигезләнеп иҗат ителгән шигырь. *«Үч алганчы, башта гыйбрәт ал», – дип әйтеп килгән фәлсәфәле гаруз* ---. Л.Шагыйрьҗан

**ГАРЫЗ** *и. гар. иск.* 1) Тәкъдим. – *Һәр кемнең гарзы булса, вәзире әгъзамга барсын, – диде.* Ф.Халиди

2) Мөрәҗәгать, үтенеч. *Әни, синдә бәнем бер гарызым бар, зинһар, шул гарызымны кабул итсәң, бәнем эшем була, әгәр син кабул итмәсәң, мин харап булам.* Ф.Халиди

3) Теләк, омтылыш. *Шәхсияттән вә гарызлардан саф улмак шарты илә, милләт мәнфәгате арзусилә язылмыш мәкалә вә фикерләр өчен «Шура» битләре һәрвакыт ачыктыр.* Р.Фәхреддин

**ГАРЫ́З ӘЙЛӘҮ** *ф. иск. к.* **гарыз иту́**

**ГАРЫ́З ИТҮ** *ф. иск.* 1) Тәкъдим итү. --- *хисапсыз изгелекләрегез өчен тәшәккер итүебезне гарыз итеп, моннан соң да мин фәкыйрьгә мәрхәмәт итеп җиһан пәһлуаны Каһарман катилләрне миңа ярдәм итәргә җибәрүегезне хозуре шаһанәгездән үтенәмен.* Дастан. --- *солых мәсьәләсе кайсы тарафтан гарыз ителгән иде?* Р.Фәхреддин

2) Үтенү, сорау, гозере булу. --- *без түбәндә язылачак имамнар вә мөәззиннәр гыйззәтлү мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов хәзрәтләренә гарыз идәмез шул хосуста кем* ---. Г.Тукай

3) Аңлатып бирү, сөйләү, тәкъдим итү

4) Сузылып бирү, алга китереп бирү. *Кулларына тоткан киемнәрне кияүгә гарыз итте.* Ф.Әмирхан

**ГАРЫ́З КЫЛУ** *ф. иск. к.* **гарыз итү**. *Ләкин комедиядә тасвир ителгән кыяфәтләрнең һәрберсенең табигать вә кыйланышлары һәм --- сөйләгән сүзләре һәм гарыз кыйлган фикерләре, хәкыйкатән, көленечтер.* Г.Камал. --- *ул һәм, кайтып килеп, ишеткәнен гарыз кылды.* Шәҗәрәи төрек

**ГАРЫК** *хәб. с. гар.* 1) Тую, күңел кайту. *Арыш ипие дә тозлы кильки балыгы ашаудан тәмам гарык.* А.Расих. *Бүген адәм баласы цивилизация шаукымыннан гарык, энем.* Н.Гыйматдинова

2) Тулы; баткан, күмелгән. *Нигә кардәш кул сузмый соң кардәшкә, Нигә хәят гарык һаман кан-яшькә?* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ГАРЫ́К БУЛУ** *ф.* 1) Бату, суга батып үлү. *Иделгә таш вә бүрәнәләр салып, юлын кистеләр, шул сәбәпле көймәләр бер-беренә һәм дә таш вә бүрәнәләргә сугылып, борылып, гарык булып беттеләр.* Р.Фәхреддин. *Һәрзаман дәрьяларда көймәләре гарык булып һәлак булсалар, буйлә язу илә язып, шешәгә салып, агызыны мөхкәм итеп, дәрьяга ташлыйлар.* Ф.Халиди

2) Күмелү, каплану. *Таулар, багълар, бакчалар Нурга гарык булганнар.* Г.Тукай

3) *күч.* Туеп бетү, күңел кайтырлык дәрәҗәдә тую. *Бу хәлдән гарык булган безнең начальствобыз, беләсезме, ни уйлап тапты?* Р.Мостафин. *Чакырып килмәгез дә, ялынмагыз да. Бетте. Җитте. Гарык булдым.* Х.Вахит

◊ **Гарык булганчы** 1) Теләгән кадәр, туйганчы; 2) Чамадан тыш, артык, күңелне кайтарганчы. *Үзем толлык ачысын гарык булганчы эчтем.* Р.Мулланурова

**ГАРЫ́К ИТҮ** *ф.* 1) Батыру. *И Ходаем, суга гарык итмәсәнә, үзең коткар* ---. Ш.Маннапов

2) *күч.* Туйдырып бетерү, биздерү. *Ялыктырды чит-ят гадәтләр, Гарык итте ашы, табыны. Бушка узган күпме сәгатьләр, Ятлар почмагына табынып.* Л.Шагыйрьҗан. --- *таш шәһәрләр, алардагы көн-төн туктамый дәвам итүче ыгы-зыгы, бетмәс-төкәнмәс ашыгу, каударлану, нервлану адәм балаларын инде тәмам гарык иткән...* М.Вәлиев

**ГАРЫ́К КЫЛУ** *ф.* Батыру; күмү. *Зөһрә, минем шаһым син, зөлфе сияһ ярым син, нурга гарык кыйлганың, кояшым син, маһым син* ---. Ә.Уразаев-Кормаши

**ГАРЫС** *и.* **1.** Йоннан (сирәгрәк киҗе-мамыктан) махсус ысул белән эрләнеп катылган, чигү яки бәйләү өчен билгеләнгән йомшак җепнең бер төре. *[Кулмәкләрнең] Татар хатын-кызы кигән берсеннән берсе матур, күпертмәле җилкә-җиңле, чачаклы-чуклы --- итеп тегелгән, төрле алтын-көмеш, гарыс һәм гади йон җеп, ефәк җеп белән чигелгән, тәңкәләр, энҗеләр тезгән, якасы иң гади утыртма якадан алып, челтәрле-челтәрле бөреп теккәннәре, итәге киңен һәм таррагын атарга мөмкин булыр иде.* Б.Рәхимова

**2**. *с. мәгъ.* Шундый җептән бәйләнгән, тукылган. *Гарыс яулык*

**ГАРЫСЛА́У** *ф. иск.* Гарыс кушып эшләү, гарыс белән сугу. *Гарыслап чигү*

**ГАРЬ** *и. гар.* **1.** 1) Оят, хурлык, мәсхәрәлек. *Өйрәнүдә гарь юк.* Мәкаль. *Синең бу алама сурәтеңнән вә ямьсез килешеңнән җенесебезгә гарь килер, ягъни «мәче» дигән хайван башкалар арасында синең аркаңда һиммәтсез саналыр.* Дастан

2) Гарьлек белү; горурлык, әдәп, намус. *Сәүдәгәрдә иман юк – гарен сата, Ялганчыда иман юк – җанын сата.* Мәкаль. *Карак башканың малын ашар, үзенең гарен ашар.* Мәкаль

**2.** *хәб. с. мәгъ.* Оят. *Надан булу – гарь, татар, Аңгар дөнья тар, татар* ---. Г.Тукай

**ГА́РЬ ИТҮ** *ф. иск.* Гарьләнү, хурлану, оялу. *Татарлыктан татар һич гарь итәрме, Кеше үз исмене инкяр итәрме.* Дәрдемәнд

**ГАРЬЛӘНДЕРҮ** *ф.* Хурландыру, гарьлек хисе уяту, намусына кагылу. *Үзе шикелле үк бәхетсез бу кешеләрнең һаман әле аңа ышанмаулары Мостафинны гарьләндерде.* К.Нәҗми. *Оялтып, гарьләндереп язарга кирәк аны, тетмәсен тетеп!* Н.Фәттах. *Малайны тәмам гарьләндереп, әтисе Зәйтүннең борынына чиртте ---.* А.Гыйләҗев

**Гарьләндереп бетерү** Бик көчле гарьлек хисе уяту

**ГАРЬЛӘНҮ** *ф.* 1) Уңайсызлану, оялу, хурлыкка санау. *Хәзер шаркылдап көләрлек берәр нәрсә сөйли алмавымнан гарьләнәм дә, аптырыйм да.* А.Расих

2) Хурлану, күңеленә авыр кабул итү, үзе өчен гарьлек санау. *Авырттырырлык итеп түгел, гарьләнерлек итеп сукты.* М.Кәрим

3) Хәтер калу, үпкәләү. *Гарьләнде яшен, Качты офыкка. Ачы яшьләрен Түкте болытка.* Ф.Яруллин. *И гарьләнде, и рәнҗеде Шәкүрҗан хатынының шул рәвешле мыскыллавына.* Р.Гаффар

**Гарьләнеп алу** Бераз, берникадәр гарьләнү. *Карчыгының бу сүзенә каршы Тимери берни дә әйтмәде. Бераз кимсенде, азрак гарьләнеп алды.* Г.Бәширов

**Гарьләнеп бетү** Бик нык хурлану, оялу

**Гарьләнеп йөрү** Озак вакытлардан бирле гарьлек кичерү. *Шуннан соң Әнкәй бик нык гарьләнеп йөрде, авылдашлары алдында башка докладлар сөйләмәс булды.* Р.Миңнуллин

**Гарьләнеп куюу** Бераз гарьлек хисе кичерү. *Бу сүзләрнең авторы Дамир Гыйсметдин бит әле дип исемә төшердем дә, үз җыр текстымны һаман да яза алмавыма гарьләнеп куйдым.* Л.Лерон. *Шул вакытлар өчен киң күңелле, гадел һәм таләпчән туган җир алдында ул әле гарьләнеп куйды.* М.Кәбиров

**ГАРЬЛӘНҮЧӘН** *с. к.* **гарьчел**

**ГАРЬЛӘНҮЧӘНЛЕК** *и.* Гарьчеллек, гарьләнүчән булу

**ГАРЬЛЕ** *с.* 1) Гарьчел, хурланучан

2) Гел гарьлек кичерергә мәҗбүр булган. *Ярлы башым – гарьле башым.* Әйтем

3) Гарьлек белән сугарылган; гарьләнгән. *Ходай «бирәм» дигән колына чыгарып куяр юлына, дигәндәй, минем гарьле, кәефсез көннәремдә әнинең энесе Хәсиб әзи шәһәрдән ялга кайтып төшмәсенме.* Т.Галиуллин

**ГАРЬЛЕК** *и.* 1) Кимсенү хисе, оят, хурлык. --- *үз гомеремнең шундый арзан, шундый мәгънәсез очлануын күрү күңелдә гарьлек, үкенүләр тудыра.* Ф.Яруллин. *Аны, гадәттә, кызлар үйныйлар, малайлар андый уенга катнашуны үзләренә гарьлек саныйлар иде.* М.Мәһдиев

2) Рәнҗеш, үпкә, хәтер калу. *Болганган су да бер тона бит. Үпкәләр, гарьлекләр, зарлар төпкә батты.* М.Кәрим. *Шәйдулланың гарьлеге ташып тышка чыкты, үкереп елап җибәрде дә китап-дәфтәрләрен җыештыра башлады.* М.Мәһдиев. *Кичә генә миңа хат язган иде, бүген – Мәдинәгә! Гарьлегемнән әз генә елап җибәрмәдем.* Р.Хафизова

**ГАРЬЛЕКЛЕ** *с.* 1) Гарьләндерә торган. *Гарьлекле мәкаләсен дә исенә төшердем.* Казан утлары

2) Гарьлек белән сугарылган, гарьлек кичерелгән. *Ачлык, ялангачлыкка «сатлыкҗан халык» дигән тамга да өстәлгәч, гарьлекле көн күрәләр.* Ватаным Татарстан

**ГАРЬ-НАМУС** *и.* Характердагы ояла, гарьләнә белү сыйфатлары

**ГАРЬСЕЗ** *с.* **1.** 1) Гарьләнмәүчән, үпкәсез. *Әрсез гарьсез булыр.* Мәкаль

2) Әрсез, тәрбиясез

**2.** *и. мәгъ.* Әрсез, тәрбиясез, оятсыз кеше. *Тукайлар, Бабичлар, Такташлар, Мусалар, Кутуйлар, Бурнашлар, Камаллар йортына Әрсезләр, гарьсезләр, дөм сукыр тычканнар, Бөҗәкләр ябырыла, абына-сөртенә---.* Х.Туфан

**ГАРЬСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Әрсезләнү, ояла, тартына белмәү

**ГАРЬСЕЗЛЕК** *и.* 1) Гарьләнмәү, үпкәсез булу

2) Әрсезлек, ояла, тартына белмәү

**ГАРЬСЕНДЕРҮ** *ф.* Гарьлек хисе уяту, гарьләндерү

**ГАРЬСЕНҮ** *ф.* Беркадәр гарьлек хисе кичерү; гарьләнү, хурлану

**ГАРЬЧӘН** *с.* Тиз гарьләнә торган, хурланучан. *Бабай гарьчән кеше иде.* Х.Камалов. *Ул кушаматны мин кушмадым лабаса. Син бигрәк тә гарьчән инде.* Ә.Хәсәнов

**ГАРЬЧЕЛ** *с.* Гарьчән, үпкәчел. *Арыслангәрәй агайның Таһиры турында язган идем инде. Бик кыю, көчле һәм... гарьчел малай!* Ә.Еники. *Гадәттә, кияүгә чыга алмыйча, яки чыгарга теләмичә олыгайган кызлар артык гарьчел, хәтта усал табигатьле булалар, алар күп вакытта кеше белән тынышып яши алмыйлар.* А.Расих. *Артык нечкәләп тормый торган крестьян егетләре дә шундый тойгы кичергәч, юка тиреле, гарьчел Тукайга ни кала?!* И.Нуруллин

**ГАРЬЧЕЛЛЕК** *и.* Һәр нәрсәгә, бик еш гарьләнү. *Тырышлык, гарьчеллек, чәмләнеп яшәү хисләре тәрбияләде.* Кызыл таң

**ГАРЬЧЕЛЛӘНҮ** *ф.* Һәр нәрсәгә гарьләнә торган булып китү, гарьчелгә әйләнү

**ГАСА** *и. гар.* Киеренкелек, түземсезлек, нервлы халәт; гасаб. *Ул аларның килүен тели башлаган иде инде, хәтта гасага сабышкан иде.* М.Хәбибуллин

**ГАСАБ** *и. гар. кит.* Нерв. *Ник, гасаб, нечкә син кыллардан, Чыдамсыз, тиз туза торганнан?* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ГАСАБИ** *с. гар. кит.* Нервлы, борчулы. --- *милләттәшләрем арасында*

*ике чын әдип йитешә: берсе – хәссас, атәшле милләтпәрвәр, идеалист вә романтик Гаяз [Исхакый], икенчесе – гасаби тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист – Ф.Кәрими.* Й.Акчура. *Каршыма килеп туктады, гасаби тавыш белән кычкырып җибәрде: «Син – халык дошманы!..»* Г.Ахунов

**ГАСАБИЛАНДЫРУ** *ф.* Гасабига әйләндерү, гасаби итү

**ГАСАБИЛАНУ** *ф.* **1.** Нервлану, борчылу, пошыну. *Әйтергә кирәк: соңгы вакытларда аңа гасабилану, нервы бозу бер дә ярамый иде.* Ә.Еники. *Күңел яз белән яңа үзгәрешләр көтә, хистойгыларның чамасызлыгыннан үрсәләнеп гасабилана.* Н.Гыйматдинова. *Юлдашев үзенә-үзе аптырап куйды: әллә нинди катлаулы, хәвефле ээзәрлекләү вакытларында да болай гасабиланмый иде ләбаса!* Ф.Баттал

**2. гасабиланып** *рәв. мәгъ. к.* **гасабича**. *Мөгезле эре терлек үкерә, гасабиланып, алгы аягы белән җир тырный башлый, атлар пошкыра, сарыклар тетрәнеп бер-берсенә елыша, бөтен җәйләү хәрәкәткә килә.* А.Расих. --- *ул, аптырап, хәлдән таеп, утыргычка утыра да, үзенең көчсезлегеннән гасабиланып, тавышсыз гына үксеп җибәрә.* Р.Вәлиев. *Капитан Минаев кашын җыерды, арыганлыгын аз гына булса да киметү өчен, гасабиланып чигәсен уды.* З.Фәтхетдинов

**3.** *и. мәгъ.* Борчылу халәте, нервлану билгеләре. *Хорошев, гасабилануын тышка чыгармаска тырышып, үзе дә сизмичә, икенче урындыкка күчеп утырды.* Р.Мөхәммәтҗанов

**Гасабилана башлау** Гасабилык барлыкка килү. *Гасабилана башлаган Филатов, тәмәке кабызып, тәрәзә янына килеп басты.* З.Мәхмүди. *Тынлык тансык булса да, ул бераздан ялыктыра, ниндидер гайре табигыйлекне сизеп гасабилана башлыйсың...* Р.Зәйдулла

**Гасабилана төшү** Бераз гасабилану; тагы да ныграк гасабилану. *– Инде нишлибез, хан? – диде Яким Кучтем. – Нишлибез, китәбез, – диде Илһам хан, гасабилана төшеп.* М.Хәбибуллин

**Гасабиланып бетү** Чиктән тыш гасабилану. *Ул бөтенләй гасабиланып бетте, ләкин үзлегеннән хәрәкәт итәргә актык чиктә курыкты.* Г.Әпсәләмов

**Гасабиланып йөрү** Күптәннән бирле гасабилану. *Һич аңлашылмый, Маратның гасабиланып йөрүенә исләре дә китми.* Ф.Сафин

**Гасабиланып кую** Борчылу билгеләре чыгару, бераз нервлану. *Рашат гасабиланып куйды, кулларын әле төшерде, әле күтәрде, өстәлдәге әйберләрне күчергәләде ---.* Ф.Садриев

**Гасабиланып тору** Хәзерге моментта гасабилы булу, күпмедер вакыт гасабилану. *Егет озак вакыт гасабиланып торды. Хәзер аның авыр сулавы һәм ыңгырашуы гына ишетелә иде.* А.Расих

**Гасабиланып утыру** Шактый вакыт борчылу, дулкынлану халәтендә булу. *Хезмәтче хатыннар --- көләшә-сөйләшә ашап-эчәләр. Бер Айбиби генә гасабиланып утыра.* М.Хәбибуллин. *Тукта әле, нишләп мин бер дә юкка гасабиланып утырган булам?* И.Иксанова

**Гасабиланып чыгу** Билгеле вакытны (тәүлек, көн һ.б.ш.) гасабиланып үткәрү. *Азаплана мескен ана, үзенә урын табалмый, үзен кая куярга белми, төннәрен йоклый алмый гасабиланып чыга...* Ә.Сафиуллин

**ГАСАБИЛЫ** *с. кит.* 1) Нервлы, нерв авырулы

2) Борчулы, тынычсыз. *Халыкның гасабилы язмышын йөрәгеңнән үткәреп, үз җырларың аша Син аңлаттың, яңа аһәңнәрең белән Син уяттың, өмет канатларын терелтеп, очар офыкларын Син киңәйттең.* М.Гали. *Һәм шул мәлдә миемне бер гасабилы уй көйдереп узып китте: «Йа Хода бәндәсе, тегеләйрәк түгелме соң син?»* Н.Гамбәр

**ГАСАБИЛЫК** *и.* 1) Түземсезлек; нервлы холык. --- *ялганлаулары яисә икейөзлелекләре шулкадәр җенемне чыгара, кайвакыт хәтта башыма каба. Үземне үзем тоту кыенлаша башлый. Бәлки, бу – гасабилыктан гына түгелдер, рухның, сиземләүнең бик нечкәреп китүеннән шулай була торгандыр.* Г.Бәширов. --- *Зәки Вәлиди үзенә хас гасабилык белән мондый уеннан чыга һәм бер төркем фикердәшләре белән таҗиклар иле аша Персиягә, аннан Төркиягә юл ала: кача.* А.Хәлим

2) Нервлар киеренкелеге, борчулы, ярсулы халәт. *Гасабилык, аерым урыннарда ихласлык, эчке газаплану, өзгәләнү кебек сыйфатлар хас булды бу геройга.* А.Әхмәдуллин

**ГАСАБИ́ЧА** *рәв. иск.* Нервлы хәлдә, борчылып; ярсулы рәвештә

**ГАСӘЛ** *и. гар. иск.* Бал. *Саирләренә гасәл вирәсез халегезә муафикъ...* З.Бигиев

**ГАСКӘР** *и. гар.* 1) Дәүләтнең коралллы көчләре, армия. *Бу гаскәр – Һинд падишаһының гаскәренә каршы Һушәң шаһ тарафыннан җибәрелгән гаскәр, имеш ---.* Дастан. *Узган ел бортаслар өстенә яу белән барганда да, олуг бәкләр арасыннан Талиб үз алайлары белән гаскәргә иң соңыннан гына килеп кушылды.* В.Имамов

2) Кораллы көчләрнең аерым бер төре. *Танкларга төялгән десант гаскәрләре иде болар.* Х.Камалов. --- *ул еракта, Батумидан ары чик буе гаскәрендә сверхсрочный хезмәттә иде.* М.Мәһдиев

3) Сугышчы, хәрби хезмәттәге кеше. *Төрле биючеләр, гаярьләр, барабанчылар, уенчылар вә гаскәрләр, ул падишаһларның тирәсендә төрле уеннар уйнап, биеп, зур шәүкәт белән сарайга килеп керделәр.* Дастан. *Гаскәрләр һәм аучы-сунарчылар, йөгерек аргамакларга менеп, Камәрҗаннар киткән дала, яланнар, елга һәм күлләрнең аркылысын-буен эзәрләп чыктылар.* К.Насыйри

4) *күч.* Күп булып тезелеп торган, тезелеп үскән, рәт-рәт торган җансыз әйберләр төркеме. --- *колхоздагы балалар отряды алабуталар гаскәре өстенә ташландылар.* М.Әмир. *Койманың эчке ягында – гаскәр сыман рәт-рәт тезелеп киткән каен, нарат, чыршы, зирек агачлары, канәфер, шомырт, сәрви куаклары.* В.Имамов. *Вал өстенә ишелеп килә иген гаскәре: дулкынлана арыш сафлары, шаулап килә бодай...* Р.Әхмәтҗанов

5) *күч.* Бер мөһим бурыч үтәү өчен тупланган кешеләр төркеме; гомумән, берәр төркем, катлам. *Әлеге урыс-япон сугышы, 1905 елгы инкыйлаб җилләре авыл халкын да нык кузгатты. Бәхет эзләп китәләр дә баралар. Шуңа күрә зимагурлар гаскәре дә шактый ишәйде.* С.Поварисов

6) *күч.* Берәр нәрсәнең бик күп булуы турында. *Тирә-ягымны кайгы гаскәре чолгаган, ни эшлим?* Г.Тукай. *Үрли кояш, үрли һаман өскәре, Кыскарадыр күләгәләр гаскәре.* Р.Низами

**ГАСКӘРБАШ** *и.* Яубашы, гаскәр башлыгы, полководец. *Гаскәрбаш авызыннан егылып төшкән хәлсез сүз аркасында күпме атакалар барып чыкмас иде!..* М.Галиев

**ГАСКӘРБАШЫ** *и. к* **гаскәрбаш**. *Канлы бәрелешләр ешая, берсендә магулларның гаскәрбашы Кечек бәк хәтта әсирлеккә дә төшә.* С.Шәмси

**ГАСКӘРИ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Гаскәр белән бәйле, гаскәргә караган. --- *көннәрдән бер көнне әтине, урамда тотып, гаскәри хезмәткә ала башлыйлар.* А.Расих. *Ашыгыч ярдәм күрсәтүне, гаскәри частьлар җибәрүне таләп итә алар берөзлексез.* Р.Мөхәммәдиев

2) Хәрби; гаскәргә, армиягә хас. *Янында гаскәри киемле кешене күргәч, мулла куркып һәм сискәнеп китте.* Ш.Усманов. *Сәет күреп торды, Санька гаскәри киемледән бераз шикләнә, андый-мондый зыян салмагае дип шөбһәләнә иде.* Ф.Латыйпов

**2.** *и. мәгъ.* Хәрби хезмәттәге кеше. *Тагы өч көннән Көнчыгыш фронтының 5 нче армиясе политбүлегенә башкорт гаскәриләренең, Кызыл Армия белән бер сафка басып, Колчакка каршы көрәшергә әзер булуы хакында хәбәр җиткерелә.* Р.Мөхәммәдиев. *Халык дәрьясы чиксез, гаскәриләр музыка уйный.* А.Расих. *Гаскәри исә моны сизде, елмаеп җавап бирде: «Курыкма ---. Без сиңа зыян китермәбез».* Ф.Латыйпов

**ГАСКӘРИЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Хәрбиләргә хас җитезлек, тәвәккәллек белән, хәрби кешеләргә хас рәвештә. *Искәндәр атасының барлык сөальләренә бу юлы җитди, чын гаскәриләрчә җаваплар бирә иде.* К.Тинчурин. *Зиннуровның гаскәриләрчә ачык итеп, өзеп, «мин» дип җавап бирүенә класс кына түгел, Солтан үзе дә көлеп җибәрде.* Г.Кутуй

**ГАСКӘРИЛЕК** *и.* 1) Хәрби кешеләргә хас үзлек, тотыш-йөрештә хәрбиләргә охшашлык. *Аңарда сүзләр, җөмләләр бер-бер артлы тезеләләр дә узышалар, ашыгалар, аларның тизлегендә гаскәрилек бар.* Г.Кутуй

2) *иск.* Хәрби хезмәт, армия. *Гаскәрилеккә алынган татар крестьяны тәмам картайганчы хезмәт итәдер иде.* Г.Гобәйдуллин. *Һәрбер төрек-татар җенесеннән булган ир кешенең башлыча эше гаскәрилек булып, һәркем үсеп җиткәч, сугыш вакытында сөңге, кылыч, ук, җәя ала да, атка атланып, ардуга барып керәдер иде.* Г.Гобәйдуллин

**ГАСКӘРИЯ** *и. гар. иск.* Хәрби хезмәт, гаскәрлек, гаскәрият. *Моның гаскәрия мәдрәсәсендә укыган шәрикләре һәнүз янгура дәрәҗәсеннән чыкканнары юк.* Ф.Халиди

**ГАСКӘРИЯТ** *и. гар. иск. к.* **гаскәрлек**. *Гаскәриятдән качмак фикере башыма кәлмәмеш, һич кәлмәйә җәндер.* З.Бигиев

**ГАСКӘРЛӘ́РЧӘ** *рәв. к.* **гаскәриләрчә**. *Болар инде кызыллар иде. Сафларга тезелеп, кызыл байракларын күтәреп, бөтенесе бер тавыштан җырлап, чын гаскәрләрчә төп урам буйлап уздылар.* Ә.Еники

**ГАСКӘРЛЕК** *и. иск.* Хәрби хезмәт, армия. --- *ул, иске гадәтенчә, ике мәртәбә зур акча белән гаскәрлектән котыла.* Г.Ибраһимов

**ГАСТРИТ** *и. гр. мед.* Ашказанының лайлалы тышчасы ялкынсынудан гыйбарәт авыру. *Күрерсең: ике-өч айдан экипажның яртысы гастрит белән интегә башлаячак.* М.Юныс. *Аларны күп кенә инфекцион һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларын дәвалаганда, шулай ук анацид гастритлар һәм эч китүләр вакытында да кулланалар.* Урман аптекасы

**ГАСТРОЛЁР** *и. нем.* 1) Гастрольләргә килгән артист, гастрольләрдә катнашучы. *Шулай итеп, үзем башлаган беренче Татар опера театрында, гастролёр булып кайтып, «Наемщик»та Батырҗан ролен уйный башладым.* У.Әлмиев. *Гастролёр-трагик сыйфатында М. Мутин 1912 елга кадәр йөри.* М.Арсланов

2) *күч.* Яшәү урынын, эшен еш алмаштыручы кеше. *Россиянең әллә ничә театрында эшләп тә эш майтара алмаган бер гастролёр буш куык шунда.* Т.Миңнуллин. *Ләкин ул «гастролёрлар»ның язганнары укучы күңелен яулый алмый иде шул!* Ә.Рәшит

3) *күч. жарг.* Чит өлкәдән, чит шәһәрдән килеп җинаять кылучы, килмешәк җинаятьче. *«Гастролёр»дыр, чит шәһәрдән килеп, вакытлыча вокзалга кунаклагандыр.* Ш.Галиев. *Чөнки тәҗрибәле оперативник, әгәр угрылык узгынчы «гастролёрлар» эше булмаса, һичшиксез, яңадан кабатланачагын аңлый.* Безнең гәҗит

**ГАСТРОЛЁРЛЫК** *и.* 1) Гастрольләргә йөрү белән бәйле эшчәнлек

2) *күч.* Гастролёр (*2 мәгъ.*) булу, һәр урында вакытлыча яшәү рәвеше

3) *күч.* Гастролёр (*3 мәгъ.*) булу, читтән килеп җинаять кылу күренеше

**ГАСТРОЛЬ** *и. нем.* 1) Чит шәһәрдән килгән артистның чыгышы, читтән килгән театр труппасы бирә торган спектакль. *Кышкы айларның берсендә шул ук шәһәр циркында Мюзик-холл гастрольләре башланды.* А.Расих. *Үз ватаныбызда Вафирәнең гастроль маршрутлары – Карпаттан башлап Чукоткага кадәр.* Г.Ахунов. *Моңарчы күрелмәгән хәл: Чуваш дәүләт театры гастрольләргә килеп төште.* Мирас

2) *күч.* Читкә китеп, кунакта булып кайту, гомумән китеп йөрү. *Менә шуңа күрә Таифә апаның «гастрольләренә» чик куярга булдым мин.* В.Нуруллин

**ГАСТРОНОМ** *и. фр.* 1) Гастрономия (*1 мәгъ.*) әйберләре белән сату итә торган кибет. --- *менә инде бер атна ул һәр кич, ашханәдән чыкканда, мине гастроном чатында көтеп тора.* И.Салахов. *Фуат педагогия институтын тәмамлаган, әлеге фәлән шәһәрдә урта мәктәп директоры икән, хатыны – гастрономда бүлек мөдире.* М.Мәһдиев

2) Нәзакәтле ризыкларны белүче һәм яратучы. *«Гастроном» балыклар да очрый: аларның бер төрләре –*

*краблар, кыслалар, креветкалар (диңгез кыслалары), ә икенчеләре – устрица һәм башка нәзакәтле моллюсклар белән генә тукланалар.* Кызыклы ихтиология

**ГАСТРОНО́МИК** *с.* Гастрономиягә караган, шуның белән бәйле. *«Ауропаны тәмләп кара!» дигән быелгы гастрономик фестиваль азык тәмләп карау белән генә чикләнмәде, билгеле.* А.Фәхретдинова. *Грузия шәрабы, --- татар чәкчәге, башкорт балы, чуваш сырасы, үзбәк пылавы – урыс халкының һәм аларга ияреп бүтән милләтләрнең дә бер-берсен үз итүе менә шундыйрак гастрономик рухтагы милли нәрсәләрне яратудан башлана да шуның белән үк тәмамлана.* Татарстан яшьләре

**ГАСТРОНО́МИЯ** *и. фр.* 1) Ашарга яраклы продуктларның һәммәсе, ашамлыклар; ризыклар. --- *минем өчен дә, синең өчен дә Карден гастрономиясе белән беренче танышуыбыз булыр, – дип шаярткан булды егет.* Р.Мирхәйдәров

2) Кулинария сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен аңлау үзлеге

**ГАСТРОСКОПИ́Я** *и. гр. мед.* Ашказанының эчен махсус прибор – гастроскоп ярдәмендә тикшерү

**ГАСТРОЭНТЕРОКОЛИТ** *и. гр. мед.* Ашказанының һәм эчәкләрнең лайлалы катламы ялкынсынудан гыйбарәт авыру. *Ике врач, киңәшеп, якынча диагноз куялар: гастроэнтероколит – ашказаны һәм эчәкләр авыруы.* С.Сөләйманова

**ГАСЫЙ** *и. гар. иск.* **1.** 1) Буйсынмаучы, каршылык күрсәтүче кеше, гыйсъянчы. *Гөнаһлы кеше, гөнаһ кылучы Сап-сары шәйтаннар анлар шунда янсыннар иде, Җөмлә гасыйлар үчен шунлардан алсыннар иде.* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* Аллаһ каршында гөнаһлы; диннән язган. *Нух нәби, кавеме иман китерми гасый булгач, кавеменә җәза сорады.* Ф.Халиди

**ГАСЫР** *и. гар.* 1) Тулы йөз елга тигез булган вакыт аралыгы, йөз. *Н.Я.Мерперт, борынгы болгарлар автохтон халык түгел, бәлки төрки кабиләләр булганнар, алар гуннарга кадәр күп элек, яңа эраның беренче гасырларында ук Азиядән Азов һәм Дон буйларына килеп чыгып, анда сабир һәм аланнар белән аралашканнар дип уйлый.* Ә.Кәримуллин. *Дөньяның төрле илләрендә кайчандыр гөрләп торган, гасырлар узу белән, җир өстендә эзе дә калмаган шәһәрләр булганын беләбез.* Казан утлары

2) Зур үзенчәлекләр, гадәттән тыш тарихи вакыйгалар белән аерылып торган чор. *Кадим чорлар кадим мәхәббәте, Ни дисәң дә, күркәм мәһабәт --- Безнең канлы атом гасырында Танымастай ник соң мәхәббәт?* Ә.Сиңугыл-Куганаклы

**ГАСЫРЛАП** *с.* Гасырга якын, гасыр чамасы. *Чирек гасырлап вакыт сиздермичә үтеп тә китте – Рушанның күз алдында бу кешеләрнең бөтен тормышы пыран-заран килеп бетте.* Р.Мирхәйдәров

**ГАСЫРЛА́РЧА** *рәв.* Гасырлар буе, әллә ничә гасыр буена. *Болар арасында гасырларча тартышу дәвам иткәндер.* Г.Исхакый. *Тимер челтәр аша карыйкарый, Гасырларча бу ил тилмерде...* Х.Туфан

**ГАСЫРЛЫК** *с.* Гасыр буе дәвам иткән, бер гасырга сузылган; билгеле гасырны үз эченә алган. *Мизгел булса, гасыр яшәр иде, Бер гасырга мизгел сыймады --- Узып китте бер гасырлык мизгел, Бер гасырлык! – беркем тоймады!..* Р.Әхмәтҗанов. *Яр буйларындагы ничә гасырлык өянкеләр булмагандай юкка чыкты.* Р.Гарипов

**ГАТА** *и. гар. иск.* Бүләк

**ГАТА́ КЫЛУ** *ф. иск.* Бүләк итү. *Әй атам, Хак сөбханә вә Тәгалә хәзрәтләре мәңа буйлә гүзәллек һәм күркәм гакыл гата кылган...* Ф.Халиди

**ГАТАЛӘТ** *и. гар. иск. кит.* 1) Эшсезлек, бушка вакыт уздыру. *Мәгатыйль кыйлды милләтне гаталәт вә кәсаләтдән; Бу хезмәтчөн азад улды ул цензур нам әсарәтдән.* Г.Тукай

2) Хәрәкәтсезлек; дәртсезлек, сүлпәнлек; ялкаулык

**ГАТТАР** *и. гар. иск.* Хуш исле майлар сатучы. *Берәүдән, дөньяны ни кәйфияттә күрәсең, дип сорадылар, ул әйтте: бер кабихә хатындыр, бер көн гаттарда, бер көн байтарда, диде.* К.Насыйри

**ГАТТЕ́РИЯ** *и. гр. зоол.* Хәзерге заманга кадәр сакланып калган томшыкбашлы сөйрәлүчеләр отрядының чөйтешлеләр семьялыгына караган бердәнбер төр – Яңа Зеландиядә яши торган кәлтәгә охшаш хайван. *Гаттерияләр – бик борынгы тереклек ияләре, чын мәгънәсендә тере казылма хайваннар.* Кызыклы физиология

**ГАТЫРША** *и. гар. иск.* Ислемай, хушбуй. *Изге Ана, юл тузанын коеп, юынып, бераз хәл алгач, яукызның бөтен тәнен җофар мае белән майлап, чәч-башына гатырша сиптерделәр.* Р.Батулла

**ГАТЫРША́ ГӨЛЕ** *и. к.* Исле гөл; *русчасы:* **герань**

**ГАТЫРША́ МАЕ** *и. к.* **гатырша**. --- *бер ис тулып тора; --- гает көнендә муллалар йортында гатырша мае исе кебек, туйлы йорттагы чәкчәк, катлама исе кебек бөтен исләрне басып та тормый.* Г.Исхакый. *Чыгып китәр алдыннан, сандык төбеннән алып, әнисеннән калган гатырша маен сөртте.* Г.Бәширов

**ГАТЫЯ** *и. гар. иск.* Бүләк итеп бирү, бүләк. *Гатыя аламын дип, сөенеп хәбәр бирде.* К.Насыйри

**ГАТЬ** *и. рус* Баткак урыннардан ат, машина яки башка техника белән узу өчен, бүрәнәләр яки чыбык-чабык түшәп ясалган юл, түшәмә

**ГА́УБИЦА** *и. нем.* Кыска көпшәле артиллерия тубы. *Гаубицалар тулысы белән квадратларга гына аталар. Индивидуаль цельләр аларга куелмый да иде.* Х.Камалов. *Баржага снаряд кына түгел, ике гаубица, атлы повозкалар, хезмәтче солдатлар да төяләчәк.* И.Низамов. *Минем күзәтү пунктыма килеп, гаубица батареясының разведка отделениесе командиры --- полк командиры исеменә рапорт язарга булышуымны үтенде ---.* Казан утлары

**ГАУВАС** *и. гар.* Чумучы, чумып, су астыннан энҗе, суүсемнәр, губка һ.б.ш. чыгаручы. *Казанда бер фазыйль чыкды, алмас булып --- Хәкаикъ диңгезендә гаувас булып.* М.Акмулла. *Бернинди җайланма-коралсыз диңгез төбенә*

*чумучы гаувас хәлендә калмыйммы?* Р.Фәйзуллин

**ГАУВАСЛЫК** *и. иск.* Гаувас эше, шөгыле; су астына чуму һөнәре

**ГАУВӘМ** *и. к.* **гавам**. *Салих задә булмаганлар да чагыр эчкәй, Гаувәм халкы хәрам эшкә хирыс булгай ---.* Г.Чокрый

**ГАУГА** *и.* 1) Тавыш-кычкырыш, шау-шу. *Менә ул яңадан кулын селтәде. Гауга кинәт киселгәндәй булды.* М.Хәсәнов

2) Ызгыш, талаш, җәнҗал, үзара даулашып кычкырышу. *Үсеп килүче нарасый бала гаиләдә нинди гауга, җәнҗал барганын бөтенләй белми дә.* Х.Вәлиәхмәтов. *Көн саен диярлек яңалык, көн саен диярлек гауга.* Э.Касыймов. *Ни сәбәптер, холыксыз, гауга куптаручан кешедән курку, аңа юл биреп, аны урап узу модага керә башлады хәзер.* М.Юныс

3) Бәхәс, тартышу; дау. *Инде сөйләгез. Нидән гауга чыгардыгыз?* Т.Миңнуллин. --- *әдәбиятта төрле милләт халыклары тормышындагы, милли телләрдәге һәм, аеруча, милли мөнәсәбәтләр арасындагы үзгәрешләр хакында гауга бара.* Казан утлары

◊ **Гауга кубу** Тавыш чыгу, ызгыш-талаш башлану. *Гауга купкан, тавыш купкан, Һәркем нидер кычкырган. Телләр генә түгел, хәтта Куллар бәйдән ычкынган.* Ф.Яруллин. **Гауга куптару** Бәхәс башлау, дау, ызгыш кузгату. *Директор: «Тукта, булыр-булмас эшкә гауга куптарып йөрмә әле, мәсьәлә хәл ителмәде бит», – дигәндер инде, кире кергәч, гауга куптармады үзе.* М.Маликова. **Гауга күтәрү** *к.* **гауга куптару**. *Ә асылда исә Корүзәнгә төшкән һичбер кеше халык алдына чыгып гауга күтәрмәде.* В.Имамов

**ГАУГА́ БАРАБАНЫ** *и. тар.* Куркыныч янаганда халыкка хәбәр бирү өчен кулланыла торган барабан

**ГАУГАЛАНУ** *ф. сир.* Гауга, җәнҗал куптару, ызгышу, тавыш чыгару. *Һичбер эштә дошманлашмагыз, гаугаланмагыз! Аллаһы Тәгалә дошманлык кылмас һәм каршы килмәс!* Ф.Яхин

**ГАУГАЛА́У** *ф.* Җәнҗал куптару, тавышлану

**ГАУГАЛАШУ** *ф.* 1) Үзара даулашып кычкырышу

2) *к.* **гаугалау**. --- *каберне күмеп тә куйдылар. «Нигә шулай ашыгалар икән алар?» – дип уйлады Ярмөхәммәт. Әйтерсең лә Айдаш карт кабердән чыгарга гаугалаша.* Р.Батулла

**Гаугалаша башлау** Гаугалашырга керешү. *Кайсы авылга бару хәбәрем чыгу берлә, базардагы башкортлар мине сарып алып --- гаугалаша да башладылар.* Г.Исхакый

**Гаугалашып китү** Гаугалашу дәрәҗәсенә җитү; кинәт гаугалаша башлау. *Алар тагы ырылдашып, гаугалашып китә яздылар.* Х.Камалов. *Бакча арты күршеләре электрик Габбас агай белән савымчы Сәрия апа үзара гаугалашып киткәли.* Г.Якупова

**Гаугалашып тору** Гел гаугалашу; хәзер гаугалашу

**ГАУГАЛЫ** *с.* 1) Тавышлы, шаушулы. *Шактый гаугалы булачак бәхәскә дә ерак калмаган иде инде, ләкин нәкъ шул чакта банкет залына, кулларына пар бөркеп торган поднос тотып, өч «официант» килеп керде.* Р.Мирхәйдәров

2) Гел гауга булып торган, тынычсыз, җәнҗаллы. *Бердәм өйдә бәрәкәт бар, Гаугалы өйдә һәлакәт бар.* Мәкаль. *Гаугалы йорттан бәрәкәт китәр, дигәндәй, үтерешләр белән шөгыльләнгән ханның ил белән идарә итәргә әллә ни вакыты калмаган булса кирәк.* С.Шәмси. *Ә бит, ныклабрак уйлап карасак, үтә тынгысыз һәм гаять гаугалы бу Җир шарында бәхетле чор тормышының бәхетле баласы булып туу үзе үк күпләр көнләшердәй вакыйга түгелме соң?* Казан утлары

3) Бәхәсләр чыгу өчен сәбәп булып торган, дәгъвалы. *Бу су зур түгел, ләкин бер-ике тегермән ташын әйләндерерлек көнә куәте бар иде. Шуңа күрә, ахры, элек-электән гаугалы елга булган.* М.Шабай

**ГАУГАСЫЗ** *с.* **1.** Тыныч, ыгы-зыгысыз; ызгыш-талаш булмый торган. *Эшен ташламады, тик эше һаман бертөрле, кызыксыз иде: типовой проектларга нигез проекты ясау. Тыныч, гаугасыз, җиңел эш.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Тыныч рәвештә, бәхәссез. *Гаугасыз, тыныч кына эшләп йөргән Ринат кай ягы беләндер аңа ошап китте, күңелендә нindидер тынгысызлык чаткысы уятты.* Н.Хәсәнов. *– Минем бер генә пьесам да гаугасыз чыкмады, – ди Нәкый ага.* Р.Батулла

**ГАУГАЧАН** *с.* Бәхәсче, дәгъвачыл, низагълашып йөрүчән. *Эчсә, холкы бик начар була торган иде. Бәйләнчек, гаугачан иде, мәрхүм.* Р.Батулла

**ГАУГАЧЫ** *и.* Гел гауга куптарып торган кеше, җәнҗалчы; гаугада катнашучы. *Аларга үз фикереңне генә әйт, шуны расларга омтыл – хәзер «гаугачы», «җәнҗалчы» исеме тагып куялар.* Ф.Сафин. *Бар да аракы эчә. Бераз утыргач, гаугачылар тагын якага-яка килә.* Р.Батулла

**ГАУГАЧЫЛ** *с. к.* **гаугачан**. *Берәр гаугачыл, чәнчәләк кеше булса, бу хакта авызыннан утлар чәчәр иде, ә эшче кеше гади шул, әйбәт.* Х.Камалов. *Стаинның гаугачыл җәнҗалчы булып танылуы ул күздә үскәннән-үсә барды.* Р.Мирхәйдәров

**ГАУГАЧЫЛЛЫК** *и.* Характерда булган гауга, скандал чыгару хирыслыгы

**ГАУГАЧЫЛЫК** *и.* Гаугалашу, тавышлану күренеше, гауга чыгару гадәте

**ГАУПТВА́ХТА** *и. нем. хәр.* Хәрбиләрне арестта тоту өчен махсус бина. *Вәрәшбашның Гарифҗанга мондый «шаяруы» өчен ничә көндер гауптвахтада утырып чыгарга туры килсә дә, ул һаман шаянлыгын ташламады.* Г.Ахунов. *Ефрейторны гауптвахтага керттеләр. Бил һәм чалбар каешын милициядәге кебек үк дежурный алып калды.* Г.Кашапов. *– Хәзер үк сак астына алырга! Гауптвахтага! – дип акырды генерал һәм минем гимнастёркадан комсомол значогын йолкып алды.* М.Маликова

**ГАУРӘТ** *и. гар.* 1) Тәннең кешегә күрсәтергә ярамый торган өлеше. *Җайлы-җайсыз селкенүенә, гаурәт җирләре: «Без монда!» – дип кычкырыша башлыйлар.* Ф.Яхин. *Намаз укучы кешенең гаурәт җирләре ябык булу фарыз.* Юлдаш

2) Хатын-кыз

3) *күч.* Җитешмәгән җир, кимчелек, гаеп. *Зәррәдәй гаебеңне күрә калса, Гаурәтне җабмауга – бар, ачмауга – юк!* М.Акмулла

**ГАФИЛ** *с. гар.* **1.** 1) Гамьсез, игътибарсыз, ваемсыз. *Гафил булып, мүкле таштай ятмасламы? Ата йортын сүтеп, учак якмасламы?* Р.Рахмани

2) Белексез, надан, томана. *Ярый әле бер карт хәлебезгә керде: «Сез, кадерлем, гафил булмагыз, кабер казучыларның башлыгын күреп сөйләшегез, алар акча төрткәнне көтәләр».* Г.Ахунов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Гамьсез кеше, битараф, ваемсыз кеше. *Дия гафилләргә айхай, хай, Дөшебдер монлари гаҗәткярә.* М.Акмулла. *Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр ---.* Г.Тукай

2) Белемсез кеше, надан. *Йук, йук бундай хәдис булмаз, син надан, гафил ---.* М.Акъегет. *--- хакыйкатьне бар кеше дә бертигез күтәрә алмый, надан вә гафилләр турында әйтеп тә торасы юктыр.* М.Хәбибуллин

**3.** *хәб. функ.* Хәбәрдар түгел, билгесезлектә, нәрсәдәндер мәхрүм. *Үткәндә матур мәхәббәте булмаган кеше кызганыч. --- чөнки ул мәхәббәтнең тетрәткеч бәхетеннән гафил.* Ш.Хөсәенов

**ГАФИЛЛӘНҮ** *ф.* Гафиллек күрсәтү; гафилгә әйләнү

**ГАФИЛЛЕК** *и.* 1) Ваемсызлык, игътибарсызлык, алдагысын уйламау; гамьсезлек. *--- һәр эштә сабыр ит, ашыкма, сабыр – икенче гакылдыр, диерләр. Вәдәхи һәр эшеңдә гафил булма, гафиллек – икенче ахмаклыктыр.* К.Насыйри

2) Наданлык, караңгылык, томаналык. *Үзләренең гафиллекләре аркасында сатлык җаннар Мамай белән Агиш морзалар атамызны үлтерделәр, һәм ул теләген тормышка ашыра алмый калды.* М.Хәбибуллин

**ГАФИФ** *с. гар. иск.* Гыйффәтле, намуслы, саф. *Бер гафиф, ап-ак, сылу япь-яшь егет күрдем, әти.* С.Сүнчәләй. *Мәйданлыкны ак күбәләкләр төсле пакь, гафиф болгар кызлары чолгап алдылар.* Н.Думави

**ГАФИФӘ** *с. гар. иск. к.* **гафиф**. *Беләм: сине ачы тормыш изә, гафифәм! Кайгыларыңны бетерсәңче.* С.Сүнчәләй

**ГАФИФАНӘ** *с. гар.-фар. иск.* Самими, саф, эчкерсез рәвештә

**ГАФИЯТЬ** *и. гар. иск.* Тән сәламәтлеге, саулык, исәнлек. *– Әлхәмдүлилләһи гафиять булдык. Шаһзадә --- атасы хәзрәтләренә мәктүб язмыш, безләрне гыйтабтан коткарып, – диде.* Ф.Халиди

**ГАФЛӘТ** *и. гар. иск.* 1) Гафиллек, ваемсызлык, сүлпәнлек, пассивлык. *Гафләтдән уяну җук, оялу җук, Кәрваннар үтеп җатыр катар-катар.* М.Акмулла

2) Наданлык, белемсезлек. *Саталар фәлсәфә анлар, оралар дәм дә хикмәттән, Аяк астында базны күрмиләр шул хәлдә гафләттән.* Г.Тукай. *Басты гафләт, мәгърифәтсезлек татарлар дөньясын, Белмәде һичкем ки милләтне бәхеткә юлласын.* С.Сүнчәләй

3) Игътибарсызлык, дикъкатьсезлек. *Һәркем --- Гаяз [Исхакый] әфәндевең авызыннан чыккан җөмләләрне, сүзләрне генә түгел, бәлки һичбер хәрефне гафләт итми тыңлап утырды.* Г.Гыйсмәти

**ГАФУ** *и. гар.* Гаепне, кимчелекне, начарлыкны кичерү, игътибарсыз, җәзасыз калдыру, оныту күренеше. *Барын да сөйләп, үкенермен, ялварырмын, гафу сорармын.* Ш.Хөсәенов. *Әнә бит ул чын күңелдән сөйләгәндәй итенә, кылган әшәкелекләре өчен, турыдантуры гафу үтенмәсә дә, үкенгәндәй күренә.* Э.Касыймов. *--- кылган яман эшеннән тәүбә итеп, гафу сорарга килгән бәндә үзен менә ничек тота икән: елмаерга, кешенең күзләренә туры карап торырга тырыша ---.* М.Маликова

**ГАФУ́ ИТҮ** *ф.* Кичерү, ярлыкау. *Юк, гафу итмәм инде мин аларны.* Г.Нәбиуллин. *Әллә ниләр яздым, гафу итәрсең, дөресен язмыйча, күңел чыдамады.* Г.Ахунов

◊ **Гафу итегез** «Гафу үтенү», «игътибар сорау», «каршы килү» мәгънә төсмерләрен белдерә торган сүз. *– Гафу итегез, сез Мәскәүдән яки Ленинградтан килгән вәкилме әллә? – диде ул, шаярып.* М.Маликова. *Тик шуны аңламыйм: безнең ташпулатны ташлап, нигә бу шаламага, гафу итегез, монда килергә кирәк булды?!* Х.Ибраһим. **Гафу итәсез** *к.* **гафу итегез**. *Иптәшләр, гафу итәсез, афишада матбага хатасы киткән.* Ш.Камал

**ГАФУ́ КЫЛУ** *ф. к.* **гафу итү**. *Сән үзеңнең ихтиярың илә падишаһның әмерене көтмәгән өчен, сәне падишаһ, әлбәттә, бу тугърыда гафу кылмас, кател кылдырыр яки газел кылыр.* Ф.Халиди

**ГАҺЕД** *и. гар. иск.* 1) Килешү, договор. *--- илче Аппак морза белән Мәскәү кенәзе Сәхиб Гәрәйне хан итү хакында гаһед ясамышлар.* Р.Фәхреддин

2) Йөкләмә, үз өстенә алынган бурыч; вәгъдә ителгән эш яки әйбер. *Казаклар, үзләренең гаһедләрен бозып, бөтен ватан дошманнары, поляклар, литвалылар һәм рус «вор»ларына каршы сугышалар ---.* Г.Гобәйдуллин. *--- бар җанвар: арыслан, хәтта капланнар нәбиләргә тимәслекнең мөкаддәс гаһден алганнар.* Г.Тукай. *Алардан җыелган алтын-асылташлар һәм червонецлар урынына Шәфи һәртөрле имзанамәләр, үзара язышкан гаһед кәгазьләре бирә барды.* Ш.Маннур

3) Ант, ант итү, сүз бирү. *Мәскәү тарафыннан илче булып барган Андрей Пильемов хан һәм зур дәүләт эшлекләреннән ямин вә гаһед алды.* Р.Фәхреддин. *Бу гаһедтән соңра Башның күзләре Яктырып китте: ачылды йөзләре.* Г.Тукай. *Мин яшьтән ышандырган гаһед, вәгъдәм шушы иде ---.* С.Сүнчәләй

4) Дәвер, заман, гасыр

**ГАҺЕ́Д БИРҮ** *ф. к.* **гаһед итү**. *Мин сине мәңге онытмаска гаһед бирдем.* З.Ярмәки

**ГАҺЕ́Д ИТҮ** *ф.* Ант итү, сүз бирү, ышандыру. *--- хәсрәт илә шатлыкны җыйган хәлемдә аерылдым, вәгазьләре илә гамәл идәргә гаһедләр итдем ---.* Р.Фәхреддин

**ГАҺЕ́Д КЫЛУ** *ф. к.* **гаһед итү**. *Әквал мәлгунь: «--- һәммәсен һәлак итмичә үз урыныма кайтмам», – дип гаһед кылып, гаскәре белән Гөлстан Ирәм шәһәрен мөхасирә хәленә алган иде.* Дастан

**ГАҺЕДНАМӘ** *и. гар.-фар. иск.* Язулы килешү, договор. *– Тәнәкә гаһеднамәне тулысы белән үткәрергә боер-*

*ды бит, ә бу хәл, үзеңә мәгълүм, морза, бик сирәк була, – диде Фәйрузат, уйчан гына.* М.Әмирханов

**ГАҺЕТ** *и. гар. иск. к.* **гаһед**. *Бар, алай булса, гаһетеңә вафа кыл, йәнә сәламәт кайтып кил.* К.Насыйри. *Гаһетләрне җиренә җиткерү, хакларын ригая итүнең галиҗәнаплык икәнлегендә шөбһә юк.* Р.Фәхреддин

**ГАЧИ́ АГАЧЫ** *и. тар.* Патша Россиясендә берәр гаебе булган, баш күтәргән авылның җәзалы икәнен күрсәтү, аеру, кешеләре белән аралашуны тыю өчен билге, тамга буларак, авылга керә торган юл башына утыртып куелган багана (һәр юлаучы бу авылны урап узарга тиеш була); кара багана. *Падишаһ хәзрәтләре бу Сиражҗи мәхдүмнең авылы башына кара гачи агачы, ягъни кара багана утырттырганнан бирле, аннан хәбәр болайга таба чыкмый, аларга таба хат-мәктүп ирешми иде.* Ф.Яхин

**ГАШЕ́ТКА** *и. фр.* Утлы коралларда (гадәттә, автоматик коралда) курокны ычкындыру җайланмасы. *Огонь! – лётчик шулай диюгә, ромблы кеше гашеткаларны кысты – тек-тек, тек-тек.* Г.Гобәй. *Хәтеремдә кулы белән чак кына сизелерлек хәрәкәт ясавы уелып калган: --- үз уендагы пулемёт гашеткасына басуына шикләнмәдем.* Ә.Гаффар. *Солдат шинеленең якасын күтәргән, кечкенә башы пилоткага сыеп беткән, пулемёт гашеткаларын җайлап маташа иде.* Х.Камалов

**ГАШИР** *и. гар. иск.* Гошер алучы, гошерне аласы кеше

**ГАШИРӘТ** *и. гар. иск.*1) Кабилә, ыруг, кавем. *Сәгыйд, моны күрү белән, үзләренең Гарәбстандагы гаширәт башында шәех урынындагы кеше икәнен аңлады.* Г.Гобәйдуллин

2) Туганнар, кардәшләр

**ГАШИШ** *и. гар.* Һинд киндеренең чәчәкләре бүлеп чыгара торган, составында нерв системасына көчле тәэсир итә торган агулы каннабиол матдәсе булган, шуңа күрә наркотик саналган яшькелт көрән төстәге исле сумалалы матдә. *Габделнур гашиш, анаша кебек әйберләрнең зеклар жаргонында «план» дип йөртелүен бу участоктан киткәндә дә белмәде.* Р.Кәрами. *Наркотик матдәләр группасына опийдан алынган матдәләр (морфин, героин, кодеин), барбитуратлар, кокаин, гашиш һәм алкоголь керә.* Сәламәтлек нигезләре

**ГАШҮРӘ** *и. гар.* Мөселман календаре буенча мөхәррәм аеның унынчы көнендә үткәрелә торган дини бәйрәм. *[Иманкол] Бүген бит гашүрә бәйрәм көне, шул турыда бераз халыкка вәгазь сөйләмәкче булам.* Т.Гыйззәт

**ГАШЫЙК** *с. гар.* **1.** 1) Берәр кешегә мәхәббәте төшкән, яратучы, сөюче. *Нәркәсне сөйгән Иштирәк батыр, Гашыйк егеткәй – арыслан тотар.* Н.Әхмәдиев. *Еракларда карашлары белән Тартып алды, зарыгып, гашыйк күз.* Х.Әюп. *Кайда соң Сез сәмәви рухлы, Гашыйк җанлы Фәрхад, Ширин-нәр?* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) *күч.* Бер эшкә, шөгыльгә бик нык бирелгән, бер нәрсә белән бик кызыксынган, мавыккан. --- *заводта токарь булып эшләү чорында, мин инде техникага гашыйк кеше булып җитлеккән идем.* А.Расих

**2.** *и. мәгъ.* 1) Мәхәббәт тотучы кеше, яратып йөрүче, сөюче. *Һушәң шаһ, бу ике гашыйкның серләрен әүвәлдән үк белгәнгә күрә, үзе ике арада яучы булып, --- бу ике гашыйкны бер-берсенә кавыштырдылар.* Дастан. *Кәккүкләр бу гашыйкларга Тигез гомер юрады.* Ф.Яруллин. *Ихтимал, бу көнне өстәл тирәсенә бары тик гашыйклар гына җыелган булгандыр...* Р.Мирхәйдәров

2) Берәр нәрсә белән мавыгучы, шуны яратучы, аңлаучы, кадерен белүче. *Китап гашыйгы. Билгеле инде, бу – гүзәллек гашыйгы, аңа карап, үзен мәхәббәттән өстен тотканы юк.* Н.Исәнбәт

**3.** *хәб. с.* Ярату хәлен, мәхәббәт тоюны, кемгә яки нәрсәгә дә булса тартылуны белдерә. *Беләсең, ат белән хатын-кызга үлеп гашыйк бит мин!* З.Хөснияр. *Митя аерата Сәйдәш музыкасына гашыйк.* А.Расих. *Китапка балачактан ук гашыйкмын. Аз гына вакыт тидә исә, хәзер дә кулыма китап алам.* Сөембикә

**ГАШЫЙКАНӘ** *рәв. гар.-фар. иск.* Гашыйк кеше кебек, гашыйк булган кебек, гашыйкларча. *Боны аңлап, менла, Хәнифәя гашыйканә бер казар итеп, диде ---.* М.Акъегет

**ГАШЫ́ЙК БУЛУ** *ф.* 1) Ярата башлау, мәхәббәт төшү, сөю хисе уяну. *Гүзәл һинд кызы Лакме үз илен басып алган Англия армиясендәге бер офицерга гашыйк була.* М.Мәһдиев. *Гашыйк булудан, гадиләштеребрәк әйтсәк, үзең танып белгән дөньяны яратудан шагыйрьлек башлана.* Л.Лерон. *Кыз бик чибәр дип сөйләделәр Мәрьямгә аның хакында, үткен, өлгер дә икән үзе. Шәүкәткә бер күрүдә гашыйк булган, имеш.* М.Маликова

2) *күч.* Бик нык кызыксыну, мавыгып китү, мөкиббән китү (берәр шөгыль, күренеш һ.б.ш. турында)

**ГАШЫ́ЙК ИТҮ** *ф.* 1) Яраттыру, сөйдерү, үзенә карату. *Ярамый кызлар күрергә. – Гашыйк итеп куялар.* Г.Сәгыйров. *Тоймый, күрми калу мөмкин түгел: бу күксел күзләрнең офыгы шулкадәр киң, чиксез, Самат хәтта куркып куйды: гашыйк итә күрмәсен тагы!* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Игътибарны тарту, мавыктыру, җәлеп итү. *Аны гашыйк иткән нәрсә – артистларның осталыгы, режиссёрның табышы.* Ф.Яруллин. --- *шахмат буенча спорт мастеры Азамат бу уенга бөтен дусларын да гашыйк итте.* М.Кәбиров

**ГАШЫЙКЛА́РЧА** *рәв.* Гашыйк булган кеше кебек, гашыйкларга хас булганча. *Чыгар мине бәхет сукмагына, Дәртле чишмәләргә тиендер! Кыяларга басып, гашыйкларча, Күкрәгеңә башым иим бер!* С.Гәрәева

**ГАШЫЙКЛЫК** *и.* Сөю хисе, мәхәббәтле мөнәсәбәт, сөю халәте. *Сүз дә кирәкми. Күз карашлары аңлатты гашыйклыкның җитдилеген.* С.Поварисов. *Шулай башланган гашыйклык галәмәте көн саен Рәмзияне үзгәртә барды: күз карашына моң салды, тавышына ягымлылык кертте, күңеленә шәфкать өрде.* К.Тимбикова

**ГАШЫЙК-МӘГЪШУК** *җый. и. гар.* Бер-берсен яраткан кешеләр, бер-берсенә гашыйк булган кешеләр, ике яр. *Гашыйк-мәгъшук икәве дә бичаралар ул залимнең зыкмыннан кара таш булып калдылар ---.* Дастан

**ГАШЫ́ЙК ТОТУ** *ф.* Яратып йөрү. *Яшьлегемдә һәрбер чибәр кызга Гашыйк тоткан идем мин исәр.* Н.Әхмәдиев

**ГАЯ** I *и. гар. иск.* **1.** Чик, соң, ахыргы нокта; нәтиҗә. *Һәрбер нәрсәнең гаясе бардыр.* К.Насыйри

**2.** *рәв. мәгъ.* Соң дәрәҗәдә, бик нык

**ГАЯ** II *и. гар. иск.* Идея. *Соң көннәрдә Русия кенәҗләре арасында хыялый йиңеллек илә таралган яңа бер гая --- Гаязның даим гадәләт вә сәгадәт аркасында йөгерməктә армый торган хәссас рухыны тиз кулына алды.* Й.Акчура. *Тарихның гаясенә килсәк, анда да төрле фикерләр очрата аламыз: тарих вәгазь булырга кирәк, вөҗдан кагыйдәләрен өйрәтергә кирәк, диләр ---.* Г.Гобәйдуллин

**ГАЯН** *с. гар.* **1.** Ап-ачык, билгеле, күренеп торган

**2.** *хәб. сүз* Билгеле, чын булу. *Күрәмсез: бу кырык башлы чаян бит, Ачык күз алдыңызда бит, гаян бит.* Г.Тукай

**ГАЯ́Н ИТҮ** *ф. иск.* Ачып бирү, күрсәтү, ачыклау. *Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит, Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.* Дәрдемәнд

**ГАЯ́Н КЫЛУ** *ф. иск. к.* **гаян итү**. *Көч йитәрчә кылайым барча гаян.* Мөхәммәдьяр

**ГАЯРЬ** *с. гар.* **1.** 1) Батыр йөрәкле, дәртле, кыю. *Озак еллар сугышта йөреп каты куллыланган, кырысланган бу гаярь кеше балаларны шулай өзелеп ярата торгандыр, йөрәгендә шундый нечкәлекләр саклангандыр дип, кем уйлаган?* Г.Бәширов. *Бүре каны эчкән ир бала гаярь булыр, дия иде мәрхүм бабаң.* Н.Гыйматдинова. *--- ул көн-төн эштә, булмаганны булдырырга сәләтле гаярь ир-егет.* Казан утлары

2) Көчле, нык гайрәтле, кодрәтле. *--- имән яфракларын сыйпаган кулын күрде, сөенеч белән аралашкан гаярь тавышын ишетте һәм шул җитте: йөрәктә дөрләп ут кабынды.* Н.Гыйматдинова. *Көчсезлегең күреп, йөрәк әрни – Кайда синең гаярь чакларың?..* Л.Лерон

**2.** *и. мәгъ.* 1) *иск.* Баһадир, пәһлеван (дошман баһадирын икәүдән-икәү ачык көрәшкә чакырып, сугышның нәтиҗәсен хәл итүче сугышчы). *Син әле чын гаярьләрне күргәнең юк икән, менә минем бер Дизид Әфсәр исемле гаярем бар, син аны күргән булсаң, Кәрдән Кешанны бу кадәр мактап утырмас идең ---.* Дастан

2) Батыр кеше. *--- арадан иң тәвәккәл һәм гаярьләре үз җаен үзе карарга керешә.* С.Шәмси

**3.** *рәв. мәгъ.* Батырларча, нык булып. *Шулай да ул үзен егетләрчә гаярь тотарга тырыша.* Ш.Маннапов

**ГАЯРЬЛӘНҮ** *ф.* Батыраю, кыюлану. *Йөргән таш шомара, диләр. Турганов күзгә күренеп гаярьләнә иде.* Х.Камалов. *--- алдагы көнебезгә ышаныч бар әле. Тәтешлеләрнең тыгыз иген кырлары, дөньяда барган ыгы-зыгыларга карамыйча, гаярьләнеп эшкә керешкән авыл кешеләре раслый бу ышанычны!* М.Галиев

**Гаярьләнә башлау** Гаярьлек билгеләре беленү

**Гаярьләнә төшү** Бераз гаярьләнү

**Гаярьләнеп бару** Торган саен ныграк гаярьләнү. *Дөрес, башка регионнарда хатын-кыз киллерлар гаярьләнеп бара диләр.* Т.Галиуллин

**Гаярьләнеп китү** Билгеле бер моменттан соң гаярьләнү, батырлыгы арту

**ГАЯРЬЛЕК** *и.* 1) Кыюлык, батырлык, дәртлелек, егетлек. *– Әй, гаярь егет, һич гаярьлек күрсәтә алмадың, гаярьлек шундый буламени, – дип, күп шелтә кылды вә орышты.* Дастан. *Зәкиев озак сөйләде, тик Сәхи күңеленнән аның сүзләрен ниндидер гаярьлек белән кире кага барды.* Ф.Яруллин. *Матросларның батыр гына килеп керүләре, чишенеп, үз өйләрендәге кебек иркенләп йөрүләре, тәмәке тартып җибәрүләре Билалга да гаярьлек өстәде.* А.Таһиров

2) *иск.* Сугышчы хезмәте, хәрбилек. *--- Дизид Әфсәр шәкертләре белән бергә, гаярьлек киемнәрен киеп, Ислам гаскәре арасында төрле мәкер вә хәйләләр кылырга форсат вә вакыт эзлиләр иде.* Дастан. *Кәрдән Кешан гаярь --- гаярьлек әсбапларын янына алып, хәлифәсе Ширпәнҗә белән һинд гаскәренә таба юнәлделәр.* Дастан

**ГАЯСЕЗ** *с. иск.* Идеясез, максатсыз

**ГАЯСЕЗЛЕК** *и.* Идеясезлек, максатсызлык

**ГАЯТЬ** *рәв. гар.* Шактый, бик, ифрат, артык. *Хөсәен карт һәрбер язны гаять көтеп, рәхәтләнеп каршы ала, язның һәрбер сулышын, аның һәрбер хәятын күзәтә, шуннан зур ләззәт аладыр иде.* Г.Гобәйдуллин. *Менә торган баскычы гаять тар, текә, ике кеше очрашса, үтәрлек түгел.* Ә.Еники

**ГӘБА** *и. гар. к.* **габа**. *Сәгыйд вә Кәрим, бик матур гәба һәм башларына ап-ак чалма киеп, --- атларга атланып, сарайга киттеләр.* Г.Гобәйдуллин

**ГӘВЕР** *и. гар.* Кяфер, динсез, гавер. *Бу гәвер менә серен чыктырмай, Ак мәсҗедләр салдырмай... Кайтмам да!* Әкият

**ГӘҖИТ** *и. сөйл. к.* **газета**. *--- хикәя язачакмын. Ай-яй кызык булачак ул. Гәҗиттә басылып чыккач, укып исегез китәр әле.* Н.Мадъяров. *Чираттагы мәкаләсе – Казан гәҗитендә басылганы – бөтен районны дер селкетте.* Ф.Баттал

**ГӘЗИТ** *и. сөйл. к.* **газета**. *Казаннан килгән татарча гәзитләрне никадәр җентекләп укымасын, берничек тә андый институт барлыгын белә алмады.* Н.Фәттах. *Күптән түгел генә гәзиттән укыдым. Франциядә бер рельслы тимер юллар сала башлаганнар, ди.* Р.Вәлиев. *Өйдә, телевизор карап, Гәзитләр актарганда, Экрандагы сәгать кинәт Китереп сукты аңга...* Л.Лерон

**ГӘЗИТӘ** *и. сөйл. к.* **газета**. *– Гафу итеңез, бу гәзитә нинди телдә язылган? – дип сорады.* Ф.Әмирхан. *Озак та үтмичә, «Игенче вә һөнәр» исемле бер гавам гәзитәсе чыга башлый.* Ж.Вәлиди

**ГӘЗНИЧ** *и. диал.* Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан, каурыйсыман яфраклы, аш тәмләткеч, яшелчә һәм терлек азыгы буларак файдаланыла торган ике яки күпьеллык үлән үсемлекләр ыругы; куян тубыгы; *русчасы:* **пастернак**

**ГӘЛӘФИ** *и. сөйл. к.* **галифе**. *--- мөдир аркалыкларны тартып-тартып*

*куйды, аннан соң кулын иснәде, бармакларын гәләфиенә сөртте.* А.Гыйләҗев. *Капка төбендә, зәңгәр гәләфи чалбарыннан тузан каккалап, терсәккә кадәр күн перчатка кигән чибәр старшина тора.* М.Мәһдиев

**ГӘП** *и. фар.* Сүз; үзара сөйләшү, әңгәмә. *Куеп тор, инде сөйләмә юк-бар гәбеңне ---.* Дәрдемәнд. *Әйтик, сиңа унсигез яшь, Бер чибәргә күз төшә. Сүз катасың, озатасың – Гәп куера, сүз «пешә».* Ф.Яруллин. *Гәп әлеге дә баягы хәмер тирәсендә куера.* М.Дусай

◊ **Гәп кору** *к.* **гәп сугу**. *Шундый токым белән горур картлар, Утырып алып җайлы урынга, Гәп коралар, Селекция фәне Һәм яхшырту фәне турында* Х.Туфан. *Һиндләр аз сүзле, үзара җай гына гәп коралар.* М.Мәһдиев. **Гәп куерту** *к.* **гәп сугу**. *Шактый озак сөйләшеп утырды алар. Телгә ни килә, шул хакта гәп куерттылар.* С.Поварисов. *Дон Кихот белән Санчо Пансоны хәтерләткән ике егет, банкаларындагы сыраны ара-тирә йоткалап, бер тәмәкене алмаш-тилмәш суырасуыра, гәп куерта.* Л.Лерон. **Гәп кузгату** Сүз башлау, нинди дә булса бер темага кереп китү. *Нигә бу юк кына нәрсә турында гәп кузгаттың диярсез.* Г.Тавлин. **Гәп ору** *к.* **гәп сугу**. *Миңа нинди пачут шәп! Нинди генә орам гәп!* Г.Камал. **Гәп сату** *к.* **гәп сугу**. *Чәй эчәбез, беребездә яңа, моңарчы күренмәгән чәй әйберсе пәйда булса, кысташып сыйланабыз, яки инде болай гына яңалыклар уртаклашып гәп сатабыз.* А.Расих. *Иң әүвәл көннәрнең торышы, эш барышы, иген уңышы турында гәп саттык.* М.Хәсәнов. **Гәп сугу** Сөйләшеп утыру, әңгәмә кору. *Кичен, өреле куе кара балык ухасы ашап, сүнәр-сүнмәс янган учак тирәсендә озак кына гәп сугып утырдылар.* А.Гыйләҗев

**ГӘП-ӘҢГӘМӘ** *җый и.* Сөйләшүләр, фикер алышулар, әңгәмәләр, бәхәсләр

**ГӘПЛӘ́Ү** *ф. диал.* Сөйләү, әйтү. *Гәпләсәң, әйбәт гәплә*

**ГӘПЛӘШҮ** *ф.* Үзара сөйләшү, әңгәмә кору. *Җәмг улыб өч-дүрт кеше һәр чат саен, Гәпләшеп кайгырталар Башның хәлен.* Г.Тукай. *Чуерташлар өстенә түгәрәкләнеп утырганнар да гәпләшәләр.* М.Мәһдиев. *Тормыш хәлахвәлләре турында сүз куерып китә – онытылып гәпләшәбез.* Ф.Баттал

**Гәпләшә башлау** Гәпләшергә керешү. *[Колхоз рәисе] Уңышларын да, проблемага әйләнеп торган мәсьәләләрне дә ачыктан-ачык әйтеп гәпләшә башлады.* Х.Вәлиәхмәтов

**Гәпләшә бирү** Бернигә карамый гәпләшүне дәвам итү; һаман гәпләшү. *--- кемгә генә инәлеп баксам да, күз карашларын тоталмыйм: күзләрен кая туры килде, шунда текәгәннәр дә рәхәтләнеп гәпләшә бирәләр.* Җ.Дәрзаман

**Гәпләшеп алу** Аз гына, кыска вакыт аралыгында гәпләшү. *Ул арада чумнан тагын бер ир, матур туннар кигән ике хатын, өч бала чыкты. Алар үзара гәпләшеп алдылар.* Р.Кәрами. *Бераз гәпләшеп алганнан соң, бер карарга килделәр: «Барчабыз акча җыелышып, Аннага нинди дә булса аяк киеме сатып алырга».* Ф.Зыятдинов

**Гәпләшеп китү** Сөйләшә башлау, әңгәмәгә керү. *Нәгыйм минем белән бер сүз, ике сүз гәпләшеп китте.* Ш.Камал

**Гәпләшеп тору** Шактый вакыт гәпләшү; хәзерге моментта гәпләшү, гәп белән мәшгуль булу. *Әмир регистратура янындагы чиратка баскан, алдындагы ике ир-ат белән гәпләшеп тора.* М.Насыйбуллин. *Алар гәпләшеп торган арада, каршы бүлмәдән зифа буйлы, кара чәчле мөлаем гына бер кыз килеп чыкты ---.* З.Фәтхетдинов

**Гәпләшеп утыру** *к.* **гәпләшеп тору**. *Безгә кереп утыр, Әнисә түти! Гәпләшеп утырырбыз ---.* Р.Хәмид

**ГӘПТӘШ** *и.* Әңгәмәдәш, бергә сөйләшеп утырган, әңгәмәдә катнашкан кеше. *Гәптәшләр арасында зыялы гына кешеләр дә: врачлар һәм инженерлар, галимнәр һәм язучылар, укытучылар һәм җитәкче работниклар булгалый...* Ә.Кәримуллин. *Ул арада, әлбәттә, әни аш-су хәстәрләп, әтигә шыпырт кына табын янына кучү кирәклеген сиздерер, шуннан инде гәптәшләр күчеп утырышыр, әти үзенең кунагын сыйлап җибәрер иде.* К.Миңлебаев. *Уйлап әйтәсеңме син моны дигәндәй, гәптәшенә текәлеп торды.* Х.Камалов

**ГӘР** *терк. фар.* Әгәр. *Иртәгә килгәнче дуслар, тәндә җаным торса гәр ---.* Г.Тукай. *--- тел ясалмас, гәр туган сүз ятмаса үз ибенә!* Дәрдемәнд. *Төшсә гәр загъ күзәйе саббага тависмы улыр?* М.Акмулла

**ГӘРӘБӘ** *и.* **1.** 1) Борынгы ылыслы агачларның чәере катып, шуннан барлыкка килгән, ачык балавыз төсеннән алып куе кызылга кадәр төсләрдә булган, медицинада, приборлар, бизәнү әйберләре ясауда кулланыла торган таш. *--- аннан яңа күлмәкләр, яулыклар, эре гәрәбәдән тезгән муен төймәсе, яңа резин галош, бер кисәк исле сабын һәм бер-ике кечкенә тартма чыгарды.* Ә.Фәйзи. *Дулкыннар ярларга Ашкынып җан ата, Җир әнкәм, сиңа дип, Гәрәбә тарата.* Ш.Галиев

2) Шул таштан ясалган муенса, брошь һ.б.ш. бизәнү әйбере. *Муендагы гәрәбәмне Өзәмен дә тезәмен. Өзелә үзәккәйләрем, Өзелсә дә түзәмен.* Җыр. *Муенында ике рәт эре гәрәбә. Чәч юлы кыл уртадан ярылган.* М.Мәһдиев. *Кызыл чәчәк төшкән утыртма якалы күлмәктән, муенында куе көрән гәрәбәләр.* Ә.Гаффар

**2.** *с. мәгъ.* 1) Әлеге таштан эшләнгән. *Уемда – туган як, Йөрим яр буенда. Җыям мин әнкәмә Гәрәбә муенса.* Ш.Галиев. *--- ул өстәл өстендә Рәшиткә бирелгән гади генә бүләкләрне күрде: портсигар, гәрәбә мөштек, тар гына ак атлас шарф ---.* Р.Мирхәйдәров

2) Матур сары төсе белән шул ташны хәтерләткән (гадәттә, сокланып, мактап әйтелә). *Халык тирләп-пешеп беренче буразналарга бодай сибә, борынгылар әйткәнчә, сабанда сайрашып, ярышып эшли, өр-яңа ындырларда беренче бай уңышны – гәрәбә бодай өемнәрен күрергә өметләнә иде түгелме соң?* И.Салахов. *Менә мин өч ел буе байда ат карадым, бай атларына гәрәбәдәй солы бирә торган идем.* М.Мәһдиев

**ГӘРӘНКӘ** *и. бот.* Әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан, шалканга охшаш ике еллык яшелчә; *русчасы:* **брюква.** *Элек безнең станциядә пары өч тиенгә ат башы хәтле кап-кайнар*

*гәрәнкәләр була иде. Хәзер тү-тү!* К.Нәҗми. *Эт какысы, кәбестә, редиска, шалкан, торма, гәрәнкә (төче торма), шеббуйның җимешләре кузакча формасында.* Биология. *Гәрәнкә һәм рапс орлыклары кәбестә орлыгыннан коңгыртрак төсләре һәм түгәрәгрәк формалары белән аерылалар ---.* Яшьчелек

**ГӘРДАП** *и. фар. иск.* Упкын, чоңгыл, тирән чокыр. --- *ахшам якын булдык вакытда, көймәм бер гәрдабка тугыры килеп, көймәм, әйләнеп-әйләнеп, бер тарафка ук кеби атылып, бер җәзирәгә барып чыкты.* Ф.Халиди. *Күз алдында гарасат капылт кына дуамаллана да мине гәрдап кырыена китереп асылындыра, шул упкынга очмас өчен, бармак очларым уелып-ертылып беткәнче тырышам.* М.Хуҗин

**ГӘРЕЗ** *и. сөйл. к.* **гарыс**

**ГӘРНИЧ** *и. рус иск. сөйл.* 1) 3,28 литрга тигез үлчәү берәмлеге; *русчасы:* **гарнец**

2) Тегермәндә ярма ярдырган, он тарттырган яки сепараторда сөт аерткан өчен, натуралата бирелә торган түләү

**ГӘ́РЧӘ** *терк.* Иярчен кире җөмләне баш җөмләгә терки торган иярт үче теркәгеч. *Гәрчә тел әйләндереп сүзен әйтә алмаса да, рәхәт булып китте безнең бәләкәй һөнәрчебезгә.* Ф.Хөсни. *Гәрчә портреттагы кешене син беркайчан да күрмәгән, аның белән бер җирдә дә очрашмаган булсаң да, аның хакында озаклап, вәземләп сөйли алачаксың...* Г.Ахунов. *Гәрчә сүз монгол-татар, Чыңгыз хан яки Бату урдалары турында барса да, укучы аларны Казан татарлары белән тиңләштерә.* К.Гыймади

**ГӘҮДӘ** *и.* 1) Кешенең яки хайванның физик яктан конкрет формада чагылган бөтен организмы; *русчасы:* **тело**. *Ул, үз колакларына үзе ышанмыйча, кинәт бөтен гәүдәсе белән ишеккә борылды.* А.Сафин. *Уйлап кына кара, кулында – ярты гәүдәсен паралич суккан авыру әнисе. Эше, тегесе-монысы. Шуның өстенә мең төрле мәшәкать.* М.Хәсәнов

2) Кешенең башы һәм очлыкларыннан башка тәне; *русчасы:* **туловище**

3) Тән төзелеше, буй-сын, килешкилбәт. *Хәтерлисеңме икән: җирән сакаллы, мәһабәт күркәм гәүдәсе өстенә, холкы-фигыле дә күркәм иде мәрхүмнең.* А.Гыйләҗев

4) Үлгән кеше, җәсәд, мәет. *Инде кар томалап өлгергән канлы эзләрне яңадан җентекләп актардылар, Савченко гәүдәсе табылган урыннан өч метр ераклыкта да канлы эзләр булуы беленде.* Х.Вәлиәхмәтов. --- *халык теленә «авыл хәбәрчесе» дигән абруйлы аты чыккан Үшән Халәпне үтереп ташладылар. Гәүдәсен су буена төшә торган караңгы тыкрыктан – Иргалиләрнең коймасы буеннан табып алдылар.* М.Хәсәнов. *Заһриның гәүдәсен докторлар районнан ике көннән соң гына биреп кайтардылар.* М.Мәһдиев

5) *диал.* Өс киеменең билдән өстәге өлеше; кыса. *Күлмәкнең гәүдәсен тегү*

6) *тех.* Аерым детальләр һәм агрегатлар урнаштырыла торган нигез, кыса, каркас. *Двигательнең барлык механизмнары урнаштырылган гәүдәсе «блок-картер» дип атала.* Тракторлар һәм автомобильләр

**ГӘҮДӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Әдәби образлар ярдәмендә ачып бирү, чагылдыру. *Элеккеге әдипләребез кешеләрдәге уңай әхлакый сыйфатларны еш кына аларның тискәреләре белән бергә гәүдәләндерәләр.* Х.Миңнегулов. *Шагыйрь халыкның уңай кеше турындагы хыялына якын образ тудыра, аның ирекле һәм саф мәхәббәт хакындагы күзаллавын сәнгатьчә нәфислек белән гәүдәләндерә.* Т.Галиуллин. *Менә бу шигырь яшь шагыйрь иҗатында киң чагылган бер сыйфатны иң калку итеп гәүдәләндерә.* Казан утлары

2) Образны, күренешне, вакыйганы аңлатып бирү, сурәтләү, тасвирлау. *Ханбикә язмышы аша халык дәүләт, милләт язмышын гәүдәләндерергә теләгән.* Р.Мостафин. *Шул ук вакытта классик реализм кеше табигатенең аерым бер ягын кабартып гәүдәләндерү традициясен дә кире какмады.* Ф.Хатипов. *Яшь шагыйрьләр әнә шулай итеп үзләренең лирик геройларын гәүдәләндерәләр.* Казан утлары

3) Сәхнәдә, фильмда герой ролен уйнау, шуның образын тудыру. *Аның иҗат биографиясен безнең замандашлар, тарихи шәхесләр, акыл ияләре бизи. Ул аларны үзенә генә хас романтик дәрт белән тормышчан итеп гәүдәләндерә.* И.Илялова

4) Идея, фикер, хис, сыйфат һ.б.ш. чагылышы, символы булып хезмәт итү. *Гомумән, Агыйдел елгасы, ни өчендер, татар халкында Ана йорт образын гәүдәләндерә.* Ф.Урманчеев

**Гәүдәләндерә бару** Эзлекле рәвештә гәүдәләндерү. *Шигырьләрен укыган саен, үз алдымда аның үземчә булган кыяфәтен дә күз алдымда гәүдәләндерә бара идем.* Г.Камал

**Гәүдәләндерә башлау** Гәүдәләндерүгә керешү. *Әмма тиздән аңа бабайлар образын да гәүдәләндерә башларга туры килә.* Ф.Фәтхи. --- *ул [Такташ], күбесенчә, Октябрьдән соңгы авыл күренешләрен, социалистик кырлар һәм шәһәр күренешләрен гәүдәләндерә башлый.* Каһарман каләме

**Гәүдәләндереп бирү** Тасвирлап чыгу, һәрьяклап гәүдәләндерү. *Сиңа Галиябануның көчле, саф мәхәббәтен гәүдәләндереп бирергә кирәк булачак.* Г.Бәширов

**Гәүдәләндереп килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә гәүдәләндерү. *«Иреклелек, тигезлек һәм гаделлек» лозунгы гасырлар буе хезмәт ияләренең изге теләкләрен гәүдәләндереп килә.* К.Гыйззәтов

**Гәүдәләндереп тору** Даими рәвештә гәүдәләндерү. --- *халыкның туган һәм үскән нигезен, яшәү нигезен гәүдәләндереп торучы якты, матур образ да бит әле ул учак.* М.Вәлиев

**Гәүдәләндереп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, беткәнче гәүдәләндерү; берсен дә калдырмыйча, барысын да гәүдәләндерү. *Бу язучыларның барысы да диярлек 1905 елгы революция ялкыны белән күтәрелеп, шул чорның алдынгы, прогрессив идеяләрен гәүдәләндереп чыктылар.* М.Җәлил

**ГӘҮДӘЛӘНЕШ** *и.* 1) Чагылыш үзенчәлеге; гәүдәләндерү рәвеше, гәүдәләндерү дәрәҗәсе. *Кешелекнең «яшьлегендә» иҗат ителгән хыялый*

*образлар, шул заманнарның иҗтимагый фикеренә бәрабәр гәүдәләнешләр соңгы дәвердә яшәүчеләр өчен дә мавыктыргыч, кызыклы булып калалар.* Ф.Галимуллин. *Ләкин фельетон герое, тәнкыйтьчеләр теле белән әйткәндә, тулыканлы гәүдәләнеш тапмаган.* М.Сәлимов

2) Идеянең, фикернең чынбарлыктагы реаль чагылышы, тышчасы. *Без бәйрәм парадларында югары чөеп тоткан портретларның тере гәүдәләнеше, сез кайда идегез?* М.Галиев

3) Билгеле идеяләрнең, фикерләрнең чагылышы, гомумиләштерелгән образы, символы

**ГӘҮДӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Әдәби образ буларак барлыкка килү, тудырылу, бирелү. *Риваятьләрдә дә, шулай ук шигъри әсәрләрдә дә Йосыф газап чигүче булып гәүдәләнә.* К.Гыйззәтов. *Истәлекләрдә Зариф мулла бик мәһабәт кыяфәтле, ачык-мөлаем йөзле, кешеләрнең күңелен тиз җәлеп итүчән зат буларак гәүдәләнә.* Р.Әмирханов

2) Әдәби образ тере кеше буларак сәхнәдә яки фильмда күрсәтелү, роль башкарылу. *Андагы геройлар кыю көрәшче, зур эшләр башкарырга сәләтле көчле кешеләр булып гәүдәләнә.* М.Арсланов

3) Бер шәхестә, предметта аермачык күренү, бергә туплану, тулы чагылу. *Милли характер – реаль күренеш, ул чынбарлыкның үзендә, шулай ук сәнгатьтә дә чагылыш таба. Аның реальлеге нәрсәдә гәүдәләнә соң?* К.Гыйззәтов

4) Күз алдына килү. *Күптән күргән кешеләрнең төсләре, кыяфәтләре, гәүдәләнеп, алдымда хәрәкәтләнә башлыйлар.* Гали Рәхим. *Газизәнең зиһененә килеп күз алдында гәүдәләнгән сурәтләрне аллы-гөлле нур дулкыннары арасында тирбәтә иде...* Ш.Камал

**Гәүдәләнә бару** Торган саен ныграк гәүдәләнү

**Гәүдәләнә башлау** Гәүдәләнүгә килеп җитү. --- *Рәмзи күз алдында ул әкиятләрдәге аждаһа төсле коточкыч дәү авызлы, куркыныч озын тешле явыз ерткыч булып гәүдәләнә башлады.* Г.Бәширов. *Укый торгач, барлык вакыйгалар Искәндәр Бәхтияровның күз алдында театр сәхнәсендәге кебек аермачык гәүдәләнә башлады.* М.Насыйбуллин

**Гәүдәләнә төшү** Бераз гәүдәләнү

**Гәүдәләнеп җитү** Тулысынча гәүдәләнү; дөрес, җитәрлек дәрәҗәдә чагылу

**Гәүдәләнеп килү** Акрынлап, аз-азлап гәүдәләнү. --- *татарның яңа тип мирзалары аерым бер дулкын – аерым агым рәвешендә гәүдәләнеп килгәнлеген күрсәтүче хәлләр булалар.* Г.Ибраһимов

**Гәүдәләнеп калу** Билгеле гәүдәләнеш алып, шул көе саклану. *Патша заманының тупас күсәге – кызыл борынлы исерек урядниклар – аларның яшьлек истәлегендә имәндергеч шомлы карачкы булып гәүдәләнеп калган ---.* Г.Бәширов

**Гәүдәләнеп тору** Даими рәвештә гәүдәләнү. *Фикер үзе чишелеп-ачылып җитмәгән, ул тудырган кәефне тоясың, бербөтен булып гәүдәләнеп торуын сизәсең.* Ш.Галиев

**ГӘҮДӘЛЕ** *с.* 1) Гәүдәсенең аерым бер үзенчәлеге булган. *Вак-вак сипкелле, түгәрәгрәк гәүдәле мөлаем гына бер кыз иде ул.* Э.Касыймов. *Аны пенсия яшендәге, әмма һаман да әле хәрбиләрчә төз гәүдәле, озын гына бер агай каршы алды, күрәсең, яшьлек елларында шактый җитди эшләр белән шөгыльләнгән булгандыр.* Р.Мирхәйдәров

2) Эре сөякле, таза һәм буйчан. *Яшь чакта бу кеше шактый гына гәүдәле булган.* Р.Батулла. *Сыйныфның иң көчле һәм иң гәүдәле малае Ленарның килгәнен дә күргән хәтта.* Р.Галиуллин

**ГӘҮДӘ-СЫН** *җый. и.* Тәннең барлык әгъзалары, бөтен гәүдә. --- *гәүдә-сыным кыйналган эт кебек, уй-хисләрем болганчык, авыр иде.* З.Хөснияр

**ГӘҮҺӘР** *и. фар.* **1.** 1) Асылташ, барлык кыйммәтле ташларның гомуми атамасы. *Куш канатлы алтын таҗ, Күз урынында гәүһәр каш ---.* Дастан. *Алтыннар, көмешләр, гәүһәрләр... Күзләрен яндырган кемнәрнең!* Р.Фәйзуллин. *Янә күп сандал, гуд агачы, гамбәр, Янә төрле җимешләр, күбе – гәүһәр.* Сәйфелмөлек китабы

2) *иск.* Энҗе

3) Тау кристаллы. *Әлеге көндә гәүһәр таш-тау кристаллы тагып йөрергә мөмкин, әмма гәүһәр таш барлык кешегә дә ярамаганны онытмаска кирәк.* С.Шәрипова

4) *күч.* Иң гүзәл сәнгать әсәре, шедевр, иң камил, үрнәк әсәр; шундагы иң матур урын, алым һ.б.ш. *Башкайларың ниләр генә Күрмәде, газиз халкым! Гәүһәрләреӊ юк ителде, Йортыңны алды ялкын.* И.Хөсни. *Әсәрдәге гәүһәрләрне күрмиләр, шул гәүһәрләр асылына сыенган көферлекне эзләп маташалар.* С.Поварисов

5) *күч.* Кешелек кыйммәтләре; рухи, әхлакый, мәдәни һ.б.ш. күзлектән караганда, иң кыйммәтле дип кабул ителгән нәрсәләр. *Туган илгә мәхәббәтебезнең Гәүһәрләрен талый мародёр...* Х.Туфан

**2.** *с. мәгъ.* Гәүһәрләрдән торган, гәүһәрдән ясалган. *Гәүһәр муенса*

**ГӘҮҺӘРЧЕ** *и.* Асылташлар белән эш итүче, ювелир, зәркән

**ГӘҮҺӘРЧЕЛЕК** *и.* Ювелирлык, зәркәнчелек

**ГӘҮҺӘР-ЯКУТ** *җый. и. фар.-гар.* Төрле асылташлар. *Алтын-көмеш – дөньяда, Гәүһәр-якут – дәрьяда.* Мәкаль. --- *очраклы рәвештә генә бер әйбергә күз салдың. Әйтик, гәүһәр-якутлардан тезеп ясалган бер муенсага.* М.Мәһдиев

**ГВАРДЕ́ЕЦ** *и. рус сөйл. к.* **гвардияче.** *Әле чех фетнәчеләре Дәүләкәнне калдырып чыгар алдыннан ук, сигез кызыл гвардеецны атып киттәләр.* Ә.Еники. *Папаның 498 гвардеецы, 142 жандармы һәм почётлы каравылдагы 60 солдаты исәпләнә иде.* М.Мәһдиев

**ГВАРДИН** *и. сөйл. к.* **гвардияче**. *«Нинди молодец, нинди молодец! – дип сөйләнде Идрисов сөенеченнән. – Сталинград гвардины икәне әллә каян күренеп тора».* Х.Камалов

**ГВА́РДИЯ** *и. ит.* Дәүләт башлыгының яки военачальникның шәхси сакчылары. *Аксөякләр – ханны саклый торган гвардия (хан алае) гаскәрләре, боларны «угълан» дип атыйлар.* Г.Гобәйдуллин. *Арада «каучин» дигәне*

*башта, ыру булмыйча, Тимер мирзаның 1000 кешелек шәхси гвардиясен тәшкил иткән.* С.Шәмси. *Татарлар – тырыш һәм эшчән халык. Алар ышанычлы. Юкка гына урыс патшаларын саклаучы гвардия татарлардан оештырылмаган бит.* М.Юныс

2) Иң яхшы, сайланма хәрби частьлар. *Бу сугышчан батырлыгы өчен, гвардия рядовое Хөсәен Гәрәйшин Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.* Ә.Гайнуллин. *Фронттан түш тутырып орден-медальләр тагып кайткан гвардия сержанты Мөхәммәтгали үзенең малаена немец исеме кушкач, аңа каршы бөтен авыл күтәрелә.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Берәр социаль катлауның, дәрәнең, оешманың һ.б.ш. иң алдынгы өлеше. *Минем проза өлкәсенә керүемә Рафаэльдан [Мостафин] башка берәү дә шатланмады. Бигрәк тә өлкәннәр гвардиясе каршы торды.* М.Мәһдиев. – *Үсеп буламы, яшь гвардия!* – *ди бу безгә.* Г.Нәбиуллин. – *Ну, гвардия, тотындык эшкә!* – *диде Габдрахман абый.* Р.Хафизова

4) Кайбер илләрдә махсус полиция яки хәрби берләшмәләрнең исеме

**ГВА́РДИЯЧЕ** *и.* Гвардиядә хезмәт итүче солдат яки офицер. *Урманга кереп бераз баргач, гвардиячеләр: «Бик туңдырды, азрак туктап, аякларны җылытып алыйк»,* – *диделәр.* В.Нуруллин. *Аннары бөтен полк, бердән җиргә чүгеп, гвардиячеләр анты сүзләрен кабатлады.* Ш.Рәкыйпов. *Гвардиячеләр Папаның үзен саклыйлар, солдатлар Изге Пётр мәйданындагы церемонияләрдә катнашалар, жандармнар гадәти патруль хезмәтен башкаралар.* М.Мәһдиев

**ГЕБРАЙ́СТ** *и. рус* Гебраистика белгече

**ГЕБРАЙ́СТИКА** *и. гр.* Борынгы яһүд телен, язуын, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнә торган фәннәр комплексы

**ГЕ́ГЕЛЬЧЕ** *и. филос.* Гегельчелек юнәлешен алга сөрүче фәлсәфәче

**ГЕ́ГЕЛЬЧЕЛЕК** *и. филос.* Немец фәлсәфәчесе Гегельнең идеяләреннән үсеп чыккан, XIX йөзнең 30–40 нчы елларында Германиядә барлыкка килгән идеалистик агым

**ГЕГЕМОН** *и. гр. сәяси* Җитәкче, юлбашчы, әйдәп баручы (гадәттә, эшче сыйныфы турында әйтелә). --- *пролетариат ул хезмәт ияләренә, шулар эчендә хезмәткәрләргә дә җитәкчелек итә. Диктатура мәсьәләсендә гегемон.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Ә минем властьлар өчен куркыныч нәрсәм юк, милли лидер була алмыйм мин, чөнки өскормага түгел, гегемон сыйныфына карыйм.* Идел

**ГЕГЕМО́НИЯ** *и. гр. кит. к.* **гегемонлык**. *Гегемония урнаштыру өчен алып барылган сугышларны гадел һәм азатлык сугышлары белән бутамаска кирәк.* Инсан һәм дин

**ГЕГЕМОНЛЫК** *и.* Гегемон булу; гегемон дәрәҗәсе, гегемон урыны; әйдәп баручы роле. *Күпләргә, әлбәттә, бу хәл ошамый иде, алар үзара чыш-пыш та килгәләделәр, әмма мин үземнең гегемонлыгымнан файдаланып әз генә баш калкыта башладым исә – бар да авызына су каба иде.* Идел

**ГЕ́ЙЗЕР** *и. исл.* Хәрәкәттәге яки күптән түгел генә сүнгән вулканнар зоналарында урнашкан, әледән-әле кайнар су һәм пар бәреп торган чыганак. *Камчаткадагы гейзерлар үзәне. Баганаларның эче куыш, шунлыктан алар ике-өч метр биеклектә катып калган гейзерларга охшап торалар.* А.Муранов. *Камчаткага аяк баскан һәр каderле кунакка сыйның иң зурысы итеп Гейзерлар үзәнен күрсәтергә тырышалар.* М.Маликова. *Кайнар чыганакларда һәм гейзерларда йомырка пешереп була, алардагы суның температурасы кайберләрендә +120° ка җитә.* Кызыклы география

**ГЕ́ЙША** *и. яп.* Япониядә музыка, бию, теләсә нинди темага әңгәмә алып бару, чәй әзерләү церемониясе сәнгатенә һ.б.ш. махсус өйрәтелгән, банкет, мәҗлесләргә кунакчыл хуҗабикә роленә чакырыла, һәрвакыт традицион макияж һәм причёска белән кимонодан йөри торган түләүле хатын-кыз. *Тыңлаучыларга гейшалар самурайларның серләрен ачарга җыеналар, «сакура», «суши», «каратэ» кебек мәдәни стереотиплар турында мәгълүмат бирмәкчеләр.* Л.Шәкүрова. *Еллар җитүгә, Чирмешәненә кайтып китә дә япон гейшалары төсле вак-вак атлап килә кире шәһәргә.* Татарстан яшьләре

**ГЕКЗА́МЕТР** *и. гр. әд.* Хорей үлчәменә хас ахыры булган, алты буынлы дактильга туры килгән шигырь үлчәме

**ГЕКСА́ЭДР** *и. гр. мат.* Алты кырлы геометрик җисем

**ГЕКТАР** *и. гр.-фр.* 10000 кв. метрга тигез җир мәйданын үлчәү берәмлеге. *Гектарыннан тартып-сузып сигез-тугыз центнер арыш алган басулардан егермешәр-утызар центнер уңыш каералар.* Ф.Яруллин. *Инде нибары ике мең гектар чәчәсе җир кала.* И.Салахов. *Биредә менә безнең аркада җиде йөз гектар алма бакчасын су күмә.* Ә.Гаффар

**ГЕКТАРЛАП** *с.* **1.** Бер яки күпмедер гектар күләмендә, билгеле гектар чамасы. *Солыбыз гына да бер утыз гектарлап бардыр әле.* Г.Бәширов

**2.** *рәв. мәгъ.* Гектар белән исәпләгәндә, гектарларга бүлеп. *Урман мәйданнарын гектарлап санар чаклар үтеп бара, һәр агач, һәр яшел яфракны берәмләп санарга туры килмәгәе.* М.Зарипов. *Гаилә башына гектарлап бүлеп бирәләр ул колхоз бәрәңгесен.* К.Кәримов

**ГЕКТАРЛЫ** *с.* Билгеле гектар тәшкил иткән. *Менә бу басу – тоташ дүрт йөз гектарлы мәйдан.* М.Мәһдиев. --- *ялкын гектарлы складның түбә-түшәмен дә, стеналарын да ялый башлады.* Ф.Баттал

**ГЕКТАРЛЫК** *с.* 1) Бер яки күпмедер гектар тәшкил иткән. *Авылдан чыгып бераз баргач, кырык-илле гектарлык җиләк-җимеш бакчасы буена килеп чыктылар.* Г.Бәширов. *Ун километр чамасы юл баргач, түбәнрәк җирдә берничә генә гектарлык урман.* А.Таһиров

2) Бер яки башка билгеле гектарга җитәрлек. *Шуннан кызыксынып китеп, мин аннан бер гектарлык кукуруз орлыгы соратып алдырып, үзебезнең кырга чәчеп карадык.* В.Нуруллин

**ГЕКТО-** *гр.* Физик зурлыкларны атаган кушма терминнарда йөз берәм-

лекне белдергән беренче кисәк (мәс., *гектоватт, гектолитр, гектометр*)

**ГЕКТО́ГРАФ** *и. гр.* Әзер басма текстның яки кульязманың күчермәсен желатин өслеккә алып, шуны күбәйтү өчен үтә гади басу аппараты. *Ибраһим Аитов истәлегеннән Фатихның [Ф.Әмирханның], Гассар белән бергә, гектографта листовкалар басып таратуда катнашканлыгы билгеле.* И.Нуруллин. *Яшерен рәвештә, гектографта басып, «Әлислах» газетасы чыгардылар.* Казан утлары

**ГЕЛ** *рәв.* 1) Һәрвакыт, һәрчак, һаман. *Гел тугры сөйлә, Балам, сүзеңне! Уйнап та алдама, Тыңла сүземне!* М.Фәйзи. *Ачык дәрестән соң әнә гел шулай була.* М.Мәһдиев. *Эштән буш сәгатьләрдә аның кулында гел гармун булыр иде.* Г.Ахунов

2) Бертуктаусыз, өзлексез. *Җилләрдә гел ишелә торды «Тормыш» дигән кибәнегез.* Ф.Яруллин

3) Бары тик, гына. *Улым – өйдә магнитофон, китап, кассеталар, пластинкалар, гитара белән генә яшәгән, дөньяны гел алсу кершәндә генә күреп өйрәнгән улым – чит җирләрдән хат яза.* М.Мәһдиев

4) Бөтенләй, тулысынча. *Утызынчы елларда безнең авыл гел марксистка әйләнде дә бетте.* М.Мәһдиев. --- *игътибар белән укысаң, аларның, киресенчә, гел дөньяви рух белән сугарылган, хәтта кешеләрне гыйш-гашрәткә, уен-көлкегә чакыручы «бидгатьләрдән» торган булуын күрәсең.* М.Госман. *Әллә соң мин гомерем буйларына Гел ят көйләр генә көйләдемме?* Х.Әюп

5) Төп-төгәл, нәкъ. *Халык күңелен дәвалауда Гел табиблар төсле сез. Мәдәниятле, сәнгатьле, Рухиятле кеше сез.* И.Әширов. – *Шахта бабай, бер җырлыйбызмы? – диде. – Әйдә! – диде Габдрахман абзый, гел шуны гына көткән кебек.* Ә.Галиев

6) Һәммәсе, барысы да, барчасы. *Тамашачы да – гел шул ук кешеләр, «концертка» дигән акчалары җыелып өлгерми хәзер.* К.Кәримов

7) Бер дә, һич, әз генә дә. *Һәрвакытта ул җиңгән. Мактаганнар аны һәрчак, Бер дә төшерми телдән. Ләкин Айгыр шатланмаган Бу мактауларга гел дә.* Ф.Яруллин. *Зәлия белән алар институт коридорында гел көтмәгәндә очраштылар.* Р.Вәлиев. *Авылда әле тугыз баш ат бар. Аларның дүртесе гел җигелми, чөнки җигеп йөрер кеше юк.* В.Нуруллин

**ГЕЛӘГӘЙ** *рәв. диал. к.* **гел** (*1 мәгъ.*). *Кояшны иләмсез болыт каплап китсә дә, машинабыз геләгәй юлда имгәкләп ятса да, берәрсе караңгы чырай күрсәтсә дә, шуңа сылтый идек.* Х.Сарьян

**ГЕЛӘН** *рәв. диал.* 1) *к.* **гел** (*1 мәгъ.*). *Сабак бирмәй, таяк бирә гелән ул, Әмәндә үзенең бар алганы шул!* Дәрдемәнд. – *Җәүдәт абзый, кичер инде. Гелән дә алай итмәбез инде, – дигәч, сынау шарты белән, мин аларны калдырдым.* Җ.Фәйзи. *Атларны мин камчы белән түгел, Солы белән куганны белгән. Камчы ысулы белән атларның Сулыш була кысулы гелән.* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) *к.* **гел** (*7 мәгъ.*). – *Аты – Александр, безнеңчә Искәндәр, – диде атасы, гелән исе китмичә.* М.Хәбибуллин. *Мин дә гелән яманлык булып кына кайтты димим ич.* М.Хәсәнов

**ГЕ́Л-ГЕЛ** *рәв.* 1) Һәрвакыт, һаман саен, даими рәвештә. *Җилләр гел-гел дуламаслар, Тынар бер бураны да...* Л.Лерон. *Гел-гел өскә чөелеп йөри торгач, Кул тубы болай дип уй йөрткән: «Мин очамын, димәк, мин канатлы, Мин төшмәскә тиеш биектән...»* Ф.Яруллин

2) Бик еш. *Әйдә, гел-гел туй булмый, әкрен генә бар да җайланыр, бурыч та түләнер дип фикер йөртте.* Казан утлары

**ГЕЛЕ́РТЕР** *и. нем. кит.* Тормыштан аерылган, китап белеменә генә ия булган кеше, сколаст галим

**ГЕ́ЛИЙ** *и. гр. хим.* Инерт газлардан, төссез, иссез, водородтан соң иң җиңел газ, химик элемент. *Гелий һәм азот катнашмасының нормаль халәттәге тыгызлыгы S = 0,60 г/л. Бу катнашмадагы гелий атомнарының концентрациясен табыгыз.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Дөрес, Швейцария инженеры Кемер 1964 елда аквalанг белән 300 метрга төшә, ләкин ул, сулау өчен, һава урынына баллонга кислород белән гелий катнашмасын тутыра.* Кызыклы ихтиология

**ГЕ́ЛИЙЛЫ** *с.* Составында гелий булган; гелий тутырылган

**ГЕЛИКОН** *и. гр.* Тынлы оркестрда иң түбән тавышлы, боҗрасыман уралган киң авызлы торба формасындагы җиз уен коралы

**ГЕЛИКО́ПТЕР** *и. гр.* Вертолёт. *Хушлашып кул болгауга, геликоптер, үкереп, күккә ыргылды һәм мамык кырларына таба борылып очып та китте.* Р.Мирхәйдәров. *Геликоптер уңгарак китте дә параллель курска ятты.* И.Хуҗин

**ГЕЛИО-** *гр.* «Кояшка һәм кояш нурланышына караган», «кояш белән бәйле» мәгънәсен белдереп килгән кушма сүзләрнең беренче компоненты (мәс., *гелиостат, гелиотерапия, гелиограф*)

**ГЕЛИОМОБИЛЬ** *и. гр.-лат.* Кояш батареялары ярдәмендә, кояш энергиясен файдаланып хәрәкәт итә торган автомобиль

**ГЕЛИОЦЕНТРИЗМ** *и. гр.-лат.* Планеталар системасының үзәге – Кояш дип раслый торган, Европада Коперник хезмәтләреннән соң геоцентризмны кысрыклап урнашкан тәгълимат. *Ул Платон һәм Птолемейның (2 гасыр) космологик системаларын юкка чыгара һәм Галәмне аңлатуда Кояшның үзәк урын тотканлыгы (гелиоцентризм) карашын алга куя.* К.Гыйззәтов

**ГЕЛИОЦЕ́НТРИК** *с.* Кояшны үзәк дип таныган, үзәгендә Кояш торган. *Күренекле фикер иясе Николай Коперник 30 елдан артык вакыт буена дөньяның гелиоцентрик картинасы идеясен иҗат итә (грекча «гелиос» – кояш).* Галәм. Җир. Кеше

**ГЕЛЬМИНТОЗ** *и. гр. мед.* Организмга үтеп кергән паразит кортлар китереп чыгарган авыруларның гомуми атамасы. *Шулай ук туберкулёз, бруцеллёз, лейкоз, микроспория, гельминтоз кебек авыруларны вакытында ачыклау максатыннан диагностика үткәрелә.* Шәһри Чаллы. *1954 елда якташыбыз Мәскәүдә «Малларда гельминтоз*

*белән бәйле авыруларны ачыклау һәм нәтиҗәле дәвалау» темасына диссертация яклый.* Кызыл таң

**ГЕЛЬМИНТО́ЛОГ** *и. рус* Гельминтология белгече

**ГЕЛЬМИНТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Паразит кортлар һәм тере организмда алар китереп чыгарылган авырулар турындагы фән

**ГЕМАТИТ** *и.* Тимер оксидыннан гыйбарәт булган, тимер рудасы һәм декоратив таш буларак файдаланыла торган минерал. *Кара металлар алу өчен чимал булып, оксидлар классына кергән минерал рәвешендәге тимер, марганец, хром рудалары хезмәт итә, мәсәлән: магнетит (FeFe2O4), гематит (Fe2O3), пиропизит (MnO2), хромит (FeCr2O4) һ.б.* Төзү материаллары

**ГЕМАТО-** *гр. к.* **гемо-**

**ГЕМАТО́ЛОГ** *и. рус* Гематология белгече. *Нейрохирург, гематолог, проктолог, кардиолог, кардиохирург, пульмонолог, уролог, ортопед-травматолог, кан тамырлары авырулары хирургы белгечләре исә июль аенда ДРКБның яшүсмерләр үзәге базасында кабул итә.* Ватаным Татарстан. *Әти – балалар гематологы, әнием – офтальмолог.* Шәһри Казан

**ГЕМАТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның канның составын, үзлекләрен, авыруларын, аларны дәвалау ысулларын һ.б.ш.ны өйрәнә торган тармагы. *Федераль балалар гематологиясе, онкология һәм иммунология фәнни-клиник үзәге белгечләре Айратка химиотерапия курслары килешми, аны, коткарса, заманча яңа дәвалау методы гына коткара ала дип саныйлар.* Ватаным Татарстан. *– Бигрәк тә травматология, гематология, күкрәк хирургиясе, яңа туган балаларның патологиясе үзәкләрендә һәм бүлекләрендә донор канына ихтыяҗ зур, – ди Раил Рәфис улы.* Кызыл таң

**ГЕМАТО́МА** *и. гр. мед.* Тәннең бәрелгән-сугылган урынында вак кан тамырлары шартлау нәтиҗәсендә, кан саву күренеше, шуның тирәсендә күгәреп торган урын. *Табиблар мондый күңел ачу урыннарында булган үлем очраклары инсульт, баш мие гематомасыннан килеп чыккан дип саный.* Шәһри Казан. *Ә суд-медицина экспертизасында андый гематомалар табылмады.* Акчарлак

**ГЕМО-** *гр.* Кушма сүзләрдә «кан» мәгънәсен белдерә торган беренче компонент

**ГЕМОГЛОБИН** *и. гр.-лат. мед.* Кеше һәм югары төзелешле хайваннарның канында сулыш органнарыннан тукымаларга кислород йөртә торган, составында тимер булган кызыл пигмент. *Әгәр кеше үзе сулаган һаваның кислородын гемоглобинның кызыл кан шарчыкларында калдырып, углекислый газын яңадан чыгарып ташлый икән, «кара алтын» дигәнебез исә һавага углеводород парлары бүлеп чыгара.* Казан утлары. *Кабат эчкәндә, женьшень организмны ныгыта, канда гемоглобин микъдарын арттыра, миокардиодистрофия, гипотония һәм гипертония вакытында организмга уңай тәэсир итә ---.* Урман аптекасы

**ГЕМО́ЛИЗ** *и. гр. мед.* Кандагы эритроцитлар таркалып, гемоглобин бүленеп чыгу күренеше

**ГЕМОРРОЙ** *и. гр. мед.* Туры эчәктә веналар киңәю белән бәйле авыру. *Кассия, эч йомшарткыч буларак, хроник эч кипкәндә, эч күпкәндә, туры эчәклек җәрәхәтләнгәндә һәм геморрой вакытында кулланыла.* Ватаным Татарстан. *Әйтик, бер табиб геморройны дәвалауның иң үтемле чарасын уйлап тапкан.* Татарстан яшьләре

**ГЕМОТЕРАПИ́Я** *и. гр. мед.* Кан кертү: икенче кешенең канын салу, үз канын тукымага җибәрү, каннан ясалган препаратлар кабул итү юлы белән дәвалау

**ГЕМОФИЛИ́Я** *и. гр.* Кан акрын оешу һәм, канда махсус аксым матдәсе җитешмәү сәбәпле, әгъзалар тиз һәм еш канау белән характерланган, ирләр авырый, әмма ана аша нәселдән күчә торган авыру. *Яшь гаиләнең булачак балалары арасында гемофилия авыруы очрау ихтималлыгы нинди?* Р.Зәкиев

**ГЕН** *и. гр.* 1) Конкрет хромосоманың билгеле урынында урнашкан, кабатлану сәләтенә ия булган нәселдәнлек (генетик) мәгълүмат бирәмлеге, нәселдәнлекне йөрткән материаль берәмлек. *Әтәйләрнең геннарыннан күчкән, Иңгән, ахры, сеңгән бу каннарга: «Яшәсен...» дип кычкырасы килә Мәйданнарга чыгып, урамнарга...* Л.Лерон

2) *күч.* Нәселдән килгән берәр характерлы билге, холыктагы яки кыяфәттәге үзенчәлек. *Бу малайларның канында әллә борынгы болгар бабаларыбызның геннары уйный микән дип уйлап куям, Мансур!* М.Мәһдиев. *Сезнең кан тамырларында нинди геннар? Сез бит үзегезне тудырган, үстергән ата-аналарыгызга, әби-бабаларыгызга хыянәт итәсез.* И.Салахов

**ГЕНӘ** *кис. к.* **гына**. *Сөйгән ярын назга күмеп, бәхет бишегендә генә тибрәтү турында кем генә хыяллանмый икән?* М.Маликова

**ГЕНЕАЛОГ** *и. рус* Генеалогия белгече

**ГЕНЕАЛО́ГИК** *с.* Генеалогия фәненә караган, генеалогиягә багышланган, генеалогияне чагылдырган. *Р.Фәхреддинов нәселе хакындагы шәҗәрәнең кульязма вариантлары да бар. Күчермә нөсхә «Иске шәҗәрәләр (нәсел-ыруг язулары)» исемле генеалогик җыентыкның 18 нче битенә язылган.* М.Әхмәтҗанов

**ГЕНЕАЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Ыруның килеп чыгышын, тарихын өйрәнә торган тарихи дисциплина. *Р.Фәхреддинов – тарих, педагогика, тел белеме, әдәбият, философия, сәнгать, география, этнография, генеалогия --- буенча төпле, тирән эчтәлекле хезмәтләр язган галим.* Казан утлары

2) Ыруның тарихы, килеп чыгышы, шәҗәрә

3) Гомумән, берәр күренешнең килеп чыгышы, тарихы. *Шулай итеп, ул татар нәкыш сәнгатенең тамырларын, традициясен эзли, аның генеалогиясен өйрәнә.* Р.Вәлиев

**ГЕНЕ́ЗИС** *и. гр.* Чыгыш, килеп чыгыш, туу, барлыкка килү; үсештәге күренешнең оешу һәм үсү процессы. *Димәк, киләчәктә, дастанның генезисын өйрәнгән чакта, аның тарихи җирлеген бер милли кысалар белән генә чикләп куймыйча --- фикер йөртергә кирәк.* М.Госман. *Кеше генезисының*

*сәбәпләрен ача алмаса да, Ламаркның идеяләре фәнни фикернең үсешенә, хосусан, бөек инглиз табигать белгече Ч.Дарвинга да, гаять зур йогынты ясаганнар.* Галәм. Җир. Кеше

**ГЕНЕРАЛ** *и. лат.* Кораллы Көчләрдә югары офицерлар составының хәрби званиесе һәм шул званиегә ия кеше. *Тәрәздән карыйбыз: кара тарантаста мәһабәт утырган ак сакаллы генерал бара.* М.Мәһдиев. *Фуражкасының маңгаенда хәрби эмблемасы, кулбашында алтын погоннары, йолдызлары булса, аны полковник я генерал дип уйларга да булыр иде.* Н.Фәттах

**ГЕНЕРАЛИ́ССИМУС** *и. лат.* Кайбер дәүләтләрнең кораллы көчләрендә иң югары хәрби звание һәм шул званиегә ия кеше. *Сталинның үзе. Ак мундирдан, генералиссимус погоннарыннан.* М.Мәһдиев. *Моннан кайту белән Мәскәүгә – генералиссимусның үзе янына барачакмын!* В.Нуруллин

**ГЕНЕРАЛИТЕТ** *җый. и. нем.* 1) Армиянең югары командирлары составы, генераллар. – *Сенат генералитеттан үзе теләгән кешене үзе билгеләсен, – дип җавап кайтара [хәрби коллегия].* Казан утлары. *Генералитетның хәрби реформаларга карата фикерен белү*

2) *күч.* Бер өлкәдә иң зур авторитетка ия шәхесләр яки иң югары катлам җитәкчеләр. --- *аның янәшәсендә Мәскәүнең җинаятьчел «генералитеты» – Шаман, Дантес һәм әлегә шәхесен ачыклап булмаган ниндидер чандыр гәүдәле бер әфәнде утыра ---.* Р.Мирхәйдәров

**ГЕНЕРАЛЛА́РЧА** *рәв.* Генераллар кебек, генералларга хас рәвештә, генераллар арасында кабул ителгәнчә. --- *[Курамшин] җәенке борынын күмә язган ап-ак калын мыегын, борынгы генералларча, як-якка сузып, тарап йөртә.* Ә.Еники

**ГЕНЕРАЛЛЫК** *и.* Генерал дәрәҗәсе. *Г.Исхакыйның исә утары-җирләре дә, завод-фабрикалары да, кибет-банклары да, министр-генераллык дәрәҗәләре дә, туплаган алтын-көмешләре дә юк.* Х.Миңнегулов

**ГЕНЕРАЛЬ** *с. лат.* 1) Төп, нигез. *Сүз киләчәк эшебезнең формалары һәм Россиядә мәдәният үсешенең генераль мәсьәләләре турында барды.* М.Сәлимҗанов

2) Гомуми, ныклап эшләнә торган, бик мөһим

3) Эшләнеше ягыннан иң тулы, иң җентекле, төп документ булып санала торган. *Ул арада урман полосаларының генераль планы да газеталарда күренде.* М.Мәһдиев. *Нәрсә, Нурислам энекәш, генераль планга үзгәреш керттегезме әллә?* Р.Вәлиев. *Урам киптерүнең генераль планын расларга торганда, Рөстәм әнисенең ачулы тавышы ишетелде.* Р.Хафизова

4) Аерым бер өлкәне, тармакны, оешмалар яки учреждениеләрне җитәкләгән, баш. *Әйе, Зәлифә дә, башкалар шикелле, татар театры энтузиасты, предприятиенең генераль директоры Лемаев приказы белән ун көнгә эштән бушатылган иде.* Р.Хисмәтуллин. *Генераль прокурор. Генераль подрядчы. Генераль штаб*

5) Хәлиткеч, соңгы, иң әһәмиятле. *Әлеге уеннар һәм бигрәк тә 5 майда куелган спектакльләр 1906 елның 22 декабрендә уйналган әсәрләрнең генераль репетициясе ролен үти.* Р.Әмирханов

**ГЕНЕРА́ЛЬША** *и. рус сөйл.* Генерал хатыны. *[Эмигрантларның ашханәләрендә] Идән себерүче, кашык-савыт юучы – киләчәктә генеральша булырга әзерләнгән мадемуазельләр һәм стажлы карт генеральшалар.* Г.Гали

**ГЕНЕРАТИВ** *с. лат. биол.* Тудыручы; җенси. *Генератив бөреләр, кагыйдә буларак, тышкы күренешләре буенча вегетатив бөреләрдән аерыла.* Биология. *Орлык бирү нормаль яңарсын һәм дәвам итсен өчен, яхшы үскән генератив тармакларның бер өлешен, тимичә, калдыра барырга кирәк.* Урман аптекасы

**ГЕНЕРА́ТОР** *и. лат. тех.* Берәр матдә (мәс., *ацетилен, боз, пар, газ* һ.б.ш.) эшләп чыгара, электр энергиясе җитештерә яки энергиянең бер төрен икенчегә әверелдерә торган җайланма, аппарат яки машина. *Әле кичә генә колхозга генератор алып кайттык...* Ә.Гайнуллин. *Пыяла көпшәнең икенче башына динамик урнаштырып, аңа тавыш генераторыннан билгеле бер ешлыктагы тавыш сигналы бирәләр.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Ягулык, агым су һәм җил энергиясен электр энергиясенә әверелдерү өчен, төрле машиналар – пар һәм су турбиналары, электр генераторлары кулланыла.* Серле кристаллар

**ГЕНЕРА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) *биол.* Бер биологик төрнең бер үк вакытта туган вәкилләре; буын

2) Җитештерү, барлыкка китерү, тудыру. *Соңгы елларда, җиһазларны реконструкцияләү һәм ремонтлау программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә, электр энергиясен иң күп кулланырга мәҗбүр булган вакытларда да, без аның ышанычлы һәм нәтиҗәле генерациясен тәэмин итә алдык.* Ватаным Татарстан. *Махсус стипендия иясе, Казан дәүләт техник университетының техник кибернетика һәм информатика магистратурасында укучы Илья Фёдоров гади кеше колагына бик сәер яңгырый торган өлкә – очраклы саннар генерациясе белән шөгыльләнә икән.* Татарстан яшьләре

**ГЕНЕРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Җитештерү, эшләп чыгару; барлыкка китерү, тудыру. *«Бу ведомствода профессионаллар, экспертлар, дәүләт сәясәте идеяләрен генерацияләргә сәләтле кешеләр эшләргә тиеш», – ди ул.* Татар заманы

**ГЕНЕРА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. к. төш. юн.* **генерацияләү**. *Бүген Татарстанда яңа идеяләр генерацияләнә.* А.Фәхретдинова. *Бу формуладан күренгәнчә, баштагы ешлыктагы нурланышлар белән беррәттән, тирәлектә статик полярлашу туа, икенче гармоникаларда һәм суммар, һәм аерма ешлыкта дулкыннар генерацияләнә.* Фән һәм тел

**ГЕНЕ́ТИК** I *с.* 1) Генетикага бәйле, генетикага мөнәсәбәтле; геннар белән бәйле. *Болай булмый, генетик яктан тикшертергә кирәк сезнең халыкны!* М.Галиев. --- *корылыкта уңыш бирә торган яңа сорт арыш, бодай чыгарырга кирәк. Яңа сорт чыгару генетик юл белән генә була.* Х.Камалов

2) Генезиска бәйле, килеп чыгышына караган. --- *бу ике язма вариантта, кайбер мөһим үзгәлекләр булуга карамастан, генетик уртаклык ык сизелә.* М.Госман

**ГЕНЕ́ТИК** II *и. рус* Генетика белән шөгыльләнүче галим. --- *1927 елда Америка генетигы Г.Меллерның кыска гына бер мәкаләсе басылып чыкты. Совет генетигы А.С.Серебровский фикеренчә, ул биология дөньясын «дер селкетте».* Галәм. Җир. Кеше

**ГЕНЕ́ТИКА** *и. гр.* Организмнарның нәселдәнлек һәм үзгәрүчәнлек законнары турындагы фән. *Генетика галиме академик Тимофеев-Ресовский әйтә торган булган: «Иң кирәк әйбер катлаулы булмый, ә катлаулы әйберләрнең кирәге булмый».* М.Мәһдиев. *Генетиканың бөек ачышларын кире кагып, советчыл Мичурин-Лысенко биологиясе уйлап чыгаручылар – бөтен дөньяны ипи белән тәэмин итә алырлык илне ачтан тилмертүчеләр дә шулар.* А.Тимергалин. *«Генетика» дигән фән белән таныш түгел бугай син, әнкәй.* Р.Вәлиев

**ГЕНИАЛЬ** *с.* 1) Гений югарылыгындагы сәләткә ия, үтә талантлы. *Гениаль галим. Гениаль язучы*

2) Уйлап табу сәләтенең, талантның нәтиҗәсе, җимеше, гений чагылышы булып торган. *Социализмның тигезләү идеясе – гениаль идея бит. Шуны юкка чыгаручы икенче максатны куясы булмаган.* Ф.Садриев. *Прогрессив галимнәр табигатьнең бу серен ачарга күп тапкырлар талпынып карадылар, байтак кына гениаль фикерләр әйттеләр.* Г.Платонов

**ГЕ́НИЙ** *и. лат.* 1) Талантлылыкның, иҗади сәләтнең иң югары дәрәҗәсе

2) Талантлылыкның, сәләтлелекнең иң югары дәрәҗәсенә ия булган кеше. --- *әдәбият-сәнгать даһиларына килгәндә, алар бит явызлык түгел, ә яхшылык генийлары, һәм аларга, кешелекне батыручыдан бигрәк, инсаниятне коткаручы орлыгы салынган була.* Р.Сибат. *Дошманың гел үзен «гений», Сине һаман чүп күрде.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Халык генийны тудыра, үстерә, аңарга тәҗрибә, акыл бирә, кулына корал тоттыра, аны ашата-эчертә, киендерә. Буш урында гений туа алмый!* М.Маликова

**ГЕНИТАЛИЯ** *и. гр.* Җенес органнары

**ГЕНИТАЛЬ** *с. гр.* Җенес органнары белән бәйле, шуңа караган. *Барлык яралгыларның элгәр гениталь структуралары бертөрле, ягъни индеферент – җенесне генетик яктан билгеләүгә бәйсез була.* Фән һәм тел

**ГЕНОТИП** *и. гр.* Организмның барлык нәселдәнлек факторларының берлеге. *Иван Грозный чорында һәм аннан соңгы гасырлардагы катаклизмнар иң чыдам, иң түзем генотип вәкилләрен генә исән калдырган.* М.Юныс. *Кеше генотибында 120000 чамасы ген бар диләр*

**ГЕНОФОНД** *и. гр.-лат.* Бер популяция, группа, төр, ыру, халык һ.б.ш. вәкилләренең геннар җыелмасы, шул берлекнең ген байлыгы. *Минзәлә белән Актаныш тирәсендә инде ул татар кызларының иң гүзәл генофонды.* М.Мәһдиев. --- *бүтән телләрдә иҗат итүче егетләребезне нигә онытырга? Булган дәрт рухларының, иҗат мөмкинлекләренең беразын гына булса да уртак генофондыбыз тамырына нигә тоташтырырга тырышмаска?* Р.Фәйзуллин. *Бу тарихи көрәштә татар милләте үзенең нәсел чыдамлылыгын, генофондның үлемсез булуын раслады.* А.Хәлим

**ГЕНОЦИД** *и. гр.-лат.* Халыкның расасы, милләте яки дине белән аерылып торган группасын эзәрлекләү, үтерү, кыру – кешелеккә каршы кылынган иң явыз җинаятьләрнең берсе. *Бу – чын мәгънәсендә геноцид, чөнки ватаннарыннан куылу вакытында әлеге халыкларның яртысына якыны һәлак ителгән.* Т.Әйди. *Сирин Сабиров үз илендә геноцид процедураларын башыннан кичерә, Акчуриннар исә, чит илгә качып та, коммунистлар эзәрлекләвеннән котыла алмыйлар.* Казан утлары

**ГЕНШТАБ** *и. рус* Кыскартылма: генераль штаб – хәрби җитәкчелекнең иң югары органы. *Һич уйламаганда, дивизиягә генштабтан инспекция килүе беленде.* Ф.Яруллин. *Полковник аптырап калды: – Соң бит бу – хәрби эшелон. Безнең барганны Мәскәү үзе күзәтеп тора. Генштаб.* М.Мәһдиев

**ГЕНШТАБЧЫ** *и.* Генштаб әгъзасы; генштабта хезмәт итүче

**ГЕО-** *гр.* Кушма сүзләрнең «Җир белән бәйле, Җиргә мөнәсәбәтле» мәгънәсен белдергән беренче компоненты (мәс., *геоботаника, геохронология*)

**ГЕОБОТА́НИК** I *и. рус* Геоботаника белгече. *Әйтик, Акжигитова Надирә Ибраһим кызы, геоботаник, биология фәннәре докторы, профессор, Үзбәкстанда яши* ---. Безнең гәҗит

**ГЕОБОТА́НИК** II *с.* Геоботаника белән бәйле, шуңа караган. *Аерым регионнарга хас үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы вәкилләренең атамалары (геоботаник һәм зоонимик терминнар) һәм географик объектның --- характерлы билгеләрен, үзлекләрен белдерүче лексемалар (апеллятивлар) күп кенә җирле топоним һәм микротопонимнарның асылында ята* ---. Фән һәм тел

**ГЕОБОТА́НИКА** *и. гр.* Биологиянең ботаника, география һәм экология белән чиктәш тармагы. *Русия Фәннәр академиясе Уфа фәнни үзәге Биология институтының геоботаника һәм үсемлекләрне саклау лабораториясе мөдире Василий Мартыненко сүзләренә караганда, аеруча сакланучы бу табигать территорияләре биологик төрләргә бай.* Кызыл таң

**ГЕО́ГРАФ** *и. рус* 1) География белгече, география фәнендә эшләүче, география белән шөгыльләнүче. *Күпчелек географлар бу ике фаразны берләштерәләр.* Р.Мостафин. *Дөньяда күлләр бик күп. Ләкин, географлар һәм экономистлар фикеренчә, Каспий шикелле бай һәм үзенчәлекле күл бүтән беркайда да юк.* А.Муранов. *Гарәп географы Идриси тарафыннан 1154 елны сызылган дөнья картасында башкорт кабиләсе урнашкан җирләр Кама елгасының югары агымы ярларында итеп күрсәтелә.* Ф.Гарипова

2) Уку йортында география фәнен укытучы педагог. *Мәктәп, әйткәнемчә,*

*мәшһүр. Директоры – географ Госман Бикташев, яшел френчтән, шахмат уйнарга ярата.* М.Мәһдиев

**ГЕОГРА́ФИК** *с.* Географиягә мөнәсәбәтле, географиягә караган. --- *географик карталарда бөтенләй күрсәтелмәгән шушы елга без телгә алган кешеләрнең язмышында искиткеч зур роль уйнаячак.* А.Гыйләҗев. *Ул заманнарда, бигрәк тә күчмә тормыш шартларында, климатик һәм географик факторлар хәлиткеч роль уйнаган.* Ә.Кәримуллин. *Географик яктан ул Казакстан җире белән янәшә, Төркстан шәһәрләреннән аңа кәрван юлы сузыла ---.* Г.Ахунов

**ГЕОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Җир шарының өслеген, аның табигый шартларын, төрле ресурсларын, халыкларның урнашуын һ.б.ш. өйрәнә торган фәннәр комплексы. *Мәктәптә ул географияне һәм физкультура дәресләрен аерата нык яратты.* А.Гыйләҗев. *Физик географиягә гомуми җир белеме һәм ландшафт белеме керә. География белән чиктәш фәннәр: климат белеме, океанология, геокриология һ.б.*

2) Билгеле әйбернең, күренешнең һ.б.ш. таралышы, урнашу киңлеге. *Китапханәбездә саклана торган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылу географиясе дә шактый киң.* Казан утлары

**ГЕОДЕ́ЗИК** *с.* Геодезия белән шөгыльләнә торган, геодезиягә мөнәсәбәте булган. *60 нчы елларда утрауга геодезик экспедиция килә.* Кызыклар дөньясында

**ГЕОДЕЗИСТ** *и. рус* Геодезия белгече. *Ротада бөтен һөнәр иясе – очучыдан башлап геодезист, элемтәче, танкистка кадәр бар иде.* М.Мәһдиев. *Теодолиттан карый еракка ул, Юнәлешне эзли турыга. Безгә кирәк, кешеләргә кирәк Геодезистлар кебек булырга.* Р.Вәлиев

**ГЕОДЕЗИ́Я** *и. гр.* Җирнең формасын һәм зурлыкларын, мәйданнарны үлчәү һәм җир өстендәге кирәкле нокталарны табу турындагы фән. *Татарстан Дәүләт Советы карары чыкканнан соң, документлар, экспертиза уздыру өчен, геодезия һәм картография федераль агентлыгына җибәрелә.* Мәдәни җомга. *Икътисад министры М.Сафиуллин, 8 март – геодезия һәм картография хезмәткәрләре көне уңаеннан, әлеге тармакта эшләүчеләрне һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.* Мәдәни җомга

**ГЕО́ИД** *и. гр.* Җир планетасының океан өслеге белән чикләнгән фигурасы. *Җирнең чын формасын «геоид» дип йөртәләр.* Кызыклы география

**ГЕО́ЛОГ** *и. рус* Геология белгече; файдалы казылмаларны эзләп табу белән шөгыльләнүче. *Бу башта геолог, юрист, химик булырга хыялланган, әмма аларга кирәрлек әзерлеге булмаган.* М.Мәһдиев. *Геолог, төрле төстәге ташлар күрсәтә-күрсәтә, кайсы урында нинди казылма байлыклар ачканнарын сөйләде.* М.Маликова. *Академик И.М.Губкин җитәкчелегендәге геологлар, махсус тикшеренүләр үткәргәннән соң, Идел белән Урал арасында бик зур нефть ятмалары булырга тиеш дигән нәтиҗәгә киләләр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ГЕОЛО́ГИК** *с.* Геология белән бәйле, геологиягә караган, геология фәненә мөнәсәбәтле. --- *Һиндстан спутнигы, беренче чиратта, метеорология службасына, геологик разведкага, сулыклар, каналлар өчен оптималь мәйданнар сайлап алу максатына хезмәт итәчәк.* М.Мәһдиев. *Әлеге таныклаларның дөреслеген геологик тикшеренүләр дә раслый.* Р.Мостафин. --- *бик борынгы геологик эпохалар заманында хәзерге Кара диңгез, Каспий һәм Арал диңгезләре урынында --- борынгы бик зур Тетис диңгезе булганын ачыкладылар.* А.Муранов

**ГЕОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Җир кабыгының һәм Җирнең тирәнрәк катламнарының составын, төзелешен, үзгәреш тарихын һәм файдалы казылмаларның Җир кабыгында урнашуын өйрәнә торган фән. --- *бар шундый кызлар: йә була университетның әдәбият бүлегеннән, геологиядән, журналистикадан ---.* М.Мәһдиев. *Безнең геология партиясе беркетелгән разведрайон белән янәшә урнашкан боланчылык совхозында үз әнием шикелле якын күреп йөргән эвен карчыгы Анчак бар.* М.Шабай. *Ыссык күл буенда яшәгән халыклар тарихы һәм күл төбәге геологиясе Җир шарының бу кызыклы урыны турында безгә күп нәрсәләр сөйли.* А.Муранов

**ГЕОЛОГОРАЗВЕ́ДКА** *и. рус* Төрле файдалы казылмалар эзләү, табу һәм чыганакларны файдалануга әзерләүгә юнәлдерелгән геологик һ.б. махсус эшләр һәм чаралар комплексы. *Ләкин миңа син әйт, геологоразведкага «озын» акча өчен килмәдем, диген – гомергә ышанмаячакмын.* И.Хуҗин. *Ул нефть һәм газ тармагында (геологоразведка, чыганакларны эшкәртү, бораулау, скважиналарны тикшерү һәм башкасы) югары технологик хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнә.* Яңарыш

**ГЕОЛОГОРАЗВЕ́ДКАЧЫ** *и.* Геологоразведка белгече, шул тармакта эшләүче кеше

**ГЕОЛОГОРАЗВЕ́ДЧИК** *и. рус к.* **геологоразведкачы**. *Мин шәҗәрәбезне төзүне Төмәннең Геологоразведчиклар урамында урнашкан архивта эзләнүдән башладым.* Яңарыш

**ГЕО́МЕТР** *и. рус* Геометрия белгече. *Димәк, сез яшь геометр, яшь Евклид буласыз?..* Җ.Тәрҗеманов

**ГЕОМЕ́ТРИК** *с.* Геометриягә караган, геометрия белән бәйле; геометриягә нигезләнгән. *Андагы [сызымнардагы] математик, геометрик бәйләнешләрне төзеләсе бина үлчәмнәренә күчереп, аны төгәл, матур, мәһабәт итәргә теләгәннәр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Икенче буыннан башлап һәр буыны үзеннән алда килгән буынны бер үк санга тапкырлаганга тигез булган нульдән үзгә саннар эзлеклелеге «геометрик прогрессия» дип атала.* Алгебра. *Алтын сары, чия кызыл, ачык зәңгәр, миләүшә төсләр ясылыгында урнашкан геометрик фигуралар аерылып, аермачык булып күренеп тора.* Казан утлары

**ГЕОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Математиканың пространство мөнәсәбәтләрен һәм формаларны өйрәнә торган бүлеге. *Казан инде ничә гасыр медиклар мәктәбе, химиклар мәктәбе белән дан тота. Дөньякүләм ачышлар геометриядән, химиядән Казанда ясалды.* Г.Ахунов.

*Яңа геометриягә нигез салучы бөек математик Н.И.Лобачевский (1792–1886) 20 елга якын университетның ректоры була.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ГЕОМОРФОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Җир рельефы, аның тышкы күренеше, килеп чыгышы, үзгәрү тарихы, хәзерге динамикасы һәм географик таралыш закончалыклары турындагы фән. --- *Ада белән Казан дәүләт университетына имтихан тоттык. Ул физика-математика, мин геоморфология белгечлеге буенча укырга теләдем.* Мәдәни җомга

**ГЕОПОЛИ́ТИК** *с.* Геополитика белән бәйле, геополитика күзлегеннән чыгып билгеләнгән. *Болгар иле, үзенең бик тә уңайлы геополитик урыны аркасында, көньяк һәм төньяк сәүдәгәрләренең арадашчысына әверелә.* Ф.Хуҗин. *Мәскәү дәүләте белән Казан ханлыгы арасындагы сугыш геополитик киңлек һәм сәүдә юллары өчен түгел, бәлки Казан хәзинәсе өчен барган ләбаса ---.* Сөембикә. --- *регионның геополитик хәле тотрыксыз була, бу чорда әле бер көч, әле икенче көч өстенлек ала.* Мирас

**ГЕОПОЛИ́ТИКА** *и. гр.* Дәүләтнең билгеле территорияләргә карата сәясәте, аның үз территориаль мәнфәгатьләрен яклау, алга сөрү сәясәте

**ГЕОРГИН** *и. рус бот.* (*рус галиме И.И.Георги исеменнән*) Оешма чәчәклеләр семьялыгына караган, төрле төстәге эре шарсыман чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек, бакча гөле; дәлия. *Руфинә --- ишекне ачты. Анда чал чәчле, күзлекле, кулына георгин чәчәкләре тоткан хатын күренде.* Ф.Садриев. *Урам чатында чәчкә сатучы очрады. Мәрьям аннан зур, йонтәс, куе кызыл георгин сатып алды.* М.Маликова. *Георгиннарны, бүлбеләрен бүлеп, чыбыкчадан һәм орлыктан үрчетәләр.* Йорт эшләре

**ГЕОСӘЯСИ** *с. к.* **геополитик**. *Кайбер чыганаклар белән, бигрәк тә аларны геосәяси рус тарихы тарафдарлары язган булса, аеруча сак булырга кирәк.* И.Гафаров. *Хәзер инде әлеге агрессиянең чын сәбәпләре дә шик тудырмый: АКШның Гыйрактагы нефть ятмаларына хуҗа булу һәм бер үк вакытта әлеге төбәктә геосәяси өстенлеккә дә ирешү теләге.* Мәдәни җомга

**ГЕОФИ́ЗИК** I *с.* Геофизикага мөнәсәбәтле, геофизика белән бәйле. *Су һәм аның парлары җирдә төрле геофизик һәм биологик процессларда гаять зур роль уйный.* Галәм. Җир. Кеше. *Бу ритмнарның ешлыгы Җирнең геофизик циклларына нык бәйле, һәм алар организмның тышкы тирәлек шартларына яраклашуын тәэмин итәләр.* Сәламәтлек нигезләре

**ГЕОФИ́ЗИК** II *и. рус* Геофизика белгече, геофизика белән шөгыльләнүче галим. --- *монда җәйгә тикле эшлим дә киләсе уку елына университетка керәм.* Э.Касыймов. *Азактан шагыйрь Туфан белән геофизик Хәмитов дуслашып киттеләр, бер-берсенә хатлар язып тордылар.* Г.Ахунов. *Татарстанның нефть башкаласы Әлмәттә, мәсәлән, геофизиклар 1986–1988 елларда 200гә якын җир тетрәү булганлыгын теркәгәннәр.* Казан утлары

**ГЕОФИ́ЗИКА** *и. гр.* «Каты Җир» эчендә барган физик процесслар турындагы һәм, гомумән, Җир турындагы фәннәр комплексы. *Ә Шмидт космогония проблемаларын астрономия һәм Җир турындагы фәннәр, беренче чиратта геофизика, геология, геохимия фәннәренең бердәм тырышлыгы белән хәл итәргә мөмкин булуын күрсәтте.* Галәм. Җир. Кеше

**ГЕОХИ́МИК** I *и. рус* Геохимия белгече

**ГЕОХИ́МИК** II *с.* Геохимия белән бәйле, геохимиягә караган

**ГЕОХИ́МИЯ** *и. гр.* Җирнең химик составын, химик элементларның таралышын һәм бүленешен, табигый процесслар барышында атомнарның берләшүе һәм күчеше закончалыкларын өйрәнә торган фән

**ГЕОЦЕНТРИЗМ** *и. гр.-лат.* Гелиоцентризмга хәтле булган, «Җир галәмнең үзәге булып тора» дип раслаган, башлыча борынгыларның садә дөнья картинасына нигезләнгән ялгыш тәгълимат

**ГЕОЦЕ́НТРИК** *с.* Җирне үзәк дип таныган, шулай дип раслаган. *Ф.Энгельс болай дип язган иде: «Безнең өчен бары тик геоцентрик (ягъни безнең планета шартларына туры килә торган) химия генә булырга мөмкин ---».* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

**ГЕПАРД** *и. фр. зоол.* Мәчесыманнар семьялыгына караган, Көньяк-Көнбатыш Азия һәм Африка далаларында яши торган, озын аяклы, сыгылмалы җиңел гәүдәле, имезүче ерткыч хайван. *Гепард – иң тиз йөгерә торган хайван ---. Гепард ерак араларга йөгерә алмый, әмма ярты чакрымга хәтле араны сәгатенә 100 километрдан артык тизлек белән чабып үтә ала.* Кызыклар дөньясында

**ГЕПАТИТ** *и. гр. мед.* Бавыр ялкынсынуы, шуннан гыйбарәт авыру; сары авыруы. *Байтак еллардан бирле борчып килә торган «гепатит» дигән нәрсәдән арынып булмасмы икән соң?* Г.Бәширов. *Медицинада шиңмәс үлән ялкынсынуга каршы, антибактериаль, спазмолитик һәм үт кугыч дару сыйфатында, үт куыгы, үт юллары һәм бавыр авыруларыннан, холецеститлардан, гепатитлардан, үтташ авыруларыннан кулланыла.* Урман аптекасы

**ГЕР** *и. рус* 1) Әйберләрнең төгәл массасын үлчәү өчен кулланыла торган, билгеле авырлыктагы металл коелма. *Бизмән белән гер бергә, Хатын белән ир бергә.* Мәкаль. *Абыстай менә шул эре чикләвекне бөкләп салган тастымал өстендә ике кадаклы гернең чокыры белән бәреп вата да, төшен чүпләп, күрәгә һәм йөзем белән кушып, кыстый-кыстый, малаена ашата ---.* Ә.Еники. *Кайчак аны әз-мәз генә Майладылар, Герләренә ташлар өстәп Җайладылар.* Ф.Яруллин

2) *спорт* Авыр атлетикада махсус спорт снаряды. *Профессорга да әйттем: Гөлфәния килгәч, иң башта йөз илле мәртәбә гер күтәреп күрсәтәм, дидем.* Ә.Галиев. *Башына бер потлы гер белән китереп органдай булды!* Г.Ахунов. *Көрәш, бау тарту, гер күтәрү, капчык белән «сугышу» һәм башка уеннарның уртак кагыйдәләре эшләнә.* Казан утлары

3) Каршы авырлык бирү яки механизмны хәрәкәткә китерү өчен асылып куелган йөк. *Миңа һәм минем кебек иң кырыйга туры килгән бер малайга сәгать гере сыман бер цилиндр тоттырды.* А.Расих

**ГЕРА́ЛЬДИК** *с.* Геральдика белән бәйле, геральдикага караган. *Икенче төрки династиянең --- геральдик билгесе башы ромб формасында ясалган кәҗә тәкәсе сурәте булган.* Г.Дәүләтшин

**ГЕРА́ЛЬДИКА** *и. лат.* 1) Герблар төзү, аңлату һәм өйрәнү, дворян нәсел агачларын төзү эше. --- *мондый геральдикага лаек бер генә саланы белә Фазыл: ул – Шәле!* Казан утлары. *Ананьино культурасына хас стильне чагылдыра торган геральдика үрнәкләре табылган.* Ватаныбыз тарихы

2) Тарих фәненең гербларны өйрәнә торган аерым тармагы. *Геральдика символикасына карата мөнәсәбәт үзебез яши торган җиргә мөнәсәбәт кебек булырга тиеш.* Казан утлары

**ГЕРБ** *и. нем.* Дәүләтләрнең, шәһәрләрнең, сословие, ыру һ.б. шундыйларның флагларында, акчаларында, мөһерләрендә сурәтләнә торган махсус билге, символ. *Әгәр Язкилде адәмнәре борынгы графлар кебек үз гербларын булдырсалар, Сәләхетдиннең гербы уртасында кытыршы яфраклы яшел кыяр чәчрәп торыр иде.* А.Гыйләҗев. *Зирәк акыл һәм үлемсезлек символы булган оча торган елан Идел Болгарының гербын бизәп торган.* Р.Мостафин. *Бу вакыйга онытылган иде, Күмгән иде тормыш өресе. Искә төште, искә төште күргәч Гербтагы чечен бүресен.* Р.Харис

**ГЕРБА́РИЙ** *и. лат.* 1) Өйрәнү һәм системага салу максатыннан махсус җыеп киптерелгән үсемлекләр коллекциясе, үсемлекләр җыелмасы. *Мин әле генә үзем гербарийлар карап утырган аудиториягә керәм.* А.Расих. *Бүлмә гөлләренең яфракларын һәм гербарийдагы яфракларны карагыз.* Биология. *Яшел үсемлекләрне киптереп, гербарий эшләү – бик җиңел эш, һәм аның яңалыгы да юк.* Робинзон эзләреннән

2) Шундый коллекцияләрне саклау һәм аларны фәнни эшкәртү белән шөгыльләнә торган учреждение. *Гербарийга экскурсиягә бару*

**ГЕРБИЦИДЛАР** *и. лат. күпл.* Чүп үләннәрен бетерү өчен кулланыла торган химик матдәләр. --- *язын самолётларга гербицидлар, төрле көчтәге пестицидлар төяшкән, ни кылганын, ни сулаганын уйламаган Йосыфның организмы агудан тәмам йончыган ---.* А.Гыйләҗев. --- *моннан бер ай чамасы элек аларга гербицид сибелде. Ул, гадәттә, кукуруз өч-дүрт яфрак җибәргәч сибелә.* Г.Ахунов

**ГЕ́РБЛЫ** *с.* Герб ясалган, гербы булган. *Аннары «Эш» дигән юка папканы ачып, шуннан герблы марка ябыштырылган бер кәгазь чыгарды.* Ә.Еники. *Сез бүген, Виктория Фёдоровна, кесәгездә урак-чүкеч герблы паспорт урынына аусвайс йөртәсез.* Ш.Рәкыйпов

**ГЕРДӘ** *и. диал.* 1) Хәергә бирү өчен әзерләнгән вак икмәк

2) Керәшеннәрдә мәет күмгән көнне яки үлгәннәрне искә алганда пешерелә торган вак күмәч

**ГЕРЕС** *и. диал.* Авыр физик эштән, мәсәлән, авыр нәрсә күтәрүдән, мускул зарарланып, шунда кан саву, кара яну

**ГЕРЕШ** *и. диал. иск.* Суда чылатылган киндернең сүсе кабыгыннан аерылырлык булып җитүе, әзер булуы

**ГЕРКУЛЕС** *и. лат.* 1) Атлетларныкы кебек матур таза гәүдәле һәм физик көчле ир кеше (борынгы грек мифологиясендәге Геракл исеменең латин вариантыннан). *Кемнәр алар бу сафта бара? – Прометейлар, Геркулеслар бара, Спартаклар, Кировлар бара!* Х.Туфан

2) *астр.* Һаваның төньяк ярымшарында урнашкан бер йолдызлык исеме

3) Яньчелгән солы бөртекләреннән гыйбарәт ярма. *Берсендә, мәсәлән, [балык] суалчанга яхшы чиртә, икенчесендә арпа ярмасына эләгә, кайсысындадыр геркулеска менә мо-ондыйларны чыгаралар ---.* Д.Гыйсметдинов. *Солы орлыгыннан талкан, солы ярмасы, геркулес һәм башка продуктлар әзерлиләр, аны терлек азыгы культурасы итеп тә файдаланалар.* Биология

**ГЕРМАН** *и.* 1) *сөйл.* Алман, германияле, немец. – *Иптәшләр! Яман хәбәр килде: германнар безгә каршы сугыш башлаган! – диде.* Г.Ахунов. *Бу дүрт кырлы күгәрек штык белән шул ук бабай Ундүртенче елдан Унҗиденче елга хәтле германнар белән сугышып йөргән.* Ә.Гаффар. *Төз гәүдәле, озын сыйраклы, пөхтә киемле герман армиясе фельдмаршаллары, генераллары танкларын, тупларын тыныч йокыда җәелеп яткан Россия кырларына кертә ---.* М.Мәһдиев

2) Үзәк һәм Төньяк-Көнбатыш Европада яшәгән, охшаш телләрдә сөйләшкән халыкларның гомуми атамасы, макроэтнонимы. *Атилла үлгәч, элек уллары кулыннан икътисади яктан утраклы вә мәдәни булган күршеләре германнар аларга каршы коралландылар ---.* Г.Гобәйдуллин. *Шул ук вакытта нигез этнонимнарга М.А.Членов макроэтнонимнарны да, ягъни югарырак этник гомумилекне белдерә торган атамалары да кертә (мәсәлән, славяннар, төркиләр, германнар һ.б.)* Ә.Кәримуллин

**ГЕРМАНИЗМ** *и. рус лингв.* Герман телләреннән кергән сүз яки гыйбарә

**ГЕРМА́НИЙ** *и. лат. хим.* Иң кыйммәтле ярымүткәрүчән материаллардан саналган, аксыл соры төстәге, Ge символы белән белдерелә торган химик элемент. *Озынлыгы l = 2 см, киңлеге b = 1 см, калынлыгы a / 0,5 см n – тибындагы германий пластинасы сагнит индукциясе сызыкларына перпендикуляр итеп урнаштырыла.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Мәсәлән, кристаллик матдә булган германийда һәм кремнийда атомнар үзара дүртәр электрон белән бәйләнгән булалар.* Серле кристаллар. *Мәсәлән, германийның саф хәлендә бик яхшы ярымүткәргеч икәнлеге беленмәгән булса, ул кайдадыр шунда читтә калган булыр иде.* Химиянең киләчәге

**ГЕРМАНИСТ** *и. рус* Германистика белгече

**ГЕРМАНИ́СТИКА** *и. лат.* Герман халыкларының телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнә торган фәннәр җыелмасы

**ГЕРМА́НИЯЛЕ** *и.* Германиядә яшәүче кеше. *Россия башкаласына килгәч, «футбол патшасы» Пеле, англияле Бобби Чарльтон, германияле Франц Беккенбауэр һәм башка танылган футболчылар Яшин һәйкәленә букет куймыйча китмиләр.* Кәеф ничек?

**ГЕРМАФРОДИТ** *и. гр.* Ир-ат һәм хатын-кыз җенесләренең билгеләрен берләштергән организм, һәр ике җенес билгеләре булган кеше яки хайван

**ГЕРМАФРОДИТЛЫК** *и.* Гермафродит булу. *Гермафродитлык нәрсә ул?* Биология

**ГЕРМЕТИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Герметиклаштыру эше. *Шуннан соң белгечләр герметизация үткәрә һәм суны суырту эшен башлый.* Яңа гасыр

2) Герметиклык, герметик булу хәле. *2012 елның 27 ноябрендә Казаннан Мәскәүгә юнәлгән очкычның, һавага күтәрелеп 20 минут узганнан соң, өлешчә герметизациясе бозыла.* Безнең гәҗит

**ГЕРМЕ́ТИК** I *и. лат. неол.* Герметиклаштыру өчен махсус матдә, материал. *Төзелештә герметиклар куллану*

**ГЕРМЕ́ТИК** II *с.* **1.** Һава, су, химик кушылмалар һ.б.ш. үткәрми торган, тулысынча изоляцияләнгән. *Җиргә кайтып төшүгә, галимнәр үз ватандашларын чын мәгънәсендә «эләктереп» алалар. Бик яхшылап, [экипажны] герметик фургонга кертеп ябалар.* Кызыклар дөньясында

**2.** *рәв. мәгъ.* Һава, су, газлар һ.б.ш. үткәрмәслек итеп, тулысынча томалап, изоляцияләп

**ГЕРМЕ́ТИКЛАШТЫРУ** *ф.* Герметик үзлекләр бирү, герметик ясау өчен чаралар күрү

**ГЕРМЕ́ТИКЛЫК** *и.* Герметик булу үзлеге, һава, су һ.б.ш. эчкә яки тышка үткәрмәү сәләте. *Ул чакта төшү аппараты герметиклыгын югалтты, һәм Г.Добровольский, В.Волков, В.Пацаев һәлак булдылар.* Кызыклар дөньясында. *Пешкәкле май кудыргычлар һәм двигательләр, герметиклык аркасында, эшче сыекчаның зур --- басымы астында эшли алалар.* Тракторлар һәм автомобильләр

**ГЕРОИЗМ** *и. к.* **геройлык**. *«Көчле героизм турында рухланып укырлык» шигырь язып булмый.* Ф.Кәрим. *--- М.Гафури Октябрьнең беренче көннәреннән үк революцион патриотизм һәм героизм турында җырлады.* Ф.Ибраһимова

**ГЕРО́ИК** *с.* 1) Героизмны белдергән, асылы героизм булган, геройлыктан гыйбарәт. --- *халык өстенә ябырылган фаҗига [язучыларның] иҗатка дәртләрен, ил язмышына ышануларын сакларга булышты, героик башлангыч талант күзәнәкләрен ачып җибәрде ---.* Т.Галиуллин

2) Геройларча башкарылган, батырларча үтәлгән. --- *героик эшләр белән янәшә үк безнең тормышта көн саен, сәгать саен һаман үзен күрсәтеп килә торган тырышлык та бар бит әле.* Г.Бәширов. *Әтиләре Газиз ага 1942 елны Сталинград өчен барган героик көрәштә батырларча үлеп кала.* Э.Мөэминова

3) Батыр, кыю, геройлык күрсәткән. *Андый роль сирәк була. Аңлыйсызмы, шундый героик хатын-кыз образы ---.* М.Маликова

4) Геройларны һәм алар күрсәткән батырлыкларны сурәтли торган. *Күңелемнән нindидер героик вакыйгалар чыгарам, күңелдән гаҗәеп әсәрләр язам, хәтта, шулар белән җенләнеп, керәсе капкаларымны узып китәм.* А.Расих. --- *героик чор, героик характерлар белән беррәттән, яңа әсәр яңача фикер йөртү, яңа форма да таләп итәчәк.* М.Хәсәнов. *Китап угыз баһадирларының басып алган Кавказ җирләрендә кяферләргә каршы сугышкандагы батырлыклары турында героик дастаннар циклын тәшкил итә.* Казан утлары

**ГЕРО́ИКА** *и. рус* Берәр төрле эшчәнлекнең, вакыйгаларның һ.б.ш. героик эчтәлеге, героик ягы. --- *бүгенге көн – бар, аның героикасы һәм анда катнашучылар – бар, әмма аларның әдәби образлары юк дәрәҗәсендә.* Л.Шагыйрьҗан. *Дастан героикасы әкият фантастикасы, әдәбият поэтикасына якын традицияләр белән алмаштырыла бара, һәм бу бары безнең дастаннарга гына хас үзенчәлек түгел.* Татар халык иҗаты

**ГЕРОЙНЯ** *и. рус* Герой хатын-кыз; *к.* **герой**. *Режиссура яшь артисткага биел --- А.Островскийның «Бирнәсез кыз» трагедиясендәге героиня – Лариса ролен тапшырды.* Г.Ахунов. *Героиняны читләтеп характерлаучы деталь буларак, тәңкә карлар темасы бөтен поэма буена сузыла.* Р.Мостафин. *Рафаил абый [Төхфәтуллин] гөлләргә, чәчәкләргә шулкадәр гашыйк, хәтта аның әсәрләрендәге героиняларның исемнәре дә «гөл» белән башлана.* А.Хәсәнов

**ГЕРОЙ** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә: әтисе – Алла, әнисе – гади Җир кешесе, яки әтисе – гади Җир кешесе, әнисе – Алиһә булган, көче, батырлыгы һ.б. сыйфатлары белән гади кешеләрдән аерылып торган зат (мәс., *Геракл, Ахиллес*). *Тесей борынгы Грециянең иң шөһрәтле геройларыннан саналган.* М.Мәһдиев. *Борынгы заманны ихтирам итүчеләр монастырьларның идән асларыннан борынгы кульъязмаларны эзләп табалар, грек аллаларының һәм геройларының җиргә күмелеп калган таш сыннарын казып чыгаралар.* Урта гасырлар тарихы

2) Батырлыгы, кыюлыгы, тәвәккәллеге белән башкалардан нык аерылып торган кеше; батырлык күрсәткән кеше, батыр, каһарман. *Алар куркуны, үлемне онытып, дошманга каршы ташланалар, аны чигенергә мәҗбүр итәләр. Шундый чын геройларның берсе безнең арада да бар.* Х.Камалов. *Бәлкем, ул билгесез герой менә хәзер дә аларны күзәтәдер.* И.Салахов

3) Гадәттән тыш батырлыгы, каһарманлыгы өчен, Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган һәм Алтын Йолдыз белән бүләкләнгән кеше. *Аның белән бер ротада сугышкан --- бик күпләргә орден-медальләр биргәннәр, командирларына «герой» бирелгән, Котдус Мөхетдиновны исә --- бер айга ялга җибәргәннәр.* Н.Фәттах. *Менә гимнастёрка түшенә Алтын Йолдыз кадаган герой абый күренде.* Г.Нәбиуллин

4) Әдәби әсәрнең төп персонажы, әдәби каһарманы. --- *дастан геройлары белән конкрет тарихи шәхесләр*

*арасында абсолют тәңгәллек билгесе куеп булмый.* М.Госман. *Үзен ул укытучы тасвирлаган геройлар арасында хис итә.* Ф.Яруллин. *--- мин героемның эчке дөньясын тудырырга тырыштым, ә тышкы дөньясын тудыру минем өчен берни тормый ---.* М.Маликова

5) Үз чорының, тарихи эпоханың типик вәкиле булган, чорының иң үзенчәлекле билгеләрен алган кеше. *Гражданнар сугышы геройлары турында спектакль куябыз.* Х.Вахит. *Алар --- сәнгать, әдәбият, музыка дигән матур исемнәр астында яңа дөнья, яңа кеше яратмак булалар, шул уйдырма геройларга табыналар ---.* Р.Вәлиев. *Дөньяны шаккатырып һәм калтыратып торткан заман геройлары искә алынган персонажлардан гыйбарәт түгелме?* Казан утлары

6) Халыкны берәр нәрсә белән шаккатырган, игътибарын җәлеп иткән кеше. *Әгәр кем дә булса аэропланны төшкән җайга тотып ала алса, ул инде шул көннең героена әверелә, аэроплан аныкы була.* Р.Вәлиев

7) *күч.* Куркак. *Ул үз тавышын үзе танымады: «Минем партбилетым кирәкмени сезгә, тыл герое?»* М.Мәһдиев

**ГЕРО́Й АНА** *и.* Ун бала тудырып тәрбияләгән аналарга бирелә торган шәрәфле исем һәм шуның ордены. *Кәгазь күрсәтә, имеш, – әнекәченең герой ана таныклыгын!* З.Фәтхетдинов

**ГЕРОЙЛАНУ** *ф.* Кирәкмәгәндә батыраю, шапырыну, әтәчләнү; куркыныч янамавын белеп, ясалма батырлык күрсәтү. *Экран каршында гына геройланып ерак китеп булмый. Җир егетләрен эзләгез, кызкайларым, җир егетләрен!* Р.Галиуллин

**Геройланып йөрү** Үзен күрсәтергә тырышу, ясалма күрсәтү

**ГЕРОЙЛА́РЧА** *рәв.* Батырларча, кыю рәвештә, герой кебек. *Алар бит өчесе дә сугышта үлгән. Геройларча!* Р.Хафизова. *1945 елның 12 гыйнварында Германия территориясендәге каты бәрелешләрнең берсендә ул [Я.Рәфиков] геройларча һәлак була.* Казан утлары

**ГЕРОЙЛЫК** *и.* 1) Тиңдәшсез батырлык, кыюлык, баһадирлык. *Андый китапларда шторм вакытында диңгезчеләр геройлык күрсәтәләр.* М.Юныс. *Әнә нинди зур һәм күпме геройлыклар эшләү мөмкинлекләребез файдаланып җиткерелми тора?!* Казан утлары

2) Зур ихтыяр көче, тәвәккәллек, кыюлык таләп итә торган гамәл. *Геройлыкмы соң ул китап язу? Менә шушындый сорауларга җавап эзли башласаң – беттең.* М.Юныс. *Тарих, филология өлкәсендә, идеологиядә корбаннар китте. Моны Өлкә комитетының идеология бүлеге башында торучылар үзләренә бер геройлык санап алга таба өстерәделәр, яңа корбаннар сорадылар.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Килешмәгән кыланыш, тәртипсезлек, гаеп эш

**ГЕРО́Й ШӘҺӘР** *и.* Бөек Ватан сугышы чорында фашистларга батырларча каршы торган шәһәрләргә бирелгән шәрәфле исем. *Герой шәһәр Севастополь авыр чорда үзен саклаган каһарманнарны онытмый, алар истәлеген кадерләп саклый.* Н.Максимов

**ГЕРОЛЬД** *и. нем.* Көнбатыш Европада Урта гасырларда корольнең яки феодалның әмерләрен җиткерүче, мәҗлесләрдә һәм турнирларда кагыйдәләр үтәлүе өчен җаваплы кеше. *Махсус сөрән салучылар – герольдлар – ярышта катнашучы рыцарьларның исемнәрен игълан итә.* Урта гасырлар тарихы

**ГЕРОЛЬДМЕ́ЙСТЕР** *и. нем.* Геральдика һәм төрле тантаналы церемонияләр, парадлар, кабул итүләр һ.б.ш. оештыру белгече. --- *Минтимер Шәймиевнең РФ Президенты каршында эшләп килүче Геральдика советы рәисе – дәүләт герольдмейстеры Георгий Вилибаков белән очрашуында катнашучылар тарихи вакыйга шаһиты булдылар.* Казан утлары

**ГЕРОНТО́ЛОГ** *и. рус* Геронтология белгече, шул белгечлектә махсуслашкан галим. *Картлыкны кайбер геронтологлар әҗәл гены, янәсе, махсус бер агулы гормон белән бәйләп аңлатмакчылар.* Г.Хөсәенов. *Геронтологлар раславынча, 1990 елда туган кешеләр Япониядә уртача 78,3 ел, Исландия, Швеция, Швейцария, Голландиядә һәм АКШта туганнар – 78 елдан бераз кимрәк, ә Россиядә туганнар нибары 66 ел яшәячәк.* Кызыклар дөньясында

**ГЕРОНТО́ЛОГИЯ** *и. гр.* Организмнарның картаю күренешләрен өйрәнә торган медицина һәм биология тармагы. *Шулай да Газинең геронтологиягә багышланган хезмәте бөтенләй үк файдасыз калмаган.* М.Хәсәнов. *Хәзер геронтология гомерләрне кыскартуга сәбәп булган төрле биологик, бүтән факторларны өйрәнү белән күбрәк мәшгуль.* Г.Хөсәенов

**ГЕРПЕТО́ЛОГ** *и. рус* Герпетология белгече. *Шулай да герпетологлар (еланнарны өйрәнүче белгечләр) раславынча, еланның бөтен гәүдәсе... – колак!* Кызыклар дөньясында

**ГЕРПЕТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Зоология фәненең сөйрәлүче һәм җир-су хайваннарын өйрәнә торган тармагы

**ГЕРЦ** *и. физ.* (*немец физигы Г.Герц (Heriz) исеменнән*) Периодик тирбәнешләр ешлыгын үлчәү өчен хезмәт итә торган, бер секундта бер тибрәнешкә тигез булган үлчәү берәмлеге. *Тавыш тирбәнешләре шул резонатор камераларда көчәя, һәм хайван нибары 2 герц ешлыгындагы тавышларны да аера ала (кеше колагы 16 дан алып 20000 герцка кадәр ешлыктагы тавышларны ишетә).* Галәм. Җир. Кеше

**ГЕ́РЦОГ** *и. нем. тар.* 1) Борынгы германнарда сайланып куела торган хәрби юлбашчы, соңрак – ыруг башы. *Оттон вакытлыча хәлсезләндерә һәм буйсындыра алган герман кабиләләренең элеккеге башлыклары – герцоглар – акрынлап корольдән бәйсезлек алуга ирешәләр.* Урта гасырлар тарихы

2) Урта гасырларда феодаль иерархиядә корольдән кала беренче урында торган эре феодал, зур бер өлкәнең хуҗасы. *Операның төп эчтәлеге исә мондый: Брабанд герцогы кызы Эльзаны энесен үтерүдә гаеплиләр.* Т.Әйди. *Король герцоглар һәм графлар өчен сеньор була ---. Бер баскыч түбәнрәк герцог һәм графларның вассаллары – бароннар һәм виконтлар тора.* Урта гасыр тарихы. *Эре феодаллар (герцоглар һәм графлар) «король бары тик тигез хокуклылар арасында гына беренче»*

*дип саныйлар һәм вакыт-вакыт аның боерыкларына буйсынмыйлар да.* Урта гасырлар тарихы

3) Көнбатыш Европада иң югары дворян титулларының берсе. *Англия герцогларының берсе үткәргән тантаналы кичә вакытында табында кытай савытына тутырылган кара салат бөтен кешенең дикъкатен үзенә тарта.* Робинзон эзләреннән

**ГЕРЦОГИ́НЯ** *и. рус* Герцог титулы булган хатын-кыз

**ГЕ́РЦОГЛЫК** *и.* 1) Герцог дәрәҗәсе, герцог титулы

2) Герцог тарафыннан идарә ителә торган феодаль дәүләт. *Тоскана герцоглыгы X гасырда Италия музыка культурасының үзгә ролен уйный башлый.* К.Гыйззәтов

3) Бер герцогның җир биләмәләре

**ГЕРЧЕ** *и.* Гер күтәрү белән шөгыльләнүче спортчы. *Герчеләр арасында Кукмарадан Игорь Сапаркин, Фарил Миңнемулин, Арчадан Фаил Һадиев үз үлчәү авырлыкларында көмеш медальләр яулады.* Татарстан яшьләре. *Герчеләребез хәзер сентябрь аенда Ростовта булачак Русия чемпионатына һәм октябрьдә Латвиядә узачак дөнья беренчелегенә әзерләнә.* Татарстан яшьләре

**ГЕСТА́ПО** *и. нем.* Фашист Германиясендә яшерен дәүләт полициясе, фашизмның төп террористик оешмаларының берсе. *Ә гестапоның төп максаты – СССРның оборона сәләтен какшату, беренче чиратта, армиянең үзендә, шулай ук фән һәм техника өлкәсендә иң яхшы совет кадрларын юк итү.* Д.Шәрәфетдинов. *Гестапо шымчылары зур зыян китергәнлектән, отряд җитәкчеләре партизаннар хәрәкәте үзәк штабыннан ярдәм сорарга мәҗбүр булганнар.* З.Фәтхетдинов. *Очучылар арасында гестапо йортын дөмбәсләгән Казан егете Алексей Федоров, Советлар Союзы Герое Тамерлан Ишмөхәммәтов, әле 1941 елда ук Берлинны бомбага тоткан полковник Гали Борһан һәм башкалар дан казана.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ГЕСТА́ПОЧЫ** *и.* Гестапода хезмәт итүче. *--- ул авылда немецлар юк, шуңа күрә анда яшәүчеләрдән партизаннар бик шикләнмиләр иде. Гестапочыларның исә шуннан файдаланулары бик мөмкин.* З.Фәтхетдинов. *Ике сәгать үтәр-үтмәс, гестапочылар больницага өерләре белән килеп керделәр.* Ш.Рәкыйпов

**ГЕТЕРОГЕН** *с. гр.* Составы буенча төрле нәрсәләрдән торган, бердәй булмаган. *Электролит-суспензияләрдән гетероген композицион материаллар табуның төрле ысуллары билгеле.* Фән һәм тел

**ГЕТЕРОГЕНЛЫК** *и.* Гетероген булу күренеше

**ГЕТЕРО́ЗИС** *и. гр. биол.* Беренче буын гибридның күп күрсәткечләр буенча кушылдырылган организмга караганда көчлерәк булу күренеше. *Аның [гибридның] беренче буынына гетерозис күренеше, ягъни аеруча көчле үсү, бик зур уңыш бирү хас ---.* Казан утлары. *«Гетерозис» термины 1914 елда швед галиме Дж. Шелл тарафыннан кертелгән*

**ГЕ́ТМАН** *и. нем. тар.* 1) Польша һәм Литвада XVI–XVIII йөзләрдә барлык коралллы көчләрнең баш командующие; гаскәрбашы

2) Украинада XVI–XVII йөзләрдә казак гаскәренең сайлап куелган башлыгы

3) 1657–1764 елларда Украинаның сул яр буе өлешендә югары хәрби һәм гражданлык властена ия идарәче

**ГЕ́ТМАНЛЫК** *и. тар.* 1) Гетман дәрәҗәсе, гетман вазифасы

2) Гетман хакимлеге, гетман идарәсе

**ГЕ́ТМАНЧЫЛЫК** *и. тар.* 1) Украинада идарәдә гетман хакимлеге чоры

2) 1918 елда Украинада «гетман» дип игълан ителгән Скоропадский урнаштырган хәрби диктатура

**ГЕТР** *и. фр.* Аякны тубыктан тезгә кадәр каплый, җылылык өчен аяк киеме өстеннән киелә торган җылы оек төре. *Өстенә күн тужурка, башына зур кепка, аягына гетр киеп йөри торган урта буйлы сөйкемле бу егет белән сөйләшүе бик күңелле.* Җ.Фәйзи

**ГЕ́ТТО** *и. ит.* 1) Урта гасырларда Европада һәм фашистлар Германиясендә яһүдиләр яшәү өчен махсус аерымланган, изоляцияләнгән шәһәр районы. *Өстән Варшава геттосы буенча заместитларга үзләре өчен генә информация килде, ләкин яралыларга сөйләшмәскә кушылган иде.* Х.Камалов. *Аронның авыр кайгысы турында да сөйләделәр: барлык туганнары Киевта яһүдләр геттосында һәлак булган икән.* З.Фәтхетдинов

2) Сирәгрәк дискриминацияләнгән милли азчылыклар урнашкан районнарны билгеләү өчен кулланыла. *Негр геттосы*

**ГИББОН** *и. ингл. зоол.* Кешесыман маймыллар семьялыгына караган, гәүдәсенә карата бик озын куллы, Көньяк-Көнбатыш Азия урманнарында яши, башлыча яфраклар һәм җимешләр белән туклана торган маймыл. *Стоматит белән авырган гиббоннар (маймылның бер төре), мәсәлән, дару үләннәрен башта бик әйбәтләп чәйниләр, аннары гына яраларына ябалар.* Кызыклар дөньясында

**ГИБИ́СКУС** *и. лат. бот.* Мальвачалар семьялыгыннан, субтропик һәм тропик районнарда үсә торган, сары ялгыз чәчәкле үлән үсемлек; бамия. *Гибискус (кытай розасы) – мәңге яшел, күп таралган гөл.* Йорт эшләре

**ГИБРИД** *и. лат. биол.* **1.** Хайваннарны яки үсемлекләрне гибридлаштыру, катнаш кушылдыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән организм. *Тын океан яр буеның көньяк өлешендә (Калифорниянең сугарыла торган җирләрендә) апельсиннар, лимоннар, грейпфрутлар (лимон белән апельсин гибриды), дөге, шикәр чөгендере игелә.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Бу гибрид генетик яктан төрдәш булмаган формаларны кушылдыру нәтиҗәсендә туа.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Кушылдыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Гибрид грейпфрутлар ничек тәмсез булса, боларның каннары кушылу нәтиҗәсендә дөньяга килгән «җимешләр дә» шундый ук «чилепешле» була торгандыр.* З.Хөснияр

**ГИБРИДЛАШТЫРУ** *ф.* Яңа үзлекләргә ия организмнар барлыкка китерү өчен, төрле астөрләргә караган хайваннарны яки үсемлекләрне кушылдыру. *Аквариумда яңа төр балык-*

*лар акклиматлаштырыла, сайлап алу һәм гибридлаштыру юлы белән яңа токым балыклар булдыру буенча зур эш алып барыла.* Кызыклы ихтиология

**ГИГАБАЙТ** *и. гр. > ингл. информ.* Исәпләү техникасында мәгълүмат күләмен үлчәү берәмлеге

**ГИГАНТ** *и. гр.* **1.** 1) Алып, озын буйлы, зур гәүдәле кеше яки бик зур хайван. *Гигант булмаса да, кәрлә түгел, Бәхетемә җитә буйларым ---.* Ф.Яруллин

2) Зурлыгы белән аерылып торган, гадәттән тыш зурлыктагы объект. *Түбән Кама һәм Казандагы нефтехимия гигантлары продукция эшләп чыгару (шул исәптән экспорт өчен дә) темпларын ышанычлы тизләтеп киләләр.* Казан утлары

3) Әһәмияте, тоткан урыны, уйнаган роле ягыннан башкалардан өстен торган нәрсә яки шәхес

**2.** *с. мәгъ.* 1) Гадәттән тыш зур, күләмле, әһәмиятле. *Татарны мең ел яшәтә алган гигант «Йосыф китабы»ның да бүген кыйммәте, көче, туплау хикмәте сизелми.* А.Гыйләҗев. *Кинәт каяндыр килеп чыккан күзгә күренмәс гигант печәнче каршыга ыргылган төркемне чалгы белән кыйрата башлагандай булды.* Г.Нәбиуллин. *Гигант танкер, безгә бәрелә язып, янәшәдән узып китте.* М.Юныс

2) Эре, зур (бер ыруга һәм төргә караган хайваннарның яки үсемлекләрнең эре төрчәсен белдерә). *Гигант кәлтәләрнең – вараннарның – койрыкларында гаять күп май запасы бар.* Кызыклы физиология. *Гигант акула да шулай ук ерткыч түгел, ул нигездә планктон һәм моллюсклар белән туклана, бары тик сирәк очракларда гына вак балыклар белән сыйлана.* Кызыклы ихтиология

**ГИГАНТИЗМ** *и. гр.* 1) Кешенең яки хайваннарның артык зур үсүе

2) *к.* **гигантомания**. *Охшашлар!.. Икесендә дә инсаният табигатен таптап барган гигантизм!..* А.Хәлим

**ГИГАНТОМА́НИЯ** *и. гр.* Кирәксә-кирәкмәсә дә артык зур нәрсәләр оештыруга, төзүгә омтылыш. *Арча, Балтач, Тукай районнары зур бер районга әйләнде. Гигантомания кузгалды җитәкчеләр күңелендә.* Г.Ахунов. *--- аның [Ф.Табеевның] «гигантомания чире», яисә кеп-кечкенә Татарстан җиренә туктаусыз завод-фабрикалар утырту, шәһәрләр кору белән мавыгуы татар милләтен кысуга, аның азаюына, урыслашуына алып килде.* Т.Галиуллин

**ГИГИЕ́НА** *и. гр.* 1) Профилактик медицинаның авыруларны булдырмау һәм сәламәтлекне саклауга юнәлдерелгән чаралар белән шөгыльләнүче тармагы. *Доктор Әбүбәкер Терегулов – медицина, гигиена, адвокат Сәедгәрәй Алкин – хокук, Фатих Әмирхан төрле партияләр турында --- дәресләр бирде.* Казан утлары. *Шәһәрләребез өстендәге һава бассейнының чисталыгы – иң әһәмиятле гигиена проблемаларыннан берсе.* Кызыклы физиология

2) Чисталык саклау, авырулар булдырмау максатыннан үтәлә торган гамәлләр, чаралар системасы. *Учительская школа укытучысы И.В.Терегулов җыелганнарга йогышлы авыруларның, аерым алганда, ваба кизүенең килеп чыгу сәбәпләрен аңлата, шәхси гигиена мәсьәләләре һәм шәһәрдә суның чисталыгын саклау өчен зарур чаралар турында сөйли.* Р.Мостафин. *Кайттык, кичке гигиена башланды, Эльвирага мин егете белән төнге уникегә кадәр калырга рөхсәт бирдем.* М.Мәһдиев

**ГИГИЕНИСТ** *и. рус* 1) Гигиена белгече. *Шәһәрдә яшәүче кешеләр ябык бүлмәләрдә 80–90 процентка якын вакытын үткәрә дип билгели социологлар һәм гигиенистлар*. Н.Хәлил

2) Хезмәт гигиенасы һ.б.ш. буенча санитария табибы. *Бу очракта гигиенистлар мондый киңәш бирә ---.* Ватаным Татарстан

**ГИГРО-** *гр.* Кушма сүзләрдә «дым, дымлылык» мәгънәсен белдерә торган беренче компонент (мәс., *гигроскоп, гигроскопик*)

**ГИГРО́МЕТР** *и. гр.* Һава дымлылыгын үлчәү приборы. *Лицензия бары тик 20 квадрат метрдан да ким булмаган, стеналары юыла торган, аерым бүлмә, суыткыч, бикләнә торган шкафлар, термометр һәм гигрометр, витриналар белән тәэмин ителгән хәлдә генә бирелә.* Кызыл таң

**ГИД** *и. фр.* 1) Сәяхәтчеләргә, туристларга шәһәрне, тирә-якны күрсәтеп, аларны озатып йөрүче кеше, экскурсовод. *Легендаларның чынлыгына гид үзе әллә ышана, әллә юк.* С.Сөләйманова. *Озатып йөрүче гид – Рауль исемле мулат, туры муенлы, серле карашлы егет – залдагы ак костюмлы берәү белән сөйләште ---.* М.Маликова. *Төрек гидлары шаяртканча, ихтимал, бу язу – дөньядагы беренче реклама – белдерү язуы булгандыр.* Р.Мирхәйдәров

2) Төрле туристик объектлар, музейлар, күргәзмәләр турындагы белешмәлек

**ГИДАЙ** *и. фар.* **1.** 1) *иск.* Ярлы кеше, юксыл, фәкыйрь кеше. *Гидайның казысын җигән угры казый булмас.* Мәкаль. *Тәмле булганга гаҗәпләнмә, бу – байлар ашлары, Күп вакыт борчы, тозы – мискин гидайлар яшьләре.* Г.Тукай. *Гидайларга шәфкать күрсәтү, мөселманнарның үзара тату, ярдәмләшеп яшәве яхшырак.* Т.Әйди

2) Зимагур, йортсыз-җирсез кеше. *Вәт бит дип уйлады ул, бу эшлексез гидайны ата-анасы кеше итә алмаган.* М.Мәһдиев. *Әлфәритнең кисәтү-үгетенә карамастан, дөмбәсләшеп алган гидайлар һаман тынычланып җитә алмыйлар иде әле.* З.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* Ярлы, фәкыйрь. *Ә гидай казакларның ялгыз-ярым маллары җотның беренче көннәрендә үк аякларын суздылар.* И.Салахов

**ГИ́ДРА** *и. гр.* Эчәккуышлылар семьялыгыннан иң гади төзелешле, вегетатив ысул белән үрчи, төче сулыкларда яши торган умырткасыз хайван. *Гидра чаккыч күзәнәкле кармавычлары ярдәмендә судагы вак тереклек ияләрен эләктерә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ГИДРА́ВЛИК** *с.* Гидравлика нигезендә эшли торган. *Гидравлик тирбәнеш сүндергечнең эш принцибы бик гади: майны сүндергечнең әле бер, әле икенче ягына чыгару өчен киткән энергия тирбәнүләрне бетерә.* Тракторлар һәм автомобильләр

**ГИДРА́ВЛИКА** *и. гр.* Сыеклыкларның тигезлек саклау һәм хәрәкәт итү закончалыклары һәм ул закончалыкларны гамәли инженерия мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерү турындагы фән

**ГИДРАНТ** *и. гр.* Су үткәрү челтәренең аерым линияләрендә урамнарга су сибү, янгын сүндерү һ.б.ш. максатларда су алу өчен куела торган кран яки колонка. *Яңгырлау канатлары һәм су китерү торбасы --- күчереләләр һәм, су алу өчен, һәр 120 метр аша даими трубопровод гидрантларына тоташтырылалар.* Яшелчәчелек

**ГИДРАСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Чагучылар тибындагы умырткасыз су хайваннары классы

**ГИДРАТ** *и. гр. хим.* Химик матдәләрнең су белән кушылмасы. *Профессор Ф.М.Флавицкий терпеннар төзелеше теориясен үстерүгә һәм төрле тозларның гидратларын тикшерүгә багышланган хезмәтләре белән танылa.* Казан химиклары. *Бик кызыклы кушылмалар булган оргон, криптон һәм ксенон гидратлары табылды.* Химиянең киләчәге

**ГИДРИД** *и. гр. хим.* Водородның башка элементлар белән химик кушылмасы

**ГИ́ДРО-** *гр.* Кушма сүзләрдә «суга, сулыкларга мөнәсәбәтле» дигән мәгънәне белдерә торган беренче компонент (мәс., *гидрология, гидрография, гидрогенератор, гидрометрия, гидромеханика, гидромонитор* һ.б.ш.)

**ГИДРОАКУ́СТИКА** *и. гр.* Физиканың тавыш дулкыннарының суда таралу үзенчәлекләрен өйрәнә торган тармагы. *Куәтле прожекторлар якынтирәдәге нәрсәләрне күрергә, ә ультратавыш белән эшләүче гидроакустика приборлары шактый еракларагы балык өерләрен табарга мөмкинлек бирәләр.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРОБИО́ЛОГ** *и. рус* Суның яки сулыкларның биологик үзенчәлекләрен тикшерүче, тере организмнарны өйрәнүче галим. --- *Тим Динсдейл материаллары тулы ышануга лаеклы. Бу мәсьәләдә күренекле совет океанологы һәм гидробиологы --- Лев Александрович Зенкевич та әлеге фикергә кушыла.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРОБИОЛО́ГИК** *с.* Гидробиология белән бәйле, су биологиясенә караган

**ГИДРОБИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Суда һәм сулыклардагы тере организмнарны, суның биологик үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән

**ГИДРОГЕНИЗА́ЦИЯ** *и. гр.* Химик кушылмаларга водород кушу. *Пахта мае, җитен мае тулып ята. Бары гидрогенизация цехына гына барырга иренмә!* А.Расих. *Майлар гидрогенизациясе. Ягулык гидрогенизациясе*

**ГИДРО́ГРАФ** *и. рус* Гидрография белгече

**ГИДРОГРА́ФИК** *с. махс.* Гидрографиягә мөнәсәбәтле; сулыкларның географиясен өйрәнә торган. *«Мстислав Келдыш» – дөньядагы иң зур гидрографик судно. Ладога күленең гидрографик системасын өйрәнү тагын шуны да ачыкларга ярдәм итте: аның суы кайчандыр төньякка таба аккан булган.* А.Муранов

**ГИДРОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Географиянең җир өсте сулыкларын тикшерү һәм тасвирлау белән шөгыльләнә торган тармагы

**ГИДРОДИНА́МИК** *с.* Гидродинамика закончалыкларына нигезләнгән; гидродинамика белән бәйле. *Энәтәнлеләрнең хәрәкәт итү аппараты иң камил гидродинамик җайланмалардан санала ---.* Кызыклы физиология

**ГИДРОДИНА́МИКА** *и. гр.* Сыеклыкларның хәрәкәт итүен һәм каты җисемнәр белән мөнәсәбәтен өйрәнә торган фән

**ГИДРОКОРЫЛМА** *и.* Су көченнән файдалану яки су стихиясенә каршы тору өчен торгызылган махсус техник корылма. *Балхашка коя торган елгаларда тагын күп кенә гидрокорылмалар һәм сусаклагычлар төзергә мөмкин.* А.Муранов. --- *браконьерлык һаман да яшәп килә, зур гидрокорылмалары күп булган елгаларда балык үрчетү һәм яшь балыкларны саклап калу өчен җитәрлек эффектлы шартлар тудырылмаган.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРО́ЛИЗ** *и. гр. хим.* Су һәм башка матдәләр арасында ионнар алмашу реакциясе. --- *сыерны агуланудан саклау өчен, уреаза ферменты гидролизына комачаулаучы шартлар тудырырга яисә микроорганизмнарның эшчәнлеген көчәйтергә кирәк.* Кызыклы физиология

**ГИДРО́ЛОГ** *и. рус* Гидрология белгече, сулыкларны тикшерү белән шөгыльләнүче галим. *Күренекле гидрологларның (сулыкларны тикшерүчеләрне шулай дип атыйлар) әйтүенә караганда, соңгы кырык-кырык биш ел эчендә Каспийның суы ике метр ярымга саеккан.* А.Муранов. *Гидрологлар һәм шәһәрнең инженерлык саклануы вәкиле Болакның шәһәр бизәге генә булмавын искә төшерделәр.* Р.Мостафин. *Космонавтлар геолог, метеоролог, гидролог һәм башка белгечләргә Җир өслеген өйрәнү, файдалы казылмаларны табу һәм бүтән әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүдә әллә никадәр ярдәм күрсәттеләр инде.* Кызыклар дөньясында

**ГИДРОЛО́ГИК** *с.* Гидрологиягә караган, сулыкларны тикшерү фәне белән бәйле. *Соңгы елларда үткәрелгән геологик һәм гидрологик тикшеренүләр, канал казылганга кадәр, ул урында кыска, ләкин шактый мул сулы елга акканлыгын бәхәскә урын калмаслык итеп раслады.* Р.Мостафин

**ГИДРОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Табигатьтә су әйләнешен һәм барлык сулыкларны тикшерә торган фән

**ГИДРОЛОКА́ТОР** *и. гр.-лат.* Гидролокация эшләре өчен махсус акустик прибор. *Дельфинның гидролокаторын күчереп алгач, галимнәр, су асты дөньясын өйрәнү өчен, ышанычлы җайланмага ия булачаклар.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРОЛОКА́ЦИЯ** *и. гр.-лат.* Су астындагы тавышларны тоту; тавыш сигналлары ярдәмендә су астындагы объектларның урынын билгеләү, су астының ландшафт үзенчәлекләрен өйрәнү

**ГИДРОМАССАЖ** *и. гр.-фр.* Су ярдәмендә массажлау, төрле басымдагы су агымын юнәлтеп массаж ясау. *Зәп-*

*зәңгәр диңгез төсендәге зур бассейн бар, шуның стеналарыннан су атты-рып, сиңа гидромассаж ясый.* Татарстан яшьләре

**ГИДРОМЕТЕОРО́ЛОГ** *и. рус* Гидрометеорология белгече, һава торышын тикшерүче, өйрәнүче белгеч

**ГИДРОМЕТЕОРОЛО́ГИК** *с.* Гидрометеорологиягә караган

**ГИДРОМЕТЕОРОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Атмосферада суның әйләнешен һәм шуның белән бәйле физик процессларны, шул исәптән һава торышының үзгәрүен өйрәнә торган фән. *Күл буендагы гидрометеорология станциясе хезмәткәрләре тау районы климатын, һава торышын һәм күлдәге үзгәрешләрне даими күзәтәләр.* А.Муранов. *--- кайбер районнарда боз явуы көтелә, дип хәбәр итә Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе.* Ватаным Татарстан

**ГИДРООЧКЫЧ** *и. к.* **гидроплан**. *Ике гидроочкыч, командующий фәрманы белән, флотилияне куа китте.* И.Низамов

**ГИДРОПЛАН** *и. гр.-лат.* Су өстеннән күтәрелеп китү һәм су өстенә төшү өчен җайланган очкыч, гидросамолёт. *Әле Ослан өстеннән үткән гидропланнарның берсе бүген икенче тапкыр күтәрелгән иде инде ---.* И.Низамов

**ГИДРОСАМОЛЁТ** *и. гр.-рус к.* **гидроплан**

**ГИДРОСТА́НЦИЯ** *и. гр.-лат. к.* **гидроэлектростанция**. *Әнә бит гидростанция салучылар күпме зиратны җир белән тигезләделәр.* Г.Ахунов. *Нил елгасы башына корылган Оуенфоллс гидростанциясе бөтен Угандaны электр энергиясе белән тәэмин итә, беркадәр өлешен Кениягә дә бирә.* А.Муранов. *Бирегә салынган тимерле бетонның авырлыгы гына да 360 мең тонна. Бер яңа гидростанция төзергә җитә!* А.Хәлим

**ГИДРОСТАТ** *и. гр.* Су тирәнлекләрен өйрәнү максатыннан XX гасырның икенче яртысында файдаланылган (гадәттә, бер кешелек), корабльдән су астына төшү аппараты. *Мәнә шул вакыт галимнәр тирәнлекләрне гидростат ярдәмендә тикшерергә тәкъдим итәләр, чөнки, аркан өзелгәндә, гидростат су өстенә үзе дә күтәрелә алачак.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРОСТА́ТИК** *и.* Гидростатикага мөнәсәбәтле, гидростатика законналыкларыннан килеп чыга торган. *--- сусаклагычның гидростатик басымы тәэсирендә җир асты горизонтларыннан күлләргә беркадәр су кереп тора ---.* Р.Мостафин. *Гидростатик скелет хайваннар өчен дә бик җайлы.* Кызыклы физиология. *Гидромеханик көч тапшыргычлар гидродинамик һәм гидростатик төрләргә бүленәләр.* Тракторлар һәм автомобильләр

**ГИДРОСТА́ТИКА** *и. гр.* Сыеклыкларның тигезләнгән һәм аларның сыеклыкны чикләп торган өслекләргә һәм шунда салынган җисемнәргә тәэсирен тикшерә торган фән тармагы

**ГИДРОСТРО́Й** *и. гр.-рус* 1) Гидротехник корылмалар проектлау, төзү белән шөгыльләнә торган предприятие. *Гидростройга барсагыз, борып җибәрмиләр инде. Үзләренең дә сезгә йомышлары төшә бит...* Р.Вәлиев

2) Гидротехник корылмалар төзү алып барыла торган урын, төзелеш

**ГИДРОСФЕ́РА** *и. гр.* Җир шарының атмосферасы һәм Җир кабыгы (литосфера) арасында урнашкан, тоташ булмаган су тышчасы: океан, диңгез, күл, елга һ.б.ш.ларның барысы. *Күтәрелеш һәм чигенеш дулкыннары Җирнең гидросферасында гына түгел, бәлки каты кабыгында һәм һава катлауларында да барлыкка килә.* Галәм. Җир. Кеше

**ГИДРОТЕРАПИ́Я** *и. гр.* Су ярдәмендә дәвалау, дәвалау максатыннан душ һәм ванналардан файдалану

**ГИДРОТЕ́ХНИК** I *и. рус* Гидротехника белгече. *Шулай итеп, ихтиологлар инженер гидротехниклар белән эшкә керешәләр.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРОТЕ́ХНИК** II *с.* Гидротехника максатларыннан корылган, шуңа хезмәт итә торган, гидротехника белән бәйле. *Елгалардагы борынгы сугару каналларының һәм гидротехник корылмаларның җимерекләре әле дә бар.* А.Муранов

**ГИДРОТЕ́ХНИКА** *и. гр.* Техниканың сулыкларны хуҗалыкта файдалану һәм гидротехник корылмалар ярдәмендә суларның тискәре йогынтысына каршы тору юлларын өйрәнә торган тармагы

**ГИДРОТӨЗЕЛЕШ** *и. к.* **гидрострой**

**ГИДРОТӨЗҮЧЕ** *и.* Гидрокорылмалар төзү эшендә хезмәт итүче. *Шәһәрнең бу өлеше «Гидротөзүчеләр бистәсе» дип атала икән.* А.Хәлим

**ГИДРОФОН** *и. гр.* Су астындагы төрле тавышларны тоту, тыңлау, яздыру өчен махсус җайланма. *Гидрофон ярдәмендә балыкларның тавышларын тыңларга гына түгел, хәтта плёнкага язып алырга да мөмкин булды.* Кызыклы ихтиология. *Бу тавышларны гидрофон ярдәмендә магнит лентасына язып, аны яңадан суда тапшырып карыйлар.* Кызыклы ихтиология

**ГИДРОХИ́МИК** I *и. рус* Суның яки сулыкларның химик үзенчәлекләрен өйрәнүче белгеч, су химиясе белән шөгыльләнүче галим. *Арал диңгезендә, --- тирәнрәк кергән саен, аның суында кислород күбәя. Моның серен соңгы вакытларда гидробиологлар һәм гидрохимиклар ачты.* А.Муранов

**ГИДРОХИ́МИК** II *с.* Су химиясенә караган, суның яки сулыкның химик үзенчәлегенә бәйле, су химиясен өйрәнә торган. *Мәнә без көймәдә Кабан буенча йөзәбез. «Без» дигәнем – шәһәр һәм район санэпидстанцияләреннән ике санитар врач, гидрохимик лаборатория инженеры, лаборант кыз һәм без фәкыйрегез.* Р.Мостафин. *Гидрохимик анализ ясап карасалар, суның селтеле булуын, анда сода һәм хлорлы натрий барлыгын белгәннәр.* А.Муранов

**ГИДРОХИ́МИЯ** *и. гр.* Суның һәм сулыкларның химик үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән

**ГИДРОЭЛЕКТРОСТА́НЦИЯ** *и. гр.-лат.* Электр энергиясен җитештерү өчен, су агымының көченнән файдалана торган электр станциясе. *Волгадагы электростанцияләрнең куәте кимиячәк.* А.Муранов. *Тирән уйга чумып, тәрәзәдән Чаллыяр гидроэлектростанциясенең мәгърур корылмаларына*

*карап утыручы Вергилий Никифорович --- Алексей Мирковның бүлмәгә керүен сизмәде.* Г.Кашапов. *Кыш көннәрендә гидроэлектростанцияне эшләтү өчен, су җитми, ә яз башында су бик күп була.* Дөньяда ниләр бар

**ГИДРОЭНЕРГЕТИК** I *и. рус* Гидроэнергетика өлкәсендә эшләүче кеше, шул өлкәдәге белгеч

**ГИДРОЭНЕРГЕТИК** II *с.* Гидроэнергетикага бәйле, шуңа караган. *Ул – югарыда телгә алынган, салкын көндә җылытучы гидроэнергетик корылма.* Шәһри Чаллы

**ГИДРОЭНЕРГЕ́ТИКА** *и. гр.* Су ресурсларының потенциаль энергиясеннән файдалануга бәйле булган энергетика тармагы. *Гидроэнергетика суны «үтерә», суның үзен-үзе чистарту сәләтен киметә, елгадагы планктонны бетерә ---.* М.Хәсәнов. *«Альстом» машиналар эшләү компаниясе республикада гидроэнергетика җиһазлары җитештерү заводы төзи.* Кызыл таң

**ГИЕ́НА** *и. гр. зоол.* Көньяк-Көнбатыш Азия һәм Африка чүл һәм ярымчүлләрендә яши, башлыча үләксә белән туклана торган имезүче ерткыч хайван, сыртлан. *Гиена һәм леопард якын килеп кенә карасын, этләр өере аларны хәзер өзгәләп ташлый.* Кызыклар дөньясында

**ГИЗЛӘНҮ** *ф. иск.* Яшеренү. *Гарзы хаҗәт әйләмәк чөн киттеңезме «Тур» ә сез? Яки дә гизләндеңезме галәме мәстүрә сез?* Г.Тукай

**ГИЗЛӘ́Ү** *ф. гар. иск.* Яшерү. *Ни гомер мин хәсрәтемне Эчтә гизли белмәдем.* С.Сүнчәләй

**ГИЗЛЕ** *с. иск.* Яшерен, серле. *Беләлмим, нинди гизле моңың бар, Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?* Дәрдемәнд

**ГИЗҮ** *ф.* 1) Сәяхәт итү, ерак юл йөрү. *Кешеләр, диңгезләр кичеп, карурманнар гизеп, бер-берләрен табышалар.* Ф.Яруллин. *Зәңгәр галәм диңгезендә, Дөньялар гизә-гизә, алтын кораб – Кояш, ак җилкәнле болытлар йөзә.* Л.Лерон. *Илләр гиздем, кичтем диңгезләр; Эзләмәгез, табалмассыз җирдә Бәхет-шатлыгыма тиң эзләр.* Г.Сәгыйров

2) Ачык һавада йөрү, сәйран кылу. *Мин ашыкмый гына урамнар гизәм.* А.Расих. *Солдат итеге белән басу балчыгын изеп, Тимерхан кырны иңләп-буйлап гизде.* М.Мәһдиев. *Акчарлаклар очкан Агыйделдә Тугайларны ялгыз гизәмсең, Раушаниям, бәгырем ---?* Ш.Галиев

**Гизеп йөрү** Күп йөрү, еш гизү, төрле җирләрне гизү. – *Дөньяны аркылыдан-буйга гизеп йөргән һәр өч туристның берсе – японнар, ахры, – диdem, гаҗәпләнүемне яшермичә.* Р.Мөхәммәдиев

**ГИЗҮЧЕ** *и.* **1.** Сәяхәтче, сәйяр

**2.** *с. мәгъ. махс.* Тотрыклы бер урыны булмаган, урыныннан күчә торган. *Гизүче бөер. Гизүче йолдыз*

**ГИ́ЛЬДИЯ** *и нем.* 1) Урта гасырларда сәүдәгәрне, һөнәрчеләрне һ.б.ш. берләштергән һәм аларның һөнәри мәнфәгатьләрен яклаган союз, берлек. *Талаучылардан сакланыр һәм бер-берсенә ярдәм итәр өчен, сәүдәгәрләр союзларга – гильдияләргә берләшәләр. Гильдия әгъзалары, үзләренең эшләрен хәл итәр өчен, җыелышларга җыелалар һәм җитәкчеләрен сайлап куялар.* Урта гасырлар тарихы

2) Патша Россиясендә купецларның сословие берләшмәсе; капитал күләменә карап, өч гильдия булган. *Беренче гильдиягә күчкәч, Хөсәеновлар 1889 елда мәдрәсә ачып җибәрәләр.* Казан утлары

3) *неол.* Иҗат кешеләренең һөнәри берлеге, союзы

**ГИ́ЛЬЗА** *и. нем.* 1) Пуля, шартлаткыч матдә һ.б.ш. салына торган, төбендә капсюль кую өчен тишеге булган цилиндр, көпшә; пуляның тышчасы. *Сәет пулемётның суы кайнап чыкканын, атылган буш гильзаларның күп булып өелгәнен сизми.* Ш.Усманов. *Күз күреме җирдә воронкалар, гильзалар, ящик такталары --- ята иде.* М.Мәһдиев. *Арон үлән арасыннан винтовка патроны гильзасын табып бирде.* З.Фәтхетдинов

2) *тех.* Двигатель цилиндрларының эченә урнаштырыла һәм шуның эчендә пешкәк йөри торган җайланма. *Су белән суытыла торган двигательләрдә цилиндр гильзалары блок-картерның өске өлешендәге махсус ояга беркетелә.* Тракторлар һәм автомобильләр

**ГИЛЬОТИ́НА** *и. фр.* Бөек француз революциясе чорында Франциядә врач Ж.Гильотен тәкъдиме белән кертелгән баш кисү җайланмасы. *Гильотина шәүләләре Чайкала синең өстә ---.* Г.Хуҗиев. *Гильотинада чапса да катыйль, калдырып башсыз, Бар микән, Милләтем синдәй бер милләт кадер-сансыз?!* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Король дә «турылыклы колларының иминлеге» турында кайгыртып интегүдән котыла: аның башы гильотина пычагы астында киселә.* Күзгә күренми торган матдәләр турында хикәяләр

**ГИЛЯК** *и. тунг.* Нивхларның – Россия һәм Япония территориясендә яшәгән аз санлы халыкның – элекке исеме. *Аңа кадәр монда «шыпырт кына» җирле халыклар – нивх-гиляклар, уилталар, ороклар, эвенклар, нанайлар яшәп яткан, серле айналар, японнар утрауда тирән эз калдырган, Сахалинның Кытай һәм Япония кул астында яшәгән вакытлары да булган.* Ф.Бәйрәмова

**ГИМН** *и. гр.* 1) Борынгы Грециядә аллалар һәм геройларны мактаган тантаналы җыр; Көнбатыш Европада XIX гасырга кадәр чиркәү җырының төре. *1948 елда Эрнст Шертель дигән немец галиме түгәрәк балчык тактада латин теленә якын ниндидер «һинд-европа» телендә Зевска һәм Минотаврга гимн сүзләре язылган дигән фикергә килгән.* Н.Фәттах

2) Дәүләт символы булып саналган яки социаль бердәмлек символы буларак кабул ителгән тантаналы җыр, көй. *Гадәти булмаган тынлыкка чумган урамнарга Кремль курантлары суккан аваз таралды. Гимн яңгырады.* Ш.Хөсәенов. *Кайчагында мактанышабыз без: Булды дибез, үзебезнең флаг. Икенчебез өсти: уянабыз Үзебезнең гимныбызны тыңлап.* Ф.Яруллин

3) Гомумән, тантаналы мактау җыры, яисә кемне яки нәрсәне данлауга багышланган әсәр. *Ул ел җәенең үз җырлары туды, болар – «Шомыртым»*

*һәм «Уяна таңы илемнең...» Болар тынычлыкка гимн булып яңгырадылар.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Кемнең дә булса аеруча яратып, еш җырлый торган җыры. *Әсгатьләр семьясының гимнына әйләнгән бу соңгы көй уйландыра, кешене кисәтә.* Р.Хафизова

◊ **Гимн җырлау** Артык мактау, мәдхия җырлау; үсендерү

**ГИМНАЗИСТ** *и. рус* Гимназия укучысы. *Аны инде ике-өч тапкыр балга, атасының Петроградта чагына туры китереп, сеңлесе Суфия тарафыннан оештырылган гимназистлар кичәсенә чакырдылар.* К.Нәҗми

**ГИМНАЗИ́СТКА** *и. рус* Гимназиядә укучы кыз бала. *Иптәш кызы гимназистка Хәят белән Әминә килеп керә. Икесе дә пөхтә киенгәннәр.* Ә.Фәйзи. *[Ф.Әмирхан] Казанның күп кенә билгеле гаиләләренә үтеп керә, төрле даирәләрдә күренә, студент һәм гимназистлар, курсистка һәм гимназисткалар --- белән аралаша башлый.* И.Нуруллин

**ГИМНА́ЗИЯ** *и. гр.* Гомуми урта белем бирә торган уку йорты. *Суфия гимназиягә киткән чакта, ул йоклап кала.* К.Нәҗми. *Морза туганнары кебек ерак шәһәрләргә барып гимназияләрдә, университетларда уку турында хыяллана иде ул.* Р.Мөхәммәдиев

**ГИМНАСТ** *и. гр. спорт* 1) Спорт гимнастикасы яки нәфис гимнастика белән шөгыльләнүче спортчы

2) Махсус жанрда – цирк гимнастикасында чыгыш ясаучы артист. *Аларга биеклектә уйнаучы гимнастлар хәленә керергә дә, кыл өстендә биюче артист ролен башкарырга да туры килде.* Казан утлары

**ГИМНАСТЁРКА** *и. рус* Совет Армиясендә 1969 елга кадәр хәрби кием формасы буларак кабул ителгән, тыгыз тукымадан тегелгән туры якалы күлмәк рәвешендәге өс киеме. --- *гимнастёркалары манма су булган, иңбашларына тир тозы бәреп чыккан...* Ә.Еники. *Фронтовиклар тегеләй уйлап карадылар, болай итеп карадылар, гимнастёркалар уңды, медальләрне, салып, карт әниләренә бирделәр...* М.Мәһдиев. *Өстенә ул затлы яшел гимнастёрка, шундый ук төстәге галифе чалбар, аягына озын кунычлы хром итек кигән ---.* Н.Фәттах

**ГИМНАСТЁРКАЛЫ** *с.* Гимнастёрка кигән. *Фронттан кайткан гимнастёркалы егетләр арасында мондый заказчиклар очрый иде.* М.Мәһдиев

**ГИМНА́СТИК** *с.* 1) Эчтәлеге гимнастикадан гыйбарәт, гимнастика функциясен үти торган

2) Гимнастикага караган, гимнастика өчен билгеләнгән. *Кызларның тездән югары юбка кигән, колагына гимнастик боҗра сыман зур алка таккаңы, кызыл иренен җәеп, Иреккә баш какты.* Ф.Садриев

**ГИМНА́СТИКА** *и. гр.* 1) Сәламәтлекне ныгыту, организмны чыныктыру максатларыннан ясала торган физик күнегүләр комплексы. *Митя көндезгәчә үлеп йоклый, тавышлар ишетми, торгач, ике сәгать гимнастика ясый, гер күтәрә...* А.Гыйләҗев. *Бибисара инде, фойега чыгып, кәнәфигә утыра, юынгычка барып, кул-аягына гимнастика ясый.* С.Сөләйманова. *Авызны ачып иснәү баш миен кислород белән баета һәм гимнастиканың бер төре булып тора.* Кызыклар дөньясында

2) Махсус гимнастик снарядларда яки алардан башка (спорт гимнастикасы), яки музыкага ияреп төрле гимнастик әсбаплар (туп, лента һ.б.) белән (нәфис гимнастика) яки әсбапсыз төрле катлаулы физик күнегүләр күрсәтүдән гыйбарәт спорт төре. *Футболчы Галимҗан Хөсәенов, хоккейчы Зиннәтулла Билалетдинов, гимнастика остасы Галимә Шөгероваларны ал! Халкыбызның данын кайларга илтмәгән алар!* А.Гыйләҗев. *Зифа иде Кәримәнең сыны, җиденче класста укыганда, аны һәм классташы Зөбәрҗәтне гимнастика секциясенә язганнар иде.* М.Хәбибуллин. --- *теннис, гимнастика, акробатика һәм җәядән ату турындагы хәбәрләрне минем күптән инде укыганым юк.* Казан утлары

3) Цирк сәнгатенең бер төре, манежда (партер гимнастикасы) яки манеж өстендә югарыда (һава гимнастикасы) беркетелгән махсус снарядларда һәм аппаратларда катлаулы күнегүләр күрсәтү

**ГИНЕКО́ЛОГ** *и. гр.* Гинекология белгече, хатын-кыз авыруларын дәвалаучы табиб. *Бөтен районына өч хирург, врачлар җитми, үзләре гинеколог та, уролог та.* Ф.Садриев. *Кичә гинекологка барган иде, врач аңа: «Балага узгансың», – диде.* М.Хәбибуллин. *Гинеколог Роза Хәмидуллина авыруны карагач, эшнең җитдилеген аңлый, шунда ук баш врачка телефоннан хәбәр итә.* Казан утлары

**ГИНЕКОЛО́ГИК** *с.* Гинекология өлкәсенә караган, гинекология белән бәйле. *Медицинада монгол чәе препаратларын бактерицид дару, кан агуны туктаткыч һәм беректергеч средство буларак ашказаны-эчәк һәм гинекологик авыруларны дәвалаганда кулланалар.* Урман аптекасы

**ГИНЕКОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның хатын-кыз организмының үзенчәлекләрен һәм җенси органнарының авыруларын, аларны дәвалау ысулларын өйрәнә торган тармагы. *Гинекология бүлеге клиниканың икенче катында урнашкан.* М.Маликова. *Гинекология бүлегенә Казаннан профессор килгән, хәзер урынбасар бүлмәсендә, керергә рөхсәт сорыйлар.* С.Сөләйманова

**ГИПЕ́РБОЛА** I *гр. әд.* Образлы рәвештә арттырудан, күпертүдән гыйбарәт стилистик фигура, алым. *Метафорадан башка табышмакларда тагын гипербола, чагыштыру, охшату, аллегория һәм аллитерацияләр бик еш кулланылалар.* Х.Ярми. *Гипербола – кыю фикер нәтиҗәсе булып торган баһадир образ ул, аның ярдәмендә реаль җирлектәге иң фантастик вакыйгаларны күрсәтеп була.* З.Нури. *Нигә алай кешене куркытырга, шул гипербола белән эш итү галәмәтедер инде.* К.Латыйп

**ГИПЕ́РБОЛА** II *и. гр. мат.* Туры түгәрәк конусны аның ике ягына параллель яссылык белән кискәндә барлыкка килгән, чиксез сузылган ике тармактан торган ачык кәкре. *Тигезьяклы гипербола $xy=const$ тигезләмәсе белән тасвирлана.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *$y=x^k$ гиперболасы белән $y=kx$*

*турысының кисешү нокталары арасындагы ераклыкны табыгыз.* Алгебра. *Эллипс, гипербола һәм парабола – борынгы грек галимнәре тарафыннан яхшы өйрәнелгән кәкреләр.* Югары математика нигезләре

**ГИПЕРБО́ЛИК** I *с. әд.* Гипербола I рәвешендәге, гипербола характерындагы; гиперболага бәйле

**ГИПЕРБО́ЛИК** II *с. мат.* Гипербола II формасындагы; гиперболага мөнәсәбәтле. *Мәсәлән, $AA_1$ һәм $BB_1$ гиперболик сызыклар, аркылы кисүче AB сызыгы белән кысынкы почмаклар ясап, бер-берсенә асимптотик якыная алалар.* Җ.Тәрҗеманов

**ГИПЕРБОЛО́ИД** *и. гр. мат.* Икенче тәртиптәге үзәкле чиксез өслек

**ГИПЕРЕМИ́Я** *и. лат. мед.* Авыру әгъзада кан тизрәк агу сәбәпле, тире яки лайлалы тышча гадәттәгедән күпкә кызыл булу; кызару, кызыллык

**ГИПЕРТО́НИК** I *и. рус* Гипертония белән авыручы кеше

**ГИПЕРТО́НИК** II *с.* Гипертония авыруы белән бәйле, шул авыру аркасында барлыкка килгән. *Дүләнә препаратлары, гипертоник авыруның башлангыч стадиясендә артериаль кан басымын төшерү өчен, аеруча киң файдаланыла.* Урман аптекасы. *Гипертоник криз*

**ГИПЕРТОНИ́Я** *и. гр. мед.* Тән тукымаларының тонусы арту һәм артериаль басым күтәрелү күренеше. *Илле тугызынчы елдан бирле гипертония белән җәфалана.* Г.Әпсәләмов. *Билгеле булганча, гипертония (кан басымының шактый нык күтәрелүе) организм өчен үтә куркынычлы, чөнки ул системаның җимерелүенә, кан юлларының шартлавына китерергә мөмкин.* Кызыклы физиология. *Тибет табиблары, гипертония белән көрәшү өчен, шактый үзенчәлекле ысул тәкъдим итәләр.* Идел

**ГИПЕРТРО́ФИК** *с.* Гипертрофиягә дучар булган. *Азатлыкны син гипертрофик хисләр аша кабул итәсең.* Р.Батулла

**ГИПЕРТРОФИ́Я** *и. гр. мед.* Организмның туганнан соңгы үсеше чорында, тукыма элементларының күләме арту исәбенә органнар яки тукымаларның зураюы. *Сыеклыкны, ягъни сыраны, күп күләмдә эчкәнлектән, беренче чиратта, бөерләр эштән чыга һәм йөрәк зурая (миокард гипертрофиясе).* Татарстан яшьләре

**ГИПНОЗ** *и. гр.* 1) Кешедә һәм кайбер хайваннарда була торган, ми эшчәнлегенең тоткарлануы белән бәйле, йокыга охшаш үзенчәлекле халәт. *Өйдә кеше булмавыннан файдаланып, без дә Мөхәррәмов белән гипноз сеанслары уздырырга булдык.* А.Расих. *Яшерен мөмкинлекләр кайчак һич көтмәгәндә, әйтик, гипноз вакытында ачыла.* Кызыклар дөньясында

2) Кешене гипнозлы йокыга талдырып, аңа тәэсир итү ысулы. *Фәнияр, көчле гипнозга ия булган кеше шикелле, үзенә килүчеләрне тиз генә җибәрми.* Ф.Яруллин. *Мортазин, гипноз астына эләккән кеше төсле, гүзәл йөздән карашын аера алмыйча озак утырды.* В.Имамов. *Гипнозга бирелми калган ике малай бу тамашаны куркынып күзәтеп тордылар ---.* Казан утлары

**ГИПНОЗЛА́У** *ф.* 1) Гипноз (*2 мәгъ.*) белән тәэсир итү, гипноз (*1 мәгъ.*) халәтенә китерү. *Бистәдә ниндидер бик көчле, бөтен халыкны берьюлы гипнозлый ала торган экстрасенс хәрәкәт итә.* Р.Фәизов. *Киноларда гына була торган сәер хәлләр Хәлимне гипнозлады, сихерләде, ахры ---.* Г.Гыйльманов. *– Бөтен классыгыз белән гипнозласам, ризамы соң сез? – дигән иде, балалар бик тиз күнделәр.* Казан утлары

2) *күч.* Бик нык тәэсир итү, үзенә җәлеп итеп, тарту

**ГИПНОЗЛЫ** *с.* 1) Гипноз тәэсирендә булган, гипноз халәтендәге

2) Гипноз алымына ия булган, гипнозлау көче булган. *– Әйе, язгалыйм, – дидем мин, башны ия төшеп һәм бу хатынның, гипнозлы дип әйтимме, күңел түренә үтеп керә торган үткен карашыннан куркынып.* А.Расих

**ГИПНОЗЛЫК** *и. к.* **гипноз** (*1мәгъ.*). *Алар, үзләре дә сизмәстән, сезнең белән рухи элемтәгә кергәннәр, чөнки сездә дә гипнозлык көче бар икән.* Ә.Гадел

**ГИПНОЗЧЫ** *и.* 1) Гипноз алымы белән дәвалаучы табиб. *Ун минутлар чамасы вакыт үткәч, Әхәт йокыга китә һәм гипнозчы кушканнарның һәммәсен үти.* Казан утлары

2) Гипноз көченә ия булган кеше, гадәттә, чыгышларында гипноз алымнарын кертеп җибәрүче иллюзионист. *Әле күптән түгел генә Вахитов клубында гипнозчы булып китте.* А.Расих. *Шәһәр тулы афишалар атаклы гипнозчы килүе турында хәбәр итә.* Җ.Фәйзи. *Зөбәйдә ханым белән Исмәгыйль бәй – гипнозчылар, цирк артистлары.* Ә.Гадел

**ГИПНОЗЧЫЛЫК** *и.* Гипнозга сәләтлелек, гипноз эше. *Миндә гипнозчылык һөнәре барлыгы тиз арада тирә-як авылларга да билгеле булган.* Җ.Фәйзи

**ГИПНОТИЗЁР** *и. фр. к.* **гипнозчы**. *Атаклы гипнотизёрларның серле эшләрен күргәнем бар.* Җ.Фәйзи. *--- матавыклы авыр көннәрдә ул һәрчак Артур Александровичны эзләп таба ала, аның белән, берәр чынаяк чәй эчеп яисә бер рюмка коньяк җибәреп, ярты сәгать кенә сөйләшеп утыру да тәҗрибәле гипнотизёр, экстрасенс янында булгандай тәэсир итә иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГИПНОТИЗМ** *и. фр.* 1) Гипноз белән бәйле күренешләрнең барлыгы. *Үзегез белгәнчә, гипнотизм ул – медицина фәненең психикага бәйләнгән бер өлкәсе.* Җ.Фәйзи

2) *күч.* Үзенә җәлеп итү, тартып тору, карату үзенчәлеге. *Бу шәхеснең гипнотизмы искиткеч зур иде*

**ГИПНО́ТИК** *с.* 1) Гипноз тәэсирендә барлыкка килгән, гипноз тәэсире белән аңлатыла торган. *Гипнотик халәт. Гипнотик йокы*

2) Гипноз белән бәйле, гипноз күренешенең катнашы булган

**ГИПОТАЛА́МУС** *и. гр.* Баш миенең күрү калкымнары астында урнашкан, вегетатив нерв системасы, эчке секреция бизләре аркылы эчке тирәлекне, вегетатив функцияләрне көйли торган өлеше. *Мәченең гипоталамусын көчсез генә электр тогы белән тынычсызлау, киресенчә, аның ачуын кабарта.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ГИПО́ТЕЗА** *и. лат.* Теге яки бу күренешне аңлату өчен әйтелгән һәм, фәнни теория көчен алсын өчен, тәҗ-

рибәдә тикшерелергә һәм фактлар белән дәлилләнергә тиешле фәнни фараз, гөман. *Безнең якларда алар [тимердән ясалган хезмәт кораллары], мең ел чамасы элек барлыкка килгән дигән гипотеза яши.* Р.Мостафин. --- *ул гипотезаларның берсе дә диңгез суының нигә шулай артып я кимеп тору сәбәбен дөрес итеп аңлатып бирә алмадылар.* А.Муранов. *О.Сөләйманевнең борынгы Шумерстанда борынгы прототюрк халыклар яшәгән, аларның теленнән сүзләр шумер теленә үтеп кергән дигән гипотезасы өчен нигез бар.* Ә.Кәримуллин

**ГИПОТЕНУ́ЗА** *и. гр. мат.* Турыпочмаклы өчпочмакның туры почмагына каршы ягы. *Әгәр зур катетны 4 дм га арттырып, икенчесен 8 дм га киметсәк, табылган турыпочмаклы өчпочмакның гипотенузасы озынлыгында булыр.* Алгебра

**ГИПОТЕРМИ́Я** *и. гр. мед.*1) Кеше яки җылы канлы хайваннарның температурасы түбән төшү нәтиҗәсендә, тәндәге җылылыкның таралуы. *Тән температурасы 35 градустан да түбәнәя икән, бу гипотермиягә китерә.* Ватаным Татарстан

2) Дәвалау максаты белән, организмны яки аның аерым өлешләрен ясалма суыту

**ГИПОТЕ́ТИК** *с.* Гипотеза буларак кына китерелә яки кабул ителә торган, фараз ителгән, фәнни фактлар белән дәлилләнмәгән. --- *авторның бәхәссез яңа, уңышлы, оригиналь эшкәртмәләре белән бергә, --- артык гипотетик, расланып җитмәгән куелышлары, үзенчә әйткәндә, фараз-юрамалары бар.* Л.Җәләй. *Минә әгәр физиклар гипотетик гравитоннарны, «тартылу көче кисәкчекләрен» эзләп тапсалар, аларның чыннан да бар икәнен исбат итсәләр, ул вакытта, ихтимал, саклагыч экраннар, авырлыгы булмаган очу аппаратлары һәм космик корабльләр турында сөйләү урынлы булыр иде.* Химиянең киләчәге

**ГИПОТО́НИК** I *и. рус* Гипотония белән авырый торган кеше

**ГИПОТО́НИК** II *с. мед.* Гипотониягә караган, гипотония сәбәпле барлыкка килә торган

**ГИПОТОНИ́Я** *и. гр. мед.* Органнарның, тукымаларның киеренкелеге, тонусы кимү һәм шуның белән бәйле кан басымы төшү күренеше

**ГИПО́ФИЗ** *и. гр. анат.* Умырткалы хайваннарда һәм кешедә баш мие нигезенә кушылып киткән, организмның үсешенә, җитлегүенә тәэсир итә торган эчке секреция бизе, ми үсентесе. --- *сөт ясалуны регуляцияләүдә --- гипофиз гормоны – пролактин әһәмиятле роль уйный.* Кызыклы физиология. *Мәрсин балыгына мәрсин гипофизын керткәч, уылдыкның берничә ай урынына тәүлек ярым вакыт эчендә өлгерүе билгеле була.* Кызыклы ихтиология

**ГИПОФУ́НКЦИЯ** *и. гр. мед.* Нинди дә булса орган, тукыма яки системаның функциясе түбән булу

**ГИППОПОТАМ** *и. гр.* Бегемот

**ГИПС** *и. гр.* **1.** 1) Минерал, ак яки сары төстәге акбурлы матдә. *Ул күлләр тиз җеби торган ак балчык, гипс, доломит токымнар яткан карст катлауларда урнашканнар.* А.Муранов. --- *ул башкарган монументаль эшләр дә байтак – мозаика, сграффито, гипс резьбасы, стена бизәлеше – болар Татарстанның һәм Башкортстанның урам һәм мәйданнарында --- сакланалар.* Г.Ахунов. *Әнә «Кама тамагы гипс руднигы»нда эшче кулларга кытлык юк.* Ватаным Татарстан

2) Сынган әгъзаны хәрәкәтсез хәлдә беркетү өчен, шушы матдәне файдаланып салына торган хирургик бәйләү. *Гипска салынган аягы тазарырга өлгерми, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, ул кабат больницага килеп эләгә.* Р.Вәлиев. *Минә ул гипста ятучы яралылар палатасына килеп керде.* Х.Камалов. *Син гафу ит, тора алмыйм әле: сул аягым тагын гипста.* Р.Харис

**2.** *с. мәгъ.* Шул материалдан ясалган. *Марля белән уралып беткән Гавашев стенага сөяп куелган ак гипс статуяны хәтерләтә иде.* З.Фәтхетдинов

**ГИ́ПСЛАУ** *ф.* 1) Сынган әгъзаны хәрәкәтсез хәлдә беркетү өчен, гипс белән махсус хирургик бәйләү салу. *Тәрәзә төбенә сөялгән агайның ачык якасыннан бинт белән уралган күкрәге агарып күренә, уң кулы, гипслап, муенына асып куелган ---.* Р.Вәлиев

2) Гипс кертү, гипс катнаштыру. *Клеверга файдалы булган шикелле, гипслау люцерна өчен дә бик файдалы.* Күпьеллык үләннәр

**Гипслап кую** Гипс белән бәйләү салып калдыру

**ГИ́ПСЛЫ** *с.* 1) Составында гипс булган, гипс кушылмаларыннан торган. --- *күл астында суны үткәрә торган, известьлы һәм гипслы катламнар ята.* Р.Мостафин

2) Гипс салынган. *Гипслы кул*

**ГИПЮР** *и. фр.* **1.** Бераз кабарып торган бизәкләре булган челтәр тукыма төре

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Гипюр күлмәк*

**ГИРЛЯ́НДА** *и. ит.* 1) Лента, тезмә формасында үрелгән чәчәкләр һәм (яки) яшел ботаклар бәйләме. --- *грекләр венок ясарга яратканнар. Ә Көнчыгыш илләрендә чәчәкне гирлянда итеп үргәннәр.* З.Фәтхетдинов

2) Шундый формада ясалган, архитектура бизәлешенең бер элементы булган, күләмле яки буяу белән эшләнгән бизәк, орнамент

3) Бәйрәмчә бизәү өчен файдаланыла торган электр лампочкалары тезмәсе. *Утлар гирляндасы – бер дәрья! Иллюминаторгаябышып, чынчынлыклап эзлим Синең тәрәзәдәге шәм яктысын...* Р.Фәйзуллин. *Аллыгөлле нурлар сибүче гирляндалар, фонарьлар тирәсендә күч аерган корт иле шикелле биешүче кар бөртекләре --- бөтерелә.* Ф.Садриев

**ГИРОКО́МПАС** *и. гр.-ит.* Гироскоп принцибында эшләнгән механик компас. *Күңелем – суднодагы гирокомпасның спирты кебек саф, үтә күренмәле.* М.Мәһдиев. *Гирокомпас әйләнми, руль эшләми башлады, навигация утлары сүнде.* М.Юныс

**ГИРОСКОП** *и. гр.* Тиз әйләнгәндә, үзенең юнәлешен төп-төгәл саклый һәм, шуның белән судноларга тотрыклылык бирү, очкыч һ.б.ш. белән идарә итү өчен, навигация приборларында файдаланыла торган күчәрле прибор. *Әмма соңгы вакытларда очучыларны*

*гироскоп кына канәгатьләндерми башлады.* Кызыклар дөньясында

**ГИРЬЯН** *и. гар. иск.* Яшь түгүче, елаучы кеше. *Сезне гирьян иткән дошман явы – Аллаһ биргән сынау вәгъдәсе.* Казан утлары

**ГИСТО́ЛОГ** *и. рус мед.* Гистология белгече

**ГИСТОЛО́ГИК** *с. мед.* Гистология белән бәйле, шуңа караган. *Гистологик тикшеренү*

**ГИСТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Кеше һәм хайван тукымаларының үсешен, төзелешен һәм функциональ үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән

2) *сөйл.* Тукымаларның нормага туры килү-килмәвен билгеләү өчен ясала торган анализ. *Гистология нәтиҗәсе әйләнеп килә: рак.* С.Сөләйманова

**ГИТА́РА** *и. гр.* Сигезле формасындагы агач резонатор корпуслы, чиртеп уйнала торган кыллы музыка коралы. *Я, гитараларын күтәреп, комсомоллар килде, я --- авыл яшьләре кереп тулдылар.* Ф.Яруллин. *Әнә тегендәрәк транзистор җыр сиптерә, мондарак гитара чирттерәләр.* Э.Касыймов. *Ул гитарада яхшы уйный, тыпырдатып, чечётка бии ---.* Р.Мирхәйдәров

**ГИТА́РАЧЫ** *и.* Гитарада уйнаучы кеше, гитарада уйнау остасы. *Ул [Заһидә] гитарачы студент Янбулатов янына килеп утыра да җырлый башлый.* Р.Батулла. *– Сезнең бакчада нинди гитарачы яшеренгән? – дип сорады Рушан.* Р.Мирхәйдәров

**ГИТАРИСТ** *и. рус к.* **гитарачы**. *– Килде, безнең гитарист килде! – дип шаулашты алар.* Р.Вәлиев. *Барселона минем күз алдыма кафедраль собор янында утыручы акылдан шашкан гитарист сурәтендә килеп баса.* М.Юныс

**ГИТЛЕРИЗМ** *и. рус тар. к.* **гитлерчылык**. *Гитлеризмга каршы сугыш корбаннарының диварга чокып язылган багана-багана исемнәрен күргәч, башы әйләнеп китте.* А.Хәлим

**ГИ́ТЛЕРЧЫ** *и.* Гитлерчылык тарафдары; фашист армиясендә сугышучы солдат. *Гитлерчыларга нәләт яудырып кына күңелгә тынычлык табып булмый.* Х.Камалов. *Гитлерчылар хыянәтче Сосновскийны шәһәр комендfestival итеп куялар.* Р.Вәлиев. *Гитлерчылар, отрядтагы разведчиклары белән элемтә тоту өчен, авылда берәр кеше урнаштырмадылар микән?* З.Фәтхетдинов

**ГИ́ТЛЕРЧЫЛЫК** *и. тар.* Германиядә 1933–1945 елларда А.Гитлер хакимлеге, шул хакимият тарафыннан рәсми үткәрелгән нацистик идеология һәм сәясәт

**ГЛАДИА́ТОР** *и. лат. тар.* Борынгы Римда цирк аренасында үзара яки кыргый хайваннар белән сугышырга махсус өйрәтелгән кол яисә хөкем ителгән кеше һ.б.ш. *Нәрсә турында гына сөйләмәсен – гладиаторларның Колизейда кичәге чыгышлары турындамы, Рим шәһәрендә яңадан бер мунча салу турындамы – үзенең чыгышын Катон бер генә төрле итеп тәмамлый икән ---.* М.Мәһдиев. *--- ул [Коммод], көрәш мәйданында гладиаторлар белән сугышып, үзенең императорлык дәрәҗәсен түбәнсетте ---.* Н.Макиавелли. *Надмахиида сугышасы корабльләргә команданы хөкем ителгән җинаятьчеләр һәм гладиаторлардан туплыйлар.* Кызыклар дөньясында

**ГЛАДИО́ЛУС** *и. лат. бот.* Сусынчалар семьялыгыннан, озын кыяк яфраклы, бик күп төрле төсле эре бүрәнкәсыман чәчәкләре сабакка урнашкан, бүлбе-суганчалы күпьеллык үлән үсемлек; кылыч гөл. *Менә алар биек сәхнәгә менделәр, кызыл бәрхет җәелгән озын өстәлдәге савытларга гладиолусларны бүлеп утыртып куйдылар.* М.Маликова. *Кашкарый, дәлия, гладиолус һәм күп кенә башка үсемлекләрнең чәчәкләре чәчәк төркеменә тупланган була.* Биология. *Гладиолусларны бүлбе суганчалардан һәм орлыктан үрчетәләр.* Йорт эшләре

**ГЛАЗУРЬ** *и. нем.* 1) Балчык, фаянс һ.б.ш. савытларны каплый торган ялтыравык пыяласыман эремә. *Көндәлек тормыш әйберләренә эмаль, глазурь, төрле төстәге лаклар төшерү, чигү, ташка, бамбукка, фил сөягенә сырлап (уеп) бизәкләр ясау кебек эшләр башлана ---.* К.Гыйззәтов

2) Камыр ризыклары өстенә сөртелә торган куе шикәр эремәсе. *Глазурь кибеп җиткәнче, тортны үтәли җилдә тотарга ярамый, чөнки аның суы чыгып, ялтыравыгы бетүе мөмкин.* Йорт эшләре

**ГЛАЗУРЬЛА́У** *ф.* Глазурь белән каплау, глазурь йөгертү. *Аквариумның өч бүлеге дә, бигрәк тә аларның төпләре, яхшы глазурьланган кызгылт керамик плитә белән балкый, стеналары бассейндагы кебек зәңгәрсуга төрелгән иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГЛАЗУРЬЛЫ** *ф.* Глазурьланган. *Ачык төсләрдәге ялтыравык йөгертелгән глазурьлы, гадәти булмаган гипсокерамик әкияти аждаһалар, сигезаяклар, сугышчан кыяфәтле әтәчләр, горур оҗмах кошлары --- – бу эшләр ул вакытта ук танылган Зураб Каргарелиныкы иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГЛА́НДА** *и. фр. сөйл.* Аңкау артындагы бадәмсыман биз. *Рамилнең шул булыр инде: безнең сыман тамак шешә димәс, гланда дияр.* Н.Әхмәдиев

**ГЛА́СНЫЙ** *и. рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә: шәһәр думасы яки башка җирле идарә органының әгъзасы. *Безнең шәһәрдә мин гласный булып торган чакта, шунда, думада, писерме булып торган бер карт морза бар иде ---.* Г.Камал. *Сәхип солдат үзе болай аңлатты: шәһәр башлыгы Дьяченко бу эшкә риза булган, әмма управада казначылык эшен алып баручы гласный Борһан Муллин моңа каршы килгән.* Ә.Фәйзи

**ГЛА́СНЫЙЛЫК** *и. тар.* Гласный булу, гласный вазифасы. *Казан шәһәр думасына гласныйлыкка калын корсаклы, таза, йокычан бай кешеләр кирәк.* Г.Тукай. *Узган ел гласныйлыкка сайланырга да йөреп караган идем, булдырып булмады.* Г.Камал

**ГЛА́УБЕР ТОЗЫ** *и. хим.* Сульфатлар төреннән, медицинада, пыяла, сабын, текстиль җитештерүдә кулланыла торган матдә. *Шул ук вакытта мирабилит, ягъни глаубер тозы да чыгарыла башлый.* А.Муранов

**ГЛАУКО́МА** *и. гр. мед.* Күз эчендә басым күтәрелү һәм күрү сәләте начарлану белән характерлана торган күз авыруы. *--- глаукома белән авырган дөм сукыр Садри, үзе белән бер камерада*

*кып-кызыл киселгән бер коммунистны күргәч, авыр сулап болай ди: – Их, Галимҗан иптәш [Ибраһимов], син ничек монда? Син бит – ата коммунист булып йөргән кеше.* М.Мәһдиев. *[Йокы үләненең] Яңа сыгып алынган согы белән глаукоманы дәвалыйлар.* Урман аптекасы

**ГЛИ́ССЕР** *и. фр.* Су өстеннән җиңел шуып бара торган яссы төпле тиз йөрешле көймә

**ГЛИЦЕРИН** *и. гр.* Майлардан җитештерелә торган, медицинада һәм техникада файдаланылган, тәмгә төчкелтем, төссез куе сыекча. *Соя мае конфет, соус, соя сөте, шулай ук маргарин, сабын, глицерин, лак һәм буяу җитештерүдә кулланыла.* Л.Мәүлүдова. *Майлы тире өчен глицерин белән ясалган крем куллану яхшы.* Йорт ашлары

**ГЛИЦИ́НИЯ** *и. гр. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, яфракларын коючан зур лианалар ыругы, хуш исле чәчәкле төрләре декоратив үсемлек буларак үстерелә. *Сары акация, ак акация, глициния һәм хуш исле борчак кебек декоратив үсемлекләр күп таралган.* Биология. *Соры коймалардан «глициния» дигән үрмәле үсемлекнең аксыл шәмәхә тәлгәшләре түбәнгә сузыла.* Дөньяда ниләр бар

**ГЛИ́Я** *и. гр.* Нерв тукымаларының нейроннардан башка күзәнәкләр җыелмасы. *Элек глияләр бары тик терәк функциясен генә үтиләр, нейроннарны барлык кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итәләр дип исәплиләр иде.* Кызыклы физиология

**ГЛОБАЛЬ** *с. фр.* 1) Бөтен дөньяны үз эченә алган, бөтен Җир шарына караган. *Җир шарында бара торган зур, глобаль үзгәрешләр сәүдә, хезмәт күрсәтү, мәгълүмат алмашу, мәдәниятләр үсешендәге күп кенә географик һәм сәяси киртәләрне алып ташлады.* Казан утлары

2) Тулы, һәрьяклы, һәр якны үз эченә алган; гомуми. *Глобаль фикерләү һәркемгә дә бирелми шул.* Т.Галиуллин. --- *бүген җанда канәгатьсезлек: глобаль масштабта әнә табигать көйсезләнә, яңалыкларны кертү дә озаккарак сузыла...* Р.Хисмәтуллин

**ГЛОБАЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* Глобальләшүгә китерү, глобальләшүгә дучар итү. *Глобальләштерү идеясендә Чыңгыз ханның рухы – бөтен дөньяда хакимлек итү хыялы – кабат-кабат чагылып китә.* Р.Хәкимов

**Глобальләштереп бетерү** Нык глобальләштерү

**ГЛОБАЛЬЛӘШҮ** *ф.* Бөтен дөньяда барган сәяси, иҗтимагый, икътисади процессларның аерым җәмгыятьләргә тәэсир итүе, барлык җәмгыятьләрнең үзара бәйлелеге арта бару

**Глобальләшә төшү** Бераз глобальләшү; тагын да ныграк глобальләшү

**Глобальләшеп бетү** Тәмам глобальләшү

**ГЛОБАЛЬЛЕК** *и.* 1) Глобаль булу. *Мәсьәләнең глобальлеге*

2) *сәяси* Дөньяның бербөтен икътисади, социомәдәни һәм сәяси система буларак формалашуын һәм үсүен яклый торган идеология. *Инде шигърияттә глобальлек чире – Җир шарын иңгә утыртып, яисә учка алып, үзең күтәрә алмаслык «олы гамьгә» чумулар – сурыгып, саркып бара иде.* Ватаным Татарстан

**ГЛОБУС** *и. лат.* Җирнең, Айның яки Кояш системасының башка планеталарының шар өстендә бирелгән картографик сурәте. *Классны кемдер җыештырып куйган иде. Фәридә ападыр әле. Алай дисәң, глобусны, тәрәзә пыялаларын сөртергә оныткан.* Г.Нәбиуллин. *Картада яки глобуста күрсәтелгән күлләргә игътибар итсәк, аларның кайберләре – зәңгәр, кайсылары шәмәхә төскә буялганын күрербез.* А.Муранов. *Шкаф өстендә бер глобус, ялангач стенада ярымшарлар картасы.* М.Мәһдиев

**ГЛОКСИ́НИЯ** *и. лат.* Геснерийлылар семьялыгыннан, ачык төсле чәчәкле, Америкада таралган, декоратив үсемлек буларак үстерелә торган күпьеллык үлән һәм ярымкуак үсемлек. *Глоксиния – бәрхетсыман йомшак эре яфраклы, матур чәчәк атучы бүлбеле гөл.* Йорт эшләре. *Гөл чүлмәгенә дымлы комга нинди дә булса бер үсемлек – миңле гөл, узамбар миләүшәсе яки глоксиния яфрагын утыртып тамырландырыгыз.* Биология

**ГЛОССА́РИЙ** *и. лат.* Нинди дә булса белем тармагының авыр аңлаешлы терминнарын аңлата яки тәрҗемәсен бирә торган сүзлек

**ГЛУШИ́ТЕЛЬ** *и. рус* Техникада тавышны, шауны киметү өчен махсус җайланма. *Глушительне алганнар. «Ява» узганда, тәрәзә рамнары селкенә.* М.Мәһдиев. *Глушитель ычкынган, юлларыгыз – чокыр да чакыр.* Р.Вәлиев

**ГЛЮКО́ЗА** *и. гр.* Табигатьтә иң киң таралган, тере тукымаларда һәм үсемлекләрдә була торган һәм тереклек итү өчен, энергиянең төп чыганагы булып торган углевод, моносахаридлар классыннан органик катнашма: виноград шикәре. --- *бер дә өзми тукландыру уколлары ясап торалар, кан тамырына глюкоза җибәрәләр.* Х.Камалов. *Чынында организм бер генә төрле ягулыкны – глюкозаны гына файдалана.* Кызыклы физиология. *Химик матдәләр тәэсирендә, алар чын глюкозага әйләнә, ә моннан инде спирт яисә ашарга яраклы аксым продуктлары җитештереп була.* Кызыклар дөньясында

**ГНЕЙС** *и. нем. мин.* Башлыча шпат, кварц һәм слюдадан торган тау токымы. *Тротуар плитәсе гнейс һәм аңа охшаган катламлы тау токымнарыннан эшләнә.* Төзү материаллары. *Уртача биеклектәге таулар гранит, гнейс, комташ, известь катнашкан тау токымнарыннан ясалган һәм киң үзәннәр белән аерылган.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ГНОМ** *и. лат.* Көнбатыш Европа мифологиясендә җир асты хәзинәләрен саклый торган сакаллы кәрлә. *Балалар өчен «Кечкенә гном» дигән махсус бит безнең гәзиттә дә булган, ләкин аны чыгаручылар әле районның демографиясен яхшырту белән мәшгуль, ягъни декрет ялында.* Кызыл таң

**ГНОСЕОЛО́ГИК** *с.* Гносеология белән бәйле, гносеологиягә караган

**ГНОСЕОЛО́ГИЯ** *и. гр. филос.* Танып белү тәгълиматы; танып белүнең мөмкинлекләрен, чыганакларын, форма һәм алымнарын һ.б.ш. өйрәнә торган фәлсәфә белеме тармагы

**ГНОСТИЦИЗМ** *и. гр. филос.* Борынгы грек идеалистик фәлсәфәсе

һәм Көнчыгыш диннәр нигезендә үстерелгән христиан догматларыннан гыйбарәт, христианлыкның башлангыч чорындагы дини-фәлсәфи агым

**ГОБЕЛЕН** *и. фр.* 1) Югары сәнгать әсәре дәрәҗәсендә, кулдан тукылган, картина, пәрдә һ.б.ш. буларак кулланылган декоратив тукыма. *Гобелен ау йорты өчен махсус эшләнгән диярсең, ауга чыккан патша, ау этләре, ярannары, вельможалар, матур хатыннар, кавалерлар...* Р.Мирхәйдәров

2) Төрле бизәкләр, сурәтләр төшереп, машинада тукылган тукыма яки келәм

**ГОБОЙ** *и. фр. муз.* Тавыш югарылыгы ягыннан флейта белән кларнет арасындагы, очы бүрәнкәләнеп торган зур булмаган конус формасындагы тынлы агач уен коралы. *--- музыка уен кораллары --- камилләшкәннәр. Мәсәлән, торба, кларнет-саксофон, гобой һәм алар семьялыгына кергән башка уен кораллары.* Казан утлары

**ГОБОЙЧЫ** *и.* Гобойда уйнаучы кеше, оркестрда гобой партиясен алып баручы музыкант. *Фәрит [Яруллин] гобойчы М.Батталов белән бер бүлмәдә торды.* Казан утлары. *[Рафаэль Ильясовка] – Гобойчы булдым, дисез. Радиода гобойчы буларак язмаларыгыз бармы соң?* Мәдәни җомга

**ГОГЫЛДА́У** *ф.* Тамак төбеннән килгән калын тавыш белән көлү. *Кировоград өлкәсендәге авылдан килгән, «Молотов» крейсерында боцман булып хезмәт итүче метр да сиксәнле Панас Перешибайло гогылдап көлде ---.* М.Мәһдиев

**ГОЗЕР** *и. гар.* 1) Үтенеч, ялыныч, йомыш. *Ленинның сеңлесе гозеремне аңлады, мине ВТУЗга восстановить итеп кайтарды.* А.Расих. *Әтисе сугышка кадәр шәһәрдә милиционер булып эшли иде, тегенди-мондый гозер төшсә, авыл халкы гел шуның янына барды – әтисе барысына да ярдәм итте.* М.Мәһдиев. *--- безнең мөдир гозереңне колагына да элми, аптырагач, министрга жалу яздым.* Н.Гыйматдинова

2) Сәбәп, сылтау

**ГОЗЕ́Р ИТҮ** *ф. иск. к.* **гозер кылу**

**ГОЗЕ́Р КЫЛУ** *ф. иск.* Гозерләнү, үтенеп сорау, ялыну

**ГОЗЕРЛӘНҮ** *ф.* **1.** Үтенеч белән мөрәҗәгать итү, үтенеп сорау, ялыну, ялвару. *Сугышка җибәрүләрен ачынып-ачынып гозерләнүче яшь солдатларга офицерлар җавапны кыска тоталар: «Без вас обойдутся!»* Г.Ахунов. *– Миңа бик куркыныч, – дип гозерләнергә тотына. – Күкрәгемдә ниндидер авырлык бар, зинһар, коткарыгыз!* Х.Камалов

**2. гозерләнеп** *рәв. мәгъ. к.* **гозерләп**. *Егет нихәтле гозерләнеп, ялварып сораса да, бай үз сүзеннән кайтмый...* А.Муранов

**Гозерләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта бик нык үтенү, ялвару

**Гозерләнеп йөрү** Күп кешегә үтенү, ялвару

**ГОЗЕРЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Сорау, үтенү, ялвару. *Гадәти генә үтенү, гадәти генә гозерләү түгел иде бу.* Б.Камалов. *– Малайлар, бәхәсләшмәгез, без өчебез дә дус булдык, дуслар булып аерылышыйк, – диде ялварган, гозерләгәндәй.* Х.Камалов. *Ат җигеп, аның хозурына киләләр һәм газаплардан йолуын гозерлиләр иде.* Казан утлары

**2. гозерләп** *рәв. мәгъ.* Ялварып, үтенеп, түбәнчелек белән, нык ялынып. *Гозерләп килгән Алла бәндәсенә күрсәткән бер изгелек кайчан да булса уны белән үзеңә кайтыр.* Ф.Латыйфи. *«Зинһар, бер юлга какмагыз инде», – дип, гозерләп үтенгәндәй кыланды ---.* Э.Касыймов. *Мәҗлесләргә йөртәләр үземне. Гозерләп, ялварып чакыралар.* Б.Камалов

**Гозерләп тору** Шушы моментта яки шактый вакыт дәвамында үтенү, ялвару

**ГОЗЕРЛЕ** *с.* 1) Үтенеч, ялвару белдерә торган. *Гозерле караш*

2) Үтенече булган, йомышы булган. *Гозерле кеше*

**ГОЗЕ́Р ТЕЛӘҮ** *ф. иск.* Гафу үтенү. *Барып кызыма әйтеңез: сарайның ишек-тәрәзәсен ачсын, ул егетне үз катыйна алсын, гозерләр теләсен, дога үтенсен!* Дастан

**ГОЛ** *и. ингл. спорт* Командалы спорт уеннарында каршы команданың капкасына кергән туп (алка), шуның өчен алынган очко. *Ул мәчедән дә җитезрәк кыланды: сикерде, очты, мәтәлчек атты, аркасына ятты, тәгәрәде, әмма бер гол да керттермәде.* А.Гыйләҗев

**ГОЛӘМА** *и. гар. к.* **голяма**. *Хәзрәт киткән җирендә бер голәма мәҗлесенә туры килгән ---.* Г.Ибраһимов. *Анда бөтен шәһәрнең, якын-тирәдәге авылларның атаклы дәмулла һәм ишаннарыннан башлап, мәзиннәр, хәлфәләр, --- ул заманның голәмасы – барысы да шунда булып, арада Әкрәм карый шикелле болай гына туры килүче мөсафир, гыйлем әһелләре дә күп иде.* М.Галәү. *Мөселман голәмасы күп җыелса, вәгазен ишек алдындагылар да ишетсен, янәсе.* Г.Мөхәммәтшин

**ГОЛДЫРА́У** *ф. к.* **голдырдау**

**ГОЛДЫР-ГОЛДЫР** *иярт.* **1.** 1) Күркәләр чыгарган көчле түбән тавышларны белдерә. *--- ияк асларындагы катлы-катлы борынгы алкаларын дерелдәтеп, күләгәдән кояшка голдыр-голдыр күркәләр кабарынып чыкты ---.* А.Гыйләҗев

2) Кешеләр калын түбән тавыш белән сөйләшкәндә, көлгәндә чыккан тавышларны белдерә

**2.** *с. мәгъ.* Горылдап торган, түбән, калын (тавыш турында). *Тимер исе. Аракы исе. Голдыр-голдыр тавышлар.* А.Гыйләҗев

**ГОЛДЫРДА́У** *ф.* 1) Каты, ямьсез, голдыр-голдыр иткән тавыш чыгару (күркәләр турында)

2) *күч.* Бугаз төбеннән чыккан калын тупас тавыш белән сөйләшү, кычкырышу

**Голдырдап кую** Бер тапкыр голдырдаган тавыш чыгару

**Голдырдап тору** Бертуктаусыз голдырдаган тавышлар чыгару

**Голдырдый башлау** Голдырдарга тотыну

**Голдырдый бирү** Голдырдавын дәвам итү, һаман да голдырдау

**ГОЛЕЦ** *и. рус* 1) Балитор семьялыгыннан, озынча яссы гәүдәле, тәңкәсез, тирәндә яшәүче төче су балыгы. *Бу күлдә сиг, голец, муксун ди-*

*гән кыйммәтле промысел балыклары яши ---.* А.Муранов

2) Сөләйман балыклар семьялыгыннан диңгез балыгы

**ГОЛИАФ** *и. лат.* 1) Тәүраттагы риваятьтә тасвир ителгән, булачак Иудея патшасы Давид тарафыннан җиңелгән алып

2) *күч.* Алып, гигант

3) Пластинкамыеклылар семьялыгына караган, Африканың тропик урманнарында яши торган, 10 см гача озынлыктагы коңгызлар ыруы

4) *зоол.* Африканың экваториаль һәм тропик урманнарында яши, нигездә бөҗәкләр, кыслалар, кечкенә бакалар белән туклана, авырлыгы 3 кг, буе 30 сантиметрга җитә торган бака төре. *Голиаф Камерунның һәм Экваториаль Гвинеяның куе урманнарындагы тулы сулы елга шарламаларын аеруча ярата.* Кызыклар дөньясында. *Өлкән голиафлар бик сак һәм куркучан, аларга якынаеп булмый.* Кызыклар дөньясында

**ГОЛКИ́ПЕР** *и. ингл.* Спорт уеннарында капкада торучы уенчы, капкачы. *Капкада торучы теге... ничек әле үзе, аты коргыры? – голкипер Гыйззәтуллина, селкенергә дә өлгермичә, авызын ачып кына калды.* Ә.Еники. *Алган җәрәхәт шактый җитди: голкиперның бармагы сынган булып чыга.* Мәдәни җомга

**ГОЛКЫЛДАТУ** *ф.* Сусаганда, эчемлекне теләп эчкәндә, зур-зур йотымнар ясау, голт-голт йоту

**Голкылдатып җибәрү** Зур йотымнар белән тиз эчеп бетерү

**ГОЛЛАНД** *и.* Голландиядә яшәүче төп халыкның вәкиле

**ГОЛЛА́НДИЯЛЕ** *и.* Нидерландта (Голландиядә) яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Голландиялеләр татар авылын да карап кайтырга җитешкәннәр. Арьэн – мунча керүне, ә Эстер татар гаиләсен бик яраткан.* Шәһри Казан

**ГОЛОГРА́ФИК** *с.* Голографиягә нигезләнгән, шуңа бәйле. *– Кенәгәбезгә берәр төрле кызыклы яңа хәбәр язып калдырырсың, энем! – диде Хәбәрия ханым һәм тышлыгы голографик рәсемнәр белән бизәлгән бер китап суз-ды.* Р.Нуруллин. *Аны хәзер, голографик ысул белән төшерелгән заманча портретлар эшләнгән кебек, укучы алдына тулы гәүдәсе белән китереп бастыру зарур.* Л.Хәмидуллин

**ГОЛОГРА́ФИЯ** *и. гр. махс.* Төрле яктылык дулкыннарын бер-бер өсле куюга нигезләнгән күләмле сурәт алу ысулы. *Голография осталары*

**ГОЛОМЯ́НКА** *и. рус зоол.* Скорпенасыманнар отрядына караган, бары тик Байкал күлендә генә очрый торган, тәңкәсе һәм корсак йөзгече булмаган балык. *Байкалда бик гаҗәеп балыклар бар. Мәсәлән, озынлыгы карандаш буе гына, 50 грамм авырлыктагы голомянка дигән балык.* А.Муранов. *Маймычларын тереләтә тудыра торган кечерәк кенә голомянканың язмышы бигрәк тә фаҗигале.* Кызыклы ихтиология

**ГОЛОТУ́РИЯЛӘР** *и. зоол. күпл.* Энәтирелеләрнең бер классына караган, мичкәсыман гәүдәле, төрле үсентеләре – кармавычлар, аякчыклар, җилкәннәре булган тереклек ияләре; диңгез кыярлары. --- *ул [гидродинамик җәйланма] бигрәк тә диңгез йолдызлары һәм керпеләрендә, офиура һәм башка күп кенә голотурияләрдә нык үсеш алган.* Кызыклы физиология. *Куркыныч туганда, бу балыклар диңгез кыярының – голотуриянең эченә кереп яшереналәр.* Кызыклы ихтиология

**ГОЛТ-ГОЛТ** *иярт.* Сыеклыкны зур йотымнар белән эчкәндә чыккан тавышны һәм шулай эчү рәвешен белдерә. *Хатын шешә авызыннан, голт-голт итеп, шифалы су эчә.* С.Сөләйманова. *Ул шешә капкачын таза теше белән генә каерып алды да, башын артка ташлап, голт-голт эчә башлады.* М.Маликова. *Теге ташбаш шикәрен чәенә салмады, башын артка чөеп учыннан тамагына сипте дә, голт-голт итеп, бер кружка чәйне ике генә йотты.* А.Гыйләҗев

**ГОЛТЛАТУ** *ф.* Зур-зур йотымнар белән, ашыга-ашыга эчү. *Армен, голтлатып, бер стакан минераль суны эчеп куйды, күрәсең, дулкынланудан, тамагы кипкән иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГОЛУВИЯТ** *и. гар. иск.* 1) Бөек, югары фикерләр, идеяләр

2) Бөеклек, югарылык. *Гаязга әүвәлдән бирле мәүҗүд җитди хөрмәт вә мәхәббәтеме, хәтта голувият хисенә каршы булган тәэсәйеремне җиңеп, игътикадымча файдалы милли ноктаи нәзарны мөдәфәгага мәҗбүр булдым.* Й.Акчура

**ГОЛУФӘ** *и. гар. тар.* Алтын Урда дәүләтендә гражданнарга йөкләнгән мәҗбүри вазифаларның берсе: гаскәр яки дәүләт кешеләрен атлар белән һәм ат азыгы белән тәэмин итү. *Бу Шаһгали хан Чура батырның килгәнен ишетеп, чакыртып алып, күп хөрмәтләр итеп ---, сәрбайлар, садак-савыт, күп голуфәләр биреп, батырларга кушып, һәр нә батырларга баш кылды.* Әкият. *Һәр кеше хәзинә малын, гаскәр йөртү өчен, ат, үгез, дөя шикелле хайванын бирергә тиеш булып, моны «голуфә» диләр: аларны түйдырырга тиеш булып, моны «шусун» диләр иде.* Г.Гобәйдуллин

**ГОЛҮВИЯТ** *и. к.* **голувият**. *Габдулла әфәнде чәчәк эчендә көлгән кыяфәттә, үзенә махсус булган бер голүвият илә ята, ул гүя дөньядан китүенә бер дә кайгырмый, ул аны көлеп кенә каршы ала төсле тоела.* Кызыл таң

**ГОЛҮМ** *и. гар. иск. к.* **гыйлем**. *Голүм әкъфаленең сез ачкычысыз, Тәрәкъкый күкләренең баскычысыз.* Г.Тукай

**ГОЛЬФ** I *и. ингл.* Аякны тезгә кадәр каплый торган оек. *Татцик кызлары косынка бәйләп, ак гольфы урынына эре челтәрле кара оек кигәннәр.* К.Кәримов. *Аякларына исә гольфлар һәм металл пряжкалы тупас башмак кияләр.* Кызыклар дөньясында

**ГОЛЬФ** II *и. ингл.* Кечкенә генә тупны, кәшәкә белән сугып, җирдәге махсус уемга, кечкенә базга кертүдән гыйбарәт уен төре. *Без бридж һәм гольф уены, сәясәт һәм галстуклар турында сөйләшә идек.* Р.Вәлиев

**ГОЛЬЯН** *и. рус зоол.* Карплар семьялыгына караган, суүсемнәр һәм бөҗәкләр белән туклана торган, яшькелт соры сыртлы, вак тәңкәле бик киң таралган төче су балыгы. --- *карасу төстәге гольян һәм табан балыкларын кармакка кигезер алдыннан, берничә сәгать буена яхшы яктыртылган ак*

*савыттагы суга салып тоталар.* Кызыклы ихтиология. *Балхаш – балыклы күл. Аның төп балыклары – Балхаш һәм Или кара балыгы (маринка), Балхаш алабугасы, губач, гольян.* А.Муранов

**ГОЛЯМА** *и. гар.* 1) Ислам дине хакимлек иткән илләрдә дин һәм хокук белгечләре, фәкыйһ. --- *реакцион голяма балаларны кулай вә уңай ысул белән укытуны «харам» дип игълан итә.* Н.Гасрый

2) Укымышлы кешеләр, галимнәр. *Голямалар сыйныфы – бер төркем укымышлылар – әһәмиятсез, буш мәсьәләләр белән шөгыльләнеп вакыт уздыралар.* Н.Гасрый. *Раббанә голямада мәкер дә юк, Вәләкин күңелләре бәлид ирләр һәр кемне хурлауга бар, мактауга – юк.* М.Акмулла

**ГОМЕОПАТ** *и. гр.* Гомеопатия алымнары белән дәвалаучы табиб. *Гомеопатның иң ышанычлысы – Мәскәүдә. Ләкин аңа чират бик зур.* М.Мәһдиев. *– Теге гомеопат сиңа бирәр нәрсә эчертмәдеме? – Доктор ишеккә таба ымлап күрсәтте.* М.Юныс

**ГОМЕОПА́ТИК** *с.* Гомеопатиядә кулланыла торган, гомеопатиягә караган. *Гомеопатик даруханәләрдә хәзер дә «ликоподий» порошогы (сибә торган онта) алырга була («ликоподиум» – плаунның латинча исеме).* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ГОМЕОПА́ТИЯ** *и. гр.* Авыруны охшаш симптомнар китереп чыгара торган даруларның минималь дозалары белән дәвалау системасы. *Гомеопатиядә арчан ревматизмны һәм сидек куыгы авыруларын дәвалаганда файдаланыла.* Урман аптекасы

**ГОМЕР** *и. гар.* **1.** 1) Теләсә кайсы тереклек иясенең яшәү халәте, тууыннан алып үлгәнгә кадәр булган физиологик хәле. *Ул да бит бу озын гомерләрендә ниләр генә кичермәгәндер.* Э.Касыймов. *Гомер тирәгемнең һәр яфрагы Вакыт узуларга бик сизгер. Мизгелләре кайчак – тулы гасыр. Гасырлары – тулмас бер мизгел!..* Р.Әхмәтҗанов. *Әнә бит, алар да яшь булган кайчандыр, аларның да гомерләре гыйш-гыйшрәтсез генә үтмәгән.* Ф.Баттал

2) Җансыз предметларның яки күренешләрнең кулланылышта, гамәлдә булу, хәрәкәт итү чоры. *Зиратларны ныграк карый башладылар, зиратларда озак гомергә исәпләнгән чардуганнар, мәрмәр ташлар ешайды, авыл арасы юл тирәләренә агач утырталар...* А.Гыйләҗев

3) Җан, тормыш. *Риясыз җан булуыннан чыгып, күз алдына китерергә була: күпме минем ишеләрнең гомерләрен саклап калмагандыр ул!* Х.Камалов

4) *күч.* Яшәү ләззәте, тормышның мәгънәсе. *Күңел сере бар кешенең генә гомере тулы, түгәрәк икән.* А.Гыйләҗев

5) Кеше тормышының билгеле үзенчәлекләр белән аерылып торган бер өлеше, чоры. *Алар кыска гына гаилә гомерләрендә дә бер-берсенә ялгышып кына да каты сүз әйтмәделәр.* Г.Гыйльманов. --- *кызлар гомере күбәләк гомередәй кыска. Аның ихтыярын бездә кем санга суга инде?* Т.Әйди

6) *күч.* Шактый зур вакыт аралыгы, байтак вакыт. *Күпме гомер үзеңне егет булып сизмәгән көе әрәм узган бит!* М.Мәһдиев. *Көлке түгел диген: күпме гомер минем башны катырды-катырды да инде «оныт», имеш.* Р.Мостафин. *Ул хәзер бик олыгайгандыр инде. Утыз дүрт ел гомер узды лабаса!* Б.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Гомергә, һичбер вакыт, бервакытта да, беркайчан да. *Башына да гомер күрмәгән колакчынлы соры бүрек кияр, илле җиденче үлчәмлесен.* М.Насыйбуллин. *Сәетҗан абый, гомер булмаганча, хатынын этеп, кире залга узды.* М.Маликова

2) **гомергә** Бөтен гомере буена, яшәгән кадәр, үлгәнче, гомерлеккә, бик озак вакытка. *Чәчләр дә, кешеләр дә бер өйрәнгән уңайга ятучан, аннары гомергә шулай кала.* Ш.Галиев

3) Һәрвакыт, гел, гадәти рәвештә. *Син, сеңлем, гомергә шундый кызганучан йөрәкле булдың инде.* З.Хәким. *Телсез йөрде гомергә. Хәзер баеган сергә, – Бик тели сөйләшергә.* З.Мәҗитов. *Бу шатлыклы көннәре гомергә шулай дәвам итәр дип өметләнә.* Ф.Яхин

4) Мәңге, мәңгегә; бөтенләйгә. *Мин килмәгән җиргә гомергә.* М.Җәлил

5) Беркайчан да, һич. *Аю белән бүре гомергә дус булмас.* Мәкаль. *Юк, гомергә башыңа китерә алмаячаксың.* Т.Галиуллин. *Ашыгып аккан суга карап Торсалар да гел бергә, Елгаларның да ярлары Кавышалмый гомергә.* Рәшит Гатауллин

6) **гомердә** Беркайчан да, һич бер вакыт, бервакытта да. *Гомердә сүгенми торган Кәлимуллинның: «Батырдың, сукин сын!» – дип кычкырган тавышы гына колак төбендә тора.* М.Әмир. *Харам килешмәгәнне белә иде, бәлки, шуңадыр, гомердә кеше малына кызыкмады, кеше исәбенә яшәргә тырышмады ---.* М.Хөсәенов. *Гомердә булмаганны, зиратка хатын-кызларны да керттеләр.* Г.Гыйльманов

◊ **Гомер бакый** 1) Мәңге; мәңгегә. *«Әгәр шушы эшең чын икән, гомер бакый бәхиллегем юк, Хәнәфетдин!» – дип үкси-үкси бер җылады да шуның белән тынды.* В.Нуруллин; 2) Һәрвакыт, гел, гомер-гомергә. *Гомер бакый әзли кеше үзен, Тапса таба мыскал вә граммлап.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Гомер бакый гаилә нигезенә халыкның үзенә генә хас тәрбия алымнары, гореф-гадәтләре, йолалары, үз-үзен тоту рәвеше, әхлак нормалары, милли үзенчәлекләре салынган.* Фән һәм тел. **Гомерен бирү** Үзен корбан итү, гомерен дә жәлләмәү, башын салу, җанын фида кылу. *Гармун хуҗасы илемнең Батыр солдаты иде. Ил өчен авыр көрәштә Газиз гомерен бирде.* Г.Зәйнашева. **Гомерен кисү** Үтерү, һәлак итү, җанын алу. *Фашист уты гомерен кискән тәне Ятып калды күпер төбендә.* М.Җәлил. *Иртәнге саба җиле аңа шифа булып исте, кичке саҗдә җиле гомерен кисте.* С.Поварисов. **Гомерен өзү** *к.* **гомерен кисү**. *Тикшерү вакытында куелган сорау да, нәкъ тормыштагыча, катгый булды: «Гөлчәчәкнең гомерен кем, ни өчен өзгән?»* М.Насыйбуллин. *Гомерләрне өзеп, үлем йөри, Вакыт бирми Төзәлергә йөрәк ярасы.* Г.Сәгыйров. **Гомерен чикләү** *к.* **гомерен кисү.** *Татар мәдәниятенең иң якты йолдызларыннан берсен, контрреволюцион милләтчелектә гаепләп, таш капчыкта гомерен чиклиләр ---.* Г.Тавлин. **Гомер җебе**

Гомер (*1 мәгъ.*), аның озынлыгы. *Гомер җебе кыска: бер саплам.* Н.Гамбәр. **Гомер җебе киселү** *к.* **гомер өзелү**. **Гомер җебе өзелү** *к.* **гомер өзелү.** *Аның инде гомер җебе өзелеп бара, ул бик нык авырый, ләкин, терелмәслеген белсә дә, тереләм дигән өмет белән яши иде.* Н.Гыйматдинова. *Мәңгелеккә тумый адәм баласы, фани дөньяда ул бакыйлык алдыннан сынау үтә, гомер җебе өзелер вакытны беркем дә алдан белми.* Р.Якупова. **Гомер итү** 1) Яшәү, тереклек итү, тору. *Хуш, гомер иткән шәһәр! Инде еракта калдыгыз...* Г.Тукай. *Ярый, тормыш коргансыз икән, бергәбергә тату итеп гомер итегез, бездән хәер-фатиха шул.* Р.Вәлиев; 2) Тормыш алып бару, тормыш көтү. *Җимерсәң иде шуларның Дөньясын Пыр туздырып!.. Эх, гомер итсәң иде бер, Үзеңчә тормыш корып!..* Х.Туфан. *Кушылгач яратышканнар, гөрләтеп гомер иткәннәр, балалар үстергәннәр.* Г.Тавлин. **Гомер киселү** *к.* **гомер өзелү**. *Азмы тапкыр таланды бу җаным, Азмы минем гомерем киселде, Азмы тапкыр үлем каралары Рамкалады минем исемне.* Х.Туфан. **Гомер кичерү** Яшәү, гомер итү. *Дүрт якта да җил генә уйный, күрше-фәлән юк, тәгәрәп гомер кичер!* Н.Гыйматдинова. *Шул нигездә гомер кичердек без. Таллар үсте кабат ничаклы! Яңа өй җиткердек әнкәй белән, Зур тәрәзле, алты почмаклы!* Д.Камалетдинова. **Гомер көзе** *шигъ.* Картлык, гомернең соңгы өлеше. *Гомер көзенең яфраклары саргая, тиздән алар, ботагыннан өзелеп, салкын җиргә кунар да тапталыр. Аңа кадәр көрәшәсе иде.* Н.Гыйматдинова. **Гомер өзелү** Үлү, вафат булу. *Тагын корбан!.. Менә тагын инде Өзелә гомер яшьлек таңында.* Г.Сәгыйров. *Күргән-белгән сөйли һаман: Көтте, мескен, бизмәде, Гомерләре өзелгәнче Өметләрен өзмәде.* Х.Туфан. **Гомер сөрү** *к.* **гомер итү.** *Дәү әнием белән егерме ел гомер сөргәннән соң, Хәйдәр бабай да үлә.* А.Расих. *Ихтирамга лаек булган һәрбер кеше Кайгыларга батып гомер сөрә хәзер.* Х.Туфан. *Гаделлек белән гомер сөрү кыен бу дөньяда. Хәйләсез дөнья файдасыз, диләр бит.* Г.Тавлин. **Гомер таңы** *шигъ.* Яшьлек. *Андый хәлләрне кыз баланың гомер таңында язмышын имгәтү, кара бәхетсез итү дип аңлый идем чөнки.* М.Маликова. **Гомер уздыру** *к.* **гомер үткәрү.** *--- гомернең барлык фани көннәрен сөйгән затың белән бергә рәхәт яшәп уздыр ---.* М.Хәбибуллин. *Яшерендем яшел сахраларда, Ялгызлыкта гомер уздырам.* Р.Бикбаев. **Гомер узу** *к.* **гомер үтү.** *Гомер үтте, йортка картлык иңде.* Р.Зәкуанов. **Гомер үткәрү** 1) Яшәү, гомер итү. *Ул менә шигырь язып, кызлар белән йөреп гомер үткәрә.* Н.Фәттах. *Яисә Идел буендагы берәр комлыкта аунап гомер үткәрер иде.* Г.Гыйльманов. *Дуся түтәй гомерен Тимоша исемле ата мәчене тәрбияләп үткәрә.* М.Маликова; 2) Вакыт уздыру, вакытны файдасыз, бушка үткәреп әрәм итү. *Ник сөймәгән, сөйкемсез ир көе көйләп, яшь гомерен коллыкта үткәрсен соң?! Ярамый яшь гомерне әрәм-шәрәм итәргә.* Р.Мулланурова. **Гомер үтү** 1) Адәм баласына бирелгән тормыш еллары узу, вакыт үтү. *Үткәннәрем, зәңгәр хыял булып, Йөрәгемдә һаман саклана, Гомер үткән саен матурлана, Кадерләнә бара, сафлана...* Х.Туфан. *Колонияләрдә, төрмәләрдә гомерем үтте минем.* Г.Гыйльманов; 2) Олыгаю, картаю. *Агыйделкәйләргә (лә) басма салдым, Үрелеп сулар ала алмадым. Шушы гомерләрнең үтүенә Һичбер хәйлә таба (ла) алмадым.* Җыр. **Гомер юлдашы** Тормыш иптәше, ир яки хатын; сөйгән яр. *Сүрелми лә сөюләрем, Сүнми гомер юлдашым...* Х.Туфан. **Гомер юлы** Тормыш, гомер. *Гомер юлы тигез асфальт түгел, Чокыр да бар кайбер урында...* Х.Туфан. *Менә син гомер юлыңны тәмамлап киләсең инде, әни.* М.Маликова. **Гомер язы** *шигъ. к.* **гомер таңы.** *Үзе сизми: гомер язы үткән, Яшимен дип, һаман талпына.* И.Әширов

**ГОМЕ́Р-ГОМЕРГӘ** *рәв.* 1) Һәрвакыт, гел, гомер бакый. *Татар кызы гомер-гомергә бераз гына кырыс булган, горур булган.* Н.Фәттах. *Безнең умарталык гомер-гомергә авыл башындагы таллыкта иде.* Ф.Яруллин. *Бит Борынгы Владимир-Суздаль һәм Идел буе төрекләре, Болгар дәүләте гомергомергә сәүдә итеп көн күргәннәр.* М.Хәбибуллин

2) Бөтен гомере буена. *Адәмне гомер-гомергә үзен дөнья кочагына үстереп тапшырган туган туфрагы, нигезоясы озата бара.* Роберт Әхмәтҗанов

**ГОМЕ́Р-ГОМЕРДӘН** *рәв.* Бик күптәннән, борынгыдан. *Россия гомергомердән читләргә кызыгып, читләрдән өлге алып яшәде.* Р.Вәлиев. *Әнисе: «Улым, гомер-гомердән татарларның сыеныр урыны булган Кызыл мәчеткә күңелем әрни. Шул мәчетне аякка бастыр, васыятем шул», – дип әйтеп калдыра аңа.* Ватаным Татарстан

**ГОМЕРЕ́НЧӘ** *рәв.* Гомере буе, гомер буена. *Куллары, бөтен гомеренчә каты хезмәттә булу сәбәбеннән, катып, сөяlләнеп, каешланып беткән.* Г.Ибраһимов

**ГОМЕРЛЕ** *с.* 1) Яшәүгә сәләтле, озак яшәүче, гомере озын булган. *Әле кичәгенәк кенә сине телгә алып утырган идек. Гомерле бала булырсың...* Р.Вәлиев. *«Нургалиевләр токымы озын гомерле!» – дип мактанырга ярата иде Нәҗип.* А.Гыйләҗев. *Торган саен торасы килә... Иптәш Киров кебек ир уртасы, Тик гомерле буласы килә.* Х.Туфан

2) Чыдамлы, озакка бара торган. *Әрнү-газапларны язган, Сөюдә янган йөрәк Кояштан кайнаррактыр, Ташлардан гомерлерәк...* Х.Әюпов

3) Мәңгелек, онытылмый торган

**ГОМЕРЛЕК** *с.* **1.** 1) Гомер буена дәвам иткән; гомергә җитә торган. *Уемда минем ил гаме. Телемдә шигырь тәме. Өстемдә «Түләргә!» дигән Гомерлек бурыч әле...* Ф.Гыйззәтуллина. *Рәхмәт Мирзаһитка, кирәк чагында сабыр була белеп, Бибинурның кыен минутларын җиңеләйтте, күңел түрендә гомерлек якты урын алып калды...* А.Гыйләҗев

2) Үлгәнгә кадәр дәвам итә торган. *Бу минутлар хатынның яшь йөрәгендә гомерлек эз калдырдылар.* Г.Ибраһимов. *Патша суды аны гомерлек сөргенгә хөкем итә.* Р.Вәлиев

3) Мәңгелек. *Һәр шагыйрьнең чишмә башы, --- гомерлек таяну ноктасы ул – халык иҗаты.* Р.Фәйзуллин.

*Куркаклар һичкайчан булалмый азат, Куркаклык – милләткә гомерлек газап.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Өч көнлек дөньяда гомерлек мөсафир һәр яфрак ---.* Р.Әхмәтҗан

**2. гомерлеккә** *рәв. мәгъ.* 1) Мәңгегә, бөтенләйгә. *Тарихта үзенең кара урынын алган, халык хәтерендә гомерлеккә сакланып калган «егерме беренче ел ачлыгы»ның башы иде инде бу!* Ә.Еники. *Биюләр турында гомерлеккә онытырга туры килде, кайгыдан эчүгә сабыштым, типтерергә тотындым, институттан кудылар, шуннан тормышым түбән тәгәрәде дә китте инде...* Р.Мирхәйдәров

2) Гомер буена. *Яраталар алар берсен берсе, Кичә генә өйләнешкән төсле; Шатлык тулы сөйләп көлүләре, Гомерлеккә җитәр сөюләре.* Г.Сәгыйров. *– Син минем бердәнберем идең бит! Гомерлеккә шулай булачак идең! – Лариса аның муеныннан кочып алды да күкрәгенә ятып үкси башлады.* М.Маликова. *Бу «унөч» кайберәүләр өчен гомерлеккә бәхетсез сан булып калыр...* Ф.Садриев

**ГОМЕРЛЕЛЕК** *и.* Гомерле булу, гомере озын булу

**ГОМЕРСЕЗ** *с.* 1) Кыска гомерле, аз яшәп калган. --- *зур үкенечкә, Таһир гомерсез булды, 12–13 яшенә җиткәндә ул үлеп тә китте.* Ә.Еники

2) *күч.* Озакка бармый торган, тиз бетүчән, чыдамсыз, яшәүгә сәләтсез. --- *ул җыр умырзая чәчәкләре кебек гомерсез булды.* Җ.Фәйзи. *Ясалма сәнгать тудыру мөмкин түгел, ясалма сәнгать гомерсез...* М.Хәбибуллин. *Китаплар да кешеләр кебек бит: Гомерле була йә гомерсез...* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ГОМИНЬДАН** *и. кыт. тар.* Кытайда Сунь Ятсен тарафыннан 1912 елда оештырылган, баштагы чорда прогрессив роль уйнаган, 1949 елга кадәр җитәкчелек иткән сәяси партия. *Шигырь Кытай республикасының 1943–1949 еллардагы президенты Чан Кай-Шиның (1887–1975) 1927 елда Гоминьдан партиясенә җитәкче булып килүе һәм аның тоткан юлын кискен үзгәртүе уңае белән язылган.* М.Җәлил

**ГОМИНЬДАНЧЫ** *и. тар.* Гоминьдан партиясе әгъзасы, шул партиянең тарафдары

**ГОМОГЕН** *с. гр.* Үзенең составы, үзенчәлекләре, килеп чыгышы ягыннан бертөрле. *Гомоген система*

**ГОМОСЕКСУАЛИЗМ** *и. гр.-лат.* Үз җенесеңдәге кешегә тартылу, җенси теләктә булу; ир-атларның бер-берсенә тартылуы. *Глобальләшү тарафдарлары җиңгән очракта, «яхшылык» һәм «явызлык» үз урыннарын алыштырачаклар, наркоманлык, педофиллык, гомосексуализм, «эвтаназия» исеме астында карт кешеләрне һәм авыруларны үтерү, ерткычлык, төрле сихерчелек өстенлек алачак.* Р.Вәлиев. *Сезгә гомосексуализмнан арынырга теләп килаләрме?* Безнең гәҗит

**ГОМУД** *и. гар. иск.* Күсәк, авыр тукмак, чәкән; гөрзи. *Каһарман тиз гомудине кулына алып, һиндлеләр эченә кереп, гомуд белән бер сукканда, биш-алты кешене туфрак белән тигез итә ---.* Дастан

**ГОМУМ** I *и. гар. иск.* Халык, гавам, киң халык массасы

**ГОМУМ** II *с. гар.* Киң итеп ала торган, аерым-аерым түгел, глобаль күзлектән каралган. *Гомум тырышлык белән җинаятьнең тиз арада ачылуы – әйбәт күренеш, сүз дә юк.* Х.Вәлиәхмәтов. --- *татарлар арасында озак гизүләр, алар белән һаман мөнәсәбәткә керүләр миңа мондый «гомум» мәсьәлә-нәтиҗәләр хакында да хөкем йөртергә хокук бирә шикелле.* М.Госман

**ГОМУМ-** *гар.* Кушма сүзләрнең «барысы өчен дә бер, уртак, барысына да караган» мәгънәсен белдерә торган беренче өлеше (мәс., *гомумдәүләт, гомумкешелек, гомумхалык, гомумшәһәр* һ.б.)

**ГОМУМӘН** *рәв. гар.* **1.** 1) Тулаем алганда, аерым үзенчәлекләрне исәпкә алмаганда

2) Һәрвакытта да, гел, һәрчак

**2.** *кер. сүз* 1) Нәтиҗә ясап әйткәндә, гомумиләштереп әйткәндә. *Туфан Миңнуллин йокымсырап яшәүче, эшлексез һәм мокыт бәндәләрне, буш күңелле кешеләрне, гомумән, җәмгыятьтәге, тормыштагы бушлыкны яратмый.* Р.Вәлиев

2) Нигездә, аерым нюансларны исәпкә алмаганда

**ГОМУМИ** *с. гар.* **1.** 1) Бөтен кешегә, бөтен нәрсәгә караган; һәркем, һәрнәрсә өчен уртак. --- *укучылар, укытучылар, кунаклар, гомуми күтәренкелек тойгысына бирелеп, кинәт шып булдылар ---.* Н.Фәттах

2) Берлектә башкарыла торган, күмәк, бердәм

3) Объектның иң төп, асыл билгеләренә караган, аны, бербөтен буларак, киң итеп тасвирлаган

4) Барысын да берләштергән; берләштерелгән, барысын да кушкач килеп чыга торган, барлыгы, бөтенесе. *Уку елы дәвамында каникулларның гомуми озынлыгы 30 көн тәшкил итә.* Ватаным Татарстан

5) Бербөтен, тулы; бөтен, барлык. *Драматургик сюжет төзелеше, образлар бирелеше, гомуми эчтәлеге ягыннан караганда, мин бу хезмәтне, нигездә, тәмам ителгән дип карыйм.* М.Җәлил. *Ә конкрет, көндәлек тормыштагы геройларның тормыш юлын, кылган яхшы эшләрен күзәтү – гомуми әдәбиятның бер генә – очерк жанрының гына күзәтү объекты була ала.* Ф.Урманче

6) Уртача, чагыштырмача исәпләнгән

7) Зур масштабтагы, глобаль, тоталь

**2.** *рәв. мәгъ.* Киң итеп, төп үзенчәлекләрдән чыгып, гомумән

**ГОМУМИЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Берләштерү, уртак итү

2) Аерым предмет, күренеш, фактларны һ.б.ш. анализлап, шул нигездә гомуми нәтиҗә ясау. *Эшли белү генә бик аз, уйлый белергә, гомумиләштерә, перспективаны күрә белергә кирәк бу заманда.* Р.Вәлиев

3) *әд.* Типиклаштыру, гомуми образ тудыру. *Вакыйгаларга фәлсәфи гомумиләштерүләр ясап, китапны монументаль әсәр дәрәҗәсенә күтәрә алырмынмы?* М.Хөсәенов. --- *автор реаль тормышта үзе күргән форма һәм төсләрне гомумиләштереп бирер-*

*гә, табигатьтә каршылыкларны тирәнрәк, ныграк ачарга омтыла ---*. Казан утлары

**Гомумиләштереп бетерү** Бар булган нәрсәне гомуми итү, уртак итү, берләштерү

**Гомумиләштереп кую** Иң ахырда гомуми нәтиҗә чыгару

**ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ** *с. махс.* 1) Аерым өлешләрне төп бер формага туплаган. *Гомумиләштерүче бюджет*

2) *лингв.* Бөтен тиңдәш кисәкләр өчен дә уртак билге булган. *Гомумиләштерүче сүз*

**ГОМУМИЛӘШҮ** *ф.* Гомуми булып китү, гомуми төс алу; киң таралу, халык арасында җәелү

**Гомумиләшеп бетү** Бөтенләй гомуми, тоталь төс алу

**Гомумиләшеп китү** Кинәт, тиз арада гомумиләшү. *Тукаев әдәбиятының тиз арада гомумиләшеп китүенә тагы ике мөһим сәбәп бар.* Г.Рәхим

**ГОМУМИЛЕК** *и.* Гомуми булу үзлеге. *Идеологияләштерелгән бер үк эстетик таләпләргә буйсынып иҗат итү язучыларда индивидуальлектән бигрәк гомумилекнең өстенлек алуына китерергә тиеш иде.* Ф.Галимуллин

**ГОМУМИЯТ** *и. гар. иск. к.* **гомумилек.** *Галиәсгар әфәнде бу әсәрен хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган булса да, --- комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумият бирә.* М.Гали. *Ләкин аның кебек аз чыгармалар кагыйдәнең гомумиятенә зарар бирмәйдер.* Г.Бубый

**ГОМУМТӨРКИ** *с.* Барлык төрки халыклар өчен уртак; барлык төрки телләргә караган. *Соңгы вакытларда рус алынмаларын гарәп-фарсы сүзләре һәм гомумтөрки тамырлы сүзләр кысрыклавы сизелә.* А.Тимергалин

**ГОНВАН** *ис. гар. иск.* Дәрәҗә, данлыклы исем; гомумән исем, атама. *Инде аның нәзарында бәхетсез инсаннар көтүе залим вә мәзлум, мөсафир вә ач гонваннары илә икегә генә бүленә иде, башка тәкъсимат бу зур фандигъ, мөәссир бүленү янында әһәмиятсез калган иде.* Й.Акчура

**ГОНГ** *и. индонез.* Металл диск формасындагы уен коралы, шулай ук сигналлар бирү өчен кулланыла. --- *Рушан чак кына нокаутка егылмый калды, ярый әле, гонг коткарды: беренче раунд тәмамланган иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГОНДО́ЛА** *и. ит.* 1) Венециядә борыны һәм койрыгы күтәрелеп торган, пассажирлар өчен ышык урыны булган, бер ишкәкле озын сай көймә. *Кабан күлендә тәгәрмәчле пароход, венеция гондолаларына охшаш көймәләр йөзәчәк, яр буйлап атлы трамвай (конка) йөриячәк.* Р.Мостафин. *Борынгарын ярга төртеп, су өстендә гондолалар чайкала.* М.Юныс

2) Аэростат, дирижабль, һава шарына эленә торган, экипаж утыру, механизмнар кую һ.б.ш. өчен махсус кәрҗин. *Һава шары атмосферада гондоланы югары күтәреп менгән кебек, һава куыкчыгы да үзенә асылынган кисәкчекне өскә калкытып чыгара.* Кызыклы физика

3) *махс.* Үзбушаткыч вагон төре

**ГОНДО́ЛАЧЫ** *и.* Гондолада ишкәкче

**ГОНҖӘ** *и. фар.* Чәчәк бөресе, ачылып җитмәгән чәчәк. *Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр Беләп бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.* Г.Тукай

**ГОНОРАР** *и. лат.* Сәнгать яки әдәбият әсәре, фәнни хезмәт һ.б.ш.ның авторына бирелә торган акча; каләм хакы, каләм балы. *Төрекмәнстан хөкүмәте, гонорарларны исәпкә алмыйча, пенсияләрне санамыйча, һәр язучыга гына икешәр мең сум акча биреп бара.* А.Гыйләҗев. *Иллә мәгәр шәп булыр, Ахыры да шәп булыр, Тәмамланса бу шигырь, Гонорар да күп чыгар...* Л.Лерон

**ГОНСЫР** *и. гар. иск.* 1) Катлаулы нәрсәнең аерым бер состав өлеше; элемент. *К. Насыйри үзенең терминологик эшкәртмәсендә «элемент» терминының өч эквивалентын тәкъдим итә: асыл, матдә, гонсыр.* Фән һәм тел

2) Яралыш, табигать

3) Токым. --- *Сәетгалиев – Борһан Мансуровлар агымының бу ачлыкны татар гонсыры башына китерүдә бик зур рольләре бар ---.* Ф.Әмирхан. *Аларның хөкүмәт сөрүче сыйныфлары да, гаскәри вә тормышлары да вә икътисади яклары талауга, ганимәт малга тәрәгән бер гонсырдан булган.* Г.Гобәйдуллин

**ГОНЧӘ** *и. фар. иск. к.* **гонҗә**. *Әй назнин, сез кайу гөлнең гончәсе, кайу бакчада тәрбиядә булынмыш?* Ф.Ханифи

**ГОПАК** *и.* Украин халык биюе һәм шуның музыкасы

**ГОРАБ** *и. гар. иск.* 1) Карга

2) Козгын. *Син гораб диб уйлаганың асле шоңкар улмасын.* М.Акмулла

**ГОРӘФӘТ** *и. гар.* Хорафат, төрле ырымга, сихергә һ.б.ш. ышану. *Әлбәттә, горәфәт бу, горәфәт булса да, күрәсең, бар әйбердер.* М.Кәрим

**ГОРБӘТ** *и. гар. иск.* 1) Мөсафирлек, туган ягыннан читтә яшәү. *Иманнан язмадым, Илдән язсам да, Горбәттә чиксәм дә күп бәла-каза.* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Ялгызлык. *Бимәкян вә бичара горбәт чигеп, йөрәкендә хасрәт уты янар иркән.* М.Колый

**ГОРБӘТЛЕК** *и. к.* **горбәтчелек**. *Горбәтлектән, Татарстан, татар кайта, Милләт өчен син милләткә акаата.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Беркөнне көндезен кара төн туды, Карулы дошманнар каралар якты... Бугазлап бугаздан Газраил буып, Горбәтлек иленең базына атты.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Ә менә «Биздерсәләр туган җиреңнән» исемле шигъри повесте (1993) читкә, горбәтлеккә киткән миллионнарча татарлар, мөһаҗирләребез турында.* Р.Гаташ

**ГОРБӘТЧЕЛЕК** *и. иск.* Читтә яшәү, ят җирләрдә йөрү; эмиграция. *--- аның, горбәтчелектә чагында, кысынкы көннәрендә ярдәм итешү кайда, үзенә каршы берләшү кебек эшләре Газны дәһшәтле сурәттә газаплый, җанын кыйный иде...* Ш.Мөхәммәтьяров

**ГОРБУ́ША** *и. рус* Сөләйман балыклар семьялыгына караган, Ерак Көнчыгышта яши торган узгынчы балык. *Горбуша күбрәк диңгездә яши. Ул бу вакыт бик зифа сынлы — йөзәргә уңайлы орчыксыман гәүдәле була.* Кызыклы ихтиология

**ГОР-ГОР** *иярт.* Калын яки карлыккан тавыш белән сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә

**ГОРГЫЛДАТУ** *ф.* Гор-гор иткән авазлар чыгарту

**ГОРГЫЛДАУ** *ф.* Гор-гор иткән тавышлар чыгару, шулай сөйләшү

**ГОРГЫЛДЫК** *с.* Калын, карлыккан, горгылдап торган. – *Хәзер, хөрмәтле иптәш журналист, күзегезне йомыгыз, – диде тантаналы горгылдык тавыш белән Сәлимов.* А.Гыйләҗев

**ГОРЕ́ЛКА** *и. рус* Сыек ягулыкны яки газны кирәгенчә генә яндырып тота торган җайланма. *Ике ай эчендә биредә Ижау котельный заводының яңа модуле, яңа казаннары, Италия комплектациясендәге горелкалар, өряңа автоматика барлыкка килгән.* Ватаным Татарстан. *Ул Италиядән кайтартылган газ горелкасы белән җиһазландырылган.* Кызыл таң

**ГОРЕЛЬЕФ** *и. фр.* Сынның фон яссылыгы өстенә үз күләменең яртысыннан күбрәк өлешенә калку итеп ясалган кабарынкы рельеф төре. *Заводка кергән һәркемне ишегалдында хәзер әнә шундый горельеф каршылый.* Татарстан яшьләре

**ГОРЕФ** *и. гар. иск. к.* **гореф-гадәт**. *Ул төрек халыкларының телен, горефен белә, ул, ислам динендә булганлыгы өчен, Мәскәүдә Европаның малын Шәрыкка --- китерүчегә әйләнде.* Г.Гобәйдуллин

**ГОРЕФ-ГАДӘТ** *җый. и. гар.* Халыкның, аерым төркемнең яки социаль катламның тарихи үсеше нәтиҗәсендә тупланган традицияләре, йолалары. *Авылда беренче тапкыр борынгы гореф-гадәт бозылды: капка төбендә басып каласы урынга, бер төркем хатын-кыз, яшьрәкләр, башларын түбән иеп, минем белән бергә җеназа артыннан атладылар.* Э.Касыймов. *Элеккечә булса, бер оя булып, гореф-гадәтләрне саклап, телгә тугры калып яшиселәр иде дә, дөнья бозылды, авыллар таралды, халыклар чегәнгә әйләнде.* А.Гыйләҗев. *Әйе, милләтне милләт итеп саклап калучы – тел, моң, гореф-гадәтләр, аш-су.* Сөембикә

**ГОРЕФ-ГОРӘФӘТ** *җый. и. гар.* Төрле ырымнарга, сихер һ.б.ш. ышану. *Мин, әлбәттә, гореф-горәфәт колы түгел, шулай да шомлы уйлар мине әсир итте.* М.Кәрим

**ГОРЖЕ́ТКА** *и. фр.* Яка урынына муенга салып йөртелә торган, тар мех полосадан гыйбарәт булган хатын-кыз киеме элементы. *Ул, киң селтәнеп, муенына озын ак яка – горжетка салганда, чыннан да, җиде буын аксөяктән бер дә ким булмагандыр.* М.Маликова

**ГОРИЗОНТ** *и. гр.* 1) Күк гөмбәзенең җир өслеге белән тоташкан булып күренгән сызыгы. *Эскертләрнең теге ягында, горизонтта, таш юл сузылган, ул юлдан анда-санда йөк машиналары уза...* М.Мәһдиев. *Март кояшы инде горизонтка төшеп бара, инде хатын-кыз ачлыктан бөгелеп төште, ике тапкыр тәнәфес ясалды, ирләр тәмәке төтененә батып алды.* М.Мәһдиев. *Ташны горизонта* $\alpha_0$ *почмак белән авыштырып,* $v_0$ *тизлеге белән ыргыталар.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

2) *махс.* Диңгездә, елгаларда, күлләрдә һәм сусаклагычларда суның биеклеге. *Әмма монда ләм тыгылган сулы горизонтларны терелтү мөмкин булып чыкмады.* Р.Мостафин. *Күлдә су горизонты гасырлар буена ничек үзгәргән соң?* А.Муранов

3) *геол.* Бер үк төрле казылма организмнарны үз эченә алган тау токымнары комплексы, горизонталь катлау. *Җир-туфрак, балчык катламнарын узып, күмергә кагылсаң, бу беренче горизонтның төбе була.* Ә.Галиев

4) *күч.* Белем дәрәҗәсе, фикерләү, күзаллау киңлеге

5) *күч.* Мөмкинлекләр, эш итү өчен иркенлек

**ГОРИЗОНТАЛЬ** *с.* **1.** Горизонтка параллель урнашкан, ятма; *киресе:* **вертикаль**. *Ул өч кадрда гына күренсә дә, горизонталь юнәлештә 15 узел тизлек белән хәрәкәт итә.* А.Муранов. *Чаңгычы таудан 40 м араны 10 секундта узган, аннан соң горизонталь юлдан 20 м шуып баргач туктаган.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Чыннан да, туптан горизонталь юнәлештә атып җибәрелгән снаряд иртәме-соңмы барыбер җиргә төшә, ни өчен?* Кызыклы физика

**2.** *и. мәгъ.* 1) Горизонт яссылыгына параллель туры сызык

2) *геод.* Җирнең рельефын күрсәтү өчен үткәрелә һәм бер биеклектә урнашкан нокталарны тоташтыра торган кәкре сызык

**3.** *рәв. мәгъ.* Горизонт белән параллель рәвештә. *Пеликан-киңавыз балыгы да зуравызга охшаган, ләкин аның авызы балыкларныкы шикелле горизонталь урнашкан.* Кызыклы ихтиология

**ГОРИЗОНТАЛЬЛЕК** *и.* Горизонталь торыш, горизонталь булу

**ГОРИЗО́НТ СЫЗЫГЫ** *и. к.* **горизонт** (*1 мәгъ.*)

**ГОРИ́ЛЛА** *и. ингл. зоол.* Приматлар отрядыннан, Экваториаль Африканың тропик урманнарында яши торган, кешесыман маймылларның иң эресе булган имезүче хайван. *Горилла – кешесыман маймыллар арасында иң зурысы. Аның буе озын – адәмгә тиңләшә, гәүдәсе гаять юан, тупас, биле бөтенләй беленми.* Кызыклар дөньясында

**ГОРКОМ** *и. рус* Совет чорында Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең шәһәр комитеты. *Бәйрәмгә ике көн кала зур эш итеп, парткомнар аша, мине яңадан горкомга чакырып алдылар...* М.Мәһдиев. *Ни гаҗәп: әүвәл элеваторларга баш булып йөрде, горкомда эшләп алды, аннан Юдинога тимер юлга күчерделәр.* А.Гыйләҗев. *Безнең капитанны порт начальнигы белән горком секретаре арасына утырткannар.* М.Юныс

**ГОРМОН** *и. гр.* Эчке секреция бизләре тарафыннан эшләп чыгарылган, организмның функцияләрен җайга салып торуда катнаша торган физиологик актив матдә. --- *сөт ясалуны регуляцияләүдә --- гипофиз гормоны — пролактин әһәмиятле роль уйный.* Кызыклы физиология. *Табигатькә унлап гормон җитә, ә кеше аларны йөзләп барлыкка китерде; табигый матдәләр гаҗәеп үзлекләргә ия иде, ә кеше ул үзлекләрне меңнәрчә тапкырларга арттырды ---.* Химиянең киләчәге

**ГОРМОНАЛЬ** *с.* Гормоннар белән бәйле, гормоннарга тәэсир итә торган, гормоннар кулланып эшләнелгән.

*Гормональ төймәләр тәкъдим итүдән дә мәгънә юк (исерек аларны үз вакытында эчәргә кирәген исендә тотамыни?!).* Сөембикә

**ГОРН** *и. нем.* 1) Металлар эретү, балчык әйберләр яндыру өчен махсус мич; тимерче учагы. *Картайгач та әле ул, горндагы берәр потлык тимер кисәкләрен, авыр кыскычка каптырып, уйнатып кына күтәрә...* К.Нәҗми

2) Домна миченең аскы өлеше

**ГОРНА** *и. сөйл. к.* **горн**

**ГОРНОВОЙ** *и. рус* Горн янында эшләүче эшче, металл эретүче

**ГОРНЯК** *и. рус* Тау сәнәгатендә эшләүче эшче яки инженер

**ГОРОДНИ́ЧИЙ** *и. рус тар.* XIX гасырга кадәр Россиядә өяз шәһәренең башлыгы

**ГОРОДОВОЙ** *и. рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә шәһәр полициясенең түбән чинлы хезмәткәре. *Городовой, урядниктан башлап тәмам министрга кадәр барлык түрәләрнең, бөтен чиновникларның кылган эшләрен, күрсәткән һөнәрләрен тикшерделәр.* Ш. Мөхәммәдев. --- *урядник та, кулына портфелен кыстырып, артына городовойны ияртеп, протокол язар өчен, тау башыннан төшеп килә.* Ш.Усманов. *Ә бит шәһәрдәге эшләр, Чынлап та, хәттин ашкан: Бәласеннән башаяк, дип, Городовой чыгып качкан.* Ф.Яруллин

**ГОРОНО** *и. рус* Шәһәр халык мәгариф бүлеге. *Алар, --- Фәрит Фәнирович белән икәү, гороно хәлләрен сөйләп көлешә, серләшә башладылар.* Г.Мирһади

**ГОРОСКОП** *и. гр.* 1) Астрологиядә: билгеле вакытта планета һәм йолдызларның үзара урнашуын күрсәткән һәм берәр кешенең язмышын яки вакыйганың нәтиҗәсен күрәзәләү өчен файдаланыла торган таблица; йолдызнамә

2) Билгеле йолдызлык астында туган кешеләрнең киләчәгенә (киләсе ел, көн һ.б.ш.) карата астролог фаразы. *Хәзер, егерменче йөз тәмамланып килгәндә, --- һәртөрле күрәзәчеләр, экстрасенслар, шарлатаннар, гороскоплар белән мавыга башлады халык.* Р.Мирхәйдәров

**ГОРРӘ** *и. гар. иск.* Яктылык. *Аларның морадынча йөри бирсәң, Дин-ислам горрәсене кормак кирәк.* М.Акмулла

**ГОСЕЛЛЕ** *с.* Госеле булган, госелен югалтмаган. *Тәһарәтле, госелле, чиста күңелле, догалы бул.* Безнең гәҗит

**ГОСЕЛЛЕК** *и.* Госел коену бүлмәсе яки урыны. *Мич артындагы госеллек*

**ГОСЕЛСЕЗ** *с.* Госеле булмаган, госелен югалткан. *«Илаһият һич тә шакшылыкны күтәрми, шапшак өс-баш, юынмаган бит-кул, госелсез тән белән укылган намаз-доганың булуыннан булмавы артыграк!» – дип сөйләнгән җиреннән һаман да кияүләре Мөхәммәдне мисалга китерә.* Ф.Яхин

**ГОРСОВЕТ** *и. рус* Шәһәрдә халык депутатларыннан торган дәүләт идарәсе органы. *Эшкә керешеп, агач утыртырсың, йорт сала башларсың, ә җирне горсовет тартып алыр!* А.Гыйләҗев

**ГОРТЕ́НЗИЯ** *и. фр.* Ташкуранчалар семьялыгыннан, алсу яки аксыл шәмәхә төстәге шарсыман оешма чәчәкле декоратив үсемлек. *Бакча гортензиясен июльдә – ярымагач чыбыклардан, язын үскән үрчелектән һәм язын кышкы чыбыклардан үрчетәләр.* Йорт эшләре

**ГОРУР** *с. гар.* **1.** 1) Үз дәрәҗәсен белгән, үзенә ышаныч тоя торган, үз кадерен белгән. *Син тугансың горур рухлы җаннан, игелекле булган нәселең.* Г.Сәгыйров. --- *горур Исмәгыйль нәрсәне булса да сирәк үтенә, ә аның сүзе һәм абруе кире каккысыз иде...* Р.Мирхәйдәров

2) Дәрәҗәле, мактанырлык, куанырлык

3) Горурлык белдергән, мәһабәт, мәгърур кыяфәтле. *Авиация формасында бик горур кыяфәт белән чыккан фотомны күргәч, кызлар мине бик гайрәт егет дип күз алдына китергәндер, күрәсең.* Ф.Яруллин

4) Мәгърур, баш имәс. *Муллалык указыннан мәхрүм ителү дә галимнең горур характерын сындыра алмый.* Кызыл таң

5) Һавалы, тәкәббер, масаючан, эреләнүчән

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кыю рәвештә, үз дәрәҗәсен белеп, үзенә ышанып. *Кытай тарихчыларының сүзләренә караганда, кулга төшкән Бачман үзен бик горур тота.* М.Госман

2) Тәкәббер кыяфәт белән, бик эреләнеп, масаеп. --- *һәммәсе дә абруйлы дәрәҗәлеләр, затлы киенгәннәр, үзләрен бик горур һәм тәкәллефле тоталар...* Р.Мирхәйдәров

**3.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **горурлык** (*1 мәгъ.*). *Әгәр синдә оят һәм горур булса иде, безгә каршы сугышыр идең, әгәр безнең белән чын ихластан дус буласың килсә, безнең йортыбыз Әстерхан һәм Казанны бир...* Г.Гобәйдуллин

2) Канәгатьлек, куаныч хисе уята торган нәрсә, мактаныч

3) Башкалардан үзен өстен кую, тәкәбберлек

4) Горурлыгы булган кеше. *Тормыш юлы туры гына түгел, Адым саен үр йә борылыш. Үрә катып йөргән горурларны Тиз сындырып ташлый бу тормыш.* Ф.Яруллин

**ГОРУРАНӘ** *рәв. гар.-фар. иск.* Горур рәвештә, горур кыяфәт белән. --- *бүлмә эчен тагын бер мәртәбә җентекле күз карашы аша үткәзде дә, --- горуранә атлап, ишеккә юнәлде.* М.Галәү. *Табигатемезнең яхшы яклары исә – горуранә, үзләрен ваксытмыйча, башка халыктан зур тотулары, сабыр, һәрнәрсәне күтәрә торган, үткен, һәрнәрсәне белергә кабил --- бер табигатьтер.* Г.Газиз

**ГОРУРЛАНУ** *ф.* 1) Горурлык хисе тою, кем яки нәрсә белән хаклы рәвештә мактану, шуннан канәгатьлек алу

2) Эреләнү, тәкәбберләнү, масаю, һавалану. *Горурланма алай, бу гадел җиңүең булмады.* М.Хәбибуллин

**Горурланып китү** Үзен эре тота башлау, тәкәбберлек күрсәтү

**ГОРУРЛЫ** *с.* 1) Үз-үзенә хөрмәте булган, үз дәрәҗәсен белгән, горур (*1 мәгъ.*)

2) Тәкәббер, һавалы, эреләнүчән, масаючан

**ГОРУРЛЫК** *и.* 1) Үзеңне хөрмәт итү, үз дәрәҗәңне тою, үз кадереңне белү үзлеге. *Әллә минем бер дә горурлыгым, мин-минлегем юкмы?*

Х.Камалов. *Кайчан, нинди җилләр сындырды соң Горурлыгың синең, татарым?..* Л.Лерон. *Морякларның үз горурлыгы шул, пехотага өстәнрәк карыйлар.* И.Низамов

2) Хаклы рәвештә мактану, канәгатьлек тою. *Бу сорау үзеннән-үзе горурлык та, сагаю һәм каушау да тудыра иде.* Н.Фәттах

3) Тәкәбберлек, һавалылык, эреләнү, масаю. --- *сүз кушарга җае килгәне юк әле. Соңгы курс студенты булу горурлыгым комачаулык итә булса кирәк.* Ж.Фәйзи. *Ләкин барыбер аның битараф горурлыгына җитү өчен, миңа күп кирәк әле.* Р.Вәлиев. *Гадәти һавалы горурлыгының эзе дә юк.* Казан утлары

4) Мактаныч; канәгатьлек, куаныч хисе бирә торган нәрсә. *Яшәү – бәхет: илең – синең өчен, син ил өчен булсаң горурлык.* Р.Фәйзуллин. *Әйе, күл – әлбәттә, Казанның горурлыгы, тарихи бизәге...* Р.Мостафин. --- *сез – татар халкының горурлыгы булу дәрәҗәсенә күтәрелгән бөек шәхес.* С.Поварисов

**ГОРЧАК** *и. рус* Нурканатлылар классының карп балыклар семьялыгыннан Европа һәм өлешчә Азия сулыкларында яши торган, чиста агым суны яратучан, түбән температурага һәм сусызлыкка чыдам балык; әче балык. *Горчак дигән кечкенә генә балык үзенең уылдыгын менә ничек чәчә. Ана балык уылдыгын ике капкачлы моллюскларның --- тире катлавы арасындагы куышлыгына сала.* Кызыклы ихтиология. *Төче суда яшәүче ташбашны, җилембалыкны һәм верховканы кем генә белми икән?! Чәнечкеле балык, горчак һәм гамбузия тагын да кечерәк.* Кызыклы ихтиология

**ГОРЧИ́ЦА** *и. рус* 1) Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан сары чәчәкле, орлыгы медицинада һәм азык сәнәгатендә файдаланыла торган үлән үсемлек. *Азыкка яраклы һәм техник максатларда майлар алу өчен, соя, җитен, майлы рапс, горчица, кастор үләне кебек үсемлекләр үстерелә.* Биология. *Умарта кортлары ак һәм ал клевер, донник-буркун, карабодай, сурепка, горчица, кура җиләге һәм арчан чәчәкләренә, һичбер өйрәтүләрдән башка ук, бик теләп киләләр.* Умарта кортлары. *Тышкы күренешләре буенча кәбестә орлыклары кәбестәгә семьядаш булган рапс, горчица һәм гәрәнкә орлыкларына охшыйлар.* Яшелчәчелек

2) Шул үсемлекнең орлыгын төеп ясалган порошок һәм шул порошоктан әзерләнгән аш тәмләткеч. *Хәзер инде җылы су сал ак тазга. Аңа өстә берәр кашык горчица, Аягымны тыгып утырыйм беразга.* Ф.Яруллин. *Кок аңа, казаннан алып, зур ит калҗасы тоттырды: – Томат пастасы, горчица сөртеп аша ---.* М.Мәһдиев. *Горчица, тоз, борыч һәм шикәрне майда изеп, серкә өстәп сыекларга.* Йорт эшләре

**ГОРЧИ́ЦАЛАУ** *ф.* Горчица (*2 мәгъ.*) өстәү, горчица белән тәмләтү, горчица тидерү

**ГОРЧИ́ЧНИК** *и. рус* Авырткан урынга кан әйләнешен тизләтү, авыртуны киметү h.б.ш. өчен ябыштырыла торган, горчица оны капланган кәгазь бите, пластырь. *Балаларга тагын суык тиячәк. Горчичниклар, дарулар, йокысыз төннәр.* А.Гыйләҗев

**ГОРЫК-ГОРЫК** *иярт.* **1.** Көчле йөткерү вакытында чыккан тавышны белдерә. *Бала төне буе горык-горык йөткереп чыкты*

**2.** *и. мәгъ.* Йөткерү, ютәл. *Горыкгорыкларың бик озакка сузылды*

**ГОРЫЛДА́У** *ф.* 1) *к.* **голдырдау**

2) *к.* **гырылдау**

**ГОРЬЯН** *с. гар. иск.* Шәрә, ялангач. *Күңелем горьян улгандыр, җенерем бер йан улгандыр.* Ә.Уразаев-Кормаши

**ГОСЕЛ** *и. гар.* Коену, юыну, чистарыну гамәле. *Әгәр ул чишмәнең суындан эчеп, чишмәнең балчыгы илә бөтен әгъзасыны буяп, соңра чишмәнең суы берлән госел кылсалар, --- шул мәгарәнең капусы бу адәмгә ачылыр.* Ф.Халиди. *Син, якташкаем, госел коенып, тәһарәт яңарттым да эш бетте, фәрештәгә әйләндем,--- дип фикер йөртәмсең?* Б.Камалов. *Пәйгамбәребез госел коенды, чәчләрен тарады, мәчеткә кереп, дүрт рәкәгать өйлә намазын укыды һәм Зөл-Хәлифәгә юнәлде.* Ф.Яхин

**ГОСЕЛХАНӘ** *и. гар.-фар. иск.* Госел коену өчен махсус бүлмә, тәһарәт бүлмәсе. *Фарукҗан, бит-күзен чылатырга кирәклеген тоеп, ирексездән госелханәгә атлады.* Т.Әйди

**ГОСМА́Н БАЛЫК** *и. зоол.* Карп балыклар семьялыгыннан, Алтай һәм Монголиянең төче сулы елга һәм күлләрендә яши торган, бик вак тәңкәле, биек сырт йөзгечле, озын гәүдәле балык төре. *Безнең төче су балыкларыннан маринка һәм госман балыкның уылдыгы белән ата балык агы агулы була.* Кызыклы ихтиология. *Урта Азиядә яши торган маринка һәм госман балык агулы уылдык чәчә.* Кызыклы ихтиология

**ГОСМАНЛЫ** *и.* **1.** 1) Госман тарафыннан нигез салынган империядә, элекке Төркиядә яшәүче кеше. *Безгә кардәш булган халыкларны төрле исемнәр белән: сарт, кыргыз, казак, үзбәк, госманлы, азәрбайҗанлы, төрекмән дип атыйлар.* Г.Гобәйдуллин. *Бу ике халык бер кавышып, укмашып вә оешып җитсә, каршы торыйм димә, чөнки ул халык – госманлылар белән канкардәш.* М.Хәбибуллин

2) Иске төрек теле. *Дөрес, мин төрекчә госманлыны бер дә белми идем, дип яза әни, хәлбуки Бубида күп фәннәр шул телдә укыла.* А.Расих

**2.** *с. мәгъ.* Иске төрек теленә, әдәбиятына, Госманлы империясенә караган. --- *Урта Азиядә сәлҗүк вә соңра госманлы төрекләре дәүләтләре ясалды.* Г.Гобәйдуллин. *Гаяз әфәнде, хәзерге татар әдәбияты илә госманлы әдәбиятына мөкаясә нәзары илә карап, хәзерге русияле татар әдәбиятын вә, гомумән, Русия мөселманнарының тәрәкъкый вә тәмәдден юлын төрекләргә караганда күп җитди вә төплерәк таба.* С.Рахманколый

**ГО́СПИТАЛЬ** *и. лат.* 1) Хәрбиләрне дәвалау белән шөгыльләнә торган хастаханә. *Гимнастёркасын салдырып госпиталь халатын киерткәндә, военврач аның күкрәк кесәсеннән телеграмма бланкысын алып укый.* М.Мәһдиев. *Шофёр авария вакытында җәрәхәтләр алган, госпитальгә озаттык.* Ф.Яруллин. *Госпитальгә тагы бик күп авыр яралыларны китерделәр.* Х.Камалов

2) Гомумән дәвалау учреждениесе, хастаханә. *Бөтен яр буендагы иң зур бина булган бу йортта госпиталь урнашкан. --- Госпитальгә йокы авырулы кешеләр дә килгәли.* А.Муранов. *Чечняда сугыш башлануга, машиналар, самолётлар белән күпме илләрдән килеп җиттеләр, ә французлар госпиталь ачып җибәрделәр хәтта*. М.Маликова. *Архитекторлар яңа типтагы биналар — палаццолар төзиләр. Бу биналар алгы якларыннан кырыс булып күренгәннәр һәм замокларны, шәһәр читендәге виллаларны, университетларны, госпитальләрне, базарларны хәтерләткәннәр.* Урта гасырлар тарихы

**ГОСПОДИН** *и. рус сөйл.* 1) XX йөз башында актив кулланылышта булган, ир-атны, гадәттә олырак яки дәрәҗәсе ягыннан югарырак торган кешене атый торган сүз

2) Шундый кешегә мөрәҗәгать итү сүзе. *Господин командир, Саранов отряды фронт ярып чыкты, --- аның атлы ротасы хәзер авылны килеп баса!* Г.Ибраһимов. *Ни боерасыз, господин мой, Мин әзер барчасына.* Ф.Яруллин

**ГОССОВЕТ** *и. рус сөйл.* Дәүләт Советы, кайбер илләрдә, шул исәптән Татарстанда, закон чыгаручы югары власть органы. *Госсоветта бара зур сессия, Депутатлар сөйли кызып-кызып. Президиумның озын өстәленә Татар телен кемдер салган сузып.* Ф.Яруллин

**ГОСТИ́НИЦА** *и. рус сөйл.* Кунакханә, отель. *Гостиницага кайткач, төн уртасында Исмегөл бу хәлләрнең хикмәтен Сафиягә көлә-көлә сөйләде...* М.Маликова. *Гостиница белән вокзал арасында киләп сарып, төн узды.* Ш.Хөсәенов. *Мин «Бригантина» исемле кунак йортына тукталдым. Диңгезчеләр өчен салынган унике катлы гостиница.* М.Юныс

**ГОСТИ́НЫЙ ДВОР** *и. рус* 1) *тар.* Элек зур рус шәһәрләрендә үзәк урамда яки мәйданда, гадәттә, чит илләр белән сәүдә итүче купецлар өчен, таштан салынган сәүдә рәтләре. *Нәкъ шушы вакытта Казанда күркәм биналар да төзелә. Шулардан гостиный двор, университет, аның ишек алдында төзелгән анатомия театры, астрономия обсерваториясе биналары, дворяннар җыелышы йорты...* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) *неол.* Зур сәүдә үзәге

**ГОТ** *и. нем. к.* **готлар.** *Гот ир-егетләре әлеге фин хатыннарын үз җирләреннән ерак төньякка, кеше яшәми торган җирләргә куганнар.* Ф.Урманче

**ГО́ТИК** *с.* Готика стилендә эшләнгән, готикага караган. *Миңа димәгәе, готик алфавит булсын. Без яшьләр өчен яңалыкны өйрәнү берни түгел.* Ж.Фәйзи. *Роман сыннарына караганда готик сыннарда кешеләрнең кыяфәте төгәлрәк бирелә, кием сырлары астында гәүдә рәвеше ачыграк сиземләнә, сурәтләнгән образлар да хәрәкәтчәнрәк булып күренәләр.* Урта гасырлар тарихы

**ГО́ТИКА** *и. фр.* 1) Франциядә XII гасырда барлыкка килгән һәм соңрак Көнбатыш Европада таралган, башлыча архитектурага караган сәнгать стиле. *Мәскәүдә яисә безнең Казанда художник яки архитектор готика әсәрләренә музей нәрсәсенә караган кебек карасалар, Ригадан башлап инде готика әсәрләре һәм готика стиле (дөресрәге калдыгы) куера башлый.* Г.Гобәй. *Безнең каршыда XIII гасырда маврлар тарафыннан салынган готика стилендәге карачкыл замок тора иде – пляжга арт белән борылдык та шул замокны фотога төшерергә тотындык.* М.Мәһдиев. *Венеция готикасы ысулында төзелгән бер сарай янына җиткәч, чемоданымны тротуарга утыртып, сокланып карап тора башладым.* М.Юныс

2) *неол.* Мистицизм, фатализм белән сугарылган, «теге дөнья», караңгы көчләр һ.б.ш. белән кызыксынган, хәзерге яшьләр арасында популяр, формаль булмаган юнәлеш

**ГОТЛАР** *и. нем. күпл.* 1) *тар.* Борынгы герман кабиләләре группасы. *Һуннар элегрәк Төньяк Кара диңгез буена күчеп утырган готларның кабилә берлекләрен җимерә һәм аларны Балкан ярымутравына күчәргә мәҗбүр итә.* Урта гасырлар тарихы. *Безнең эраның 262 елында илгә бәреп кергән готлар аны [Артемида храмын] яндырганнар.* Кызыклар дөньясында

2) *неол.* «Теге дөнья», караңгы көчләр, гомумән, мистика белән кызыксынган яшьләр арасында популярлашкан «готика» юнәлеше тарафдарлары

**ГОТОВА́ЛЬНЯ** *и. рус* Махсус тартмага тупланган сызу әсбаплары, сызым инструментлары җыелмасы. *Торшердан төшкән йомшак яктылык астында Әнвәр өстәлгә алсу кәгазен җәя, готовальнясын ача.* М.Маликова

**ГОФР** *и. фр.* Түбә ябу, стеналар тышлау кебек эшләрдә файдаланыла торган, сырлы, дулкынлы өслекле нечкә металл, асбест-цемент һ.б.ш. табаклар

**ГОФРЕ** *и. фр.* **1.** Нык беленеп торырлык итеп, үтүкләп салынган бормалы сырлар

**2.** *с. мәгъ.* Шундый сырлары булган, сырлы өслекле. *Соры гофре юбка кигән кыз, минем айдан артык сәяхәтем сине дә кызыксындырмый мени?* М.Юныс

**ГОФРЕЛА́У** *ф.* 1) Тукыма, тасма, калай, картон кебек материалларда дулкынсыман сырлар ясау

2) Тукыма өслегендә рельефлы, күпереп торган бизәк төшерү, басып бизәк төшерү

**Гофрелап чыгу** Булган берсен гофрелау

**Гофрелый башлау** Гофреларга тотыну

**ГО́ФРЕЛЫ** *с.* Гофре сырлары булган, гофрланган, сырланган; гофре **2.**

**ГО́ФРЛАУ** I *ф. к.* **гофрелау**. *Калайны гофрлау*

**ГО́ФРЛАУ** II *и.* Гофрлар ясау процессы. *Гофрлау эше*

**ГОШЕР** *и. гар.* 1) Мөселманнардан ярлылар файдасына алына торган салым. *Алар гыйлемсез, һөнәрсез, барысы да ярлы булса, зәкятны ничек бирсен? Гошерне кайдан алып бирсен?* Ф.Кәрими. *Хан ялчыларының зур катламы казнага акча кертүне кайгыртып торган: ясак, гошер (пошлина) җыючылар, тамгачылар (таможнячылар), үлчәүчеләр, бахшилар (язу-сызу эшен башкаручылар) һ.б.* Р.Мостафин

**ГОШЕР-ФЫТЫР** *җый. и. гар.* Һәртөрле сәдака. *Гошере-фытыры моның*

*ихатасына, сәдакасы-хәере моның кесәсенә ага...* Ф.Хөсни

**ГӨБӘДИЯ** *и.* Гадәттә, чәй янына бирелә торган, эчлеге дөге, корт, җимеш, пешкән йомыркага май, шикәр кушып, әче камырдан пешерелгән бәлеш, татарларның милли ризыгы. *Чәй кирәкми, тамагым тук, әнкәй яныннан әлерәк кенә гөбәдия ашап чыктым. Гөбәдиясе!..* А.Гыйләҗев. *Бәйрәмнән калган гөбәдия, чәкчәк янына кучтәнәч тары ярмасы онынннан коймак та пешергән.* С.Сөләйманова. *Район башлыгының мәйдан буйлап йөреп, һәрберсе белән ике куллап исәнләшеп чыгуы, хәл-әхвәл сорашуы, болай да мул табынга бәлеш, гөбәдия, чәкчәк, өстәвенә мәтрүшкәле чәй дә китерүләре күңелләрен нечкәртте...* Сөембикә

◊ **Гөбәдиягә арка кую** Аштан олы булу, ризыктан йөз чөерү. --- *табынга килгән бу нигъмәттән, билгеле, Тукай да торып кала алмый. Халыкта «гөбәдиягә арка кую» дигән сүз дә бар бит әле.* Н.Исәнбәт

**ГӨБЕ** *и.* Каймакны майга атлау өчен кулланыла торган тар тирән агач савыт, кечкенә кисмәк. *Казан вә әтрафында, хәтта Башкортстанда XVIII гасырда татарлар төрле нәрсәләр ясап (арба, кисмәк, чиләк, балта сабы, гөбе кук нәрсәләр), кустарьлык һөнәре белән дә шөгыльләнәләр.* Г.Гобәйдуллин. *Әйрәннән бушаган гөбегә сап-салкын чишмә суы тутыра, гөбене су белән чайкатып, сап-сары, хуш исле майны учлап-учлап алып, йомарламнарга тәгәрәтә.* А.Гыйләҗев. *Аның эшенә мин сүз эзләп торам. Гөбедә май урынына су язган шикелле.* Ә.Гаффар

◊ **Гөбедән чыккан кебек** Калын, көчле (тавыш). *Солтан абый малайның үзсүзлелеген, сәләтен күреп, мыек астыннан гына елмая-елмая, гөбедән чыккан кебек калын тавыш белән ашыкмый гына сөйли бирә.* Р.Хафизова

**ГӨБЕ́ АТЛАУ** *ф.* Гөбедә май язу, каймакны гөбегә салып, атлап, май төшерү

**ГӨБЕ́ МАЕ** *и.* Атланмай, акмай

**ГӨБЕР-ГӨБЕР** *иярт.* Берәр сыеклык кайнаганда, көчле агым белән бәргәндә барлыкка килгән авазны белдерә. *Казаннарда гөбер-гөбер Бәрәңге кайнап тора.* Ф.Яруллин

**ГӨБЕРДӘТҮ** *ф.* 1) Гөбер-гөбер иткән тавыш чыгару. *Сыерларын саткаnnар иде: савар кешеләре юк; хәзер сыер алдылар, гөбердәтеп сава, күз тимәсен!* А.Гыйләҗев

2) *диал.* Кабарту, күпертү, күбекләндерү, мамыкландыру

**Гөбердәтә башлау** Гөбердәтергә тотыну

**Гөбердәтә бирү** Бернигә карамый гөбердәтүен дәвам итү, һаман да гөбердәтү

**Гөбердәтә төшү** Тагы да бераз гөбердәтү

**Гөбердәтеп алу** Җиңелчә генә, бераз вакыт гөбердәтү

**Гөбердәтеп кую** Гөбердәгән хәлгә китереп калдыру

**Гөбердәтеп тору** Бертуктаусыз гөбер-гөбер иткән тавыш чыгару

**ГӨБЕРДӘ́Ү** *ф.* Берәр сыекча кайнаганда, гөжләп акканда, һава аралаш торбадан килгәндә шуңа охшаш тавыш чыгару, гөбер-гөбер итү. *Өч көн дигәндә Шәмсеҗиһан апаны тагын бура кебек сыер мөгрәп каршылый, ак чиләккә тагын, гөбердәп, сөт ага иде.* Г.Нәбиуллин

**Гөбердәп алу** Аз гына вакыт гөбердәү

**Гөбердәп кую** Бер тапкыр гөбердәгән тавыш чыгару

**Гөбердәп тору** Гөбер-гөбер кайнап тору, бертуктаусыз гөбердәү

**Гөберди башлау** Гөбердәргә тотыну

**Гөберди бирү** Һаман да гөбердәү, гөбердәвен дәвам итү

**Гөберди төшү** Тагы да бераз гөбердәү

**ГӨБЕРКӘ** *и.* 1) Агач кайрысында, бака тәнендә һ.б.ш. була торган оры, төерчек, кабырчык һ.б.ш.

2) Тукымадагы, җептәге калкып торган төен, элмәк һ.б.ш. тигезсезлек

**ГӨБЕРКӘЛЕ** *с.* 1) Гөберкәләре булган

2) Өстендә тигезсезлекләр (төеннәр һ.б.ш.) булган, шома түгел, кытыршы (тукыма, җеп һәм шулардан эшләнгән әйберләр турында). *Гөберкәле галстук*

**ГӨБЕРЛЕ́ БАКА** *и.* Бакчаларда, каралты-кура тирәсендә яши, бөҗәкләр белән туклана, бакадан коры тиресе һәм кыскарак арт аяклары белән аерылып торган койрыксыз җир-су хайваны; баз бакасы, җир бакасы, сасы бака; *русчасы:* **жаба.** *Яңгыр ире дәшмәде, эсседән таш астына качкан гөберле бака сыман, җәймә җәеп, кызыл «Волга»сы астына кереп ятты.* Ә.Гаффар. *Гөберле бакалар һәм эт балыклар мыркылдыйлар.* Кызыклы ихтиология. *Утрауда Көньяк Америкадан китерелгән, озынлыгы 20 сантиметрга җиткән әкәмәт пәһлеван гөберле бакалар пәйда була.* Кызыклар дөньясында

**ГӨБЕРТ** *иярт.* Өелгән, эленгән зурзур әйберләр ишелеп төшү рәвешен белдерә

**ГӨБЕ́ ТАЯГЫ** *и.* Атлавыч

**ГӨБЛӘ** *и.* Үсемлек согы белән тукланып тереклек итә торган вак корткыч бөҗәк; *русчасы:* **тля.** *Корткыч бөҗәкләрдән роза гөлен гөблә (тля) һәм пәрәвез талпаны зур зыян китерергә мөмкин.* Юлдаш. *Җәй ахырында еш кына кәбестәдә бик вак бөҗәкләр – гөблә колонияләре (төркемнәре) күренә; алар кәбестә яфракларының сүлен суыралар.* Яшелчәчелек

**ГӨЖ** *иярт.* Бик күп һәм төрлетөрле җанлы-җансыз объектлар чыгарган, тоташ бер шау булып ишетелгән тавышлар кушылмасы

**ГӨ́Ж ИТҮ** *ф. к.* **гөж килү.** *Шимбә иртәсе иде — казарма гөж-ж итте.* М.Мәһдиев

**ГӨ́Ж КИЛҮ** *ф.* 1) Гөжләү, бертуктаусыз тигез гүләп торган, бызылдаган һ.б.ш. тавыш чыгару. *Умарта кортлары гөж килә. Бал булыр. Бал – колхозның табышы.* Г.Ахунов

2) Шау-шу килү, гөрләү, тавыш күп булу. *Халык гөж килде, директорны таләп итте. Җир йоткан диярсең, директоры да күренми бит.* М.Насыйбуллин. *Эш-көшләр беткәч, алар: «Ягез әле, балалар, урын әзерләгез!» дип әйтүгә, «кечкенә өй» бермәлгә гөж килеп ала.* З.Рәсулева. *Теге якта яшьләр гөж киләләр. Ник кенә берсе Хәкимулланы искә алсын.* М.Мәһдиев

3) Хәрәкәттә булу, кайнап тору; кеше бик күп булу. *Кышкы сессия бара. Баскычлар тулы тышланган дәфтәр, китап, брошюралар, коридор гөж килә.* М.Мәһдиев. *Гөж килеп, кырлар, басулар тормыш җырын җырлыйлар.* Г.Сәгыйров. *Тирә-юнь нәкъ тузгытылган умарта күче кебек гөж килеп тора.* М.Хөсәенов

**ГӨЖГЕЛӘ́Ү** *ф.* Торба, төннек кебек куыш нәрсәләрне чистарту өчен, пумала һ.б.ш. тыгып бутау

**ГӨЖЕЛДӘВЕК** *с.* Гөжләп торган, гөжләп чыга торган. *Колагына каяндыр кер юу машинасының гөжелдәвек тавышы да килеп киткәндәй булды.* Казан утлары

**ГӨЖЕЛДӘТҮ** *ф.* Кайнату, шаулату

**Гөжелдәтеп алу** Тиз генә кайнатып чыгару. *Тиз генә самавыр гөжелдәтеп алу*

**ГӨЖЕЛДӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Гөжләү, гөжләгән тавыш чыгару, бызлау (бөҗәкләр турында). *Һәр тарафта бал кортлары оча, төклетура гөжелди, ул исемен белмәгән әллә никадәрле алтын сары, чуар бөҗәкләр үрмәлиләр...* А.Гыйләҗев

2) Шаулашу, берьюлы күп кеше сөйләшеп, тигез шау барлыкка китерү. *Бүлмә эче умартадай гөжелдәргә тотынды.* М.Галәү

3) Гүләү, гөрелдәү (техника, механизм һ.б.ш. турында). *Стартер гөжелди башлады, калын тонык тавыш белән двигатель эшләргә тотынды.* Г.Кашапов

**2.** *и. мәгъ.* Шау-шу, тавыш. *Солдатлар, кылычларын шәрәләндереп, ишекнең ике ягына тезелеп бастылар. Залдагы гөжелдәү берьюлы тынды.* М.Галәү. *Колхозчылар, гөжелдәүдән тынып, Сабир Салихович ни әйтер дип көтә башладылар.* Г.Кашапов

**Гөжелдәп алу** Аз гына гөжелдәү

**Гөжелдәп кую** Кыска гына гөжелдәгән тавыш чыгару

**Гөжелдәп тору** Бертуктаусыз гөжелдәү. *Кайдадыр еракта дөнья гөжелдәп тора иде.* Ф.Яхин

**Гөжелди башлау** Гөжелдәргә тотыну

**Гөжелди төшү** Тагы да көчлерәк гөжелдәү

**ГӨЖЛӘТҮ** *ф.* 1) Кайнатып чыгару (чәйнек-самавыр турында)

2) Җиренә җиткереп, тырышып эшләү

**Гөжләтеп алу** Тиз арада гөжләтү

**Гөжләтеп тору** Әледән-әле, бертуктаусыз гөжләтү

**ГӨЖЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Күпсанлы бөҗәкләр бызлап, гөжелдәп тору. *Мичкә тирәсендә бал кортлары гөжли, товар өемнәре өстенә брезент каплаганнар.* М.Юныс

2) Гөж килү, шаулашу, шау-гөр килү. *Ирек шунда гына бу халыкның ни өчен гөжләгәнен, дулкынланганын аңлады.* Ф.Садриев

3) Эшләп торган төрле механизмнар тигез тавыш белән гүләү, улау. --- *аппарат эчендә нәрсәдер гөжли, гүли, җан ачысы белән сызгыра.* Ф.Баттал

4) Көчле янган ут дөрләү, көчле аккан яки кайнаган су яки һава агымы шаулау. --- *туктаусыз гөжләгән бу сөт агымы бөтен йортка ямь бирә һәм, бу тавыш яңгырамаса, бу йорт, бу ишегалды бик җансыз, бик күңелсез, бик коры һәм бөтенләй буш булыр иде.* Г.Галиев. *Гөжләп торган самавырны өстәлгә китереп утырттым.* Х.Вәлиәхмәтов

5) *күч.* Шаулау, әйләнү, авырту (баш турында). *Ыгы-зыгы. Башым гөжли. Нишлим? Зәңгәр киңлек сорый фикерләрем.* Л.Лерон

**2.** *и. мәгъ.* Гөж иткән тавыш. --- *тагын умарталарны тыңлап карадык. Гөжләү әкренәймәгән иде.* Ф.Яруллин. *Күчнең гөжләве көчәйгәннән-көчәя бара, кортлар, иреккә чыга алмаган ачудан, яндырып-яндырып тешлиләр, чыгарга юл эзлиләр сыман.* Р.Вәлиев

**Гөжләп алу** Бераз гына, кыска вакыт гөжләп, шуннан туктау. --- *эссе көн кичкә авышкан бервакытта Җир йөзендәге бөҗәкләр гөжләп ала, күбәләкләр куыша, чикерткәләр сикерешеп уйный.* М.Мәһдиев. *– Башкорт көен без бик яратабыз, – диешеп, табын гөжләп алды.* Х.Сарьян

**Гөжләп тору** 1) Бертуктаусыз шаулау, гөж килү. *Аннары инде, бу тамчы тавышлары көчәйгәннән-көчәя барып, тоташтан сөт ага башлады, һәм туктаусыз гөжләп торган сөт тавышы өстенлек алды.* Г.Галиев. *Станция эче гөжләп тора, салкынча, су, юеш, агач, механизмнар исе белән тулы...* Ә.Гаффар. *Алты җан, арадан икесе – шук малай, иртәдән кичкә кадәр бакча гөжләп тора, турникта атыналар, шаулап, балыкка баралар, гөрләп кайтып керәләр.* А.Гыйләҗев

2) Гел хәрәкәттә булу; хәрәкәттәге кешеләр белән тулып тору. *Чыннан да, безнең гостиницада ике йөзләп артистка кыз гына бар, кичләрен гостиница алды гөжләп тора, төн йокламыйча бәйрәм итәләр.* М.Мәһдиев. *Барак яны Сабантуе кебек гөжләп тора. Халык автобусны сырып алган.* Ә.Галиев. *Бу вакытта Чаллының кырмыска күчедәй гөжләп торган чагы була.* Казан утлары

**ГӨЖТ** *иярт.* Зур тизлек белән узып китү яки килеп туктау рәвешен һәм тавышын белдерә

**ГӨЛ** *и.* 1) Өйдә яки бакчада матурлык өчен үстерелә торган үсемлек. *Тәрәзә төбендә гөл чүлмәкләре тирәли чүпләм башлы ап-ак сөлге өстендә суган кабыгы суында манылган күкәйләр тәгәрәшеп ята...* А.Гыйләҗев. *Сине генә хәтерләтә Бакчадагы гөлләрем.* Л.Лерон. *Гөлбакчаны кем үстерсә карап, Шулар күбрәк исни гөл исен.* Ф.Гыйззәтуллина

2) *иск.* Гомумән, чәчәк ата торган үлән яки куак үсемлек. *Бизәнде тау, бизәнде кыр, гөлләр үсте.* Дәрдемәнд. *Карасу буендагы гөлләрне рәсем дәфтәрендә күреп, әтиең хәйран калды.* Ә.Галиев. *Бу тоз чүлендә үсмәде гөлләр, шытканнары да саргайды, кипте...* Г.Сәгыйров

3) Үсемлекләрнең чәчәк өлеше. *Мин ялгызым гел искәреп йөрим, Гөлләр ачылганда тугайда, Парлы чакта без төзегән оя Исән әле анда шулай да...* Ф.Гыйззәтуллина. *Чит тарафта күк тә нурлы, чәчәк тә гөл генә ---.* С.Сүнчәләй. *Ул [Гелиогабал] үзе яшәгән бүлмәләрне, ашханәләрне һәм хәтта өйалларын роза гөлләре белән түшәргә куша, шулар өстеннән йөрергә ярата.* Кызыклар дөньясында

4) Роза. *Талгын гына искән җилләр Гөлләр исен китерде. – Гөләпләрдән күбәләккә сәлам! – дигән шикелле.* Х.Туфан

5) *күч.* Гомумкешелек кыйммәтләре, мөһим нәрсәләр. *Ашлыйбыз еллар буе рух гөлләрен... Шунда бер тәнкыйтьче мәллә Кигәвен?!* Р.Гаташ

6) **гөлем, гөлкәем** Иркәләп, яратып эндәшү сүзе. *Тыңла әле, гөлем, мин сиңа үткән атнада да әйткән идем.* Ю.Әминов

◊ **Гөл кебек** Бик матур, һәр яктан да килгән. *Әлегә икесе дә сау-сәламәтләр, гомерләре дә гөл кебек.* М.Маликова

**ГӨЛАБ** *и. фар. иск.* Гөл суы, гөлчәчәктән ясалган хуш исле сыекча. *Вәзирләр гөлабләр сәйярнеп хәлифәне һушына китергәч, хәлифә җасусдан сөаль кылды...* Ф.Халиди

**ГӨЛӘНДӘМ** I *с. гар. иск.* Нәфис гәүдәле, зифа буйлы. *Ишек төбендәге стена буена алсу ак йөзле, гөләндәм буйлы керәшен кызлары тезелеп баскан, ә бер читтәрәк аларга яны белән үзләренең баянист егетләре утырган иде.* Х.Сарьян

**ГӨЛӘНДӘМ** II *и. гар.* Чәчәк бәйләме, букет. *Алар кинәт кенә ап-ак туй күлмәге кигән килен-кызлар, кара смокинг кигән кияү-егетләр, кулларына чәчәк гөләндәмнәре тоткан килеш чыр-чу килеп буталган, черт-черт фотога төшкән яшьләр арасында торып калдылар.* А.Хәлим

**ГӨЛӘП** *и. фар.* 1) *к.* **гөлҗимеш.** *Без бер җирдә, гөләп чытырманлыгы арасында, күп кенә кара бөрлегән таптык.* Г.Рәхим. *Кемнәр сине гөләп белән Каймалап алган, урман?..* Р.Гәрәй. *Чәчәк аткандай кырларда Ландышлар, гөләпләр, Терелде инде безнең дә Өметләр, теләкләр!* Х.Туфан

2) *иск.* Гөлчәчәк, роза. *Талгын гына искән җилләр Гөлләр исен китерде. – Гөләпләрдән күбәләккә сәлам! – дигән шикелле.* Х.Туфан

**ГӨЛБАБА** *и.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, сары чәчәкләре кәрзин булып үскән, болыннарда, куаклыкларда очрый торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **кульбаба**

**ГӨЛБАДРАН** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, яфраклары абагага охшаган, сары чәчәкләре зонт хасил иткән үлән үсемлек, дару үләне; *русчасы:* **пижма**. *Ызаннарда күк чәчәк зәңгәрләнә. Кырлыган, сары мәтрүшкә, гөлбадран җитешкән.* Г.Ахунов. *Шәрыкка хас әчкелтем-төчкелтем исләр: борыч, канәфер, ваниль, гөлбадран, чери башлаган җимеш һәм ашка сала торган үлән исе.* М.Юныс. *Имбирьны һәм дарчинны алмаштыручы үсемлек итеп, оешма чәчәклеләр семьялыгыннан булган гөлбадранны файдаланалар.* Робинзон эзләреннән

**ГӨЛБАКЧА** *и.* Чәчәк бакчасы, гөлләр үстерелә торган бакча. *Идел вә Чулман буйлары Гөлбакчага тиң иде.* Г.Зәйнашева. *Карт Газраил яшь һәм чибәр Фәрештәгә гашыйк булган; Аның белән сүз куертып, Гөлбакчада басып торган...* Г.Сәгыйров. *Маннур машинасын кинәт кенә сулга борып, олы юлдан чыгарды да гөлбакчага күмелеп утырган йорт янына туктатты.* М.Хәсәнов

**ГӨЛБӘНӘК** *и. фар.* 1) Роза чәчәкләре бәйләме

2) Шундый чәчәккә охшатып әзерләнә торган камыр ашы. *Башкала буйлап экскурсия дә, «Татар ашлары» йортында төрле милли ризыклар пешерүебез дә (мин анда татлылыгы белән чәкчәккә охшаган «гөлбәнәк» дигән камыр ризыгы әзерләгән идем) --- күңелле сәяхәтнең якты мизгелләре булып кына хәтердә саклана хәзер.* Сөембикә

**ГӨЛБӘЧ** *и. диал.* 1) Авыл өйләрендә мич белән стена арасында калдырылган ара, ачыклык

2) Өйнең аш ягы, мич-казан тирәсе

**ГӨЛБОСТАН** *и. гар. иск. к.* **гөлбакча.** *Бермәлгә үзеңне гарәп шаһларының гөлбостанында күргәндәй буласың...* Ә.Еники

**ГӨЛДЕРӘВЕК** *с. к.* **гөлдерек**

**ГӨЛДЕРӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Күк күкрәү. *Туктый яңгыр, тагы бер якта яшен яшьнәп китә, Гөлдери күк, селкенә җир, өй авар хәлгә җитә.* С.Сүнчәләй. *--- еракта-еракта, гөлдерәп, күк күкрәгән авазлар ишетелә башлады, салкынча дымлы яңгыр җиле исеп куйды.* Т.Мөбарәков

2) Күк күкрәвен хәтерләткән көчле яңгыравык тавыш чыгарып шартлау, бәрелү, дөмбердәү һ.б.ш.

3) Чылтыр-чылтыр агу, су шаулау. *Гөрлиләр моңлы күгәрченнәр. Ташулар гөлдери, Язга сөенеп, мәгъсумә кызлар урамнарда йөри.* С.Сүнчәләй. *Әнә салмак кына гөлдерәп, инеш ага.* Г.Сабитов

4) Күгәрчен гөрләү. *Артта, каядыр зәңгәр урманнар эчендә, урман күгәрчене гөлдери.* Ф.Шәфигуллин

5) Күркәнең үзенчәлекле тавыш чыгаруы, гөлдердәү. *Дуңгыз булып мыркылдыйм, Тавык булып кыткылдыйм, Күркә булып гөлдерим, Елатмыйм, дим, көлдерим.* Ш.Галиев

6) *күч.* Бик ягымлы, матур итеп сөйләшү. *Кара мыеклы, якын туганын көтмәгәндә очраткан сыман, гөлдерәп сөйләшергә кереште.* Г.Галиев

7) *күч.* Бик яңгыравык, көчле тавыш белән сөйләшү, көлү. *Шунда берсе күк күкрәгәндәй гөлдерәп көлеп җибәрде.* М.Мәһдиев. *Яратам мин аның гөлдерәп көлүен. Шул көлү минем картаеп туза барган нервыларымны тынычландыра, минем кәефемне күтәреп җибәрә.* Г.Ахунов

**2.** *и. мәгъ.* Күк күкрәве яки шуңа охшаш яңгыравык калын көчле тавыш. *Әнә шул ерактагы гөлдерәү аны тагын балачак истәлекләренә алып китте.* Г.Ахунов

**3. гөлдерәп** *рәв. мәгъ.* Бик әйбәт, бик тату, матур итеп (*яшәү, тормыш итү, килеп керү*)

**Гөлдерәп алу** Бераз гына, кыска гына гөлдерәү. *Аһ, нәрсә бу кышлар күкрәгендә Күкләр алды сыман гөлдерәп... Кайнар тының өргән тәрәзәңнән Яшьле күзең чакыра, мөлдерәп.* Р.Шиһапов

**Гөлдерәп китү** Кинәт көчле гөлдерәгән тавыш ишетелү, яңгыратып җибәрү. *Күкләр бермәл китәр гөлдерәп... Тизрәк, тизрәк! – зәңгәр ояңда Кәрәзләрең көтә мөлдерәп.* Г.Сәлим

**Гөлдерәп кую** Бер мәртәбә гөлдерәү

**Гөлдерәп тору** 1) Бертуктаусыз гөлдерәү. *Җир асты басымыннан, скважина авызына куелган «ёлка» – арматуралар яман гөлдерәп, калтырап-*

*дерелдәп торалар иде.* М.Хәсәнов. *Хуш исле үлән чәе барысын бергә җыйган табында рус, украин, татар сүзләре бергә кушылып, гөлдерәп торды.* М.Галиев

2) Шау-гөр килеп тору, тавышлы, шау-шулы булу

3) Яңгыравык, көчле булу. – *Кунак бар икән. Исәнмесез! – диде ул, гөлдерәп торган тавыш белән.* Р.Сибат. – *Әтил улым түгелме соң бу? – диде ул, гөлдерәп торган күкрәк тавышы белән.* Ф.Бәйрәмова

**Гөлдери башлау** Гөлдерәү тавышы барлыкка килү. *Көлтәчеләр арбаларны төяп бетергән чакта, күк гөлдери, күкри башлады.* А.Таһиров

**Гөлдери бирү** Гөлдерәвен дәвам итү, һаман да гөлдерәү

**Гөлдери төшү** Бераз гөлдерәү; тагын да ныграк гөлдерәү. *Шофёр --- бераз гөлдери төшеп сөйли иде.* Г.Әпсәләмов

**ГӨЛДЕРӘШЕП** *рәв.* Бик матур, бик җайлы; тату, бердәм (*яшәү, эшләү һ.б.ш.*). *Әсма гаилә тормышына керә дә матур балалар таба. Алар белән гөлдерәшеп гомер итәргә әзерләнә.* Ш.Әхмәдиев

**ГӨЛДЕР-ГӨЛДЕР** *иярт.* 1) Күк күкрәгән яки шуңа охшаш көчле яңгыравык дөмбердәү тавышларын белдерә. *Гөлдер-гөлдер килгән болытларны Төн кочагы ерак яшергән.* Г.Сәгыйров. *Буровой көнне-төнне белми, гөлдер-гөлдер, дөбер-шатыр килеп эшли, ә әрсез борау каты тау токымын кимерә, җимерә башлады.* Ә.Салах

2) Күгәрчен гөрләвен белдерә. *Тәрәзә төбендә күгәрченнәр: «Гөлдер-гөлдер». Гомер бердер.* К.Латыйп. --- *аркасына янтая төшеп, авызын зур итеп ачкан килеш, түбә астында гөлдер-гөлдер килгән күгәрченнәрне күзәтә башлады.* Р.Мөхәммәдиев

3) Бик ягымлы, тату, дусларча сөйләшүне белдерә. *Мин гөлдер-гөлдер сөйләшкән тавыштан айный алмыйча (йокыдан айный алмыйча дип әйтүем) ятам.* М.Мәһдиев. *Сүз китә гөлдер-гөлдер, Күз итә мөлдер-мөлдер. Бүрек баштан ташлана, Тормыш кабат башлана.* Ф.Яруллин

**ГӨЛДЕРДӘ́Ү** *ф. к.* **гөлдерәү.** *Аның баш очыннан гына пар күгәрчен пырлап үтте, алар, кыеклап, аннан алдарак кына юлга төштеләр һәм гөлдердәп шаяра-уйный башладылар.* А.Гыйләҗев

**ГӨЛДЕРДӘШҮ** *ф.* 1) Күгәрченнәр гөрләшү

2) *күч.* Куанып, матур иттереп, озаклап сөйләшү, серләшү

**Гөлдердәшеп алу** Бик аз гына гөлдерәшү. *Аның артыннан ук ысылдап килүче ана каз белән гөлдердәшеп алалар.* М.Әхмәтшина

**ГӨЛДЕРЕК** *с.* Гөлдерәп торган, яңгыравык. *Булганинның пышылдауга сыймаган ярсу гөлдерек тавышы белән: – Ну-с, пор-ручик, только посмей!.. – дигәнен аермачык ишетәм.* Ә.Гаффар. – *Исәнме, энекәш! – диде ул, гөлдерек мул тавышы белән коендырып.* Ә.Гаффар

**ГӨЛҖИМЕШ** *и.* Розачалар семьялыгыннан, ал яки ак чәчәкле, С витаминына бай җимеш бирә торган чәнечкеле куак үсемлек. *Яр кырыендагы тар гына сукмак, бормаланып, куе таллыклар арасыннан, гөлҗимеш, карлыган, зелпе куаклары яныннан уза.* Ә.Еники. *Гөлҗимешем тармак кына, Тармаклары кармак кына; Чәчәкләрен өзми беркем, Китәләр гел карап кына.* Ф.Яруллин. *Әй гөлҗимеш, син нихәтле генә гүзәл, нихәтле генә хуш исле булма, мин барыбер сиңа кунмам, баштан-аяк чәнечкеле бул.* Н.Исәнбәт

**ГӨЛҖИМЕШЛЕК** *и.* Гөлҗимеш күп үскән урын

**ГӨЛЗАР** *и. фар. иск. к.* **гөлбакча.** --- *Әнә Кояш, менә урам, гөлләр үсә гөлзарларда; күбәләкләр куыш уйный, оча-куна узганнарга.* Г.Сәгыйров

**ГӨЛЗӘМИН** *и. бот.* Бальзаминнар семьялыгыннан, җете кызыл чәчәкләре сабак тирәли тыгыз булып урнашкан берьеллык үсемлек; бохар кынасы; *русчасы:* **бальзамин**

**ГӨЛКӘ́Й ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан, урман, болын, сазлык, далаларда үсә торган, бөтен дөньяда 80 ләп төре булган үлән үсемлек; күгәрчен күзе; *русчасы:* **незабудка**

**ГӨЛЛӘ́МӘ** *и.* 1) Чәчәклек, гөлләр үсә торган урын, клумба

2) Букет. – *Бар андый чәчәк. Менә ул. – Самат иң түрдә балкып утырган ак лилияләр гөлләмәсенә ишарәләде.* Г.Гыйльманов

**ГӨЛЛӘНҮ** *ф. сир.* Чәчәк ату, чәчәге ачылу, чәчәккә күмелү

**ГӨЛЛЕК** *и.* Гөлләр үсә торган урын, гөлзар, гөлләмә. *Тәрәзә турысына гөллек ясарга*

**ГӨЛСИРИН** *и. сөйл. к.* **глицерин.** *Куыклар озак торсыннар өчен, сабын эремәсенә аның өчтән бере кадәр (күләм ягыннан) гөлсирин кушарга кирәк.* Кызыклы физика

**ГӨЛСТАН** *и. фар. иск.* Гөлбакча

**ГӨ́Л СУЫ** *и. иск.* Хушбуй. --- *алар артыннан биш мең кеше юлдагы ташларны арчып киләләр, алар артыннан алты мең күркәм егет кулларына шешә белән гөл суы тоткан, падишаһның юлына сибеп хуш исләндерәләр.* Дастан

**ГӨЛТ** *иярт.* Утның, яктылыкның һ.б.ш. кинәт кабынып яки яктырып китүен белдерә. *Таш каланың өсләрендә Гөлт тә гөлт ут ялтырый.* Ф.Бурнаш

◊ **Гөлт итеп тора** 1) Яп-якты, бөтен утлары янып торган. *Өйләр гөлт итеп тора, Ильич уты астында нигә утырмаска – гомерләре буена көттеләр...* Ә.Гаффар; 2) Бик матур, бик чиста, һәр яктан килешкән, ялтырап торган (гадәттә өй). *Карчыгы Банат эшнең нидә икәнен иреннән алда сизенгән, күрәсең, каушый төшеп, болай да гөлт итеп торган өстәл өстен сөртеп алды---* Җ.Рәхимов. **Гөлт иткән** *к.* **гөлт итеп тора**

**ГӨЛТАШ** *и.* Балчык, гипс һ.б.ш. материалдан әвәләп, пресслап яки башка ысул белән ясалган архитектур бизәк. *Дивардагы гөлташлар*

**ГӨЛТАШЛЫ** *с.* Гөлташ белән бизәлгән, шундый бизәкләре булган. *Гөлташлы бина дивары*

**ГӨЛТ-ГӨЛТ** *иярт.* Утның, яктылыкның әледән-әле янып, көчәеп, яктырып китүен белдерә. --- *басуның күк белән тоташкан урынында, күк капусы ачылгандай гөлт-гөлт итеп, арыш камчылый: аҗаган уйный.* М.Мәһдиев. *Гөлт-гөлт итә басу артында аҗаган, җир йөзен серле, моңсу, җылы кич*

*каплый...* М.Мәһдиев. *Көпшә очларында ялкын гөлт-гөлт кабынып куйганы күренеп кала.* Х.Камал

**ГӨ́ЛТ ИТҮ** *ф.* Кинәт ут һ.б.ш. кабынып, янып, яктырып, ялтырап китү. *Гөлт итеп ут кабынгач, ул бераз күзләрен челт-челт йомды да як-ягына каранды.* М.Маликова. *Әллә күктә яшен гөлт итте, Әллә кызлар кашын сикертте: Өлгермәдем һични аңларга, Ялкын капты зәңгәр таңнарга.* Ф.Яруллин. *Малайлар буржуйка авызына консерв савыты белән солярка сибеп өлгерәләр һәм калай моржадан гөлт итеп кисәк бүселеп чыккан каракучкыл ялкынлы төтенгә күмәкләшеп: «Һа-а!» – дип куаналар.* Казан утлары

**ГӨЛТЛӘ́Ү** *ф. к.* **гөлт итү.** *Шырпы кебек гөлтләп кабынсаң да, Дошман була «дошманлык» каныңа.* Ә.Сигугыл-Куганаклы

**ГӨЛХӘЙРЕ** *и. фар. бот.* Тырнакгөлчәләр семьялыгыннан озын сабагында эре-эре чәчәкләр ата торган декоратив бакча үсемлеге; *русчасы:* **штокроза**

**ГӨЛЧӘЧӘК** *и.* 1) Роза. *Монда мәңге җәй, җылы көн, гөлчәчәк мәңге ата.* С.Сүнчәләй. *Сукмакның ике ягына ике рәт тезелгән купшы гөлчәчәкләр исә, үз бәяләрен бик белеп, назлы елмаялар сыман.* Ш.Рәкыйпов. *Гөлчәчәккә якын барсам, Чәнечкесенә кадалсам, Гомерлек җәрәхәт алсам, Дәвачы да ул булырмы?* Р.Гаташ

2) Гомумән, чәчәк ата торган гөл. *Яшә шунда, гөлчәчәкләр утырт, бәрәңге, кишер!* А.Гыйләҗев. *Нур-җеп белән гөлчәчәкләр чигеп менә Керәп барам сөйгәнемнең күңеленә.* Л.Лерон

**ГӨМАН** *и. фар. иск.* 1) Уй, фикер, фараз, юрау. *Өйдән, фронттан берәр начар хәбәр алгандыр, мөгаен, дигән гөман башына килде.* Х.Камалов. *Кабанның үзен карст күлләре исәбенә кертәләр. Әмма --- бу, инде киңәйтелгән гөманга да сыймый торган бер факт бар әле.* Р.Мостафин

2) Шик, шөбһә, икеләнү. *Әй Идегәй, Идегәй, Юк гөманга син чумган, Туктамыштай олы хан – Аңа каршы кем торган?* Дастан. *Ушбу дөши билә күрдем, һич гөмансыз.* Кыйссаи Йосыф. *Минем дә күңелемдә ул вакыт әйтеп бетергесез юраулар, гөманнар, шикләр бөтерелде.* А.Расих. *Киләчәкне томан томалаган, Гөман һәм шик сарган үткәннәрне.* Р.Зәйдулла

**ГӨМА́Н ИТҮ** *ф. к.* **гөман кылу.** *--- революцион процессның Азия, Африка, Латин Америкасы илләрендә милли азатлык көрәшенең үсешенә бәйле булуы турындагы аның [Солтангалиевнең] гөман итүләре пәйгамбәрләрчә алдан күрү кебек иде.* Казан утлары

**ГӨМА́Н КЫЛУ** *ф.* Фараз кылу, юрау, ... дип уйлау. *«Тәңрем!» – диде – агачка табынды, Чәчәклек гөман кылды – чүплеккә абынды.* Дәрдемәнд. *Култыкның суы кая китеп юкка чыгып баруы хакында беренче мәртәбә дөрес гөман кылучы кеше – Г.С.Карелин.* А.Муранов. *Бу сүзләрне ул ярсып-ачуланып түгел, гадәтенчә, йөзенә каткан елмаю аша гөман кылды.* М.Хәсәнов

**ГӨМАНЛА́У** I *ф.* Гөман итү, нәрсәнеңдер ничек буласын алдан чамалау. *Әйтерсең чал чәчле абзый сөйләгәннәрне ул, чагыштырмача яшь егет, инде мең ел элек белгән, ишеткән яки гөманлаган гына түгел, үткәндәге шанлы вә шомлы вакыйгаларда катнашкан, карап торган.* Ф.Сафин

**Гөманлап карау** Гөманларга тырышу. *Хикәяләүче, ябылу сәбәпләрен гөманлап караса да, гүя дөреслекне белми.* Р.Гали

**Гөманлап тору** Әледән-әле, гел яки хәзерге моментта гөманлау. *Мәскәү матбугаты, Татарстан Югары Советының кайбер депутатлары шундый референдум үткәрү кан коюга китерәчәк дип гөманлап торганда, бу адымга бару, беренче чиратта, Татарстан Президенты М. Шәймиевтән зур батырлык таләп итеп, үз өстенә гаять зур җаваплылык алу булды.* Ватаным Татарстан

**Гөманлап утыру** Әле, хәзерге вакытта гөманлау. *Инде әбиләргә килгәндә, мөгаен, «Әмирҗанның хәләл җефете – Зәйтүнә Шәмсемөхәммәт кызы», «Минһаҗетдиннең хәләл җефете – Бәһиҗәтелҗинан Гарифулла кызы» дип дөресләп язарга кирәк булыр дип гөманлап утырам.* Ватаным Татарстан

**ГӨМАНЛА́У** II *и. к.* **гөман.** – *Хәтеремнән чыккан, илегез ничек атала әле? – дип сорады, башында ниндидер өзек-өзек гөманлаулар сизеп.* И.Хуҗин

**ГӨМБӘ** *и.* 1) Үсемлекләргә, хайваннарга яки аларның калдыкларына урнашып, споралар ярдәмендә үрчи торган, хлорофиллсыз түбән төзелешле үсемлекләр классының гомуми атамасы. *Сапрофит гөмбәләр үле органик матдәләр белән туклана, паразит гөмбәләр тере организмнарда урнашалар һәм алар исәбенә тукланалар.* Биология

2) Әлеге классның сапротрофлар бүлегенә караган, кеше һәм хайваннар өчен ашарга яраклы һәм агулы төрләргә бүленә торган үсемлекләрнең гомуми атамасы. *Бермәлне шулай өч малай урманга гөмбәгә дип киттек.* Э.Касыймов. *Әкрен генә атлап бара идем, игътибарым былтыргы яфракларны төртеп чыккан биш тиеннән чак кына зуррак бер гөмбәгә төште.* Н.Әхмәдиев. *Ә урманнарда йөреп, чикләвек, төрле җиләкләр, гөмбә, дару үләннәре җыю, печән чабу үзләре генә дә ни тора?!* Кызыклар дөньясында

3) Агач кәүсәсенә ябышып үсә торган каты үсенте, оры. *--- дөньяга чиста, балалар күзе белән карый башлыйсың: онытылып яткан уй-хисләр яңара, карурманнар аклана, һәр агач, куак, һәр үлән, һәр кырмыска күче, кош оясы, агач гөмбәсе якын дустыңа әйләнә дә синең серләреңә күчә.* Р.Вәлиев. *Каты гөмбә белән йогышлануны булдырмас өчен, агачларны ботаклары сынудан һәм кабыклары бозылудан сакларга, ә гөмбәне агачтан аерып алырга һәм яндырырга кирәк.* Биология

4) Кыяклы үсемлекләрне зарарлый торган авыру, кисәү авыруы. *Төрле төрдәге кисәү гөмбәләре солы, арпа, тары, кукуруз, бодай һәм башка кыяклы икмәк культураларын зарарлый.* Биология

5) Төрле үсемлекләрне, агачларны зарарлый торган авыруларның гомуми исеме. *Мин тәҗрибә үткәреп маташканда, тышта көчле җил чыгып, тәрәзәне ачып җибәрде һәм пробиркаларга күгәрек гөмбәсе спораларын китереп салды.* Кызыклар дөньясын-

да. *Бу гөмбә мамыксыман кунык рәвешендә еш кына икмәк, яшелчә, тирес (ат тиресе) өсләрендә була, беркадәр вакыттан соң ул кара төскә керә.* Биология. *Дару буларак, карагай гөмбәсенең мәшкәкләрен файдаланалар.* Урман аптекасы

6) Үзагачны зарарлый торган авыру. *Идән черек, стеналар юеш, почмакларда гөмбәләр үсә.* К.Нәҗми

7) *мед.* Яшь балаларның авызындагы лайлалы катлау бозылу; сөт авыруы

8) *күч.* Яңгырдан яки кояштан ышыклау өчен ясалган гөмбә формасындагы корылма – чатыр. *Гөмбәзонтикларның төсле материядән тартылган түбәләре киләсе җәйгә кадәр салдырылып алынган.* Г.Тавлин

9) *күч. мыск.* Берәр эштә, ешрак фикер йөртүдә, аңлауда сүлпән булган кешегә карата әйтелгән хурлау сүзе. *Шундый бул, акча үзе сине тапсын, гөмбә!..* Х.Камалов. *Теге тинтәк гөмбә тыңлатырга теләми инде безгә Лондонны!* Т.Әйди

◊ **Гөмбә баш** *кимс.* Аңсыз, ахмак. *«Бераз ял итеп алу комачауламас иде», – дигән була. Дипломат, янәсе, гөмбә баш.* Р.Вәлиев

**ГӨМБӘЗ** *и.* 1) Ярымшар формасында эшләнгән кабарынкы түбә; купол. *Чиркәүләр дәшми. Аларның иске гөмбәзләре безгә карап, дәшмичә генә, безне сынап утыралар.* М.Мәһдиев. *Чиркәү гөмбәзләре шәйләнә. Өй түбәләре.* А.Гыйләҗев. *Ул [Таһир мунчасы] борынгы болгар мунчалары үрнәгендә төзелә, идәне җылытыла, гөмбәзләре биек ителә, бассейннары, фонтаннары була...* Р.Мостафин

2) Берәр предметның ярымсфера формасындагы өлеше. *Су асты кыңгыравын да кешеләр су үрмәкүченнән күчереп эшләгән булса кирәк. Бу «водолаз» су астында пәрәвездән гөмбәз ясый.* Кызыклы ихтиология. *Сакланып калган таныкламалардан күренгәнчә, юлның [җир асты юлының] өсте таш гөмбәз белән ныгытылган булган.* Р.Мостафин

3) *күч.* Күк йөзенең һәр яктан күренеп торган ярымшар формасындагы офыктан өстәге өлеше; күк чатыры. *Мин тургай булып гөмбәзнең үзгенә очып мендем – күрдем: кояш батыш яктан илгә тузан тавы килә, бу – тәгаен, угыз явы.* Р.Харис. *Күк гөмбәзен ут-чыбыркы кыйный: уйный яшен ташы...* Исә җил. Л.Лерон. *Күк гөмбәзе чамасыз биек, йортлар-агачлар саф көмештән коелган, аяк асты – йомшак чыклы чирәм...* А.Гыйләҗев

**ГӨМБӘЗЛӘНҮ** *ф.* Гөмбәз формасына керү; гөмбәзгә охшый башлау, ярымшар формасын алу. *Тигез, шома итеп кырылган таш стеналарга, гөмбәзләнеп уелган түшәмгә төбәлеп ятасың да ятасың...* Г.Гыйльманов. *Миңа, казак илендә туып-үскән кешегә, бу яңа забой ошап китте. Ул киез өй кебек гөмбәзләнеп утыра.* И.Салахов. *Залның гөмбәзләнеп күтәрелгән түшәменнән тын гына музыка агыла. Поль Мориа оркестры уйный.* С.Шәмси

**Гөмбәзләнеп килү** Аз-азлап, шома гына итеп гөмбәз формасына керү

**Гөмбәзләнеп китү** Кинәт гөмбәзләнү. *Йөртеп ала кайчак яшел кырга Ярты гына ачылган күзен, Ара-тирә шунда карап ала Гөмбәзләнеп киткән күк йөзен.* Г.Рамазанов

**Гөмбәзләнеп тору** Гөмбәз формасына охшаган хәлдә булу

**ГӨМБӘЗЛӘ́Ү** *ф.* Гөмбәз формасына кертү, гөмбәзсыман итү. *Баш өстендәге түшәм дә гөмбәзләп уелган.* Г.Гыйльманов. *Түбәсе, нәкъ шәрык илләрендәгечә, гөмбәзләп эшләнгән.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ГӨМБӘЗЛЕ** *с.* 1) Гөмбәз формасында эшләнгән; гөмбәзләнеп торган. *Алар килеп кергән җир таш бина астындагы гөмбәзле тар аралык булып, аның икенче башында тагын бер бикле ишек бар иде.* М.Галәү

2) Гөмбәзе булган; гөмбәзләп эшләнгән

**ГӨМБӘЗСЫМАН** *с.* Ярымшар формасындагы, гөмбәз рәвешендәге. *Күп кешеләр җирне гөмбәзсыман күк йөзе белән капланган тәлинкә итеп күз алдына китерәләр, ә күк йөзе буйлап Кояш, Ай һәм биш планета йөри дип уйлыйлар.* Урта гасырлар тарихы

**ГӨМБӘЛӘНҮ** *ф.* Гөмбә (*4–6 мәгъ.*) белән зарарлану, гөмбә белән каплану

**ГӨМБӘЛЕ** *с.* 1) Гөмбә (*2 мәгъ.*) кушып яки гөмбәдән әзерләнгән

2) Гөмбә (*4–6 мәгъ.*) белән зарарланган, гөмбә авыруы булган

3) Гөмбә (*2 мәгъ.*) күп үсә торган, гөмбәгә бай

**ГӨМБӘЛЕК** *и.* 1) Гөмбә (*2 мәгъ.*) күп үсә торган, гөмбәгә бай урын

2) *к.* **гөмбәлек җебе**. *Эшләпәле һәр гөмбә гөмбәлек (грибница) һәм гөмбәнең җир өсте өлеше булган үрчү органыннан (плодовое тело) тора.* Биология. *[Яфрак гөмбәчеге] Үзагачны тишеп чыгучы гөмбәлектән (мицелий) һәм агач кайрысы өстендә сузынкы-цилиндрсыман яки тояксыман утырма эшләпәләр булып киткән мәшкәктән тора.* Урман аптекасы

**ГӨМБӘЛЕ́К ҖЕБЕ** *и. бот.* Гөмбәнең вак һәм тармакланучан җепселләрдән гыйбарәт булган, гадәттә субстрат эчендә, сирәк кенә аның өстендә була һәм азык матдәләре суыру өчен хезмәт итә торган вегетатив өлеше. *Черемәгә бай, дымлы туфракта гөмбә споралары шытып чыга. Алардан гөмбәлек җепләре үсеп китә.* Биология

**ГӨМБӘ́СЫМАН** *с.* Гөмбә формасында булган, гөмбә шикелле. *Гөмбәсыман этәргеч*

**ГӨМБӘЧЕ** *и.* Гөмбә (*2 мәгъ.*) җыючы. *Арыш башакка утыргач, гөмбәчеләр урманга юл тота.* К.Тәхау. *Истәлекләр, тәэссоратларга кереп китсәң, аның [Э.Касыймовның] табигатькә якынлыгын, гөмбәче, балыкчы булуын --- да читләтеп үтәсе түгелдер.* Т.Галиуллин

**ГӨМБӘЧЕК** *и.* Үсемлекләрне зарарлый торган паразит, гөмбә. *Гөмбәчек урнашкан агач акрынлап үзенең гадәттәге төсен үзгәртә, карала, ярыла ---.* Йорт эшләре. *[Бәрәңге] Яңа мәйданнарга тарала бару белән, күзгә күренмәс үтерүчеләр – гөмбәчекләр һәм бактерияләр корбанына әйләнә.* Кызыклар дөньясында

**ГӨМБӘ́ ЯҢГЫРЫ** *и.* Тиз үтүчән, кояшлы көнне ява торган җылы вак яңгыр

**ГӨМБЕР** *и. сөйл.* Суны болгатып, тавыш чыгарып, балыкны куркытып куу өчен балыкчы әсбабы; дөмбе

**ГӨМБЕР-ГӨМБЕР** *иярт.* Вагоннар хәрәкәткә килгәндә, буш мичкә, зур тимер әйберләр һ.б.ш. бәрелгәндә чыга торган калын тавышны белдерә

**ГӨМБЕРДӘТҮ** *ф.* Гөмбердәгән тавыш чыгарып бәргәләү, сугу, аудару

**Гөмбердәтеп тору** Бертуктаусыз гөмбердәгән тавыш чыгару

**ГӨМБЕРДӘ́Ү** *ф.* Зур күләмле калай, тимер предметлар бәрелеп, сугылып, авып һ.б.ш. көчле яңгыравык тавыш чыгару

**Гөмбердәп китү** Кинәт кенә гөмбердәгән тавыш ишетелү

**Гөмбердәп тору** Бертуктаусыз гөмбердәү

**ГӨМБЕРЛӘ́Ү** *ф. сир. к.* **гөлдерәү.** *Болыт үтте. Гөмберли күк еракларда.* Дәрдемәнд

**ГӨМБЕРТ** *иярт.* 1) Зур, авыр нәрсә җиргә ауганда, биектән төшкәндә чыга торган саңгырау тавышны белдерә

2) Зур, авыр әйбернең яки кешенең кинәт аву, егылу, төшү рәвешен белдерә

**ГӨНАҺ** *и. фар.* **1.** 1) *дини* Дин кануннарын бозу, шәригать таләпләрен үтәмәүдән гыйбарәт Алла каршындагы гаеп, язык. *Гөнаһыбыз булса, ярлыкагыл, И Ходаем, безне кызган бер!..* Л.Лерон. *Ул тайчанмый һәрбер гөнаһтан: соңгы тапкыр кайчан оялган?* Г.Сәгыйров. *Ник яраттың, кылыр булгач гөнаһ, Азгын итеп Җиргә без колыңны?* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Традиция, тәртип, әдәп-әхлак кагыйдәләрен һ.б.ш. бозу; гаеп эш. *Үз гөнаһын башкалар өстенә аудару – иң мордар, иң әшәке кешеләрнең эше.* Дәрдемәнд. *Митяның үги әтисе Борьканы табуреткага корсагы белән яткыра да, чалбарын төшереп, атна буена малай ясаган «гөнаһларны» саный һәм һәрбер «гөнаһысы» өчен, ясаган тәртипсезлекләренең дәрәҗәсенә карап, каеш белән суктыра.* А.Расих

3) Гомумән ялгышлык, кимчелек, хата, җитешсезлек. *Җиргә тагын карлар ява инде, Җир төрәнә тагын аклыкка. Җир яшерә үзенең гөнаһларын, Җир күмелә сафлык, пакьлеккә.* Р.Вәлиев. *Гөнаһны яшермик: өч-дүрт ел үтте, әмма Гарәфи дөрес язарга өйрәнә алмады, тыныч кына укуын дәвам итте.* Ф.Баттал. *Вертолёттан басуларның торышы, чәчкән чакта җибәрелгән гөнаһлар уч төбендәге кебек ярылып ята.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Дин һәм шәригать кануннарына туры килми торган

2) Гаеп булып санала торган, дөрес, матур булмаган. *Гөнаһ эшне юк файда Инде безгә сылтауда.* Г.Тукай. --- *ят җирдә алар инде әзрәк үз кешеләр – якташлар иде. Ә якташны ярдәмсез калдыру – гөнаһ эш.* М.Маликова

**3.** *хәб. сүз* Начар, гаеп; дөрес түгел

**4. гөнаһтыр** *кер. сүз* Каргану, ант итү сүзе: анттыр, чынлап, билләһи

◊ **Гөнаһ шомлыгы** 1) Бәхетсезлек, бәла. *Уйнаучылар да, бер гөнаһ шомлыгы төшкән кебек, бичара «Алдымбирдем»не һич танымаслык иттереп боздылар.* Ф.Туктаров. *Нинди гөнаһ шомлыклары икән, Ни булды соң әле иленә?!* Х.Әюп. *Ниһаять, мин үзем дә шул караңгы читлек эчендә. Ни өчен? Нинди гөнаһ шомлыгына?* М.Салахов; 2) *кер. с. к.* **гөнаһ шомлыгына.** *Гөнаһ шомлыгы, бу вакытта Фәндиләя почмак якка чыгып китте дә керми дә керми!* Г.Ахунов. *Бу теш, гөнаһ шомлыгы, моннан 145 миллион ел элек үк үлеп бетеп юкка чыккан оча торган кәлтә еланы теше булып чыга!* Кызыклар дөньясында; 3) Җиңелчә тиргәнү, ачулану сүзе; канәгатьсезлек, ризасызлык, үпкә кебекләрне белдерә. *Хатын, тор, таптым мин теге гөнаһ шомлыгын!* Ф.Баттал. *Син үзеңнең кем малае икәнеңне әйтмәдең инде мин карт кешегә, яшердең. Әллә минем алма бакчама кереп тотылганың барыемы, гөнаһ шомлыгы?* Г.Тавлин. **Гөнаһ шомлыгына** *кер. сүз* Бәхетсезлеккә, бик кызганыч. *Ләкин, гөнаһ шомлыгына, көнбагыш сабаклары арасыннан чыгуга, безгә таба якынлашып килгән бер марҗа түтәен күреп алдык.* Ә.Еники. *Гөнаһ шомлыгына, ташу көчәеп кузгалганны сизмичә калдык.* Р.Вәлиев. *Гөнаһ шомлыгына, ул көнне Васбиҗамал, Убырлының сөякләре җылынсын әле дип, мичenә бик каты яккан ---.* Ф.Садриев

**ГӨНАҺКЯР** *и. фар.* **1.** Гөнаһлы кеше, бозык кеше. *Языкка батып, өченче атна күпме гөнаһкярларны яшереп асрыйм.* А.Гыйләҗев. *Мин – гөнаһкяр, әмма синнән гайрене сөймим икән ---.* С.Сүнчәләй

**2.** *с. мәгъ.* Гөнаһлы, гөнаһ кылучы, бозык, азгын

**ГӨНАҺКЯРЛЫК** *и.* Гөнаһкяр булу

**ГӨНАҺЛАНУ** *ф.* 1) Гөнаһ кылу, гаепле эш эшләү

2) Нигезсез сөйләү, ялгышу; белмичә сөйләп, шуның гөнаһын үз өстенә алу. – --- *шул бүләк өчен кешелегеңне җуйдың... – Юк, мин бүләкне хаклы алдым... Гөнаһланма!* Х.Камалов

**Гөнаһланып бетү** Гаеп эшләр эшләп, үз өстенә күп гөнаһ алу, гөнаһ җыю

**ГӨНАҺЛЫ** *с.* 1) *дини* Шәригать канунына туры килми торган; гөнаһы булган, гөнаһ эш эшләгән. *Адәм булып туган өчен генә, Мин гөнаһлы икән Җирдә нигә?* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) Гаебе булган, гаеп эш эшләгән; тәртип, гадәт һ.б.ш. бозган. *Бу дөнья, күрәмсең, бер генә чакта да гөнаһлы кешеләрдән бушап тормаган.* Ф.Баттал

**ГӨНАҺЛЫК** *и. сир.* Гөнаһ, гөнаһ эш, язык

**ГӨНАҺЛЫЛЫК** *и.* Гөнаһлы булу факты, гөнаһлы булу

**ГӨНАҺСЫЗ** *с.* **1.** 1) Дин һәм шәригать күзлегеннән бер гөнаһы да булмаган

2) Гаебе булмаган, гаеп эшләмәгән

3) *күч.* Кимчелеге, җитешсезлеге булмаган, әйбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бер гаебе дә булмый торып, хаксыз рәвештә. *Бик күп яхшы кешеләр гөнаһсыз рәвештә шәхес культының корбаны булдылар.* И.Салахов

2) Гөнаһ кылмыйча; хаталанмыйча. *Бу гөнаһлы Дөньяда гел генә дә гөнаһсыз яшәү үзе, бәлки, гөнаһтыр...* Р.Фәйзуллин

**ГӨНАҺСЫЗГА** *рәв.* Гаепсезгә, хаксыз рәвештә, урынсыз, сәбәпсез. *Инде җитәр, юк җиргә, гөнаһсызга адәм балаларын әрәм итү олуг падишаһлар шанына муафыйк эш түгелдер.* Дастан. *Бандит нәрсә ул: теге чакта да һичбер гөнаһсызга Габдулла*

*дигән бер кешене атып үтерде.* Г.Ибраһимов. *Ничә айлар буе үбәргә дә базмый кадерләгән җан иясен гөнаһсызга үпкәләттем.* Ә.Гаффар

**ГӨНАҺСЫЗЛЫК** *и.* 1) Дин, шәригать алдында пакь булу халәте

2) Берәр гамәлдә гаебе булмау, намусы чиста булу. --- *Нәркис аңа шундый саф, беркатлы итеп, һәр сүзенә инангандай карап утыра иде ки, Алтынчәч аның гөнаһсызлыгына сүзсез дә ышанды.* М.Маликова. --- *ул [Арсланов] менә хәзер дә үзенең гөнаһсызлыгы, турылыгы, гаделлеге белән аларның бөтенесеннән дә өстен тора.* Ф.Садриев

**ГӨНАҺЫ** *и. фар. сөйл. к.* **гөнаһ.** *Бер гөнаһысы юк иде бичараның... Минем урынга кара кабергә ятты...* А.Гыйләҗев. *Андый кешеләрнең сүзе кайда да үтә, гөнаһысы килеп чыкса да, күпертмиләр.* Х.Камалов. *Гөнаһысыннан куркам. Кешенең тиене дә кирәк түгел.* В.Нуруллин

◊ **Гөнаһысына керә алмыйм (кермим, кермик)** «Төп-төгәл белмим», «ышанып әйтә алмыйм», «нигезсез фараз итәсем килми» мәгънәсендә. – *Юк, Әнәс дус, гөнаһысына кермик, ашамыйм, – диде Миша да.* Ә.Галиев

**ГӨНАҺЫКЯР** *и. фар. к.* **гөнаһкяр.** *Мәңгелекнең юл өстендә әле син дә бар – Алмаштырып булмый торган гөнаһыкяр.* Х.Әюп

**ГӨНҖӘЛӘ** *и.* 1) Эрләр өчен әзерләнеп куелган, эрләгәндә, кабага бәйләнә торган йон яки сүс төргәге; көнҗәлә. *Иртән эшкә киткәндә, сумкасына бер гөнҗәлә йон да тыкты [Тәнзилә].* Р.Төхфәтуллин

2) *диал.* Дала һәм чүлләрдә таралган, шарсыман формадагы, орлыгы өлгергәндә тамырыннан аерылып, тәгәрәп йөри торган үлән үсемлек; өермә үләне, дүңгәләк; *русчасы:* **перекати-поле**

**ГӨП** *иярт.* Кинәт кенә зур авыр әйбер белән икенчесенә сукканда, авыр әйбер җиргә төшкәндә чыккан һ.б.ш. саңгырау тавышны белдерә. *Шулчак «гөп» иткән тавыш ишетелде.* Ф.Баттал. *Уткән чакта шактый шикләндем; Ун адымнан артык китмәдем: Гөп! иткәнгә кинәт сискәндем...* Г.Сәгыйров

**ГӨПӘШ** *с. сөйл.* Кыска буйлы, тыгыз, таза гәүдәле

**ГӨП-ГӨП** *иярт.* Берничә тапкыр яки даими кабатланган гөпелдәгән тавышны белдерә. *Бермәл, таң яктырып килгәндә, гөп-гөп итеп, баш очында гына ике тапкыр мылтык аттылар.* М.Кәрим

**ГӨПЕЛДӘТҮ** *ф.* 1) «Гөп» иткән тавыш чыгару

2) Егу, аудару

3) Авыр әйбер белән яки кул белән нык бәргәләү, гөп-гөп сугу. --- *Гераклныкыдай тыгыз беләкле бер түтәй уттай кояш астында, кәйлә белән гөпелдәтеп, иске асфальт вата.* Ф.Баттал

4) Каты кыйнау

5) Утлы коралдан ату. *Байкучатов сорау-фәлән бирмәде, унатарын чыгарды да, сынатмаска тырышып, бер-бер артлы өч мәртәбә гөпелдәтте.* Т.Әйди

6) Атып үтерү. *Егет --- имәннәр тирәсендә әйләнде. – Киссеннәр генә! Мин аларны мылтыктан гөпелдәтәм. Ант мәгәр!* Н.Гыйматдинова. *Монда арттан гөпелдәтәләр, кардәш, шуны исегездә нык тотыгыз.* Т.Әйди

**ГӨПЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Гөп иткән тавыш чыгу, шундый тавыш чыгару. *Икенчеме-өченчеме каттан, Хәлисәдән күп булса илле метр ераклыкта, асфальтка нидер гөпелдәп төште.* Ә.Гадел

2) «Гөп» иткән тавыш чыгарып нидер эшләү. *Урманчык яңа эшчеләр, өстәмә техника белән тулды; кара төтен, сумала исе таралды, үзбушаткычлар әрле-бирле йөрергә кереште, экскаватор чүмечләре гөпелдәде.* Ф.Баттал

**Гөпелдәп тору** Бертуктаусыз «гөп-гөп» иткән тавышлар чыгу

**ГӨПКОРСАК** *и. гади с.* Капкорсак, зур корсаклы кеше; туймас кеше

**ГӨПЛӘ́Ү** *ф. сир. к.* **гөпелдәү**

**ГӨР** *и.* 1) Гөрелте, көчле калын авазлар кушылып барлыкка килгән шау. *Гөрләвекнең гөре – Күкне сагынып үксеп елавы.* Р.Фәйзуллин

2) Күгәрченнәр гөрләве

**ГӨРАЗ** *с. гар. иск.* **1.** Батыр, кыю; ярсу

**2.** *и. мәгъ.* Батырлык, кыюлык. *Газимәт әйләде сүз гөраз илә, сәнең дәргяһыңа гаҗиз ниазилә...* Дәрдемәнд

**ГӨРӘНКӘ** *и. рус иск.* Фунт, бер кадакка тигез булган (405 гр.) авырлык үлчәү берәмлеге. *Бүген тоз алган кешеләр, тоз хакын онытa күрмәгез. Ике гөрәнкә тоз – бер пот арыш.* Ю.Әминов. *Кызым, алай да һай каты кеше Әхмәт бай, ике ишек төзәткәнгә барысы кырык биш тиен бирде; ярты гөрәнкә вак кадак та үзем алдым әле, барсына – кырык биш тиен.* Ф.Халиди. *Бер каз, бер кадак май, бер гөрәнкә язгы йон алып килгәнен белгәч, күрәзәче агай, батырның анасына карап, авызын ерды.* Р.Батулла

◊ **Гөрәнкәсе җиңел** Тулы түгел, акылга зәгыйфь, тинтәк

**ГӨРБИЯН** *с. рус сөйл.* Дорфа холыклы, тупас телле, холыксыз

**ГӨРБИЯНЛАНУ** *ф.* Гөрбиянга әйләнү; үз-үзеңне гөрбияннарча тоту

**Гөрбиянланып китү** Соңгы арада гөрбиянлану

**ГӨРБИЯНЛЫК** *и.* 1) Гөрбиян булу

2) Дорфалык, тупаслык, тәкәллефсезлек. *Гөрбиянлык күрсәтү*

**ГӨРГЕЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **гөҗгеләү**

**ГӨРГЕЛДӘ́Ү** *ф. к.* **гөрелдәү** (*4 мәгъ.*). – *Кәкрәймә, үзеңне куып чыгармасын, – диде балта остасы Мотыйк һәм, гөргелдәп, ләззәт белән көләргә тотынды.* Р.Вәлиев

**ГӨРГЕЛДЕК** *с.* Гөрелдәп, гүләп ишетелгән, гөрелдәп торган. *Олы юлдагы гөргелдек тавыш*

**ГӨРГЕРИ** *и. сөйл. к.* **гөр-гөр** (**2.**)

**ГӨРГЕЧ** *и.* Агачның каерысын сыдырып төшерү, каезлау өчен кулланыла торган, ике яктан тоткалы кәкре пычак; *русчасы:* **скобель**

**ГӨР-ГӨР** *иярт.* **1.** Күгәрчен гөрләгәндә чыккан авазларны белдерә. *Көяр аһымда һәм күгәрчен гөр-гөр, Булыр дәртемә кара төн – ут, күмер.* Сәйфелмөлек китабы

**2.** *и. мәгъ.* Качышлы уены, «әби» ролендәге уйнаучы күзен каплап «гөрләгәндә», башкалары качып, «әби» аларны эзләп табудан гыйбарәт уен

**ГӨ́Р-ГӨР КИЛҮ** *ф.* Бик мавыгып сөйләшү, теләп, рәхәтләнеп сөйләшү. *Сөйләшкәндә дә ул, күгәрчен тавышына охшатып, гөр-гөр килеп тора, артык каты кутарылып орынмый,*

*ирененнән беркайчан да елмаю китмәс: суйган да каплаган күгәрчен инде.* Р.Вәлиев. *Почта кызлары гөр-гөр килеп сөйләшәләр, алар Бибинур карчыкны юри күрмәмешкә салышалар.* А.Гыйләҗев. *Ике әби әнә гөр-гөр килә: Колак исе керә борынга.* Л.Лерон

**ГӨРЕЖДӘ** *и. рус* Сөтчел гөмбәләр ыруыннан, каен яки нарат урманнарында төркем-төркем булып үсә торган, киң ак эшләпәле, бераз лайлалы һәм йонтәс, ашарга яраклы гөмбә; нарат гөмбәсе; *русчасы:* **груздь.** --- *ул поты-поты белән бал бирә торган юкәлекләр дисеңме, ул гөрежҗдәләр чәчелеп үсә торган каенлы аланнарын әйтәсеңме ---, һәммәсе – муллык-саулык чыганагы!* А.Гыйләҗев. *Ул келәт базында август уртасында ук тозлап куйган гөрежҗдә гөмбәләрен исенә төшерде.* Ә.Гаффар

**ГӨРЕЛДӘВЕК** *с.* **1.** Гөрелдәп ишетелгән. *Кайгыдан кара көеп чыккан Рәйханаы чакырып кертте дә, тантанасын яшерә алмыйча, гөрелдәвек тавыш белән боерык бирде: ---.* З.Зәйнуллин. *Шулчак гүя дә күк күкрәде, гүя дә янгын оясына су шәлкеме бөркелде: Әнфиснең --- гөрелдәвек калын тавышы яңгырап китте.* Д.Булатова

**2.** *и. мәгъ.* Гөрелдәп ишетелгән тавыш. *Ләкин бу барып чыкмады, ниндидер хәтәр гөрелдәвек аны сискәнеп уянырга мәҗбүр итте.* Г.Гыйльманов

**ГӨРЕЛДӘҮ** *ф.* **1.** 1) Көчле калын яңгыравыклы тавыш чыгарып тору; шау хасил итү. *Трактор, комбайн, автомашина моторлары туктаусыз гөрелдиләр.* И.Салахов. *Ләгънәт суккан шәһәр тавышын ишетәсеңме? Гөрелди ул, шат ул шәһәр.* С.Сүнчәләй

2) Көчле гөрелте тудырып шартлау, күк күкрәү һ.б.ш. яңгыравык шау ишетелү. *Төне-көне таза дулкыннар өстемдә гөрелдиләр, Кояш, ай, нурлы йолдызлар миңа һичбер күренмиләр.* С.Сүнчәләй

3) Шаулашу, шау-гөр килү. *Зал гөрелди... Һәркем утыра урнына... Пәрдә калка... Зал сүнә... Бердән тына.* С.Сүнчәләй

4) Түбән тембрлы, калын көр тавыш белән сөйләү яки көлү

5) Бик ягымлы тавыш белән иркәләнеп сөйләшү. *Ишек ачылуга, очынып, күгәрчендәй гөрелдәп, Лариса килеп керде, Зәйтүнәнең муенына асылынды.* М.Маликова. *– Я инде, ул кадәр аю булма, – дип гөрелдәде Лариса.* М.Маликова

**2.** *и. мәгъ.* Шау, гөрелте. *Йокымсырап утырган пассажирларны сискәндереп, моторларның тигез гөрелдәвенә эре калибрлы пулемёт тавышы кушылды.* З.Фәтхетдинов

**Гөрелдәп алу** Бераз вакыт гөрелдәү

**Гөрелдәп тору** 1) Берөзлексез гөрелдәгән тавыш чыгару

2) Шау-шулы булу

3) Яңгыравыклы, калын, көр булу (тавыш турында)

**ГӨРЕЛДӘШҮ** *ф. к.* **гөрләшү**. *Гөрлә әйдә, гөрлә, гөрләвек, Без дә гөрләп яши беләбез, Без тормышны гөлгә бизәдек, Шуңа гөрелдәшеп көләбез.* Р.Рахман. *Кичләрен караңгы почмакта пар күгәрчендәй гөрелдәшкән тавыш ишетелсә, бүтән булмас, шул Хөсәен белән Лариса булыр.* М.Маликова. *Тора-бара теге тагын: «Ташла Хәлимәңне, күч безгә дә гөрелдәшеп яши башлыйк», – дип әгъваларга тотынды.* В.Нуруллин

**ГӨРЕЛДЕК** *и.* **1.** Гөрелте, шау-шу. *Ул яктан аңа җиңелчә гөрелдек – күңелле шау-шу һәм өзек-өзек кычкырган, --- атлар кешнәгән тавышлар ишетелгәндәй булды.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Гөрелдәп чыккан, яңгыравык. *Табигать үз баласына берсен бирсә, икенчесен кызгана: гәүдәле адәмнең тавышы нечкә була яисә чандыр гәүдәле берәүнең нечкә бугазыннан, һич көтмәгәндә, гөрелдек аваз бөркелеп чыга.* М.Маликова. *– Ләйлә Мөбәрәковна! – диде ул ерактан ук, гөрелдек тавыш белән.* М.Маликова

**ГӨРЕЛТЕ** *и.* 1) Шартлау, күк күкрәү кебек һаваны яңгыраткан нәрсәләрдән барлыкка килгән тавыш. *Еракта-еракта күк гөрелтесе ишетелгәләп куя.* Р.Батулла. *Колакка машина гөрелтесе кереп тулды, өлкән лейтенант Киреевның өзек-өзек сүзләре ишетелде.* Р.Вәлиев. *Шул вакыт туплар гөрелтесе портка хәрби корабль килүен хәбәр итә.* Кызыклар дөньясында

2) Бик күп төрле чыганаклардан ишетелгән төрле авазлардан, тавышлардан кушылып барлыкка килгән шау. *Урамнарда кар суларының гөрелтесе басылгач, --- апа укуын бетереп кайтты.* Ф.Яруллин. *Шәһәрнең өзлексез гөрелтесенә күнеккән колак тынлыкны каты шартлау кебек үк сискәнеп кабул итә.* Ә.Гаффар

**ГӨРЕЛТЕЛЕ** *с.* Һәртөрле тавышлар, шаулар белән тулы, гөрләп торган, шаулы. *Ялкынлы, гөрелтеле фронт сызыгы һаман якыная барды.* Г.Бәширов. *Мин театрда... Халык шаулап йөри шат фойеда, Яңгырый бар шау-шудан залда гөрелтеле сада.* С.Сүнчәләй

**ГӨРЕС** *иярт. к.* **гөрс.** *Үзебезнең самолётлар булган икән: Сивашның теге ягында гөрес-гөрес бомбалар ярыла башлый.* И.Гази

**ГӨРҖӘ** I *и. к.* **гюрза**

**ГӨРҖӘ** II *и. к.* **гөрҗи**. *Ә ул гөрҗәнең үзен, Газазилне күктән сөргәндәй, Мавзолейдан чыгарып, җиргә күмделәр ---.* Ә.Еники

**ГӨРҖИ** *и.* Грузин. *Үзе, референт итеп, Мәскәүдән Казанга кайтарткан чибәр гөрҗи хатынын алды.* А.Гыйләҗев

**ГӨРЗӘ** *и. фар.* Кара еланнар семьялыгыннан соргылт сары яки кызгылт көрән өстенә коңгырт таплары булган агулы елан. *Гөрзә тәңкәсе*

**ГӨРЗИ** *и. тар.* Авыр чукмар башлы таяк формасындагы борынгы сугыш коралы. *Ун яшенә җиткәндә, аңарда баһадирлык галәмәтләре күренеп – кылыч һәм дә гөрзи тотмак, ук атмак һәм башка баһадирларга кирәк булган һөнәрләрне өйрәнеп вакыт үткәрә иде.* Дастан. *Әйлә, тиде, йөреде тәкъдир белә, Мең батман гөрзисе бар үзе белә.* Г.Тукай. *– Бу бәләкәй диюгә каршы мин үзем дә җиткән, кая минем гөрзи? – диде ул ---.* Ә.Фәйзи

**ГӨ́Р ИТҮ** *ф.* **1.** *к.* **гөр килү**

**2. гөр итеп** *рәв. мәгъ. к.* **гөр килеп**. *Кешедән ким яшәмиләр тагы, гөр итеп бишәр бала үстереп яталар [Мисхәт белән Гөлсинә].* Җ.Рәхимов

**ГӨ́Р КИЛҮ** *ф.* **1.** 1) Шаулашу, шау-гөр килү (кешеләр турында). *Эләккән каракны милициягә биреп тору юк, базар халкы тоталар да гөр килеп вата башлыйлар.* Ә.Еники. *Пьесаны укыганда, артистлар гөр килеп утырдылар, көлделәр, бүлдерделәр, «бурный» тәнәфесләр булды.* М.Мәһдиев

2) Тавышлар белән тулып яңгырап тору. *Сүзләр очты ук булып, Телләр кызды ут булып. Шау да гөр килде урам, Сүзләрдән купты буран.* Ф.Яруллин. *Ул көнне институт гөр килде. Барысының да йөзе тынычсыз, барысы да кемгәдер нәфрәт белдерә, кемнедер кызгана, кемнедер каргый иде.* Р.Вәлиев

3) *к.* **гөрләү** (*7 мәгъ*). *Драма түгәрәкләре гөр килә, яшьләр ялындырып тормый, театр уйныйлар, концертларда катнашалар.* Г.Ахунов

**2. гөр килеп** *рәв. мәгъ.* Дусларча, тату, бердәм; бик яхшы (*яшәү, эшләү*)

**ГӨРЛӘВЕК** *и.* **1.** 1) Язын кар эреп, җәен яңгыр явып җыелган суларның зур булмаган агымы. *Гөрләвекләр булып, тулып ага, Урам буйлап ага кар сулары...* Л.Лерон. *Түбәдән пычтыр-пычтыр су ага; ишегалдында, урамда гөрләвекләр акканы ишетелә.* Р.Батулла

2) Шау-шу, гөрелте

**2.** *с. мәгъ.* Шаулы, гөрләп торган, гөрелтеле. *Урман кары кузгалгач, таудан, сугылып-бәрелеп, гөрләвек ташкыннар төште...* А.Гыйләҗев

**3.** *и. мәгъ. к.* **гөр-гөр 2.**

**ГӨРЛӘВЕКЛЕ** *с.* **1.** Гөрләвекләр булган, гөрләвекләр агып торган. *Гөрләвекле яз*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Гөрләвекләрдә көймә агызып уйнау. *Бабай, дим, мин дә гөрләвекле уйнарга чыгыйм әле.* Р.Батулла

2) *к.* **гөр-гөр 2.**

**ГӨРЛӘМЕШ** *и.* Качышлы уенының бер төре. *Гөрләмеш уйнау*

**ГӨРЛӘТҮ** *ф.* **1.** 1) Шаулату, яңгырату. *Кызлар гөрләтеп кул чаптылар. Фиданга бу ошамады.* Р.Вәлиев. *Мөдир әле сөйләп тә бетермәде, минем күз алдыма шыгрым тулы залның гөрләтеп кул чабуы, куеласы концертымнан мөкиббән булып әсәрләнүе күренә башлады.* Ф.Баттал

2) Януын, кайнавын һ.б.ш. көчәйтү

3) Су, сөт кебек сыеклыкларны мул итеп, көчле итеп агызу; гөбердәтү

4) *күч.* Таныту. *Гөрләт Татарстан җиренең дан-шөһрәтен ерак-еракларга!* Л.Шагыйрьҗан

**2. гөрләтеп** *рәв. мәгъ.* 1) Бик яхшы, нәтиҗәле, уңышлы рәвештә, бик җайлы итеп. *Кибетләр гөрләтеп сату итә. Каяндыр товары да чыга, товары да килеп тора.* Ә.Еники. *Крестьян атлы, сыерлы булды, гөрләтеп иген игә башлады.* М.Мәһдиев. *Аларның да гаиләләре бар иде. Әмма укырга да вакыт таптылар, эшләрен дә гөрләтеп алып бардылар.* В.Нуруллин

2) Күңелле итеп, рәхәтләнеп, канәгатьләнерлек дәрәҗәдә. *Гөрләтеп сабантуйлар үткәрү*

**Гөрләтеп алу** Бераз гөрләтү, аз гына вакыт яңгырау, шаулату. *Педсовет башланыр алдыннан, мәктәпнең дәү генә венский гармунын тартып чыгардылар, военрук Хәкимҗан аны гөрләтеп алды.* М.Мәһдиев

**Гөрләтеп җибәрү** 1) Гөрләгән тавышлар чыгара башлау. *Иптәш егетләре кайсы кая таралгалап беттеләр, рус егетләре, кызларын култыклап, болынга таба юнәлделәр, берсе двухрядкасын гөрләтеп җибәрде ---.* М.Мәһдиев

2) Ут тергезү, яндырып җибәрү, ут кабызып яндыра башлау

3) Кайнарга кую; кайнавын көчәйтү

**ГӨРЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Күгәрченнең тавыш бирүе, гөр-гөр килүе. *Җилфер-җилфер җилләрдә лә, хәлләр хәтәр илләрдә. Күгәрченем, Өмми-кошым, хәлең бармы гөрләргә?* Җыр. *Кыегында сары нарат йортның Күгәрченнәр гөрләп утыра.* Г.Хуҗиев. *Парлыга саныйлар кешеләр, Кыекта күгәрчен гөрләсә...* Ф.Гыйззәтуллина

2) *күч.* Йомшак, ягымлы тавыш белән сөйләү. *– Бибинурга бүләк булдымы? – дип сорады Зөһрәбану. – Аңа да эләкте, – дип гөрләде --- Галикәй.* А.Гыйләҗев

3) Хәрәкәттәге техника, эшләп торган механизмнар тоташ шау, гөжләү, гөрелте чыгару. *Авыл тутырып техника гөрләде, тыз-быз чабыштылар.* М.Мәһдиев. *Көлемсерәп йөзеп йөргән Ай яктысында Машина гөрли, үкерә кыр уртасында.* Г.Сәгыйров. *Дүртенче көнне, экипажның сугыш припаслары беткәч, мотор гөрләгәне ишетелә.* Казан утлары

4) Шау-гөр килү, шаулашу; төрле тавыш белән тулу. *Бәйрәм иртә таңнан башлана, шахтёрлар посёлогы көн буена гөрли.* Ә.Галиев

5) Көчле аккан су шаулау, шарлау, көчле янган ут гөжләү һ.б.ш. *Таулы матур илләрендә Гөрли агым сулары...* Дәрдемәнд. *Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар, Сез кабат чыктыгыз юлларга. Кар суын кояшта җылытып, Дөньяның йөзләрен юарга.* Н.Дәүли. *Җыелган сулары көндез генә юл салган зур елганың гөрләп акканы ишетелә.* Г.Сәгыйров

6) «Гөр-гөр» уенында «әби» ролен үтәү, качкан уенчыларны эзләү

7) *күч.* Уңышлы булу, бик җайлы бару (*эш, тормыш* һ.б.ш.). *Кырлар уяна, Басулар гөрли, Һәрбер үсемлек Кояшка үрли.* Ф.Яруллин. *Саумы, Серёга. Городецкий әле бу. Тормышларың ничек, эшләрең гөрлиме?* Р.Мирхәйдәров. *Гөрләгән дә булды, дөрләгән дә – Язып бара хәтер барын да: Югалтырга безнең хакыбыз юк Ялганын да, яхшыларын да.* Х.Әюпов

8) *күч.* Берәр өлкәдә зур уңышларга ирешеп, исеме танылу, даны таралу

**2.** *и. мәгъ.* 1) Күгәрчен тавышы. *Бераз гына колак салып торсаң, тартар кычкыруын да, урман күгәрчене гөрләвен дә, чуллыкның сарык бәэлдәвенә охшаш өзек-өзек җырын да аерасың.* Р.Мостафин. *--- урман күгәрченнәренең гөрләгәне күңелемә тыныч бер рәхәтлек иңдерә, йөрәгем ярасына мин юаныч-дәвалар табам.* Г.Ахунов

2) Халык төркеменең шау-гөр килүе, гөрләшү

3) Аккан су, янган ут һ.б.ш. чыгарган тоташ шау

**3. гөрләп** *рәв. мәгъ.* 1) Шыбырдап, шаулап, көчле агым белән. *Гафу сорый кызың: зәңгәр дулкыныңа Гөрләп аккан канны бик күп куштым, Идел!* Зөлфәт. *Сугуы шулкадәр көчле булды: Ирек*

*тизлеген югалтты, --- борыныннан гөрләп кан китте, һәм ул авыртудан кычкырып җибәрде.* Ф.Садриев

2) *күч.* Бик уңышлы, бик җайлы, шәп. *Аллага рәхмәтләр укыйм, Гөрләп бара эшләрем.* Ф.Яруллин. *Без су сибеп үстергәнгә күрә Гөрләп үсте рухи гариплләр.* Зөлфәт. *Егерме яшь... Йөрәкләрдә мәхәббәтнең гөрләп чәчәк аткан чагы...* Казан утлары

◊ **Гөрләп торган** Нык үсеш алган, алга киткән, чәчәк ату чорында булган. *Гөрләп торган зур цехларда, ышанычлы, җаваплы җитәкчеләрнең кул астында, зур коллективларда җимерттереп эшләгән кешеләр бит алар!* М.Маликова. *Ә бит заманында гөрләп торган авыл иде шушы Куралык.* В.Нуруллин. *Гөрләп торган гүзәл шәһәрләрне этләр ята торган хәрабәләргә әйләндерүе ихтималын искәртә.* Татар әдәбияты тарихы

**Гөрләп алу** Бераз гына гөрләү. --- *боз колонналары арасында кышның адашып калган соңгы җилләре уфтанышa, күгәрченнәр гөрләп ала.* Ә.Гаффар

**Гөрләп кую** Шаулашып алу, шаугөр килеп алу. *Сафта торганнар гөрләп куйдылар: «Разведкага-а-а?»* З.Зәйнуллин

**Гөрләп тору** 1) Гөрелте тудыру, бертуктаусыз гөрләү. *Гөрләп торсын шытыр-шытыр янган мичләр.* Г.Тукай. *Туп, пулемёт тавышы гөрләп торган кырларда, окоп эченә ятып, иптәшләре белән, көлешеп, махорка төрә.* Ш.Усманов

2) Һәрвакыт шау-шулы булу, гөр килеп тору. *Бокалларда шампан ташыр, Гөрләп торыр бәйрәмнәр.* Ф.Яруллин. *Парк, төрле төсләрдәге утларга чумып, бала-чага чыр-чуына күмелеп, гөрләп тора.* Р.Вәлиев

**ГӨРЛӘҮЧЕ** *и.* Гөр-гөр, ягъни качышлы уенында уенны алып баручы, куучы яки эзләүче

**ГӨРЛӘШҮ** *ф.*1) Гөр-гөр итеп, берничә яки бик күп күгәрчен гүләү. *Агачларда пар-пар кошлар Гөрләшә дә серләшә... Минем иләс-миләс җаным Гөлләр белән сөйләшә.* Л.Лерон

2) *күч.* Үзара бик матур, ягымлы, дусларча сөйләшү. *Башта тынсызрак утырдым, агай-эне, «ыхым-ыхым» килеп, яшел суган каба, табактагы иткә үреләү, бәхетле гөрләшә иде.* М.Мәһдиев. *Капка төбе. Авыл төне айлы, якты. Кыз һәм егет гөрләштеләр төнгә чаклы.* Ф.Яруллин. *Бер-ике сәгатьтән хатын эшкә китәргә тиеш. Иркенләп гөрләшербез.* Ф.Баттал

3) *күч.* Тыныч, тату яшәү, эшләү. *Оныклары белән гөрләшеп чәй эчкәннән соң, Җәмилә җиңги, яңа гына күргәнгә салышып, Гөлназның күлмәк итәгеn кулына алды.* Г.Сәгыйров. *Шул ук төндә татулаштык асылкошым белән, яңадан гөрләшеп яши башладык.* Ф.Баттал. *Йә инде, сугыш башланганда гына биш кеше үзләренчә гөрләшеп яшиләр иде, бичаралар. Хәзер менә берсе дә юк.* З.Зәйнуллин

4) Шаулашу, күтәренке тавышлар белән кычкырып сөйләшү. *Сигез кеше менә дигән ресторан каршына барып төштеләр. Алар, гөрләшеп, көлешеп, эчкә керделәр.* С.Сүнчәләй. *Артистларның һәр әйткән сүзе саен, шыгрым тулы залда утырган тамашачы гөрләшеп көлә.* Ватаным Татарстан

**Гөрләшеп алу** Бераз вакыт бердән, дәррәү, бөтен кеше шаулашу, гөрләшү. *Гөрләшеп алды угызлар: – Хәбәр хактыр: Сувар бәгенең җәмәгате – угыз кызы, ул да безгә ирештерде... – туганнардан тапны юарга, арттырырга князь данын, байлыгы санын!* Р.Харис

**Гөрләшеп тору** Шау-гөр килү, бертуктаусыз гөрләшү

**Гөрләшеп утыру** *к.* **гөрләшеп тору**. *Шул гөрләшеп утырган төркем ягына күз төшергәч, Мәдинә дә түзми, елмаеп куя.* М.Хәсәнов. *Әйбәт кенә сөйләшеп, гөрләшеп утырганда, бу ике тол хатын тагын шулай, уйламаган җирдән генә ачуланышып китәчәк.* М.Вәлиев

**ГӨРЛЕ** *и.* Гөр-гөр уены, качышлы

**ГӨРЛИ-ГӨРЛИ** *рәв.* 1) Гөрелдәп, гөрләп, гөрләшеп (күгәрченнәр турында)

2) Бик ягымлы иттереп, бик тыйнак, матур, итагатьле (*сөйләшү*)

3) *күч.* Бик тату, бердәм (*эшләү, яшәү*). *Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли, шахталарда күмер чабабыз, ди торган идек без заманнарда.* Ә.Галиев

4) *күч.* Теләп, авырсынмыйча, җиңел, күңелле иттереп

**ГӨРНӘДИР** *и. рус сөйл. к.* **гренадер.** *Әни кайда? --- Кем үстерде соң бу гөрнәдир күк егетне?* М.Мәһдиев

**ГӨРНӘК** *и. бот.* Әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан, сары чәчәкләре чук чәчәк төркемендә булган кузаклы үлән үсемлек, эңер үләне; *русчасы:* **жерушник**

**ГӨРС** *иярт.* 1) Кинәт яңгыраган көчле тавыш, шауны белдерә. *Бөтен зал «гөрс» итеп көлеп җибәрде.* Ф.Баттал

2) Зур гәүдәле, зур күләмле объектларның авыр итеп, кинәт егылу, аву, килеп төшү рәвешен белдерә. *Һәм әле унбиш минут элек кенә Опера театры сәхнәсендә «Дон Карлос» партиясен башкарып, дуэльдә «гөрс» итеп егылган Рафаэль Сәхәбиев, елмаеп, банкет түрендә утырган Сибгат абый каршына килеп баса.* М.Мәһдиев

**ГӨРС-ГӨРС** *иярт.* 1) Көчле шартлау яки күк күкрәүдән барлыкка килгән көчле кабатлаулы тавышны белдерә. *Бакир кесәсеннән пистолет тартып чыгарды да гөрс-гөрс һавага атты.* Н.Гыйматдинова

2) Зур, авыр нәрсәне җиргә бертуктаусыз бәреп торганда чыккан тавышны белдерә. *Әлеге авыр итекләр бертуктаусыз идәннән ут чыгара... «Шап-шап-шап! Шоп-шоп-шоп! Гөрс-гөрс!»* Ф.Баттал. *Табанына, примир әйтик, нәстәяшии болгар олтаны салып... биек үкчә куеп, минсиңайтим... әфисәрләр итеге шикелле гөрс-гөрс итеп торсын...* Ә.Фәйзи. *Араннан гөрс-гөрс басып йөгереп чыккан айгырны күргәч, бияләр өерләре белән каршы якка чапты.* Идел

3) Дулкынланганда, курыкканда, ашыкканда һ.б.ш. очракларда йөрәкнең бик нык кагу рәвешен белдерә. *Йөрәкнең гөрс-гөрс тибүе басыла төшкәч, мин аякларымның туңа башлаганын сиздем.* Ә.Хәсәнов

**ГӨРСЕЛДӘТҮ** *ф.* 1) «Гөрс-гөрс» иткән тавышлар чыгару, яңгырату, гөрелдәтү. *Калын тавыш белән бөтен клубны гөрселдәтте...* Э.Касыймов. *Әмма чирек сәгать тә үтмәгәндер,*

*кемдер зур якның ишеген каерып ачты, нидер карады, эзләде дә, гөрселдәтеп, кире япты.* Казан утлары

2) Шартлату, утлы коралдан ату. *Килгән атлы кешеләр, кызыл тасмалылар, мылтыкларын күккә күтәреп, өч тапкыр гөрселдәтәләр.* Р.Сибат

**Гөрселдәтеп җибәрү** Кинәт кенә атып, шартлатып, сугып һ.б.ш. рәвешле «гөрс» иткән тавыш чыгару, яңгыратып кую

**Гөрселдәтеп тору** Әледән-әле көчле «гөрс-гөрс» иткән яңгыравык тавышлар чыгарып сугу, ату һ.б.ш.

**ГӨРСЕЛДӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Гөрс итү, шартлаганда, ауганда, күк күкрәгәндә көчле «гөрс» иткән тавыш чыгару. *Ату көчәйде, каядыр гөрселди, ухылдый, «шап» иттереп тә куя – без «ләхәүлә»не укып, тыңлап кына ятабыз.* Ә.Еники. *Әле дә гөрселдәп Тетрәнә һавалар: Сапёрлар җиремнән Үлемне алалар...* Ш.Галиев. *Кинәт, караңгы күкне чәрдәкләп, яшен яшьнәгәндәй булды, җир гөрселдәде, аяк астындагы дала бер якка таба шуышып китте дә томан арасына кереп юкка чыкты.* Р.Вәлиев

2) Зур, авыр, күләмле әйбер кинәт җиргә төшү, бөтен авырлыгы белән өстән килеп төшү. *Снаряд кыйпылчыгы Хисмәтнең тез башын чәлпәрәмә китерде, иптәшләре белән йөгереп барган Хисмәт нарат астындагы чокырга гөрселдәп барып төште.* М.Мәһдиев. *Кинәт икесе дә, гөрселдәп, идәнгә аудылар.* Ф.Баттал. *Манара, кайсы якка түним икән, диган сыман аз гына чайкалды да тракторга ияреп янтайды һәм, мәктәп түбәсенең бер өлешен шатыр-шотыр җимереп, гөрселдәп, җиргә ауды. Г.Тавлин*

3) Ике өлештән торган әйберләр бик тиз һәм кинәт каплану, ябылу, «шап» итеп бәрелү. *Домкратның очып төшүе булды – бүрәнә арасы, олы капкын булып, гөрселдәп ябылып та куйды.* К.Кәримов

4) Көчле тибү, каты кагу (йөрәк турында). *Гөрселдәсен йөрәк тибешләре, Шул кыядан ашсын күкләргә – күтәрелсен барлык хыялларым Күкләр белән бергә күкрәргә.* Зөлфәт

**2.** *и. мәгъ.* Шартлау, ату тавышы. *Анда-санда саңгырау гөрселдәүләр, өзек-өзек шартлаулар ишетелгәләп кала.* Ф.Хөсни. *Туп гөрселдәгән тавыш шул гөрселдәүдән үлүчегә ишетелми, диләр.* Ш.Хөсәенов. *Дөбер-шатыр... Ыгы-зыгы... Гөрселдәүләр... Авыр тынлык... Кеше түгел, җансыз ташның салкын тәне авыртырлык.* Р.Харис

**ГӨ́РС ИТҮ** *ф. к.* **гөрселдәү.** *Диңгез ягында «гөрс-гөрс» иткән шомлы тавышлар. Учение булгандыр, дип уйлый хәзер.* М.Мәһдиев

**ГӨРСТ** *иярт. к.* **гөрс**

**ГӨРСТ-ГӨРСТ** *иярт. сир. к.* **гөрс-гөрс**

**ГӨРТ** *иярт.* Кинәт гөрләп кабынып китү, эшли башлау рәвешен белдерә

**ГӨРУҺ** *и. фар. иск.* Төркем. *Вәзире күрде: шәһәрнең капкасыннан бер гөруһ гаскәр чыкды ---.* К.Насыйри. *Бу заманда алпавытлар золымыннан гаҗиз булган, --- Идел буйларында качып, талау белән мәшгуль булып йөргән гөруһ халык бар ---.* Г.Гобәйдуллин. *Шылтырый йомшак нәфис яфрак – гөруһы чеңләшә, Чеңләшә, башка-муенга сирпелеп, сүз эндәшә.* С.Сүнчәләй

**ГӨРУҺ-ГӨРУҺ** *рәв.* Төркем-төркем, төркемләп, төркем булып. *Капкадан карап күрде: сахра йөзендә гөруһ-гөруһ хисапсыз гаскәр шәһәргә килә.* К.Насыйри

**ГӨРҮНКӘ** *и. иск. к.* **гөрәнкә**. *--- йәнә бер гөрүнкә чәй, ун гөрүнкә бал вирәсез, мәгъзүр!* З.Бигиев

**ГӨСЛӘ** *и.* Күп кенә халыкларда таралган, чиертеп уйнала торган күп кыллы халык уен коралы. *Кубыз, сорнай, гөслә моңнарыннан Нечкәргәннәр күңел кыллары, Ә күзләргә рәсем булып төшкән Болгар сылуының сыннары.* Ш.Галиев. *Гөслә, бандура, кантеле кебек уен кораллары чиертеп уйнала. Гөслә – бик күп төрле халыкларның яраткан уен коралы. Татарларда да гөслә элек-электән үк кулланышта булган.* Казан утлары

**ГӨСЛӘЧЕ** *и.* Гөсләдә уйнау остасы, гөсләдә уйнаучы, гөслә партиясен башкаручы. *Хәзер гөсләчеләр бик сирәк*

**ГӨСТАХ** *с. фар. иск.* Әдәпсез, әрсез, дорфа. *Алтмыш егет, Түләкне гөстах күреп, пычакка эләккүтик булдылар.* Дастан

**ГӨФТЕГҮ** *и. фар. иск.* Әңгәмә, сөйләшеп утыру. *Һай, гомерләр... үтте китте... Кая китте ул заман! Кайда ул шәп һау-һалар! Гөфтегүләр бар иде...* Дәрдемәнд

**ГРАБ** *и.* Каенчалар семьялыгыннан, соры төстәге шома кәүсәле агач, күгагач. *Күлне каймалап алган биек тауларда чыршы, нарат, ак чыршы, граб, бүк агачлары һәм мәңге яшел тәбәнәк куаклар үсә.* А.Муранов

**ГРАВЁР** *и. фр.* 1) Гравёрлык белән шөгыльләнүче кеше, гравёрлау остасы

2) Агач, металл, сөяк, таш кебек өслекләрдә кисеп, уеп һ.б. ысуллар белән сурәтләр ясаучы сәнгатьче, рәссам

3) *күч. неол.* Ялган акча ясау остасы, фальшивомонетчик. *Әгәр дә «гравёр»ны эзләп тапса, Карлен гомерлеккә башкалада торып калачак, әкренләп шымчылык шөгылен киметә барачак ---.* Р.Мирхәйдәров

**ГРАВЁРЛА́У** *ф.* Махсус пычаклар белән кисеп яки чокып, ачы белән яндырып һ.б.ш. ысуллар белән агач, металл, таш кебек өслекләрдә рельефлы рәсем яки язу төшерү (мәс., басма өчен төрле калыплар ясаганда)

**ГРАВЁРЛЫК** *и.* Гравёр эше, гравёр булу

**ГРА́ВИЙ** *и. фр.* Төзелеш материалы буларак файдаланыла торган, берберсенә берекмәгән шома йомры вак ташлар рәвешендәге көпшәк утырма тау токымы

**ГРАВИРО́ВКА** *и. рус* Каты материал (металл, таш, агач, пыяла һ.б.ш.) өстенә рәсем, бизәк яки язу төшерү ысулы һәм шундый ысул белән төшерелгән рәсем, бизәк, язу һ.б.ш. *Билгеләп үтәргә кирәк: --- дискның урта өлешенә --- [мәгълүмат] гравировка ысулы белән язылып, андагы хәрефләр һәм саннар өстән буяу белән буялган булган.* Казан утлары

**ГРАВИТАЦИОН** *с.* Гравитациягә караган, шуның белән бәйле. *Хәрәкәтчән бетон измәсен җитештерү өчен, гравитацион туглагыч кулланыла, аңарда материал иркен төшеп туглана.* Төзү материаллары

**ГРАВИТА́ЦИЯ** *и. лат. физ.* Бөтендөнья тартылышы; материянең күк җисемнәреннән алып җирдәге һәр предметкача үзара тартылу күренеше. *--- атом бомбасы, водород, нейтрон, плазма, нейтрино, гравитация --- бомбалары җан иялəре яшәгән аралыкны тәмам бетерә торган көч түгелмени?!* Ә.Гаффар

**ГРАВЮРА** *и. фр.* 1) Сәнгатьтә графиканың гравёрлау ысулы белән ясалган, махсус калып-пластинадан төшерелгән рәсемнән гыйбарәт төре. *Иҗатының беренче чорында төрле жанрларда көч сынап караса да, тора-бара графика, бигрәк тә гравюра, рәссамны бөтенләе белән диярлек үз дөньясына алып керер китә.* Р.Вәлиев. *Ул [Е.В.Киселёва] – зур полотнолы графика өлкәсендә дә, калайга чүкеп рәсем ясау, политик плакат һәм гравюра эшләү, рәсем сәнгатенең башка төрләрендә дә зур уңышка ирешкән рәссам.* Казан утлары

2) Гравёрлау ысулы белән рәсем ясалган пластина

3) Гравёрланган пластинадан алынган басма сурәт. *Пугинның ул кибетендә, моннан тыш, төрле географик карталар, гравюралар, картиналар сатыла.* Җ.Тәрҗеманов. *--- ул чакта бит рәссам бу сюжетларны гравюра итеп эшләгән иде. Ә хәзер акварель белән язган.* М.Маликова. *--- Наталья янә үзенә ошаган картиналар, гравюралар каршысында озаклап туктапып торды, камин мичле зур залның галәмәт тәрәзәсе янына барып, --- урам һәм ишегалдын күзәтеп торды.* Р.Мирхәйдәров

**ГРАДА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Әйберләрне урнаштыруда эзлеклелек; бер нәрсәдән икенчесенә күчүдәге салмаклык, эзлеклелек

2) Бүленеш, объектларның билгеле сыйфатлары арту яки кимү принцибыннан чыгып төркемләү. *Җитмешенче елларда язучылар арасында, ничектер, бер бик нык градация уздырылды.* М.Мәһдиев

3) *әд.* Сүзләрне аларның мәгънә яки эмоциональ көче арту яки кимү тәртибендә урнаштырудан гыйбарәт стилистик алым. *Антитеза көчәю лирикадагы эмоциональ-психологик градациянең дә тирән үзгәрешенә китерде.* Г.Халит. *Шагыйрь иҗатын тикшерүче Х.Госман дөрес билгеләп үткәнчә, Такташ рефреннары градация тәртибендә, ягъни лирик хисләнең үсә-көчәя бару --- рәвешендә урнашалар.* Р.Мостафин

**ГРАДИ́РНЯ** *и. нем.* 1) *иск.* Тозлы суны кайнатып тоз алу өчен махсус җайланма. *Ә, градирнялар! Чыннан да, харап бит кыяфәтләре: биниһая зур чүлмәк рәвешендә үзләре, өсләреннән төрле тарафка пар бөркелә ---.* М.Маликова

2) *махс.* Промышленность предприятиеләрендә кайнар суны суыту җайланмасы. *Экономия максатыннан, градирнялар төзү һәм суны кабат файдалану кебек «вак-төякләр» искә алып торылмый.* Р.Мостафин. *Техника дөньясы кешене станок һәм моторлар шау-шуы белән, машина гүләүләре һәм дөбердәүләре, мич сөреме, насослар тукылдавы, градирня өстендәге пар болытлары, тузан һәм газ исләре белән каршы ала.* Химиянең киләчәге

**ГРА́ДУС** *и. лат.* 1) Әйләнәнең 1/360 өлешенә тигез булган, почмаклар һәм дугаларны үлчәү берәмлеге. *--- кайчандыр партия органнарында ялагайланып йөргән кайбер бәндәләр йөзләрен 180 градуска бордылар ---.* Г.Ахунов. *Либериянең башкаласы Монровияне үткәннән соң, безнең кораб кырык ике градуска көнчыгышка борылачак һәм, Көньяк Африка республикасы порты Кейптаунга турылап, Шәфкатьле Өмет борынына таба юл тотачак ---.* М.Юныс. *Астрономнар меридиан градусының озынлыгын үлчиләр.* Урта гасырлар тарихы

2) Температураны үлчәү берәмлеге (төрле шкалаларда төрле күрсәткечкә туры килә). *Ун градус салкынга шакыраеп каткан арыш икмәген, бүкәнгә куеп, балта белән ваттылар.* Г.Бәширов. *Төннәрен салкынлык уникe-унбиш градусларга җитте.* Э.Касыймов. *Монда уртача еллык температура 25 градустан да артып китә.* А.Муранов

3) Суның катылыгы, сыекчаларның үзлелеге, күкерт кислотасының концентрациясе һ.б.ш. зурлыкларның шартлы берәмлеге. *Энглер градусы. Боме градусы. Фаренгейт градусы*

4) Спиртлы, исерткеч эчемлекләрнең куәтлелеге. *Градус кирәк сезгә, сугып аяктан ега торган алкоголь дәһшәте кирәк.* М.Юныс. *Сез борчылмагыз, бу шәрабның градусы юк. Ширбәт мисалында гына.* И.Салахов. *Градусы бармы икән дип тәмләп караган идем, ни инде, «башланган эш – беткән эш» ди, төбенә төшкәнмен дә куйганмын.* Х.Мөдәррисова

**ГРА́ДУСЛАУ** *ф.* Градусларга бүлү, градуслы бүленешне шкалада чагылдыру

**Градуслап кую** Градуслы шкала төзеп, алдан әзерләү

**Градуслап тору** Даими рәвештә яки сөйләү моментында градусларга бүлү, шкалага салу эшен башкару

**Градуслап чыгу** Башыннан ахырына кадәр градуслы шкалага салу

**ГРА́ДУСЛЫ** *с.* 1) Билгеле градусы булган, билгеле градуска җиткән. *--- чирек литрлы шешәдә алтмыш градуслы виноград аракысы сатыла иде.* М.Мәһдиев. *Ә өстә, утыз градуслы суыкта, ягъни җиде җил уртасында, измә түшәп, кирпеч салалар ---.* Ф.Баттал. *Авышлыгы җитмеш-сиксән градуслы лаваларда эшләү үзе бер осталык сорый.* Ә.Галиев

2) Градуслар белән эш итә торган, үлчәү берәмлеге буларак градус хезмәт иткән. *Радианлы үлчәмнән градуслы үлчәмгә һәм градуслы үлчәмнән радианлы үлчәмгә күчүгә мисаллар карыйк.* Алгебра

3) Зур градуслы, куәтле, башка китә торган (исерткеч эчемлекләр турында)

4) *күч.* Көчле, куәтле. *Мускулларны ертып чыгар төсле, Энергия дулый беләктә, Үлчәнмәслек чиксез градуслы Ялкынлы дәрт кайный йөрәктә.* Р.Рахман

**ГРА́ДУСНИК** *и. рус* Тән температурасын үлчәү өчен медицина әсбабы, термометр. *Унбиш минут үткәч, градусникны алдылар.* М.Әмир. *Менә шәфкать туташы градусниклар куяр-*

*га керер, иртәнге ыгы-зыгы башланыр.* С.Сөләйманова. *Култык астына градусник кыстырды да, диванга утырып, вәсвәсә упкынына батты.* Ш.Хөсәенов

**ГРАЖДАН** *и. фр.* Бер дәүләттә даими яшәгән, шуның яклавыннан, хокукларыннан файдаланган, шуның алдындагы бурычларын үтәгән кеше. *Һәрбер граждан җәмәгать эшендә актив катнашырга бурычлы.* М.Сәлимов. *Согуд Гарәбстаны, нефтьтән кергән акча хисабына, үз иленең гражданнарына теләсә кайсы илдә югары белем алуда ярдәм итә.* Татарстан

**ГРАЖДАНИН** *и. рус* 1) *к.* **граждан**. *Мин бу илнең ватанпәрвәр Гражданины – Һәр җырымда раслап яшим менә шуны.* Ф.Яруллин

2) Ир-атка рәсмирәк төсмер белән мөрәҗәгать итү сүзе. *Гражданин начальник, зинһар, мине дөрес аңлагыз, гаепләштән булмасын.* М.Насыйбуллин. *Бүтән сүзегез юкмы? Утырыгыз, гражданин Гарифуллин ---.* Т.Миңнуллин

**ГРАЖДА́НКА** I *и. рус* 1) Граждан хатын-кыз. *Гражданка Сәгыйдуллина – минем сөйгән кызым.* Ш.Хөсәенов. *Әнә мотоцикл янындагы гражданканың әйберләрен урлагансыз, алар кайда?* Г.Тавлин

2) Хатын-кызга рәсми рәвештә мөрәҗәгать итү сүзе. *Гражданка, сез нишләп кеше квартирына керәсез?..* Х.Камалов. *– Бохара ул Урта Азиядә, гражданка, – диде карчык янында басып торган хәрби кеше.* М.Юныс. *Тик кенә утырыгыз, гражданка. Монда суд бара.* Т.Миңнуллин

**ГРАЖДА́НКА** II *и. рус сөйл.* Хәрби хезмәттән аермалы буларак гадәти тормыш, гадәти эш. *--- башка күп кенә солдатларга туктаусыз комачаулап торган «гражданка» җепләре аны бәйләмәде дә, тартмады да, ул бөтен барлыгын хәрби хезмәткә бирде.* И.Салахов

**ГРАЖДАНЛЫК** *и.* 1) Бер дәүләтнең гражданы булу хәле, подданныйлык, бер дәүләтнең гражданнарыннан исәпләнү. *Гражданлыкның иң мөһим күрсәткече – ватандарлык тойгысы.* И.Нуруллин

2) Гражданин булу белән бәйле хокуклар һәм бурычлар. *Икенче көнне гражданлык хәлләрен теркәү бүлегендә никях теркәлеп кайткач, Шәфигулла агай Сәрвине яңадан «катын» дип йөртә башлады.* Ф.Әмирхан. *Ә Наполеон төзегән гражданлык кодексы бүген дә гамәлдә икән: Франциядә, тагын кайсыдыр илләрдә.* З.Фәтхетдинов. *Мин үземнең гражданлык бурычымны үтәдем дип саныйм. Һәрберегез берәр ел шунда барып эшләп карагыз әле!* М.Маликова

3) *иск.* Армиягә, хәрби хезмәткә мөнәсәбәте булмаган гадәти тормыш

**ГРАЖДАННА́Р СУГЫШЫ** *и.* Бер дәүләт эчендә, бер халык арасында барган сугыш. *Әтисе аның – Бондюг эшчесе, алай гына да түгел, Бондюгта гражданнар сугышы чорында кызыл партизан булып йөргән кеше.* А.Расих. *Аннан соң озакламый гражданнар сугышы башланып китте, миңа, мылтык асып, сугышка китәргә туры килде.* Э.Касыймов

**ГРА́ЖДАННАРЧА** *рәв.* Гражданнарга хас булганча. *Татарстан матбугат эшчеләре оешмасы, Гыйльми үзәк, «Гажур», Дәүләт нәшрияты гражданнарча күмү ягында була.* Р.Әмирхан

**ГРАЖДА́Н СУГЫШЫ** *и. к.* **гражданнар сугышы**. *Граждан сугышының беренче айларында каһарманнарча сугышкан, армый-талмый эшләгән егет соңгы вакытларда әллә ничек рухсызланып киткән иде.* Ш.Усманов

**ГРАЖДАНЧЫЛЫК** *и.* Үз иленең патриоты, гражданы булу, шуның белән горурлану хисләрен чагылдыру үзенчәлеге; *русчасы* **гражданственность**

**ГРАММ** *и. гр.* Метрик системада бер куб сантиметр суның авырлыгына тигез үлчәү берәмлеге. *Колхозга эшкә йөргән кешеләргә өч йөз грамм ипи бирәләр.* Ф.Яруллин. *--- авыл казны күп асрый һәм кыш буе, бәрәңге шулпасына йөз грамм гына каз итен салып, шулпага тәм биреп, ачлыкны җиңеп яши иде...* М.Мәһдиев

**ГРАММА́ТИК** I *и. рус* Грамматика өлкәсендәге белгеч, грамматист

**ГРАММА́ТИК** II *с.* Грамматикага караган, грамматика белән бәйле. *--- ул дәфтәрләрдә әдәби текстларның телстиль үзенчәлеге, ягъни лексик һәм грамматик хосусиятләре дә иске татар әдәби теле нормаларыннан чыкмый ---.* М.Госман. *Әгәр үз телеңнең грамматик нормаларын җимереп сөйләшсәң, үз сүзеңнең дә чит булуы бар.* Х.Сарьян

**ГРАММА́ТИКА** *и. гр.* 1) Телнең төзелеше; аның формаль төзелешен тәшкил иткән барлык морфологик һәм синтаксик категорияләр һәм формалар системасы. *Сүз ясалышының фонетика, лексикология һәм грамматика (морфология һәм синтаксис) белән бәйләнешен аңлатыгыз.* Ф.Хисамова. *Достоевский, һәркемнең үз грамматикасы бар, дигән фикер әйтә.* Р.Низами

2) Телнең әлеге төзелешен, аның катлаулы оештырылышын, категорияләрен һәм аларның үзара бәйләнешен өйрәнә торган тел белеме тармагы. *Грамматика – телнең анатомиясе турындагы фән.* Ш.Галиев. *Әдип тере тел белән эш итә, шуңа грамматиканы өнәмидер.* Ш.Галиев. *Немец теле грамматикасын ятлауга киткән зая вакытларымны кызганып куйдым.* М.Юныс

3) Телнең төзелешен аңлаткан, кагыйдәләрен туплап биргән китап, дәреслек

**ГРАММАТИСТ** *и. рус. к.* **грамматик** I

**ГРАММЛАП** *рәв.* 1) Граммнар белән, граммнарга бүлеп. *Йөз граммлап он исәпли торган дүшәмбемени ул Сабантуйдан соң!* Г.Нәҗмиев

2) *күч.* Бик азлап, аз-аз гына; бик ваклап, бик җентекләп. *Граммлап сөт арттыру өчен көрәш барганда, кемнәрнеңдер җиңел юл белән генә алдынгы булып күренүләре – уен эшмени!..* М.Хәсәнов

**ГРАММЛЫ** *с.* 1) Бер грамм авырлыгындагы

2) Үзеннән алда килгән сан белән шул авырлыкны белдергән, гомумән, грамм белән үлчәнә торган. *Кимендә берничә дистә граммлы саф алтын җәйрәп ята иде.* Т.Галиуллин

**ГРАММОФОН** *и. гр.* Махсус пластинкадан тавыш чыгару, уйнату

өчен механик җайланма. --- *этажерка өстендә утырган граммофонны борып җибәреп, аңа кушылып җырларга, кечкенә малаен «Әпипә» көенә биетергә ярата торган иде.* М.Әмир. *Залда пышылдау китте, ә Каһир граммофонның тавыш чыгаргычын янга кайтарып, боргычын борды да тагын әйләндереп җибәрде һәм урындыгына утырды.* Ә.Гаффар. *Атаклы башкаручыларның граммофон язмаларын, бигрәк тә Ф.Шаляпин җырларын ул йотлыгып тыңлады, күңелендә музыканың иң кирәкле бер ихтыяҗга әверелә баруын тойды.* Казан утлары

**ГРА́МОТА** *и. гр.* 1) Укый-яза белү. *Ул аларга төрле эш кәгазьләре язып бирә ---. Чөнки тегеләрнең грамоталары юк.* Х.Камалов. *– Грамотаң бармы? – Гарәпчә, латинча бераз сукалыйм. Теге узган ел керткән хәрефләре белән булып ук бетми әле ---.* М.Мәһдиев. *Һәр мәктәп баласы укый-яза белмәүче әти-әнисенә, абыйсына яки апасына грамотага өйрәнергә булыша.* Г.Тавлин

2) Гомуми әзерлек, белем, мәгълүмат. *Кай җиреннән тотып ары дәвам итәргә аңышып бетмим әлегә үзем дә. Грамота җитенкерәми.* Р.Хәмид. *Укытсын, бер тиенгә эшләсен, но чтобы бөтен Акбалык баласына музыка грамотасы бирсен.* М.Мәһдиев. *Грамота мәсьәләсе Тимерханның иң авырткан урыннарыннан берсе иде.* Р.Вәлиев

3) Рәсми документ, кайбер эш кәгазьләренең гомуми исеме. --- *беренче Романовлар Әстерхан кебек татар калаларына язган грамоталарда татар морза вә князьләренә яхшы мөгамәлә кылырга, аларны «юмаларга» әмер итә.* Г.Гобәйдуллин. *Микаилны сайлап кул куйган грамотада вакыйган без татарча язылган шундый кешеләрнең кулларын күрәбез.* Г.Гобәйдуллин. *Тау ягы авылларында Иван Грозный тарафыннан бирелгән грамоталар саклануын дә искәртә.* Казан утлары

4) Күрсәткән хезмәтләрен тану, олылау, мактау билгесе итеп бирелә торган символик бүләк. *Биш-алты грамотасы гына бар. Яхшы күрсәткечләр өчен ---.* М.Мәһдиев. *Грамоталар, жетоннар, бүләкләр тапшырган тантана беткәннән соң, башкалар сизми дә калган бер вакыйга булып алды ---.* Р.Мирхәйдәров. *Ә грамотада мондый сүзләр язылган: «--- 1967 елның иң яхшы опера җырчысы булып танылган А.З.Аббасовка – кешеләргә бәхет китерүче дәртле башкару осталыгы өчен».* Казан утлары

**ГРА́МОТАЛЫ** *с.* **1.** 1) Укый-яза белгән, грамотасы (*1 мәгъ.*) булган. *Бу гомум әзерлекнең бер нигезен, һичшиксез, халыкның чагыштырмача киң грамоталы булуы, шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да гади халык вәкилләренең шактый өлеше укый-яза белүе тәэмин иткән иде.* М.Госман. *Авторны татарлар арасында укый-яза белүнең җәелүе сокландырмый, бу аны борчый гына, чөнки, аның фикеренчә, грамоталы татарлар чуваш, мари, удмурдларны «бозалар», мөселманлыкка тарталар.* Ә.Кәримуллин. *Димәк, Калькутта урамнарында кеше өчен хат язып тамак туйдыручылар һәм хат та язарлык грамоталы кешеләре булмаган гаиләләр бар.* М.Мәһдиев

2) Дөрес, таләпләргә туры китереп эшләнгән

3) Үзенең эшчәнлеге өлкәсендә әзерлеге, белеме, тәҗрибәсе зур булган. *Без инде моны безгә ярдәм итү дип уйлап шатланып куйдык: менә бит грамоталы командир белән эш итүе нинди рәхәт.* М.Мәһдиев. *Шул ук вакытта республикабызда сәләтле, грамоталы яшь иҗатчылар күп.* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Дөрес итеп, таләпләргә җавап бирерлек, төгәл. *Грамоталы төзелгән, мәгәр халык арасыннан аерым-аерым хәлдә табылган кулъязмаларның күпчелегендә начаррак почерк, чамалырак грамота белән язылган төрле характердагы өстәмә текстларны очратырга мөмкин.* М.Госман

**ГРА́МОТАЛЫЛЫК** *и.* Грамоталы булу дәрәҗәсе, белем дәрәҗәсе, белемлелек. *Грамоталылык ягына кереп китсәң – беттем, диген.* М.Мәһдиев. *Татарларда грамоталылыкның хәтта Көнбатыш Европа халыкларыннан да өстен торуы билгеле.* Ә.Кәримуллин

**ГРА́МОТАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Укый-яза белмәгән, грамотасы (*1 мәгъ.*) булмаган. *Грамотасыз көе, тутыккан калай кебек, бернигә дә ярамыйсың.* Х.Камалов

2) Белемсез, әзерлексез; надан

**2.** *рәв. мәгъ.* Хаталы, төгәлсезлекләр, ялгышлар җибәрелгән, дөрес түгел

**ГРА́МОТАСЫЗЛЫК** *и.* 1) Грамота түбән булу, грамота җитмәү күренеше, белемсезлек

2) Грамота җитмәү очрагы, тупас хата, ялгыш. *Радиокомитет булып радиокомитетта шундый грамотасызлык җибәргәч, нәрсә була инде ул?* М.Мәһдиев

3) *күч.* Артык гадилек, беркатлылык, ваемсызлык. *Ул «аучылар өе» нәрсә соң? Анда нишлиләр? Иван дәдә минем «грамотасызлыктан» бераз көлеп алды.* М.Мәһдиев

**ГРАНАТ** I *и. лат. бот. к.* **анар**. *Анармы? --- эче тулы кызыл төш инде, кыссаң, әчкелтем ширбәт сиптерә... Сездә ничек диләр соң әле аны? ... Гранат! Гранат диләр!* Р.Вәлиев

**ГРАНАТ** II *и. лат.* Шактый киң силикат-минераллар группасы; шуларның матур төсле һәм үтә күренмәлеләре – пироп, альмандин һ.б. асылташлардан санала

**ГРАНА́ТА** *и. нем.* < *лат.* 1) Цилиндр конуссыман корпус эченә тутырылган шартлаткыч матдәдән гыйбарәт, килеп бәрелгәч яки һавада шартлый торган артиллерия снаряды. *Фугаслы граната. Кыйпылчыклы граната. Бризант граната*

2) Дошманның тере көченә һәм сугышчан машиналарына каршы кул белән ыргытыла торган зур булмаган снаряд. *Әйе, теге якка сикереп төшеп, пулемётка граната ыргытыр өчен, тагын бер генә сулыш вакыт та җитәсе иде...* Г.Бәширов. *Шул секундта алар өстенә кул гранаталары очты.* Г.Нәбиуллин. *Кая мылтык кына! Машинада граната да йөртә әле ул.* З.Хөснияр

3) *спорт* Җиңел атлетикада ераклыкка яки бер ноктага төбәп ыргытыла торган снаряд, спорт әсбабы. --- *иңбашлары өзелеп төшәр хәлгә җиткәнче, граната ыргыттылар,*

*билләре торaташка әйләнгәнче, парашют сүттеләр, парашют җыйдылар.* Р.Вәлиев

**ГРАНАТОМЁТ** *и. рус* Гранаталар (*1 мәгъ.*) белән ата торган, үзе зур булмаган, әмма шактый зур үтерү көченә ия сугыш коралы, артиллерия тубы. *Миргазизовка гранатомёт та кирәк түгел, ул болай да гранатомёттан ераграк ата ---.* Р.Вәлиев. *– Менә бусы – кул гранатомёты, аны менә болай итеп иңбашыңа куясың да менә шушылай атасың ---, – дип аңлатырга кереште ул.* М.Маликова

**ГРАНАТОМЁТЧЫ** *и.* Гранатомёттан атучы

**ГРАНД** *и. лат. иск.* 1) Испаниядә югары дәрәҗә дворян титулы; гомумән, аристократ, аксөяк

2) *күч.* Бер өлкәдә бик зур хезмәтләр күрсәткән, уңышларга ирешкән, бик югары авторитетка ия шәхес. *Опера сәнгатенең грандлары*

**ГРАНДИОЗ** *с. ит.* Бик зур; зурлыгы, көче, тәэсире ягыннан тиңдәше булмаган; көчле тәэсир калдыра торган, галибанә. *Предприятиебезнең перспектив планнары, реаль резервлары производстводагы кадрлардан, коллективтан контактлы темп, активлык сорыйлар, грандиоз проблемага әверелеп баралар.* Ф.Баттал. *Тиздән, бик тиздән без грандиоз ачышларның шаһиты булачакбыз.* М.Хөсәенов. *Хыялларның чынбарлыкка әверелеп, грандиоз планнарның тормышка аша баруын шушы авыл мисалында да күреп була.* А.Гыйләҗев

**ГРАНДИОЗЛЫК** *и.* Масштаблылык, грандиоз булу. *Грандиозлыгы белән шаккатыру*

**ГРАНИТ** *и. лат.* **1.** Кварц, кыр шпаты һәм слюдадан торган, тирән катламнарда яткан иң киң таралган кристаллик тау токымы; кыйммәтле төзелеш материалы. *Нинди көч һәм осталык бу гранитны шулай мәһабәт һәм тантаналы итеп торгызып, көзгедәй шомартып куя алды икән?* И.Салахов. *Аккургаш рудалары, тирә-яктагы гранит ташлары – гранитоидлар да шул вулканнар эшчәнлегенең нәтиҗәсе.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Асылы гранит булган; граниттан ясалган. *Гранит ташлар астыннан күз яше кебек саф һәм кар суы төсле салкын чишмәләр сирпеп чыгып, көне-төне йокламыйча, чылтырап агалар, көмеш ялкыннар булып текә ярлардан сикерәләр.* И.Салахов. *Бу – күлдән биек булып калкып торган һәм өсте бик шәп нарат урманы белән капланган гранит утрау.* А.Муранов

**ГРАНИТЛЫ** *с.* Эчендә, составында гранит булган; гранит белән тышланган яки бизәлгән

**ГРА́НКА** *и. рус полигр.* Типографиядә җыелып, битләр яки полосалар рәвешенә китерелмәгән набор һәм шул набордан алынган басма копия, күчерелмә. *--- корректордан соң гранканы да, полосаны да үзең укыйсың, ди---.* И.Гази. *– Менә бу мәкаләне унбиш юлга кыскартырга кирәк, – дип, өстәлгә ике гранка ташлады ул.* М.Маликова

**ГРАН-ПРИ** *и. фр.* Фестивальдә, конкурста иң югары бүләк. *Җыр буенча ярыш уздырылса, Җир шарында барлык кошларга, булыр иде сиңа Гран-при кошларара конкурсларда!* Р.Әхмәтҗан. *Жюри бертавыштан фестивальнең Гран-приен Марат Фәйрушинга бирергә булды.* Сөембикә. *--- Гөлнара анда [Афиныда], каршылык белән 3000 метрга йөгереп, дөнья рекорды куйды һәм Гран-при алды ---.* Сөембикә

**ГРАНТ** *и. ингл.* Фән, мәгариф һ.б.ш. өлкәләрдәге эшчәнлекне өстәмә рәвештә – дотация, субсидия, стипендияләр формасында финанслау ысулы. *Үткән елны 90 еллык юбилеен билгеләп үткән мәктәп бүген заманча җиһазланган өр-яңа бинада урнашкан, күптән түгел бер миллион сумлык грант откannar ---.* Сөембикә

**ГРА́НУЛА** *и. лат.* 1) Билгеле шартларда онсыман, тузансыман матдәләр укмашып хасил була торган бөртек, төерчек. *Ашлама кисәкчекләрен, гранулаларын пластмасса сүрүләр белән каплаячаклар. Ул чагында --- үсемлекләр үзләренең химик азыкларын берьюлы түгел, ә акрынлап кына алачаклар.* Химиянең киләчәге. *Ашламаларны органик-минераль гранулалар яки катнашмалар рәвешендә куллану – тагын да нәтиҗәлерәк.* Яшелчәчелек

2) *астр.* Кояшны телескоптан күзәткәндә яки фотографияләрдә күренә торган бөртекләр

**ГРА́НУЛАЛАУ** *ф.* Гранула хәленә китерү, гранулаларга әйләндерү. *Онсыман катнашманы гранулалау*

**ГРА́НУЛАЛАШТЫРУ** *ф. к.* **гранулалау**

**ГРАНУЛЁМА** *и. лат. мед.* Тукыманың төерсыман, калкулыксыман үсеп китүеннән гыйбарәт авыру

**ГРАНУЛЯ́ЦИЯ** *и. нем.* 1) Гранулалау процессы, гранулаларга әйләнү-әйләндерү процессы

2) *астр.* Кояшны, зурайтып, фотографиягә төшергәндә яки телескоптан караганда күренә торган гранулалар челтәре

3) *мед.* Яралар төзәлгәндә, аны тутыра торган яшь, кан тамырларына һәм күзәнәк элементларына бай тукыма

**ГРАФ** *и. нем.* 1) Борынгы Франк дәүләтендә һәм Англиядә король вәкиле, чиновнигы, судья; соңрак зур феодал. *Хлодвиг зур илнең һәр өлкәсенә үзенең якын кешеләре арасыннан идарәчеләр – графлар билгеләп куя.* Урта гасырлар тарихы

2) Россиядә Пётр I тарафыннан кертелгән, нәселдән-нәселгә күчә торган дворян титулы. *Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ.* Г.Тукай. *Энҗе муенсалар, алтын балдаклар, сабы асылташлар белән бизәлгән хәнҗәрләр тулы сандыкны Болгин атлы графның бакчачысы алмагач төбеннән казып чыгара.* Р.Мостафин. *Граф һәм графинялар өчен нәрсә инде ул, кара, бу татарларда да язучылар бар микәнни, дип уйлаганнардыр, бәлки.* Р.Мөхәммәдиев

**ГРАФА** *и. гр.* Контора кенәгәләрендә һ.б.ш. ике вертикаль сызык белән чикләнгән, бүленгән багана, полоса. *Аны линейка белән графаларга бүлде дә иртәгә эшләячәк эшләргә план төзеде.* М.Әмир. *Вәсимә апа язып куйды, паспортның бүтән графаларын*

*тутырып, эшен бетергәч, Габделхәйгә якынрак килергә, кул куярга кушты...* Н.Фәттах. *«Кандидатның исем-фамилиясе» дигән юлны таләпчән кул әлегә буш калдырган, ләкин алдагы графаларда кәгазьне тишәрдәй куәт белән усал, калын тезгән.* В.Имамов

**ГРАФАЛА́У** *ф.* Графаларга аеру, бүлү, графалар сызу. *Дәфтәр битен графалау. Саннарны графалап язу*

**ГРАФАЛЫ** *с.* Графалары булган, графаларга бүленгән

**ГРА́ФИК** I *и. гр.* 1) Төрле процессларның, күренешләрнең сан бәйләнешләрен чагылдыра торган сызым, диаграмма. – *Ә менә бу нәрсә? – Кемдер стенадагы графикка төртеп күрсәтте.* М.Хәсәнов. *Ул графикка карагандa, диңгез суының, бер халәттә генә булмыйча, әле саегып, әле артып, гел тирбәлеп торуы ачык күренә.* А.Муранов. *Үткән юлны һәм тизлекне графикта күрсәтергә.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

2) Җитештерү, транспорт һ.б.ш. өлкәләрдә нормалар һәм үтәлеш вакыты төгәл күрсәтелгән эш планы. *Ашлык әзерләүнең алдагы бишкөнлек графигы нибары унөч процентка үтәлде.* Ф.Садриев. *Ярдәмгә килергә әзер булганнарны теркәп, график төзеделәр.* Р.Мостафин. *Нәҗип, дулкынлануын басарга тырышып, Моратовның теге бәхетсез көнне кайсы сменада эшләгәнлеген белеште. Графикта акка кара белән язылган иде: икенче сменада!* З.Фәтхетдинов

**ГРА́ФИК** II *и. рус* Графика (*1 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче рәссам. *Соңрак [Мөхәммәд Идрисев] график һәм хәреф кисүче буларак танылa һәм ахырда басмаханәнең хуҗасы булып кала.* А.Тимергалин. *Бүлмәгә, торбалап төргән кәгазьләр күтәреп, кайчандыр Зуфирә белән бергә художество училищесын тәмамлаган, хәзер абруйлы график һәм ярыйсы гына картиналар авторы Илдус Зәйнуллин килеп керде.* М.Маликова. *Ш.Мәрҗани образын нәкышьче, сынчы, график буларак иҗат итүдә Татарстан сәнгать осталары берникадәр файдалы эш башкардылар ---.* Фән һәм тел

**ГРА́ФИК** III *с.* 1) Графика (*2 мәгъ.*) белән бәйле, графикага мөнәсәбәтле

2) Сызымнар, диаграммалар белән бәйле, шуларны төзүгә мөнәсәбәтле. *Координаталар методы функцияләрне график юл белән тикшерү һәм тигезләмәләрне график юл белән чишүдә киң кулланыла башлый.* Алгебра. *Алгебраик тигезләмәләрне график юл белән чишү координаталар методына нигезләнә.* Югары математика нигезләре

**ГРА́ФИКА** *и. гр.* 1) *сәнг.* Нигездә буяусыз, сызыклар һәм штрихлар белән генә эш итә торган рәсем сәнгате төре. *Ул [Е.В.Киселёва] – зур полотноны графика өлкәсендә дә, калайга чүкеп рәсем ясау, политик плакат һәм гравюра эшләү, рәсем сәнгатенең башка төрләрендә дә зур уңышка ирешкән рәссам.* Казан утлары. *Нәрсә бу? Китап графикасы казанышларын иҗади куллануммы? Ата-бабалардан калган ювелирлык нәфислегенә тартылумы?* Казан утлары. *Полиграфия, графика белән шөгыльләнүче дизайнерлар да бар.* Мәдәни җомга

2) Шундый ысул белән иҗат ителгән сәнгать әсәрләре. *Әдәбият, белешмәләр, Әрмәнстан хакында бюллетеньнәр һәм, әлбәттә инде, картиналар, акварельләр, графика, натюрмортлар да бар монда.* Идел

3) *лингв.* Язу, алфавит; бер телнең авазларын белдерә торган барлык хәрефләр. *--- мең елдан артык мәдәниятебезгә хезмәт иткән әлифбабызны «Коръән хәрефе», «реакцион графика» дип игълан иттеләр.* Ә.Кәримуллин. *Болар мәгълүм инде: латинга күчү һәм шундук, ун еллар узар-узмас, рус графикасына күчү.* М.Мәһдиев. *Укучыларны латин графикасына мөмкин кадәр тизрәк күнектерү максатында эшләнгән бу эш мактауга һәм хуплауга лаек.* Казан утлары

4) *лингв.* Язу турындагы фәннең хәрефләр һәм авазлар арасындагы мөнәсәбәтне өйрәнә торган тармагы

**ГРА́ФИКЛЫ** *с.* Графигы булган; график тәртибендә оештырылган, графикка буйсындырылган. – *Графиклы эштә ул, бу елларда вакыты юк, – диде яшь хатын, сөрмәле күзләреннән нур сирпеп.* Ф.Баттал

**ГРАФИН** *и. ит.* Су, шәраб һ.б. эчемлекләр салу өчен озын тар муенлы пыяла яки хрусталь савыт. *Фәнияр калтыранган куллары белән графинга үрелде.* Ф.Яруллин. *Гомәр графиннан су агызып эчте дә, чак кына тамак кырып (килештерә дә инде), тагын тезеп китте ---.* Г.Нәбиуллин. *Ул маңгаена төшкән чал чәчләрен сыпырып куйды, графиннан агызып су эчте һәм арыган, хәлсез тавыш белән чыгышын дәвам итте ---.* Ф.Садриев

**ГРАФИ́НЯ** *и. рус* Графлык дәрәҗәсенә, титулына ия хатын-кыз. *Парижда аны тагын бер тетрәнү көтә иде. Графиня Шарлотта дөнья куйган...* Н.Гыйматдинова. *Графиня Шереметева белән ул чактагы очрашуыбыз хакында, дөресен әйтергә кирәк, мин инде оныткан идем.* Р.Мөхәммәдиев. *Безнең көннәрдә графиня Форлидан башка беркемгә дә ныгытмаларның файдасы булмады.* Н.Макиавелли

**ГРАФИТ** *и. гр.* **1.** Саф углеродның Җир кабыгындагы иң тотрыклы кристаллик төре булган кара яки коңгырт төстәге минерал; утка чыдам детальләр, машиналар майлау өчен катнашмалар, графитлы буяу, карандаш үзәге һ.б. ясау өчен файдаланыла. *Двигательгә куяр алдыннан, астар өслеге ике яктан да графит белән сылана.* Тракторлар һәм автомобильләр. *Графит, селен, мышьяк һәм сөрмә формасындагы углерод кебек кайбер башка табигый элементлар да – полимерлар.* Химиянең киләчәге. *Тактаның рәсемле урынын бик юка гына графит катлавы белән каплыйлар, шуның аркасында аның ул ягы электр тогын үткәрә торган була.* Физика курсы

**2.** *с. мәгъ.* Шул минералдан эшләнгән

**ГРАФИТЛА́У** *ф.* Нәрсәнеңдер өстен графит белән каплау

**Графитлап кую** Нәрсәнең дә булса өстен тиз арада графит катламы белән каплату

**Графитлап тору** Әледән-әле, регуляр графитлау

**Графитлап чыгу** Нинди дә булса әйбернең өстен графит белән каплатып бетерү

**ГРАФИТЛЫ** *с.* 1) Составында графит булган. *Карап үтелгән барлык графитлы чуеннар да төзелештә кулланыла.* Төзү материаллары

2) Графиттан ясалган. *Беренче карашка графитлы карандаштан да гади нәрсә юк кебек.* Шәһри Казан

**ГРАФЛЫК** *и.* 1) Граф дәрәҗәсе, граф титулы, граф булу

2) Урта гасырларда граф тарафыннан идарә ителә торган административ-территориаль бүленеш берәмлеге; бер графның биләмәләре. *Саксония графлыкларга бүленә. Графлар итеп аксөяк франклар һәм саксларның юлбашчылары билгеләнә.* Урта гасырлар тарихы

3) Кайбер дәүләтләрдә (*Англия, АКШ һ.б.*) административ-территориаль берәмлек. *Копролитларның --- иң мул ятмалары Англиянең Йоркшир графлыгында һәм ГФРда табылган.* Кызыклы физиология. *Бөекбританиянең Бунингемпшир графлыгында 1854 елда урманчы Лесер тапкан агачта үскән гөмбә 127×38 сантиметр зурлыкта була.* Кызыклар дөньясында

**ГРАФОЛОГ** *и. рус* Графология, язуларны өйрәнү белән шөгыльләнүче белгеч

**ГРАФОЛО́ГИК** *с.* Графология белән бәйле, графологиягә нигезләнгән

**ГРАФОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Кешенең холык-фигылен, сәләтен аның язу рәвеше, почерк үзенчәлекләренә бәйләп өйрәнә торган фән

**ГРАФОМАН** *и. гр.* Графоманиягә бирелгән кеше, бик язарга ярата торган кеше. *Һәрвакыттагыча, эшнең игечиге юк, бер сәгатьтән редколегия, ә син монда чираттагы графоман – язу чире кагылган берәүнең кульязмасын ничек итеп ипләбрәк кире кагарга икән дип борсаланып утыр.* Р.Мостафин. *--- яхшыны – яманнан, талантны графоманнан аера торган критерийлар да буталып бетте.* Ф.Миңнуллин

**ГРАФОМА́НИЯ** *и. гр.* Таланты булмауга карамастан, язучылык белән шөгыльләнү, язарга ярату һәм бик күп язу күренеше

**ГРАФФИ́ТИ** *и. ит.* 1) Борынгы биналарның диварларына, төрле савытларга һ.б. язылган, эчтәлеге ягыннан көнкүреш характерындагы язулар яки рәсемнәр

2) Көнбатышта официаль пропагандага каршы ризасызлык формасы буларак барлыкка килгән, соңрак яшьләр арасында киң таралган стеналарга язу һәм рәсем ясау шөгыле; шундый язулар һәм рәсемнәр

**ГРАЦИОЗ** *с. ит. к.* **грацияле**

**ГРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Борынгы Рим мифологиясендә өч гүзәллек алиһәсенең гомуми исеме. *Әнә Вика, Люда, Липа – курсыбызның өч грациясе.* М.Юныс

2) Гәүдә торышындагы, хәрәкәтләрдәге гүзәллек, җиңеллек, табигыйлек, нәзакәтлек

**ГРА́ЦИЯЛЕ** *с.* Матур хәрәкәтле, пластикалы, гүзәл. *Кеш туктаусыз хәрәкәттә, күз иярмәстәй ялт та йолт, җиңел һәм грацияле, яшендәй җитез һәм шул ук вакытта ашык-пошык та түгел.* Кызыклар дөньясында. *Ханым һәм туташларны шәрык көйләре, матур, грацияле хәрәкәтләр үзенә җәлеп итә бугай.* Сөембикә

**ГРА́ЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Грацияле булу

**ГРЕ́ЙДЕР** *и. ингл. мах.* Юллар салуда, юл кырыйларын тигезләү һ.б.ш. өчен хезмәт итә торган, шул эшләрне башкару өчен махсус пычагы булган җир казу машинасы. *Ниһаять, грейдер әрәмәлекнең уртасына җитәрәк, бер кулына кәләпүшен, икенче кулына гәҗитләрен йомарлап тоткан Дәүләтша абзый юл читендәге чирәмлеккә чыгып ауды.* Ф.Шәфигуллин

**ГРЕ́ЙДЕРЧЫ** *и.* Грейдерда эшләүче. *Грейдерчы Анатолий Мокин ике метрлап югары күтәртелгән юлның ян-якларын тигезләп йөри.* Ватаным Татарстан

**ГРЕЙПФРУТ** *и. ингл.* Рутачалар семьялыгыннан, формасы һәм тәме белән әфлисунга охшаш әчкелтем җимеш бирә торган субтропик җимеш агачы һәм шул агачның җимеше. *Тын океан яр буеның көньяк өлешендә (Калифорниянең сугарыла торган җирләрендә) апельсиннар, лимоннар, грейпфрутлар (лимон белән апельсин гибриды), дөге, шикәр чөгендере игелә.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Лимон, грейпфрут, розмарин (бәбрия) исләре күңелгә ятышлы.* Мәдәни җомга

**ГРЕК** *и.* Грециядә яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе, вәкиле. *Мин яшәгән чакта да бу шәһәрдә инде ассимиляция аша үтеп өлгергән урыс телле (Одесса шивәсе) төрекләр, греклар, яһүдләр, французлар, итальяннар, арнаутлар (румыннар), болгарлар һәм урыслашып беткән татарлар очрый иде.* М.Юныс. *Грекларның яраткан Аккош йолдызлыгын гарәпләрнең тавыкка охшатуы кызык түгелмени?* Н.Әхмәдиев. *Ә аргонавтлар походы хакында моннан ике мең ярым ел элек яшәгән грек шагыйре Һомер язып калдырган.* А.Муранов

**ГРЕ́К УТЫ** *и. тар.* Урта гасыр сугышларында кулланылган, су сипкәч тә сүнмәүчән, нефть һәм сумаладан торган яндыргыч катнашма. *Корбанга дип – тереклеккә, каршысындагыга дип, киләчәккә таш аткан... ук аткан... грек уты... дары... бомба... напалм... атом... Тукта, уем, артык алга чаптың...* Р.Харис

**ГРЕ́КЧА** *рәв.* **1.** 1) Грек телендә. *«Бион» грекча «тереклек ячейкасы» дигәнне аңлата.* Кызыклы ихтиология

**2.** *и. мәгъ.* Грек теле. *Грекчаны әйбәт белү*

**ГРЕ́ЛКА** *и. рус* Тәннең аерым өлешен җылыту өчен кулланыла торган әсбап, җылыткыч

**ГРЕНАДЕР** *и. фр.* 1) XVI–XIX гасырларда граната ыргытырга махсус өйрәтелгән солдат

2) Күп кенә армияләрдә: сайланма частьләрдә хезмәт итүче солдат яки офицер. *--- ул бүлмәне йозак белән бикләп пичәтләгәннәр һәм, аны саклау өчен, ике гренадер куйганнар.* Кызыклы физика

3) *күч.* Озын буйлы, нык гәүдәле таза кеше. *Гренадерлар сыман зур һәм дәүләр, Юлбарыслар кебек көчлеләр, «Кузгал!» дигән сигнал булу белән Ыргылырга әзер эшчеләр ---.* Х.Туфан. *Гренадер кебек тап-таза булуына карамастан, нигә бер җирдә дә ныгытып*

*торып хезмәт итми?* Ш.Рәкыйпов. *Килеп керделәр берзаман ак халатлы гренадер кебек ике егет ---.* Идел

**ГРЕЧА́НКА** *и. рус* Грек хатыны, грек кызы. *«Кызым» ди ул сөеп гречанканы, Якын күреп сине «улым» ди.* Г.Хуҗиев

**ГРИ́ВНА** *и. рус* 1) Борынгы Русьта акча һәм авырлык берәмлеге булып хезмәт иткән ярты кадак авырлыктагы көмеш коелмасы. *Иң күбе көмеш рус гривналары һәм гарәп дирһәмнәре булган.* Р.Мостафин. *Гомумән, Россиядә мәчене үтергән яки урлаган кешегә өч гривна (өч ат яки утыз сарык бәясе) штраф салынган.* Кызыклар дөньясында

2) Борынгы Русьта көмеш яки алтын пластина формасындагы муенса

3) Украинаның 100 грошка тигез төп акча берәмлеге

**ГРИЛЬЯЖ** *и. фр.* Кыздырылган, шикәрләнгән чикләвек төше; шундый чикләвекле конфет сорты

**ГРИМ** *и. фр.* 1) Башкара торган роленә туры китереп, актёрның йөзен махсус буяулар, сакал-мыек һ.б.ш. ярдәмендә үзгәртү сәнгате; үзгәртелгән, буялган йөз. *Бик еш, гримыңны да сөртмичә, миңа, минем яныма, кочагыма ашыга идең.* Г.Кутуй. *Аның гримда реквизит костюмнан төшкән фотолары миндә әле дә саклана.* А.Расих

2) Йөзне, чырайны үзгәртү өчен, башлыча актёрлар тарафыннан кулланыла торган махсус косметика чаралары: майлы төсле карандашлар, буяулар һ.б.ш. *Менә ул көзге каршына утырды, көлсу чәч алкаларын ике яктан шома яңаклары тирәсенә җәйлап куйды һәм, грим тартмасын ачып, болай да кара керфекләрен нәни щётка белән каралтырга кереште.* М.Маликова. *И Евгений Матвеев рәхәтләнде инде безнең Генсекны уйнап! Ходай койган да куйган аны Брежнев итеп, бернинди грим саласы юк.* М.Мәһдиев

**ГРИМА́СА** *и. фр.* Юри кыланып үзгәртелгән яки ирексездән үзгәргән йөз, чырай

**ГРИМЁР** *и. фр.* Актёрларны гримлау, грим әйберләре әзерләү белән шөгыльләнүче театр хезмәткәре, грим белгече

**ГРИМЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **гримлау**. --- *гүя бернинди вакыт үтмәгән, ә тегермән, кино төшерер өчен, фанердан ясалган булган да, хәзер декорацияләрне алыштырып кына куйганнар, ә без – бүтәнчә гримланган артистлар ---.* Ә.Гаффар

2) *кайт. юн.* Үз-үзеңне гримлау. *Хәйдәр, өстенә кара камзул, башына хәтфә кәләпүшен киеп, Хәлил булып гримланды да борчылган хәлдә сәхнә артына чыкты, дулкынланып, уен барышын күзәтә башлады.* Г.Бәширов

**ГРИМЛА́У** *ф.* Грим салу, махсус чаралар ярдәмендә йөзне, чырайны үзгәртү

**ГРИМЛЫ** *с.* Гримланган, грим салынган. *Без, гримлы битләрне юып, төзәнеп-таранып, өстәл әйләнә урнаштык.* Х.Сарьян

**ГРИПП** *и. фр.* Сулыш юлларының ялкынсынуы, югары температура, баш авыртуы һ.б. күп кенә симптомнар белән характерлана торган вируслы авыру. --- *Гонконг гриппының беренче тапкыр безнең илгә килеп кергән вакыты – 1957 елның октябрь башы иде, медицина кешеләре югалып, каушап калган...* М.Мәһдиев. *Барып җитә, ә ишеккә Язу куелган: грипп! Ничек кермичә китәсең, Авылдан тикле килеп?!* Ф.Яруллин. *Сазанакның эфир мае препаратын (элеоптен) ринитан һәм гриптан кулланалар.* Урман аптекасы

**ГРИППЛА́У** *ф. сөйл.* Грипп белән авыру

**Гриплап алу** Кыска гына вакытка грипплау

**Гриплап йөрү** Күптәннән бирле, озак грипплау

**Гриплап тору** Әледән-әле, гел яки хәзер грипплау

**ГРИФ** I *и. нем.* 1) Кылыч һ.б.ш. салкын коралларның кул белән тота торган өлеше, сабы

2) Кыллы уен коралларының өске өлешендә («муенында») ябыштырылган, кылларны басып, тавыш югарылыгын үзгәртү өчен хезмәт итә торган агач пластинка. *Аның медиаторы бервакытта да сөртенми, һәрвакыт тигез тавыш чыгарып тора. Шуның белән бергә ул мандолина грифының теләсә кайсы җирендә уйный ---.* Г.Ахунов

3) Штанганың дисклар кидерелә торган корыч күчәре, тотып күтәрә торган өлеше

**ГРИФ** II *и. фр.* 1) Имза яки башка берәр текст язылган мөһер; штемпель һәм шул мөһернең документка төшерелгән тамгасы

2) Документта яки китапта аннан файдалану тәртибен билгели торган язу. --- *журнал «Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз башкарма комитеты белән Халык Комиссарлары советы нәшере» дигән гриф астында чыга.* М.Мәһдиев. *Машинкада басылган юллар, ә алар «аерым игътибар сорый» грифында бирелгән иде, прокурорны утка салгандай итте.* Р.Мирхәйдәров. *Сугыш бетеп, озак еллар үткәч, моңа кадәр «совершенно секретно» грифы белән сакланган шактый документларны өйрәнү мөмкинлеге туды.* М.Әхмәтҗанов

**ГРИФ** III *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә: бөркет башлы, канатлы арыслан

2) Карчыгалар семьялыгының бер төркеменә караган, башлыча үләксә белән туклана һәм табигый санитар ролен үти, Көньяк Европа, Африка һәм Көньяк Азиядә яши торган эре кошлар ассемьялыгы. *Бу тауларда барслар, тау кәҗәләре, селәүсен, аю, бүреләр яши: кеше менә алмастай текә кыяларда мәгърур грифлар оя ясый, аларның канатлары өчәр метрга җитә.* А.Муранов. *Биек нарат башларында гриф дигән бик зур ерткыч кошлар оя кора ---.* Дөньяда ниләр бар. *Инде аэропортка килеп җитәргә берничә чакрым гына калгач, очкычка гриф ташлана.* Кызыклар дөньясында

**ГРИ́ФЕЛЬ** *и. нем.* Аспид тактага язу өчен, балчыклы сланецтан ясалган таш каләм. *Менә ул, одеялын читкә этеп, урыныннан сикереп торды, киенде һәм грифелен, аспид тактасын, көндез яшереп куйган шәм кисәген алды.* Җ.Тәрҗеманов

**ГРИФТА́Р БУЛУ** *ф. гар. иск.* 1) Туры килү, очрау, юлыгу; дучар

булу. *Әй бер Ходай, ошбу йиргә сәнең хөкемең берлә грифтар булдым ---.* Дастан. *Мәрхүм атам ни беләдер, мәхәббәт – бер бәладер, кем грифтар булмайын белмәс, дигәннәр.* Ф.Халиди

2) Эләгү, кемнең дә булса кулына төшү, ирексез булу, тоткынлыкка төшү. *Шул мескен, атасыз, анасыз калган, дошман кулына грифтар булган, баласыннан – җөда, иреннән мәхрүм булган Зөләйханең эшләрен асан кыл!* М.Галәү

**ГРИФТА́Р ИТҮ** *ф. гар. иск.* Дучар итү, кулына төшерү

**ГРИФТА́Р КЫЛУ** *ф. гар. иск. к.* **грифтар итү**

**ГРОБ** *и. рус сөйл. к.* **табут**. *Салкын җилгә каршы гроб бара. Гробны укытучылар күтәргән.* М.Мәһдиев. *Язгы шарлавык сыман халык агымы веноклар һәм Тукташ гробы артыннан агыла да агыла...* Җ.Фәйзи

**ГРОССМЕ́ЙСТЕР** *и. нем.* 1) Шахматта, сирәгрәк башка спорт төрләрендә, иң югары дәрәҗә осталыкны белдерә торган исем һәм шул исемне йөртүче кеше. *Гроссмейстер килде!* А.Гыйләҗев. *--- атаклы А.Алехин, такталарга карамыйча гына, ягъни гади итеп әйтсәк «сукыр» килеш, берүзе илле кешегә каршы шахмат уйный ---. Гроссмейстер Михаил Таль да утыз тактада «сукыр» килеш уйный.* Кызыклар дөньясында

2) Урта гасырларда католикларда дини-рыцарьлек ордены башлыгы, бөек магистр

**ГРОТЕСК** *и. фр.* **1.** 1) Яңарыш чорында борынгы Рим корылмаларында табылган бизәкләргә иярү буларак барлыкка килгән, үрелгән үсемлекләр, хайваннар һ.б. сурәтләреннән гыйбарәт бизәк

2) Әдәбиятта, театрда һ.б. сәнгатьтә кешеләрне, әйберләрне, вакыйгаларны артык күпертеп, фантастик, ямьсез яки комик хәлдә күрсәтү алымы

3) *мах.* Типография шрифтының бер төре

**2.** *с. мәгъ.* Гротеск **1.** (*1 мәгъ.*) алымы белән башкарылган, эчтәлеге гротесктан гыйбарәт булган. *Верховный Советка сайлау күренеше, җыелышта Сталинның телгә багышланган кигабын өйрәнүләр, сатирик алымнар белән, вакыты-вакыты белән гротеск дәрәҗәдә язылганнар.* А.Гыйләҗев. *Бу патриотизм Батыргали образында сатирик планда гротеск алымда бирелә.* Татар әдәбияты тарихы

**ГРО́Т-МАЧТА** *и. голл.* Җилкәнле суднода борыннан икенче, иң зур, иң биек мачта. *Өченче штурман портнадзордан диңгезгә чыгарга рөхсәт алып кайту белән, матрос Деримедведь грот-мачтага лоцман чакыра торган флагны күтәрде.* М.Юныс. *1913 елда яшен «Клоринда» фрегатын суга, грот-мачта, йомычкага әйләнеп, һавага оча ---.* Кызыклар дөньясында

**ГРУЗИН** *и.* Грузиядә яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Грузин егете Давид белән без иң соңыннан кузгалдык.* Г.Нәбиуллин. *Карт, ихтимал, урыстыр, яшь егет белән кыз – әрмәннәр, калганнары – грузиннар яки осетиннар.* Р.Мирхәйдәров. *Ван дәүләтенең тарихи әһәмияте гаять зур: ул әрмән һәм грузин халыкларын формалаштыра...* А.Муранов

**ГРУЗИ́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Грузиннарга хас булганча, алар рәвешле, грузиннар кебек

2) Грузин телендә

**2.** *и. мәгъ.* Грузин телендә сөйләшү рәвеше, грузин теле. *Җитмәсә, Давид ачуы килгәндә сиптерә торган грузинчасы белән малайның шиген арттырды.* Г.Нәбиуллин

**ГРУЗОВИК** *и. рус сөйл.* Йөк машинасы. *Көчле грузовиклар ташырлар кешеләрнең бик күп кирәген, Шуңа чаклы безнең эшләрнең атлар тотачаклар үзәген.* М.Гафури. *Далада февраль чабып йөри, һәм әнә шундый коры җилле салкында, ачык грузовик өстендә ике йөз илле километр чамасы җир килгәннән соң, --- бер хуторда кунарга туктадык.* Ф.Хөсни. *Күршеңә кайткан грузовикны алып киттеңме?* Х.Вахит

**ГРУ́ЗЧИК** *и. рус* Йөк төяү һәм бушату эшен башкаручы эшче. *Яр кырында басып торган ике-өч грузчик белән --- ике кызылармеец кына алар артыннан карап калдылар.* Ш.Усманов. *Грузчик булып йөргәндә, буш араларда шадра Вафа бокс серләрен өйрәткәләгән иде ---.* А.Гыйләҗев. *Берсе – --- Гөлзифа. Икенчесе – колхозыбыз амбарының грузчигы Нәфисә.* Ф.Баттал

**ГРУНТ** *и. нем.* **1.** 1) Җирнең өске катлавы, балчык, туфрак. *Кар һәм яңгыр сулары агач тамырларында, йомшак туфракта тоткарлана, шуннан грунт аларны үзенә суырып ала.* Кызыклар дөньясында. *Грунт сулары якын булган участокларга пионнарны утыртырга ярамый ---.* Йорт эшләре. *Грунт сулары югары торган юеш урыннарда кәбестә начар үсә һәм уңышны аз бирә.* Яшелчәчелек

2) Елга, диңгез һ.б.ш. төбе. *Яңа гына чәчелгән уылдыклар грунтка ябышалар, – бу вакыт алар агым суда яхшырак үсәләр.* Кызыклы ихтиология

3) *махс.* Буяласы яки рәсем ясаласы өслекне – агачны, киндерне – әзерләгәндә салына торган буяуның яки махсус составның беренче катламы, җирлек

**2.** *с. мәгъ.* Түшәлмәгән, бернинди түшәлмәсе дә булмаган, асфальт, таш һ.б.ш. салынмаган, йөреп тыгызланган җирдән генә гыйбарәт. *Каршы яктагы тезмә таулар итәгенә таба чокыр-чакырлы грунт юл төшеп китә иде.* Казан утлары. *Грунт юл, бу колхоз җиренә килеп керү белән, биек итеп күтәртелгән олы юлга әверелде.* Казан утлары

**ГРУНТЛА́У** *ф.* Өслекне беренче кат буяу, беренче состав белән каплау, грунт салу. *Гадәттә, өслекне дымны йотуын киметү өчен грунтлыйлар ---.* Йорт эшләре

**Грунтлап кую** Грунт салу эшен алдан бетерү

**ГРУ́ППА** *и. нем.* 1) Бергә тупланган җанлы яки җансыз предметлар җыелмасы, төркем

2) Уртак мәнфәгатьләр, эшчәнлек һ.б.ш. нигезендә берләшкән кешеләр. *--- рус әдәбиятында да «солтангалиевчелек» белән тиңләштерерлек «переверзевчылык», «воронскичылык» кебек группалар һәм агымнар эзләп табыла.* Ф.Галиуллин

3) Зур хәрби берләшмә. *Немецларның һәм финнарның берләшкән төньяк*

*группа гаскәрләренең төп бурычы – Киров магистрален кисү һәм Мурманск шәһәрен алу иде.* Г. Әпсәләмов. --- *безнең часть Опильи шәһәре тирәсендә дошман гаскәрләренең зур группасын камалышта калдырды һәм анлары юк итте.* Р.Вәлиев

4) Нәрсәнең дә булса категориясе, классы, разряды; билгеле үзлек ягыннан бүленеше; төркем. *Группа туры килсә дә, организм чит канны кабул итеп җиткерми.* Х.Камалов. *Ә миннән кан алмадылар. Группаң туры килми, диләр.* Р.Вәлиев

5) Бергә уку, махсус шөгыльләнү, өйрәнү өчен берләшкән кешеләр тупланмасы; төркем. *Безнең группада тагы Хәйруллин дигән егет тә бар.* А.Расих. *Балалар бакчасындагы татар группасын ябачаклар* ---. Н.Фәттах. *Гөлчәчәгемне бирәүгә дә алыштырмадым. Группа кызлары «Однолюб» дип кушамат тактылар.* З.Хөснияр

**ГРУ́ППАДАШ** *и.* Бер-берсенә карата бер группада булган кешеләр. --- *аның белән бергә укучы группадашлары да аны санга сукмыйлар иде.* Х.Камалов

**ГРУ́ППАЛАУ** *ф.* Группаларга, төркемнәргә бүлү, аеру; группалар итеп оештыру. *Һәр көнне группалап фронтка яки кайберәүләрне (сирәк кенә) Көнчыгышка җибәрәләр.* М.Җәлил

**Группалап кую** Группаларга бүленгән хәлгә китерү

**Группалап тору** Группалау эшен башкару

**Группалап чыгу** Барысын да башыннан алып ахырына кадәр группаларга бүлү

**ГРУ́ППАЛАШУ** *ф.* Группаларга оешу, группа-группа булып төркемләшү

**Группалаша башлау** Группалашырга тотыну

**Группалашып бетү** Группалашуны тәмамлау

**ГРУ́ППАЛЫ** *с.* 1) Группага хас; группа белән башкарыла торган. *Группалы уеннар*

2) Нindидер бер группаган караган. *Өченче группалы кан*

**ГРУ́ППАЧЫЛЫК** *и.* Бер коллективта мәнфәгатьләре, эш алымнары, максатлары белән аерылып торган төрле төркемнәр булу күренеше, таркаулык, бердәмлек булмау

**ГРУППИРО́ВКА** *и.* 1) *к.* **группа** (*2 мәгъ.*)

2) Зур хәрби берләшмә. *Чолганышта калган Паулюс группировкасының, капитуляциягә килмәгәнлектән, безнең гаскәрләр тарафыннан тәмам тар-мар ителүе турындагы хәбәрне без юлда ишеттек.* Ф.Хөсни. *Ул арада безнең зур көчләр дә килеп җитә, һәм дошманның кичү районындагы группировкасы тәмам тар-мар ителә.* Казан утлары

3) *неол.* Җинаятьчел оешма, оештырылган җинаятьчеләр төркеме

**ГРУҺ** *и. фар. иск.* Төркем. *к.ш.ук* **гөруһ**. – *Бетсен эшче-крестьяннарның канын түгә торган сугыш! – дип кычкырганнарын сизми дә калдылар һәм шушы теләкләрен --- сөйләрлек бер груһның чыгуын көтәргә башладылар.* М.Гафури. *Теләсә кайда күмсеннәр, кыямәт көнне Аллаһы Тәгалә мөэминнәр груһыннан аермасын.* Г.Исхакый

**ГРУҺ-ГРУҺ** *рәв.* Төркем-төркем, төркемләнеп. *Мәмләкәтнең олуглары, задәляннары вә гайреләр, груһ-груһ булып килеп, падишаһка бәйгать бирәләр вә баш оралар һәм тәбрик итәләр иде.* Дастан

**ГРУҺЛАНУ** *ф. иск.* Төркем булып оешу, төркемнәргә җыелу, туплану, төркем-төркем булып тору

**ГРУ́ША** *и.* 1) Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, эре, сусыл, итләч, түгәрәк озынча җимешләр бирә торган агач һәм шуның җимеше. *Монда бодай, кукуруз, кузаклы үсемлекләр, яшелчә уңа; груша, алма, өрек зур уңыш бирә.* А.Муранов. *Тешләре сынган таракка охшап калган койманың теге ягындагы груша агачыннан яшелле-көрәнле йомшак җимешләр коела.* Ә.Гаффар. *Алмагачына, чиясенә, грушасына күмелеп утырсын ул авыл өе – их!* Р.Төхфәтуллин

2) Боксчылар күнекмә алу өчен файдалана торган, тыгыз итеп төелгән күн капчыктан гыйбарәт спорт әсбабы. *Митя көндезгечә үлеп йоклый, тавышлар ишетми, торгач, ике сәгать гимнастика ясый, гер күтәрә, коридор буйлап чаба, иелә, бөгелә, бүлмә почмагына эленгән бокс грушасын төя, тәпәли, соңыннан бозлы су белән юына.* А.Гыйләҗев

**ГРУ́ШАСЫМАН** *с.* Груша формасында булган, груша шикелле. *Конвертёр ысулы грушасыман зур конвертёрда (савытта) эретелгән чуенга кысылган һава өрдерүгә нигезләнә.* Төзү материаллары

**ГРУШО́ВКА** *и. рус* Җәен өлгерә торган татлы алма сорты. *Әлеге романтик исемле сортның авторы Геннадий Осипов әйтүенә караганда, бу төр алмагач «Грушовка» сортына караганда күбрәк уңыш бирә, алмалары татлы һәм озак саклана.* Безнең гәҗит

**ГУА́НО** *и. исп. а. х.* 1) Ашлама итеп кулланыла торган диңгез кошлары тизәге. *Гуано ятмалары*

2) Балык тоту һәм җәнлек аулау кәсебе калдыкларыннан эшләнгән ашлама

**ГУАҺ** *и. гар. иск.* Шаһит, танык

**ГУАҺЛАНДЫРУ** *ф. иск.* 1) Күргән, белгән кешене шаһитлыкка чакыру, дөресләтү, раслату

2) Раслату, дөрес булуына рәсми шаһитлык алу

3) Белдерү, алдан әйтеп кую; берәр нәрсә эшләргә сүз бирүенә, алынуына шаһит ясау

**ГУАҺЛА́У** *ф. иск.* Раслау, дөресләү, шаһит булу

**ГУАҺЛЫК** *и. иск.* Шаһитлык, шаһит булу; таныклык, дәлил. *Һәммәсен табарга, юнәлтергә, җәйларга, майларга, --- күз буярга, ялган гауаһлык итәргә туры килә иде.* А.Гыйләҗев

**ГУАҺНАМӘ** *и. гар.-фар.* Таныклык; шаһитның язмача күрсәтмәләре. --- *аны оештыруда катнашкан кайбер кешеләрнең гуаһнамәләре сакланып калган.* Мәдәни җомга

**ГУАШЬ** *и. ит.* 1) Рәсем ясау өчен, суда изелгән, үтәли күренми торган буяу. *Рәсем мәктәбендә укучы оныгыма мин элекке СССРның ничәмә-ничә каласыннан эзләп тә таба алмаган акварель буяуларны, пастельне һәм гуашьны бик җиңел генә таба алдым.* Г.Ахунов. --- *кара гуашьның тоник*

*өслегенә ак буяулар белән гаять нечкә штрихлар ясап, Хаҗиәхмәтов детальләрне эшкәртеп чыккан.* Казан утлары

2) Шундый буяулар белән ясалган рәсем

**ГУБ-** *рус* Кушма сүзләрдә: «губернага бәйле» мәгънәсендәге беренче кисәк: *губком, губисполком*

**ГУБЕ́РНА** *и. рус* Элек Россиядә административ-территориаль берәмлек. *Ул бүген этап белән Пермь губернасына озатылды ---.* Г.Ибраһимов. *Губернаның мәгариф бүлегеннән ике тапкыр хат яздылар инде.* Э.Касыймов

**ГУБЕРНА́ТОР** *и. лат.* 1) Губерна белән идарә итүче дәүләт эшлеклесе, губерна башлыгы. *Губернатор килгәндә, Янында – баш казагы; Бу эшләрнең мисалы – Гүя тәмуг газабы.* Бәет. *--- татар иҗтимагый тормышының юнәлешен һәм үзенчәлекләрен шактый яхшы белүче кеше губернаторга түбәндәгечә җавап бирә: «Соңгы вакытларда татар интеллигенциясенең идеаллары – Европа культурасын үзләштерү ---».* Ә.Кәримуллин

2) Бөекбритания, Франция һ.б. дәүләтләрнең колонияләрендә иң югары чиновник, колония башлыгы

3) АКШ һәм башка дәүләтләрдә сайланып куелган штат башлыгы

4) Хәзерге мәгълүмат чараларында өлкә һәм крайларның хакимият башлыкларын атау сүзе

**ГУБЕРНА́ТОРЛЫК** *и.* Губернатор урыны, губернатор дәрәҗәсе, аның хезмәте

**ГУБИСПОЛКОМ** *и. рус* Губерна башкарма комитеты. *Кичә губисполком утырышында булган булсаң, болай сорашып тормас идең.* Ш.Усманов

**ГУ́БКА** *и.* 1) Болытсыманнар семьялыгына караган, суда бер урында берегеп яши торган күп күзәнәкле умырткасыз хайван

2) Әлеге хайванның скелетыннан гыйбарәт яки синтетик юл белән ясалган, суны тиз сеңдерүчән һәм юу-юыну өчен файдаланыла торган йомшак, тишекле материал

**ГУВЕРНА́НТКА** *и. рус* Балаларга өй, гаилә шартларында белем һәм тәрбия бирү өчен ялланган педагог, тәрбияче

**ГУВЕРНЁР** *и. фр.* Балаларны өйдә карау өчен ялланган тәрбияче ир кеше. *Гувернёр булып эшкә урнашу*

**ГУД** *и. гар. к.* **гут.** *Гуд, ганбәр, мишекләр төтәтсеннәр.* К.Гали. *--- ничә җарияләр Дәһханәнең сачыны гуд, ганбәр илә тарап --- Дәһханә ничә мең наз илә боргаланып, фәйтунга утырып, уен бакчасына китте.* Ф.Хамиди

**ГУДОК** *и. рус* 1) Сызгырган тавыш чыгару өчен механик җайланма. *Гудок тавышы яңгырады.* К.Нәҗми

2) Әлеге җайланмадан чыккан сызгыру яки сирена тавышы. *Яңа рифмалар бар, корыч турында, гудок турында сүзләр бар, ә менә кешеләр, аларның күңелне ышандыра торган үзара мөнәсәбәтләре юк.* Ф.Хөсни. *Егетләр ничектер уңайсыз хәлдә утырганда, тыштан машина гудок биргәне ишетелде.* Х.Камалов

3) Телефон трубкасында ишетелгән, аппаратның эш хәлендә булуын белдергән сигналлар. *Аллаяров телефон трубкасын алып номер җыйды, теге яктан озын гудоклар ишетелде.* С.Сөләйманова

**ГУДРОН** *и. фр.* Нефтьтән бензинлы, керосинлы һәм майлы фракцияләрне аерганнан соң кала торган, битумнар җитештерү өчен чимал хезмәтен үтәгән кара сумаласыман үзле масса. *– Күрәбез. Бу хәтле гудронны автоген белән эретеп төшерсәң генә, юкса кырып кына бетерә торган түгел! – дип, яңадан көлеп алды Хан.* З.Фәйзи

**ГУДРОНЛА́У** *ф.* Гудрон белән эшкәртү, гудрон сеңдерү, каплау, җәю

**Гудронлап чыгу** Барысын да гудрон белән эшкәртү

**ГУҖ** *и.* **1.** 1) *миф.* Ислам дине буенча ахырзаманда дөньядагы барлык ризыкны ашап, суны эчеп бетерәчәк җан иясе

2) *күч.* Бик күп ашаучы, туймас тамак, комагай кеше, бирән

3) Гомумән комсыз кеше, карун, туймас күз, ач күз. *Илла гуҗ да син, Тәкый абзый. Булдыра алсаң, урманы белән күтәреп апкитәр иең.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* 1) Күп ашый торган, ашамсак. *Балыкны бигрәк тә пеликаннар шәп аулый. Алар --- балыкны сайга куып китерәләр дә, аскы казналарындагы капчыкларына тутырып, үзләренең гуҗ балаларына ташыйлар.* А.Муранов

2) Комсыз, ач күзле

◊ **Гуҗ корсак** *к.* **гуҗ 1.** (*2 мәгъ.*)

**ГУҖЛЫК** *и.* 1) Артык күп ашау гадәте. *--- Лукулл сугыштагы батырлыгы һәм даһи гаскәр башлыгы булуы белән генә түгел, бәлки, зиннәттә яшәргә яратуы һәм гуҗлыгы белән күбрәк дан казанган.* Кызыклы физиология

2) Комсызлык. *Гуҗлык түгел бу – эш хакы, имештер, ат җиккән килеш, урманнан буш арба белән кайт!* Ф.Хөсни. *Рәсәй бу... Туймас гуҗлык калыбы: Чуртан йоткан маймыч төсле Илнең күпме халыгы.* И.Гыйләҗев

**ГУЛЯШ** *и. венгр.* Томалап пешерелгән кисәкле сыер ите һәм кызыл борыч белән ясалган соустан торган ашамлык. *Повар аш пешерә, гуляш йә биточки ясый.* Х.Камалов. *«Гуляш» дип биргән нәрсәләре гел ярыдан гына тора.* Ф.Яруллин

**ГУМАН** *с. к.* **гуманлы**. *– Алексей кебек кеше юк инде ул, юк!.. – Бик гуман иде, бик гуман.* Х.Камалов. *Законнар артык гуман бездә, Якуб ---.* М.Хәбибуллин

**ГУМАНИЗМ** *и. лат.* 1) Яңарыш дәверендә (XIV–XVI йөзләр) Көнбатыш Европада чиркәүнең рухи өстенлегенә каршы, антик чордагы кешелеклелек һәм матурлык идеалларын кайтаруга юнәлдерелгән иҗтимагый һәм әдәби хәрәкәт. *Югыйсә ул бит кичә генә безгә уналтынчы йөз әдәбияты, гуманизм турында ничек дәртләнеп сөйләгән иде.* Р.Вәлиев

2) Кешелеклелек, кеше сөючәнлек. *Гуманизм рухында тәрбияләнгән, бездә ору-сугу кебек җәзаларның булуы мөмкин түгел дигән кагыйдәне үзләштергән кешегә бу җитә калды.* А.Расих. *Кемнәрдер көрәшә, кемнәрдер йөгерешә, кемнәрдер, Сабантуйның халык гуманизмыннан килгән тирән эчтәлеген аңламыйча, авыш*

*колга башына элеп куйган әтәчне җәзалаудан тәм таба, ихахайлап көлә ---.* М.Мәһдиев. --- *имеш, сугыш корбаннар сорый --- Алай булмый ул, туганнар. Дөньяда әле «гуманизм», ягъни «игелеклелек» дигән нәрсә дә бар.* Идел

**ГУМАНИСТ** *и. рус* **1.** 1) Гуманизм (*1 мәгъ.*) тарафдары, гуманизм карашларында торучы. *Сәлам сиңа, бөек гуманист Сервантес, даһи художниклар Веласкес, Гойя иле!* М.Мәһдиев. *Гуманист язучылар табигатькә дан җырлыйлар, аның матурлыгына сокланалар.* Урта гасырлар тарихы

2) Гуманлылык, кешелеклелек күрсәтүче кеше. *Барыннан да элек ул – гуманист, кешене һәм аның матурлыгын ярата.* Х.Госман. *Бу фани дөньяда син, соңгы гуманист дәрәҗәсенә төшеп, Лев Толстойлар кебек кыланмакчы буласыңмы?* Т.Галиуллин. *Кырымда бөек кырым татар гуманисты һәм мәгърифәтчесе Исмәгыйль бәк Гаспринскийның 140 еллыгы киң билгеләп үтелә.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ. к.* **гуманлы**. --- *ул үз вакытында Троицкиның иң алдынгы, кешелекле, гуманист укытучыларыннан берсе булган абруйлы Лотфулла учитель улы иде.* А.Расих. *Бу алымны гуманист Сәяр Яруллович хупламас.* Т.Галиуллин

**ГУМАНИ́СТИК** *с.* Гуманизм белән сугарылган, кешелеклелек белдергән, гуманлы. *Әйе, гуманистик сәнгать һәрвакытта да интернациональ була ---.* М.Мәһдиев. *Кабатланмас салмак-сабыр музыкаль аһәң, йөрәккә үтәрлек поэтик моң һәм, иң мөһиме, чын гуманистик рух белән сугарылган «Йосыф китабы» ---.* М.Госман. *Китаптагы иң гуманистик, якты өметләр белән сугарылган һәм шул ук вакытта дәһшәтле хәлләрне онытмаска чакырган шигырьләрнең берсе бу.* Казан утлары

**ГУМАНИСТЛЫК** *и. к.* **гуманлылык**. --- *Р.Фәхреддинов, нигездә, шушы реалистик һәм тарихи позициядә торды, абстракт рәвештә булса да, киң карашлы гуманистлык сыйфатын җуймады.* М.Госманов

**ГУМАНИТАР** *с. кит.* 1) Кеше шәхесенә, хокукларына, мәнфәгатьләренә караган

2) Табигый һәм техник фәннәрдән аермалы буларак, җәмгыятьне, халыкның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнә торган. *Гуманитар фәннәр өлкәсендә милли кадрлар әзерләүдә дә Казан университетының роле зур булды.* Х.Яруллин. *Ул укыган гуманитар факультетта фәлсәфә, социология, психология фәнен тирәнтен өйрәнәләр.* З.Хөснияр

**ГУМАНИТА́РИЙ** *и. фр. кит.* Гуманитар фәннәр белгече. *Китаптагы «Кала-тау өстендә» дип исемләнгән повесть гуманитарийлар белән прагматик технократлар арасындагы күптәнге бәхәсне дәвам иттерә.* Р.Шәрипов. *Төгәл фән студентлары белән гуманитарийлар очрашып, бер фәнне яклап, икенчесен тәнкыйтьли башлау белән, фикер йөртү әллә нинди катлаулы проблемаларга бәреп керә иде.* М.Юныс. *Гуманитарийлар хисчәнрәктер, табигыйрәктер, кайнарރактыр сыман тоела иде миңа.* Казан утлары

**ГУМАНИТАРЛАШТЫРУ** *ф.* Гуманитар фәннәрнең йогынтысын арттыру. *Мәгарифне гуманитарлаштыру*

**ГУМАНЛЫ** *с.* Гуман, кешелекле, кеше сөючән, кешеләргә карата мәрхәмәтле, миһербанлы. *Әйе, галим кеше бөек җанлы, гуманлы булырга тиеш.* Х.Мәһдиев. *Медицинаны ихтирам итәм. Сезне дә иң гуманлы профессия кешесе булганыгыз өчен ихтирам итәм.* М.Мәһдиев. *Белгәнегезчә, безнең җәмгыятьтә, гуманлы җәмгыятьтә, кешене кимсетү, аның хокукларын кысу, сәламәтлегенә зыян китерү закон белән тыела.* Ф.Баттал

**ГУМАНЛЫК** *и. к.* **гуманлылык**

**ГУМАНЛЫЛЫК** *ис.* Кешелеклелек, кеше сөючәнлек, гуманизм. *Алдау, хәйлә белән ышандырып, Боерык арты боерык үтәтеп, Кем казанган халык ихтирамын, Ялган гуманлылык күрсәтеп?!* Э.Мөэминова

**ГУММИАРА́БИК** *и. лат.* Акациянең кайбер төрләре бүлеп чыгара, һавада катып китә торган үтәкүренмәле сумала (элек җилем буларак файдаланылган). *Суда 50 грамм тимер купоросын, 50 грамм гуммиарабикны яки чия җилемен эретеп, 1 грамм креозот яки карбол кислотасы кушалар.* Робинзон эзләреннән

**ГУМАНО́ИД** *и. лат.* Уфологиядә: Җирдә яки башка планеталарда тереклек итүче кешегә охшаш җан иясе

**ГУ́МУС** *и. лат.* Үсемлек һәм тереклек калдыклары таркалып барлыкка килә һәм туфракның физик сыйфатларын яхшырта торган органик матдә; черемә. *Кара туфрак гумуска бай*

**ГУМУСЛАШУ** *и. махс.* Органик калдыкларның микроорганизмнар, дым һәм атмосфера кислороды катнашлыгында таркалып, гумуска әйләнү процессы

**ГУ́МУСЛЫ** *с.* Гумуска бай, гумусы булган. *Ара-тирә сланецлы һәм комсыл туфраклар да очрый. Туфрак уртача гумуслы.* И.Салахов

**ГУ́ППИ** *и. нем. зоол.* Пецилияләр семьялыгына караган, чыгышы белән Кариб диңгезе утрауларыннан булган, балаларын терелэй тудыра торган, хәрәкәтчән вак аквариум балыгы. *Ата гуппи бик купшы була. Табигать аларга буяуларын кызганмаган.* Кызыклы ихтиология

**ГУРА́МИ** *и. малая зоол.* Макроподлар семьялыгының алабугалар отрядына караган, Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия төче суларында таралган, аквариумда һәм күлләрдә үрчетелә торган балык. *Соңрак галимнәр гурами, макропод һәм сугышчан балыкларның лабиринт аппараты барлыгын ачалар.* Кызыклы ихтиология. --- *гурами, урыныннан кузгалмыйча гына, бер мыекчасы белән – алдагы әйберләрне, ә икенчесе белән арттагы әйберләрне капшап карый ала.* Кызыклы ихтиология

**ГУРМАН** *и. фр.* Тәмле ризыклардан ләззәт алучы кеше, тәмле ризыкны аера белүче, аңлаучы, кадерен белүче; тәмлетамак. *Күзем чәй савытына төште. Нәзберек инглиз гурманнары гына эчә торган фузьян чәе.* М.Юныс

**ГУРОН** *и.* Төньяк Америка индеецларының бер кабиләсе, шул кабилә кешесе. *Бу исемне аңа виандотлар кабиләсе индеецлары – гуроннар биргән.* А.Муранов

**ГУРТ** *и. пол. сөйл.* 1) Суярга, сатырга, куып алып китәргә әзерләп тупланган мал-туар көтүе, соңрак гомумән эре терлек көтүе. *Себерләрдән качып килгән чакта Очрадым сарык гуртына ---.* Бәет. *Гуртоправ белешеп тора: әгәр инде Бөгелмәдә, төрле яклардан көтү килеп тулу сәбәпле, чират икән, гуртны куарга ашыкмый ---.* М.Гали

2) *күч.* Төркем, шактый күп кеше. *Синнән башка да монда синең кебекләр гурты-гурты белән ---.* Р.Хәмид. *Имештер, бу Җир йөзенең аркылысы-буена, өстеннән астына кадәр һәммә урыннарда меңләгән вә йөзләгән дию гуртлары кавеме булып, алар кешеләргә һәрдаим зыян эшләргә генә торалар икән.* Ф.Яхин

**ГУРТЧЫ** *и.* Гурт куып баручы; эре терлек көтүен караучы; көтүче

**ГУСАР** *и. венгр. тар.* 1) Дошман тылында сугыш хәрәкәтләре алып бару, разведка ясау һ.б.ш. өчен махсус җиңел кавалерия, атлы гаскәр төре. *Моннан өч-дүрт көн элек мин гусар полкының икенче эскадроны яныннан үтеп барганда, ул ярты эскадронны өйрәтә иде.* А.Таһиров

2) Шул гаскәрдә хезмәт итүче кеше

**ГУ́СЕНИЦА** *и. рус* Шарнирлы бәйләнешле сегментлардан, буыннардан торган, трактор, танк һ.б.ш. машиналарда көпчәк урынына хезмәт итә торган тимер яки резин тасма. *Тагын шаян сүзләр, моторлар гөрелдәве, гусеницаларның җир тырнап уралулары ишетелә ---.* И.Салахов. *Гусеницалар, шомарганлыктан, шыгырдап келтери иде.* Г.Кашапов. *Немец танкы гусеницалары белән кар туздырып туктап кала.* Казан утлары

**ГУ́СЕНИЦАЛЫ** *с. тех.* Гусеница ярдәмендә эшли торган. *Әлеге тракторны файдалану һәм карау чыгымнары гусеницалы тракторларга караганда 30 процентка кимрәк.* Татарстан яшьләре

**ГУСТЕРА** *и. рус* Карплар семьялыгыннан, 35 сантиметрга кадәр озынлыктагы Көнчыгыш Европа елга-күлләрендә очрый торган төче су балыгы. *--- Себер елгаларының суы хәзергегә караганда шактый җылы булган һәм анда подуст, җитез балык (быстрянка) һәм густера балыклары яшәгән.* Кызыклы ихтиология. *Тышкы кыяфәте белән густера корбан балыкка охшаган.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ГУТ** *и. гар. иск.* 1) Агач

2) Хуш исле матдә алу яки төтәсләү өчен файдаланыла торган тропик агач төре

3) Кыллы уен коралының бер төре, лютня

4) Алоэ гөле

**ГУТАЛИН** *и. лат. иск.* Күн аяк киемен чистарту өчен майлы крем, вакса. *Ә күн итегенең гуталины ышкылып бетеп, башы агарып диярлек калган.* Ә.Гаффар. *Әгәр дә корымга эрегән балавыз белән скипидар кушсаң, менә дигән гуталин аласың.* Робинзон эзләреннән

**ГУТТАПЕ́РЧА** *и. малая* Кайбер үсемлекләрнең оешкан сөтчел сыекчасы; углеводородтан-гуттадан һәм табигый сумалалардан тора, суны һәм электрны үткәрми, ешрак изоляция материалы буларак файдаланыла

**ГУ-У** *иярт.* Очкыч, ядрә һ.б.ш. һаваны ярып үткәндә барлыкка килгән көчле гүләү тавышын белдерә

**ГУЦУЛ** *и.* Украин халкының Закарпатьеда, Иванофранковск һәм Черновцы өлкәләренең таулы районнарында яшәүче этник төркеме вәкиле

**ГҮӘРДИН** *и. рус сөйл.* Буйлы, таза ир-егетләр турында әйтелә (гвардиягә шундый ирләр генә алынган). *Вәрәшбашның гүәрдин күк егете яу кырында ятып калды.* Г.Ахунов. *Гүәрдиндәй гәүдәле, бөркет карашлы, гайрәтле егет.* Казан утлары

**ГҮБӘН** *с. диал.* Кыска буйлы һәм тулы гәүдәле, базык

**ГҮБӘ́Н ЧӘЧ** *и.* Тумыштан ук аерылып торган, калын чал чәч тотамы

**ГҮ-ГҮ** *иярт.* 1) Күгәрчен гөрләвен белдерә

2) Сөйләшергә өйрәнә торган яшь баланың беренче авазларын белдерә

**ГҮЕЛДӘ́Ү** *ф.* Машина һәм механизмнарның, тоташ шау чыгарып, гүү итеп эшләве. *Индонезия тераконнары автомашина кебек үк гүелдиләр.* Кызыклы ихтиология

**Гүелдәп тору** Берөзлексез гүләгән тавыш чыгару

**Гүелдәп утыру** *к.* **гүелдәп тору**. *Куәтле крейсерларның, мазут исе бәреп, салмак кына гүелдәп утырган дизельләре, ак киндер чалбар кигән матросларның складтан кәрзин белән бәрәңге ташулары ---.* М.Мәһдиев

**Гүелди башлау** Гүелдәргә тотыну. *Чык төште, авылга сыер исе, сөт исе таралды, келәтләрдә сепараторлар гүелди башлады.* М.Мәһдиев

**ГҮЕЛДЕК** *с.* Гел гүләп, гүелдәп торган

**ГҮЗӘЛ** *с.* **1.** 1) Тышкы кыяфәткә, йөзгә матур, чибәр, күркәм. *Гүзәл кызлар әнә су коена, Чыгып күлнең аръякларына ---.* Ф.Гыйззәтуллина. *Гүзәл кыз Мәйсәрәнең язмышы бик фаҗигале булды.* Г.Ахунов

2) Сыйфаты, эчтәлеге, тышкы күренеше һ.б. ягыннан сокландыргыч, бик яхшы. *Антиканың гүзәл һәм мәһабәт сәнгате, Яңарыш чорының һәм аннан соңгы гасырларның бөек казанышлары аны сокландырды.* Ш.Хөсәенов. *Киләчәккә тагын да гүзәлрәк хыяллар торгызды, планнар корды.* Казан утлары. *--- яшьләр якын киләчәгебезнең матур әдәбиятта мавыктыргыч, сокландыргыч, эмоциональ гәүдәләнешен, заманыбызның актуаль мәсьәләләренең иң гүзәл, иң гуманлы чишелешен күрергә тели.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чибәр кыз. *--- район үзәгендә ашханәдә эшләүче бер гүзәл белән танышкан икән дә, шимбә көн кичкә очрашу билгеләп ташлаганнар.* М.Мәһдиев. *Безнең авылда мондый гүзәлләр юк иде шикелле.* Ф.Яруллин. *И Казан, Гөлйөзем атлы гүзәлеңне кай тарафларыңа яшереп саклыйсың?* Ф.Латыйфи

2) Гүзәллек бәйгесендә катнашкан яки җиңгән кыз. *Экранда – төрле кыйтгалардан сайлап җыелган дөнья гүзәлләре ---.* М.Галиев

3) **гүзәлем** Яратып, иркәләп эндәшү сүзе. *Гашыйк дала кызына, Ай, йөрәгем тузына. Кара кашым, гүзәлем, Өзгәләнә үзәгем Исемә төшкән саен.* Г.Сәгыйдуллин

**ГҮЗӘЛЛӘНҮ** *ф.* Матурлану, яхшыру, чибәрләнү; матур булып китү; матурлыгы арту

**Гүзәлләнә бару** Вакыт үткән саен гүзәллеге арту, торган саен ныграк гүзәлләнү. *Сеңлем Гайшә, син һаман гүзәлләнә генә барасың икән ич! Саумы, исәнме!* М.Хәбибуллин

**Гүзәлләнеп китү** Билгеле бер моменттан яки бер сәбәп аркасында гүзәлләнү. *Бала тапкач, бала имезә башлагач, ханбикә тагы да гүзәлләнеп китте ---.* М.Хәбибуллин

**ГҮЗӘЛЛӘ́Ү** *ф.* Матурлау, матур итеп күрсәтү; бизәү, матурлыгын арттыру, матурлык өстәү

**Гүзәлләп җибәрү** Бераз матурлыгын арттыру, матурлык өстәү

**Гүзәлләп тору** Бик килешү, матурлыгын күрсәтеп тору, гүзәллек бирү

**ГҮЗӘЛЛЕК** *и.* 1) Барлык матур, камил нәрсәләр, эстетик һәм рухи канәгатьләнү хисе тудырган, сокландырган нәрсәләр. *Чәчәкле аланнарда куыша-куыша бер уйнап кайтсалар, җаннарына никадәр гүзәллек сеңәр иде.* Ф.Яруллин. *Әмма болай гына казак даласының бөтен гүзәллеген күреп булмый икән әле.* А.Расих. *Тик аерма шунда гына: төзүчеләр гүзәллекне үз куллары белән тудыралар.* И.Ихсанов

2) Кешегә хас булган чибәрлек, матурлык, тышкы гармониялелек. *Гүзәллек белән талант ник соң адәм балаларына бәхет китерми икән?* Г.Ахунов. *--- аның бар игътибары шигырьдә – сылу гәүдәсеннән нәфислек, гүзәллек, яклаучысыз гаҗизлек бөркелеп тора иде.* Р.Мирхәйдәров

**ГҮ́ КИЛҮ** *ф.* Шаулашу, шау-гөр килү; ыгы-зыгы килү (халык турында). *Әле мин Казан каласына ашкынып, гү килеп, очкычка барган авыл кешеләре белән очрашу куанычыннан айнып та җитмәгән мәлдә, Мофаваза әбекәйнең җылы кунакчыл өенә килеп эләктем.* Г.Ахунов

**ГҮЛӘТҮ** *ф. к.* **гөрләтү**

**Гүләтеп тору** Бертуктаусыз, шактый вакыт гүләтү. *Сабирҗан машинасын кабызды, бераз гүләтеп торды да капка төпләренә таба кузгалып китте.* Ф.Яхин

**ГҮЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тирә-як, бина эче һ.б.ш. һәртөрле авазлардан һәм шаудан хасил булган тоташ бер шау белән тулы булу

2) Шау-гөр килү, шаулашу (халык турында). *– Нәрсә ул мең сум?! – дип гүләде халык. – Нибары үтүк бәясе ич ул ---.* Ф.Баттал

3) Машиналарның, механизмнарның тоташ бер шау чыгарып эшләве, гүелдәү. *Ниһаять, колакны кытыклап торган озын гүләү авазын бүлеп, телефоннан таныш тавыш ишетелде ---.* Р.Вәлиев. *Гүләгән тавыш ишетелгән саен, миндә, бу машинага утырып Рафис кайтмадымы икән, дигән тиле өмет кабына иде.* М.Маликова. *Кайвакыт бу бөҗәкләр, ялгышып, электростанция янына күпләп очалар, чөнки генераторның гүләве ана озынборыннарның канаты тибрәнү ешлыгына туры килә икән.* Кызыклар дөньясында

4) Җирдән, һавадан көчле шау килү, улау. *Кемнедер тотып өзәрдәй булып, Ачы җил гүли.* Ф.Гыйззәтуллина. *Баш өстендә гүләгән кара үлемне күрмәмешкә салынып, күпер коруны дәвам иттерәләр.* Ш.Рәкыйпов

5) Сөйләшә белми торган яшь баланың «гү-гү» дип, беренче авазлар чыгаруы. *--- Тимербулатны күтәреп ала. ...Гөлзәйнәп карчыкның хәлен белешә... Аның артыннан бала – гүләп, карчык елмаеп кала.* М.Маликова. *Айтуган күптән инде әнисен таный ---. Аны күргәч, сөенеп елмая, төкерекләрен чәчеп гүли.* М.Маликова

**Гүләп тору** Берөзлексез гүләү. *--- аяклары, салкында кылдай тартылган телефон чыбыклары шикелле, гүләп тора.* Р.Мирхәйдәров. *Җан күченә, диләр --- Газраилнең Канат җиле миңа тигәндә, Бер өн булып күчәр, ахры, җаным Мәңге гүләп торган имәнгә.* Зөлфәт. *Бөтен тирә-юнь, җир һәм күк ике яктан да аткан снарядлар выжылдавыннан, аларның коточкыч шартлавыннан тоташ гүләп тора иде.* Х.Камал

**Гүли башлау** Гүләргә тотыну. *Тагын җир гүли башлады, шунда гына җир тетрәвен, үзебезнең исән калуыбызны аңлап алдым.* А.Гыйләҗев

**Гүли төшү** Тагы да ныграк гүләү

**ГҮЛӘШҮ** *ф.* Һәрьяктан һәртөрле тавышлар белән шаулашу, шау-гөр килү, гүләү

**Гүләшеп тору** Бертуктаусыз шаулашу, гүләшү

**ГҮР** *и. фар.* 1) Кабер. *Көн яктысын күргәч, ничек сөенгәнемне сөйләп тормыйм. Ул – гүр караңгылыгыннан кире кайту белән бер.* М.Маликова. *Караңгы гүргә күз сал бер, бәндәм: Якты дөньяның һәр көне – бәйрәм!* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Беләсеңдер инде аның гүрен: зиратның басу почмагында ---.* М.Хуҗин

2) *куч.* Үлем. *Гүрем кайда – белмәдем, Үлемем кемнән – белмәдем ---.* Дастан

◊ **Гүр газабы** *дини* 1) Кеше үлгәннән соң, теге дөньяда гөнаһлары өчен биреләчәк җәза. *Аңа юлда күргәннәре гүр газабы шикелле булды.* Ф.Мансуров; 2) Бик каты газап. **Гүргә индерү** 1) Үлгән кешене кабергә төшерү. *Рәмзинең ак кәфенгә төргән мәетен гүргә иңдерә башладылар.* Ф.Садриев; 2) Җирләү. *Чиста кием кидерербез, Гүргә үзебез иңдерербез.* Ф.Яруллин. *Язгы матур көннәрнең берендә аны [Камәрне] гүргә иңдерделәр.* М.Хәсәнов. **Гүргә иңү** Үлү, вафат булу. *Гел елмаер, гел көлер иде --- Зарлана белмәде. Шуңа күрә яраталар да иде кешеләр. Йөзгә җитеп гүргә иңде.* А.Гыйләҗев. **Гүргә кертү** Интектереп, үлемен тизләтү, үлеменә сәбәпче булу. *Минем хәбәр-хәтерсез юкка чыгуым бабакай-әтиемне гүргә керткән.* Җ.Тәрҗеманов. *Әнине газап утларында яндырып, вакытсыз гүргә керткән шул кыланчык Кифаяга зурлап-олылап «апа» дип тел әрәм итәмме соң?!* Р.Габделхакова. **Гүргә керү** Вафат булу, үлү. *Чиркәнмәдек, бу хәлләрдән Вакытсыз гүргә керсәк тә.* Г.Тукай. *Кол булып гүргә керергә дипме картайган яшем?* С.Сүнчәләй. *Күрәчәген күреп бетермичә, Гүргә керми адәм башлары.* Ф.Яруллин. **Гүр иясе** Үлгән кеше, мәрхүм, мәрхүмә. *Ул хәзер инде – күптән гүр иясе.* А.Расих. **Гүр иясе булу** Үлү, вафат булу. *Карчыгы гүр иясе булу белән, шушы Хатирәгә күзе төшкән бит.* Сөембикә. **Гүр иясе итү**

Ниндидер шартлар, сәбәпләр үлеменә сәбәпче булу. *Биш хатын алып, барсын да гүр иясе итте. Инде миңа үрелмәкче.* Ф.Яхин. **Гүр тынлыгы** 1) Тулы тынлык; 2) Шомлы, куркыныч тынлык

**ГҮРГӘ́ЧӘ** *рәв.* Гомер беткәнче, үлгәнче, гүргә кергәнче. *Ул – тәкъдиргә кол. Гүргәчә иргә бөгеп баш, күп кыенлыклар татый, Ир сөенсә – ул бәхетле, булмаса – бәгъре ачый.* С.Сүнчәләй. *Сугыш күрми язган шигыреңне, энем, соңгы кабат яз да нокта куй. Тик... хәтердә сакла... гүреңәчә. Нәфрәтеңне янган утка кой!..* Р.Әхмәтҗан

**ГҮРЛӘ́Ү** *ф. иск.* 1) Үлү, гүргә керү

2) Җирләү, гүргә иңдерү

**ГҮРЛЕК** *и. иск.* Каберлек. *Алда, артта шаулый туплар, Уйный уклар шәүләсе, Баскан эз – гүрлек-каберлек, Канлы илнең гәүдәсе...* Һ.Такташ

**ГҮРНӘЧӘ** *и. рус сөйл.* Зур, иркен, якты өй. *Казакларда мине белмәгән кеше юк, гүрнәчә табып бирәм, әгәр теләсәң.* Ф.Хөсни. *Билләһи, дип әйтәм, мондый да күркәм гүрнәчә өйне бер авылда да күргәнем юк әле минем.* М.Галиев. --- *ул бу йортны, елап үлсә дә, менә шушылай гүрнәчә шикелле итеп, бөтен шартын китереп салдыра алмас иде.* В.Нуруллин

**ГҮРНИЧӘ** *и. к.* **гүрнәчә.** *Бу нигездә тоташ коймалар – таза ихатакура, калай түбәле гүрничә өй, минем хәтеремнән көлгән шикелле, тәкәббер биеклектә тора.* М.Галиев. *Син килерсең безгә кунакка дип, Бизәп куйдым ап-ак гүрничә ---.* Р.Батулла

**ГҮ́Р СӘДАКАСЫ** *и. дини* Үлгән кеше җирләнгәннән соң, якыннары тарафыннан бирелергә тиешле сәдака. *Бишәр, унбишәр тиен гүр сәдакасы эләктергән малай-шалай да зираттан чыкты.* Р.Батулла

**ГҮРСТАН** *и. фар. иск.* Каберлек. *Үз илең – Гөлстан, кеше иле – гүрстан.* Мәкаль. --- *адәм балаларын гүрстан да тигезләп җиткерә алмый булса кирәк.* М.Вәлиев

**ГҮ-Ү** *иярт.* Эшләп торган прибор-лар, механизмнар, агрегатлар чыгарган тоташ тавышны белдерә

**ГҮ́Я** *терк. фар.* Җөмләдә охшату, чагыштыру мөнәсәбәтен белдерә торган синтаксик чара ролендәге сүз; әйтерсең лә, кебек, нәкъ. *Гүя ул шаулап агучы тау елгасына егылып төшкән дә ярга чыга алмыйча ага да ага.* Р.Вәлиев. *Күзем йомган саен, куркыныч төш: очам гүя төпсез упкынга.* Г.Сәгыйров. *Менә кабер. Зәйнәп әби кабере. Янәшәдә Рамиз. Риф ята. Зәйнәп әби ике буын оныгын Гүя шулай карап йоклата.* Ф.Яруллин

**ГҮ́ЯКИ** *терк. к.* **гүя**. *Диңгез өсте тыныч, ямьле, җем-җем алтын нурга тулган. Гүяки гыйлем иясе олы, тирән уйга чумган.* Г.Сәгыйров. --- *ул, ишекне каерып ачып, «Сталин» дип кычкыра, гүяки граната ыргытып, ләүкә астындагы җеннәрне түшәп салганнан соң гына, мунчага атылып керә иде.* Казан утлары

**ГЫ-ГЫ** *ияртт.* Тамак төбеннән өзек-өзек көлгәндә чыккан тавышны белдерә. *Галәвиев эре тешләрен күрсәтеп көлде. – Гы-гы-гы-гы...* М.Мәһдиев

**ГЫГЫЛДА́У** *ф.* 1) Сөйләшә белмәгән бала беренче авазлар чыгару, гуләү

2) Тамак төбеннән, гы-гы-гы итеп көлү

**ГЫЖ-ГЫЖ** *иярт.* Сулыш капканда, йөткергәндә, сулыш юлларыннан һава шау белән үткәндә чыккан тавышны белдерә. *Ханзадәләр гыж-гыж курай уйнаган. Курай моңы урманнарга сыймаган.* Ә.Синугыл-Куганаклы. *Кайсысы коры идәнгә баш астына кулларын куйган, тешләрен кысып, авыртуга бирешмәскә тырышып, гыж-гыж сулый.* Х.Камалов. *Ул минем артыма баскан. Гыж-гыж сулый, тешләрен шыкырдата.* Б.Камалов

**ГЫ́Ж-ГЫЖ КИЛҮ** *ф.* 1) Гыж-гыж иткән тавыш чыгару. *Яралы үзе гыж-гыж килеп сулыш ала, авызын аңсыз рәвештә ача, яба, тешләрен шак-шак китерә, шыгырдата.* Х.Камалов. *Ул, тынына капкан төсле, гыж-гыж килә иде.* Б.Камалов. *Тальянның бөтен җиреннән һава өрә. Гыж-гыж килә. Хәер, карт үзе дә шулай: гыж-гыж килә.* М.Мәһдиев

2) Бик авыр сулау. *Шундый кичләрнең берендә безгә, гыж-гыж килеп, Мукум абзый килеп керде.* А.Хәсәнов. *Завод директоры да йөгерә, пенсиягә чыкмыйча, конторада эшләп утырган апа-әбиләр дә йөгерә, гыж-гыж килеп, сугыш ветераны да йөгерә.* М.Мәһдиев

**ГЫЖЛАВЫК** *с. к.* **гыжылдавык**

**ГЫЖЛА́У** *ф.* 1) Сулыш алганда хәлсезлектән, авырудан һ.б.ш. гыж-гыж иткән тавыш чыгару. *Дөресен генә әйткәндә, [Дугласның] исәнлеге дә какшады соңгы вакытта. Кайчак күкрәге дә гыжлый сыман.* Р.Ишморат

2) Сулыш кабу; авыр сулыш алу

**Гыжлап бетү** Тәмам сулыш кабу, нык гыжлау

**Гыжлап тору** Хәзерге моментта гыжлау

**Гыжлый башлау** Гыжлау барлыкка килү. *Гыжлый башлагачтын күкрәк, карт хатының кабул итсә, Сөенечтән тула йөрәк – Без ирләргә күпме кирәк!* Ф.Яруллин. *Йөгерүдән тәмам гыжлаган. Агай бигрәк каты гыжлый башлаган.* А.Хәсәнов

**ГЫЖНА́У** *ф. к.* **гыжлау**. *Нәрсә янап гыжный бу зәкъкумнар? Тарата шом, чыш-пыш, шыр ялган?* А.Хәлим

**ГЫЖЫЛДАВЫК** *с.* **1.** Гыжлап чыккан, үз тавышы белән катыш кыштырдау, гыжылдау чыгара торган; карлыккан тавышлы. *Иске патефон гыжылдавык тавыш белән фокстрот көйли башлады.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* Гыжлап чыккан тавыш. *Шуңа күрә аның көлүе дә кыска-кыска бер гыжылдавык кына булып чыкты.* Н.Фәттах

**ГЫЖЫЛДА́У** *ф. к.* **гыжлау** (*1 мәгъ.*). *Данило Михеевич дигәннәре, челемен суыра торгач, бик каты йөткерергә тотынды, бераздан сулыш ала алмыйча гыжылдап туктады.* Г.Бәширов. *Стенадагы иске сәгать, ютәленнән буылган карт сыман, озак гыжылдап, иртәнге алтыны сукты.* Р.Вәлиев. *Кемдер рельслар буйлап безгә таба йөгерә. Килде, гыжылдый, сөйләшә алмый.* М.Мәһдиев

2) *к.* **гыжлау** (*2 мәгъ.*). *Йөгереп килде станция начальнигы, йөгереп килде линейный милиционер, йөгереп килде гыжылдаган эшелон начальнигы.* М.Мәһдиев

**Гыжылдап бетү** Нык гыжылдау. *Сафа бабай килеп җитте: яланаяк, күлмәкчән, үзе йөгерә-йөгерә арып, гыжылдап беткән ---.* Г.Ибраһимов. *Картның гыжылдап беткән биш планкалы тальяны бар.* М.Мәһдиев

**Гыжылдап тору** Шактый вакыт гыжылдау; бертуктаусыз гыжылдау. *Әнә югары очның берәү тәмәке суы эчеп кенә котылды. Гыж-гыж килеп, тик гыжылдап тора, ди ---.* Г.Бәширов. *Тор әйдә, салкын тидерәсең. Болай да гыжылдап торган үпкәңә...* М.Галиев

**Гыжылдый башлау** Гыжылдарга керешү. *Ат коточкыч аяныч тавыш чыгарып гыжылдый башлады.* Г.Бәширов

**ГЫЖЫЛДЫК** *с. к.* **гыжылдавык**

**ГЫЙБАД** *и. гар.* 1) Алла колы, адәм баласы, бәндә. *Без богауда! Әллә без коллармы? Нинди зур гөнаһ! Ник гыйбадыңны болай кимсеттерәсең, йа Аллаһ?* С.Сүнчәләй

2) *кимс.* Надан кеше, белемсез зат, томана. *Белгәнрәк кешеләрнең әйтүләренә караганда, ул, имеш, гади авыл гыйбады гына түгел, утырган, чарланган һәм күпмедер укыган да егет, янәсе ---.* Ә.Еники. *Кем чиратсыз кергән? Теге авыл гыйбадымы?* М.Мәһдиев

**ГЫЙБАДӘТ** *и. гар.* 1) Дин тотучыларның үзе инанган Аллага мөрәҗәгать итүе, аңа табыну, ялвару, аны олылау белән бәйле дини гамәл. *Ул чагында шәһәрләрдә гыйбадәт кылу һәм мәҗүси аллаларга корбан китерү өчен корылган храмнар иҗтимагый фикерләү үзәге хезмәтен дә үтәгән.* Р.Сафин

2) Намаз. *Гыйбадәтне тәмамлап, битләрен сыпырып куйдылар.* Ф.Латыйфи

3) Дога. *Карчык, авыз эченнән генә гыйбадәтен укый-укый, бер кулына янчык салынган сумка күтәреп, икенчесенә шомарып беткән таягын алып, ишектән чыкты.* Х.Вәлиәхмәтов

**ГЫЙБАДӘ́Т ИТҮ** *ф. к.* **гыйбадәт кылу**. *Бу пьесада Гафифә, --- халык сүзенә гыйбадәт итә торган иске мәгыйшәт җимешләре хатыннарны бик яхшы күрсәтәдер.* С.Рәмиев. *Хәятеңнең калган соңгы кисәгендә Ул халикы гавалимгә гыйбадәт ит!* Г.Харис

**ГЫЙБАДӘ́Т ЙОРТЫ** *и. к.* **гыйбадәтханә**. *Монда хакимнәр киләләр. Ач гыйбадәт йортларын!* Н.Исәнбәт. *Кем әйтте сиңа мәчеттә яшиләр дип? Мәчет – гыйбадәт йорты ул.* М.Юныс

**ГЫЙБАДӘ́Т КЫЛУ** *ф.* Гыйбадәт йоласын башкару, гыйбадәткә караган гамәлләрне үтәү. *Кабанбәк кешеләре монда килеп гыйбадәт кыла башлыйлар, соңрак бу урында җомга намазлары өчен мәчет тә салалар.* Р.Мостафин. *--- кылган гөнаһларым җуяр өчен, өч көн, өч төн монастырь чиркәвендә гыйбадәт кылырым, Аллаһы Тәгалә ярлыкар әле дип, үз-үзен юаткан иде, аны да эшли алмады.* М.Хәбибуллин. *Гыйбадәт кылуларны да тәртипкә салырга кирәк бит инде.* Ф.Баттал

**ГЫЙБАДӘТХАНӘ** *и. гар.-фар.* Дин тотучы, ышанучы кешеләр җыелып, үзенең дине таләп иткәнчә гыйбадәт кылу өчен махсус бина, йорт (мәс., мәчет, чиркәү, синагога һ.б.). *Ә безнең мәшһүр гыйбадәтханәләр каласы Анкорда булдыгызмы соң?* М.Кәрим. *Кыя уемында кечкенә генә гыйбадәтханә, будда диненеке.* Кызыклар дөньясында

**ГЫЙБАДӘТЧЕ** *и. сир.* Гыйбадәт кылучы

**ГЫЙБАДӘТЧЕЛ** *с.* Гыйбадәтен калдырмыйча, гел үтәп баручы, һәрвакыт гыйбадәт кылып торучы; диндар

**ГЫЙБАДЛЫК** *и. иск.* Наданлык, караңгылык, томаналык. *--- утрак тормыштагы Мәвараэннәһер халкы дала батырларының тупаслыгыннан, гыйбадлыгыннан көлә торган булып китә.* С.Шәмси. *Болай гына сорау бирәсең; Дәшмәвемне – зиһен торгынлыгы, Гыйбадлык дип, әнә көләсең ---.* Р.Рахмани. *Авылдан икәнем, гыйбадлыгым – йөземдә. Объективка күзләремне шар ачып текәлгәнмен дә авызымны да ябарга онытканмын.* Г.Тавлин

**ГЫЙБАРӘ** *и. гар.* 1) Тексттан алынган өзек, өземтә, цитата

2) Сүзтезмә, әйтелмә, тәгъбир. *--- бар булган тормыш тәҗрибәсе, яшәүнең асыл кагыйдәләре, мәхәббәт-гаилә законнары, күңел эчтәлеге, иман, ачы нужа сабаклары әнә шул кып-кыска мәкальләрдә, гыйбарәләрдә сакланып калган.* А.Гыйләҗев. *Татар фольклоры һәм шигъриятендә «Йосыф матурлыгы», «Ягкуб түземлеге», «Зөләйха мәхәббәте» кебек гыйбарәләр «Йосыф китабы»ның идея-эстетик йогынтысына бәйле.* Татар халык иҗаты

3) Сүз. *Әдипнең җанлы сүзе, кәлимәсе, үткен гыйбарәсе, шаян әйтеме укучы йөрәгенә китап сүзенә караганда тизрәк барып җитә һәм озаграк саклана ---.* Т.Галиуллин

**ГЫЙБАРӘТ** *хәб. сүз гар.* Тәшкил итә, хасил итә, эченә ала, аңлата, белдерә. *Миңа калса, риваятьнең асыл мәгънәсе шуннан гыйбарәт: кала салганда, күлнең балыкка бай булуы да исәпкә алынган.* Р.Мостафин. *Гыйбрәтле хикәя – дидактик характердагы, төп вазифасы үгет-нәсыйхәт, вәгазь бирүдән гыйбарәт булган жанр.* Казан утлары

**ГЫЙБРӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Сабак; акылга өйрәнерлек, уйландырырлык вакыйга, эш, хәл. *Үткәннән калган үрнәкләр дә, гыйбрәтләр дә бүгенге көнгә һәм киләчәккә хезмәт итә бит.* Ә.Баянов. *Менә, менә шуларны языйк. Үзенә күрә сабак-гыйбрәт булыр.* Ә.Рәшит

2) Яхшыга өйрәтерлек, үрнәк алырлык, иярерлек, уңай мисал булырлык яхшы эш, сүз. *Мин Толстойны башта кызык өчен, гыйбрәт өчен, тормыш өчен, культурам үссен өчен генә укыганмын икән!* Ә.Галиев. *Чиркәү кешесе, Алланың юаш колы, ә үз куллары белән комбедта өч большевикны буып үтерде. Менә сезгә өлге! Менә сезгә гыйбрәт.* А.Гыйләҗев

3) Бик сәер хәл. *--- кайгылы рәвештә кайтып, Шаһбалга хәбәрне белдерделәр. Шаһбал, бу гыйбрәтне ишеткәч, тәмам хушыннан язды.* Дастан. *Бер тәлинкә өреле тавык шулпасы ашады, чеметеп кенә ике-өч тапкыр ит капты, сәхабәләр тормышыннан риваятьләр, гыйбрәтләр сөйләде ---.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ. к.* **гыйбрәтле**. *Менә шундый гыйбрәт хәлләр бик күп.* Р.Низами

**3.** *ы. мәгъ. сөйл.* Шаяртып ачулану сүзе; юньсез. *Менә сезгә гыйбрәт: йә нинди председатель инде үз колхозчыларын шулай көттерә? Юньле кеше эшеме бу?*

**ГЫЙБРӘ́Т АЛУ** *ф.* 1) Сабак алу, күргән, ишеткән, укып белгән хәлләрдән яхшы һәм начар гамәлләр турында үзендә фикер булдыру. *Тарихыңның башларына бак та Гыйбрәтләр ал син дә ---.* Х.Туфан

2) Үрнәк алу, уңай мисалга, яхшы эшкә иярү. *Аларның хезмәтләре зиһенебезне баета, тарихи офыкны киңәйтә, үткәннәрдән тәҗрибә, гыйбрәт алырга ярдәм итә.* Х.Миңнегулов

**ГЫЙБРӘ́Т БИРҮ** *ф.* Сабак бирү, тәҗрибә бирү, акылга өйрәтү. *Какты бераз тормыш, сукты бераз, Акыл да бирде, гыйбрәт тә.* Х.Туфан

**ГЫЙБРӘТЛӘНҮ** *ф.* Гыйбрәт алу, сабак алу, акылга өйрәнү; үрнәк алу, иярү

**ГЫЙБРӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Эчтәлекле, уйландыра торган; сабак алырлык, уйланырлык, акылга өйрәтерлек (*эш, хәл, вакыйга һ.б.ш.*). *Үткән белән исәпләшмәүнең бер гыйбрәтле мисалы бу!* Р.Мостафин. *Пинскийгә шул бик ошый, ул майорны төрле гыйбрәтле мисаллар китереп «җиңә», һәм шул нәрсә Пинскийнең кәефен күтәреп җибәрә.* Х.Камалов. *Муса Җәлил теле дип, татарча өйрәнүче бер немец малае турында гәзит хәбәре укыдым. Гыйбрәтле хәл бу.* Ш.Галиев

2) Үрнәк алырдай, өйрәтердәй, яхшылыкка өнди торган. *Бәләкәй генә җан иярәре булсалар да, аларның тормышларында гыйбрәтле хикмәтләр бар.* М.Галәү. *--- роман һәм повестьлар гыйбрәтле, файдалы, җанга ятышлы булсын, тарихи, гадел, акыллы һәм фәһемле булсын дип таләп итәләр.* Г.Ахунов

**2.** *хәб. сүз* Гыйбрәткә ия, гыйбрәте бар. *Бүгенге яшь буын өчен сугыш совет кешеләренең көчле рухын, ныклык һәм кыюлык сыйфатларын бөтен тулылыгы белән ачкан фаҗигале сынау буларак гыйбрәтле.* Казан утлары

**ГЫЙБРӘТЛЕЛЕК** *и.* Үрнәк алырлык, уйлатырлык, сабак булырлык эчтәлек, мәгънә. *Битарафлык гыйфритенең берсен, әсәрләре яратып укыла, гыйбрәтлелеге белән күңелгә иңеп кала торган авторларның берсе Камил Кәримов «Сакау күке» романында --- бөтен фаҗигасе, аянычы белән ачык күрсәткән.* Казан утлары. *--- әкияткә дә һәм гыйбрәтле хикәягә дә гыйбрәтлелек хас, һәркайсында гыйбрәтле нәтиҗә бар.* Казан утлары

**ГЫЙДДӘТ** *и. гар.* Ирсез калган хатын икенче иргә барганчы үтәргә тиешле вакыт аралыгы. *Гыйддәт, югарыда әйткәнебезчә, ире үлгән яки иреннән аерылган хатынның никах яңартырга ярамаган вакыты ул.* Сөембикә

**ГЫЙЗЗӘТ** *и. гар.* 1) Дәрәҗә, мәртәбә. *Мал вә гыйззәт, мәгърифәт, Хикмәт вә хөрмәт кирәкме?* Г.Тукай. *Бунда бит коры бер Җәгъфәр агайны коры бер таш басып үтерми, бәлки, милләтне бөтен шан вә гыйззәте илә бергә үзенең иске манарасы басып үтерә.* Җ.Вәлиди. *--- әллә кемнәр гыйззәтеңнән, Хәсрәтеңнән көлсәләр, --- Мәңлы күңлеңнән мине син Шул читен хиндә сагын ---.* С.Сүнчәләй

2) Кадер, хөрмәт, ихтирам. *Гатард --- афәрин синең бу егетлекләреңә, – дип, күп гыйззәт вә илтифат әйләде һәм Азрыкны кулга төшерүемә шатланды.* Дастан

**ГЫЙЗЗӘТЛӘ́Ү** *ф. иск.* Ихтирам итү, олылау, гыйззәт күрсәтү

**ГЫЙЗЗӘТЛЕ** *с.* Хөрмәтле, ихтирамга лаеклы, абруйлы. *Гыйззәтле Муса әфәнде! Бүген сәгать унбердә сезгә киләм.* З.Бигиев. *Йолдызларны гына карагыз. Салют ясап сипкәннәрмени! Кемнәр хөрмәтенә икән, белмисеңме, гыйззәтлем?* М.Маликова

**ГЫЙЗЗӘТЛЕЛЕК** *и. иск.* Ихтирам ителү, авторитет, дәрәҗә. *Гыйззәтлелек вә олуглык – зур тырышлык беләндер, черүче туфрак белән иңмәстер, ягъни озын буй, вә олуг сакал, вә җуан корсак белән түгелдер.* К.Насыйри

**ГЫЙЛАВӘ** *и. гар. иск.* Өстәмә, кушымта, берәр нәрсә янына өстәлгән өлеш. *Шагыйрь тагы «үземнән гыйлаявә» дип язмасына өстәп куя.* М.Гарипов

**ГЫЙЛАВӘ́ ИТҮ** *ф. иск.* Өстәү, кушып кую. *Мәзкүр гәзитә бу микъдарны язып кына да калмаган. Аның өстенә шул сүзләрне дә гыйлавә итәдер.* Г.Камал. *Хикәянең икенче басылуында гыйлавә ителгән хатны укыганда чыдый алмадым.* Й.Акчура

**ГЫЙЛАВӘ́ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **гыйлавә итү.** *--- илче шушы вакыйганы язганда, мин аны беләдер идем, юри сорадым, ди дә, шушы сүзләрне гыйлавә кыла ---.* Г.Гобәйдуллин

**ГЫЙЛАҖ** *и. гар. иск.* 1) Әмәл, чара. *Урыс гаскәре Чура батырны үлтермәккә гыйлаҗ тапмый ---.* Әкият

2) Дәва, дару; ярдәм. *Биһүдәдер! сорыкорттан котмәк гыйлаҗ ---.* Г.Тукай. *--- Габделмалик хакимне, кызы Дәһханә хаста булса да, бергә алып кил. Мән Дәһханәгә гыйлаҗыны монда кылдырамын ---.* Ф.Халиди

**ГЫЙЛЕМ** *и. гар.* **1.** 1) Белем. *Син гыйлем тупла, наданлыктан уян, Ахирәт көнне надан – эттән яман.* Г.Утыз-Имәни. *Ганасыйрны әсир иткән табигать, Булып мозтар, гыйлемгә кыйлды бигать.* Дәрдемәнд. *Укымышлы кеше – Кол Шәриф мәдрәсәсендә гыйлем алган.* Р.Мостафин

2) Фән, белем тармагы, фән өлкәсе. *Нитәк ки гыйлем укып, остаздан фатихасыз чыккан кеше файда күрмидер.* К.Насыйри. *Монда мин гыйльме тыйб әһелләренә бер-ике кәлимә сүз юлладым.* Ф.Латыйфи. *Мәдрәсәнең бер еллык «галия» бүлегендә укучылар, дин гыйлемен үзләштереп, имаммөдәррислеккә әзерләнделәр.* Казан утлары

3) Тормыш тәҗрибәсе, һәртөрле белем. *Йөрәге нинди бәхеткә сусап канатлана? Асыл малгамы, чит илләрне күреп танышугамы, ят халыклар белән аралашып гыйлем туплаугамы ---.* Ф.Латыйфи

4) Галим, укымышлы кеше

**2.** *с. мәгъ.* 1) Укымышлы, белемле, эрудицияле. *--- ул чакта ук Кызыл Армиядә театр дөньясын яхшы белгән, әзерлекле, хәтта гыйлем кешеләр булган икән.* М.Маликова. *Илфас Кәримовның Татарстанда иң намуслы, иң булдыклы, иң гыйлем, иң кешелекле зат булуы турында бер-бер артлы чыгышлар ясап, халыктан кул чаптырдылар.* Ф.Баттал

2) Акыллы, фәнни. *Иртән килү белән, үзгәртеп кору турында бик гыйлем*

*сүзләр сөйли башлаган иде Сәйфияр Хәкимович ---.* Ф.Баттал

**ГЫЙЛЕ́М ИЯСЕ** *и. к.* **галим**. *Диңгез өсте тыныч, ямьле, җем-җем алтын нурга тулган. Гүяки гыйлем иясе олы, тирән уйга чумган.* Г.Сәгыйров

**ГЫЙЛЕ́М ЙОРТЫ** *и.* Уку йорты, белем бирү үзәге. *Моңа махсус һич гыйлем йорты булмаганга, Уфадамы, Бубидамы, башка бер йирдәме җәйге курслар игълан кылына икән, --- шул курслар бар дигән шәһәрләргә груһ-груһ агылалар.* Г.Ибраһимов

**ГЫЙЛЕМЛЕ** *с.* Укымышлы; белемле. *Җимеш агачы – җимешләре белән, укый-яза белгән кеше гыйлемле булуы белән файдалы.* Р.Фәхреддин. – *Монда, Ялта белән Әнкара арасында, таулар юк, тавыш туп-туры диңгез өстеннән килә, чиста көе килә, – дип, Хәмит ага үзенең радиотехникада да гыйлемле икәнлеген исбат итте.* М.Мәһдиев

**ГЫЙЛЕМЛЕК** *и.* 1) Белем. *Сез белеп бетермисез әле борынгы гыйлемлекләрне.* М.Маликова. *Кешелек дөньясы, гыйлемлекләрне үзенә ничек кирәк, шулай квалификацияләп, берәүләрне – бүгенгенең күрәзәчеләре, икенчеләрне кичәге һәм туасы көннәрнең йә каһарманнары, йә җәфа чигүчеләре итә.* Г.Тавлин

2) Белемлелек, укымышлылык. *Йосыф бәкнең тиңе булмаган кызы аның хатыны булыр: гүзәллеге, акылы, гыйлемлеге берүзе дүрт хатынга торыр.* М.Хәбибуллин

**ГЫЙЛЕМЛЕЛЕК** *и.* Эрудиция, белем дәрәҗәсе; укымышлылык, белемле булу үзлеге. *Мичеңне белми томаласаң, усак утыны да агулап куя. Шуңа күрә гыйлемлелекне арттырырга, табигатьтәге көчләрдән дөрес файдалану юлларын өйрәнергә кирәк безгә!* К.Тимбикова

**ГЫЙЛЕМ-МӘГЪРИФӘТ** *җый. и. гар.* Мәгариф, һәртөрле белем. *Бездә гыйлем-мәгърифәт турында мәкальләрнең күп булуы аерым игътибарга лаек.* Н.Исәнбәт

**ГЫЙЛЕМСЕЗ** *с.* **1.** 1) Караңгы, томана, культурасыз. *Гыйлемдән башка – байлык, байлыктан башка гыйлем булмас. Ягъни гыйлемсез милләт баемас вә алга китмәс, баемаган милләт гыйлем тәксил итә алмас.* Р.Фәхреддин

2) Надан, белемсез, аңгыра

**2.** *рәв. мәгъ.* Гыйлем алмыйча; гыйлемнән башка, гыйлемгә таянмыйча. *Гыйлемсез гыйбадәт кыйлган кеше тегерменгә җиккән ишәк кебектер ки, әйләнә-әйләнә, барып җитә алмай.* К.Насыйри

**ГЫЙЛЕМСЕЗЛЕК** *и.* Грамотасызлык, белемсезлек, томаналык, наданлык. *Шуңарга күрә дә ислам галәменең тәдәнниенә сәбәбләрне һәммәсен дә шушы гыйлемсезлектән таба иде.* Г.Гобәйдуллин

**ГЫЙЛЕМХАНӘ** *и. иск. гар.-фар.* Уку йорты

**ГЫЙЛЬЛӘТ** *и. гар. иск.* 1) Кимчелек, җитешсезлек. *Милләтеңне белмәсләр, Гыйльләтеңне күрмәсләр ---.* Г.Тукай

2) Авыру. *Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйльләтеңдер гыйльләтем.* Г.Тукай

**ГЫЙЛЬМАН** *и. гар. дини* Җәннәт хезмәтчесе

**ГЫЙЛЬМИ** *с. гар.* Фәнни; белемгә, фәнгә караган. *Марат тәмамлаганда, ул институтта гыйльми секретарь булып эшли иде.* М.Мәһдиев. *Көннәрнең берсендә минем кулга бер гыйльми китап килеп керде.* Р.Мостафин. *Бәхәс бара. Гыйльми бәхәс Инде менә ничә еллар: Сөембикә манарасын Кемнәр салган, нинди куллар?* Ф.Яруллин

**ГЫЙМАД** *и. гар. иск.* Тирәк, терәү, багана. *Мескини һәм нары гыймад үртәмештер нәйләйен, Маҗәри мөбрәм казага бәндә инкяр улмайә.* М.Акмулла. *Болардыр дине исламның гыймаде, Боларга итмәмиз игътимаде.* Г.Тукай

**ГЫЙМАРӘТ** *и. гар. иск.* 1) Корылма, каралты. --- *ханның хөкеме илән шәһәргә ут төрттеләр, Бохараның каср гыймарәтләре янды. Таштан салынган гыймарәтләре янмады ---.* Шәҗәрәи төрек

2) Төзү эше, төзелеш. *Ул көн – гыймарәт башламак, боглар вә агачлар дикмәк көнидер.* Тәварихе Болгария

**ГЫЙМАРӘ́Т ИТҮ** *ф.* Төзү, салу, кору, торгызу. --- *мин зәкят тә бирдем, мин Казанда йөзләгән матур биналар гыймарәт иттем, ятимнәргә, хәерчеләргә ярдәмем тиде.* Р.Батулла

**ГЫЙМАРӘ́Т КЫЛУ** *ф. иск. к.* **гыймарәт итү.** *Безләр таштан гыймарәт Кыламыз атамның, ягъни Нух нәбинең догасы илә.* Ф.Халиди

**ГЫЙМАРӘТЧЕ** *и.* Архитектор, төзелеш белгече. --- *бу мастерскойлар имтихан биреп кергән яшьләрне я рәссам, я һәйкәлтараш, я гыймарәтче итеп чыгарачак икән.* Ә.Еники

**ГЫЙМАРӘТЧЕЛЕК** *и.* Төзүчелек сәнгате, архитектура. *Казанда рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыймарәтчелек мастерскойлар бар икән.* Ә.Еники

**ГЫЙНАД** *и. гар. иск.* Кирелек, үзсүзлелек, тискәрелек. *Бу мидә йөзләп гыйнад амбары бар ---.* Г.Тукай

**ГЫЙНАДЧЫЛЫК** *и. иск.* Үзсүзлелек, кирелек. *Гаязның [Г.Исхакый] рәсеме уемны куәтләндерә иде. --- ике матур кара күз, күләргә дә, егъларга да хәзер тетрәк иреннәр, гайрәтлелекне, тырышлыкны, хәтта бераз да гыйнадчылыкны күрсәтә торган мөнтазам таррак маңлай.* И.Акчура

**ГЫЙНАЯТЬ** *и. гар.* 1) Кайгыртучанлык, булышлык, ярдәм. *Пигамбәр хәзрәтендән йитде нагяһ, Гайнаять намәңездән йитде агяһ.* Дәрдеманд. *Гыйнаять кылсаңый, йа Рабб --- Илаһи, җөмлә хаҗәтем, Кабул әйлә мөнәҗәтем.* М.Акмулла

2) Яхшы тормыш. *Бу гыйнаять, бу дәүләт нәдин торыр, белмәймүсән?.. Әй, әмире мәмләкәт, бу гыйнаять сәндин торыр!* Дастан

**ГЫЙНВАР** *и.* Хәзерге календарьда елның беренче ае, январь. *Гыйнвар азагында Наилә тагын бер йомры башлы малай алып кайтты, исемен Рөстәм дип куштылар.* А.Гыйләҗев. *Гаскәр туплау, аны коралландыру 1545 елның гыйнвар аенда гына тәмамланды.* М.Хәбибуллин

**ГЫЙРФАН** *и. гар. иск.* **1.** Аң-белем, тәрбия, тәрбиялелек. *Һәр тарафка сөйүлед дәкаикъдан агызган йиме гыйрфан ташын аның.* М.Акмулла. *Татарда да гыйрфан уты кабынганны*

*Күрсәтергә күтәрелгән бөтен кеше.* Г.Тукай. *Ходавәндәи кәрим ихсан безгә кыйлды бераз гыйрфан, Вә ләкин юк аңа мәйдан, танучы аны бик мәхдүд.* М.Иманколый

**2.** *с. мәгъ.* Белемле, тәрбияле, алдынгы. *Бетсен истибдад, тәхет-таң! Мәкъфур улсын золмәте! Яшәсен өммәт – Рәсүлнең ирекле, гыйрфан өммәте!* С.Сүнчәләй

**ГЫЙСМӘТ** *и. гар. иск.* Намуслылык, пакьлек, гөнаһсызлык. *Гайбенә күз салма дустның, гыйсмәте мәнзур имәс, Гайбе заһир улса улсын, гайбә мөзаһир улмасын.* М.Акмулла. *Адәм балалары, Искәндәр әфәнде, сирота мөселманнар, тәүфыйк вә гыйсмәт, ягъни рухи чисталык белән мәртәбәле булырлар.* М.Хәбибуллин

**ГЫЙСЪЯН** *и. гар.* **1.** 1) Каршылык күрсәтү, баш тарту; баш күтәрү, фетнә. *Дүрт ягым гыйсъян уты – сүнмәс һич, ул сүндермәсә.* Г.Тукай. *Эстәсә бәйрәм, рәхәт – сөйсен кояшның ул нурын, Эстәсә хөррият ул – тотсын олугъ гыйсъян юлын ---.* С.Сүнчәләй. *--- үз гыйсъяннарының эчтәлеген сәнгатьчә ачып салыр өчен, гыйсъянчыларның бер өлеше чара итеп шул ук дини легендалардан файдаланды.* Х.Госман

**2.** *с. мәгъ.* Каршылыклы, ризасыз. *Урманнарга керсәм уйландыра, бүлмәм бик тар гыйсъян уйларыма.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ГЫЙСЪЯНЧЫ** *и. иск.* **1.** Фетнәче, бунтарь. *Еллар чиратына бераз гына алданрак баскан булсамчы! Без очрашкан булыр идек юлда, мин дә бит бер исәр, гыйсъянчы ---.* Л.Шакирҗанова

**2.** *с. мәгъ.* Баш күтәрүче, буйсынмый торган. *К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә Булат, Ф.Бурнашның «Хөсәен мирза» әсәрендәге Муса һәм икесендә дә сурәтләнгән качкыннар гыйсъянчы геройлар иде.* Ф.Галимуллин. *Гыйсъянчы герой үзен һәрьяктан камил булып җиткән саный торган булса, Такташ героенда мондый караш хәзер инде юк.* Х.Госман

**ГЫЙСЪЯНЧЫЛЫК** *и.* XX йөз башында барлыкка килгән, символизм һәм романтизм белән сугарылган, иске тормыштан баш тартып, яңа тормышка омтылуны чагылдырган әдәби агым. *--- безнең әдәбиятчылар, әйтергә кирәк, Такташ иҗатын өйрәнгәндә, аннан гел гыйсъянчылык һәм революция темаларын гына эзлиләр.* М.Мәһдиев. *Г.Халит гыйсъянчылыкны да «үтәдән-үтә романтик күренеш» дип атады.* Ф.Галиуллин

**ГЫЙТАП** *и. гар. иск.* Шелтә, орышу, бәреп әйтү. *– Шаһзадә юк булуыннан атасы хәзрәтләренә мәктүб язмыш, безләрне гыйтабтан коткарып, – диде.* Ф.Халиди

**ГЫЙТА́П КЫЛУ** *ф. иск.* Орышу, шелтәләү. *Шул мәктүбне атамызга илтеп бирәсез. Сезгә, әлбәттә, гыйтаб кылмас, димеш.* Ф.Халиди

**ГЫЙФРИТ** *и. гар.* 1) *миф.* Зур, көчле, куркыныч җан иясе, дию. *Вакыты-вакыты белән Мидхәтнең машинасы аның күзенә сары шайтан, гыйфрит булып күренә башлый ---.* А.Гыйләҗев. *Бу гыйфрит, диюләрнең кайберләре белән хәзер иске китапларда гына очрашырга мөмкин, аларның заманы узды.* А.Муранов. *Имеш, тегермән буасында җиде башлы гыйфрит яши ---. Гыйфрит караңгы төннәрдә генә яр буена чыга ул.* Р.Хафизова

2) *күч.* Мәкерле, явыз, рәхимсез кеше. *Шуннан берәм-берәм аягүрә бастык, шундый гыйфрит каршында басмый чыдап кара.* М.Кәрим. *Гыйфритләрнең соңгысы чыгып китүгә, ханым, бер иптәшендә качып яткан --- иренә шалтыратып, үкереп елыйелый, хәл-әхвәлне аңлатып бирә.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Тискәре сыйфатларның җыелмасы: ямьсез үзенчәлекләрне җыеп атау. *Битарафлык гыйфритенең берсен --- Камил Кәримов «Сакау күке» романында --- бөтен фаҗигасе, аянычлыгы белән ачык күрсәткән.* Казан утлары

**ГЫЙФРИТЛӘНҮ** *ф.* Явызлану, усаллану

**ГЫЙФФӘТ** *и. гар.* 1) Кызлык, сафлык. *Бозыклык, ялган, ачу күрәм хакыйкать, гыйффәт, мәхәббәт эчендә.* С.Рәмиев. *Яшь бала күк җылмаеп сөйнәм менә мин әллә ник, Ал чәчәк күк изге гыйффәт, изге ямь эсти җаным?* С.Сүнчәләй

2) Намус, абруй. *Тарыксам хәсрәтем күптән, Күңелдән һәм янып көйсәм, Китәм читкә халыктан мин, Дәхи гыйффәт вә ямь сөйләм.* С.Рәмиев

**ГЫЙФФӘТЛЕ** *с.* 1) Кызлык намусы булган, саф. *Бу сүзләрне кемдер Кәримә атлы гыйффәтле кызның колагына пышылдый иде.* З.Хөснияр. *Шактыйларының күңелендә кияүләренә рәнҗеш саклана: гыйффәтле кыз баланың кичерешләрен аңламаган, тупас кыланган, түземсезләнеп, үз рәхәтен күрергә ашыккан...* М.Маликова

2) *күч.* Саф, пакь, намуслы. *Моңарчы биниһая киң вә зур галәм йөзендә иң бәхетле гаилә корган гөнаһсыз, саф күңелле, шәфкатьле ата-ана кеби тату, гыйффәтле мәхәббәт белән яшәдек ---.* С.Поварисов

**ГЫЙФФӘТЛЕК** *и.* Сафлык, намуслылык. *Анасы балага сөйкемлелекне, зифалыкны, сылулыкны, гыйффәтлекне, йомшак мөгамәләне, мөгаен, бар булганы белән биреп калдыргандыр.* М.Хәбибуллин. *Цезарь хатыны да гыйффәтлеккә Беләсез бит! – дәгъва итмәгән. Байлык һәм дан – һәммә нәрсә булган, Тик барыбер --- нидер җитмәгән.* Ә.Рәшит

**ГЫЙФФӘТЛЕЛЕК** *и.* 1) *к.* **гыйффәт**

2) Гыйффәтле булу

**ГЫЙФФӘТСЕЗ** *с.* 1) Гыйффәтен югалткан. *--- үзен яраткан, яшьлеген биргән кыз балага әллә нинди ялалар ягалар. Имеш, кыз бала элек үк гыйффәтсез булган.* С.Зыялы

2) Намуссыз, төрле хәйлә, гөнаһ, намуссыз гамәлләр тулы. *Күзләрендә инде күркәм Җан нуры сүнгән иде. Инде гыйффәтсез гомергә Мескинем күнгән иде.* С.Сүнчәләй

**ГЫЙФФӘТСЕЗЛЕК** *и.* 1) Гыйффәтле, кызлыклы булмау

2) Әхлаксызлык, бозыклык

**ГЫЙШ-ГАШРӘТ** *и. гар. к.* **гыйшгыйшрәт**. *Һәрбер мәнзилдә ял итеп, гыйш-гашрәттә уларак фарсыча якынайдылар ---.* Дастан. *Менә шул көенчә Һиндстан шәһәрендә бик озак вакытлар гыйшь вә гашрәт илә яшәделәр.* Дастан

**ГЫЙШ-ГЫЙШРӘТ** *и. гар.* 1) Күңелле вакыт уздыру, ашап-эчеп кәефләнү, күңел ачу, кәеф-сафа. *Бәһрам шаһзадә, падишаһлык эшләрен җайга салганнан соң, һәммә кирәкләрен – зиннәт вә гыйш-гыйшрәт әсбапларын әзерләп, зур туй ясап, Диләрамны никахлап үзенә хатынлыкка алып, үзенең теләгенә ирешеп, һәр икәве чиктән тыш шатландылар.* Дастан

2) *к.* **гыйшык-мәхәббәт, гыйшык-мыйшык.** *Берәүләр гаять белдекле кыяфәт белән хатын-кызлар турында сүз куерта, ниндидер яңа кафешантан җырчысы һәм аның гыйш-гыйшрәт маҗаралары турында гайбәт сата.* М.Галәү. *Әнә бит, алар да яшь булган кайчандыр, аларның да гомерләре гыйш-гыйшрәтсез генә үтмәгән.* Ф.Баттал

**ГЫЙШРӘТ** *и. гар. иск.* Ашап-эчеп кәефләнү. *Гыйшрәт мәйданының бәдәви толпары Һава – һәвәс галәменең очкыр шоңкары.* Дәрдемәнд

**ГЫЙШЫК** *и. гар.* Сөю, ярату, мәхәббәт. *Имеш, хатын-кыз гыйшкы язгы ташу кебек: бер күтәрелеп бәреләдә тына!* А.Гыйләҗев. *Сакля кырындагы учак янында кечкенә Мостафа бу картның гыйшык җырларын берничә тапкыр тыңлаган һәм йөрәгенә сеңдергән иде.* М.Мәһдиев. *Мәдхия өченме бу гасыр? Син, дөнья? Күп вакыт каргандык. Аннары, тәүбә! Дип, җыр яздык; Гыйшкыбыз яңарттык: сафландык...* Р.Гатауллин

**ГЫЙШЫК-ГАШРӘТ** *и. гар.* Сөю-мәхәббәт. *Хафиз гыйшык-гашрәт хәлләрен аңлаган!..* А.Гыйләҗев

**ГЫЙШЫКЛЫК** *и.* Гыйшык тору, гашыйк булу күренеше. *Ләкин мин яраттым! Иң мөһиме: сөю – гыйшыклык, мәхәббәт ич!* Р.Сибат

**ГЫЙШЫК-МӘХӘББӘТ** *җый. и. гар.* Гашыйклык, мәхәббәт тоту хисләре, шулар белән бәйле хәлләр

**ГЫЙШЫК-МЫЙШЫК** *и.* **1.** Гыйшык-гашрәт, сөю-мәхәббәт. *Безнең ике арада берниндигыйшык-мыйшык та була алмаганын аңларга күптән вакыт иде бит инде сезгә?* В.Нуруллин. *Мәхәббәт ул – серле талант, Гыйшык-мыйшык кына түгел. Кыйшык-мыйшык уеннардан Җәберләнә генә күңел.* Л.Шагыйрьҗан. *Бусы инде – Мотаһара апаң белән гыйшык-мыйшык уйнаганда төшкән сурәтебез.* Г.Тавлин

**2.** *с. мәгъ.* Мәхәббәт тирәсендәге, гашыйк булулар белән бәйле. *Героем әле карт түгел – Кырык-кырык бишләрдә. Тәҗрибәсе дә күп түгел Гыйшык-мыйшык эшләрдә.* Ф.Яруллин

**ГЫЙШЫ́К ТОТУ** *ф.* Ярату, сөю. *Аның гыйшык тотып йөргән кызы булган. Барый белән бер авылда туып үскән, ди, ул кыз ---.* Г.Гыйльманов

**ГЫЙШЫКЧАН** *с.* Бик тиз һәм еш гашыйк булучан. *Шәкертләр бик гыйшыкчан булалар. Син соң бер кызны да сөймәдеңмени?* Н.Исәнбәт

**ГЫК** *иярт.* Кинәт кенә тын кысылу яки сөйләгән җирдән ихтыярсыз сүзне өзү рәвешен белдерә

**ГЫЛДА́У** *и. диал.* Бугаз төере

◊ **Гылдавыннан алу** Көчләп, нәрсәдә булса эшләтү

**ГЫЛДЫР-ГЫЛДЫР** *иярт. к.* **голдыр-голдыр**

**ГЫНА** *кис.* 1) Предметның, күренешнең, санның, сыйфатның бары тик күрсәтелгәне генә булуын-булмавын, эш-хәрәкәтнең шунысы гына үтәлүен-үтәлмәвен аңлата, шуларны аерып, чикләп күрсәтә: фәкать, бары, бары тик, тик. *Мәхәббәтне сатып алып булмый, дип, бушбугазлар гына гайрәт чәчә бит ул.* В.Имамов. *Хыялда гына булса да Галәмне гизсәң икән.* Л.Лерон. *Әле утызга гына якынлашып килсә дә, илле яшьлек кешегә охшап, картаеп, ябыгып калган иде.* В.Нуруллин

2) Урын һәм вакыт рәвешләре белән килеп, шул вакытны яки урынны аныклый, чикли төшә, аралык ерак булмавын, якында гына булуын белдерә. *Безнең бакча артында гына урман.* В.Нуруллин. *«Тизме-соңмы, бар да китәсе бит Тарих дигән тирән китапка...» Янда гына яткан иркә песи Уйлый бугай бүген шул хакта.* Р.Әхмәтҗан. *Безнең аяк астыннан гына күгәрчен пырылдап очып китте.* Дөньяда ниләр бар

3) Шарт фигыль, хәл фигыль, сәбәпне белдергән сүзләр янында килеп, әлеге шарт, сәбәп, рәвеш һ.б.ш. бердәнбер булуын аңлата: фәкать шулай. *Кем белә, бәлки, безнең иман, вөҗдан да әниләр шәфкатеннән җылылык алып торганда гына саклана аладыр?* М.Юныс

4) Гел, бөтенләй; тулысынча. *Күк төтеннәр ягыннан киләм, шырт камыллар гына бар тирәм.* Р.Әхмәтҗан. *Запаньнарда бүрәнә шулкадәр күп җыела: бөтен елга агачтан гына тора икән диярсең.* Дөньяда ниләр бар

5) Сыйфат һәм рәвеш янында килеп, «байтак, шактый, чагыштырмача» мәгънәсен белдерә. *Талгын гына искән җилләр гөлләр исен китерде. – Гөләпләрдән күбәләккә Сәлам! – дигән шикелле.* Х.Туфан. *--- мине, шактый өлкән яшьләрдә булса да, әле нык, җитез һәм ягымлы гына карт каршылады.* В.Нуруллин. *Уйчан гына авышып бара август кавын исе килгән кырлардан!..* Р.Әхмәтҗан

6) Фигыль янында килеп, ул белдергән эш-хәрәкәтнең көчле, интенсив, кабатлаулы булуын күрсәтә. *Очтым гына кырмыска түмгәкләре өстеннән.* Ф.Яруллин. *--- каршыга килүче машиналарга кул болгый башладым. Чабалар гына!* А.Галиева

7) Фигыль янында килеп, аңа янау, кисәтү мәгънәсе өсти. *Котылыйм гына әле шушы төрмәдән!.. Кайтыйм гына!.. Күрсәтермен менә йөз граммны!* Г.Гыйльманов

8) Инкярләү формасындагы раслау җөмләләрдә *кем, нәрсә, кая, ничек, нинди* кебек алмашлыклардан соң килеп, аларда белдерелгән сан-сыйфат мәгънәсен арттыра, җөмләгә өндәү төсмере бирә. *Аның кебек ак айгырга атланып, Тарагыш урамнарын дер селкетеп чабып узу турында кайсы гына малай хыялланмады икән?* М.Маликова. *Җир өстендә дә су бик күп. Ләкин кайда гына булмасын, бер җирдә дә ул үз-үзенә аерым яшәми.* Дөньяда ниләр бар

9) Гомумән, җөмләдә бигрәк тә хәбәр белән белдерелгән фикерне интенсивлаштыра. *Директор, никадәр генә каты итеп ачуланырга тырышса да, булдыра алмады.* М.Мәһдиев

10) Ике эш-хәрәкәтнең үтәлү арасы аз булуын яки бөтенләй булмавын, бер үк вакытта үтәлүен белдерә. *Сәет алдагы тормышлары, киләчәк белән бәйле хыяллары хакында дәртләнеп сүз башлый гына, Хәния шундук зифа бармаклары белән аның иреннәрен ябып куя---.* Г.Гыйльманов. *Тау кадәр трактор, утлары белән авыл урамын тутырып, буран эченә кереп югалган гына иде, өстендәге карны кага-кага, чаттан уларының укытучысы килеп чыкты.* Г.Гыйльманов

11) Мөнәсәбәтле сүзләрнең иярчен җөмләдәгесе янында килеп, «һәммәсе, һәр» мәгънәсен тудыруда катнаша. *Газета-журналда басылган шигырьләрнең дә кайсын гына карасаң да, тынычлык һәм сугыш турында булыр.* Р.Миңнуллин

12) Сорау алмашлыгы белән килеп «һәммә, һәр, теләсә кайсы» мәгънәсен белдерә. *Исән булса, нинди нужаларга гына түзми адәм баласы!* М.Әмир. *Үзенә ошамаган яки, үзенә ошап та, укучылар күңеленә барып җитә алмаган әсәрләр кайсы гына язучының иҗат биографиясендә булмый соң?* Н.Фәттах

13) Кечерәйтү-иркәләү кисәкчәсе *-кай/-кәй* функциясен башкара. *Калмады туган ил генәм, калды нечкә бил генәм.* Җыр. *Янма, йөрәк, сызма, күңел, Өзгәләнмә, җан гынам. Күк айкала, җир чайкала, Сынма, рухым, бул чыдам.* Р.Вәлиева

14) Шигырьләрдә, җырларда иҗек санын саклау, ритмында тулылык булдыру өчен кулланыла. *Кызыл да гына төлке – урман күрке, Батыр егет, дусларым, ил күрке.* Җыр

15) **... гына түгел..., да** каршы куючы теркәгеч составында килеп, «бары тик, фәкать» мәгънәсен белдерә. *Әйе, явызлык кылган кеше теге дөньяда гына түгел, фанилыкта да үз җәзасын ала.* И.Сираҗи. *Ул [ефәк корты] тут агачының яфрагын гына түгел, җимешен һәм яшь ботакларын да ашый башлый.* Дөньяда ниләр бар

**ГЫРГЫЛДА́У** *ф.* Көлгәндә, тамак кырганда һ.б.ш. бугаз төбеннән өзек-өзек калын тавышлар чыгару

**Гыргылдап алу** Бераз гына, кыска гына гыргылдаган тавыш чыгару. *Шунда тәмәке тартып торган янә ике-өч кеше – шайка членнары – бертавыштан гыргылдап алдылар.* Ш.Шәйдуллин

**Гыргылдап тору** Бертуктаусыз гыргылдаган тавышлар чыгару

**ГЫРГЫЛДЫК** *с. к.* **гырылдык**

**ГЫР-ГЫР** *иярт.* **1.** Йоклаганда, авыр сулыш алганда, һава агымы йомшак аңкау тукымаларын калтыратып үткәндә барлыкка килә торган тавышны белдерә. *Зиндандагы әсирләр көнозын кырда каты хезмәт итеп тәмам арыганлыктан, һәммәсе баһадирлар йокысы илә гыр-гыр йокламакта иделәр.* Ш.Мөхәммәдев. *Семён һаман гыр-гыр йоклый, ат тотучы да дилбегәсен бушатып, ял итеп бара.* М.Хәбибуллин

**2.** *и. мәгъ.* Сулыш юлы, бугаз; бугаз төене. *Шуннан [Биктимер Нургалие] бугазымнан тотып алып, мунча идәненә сузып салды да гыр-гырымнан буа башлады...* Т.Гыйззәт

**ГЫ́Р-ГЫР КИЛҮ** *ф.* Гырлау, гыр-гыр иткән тавыш чыгару. *Мич башында йоклаган чакта бабай, гыр-гыр килеп, Син дә йоклыйдыр идең бер читтәрәк, мыр-мыр килеп.* Г.Тукай. *Кайдадыр Гәрәй Солтан күренде, аны асарга алып баралар, дар агачына китереп, муенына җеп сала башлауга, ул кайдадыр югала да, баштанаяк кызыл киенгән кара йөзле палач үзе аның урынына асыла, нидәндер гыр-гыр килә, күзләре коточкыч булганнар.* Г.Ибраһимов. *Мендәремне кочаклап, гыр-гыр килеп, рәхәтләнеп йокларыем мин.* Ә.Хәсәнов

**ГЫРЛА́У** *ф.* 1) Гыр-гыр иткән тавыш чыгару (гадәттә, йоклаганда). *Элеккеге бабасы шулай чалкан ятса гырлый иде. Гырламаганда, мыш-мыш килеп сулыш алып йоклый иде.* Р.Батулла. *Йокыдан, арып-талып, авыр эштән котылган кебек торды. Агайлар гырлап йоклыйлар.* Р.Вәлиев. *Авыл йоклый... Авыл гырлап йоклый, эшләгәне йокмый үзенә.* Ә.Синугыл-Куганаклы

2) *сөйл.* Йоклап яту. *Җилкәсе артында сәер тавышка борылып караса, өстәл астындагы урындыкка утырган ир кеше, башын өстәлгә куйган да, ваемсыз гырлый иде.* Р.Вәлиев

**Гырлап алу** Бераз, кыска гына ара гырлау. *Тора-бара йокы авырлыгыннан, ахры, аяклары сыгыла барып чүгәләде һәм шул чүгәләгән хәлендә берничә тапкыр гырлап та алды.* Н.Әхмәдиев

**Гырлап җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә гырлый башлау. *Ә теге... Берни белмичә йоклый. Җитмәсә, шундук гырлап та җибәрде...* Л.Лерон. *Менә-менә йоклап китәм дигәндә генә, берәрсе ыңгыраша башлый, икенче берсе бүрәнә тарттыручы трактордан да катырак итеп гырлап җибәрә ---.* И.Сираҗи

**Гырлап кую** Кинәт, бер мәртәбә яки сирәк кенә гырлау. *[Мәсәй] Яман гырлап куям кайчакта. Кычкырам да... [Рәхилә] Рәхәтләндерәсең бар икән әле. Фу!* А.Гыйләҗев. *Гыйрфан мулла үзе йоклаган булып ята. --- Ара-тирә гырлап та куйгандай итә.* С.Поварисов

**Гырлап тору** Һәрвакыт, гел яки хәзерге моментта гырлау

**Гырлый башлау** Гырлап җибәрү. *Мәгарә эчендә Алып Бәргән батырларча гырлый башлады.* Р.Батулла. *Шуннан соң кайберәүләр өйләренә кайтып китте, кемнәрдер чирәм өстенә авып гырлый башлады ---.* М.Шаһимәрданов

**Гырлый бирү** Бернигә карамый гырлавын дәвам итү; һаман да гырлау

**ГЫРЫЛ-ГЫРЫЛ** *иярт. к.* **гыр-гыр**

**ГЫРЫЛДАВЫК** *с.* **1.** Тамак төбеннән чыккан, түбән, гырылдап торган. *Урамнан берәү таза, гырылдавык тавыш белән җырлап узды: «Әйдә киттек Чиләбегә, Ничу монда чиләнергә ---».* М.Мәһдиев. *Рашат әллә нинди гырылдавык тавыш белән көлеп җибәрде.* Ф.Садриев

**2.** *и. мәгъ.* Бугаз, гыр-гыр

◊ **Гырылдавыгын өзү** *туп.* Үтерү

**ГЫРЫЛДА́У** *ф.* **1.** 1) Гыр-гыр иткән тавыш чыгару, гырлау. *Гитлерчы, тамак төбе белән гырылдап, ике тапкыр номерларны әйтеп чыкты ---.* Г.Әпсәләмов. *--- эт атылып торды да экран янына сикерде. Гырылдаган тавыш белән экранга карап өрә башлады.*

М.Мәһдиев. *Ирләрдәге ике сыйфат пычаксыз суя мине: исерек баштан сырышу һәм гырылдап йоклау.* М.Юныс

2) *күч.* Йоклау. *Зөһрә ачудан бер чүмеч салкын су чумырып алды да гамьсез гырылдап ятучы Гайфулланың муенына койды.* Ф.Яруллин. *Моны әйтәм, син эт булып арып кайтасың, ә ул аю сыман гырылдап ята.* И.Юзеев

**2.** *и. мәгъ.* Гырлау тавышы, гырлау күренеше. *Ул, әлбәттә, болай шакуга гына уянмады, бөтен өйне дер китереп гырылдавын дәвам итте.* З.Фәтхетдинов. *Полицай кыймылдап куйды һәм гырр-гырр килде. Бу үлем гырылдавы иде.* Х.Камалов

**Гырылдап җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә гырылдый башлау. *Харис абыйның йокы арасында гырылдап җибәрүе миңа җитә калды: тагын катырак елый башладым.* Г.Садри

**Гырылдап китү** Әкренләп, сизмәстән гырылдый башлау. *Нәҗип әкрен генә гырылдап китте, Фәрхетдиннең дә күзен әчеттереп йокы тырный башлады.* Ш.Бикчурин

**Гырылдап тору** Гел, бертуктаусыз гырылдау; шушы моментта гырылдау

**Гырылдап яту** Бик озаклап, иркенләп гырылдау. *[Мәннан] Йокламадым мин, йокламадым, аңымны җуеп егылганмын. [Әхтәм] Тагы нәрсә шыттырасың? Аңын җуйган кеше алай гырылдап ятмый.* Аманулла

**Гырылдый башлау** Гырылдап җибәрү, гырылдарга керешү. *Суров һаман да сөйләр иде, ләкин Ковальчук гырылдый башлады. Суров, аңа ачуланып карап: – Бу бозау йокларга да өлгерде, – дип сүгенеп куйды.* А.Таһиров. *Камыт бууыннан, авыз-борынына су тулудан күзләре акайган ат яман пошкыра, ул да түгел гырылдый ук башлады.* Ж.Дәрзаман

**Гырылдый бирү** Бернигә карамый гырылдавын дәвам итү

**ГЫРЫЛДЫК** *и.* **1.** 1) Бугаз

2) Бугаздан чыккан тавыш, бик түбән саңгырау аваз. *Кычкырырга уйлады. Әмма тавыш чыкмый. Ниндидер гырылдык кына килә тамак төбенә.* С.Поварисов

3) Йоклаганда гырлаучы кеше

**2.** *с. мәгъ.* Гырылдап, тамак төбеннән чыга торган. *Коридорда ниндидер ыгы-зыгы башланды. Швейцар картның гырылдык тавышы ишетелде.* М.Мәһдиев. *Теге гырылдык тавышы белән СССРны җимергән җырчы бар иде бит әле?* А.Хәлим. *Озын адәм гырылдык тавыш белән тамак кырып куйды.* Ф.Садриев

**ГЭБЭЧЫ** *и.* Дәүләт куркынычсызлыгы органнарында эшләүче кеше (ГБ – «госбезопасность» кыскартылмасыннан ясалган). – *Узеңне бик кыю тотасың син, кайда икәнеңне оныттың, ахры? – почмактан яшь гэбэчы тавыш бирә.* Идел

**ГЭБЭ́ШНИК** *и. рус сөйл.* Дәүләт куркынычсызлыгы органнарында эшләүче кеше. *Әлеге гэбэшник белән һич тә уйламаганда очрашкан идек без.* Идел. *Гэбэшник өркетүен дәвам итә: – Беләсезме, мин каян килдем? Куегыз кулыгызны!* Идел

**ГЮРЗА** *и. фар.* Кара еланнар семьялыгыннан, Төньяк Африкада һәм Көньяк-Көнбатыш Азиядә таралган агулы елан. *Еланнар тота торган махсус питомникларда, серпентарийларда, фармакология белгечләре еланның «агуын кысып» чыгаралар һәм аеручa хәтәр (куркыныч) агулы еланнар – гюрза, кобра, эфа чагуына каршы сыворотка ясыйлар.* Татарстанның үсемлек һәм хайваннар дөньясы

**ГЯҺ** *рәв. фар.* Кайчак, кайвакыт, әле, кайчакта. *Хатыны Гөлсаз бер кеше илә көлеп, гяһ егълап сүзләшәдер.* Ф.Халиди

**ГЯҺ-ГЯҺ** *рәв. фар.* Әледән-әле, вакыт-вакыт; кайвакыт. *Әмма Дәһханә сандык эчендә дәва иснәп, --- гяһ сандык илә өстән, гяһ астан агып барыр иде.* Ф.Халиди

# Д

**ДА** I *кис.* 1) Үзеннән алда килгән сүзнең тәэсирен, мәгънәсен көчәйтү максатында кулланыла, шул сүзгә басым ясауны белдерә. *Аның өчен үтә җаваплы эш иде бу. Эш кенә дә түгел, сынау. Сынауның да ниндие әле.* Р.Мөхәммәдиев. *[Мирвәли:] Алпавытның да ниндие генә әле. Бер миллион десятина җире бар.* Т.Гыйззәт. *Айгырның да ниндие әле: кеше талый торганы!* Ш.Маннапов

2) Кабатлап әйтелгән исемнәр арасында килеп, соклану хисе белән белдерелгән тезмәдә басымны куәтли. *Атлары да атлары, --- канатлары гына юктыр*. М.Хәбибуллин

3) Тиңдәш кисәкләрдән соң кабатланып килеп, аларны үзара бәйләү белән бергә экспрессияне арттыра, мәгънәне көчәйтә төшә. *Минем җаныем – бригадир, Күкрәгендә медале; Казанда да, Мәскәүдә дә Белмәгән юк инде аны.* Җыр. *Янында Зыя да юк, бакча да, нур да, чәчәкләр дә, теге чатыр эчендәге диңгез дә – берсе дә юк.* Г.Ибраһимов

4) «Хәтта» мәгънәсен белдерә. *Авыл башындагы куш наратка атлар да бит борылып карады.* М.Галиев

5) Исемнәр янында ялгыз үзе генә килеп, «тагын», «шулай ук» мәгънәсен белдерә. *Башкалар белән Җиһанша бабай да килгән иде.* Г.Ибраһимов. *Быел Шәмгун Сафасы да язны мыек чыккан егет кебек каршы алды.* А.Шамов

6) Иярчен урын җөмлә хәбәреннән соң килеп, «шунда ук», «шуннан соң ук», «үтү белән» сүзләренә якын тизлек, кинәтлек мәгънәләрен белдерә. *Йортның эргәсе янында ятып торган Караборын, бу көтелмәгән шәһәр киемендәге кунакларны куркытырга теләп, урыныннан сикереп торды да, арка йоннарын торгызып, аларга ташланды.* Һ.Такташ

7) Шарт фигыльләр составында килгәндә, кире шарт мәгънәсен белдерә. *Сәгать сигез булды. Кияү мулладан элек чәй эчү әдәпсезлек булса да, Мәрфуга абыстай чәйсез түзә алмады.* Г.Исхакый. *Сагынсам да сине, яратсам да сине, Кайта алмыйм әле хәзергә.* Һ.Такташ

8) Сузып җырлана торган озын көйле халык җырларында ритмик төзеклекне саклау өчен кулланыла (гадәттә «ла» кисәкчәсен алмаштыра). *Ай-һай да гына дими көйләр килми, Кайгылар ук күрми ир булмый. Нинди генә итеп сөйләсәң дә, Чит-ят илләр туган ил булмый.* Җыр

**ДА** II *терк.* 1) Гади һәм тезмә кушма җөмләләрдә, тиңдәш җөмлә кисәкләрен яки гади җөмләләрне теркәп, «аннан соң» мәгънәсендә кулланыла. *Кесәләр тулгач, артык озак баш ватып тормыйча, пинжәгемне асфальтка җәеп куйдым да акчаны шунда ыргыта башладым.* З.Мәхмүди. *Паровоз берничә мәртәбә ахылдап куйды да урыныннан кузгалды.* Р.Ильяс

2) Сан, микъдар-күләм, яшьне һ.б.ш. белдергән сүзләрне теркәп килә. *Алты ай да җиде көн*

3) Күп урынлы саннарның янәшә буыннарын теркәп килә. *[Хәбибрахман:] Йөз, йөз ун, йөз егерме – булды бер сум да егерме тиен. Бусы өч тәңкә, барысы була... Ике, өч, дүрт сум да егерме тиен.* Г.Камал. *Шадра түти биш сум тиешле. Тешсез карчыктан бер сум да егерме биш тиен аласы.* М.Галәү

4) Эш-хәлнең тиз үтәлүен, җитез башкарылуын белдергән фигыль тезмәләрендәге сүзләрне теркәп килә. *Дәресләр күпвакыт урамда, спорт мәйданчыгында үткәнлектән, пунктлап яза да куя: бару, фәлән-фәлән күнегүләр эшләү – шуның белән вәссәлам!* Р.Низамиев. *Сикереп, кинәт иярга басты, артына борылды... борылды да, күз ачып йомган арада, сөңгесен ераклаша барган җайдакка тондырды.* Н.Фәттах

5) Тиңдәш кисәкләрне теркәп, чикләүне белдерә. *Һи-и, мин дә хатын бар дип яшәгән булам бит бу дөньяларда. Бөтен белгәне – бәлеш тә өчпочмак, кыстыбый да коймак, пылау да пилмән.* Ф.Баттал

6) Фигыль кабатланып ясалган тезмәдә, шул ике фигыль арасында килеп, процессның дәвамчанлыгын белдерә. *[Әбүзәр:] Әйе, исән, пленга эләккән. Харьков янындагы лагерьда ята икән. Егетнең тормышы авыр, ди... Анасы, мескен, башын да күтәрми, елый да елый...* Г.Исхакый. *Буран дулый да дулый, әти һаман юк.* Г.Бәширов. *Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә.* Ә.Еники

7) Беренче сүзенә логик басым төшкән тезмәдә кабатлап әйтелгән фигыльләрне теркәп, шөбһәсезлекне, ассызыклап әйтүне белдерә. *Ирләрне күрсә, Иблис кача да кача инде ул!* Ф.Яхин

8) Ымлыкларны, ияртемнәрне кабатлап ясаган тезмәдә кулланылып, тизлекне, эш-хәлнең активлыгын белдерә. *Һавада, выж да выж килеп, өзелгән колаклар, йолкынган чәчләр, сынык тешләр очып йөри башлады.* З.Мәхмүди

9) Каршы куюу бәйләнешендәге җөмлә кисәкләрен яки җөмләләрне теркәп, «ләкин», «карамастан» дигәнне белдерә. *Һавада очарга яратсам да, мин – җир кызы.* Шәһри Казан

10) Тезмәдә тиңдәш кисәкләрнең һәрберсеннән соң кабатланып, аларга басым ясый, ассызыклый; «һәм» функциясен үти. *Озын коридор да, бина эче дә нииндидер үзгәреш кичергән, ямьсезләнгән кебек тоелды аңа.* Р.Фәизов. *Ык аръягындагы яшел куаклар да, зәңгәрләнергә өлгермәгән күк тә әле төн шәүләсен саклыйлар.* Ф.Садриев. *Бер үк вакытта чибәр дә, акыллы да, тыйнак та, булдыклы да.* Мәгърифәт

**ДАВЫЛ** *и.* 1) Явым-төшем алдыннан яки явым-төшем вакытында була

торган бик көчле, җимергеч җил. *[Акчарлак:] Әй ана, очыйк диңгезгә, Бу җирләрдә һава тар сиңа. Авыруларың суга салырсың, Давыллардан гыйбрәт алырсың.* Ф.Яруллин. *Агач башларын җай гына тибрәтеп искән бу җил кинәт көчәйгәннән-көчәя барды. Берничә минуттан соң инде ул көчле давылга әверелде.* Г.Галиев. *Давыл бәпкәкиштәләрне чытырдатты, өй түрендәге топольнең ботакларын, сындырып, күккә күтәрде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Көчле бәрелеш, зур куәт, дәһшәтле ыгы-зыгы белән үтә торган эш-хәл, процесс, күренеш. *[Сугыш кырындагы] Бу котырынган ут һәм тимер өермәсенә кемнең дә булса җитәкчелек итүе, бу коточкыч давылның кемнеңдер ихтыярына буйсынуы акылга сыймаслык бер нәрсә кебек тоела.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Иҗтимагый тормыштагы, җәмгыять тормышындагы дәһшәтле вакыйгалар, бәрелешләр. *Әле бит геройларның язмышы төйнәлгән, чуалган килеш калды. Әле алда – очсыз-кырыйсыз тормыш давыллары.* Ф.Садриев

4) *күч.* Зур ызгыш, талаш, гауга. *Давылның беренче өермәсе озак көттермәде. Ык буеннан кайтышлый, аңа Мосаллия очрады.* Ф.Садриев

5) *күч.* Хисләрнең чамадан тыш көчле булуы, бөтен күңелне биләп алып, тулышып торуы турында. *Галимҗан, эчке кичерешләр давылында бәргәләнсә дә, үзен нык тотты, коелып төшмәде.* С.Поварисов. *Илһамның гәүдәсе авырайган, күңелендә аңлаешсыз кичерешләр давылы бөтерелә иде.* Ф.Садриев

6) *махс.* Кояш плазмасының активлыгы көчәю нәтиҗәсендә, Җирнең магнит кырындагы зур үзгәрешләр. *Дизентерия һәм корсак тифы, талпан энцефалиты һәм туляремия, балаларда дифтерия һәм кызамык – барлык бу куркынычлы авырулар Кояш «давылы» чакта көчәяләр.* Могҗизалар энциклопедиясе

◊ **Давыл кузгату** Көчле хисләр уяту, җанландыру

**ДАВЫЛБАЗ** *и. фар. муз.* Бәрмә музыка уен коралы. *Шәһәр капкалары өстендәге күзәтчеләрнең дум-думбакларда, давылбазларда бәреп, Казанның олы сәүдәгәрләренә яшерен телдә хәбәр биреп, базарга кай тарафтан нинди кәрван килүен белгертеп торуын да шул чакта белде Сәет.* Ф.Латыйфи

**ДАВЫ́Л КОШЫ** *и. зоол.* Көпшәтомшыклылар семьялыгыннан, тар һәм озын канатлы, ыргак сыман томшыклы диңгез кошы; *русчасы:* **буревестник.** *Күп төрле меңнәрчә кошлар: акчарлаклар, кайралар, чистиклар, давыл кошлары, гагаралар, бакланнар, шөлдиләр боз араларында --- туенып йөриләр.* Дөньяда ниләр бар

**ДАВЫЛЛАНУ** *ф.* 1) Давыл чыгарып хәрәкәтләнү. *Давылланып, яңгыр килә иде.* Р.Сибат. *Ак чәчәкләр Җиргә сибелә Давылланып яуган яңгырдан.* Х.Камалов

2) Давыл тәэсире астында бик көчле хәрәкәт итү. *Диңгез давыллана*

3) *күч.* Талашу, ачулану һ.б.ш. көчле хисләрне тышка чыгару; ярсу. *Әйе, шундый чакларым бар: Давылланып чатнавым бар. Табылмасын табар кебек, Көндез чыра якканым бар.* Н.Арсланов

4) *күч.* Бик зур куәт, үтә көчле дәрт белән ашкынып, нәрсәгәдер омтылу, алгысу һ.б.ш. *[Шагыйрь] Давылланып яшәргә омтыла.* Г.Хуҗиев. *Тик төн буе шагыйрь бүлмәсендә Ут балкыды көннән яктырак. Давылланып, аның йөрәгеннән Ак кәгазьгә хисләр актылар.* М.Җәлил. *Ул гомер буе давылланып эшләп йөрде.* Ватаным Татарстан

**Давыллана бару** Давыллануы акрынлап көчәю. *Көн давыллана барды*

**Давыллана башлау** Давылланырга тотыну. *Яратам мин, күкрәк куеп шул давылга, Бертуктаусыз һаман алга ыргылырга. Давыллана башлый шунда барлык хисем, Шул давыллы чорда чөнки туып-үстем, Шул давыллы чорны кичтем!* Ә.Исхак

**Давыллана төшү** Тагын да давыллану. *Кояш чыкса да, көн давыллана төште*

**Давылланып алу** Бераз давыллану. *Диңгез өсте давылланып алды*

**Давылланып калу** Ниндидер тышкы тәэсирдән, этәргечтән соң давыллану. *Ул киткәч, күңелем давылланып калды*

**Давылланып китү** Кинәт давыллану. *Салмак җил көчәеп, давылланып китте*

**Давылланып кую** Бераз гына давыллану

**Давылланып йөрү** 1) Озак вакытлар дәвамында, сөйләү моментында давыллану

2) *күч.* Көчле дәрт, бик зур куәт белән эшләү, хәрәкәтләнү һ.б.ш. турында

**Давылланып тору** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында бераз давыллану

**ДАВЫЛЛА́У** *ф.* Давыллы булу. *Ул да түгел, пәри туе уйнатып, давыллап, җил исә башлады.* Р.Мөхәммәдиев. *Кичтән үк давыллау*

**Давыллап алу** Бераз, озак булмаган вакыт аралыгында давыллау

**Давыллап кую** Кинәт, көтмәгәндә давыллау

**Давыллап тору** Әледән-әле яки берөзлексез давыллау; сөйләү моментында бераз давыллау

**Давыллый бару** Давыл артканнанарту, көчәю, көчәя барып давыллау

**Давыллый башлау** Давылларга тотыну. *Вакыт-вакыт җил давыллый башлый, Күккә өермәләр сузыла.* Р.Маннапов

**Давыллый бирү** Бернигә, бернәрсәгә карамастан, давыллауны дәвам итү, һаман да давыллау

**Давыллый төшү** Тагын да давыллау

**ДАВЫЛЛЫ** *с.* 1) Давылы (*1 мәгъ.*) булган; давыл белән бергә була торган. *Авыл читендәге зәңгәр тәрәзәле йорт эчендә давыллы, караңгы төндә, үксепүксеп, аталы-уллы ике ир елый иде.* М.Мәһдиев

2) Давыл тәэсирендә хәрәкәтләнеп, көчле болганып торган. *Давыллы-җилле диңгез киңлегендә Күрсәң икән син дә дусыңны.* Ш.Маннур

3) *күч.* Көчле, ташып торган хис һ.б.ш. турында. *Галимҗан үзен тыныч тотты. Гөлсемнең исә эче давыллы иде.* С.Поварисов

4) *күч.* Хәвефле, дәһшәтле, шау-шулы иҗтимагый һәм шәхси бәрелеш-

ләргә бай булган. *Мине һаман очу, ил гизү, давыллы тормыш үзенә тарта иде.* М.Юныс

**ДАВЫ́Л ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, катмарлы сары чәчәкле, дымлы урыннарда үсә торган күпьеллык яки берьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы*: **купальница европейская**

**ДАГА** *и.* 1) Ат тоягын зарарланудан саклый, гомумән, таймасын өчен, ат тоягына кадаклап беркетелә торган, тояк формасында металлдан эшләнгән махсус җайланма. *Берәр җиргә китәсе булса, ул җигә торган атларының дагаларын алдырып, фаэтон көпчәкләрен бикләп китә иде.* М.Галәү

2) Табаны ашалудан, тузудан саклау өчен, күн аяк киеменең үкчәсенә һәм табанының алгы өлешенә кадаклап беркетелә торган, дуга формасындарак итеп эшләнелгән юка металл җайланма. *Немец солдатлары бүлмәләргә кереп йөриләр. Тимер дагалы итекләрнең тавышы якынлаша бара.* Н.Дәүли

**ДАГАБОРЫН** *и. зоол.* Борыны ат дагасына охшаган зур колаклы ярканат

**ДАГАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **дагалау**. *Атлар дагаланган*

2) *күч. сөйл.* Тәҗрибәле, чыныккан, үткен кешегә әйләнү. *Сәлимов каладан дагаланып кайткан.* Ф.Хөсни

**ДАГАЛА́У** *ф.* 1) Дага беркетү, дага кадаклау. *Иртышның ярларын мин аралыймын, Боз булса, күк атымны дагалыймын.* И.Салахов. *Кыргыз атларының сыртлары гаҗәп чыдам һәм тояклары бик нык була, хәтта аларны дагаламыйлар да.* Дөньяда ниләр бар?

2) *күч. сөйл.* Нинди дә булса өлкәдә яхшы белем бирү, тәҗрибә туплату. *Умартачылык һөнәренә дагалау*

3) *күч. сөйл.* Алдау. *Кара аны, дагалый күрмәсеннәр үзеңне*

**Дагалап бетерү** Дагалауны тәмамлау; бөтенесен дә дагалау. *Ниһаять, атларның барысын да дагалап бетерделәр*

**Дагалап кую** Алдан дагалау, дагаланган хәлгә китерү. *Итекләрнең табаннарын дагалап кую*

**Дагалап тору** 1) Әледән-әле, еш, һәрвакыт дагалау. *Атларны гел дагалап торалар*

2) Сөйләү моментында дагалау белән шөгыльләнү

**Дагалап яту** *к.* **дагалап тору**

**Дагалый башлау** Дагаларга керешү

**Дагалый бирү** Бернигә игътибар итмәстән дагалауны дәвам итү

**ДАГАЛЫ** *с.* Дагаланган; дага кагылган, дагасы булган. *Хасбулатова, рәхмәт әйткәч, дагалы ат асфальттан баргандай, керт-керт басып, янбашларын килешле уйната-уйната чыгып китте.* Ф.Садриев

**ДАГАН** *и. сөйл.* Гадәттә асылма утыргыч рәвешендә булган, атынып уйнау өчен ясалган җайланма; таган. *[Сөләйман:] Чәченә чал кергән кешегә даган атынып йөрү килешер микән соң?* Ф.Әмирхан. *Лапасның матчаларына даган асканнар, без, чиратлашып, шул даганда атынабыз.* А.Расих

**ДАГЕРРО́ТИП** *и. фр.* Дагерротипия ысулы белән эшләнгән сурәт. *Бүлмәгә күп итеп дагерротиплар эленгән*

**ДАГЕРРО́ТИПИЯ** *и. фр.* Металл пластинкага сурәт төшерү ысулы (йодлы көмеш катламы белән каплау турында)

**ДАГСТАНЛЫ** *и.* Дагстан Республикасында яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе, вәкиле. *Алар өчәү, чеченнәр бугай, ә бәлки, дагстанлылардыр, алар бит барысы да бер төсле.* Р.Мирхәйдәров

**ДАИМ** *рәв. гар. кит.* Һәрвакыт, һәрчак, гел. *«Катгый күрсәтмәләрен» биреп, Хрущёв һәм Брежнев заманнарында гадәткә кергәнчә, мул итеп сыйланалар да, алар киткәч, көндәлек даим оператив җитәкчелек, чутлап бетергесез нужа-проблемалар, чишәсе төеннәр, үрлисе үрләр шәһәр комитеты өстенә авып кала*… Ф.Дунай. *Нинди генә җиңел комедияләрдә уйнамасын, ничек кенә «ат койрыгына асылынып» йөрмәсен, сизгер тамашачы бу актёрның гамьсез кыланышлары астында ниндидер кешелек фәлсәфәсе яшеренгәнлекне, фаҗигале һәм кешеләргә яхшылык теләүче гадел җан барлыгын даим сизеп утыра.* Ф.Хөсни. *Вәзир әйтте: – Даим моны [табутны] күрсәм, үзен күргән кебек булырмын.* Мәҗмугыл-хикәя

**ДА́ИМӘН** *рәв. гар. кит.* Һәрвакыт, гел, өзлексез. *Яхшы кеше Аллаһ Тәгаләне даимән зикер итүчедер.* Татар мөселман календаре

**ДАИМИ** *с. гар.* **1.** 1) Гадәти, һәрвакыттагы, үзгәрми торган. *Чәй мәҗлесе… Гыйльми Совет әгъзаларының бик күбесе моңа йөрми… Ләкин «банкет» дигән мәҗлеснең даими халкы, яратучылары була.* М.Мәһдиев. *Хәзерге заман хикәя фигыль һәрвакыт булып торган яки кабатланган (даими һәм гадәти) эш-хәлләрне белдерә.* Татар теле. *Маңгай тамырыннан кан алу баш-күз авыруына вә даими баш авыртуга бик файдалыдыр.* Мирас

2) Озак срокка билгеләнгән, вакытлы гына булмаган. *Казан ханлыгын яулап алу – даими гаскәр оештыру эшенең барышын өзгән.* И.Измайлов. *--- Гөлсем 1927 елда Казан радиокомитетына даими җырчы булып хезмәткә урнаша*… Ф.Хөсни

3) Туктаусыз, өзлексез килә торган. *Соңрак, Шиһабетдинов үз отряды төзегән совхозда директорның тәэминат һәм төзелеш буенча урынбасары булып эшләгәндә, болай да рәхәт тормышка яхшы һәм даими эш хакы, даими премияләр һәм хезмәт машинасы да өстәлә.* Татарстан

4) Үзгәрми торган. *Даими капитал. Даими зурлык*

**2.** *рәв. мәгъ.* Өзлексез, туктаусыз. *Бу әсәр --- соңгы ике гасыр дәвамында, даими нәшер ителеп, басма китап хәлендә дә бөтен Урта Идел һәм Урал буена таралган*… Ф.Фәсиев

**ДАИМИЛЕК** *и.* Даими булу. *Даимилек бар, мәңгелек ул.* Ш.Галиев. *Саматта – авыл егетендә – тырышлык, даимилек, эш-планнарда төгәллек, тотрыклылык көчле.* М.Вәлиев

**ДАИМЧЫЛЫК** *и.* Даими булу хәле һәм сыйфаты. *Олуг гөнаһлар олуг гөнаһлыктан чыгалар вә даимчылык кылу сәбәбеннән кече гөнаһлар да олуг гөнаһ булалар.* Татар мөселман календаре. *[Аллаһ Тәгалә] Ун төрле төркемне, тәүбә кылмасалар, ярлыкамас: сихерчене --- исерткеч эчәргә даимчылык кылучыны вә зиначыны ---.* Татар мөселман календаре

**ДАИР** *бәйл. гар. иск. кит.* Нәрсәгә дә булса, кемгә дә булса кагылышлы, мөнәсәбәтле; шуңа караган, шуның хакында. *Хәсби әби бу урманнарның бетүләренә даир әллә ничаклы [эшләрне белә].* М.Гафури. *Кыз Москва тормышына даир сөальләр бирә ---.* Ф.Әмирхан. *[Җәгъфәр әфәнде] Руслардан берсе-берсе моңарча даир бербер сүз ачмасын дип, тиз генә икенче якка чыкты.* Г.Исхакый

**ДАИРӘ** I *и. гар. кит.* 1) *иск.* Түгәрәк

2) Әйләнә-тирә, мохит, чолганыш. *Василий, гадәт буенча, Урдага хан хәзрәтләре хозурына барып, илтифатына лаек булды, һәм, үтенүенә күрә, Мәскәү кенәзлегенең даирәсен киңәйтергә вә көчәюенә сәбәп булган өстенлекләр бирелде...* Һ.Атласи

3) Бер үк һөнәр, уртак эш, уртак карашлар белән бәйле кешеләр төркеме. *Кайвакыт ул мәдрәсәгә үзе килә, кайвакыт исә шәкертләрне үз өенә чакыра: татарның дини һәм «голәмә» даирәләре белән даими бәйләныш тота иде.* М.Галәү. *Укучы масса өчен иң мөһиме – әсәр; ул үзе бар, объектив рәвештә яши һәм хәрәкәт итә; ул кешеләрне, үзенчәлекле әдәби зат – персонаж буларак, үзенә җәлеп итә, укучы-тыңлаучылар даирәсен оештырып, аларны үзенә дәшеп, чакырып тора.* Ф.Фәсиев. *Җитәкче даирәләрдә эшләүчеләр арасында --- «Ике мишәр башы бер казанга сыймады» дигән мәзәк таралды.* Ф.Дунай

4) Бербөтен итеп карала торган темалар, мәсьәләләр берләшмәсе, җыелмасы, шуларны үз эченә алган берәр өлкә. *Психик даирә ул физик даирә түгел, һәм шуңа күрә ул фәнни тикшерүгә бирелми.* Могҗизалар энциклопедиясе

5) Гореф-гадәт, үз-үзеңне тоту нормалары. *Әдәп даирәсе*

**ДАИРӘ** II *и. гар. муз.* Шәрык халыкларының бәрмә уен коралы. *Даирәдә уйнау*

**ДА́ЙДЖЕСТ** *и. ингл.* Башка басмалардагы материалларны (еш кына кыскартып) бастырып бара торган вакытлы басма яки шул басмадагы бер бүлек, рубрика

**ДАК-ДАК** *иярт.* **1.** Шакылдап ишетелгән түбән тондагы саңгырау, көчле тавышларны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шуңа охшаш шакылдаган тавышлар чыгарып. *Дак-дак басып килү. Дак-дак басып чыгып китү*

**ДАКА́ ТУН** *и. к.* **доха** (эче-тышы мехлы тун). *Аның өстенә йонын тышка калдырып тегелгән дака тун килеп капланды.* Н.Фәттах

**ДАК-ДОК** *иярт. к.* **дак-дак**

**ДАКТИЛОСКО́ПИК** *с.* Дактилоскопиягә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Ни өчен миллиардлаган кешеләрнең бармак башларында һәм уч төпләрендә кабатланмас дактилоскопик бизәкләр ясалган? Бармак эзләре организмның үзенә генә хас ниндидер индивидуаль үзенчәлекләрен чагылдыралар, үзенең хуҗасы турында күп нәрсә сөйли алалар дип уйларга кирәк.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДАКТИЛОСКОПИ́Я** *и. фр.* 1) Бармак эзләрен өйрәнүгә юнәлтелгән фән. *Дактилоскопия белгече*

2) Бармак эзләре буенча кешенең шәхесен билгели торган ысул, алым. *Әлеге документка караганда, Русия армиясендә теләсә кайсы илдән, урыс телен белгән һәм дактилоскопия аша үткән, 18 яшьтән 30 яшькәчә булган һәркем хезмәт итә ала.* Татарстан яшьләре

**ДА́КТИЛЬ** *и. гр. әд.* Силлаботоник шигырь төзелешендә (рус, немец, инглиз телләрендә) басымы беренче иҗеккә төшә торган өч иҗекле шигырь буыны. *С.Р.ның вәзеннәр тугърысында артык лаф сугуына исегез китмәсен. Әле без татарларда теория словесности вә шигырьләр өчен хорей, дактильфәләннәр ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк.* Г.Тукай

**ДАЛА** *и.* **1.** 1) Бик зур мәйданга җәелгән, күбесенчә үләнчел үсемлекләр белән капланган тигез җир, кыр (коры якларга хас, мәс., Себердә – Кулунда даласы). *Без Талас даласы кебек очсыз-кырыйсыз диңгезләр барын, анда таудай кораблар йөзеп йөргәнен, лампага сала торган керосинның җир астыннан чыгуын белдек.* Ч.Айтматов. *Бу язда дала бөтенләй үзгәргән: аксыл кылган урынына – кубарылып ташланган дымлы кап-кара җир.* И.Салахов

2) Гомумән, зур мәйдан биләгән тигез җир, ачыклык. *Төнге далада иснәнеп, каранып йөри торгач, ул шулай да билгеле бер карарга килә алды.* Н.Фәттах. *Әйе, әйе, ун-унбиш ел дигәндә, дала уртасында --- гигант автозавод [КамАЗ] калкып чыкты.* Казан

**2.** *с. мәгъ.* Киң, иркен, җәйрәп ята торган

**ДАЛА́Й-ЛА́МА** *и. монг.* Тибетта баш рухани; 1951 елга кадәр дәүләт башлыгы; чиркәү оешмасы башлыгы, хөкемдар (тере Аллага тиңләштерелә; олылап, хөрмәтләп йөртелә). *Шушы көннәрдә генә газета битләрендә далай-ламаның Тибеттән китеп югалуы, чит ил журналистларының хәбәрләренә караганда, аны кытайлар урлавы турында мәкалә күзгә чалынып калган иде.* М.Юныс

**ДАЛАК УТЫ** *и. зоол. к.* **болан мүге**

**ДАЛА́ КЫЛГАНЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, кыйммәтле терлек азыгы буларак кулланыла торган үләнчел үсемлек; даланың төп үсемлеге; *русчасы*: **ковыль**. *Кояш нурлары дала кылганнарын сыйпап узды, өй кыеклары буйлап йөгерде ---.* Р.Вәлиев. *Чү! Ә монысы каян килеп эләккән бирегә? Без бала чакта әбиләр «әче» дип йөрткән үзенә генә хас гүзәллеккә ия дала кылганы түгелме соң? Юктыр, кызыл китапка кертерлек бик сирәк урыннарда гына калган дала кылганы, каян килеп, Чистайның алама урамы кырыйларында үсеп утырсын инде?* Ватаным Татарстан

**ДАЛАЛЫ** *с.* Даласы яки далалары булган; даладан яки далалардан торган. *Агач бөтенесенә кирәк! Яртыдан артыгын Украинага, далалы төбәкләргә алтын бәһасенә аткарабыз!* А.Гыйләҗев. *Мук җиләге, нарат җиләге, кара җиләк – болар барысы да төньяк үсемлекләре, --- бит без көньякның далалы районнарында йөрибез.* Дөньяда ниләр бар

**ДАЛАЛЫК** *и.* Иректә, кыргый, дала тормышы белән яшәргә күнеккән

булу, шундый гадәтләрдән арына алмау сыйфаты. *Банхуа аңа беренче караштан ук ошамады. Аның өендә, карашларында, үз-үзен тотышында, телендә – бөтен нәрсәдә кыргыйлык, далалык, кансызлык сизелә иде.* Н.Фәттах. *Ул [Ташбай] далалыгына, кыргыйлыгына кайтты.* Ә.Айдар

**ДАЛА́ МӘЧЕСЕ** *и. зоол.* Урта Азиядә һәм Көньяк Себер далаларында яши торган, йорт мәчесенә охшаган кыргый хайван; *русчасы*: **манул**

**ДАЛА-САХРА** *җый. и.* Далалар һәм сахралар. *Хәрәкәт бер җирдән икенче җиргә, дала-сахрадагы кабиләләрдән шәһәрләргә, төрле дин һәм этносларга, төрле ил, дәүләт, цивилизацияләргә күчә һәм, ниһаять, халыкара актуаль бер проблемага килеп төйнәлә.* Ф.Фәсиев

**ДАЛА́ ТОРЫМТАЕ** *и. зоол.* Лачынсыманнар семьялыгыннан, җирән төстәге ерткыч кош; *русчасы:* **степная пустельга**

**ДАЛА́ ТУРГАЕ** *и. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан, чыпчык зурлыгындагы яки аз гына зуррак, гәүдәсенең өске ягы соры, астан аксыл, күкрәгендә ике зур кара тап, канат очларында ак юл булган, яңгыравыклы тавышлы, ачык урыннарда яши, оясын җир өстенә кора, очканда сайрый торган дала кошы; *русчасы:* **жаворонок степной**, **джурбай**, **каландра**. *Далада бөҗәкләр күп... Алар белән күп кенә кошлар туклана. Бигрәк тә, бөҗәкләрне чүпләп, ал сыерчык белән дала тургае аеруча зур файда китерәләр.* Табигать белеме

**ДАЛА́ ШОҢКАРЫ** *и. зоол.* Лачынсыманнар семьялыгыннан, сырты көрән соры төстә, очлаеп торган бик үткен томшыклы ау кошы; *русчасы:* **кречет степной**. *Аның [Мусаның] --- ияк һәм борын очлары, һөҗүмгә ташланачак дала шоңкарыныкы кебек, аеруча үткенәеп тора ---* Ш.Маннур

**ДАЛЬТОНИЗМ** *и. ингл.* Кайбер төсләрне аера алмау белән характерлана торган күз авыруы. *Әтисе дә, улы да – дальтоник, ә энисе төсләрне дөрес аера. Бу гаиләдә балага дальтонизм (төсләрне аера алмау үзлеге) әтисеннән бирелгән дип әйтү дөрес булырмы?* Р.Зәкиев. *Дальтонизм ирзатлар арасында 8%, ә хатын-кызларда 0,5% тәшкил итә.* Өмет

**ДАЛЬТО́НИК** *и. рус* Кайбер төсләрне (гадәттә, кызыл һәм яшел төсләрне) аера алмаучы. *Ул инде башкаланың зур бер институтында доцент, укымышлы Мәрдиев дәрәҗәсенә иреште. Ләкин, дальтоник булуы сәбәпле, аңа машина сатып алу бәхете тәтемәде.* М.Галиев. *Этләр, гадәттә, төсләрне аера алмыйлар – дальтониклар, ә попугайлар бик яхшы аера.* Татар календаре

**ДА́МА** *и. фр.* 1) Гадәттә, бай катлаудан, шәһәр интеллигенциясе даирәсеннән булган хатын, хатын-кыз. *Халык артык күп булмаса да, бай туалетлы чыркылдык дамалар шактый күренәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Ефәккә, бизәккә чумган дамалар арасында мода эзләп йөрүдән башка эшләре булмаганнар да юк түгел.* Г.Гали

2) Гомумән хатын-кыз. *Бу даманың әйткән сүзләре һәммәсе Җәгъфәр әфәндегә шулкадәр тәэсир кылды: ул болгарларның Габделкаюм әл-Насыйри, Шиһаб әл-Мәрҗанидән үзенә кадәр булганнарының һәммәсен хәтереннән кичерде.* Г.Исхакый. *Минем дә күз алдыма «Державин»да йөргән нәзек дамалар белән Балык базарында куас сатучы бабалар килә.* Г.Тукай

3) Ир-ат заты өчен: ошатып, дуслашып, яратып йөргән кызы, хатыны, гомумән, дус хатын-кызы. *Бу аның, турыдан-туры әйтергә кыймыйча, әмма читләтеп: «Син мине озата барырсыңдыр бит, егет. Нинди кавалер син, кичне бергә уздырган даманы озатып та куймагач», – дигән сүзләре иде.* Ф.Хөсни

4) Кияүгә чыкмаган туташлардан аермалы буларак, кияүдәге ханым. *Җәннәт киемнәре шикелле юка җәйге күлмәкләр кигән кызлар, дамалар.* Ф.Әмирхан. *Агач араларындагы аллея буйлап бакча эчендә ак күлмәкле яшь кызлар, эшләпәләренә каурый кадаган олы дамалар, ак якалы песнәк әфәнделәр йөри.* И.Гази

5) Кавалеры белән парлап биюче туташ яки ханым. *Алар [Айсылу белән Газиз] парлашуга, залдагылар бер нәрсәгә игътибар иттеләр: кавалер белән дама икесе дә пөхтә, матур, ак киемнән, икесе дә төз, сылу гәүдәле, икесе дә, җилкенеп, вальска бииләр ---.* Ә.Салах

6) Хатын-кыз сурәте төшкән, дәрәҗәсе буенча туздан, корольдән түбәнрәк торган уен кәрте. *Көндәшеңнең кулында күз иярмәс тизлек белән йөргән кәртне буби валеты яки пики дамасыдыр дип утырасың, ә ул, ни өчендер, көтмәгәндә, уен тузы булып чыга – беркемне дә гаепли алмыйсың.* Р.Мирхәйдәров. *Флоренциядә П.И.Чайковский үзенең «Пики дамасы» операсын иҗат иткән.* Ф.Хөсни

**ДА́МБА** *и. голл.* Су басудан саклау, су бүлү яки су баса торган урыннарга юл салу һ.б.ш. максатлардан чыгып төзелгән махсус гидротехник корылма. *Ничә сәгать инде менә, бу орудиеләрнең көйдергеч сулышы Кәҗә бистәсе дамбасы буйлап килүче отрядларны чокырларга, казылмаларга ышыкланырга мәҗбүр итте.* К.Нәҗми. *Ул вакытта шәһәр белән Бишбалта арасында бертөрле дә зур дамбалар булмаганлыктан, алар болын буйлап кына Мокрыйга барып чыктылар.* М.Гали. *Мина кырын үткәч, разведчиклар туптуры тимер юл дамбасына таба юл алды.* Г.Әпсәләмов

**ДАМЕЛЛА** *и. фар. дини* Мәдрәсә тотып, шунда сабак укытучы, дәрес бирүче мулла. *Бу хәзрәт – Каргалының иң зур мөдәррисләреннән дамелла Гайнетдин хәзрәт була...* Ф.Әмирхан

**ДА́МКА** *и. рус* Шашка уенында: каршы якның соңгы рәтенә җитеп, төрле юнәлештә (алга, артка; теләсә ничә шакмакка) йөрү мөмкинлегенә ирешкән шашка. *Өстәл янында --- капитан берәү белән шашкалы уйнап утыра иде. --- [Капитан:] Хәзер!.. Каяле, монысын дамка итеп куйыйк та...* З.Фәйзи

**ДАМО́КЛ КЫЛЫЧЫ** *и.* Рәхәт, уңай булып күренгән, муллыкта яшәгән нинди дә булса кешенең тормышына һәрвакыт янап торган үлем куркынычы. *Шулай да, баш очында «кулак улы» дигән дамокл кылычы эленеп торуга карамастан, әти еш кына карарларны идеологиягә буйсынып түгел, ә*

*халыкка яхшы булсын дип кабул итте.* М.Шәймиев

**ДАН** *и.* **1.** 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса яхшы яклары, аны башкалардан аерып торган, өстен итеп күрсәткән уңай сыйфатлары турында киң таралган сүз; шөһрәт, мактау, исем. *Дан иярле булмаса да, кайберәүләр аңа атланырга, шуның белән тормыш юлындагы барлык киртәләрне сикереп чыгарга телиләр.* Ф.Яруллин. *Мамайга тиячәк данны рус кенәзләре Туктамыш ханга илтеп тапшырырга мәҗбүр булдылар...* Р.Әмирхан. *Баграт киләчәкнең дан, бәхет, уңыш алып киләчәгенә чын күңелдән ышанучы оптимист иде.* М.Юныс

2) *юг.* Күтәренке тон, хис белән әйтелә торган тантаналы мактау сүзе. *«Яктыга дан!» диеп сөрән салабыз, Караңгыда рәхәт чигеп калабыз.* Я.Игәнәй

3) Гомумән, нинди дә булса гамәле, холкындагы үзенә хас сыйфаты, аерылып торган ягы белән танылганлык. *Күрше фабрикаларның берсеннән Каганин дигән, усаллык белән даны чыккан бер урыс килеп чыкты.* Ш.Усманов. *Колхоз бакчасының даны бөтен тирәякка таралып, уңышны шәп биргән елы икән.* Г.Бәширов

4) **даны** *гадәттә тарт. форм.* Яхшы эше, мактаулы хезмәте, батырлыгы, уңай сыйфаты белән берәр кешенең, оешманың яисә илнең исемен таныткан, аңа шөһрәт, мактау китергән зат. *Миңа шушы бөек артист – гали җан, татар халкының даны һәм сөенече – бүген арестант.* И.Салахов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Атаклы, мәшһүр, данлыклы; бик мактаулы. *Дан егет. Дан кеше*

2) Мактап сөйләрлек, мактанырлык, яхшы, шәп. *Йортлары бик дан түгел! Яңартырга кирәк булыр*

◊ **Дан алу** 1) Кемнең дә булса мактаулы исеме таралу, шөһрәт казану. *Айдалада утырып, Ундүрт дауны бетергән, Туксан бала эчендә Бәйге тотып дан алган ---.* Дастан; 2) Гомумән, берәр эше, сыйфаты белән халык теленә керү, танылу. **Дан җырлау** *юг.* Кемне, нәрсәне дә булса бик нык мактап сөйләү, язу. *Җитмәсә, бер еллап та әүвәлрәк түгелдер, тәнкыйть кармагыма хәзер сукыр шыртлака кебек капкан һәм шәрә хәлендә ярга ыргытылган теге «олпат» галимебезгә дан җырлаган олуг бер мәкалә-әңгәмә дә шушы ук гәҗиттә сәхифә тутырып урын алган иде.* Ф.Яхин. **Дан казану** Танылу, халык теленә керү. *Мәсьәлә чишүдә дан казанган нечкә муенлы даһи математиклар, --- иртәгәге сынауда булачак мәсьәләләрне чишеп, тикшереп утыралар.* М.Юныс. **Дан кеше** Хөрмәтле, бәяле кеше, яхшылыгы белән мактаулы, уңган кеше. **Дан сату** Дәрәҗә төшерү, яманат чыгару. *Бөтен районда алдан барырлык булмагач, «Чулпан»ның данын сатып, тавыш күтәреп йөрмим дә мин.* Г.Бәширов. **Дан тоту** Данлыклы булу. *Кече инәем үзенең русчага осталыгы белән Келәштә дан тоткан хатын булды.* М.Кәрим. *Зәңгәр чишмә – үзенең зур базары белән бөтен Агыйдел буенда дан тоткан авылларның берсе, бәлки, беренчесе.* Г.Ибраһимов. **Дан чыгу** Уңай яки кире яктан исеме таралу. *Ә кызыллар, Тинсез дан чыгарып, Батыр калып, власть алдылар.* Х.Туфан. **Дан эш** *юг.* Мактаулы, дан китерә торган эш. *Дан эшләре һаман күтәрелә*

**ДАНӘ** *и. фар.* Сан һәм микъдарны белдергән сүзләр янында килеп, бер төрдән булган әйберләрнең берсе; берәмлек. *Райкомның пропаганда бүлеге мөдире Миңнуллин самолётны машина белән килеп каршылаган һәм әлеге газетаны бушатканда ук өч-дүрт данә алып, райкомга элдергән.* Ф.Садриев. *Ул плакат хәзер нәшрият архивларында бер-ике генә данә сакланадыр инде, ләкин ул, хәтерләвемчә, берничә миллион тираж белән чыккан иде.* М.Мәһдиев. *Менә быел Күкчәтау өлкәсенә килгән яки безнең адрес белән юлга чыккан кайбер авыл хуҗалыгы техникасы турында саннар: тракторлар 20709 данә, автомашиналар 8153 данә, комбайннар --- 9154 данә.* И.Салахов

**ДАНӘДАР** *и. фар.* Каракүл бәрәне тиресенең (илтернең) вак кына бөртекләр булып торган соры төсле төре. *Кияләр тагы каракул бүрек, данәдар бүрек, һәркем хәленә күрә.* К.Насыйри

**ДАНӘЛӘП** *рәв.* Данә белән, данәданә. *Урам чатларында, җәмәгать транспорты тукталышларында тәмәкене данәләп сатып утыручыларга да көн бетә.* Ватаным Татарстан

**ДАНӘЛЕ** *с.* Аерым әйбергә карый торган, данәләп исәпләнә торган. *Булган 3–4 мең данәле тираж да кайбер газета-журналларда ясалма рәвештә тудырыла.* Безнең гәҗит

**ДАНДАРА** *и. диал.* Буш, юк әйбер

◊ **Дандарага җон тетеп йөрү** Бер эшсез йөрү. *Хәзер бит ирләр азынды. Хатыннары түйдыра, ә аларның эше рәхәт, дандарага җон тетеп йөриләр шунда.* М.Мәһдиев

**ДА́НИЯЛЕ** *и.* Даниядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Данияле язучы – Һанс Кристиан Андерсен*

**ДАНЛА́У** *ф.* Дан китерү, данлыклы итү; зурлау. *Данлап аны, кулдан алкыш бирәм...* Н.Исәнбәт. *«Татарстан» журналын республиканың кордашы дияргә мөмкин... Журнал заман белән бергә атлады, республикага хилафлык китермәде, аны данлады.* Татарстан. *Раббебез, Син боларны юкка гына бар кылмадың бит, Данлыйбыз Сине*. Татар мөселман календаре

**Данлап килү** Күптәннән, элек-электән дәвамлы рәвештә данлау

**Данлап тору** Һәрвакыт, гел данлау. *Яшьлек тә, син дә йөрәкләрдә Тудырасыз данлый торган җыр. Ил-халкымның көчен, батырлыгын, Горурлыгын данлый торган җыр.* Ш.Маннур

**Данлый бару** Торган саен көчлерәк данлау

**Данлый башлау** Данларга керешү. *Барысы да моңа хәйран калдылар, Аллаһыны данлый башладылар һәм, куркуга төшеп: «Без бүген искитәрлек нәрсәләр күрдек!» – диделәр.* Изге язмалар

**Данлый төшү** Тагы да данлау. *Янгын сүндерүчеләрне данлый төшү*

**ДАНЛЫ** *с.* 1) Данга ия, даны булган; шөһрәтле, атаклы. *Данлы исемеңне мәңгелеккә Дога итеп язам: Казан... Казан...* М.Кәрим. *Революциягә кадәр Мәскәүнең данлы «Яр» ресторанында официант итеп гел татарларны гына тота торган булганнар. Бу турыда*

*миңа бер карт капитан сөйләде. Аның шул ресторанда Горький, Шаляпин, тагын әллә нинди данлы кешеләр белән утырып эчкәне булган...* М.Юныс

2) Дан-шөһрәт китерә торган, мактаулы

**ДАНЛЫК** *и. сөйл. сир.* Дан (*1 мәгъ.*); танылган, мактаулы исем. *Данлыкка ирешү*

**ДАНЛЫКЛА́У** *ф.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса исемен таныту, дан (*1 мәгъ.*) белән телгә алу, олылап, халык арасында тарату. *Хезмәт батырларын данлыклау*

**Данлыклап бетерү** Бик нык данлыклау. *Галимне күкләргә чөеп, данлыклап бетерделәр*

**Данлыклап йөрү** Һаман, гел, һәр җирдә данлыклау

**Данлыклый башлау** Данлыкларга керешү

**ДАНЛЫКЛЫ** *с.* 1) Исеме, даны киң таралган; күренекле, атаклы. *Мин данлыклы Камали хатыны булырмын.* М.Мәһдиев. *Әтнә һәм Бәрәзә --- җырчылар һәм көрәшчеләр ягы, мәкальләр һәм әкиятләр оясы – кем генә җырламаган сине, данлыклы Казан арты.* Ф.Хөсни. *Каланың иң гүзәл сарайлары, данлыклы мәчет-гыйбадәтханәләренең барлыкка килүендә аларның өлеше ифрат зур.* М.Юныс

2) Данга (*1 мәгъ.*), мактауга, данлыклауга лаек булган. *Данлыклы тормыш юлы*

**ДА́НСИНГ** *и. ингл.* Ресторан яки кафеда бию залы. *Заманча җиһазландырылган дансинг*

**ДАН-ШАН** *җый. и. к.* **дан-шөһрәт.** *Татар халкының асылы турында мәгълүматы булмаган Аурупа халыкларына: менә татар милләтенең йөзе, менә ул татарның җаны, менә ул татарның даны-шаны дип горурланырлык сурәт бу, әфәндем.* Р.Батулла

**ДАН-ШӨҺРӘТ** *җый. и.* Хөрмәт белән танылганлык, танылу. *Шәһри Болгарның сәүдә үзәге буларак даны-шөһрәте тагын да арткан.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ДАНЬ** *и. рус тар.* Борынгы Русьта һәм башка кайбер илләрдә князь, гаскәр башлыгы яки җиңүче тарафыннан җиңелгән кабиләдән, халыктан алына торган салым, ясак. *Дань түләү күптән юк иде. Хәлбуки «татарларга дань» дип халык өстенә салынганнары элеккечә җыелып торылыр вә Мәскәү кенәзе бу акчага мәмләкәт эчен төзәтер иде.* Р.Әмирхан

**ДАҢГЫЛДА́У** *ф.* «Даң» сыман авазлар чыгарып, шундый авазларны хәтерләтеп, өзек-өзек яңгырау. *«Изге» тавыш тутырып дөньяга, Колокольняда Тәңре даңгылдый: Манарасыз мәзин морҗада Канатларын җәеп каңгылдый...* Х.Туфан

**Даңгылдап алу** Кыска вакыт аралыгында даңгылдау. *Балта, кадакка тиеп, даңгылдап алды*

**Даңгылдап кую** Кинәт, кыска гына, бер тапкыр даңгылдау. *Сәгать даңгылдап куйды: берне сукты*

**Даңгылдап тору** Бертуктаусыз даңгылдау; сөйләү моментында даңгылдау. *Җиз кыңгырау берөзлексез даңгылдап тора*

**Даңгылдый башлау** Даңгылдарга тотыну

**Даңгылдый бирү** Бернигә дә карамый даңгылдауны дәвам итү

**ДАҢГЫЛДЫК** *с.* 1) «Даң» авазлары чыгара, даңгылдый торган. *Даңгылдык музыка*

2) Сикәлтәләре, чокыр-чакырлары күп булган. *Даңгылдык юл*

**ДАҢГЫР-ДОҢГЫР** *иярт.* **1.** Дөбердәү катнаш даңгылдау авазларын белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шуңа охшаш шакылдаган тавышлар чыгарып. *Костакиның джаз оркестры даңгыр-доңгыр уйнап торган җәйге парк ресторанында көн саен кәеф-сафа коручы бу елгыр бертуганнарның берәр көн генә кайда булса да эшләгәнлекләрен Рушан хәтерләми.* Р.Мирхәйдәров

2) Катканаклы, даңгырдык юлдан арбага һ.б.ш. утырып барганда бик каты селкетеп, селкенеп. *Кайчандыр, беркемнән дә сорап тормастан, ничек кирәк алай асфальт салынган, хәзер инде чокыр-чакырланып беткән тузанлы үзәк урамыннан даңгыр-доңгыр дөбердәп узып, базарга барып чыкты ул [Рушан].* Р.Мирхәйдәров

**ДАҢГЫРДА́У** *ф.* 1) «Даңгыр» авазын хәтерләткән тавышлар чыгару; дөбердәү катнаш даңгылдау. *Бу сиңа таш яки асфальт өстеннән, даңгырдый-доңгырдый, «моторыңны рамага беркеткән шөрепләрең кайчан коелып кала инде» дип курка-курка --- өстерәлү түгел шул инде! Мондагы юл мендәр кебек.* Җ.Юныс

2) Катканак, даңгырдык юлдан арбага һ.б.ш. утырып барганда селкенү

**Даңгырдап алу** Берара, берникадәр вакыт даңгырдау

**Даңгырдап кую** Кыска вакыт аралыгында, бер тапкыр даңгырдау

**Даңгырдап тору** Гел, берөзлексез даңгырдау; даңгырдау процессының дәвамлылыгын аңлата. *Калайдан эшләнгән басу капкасы җилдә даңгырдап тора*

**Даңгырдый башлау** Даңгырдарга тотыну

**Даңгырдый бирү** Бернигә карамастан даңгырдавын дәвам итү, һаман даңгырдау

**ДАҢГЫРДЫК** *с.* 1) «Даңгыр» сыман тавышлар чыгара, даңгырдый торган. *Мәдәният сараенда яшьләр кичәсе иде. Роза, репетиция тәмамлануга, фойега төшеп китте. Андагы даңгырдык музыка шулкадәр көчле: колак пәрдәләре генә түгел, таш бинаның диварлары дерелди кебек!* З.Фәйзи

2) *к.* **даңгылдык** (*2 мәгъ.*). *Даңгырдык күпер аша үтү*

**ДАҢГЫРТ** *иярт.* Кинәт кенә даңгырдап куюны белдерә. *Даңгырт!!! Буш чиләк, кулдан ычкынып, кое төбенә барып төште*

**ДАҢ-ДАҢ** *иярт. к.* **даң-доң**

**ДАҢ-ДОҢ** *иярт.* **1.** Калын, авыр металл әйберләргә һ.б.ш. бәргәндә яки бәрелгәндә барлыкка килә торган түбән тондагы көчле тонык тавышны белдерә. *Вахта каршындагы баганага элеп куелган рельс кисәгенә сугалар. Даң-доң! Даң-доң!* И.Салахов. *Даң-доң! Сәгать уникене суга. Өстәл янындагы кешеләр барысы да аягүрә басалар. Шешәләр ачыла.* И.Салахов

**2.** *рәв. мәгъ.* Шуңа охшаш шакылдаган тавышлар чыгарып. *Даң-даң бәреп, пианинода уйнау*

**ДАР** *и. фар.* Кешене асып үтерү юлы белән җәзалау җайланмасы: баганага аркылы агач беркетеп ясалган корылма. *Җөмләдән, фараонга каршы фетнәдә гаепләнгән ике сарай хәдименең төшләрен юрап, алардан шәрабченең бәладән котылачагын, элеккечә сарайга кайтачагын, икмәкченең исә дарга асылачагын алдан дөрес әйтеп бирә.* Ф.Фәсиев. *Бераздан мин үземне дә дарга асылган кеше хәлендә сизә идем инде. Адәм балаларын дарга асучы палачларга булган нәфрәтем, эчемә сыймыйча, ташып чыга.* М.Юныс

◊ **Дар агачы** *к.* **дар.** *Аннан инде дар агачына асыламы, яисә, кул-аяклары богауланып, «катыр» китәме – барыбер мәңгелек йөрәк ярасы тутыясын бүтән күрә алмас.* Җ.Рәхимов

**ДАРВИНИЗМ** *и. ингл.* Тереклек дөньясының үсеш закончалыкларын материалистик нигездә аңлата торган тәгълимат (термин А.Уоллес тарафыннан кертелгән). *Дарвинизм тәгълиматының иң мөһим өлеше – Чарльз Дарвинның табигый сайланыш теориясе.* Биология

**ДАРВИНИСТ** *и. рус* Дарвинизм тарафдары

**ДАРВИНИ́СТИК** *с.* Дарвинизмга мөнәсәбәтле; дарвинизмга нигезләнгән. *Дарвинистик тәгълимат*

**ДАРВИНЧЫ** *и. к.* **дарвинист**

**ДАРДАР** *и. гар. сөйл.* Элмә агачы; көньяк карамасы. --- *һавада ялтырап очкан һәм юлга түшәлгән кызгылт, алтын сары өрәңге, юкә һәм дардар яфраклары бу күренешне тагы да матурлата.* Р.Зарипова

**ДАРЕЛБӘКА** *и. гар. дини* Мәңгелек йорт, бакыйлык, теге дөнья; *киресе:* **дарелфәна**. *Йосыф мирза хатынының кабер ташына алтынсу хәрефләр белән шулай яздырды: «Казан каласыннан Нугай иленә килен булып төшкән Мәхмүт хаҗи кызы, --- игезәкләре Сөен бәк олан белән Сөем тутайны калдырып, дарелфәнадин дарелбәкагә рихләт итте».* Р.Батулла

**ДАРЕЛМӨГАЛЛИМАТ** *и. гар. иск.* 1) Хатын-кызлар өчен югары уку йорты; гомумән уку йорты. *Әнием, шул мәгълүм хат килгән Курсада икенче елын укыганда, Бубида кызлар дарелмөгаллимате барлыгын ишетә һәм бай, хәлле кешеләрнең кызлары шунда укыганлыгын белә.* А.Расих. --- *Троицкида татар зыялылары арасыннан шактый күп күренекле шәхесләр үсеп чыга. Мин шулар арасыннан Габдрахман Әхмәровны (ул шәһәрдә хатын-кызлар өчен дарелмөгаллимат оештыра), фельдшер Дәүләтша Мухинны атар идем.* А.Расих

2) Башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар әзерли торган уку йорты. *Сәүдәгәр Яушевлар Троицкида дарелмөгаллимат (башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар әзерли торган уку йортлары) ача.* Мәгариф

**ДАРЕЛСӘНӘГАТЬ** *и. гар. иск.* Һөнәр йорты, предприятие. *Бу тавыш Җәгъфәр әфәнденең үзен дә йокыдан уяткан кебек булды. Ул: «Нинди болгар яшәсен? Ничек яшәсен? Баягы мәдрәсәләре, больница, мәсҗетләре, дарелсәнәгатьләре булган болгарлар яшәсенме?..» – дип, үзенә үзе сөйләнергә тотынды.* Г.Исхакый

**ДАРЕЛФӘНА** *и. гар. иск.* Вакытлы йорт, фанилык, бу дөнья; *киресе:* **дарелбәка**. *Без анда өчәү. Өчәү… Хәзер мин берүзем генә. Япа-ялгыз. Икебез анда дөнья куйды – дарелфәнадән дарелбәкагә рихләт әйләде.* И.Салахов

**ДАРЕЛФӨНҮН** *и. гар. иск.* Югары уку йорты. *Казанлы дарелфөнүн студенты мандолинада шәп уйнады, Гариф әфәнде белән таныштык, һәм аңардан мандолина чиертергә өйрәнә башладым.* А.Расих. *Мин дә хәзер ирекле сыйфатында дарелфөнүнгә атнага дүрт көн лекция тыңларга йөрим.* А.Расих

**ДАРУ** *и. фар.* 1) Чирне, авыруны, төрле сырхауларны алдан кисәтү яки дәвалау өчен кулланыла торган матдә. *Фагыйлә бит минем кычкырганымны ишетеп түгел, ә, бәлки, йокы даруына дип кенә кергән.* Ф.Садриев. *Авыл миченең майлы кирпеченә тәрәлеп торган кешегә бернинди дару, уу, майлау кирәк түгел билне.* М.Мәһдиев

2) Җәрәхәтне, гомумән авырткан җирне турыдан-туры эшкәртә торган сыекча, мазь. *Фельдшер аның имгәнгән урынын тапты булса кирәк, нindидер дарулар сөртеп, кабык белән төреп, аксак аягын бәйләп китте.* Г.Галиев. *[Айдар:] – Әни яшерә ---. Буфетны да, шкафны да бикли, – диде малай, нык ук еламсырап. – Эзләдем инде. Тапмадым --- шунда дару шешәсен ваттым, бармагым киселде.* А.Гыйләҗев

3) Төрле паразит бөҗәкләрне бетерү, зарарсызландыру һ.б.ш. өчен кулланыла торган агу. *Әхтәм әнисеннән акча өмет итми иде, эчү мәсьәләсендә ул шулкадәр талымсыз, җәйлы кеше икән: рәттән барысын да эчте… Кибеткә тирләүгә каршы бер сум ун тиенлек бер сыеклык кайткан иде – аңа рәхәтләнде, бераздан «зубной эликсир»га күчте, аннан – кәя даруына.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Эч пошу, күңел төшенкелеге һ.б.ш. борчуларны җиңелрәк үткәрү яисә шул халәтне бераз җиңеләйтү чарасы. *Агыйдел буе табигатенең никадәр матурлыгын, никадәр көчлелеген – аның төшенке күңелләрне күтәрү, сәламәтлекне ныгыту өчен кирәк булган барлык даруларга иксез-чиксез дәрәҗәдә бай табигать икәнлеген – фәкать шул иртәдә генә сиздем булса кирәк.* М.Әмир. *Сатыламы Дөнья базарында бу афәткә каршы дару, чара?!* Л.Шагыйрьҗан. *Безнең тамырлардан аккан сөмсез агуга шигырьләр дару була алырмы?* Идел

**ДАРУГА** *и. монг. тар.* Хан идарәчелеге астында булган бик вак административ-территориаль берәмлек. *Алар, күрәсең, дәүләтнең кайбер өлкәләре белән дә идарә иткәннәрдер. Административ яктан ханлык даругаларга – Алат даругасына, Арча даругасына, Атыз даругасына, Галич/Гареч даругасына, Нугай даругасына, --- чуаш даругасына… һ.б. бүленгән.* Казан утлары

**ДАРУГАЛЫК** *и. тар.* Дәүләттәге житештерү тармаклары һәм алардан килә торган керем эшләре белән идарә итү. *Даругалык эшен үз өстенә алды, Ашлык-иген бик күп игәргә боерды.* Кол Гали

**ДАРУГА́У** *и. тар.* Алтын Урда чорында административ-территориаль берәмлек – даруга белән хакимлек итүче бәк; баскак. *Мәмләкәтнең төрле җи-*

*рендә башта хан тарафыннан аксөякләрдән куелган «баскак» яисә «даругау» дигән бәк торган.* Г.Гобәйдуллин

**ДАРУ-ДӘРМАН** *җый. и. фар.* Һәртөрле дарулар. *Төрле кимсетелүләргә һәм эзәрлекләүләргә дучар ителгән халык вәкилләре өчен, аның әсәрләре шифалы дәва, дару-дәрман буларак кабул ителә.* М.Гайнетдинов

**ДАРУЛА́У** *ф.* 1) *к.* **дәвалау.** *Рувим Михайлович ул төшне бик фәсмәнләп эшкәртте, аннан дару куйды. Берочтан бөтен яраны үзе чистартты, үзе дарулап бәйләтте.* Х.Камалов

2) *сөйл.* Дару (*3 мәгъ.*) белән агулап эшкәртү

**Дарулап алу** Бераз, тиз генә дарулау. *Авырткан кулны берничә көн дарулап алдык*

**Дарулап йөрү** Әле, хәзерге вакытта дарулау белән шөгыльләнү. *Күзләремне дарулап йөрим. Күрше карчыгын дарулап йөрим*

**Дарулап карау** Даруларга тырышу. --- *табиблар һәм төрле сихерчеләр, килеп, Гөлрохны үзләренчә дарулап, им-том кылып карадылар, ләкин тырышулары бушка чыкты: кызның бертөрле дә авыруы табылмады.* К.Насыйри. *[Симулянт:] Һай, сорамагыз, доктор, минем үкчәләрем артка әйләнгән. Никадәр генә дарулап карасам да, һаман артка әйләнгән көенә тора.* Г.Камал

**Дарулап кую** Даруланган итү. *Бер утырышта сүз биргәннәреннән соң, мактап әйтергәме, тешләп тә куяргамы дигән уй килде. Иң яхшысы: әүвәле тешләп, аннары сыпырып, «дарулап» куярга кирәктер, дидем.* Ф.Яхин

**Дарулап ташлау** Тиз арада, кыска вакыт аралыгында, аннан-моннан дарулау. *Теш табибы, күз ачып йомган арада, тешләремне дарулап ташлады*

**Дарулап тору** Һәрвакыт, гел дарулау, хәзер, сөйләү моментында дарулау

**Дарулый башлау** Даруларга керешү

**Дарулый бирү** Бер нәрсәгә карамастан дарулауны дәвам итү

**Дарулый төшү** 1) Бераз даруын арттыру

2) Дарулауны һаман да дәвам итү

**ДАРУЛЫ** *с.* 1) Дару салынган, эчендә даруы булган; гомумән даруы булган. *Янда туташлар кайсы кашык белән шулпа тоткан, кайсы дарулы су эчертергә азаплана.* Р.Батулла. *Суынып каткан балавызлы марляны орчыкның нечкә очы ягына шудырып төшерәсең. Шулай итеп, очлы түбәсе киселгән конуссыман трубка, ягъни «дарулы җиһаз» әзер була.* Ватаным Татарстан

2) Дару йоккан; дару исе сеңгән. *Дарулы хастаханә халаты. Дарулы бүлмә*

3) Даруланган, дару кулланып йогышсызландырылган, эшкәртелгән. *Дарулы җәрәхәт*

4) Даруы булган, дару ясауда кулланыла торган. *Дарулы шалфейның яфракларын антисептик чара буларак кулланалар.* Ботаника

**ДАРУЛЫК** *с.* **1.** Даруга ярый торган, дәва була алырдай. *Дарулык чималны үсемлекләр чәчәк аткан чорда, коры, аяз көнне, чык кипкәннән соң әзерлиләр.* Юлдаш

**2.** *и. мәгъ.* Дәва, дару. *Ул [Ат кузгалагы] төрле өлкәләрдә кулланыла торган борынгы дарулык булып тора.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Һәр үсемлекнең дә диярлек дарулыгы бар. Иске «дарулык» китапларында мүк җиләге (клюква) һәм шикәрне бермә-бер кушуның файдалы булуы язылган.* Сәламәтлек календаре

**ДАРУХАНӘ** *и фар.* Дарулар (ясап) сата торган урын; аптека. *[Мансур] --- даруханәдән дарулар алып эчте дә, баш авыртуы бераз басыла төшкәч, хастаханәгә барып тормады.* Г.Галиев. *Гүзәл Илбрус кызы Сираҗиева, Казан медицина училищесын тәмамлап, даруханәдә эшли.* Э.Шәрифуллина. *Аннан [кыргый укроптан] даруханәләрдә укроп суы әзерлиләр.* Юлдаш

**ДАРУХАНӘЧЕ** *и.* Даруханә хезмәткәре. *Даруханәчеләрне Ходай Тәгалә дөньяны яраткач ук яраткан дип раслап булмый, әлбәттә.* Юлдаш

**ДАРУХАНӘЧЕЛЕК** *и.* Даруханәче һөнәре һәм эше. *IX гасырда --- Ислам дөньясында даруханәчелек киң таралып, Багдад шәһәрендә генә дә 60 даруханәче авыруларга рецепт белән дару сатканнар.* Татар мөселман календаре

**ДАРЧИН** *и. фар.* Лаврлар семьялыгыннан булган тропик дарчин агачының киптерелгән кайрысы (аш тәмләткеч буларак, шулай ук медицинада кулланыла); *русчасы:* **корица**. *Соуслар һәм аш тәмләткечләр: лавр яфрагы (лавр), укроп, петрушка яфрагы, дарчин, канәфер; азрак каймак салынган сөтле соус, җиләк-җимеш соуслары.* Татар халык ашлары. *Кан алдырган кешегә соңыннан алма шәрабы яки айва шәрабы эчерергә кирәк. Әмма табигате салкын булган кешегә канәфер белән айва шәрабы вә дарчин (корица) шәрабы эчәргә --- кирәк.* Мирас. *Борыч, шулай ук канәфер, дарчин кебек башка татлы тамырлар дару буларак, җылыту һәм аш сеңдерүне яхшырту чарасы буларак бәяләнгән.* Дөньяданиләр бар

**ДАРЫ** *и. фар.* Тиз кабынып китүчән, янганда, газ хасил итеп, мылтык һ.б.ш. ату кораллары көпшәсеннән пуляны этеп чыгара торган шартлагыч матдә. *Шәһәр ерак әле. Дары катыш көйгән ис тамак төбенә утыра.* Н.Дәүли. *Воеводаларның тәкъдиме буенча дары запасына су сибеп боздырган, кальга диварларындагы кайбер тупларны Зөя каласына җибәргән дигән мәгълүматлар бар.* С.Әминов

◊ **Дары исен иснәү** Сугышта катнашу. *[Мингәр:] Кая алып баруларын гына булса да әйтә алалар иде бит. Дары исе иснәмәгән яшь бүлтерекләр түгел. Аңлар идек.* Ф.Латыйфи. **Дарыны коры тоту** Теләсә нинди көтелмәгән хәл-вакыйгаларга әзер булып тору. *Дарыны коры тотарга җирле үзидарә башлыкларын бүген көн дәвамында өйрәтәчәкләр.* Шәһри Казан

**ДАСТАН** *и. фар. әд.* 1) Чынбарлыкта булган хәлләр, вакыйгалар хакында буыннан-буынга сөйләнеп, тапшырылып килә торган хикәя. *Дастан һәм әкиятләрдән, Фирдәүси һәм Низамидан, Шекспир һәм Гётедан, Пушкин һәм Толстойдан, Исхакый һәм Тукайдан башка без бүгенге тормышыбызны да, үткән юлыбызны да күз алдына китерә алмыйбыз.* Ф.Садриев. *Язма*

*әдәбият үзенең башлангыч чорында, гомумән, язма чыганаклардан, язуга күчерелгән фольклор әсәрләреннән (дастаннардан) катгый рәвештә аерылып тормаган.* Ф.Фәсиев

2) Тарихи әһәмияте булган вакыйгалар, хәлләр турында язылган зур күләмле әдәби әсәр; эпопея. *«Идегәй» – гадәти дастан гына түгел, ә Алтын Урданың җимерелү сәбәпләрен, фаҗигале елъязмаларын гәүдәләндергән бөек мәрсия, моң-зар тулы сыктау да ул.* Х.Миңнегулов

**ДАСТАНЧЫ** *и. әд.* Дастаннар сөйләүче яки язучы. *Классик дастанчы*

**ДА́ТА** *и. лат.* 1) Нинди дә булса вакыйганың төгәл, анык календарь вакыты. *Хәер, ул үзе дә каләм тибрәтмичә тормады торуын. Редакцияләрнең заказлары буенча төрле даталарга карата мәкаләләр, тегe яки бу темага багышланган брошюралар, чыккан китапларга рецензияләр, кыскасы, шуның кебек вак нәрсәләр шактый күп язды.* Ә.Еники. *Алар [парчалар] арасында --- төрле әдәби даталарга карата язылган мәкаләләр --- дә бар.* Ф.Хөсни. *Тарихи вакыйгаларга, истәлекле даталарга, халыкара теләктәшлеккә һ.б. календарь даталарга багышлап, тантаналы җыелышлар уздыру гадәте дә кешеләрнең күңеленә хуш килә.* Яшәү яме

2) Гариза һ.б.ш. документлар, хат, төрле язма әсәрләрнең язылу-эшләнү вакытын (елын, елы белән аен һәм көнен) күрсәткән сан, билге, язма. *Имзасы бар, датасы...* А.Гыйләҗев. *Институтка керү яки эшкә урнашу өчен, кагыйдә буларак, соңгы тикшеренүнең датасы күрсәтелгән медицина картасы кирәк.* Татар мөселман календаре

**ДА́ТАЛЫ** *с.* Датасы куелган яки билгеләнгән. *Даталы кульязма*

**ДА́У** *и. гар.* 1) Нәрсә дә булса таләп итеп күтәрелгән шау-шу, ыгы-зыгы, көчле дәгъва (*1, 2 мәгъ.*). *Без яңа җир, яңа кеше өчен җирдә зур дау алып барабыз.* Һ.Такташ. *Җир давы шулай кызып киткән көннәрдә, Тигәнәле уртасына мичәүләп җигелгән дүрт атлы кибитка килеп туктый.* К.Нәҗми

2) Ызгыш, талаш, гауга

3) *куч.* Көрәш, сугыш. *Планетада бүген зур дау бара...* Һ.Такташ

◊ **Дау кубару** Тавышлану, бәхәс чыгару, дәгъвалашу. *Сәхипҗамал ханым, ишетелүенчә, андагы шартларга түзә алмый, дау куптара.* А.Расих. *«Ә-ә, үзенә эләкмәгәнгә дау куптарып йөри икән бу ришвәтче!» – диделәр кайберәүләр.* А.Гыйләҗев. **Дау күтәрү** *к.* **дау кубару**

**ДАУЛА́У** *ф.* 1) Нәрсә дә булса таләп итеп, дау күтәрү. *Минем күршенең малае эчеп килә дә әнисеннән акча даулый.* М.Юныс

2) Берәр нәрсәне рәсми төстә яки суд аркылы таләп итү. *Сатып алучылар хокукын даулау*

3) *куч.* Нәрсәнедер яклап көрәшү, аңа ирешергә омтылу, аның өчен сугышу. *Яңалык үзенә урын даулап, искелек үз урынынын бирергә теләмичә, җирдә бөек тартыш алып баралар.* Ф.Хөсни. *Көчле агым белән берләшеп, алар Санькаsuccessfully җанын даулыйлар, дәһшәтле тирәнлеккә суыралар иде.* Ф.Латыйфи. *Әмма килер бер көн, бүген буйсындырылган халык ирек даулый башлар, баш күтәрер.* М.Хәбибуллин

**Даулап алу** Берникадәр вакыт кына (озак булмаган вакыт аралыгында) даулау. *Эшчеләр берничә көн даулап алдылар*

**Даулап йөрү** Төрле инстанцияләрдә йөреп, нәрсәдер даулау. *Синең тавыш куптарып, очу эшенә кире кайтаруларын даулап йөрүең мине шикләндерә.* М.Юныс. *Халыкларны юлдан читкә этеп, Адаштырган иблис гаепле. Үз илендә килмешәкме татар, Дәүләт даулап йөрсә, гаепме?* Х.Бәдигый

**Даулап калу** Мөмкинлек туганда, форсаттан файдаланып даулау, дауларга өлгерү. *Җай булганда даулап калыйк*

**Даулап тору** Һәрвакыт, гел даулау. *Эшчеләр өч көн саен даулап торалар*

**Даулап яту** Әле, хәзерге вакытта даулау. *Кытайда – дракон, Төркидә – аждаһа, Оча торган кәлтә. Хокук даулап ята.* Г.Афзал

**Даулый бару** Бер-бер артлы һәрберсен даулау; торган саен ныграк даулау

**Даулый башлау** Дауларга керешү. *Шакир абый, караватка яткан килеш, тәмәке тарта. --- Мин аңардан папирос суыртып карауны даулый башлыйм.* А.Расих. *Атларны җиккән арада, абзарга авыл советы рәисе килеп керә. Керә дә заемга түләргә акча даулый башлый.* Кызыл таң

**ДАУЛАШ** *и. сир.* Дау, дәгъва. *Күк булып күкрәр һавада хәр яшәү даулашлары.* Г.Тукай

**ДАУЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **даулау**

2) Берәр нәрсә таләп итеп, үзара дау күтәрү; бер-берсенә каршы ызгыш куптару, сатулашу. *[Староста:] Әгәр дә без шушылай килешә алмый даулашабыз икән, ул чагында паёк бүлүне куеп торырга туры киләчәк.* М.Галәү

**Даулаша бару** Даулашу торган саен арту, көчәю. *Тынычланасы урынга, һаман да даулаша баралар*

**Даулаша башлау** Даулашырга тотыну. *Ул [Җамал] башкаларның аның ихтыярына буйсынуын тели, әгәр каршылыкка очраса, алдын-артын уйлап тормый, даулаша башлый.* Ф.Сафин. *Әлеге суфи өенә керсә, тегесе: «Кайда миңа дигән өлеш, бусы – иптәшеңә дип әйтте ич», – дип даулаша башлый.* А.Рәшит

**Даулашып алу** Озакка сузылмаган вакыт аралыгында даулашу; берникадәр даулашу. --- *Гаяр Әббәсов мәрә судьясы янына барып: «Бу алка саналмый, уенны ник туктатмадың, уен вакыты беткән булган», – дип даулашып алды.* Ә.Камалетдинов

**Даулашып йөрү** Даулашу хәлендә булу; әле, хәзерге вакытта даулашу. *Әле кичә генә, үзара төрткәләшә-төрткәләшә, байбәтчә җирләрен даулашып йөргән ярлы-ябагай, утлы кисәү күргән эт баласы сыман, койрыкларын кысты, эчкә бөгәрләнде.* В.Имамов. *Дәүләтбикә белән Гәүһәр тату гына булгач, кайнана белән килен даулашып йөрмәде ---.* Г.Якупова

**Даулашып кую** Тиз арада, аз вакыт аралыгында даулашу. *Хатыннар тагын даулашып куйдылар*

**Даулашып тору** Әледән-әле, бертуктаусыз даулашу. *Аңламассың бу күршеләрне, гел даулашып торалар*

**ДАУЛЫ** *с.* 1) Дау белән булган, ызгышлы, талашлы; дау, ызгыш-талаш белән тәмамланган (*эш, мәҗлес, вакыйга һ.б.ш.*). *Даулы җыелыш*

2) Гауга, гауга чыгаруга сәбәп булган; бәхәсле. *Ләкин мең елдан бирле чишелмәгән даулы мәсьәләләр шул килеш кала бирде.* М.Галәү

3) *күч.* Дау, ызгыш-талашка бай булган; гаугалы, тынычсыз (*тормыш, көрәш күренешләре, чор*). *Үткән ул даулы гомерләр, Кан-көрәштә яңгырап. Саклаганмын тик күңелдә Шул көрәшнең моңнарын.* Н.Исәнбәт. *Низаглы, даулы дөньяга Кул селтәмәк булдым да Киттем хәтер өермәсе Өергән шул болынга!* Зөлфәт

4) Зур, тарихи көрәшләргә бай (*чор, дәвер һ.б.ш.*). *Шигъри сафлар! Сезне даулы кырга Шагыйрь күңеле күпме үткәрде!..* Р.Әхмәтҗанов

**ДА́УН** *и. ингл. мед.* 1) *к.* **даун авыруы**

2) Шундый авырулы кеше. *Хатын-кыз олыгайган саен, аның дауннар тудыру ихтималы арта. 18–30 яшьтәге хатыннар өчен бу сан 0,001 процентны тәшкил итсә, 35–40 тагылар-ныкы 100 тапкырга арта.* Ватаным Татарстан

**ДА́УН АВЫРУЫ** *и. мед.* Олигофрения; мускул тонусы түбәнәю, эндокрин бизләренең эшчәнлеге бозылу һәм кайбер тышкы билгеләр (ярым ачык авыз, кыска бармаклар һ.б.ш.) белән характерлана торган авыру. *Даун авыруы вакытында балаларның акыл үсеше нык артта кала, ә бөтен сәбәп – егерме беренче пардан бер хромосоманың артыклыгында.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДАУЧАН** *с.* 1) Дау кузгатырга, дауларга, даулашырга яратучан; дәгъвачыл. *Даучан хатын*

2) Сугышка-көрәшкә әзер, кыю табигатьле, батыр. *Җитмеш биш яшьлек чал аксакал гел яшь омтылышлы, яучан, даучан шәхес булып күзаллана.* Р.Гаташ

**ДАУЧЫ** *и.* Дау (*1 мәгъ.*) чыгаручы, дау чыгарырга яратучы; дәгъвачы. *Илен һәлак итәр чиккә җитә туганлыктан туйган вак даучы.* З.Мансуров

**ДА́ФНИЯ** *и. гр. зоол.* Кысласыманнар ыруыннан, төче суда яши торган бөҗәк; су борчасы. *Кәрлә ата дафния көзен генә барлыкка килә.* Зоология

**ДА́ФНИЯЛӘР** *и. зоол.* Төче сулыкларда яшәүче кысласыманнарның бер ыруы. *Дафнияләр – маймычлар һәм вак балыклар өчен яхшы азык. Дафнияләрнең хәрәкәт органнары хезмәтен ике пар тармакланган мыекчалары башкара.* Зоология

**ДАҺИ** *с. гар.* **1.** 1) Иҗади сәләтлекнең иң югары дәрәҗәсенә ия булган, чиктән тыш талантлы. --- *Такташ киләчәк кешеләренә үзен «җырчы-философ» дип тәкъдим итә: «Сезнең заман халкын философлык, даһи җырчы булу белән дә шаккатырып булмас...».* М.Гайнетдинов. --- *бервакыт факультетта зур кичә әзерләгәндә, бөек остазыбыз, шигъриятнең даһи галиме Хатип ага Госман --- Рәдифне чакырып алды да шул кичәдә шигырь укырга тәкъдим итте.* Н.Хисамов

2) Бөек, танылган, данлыклы. *Адәм баласы нинди даһи бит: ул шушы өч төстән [зәңгәр, яшел, кызыл] меңгә якын төс һәм төсмер иҗат иткән.* Ә.Баян. *Ялган даһи, ялган ышанулар, ялган яшәү, ялган тәгълимат.* К.Нәҗми

3) Иҗади сәләтлелекнең, талантлылыкның җимеше булган; шедевр (сәнгать әсәрләре һ.б.). *Даһи әсәрләрне генә --- халык гасырлар дәвамында кулыннан, теленнән, алдыннан төшермичә саклап килә ---.* Ф.Фәсиев. *Кеше – даһи тереклекнең терәге ул ---.* Г.Афзал

4) *ирон.* Чиксез, гадәттән тыш отышлы (*уй, план һ.б.ш.*). --- *минем башка да кайвакыт даһи фикерләр килеп ала.* М.Мәһдиев. *Шулчак аның башына даһи бер уй килде.* Ф.Садриев

**2.** *и. мәгъ.* Нинди дә булса өлкәдә яки, гомумән, сәләтлелекнең иң югары дәрәҗәсенә ия булган кеше; чиктән тыш талант иясе. *Даһиларның үткен зәвыксыз әсәрләре алар яшәгән, иҗат иткән чорның кайнар сулышын алып кайтты.* Ф.Латыйфи

**ДАҺИЛА́РЧА** *рәв.* Даһилар (*2 мәгъ.*) рәвешендә, даһилар кебек. – *Менә бусы даһиларча, инде мәктәпкә йөри башлыйбыз, – диде Ардалион, мыскыллы көлеп.* И.Салахов. *Үзләрен моңа кадәр акыл ияләре ирешә алмаган даһиларча тоталар.* М.Юныс

**ДАҺИЛЫК** *и.* Даһиларга, даһи кешеләргә хас сыйфатлар; даһи булу халәте. *Даһилык – адәм баласындагы иҗади мөмкинлекләр тормышка ашырылуның иң югары дәрәҗәсе.* К.Шакиров. *Даһилык – бер процент илһам һәм туксан тугыз процент тир түгү ул, дияргә яраткан Эдисон.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДА́ЧА** *и. рус* 1) Шәһәрдә яшәүченең, җәйге көннәрдә ял итү өчен, шәһәрдән читтә урнашкан йорты, бакчасы. *Бәлки, синең гозерне иртәгә минем дачада икәү генә калып уйлашырбыз, хәл итәрбез?* М.Мәһдиев. *Безнең күпчелегебез әле дә Рәис Кыямыч ярдәме белән алынган фатирларда яшибез, дача-бакчаларыбыз бар.* Ф.Дунай

2) Дачалар урнашкан махсус урын, территория. *Бу дача – Казандагы бер заводның дачасы.* Г.Мөхәммәтшин. *Машина тимер юл белән янәшә сузылган асфальттан бара, дачалар, авыллар кала.* Р.Кәрами

**ДА́ЧА-АВЫЛ** *и. к.* **дача** (*2 мәгъ.*) *Бу урында элек кечкенә генә дача-авыл булган. Анда мәк чәчәкләре, гөлчәчәкләр, сиреньнәр, алмагачлар үскән. Дошман әлеге урамга бомба ташлаган. Күз ачып йомганчы, дача-авыл җимерелгән.* Мәгариф

**ДА́ЧАЛЫК** *и.* **1.** *к.* **дача** (*2 мәгъ.*). *Роща дигән дачалыклар шәһәргә тоташ диярлек.* Р.Гайфуллин

**2.** *с. мәгъ.* Дача төзүгә яраклы, дача төзү өчен билгеләнгән. *Бер дачалык төзү материаллары сатып алу*

**ДАШНАК** *и. тар.* XIX гасырның 90 нчы еллар башында барлыкка килгән әрмән милли-буржуаз контрреволюцион партиясе әгъзасы

**ДАЯ** [дайә] *и. фар. кит.* Сөт анасы, гомумән, баланы карап, тәрбияләп үстерүче хезмәтче хатын-кыз. *Зөләйха бер көнне йоклап ята иде, Бер даясе, кереп, аның хәлен күрде...* Кол Гали. *Казага күрә, шулай булды: даянең йокысы килде, ятып йоклады.* Мәҗмугыль-хикәят

**ДӘ** I *кис. к.* **да**

**ДӘ** II *терк. к.* **да**

**ДӘВА** *и. гар.* 1) Дару. *Дәва әзерләү өчен, чиянең җимешләрен, яшь ботакларын вә яфракларын файдаланалар.* Татар мөселман календаре

2) Гомумән савыктыру чарасы, сихәтләнү юлы, им. *Әҗәлгә дәва юк, диләр, мәхәббәткә бар микән?* Җыр. *--- курорт дәвасын тулыландыра һәм аларның уңышлы баруына булыша.* Татар халык ашлары

3) *күч.* Авыр хәлдән чыгуга ярдәм иткән чара, әмәл. *Дәртсезгә дәва юк.* Әйтем. *Сүз сихәте, сүз дәвасы – уятучысын көтеп, күпме шигырь юлларына салынган хикмәтле дога.* М.Галиев. *Безнең халыкны исә язмыш дөньяга чәчкән дә үзе үк, югалмасыннар болар дигәндәй, дәвасын, чарасын да табып биргән – җыр!* К.Йосыпов

**ДӘВАЛАНУ** *ф.* Өй шартларында, хастаханәдә һ.б.ш. урыннарда нинди дә булса авыруны дәвалау. *Сакмановка озын-озак дәваланырга, капиталь ремонт узарга туры киләчәк.* Т.Галиуллин

**Дәвалана башлау** Дәваланырга керешү. *Шифаханәдә дәвалана башлап, бераз аякка баса башлагач ук, мин аның хәлен белешергә кердем.* Г.Бәширов. *Иптәшләремнең балаларын күреп кызыга да идем. Ахыр килеп, дәвалана башладым.* Шәһри Казан

**Дәвалана төшү** Бераз дәвалану

**Дәваланып алу** Берникадәр вакыт дәвалану

**Дәваланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта дәвалану белән мәшгуль булу

**Дәваланып карау** Дәваланырга тырышу

**Дәваланып тору** Әледән-әле яисә еш дәвалану. *Кирәгенчә ял итеп, дәваланып тормаса, рәте юк.* З.Фәйзуллин

**Дәваланып яту** Әле, хәзерге вакытта дәвалану. *Мин ул вакытта Казан шәһәренең Горький урамындагы Ортопедия һәм травматология институты дип аталган хастаханәдә дәваланып ята идем.* Ф.Яруллин

**ДӘВАЛА́У** *ф.* **1.** 1) Сырхауны, чирне дарулар һ.б.ш. чаралар ярдәмендә бетерү. *Дөрес дәвалау өчен, авыру турында барысын да белергә кирәк.* Яшәү яме. *Саф һавалы аллеялар буйлап салмак кына атлаганда, күп төрле бихисап кабинетларда дәваланганда, --- иксез-чиксез шатланасың.* Яшәү яме. *Җимеш агачларының зарарланган урыннарын дәвалыйлар һәм дезинфекциялиләр.* Татар мөселман календаре. *[Мария Петровна:] Каюмова, нигә елыйсыз, әллә дөрес дәваламыйлар дип уйлыйсызмы? Дөрес дәвалыйбыз, әле менә бүген сезнең авыру буенча консилиум үткәрдек.* Мирас

2) Чирле кешене махсус шартларга урнаштырып, аңа яраклы режим тудырып, уңай мохиткә күчереп, кирәк очракта дарулар да кулланып сәламәтләндерү, савыктыру. *Бу кечкенә курорт Әлмәттән әллә ни ерак түгел. Шөгер тирәсендә генә. Анда ләм белән дәвалыйлар.* Ю.Әминов

3) *күч.* Төрле борчу, авыр хәлдән чыгу юлын җиңел кичерергә, алардан арынырга ярдәм итү

**2.** *и. мәгъ.* Чирне, җәрәхәтне, авыруларны бетерү өчен махсус ысуллар, чаралар. *Зәйнәп Гафурова күптән инде пенсиядә. Ләкин эшен ташламый, аны һаман дәвалау корпусында --- күрәсең.* Яшәү яме. *Диетик туклану дәвалау учреждениеләрендә, санаторий, курортларда --- дәвалау чараларының бер өлеше булып тора.* Татар халык ашлары

**Дәвалап алу** Берникадәр вакыт дәвалау, озакка сузылмаган вакыт аралыгында дәвалау

**Дәвалап бетерү** Барысын да дәвалау; тәмам, тулысынча терелгәнче дәвалау. *[Карчык:] Һи, балам. Духтырлар кемне генә дәвалап бетерсеннәр. Корткалардан башка да кешеләре җитәрлектер.* Ф.Яруллин. *Психиатр авыруга: – Мин сине кеше иттем бит, әй. Ниһаять, арттырып сөйләү, даһилык, бөеклек зәхмәтеннән дәвалап бетердем.* Р.Гаффаров

**Дәвалап йөрү** Әле, хәзер, сөйләү моментында дәвалау белән мәшгуль булу. *Рита, бар булдыклылыгын эшкә җигеп, Инганы дәвалап йөрде.* Х.Камалов. *Ханга шәһәрдә өч тат [гарәп] табибының кешеләрне дәвалап йөрүләре турында әйтәләр.* Т.Нәбиуллин

**Дәвалап карау** Дәваларга тырышу. *Патша сорый моннан: – Нәрсә кирәк, улым, ни йомыш? – ди. – Минем йомыш шул гына: кызыңны дәвалап карар идем, – ди.* Әкият

**Дәвалап тору** Туктаусыз дәвалау; гел, әледән-әле дәвалау. *Таңсылу никадәр кешеләрне дәвалады һәм әле дә дәвалап тора.* Ф.Яруллин

**Дәвалап чыгу** 1) Билгеле бер вакытның башыннан алып ахырына кадәр дәвалау. *Күрше карты аны төне буе карап, яра-җәрәхәтләрен дәвалап чыккан, ахры ---.* Г.Гыйльманов

2) Барысын да бер-бер артлы дәвалау

**Дәвалап яту** *к.* **дәвалап йөрү**. *Больницага алып килсәк, анда инфаркт диделәр. Анысын дәвалап ятканда, ашаганы үтми башлады.* Г.Бәширов *Җанга, тәнгә сеңгән яраларны Мин дәвалап ятам авылда.* Р.Гатауллин

**Дәвалый бару** Һәрберсен, акрынлап барысын да дәвалау

**Дәвалый башлау** Дәваларга керешү. *Ханның хәле авырая төшкәч үк, дәвалый башлаган гарәп табибы ханбикәгә әйтте: «Хан озак яшәмәс».* М.Хәбибуллин. *Машаны дәвалый башлау мәшәкатьле булмады: бер танышым моны үз өстенә алды.* М.Насыйбуллин

**Дәвалый төшү** Тагын да бераз дәвалау

**ДӘВАЛАУЧЫ** *с.* **1.** Дәвалый торган, дәвалау белән шөгыльләнә торган. *Рухияне дәвалаучы табибә Әминә исемле икән.* Г.Гыйльманов. *--- дәвалаучы песиләр турында газетләрдә дә яза башладылар.* Ш.Маннапов. *Дәвалаучы врачларның күрсәтмәсе нигезендә аэротерапияне медицина сестрасы уздыра.* Яшәү яме

**2.** *и. мәгъ.* Авыруны дәвалау белән шөгыльләнүче кеше; табиб. *Түрәләрне, байларны дәвалаучылар табылыр ул. Ә гади халыкны?..* Р.Батулла. *Күрәзәчеләр, дәвалаучылар хәзер буа буарлык, аларның ялганчы икәнен каян белергә?* Кәеф ничек?

**ДӘВАЛЫ** *с.* Дарулый, савыктыра торган; шифалы. *[Ярмөхәммәт:] Ул тауда дәвалы үләннәр үскәнгә, аны*

*«Дәватау» дигәннәр, иеме, бабай?!* Р.Батулла. *Яратам мин сине, алтын көз, Дәвалы, шифалы сулышың.* Х.Җәгъфәр. *Мин бит дәвалы үлән – Таптамагыз, тимәгез (Песи үләне).* Р.Вәлиев

**ДӘВАЛЫК** *и. сир.* Дәвалы булу. *Дару үләннәренең дәвалыгы*

**ДӘВАМ** *и. гар.* 1) *күбесенчә тарт. форм.* Нәрсәнең дә булса билгеле бер чиктән узып, арырак сузылган өлеше. *Тауларның дәвамы күренми дә*

2) Эш-хәрәкәт, процесс, хәл-вакыйганың вакыт эчендәге сузымы. *Бу уйларның дәвамы Шакирны, әллә кайлардан әйләндереп, яңадан әүвәлге тыныч өметсезлеккә кайтарды.* Ф.Әмирхан. *Гомерем дәвамы булып Илнең даны ялганыр.* Ә.Ерикәй. *И-их, Каласы, Зур өметләр бакчасы, Ярсу дәртнең, Бар теләкнең Синдә табыла дәвамы.* Ш.Маннур

3) Берәр нәрсәнең бүленеп торганнан соң килгән өлеше, кисәге. *Әлеге китап [Оҗмахка бер адым] – 2004 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Пәйгамбәр таңы» романының дәвамы.* С.Поварисов

4) *к.* **дәвамчы**. *Зәйтүнәнең бөтен җире анасына охшаган, аның дәвамы.* Ф.Хөсни

5) Дәвамлылык, озынлык. *Көннәр озын булганда, аның дәвамы – егерме, ә төннең – дүрт сәгать. Кыш кергәч, киресенчә, төн – егерме, ә көн дүрт сәгать.* Татар халык иҗаты

**ДӘВА́М ИТҮ** *ф.* 1) Пространствода, җирдә яки берәр өслектәге нәрсә арырак сузылу, тагын да булу

2) Эш-хәл, хәрәкәт, халәт, уйлар һ.б.ш. тәмамланмый, бетми тору, сузылу. *Хат болай дәвам итә: «Шәһәрдә хәлләр шулай».* Ш.Камал. *Хөрмәтле сәр, күрсәтмәләрегез буенча, Бохара әхвәлләрен ачыклауны һәм кайбер ашыгыч чаралар күрүне дәвам итәм.* Т.Әйди. *Киләчәккә күкрәп баруында Дәвам итсен безнең Туган ил.* Ш.Маннур

3) Вакытны белдергән сүзләрдән соң килеп, эш-хәл, хәрәкәт, халәт, уй һ.б.ш. шул вакыт эчендә булуы, узуы. *Әз генә вакыт дәвам иткән буталыш, чуалыш һәм әүмәләш, ябырылып, кеше кыйнауга әверелде.* М.Галәү

4) Урын-вакыт килешендәге сүздән соң килеп, шул хәлдә калу, булу, шуны өзми-бүлдерми алып бару. *Камил --- укуында дәвам итә.* Һ.Такташ. *[Отряд] Икегә аерылып, бер пары көнчыгышка таба томырылды, икенчесе юлын әүвәлге юнәлештә дәвам итте.* Т.Әйди

5) Эшне-хәрәкәтне туктатмау, бетермәү. *Без утыргач, кичә тагын шулай Дәвам итте чиксез күңелле.* Ш.Маннур. *Моннан тыш, алар икенчел төркем культларны тәшкил итүче сыннарга табынганнар, төрле рухларга, теге дөньяда яшәүнең дәвам итүенә ышанганнар.* Г.Дәүләтшин

6) Бетерми саклап бару. *Хуш, онытма! Сөюеңдә яшьлегем дәвам итсен.* Г.Хуҗи

**ДӘВАМЛЫ** *с.* Вакыт эчендә сузылган, озак дәвам итә торган. *Мәктәптә балага интернациональ тәрбия бирү – дәвамлы процесс.* Тарих. *Безгә сеңдереп ява торган җәйге шифалы, дәвамлы яңгыр кебек булырга кирәк.* Татар мөселман календаре

**ДӘВАМЛЫЛЫК** *и.* Дәвамлы булу; барыш, озынлык. --- *шигърият күчемлелектән, дәвамлылыктан башка яши алмый.* Т.Галиуллин. *Кичәге ул – бүген, ә бүген – иртәгәге ул. Бу – Вакыт агышы, дәвамлылык, тормыш. «Хәтер» дигән нәрсә шушы дәвамлылыкны онытмас өчен кирәк тә инде...* Р.Фәйзуллин. *Мирвәли гомере – вакыйгалар агышыннан югарырак күтәрелеп, аны тарихи дәвамлылыкта һәм алмашынучанлыкта күрә алмауның типик бер мисалы.* М.Вәлиев

**ДӘВАМЧАН** *с. кит.* Эзлекле рәвештә, эзлеклелеген саклап дәвам итә торган. *Әбекәйнең, бу дөнья белән хушлашканнан соң, дәвамчан рухын үзенә сеңдерә алган Сәвилә --- яктыга таба юл тота.* Д.Гыймранова

**ДӘВАМЧАНЛЫК** *и.* Дәвамчан булу, даимилек. *Гаилә – балалар бакчасы – мәктәп эшчәнлегендә дәвамчанлык югалса, туган телнең йогынтысы түбән булачак.* А.Низамов. *Иске цех мастерлары белән иң соңгы капиталистик мануфактура принциплары арасында турыдан-туры дәвамчанлык һәм бәйләнеш булуын күрәбез.* Тарих

**ДӘВАМЧЫ** *и. кит.* Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсендәге алдынгылар, әйдәп баручылар артыннан барып, аларның эшен дәвам итүче яңа буын; варис. *Дөнья шулай яратылган: киләчәгең – дәвамчыда.* Р.Фәйзуллин. *Кызы Әлфияне Шаһмәлиев малае белән кавыштырып, «укмаштырып», шундый таяныч, дәвамчы булдырырга иде исәбе [Садыйк Сираевичның].* З.Хөснияр. *Биредә, ислам дөньясында, мәшһүр Сахибзадә ишанның хәлифәләреннән дәвамчы санала.* Казан утлары

**ДӘВАМЧЫЛЫК** *и.* Яңаның, искене алмаштырганда, үзендә аның ниндидер үзенчәлекләрен саклау, дәвам иттерү. *Фән өчен дәвамчылык, традицияләрне югалтмыйча, башланган эшне ахырына җиткерү, лаеклы алмаш үстерү...* Ф.Яхин

**ДӘВАМЫНДА** *бәйл.* 1) Вакытны белдергән сүзләрдән соң килеп, «шул вакыт эчендә» дигәнне аңлата. *– Казан татарлары, – дип яза ул [К.Фукс], – буйсындырылган өч йөз ел дәвамында үзләренең шулкадәр күп милли үзенчәлекләрен саклап киләләр.* И.Гафаров. *Ул [сәнәкчеләр фетнәсе], 1920 елның 7 февралендә башланып, 35 көн дәвам итә.* И.Таһиров

2) Эш-хәлне, вакыйганы, хәрәкәтне белдерә торган сүзләрдән соң килеп, «шуның барышында, шул процесс вакытында» дигәнне аңлата. *Шул картиналар дәвамында бөтен кеше аш әзерлиләр, барысы да Гөлгенәне каршылыйлар.* М.Җәлил. *Сугыш дәвамында андый хәлләр аз булмады.* Г.Минский

**ДӘВАСЫЗ** *с.* 1) Дәва табып булмый торган. *Ярасыз батыр булмас, дәвасыз яра булмас.* Мәкаль

2) Төзәлми, дәваланмый торган, бетәү

**ДӘВАСЫЗЛЫК** *и.* Дәвасыз булу

**ДӘВАХАНӘ** *и. гар.-фар.* Авыруларны дәвалый торган йорт; больница. *Хатын дәваханәдә наркоманнарның ничек җәзаланып үлүләре хакында җан әрнеткеч хәлләрне сөйләп торса да, Сергей аны аңламады.* М.Кәбиров

**ДӘВАЧЫ** *и. иск.* **1.** Даручы, имче, дәвалаучы, дәвалый торган кеше. *Яраланган иде күкрәк сугышта, Ала алмый*

*идем юньләп сулыш та. – Төзәлмәс тиз яраң, – диде дәвачы, – Фәкать сабрың, – диде, – барлык дәвасы.* Ә.Исхак. *Гөлчәчәккә якын барсам, Чәнечкесенә кадалсам, Җаныма җәрәхәт алсам, – Дәвачы да ул булырмы?* Р.Гаташ. *Кичерү соравы аша саулыгын үзе үк кайтарган авыру, мине дәвачы савыктырды, ди.* Шәһри Казан

**2.** *с. мәгъ.* Дәвалау белән шөгыльләнә, дәвалый торган. *Дәвачы карчык кулыннан да йомшаграк, анықыннан да шифалырак кул булмый дип санаган авыл балалары* ---. Рифә Рахман

**ДӘВӘ** *и. иск. к.* **дөя.** *Көчле көчсезгә кул сузмасын, арыслан дәвәнең муенын өзмәсен, эт төлкенең тунын ертмасын --- дип боерган, дигән.* Әкият

**ДӘВӘТ** *и. гар.* 1) Язу карасы савыты

2) *этн.* Күкрәкне бизәү өчен, иңгә кыеклап бәйләнә торган киң тасма. *Әзерләнгәндә, кыз Борды мәктәбе музееннан керәшен халык киемнәре алган, Зәй районына кадәр барып, керәшен хатын-кызларының беләзек, тамакса, сүрәкә, чигәчә, дәвәт кебек бизәнү әйберләрен юллаган.* Якты юл

**ДӘВӘЮ** *ф. диал.* 1) Зураю, эрегә әйләнү

2) Үсү, өлкәнәя төшү, балигъ булу. *Бу бала, шөбһәсез, дәвәйгәч --- мөхәррир булыр.* Г.Тукай

**ДӘВЕР** I *и. гар.* 1) Җәмгыять тормышының үзенә хас вакыйгалар белән билгеләнгән бер вакыты; чор; заман. *Алтын Урда заманындагы мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән Болгар мәдәнияте Казан ханлыгы һәм аннан соңгы дәверләрдәге мәдәниятнең дә гомуми әсасе һәм аның дәвамы булып тора.* Ш.Абилов. *Чын шагыйрь, Иман биеклегеннән торып, дәверләр арьягына сүз йомгагын чөя алган икән, аны дәвер ызаннарында кузы калган учак көле арасыннан Вакыт кайтып күтәреп ала да мәңгелек бишегенә сала.* М.Галиев

2) Билгеле бер вакыт аралыгы; цикл. *Госпитальдә эшләү дәверендә, аның үтә йомшак холкы шактый ныгып өлгерде.* Г.Әпсәләмов

3) Нинди дә булса процесс үсешендә, билгеле бер этап, баскыч, стадия. *Безнең әдәби тел әле эшләнү дәверен кичерә.* Җ.Вәлиди. *Ул [Газизхуҗа апа] башта, туу-үлү шикелле, яшәү дәверендәге иң мөһим вакыйгаларга кагылды...* М.Юныс

4) *геол.* Геологик система катлауларында тау токымнары барлыкка килгән билгеле бер вакыт аралыгы; эраның бер өлеше. *Бозлык дәверендә Көнчыгыш Европа тигезлеге төньяк яртысының шактый өлеше гигант бозлык белән капланган булган.* Физик география

**ДӘВЕР** II *и. гар. дини этн.* Мәрхүмнең гөнаһларын кичерү йоласы: варис тарафыннан бирелгән сәдаканың бирүче белән алучы арасында күченеп йөрүе, мәрхүмнең 12 яшеннән соң яшәгән еллары санынча кат-кат әйләнеп йөрүе

**ДӘВЕРЧЕ** *и. дини этн.* Дәвер (II) йоласын башкаручы кеше. *Мәетнең сул ягы буйлап, ишектән түргәчә ике рәт булып, дин әһеле – дәверчеләр, фидиячеләр сафланганнар.* Г.Ибраһимов

**ДӘГЪВА** *и. гар.* 1) Нәрсәгә дә булса омтылыш; берәр нәрсәгә хокукның булуын белдереп куйган таләп; претензия. *Бу хакта китергән башка матдәләрендә ул [шагыйрь] шушы фикерен үстерә, үз дәгъвасына яңа дәлилләр өсти.* Г.Нигъмәти. --- *Х.Туфан, исемсез һәм дәгъвасыз хәлдә, әдәбиятның иң авыр йөген «Туфанчалап» күтәрешергә – батрак крушнигы булырга әзер язмыш белән шигъриятебезгә килеп керә.* М.Гайнетдинов

2) *юр.* Нинди дә булса бәхәсне хәл итү максатыннан, судка һ.б.ш. органнарга ясалган мөрәҗәгать. *Мәсәлән, бер сәүдәгәрнең икенчесендә алачагы булып, араларында вексель яки расписка булмаенча, эшләре дәгъвага китсә, алачак адәмнең дәфтәрләре бухгалтерия ысулына тугыры йөртелгән булса, торговый уставның 617 нче маддәсенә бинаән хакын судлашып ала аладыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Өч айдан соң окружной судның гражданский бүлегеннән чакыру кәгазе килсә дә, Михаил үзенең дәгъвасы дөреслеген исбат итәргә бара алмады...* Ш.Камал. *С.Нәфиев рәислегендә Татарстан Республикасы Конституция суды төрле предприятие һәм физик затларның байтак дәгъвасын карап тикшерде.* Мирас

3) Берәр нәрсәгә карата белдерелгән катгый ризасызлык, канәгатьсезлек. *Мөхип әби Гайниҗамалның бу хаклы дәгъвасын игътибарсыз калдырмады.* Ф.Әмирхан. *Тылмачның соңгы җөмләләрен ишетүгә, ялангдагы халыкның түземлеге сынды. Төрле якта ризасызлык, дәгъва, кычкырыш купты.* В.Имамов

4) Масаючан, мин-минлеккә корылган, һавалы, ләкин нигезсез омтылыш, теләк

**ДӘГЪВА́ ИТҮ** *ф.* Дәгъва белдерү, дәгъвалау, таләп итү. *Моннан соң кунаклар белән Кәрим арасында чәй ясау турында манзара башлана, кунаклар, чәйне хуҗа ясап эчерергә тиеш, дип дәгъва итәләр.* Ф.Әмирхан. *Учредительный собрание закон чыгармыйча торып, җир дәгъва итү* --- И.Гази

**ДӘГЪВА́ КЫЛУ** *ф. к.* **дәгъва итү**. *Шунлыктан җитәкчелеккә быел Халидә апа әллә ни дәгъва да кылмады: телгә-тешкә килмичә, сүзсез генә Фәрхәнә апага юл бирде.* Н.Фәттах

**ДӘГЪВАЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса хокукы булу турында белдерү. *Боларның уң яктагысы Византия стиленә тартым, куполлап эшләнгән, сул яктагысы тешләк башнялары белән готик стильне дәгъвалап маташа иде.* Ш.Камал. *Башка республикалар кебек үк, башлыча рус халкы яшәгән бик күп регионнар зуррак мөстәкыйльлек таләп итәләр, үзләренең статусларын күтәрүне дәгъвалыйлар.* Казан

2) Нәрсәгә дә булса омтылу; берәр нәрсәне таләп итү, дәгъва итү, сорау даулау. *Ул, озын кулларын болгый-болгый җир дәгъвалаганда, Гафият, аның янына басып: – Миңнулла дус, акрын! – дип, Миңнуллага торып китәргә ирек бирмичә торды.* И.Гази

**Дәгъвалап алу** Кыска, аз вакыт арасында дәгъвалау; берникадәр вакыт дәгъвалау

**Дәгъвалап йөрү** Әле, хәзерге вакытта дәгъвалау. *Чаллылар 6–7 сыйныфлар өчен «Ватан тарихы» дәреслеген тыюны дәгъвалап йөриләр.* Шәһри Чаллы

**Дәгъвалап тору** Даими, әледән-әле дәгъвалау

**Дәгъвалый башлау** Дәгъваларга тотыну

**Дәгъвалый бирү** Дәгъвалавын дәвам итү, һаман да дәгъвалау

**Дәгъвалый төшү** Бераз дәгъвалау

**ДӘГЪВАЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **дәгъвалау.** *Карар укый: – Бу ике дус инде, Дәгъвалашып судка йөрмәсен, Өйләренә кайтып, Ничек кирәк, Өзмәсеннәр шулай араны.* З.Мансур

2) Талаш-низаг китереп чыгару, даулашу. *[Сафый:] Миңа бу пианиноны шул Рокыя өчен дәгъвалашып алдырттыгыз бит.* Ф.Әмирхан. *[Әхәт:] Шулайрак… Фактларның шактые моның яклы иде!.. Дәлилсез тотынган ул егет дәгъвалашырга!* А.Гыйләҗев

**Дәгъвалаша башлау** Дәгъвалашырга тотыну

**Дәгъвалаша бирү** Дәгъвалашуын дәвам итү, һаман дәгъвалашу

**Дәгъвалашып алу** Аз вакытка, кыска гына дәгъвалашу

**Дәгъвалашып бетү** Бик нык дәгъвалашу, дәгъвалашуның ахыр чигенә җитү

**Дәгъвалашып тору** Даими, әледән-әле, еш дәгъвалашу. *Минем гаҗәпләнүемә, анам да, атам да аның өчен дәгъвалашып тормадылар.* Ф.Әмирхан

**ДӘГЪВАЛЫ** *с.* 1) Даулы, талашлы, низаглы; тынычсыз

2) Бераз гына мин-минлекле, һавалы. *[Хөсәен] – дәгъвалы гына --- сәүдәгәр.* Ф.Әмирхан

**ДӘГЪВАТ** *и. гар.* 1) Иманга чакыру, дингә килергә өндәү; исламны пропагандалау. *Мөселманның алтынчы сыйфаты – дәгъват. Ягъни үзенең белемен башкаларга җиткерү һәм кешеләрне дингә һәм яхшы гамәлләр кылырга өндәү.* Татар мөселман календаре

2) Гомумән чакыру

**ДӘГЪВАТНАМӘ** *и. гар.-фар. иск.* Мәҗлескә, кунакка һ.б.ш. чакыру кәгазе. *Никах мәҗлесенә ашыгып дәгъватнамәләр таратылды.* Ш.Әхмәдиев

**ДӘГЪВАЧЫ** *и.* 1) Дәгъва (*1, 2 мәгъ.*) белдерүче, дәгъва итүче, дәгъвалаучы

2) *күч.* Талаш, ызгыш, низаг чыгаручы, даулаучы

**ДӘГЪВАЧЫЛ** *с.* Талашучан, ызгыш, низаг чыгара торган, даучан

**ДӘГЪВАЧЫЛЫК** *и.* Гел нәрсәгә дә булса дәгъва белдерү, таләп кую күренеше; артык күп нәрсәгә дәгъва итү. *Куанып, «Өлфәт» белән дуслык корыйк: Дәгъвачылык һәм тәкәллефне читкә ташлыйк!* Г.Тукай

**ДӘДӘ(Й)** *и. рус диал.* 1) Әтисенең яки әнисенең абыйсы (яки энесе). *Мин, бик яшьли үксез калып, ундүрт яшемә кадәр мәрхүм дәдәм өендә тәрбияләндем.* Ш.Камал

2) Үзеңнән күпкә өлкән, ләкин карт булмаган кеше, агай (гадәттә, русларга һәм керәшеннәргә карата кулланыла). *Һәм Илсөяр, аучы җәнлек артыннан күзәткән шикелле, бабай белән Андрей дәдәне күзәтә башлады.* Г.Гобәй. *Иргали миңа ничәнче кат инде, әллә, чыннан да, нэпман Иван дәдәйгә барып, эшкә ялланып караргамы дип өмсенеп куйгалады.* М.Хәсәнов

**ДӘҖҖАЛ** *и. гар.* 1) *дини* «Ялган мәсих»; ахырзаман җиткәч, ишәккә атланып, Иблис коткысы белән, Аллага һәм аңа ышанучыларга каршы чыгачак алдар зат; аны күргән мөселманнар һәлак булачак; христиан динендә аны «ялган Христос» – «антихрист» дип атыйлар. *Мөселман хәдисләрендә Дәҗҗал диңгез буендагы кыяга кадакланган дип күрсәтелә.* Ислам

2) *күч.* Алдакчы, ялганчы. *– Бер күзле ул дәҗҗалны өемә кертәсем юк, – диде мәрхүм.* Д.Йосыпова

**ДӘКЫЙКА** *и. гар. иск. кит.* Бик кыска вакыт аралыгы, мизгел, секунд. *Әхмәт әфәндегә офицерның ике-өч дәкыйка бер мөддәт эчендә карап торуы бер ел кебек озын тоелды.* Г.Газиз

**ДӘЛАЛӘТ** *и. гар. иск.* 1) Кемне дә булса эшкә яки башка җиргә урнаштырганда, аның ышанычлы булуына инанып, аның өчен җаваплылыкны үз өстеңә алу; рекомендация. *Партиягә Костомаров дәлаләте белән Шевченко да керде.* Г.Ибраһимов

2) *филос.* Күрсәтмә

**ДӘЛАЛӘ́Т ИТҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса юл күрсәтү

2) Нәрсәне дә булса дәлил итеп китерү; ишарәләү

**ДӘЛАЛӘ́Т КЫЛУ** *к.* **дәлаләт итү**. *[Күз яшьләре] Ачлык белән хәерчелеккә дәлаләт кыла.* М.Гафури. *Газет укучылар гыйлем һәм мәгарифкә дәлаләт кылалар, укырга кушалар.* З.Һади

**ДӘЛИЛ** *и. гар.* 1) Нәрсәне дә булса раслап, исбатлап, нигезләп әйтелгән аргумент; әсас, анык караш. *Вөҗдан бу дәлилләрнең ышандырырлык түгелләген белгертә.* М.Юныс. *Сүз көрәштерергә кирәк тә тапмадым, аның иманын үзгәртерлек дәлилләрем дә юк иде.* М.Әмир. *Кулда дәлилләр юк, ә дәлилсез сөйләү яла ягуга тиң ---.* Ф.Садриев

2) Нигезле, раслый, исбат итә торган факт; аргумент. *«Мәдәни» дигән даирәләрдә исә, гомумән, динне логикасыз, реаль дәлилләрсез «фаш итү», әтәчләнеп сүгү бик күпләрнең көн итү – тамак туйдыру әмәленә әверелде.* Ф.Дунай

**ДӘЛИЛЛӘНҮ** *ф.* Тиешенчә исбатлану, җитәрлек дәлилләре булу. *Гаҗәеп дәрәҗәдә дәлилләнгән, ифрат тирән фикерле, нәкъ вакытында язылган хезмәт иде ул.* Р.Мирхәйдәров. *Тикшерү барышында ошбу өчлекнең җинаятьчел гамәлләре дәлилләнсә, алар яңадан гаепләнүчеләр эскәмиясенә утырачак ---.* Безнең гәҗит

**Дәлилләнеп бару** Эзлекле рәвештә, бер-бер артлы дәлилләнү. *--- әйтеләсе фикер расланмаса, аны язудан файда юк. Әлеге басмада, киресенчә, һәрбер факт тарихи чыганаклар белән дәлилләнеп бара.* Ватаным Татарстан

**Дәлилләнеп килү** Электән үк, һәрвакыт эзлекле рәвештә дәлилләнү. *Әмма Америкада да ул законның идеаль эшләмәве гел дәлилләнеп килә, Мәскәү мәктәбендәге вакыйга да ау мылтыгына гына рөхсәт булу да нинди бәлаләргә китереп җиткерә алуын исбатлап күрсәтте.* Шәһри Казан

**Дәлилләнеп җитү** Тиешенчә, җитәрлек дәрәҗәдә дәлилләнү

**Дәлилләнеп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле дәлилләнү. *Моңа мисаллар эзләп тә каядыр барасы, сорашасыбелешәсе, фәнни мәкаләләр актарасы юк, ул көнкүрешебездә дә адым саен дәлилләнеп тора.* Шәһри Казан

**ДӘЛИЛЛӘ́Ү** *ф.* Нәрсәне дә булса дәлилләр белән раслау, исбат итү; фактлар белән нигезләү. *Әлеге мәкалә --- иҗат интеллигенциясенең кулына идеология богаулары кидерергә маташуның нинди күңелсез нәтиҗәләргә китерүен этрафлы итеп дәлилләп исбатлады.* Ә.Сәхапов. *Яхья Ханов бакча оештыру эшенең баштан ук уйланып җитмәгәнлеген дәлилләргә кереште.* Ф.Садриев. *Алар – Пәйгамбәребез сүзләре белән дәлилләнгән хакыйкатьтер.* Татар мөселман календаре

**Дәлилләп бару** Һәрберсен, барбер артлы дәлилләү. *Шунысы да әһәмиятле: диссертант үзенең фәнни фикерләрен, тикшеренүләрен шагыйрь иҗатыннан мисаллар белән дәлилләп бара, икеләнерлек, шикләнерлек урын калдырмый.* Р.Миңнуллин

**Дәлилләп бирү** Дәлилләнгән итү. *Коперник әгәр дә Җирнең, Кояш системасының физик халәтен ачыклаган, дәлилләп биргән булса, Солтан – прогресс һәм фән заманында яшәүче галим – үз хезмәтләрендә аларны инкяр итәргә җыенмады* ---. Ф Яхин

**Дәлилләп бетерү** Нәрсәне дә булса тәмам, ахырынача, анык нәтиҗәгә ирешкәнче дәлилләү. *Галим үз фикерен дәлилләп бетерде*

**Дәлилләп карау** Дәлилләргә тырышу. *[Илдар:] Анда шундый механизм, матурым... Ришвәт бирүне дәлилләп кара син! Ул фактик яктан рәсми рәвештә бирелә.* Г.Әкбәр

**Дәлилләп килү** Элек-электән, күптәннән, даими, системалы дәлилләү. *Республикабыз яшьләр оешмалары үзләренең актив булуларын һәр эштә дәлилләп килә.* Шәһри Казан

**Дәлилләп тору** Даими яки әледәнәле дәлилләү. *Илгиз милли җанлы иде, халкыбызның аһәңен, моңын тоеп яшәде. Моны аның чын халык моңы белән сугарылган дистәләгән әсәрләре дәлилләп тора.* Д.Гыйсметдинов. *--- җиһазларының яхшылыгы Әхмәди Хәмитовның бай адәм икәнлеген дәлилләп торалар иде.* З.Бигиев

**Дәлилләп чыгу** Барысын да, башыннан ахырына кадәр дәлилләү. *[Фейербах] --- немец философиясендә озак еллар дәвамында хакимлек итеп килгән идеалистик карашларны каты тәнкыйтьләп, материалистик карашларны нигезле дәлилләп чыга һәм фәлсәфи материализмны Аурупа күләмендә яңадан торгыза.* К.Гыйззәтов

**Дәлилли бару** Акрынлап һәрберсен бер-бер артлы дәлилләү. *Ул – эше белән әйткәннәренең дөреслеген дәлилли барды*

**Дәлилли башлау** Дәлилләргә керешү. *--- күптән түгел генә ачылган түләүсез юридик консультацияләр үзләренең нәтиҗәлелекләрен дәлилли башлады.* Шәһри Казан

**Дәлилли төшү** Тагы да күбрәк дәлилләр китерү. *Фән аксакаллары яшь галимнең соңгы ачышын дәлилли төшү кирәк дип таптылар*

**ДӘЛИЛЛЕ** *с.* Дәлиле булган, анык фикер белән дәлилләнгән, исбатланган. *Кавиның дәлилле чыгышы Рәхимгә карата җыелышның карашын үзгәртте.* А.Расих

**ДӘЛИЛСЕЗ** *с.* Нигезсез, нигезләнмәгән, буш, расланмаган, фактларсыз. *Үзгәртеп коруда рәсми оешмаларга ярдәм итү йөзеннән шул чакта әле оеша гына башлаган татар мәдәнияте клубы һәм аның ун-унбиш бөртек әгъзасы беренче җыелыштан ук «милләтчелектә һәм экстремистлыкта» гаепләнделәр. Алар төрле активларда һәм матбугатта бөтенләй дәлилсез тәнкыйтькә дучар ителделәр* А.Хәлим

**ДӘЛИЛСЕЗЛЕК** *и.* Тиешле дәрәҗәдә дәлилләнмәгән булу, дәлилләр җитмәү күренеше. *Хат бисмилласыз башлана һәм журналистларны дәлилсезлектә гаепләү белән дәвам итә ---.* Безнең гәҗит

**ДӘЛИЯ** *и. лат.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, төрле төстәге (ак, кызыл, зәңгәр, шәмәхә) чәчәк ата торган бүлбеле бакча гөле*; русчасы*: **георгин**. *Ерак түгел нәни каштан үсентесе кояшка тартылып утыра, дәлияләр, тырнак гөлләр, канәферләр чәчкәдә.* Кәеф ничек?

**ДӘЛЛӘТЧЕ** *и. иск.* Рекомендация бирүче кеше. *[Сөләйман:] Мин бик тырышып хезмәт итәр идем, бай абзый. [Бай:] Дәлләтчең бармы, дим син сиңа? --- Сине миңа кем җибәрде? Сине шәһәрдә кем белә?* К.Тинчурин

**ДӘМ** I *и.* Мизгел, мәл, бик кыска вакыт аралыгы. *Мән шикәстә гарибнең хәлен бер дәм сурмадың?* Кол Шәриф. *Шул халәттә гаять мохтаҗ улам шул дәмдә мин Якты юлны күрсәтүчегә, бөек ярдәмгә мин.* Г.Рамазанов

**ДӘМ** II *и. диал.* Тәм. *– Авызың кибеп калгандыр, бераз дәм итсәңче! – дип, ишек төбендәге кечкенә күн турсыктан Бохараның яшькелт пыяласына салып, кымыз китерде.* Г.Ибраһимов

**ДӘМЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Ботка, чәй, бәлеш һ.б.ш.ны берәр нәрсә белән каплап, төреп куеп, парланып (изелеп) пешеп җитәргә мөмкинлек бирү. *Аның театрдагы кунакчыл хөҗрәсендә, хуҗа чәй дәмләп мәшәкатьләнгән арада, диварлардагы «байлыкны» кызыксынып күзәтәм.* Сәхнә. *Кәбестә бөккәнен дәмләү*

**ДӘРӘҖӘ** *и. гар.* 1) Нәрсәнең дә булса икенче бер нәрсә белән чагыштырмасы, үлчәм кимәле. *Илсөяр, моны ишетүгә, партизаннар алдына чыкты һәм соң дәрәҗәдә сакал-мыек белән капланган әтисен танып алды.* Г.Гобәй. *Моннан тыш, аларда байлыклары төрле дәрәҗәдә булган һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр яшәгән.* Г.Дәүләтшин. *Клуб эшеләр дәрәҗәгә якынлашты.* З.Хәким

2) Кабат, тапкыр, мәртәбә. *[Телескоп] Нәрсәне үз зурлыгыннан ничә дәрәҗәләр зурайтып күрсәтә.* Г.Ибраһимов

3) Үсеш баскычындагы бер басма, ирешелгән чик. --- *шул рәвештә бер атна-ун көн чамасы Галиәкбәр агай, шәһәрнең астын өстенә китереп, беренче класс ресторанынннан башлап түбән дәрәҗәдәге кабакка кадәр, һичбер зыярәт итмәгән җирне калдырмады.* Ш.Мөхәммәдев

4) Нинди дә булса бүленеш системасында, рәсми һ.б.ш. бүленешләрдә: бер баскыч, урын, тәртип. *Ләкин бу нәрсә бит чын сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә менеп җитмәгән, бары гади бер панорама гына.* Г.Бәширов

5) Төрле авырулар һ.б.ш. вакытында стадия, баскыч, бүленеш. *Пешүне дәрәҗәләргә бүлеп йөртәләр. Беренче дәрә-*

*җә пешү булганда, тире кызара һәм бераз шешә.* Социалистик Татарстан

6) Абруйлы эш урыны: югары дәүләт яки хөкүмәт посты; җәмгыятьтә торткан урын. *Азымбай яше зур, сакалы ак булса да, байлыгы юк, кабилә эчендә дәрәҗәсе кечкенә, шуңа күрә аның белән бераз юләрләрчә шаяралар иде.* Г.Ибраһимов. *Кирәк түгел таш пулатлар, Зур дәрәҗә, юрга ат.* Т.Гыйззәт

7) Рәсми бирелә торган һәм эшхезмәт баскычын күрсәткән исем. *Сугыш сугыш инде, 1942 елның 12 ноябрендә унтугыз яшьлек абыебыз да гвардия өлкән лейтенанты дәрәҗәсендә Витебск юнәлешендә һәлак булды.* К.Йосыпов. *Хөкүмәт аны генерал-майор дәрәҗәсенә мендерде.* Урал

8) Авторитет, җәмгыятьтә торткан урын, абруй. *Үз остазыңның дәрәҗәсен төшерергә, укый торган изге йортыңның яман атын сатарга кемнән өйрәндең?* Т.Гыйззәт. *Үз бәһаң, үз-үзеңнең кадереңне белү; кешелек горурлыгы. Әнисә, үзенең дәрәҗәсен – бәясен яхшы аңлап, үзен пакь, чиста тотуы белән дә башка кызлардан аерылып тора.* З.Бәшири. *Миңлегаяз белән Азатның да дәрәҗәсе, көне түгел, сәгате белән артты малайлар арасында.* Р.Мөхәммәдиев

9) Нәрсәнең дә булса бәһасы, кыйммәте, үтемлелеге, әһәмияте. *Зәвык белән бизәкләп эшләнгән җыйнак өйләр, чирәмгә, бәпкә үләннәренә төренеп утырган тигез иркен урам, пөхтә итеп себерелгән капка төпләре, койма читендә үсеп утырган ак каен, миләш, шомырт агачлары – боларның берсе дә дәрәҗә яисә байлык күрсәткече саналмаган.* Р.Мөхәммәдиев

10) *мат.* Санны (кыйммәтне) үзүзенә тапкырлаганнан чыккан тапкырчыгыш. *Дәрәҗәләрне хәзергечә язу ($a^2$, $a^3$ һ.б.) Декарт тарафыннан кертелә, өстәвенә аның икенче дәрәҗәсен, ягъни $a^2$ ны ул аа тапкырчыгышы рәвешендә бирә.* Алгебра

11) *лингв.* Сыйфатларда һәм рәвешләрдә: билгенең-сыйфатның микъдар дәрәҗәсен белдерә торган грамматик форма. *Асыл сыйфат белән белдерелгән билге төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин: бер предметтагы билге, икенче бер предметтагы шундый ук билге белән чагыштырганда, аннан бераз артык, яки иң югары дәрәҗәдә, яисә гадәттәгедән ким булырга мөмкин.* Татар грамматикасы

12) *лингв.* Фигыльләрдә: эш-хәлнең яки процессның дәвамлылык яки кабатлаулылык, тизлек яки кинәтлек, тулылык яки кимлек төсмерләрен белдерә торган грамматик форма. *«-п» га тәмамланган хәл фигыльгә «калу» модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр ---.* Татар грамматикасы

**ДӘРӘҖӘЛЕ** *с.* 1) Югары дәрәҗәгә (*4, 5 мәгъ.*) ия булган, югары дәүләт яки хөкүмәт постын биләгән; урындагы. *Шул сәгать дәрәҗәле, олуг Патша, сикерә-сикерә, елан янына килеп җитте.* М.Гали

2) Авторитеты, абруе югары булган; хөрмәтле, хөрмәткә лаек. *Дәрәҗәле эшләпәнең карачкы башында эленеп торуы хыялын челпәрәмә китерде малайның...* Т.Миңнуллин

3) Бик яхшы дип табылган, уңай бәяләнгән, мактаулы, хөрмәтле (эш, шөгыль, ысул һ.б.ш. турында). *Билгеле, киләчәктә Өметгалине дәрәҗәле урын, ихтирамлы эш көтә.* М.Юныс

**ДӘРВИШ** *и. фар.* 1) Дөнья рәхәтләреннән, төрле ләззәтләрдән ваз кичеп, бөтен гомерен ислам диненә хезмәт итүгә багышлаган, ярым теләнче хәлендә мөсафир булып йөрүче кеше. *Кайсы асыл зат иҗат иткән бу көйне? Кыйблага карап юл тоткан берәр хаҗимы, әллә үзенең барлы-юклы тауарлары белән шул якларга барып чыккан сәүдәгәрме, әллә... чукындырудан кача-кача, иленнән язган берәр дәрвишме?* К.Йосыпов. *Дәрвишләр йон тукымадан тегелгән чапан-җилән кияләр.* Ислам

2) *күч.* Мөмкин булган дөнья рәхәтләрен, уңайлыкларны ташлап, үз идеалларын тормышка ашыру өчен, кагылып-сугылып йөргән кеше

**ДӘРВИШЛӘНҮ** *ф.* 1) Дәрвиш булып китү, дәрвишкә әйләнү

2) *күч.* Дәрвиш булып кылану, сукбайлану, сукбайланып йөрү. *Үпкәләп йөрмә, өйгә кайт, синең дәрвишләнүеңнән кемгә ни файда?*

**ДӘРВИШЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Дәрвишләргә охшатып, дәрвишләрдәй; дәрвишләргә хас булганча. *Режиссёр Ренат Әюпов әлеге серле, маҗаралы һәм күпмәгънәле әсәргә янә бер мәгънә өстәгән: испан егете Сантьягоның, илдән-илгә дәрвишләрчә сәяхәт итеп, акыл ташы эзләвенә ул безнең заман яшьләренең мәгънәсез яшәешен китереп кушкан.* Тамаша. *Әнә Рәмилә егетнең кайгысын күптән күреп алган, ә ул дәрвишләрчә сукыр икән...* Х.Ширмән

**ДӘРВИШЛЕК** *и.* 1) Дәрвиш булу, дәрвишкә хас сыйфатлар. *Даниял исә, башын дәрвишлеккә салып, аның каршында әкият сөйләп тора, фәлсәфә сата.* Б.Камалов. *Аллага чын күңелдән инану, аның белән бәйләнешкә керергә омтылу дәрвишлекнең үсүенә китергән.* Ислам

2) Дәрвиш тормышы. *Диңгез синнән качмас. Белмим, нинди мәгънә табарсың икән дәрвишлектә йөрүдән.* М.Юныс

**ДӘРГЯҺ** *и. фар. иск.* 1) Капка төбе, ишек төбе, бусага

2) Дәрвишләр торагы

◊ **Дәргяһтан куылган** *к.* **дәргяһтан сөрелгән**. **Дәргяһтан сөрелгән** «Аллаһның рәхмәтенә ирешер өчен, Аның ишек төбенә килеп тә максатына ирешмәгән, куып җибәрелгән» мәгънәсендәге тиргәү сүзе. *Иллә мәгәр, күзе чыккыры Гитлерны әйтәм, җимерде тормышны, дәргяһтан сөрелгән.* М.Мәһдиев

**ДӘРЕС** *и. гар.* 1) Билгеле бер предмет буенча уку, укыту сәгате һәм шул вакыттагы уку-укыту эше. *Ул дәресне мин гомергә онытa алмаячакмын. Укытучы Ульян Андреевич карлыккан тавыш белән, сүз саен басым ясап, дәрес сөйли...* М.Юныс. *Дәрес арасындагы унбиш минутлык кына тәнәфес иде – еракка китә алмадык.* И.Салахов. *Башларын түбән иеп, борыннарын мышкылдатып басып торган дүрт малайның кичә дәрестә булмаганлыкларын ул яхшы белә иде.* Г.Гобәй

2) Нинди дә булса уку йортларында (мәктәп, урта яки югары уку

йортлары һ.б.ш.) укытыла-укыла торган фән. *Мәктәп вә мәдрәсәләребездә татар әдәбият дәресләре булмавы әйтеп бетерә алмаслык зарарлыдыр.* Ф.Әмирхан. *Җәмгыятьне өйрәнү, сәяси белем дәресләреннән мөгаллим абзыеңа имтихан бирү генә җитми.* М.Әмир

3) Укучыга, мөстәкыйль эш буларак, өендә эшләргә бирелгән эш. *[Мөнирә:] Дәресләреңне әзерләдеңме? [Рамил:] Иртәгә ял.* Т.Миңнуллин. *Әнисе, бу дәрес әзерләргә бара икән, дип уйласын өчен, ул конспектларын алган иде.* М.Юныс. *Бүген кич нигәдер эч пошты. Дәресләремне дә әзерли алмадым, күңелсез…* И.Салахов

4) Берәр һөнәргә, кәсепкә өйрәнү, осталык, тәҗрибә туплау максатында, остаздан алган хезмәт күнекмәсе, остаз күзәтүе астындагы өйрәнчекнең хезмәт вакыты. *Ул я Карл Васильевич янына урман дәресенә, я Миша Степанов янына электр дәресенә, я кызыл почмакка Катя янына рус телен өйрәнергә, я политграмота түгәрәгенә йөгерә.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Акыл-тәҗрибә бирердәй, алга таба нәтиҗә ясарлык гыйбрәтле эш; сабак. *Бай баласы мут буладыр, чыкмыйдыр кафе-шантаннан, белмәгән бозыклыгы булса, дәрес аладыр ул шайтаннан.* Ш.Мөхәммәдев

**ДӘРЕСЛЕК** *и.* Уку-укыту программасына нигезләнеп, билгеле бер фәнне укыту, өйрәтү өчен билгеләнгән махсус китап. *Бүлмәсендә иске одеяллы кровать белән керле тышлы мендәрдән, анатомия белән физиология турында ике зур, калын дәреслектән башка нәрсә тапмадылар.* Г.Ибраһимов. *Шәмсия, китапларны актарганда, география дәреслеген китереп чыгара…* М.Җәлил. *Хәзер гарәп язуы --- буенча дәреслекләр күп.* Татар мөселман календаре

**ДӘРЕСХАНӘ** *и. гар.-фар.* Дәрес алып бару өчен билгеләнгән бүлмә, махсус бина; класс. *Дәресханәдәге шәкертләр, матбагадагы хәреф җыючылар, --- парталар арасындагы мөгаллим-мөгаллимәләр – һәммәсе шул эшләрнең берәр кисәген ала.* Ф.Бурнаш. *Дәресханәдә күрәк кебек сакаллы, зур вә мәһабәт хәлфәләр, явыз телле, дәһри башлы, сүз бирмәс имансыз пишкадәмнәр арысландай бер ашкыну белән моназара итешәләр.* Г.Ибраһимов

**ДӘРИГА** *ы. фар. иск.* Пошынуны, аянычны белдерә. *Күрә алмыйлар галәмгә фашын аның! Аһ, дәрига! Баралмадым каршына аның ---.* М.Акмулла

**ДӘРИГЪ** *и. фар. иск.* Үкенеч, аяныч хәл. *Хәзер тарихыбыз барын кайберәүләр Бик авырлык белән төшенә Онытырга өйрәнгән без, дәригъ!* Р.Зәйдулла. *Вәйля, дәригъ, ни аяныч ки, бу изге эшкә – Коръәнне татарчага тәрҗемә итәргә – Риза Фәхреддиннең вакыты җитми.* Р.Батулла

**ДӘРМАН** *и. фар.* 1) Рухи һәм физик мөмкинлекләр; эш башкарырга сәләтлелек, көч, куәт. *Бу бәхетсез әсирләрнең арасында бик зәгыйфь бәдәнле, ак чырайлы бер яшь егет, көннең кызулыгына, хезмәтнең авырлыгына тәкать итеп, хәле, дәрманы беткәч, бераз хәл җыймак өчен, тау буендарак үскән бер агачның күләгәсенә барып утырмыш иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Анда икмәкне табалар көч белән, дәрман белән, Монда һәр ни – бар да әзер акча һәм фәрман белән.* Г.Камал. *Мәдинә белән ун минуттан артык, өзлексез, бөтен көчен куеп көрәшкән бандитның дәрманы шактый шиңгән иде, ахрысы.* Ш.Камал

2) *күч.* Матди мөмкинлек, матди хәллелек; акча. *Керосин алырлык та дәрманы булмаганлыктан, [Хафиз] дәресләрен читтә, сандыклар өстендә, караңгыда әзерли.* К.Тинчурин

3) *күч.* Күңел төшенкелеген һ.б.ш. борчылуларны җиңел кичерергә ярдәм итә торган яки рухи канәгатьләнү китерә торган нәрсә турында. *Шул синең тавышың гына тик дәртемә дәрман бирә, шул бирә һәр нәрсәне; шул җан бирә, шул ямь бирә.* Ш.Бабич. *Дәртен белгән дәрманын белер, диләр, бик дөрес сүз.* Г.Камал. *Туган илем, син – кадерле анам, Кадерле атам, сөенечем минем, Йөрәгемә дәрт, Яшәргә дәрман бирүчем минем.* Р.Ишморат

**ДӘРМАНА** *и. фар. бот.* 1) Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, ачык соры, агачсыман туры тамырлы, бер урында күп булып үсә торган күпьеллык җылы як үсемлеге, ярымкуак; *русчасы*: **полынь цитварная**

2) Шул үсемлекнең киптерелгән чәчәге (төнәтмәсе эчәкләрдән суалчаннарны кудыру өчен кулланыла)

**ДӘРМАНЛЫ** *с.* Көчле, сәламәт; дәрте, дәрманы булган. *Еш кына ул үзенең яшьләрчә дәртле, дәрманлы булуын хатыныннан күрә.* Р.Мирхәйдәров. *Абзыйның әле дәрманлы чагы, колхозда яшьләрдән калмыйча эшләп йөргән заманы иде.* Л.-Х.Таналин

**ДӘРМАНСЫЗ** *с.* 1) Көчсез, куәтсез; хәлдән тайган, арыган. *Карасаң-карамасаң да, күз алдыңда – аларның дәрмансыз гәүдәләре, мескен кыяфәтләре.* К.Миңлебаев. *Түләк намаз өстендә догалар укып әйтте: «Илаһи, бу кызны, кауме-халкы, малы-туары белән бергә, көн эсселеге белән бергә дәрмансыз ит!» – диде.* Г.Гыйльманов

2) *иск. шигъ.* Дәвасы булмаган, дәвалап булмый торган, сәламәтләндерү, савыктыру ысулы табылмаган

**ДӘРМАНСЫЗЛЫК** *и.* Көчсезлек, хәлсезлек. *Дәрмансызлыктан интегү*

**ДӘРРӘ́Ү** *рәв. фар.* 1) Күмәк рәвештә, барысы бердән, бердәм. *Сибелеп яткан, алка сыман бөтәрләнгән йомычкалар дәррәү купты.* Р.Мөхәммәдиев. *Кайраучы аларга ниндидер көлке сүз сөйли, хатыннар дәррәү көлеп җибәрәләр ---.* М.Юныс

2) Кинәт, шул мизгелдә үк, бик тиз генә. *Фәләхов тыйнак кына баш какты, Мәйдан дәррәү кул чапты.* Р.Мөхәммәдиев

**ДӘРТ** *и. фар.* 1) Рухи һәм физик омтылыш, рухи көч; күңел күтәренкелеге, илһам, көчле омтылыш. *Шәяхмәтнең дәрте зур иде.* Г.Ибраһимов. *Татымадым элек мин һичкайчан Мондый көчле, мондый әрнешле Йөрәктәге дәртне һәм нәфрәтне, Мәхәббәтне, үчне, сагышны!* М.Җәлил. *Көмеш медальле солдат, аның сүзенә ачуланып: «Әгәр сугышырга дәртең булса, мин сиңа үземнекенә өстенә тагын бер-ике медаль бирермен», – диде.* М.Гали

2) Уй-фикерне, тормышны биләгән нәрсә; кызыксыну. *Һәр кешенең үз дәрте – тегермәнчедә су дәрте.* Мәкаль

3) Ярату, мәхәббәт хисе, гашыйклык. *Авылның һәммә егетләре, Мәрьям туташны күргән саен, «ах, туташ... сине!» дип, дәртләренә чыдый алмый калсалар да, һичбере, яңгыш кына да, аңа бер мөнәсәбәт бәйләргә уена китерә алмый.* Г.Ибраһимов. *Кайбер җаннар сөю дәрте белән тулып яратылалар.* Г.Ибраһимов. *Тимер челтәр арасыннан пыялага өргән сулыш эзендә мин аның Фәйрүзәне сүрелмәс дәрт белән яратучы кайнар йөрәк тибешен укыдым ---.* К.Нәҗми

4) Капма-каршы җенес вәкиленә омтылу, тартылу хисе; җенси омтылыш. *Хайвани дәрте котырып кузгалган кызмача ир кулыннан ычкыну алай ансат түгел иде [Гайниягә].* Ф.Хөсни

◊ **Дәрте почмаклану** Теләгәнгә ирешү, күңел салган, дәрт иткән нәрсә тормышка ашу; канәгатьләнү. *Ярый, минәйтәм, эчтән генә, дәртең почмаклансын, әйдә, алып барыйм, дим.* Г.Ибраһимов. *Я, күрдеңме, дәртең почмакландымы инде?* Г.Бәширов. **Дәрт сүнү** Берәр нәрсәгә күңел суыну; ошатмый, яратмый башлау. *Ләкин анда бару белән тагы дәртем сүнә иде.* Г.Ибраһимов. *Шулай бу кимчелек бүгенге дәртебезне сүндерә алмады.* М.Әмир. **Дәрт сүрелү** *к.* **дәрт сүнү.** *Моны күреп, халыкның да дәрте сүрелде.* Г.Бәширов

**ДӘ́РТ БИРҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса күңел биреп, ошатып, яратып эшләү, рәхәтлек, канәгатьлек алу

2) Кемне дә булса канатландырып тору, аңа рухи көч-куәт бирү, теләкомтылышын үстерү. *Күңелле була шул яз көне, Йөрәккә дәрт бирә яз җиле.* Ә.Ерикәй

**ДӘ́РТ ИТҮ** *ф.* Нәрсәгә дә булса омтылу, бик нык теләү, кызыксыну

**ДӘРТЛӘНДЕРГЕЧ** *с.* Дәрт, илһам бирә торган; рухландыргыч; көч-куәт бирә торган. *Хуш исле тәмләткечләр арасында дәртләндергеч үләннәр исемлегенең башында сельдерей тора.* Гаилә

**ДӘРТЛӘНДЕРҮ** *ф.* Дәрт бирү, дәрт уяту; рухландыру, рухын күтәрү

**Дәртләндерә төшү** Тагы да дәртләндерү

**Дәртләндереп алу** Бераз дәртләндерү

**Дәртләндереп җибәрү** Кинәт дәртләндерү. *[Зөфәр абый] Кичке уеннарда --- берәр кызык әйтеп, биючеләрне дәртләндереп җибәрүләре турында әйткән дә юк.* Р.Мөхәммәдиев

**Дәртләндереп кую** Кинәт, бер тапкыр дәртләндерү

**Дәртләндереп тору** Һәрвакыт, гел дәртләндерү

**ДӘРТЛӘНҮ** *ф.* Дәрт керү, рухи көч барлыкка килү; ашкыну, омтылу. *Ул һаман элеккечә дәртләнеп эш артыннан чаба.* И.Салахов

**Дәртләнә бару** Торган саен ныграк дәртләнү; акрынлап дәртләнү арту. *Әхәт абый, торган саен дәртләнә барып, чебеш алырга җыенган тилгән сыман, кунак кыз тирәсендә бөтерелә башлады.* Г.Бәширов. *Шигырь дөньясына эчкәрәк кергән саен, артист дәртләнә бара, дулкынлана бара.* Р.Заһидуллина. *Гайнулла бабай бер нәрсә белән «чирләсә», үзе дә шул Утлы Мәлик кебек, туктый алмый, дәртләнгәннән-дәртләнә бара иде.* Г.Мирһади

**Дәртләнә башлау** Дәртләнергә тотыну. *Хәзер минем кунагым булган кыр казы бигрәк дәртләнә башлады.* М.Гафури

**Дәртләнә төшү** Бераз дәртләнү, дәрте берникадәр арту. *[Биюче] Дәртләнә төште, аның аяклары тагын да җиңелрәк --- тыпырдый башлады.* А.Шамов. *Минем яхшы ук йомшара башлавымны тоеп алган Дамир, тагын да дәртләнә төшеп, болай дип өстәде: «Фонд өчен кирәкле ике-өч кешенең хезмәт хакы «ТатАрт» тарафыннан түләнәчәк».* М.Госманов. *Ул [Шамбы], тагын да дәртләнә төшеп, атна буе разведка ясауларын, таланачак квартираны җентекләп өйрәнүләрен сөйләргә тотына.* М.Насыйбуллин

**Дәртләнеп алу** Азга гына, бераз вакытка дәртләнү

**Дәртләнеп бетү** Тәмам, бик нык дәртләнү

**Дәртләнеп йөрү** Әле, хәзер дәртләнү хәлендә булу. *Ике-өч көн буена ул [Габделхәй] әлеге куаныч тойгысы белән дәртләнеп йөрде.* Н.Фәттах. *Ул [Гафият], совет өндәмәләренә ышанып, сәләтенә, зирәклегенә таянып, үрнәк хуҗалык булдырырга дәртләнеп йөри.* Ф.Хатипов

**Дәртләнеп китү** Кинәт дәртләнү, дәртләнүгә этәргеч алу. *Музыкага җаны-тәне белән бирелгән Салих Сәйдәшев, милли музыкабызның үсеше, киләчәге хакында сөйләгәндә, тагын да җитдиләнеп, дәртләнеп китте ---.* Р.Низамиев. *Өстәвенә әнә Миләш тә әнисенең авызыннан «туган йортың», «әтиең йөргән юллар» дигән сүзләрне ишетү белән ничек дәртләнеп китте!..* Г.Якупова

**Дәртләнеп кую** Кинәт бераз дәртләнү кичерү. *Ул бакчага керсә, иркен тын алган кебек була, рәхәтләнеп китә, һавага карап, очарга иткән кебек дәртләнеп куя...* М.Гафури

**Дәртләнеп тору** Һәрвакыт, гел дәртләнү. *Дистә еллар театрыбызда директор булып эшләгән Рәшидә апа Җиһаншина да әйтеп куйды: «Иҗат итәргә дәртләнеп торган ветераннарыбызга сәхнә кирәк, сәхнә!»* Гомер сәхнәсе

**ДӘРТЛЕ** *с.* **1.** 1) Дәрте, илһамы булган; ашкынулы, дәртләндерә торган, омтылучан. *Нәфисә кечкенәдән үк бөтен нәрсә белән кызыксынучан, күп белергә, һәммә нәрсәне төпченергә яратучан дәртле бала булып үсте.* Г.Бәширов. *Күзләре сөйде чибәрне, Дәртле, илһамлы кич...* Г.Афзал

2) Җенси дәрте булган, тиз хисләнүчән, темпераментлы. *Ә менә төштә күргәне чын булды бугай. Кайнар иде, дәртле иде ул кыз. Кочагына сеңеп бетә язган иде... бәлки, тагын килер?* Ә.Дусайлы

**2.** *рәв. мәгъ.* Дәртләнеп. *Һәм әткә кошкай да шундый дәртле итеп, шундый онытылып сайрады.* Г.Хәсәнов

**ДӘРТЛЕЛЕК** *и.* Дәртле булу сыйфаты. *Аның рәсеме дә батыр егетнең ихтыяр көченә бай булуын, ныклыгын, дәртлелеген сөйли.* Г.Кашшаф

**ДӘРТСЕЗ** *с.* 1) Сүлпән, пассив, инерт. *Шаян дусты хәзер кулбашлары салынган, йөзе кара сары булып кипкән, күзләре нурсыз, үзе дәртсез бер казак хатынына әверелгән иде.* Г.Ибраһимов. *Хәрәкәтләре артык салмак, дәртсез, хәлсез иде аның.* Р.Вәлиев. – *Бәхетләме,*

*дисең син, Мулланур, кем өчен саклadың, дисең, – дип телгә килде, ниһаять, Рәйхан һәм дәртсез, хиссез генә үзенең тормышын сөйләп бирде.* Д.Каюмова

2) Җенси хискә, тойгыга тиз бирелмәүчән, сүрән, темпераментсыз. *Ул карчыгы белән ятмый, --- чөнки, аның үзенең тәгъбиренчә, карчыгы Хөсние – коры кеше, дәртсез кеше иде.* Г.Гобәйдуллин. *Дәртсез йөрәк таш курчакта була ул.* Р.Батулла

**ДӘРТСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Дәрт бетү, сүлпәнләнү

**ДӘРТСЕЗЛЕК** *и.* Дәртсез булу. *Азат итте милләтне ул дәртсезлек һәм ялкаулыктан ---.* Г.Тукай. *Дәртсезлек һәм гафиллек авыл халкының менталитетына әверелде.* Сөембикә

**ДӘРТСЕНҮ** *ф.* Дәртләнү; бик теләү, ашкыну, рухлану. *Шәфи, килү белән үк, дәртсенеп, лекциягә тотынды.* Ш.Маннур. *Яшьрәк чак булса, әллә дәртсенгән дә булыр идем.* А.Гыйләҗев

**Дәртсенә бару** Акрынлап дәртсенүгә күчәю. *Йөрәгем дәртсенә бара*

**Дәртсенә башлау** Дәртсенергә тотыну

**Дәртсенә төшү** Берникадәр дәртсенү

**Дәртсенеп алу** Азга гына, берникадәр вакытка гына дәртсенү

**Дәртсенеп китү** Нинди дә булса сәбәпләр аркасында дәртсенү; уйламаганда, кинәт дәртсенү. *Күңеле дәртсенеп китте Мәгъфурәнең: роза чәчәкләрен бик ярата ич ул.* Р.Закиров. *Мөсәвирдән күреп, мин дә шул курайда уйнарга дәртсенеп киттем бит.* И.Бәдретдинов

**Дәртсенеп кую** Кинәт бераз дәртсенү

**Дәртсенеп тору** Һәрвакыт, гел дәртсенү. *Ә эчтә нindидер дәрт һаман кимеми, колын кебек уйнаклап чабарга дәртсенеп тора.* М.Галиев

**ДӘ́РХАЛЬ** *рәв. фар. иск.* Кинәт, бик тиз, шул секундта ук. *Бер яңа хәбәр улса, дәрхаль сачыләдер.* М.Акъегетзадә

**ДӘ́РХӘЛ** *рәв. фар. иск. к.* **дәрхаль**. *Кечкенә чагымда миңа бервакыт утыз тиен кадәр бакыр акча бирделәр. Бу кадәр байлыкка куанып, мин дәрхәл уенчыклар сатыла торган кибеткә йөгердем.* Г.Тукай. *Күрсә, ул кулларны дәрхәл уйгатыр ---.* Ш.Бабич

**ДӘРЬЯ** [дәр’йа] *и. фар.* **1.** 1) *шигъ.* Бик зур су, зур елга. *Дәрьяларның көче кушылдыкларның исән булуында.* М.Әмир. *Тыелгысыз кәеф-сафа, ис-киткеч сый-хөрмәтләрне дә, азгынлык-фәхешлекләрне дә, төрле низаг-ызгышларны да, үлем-китемнәрне дә күп күргән сарай һәм пайтәхет өстеннән узган төнге зилзилә дәрья уртасындагы утрау-кальганың өч сажин ярым калынлыгындагы диварларын үтеп керә алмады.* Җ.Рәхимов

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса күплеге, чиксезлеге. *Тел дәрьясы дәшми. Ул көтә, сабырлыгын һәр сүз кальбенә тигез таратып, синең колач салып йөзәргә өйрәнүеңне көтә.* М.Галиев. *Сугыштан алдагы еллардан калган, Шакирны каршылау өчен саклап тоткан «Магнолия» исле маен сөртенде, көзге алдына басып матурланды да, кызын җитәкләп, урамга, халык тантанасы дәрьясына атылды.* Г.Минский

**2.** *с. мәгъ. күч.* Чиксез күп булган, дәрья кебек, дәрьяга тиң

**ДӘСТӘРХАН** *и. фар.* Өстәл җәймәсе, ашъяулык. *Тәбәнәк түгәрәк өстәлгә ябылган дәстәрхан өстендәге --- бавырсак, корт, эремчек, тозлы майлар әллә кайчан бетте.* И.Салахов

**ДӘСТҮР** *и. фар. иск.* 1) Кагыйдә. *Ихлас дәстүрләре. Беренче дәстүр*

2) Рөхсәт, күрсәтмә. – *Атамдин дәстүр булды, хәбәр кәлде: сине җефетлеккә алмага! – тиде.* Татар халык иҗаты

**ДӘ́Ү** *с. фар.* **1.** 1) Зур, күләме олы булган. *Эшкә килгәндә, ул кемне дә үзеннән алда җибәрмичә, ирләр белән беррәттән эшләп, беррәттән дүртбиш җамаяк аш ашап, аштан соң әле тагы дәү генә тустаган белән мөлдерәгән катыкны да ялтырата торган булган.* Г.Минский. *Аның дәү бите бурлат төсенә керде.* Г.Бәширов. *Апасы белән җизнәсе аны олы кунак сыман үз итеп каршылар һәм әлеге шул дәү сандык өстенә утыртырлар иде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Өлкән, олы яшьтәге. *Сүзнең дөресе кирәк, дәү абый, яратам шул мин аны. Миңа дөньяда бүтән бер кеше дә кирәк түгел.* М.Мәһдиев. *Без, Суфиян, дәү кешеләр, мәсьәләгә айнык карарга тиешбез.* Ә.Еники

3) Авторитетка, абруйга лаек; дәрәҗәле. *Дәү галим*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Зур булу, буйга җитү. *Аннан соң менә, дәү булгач, сине остабикәгә бирербез.* Г.Камал. *Менә берзаман син дәү үсәрсең, атаң шикелле батыр кеше, илгә кирәкле кеше булырсың ---.* Г.Бәширов. *Үс син тизрәк, күбәләгем минем, Дәү булып җит атаң кайтканчы, Ул, бичара, күп бөксә дә билен, Көн күрмәде бу таң атканчы...* Ш.Маннур

2) Эре, киң итеп. – *Хе. Нәҗип ялгышамы соң, – дип, кулларын кесәсеннән чыгарды һәм, дәү атлап, Гыйлемханның каршысына ук килеп басты.* Р.Мөхәммәдиев

**ДӘ́Ү ӘНИ** *и.* 1) Әнисенең яки этисенең әнисе. *Мәүлиягә быел унике тулды. Кечкенә чагыннан ук аны «дәү әнисе кызы», «чат дәү әнисе» дип аптыраталар иде.* И.Гази. *Шат күңелле җырчы әби ике оныгы өчен дәү әни дә, әни дә икән.* Ватаным Татарстан

2) *диал.* Әтисенең иң өлкән абыйсының хатыны

**ДӘ́Ү ӘТИ** *и.* 1) Әтисенең яки әнисенең этисе. – *Алайса, – ди, – Нурдидә, Әтиеңнең этисе? – Әтиемнең этисе?.. Ул – дәү әти бит инде, шуны белми, кит инде!* Ш.Галиев

2) *диал.* Әтисенең иң өлкән абыйсы

**ДӘҮКӘДИ** *и. фар.* 1) Ирләрсыман хатын (Дию бичәсе); ирдәүкә

2) *диал.* Алпат гәүдәле кеше. *Ишектән танытмас өчен битләренә кара яулыклар бәйләгән билгесез ике дәүкәди кереп, егетнең кулларын каерып алалар.* Ф.Хөсни

**ДӘҮЛӘТ** *и. гар.* 1) Илдә хөкем сөргән тәртипне саклау, үзара каршы булган сыйныфлар арасындагы төрле бәхәсләрне бастыру өчен, хаким сыйныф тарафыннан төзелеп, башында хөкүмәт һәм аның органнары торган сәяси оешма; шундый сәяси оешмасы булган ил. *Сәүдә дәүләт казнасы-*

*на зур табыш китерә.* Г.Дәүләтшин. *Ләкин сез борчылмагыз, йорт салырга акчаны сезгә дәүләт тә биреп торыр.* Ә.Еники

2) Байлык, мал-мөлкәт. *Бертуганың чит тибәдер, Дәүләт тигез булмаса.* Дәрдемәнд. *Бүген төшемдә ак җәймә белән зур-зур балыклар тотканыңны күргән идем, дәүләт, байлык килергә булган икән.* Т.Гыйззәт. *Шәйхулла байны җиңгәч, аның дәүләтен менә өчебезгә бүлеп алырбыз.* Д.Аппакова

3) Бәхет, куаныч. *Әгәр бер тычкан тотса, аны олы бәхет вә дәүләт саный иде. Һәм ничә көн, куанып, аны теш даруыдай газиз тотып, аз-аз гына ашый иде.* Татар халык иҗаты

**ДӘҮЛӘТАРА** *с.* 1) Ике яки берничә дәүләт өчен уртак булган, дәүләтләр арасындагы. *Дәүләтара оешмалар*

2) Ике яки берничә дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләргә караган. *XVII–XVIII гасырларда дәүләтара мөнәсәбәтләрдә дә татар теле кулланыла.* Р.Фәттахова. --- *1994 елның 15 февралендә Россия белән Татарстан арасында ике яклы дәүләтара Шартнамә барлыкка килде.* Казан утлары

**ДӘҮЛӘТКҮЛӘМ** *с.* Дәүләт күләмендәге; дәүләт өчен тулаем әһәмиятле. *Дәүләткүләм мөһим хәбәр игълан ителәэ. Тыңлагыз! Дәүләткүләм мөһим хәбәр!* Ш.Алпар

**ДӘҮЛӘТЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Дәүләт милке итү, дәүләтнекенә әверелдерү, национализацияләү. *Әмма, шушындый авыр хәлгә дә карамастан, авыл хуҗалыгы җитештерүен дәүләтләштерү һаман дәвам иттерелә.* Ватаныбыз тарихы

2) Дәүләт карамагына күчерү, тапшыру. *Троцкийчыларның лозунгысы профсоюзларны кичекмәстән дәүләтләштерү булды.* Тарих

**Дәүләтләштерә бару** Акрынлап, бер-бер артлы дәүләтләштерү

**Дәүләтләштерә башлау** Дәүләтләштерергә керешү

**Дәүләтләштереп бетерү** Тулысынча дәүләтләштерү

**ДӘҮЛӘТЛӘШҮ** *ф.* 1) Дәүләт милкенә әйләнү, дәүләт карамагына күчү

2) Хакимият органнарының теге яки бу өлкәгә һ.б. карата контроле, җаваплылыгы арту

**Дәүләтләшеп бетү** Тәмам дәүләтләшү, барысы да дәүләтләшү

**ДӘҮЛӘТЛЕ** *с.* 1) Дәүләт (*1 мәгъ.*) системасы булган. *Һуннар, борынгы төркиләр турында сүз алып барганда, шуны басым ясап әйтергә кирәк: тарихта алар дәүләтле халыклар буларак билгеле.* Г.Дәүләтшин. *Милли азатлык хәрәкәте, хокук һәм ирек өчен көрәшкә әйләнеп, гасырлар дәвамында дәүләтле булган чакларыбызны искә төшереп торган.* Мәгърифәт

2) Дәүләте (*2 мәгъ.*) булган, бай. *Атаң үзе зур дәүләтле кешеме соң, энем?* Ш.Камал. *Шанлы, дәүләтле Хантимер мирзаның --- гайрәтле улы Шаһтимер белән --- асыл токым Сәлим мирзаның --- гүзәл кызы Хәмдия бер-берсенә яр булырга вәгъдә бирделәр.* М.Фәйзи

**ДӘҮЛӘТСЕЗ** *с.* 1) Дәүләт (*1 мәгъ.*) системасы булмаган. *Калдың бүген дәүләтсез, чишмә агар яшеңдән. Кайда калды шатлыгың, Кайда сәнең байлыгың?* Бәет. *15 октябрь, һичшиксез, татарлар өчен иң кайгы-хәсрәтле көн, кара көн, кояшыбыз баткан, илсез, дәүләтсез калдырган көн.* Юлдаш

2) Дәүләте (*2 мәгъ.*), байлыгы булмаган, бай түгел; мөлкәтсез

**ДӘҮЛӘ́ТЧӘ** *рәв.* Дәүләт ихтыяҗын күздә тотып, аны беренче урынга куеп. *Дәүләт средстволарына дәүләтчә карый белмәү җәзасыз кала алмый.* Социалистик Татарстан

**ДӘҮЛӘТЧЕЛ** *с.* Дәүләт югарылыгында, дәүләт дәрәҗәсендә булган. *Ә бит алга киткән илләрдә урманнарга башлыча дәүләт хуҗа.* --- *моңарчы бездә дә урманнарга карата һәрвакыт дәүләтчел караш өстенлек итте.* Ватаным Татарстан

**ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК** *и.* Дәүләт төзелеше, дәүләт оешмасы. *Бу, мәсәлән, үз дәүләтчелеген югалтып, Кытайга коллыкка төшкән күк, төрекләрнең аянычлы-үкенечле хәлен тасвирлаган яки халыкны каганга тугрылыклы, бердәм, уяу булырга чакырган юлларда аеруча ачык күренә.* Х.Мәхмүтов. *Бакунин эшчеләр сыйныфының көчләренә ышанмады, ул һәртөрле дәүләтчелекне, шул исәптән пролетариат дәүләтчелеген инкяр итте, анархизм идеологы сыйфатында чыкты.* Социалистик Татарстан

**ДӘФГА** *и. гар. иск. кит.* Мәртәбә, тапкыр. *Беренче дәфга чыккан вакытта ук --- болай бәла килүе --- Җәмиләнең өметен кисте.* М.Гали

**ДӘ́ФГАТӘН** *рәв. гар. иск. кит.* Кинәт; алай булыр дип исәпләмәгәндә, уйламаганда, көтмәгәндә. *Дәфгатән яктыртты һәм балкытты нур, Нур белән тулды җиһан, ялт итте җир!..* Ш.Бабич. *Егәрле вә елдам ике-өч чирүгә бүленеп, берничә кальга вә авылларга дәфгатән тәҗавез кылуны отышлырак, мәслихәтрәк саныйм.* В.Имамов

**ДӘФЕН** *и. гар.* Мәетне җирләү, күмү йоласы. *Җитте дәфенем вакыты, Кәфенем бүзләрен мана алмадым.* Дәрдемәнд. *[Якуп] – --- заманында мәдрәсәдә байтак укыган, җеназа тәртипләрен белүче бер адәм.* Г.Ибраһимов

**ДӘФЕ́Н ИТҮ** *ф. к.* **дәфенләү**. *Моннан 3 ай ярым элек, әтине ничек дәфен итсәләр, әни дә шулай дәфен ителде. Ләкин бу югалту минем өчен бигрәк тә зур югалту булды.* М.Гали

**ДӘФЕ́Н КЫЛУ** *ф. к.* **дәфенләү**. *[Абдулла] --- башы-аягы белән мәгърифәт вә голүм дөньясына чумды, мәхәллә эшләре белән мавыкты: гаилә коручы яшьләргә никах укыды, яңа туган сабыйларга ат куйды, бу фани дөньядан киткәннәргә ясин укып, аларны дәфен кылды.* Ж.Рәхимов

**ДӘФЕНЛӘ́Ү** *ф.* Мәетне, дәфен йоласын үтәп, гүргә иңдерү, җирләү. *[Галимәне] --- ике көн үткәч кенә табып алдылар. Өч көннән соң гына дәфенләп күмдек.* М.Гафури

**ДӘФНӘ** *и. фар.* Дәфнәсыманнар семьялыгыннан, көньякта үсә, хуш исле озынча яфраклары аш тәмләткеч буларак кулланыла торган, мәңге яшел агач яки куак; *русчасы:* **лавр**. *Дәфнә яфрагы эфир майларына бик бай.* Ватаным Татарстан

**ДӘФНӘЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Күбрәк дымлы тропик урманнарда үсә

торган һәм эфир майларына бай агачлар, куаклар, үлән үсемлекләрне берләштерә торган семьялык атамасы; лаврчалар; *русчасы*: **лавровые**. *Авокадо – дәфнәчәләр семьялыгыннан 8–10 (20–25) м га җитеп үсә торган мәңге яшел тропик агач.* Дару үсемлекләре

**ДӘФТӘР** *и. гар.* Шакмаклы яки сызыклы ак кәгазь битләрен калын яки юка тышлык (тышсыз да булырга мөмкин) эченә теркәп ясаган язу-сызу әсбабы. *Өстәлнең бер кырыенда пөхтәләп өелгән китаплар, икенче кырыенда – дәфтәрләр.* И.Салахов

**ДӘФТӘРЧЕ** *и.* 1) *тар.* Россия империясендә (1917 елга кадәр) дәүләт оешмаларында документлар тутыру, әзерләү белән шөгыльләнүче; канцелярист

2) *күч.* Формализмга нык бирелгән, язу-сызу, кәгазь эшләре белән артык мавыга торган хезмәткәр, җитәкче

**ДӘХЕЛ** *и. гар. сөйл.* Нинди дә булса эш-хәлгә мөнәсәбәт, кагылыш. *Үзара сугышуларның сиңа ни дәхеле бар?* Ш.Әхмәдиев

**ДӘХЕЛЛЕ** *с. сөйл.* Мөнәсәбәтле, кагылышлы. *Инде хәзер «башкорт» этнонимына дәхелле тарихи, этнографик һәм фольклористик мәгълүматлар вә закончалыклар илә танышып карыйк.* Мирас

**ДӘХИ** *рәв. иск. кит.* 1) Тагын бер мәртәбә; яңадан. *Дәхи дә килеп баш балам Мирзанур белән төпчегем Кәшифәгә сагынычлы сәламнәр күндерәм.* Г.Ахунов

2) Шулай ук. *[Комаров:] Чакыру кәгазьләрегездә, хәрбиләр әйтмешли, повесткаларыгызда әйтелгән «өч көнлек ризык, янә һәм дәхи кашык-кружка»ларыгызны онытмадыгызмы?* Ф.Латыйфи. *Аллаһымның барлыгына, әүвәл – ахыр юк аңа, Бетү дәхи юк аңа – бердер Аллаһым бәнем.* Татар халык иҗаты

**ДӘҺРИ** *с. гар. дини* **1.** 1) Атеист, дин тотмаучы; динне танымаучы. *Абдулла малай чагында укыган Карышбаш мулласы Мостафа тыңлап торса, шик юк ки, Габделрахманны дәһри дияр иде.* Җ.Рәхимов. *Дәресханәдә көрәк кебек сакаллы зур вә мәһабәт хәлфәләр, явыз телле, дәһри башлы, сүз бирмәс имансыз пишкадәмнәр арысландай бер ашкыну белән моназара итешәләр.* Г.Ибраһимов

2) Дин тотмый торган, дингә, Аллага ышанмый торган; динсез, Алласыз. *Аннан да китеп, яңа схоластика тарафдары әфәнде ролен уйнаучы артистка: – Дәһри, кяфер, мәлгунь! – дип йодрык күрсәтә...* Ф.Әмирхан. *Дөнья гыйлемнәре укырга кирәк дип, дәһри сукыр Каюмнар фикерен мәдрәсәмдә таратасың.* Т.Гыйззәт. *[Мулла:] Ишеткән бер сүзгә ышанып йөрмә. Шул дәһри Әгъләм сүзен тыңлап, үзеңә гөнаһ кына өстисең.* С.Рафиков

3) Динсезлек белән сугарылган, динсезлеккә өнди торган. *Марксистик-ленинчыл философиянең «инкяр итүне инкяр итү» --- дигән кануни-категориясе VII гасырда ук Ислам дине тарафыннан расланган, кабул ителгән вә --- дәһри марксизм-ленинизмның үзен дә «бәреп егарга» бик сәләтле, кодрәтле, бакый хакыйкать икән бит.* Ф.Дунай

**2.** *и. мәгъ.* Дин тотмаучы, Аллага ышанмаучы кеше; атеист. *Ислам дине руханилары дәһриләрне мәчеттә халык алдында гаепләгәннәр, аларга җәза бирү, суктыру очраклары да булган.* Ислам

**ДӘҺРИЛӘНҮ** *ф.* 1) Дингә, Аллага ышанмый башлау, диннән китү

2) Динсез, Алласыз булып кылану; дәһри булып күренергә тырышу. *Бер карасаң – мулла, икенче карасаң, дәһриләнеп, аумакайланып йөргән Чыгтай дигән принципсыз бер кеше Тукайның --- дошманнарыннан берсе булды.* С.Кудаш

**Дәһриләнеп бетү** Тәмам, бик нык дәһриләнү

**Дәһриләнеп җитү** Ахыргача, бик нык дәһриләнү

**Дәһриләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта дәһриләнү

**Дәһриләнеп китү** Ниндидер сәбәптән, тәэсирдән соң дәһриләнү

**ДӘҺРИЛЕК** *и.* Динсезлек, дингә ышанмаучылык

**ДӘҺРИЯТ** *и. гар.* Динсезлек. --- *бөтен татарлар арасыннан дәһриятне куып чыгарачак.* Ф.Әмирхан

**ДӘҺШӘТ** *и. гар.* 1) Курку сала торган зур, җимергеч көч; гарасат. *Калтырый җир. Таудай танкларның Дәһшәтләрен күрсә идегез!* Ф.Кәрим. *Әмма шул ук «нечкә күңелле» солдат, атакага барганда, дошман өстенә дәһшәт булып, өермә булып ташлана.* Г.Бәширов

2) Гомумән зур көч, куәт. *Зур тауларга дәһшәт биреп торган Бу заводлар нинди күңелле.* М.Гафури. *Артым – салкын, алдым – ялкын, Какты дулкын, акты яшь; Сүздә – ләгънәт, күздә – хәсрәт, Эчтә – дәһшәт, калтыраш...* Ш.Бабич

3) Афәт; бик зур куркыныч. *Капкара урманда ерткычлар улый, һәм дә җир астында гыйфритләр дулый. Җирне, күкне куркыныч дәһшәт ала --- (Әмма күктә бар фәрештә шатлана).* Ш.Бабич. *Аның йомшак күңелен ниндидер бер дәһшәт каплап алган да, гүяки шул дәһшәт аңа еларга ирек бирмичә тора.* М.Гафури. *Болгарларның әле тарихта объектив бәя биреп җиткерелмәгән бу җиңүләре нәтиҗәсендә, болгар җирләре өчен генә түгел, Русь дәүләте һәм башка халыклар өчен дә вакытлыча гына булса да (13 елга якын) киләчәк дәһшәт алдыннан тын алу өчен мөмкинлек туа.* Г.Дәүләтшин

**ДӘҺШӘТЛӘНҮ** *ф.* Хәтәр, куркыныч була бару, дәһшәтлегә әйләнү. *Җил ыжгыра тышта, дәһшәтләнеп, Көлгән төсле солдат кешедән.* Ш.Маннур

**Дәһшәтләнә бару** Дәһшәтлелеге тагын да көчәю

**Дәһшәтләнеп китү** Кинәт кенә дәһшәтләнү. *Ураловның йөзе дәһшәтләнеп китте.* Х.Камалов

**Дәһшәтләнеп тору** Бертуктаусыз дәһшәтләнү

**ДӘҺШӘТЛЕ** *с.* 1) Курку сала торган; зур бәла-каза китергән, афәтле. *Дәһшәтле сугышның тере шаһиты булган каһарманнарыбызның күп булуын белсәк тә, ни кызганыч, аларның һәркайсының язмышы, яу кырында күрсәткән батырлыкларыннан хәбәрдар түгелбез.* Ватаным Татарстан

2) Бик хәтәр, бик куркыныч. *Гүя анда, иксез-чиксез киңлектә, ниндидер дәһшәтле көчләр арасында мәрхә-*

*мәтсез көрәш бара...* М.Хәсәнов. *Солдатның бу сүзе Сөләйманга аның йөрәген тишеп чыгачак пулядан бик күп өлеш дәһшәтлерәк булып тоелды.* К.Тинчурин

3) Куәтле, мәһабәт, көчле булуы белән күңелгә курку, шом һ.б.ш. хисләр сала торган. – *Муллалыгымны ташлыйм!.. – диде ул, тагын да дәһшәтлерәк тавыш белән.* А.Шамов

4) Күңелне бик нык тетрәндерә, көчле тәэсир ясый торган. *Гомумән, бул дәһшәтле, беркадәр куркыныч син.* Г.Дәүләтшин

**ДӘҺШӘТЛЕЛЕК** *и.* Хәтәр, куркыныч булу; коточкыч афәтле, гарасатлы булу (сугыш, бәла-каза, табигать китергән афәтләр һ.б.ш.). *Аның Бөек Ватан сугышы вакыйгалары хакындагы романнары һәм повестьлары да, үзе фронтта күргәннәре һәм кичергәннәре тәҗрибәсе буенча, шулай ук чынбарлыктагы сугышның бөтен дәһшәтлелеге һәм кыргыйлыгы героизм һәм трагизм белән күз алдыбызга баса ---.* Ватаным Татарстан. *Ачлык елларының дәһшәтлелеге халык хәтерендә әле дә саклана*

**ДӘШМӘКИ** *и. диал.* Аз сөйләшә торган кеше. *Мишәрләр Казан тирәсендәге татарларны эчкерле һәм дәшмәки дип саныйлар, аларны клугур, лугур, нугур дип атыйлар.* Р.Әхмәтьянов

**ДӘШМӘС** *с.* Бик аз сөйләшә торган, мыштым. *Дәшмәс Хәсән, елмаеп, хатынының «котырганын» карап утыра.* З.Зәйнуллин. *Малик өйдән караңгы көн кебек чыгып китә, май кояшы кебек кайтып керә, тик биш-ун минуттан ук дәшмәс бер букәнгә әверелә.* Шәһри Казан. *Безнең дә нәкъ «В бой идут одни старики» киносындагыча булды: Муса командирга өйләнергә рөхсәт алырга барды, анысы: «Карап торуга бик тыныч, дәшмәс кешесең, үзең кызларның башын әйләндерәсең икән», – дип тел шартлаткан.* Кызыл таң

**ДӘ́ШМӘҮЧӘН** *с.* Тыныч, аз сүзле, йомык. *Сәрви, кызларча беркатлы һәм бик сөйкемле итеп абыйсының мастерскойдан хаксызга куылуын, абыйсының дәшмәүчән табигате белән моңа каршы тора алмавын һәм, бер сүз дә әйтә алмагач, үзенең эченә тулган әрнүен күз яше белән аңлатуын сөйләп бирде.* Ә.Фәйзи

**ДӘШМИ-ТЫНМЫЙ** *рәв.* Шыпырт кына, дәшмичә, берни әйтмичә, сөйләмичә, бер дә хәбәр итмичә. *Кемдер, дәшми-тынмый гына, авылны әйләнеп чыга.* Р.Батулла. *Ә без әбекәй белән, бер сүз дә катмастан, ул кайткан уңайга, ул ачкан ишекне дә япмыйча, дәшми-тынмый гына өйдән чыктык та киттек.* Н.Шәрифуллин. *Сабиралар, тынычланып, бу юлы дәшми-тынмый, эшләрен дәвам иттерделәр.* Ф.Яхин

**ДӘ́ШМИЧӘ** *рәв.* Бер сүз дә әйтмичә, сөйләшмичә; сөйләшеп тормыйча. *Дәшмичә генә аягөсте басып тордылар да аңсыз ана белән хушлашып чыгып киттеләр.* Р.Батулла. *Мин дә үзгәргәнмендер, күрәсең, аны-моны дәшмичә, минем йөзгә озак карап торды Шәмгун.* Ф.Шәфигуллин. *Фрунзе баскан урынында бераз дәшмичә уйланып торды.* З.Зәйнуллин

**ДӘШТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **дәшү**

2) Янына чакыртып алу, килергә кушу, кеше аша чакыру җибәрү. *Бу хәл-гамәлне карап торган аксакал хан янына килә дә болай ди: «Илбашым, син, Кояшны чакырып чыгарырга, бәйгеләрдә алга чыккан иң гүзәл кызыңны дәштер».* Шәһри Казан

**ДӘШҮ** *ф.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса сүзеңне, соравыңны һ.б.ш. юнәлдерү; кешегә мөрәҗәгать итү; сүз кушу, эндәшү, чакыру. *Ул бары: «Безнең абызый...» – дип әйтергә генә өлгерде, аны дәштеләр – ишегалдыннан хатынкыз тавышы ишетелде: «Маһибикә!»* М.Әмир. *Тел дәрьясы дәшми. Ул көтә, сабырлыгын һәр сүз кальбенә тигез таратып, синең колач салып йөзәргә өйрәнүеңне көтә.* М.Галиев. *Җил искән кебек кенә, каршысына кемдер очрап, бәрелеп диярлек узып китте. Узып кына китмәде, дәшеп китте...* Г.Гыйльманов

2) Гомумән сөйләшү; сөйләшә башлау, сүз әйтү. *Халисәнең кабат дәшүеннән Илһам аягүрә басты.* Ф.Садриев

3) Җавап бирү; эндәшү. *Һични дәшми Валентина. Ул бүген сүзгә саран.* Г.Халит

**Дәшә башлау** Дәшергә тотыну. *– Синең аккошың булсаммы, – дип, якын итеп, хан кызына дәшә башлады Ислам ---.* М.Хәбибуллин

**Дәшеп алу** Вакыт-вакыт дәшү. *Әхмәтсафа, шаян күз кысып, Рабигага дәшеп ала: – Рәбуш, ник инде коймакларны читкә алып куйдың?* Ф.Сафин. *[Кошлар] Тик эш белән генә, йомыш белән Бер-берсенә дәшеп алалар.* К.Булатова

**Дәшеп калу** Дәшергә өлгерү; яннан үткәндә, артыннан дәшү. *Алыпсатар хатын очраган бер кешегә, шыпырт кына: «Ситсы кирәкмиме? Галош кирәкмиме?» – дип дәшеп кала.* М.Ибраһимов. *Үткәнемдә миңа дәшеп калма – Ябалдаштан җепшек кар төшә.* Р.Рахман

**Дәшеп карау** Сынап дәшү; игътибарны җәлеп иттерү максатында дәшү. *Иргали аның башын күтәреп тезенә салды, дәшеп карады.* М.Хәсәнов. *Дәшеп карыйм – чыкмый тавышым, Барыр юлларымны ялгыштым.* С.Әхмәтҗанова

**Дәшеп кую** Бер тапкыр дәшү; аратирә дәшү. *Бераздан әни йомшак кына тагын бер дәшеп куйды.* Г.Бәширов. *--- олаучы бабайның мәзәк итеп: «Яле, йоклама әле, койрыгыңны бүре тешләп өзгере!» – дип, атка дәшеп куюы да аның өчен искиткеч кызык һәм яңа иде.* А.Гыйләҗев

**Дәшеп тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле дәшү. *Елга буе үзәне, сихри әкият кебек җанланып, үзенә дәшеп тора иде.* А.Фәләх. *--- Әмирне авылда әле кунакка дәшеп торган кешеләр сирәк иде.* В.Имамов

**ДӘШҮЛЕ** *с.* Чакырулы

**ДӘЮ** *ф. иск. к.* **дию** I. *Хәлебез кадәренчә авыл картлары илә мәсҗид туе кылыр идек дәю бәс безләр.* К.Йосыпов

**ДВИ́ГАТЕЛЬ** *и. рус тех.* Билгеле бер төр энергияне механик энергиягә әверелдерү машинасы. *Совхозга берәр яңа машина яки двигатель килсә, аның янына иң элек Александров барып җитә.* И.Салахов

**ДВИЖОК** *и. рус тех.* Эчке янулы, зур булмаган күчмә двигатель. *Бер*

*төнне движоктан Наузань Ингельне арестовать итеп алып киттеләр.* Х.Камалов

**ДВОР** *и. рус сөйл.* Патша Россиясендә: җәяүлеләр һәм атлы юлчылар кереп куна торган йорт. *Барлык постоялый дворлар, чәйханә, мөсафирханәләр эшсез һәм хәерчеләр белән тулган иде.* М.Галәү. *Әллә ничә кеше әйтте --- урамда да, дворда да...* Ф.Садриев

**ДВОРЕЦ** *и. рус сөйл.* 1) Патша, дәүләт башлыклары, шулай ук патша гаиләсе әгъзаларының даими яшәү урыны булган бина, йорт

2) Зиннәтлелеге, байлыгы, зурлыгы белән аерылып торган бина. *Һәйбәт өйләр байтак булса да, Ишминең өйләре арада бер дворец кебек тора. Ике катлы, асты таш, өсте агач, урамга 15 тәрәзә караган бер өйне авыл җирендә «дворец» дип атау күпертү булмастыр, шәт.* М.Фәйзи

3) Җәмәгать оешмалары урнашкан зур бина. *Нинди спектакль булуын сорашып, төпченеп тору кайда инде ул! Дворецка (ул чакта театрны шулай дип тә йөртәләр иде) эләгү үзе бәхет иде.* М.Кәрим

**ДВО́РНИК** I *и. рус сөйл.* Ишегалды, йорт тирәсен чистартып торучы кеше. *Иртән иртүк дворник йоклап утырган малайны төрткәләп уятты да байлар йортына куды.* М.Галәү

**ДВО́РНИК** II *и. рус сөйл.* Автомашиналарның алгы һәм арткы пыялаларын яңгыр, кар, тузаннан чистарту өчен куелган, ук формасындагы махсус җайланма. *Машина эче яктырып китте, «дворникларның» пыяла буйлап бертуктаусыз алга-артка хәрәкәте шәйләнә башлады.* Казан утлары

**ДВО́РНИКЛЫК** *и.* Дворник хезмәте, дворник вазифасы. *Вафа, Әрләнгә дворникլыкка ялланып, күздән алып язга чаклы эшләргә сүз бирде.* М.Галәү. *Ә кием, мода мәсьәләсенә килгәндә, стилягалык ул --- үзенә күрә бәйсезлеккә, хөрлеккә омтылу да иде. Юкса, бер җирдән килере булмаган, стипендиягә генә яшәп яткан студентлар, югын бар итеп, буш вакытларында вагон, баржа бушатып, дворниклыкка ялланып, --- тар чалбар, кара күлмәк, калын табанлы туфли юнәтергә тырышмаслар иде.* Ф.Латыйфи. *Ул вакытта Әхмәт, домоуправлениедә өстәмә дворник булып эшләп, Татарстан урамындагы ике бүлмәле фатирның бер бүлмәсендә тора иде... Дворниклыкны концерт куеп кайтарырга кирәк бит инде.* Юлдаш

**ДВОРО́ВЫЙ** *и. рус сөйл. иск.* Алпавыт, бай йортындагы крепостной хезмәтче. *Күшәр авылында һәм Мукшы пүчинкәсендә морза кенәзләре Мөхәммәт һәм Муса Мортазиннар (Яушев балалары), аларга хезмәт итүче дворовый кешеләр, йомышлы татарлар яшәгән.* Ф.Гарипова

**ДВОРЯН** *и. рус* Феодаль җәмгыятьтә идарә итүче, өстенлекле эксплуататор сыйныфны тәшкил иткән эре җирбиләүче катламның бер вәкиле. *Мәскәүдәге полякларны куып чыгару өчен, дворян Ляпунов җитәкчелегендә кораллы көчләр (ополчение) оеша.* Р.Әмирхан

**ДВОРЯНЛЫК** *и.* 1) Дворян титулына ия булу. *Дәрәҗәле татар руханиларына һәм морзаларга дворянлык хокукы бирелә.* А.Әминов. *Русиянең табигать фәннәре академиясе академигы Илдар Үтәмешев фикеренчә, Русиянең дворянлыгы татарларга бурычлы.* Безнең гәҗит

2) Дворянга хас сыйфатлар

**ДЕ-** *лат.* Юклык яки каршы куюны белдерә торган алкушымча (мәс., *демонтаж һ.б.*)

**ДЕБАРКА́ДЕР** *и. фр.* 1) Пароходлар туктау өчен көйләнгән йөзмә пристань. *Раббани абый белән тагын ике кеше чабып килеп җиткәндә, пароходның борыны гына түгел, биле дә дебаркадердан кеше буе аерылган иде инде.* Х.Сарьян. *Эстрада театры каршысына, Мәскәү елгасының бетон ярына беркетелгән дебаркадерга су трамвае килеп туктаган иде.* М.Юныс. *Без заманында «Мурзиха затоны» дип йөртелгән, тик бу затоннан хәзер инде бер бәләкәй дебаркадер гына калган кыек-мыек бинадан мең бәлаләр белән билетлар эләктереп, Кама – Идел буйлап Казанга йөзүче пароходка кереп кысылдык.* Ф.Дунай

2) *иск.* Тимер юл станциясендә платформа. *Вокзал дебаркадерында халык күп*

**ДЕБАТ** *и. фр. кит. гадәттә күпл. форм.* Төрле формадагы утырыш-җыелышларда әңгәмә рәвешендә алып барылган бәхәс һәм фикер алышу тәртибендә ясалган чыгышлар. *Милләт мәсьәләсе куерган дебатларда Фәндәс Сафиуллин күңелендәге фикерен уеп-уеп әйтә белә иде.* Татар иле

**ДЕБЕ́Т** *и.* **1.** 1) Хайван яки кошкортның искиткеч йомшак, нәфис мамыгы. *Алмагачлар – ак дебет, Ап-ак шәл япкан кебек.* Р.Вәлиева

2) Шул мамыктан эрләп эшләнгән чигү җебе. *Бүлмә тактасы буенда тимер карават. Аның өстендәге мендәрләрне дебет белән нәфис чәчәкләр чигелгән ал бөркәвеч каплап тора.* Г.Бәширов. *[Килен] Элеккедән калган, башлары кызыл дебет белән чиккән ике сөлге бирде.* Х.Камалов

**2.** *с. мәгъ.* Дебеттән эшләнгән. *Маһинур, башындагы дебет шәлен сатып, чиләк, чәйнек, табак-савыт, кашык һәм бер кило ит алган булган.* И.Салахов. --- *Өммегөлсемнең тырышлыгы, сыер имчәге тарткан, дебет шәл бәйләгән бармакларның көче белән, Әхмәтшәриф картның нигезендә яңа өй төзелә.* Ш.Янбаев

**ДЕ́БЕТ** *и. лат. махс.* Бухгалтер кенәгәсендә: бөтен кыйммәтләр, кеременнәр, чыгымнар һәм бурычлар теркәлеп бара торган графа; *киресе:* **кредит**. *Уебызда дебет, кредит һәм тагын сальдо безнең, Бер минут та тик тормыйбыз, Эшебез саллы безнең.* Н.Әхмәдиев

**ДЕБИТ** *и. фр. махс.* Нинди дә булса чыганактан алына торган сыек матдәнең яки газның мәгълүм вакыт берәмлегенә туры килгән микъдары, күләме. *Әлегә елына 30 млн тонна нефть чыгарылса да, һәр скважинаның уртача дебиты 4 тоннадан артмый.* И.Әмирхан

**ДЕБИТОР** *и. лат. махс.* Бурычы булган кеше яки учреждение

**ДЕБИТОРЛЫК** *с.* Дебиторга караган, шуның белән бәйле. *Предприятиенең 7 млн сумнан артык дебиторлык бурычы да бар.* Ватаным Татарстан

**ДЕБОШ** *и. фр.* Тавышлану, скандал һәм сугышуга әверелгән җәнҗал, гауга. *[Эмилия:] Ресторанда дебош, ә биредә... йа Рабби! Әти синең бу эшеңне белсә?* Н.Исәнбәт

**ДЕБОШИР** *и. фр.* Дебош оештыручы; тавыш-гауга, скандал чыгаручы. *Тормыш бит ул мин кушкан, син кушкан, күршең дебошир кушкан сукмаклардан гына йөрми.* Р.Галимуллин

**ДЕБЮТ** *и. фр.* 1) Сәхнәдә, яки гомумән нинди дә булса берәр өлкәдә ясалган беренче чыгыш. *Репетициядән соң өскә, үз бүлмәсенә менсә, анда аны Муса Җәлил көтеп тора икән ләбаса: – Шәфика ханым, дебютыгызны шундый да уңышлы башкаруыгыз белән тәбрик итәм...* Мирас

2) Шахмат, шашка уеннарында партия башы, уен башы

**ДЕБЮТАНТ** *и. фр.* Кайдадыр дебют ясаучы, беренче тапкыр халык алдында чыгыш ясаучы. *Быелгы дөнья беренчелегендә Россия җыелма командасы данын 10 дебютант яклады.* Шәһри Казан

**ДЕВАЛЬВА́ЦИЯ** *и. фр. махс.* Хөкүмәт акты нигезендә акча берәмлегенең номиналь кыйммәте кимү. *Көннәрдән бер көнне акча бәясе үзгәрәчәк, девальвация булачак дигән хәбәр таралды.* А.Расих

**ДЕВАЛЬВА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. махс.* Рәсми рәвештә акчаның кыйммәтен төшерү. *Хокук һәм закон кыйммәтләрен девальвацияләү процессы башланды, гражданнарның хакимият институтларына ышанычы кими дип билгеләп үтте Татарстан парламенты җитәкчесе.* Ватаным Татарстан

**Девальвацияләп бетерү** Тәмам, ахыргача девальвацияләү; девальвацияләүне төгәлләү. *Россиядә кәгазь акчаларны девальвацияләп бетерделәр, алар «агач» акчага әверелде*

**Девальвацияләп тору** Әледән-әле, еш девальвацияләү. *Акчаның бәрәкәте юк, гел девальвацияләп торалар*

**ДЕВИА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* 1) Төрле тәэсирләр нәтиҗәсендә, компас угының магнит полюсларын ялгыш күрсәтә башлау күренеше. *Девиация аркасында адашу*

2) Төрле сәбәпләр, тәэсирләр нәтиҗәсендә, снаряд һ.б.ш. үз юнәлешеннән читкә тайпылу күренеше. *Самолёт девиациясе*

3) Чит нурланышка юлыгу нәтиҗәсендә, радиодулкынның тиешле юнәлешеннән читкә тайпылуы

**ДЕВИЗ** *и. фр.* 1) Кемнең дә булса эшчәнлегенең яки ният, максатының төп идеясен чагылдырган кыска тәгъбир, сүз. *Аның девизы – борынгы халык җырларындагыча: «Агай-эне – ак мыек, бер-беребезне какмыек!».* Ф.Хөсни. *Безнең шәһәрнең төп девизы: спорт – сәламәтлек нигезе.* Татарстан

2) Конкурсларда әсәр (проект, сочинение) авторы үз исеме урынына куя торган шартлы имза: кыска тәгъбир яки сүз. *Беренче премия «Татарлар» девизы астындагы проектка бирелә*

**ДЕВОН** *и. ингл. геол.* 1) Җирнең геологик тарихында палеозой эрасының дүртенче дәвере

2) Җир кабыгының шул дәвергә туры килә торган катламы, катламнар системасы. *Ә теләсәң, кил син вузга, Күтәреш фәннәр үрен. Юллар салыш девоннарга, Я ачыш атом серен...* Г.Хуҗиев

**ДЕВО́Н СИСТЕМАСЫ** *и. к.* **девон** (*2 мәгъ.*)

**ДЕВО́Н ЧОРЫ** *и. к.* **девон** (*1 мәгъ.*) *Моннан 326 миллион ел элек Татарстанда девон чоры диңгезе барлыкка килә. Девон чоры 50–60 миллион еллар дәвам итә.* Кызыклы география

**ДЕГАЗА́ТОР** *и. рус* 1) Дегазацияләү аппараты

2) Дегазацияне башкаручы кеше, дегазацияләүче; дегазация белгече

3) Дегазация чарасы, зарарсызландыру матдәсе

**ДЕГАЗА́ЦИЯ** *и. рус* Агулагыч матдәләр белән зарарланган урынны, кием, корал һ.б. зарарсызландыру күренеше

**ДЕГАЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Нәрсәгә дә булса дегазация ясау, зарарсызландыру. *Тирә-як мохитне дегазацияләү. Химия комбинаты лабораториясендә эш киемнәрен дегазацияләү*

**Дегазацияләп бетерү** Тәмам, ахыргача дегазацияләү

**Дегазацияләп чыгу** Барысын да бер-бер артлы дегазацияләү

**ДЕГӘ-ДЕГӘ** *ы.* **дегешки-дегешки**

**ДЕГӘНӘК** *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, Көньяк Уралда, Көнбатыш Себердә, Төньяк Кавказда таралган, төрләре бик күп булган күпьеллык үлән үсемлек; *ручасы:* **мордовник**

**ДЕГӘНКӘЙ** *и. диал.* Бераз үсә төшкән каз бәпкәсе

**ДЕГӘШКИ-ДЕГӘШКИ** *ы.* **дегешки-дегешки**

**ДЕГЕ-ДЕГЕ** *ы.* **дегешки-дегешки**. *Минем күзем төшкән әлеге үсмер малай, күпер аркылы аргы якка чыгып, яр буена чүгәләде дә: – Деге, деге, деге! – дип, казларны үз янына чакыра башлады.* Г.Галиев

**ДЕГЕНЕРАТ** *и. лат. кит.* Токым бозылуның, дегенерациянең билгеләре булган кеше; нәселдән килгән уңай биологик һәм психик билгеләрен югалткан кеше

**ДЕГЕНЕРАТИВ** *с.* Дегенерациягә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Умырткалыкның киң таралган авыруларыннан берсе – остеохондроз (грекчадан osteon – сөяк, chondros – кимерчәк). Бу – умырткаара дискларның дегенератив авыруы, бу вакытта умыртка сөякләренең тукымасында биохимик үзгәрешләр барлыкка килә.* Республика

**ДЕГЕНЕРА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Организмның биологик һәм психик билгеләренең начарлануы, бозылуы, токымлылыгы бетү, коруга, таркалуга йөз тотуы

2) *биол.* Тере организмнарның әгъза яки күзәнәкләрендә таркалу күренеше. *Кәлтә еланнарның очлыклары дегенерациясе*

**ДЕГЕНЕРА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. юн.* Дегенерация кичерү. *Соңгарак күзәнәкләр дегенерацияләнә, тәңкәсыман калкым эченә холестерин туплана, башка төрле липидлар да җыела.* Фән һәм тел

**Дегенерацияләнә башлау** Дегенерациягә йөз тоту

**Дегенерацияләнеп бетү** Тәмам дегенерацияләнү, дегенерацияләнүнең соңгы чигенә җиту

**ДЕГЕТ** *и. рус* Агач, торф, таш-күмерне корылай куу юлы белән алына торган, куе кара төстәге сумаласыман масса. *Бер солдат почмактагы дегет чүлмәгенә бармагын тыгып, бал дип ялап карады.* С.Шакир. *Дегет сатарга килгән марилар янына, кулларына дегет чиләкләре тотып, авыл агайлары җыелган. Алар бармакларын дегеткә манып алып, дегетне уч төпләренә ышкып карыйлар, сатулашалар, бәһасен килешсәләр, дегет агызырга чиләкләрен китереп куялар.* М.Галәү

◊ **Дегет лагуны** *к.* **дегет чиләге**. *Арба артына таккач, дегет лагуны да хаҗга барган.* Мәкаль. **Дегет чиләге** *кимс.* Үзенең сүзе, инициативасы булмаган, ихтыярсыз кеше. *Анысы – профсоюз комитеты рәисе дигән «дегет чиләге». Заманасына күрә алай дисәң дә ярыйдыр. Чөнки хәзер, кыл кыймылдатса да, адәм баласы «акча» дип авыз ача. Рафикъ, авырыксынмый, «бесплатно» тарта бу йөкне.* Авыл утлары

**ДЕГЕТЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **дегетләү**. *Тәгәрмәч көн саен дегетләнә*

2) Дегеткә буялу, дегет белән пычрану

**Дегетләнә башлау** Бераз дегетләнү

**Дегетләнеп бетү** Тәмам дегетләнү, бөтен җире дегетләнү

**ДЕГЕТЛӘ́Ү** *ф.* Дегет белән майлау, дегеткә буяу. *Аягымдагы читекне Элеп куйдым дегетләп; Сорап-сорап үптермәсә, Йөрмә икән үгетләп.* Т.Миңнуллин. *Йоклый торган түшәкләрен Дегетләп ята микән? Ашый торган ашларына Мунчала сала микән?* Р.Фәйзуллин. --- *үгетләп түгел, дегетләп ташласаң да, булмаганнарын без инде аны альманахка басып та тормыйбыз.* Х.Сарьян

**Дегетләп алу** Тиз генә дегетләү. *Арба күчәрен дегетләп алу*

**Дегетләп бетерү** Дегетләүне төгәлләү, тәмамлау яки бөтенесен, барысын да дегетләү. *Кушылган кадәр өлешен дегетләп бетергәннәр. Бөтен капканы дегетләп бетергәннәр*

**Дегетләп тору** Әледән-әле, еш, бертуктаусыз дегетләү. *Арба күчәрен мае беткән саен дегетләп торалар. Шпалларны дегетләп торалар*

**Дегетләп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы дегетләү; башыннан ахырына кадәр дегетләү

**Дегетли башлау** Дегетләргә тотыну

**Дегетли төшү** Тагы да бераз дегетләү

**ДЕГЕТЛЕ** *с.* 1) Дегете булган; дегет салынган яки дегет катнашкан. *Агач кәүсәләрен кимерүчеләр зарарламасын өчен, аларга иске синтетик оек, рубероид урарга, яки махсус состав (1 чиләк состав ясау өчен 1 өлеш кызыл балчык, 1 өлеш коровяк, 100 г дегетле сабын, 2 аш кашыгы төелгән кара борыч, 50 г агач җилеме алына) белән капларга киңәш ителә.* Кәеф ничек?

2) Дегеткә буялган, дегет чәчрәгән, дегеткә баткан, дегет сеңгән. *Заһит ниндидер дегетле капчыктан алтын алкалар, йөзек һәм беләзекләр тартып чыгарды.* Ф.Яруллин. *Ярдагылар укларына дегетле чүпрәкләр, каен тузы яндырып тага башлагач, исән калганнар үзләре ярга чыга башлады*. Р.Батулла

3) Дегетләнгән, дегет сөртелгән, дегет сеңдерелгән, дегет белән махсус майланган. --- *арбадан төшәбез, малкайларга авырга килмәсен дип, арттан этәбез, дегетле күчәр башыннан тотып күтәреп, тәгәрмәчне чокырдан чыгарабыз...* А.Тимергалин

**ДЕГЕТЧЕ** *и.* Дегет ясау, житештерү, дегет куу яки дегетне сату-алу эше белән шөгыльләнүче кеше. *Дегетче күмерчегә, мине буяма, дигән*. Әйтем

**ДЕГЕТЧЕЛЕК** *и.* Дегетче һөнәре яки кәсебе. *Хәзер хуҗалыкта дегет бик кулланылмагач, дегетчелек тә онытылып бара*

**ДЕГЕШКИ-ДЕГЕШКИ** *ы.* Каз-үрдәк кебек кош-кортларны чакыру сүзе

**ДЕГРАДА́ЦИЯ** *и. фр.* Кыйммәтле үзлекләрнең һәм сыйфатларның эзлекле рәвештә кимеп, начарланып юкка чыгу күренеше; таркалыш; кирегә, артка китү. *Барлык сыйнфый җәмгыятьләрнең тарихи спираль буенча хәрәкәтләрендә деградация башланган мизгелдән, җитештерү алымнары (колбиләүчеләр, феодаллар, буржуазия) өчен һөҗүм характерлы булды.* Татарстан. *Без, үз чиратыбызда, башка консервларга караганда арзанрак та булгач, салака белән килькины рәхәтләнеп алабыз һәм «деградация», ягъни таркалу гормоны белән тулы әлеге балыкларны еш кулланабыз.* Юлдаш

**ДЕГРАДА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Кыйммәтле үзлекләр, әһәмиятле сыйфатлар югала бару, акрынлап начарлану-бозылу. *Нәшриятта чыккан җыентыкларның тиражларына карыйсың да аптырашта каласың: йә без, рәсми статистика икърарлаганча, җиде миллион түгел, яисә инде безне «милләт» диеп атап булмый, без инерция белән «татар» исемен йөртүче деградацияләнгән җаһил бер илат кенә...* Идел

**Деградацияләнә бару** Торган саен ныграк деградацияләнү; тагын да деградацияләнү. *Тарихын, үткәнен белмәгәннәр деградацияләнә бара*

**Деградацияләнә башлау** Деградацияләнергә тотыну

**Деградацияләнеп бетү** Тәмам деградацияләнү. *Деградацияләнеп беткән җәмгыять*

**ДЕГУСТА́ТОР** *и. фр.* Дегустация буенча белгеч; дегустацияләүче кеше. *[Зөбәйдә:] --- сез дегустатор, ахрысы. – Чынлап түгел, ә, бәлки, шаярып кына әйткәнлегем аңлашылсын өчен, мин көлеп куйдым.* Ф.Садриев

**ДЕГУСТА́ЦИЯ** *и. фр.* Дегустацияләү яки дегустацияләнү эше. *Патша өчен әзерләнгән фатирларда аракы дегустациясен алуны да аңа йөкләде бит Беренче, аңа!..* Р.Юсупова

**ДЕГУСТА́ЦИЯЛӘҮ** *и.* Нинди дә булса азыкны, эчемлекне (шәраб, тәмәке, чәй һ.б.ш.) әзерләгәндә, аның кыяфәтенә, төсенә, тәменә карап, сыйфатын билгеләү. *Йөзем шәрабын дегустацияләү*

**Дегустацияләп бетерү** Дегустацияләүне тәмамлау; барысын да дегустацияләү. *Белгечләр аракының яңа сортын дегустацияләп бетерделәр дә өйләренә таралыштылар*

**Дегустацияләп тору** Гел, һәрвакыт, әледән-әле дегустацияләү. *Яңа сорт продуктларның һәркайсын дегустацияләп торалар*

**Дегустацияләп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы дегустацияләү

**Дегустацияли башлау** Дегустацияләргә керешү

**ДЕД** I *и. рус сөйл.* Ике елга исәпләнгән армия срогының ел ярымын үткән хәрби хезмәткәр. *Ә «дед»лар белән араларны җайлауның чарасы бик гади: армиягә ныгып-чыныгып барырга кирәк.* М.Маликова

**ДЕД** II *и. рус сөйл.* Өлкән механик. *Кемдер Сукач фикерен куәтләп җибәрде: – Бер минут та ял итә алмадык. Вахта алышыныр вакыт үтеп китте. Дед шелтәләсә, дневальный соңга калдырды, диячәкмен.* М.Юныс

**ДЕДОВЩИ́НА** *и. рус сөйл.* Армиядә: кайбер «дед»ларның (I) башка хәрби хезмәткәрләргә карата тискәре, начар мөнәсәбәтен чагылдыра торган тискәре күренеш. *Дүртенче ротада, бер уйласаң, «дедовщина» әллә ни куркыныч төс алмаган.* С.Шәрипов. *Гомер өзелүләрнең зур өлеше бүгенге Русия армиясендәге иң кыргый, иң кабахәт нәрсә дедовщина аркасында булып чыкты.* Мәдәни җомга

**ДЕДУКТИВ** *с.* 1) Дедукциягә нигезләнгән. *Теге яки бу бәйләнешнең законченлыклы күренеш икәнлеген дәлилләгәндә, исбат итүләрнең төрле системасы (индуктив һәм дедуктив, тәҗрибә-эксперименталь һәм теоретик, логик һәм тарихи, математик һәм сүз белән сөйләп-логик) кулланыла.* Совет мәктәбе

2) Дедукциягә мөнәсәбәтле. *Дедуктив ысул*

**ДЕДУ́КЦИЯ** *и. лат. лог.* Гомуми тәгълиматлардан хосусый тәгълиматларга күчеп фикерләү алымы, нинди дә булса гомуми фикердән логик исбатлау юлы белән хосусый фикер чыгару; *киресе:* **индукция.** *Әгәр яңа материал логик эзлеклелектә булса (аның иң мөһим законнары сәбәп һәм нәтиҗә бәйләнешләре, аналогия, индукция һәм дедукция тиешле тәртипкә китерелсә) --- укучылар мөстәкыйль рәвештә объектлар һәм күренешләрне (төшенчәләрне) тасвирлый, билгеләмәләрне әйтә, чагылдыра һәм хикәяләр төзи белә ---.* Совет мәктәбе

**ДЕЖУР** *и. фр. сөйл.* **1.** 1) Чират тәртибендә дежурлык хезмәтен башкаручы кеше, кизү торучы. *Бүген ул дежур. Барчасының игътибары Илдар Илдаровичка юнәлә.* С.Гаффарова

2) *кыек килешләрдә.* Дежурлык. *Эчү-эчмәүнең әһәмияте юк. Ул бүген дежурда. Мин аңа киләбез дидем.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кирәк булганда тиз генә куллану өчен әзерләп куелган. *Ресторанда дежур өстәл*

2) *күч.* Гел кулланыла, файдаланыла торган. *Америка егете тагын бер кат елмаеп куйды. Әмма ул эшкуарларга хас дежур елмаю түгел иде инде.* Ф.Латыйфи

**ДЕЖУРЛЫК** *и.* Дежур хезмәте һәм вазифасы, дежур тору, кизү. *Партия җыелышы шунда узды, агитколлектив шунда эшләде. Фермада коммунистлардан дежурлык булдырылды.* М.Мәһдиев. *«Фабрикага – төнге дежурлыкка барасым бар», – дигән булып, хатынын иртәтеп чыгып киткән Азатны сизмәде дә кунак, җыелмалы креслода изрәп калды.* Х.Закиров

**ДЕЖУ́РНЫЙ** *и. рус сөйл.* **1.** *к.* **дежур 1.** (*1 мәгъ.*). *Торакта чакта, сигнал булгач та, бер-ике генә минут булса да изрәп яту өчен тартышырга, дежурныйның кәефен бозарга туры килгән көннәр күп була иде.* М.Әмир. *Ул, тынычсызланып, дежурный янына китте. Әхнәф Шәрифуллинның кайсы бүлмәдә яшәвен сорады. «Икенче катта андый кеше яшәми», – диде дежурный, кенәгәсеннән тикшереп чыккач.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Бүтәннәр эшләмәгәндә, гадәти көн тәртибеннән тыш эшләүче. *[Колхоз] Яңа типовой йортлар сала. Анда – суы, кибете, мәктәбе, гастрономы, дежурный кибете, ательесы, больницасы, почта-телеграфы, ял паркы.* М.Мәһдиев

**ДЕЖУ́Р ТОРУ** *ф.* Дежурлык итү; кизү хезмәтен башкару, шул вазифаны үтәү. *Инструктор чагында райкомның кабул итү бүлмәсендә дежур торганда, аны Арсланов чакырып кертте дә: «Шушы телеграмманы хәзер үк җибәр әле», – диде.* Ф.Садриев

**ДЕЗ-** *фр. кит.* Нәрсәнең дә булса булмавын, бетерелүен, алып ташлануын, юкка чыгарылуын, туктатылуын һ.б.ш. белдерә торган алкушымча (мәс., *дезинформация, дезориентация*)

**ДЕЗАКТИВА́ЦИЯ** *и. фр.* Төрле предмет, корылма һ.б.ш. өслегеннән радиоактив пычрануларны, утырмаларны чистарту, зарарсызландыру эше

**ДЕЗЕРТИР** *и. фр.* Дезертирлык итүче кеше, качкын. *Немецлар ягына чыккан кешегез юкмы? Семьягызда дезертирлар булдымы?* М.Мәһдиев. *[Мөҗәһит Хәйретдинов] Сугыш язмаларында әнә шулар турында язып китә дә, чын качкыннар, Ватанын ташлап качкан дезертирлар, дошманга сатылган хыянәтчеләр турында йөрәктән чыккан иң көчле нәфрәтен белдерә.* С.Шакир. *Вәкилнең карашы бу юлы кырыс иде: «Син – дезертир! – диде ул тешләрен кысып. – Сез, эштән куркып, качып ятасыз!»* С.Зыялы

**ДЕЗЕРТИРЛЫК** *и.* 1) Аңлы рәвештә, хәрби хезмәт урыныннан яки сугыштан, яудан баш тартып, качып китү күренеше. *Һәр көн үзе белән бер яңа мәшәкать, һәр төн куркыныч алып килә. Кайдадыр, кемнәрдер, сугыштан качып, дезертирлыкта йөриләр, ди.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Җәмгыятькә файда китерә торган хезмәттән, үзеңнең гражданлык бурычыңны үтәүдән качарга тырышу күренеше

**ДЕЗИНСЕКТАЛЬ** *и. фр.* Торак йортлардагы зарарлы бөҗәкләрне бетерү өчен кулланыла торган агулы сыекча (дуст порошогын керосинда эретеп ясала)

**ДЕЗИНСЕ́КЦИЯ** *и. фр.* Зарарлы бөҗәкләрне махсус чаралар кулланып агулап юкка чыгару эше. *Бодай саклана торган келәтләрдә даими дезинсекция үткәреп тору каралган*

**ДЕЗИНТОКСИКА́ЦИЯ** *и. фр.* Агусызлану күренеше; агулы матдәләрнең организмга тәэсире кимү яки бетү, агу тәэсирендә функцияләрнең кире үз хәленә кайту күренеше. *Дезинтоксикация күп көч, сабырлык һәм вакыт сорый*

**ДЕЗИНТОКСИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Агулы матдәләрнең организмга тәэсирен киметү яки бетерү, алар тәэсирендә бозылган функцияләрне кире үз хәленә кайтару; агусызландыру

**Дезинтоксикацияләп алу** Берникадәр, тиз арада дезинтоксикацияләү.

*АЭСта авария булу сәбәпле, кайбер эшчеләрне дезинтоксикацияләп алдылар*

**Дезинтоксикацияләп бетерү** Дезинтоксикацияләүне тәмамлау; тулаем, тулысынча дезинтоксикацияләү

**Дезинтоксикацияләп тору** Һаман, әледән-әле дезинтоксикацияләү. *Палаталарны гел дезинтоксикацияләп торалар*

**Дезинтоксикацияләп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы яки башыннан ахырына кадәр дезинтоксикацияләү

**Дезинтоксикацияли башлау** Дезинтоксикацияләргә керешү

**Дезинтоксикацияли төшү** Тагы да бераз дезинтоксикацияләү

**ДЕЗИНФЕ́КТОР** *и.* Дезинфекция ясаучы кеше, дезинфекцияләүче; дезинфекцияләү белгече. *Минем әтәй --- ликбездә, өяз каласына барып, ике айлык курсны бетереп кайткан ---. Аны да чакыртып алалар, район үзәгенә – ветпунктка дезинфектор кирәк икән.* Ж.Рәхимов

**ДЕЗИНФЕКЦИОН** *с.* Дезинфекциягә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Дезинфекцион чаралар. Дезинфекцион камера. Дезинфекцион станция*

**ДЕЗИНФЕ́КЦИЯ** *и. фр.* Йогышсызландыру; йогышлы авырулар тудыручы микроорганизмнарны физик, химик һәм биологик чаралар белән юк итү. *Георгий плитә белән ике арада әйләнде: эш коралларын кайнатты, урын-җиргә дезинфекция ясады.* И.Салахов

**ДЕЗИНФЕ́КЦИЯЛӘҮ** *ф.* Авыру таратучы микробларны юк итү яки йогышсызландыру. *Мин: «Ильяс! Бар, кулларыңны сабынлап ю да, өстәлдәге әнә теге ак флаконнан учыңа спирт агызып, кулларыңны дезинфекцияләп, минем яныма кил! Тиз бул!» – дип кычкырдым.* Г.Галиев

**Дезинфекцияләп алу** Озакка сузылмаган, кыска вакыт аралыгында гына дезинфекцияләү. *Камераларны дезинфекцияләп алу*

**Дезинфекцияләп бетерү** Тулысынча, ахырына кадәр дезинфекцияләү яки, гомумән, дезинфекцияләү эшен тәмамлау. *Бөтен бүлмәне дезинфекцияләп бетерү*

**Дезинфекцияләп карау** Дезинфекцияләргә тырышу

**Дезинфекцияләп тору** Әледән-әле, еш дезинфекцияләү. *Ашлык складларын дезинфекцияләп тору үзенең нәтиҗәләрен бирә*

**Дезинфекцияләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тулысынча дезинфекцияләү. *Ноябрьнең бозлы елгасына чумдырдылар безне ---, дезинфекцияләп чыгардылар өсне-башны чишендермичә.* Р.Харисов

**Дезинфекцияли бару** Һәрберсен бер-бер артлы дезинфекцияләү, системалы дезинфекцияләү. *Бакчада бөҗәкләр күбәйгән, шуңа күрә аларны дезинфекцияли баралар*

**Дезинфекцияли башлау** Дезинфекцияләргә керешү

**Дезинфекцияли төшү** Тагы да бераз дезинфекцияләү. *Дезинфекцияли төшү – зарарлы бөҗәкләрдән котылу эшендә яхшы чара булачак*

**ДЕЗИНФОРМА́ТОР** *и. рус кит.* Дезинформация бирүче кеше

**ДЕЗИНФОРМАЦИОН** *с.* Дезинформация максаты белән кулланылган; эчтәлеге, асылы дезинформациядән гыйбарәт булган

**ДЕЗИНФОРМА́ЦИЯ** *и. фр. кит.* Кемдә дә булса ялгыш фикер, ялгыш караш тудыру максатыннан чыгып таратылган ялган информация. *Дезинформация тараткан өчен, суд җаваплылыгына тартылу*

**ДЕЗИНФОРМА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Ялган хәбәрләр, дөрес булмаган мәгълүматлар биреп, ялгыш фикер, ялгыш караш тудыру. *Дошманны дезинформацияләү*

**Дезинформацияләп тору** Әледән-әле, еш дезинформацияләү. *Укучыларны гел дезинформацияләп тору уңай нәтиҗәләргә китермәс*

**ДЕЗОДОРАНТ** *и. фр.-лат.* Исне маскировкалау, киметү яки юкка чыгару максаты белән кулланыла торган косметика чарасы. *Балта, кадак, идән буявы белән беррәттән, әллә ничаклы матур духи, дезодорантлар тезелеп киткән.* А.Гыймадиев. *Җәй көне дезодорантлар, хушбуйларны да онытып торыгыз.* Ватаным Татарстан

**ДЕЗОДОРА́ТОР** *и. фр.-лат.* Кирәкмәгән исне бетерү өчен махсус прибор яки матдә

**ДЕЗОДОРА́ЦИЯ** *и. фр.* Кирәкмәгән исне бөтенләй бетерү яки башка тәмлерәк ис белән маскировкалау процессы

**ДЕЗОРГАНИЗА́ТОР** *и. фр.-лат.* Дезорганизация белән шөгыльләнүче кеше, дезорганизация китереп чыгаручы

**ДЕЗОРГАНИЗА́ЦИЯ** *и. фр.* Дезорганизацияләү күренеше. *Дезорганизация белән шөгыльләнеп, эшчеләр белән җитәкчеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кискенләштерүгә зур өлеш кертkәнe --- өчен, Нурислам Миңсалих улы Фарукшинга каты кисәтү ясап, шелтә белдерергә, ягъни мәсәлән.* Р.Вәлиев. *Бу бит, турысын гына әйткәндә – дезорганизация!* Р.Батулла

**ДЕЗОРГАНИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Системалы, эзлекле, тәртипле эш-гамәлнең агышын бозу, тотрыксызлык, буталчыклык кертү

**ДЕЗОРИЕНТА́ЦИЯ** *и. фр. кит.* Нәрсәнең дә булса асылын аңлап белү, төшенү сәләтеннән мәхрүм булу, ориентациянең ялгыш булуы, фикер буталчыклыгы туу. *Менә шундый киңәшләр бирүче әрсезләр безнең гамьсезлектән файдаланалар: аларның кәсепкә генә нигезләнеп «иҗат» ителгән дистәләрчә җыентыклары башлап язучы яшьләр арасында дезориентация тудыра.* Х.Туфан

**ДЕЗОРИЕНТА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **дезориентацияләү**

2) Ялгыш ориентация алу; ориентацияне югалту; дөрес юлдан адашу

**ДЕЗОРИЕНТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Ялгыш ориентациягә дучар итү, этәрү, фикер буталчыклыгы китереп чыгару. *Каршы якны дезориентацияләү*

**Дезориентацияләп алу** Кемне дә булса вакытлыча дезориентацияләү, билгеле бер вакытка дезориентациягә дучар итү. *Хөкүмәт тагын, инфляция мәсьәләсен кузгатып, халыкны дезориентацияләп алды*

**Дезориентацияләп бетерү** Тәмам, тулысынча, бөтенләй дезориентацияләү. *Оста оратор бөтен тыңлаучы-*

*ларны үз ягына аударып, дезориентацияләп бетерде*

**Дезориентацияләп тору** Берөзлексез яки әледән-әле дезориентацияләү. *Район матбугаты, газета битләрендә төрле хәбәрләр таратып, авыл кешеләрен дезориентацияләп тора.* Татар иле

**Дезориентацияли бару** Даими рәвештә, системалы дезориентацияләү. *Төрле секталар үзләренә иярүчеләрне дезориентацияли бара*

**Дезориентацияли башлау** Дезориентацияләүгә керешү

**Дезориентацияли төшү** Бераз дезориентацияләү. *Яшьләрне төрле эчтәлектәге кинолар да дезориентацияли төшә*

**ДЕИЗМ** *и. лат. махс.* Дөнья Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылса да, аның үсешенә һәм вакыйгаларның закончалыклы агымына ул катнашмый дип раслаган дини-фәлсәфи тәгълимат (яңарыш чорында таралган)

**ДЕИСТ** *и. лат. махс.* Деизм тарафдары

**ДЕ́КА** *и. нем. махс.* Кайбер кыллы музыка уен кораллары корпусының авазларны көчәйтү һәм чагылдыру өчен хезмәт итә торган бер өлеше. *Скрипканың өске декасы*

**ДЕКА-** *гр. кит.* Кушма сүзләрдә «ун» дигәнне белдерә торган беренче кисәк (мәс., *декаграмм, декаметр, декатонна*)

**ДЕКАБРИСТ** *и. рус тар.* 1825 елның 14 декабрендә коралллы фетнә белән тәмамланган революцион-азатлык хәрәкәтендә катнашучы рус дворян инкыйлабчылар вәкиле. *Менә нинди икән син Тубыл – Русия арестантларының пайтәхете – декабристлар, Петрашевичлар интеккән шәһәр.* И.Салахов

**ДЕКАБРЬ** *и. лат.* Календарь елының утыз бер көннән торган уникенче ае. --- *аның [театр куюның] киңрәк төс алып, шәһәр күләмендә беренче мәртәбә ясалуы 1906 елның декабрендә приказчиклар клубы залында булды.* Ф.Бурнаш. --- *1954 елның декабре иде. Чатнап торган суык.* И.Салахов. *Шамил Усманов – шәхес культы корбаны. Аның гомере 1937 елның 3 декабрендә Казанда өзелде.* Татар әдәбияты

**ДЕКА́ДА** *и. гр.* 1) Ун көнлек вакыт аралыгы, айның өчтән бер өлеше. *[Мадрид:] Мәмәтуглы әйтә, әгәр без яхшы забойда булып, норманы тутырып барсак, бер хәл иде. Ә бу «бака»да инде ике декада норма тутыра алмыйбыз*... И.Салахов

2) Нәрсәгә дә булса багышланган ун көнлек вакыт; берәр кампаниягә караган махсус ункөнлек. *Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасының бәйрәм көннәре шаулап узды.* А.Расих. *Мәскәүдә узган декадада билгеләп үтелгән уңышлар турында сөйләп торуның кирәге юк булса кирәк.* А.Расих. *Труппа күтәренке күңел белән олуг бәйрәменә әзерләнә: декада көннәре җитәргә дә күп калмады инде.* Мирас

**ДЕКА́ДАЛЫ** *с.* Декадаларга бүленгән; декадалардан торган

**ДЕКА́ДАЛЫК** *с.* Декадага каралган, бер декада өчен булган, бер декада өчен алынган. *Төп бәла – ныклы, ышанычлы көнлек, декадалык исәп-хисап, контроль җитмәүдә!* Авыл утлары

**ДЕКАДЕНТ** *и. фр. кит.* **1.** Әдәбиятта һәм сәнгатьтә декадентлык тарафдары

**2.** *с. мәгъ.* Декадентлыкка нигезләнгән; декадентчыл. *Декадент әдәбият*

**ДЕКАДЕНТЛЫК** *и. кит.* XIX йөз ахыры – XX йөз башы гуманитар мәдәниятка хас төшенкелек, тормыштан бизү, гаҗизлек һ.б.ш. күренешләрнең гомуми атамасы. *Өченче схема исә Дәрдемәнднең шигъри идеяләрендәге пессимистик һәм фаталистик мотивларны абсолютлаштырудан тора. Шагыйрьгә тагылган «декадентлык» ярлыгы укучыларны озак шомландырып килде.* Н.Хисамов

**ДЕКАДЕНТЧЫЛ** *с. кит.* Декадентлык белән сугарылган, шуңа нигезләнгән

**ДЕКАЛИТР** *и. рус* 1) Ун литр

2) Ун литрга тигез булган сыеклык үлчәү берәмлеге. *Росстаттан алынган мәгълүматларга карганда, былтыр илдә 176 миллион декалитр аракы сатылган, ә җитештерелгән алкогольле эчемлек күләме моннан 50 миллион декалитрга кимрәк.* Ватаным Татарстан

**ДЕКАН** *и. лат.* Югары уку йортларында факультет җитәкчесе, факультетның башында торучы кеше. *Декан безгә сынауларны чирәм җиргә китүчеләр белән бергә тапшырырга рөхсәт итте.* М.Юныс. *Тарих-филология факультетының деканы булып эшләү дәверендә, ул филология фәннәре буенча кандидатлык яклау советы ачуга ирешә.* Т.Галиуллин

**ДЕКАНАТ** *и. нем.* 1) Факультетның декан җитәкчелегендә уку-укыту һәм административ эшләрен алып бара торган идарәсе. *Эшкә урнашу өчен, аттестат кирәк. Деканаттан аттестатымны алып, миңа җибәрә алмассыңмы?* М.Юныс

2) Шушы идарә урнашкан бүлмә. *Деканат ишеге төбендә чират*

**ДЕКАНЛЫК** *и.* Декан вазифасы һәм хезмәте. *Алабуга пединститутында унбиш ел ректор булып эшләгән бу галимнең оештыру, җитәкчелек тәҗрибәсе аңа деканлык вазифаларын башкаруда да бик нык ярдәм итте.* Х.Миңнегулов

**ДЕКАТО́ННА** *и. рус* 1) Ун тонна

2) Декатоннага тигез авырлык үлчәү берәмлеге

**ДЕКА́ЭДР** *и. гр. мат.* Ун яссылык белән чикләнгән геометрик җисем; ункырлык

**ДЕКВАЛИФИКА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Һөнәри белемне, тәҗрибәне, квалификацияне югалту күренеше

**ДЕКЛАМА́ТОР** *и. лат.* Әдәби әсәрләрне бик оста итеп сөйләүче; декламация белән чыгыш ясаучы артист. *Ул кешенең [Мәхмүт Бөдәйлинең] ифрат күңелле җырчы, декламатор, мәзәкче икәнлеген сөйләгәннәре хәтеремдә.* А.Расих

**ДЕКЛАМА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Шигырь һәм проза әсәрләрен яттан сәнгатьле итеп уку осталыгы; әдәби әсәрләрне сәнгатьле уку. *Әстерханда әдәбият кичәсе үткәрелә. Кичәдә Г.Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырен Г.Батыров декламация итеп сөйли.* Идел

2) Халык алдында сәнгатьле итеп уку өчен билгеләнгән матур әдәбият әсәре

3) *күч.* Ясалма күтәренкелек, һавалылык, күперенкелек белән сөйләү гадәте; һавалы, күперенке сөйләм, сүзләр. *Кара син аны, декламация сөйлимени, чәчә генә борчакны.* Җиде юл чатында

**ДЕКЛАМА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Әдәби әсәрләрне сәнгатьле итеп яттан уку. *Декламацияләү өчен барлык шигырьләр дә туры килмәскә мөмкин*

2) *күч.* Пафос, күтәренке тон, күперенкелек, һавалылык белән сөйләү

**ДЕКЛАРАТИВ** *с. кит.* 1) Декларация (*1 мәгъ.*) формасында булган, тантаналы. --- *поэзия декларатив лозунглар, кешедә билгеле бер хис тудыру максатында әйтелгән лирик-эмоциональ чакырулар белән генә чикләнми, әлбәттә.* Казан утлары

2) *күч.* Гомуми сүзләрдән генә торган, коры вәгазь, акыл сатуга корылган, шундый формадагы. *Декларатив телдә сөйләнгән доклад*

**ДЕКЛАРАТИВЛЫК** *и.* 1) Декларациягә хас тантаналылык, күргәзмәлелек

2) Буш сүздә генә калу, игълан итү, белдерү белән чикләнгән булу үзлеге. *Әйткәнебезчә, бу, беренчедән, Конституцион закон, шунлыктан ул декларативлыктан котыла алмый.* Р.Миңнуллин. *Заманында сәхнәдә шактый көчәйгән схемачылык һәм ясалмалык, декларативлык һәм догматизмны кысрыклап чыгаруда драматург Т.Миңнуллин үзеннән зур өлеш кертә.* А.Әхмәдуллин

**ДЕКЛАРАЦИОН** *с.* Декларация (*1 мәгъ.*) формасында булган. --- *шуны [карарны] рәсми гәзитәләрендә «Учредительное собрание» әгъзаларының декларационы (декларациясе) тарызында (рәвешендә) игълан иттеләр.* Г.Исхакый

**ДЕКЛАРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Халыкара оешмалар, партия, дәүләт һ.б.ш. исеменнән нинди дә булса тәгълиматларны, принципларны рәсми рәвештә игълан итү; шул тәгълимат, принципларны үз эченә алган, шуны яктырткан документ. *Татарстан мөстәкыйльлегенең язмышы Рәсәй белән нинди мөнәсәбәтләрдә булуына нык бәйләнгән. Шуңа күрә дә, дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителгән көннән башлап, сәяси көрәшнең үзәгендә нәкъ менә шушы мәсьәлә тора.* К.Фәсахов. *1990 елның 30 августында дәүләт суверенлыгы турында Декларация игълан ителде.* Мирас

2) Аерым бер кешенең яки оешманың шундый белдерү, игълан белән ясаган чыгышы

3) *махс.* Нинди дә булса кирәкле, мөһим мәгълүматларны хәбәр итә торган кайбер рәсми документларның исеме

**ДЕКЛАРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Тантаналы яки рәсми рәвештә берәр эшчәнлек программасы, карашлар, тотылган мәсләк һ.б.ш. турында игълан итү, белдерү. *Әсәрнең традицион нәсыйхәтчелек калыбы хәрәкәтнең конфликтсыз, тыныч юлга салынганлыгын декларацияли.* М.Гайнетдин

2) Таможня, салым инспекциясе кебек рәсми органнарга тиешле формада тиешле мәгълүмат тапшыру. *Шуңа да бүген чиновникларның керемен генә түгел, ә, бәлки, чыгымнарын да декларацияләү турында сүз бара торгандыр.* Татарстан яшьләре

**Декларацияли башлау** Декларацияләргә керешү. *Прокурор киләсе елның 1 гыйнварыннан муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәрен генә түгел, ә, бәлки, чыгымнарын да декларацияли башлаячакларын җиткерде.* Әлмәт таңнары

**Декларацияләп бетерү** 1) Декларация эшен төгәлләү

2) Барысын да, тулысынча декларацияләү

**ДЕКОЛОНИЗА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Деколонизацияләү, деколонизацияләнү эше һәм чаралары. *Озакка сузылган деколонизация*

**ДЕКОЛОНИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Колония булудан азат итү, колониялелектән коткару

**ДЕКОЛЬТЕ** *и. фр.* **1.** 1) Хатын-кыз күлмәгендә: муен, иңнәрне, арка-күкрәкнең өске өлешен ачык калдырылрлык итеп уелган киң уем, изү. *Нәкыя гәүдәсенә сыланып торган куе шәмәхә күлмәк кигән, --- күкрәк турындагы декольтесы аның муенына һәм иңбашларына килештереп, таман гына уелган иде.* Ф.Садриев

2) Шул ачык калган өлеш

**2.** *с. мәгъ.* Декольте итеп тегелгән. *Тумбочка яныннан узышлый, декольте күлмәктән рәсемгә төшкән мәшһүр таныш артистка, сихерле зур күзләре белән елмаеп, кичен концертка чакыруын исенә төшерә.* Г.Бәширов

**ДЕКОР** I *и. лат.* Архитектурада бизәү элементлары җыелмасы

**ДЕКОР** II *и. лат.* Гектарның уннан беренә тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Әгәр гадәти бодай чәчелгән басулардан декорына (декор гектарның уннан бер өлешен тәшкил итә) 250–300 килограмм уңыш алынса, «Тодора» бер декордан 900 килограмм уңыш җыеп алырга мөмкинлек бирә.* Татар мөселман календаре

**ДЕКОРАТИВ** *с.* 1) Нәрсәне дә булса бизәү, матурлау өчен хезмәт итә торган, шуның өчен билгеләнгән. *Парк, сквер, аллеялардагы элек ямь-яшел булып утырган агачлар, декоратив куаклар --- корып төшкән, кибеп беткән.* Ә.Салах. *Гөлчәчәк хәзер декоратив үсемлек һәм хуш исле май – роза мае чыгару максаты белән үстерелә.* Г.Насыйров. *Без өй тирәләренә, урамнарга декоратив агачлар һәм чәчәкләр утыртсак, алар, безгә үзләренең рәхмәтләрен белдергәндәй, төрле төстәге матур чәчәкләре белән, елмаеп, тирә-якка ямь, хуш ис тараталар.* Кызыклы география

2) Декорациягә караган, шуңа мөнәсәбәтле

3) *күч.* Тыштан гына матур булып күренгән, артык «ялтыравыклы», ясалма. *Ә ике яклы килешүләр бары тик үзенә күрә бер декоратив өстәмәгә генә әверелгәннәр, һәм алар закон нигезе ныклыгына ия түгелләр.* Татарстан

**ДЕКОРАТИВЛЫК** *и.* 1) Берәр предметның бизәү, матурлык бирү әйбере буларак кулланылу мөмкинлеге, бизи алу үзенчәлеге. *Сурәт төшерү һәм чынбарлыкны чагылдыру Урта гасырлар сәнгать аңы кысаларында бара, аның тасвирлау теленең аерма-*

*лы үзенчәлеге булып, мөселман сәнгатенең төп принциплары – орнаментальлек һәм шартлы декоративлык тора.* Г.Вәлиева-Сөләйманова

2) Нәрсәнеңдер чын файдасы, әһәмияте булмау, бушлык, ясалмалылык. *Ялганнан, декоративлыктан, милли гламурдан куркам.* Сәхнә

**ДЕКОРА́ТОР** *и. фр.* 1) Декорацияләр ясаучы рәссам

2) Декорация җиһазларын урнаштыручы сәхнә эшчесе

3) *махс.* Бина, торак һ.б.ш. бизәлеше, җиһазландырылышы буенча белгеч

**ДЕКОРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Спектакльләр өчен сәхнә бизәлеше

2) Нәрсәнең дә булса җитешсезлеген, кимчелеген каплау яки яшерү өчен, аны тышкы яктан бизәү

**ДЕКОРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) *иск.* Сәхнәгә декорацияләр кую

2) Матурлау, бизәү

**Декорацияләп бетерү** Декорация эшен төгәлләү

**Декорацияләп тору** Гел, даими рәвештә яки хәзерге моментта декорацияләү

**Декорацияләп чыгу** Барысын да, баштан ахыргача декорацияләү

**Декорацияли башлау** Декорацияләргә керешү

**Декорацияли төшү** Бераз декорацияләү

**ДЕКОРА́ЦИЯЛӘҮЧЕ** *и.* Декорация эшләрен башкаручы, декоратор

**ДЕКОРА́ЦИЯЛЕ** *с.* Декорацияләре булган. *Мәсәлән, Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым» комедиясен куйганда, мин әткәйдән ширмалар эшләтеп, аларга обойлар беркетеп, «чын декорацияле спектакль куеп», бөтен авылны шаккатырдым.* Р.Батулла. *Иң «авырта» торган җир – авыр сүтелә торган күп һәм җәйсыз декорацияле спектакльләр булганда, вакытка сыеша алмау.* Шәһри Казан

**ДЕКРЕТ** *и. лат.* 1) Югары органнарның нинди дә булса мәсьәлә, сорау буенча, закон көченә ия булган карары; указ, закон. *Декрет, мандат белән «шәп кеше» булырга тырышудан кайтырга кирәк.* Социалистик Татарстан

2) *сөйл. гадәттә кыек форм. к.* **декрет ялы**. *Әле яңарак кына беренче баласын табып декреттан килгән Алсу да, яшь кенәдән баш-аягы белән дингә чумган Хәдичә дә – һәрберсе үзенчә матур, үзенчә соклангыч иде.* М.Кәбиров

**ДЕКРЕТЛАШТЫРУ** *ф.* Нәрсәне дә булса декрет белән, декрет ярдәмендә законлаштыру, тормышка ашыру

**ДЕКРЕ́Т ЯЛЫ** *и.* Хатыннарга бала тудыру алдыннан һәм тудырганнан соң бирелә торган, өлешчә түләүле, озын сроклы ял. *Баланы үстер, өйдә эшлә, шуның өчен сиңа декрет ялы бирелгән.* Ф.Садриев

**ДЕКСТРИН** *и. фр.* Сәнәгатьнең төрле тармакларында кулланыла торган, крахмалдан алынган, шуннан җитештерелгән, ябыштыра торган җилемсыман матдә. *Бик куе декстрин*

**ДЕЛЕГАТ** *и. лат.* Нинди дә булса оешмадан, учреждениедән, төркемнән һ.б.ш. сайлап куелган яки билгеләнгән вәкил. *Анда [телеграммада] Бөтенроссия мөселман хәрбиләренең съезды уздырылу һәм шуңарга делегатлар сайлау зарурлыгы хәбәр ителә.* Р.Мөхәммәдиев

**ДЕЛЕГА́ТКА** *и. рус* Хатын-кыз делегат. *Укытучы Зәйтүнә Мәүлетова җитәкчелегендә делегаткалар пункты башта 16 кешедән оештырылган иде. Менә алар – Шәле авылында беренче хатын-кыз делегаткалар.* А.Расих

**ДЕЛЕГАТЛЫК** *и.* Делегат вәкаләте яки вазифасы. *Делегатлык мандаты*

**ДЕЛЕГА́ЦИЯ** *и. лат.* Нинди дә булса оешма, учреждение, дәүләт һ.б.ш. вәкаләтен чагылдырган делегатлар төркеме. *[Рәис] Озакламый беренче секретарь да булып алды, яшьләр делегациясен җитәкләп, чит илләрдә дә йөреп кайтты.* Ф.Дунай

**ДЕЛИКАТЕС** *и. фр. кит.* 1) Бик нәзакәтле, тәмле, затлы ризык. *[Әхәт:] Анысында да мал! Деликатес! Бер банка кара икра.* А.Гыйләҗев. *Диңгез аръягыннан кайткан деликатеслар янына куяр өчен каклаган каз, тутырган тавык, ат казылыгы ---, кыскасы, татар кухнясының чиксез мөмкинлекләрен эшкә җигәрдәй уңган аш пешерүчеләр, бер-берсен уздырырга тырышып, кул кыздырадыр.* М.Галиев

2) Гомумән, нинди дә булса бик тансык, ымсындырып торган ризык. *Йомшак итеп артларына түгел, ник шул кисәү агачы --- белән бәргәләмисең – болар, әнә шул деликатесны эләктермичә, мич буеннан китмәячәкләр.* М.Мәһдиев

**ДЕЛИКАТЛЫ** *с. сөйл.* Тәрбияле, кешеләр белән йомшак мөгамәләле; нәзакәтле. *Кеше арасында деликатлы итеп сөйләшә белә инде ул.* Татар иле

**ДЕЛИКАТЛЫК** *и.* Йомшак мөгамәләлек, игътибарлылык, түбәнчелеклек, нәзакәтлелек һәм ягымлылык сыйфатлары. *Ул беркайчан да кешенең кимчелеген йөзенә бәреп әйтмәячәк, деликатлылыгы комачаулый*

**ДЕ́ЛО** *и. рус махс.* 1) Эш кәгазьләрен, документларны һ.б.ш. салып, теркәп бара торган папка. *Партком секретаре, кулындагы делоны ачып, Ирекнең партиягә алуны сорап язган гаризасын укыгач, аның анкетасы белән таныштырды...* Ф.Садриев

2) Папкага салып теркәлгән эш кәгазьләре, документлар һ.б.ш. җыелмасы. *Прокурор алдында яткан чуар тышлы «дело»ның тәгаен үзенеке икәнен белгәч, аның кикриге шиңде, кызуы шактый сүрелде.* А.Гыйләҗев

**ДЕЛОПРОИЗВОДИ́ТЕЛЬ** *и. рус* Канцелярия эшен, кәгазьләрен, документларын алып бару, барлау һ.б.ш. белән шөгыльләнүче дәүләт хезмәткәре. *Салихов бер кооперативта делопроизводитель булып хезмәт итә икән...* Г.Газиз

**ДЕ́ЛЬТА** I *и. гр.* Елгадагы утырма катламнардан барлыкка килгән утырым; дуенлы тигезлеге һәм күпсанлы ермаклары, уентыклары булган елга култыгы. *Җир шарында иң зур елга дельтасы – Ганг һәм Брахмапутра елгаларының гомуми дельтасы.* Кызыклы география

**ДЕ́ЛЬТА** II *и. гр.* Грек алфавитындагы дүртенче хәрефнең исеме (*язылышы буенча өчпочмак формасында булган δελτα (Δ)*)

**ДЕЛЬТА́ НУРЛАР** *и. физ.* Корылган атом кисәкчекләре җисем аша

үткәндә, атомнардан бәреп чыгарыла торган электроннар

**ДЕЛЬТАПЛАН** *и. гр.-лат.* Очучының гәүдә торышы үзгәрүе белән идарә ителә торган, өчпочмак формасында булган киң, яссы өслекле, двигательсез очкыч аппарат (грек хәрефе δελτα (Δ) һәм латинча *planum* – «яссылык» сүзләреннән ясалган). *Данлыклы Кырлай мәктәбендә --- укыганда да, күпләр белән аралашмый гына, зур адымнар белән, очарга әзерләнгән дельтаплан кебек йөрде Булат.* Акчарлак

**ДЕЛЬТАПЛАНЕРИЗМ** *и. гр.-фр.* Дельтаплан спорты, дельтапланда очу шөгыле. *Монда да Марс ага, зәңгәр күктән аерыласы килмичә, ДОСААФның Казакстан Үзәк Комитетында эшли, яшьләргә дельтапланеризм серләренә төшенергә ихластан булыша...* Гасырлар авазы. *Ушу, каратэ, джиу джитсу, дельтапланеризм, акробатик гимнастика, спорт биюләре, софтбол, регби, сквош, боулинг, җәядән ату, пауэрлифтинг, бильярд, кыяга менү, дуатлон, ярышта юнәлеш алу кебек спорт төрләрен үз эченә ала уеннар.* Кызыл таң

**ДЕЛЬТАПЛАНЧЫ** *и.* Дельтапланда очу белән шөгыльләнүче кеше. *Аларны дельтапланчылар күптән үз иткән.* Кызыл таң

**ДЕЛЬФИН** *и. гр. зоол.* Китлар отрядына караган дельфиннар семьялыгыннан, сыртлары кара, куе көрән яки соры төстә булган, орчык шикелле сылу гәүдәләренең озынлыгы 4 метрга, авырлыклары 300 килога кадәр җитә торган, ишетү сәләтләре бик югары булган имезүче диңгез хайваны. *Дельфинның 96 теше бар, шуңа да карамастан, ризыкны ул чәйнәми йота.* Татар мөселман халык календаре. *Фьордларда күп төрле тюленьнәр, моржлар, тешле китлар, ак дельфиннар тереклек итә.* Кызыклы география

**ДЕЛЬФИНА́РИЙ** *и. гр.* Тамашачыларга өйрәтелгән дельфиннар катнашындагы шоу күрсәтү өчен махсус бассейн һәм шул тамаша үзе. *Шәһәребездә татар, рус драма, курчак театрлары, дельфинарий, орган залы бар.* Шәһри Чаллы

**ДЕЛЬФИНА́РИУМ** *и. гр. к.* **дельфинарий**

**ДЕЛЬФИНСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Китсыманнар отрядына караган имезүче су хайваннарының бер семьялыгы

**ДЕЛЯ́НКА** *и. рус* Урманның киселергә билгеләнгән өлеше; диләнке. *Кешеләргә утын өчен алган делянканың да яртысы гына киселгән килеш, чөнки районның барлык транспорты – дәүләткә ашлык ташуда, утынны алып кайтырга мөмкинлек юк иде.* Ф.Садриев

**ДЕМАГОГ** *и. гр. кит.* Үз эшчәнлегендә демагогиягә таянып эш итүче, демагогиядән файдаланучы кеше. *– Пацифист булу өстенә --- демагог та икәнсең син, Сабиров... – Капитан, теше сызлагандай, йөзен чытты...* Ф.Латыйфи. *[Мифтахов:] Алдыйсың, демагог, кулга алыгыз үзен.* Н.Исәнбәт

**ДЕМАГО́ГИК** *с. к.* **демагогияле.** *Без күтәргән мәсьәлә принципиаль әһәмияткә ия. Бу турыда барысы да көн кебек ачык, бернинди аклашу һәм демагогик фәлсәфә сатулар була алмый.* А.Расих

**ДЕМАГО́ГИЯ** *и. гр.* Нинди дә булса максатларга ирешү өчен ялагайлану, икейөзләнү, ялган вәгъдәләр бирү алымы һәм чаралары. *Соң, шулай булгач, «яшьләрне басмыйлар» дигән уйдырманың демагогиядән башка нинди мөндәриҗәсе кала?* Ф.Бурнаш

**ДЕМАГО́ГИЯЛЕ** *с.* Демагогиягә нигезләнгән, демагогия белән сугарылган

**ДЕМАГО́ГИЯЧЕ** *и. к.* **демагог**

**ДЕМАГОГЛАНУ** *ф.* Демагогия белән шөгыльләнү; демагогка әйләнү

**ДЕМАГОГЛА́РЧА** *рәв.* Демагоглар кебек, демагогиягә нигезләнеп

**ДЕМАГОГЛЫК** *и.* Демагог кешегә, демагогка, демагогиягә хас сыйфатлар. *Инде шул чагында ук, конституцион ирекләр һәм гарантлар турында сөйләшкәндә, демагоглыкта шомарып-каешланып беткән [Жорик] ---.* Р.Мирхәйдәров

**ДЕМАРКАЦИОН** *с.* Демаркациягә мөнәсәбәтле; демаркацияләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Демаркацион чик*

**ДЕМАРКА́ЦИЯ** *и. фр.* Күрше дәүләтләр арасындагы, махсус билгеләр белән күрсәтелгән чик сызыгы. *Ышанычлы демаркация*

**ДЕМАРКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Ике яки берничә күрше дәүләт арасында чик сызыгы үткәреп, аны махсус тамга, билге белән күрсәтү

**ДЕМАРШ** *и. фр. махс.* Нинди дә булса дәүләт хөкүмәтенә адресланган дипломатик чыгыш. --- *Төркиянең бу планына каршы дөнья сәяси мәйданында кампанияләр, коалицияләр, демаршлар оештыруларга сәбәп булулары бар.* М.Гайнетдинов

**ДЕМИКОТОН** *и. фр.* XIX гасыр башында кулланышта булган калын кәгазь тукыма. *Калын зәңгәр демикотон белән тышланган китап*

**ДЕМИЛИТАРИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* Дәүләтне, аның аерым бер территориясен, билгеле хәрби объектны, икътисадны һ.б.ш. коралсызландыру, хәрби объектлардан азат итү, хәрби максатлардан башка максатларга юнәлдерү

**ДЕМИЛИТАРИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Демилитаризация чаралары үткәрү

**Демилитаризацияләп бетерү** Демилитаризация эшен төгәлләү

**Демилитаризацияли башлау** Демилитаризация эшенә керешү

**ДЕМИСЕЗОН** *с. сөйл.* Көз һәм яз кию өчен билгеләнгән, шуңа яраклы булган. *Мин мәскәүлеләрнең атна буе миңа күтәрелеп тә карамаганнарының сәбәбен белдем: сәбәбе минем гадәти демисезон пальто белән ике йөз сиксән сумлык ондатра бүректә түгел (Мәскәү алай киенми), бәлки, кулымда «Кубик Рубика» булмауда икән.* М.Мәһдиев. *Стаин шулай ук кара, ике капламлы, җилкәләренә үк менгән биек якалы, пинжәкнеке шикелле тышкы күкрәк кесәле яңа демисезон пәлтә киеп, көязләнеп йөри* ---. Р.Мирхәйдәров

**ДЕМОБИЛИЗАЦИОН** *с.* Демобилизация белән бәйле, демобилизациягә мөнәсәбәтле. *Демобилизацион чор*

**ДЕМОБИЛИЗА́ЦИЯ** *и. фр.* Демобилизацияләү эше. *Көзге демобилизация белән [авылга] Мисхәт кайтып төште.* М.Мәһдиев. *[Полковник:] Вәгъдә биреп әйтәм, бу задание*

*үтәлгәннән соң, сезне туган илгә озатачакбыз. Кыскасы, демобилизация!* Ф.Латыйфи. *Без бит, чибәр туташ, армиядән кайткан кешеләр. Демобилизация безне һөнәрсезгә әйләндерде.* М.Юныс

**ДЕМОБИЛИЗА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Демобилизациягә тартылу. *Ә яшьрәге – Тугаев, демобилизацияләнгән офицер, тау институтында укый.* Х.Камалов. *1945 елның 30 сентябрендә Совет Армиясе капитаны И.Г.Сөләйманов, авыруы аркасында, запаска демобилизацияләнә.* Гасырлар авазы. *Демобилизацияләнгәннән соң, ул Оренбургның ГубОНО мөдире һәм «Юксыллар сүзе» газетасының редакторы була.* Фән һәм тел

**Демобилизацияләнеп бетү** Тулысынча, барысы да демобилизацияләнү

**ДЕМОБИЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Хәрби хезмәт срогы тулганнарны яки, сугыш беткәннән соң, кораллы көчләрдә хезмәт итүчеләрне өйләренә кайтару. *Мин шул көнне үк, демобилизацияләүне сорап, рапорт яздым.* М.Юныс

2) Кораллы көчләрне һәм икътисадның барлык тармакларын хәрби халәттән тынычлык халәтенә күчерү. *Армияне демобилизацияләү. Сәнәгатьне демобилизацияләү*

**Демобилизацияләп бетерү** Тәмам, гомумән демобилизацияләү яки демобилизацияләүне тәмамлау. *Хәрбиләрнең барысын да демобилизацияләп бетерү берничә айга сузылачак*

**Демобилизацияләп тору** Даими демобилизацияләү яки әледән-әле демобилизацияләү. *Хезмәт итү срогы тулган һәр солдатны демобилизацияләп торалар*

**Демобилизацияли бару** Һәрберсен бер-бер артлы демобилизацияләү

**Демобилизацияли башлау** Демобилизацияләүгә керешү. *Сугыш бетәргә берничә ай кала, хәрбиләрне демобилизацияли башладылар*

**ДЕМО́ГРАФ** *и. гр.* Демография белгече. *Демографлар бүгенге көнгә безнең ил буенча гына сигез миллион кешегә ялгышканнар.* А.Гыйләҗев. *Демографлар исәпләп чыгарган фактларга тукталыйк: соңгы вакытта ир-атларның байтагы үзеннән олырак хатынга өйләнә.* Юлдаш

**ДЕМОГРА́ФИК** *с.* Демографиягә караган, демографиягә мөнәсәбәтле. *Татарларның демографик күрсәткечләре ничек һәм кая таба бара дигән сорауга җавап бирү өчен, 1979 һәм 1989 елгы сан алу мәгълүматларына мөрәҗәгать итик.* М.Зәкиев. *Халык санын алу – ул илдәге демографик хәлнең чын торышын белү, --- ил халкын тәшкил итүне аерым кешеләрнең яшен, белемен, һөнәрен исәпкә алып планлаштыру өчен эшләнә.* Сөембикә

**ДЕМОГРА́ФИЯ** *и. гр. махс.* Иҗтимагый-тарихи шартларда халык санын, составын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, андагы халыкның бер урыннан икенче урынга күченүен һ.б.ш. өйрәнә торган фән, статистиканың бер бүлеге. *Демография күрсәткечләре*

**ДЕМОКРАТ** *и. гр.* **1.** 1) Демократия яклы кеше. *Хәтта караңгы, Романовлар династиясенең иң ямьсез елларында да алар демократ һәм гуманист булып калдылар.* А.Расих

2) Демократик партия әгъзасы. *Аның [Валерия] тирәсендә бер демократ бөтерелеп йөрде, чехмы, полякмы.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* Демократия яклы яки демократик партия әгъзасы булган

**ДЕМОКРАТИЗМ** *и. гр. кит.* Демократия (*1, 2 мәгъ.*) кануннарына нигезләнгәнлек; демократияне тормышка ашыручанлык. --- *әсәрләр форма демократизмы белән генә түгел, теленең халыкчанлыгы белән дә киң катлау укучыга йөз тоталар.* М.Гайнетдинов. *Идел буе регионында һәрчак өстенлек иткән тел-стиль регионализмы, шигырь фактурасы демократизмы --- авторны әрнү-ярсу, тетрәнүенә җиткергән ---.* М.Әмин

**ДЕМОКРА́ТИК** *с.* Демократия принципларына нигезләнгән. *Федератив дәүләттә, әгәр дә ул чын мәгънәсендә демократик федерация булса, сәяси тормышның төп үзәге милли парламентларда була.* К.Фәсахов. *Кемдер әйткән – онытканмын исемен дә, Фәкать шомлы сәер сүзе: «Бик дәү демократик империя җитәчәк, дип, үз башына үзе...».* Л.Шагыйрьҗан

2) Демократиягә мөнәсәбәтле, аңа бәйләнешле, шуңа караган. *Ул [«Кыйссаи Йосыф»] бер үк вакытта традицион мифологик сюжет мөмкинлек биргән кадәр җирле фольклор-эпос элементлары белән дә баетылып, табигый-реалистик һәм демократик рухлы мотивировкалар белән дә сугарылган.* Ф.Фәсиев

3) Демократия яклы булган. *Элеккеге «демократик» уеннар: куыш уйнау --- «шәткәли» (цифрлар язылган озынча шакмакны калак белән сугып уйнау) уйнаулар гомумән бетте.* М.Мәһдиев

**ДЕМОКРА́ТИЯ** *и. гр.* 1) Югары хакимият халык кулында булырга тиеш дип тануга нигезләнгән, аны хөкүмәт эшләрен алып баруда катнашырга хокуклы дип тапкан, җитәрлек дәрәҗәдә ирек һәм хокук белән тәэмин иткән сәяси оештыру формасы. *Ә бездә – демократия. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев уйлап тапкан «Без булдырабыз!» шигарен океан артында теләсә кем әйтә алмый.* Ватаным Татарстан

2) Нинди дә булса күмәк эшне оештыруда коллективтагы бөтен әгъзаларның да тигез, актив катнашу мөмкинлеге булдырылган җитәкчелек итү формасы

3) *җый. и.* Демократлар һәм демократия яклы кешеләр; халыкның алдынгы катлавы. *Демократия канаты астында булу*

**ДЕМОКРА́ТИЯЛӘШТЕРҮ** *ф.* Демократик башлангыч урнаштыру, хөкүмәт, җәмгыять, берләшмә һ.б.ш. демократик нигезгә яраклаштырып үзгәртү. *Чын федерализм – демократиянең территориаль формасы, ансыз сәяси структураларны демократияләштерү мөмкин түгел.* Татарстан. *Җәмгыять тормышының һәр ягын демократияләштерү бара, милеккә карата мөнәсәбәтләр үзгәрә...* Мирас. *Монда белем бирүне демократияләштерү, дифференцияләштерү, аны гуманлы итү, балаларның һәм яшьләрнең шәхси кызыксынуларын, сәләтләрен исәпкә алып укытуны интегральләштерү әһәмиятле.* Мәгариф

**Демократияләштерә бару** Демократик нигездә үзгәртүне акрынлап арттыру, эзлекле рәвештә демократияләштерүне көчәйтү. *Сайлау системасын елдан-ел демократияләштерә баралар*

**Демократияләштерә башлау** Демократияләштерергә керешү

**Демократияләштерә төшү** Бераз демократияләштерү

**Демократияләштереп бетерү** Тулысынча демократик нигездә үзгәртү, демократияләштерүне тәмамлау. *Массакүләм информация чараларын тулысынча демократияләштереп бетерү*

**Демократияләштереп тору** Әледән-әле яки берөзлексез, бертуктаусыз демократияләштерү. *Коллектив эшен җитәкче демократияләштереп торырга тиеш*

**ДЕМОКРА́ТИЯЛӘШҮ** *ф.* 1) Демократик нигезгә яраклашып үзгәрү; демократик төс алу. *Карашлар демократияләшү*

2) Демократия тарафдары булып җитешү

**Демократияләшә бару** Акрынлап демократияләшү, аз гына күләмдә булса да демократик төс алу. *Күп кенә партияләрнең лозунглары демократияләшә бара*

**Демократияләшеп бетү** Тулысынча демократияләшү. *Илдә система үзгәрү караш-идеяләрнең демократияләшеп бетүенә китерде*

**Демократияләшеп житү** Тәмам, тулысынча демократияләшү. *Яшәеш кануннары демократияләшеп җитте диярлек*

**ДЕМОКРА́ТИЯЛЕ** *с. к.* **демократик.** *Гомеребез буе бердәнбер кандидат арасыннан бер депутат «сайлап» яшәсәк тә, ул системаны демократияле дип мактандык.* Казан утлары. *«Демократияле Россия» дип йөртелгән мең еллык дәүләтнең Конституциясенә түбәндәгечә язып куярга кирәк: «Россиянең кораллы көчләрендә хезмәт итү – һәр гражданинның изге бурычы».* Ватаным Татарстан. *Русия Европаның демократияле бер кисәге булмакчы.* Татарстан яшьләре

**ДЕМОКРА́ТИЯЛЕЛЕК** *и. к.* **демократизм**

**ДЕМОКРАТЛАШТЫРУ** *ф.* Нәрсәнең дә булса демократияләшүен тормышка ашыру, демократияләштерү. *Аларда [Көнбатыш Европа, Төньяк Америка һәм кайбер Азия илләрендә] XX гасырның икенче яртысыннан башланган капиталны демократлаштыру сәясәте һәм тәҗрибәсе аркасында, «социалистик» революцияләр һөҗүме тукталып калды яки алар көн тәртибеннән бөтенләй алып ташланды.* Татарстан

**Демократлаштыра бару** Демократлашуны акрынлап арттыру. *Җәмгыятьне демократлаштыра бару торган саен тирәнәя төшә*

**Демократлаштыра башлау** Демократлаштырырга тотыну

**Демократлаштыра төшү** Бераз демократлаштыру

**Демократлаштырып бетерү** Демократлаштыруны гомумән тәмамлау, тулысынча демократлаштыру

**Демократлаштырып тору** Даими демократлаштыру. *Яшь буынны тәрбияләү принципларын демократлаштырып тору көнүзәк мәсьәләгә әйләнде*

**ДЕМОКРАТЛАШУ** *ф.* Демократка әйләнү. *Җәмгыятебез демократлаша*

**ДЕМОКРАТЛЫК** *и. к.* **демократизм.** *Тукайның дөньяга карашы, Тукайның гражданлык сыйфатлары, Тукайның демократлыгы һәм, ниһаять, Тукайның бөек рус әдәбиятыннан һәрдаим өйрәнүе турында шактый гына этрафлы әдәби-гыйльми хезмәтләр бар бездә.* Ф.Хөсни

**ДЕМОНСТРАНТ** *и. рус* Демонстрациядә (*1 мәгъ.*) катнашучы, демонстрацияче. --- *Мәскәүдә, Ленинградта, тагын нindидер шәһәрләрдә, кызыл байраклар, портретлар, транспарантлар күтәреп, ташкын булып, демонстрантлар узды.* Н.Фәттах. *Дәүләт Советының чираттагы сессиясенә килгәндә, кулларына һәртөрле язулар язылган кәгазь лозунглар тотып торучы демонстрантлар янына тукталдым.* Т.Миңнуллин

**ДЕМОНСТРАТИВ** *с. кит.* **1.** 1) Нәрсә белән дә булса килешмәүне, кемгә дә булса тискәре мөнәсәбәттә булуны белдергән, махсус ясалган яки эшләнгән. *Демонстратив адым*

2) Күрсәтү өчен, тамаша өчен оештырылган; күрсәтмә. *Демонстратив чаралар*

3) Демонстрациягә (*3 мәгъ.*) нигезләнгән, игътибарны читкә юнәлтү максатыннан эшләнгән. *Демонстратив һөҗүм*

**2.** *рәв. мәгъ.* Махсус, юри; ачыктан-ачык. *Ул [Юрок], ишекне демонстратив бу яктан бикләп, ачкычын күтәрде.* Р.Батулла

**ДЕМОНСТРАЦИОН** *с.* 1) Демонстрация (*2 мәгъ.*) өчен билгеләнгән, демонстрация өчен хезмәт итә торган. *Демонстрацион зал. Реактив самолётның демонстрацион очышы*

2) Демонстрация (*3 мәгъ.*) рәвешендәге, характерындагы, шуңа мөнәсәбәтле. *Демонстрацион манёвр*

**ДЕМОНСТРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса иҗтимагый-сәяси теләкләрне, таләпләрне белдерү максатында оештырылган массакүләм хәрәкәт, чыгыш. *Бүтән елларны демонстрациягә барганда-кайтканда, укучылар безнең урамнан уза торганнар иде.* Э.Касыймов. *Мондагы мәйданда, гадәттә, митинглар, тантаналы демонстрацияләр уздырыла, ул шактый зур.* А.Расих

2) Тамашачылар алдындагы чыгыш; халыкка җиткерүне максат иткән тамаша. *Яңа модельләр (кием турында) демонстрациясе. Физик тәҗрибәләр демонстрациясе. Мөселман фильмнары демонстрациясе*

3) *хәрби* Төп һөҗүм булырга тиеш урыннан дошманның игътибарын читкә юнәлтү максатында эшләнгән хәрәкәт, чара, манёвр. *Артиллерия уты демонстрация генә, дошманның игътибарын һава һөҗүменнән читкә юнәлтү алымы*

4) *күч. кит.* Хисләрне, теләк-омтылышларны ачыктан-ачык белдерү күренеше; билгеле бер мөнәсәбәт күрсәткече. *Сәгыйть Рәмиев, үзенең «Яшә, Зөбәйдә»се белән иске тормыш, тарихи җәһаләткә дуамал булса да һөҗүм ясап, Печән базарының кәефенә зур «ихтирамсызлык» күрсәтеп демон-*

*страция ясады.* Ф.Бурнаш. --- *халык, су агымы төсле, бакчаның бер башыннан икенче башына бер дә өзлексез агып тора вә бу чем-чуар, аллы-гөлле агынты ---. Ул яшь халыктагы шатлык, ачыклык, ул кычкырып-кычкырып сөйләшү, көлү --- – күңелле күренеш, күңелдәге өметсезлеккә каршы бер демонстрация!* Ш.Камал

**ДЕМОНСТРА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **демонстрацияләү.** *Бирелдә ел саен юл хуҗалыгы һәм транспорт өлкәсенә кагылышлы фәнни-техник казанышлар демонстрацияләнә ---.* Шәһри Казан. *Конкурстан тыш, француз классикасы үрнәге һәм француз телендәге ике Канада фильмы да демонстрацияләнәчәк.* Ватаным Татарстан

**Демонстрацияләнеп бетү** Тулысынча, барысы да демонстрацияләнү

**Демонстрацияләнеп тору** Әледәнәле, еш демонстрацияләнү. *Казанда мөселман кинолары ел да демонстрацияләнеп тора*

**ДЕМОНСТРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Демонстрация (*2 мәгъ.*) ясау, нәрсәне дә булса тамашачылар алдында күрсәтү, күзәтүгә тәкъдим итү. *Фабриканың уңышларын, казанышларын демонстрацияләү анда җитештерелгән әйберләргә сорауны арттырды*

**Демонстрацияләп бару** Бер-бер артлы демонстрацияләү

**Демонстрацияләп бетерү** Барысын да демонстрацияләү; нәрсәне дә булса демонстрацияләү эшен ахырына җиткерү. *Барлык яңа күлмәк модельләрен демонстрацияләп бетергәч, аларны сату оештырылды*

**Демонстрацияләп тору** Даими рәвештә, әледән-әле демонстрацияләү

**ДЕМОНСТРА́ЦИЯЛӘҮЧЕ** *и.* Нәрсәне дә булса демонстрацияләү белән шөгыльләнүче кеше. *Киемнәрне демонстрацияләүче итеп, теләсә кемне алмыйлар, аның өчен махсус модельләр курсын үтәргә кирәк.* Татарстан яшьләре

**ДЕМОНСТРА́ЦИЯЧЕ** *и. к.* **демонстрант.** *Демонстрациячеләр төрле лозунглар белән чыккан иде*

**ДЕМОНТАЖ** *и. фр. тех.* Нинди дә булса корылма, җиһазны сүтү яки урнаштырылган урыныннан алу эше (ремонт, күчерү, сүтү һ.б.ш. шундый эшләр вакытында). *Үзем киту белән, Шәми йөгереп килә дә микрофонга пышылдый башлый: – Тимерҗан! Ул, – ди Шәми, минем якка ымлап, – хәйләләп, сезгә демонтаж ясарга йөри. – Нәр-рсә ул де-мон-таж? – Сүтеп ташлау...* Р.Батулла

**ДЕМОНТАЖЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **демонтажлау**. *Әлеге участокта трамвай юллары тулысынча демонтажлана.* Мәдәни җомга. *Мәскәү районы буенча уздырылган рейд нәтиҗәсендә, дүрт киоск демонтажланды.* Кәеф ничек?

**Демонтажланып бетү** Тулысынча, барысы да демонтажлану

**Демонтажланып тору** Хәзерге моментта демонтажлану

**ДЕМОНТАЖЛА́У** *ф.* Төзеп, көйләп, корып куйган, урынына урнаштырылган нәрсәне кире сүтү, урыныннан алу. *Һәйкәл демонтажлау. Иске күперне демонтажлау. Ремонт үткәрелгән урамнарда тамгалар ясау һәм демонтажланган юл билгеләрен яңарту мәсьәләләре*

**ДЕМОРАЛИЗА́ЦИЯ** *и. фр. кит.* 1) Әхлаксызлыкка бирелү, мораль таркалу. *Халык арасында һәм җәмгыятьтә деморализация искиткеч зур тизлек белән үсә*

2) Күңел төшенкелегенә бирелү, эшхәрәкәткә сәләт бетү күренеше. *Дошман гаскәрләренең деморализациясе*

**ДЕМОРАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Деморализация китереп чыгару

**ДЕ́МОС** *и. гр. кит.* Сыйныфларга бүленгән җәмгыятьтә түбән катлау, гади халык массасы. *Борынгы Римда демос һәм аристократлар көрәше*

**ДЕ́МПИНГ** *и. ингл. махс.* Конкурентларны кысрыклап чыгару чарасы буларак, товарларны тышкы базарда эчке һәм дөнья базары бәясеннән (еш кына җитештерү чыгымнарыннан да) түбәнрәк бәягә сату күренеше. *Демпинг алымы*

**ДЕН** *и. диал. к.* **дин**. *[Поп:] Исемегезне, фамилиягезне һәм денегезне алмаштырырга кирәк.* М.Галәү. *«Исемең кем?» диярләр, «Белмим» диярсең. «Денең ни?» диярләр, «Ислам» диярсең...* М.Мәһдиев

**ДЕНАТУРАТ** *и. лат.* Техникада куллану өчен махсус ясалган, эчәргә, медицинада куллануга яраксызландырылган спирт

**ДЕНАТУРЛАШТЫРУ** *ф.* Спиртка төрле агулы, тәмсез яки начар исле матдәләр кушып, аны эчү, медицинада куллану һ.б.ш. өчен яраксыз хәлгә китерү

**ДЕНАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯ** *и. нем. кит.* Денационализацияләү, денационализацияләү эше. *Хәзер сәнәгатьнең кайбер тармакларында денационализация киң җәелгән*

**ДЕНАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. кит.* Дәүләт тарафыннан национализацияләнгән милекне элекке хуҗаларына кайтару, милекне аерым кешеләргә биреп, хосусый милекчеләр булдыру. *Завод-фабрикаларны денационализацияләү халык арасында канәгатьсезлек китереп чыгарды*

**Денационализацияләп бетерү** Денационализацияләү эшен төгәлләү, тулысынча денационализацияләү. *Иң мул табыш китерә торган предприятиеләрне денационализацияләп бетерү нәрсәгә китерәчәген әле беркем дә ачык күзаллый алмый*

**Денационализацияләп тору** Даими, әледән-әле денационализацияләү. *Бай рудникларны денационализацияләп тору*

**ДЕНАЦИФИКА́ЦИЯ** *и. нем. кит.* Германиянең иҗтимагый-сәяси тормышын, икътисадын фашизм (нация) хакимлегеннән, аның йогынтысыннан арындыру эше, шуңа караган чаралар

**ДЕНДРА́РИЙ** *и. гр. биол.* Фәнни тәҗрибәләр өчен төрле чәчәкләр, куакүсемлекләр, агачлар үстереп, күзәтү алып бара торган махсус тәҗрибә участогы яки бакча. --- *Сочи шәһәренә дә алып бардылар. Истәлекле урыннарда, музейларда, хәтта дендрарий дигән җирдә дә булдык.* Т.Нәҗмиев. *Ак чыршыларның ябалдашы матур, куе яшел төстә, шуңа күрә аларны дендрарий һәм ботаника бакчаларында, шулай ук паркларда күрергә була.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ДЕНДРИТ** *и. гр. биол.* Нерв күзәнәгенең күп тармаклы кыска үсентесе. *Дендритларның күпчелеге (грекча «дендрон» – агач) – нык тармакланган кыска үсентеләр. Бер нейронда алар берничә булырга мөмкин. Нерв импульслары дендритлар буйлап нерв күзәнәгенең тәненә керәләр.* Кеше

**ДЕНДРОЛО́ГИЯ** *и. гр. биол.* Ботаниканың агачларны һәм куаклы үсемлекләрне тикшерү, өйрәнү белән шөгыльләнә торган тармагы

**ДЕНОМИНА́ЦИЯ** *и. лат. икът.* Деноминацияләү, деноминацияләү эше. *[Рафис:] Абый, сез деноминация, дигез. Нәрсә була соң ул? Акча алыштырумы? – Гади акча алыштыру гына түгел, энем. Акча знаклары гына түгел, аларның кыйммәтләре үзгәрә. Әйтик, ун тапкыр яки йөз тапкыр ---.* Ф.Зыятдинов

**ДЕНОМИНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Акча әйләнешен тәртипкә китерү, тәртипкә салу һәм исәп-хисапны гадиләштерү максатында, акча билгеләренең күрсәтелгән (номиналь, өстенә язып куелган) хакларын үзгәртү. *1998 елның 1 гыйнварыннан соң, акча салучы беренче тапкыр калага килгәндә, аның саклык кенәгәсенә калган акчасы деноминацияләнгән сумнарда күчереп языла.* Юлдаш

**Деноминацияләп бетерү** Ахыргача деноминацияләү, деноминацияне тәмамлау. *Ун меңлекләрне деноминацияләп бетерделәр*

**Деноминацияләп тору** Даими яки периодик рәвештә деноминацияләү. *Акчаны гел деноминацияләп тору икътисадка зур зыян китерәчәк*

**ДЕНСЕЗ** *с. диал. к.* **динсез**. *[Улибаева:] Иманың юк синең. Денең юк синең. Денсез син.* М.Мәһдиев. *Денсез дәүләтнең юлы җиңелүгә илтә.* В.Имамов

**ДЕНЩИК** *и. рус* Инкыйлабка кадәр: офицер янындагы хезмәтче солдат. *Иргали күпмедер вакыт прапорщик Клочкинда денщик булып торган иде.* М.Хәсәнов

**ДЕҢ** *иярт.* Вак металл әйбер бәрелеп куйганда яки төшеп китеп җиргә бәрелгәндә чыккан тавышны белдерә

**ДЕҢГЕЛДӘВЕК** *с. к.* **деңгелдек**

**ДЕҢГЕЛДӘТҮ** *ф. сөйл.* Кыллы музыка коралының кылларына махсус чирткеч ярдәмендә яки бармак белән чиртү. *Мандолина деңгелдәтү. Балалайка деңгелдәтү*

**Деңгелдәтә башлау** Деңгелдәтергә тотыну

**Деңгелдәтеп алу** Бер тапкыр, тиз арада деңгелдәтү

**Деңгелдәтеп җибәрү** Кинәт деңгелдәтә башлау

**Деңгелдәтеп карау** Тикшерү яки кызык өчен бер-ике мәртәбә деңгелдәтү

**Деңгелдәтеп кую** Бер тапкыр деңгелдәтү

**Деңгелдәтеп тору** Бертуктаусыз, гел яки әледән-әле деңгелдәтү

**ДЕҢГЕЛДӘ́Ү** *ф.* «Деӊ» авазлары чыгару, шундый авазларны хәтерләткән өзек-өзек яңгырау. *Түбә калайлары деңгелди*

**Деңгелдәп алу** Бик аз гына деңгелдәү, деңгелдәгән тавыш чыгару

**Деңгелдәп кую** Кыска гына вакытка, бер тапкыр деңгелдәү

**Деңгелдәп тору** Бертуктаусыз деңгелдәү

**Деңгелди башлау** Деңгелдәргә керешү

**ДЕҢГЕЛДЕК** *с.* Деңгелди торган

**ДЕҢГЕР** *иярт.* Җиңелчә дөбердәүле-калтыраулы «деӊ» авазларын белдерә

**ДЕҢГЕРДӘВЕК** *с. к.* **деңгердек**

**ДЕҢГЕРДӘТҮ** *ф. к.* **деңгелдәтү**. *Гитара деңгердәтү*

**Деңгердәтә башлау** Деңгердәтергә тотыну

**Деңгердәтеп алу** Бер тапкыр, тиз арада деңгердәтү

**Деңгердәтеп җибәрү** Кинәт деңгердәтә башлау

**Деңгердәтеп карау** Тикшерү яки кызык өчен бер-ике мәртәбә деңгердәтү

**Деңгердәтеп кую** Бер тапкыр деңгердәтү

**Деңгердәтеп тору** Бертуктаусыз, гел яисә әледән-әле деңгердәтү

**ДЕҢГЕР-ДЕҢГЕР** *иярт. к.* **деңдең**. *Су ташкыны, ургылып, турбина куласасына агып төште. Ул деңгердеңгер әйләнә башлады.* Р.Батулла

**ДЕҢ-ДЕҢ** *иярт.* Вак металл әйберләр бер-берсенә яки нәрсәгә дә булса бәрелеп яисә металл өслеккә сугып торганда яңгырап ишетелгән тавышларны белдерә. *«Деӊ-деӊ» барабан вә быргы авазлары тугыз кат күк өстенә чыкмыш.* К.Насыйри

**ДЕҢГЕРДӘ́Ү** *ф.* 1) «Деңгер» авазларын хәтерләткән тавыш чыгару; җиңелчә яңгырау, җиңелчә дөбердәү. *Буш мичкә деңгердәү*

2) Нинди дә булса транспорт чарасының, катканаклы, начар юлдан барганда, селкенеп, җиңелчә дөбердәве. *Ат арбасы деңгердәү*

**Деңгердәп кую** Кинәт, бер тапкыр деңгердәү

**Деңгердәп тору** Берөзлексез, бертоташтан деңгердәү

**ДЕҢГЕРДЕК** *с.* 1) Деңгерди торган, деңгердәү халәтендә булган

2) Деңгердәп торган, җимерелергә торган. *Деңгердек баскыч*

3) *к.* **дыңгырдавык** (*2, 3 мәгъ.*). *Деңгердек юл*

**ДЕҢГЕРТ** *иярт.* Кинәт деңгердәп чыккан тавышны белдерә

**ДЕҢК** *иярт.* Кинәт бәрелгәндә деңгелдәп куйган тавышны белдерә

**ДЕҢЛӘ́Ү** *ф. к.* **деңгелдәү**

**ДЕПАРТА́МЕНТ** *и. фр. махс.* 1) Хәзерге Россиядә: министрлыкларның һәм башка югары дәүләт учреждениеләренең бер бүлеге. *Россиянең департаментлары бюрократлык пәрәвезләре белән күмелгән.* Ф.Хөсни. *Иң элек, Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты тарафыннан, Мәскәүдә, Алма-Атада һәм Санкт-Петербургта сәүдә-икътисад вәкиллекләре ачылды.* Сөембикә. *Швециянең азык-төлек департаменты бу хакта инде узган елны ук чаң суккан һәм хатын-кызларга салаканы айга бер тапкырдан артык ашамаска киңәш биргән.* Юлдаш

2) Патша Россиясендә: министрлык яисә башка югары идарә органы каршындагы бүлек. *Полиция департаменты*

3) АКШ һәм Швейцариядә: министрлык атамасы. *Дәүләт департаменты* (*АКШның чит илләр министрлыгы*)

4) Франциядә: административ-территориаль берәмлек

**ДЕПЕ́ША** *и. фр. дипл. хәрби* Нинди дә булса ашыгыч хәбәр, телеграмма һ.б.ш. *Депеша тапшыру*

**ДЕПО** *и. фр.* 1) Локомотив һәм вагоннар торган һәм аларга агымдагы ремонт ясау өчен махсус җиһазландырылган бина. *Бу солдат минем якташ булып чыкты. Ул сугышка кадәр Юдин станциясендә депода эшләгән.* Н.Дәүли

2) Янгын сүндерү машиналары торган бина. *Янгын депосы*

**ДЕПОЗИТ** *и. лат.* Кредиторга яки бүтән бер затка тапшырылу максаты белән, кредит учреждениеләренә (банк, саклык кассасы, нотариаль конторага) кертелә торган акча яки кыйммәтле кәгазь

**ДЕПОЗИТА́РИЙ** *и. ингл.* Халыкара шартнамәнең һәм башка рәсми кәгазьләрнең төп нөсхәсен саклауны үз өстенә алган дәүләт яки учреждение. *Кыйммәтле кәгазьләр базарында һөнәри катнашчыларның берсе – депозитарий – нәкъ менә шул эш белән шөгыльләнә. Ягъни ул клиентларның «депо исәбен» алып бара.* Юлдаш

**ДЕПОЗИ́ТОР** *и. фин.* Депозитка салучы; кертемче

**ДЕПОНЕНТ** *и. лат.* Депозит салучы кеше; депозитчы. *Депозитарий ул – тик юридик зат. Аның хезмәтеннән файдаланучылар «депонент» яисә «клиент» дип атала.* Юлдаш

**ДЕПОРТА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Халыкны үз территориясеннән сөрү. *Депортация сәбәбе көлке рәвештә гади булды: янәсе, безнең Казан кунакханәсе өчен ваучерыбыз юк иде.* Р.Вәлиев. *Татар халкына карата илдән куылу, депортация инде 1930 елда ук, Магниткага нигез салган көннән башлана...* Ф.Бәйрәмова

**ДЕПОРТА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Депортациягә дучар булу, депортациягә дучар ителү. *Башта яһүдләргә каршы юнәлтелгән бу кара дулкын депортацияләнгән (илләреннән куылган) халыкларга, беренче чиратта, кырым татарларына китереп бәрде.* Сөембикә

**Депортацияләнеп бетү** Барысы да, тулысынча депортацияләнү

**Депортацияләнеп тору** Даими рәвештә, вакыт-вакыт депортацияләнү

**ДЕПОРТА́ЦИЯЛӘҮ** *и.* Илдән куу, бөтенләйгә чыгарып җибәрү; сөрү. *Кырымнан кырым татарларын депортацияләгәннән соң, озак еллар безнең әдәбиятыбыз рәсми рәвештә яшәүдән бөтенләй диярлек туктап торды.* Казан утлары

**Депортацияләп бетерү** Барысын да, тулаем депортацияләү. *Тиеш булган чит ил гражданнарының барысын да депортацияләп бетерделәр*

**Депортацияләп тору** Даими, әледән-әле депортацияләү. *Миграцион бүлек хезмәткәрләре чит ил кешеләрен гел депортацияләп торалар*

**ДЕПОЧЫ** *и.* Депо эшчесе. *Депочылар җыелышы*

**ДЕПРЕССИВ** *с.* Депрессия хәлендәге. *Хәер, күп кенә очракларда даһилык белән психика зәгыйфьлеге дә кулга-кул тотынып йөри: даһиларның күбесе маниакаль депрессив психоздан җәфа чиккәннәр.* К.Шакиров

**ДЕПРЕ́ССИЯ** *и. лат.* 1) Кешедәге күңел боеклыгы, өметсезлек, рухи төшенкелек өстенлек иткән психик халәт. *Билгеле булганча, җинаятьчеләр арасында циклотимиклар – ярсыну һәм депрессия, төшенкелек кичерүче кешеләр бар.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Бик күп яшьләр, үзендә рухи көч таба алмыйча, депрессиягә бирелде, наркотиклар кулланып, «җиңел» тормыш итә башлады.* Мәдәни җомга. *Кешегә депрессия хас. Бу – үтеп китә торган эч пошу, сагыш. Депрессия вакытында бөтен организм зыян күрә: начар йоклана, аппетит бетә, тиз арыла.* Сәламәтлек календаре

2) *икът.* Җәмгыятьтә хуҗалык тармакларының торгынлык чоры, эшләп чыгаруның бик түбән булуы һәм эшләп чыгарылган товарларның да сатылмавы

**ДЕПУТАТ** *и. лат.* 1) Закон чыгаручы яки башка сайлаулы органнарга (Думага, Парламентка һ.б.ш.) сайланган кеше. *Тагын бер сызык: авыл советы сессиясе, авыл советы депутатының үз округында сайлаучылар белән очрашуы; район советы сессиясе, район советы депутатының үз округында сайлаучылар белән очрашуы ---.* М.Мәһдиев

2) Берәр җәмәгать эше буенча зур җыелышларга, съездларга коллективтан махсус сайланган кеше, вәкил

**ДЕПУТАТЛЫК** *и.* 1) Депутат булу. *Мин язучыга иң әүвәл депутатлыгына карап түгел, язган әсәренә карап бәя бирәм.* Р.Вәлиев

2) Депутат вәкаләтләре һәм вазифалары. *Ул арада Саимәне район советына депутатлыкка сайлап куйдылар.* М.Мәһдиев

**ДЕПУТА́ЦИЯ** *җый. и. фр.* Нинди дә булса җәмәгать эшен, йомышын башкару өчен, коллектив тарафыннан билгеләнгән яки сайланган депутатлар төркеме. *Депутацияне кабул итү. Банк хезмәткәрләреннән торган депутация*

**ДЕР** I *иярт.* Нәрсәнең дә булса төрле дулкыннар тәэсире астында барлыкка килгән калтыраулы хәрәкәтен, селкенү рәвешен белдерә. *Көшелләр өстенә капланган җәймәләрне дер селкетте, чит-читкә өелгән кибәкләрне тузгытты җил.* Р.Мөхәммәдиев

**-ДЕР** II *кис. к.* **-дыр.** *Моны, белсә, Зәйнәб җиңги үзе генә белгәндер.* М.Мәһдиев. *Шулвакыт аның йөрәк турында, нәкъ җан яшәгән җирдә, нинди-дер бер чың барлыкка килде, ул һаман көчәя барды һәм, каядыр чакырып, дәшеп, чыңлап тора башлады.* Г.Гыйльманов. *Кемдер көлде, кемдер, көнләшеп, эчтән янды, көйде, ә кемдер, бөтен эшен ташлап, үзе дә йорт нигезен казырга кереште.* Г.Гыйльманов

**ДЕР-ДЕР** *иярт.* Калтырап, дерелдәп тору рәвешен белдерә. *Ташпулатлар җөмлә дер-дер селкенә...* Г.Тукай. *Аның күзләре көя төшкән, бите бер көн эчендә ике еллык ябыккан, кулы дер-дер калтырый ---.* Г.Исхакый. *Көтүче белән кызы, куркуларыннан һәм салкыннан дер-дер калтыранып, мулла алдында басып тора бирделәр.* М.Галәү

**ДЕР-ДЕРИ** *иярт. к.* **дер-дер**

**ДЕ́Р-ДЕРИ КИЛҮ** *ф. к.* **дерелдәү**

**ДЕ́Р-ДЕР ИТҮ** *ф. к.* **дерелдәү**. *Атлый алмый бер-ике оч та, Туктала да тын ала. Дер-дер итә гел бабай да, Бик суык... һич юк чара...* Г.Сөнгати. *[Ахун] (иреннәре дер-дер итеп тора). Күкерт! Башым китте минем! Бәхил булыгыз, оланнар! (Елап җибәрә).* Н.Исәнбәт

**ДЕ́Р-ДЕР КАЛТЫРАУ** *ф. к.* **дерелдәү**. *Меңләгән йолдызлар, нәрсәдәндер куркынган шикелле, дер-дер калтырап җемелдәшәләр.* Н.Дәүли. *Нургалиев Фәйрүзәнең дулкынланудан дер-дер калтыраган нечкә кулын үз кулына алды.* Н.Измайлова

**ДЕ́Р-ДЕР КИЛҮ** *ф. к.* **дерелдәү**. *Куллары дер-дер килә, түшләренә төшкән сакаллары калтырый.* Х.Камалов. *Елаудан, гарьләнүдән, оялудан ябык аркасы дер-дер килә...* Ф.Бәйрәмова. *Булатның әтисе аны куян баласы дип белгән. «Куян, куян!» – дип йөгереп барсалар – дер-дер килеп, куркынган көчек утыра.* Г.Гыйльманов

**ДЕРЕЛДӘВЕК** *с.* **1.** Калтырап, дерелдәп торган, шул торыштагы. *Васил аның [Нәфисәнең] дерелдәвек керфекләре белән борын очындагы сипкелләрен генә күреп калды* ---. Г.Әдһәм. *[Дудинскаяның] --- назлы сусау кунган дерелдәвек иреннәре гел бер үк сүзләрне пышылдады: «Рәхмәт, Рудик!»* Р.Вәли

**2.** *и. мәгъ. кулин.* Озак кайнатылган аяк-тубык яки сөяк шулпасына (саркындысына) вак кына ит яки балык кисәкләре катнаштырып, суытып куертылган салкын ашамлык; койка. *Өстәлләрдә дерелдәвектән --- алып, төрле төр салатларны кушып, дистә катламлы һәртөрле баллы катламалар* ---. Б.Рәхимова

**ДЕРЕЛДӘТҮ** *ф.* 1) Селкетү, селкү. *Ул тагын башын дерелдәтте.* М.Мәһдиев. *Урамда торган машина, тәрәзә пыялаларын дерелдәтеп, урыныннан кузгалып киткәч кенә, дәшәр җай тапты* ---. Р.Мөхәммәдиев. *Кемдер, кәгазьләр кыштырдатып, өстәлне дерелдәтеп, ашкына-ашыга язып утыра.* Ф.Баттал

2) Куркыту, курку салу. *Кемдер мич башыннан бер капчык сөяк өстерәп төшерде, үзе куркыныч тавыш белән халыкны дерелдәтте* ---. Г.Ибраһимов

**Дерелдәтә башлау** Дерелдәргә тотыну. *Күзләрен йомып, дога кылган сыман, иреннәрен дерелдәтә башлады.* Казан утлары. --- *көчле тавышка кечкенә улыбыз да иләшә алмый, перфоратор белән дерелдәтә башлауга: «Усал абый килгән», – дип, куркып, кочагыма сарыла* ---. Ватаным Татарстан

**Дерелдәтеп алу** Бер тапкыр, тиз вакыт арасында дерелдәтү

**Дерелдәтеп тору** Бертуктаусыз дерелдәтү; һәрвакыт, еш дерелдәтү. *Айһай таләпчән, кырыс, тәкәббер, ди, бөтенесен дерелдәтеп тора, ди.* Н.Көбәш

**ДЕРЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Калтырау, дер-дер килү (салкыннан, берәр төрле авырудан, куркудан). *Аның картлыктан һәм ачлыктан суырылган, тиресе җыерчыкланып сөяккә ябышкан куллары калтыранып, бармаклары саксаул ботакларыдай катып, бөгелә алмыйча, бер-берсенә кушыла алмыйча тыпырпаеп дерелдиләр.* И.Салахов. *[Гайшә:] Әйдәгез, түр өйгә, улыгыз янына узыгыз. Туктагыз, өстегезгә шәл салыйм, дерелдисез...* И.Салахов. *Көчекләр, дерелдәп, сөт эчтеләр дә, кояшта җылынган басма тактасы өстендә икесе бер йомгакка әверелеп, йоклап киттеләр.* Ф.Шәфигуллин

2) Тирбәлеп, селкенеп тору. *Тимер рәшәткә белән капланган тәрәзә пыялалары тавыштан дерелдәде.* Ш.Усманов. – *Рәхмәт! – дидем мин, дерелдәгән иреннәрем белән генә.* Ә.Еники

3) Йөрәк аритмиясеннән бөтен тәнне, эчке органнарны хәл бетергеч калтырану биләп алу

4) *күч.* Куркуга бирелү

◊ **Дерелдәп төшү** Бик нык куркуга калу. *Тирә-якны айкап йөрүче бандитлар да, җир чәчеп, мал асрап көн күрүче җирле халык та – бар да кечкенә генә буйлы, какча битле, зур зәңгәр күзле, киң җилкәле пограничник Василийны беләләр, бандитлар аның исемен ишетү белән дерелдәп төшә, җирле халык батыр кызылармеец белән мактана торган булган.* Ә.Айдар

**Дерелдәп алу** Берникадәр вакыт дерелдәү

**Дерелдәп бетү** Дерелдәү дәрәҗәсенә җитү

**Дерелдәп китү** Кинәт дерелди башлау; аз гына дерелдәү кичерү. *[Гаянов] Йөзен куллары белән каплап, җиргә сузылып ятты да тынып калды. Тик гәүдәсе генә әледән-әле дерелдәп китә иде.* Н.Дәүли. *Идриснең дәү, нык гәүдәсе дерелдәп китте, мускуллары тыгызланып тартыштылар.* А.Гыйләҗев. *Нәни генә, йомшак кына кулларына кагылгач, йөрәгем сулкылдап, тәнем дерелдәп китте.* И.Юзеев

**Дерелдәп кую** Кинәт, кыска вакыт аралыгында гына дерелдәү. *Вәли Гаязовичның иреннәре дерелдәп куйды.* Ф.Садриев. *Илсөяр җиңел генә дерелдәп куя һәм, әтисенең куенына сыена төшеп, әкрен генә эндәшә: – Әти!* Г.Гобәй

**Дерелдәп тору** Бертуктаусыз дерелдәү. *Идрис малайдан пиджакны салдырып алды, куркуданмы, суыктанмы дерелдәп торган курач, җиңел гәүдәне, култык асларыннан эләктереп, каешка буе җитәрлек итеп күтәрде.* А.Гыйләҗев. *Әллә нинди дерелдәп торган тимерләргә абына-сөртенә, кабинага кереп тә утырам.* Ф.Бәйрәмова

**Дерелди бару** Дерелдәве арткан-нан-арту

**Дерелди башлау** Дерелдәргә тотыну. *Әмма озак та үтмәде, апайның чырае бозылып, иреннәре дерелди башлады.* Г.Бәширов. *Васфикамалның күзен кан басты, борын яфраклары дерелди башлады.* М.Мәһдиев. *Бите чин кәгазедәй агарып калды, бармаклары дерелди башлады.* Ф.Латыйфи

**Дерелди төшү** Бераз дерелдәү

**ДЕРЕЛДЕК** *с.* **1.** 1) *к.* **дерелдәвек** (*1 мәгъ.*). *Нуриев партбилетларны дерелдек кулларына алды, берәм-берәм ачып карый башлады* ---. Ф.Садриев. *Бабасы дерелдек кулына сонган бөрлегәннәр чәчелде.* Р.Мулланурова

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **дерелдәвек** (*2 мәгъ.*). *Фазыйлә, дерелдек кебек калтыранып, көч-хәл белән чанадан төште һәм, хәлсез аякларын сөйрәп, эчкә үтте.* Ф.Җамалетдинова

2) Дерелдәп торган нәрсә. *Кешеләрнең тәне буенча тыелгысыз бер дерелдек йөгереп узды* ---. Н.Фәттах. *Шахминның башы вак дерелдек белән калтырарга тотынды.* Ф.Садриев

**ДЕРЖА́ВА** *и. рус юг.* Мөстәкыйль сәясәт алып баручы бәйсез, куәтле, зур дәүләт. *Ул [Табеев] Татар иленең куәтмөмкинлекләрен, державача, хуҗа агайларга --- санап чыгып күрсәтте.*

Ф.Дунай. *Бөек держава. Бөек чор. Кем тели, мондый бөеклекне үзегезгә алыгыз.* Казан. *Мондый барлык хәрәкәтләр --- Болгарда да, Казан державасында да халыклар тигез хокуклы һәм ирекле булганнар дип фараз кылырга мөмкинлек бирә.* Казан утлары

**ДЕРЖА́ВАЧЫЛ** *с.* Башка халыклар һәм дәүләтләр алдында үзен өстен санаган. *Державачыл милләтләр. Державачыл илләр*

**ДЕРЖА́ВАЧЫЛЫК** *и.* Державага хас булу, державага караган күренеш, вакыйга һ.б.ш. *1930 еллар уртасыннан башлап, совет тарихы фәнендә кабаттан революциягә кадәр яшәп килгән бөек державачылык авазлары яңгырый башлый.* Б.Хәмидуллин

**ДЕРИВАТ** *и. лат. махс.* **1.** 1) Нинди дә булса беренчел булган әйбердән ясалган, алынган продукт. *Нитробензол – бензол дериваты. Туфрак таркалудан барлыкка килгән дериватлар*

2) *лингв.* Сүз ясагыч чаралар ярдәмендә тамыр сүздән барлыкка килгән, яңа төшенчәгә ия сүз. *Дериват – ясалма сүз.* Г.Галиуллина

**2.** *с. мәгъ.* Икенчел, ясалма. *Дериват продукт*

**ДЕРИВАЦИОН** *с.* Төп юнәлешеннән, юлыннан, траекториясеннән читкә тайпылган. *Деривацион канал. Деривацион корылмалар*

**ДЕРИВА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* 1) Елгалардан, сусаклагычлардан һ.б.ш. урыннардан насос, су станцияләренә су җибәрү; шушы процессны үтәүдә кулланыла торган гидротехник корылмалар җыелмасы

2) *лингв.* Яңа сүзләр ясалышы

**ДЕ́Р ИТҮ** *ф. к.* **дер селкенү**

**ДЕ́Р КАЛТЫРАУ** *ф.* 1) Дерелдәү, дер-дер килү

2) Бик нык курку, куркудан югалып калу. *Дер калтырап утырган Нургали карт та берни әйтә алмаган.* М.Мәһдиев

**ДЕ́Р КИЛҮ** *ф. к.* **дер селкенү**

**ДЕ́Р КУБУ** *ф.* Көчле ыгы-зыгы башлану, тавышлану

**ДЕРЛӘ́Ү** *ф. к.* **дерелдәү**

**ДЕ́РМА** *и. гр. биол.* Умырткалы хайваннар һәм кеше тиресендә тоташтыргыч тыгыз тукыма. *Эпедермис астында тоташтыргыч тыгыз тукыма – дерма. Монда – күпсанлы рецепторлар, май һәм тир бизләре, төк, чәч тамырлары, кан һәм лимфа тамырлары.* Кеше

**ДЕРМАТИН** *и. гр.* **1.** Нитроцеллюлоз тышчалы тукымадан эшләнгән ясалма күннең бер төре; гранитоль. *Дерматин белән тышланган ишек тартканчы ук ачылып, безне яшь кенә лейтенант каршы алды.* М.Мәһдиев. *Кара дерматин белән тышланган ишектән кемнәрдер кызарынып, кемнәрдер агарынып килеп чыга, алар урынына икенчеләре кереп китә.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Дерматиннан яки шуны катнаштырып эшләнгән, тышланган. *Кыз кара дерматин ишек артына кереп китте һәм тиз үк әйләнеп чыкты.* А.Гыйләҗев. *Ул көнне төштән соң дерматин ишекнең ике ягына көмеш язулы ике кара пыяла беркетелде.* М.Мәһдиев. *Проводниклар, кара дерматин сумкаларын култык асларына кыстырып, соңга калган пассажирларны көтеп торалар.* М.Юныс

**ДЕРМАТИТ** *и. гр. мед.* Механик, физик, химик, биологик тәэсирләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән тире ялкынсыну авыруы. *Ультралан препараты 3–5 көн эчендә аллергик һәм аралашудан килеп чыккан дерматитны төзәтә.* Татар мөселман халык календары. *Бака үләне препаратларын --- дизентерия, колитларны, бизгәк, дерматит һ.б. дәвалаганда файдаланалар.* Татар мөселман календаре

**ДЕРМАТОГЛИ́ФИКА** *и. гр. махс.* Тән тиресе өслегендәге бизәкләрне өйрәнә торган фән. *Дерматоглифика фәне бармактагы һәм уч төбендәге бизәкләр буенча, авыру үзен сиздергә башлаганчы ук, нәселдән килгән кайбер авыруларны врачларга белергә мөмкинлек бирә.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДЕРМАТО́ЛОГ** *и. гр.* Дерматология буенча белгеч, табиб. *Кан тамырлары киңәйгәндә биткә --- пудра-порошок тидерегез. Билгеле, дерматологка мөрәҗәгать итәргә кирәклекне онытмагыз.* Өмет

**ДЕРМАТОЛО́ГИК** *с.* Дерматологиягә караган. *Дерматологик авыру*

**ДЕРМАТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Тиренең төзелешен, функцияләрен, тире авыруларын һәм аларны дәвалауны, профилактика ысулларын өйрәнә торган фән; медицинаның шундый тармагы

**ДЕР-Р** *иярт.* Калтыраулы хәрәкәтне яки тавышны белдерә

**ДЕ́Р СЕЛКЕНҮ** *ф.* Бик нык дерелдәп куюю, көчле селкенү

**ДЕ́Р СЕЛКЕТҮ** *ф.* 1) Бик нык дерелдәтү

2) *күч.* Бик көчле тәэсир калдырырлык вакыйгаларга сәбәпче булу, тетрәтү. *– Берсе – татар музыка тәсбихының бисмилласы, икенчесе – театрыбыздагы искелекне дер селкетеп алган тугыз балл көчлелегендәге дулкын, – дип куйды.* Ш.Рахманкулов

**ДЕРТ** *иярт.* 1) Җиңелчә генә дерелдәүне белдерә

2) Кинәт сискәнеп китүне, дерелдәп куюны белдерә

**ДЕРТ-ДЕРТ** *иярт.* Кинәт тартылып-тартылып куйган өзек-өзек хәрәкәтне белдерә. *Картның сул як бите дерт-дерт селкенә башлады.* Ә.Еники. *Үзем сиңа карыйм, ә үземнең Дерт-дерт үзәкләрем өзелә ---.* Д.Нәгыймуллина. *Үземнең йөрәк дерт-дерт тибә, үзем сөенәм, үзем оялам да биткә кершән сөртергә тотынам.* Шәһри Казан

**ДЕ́Р ТЕТРӘТҮ** *ф. сир. к.* **дер селкетү**

**ДЕ́РТ ИТҮ** *ф. к.* **дертләү.** *«Авыр» сүзен кабатлап әйткәндә, йөрәк дерт итеп куя.* Р.Мөхәммәдиев. *[Зәйтүнә] Сукмактан чыгып, сыер артыннан киткән иде, дерт итеп, шып туктады.* А.Гыйләҗев

**ДЕРТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кинәт селкенеп, хәрәкәт ясап кую

2) Кинәт калтырап кую; куркынып, сискәнеп китү. *Аның моңы мине капыл арбап алды. Дертләп, башымны югары чөйдем.* М.Кәрим

**Дертләп китү** Кинәт дертләп кую. *«Бер мәлаем караш сал! Сал! Сал!» – дигән ялвару сүзләрен ишеткәч кенә, [бия] дертләп киткәндәй итте.* М.Кәрим

**Дертләп кую** Кинәт, бер тапкыр дертләү

**ДЕРТ-МЕРТ** *иярт. к.* **дерт-дерт**

**ДЕ́РТ-МЕРТ КИЛҮ** *ф. к.* **дертләү**. *Күрекле әкәнең генә күңеле борчулы булды. Дерт-мерт килеп, әледән-әле ишеккә каранды, әледән-әле тыштагы тавышларга колак салды.* Н.Фәттах. *Мәхүбечнең мыеклары дерт-мерт килеп кабара башлады, күзләреннән нәфрәт очкыннары чәчрәгәндәй булды, иреннәре кысылды.* Ф.Баттал

**ДЕСАНТ** *и. фр.* 1) Каршы якта хәрби хәрәкәтләр алып бару өчен махсус әзерләнгән гаскәрләрне корабльдән яки самолёттан дошман җиренә төшерү. *[Военком:] --- үз әтиләренә кул суза башлаган ул егет калдыкларын мин нинди төр войскога җибәрим? Ә? Чик буе гаскәрләренәме? Хәрби диңгез флотынамы? Десанткамы?* М.Мәһдиев. *Ул – Люберцыдан, кушаматы – Самурай, махсус десант гаскәрләренең аерым подразделениесын да төгәлләгән.* Р.Мирхәйдәров

2) Шул рәвешле төшерелгән гаскәр (корабльдән, самолёттан һ.б.ш.). *Вячеслав Михайлович Неделин ике ел Ерак Көнчыгышта десант гаскәрләрендә хезмәт иткән икән ---.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Аерым, махсус максатлар куеп, халык арасында билгеле бер эшчәнлек алып баручы төркем. *Татар милләтен икенче тапкыр глобаль башкортлаштырырга омтылып караучылар --- татар авылларына якындагы елларда «десант» төшерү өчен, меңләгән башкорт теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләп өлгерделәр.* Казан утлары

**ДЕСАНТЧЫ** *и.* 1) Десант гаскәрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәр, яки десантта катнашучы сугышчы. *Миңа тагын ике-өч кеше кирәк: ләкин миннән яшь булсыннар, элекке десантчылар, спортчылар, коралны яхшы тотучылар, нәрсәгә барганнарын белеп баручылар.* Р.Мирхәйдәров

2) Халык арасында аерым эшчәнлек алып бару өчен оешкан төркемнең бер кешесе

**ДЕСЕРТ** *и. фр.* 1) Аш соңында яки көндезге аштан соң бирелә торган тәмле, татлы ашамлык, җиләк-җимеш яки конфетлар. *Десертка туңдырма бирделәр*

2) *күч.* Гомумән нинди дә булса эш, гамәл һ.б.ш. – *Өстәвенә, десертка чәчәк кебек яшь кызлар да алып бара, тере ит белән сыйламакчы, күрәсең, – дип, җиңелчә чеметтереп алдым.* С.Сабиров

**ДЕСЕ́РТ КАШЫГЫ** *и.* Чәй кашыгыннан зуррак, ләкин ашныкыннан кечкенәрәк булган кашык. *Махсус диета вакытында чәйгә --- бер десерт кашыгы 5 процентлы натрий салицилаты эремәсе салып эчү шарт.* Юлдаш

**ДЕСЕ́РТ ШӘРАБЫ** *и.* Баллы йөзем шәрабы

**ДЕ́СПОТ** *и. гр.* 1) *тар.* Борынгы Көнчыгышның колбиләүче дәүләтләрендә чикләнмәгән хокукларга ия булган хөкемдар

2) *күч.* Башкаларның теләкләре һәм ихтыяҗлары белән санлашмаучы, үзен генә тулы хокуклы итеп тоючы, кул астындагыларны үз мәнфәгатьләренә буйсындырып яшәүче кеше. *Власть башына наданнар, деспотлар, тираннар килгән.* Т.Миңнуллин. *[Сатыбал:] Син беләсеңме кем? Фашист! --- Үзсүзле деспот! Шушы холкың белән гомер буе Балбикәне азапладың!* Н.Гаетбай

**ДЕСПОТИЗМ** *и. гр. к.* **деспотлык**. *Рус тарихчылары исә хөкүмәте мөстәбдә, ягъни хөкүмәт деспотизмы вакытында вә аның сәясәтен хуплап язарга мәҗбүр булганлыктан, шулай мөбалага, ягъни күпертергә вә ялганнарны теләр-теләмәс язган булырлар.* Р.Фәхреддин

**ДЕСПОТИЯ** *и. гр. к.* **деспотлык**. *Деспотия, басым, бик кырыс цензура шартларында иҗат иткән язучылар сафына 1896 елда Гаяз Исхакый да кушыла.* М.Әрәле-Салихов

**ДЕ́СПОТЛАРЧА** *рәв.* Деспотлар кебек, деспотларга хас булганча. *Беренче төркем вәкиле Биктимер, мәсәлән, деспотларча эш итә: бердәнбер кызын эчеп-исереп йөрүдән башканы белмәгән, надан һәм аңгыра Җантимергә бирергә җыена.* Әдәбият

**ДЕ́СПОТЛЫК** *и.* 1) *тар.* Абсолют, чикләнмәгән хокукларга таянып, законсыз, башбаштаклык белән идарә итү формасы. *[Дуамал губернатор] «Безнең федераль хөкүмәт деспот була башлады. Аның деспотлыгы хөкүмәт аппараты зурлыгында, гражданнар тормышына катышуында һәм безнең штат эшләренә кысылуында чагыла», – диде.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Деспот (*2 мәгъ.*) кешегә хас сыйфатлар

**ДЕ́СПОТЧЫЛ** *с.* Буйсындыручан, боеручан, боера торган, буйсындыра торган; боерулы. *Шушы явыз шайканың 1917 елны 150 миллионлы рус халкы өстеннән деспотчыл хакимият урнаштыра алуының сере – яһүдчелекнең һәрвакыт үз сион программасы булуында.* Гасырлар авазы

**ДЕСТРУ́КЦИЯ** *и. лат. кит.* Нәрсәнең дә булса структурасы, төзелеше җимерелү-таркалу күренеше

**ДЕСЯТИНӘ** *и. рус к.* **дисәтинә**. *[Мирхәйдәр:] Әйләнеп тә карамас идем, абый, кыш көне бер чана печән алган идек, шуның өчен ике десятинә чабарга туры килде.* Т.Гыйззәт

**ДЕСЯТИНӘЛЕ** *с.* Бер дисәтинәгә тигез булган. *Кузьма Минин үлгәннән соң, --- аның гаиләсенә патша 2415 десятинәле җире белән Богородское һәм башка тирә-күрше авылларны вотчина итеп биргән.* С.Хатыйпов

**ДЕСЯ́ТНИК** *и. рус к.* **дисәтник**. *Староста, десятник, кая, тизрәк килсеннәр!* К.Тинчурин. *Җир төзү техникумын тәмамлагач, 1930 елның гыйнвареннан көзенә кадәр, А.Алиш Минзәлә кантоны җир бүлегендә мелиоратор булып эшли, аннары, 1931–1933 елларда, Казгрэс (ТЭЦ № 1) төзелешендә гидротехника буенча десятник һәм Казан шәһәре канализация төзелешендә техник хезмәтен башкара.* Татар әдәбияты тарихы. *Ул вакытта мин 1955 елның августына кадәр Казакстанда «ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник профессияләре»н үзләштереп кайткан А.Гыйләҗевның моңарчы Казанда ике-өч ел эшкә урнаша алмый, язган-сызганнарының кат-кат «иләктән» уздырылып йөргәнлеген белми идем, билгеле.* Татарстан яшьләре

**ДЕСЯ́ТСКИЙ** *и. рус к.* **дисәтник**. *Фәйзулла староста сотский белән де-*

*сятскийларга халыкны каравыл өенә җыярга кушты.* М.Галәү

**ДЕТАЛЬ** *и. фр.* 1) *тех.* Механизмның, машинаның тагын да вак, тагын да гади өлешләргә таркалмый торган кисәге. *[Александров:] Менә язгы чәчү генә бетсен, заводка жалоба язам. Детальләрне яхшылап эшләсеннәр*... И.Салахов. *Мин торакка кайттым. Их, дусларым, Деталемне ясый алмадым. Боздым, барысын боздым*... И.Юзеев. *Еш кына бу элементлар, детальләр тәртипсез урнашалар: аларның төньяк һәм көньяк полюслары төрле якка юнәлгән була, һәм бу магнитчыкларның магнит көчләре берберсен юкка чыгаралар.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Нинди дә булса вакыйганың, эш-хәлләрнең аерым бер факты; вак җентеклелек; вак-төяк, кечкенә нәрсә. *Дөрес, башка әсәрләрдә чагылыш тапкан традицион сюжетта соңгы мотив – Йосыф табутының Кәнганә кайту мотивы юк. Аның Кол тарафыннан өстәлгән деталь булуы бик ихтимал.* Ф.Фәсиев. *Характерлы бер деталь: хикәя Әбдүшнең «өстәл янында язып утырды» белән башлана, «өстәл янында язып утырды» белән тәмамлана.* Ф.Хөсни. *Соңгы сүзне Тояк Бөркетбаев алды. Ул да парторг тарафыннан тәкъдим ителгән планга һәм конкрет чараларга нигездә каршы булмады, бары кайбер детальләрне ачыклап, берничә агитаторны алыштырырга кирәк дип тапты.* И.Салахов

**ДЕТЕКТИВ** *и. ингл.* **1.** 1) Җинаятьчеләрне эзләү, эзләп табу полициясе агенты, шымчы

2) Детектив эчтәлекле хикәя, мажаралы роман, кинофильм. *Н.Гаетбайның «Ир командировкадан кайткач» детектив комедиясе үз жанрына бөтенләй туры килми.* Сәхнә

**2.** *с. мәгъ.* Детектив эчтәлектәге. *[Улым] Өйдә китап укыды, фотография белән шөгыльләнде, магнитофон, кассеталар, детектив әдәбият, маркалар* ---. М.Мәһдиев. *Фәлсәфи уйланулар, психологик эзләнүләр җәһәтеннән кызыклы әсәр. Детектив жанрга да тартым үзе.* Казан утлары

**ДЕТЕ́КТОР** *и. лат. махс.* 1) Югары ешлыктагы тирбәнешләрне ишетү органнары ярдәмендә кабул ителерлек түбән ешлыкка күчерү җайланмасы. *Һидият бу сөйләшү вакытында, ярый әле өйдә ялганны фаш итә торган детектор юк, дип сөенеп утырды.* Д.Гыйсметдин

2) Җылылык, яктылык һ.б.ш. кабул итү җайланмасы. *Сәхнәгә чыкканда, ул [Григорий Булах] гүяки кесәсенә кеше гомерен озайта торган детектор салып чыга иде. Тамашачы залын шул детектор нуры белән нурландыра* ---. А.Хәлим

**ДЕТЕ́КТОРЛЫ** *с.* Детектор ярдәмендә эшли торган, детекторы булган. *Һәр катлаулы нәрсә гадирәк өлешләрдән тора, гадидән катмарланып, әкренләп югары үсешкә ирешә бит. Шулай булмаса, Попов детекторлы радио урынына төсле телевизор уйлап таптапкан булыр иде* --- З.Мифтахов

**ДЕТЕРМИНИЗМ** *и. лат. филос.* Матди һәм рухи дөнья күренешләренең сәбәпле закончалылыгы һәм шартлылыгы турында материалистик тәгълимат

**ДЕТЕРМИНИСТ** *и. рус филос.* Детерминизм тарафдары

**ДЕТЕРМИНИ́СТИК** *с.* Детерминизмга караган; детерминизмга нигезләнгән

**ДЕТОНА́ТОР** *и. лат. махс.* 1) Детонация китереп чыгара торган шартлаучан матдә; шартлаткыч җайланма

2) Шартлау барлыкка китерү өчен кулланыла торган капсюль, кабызгыч (запал)

**ДЕТОНА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* Нинди дә булса шартлаучан матдәнең, бүтән бер матдә шартлавы яки тетрәве, бәрелүе нәтиҗәсендә, бик тиз ялкынланып китүе

**ДЕ-ФА́КТО** *рәв. лат. кит.* Фактта, асылда, чынында; *киресе*: **де-юре**

**ДЕФЕКТ** *и. лат. кит.* Кимчелек, җитешсезлек. *Кешенең, биологик төр буларак, нәселдәнлек үзенчәлекләрен, аның килеп чыгышының генетик нигезләрен һәм аның киләчәген өйрәнү, аерым кешеләрдә дефектларны төзәтү методларын эшләү – хәзерге вакытта генетика фәненең бурычлары менә шулардан гыйбарәт.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Яңа ГОСТ буенча, киемдә яшерелгән дефект булган очракта, химчистка аның хакын тулысынча түләүдән азат ителә.* Юлдаш

**ДЕФЕ́КТЛЫ** *с.* Дефекты булган, нормаль булмаган, кимчелекле. --- *лебедка барабанына трос чорналмады. Дефектлы ул.* Х.Камалов. --- *кайбер дефектлы кристалларның ныклыгы бик югары була.* Физика

**ДЕФЕ́КТЛЫЛЫК** *и.* Физик яки психик кимчелекле, дефектлы булу. *Конкурсның бөтен лауреат һәм дипломантлары тотрыклы финанс хәленә ия, хезмәт җитештерүчәнлеге һәм производствоның табышлылыгы үсә, дефектлылык күрсәткече кими.* Ватаным Татарстан

**ДЕФЕКТОЛО́ГИК** *с.* Дефектологиягә караган, дефектологиягә мөнәсәбәтле

**ДЕФЕКТОЛО́ГИЯ** *и. лат.* Тумыштан физик кимчелекле яки психикасы үзгәргән балаларның үсеш үзенчәлекләрен, аларны укыту, тәрбияләү методларын өйрәнә торган фән. *Психология һәм дефектология фәнендә компенсация, ягъни кешене элекке хәленә кайтару тәгълиматы да барлыкка килде хәттә.* Мәдәни җомга

**ДЕФЕКТОСКОП** *и. фр.* Металл һәм металл булмаган материалдан эшләнгән әйберләрдәге җитешсезлекләрне (дефектларны) табу җайланмасы

**ДЕФИС** *и. лат. грам.* Парлы сүзләрне берләштергән сызык; сүзне бер юлдан икенче юлга күчерү билгесе һәм сүзләрне кыскарту күрсәткече; сызыкча (мәс., *ап-ак, бала-чага*)

**ДЕФИЦИТ** *и. лат.* **1.** 1) Чыгымның керемнән артык булуы сәбәпле барлыкка килгән зыян. *Бюджет дефициты*

2) Нәрсәнең дә булса җитмәүчелеге, җитәрлек булмавы. *Мәсәлән, шикәр заты бөтенләй юк. Сатучылар: «Бездә андый әйберләр дефицит», – диләр.* А.Расих. *Мәскәүгә барырга туры килгәндә, мин күчтәнәчкә «Бородино» ипиен алып кайтам. Дөресрәге, идем. Хәзер ул да дефицитка әйләнде.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ. к.* **дефицитлы**. *Бәхетсезлегенә, табигать бүрене Җир йөзендәге иң калорияле дефицит ризык – ит ашый торган итеп яраткан.* М.Мәһдиев. *Ул кибетләрнең вазифасы, исеменә караганда, чит ил кешеләрен тәэмин итү булса да, асылда, дефицит товарлар исәбенә, җирле халыкның алтынын җыю иде.* А.Расих

**ДЕФИЦИТЛЫ** *с.* 1) Дефицит (*1 мәгъ.*) барлыкка китергән, дефицит тудырган

2) Җитәрлек күләмдә булмаган, даими җитенкерәми торган. *Дефицитлы киемнәр*

**ДЕФОЛТ** *и. ингл. икът.* Юридик яки физик затның алган бурычын түләргә теләмәү яки түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, аны өлешчә генә түләве белән аңлатыла торган күренеш. *Дефолт башлангач, нефтьне читкә сатып, әйберләрнең бәяләрен күтәрмәдек.* Безнең гәҗит

**ДЕФОРМА́ЦИЯ** *и. лат.* Берәр нәрсәнең формасы үзгәрү, формасы бозылу. --- *аның тексты мәгълүм дәрәҗәдә «эшкәртүләргә» – үзгәрешләргә дучар булган, хәтта аерым очракларда мәгълүм деформация дә кичергән.* Ф.Фәсиев

**ДЕФОРМА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Деформациягә дучар булу. *Сынган сөякнең деформацияләнеп ялгануы*

**Деформацияләнә башлау** Деформацияләнергә тотыну

**Деформацияләнә төшү** Бераз деформацияләнү

**Деформацияләнеп бетү** Тәмам, тулысынча деформацияләнү. *Күкрәк сөяге деформацияләнеп бетү*

**ДЕФОРМА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Деформациягә дучар итү; деформацияләп, формасын үзгәртү. – *Менә деформацияләү җөйләрен салам, – ди, эшеннән беразга гына башын күтәреп, бригадир Фәргать Алиев.* Ватаным Татарстан. *ТР Президентына һәм республика делегациясе вәкилләренә заводның цехларын, Германиядә җитештерелгән металлны деформацияләү җайланмасының ничек эшләвен күрсәттеләр.* Дуслык

**ДЕФОРМА́ЦИЯЛЕ** *с.* Деформациягә дучар ителгән; деформацияләнеп, формасын үзгәрткән. *Тросларны тарттырганнан соң, таянычлар арасындагы --- плитәләрне урнаштырасы һәм деформацияле җөйләрне монтажлыйсы була.* Ремонт эшләре

**ДЕЦЕНТРАЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* Үзәк хакимиятнең кайбер функцияләрен җирле хакимияткә тапшыру сәясәте, шуңа бәйле чаралар. *«Децентрализация» дигән нәрсә башланып, җирле үзидарә системасы кергәч, бу хокукларның барысын да җирле бюджетларга – районнарга, шәһәрләргә бирдек.* Р.Вәлиев. *Берничә елдан децентрализация булачак, бүтән болай дәвам итә алмый.* Татарстан яшьләре. *Медведев белән Путинның децентрализация турында кат-кат сөйләве ул, һичшиксез, вертикальнең тискәре якка эшли башлавын күрсәтте.* Татар заманы

**ДЕЦЕНТРАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Үзәк хакимиятнең вәкаләтләрен киметү. *Дәүләт Думасына децентрализацияләү турында закон проектлары пакеты тапшырылачак.* Ватаным Татарстан. – *Темалар рәтенә, шул исәптән, бюджет чыгымнарының өстенлеге, хакимият органнары арасындагы вәкаләтләрне децентрализацияләү, имиият взносларына үзгәрешләр кертү, шулай ук Россия икътисадын модернизацияләүдә ярдәм итү юнәлешләренә бәйле мәсьәләләр дә керә, – диде Дворкович.* Шәһри Казан

**ДЕЦИ-** *лат.* Үлчәү берәмлеген аңлаткан кушма сүзләрнең беренче өлеше буларак килеп, «уннан бер» дигән төшенчәне белдерә (мәс., *дециметр, децилитр* һ.б.ш.)

**ДЕЦИГРАММ** *и. лат.* Граммның уннан беренә тигез үлчәү берәмлеге

**ДЕЦИЛИТР** *и. лат.* Литрның уннан беренә тигез үлчәү берәмлеге

**ДЕЦИМЕТР** *и. лат.* Метрның уннан беренә тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге. *Дулкынның озынлыгы – биш дециметр*

**ДЕЦИМЕ́ТРЛЫ** *с.* 1) Бер дециметрга тигез булган, бер дециметр озынлыктагы. *Дециметрлы таякчык*

2) Дециметрларга бүленгән. *Дециметрлы тасма. Дециметрлы линейка*

**ДЕ-Ю́РЕ** *рәв. лат. кит.* 1) Законга салып, юридик тәртиптә; *киресе:* **дефакто**

2) Фактларга нигезләнми генә, формаль рәвештә

**ДЖАЗ** *и. ингл.* 1) Күпчелек очракта бәрмә һәм тынлы уен коралларыннан, шулай ук җырчы солистлардан торган оркестр яки ансамбль. *Чират белән бүлмәдән бүлмәгә йөри-йөри кыршылып беткән иске «Рекорд» радиоласына кемдер патефон табасы куеп җибәрде, Олег Лундстремның джаз оркестры бүлмәне дәртле авазларга күмде.* Ф.Латыйфи

2) Шундый оркестр өчен, күпчелек очракта бию көе буларак язылган музыка

**ДЖЕМ** *и. ингл.* Тыгыз бердәм масса тәшкил иткән, җиләк-җимештән ясалган куе варенье. *Татлы ашамлыклар, җиләк-җимешләр (караҗимеш, кавын һәм абрикослардан тыш), җиләк-җимешләрнең баллы сортларыннан кесәлләр, --- кызуда сусыз пешергән алма, грушалар, баллы җиләк һәм җимешләрдән варенье, джемнар.* Татар халык ашлары

**ДЖЕ́МПЕР** *и. ингл.* Баштан киелә торган, якасыз итеп бәйләнгән эләктермәсез кофта. *Гыйлемдарга джемпер бәйләп утырган Ак әби, ниһаять, сүзгә кушылды ---.* А.Тимергалин. *Ирегетләр дә кайсы яңа костюм-чалбардан, кайберләре кыйммәтле джемпер киеп килгән иде.* З.Хөснияр

**ДЖЕ́НТЕЛЬМЕН** *и. ингл. кит.* 1) Англиядә: аристократик буржуазиянең югары даирәсеннән булып, аристократларга хас барлык әхлак, әдәп нормаларын бөтен нечкәлеге белән үтәүче ир кеше

2) Тәрбияле, әдәпле кеше; үз-үзен тотышында зәвыклылыгы белән аерылып торучы ир кеше

3) *күч. ирон.* Үз-үзен тотышында, киемендә ясалма нәзакәтлелек, зәвык һ.б. сыйфатлары сизелеп торган ир кеше; ясалма джентельменлык. *Гомумән, үткән сезонда эш башындагы артистлар (Мутин, Шамил, Айдарский) геройлары – иннек-кершән ягынган джентельменнарга күбрәк үзләре*

*туктала алырдай иде ---.* Ф.Бурнаш. *Бу «джентельменның» зонада бер генә түгел, ә, мөгаен, берничә мәртәбә булып кайтканлыгын бик акыллы булмаган кеше дә аңлап алыр иде.* Р.Мирхәйдәров

**ДЖЕ́НТЕЛЬМЕНЛЫК** *и. кит.* Джентельмен булу, джентельменга хас сыйфатлар. *Кунак егетләре, кызлары җырлы-биюле әйлән-бәйләннәрдә танышалар һәм дуслашалар. Монда аек акыл, әдәплелек, джентельменлык өстенлек итә.* Сөембикә

**ДЖЕ́НТЕЛЬМЕННАРЧА** *рәв.* Джентельмен кебек; джентельменнарга хас булганча. *Райкомга керүемнең икенче көнендә Рәисә ханым, эштән кайткач, Салих белән миңа: – Егетләр, апагызны бүген, зур илтифат күрсәтеп, джентельменнарча икегез ике ягымнан култыклап, театр каратып кайтыгыз әле, – диде.* Г.Тавлин. *Гадәттәгечә, кайгыртучан, игътибарлы, чын джентельменнарча ул.* Сөембикә

**ДЖЕРСИ** *и. ингл.* **1.** 1) Йон яки ефәк трикотаж тукыма

2) Шундый тукымадан тегелгән кием. *Джерси модага керә*

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Джерси костюм*

**ДЖИН** *и. ингл.* Артыш җиләгеннән ясалган инглиз аракысы. *Сез сыра өнәмисезмени? Сыра – плебейлар эчемлеге шул... Сез әллә джин, кальвадос, виски гына эчәсезме?* М.Юныс

**ДЖИНС** *и. ингл.* **1.** Махсус тукымадан тегелгән төрле фасондагы чалбар. *Мидхәт, --- кесәсеннән җиз төсле бер кечкенә озынча калай алып, әнисенә сузды. Калайга латинчага охшаган язу, эт башы төшерелгән иде. – Джинсыга тегәргә ул...* Ф.Садриев. *--- килешсез, корсаклы гәүдәсенә яшьләрчә модный футболка, джинсы киеп куюы аны тагын да көлкелерәк, кызганычрак итеп күрсәтә иде.* Х.Мөдәррисова

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Урман юлыннан джинс чалбар кигән егет белән кыз утырган мотоцикл килеп чыкты.* И.Юзеев

**ДЖИ́НСЫ** *и. ингл. к.* **джинс**

**ДЖИП** *и. ингл.* 1) Төрле максатларда куллану өчен, Америкада җитештерелә торган автомобиль. *«Москвич» кына димәссең, тәрәзәләренә кара плёнка ябыштырылган; бампер алдында – джипларда гына була торган никельле ялтыравык «кенгуру» ---.* Ж.Юнысов

2) Теләсә нинди начар, үтүе бик авыр булган юллардан да узып йөри ала торган автомобиль

**ДЖИ́У-ДЖИ́ТСУ** *и. яп.* Японнарда коралсыз килеш һөҗүм итү һәм һөҗүмнән саклану алымнары җыелмасы, шул алымнар системасы

**ДЖО́УЛЬ** *и. ингл. физ.* Энергия, эш һәм җылылык күләмен үлчәү берәмлеге

**ДЖУ́НГЛИ** *и. ингл.< һинд* Тропик һәм субтропик поясларындагы елга буе үзәнлекләрендә кеше үтеп чыга алмаслык, сулыклы тәбәнәк урманнар. *Куе ботаклар ерып, иелә-иелә баруы үзе кызык. Үзеңне джунгли эчендә дип хис итәсең.* Ф.Садриев. *Түбәндә, сазлыклар арасында, чын-чынлап джунгли җәелеп ята.* Кызыклы география

◊ **Джунгли законы** Ачыктан-ачык көчләү, изү һәм башбаштаклык; законсызлык

**ДЖУТ** *и. санск.* **1.** Юкәчәләр семьялыгыннан, кырыйлары теленмә овал яфраклы, сүсе җиһаз ясауда, әйбер төргәндә һ.б.ш. техник тукымалар җитештерүдә кулланыла торган биек куак, ярымкуак һәм үләнчел берьеллык үсемлек

**2.** *с. мәгъ.* Шул үсемлектән җитештерелгән, шуның сүсеннән, җебеннән эшләнгән. *Джут бау*

**ДЗОТ** *и. рус хәрби* Пуля һәм ядрәләрдән саклану корылмасы (сугыш кырында агач белән балчыктан эшләнгән ут ноктасы)

**ДЗЮДО** *и. яп. спорт* Японнарда джиу-джитсу алымнарына нигезләнеп барлыкка килгән, спортның махсус бер төренә әверелгән ирекле стильдәге милли көрәш. *[Хәбил] Дзюдо буенча авыр үлчәүдә Европа чемпионы исемен яулый.* Шәһри Казан

**ДЗЮДОЧЫ** *и. спорт* Дзюдо белән шөгыльләнүче спортчы; көрәшче. *Укучыларга газета, бонус сыйфатында, дзюдочы Тедди Ринерның төсле фотосурәтен дә бүләк итә.* Шәһри Казан. *Беренче алтын медаль хуҗасы – дзюдочы Арсен Галстян.* Кызыл таң

**ДИ-** *гр.* «Ике», «икеле» дигәнне белдерә торган алкушымча (мәс.: *диалог, дилемма*)

**ДИАБАЗ** *и. гр. геол.* 1) Башлыча, юлга түшәү материалы сыйфатында кулланыла торган каты тау токымының бер төре

2) Составында шундый токым булган, шундый токымнан торган тау, кыя һ.б.ш. турында

**ДИАБЕТ** *и. гр. мед.* Организмнан сидекнең артык күп бүленеп чыгуына һәм бик нык сусауга бәйле авыруларның гомуми атамасы. *Индометацин һәм кан басымын төшерә торган препаратлар кабул итү нәкъ менә яралгының йөрәген зәгыйфьләндерә дә инде. Йөкле хатын-кызның шикәр диабеты белән авыруы да шундый ук нәтиҗәгә китерергә мөмкин.* Юлдаш

**ДИАБЕ́ТИК** *и. рус сөйл.* **1.** Диабет белән авыручы кеше. *Коры мунча диабетиклар өчен аеручы шифалы.* Сәламәтлек календаре

**2.** *с. мәгъ.* Диабетка мөнәсәбәтле, бәйләнешле. *Диабетик препаратлар*

**ДИА́ГНОЗ** *и. гр. мед.* 1) Авыру һәм авыру кешенең хәле турында табиб ясаган нәтиҗә. *Аннары аның диагноз куюларына гына игътибар итегез сез, тулы консилиумның бер читтә торсын...* М.Хәсәнов. *Кан анализы, яралгы тирәсендәге сыекчаны тикшерү һәм башка методлар диагнозны үз вакытында куярга мөмкинлек бирә.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Ул, диагнозны язып, абыйсына машина белән сырхауханәгә алып барырга куша.* Сөембикә

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса төп характерын, асылын, эчтәлеген ача торган күрсәткеч; бәяләмә. *Яшәргә ашыгып сусау! Бөтенесенә һәм бернинди көч куймыйча ия булырга омтылу... Мөгаен, истериялелек буенча алда баручы бөтен Россиянең универсаль диагнозыдыр бу.* Татарстан

3) *күч.* Нинди дә булса мәсьәләгә һ.б.ш. карата бирелгән ачыклау, аңлатма; юрама. *Гайшә карчыкның диагнозы бәхәссез булды: – Мәет инде ул Гыйззәтулла, мәет...* М.Мәһдиев

**ДИАГНОСТ** *и. рус* Диагноз куя торган табиб. *Бүген Айгөл Галиәкбәрованың табиб буларак өч белгечлеге бар: травматолог-ортопед, терапевт һәм фунциональ диагност (ЭКГ белгече).* Кызыл таң. *Диагност һәм хирург кебек, безгә ялгышырга ярамый: көн саен өстәлләргә килә торган ризыкның сыйфаты өчен җавап бирәбез.* Якты юл

**ДИАГНО́СТИК** *с.* Диагностикага мөнәсәбәтле. *Диагностик ысуллар*

**ДИАГНО́СТИКА** *и. гр.* 1) Медицинаның диагноз кую ысулларын, алымнарын, чараларын өйрәнү тармагы. *Профилактика чаралары һәм иртә диагностика гомерне саклап калырга ярдәм итә.* Юлдаш

2) Диагноз кую эше

**ДИАГОНАЛЬ** *и. лат.* **1.** 1) *геом.* Күппочмакның янәшә булмаган ике түбәсен, күпкырлыкның бер яссылыкта ятмаган ике түбәсен тоташтыра торган туры сызык

2) Кыйгач сырлы тыгыз тукыма

**2.** *с. мәгъ.* 1) Диагональ юнәлештәге, диагональ рәвешендәге (сызык, юнәлеш һ.б. турында)

2) Диагональдән (*2 мәгъ.*) тегелгән. *Диагональ костюм*

**ДИАГРА́ММА** *и. гр.* Нинди дә булса зурлыкларның тиңдәшлеген исәпләп күрсәтә торган сызым, схема. *Физика, химия, география дәресләрендә укучылар формулалар белән танышалар, төрле зурлыкларны исәплиләр, схема, таблица, диаграмма төзиләр.* Мәгариф. *Америка галиме Д.Симпсон диаграммасында, Кояш активлыгы дәрәҗәсе тиз һәм кискен алышынганда, җир тетрәүләрнең ешрак булуы күренә.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИАДЕ́МА** *и. гр. тар.* 1) Патша хакимиятенең символын белдерә торган, асылташлар белән бизәлгән махсус баш бәйләме яки башка киелә торган металл кыршау; таҗ. *Бриллиант диадема*

2) Хатын-кызлар өчен ачык таҗ рәвешендәге кыйммәтле бизәнү әйбере

**ДИАКРИ́ТИК** *с. лингв.* Хәрефнең өстенә яки астына өстәлеп, авазларның укылышын төгәл ачыклап күрсәтә торган (график билге, тамга). *Бу таш текстында да диакритик билгеләр һәм башка палеографик үзенчәлекләр бар.* Гасырлар авазы. *Болгар һәм Алтын Урда чоры кабер ташларындагы язуларда бик еш, ә Казан ханлыгы дәвере ташларында сирәгрәк кулланылган аерым бер төрле диакритик билгеләр («дәл», «ра» һәм «тый» хәрефләре астына берәр нокта кую күренеше) бу ташъязмада да бар.* Татардагы ташлар тарихы

**ДИАЛЕКТ** *и. гр. лингв.* 1) Фонетик, морфологик, лексик һ.б.ш. үзенчәлекләре булган һәм сөйләм телендә чагыла торган, гомумхалык теленең билгеле бер җирлеккә хас төре. *Тәрәзә каршысыннан гына ике кеше сөйләшеп узды. Ләкин бу нинди сәер диалект икән соң?..* М.Хуҗин. *Себер татарлары диалектында «шыпытый» – «чүәк» дигән сүз.* Сөембикә

2) Гомумхалык теленең билгеле бер социаль катламга, төркемгә хас булган формасы. *Буржуазия диалекты*

**ДИАЛЕКТАЛЬ** *с. лингв.* Диалектка мөнәсәбәтле, диалектка караган, диалектка хас булган. *Шулай да куанычлы: соңгы еллар әдәбиятында персонаж сөйләшендә генә түгел, автор сөйләмендә дә, җирле төбәк колоритын бирү өчен, диалекталь сүзләр куллану арта бара.* Казан утлары

**ДИАЛЕКТИЗМ** *и. гр. лингв.* Әдәбиятта, әдәби сөйләмдә кулланыла торган диалекталь сүз, фраза яки форма. *Дастанның сюжетындагы тарихи ономастика, борынгы лексика һәм диалектизм үрнәкләре әсәрнең типик Себер әсәре буларак үзенчәлекләрен тәшкил итәләр.* М.Әхмәтҗанов

**ДИАЛЕ́КТИК** I *и. гр.* Диалектик методлар белән эш итүче, диалектик фәлсәфә тарафдары

**ДИАЛЕ́КТИК** II *с.* 1) Диалектика (*1 мәгъ.*) законнары нигезендә була, үсә, тормышка ашырыла торган (*процесслар, күренешләр, вакыйгалар*)

2) Диалектикага (*2 мәгъ.*) мөнәсәбәтле; диалектикага нигезләнгән. *Язылган монографиянең методологик нигезе җәмгыятьнең диалектик үсеше турындагы өйрәтүләргә таянып эшләнде.* М.Әхмәтҗанов

**ДИАЛЕ́КТИКА** *и. гр.* 1) Эчке чыганаклары капма-каршылыклар бергәндә һәм көрәшендә чагылган, табигать, кешелек җәмгыяте һәм фикерләү үсешенең гомум законнары турындагы фәлсәфи тәгълимат; чынбарлыкны танып белү һәм үзгәртеп кору теориясе һәм методы. *Ә һәр момент җиңү генә була алмый! Диалектикадан моны беләбез.* Х.Камалов. *Танып белү процессының диалектикасы шундый: фән, танып беленгәннең чикләрен даими рәвештә киңәйтеп, тикшеренүче алдына җавап көтә торган яңаданяңа мәсьәләләр куя.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Табигатьтә, җәмгыятьтә, фикерләүдә булган үсеш-хәрәкәт процессы. *Шөкер, әле тормыш-хәятның үз диалектикасы, үз мантыйгы-логикасы бар шул.* Ф.Дунай

**ДИАЛЕКТО́ЛОГ** *и. гр.-лат.* Диалектология белгече. *[Д.М. Исхаков] Остякларны пермь татарларының бабалары дип саный, диалектологларның, этнографларның хезмәтләрен һәм башка әдәбиятны, архив документларын да файдаланып, Урал алды территориясендә XVII гасырга хәтле иштәк-остяк кабиләсе яшәгән дип исбат итә.* Д.Рамазанова. *Һәр диалектологның фәнни хезмәтләрендә кушымта рәвешендә диалектологик сүзлек бирелә бара.* Ф.Сафиуллина

**ДИАЛЕКТОЛО́ГИК** *с.* Диалектологиягә бәйле; диалектологиягә караган. *Татар теленең диалектологик атласы да, беренчедән, пермь сөйләшенең бөтен таралыш территориясендә дә бертөсле булуын, икенчедән, татар теленә каравын, бигрәк тә урта диалект сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтүен дәлилләде.* Д.Рамазанова. *«Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә (1969) бау белән киндерә арасындагы аерма ачык күрсәтелгән: «ишкәч, бау була, борып кына куйгач, киндерә, дибез».* Сөембикә

**ДИАЛЕКТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Тел фәненең диалектларны, сөйләшләрне өйрәнә торган тармагы. *Инсани тикшеренүләрнең барлык мөһим тармаклары: фундаменталь тел гыйлеме,*

*сүзлекчелек, диалектология, --- театр гыйлеме, тасвири һәм музыкаль сәнгать – менә күпме тармак һәм өлкәләрне берләштерә әлеге гыйльми комплекс.* Ватаным Татарстан

**ДИАЛОГ** *и. гр.* 1) *кит.* Ике яки берничә кеше арасында кара-каршы әңгәмә, фикер алышу, сөйләшү. *Берничә минутлык диалог*

2) Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе формасында бирелгән туры сөйләм. *Язма әдәби телдә, бигрәк тә матур әдәбият стилендә, туры сөйләмнең иң күп кулланылган төре – диалог.* Татар грамматикасы

3) Әдәби әсәрнең ике кеше әңгәмәсен сурәтләгән өлеше. *Бу әсәр, темасы, персонажлары, үзенең күп өлешендә нык кына чарланган драматик диалогы ягыннан, аерым тукталуны сорый.* Ф.Хөсни. *Моның өчен әдәби квалификацияне өзлексез күтәрергә, каләмне һаман чарлый торырга, шулай ук сюжет, фабула, тел, диалог, пейзаж кебек форма чараларын да, әлбәттә, нык өйрәнергә ---.* Ф.Хөсни

4) Әңгәмә формасында язылган әдәби әсәр

**ДИАЛО́ГИК** *с.* 1) Ике яки берничә кешенең кара-каршы сөйләше рәвешендәге. *Диалогик формага кыскалык һәм үткенлек биреп, язучы эчке мәгънәле, кинаяле сөйләмгә ирешә ---.* М.Җәләлиева

2) Диалогка хас

**ДИАМАГНЕТИЗМ** *и. гр.* Кайбер җисемнәрнең магнитка тартылмый, ә киресенчә, аннан читкә этәрелү үзлеге; *кирес*е: **магнетизм**. *Алтынга диамагнетизм хас*

**ДИАМАГНЕ́ТИК** *с.* Диамагнетизмга мөнәсәбәте булган. *Магнитка тартылмый, аннан читкә этәрелә торган матдәләр дә бар. Көмеш, висмут, мәсәлән, шундыйларга керә. Болар – диамагнетиклар.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Висмутта яисә алтында барысы да киресенчә: магнитның төньяк полюсы янында – төньяк полюс, ә көньяк полюсы янында көньяк полюс барлыкка килә. Менә ни өчен диамагнетиклар магниттан читкә этәреләләр.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИАМАТ** *и. рус сөйл.* Диалектик материализм. *Ә диаматтан имтиханны миннән Казбек Гыйззәтов алды.* Р.Миңнуллин

**ДИА́МЕТР** *и. гр. мат.* 1) Әйләнәнең (гомумән түгәрәк әйбернең) үзәгеннән үтеп, аның ике ноктасын тоташтыра торган туры сызык; әйләнә үзәгеннән үтә торган хорда

2) Теләсә нинди түгәрәк яки түгәрәк сыман булган җисемнең, сыешлыкның, савытның, мәйданның иңе, аркылысы. --- *диаметры кырык сантиметр чамасы, алты кило авырлыгындагы түгәрәк ипи, өсте кызарып, бераз ялтырап тора...* М.Мәһдиев. *Мексикадагы Санта Мария де Туле авылы зиратындагы гигант кипарис иң карт агачларның берсе санала. Бу агач әле гөрләп үсеп утыра; кәүсәсенең диаметры – уналты метр; аны егерме кеше көчкә колачлый.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИАМЕТРАЛЬ** *с.* 1) *мат.* Диаметр сызыгы буенча урталай бүлгән. *Диаметраль өслек*

2) *күч. Каршы, капма-каршы, капма-каршы кую* һ.б.ш. сүзләр янәшәсендә «бөтенләй», «тулысынча» кебек төшенчәләрне белдерә. *Әмма, шулай да, яңа әдәбиятка иске әдәби мирасны диаметраль капма-каршы куюы, искене сүздә булса да бөтенләй инкяр итүе белән, Г.Тукай үзенең теоретик әзерлеге йомшаклыгын күрсәтә дә.* Ф.Фәсиев. *Мин Гази Кашшафның һәр искәрмәсе бәхәссез дип уйламыйм, чөнки аңа диаметраль каршы фикерләр дә ишетәм.* А.Расих

**ДИАПАЗОН** *и. гр.* 1) *муз.* Музыкаль уен коралы яки җырлаучының төрле югарылыктагы авазларны чыгара алу мөмкинлеге дәрәҗәсе. *Күпләр өчен җыр башта хобби була да, шул мавыгу соңгарак профессиягә әйләнеп китә. Югыйсә, укыган булсалар, диапазоннары киңәеп китәр иде.* Акчарлак

2) *махс.* Физик күренешнең, нинди дә булса җисемнең хәрәкәт-тәэсир зонасы. *Психик яктан сәламәт кешеләр белән махсус үткәрелгән тәҗрибәләр дә шуны күрсәтә: билгеле бер диапазондагы электромагнитик нурланышлар тавыш тоюны китереп чыгарырга мөмкин.* Могҗизалар энциклопедиясе

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса таралу чиге; күләме, колачы, киңлеге. *Ә.Еникинең иҗат диапазоны киңлеге, психология процессларын оста тасвирлавы тәрҗемә эшендә дә ачык чагыла.* Казан утлары

**ДИАПОЗИТИВ** *и. гр.* Махсус проекцион җайланмалар ярдәмендә күрсәтелә торган үтә күренмәле плёнка яки пыялага төшерелгән төсле фотосурәт

**ДИАСКОП** *и. гр.* Үтә күренмәле материалдагы (плёнкадагы) сурәтләрне (диапозитивларны, диафильмнарны), зурайтып, экранга төшерә торган оптик-механик прибор

**ДИА́СПОРА** *и. гр. кит.* Үз илләреннән**,** тарихи Ватаннарыннан читтә яшәүче бер милләттән булган кешеләр; шундый этник җәмгыятьнең бер өлеше. *Милли мәҗлес Татарстанга кагылышлы мәсьәләләр белән генә түгел, гомумән, читтә яшәүче татарлар диаспорасы белән дә эш итәргә җыена.* Мирас

**ДИАПРОЕ́КТОР** *и. гр. к.* **диаскоп**. *Төрле экспонатлар, диапроектор, фильмоскоп, кинопроектор, магнитофон ише әсбапларны җыештырып йөрүче укучыларның тәэсирләнүдән шау-гөр килүләре дә [Григорий Ивановичның] уйлары агышын бозмады.* Җ.Рәхимов

**ДИА́СТОЛА** *и. гр. мед.* Йөрәк мускулының йомшару фазасы. *Кан басымын үлчәгәндә, ике сан языла: беренчесе – система, ягъни йөрәк кысылу, икенчесе – диастола басымы.* Татар мөселман халык календаре

**ДИАТЕЗ** *и. гр. мед.* Организмның кайбер авыруларга бирешүчәнлеге, каршы тора алмавы. *Аналары аны орышалар: «Баллыны күп ашатасың, диатез булуы бар», – диләр.* С.Шәмси

**ДИАФИЛЬМ** *и. гр.* Диапозитивлардан төзелгән фильм. *Марина Викторовна һәрвакыт диярлек үзе белән диафильмнар алып килә. Больницада врачлар юграк чакка туры килсә, палата саен кереп, урыннарыннан тора алмаган авыруларга шул диафильмнарын күрсәтеп йөри.* Ф.Яруллин

**ДИАФРА́ГМА** *и. гр.* 1) *анат.* Имезүчеләрдә күкрәк куышлыгы белән корсак куышлыгы арасындагы яры, юка мускул катлавы, пәрдә. *Диафрагма ике функция башкара: очкылык тотканда һәм сулыш алуда катнаша. Очкылык тоту газлар җыелу галәмәтеннән була дип уйларга ярамый, ул диафрагманың, контроль югалтуы аркасында, ритмны бозып кыскаруыннан барлыкка килә. Диафрагма аша иң эре кан юллары – аорта, вена --- үтә.* Юлдаш

2) *махс.* Оптик аппаратта (фотоаппаратта һ.б.ш.) яктылык нурларының үтү юлын киңәйтү һәм тарайту өчен куелган җайланма

**ДИАХРО́НИК** *с. лингв.* Диахрониягә мөнәсәбәтле, диахрониягә караган. *Диахроник фонология*

**ДИАХРОНИ́Я** *и. гр. лингв.* Аерым тел күренешләренең үсешендә тарихи эзлеклелек һәм тел системасының, лингвистик өйрәнүнең бер предметы буларак, гомуми үсеше; *киресе:* **синхрония**. *Татар телен диахрониядә һәм синхрониядә өйрәнү*

**ДИБАҖӘ** *и. гар. иск.* Китаптагы кереш сүз. *Җәгъфәр --- шул вакытта ук кылт итеп элгәреге болгарларда фәннәр укылмавы, төрле фәннән, төрле гыйлемнән төрле китапларның (дибаҗә) башлары гына укылуы исенә төште дә теге язуның да шул китапларның исеме икәнлеген белде.* Г.Исхакый

**ДИБАШӘ** *и. гар. иск. к.* **дибаҗә**

**ДИВАН** I *и. фар. иск.* 1) Төркия солтаны каршында: югары дәрәҗәдәге кешеләрдән төзелгән, киңәш хокукы булган совет, мәҗлес. *Хан карамагында диван (совет) булган.* Г.Дәүләтшин

2) Шушы мәҗлеснең кешеләре җыелышып киңәшә торган зал; диванханә. *Берничә палатадан торган диванга ханның якын туганнары, уллары, илнең югары феодаль, гаскәри, дини катламы кергән.* Г.Дәүләтшин

**ДИВАН** II *и. фар. иск. кит.* Урта һәм Якын Көнчыгыш халыклары әдәбиятында: җыентык, тупланма, китап. *«Диван...»дагы мәкаль-әйтемнәрнең күпчелеге шул килеш тә, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр алып та хәзерге төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә кулланылуын дәвам итәләр.* Әдәбият

**ДИВАН** III *и. фар.* Сөялеп утыру һәм яту өчен эшләнгән артлы һәм янлы, зур йомшак җиһаз. *Сул якта зал. Анда телевизор, сервант, китап киштәләре, бер диван һәм дүрт-биш урындыктан бүтән әйбер юк.* Ф.Садриев

**ДИВАНА** *с. фар.* **1.** 1) Аңгыра, юләр, башсыз; акылдан язган. *[Кызлар:] – Газиз агай! Газиз агай килгән! – дип, сөенешеп шаулаша башладылар. Бөтен тирә-якка билгеле бер дивана иде бу.* М.Галәү. *Авылда күңелсез хәбәрләр йөреп тора әле, улым. Фатыйма әбиеңнең оныгы дивана Зәбирә, кемнәндер алданып, кыз бала тапты.* Х.Мөдәррисова

2) *күч.* Уйламый эш итә торган, аңгыра, башсыз, булдыксыз. *Өлгергән ич, димәгез, Җиләкләргә тимәгез. Миндәй дивана булырсыз, Яшь кызларны сөймәгез!* И.Юзеев

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. *Бу коточкыч фаҗигадән соң, Фәрит диваналар шифаханәсендә ятачак, ләкин аннан чыккач та, эчкечелеген ташламыйча, ахырда агуланып үләчәк.* А.Расих. *Өч көннән соң, тагын да хәле начарая башлагач, Зәбирәне диваналар йортына озаттык.* Х.Мөдәррисова

**ДИВАНАЛАНУ** *ф.* 1) Акылдан язу, дивана булып китү; исәрләнү, юләрләнү

2) *күч.* Уйламыйча, җиңел акыл белән эшләү; юләр булып кылану. *[Вахидов:] Янә ахмак булма, диваналанма! Тирәнрәк уйла, тойгыга бирелмә, акылга кер!* Сөембикә

**Диваналана бару** Торган саен ныграк диваналану

**Диваналана төшү** Бераз диваналану

**Диваналана язу** Аздан гына диваналанмый калу

**Диваналанып бетү** Тәмам, бөтенләй диваналану

**Диваналанып йөрү** Әле, хәзерге вакытта дивана халәтендә булу

**Диваналанып калу** Нинди дә булса шартлардан соң диваналану; диваналанган хәлгә килү

**Диваналанып китү** Кинәт диваналану. *Чибәр кызны күреп, кинәт диваналанып киткән бригадир егет гыйшык-гашрәт сүзләре сөйләп азапланган арада, кибеткә тагын икенче бер дивана килеп керде.* Н.Фәттах

**Диваналанып тору** Диваналанган, юләрләнгән хәлдә булу

**Диваналанып утыру** *к.* **диваналанып тору**. *Дөньясы тәмам түгәрәкләнгән кеше сыман диваналанып утыруын гына күрче син!* М.Хәсәнов

**ДИВАНАЛЫК** *и.* Дивана булу. *Диваналык сыйфаты да картая-картая гына килми, тумыштан ук синдә була да сабый чагыңнан ук үзен сиздерә.* К.Миңлебаев. *Казан әтрафын ярым шат, ярым канга сусау, ярым диваналык илә дәртләнү, каргыш-сүгенү, янау авазлары каплады.* Р.Батулла

**ДИВАН-КАРАВАТ** *и. рус* Аркасы төшерелеп, кровать сыйфатында кулланыла торган диван. *Шул цехта иске, җимерек хәлдәге диван-караватлар, кәнәфи, урындыкларны өр-яңа итеп ясыйлар.* Ирек мәйданы. *Шунысы кызык: биредә диван-караватлар асларында да утлар яна икән.* Кызыл таң. *Тормышны бер марҗа әбинең Киров районындагы Елан тавы итәгенә сыенган, бала караваты белән диван-караватын куйгач, аның читенә аякны салындырып, тезгә дипломат куеп, аның өстенә бер бит кәгазь җәеп мәкаләләр язарлык кына урын калган бүлмәсендә башлыйбыз.* Татарстан яшьләре

**ДИВАН-КӘНӘФИ** *и.* Зур булмаган диван. *Тугыз катлы бер йортның идән астында «Мебель цехы» ачылган, урманнан әле генә кисеп алып кайткан чи усаклардан, дөбердәтеп, диван-кәнәфиләр укмаштыралар.* М.Маликова

**ДИВАН-МӘҖЛЕС** *җый. и. к.* **диван** (I). *[Гәрәй хан:] Гаскәри кешеләргә дәүләт белән идарә итүне бирмәү хәерлерәк булыр, исән-имин сәламәтләнсәм, киләсе диван-мәҗлестә ил белән үзем идарә итә башлармын.* М.Хәбибуллин

**ДИВАНХАНӘ** *и. фар. иск.* Диван (I) сарае, диван җыела торган йорт

**ДИВАР** *и. фар.* 1) Нинди дә булса торак, каралты, бинаның ян корылмасы; стена. *Түшәмнәрен сурәт белән бизәсеннәр, Дүрт диварга төрле рәсем*

*ясасыннар*... Кол Гали. *Диварда алтын рамда Шакирҗанның зур иттереп эшләнгән үз рәсеме, аның бер ягында солтан рәсеме, бер ягында бер урядник рәсеме. Диварларда әллә ничә төрле сәгатьләр*... Г.Исхакый

2) Ныгытма хезмәтен үти торган корылма. *Шул акчаны – ташка, ташларны дивар һәм манараларга әйләндерерлек талантлы архитектор --- кирәк булган.* М.Юныс. *Үзәк хакимият көчле булганга күрә, күп шәһәрләр диварлар белән ныгытылмый.* Г.Дәүләтшин. *Бөтен халык бер булып, җимерелгән дивар урынына тиз арада яңа буралар корып куйганнар.* С.Алишев

3) *күч.* Ниндидер сәбәпләр аркасында барлыкка килгән томан пәрдәсе. *Шундый рәхәт, гәүдәнең авырлыгы юк, берниндИ уй юк, бөтен барлыгыңны шушы яктылык, шушы моңлы көй, шушы син ике якка ярып бара торган көмеш дивар биләгән.* Ф.Садриев

**ДИВЕРСАНТ** *и. фр. к.* **диверсияче**. *Безнең гамьсезлегебез аркасында, Мортаза кебек аферистлар безнең заводта урын табалачак икән, диверсантлар, шпионнарның да урын табулары мөмкин түгелмени?* Р.Ишморат. *Ул [прокурор] бик дәһшәтле итеп башлаган гаепләү речендә Муса белән Алишны язучы маскасы астында Мәскәүдән яшерен җибәрелгән шпион-пропагандистлар итеп, --- Әхмәт Симаевны десант белән ташланган диверсант, немец гаскәре эшелоннарын шартлатучы, хәрби объектларны җимерүче итеп һәм, ахырда, фюрерны үтерергә йөрүче итеп күрсәтте.* Ш.Маннур

**ДИВЕРСИОН** *с.* Диверсия ясаучы яки шуның өчен билгеләнгән; диверсиягә китерә торган. *Анда Недемен диверсион һәм диверсияләргә каршы тору мәктәбен үткән, чит телләр өйрәнгән, радиотапшыруларны тотып алу һәм эфирда эшләү серләренә төшенгән...* Р.Мирхәйдәров

**ДИВЕ́РСИЯ** *и. лат.* 1) Дошманның сизгерлеген какшату һәм аның һөҗүмен төп юнәлешеннән читкә тайпылдыру максаты белән ясалган сугыш хәрәкәте (хәрби манёвр). *[Карабанов:] Сигнал шушы: манёвр сылтавы белән, буш атудан башларга. Бер үк вакытта штатский киемнән, эчтән коралланып, диверсия алып барачакбыз.* Н.Исәнбәт

2) Дошманның хәрби һ.б.ш. әһәмиятле объектларына зарар салу, аларны җимерү, сафтан чыгару эшләре; нинди дә булса илдә башка дәүләт агентлары тарафыннан алып барыла торган җимерү, таркату, корткычлык эшләре. *Россия исә чеченнарның бу финанс диверсиясе тискәре йогынтысын Америкадан алданрак сизәчәк әле, чөнки бүген аның киңлекләрендә «рубль» түгел, ә доллар бәйрәм итә.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Гомумән корткычлык, җимерү, тар-мар итү, нәрсәне дә булса какшату күренеше. *[Вахтёр:] Норманы тутырмау – аңлы рәвештә контрреволюцион корткычлыкны дәвам итү. Экономик диверсия!* И.Салахов

**ДИВЕ́РСИЯЧЕ** *и.* Диверсия ясаучы, диверсияне тормышка ашыручы кеше. *Диверсиячеләрнең эзенә төшү*

**ДИВИДЕНД** *и. лат. махс.* Акционерлар җәмгыятендә табышның акция ияләре арасында ел саен, салган капиталларына бәрабәр бүленә торган өлеше. *Дивиденд алу. Дивиденд күп булу*

**ДИВИЗИОН** *и. лат. хәрби* 1) Кайсы да булса илнең төп сугышчан оешмасы (күпчелек очракта ракета гаскәрендә һәм артиллериядә, сирәгрәк – бронетанк гаскәрендә һәм кавалериядә). *Безнең дивизионнарны укчы полкларга беркеттеләр, һөҗүмгә бергә бардык.* Казан утлары

2) Флотта: бер үк типтагы берничә корабтан торган берләшмә. *Диңгез дивизионы*

**ДИВИ́ЗИЯ** *и. лат.* Төрле дәүләтләрнең барлык төргә караган хәрби оешмаларында (коры җир гаскәрендә, хәрби-һава көчләрендә, хәрби-диңгез флотында) эре тактик берләшмә (һәр дәүләттә һәм һәр чорда төрлечә була). *Һөҗүм алды. Мәскәү фронт командующиен кыса, тегесе – дивизия штабын: «Давай тел», – диләр.* М.Мәһдиев

**ДИДАКТ** *и. гр. сир. к.* **дидактик** (I)

**ДИДАКТИЗМ** *и. гр. кит.* Үгет-нәсыйхәт биреп, турыдан-туры киңәшләр белән үгетләүне генә максат итеп куйган алым; үгет-нәсыйхәтчелек, коры дидактика; вәгазьчелек. *Дидактизмга каршы көрәш*

**ДИДА́КТИК** I *и. гр.* Дидактика белгече. *Бик укымышлы дидактик*

**ДИДА́КТИК** II *с.* 1) Дидактикага караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Дидактик алым. Дидактик карашлар*

2) Коры дидактика, үгет-нәсыйхәт бирү, вәгазьләү сыйфатында, шул формадагы. *Дидактик әдәбият*

**ДИДА́КТИКА** *и. гр.* 1) Педагогикада: укытуның гомуми методлары турындагы тармак. *Югары үсеш алган дидактика*

2) *к.* **дидактизм**

**ДИДЖЕЙ** *и. ингл. к.* **ди-джей**

**ДИ-ДЖЕЙ** *и. ингл.* Дискотекада, яшьләр кичәсендә һ.б.ш. пластинкага, тасмага, дискка яздырылган музыкаль программаны алып баручы кеше; дискжокей. *Шулай бервакыт дустым: «Радиога ди-джейлар чакырыла, конкурс игълан иткәннәр, әйдә, барыйк әле», – дигәч, мин аңа иптәшкә дип кенә барган идем.* Сөембикә

**ДИЕТ-** *гр.* «Диетага бәйле, диетага караган» мәгънәсен белдергән кушма сүзләрнең беренче компоненты. *Диеттуклану*

**ДИЕ́ТА** *и. гр.* 1) Билгеле бер туклану режимы. *Хәзер исә «мода корбаны» дип: а) кием-салым турында гына уйлаучы гламур кызларга; ә) кибет чире йоктырган «шопоголик»ларга; б) диеталар белән еш мавыгучыларга --- әйтәләр.* Шәһри Казан

2) Авыру кешегә билгеләнгән рацион. *Инсульт кичергән кешегә махсус диета билгеләнә. Аерым алганда, үсемлек һәм сөт продуктлары ашарга, тоз һәм шикәрне аз күләмдә генә кулланырга кирәк.* Шәһри Казан

◊ **Диетага утыру** Махсус режим буенча туклана башлау (вакыты төрле озынлыкта булырга мөмкин). *Тазарудан интегүчеләргә аз калорияле диетага утырып изалануның файдасына караганда зыяны күп.* Ватаным Татарстан

**ДИЕ́ТАЛЫ** *с.* Диетик. *Икенчедән, алар салат, аз калорийлы шаурма кебегрәк төрелмә, диеталы эчемлекләр*

*сайлый.* Ватаным Татарстан. *Дженифер Лопеска әверелү серләре яки Диеталы тормыш тормышмы?* Ялкын

**ДИЕТЕ́ТИКА** *и. гр. к.* **диетология.** *Чи кәбестә согы диететикада ашказаны-эчәк ярасы булган авыруларны дәвалаганда кулланыла...* Татар мөселман календаре

**ДИЕ́ТИК** *с.* Диета таләпләренә җавап бирә торган, диета режимына җайлаштырылган. *Диетик туклануда – манный, арпа, тары һ.б. боткалар да файдаланыла.* Татар мөселман календаре. *Авокадо туклыклы, анда авыр майлар юк. Белгечләр исбатлавынча, ул – диетик ризык.* Ватаным Татарстан

**ДИЕТО́ЛОГ** *и. гр.* Диета белгече, диетология белгече. *Минем кызыксынуым чиктән ашты. «Кем икән соң бу? – дип сорадым, үз-үземнән. – Берәр фән кешесеме, врач яки диетолог-мазармы?»* Ф.Садриев. *Без табигый булмаган һәм хәтта зарарлы азыкларны артык күп кулланабыз. Шуңа күрә дөньяның танылган диетологлары Г.Шелтон, Н.Уокер, П.Броггны яки Ю.Андреевның «Три кита здоровья» дигән китабын укып чыгу зыян итмәс.* Юлдаш

**ДИЕТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Дөрес туклану турындагы фән

**ДИЗ-** *гр.* **дис-** алкушымчасының яңгырау тартыклар алдыннан килгәндә кулланыла торган пары (мәс., *дизартрия*)

**ДИЗАЙН** *и. ингл.* Сәнәгать тарафыннан җитештерелгән әйберләрне сәнгатьчә проектлау; сәнгатьчә конструкцияләү, бизәү. *Театрның виртуаль дөньядагы йөзе чынбарлыктагы йөзенә туры килми. Дизайн заманча түгел.* Сәхнә

**ДИЗА́ЙНЕР** *и. ингл.* Сәнәгатьчә җитештерелгән әйберләрне, сәнәгать объектларын, иҗтимагый биналарны, торакларны һ.б.ш. сәнгатьчә проектлау буенча белгеч, рәссам-конструктор. *Алар алтынчы катның иркен баскыч алдына чыктылар. Анда бары тик ике генә квартира ишеге бар һәм икесе дә Константин Николаевичныкы булганга күрә, дизайнер Виленкин аны бик әйбәтләп тәртипкә китереп куйган иде инде.* Р.Мирхәйдәров

**ДИ́ЗЕЛЬ** *и. нем.* Кысылу нәтиҗәсендә ялкынланып эшли торган эчке янулы двигатель. *Промышленностьта инфратавышлар көн саен барлыкка килеп тора. Аларны завод вентиляторлары һәм компрессорлары, дизельләр --- тарата.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Дизель форсажының танк движогына охшаган үкерүе минем күңелемдә Сәйдәшнең рухны күтәрә торган горур, ләкин гаҗәеп аһәңле һәм җанга якын «Совет Армиясе маршы»н уятты.* Казан

**ДИ́ЗЕЛЬЛЕ** *с.* Дизель белән эшли торган, дизеле булган. *Дизельле агрегат. Дизельле механизм*

**ДИ́ЗЕЛЬЧЕ** *и.* Дизельле, дизель моторы булган машинада эшләүче. *Юлымда әле яңа гына «аттырган» скважина янына сугылам. Анда металл шлемнардан бер төркем татар егетләре күренә. Алар – дизельчеләр.* А.Расих

**ДИЗЕНТЕРИ́Я** *и. гр.* Канлы эч китү белән характерлана торган куркыныч йогышлы авыру. *Соңыннан дизентерия башлана. Бикле вагонда дизентерияне күз алдына китереп карагыз...* И.Салахов. *Дизентерия һәм корсак тифы, талпан энцефалиты һәм туляремия, балаларда дифтерия һәм кызамык – барлык бу куркынычлы авырулар Кояш «давылы» вакытында көчәяләр.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИКОБРАЗ** *и. рус зоол.* Кимерүчеләр отрядының бер ыругына караган, тәне озын энәләр (уклар) белән капланган имезүче хайван; уклы керпе. *Дикобразлар Евразия, Африка тропиклары һәм субтропикларының таулы һәм чүлле районнарында яшиләр*

**ДИКТАНТ** *и. лат* Укучыларны хатасыз язарга өйрәтү яки дөрес язу күнекмәләрен тикшерү максатыннан, укытучы тарафыннан әйтеп яздырыла торган язма эш. *Без узган атнада ук ике диктант язган идек.* З.Зәйнуллин

**ДИКТАТ** *и. нем. кит.* Көчле як тарафыннан көчсез якка берсүзсез үтәлү таләбе куелган күрсәтмә. *Дистәләгән еллар дәвамында экономиканың үсеше үзәк диктаты астында барды, һәм аның структурасы республика мәнфәгатьләренә җавап бирмәде.* Мирас

**ДИКТА́ТОР** *и. лат.* 1) Дәүләт белән идарәчелек эшендә чикләнмәгән хокуклардан файдаланучы кеше, дәүләт башлыгы. *Немецның зыялы уллары үзләренең кешелек сыйфатларын бер чакта да югалтып бетермәгәннәр. Әйе, явыз диктатор режимы елларында алар сагайганнар, рәхим-шәфкать нурларын алар курка-курка гына күрсәтә торган булганнар.* Ватаным Татарстан

2) Гомумән хакимлек итәргә яратучы, хакимлек сөючән кеше. *Ул [Әсгать] минем тәнкыйтьне аеруча күтәрә алмый иде. «Син – диктатор», – дия иде миңа.* Р.Хисмәтуллин

**ДИКТА́ТОРЛЫК** *и.* 1) Идарә итү системасы диктатор вазифасында булу. *Халыклар фикере белән санашмаган, киләчәкне бары тик диктаторлык күзлегеннән генә күзәткән И.Сталин әле 1918–1920 елларда ук СССРның җимерелү нигезләрен салып калдыра.* Р.Вәли. *Миңа калса, Рәсәйгә теләсә нинди милли идея, система, идарә итү ысулы килешәчәк: монархия булсынмы ул, социализммы, капитализммы, парламентаризммы, хәтта диктаторлык режимы булса да ярый.* Р.Мирхәйдәров. *Мондый омтылыш идарә итүдә диктаторлык принципларын алга сөрүче дәүләтләрдә генә булуы ихтимал.* Кызыл таң

2) Башкалар белән үз фикерен көчләп тагып, боерып аралашу яки хакимлек итү. *Ә үзе Мәскәү оешмалары, аерым галимнәр белән һәрчак элемтәдә тора, һәркайсы аны, аның эшен, диктаторлык, мафиозлык хәрәкәтләрен дә күрә торып хуплыйлар иде.* Ф.Зыятдинов. *Минем үземә диктаторлык сыйфаты якын түгел.* Ватаным Татарстан. *Ул карап торышка да бик кырыс, хәтта диктаторлык сыйфатларына ия.* Безнең гәҗит

**ДИКТАТУ́РА** *и. лат.* 1) Хакимлек итүче сыйныфка таянып, берни белән чикләнмәгән дәүләт власте һәм шуңа нигезләнгән идарә итү системасы. *Татар-башкортта «крәстиян» халкы күпчелекне тәшкил иткәнгә күрә, пролетариат диктатурасы аңа һичбер файда китермәячәге мәгълүм иде.* Н.Дәүләт

2) Диктаторның идарә системасы, диктаторлык режимы

**ДИ́КТОР** *и. лат.* Радио яки телевизион тапшыруларның текстын микрофон алдында укый яки сөйли торган радио яисә телевидение хезмәткәре. --- *Әминә апа бүгенге көндә телевидениедә диктор һөнәре булмауга да борчыла.* Шәһри Казан

**ДИ́КТОРЛЫК** *и.* Диктор вазифасы; диктор һөнәре. *28 ел дикторлык хезмәт юлы бер көндәй узып та китә.* Ватаным Татарстан

**ДИКТОФОН** *и. лат.* Сөйләгәнне яздыру һәм кабатлап сөйләтү өчен кулланыла торган махсус җайланма, аппарат. *Ул тәрәзә төбендәге диктофонны җибәрде.* Ф.Садриев

**ДИ́КЦИЯ** *и. лат.* Телдә сүзләрнең, иҗекләрнең, басымның дөрес һәм ачык әйтелеш ысулы. *Дикциясе яхшы диктор*

**ДИКЪКАТЬ** *и. гар.* 1) Фикерләү, күрү һәм тыңлау сәләтенең билгеле бер ноктага, берәр нәрсәгә төбәлгән булуы; игътибар. *Тагын да әйтәм, шуның белән бергә бу дәвер, шөбһәсез, иң кыйммәтле, иң дикъкатькә лаек дәвер иде.* Ф.Бурнаш. *Чыннан да каз, башын кырын сала биреп, Иван поварга һәм аның кулындагы зур, үткен кухня пычагына бик дикъкать белән карап тора.* Ә.Еники. *Бу кыз, икенче курста укыганда ук, минем дикъкатемне яулап алды.* М.Юныс

2) *өндәү форм.* Игътибарны көчәйтергә кушып әйтелгәндә кулланыла торган мөрәҗәгать сүзе. *Дикъкать, тамашачылар!*

**ДИКЪКАТЬЛӘП** *рәв.* Дикъкатьне җигеп, дикъкать белән, игътибар белән. *Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә разый булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәңкә акча йибәреңез.* Г.Тукай

**ДИКЪКАТЬЛЕ** *с.* 1) Дикъкате зур булган; күзәтүчән, күңел салучан

2) Игътибар итүчән, игътибарлы, илтифат итүчән. *Әминәнең озак һәм дикъкатьле карашында ошатканлык сизелә иде.* Ф.Әмирхан. *Бу бөек зат [Сафа Гәрәй хан] бездә күптәннән инде үзенең талантлы әдибен, аның дикъкатьле карашын, күңел җылысын көтә иде.* Казан утлары

**ДИКЪКАТЬЛЕЛЕК** *и.* Дикъкатьле булу, дикъкатьле кешегә хас сыйфатлар, игътибарлылык. *Дикъкатьлелек һәрвакыт кирәк*

**ДИКЪКАТЬСЕЗ** *с.* 1) Дикъкате булмаган, күңелен салмаган

2) Игътибарсыз, артык илтифат күрсәтмәгән

**ДИКЪКАТЬСЕЗЛЕК** *и.* 1) Игътибарсызлык. *Драматургны тәнкыйтьлим дип, актёрларның уңышына күз йому – кимендә дикъкатьсезлек.* Р.Батулла

2) Илтифатсызлык, саксызлык

**ДИЛӘНКЕ** *и. рус* Кисү яки чистарту өчен билгеләнгән урман мәйданы. *Бүген-иртәгә диләнкене ачабыз дип тора идек. --- диләнкене ачалар да, кемгә күпме кирәк, кисеп алып китәсең һәм вәссәлам...* Ф.Яхин. *Элек ул кадәр диләнкене пычкы-балта белән эшкәртү шактый кыенга төшсә, хәзер кисентекләрдә Финляндиядән кайтарылган «Харвестер» һәм «Форвардер» техникасы хакимлек итә.* Ватаным Татарстан

**ДИЛБЕГӘ** *и.* 1) Җигелгән ат белән идарә итү өчен, йөгәнгә ике яклап беркетелгән озын бау, каеш яки брезент тасма. *Туры айгыр, җилүдән туктап, акрын адымга күчте. Уралбай шәһәр эчендәге кебек дилбегәне дә йолыккаламый, камчыны да күтәрми, көр тавышы белән җырга мавыккан.* И.Салахов. *Көмеш дилбегә шикелле ялтырап яткан тимер юл ---.* Ә.Еники. *Моны «атлы» уйнарга дип дилбегә ишүче малайлар яхшы белә.* З.Зәйнуллин

2) *күч. гадәттә кыек форм.* Җитәкчелек, хакимият; идарә итү хокукы. *Акыл – дилбегә. Иясе хисләрен контрольдә тота һәм аларга юнәлеш бирә.* Сәламәтлек календаре

◊ **Дилбегә буе** 1) Борынгы озынлык үлчәү берәмлеге – дилбегә озынлыгына тигез ара. *Җыйнак гәүдәле ат күрше колхоз чабышкысын ким дигәндә дилбегә буе артта калдырган иде.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Бик озын. *КамАЗның кадрлар бүлегендә минем кулыма дилбегә буе исемлек тоттырдылар.* С.Таҗетдинов. **Дилбегәне үз кулына алу** Җитәкчелекне үз кулына алу, ныклык күрсәтү. *Ниһаять, ул дилбегәне үз кулына алды.* **Дилбегәне (кулдан) ычкындыру** Йомшаклык күрсәтү, җитәкчелекне йомшарту. *Бу хәлнең озак дәвам итә алмаячагын белгән Савелий Кузьмич кайгысын, газабын читкә куарга тырышты, көймә башы буларак, дилбегәне ычкындырырга ярамый иде.* Ф.Латыйфи

**ДИЛБЕГӘСЕЗ** *с. күч.* Тыйнаксыз, тотнаксыз, котырынкы; үзен контрольдә тотмаган, законга, тәртипкә буйсынмаган. *Татар әдәбиятында еш кына «бозык тәрбияле бер бай» яисә «дилбегәсез Себер сәүдәгәре» рәвешендәрәк сурәтләнгән Мәхмүт байның шәхси юмартлыгыннан да бер мисал китерик.* Л.Хәмидуллин. *Кызганыч, болар – меңгә бер очрый торган хәлләр түгел, дилбегәсез, йөгәнсез дистәләрчә әрәмтамак, беркайда эш тапмыйча, тәмам бозылып бетте инде.* Татарстан яшьләре

**ДИЛЕ́ММА** *и. гр.* 1) *лог.* Икесенең берсен сайлап алу кирәклеге зарур булган, бер-берсен инкяр итә торган ике фикерне, кагыйдәне үз эченә алган хөкем, караш яки нәтиҗә

2) Бер-берсен инкяр итә торган ике мөмкинлекнең кайсын да булса сайлауда бертигез дәрәҗәдә кыен булган халәт, торыш. *Эш дөрес куелганда, үз баегыңны белеп үсү булачак җефетеңә дә, ага-апаңны, туган илеңне ярату кебек үк, дилеммасыз – шикләнүсез мәхәббәт тәрбияләгән.* Юлдаш

**ДИ́ЛЕР** *и. ингл.* 1) Сәүдә эшләрендә арадашлык итүче юридик яки физик зат

2) Биржада яки сәүдә өлкәсендә сатучы һәм сатып алучы арасында арадашчы ролен үтәүче кеше яки фирма; бүлүче. *«КамАЗ», «Хитон», «Мелита», «Чистай сәгать заводы», «Позис» ачык акционерлык җәмгыятьләре һ.б. ның үз дилерлары бар.* Татарстан

**ДИЛЕТАНТ** *и. ит.* Махсус белеме, әзерлеге булмауга карамастан, фән яки сәнгать белән шөгыльләнүче кеше. *Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасындагы Шартнамә турында сәясәтчеләр һәм журналистлар, сәясәт белгечләре һәм икътисадчылар, профессионаллар һәм*

*дилетантлар күп язды һәм язалар әле.* Казан

**ДИЛЕТАНТИЗМ** *и. рус кит.* 1) Тиешле дәрәҗәдә әзерлек булмыйча, фән, сәнгать белән шөгыльләнү, мавыгу

2) *хуплм.* Нәрсәгәдер тиешле махсус белемең булмыйча, өстән генә карау, дилетантлык. *Ләкин мин дилетантизмны яратмыйм.* Татар заманы

**ДИЛЕТАНТЛА́РЧА** *рәв.* Дилетантларга хас, дилетантлар сыман. *Мин үземнең дилетантларча мавыгуымны эчке таләпкә, хаҗәткә санап ялгышканмын.* М.Юныс

**ДИЛЕТАНТЛЫК** *и.* Дилетантка хас сыйфатлар; дилетант булу. *«Галим» исемен йөрткән кайберәүләр, үзләренә генә билгеле сәбәпләр аркасында, нәкъ менә шундый дилетантлыктан ерак китә алмыйча, «татарлар килмешәк монгол-татарлардан килеп чыкканнар» дип раслаучы татар-татар концепциясен тудырганнар.* М.Зәкиев. *«Табигатьне буйсындырырбыз» дигән сүзләр дилетантлык билгесе генә.* М.Әхмәтҗанов

**ДИЛИЖАНС** *и. фр. иск.* Пассажирлар һәм почта йөртү өчен эшләнгән ябык карета (тимер юл һәм автомобиль транспорты үсеш алган чорга кадәр). *--- бер кеше, мәзкүр тарафларга арзан хак илә кеше ташу өчен, дилижанс арбалары йөртергә шәһәрдән рөхсәт алды.* Г.Камал

**ДИЛО́ГИЯ** *и. гр.* Уртак сюжет, уртак эчтәлек белән бәйләнгән, бер үк автор тарафыннан язылган ике роман яки драма әсәре. *Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» һәм «Болганчык еллар» романнары – дилогия*

**ДИМ** I *и. сир.* Үгет, өндәү

**ДИМ** II *и. диал.* Көз айларында яки язын бөтен елга өстен тутырып ага торган вак көпшәк боз; зим

**ДИМӘ́К** *ф. иск. к.* **дию** (I). *«Кил» димәк бар, «ишет» димәк юк.* Мәкаль

**ДИ́МӘК** *кер. сүз* «Шулай булгач», «шулардан чыгып», «шуңа күрә» мәгънәләрендә, фикерне йомгаклап, нәтиҗә ясау буларак кулланыла. *Димәк, мин җүләрләр йортында түгел. Димәк, мин җүләр түгел.* Ф.Бәйрәмова. *Альбинозаның --- юлга чыгасы көне. Димәк, аерылышалар.* Р.Мөхәммәдиев

**ДИМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кешене нәрсәгә дә булса күндерергә тырышу, үгетләү. *– Апа җаным, үзең дә утыр, әйдә, бергә-бергә эчик, – дип, үзе белән янәшәдәге урындыкка утырырга димләде аны Эльмира.* Р.Мөхәммәдиев

2) Кемнедер, өйләнергә яки кияүгә чыгарга тәкъдим итеп, үгетләү. *Үзе димләгән иде шул аны [Зәйтүнәне] Тимерҗанына...* Ә.Еники

**Димләп йөрү** Әле, хәзер димләү белән шөгыльләнү

**Димләп тору** Һаман, һәрвакыт димләү

**ДИМЧЕ** *и.* Кияүгә чыгарга, кәләш алырга, өйләнешергә димләүче кеше. *Димче диңгез кичерер.* Мәкаль. *Күз кырые белән генә бер-берсен күреп калгач, егет димчегә үзенең ризалыгын яисә кире кагуын белдерә.* Казан утлары

**ДИМЧЕЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Димче аркылы өйләнешергә, кияүгә чыгарга тәкъдим ясау. *Димчеләп өйләнештеләр*

2) *к.* **димләү**

**ДИМЧЕЛЕК** *и.* Димче кәсебе, димләү эше. *Бу сүз, күңелдәге теләкне хәбәр рәвешендә сөйләп, димчелек кылу иде.* Г.Ибраһимов

**ДИН** *и. гар.* 1) Аллаһы Тәгаләнең, гомумән, нинди дә булса югары көчләрнең чынлап та булуына, барлыгына ышану, инану белән бәйле халәт; *русчасы:* **вера.** *Укучылар арасында милли мәдәният, тарих, ислам дине белән кызыксынучылар саны күп.* А.Низамов

2) Алла, фәрештә, төрле рухларның һ.б.ш. табигатьтән өстен көчләрнең булуына ышануга нигезләнгән карашлар, күзаллаулар системасы; *русчасы:* **религия.** *Ул инде ялгыз инсаниятнең бер кисәгенә, үзе илә гайн каннан, гайн диннән булган бер кыйемене генә түгел, бөтен мәзлум --- ач-ялангач әксәриятенә хезмәт итмәк булды.* Й.Акчура

3) Кайсы да булса диндәге руханиларның һәм дин тотучыларның дини оешмасы. *Дин белән хөкүмәт бәйләнеше*

◊ **Дин дошманы** *иск.* 1) Теге яки бу дини кануннарга, дини тәгълиматка гомумән каршы булган кеше; 2) Теге яки бу дингә, яисә шул динне тотучыларга каршы булган башка дин кешесе. **Дин кардәше** Бер диндәге кеше, диндәш. *--- Себер-йортыбызны кяферләрдән сакларга кирәк, милләттәшләр, дин кардәшләр!* Ф.Бәйрәмова. **Диннән язу** Динсез булу, диннән ваз кичү. *Диннән язу – деннән язу.* Әйтем. **Дин тоту** Дингә ышанып, дини йолаларны үтәү

**ДИ́НА** *и. гр.* Механикада; бер грамм массага секундына бер см тизләнеш бирә торган көчне үлчәү берәмлеге

**ДИНАМИЗМ** *и. гр.* Хәрәкәт, гамәлләр ешлыгы. *Диалогларны автор сүзләреннән башка бирү фикерне тыгызлый, хикәяләрне кискенләштерә, динамизмны арттыра.* Ф.Сафиуллина

**ДИНА́МИК** I *и. рус* Электродинамик репродуктор. *Марс өстәле янындагы тәбәнәк тумбочка өстендә торган динамигының кнопкасына басты.* М.Хәсәнов. *[Тикшерүчеләр] биокырларны тотып алучы приборны көчәйткеч аркылы динамикка тоташтырдылар, һәм аларның тавышлары яңгырады.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИНА́МИК** II *с.* 1) Электродинамик репродукторга мөнәсәбәтле, шуңа нигезләнгән. *Динамик механизм*

2) *кит.* Динамикалы, үзгәрешләргә яки хәрәкәтләргә бай булган. *Тотрыклы эшләүче агропромышленность комплексы, шәһәрдә һәм авылда милекчеләр сыйныфының динамик формалашуы – базар мөнәсәбәтләренә тотрыклы керү нәтиҗәсе.* Татарстан

**ДИНА́МИКА** *и. гр.* 1) Механиканың көч тәэсирендә барлыкка килгән хәрәкәт законнарын өйрәнә торган бүлеге. *Механизмнар динамикасы. Динамика теориясе*

2) Берәр нәрсәнең хәрәкәте, үзгәреше, үсеше. *Дәүләт бюджеты динамикасы*

**ДИНА́МИКАЛЫ** *с. к.* **динамик** II (*2 мәгъ.*). *Динамикалы үсеш*

**ДИНА́МИКАЛЫЛЫК** *и.* Динамикалы булу. *Законнар чыгару процессының динамикалылыгы*

**ДИНАМИТ** *и. гр.* Нитроглицериннан һәм төрле өстәмәләрдән (инерт матдәләр, ягулыклар, кайбер нитратлар) торган шартлагыч матдә. *Динамит тавышы*

**ДИНАМИТЛЫ** *и.* Динамиты булган

**ДИНАМИТЧЫ** *и.* Динамит белән шартлату белгече, шул эшнең остасы. *Динамитчы террористны кулга алу*

**ДИНА́МО** *и. гр. к.* **динамомашина**. *[Якуп] Үзләренең электр станцияләренә динамомашина табып кайтырга тиеш! Якупның динамосыз кайтып керергә хакы юк!* И.Гази

**ДИНАМО-** *гр.* Физикада: кушма сүз белән белдерелгән терминнарда «көч», «көчкә мөнәсәбәтле» дигән төшенчәне белдерә торган беренче кисәк (мәс., *динамограмма, динамокардиография*)

**ДИНАМОМАШИ́НА** *и. гр.-лат. иск.* Электр тогы эшләп чыгара торган машина, өзлексез даими ток генераторы. *[Якуп] Үзләренең электр станцияләренә динамомашина табып кайтырга тиеш! Якупның динамосыз кайтып керергә хакы юк!* И.Гази

**ДИНАМО́МЕТР** *и. гр. физ.* Көч зурлыгын үлчәү приборы, көч үлчәгеч. *Кул динамометры. Пружиналы динамометр*

**ДИНАМОМЕ́ТРИЯ** *и. гр. физ.* Махсус әсбап белән егәрлекне үлчәү

**ДИНАР** *и. лат.* Кайбер илләрдәге (нигездә Көнчыгыш гарәп илләрендә) акча берәмлеге. *Икенче көнне иртән 4–5 кешелек төркемнәргә бүлендек – җитәкчебез безгә кибетләрне урап кайтырга тәкъдим итте. Әүвәл, банкка кереп, долларларны иордан динарларына алыштырып чыгарга кирәк иде.* Идел

**ДИНА́РИЙ** *и. гр. тар.* Борынгы Римда көмеш тәңкә

**ДИНА́СТИЯ** *и. гр.* 1) Бер үк нәселдән булып, идарә системасында берсен икенчесе алыштыручы монархлар (*императорлар, корольләр, шаһлар һ.б.ш.*). *Ике гасырга сузылган династия*

2) *күч. сөйл.* Бер төрле эшне, кәсепне дәвам итүчеләр нәселе. *Киләчәктә, бәлкем, врач Хәбибуллиннар династиясе турында сөйләргә мөмкин булыр.* Яшәү яме

**ДИНА́СТИЯЧЕЛ** *с.* Династия яклы, династия мәнфәгатьләрен яклауга корылган. *Династиячел никах*

**ДИ́НГО** *и. ингл. зоол.* Австралиядә көтү-көтү булып яши торган, көрән яки җирән төстәге кыргый эт. *Динго турындагы китап. Динго аулау*

**ДИНДАР** *с. фар. к.* **динле**. *Артык диндар кеше түгел ул, әмма намазлык өстендә дисбе тартып утыруының үз рәхәте, җанга тынычлык биргеч хасияте бар.* Ф.Латыйфи

**ДИНДАРЛАНУ** *ф.* 1) Диндарга әйләнү, диндар булып китү. *Әмма бу охшашлыкка карап кына, хатадан хали булмаган адәм баласы, үтә диндарланып, Болгар җыенын кире кагарга тиеш түгел, миңа калса.* Ватаным Татарстан

2) Динле булып кылану, суфыйлану

**Диндарлана бару** Көннән-көн ныграк диндарлану; акрынлап диндарлыгы арту

**Диндарлана башлау** Диндарланырга тотыну

**Диндарлана төшү** Бераз диндарлыгы арту

**Диндарланып бетү** Тәмам диндарлану, бөтенләй диндарга әйләнү

**Диндарланып җитү** *к.* **диндарланып бетү**

**Диндарланып китү** Нинди дә булса этәргеч сәбәптән соң диндарга әйләнү

**ДИНДАРЛЫК** *и.* Динилек; диндар кешегә хас сыйфатлар, карашлар. *Алар диндарлыклары белән сату итеп һәм үзләрен яклаучылар итеп күрсәтеп, кешеләрне алдаучыларны фаш итәләр.* Татар мөселман календаре

**ДИНДӘШ** *и.* Бер үк диндәге кешеләр; бер үк диндә булган ике яки берничә кешенең берсе. *Бинаны җиткезү өчен, Мәскәү эшкуары, диндәшебез һәм милләттәшебез Рәшит Баязитов үз хәләлен күп кертте.* Татар мөселман календаре

**ДИНДӘШЛЕК** *и.* Кем белән булса да бер үк диндә булу, бер үк дин тоту

**ДИНИ** *с. гар.* 1) Дингә бәйле карашлар белән сугарылган; дингә ышануга нигезләнгән. *Татар әдәбияты да бу иҗтимагый көрәшнең бер тәртәсенә җигелде һәм сәхнә аша тарихи җәһаләт, милли тәгассый, дини хорафатлардан шаркылдап көлү, --- кызларның азатлыкка чыгу хәрәкәтләрен җырлый, мактый башлады.* Ф.Бурнаш

2) Дин исеменнән эшләнгән; дингә караган, дингә мөнәсәбәтле, дин белән бәйле. *Дини бәйрәмнәребез дә, милли бәйрәмнәребез дә – милләтнең тотанагы, аның яшәеш чаралары.* Татар мөселман календаре. *Шуңа мөнәсәбәттә уйгур телендә күп кенә дини китаплар да тәрҗемә ителә.* Әдәбият

3) *к.* **динле**. *Муллахмәт абзый – --- дини карт, атын ашатып кергәч, намаз уку белән мәшгуль.* Г.Галиев

**ДИНИЯ** *и. гар.* Дини. *Әгәр ул Казан мөфтиятенә китсә, бу Татарстан Диния нәзарәте өчен зур югалту булачак иде.* Безнең гәҗит

**ДИНИЯ́ НӘЗАРӘТЕ** *и.* Мөселманнарның мөфти җитәкчелегендәге югары дин идарәсе. *Диния нәзарәтенең карарлары мөселман руханиларына һәм дин тотучыларга мөфти имзасы белән җиткерелә.* Татар иле

**ДИНЛЕ** *с.* **1.** Дин тоткан, дингә ышанучан, иманлы, Аллаһны таныган. *Бала шәһәргә чын татар булып, тәрбияле, рухи яктан ныклы, иманлы, динле, белемле, әзерлекле зыялы булып килергә тиеш.* Р.Миңнуллин

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Динле белән динсезләр сугышын аңлап та була.* Р.Миңнуллин

**ДИНЛЕЛЕК** *и.* Динле булу, дин таләпләрен җиренә җиткереп үтәп бару. *Бу инде – динлелек бары тик телдә генә, ә менә йөрәктә иман зәгыйфьләгән күрсәткән мисал.* Безнең гәҗит

**ДИНОЗАВР** *и. гр.* Мезозой эрасы вакытында яшәп, хәзер үлеп беткән, бик зур гәүдәле, ит яки үлән белән туклана торган сөйрәлүче хайваннарның бер төре. *Кытай галимнәре каурый белән капланган дүрт канатлы яңа динозаврларның скелетын табулары турында хәбәр иттеләр.* Мәдәни җомга

**ДИНСЕЗ** *с.* **1.** Дин тотмаган, дингә ышанмаган; Аллаһның барлыгын һәм берлеген танымаган. *Динсез идем, Шуның өчен дә бит Әткәй мескен кулын ташлады ---.* Һ.Такташ. *Динсез яшәүнең һәлакәт икәнен аңлап, бүген хөкүмәт тә дин тотарга бөтен*

*мөмкинлекләрне дә диярлек бирде.* Татар мөселман календаре

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Динле белән динсезләр сугышын аңлап та була.* Р.Миңнуллин

**ДИНСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Динсезгә әйләнү, дингә ышанмый башлау. *Динсезләнгән сәясәтчеләр*

2) *күч. гади с.* Явызлану, әшәкегә әйләнү, бозылу

**Динсезләнә бару** Акрынлап динсезгә әйләнү

**Динсезләнә төшү** Динсезләнү тагы да арту

**Динсезләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй динсезләнү

**ДИНСЕЗЛЕК** *и.* Динсез булу, Аллаһны танымау. *Малайның укытучыга ачуы килде, динсезлек белән әхлаксызлыкның якын йөрүен, бәлки, ул шунда аңлый башлагандыр.* З.Мурсиев

**ДИ́НЧӘ** *рәв.* 1) Дин кушканча, дин таләпләрен төгәл үтәп. *Динчә тәрбия*

2) Диндә кабул ителгәнчә. *Динчә әйткәндә*

**ДИНЧЕ** *и.* **1.** Дини оешмаларның берсендә хезмәт итүче; рухани. *Имтом, өшкерү-төкерү белән, гадәттә, динчеләр шөгыльләнгән.* Ислам

**2.** *с. мәгъ.* Динле. *Динче кеше. Динче бабай*

**ДИНЧЕЛ** *с.* Дин тоткан, диндар. *Бик динчел карт*

**ДИНЧЕЛЕК** *и.* Динне яклау, дини таләпләрне алга сөрү; дингә ышанучанлык, дини карашлар. *Башта миндә динчелек ифрат көчле иде.* А.Алиш

**ДИНЧЕЛЛӘНҮ** *ф.* Динчелгә әйләнү, динчел булып китү. *Барыбызга да динчелләнергә вакыт*

**Динчелләнә бару** Акрынлап динчел кешегә әйләнү, динчел булып китү

**Динчелләнә төшү** Тагы да динчелләнү

**Динчелләнеп бетү** Бик нык динчел булып китү, тәмам динчелләнү

**ДИНЧЕЛЛЕК** *и. к.* **динлелек**

**ДИҢ-ДИҢ** *иярт.* **1.** Кечкенә кыңгырау, гомумән, вак металл әйберләр бер-берсенә бәрелгәндә яки вак металл әйберләргә бәргәндә ишетелгән һ.б.ш. югары тондагы нечкә тавышларны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. *Сәгать җырлый «диң-диң»!* М.Җәлил

**ДИҢГЕЗ** *и.* 1) Дөнья океанының коры җир, су асты калкулыклары белән әйләндереп алынган бер өлеше. *Боз таулары арасында һәм диңгез уртасында менә дигән бер кечкенә шәһәр төзеделәр.* А.Алиш. *Илнең көнчыгыш ягында, Зур тауларның аръягында Бар бер зур диңгез.* Ә.Исхак

2) Әчкелтем тозлы сулы зур сулык

3) *күч. гадәттә тарт. форм.* Күп урын, зур мәйдан биләп торган, күплекне белдергән объект. *Бу якта аллыгөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үзалдына дулкынланып тора – болар хатын-кызлар.* Г.Ибраһимов. *Сыздыр тагын, моңга бай син, син – көйләрнең диңгезе.* Ә.Ерикәй. *Көн арты көн уза торды, аларның һәрберсе аны нәфрәт диңгезенең эченәрәк сөйрәделәр.* Ф.Садриев

◊ **Диңгездән бер тамчы** Бик аз дәрәҗәдә. **Диңгез кормаган** *диал.* Нигез кормаган, гаилә булдырмаган. **Диңгез тубыктан** Ваемсызлык, гафиллек, бернәрсәгә дә ис китмәү күренеше. *--- ярты сәгать дигәндә, Гүзәлгә диңгез тубыктан иде инде.* Г.Гобәй. **Диңгез якасында торып сусау** Мөмкинлекләрдән файдалана белмәү. *Диңгез якасында торып, без сусамыйк. Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.* Г.Тукай

**ДИҢГЕ́З АВЫРУЫ** *и.* Транспортта тирбәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән халәт: баш әйләнү, күңел болгану, баш авырту һ.б.ш.

**ДИҢГЕ́З АРСЛАНЫ** *и.* Колаклы тюленьнәр семьялыгыннан, гәүдә озынлыгы 2 метрга кадәр, авырлыгы 300 килога кадәр булган, ялтырап торган куе кара йонлы, бик җитез, хәрәкәтчән диңгез хайваны; *русчасы*: **морской лев**

**ДИҢГЕ́З ЙОЛДЫЗЫ** *и.* Тәненең үзәгеннән як-якка чыгып торган энәләре белән бераз йолдызны хәтерләткән, энәтиреләләр тибыннан булган умырткасыз диңгез хайваны; *русчасы*: **морская звезда**

**ДИҢГЕ́З КӘБЕСТӘСЕ** *и.* Ашарга яраклы һәм дару ясауда киң кулланыла торган диңгез суүсемнәренең бер төре; *русчасы:* **ламинарий.** *Йод океан балыгында, диңгез кәбестәсендә, кызыл чөгендер, суган, кавын, шалкан, җир җиләгендә күп.* Татар мөселман календаре

**ДИҢГЕ́З КЕРПЕСЕ** *и.* Тышкы кыяфәте белән керпене хәтерләтә торган, энәтиреләләр тибыннан булган умырткасыз диңгез хайваны; *русчасы:* **морской ёж**

**ДИҢГЕ́З КЛИМАТЫ** *и.* Диңгезгә якын урнашкан җирләрдәге кинәт (кискен) үзгәрми торган дымлы климат; *киресе:* **континенталь климат**

**ДИҢГЕ́З КОЗГЫНЫ** *и.* Пеликансыманнар отрядының бакланнар семьялыгына караган, кара зур гәүдәле, каты озын койрыклы су кошы; баклан

**ДИҢГЕ́З МӘЧЕСЕ** *и.* Кыйммәтле мехлы, зур гәүдәле, имезүче диңгез хайваны; *русчасы:* **морской котик**

**ДИҢГЕ́З ФИЛЕ** *и.* Зур гәүдәле, ишкәгаяклы, имезүче су хайваны; *русчасы:* **морской слон**

**ДИҢГЕЗЧЕ** *и.* 1) Диңгез флотында хезмәт итүче. *[Махиан:] Мин үзем дә – диңгезче, алты ел Кара диңгез флотында хезмәт иттем.* Т.Гыйззәт. *Багратның, мускулларын ныгытып, диңгезчеләр тормышы белән якыннан танышасы килә...* М.Юныс

2) Диңгезне яхшы белүче кеше, диңгез эшенең остасы. *Балыкчылар – бик яхшы диңгезчеләр*

**ДИҢГЕЗЧЕЛЕК** *и.* 1) Диңгездә йөрү эше, диңгез белән бәйле һөнәр иясе

2) Кораб йөртү осталыгы. *[Феликс:] Диңгезчелек – дөньядагы иң әйбәт һөнәр.* М.Юныс

**ДИҢКЕТҮ** *ф. диал.* Ардырту, алҗыту; ялыктыру, теңкәгә тию. *Чорның нефть дигән гыйфрите безнең тыйнак, гүзәл Ыкны да күп газаплады, диңкетте.* Ә.Дусайлы

**Диңкетә башлау** Диңкетергә тотыну. *«Казыган чакта көрәк сабының уртасыннанмы, очыннанракмы тотарга кирәк?» – кебек сорау куеп һәм шул юнәлештә бәхәс укмаштырып диңкетә башлый.* Р.Зарипов

**ДИҢКҮ** *ф. диал.* Нык ару, алҗу; ялыгу, туйю. Төрле сәбәпләрдән баш

чуалу, фикерләү сәләте кимегәндәй булу. *Рус теле болай да катлаулы, өстәвенә, онытылып беткән иске кагыйдәләрне чокыштырып, башыбызны диңкетәләр.* М.Юныс

**ДИОД** *и. гр. физ.* Алмаш токны бер юнәлештә генә үткәрә торган ике электродлы прибор, җайланма. *Электровакуумлы диод*

**ДИОКСИН** *и. гр.* Канцероген (яман шешләр барлыкка китерә торган матдә, фактор), мутаген (кинәт кискен үзгәрешкә китерә торган), гепатоген (гепатит барлыкка китерә торган) матдәләр төркеме. *Европа союзы Балтыйк диңгезенең бөтен балыкларын – килькаки, салака, сельдьны безнең өстәлләргә җибәрүне тыячак. Чөнки аларда «деградация гормоны» дип аталган диоксин рөхсәт ителгән нормадан шактый югары икән.* Юлдаш

**ДИО́ПТРИЙ** *и. гр. физ.* Линза яки сферик көзгенең һ.б. яктылык нурларын сындыру көчен үлчәү берәмлеге. *Катаракта белән авырганчыга кадәр күз күрүе 10 диоптрий булган ерактан начар күрүчеләргә операциядән соң күзлек кию кирәк түгел.* Юлдаш

**ДИО́ПТРИЯ** *и. гр. физ. к.* **диоптрий**

**ДИОРА́МА** *и. гр.* Үтә күренмәле тукыманың, тонык пыяланың һ.б.ш. ике ягына да ясалып, күләмлелек тәэсире бирү өчен махсус яктыртып күрсәтелә торган рәсем

2) Горизонтның бер өлешен колачлаган, шуны детальләп сурәтләгән сәнгать әсәре

3) Гомумән, махсус яктыртуга нигезләнеп эшләнгән сынлы сәнгать әсәре. *Балалар Кырымга ял итәргә баргач, Севастополь оборонасын сурәтләгән диораманы да карап кайталар.* Татар иле

**ДИПЛОМ** *и. фр.* 1) Берәр уку йортын тәмамлау яки берәр исем һәм дәрәҗә алу турында рәсми документ; таныклык. *Ике шатлык бергә якынлаша. Тиздән, институтны тәмамлап, укытучы дипломы алабыз.* И.Салахов. *Диплом өчен генә укучылар стационарда да җитәрлек...* М.Юныс. *Институтны «кызыл диплом» белән тәмамладым. Армиядә хезмәт иттем.* Татар мөселман календаре

2) Нинди дә булса оешманың, аерым бер кешенең теге яки бу эшкә (мәс., тегүчелеккә) хокукын раслаучы рәсми документ

3) Берәр төрле ярышта, күргәзмәдә, конкурста һ.б.ш. ирешкән күрсәткечләр, яулаган уңышлар өчен бүләк, приз рәвешендә бирелгән таныклык. *Искәндәр председатель кулыннан әчәнә йөз сум салынган конверт һәм лауреат дипломы алды!..* Ф. Баттал. *[Бәйрәмдә] Еллык эшкә йомгак ясала, чемпионнар ачыклана, --- почёт дипломнары, кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.* Яшәү яме

4) *сөйл.* Югары, махсус урта белем бирү уку йортын тәмамлап, таныклыкдиплом алыр алдыннан эшләнә торган мөстәкыйль фәнни-тикшеренү эше, техник проект һ.б.ш. *Диплом яздыру. Диплом яклаучы*

**ДИПЛОМАНТ** *и. рус* 1) Диплом (*4 мәгъ.*) язучы, әзерләүче; яклаучы; диплом авторы. *Дипломант чыгышы. Дипломантның диплом эше буенча җаваплары кыска һәм төгәл иде*

2) Диплом (*3 мәгъ.*) белән бүләкләнгән кеше. *Җыр һәм бию конкурсы дипломанты. Ул берләшкән милләтләр җыр фестивалендә дипломант булды*

**ДИПЛОМАТ** I *и. фр.* 1) Дипломатия (*1 мәгъ.*) эшен башкаручы; дәүләтнең халыкара мөнәсәбәтләре өлкәсендә хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән вазифалы кеше. *Дипломатның карашы минем тишелә башлаган чалбарымнан, төсен югалткан яшькелт күлмәгемнән шуышып узды.* М.Юныс. *Россия проблемаларын яхшы белүче Америка дипломаты, татаристика белән кызыксынуның арта баруына 90 нчы еллар башларында Гарвард университетында ике күренекле шәхеснең – доктор Ә.Кәримуллинның һәм президент М.Шәймиевнең чыгышлары этәргеч булды, диде.* Татарстан

2) *күч.* Кешеләр белән бик оста аралаша белүче, үтә нәзакәтле кеше

**ДИПЛОМАТ** II *и. фр.* Китап, кәгазь, дәфтәрләр йөртер өчен, зур булмаган яссы чемодан. *Беркемне дә шикләндермәс өчен, кулына дипломат та тотмады, көрән папкасына шушы мәкалә буенча авыллардан килгән утызлап хатны, ике-өч данә мәкаләнең русчасын һәм татарчасын салды да аэропортка юл тотты.* Ф.Садриев. *[Юлдашев:] Яшел эшләпәле, кара күзлекле, дипломат тоткан кеше кердеме әле генә?* Ф.Баттал

**ДИПЛОМА́ТИК** *с.* Дипломатиягә мөнәсәбәтле, дипломатиягә бәйле, шуңа караган. *Дипломатик очрашу. Дипломатик сөйләшү*

**ДИПЛОМА́ТИЯ** *и. фр.* 1) Дәүләтнең тышкы сәясәтен тормышка ашыру буенча хөкүмәт тарафыннан алып барылган рәсми эшчәнлек. *Аның петлицасындагы йолдызлар бу кешенең дипломатия генералы икәнлеген күрсәтә иде.* М.Юныс. *Дипломатия эше. Дипломатияне җайга салу*

2) *җый. и.* Дипломатия эше белән шөгыльләнүчеләр, шул өлкәдә эшләүчеләр; дипломатлар (*1 мәгъ.*). *Шул уңайдан мин – Азия илләренең берсендә АКШның дипломатия вәкиллеген җитәкләүче дипломат – Көнчыгышны өйрәнүче танышымнан АКШта Татарстанга карата булган мондый кызыксынуның нәрсә белән аңлатылуын сорадым.* Татарстан

3) Берәр максатка ирешү өчен кулланылган осталык, сизгерлек

**ДИПЛОМАТЛАНУ** *ф.* Дипломат (*2 мәгъ.*) кебек булу, дипломатларча эш йөртү. *Бигрәк дипломатланасың! Дипломатланып тормау*

**Дипломатлана бару** Торган саен ныграк дипломатлану

**Дипломатлана төшү** Бераз дипломатлану

**ДИПЛОМАТЛА́РЧА** *рәв.* Дипломатлар кебек. *Ул чит ил җитәкчеләре белән дипломатларча сөйләшә белде.* Безнең гәҗит

**ДИПЛОМАТЛЫК** *и.* 1) Дипломат хезмәте, дипломат вазифасы, шул һөнәр

2) Дипломатка (*2 мәгъ.*) хас сыйфатлар

**ДИПЛОМЛЫ** *с.* Диплом (*1–3 мәгъ.*) алган, дипломы булган. *Хәзер һәр дипломлы кешене югары күтәрү гадәте бетеп килә.* М.Юныс. *Параллель*

*классларда, Гарәфи белән янәшә торып, шул ук фәннән дипломлы бер егет укыта башлады.* Ф. Баттал. *Дипломлы врачлар, магний белән кайбер нерв авыруларын дәваларга мөмкин, дигән нәтиҗәгә киләләр.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИПЛОМЧЫ** *и.* Диплом эше язучы студент. *Мәскәүдәге әдәбият институтын тәмамлап, диплом алгач, профессорлар, остазлар һәм дипломчылар саубуллашу мәҗлесе оештыралар.* Р.Батулла

**ДИРБИЯ** *и.* 1) Көнкүреш җиһазлары, хуҗалык кирәк-яраклары, эш әсбаплары һ.б.ш. *Ярмөхәммәт кипшергән дирбияләрне учактан читкәрәк күчерә.* Р.Батулла. *Ат җигү дирбияләре. Уку дирбиясе*

2) Сугыш кирәк-яраклары

3) Аш-су әзерләү өчен кирәк булган һәртөрле азык-төлек һәм тәмләткечләр. *Дирбиясе җитешле булса, бәлеш тәмле була. Дирбиясе булса, барын да пешереп була*

4) Мал-туар, кош-кортны үстерү өчен кирәк булган азык һ.б.

**ДИРЕКТИВ** *с.* 1) Директива сыйфатындагы, директива рәвешендәге, директива булып торган. *Директив йөкләмә. Директив хат. Директив план*

2) Директивалар, юнәлеш бирә торган күрсәтмәләре булган. *Директив оешма*

**ДИРЕКТИ́ВА** *и. фр.* Югары органнар тарафыннан бирелеп, үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмәләр. *Директивалар язу. Директиваларның үтәлешен тикшерү*

**ДИРЕ́КТОР** *и. лат.* Нинди дә булса оешма, учреждение яки кайбер уку йортының җитәкчесе, башлыгы. *Гата нык каушады. Бу минутта Мәрфуга Җир шарының директорына охшаган иде.* З.Хәким. *[Нариман:] Сез – егерме биш яшьлек мәктәп директоры, минем кызымның укытучысы.* Т.Миңнуллин. *Бу кырыкларга җитеп килгән таза, мәһабәт кеше моннан ике-өч ел элек кенә шушындагы белгечләрдән күтәрелгән директор иде.* Ә.Еники

**ДИРЕКТОРАТ** *и. лат.* Генераль директор җитәкләгән бик зур ширкәтнең директорлары коллегиясе. *Чемпионатның директораты турнирның иң яхшы уенчыларын билгеләде.* Кызыл таң

**ДИРЕ́КТОРЛЫК** *и.* Директор эше, директор вазифалары; шул хезмәтнең урыны. *Җитмәсә, узган ел санаторийга киткәндә, директорлыкны аңа калдырган иде.* Ф.Садриев

**ДИРЕ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса оешма, учреждение яки уку йортының директор кул астындагы (җитәкчелегендәге) идарә органы. *[Рашат:] Син нәрсә?! Әллә син анда базар дирекциясе дип беләсеңме?!* Ф.Садриев. *[Әхтәр Әхсәнович:] Паркы булгач, аның дирекциясе була, контора кирәкме? Кирәк!* Ф.Баттал. *Авыл укытучысын мәктәп дирекциясе гомернең гомер буена, ата-аналар белән эшләү җитми, дип каһәрләп тора.* М.Мәһдиев

2) Шушы идарә урнашкан бина яки бүлмә. *Дирекциядә җыелыш үткәрү. Дирекциягә җиһазлар алу*

**ДИРИЖАБЛЬ** *и. фр.* Корпусы һавадан җиңелрәк газ белән тутырылып, аэростат белән идарә ителә торган очкыч аппарат

**ДИРИЖЁР** *и. фр.* Хорга, оркестрга һ.б.ш. җитәкчелек итүче кеше. *Ансамбль дирижёры. Бик сәләтле дирижёр*

**ДИРИЖЁРЛЫК** *и.* Дирижёр эше, дирижёр вазифасы, шул һөнәр. *Дирижёрлыкка уку. Дирижёрлыкка алыну*

**ДИРИЖЁРЛЫК ИТҮ** *ф.* Музыкаль әсәр башкаручы оркестр яки хор белән җитәкчелек итү

**ДИРҺӘМ** *и. гар.* 1) Мароккода һ.б.ш. гарәп дәүләтләрендә акча берәмлеге һәм шул бәядәге вак акча. *Айрат Ситдыйков казылмасындагы кебек, шундый ук табылдыклар һәм шул ук чорга караган биналар янында алар белән бер комплекс тәшкил иткән дирһәм дә табылса, әлбәттә, абсолют датаны да билгеләргә мөмкин.* Ә.Мөхәммәди. *Казан Кремлендә табылган чех монетасы һәм гарәп дирһәменә нигезләнеп, галимнәр безнең башкалабызга 1000 яшь булуын ачыкладылар.* Салават күпере

2) Мисыр һәм Суданда: кыйммәтле металларны үлчәү берәмлеге (3,12 граммга тигез). *Казан-йорт казнасына керәсе бер генә дирһәмең дә дошманыңа мәгълүм булмасын.* Ф.Латыйфи

**ДИС-** *гр.* Үзе ияргән төшенчәгә кире яки капма-каршы мәгънә төсмере өсти яки аеру-бүлүне, каршы килү, кире кагуны белдерә торган алкушымча (мәс., *дисгармония, дисквалификация*)

**ДИСАХАРИД** *и. нем. хим.* Полисахаридның бер төре: молекулалары ике моносахарид калдыгыннан торган углевод (дисахаридның төп төрләре – *лактоза, мальтоза, сахароза*). *Яшелчәләрдә углеводлар моно- һәм дисахаридлар рәвешендә була ---.* Татар мөселман календаре

**ДИСӘТИНӘ** *и. рус* Россиядә метрик системага күчкәнгә кадәр: 2400 квадрат сажинга яки 1,09 гектарга тигез булган җир үлчәү берәмлеге. *Кыз матур, байлыгы зур: артында ике йөз дисәтинә җире, мал-туары, бик күп урманы, бер тегермәне бар.* Г.Ибраһимов

**ДИСӘ́ТНИК** *и. рус* 1) Төзелештә һ.б.ш. төркемле эшләрдә: эшчеләр төркеменең башлыгы; бригадир

2) *сөйл.* Авыл җирлегендә, йомышюлга йөрү өчен, билгеле бер вакытка чират тәртибендә билгеләнеп куела торган кеше, кизү

3) *сөйл. иск.* Элек авылда, полиция хезмәтен башкару өчен, ун йорттан «сайлап» куелган крестьян

4) *тар.* Хәрби хезмәттә: кече командир

**ДИСБЕ** *и. гар. дини* 1) Аллаһы Тәгаләне зурлап, мактап һәм аңа шөкер кылып әйтелә торган сүзләр, догалар («сөбханаллаһ», «әлхәмдүлилләһ», «Аллаһу әкбәр», «лә иләһә илләллаһ» һ.б.ш.)

2) Тәсбих сүзләрен кабатлый-кабатлый тарту өчен, төрле төшләрдән (мәс., хөрмә җимеше төшеннән), миләш агачыннан һ.б. материаллардан муенса рәвешендә махсус ясалган, Аллаһының эпитетлары санынча, туксан тугыз төштән торган, уртасында «мулласы» (аерым зуррак төше) булган төймә; тәсбих. *Дисбе тарту*

**ДИСГАРМО́НИК** *с.* Дисгармония кертә торган

**ДИСГАРМО́НИЯ** *и. гр. кит.* 1) *муз.* Гармония бозылу, авазларның яңгырашы, аһәңе бозылганлык, диссонанс; гармониясезлек

2) *күч.* Ярашмаучанлык, татулык булмау, үзара килешмәүчәнлек, көйсезлек. *«Безнең бик нык яшисебез килү теләге картлык зәгыйфьлеге һәм гомер кыскалыгы белән сыешмый. Бу – үлем табигатенең иң зур дисгармониясе», – дигән иде күренекле биологыбыз И.Мечников.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДИСК** *и. гр. махс.* 1) Яссы түгәрәк формасындагы тәлинкә; шундый формадагы әйбер

2) Нинди дә булса җайланма, машинаның шундый формадагы детале. *Яки менә урамдагы телефон-автоматлар. Берсенең трубкасын күтәреп карыйсың – тып-тын, икенчесен күтәрәсең – пипелдәп тора, өченчесенә киләсең – трубкасы юк, дүртенчесенә йөгерәсең – сан җыя торган дискысы төшкән.* Ф.Баттал

3) *спорт* Ыргыту өчен хезмәт итә торган яссы формадагы гимнастик әсбаб

4) *хәрби* Кул пулемёты, автоматның патроннар сыйдыра, патроннар куела торган өлеше (магазины). *Автомат дискы*

5) Гадәттә, тавыш язылган, әйләнә торган грампластинка. *Магнитофон дискы үзенә бертөрле җиңелчә шау чыгарып әйләнә дә әйләнә.* Э.Касыймов. *«Сак-сок» төркеменнән музыкантлар – хатыны белән Марат Сәйфетдиновлар килгән иде, алар Германиядә минем җырларымнан диск чыгардылар.* Сөембикә

6) *информ.* Күпчелек очракта «магнит дискы» сүзтезмәсендә килеп, «мәгълүматлар язылган җайланма», «дискета», «винчестер» сүзләрен аңлата

**ДИСКАНТ** *и. лат. махс.* 1) Малайларга хас югары (нәзек, нечкә) тавыш

2) Югары (нечкә) тавышлы җырчы

**ДИСКА́УНТЕР** *и. ингл.* Арзан товарлар яки ташламалар белән клиентларны җәлеп итә торган ширкәт

**ДИСКВАЛИФИКА́ЦИЯ** *и. гр.* 1) Берәр эшне башкару өчен күнекмәләрнең яисә белемнең җитмәве сәбәпле квалификацияне югалту

2) Кемне дә булса берәр эшне башкаруда сәләтсез дип табу

3) Спорт кагыйдәләрен тупас бозган өчен, ярышларда катнашудан мәхрүм итү

**ДИСКВАЛИФИКА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. кит.* 1) *төш. юн. к.* **дисквалификацияләү**

2) Нинди дә булса эш-һөнәр буенча булган тәҗрибә, осталык кимү, күнекмәләрне, белгечлекне югалту, квалификациясезгә әйләнү

**Дисквалификацияләнеп бетү** Тәмам, тулысынча дисквалификацияләнү

**Дисквалификацияләнеп калу** Ниндидер шартлар, сәбәпләрдән соң дисквалификацияләнү

**ДИСКВАЛИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Кемне дә булса билгеле бер эшчәнлек өлкәсендә сәләтсез дип табу, квалификациясеннән мәхрүм итү

2) Әхлак нормаларын, гомум кабул ителгән таләпләрне бозган спортчыны (яки спорт командасын), вакытлыча, ярышта катнашу хокукыннан мәхрүм итү. *Танылган биатлончылар Альбина Әхәтова, Дмитрий Ярошенко һәм Екатерина Юрьеваны «эритропоэтин» дигән препарат кулланганнары өчен дисквалификацияләделәр.* Кәеф ничек?

**Дисквалификацияләп бетерү** Тулысынча, барысын да дисквалификацияләү

**Дисквалификацияләп тору** Әледән-әле, еш дисквалификацияләү

**ДИСКЕТ** *и. ингл. информ.* Электрон хисаплау машинасында эшкәртелү өчен билгеләнгән мәгълүматны үз эченә алган сыгылмалы магнит дискы. *Аның өендә үткәрелгән тикшеренүләр вакытында, бик күп санда компьютер уеннары, дискетлар табылды.* Татар мөселман календаре

**ДИСКЕ́ТА** *и. ингл. информ. к.* **дискет**

**ДИСК-ЖОКЕЙ** *и. ингл.* Дискотека программасын алып баручы кеше, диджей. *Диск-жокей карлыккан тавыш белән яңа музыканың эчтәлеген сөйли башлагач кына, [Айсылу] миңа килеп сыенды.* М.Галиев

**ДИСКИНЕЗИ́Я** *и. гр. мед.* Куыш әгъзаларда мускуллар кыскаруы бозылу. *Бефунгинны шулай ук хроник гастритлардан, ашказаны-эчәклек дискинезияләреннән дә тәкъдим итәләр.* Юлдаш

**ДИСКЛА́У** *ф.* 1) *а. х.* Дисклы корал (сука, культиватор) ярдәмендә эшкәртү. *Бодай басуын дисклау*

2) Җыр һ.б.ш. әсәрләрне, эшкәртмәләрне дискка (*5 мәгъ.*) яздыру. *Татар халык җырларын дисклау*

3) *информ.* Нинди дә булса мәгълүматларны һ.б.ш. дискка (*6 мәгъ.*) яздыру. *Фәнни хезмәтне дисклау*

**Дисклап алу** Кыска вакыт арасында, тиз генә дисклау

**Дисклап бетерү** Дисклауны тәмамлау; барысын да дисклау

**Дисклап бирү** Нинди дә булса мәйданны һ.б.ш. кемнең дә булса соравы буенча дисклау

**Дисклап йөрү** Соңгы вакытта, хәзер дисклау белән шөгыльләнү

**Дисклап кую** Алдан дисклау

**Дисклап тору** Әледән-әле, еш дисклау

**Дисклап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, беткәнче дисклау

**Дисклый бару** Рәттән, бер-бер артлы дисклау

**Дисклый башлау** Дискларга керешү

**ДИСКЛЫ** *с.* Дискы булган яки диск формасындагы. *Ул ташны тиз әйләнә торган, тешләренә каты токымнан эшләнгән кискечләр яки алмаз куелган дисклы пычаклар белән кисә.* Төзү материаллары

**ДИСКОБОЛ** *и. гр. спорт* Диск (*3 мәгъ.*) ыргыту белән шөгыльләнүче, диск атучы спортчы

**ДИСКОГРА́ФИЯ** *и.* Дискларның (гадәттә музыкаль дискларның) тасвирламасы

**ДИСКОКЛУБ** *и. ингл.* Дискотекалар оештырыла, уздырыла торган урын. *Әле ындыр табакларында, кыр станнарында дискоклублар оештырырга да исәплән торабыз бит.* Ф.Баттал

**ДИСКОМФОРТ** *и. ингл.* Уңайсызлык, җайсызлык (күпчелек очракта кешенең эчке кичерешләре, рухи халәте турында). *Дискомфорт сизү*

**ДИСКОНТ** *и. ингл. финанс* 1) Вексельләрне исәпкә алу

2) Вексельләрне исәпкә куйганда, банкларның акча алуы (тотылган процент)

**ДИСКОТЕ́КА** *и. ингл. сөйл.* Яшьләрнең биюле музыкаль кичәсе. *Акчасы булганнар әнә «Джип»ларда гүләйт итә, төнге дискотекаларга йөри, кызлар белән типтерә.* З.Мәхмүди

**ДИСКРЕДИТА́ЦИЯ** *и. фр.* Әһәмиятен киметү, абруен төшерү

**ДИСКРЕДИТА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **дискредитацияләү**

2) Көчен, абруен югалту

**ДИСКРЕДИТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Кемнең дә булса абруен төшерү, кемгә дә булса ышанычны какшату

**ДИСКРИМИНАНТ** *и. фр. мат.* Бирелгән функцияне билгеләүче зурлыклардан гыйбарәт булган, нульгә әйләнүе, функциянең нормадан теге яки бу тайпылышы белән характерлана торган аңлатма

**ДИСКРИМИНАЦИОН** *с. кит.* Дискриминациягә нигезләнгән; дискриминациягә мөнәсәбәтле. *Дискриминацион чаралар*

**ДИСКРИМИНА́ЦИЯ** *и. лат.* Дискриминацияләү чаралары; дискриминацияләү хәле

**ДИСКРИМИНА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **дискриминацияләү**

2) Хокукларда чикләнгән булу

**ДИСКРИМИНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Гомум кабул ителгән хокукларны һәртөрле юллар белән чикләү, хокуклардан мәхрүм итү, тигезсезлек китереп чыгару (расасы, милләте, җенесе, сәяси яки дини карашлары буенча). *Хатын-кызларның гражданлык һәм һөнәри ирекләрен дискриминацияләү ул заманның аеруча үткен, хәл ителмәгән мәсьәләләреннән берсе була.* Тарих

**Дискриминацияләп алу** Озакка сузылмаган дискриминациягә дучар итү

**Дискриминацияләп бетерү** Бик нык дискриминацияләү

**Дискриминацияләп тору** Гел, һәрвакыт дискриминацияләү

**Дискриминацияли бару** Дискриминацияләүне акрынлап көчәйтү

**Дискриминацияли төшү** Тагын да дискриминацияләү

**ДИСКРИМИНА́ЦИЯЛЕ** *с. кит.* Дискриминациягә караган; дискриминациягә бәйле. *Дискриминацияле сәясәт. Дискриминацияле каршылык*

**ДИСКРИМИНА́ЦИЯЧЕ** *и.* Дискриминация сәясәтен яклаучы, аның тарафдары, дискриминация кулланучы. *Дискриминацияче колонизатор*

**ДИСКУССИОН** *с.* Дискуссиягә караган, дискуссиягә мөнәсәбәтле; бәхәсле. *Дискуссион мәсьәлә. Дискуссион мәкалә*

**ДИСКУ́ССИЯ** *и. лат.* Нинди дә булса бәхәсле мәсьәлә буенча ачык формада, ирекле фикер алышу; сүз көрәштерү, бәхәс. *Фәндәс Сафиуллинның татар телен саклау турындагы фикерләре дискуссия барышында зур яклау тапты.* Татар иле

**ДИСКУ́ССИЯЛЕ** *с.* Бәхәсле, дискуссия тудыра торган. *Ләкин бу дискуссияле киңәшмәләр, оештыру эшендәге җитешсезлекләренә карамастан, файдалы башлангычлар булды.* М.Җәлил

**ДИСЛОКАЦИОН** *с.* Дислокациягә мөнәсәбәтле. *Дислокацион бурыч*

**ДИСЛОКА́ЦИЯ** *и. фр. хәрби* Хәрби частьләрне һ.б.ш. билгеле бер планда тиешле урыннарга урнаштыру. *Ничектер, кышкы көннәрнең берсендә, безгә дислокация урынын алмаштырырга туры килде.* А.Расих. *Студентларның төзелеш отрядларын дислокация нокталарына озату тантанасы быел да яхшы оештырылган иде*. Татарстан яшьләре

**ДИСЛОКА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Урнашу (хәрби частьләр, гаскәр һ.б.ш. турында)

**ДИСЛОКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Урнаштыру (хәрби частьләр, гаскәр һ.б.ш. турында)

**ДИСМЕНОРЕ́Я** *и. гр. мед.* Менструаль цикл бозылуның гомуми атамасы. *Әрем төнәтмәсен хатын-кыз авыруларын дәвалаганда, аменорея, дисменорея булганда көнгә 3 мәртәбә 1 әр аш кашыгы эчәләр.* Сәламәтлек календаре

**ДИСПАНСЕР** *и. фр.* Билгеле бер авыруны, чирне дәвалау һәм авыруларны булдырмый калу чаралары үткәрә торган медицина учреждениесе. *Диспансер табигатьнең искиткеч гүзәл почмагына урнашкан.* Татарстан

**ДИСПЕПСИ́Я** *и. лат. мед.* 1) Ашкайнату эшчәнлеге бозылу. *[Шомырт] Диспепсия, энтерит, инфекцияле колитлар, дизентерия вакытында бөрештергеч чара сыйфатында кулланыла.* Татар мөселман календаре. *Эч киткәндә (газлар күп килгәндә), диспепсия, бавыр һәм бөер авыртканда, кипкән алтынбаш үләнен төеп, порошок итеп --- кабул итәләр.* Сәламәтлек календаре

2) Күкрәк баласында аңа бирелгән азыкның күләме һәм составы белән аны эшкәртүдәге физиологик мөмкинлекләре туры килмәү сәбәпле килеп чыккан авыру

**ДИСПЕ́ТЧЕР** *и. ингл.* Үзәк пункттан торып, төрле чаралар ярдәмендә, автотранспорт хәрәкәтен, предприятиеләрдә эш барышын график нигезендә оештырып, тикшереп торучы кеше. *Дежур диспетчер аванс алыну турында квитанция язып бирергә тиеш.* И.Гази. *Бусагада идарә диспетчеры басып тора иде.* Ж.Рәхимов

**ДИСПЕ́ТЧЕРЛАШТЫРУ** *ф.* Техник элемтә чаралары, автоматика, телемеханика, сигнализация ярдәмендә, җитештерүне һ.б.ш. процесслар белән идарә итүне һәм контрольне үзәкләштерү

**Диспетчерлаштыра бару** Акрынлап диспетчерлаштыруны арттыру

**Диспетчерлаштыра төшү** Тагы да бераз диспетчерлаштыру

**Диспетчерлаштырып алу** Тиз арада диспетчерлаштыру

**Диспетчерлаштырып бетерү** Тулысынча диспетчерлаштыру

**Диспетчерлаштырып тору** Әледән-әле яки өзлексез диспетчерлаштыру

**ДИСПЕ́ТЧЕРЛЫК** *и.* Диспетчер хезмәте. *Диспетчерлык хезмәте өчен ясалган бу кечкенә, елдам пароход, суны икегә ярып, түбәннән югарыга таба чабып менеп килә иде.* И.Гази

**ДИСПЛЕЙ** *и. ингл. информ.* Электрон хисаплау машинасында язылган график мәгълүматларны экранда бирү, сурәтләү, күрсәтү җайланмасы; монитор. *Ике арага тагын бер компьютер куясың да ресторандагы сөйләшүчеләрне һәм күренешләрне шуның дисплеена күчереп бара торган өстәмә тапшыргыч җайланма гына ясыйсың.* Р.Мирхәйдәров. *Монохром (аклы-каралы) дисплей. Сыек кристаллы дисплей*

**ДИСПОЗИ́ЦИЯ** *и. лат. хәрби* 1) Гаскәрләрне сугышка кертү өчен әзерлек планы яки әзерлек хәленә китерү – урнаштыру тәртибе

2) Корабларның туктап тору вакытындагы (рейдта, гаваньда яки якорьда) урнашу тәртибе

**ДИСПРОПО́РЦИЯ** *и. фр.* Үзара мөнәсәбәттә булган нәрсәләрнең дөрес чагыштырмасы югалу; пропорциясезлек; тигезсезлек. *Сәнгать үсешендә диспропорциягә юл куймау. Кайбер тармаклар өчен фәнни кадрлар әзерләүдә диспропорция*

**ДИСПРОПО́РЦИЯЛЕ** *с.* Пропорциясе булмаган, пропорциясез

**ДИСПРОПО́РЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Диспропорцияле булу, пропорциясезлек

**ДИ́СПУТ** *и. лат.* Җәмәгатьчелек каршында фәнни, иҗтимагый, сәяси һ.б.ш. әһәмиятле темалар буенча үткәрелә торган бәхәс. – *Клубыгызда әдәби кичәләр, тематик конференцияләр, диспутлар узамы? – дип сорады Мирхәйдәров.* Ф.Садриев

**ДИ́СПУТЧЫ** *и.* Диспутта катнашучы

**ДИССЕРТАНТ** *и. лат.* Диссертация яклаучы. *Диссертантка [материал] җыйнау, өйрәнү өчен, Казаннан тыш, Мәскәү, Ленинград китапханәләрендә, архивларында булырга һәм эшләргә туры килә.* Ф.Галимуллин. *Ләкин безнекеләр никтер аңа [Әдһәм Рәхим улы Тенишевка] Татарстан Фәннәр академиясе академигы исемен бирергә «онытканнар», гәрчә ул Диссертация яклау советы әгъзасы, күп кенә диссертантларга җитәкче һәм оппонент булса да һәм татар галимнәренә Россия Фәннәр академиясе исеменнән бәяләмәләр оештырса да.* Татарстан

**ДИССЕРТАЦИОН** *с.* Диссертациягә караган; диссертациягә мөнәсәбәтле. *Диссертацион совет. Диссертацион тема*

**ДИССЕРТА́ЦИЯ** *и. лат.* Гыйльми дәрәҗә алу максатыннан язылган фәнни хезмәт. *Хәлимә Терегулова – «Качкын» буенча диссертация язган музыка тәнкыйтьчесе.* М.Җәлил. *Уңай шартлары булмаган бер бүлмәле квартирада ирем белән бергәләп ике бала үстерәбез. Үзем кандидатлык диссертациясе язам.* М.Мәһдиев. *Кандидатлык диссертациясен язар өчен бирелгән вакыт узса да, эш күренми.* К.Латыйп

**ДИССИДЕНТ** *и. лат.* 1) Үз илендә дәүләт тарафыннан кабул ителгән дингә каршы кеше

2) Гомумән үз илендә хакимлек итә торган системаны кабул итмәгән һәм шул системага каршы чыгучы кеше. *Җитмешенче еллар диссидентлары*

**ДИССИДЕНТЛЫК** *и.* Диссидент булу

**ДИССИДЕ́НТ(ЛА́Р)ЧА** *рәв.* Диссидентка охшап, диссидентлар кебек. *Диссидентларча фикер йөртү. Диссидентларча мөгамәлә итү*

**ДИССИМИЛЯТИВ** *с. кит.* Диссимиляция рәвешендәге, характерындагы. *Диссимилятив күренеш*

**ДИССИМИЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *лингв.* Фонетик охшашлыкны бетерә торган үзгәреш («директор» урынына «дилектор» дип, «шушы» урынына «тушы» дип сөйләү һ.б.ш.)

2) *биол.* Катлаулы матдәләрнең гадирәк матдәләргә таркалып, үзләрендә яшеренгән энергияне аерып чыгару процессы

**ДИССИМИЛЯ́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Диссимиляциягә дучар булу

**ДИССОНАНС** *и. фр.* 1) Шигырьдә: ким рифманың бер төре (тартыкларның гына туры килүеннән ясалган аваздашлык); *киресе:* **консонанс**

2) *психол.* Психик процессларның үзара бәйләнеше, бәйлелеге бозылу күренеше

3) *күч. кит.* Нәрсәнең дә булса көйлелеге, нормальлеге, тәртиплелеге бозылу күренеше. *Кызның йөзендә шагыйранә серле елмаю көткәндә, акылга нигезләнгән бу сүзләр аңа, скрипка тавышына диссонанс керткән барабан тавышы төсле, урынсыз тоелды.* К.Тинчурин

**ДИССОЦИА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *физ., хим.* Молекулаларның тагын да ваграк кисәкчәләргә – молекула, атом, радикал яки ионнарга таркалу күренеше; матдәнең гадирәк компонентларга кайтма рәвештә (термик, электролитик һ.б.ш.) таркалуы

**ДИСТАНЦИОН** *с.* 1) Читтән торып эшләнә торган; читтән торып эшләү өчен билгеләнгән. *Дистанцион уку (укыту)*

2) Билгеле бер ераклыкта, арада эш иткән. *Дистанцион пульт. Дистанцион бомба*

**ДИСТА́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Билгеләнгән ераклыктагы ара. *Танклар билгеле дистанциядән ут ачтылар*

2) *спорт* Старт белән финиш арасы. *Якын дистанциягә йөгерү*

3) *махс.* Һәртөрле транспорт юлындагы административ-техник бүленеш. *Дистанция дежуры*

◊ **Дистанция саклау** Үзара мөнәсәбәтләрдә билгеле бер ара булдыру, рәсмилек саклау. *Ләкин Марсель дуслык белән үзен «бәйләп куярга» теләмәде бугай, һәрвакыт арада күпмедер дистанция саклады.* Шәһри Казан. **Дистанция тоту** *к.* **дистанция саклау**

**ДИСТӘ** *и. фар.* 1) Ун берәмлек; ун данәне эченә алган санау-хисаплау берәмлеге. *Әти-әниләреннән килгән бер дистәгә якын хат чыкты.* М.Гафури. *Шанлы кешеләр арасына тиң итеп чакырылудан туган горурлану хисенә инде дистә елдан артык күңел чоңгылында яшәгән икенче бер тойгы – шикләнү һәм икеләнү килеп уралды.* Ф.Латыйфи. *Дистә ярымлап тимер тырма, урам киңлегендәй араны иңләп, дулкын өстендә баргандай айкала-чайкала, җир өстенә кереп китте.* Г.Бәширов

2) *сөйл.* Ун еллык, ун елга тигез гомер. *Белем ягы да бик сай инде минем, яшем дә алты дистәнең өске ягына меңеп бара.* Г.Бәширов. *Мал таба белүе белән шөһрәт алган, дөньяга таш ярып чыккан бу кеше, инде җиденче*

*дистәне ваклаган булса да, һаман яшь күренә...* Ф.Латыйфи

3) Күп урынлы санда ахырдан икенче цифр исеме

**ДИСТӘЛӘГӘН** *с.* Бер дистә тирәсендәге, бер дистә чамасы; дистәдән азрак яки артыграк. *Дистәләгән күзләр биюче егетнең җитез йөргән аякларына текәлделәр.* М.Гафури. *Элек бездә Габәши, Сәйдәш исемнәре белән генә чикләнелсә, хәзер дистәләгән яшь көчләр күтәрелделәр.* М.Җәлил. *Нәсел чылбырын дәвам итәргә тиешле дистәләгән язмышның чит җирләрдә җирсеп сагынуыннан үелган яра урыннары алар.* Р.Мөхәммәдиев

**ДИСТӘЛӘП** *рәв.* 1) *к.* **дистәләгән**. *Ул аларның шатлыгына бер дә кушылмый, дистәләп яудырылган сөальләрнең кайберләренә күңелсез генә җавап бирә, күбесенә бер дә җавап кайтармый.* Ш.Камал. *Мондый хатларны минем энекәш буш вакытларында дистәләп яза иде.* А.Шамов

2) Дистә, дистә итеп, унарлап. *Дистәләп сату. Себеркене бауга дистәләп элеп кую*

**ДИСТӘЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Бик күп, берничә дистә. *Идел буйлатып дистәләрчә километрларга сузылган герой-шәһәр Волгоград --- ялкынланып үтте.* Г.Бәширов

**ДИСТӘЛӘ́Ү** *ф.* Дистәләргә аеру. *Унбер кочак әйберне --- дистәләп бәйләп торучы Хәдичә түтигә илтеп аударды.* Г.Бәширов

**Дистәләп алу** Тиз арада дистәләргә аеру

**Дистәләп бару** Һәрберсен бер-бер артлы дистәләү

**Дистәләп бетерү** Барысын да дистәләү, дистәләүне тәмамлау

**ДИСТӘЛЕ** *с.* Унарлап, дистәләп санауга нигезләнгән

**ДИСТИЛЛЯТ** *и. лат. физ., хим.* 1) Нәрсәне дә булса кайнатып парга әйләндерү юлы белән аертып алынган сыек продукт, сыеклык. *Бензин, керосин – нефть дистиллятлары. 2 метрлы банкага «дистиллят» тулгач, аны 8 сәгать буе суыталар (нуль градус тирәсендә).* Сәламәтлек календаре

2) Пардан тупланган сыеклык

**ДИСТИЛЛЯ́ТОР** *и. рус* Дистиллят чыгара торган аппарат

2) Дистилляция белгече

**ДИСТИЛЛЯЦИОН** *с.* Дистилляциягә мөнәсәбәтле; дистилляция өчен билгеләнгән

**ДИСТИЛЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* Куу (кайнатып парга әйләндерү) юлы белән чистарту; матдәне төрле компонентларга аеру

**ДИСТИЛЛЯ́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Дистилляция үткән, дистилляция юлы белән чистартылган булу. *Соңрак, комендант булып эшләүче татар абзые ярдәме белән, институт кафедраларына дистилляцияләнгән су ташып та аз-маз акча эшли башладым.* Р.Вәлиев. *Шешәләре төрле дару шешәләре булып, «самогон аппараты» дигәне дару ясау өчен дистилляцияләнгән су әзерләү аппараты булуы ихтимал.* Гасырлар авазы. *Иң чиста, иң саф су ул – дистилляцияләнгән су.* Шәһри Казан

**ДИСТИЛЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Куу юлы белән чистарту, сыек кушылмаларны эзлекле рәвештә куу юлы белән фракцияләргә, өлешләргә аеру. *Халык табибы Г.Шаталова «Шифалы туклану» дигән китабында өй шартларында ничек итеп дистилляцияләнгән су әзерләү юлын өйрәтә.* Сәламәтлек календаре. *Минераль матдәләр дистилляцияләнгән суда тагын да азрак (алар анда юк чамасында).* Татар мөселман календаре

**Дистилляцияләп бетерү** Барысын да, гомумән дистилляцияләү

**Дистилляцияләп тору** Әледән-әле, еш дистилляцияләү

**Дистилляцияләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, беткәнче дистилляцияләү

**ДИСТИЛЛЯ́ЦИЯЛЕ** *с.* Дистилляция үткән, дистилляция юлы белән чистартылган, дистилляцияләнгән. *Ач тору вакытында ризык кабул итүдән тыелыгыз. Бу вакытта гадәти, магнитланган, протеинлы яки чистартылган (дистилляцияле) су гына эчә аласыз.* Сәламәтлек календаре

**ДИСТРИБУ́ТОР** *и. ингл.* Нинди дә булса предприятие, фирма тарафыннан җитештерелә торган товарны күпләп алып, аларны сәүдә оешмаларына һәм ваклап сатучыларга җиткерүне оештыручы арадашчы кеше яки оешма. *АКШ фирмасының Казандагы дистрибьюторы Михаил Щеглов исәпләвенчә, читтән кайтарылган бу һәммә продукциянең ингридиенты молекуляр авырлыгының бик кечкенә булуы белән кыйммәт...* Татар мөселман календаре

**ДИСТРИБЬЮ́ТОР** *и. ингл. к.* **дистрибутор**

**ДИСТРО́ФИК** I *и. рус* 1) *мед.* Дистрофия белән авыручы кеше

2) *ирон.* Сай фикерле кешегә карата әйтелә. *Әле малайлары нинди диген? Бер фикерсез дистрофиклар.* Ф.Бәйрәмова

**ДИСТРО́ФИК** II *с.* 1) Дистрофиягә (*1 мәгъ.*) мөнәсәбәтле, дистрофиягә бәйләнешле. *Дистрофик халәт*

2) *күч.* Кимчелекле, җитеш булмаган. *Ниндидер дистрофик, дәүләт төзелеше камил түгел, милләтләр төрмәсе булган илдә җан асрыйбыз инде.* Ш.Алпар

**ДИСТРОФИ́Я** *и. гр. мед.* 1) Организмда матдәләр алмашы бозылуга бәйләнешле патологик процесс. *Фән кыясын кимерү өчен, калорияле продукт ашау кирәк, дус кеше. Калория җитәрлек булмаган очракта, дипломга өстәп, дистрофия, гастрит ише нәрсәләрне дә алуың бар.* М.Юныс. *Дистрофия чире икенче мәртәбә шушында [заводта] аның якасыннан ала.* Сөембикә. *Авыру икенче чиккә ташлана: я бик куркыныч кырыс диетага утыра, я гомумән ашаудан тыела. Бу исә дистрофиягә китерә.* Юлдаш

2) Педиатриядә: туклану озак вакыт бозылганда, балаларда була торган патологик халәт. *Карындагы бала дистрофиясе. Яңа туган бала дистрофиясе*

**ДИСФА́ГИЯ** *и. гр. мед.* Йоту акты бозылуның гомуми атамасы. *Үңәч рагы башланып, якынча 1–2 ел дәвамында кеше авыру икәнлеген сизмичә яши. Шуннан соң авыруның беренче билгесе – йота алмау – дисфагия башлана.* Татар мөселман календаре

**ДИСЦИПЛИ́НА** I *и. лат.* 1) Коллективтагы барлык кеше өчен дә үтәлүе

мәҗбүри булган кагыйдәләр; тәртип. *Искәндәр, әледән-әле техникумга шалтыратып, Маратның өлгерешe, дисциплинасы турында белешеп торды.* Г.Гобәй

2) Бик каты тәртипкә гадәтләнү, түземлелек, чыдамлылык. *Солдат дисциплинасы*

3) Финанс эшендә, технологиядә һ.б.ш. тәртипкә салынганлык, режим

**ДИСЦИПЛИ́НА** II *и. лат.* Уку фәне, гомумән, фәннең бер өлкәсе. *Хронобиология хәзер иң актуаль фәнни дисциплиналарның берсенә әйләнде.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Физика-математика дисциплинасы*

**ДИСЦИПЛИ́НАЛЫ** *с.* Дисциплинага буйсынучан; дисциплинага күнеккән; тәртипле. *Дисциплиналы латыш полкының бу күренеше халыкларга бик начар тәэсир итте булса кирәк.* К.Тинчурин. *Шәрипов аларны [рота егетләрен] батыр, кыю һәм дисциплиналы итеп тәрбияләде.* А.Шамов

**ДИСЦИПЛИ́НАЛЫЛЫК** *и.* Дисциплинага күнеккәнлек; дисциплиналы кешегә, төркемгә, оешмага хас сыйфатлар. *Хәрби частьтагы дисциплиналылык*

**ДИСЦИПЛИНАР** *с. кит.* 1) Дисциплинага караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Дисциплинар устав*

2) Дисциплинаны бозуга бәйләнгән; төзәтү характерындагы. *Ефимов белән Кузнецовны, инде кайтабыз дип торганда, өчәр елга дисциплинар ротага, ә Сәгыйтов дигән татар егетен ун елга төрмәгә хөкем иттеләр.* Г.Гобәй

**ДИСЦИПЛИ́НАСЫЗ** *с.* Дисциплина сакламый торган, тәртипсез. *Әлеге акция дисциплинасыз автомобиль йөртүчеләрне ачыкларга һәм тиешле чаралар күрергә мөмкинлек бирә.* Ватаным Татарстан

**ДИСЦИПЛИ́НАСЫЗЛЫК** *и.* Дисциплина сакланмау, тәртипсезлек

**ДИФИРАМБ** *и. гр.* 1) Борынгы грекларда: шәраб алласы Дионис хөрмәтенә тантаналы җыр

2) *күч.* Бик каты күпертеп, арттырып әйтелгән мактау сүзләре. *Кемгә дә булса дифирамб җырлау*

**ДИФРА́КЦИЯ** *и. лат. физ.* Нурланышның, нинди дә булса дулкыннар белән тәэсир итешү нәтиҗәсендә, юнәлешен үзгәртүе яки аның таркалу күренеше. *Яктылык дифракциясе*

**ДИФТЕРИТ** *и. гр. мед.* Авыз, борын куышлыгындагы һәм йоткылыктагы лайлалы тукыманың ялкынсынуы, шешүе белән үзенчәлекле, төкерек тамчылары белән күчә торган йогышлы авыру

**ДИФТЕРИ́Я** *и. гр. мед. к.* **дифтерит**. *Тире дифтериясе. Яра дифтериясе. Токсик дифтерия*

**ДИФТОНГ** *и. гр. лингв.* Бер иҗек булып әйтелә торган ике сузык аваз кушылмасы

**ДИФТО́НГЛАШУ** *ф. лингв.* Гади сузык авазның яки авазларның дифтонгка әверелүе

**ДИФФЕРЕНЦИАЛ** *и. лат.* 1) Математикада: алмаш зурлыкка (функциягә) бәйле үсеш сызыгының төп өлеше

2) *тех.* Транспорт берәмлекләренең (автомобиль, трактор, танк һ.б.ш.) йөртүче тәгәрмәчләренә борылышларда төрле тизлек белән әйләнергә мөмкинлек бирә торган механизм

**ДИФФЕРЕНЦИАЛЬ** *с.* 1) Дифференциалга (*1 мәгъ.*) мөнәсәбәтле; дифференциалга (*1 мәгъ.*) караган

2) *кит.* Төрле шартларда төрлечә булган; аермалы

**ДИФФЕРЕНЦИАЦИЯ** *и. лат.* Нәрсәнең дә булса төрле элементларга бүленеше, аерылу күренеше. *Дифференциация ясау*

**ДИФФЕРЕНЦИЯЛӘ́Ү** *ф. кит.* Нәрсәне дә булса өйрәнгәндә, һәр анык шартның, һәр очракның үзенчәлегенә мөнәсәбәтле рәвештә аерып карау

**ДИФФЕРЕНЦИЯЛЕ** *с. к.* **дифференциаль** (*2 мәгъ.*). *Дифференцияле эш шартлары. Татарстан --- нефтьчеләргә салым салганда дифференцияле якын килү инициативасы белән чыккан.* Татарстан

**ДИФФУЗ** *с. лат. физ.* 1) Катнаш (диффузия нәтиҗәсендә кушылган). *Диффуз ут*

2) Тонык; ачык булмаган

**ДИФФУ́ЗИЯ** *и. лат. физ.* Җылылык хәрәкәте аркасында бер матдә атомнары яки молекулаларының икенче матдә атомнары яки молекулаларына үзара үтеп керү күренеше. *Сыеклыклар диффузиясе. Газлар диффузиясе*

**ДИФФУ́ЗИЯЛӘНҮ** *ф. физ.* Диффузиягә дучар ителү, диффузиягә дучар булу, үзара катнашу, кушылып китү

**Диффузияләнә башлау** Диффузияләнергә тотыну

**Диффузияләнеп бетү** Тәмам диффузияләнү, диффузия процессы төгәлләнү

**ДИФФУ́ЗОР***и. лат. махс.* 1) Чөгендердән шикәр аерып чыгара торган аппарат

2) Репродуктор, динамик кебек аппаратларда тавышны көчәйтә торган ефәк элпә, мембрана

**ДИҺКАН** *и. фар.* Урта Азиядә: игенче. *Тимер юлга Гаҗәпләнеп торды диһканнар.* Ә.Ерикәй

**ДИЭЛЕ́КТРИК** *и. ингл. физ.* Электр үткәрүчәнлеге бик кечкенә булган матдә, изолятор (мәс.: *күкерт, пыяла, сыеклык* һ.б.ш.)

**ДИЮ** I *ф.* **1.** *туры һәм кыек сөйләмне контекстка бәйләп* 1) Нәрсәне дә булса белдерү, әйтү, сөйләү, хәбәр итү кебек автор сүзе сыйфатында һәм автор сөйләме составында грамматик хәбәр булып кулланыла. *– Сез үзегез дә каботажда эшлисез бит, – дип кабатлады боцман.* М.Юныс

2) Үзеннән алда килгән сүзгә мөнәсәбәтле рәвештә «(шулай) атау, исемләү», «(шулай) карау» кебек мәгънәләрне белдерә. *– Көт кызлардан ярдәмне! – Алай димә син. Килештек – син, шаярмыйм дип сүз бирдең. Шулай бит!* З.Зәйнуллин. *Кабатланмас, димә, Кабатлана Тарих, Кабатлана әле ничек кенә...* Җ.Дәрзаман

3) «(Шулай) дип уйлау, фараз итү, чамалау» мәгънәсен белдерә. *Мәнә авам, мәнә җимерeләм дип торган салам түбәле иске каралтыны хәтерләткән гәүдәне бары кулындагы таяк кына тотып тора сыман.* Р.Мөхәммәдиев

4) «Теләү», «ният итү, ниятләү» кебек мәгънәләрне белдерә. *[Гыйлемхан] Үзенең туган нигезенә, шул нигездә төпләнгән бригадирга дип, атап ясады.* Р.Мөхәммәдиев

5) *юкл. форм.* Үзеннән алда килгән сүзгә мөнәсәбәтле рәвештә, «аңа карамау», «аңа игътибар итмәү, «аның белән санлашмау, исәпләшмәү» кебек мәгънәләрне белдерә. *[Газиз] Буш вакыт тию белән, кармакларын күтәрә дә Күәш буена йөгерә. Гел шулай. Җәй дими, кыш дими...* Г.Гыйльманов

**2. дигәннән**, **димәктән** *кер. сүз функ.* 1) Сүзтезмә яки җөмлә составында. *Динә, дигәннән, Мөнирә аңа икеле куйган...* Т.Миңнуллин

2) Кушма хәбәр составында «ди» формасында йөри; әйтелгән сүзнең, фикернең кайдандыр алынганын күрсәтеп, «имеш» мәгънәсен белдерә. *Яшәгән, ди, Арчада бер Кыш бабай...* Сабантуй. *Яшәгән, ди, бер урманда Нәни куян баласы.* Г.Гыйльманов

3) Төрле сүзләргә, сөйләүләргә, мәгълүматларга ияреп, «шулай дип әйтәләр» мәгънәсен белдерә. *Мао Цзедун сынын Борынгы Мисырның Фива шәһәре хакиме Монтуэмхет сыны янәшәсенә куйсаң, аларның гүя бер үк кешегә карап әвәләнгән кебек булуын күрергә мөмкин, ди.* Ватаным Татарстан

4) «Шулай дип фараз итсәк», «болай дип уйласак», «шулай булган очракта» кебек мәгънәләрне белдерә. *[Д.Сәфәров:] Түгәрәк өстәл, киңәшмә, семинар кебек рәсми очрашулардан чыккач, гадәттә, күңелне икеле-микеле уйлар бимазалый: очраштык, ди, сөйләштек, ди – шуннан нәрсә?* Татарстан яшьләре

**3. диярлек** *рәв. мәгъ.* Үзеннән алда килгән, үзе караган, үзе бәйләнгән сүз белдергән эш-хәлнең күләме кимрәк икәнлеген, кимрәк булганлыгын аңлата. *Безнең белән бер көндә диярлек өйләнештеләр.* Ф.Баттал

**4. дигән** *бәйл. функ.* 1) Баш килешендә килгән исемне (сүзне) аерылмышка бәйләп, «шундый исемле», «шулай дип атала торган» мәгънәләрен белдерә. *Гадел дигән малай Мирвәлинең үксез күңелен тулысынча яулап алган иде.* Г.Гыйльманов

2) Юнәлеш килештәге исемне, алмашлыкны (сүзне) аерылмышка бәйләп, «берәүгә аталган, багышланган», «берәүгә яки берәр максатка билгеләнгән» мәгънәләрен белдерә. *Балаларга дигән китаплар*

3) **дигәндә** «Шуны алсак», «шул яктан караганда», «әлеге мәгънәдә» кебек мәгънәләрдә кулланыла, шул мәгънәләрне аңлата. *«Аш» дигәндә – җанфәрман, «эш» дигәндә – юк дәрман.* Мәкаль. *«Ашау» дигәндә, безнең Кәтүк – кызык кеше: тавык кебек, аннан бер чукый, моннан бер чукый, шуның белән аның тамагы тук.* И.Гази

4) «Берәр кеше хакына», «берәр нәрсә өчен» дигән мәгънәләрне белдерә. *Син дигәндә, дөнья йөзендә булган бар җанвар да көмәк бирергә каршы килмәс.* Әкият

5) «Берәр вакыт арасы үтеп киткәндә», «күрсәтелгән, тиешле срок җиткәндә», «шул вакыт эчендә» мәгънәсен белдерә. --- *ике-өч ел дигәндә, Микәй бөтен авылны көмеш сыман елык-елык килеп торган җылы, йомшак мамыкка төрде.* Р.Мөхәммәдиев

6) «Нинди дә булса эш-хәл булды дигәндә генә», «берәр эш-хәл булыр алдыннан гына, нәкъ шул вакытта» дигән мәгънәләрдә кулланыла. *Инде упкын читенә килеп җитәм дигәндә, инде апак томан арасына соңгы тапкыр ташланам дигәндә, кинәт яр буенда мин аны күрәм.* Ф.Бәйрәмова

7) **дип** Баш һәм юнәлеш килешендәге сүздән соң килеп, «шуның хакына», «шуның өчен» кебек мәгънәләрне белдерә. *Хатын дип, хатынның туганнары, балалар дип, узган да киткән вакыт.* Р.Мөхәммәдиев

8) Юнәлеш килештәге сүздән соң килеп «шуның өчен», «шуңа атап» мәгънәсен белдерә. *Биюш бияне алып кайтырга дип килгән иде, әмма, йөгән кигезгәндә, атның чирәмне «ашап калыйм» дигәндәй ашыгыбрак кимерергә тотынуын --- күргәч, ашыктырмаска булды, түмгәккә таянып, колынның тамашаларын онытылып күзәтә башлады.* М.Хуҗин

**5. дигән** *терк. функ.* 1) Баш җөмлә белән иярчен аергыч җөмләне терки. *Расчёттан соң, иртәгә китәсе дигән көнне, иптәшләр белән бераз төшердек тә урамга чыгып киттек.* Ф.Хөсни

2) **дигәндәй** Еш кабатлана торган тәгъбирләрне (сүзләрне яки җөмләләрне), канатлы гыйбарәләрне, мәкальәйтемнәрне сөйләмгә кертеп, ялгау чарасы буларак кулланыла. *Зөфәр абый урыныннан кузгала, менә тагы бер кич узды дигәндәй, тирән сулыш ала, көрсенгәндәй итә ---.* Р.Мөхәммәдиев

3) **дип** Гадәттә кыек сөйләм формасындагы тәмамлык җөмләне баш җөмләгә терки. *Ике йортның өлкәннәре кода булды дип ишеттек, мәгәр күз белән күрмәдек.* Г.Ибраһимов. *Җеп оеклар кигән ике аягын салындырып, караватта утырды апа. Дога кылдык. Сорый: «Сине бик каты авыргансың дип ишеттек. Хәзер ничек соң хәлләрең?»* З.Зәйнуллин. *Березниковски районыннан түбән таба урында безне киселгән агачларны суга төшереп агызырга куйдылар. Анда 2 ел эшләгәннән соң, сугыш чыккан икән дип ишеттек.* Ф.Бәйрәмова

4) Максат җөмләне баш җөмләгә терки. *[Гайфулла белән Сәйфулла] Зыбау аермасына җитәләр. Хәл алырга дип, шул аермадагы ялгыз карама күләгәсенә утыралар.* М.Кәрим. *Суд ишегеннән чыккан утырышчылар, нәфрәтле күз карашларын Нәзирәгә төбәп, дәшми генә таралышканда, алар да ишетсен дип, юри кычкырып әйтте бу сүзләрен ---.* Кәеф ничек?

5) Сәбәп җөмләне баш җөмләгә терки. *Без аларны [журналларны], балалар ертып бетермәсеннәр дип, утын сараена яшердек.* Р.Мостафин

6) Диалогта: әңгәмәдәш сүзен өлешчә кабатлап җавап биргәндә, кереш сүз, сүзтезмә яки җөмлә буларак, алда әйтеләчәк сүзләрне теркәү өчен кулланыла. *Фатир алгансың икән? – Фатир дип, бер бүлмә инде*

**6.** *кис. функ.* 1) **ди** Риторик сораулы, ирониялe җөмләләрдә инкяр итүне куәтләп килә. *Сорады, ди! Төнге смена туры килмәгән булса, үзе, ялынып, басуга чыгар иде әле.* Ф.Садриев

2) **дигәч** Кабатлап әйтелгән сүзләр арасында килеп, катгыйлык төсмерен өсти һәм әйтелгәннәрне куәтли. *[Хәбибрахман:] «Бармыйм» дигәч, бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның, кайда икәнен белмим.* Г.Камал

3) **дисеңме** Үзе караган сүзгә басым ясап, «да, дә» мәгънәсендә килә. *Таулардан ыжгыртып чабып төшүләр дисеңме, егылып киткәндә баш белән карга кадалулар дисеңме, агач араларыннан борыла-борыла төшкәндә, чаңгы астыннан кар бураннары уйнап калулар дисеңме!* И.Гази

4) **дисәң** Кабатлап әйтелгән сүзләр арасында килеп, эчтәлекне куәтләп, ассызыклап, басым ясап килә. *Ну, моңы дисәң дә моңы бу магнитофонның!* Ф.Баттал

◊ **Дигән сүз** Кушма хәбәр составында килеп, нәтиҗә ясауны белдерә һәм «шуңа тиң», «шуның белән бердәй» дигән мәгънәне аңлата. *Әлбәттә, бүтән телдән алынган барлык сүз үзгәрергә тиеш дигән сүз түгел, байтак кына сүзләр татар теленең законнарына бик мач киләләр һәм үзгәрмичә йөриләр* ---. И.Гази

**ДИЮ** II *и. фар. миф.* Бер яки өч, яисә тагын да күп башлы, бик ямьсез куркыныч зур гәүдәле, кеше ашаучы итеп тасвирлана торган мифик зат. *Бу рәвешле ул татар әкиятләрендәге патша кызларын урлап китеп, җир астында тотучы дию образына охшаш.* Г.Дәүләтшин

**ДИЮ ПӘРИЕ** *и. к.* **дию** II. *Бераздан ишегалдында мәхшәр купкандай булды; трактор, шашкан дию пәриедәй, проходной капкасына таба ыргылды.* Ф. Баттал

**ДНЕВА́ЛЬНЫЙ** *и. рус сөйл.* 1) Хәрби бүлекләрдә тәртип саклау, милеккә күзәтчелек итү өчен һ.б.ш. максатларда, бер тәүлеккә билгеләп куелган рядовой. *Штабтан --- кулына ниндидер кәгазьләр тоткан дневальный чабып чыкты, ниндидер офицерларның тыз-быз йөгергәне күренде.* Ф.Латыйфи

2) Кизү торучы, дежур. *Дневальный «подъем» кычкыруга Уяу идек инде без мәгәр.* Ш.Маннур

**ДО** *и. ит.* Музыкаль гамманың беренче – башлангыч авазы, шул авазны белдергән нота исеме. *Яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль ... Менә шулай, авазлардан гамма хасил була.* Ә.Еники

**ДОБРОВО́ЛЕЦ** *и. рус сөйл.* Сугыш вакытында, үзе теләп, армия сафларына алынучы кеше. *Әле Сугыш башланмаган, Әле Тыныч тора сезнең сафыгыз, Ә шулай да Мине бүгеннән үк Доброволец итеп алыгыз!* Һ.Такташ. *Пулемётчыларның берсе, сары сакаллы, сары мыеклы бер рус крестьяны, Якубның күн курткасын, аркасындагы винтовкасын, сакал баскан йөзен ялт кына күздән кичерде дә, сугыш күрмәгән берәр доброволец булырга кирәк дип уйлап, балаларга аңлата торган тон белән сөйләргә тотынды.* И.Гази

**ДОВЕ́РЕННОСТЬ** *и. рус* Ышаныч язуы; ышанычнамә. *[Йосыф:] Васыятьнамәдә борынгы бабабыз доверенность турында бер сүз дә әйтмәгән.* Ш.Мәрҗани

**ДОВЕ́РЕННЫЙ** *и. рус сөйл.* 1) *иск.* Кемнең дә булса исеменнән билгеле бер йомыш буенча эш йөртергә вәкаләте булган кеше; ышанычлысы. --- *ул [Курамшин] заманында коммерческий училище бетергән, Уралдагы бер татар миллионерында доверенный булып эшләгән кеше икән.* Ә.Еники

2) Дәүләт Думасы, Дәүләт һәм шәһәр советына сайлау кампаниясе вакытында сайлаучыларны депутатлыкка кандидат белән таныштыру өчен билгеләнгән кеше

**ДОГ** *и. ингл.* Кыска йонлы, кара, соры яки мәрмәр төсендәге эт токымы һәм шул токымдагы эт

**ДОГА** *и. гар. дини* 1) Дини кешеләрнең, дин тотучыларның Аллаһыга аны мактап, аннан сорап, ялварып әйткән сүзләре. *Төрки каганлыгы вакытында диндә сыйнфый бүлгәләнеш тә ачык чагыла. Халык һәм аксөякләр аерым дога кылганнар.* Г.Дәүләтшин. *Коръән укып, дога кылып, өемә фатиха биреп китәрсең.* М.Әмир

2) Дин тотучыларның Аллаһыга, изгеләргә мөрәҗәгать иткәндә һәм дини йолалар вакытында әйтелгән сүзләре, махсус дини эчтәлектәге текст. *Догалар язылган китап*

3) Фатиха

**ДОГАЛЫ** *с.* 1) Дога язылган, дога укылган, догасы булган, дога әйтелгән. *Аның артыннан әле генә үлемнең үзе белән очрашып, ниндидер сихерме, тылсыммы аркасында исән калган Тимерҗанның догалы сүзләре иярде.* Г.Гыйльманов. *Аны өшкертеп тә карадылар, догалы су да эчерделәр.* Р.Вәлиев. – *Менә шуны тот, – диде Айрат, муеныннан догалы бөтиен салып, – мин юкта улбу булса, ярдәме тияр.* М.Кәбиров

2) Догада булган, дога укый (укыла) торган. *Кем соң бу догалы кеше?* Г.Гыйльманов. *Ләкин бу йорт ана телле һәм догалы йорт булсын!* Р.Батулла. *Ләкин «кеше» дигәнең шундый догалы минутларда да гел кеше булып кала икән: бераз киткәч, кире борылып, рәшәткәнең каршы ягыннан изге теләкләргә чумган ул хатынга янә күз төшермичә булдыра алмадым.* Ф.Хөсни. *Бәгырькәемнең җаны Болгарга – догалы җиргә ашкына.* Ватаным Татарстан

3) *күч.* Бәхетле, имин, бәрәкәтле. *Халыкта да бит «догалы нигез», «тынгысыз нигез» дигән сүзләр бар.* Татар заманы

**ДОГАЛЫК** *и.* 1) Дога тексты. *Догалыклар укый-укый, әллә кемнәр әткәемә ап-ак күлмәк кидерәләр.* Һ.Такташ. *Хәзрәт, килеп, Галиәкбәр агайның баш очына утырып, авыз эченнән бер-ике догалык укыды.* Ш.Маннур

2) Догалар язылган кәгазь (китап һ.б.ш.); догалар җыентыгы. *Мәчет сурәте төшкән кара пыялалы догалыклар да почмак якка күчкән иде. Мөштәри догалыкларны алып, акча биреп чыгып киткәннән соң, китапчы мыек астыннан гына көлеп калды...* Ш.Мөхәммәдев

**ДОГАЧЫ** *и.* Үзе һәм башкалар өчен Аллаһы Тәгаләгә догалар укып ялваручы, мөрәҗәгать итүче кеше. *[Хөсәен:] Сезне, пишкадәм булганчы, мәдрәсәдә укыттык. Дус-иш һәммәсе эшкә кушарга киңәш бирсәләр дә, мин, ахырдан үзебезгә догачы булырлар дип, кеше сүзенә карамадым, яшьләй эшкә кушмадым.* Ф.Әмирхан

**ДО́ГМА** *и. гр. кит.* 1) Һәр заман һәм барлык шартларда да үзгәрешсез кабул ителеп, «бәхәссез үтәлергә тиешле хакыйкать» дип танылган канун яисә теория

2) Нинди дә булса тәгълиматның төп карашлары, нигезе. *Рим хокукының догмалары*

**ДО́ГМАЛАШТЫРУ** *ф. кит.* Берәр фикерне, карашны, тәгълиматны догмага әйләндерү; аңа сукырларча иярү

**Догмалаштыра бару** Көннән-көн ныграк догмалаштыру

**Догмалаштырып бетерү** Тәмам догма дәрәҗәсенә җиткерү

**ДО́ГМАТ** *и. гр. кит.* 1) Дөреслеге сукырларча танылган, бернинди тәнкыйтькә дә дучар ителми торган тәгълимат

2) *к.* **догма** (*1 мәгъ.*)

**ДОГМАТИЗМ** *и. гр. кит.* Теләсә нинди яңа гыйлемне, белемне кире кагып, катып калган, мәңгелек догма, догматларга нигезләнгән фикерләү алымы. *Догматизм һәр эштә зыянлы.* Г.Әпсәләмов. *Догматизм – оппортунистларча фикерләү ысулы. Ул – инде чынбарлыкка туры килми торган, искергән аерым формулалар һәм положениеләр белән эш итү ---.* Тарих

**ДОГМА́ТИК** I *и. рус кит.* Догмаларга нигезләнеп фикер йөртүче, догматизм тарафдары. *Догматиклар фикере*

**ДОГМА́ТИК** II *с. кит.* Догмаларга нигезләнгән, догмалар белән дәлилләнгән. *Догматик «хакыйкать»ләрдә генә бөтенесе дә гади һәм аермачык, алар бик борын заманнардан, үзен чолгап алган дөнья турында уйлану сәләте һәм мөмкинлеге туганнан бирле, кеше аңында даими урын алып торалар.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДОГМА́ТИКА** *и. гр.* Догматлар турындагы фән; христиан диненең догматлары турындагы фән. *Бу --- дин, догматика – Илаһият фәне мәсьәләләре генә булып күренгән темаларны Г.Утыз-Имәни абыз-агайларның иң кайнар проблемаларына китереп бәйли.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар. *Хәруллаһ хәзрәт --- Исламның атаклы галиме, бохаралы Сәгадетдин Тәүтәзанинең 14 нче йөздә логика (мантыйк) вә догматика (кәлям) буенча төзегән «Тәһзиб әль-мантыйк вә әль-кәлям» дәреслеген, фәтва китапларын өйрәнә башлый.* Гасырлар авазы

**ДОГМА́ТИКЛЫК** *и.* Догмалар белән сугарылганлык, догмаларга нигезләнгәнлек

**ДО́ГМАЧЫ** *и. кит.* Догматизм тарафдары, догмаларга таянып эш итүче

**ДО́ГМАЧЫЛЫК** *и. кит.* Догматларга, догмаларга сукырларча ышанып фикерләү ысулы

**ДОГОВОР** *и. рус* Уртак, кара-каршы алынган йөкләмәләрне, бурычларны үтәү турында язмача яки телдән килешү, шартнамә. *Кыскасы, эш тәртибе һаман элеккечә диярлек барды, ә хезмәткә договор нигезендә процентлап кына түләделәр.* Ф.Садриев

**ДОГОВОРЛЫ** *с.* Килешүле; рәсми килешү белән ныгытылган, үзара килешүгә нигезләнгән. *Икенчедән, Татарстанның Россия белән төзелгән договорлы махсус статуска ия республика булуы.* Шәһри Казан

**ДО́ЗА** *и. гр. махс.* 1) Берәр нәрсәнең бер тапкыр кабул итү өчен билгеләнгән микъдары, норма. *Дару дозасы. Нурланыш дозасы*

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса күләме, билгеле өлеше, кисәге. *Һәрбер кешедә дә, беркадәр дозада гына булса да, яхшылык булмый калмый*

**ДО́ЗАЛАУ** *ф.* Дозаларга бүлү. *Даруны дозалау*

**Дозалап алу** Тиз, кыска вакыт арасында дозаларга бүлү

**Дозалап бетерү** Барысын да дозалау; дозалауны тәмамлау

**Дозалап кую** Алдан дозалау

**ДО́ЗАЛЫ** *с.* Дозаларга бүленгән

**ДОЗА́ТОР** *и. рус* Өлешләргә бүлүче яки бүлү җайланмасы. *Автомат дозатор. Тутырма дозаторы*

**ДОЗИ́МЕТР** *и. гр. физ.* Радиоактив яки рентген нурланышын үлчәү җайланмасы. *Кесәдәге дозиметрлар безнең нормадан ике-өч мәртәбә артык рентген радиация алуыбызны күрсәтә ---.* Шәһри Казан

**ДОЗИМЕ́ТРИК** *с.* Радиоактив нурланыш дозасын күрсәтә торган (*прибор* һ.б.). *Компьютер томографиясе белән органның зарарланган урыны җентекләп карала, төш белән тәэсир итү өчен, аның үзәге (мишень) сайлана, диагностика белешмәләре цифрлы форматта 3 үлчәнешле дозиметрик планлаштыру системасына кертелә, аның ярдәмендә нурландырылыш өчен оптималь физик-техник параметрлар билгеләнә һ.б.* Шәһри Казан

**ДОЗИМЕТРИСТ** *и. рус к.* **дозиметрчы**. *Дозиметристлар: «Юк, алай түгел, сезнең дозиметрлар дөрес күрсәтми», – дип, безнең белән җан талашалар.* Ә.Салах

**ДОЗИМЕ́ТРИЯ** *и. гр. физ.* Гамәли физикада ионлаштырылган нурланышларның хәрәкәтен характерлаган физик зурлыкларны, шулай ук шул зурлыкларның озынлыгын үлчәү өчен кулланыла торган алымны һәм үлчәү әсбапларын өйрәнә торган өлкә

**ДОЗИМЕ́ТРЧЫ** *и. физ.* Дозиметрия белгече, дозиметрия белән шөгыльләнүче бригада яки аерым кеше. *Чернобыльдә дозиметрчылар бик нык алдаштылар. Алдашмасалар, аларны анда утыртмаслар да иде шул.* Ә.Салах

**ДОЗОР** *и. рус* 1) Нинди дә булса урында, объектта, карап, күзәтчелек, разведка алып бару эше

2) Шуның өчен билгеләнгән отряд, төркем. *Урман дозорлары, мәктәп лесничестволары агач утыртуда, урманнарны корткычлардан, янгыннан саклауда бик зур ярдәм күрсәтәләр.* Яшәү яме

3) *хәрби* Разведка яки сак өчен җибәрелгән, зур булмаган отряд. *Дүрт кешедән торган атлы дозор. Төнге дозор*

**ДОЗО́РНЫЙ** *и. рус к.* **дозорчы**. *[Муса:] Качабыз. Карагыз аны, тагын бер әйтәм: «Бабакай»ның дозорныйлары таш күпердән бер чакрым түбәндә торачаклар.* Н.Исәнбәт

**ДОЗОРЧЫ** *и.* Дозорда, постта торучы

**ДОК** *и. голл.* Портларда суднолар ремонтлау өчен махсус корылма. *Йөзмә док*

**ДОК, ДОК-ДОК** *иярт.* **1.** Тоныграк булган, саңгырау ишетелгән шакылдау, шапылдау тавышларын белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып, тонык, саңгырау шапылдап, шакылдап. *Док-док басып йөрү*

**3.** *хәб. функ.* «Док»ны хәтерләткән тавышлар чыгарган эш-хәрәкәтне бел-

дерә. *Алдыбызда бер стена барлыкка килде, караңгыда килеп бәрелдек шуңа: «док!»*

**ДО́КЕР** *и. ингл.* Кайбер илләрдә: йөк ташучы, порт эшчесе. *Докерлар бригадасы*

**ДОКЛАД** *и. рус* 1) Халык алдында билгеле бер темага ясалган чыгыш. *Ул сөйләп бетергәч, вәкил сүз алды, турыдан-туры ораторга мөрәҗәгать итте: «Мондый докладларны еш укыйсызмы?»* Ф.Баттал

2) Шул чыгышның язма тексты

3) Җитәкчегә, башлыкка эшләнгән эш турында телдән яки язмача формада ясалган рәсми белдерү һәм шул белдерүнең язма тексты

**ДОКЛАДНОЙ** *и. рус сөйл.* Доклад (*3 мәгъ.*) язылган рәсми кәгазь

**ДОКЛАДЧЫ** *и.* Доклад (*1 мәгъ.*) ясаучы. *Доклад ясаучы (милләте белән татар) партия өлкә комитеты работнигыннан докладның эчтәлеген татарча сөйләп бирүен үтенделәр. Дөресен әйтергә кирәк, докладчы авыр хәлдә калды.* А.Расих

**ДО́КТОР** *и. лат.* 1) *сөйл.* Табиб, врач; медицина хезмәткәре. *[Равил:] Син безнең --- авылыбызның докторы түгелме соң? – Әйе, мин – фельдшер.* З.Хәким. *Докторның һичбер сүзенә гамәлән һәм игътикадән карыша алмый иде.* Ф.Әмирхан

2) Диссертация яклау нигезендә бирелә торган иң югары гыйльми дәрәҗә һәм шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Бу әлеге дә баягы доктор Джек Мотон иде.* З.Мәхмүди

**ДОКТОРАНТ** *и. лат.* Докторлык диссертациясе әзерләү өчен, билгеле бер срокка фәнни учреждениегә беркетелгән галим

**ДОКТОРАНТУ́РА** *и. лат.* Фәннәр академиясенең фәнни тикшеренү институтлары яки югары уку йортлары каршында докторлар әзерләү системасы

**ДО́КТОРЛЫК** *и.* 1) *сөйл.* Доктор (*1 мәгъ.*) һөнәре һәм вазифалары; табиблык. *Докторлыкка уку*

2) Доктор (*2 мәгъ.*) дәрәҗәсе; «фән докторы» дигән югары гыйльми дәрәҗә. *Нәзиф Мириханов, Михаил Столяровның да федерализм буенча докторлык диссертацияләре искиткеч.* Татарстан. *Фәрит Мөхәммәтшин минем докторлыкны советта бик нык яклады.* Татарстан

**ДОКТРИ́НА** *и. лат. кит.* Тәгълимат; фәнни яки фәлсәфи теория; карашлар системасы

**ДОКТРИНЁР** *и. лат. кит.* Билгеле бер доктринага сукырларча иярүче кеше; коры фәлсәфә белән мавыгучы, схоласт

**ДОКТРИНЁРЛА́РЧА** *рәв.* Доктринёрларга хас булганча, доктринёр кебек

**ДОКТРИНЁРЛЫК** *и.* Билгеле бер доктринага педантларча, сукырларча иярү күренеше, доктринёрга хас сыйфатлар

**ДОКУМЕНТ** *и. лат.* 1) Нәрсәне дә булса раслый яки берәр нәрсәгә хокук бирә торган рәсми эш кәгазе. *Эш урыныннан алынган документ*

2) Кешенең шәхесен раслаган язма, таныклык (паспорт, белешмә һ.б.). *Казанга исән-сау әйләнеп кайтуыма ифрат шатланган әниемнең хуплавы һәм изге теләге белән бик тиз арада кирәкле документларны барлыйм, анкета тутырам һәм, кайтуыма атнакөн узмый, үзем кирәргә теләгән институтка йөгерәм.* А.Расих. *[Маруся:] Документыгызны аскы катта часовой караган булыр.* Н.Исәнбәт

3) Нинди дә булса вакыйганы тарихи раслау көченә ия булган язмача акт, грамота. *Суд документлары. Шәһәр советы сессиясе документлары*

4) Тарихи вакыйгалар, күренекле шәхесләр белән бәйле булган әдәби әсәр, рәсем, язма. *Архив документлары*

**ДОКУМЕНТАЛЬ** *с.* Документка, реаль чынбарлыкка нигезләнгән, документ белән расланган. *Әсәр документаль нигезгә корылган, шуңа карамастан без авторның Мирсәет Солтангалиев образына җанлы кешегә хас булган сыйфатлар өрүен һәр биттә күреп торабыз.* Ф.Галимуллин

**ДОКУМЕНТАЛЬЛЕК** *и.* Документлар белән расланганлык, чынбарлыкка, фактларга туры килгән булу. *Әсәрләрдә автор шәхесенең роле көчәю тенденциясе сизелде. Прозада документальлеккә игътибар артты.* Казан утлары

**ДОКУМЕНТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *җый. и.* Нинди дә булса хокукка ия булуны яки берәр фактны раслый торган документлар җыелмасы; документлар. *Мәктәп документациясе. Техник документация*

2) Документлаштыру эше һәм алымнары

**ДОКУМЕ́НТ ӘЙЛӘНЕШЕ** *и.* Документларның кем тарафыннан җибәрелүе, эшкәртү, саклау һәм тикшереп тору өчен, кайчан һәм кемгә бирелүе күрсәтелгән хәрәкәт системасы. *Документлар әйләнешен дөрес оештыру*

**ДОКУМЕНТЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Документлап кую. *Оператив-тикшерү төркеме белән, яңадан-яңа җинаятьләр буенча, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында чыгып китү, җинаятьчене «кайнар эз» буенча тотып, аның законсыз эшләрен исбатлаучы дәлилләрне документлаштыру – болар барысы да тикшерүче өстендә.* Шәһри Казан

2) Документлар (*1 мәгъ.*) белән раслау, документлар белән нигезләү. *Без федераль бюджеттан килгән субсидияләрне документлаштыру белән генә шөгыльләнәбез.* Ватаным Татарстан

**Документлаштыра бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы документлаштыру; раслый торган документларны акрынлап тулыландыру

**Документлаштыра башлау** Документлаштырырга керешү

**Документлаштырып кую** Документлаштыруга ирешү, алдан документлашкан хәлгә китерү. *«Күчтәнәч» кулдан-кулга күчү белән, алыш-биреш ясалачагын алдан ук белеп торган оперлар килеп кереп, урындагы кеше тарафыннан ришвәт алу очрагын документлаштырып куя.* Безнең гәҗит

**Документлаштырып бетерү** Барысын да документлаштыру

**Документлаштырып йөрү** Әле, хәзерге вакытта документлаштыру белән шөгыльләнү

**ДОКЫЛДА́У** *ф.* «Док» авазын хәтерләтеп, өзек-өзек тавыш чыгару, тонык, саңгырау шакылдау, шапылдау

**Докылдап җибәрү** Кинәт докылдый башлау

**Докылдап йөрү** Анда-монда килеп докылдау

**Докылдап кую** Кыска гына, бер тапкыр докылдау

**Докылдап тору** Бертөзлексез докылдау

**Докылдый башлау** Докылдарга керешү

**Докылдый бирү** Бернигә карамастан докылдавын дәвам итү, һаман да докылдау

**Докылдый төшү** Тагы да докылдау

**ДО́ЛЛАР** *и. ингл.* Төп АКШныкы булып, хәзер күп кенә башка илләрдә дә киң кулланышта йөри торган акча берәмлеге. *Соңгы елларда Нью-Йоркта музей эшенә доллардардан торган миллионнар --- күздә тотыла.* Г.Гобәй. *Рекламаларның нинди төрләрен генә күрмисең дә, ниндиләрен генә ишетмисең. Әйтик, «корпорация клиентлары өчен», «затлы ледиларга – затлы туннар», «бер квадрат метры 2000 долларлык шәп фатир» ---.* Татарстан

**ДОЛОМАН** *и. пол.* Махсус өлгегә буенча тегелеп, шнурлар белән чигеп бизәлгән гусарлар мундиры. *Кызыл доломан*

**ДОЛОМИТ** *и. фр.* Составында кальций һәм магнезия булган аксыл сары төстәге минерал (пыяла, керамика һ.б.ш. җитештерүдә кулланыла). *Судагы төрле химик матдәләр һәм тозлар диңгез төбенә утыра. Шулай итеп, гипс, ангидрит, известьташ һәм доломит барлыкка килә.* Кызыклы география. *Әчелекне бетерү өчен, туфракка көзен тирес белән бергә доломит оны, сүндерелгән известь, ә инде алар булмаса – агач көле кертәләр.* Серле сандык

**ДОЛЬМЕН** *и. фр. археол.* Бик зур таш кисәкләреннән һәм плитәләрдән өстәл кебек формада төзелгән борынгы мәет күмү корылмасы

**ДОМИНАНТ** *с. лат. кит.* Нәрсәнең дә булса төп, өстенлек иткән, аерылып торган сыйфатындагы. *Доминант караш. Доминант идея*

**ДОМИНА́НТА** I *и. лат. кит.* 1) Төп, иң әһәмиятле идея; нәрсәнең дә булса төп билгесе, состав өлеше

2) *лингв.* Синонимнар рәтендә: башка сүзләргә караганда стилистик яктан нейтральрәк һәм кулланылыш ягыннан активрак булган төп берәмлек, тәгъбир һ.б.ш.

**ДОМИНА́НТА** II *и. лат. муз.* 1) Ладның бишенче баскыч исеме

2) Шушы баскычка нигезләнеп төзелгән аккордларның исеме

**ДОМИНИОН** *и. ингл.* 1) Британия империясе составына кергән үзидарәле дәүләтләр

2) 1947 елга кадәр Британия милли берләшмәсенә әгъза сыйфатында кергән һәм инглиз королен шул берләшмәнең башлыгы дип кабул иткән дәүләтләр атамасы

**ДОМИНО** *и. ит.* 28 сөяк (яки агач) пластинадан торган, өске ягына очколар төшерелгән уен һәм шулай ук бу уен өчен пластиналар җыелмасы. *Арырак – вахта. Анда бер төркем конвойчылар капка төбендәге өстәлдә домино уйный.* И.Салахов

**ДОМИНОЧЫ** *и.* Домино уйнаучы; шул уенны уйнарга оста, һәвәс кеше. *Доминочылар ярышы*

**ДОМКРАТ** *и. голл. тех.* Йөкләрне артык зур булмаган биеклеккә күтәрү җайланмасы. *[Павильонны] Нигездән башлап төзесәләр, төзү материалын кран белән өскә күтәреп торырга кирәк булыр иде. Алар аны җирдә җыеп, домкрат белән күтәрттеләр...* М.Юныс. *Механизатор егетләр аңа [Гыйлемханга] менә дигән ярдәмче – домкратларын биреп торды.* Р.Мөхәммәдиев

**ДО́МНА** *и. рус* Тимер рудасыннан чуен коя торган шахта миче. *Домналар ул, Вулкан уянган күк, Йолдызларга пожар сузалар.* Х.Туфан. *Хәзергесе көндә Сары Хисмәт Чуен эретә домна мичендә.* Ш.Маннур. *Бу күзәнәкләр исән килеш Җиргә кайтып җитсә, анда шахталар, домналар, металлургия заводлары кирәксезгә әйләнеп юкка чыгачак.* З.Мифтахов

**ДО́МНАЧЫ** *и.* Домна эшчесе. *Домначылар, тирән дулкынланып, Бар көч белән эшкә тотынды!* Ш.Маннур

**ДОМОУПРАВ** *и. рус сөйл.* Шәһәрләрдә (зур район үзәкләрендә) торак йортлар белән идарә итә торган административ орган

**ДОМОУПРАВЛЕ́НИЕ** *и. рус сөйл. к.* **домоуправ.** *Военкоматтан, домоуправлениедән, милициядән призыв мәсьәләсе буенча килделәр.* М.Җәлил

**ДОМОФОН** *и. рус* Биналарга, торак йортларга махсус код ярдәмендә ачып керү-чыгу җайланмасы; кыска функцияле телефон. *Йортта домофон, видеокүзәтү, сигнализация булуы тынычлык өстәр.* Безнең гәҗит. *Домофоннар буенча мастер*

**ДОНЕСЕ́НИЕ** *и. рус сөйл.* 1) Нинди дә булса мәгълүматлар турында җитәкчегә, начальникка телдән яки язмача рәсми хәбәр

2) Шундый хәбәр язылган кәгазь. *Данилов, донесение илтү өчен, яшьрәк, талчыкмаганрак сугышчылар арасыннан Шәмсине җибәрергә булды.* Г.Бәширов

**ДОНЖУАН** *и. исп. кит. шелт.* Мәхәббәт маҗаралары эзләүче, хатынкызлар белән артык күп чуалучы кеше. *Яшь егет үзен: «Георгий», – дип таныштырды. Ул, чынлап та, бик купшы-нәзакәтле киенгән, үзен йомшак-ягымлы тота, донжуан һәм ловелас.* Казан утлары

**ДОНЖУАНЛЫК** *и.* Донжуан булу

**ДОНКИХОТ** *и. исп. кит.* Тормышка ашмастай идеаллар артыннан куучы, беркатлы, хыялый кеше; фантазёр. *Минем, кулымдагы чыпчыкка риза булмыйча, һаман һавадагы торнага өметләнеп яшәвем, чынбарлыкны аңламавым, донкихотча коры хыялга бирелеп көн күрүем нилектән икән?* М.Юныс

**ДОНКИХОТЛАНУ** *ф.* Донкихот сыман кылану; үзен донкихот кебек тоту

**ДОНКИХОТЛЫК** *и.* Хыялыйлык, фантазёрлык; донкихотларга хас гамәлләр

**ДО́НОР** *и. фр.* Авыру һәм яралы кешеләр өчен үзенең канын яки кайсы да булса әгъзасын бирүче кеше. *Татарстанда яшәүче 1 кешегә 13,2 мл әзер донор каны бар икән.* Ватаным Татарстан

**ДО́НОРЛЫК** *и.* Авыруларга һәм яралыларга күчерү өчен кан, шулай

ук тире һәм башка әгъзаларны бирү, донор булу. *[Мөслимдә] Донорлык хәрәкәте киң җәелгән. Кан бирүдә медицина хезмәткәрләре башлап үзләре үрнәк күрсәтә.* Яшәү яме

**ДОНОС** *и. рус шелт.* Җитәкчелеккә кемне дә булса гаепләп язылган яшерен хәбәр, әләк. *[Шәйхаттаров:] Бусы начар. Ярый, син бакма. Хаклы кеше донос язмый.* Т.Миңнуллин. *Бу хәл губернаторны аерата шикләндерә, чөнки аңа язылган доноста --- «ул – бик хәвефле кеше, төрек тарафдары, төреккә акча җыя, гаскәр туплый» дип язалар.* А.Расих

**ДОНОСЧЫ** *и.* Донос ясаучы, язучы, донос язу белән шөгыльләнүче, әләкче

**ДОНОСЧЫЛЫК** *и.* Донос белән шөгыльләнү

**ДОҢГЫЛДАТУ** *ф.* Нинди дә булса каты өслеккә авыр әйбер белән сугып, бәреп, кабатланып торган «доң» авазына охшаш тавышлар чыгару

**ДОҢГЫЛДА́У** *ф.* Каты өслеккә авыр әйбер бәрелеп торудан чыккан, «доң» авазына охшаш өзек-өзек яңгырау

**Доңгылдап алу** Берара, кыска вакыт доңгылдау

**Доңгылдап җибәрү** Кинәт доңгылдый башлау

**Доңгылдап кую** Бер тапкыр доңгылдаган тавыш чыгару

**Доңгылдап тору** Гел-гел, бертуктаусыз доңгылдау

**Доңгылдый башлау** Доңгылдарга керешү

**Доңгылдый бирү** Бернигә карамый доңгылдауны дәвам итү, һаман да доңгылдау

**Доңгылдый төшү** Тагы да көчлерәк яки озаграк доңгылдау

**ДОҢГЫРДАТУ** *ф. к.* **доңгырдау**. *Тәрәзә артында, катып, тәмам бозлавыкланган кантарлы юлдан, буш арбасын яман доңгырдатып, бер атлы узды.* М.Хәсәнов

**ДОҢГЫРДА́У** *ф.* «Доңгыр» авазларына охшаган өзек-өзек яңгырау тавышы чыгару. *Вагон тәгәрмәчләре доңгырдау*

**Доңгырдап алу** Бераз, кыска вакыт доңгырдау

**Доңгырдап тору** Гел, берөзлексез доңгырдау

**Доңгырдый башлау** Доңгырдарга керешү

**Доңгырдый бирү** Бернигә карамый доңгырдауны дәвам итү, һаман да доңгырдау

**ДОҢГЫРДЫК** *с.* **1.** 1) Доңгырдый, «доң» авазлары чыгара торган

2) Доңгырдатып селкетә торган. *Доңгырдык юл*

**2.** *и. мәгъ.* Кантарлы, балчык түмгәкләреннән торган тигезсез юл, урын. *Доңгырдыктан бару бик читен*

**ДОҢГЫРТ** *ият.* Кинәт, кискен доңгырдап куюны белдерә

**ДОҢ-ДОҢ** *ият.* Каты өслеккә авыр әйбер белән бәреп торудан, куәтле авыр адымнардан чыккан өзек-өзек тавышны белдерә. *Җир өсте доң-доң итә, күк йөзе ялтырап-ялтырап китә, ди.* Әкият. *Бозланып каткан кое чиләге «Үги кыз» әкиятендәге агай агачка элеп калдырган тукмак шикелле берөзлексез чайкала, доң-доң килеп бурага бәрелә.* Сабантуй

**ДОҢК** *ият.* Каты өслеккә авыр әйбер кинәт төшеп китүдән яки бәрелүдән чыккан кискен доңгылдаган, шапылдаган тавышны белдерә

**ДОП, ДОП-ДОП** *ият.* **1.** Авыр әйбер бәрелгәндә, төшкәндә, шапылдатып куйганда һ.б.ш. ишетелгән калын яңгырау тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. *Авыр итекләр белән доп-доп йөгерү*

**ДО́ПИНГ** *и. ингл.* Организмның физик һәм нерв эшчәнлеген тиз һәм кыска вакытка көчәйтеп җибәрә торган фармокологик яки нинди дә булса башка чара. *Әмир, допинг алган спортчы төсле кыюланып, һөҗүмгә күчте.* Т.Галиуллин. *Әфганда чакта, бер өйрәнгәч, дошман өстенә баруның әллә ние юк. Бигрәк тә эчеп алсаң, шуңа наркотик белән допинг та өстәп җибәрсәң...* Н.Әхмәдиев

**ДО́ППЛЕРОГРА́ФИЯ** *и. гр. мед.* Баш миен, андагы кан тамырларын тикшереп, диагноз кую җайланмасы. *Баш миен, андагы кан тамырларын тикшерүче допплерография күрсәтмәләре буенча, бүгенге көн шартларындагы хроник стресс инде Русия җирлегендә норма булып ук киткән.* Юлдаш

**ДОПРИЗЫ́ВНИК** *и. рус махс.* Хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан башлангыч хәрби өйрәнүләр үтүче егет. *Военкомат мине яшьләр, допризывниклар эшелонының комиссары итеп билгеләде.* Г.Бәширов

**ДОПРОС** *и. рус сөйл.* 1) Нинди дә булса эшне, җинаятьне һ.б.ш. ачу максаты белән, гаепләнүчедән, шаһиттан сорау алу. *Участковыйның допросын колхозның юлбашчысы Габдрахман дәвам итте...* З.Хәким

2) *күч. сөйл. шелт.* Нәрсә турында булса да, нык төпченеп, таләпчән тон белән сорашу

**ДОПЫЛДА́У** *ф.* «Доп» сыман тавышлар чыгару, калын тавыш белән шапылдау, яңгырау

**Допылдап тору** Берөзлексез допылдау; әледән-әле допылдау

**Допылдап кую** Кинәт, бер тапкыр допылдаган тавыш чыгару

**Допылдый бару** Торган саен ныграк допылдау

**Допылдый башлау** Допылдарга тотыну

**Допылдый бирү** Бернигә карамый допылдауны дәвам итү, һаман да допылдау

**Допылдый төшү** Тагы да бераз допылдау

**ДОРО́ЖКА** *и. рус сөйл.* Идәнгә җәя торган озынча келәм, палас. *Бик матур дорожка*

**ДОРБА** *и. диал.* Тупас тукылган киндер чаршау

**ДОРФА** *с. гар.* **1.** 1) Бик тупас, кырыс мөгамәләле; тәрбиясез, мәгънәсез кыланышлы. *Чүти авылы халкы күрер күзгә дорфа, кискенрәк күренсә дә, холыклары белән тәэсирләнүчән, реакциягә җитез, кыю, тәвәккәл халык.* Ф.Дунай

2) Ямьсез, тупас (сүз, кыланыш һ.б.ш. турында). *Дорфа сүз*

**2.** *рәв. мәгъ.* Тупас, әдәпсез рәвештә. *Көтмәгәндәрәк, әллә ничек шунда, дорфарак килеп чыкты, ахры, аның бу соравы.* Р.Мөхәммәдиев. *Русчасы чамалы булгангадыр, аның сүзләре бу*

*юлы бермә-бер дорфарак яңгырады.* Р.Мөхәммәдиев

**ДОРФАЛАНУ** *ф.* Дорфалык күрсәтү, тупаслану, тупас кылану

**Дорфалана бару** Торган саен ныграк дорфалану

**Дорфалана башлау** Дорфаланырга тотыну

**Дорфалана төшү** Тагын да дорфалану. *Зиләйлә шунда бер елмаеп куйса, ирексездән көлемсерәсә, күңеле дә, теле дә йомшап китәчәк иде дә бит, тик ул тагын да дорфалана төште.* М.Маликова

**Дорфаланып бетү** Бик нык, тәмам дорфалану

**Дорфаланып кую** Кинәт кенә дорфалык күрсәтү, аз гына дорфалану

**ДОРФАЛЫК** *и.* Дорфа, тупас булу, тупаслык. *Зират каравылчысыннан барып сорау аңа бик зур тупаслык, күз алдына китерә алмаслык дорфалык булып тоелды.* Р.Вәлиев

**ДОСААФ** *и. рус спорт* Армия, авиация һәм флотка ирекле формада ярдәм итү җәмгыяте; *русчасы:* **добровольное общество содействия армии, авиации и флоту**. *[Рахманкулов] Студком члены, факультетның ДОСААФ председателе.* М.Юныс

**ДОСЬЕ** *и. фр.* 1) Нинди дә булса эшкә, мәсьәләгә кагылышлы документлар, материаллар җыелмасы. --- *досье СССР төзү чорында каршы мәгълүматлар хисабына тагын да байый төшә.* И.Таһиров

2) Шул җыелма салынган папка

**ДОТ** *и. рус хәрби* Сугыш кырында озак вакыт оборона тоту һәм миномёт, пулемёт һ.б.ш. ату өчен, бетоннан ныгытып эшләнгән корылма. *Бер дот шулай, шактый җимерелгәч тә, Бирелмичә озак тартышты.* М.Җәлил. *Дошман лагереннан – дот, дзотларыннан, яшерен пулемёт, туп ояларыннан – безгә каршы ут ачылды.* Ә.Айдар

**ДОТА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* Хуҗалык оешмаларына, предприятие, учреждение һ.б.ш. артык чыгымны каплау һәм башка кирәккә тоту өчен, хөкүмәттән бирелгән акчалата ярдәм. *Якындагы ике совхозның да байтак әйбере «Хезмәт»кә күчкән, дүрт совхозга тиешле дотацияне «Хезмәт» берүзе тоткан.* Г.Ибраһимов. *Беренчедән, биредә [Әлмәт шәһәрендә] --- дотация барлык киң катлам халыкка бирелә.* Татарстан

**ДОФАН** *и. гар. диал.* Ком бураны, өермә

**ДОХА** *и. калм.* **1.** Эче-тышы мех тун. *Бик озын доха*

**2.** *с. мәгъ.* Эче-тышы мехлы (кышкы кием турында). *Карл Фёдорович, зур кырыйлы тирән камчат бүреге белән киң якалы, озын җиңле доха толыбын киеп, Иван Никитичның биек артлы кара чанасына чыгып утырды.* М.Галәү

**ДОХОД** *и. рус сөйл.* Предприятие, учреждение яки аерым шәхес тарафыннан, берәр эшчәнлек өчен, нинди дә булса башка предприятиядән алынган керем, табыш, төшем, килер. *Колбаса фабрикасы бар, ди, аның, йөз меңнәрчә доход ала, ди...* Ә.Еники. *Алар дәүләт доходына алынган суммада булган аңлашылмаулар турында сөйләшергә керешteләр.* А.Шамов

**ДОХОДЛЫ** *с. сөйл.* 1) Доходы күп булган, икътисади яктан бай, күп доход китерә торган, төшемле. *Доходлы предприятие*

2) Доход, керем чыганагы булган. *Менә, Алла боерса, минем оптик юлга куелып җиткәч, ул эшнең нинди доходлы эш икәнен күрерсең.* Ф.Әмирхан. *Доходлы, файдалы сәүдәләр, һөнәрләр тирәсендә яһүд тә немец кына...* Ф.Әмирхан

**ДОХОДЛЫЛЫК** *и.* Доходлы булу; төшемлелек. *Фермер хуҗалыкларының доходлылыгын арттыру. Предприятиеләрнең доходлылыгы*

**ДОЦЕНТ** *и. лат.* Югары уку йортларында эшләүче укытучының гыйльми дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәне алган, шул вазифадагы кеше (профессордан түбән, ассистенттан югары гыйльми дәрәҗә). *Университет доценты. Доцент дипломы алу*

**ДОЦЕНТЛЫК** *и.* Доцент дәрәҗәсе

**ДОЦЕНТУ́РА** *и. рус* 1) Доцент дәрәҗәсе, исеме

2) Теге яки бу уку йортының барлык доцентлары

**ДОШМАН** *и. фар.* **1.** 1) Кемгә дә булса дошманлык хисе саклаучы, аңа начар мөнәсәбәттә булган кеше. *Дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә.* Мәкаль. *Дөньяда дус бар, дошман бар.* Әйтем. *Араларына килеп кергән милиционер аша да Мәрфуга апа дошманына берне «манчырга» өлгерде.* З.Хәким

2) Сугышта: каршы як. *Юк, дошман илебезне буйсындыра алмаган кебек, сугыш Әлтафи, Гыйззәтуллин, Зарифуллиннарны да җиңә алмады.* М.Мәһдиев

3) Зарар, зыян китерә торган нәрсә. *Фикерсезлек, битарафлык – дошман*

4) *тар.* Иҗтимагый карашы һәм сыйнфый ягы белән капма-каршы кеше. *Соңгы еллардагы үткенләнгән сыйнфый дошманның сугышы безне ут белән су кебек каршы куйса да, миләрнең, йөрәкләрнең юллары тагы бергә кушылып ага башлады бугай.* Г.Ибраһимов. *Ә менә кичә төнлә үзен, ректорны әйтәм, кулга алганнар, халык дошманы булган ---.* И.Салахов

5) *күч.* Гомумән нинди дә булса каршылык, каршы як турында. *Мин дә, теннис ракеткасы тотып, «дошман» каршысына басам, үземне, кулыма кылыч алып, атакага барган кеше итеп сизә башлыйм.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* 1) Дошманлык хисе саклый торган, кемне яки нәрсәне дә булса яратмый, күралмый торган

2) Сугышта: капма-каршы торган. *Әтисе дошман әсирләр арасында булсын да, андый кешене кем дип белергә кирәк, әйе.* Ф.Яхин

3) Дошманлык хисләре белән сугарылган. *Дошман карашлар. Дошман фикерләр*

**3.** *рәв. мәгъ.* Дошман кебек, дошманнарча. *Кызның карашында --- дошман тоту сыман нәрсә сизелә.* Ф.Әмирхан

**ДОШМАНЛАШТЫРУ** *ф.* Ике яки берничә як арасында дошманлык хисләре, мөнәсәбәтләре тудыру, араларын бозу. *Русия халкын дошманлаштыру була.* М.Хәбибуллин. *Бөтен Ауропаның, Кастилия, Франция, Англия, Германия, Италия, Балкан илләренең, маҗарларның, урысларның бер генә максаты булырга тиеш: шушы җиңелмәс өч баһадирны үзара дош-*

*манлаштыру, аларны зәгыйфьләтү, ул арада көч туплап, Ауропаны, динне саклап калу*. Р.Батулла. *Бер генә урында да кешеләргә карата тискәре караш, ислам диненең башка диннәрдән өстен булуы, төрле дин вәкилләрен дошманлаштыру нияте, дини сугышка өндәүләрне тапмадым.* Мәдәни җомга

**ДОШМАНЛАШУ** *ф.* Дошман булу, бер-берсен күралмау. *Бер карыш җир аркасында Дус, туганнар дошманлаша.* Р.Зәкуан

**Дошманлаша бару** Тагы да ныграк дошманлашу

**Дошманлаша башлау** Дошманлашырга тотыну

**Дошманлаша төшү** Бераз дошманлашу

**Дошманлаша язу** Аздан гына дошманлашмый калу. *[Җолдас:] Әй мин, карт җүләр, әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Шул шикчеллегем аркасында күршем белән дошманлаша яздым.* Р.Зәйдулла

**Дошманлашып бетү** Тәмам дошманлашу, дошманлашу дәрәҗәсенә җитү

**Дошманлашып йөрү** Әле, хәзерге вакытта дошманлашкан булу

**Дошманлашып китү** Билгеле бер вакыттан, эш-хәл, вакыйгадан соң, кинәт дошманлашу

**Дошманлашып тору** Гел дошманлашу, әледән-әле дошманлашу

**ДОШМАНЛЫК** *и.* Нәфрәт хисләре белән сугарылган, бер-береңне күралмауга корылган мөнәсәбәт. *Дошманлык пәйда булып, арада кылыч вә пычак йөрер.* К.Насыйри. --- *ак төскә каршы карасы бар – яратмау, дошманлык*. Ш.Галиев

**ДОШМАННА́РЧА** *рәв.* Дошманнар кебек; бер-беренә дошманлык саклап; яратмыйча, күралмыйча. *Әле яңа гына дошманнарча сугышып яткан егетләр кочаклашып аерылыштылар.* Р.Батулла. *Кичектем һәм, нәтиҗәдә, балаларым мине дошманнарча каршыладылар!..* С.Баттал. *Халыкның, алдынартын уйламыйча, безне туендырып, нигъмәтләндереп торган Җир ананы дошманнарча җәзалавы, ай-һай, бик авыр чирләр булып әйләнеп кайтмагае әле.* Татарстан яшьләре

**ДОШМАНЧЫЛЫК** *и.* Дошманнар арасындагы кебек мөнәсәбәт, дошманлык мөнәсәбәте. *Шушы фаҗигале һәм тарихи вакытта яңаручы Русиягә Көнбатышның иң куәтле дәүләтләре дошманчылык сәясәтен көчәйтмәде.* Кызыл таң. *Шуңа күрә, «Болгарны торгызу туристларга кирәкми» дигән сүз ул – гади наданлык, хәтта дошманчылык та.* Безнең гәҗит

**ДӨБЕР, ДӨБЕР-ДӨБЕР** *иярт.* **1.** Гөрселдәгән яки шалтырап дөпелдәгән, дөбердәгән һ.б.ш. каты тавышларны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. *Якуб аякларын арба кырыеннан салындырып утыргач, арба кузгалып китте: таш җәйгән урам буенча дөбер-дөбер китеп бардылар.* И.Гази. *Дөбер-дөбер итеп, егетләрнең качканы ишетелә.* М.Фәйзи. *Дөбер-дөбер килеп, больница каршысына автомашина килеп туктады.* А.Гыйләҗев

**ДӨБЕРДӘТҮ** *ф.* **1.** Дөбердәгән тавыш чыгару, шундый тавыш чыгарып шаку, кагу, шапылдату. *Дөп-дөп ишек каккан, юк, ялгыша, ахры, капка дөбердәткән тавышка уянып китте ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Шул ук көннең төнендә, яман дөбердәтеп, өйгә басып керделәр дә, Иргалине атка утыртып, коралды конвойлар арасына алып, район үзәгенә – Чаллыга алып киттеләр.* М.Хәсәнов

**2. дөбердәтеп** *рәв. мәгъ. куч. сөйл.* 1) Бик шәп итеп, зурдан кубып. *Дөбердәтеп, туй уздыру*

2) Үтә җанлы, актив һәм уңышлы төстә. *Гарифә, Уйылданның әнисе кебек, касә яки тустаган белән ташып маташмады, бәләкәйрәк мичкәгә салынган балны ашъяулык уртасына дөбердәтеп китерде дә утыртты.* Н.Мусин

**Дөбердәтә башлау** Дөбердәтергә тотыну. *Бераздан соң ул [лифт] ватылып туктый. Эчтән дөбердәтә башлыйлар.* А.Хәмзин. *Суфия ханым, уйга чумып, Мөнирәнеке кебек озын бармаклары белән өстәл өстендәге пыялага дөбердәтә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Дөбердәтә төшү** Тагы да ныграк, катырак дөбердәтү. *Ул кире борылып китәргә уйламады да, киресенчә, капканы дөбердәтә төште*

**Дөбердәтеп алу** Кыска гына вакыт эчендә дөбердәтү. *Ул ишекне тагын бер дөбердәтеп алды*

**Дөбердәтеп тору** Өзлексез яки әледән-әле дөбердәтү. *Бик ерактагы тракторларның атлар туктагач кына ишетелә башлаган тигезле-тигезсез дөпелдәүләре шул хыялый болыт стеналарына ниндидер серле таяк белән дөбердәтеп торган шикелле булып тоела.* Г.Гобәй

**ДӨБЕРДӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) «Дөбер» сыман тавышлар чыгару; дөбер-дөбер итү, дөбер-дөбер килү, шакылдау. *Вагон тәгәрмәчләре шул музыкага өстәлергә тиешле барабан кебек тигез дөбердиләр.* К.Нәҗми. *Караңгылыктан, әллә кайлардан эре яңгыр тамчылары бер-бер артлы, дөбердәп, тәрәзәгә бәрелә һәм, гүя, килеп, Мусаның йөрәгенә кадала иделәр.* Ш.Камал. *Наилә алгы өйдән кер бавы табып чыкканчы, шактый вакыт үтте, тегеләр тагын әүмәкләшеп алдылар бугай, шакылдау, дөбердәү көчәйде.* М.Маликова

2) Чокырлы-чакырлы тигезсез юлдан сикергәләп бару. *Кырык-илле олау көзге туң юлда дөбердәп, шалтырап, ике авыл арасын үтүгә, аларга тагы шул хәтле үк күршеләре кушыла.* Җ.Рәхимов

**2. дөбердәп** *рәв. мәгъ.* 1) Яхшы, шәп, уңышлы итеп. *Сәүдәләр дөбердәп бара.* Г.Иделле

2) Җиңел атлап, бик җитез хәрәкәт итеп. *Дөбердәп йөри торган карчыкны да нинди хәлгә китерде бу сугыш.* Ә.Камал

**Дөбердәп алу** Берникадәр вакыт (аз гына вакыт аралыгында) дөбердәү. *Суыткыч янтая. Дөбердәп ала*. Х.Ибраһимов. *Күк күкрәү кебек дөбердәп алды да хәзер инде барысы да тынды.* С.Поварисов

**Дөбердәп китү** Кинәт дөберди башлау. *Шулчак нидер «шап» итеп дөбердәп киткән.* Әкият. *Кычкырып килгән Газраилдәй ямьсез тавыш дөбердәп китә.* М.Гали

**Дөбердәп кую** Кыска вакыт аралыгында, бер тапкыр дөбердәү. *Яңгыр*

*чиләкләп коя, Күкләр дөбердәп куя.* Р.Вәлиева

**Дөбердәп тору** Берөзлексез дөбердәү; әле, хәзер дөбердәү. --- *караңгы күккә җыр-музыка авазлары ашкына, барабан тавышлары дөбердәп тора...* Ф.Бәйрәмова

**Дөбердәп утыру** Әле, хәзерге вакытта дөбердәү. *Урман арасында, сукамыш янында көн-төн шаулап, дөбердәп утырган тегермән миңа кайчандыр дөньяның иң сихри үзәге булып, туклык һәм бәхет чыганагы булып тоела торган иде.* Н.Фәттах

**Дөберди башлау** Дөбердәргә керешү. *Болар хәзер ай ярым баралар. Шуннан соң айгыр дөберди башлый, туктатырга куша.* Әкият. *Нәрсәдер бик каты дөберди башлагач, шофёр егет, юл кырыенарак алып, машинаны туктатты.* М.Галиев

**Дөберди бирү** Бернигә карамый дөбердәүне дәвам итү, һаман дөбердәү

**Дөберди төшү** Тагын да дөбердәү

**ДӨБЕРДЕК** *с.* Дөбердәп торган; дыңгырдык

**ДӨБЕР-ДӨБЕР** *иярт.* **1.** Дөбердәгән, гөрселдәгән каты тавышларны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Дөбердәп, дөбердәгән тавыш чыгарып

**ДӨБЕРТ** *иярт.* Кинәт, кискен барлыкка килгән «дөбер» сыман тавышны белдерә. *Дөберт! Арслангали, сискәнеп, күзләрен ачты, кулыннан тормоз рычагы ычкынган икән!* Г.Ахунов

**ДӨБЕР-ТАСЫР** *иярт. к.* **дөбер-шатыр**. *Тора торгач, Песи койрыкны селкетте, Дөбер-тасыр бу Тычканнар бары үз урынына китте.* М.Гафури

**ДӨБЕР-ШАТЫР** *иярт.* **1.** Бик каты дөбердәп төшкән, көчле дөбердәгән, бәрелгән-сугылган һ.б.ш. тавышларны белдерә. *Моңа кадәр тып-тын яткан халык, дөбер-шатыр, урыннарыннан торды.* И.Салахов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Көчле дөбердәгән, бәрелгән-сугылган тавышлар чыгарып, каты дөбердәп. *Автомобиль әрҗәсендәге утыз тонналы тау, дөбер-шатыр актарылып, җиргә ауды.* М.Хөсәен. *Өнсез-тынсыз калган халык кинәт кенә дөбер-шатыр иткән тавыштан «дерт» итеп калды – кай арададыр күк йөзен куе кара болытлар өере каплап алган.* Н.Мусин. *Бөтен дөньясын онытып, кара тиргә батып эшләгәндә, кинәт, породаларны дөбер-шатыр актарып, шахта суы килеп чыкты.* И.Гази

2) *күч.* Бик җитез хәрәкәтләнеп, актив һәм җанлы рәвештә. *Авыз суларын агызып, шушы тантаналы минутны көткән малайлар, дөбер-шатыр, тәбакларга ябырылдылар.* И.Гази. *Дөбер-шатыр китерде, Барын кырды, җимерде.* Ш.Маннур. *Дөбер-шатыр эшләп ташлау*

**3.** *и. мәгъ.* Бик каты дөбердәгән, бәрелгән-сугылган һ.б.ш. тавышлар. *Яратам сугышның дөбер-шатырын: әллә ничек, күңелне очындырып җибәрә!* И.Гази

**4.** *с. мәгъ.* Сикәлтәле, чокырлы-чакырлы. – *Шәрифҗан, туктале, мин төшим: бу дөбер-шатыр урамда бөтенләй эчәгеләрсез калырсың, – дип, Якуб арбадан сикереп төште дә җәяү китте.* И.Гази

**ДӨГӘ-ДӨГӘ** *ы. к.* **дегә-дегә**

**ДӨГЕ** *и. кыт.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан, җылы якларда сугарып игелә торган озынчарак ак яки көрән орлыклы башаклы үсемлек. *Җәһәннәм эсселеге кеби яндырып-көйдереп торган кояшта, әсирләрнең бәгъзысы печән чапмакта, бәгъзысы, янып-пешеп, арпа урмакта, дөге җыймакта иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Крестьян әнә җир сөрә, икенчеләре таш күмере чыгаралар. Ташкентта – әнә мамык, дөге дигәндәй.* А.Әхмәт

2) Шушы үсемлекнең азык буларак кулланыла торган орлыгы. *Шул көн безгә ике сажень утын, бер капчык ак он, дүрт кадак атланмай, унбер кадак дөге китерде.* Г.Ибраһимов. *Порошоклы дару каптырганнан соң, бу сестра, Җамалига сөттә пешкән сыек кына дөге боткасы китереп, аны кашык белән авызына салып-салып ашатты да соңыннан шикәрле чәй эчертте.* М.Гали. *Ул, ачык чырай белән, арасына сарык ите турап пешергән бер савыт дөгене иренең алдына китереп куя.* Э.Касыймов

**ДӨГЕЧЕ** *и.* Дөге үстерүче, дөге игүче; дөге игү буенча белгеч

**ДӨГЕЧЕЛЕК** *и.* Дөге үстерү өлкәсе

**ДӨК, ДӨК-ДӨК** *иярт.* **1.** Нәрсә дә булса бәрелгәндә ишетелә торган кыска тонык тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ. гадәттә каб. форм.* Шундый тавышлар чыгарып

**ДӨЛДЕЛ** *и. гар.* 1) *дини* Хәзрәте Гали атланып йөргән качырның исеме. *Чәчкә ыргый, баш башына үрмәли, Алла дигәч, мисле дөлдел юргалый...* Ш.Бабич

2) *миф.* Кош кебек оча торган канатлы ат. *Музыкада чакыру яңгырады, ә кыз сыны инде атка менгән. Ап-ак дөлделдә ул.* Г.Хисамов. *Басу капкасын чыгу белән, чыбыркыны сызгыртып, җирән айгырның сыртына берне салган идем, айгырым дөлделдәй оча башлады.* Ә.Айдар

**ДӨЛМӘН** *и. тар.* 1) Зур кызыл чалма (офицерлар кигән)

2) Гусарлар кия торган мундир; *русчасы:* **доломан**

3) *бот.* Лалә, тюльпан

**ДӨМ** *кис.* **1.** Сыйфатларның кайберләре алдында килеп, һәрвакыт басымны үзенә алып, шул сыйфатның артыклык дәрәҗәсен барлыкка китерә (мәс., *дөм кара, дөм сукыр, дөм ятим*). *Өй эчендә безнең кебек качып йөрүчеләрне яшерү өчен махсус әзерләнгән кебек тынычлык: тәрәзә капкачлары һәммәсе дә ябылган, өй эче дөм караңгы.* М.Әмир. *Инеш артында [урман кырые] дөм кара булып күренә.* Г.Гобәй. *Дөм ят кешеләр аны [карчыкны] исләреннән чыгармаганнар.* С.Сабиров

**2.** *рәв. мәгъ.* Кайбер сүзләр янында кулланылып һәм басымны үзенә алып, «бөтенләй, тәмам, тулысынча» дигән мәгънәне белдерә. *Урманның ике ягында күзләрен дөм йомып йоклый торган кечкенә-кечкенә өйләр кала.* Ф.Хөсни. *Комбайнчы Рябов арыш урганда эшкә 2 көн дөм исереп килде.* Татарстан яшьләре

**3.** *и. мәгъ. сөйл.* Артык караңгылык. *Бу дөмдә нәрсә күреп булсын соң?*

**ДӨМБӘСКӘ** *и. диал.* Үлән яки мүк үскән балчык кантары, түмгәк. *Дөмбәскә кебек басып тора*

**ДӨМБӘСКӘЛЕ** *с. диал.* Түмгәкле, кәсле. *Дөмбәскәле юл*

**ДӨМБӘСКӘЛЕК** *и. диал.* Дөмбәскәле, дөмбәскәләр (күп) булган җир. *Сазлыктагы дөмбәскәлек*

**ДӨМБӘСЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кыйнау, нык бәргәләп тукмау. *Лапшинның дөньясын туздырырга кирәк. Аннары бүтән авыл байларын дөмбәсләргә мөмкин.* Н.Мусин

2) *куч. сөйл.* Фронтта, гомумән, нинди дә булса сугыш вакытында: көчле һөҗүм ясау, җиңелүгә дучар итү. *Дошманны дөмбәсләү*

**Дөмбәсләп алу** Тиз генә дөмбәсләү, берникадәр вакыт дөмбәсләү

**Дөмбәсләп бетерү** Бик нык дөмбәсләү

**Дөмбәсләп ташлау** Кинәт, бик нык дөмбәсләү. *Бөтен авыл егетләре, җыелып, кунак егетен дөмбәсләп ташладылар*

**Дөмбәсләп тору** Еш, әледән-әле дөмбәсләү. *Ул, дөмбәсләп торуларына да карамастан, барыбер үзенекен итте*

**Дөмбәсләп чыгу** Беркемне дә калдырмау, барысын да рәттән дөмбәсләү

**Дөмбәсли башлау** Дөмбәсләргә керешү. *[Гөлләндәм ханым] --- йодрыклары белән Гайнанның аркасын дөмбәсли башлады.* Р.Зәйдулла. *--- җен-пәриләр, бүтән куркыныч затлар да егетне дөмбәсли башладылар.* Р.Сәгъди

**Дөмбәсли тору** Бертуктаусыз дөмбәсләү. *Ә немецлар өзлексез дөмбәсли торалар.* Г.Бәширов

**Дөмбәсли төшү** Тагын да бераз дөмбәсләү

**ДӨМБЕ** *и.* Сай сулыкларда балык сөзгәндә, су төбенә бәрә-бәрә, балыкны ятьмәгә таба куып китерә торган чукмар башлы колга яки таяк

**ДӨМБЕЛӘ́Ү** *ф.* Дөмбе белән суккалап, балыкларны ятьмәгә таба куу

**Дөмбеләп алу** Бераз дөмбеләү. *Дөмбеләп алгач, балыкчыларның эшләре җайланды*

**Дөмбеләп бетерү** Бик нык дөмбеләү; сулыкның бер җирен дә калдырмый дөмбеләү, бөтен җирен дөмбеләү; дөмбеләүне тәмамлау. *Сулыкның астын-өскә китереп дөмбеләсәләр дә, ятьмәдә балык санаулы гына иде*

**Дөмбеләп тору** Әледән-әле яки бертуктаусыз дөмбеләү. *Дөмбеләп тору өчен махсус кеше билгеләделәр*

**Дөмбеләп чыгу** Сулыкның бер җирен дә калдырмый, бөтен җирен рәттән дөмбеләү

**Дөмбели башлау** Дөмбеләргә тотыну

**Дөмбели бирү** Бернигә карамый дөмбеләүне дәвам итү, һаман да дөмбеләү

**Дөмбели төшү** Бераз дөмбеләү

**ДӨМБЕР** *и.* Бәрмә музыка уен коралы; барабан. *Туйдан соң – дөмбер* (эш узгач сүз куптару). Әйтем

**ДӨМБЕР-ДӨМБЕР** *иярт.* **1.** Тонык дөбердәү тавышларын белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. – *Дөмбер-дөмбер кем йөри? – Дөмбер-дөмбер җил йөри.* Ф.Яруллин. *Җыр-биюләр башлану белән, залдагы егетләр, урындыкларын дөмбер-дөмбер китереп, клуб каршына тәмәке тартырга чыга.* Ватаным Татарстан. *Без дөмбер-дөмбер килгән музыкадан (клубка янәшә яшибез) төнге 2 гә кадәр йоклый алмый ятабыз.* Безнең гәҗит

**ДӨМБЕРДӘТҮ** *ф.* **1.** Дөмбердәгән тавыш чыгарып шаку, шакылдау, кагу. *Әллә нинди зур барабаннар кагып, Быргы, торба һәм сыбызгылар кабып, --- Гөрләтеп, чыңгылдатып, дөмбердәтеп, Киттеләр Каф тауны буйлап иңләтеп.* Ш.Бабич

**2. дөмбердәтеп** *рәв. мәгъ. куч. сөйл.* Бик җанлы, актив рәвештә; тиз арада (*эшләү, башкару, оештыру һ.б.ш.*)

**Дөмбердәтә башлау** Дөмбердәтергә тотыну

**Дөмбердәтеп алу** Берникадәр, бераз дөмбердәтү

**Дөмбердәтеп тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле дөмбердәтү; әле, хәзер, сөйләп торганда дөмбердәтү

**ДӨМБЕРДӘ́Ү** *ф.* 1) «Дөмбер» сыман тавышлар чыгару. *Үзләре һау-һайлап кычкыра, кайсы казанга арба кендеге белән сугып, чаң тавышы чыгара; кемдер чуен таба кага, барабан дөмбердәтәләр...* М.Хәбибуллин

2) *куч.* Нәрсәне дә булса бик актив, җанлы, истә калырлык итеп эшләү, башкару. *Гомре үткән дөмбердәп, Аккан су күк гөлдердәп...* Г.Тукай

**Дөмбердәп алу** Берникадәр вакыт дөмбердәү

**Дөмбердәп бетерү** Дөмбердәүдән туктау, тукталу

**Дөмбердәп кую** Азга гына, бер тапкыр кыска гына дөмбердәү

**Дөмбердәп тору** Өзлексез дөмбердәү

**Дөмберди башлау** Дөмбердәргә тотыну

**Дөмберди бирү** Бернигә карамый дөмбердәвен дәвам итү, һаман дөмбердәү

**Дөмберди төшү** Бераз дөмбердәү

**ДӨМБЕРТ** *иярт.* **1.** Кинәт, кискен дөмбердәп чыккан тавышларны белдерә. *Егетләр, шәкерт салмасы белән сыйлыйк! Дөмберт! (Киштәдән мендәр алып һөҗүм итәләр).* Т.Гыйззәт

**2.** *хәб. функ.* Кинәт, кискен дөмбердәү тавышлары чыгарган эш-хәрәкәтне белдерә

**ДӨМЕГҮ** *ф. гади с.* 1) Үлү, һәлак булу; юк булу. *Сез көтегез безне, сөйгән ярлар, Без кайтырбыз тиздән әйләнеп, Тик дөмексен явыз юлбасарлар, Бергә итәрбез җиңү бәйрәмен.* Ш.Маннур. *Тик китмәде явыз бер адым да, Яфракларны шартлау селкетте: Партизанның утлы пулясыннан, Канга батып, бандит дөмекте.* Ә.Исхак

2) Бик авыр хәлгә юлыгу, харап булу. *[Артта калган мәдрәсәдә укучылар:] Ятабыз икән монда дөмегеп!.. «Мөхәммәдия» шәкертләре, даулашып, мәдрәсәгә яңа программа керттергәннәр... Без нәрсә карап ятабыз?* Ә.Фәйзи

3) Югалу, юкка чыгу, каядыр югалып тору. *[Ишан:] Кая дөмектең, чукрак, кафер, бөтен йортны урлап китсәләр дә сизмәссез.* К.Тинчурин. *Әтәчләре дә бүген дөмекте, кычкырмый да кычкырмый, көтә-көтә аптырап беттем.* Т.Гыйззәт

4) **дөмеккере**, **дөмексен**, **дөмеккән** Каргау, нәфрәт сүзе. *Әнкәй мине бер дөмеккән төндә Азап чиксен өчен тапкандыр...* Ш.Маннур. *Тәрәзәгә яңгыр сибеп яуганы ишетелә. – Көне дә дөмекте, өй түбәмнән үтмәсә ярар*

*иде [ди Гайнавал].* Т.Гыйззәт. *Дөмеккән малай, тукта, мин сине...* М.Фәйзи

◊ **Дөмексен (генә) икән!** Зарлану-ачулану сүзе

**ДӨМЕКТЕРҮ** *ф.* 1) Үтерү, һәлак итү. *Хәлсезләнеп егылган, шулай да һаман торырга маташкан бүрене Уйылданның чукмары тәмам дөмектерде.* Н.Мусин. *– Менә шушыннан, Гитлерны дөмектереп, безнең авылныкылар гөрләшеп кайтып төшсәләр, менә күр дә тор, Хәдичәбикә түти, менә шулай итеп, тәрәзәдән атылып чыгар идем, – дип, шаркылдап көлә-көлә, ачык тәрәзәгә килде Гөлсем дигәне.* Ф.Хөсни. *Борын башына биш-алты фашистны дөмектермичә торып, берәүгә дә үләргә рөхсәт юк.* И.Гази

2) Юкка чыгару, кая да булса җибәреп, кайтмаслык итү. *Репрессия вакытында бик күпләрне дөмектергәннәр*

**Дөмектерә язу** Чак кына дөмектерми калу. *Шул тәкелдәвеклеге аркасында, унҗиденче елда аңа ярты-лаш анархист, яртылаш милләтче, вупшым, диванарак бер егет ияләшеп, үзен дөмектерә язган.* К.Нәҗми

**Дөмектереп бетерү** Барысын да дөмектерү

**ДӨ́ММӘ-ДӨМ** *с. диал.* Нинди дә булса сыйфатка бөтен яктан да, тулысынча ия булган (мәс., *дөммә-дөм сукыр, дөммә-дөм ятим*); үтә, шомырттай (кара күзләр турында); бик нык караңгы, дөм караңгы булган. *Шул дөммә-дөм караңгылыкның шомын арттырып, әллә нинди ямьсез тавышлар гына ишетелеп-ишетелеп калгандай.* Кәеф ничек?

**ДӨНЬЯ** *и. гар.* **1.** 1) Материянең бербөтен тәшкил иткән барлык формалары; җиһан

2) Галәмнең аерым бер өлеше, планета. *Ләкин болар һәммәсе дә каядыр икенче дөньяда, болытлар өстендә ишетелгән иде.* Г.Бәширов

3) Җир йөзе, анда булган терек һәм терек булмаган нәрсәләрнең барысы. *Тайга зур ул, тайга – иркен дөнья, Ярымшарның хәтта яртысы!* Ш.Маннур. *Атасы Әхмәтсафа агай, саран булмаса да, малның кадерен белүче һәм дөньяның үгез мөгезендә вә балык өстендә торуына иман китерүче борынгы бер кеше иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Чүл һәм үсемлекләр, йолдызлар һәм бүреләр, арыклар һәм коелар, кышлак тормышы һәм үзенең егет чагы, яңа туган бәрәннәрне саклау һәм учак тергезү, чаяннар һәм ташбакалар турында – дөньяның үзе белгән барлык серләрен аңгәмә итә иде ул.* Т.Әйди

4) Безне чолгап алган бар табигать, мохит. *Май айлары, Бөтен дөнья яшел киемнәргә киенгән.* Һ.Такташ. *Бөтен дөньяны мамыктай йомшак яшь кар белән ап-ак итеп сылап куйган иде.* Ә.Еники. *Дөньяда юкны түгел, дөньяда булырга тиешлене, дөньяга кирәклене эшлиләр, кыскасы, гадәттә эшләнә торган эшне генә эшлиләр.* Ф.Хөсни

5) Табигатьнең, тереклекнең аерым бер тармагы, өлкәсе. *Киң кырга, саф һавалы үсемлекләр дөньясына килеп чыккач, үземне мин бөтенләй башкача хис иттем.* З.Бәшири. *Ул утка сентябрьнең өлгергән әремен сындыргалап салсаң, шул вакытта Чөн аръягыннан, башкорт ягыннан, зур кызыл табак булып ай да күтәрелсә, күлләр дөньясында сихри тормыш башлана.* М.Мәһдиев

6) Җирдә яшәүче һәм яшәгән барлык кешеләр; кешелек җәмгыяте. *Шуның белән мин укуымны да ташладым, бөтенләй дөнья кызы булып киттем.* Ф.Әмирхан. *Дөнья бу, улым. Ә дөньяда кылган игелек югалмый.* Р.Мөхәммәдиев. *Син әле саф, сабый, Әшәкелек күреп, дөньяны тарсынма, Өйрәтә алырсың барсын да, Сафлыкка, Намуска, Хаклыкка – Яхшылыкларның барсына, барсына.* С.Хәким

7) Җәмгыять төзелеше; иҗтимагый система. *Кузгал, уян, ләгънәт ителгән Коллар һәм ачлар дөньясы.* Интернационал. *Эшчеләрнең көчле протестлары Калтыратты капитал дөньясын.* М.Гафури

8) Кешеләр тормышы, яшәеше, гомумән көнкүреш. *Авыр ялгыз хатынга, бик авыр әлле-мәлле дөньясын алып баруы.* Ф.Сафин

9) Җәмгыять тормышының, иҗтимагый чынбарлыкның, эшчәнлекнең бер өлкәсе. *Моны без үзебезнең кечкенә дөньябыз галәмендә дә күрәбез.* Ф.Әмирхан. *Мин дә кермәкче буламын шул иҗат дөньясына.* Н.Исәнбәт

10) Аерым бер иҗтимагый төркем, кешеләр даирәсе. *Мәдрәсә гадәте буенча монда йөрүдән манигъ булмаганга, шәкерт дөньясы, бары бергә кузгалып, шул мәйданга таба агыла.* Г.Ибраһимов. *Бүлмә ишеген бикләп чыгып китәм кырга, урамга, ачлар арасына, туклар дөньясына, тормыш симфониясен тыңларга.* Һ.Такташ. *Тәрәкъкый өчен көрәш вакытында, гомумән, шәкертләрне мәдрәсәдән куу татар дөньясында безнең исемгә зур тап төшерәчәк.* Ә.Фәйзи

11) *юг.* Хисләр, һәртөрле кичерешләр, күзаллаулар белән бәйле психик халәт. *Шулай да болары аның читтән караганда күзгә ташлана торганы гына. Ә бит әле аның, шул тышкы бизәкләре өстенә, тагын күзгә күренми торган эчке дөньясы – күңеле бар.* Ф.Хөсни. *Карчыкның соргылт күзләре сагыш белән томаланды, моңсу уйлары рәхәт истәлекләр дөньясына алып киттеләр.* Г.Бәширов. *Бертөрле уйлар дөньясыннан икенче төрле уйлар дөньясына, күктән җиргә сикергән шикелле, сикерергә туры килгәндә, кемнең генә күңеле дулкынланмас икән.* И.Гази

12) *дини* Кешенең үлгәнчегә кадәр гомер иткән урыны; дөньялык; *киресе:* **ахирәт.** *Болай булгач, инде ни дөньяң, ни ахирәтең.* Ш.Мөхәммәдев. *[Мәрьям Зәйнәпкә:] Сез, өч көнлек дөнья өчен, бөтен ахирәтне онытасыз.* Ф.Әмирхан. *Син – бу дөньяның түгел, оҗмахта хурлар сазы син, саф, матур, моңлы авазларның бөек остазы син – скрипка.* Ш.Бабич

**2.** *с. мәгъ. куч. сөйл.* Искиткеч күп; бик зур. *Моның өчен Гафият дөнья кадәр тавыш чыгарды.* И.Гази. *Атларга бер солы көлтәсен артык биргән өчен дә дөнья чаклы тавыш куптара торган адәм.* Г.Ибраһимов

**3.** *рәв. мәгъ. куч. сөйл.* Чиксез, гаять күп. *Сараеңа дәүләт яусын, поты белән, йөге белән, тау-тау, дөнья-дөнья!* Д.Аппакова

◊ **Дөнья аныкы** Үзеңне бик бәхетле хис итү турында. **Дөнья ачылу** Кемгә

дә булса тормыш-яшәеш аңлашыла башлау, нәрсәне дә булса аңлау. *Шулай итеп, аларның икесе өчен дә өр-яңа дөнья ачылды.* Г.Гыйльманов. **Дөнья әйтү** Акыллы сүзләр сөйләү, төпле киңәшләр бирү турында. **Дөнья бабай** Тормыш мәшәкатьләре, борчулары һ.б.ш. турында әйтелә. *Дөнья бабай барсына да өйрәтте акрынлап, Аллага шөкер...* Авыл утлары. **Дөнья байлыгы** Бик зур байлык. *Сөембикәле Кремль – дөнья байлыгы.* **Дөнья басу** 1) Картаю, картаеп хәлсезләнү; 2) Тормыш авырлыгына бирешеп, күңел төшү, дәрт сүнү. *Тәүге мәлләрдә күкрәк киереп дәртләнеп йөргән ир белән хатынның бераз бөрешеп калуын күрүчеләр дә моңа артык әһәмият бирмәделәр: «Боларны да дөнья басты», – дип кенә куйдылар.* М.Кәбиров. **Дөнья бәясе** Бик кадерле, кыйммәт. *Дөнья бәясе кеше иде. Асыл кеше иде [Сарьян].* Г.Бәширов. **Дөнья бәясе торырлык** *к.* **дөнья бәясе**. *– Дөнья бәясе торырлык! – диде аңа [Габдерахманга] җирән сакаллы, олы гәүдәле хирург ир, саф татар телендә.* Ф.Яхин. **Дөнья безнеке** *к.* **дөнья аныкы**. *– Бүген – тарихи көн. Талкыш халкы христианлык кабул итә! – дип очынды Васька. – Гулять итәбез! Дөнья безнеке!* С.Зыялы. **Дөнья белән исәпләшмәү** Тормыш-яшәеш нормаларын, кагыйдәләрен үтәмәү, аларны бозу. **Дөнья белән саубуллашу** Үлү. *Шулай айлар-еллар айнымый эчеп, ахыр чиге якты дөнья белән саубуллашты.* Ватаным Татарстан. **Дөнья бетереп** 1) *гади с.* Бөтен көчкә, бөтен тавышка, бик нык (кычкыру һ.б.ш. турында). *Иптәшләрең дөнья бетереп котыралар, син авыз тутырып ашап утыр, имеш.* Р.Хафизова; 2) Бер җирне дә калдырмый, бөтен җирдән (эзләү турында). *Дөнья бетереп, мине эзләп йөргәннәр.* Р.Миңнуллин. **Дөнья бетү** *дини* Кыямәт җитү, ахирәт башлану. *Артык бернәрсә калмый шуның белән, дигәнең төгәлләнде; дөнья бетте, җир, күк каядыр югалды, үзең онытылдың.* Г.Ибраһимов. **Дөнья бозу** 1) Кемнең дә булса тормышын болгату, яшәргә комачаулау; 2) Нәрсәгә дә булса чуалыш, буталчыклык кертү; начар мохит (атмосфера) тудыру. **Дөнья бозылу** Тормыш-яшәеш начар якка үзгәрү. *Мәйханәдән чыккан мужиклар сөйләшеп торалар. Ак икмәккә май итеп ягарлык татлы көннең борынына сасы тәмәке төтене очырып, арадан берсе әйтеп куя: – Бозылды дөнья! – Бозылды, бик бозылды! – ди икенчесе.* Ф.Яхин. **Дөнья болгату** Барысын да бутап, бозып күрсәтү. *Ә шул ук вакытта, үзен милләт хадиме дип санаган агай-эне (ни аяныч!) өч хәрефкә койрык ялгамакчы булып мәш килә, «татармы без, болгармы?» дип дөнья болгата, дини китапчыклар белән спекуляция ясый...* М.Вәлиев. **Дөнья бу** «Акылыңа кил, хыял белән яшәмә» мәгънәсендә. *Ач күзеңне – дөнья бу!* **Дөнья бутап йөрү** *к.* **дөнья бозу**. **Дөнья бутау** *к.* **дөнья бозу**. *Кырык яшьтә дөнья бутап, Илле яшендә үлгән.* Шәһри Казан. **Дөнья газабы күрү** Гомер буе газап, мәшәкать, кайгы-хәсрәт күреп яшәү. **Дөнья газабы тату** *к.* **дөнья газабы күрү**. **Дөнья газабы чигү** *к.* **дөнья газабы күрү**. **Дөньяга килү** Туу, барлыкка килү. *Беренче кар төшәр алдыннан, бер ир бала дөньяга килгәч, икесенең дә башлары күккә тиде.* И.Гази. *Хәзер инде яңа гына дөньяга килгән яшь үсемлекнең битен юарга шифалы бер яңгыр да кирәк иде.* Г.Бәширов. *12 нче елда Сарман авылында алар дөньяга килгәндә, аларны беркем дә авызга алмады.* Һ.Такташ. **Дөньяга сыймау** Артык һавалы кылану, үзен башкалардан өстен санау. *Нәселдән үк зур бай Бикмөхәммәтев, театрга кергәндә үк исерек булып, тирә-ягына унлап яраннарын җыйнаган, дөньяга сыймыйча йөри.* Ш.Камал. *Син үзеңне дөньяга сыймас кебек тоткан идең, – Биш карыш җиргә сыярсың, тотса мәскәүләр якаң!* Ә.Исхак. *– Әй сез, кыргыйннар! Нәрсә җитми тагын сезгә, әллә маегызга чыдаша алмыйсызмы, нигә дөньяга сыймыйсыз? – дип, аларга кычкыра башлый.* М.Гали. **Дөньяга чыгу** 1) Халык арасына чыгу, кешеләр белән аралашу, мәшәкатьләренә керешү, иҗтимагый тормышның берәр өлкәсендә турыдан-туры катнашып китү. *Бу ел бер мишәр, бөтен Европа дәүләтләренең икътисади хәлләренә зур бер инкыйлап ясаучы булып, дөньяга чыгарга теләп карады.* Ф.Әмирхан. *Ул герман сугышында яраланып, Петроградта яткан... Патшаны төшергән көннәрдә, терелеп, дөньяга чыккан.* Г.Ибраһимов; 2) Басылу (китап һ.б. турында). *Шулай итеп, ул әсәр Казандагы китап бастыручы бай Кәримовлар тарафыннан тик 1900 елда гына дөньяга чыгарыла.* М.Гали. **Дөньяга энә күзе аркылы карау** Вакчыл, юк-бар өчен дә тавышгауга күтәрә торган. *Бигрәк тә аларның бик күбесе – дөньяга энә күзе аркылы гына карый торган каты куллы хәзрәтнең һәм дөньяны чапан астыннан гына күргән бер бала җанлы абыстайның «әлли-бәлли итәр бу, Бохарага китәр бу» диеп тирбәтеп үстергән баласы.* Җ.Вәлиди. **Дөнья гизү** Сәяхәт итү, әллә кайларга бару, Җир шарының әллә кай җирләрендә булу. *Шушы ватык кулымны сөйрәп, туган-үскән җирем дип, Байтиряккә кайтыйммы, әллә безнең совет иле киң бит әле, кайда да сыенырга урын табармын дип, дөнья гизәргә чыгып китимме?* Г.Бәширов. **Дөнья гүзәле** Дөньяда беренче чибәр; чибәрлек алиһәсе. *Ирина Шәрәпова «Дөнья гүзәле – 2010» бәйгесендә катнашырга әзерләнә.* Юлдаш. **Дөньядан китү** Үлү, вафат булу. *Дворкадан алып кайткан бәләкәй көрән ат ботына тибеп имгәткәч, инде бөтенләй әдәм төсле яши алмады, сырхап-сырхап, дөньядан китте, мескен.* Ш.Камал. **Дөньядан кичү** *к.* **дөньядан китү**. *[Габдулла Тукай] Милләтенең яшь буыннарына бетмәс-төкәнмәс зур бер дәүләт һибә итеп, дөньядан кичте.* Г.Рәхим. **Дөньядан күчү** *к.* **дөньядан китү**. *Аннан соң Хәким Сөләйман дөньядан күчте.* Кол Шәриф. **Дөньядан үтү** *к.* **дөньядан китү**. *Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәтеп карап, бер атнага якын ыңгырашып ятты да җомга көн иртә белән сәгать унда дөньядан үтте.* Г.Ибраһимов. **Дөньядан югалу** Нәрсәдер уйлап, нәрсәгә дә булса бик бирелеп, ваемсыз булып йөрү. *Шул авыр, тирән моң мине*

*басты, үзе дә, ахры, дөньядан югалгандыр, мине күрми үтте.* Г.Ибраһимов. **Дөнья җәһәннәме** 1) Бик үк тыныч булмаган, ыгы-зыгылы урын. *Чөнки «Мәдрәсәнең почмагы – бу дөньяның оҗмахы» дигән сүзнең бу мәдрәсәләргә тугры килмәгәнлегене аңламыш, бу мәдрәсәне «дөнья җәһәннәме» дия инанмыш иде.* З.Һади; 2) Бик ерак дип фаразланган, әллә кай җир. **Дөнья җимерелмәс** «Берни дә, бернинди куркыныч та, зарар да булмас» мәгънәсендә. **Дөнья җимерелү** Бар да начар булу, яшәүнең кызыгы бетү. **Дөнья җимереп** 1) Шәп итеп. *Кичәге приказчик, талчукчы малайлар, бүген карасаң, спекуляция белән дөнья җимереп баеп яталар.* Ш.Камал. 2) Бик каты, ташкын булып. *Ләкин ары-бире карангаласам да, андый нәрсәләр күзгә күренмәде, халык берсе өстенә берсе утырып, урын өчен талашып, дөнья җимереп баралар.* Һ.Такташ. **Дөнья җиту** *к.* **дөнья тигезләнү**. **Дөнья йөзе** 1) Җир өстендәге тереклек. *Килде көннәр, иste җилләр, нинди сулар акмады, Якты ирек көне килде, дөнья йөзен пакьлады.* Г.Камал. *Мин барам, әлбәт, барам; Бармасам, дөнья йөзе булсын харам.* Г.Тукай; 2) Кешеләр арасы. *Әнкәсе, акылыннан шашып, көн-төн елый: «Ил алдында мине хур итте, дөнья йөзенә күренерлегем калмады», – ди.* Г.Ибраһимов. **Дөнья кадәр** 1) Бик күп; 2) Бик зур. **Дөнья кайгырту** Дөнья мәшәкатьләре турында уйлау, мал-мөлкәт өчен тырышу, гомумән дөньяны алып бару, дөнья көтү. *Килен бүрәнә өстендә дөнья кайгыртып утырганда, Вәлекәй карт белән Сәләхи шулай сөйләшеп утырдылар.* Г.Толымбай. **Дөнья каруны** *гади* Бик саран кеше. **Дөнья киң** 1) «Дөньяда син генә түгел, анда һәртөрле нәрсәләр дә, кешеләр дә җитәрлек» мәгънәсендә; 2) «Дөнья иркен, дөньяда яшәү рәхәт» мәгънәсендә. *Син шулай коллыкта йөрсәң, дөнья киң булмас сиңа ---.* М.Гафури. **Дөнья кичерү** Яшәү, гомер итү. *Иң ахыр барып, күпер башларында, басу капкасы буйларында чүплекләргә, тиресләргә салынган балчык өйләр, корымлы читән куышлар, үзләренең кайгылы йөзләре, сәләмә кыяфәтләре, бураннарга каршы тора алудан өмет өзгән бер хәлдә дөнья кичерәләр.* Г.Ибраһимов. **Дөнья корткычлары** Җәмгыятькә зыян салучылар, җәмгыятьне таркатучылар. **Дөнья кору** «Башлы-күзле булып» яши башлау. *Шул вакытта язылган «Ак майларда ак вәгъдәләр» безнең гаилә бәйрәме уңаеннан туган җыр булды. Әйбәт итеп дөнья корып яшәп киттек.* Кәеф ничек? **Дөнья көтә белми торган** Тәҗрибәсе булмаган, тормышны алып бара белми торган. **Дөнья көтү** Яшәү, гомер итү; тормышны (хуҗалыкны) алып бару. *Егерме биш яшьләремдә фәкыйрь генә бер кешенең кызына өйләнеп, үз алдыбызда дөнья көтә башладык.* Ш.Камал. *Бу сугышларны бетерәм дә, авылга кайтып, яңа дөнья көтә башлыйм, элгәреге үчне кайтарам: боярдан басып алган җирләрне мамык кебек йомшартып, кадерләп сөрәм, чәчәм дә адәм кебек көн итәргә тотынам, ди торган иде.* Г.Ибраһимов. **Дөнья кубару** Шау-шу, тавыш-гауга күтәрү, буталчык итү. *Кешеләр тыныч кына йонятышынча сөйләгәндә, сиңа сүз әйтергә ярамый, дөнья кубара башлыйсың.* Ш.Камал. **Дөнья кубу** Бар нәрсәнең асты-өскә килү. *Дөнья купты, минсиңайтим! Билләһи менә, карчыктан сорагыз, ышанмасагыз.* Ш.Камал. **Дөнья куптару** *к.* **дөнья кубару**. *– Менә ул карарны болар сүзенә карап бозганнар, – диде Нәгыйм, – хәзер дөнья куптармакчы булалар: доклад, концерт, тагын әллә нәрсәләр.* Ш.Камал. **Дөнья куу** *сөйл.* Мал табу, тормышны алып бару өчен тырышу. *Шуны куарга, онытырга теләгәндәй, сүз башлыйм: – Һаман дөнья куасыз инде, ә? – Юк шул, улым, дөнья безне куа башлады инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Байдан чыгып, үз тирмәсенә атлау белән, аның җаны әрнеп китте: ул алтмыш ел дөнья куды, Ходайга: «Мал да бирче, бак та бирче!» – дип, моңлык кылды.* Г.Ибраһимов. **Дөнья кую** *к.* **дөньядан китү**. *Күп тә үтми дөнья куйды әнкәсе, Тулды күңелем, ничек итеп әйтәсе.* Г.Тукай. *Гасимә апаң гына дөнья куйды.* М.Гафури. *Сугыш бетәргә аз гына калгач, Сафый дөнья куйды.* Г.Гыйльманов. **Дөнья күкрәтү** Бик каты тавышлану, шаулау, шат, күтәренке күңел белән сөйләү. *Ләкин көннең иң һәйбәт, кызу вакытында зур өметләр баглап, дөнья күкрәтеп җыр-көй белән тартылган бу ау шатландырмады.* Ш.Камал. **Дөнья күргән** Тәҗрибәсе зур, күпне белгән. *Дөнья күргән кешенең сүзләреннән гыйбрәт алып, баш кагып тыңлады егет.* Р.Мөхәммәдиев. *Аның хуҗасы – дөнья күргән мәрхәмәтле кеше, сезгә яхшы бер бүлмә бирер, бик рәхәт, тынычлап ятарсыз, ял итәрсез, агай-эне бар да шунда, күрешерсез, сөйләшерсез.* Ш.Мөхәммәдев. *Ул башта, дөнья күргән, күпне белгән адәм дип, Сабирдан тартыныбрак торса да, моның һәр турыда ачыктан-ачык бәргәнен күргәч, берьюлы үзенең Җаббарлыгына төште дә, табам, үзем табам дип, бөтен тирә-якның кызларын саный башлады.* Г.Ибраһимов. **Дөнья күрү** 1) Күп җирләрдә булу, сәяхәт итү. *Бабайның сүзләрен бик җентекләп тыңлап яттым; үземнең дә аның шикелле йөрисем, аның шикелле дөнья күрәсем, мәшәкать чигәсем килә башлады.* М.Гали; 2) Басылып чыгу (китап һ.б.ш. турында). *Казанның «Шамил» мәчете имам хатыйбы Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдиннең «Бәхетлеләрнең серләре» дигән яңа китабы дөнья күрде.* **Дөнья күтәрү** *к.* **дөнья кубару**. *Партер көчлерәк итеп кул чапты, галерка исә дөньяны күтәрде.* Ш.Камал. **Дөньялардан имансызлар үтим** Сүзенең дөреслеген раслау өчен, каргаңып әйтелгән сүз. *Ялган булса, ике күзем чәчрәп чыксын, дөньялардан имансызлар үтим!* Г.Бәширов. **Дөнья малы** Тупланган мөлкәт, байлык. *Дөнья малы – тозлы су: эчкән саен эчәсене китерә.* Мәкаль. *Дөнья малы, дәрәҗәсе – барсы да ялгандыр ул ---.* Ә.Каргалый. **Дөнья мәшәкате күрү** *к.* **дөнья газабы күрү**. **Дөнья мәшәкате тату** *к.* **дөнья газабы күрү**. **Дөнья мәшәкате чигү** *к.* **дөнья газабы күрү**. **Дөнья минеке** *к.* **дөнья аныкы.** *Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.* Г.Ибраһимов. **Дөньяның асты өскә**

**килү** 1) Җәмгыятьтә һ.б.ш. ниндидер тәртипсезлекләр, чуалышлар, буталчыклар булу турында. *Болай да камил булмаган җәмгыятебездә, гаиләдә рольләр бөтенләй үзгәреп, дөньяның асты өскә килү ихтималы хафаландыра.* Ватаным Татарстан; 2) Бик нык тәртипсезлек урнашуга карата әйтелә. *Казармага барып керсәм, дөньяның асты өскә килеп бара.* Г.Ибраһимов. **Дөньяның астын өскә китерү** 1) Җәмгыятьтә һ.б.ш. ниндидер тәртипсезлекләр, чуалышлар, буталчыклар тудыру. *Көннәрнең берсендә бу җиргә Иблис коллары һөҗүм иткәннәр дә, бар дөньяның астын өскә китереп, гүзәллекне таптап-жимереп, үз тәртипләрен урнаштыра башлаганнар.* М.Кәбиров; 2) Бик нык, бик каты. *Тышта җил, буран дөньяның астын өскә китерерлек булып кузгалган, дулый.* Ш.Камал. *Килен белән каенана, дөньяның астын өскә китереп, бик каты талаша.* Ватаным Татарстан. **Дөньяның әчесен-төчесен күрү** Тормышның бөтен кыенлыкларын да татыган, кичергән булу. *[Гобәйдулла абзый] Дөньяның әчесен-төчесен күп күргән.* З.Зәйнуллин. **Дөнья рәхәте** Нәрсәнең дә булса бик шәп, бик яхшы булуы. *[Байлар] Чиксез саран, комсыз, ач күзле, көнче үзләре, мәңгелек суы эчкән кемсәләр кеби кыланып, көн-төн дөнья малын арттыру кайгысында йөриләр, халык файдасы, дин куәте, дөнья рәхәте өчен гамь чигеп, зарарыбызның мужибе-сәбәбе булган нәрсәләрне төзәтүгә ярдәм вә тырышлык кылганнары күренми.* З.Бигиев. **Дөнья сөрү** *к.* **дөнья көтү**. **Дөньясын оныту** 1) Ниндидер сәбәпләр аркасында бер нәрсә белән дә кызыксынмау, бар нәрсәгә дә битараф булу, онытылып йөрү. *Үлеп сусаган кеше су күреп суга капланган кебек, үз-үзен белешмичә, дөньясын онытып, мәхәббәт иркенә бирелде.* М.Хәсәнов. *Биреште Гыйлемхан, үз-үзен кулдан ычкындырды. Җанын кыршау сыман буарга керешкән аваздан котылыр җай тапмагач, кабаланып, дөньясын онытып, бригадир китереп аударган такталарны бакча якка ташырга кереште.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Төп эшен онытып, икенче эш белән мәшгуль булу. *Газизә кайда? Әнә ул тегә якта, кухняда, аш пешерүче хатын янында аңар булыша, сөенеченнән дөньясын оныткан, әнкәсе янына да килми: ашлар әйбәтрәк булсын, ди торгандыр.* Ш.Камал. *Теләсә көлдерә, теләсә елата, тели икән, дөньяларыңны оныттыра белә иде.* Г.Бәширов. **Дөнья терәге** Нинди дә булса таяныч, өмет-ышаныч. *Ир-атның дөнья терәге булуын Рухия кадәр аңлаган кеше бармы икән дөньяда?* З.Әһлиева. **Дөнья тигезләнү** Ниндидер ихтыяҗлар үтәлү, борчу-мәшәкатьләр кимү, тынычлану. *Ә хәзер дөнья тигезләнеп бара шикелле... Һәрхәлдә, Гасыйм абзаң ашаганэчкәнне, Гасыйм абзаң кигәнне һәркем диярлек ашый-эчә дә, кия дә.* Ә.Еники. **Дөнья тоткасы** *к.* **дөнья терәге**. *Хатыны дуңгыз булып чыккан белән дә бит, дөнья тоткасы ул гынамыни?* Г.Бәширов. **Дөнья тәгәлләнү** *к.* **дөнья тигезләнү. Дөнья туарылу** Гадәтләнгән тормыш бозылу, яшәүнең тәртибе чуалу. *Бер дә Гафият дигәнчә булмады: каяндыр бу аклар килеп чыкты, дөнья туарылды да китте.* И.Гази. **Дөнья туздыру** *к.* **дөнья кубару**. **Дөнья түгәрәкләнү** *к.* **дөнья тигезләнү**. *Яраткан кешемә кияүгә чыктым, һәм бер елдан көтеп алган сөекле улыбыз Фаил туды. Тормышыбызга ямь өстәлде, дөньялар түгәрәкләнде.* Кәеф ничек? **Дөнья хәтле** *к.* **дөнья кадәр. Дөнья чаклы** *к.* **дөнья кадәр**

**ДӨНЬЯВИ** *с. гар.* Дингә, руханиларга, мәчеткә мөнәсәбәте булмаган; реаль, чынбарлыктагы күренешләргә һәм фактларга мөнәсәбәтле. *Хәзрәт, Коръән укып, дога кылып беткәннән соң, --- сүзен дөньяви тормышка борып җибәрде.* М.Гафури. *Эзләнү белән еракларга газиз күңелем оча, Сызлану белән кулымнан дөньяви шөгылем оча.* Ш.Бабич. *Вакыт-вакыт кем дә булса бик ихтирам белән генә Әрали ишанга дини һәм дөньяви эчтәлекле сорау белән мөрәҗәгать итә икән.* Э.Касыймов

**ДӨНЬЯВИЛЫК** *и.* 1) Дөньяви булу 2) *к.* **дөньялык**. *Кандалыйның крестьян тормышын яманлавы яшьлек еллары өчен хас кебек күренә. Соңга таба, күрәсең, дөньявилыгы аның үзен дә югары катлаудан читләштерә, --- ул үзенә бүтән мохит та таба алмый.* М.Госман

**ДӨНЬЯКҮЛӘМ** *с.* Барлык илләргә һәм халыкларга да кагылышлы, бөтен дөнья җәмгыяте өчен әһәмиятле булган. *Бүгенге көндә безнең илебездә дөньякүләм әһәмияткә ия булган зур тарихи эшләр башкарыла.* М.Әмир

**ДӨНЬЯЛЫК** *и.* Чынбарлыктагы тормыш, яшәеш; җәмгыять тормышы; *киресе:* **ахирәт**. *Дөньялыкта авыр булса булыр, Ахирәттә килер җиңелгә.* М.Гали. *Сез бит балагызны мулла ясарга түгел, дөньялыкка ярый торган кеше ясарга, укымышлы, һөнәрмәнд кеше ясарга укытасыздыр.* Ә.Фәйзи. *Алла башка бирәүне моның өчен --- җәһәннәмдә яндырыр иде. Ә моңар әнә җәзаны дөньялыкта биреп бетерә.* Г.Гобәй

**ДӨНЬЯЛЫКТА** *и.* Фани дөньяда, яшәп торганда, исән чакта. *Дөньялыкта кавыша алмадык, Көтүче, дип хурладың.* М.Фәйзи

**ДӨНЬЯЧЫЛ** *с. сир.* Дөнья малына хирыс, дөньялык белән генә мавыгучан («ахирәтне оныткан» мәгънәсендә)

**ДӨҢ-ДӨҢ** *иярт.* **1.** Йомшаграк яңгырый торган саңгырау тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып

**ДӨҢГЕЛДӘ́Ү** *ф.* «Дөң» иткән тавышлар чыгару

**Дөңгелдәп алу** Берникадәр вакыт, аз гына дөңгелдәү

**Дөңгелдәп кую** Бер тапкыр дөңгелдәү

**Дөңгелдәп тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле дөңгелдәү

**Дөңгелди башлау** Дөңгелдәргә тотыну

**Дөңгелди бирү** Бернигә карамый дөңгелдәвен дәвам итү, һаман дөңгелдәү

**ДӨҢГЕЛДЕК** *с.* «Дөң» сыман тавышлар чыгара торган, дөңгелди торган

**ДӨҢГЕР** *иярт.* **1.** «Дөң» сыман дөбердәү катнаш тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып

**3.** *и. мәгъ. иск. этн.* Төрле сигналлар бирү өчен кулланылган, каты күн

тарттырылган түгәрәк кысадан гыйбарәт уен коралы; төңгер. *Абдулла ни дип тә җавап кайтарырга өлгермәде, кояш баешындагы Кичү кальгасы яклап дөңгер сукканнары ишетелде, атлар пошкырган тавышлар килгәндәй булды.* Ж.Рәхимов. – *Дәф, думбра, дөңгердә уйнаучылар күренә башлады, – ди ул.* Ватаным Татарстан

**ДӨҢГЕРДӘ́Ү** *ф.* «Дөңгер» сыман тавышлар чыгару; нечкәрәк яңгырап дыңгырдау

**Дөңгердәп алу** Аз гына дөңгердәү

**Дөңгердәп кую** Кинәт кенә, бер тапкыр дөңгердәү

**Дөңгердәп тору** Бертуктаусыз дөңгердәү

**Дөңгерди башлау** Дөңгердәргә тотыну

**Дөңгерди бирү** Бернигә карамый дөңгердәвен дәвам итү, һаман дөңгердәү

**ДӨҢГЕРДЕК** *с.* Дөңгерди торган

**ДӨҢГЕР-ДӨҢГЕР** *иярт.* Каты әйберләр ишелеп, коелып төшкәндә барлыкка килгән, шуңа охшаш дөбердәүле тавышларны белдерә. *Каш арасы – во, утыннар гөмберт, дөңгер-дөңгер, бах!* Р.Батулла

**ДӨҢГЕРТ** *иярт.* Авыр әйбер килеп төшкәндә, кискен дөңгердәп куйган тавышны белдерә

**ДӨҢГЕЧЛӘ́Ү** *ф.* 1) *к.* **дыңгычлау**

2) Бәреп, шакып тору

3) *куч. сөйл.* Кат-кат бәргәләү, сугу, кыйнау

**Дөңгечләп алу** Берникадәр вакыт аралыгында дөңгечләү; берничә тапкыр дөңгечләү

**Дөңгечләп кую** Дөңгечләнгән хәлгә китереп калдыру; бер тапкыр дөңгечләү

**Дөңгечләп тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле дөңгечләү

**ДӨҢК** *иярт.* Кинәт дөңгелдәп, шапылдап куюны белдерә

**ДӨП-** *кис.* «Д» авазына башланган «дөрес» сыйфатына ялганып һәм һәрвакыт басымны үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Теге хикәяткә килгәндә, Фәрит энем, аның дөп-дөресе мәнә болай булды.* Г.Мөхәммәтшин. *Анысын да дөп-дөрес итеп сөйләү зарурдыр.* К.Миңлебаев

**ДӨП, ДӨП-ДӨП** *иярт.* **1.** 1) Нәрсә дә булса бәрелгәндә, орынганда, тавышланып, шапылдап төшкәндә һ.б.ш. хәрәкәтләр вакытында ишетелгән тонык тавышны белдерә. *Аларның «дөп-дөп», «дың-дың» ритмнарыннан биш минуттан баш чатнарга тотына.* Безнең гәҗит

2) Атлаганда, чапканда яки йөрәк каты типкән вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *«Тук-тук»: бу − төнге эштән лирик геройның күршесе кайта; «дөп-дөп»: заводка юнәлгән шофёр; «тек-тек»: җиңел сөякле радиомонтажчы кызлар атлый.* Фән һәм тел. *Мин уяндым – йөрәк тагын дөп-дөп, дөп-дөп, дөп-дөп...* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. *Алкышлар тынып та бетмәде, Натан дигәннәре, кечкенә күн итеге белән дөп-дөп атлап, сәхнәгә менеп тә җитте.* Г.Бәширов. *Мотор гүләве тоныклана, йөрәкнең дөп-дөп типкәне ишетелә сыман.* Р.Мулланурова. *Баштарак, әрнешеп, уттай янган беләкләре, ботлары берни тоймас булдылар, чигәсендә, чүкеч белән дөп-дөп суккандай, кан тамыры сулкылдады.* Д.Булатова

**3.** *и. мәгъ.* Шундый тавыш. *Поезд дөп-дөбе ишетелмәс булгач, мине тәмам курку алды*. Г.Гобәй

**4. дөп тә дөп** *хәб. функ.* Эш-хәрәкәтне «дөп» сыман тавышлар чыгарып башкару. *Дошман аэропланнары килеп чыктылар да – дөп тә дөп!.. Бомба ташлый башладылар.* Т.Гыйззәт. *Тау башында дөп тә дөп – алкыш куба: «Хуш киләсез... мәрхәба! Урра... урра!!!»* Ш.Бабич

**ДӨ́П-ДӨП ИТҮ** *ф.* «Дөп» иткән тавышлар чыгару. *Төлке артыннан Кәҗә дә дөп итеп сикереп төшә.* М.Гали. *Даладагы көлү-сөйләшү тукталды, каты, ашыгыч баскан атның, дөп-дөп итеп килеп, якында туктавы ишетелде ---.* Г.Ибраһимов. *Дөп итеп, якында бер алма өзелеп төште.* И.Гази

**ДӨ́П-ДӨП КИЛҮ** *ф. к.* **дөп-дөп итү**. *Дөп-дөп килеп типкән йөрәккә пычак йөзе кагылды һәм, күз ачып йомган арада, аны урталайга бүлде.* М.Кәбиров. *Йөрәк дөп-дөп килә...* Г.Әдһәм

**ДӨПЕЛДӘТҮ** *ф.* **1.** 1) «Дөп-дөп» иткән тавышлар чыгару. *Ул, дөпелдәтеп, Исмәгыйльнең аркасыннан сөйде...* Д.Бүләков

2) Дөмбәсләү, суккалау, бәргәләү. *Зур гәүдәле ике егет дөпелдәтеп киткән иде Алмазны.* Мәдәни җомга

**2**. **дөпелдәтеп** *рәв. мәгъ.* Бик каты итеп, дөпелдәгән тавыш чыгарып. *Ул һәрбер «гөрләүче»нең аркасына «шап» иттереп китереп суга, ә тегесе: «Ай, авырттырды! Саҗидәдер бу!» – дип танып ала да, аны аркасы белән идереп, бар көченә дөпелдәтеп суга иде.* М.Галәү. – *Бар бит әле дөньяда яхшы кешеләр, – диде әни, бәрәңгесен дөпелдәтеп басма алдына куйгач.* Ф.Шәфигуллин. *Ул ачуыннан идәнгә лач иттереп төкерде дә, ишекне дөпелдәтеп ябып, каядыр чыгып китте*. Кызыл таң

**Дөпелдәтә башлау** Дөпелдәтергә тотыну. *Шуңа күрә йөрәк тибеше, күкрәгенә генә сыешмыйча, ике як баш миен дә дөпелдәтә башлады, саңаклары тартышып-тартышып куйды.* Татар әдипләре

**Дөпелдәтә төшү** Тагы да бераз дөпелдәтү

**Дөпелдәтеп кую** Бер тапкыр дөпелдәгән тавыш чыгару

**Дөпелдәтеп тору** Бертуктаусыз дөпелдәтү

**ДӨПЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Берәр нәрсә бәрелгәннән, орынганнан, төшкәннән һ.б.ш. ишетелгән тонык тавышлар чыгару. *Бик еракта тракторларның атлар туктагач кына ишетелә башлаган тигезле-тигезсез дөпелдәүләре шул хыялый болыт стеналарына ниндидер серле таяк белән дөбердәтеп торган шикелле булып тоела.* Г.Гобәй

2) Дөп-дөп итү, дөп-дөп килү. *Ул да түгел берьюлы әллә ничә дөңгер дөпелдәргә тотынды: олы чирү, кара болыт булып, Нугай юлына таба кузгалды.* Ж.Рәхимов

3) *куч.* Бик нык тибү, кагу (йөрәк); дулкынлану. *Алдагысы нәкъ Фәрит шикелле дөп-дөп дөпелдәп бара.* Г.Гобәй. *Шундый тын, ихлас белән тыңласаң,*

*пароходның дөп-дөп дөпелдәп баруына хәтле ишетелә, гүя ул Иделдән түгел, әнә шуннан гына, инеш буйлап кына узып бара.* Г.Гобәй

**Дөпелдәп тору** Бертуктаусыз дөпелдәү

**Дөпелди башлау** Дөпелдәргә тотыну. *Шул [«Яшел урам» дип язылган] калайны күргәч тә, егетнең йөрәге ничек дөпелди башлаганын белсәгез икән.* Р.Мөхәммәдиев

**Дөпелди бирү** Бернигә карамастан дөпелдәвен дәвам итү

**Дөпелди төшү** Бераз дөпелдәү

**ДӨПЕЛДЕК** *с. сөйл.* Тонык тавыш белән эшли торган. *Дөпелдек мотор*

**ДӨПЕЛТ** *иярт.* Кинәт кенә, кискен дөпелдәп куюны белдерә

**ДӨР**, **ДӨРР** *иярт.* **1.** Ишле төркем дәррәү хәрәкәт итә башлаганда, учакта ут кабынганда һ.б.ш. очракларда калтыраулы тонык тавышларны белдерә. *Печән кыштырдатып торган атлар да «дөр» итеп сискәнешеп, кайберләре сикереп үк киттеләр.* Ш.Камал. *Класс «дөр» килеп аягүрә торды.* Ә.Фәйзи. *[Кошлар] Куркынып, «дөр» итеп очып, югары күтәреләләр.* Ш.Әхмәдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып

◊ **Дөр кубып (кубу)** Арта барган дөбердекле тавышлар чыгарып килү. *Күп малайлар һәм яшьләр дөр кубып [мәчеттән] чыгып киттеләр.* Г.Газиз. *Ул арада өйалдына, дөр кубып, бер көтү малайлар килеп тулды*

**ДӨРЕЛДӘҮ** *ф.* «Дөр» сыман тавышлар чыгару

**Дөрелдәп тору** Бертуктаусыз дөрелдәү

**ДӨРЕС** *с. фар.* **1.** 1) Чынбарлыкны төгәл чагылдыра торган, фактларга нигезләнгән, хакыйкатькә туры килгән. *Әгәр сез миңа сүз бирсәгез, берничә соравыбызга дөрес җавап кайтарсагыз, мин сезне бүген үк азат итәчәкмен.* Г.Ибраһимов

2) Чын, хак, туры (сүз, фикер һ.б.ш. турында). *Бабай, уен уйнаганда да, бер-береңне алдамаска, һәрвакытта туры күңелле, дөрес сүзле булырга куша иде.* М.Гали. *Хөкем белән, зиндан белән, сөрген белән генә түгел, дөрес сүз белән аңлатырга телибез.* Г.Ибраһимов. *[Харис:] Хәзерге яшьләр, анасы, дөрес юлга басканнар инде.* А.Әхмәт

3) Оригиналга туры килгән, оригиналны төгәл чагылдырып бирә торган (тәрҗемә турында). *Чөнки матбугат, радио-телевидение материалларының телендәге күпсанлы ялгышлар – дөрес тәрҗемә итә белмәү нәтиҗәсе.* Р.Юсупов

4) Урынлы (кисәтү, сүз һ.б.ш. турында). *Дөрес сүзгә җавап юк.* Әйтем

5) Законлы, законга нигезләнгән, законга туры килгән. *Эшем дөрес, Вәли иптәш, ул товарны мин саф акча түләп алдым.* К.Әмири

6) Әхлак кагыйдәләренә, кабул ителгән нормаларга туры килгән, йолаларга каршы килми торган. *[Шкафчы:] Аларның һичберсенең никахлары дөрес түгел. Алар, динне мыскыл итеп, кыска киемнәр киеп, аякларына – шиблит, башларына картус киеп, чәчләрен-мыекларын җиткереп, кулларына әллә нинди шәйтан мөгезе шикелле таяклар тотып, ак якалар куеп, корсакларын киереп йөриләр.* Г.Камал. *[Юан:] Ул бит безнең шәригатьтә дөрес түгел дигән идек, дөрес булмаса, бармассыз, ди.* Г.Камал

7) Куелган таләпләргә җавап бирердәй; максатка ярашлы, тиешле. *Эштә дөрес юнәлеш алу*

8) Кагыйдәләргә, нормаларга туры килә, җавап бирә торган. *[Раил Садриев:] Дөрес эш һәрчак Ходай тарафыннан алдан расланып куя дип ышанам.* Сәхнә

9) Төгәл, анык. *Дусың дус булсын, исәбең дөрес булсын.* Мәкаль

10) Сәламәт, нормаль, чын; гадәттәгечә (акыл, хәтер, кыяфәт һ.б.ш. турында). *Татарстанда шундый дөрес фикерле җитәкчеләр – Шәймиев һәм Мөхәммәтшин әфәнделәр булгач, шәт иншалла, киләчәктә халык теләге өстенлек алачак ---.* Гасырлар авазы

11) Намуслы, гадел. *– Дөрес күңелле, тыңлаучан әдәм, – дип, Гыймадины Габдулла ишан үзенә кул асты йомышына алды.* Р.Шакиров

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Чынбарлыкны төгәл чагылдырырлык рәвештә, фактларга туры килерлек итеп. *Аның өчен куркыныч як беренче сүзне ачык, дөрес әйтә алу иде, инде берне әйтте, каушап, ялгышу куркынычы калмады, башка сорауларын тәҗрибәле кеше кебек, бер дә калтырамыйча, каушамыйча әйтәчәгенә ышанып тынычланды.* Г.Ибраһимов

2) Кагыйдәләргә, нормаларга, таләпләргә җавап бирерлек, туры килерлек итеп. *[Әбелхарис:] Үкенмә, син дөрес яшәдең ---. Монда иң гаепле кеше – мин.* Н.Исәнбәт. *Патронсыз гына атабыз әле: дөрес төзәргә, спусковой крючокка дөрес басарга өйрәтәләр.* И.Гази

3) Төгәл, ялгышмыйча. *– Гыймади абзый, – Якуб стенадагы сәгатькә күрсәтте, – синең бу таракан оясы дөрес йөриме?* И.Гази

**3.** *и. мәгъ. гадәттә, кыек килештә.* Дөреслек, хакыйкать. *Карт төлкенең сүзләрендә ялган белән дөрес бергә буталган икән.* Г.Ибраһимов. *Әйбәт малай син. Шулай да дөресен сөйләмисең.* Р.Мөхәммәдиев

**4.** *кер. сүз мәгъ.* 1) Әйтелгән фикергә басым ясау кирәклекне белдерә. *Менә тоймый да калырсың, өч ел үтәр дә китәр... Йөрер, дөнья күрер; дөрес, гомере әрәм була, гыйлеме артмас, ләкин китап караса, моталәгадә булса, кимемәс тә...* Г.Ибраһимов. *Дөрес, бу салкынга безнең башка ашлыклар барысы да түзәләр.* А.Алиш. *Дөрес, аны башкалар белән таныштырырга, кавыштырырга омтылып карауччылар да булмады түгел.* Р.Мөхәммәдиев

**5.** *хәб. функ.* 1) Диалогта, сөйләүченең сүзләрен раслау өчен кулланылып, «әйе», «шулай шул», «чыннан да шулай», «хак» дип хуплап әйтүне белдерә

2) **дөресе**, **дөресрәге**, **дөресендә** Аныграк, төгәлрәк әйткәндә. *Шунда мин гомеремдә беренче тапкыр Зөфәр абыйга текәлеп карадым. Дөресрәге, карамый булдыра алмадым.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Дөресен әйтергә кирәк** *кер. сүз мәгъ.* Әйтелгән фикернең дөреслегенә, хак булуына басым ясауны белдерә. *Менә хәзер дә ул, әле беркем дә телгә*

*алмаган өр-яңа нәрсә – терлекләрнең нәселләрен яхшырту мәсьәләсен кузгатты һәм, дөресен әйтергә кирәк, шактый катлаулы мәсьәләне гаҗәп бер гадилек белән, һәркем аңларлык итеп әйтеп бирә алды.* Ә.Еники. *Дөресен әйтергә кирәк, мин аның рәсемен таулар арасындагы кытай авылында күрүемә гаҗәпләнмәдем.* А.Шамов. **Дөресен әйтик** *к.* **дөресен әйтергә кирәк**. *Дөресен әйтим, мин әле хәзергә кадәр аңлап бетерә алмыйм: ник шакылдаттым мин аларга?* А.Шамов. **Дөресен әйткәндә** *кер. сүз мәгъ.* Төгәлрәк, анығрак итеп әйткәндә. *Дөресен әйткәндә, әле бик үк булмаса да, зур шатлыклар булырга тора.* А.Әхмәт. **Дөресен генә әйткәндә** *к.* **дөресен әйткәндә**. *Дөресен генә әйткәндә, аның үзен-үзе болай тотуы бик табигый рәвештә иптәшләренә дә йогып өлгерде.* Ә.Еники. *Дөресен генә әйткәндә, Гаяз туган, аның миңа нәрсәседер ошады бугай.* М.Әмир. *Дөресен генә әйткәндә, алар моны елның башка фасылларында да ярыйсы гына булдыралар, әмма яз көне --- ул бичараларның бүгенге дөньяга вәсвәсә аша караулары аеруча көчәя.* Ф.Хөсни. **Дөрес(кә) килү (чыгу)** Дөрес булып чыгу, раслану (алдан әйтелгән сүз, фараз һ.б.ш. турында). **Дөрестән дә** Чыннан да. *Дөрестән дә, авыл буенда елганың суы салкын, ләкин ул, Миләүшәдән борылып-борылып киткән, километрларга сузылган саен, үзенең суын җылыта бара.* А.Алиш

**ДӨРЕСЛӘНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **дөресләү**

2) Нинди дә булса эш-хәлнең, сүзнең дөреслеге ачыклану, билгеле булу

**ДӨРЕСЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **дөресләү**

2) *күч.* Эш-хәлнең, сүзнең дөреслеген кемнән дә булса раслату, таныклату

**ДӨРЕСЛӘ́Ү** *ф.* 1) Билгеле бер нәрсәдәге (сүздәге, язудагы һ.б.ш.) хатаны, кимчелекне, ялгышны төзәтү. *Ә икенче мин, хаталарга нигә күз йомарга, адәм баласы гөнаһлардан хали түгел бит, бергәләшеп төзәлик, төзәтик, ди.* Безнең гәҗит

2) Дөрес, төгәл итеп кую, дөрес эшләтә башлау. *Сәгатьләрне дөресләп тә булыр, Тик «дөресләп» булмас вакытны.* Ф.Яруллин

3) Билгеле бер нәрсәнең дөрес булуын раслау, дөреслеген дәлилләп күрсәтү. *[Хат язучы:] Шуның белән хәбәр итмәк булдык үзебезнең исән-сау торуыбызны. Һәм дә дөреслим синең хатыңны алганлыгымны.* Ш.Мөдәррис

4) Дөрес дип тану, раслау. *Сихер йөртеп, әби шуны белде, кара карт та, әбинең төшенә кереп, шул хәбәрне дөресләде: кызы, әбинең сихерен алып, мәңге яшәсен өчен, берәр егетнең канын эчеп, тәнен тулысынча ашап бетерергә тиеш иде.* Х.Әбделмәнов

**Дөресләп бару** Һәрберсен бер-бер артлы дөресләү. *Авызында гел Коръән сүзе, артыгын сөйләшмәс, һәр кылганын дин белән дөресләп барыр [егет].* Р.Рахман

**Дөресләп бетерү** Барысын да дөресләү; ахырга кадәр дөресләү. *Корректор бар язманы да дөресләп бетерде*

**Дөресләп җибәрү** Дөрес юнәлеш бирү; бер тапкыр дөресләү. *[Тимери] алтын битле стена сәгатен дә Кремль сәгате белән генә дөресләп җибәрә иде.* Г.Бәширов. *Хәйрулла абый исә вакыт-вакыт кушылып ала, өстәп, төзәтеп, дөресләп җибәрә ---.* Р.Миңнуллин

**Дөресләп карау** Дөресләргә тырышу. *Өсте аска әйләндереп куелган рәсемне бала, иелеп, аяклары арасыннан «дөресләп» карый.* Ш.Галиев

**Дөресләп кую** Дөрес итү; төзәтеп җибәрү. *[Нуриев:] Мин репетициягә ашыга идем, дөресләп куярга вакытым булмады.* Р.Батулла. *Аяз хатынын дөресләп куйды.* Р.Галиуллин

**Дөресләп тору** Һәр очракны, һәрберсен дөресләү. *[Ярлы аучыга:] Мин ни генә әйтсәм дә, син дөресләп торырсың, яме.* Әкият

**Дөресләп утыру** Әле, хәзерге вакытта дөресләү. --- *күпне белгән кеше төсле, «әйе, әйе, әлбәттә, шулай» дип, дөресләп утырган булам.* М.Әмир. *[Насри:] Синең дә дөресләп утыруың кирәк түгел.* Ш.Камал

**Дөресләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, берсен дә калдырмый дөресләү. --- *зинһар өчен, --- үзең, үз кулың белән чагыштырып, дөресләп чык.* М.Җәлил

**Дөресли бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы дөресләү. *Авыр-авыр сулады да ахирәтенең барлык сүзен дөресли барды.* А.Алиш

**Дөресли башлау** Дөресләргә керешү

**ДӨРЕСЛЕК** *и.* 1) Чынбарлыкка туры килгән, дөрес булган хәл. *Бүгенге кырыс шартларда эстрадада уңышка ирешү, халыкка танылу өчен зур акча кирәк диләр. Бу фикердә дөреслек бар*

2) Хакыйкать, хаклык. *Дөреслек синең ягыңда булса, кырык мең кеше каршы булса да курыкма.* Мәкаль. *Бу көрәштә кайвакыт батыр каһарманнар һәлак тә була, ләкин нәтиҗәдә яшәү – үлемне, яхшылык – явызлыкны, дөреслек ялганны, хыянәтне җиңә.* И.Юзеев

**ДӨРЕСЛЕКТӘ** *кер. сүз* Чынлыкта, асылда. *Дөреслектә, халык иң элек рекламадагы товарга түгел, ә анда тасвирланган «бәхетле, уңышлы тормыш»ка кызыга.* Шәһри Казан

**ДӨРЗИЛӘР** *и. гар. күпл.* Мөселманнарның шигыйлар (социаль-сәяси әһәмияте һәм тарафдарларының күплеге ягыннан ислам динендә икенче мәзһәп) мәзһәбе тарафдарлары. *Дөрзиләр, Алланы бер генә дип тану белән бергә, Хаким хәлифәдә (996–1021) Алла сыйфатлары бар, дип, рух бер кешедән икенче кешегә күчә, дип ышаналар, җитәкчеләрдәге буыннан-буынга күчеп килә торган рухи бердәмлекне нәкъ менә рухның бер-берсенә күчүе нәтиҗәсе дип аңлаталар.* Ислам

**ДӨРЛӘТҮ** *ф.* 1) Ут кабызу, ут алдырып җибәрү

2) Тагын да ныграк итеп яндырып җибәрү

3) *күч.* Кузгату, уяту, торгызу (хис, тойгы, теләк һ.б. турында). *Җае чыкканда рус булып кылanучы, үзләрен Иван, Пётр, Александр һ.б. дип атаучы мөселман «зыялылары» бу корылтайда иң котырынган милләтчеләргә әверелделәр һәм, шул битлек артына ышыкланып, милли хисләрне дөрләтү, эшче-крестьян властена ачыктан-*

*ачык каршы чыгу юлыннан киттеләр.* М.Юхма

**Дөрләтеп җибәрү** Кинәт дөрләтә башлау, дөрләп китәргә этәргеч бирү. *Микәйнең хәтерендә җуела барган үткәнне, тәмам онытылган бер хыялны яңартып, яңадан балкытып, дөрләтеп җибәргән төш булды бу.* Р.Мөхәммәдиев

**ДӨРЛӘ́Ү** *ф.* 1) «Дөр»гә охшаган, «дөрр» сыман тавышлар чыгару (ут, ялкын һ.б. турында). *Шалаш каршында, хисләр кайнарлыгы булып, учак дөрләде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ул, чак кына сулыш алып, өйдәге һәр аваз, һәр хәрәкәтне тыңлап ята башлады: кече яктагы мичкә якканнар икән, чарт-чорт иткән авазлар чыгарып, коры утын янганы, ялкын дөрләгәне ишетелә.* Казан утлары

2) Тагын да ныграк яна башлау, катырак гөжләү; көчәю. *Күкерт сыман тиз кабынып, дөрләп янарга керешә бәрәңге сабаклары.* Р.Мөхәммәдиев

3) Керосин лампасының уты турында: ялкыны артык сузылып һәм бик сөремләнеп яну

4) *куч.* Бик көчле, бик нык булу. *Баштарак сугыш дөрләгән яклардан кайткан бу гаиләне авыл халкы ачык йөз белән каршы алса да, соңыннан алардан бизде.* Г.Гыйльманов. *Әмма бер кабынган утның һаман да көйрисен, ниһаять, 1764 елда янә ялкынланып, шуңа көенә-көенә тагы ике ел яшәгәннән соң, туксан бер яшендә үлеп китәсен, восстаниенең аннан соң да елдан артык дөрлисен белми әле ул.* Ж.Рәхимов

◊ **Дөрләп кабыну** 1) Кинәт көчле хисләргә бирелү. *Егетнең инде ашкынуы басыла, дөрләп кабынган өмете, мае бетеп килгән шәмдәй, сүнәм-сүнәм дип калтырана башлаган иде.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Бик тиз кызып китү

**Дөрләп китү** Кинәт дөрли башлау. *Дөлдөлевичның бөтен кыяфәтенә ашкыну, рухлану төсе чыккан: халкына кайнар мәхәббәт утыннан менә-менә дөрләп китәр кебек иде ул.* М.Юхма

**Дөрләп тору** Әле, хәзер, күз алдында дөрләү халәтендә булу. *Уятырга теләп, мөгез очлары белән төрткәләде ул күз алдында дөрләп торган кешеләргә.* Р.Мөхәммәдиев

**Дөрли бару** Торган саен ныграк дөрләү

**Дөрли башлау** Дөрләргә тотыну. *Имеш-мимешләр янгынның үзеннән дә хәтәррәк дөрли башлады.* А.Гыйләҗев. *Таш кынамы?! Хәтта минем йөрәк Шул караштан дөрли башлады...* Р.Назаров

**Дөрли бирү** Бернигә карамый дөрләү; һаман дөрләү

**Дөрли төшү** Бераз дөрләү

**ДӨРС** *иярт. сир.* 1) Авыр әйберләрнең көчле бәрелүеннән чыккан тавышны белдерә

2) Туп шартлаган тавышны белдерә

3) *к.* **дөп.** *Туктамыш хан аны әйтте: – «Дөрс-дөрс» итеп, «дөрс» итеп, Дөрселдәмә, сум йөрәк; Тынычлыкка зар чакта Дөрселдәвең ник кирәк?!* Дастан

**ДӨРСЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) «Дөрс»кә охшаган, «дөрс» сыман тавышлар чыгару; гөрселдәү

2) Еш һәм каты итеп тибү. *Туктамыштай зур ханның Дөрселдидер йөрәге.* Дастан

**ДӨРТ** *иярт.* Учактагы ут кинәт яна башлаганда, мотор кабынганда, ишле төркем кинәт хәрәкәт иткәндә барлыкка килә торган һ.б. гөрелдәүле кискен тавышны белдерә

**ДӨРТЛӘТҮ** *ф. к.* **дөрләтү**

**Дөртләтеп җибәрү** Дөртләп китәргә этәргеч бирү, дөртләргә ярдәм итү. *Шикләнүләрен бер-беренә сиздермәс өчен, егетләр юри кычкырып сөйләштеләр, учакны өр-яңадан дөртләтеп җибәрделәр дә, янәшәдәге имән төпләренә утырып, утка төбәлделәр.* Ж.Рәхимов

**ДӨЯ** *и.* Партояклылар төркеменнән, дөясыманнар семьялыгыннан бер яки ике өркәчле, эре гәүдәле күшәүче хайван (чүлдә яки ярым чүлдә яши); йорт хайваны буларак йөк ташу-күчерү өчен кулланыла; ите, сөте, йоны файдаланыла. *Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк.* Мәкаль. *Әмма дөяләләрнең берсе бик тиз аңына килеп, хәвефсезрәк тоелган арт якка борылды, әче итеп сүгенә-сүгенә, Фарукҗан тавышы килгән якка ут ачты.* Т.Әйди. *Болар [ыруглар] меңләгән җылкылары, яхшы нәсел дөяләре, исәпсез куйлары белән Сары Арканың киң далаларында ак тирмәләр корып, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә үзләренең маллары артыннан рәхәт-рәхәт күчеп йөриләр иде.* Г.Ибраһимов

**ДӨЯБАШ** *и. зоол.* Дөябашлар отрядыннан, күкрәге дөя муены кебек озынча булып үскән канатлы бөҗәк; *русчасы*: **верблюдка**

**ДӨЯЧЕ** *и.* Дөяләрне караучы яки әйдәп баручы

**ДРАГУН** *и. фр. тар. иск.* Патша армиясендә яки кайбер башка ил армияләрендә: атлы гаскәрдә хезмәт итүче солдат яисә офицер. *Элекке кирмән урыны хәзерге Троицк шәһәренең уртасында калган, ул юк инде хәзер. Ә заманында ул хәрбиләр белән мыж кайнаган, анда Уфа драгуннары һәм дүрт роталы укчы полк гаскәрләре көн-төн сакта торганнар...* А.Расих

**ДРА́МА** *и. гр.* 1) Сәхнәдә башкару өчен диалог формасында язылган әдәби әсәр төре; сәхнә әсәре. *Әдәби тәнкыйтендә шигърият, проза, драма әсәрләренә бердәй тигез мөрәҗәгать итүче Н.Сафинаның активлыгы да бары хөрмәткә лаек.* Ә.Закирҗанов

2) Шул төрдәге җитди эчтәлекле (комедия һәм трагедиядән аермалы) әсәр. *Кәрим Тинчурин драмалары*

3) *куч. кит.* Тирән борчылуларга китерә торган авыр, фаҗигале хәл. *Гаилә драмасы*

**ДРА́МАЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Нинди дә булса әсәргә драматик форма бирү, драматик рух кертү. *Повестьны драмалаштыру*

2) Гади генә вакыйгаларны катлауландырып күрсәтү, киеренкелеген көчәйтү. *Хәлне артык драмалаштыру*

**Драмалаштыра бару** Драмалаштыруны акрынлап арттыру

**Драмалаштырып алу** Кыска бер вакыт арасында драмалаштыру

**Драмалаштырып бетерү** Тәмам, тулаем, тулысынча драмалаштыру

**ДРА́МАЛЫ** *с.* Драматик, драма тулы

**ДРАМАТИЗМ** *и. фр.* 1) Нинди дә булса хәлнең, вакыйганың драмага хас киеренкелеге. *Романның драматизмы*

2) Хәлнең, торышның, халәтнең ахыр чиккә җиткән киеренкелеге, авырлыгы, кыенлыгы. *Хәлнең драматизмлыгы*

**ДРАМА́ТИК** *с.* 1) Драма рәвешендәге, сәхнә өчен иҗат ителгән. *Драматик пауза. Драматик ишарә*

2) Драма (*1, 2 мәгъ.*) әсәрендәге рольләрне башкара торган. *Драматик актриса*

3) *күч.* Киеренке, авыр кичерешле, драматизм тулы. *Драматик чишелеш. Драматик момент. Драматик вакыйга*

4) *муз.* Көчле, лириктан аермалы буларак, берникадәр югары тембрлы (җырчының тавышы турында). *Драматик тенор. Драматик сопрано*

**ДРАМА́ТИКЛЫК** *и.* Киеренкелек. *Аның әсәрләренә вакыйгаларның киеренкелеге, психологик драматиклык һәм характерлар контрастлыгы хас.* Ф.Галимуллин

**ДРАМАТУРГ** *и. гр.* Сәхнә (драматик) әсәрләре язучы. *Яшь драматург. Туфан Миңнуллин – язучы һәм драматург*

**ДРАМАТУ́РГИК** *с.* Драматургиягә бәйләнешле, шуңа мөнәсәбәтле. *Язучының драматургик эшчәнлеге*

**ДРАМАТУРГИ́Я** *и. гр.* 1) Сәхнә әсәрләре язу сәнгате

2) *җый. и.* Нинди дә булса чорның, халыкның, язучының, әдәби юнәлешнең драма әсәрләре җыелмасы. *Татар драматургиясе*

3) Драматик әсәрләр төзелеше теориясе. *Драматургия нигезләре. Драматургия курсы*

**ДРАМАТУ́РГЛЫК** *и.* Драматург һөнәре

**ДРА́МАЧЫ** *и. к.* **драматург**

**ДРАМТҮГӘРӘК** *и.* Драма (*1 мәгъ.*) түгәрәге. *Беренче класста укыганда ук, драмтүгәрәккә йөри башлады кызым Алсу.* Ватаным Татарстан

**ДРАНЧА** *и. рус* **1.** *җый. и.* Штукатура астында калдырылып, түшәм һәм стенага кадаклау өчен яки түбә ябу өчен махсус такта кисәкләре яисә шуларның берсе. *Өй түбәсе дранча ла, Давыл чыкса, җил ача ---.* Җыр. *Усак агачыннан шырпы, фанер, дранча, көрәк --- ясыйлар.* Кызыклы география

**2.** *с. мәгъ.* Дранчадан эшләнгән, дранча белән ябылган. *Дранча түбә*

**ДРАНЧАЛА́У** *ф.* Агачны дранча итеп яру, телү, дранчага әйләндерү

**Дранчалап бетерү** Дранчалауны тәмамлау, төгәлләү; тулысынча дранчалау

**ДРАП** *и. фр.* **1.** Тышкы кием, диван тышлыгы һ.б.ш. тегү өчен кулланыла торган калын, тыгыз йон тукыма. *Драптан куртка тегү*

**2.** *с. мәгъ.* Драптан булган, драптан тегелгән. *Драп пальто. Драп тышлык*

**ДРА́ХМА** *и. гр.* 1) Грециядә акча берәмлеге

2) Төньяк Америка, Англия һәм Германиядә авырлык үлчәү берәмлеге

3) *тар.* Дару ясаганда табиблар һәм даруханә хезмәткәрләре тарафыннан кулланылган авырлык үлчәү берәмлеге

**ДРАЦЕ́НА** *и. лат.* Агавачылар семьялыгыннан, мәңге яшел, озын яфраклы, күп төрләре бүлмәдә һәм оранжереяларда үстерелә торган агач яки куак үсемлек

**ДРЕДНО́УТ** *и. ингл.* Көчле коралландырылган тиз йөрешле зур броненосец, хәзерге линкорның элекке төре

**ДРЕЗИ́НА** *и. нем.* Рельслар буенча двигатель яки кул көче ярдәмендә хәрәкәтләнә торган механик тимер арба

**ДРЕЙФ** *и. голл.* 1) Хәрәкәттәге кораб, самолётның җил яки агым тәэсире астында хәрәкәт юнәлешен үзгәртү күренеше

2) Бозның, судноның җил яки агым юнәлеше буенча ирексез хәрәкәте

3) *күч.* Гомумән, нәрсәләрнең дә булса билгеле бер тәэсир астында хәрәкәт юнәлешен үзгәртү күренеше. *Магнит полюсы көнбатышка тайпылганлыктан, атмосфера агымнарының да көнбатыш «дрейфын» күтәргә кирәк.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ДРЕЛЬ** *и. нем.* Агач, металл һ.б. өслеккә тишек тишү өчен кулланыла торган инструмент. *Бер төркем сәхнә уртасында басып торучы председатель һәйкәлен дрель белән кубарып төшерә.* Р.Батулла. *Абыйсы, стенаны шул ук агач остасыннан алган дрель белән бораулап, киштәне яхшылап кагып бирде.* Х.Ширмән

**ДРЕНАЖ** *и. фр.* 1) Җирне каналлар һәм трубалар системасы белән киптерү; җирне (сазлыкларны) киптерү системасы. *Дренаж катламы чүлмәкнең өчтән бер өлешен алып торырга тиеш.* Юлдаш

2) Корылмаларны, аларның фундаментларын дымланудан саклау ысуллары һәм җайланмалары. *Фундамент дренажы*

3) *мед.* Шештәге яки ярадагы үлекне махсус көпшә яки марля тасма ярдәмендә суырып чыгару эше

**ДРЕНАЖЛА́У** *ф.* 1) Дренаж (*1 мәгъ.*) ысулы белән эшкәртү. *Сазлык җирләрне дренажлау*

2) *мед.* Шеш, җәрәхәтләрне дәвалаганда, дренаж ысуллары куллану

**Дренажлап бетерү** Дренажлау эшен тәмамлау, төгәлләү

**Дренажлап тору** Даими рәвештә, әледән-әле дренажлау

**Дренажлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, беткәнче дренажлау

**Дренажлый башлау** Дренажларга керешү

**ДРОБЬ** *и. рус муз.* 1) Барабанда: таякчыкны алмаш-тилмәш бәреп уйнау

2) Балалайкада: берничә бармак белән тиз-тиз, бер-бер артлы бәреп уйнау

**ДРУЖИ́НА** *и. рус тар.* Борынгы рус дәүләтендә князь гаскәрләренең төп өлешен тәшкил итә торган кораллы төркем

2) Нинди дә булса максатлардан чыгып төзелгән ирекле төркем, отряд, берләшмә. *Яшел Үзән районының Зур Кизләү авылында янгын сүндерү дружинасы оештырганнар.* Ватаным Татарстан

**ДРУЖИ́НАЧЫ** *и.* Дружина әгъзасы. *Шуннан Мәрдәнов дружиначы егеткә бүтән маршруттагы иптәшләренә кушылырга кушты да өенә китте.* Казан утлары. *Князь дружиначылары. Коралланган дружиначылар.*

**ДУАДАК** *с. диал.* 1) Ялгыз, бәпкәсе булмаган, бала чыгармаган. *Чүл далада тинтерәп, Дуадактай хан калыр.* Дастан

2) Өйләнмәгән, гаиләсе булмаган ир кеше; буйдак. *Ул заманда дуадак булып йөргән Гарифлар да хәзер биш җанга җир чәчәләр инде.* Г.Толымбай

**ДУАЛИЗМ** *и. лат. филос.* Дөньяның нигезендә бер-берсен кире кага һәм үзара көрәшә торган ике мөстәкыйль – матди һәм идеаль башлангыч ята, дип саный торган фәлсәфи тәгълимат; *киресе:* **монизм**

**ДУАЛИСТ** *и. рус* Дуализм тарафдары

**ДУАЛИ́СТИК** *с.* Дуализмга караган, шуңа нигезләнгән; дуализмга мөнәсәбәтле

**ДУАМАЛ** *с. фар.* **1.** 1) Алдын-артын уйлап тормаучы; бик кызу канлы, тотрыксыз холыклы. *[Декан:] Бу сессияне гел «бишле»гә генә бирергә дә көчегез җитәр шикелле иде дә бит. Ә нәтиҗә ничек? Әллә нинди дуамал кеше сез, Рахманкулов.* М.Юныс

2) Уйлап җиткермичә, ашыгып һәм тупас эшләнгән; артык тәвәккәл, кыю (адым, сүз, эш, хәрәкәт һ.б.ш. турында). *Диңгезләргә алгысыган күңел Булып калса бары мал колы Һәм яшьлекне чолгап дуламаса Дуамал шул сөю ялкыны ---.* Зөлфәт. *Бер дуамал теләк күңелне кыбырсытып узды*. М.Юныс

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Уйлап тормыйча, уйлап бетермичә; кинәт кенә, кискен һәм тупас рәвештә. *Әсәрнең баш герое Ирек Сабитовның гыйбрәтле язмышы ярдәмендә язучы [Фоат Садриев] --- түрәләрнең үзләрен законнан күрәләтә өстен куюларын, дуамал кылануларын кискен фаш итә дә инде.* Авыл утлары

2) *диал.* Бик каты, бик нык, гадәттән тыш

**ДУАМАЛЛАНУ** *ф.* Дуамал рәвештә, уйлап тормыйча эш итү, артык кызу канлылану, холыксызлану. *Фәләхов ике аягы белән берьюлы атының касыгына төртеп куйды һәм, дуамалланып, йөгәнен кинәт уңга, елгыр кола биягә таба тартты.* Р.Мөхәммәдиев

**Дуамалланып йөрү** Әле, хәзер, бөтен җирдә дуамаллану

**Дуамалланып китү** Кинәт дуамаллану. *Табарсың аның җаен, бер дуамалланып китсә.* Ш.Алпар

**ДУАМАЛЛЫК** *и.* Дуамал кешегә хас сыйфатлар; башбаштаклык, акылсызлык, кызу канлылык. *Шушындый әйбәт хәзерлек мизгелен ташлап, киләчәккә ашыгу – арзанлы дуамаллык кына бит ул.* М.Юныс. *Бары тик үземнең дуамаллыгымнан, эшне уйламыйча эшләүдән генә арына алмадым.* М.Юныс. *Тик менә хәзер уйлап-хәтерләп утырам да, без, әле акыллы-тәртипле саналган балалар да, яшьлек җүләрлеге, дуамаллыгы белән әнигә күпме борчу китергәнбез.* Сөембикә

**ДУАМА́ЛЧА** *рәв. сир.* 1) Бер сәбәпсез, көтмәгәндә, тиктомалга. *Дуамалча кайтып китү*

2) Дуамалланып. *Дуамалча кызып китү. Дуамалча бәйләнү*

**ДУБЛЕТ** *и. фр. кит.* Берәр нәрсәнең икенче нөсхәсе, кабатланган данәсе. *[Өченчесе:] Кайдан килеп утырдым синең кул астыңа, әйдә, Әптерәй, куй! [Дүртенчесе:] Әйдә, шул көенчә генә, мин дублетын гына куям.* Г.Камал

**ДУБЛЁНКА** *и. рус* Дупланган сарык тиресеннән яки махсус эшкәртелгән ясалма күннән тегелгән өске кием. *Мәтрның мин аралашырга туры килгән күп кенә дуслары кыйммәтле киенә, әмма алар, минем уйлавымча, «Сейко», «Саламандер», фин костюмнары, «Туро» яки «Пиенла» дәрәҗәсендә генә калган, боларга тагын итальян дублёнкаларын --- өстәргә була, ләкин, аларга карап кына, модаларның асылы үзгәрми шул.* Казан утлары

**ДУБЛЁР** *и. фр.* 1) Бер үк эшне кем белән дә булса параллель рәвештә башкаручы һәм аны кирәкле вакытта алыштыра ала торган кеше

2) Төп башкаручыны алмаштыручы актёр. *Дублёр белән алмаштыру*

**ДУБЛЁРЛЫК** *и.* Дублёр эше; дублёр һөнәре. *Г.Кариев 1912 елда дублёрлык кертә*

**ДУБЛИКАТ** *и. лат.* Берәр документның төп нөсхә белән бер үк дәрәҗәдәге юридик хокукта булган күчермәсе. *Шулай сигез бала чиратлап уйный торгач, ул [орден] каядыр юкка чыкты, күпме эзләп, әлегә кадәр таба алганыбыз юк. Документы калды калуын, шуны күрсәтеп, киләчәктә, бәлки, дубликатын алырбыз, дип уйлыйм.* Р.Вәлиев

**ДУБЛЯЖ** *и. фр.* **1.** 1) Тавышлы кинофильмның тавыш өлешен икенче телгә күчереп чыгару эше. *Дубляж ясау*

2) Шул рәвешле эшләнгән хезмәт (*кинофильм, вакытлы басма һ.б.ш.*). *Редакциядә мине белүче юк икән. Газета, татар теленә русчадан тәрҗемә ителеп, дубляж буларак кына чыга.* А.Расих

**2.** *с. мәгъ.* Шул ук әйберне кабатлап, икенче телдә эшләнгән. *Мин, мәкаләләр күтәреп, дубляж газетага еш килгәли идем.* Р.Хисмәтуллин

**ДУБЛЯЖЛА́У** *ф. кино* Дубляж ясау. *Гомумән, фильмны дубляжлау нинди этаплардан тора?* Ватаным Татарстан

**ДУГА** *и.* **1.** 1) Ике тәртәне камытка беркетеп кую өчен, агачтан бөгеп, ярым түгәрәк итеп эшләнгән ат җигү дирбиясе. *Нечкәбил аның дугасына күзен сала, теге, хәерсез кигәвен, шул дугага кунып бара, аннан ат ботына куна, һәм ат аны койрыгы белән җиргә бәреп төшерә.* А.Алиш. *Ат абзарлары тирәсендә тимер ходлы арбаларны көйли башладылар, дугаларга кыңгыраулар тактылар.* М.Мәһдиев. *Дуга өчен махсус ясалган атаклы Валдай кыңгыраулары болар.* З.Зәйнуллин

2) Дугага охшап, ярымәйләнә рәвешендә бөгелгән һәрнәрсә. *Гармун тавышы ишетелүгә, колаклары шәмдәй тырпая, сыны җыела, муены дуга рәвешен ала.* М.Әмирханов

3) *мат.* Түгәрәк яки кәкре сызыкның ике нокта арасындагы өлеше. *Әгәр Казан – Барда радиусы белән көньякка таба уйдырма дуга сызсак... Уфа тирәсенә барып чыгабыз.* З.Мифтахов

**2.** *с. мәгъ.* Дугасыман, ярым әйләнә рәвешендә бөгелгән. *Бер буйга, туры озын сызык буенча түгел, бәлки дуга яки яңа туган ай рәвешендә, түгәрәкнең яртысы рәвешендә булып тезелделәр.* Г.Ибраһимов

**ДУГАЙ** *с. к.* **дугайлы**. *Гөлзаданең --- дугай кашлары, текә шома маңгае --- аңа тәвәккәллек төсмерләре бирәләр иде.* Ф.Садриев

**ДУГАЙЛАНУ** *ф. к.* **дугалану**. *Аның кара керфекләре озын булгангамы, әллә дугайланып, ярым бөгелеп торгангамы, күз читләрен сөрмә тарткандай күләгәлиләр, серлелек бөркеп торалар.* Ф.Садриев

**ДУГАЙЛЫ** *с.* Дуга сыман, дугайланып торган, бормалы-бормалы. *Дугайлы инеш буйлары*

**ДУГАЛАНУ** *ф.* Дугага охшау, дугасыман булып бөгелеп тору, дуга рәвешен алу. *Аның бер башы тау итәгендәге сыек ак томанга төренгән иген кырына терәлгән, икенче башы, киң тугай аша дугаланып, Сакмар өстенә төшкән иде.* Ә.Еники. *Сөекле әниемнең кабере өстеннән китап рәвешендә алсу төсле җисем калкып чыкты һәм әкрен генә күтәрелә башлады. Күтәрелде-күтәрелде дә, салават күпере сыман дугаланып, күккә ашты.* Ватаным Татарстан

**Дугаланып китү** Дугаланган булу; кинәт дугалану. *1910 елның җәендә килде Казанга Шәһит Әхмәдиев. Хәзер инде аңа егерме ике яшь. Өстә матур костюм. Уйчан йөз. Иплелек. Кара мыек. Дугаланып киткән кара кашлар. Моңсу караш.* С.Поварисов

**Дугаланып тору** Дугаланган торыш алу; дугаланган булу

**ДУГАЛЫ** *с.* 1) Дугасы булган. *Элек-электән үк, юкка гына, дугалы йорт – догалы йорт, димәгәннәр бит.* Ватаным Татарстан

2) Дуга кебек, дуга формасында. *Яңа туган ай дугалы булса, давыл булыр.* Сынамыш. *Бик матур булган ул: түгәрәк йөз, томрап торган зур күзләр, дугалы кашлар, озын керфекләр.* Сабантуй. *Әлеге ташка тимер куеп карый – тимер ябышмый, дугалы магнит куя – магнит ябышып кала.* Гасырлар авазы

3) Дугалап җигелгән. *Сайлауга килә алмаган сырхауларның өйләренә шулай ук гармун, кызыл комачтан бизәлгән дугалы яхшы чабыш атлары белән кызыл флаглар кадап барып, күчтәнәчләр биреп, сайлатып киләләр.* Ватаным Татарстан

4) *физ.* Дуга рәвешендә (кайбер приборларда һ.б.). *Бәйрәм вакытында дугалы прожекторлар, шәмнәр, шартлаткычлар куллану, фейерверклар ясау һәм янгын килеп чыгу куркынычы зур булган башка нәрсәләрне кабызу катгый тыела.* Туган як. *Металлургиядә күбрәк дугалы мичләр кулланыла.* Төзү материаллары

**ДУГАЛЫК** *и.* **1.** Дуга ясау өчен әзерләнгән, дуга бөгү өчен билгеләнгән яки шуңа яраклы материал

**2.** *с. мәгъ.* Дуга бөгү, дуга ясау өчен билгеләнгән, шуңа яраклы

**ДУГАЧЫ** *и.* Дуга бөгүче, шул эшнең остасы, шул һөнәр белән шөгыльләнүче кеше

**ДУ-ДУ** *иярт.* **1.** Кабатлаулы сузынкырак тавышны, калын гүләүне белдерә (җил исүе, машина кычкыртуы, төрле уен кораллары тавышы һ.б. турында)

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. *Ду-ду быргы кычкыртып тору*

**ДУЕН** I *и.* 1) Сулыклар (елга, буа, күл-диңгезләр) төбендәге яки аларның яры буендагы бик вак минераль һәм органик кисәкләрдән гыйбарәт утырма, ләм

2) *диал.* Юшкын

**ДУЕН** II *и. диал. тарт. форм.* Күбесенчә «уен» сүзеннән соң яки шуңа каршы куеп кулланыла: нинди дә булса тамаша, эш, шөгыльнең иң кызган чагы; эшнең-бурычның иң җаваплы, иң авыр өлеше. *Әле бит бу – уены, шуннан соң булыр дуены.* Әйтем

**ДУЕНЛЫ** *с.* Ләмле. *Дуенлы катлам*

**ДУ́ ИТҮ** *ф.* 1) *к.* **дуылдау** (*1 мәгъ.*)

2) *к.* **ду килү** (*1 мәгъ.*)

**ДУКАТ** *и. ит.* Элек кайбер Көнбатыш Европа илләрендә кулланылышта булган башта – көмеш, аннары алтын тәңкә; борынгы акча

**ДУ́ КИЛҮ** *ф.* 1) Көчле тавышлар, шау-шу күтәрү, ыгы-зыгы куптару һ.б. *Олыраклар бер урында бииләр, ә икенче бер такыр җирдә минем яшьтәшләр ду килә.* Ф.Бәйрәмова

2) *к.* **дулау** (*3 мәгъ.*). *– Сиңа нәмә кирәк?.. Нәмә җитми сиңа карт тиле!.. – дип җикеренде, ду килде хуҗа кеше.* Р.Мөхәммәдиев

**ДУ́ КИТЕРҮ** *ф. к.* **ду килү**. *Ишегалдын ду китереп, ак маңгайлы бозау уйнаклап ала.* Р.Мөхәммәдиев. *Озын, юан нарат бүрәнәсен кузнага салган да сыңар тоткалы озын пычкы белән ду китереп кисә.* М.Хәсәнов

**ДУ́ КУБУ** *ф. к.* **ду килү**

**ДУ́ КҮТӘРҮ** *ф. к.* **ду килү**

**ДУ́ КҮЧЕРҮ** *ф. к.* **ду килү**

**ДУЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **дулау**

2) *сөйл. к.* **дуылдату** (*2 мәгъ.*)

**ДУЛА́У** *ф.* 1) Бик каты гүелдәп, зур көч белән хәрәкәт итү яки тоныкгүләү авазлары чыгару (табигать көчләре һ.б.ш. турында). *Аның каравы, яңгыр куәтләнде, тоташ ташкын сыман, көймә төбен шыбырдатып, ыргып, дулап койды.* М.Хәсәнов. *Нәрсә ул – кызлар мәктәбе?! Язгы ташу кебек дулыйдулый да агып бетә...* А.Гыйләҗев

2) Нindидер сәбәпләр аркасында хайваннар чыгымлау, тәртәгә тибү. *Сыер дуласа, аттан яман.* Мәкаль. *Җылкы тагын тибенде, тагын дулады.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Ярсыну, ярсу, ашкыну (йөрәк, күңел һ.б.ш. турында). *Китте мактап, китте мактап. Минем йөрәк шатлыктан дулады...* Ф.Садриев

4) Холыксызлану. *Әнисе дулады, кычкырды, әйтмәгән сүзен калдырмады.* Г.Мирһади

**Дулап алу** Кыска гына вакыт арасында дулау. *Инде бераз тынычланган халык агрономның сүзләреннән соң тагын дулап алды.* З.Хәким

**Дулап бетерү** Дулаудан туктау

**Дулап китү** Кинәт дулый башлау. *Шәвәлигә бүре очрый да, аты дулап китә.* С.Рафиков. *Тыныч кына утырган җирдән дулап китү*

**Дулап кую** Кинәт кенә, аз гына дулау. *Тышта җил дулап куйды*

**Дулап тору** Берөзлексез, әледәнәле дулау. *Давыл чыкса, диңгез дулап тора*

**Дулап утыру** Әле, хәзерге вакытта дулаган хәлдә булу. *Самавырның өстәлдә дулап утыруын яратам.* К.Нәҗми

**Дулый бару** Торган саен ныграк дулау

**Дулый башлау** Дуларга тотыну. --- *юаш кебек күренгән үгез, чит кешеләрне өнәмичә, кинәт дулый башлаган* ---. З.Хөснияр

**Дулый төшү** Тагы да ныграк дулау; дулавы аз гына көчәю. *Халык төркеме дулый төште*

**ДУЛКЫН** *и.* **1.** 1) Су өслегенең тирбәнүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган озынча калкучыкларның берсе,

күпермәсе. *Икесе дә телләрен йоткандай тын гына утырдылар, бер-берсенә дәшмәделәр, дулкыннарның көймәгә сугылып пышылдашканын гына тыңладылар.* Р.Мөхәммәдиев. *Ярларыңда шаулый таллыклар. Дулкыныңда – балыклар.* Казан утлары

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса дулкын тирбәнүен хәтерләткән хәрәкәте. *Ул, башын чайкап, чәч дулкыннарыннан маңгаен әрчеде дә, озын керфекләрен тибрәтеп, сәгатенә карап алды.* М.Юныс

3) *физ.* Физик мохитта тирбәлү хәрәкәте. *[Беренче кунак:] Әлбәттә, без бит сезнең теле-радио дулкыннарын еш тотабыз. Сергачтан Рәшит Вагаповны яхшы беләбез.* З.Хәким. *Звенодагыларның үзенә булган нәфрәтен ул шушы кайнар һава дулкынын тойган кебек тоя.* Ф.Садриев. *Тавыш дулкыны. Электромагнит дулкыны*

4) Кемнең яки нәрсәнең дә булса хәрәкәте вакытында барлыкка килә яки берсен икенчесе алыштырып торган агым, тирбәлеш; ташкын. *Аккошныкыдай озын, йомшак ап-ак муены ачылып китте аның, таралып төшкән чәч бөдрәләре дулкын булып какты.* Р.Мөхәммәдиев

5) Ыгы-зыгылы, шау-шулы халык массасы. *Халык дулкыны*

6) *күч.* Иҗтимагый тормышта, хәрәкәттә нинди дә булса көчле күтәрелеш, үзгәреш, борылыш һ.б.ш. турында. *Инфляция дулкыны*

7) *күч.* Көтмәгәндә һәм бик көчле ташып чыккан хисләр чагылышы, эмоциональ халәт. *Аның ярсуы яман юлда йөрүчеләрнең барысын да утлы дулкын булып күмеп ташлар сыман иде.* Р.Хисмәтуллин. *Көй дулкыны, җырның сүзләрен куәтләндереп, кыз кичергән газапларны тыңлаучыга җиткерә.* М.Юныс. *Кайчакларда ул үз хыялыннан үзе исереп китә, түгәрәк йөзе эчтән алланып чыга --- бәрхет тавыш белән, шундый бирелеп, агачлар турында сөйли башлый, син, үзең дә сизмичә, әсәренеп аның дулкынында тирбәлә башлыйсың.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ. сир.* Дулкынлы, дулкынланып торган. *Әллә нинди дулкын-дулкын булып яткан кар каплап киткән болын...* Ф.Бәйрәмова. *Әле дә күз алдымда дулкын чәчең.* Ш.Маннур

**ДУЛКЫНВАТКЫЧ** *и.* Күперне көчле дулкыннан саклау җайланмасы. *Цемент кублардан эшләнгән дулкынваткыч пароходка тигезләнде.* М.Юныс

**ДУЛКЫН-ДУЛКЫН** *с.* **1.** Формасы белән дулкынга охшаган, дулкынсыман. *Яланаяклап суга кердең, тешләреңне җемелдәтеп көлә-көлә, учларыңа су тутырып миңа сиптең, дулкын-дулкын чәчеңне артка чөеп, ак йөзеңне салмак искән җилгә куйдың...* Ә.Гаффар. *Бөтенләй таныш булмаган, зур кара күзле, дулкын-дулкын булып торган озын чәчле Венера белән кайтып керә.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Дулкыннар рәвешендә, дулкынланып. *Чәчләре иңбашына дулкын-дулкын агып төшкән.* Н.Дәүли. *Ул арада булмады, айгыр һи-һаһайлап куйды, бөтен сырты буйлап дулкын-дулкын калтырану йөгерде, биясе дә билдән бөгелеп-бөгелеп килде.* Ф.Яхин. *Игътибар итегез, һәр комбайнчы, тәүдә техникасын басу читенә туктатып, дулкын-дулкын чайкалган басуга сокланып карап тора, тук башакларны кулына алып уып карый, бары тик аннан соң гына, канатланып, эшкә тотына.* Кызыл таң

**ДУЛКЫНЛАНДЫРГЫЧ** *с.* Дулкынлануга (*2 мәгъ.*) китерә торган, күңелгә нык тәэсир итеп, көчле хисләр уята торган. *Барысы да дулкынландыргыч мизгелләр кичерә. Шулай булмыйча, хан күтәрмәк тамашасына җыелдылар лабаса!* М.Әмирханов. *Менә ул дулкынландыргыч мизгелләр. «Алсу шушы була инде», – дип, кабинетыннан чыгып килүче укытучы ханым кочып алды аны.* Ватаным Татарстан

**ДУЛКЫНЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Дулкыннар барлыкка китерү. *Көчле җил диңгезне дулкынландыра*

2) *күч.* Борчу, тынычсызлап тору, тынычлык бирмәү. *Колхида турында Паустовский китап язган. Бу китап мине шактый дулкынландырган иде.* М.Юныс. *Әйе, иҗат эше – артист эше – җиңел генә бирелми. Ләкин, тамашачыны дулкынландырырлык образлар тудыргач, күңелдә иксез-чиксез шатлык, рәхәтлек сизәсең.* Яшәү яме

**Дулкынландыра бару** Торган саен ныграк дулкынландыру

**Дулкынландыра башлау** Дулкынландырырга тотыну. *Рәшиднең әледән-әле аңа игътибар итүе һәм дәшүе аны ихтыярсыздан дулкынландыра башлаган иде инде.* Ә.Еники

**Дулкынландыра төшү** Бераз дулкынландыру

**Дулкынландырып бетерү** Бик нык дулкынландыру

**Дулкынландырып килү** Күптәннән, бертуктаусыз дулкынландыру

**Дулкынландырып тору** Туктаусыз яки әледән-әле дулкынландыру. *Гражданнар сугышы чорының романтикасы мине «Сиваш»ны язганчы да, аннан соң да һаман дулкынландырып торды, әле хәзер дә шулай.* Г.Бәширов

**ДУЛКЫНЛАНУ** *ф.* 1) Дулкын (*1, 2 мәгъ.*) барлыкка китерә торган тирбәнешле хәрәкәттә булу, чайкалу. *Дулкынланып торучы шушы ипи диңгезен ул күзе белән иркәли, иреннәре белән үбә...* Ф.Садриев. *Куе яшел төстәге бәрәңге сабаклары, аның тулы, тыгыз балтырларына уралырга теләгәндәй, дулкынланып кала.* Р.Мөхәммәдиев

2) Дулкынга охшаш бөдрәләнеп тору яки дулкын сыман (рәвешендә) булу. *Көз матур иде. Саргылт чәч ташкыны, дулкынланып, җилкәләренә агып төшкән.* М.Юныс

3) *күч.* Тынычсыз хәлдә булу, тынычсызлану, көчле борчылу. *Тынлыкны бозып, Кәлимуллинның дулкынланган тавышы ишетелде...* Ф.Садриев

4) Нәрсә белән булса да килешмәү, тискәре мөнәсәбәт белдерү, ризасызлык күрсәтү. *Халык дулкынлана*

**Дулкынлана бару** Торган саен ныграк дулкынлану

**Дулкынлана башлау** Дулкынланырга тотыну. *Әлфия дә, туган көне якынлашу белән, дулкынлана башлады.* Ә.Сәйфуллин

**Дулкынлана төшү** Бераз дулкынлану

**Дулкынланып алу** Азга гына дулкынлану

**Дулкынланып китү** Кинәт, бернигадәр вакытка гына дулкынлану. *Чәчәкләргә күмелгән укытучы апа дулкынланып та китте.* Ватаным Татарстан

**Дулкынланып кую** Кинәт, бер тапкыр дулкынлану

**Дулкынланып тору** Әле, хәзер дулкынланган хәлдә булу. *Кояш зәһәрләнепме-зәһәрләнә. Һава булып, һава эри. Әнә офыкта дөрләп янган һава су өстендәге томан сыман дулкынланып тора*. М.Әмирханов

**ДУЛКЫНЛАТУ** *ф.* Дулкыннар барлыкка китерү. *Идел суын дулкынлатып, Пароход китеп барыр. Китеп барыр еракларга Яр булмый калган ярым.* Р.Харис. *Абыйларым, дәү балыклар кебек, суны дулкынлатып шаяралар.* Ватаным Татарстан

**Дулкынлата башлау** Дулкынлатырга тотыну

**Дулкынлата төшү** Тагы да ныграк дулкынлату

**Дулкынлатып җибәрү** Кинәт дулкынлата башлау. *Йомшак таң җиле кырдагы куе үләнне дулкынлатып җибәрде*. Ш.Усманов

**Дулкынлатып тору** Бертуктаусыз дулкынлату

**ДУЛКЫНЛЫ** *с.* 1) Тирбәнеп, дулкынланып торган (*диңгез, күл өсте һ.б.ш.*)

2) Дулкынга (*1 мәгъ.*) охшаган, дулкын хәрәкәте рәвешендәге. *Начальник --- алдындагы чиста кәгазьгә ниндидер дулкынлы сызыклар сызып карады.* М.Юныс

3) *күч.* Көчле кичерешләр, уйтойгылар белән сугарылган (сүз, җыр, халәт һ.б. турында). *Мин үлгәч тә, җәйге кичләрдә аккан суга карарга яңа кешеләр килер. Алар да, күңелләрендә дулкынлы тойгылар кузгалганын сизеп, --- киләчәккә планнар корырлар.* М.Юныс

**ДУЛКЫНСЫМАН** *с.* Дулкынга охшаган, дулкынны хәтерләткән. *Кыз дулкынсыман куе коңгырт кара чәчләрен аркасына сипте.* Х.Ширмән. *– Әйе... билгеле, – дидем мин, ай яктысы төшкән дулкынсыман комга карап.* Р.Вәлиев

**ДУ́МА** *и. рус* 1) Россиядә төрле законнар чыгару, кабул итү хокукына ия булган идарә учреждениесе. *Тукайның Думаны өнәмәве тарихи сиземләү нәтиҗәсе булган икән.* Т.Галиуллин

2) Дума урнашкан урын, йорт, бина

**ДУМАЧЫ** *и.* Дума әгъзасы. *Россия матбугатында чыккан кайбер мәгълүматларга ышансаң, думачылар иң элек төбәк парламентларына каршы һөҗүмгә күчәчәкләр.* Ватаным Татарстан

**ДУМБРА** *и.* Корпусы өчпочмак яки ярымтүгәрәк формасында булып, чиртеп уйнала торган, озын тоткалы ике кыллы казак халык уен коралы. *Хан чиртте, думбрадан ямьсез бер тавыш чыкты. Хан әйтте: – Әй, бу думбра бик начар икән, аны алмыйм, кирәк булса, үзеңә ал!* Әкият. *Узган ел борынгы уен коралларында уйнаучылар санаулы булса, быел дәф, думбра, дөңгердә уйнаучылар күренде*. Кәеф ничек?

**ДУМБРАЧЫ** *и.* Думбрада уйнаучы оста яки думбра ясаучы. *Думбрачылар оркестры*

**ДУҢГЫЗ** *и.* 1) Партояклылар семьялыгыннан, ите, мае һәм тиресе өчен асрала торган, чагыштырмача зур гәүдәле имезүче йорт хайваны; *русчасы:* **свинья**. *Байыйсың килсә – дуңгыз асра, бөләсең килсә – айгыр асра.* Мәкаль. *Илле җиденче елда элеккеге мәчет бинасыннан дуңгыз абзары ясадым.* Г.Гыйльманов

2) *күч. гади с. хурл.* Бик шапшак, җыйнаксыз, пычрак кешегә карата кимсетеп әйтелә. *Алкаш тәре, кичә тагын дуңгыз булып кайткансың!* Мәзәк

3) Мәдәни-рухи ихтыяҗлары бик түбән булган кеше турында. *Дуңгыз бер кеше иде. Хәрамхор (хәрам ашаучы) иде.* Татар мөселман календаре

4) Түбән җанлы, әшәке, бик юньсез, әдәпсез кеше турында

**ДУҢГЫЗ ЕЛЫ** *и.* Һәр елы берәр хайван исеме белән аталган борынгы унике еллык цикллы календарьда уникенче ел (хәзерге календарьда, мәс.: 1971, 1983, 1995, 2007 елларга туры килә). *Кеше күзенә эт шикелле – астан, мәче кебек өстән карамыйм, дуңгыз төсле туры карыйм. Чөнки мин [М.Гәрәев] дуңгыз елында туган.* Ватаным Татарстан

**ДУҢГЫЗЛАНУ** *ф. гади с.* Әшәкеләнү, әдәпсезләнү, түбән җанлылык күрсәтү

**ДУҢГЫЗЛЫК** *и. гади с.* 1) Үзен шапшак, пычрак йөртүче, җыйнаксыз кешегә хас сыйфатлар.

2) Әдәпсезлек, әшәкелек, түбән җанлылык. *Мине бу кыяфәттә күрсә, Миләүшә шунда ук йөрәге ярылып үләчәк. Больницаны белмәү – дуңгызлык.* Т.Миңнуллин

**ДУҢГЫЗЧЫ** *и.* 1) Дуңгыз фермасы эшчесе, дуңгыз караучы

2) *сир.* Үз хуҗалыгында дуңгыз асрап, дуңгыз терлеген, аның итен, маен һ.б.ш. сатып кәсеп итүче

**ДУҢГЫЗЧЫЛЫК** *и.* Авыл хуҗалыгының дуңгыз асрау, дуңгыз үрчетү һ.б.ш. белән шөгыльләнә торган тармагы. *Вәли Гаязович телефоннан дуңгызчылык фермасын җыйды.* Ф.Садриев

**ДУРШЛАГ** *и. нем.* Суда җиңелчә пешереп алынган азыкны (токмач, дөге һ.б.ш.) саркыту өчен хезмәт итә торган, зур булмаган тишекләрдән торган чүмеч. *Стовбуненко буфет чиләген табып алып килде: «Автол салып куйганнар, вәхшиләр. Дуршлаг та аларда икән, сөзгеч итеп кулланганнар».* М.Юныс. *Төнәтмәне кәстрүлдә килеш суыталар, дуршлагтагы үләннәрне кәстрүлгә сыгалар, сөзәләр һәм шешәләргә тутырып, бөкеләп куялар.* Сәламәтлек календаре

**ДУРЫЧМАК** *и. к.* **дучмак**. *«Бәрәңге дурычмагы пешергән идем, би-ик тәмле булды, хуш, бер кукәй дә сыткан идем шул», – дип, сөенечен уртаклашкан хатын.* А.Гыйләҗев

**ДУС** *и. фар.* **1.** 1) Кем белән булса да дуслык мөнәсәбәтендә торучы, ышанычлы кеше, якын иптәш. *Булып дуслар белән берлектә даим, Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.* Дәрдемәнд. *Минем Хәлфитҗан исемле бик якын балачак дустым бар иде.* Ә.Дусайлы. *Өстәлемдә саф чәчәкләр – дустым китте миңа биреп.* Р.Вәлиев

2) *күч.* Яраткан, якын күргән кеше, әйбер яки җан иясе, яисә шуларны яраткан кеше үзе. *Китап укырга яратам – Ул минем якын дустым.* Сабантуй

3) Теләктәшлек күрсәтүче, яклаучы, фикердәш, тарафдар. *Аерылмас дустыңа авыр сүз әйтмә.* Әйтем

4) **дускай**, **дускаем**, **дустым** *энд. сүз* Күпчелек очракта дустанә, якын күргән кешегә эндәшкәндә, мөрәҗәгать иткәндә кулланыла торган сүз. *Минә эләктеңме? Шул кирәк сиңа! «Бишле» көткән идең! Дускаем, дөньяда «икеле» билгесе дә була.* М.Юныс. *Шулай да, Биктимер дустым, балачагыбызның кызыклы һәм ачы бер истәлеген болай ярлы итеп сөйләвем өчен, син мине ачуланма инде.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* Яхшы мөнәсәбәттә булган. *Дус кыз. Дус егет*

**3.** *рәв. мәгъ.* Дусларча, дус булып. *Яңа гаиләсеннән уңды ул [Мәхмүтов], Мияссәрә белән, аңлашып, дус яшиләр.* Р.Мирхәйдәров

**4.** *хәб. функ. сөйл.* Нәрсә белән дә булса мавыгу турында. *Ул китап белән бик дус*

◊ **Дус кеше** Мөрәҗәгать, эндәшү сүзе. *[Шәйхаттаров:] Шулай булгач, дус кеше, койрыгыңны кыс та тик утыр.* Т.Миңнуллин

**ДУС-ИШ** *җый. и.* Гомумән дуслар, үзара якын, ышанычлы танышлар. *Дәүләт-байлык – дус-иш аркасында, яхшы исем – хатын аркасында.* Мәкаль

**ДУСЛАНУ** *ф. к.* **дуслашу**

**ДУСЛА́РЧА** *рәв.* **1.** Дуслар кебек, дус буларак, җылы хисләр белән. *Анналары, минем белән дусларча шаяргандай, өстәп куйды ---.* Ф.Баттал. *Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт.* Г.Кутуй

**2.** *с. мәгъ.* Дусларга хас булган. *Хәлим аны [Нәфисәне] карады, тәртипләде, үзенең назы, җылысы һәм дусларча мөнәсәбәте белән, бик тиз аякка бастырды.* Г.Гыйльманов

**ДУСЛАШТЫРУ** *ф.* Дуслыкка, дуслашуга этәргеч бирү. *Авылдашлар бәйрәме тарихыбызны яңарту, авылдашларны очраштыру, күрештерү, дуслаштыру, бердәмлеккә, теләктәшлеккә чакыру чарасы да булып тора.* Кызыл таң. *Безнең клубның максаты – төрле милләт халыкларын дуслаштыру, берберсенең мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән таныштыру.* Шәһри Казан

**Дуслаштыра бару** Торган саен ныграк дуслаштыру

**Дуслаштырып кую** Кинәт кенә дуслаштыру

**Дуслаштырып тору** Һәрвакыт, гел дуслаштыру

**ДУСЛАШУ** *ф.* 1) Үзара дуслык мөнәсәбәтендә булу, дус булу. *Элек якын иткән кешеләрем, моның белән дуслашсам, капитанга ошамас дип, читкә тайпылдылар.* М.Юныс

2) *күч.* Нәрсәгә дә булса мөкиббән китү, артык мавыга-кызыксына башлау, ярату. *Иренмәс җаннар әнә күптән үләннәр белән дуслашты инде: төрле ашлар, салатлар белән аш төрли, киптереп, кышкылыкка да запас әзерли.* Өмет

**Дуслаша бару** Вакыт үткән саен дуслыклары ныгу. *Ике колхоз, елданел дуслаша барып, берсен-берсе алга әйдиләр.* Г.Бәширов

**Дуслаша башлау** Дуслашырга керешү. --- *авылда күп кенә егетләр берәм-берәм Озын Хөсәен белән дуслаша башладылар.* Һ.Такташ. *Кайчандыр каныңа сеңеп калган бу караш анда үсеп җиткәч тә бетмәде, киресенчә, студент булгач, Сәгыйть белән дуслаша башлагач, тагын да ныгыды, төпләнде генә.* Н.Фәттах

**Дуслашып алу** Кыска гына вакыт аралыгында дуслашырга өлгерү; гомумән, дуслашу. *Чик буенда, эчке гаскәрләрдә, десантурада хезмәт итеп кайткан егетләр белән дуслашып алам да сугыш алымнары өйрәтүләрен сорыйм.* М.Кәбиров. *[Әти] Тиз арада шундагы халык белән дуслашып та ала.* К.Миңлебаев

**Дуслашып бетү** Бик нык дус булып китү, тәмам дуслашу. --- *без Истанбулда аның [Хәмзә бәй] белән еш-еш очрашып, күрешеп тордык. Дуслашып беттек.* Р.Батулла

**Дуслашып йөрү** Әле, хәзер дуслар булу. *Без Хаҗип белән беренчедән башлап бергә укыдык. Дуслашып йөргән чаклар да булды шикелле.* М.Юныс

**Дуслашып китү** Кинәт дуслашу; дуслашкан булу. *Күпмедер вакыттан соң Хәмит кайта, боларга килеп йөри башлый, Сәгыйдәнең атасы белән дуслашып китә ---.* Ә.Еники. *Ибраһим абый Нуруллин белән бик еш аралашмасак та, соңгы елларда дуслашып киттек.* Ф.Яруллин

**ДУСЛЫК** *и.* Кем белән дә булса үзара ихтирамга, рухи якынлыкка, мәнфәгатьләр уртаклыгына һ.б.ш. нигезләнгән мөнәсәбәт. *Быелга кадәр Михаилның Хәятка мөнәсәбәте коры дуслык кына иде.* Ф.Әмирхан. *Дуслыклары да төнбоеклы күлдәй матур иде.* Ф.Яруллин

**ДУСТ** *и. ингл.* Зарарлы бөҗәкләрне бетерү өчен кулланыла торган, порошок формасындагы химик матдә, агу

**ДУСТАНӘ** *рәв. фар. кит.* **1.** Дусларча. *Мәскәү белән дустанә яшәү – бик тә мөһим сәясәт, хан, әмма ут күршеләремез нугайлар илә араны ныгыту – иң олы фәгалиятләрнең берсе...* Р.Батулла. *Шуңа кешеләр дә һәрчак дустанә мөнәсәбәттә.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Үзара дуслыкка корылган. *Әлеге дустанә мөнәсәбәттән ике як та үзенә бер ямь таба иде.* Р.Мөхәммәдиев

**ДУТАР** *и. фар.* Корпусы груша формасында булган, чирттереп уйнала торган, ике кыллы, таҗик, төрекмән, үзбәк һәм кытайларда киң таралган халык уен коралы. *Каракалпак җирендә өч төрле уен коралы каршылый: сорнай моңы, дутар кыллары чыңлавы, дойра дөпелдәве.* Ш.Галиев. *Уйна, әйдә, алтын кыллы дутар!* Р.Миңнуллин

**ДУТАРЧЫ** *и.* Дутарда уйнау остасы; дутар ясау һәм сату белән шөгыльләнүче кеше. *Кулларга түгел, елларга Чиертеп уйный дутарчы. Бәгырьләрне өзгәлисең – Дутарчы дус, туктачы!..* Р.Миңнуллин

**ДУ́ ТУЗУ** *ф. к.* **ду килү**

**ДУХАН** *и. гар.* Элек Кавказ яки Якын Көнчыгышта зур булмаган ресторан, хәрчәүнә. – *Минә шушы духанга кереп, тамак ялгап чыгасы иде. – Феликс күпер янындагы чәйханәгә күрсәтте.* М.Юныс

**ДУХИ** *и. рус сөйл.* Хуш исле матдәләрнең спирттагы эремәсе, ислемай, хушбуй (парфюмерия чарасы буларак кулланыла). *Чөнки «Дәфтәр» язы-ла башлаган елларны «мещан» сүзе*

*бик модада иде: танец – мещанлык, духи – мещанлык, чәчәкләр – мещанлык, галстук – мещанлык... күп нәрсәне мещанлык дип «аңлаучылар» бар иде.* Г.Кутуй. *Шулай ук мине [мәтрүшкәне], чәй, сабын, духи һәм одеколон эше әйберләр ясаганда да, бик теләп кулланалар.* Ш.Фәрхетдин

**ДУХО́ВКА** *и. рус* Кайнар һава белән азык пешерү, җылыту өчен хезмәт итә торган тимер тартма (гадәттә, плитәгә кертеп эшләнә, аерым да эшләнергә мөмкин). *Духовкага өчпочмаклар тыгылды.* Ф.Яруллин. *Ирек, кереп, өстәлләрне җыештырды, духовканы сүндерде, алган көмешкәне мунча алдына яшереп куйды.* Ф.Садриев

**ДУЧАР** *с. фар.* Нииндидер бер хәлгә төшкән, юлыккан. *«Өйләрендәге альбом эчендә яткан әрем исен хәтерләтә ләса бу хуш ис! Шуңа күрә дә ул күңелне иркәли, бәхетсезлеккә, кимсетелүгә дучар җанга да рәхәтлек бирә...».* Г.Гыйльманов

**ДУЧА́Р БУЛУ** *ф.* Нинди дә булса халәткә, авыр хәлгә юлыгу, тару, туры килү. *Арсланбайның сөргенгә дучар булуын хаксыз күрәбез.* Г.Ибраһимов

**ДУЧА́Р ИТҮ** *ф.* Нииндидер бер хәлгә юлыктыру. *Гомер бик еш дучар итә Япа-ялгыз калырга.* Р.Вәлиев

**ДУ-ЧАТ** *иярт.* Ыгы-зыгылы, тәртипсез хәрәкәтләнү рәвешен белдерә. *Бүген бөтен колхоз ирләре ат абзарлары янында ду-чат килделәр.* М.Мәһдиев

**ДУЧМАК** *и.* Түгәрәкләп җәйгән юка камыр өстенә изгән бәрәңге, сөткә кушып туглаган йомырка, эремчек һ.б.ш. нәрсәләр ягып пешерелгән ашамлык, камыр ашы. *Әнисе дучмак пешерергә җыена, ахрысы, камыр җәюеннән туктап, куна тактасыннан он сыпырып төшерде.* Р.Мөхәммәдиев. *Дучмакны майлы табага яисә калайга тезеп, өстенә сөттә туглаган йомырка салалар да шунда ук мичкә тыгалар. Әзер дучмакны, майлап, табынга чыгаралар.* Татар халык ашлары

**ДУШ** *и. фр.* 1) Тәнгә су сиптереп коена торган җайланма. --- *ул [Аля], кабарынкы юеш чәчләрен чачаклы зур сөлге белән сөртә-сөртә, залга чыкты. – Бар, душ астында юын, – диде.* Р.Кәрами

2) Шундый җайланмасы булган бүлмә. *Кайберәүләр исә спортзал, компьютер бүлмәсе, душ кабиналары белән дә горурлана ала.* Ватаным Татарстан. *Ике бәдрәф һәм ике душ, өч йокы бүлмәсе, бөтен җиһазлары булган ике катлы йорт бу.* Безнең гәҗит

3) Шундый җайланмасы булган бүлмәдә юыну, чистарыну, гомуми гигиена, яисә коенып алу процедурасы. *Кайнар душтан соң полковник хушбуйларын тәненә мул итеп сөртеп тә алгач, ул ашханәгә килеп керде ---.* Р.Мирхәйдәров. *Салкын душ бераз баш чатнавын баса, дип ишеткәне бар иде аның, шуңа күрә юынып чыгарга булды. Душтан соң тамагы да ачкан кебек тоелды.* Безнең гәҗит

4) Тәнгә су сиптереп дәвалый торган гигиена һәм су дәвасы процедурасы

**ДУЫЛДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **дуылдау.** *Көз... Ишетәсеңме, көнне ничек дуылдата?* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Нинди дә булса эш-шөгыльне бик җитез, җәһәт, өлгер башкару

**Дуылдатып кую** Тиз арада дуылдатып әзер итү

**ДУЫЛДА́У** *ф.* 1) «Ду-у» сыманрак калын тавыш чыгарып, бик нык гүләү

2) Шундый калын тавыш тәэсирендә яңгырап, шаулап тору

3) Бик каты шаулау, көчле тавыш чыгару (табигать көчләре турында)

4) *күч.* Нииндидер эш-хәрәкәтне шаушу килеп, җанланып үтәү, башкару. *Ничек тиз кергән булса, дуылдап, шулай чыгып та китәр иде. Аннан соң тынлык урнаша...* Безнең гәҗит

5) *сөйл.* Ачуланып, ризасызлык белдереп дулау, холыксызлану, талашып-сугышып бетү

**Дуылдап йөрү** Әле, хәзерге вакытта дуылдау. *Кошлар әйткәннәр: – Алай син канатлы да, кош та булгач, ни өчен, хайваннар җиңгәндә: «Без җиңдек», – дип, алар арасында дуылдап йөрдең соң?* Риваять

**ДУЫЛДЫК** *с.* Дуылдый (*3 мәгъ.*) торган; кызу канлы, холыксыз (кеше турында)

**ДУЭЛЬ** *и. фр. кит.* Алдан билгеләнгән шарт буенча ике кеше (рәнҗетүче белән рәнҗетүче) арасында үткәрелгән коралы атыш. *[Фәрит:] Ә ул... сине алдап качкан адәм актыгын... дуэльгә чакырыр идем.* Ә.Дусайлы

2) *күч. кит.* Ике каршы, дошман якның көрәше. *Өзлексез артиллерия дуэле дәвам итә, пулемётлар шатырдый, мылтык тавышлары яңгырый*

**ДУЭЛЬЧЕ** *и.* Дуэльдә катнашучы

**ДУЭТ** *и. ит. махс.* 1) Ике башкаручыдан (җырчы яки музыкант) торган ансамбль. *Фәридә-Алсу дуэты*

2) Һәрберсенең мөстәкыйль башкару партиясе булган ике уен коралы яки ике тавыш өчен язылган музыкаль әсәр. *[З.Сафиуллин:] Узган ел да мин Илназның концертларында катнаштым. Аның өчен «Әби чәче» дигән җырга дуэт яздырдык, ул тамашачыга ошады булса кирәк.* Акчарлак

3) *күч.* Гомумән ике кешедән торган төркем. *Әлеге дуэт тоткарлану белән, оператив хезмәт вәкиле, аларның дәүләт оешмаларындагы вазифаи затлар белән бәйләнешләре ачыкланмады, дигән белдерү ясады.* Безнең гәҗит

**ДҮДӘК** *и. зоол.* 1) Торна кошлар семьялыгыннан, зур гәүдәле, озын муенлы, тиз йөгерә торган дала кошы; *русчасы*: **дрофа**. *Очарга сәләтле хәзерге кошларның иң авыры – дүдәк. Аның авырлыгы 20 кг чамасы.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

2) *күч.* Тол, ялгыз, гаиләсез кеше. *[Шәмсия:] Өйләнү өчен озак вакыт кирәкми, улым, һаман шулай тол дүдәк булып йөрмәссең бит.* Т.Гыйззәт. *Каравылчы Мифтахетдин, тол дүдәк булганга, төнлә генә түгел, көндез дә келәтләр янында урала.* А.Гыйләҗев

**ДҮЛӘНӘ** *и. бот.* Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, агач яки куак булып үсә торган чәнечкеле үсемлек; *русчасы*: **боярышник**. *Дүләнәдән дә авыз иттеләр. Хәтта гөлҗимеш белән баланны тәмләп карарга да онытмадылар.* Д.Бүләков. *Ә дүләнә – йөрәк чирләренә юлыккан яисә йоклый алмый интеккән кешеләр өчен менә дигән.* Ватаным Татарстан

**ДҮЛӘНӘ́ КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Ак күбәләкләр семьялыгыннан канатларында кара бизәк булган ак күбәләк; *русчасы:* **боярышница**. *Дүләнә күбәләгенең гусеницалары кайчакта җимеш агачларының яфракларын ашап бетерә.* Зоология

**ДҮМГӘК** *и.* 1) Җир өстендә калкып торган, кечкенә, әмма ныклы (гадәттә, тамырлары белән җиргә береккән) балчык, туфрак өеме. *Яшьләр, кулга-кул тотынып, җыр әйтешә башлагач, ул да түгәрәккә керде. Үзенә чират җиткәч, күңелендәге зарын җырга салды: «Җимнәр сиптем дүмгәккә, Яшел башлы үрдәккә...».* Ә.Дусайлы

2) *куч.* Калкып, кабарып торган урын. *Маңгаеның нәкъ уртасында тавык күкәеннән аз гына кечерәк бер дүмгәк үскән.* Г.Хәйри

**ДҮНӘН** *и. монг.* Дүрт яшьлек мал (гадәттә, ат турында). *Җитәкләргә тырыш дөньяи дүнәнне.* Дәрдемәнд. *Анда торып ул әйтте: – Әй Идегәй, Идегәй, Таяк тайга җиткерер, Тай дүнәнгә җиткерер, Дүнән атка җиткерер, Ат морадка җиткерер.* Дастан

**ДҮНӘ́Н БАЙТАЛ** *и.* Дүрт яшьлек бия

**ДҮНГӘЛ** *и. бот. к.* **дүңкәл**

**ДҮНЕГҮ** *ф. диал. сөйл.* Йоклау, тынып калу. *Юк, юк, ул дүнеккән (йоклаган иренә күрсәтә), сөйлә, зинһар, ни булды?* Җ.Вәлиди

**ДҮНҮ** *ф.* 1) *иск.* Бер төрдән икенче төргә күчү, бер нәрсәдән икенче нәрсәгә әйләнү, әверелү. *Я, карт атагызны менә Таптагыз җиргә салып сез, Көлгә дүнгәнгә кадәр!..* Һ.Такташ

2) Аумакайлану, әле бер якка, әле икенче якка күчү. *[Абдулла] Җае чыккан саен, ләкин үзләре икәүдән-икәү генә булганда, Янышның бөтен әшәкелекләрен чыраена бәреп әйтә, аны оялту, вәгазьләр белән тугры юлга дүндерергә ниятли.* Җ.Рәхимов

3) Билгеле бер фикерне, карашны үзгәртү, алардан баш тарту. *Әмма башына бер әйбер кереп утырдымы – аңардан дүндерү Нәгыймә өчен бик зур мәшәкать, азап була иде.* Г.Ибраһимов. *Картларны да иске нәзар һәм фикерләреннән дүндерергә тырышырга мәҗбүрият күр!* Ф.Әмирхан. *Ул фикердән инде дүндем*... М.Гали

4) Үз диненнән ваз кичеп, икенче дингә күчү. *Кайсылар күктән газап иңгән диләр, Чөнки хак диннән халык дүнгән диләр.* Ф.Бурнаш

5) Гомумән нәрсәдән дә булса баш тарту, ваз кичү. *Рухның музыкага ихтыяҗын, омтылуын нәрсә дә бетерергә мөмкин түгел, --- аңардан аны нинди куәт тә дүндерә алмый.* Ш.Әхмәдиев

6) *диал.* Ачык йөз күрсәтмәү, нинди дә булса сәбәпләр (ачу, үпкәләү һ.б.ш.) аркасында, караңгы чырайлы булу. *Хосусан, ул миңа һәм дә сеңелләремә --- күбесенчә йөз бирми, дүнеп тора иде.* Ш.Камал

**Дүнеп бетү** Тәмам, тулысынча дүнү. *Җир йөзендә без түмгәкме, Әллә зәгыйфь бер имгәкме? Дүнеп беткән әтрәк-әләм, Иләс-миләс җилбәзәкме?* Ә.Хәсәнов

**Дүнә язу** Аздан гына дүнми калу. *[Хаҗия Гыйлемдарга:] Зәңгәр мәчет мәдрәсәсенә бирдем – карт марҗа итәгенә тагылып, әлгаязы билләһи, диненнән дүнә яздың...* Т.Гыйззәт

**ДҮҢГӘЛӘК** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан, далада, чүлдә үсә торган куак яки үләнчел үсемлек; өермә үләне; йомарлак; *русчасы*: **перекати поле.** *Күз алдында төрле төстәге дүңгәләкләр зырлап әйләнә, үзе һаман ниндидер упкын төбенә очып төшүен дәвам итә сыман.* Н.Мусин. *--- әкайберләрен [дүңгәләкләрне] җил, куптарып алып, зур шар рәвешендә --- тәгәрәтеп йөртә.* Физик география

**ДҮҢКӘЛ** *и. төрки бот.* Роза чәчәклеләр семьялыгыннан, куе яшел яфраклы, кара җимешле, суыкка чыдам, күп итеп баллы чәчәк ата торган декоратив агач яки куак; ырга; *русчасы:* **ирга**

**ДҮРТ** *сан* **1.** Өч һәм биш арасында килеп, 4 санын, микъдарын белдергән сүз. *Закир, моннан дүрт ел әүвәл мәдрәсә тәмам итеп, шул заманнан бирле Казанда аттестат зрелостенә әзерләнеп ята иде.* Ф.Әмирхан. *Шуны ике татар, бер чуваш, бер рус – барлыгы дүрт авыл җыелып барганнар да үзара бүлешкәннәр.* Г.Ибраһимов. – *Ул җирне күтәрү өчен дүрт ат җигәргә кирәк иде шул, Ибрай абзасы, – диде берәү, «юкны кайгыртасың» дигән төсле, сузып, өметсезләнеп әйтте.* М.Әмир

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **дүртле 2** (*1 мәгъ.*). *Дүрткә берне кушсак, биш була бит.* А.Алиш. *Дүрт белән өч арасында әз генә, нәни генә тыныш була.* Г.Ибраһимов. *Мөселман кешегә дүрткә хәтле өйләнергә китап куша ич.* Ш.Камал

2) *к.* **дүртле 2** (*2 мәгъ.*). *[Солтан:] Арифметикадан – 4, тарихтан – 5, әдәби укудан – 5. О, әдәби укудан синең [Зөмәрәнең] гел «биш» икән.* А.Әхмәт. *Аның дәфтәрләрендә генә түгел, класс журналында, хәтта табелендә дә бары «дүрт»ләр белән «биш»ләр генә.* А.Шамов

3) Дүрт санын эченә алган күләм, авырлык, ераклык, вакыт арасын белдерә. *Бездә Җиде яшьтән алып җитмешкәчә Картлар, яшьләр, нәни балалар Тик бер теләк белән яналар: Авырлыкка-нигә карамастан, Бишьеллыкны дүрттә үтәргә!* Һ.Такташ

4) Сәгать, вакыт. *Сәгать дүрт тулу сәбәпле, шәкертләргә таралырга да вакыт җиткән иде.* Ф.Әмирхан. *Эш биредә таң белән башлана, беренче савуны дүрт белән биш арасында ук үткәрәләр.* Ә.Еники

◊ **Дүрт аяклы мал** Гомумән малтуар, җәнлек турында. *Дүрт аяклы малдан тагынниләр бар соң синең?* Г.Бәширов. **Дүрт аяклы хайван** *к.* **дүрт аяклы мал**. *«Кеше көлкесе итеп калдырма, канатым, бакчы, дүрт аяклы хайван да сөртенә, бәхил бул, килешик!» – ди.* Г.Бәширов. *Инде бүген общий җыенда, эшләрне тәртип илә караган өчен, арадан дүрт аяклы хайваннардан булса да, кошлардан булса да бер председатель сайлагыз.* Ш.Мануур. *Чөнки дүрт аяклы хайваннар безгә, карыннары ач булмаганда, зарар тидермиләр, ә бу ике аяклы җанварлар, бирән кебек, итебезне ашап, каныбызны эчеп, корсакларын тутыргач, курнос борынлы мәхәббәтсез хатыннарына модный шляпалар кидермәк өчен, саескан вә гайре гөнаһсыз кошларны үтереп, тиреләрен тунайлар, канатларын йолкалар.* Ш.Мөхәммәдев.

**Дүрт күз белән көтү** Кемне, нәрсәне дә булса бик зарыгып, бик тилмереп көтү. *Менә инде тагы җәйгә чыккач, кайгы өстенә кайгы, дүрт күз белән көтеп алган игеннәр бик начар булдылар.* М.Гафури. *Хәзер инде дүрт күз белән Әхмәди абзыйның кайтып җиткәнен көтәләр.* М.Гали. *Дүрт күз белән көтеп торган иптәшләренә күзәтүенең нәтиҗәсен хәбәр итте.* Г.Гобәй. **Дүрт стена эчендә (арасында) яту** Өй, гаилә эчендә генә яшәү, җәмәгать хәлләренә битараф, алардан читләшкән булу. *Картайган көнемдә, шәһәргә килеп, дүрт стена арасында ятмас идем, бәхетем булса.* М.Кәбиров. **Дүрт ягың кыйбла** «Ихтыярың, теләсәң кая барырга мөмкин, бәйле түгел, теләсә кая китә аласың» мәгънәсендә. *Җитмәсә тагы Зыя, мәдрәсәдән чыккан да --- дүрт ягым кыйбла дип, әллә кайларга йөри тора, кучә тора, адресы алмашына тора, кайбер хатлар югалып та кала.* Г.Ибраһимов. *Һәм, аңа илтифатсыз, үз эшендә дәвам итеп, көлкеле тәгъбиргә, дүрт ягын кыйбла ясап йөри бирде.* Г.Ибраһимов. **Дүрт ягы сигез кыйбла** *к.* **дүрт ягың кыйбла**. *Аңар монда эш тыгызрак терәлдеме – дүрт ягы сигез кыйбла.* Ш.Камал

**ДҮРТАЯК** *и. диал.* Пычкы белән утын кисү өчен дүрт аяклы борыс, җайланма; кәҗә

**ДҮРТАЯКЛАНУ** *ф.* 1) Дүрт аягына да бердән басу (хайваннар турында). *Ат дүртаякланып чабып китәргә әзер кебек*

2) Иелү яки чүгәләү, кулларына таянып һәм аякларына басып мүкәләү. *Тавышка йөгереп килгән Әхмәт балалары, Миңлесылуны дүртаякланган килеш күргәч, көлеп җибәрделәр дә: «Бу да берәр хәл, инсафтан килгән, шәригать кушуы буенча эшләнә торган эштер инде», – дип уйладылар.* Ф.Әмирхан. *Барыбер, барыбер яз килер, һәм сез тагын да алма, кыяр бакчаларына дүртаякланып кунакка йөрерсез!* Һ.Такташ. *Бу забойга тар гына бер тишектән керәсе икән. Дүртаякланып, үрмәләп керделәр.* И.Гази

**ДҮРТАЯКЛА́У** *ф.* 1) Куллар һәм аяклар ярдәмендә хәрәкәтләнү, мүкәләү. *Һай, «гомер» дигәнең, җил шикелле исеп кенә тора, әле кайчан гына дүртаяклап, мүкәләп йөргән бала иде, ә бүген 13 яшь тула үзенә.* А.Әхмәт. *Дүртаяклап башта чыгып бастым Йорт алдына үскән чирәмгә.* Ш.Маннур

2) *куч.* Кемнең дә булса бик нык, хәтта аягында басып тора алмас дәрәҗәдә исерек булуы турында

**ДҮРТӘР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) дүрт, бертигез күләмдә дүрт булуны белдергән бүлем саны. *Һәр кызга дүртәр мөгез бүләк итеп алып барабыз, ди.* М.Фәйзи. *Сәләхиев Әхмәдетдин белән Фёдор Кузьмич Ивановларның җинаятьләрен 109, 13, 118, 117 нче маддәләр буенча карап, боларга бишәр ел ябылу өстенә, дүртәр ел хокуктан мәхрүм ителүне тәкъдим кылды.* Г.Ибраһимов. *Пахомов ротаны, тыгызлап, дүртәр кешедән тезде дә, өзеп-өзеп кенә бер-ике сүз әйтте.* Г.Бәширов

**ДҮРТӘРЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Сафка тезгәндә һ.б.ш. шундый эшләрдә дүртәрләп төркемләү, дүртәрле берәмлекләп аеру, бүлү

**2. дүртәрләп** *рәв. мәгъ.* Дүртәр-дүртәр итеп. *Шахтага төшә торган эшчеләр дүртәрләп, бишәрләп клеткада шахтага төшәләр.* Ш.Камал. *Анда аларны, вагоннардан төшереп, дүртәрләп тезделәр дә, бер зур елга буена алып килеп, брезент чатырларга унарлап бүлеп тутырдылар.* З.Зәйнуллин. *Ансат юлны сайласак Һәм дүртәрләп санасак, Бер хат артып калачак.* Р.Нуруллин

**ДҮРТӘРЛЕ** *с.* Һәр төркемендә, һәр буынында, һәр рәтендә дүртәр берәмлек булган. *Дүртәрле чикләвек кәшәңкәсе*

**ДҮРТӘҮ** *сан* **1.** Барысы, бөтенесе бергә дүрт булуны белдергән җыю саны. *Кулым – дүртәү, аягым алтау түгел шул, берегезгә дә иңәлмәс идем!* М.Кәрим

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Дүртәү бергә, дүртәүләшеп. *Алар дүртәү генә калды.* Ватаным Татарстан

**ДҮРТӘҮЛӘП** *рәв.* Дүртәү бергә, дүртәү булып. *[Егетләр] Дүртәүләп пароходка утырды ---, Пермьга таба кузгалдылар.* Л.Гыйльми. *Пристав, бер жандарм, ике пүнәтәй – шулай дүртәүләп керделәр, аннан-моннан, өстән-өстән генә тентеделәр дә, егеткә апасыннан килгән ике татарча хат белән татар социал-демократлары басмасыннан берничә китапны алып чыгып киттеләр.* Г.Ибраһимов. *Әти кайткач, без анда дүртәүләп барабыз да бер казан өйрә алып кайтабыз.* Ә.Фәйзи

**ДҮРТӘҮЛӘШЕП** *рәв. к.* **дүртәүләп**. *Кич булгачдин, үзе тагы эчеп кайта, Аузы-борны сасып, өст-баш тынчып кайта; Бик зур хаҗи кайткан имеш: әйдә, җөгер Дүртәүләшеп, дүрт эт төсле, дөбер! дөбер!* Г.Тукай. *Шулай дүртәүләшеп яшәп киттеләр.* Г.Гыйльманов

**ДҮРТБУЫН** *и. тех.* Бер-берсенә тоташкан дүрт детальдән торган техник җайланма; *русчасы*: **четырёхзвенник**

**ДҮРТЕНЧЕ** *сан* Бер-бер артлы санаганда, урыны өч белән биш арасында булуны белдергән тәртип саны. *Сәхип дүртенчегә яңа күчкән.* Ш.Камал. *Мин сезне менә дүртенче ай инде эзлим...* Ф.Әмирхан. *Өч көн гает – өч минут юк... Гомер – очкын! Өч көн – хәят, дүртенче көн дөнья үлгән...* Ш.Бабич

**ДҮРТКЕЛ** *с.* **1.** 1) Дүрт ягы бертигез, дүрт почмаклы фигура формасындагы. *Юл кырыенда нindiдер зур дүрткел ташлар аунап ята.* Г.Әпсәләмов. *Зурлыгы белән бусы [бүлмә] иске фатирдан әллә ни аерылмый, әмма тегесе озынчарак, бусы дүрткел иде.* Ә.Фәйзи. *Бәләкәй флигельнең тар гына өйалдын яктыртыр өчен, такта стенага кисеп ясалган дүрткел тишеге аркылы Садыйк байның бүрегә охшаган соргылт күзләре [ялтырый] ---.* Ш.Камал

**2.** *и. мәгъ.* Дүрт ягы бертигез геометрик фигура; квадрат яки куб формасындагы әйбер. *Стенасы мәчет дүрткелләре түбәсе кебек куе яшелгә буялып, тәрәзә араларындагы озынча ак дүрткелләренә кызгылт җирән төстә ярым ай билгесе ясалган бу вагон татар байлары исеменнән хәзерге военный министр Гулковка бүләк итеп тапшыру өчен эшләнгән иде.* К.Нәҗми

**ДҮРТКЕЛЛӘ́Ү** *ф.* 1) Дүрткел формасында итеп эшләү, дүрткел ясау; дүрткел формасын бирү, шул формага китерү. *Мәйданның сул ягында – дүрткелләп эшләнгән һәйкәл.* С.Шакир. *Менә кабер өстенә рәшәткәләрне дүрткелләп куйдылар.* Х.Камалов. *Авылны, дүрткелләп, кызылармеецлар урап алып ятканнар.* З.Зәйнуллин

2) *диал.* Кара-каршы дүрткә каплап, дүрт катлап бөкләү. *Бала искесен дүрткелләп төрү*

**ДҮРТКЕЛЛЕ** *с.* Дүрткел формасындагы. *Югары тәрәзәдәге теге дүрткелле хәтәр тишек тагы ачыла.* Чаян

**ДҮРТКУЛЛАП** *рәв.* Бик теләп, бик шатланып. *[Мөршидә:] Теге план барып чыга бит безнең. «Алга» колхозчылары белән дә, райком белән дә сөйләштем. Дүрткуллап каршы алдылар.* Р.Ишморат. *Егет тә сөя, кыз да сөя, без ике баштан, дүрткуллап риза.* М.Фәйзи

**ДҮРТКЫРЛЫК** *и. мат.* Дүрт кырдан торган геометрик җисем

**ДҮРТЛӘНҮ** *ф.* Дүрт тапкырга арту, дүрт булу

**ДҮРТЛӘП** I *сан* Чама белән дүрт, якынча дүрт булуны белдергән чама саны; дүрткә якын, өч яки биш арасындагы

**ДҮРТЛӘП** II *рәв.* Дүрттән, дүрткә аерып, дүрткә бүлеп. *[Сәхипҗамал:] Кара бөдрә чәчләремне Дүртләп үрәсем килә.* А.Әхмәт

**ДҮРТЛӘТӘ** *рәв.* Дүрт мәртәбәгә, дүрт тапкырга. *Даруханәдә өстәлгән хак – 30 процент тирәсе. Әнә шул процентларны кушкач, дүртләтә кыйммәт хак килеп чыга да инде.* Ватаным Татарстан

**ДҮРТЛӘТЕЛГӘН** *с. мат.* Дүрткә тапкырланган

**ДҮРТЛЕ** *с.* **1.** Үлчәме дүрт берәмлеккә тиң. *Дүртле күкрәкчә. Дүртле галош. Дүртле ачкыч*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Дүрт санын белдерә торган берәмлекнең исеме. *Дүртле урындыкка охшаган*

2) Биш баллы бәяләү системасында иң югары «бишле» билгесеннән түбәнрәк «яхшы» билгесен белдерә. *Сынау вакытында «бишле» алу – Өметгалигә зур бәйрәм. Өметгалинең «өчле»се башкаларның «дүртле»сеннән әйбәтрәк була.* М.Юныс. *Һәр баланың төрле билгесе: «Бишле», «дүртле», «өчле», «икеле», Төрле-төрледер киемнәре: Аллы-гөлле, яшел, зәңгәрле.* Н.Нәҗми

3) *сөйл.* Машина маркасы (ВАЗ-2104). *«Салон музей ачса, беренче «дүртле»-не музейга бирер идем», – ди машина хуҗасы Гөлчәчәк ханым.* Маяк

**ДҮРТЛЕК** *с.* **1.** 1) Дүрткә бүләрлек, дүрткә бүләргә җитәрлек

2) *к.* **дүртлелек**

**2.** *и. мәгъ.* Дүрт кешедән торган төркем. *Язмыштыр инде, беркөнне бу «дүртлек» урамда Ләйсәнне очрата.* Кәеф ничек?

**ДҮРТЛЕЛЕК** *с.* «Дүрт» куярлык, «дүртле» билгесенә бәяләнерлек. *Беренче имтиханга килдем. Әле дә хәтердә: рус теленнән диктант иде. Яздым. «Дүртле»лек булган.* Шәһри Казан

**ДҮРТПОЧМАК** *и. мат.* 1) Дүрт почмактан гыйбарәт булган геометрик фигура. *Әнә шул дүртпочмакны янә кечерәк дүртпочмак тотып тора – бинаның эчке өлеше бу.* М.Хәбибуллин. *--- мөһерләр --- эллипс, түгәрәк, төзек дүртпочмак, квадрат рәвешендә --- була.* Гасырлар авазы. *Аның өстенә «колак» формасында киселгән икенче дүртпочмак кисәген урнаштырырга кирәк.* Ватаным Татарстан

2) Кайсыбер якларда, эченә ит белән бәрәңге һ.б.ш. эчлек салып, дүрт почмак рәвешендә бөкләп пешерелә торган камыр ризыгы. *Аның каруы, өчпочмак урынына дүртпочмак пешерәләр (Түбән Новгород өлкәсендә).* Татарстан яшьләре

**ДҮРТПОЧМАКЛЫК** *и. мат.* *к.* **дүртпочмак**. *Нигездән дүртпочмаклык сигезпочмаклыкка күчә, пулатның өстен ярымсфералы гөмбәз бизи.* Казан утлары. *Дүртпочмаклык ул – галәм тамгасы.* Туганайлар

**ДҮРТЬЮЛЛЫК** *и.* Дүрт юллык, дүрт юлдан гыйбарәт булган шигырь. *[Мадам Пото турында] Шәһәр фольклорында шаян дүртьюллык кына сакланып калган ---.* Сөембикә

**ДҮШӘМБЕ** *и. фар.* Атнаның беренче көне. *Һәр атнаның дүшәмбесендә кайнап, шаулап торган зур базар.* Г.Ибраһимов. *30 нчы апрельдә, дүшәмбе көн, Оренбургта Народный домда икенче дәфга татарча театр уйналды.* Ш.Мөхәммәдев. *Менә, дүшәмбе көн эш ташларга әзерләнәбез, дисең ич.* Ш.Камал

**ДЫБЫРДА́У** *ф.* Дыбыр-дыбыр килү, дыбыр-дыбыр итү

**ДЫБЫР-ДЫБЫР** *иярт.* Идәнгә үкчә белән бәреп биегәндә чыккан тавышны белдерә

**ДЫК, ДЫК-ДЫК** *иярт.* **1.** Берәр авыр әйбернең нәрсәгә дә булса бәрелүе яки ике авыр әйбернең үзара бәрелешүе вакытында ишетелгән тонык тавышны белдерә. *Ишекне «дык» итеп ябып, егетләр чыгып киттеләр.* М.Мәһдиев. *Авыз ерырга да өлгермәдем, Зөбәрҗәт «дык» итеп аркама китереп бәрде ---.* Л.Ихсанова. *Менә кемдер дык-дык коридордан узды.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Шуңа охшаш тавышлар чыгарып. *Берничә дагалы итек дык-дык китеп барды.* И.Салахов. *Башын югары күтәргән Галәвиев, дык-дык басып, строй алдында бара.* Фән һәм тел

**ДЫКЫ-ДЫКЫ** *иярт.* Туку станында кул белән тукыганда чыккан тавышны белдерә. *Хатыннарыбыз, керфек йоммыйча, дыкы-дыкы палас суга, мәш килеп, мал үрчетә.* Р.Батулла

**ДЫКЫЛДА́У** *ф.* «Дык» авазларын хәтерләтеп шапылдау, шакылдау

**Дыкылдап алу** Берникадәр вакыт дыкылдау

**Дыкылдап тору** Бертуктаусыз дыкылдау

**Дыкылдый башлау** Дыкылдарга тотыну

**Дыкылдый төшү** Тагы да бераз дыкылдау

**ДЫЛЫК** *иярт.* **1.** Акрын гына дөбердәгән, тонык шапылдау тавышларын белдерә

**2.** *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дылык» сыман тавышлар чыгарып. *Бер минуттан аның [Әмирханның] мотоциклы, дылык-дылык, авылга таба элдерә иде инде.* Ф.Садриев. *Рамил кәкре башлы*

*тимер белән борчак сабакларын дылык-дылык тартты...* Ф.Садриев

**ДЫМ** *и.* Әйбер составында аз гына күләмдә булган юешлек. *Ә янган кирпечнең ныклыгы, матурлыгы, дымга бирешмәүчәнлеге хакында барыгыз да беләсез, иптәшләр.* Ф.Баттал

**ДЫ́М КАПЛАУ** *ф. махс.* Туфракта булган дымны саклап калу максатыннан, көздән сөрелгән җирне иртә язда өстән тырмалап чыгу. *«Яңа Сәфәр» авыл хуҗалыгы кооперативы игенчеләре кичәге көнгә 700 гектарда туңга сөрелгән җирләрдә һәм 300 гектарда күпьеллык үлән басуларында дым каплаган.* Авыл утлары

**ДЫМЛАНДЫРУ** *ф.* Дымга баету, дымлы итү. *Моңа туфракны кирәгеннән артык дымландыру да этәргеч булырга мөмкин.* Ватаным Татарстан. *Ә менә кышын бүлмәне дымландыру – әйбәт идея.* Ялкын

**ДЫМЛАНУ** *ф.* 1) Дым сеңү, юешләнү, дымлыга әйләнү. *Җирләр дымлана, – Бу кайчак була? (Көз көне).* Г.Тукай. *[Равил] Төшеп җиткәндәрәк, кызыл балчык өстендә дымланып яткан ташка сикергән иде, таеп китте дә арты белән балчыкка егылды һәм аска кадәр шуып төште.* Н.Әхмәдиев

2) Күзгә бераз яшь килү, яшьләнү. *Халисәнең күзләре дымланды.* Ф.Садриев. *Кәҗә бәтиен исән күрүдән икесенең дә күзләре дымланды, бугазлары тирәсендә нәни төерләр уйнап алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Дымлана бару** Дымлану акрынлап арту; торган саен ныграк дымлану. *Җир баскычның иңкүләнгән бусагалары аска төшкән саен дымлана, салкынлана бара.* Шәһри Казан

**Дымлана башлау** Дымланырга тотыну. *[Гөлүсә] Күз яшьләрен күпме генә тыярга тырышса да, күңеле мөлдерәмә тулган иде, ахры, дымлана башлап авырайган керфекләрен четчет йомгалап алды да кисәк кенә читкә борылды...* М.Хәсәнов

**Дымлана төшү** Бераз дымлану. *Тау башына менеп җиткәч, Нургали, башын артка ташлый биреп, дымлана төшкән күзләре белән авылы өстенә беравык карап торды.* Ә.Еники. *[Нурулланың] Үзенең дә күзләре дымлана төште, сулышы ешайды.* А.Фәләхов

**Дымланып алу** Озак булмаган вакытка гына дымлану. *Булачак артистларның уены да, педагоглары Хәлил абыйларының иҗаты да мине дулкынландырды, хәтта кайчак күз керфекләрем дымланып алды.* И.Юзеев

**Дымланып бетү** Тәмам, тулысынча, ахыргача дымлану. *Тәмәке тән тиреннән дымланып беткән икән, тирә-юньгә ачы төтен исе таралды.* В.Имамов

**Дымланып китү** Кинәт дымлану. --- *Сөембикә алдындагы бәрәңге тәкәсен этеп үк куйды, аның кәефе кырылган иде, күзләре дымланып китте.* Ф.Садриев. – *Рәхмәт, кирәк түгел иде, – дип мыгырданды ул [Ногман], дымланып киткән күзләрен яшереп.* И.Хәйруллин

**Дымланып тору** Дымланган хәлдә булу. *Күзләре зур, дымланып торган эре карлыган төсле [Фәниянең].* М.Хәсәнов. *Минһаҗетдин шундагы хатыннарның балык шикелле салкын, кайсысының яңа гына суелган, дымланып торган ит шикелле җылы, ләкин җансыз кулларын тотып чыкты.* К.Тинчурин

**Дымланып чыгу** Кинәт дымлану; дымланган хәлгә килү. *Карлыгачның да бөтен тәне ялтырап, дымланып чыкты.* Ф.Шәфигуллин

**ДЫМЛА́У** *ф. к.* **дымландыру**

**ДЫМЛЫ** *с.* 1) Дымланган, дым тарткан, дым сеңгән; юеш. *Алай дисәң, Ак бабайның сүзе дә ышандыра кебек – һава дымлы, бөркү, чык та мул төшә.* Г.Гыйльманов

2) Дым белән капланган (күз, тире һ.б.ш. турында). *Артык түзә алмады ул [Микәй], сасы нәрсәне кире төкереп, дымлы күзләрен яшерергә теләгәндәй, ирләр янынннан китеп барды.* Р.Мөхәммәдиев

**ДЫМЛЫЛЫК** *и.* Нәрсәдә дә булса дым булу күрсәткече, дым сеңү микъдары, дәрәҗәсе. *Казанда һаваның дымлылыгы уртача 83–86 процент тирәсе.* Шәһри Казан

**ДЫМСУ** I *с.* 1) Бераз гына, җиңелчә генә дымланган. *Ул --- ныгытып ябыштырылган тәрәзәне дә каерып ачты. Бүлмәгә дымсу саф һава ургылып керде...* А.Гыйләҗев. *Әрекмән, үги ана яфрагы каплаган инеш ярында гына була торган дымсу ис...* М.Галиев

2) *сир.* Яшьле, бераз яшьләнгән (күз турында)

**ДЫМСУ** II *ф. сир. к.* **дымсулану**

**ДЫМСУЛАНУ** *ф.* Аз гына, җиңелчә генә дымлану, бераз дымлыга әйләнү. *Әгәр сөйгән егете кайткан кызның күзләре дымсулана, хәтта яшькә тула икән – монысы инде шатлык яшьләре ләбаса!..* М.Хуҗин

**Дымсулана бару** Акрынлап, берникадәр күләмдә дымсулану

**Дымсулана башлау** Дымсуланырга керешү

**Дымсулана төшү** Бераз дымсулану

**Дымсуланып бетү** Тәмам, бик нык дымсулану

**Дымсуланып китү** Кинәт, берникадәр күләмдә дымсулану. *Һава ничектер җылынып, дымсуланып китте.* Ф.Шәфигуллин

**Дымсуланып кую** Берара, аз гына дымсулану

**Дымсуланып тору** Дымсуланган хәлдә булу. *Агыйдел аларны дымсуланып торган зәңгәр томаннары, ургылып аккан киң сулары белән каршылады.* В.Имамов. --- *стена буендагы ятакта юантык гәүдәле, иреннәре дымсуланып, бүселебрәк торганы Мәҗит исемле егет китап актаргалап ята иде.* Ф.Шәфигуллин

**ДЫМСЫЕМ** *и. физ. к.* **дымсыешлык**

**ДЫМСЫЕШ** *и. физ. к.* **дымсыешлык**

**ДЫМСЫЕШЛЫК** *и. физ.* Туфракның я башка берәр көпшәк әйбернең суны яки башка сыеклыкны кабул итә һәм үзендә тота алу үзлеге

**ДЫМСЫЙДЫРЫШ** *и. физ. к.* **дымсыешлык**

**ДЫ́М ТАРТУ** *ф. к.* **дымлану** (*1 мәгъ.*)

**ДЫМЫГУ** *ф. сир.* Дымсулану, аз гына дымлану. *Гасимә, ашкынып, көзге каршына килде. Туткыл алсу йөзе сизелерлек агарган, калын кара бөдрә чәч толымнары ике як иңбашына таралып*

*төшкәннәр, зураеп торган күзләре дымыгып, караеп калганнар ---.* М.Ибраһимов. *«Шомырткара», – дип дәшәргә җыенганда, күз төпләренең дымыгуын тоеп, тагы тыелырга мәҗбүр булды Микәй.* Р.Мөхәммәдиев

**Дымыга бару** Акрынлап, тагын да дымыгу

**Дымыга төшү** Бераз дымыгу

**Дымыгып бетү** Бөтенләй, тулысынча дымыгу

**Дымыгып кую** Кинәт кенә, көтмәгәндә-уйламаганда дымыгу

**ДЫМЫК** *с.* 1) Аз гына дымлы, дымы сизелер-сизелмәс кенә булган. *Дымык печән*

2) Тыныч, җилсез, дымлы (*һава, көн һ.б.ш.*). *Шул хакта колхоз идарәсе белән киңәш иткәннән соң, апрель башларында, дымык һавалы бер көндә, Сабир карт, Мәликәне үзе белән янәшә утыртып, зур шәһәргә юлга чыга.* Г.Галиев

**ДЫМЫКЛАНУ** *ф.* Аз гына дымлану, дымык булып китү, дымыкка әйләнү

**Дымыклана бару** Акрынлап, тагын да дымыклану

**Дымыклана башлау** Акрынлап дымыкланырга тотыну

**Дымыклана төшү** Бераз дымыклану

**Дымыкланып бетү** Тәмам дымыклану

**ДЫҢ, ДЫҢ-ДЫҢ** *иярт.* **1.** 1) Зур кыңгырауны какканда, авыр металл әйберләрне үзара бәргәндә, гомумән, авыр металл әйберләргә бәрелгәндә яки шундый әйберләр егылып төшкәндә чыккан түбән тондагы көчле тонык тавышны белдерә. *Аларның «дөп-дөп», «дың-дың» ритмнарыннан биш минуттан баш чатнарга тотына.* Безнең гәҗит

2) Бик каты, сулкылдап, баш авыртуны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шуңа охшаш тавышлар чыгарып. *Почмак яктагы мичкәнең бөкесен дың-дың китереп бәреп ачтылар.* М.Мәһдиев

2) Бик каты, сулкылдап (баш авырту турында)

**3.** *хәб. функ.* «Дың» сыман тавышлар чыгарган эш-хәрәкәтне, шулай ук бик каты, сулкылдап, баш авыртуны белдерә

**ДЫҢГЫЛДАВЫК** *с. к.* **дыңгырдавык**

**ДЫҢГЫЛДА́У** *ф.* «Дың» сыман тавышлар чыгарып, шундый авазларны хәтерләтеп, өзек-өзек яңгырау. --- *Кәримә шофёр егеткә учындагы акчасын төртте дә туктарга кушты. Үзе, кабинадан төшешли үк, өстә дыңгылдап килгән Зәкиягә кулын сузды.* К.Булатова. --- *таяк арасыннан, ягъни капкадан тәгәрәп үткән туң бәрәңге койма тактасына дыңгылдап бәрелде.* Н.Хәсәнов

**Дыңгылдап алу** Кыска вакытка гына, берникадәр дыңгылдау

**Дыңгылдап кую** Кинәт кенә, бер тапкыр дыңгылдау

**Дыңгылдап тору** Бертуктаусыз дыңгылдау

**Дыңгылдый башлау** Дыңгылдарга тотыну

**Дыңгылдый бирү** Дыңгылдавын дәвам итү

**Дыңгылдый төшү** Тагы да бераз дыңгылдау

**ДЫҢГЫР-ДЫҢГЫР** *иярт.* **1.** Дөбердәүле, калтыраулы тавышны белдерә. *Дыңгыр-дыңгыр, Шалтыр-шолтыр, Шыгыр-шыгыр, Шалт! Трамвай дус, кешеләрне Гел күп төяп чап!* Р.Вәлиев. *Тәгәрмәчләр тавышы дыңгыр-дыңгыр, Бәлки, кайсысы да яхшы кыздыр.* В.Ильясов

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Арбадагы мичкәләр дыңгыр-дыңгыр килә*

**ДЫҢГЫЛДЫК** *с. к.* **дыңгырдавык**

**ДЫҢГЫРДАВЫК** *с.* **1.** 1) Дыңгырдый торган, бик тавышлы. *Дыңгырдавык арба*

2) Дыңгырдата торган, сикәлтәле. *Дыңгырдавык авыл юллары*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Юлдагы, аяк астындагы каткан балчык түмгәкләр, вак кантарлар, шулардан торган тигезсез һәм каты җир. *Дыңгырдавыктан бару. Дыңгырдавыкны әйләнеп үтү*

2) Дыңгырдый яки дыңгырдата торган нәрсә. *Ходай сакласын, теге тимер дыңгырдавык колакка бәреп тормаса, без җырның эчке ритмын тоя алмаячакбыз!* Сәхнә

**ДЫҢГЫРДАВЫКЛЫ** *с.* Дыңгырдатып селкетә торган. *Аның артыннан автомобильдә дубильный цех бара, аннан, утырып, «анархист» Борис дыңгырдавыклы юлдан чаба.* А.Алиш

**ДЫҢГЫРДА́У** *ф.* 1) «Дыңгыр» сыман тавышлар чыгарып тору; дөбердәү катнаш дыңгылдау. *Мин инде рельска ятам дигәндә генә, соңгы чуен тәгәрмәч дыңгырдап тәгәрәп узды.* И.Салахов. *Чыгып китим дигәндә генә Адвокатның борыны төбендә генә, дыңгырдап, төрмә ишеге ябыла.* Р.Батулла. *«Ни өчен таң тишеге белән, дыңгырдап, аш бүлмәсендә буталанып йөрисең, сасыган татар!» – дип кычкырына башлады ул.* Р.Ахунова

2) Дыңгырдык, каты юлда (арбага һ.б.ш.) утырып барганда селкенү. *Тигез юлдан сикәлтәгә төшкән арба, дыңгырдап, эчләрне селкетә иде.* Ш.Галиев

**Дыңгырдап алу** Берникадәр вакыт дыңгырдау

**Дыңгырдап йөрү** Гел, шактый вакыт дыңгырдау. *Безнең өебездә – шәһәр белән ике арада дыңгырдап йөреп көйсезләнгән аклы-каралы гади телевизор.* М.Мәһдиев

**Дыңгырдап кую** Кинәт кенә, бер тапкыр дыңгырдау

**Дыңгырдый бирү** Бернигә карамастан дыңгырдауны дәвам итү

**Дыңгырдый төшү** Бераз дыңгырдау

**ДЫҢГЫРДЫК** *с.* **1.** 1) Дыңгырдый, «дыңгыр» авазлары чыгарып яңгырый торган. *Шул сәер, гайре табигый дыңгырдык тавышлар Гаслимәне тәрәзәгә якын ук китереп бастырды.* Җ.Юнысов

2) Дыңгырдатып селкетә торган. *[Профессор] Авыр фикер сөрешенең дыңгырдык арбасын чокырлы-ташлы хәйлә юлларыннан йөретте.* Ф.Яхин. *[И.Сираҗи:] Татарны санламауларына көенә-көенә, дыңгырдык юлларны каргый-каргый, Яңа Чишмәнең үзенә дә барып җиттем.* Акчарлак

**2.** *и. мәгъ.* Дыңгырдый яки дыңгырдата торган нәрсә (*2 мәгъ.*)

**ДЫҢГЫР-ДЫҢГЫР** *иярт.* Нәрсәдер яки нәрсәгәдер бәрелгән, суккан, төйгән вакытта яки транспорт йөргәндә һ.б чыккан тавышны белдерә. *Поезд белән ту-ут, ләхет-лохыт, пу-уф, туктук, ләхет-лохыт, ләхет-лохыт, пу-уф, чашш-пышш, чашш-пышш, аннары машина белән ти-ит, виу-виу, врң-ң, алпан-тилпән, дыңгыр-дыңгыр барып җиттек.* Р.Батулла. *Тәгәрмәчләр тавышы дыңгыр-дыңгыр ---.* В.Ильясов

**ДЫҢГЫРТ** *иярт.* Кинәт кенә дыңгырдауны, дыңгырдап куюны белдерә

**ДЫҢГЫЧЛА́У** *ф.* Бик каты басып, көчләп, төя-төя тыгызлау. *Халык клубка дыңгычлап тулды.* З.Хәким. *Тишеккә дыңгычлап тутырылган иске сырманы карчыклар ягына төртеп төшерү җиңел булмады.* Г.Гыйльманов

**Дыңгычлап бетерү** Тәмам дыңгычлау; дыңгычлауны тәмамлау

**Дыңгычлап карау** Дыңгычларга тырышу

**Дыңгычлап кую** Дыңгычланган хәлгә китерү. *[Хәмдия әби] Тишек-тошыкларны чүпрәк, кәгазь кебек чүп-чар белән дыңгычлап куйды да, ашны ис-кечә, керосинкада пешерә бирде.* И.Гази

**Дыңгычлап яту** Әле, хәзер дыңгычлау. *Бераздан, чемоданын шыплап тутырып бетергәч, ир күрә: моның хатыны да чемоданына киемнәрен дыңгычлап ята.* Л.Лерон

**Дыңгычлый башлау** Дыңгычларга керешү. *Капчыклары артыннан, «юан» дисәм, аз булыр, ике марҗа шаулашып керделәр дә өске сәндерәгә бу нигъмәтләрен дыңгычлый башладылар.* А.Хәмзин

**Дыңгычлый бирү** Бернигә карамастан, дыңгычлауны дәвам итү

**Дыңгычлый төшү** Тагы да бераз дыңгычлау

**ДЫҢ-ДЫҢ** *иярт.* Нәрсәдер бәрелгән, орынган тавышны белдерә. *Почмак яктагы мичкәнең бөкесен дың-дың китереп бәреп ачтылар.* М.Мәһдиев. *Җирдән аерылган тәгәрмәчләр, арбаны бер якка ычкындырып, кабинаны изә-изә, дың-дың бәрелеп һәм туп сымак сикерә-сикерә, үзәнгә таба очты, ахыр чиктә елга үзәнендә тынып калды.* Н.Хәсәнов

**ДЫҢК** *иярт.* Нәрсәнеңдер кисәктән каты итеп килеп (төшеп) бәрелгәндәге тавышны белдерә. *Агач чиләк төбенә суккандай тонык кына «дыңк» сымаграк аваз чыкты.* З.Зәйнуллин

**ДЫҢК-ДЫҢК** *иярт.* Йомшак әйбергә каты итеп суккан тавышны белдерә. *Тагы кемнәргәдер, дыңк-дыңк итеп, йодрык белән кундырганы да ишетелде.* М.Әмир

**ДЫҢК ИТҮ** *ф.* «Дыңк» сыман тавыш чыгару. *– Карау-ыыл! – дип кычкырырга да өлгермәде Бәкер, «дыңк» итеп, күкрәк авызына утырттылар моның.* Р.Батулла. *Аның олы йодрыгы, «дыңк» итеп, өстәлгә килеп төште.* Ф.Латыйфи. *Шулай морҗа артына ышыкланып, пүләмиттән сиптереп ятканда, «дыңк» итеп, нәрсәдер килеп бәрелде.* Аманулла

**ДЫҢЛА́У** *ф.* «Дың-дың» сыман авазлар чыгарып яңгырау

**Дыңлап алу** Берара (озак булмаган вакыт аралыгында) дыңлау

**Дыңлый төшү** Тагы да бераз дыңлау

**ДЫР-ДЫР** *иярт.* **1.** Нәрсәнең дә булса бик кызу бөтерелеп, әйләнеп яки калтырап, дерелдәп торуын яисә шул вакытта ишетелгән калтыраулы тавышны белдерә. *«Ә коляскадагы баланы, елаган саен, дыр-дыр селкетергә кирәк, шуңа күрә андыйлар нервный булып үсә», – дип, товарының файдасы турында да сөйләп алды Сәйдәр әфәнде.* Шәһри Казан

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып. *Вышка, станоклар дыр-дыр дырылдый.* Татар әдипләре

**-ДЫР** *кис.* **1.** 1) Үзе ялганып килә торган сүзләргә чамалау, фаразлау, икеләнү төсмере өсти. *Күрәсең, безнең язмышлар шулайдыр инде. Без соңгы сулышыбызга кадәр үз халкыбызга турылыклы булып калабыз...* А.Алиш

2) Сорау сүзләре кулланып яки сорау интонациясе белән ясалган контекстларда үзе ялганып килгән сүзгә билгесезлек төсмере өсти. *Кайсыдыр бер өйдә бер Сыерчык бар иде.* Г.Тукай. *Болгарларның кайсыдыр бер өлеше, коньякта – хәзәрләр арасында яшәгән чорда, бу яңа дин белән танышкан.* Р.Фәхретдинов

3) Сорау алмашлыкларыннан билгесезлек алмашлыклары ясауда кулланыла (*кайдадыр, кайчандыр* һ.б.ш.). *Кайчандыр бу урын Каргалган җир булган, Таш атып, ут чәчеп Тетрәгән, убылган.* И.Юзеев

4) Ант итеп сөйләгәндә, ант сүзен куәтләү өчен кулланыла. *Валлаһидыр менә! Шулчак бая гына юл аша бу якка чыгып җиткән аклы-каралы йонлач мәче, бик күптән күрешмәгән дусты кебек, тере бутафориянең янына ук килде ---.* Җ.Юнусов

5) Тиңдәш исемнәргә ялганып, «шуның кебек, шуның ише» дигән мәгънәне белдерә. *Өйгә кайтуга, тавык пешерде, әбисе белән вак бәлешләр ясады, пыяла банкаларга тозлы кыярдыр, кайнатмадыр кебек тәм-том тутырды ---.* Р.Мирхәйдәров

6) *сөйл.* Ниндидер көчле хис белдергән җөмләнең билгеле бер кисәгенә ялганып, берәр сыйфатын ассызыклап күрсәтә. *Мин аны шундый яратам. Ул шундый яхшыдыр, матурдыр...*

**2. дыр** *и. мәгъ., сөйл.* Нигезсез, дәлилсез мәгълүмат, хәбәр; имеш-мимеш. *Дырны чәчкәнгә – кырык ел, әле дә булса тишелеп чыкканы юк.* Әйтем

**ДЫРКЫЛДА́У** *ф.* 1) «Дырык» авазларын хәтерләтеп, шапылдау-шакылдау

2) Кантарлы, дыңгырдык-дыркылдык юлда арба һ.б.ш. нәрсәләр селкенү, тигезле-тигезсез хәрәкәт итү

**Дыркылдап алу** Берникадәр вакыт аралыгында дыркылдау. *Ниһаять, вагоннар дыркылдап алдылар да алга таба шуыша башладылар.* М.Маликова

**Дыркылдап бетерү** Дыркылдаудан туктау

**Дыркылдап йөрү** Әле, хәзерге вакытта дыркылдау. *Энең райком башлыгы булса, тракторда дыркылдап йөрмәс идең, янәсе.* Авыл утлары

**Дыркылдап кую** Кинәт, бер тапкыр дыркылдау

**Дыркылдап тору** Әледән-әле яки өзлексез дыркылдау

**Дыркылдый башлау** Дыркылдарга тотыну

**Дыркылдый төшү** Тагын да бераз дыркылдау

**ДЫРЛА́У** *ф. к.* **дырылдау**

**Дырлап кую** Кинәт дырлау

**ДЫРЫК-ДЫРЫК** *иярт.* **1.** 1) Дөбердәүле тонык шапылдау, шакылдау тавышларын белдерә

2) Сикергәләп бару рәвешен белдерә. *Гарип ат сыртында дырык-дырык азапланып, Тимофеевна ялыккандыр, ахрысы, икенче әйләнгәндә, ул аттан төшеп калды.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шундый тавыш чыгарып. *Озак та үтми, җигүле арба, урманнар аша чыгып, офыкка тәгәрәгән кояшка таба дырык-дырык бара иде инде.* Н.Хәсәнов

2) Калтыраулы сикергәләп, дыркылдап. *Дырык-дырык сикертә торган арбада янәшә утырып барганда, бай мәзин белән ярлы хәлфә бер үк уй белән мәшгуль булдылар.* М.Галәү

3) Эшсез чабышып, кирәксезгә йөгерешеп. *Ана күпме генә тырышса да, ирдәүкә кебек, дырык-дырык, урамда да, кырда да аның кызлары чапты.* Безнең гәҗит

**ДЫРЫЛДАВЫК** *с.* 1) «Дыр» сыман тавышлар чыгарып шаулыйкалтырый торган; дырлый, дырылдый торган

2) Дырылдата, селкетә торган; дөбердәүле калтырау барлыкка китерә торган

**ДЫРЫЛДАТУ** *ф.* Дырылдаган тавыш чыгару. *Шулай итеп, аю Әппәс имән чырасын дырылдатып көй чыгарган.* Р.Батулла

**ДЫРЫЛДА́У** *ф.* 1) Дыр-дыр итү, дыр-дыр килү. *Дыр-дыр, дыр имән, Ник дырылдый бу имән, Әллә бизгәк тотамы?* Табышмак

2) Дырылдавык, дыңгырдык яки сикәлтәле юлда арбага һ.б.ш. утырып барганда селкенү

**Дырылдап алу** Берара дырылдау. *Атым, ыргылып, аякларына басты, бөтен тәне белән дырылдап алды һәм күзләрен мөлдерәтеп миңа карады.* М.Ибраһимов

**Дырылдап кую** Кинәт, бер тапкыр дырылдау

**Дырылдап тору** Бертуктаусыз дырылдау; әле, хәзер дырылдау. *Бәхетемә, автобус кузгалып китмәгән, куе төтен чыгарып, дырылдап тора.* Татарстан яшьләре

**Дырылдый башлау** Дырылдарга керешү. *Мотоцикл, кабынып, дырылдый башлады.* Р.Могыйнов

**Дырылдый төшү** Тагы да бераз дырылдау

**ДЮ́ЖИНА** *и. фр.* Бер үк төсле, бер үк типтагы унике әйбер; унике данәгә тигез булган санау-хисаплау берәмлеге. *[Бер кеше (шкаф янына килеп):] Әфәнде, миңа бер ярты дюжина ак яка кирәк иде.* Г.Камал

**ДЮЙМ** *и. голл.* Озынлык үлчәү берәмлеге (2,54 см). *Татарстанда «Укытучы елында һәр укытучыга – ноутбук» программасын гамәлгә ашыру кысаларында бирелачәк портатив компьютерлар диагональ буенча 15 дюйм экранлы, Wi-Fi һәм Wi-Max модульләре белән тәэмин ителгән булачак.* Ватаным Татарстан

**ДЮ́ЙМЛЫ** *с.* Бер үлчәме (диагонале, диаметры, озынлыгы һ.б.ш.) билгеле дюймга тигез булган. *Ә эченә шәхси компьютер һәм 19 дюймлы экран урнаштырылган.* Сабантуй. *Шундыйларның берсе – Русиянең корал остасы Владимир Барановский 1872–1875 елларда эшләгән 2,5 дюймлы тиз атучы пушка.* Кызыл таң

**ДЮ́НА** *и. нем.* Җил өйгән һәм җилдә күченеп йөри торган ком таучыклары. *Сахарада бик күп мәйданнарны ташлы чүлләр алып тора. Алар урыны урыны белән дюналар һәм барханнар калкып торган, кызыл балчыклы һәм комлы чүлләр белән чиратлаша.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ДЮНАЛЫ** *с.* Дюналар булган; дюна белән бәйле, дюнага хас. *Унга якын техникага зыян салган һәм ике мотоциклчының гомерен өзгән комлы һәм дюналы трасса бетте.* Ватаным Татарстан

**ДЮРАЛЬ** *и. к.* **дюралюминий**

**ДЮРАЛЮМИ́НИЙ** *и. лат.* **1.** Алюминийның бакыр, магний һәм кремний белән катнаш, җиңел һәм бик ныклы эретмәсе

**2.** *с. мәгъ.* Шул эретмәдән җитештерелгән, шуңардан эшләнгән, ясалган. *Дюралюминий деталь*

**ДЬЯК** *и. гр.* 1) Борынгы Русьта: XIV гасырга кадәр сәркятип хезмәтен башкаручы. *Губерна канцеляриясенең әмерен үтәү йөзеннән, дьяк (бу очракта: канцеляриядә эшләүче, писарь) Андрей Михайлов шәһәрлекне барып карый – монастырьга бирелэсе җирдәниләр барын кәгазьгә терки.* Р.Фәхретдинов

2) XIV–XVII гасырларда дәүләт оешмаларында җаваплы урын тотучы кеше. *Воеводалык штатында пристав, рассыльщик, целовальниклар, дьяклар булган.* И.Тимершин

**ДЬЯ́КОН** *и. гр.* Православие чиркәвендә: иң түбән рухани дәрәҗәсе, чиркәү гыйбадәте вакытында руханиның ярдәмчесе. *Я.Емельяновны 1874 елда Казандагы Духовная академиягә укырга чакыртып алалар. Аннан ул «дьякон» исеме алып чыга.* Татар әдәбияты тарихы

**ДЬЯЧОК** *и. гр.* Православие чиркәвендә: руханилык дәрәҗәсе булмаган, иң түбән чиркәү вәкиле, чиркәү эшчесе; псаломчы. *Бу Толковый дигәнебез үзенең дьячок улы булуы һәм хәзерге яшәү рәвеше белән горурлана.* Ф.Галимуллин

# Е

**ЕВА́НГЕЛИЕ** *и. гр.* Христиан динендә Гайсә пәйгамбәрнең җирдәге тормышы, тәгълиматы, могҗизалары турында сөйләгән һәм 27 китаптан (хәбәрләр һәм хатлардан) торган Библиянең икенче өлеше; Инҗил (яһүдләрнең һәм христианнарның Изге китабы). *Ул үз өеннән берни алып чыкмады, фәкать Библия белән Евангелие китапларын гына калдырмады, кочагыннан төшермәде.* Ә.Гаффар

**ЕВАНГЕЛИСТ** *и. рус* 1) Христиан динендә Инҗилгә нигез салучылар: Маттай, Марк, Лүк, Яхъя

2) Шул динне тотучы, шул диннең тарафдары. *Аннан соң евангелистлар үзләренең вәгазь сүзләрен башлар.* Б.Рәхимова

**ЕВГЕ́НИК** *и. гр.* Евгеника фәне белән шөгыльләнүче кеше. *Фрау – моннан берничә ел элек вафат булган мәшһүр евгеник, профессор Фридрих фон Клейнның хатыны. Арийлар канының иң затлы кан булуын исбатлаган ире өчен, ул исемле пенсия алып яши.* А.Тимергалин

**ЕВГЕ́НИКА** *и. гр.* Кешенең нәселдән нәселгә күчеп барган авыруы, аларны кисәтү һәм чикләү мөмкинлекләре, шулай ук нәселдән килгән сәламәтлеген саклап калу һәм яхшырту проблемаларын өйрәнә торган фән атамасы. *Биологиядә – евгеника, биотехнология, клонлаштыру теорияләре калкып чыкты.* К.Гыйззәтов. *Евгениканың башлангыч принциплары.* Биология

**Е́ВНУХ** *и. гр.* Мөселман илләрендә хәрәм өендә хезмәт итүче һәм хатын-кызларга күзәтчелек итүче печтерелгән ир кеше; хәрәм агасы. *Тимер ишекләр, евнух сакчылар: җарияләрнең ятакларыннан ник бер тын чыгар?* М.Мирза

**ЕВРЕ́Й** *и. гр.* 1) б.э.к. I–II йөзләрдә Палестинада яшәгән халыктан килеп чыгып, соңыннан төрле илләргә таралган, ләкин уртак милли үзенчәлекләрен, өлешчә дин уртаклыкларын саклаган халык (нигездә, үзләре яшәгән илдәге төп халык телендә сөйләшәләр); яһүд. *Исегездә тотыгыз: большевиклар белән еврейларны яклаудан баш тартып, безнең якка чыккан һәрбер рус солдатын без шулай каршы алачакбыз.* Ә.Еники

2) Шул халыкның бер кешесе. *532 елда Хөсрәү Анушираван бик күп еврейларны күчереп утырта.* Г.Дәүләтшин

**ЕВРЕ́ЙЧА** *рәв.* Еврей (яһүд) телендә, яһүдчә. *Кечкенә генә өстәл янында утырган бөдрә чәчле, ялтыравык күзле бер кеше белән еврейча сөйләшеп тора иделәр.* Ш.Камал

**Е́ВРО** *и.* 2002 елның 1 январеннан кулланылышка кертелгән, Европа союзы зонасына караган илләрнең уртак рәсми акча берәмлеге (1 евро 100 евроцентка тигез). *Ул мәйданның 60 мең акры инде валютага (еврога, фунт-стерлингка) сатылган.* Мәдәни җомга

**ЕВРОВИ́ДЕНИЕ** *и. рус* 1) Европа илләренең телекомпанияләре арасында тапшыруларны даими рәвештә алыштырып тору белән шөгыльләнгән халыкара оешма

2) Шул халыкара оешма каналында алып барылган тапшырулар

**ЕВРОДО́ЛЛАР** *и. рус* Америка Кушма Штатларының Европа илләре банкларында һәм аерым затларда, төрле финанс максатларыннан чыгып, әйләнештә йөртелә торган доллары

**ЕВРОЗО́НА** *и. рус* Берләшкән Европа илләре турындагы килешү нигезендә барлыкка килгән Европа союзы зонасы

**ЕВРОКОМИ́ССИЯ** *и. рус* Көнбатыш Европа илләре вәкилләреннән төзелгән комиссия

**ЕВРО́ПА** *и. гр.* 1) Җир шарының Азия белән берлектә Евразия материгын хасил иткән бер өлеше; Аурупа (ул төньяк, көньяк, көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләргә аерыла). *Алга таба ул [Һун каганаты] Европа һәм Азиянең байтак кабиләләре һәм халыкларының катлаулы этник процессларында үз ролен уйный.* Т.Кәримов

2) Шул җирлектәге илләргә мөнәсәбәте булган берәр нәрсә. *Күпчелеге европа капиталы кул астында изелгән мөселман халкын азат итү турында сүз башлагач, ул үзенең дингә мөнәсәбәтен сиздерми кала алмады.* А.Расих

3) Грек мифологиясендә: Финикия патшасы кызы (Зевс, үгезгә әверелеп, аны җилкәсенә утыртып, Крит утравына йөзеп, урлап алып китә; анда аларның уллары Минос туа)

**ЕВРО́ПАЛАШТЫРУ** *ф.* Европа илләренең мәдәнияте, гадәтләре үрнәгендә үзгәртү. *[Камил әфәнде] «Кара урман»-ны җырлады һәм нindидер бер хәерле илһам белән аны бозмады, ватмады, европалаштырмады.* Ф.Әмирхан. *Мәгълүм булганча, XX йөз башында татар укучы яшьләренең мәктәп реформасы, уку-укыту процессын европалаштыру өчен, куәтле хәрәкәте җәелеп китә.* Р.Әмирхан. *Европача киенү, өй җиһазларын европалаштыру һ.б. шундый күренешләр килеп чыкты.* Мирас

**Европалаштыра бару** Акрынлап, аз-азлап европалаштыру

**ЕВРО́ПАЛАШУ** *ф.* Европа илләренең мәдәниятенә, гадәтләренә ияреп үзгәрү. *[Абыйзов] Ничек кенә европалашмасын, эше бөтенләй татар байларынча килеп чыккан.* Г.Ибраһимов

**Европалаша бару** Акрынлап, аз-азлап европалашу; европалашу процессы көннән-көн арту

**Европалаша төшү** Берникадәр, өлешчә европалашу

**Европалашып бару** *к.* **европалаша бару**. *Казан үзе дә тышкы кыяфәте белән, әгәр дә мәчетләрне исәпкә алмасак, европалашып бара шикелле.* Р.Миңнуллин

**Европалашып бетү** Тулысынча, тәмам европалашу

**Европалашып җитү** Нәкъ европадагычага әйләнү

**Европалашып китү** Кинәт кенә, ниндидер шартлардан соң европалашу

**ЕВРО́ПАЛЫ** *и.* **1**. 1) Европада яшәүче төп халык. *[Кремлев] Безнең көннән-көн европалылардан калыша баруыбызны сез бер дә күрмисезмени?* Р.Ишморат. *XVI гасырда европалылар уртача – 21 яшькә, XVIII гасырда – 26 га, XIX гасырда 34 кә кадәр генә яшәгәннәр.* Г.Тавлин

2) Европада туып үскән, яшәгән яки чыгышы белән шуннан булган кеше. *Галата – Истанбулның иң зур өлеше, европалылар яши торган район.* Ш.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Европада туып үскән, яшәгән яки чыгышы белән шуннан булган. *Ә европалы хатын-кыз, аз гына кояш күрендеме, тизрәк чишенү ягын, суга керү ягын карый.* М.Мәһдиев

**ЕВРО́ПАЛЫЛЫК** *и. сир.* Европа илләрендә кабул ителгән гадәтләргә (мәс., киенү, сөйләшү, үз-үзен тоту манерасына һ.б.) иярү күренеше; европалы сыйфатларына ия булу. *[Уфа шәһәренең] «Авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем --- европалылыгымны, шау-шу яратучанлыгымны --- үчекләгән кебек булды.* Г.Тукай

**ЕВРОПАРЛА́МЕНТ** *и. рус* Европа союзы илләре тарафыннан биш елга сайланган депутатлардан торган парламент. *Европарламентның пленар утырышлары Страсбург (Франция) һәм Брюссель (Бельгия) шәһәрләрендә үтә*

**ЕВРО́ПАЧА** *рәв.* Европа илләрендә кабул ителгәнчә, Европа илләрендәге кебек; европалыларга хас булганча. *Шәрәфетдин башыннан-аяк европача киемдә, Хөснулла иске суфи байларча киенгән.* М.Фәйзи. *Фатих абый минем күз алдымда европача фикер йөртә торган, киң диапазонлы интеллигент бер кеше булып калган.* З.Әмирханов. *Яңа йортларда включательләр европача урнаштырылган.* Ватаным Татарстан

**ЕВРО́ПАЧЫЛ** *с.* Европа илләренә, аның мәдәниятенә, халкына хас булган яки караган, шуны хуплаган. *Француз, инглиз яки немец әдәбияты кебек европачыл культурада ул рыцарьлык формасында чагылыш таба.* Ф.Бәшәр

**ЕВРОПЕИЗМ** *и. рус* Көнбатыш Европа илләренең тормышына, мәдәниятенә, гадәтләренә хас сыйфатлар җыелмасы

**ЕВРОПЕО́ИД** *и. гр. антроп.* Евразия расасы вәкиле: ак тәнле, йомшак туры яки дулкынлы чәчле, төз борынлы, юка иренле, яңак сөякләре калкып тормаган, дөньяда киң таралган төп расаларның берсе. *Сублапоноид тибы Көнчыгыш Европага безнең эраның башларында Себер кабиләләре үтеп кереп, аларның җирле европеоидлар белән кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән.* Р.Фәхретдинов. *Европеоидларның чәчләре дулкынланып та торырга, туры да, аксыл да, кара да булырга мөмкин.* Физик география

**ЕВРО́ПИЙ** *и. лат. хим.* Лантаноидларга караган көмешсыман көксел төстәге металл; химик элемент

**ЕВРОПОЦЕНТРИЗМ** *и. рус к.* **евроцентризм**. *Чөнки XIX гасыр уртасына кадәр Европада хакимлек иткән «европоцентризм» теориясе башка илләрне һәм халыкларны «тарихның дөрес үсү юлыннан читтә калганнар» дип күрсәтергә тырыша.* Ф.Сафин

**ЕВРОРЕМОНТ** *и. рус* Чит илләрдән кайтарылган төзелеш материалларын һәм аларның технологиясен кулланып, квартира, йортка яки оешма бүлмәләренә ясалган ремонт. *Бүген инде машиналарга, бигрәк тә иномаркаларга, кыйммәтле туннарга, евроремонтларга, коттеджларга мода китте.* Р.Миңнуллин. --- *һай-һай, кабинет сәләмә, евроремонт ясатырмын, ахры*. Н.Гыйматдинова

**ЕВРОСОЮЗ** *и. рус* «Берләшкән Европа илләре» турындагы килешү нигезендә, 27 илдән оешкан Европа союзы (алар гомуми базар, таможня, валюта, авыл хуҗалыгы, балык тоту һ.б. мәсьәләләрне бергә хәл итәләр). --- *без – Россиядә Евросоюз кафедрасы ачарга рөхсәт алган бердәнбер югары уку йорты*. Э.Шәрифуллина

**ЕВРОСТАНДАРТ** *и. рус* Сыйфаты, формасы, үлчәме һ.б.ш. билгеләре белән Көнбатыш Европада кабул ителгән стандарт. *Такы-токы, гарип юллар Бары Рәсәйдә генә. «Евростандарт»ка керәләр Бары тик җәйгә генә.* Л.Шәех

**ЕВРОЦЕНТ** *и. рус* Евроның йөздән бер өлешенә тигез акча берәмлеге

**ЕВРОЦЕНТРИЗМ** *и. рус* Барлык прогрессив яңалык беренче мәртәбә Европа цивилизациясендә барлыкка килгән һәм бары Европа дәүләтләренең үсеш юлы гына башка илләр өчен уңайлы дип белдергән тәгълимат. *Ничек кенә гаҗәп булмасын, урыс тарихы евроцентризм эталоннары буенча язылган.* Р.Хәкимов

**ЕВСТА́ХИЙ КӨПШӘСЕ** *и. анат. мед.* (Италия анатомы Б.Евстахио исеменнән) Кешедә һәм коры җир умырткалы хайваннарында, урта колактагы басымны тышкы тирәлекнең атмосфера басымына тигезләү өчен, урта колак куышлыгы белән йоткылыкны (йоткылык өстен) тоташтыручы канал; ишетү көпшәсе; *русчасы:* **евстахиева труба, слуховая труба**

**ЕГӘР** *и. фар.* 1) Физик көч, куәт; кешенең физик хәрәкәт ясауга бирелгән көче, гайрәт. *Бер дә кирәкмәскә суны буып куйдыгыз. Сезнең аркада безнең станциянең егәре китә башлады.* Ф.Хөсни. *Әйтерсең ул үзендә таулашларны актарырлык егәр тойган яшь егет түгел, ниндидер бер сыек бөҗәк, әкәм-төкәм.* Ф.Латыйфи. *[Карчык Нәҗипкә:] Сине танырлык егәре калган икән күземнең.* А.Гыйләҗев

2) Эшчәнлек көче, энергия. *Бирелә ул [А.Тәхәбиев] зур әдәбият мәйданына аяк баса, үзенең потенциаль егәрен, илһамланып, яңа эшкә җигә.* Р.Әмирхан. *Икенче яктан – кырыс мантыйк, математика төгәллеге, абстракт фикер егәре [бар].* Ф.Зөлкарнәй

3) Рухи көч, дәрт, күңел күтәренкелеге. *Бу әлеге яңа чор, кояшлы һәм нурлы апрель иртәседәй, йөрәкләргә бетмәс-төкәнмәс егәр һәм ышаныч биреп тора.* М.Хәсәнов. *Икмәк ул – ирнең дә, илнең дә егәре, дан-шөһрәте.* И.Низамов

4) Үз-үзен хис итү халәте; көч, хәл, дәрман. *Шәмсеруй апаның бер дә егәре*

*юк.* Я.Зәнкиев. *Өлфәт, бөтен егәрен җыеп, сорап карамакчы, шул сорауга нярең килгән җавап белән бу сәер, сихри дөньядан җир дөньясына --- хәятка кайтмакчы булды.* Г.Гыйльманов

**ЕГӘРЛӘНҮ** *ф.* Физик яктан ныгу, хәлләнү, көч керү. *Тамакка таза иде, хуҗалар да ашауны кысмады, малай елдан-ел егәрләнде, үсте, ныгыды, егет булып җитте.* Я.Зәнкиев. *Аннан соң алар, күмәкләшеп, юлларында очраган Сикертән, Казаклар, Му, әллә ничә Масра авылларында он тартып, тагы да ишәеп, егәрләнеп, Казансуга кушылалар.* Т.Мөбарәков

**Егәрләнә бару** Акрынлап, әзлекле рәвештә, көннән-көн ныграк егәрләнү, егәрлеге көннән-көн арту. *Тел хасияте тулы канлы яши; дулкынлана, кайный, карынында янар таулар дөрләтеп, яңа сүзләр хикмәте тудыра, үсә, ныгый, вакыт иярендә егәрләнә бара.* М.Галиев

**Егәрләнә төшү** Бераз, берникадәр егәрләнү. *Мин шактый егәрләнә төштем.* М.Шабай

**Егәрләнеп бетү** Тәмам егәрләнү, мөмкин булган кадәр, тулысынча егәрләнү

**Егәрләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә егәрләнү

**Егәрләнеп килү** Аз-азлап, акрынлап егәрләнү

**Егәрләнеп китү** Билгеле бер хәлдән, шартлардан соң егәрләнү. *Мин моңарчы авыруның, егәрләнеп китеп, аякка басуына ышана идем.* Ш.Маннур

**ЕГӘРЛЕ** *с.* 1) Эш-хәрәкәткә егәре булган; ныклы, көчле. *Фарукҗан хәлне тәмам чамалап алып: – Кайсыгызның аты егәрлерәк, җитезрәк – шуның артыннан икегез китегез! – дип боерды.* Т.Әйди. *Авыл артта калды, әлегә хәвеф-хәтәрсез бардылар, юл да берккөнгегә караганда шактый кипшегән, машина да егәрле иде.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Нык йогынты ясый торган, ышандыра торган, тәэсирле. *Хәер, егәрле вә төпле язмалары һәм дә кыюкискен кыланышлары белән укучыларны сискәндереп вә сөендереп яшәргә күнеккән яшьләр журналында әллә ни гаҗәп тоелмады ул.* Ф.Зөлкарнәй

**ЕГӘРЛЕК** *и.* 1) *физ. тех.* Вакыт берәмлеге эчендә башкарылган эш микъдары белән исәпләнә торган зурлык. --- *реактив двигательләр тавыш куптарып гөрелдәшә башлый. Бетон полосада старт алып, двигательләрне бар егәрлегенә эшләтергә куям.* Р.Ибраһимов. *Йөртүче ракетаның сыекчалы алты ракета двигателе, 500 тонналы гомуми тарту көче хасил итеп, очышта, тулаем алганда, 20 миллион ат көченә кадәр файдалы егәрлек бирә.* А.Романов

2) Хәллелек, физик көч, энергия. *Чәчләр дә агарды. Егәрлек тә кимеде.* Р.Ишморат. *Һәрбер хәрәкәтендә ныклы егәрлек сизелеп тора.* Р.Ишморат. *Каян хәл, егәрлек алган диген. Ай буе кузгалмыйча, кеше кулыннан эчеп-ашап яткан, сөяк-тактага калган бу шәүлә --- Мөсәллим каршында басып тора.* Г.Гыйльманов

3) Көч-куәт, дәрт, дәрман, хәл. *Әмәт туган иленең киңлегенә, --- урманнарның мәһабәтлегенә, елгаларның куәтенә, җилнең егәрлегенә, тауларның дәһшәтенә сокланып барды.* Т.Нәбиуллин. *Аның эчендә ниндидер бер егәрлек туа башлады. Шул егәрлек, заданиегә очкан саен, һаман үсә, ныгый бара иде.* М.Юныс

4) Нәрсәнең дә булса көче, нык тәэсир итү сәләте. *Шунысы мөһим: үзләренең поэтик сурәтләре һәм мәгънәви егәрлекләре ягыннан нәсерләр еш кына поэма-романнар белән чагыштырырлык әһәмияткә ия булалар.* Г.Гыйльманов

5) Файда бирү, җитештерү мөмкинлеге. *Авыр промышленность егәрлеге*

**ЕГӘРЛЕКЛЕ** *с.* Егәрлеге (*1 мәгъ.*) булган. *Шәхси гороскобында көчле якты йолдыз, әйтик Кояш, Таң йолдызы һ.б. булган очракта, ул кешеләр --- эш ягыннан егәрлекле, уңганнар, тәрбиялеләр.* С.Шәрипова. *Тикшеренүчеләр миллиметрлы диапазондагы түбән егәрлекле ясалма электромагнит нурланышларның биологик объектларга йогынтысын 1965 елдан ук тикшерә киләләр.* Фән һәм китап

**ЕГӘРЛЕЛЕК** *и.* Егәрле булу

**ЕГӘРСЕЗ** *с.* Көчсез, хәлсез, физик көче булмаган. *Ул [карт] егәрсез аяклары белән үз юлына таба атлады.* М.Мәһдиев

**ЕГӘРСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Көчсезләнү, хәлсезләнү

**Егәрсезләнә бару** Көннән-көн егәрсезләнү, егәре көннән-көн кимү

**Егәрсезләнә төшү** Бераз егәрсезләнү

**Егәрсезләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй егәрсезләнү

**Егәрсезләнеп китү** Кинәт егәрсезләнү

**ЕГӘРСЕЗЛЕК** *и.* Хәлсезлек, дәртсезлек; егәр, энергия булмау; оешмаганлык

**ЕГЕРМЕ** *сан* 20 санын, микъдарын һәм цифрын белдергән сан атамасы. *Локман карт, «әһ» тә димичә, рәхәтләнеп, үз җанын бирергә әзер иде, тик ул гына, Зәйтүнә генә, әле егермедән дә узмаган яшь ана – бичара гына китмәсен иде!* Ә.Еники

◊ **Егерме бер** Комарлы карта уеның бер төре; очко. *Бер карчык үзенең, карта уйнап, эштән чыгып беткән улына: «Их улым, улым, шул егерме бер харап итте инде сине», – ди икән.* М.Гали

**ЕГЕРМЕБИШЛЕК** *и. тар.* Егерме биш сумлык кәгазь акча. *– Ай-яй-яйяй! Егермебишлектән сдача алмады.* Р.Вәлиев. *[Уварова] Пычрак галошларын да салып тормыйча түргә узды да өстәлгә егермебишлек ыргытты.* Г.Ахунов. *Чырык-чырык килеп торган мунча кич соң гына бушый, шат авазлар тына, егермебишлекләр иплән кенә Григорьянның --- йөнтәс бармаклары арасына кереп югалалар.* А.Гыйләҗев

**ЕГЕРМЕБИШМЕҢЧЕ** *и. тар.* 1930 елда эре сәнәгать үзәкләреннән авылларга колхозлар оештыру өчен җибәрелгән 25 мең алдынгы эшченең берсе. *Минзәләгә китәр алдыннан, Разумов, үзе сыман егермебишмеңчеләрне өлкә комитетына чакырып, --- аяк чалучы корткыч-дошманнар турында сөйләгән иде.* Ф.Сафин. *Колхозлашу елларында әткәй – Сөләйманов Гаделша – егермебишмеңчеләр рәтеннән «Восток» артеле оештыручыларның берсе булган.* С.Сөләйманова

**ЕГЕРМЕГӘ́ЧӘ** *рәв. сир.* Егерме санына җиткереп, егермегә кадәр. *Мин укыттым... егермегәчә тәрбияләдем...* Г.Ибраһимов

**ЕГЕРМЕЛӘГӘН** *сан* Егерме тирәсе, чама белән егерме булуны белдергән чама саны. *Шушы дәвердә егермеләгән чыганак ачылды, 167 миллион тонна нефть алынды.* Яңарыш. *Бүгенге көндә республика перинаталь үзәгендә суррогат әниләр ярдәменнән файдаланырга теләгән егермеләгән гаилә пары исәптә тора.* Өмет

**ЕГЕРМЕЛӘП** *сан* Чама белән егерме, егермегә якын булуны белдергән чама саны. *Бар кешегә берьюлы гайрәт кертү мөмкин түгел шул, егермеләп авылдашым тәвәккәлләүгә дә шөкер итәргә кирәк хәзергә, дип уйлады ул.* Т.Әйди. *Аларны куып баручы болгарлар чигенүче чалбайлыларны бертуктаусыз укка алалар, алай да егермеләп чалбайлы капкага якынлашты.* М.Хәбибуллин. *Аның [өстәл] тирәсендә, кулларын догага кушырып, егермеләп карт утыра.* Г.Гыйльманов

**ЕГЕРМЕЛӘТӘ** *рәв.* Егерме тапкыр (*кимү, арту*)

**ЕГЕРМЕЛЕ** *с.* Бер төрле әйберләрнең яктылык, көч, куәт дәрәҗәсен, үлчәмен белдергән. *Түшәмнең кыл уртасында --- абажуры тутыккан егермеле керосин лампасы асылынып тора иде.* Ф.Хөсни

**ЕГЕРМЕНЧЕ** *сан* 1) Бериш нәрсәләрнең урнашу тәртибе егерме санына туры килүен белдергән тәртип саны. *Фарукҗан, үзе кизү торган егерменче октябрь төнен уйлап, күңелсез көрсенеп куйды.* Т.Әйди

2) Берәр нәрсәнең шул санга туры килгән үлчәмен, номерын белдерә. *Егерменче трамвай*

**ЕГЕРМЕШӘР** *сан* 1) Һәркайсына бертигез – егерме итеп бүленгән булуны белдергән бүлем саны. *Икесенә егермешәрдән --- телләренә йозак салып булырмы?* Ф.Латыйфи

2) Бербөтеннең һәрбер өлеше егермегә тигез булуын белдерә. *Ә инде егермешәр, егерме бишәр ел гади солдат газабын кичергәннәр – җитәрлек.* Л.Хәмидуллин

3) Беришле әйберләрнең үлчәм дәрәҗәсе шул санга (егермегә) туры килгәнне белдерә. *Бәхәскә китсә, [Фәйзелхак] алты метрга киселгән егермешәр сантиметр юанлыктагы бүрәнәләрне прицепка ялгызы төйи.* Ю.Әминов

**ЕГЕРМЕШӘРЛӘП** *рәв.* Һәрберсендә егерме-егерме итеп. *Китапларны егермешәрләп төрү*

**Е́ГЕРЬ** *и. нем.* 1) Сунарчылык белгече, профессиональ аучы. *Егерь үзенең кешеләре белән пошиларны ау урынына куып китерергә тиеш.* М.Галиев. *Аучы өенең хуҗасы – егерь Тисленко Виктор Петрович – үз хуҗалыгы, дөресрәге, тайга киңлекләре белән таныштырып йөрде.* Р.Фәйзуллин

2) Урман һәм аучылык хуҗалыгы эшчесе. *Ә каршысында... егерь Минһаҗның бозау кадәр овчаркасы басып тора.* М.Мәһдиев. *Белә бар җәнлекләрне ул. Белә бөтен кошны ул. Ул аларга зыян салмый, үзе алар дусты ул! Егор түгел, егерь ул!* Р.Фәйзуллин

3) Таныклык. *Махсус курслардан соң кулыма егерь тоттырдылар.* Р.Низамиев

4) *тар.* 1917 елга кадәр Россиядә һәм хәзерге кайбер армияләрдә (атлы яки җәяүле) махсус укчылар полкында хезмәт итүче солдат. *Кара кительле исерек егерьләр --- атака артыннан атакага күтәрелделәр.* Г.Әпсәләмов

**ЕГЕТ** *и.* 1) Яшүсмерлектән өлгергәнлек чорына күчкән, балигъ булган, буйга җиткән яшь ир кеше. *Тулган ай --- кыюсыз басып торган егет белән кызны яктыртты.* Ф.Латыйфи. *Башта әле мин сезгә шуны әйтергә тиеш: ул чагында әле мин дә сезнең шикелле ять-яшь егет идем.* А.Шамов

2) Өйләнмәгән, буйдак ир-ат. *Яшьтән сөйгән үз танышың егет башы белән шулай өзелеп тора икән, әйдә, кире какма, андыйлар хәзер бик исәпле.* Г.Бәширов

3) Гомумән төрле яшьтәге ир кеше. *Бөтен җирдә, бөтен дөньяда бары тик җыр, шушы җыр гына калды, ул әле генә боегып утырган егетләргә канат куйды, йөрәкләргә дәрт, кыюлык өстәде, аларны бөркет итеп күккә күтәрде.* Р.Вәлиев. *Карсак кына буйлы, киң җилкәле бу егетнең Гали Галиев исемле икәнен белми идем әле.* М.Әмир

4) **егете, егетем** *тарт. форм.* Яраткан кеше, сөйгән яр. *[Каимә] Тегеләргә, чебен кугандагы кебек, кулларын гына селеккәли: – Йә, йә, йөрмәгез юкка, егетем бар!* С.Хафизов

5) **егетем, егеткәем** *энд. сүз мәгъ. тарт. форм.* Яратып йөргән ир-егеткә ягымлы мөрәҗәгать сүзе яки гомумән ир кешегә карата әйтелгән иркәләү сүзе. *Күр ничек күкләрне, егетем, балкытадыр йөзләрең, Аh, мине тоткын итә, егетем, сихерле күзләрең.* Ф.Бурнаш. *Мин сиңа сокланам, аны табарыңа ышанам. Бәхетеңне китереп бирмәсләр, егеткәем.* Ф.Латыйфи. *Шул, егетем, теләгең булса, өйрән – әкренләп, барысын да төшендереп бирермен.* Г.Әпсәләмов

6) **егетләр** *энд. сүз мәгъ. күпл.* Берничә ир кешегә берьюлы мөрәҗәгать иткәндә, «иптәшләр, дуслар» мәгънәсендә кулланыла. *– Егетләр, карагыз әле, бу олы борын безнең өскә килә түгелме соң? – диде.* Ә.Еники. *Шул искә ябышып була бит, ә, егетләр?!* З.Фәтхетдинов

7) *күч.* Ир кешенең уңганлык, тәвәккәллек, кыюлык, батырлык, намуслылык сыйфатларына ия булуын белдерә (гадәттә, мактау сүзе буларак кулланыла). *Төпле егет икәнсең, энем, бәрәкалла, машалла.* Г.Ибраһимов. *Начальник Акбүзгә карап алды да, шаярып, бармак янады: – Ләкин, карагыз аны, авызыгызны ачып калмагыз! Анда да таш астыннан чыккан егетләр бар.* Г.Гобәй

◊ **Егет солтаны** Егетләр арасында абруйлы, үрнәк, дәрәҗәле булуы белән аерылып торган егет. *Аягыңдагы итегең – Болгар икән олтаны; Сине сөйми, кемне сөйим, Син бит – егет солтаны.* М.Фәйзи

**ЕГЕТ-ҖИЛӘН** *җый. и.* Яшь егетләр, яшүсмерләр. *Балам, син инде хәзер җиткән кыз булып киләсең. Һаман-һаман ут, корым арасында, егет-җилән, ир-ат тирәсендә йөрү килешмәс.* Ф.Латыйфи. *Башта мәчет янына бала-чага, аннары егет-җилән аяк басты.* Т.Әйди. *Ләкин [әнисе] караштырмаганда да, егет-җилән Газизгә әдәпсезлек күрсәтми иделәр.* Ш.Камал

**ЕГЕТ-ҖИЛКЕНЧӘК** *җый. и. к.* **егет-җилән**. *Егет-җилкенчәк булсын да, сөзешмичә, йон коймыйча гына йөрсен, ди, сиңа.* Э.Касыймов. *Заһит, чүмәлә тарттыручы малайларның мәйханә килүләрен күзәтеп, абайламыйча да калган, кыз-кыркын, егет-җилкенчәк кибән тирәсенә җыелган икән.* М.Әмирханов

**ЕГЕТЛӘНДЕРҮ** *ф. сир.* Батырлык, кыюлык һ.б.ш. сыйфатларны көчәйтү; көч-куәт бирү; егет (*7 мәгъ.*) итү. *Адәмне егетләндерә торган нәрсә – фәндер.* К.Насыйри

**Егетләндереп җибәрү** Бераз егетлек сыйфатларын арттырырга этәргеч бирү, кыюсызлыгын киметергә ярдәм итү

**ЕГЕТЛӘНҮ** *ф.* 1) Егет булу, егеткә әйләнү, ир заты яшүсмерлектән өлгергәнлек чорына күчү

2) Егет (*1 мәгъ.*) булып күренергә тырышу, егет кебек кылану. *Гайнан, кунак кыз алдында егетләнеп, чәчен биш бармаклап артка сыпырырга тотынды.* Г.Бәширов. – *Ун килога җиңеләйдем, картлык сәфәргә йөк алырга теләмидер! – дип егетләнә.* Ш.Галиев

3) *күч.* Кыюлану, батырчылык итү; тәвәккәлләү. *Ул, егетләнеп: – Мин аңладым, Камил абый! Урманны бу хәлгә төшерергә ярамый.* Г.Бәширов

4) *күч.* Егетлек (*2 мәгъ.*) күрсәтү; мактану, горурлану. *[Ишназар әкә:] «Революция» дип сайрап кына йөрмәсен, йөз пот ашлыгын чыгарып салып егетләнсен!* Т.Әйди

**Егетләнә бару** Торган саен ныграк егетләнү

**Егетләнә төшү** Аз гына, бераз егетләнү, кыюлыгы арту

**Егетләнеп алу** Кыска вакыт арасында егетләнү, бераз егетләнү; вакыты-вакыты белән егетлек күрсәтү

**Егетләнеп бетү** Тәмам егетләнү, егетлек сыйфатларын тулысынча алу

**Егетләнеп йөрү** Күптәннән, озак вакытлардан бирле егетлек күрсәтү. *Мәрвәр тирәсендә яратучы булып, ягъни «яратам» дип, үзен ышандырырга тырышып, башта бик бөтерелеп, егетләнеп йөрде.* Ә.Еники

**Егетләнеп китү** Нindidер бер этәргечтән, сәбәптән соң егетлек сыйфатлары арту, кинәт егетләнү. *[Баграт:] Тукта, карыйм әле, пират тормышы нишләтте икән сине? Төс кергән, егетләнеп киткәнсең.* М.Юныс. *Карт алашага өйрәнгән гадәт буенча, егетләнеп китеп, тезгенне тарткаларга, аякларым белән атның корсагын төяргә керештем.* З.Хөснияр

**ЕГЕТЛӘР-КЫЗЛАР** *җый. и.* Егетләр һәм кызлар, яшьләр. *Төнге утрау егетләр-кызларның күңелле тавышларыннан гөрләп тора иде.* Н.Хәсәнов

**ЕГЕТЛӘ́РЧӘ** *рәв.* 1) Егетләргә хас булганча, яшь ир-атлар кебек (кешенең йөрешенә, үз-үзен тотышына һ.б. карата әйтелә). *Кави Салихович – егетләрчә какча гәүдәле, төз буйлы, ябык яңаклы ир.* Ә.Баянов. *[Әминә] Кубесенчә костюм-чалбар, водолазка кия, чәчләрен егетләрчә кыска итеп йөртә.* Ф.Садриев. *Корычбай, аңа сырышып, нидер әйтә, гәүдәсен егетләрчә тотып, кулын бутый-бутый сөйләшеп тора.* Г.Ибраһимов

2) Егет (*1 мәгъ.*) булып, шуларга охшарга тырышып (*егет яшенә туры килмәгән кешеләр*). *[Равил] Өйләренә барып керә һәм, егетләрчә кыю гына итеп: «Гафу итегез, Басыйрова Рухия шушында яшиме?» – дип сорый.* В.Нуруллин. *Уртадагы озын торыклы җирән кашкага атланып, бик егетләрчә, бик эре кыяфәттә чыгып китүләре --- күңел күген сихри бер яктылык белән бизи торган күренешләр иде.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Егетләр шикелле, батырларча, кыю. *Күзгә карап әйт шуны, егетләрчә дөресен әйт. Ялганламый гына...* Р.Мөхәммәдиев

**ЕГЕТЛЕК** *и.* 1) Яшь ир-егет булу чоры, егет чак. *Егетлек кадерен картлар белер.* Мәкаль. *Үскән бит, каһәр, егет булган бит! Аз дигәндә, егетлек юлына кереп бара бит.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Берәр эшне икеләнүсез башкарырга әзер тору, кыюлык, батырчылык, тәвәккәллек. *Миннән егетлек көтелә? Тузга язмаган да бит, шулай да ул формальлек аны тотып торыр иде әле, чөнки ул формальлек хыянәтең турында ачыктан-ачык «мин китәм» дип әйтүне таләп итәр иде, ягъни ни дисәң дә, егетлек сорар иде.* В.Нуруллин // Нинди дә булса эштә күрсәткән уңганлык, намуслылык, кыюлык һ.б.ш. сыйфатларның чагылышы яки шул сыйфатларга лаек булу. *Күп чакларда, әйе, дәшми калу зур егетлек булып саналган. Төпле кешенең, тискәрелеккә бирелмичә, фикерен үзгәртә алуы – үзе генә дә чын егетлек ул! Иң яхшысы: егетлекне кинәт күрсәтү, кеше көтмәгәндә күрсәтү.* Ф.Садриев

3) *күч.* Сафлык, гыйффәт. *Мин биш ел солдат булып йөрдем, әмма ләкин үземнең егетлегемне сакладым.* А.Расих

**ЕГЕ́ТЧӘ** *рәв. к.* **егетләрчә**. *Егет үлеме егетчә булырга тиеш.* Ш.Маннур. --- *Бибинур шатланган тавыш белән: – Менә монысы егетчә булды! – дип, артымнан кычкырып калды.* Ш.Камал

**ЕГИ́ПЕТЛЫ** *и.* 1) Күпчелеге ислам динендәге, туган телләре гарәп теле булган, Египетта (Мисырда) яши торган төп халык. *Борынгы египетлыларның алласы Ра – Кояш.* М.Әхмәтҗанов

2) Египетта (Мисырда) туып үскән яки чыгышы белән шуннан булган кеше

**ЕГИПТО́ЛОГ** *и. гр.* Борынгы Египетның (Мисырның) тарихын, мәдәниятен, телен һ.б. өйрәнүче белгеч; египтология белгече

**ЕГИПТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Борынгы Египетның (Мисырның) телен, әдәбиятын, тарихын, сәнгатен, икътисадын һ.б. өйрәнә торган фәннәрнең җыйма атамасы. *Ул египтология буенча белгеч икән.* М.Мәһдиев

**ЕГЛАК** *с. иск. к.* **елак**. *Әрмән еглак мөхәррирләреннән тәмам-тәмамга аерыла.* Ф.Әмирхан

**ЕГЛАТУ** *ф. иск. кит. к.* **елату**. *Ячы болгатып, шулай сыкратып, Бирерләр картка кызны еглатып.* Бәет. --- *бер курчакны «Сөннәтче бабай» атыйлар, сөннәт туйлары ясап, аның исеменнән әллә никадәр сүзләр сөйләнәләр, ир балаларны еглаталар иде.* Г.Исхакый

**ЕГЛА́У** *ф. иск. кит. к.* **елау**. *Элекке шагыйрьләр гыйшык уты белән көеп яналар иде, хәзерге шагыйрьләр сөяргә бернәрсә таба алмыйлар вә шуның өчен зар еглыйлар, чөнки сөю – шагыйрь өчен тын алу кебек бер рухи ихтыяҗдыр.* Җ.Вәлиди. *Бу да, гүя, бүген озатылган Садыйкның китүе өчен еглаган йөрәкнең «аһ» итеп куюы кебек тоела иде.* Г.Ибраһимов

**ЕГУ** *ф.* 1) Берәр кемне яки нәрсәне көч белән (мәс., сугып, бәреп, төртеп, этеп һ.б.) бер якка аудару, аварга мәҗбүр итү. *Тарткалаша торгач, ул аны шулай да аркасы белән җиргә екты.* Г.Ахунов. *Ул көчле түгел, ләкин бик үткен, бик хәйләле: кайбер вакытларда һич көтелмәгән җирдән килеп, берничәсен бәреп ега.* Г.Ибраһимов

2) Үсеп утырган нәрсәне кисеп яки чабып бер якка аудару. *Фәрит, урман егу көннәрен хәтерләп, үзалдына елмаеп куйды.* Р.Низамиев. *Урманга кердек тә ектык ике имәнне.* Т.Нәҗмиев

3) Буып, һөҗүм итеп, җәрәхәтләп, үтереп аудару (ерткычлар турында). *Чөнки бүре капкыны ясау аңа да кирәк: үткән елны аның сыер кадәр танасын ике бүре егып ашады.* З.Зәйнуллин

4) Мылтык, автомат һ.б.ш. кораллардан атып (үтереп яки җәрәхәтләп) аудару. *Каршы төшкәнне автоматлар аямый, кыргыйларча ата, итлеккә сарыгын да, бозавын да ега: төенчекләр актарыла, җиргә чәчелә.* Н.Хәсәнов. *Ләкин яуда еккан дошманымнан мин өйрәндем ләззәт табарга.* Ш.Маннур

5) Җиргә сылап яткыру, аудару, ию, сөрлектерү (үсемлекләр, игеннәр турында). *Син күргәнең бармы, зур давылның Урманнарны егып үткәнен?* Ш.Маннур

6) *спорт* Көрәштә каршы як көрәшчене аркасы белән җиргә салу; җиңү. *[Әлемгол:] – Хафиз агакай, – ди, – мин, сине екканда, хәйлә ясадым.* Г.Ибраһимов

7) *сөйл.* Күпләп үтерү, юк итү. *Бүре --- малларыбызны ега.* М.Әмир

8) *күч.* Авыруга сабыштыру, ятарга мәҗбүр итү, хәлне алу (авыру, ачлык һ.б.ш. турында). *Зыкы суыкларда урманнан ач-ялангач килеш утын тартып ташулар, --- бер дә бер көнне Маһиянең үпкәсен кабартып, аны түшәккә екты.* Н.Хәсәнов

9) *күч.* Кемне дә булса җиңү, каршы тора алмаслык итү; үз көченә буйсындыру. *Беләге юан берне егар, белеме юан меңне егар, ди безнең Галәк бабай.* Г.Әпсәләмов. *Син екмасаң, сине дошман егачак.* Ә.Ерикәй. *Борһан кадәр Борһанны алай гына ега алмассың!* М.Хәсәнов

10) *күч. сөйл.* Җитәкчелек вазифасыннан алу, берәр урындагы кешене китәргә мәҗбүр итү, куу. *Патшаны егу*

11) *күч.* Берәр кешене оешманың җаваплы хезмәт урынына уздырмау, сайлатмау; конкурстан төшереп калдыру. *[Мирвәли:] Депутатлыкка кандидат итеп куелырга уйланган Аюханов кандидатурасын без егарга тиеш.* Т.Гыйззәт

12) *күч. сөйл.* Кая да булса тапшырырга дип төзегән, төзәтелгән һ.б. берәр документны (мәс., хисапны һ.б.) ниндидер сәбәпләр аркасында кабул итеп алмау, тәнкыйтьләү. *Шушы кешеләр горкомда отчётымны ектылар, шушы кешеләр монда графикны өзделәр.* Н.Исәнбәт

13) *сөйл.* Имтихан алганда кемнең дә булса белемен түбән бәяләү, икенче тапкырга яки көзгә калдыру

14) *күч.* Абруйлы исемгә, намуска тап төшерү, хурлыклы итү. *Йортны тоткан Белгуарлар мәйданында Атабызның олуг исемен ектыңмыни?* Н.Исәнбәт

15) *күч.* Игътибарсыз калдыру, колакка да алмау. *Бер көн әйтәләр иде әле, Камали әйтә, имеш, ди: «Зифа апай килеп тыйганчы эшлим әле, ул әйтсә, аның сүзен егарга күңел бармый», – дип...* М.Фәйзи. *[Маһруй:] Шундый күңелле хәбәрләр алып кайткан егетнең сүзен егып булмый инде.* М.Фәйзи

16) *күч.* Бетерү, юкка чыгару, юк итү. *[Гәрәй:] Ярый, алайса, дип җавап бирәләр моңа, патриотик хисләреңне егасыбыз килми.* К.Нәҗми

17) *күч.* Баш тарту, кире кагу. *Минем күңелемне егып, башкага китүнең ахыры бик яхшы булмавын уйлап кара.* М.Фәйзи

**Ега бару** Берсе артыннан берсен рәттән егу, бер-бер артлы егу

**Ега башлау** Егарга тотыну. *Бусы король! Королева! Фигуралар!.. Аннан пешкалар китә. Берәм-берәм ега башлыйсың үзләрен!* А.Гыйләҗев

**Ега тору** Һәрберсен, булган берсен егу. *Егетләр дәртләнеп чыга тордылар. Гайрәтлеләр, осталар ега тордылар. Мәйдан уртасында көрәшчеләр саны азайганнан-азайды.* Ф.Абдуллин

**Ега язу** Ялгышлык белән чак кына екмый калдыру. *Ишектән чыкканда, ул Сәлимәне бәреп ега язды.* Н.Гыйматдинова

**Егып ату** Һич уйламаганда, көтмәгәндә дуамалланып егу. *Алар инде Булатны тәмам бутадылар, аударып, егып аттылар.* М.Вәли-Барҗылы

**Егып бару** *к.* **ега бару**. --- *бер урам чатында көрәшеп яталар. Карап тора патша – бер егет бөтенесен дә егып бара икән.* Т.Миңнуллин

**Егып бетерү** Берсен дә калдырмыйча, бөтенесен дә егу. *Авыл балаларын берәм-берәм кызамык чире егып бетерә, ә моңа, минсиңайтим, чир дә тими, чорт та...* Ф.Шәрифуллин. *Бөтен борчуы – бу басудагы икмәкне ничек тә тизрәк егып бетерергә, тизрәк сугып алырга...* Г.Гыйльманов

**Егып карау** Егарга омтылу. *[Тормыш] Кырык тапкыр мине сынады. --- Аяк чалып егып карады.* Р.Ягъфәров

**Егып килү** Эзлекле рәвештә, электән үк һәрберсен, булган берсен егу

**Егып кую** Уйламаганда кинәт егу. *Аю егып куймасын башмак тананы, дип, чак әйтеп җибәрмәде.* Г.Якупова

**Егып салу** 1) Көтмәгәндә, уйламаганда егу. *Арыслангали --- аны кинәт кенә җиргә егып салды.* Д.Каюмова. *Димәк, минем бәрәнемне дә пычак астына егып салырлар.* Н.Дәүли

2) Нинди дә булса эшне тиз арада башкарып чыгу. *Шушы җирне урак белән егып сала идек без, уч төбе хәтле кәкре урак белән.* Р.Вәлиев. *Торабара җаен таптылар, агрегатлар, акрын тизлек белән булса да, тамырда басып торган килеш каралып калган игеннәрне егып сала башладылар.* Б.Камалов

**Егып ташлау** Кинәт егу, тиз арада егу. *Шулай да аны буынсыз итеп, һушсыз калдырып, җиргә егып ташлаган бәндәләр, серле затлар кайчакта хәтеренә килеп төшә.* Г.Гыйльманов

**Егып тору** Тоташтан, рәттән, бербер артлы егу. *Уңышсызлык аяк чалып, Егып торды, Кояш көтсәң, кара болыт Чыгып торды, Көрәшкәндә кылычларым Сынып торды.* Ф.Яруллин

**Егып чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы егу, бөтенесен дә башыннан-ахырына кадәр егу. *Әмир, күлне тирәләп йөреп, кыяк үләнне өч теземгә егып чыккан иде инде.* В.Имамов

**ЕГЫЛА-ЕГЫЛА** *рәв. к.* **егылып** (*1 мәгъ.*). *Ике иптәш бу хәбәрдән егыла-егыла көлделәр.* Ә.Фәйзи

**ЕГЫЛА-ТОРА** *рәв.* 1) Кызу-кызу барганда, нык дулкынланганда, борчылганда, тигезлекне югалтып; бер егылып, бер торып, нык ашыгып, кабаланып. *Озакламый без аның, егылатора, урман юлыннан йөгерүен күрәбез.* Л.Ихсанова

2) *күч.* Авырлык белән, кыенлыклар аша; тырыша-тырмаша. *Мәдәният мәйданында урын алыйк, Егыла-тора, алга таба атлыйк.* Г.Тукай

**ЕГЫ́ЛГАНЧЫ** *рәв.* 1) Арып, хәлдән тайганчы. *Егылганчы эшләп арыганнан соң гына була торган татлы, изрәткеч йокыдан Марат тәмам ял итеп, көч җыеп уянды.* Ф.Латыйфи

2) *күч.* Тәкатьсез булып, бик каты итеп; эч катканчы. *Аңа карап, көлмичә түзү мөмкин түгел иде, кызлар һәммәсе, эчкән чәйләрен онытып, егылганчы көләргә тотындылар.* Х.Ширмән

**ЕГЫЛУ** *ф.* **1.** 1) Абынып, аяк таеп, кемдер аяк чалып, һуштан язып һ.б. җиргә аву. *Шул секундта, тамыры киселгән агач кебек, «лап» итеп җиргә егылды.* Г.Ибраһимов. *Каршы килә башлауларын сизү белән, дулкынланып, юри, өянәге килгән кешедәй, һушыннан язып егыла икән.* Н.Хәсәнов

2) Аяк өстендә басып яки йөреп торырлык хәл юклыктан, берәр нәрсә өстенә (барып) аву (арып, хәлсезләнеп, яраланып һ.б.). *Кичкә ул кунакханәгә хәлсезләнеп кайтып егылды, хәтта яшел күлмәген дә салмады.* Ф.Садриев. *Иртән ач карынга чыгып чаптык, кичен, ашарлык хәл дә калмаганда, кайтып егылдык.* А.Гыйләҗев. *Тән кайнарлыгын басмасмы дип, көч-хәл белән торып су эчәм дә тагын урынга килеп егылам.* Р.Вәлиев. *[Илдус:] Үзебезнең параллель курстагы бер центнерлы урыс малае белән бәхәсләшеп эчтек, теге егылды, ә миңа хоть бы!..* Д.Салихов

3) Тигезлекне югалтып, югарыдан түбәнгә мәтәлеп төшү. *Азат абыйсы биш катлы йорт түбәсеннән егылып та исән калды.* Р.Вәлиев. *[Табындагыларның] Сүз елгасы самолётларның егылуы, поездларның бәрелүе, газларның шартлавы, җирләрнең тетрәве кебек утрауларга кагылып узды.* Ф.Садриев

4) Җиргә түшәлү, берсе өстенә берсе авып сөрлегү (иген, үсемлек җил, яңгыр, боз һ.б. көче белән). *Әле кичә генә өскә таба ашып утырган яшькелт бәрәңге сабагы дулкыны карачкылланып, саргаеп егылган да калган.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Каты авырый башлап, урын өстенә яту, сәламәтлеге какшау. *Мәнә без дә, Уфадан кайтып, күпмедер торырга өлгермәдек, өй эчебез белән тифтан егылдык.* Ә.Еники. *Иртә ватты мине дөнья. --- Мин инде ватылып егылдым.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Йомыш белән мөрәҗәгать итү, кемнең дә булса янына ялыныч белән килү, ялыну, ялвару, баш ию. *Дөресен әйтергә кирәк, урыс кавемендәге егетнең каршына килеп егылуында үзенчәлекле фал күрде Кол Шәриф.* Ф.Латыйфи. *Теге чакта эшеннән куылгач һәм партбилетыннан колак каккач, дүрт ай эшсез --- йөргәннән соң, Шәриф хозурына килеп егылды Хәбибуллин.* В.Нуруллин. *Кеше алдына егылып, бурыч сорап йөргәнче, шулай итсәң яхшырак булмасмы?* И.Гази

7) *күч. сөйл.* Җиңелү, каршы тора алмау. *Көрәшне малайлар башлап җибәрде. Габделхәй дә, чыгып, бер малайны егып, икенчесеннән үзе егылып, ике йомырка алып керде.* М.Гали

8) *күч.* Көч-хәл белән кире әйләнеп кайту (туган илгә, туган авылга һ.б.). *Берничә ел иза чиккәч, авылга кайтып егылдым.* Р.Вәлиев. *Һәм ул үйланды, үйланды да, гарьлекне күтәрә алмый, җанына тынычлык эзләп чыгып китте һәм әтисе йортына кайтып егылды.* Н.Хәсәнов. *Шул китүеннән елдан артык юк булып торып, унтугызынчы елның декабрь азагында гына, ранный булып, ватылып кайтып егылды.* З.Зәйнуллин

9) *күч.* Кыерсытылу, авыр хәлдә калу; уңышсызлыкка очрау. *Тормыш сукмагы тайгак бит ул, буының сыек булса, егылуыңны көт тә тор.* Р.Кәрами

10) *күч.* Имтихан тота алмау; имтиханда «начар» билгесе алу, көзгә калу. *Ул, болардан «икеле» алып, ике тапкыр имтиханда егылды, быел яз өченче имтиханга керә.* Г.Ибраһимов

11) *күч.* Хис-тойгыга бирешү, рухи сыгылу. *Хыяллары тормышка ашмаганга рухи имгәнеп егылганын ул өлешчә Фәридун Фазлыев белән Фаина Марковнага гына ачып салды.* А.Гыйләҗев. *Иптәш Муллаянов әхлакый егылуының беренче симптомнарын күргән һәм, безгә хәбәр итеп, изге эш эшләгән.* Б.Камалов

12) *күч.* Көнләшү, кызыгу; кемнеңдер уңышына эч пошу. *Иренең култыгы астында «Ядерная физика» китабы күреп егылсыннар.* А.Гыйләҗев

13) *күч.* Һәлак булу, үлү. *Күп юллар узгач, талчыгыр булсам, Туган туфракка кайтып егылсам, Сез күкрәгемә куегыз, зинһар, Кыр бизәп үскән арыш чәчәген.* Ә.Баян. *Өлкән лейтенант – архитектура академиясен тәмамлаган Шейнкман – солдатларны атакага күтәргәндә, японнар пулясыннан егыла.* Г.Ахунов

**2. егылган** *и. мәгъ. күч.* Кыерсытылган, авыр хәлдә калган кеше. *Ә Мортаза хуплап утыруын гына белде: – Шул инде. Егылганны дөмбәсләргә безгә генә куш!* М.Хәсәнов

**3. егылып** *рәв. мәгъ. күч.* 1) Бик каты, бик нык; көчле. *Олы абыйсы нидер сөйли, бөтенесе шуннан егылып көләләр.* Ф.Садриев

2) Мул булып, күкрәп, бик яхшы. *Быел игеннәр егылып уңды*

◊ **Егылып үлү** 1) Нәрсәгә дә булса бирешү, каршы тора алмау. *Һа-а, малай, гыйшык утына түзә алмыйча*

*егыласың да үләсең инде!* Ә.Айдар. *Сөембикә дә гайбәттән егылып үләрдәй зәгыйфь түгел.* Р.Батулла; 2) *шаярт.* Тормышын аямыйча, кем яки нәрсә өчен үзен корбан итәргә әзер булу

**Егыла бару** Һәрберсе, булган берсе рәттән егылу

**Егыла язу** Чак кына егылмау

**Егылып алу** Бер тапкыр егылу

**Егылып бетү** Барысы да егылу; бөтенесе егылу. *Бу дулкыннарның куәтеннән безнең юлдашлар инде пароходның идәненә егылып беттеләр.* Ф.Әмирхан

**Егылып китү** 1) Кинәт, көтмәгәндә егылу. *[Мулла бабай:] Ике кулын да күккә сузганлыктан, көймә чайкалганда егылып китә, башы белән көймә кырына бәрелә.* З.Хөснияр. *[Малай:] Берсендә, егылып китәм дигәндә генә, көч-хәл белән каршындагы ботакка тотынып өлгерде.* Р.Низамиев. *Бүтән урында Әнәс шушылай суккан булса, ихтимал, егылып та киткән булыр иде.* В.Нуруллин. *Гази, егылып китмәс өчен, карт тирәкне кочаклады.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Гаҗәпләнү, аптыраушта калу. *[Фәридун Фазлыев Нәҗипкә:] «Минем хезмәт хакымның күпме икәнен әйтсәм, егылып китәрсез!»* А.Гыйләҗев. *Иртә белән күзе зачёт кенәгәсенә төшеп, ачып караса, артына егылып китә язган.* Т.Нәҗмиев

**Егылып тору** Еш, әледән-әле егылу

**Егылып төшү** 1) Биеклектән түбәнгә егылу. *Берни уйламый чабып барганда, бер чокырга егылып төшкән ул.* Х.Шәриф

2) *күч.* Уңышсызлыкка очрау, күңелсез хәлдә калу. *Ә менә проблема бар: тагын нинди зигзаглар үтәргә тиеш булырбыз, һәм борылышларның берәрендә безгә егылып төшү куркынычы янамыймы?* Р.Сафин

**Егылып яту** Егылган хәлдә булу. *Бибисараттәйнең егылып яткан бәрәңге сабакларын сыпыра-сыпыра елаганын күргәч, йөрәгем бөтенләй урынынннан купты.* М.Юныс

**ЕГЫЛЫР-ЕГЫЛМАС** *рәв.* 1) Ярым егылу, ярым басып тору хәлендә; менә егылам, менә егылам дигән хәлдә, көчкә. *Сыртак ике кулы белән бугазын кысып тоткан килеш, әкрен генә аякка басты, --- егылыр-егылмас атлап, урман авызына чыкты да егылды.* Р.Батулла

2) Авырлык белән, кыенлыклар кичереп. *Колхозыбыз болай да егылыр-егылмас кына бара, каш ясыйбыз дип, күз чыгармагаең.* Г.Бәширов

**ЕГЫЛЫШУ** *ф.* **1.** 1) Ике яки берничә кеше бергәләп яки бер-бер артлы егылу. *Тулай торак алдында бозлавык. Егетләр, кызлар берәм-берәм егылышып имгәнә.* Ш.Галиев

2) Көрәштәшләре бер-бер артлы җиңелү

**2. егылышып** *рәв. мәгъ.* 1) *к.* **егылганчы** (*2 мәгъ.*). *Аннан соң, бераз тынычлангач, мине күреп алдылар һәм егылышып көлә башладылар.* Ф.Яхин

2) Өзгәләнеп. *Егламагыз шулай егылышып: су эчендә ятар әрвахлар.* З.Мансуров

**Егылышып бетү** Барысы да, берсе дә калмастан егылышу. *Әтиләре әйтмешли, сөяк-санакларын җылытырга җае чыкмаса, салкын тиеп, лазаретка егылышып бетәрләр...* К.Кәримов

**Егылышып китү** Кинәт егылышу

**Егылышып яту** Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында егылышкан булу. *Ишегалды тулы казлар егылышып ята.* Д.Гайнетдинова

**ЕГЫШУ** *ф. спорт* Көрәштә берсе икенчесен егу. *Ничә ел инде Сабан туенда да, шахтада да батырлыкны һичкемгә бирми Әнәс. Быел --- Габбани белән сәгатькә якын җәфаланды дипделәр. Егыша алмаганнар.* Ә.Галиев

**ЕГЪЛА́У** *ф. иск. кит. к.* **елау** (*1 мәгъ.*). *Ходайдыйн егълап сорыйлар дошманнарны җиңәргә.* Бәет. *Берөзлексез Йосыф диеп егълаганга, Бар өметен егълау белән баглаганга.* Кол Гали. *Борынгыдагы куанычлар, андагы кәеф-сафалар өчен, хәзерендә егълаулар, ачы күз яшьләре килде.* З.Хөснияр

**ЕЛ** *и.* 1) Җирнең Кояш тирәсендә бер кат әйләнеп чыгуына тигез вакыт үлчәү берәмлеге (1 гыйнвардан исәпләнә башлый һәм 12 календарь айдан тора). *Менә инде ике дистәдән артык ел дәвамында җәмгыять үзгәрешләр чорында яши.* Ф.Галимуллин. *Күк йөзенең күчмә картасыннан файдаланып, сезнең һәркайсыгыз йолдызлы күк йөзенең ел дәвамында өзлексез үзгәрә барганлыгын белә ала.* Астрономия

2) Нинди дә булса көннән алып исәпләнгән 12 ай вакыт арасы. *Ир-хатын булып торуларының өченче елында Садыйк тагын эшсез калды.* Г.Ибраһимов. *Өч-дүрт елдан аларның һәркайсы өч сыер биргән сөтне берүзе бирер иде.* Ә.Еники. *Моннан өч ел элек мин сезне мәктәп ишегалдында күрдем.* Р.Юсупова

3) Нинди дә булса эшләр, укулар циклы башкарыла торган вакыт арасы. *Мәдрәсәдә актык ел укып кайттык.* М.Гафури

4) Берәр нәрсәнең вакыты, срогы. *Зыяның солдатка каралыр елы якынлашып килә.* Г.Ибраһимов

5) **еллар** *күпл.* Берничә елны эченә алган вакыйгаларны берләштергән, аерымланып торган вакыт арасы, чор. *Сугыштан соң гына өйләнештеләр алар. Шул авыр елларда башка чыгып, йорт-җир җиткереп, үз көчләренә таянып яшәделәр.* М.Хуҗин. *Үзе укыган педучилищены, шаулы студент елларын сагыныр, иптәшләрен, дусларын юксыныр.* А.Сафин

6) Озак вакыт, озын бер чор. *Картайдым шул, – Еллар шулай итте.* Һ.Такташ. *Кеше – катлаулы җан; син аны еллар буе өйрәнеп тә белеп бетерә алмаска мөмкин, ә төгәл бер очрак, ситуация аны ача да сала сиңа.* Г.Ахунов

7) Дистәне белдергән тәртип саннары белән килгәндә, шул ун ел эчендәге вакыт арасын аңлата. --- *утызынчы елларда инде язучылар арасыннан «халык дошманнары»н эзләү, табу һәм аларны җисмән юк итү бурычы алгы планга чыкты.* Ф.Галимуллин. *Әйтик, илленче елларның башларында тарих фәне өлкәсендә ниндидер бер торгынлык хөкем сөрә иде.* Ә.Еники

◊ **Елныкы(н) елга** Шул ел эчендә (азык-төлек, керем һ.б.ның тотылуы, сарыф ителүе, төгәлләнүе турында). *Барыбер елныкын елга тотарга кирәк, юкса кисәләр.* Н.Хәсәнов. **Елның ел буена** Бөтен ел дәвамында. *[Сыерлар-*

*ны] Елның ел буена сусыл яшел азык белән тәэмин итеп торырга кирәк.* Ватаным Татарстан. **Елның елында** Елдан-ел, ел саен, һәр елны. *Ни гаҗәптер, тау өстендәге басуда елның елында күкрәп арыш үсә иде.* Р.Низамиев. *Елның елында үткәрелгән тикшерү-барлау мәгълүматларының акка күчерелгәне, утырыш беркетмәләре колхоз идарәсендә сакланса, караламасы – өендә, нәкъ шул киштәдә, гомуми дәфтәргә теркәлгән иде.* Р.Кәрами. *Тар урамнар, елның-елында ремонтланып та, елның-елында аламалана торган иске йортлар сакланса да, фәкать шушы мемориал эчендә генә сакланып калыр.* Г.Кашапов. **Ел озынлыгы** Бик-бик озын. *Ел озынлыгы кышкы төн үзенекен иткән: әти тәмам арыган да, бераз ял итеп алырга дип, кар өстенә утырган.* В.Нуруллин. **Ел үсәсен көн үсү** Бик тиз, кыска вакыт эчендә үсеп җитү. *Анадан ятим калган угыл ел үсәсен көн үсә, буй җиткерә һәм, күп тә үтми, атасының малларын көтә башлый.* М.Хәбибуллин. **Елы белән** Кайбер елларда. **Елы-елы белән** Берничә елның берәрсендә, кайбер елны. *Елы-елы белән аны колхоз рәисе итеп тә сайлыйлар.* К.Кәримов. **Елы (туры) килү** 1) Игеннәр уңу өчен уңай һава шартлары булу. *Елы килеп, ашлык уңса, кәнишнә.* Р.Ишморат; 2) Яше тулу, тиешле яшькә җитү. *Халитов белән Масловның да [солдатка каралу] елы туры килде.* Х.Садрый. **Елын уздыру** *дини* Йола буенча, якын кешенең үлүенә бер ел тулу уңае белән, искә алу мәҗлесе үткәрү. *Мәрхәбә ---, мөәзин бабайны гына чакырып булса да, аш-чәй ясап [әнисенең] елын уздырырмын дип уйлады.* Г.Ибраһимов

**ЕЛАВЫК** *с. диал. к.* **елак**. (*1 мәгъ.*)

**ЕЛАК** *с.* **1.** 1) Еш елый торган. *Минем өчен һаман шул мәм-мәм сорап яткан елак кыз әле ул.* Р.Вәлиев. *Биләүдә дә, бишектә дә, тәпи йөри башлагач та, син бик елак булдың.* К.Латыйп // Үзе теләгәнчә эшләтү өчен, өлкәннәрне елап куркытырга гадәтләнгән (*бала, яшүсмер*). *Әткәй ярым шелтә, ярым елмаю белән каршы алды: – Елак малай! Җиңдең бит, ахрысы!* Г.Ибраһимов

2) Еламсыраган, кызгану хисе уята торган (*аваз, тавыш). Икебезнең дә кулларыбызны кысып, ярым елак тавыш белән зарлана башлады.* М.Әмир. *Әтәч флюгер әкрен генә шыгырдап әйләнә: бу иске, бәхетсез йортның хуҗаларын сагынган кебек итеп, моңсу елак аваз чыгара.* З.Фәхретдинов

3) *күч.* Төшенке, күңелсез; зарлана торган. *Менә шундый елак уйлар өрлектәй ирләрне дә балавыз итә инде ул, Илфат.* Б.Камалов

4) *күч.* Җебегән, пешмәгән. *Габидулла карт арбалар янына теге елак малайның камытын рәтләргә дип китте.* М.Әмирханов. *Икенче көн иртә белән минем башым үземне Мәрфуга апага ничек итеп батыр, һөнәрле, елак түгел итеп күрсәтүне уйлау белән мәшгуль булды.* Ф.Әмирхан

5) *күч.* Яңгырлы. *Утырсам мин синең белән, алсу йөзем, Кочып сине, йотып мәйне, кабып йөзем, – Җылы җәйгә әверелә салкын кышым, Яшел язга – саргылт, елак, шыксыз көзем.* Ә.Исхак

**2.** *и. мәгъ.* 1) Бик еш елый торган бала. *Төннәр буе син елакның бишегее янында каравыллап чыга идем.* Т.Гыйззәт. *– Юләрләр, мин сезне куркыттым гына шулай, елаклар, – дип тә әйтер шикелле.*Н.Дәүли

2) Канәгатьсез, зарланучан, пессимистик рухлы кеше. *Апасы үлгәч, ул бөтенләй елакка әверелде.* Ә.Фәйзи

◊ **Елак җыю** Еларга җыену. **Елак капчыгын чишү** Күз яшен чыгару, елый башлау

**ЕЛА́К КАРЧЫГА** *и. зоол.* Карчыгалар семьялыгыннан, башка төрләреннән сузынкы нечкә тавыш чыгарып кычкыруы белән аерыла, табышын һавада озак вакыт канат какмый очып йөреп күзли торган ерткыч кош; сарыча, сарыч; *русчасы:* **канюк, сарыч обыкновенный, мышелов**

**ЕЛАКЛАНУ** *ф.* Елакка әйләнү

**Елаклана бару** Торган саен ныграк елаклану

**Елаклана башлау** Елакка әйләнү

**Елаклана бирү** Елаклануын дәвам итү

**Елаклана төшү** Бераз елаклану

**Елакланып алу** Бераз, берара елаклану

**Елакланып бетү** Тәмам, бик нык елаклану

**ЕЛАКЛЫК** *и.* Елак булу. *Безнең нәселгә елаклык, гомумән, чит нәрсә.* Г.Минский. *Сәнгатьнең илаһи көчеме, әллә минем елаклыгыммы?* Г.Бәширов

**ЕЛАК-МЫЛАК** *с. сөйл. кимс.* Бик еш елаучан, еларга яратучан, елавык (кешегә карата мыскыллап әйтелә). *Бәләкәйләр генә елак-мылак, ертык колак була. Менә мин, зур булгач, еламыйм да, колагым да ертык түгел.* Р.Хафизова

**ЕЛАМСАР** *с. сир. к.* **еламсыр**. *[Дачалар] Пальма, мәҗнүн (еламсар) таллар, байтирәкләр, кәрнизләргә үрелгән йөземнәр ышыгында [утыра].* Т.Әйди

**ЕЛАМСЫР** *с.* 1) Ботаклары озын һәм куе булып салынып торган. *Еламсыр талларга тия-тия астан инеш ыңгыраашты.* А.Гыйләҗев

2) Явым-төшем күп булган, яңгырлы. *Бу – еламсыр салкын елның көзе.* К.Булатова

**ЕЛАМСЫРАК** *с. сир. к.* **елак** (*2 мәгъ*). *– Малай, хәлләр хөрти бит әле минем, – диде ул, еламсырак тавыш белән.* Р.Вәлиев

**ЕЛАМСЫРА́У** *ф.* Елагандай итү, җиңелчә генә елау, тавышка елаган төсмер чыгару. *– Тс-с, хатын, – дип еламсырады ул һәм бармак янады.* Р.Вәлиев. *Мәрьям абыстай рәнҗеп еламсырый башлады.* Ә.Еники. *– Әни яшерә ---. Буфетны да, шкафны да бикли, – диде малай, нык ук еламсырап.* А.Гыйләҗев

**Еламсырап алу** Кыска вакыт эчендә еламсырау. *Хатыны тагын еламсырап алды.* Р.Зәйдулла

**Еламсырап китү** Көтмәгәндә, кинәт еламсырау

**Еламсырап кую** Аз гына, кыска вакыт арасында еламсырау. *– Кеше арасына киеп барырлык киемең дә булмагач, адәм мәсхәрәсе булганчы, өйдә торуың артыграк, – дип еламсырап куйды.* К.Тинчурин

**Еламсырап тору** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында еламсыраган хәлдә булу. *Кешеләре киткән, авыл беткән. Урыны гына ята каралып. Кычыткан-*

*нар тора еламсырап, Нигез ташларына сарылып.* И.Әширов

**Еламсырый башлау** Еламсырарга тотыну. *[Алмаз] «Әни» сүзен ишетсә, хәзер еламсырый башлый.* Л.Гыймадиева

**Еламсырый төшү** Бераз, аз гына еламсырау, еламсыраган кебек итү

**ЕЛАМСЫРАУЛЫ** *с.* Еламсыраган, кызгандыра торган. *Әнисенең: «И улым!» – дигән еламсыраулы тавышы ишетелгәндәй булды.* Р.Вәлиев

**ЕЛАН** *и. зоол.* 1) Тәңкәлеләр отрядының сөйрәлүчеләр төркеменә караган, күбесенең авызында агулы бизләре булган, мускуллары кыскару нәтиҗәсендә боргалана-боргалана сөйрәлеп хәрәкәтләнә торган, аяксыз, гадәттә нечкә озын гәүдәле хайван. *Кайчандыр Мәдинә, Казан крепостена каршы музейга кереп, тере хайваннар бүлегендә пыяла ящикка салынган зур еланны күргән иде.* К.Нәҗми

2) *астр.* Борынгы Көнчыгыш йолдызнамәсендә алтмыш еллык календарь циклның 12 төрле хайван белән билгеләнгән алтынчы билгесе; шул билгегә туры килгән елда туган кеше

3) *күч.* Мәкерле, астыртын эш йөртүче, явыз ниятле кеше. *Мин тәхетемә сез еланнарны үрләтмәм...* М.Фәйзи. *Сезгә мәңге төзәлмәслек йөрәк ярасы салырга, балагызны әтисеннән аерырга, бәхетегезне тартып алырга омтыла ул елан.* М.Маликова

4) *күч.* Сугышта дошман. *Җирән, чиркан син аннан – Немец-фашист еланнан.* Ш.Маннур

5) *күч* Хәйләкәр, елгыр, бик үткен, булдыклы кеше

6) *күч.* Явызлык, әшәкелек, астыртын ният. *Син мине эчеңдә асраган --- еланнарыңнан чактырмакчы буласың икән.* М.Фәйзи

7) *күч.* Формасы, тышкы кыяфәте белән еланга охшаш нәрсә, әйбер. *Динамитның газы – соры елан – Сузылып йөри забой буенча.* Ш.Маннур

◊ **Елан авызына керергә әзер** Кемнең дә булса күңелен табарга, аңа бик ошарга, ярарга, бөтен теләкләрен дә үтәргә әзер булган (икейөзле кешегә карата әйтелә). *Елан авызына керергә әзер --- карчыклар шикелле, Ария ханым да ире һәм урыс милләтенең санын арттырган балаларына шулай ярарга тырыша.* Т.Галиуллин. **Елан авызыннан зәһәр эчәргә риза** *к.* **елан авызына керергә әзер**. *Гөлбану өчен, аның бүлмәсенең матурлыгы, киявгә ошарлык төзәлүе өчен, ул елан авызыннан зәһәр эчәргә риза кебек иде.* Г.Ибраһимов. **Елан аягын кискән** Чамасыз үткен, чая; күпне кичергән, тәҗрибәсе зур булган. *Тик зимагур булып яки кызыл мал белән йөргән, елан аягын кискән бәндәләр генә... Мәкәрҗәнең үзенә үк, дип җибәрәләр.* З.Зәйнуллин. **Елан булып йөрү** Сиздермичә, явыз эш йөртү, әшәкелек эшләү. *Арабыздан алып ташлый белдек Елан булып йөргән кешене.* Ф.Кәрим. **Елан йоткан** Бик усал, явыз. **Елан кабыгын салу** Мәкерле уй-теләкне сиздермәү, белгертмәү, яхшы булып кылану; икейөзләнү. *Мәйсәрә, елан кабыгын салып, беркатлылык күрсәтмәкче булды.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Елан маен ялаган** Бик хәйләкәр, мәкерле. **Елан мөгезе** Четерекле, катлаулы, аңлашылып җитмәгән урын. *Мине бигрәк тә шунысы шаккатырды: үз коллективында кайда нинди шуклык, кайда нинди елан мөгезе яшеренеп ятканын чамалап йөргән, имеш.* Ф.Хөсни. **Елан мөгезе генә юк** Җаның теләгән барысы да бар; ни кирәк, шул бар. **Елан тел** Усал, төртмә тел. *Һәм шунда Заһидулла кинәт кенә ярсып китте: – Әле син минем Заһидәгә тел тидерәсеңме, өзеп атармын ул елан телеңне!!!* Р.Сибат. **Елан яшен ялаган** *к.* **елан маен ялаган**

**ЕЛА́Н АБАГАСЫ** *и. бот.* Елан абагачалары семьялыгыннан, вегетатив һәм споралы сегментларга телгәләнгән сәнәксыман яфраклы үсемлек; *русчасы:* **ужовник обыкновенный**. --- *гади елан абагасы дымлы болыннарда үсә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ЕЛАНБАЛЫК** *и. зоол.* 1) Еланбалыксыманнар отрядыннан, елан сыман озын, шома гәүдәле, ялангач тәнле яки вак тәңкәле, сырт һәм койрык асты йөзгечләре койрык өлешенә тоташып киткән кара яки ак төстәге балык; *русчасы:* **угорь**. *Ә Цивильнең кечкенә бер инеш кушылган җирендә, кыяклы үләннәр арасында, еланбалык та эләгә иде.* А.Емельянов

2) Еланбалыксыманнар отрядыннан, йөзгечләре начар үскән, елан сыман озын, шома, тәңкәсез гәүдәле, озын койрыклы, үткен тешле, чуар төстәге ерткыч балык; *русчасы:* **мурена**. *Кыя тишегеннән агулы еланбалык – мурена карап тора иде.* М.Юныс

**ЕЛАНБАЛЫКСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Елан сыман озын, шома гәүдәле балыклар отряды атамасы

**ЕЛАНБАШ** *и.* 1) *бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, күгелҗем шәмәхә яки ак чәчәкле, эфир мае алу өчен үстерелә торган берьеллык үсемлек; *русчасы:* **змееголовник**. *Аларга [дала үләннәренә, бакча гөлләренә, болын чәчәкләренә] үсендереп үстерә торган сүз тылсымы салынган ...Укъяфрак, канәфер, умырзая, кашкарый, гөлбадран, тамчы гөл, яушан гөл, тайтояк, баллы баба, еланбаш, ташкуран, сарана, абага, төнбоек ---.* М.Галиев

2) *зоол.* Алабугасыманнар отрядының еланбашлар семьялыгыннан, атмосфера һавасын сулау өчен махсус органы булган елан сыман башлы балык; *русчасы:* **змееголов**

**ЕЛАНБАШЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Чын кәлтәләр семьялыгыннан, кечкенә, җыйнак кәлтәләр ыругы; *русчасы*: **змееголовки**

**ЕЛАНГӨЛ** *и. бот.* Сусынчалар семьялыгыннан, төрле төсләрдә бүрәнкәсыман чәчәк ата торган бүлбесуганчалы күпьеллык үсемлек; гладиолусның бер төре; *русчасы:* **шпажник посевной**

**ЕЛА́Н КАМЫШЫ** *и. бот.* Камышчалар семьялыгындагы күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругыннан, су җыелган урыннарда, яр буйларында үсә торган шуышма тамырчалы үлән (су җәнлекләре өчен азык булып тора); *русчасы:* **хвостник обыкновенный** яки **сосенка водяная**

**ЕЛАНКОЙРЫКЛАР** *и. күпл. зоол.* Энәтирелеләр тибының бер классы; диңгез-океаннар төбендә яшәүче, диск сыман гәүдәсеннән 5–10 сыгылмалы

нурлар («куллар») китә торган офиураларны берләштерә; *русчасы*: **змеехвостки**

**ЕЛА́Н КӨПШӘСЕ** *и. бот.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, бүлбе яки цилиндрсыман тамырлы үсемлек; *русчасы:* **бутень**. --- *халык – шагыйрь булган! Югыйсә кинәнеп үскән һәммә үсентегә шундый да балкышлы аталар бирә алыр идеме; --- әгәр шагыйрьлек илһамы кальбендә булмаса? Чыпчык күзе, аткый, --- каз юасы, балтырган, абага, үги ана яфрагы, елан көпшәсе, тал песие, әби чәче...* М.Галиев. *Монда нинди генә нигъмәтләр юк: балтырган дисеңме, какы, дәгел дисеңме, елан көпшәсе, кузгалак дисеңме, зәрдә яки каз тәпие дисеңме – бары да бар.* Ш.Маннапов

**ЕЛАНЛЫК** *и. күч.* Астыртын усаллык, әшәкелек, мәкерлелек. *[Булат бәк Ширин турында] – Элеккеге еланлыкларын юарга тырыша! – диде Кошчак углан.* Р.Батулла. *Фәридә, каян килә сиңа мондый еланлык? Кияүгә чыгуыңа сөенер чагың ич!* Г.Галиева

**ЕЛА́Н ТАМЫРЫ** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, хуш исле эре чәчәкле, тоташ яфраклы дару үләне; *русчасы:* **шалфей**

**ЕЛА́Н ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан, кызгылт күк чәчәкле, баллы үсемлек; *русчасы:* **синяк обыкновенный**

**ЕЛАНЧАЛАР** *и. күпл. зоол.* Бөҗралы суалчаннар тибының төкле аяклылар асклассына керә торган, диңгездә яшәүче бөҗәкләр семьялыгы; *русчасы:* **змейковые**. *Еланчаларның саңаклары була*

**ЕЛАН-ЧАЯН** *җый. и.* Чага торган, төрле сөйрәлүче хайваннар. --- *зәкятсез маллар кыямәт көнендә, еланчаян сурәтендә булып, иясенә ябышырлар.* К.Насыйри. *Ул чүлдә хәтта еланчаяннар сызгырганы да, ач шакаллар чинаганы да ишетелми, җилләр дә исми.* Ш.Маннур

**ЕЛАП-СЫКРАП** *рәв.* 1) Рухи газап кичереп, бик интегеп, күз яшьләре түгеп. *Олыяз, Пүкәл, Өтернәс, Эзмә авыллары халкы шулай мәсхәрәләнгән өчен елап-сыкрап калалар, әмма коралы отрядка каршы балта-сәнәккә тотынмыйлар.* Борынгы Калатау итәгендә

2) *күч.* Ризасыз булып, зарланып, йөз чытып

**ЕЛАП-СЫКТАП** *рәв.* Интегеп, газапланып; күңелсез. --- *«шатлык» дигән нәрсә безнең өйдә көн саен кунак булмаса да, бу әле бөтен гомер елап-сыктап узды дигән сүз түгел.* Г.Бәширов

**ЕЛАР-ЕЛАМАС** *рәв.* Ярым елаган хәлдә, елап җибәрергә әзер хәлдә. *Бу юлы инде елар-еламас эндәште Айсылу җиңгәсе.* Р.Мөхәммәдиев

**ЕЛАТУ** *ф.* **1.** 1) Елау дәрәҗәсенә җиткерү, еларга мәҗбүр итү. *Җитмәсә, [Фәрит] скрипкада шундый итеп уйный: тели икән – әбиләрне елата, тели икән – кызларны җырлата.* Җ.Тәрҗеманов. *Аның болай чын ихластан кызганган рәвештә шөгыльләнүе, самими һәм садә кыланышы Гарифны эчтән көлдерә дә, елата да, тәмам үзгәген өзә иде.* Ш.Камал

2) *күч.* Рәнҗетү, бик нык кимсетү, кыерсыту, начар сүзләр әйтеп җәберләү

**2. елатып** *рәв. мәгъ.* Көчләп, мәҗбүри рәвештә, ирексезләп, теләккә каршы барып. *Хатынын елатып булса да талап алып, сораган сумманы бирде.* М.Ибраһимов. *Мәмдүдәне, елатып, Кушлавыч авылының тол калган мулласы Мөхәммәтгарифка биргәннәр.* З.Рәсулева

**Елата башлау** Елатырга тотыну

**Елата бирү** Елатуын дәвам итү

**Елата төшү** Тагын да бераз елату

**Елатып алу** Кыска вакыт эчендә, бераз елату

**Елатып бетерү** Тәмам, соңгы чиккә җиткереп елату; елау дәрәҗәсенә җиткерү

**Елатып тору** Даими рәвештә, туктаусыз, гел елату

**Елатып чыгу** Һәркемне, һәрберен, барысын да елату

**ЕЛА́У** *ф.* 1) Яшь агызу, яшь чыгару, күзләрне яшьләндерү (авыртудан, төрле кичерешләрдән һ.б.). *«Аһ, әни!» – ди, ләкин яшьләренә буыла һәм сүзсез генә, бөтен тәне белән калтыранып елый, елый да елый.* Ә.Еники. *Ә сәхнә артында Айдар, кайнар шатлык һәм чиксез югалту хәсрәте уртасында калып, үкси-үкси елый.* Р.Хисмәтуллин. *Күрәм: Мохтар абый да елый, солдатларча, күз яшен күрсәтми генә елый.* Н.Дәүли

2) Кеше кычкырып елауга охшашлы сузынкы тавыш чыгару. *Эт, авызын бакча рәшәткәсенә таба сузып, елап-елап өрә.* Ф.Хөсни. *Яланнардан бер әйләним дисәң, Кошлар елый...* Х.Әюп

3) *күч.* Үзәк өзгеч, ялыктыргыч сузынкы тавышлар чыгару. *Җил җан ачысы белән сызгырды, үкси-үкси елады.* Р.Вәлиев. *Идел белән хыял тоташкан ил, Ничек карыйм синең күзеңә? Чиркәү нигезендә ташлар елый, Җаннар иңри, йөрәк өзелә.* К.Сәгъдәтшин. *Сары күлмәкләрен аяк астына салып ташлаган каен кызларына карый-карый, бар табигать тавышсыз гына елый иде.* Р.Вәлиев

4) Моңлы итеп, озын көй уйнау. *Кайдадыр, илереп-илереп, гармун елады.* А.Гыйләҗев

5) *күч. сөйл.* Кемнән яки нәрсәдән дә булса ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү яисә аларның начар ягы турында сөйләү; зарлану. *Түрәләрдән рөхсәт сорап кына, Алга барып булмый, елап кына.* Г.Афзал

**Елап алу** Бераз, аз вакыт арасында елау. *Карчык мышык-мышык елап ала.* Ф.Сафин. *[Гөлшаһидә] Аулакка китеп, туйганчы бер елап алгач кына бераз тынычланды.* Г.Әпсәләмов. *Пароход тагын озын итеп ялварып елап алды.* М.Юныс

**Елап бетү** Соңгы чиккә җитеп елау, озак һәм каты елау, елау дәрәҗәсенә җитү. *Сагынып каршы алсыннар! Көтә-көтә зарыгып, елап бетсеннәр. Хатын-кызның йөрәк хисләре, ачы күз яшьләре белән юылса, яңарып, ялтырап китә!* М.Маликова. *[Мәрьям апа:] Елап беткәнсең, Роза. Бу ниткән эшең, ә?* Б.Камалов

**Елап җибәрү** Көтмәгәндә, кинәт елый башлау. *Сәлимәм җавап бирәсе урынга елап җибәрде.* Ф.Яхин. *– Гомәр! – диде дә: – Исән кешеләр бер кайталар! – дип, үксеп елап җибәрде.* Ә.Еники. *Бер кул белән якасыннан тотып, икенче йодрыкны йомарлап тор-*

*дым-тордым да, үзем дә сизмәстән, елап җибәрдем.* Р.Вәлиев

**Елап йөрү** Өзлексез, даими рәвештә елау. *Их Дамир, Дамир, нинди генә кызлар артыңнан елап йөрмәде.* Д.Салихов. *Күрәм: эшче халык баласын күтәреп елап йөри.* Р.Мөхәммәтҗан. *Ә мин... Алай елап йөрмим. Мин шундый чыдам! Мин бит... Караңгы чоланга Еларга чыгам.* Г.Гыйльманов

**Елап карау** Ышандыру өчен елау юлын сынау. *Алар, туган көннәрендә назлана төшеп, авызларын ачып берничә елап карасалар да, эштән бушамаган аналарыннан иркәләү ала алмагач: – Булмас, ахры, – дип, еламаска булдылар.* Һ.Такташ

**Елап кую** Кинәт елау. *Сайрый былбыл, сайрый былбыл, Сайрыйдыр ла таң булгач; Чыдый алмый елап куям, Сагынып, күңелем тулгач.* Җыр

**Елап тору** Сөйләү моментында елау, елаган кыяфәттә булу. *Капка баганасы янында бер нәни кыз елап тора иде.* М.Юныс. *--- төксе, төмсә әтисенең бер көнне лапас эчендә елап торганын күрде ул.* Р.Зәйдулла

**Елап чыгу** Нинди дә булса вакыт аралыгын елап үткәрү. *Илфир белән Галяның туе көнне мин --- төне буе елап чыктым.* Р.Кәрами. *Шул янгында ире үзе дә янып үлмәде микән дип, төне буе керфек какмады, елап чыкты ул.* Р.Сибат. *Төннәрен мендәр кочаклап елап чыккан чакларым бар.* М.Кәбиров

**Елый башлау** Еларга тотыну. *Янына барсам, ныграк елый башлый, бармасам, елый-елый да, тынычланып, йоклап китә.* Г.Гыйльманов. *Председательне управада туры китерүе бик читен, ә туры китерсәң, вакыт юк дип елый башлый.* И.Гази

**Елый бирү** Елаган саен елау, берниндн юатуларга карамыйча, бертуктамый елау. *Мин аның саен ярсыдым, аның саен елый бирдем.* Г.Ибраһимов. *Әнием, башын түбән игән килеш, тавышсыз гына елый бирде.* Н.Дәүли

**ЕЛАУЛЫ** *с. сир.* 1) Елау билгеләре булган, елаган; яшьләнгән, елап кызарган. *– Сез Надыйровны стрелочник иткәнсез! – Сәриянең тавышы елаулы, күкле-яшелле чыкты.* Х.Камалов

2) *күч. сир.* Моңсу, сагышландыра торган, кайгылы (*көй, җыр*)

**ЕЛАУ-СЫКТАУ** *җый. и.* Елау һәм шыңшу, елый-елый зарлану. *Бу шау-шулар, елау-сыктаулар, каргыш һәм нәләтләр белән буталып, көннең кичкә авышуын да сизми калганмын.* И.Салахов

**ЕЛАУЧАН** *с.* Бик еш елый торган; еларга яраткан. *Аның мәхәббәт лирикасы да «елаучан» сагынуга, моңлануга гына кайтып калмый.* Р.Зәйдулла

**ЕЛАШ** *и. сөйл.* Елау халәте. *Наҗарның тәкъдиргә бераз үпкәләргә хакы бар кебек: ул бәхетле йолдыз тыныч җемелдәгән чакта тумады, ә бөтен җирне калтыраткан залплар, шартлаулар, дөбердәүләр һәм елашлар белән бергә дөньяга килде.* Ә.Баянов

**ЕЛАШ-КАРГЫШ** *җый. и.* Бер үк вакытта булган елау һәм кычкырып каргау тавышлары; елый-елый каргау. *Колхоз төзүчеләр кереп чыккан өйләрдән чыр-чу, елаш-каргыш ишетелгәч төшенде моңа Хәбиб.* Р.Гыйззәтуллин

**ЕЛАШ-КЫЧКЫРЫШ** *җый. и.* Бер үк вакытта булган елау һәм кычкыру яки елашу һәм тиргәшү тавышлары. *Мәхәлләләрдә – елаш-кычкырыш. Байтак йортлар җимерелгән. Имин калган кешеләр җимерекләр арасында казына, таш йә бүрәнә баскан туганнарын коткарырга тырыша.* Б.Рафиков

**ЕЛАШ-СЫКРАШ** *җый. и. сөйл.* Бер үк вакытта булган елау һәм кычкырып сыкрану, зарлану тавышлары. *Елаш-сыкраш, ызгыш-талаш инде басыла дигәндә, яңадан шау-шу күтәрелә.* И.Туктар

**ЕЛАШ-СЫКТАШ** *җый. и. к.* **елаш-сыкраш**. *Әлегәчә җайлы гына аккан тормышын олы мәшәкатьләргә дучар итеп, өендә елаш-сыкташ мәхшәре тудырып, туган-үскән якларыннан кузгалып китүенең сәбәбе әнә шул чир йогудан була да инде.* Л.Хәмидуллин

**ЕЛАШУ** *ф.* Ике яки берничә кеше бергәләп елау, берьюлы елау. *– Юк инде, безгә патшадан бер рәхим дә, берниндн ярдәм дә буласы юк, – дип, әти-әниләре елашалар.* Әкият. *Өлкәннәре сөйләшми, бала-чага исә ашарга даулап елаша.* Җ.Рәхимов. *Алар, хатын-кызларга хас булганча, кочаклашып елаштылар.* Г.Ахунов

**Елаша башлау** Елашырга тотыну

**Елаша бирү** Елашуларын дәвам итү

**Елашып алу** Кыска вакыт арасында бераз елашу. *Хәтта аны [бәпкә Пеппины] кызганудан, чыпчыклар елашып алганнар.* Ф.Яруллин. *Оньк-оныкчалар кинәнеп уйный, шаулаша, елашып та ала.* Г.Хөсәенов

**Елашып бетү** Бик нык елашу, елашу дәрәҗәсенә җитү. *Без сиңа ун ел хезмәт ит дип әйтеп җибәрдекмени? Кайдалыгыңны чуртым да белми, монда елашып беттек!* Ф.Яхин. *И-и, әллә елашыплар беткәнсез инде?* А.Хәсәнов

**Елашып йөрү** Төрле урыннарда, билгеле бер вакыт дәвамында җыйнаулашып елашу. *Кияүгә ярәшелгән кыз кияү янына кергәнгә тиклем өйгә төшми, ахирәт кызлары белән елашып йөри.* М.Әмир. *Ул көнне чиркәүләрдә чаң кактылар, кешеләр урамда елашып йөрде.* Р.Зәйдулла

**Елашып тору** Әле, хәзерге вакытта елашу. *Шунысы нык хәтеремдә калган: чиркәүнең колоколын сүтеп төшергәндә, марҗалар, бала-чагалары белән капка төпләренә чыгып, күз карашларын чиркәүгә төбәп елашып тордылар.* Г.Галиев

**Елашып утыру** Әле хәзерге вакытта елашу. *[Гатаулла бабай:] «Нигә эшеңнән туктап калдың? – диде. – Тизрәк булыгыз, кайгырышып, елашып утырасы вакытлар түгел».* Н.Дәүли

**ЕЛ АШЫ** *и. дини* Үлгәнә ел булгач, мәрхүм кешегә багышлап уздырылган мәҗлес. *Нуретдиннең «кырык кичәсе» дә үтте, «ел ашы» да үтеп китте.* Ш.Камал

**ЕЛБЫР** *с. диал.* Озын һәм куе, ялтырап торган. *Ул, барган уңайга, елбыр чәчләрен тарады.* А.Гыйләҗев

**ЕЛГА** *и.* 1) Башланган урыныннан койган җиренә кадәр табигый рәвештә салынган үзәнә буйлап туктаусыз агып торган шактый күләмле су агымы. *Идел шикелле җәелеп, ике арада Ашыт елгасы ага.* Р.Вәли

2) *күч. гадәттә тарт. форм.* Чиктән тыш күп күләм (сыеклык һәм бөртекле әйберләр турында). *Күз яшьләре*

*елгалар булып ага.* А.Алиш. *Ләкин аның күз алдына атасының башыннан агып төшкән кан елгалары килеп төшү белән, ул --- тиз генә Вәли бай йортына таба чапты.* Һ.Такташ.

3) *күч.* Нәрсәнең дә булса барышы, юнәлеше; агым. *Анда [райкомда] хәят елгасына юнәлеш бирелә, аның агышы тизләтелә, төрле чүп-чарлар, киртәләр алып атыла.* Ф.Садриев

**ЕЛГА-ЕРЫМТЫ** *җый. и.* Агып торган табигый елга һәм кар, яңгыр сулары ермачлаган яки махсус казылган төрле зурлыктагы канаулар, ермаклар. *Ул инде звенода эшләүче егетләрне токарлаудан уңайсызлана, елга-ерымты буйларын ялгызы гына эшкәртә иде.* Р.Фәизов

**ЕЛГА́ КОҢГЫЗЫ** *и. зоол.* Төклеканатлылар отрядыннан, кортлары һәм курчаклары – суда, ә үзе корыда яшәргә җайлашкан, тиз йөгерә, начар оча торган, озын җепсыман мыеклы бөҗәк; *русчасы:* **ручейник**

**ЕЛГА-КҮЛЛӘР** *җый. и. күпл.* Елгалар һәм күлләр; һәртөрле сулыклар. *Агачлар тәмам шәрәләнеп калды, елгалар-күлләр юка гына боз белән капланды, ялан-кырларга ак кырау ятты.* Ә.Еники. *Елга-күлләр өстендә, урман-кырлар кочагында кояш нурлары уйный, һавада яз исе, яшь яфраклар исе, үләннәр исе аңкый.* Мәдәни җомга

**ЕЛГАЛАП** *рәв.* Елга булып, бик күп. *Юк! Меңнәрчә-меңнәрчә яхшы кешеләребезнең тормышларын биреп, елгалап, каныбызны агызу бәрабәренә яулап алынган азатлыкны бернинди дошманга да бирмәбез.* М.Әмир

**ЕЛГАЛЫК** *и. сир.* Елга үзәне, коры үзәнлек. *Без шулчаклы тиз чабабыз инде: безгә дөньяда һичбер нәрсә күренми: әллә юлдан, әллә җир өстеннән, әллә тигезлектән, әллә елгалыктан барабыз шунда.* М.Гали

**ЕЛГА́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Су кәбестәчәләре семьялыгыннан, озын сабаклы, яфраклары өлешчә – су астында, өлешчә су өстендә йөзә торган вак чәчәкле су үсеме; *русчасы:* **рдест**

**ЕЛГАЧЫ** *и.* 1) Елга транспортында эшләүче кеше. *Пристань күперендә биреге килүче пароходларны каршылаучы елгачылар да балык каптырырга килгән олы яшьтәге бернича кеше – ямьшәйгән киез эшләпәле абзыйлар гына торып калды.* Г.Ахунов. *Әтисе – елгачы, Идел – Кама буйлап төрле калаларга йөк ташучы баржада капитан ярдәмчесе.* Г.Мөхәммәдиев. *Вахитов, Иделдә эшли башлагач, елгачылар тормышын тирәннән өйрәнергә кереште.* И.Низамов

2) Елга флотында хезмәт итүче. *Ләкин начальник риза түгел: әле өчдүрт көн генә элек кече лейтенант погоннары таккан елгачылар исәнләшә белмиләр, төрлесе-төрле вакытта, төрлечә кычкыра.* М.Мәһдиев

**ЕЛГАЧЫК** *и.* Инеш, тар һәм сай булган кечкенә елга. *Вакытлы буаның аскы ягыннан кечкенә генә елгачык чылтырап агып ята иде.* А.Алиш. *Елгачык чуерташлар өстеннән сырлана-сырлана йөгерә...* Ә.Еники

**ЕЛГЫ** *с.* **1.** Ничәнчедер елда булган, әзерләнгән, туган һ.б. *Киләсе елгы чыгарылыш имтиханына элекке шикелле дәүләт экзамены һәм диплом эше кермәячәк икән.* М.Юныс. *Телефон өзелгәч, Минзөфәр: «Узган елгы әкәмәтләреңне хатын әле дә төрттереп искә ала», – дип куйды.* Н.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ. күпл.* Кайсыдыр елда туган кеше. *Бакчы: хәтта 1918 елгылар да бар.* Ш.Маннур

**ЕЛГЫЙЛА́У** *ф. диал.* Һавада тирбәлү, тибрәнеп очып төшү. *Күп тә үтми, аккошның өч каурыйсы һавада елгыйлап очып күлгә төште.* Дастан

**ЕЛГЫР** *с.* **1.** 1) Җитез, хәрәкәтчән. *Елгыр юнкерлардан берәү сәхнәгә йөгереп менеп, кычкырып сөйли башлады.* Я.Чанышев. *Елгыр адымнар артыннан көчкә өлгерәм.* Р.Низамиев. *Ишек төбендә урта буйлы, гәүдәгә нык, төпле, елгыр карашлы бер егет басып тора иде.* Р.Мөхәммәтҗан

2) Үткен, булдыклы, сәләтле; өлгер. *Һәй, елгыр малай иде Муса.* Ф.Сафин. *Нина елгыр кыз ул, укый да, хатлар да ташый.* К.Латыйп

3) Хәйләкәр, мут. *Безнең картлар бик елгыр, машинагызның тәгәрмәчен чәлдермәсеннәр.* А.Гыйләҗев. *Тагын бер нәрсәгә игътибар итте сәүдәгәр: сатып алучылар арасында, кайдан, кем икәнлекләрен танытмаслык итеп, тоташ карадан киенгән елгыр адәмнәр күп.* Ф.Латыйфи. *Кызганычка, бар шундый «елгыр» шагыйрьләр. Бар.* Казан утлары

4) Зур тизлек белән хәрәкәтләнә торган. *Ирексездән ул юлларны, аларда чабышкан елгыр машиналарны бездәге чокыр-чакырлы, баткак-түмгәкле юллар, аларда ватылып яткан машиналар --- белән чагыштырдым.* Г.Тавлин

5) Кызу гына агып торган; йөгерек. *Төннәрен шактый гына салкыннар булгаласа да, елгыр елга туңарга өлгермәгән.* Җ.Рәхимов

6) *күч.* Көр, симез; көчле, нык. *Булачак хөкемдар җыелган халык алдына елгыр чабышкы өстендә килеп баса.* К.Нәфыйков. *Елгыр атын уйнатып, Сафа Гәрәй хан Казанга кайта.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиз-тиз, бик кызу. *Әй җибәрде чылбырын әйләндереп, Ут чәчә чылбыр да очкынландырып!.. Нинди елгыр әйләнә чылбыр хәзер! Бөтерелә чылбырда иблис зыр да зыр!* Ш.Бабич

2) Тиз арада, кызу (итеп). *Сулы кисмәкне урынына елгыр гына илтеп, кызлар йөгерешеп чыкмас борын, печәнлеккә таба атын юыртып китеп барды Рәхимҗан.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Елгыр зиһенле** Бик үткен, зирәк фикер йөртә алган. *Дошман белән бәрелеш вакытында солдатның физик яктан көчле һәм елгыр зиһенле булуы – бик мөһим нәрсә.* Х.Камалов

**ЕЛГЫРЛАНУ** *ф.* Елгырга әйләнү. *--- елгырланып, анда-монда чапкан су чикерткәләрен кудылар ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Яңа ел җитә башласа, иске ел елгырлана, койрыгын тоттырмый башлый.* Ф.Садриев

**Елгырлана бару** Торган саен ныграк елгырлану. *Елдан-ел елгырлана бара әмир Хаҗи угланы.* М.Хәбибуллин. *[Актырнак] Шулай йөртә торгач, көннән-көн исәя, елгырлана барды.* З.Фәйзи

**Елгырлана башлау** Елгырлыгын күрсәтү

**Елгырлана төшү** Бераз елгырлану

**Елгырланып бетү** Тәмам, бик нык елгырлану

**Елгырланып җитү** Үтә елгырлык дәрәҗәсенә ирешү

**Елгырланып китү** Тагын да елгырлану. *Бик ярата Алмаз маэмаен, Чакыра аны: «Кил, – дип, – Акбаем!» Эте килә чабып янына... Елгырланып киткән тагын да!* Ә.Кари

**ЕЛГЫРЛЫК** *и.* Елгыр булу үзлеге. *Фаягөл – Туймазы кызы – эшендә үтә елгырлык күрсәтеп, утлар уйната белсә дә, тормышта – болай юаш кына, йомшак кына холыклы җан иясе.* Э.Касыймов. *Һәм шул арада, яшь егетләргә хас бер елгырлык белән, Асиягә күз кысып алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев. *Инде өлкәнәеп килүенә карамастан, яшьлек елгырлыгын саклаган --- Лукьянов та баштарак сәерсенеп куйды.* М.Маликова

**ЕЛГЫСЫЗЛАНУ** *ф. диал.* Авыру, курку һ.б.ш. сәбәпләр аркасында, (ләкин физик арудан түгел) аяк яки кулларның вакытлыча тою сәләтен югалтуы, хәлсезләнүе, егәре китү. *Хәтта җиләклекләргә барсаң да, шушы [землемер] баганаларын күргәч, синең кулыңнан савытлар төшеп китә, --- кулларың елгысызлана.* Г.Галиев

**Елгысызлана бару** Торган саен ныграк елгысызлану

**Елгысызлана төшү** Бераз елгысызлану

**Елгысызланып бетү** Тәмам, бик нык елгысызлану

**Елгысызланып китү** Кинәт елгысызлану

**Елгысызланып тору** Бераз, күпмедер вакытка елгысызлану

**ЕЛДАГЫ** *с.* Ел да кабатланып килгән, ел саен була торган. *Хәлфә дә, елдагы гадәте буенча, Коръән укып, сәдака җыеп йөрер өчен, җәй башыннан ук авыллар арасына чыгып китә.* Ә.Еники

**ЕЛДАГЫ́ЧА** *рәв.* 1) Һәр елдагы кебек, һәр елны кабатланып килгәнчә, ел саен булып торган шикелле. *Елдагыча зарыгып көтелгән җәй башы иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Дәүләтҗан ул көлне, яз җиткәч, елдагыча үлчәми-нитми, басуга таратырлар дип уйлаган иде.* Р.Шәрифуллин. *Елдагыча башта митинг булды, шофёрларга бүләкләр тапшырылды.* Т.Нәҗмиев

2) *Теге, шул* алмашлыклары янында килеп, сөйләүчегә билгеле булган үткән елларда булганча. *Факиһә нәкъ теге елдагыча итеп елмаеп алды.* М.Мәһдиев

**ЕЛДАМ** *с.* **1.** 1) Җитез, өлгер, тере. *Дәү әнием минем – соргылт күзле, йомры гына гәүдәле, --- ачык һәм елдам карчык.* А.Расих

2) Хәрәкәтчән, тиз йөрешле, җәһәт. *Елдам пароход, суны икегә ярып, түбәннән югарыга таба чабып менеп килә иде.* И.Гази. *Елдам, уенчак, чекри күзле, озын койрыклы хайваннардан да кызыграк нәрсә юктыр дөньяда!* А.Расих

3) Үткен, булдыклы, эшлекле. *Берсе уңган, берсе елдам, Берсе – алдынгылардан.* Җыр. *Әмма ул эшен тиз тота торган елдам бәндә булып чыкты.* Г.Тавлин. *Елдам ирдән елан да кача алмый шул!* Р.Сибат

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз, кызу итеп. *Ат шулхәтле өлгер, елдам чаба иде ки, күз төшүгә сикереп атланасы килеп китә.* М.Хәбибуллин. *[Фарукҗан] Сәгатенә күз салгач, ашыгып киенде, солдат гадәтенчә, елдам гына юынды.* Т.Әйди

**ЕЛДАМЛАНУ** *ф.* Елдамга әйләнү, җитезләнү; тизлекне арттыру. *Кайтыр юлга чыккач, ат та елдамлана.* Мәкаль

**Елдамлана бару** Елдамланганнан елдамлану, елдамлыгы торган саен арту

**Елдамлана башлау** Елдамлану билгеләре барлыкка килү

**Елдамлана төшү** Бераз, берникадәр елдамлану

**Елдамланып җитү** Тәмам елдамлану

**Елдамланып китү** Бераз елдамлану

**ЕЛДАМЛЫК** *и.* Елдам булу. *Ул, үзе дә сизмәстән, гүя, аларның елдамлыгын, җитезлеген сынап карагандай, уң кулының бармакларын кыймылдатып ала.* Г.Бәширов. *Мортазин күзәтүчәнлек, елдамлык кебек сыйфатлардан мәхрүм түгел иде.* В.Имамов

**ЕЛДАН-ЕЛ** *рәв.* Ел саен, һәр елны, еллар үткән саен. *Соңгы елларда Фәттах әфәнденең тавышы елдан-ел зәгыйфьләнә бара дигән бер хөкем халык арасында тарала башлаган иде.* Ф.Әмирхан. *Авылда картлар елдан-ел кимеп бара иде.* Р.Вәлиев. *Ә менә ишегалды ягы бөтенләй ачык, андагы тавык кетәклекләре, баз өстендәге куыш, хәтта мунча да елдан-ел җиргә иңә, искерә бара, җил алар өстеннән уйнаклап кына уза.* М.Маликова

**ЕЛДАШ** *и. сөйл.* Берәрсе белән бер үк елда туган, бер елдагы кеше; яшьтәш. *«Кордаш», «елдаш» дип әйтәсе урынга аңа Сабир шулай «годок» дип эндәшә.* А.Хәлим

**ЕЛДЫРУ** *ф. сөйл.* **1.** Берәр әйбергә төбәп ыргыту яки шуңа таба шудырып җибәрү. *Хәлим, бик каты кизәнеп, бер таш кисәгән кыекка таба елдырды.* И.Гази

**2. елдырып** *рәв. мәгъ.* Җәһәт, җәлт, бик тиз. *Ала тәкәгә атланып, елдырып кына узсаң, теге якта җитмеш хур кызы кочагын җәеп тора инде...* Г.Сабитов

**Елдыра башлау** Елдырырга тотыну

**Елдыра бирү** Елдыруын дәвам итү

**Елдырып бетерү** Барысын да елдыру

**Елдырып җибәрү** Кинәт, бөтен көчкә елдыру

**Елдырып тору** Әле, хәзерге вакытта елдыру; бертуктаусыз елдыру

**ЕЛДЫРЫМ** *и.* **1.** 1) Җәй көне, арыш өлгергән вакытта, кичләрен, төннәрен бик еракта – офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; аҗаган. *Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында ул күк күкрәүсез яшен елдырымны, никтер, «рәшә уйнау» дип атыйлар.* А.Хәмидуллин

2) *диал.* Яшен. --- *бөтен тирә-якны сызылып яктырткан елдырым балкышындагы төсле [күзаллады].* Т.Әйди

3) Нинди дә булса утлар уйнау чагылышы. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов

4) *күч.* Берәр өлкәдә аз вакыт эчендә эз калдырган күренекле кеше. *Үзе дә әдәбият тарихында якты эз калдырган, мәдәниятебез күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь*

*турында мондый сүзләр язып калдырган ---.* Л.Хәмидуллин

5) *күч.* Көтмәгәндә һәм тиз арада булып алган нинди дә булса физик яки рухи халәт, психик күренеш. *Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды.* Х.Камалов. *Теге вакытта тәрәзә ваткандагы кебек, тәнемнән кинәт чиксез бер рәхәт елдырым йөгереп узды.* С.Хафизов

**2.** *с. мәгъ. күч.* Елгыр, җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем. [Гарифҗан:] Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н.Исәнбәт

**ЕЛ ИСӘБЕ** *и.* Шартлы рәвештә алынган нинди дә булса тарихи бер моментка мөнәсәбәттә вакытны еллар белән күрсәтү системасы. *Андагы иң борынгы таш һиҗри ел исәбе белән – 822, милади буенча 1420 елга туры килә.* М.Әхмәтҗанов

**ЕЛКЫ** *и.* 1) Ат. *Дөньяны күп күргән, күп елкы асраган картлар колынның да, туганда башка төстәрәк булса да, әзрәк үскәч, алмачуарга әйләнәчәген алдан беләләр икән.* Г.Ибраһимов. *Балчык белән сыланган мондагы иске сарай кайчандыр бер байның елкылар абзары булган.* Ч.Айтматов

2) Иркендә, утлауда йөргән ат. *Биек тауның башларында елкы йөри көтүсез.* Җыр

3) Эшкә җигелмичә, иркендә йөртеп, сугымга дип симертелгән ат; сугым аты. *Тауда ятты, тай бакты, Кырда ятты, куй бакты, Елкы бакты – кол булды, Өстендә ямар тун булды.* Дастан. *Башкорт елкы ите генә ашый, җәен – кымыз, ә кышын сары май эчә, ашына корт яки катык ката.* Р.Камал. *[Габдулла:] – Симез генә елкы ите үлчәп җибәрсен әле дигән иде дәү апа, – диде.* Ә.Фәйзи

**ЕЛКЫЛДАВЫК** *с.* 1) Бер кабынып, бер сүнеп торган, ялт-йолт килеп торган. *Шофёр елкылдавык утны бер кабызып, бер сүндереп торды.* Б.Камалов

2) *күч.* Елык-елык килгән, җемелдәп торган; асыл, затлы. *Алтын-көмешләр, елкылдавык затлы мехлар – болар бар да русларга соңлап килгән әкияти хыял.* М.Галиев

**ЕЛКЫЛДАТУ** *ф.* 1) Ялтырату, якты нурлар сибү, нурлар уйнату. *Махсус машиналар, түбәләрендәге шәмәхә утларын елкылдатып, күңелдәге шомны тагын да арттырып, шул ук вакытта нииндидер ышаныч та биреп, гөрләп узып киттеләр.* М.Маликова. *Диңгез тубыктан аңа хәзер, күкрәгендәге орден-медальләрен елкылдатып, җиңел машинада район буйлап җилдерә.* Г.Тавлин

2) Берәр нәрсәнең өстен ялтыраганчы чистарту, шомарту; матурлау. *Ботинканы елкылдату*

**Елкылдата башлау** Елкылдатырга тотыну

**Елкылдата бирү** Елкылдатуын дәвам итү

**Елкылдата төшү** Тагын да бераз елкылдату

**Елкылдатып алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында елкылдату

**Елкылдатып йөрү** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында елкылдату. *Көрән күк йоннарын тыйнак кына балкыган кояшта елкылдатып йөрүче бу изге җан ияләренең тавышлары да нинди-дер серле, моңлы һәм шаукымлы икән.* Г.Гыйльманов

**Елкылдатып кую** 1) Аз гына, бер тапкыр елкылдату. *Болыт арасыннан чагылып киткән кояш роза таҗларындагы чык тамчыларын елкылдатып куйды.* Казан утлары

2) Елкылдаган хәлгә китерү; алдан ук елкылдату. *Туфлиләрен кичтән елкылдатып куйган иде*

**Елкылдатып тору** Һәрвакыт, әледән-әле елкылдату. *Талант бит ул – ат, атны да бит тәрбия кылырга кирәк: ашатырга-эчертергә, юып, ялын тарап, елкылдатып торырга кирәк.* Р.Батулла

**ЕЛКЫЛДА́У** *ф.* Берәр нәрсәнең өслегендә яктылык нурлары кире чагылып ялтырау; җем-җем килү. *Керфекләр майлы суда чылаткан кебек елкылдый.* Р.Батулла. *Ерак түгел, атлас тасмадай елкылдап, зур су җәелеп ага.* Ф.Бәйрәмова

2) Ялтырап, уйнаклап тору, елтыр булу. *Ыруг җирләре күп, хәтта чикләре дә мәгълүм түгел: болын-тугайларында елкылдап чапкан елкы көтүе; елга-күлләрендә балык, кондыз; аюлар гына менгән карт юкә, имән куышларында кыргый корт балы...* Х.Сарьян

**Елкылдап алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада елкылдау. *Кулына бәйләнгән сәгате елкылдап ала.* Р.Батулла. *Ут яктысында йокычанның сары туны бер елкылдап алды да... сәйлән күзләр юкка чыкты.* М.Рәфыйков

**Елкылдап калу** Берәр тәэсирдән елкылдаган хәлгә килү. *Төп корпусның паркет идәннәре көзгедәй елкылдап калды.* М.Хәсәнов

**Елкылдап китү** Кыска вакытка, кинәт, ара-тирә елкылдау. *Өстән төшкән яктылыкта чәче, бер борылганда, ничектер җәй килеп, куе коңгырт ефәктәй затлы төскә кереп елкылдап китте.* Г.Бәширов. *Мизгел эчендә елкылдап киткән ул караш кызгану түгел, ышаныч белән тулы иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Елкылдап кую** Бер тапкыр елкылдау

**Елкылдап тору** 1) Бертуктаусыз елкылдау; һәрвакыт, гел елкылдау. *Тирәк яфраклары балавызланган шикелле елкылдап тора.* М.Юныс. *Язның көмеш кояшы астында бөтен дөнья елкылдап тора.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Мал-туарның симезлеге күренү, көрлеге беленеп тору. *Тимерхан Шәехеч --- бүлмәләрнең дәү йозакларын ача һәм нәфис гәүдәле, елкылдап торган сылу атларны коридорга җитәкләп алып чыга.* Ф.Сафин. *Атлары симезләр, елкылдап торалар, аклы-каралылары да, аклы-сорылы төстәгеләре дә бар.* Г.Ахунов

3) *күч. сөйл.* Киемнең кыйммәтле, затлы, яңа булуына ишарәләү. *Рашатның өстендә чем-кара кыйммәтле костюм-чалбар, кофе төсендәге күлмәк, муенында куе зәңгәр галстук, аякларында елкылдап торган шундый ук кара төстәге затлы туфлиләр.* Ф.Садриев

**Елкылдап яту** Әле, хәзер елкылдаган хәлдә булу. *Кызыл бәрхет эчендә ак тимер җәзбә, каләмнәр елкылдап ята иде.* М.Маликова

**Елкылдый бару** Торган саен ныграк елкылдау

**Елкылдый башлау** Елкылдарга тотыну

**Елкылдый бирү** Елкылдавын дәвам итү

**Елкылдый төшү** Бераз елкылдау

**ЕЛКЫЛДАУЛЫ** *с.* Елкылдап торган, җем-җем иткән. *[Сабыйның] Аксыл сары, елкылдаулы чәче тап урталай, Киек каз юлы ясап аерылган.* Р.Батулла

**ЕЛКЫЛДЫК** *с. к.* **елкылдавык**. *Баскыч буенча өскә менеп килгән кешенең бераздан киң читле ак эшләпәсе, елкылдык, зәңгәрсу крепдешин күлмәк итәге, җиңнәре, кулбашы күренә башлады*. Н.Фәттах

**ЕЛКЫЧЫ** *и.* Елкылар көтүче, елкылар көтүен караучы. *[Мирза:] Юк инде, монысы булмас, даладагы елкылар, елкычылар шәһәрдә яши алмас.* Р.Батулла

**ЕЛКЫЧЫЛЫК** *и. сөйл.* Елкы үрчетү эше, елкы асраучылык

**ЕЛЛАГАН** *с.* 1) Яше тулган, бер яшьлек булган. *Бу йөз илле сум бурычны --- түләү өчен, бер ат, йөз пот бодай, еллаган чуар үгез кереп китте.* Г.Ибраһимов

2) Бер яки берничә ел торган, саклanган. *[Сәхип байның ындырында] Еллаган кибәннәр каралып --- утыралар.* С.Рафиков

**ЕЛЛАП** *рәв.* 1) Ел дәвамында, һәр ел саен. *Еллап түгел, айлап-көнләп алга бара бит хәзер тормышыбыз.* Р.Төхфәтуллин

2) *сир. к.* **еллыклап**. *[Шаһибәк] Юаш, акыллы күренгәнгә, аны [Байморзалар] кайтармыйлар, еллап хезмәткә яллыйлар.* Г.Ибраһимов

3) Саннар белән килгәндә, җөмләгә «чама белән, якынча» дигән төшенчә өсти: «... ел чамасы», «... елга якын». *Ниса кайнанасы белән ике еллап яшәп калды.* М.Хуҗин. *[Әти] Сигез еллап югалып торган, әллә диңгез, океаннар кичеп йөргән инде.* Р.Кутуй. *Башта Фәйзулла абый үзе, аннан аның карчыгы вафат булганнан инде унбиш-егерме еллап вакыт узган.* Н.Хәсәнов

4) Ел буена, еллар буена

5) *күч.* Бик озак. *[Шәмсия ирена:] Бар, алайса, еллап йөрмә, мин хәзер мичкә ягам.* Т.Гыйззәт

**ЕЛЛАП-ЕЛЛАП** *рәв.* Елныкын елга аерып, аерым туплап. *Шүрлекләргә еллап-еллап куелган журналлар --- элек юк иде.* Г.Әпсәләмов

**ЕЛЛАРДАГЫ́ЧА** *рәв.* Үткән елларда булганча, моңарчы кабатланып килгәнчә, гадәттәгечә. *Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин Русия кояшы бүтән еллардагыча нурын киметми, дөнья йөзенә, чыраен сытып, салкынлык бирергә ашыкмый.* Г.Тукай. *Сәет тә моңа ышана, элек еллардагыча, урыс Казанга килеп җиткәнче үк таркалып качар дип өметләнә иде.* Ф.Латыйфи

**ЕЛЛА́РЧА** *рәв.* 1) Еллар буенча, күп еллар дәвамында. *Елларча тау тишегендә ятып чыккан кыяфәттәге бу кешеләрне күреп, Габделкаюм бик нык гаҗәпләнде.* М.Гали

2) Бик озак, ел кебек. *Шушы берничә айга кыска гына аерылу аңа [Саҗидәгә] елларча озак тоелды.* С.Рафиков

**ЕЛЛАТУ** *ф.* Ел буена саклау (тоту, карау, тәрбияләү). *Әнә саклыгым да бар, өч кибән еллатам.* Г.Ибраһимов. *Өч үгез еллатам, өч сарык кышлатам...* Г.Бәширов

**Еллатып чыгу** Билгеле бер вакытның башыннан ахырына кадәр еллату

**ЕЛЛА́У** *ф. сир.* Ел буе тору, еллар буе саклану, елларга исәпләнү

**ЕЛЛЫК** *с.* **1.** 1) Төгәл бер ел өчен каралган, бер ел эчендә үтәлергә тиеш булган. *Еллык күрсәткечләр буенча, ул узган ел совхозда да беренче урынны алган иде.* М.Мәһдиев. *Ваклап түләгән өчен, еллык процент та түләргә кирәк.* В.Юныс. *Еллык норма 10–15 китап тәшкил итә.* Мәдәни җомга

2) Бер елга исәпләнгән, бер елга җиткән, җитәрлек булган. *Үткен сәүдәгәр бу базарда еллык мая туплый, малын алыштыра, бәхәсләшә, тарткалаша, сата, ала, алдый, алдана.* Ф.Латыйфи. *Малайлар --- җәйләрен еллык утын кисеп яру, печән әзерләү --- кебек эшләрне бөтенләе белән үз кулларына алалар.* Р.Төхфәтуллин. *Ул, беләсең килсә, үзенең түш кесәсендә генә дә синең еллык зарплатаң хәтле акча йөртә!* Н.Акмалов

3) Бер ел эчендә башкарылган. *2002 ел ахырында һәм 2003 ел башында барлык җирле үзидарә советлары рәисләре үзләренең еллык эшчәнлекләре турында халык җыеннарында хисап тоттылар.* Т.Нәҗмиев. *Колхозның еллык уңышлары өчен унбиш мең сум премия бирелгән.* Р.Сибат. *Әхмәтсафа статистика бүлегенә ел ахырында килгәнгә, еллык исәп-хисап, бөтен мәгълүматларны мәркәзгә җибәрү дә аның өстенә өелде.* Ф.Сафин

4) Бер ел булган, бер елга каралган. *Айлык түгел, еллык түгел – Гомерлек яр булаем.* Җыр. *Ладога суының еллык тирбәлеше алай зур түгел, тик бер метр чамасы гына.* А.Муранов. *Кояшның еллык хәрәкәткә ия булуын инде борынгы астрономнар да белгәннәр.* Астрономия

5) Елга бер тапкыр чыга торган // Елга бер тапкыр уздырыла торган. *«Җим чәчәк» – --- яшьләрнең еллык йоласы.* Сөембикә

6) Бер ел эчендә барлыкка килгән, формалашкан. *Хәйретдин түмәрдәге еллык боҗраларны санарга керешә.* Я.Хамматов

7) Саннар белән килгәндә: шул сан күрсәткән елга исәпләнгән, җитәрлек булган яки шул вакыт дәвамында башкарыла торган. *[Искәндәров:] – Сөт буенча ярты еллык планны үтәү бик авыр булачак, – дип сөйләп китте.* М.Маликова. *Шулай да барыбер бер атна эчендә өч еллык материалны кабатлап бетереп булмас, әйдә, су коенып килик.* М.Юныс // Шул ел эчендә тупланган. *Көймәче ишкәкләрне үзенә алды, гомер иткән чал картның Зур Суда бер еллык кына булса да тәҗрибәсе бар иде.* З.Хөснияр. *Яшь хәдим әле --- меңмең еллык белем, тәҗрибә тупланган, борынгыларның бүгенгеләргә җиткерәселәре язып калдырылган ул акыл хәзинәсенең кыйммәтен тулы дәрәҗәсендә күз алдына китерә алмый иде.* Ф.Латыйфи. *Минем бит, дигән, унике еллык эш тәҗрибәм бар.* Г.Бәширов

8) Шул сан күрсәткән яшьтә булган, шул ел үскән, шул ел яшәгән. *Аның күкрәвеннән арысланнар калтыранып, ул чыгарган давылдан мең еллык калын имәннәр сыгылмыйлармы?* Г.Коләхмәтов. *Урманнарында меңәр*

*еллык карт наратлар, чыршылар, җәен-кышын яшәреп, шаулашып утыралар.* Г.Ибраһимов. *Менә мин дә җитмеш еллык гомеремнең илле елын сездә уздырган идем.* Т.Гыйззәт

9) Нинди дә булса вакыйгага ничәдер ел үткән, тулган. – *Бу безнең мәхәббәтнең бер еллык юбилеена миннән бүләк булсын, – дип пышылдады.* Д.Каюмова. *Районыбыз газетасы үзенең 75 еллык юбилеена әзерләнә.* Т.Нәҗмиев. *Тукайның 90 еллык юбилее вакытында, ул [Хәсәнов] Арчага атнасына ике мәртәбә кайтып йөрде.* Г.Ахунов

**2.** *рәв. мәгъ.* Саннар һәм *яшәрү, картаю* фигыльләре белән килгәндә, сан күрсәткән елга тиң дәрәҗәдә, шул күләмдә, шуңа торырлык. *[Әхмәтҗан:] Синең хатыңны алгач, хафамнан, өч көн эчендә ун еллык картайдым.* Г.Камал

**3.** *и. мәгъ.* 1) Уку елында дүрт чирекнең нәтиҗәләреннән чыгып, гомуми билгеләр куела торган ахыргы өлеше. *Урыс теленә җитәрлек дәрәҗәдә игътибарлы булмаган укучыларны ул әледән-әле чиреккә, еллыкка «начар» кую белән, икенче елга класста утыртып калдыру белән куркыта.* Н.Фәттах

2) Нинди дә булса вакыйгага шул көннән алып ничәдер ел үтүен, тулуын билгеләп үтә торган дата. *Октябрьнең 12 еллыгы уңае белән, шул яңа клубта доклад һәм спектакль булачак иде.* М.Гали

3) **еллыгы** *тарт. форм.* Бер ел өчен исәпләнгән нәрсә (мәс., *хезмәт хакы*). *Имеш [Сабир], --- авылга кайтып, еллыгы егерме сум торган ялчылар белән беррәттән сабан сөреп йөрсен!* Г.Ибраһимов

**ЕЛЛЫКЛАП** *рәв.* Ел исәбеннән түләү тәртибендә. *[Фәтхетдинов] Миңа үзенең байда еллыклап хезмәт итүен сөйли.* А.Таһиров

**ЕЛМАГАЙ** *с. диал.* Елмаючан, елмаюлы. *Ялагай дус елмагай.* Әйтем

**ЕЛМАЕП-КӨЛЕП** *рәв.* Шаярып, уйнап; елмайган, көлгән булып. *Җәен Бөгелмәдән машинасына утыртып кайткандагы кебек, бәлки, елмаеп-көлеп кенә, тагын кул салып карарга җай эзли торгандыр?* Г.Бәширов. *Иртән эшкә килгәндә, вахтадагы каракучкыл егет янында басып тора идең, мине күргәч, аның белән елмаеп-көлеп үк сөйләшә башладың.* Ә.Баянов. *Кичтән кәеф-сафа коргандагы шикелле елмаеп-көлеп кенә, тикшерүче сорауларына җавап бирәләр.* Мәдәни җомга

**ЕЛМАЕШУ** *ф.* Ике яки берничә кеше үзара бер-берсенә карашып елмаю. *Давыт читтән генә аларның биегәнен, сөйләшкәнен, елмаешканын күзәтеп торды.* М.Маликова. *Бер-беренә елмаешып, нидер сөйләшәләр.* Н.Хәсәнов

**Елмаеша башлау** Елмаешырга тотыну. *Гаҗәеп бу адашлыктан кызык табып елмаеша башлыйбыз.* Р.Батулла

**Елмаешып алу** Тиз арада, кыска гына елмаешу. *Бик озак тын торгач кына берсүзсез елмаешып алдык.* Г.Исхакый

**Елмаешып кую** Бер тапкыр елмаешу. *Бу сүз уйнатуга, бар да елмаешып куялар.* Ә.Фәйзи. *Зал халкы, үзара пышы-пышы сөйләнеп, бер-беренә елмаешып куйдылар.* Г.Ибраһимов. *«Кызык» диюгә үк, кызлар дәррәү елмаешып куйдылар.* Р.Вәлиев

**Елмаешып тору** Бертуктаусыз, һәрвакыт елмаешу. *Тыйнак кына утырырлар, Елмаешып торырлар.* Р.Миңнуллин. *Егет белән кыз елмаешып кына тора.* Ш.Галиев

**ЕЛМАЮ** *ф.* **1.** 1) Шатлану, канәгатьләнү, риза булу һ.б.ш. хисләрне, йөз (ирен, күз) хәрәкәтләре ясап, тавышсыз белдерү; көлемсерәү, авыз еру. *Интизар мәгънәле итеп елмайды да урынына утырды.* Р.Вәлиев. *Бар күзләрдә елмаю һәм җылы күрәм --- Авылымны хәтеремә ныграк үрәм.* С.Гәрәева

2) *күч. шигъ.* Ай, кояш, йолдыз һ.б. яп-якты булып, балкып, нур сибеп тору. *Көмеш ай елмайган кичләр тупыллар түбәсендә.* Г.Афзал

3) *күч.* Ялтырау, җемелдәү. *Бары тик ак клавишлары гына, ап-ак тешләргә охшап, елмаеп, балкып тора.* Р.Вәлиев

**2.** *и. мәгъ.* Нинди дә булса хистойгыны яки кемгә-нәрсәгә булган мөнәсәбәтне белдерү өчен ясалган көлүгә охшашлы йөз (ирен, күз) хәрәкәтләре. *[Сәет] Һәр авазга җавап биргәндәй, башын селкеп, «ыһы, ыһы, ыһы» дияргә кереште, саргылт мыегы астыннан, ялтырап, ак тешләре күренде, битенә канәгать елмаю чыкты.* Ф.Латыйфи. *Кояш елмаюын тойган урам рәхәтләнеп ята.* Ә.Баянов. *Елмаюы күңелгә рәхәтлек биреп тора.* Н.Хәсәнов

**Елмаеп алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына елмаю. *Дилбәр, язучы ягына карап, «Менә күрдегезме, нинди юк-барга ышаналар!» дигәндәй, иңбашларын сикертеп, елмаеп алды.* Г.Бәширов. *Факиһә нәкъ теге елдагыча итеп елмаеп алды.* М.Мәһдиев

**Елмаеп җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә елмаю. *Кичәге ачуымны искә төшереп елмаеп җибәрдем.* Ш.Усманов. – *Сүзне бушка сибә торган гадәт юк анысы. Килештекме, – дип, авыз читләреннән төкерек чәчеп елмаеп җибәрде ул [Нәҗип].* Р.Мөхәммәдиев. *Аннары, үзе дә сизмәстән, авыз тутырып елмаеп җибәрә.* Р.Вәлиев

**Елмаеп кую** Кинәт һәм кыска гына елмаю. *Фидая үзалдына елмаеп куйды: «Сөйләсеннәр, әйдә! Эшләре генә уң булсын!»* М.Маликова. *Әминә белән бокаллар чәкештергәндә, инде күптән күргән төшем искә төшеп, елмаеп куйдым.* Р.Вәлиев. *Шофёр халкы кояшлы көн сыман итеп елмаеп куя.* Ә.Баянов

**Елмаеп тору** 1) Һәрвакыт, гел елмаю. *Күк йөзе төсле якты түшәмнән, кояш кыйпылчыгына охшап, сүрән лампочка елмаеп тора.* Р.Вәлиев. *Ул чәчәк һаман синең йөзең кебек елмаеп тора.* Н.Дәүли

2) Сөйләү моментында елмайган хәлдә булу. *Фатыйма, нәрсә әйтергә белмичә, алдына караган килеш елмаеп тора иде.* Ш.Камал

**Елмая бирү** Һаман елмаю, елмаюын дәвам итү. *Нәсимә, елмая биреп, кнопкага гына басты һәм үз-үзенә дәшкән сыман: «Ач инде тизрәк!» – дип куйды.* М.Вәли-Барҗылы

**Елмая төшү** Бераз, җиңелчә елмаю. *Ул бертуктаусыз үзенең матур күзләре белән Мәрьямгә карый да, бик аз гына елмая төшеп, йөрәгенең әллә кай җиреннән кайнап килгән бер тойгы-*

*сын сөйли.* Г.Ибраһимов. *Фидая, елмая төшеп: – Эш бармый әле, – дип көрсенеп куйды.* М.Маликова. *– Һәй, абзый кеше, – дип, чертләтеп читкә төкереп алды бригадир һәм канһгать елмая төшеп тезеп китте. – Билләһигазим, сәер кеше икән син...* Р.Мөхәммәдиев

**ЕЛМАЮЛЫ** *с.* Йөзенә елмаю билгеләре чыккан, елмаеп торган; ягымлы, күркәм булган. *Ул, үзенә ике яктан бөгелгән бүрекле башларга, дага сакалларга, елмаюлы йөзләргә игътибар итмичә, туп-туры Нәҗипкә каршы китте.* А.Гыйләҗев. *Инде Сәгыйдулланың калын мыегына да соргылт төс кунды, үзе көлмәсә дә, һәрчак елмаюлы булган күзе эчкә батып, уйчанланып калды.* Ә.Гаффар

**ЕЛМАЮЧАН** *с.* Еш елмая торган, гадәттә елмаерга яраткан. *Сәхнә түрендә күпләргә таныш йөз. Һәр авылда, һәр калада бар шундый гади, сагышлы елмаючан йөзләр.* Р.Миңнуллин

**ЕЛНАМӘ** *и. к.* **елъязма**. *Алар арасында югарыда күрсәтелгән сүз ясагыч мәгънәле елнамә – аерым тарихи шәхесләр турында еллап язып барылган язма, истәлек, гомумән чор, дәүләт турындагы язмаларны туплаган елъязма.* Р.Мөхиярова

**ЕЛТ** *иярт.* **1.** Эш-хәрәкәтнең бик тиз, кинәт башкарылу рәвешен белдерә. *[Басыйр Бариевич] Очлы ияген каккандай итеп исәнләште, машина ишеге кинәт елт ачылды, төргәк кулдан-кулга күчте.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Зур тизлек белән, тиз генә, җәһәт. *Мингазый абый елт кына миңа карап алды.* М.Кәрим

2) Тиз һәм кискен хәрәкәт белән, импульсив рәвештә, кинәт, капыл. *Сафа елт кына урыныннан сикереп торды да карчык янына барды.* Ю.Әминов. *Мирсәет исә елт кына аның өстенә үк менеп атланды.* Р.Мөхәммәдиев

**3.** *хәб. функ.* Кинәт кенә, көтмәгәндә зур тизлек белән юкка чыгу. *[Балыкны] Ачык калдырсаң, сикерә-сикерә, сикерә дә – елт!* Ш.Камал

**ЕЛТ-ЕЛТ** *иярт.* **1.** *к.* **елт 1.** *Кояшка җылынырга чыккан кәлтә елан елт-елт яфраклар арасына кереп югалды.* И.Гази

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) *к.* **елт 2.** *Алар, шөгыльләреннән туктап, тагын кем комачаулый дигәндәй, башларын күтәреп, муеннарын тырпайтып, елт-елт карагандай иттеләр.* Г.Үзиле

2) Бер-бер артлы, тиз-тиз, еш. *Карип абый елт-елт бер директорга карап куя, бер – Исмай әзигә, гаризасын язганчы, бөтенләй тирләп пеште.* Ш.Алпар. *Күзләрне елт-елт йому*

**ЕЛТ-ЕЛТ ИТҮ** *ф.* 1) Елтырау; якты нурлар уйнатып җемелдәү. *Бал-май ашар үзләре, Елт-елт итәр күзләре.* Такмак. *Минем манто елт-елт итә.* Г.Афзал

2) Хәрәкәт вакытында тиз-тиз йөрү, күренеп китү, күзгә чалынып калу. *Имән бармагына тишекле-тишекле уймак кигән сөякчел кулы елт-елт итеп тукыма кисәге өстендә йөри.* М.Галәү

**ЕЛТ-ЕЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **елт-елт итү**. *Елт-елт килеп тора иде, Горур иде каргалар.* Ш.Галиев. *Елт-елт килеп торган юргалар... Кемгә – тарих, Кемгә – риваять.* И.Иксанова. *Хатынның башына бәйләнгән зәңгәр тасмасы җилферди, тоташ актан булган күлмәге астыннан юантык чәркәләре елт-елт килә.* М.Хәбибуллин

**ЕЛТ ИТҮ** *ф.* 1) Бик тиз генә, тиз арада күренеп, селкенеп, чагылып китү. *Каршындагы куаклык арасында, елт итеп кенә, нindидер саргылт нәрсә күренеп алды.* Г.Бәширов. --- *чибәр кызлар икенче почмакта бертуктаусыз сөйләшәләр, көлешәләр һәм, сирәк-мирәк булса да, елт итеп, егетләр ягына күз аталар.* Р.Сибат

2) Яп-якты булып, балкып алу, ялт итү. *Өй тәрәзәсеннән, елт итеп, ут күренә.* С.Җәләл

**ЕЛТЫН-ЕЛТЫН** *иярт.* **1.** Эш-хәрәкәтнең тиз генә, кызу, сиздермичә генә башкарылуын белдерә. *Астан гына елтын-елтын карау*

**2.** *рәв. мәгъ.* Анда-монда карангалап, шикләнерлек итеп. *Нindидер бер кеше баядан бирле, елтын-елтын, йорт тирәсен күзәтә*

**ЕЛТЫР** *иярт.* **1.** Ялт-йолт ялтырап, җем-җем итеп җемелдәп тору рәвешен белдерә. *Иртән үләннәрдә, энҗе сипкән кебек, елтыр тамчылар җемелди*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Елтыравы, җемелдәве белән күзгә бәрелеп торган. *Ул, чыннан да, башка иде шул: аякта елтыр ботинка, өстә «шәһәрски» күлмәк-чалбар.* Р.Низамиев. *Еракларга сузылып киткән елтыр юеш рельслар, күперләр, юл кырыендагы кечкенә өйләр, сарайлар, поезд артыннан, байтак вакытка кадәр тынычлана алмыйча, гүләп, жуылдап торалар.* Г.Бәширов. *Шунысы истә калган: күз төбендә мин аның нәни генә елтыр тамчы яшь бөртекләре күрдем.* Р.Сибат

2) *күч.* Очкынланып, ялтырап торган, бик хәрәкәтчән. *Әҗәм картны кара мыеклы, зур елтыр күзле, гаскәриләр киемендәге чибәр егет сурәте алыштырды.* Ф.Латыйфи. *Ул [Микәй] да үзенә текәлгән елтыр күзләрнең кадерен белергә тели торгандыр.* Р.Мөхәммәдиев. *Каш-керфекләре астыннан елтыр күзләренең очкыны чагылып-чагылып кала.* С.Шәкүров

3) *күч.* Үткен; хәйләкәр, мут. *Бик үткен, елтыр егет күренә*

**ЕЛТЫРАВЫК** *с. к.* **елтыравыклы**. *Ул үзенең кыяфәте өчен – ап-ак күлмәк якасы, пөхтә эшләпәсе, галстугына кадаган елтыравык булавкасы өчен оялды.* М.Маликова

**ЕЛТЫРАВЫКЛЫ** *с.* Елтырап, җемелдәп торган. *Брежнев кесәсеннән елтыравыклы нәни тартма чыгарды да, иелеп, ачарга кереште.* Ф.Садриев

**ЕЛТЫРАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **елтырау**. *Аннан беркадәр калышып, погоннарын, китель төймәләрен, күкрәгендәге гвардия значогын елтыратып, озын буйлы чибәр лейтенант килә иде.* Н.Фәттах. *Күземне йомар хәлем юк, әллә кайдан гына килеп чыга да тешләрен елтыратып көлеп тик тора.* Ф.Хөсни

2) Берәр нәрсәнең өстен ялтырагалганчы чистарту, шомарту; матурлау. *Зәйтүнә кыска җиң бөрмәсеннән кульяулыгын алды да велосипедны елтыратып сөртергә кереште.* М.Маликова

3) *күч.* Күзләрне очкынландыру; уйнакландыру, мутландыру. *Шаян күзләрен елтыратып, Гайнанның ачык изүенә, таралмаган бөдрә чәченә карап торды.* Г.Бәширов

**Елтыратып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада елтырату. *Билге тешләрен елтыратып алды*. Б.Рәфыйков

**Елтыратып кую** Елтыраган хәлгә китерү

**Елтыратып тору** 1) Һәрвакыт, гел елтырату

2) Сөйләү моментында, әле, хәзер елтырату. *Алардан бераз арттарак беренче күрүдә үк егетнең йөрәгенә ут салып өлгергән Заһидә коңгырт күзләрен елтыратып тора*. Ф.Сафин. *Эх, мәлгунь, алтын тешен елтыратып тора бит әле, җитмәсә!* Ф.Баттал

**ЕЛТЫРА́У** *ф.* 1) Ялтырау, җемелдәү, нур чәчү. *Юл буендагы үләннәрдә чык тамчылары елтырый.* Н.Фәттах. *Аның йөзе балкый, чем-кара мыеклары астыннан ап-ак тешләре елтырый.* Ф.Латыйфи

2) *күч.* Берәр төрле хис белдереп очкынлану. *Кечкенә күзләре куаныч белән елтырыйлар.* Ә.Еники. *Ул, кызның күңеле тулгандыр, елый torгандыр дип уйлаган иде, әмма, якынрак килгәч, аның күзләре күмердәй елтыраганын күрде.* М.Маликова. *Елмаябыз, яшьлегебез безнең Киләчәктә озак яшәр дип. Күзеңдә тик елтырый сары моңмы, Мөлдерәмә торган яшьләрме.* Ә.Баянов

3) *күч.* Майланган шикелле ялтырау (йөзгә, күзгә чыккан исереклек билгесе). *Азрак төшереп тә алган үзе, күзләре елтырый.* Ф.Хөсни. *Балчык кувшиннардагы шәраб кимегән саен, Касыймның күзләре ныграк елтырый, сүзләре кими.* Ф.Латыйфи. *Аның аракы эчүдән һәм кайнар ризык ашаудан тирләгән йөзе хәтәр елтырый иде.* Ф.Садриев

**Елтырап алу** Кыска вакыт эчендә, азга гына елтырау. *Асяның зәңгәрсу күзләре зураеп ачылды, күз аклары көмештәй елтырап алды*. Х.Камалов

**Елтырап китү** Кинәт, көтмәгәндә елтырау. *Егетләрнең аракыны эчә белүләре немецка ошады булса кирәк, кечкенә күзләре, караңгыда утырган мәченекедәй, елтырап китте.* Ә.Еники. *Рәхмәтинең күзлек пыялалары елтырап китте.* Ш.Маннап

**Елтырап кую** Кыска вакытка, азга гына елтырау. *Аның әйләнеп төшкән калын кабаклары астындагы кысык күзе хәтәр елтырап куйды.* Ф.Хөсни

**Елтырап тору** Һәрвакыт, гел елтырау. *Кашлары нечкә һәм матур, ләкин аның маңгаена әле генә, менә шушы арада гына сызылгандай --- бер-ике генә бөртек ак чәче елтырап тора иде.* Г.Бәширов. *Компания агенты буылабуыла йөткерә, күзләре бизгәктән елтырап тора.* Д.Лондон

**Елтырап яту** Елтыраган хәлдә булу; тыныч бер иркенлектә булу. *Аста Зәйчә инеше елтырап ята. Бакчада гаҗәеп агачлар, гаҗәеп гөлләр үсә, түгәрәк күлләр елтырап ята, чылтыр-чылтыр, чишмәләр агып тора.* Ә.Еники

**Елтырый башлау** Елтырарга тотыну. *Хәдичә хатын янә Айбибигә килеп сыенды һәм елтырый башлаган күзләре белән хан кызына карады*. М.Хәбибуллин. *--- иң элек аның йөзе көләчләнде, шуннан бу аның күзләренә күчте, иреннәре ярым ачылып, тешләре елтырый башлады*. Д.Бүләков

**Елтырый бару** Торган саен ныграк елтырау

**Елтырый бирү** Һаман да елтырау, елтыравын дәвам итү. *Чү! Кемнең анда күз төпләрендә яшь тамчысы елтырап китте? Күрмәгез, елтырый бирсен.* И.Гази

**Елтырый төшү** Тагын да ныграк елтырау

**ЕЛТЫРГЫЧ** *и. диал.* Кармакка беркетелгән елтыравыклы металл пластинкадан гыйбарәт балык тоту кирәк-ярагы; алдавыч. *Нинди елтыргычларым бар – һәммәсен [кармакка] куеп карадым.* Ә.Исхак

**ЕЛТЫР-ЕЛТЫР** *иярт.* **1.** *к.* **елтыр**. *Елтыр-елтыр май кайный.* Н.Исәнбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* Елтырап, ялтыравык нурлар уйнатып, җемелдәп. *Кызларның, хатыннарның алъяпма бавы берлә нечкәләнгән билләре өстеннән язгы ак су кеби агып төшкән озын сачтакмалары ---, кулларындагы нечкә үткен уракның селкенүе берлә селкенеп, кояшка каршы елтыр-елтыр уйныйлар ---.* Г.Исхакый. *Җәйге кояшлы көндә тирән яр төбеннән көмештәй инешнең елтыр-елтыр уйнаклавын күрерсең.* Ф.Сафин

**ЕЛТЫ́Р-ЕЛТЫР ИТҮ** *ф. к.* **елтырау**. *Еракта-еракта, елтыр-елтыр итеп, тычкан күзе хәтле генә бер ут күренә.* Әкият. *Зиндан капусы янындагы елтыр-елтыр иткән фонарьга якынрак килгәч, --- бер адәм икәне аңлашылды.* Ш.Мөхәммәдев

**ЕЛТЫ́Р-ЕЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **елтырау**. *Күзләре ачылды – елтыр-елтыр килеп яналар.* Ф.Гыйззәтуллин. *Нәрсә булса булды, соры ерткыч та, Микәйгә охшатып, арт аякларына чүгеп, карга утырды. Күзләре елтыр-елтыр килә.* Р.Мөхәммәдиев

**ЕЛТЫ́Р-ЕЛТЫР КИТЕРҮ** *ф. к.* **елтырату.** *Чөнки аның, мәче күзләрен елтыр-елтыр китереп, мал карагандай сөзеп каравы, мышнаулары мине чиркандырды.* Г.Кутуй. *Ә еракта, калай түбәсен елтыр-елтыр китереп, ялгыз йорт сәлам биреп тора...* Л.Шәех

**ЕЛТЫРЫЙК** *с. к.* **елтыравыклы**. *Мин Мәгъсүмгә күренмәслек итеп баскан идем, идәннән түшәмгә тоташкан, елтырыйк уенчыклар, төрле төстәге лампочкалар асылган зур чыршы арабызны бүлеп тора.* М.Маликова

**ЕЛТЫРЫК** *с. к.* **елтыр 2.** *[Ибрай малайларга:] Күргән-белгәннәр сезнең елтырык борын төбеннән бик ерак китми шул инде хәзер.* Ш.Маннап

**ЕЛУ** *и. диал.* Сулыкларда кышын су катмаган ачык урын. *Күп төрле меңнәрчә кошлар: акчарлаклар, кайралар, чистиклар, давыл кошлары, гагаралар, бакланнар, шөлдиләр боз араларында һәм елуларда туенып йөриләр.* Дөньяда ниләр бар

**ЕЛЪЯЗМА** *и.* 1) Ил, шәһәр яки берәр төбәкнең тарихи вакыйгалары турында даими теркәлеп барылган еллык язма; шундый язмалардан торган китап. *Н.Я.Бичурин Кытай елъязмасы «Вейшу»дан төркиләрнең Бодынинли исемле башы шәрә биек тауны изгеләштерүләре хакындагы хәбәрне китерә.* Г.Дәүләтшин. *Әй, ни генә дисәң дә, Сафагәрәйнең тәхеткә кайтуы – олы җиңү, елъязмалар бизгәге булырлык бөек вакыйга.* Ф.Латыйфи. *Елъязмалар фәлән-фәлән елларда коточкыч хәлләр булуны аеруча басым ясап әйтергә һич тә онытмаганнар.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Басылып чыккан яңа китаплар турында белешмә биреп бара торган (*атналык, кварталлык, еллык*) библиографик журнал. *1930 елдан Китап палатасы чыгара башлаган «Китап елъязмасы» (хәзерге «Татарстан Республикасы матбугат елъязмасы») да әнә шул максатка [нәшер ителгән барлык басма продукцияне туплау, библиографик эшкәртү һәм саклау вазифасына] хезмәт итә.* М.Вәлиев

**ЕЛЪЯЗМАЧЫ** *и.* 1) Елъязма (*1 мәгъ.*) язучы. *– Борынгы елъязмачылар безгә караганда бик күпкә акыллырак, күп тапкырлар гаделрәк булган, – дип башлады Таһир сүзен.* Н.Акмалов. *Юл йөргәндә, олылар ни сөйләсә, ни маҗарага тап булсалар, Зөннар шуны яза йөрде. Ул Сафа ханның елъязмачысына әверелде.* Р.Батулла

2) *күч.* Заман, чор вакыйгаларын матур әдәбият әсәрләрендә чагылдырып баручы язучы яки журналист. *Халык, милләт булып сакланып калырга телибез икән, иҗат кешеләренең, шул исәптән заман елъязмачылары – язучыларның кадерен белик!* Мәхмүт Әхмәтҗанов

**ЕЛЪЯРЫМЛЫК** *с.* Бер һәм тагын ярты елдан торган. *Аны әле алда тагын елъярымлык солдат хезмәте көтә иде.* З.Хөснияр

**ЕЛЫЙ-ЕЛЫЙ** *рәв.* 1) Елап, күз яшьләре белән. *Иплән кенә Халитне сәкегә салды да елый-елый ипи кисеп булашкан хатынының кулыннан пычагын алды ---.* З.Зәйнуллин. *Әни кеше моңа чиксез куана һәм Вәлиевкә рәхмәтләрен мең тапкырлар әйтеп чыгып китә дә зиндан капкасына таба елый-елый йөгерә.* Ф.Яхин. *Янына барсам, ыграк елый башлый, бармасам, елый-елый да, тынычланып, йоклап китә.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Теләмичә, үз-үзенә каршы килеп, авырлык белән. *Мин елый-елый имтихан биргәндә, ирем шакката иде.* Безнең гәҗит. *Мәсәлән, Малогвардейская урамында яшәүчеләр елый-елый күченә.* Ватаным Татарстан

**ЕЛЫК** *иярт.* Кинәт кенә балкып китү, ялтырап китү рәвешен белдерә. *Су өстен шадралап, елык ялтырап, балык сикерә*

**ЕЛЫК-ЕЛЫК** *иярт.* **1.** Нур сибү, ялтырау, җемелдәү рәвешен белдерә. *Якынлаша барган саен, Казан да ачыклана бара – чиркәүләр бик күп икән, алтын гөмбәзләре, елык-елык, нурда уйныйлар.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Нур сибеп, ялтырап, җемелдәп. *Ул үзенең матурлыгы, көрлеге белән, куе кара ялларының, атлаган саен, әнә шулай дулкынланып елык-елык җилфердәве, муенының дугадай бөгелеп килүе белән, җирән байтал яныннан горурланып узды.* Г.Бәширов

**ЕЛЫ́К-ЕЛЫК ИТҮ** *ф. к.* **елкылдау**. *Ул озын кызыл тырнаклы бармаклары белән канәфер чәчәкләрен бөтерә, атсыз бармагындагы балдак елык-елык итә.* М.Маликова

**ЕЛЫ́К-ЕЛЫК КИЛҮ** *ф. к.* **елкылдау**. *Кич гаражына чыгып караса, «Волга»сы, елык-елык килеп, үз урынында тора.* Р.Вәлиев. *Малайга аларның елык-елык килеп торган аеллы күн каешлары да, бүрекләрендәге матур йолдыз да, янтыкларындагы кара кобуралары – барысы да кызык һәм мавыктыргыч иде.* Р.Кәрами

**ЕЛЫК ИТҮ** *ф.* Елкылдап алу, ялтырап кую. *Зәңгәр гөмбәз эчендә, чекерәеп, йолдызлар җемелдәшә, әнә Таң йолдызы, елык итеп, аңа якты нурын сирпеп алды.* Р.Мөхәммәдиев

**ЕЛЫК-ЯЛЫК** *иярт. к.* **елык-елык**. *Яңа ел чыршысының бизәкләре елык-ялык җемелдәшәләр*

**ЕЛЫ́К-ЯЛЫК КИЛҮ** *ф. к.* **елкылдау**. *Таңсылуга нәрсә: авыз мыймылдык, күз-каш тирәләре каймаланып бизәлгән, колак алкалары болыт арасында уйнаган яшендәй елык-ялык килә.* А.Гыйләҗев

**ЕЛЫМ** *и.* Балык тота торган ау, ятьмә. *«Өй» димәсәң, хәтере калыр: дугаыңгырчак, камыт бөятләре, елымнар, җәтмәләр арасында аның тар гына агач караваты бар иде.* Я.Зәнкиев

**ЕЛЫНДА** *рәв.* Бер ел эчендә, бер ел вакыт арасында. *Ат – аенда, ир елында танылыр.* Мәкаль

**ЕЛЫН-ЕЛ** *рәв. сөйл.* Ел саен, һәр елны, ел да. *Тау белән елга арасында яткан тар гына бер мәйдан булганлыктан, ул [җир] елын-елда буш кала.* Ә.Еники

**ЕЛЫШТЫРУ** *ф.* 1) Бер-беренә якын китерү, араны якынайту; якын итеп кую. *Милиционер «Медицинский справочник»ларны Мотаһирга таба этәрде, ә кара тышлы дәфтәрне үзенәрәк, өстәл читенәрәк елыштырды.* Р.Кәрами. *Ачык йөк машинасының шәрә кузовына, селкенә дә алмаслык итеп, кырык кешене бер-беребезгә елыштырып утырттылар.* Г.Тавлин

2) Янтаю, бөкрәю. *Гәүдәңне таугарак елыштыр, әйләнеп китә күрмә!* Р.Фәйзуллин

3) *диал.* Якынайту, иярләштерү. *[Әптерәй] Ишекне бикләп, аркылы такта сукты. --- Соры мәче боегып кына бер читтәрәк утыра иде. – Син, Гатифә, мәчене үзегезгә елыштыр инде, – диде Сирай бабай.* Г.Сабитов

**Елыштыра бару** Берсе артыннан берсен елыштыру, һәрберсен бер-бер артлы елыштыру

**Елыштыра бирү** Һаман да бер якка елыштыру, елыштыруын дәвам итү. *Мондый хәлне күрмәгән әтәч, зур, көчле гәүдәсен елыштыра биреп, урам якка сыпырта.* З.Зәйнуллин

**Елыштыра төшү** Бераз, тагы да елыштыру

**Елыштырып бетерү** Берәр нәрсәгә бик якын итеп, ара калдырмыйча терәтеп елыштыру

**Елыштырып кую** Елыштырган хәлгә китереп калдыру. *[Апалар, җиңгиләр] Түгелмәсен дигәндәй, сөт тулы чиләкләрен сак кына ак алъяпкычларына таба елыштырып куйдылар.* Р.Мөхәммәдиев

**Елыштырып тору** Әле, хәзерге вакытта елыштыру

**ЕЛЫШУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә якын ук килү, якын урнашу, әкрен генә якынаю. *Ул, аякларын көчкә сөйри-сөйри, купега керде дә, хәлсезләнеп, утыргычка елышты.* Р.Вәлиев. *Куркудан айнып киткәндәй булган Тәнзилә --- стена буена елышты.* З.Фәйзуллин

2) Шуышу, үрмәләү. *Бигрәк тә өченче рота солдатлары алга нык елышалар.* С.Җәләл. *Һәм китте ул, җиргә елыша, елыша, Күкрәк канын тамызып ак карга. Ә лазарет – урман арасында... Ерак әле, ерак аңарга.* Ш.Маннур

3) Бик якын килеп хәрәкәт итү. *Зенитчыларның яки ракеталы җайланмаларның утыннан котылыр өчен, самолётлар я бик биеккә, стратосферага чаклы күтәрелергә тиеш булалар яки җиргә елышып ук очалар.* Казан утлары

4) Кемгә яки нәрсәгә дә булса якын килү, якынаеп урнашу; янына күчеп утыру яки басу. *Гармунчы янына елышкан яшьләрдән читтәрәк галифе чалбар күземә чалынып китте.* Ә.Гаффар. *Фарукҗан сәер абзыйга кызыксынып бер карап алды да, халыкны ерып, тагын да мәйдан уртасынарак елышты.* Т.Әйди. *Мөгезле эре терлек үкерә, гасабиланып, алгы аягы белән җир тырный башлый, атлар пошкыра, сарыклар, тетрәнеп, бер-берсенә елыша, бөтен җәйләү хәрәкәткә килә.* А.Расих

5) Берәрсе күрмәслек итеп, нәрсәгә дә булса сыену, ышыклану, яшеренү. *Ләкин Чаев бу ят кешене никадәр генә танып-хәтерләп калырга тырышмасын, ул, шуны сизенгән кебек, гел күләгәгә, караңгыга табарак елышты.* З.Фәтхетдинов. *Якында елга күренә, ләкин Баязит аңа барып җитә алмады, беренче очраган чокырга сикерде, тузан бөртегенә әйләнердәй булып, җиргә елышты.* С.Сөләйманова. *Югартын бар нәрсәне изеп, сытып, ватып, чәрдәкләп, әвәләп ишелеп төшкән кар ташкынынннан кыяның тар кыегы астына елышып, үзе аша уздырып җибәргәч, бөтен күкрәге белән тауның сыек һавасын сулап алдымыни.* Ә.Гаффар

6) Кемнең дә булса куенына керү, кочаклау яки аңа бик якын килеп басу, сыену (иркәләнеп яки яклау эзләп). *Учак янына утыргач, кыз Таһирга елышты: – Сиңа рәхмәт, абый, – дип, аның куенына керде.* Н.Акмалов. *Ятсытылып, кыерсытылып яшәгән ятим бала, ямансылаган саен, миңа елыша: «Рабига енгәм, нигә минем әсәем юк?» – дип, сулыгып-сулыгып елый торган иде.* М.Әмир. *Шуны сизгәндәй, мәче үткен тырнаклары белән костюм якасына ныграк ябышты, кешеләрчә бер наз белән Сафинга елыша-елыша, ялварулы аваз чыгарды.* Г.Дәүләтказин

7) Кемнең дә булса яклавына таяну, аркалану. *Шуңа күрә кем куша, шуңа елыша.* Ф.Садриев. *Буйсындырылган халыкларның аксөякләре дә Сарай тирәсенә ныграк елышалар.* М.Мәхмүтов. *Моның өстенә илдә иминлек китеп тора: чирмешләр мәскәүлеләргә елышырга җыеналар.* М.Хәбибуллин

8) Берәр яхшы урынга эшкә урнашу. *Минемчә, кибет тирәсенә елышсаң, хәзерге заманда бер дә начар булмас, улым.* З.Хөснияр

9) Нәрсәгә дә булса бик якын урнашу, янәшә булу. *Күл читендәге биек наратлар артына биек койма белән уратып алынган ике катлы мәһабәт бина елышкан.* Р.Мөхәммәдиев. *Тәрәзәләргә сирень куаклары елышкан.* Р.Кутуй

**Елыша бару** Әкрен генә елышу, елышканнан-елышу, торган саен ныграк елышу. *Кызы, аның саен атасына елыша барып, аның тезенә башын куеп, тыныч кына әйтте.* Р.Батулла. *– Син әйт кенә, – диде Шәмсүн, Гөлфинурга елыша барып, – мин сиңа бөтенесен эшләрмен.* А.Вергазов

**Елыша башлау** Елышырга тотыну

**Елыша бирү** Һаман да елышу, елышуын дәвам итү

**Елыша төшү** Бераз, аз гына, тагы да елышу. *Кызлар, аналарына елышкан иркә балалар кебек, хискә бирелеп, Фәрхана апага елыша төштеләр, берсе бер яктан, икенчесе икенче яктан аның күкрәгенә капландылар.* Н.Фәттах. *Светлана, Озерцовка елыша төшеп: «Әнә теге өч егет безнең арттан килмиләрме?» – диде.* Р.Мөхәммәтҗан. *Кулларымны угалап, учакка елыша төштем.* Р.Сибат

**Елышып бару** *к.* **елыша бару.** *Габделфәрт, Эляга елышып барган җиреннән, берникадәр читкә авышты.* Х.Ибраһимов

**Елышып йөрү** Һәрвакыт якында булу, елышырга тырышу. *Активист булып, стена газетасы чыгарып, безгә елышып йөри иде...* Х.Камалов

**Елышып китү** Кинәт елышу. *Ничектер бервакыт ул бөтен гәүдәсе белән миңа якын ук елышып китте.* Ф.Әмирхан

**Елышып калу** Кемгә яки нәрсәгә дә булса елышкан хәлдә булу, елышырга өлгерү. *Аларны ул елларда «сундук» дип йөртәләр, алар, «гражданкада» – авыр тормышта яшәүдән куркып, көненә өч мәртәбә ашата һәм даими рәвештә киендерә торган җирдә елышып калган кешеләр иде.* М.Мәһдиев. *Эреле-ваклы ак һәм соры боз кисәкләре, бер-берсен куышып, каядыр алга, алга омтылалар, кайбер кечерәк, көчсезрәк бозчыклар зур бозлар арасыннан бөтерелеп килеп чыгалар да ярга елышып калырга тырышалар, кайберләре елышып калалар да.* Ә.Фәйзи

**Елышып кую** Искәрмәстән бераз елышу. *Шунда Мәмдүдә, үзе дә сизмәстән, куркынган нарасый кебек, иренә елышып куйды.* Ә.Фәйзи

**Елышып тору** 1) Һәрвакыт, гел елышкан хәлдә булу, бер-беренә якын ук тору. *Озын буйлы, карашы да ипле, ояла да белә, күзләре дә Котбыйныкы шикелле бер-берсенә елышып тормыйлар.* М.Хәбибуллин

2) Һәрвакыт, гел кемгә яки нәрсәгә дә булса елышу, сыенган булу. *Алар инде шактый аралашып өлгергән, шуңадырмы, кыз Саҗидә янынарак елышып тора иде.* Н.Акмалов

3) Әле, хәзер, сөйләү моментында елышкан булу. *Алар, абый белән эне кебек, беркавым бер-берсенә елышып тордылар.* Р.Сибат

**ЕНОТ** *и. гар. зоол.* **1.** Янутсыманнар семьялыгыннан, кыйммәтле мехы өчен үрчетелә торган, кечкенә гәүдәле, куе сары йонлы имезүче ерткыч җәнлек, янут

**2.** *с. мәгъ.* Шул җәнлек мехыннан эшләнгән, тегелгән. *Енот тун*

**ЕПА́РХИЯ** *и. гр.* Чиркәүнең административ берәмлеге. *Василий II нең тездән яңа төшкән улларын Муром чиркәвенә алып килделәр. Тиешле гыйбадәтен кылып, Рязань епархиясе карамагына аларны булачак митрополит үз куллары белән кабул итеп алды.* Равил Вәли

**ЕПАРХИАЛЬ** *с.* Епархиягә мөнәсәбәтле, епархиягә караган. *Моннан тыш, Казан, Уфа, Вятка, Оренбург, Томск семинарияләрендә, шулай ук епархиаль училищеларда да байтак кына керәшен егет һәм кызлары белем алган.* М.Глухов

**ЕПИ́СКОП** *и. гр. дини* 1) Христиан чиркәвендә руханилык вазифасының югары дәрәҗәсе. *Хәлифә Гомәр заманында дини кинәшче вазифасын гына башкарган мөфтиләр, рим-христиан чиркәве мисалында, рәсми дин башына куела башлыйлар, ягъни аларга шул ук епископ вазифалары йөкләнә.* И.Әмирхан

2) Шушы дәрәҗәгә ия булган зат. *Шулай да Кавказ хәзәр-болгарларын чукындырырга килгән албан епископы Исраэл аны борынгы грек алласы Афродита иseме белән атый.* Г.Дәүләтшин. *Патриарх белән епископлар бу никахны законлы дип танымадылар.* С.Горский. *Шуннан күп тә үтми, Болгар епископы Габбасны үтерәләр һәм чиркәүгә ут төртәләр.* М.Хәбибуллин

**ЕПИ́СКОПЛЫК** *и.* Епископ дәрәҗәсе һәм теге яки бу епископның идарә итү вакыты

**ЕПШЕК** *с. диал. к.* **җепшек**. *Апрель аеның епшек бер кичендә без --- «Татар ашлары йорты»нда үткәрелгән мәҗлестә булдык.* Ә.Еники. *Бүген әзерләгән, әбиләр чәче кебек тип-тигез тарап, тырмалап куйган басу өстенә иртәгә, үч иткән сыман, тагын яңгыр сулары сибелде, аннан епшек кар явып үтте.* Г.Кашапов

**ЕРАГАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **ераклаштыру**. *Әмма ирләргә хас булганча төптән уйлану Нурхановның мөлаемлыгын киметмәде, тик аны серлерәк, аңлаешсызрак итте, [Давыттан] ерагайтты кебек.* М.Маликова. *Әллә нинди бер шаукым ерагайтты да ерагайтты Фирәзәне Искәндәреннән.* Г.Үзиле

**Ерагайта бару** *к.* **ераклаштыра бару**. *Габдулланың хыянәтеннән соң, алар кабат вакытлыча татуланышсалар да, автор алга таба аларны бер-берсеннән ерагайта бара.* Ф.Габидуллина

**Ерагайта башлау** *к.* **ераклаштыра башлау**. *Күп тә үтмәде, ул [самолёт] Зуфирәнең баш өстеннән очып үтте һәм Өмит белән ике араны минут саен күп чакрымнарга ерагайта башлады.* М.Маликова

**Ерагайта төшү** *к.* **ераклаштыра төшү**

**Ерагайтып бетерү** *к.* **ераклаштырып бетерү**

**Ерагайтып тору** *к.* **ераклаштырып тору**

**ЕРАГАЮ** *ф. к.* **ераклашу**. *Диңгездә ерагаеп күздән югалган җилкәндәй, әллә кая очып гаип булды.* Т.Әйди. *Миңа Казан биләмәләреннән чыгарбыз, ара ерагайган саен, күңеле суыныр дип өметләнә.* Г.Әпсәләмов. *Тыенкы гына ат кешнәде, тояк тавышлары бик тиз ерагайды.* Р.Төхфәтуллин

**Ерагаеп бару** *к.* **ерагая бару**. *Юлда басып калган Виленга кара «Волга» белән бергә ниндидер бер аяусыз, дәһшәтле көч ерагаеп барган кебек тоелды.* М.Маликова

**Ерагаеп калу** *к.* **ераклашып калу**. *Аның өчен инде Нәфисә ерагаеп калды, аның өчен хәзер ераклаша баручы Әхнәфне кабат элекке хәленә кайтару үтә мөһим нәрсәгә әверелде.* Ф.Садриев

**Ерагаеп китү** Кинәт ерагаю. *Ә Борһанның иреннәре, соңгы чиккәчә калынаюдан аралары ерагаеп китеп, пыяла кебек ялтырап торалар.* З.Фәйзи

**Ерагая бару** Торган саен күбрәк ерагаю. *Артта калган маяклар, агымга каршы аккан төсле булып, ерагая баралар.* Г.Гобәй. *Ә ул җырлар, туган яклардан ерагая барган саен, отыры җанга ятышлырак, кадерлерәк була бара.* Г.Ахунов. *«Ерагая барам түгелме мин аннан? – дип уйланды ул. – Йа Ходай! Әле бит өйләнешкәнгә дә күпме генә...».* Р.Сибат

**Ерагая төшү** *к.* **ераклаша төшү**. *Зиннәт ерагая төшкәч, Нәфисә аңа тагын бер күз салды.* Г.Бәширов

**ЕРАК** *рәв.* **1.** 1) Зур ара белән; *киресе:* **якын**. *Сагынсаң да юк чаралар, Ерак булгач аралар.* Җыр. *Юллар озын, юллар ерак, тагын кайтып барышым.* Р.Низами. *Яшәсәк тә бер калада, Нинди ерак безнең ара. Йөрәгеңдә бармы җаның? --- Килер идең бер яныма.* Г.Садә

2) Озак, шактый, байтак, тиз генә түгел. *Урманнарны ул ерткычлардан тулысы белән чистартып бетерергә ерак әле.* Ш.Шәйдуллин. *– Иртә ич әле, – дип каршы төште Альберт, сәгатенә күз салып. – Имтиханнарга тикле ерак, укыйсы килми.* А.Тимергалин

3) *күч.* Кеше күрмәслек, белмәслек итеп, ышанычлы урынга качырып. *Мин, ераграк тыгып куйган акчамны чыгарып, вакыт үтсен өчен, буфетка кереп утырдым, ашарга-эчәргә китерттем.* А.Шамов

4) Кем яки нәрсә булу өчен «күп нәрсә җитми», «күп нәрсә кирәк» дигән мәгънәне белдерә. *Кояшта да тап була, дип, Тырышма акланырга; Бик ерак әле, туганкай, Сиңа кояш булырга!* Ә.Исхак

**2.** *с. мәгъ.* 1) Зур ара белән аерылган, озак үтелгән, якын булмаган. *[Хөсәенов] Ничек итсә иткән, [командирны] ерак кыр госпиталенә тапшырган.* М.Мәһдиев. *Ул әлегә бөтенләй үк түзә алмаслык түгел, әмма инде ерак офыктагы куркыныч кара болыт сыман, аның йөрәгенә таба үрмәли иде.* Г.Үзиле. *Кайсыдыр журналдан кисеп алынган бу сурәт сине, «ә» дигәнче, табигатьнең кул җитмәстәй ерак бер почмагына илтеп куя.* Р.Низами

2) Киләчәктә, алдагы көннәрнең берсендә булачак. *Алай-болай, ерак киләчәктә киленгә әйләнеп куйса (тфү, тфү! әйтмәгәнем булсын!), моның килеш-килбәте дә (тфү, тфү, күз тимәсен!) Аллага шөкер, эшкә дисәң дә, курка торган түгел.* Ф.Садриев. *Шул көннән башлап, Чыңгызның тормышында да бертөрле эзлеклелек, нур кебек туры, якты, ерак бер максат барлыкка килде.* З.Садыйков. *Әнисенә сыер алып бирү дә чынга ашмас, ерак бер хыял гына булып калды.* М.Әмирханов

3) Күптән үткән, әллә кайчан булган. *Ерак заманнарда тәкъдир кушуы аркасында гына аерылышканнардыр.* Ә.Баянов. *[Безнең] Үз милли телебез, культурабыз, әдәбиятыбыз, сәнгатебез, ерак гасырларга барып тоташкан бай тарихыбыз бар.* Г.Тавлин. *Саргаеп һәм теткәләнеп беткән берәр конвертны кулыңа алганда, --- үзеңне еллар аша ерак үткәннәрдән килгән хатның беренче шаһиты итеп сизә башлыйсың.* Казан утлары

4) *диал.* Әнисенең ата-анасына карата: гаилә эчендә бергә яшәмәгән.

*Һәм, шуны белүгә, шәһәрне үк ташлап, ерак әбисенең туган якларына китеп барды.* З.Хөснияр. *Безнең ерак бабай күреп белгән аны, Пётрны.* Г.Гобәй

5) Ата яки ана ягыннан гаиләгә, ыругка, кабиләгә нигез салган, башлап җибәргән. *[Гомәр Әбүбәкеровның] Ерак бабасы Юлыкка килеп беренче төпләнүчеләр исемлегендә китерелә.* М.Хәмидуллин. *[Мәмәт би] Ерак бабаларың дошманга тез чүкмәде, авызы тулы кан булса да, дошман каршында төкермәде.* Ф.Латыйфи

6) *күпл.* Моннан бик күп еллар элек яшәгән. *Димәк, монда, әле авыл барлыкка килгәнче дүрт-биш гасыр элек үк, ерак бабаларыбыз эз калдырган икән.* М.Хәмидуллин. *Төптән уйлап карасаң, бу – халыкның ерак бабаларыбызны хөрмәт итүе, минемчә.* Ә.Галиев

7) *күч.* Берәр нәрсәгә бөтенләй бәйләнеше, мөнәсәбәте булмаган. *Бу кичәләр хәтта җырлый белми торган һәм, гомумән, музыкадан ерак кешеләрнең дә дәртен кузгатты.* Ә.Фәйзи. *Комитет әгъзаларының, председателеннән башка, күпчелеге – әдәбият һәм сәнгатьтән бик ерак торган кешеләр.* Ә.Еники

8) *күч.* Чит, ят, кирәк булмаган. *Аның эчендәге өр-яңа ике дәфтәр белән «Казачий гаскәрдә балык тоту кагыйдәләре», школага килгән чакта, нинди кирәкле, нинди әһәмиятле әйберләр булса, хәзер алар шулкадәр кирәксез һәм Габдулладан ерак әйберләр булып калдылар.* Ә.Фәйзи

9) Өченче буыннан да якын булмаган уртак бабага кайтып кала торган (кардәшлек турында). *Рөстәм исә, актыккы сыйныфка күчкәндә, җәен дә укыштыргалармын, дип, Казандагы бер ерак кардәшләрендә кала.* С.Җәләл. *Воротынскийның Ирина исемле ерак кардәше бар иде.* С.Горский

**3.** *хәб. функ.* 1) *Иде* ярдәмче фигыле белән яки үзе генә килгәндә, субъектның җөмләдән аңлашылган нәрсәне белмәвен, аңламавын, аңа бөтенләй мөнәсәбәте булмавын белдерә. *Ул, дөньяда тагын кеше чәйни торган этләр дә бардыр, дип уйлаудан бик ерак иде.* И.Гази. *Ул туган телен белми, табигатьтән аерылган, халык тәрбиясе аңардан ерак.* Р.Рахмани. *[Кадыйров:] Кәефем даими бертөрлелектән ерак, юктан гына да үзгәрә, ягъни тотрыклы түгел, тая тора, диюем.* Г.Тавлин

2) Нинди дә булса эш эшләргә уйламавын, хәтта нияте булмавын белдерә. *Хәким дә немецларны бик җентекләп күзәтеп бара, ләкин Василий шикелле үк алай ашыгып нәтиҗә ясаудан ерак иде.* Ә.Еники. *Әмма Хәйдәр андый сорауны бирүдән, бу якларга «төпләнергә» дип кайткан яшьтәшенең хәлен белешүдән ерак иде.* Г.Үзиле

◊ **Ерак бара алмау** 1) Бернәрсә дә эшли алмау, уй-теләкне тормышка ашыра алмау. *Юкса, кеше арбасына утырып, ерак бара алмабыз.* Р.Ягъфәров; 2) Чыгыш килешендәге исем фигыльдән соң килеп, «башка берни дә эшли алмау» мәгънәсен белдерә. *Буржуаз язучылар ялгыз бунтарьлыктан, яхут өметсез ачынып елаудан ерак бара алмадылар.* М.Җәлил; 3) Теге яки бу ашамлыкның туклыклылыгы аз булуга ишарә йөзеннән әйтелә. *Әйдә, [пәрәмәч белән] сыйлыйм үзеңне ---. Балык белән ерак бара алмассың.* Ш.Камал. **Ерак барасы түгел** *к.* **еракка бармыйча**. **Ерак барасы юк** *к.* **еракка бармыйча**. --- *язучылыкны һәм әдәби тәнкыйтьне иҗаты буе бергә алып баручылар да аз түгел. Мисалга тагын да ерак барасы юк: кафедра доценты Зәет Мәҗитов шигырьләр яза, җыентыклар чыгара.* А.Әхмәдуллин. **Ерак булу** *к.* **ерак тору**. *Ләкин хәтерле җәнҗалның Нәгыймнең үзеннән еррак булуын теләгәнлектән, ул хәйләләшеп маташа иде.* Ш.Камал. *Үзен начар күрсәтүдән һәрвакыт ерак булыр.* М.Гали. **Ерак итү** 1) Нәрсәдән дә булса өлешсез калдыру. *Рәхмәтемнән сине ерак иттем, син калырсың мәңге хур булып.* М.Гафури; 2) Үз итмәү, читкә кагу, якын итмәү. *Шулай итеп, ул үз туганнарын үзенә ерак итте, алардан бизде, читтә үзенә карендәш тапмый җәфаланып үлде.* Н.Исәнбәт. **Ерак йөрү** Читтә булу, аралашмау. *Мин, гомумән, хатын-кызлардан ераграк йөрергә тырышам, алардан уңайсызланам.* Г.Тавлин. *Фән бик хикмәтле нәрсә инде ул, күп серләрне ачып бирә белә, тик минә Саҗидә апа тирәсеннән ул, «фән» дигәнебез, еракторак йөри шул.* Ә.Еники. **Ерак киная** Бик читләтеп әйтелгән сүз, фикер. *[Бирем әкә] Ерак киная белән китереп, --- йортны ак патшага кол итүдә булышлык иткән бабаларына күләгә ташлады.* Г.Ибраһимов. **Ерак китә алмау** *к.* **ерак бара алмау**. *Бала түгел ләбаса инде ул: белә иде, ишеткәне бар иде бит ялган белән ерак китеп булмаганны!* В.Нуруллин. *Ана бәддогасын алсаң, бик ерак китә алмассың.* Г.Камал. **Ерак китү** Зур уңышларга ирешү, үсү, дан казану. *Хуҗамның кәефе килде. «Молодец, --- бу юлда ерак китәрсең», – [дип] , --- мине канатландырып куйды.* Ш.Усманов. **Ерак тору** 1) Начар, күңелсез кешеләр белән аралашмау, якын итмәү; күңел ятмаган, начар эшләрдә катнашмау. *Беләсеңме, кореш, әгәр чын диңгезче буласың килсә, аннан ераграк тор.* М.Юныс. *Андыйлардан ерак торуың хәерле, дидем...* Ә.Фазылҗанов. *Гәрчә без бер-беребездән шактый ерак торсак та, мин аңардан шикләнми идем, гадел кеше булуына ышана идем.* Ә.Еники; 2) Бәйләнеше, мөнәсәбәте булмау. *Изге теләк сиңа һәммәбездән: Куркулардан, егет, ерак тор!* Ф.Бурнаш. *Сиңа таныш кеше түгел, бик-бик ерак торган кеше, теләсәгез таныштырырмын.* Ш.Камал

**ЕРАККА** *рәв.* 1) Ерак урынга, әлләкая. *Чөгендер кырлары да юл читеннән каядыр еракка сузылган яшел тасма рәтләр булып күкрәп утыралар.* М.Маликова. *Аның өчен моң бар, үзенең җиңел канатларында отыры биеккә, күккә, еракка алып киткән җыр бар.* Г.Ахунов. *Аннары, чалгысына таянып, моңсу күзләрен еракка, бик еракка – Вятка болыннары аръягына төбәде.* Р.Вәлиев // *кбт. форм.* Бик еракка. *Бу төсләр --- берсен-берсе куа торган төрле киемдәге кешеләр кебек, берсеннән-берсе узышып, еракка-еракка китәләр иде.* Г.Исхакый. *Дөнья үз канунына тугрылыклы шул; бер кергән суга яңадан кереп булмый. Без коенган су-

*лар олпат өянкеләр күләгәсеннән еракеракларга агып киткән, кабатлану булмый.* М.Галиев

2) *күч.* Киләчәккә, алга. *Еракка төбәлгән бик мәкерле исәп иде бу. Кайсы илнең, кайсы халыкның шундый корычтай нык, көчле, еракка карый торган акыллы юлбашчысы бар?* Г.Әпсәләмов

◊ **Еракка бармыйча** Читкә чыкмыйча, үзебезнең арадан. *Еракка бармыйча, ире Газдалны гына алыйк.* Ф.Садриев. **Еракка җибәрү** Ямьсез, тиргәү сүзләре белән куу; тынычта калдырсын өчен, ямьсез ачулану сүзләре әйтү. *Кисәтү ясаган өлкәннәрне «еракка җибәреп», кычкырып көлгән тавышлары бөтен йортны тынычсызлый.* Мәдәни җомга. **Еракка китү** *к.* **ерак китү**. *Кырыкка яңа гына җитеп килүче бер кеше, Заманов уйлавынча, еракка китәргә тиеш иде.* Ф.Сафин

**ЕРАКЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **ераклашу**. *Кайтыр диеп көтә ана, һаман еракла-на бала.* Мөнәҗәт. *Ул [Зыя], кыр, иген эшләрен ташлаганнан бирле, болай да авыл халкыннан аерылган, ераклангaн иде.* Г.Ибраһимов

**ЕРАКЛАП** *рәв.* 1) Ерактан, читтән; берникадәр ара калдырып. *Кайбер вакыт ялгыз бүрене аучылар ераклап әйләндереп алалар.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Кеше аркылы, башкалар аша. *Мин ераклап ишеттем, йөзендә, күзендә мөселман төсе юк, бөтен кыланышы коеп куйган марҗа гына дип әйтә икән, ди.* Г.Ибраһимов

**ЕРАКЛАТУ** *ф. сир. к.* **ераклаштыру**. *Куркынычлар юлны ераклатыр төсле.* М.Җәлил. *Ераклатып безне үткәннәрдән, Әйләнәләр-әйләнәләр дә, Сагынуларын җанның күтәрәләр Иң югары дәрәҗәләргә.* Х.Туфан

**ЕРАКЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Ераграк арага (урынга) күчерү. --- *сөттәй ак томан ул дәһшәтләрне үз эченә яшерә һәм кешедән ераклаштыра.* Ә.Еники

2) Берәр нәрсәнең үтәлү срогын кичектерү, соңрак вакытка күчерү

3) *күч.* Читләштерү, мөнәсәбәтләрен бозу, аралаштырмау. *«Берәү» дигәне – беренче яратканы, тугры булырга антлар итешкән, әмма язмыш ераклаштырган, нәкъ илле ел инде күз карашы, кыяфәте, гәүдәсе, күкрәк җылысы онытыла, күңеленнән җуела алмаган Мулланур.* Д.Каюмова. --- *авыл кешеләрен, бигрәк тә яшьләрне, авылдан, аның рухи дөньясыннан ераклаштыра, һәм, кем әйтмешли, шушы төбәккә бәйләп торган нечкә кыллар шартлап өзелә.* А.Вергазов

**Ераклаштыра бару** Акрынлап, азазлап ераклаштыру, торган саен ныграк ераклаштыру

**Ераклаштыра башлау** Ераклаштырырга тотыну

**Ераклаштыра төшү** Тагы да, берникадәр ераклаштыру. *[Әсәрдәге] Менә шул хәлләр һәммәсе бергә килеп, конфликт чишелешен ераклаштыра төшәләр.* Г.Нигъмәти

**Ераклаштырып бару** *к.* **ераклаштыра бару**

**Ераклаштырып бетерү** Соңгы чиккә җиткереп ераклаштыру

**Ераклаштырып кую** Кинәт ераклаштыру

**Ераклаштырып тору** Һәрвакыт, гел ераклаштыру

**ЕРАКЛАШУ** *ф.* 1) Билгеле бер урыннан ара ераклыгы арта бару. *Алар инде больница бинасыннан шактый ераклашканнар.* М.Маликова. *Күпме ераклашканын чамаларга теләп, ул артка – авыл ягына борылып карады һәм, әлбәттә, иң элек үзләренең өен күрде.* Р.Низамиев. *Аннары аның шәүләсе томандагы әйбер төсле сары булып кына төсмерләнә, ераклаша.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Вакыт үткән саен онытыла бару, артта калу; истәлеккә әйләнү. *Хат шул хәлендә сакланды, ә мәхәббәте, кайчандыр күргән бик матур хыялый төш шикелле, ераклашканнан ераклашты.* А.Шамов. *Ерагайган саен, Агыйдел буйларына, табигатькә тирәнрәк үткән саен, күңел кайтаргыч күренешләр дә ераклаша.* Г.Гобәй

3) *күч.* Берәр эш-хәлнең үтәлү срогы кичектерелү, озак вакытлардан соң булу, соңлау. *Ә Мәскәүдә аспирантурада укый башлагач, аның хыялларының чынга әверелү мөмкинлеге тагын да ераклашты.* В.Нуруллин

4) *сир.* Тормыштан, заман таләпләреннән артта калу. *Мәктәп-мәдрәсәләребез белән бергә [тормышыбыз да], заманнан шулкадәр ераклаша вә, тараеп, үзебезне кыса башлаган.* Ф.Әмирхан

5) *күч.* Аралашудан туктау, мөнәсәбәтләр акрынлап сүрелү, кызыксыну бетү. *Тик менә бәхетле булып киткән балалары аңардан, ничектер, шактый ераклаштылар шикелле.* Ә.Еники. *Баштарак бер нәрсә бимазалады: әти-әнисе, туганнары белән ара ераклашты.* А.Гыйләҗев. *Әтисенең исерек, бигрәк тә чайкала-чайкала кайтып кергән чагын күрсә, ул аны кызгана, аңардан ераклаша иде.* Р.Низамиева

6) *күч.* Читләшү, чит итү, якын күрмәү. *Әллә инде кояшы да бездән ераклашты шунда?* Р.Газизов

7) *күч.* Темадан, төп мәсьәләдән читкә китү, сүзне икенчегә бору, уйфикер икенче юнәлеш алу

**Ераклаша бару** Акрынлап, аз-азлап ераклашу, торган саен ныграк ераклашу. *Хәзер инде кулны селкетәсе дә юк, ул, граната тоткан уң кулын алга сузган килеш, талпына-талпына күккә оча, җирдән һаман саен ныграк ераклаша бара иде.* Р.Вәлиев. *Үткәненнән һәм рәнҗүләрдән ераклаша барып, ялгызлыкка һәм азатлыкка сусаган күңелнең биеккәрәк ашкынуы бу.* Р.Низамиев. *Инде офык артына таба тәгәрәгән кояш, артта калып, миннән ераклаша бара.* Н.Хәсәнов

**Ераклаша башлау** Ераклашырга тотыну. *Илгиз, чигенә-чигенә, өрәңге төбеннән ераклаша да башлаган иде инде.* Ф.Шәфигуллин

**Ераклаша бирү** Ераклашуын дәвам итү

**Ераклаша төшү** Тагы да бераз ераклашу. *– Сабыр итик, бераз ярдан ераклаша төшик, югыйсә хәзрәт ишетер, – диде икенчесе.* Ә.Фәйзи. *Зәкәрия армиядән йөреп кайткач һәм өйләнгәч, суга сикереп төшкән ярлардан бераз булса да ераклаша төшү өчен, --- ярыйсы ук мәшәкатьле чара уйлап тапты Ильяс.* Ә.Баян

**Ераклашып бару** *к.* **ераклаша бару**. --- *аның тавышы, ераклашып барган поезд тавышын хәтерләткәндәй,*

*кайтавазлар булып ерагайганнан-ерагая.* Д.Салихов

**Ераклашып бетү** Бөтенләй, тәмам, соң дәрәҗәгә җитеп ераклашу. *Бер-береннән ераклашып беттеләр. Бик күпләре якын бабаларының да исемнәрен белмиләр.* Ш.Җәләлиев

**Ераклашып җитү** *к.* **ераклашып бетү**

**Ераклашып килү** Ераклашу хәле эзлекле рәвештә артканнан арту. *Ашыгырга кирәк иде, чөнки эскадрон ераклашып килә.* А.Шамов

**Ераклашып тору** Әлегә, хәзергә, вакытлыча ераклашу. --- *ул онытылырга, аз вакытка гына булса да бу күз яшьле дөньясыннан аерылып, ераклашып торырга тели иде сыман.* Р.Бәшәр

**ЕРАКЛЫК** *и.* 1) Ерак ара. *Ильяс белән аның сөекле кешесе арасында – үлчәнмәгән ераклыклар!* Ә.Баян. *Авылдан ике километр ераклыкта сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә.* Ә.Еники. *Еллар аша, ераклыклар аша гел бер-берсенә тартылган, тартылачак җаннар бит без синең белән, улым.* С.Хафизов

2) *күч. сөйл.* Вакыт арасы. *Бу җәһәттән үзенә дә еллар ераклыгыннан караш ташлый.* Б.Камалов. *20–25 еллык ераклыкта калган шул кадерле мизгелләрне ничек сагынмыйсың?!* К.Тимбикова. *Тимергалиев шактый соң төшенгән бер нәрсә булды: ул ераклык дистанциясен аерып җиткерми, еракка йөгерүчеләр өчен бер сулыш, якынга йөгерүчеләр өчен икенче сулыш кирәк икәнне белми иде.* Г.Ахунов

3) Әйбер, предмет яки кешеләрне бер-берсеннән аерып торган ара озынлыгы. *Рифкать, башын борып, артка карады һәм кул сузымы гына җирдә, үзеннән егерме метр чамасы гына ераклыкта, олы-олы атлап килүче генералны... күрде.* Р.Вәлиев

4) Нәрсәнең дә булса бер ноктадан алып икенче ноктага кадәр үтә алу арасы. *Махсус оештырылган комиссияләр --- шартлау дулкынының көчен, кыйпылчыклар траекториясенең ераклыгын хисаплап чыгарды.* Ф.Шәфигуллин. *Менә немецлар белән ике ара мылтык атарлык ераклыкта гына калды.* А.Шамов

5) Күз күреме иңли алырлык ара. *Язгы көндә оеп утырган Сакмар урманы да, аксыл томанга уралып беткән ераклыклар да дәшмиләр иде.* Ф.Сафин. *Әнә шул эңгер-меңгер иңеп килгән моңсу тау буйларында, әнә шул зәңгәр ераклыкта ниндидер серлелек бар.* Г.Бәширов. *Офыкта, күз күреме ераклыктагы урманнар өстендә, салават күпере пәйда булды.* Ф.Латыйфи

6) *күч. сир.* Аерма, үзгәлек. *Ветеринария белән медицинаның әллә ни ераклыгы юк бит.* А.Расих

7) *күч.* Башкалардан бик ерак булу. *Нигә ул үзен яшьләрдән шулкадәр ераклыкка аерып куя соң әле?!* К.Тимбикова

8) *күч.* Дуслыкка комачаулаган салкын мөнәсәбәт, мөнәсәбәтләрдәге салкынлык. *Арадагы ераклык вә салкынлык боздай эреп юкка чыксын, безне борадәрләргә әверелдерсен иде.* В.Имамов

**ЕРАКЛЫ́К ҮЛЧӘГЕЧ** *и. физ.* Ерактагы берәр нәрсәгә кадәр булган араны урыннан торып билгели торган прибор. *Акустик ераклык үлчәгеч*

**ЕРАКТА** *рәв.* 1) Ерак урында, ерак җирдә; әллә кайда. *Ул инде хәзер һәлакәт булган җирдән еракта, Гарәбә диңгез янындагы оҗмах бакчасында сәламәтлеген ныгыта.* Г.Үзиле. *Ул синнән гел читтә, ул синнән еракта, ләкин һаман да синең йөрәктә.* Г.Ахунов // *кбт. форм.* Бик еракта. --- *килеп җиткәнче үк, алар күрде: агачлык янында бер-ике дөя тора, еракта-еракта тагын бернечә кучкыл күзгә чалына.* Р.Батулла. *Кайдадыр, еракта-еракта, эт өрә.* Ф.Гыйльми

2) *күч.* Үткәндә; борынгылыкта, тарихта. *Картның тавышы карлыкты, әллә кайчангы, еракта, бик еракта калган үткәннәрне уйлап булса кирәк, карашын тәрәзәдән күренеп торган урманнарга төбәп уйга калды.* Ф.Латыйфи. *Бәйрәмнең тамырлары бик еракта – ыруглык мөнәсәбәтләренә барып тоташа.* Казан утлары

3) *күч.* Читтә, икенче юнәлештә. *Аның уйлары хәзер кайдадыр читтә, еракта, чабышып йөрде.* Н.Фәттах

◊ **Еракта йөрү** Нәрсә дә булса якынлашмау, урап үтү, аңа ия була алмау. *Килдеме соң аңа үзе көткән бәхет? Нигә ул әйләнеп узды, аңардан читтә, еракта йөрде?* Н.Хәсәнов

**ЕРАКТАН** *рәв.* 1) Ерак урыннан, ерак җирдән, әллә кайдан. *Аның тавышы, йолдыз чыңына охшап, бик тирәннән, ерактан килә иде.* Р.Вәлиев. *Алар [шәһәр кешеләре], безне күргәч, ерактан ук сәлам бирәләр, җиңүебез белән котлыйлар, шатлыгыбызны уртаклашалар.* А.Шамов. *Менә ул ерактан ук нурлар балкытып утырган таныш өйнең таныш капкасы янына килеп җитте.* Н.Фәттах // *кбт. форм.* Бик ерактан. *Шуңа күрә дә ир-егетләр ерак-еракларда авылда ялгыз калган әнкәләре янына кайтып төпләнәләр.* Б.Камалов. *Ерак-ерактан акрын һәм шомлы гына чаң каккан тавыш ишетелә, ул тора-бара көчәя.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Читләтеп, кинаяләп. *Атасы сүзне ерактан башлады.* Ф.Латыйфи. *Мин Шилов белән сүзне бик ерактан башлап җибәрдем.* Ә.Галиев. *[Арсланов:] – Бездә иртәнге яңгыр туктады, сездә ничек? – диде ул, сүзне ерактан башлап.* Ф.Садриев

3) Бик борынгыдан. *[Мәмәт би:] Беләм, беләм ул нәселне, безнең кадәр үк булмаса да... тирәннән, ерактан килүче ырудан.* Ф.Латыйфи

◊ **Ерактан күрү** Киләчәктә нәрсәнең ничек буласын алдан ук аңлап эш итә белү; шул юнәлештә эш йөртү. *Без, педагоглар, илебезнең киләчәген ерактанрак күрергә омтылмаганбыз, шул киләчәккә яшь буынны әзерләү турында кыюрак фикер йөртмәгәнбез.* Г.Бәширов. *[Генерал:] Сез яхшы солдат, контрразведчик, мәгәр ерактан күрә белүче политик түгел, полковник.* Ә.Гаффар. **Ерактан суктыру** Әйтәсе килгән уй-фикерне читләтеп, кинаябелән әйтү. *Әмма да хикмәтле кеше бу Гатаулла абзый, һәр сүзгә мисаллар китереп сөйли, ерактан суктыра.* Н.Исәнбәт. **Ерактан уйлау** Киләчәк көннән чыгып уй йөртү; эш-хәрәкәт нәтиҗәләрен алдан күзаллый белү. *[Салават] Ерактан уйлап эш итә ул.* А.Шамов. **Ерактан уратып** Бик читләтеп, зур кинаябелән. *[Га-*

*зинур:] Сез, Павел Иванович, безнең Хуҗа Насретдинчарак, ерактан урап әйтәсез икән.* Г.Әпсәләмов. **Ерактан чиерттерү** *к.* **ерактан суктыру**

**ЕРГАВЫЛ** *и. тар.* Разведкага җибәрелә торган туплам; авангард; иравыл (Пётр патшага кадәр алгы атлы гаскәрне шулай атап йөрткәннәр)

**ЕРГАЛАНУ** *ф.* Ерганаклыга һәм ерымтылыга әйләнү, ерганаклар барлыкка килү

**Ергалана бару** Торган саен ныграк ергалану

**Ергалана башлау** Ергаланырга тотыну

**Ергалана бирү** Ергалануын дәвам итү, һаман да ергалану

**Ергалана төшү** Тагын да ныграк ергалану

**Ергаланып бетү** Нәрсәнең дә булса өслеге бик нык, артыгы белән ергалану. *Калкулыкларның уртадагысы башкаларына караганда биегрәк тә, зуррак та иде, һәм аның түбәсендә җил-яңгырдан ергаланып беткән кара ташлы кыялар тырпаеп утыра иде.* Н.Фәттах. *Битләрен тырный-тырный елаган ул [яшь ана]. Бит очлары ергаланып беткән.* С.Поварисов

**ЕРГАЛА́У** *ф.* 1) *к.* **еру**. *Ара-тирә җил җилпенеп үтә дә тын күлләрнең битен ергалый.* Х.Госман. *Самолёт, болытларны ергалый-ергалый, җиргә якынлаша башлады.* Р.Вәлиев

2) *к.* **ермачлау** (*1, 2, 4 мәгъ.*). *Нурга тулып пешкән алмаларның Үзәкләрен кортлар ергалый.* Р.Вәлиева

**Ергалап бетерү** Тәмам, бик нык ергалау. *Ул [укытучы] шактый таушалган, битен тирән җыерчыклар ергалап бетергән.* Х.Камалов

**ЕРГАНАК** *и.* 1) Ташкын яки яңгыр суы белән юылып, ашалып ясалган, тирән булмаган сулы яки сусыз озын чокыр. *Ниһаять, ерганактан су агып төшә башлады.* Н.Хәсәнов. *[Искәндәр белән Тралмакс бабай] Бераз баргач, яшеллеккә күмелеп утырган тирән ерганак төбенә төшеп җиттеләр.* Г.Үзиле. *Яшел болыннар, аллы-гөлле чәчәкләр каплаган Җәбәл (гарәпчә «тау» дигән сүз) тавының итәге һәм бормалы ерганаклар, мәгърур кыялар каплаган тау бите сиңа янәшә диярлек күренеп тора.* М.Юныс

2) Шундый урыннан ага торган язгы ташкын яки көчле яңгыр суы. *Юл буйларында ерганаклар ага, кояш җылыта.* Ф.Галиев. *Кар көртләре чүктеутырды, тау түбәсендәге бозлавыклар эреде-шуышты, ерганаклар кузгалды.* Ч.Айтматов. *Ерганаклар аша эздәнэзгә сикергәли-сикергәли үтүләре үзе бер күңелле иде.* Р.Төхфәтуллин

3) *күч.* Юл, эз, җыерчык, сызык. *Разыя апаның күзеннән мөлдерәп яшь ага. Ул аларны ак яулыгының бер чите белән сөртеп ала, әмма яшьләре һаман тыңламый, әбинең җыерчыклы битләре буйлап, тирән ерганаклар ясап, һаман тәгәриләр дә тәгәриләр.* Ф.Бәйрәмова

**ЕРГАНАКЛАНУ** *ф. к.* **ермачлану**. *[Әхмәтнең] Көннәр буе ботак юнудан маңгай тирләре агып ерганакланган йөзе көн сүрәнлегенә карамый янып пешкән.* К.Кәримов

**ЕРГАНАКЛЫ** *с.* Ерганаклары булган. *Атлыйсы юлларын картадан җентекләп өйрәнгән булса кирәк, ташлы, үткелле ерганаклы урыннарны сайлаган ул.* Р.Низамиев

**ЕРГАЧЛАНУ** *ф. к.* **ермачлану**. *Дәү апасы тәмам бетәшкән иде аның. Төшереп бәйләнгән чуклы яулык уртасында аркылыга-буйга ергачланган җыерчыклардан гыйбарәт нәни какча йөз утырып калган.* Р.Мөхәммәдиев

**ЕРГАЧЛА́У** *ф. к.* **ергычлау**

**ЕРГЫЧ** *и.* 1) Итчеләр пычагының бер төре

2) *диал.* Рамга ырмау ясый торган корал

**ЕРГЫЧЛАНУ** *ф. к.* **ермачлану**

**ЕРГЫЧЛА́У** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **еру**. *Чаларган сакал, бит-маңгайны аркылыга-буйга ергычлаган тирән җыерчыклар --- Сафаның ил гизеп йөрүләре бик үк татлы булмаганлыгын күрсәтеп торалар иде.* М.Галәү

2) *күч.* Тырнау, җәрәхәтләү; йомшак нәрсәгә эз калдыру. *Гүзәлләр гүзәле, шөһрәтле ханбикәнең йөзен воеводалармы шулай гарипләгән? Әллә бикәнең кан дошманы Булат бәк Ширин этләреме ергычлаган?* Р.Батулла

**ЕРЕВАНЛЫ** *и.* **1.** Ереван шәһәрендә яшәүче кеше

**2.** *с. мәгъ.* Ереван шәһәрендә туып үскән, яшәгән. *Бу ереванлы дуслар Мәскәүдә ярым легаль хәлдә яши, пропискалары юк, төрле җирдән фатирдыр, бүлмәдер юнәтеп, вак-төяк бизнес белән шөгыльләнә.* Р.Мирхәйдәров

**Е́РЕСЬ** *и. гр.* 1) Өстенлек итеп килгән дин кануннарына каршы булган дини тәгълимат, бидгать. *Мәсәлән, ул анда Зәйнулла ишан турында, аның башкортлар арасында беренче тапкыр зекер әйтүне кертеклеген һәм, шуның аркасында дошманнары аның өстеннән «ересь тарата» дип әләк язып, төрмәгә утыртулары, аннан сигез елга сөргенгә җибәрүләре турында яза.* Г.Ибраһимов

2) *күч. сөйл.* Сафсата, буш, мәгънәсез сүз

**ЕРЕТИК** *и. рус* Ересь (*1 мәгъ.*) таратучы кеше, ересь тарафдары, зиндикъ. *Нәкъ менә шул кешене логофет белән архиепископ яратып бетермәделәр, имеш, еретик, имеш, чиркәүгә каршы сүз әйтә.* М.Хәбибуллин. *Руханилар бөтен гаепне еретиклар өстенә аударалар.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ЕРЕТИКЛЫК** *и.* Еретик булу. --- *ул сине шунда ук еретиклыкта гаепләр, ә андыйларның язмышы Румда ут учагында тәмамлана.* М.Хәбибуллин

**ЕРМА** *и.* 1) Су ташкыны белән юылып ясалган сулы чокыр

2) Махсус ерып, чокып ясалган урын. *Эссәт әкә әртиле, җиде көймә белән, сазлы урыннарда ерма ясап, этенә-төртенә, бу араны җиде көндә үтте.* Г.Ибраһимов

**ЕРМАК** *и.* 1) Бик үк киң һәм тирән булмаган озын чокыр; ерганак. *Кыйгачлап күтәрелә торгач, тауның буеннан буена аска таба сузылган ермак читенә килеп чыккан иде ул.* Р.Низамиев. *Ермак әлегә тирән түгел, әмма читләре ишелергә генә тора.* И.Низамов. *Үлән билдән, төнбоек яфраклары каплаган кечкенә күлләр, ермаклар күп.* Казан утлары

2) Елганың, күлнең тар гына булып ярдан эчкә таба кереп торган урыны; култык. *«Ак күл»нең --- тирән*

*ермагында миңа су анасы чәчен тарап утырган кеби булды.* М.Җәлил. *Ул инеш үзе әллә ни зур булмаса да, бик олы ермак ясаган.* Г.Ахунов

**ЕРМАКЛАНУ** *ф.* Ермакка әйләнү, тармаклану. *[Яр чите] Яңгыр сулары белән ермакланган.* М.Хәсәнов

**Ермаклана бару** Торган саен ныграк ермаклану

**Ермаклана башлау** Ермакланырга тотыну

**Ермаклана бирү** Һаман да ермаклану, ермакלануын дәвам итү

**Ермаклана төшү** Бераз ермаклану

**Ермакланып бару** *к.* **ермаклана бару**

**Ермакланып бетү** Бик нык, үтә ермаклану, күп ермаклар барлыкка килү. *Утрау ермакланып беткәч, андагы күп кенә күлләр бергә кушылгач, кировлылар Агыйдел ярларыннан бераз читләштеләр.* Я.Шәфыйков

**Ермакланып килү** Акрынлап, азазлап тирәсенә ермаклар ясалу, ермаклану процессы бару

**Ермакланып китү** Кинәт, ниндидер сәбәптән соң ермаклану

**Ермакланып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә ермаклану, ермакланган торыш алу

**ЕРМАКЛА́У** *ф.* Ермаклар барлыкка китерү, чокырчыклар белән телгәләү. *Мохтар бүлмәгә кереп йокларга ятты. Байтак вакытлар аның хыялында төрле уйлар, ермаклап җәелгән ташкын шикелле, әрле-бирле агып тордылар.* Ш.Камал

**Ермаклап бетерү** Бөтен җирен бик нык ермаклау. *Хәзер Чүлмәк тау ерактан ук түмен татытырга кызыктырган иләмсез дәү бәлешкә охшамый, аңардан нур качкан, аны җиде йөз ат көчле куәтле тракторлар төрле ягыннан аркылыга-буйга ермаклап бетергәннәр.* Г.Тавлин

**Ермаклап калдыру** Нинди дә булса эш, хәл, вакыйга сәбәбендә ермаклар барлыкка килү

**Ермаклап тору** Һәрвакыт, даими рәвештә ермаклау, ермаклаган хәлгә китерү

**Ермаклый бирү** Һаман да ермаклау, ермаклауны дәвам итү

**Ермаклый төшү** Бераз, берникадәр ермаклау

**ЕРМАКЛЫ** *с.* Ермаклары күп булган, чокыр-чакырлы. *Югары тау башына урнашкан Виктория күленең яр буйлары сөзәк һәм ермаклы – континент җилләренә монда һәр яктан юл ачык.* А.Муранов

**ЕРМАЛА́У** *ф. сөйл. к.* **ермачлау**. *[Харис:] Һи, телеграмма ич бу, кая, карчык, икәүләп ермалыйк әле.* А.Әхмәт

**ЕРМАЛЫ** *с.* Ерылган, ермасы булган. *Бу шинель үзе бик сәер – Киң итәге ермалы. Төймәсе юк – каптырмалы, Шундый җылы сырмалы. Басып кергән фашистлардан Коткарганда илемне, Бабам дүрт ел буе кигән Менә шушы шинельне.* М.Фәйзуллина

**ЕРМАЧЛАНУ** *ф.* 1) Ерганак һәм ерымнар барлыкка килү, телгәләнү

2) *күч.* Җыерчыклар, тирән эз барлыкка китерү. *Ачы күз яшьләре, канга кушылып, Ермачланып акты битеннән.* Ш.Гәрәй

**Ермачлана бару** Торган саен ныграк ермачлану

**Ермачлана башлау** Ермачланырга тотыну

**Ермачлана бирү** Һаман да ермачлану, ермачлануын дәвам итү

**Ермачлана төшү** Бераз ермачлану

**Ермачланып бетү** Бик нык чокырлы-чакырлыга әйләнү, бөтенләй ермачлану. *Ермачланып беткән борынгы тау битләре хәзер җимеш бакчаларына әверелгән иде.* Г.Бәширов. *Машина туктап җитәр-җитмәс, кабинадан чыкты, трактор табаннары белән ермачланып беткән такыр басу өстеннән факел утларына таба китте.* Г.Ахунов

**Ермачланып калу** Ниндидер сәбәптән ермачланган хәлгә килү

**Ермачланып килү** Акрынлап, азазлап ермачлану

**Ермачланып тору** Әле, хәзерге вакытта ермачланган хәлдә булу

**ЕРМАЧЛА́У** *ф.* 1) Аркылы-торкылы тирән юллар, чокырлы-чакырлы эзләр ясау; ерып, буразналар салу. *Актта ике аягы сынган, пыяласы ватылган, бер ягын очлы кадак тирән ермачлаган ниндидер шкаф турында сүз бара иде.* А.Гыйләҗев. *Бәрәңге бакчаларын ермачлап, гөрләвекләр агып төште.* Казан утлары

2) Өслекне тигезсезләү, шома өслектә шадралар барлыкка китерү, дулкынландыру. *Идел киңлекләрен ракета һәм метеорлар ермачлый.* А.Тимергалин

3) *күч.* Җыерчыклар барлыкка китерү. *Аннары, скрипка моңына сокланып, бабасының җыерчыклар ермачлаган, җилдә-кояшта какланып бронзаланган олпат йөзенә текәлеп утырды.* Б.Камалов. *Карчыкның җыерчыклар ермачлаган чырае кинәт караңгыланып китте.* Х.Камалов

4) *күч.* Берәр эшне зур кыенлык белән башкару. *Өстәвенә, безнең адресны конверт тышына язарлык дәрәҗәдә генә булса да, урыс хәрефләрен дә ермачлый ала башлаган иде.* М.Галәү. *Малай башта авыррак ермачлый, соңга таба «шома гына, төртелмичә генә укый» башлый.* Ф.Хатипов

5) *күч.* Төрле якка аеру, телгәләү. *Барып карасалар, Фәрит абынып егылган урында, корыган ботаклары белән күкне ермачлап, нибары карт шомырт агачы басып тора.* Казан утлары

**Ермачлап бетерү** Тулысынча бөтен өслеген ермачлау. *Нефтьчеләр болыннарны, басу өсләрен ермачлап бетергәннәр.* Г.Ахунов. *Дөрес, күз ияләнә төшкәч, райүзәкнең тузаннары да, авыр йөк машиналары ермачлап бетергән урамнары да килеп чыкты.* Г.Ахунов. *Менә куәтле машина-тракторлар ермачлап бетергән --- урамнарың!* Ф.Садриев

**Ермачлап ташлау** Бик тиз генә ермачлау

**Ермачлап тору** Һәрвакыт, гел ермачлау

**Ермачлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр ермачлау. *Белмим, сабанны ничек ермачлап чыгарсыз.* Г.Бәширов

**Ермачлый башлау** Ермачларга тотыну

**Ермачлый бирү** Ермачлавын дәвам итү

**Ермачлый төшү** Тагы да бераз ермачлау

**ЕРТКАЛАНУ** *ф.* Берничә урыннан ертылу, теткәләнү, тузу, сәләмәләнү.

*Тик ул [болыт] көчсезләнеп, урыны-урыны белән тоныкланган, ерткаланып тишкәләнгән инде.* Н.Гариф

**Ерткаланып бетү** Тәмам, бик нык ерткалану. *Күлмәкләре ерткаланып беткән, аяк-куллары сыдырылган, чәчләре тузгыган, урман пәрие диярсең.* Р.Вәлиев. *Декабристлар урамында ерткаланып беткән иске бер плакат бар.* Р.Батулла

**ЕРТКАЛА́У** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **ерту**. *Сөен тутай --- Ализәк язуны, ачу белән ерткалап, далага сипте.* Р.Батулла. *Шулай дип, Шәвәлиев гаризаны ерткалады да чүп савытына ыргытты.* Ф.Садриев

2) *күч.* Җирне начар сөрү. *Аннан-моннан ерткалап, --- шундый тигезсез чыккан дүрт дисәтинә арыш аламасы ята.* Г.Ибраһимов

**Ерткалап бетерү** Тәмам, бик нык ерткалау

**Ерткалап чыгу** Барысын да рәттән, башыннан ахырына кадәр ерткалау

**Ерткалый башлау** Ерткаларга тотыну. *Шуны гына көтеп торган симертелгән бурзайлар, конвойчыларның шат хахылдавы астында, аның өске киемнәрен, бүреген ерткалый башлыйлар.* М.Арсланов

**Ерткалый төшү** Бераз ерткалау

**ЕРТКЫЧ** *и.* **1.** 1) Башка тереклек ияләрен аулап туклана торган җәнлек яки кош. *Галим-голәма күпме генә мактаса да, табигатьнең тигезлеген тотар өчен бүре кирәк дип, күпме генә сөйләсәләр дә, бүре – ерткыч. Комсыз ерткыч.* М.Мәһдиев. *Соңрак диңгезләрдә төрле балыклар, шул исәптән бик зур ерткыч – башка диңгез хайваннарының котын алып торган динихтис барлыкка килгән.* Табигать белеме

2) *күч.* Чиктән тыш явыз, рәхимсез, аяусыз, кансыз кеше. *Зинданнарда ята-ята кыргый ерткычка әйләнгән бу бәндәләр.* Г.Үзиле. *Ә син бүген, дөнья алга киткән заманда – ерткыч!* М.Хуҗин. *– Туктагыз, ерткычлар! Туктагыз! Җибәрегез аны, җибәрегез! Алтынай! – дип кычкыра иде Дүшән, йөгереп килә-килә.* Ч.Айтматов

3) Сугышта явыз дошман, фашист. *Җаныбыз әрни, йөрәкләребез ярсый, боларның барысы өчен дә фашистлардан – котырган ерткычлардан – үч алырга, изге, мөкатдәс үчкә ашкынабыз.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Башка хайваннарны аулап туклана торган. *Аны ерткыч кош --- яки ерткыч җәнлек үткер тырнагына алгандыр.* Г.Хәсәнов. *Ара-тирә яр тирәсендә ауга чыккан ерткыч чуртаннар гына шопыр-шопыр килеп ала.* Я.Зәнкиев

**ЕРТКЫЧЛАНУ** *ф.* Ерткычка (*2 мәгъ.*) әйләнү; артык явызлану, аяусызлык күрсәтү. *Г.Ибраһимов «Адәмнәр» дигән әсәрендә 1921 елгы ачлык вакытында кешеләрнең соң чиккә җитеп ерткычлану күренешләрен тасвирлый.* Ф.Галимуллин

**Ерткычлана бару** *к.* **ерткычланып бару**. *Мин каршылык күрсәткән саен, ерткычлана гына бардың.* З.Дәүләтов

**Ерткычлана башлау** Ерткычланырга тотыну

**Ерткычлана бирү** Ерткычлануын дәвам итү

**Ерткычлана төшү** Тагын да ерткычлану

**Ерткычланып алу** Кинәт, азга гына ерткычлану. *Ике сәгатьтән соң Гыйлфан аңа илле грамм чамасы ипи бирде. Солдат моны чәйнәмичә йотты, шулвакыт күзләре ерткычланып алды.* М.Мәһдиев

**Ерткычланып бару** Көннән-көн ерткычлыгы арту

**Ерткычланып бетү** Тәмам, соңгы чиккә җитеп ерткычлану

**Ерткычланып йөрү** Бик күп ерткычлыклар күрсәтү. *Ермакның Иртыш буенда ерткычланып йөрүе турында хәбәрләр Күчем ханга да килеп җитте.* Ф.Бәйрәмова

**Ерткычланып китү** Кинәт ерткычлану. *Ул, ерткычланып китеп, Мәдинәне янә таптап ташламакчы булды.* С.Поварисов

**Ерткычланып тору** Еш, әледән-әле ерткычлану

**ЕРТКЫЧЛА́РЧА** *рәв.* 1) Ерткычлар кебек, бик явызланып, аяусыз рәвештә. *Узган ел алар йөргән якларда да егермебишмеңче колхоз председателен кулаклар ерткычларча кыйнап үтергәннәр иде.* С.Шәкүров. *Ә анда, аста, ярым исерек кешеләрнең ерткычларча кычкырышуы ишетелә иде.* С.Горский

2) *күч.* Юкка чыгаруга, кырып бетерүгә алып килә торган, киләчәкне кайгыртмыйча, бүген, тиз арада булачак файдага гына исәп тотып. *Ә үзебез яшәгән табигатькә мөнәсәбәт, аны ерткычларча туздыру, күрәләтә агулауны, суларга һава булмаган шәһәрләрдә, халыкны алдап-йолдап, тагын, тагын, тагын яңа химия гигантлары торгызуны ничек бәяләргә?* Г.Үзиле

**ЕРТКЫЧЛЫК** *и.* 1) Ерткыч булу; әшәкелек, усаллык, явызлык. *Дошманның шушы оятсызлыгы һәм ерткычлыгы безнең егетләрне иң караңгы, иң газаплы уйларга төшерде.* Ә.Еники. *Нигә ул яңа туган мәче балаларын суга салып үтердегез, бу бит – вәхшилек, ерткычлык?!* Р.Вәлиев. *[Фирәзә] Сине кеше арасында кеше итеп яшәтә, синең эчеңә яшеренгән ерткычлык, гайре табигый тойгыларыңны тышка чыгартмау серен белә иде.* Г.Үзиле

2) Хуҗалыкны ерткычларча (*2 мәгъ.*) алып бару, нәрсәдән дә булса ерткычларча файдалану

**ЕРТЛАЧ** I *с.* Йөзе шадра, ямьсез булган. *Варяның ертлач-ертлач шадрасы портретта бөтенләй беленми.* Ф.Әмирхан

**ЕРТЛАЧ** II *с.* **1**. Чиктән тыш усал, әшәке, явыз. *Бүтән малайларны үз кубызына биетеп күнеккән Зөфәр үзеннән дә ертлач кыздан шүрләде булса кирәк.* Ф.Шакирова. *Терентьев, кызының хәленә кереп: «Ул Әюпов нишләп сиңа бәйләнә, тыштан гына шулай әдәпле күренә, үзе ертлач бер донжуан икән», – дип әйтмәкче иде дә, кызының чәнчеп каравын тойгач, сабыр итәргә булды.* Ә.Мушинский

**2.** *и. мәгъ.* Әшәке, комсыз, оятсыз кеше. *Авылда бер ертлач, сугыш башлангач, авыл советы председателе булып алган.* Х.Камалов. *Бу нинди ертлач, нинди садист?* Н.Хәсәнов // Ояла, уңайсызлана белми торган әрсез кеше. *Шунда ук басынкылары, сөйләшмичә, каударланмыйча йөрүчеләре дә, ярыйсы гына ертлачлары, керпе кебекләре дә бар.* З.Фәйзуллин

**ЕРТЛАЧЛАНУ** *ф. сөйл.* Ертлачка (II) әйләнү. *Әнвәр шуны аңлады: ертлачланып, берәр нәрсә кулга төшерергә, йөз ертырга алар икесе дә сәләтсез икән.* Х.Камалов

**Ертлачлана бару** Көннән-көн ертлачлыгы арту

**Ертлачлана башлау** Ертлачланырга тотыну

**Ертлачлана төшү** Бераз ертлачлану

**Ертлачланып бетү** Бөтенләй, тәмам ертлачлану, тулысынча ертлачка әйләнү

**Ертлачланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта күп ертлачлыклар күрсәтү. *Ертлачланып йөрсә, яман булыр иде.* Ш.Галиев

**Ертлачланып китү** Кинәт ертлачлану. *Кыю булам дип, ертлачланып та китмисеңме, Хәйдәр?* Р.Төхфәтуллин

**Ертлачланып тору** Һәрвакыт, әледән-әле ертлачлану

**ЕРТЛАЧЛЫК** *и. сөйл.* Ертлач (II) булу. *«Калай әтәч»нең ертлачлыгы аны соң дәрәҗәдә тетрәндереп җибәрде.* Н.Гыйматдинова

**ЕРТМАЧЛА́У** *ф. к.* **ермачлау** (*1 мәгъ.*). *[Санька] Бер генә нәрсәне абайлап бара: монда урманнарны дуңгыз ертмачламаган, пычрак юк, куркып атлыйсы түгел.* Ф.Латыйфи. *Бәргәләнә, акыра ерткычтай, Тәнен үзе тырмый, ертмачлый...* Х.Камалов

**ЕРТУ** *ф.* 1) Кәгазь, тукыма һ.б. нечкә тоташ әйберне кисәккә аеру, кисәкләргә бүлгәләү. *Иртәгә театрга дип алынып кайткан театр билетларын күреп, алардан үчен алган кебек, ваклап-ваклап ертып ыргытты.* Г.Исхакый. *Безнекеләр дүрт кырлы каты әйбернең пергаментын ерттылар: алар кулында, чыннан да, икмәк иде.* Ә.Еники. *Су басымы колак пәрдәсен ерту белән генә чикләнми, буыннарны катыра, бәвел куыгын эштән чыгара.* М.Юныс

2) Җир сөрү. *[Истән чыкмый] Абый белән бергәләшеп кара җирне Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.* Г.Тукай. *Игенче орлык чәчәр, Җир ертып, ризык юлын ачар.* Н.Исәнбәт

3) Нинди дә булса үткен, очлы әйбер белән ерып, тырнап эз калдыру

4) *күч.* Ислемай, төтен, агулый торган газ, хлор һ.б.ш. нәрсәләрнең исе яки үтә көчле тавышның сизү органнарына (күзгә, колакка) көчле тәэсир итүе. *Әмма кемдер аны бик кирәксенә, ахры, ямьсез зыңгылдау, колакны ертып, озак-озак кабатлана.* М.Маликова. *Ул көй чыгара белми, әллә нинди ямьсез, колак пәрдәләрен ерта торган тавыш чыгара.* А.Емельянов

5) *күч.* Тию, кагылу, тынычсызлау. *Манараның үткен очы ерта Кемнәрнеңдер мин-минлекләрен.* Х.Әюп

6) *күч.* Яру, аеру. *Төн пәрдәсен ертып, Гөлйөземнең ачыргаланып кычкырганы ишетелде.* Ф.Латыйфи. *Пароход кына, шул төпсез-чиксез караңгылыкны ертып, алга барырга маташа.* Г.Исхакый. *Хәким Нәбиевич кире борылды, әмма шул мәлдә, кичке эңгерне ертып, күпер яклап, үзбушаткыч килеп чыкты.* М.Хәбибуллин

**Ертып алу** Тиз генә ерту; зур өлештән кечерәк өлеш аерып алу. *Өстәлдән лезвие алып, каты тукыманы телеп җибәрде, аннан озын тасма ертып алды да Мортазаның беләген кысып урады*. М.Маликова

**Ертып ату** Кискен хәрәкәтләр белән тиз-тиз ерту; ертып юкка чыгару, юк итү. *Хатны ул кабат укырга теләмәде, ертып атты һәм гомерендә беренче тапкыр үксеп-үксеп елады.* Д.Каюмова. *Башта бер академик теориясен ятлаталар, аннары, ул үлгәч, аның китапларын ертып аталар.* З.Садыйков

**Ертып бетерү** Бөтен җирен, күп итеп ерту, бик нык ерткалау. *Әллә нинди чәнечкеләр аягымны ертып бетерде.* И.Салахов. *Без аларны [журналларны], балалар ертып бетермәсеннәр дип, утын сараена яшердек*. Р.Мостафин. *Өйдә булган рәсемнәрен, хатларын ертып бетерде*. Т.Галиуллин

**Ертып җибәрү** Кинәт ерту, көтмәгәндә ерту. *Карт итәк очын әз генә кискәч, ике ягын ике кулы белән тотты да күлмәкне шытырдатып ертып җибәрде.* Ф.Садриев

**Ертып керү** 1) Эчкә үтеп, тирәнгә таба ерту

2) Бик нык ерту. *Әлеге тавыш аның колагын ертып керде.* Р.Сибат

**Ертып кую** Ертылган хәлгә китереп калдыру

**Ертып ташлау** *к.* **ертып ату.** *Ул, погоннарын ертып ташлап, крестьян киемнәренә киенеп, фронттан кача.* Н.Юзиев. *Башта бөтен фотоларны ертып ташлады.* Н.Измайлова. *Ясадым мин дәфтәремә Бүренең би-ик явызын: --- Курыктым да, бүрене мин тизрәк ертып ташладым.* Р.Миңнуллин

**Ертып тору** 1) Бертуктаусыз ерту

2) *күч.* Күккә ашкан булу; текә басып тору. *Нык калын сыйраклар өстендә торган тыгыз тән, туры муен һәм текә маңгай, --- бер пар чалгы сыман һава ертып торган туры озын мөгезләрме – болар бары тик аңарда, Микәйдә генә.* Р.Мөхәммәдиев

**Ертып узу** 1) *к.* **ертып үтү.** *Яра зур түгел, пуля сөяккә тимәгән, ә итне генә ертып узган.* А.Шамов

2) *күч.* Тиз арада көчле тәэсир итеп ерту. *Тупас Гайфулланың бакыруы икенче тапкыр бәгырьне ертып узды.* Ф.Яхин

**Ертып үтү** Үтәли ерту; тирән эз салып, икегә аерып ерту. *Ак болытлар, җирне каплап тормагыз, --- Мин барыбер сезне ертып үтәрмен.* М.Җәлил

**Ертып чыгу** 1) Һәрберсен бер-бер артлы ерту

2) Үтәли ерту. *Бу – ачлыктан йонлары коелган, кабырга, янбаш сөякләре тиреләрен ертып чыккан бер усал эт иде.* Г.Ибраһимов. *--- җаным, тәнемә сыймыйча, тиремне ертып чыгардай булып чәбәләнә.* М.Кәбиров. *Тау өстенә ябылган калын юрган төсле йомшак булып күренгән яшел урманны ертып чыккан ялангач кызыл ташлар – кыялар очрыйлар*. М.Әмир

**ЕРТЫК** *с.* **1.** 1) Берничә кисәккә бүленгән, аерылган. *Күрәм: ертык болыт кисәкләре, Куркынышып, читкә китәләр.* М.Гафури. *Ертык кәгазь битләрен өстәл өстенә тезеп, сүзне – сүзгә, хәрефне хәрефкә җыеп укуын дәвам итте егет.* Ф.Яхин. *Һәм менә астан, дошман өередәй булып, ертык-ертык яман болытлар очып чыкты.* Ә.Мушинский

2) Ертылган; озак кулланудан яисә очраклы рәвештә берәр нәрсәгә эләгеп

аерылган, тишелгән. *Фазыйлга карап: – Менә бу ертык киемле бала кем ул? – дип сорады.* Г.Ибраһимов. *Костин картның ертык җиңеннән күренеп торган мускулсыз беләгенә, арык җилкәсенә карап торды.* Г.Гобәй

3) Нык тузган, тузып тишелгән, сүсәргән, сәләмә. *Айлар буе, еллар буе, ертык кием өстендә.* Н.Исәнбәт. *Ләкин көчле чагы үтте дә китте, ә иңбашыннан һаман ертык туны төшкәне юк.* И.Гази. *– Әйе, – ди өченчесе, өшегән борынын бияләй белән капларга тырышып, – төлке тун кисәң, бу салкын сәлам биреп кенә үтәр иде дә, ертык бушлатның куенына ук керә шул.* Р.Кәрами

4) *куч.* Бәйләнеше булмаган, өзек-өзек. *Дөресрәге, уйлар да түгел, өзек тә ертык уй кисәкләре генә чуала иде башта.* Р.Төхфәтуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Бербөтен әйбернең кисәге, аерым кисәкләр. *Сулышыннан обой ертыгы дерелдәп куя.* Н.Хәсәнов. *Кай ара, нәрсәдәндер куркып качкан сыман, тузгак болыт ертыклары арасыннан, өшеп калтырангандай, тонык йолдызлар йөзеп уза.* Ш.Шәйдуллин

2) Ертылган, тишелгән урын. *Тез башларым чалбар ертыгыннан кызыл чөгендер башлары кебек күренеп тора.* Н.Дәүли. *[Әбинең] Күңелләре күтәрелә, Бер ертыкны ямаса.* Ф.Яруллин. *Аның тез башлары умырылып чыккан, чалбар ертыгыннан канлы җәрәхәтләре күренә, үзе еш-еш сулый.* Ф.Латыйфи

3) *куч.* Җитешсез як, кимчелек. *Җырның ертыгы юк.* Мәкаль. *Еш кына шулай була ич: эш эленке-салынкы гына бара, анда сүтек күренә, монда ертык күзгә ташлана.* Б.Камалов

◊ **Ертык авыз** Сертотмас. *«Их, Мингазый абый, – дидем мин эчтән генә, – ертык авыз икәнсең, ирләрчә сөйләшү шулай буламыни?»* М.Кәрим. **Ертык битләр** Билгесез булып калган, сер итеп сакланган чын тарихи вакыйгалар. *Кайчан безнең тарих алга басар Ак тапларсыз, ертык битләрсез?* Б.Рәфыйков. **Ертыктан сүтек эзләү** Үтә чокчынып, юк гаепне күпертергә тырышу; буш эш белән шөгыльләнү. *Әлбәттә, бу – ертыктан сүтек эзләү булып кабул ителмәстер.* Р.Әхмәтҗанов

**ЕРТЫК-ПОРТЫК** *с. сөйл. к.* **ертык-пыртык**. *Шунысына шөкерана кылды: аны, вакытлыча гына булса да урман кисү эшеннән алып, тоткыннарның ертык-портык киемнәрен – тишек бүрек, бияләй, телогрейкаларын ямап торырга күчерделәр.* Н.Хәсәнов

**ЕРТЫК-ПЫРТЫК** *с. сөйл.* Бик сәләмә, теткәләнеп, тишелеп беткән. *Кая карама – ертык-пыртык галушлар, ватык тәгәрмәч тугымнары --- һәм төрледән-төрле тимер-томырлар чәчелгән иде.* А.Гыйләҗев

**ЕРТЫК-СҮТЕК** *с. сөйл. к.* **ертык-тишек**. *Тормышның авырлыгын күбрәк ул [Зөһрә] күтәрә, тегү тегеп булса да, тормышның ертык-сүтекләрен каплый.* З.Бәшири

**ЕРТЫК-ТИШЕК** *с. сөйл.* **1.** 1) Ертылган, тузып тишелгән; ертылып, тишелеп беткән

2) Җитмәгән, мохтаҗ булган. *Алманың акчасы кесәгә дә йокмады; ертык-тишек урын күп булган, акчаны күрми дә калдылар.* И.Гази

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ертылган яки тузып тишелгән урын. *[Гәрәфи абзый] Барлык ертык-тишекләрен яматты, өзелгән төймәләрен тактырды.* Г.Әпсәләмов

2) Ихтыяҗ, мохтаҗлык; кирәк-ярак. *[Хәйретдин] Тормышның авырлыгыннан, көн-төн эшләп тә, кечкенә генә тормышның ертык-тишекләрен дә ямап булмаудан зарлана.* М.Гали

**ЕРТЫЛГАНЧЫ** *рәв. гади с.* 1) Озак һәм бик каты, бөтен көчкә. *Атакага барганда, ертылганчы «ура» кычкырдык, штык белән кададык.* И.Гази

2) *куч.* Чамадан тыш күп, кирәгеннән артык; шартлаганчы. *[Бохари хәлфә] Көн дә ертылганчы ашарлык үпкә-бавыр, баш-аяк алып китә.* А.Расих

**ЕРТЫЛУ** *ф.* 1) *төш., кайт. юн. к.* **ерту** (*1, 3, 4, 5 мәгъ.*). *Якимов артыннан сүзсез генә ияргән Мулицынның җилфердәгән буш чалбар балагы тез астыннан кадакка эләгеп ертылган иде.* Н.Хәсәнов. *Әлегә, Аллага шөкер, Гыйммранның бары тик колак пәрдәләре генә ертылган иде.* М.Юныс

2) Ачылу, таралу. *Күзләрдәге караңгылык пәрдәсе, томан беркайчан да ертылмас шикелле.* К.Латыйп

3) *куч. гади с.* Бөтен көчкә кычкыру, акыру. *– Гранаталарны әзерләргә! – Командирның җан ачысы белән ертылып кычкырган авазы, яңгыр пәрдәсен үтеп, солдатларга ишетелде.* Г.Әпсәләмов

4) *куч.* Каты ачулану, шашып ярсу, нишләргә белмичә усаллану. *Гарьлегеннән ертылыр дәрәҗәгә җитте*

5) *куч.* Кирәк-ярак, җитмәгәнне булдыру өчен, бөтен көчне куеп эшләү. *Сез минем күпме ертылганымны беләсез... ничә еллар буе...* Ф.Садриев. *Заманы шундый иде. Ничарадан бичара ертылдык.* Б.Камалов

6) *куч.* Кемгә дә булса ярарга тырышу. *– Кем өчен ертыласың, кемнәрнең табанын ялыйсың? – дип кычкырды ул, бөтен ферманы яңгыратып.* Ф.Садриев

**Ертыла бару** Торган саен ныграк ертылу

**Ертыла башлау** Бераз ертылу. *Ертыла башлаган күлмәк тагын каядыр эләкте.* Ф.Яруллин

**Ертыла бирү** Һаман да ертылу, ертылуын дәвам итү

**Ертыла төшү** Бераз, җиңелчә генә ертылу. *Бик ул хәтле зур тишекләре юк бугай. Тик берсенең балтыры ертыла төшкән, икенчесенең олтаны кубып киткән.* Ш.Камал

**Ертыла язу** 1) Чак ертылмый калу

2) Бик нык шашыну, нишләргә белмәү. *Кызның аты-чабы чыкты. Ата, боларны ишеткәч, хурлыгыннан ертыла язды.* Г.Ибраһимов

**Ертылып бетү** Тулысы белән, бөтенләй ертылган булу. *Аның күлмәкләре ертылып беткән.* М.Гафури. *Стеналарга ябыштырылган сары төстәге обойлар ертылып беткән.* А.Вергазов

**Ертылып калу** Ертылган хәлгә килү. *Гитлерның үзе түгел, «күләгәсе»нең чалбары гына ертылып калган.* Ш.Маннур. --- *күк йөзендә, бик биектә, ертылып калган берничә ак болыт кисәге дә, туктап, аларны күзәтә иде.* М.Мәһдиев

**Ертылып китү** Кинәт, искәрмәстән ертылу. *Комган эчендәге чүпрәк ертылып китте дә, җиргә, ялтыр-йолтыр килеп, бер-бер артлы тәңкә акчалар коела башлады.* Г.Мөхәммәтшин

**Ертылып тору** 1) Һаман, бертуктаусыз ертылу

2) Әле, хәзер ертылу

**Ертылып чыгу** Бөтенләйгә ертылу. *Ихтыяр бары шунда гына бөтен киеменең тузанга батканын, чалбарының тез турыннан ертылып чыкканын күрде.* Р.Вәлиев

**ЕРТЫШ** I *и. зоол.* Алабугасыманнар семьялыгыннан, йөзгечләре зур чәнечкеле, вак тәңкәле, ите бик кылчыклы елга балыгы; *русчасы:* **ёрш**

**ЕРТЫШ** II *и. диал. этн.* Туй бүләге итеп бирелгән тукыманы шаулашыпшаярышып ерту йоласы

**ЕРУ** *ф.* 1) Көчле су ташкыны белән юлында очраган әйберләрне юып, җимереп, нәрсәгә дә булса үтеп керү. *Дим, җәй көннәрендә кояшның нурлары астында көлә-көлә, яшел үләннәр, төрле чәчәкләр белән томаланган болыннарны ерып, кичләрен ай яктысында җем-җем итеп ялтырап ага да ага.* С.Җәләл

2) Сулыкны тотып торган ныгытманы җимерү, суга юл ачу. *Алла сакласын, ул [Миркәй] авылга ут салыр, тегермәнне ерыр.* Н.Исәнбәт

3) Нәрсә дә булса эшләү, үткәрү өчен, җирне озынлыкка таба казып чокыр ясау. *Бакчага күлдән су ерып кертәм.* И.Гази

4) Кар, пычрак, су эченнән бару; карлы яки пычрак юлдан кыенлык белән үтү. *Хәнифә Вәлиулловна, билдән кар ерып, Равил янына килде.* В.Нуруллин. *Тездән лай ера-ера, су чупырдатып, арба янына Мөнир килеп басты.* А.Гыйләҗев. *Бу юлы да шулай: кар ерып, алдан Дүшән китте.* Ч.Айтматов

5) Үсеп утырган нәрсәләрне, юлда очраган кешеләрне, агымны һ.б.ш. ике якка этәреп юл яру, икегә аеру. *[Пароход] --- берничә тапкыр өзеп-өзеп кычкыртты да, каты су агымын ерып, авыр-салмак кына кузгалып китте.* Ә.Еники. *Ни туктарга, ни әйләнеп карарга, ни еларга белмичә, куе арышны ерып чапты да чапты.* Ә.Гаффар. *Җиһангир, кәрҗинен кулына тоткан көе, камышлы күлне ерып, сай суда йөзгән балыкларны күзәтеп бара.* Н.Хәсәнов

6) Киң итеп ачу. *[Мортыйның] Күлмәк якасы күкрәгенә кадәр ерылган.* Г.Әпсәләмов

7) Ике якка аеру, аерып кую. *Томми аякларын ерып утырды.* А.Расих

8) *күч.* Нинди дә булса очлы әйбер белән эз калдыру. *Биш минуттан соң инде мин үзем ясаган «Мәрфуга апа»ның кызыл вә зәңгәр күзләрен чукып алдым, авызын шырпы белән колакларына кадәр ердым.* Ф.Әмирхан

9) *күч.* Нинди дә булса каршылыкларны үтү, үтеп чыгу. *Мин зарыгып алга... алга карыйм: Җир тетрәткән дошман тупларын, Дошман миналары өермәсен Ерып, алга бара дусларым.* Ф.Кәрим

◊ **Ерып йөргесез** Нәрсәнең дә булса чиктән тыш күп булуын, арасыннан авырлык белән генә үтәргә мөмкин булуны белдерә. *Анысында кеше без ит саткан базардагыдан да күбрәк: ерып йөргесез иде.* В.Нуруллин. *Сабан ашлык күкрәп үсте, болыннарда печән ерып йөргесез булды.* Г.Ахунов. **Ерып үтәсең юк** *к.* **ерып чыккысыз**. *Җыелды халык, җыелды халык... Безнең балалар бакчасы турысыннан ерып үтәсең юк.* Э.Касыймов. **Ерып чыккылы** Ахырына кадәр эшләнә торган, башкарыла торган. *Мондый эшкә хатын-кыз кушылса, ерып чыккылы булмый икән.* Ф.Сафин. **Ерып чыккысыз** Нәрсәнең дә булса бик күп булуын, башкарып булмаслыгын, «аны ерып булмый, ерып чыгарга көч җитми» дигән мәгънәне белдерә. *Олпат морзаны еллар авырлыгы түгел, уйларының ерып чыккысыз тирәнлеге сыкты.* Ф.Латыйфи. *Пароход туктыйсы пристань Усиядә, Казанка елгасының Иделгә кушылган урынында. Әхмәтсафалар килеп җиткәндә, анда ерып чыккысыз халык иде.* Ф.Сафин

**Ера бару** Торган саен ныграк еру

**Ера башлау** Ерырга тотыну. *Тилемсә кешедәй, тик торганда, авызын ера башлый.* Н.Хәсәнов

**Ера бирү** Һаман да еру, еруын дәвам итү

**Ера төшү** Беркадәр, тагы да беразеру

**Ерып бетерү** Күп ерымнар еру, күп ерымнар ясау. --- *чирәмле капка төпләрен дә машиналар таптап, газовиклар ерып бетерде.* Г.Мирһади

**Ерып җибәрү** Нәрсәне дә булса читкә таба юнәлдерү, ерып, юл салу. *Яз җиткәч, бер урыннан суны ерып җибәрәләр дә, аннары тагын эшкә кушалар иде.* Г.Кашшаф-Үзиле

**Ерып керү** 1) Икегә аерып, ертып, эчкә үтү

2) *күч.* Нинди дә булса дәрәҗәгә, үсешкә ирешү, күтәрелү; шул дәрәҗәдәге кешеләр арасына үтү. *Укуы уртача булса да, кайбер чирекләрдә Зиннәт, кысыла-кысыла, алдынгылар рәтенә дә кереп баскалады. Ләкин соңгы ике елда бу рәтне ерып керә алмады.* Р.Кәрами

**Ерып кую** Ерган хәлгә китерү. *Шуннан соң читтәрәк басып торган Касыйм бабай юка иреннәрен ерып куя.* Т.Нәҗмиев

**Ерып салу** *күч.* Каршылыкларны җиңү, көч куеп, көрәшеп, өстен чыгу. *– Аның принцибы: һәр кеше үз теләген үзе тормышка ашырырга, тормышта юлны күкрәге белән ерып салырга тиеш, – диде Эдик, пышылдап.* М.Юныс

**Ерып ташлау** Көтмәгәндә көч һәм тизлек белән киртәләрне еру. *– Беләм, беләм, – диде әтием, – таш буаларны да ерып ташлый торган нәрсә бу.* Н.Дәүли

**Ерып чыгу** 1) Бер башыннан икенче башына кадәр еру

2) *күч.* Нинди дә булса эш-хәрәкәтне ахырына кадәр үтәү, тәмамлау. *Аннары бу гаять җаваплы «теманы» ерып чыга алмам, буталып бетәрмен дип курыктым да, әллә бөтенләй язып тормаска микән дигән фикергә дә килгәндәй булдым.* Ә.Еники. *Аннары, читтән торып, сәүдә институтын «ерып» чыга.* Ә.Сафиуллин. *Бу матавыклы эшне ерып чыгуда аңа тәҗрибәле редактор Рәсим Әмирхановның зур гына ярдәме тия.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Кыенлыкларны, катлаулы мәсьәләләрне нинди дә булса юл табып хәл итү, җиңү. *Евгений шактый*

*уңайсыз хәлдә калырга тиеш булса да, осталыгы белән яхшы ерып чыкты.* Ф.Әмирхан. *Ил белән килгәнгә түзәрбез, авырлыкларны ерып чыгарбыз.* Ф.Сафин

4) *күч.* Нәрсәне дә булса ахырынача аңлап, төшенеп үзләштерү; өйрәнеп белү. *Атасы дөрес хәтерләп калган: авыл мәдрәсәсендә ул, зирәк шәкерт булганлыктан, төрки язуны, Коръәнне бик тиз укып китте, дин белеме, шәригать кануннары, мөселман әхлагы, хокук кебек белемнәр бәян ителгән «Төхфәтел мөлек», «Мохтасарел викая», «Фикыһ кайдани» дәреслекләрен дә ерып чыкты.* Т.Әйди. *Гарәп теле белгечләрен исәпләмәгәндә, минем кордашлардан кем генә бу борынгы язуларны ерып чыга алыр иде икән?* Р.Мостафин

**ЕРУНДА** *и. рус сөйл.* 1) Юк-бар, буш сүз, сафсата. *«Сафсата!» дип кемдер көләр, бәлкем, Башка акыл сатар. Әйтер: алай булмый ла ул, диеп, Ялган бу, ерунда!..* Ш.Җиһангирова

2) Вак-төяк әйбер, берни түгел. *Акча – ерунда ул алар өчен.* З.Хөснияр. *Әчәчләргә чаллар төшкән икән, Ансы гына аның – ерунда!* Р.Миңнуллин

3) Бик җиңел, ансат эш, гамәл. *– Ерунда! – диде Равил, сер бирәсе килмичә. – Тоймадым да мин алар тукмаганны.* В.Нуруллин

**ЕРШАЮ** *ф. диал.* Авызны кыегайту

**Ершаеп китү** Кинәт ершаю. *[Вәли карт] Еламаска тырыша иде, ләкин ихтыярсыз авызы ершаеп китте.* Ш.Камал

**ЕРЫК** *и.* **1**. 1) Киемдә җөй тоташмыйча калган урын яки махсус калдырылган тар гына ачыклык. *Шулай уйласа да, күзе чалмабаш чәчәге өзәргә иелгән Наиләнең түшенә, күлмәк ерыгына төште.* А.Гыйләҗев. *[Заһидулла] Аяк астында беләктән дә юан кап-кара елан күреп коты очты, чалбар ерыгын сәдәпләп тә тормыйча, өенә ыргылды.* Р.Сибат. *Ул киемнәрне кигәндә-салганда, кармак һәм сәдәф төсле каптырмалар черт-черт итте, керешле тарттырмалар чирттергән тавыш чыгарды, кара-каршы китереп тәргән вак пычкы теше төсле елтыравыклы нәрсәләр тезелдәп эләкте һәм олы ерык ясап аерылды.* Ф.Садриев

2) Эчкә таба батып яки ярылып торган тар гына уем. *Өч-дүрт атналык яралгы инде балыкка охшый, аңарда саңак ерыклары күренә.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ертылган, ерылган, ертык. *Кайтканда, юл буе бер авыз сүз сөйләшмәделәр. Тик Василий Степанычның ерык ирене генә селкенеп торды.* Г.Әпсәләмов

2) Ерыгы булган, ерыклы

◊ **Ерык авыз(лы)** *гади с.* 1) Тиктомалга, бер сәбәпсезгә көләргә яраткан. *Батырга диган тәкә белән мәш килгән арада абайламый да калганмын: кечерәк кенә буйлы, чандыр, кош күкәе төсле чуар сипкелле, ерык авызлы ---, кыскасы, кыю бер малай тора янымда.* Ф.Хөсни; 2) Кирәгеннән артыгын, урынлы-урынсыз теләсә нәрсә сөйләргә ярата торган кеше. *Һи, тел бистәсе, һи, ерык авыз! Телеңә салынып утырган буласың.* Г.Бәширов

**ЕРЫКЛЫ** *с.* Ерыгы булган. *Бу юлы ул итәгенең бер ягы ерыклы, бәрхеткә охшаганрак куе зәңгәр күлмәк һәм аның өстеннән шул ук материалдан тегелгән, күкрәкне каплый торган жакет кигән иде.* З.Фәйзуллин

**ЕРЫЛУ** *ф.* 1) *кайт., төш. юн. к.* **еру**. *Күреп торасың бит: былтыр буа ерылганнан соң, Әверлән инеше, төбен ашап, аска төште, ярлары җимерелде, болыннар корыды, такырга әйләнде.* Г.Бәширов

2) Киң итеп елмаю. *Баязитның авызы колагынача ерылган, йөзе көлә, күзендә ут уйный иде.* Г.Ибраһимов

**Ерылып китү** Кинәт ерылу. *Малайларга кызык: әле бер минут кына элгәре, йөрәге уч төбендә булып, тын алырга да куркып яткан җирдән торганда, авызлар ерылып китә.* Р.Мөхәммәдиев

**Ерылып төшү** Буйдан буйга ерылу. *Борыннан ике ягыннан тирән генә сызык ерылып төшкән.* Г.Бәширов

**ЕРЫМ** *и.* 1) Яңгыр һәм кар сулары белән юылып, ашалып ясала торган киң һәм тирән озын чокыр; сыза, балка. *Авылның ике очы да тирән ерымнар белән чикләнә.* А.Расих

2) Бернинди дә үсемлекләр үсми торган текә ярлы чокыр; коры елга. *Шәһәрләр төзегәндә, юллар салганда һәм башка эшләр вакытында, тигезлекләрнең рельефы сизелерлек үзгәрә: ерымнар күмелә, кайчагында өемнәр ясала.* Физик география

3) Махсус ерып, казып ясалган зур, озын, сулы яки сусыз канау. *Иң әйбәт урыннарның берсе ул каршы яктагы Комач белән Димне тоташтырган ерым иде.* Ә.Еники. *Автомобиль чыра кебек яна башлады, ә шофёрны шартлау дулкыны юл кырыендагы ерымга алып ыргытты.* Б.Камал

**ЕРЫНКЫ** *с. сир.* Зур, киң җәелгән. *Габделбасыйрның йөзе матурлык белән аерылмык түгел иде: төссез генә соры күзләр, --- шактый ерынкы авыз, таррак кына маңгай.* Ф.Әмирхан

**ЕРЫНТЫ** *и. к.* **ерым**. *Шулай сөзә торгач, ул да өске ерынтыларны кочагына ала торуы белән бер үк вакытта, былтыргы күлгә үзе дә бик астыртын гына омтылган, тоташа ук язган булып чыкты.* Ә.Баянов

**ЕСАУЛ** *и. төрки* Патша армиясенең атлы казак гаскәрләрендә офицер чины; шул чиндагы хәрби кеше; ясавыл (бу чин җәяүле гаскәрләрдәге капитан дәрәҗәсенә тиң була). *– Ялгышкансың, әбекәй. Шул ярпач есаулга чыкканчы, төрек капитанына чыккан булсаң, без хәзер Истанбул мәчетендә яшәгән булыр идек, – диде Галя.* М.Юныс

**ЕФӘК** *и.* **1.** 1) Ефәк кузысыннан сүтеп алынган җеп. *[Сәрвәр:] Ефәкләрем төшми тамбур булып Сөйгәнемә диган сөлгегә.* К.Тинчурин

2) Шундый җепләрдән, шулай ук ясалма, синтетик сүстән эшләнгән тукыма. *Ефәк – асыл мал! Мондый товар белән хан сараена да, Казаннан көнбатыштагы башка мәмләкәтләргә дә үтеп керәп була.* Ф.Латыйфи

**2.** *с. мәгъ.* Шундый җепләрдән бәйләнгән, үрелгән; шундый тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Диварлар белән бер иш ефәк чаршаулар корылган янәк ишекләр ачылып китте.* Ф.Латыйфи. *Нәкъ урта бер җиреннән ефәк тасма белән буып бәйләнгән ап-ак юрган эчендә бала түгел, әйтерсең*

*тыгызлап тутырылган мамык кына иде.* Ә.Фазылҗанов. *Бу ефәк күлмәкне Зәнфирә инде атнадан артык кия.* Ф.Садриев

2) *күч.* Йомшаклыгы, нәфислеге, елтыравы белән шундый җепләрне, тукымаларны хәтерләткән. *Гүя ул ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.* Ә.Еники

◊ **Ефәккә төрелгән** Уңайлы шартларда гына, мул, тук тормышта яшәгән (үскән). *Килер бер көн, аның ефәккә төрелгән баласы зур кеше булып өлгереп җитәр, иң юк дигәндә, ахыр чиктә, атасы эшенең дәвамчысы булыр.* З.Хөснияр. **Ефәктә генә йөртү** Кадерләп, саклап, матурдан-матур, затлы киемнәр кидертеп кенә яшәтү. *Мин сине шундый кадерләрмен, ефәктә генә йөртермен үзеңне.* Г.Кутуй. **Ефәктәй булды** Кемнең дә булса мөнәсәбәте уңай якка үзгәрү, кырыслыгы йомшару; берсүзсез ризалашу. *Дуңгызны ресторанга алып кереп, нык кына авызын майлаган идем, кая хәзер миңа аяк чалып йөрү! Ефәктәй булды!* Н.Исәнбәт. **Ефәктән төренгән** *к.* **ефәккә төрелгән**. *Бөтен җире җитешкән, кияве, кыр кәҗәсе кебек, тирәсендә сикергәләп йөри, үзе тоташ ефәктән төренгән, бер кулы – балда, икенчесе майда булачак.* Ф.Хөсни. **Ефәк юлы** *бор.* Монгол яуларына кадәр сәүдәгәрләрнең Кытайдан көнбатышка кәрван белән ефәк ташу юллары; аларның берсе Иран аша Византиягә, икенчесе төньяктан Болгар аша Көнбатыш Европа, Скандинавия илләренә сузылган булган. *Ике ара сибелгән, чәчелгән нигъмәтләре белән Кытайдан Урта Азиягә сузылган атаклы ефәк юлын хәтерләтеп тора.* Т.Галиуллин

**ЕФӘ́К АГАЧЫ** *и. бот.* Тутчалар семьялыгыннан, ефәк кортларының төп азыгы булган, яфрагын коючан агач; тут агачы; *русчасы*: **шелковица**

**ЕФӘК-АТЛАС** *җый. и.* Ефәк һәм атлас тукымалар; кыйммәтле тукымалар. *Автор, үзенең ефәк-атласларын мангандай, тылсым казаннарына чумырып-чумырып ала.* Б.Рәхимова. *Палата Нурислам кызлары затлы киемнәрдән генә – ефәк-атлас һәм сатиннан гына йөриләр.* Ә.Салах

**ЕФӘК-БӘРХЕТ** *җый. и.* Ефәкләр һәм бәрхетләр; кыйммәтле тукымалар. *«Һе-һей, менә сиңа мә, “Сәер Зәмзәмия”гә дә кияү чыккач, ул да ефәк-бәрхеткә төренеп йөрерлек булгач, безнең кызларга ни сан инде», – дип, хатыннар тел шартлата.* Р.Вәлиев

**ЕФӘ́К КОРТЫ** *и. зоол.* Ефәк күбәләгенең курчаклану стадиясенә кадәр булган тереклек хәле. *Ефәк корты шуларны [тут агачы яфракларын] ашап көн күрә, ефәк җебе үрә.* Ф.Абдуллин. *Бу көннәрдә агачлардан ефәк корты һәм алтынкорсак гусеницаларын да бетерәләр.* А.С.Девятков, А.И.Макаревич

**ЕФӘ́К КУЗЫСЫ** *и. зоол.* Ефәк кортының курчаклык стадиясенә күчү чорында үзеннән чыгарган бик нечкә, нәфис җепселләргә чорналуыннан барлыкка килгән йомгакчык. *[Сун] Ефәк кузыларын күп итеп алып кайта да алардан, җепләр эрләп, тукымалар тукый.* З.Бәшири

**ЕФӘ́К КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Төрле семьялыкларга караган, кортлары (гусеницалары) ефәк кузылары үрә торган күбәләкләр. *Агачларның салкыннарга чыдамлылыгы --- яфракларны ефәк күбәләге, алма көясе кырып бетерү яки аларның кутыр авыруы нәтиҗәсендә кими төшә.* А.С.Девятков, А.И.Макаревич

**ЕФӘ́К КҮБӘЛӘКЛӘРЕ** *и. биол. күпл.* Кортлары ефәк кузылары үрергә сәләтле булган төн күбәләкләренең берничә семьялыгын берләштергән гомуми атамасы; *русчасы:* **шелкопряды**

**ЕФӘКЛӘНҮ** *ф.* Ефәккә әйләнү, ефәк кебек булу; ефәк сыман нәфис булу

**Ефәкләнә бару** Акрынлап, аз-азлап ефәкләнү, ефәкләнгәннән ефәкләнү

**Ефәкләнеп китү** Кинәт ефәкләнгән хәлгә килү

**Ефәкләнеп тору** Ефәк сыман хәлдә булу. *Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык дулкынланып, ефәкләнеп тора.* Г.Ибраһимов

**ЕФӘ́КТӘЙ** *с.* 1) Ефәк кебек, ефәк сыман нәфис, йомшак. *Ану – алмачуар, озын торыклы, нәзек озын муенлы, тездән түбән дүрт аягына да кара «оеклар» кигән, ялы ефәктәй, койрыгы арыш көлтәседәй.* Г.Госман. *Бүген юына торган су күбектәй йомшак, сөлге ефәктәй назлы, бүген дөнья матур, бүген...* Х.Ширмән

2) *күч.* Нәфис, йомшак. *Татар җырында – Бөек диварлар белән чикләнгән Күк асты иле – борынгы кытай халыкларына күчкән ефәктәй нәфис көй борылмалары бар!* М.Галиев. *Татар һәм башкорт халык көйләрен, композиторларыбыз җырларын үзенә генә хас бер җанны иркәли торган җылылык белән, йөрәкләрне эретерлек сары май кебек йомшак, табигый ефәктәй нәфис тавышы белән башкарып, Фәридә Кудашева халыкның чиксез зур мәхәббәтен казанды.* Шәһри Казан

**ЕФӘКЧЕ** I *и.* Ефәк күбәләге. *Күке – ефәкчеләр дошманы.* Г.Хәсәнов. *Ата җенес күбәләкләрнең кузысындагы ефәк ана җенеснекенә караганда шактый күбрәк. Шуңа күрә тут ефәкчесенең үсешен күзәтеп торалар һәм яшь күбәләкләрнең башлыча ата җенестән булуына ирешәләр.* Зоология

**ЕФӘКЧЕ** II *и.* 1) Ефәк үрчетү хуҗалыгында эшләүче, шул өлкә белгече

2) Ефәк сәүдәсе белән шөгыльләнүче. *Төядән: – Һөнәрең ни? – дип сораганнар икән: – Ефәкче, – дип җавап биргән, ди.* Н.Исәнбәт

**ЕФӘКЧЕЛЕК** *и.* Хуҗалыкның ефәк җитештерү һәм эшкәртү тармагы. *[Сун] Сарай ефәкчелегендә булган бөтен ефәк кузыларын карап, тикшереп чыга.* З.Бәшири

**ЕФРЕ́ЙТОР** *и. нем.* Армиядә солдаттан югары беренче звание, дәрәҗә; гади солдатка бирелә торган икенче хәрби чин; шул чиндагы кеше. *[Хәбир] Әледән-әле руль тотып утырган ефрейтор егеткә күз ташлап алды.* Н.Акмалов. *Мин – латыш, сезнең танышыгыз Фәрит Айтуганов хезмәт итә торган частьның ефрейторы Гунар Дунис.* Р.Сибат

**ЕФРЕ́ЙТОРЛЫК** *и.* Ефрейтор булу. *Подполковник Орлов, отрядта*

*дисциплина бик начар куелган, дип санап, Павловны гаепләгән, --- ә комсоргны сержант дәрәҗәсеннән ефрейторлыкка төшергән.* А.Шамов

**ЕХИ́ДНА** *и. гр. зоол.* 1) Аспидлар семьялыгыннан, озын гәүдәле агулы елан (күбрәк Австралиядә очрый)

2) Йомырка салучылар отрядыннан, аркасы очлы энәләр белән капланган, сумкалы, имезүче кечкенә хайван. *--- хәзерге имезүче хайваннар арасында йомырка салучылары да бар. Атаклы үрдәкборын белән ехидна шундыйлардан санала.* Кызыклы физиология

**ЕХИ́ДНАСЫМАННАР** *и. зоол. күпл.* Чәнечкеле гәүдәле, очлы нәзек томшык очындагы авызы мөгез тышча белән капланган, сумкалы имезүче хайваннарның семьялык атамасы; *русчасы:* **ехи́дновые**

**ЕШ** I *рәв.* 1) Бер-беренә бик якын итеп; куе; *киресе*: **сирәк**. *Күршеңне дус тот, читәнеңне еш тот.* Мәкаль

2) Бер-берсенә бик якын, орынып, тыгыз; *киресе*: **иркен**. *Рәттән аслыөсле, еш итеп тактадан тезелгән сәке сыман урыннар --- башта Гарифка бик күңелсез булып күренде.* М.Гафури

3) Чагыштырмача аз вакыт эчендә бер-бер артлы (бердәй хәрәкәт, тавыш, күренеш һ.б. кабатлау турында). *[Җәүдәт абый] Тәмәкесен еш-еш суыра башлый.* М.Галиев. *Әле булса хәтерендә: күктәге айдай чибәр кыз, озын керфекләрен еш-еш каккалап, каршына килеп баскач, Кубратның аяк астындагы җир чайкалып киткән кебек булган иде.* М.Хәбибуллин. *Ләкин еш-еш туктый, хәрәкәтләре әкренәя, күрәсең, яраланган.* Г.Әпсәләмов

4) Әледән-әле, гел, даими рәвештә (билгеле бер эш-хәрәкәтнең торган саен кабатлануы турында). *Еш булмаса да, балаларым белән бергә су кирәргә барам, урманга чыгам.* Г.Кутуй. *Түбә башына гына түгел, җәйләрен миләш очына да еш үрмәли иде малай.* Р.Низамиев

4) *Кына/кенә* кисәкчәсе белән «күп вакытта», «күп очракта» дигән мәгънәне белдерә. *Бу охшаш күренешләрне игътибар белән өйрәнү еш кына археологик материалларны язма чыганаклар белән тоташтырырга мөмкинлек бирә.* Г.Дәүләтшин. *Еш кына йөрәк, кан тамырлары яки нервлар бирешә.* Ф.Әгъзамов. *Тышкы кыяфәт еш кына алдый, бутый.* А.Гыйләҗев

**ЕШ** II *и. бор.* Урманлы таулар белән әйләндереп алынган үзән. *Һәр ешның үз сандугачы бар.* Мәкаль. *Иш – ише белән, еш – кошы белән.* Мәкаль

**ЕШАЙТУ** *ф.* 1) Берсен икенчесенең янына утырту; тыгыз, куе итү; араларын бик якын калдыру, янәшә урнаштыру

2) Эш-хәрәкәтнең темпын арттыру, тизләтү, кызулату. *Авыл башындагы йортлар күренгәч, [айгыр] адымнарын ешайта, озакламыйча юыртып китә.* К.Миңлебаев. *Нәҗип адымнарын ешайтты.* Казан утлары

3) Нинди дә булса эш-хәрәкәтне вакыт үткән саен кабатлап тору. *Алар очрашуларны ешайттылар, ләкин Люба Олегка дусларча мөнәсәбәт чикләрен атлап чыгарга ирек бирмәде.* Ф.Әгъзамов

**Ешайта бару** Эзлекле рәвештә ешайту, торган саен ешайту. *Уртавыл волостена аклар әлегә тоташ һөҗүм итеп килеп җитмәсәләр дә, аерым группалары белән халыкны талауларын көннән-көн ешайта баралар иде.* В.Нуруллин

**Ешайта башлау** Ешайтырга тотыну. *Таң алдыннан австриецлар мылтык, пулеметтан атуларын, траншей туптан, бомбометтан атуларын ешайта башладылар.* А.Таһиров

**Ешайта төшү** Тагы да бераз ешайту. *Газизләренең исән-сау җиңеп кайтуларын теләргә кирәксенеп, Хәдичә түти намазны ешайта төште.* Г.Бәширов

**Ешайтып алу** Берара, кыска вакытлы ешайту

**Ешайтып бетерү** Бик нык, кирәгеннән артык ешайту

**Ешайтып килү** Электән үк, эзлекле рәвештә, системалы ешайту

**Ешайтып тору** Әле, хәзергә, вакытлыча ешайту

**ЕШАЮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса кабатлану ешлыгы арту. *[Акмалның] йөрәге кабат-кабат кысылып килде, сулыш алуларына хәтле ешайды.* Г.Ахунов

2) Еш булу, еш кабатлану. *Җил ерак офык артларыннан салкын болытларны куып китерде, яңгырлар ешайды.* Р.Низамиев. *Колхоз идарәсе «хуҗасыз» калгач, бу хәл аеруча ешайды.* М.Хәсәнов. *Берлинны бомбага тотулар ешайды.* Т.Әйди. *Канлы бәрелешләр ешая, берсендә магулларның гаскәрбашы Кечек бәк әсирлеккә дә төшә.* С.Шәмси

3) Күбрәк очрау, ишәю, күләме яки саны ягыннан арту. *Агачлар ешайды, каршымнан, күгелҗем яшькелт ташкын булып, урман шуыша.* Р.Низамиев. *Зиратларны ыграк карый башладылар, зиратларда озак гомергә исәпләнгән чардуганнар, мәрмәр ташлар ешайды, авыл арасы юл тирәләренә агач утырталар...* А.Гыйләҗев

4) Нәрсәнең дә булса көче арту, эшхәрәкәт, процесс интенсивлашу. *Шуннан бирле авырулары ешайды, хәлсезләнә барды.* Ф.Әхмәтова

**Ешаеп алу** Бераз, аз гына вакытка ешаю. *Җил көчәеп киткәндә генә ешаеп ала да һаман шул бертөрле көйгә тәрәз пыяласын кага тамчы.* Н.Нотфуллина

**Ешаеп бару** *к.* **ешая бару**. *Ил-җирне басып алып, яуланган халыкны үз диненә көчләп керткән яулаучылар ешаеп бара.* М.Хәбибуллин

**Ешаеп бетү** Бик нык, тәмам ешаю

**Ешаеп калу** Нинди дә булса эшхәрәкәттән соң ешаю

**Ешаеп китү** Нindидер сәбәптән соң кинәт ешлыгы арту. *Спорт киеме – чалбар, майка – [Аняның] сыгылмалы, альпинистларча көчле буенның зифалыгын яшерми генә түгел, киресенчә, көчәйтебрәк күрсәтә, һәм бу хәлдән Матушкинның пульсы бермә-бер ешаеп китте.* Ә.Мушинский. *Йомшак әсәрне мактау белән мавыгу яисә уңышлы әсәрне күрмәмешкә салышу очраклары да ешаеп китте.* Ә.Закирҗанов

**Ешаеп тору** Ешайган хәлдә булу, соңгы вакытта әледән-әле кабатлану. *Ешаеп торсын иде шундый матур манзаралар, күңелдән агылган теләкләр.* Б.Рәхимова

**Ешая бару** Эзлекле рәвештә ешаю; ешайганнан ешаю. *Күзге яңгырлар башланганчы эшне төгәлләү өчен, сменадан соң калулар ешая барды.* Р.Вәлиев. *Минә шул кичтән безнең Маһирә белән очрашулар ешая барды.* Г.Галиева

**Ешая башлау** Ешаерга тотыну, ешрак була башлау

**Ешая төшү** 1) Тагы да ешаю, ешрак кабатлану. *Бозауларын имезүдән аергач, бу хәл тагы да ешая төште.* М.Хәсәнов

2) Көче арту, куәтләнү, интенсивлашу. *Яңгыр --- ешая төште.* М.Шабай

**ЕШКЫЛДАТУ** *ф. диал.* Чапылдату, суктыру, кыйнау. *Ә мин шомырт чыбык пешереп, шуның белән бер йөз тапкыр ялангач тәнгә ешкылдатыр идем.* Г.Толымбай

**ЕШКЫН** *с. диал.* Урманда, әрәмәдә агачлар куе булып, ботаклары берберясенә керешеп үскән, чытырман. *Штаб ерак түгел, әмма барыр җире җайсыз: ешкын таллык, чокыр-чакыр.* Мирас

**ЕШКЫНЛЫК** *и. диал.* **ешлык** (*5 мәгъ.*). *Ешкынлыкка карамаска тырышыбрак, усак агачы төбенә урын җаям.* М.Галиев. *Кая таба күз салма – көмеш томан бөркелгән урман киңлекләре, шомлы һәм серле карурман ешкынлыгы.* М.Хәсәнов

**ЕШЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **ешаю**. *Күләгәләр һаман ешлана, шавылты көчәя.* Ш.Камал

**ЕШЛАТУ** *ф. сөйл. к.* **ешайту** (*3, 4 мәгъ.*). *Янгураз фрау Софи белән аралашуны ешлатырга ниятләсә дә, яңадан-яңа мәшәкатьләр моңа ирек бирмәде.* Т.Әйди

**Ешлата бару** *к.* **ешайта бару.** *Поезд кызулый. Вагон тәгәрмәчләре рельс ялгаулары өстеннән тигез тавыш белән сугып үтүләрен ешлата баралар.* Ә.Еники

**Ешлата башлау** *к.* **ешайта башлау**. *Хәләл җефете белән булган фаҗигадән соң, морза бу урыслар урнашкан авылга йөрүен ешлата башлады.* Т.Нәбиуллин

**ЕШЛА́У** *ф. сөйл.* 1) *к.* **ешайту** (*1, 2 мәгъ.*)

2) Кая да булса яки кемдер янына еш барып йөрү. – *Кая йөгерәсең, Гөлйөзем? Болай чибәрләнеп... Ешладың әле...* Ф.Латыйфи. *Шул көннән башлап, Әхсән бу йортка ешлады.* Н.Акмалов

3) Тизләтү, кызулату. *Хәрби тормышка өйрәнгән күндәм малкай хуҗасыннан бер адым да калышмый барды. Хуҗасы ешласа, ул да тизләде, йөгерсә, ул да юыртты.* Ш.Шәйдуллин

**ЕШЛЫК** *и.* 1) Нәрсәләрнең дә булса бер тирәгә күп һәм бер-берсенә бик якын, тыгыз торуы, урнашуы. *Күплекләре һәм ешлыклары белән шаулап утырган --- биек вышкалар арасында «Челекон» тавы, горурланып, күкрәген калкыткан.* Р.Ильяс

2) Нәрсәнең дә булса еш кабатлану дәрәҗәсе

3) *махс.* Билгеле бер вакыт эчендәге хәрәкәтнең, тирбәнешнең саны, зурлыгы. *Тояк тавышлары йөзләрчә думбакка бәргән ешлык белән тар урамнарда, тыкрыкларда бәргәләнде.* Ф.Латыйфи. *Ул да, Марат шикелле үк, нурланыш ешлыгының җан ияләренә, терек һәм терек булмаган табигатькә тәэсирен өйрәнә.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Оркестр, «Каз канаты» көен уйнап, күңелләрдәге очынуларны баса төште, аннан «Ком бураны» көе уйналып, йөрәкләр тибешен шушы кичәгә кирәк кадәренчә ешлыкка җиткерде.* Ф.Сафин

4) *физ.* Дулкын. *Кайвакыт бу бөҗәкләр, ялгышып, электростанция янына күпләп очалар, чөнки генераторның гүләве ана озынборынның канаты тибрәнү ешлыгына туры килә икән.* Кызыклар дөньясында. *Пыяла көпшәнең икенче башына динамик урнаштырып, аңа тавыш генераторыннан билгеле бер ешлыктагы тавыш сигналы бирәләр.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы. *Аналог форматында исә һәр каналга аерым ешлык кирәк.* Ватаным Татарстан

5) Урманда, әрәмәдә агачларның куе булып, ботаклары бер-берсенә аралашып үскән урын; куаклык, чытырманлык. *Кәүсә һәм ябалдашлар ешлыгында югалып тора да, утлы шар сыман яңадан каршыма тәгәрәп чыга.* Р.Низамиев. *[Зиннәт] Иярендә җай гына калкына биреп, юан усаклар ешлыгын узды.* Ш.Шәйдуллин. *Аның шофёрлар янына куе ешлыктан парлашып чыгасы килмәгәнен аңлады Давыт.* М.Маликова

**ЕШЛЫКЛЫ** *с.* Билгеле ешлыкта булган. *Ультратавыш ысулын кулланганда, югары ешлыклы электр импульслары тудыра торган электрон генератор алына, аның импульслары махсус нурландыргычта механик ультратавыш дулкыннарына әверелә.* Төзү материаллары. *Электрон парамагнитик резонансын күзәтү өчен, утә югары ешлыклы 103÷104 МГц диапазонындагы электромагнитик дулкыннар кулланыла.* Фән һәм тел. *Бигрәк тә түбән ешлыклы музыка – хип-хоп, рок, хардрок, электрон музыка – тыңлаучыларны күңел төшенкелегенә китерергә мөмкин.* Шәһри Казан

**ЕШУ** *ф. диал.* Ышкылау; ышку. *Бакырны күпме ешсаң да, алтын булмас.* Мәкаль

**ЕШЫНУ** *ф.* 1) *диал. к.* **елышу** (*5 мәгъ.*). *Тирә-якка карана-карана, без шушы өй янына барып җиттек тә арт як стенасына ешындык.* Ф.Кәрим

2) Берәр кем яки нәрсә икенче бер нәрсәгә тиеп, кагылып үтү; ышкыну. *Юл ягына чыгыбрак торган, бүрәнә башларына арба тәгәрмәчләре ышкылып киткән, сыерлар, сарыклар ешынып, төкләр, йоннар эләгеп калган амбар почмагы иде бу.* Н.Фәттах

**Ешынып алу** Бик тиз арада ешыну

**Ешынып йөрү** Озак вакыт ешыну. *Хәер, Талиясеннән аерылгач, янган йөрәген басу өчен, ул үзе, кәҗә тәкәсе кебек, койма тирәсендә ешынып йөрде.* Н.Фәттах

**Ешынып китү** Кинәт, көтмәгәндә ешына башлау

**Ешынып тору** Һаман, гел ешыну

# Ж

**ЖАБО** *и. фр.* Күлмәк, блузка кебек киемнәрнең якасында яки изүеннән күкрәккә таба төшеп торган челтәр яки җиңел тукымадан бөреп, сырлап тегелгән матур, зиннәтле бизәк. *Ак батист күлмәгенең якасы, унсигезенче гасыр француз франтларыныкы шикелле, жабо рәвешендә эшләнгән.* М.Юныс

**ЖАКЕТ** *и. фр.* 1) Хатын-кызларның пальтодан кыскарак һәм җиңелрәк итеп тегелгән өс киеме. *Ул, шулай ук кычкырып көлә-көлә, өстенә плюш жакетын киде.* М.Хәсәнов. *Ялтырап торган кара плюш жакет һәм эре кызыл чәчәк төшерелгән кәшимир шәл кызның гәүдәсен бер дә бозмаган, киресенчә, аның сыгылмалы билен тагы да ымсындыргычрак итеп яшергән.* Ә.Дусайлы

2) Хатын-кыз яки ир-атларның бәйләнгән кыска өс киеме, кофта. *Каты дуылдап, Әлфинур килеп керә дә кулындагы жакетын почмакка ыргыта.* Р.Ишморат. *Миңнурыйның иңбашындагы кыска жакеты җиргә төште.* Г.Әпсәләмов

3) Бер генә якка төймәләнә торган кыска сюртук. *Ак күлмәк өстеннән килгән шакмаклы жакет егетләрне тагын да күркәмрәк итә.* К.Закирова

**ЖАКТ** *и. рус иск.* СССРда 1937 елга кадәр җирле совет карамагындагы торак йортларны арендалау һәм үзенең пайчыларына шуннан билгеле бер хакка вакытлыча файдалануга торак мәйданы биреп тору белән шөгыльләнгән кооператив берләшмә. *Гомеремдә бер тапкыр жакт собраниесендә сөйләргә булып сүз алган идем, әлләниләр бутап бетердем.* Т.Гыйззәт. *Инде жакт председателе якын дусың булып, алай-болай фатирга эләгә алсаң, асрау тотма.* К.Тинчурин

**ЖА́ЛОБА** *и. рус сөйл.* Берәр кеше яки оешманың ялгыш, законсыз, начар эшләрен яки гаебен күрсәтеп язган рәсми гариза; шикаять, шикаять язуы (кәгазе). *Сельсовет председателе: «Сәгыйдулла абзый, сезнең өстән жалоба килде бит әле», –* ди. Р.Вәлиев. *Башта ук шунысын әйтеп куям: моңарчы аның өстеннән безгә берниндиjа-лоба-фәлән кергәне булмады.* Ә.Фазылҗанов. *Берсен-берсе сытып, берсе өстеннән берсе өлкә комитетына жалоба язып... Мин язучыларны гел әсәр генә язалар дип уйлый идем, аларның кайберсе, баксаң, жалоба һәм анонимкалар да яза икән.* М.Мәһдиев

**ЖА́ЛОВАНЬЕ** *и. рус иск.* Хезмәт хакы, эш хакы. *[Мирзаны] Касыймнан юньле хәбәр килмәве, аның ел саен егермешәр урынга авышуы, жалованьесыннан тыш та өйдән күпләп акча алуы һаман борчый.* С.Җәләл. *Мин үзем военный комиссарда кучер булып торам, анда болай тамак тук, өс-баш бөтен булса да, жалованье бик зурдан түгел.* М.Гали

**ЖАЛУ** *и. сөйл. к.* **жалоба**. *[Искәндәров Фидаяга:] – Синең өстән жалу бар анда, – диде. – Берәү генә түгел, икәү хәтта.* М.Маликова. *Әхмәт Хәйретдине өстеннән жалу бирәсем бар!* Б.Камалов. *Уфа провинциясенең вице-губернаторы Аксаковка бәйле жалулар билгеле.* Җ.Рәхимов

**ЖАЛЮЗИ** *и. фр.* Яктылык һәм һава агымы үтеп керә торган итеп көйләнгән рәшәткәле тәрәзә капкачы. *Куышлыкның эченә өч секция жалюзилар куелган.* Терлекче-механизатор белешмәсе

2) Туры төшкән кояш нурларыннан саклый һәм һава агымы үтеп керерлек итеп көйләнгән вертикаль яки горизонталь металл, пластмасс һ.б. шундый каты тар һәм күп пластинкаларны яки шторaларны төрле якка бөтерелә ала торган итеп шнурлар белән тоташтырган тәрәзә пәрдәсе. *Исеме дә, җисеме дә – Чит илдән килгән бар да. Ник кирәк миңа жалюзи, Татарда пәрдә барда.* И.Юзеев

**ЖАНДАР** *и. к.* **жандарм**. *Инде сугылучы татарның аркасы чи канга тулган, розга сугучы жандар Андрәй Палич, кулындагы талчыбык белән зур-зур кизәнеп, садистларча бер дәрт белән һаман сугуын белә.* Л.Толстой

**ЖАНДАРМ** *и. фр.* 1) Жандармериядә хезмәт итүче кеше. *Безнең арттан ук озакламый жандарм килеп керде.* Ш.Камал. *Жандармнан койма аша сикереп качтым.* А.Әхмәт

2) *күч. сөйл.* Башка кеше яки кешеләрне ирексезләп, аларның омтылышын, теләген басып торган залим кеше, деспот, тиран. *Гомер буе кемдер корбан булды, Көчлеләргә булды жандарм!* Н.Әхмәдиев. *Тәрбия эшендә жандарм алымнары кулланучылар да җитәрлек.* Г.Афзал

**ЖАНДАРМЕ́РИЯ** *и. фр.* 1) *тар.* 1917 елга кадәр Россиядә һәм кайбер илләрдә революцион хәрәкәткә каршы көрәш алып бару, революционерларны эзәрлекләү өчен оештырылган полиция гаскәре. *Ул шунда ук округ командующиен, полицмейстерны, жандармерия башлыгын һәм казачий полк командиры Дашковны чакыртты.* К.Нәҗми. *Киресенчә, аның артыннан жандармерия тарафыннан яшерен күзәтү куелганлыгын исбатлап торган документлар күрдем мин анда.* А.Расих

2) Шул гаскәр оешмасы урнашкан бина. *Мәдрәсәдән алынган нәрсәләр, алты-җиде йөккә төялеп, жандармерия йортына озатылды.* Г.Ибраһимов. *Жандармерия идарәсенең ахмаклары (ирония белән) аны Казаннан кырык чакрымга сөргенгә сөрәләр.* Ә.Гаффар

3) Франция һәм Төркия илләрендә коралл ы гаскәрнең бер өлеше

**ЖАНДА́РМЛЫК** *и. тар.* Жандармнарга хас күренеш, сыйфат. *Коридорда «Марсельеза» җырлауга каршы бәйләнеп йөрү сез [мөгаллимнең] эше түгел, бу – жандармлык.* Г.Ибраһимов. *Бу фикер хәзерге көндә көчле дәүләтләрнең көчсез илләрнең эчке эшләренә оятсыз рәвештә тыкшынуына да, бу*

*жандармлык вазифасын «демократия урнаштыру» дип аңлатырга тырышуына да карый*. Җ.Дәрзаман

**ЖАНР** *и. фр.* 1) Нинди дә булса әдәбият яки сәнгать әсәренең сюжет, төзелеш үзенчәлекләре һәм стилистик билгеләре белән аерылып торган тибы; шул типның аерым төркемчәләре. *Риваятьләр, легендалар һ.б. фольклор жанрларын этнокультур процесслар мәсьәләләрен хәл итәргә тарту бик уңышлы булып чыкты.* Г.Дәүләтшин. *Дистәләрчә шигырь язучы авторларның бик сирәге генә җыр жанрында уңышлы эшли.* Т.Галиуллин. *Әдәбияттагы һәр яңалыкны, барлыкка килгән һәр тенденцияне йә булмаса юкка чыккан, төсен югалта башлаган һәр хасиятне тәнкыйть жанры күрә.* Ф.Галимуллин

2) *сәнг.* Сәнгать төре. *[Айрат Арсланов] Нәфис сүз осталары, дөресрәге, сөйләү жанрында эшләүчеләр өчен драматик театр – әйләнеп узылмаска тиешле зур бер мәктәп, дип карый.* Р.Заһидуллина

3) Рәсем сәнгатенең көндәлек тормыш-көнкүреш күренешләрен тасвирлый торган төре; шундый эчтәлеккә нигезләнеп ясалган аерым бер рәсем. *Пейзаж һәм жанр*

4) *иск.* Әдәбиятта халыкка хас көндәлек тормыш күренешләре. *Әгәр дә «Татар хатыны ниләр күрми»нең өченче басмасын укып карасак, анда да жанр күренешләренең тулы һәм киң итеп бирелгәнен күрербез.* Г.Нигъмәти. *Шундый ук жанр сурәтләренең башка төрләрен тулы рәвештә әсәрнең XVIII дән башлап XXXIV кә хәтле булган башларында, Байтүрә җеназасын язган җырләрдә, шулай ук Сарсымбай йортының башка җәйләүгә күчү күренешләрен биргән урыннарда очратабыз.* Г.Нигъмәти

**ЖАРГОН** *и. фр.* **1.** 1) Күп санда, гадәттә, ясалма яки шартлы сүзләр һәм тәгъбирләрдән гыйбарәт нинди дә булса социаль яки профессиональ төркемнең сөйләме. *Алар сәүдә жаргонын күп телләрдә беләләр.* М.Мәһдиев. *Алар миңа аңлашылып бетмәгән жаргонда әңгәмә алып баралар иде.* М.Юныс

2) Шушы төркемнәр телендә генә кулланыла торган сүзләр, арго. *XX гасырның азакларыннан алып халык телендә жаргон сүзләренең активлашып китүе --- күзәтелә башлады.* И туган тел

**2.** *с. мәгъ.* Билгеле бер төркем теленә генә хас булган, шул төркем кулланган. *Синонимнарны барлыкка китерүдә жаргон сүзләр дә катнаша.* Ф.Сафиуллина

**ЖАРГОНИЗМ** *и. рус лингв.* Жаргон сүзләр яки тәгъбирләр. *Ә журналистлар исә жаргонизмнарны тормыш дөреслеген чагылдыру, текстларын иркен ага торган җанлы сөйләшү стиленә якынайту максатыннан куллана.* И туган тел

**ЖАРГОНЛАШТЫРУ** *ф.* Жаргонга әйләндерү, жаргон ясау

**ЖАРГОНЛАШТЫРЫЛГАН** *с.* Жаргонга әйләнгән, жаргон булып киткән. *Тел белемендә хәзер «жаргонлаштырылган сөйләшү теле» дигән төшенчә дә кулланыла.* И туган тел

**ЖӘЛ** *рәв. рус сөйл.* **1.** Кызганыч, аянычлы. *Кара көннәр аның --- маңгаена тирән эзләр салган, аркасын бөккән, күзләрендә нурны сүндергән иде. Бу вакыт ул миңа әйтеп бетергә алмаслык җәл тоелды.* С.Җәләл

**2.** *хәб. функ.* 1) Кызгану, аяу хисе тудыру турында. *Тик бабай гына җәл, ялгыз кала.* Г.Бәширов. *Ләкин аларны монда калдырып булмый, җәл.* З.Хөсният. *[Ябалак] Икенче куыш эзләр иде, монысы кызганыч, куыш янында кагаеп утырса, үзе җәл.* Н.Сладков

2) Нәрсәне дә булса югалту алдыннан яки югалткач барлыкка килгән хис-тойгылар турында. *Акча җәл түгел. Торгызып куегыз шул манараны.* Р.Вәлиев. *Әни, әйдә болай итик: кара җиргә тиенәбез, нужәли үләрбез? Бергә булыйк, алып кайтыйк энекәшләрне. Бик җәл бит...* М.Мәһдиев

**3.** *кер. сүз мәгъ.* Кызганыч, кызганычка. *Җәл, сыйлары шәп, тәмтомнары бик күп иде.* Н.Акмалов. *Җәл, бер күрүдә күңелгә кереп урнашкан иде!..* З.Фәйзуллин

**ЖӘЛЛӘТҮ** *ф. сөйл.* Җәлләү (кызгану) хисе уяту. *Асыл ир-ат катынкыздан җәлләтеп сыктамас, олан.* Н.Гыйматдинова

**Җәлләтеп утыру** Әле, хәзерге вакытта җәлләтү. *Соң, шуннан, хатынын эзлисе урынга, ул монда балавыз сыгып, үзен кулак калдыгыннан җәлләтеп утыра.* Т.Галиуллин

**ЖӘЛЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Берәр кемгә теләктәшлек күрсәтү, кемне яки нәрсәне дә булса кызгану. *Ул да җәл инде дә... Тик мин аны ул тикле җәлләй генә алмаем. Булмай!* Г.Бәширов. – *Ник елыйсың, кызым? – Сине җәлләп, әти.* Ә.Гаффар. *Бердән, аны җәлләү тойгысы уянса, икенчедән, эш сөючән медицина хезмәткәре табылуга сөенеп туя алмады [доктор].* Р.Кәрами

2) Берәр нәрсәне «әрәм» дип санау. *Бер тимер кисәген җәлләп, ничә сәгать поездлар хәрәкәтен тоткарлыйкмы?* Ф.Абдуллин

3) Бик саклап тоту, бик сак сарыф итү. *Гөлгенә кинәт уйчанланды, бу халәтен Нәҗипкә сиздерәсе килмәде, юри наян, ясалма тавыш белән: «Мунчаң эссе булсын, утыныңны җәлләмә!» – диде.* А.Гыйләҗев

**Җәлләп алу** Кинәт, кыска вакыт эчендә, бераз җәлләү хисе кичерү

**Җәлләп йөрү** Күптәннән, әллә кайчаннан җәлләү

**Җәлләп килү** Электән үк җәлләү

**Җәлләп кую** Кинәттән, аз гына вакытка җәлләү хисе уяну. *«Ах-ма!» – диде, мине җәлләп куйды, яныма ук килеп утырды.* Ш.Маннур. *[Йосыф абый:] Сине дә җәлләп куйдым.* В.Нуруллин

**Җәлләп тору** 1) Гел, һәрвакыт җәлләү. *Моның хәтле асыл затка акча җәлләп торырга, мине әллә карун дип беләсеңме?* З.Зәйнуллин

2) Әле, хәзер, сөйләү моментында җәлләү. *Официант кыз аны читтән генә күзәтеп, җәлләп торды.* М.Ибраһимов

**Җәлли төшү** Җәлләү хисе бераз көчәю

**ЖӘЛЛӘҮЧӘН** *с.* Кызганучан, авыр хәлдәге кешегә теләктәшлек күрсәтә торган. *Бөтен ирләр эшен дә башкара алганга һәм ярдәмчел, бигрәк тә бездәй олыларны, ялгызларны җәлләүчән булганга күрә, миңа ул башта ук ошады.* Шәһри Казан

**ЖГУТ** *и. рус* 1) Каеш, тукыма, салам һ.б.ш. әйберләрдән каты итеп үрелгән яки ишелгән бер тотамлык бау. *Караңгылык эчендә барлык яклардан*

*уралып буталган жгутлар эленеп торалар*. В.Исламетдин

2) *мед*. Кан китүне вакытлыча туктату өчен, кул яки аякны кысып бәйли торган сузылмалы резин көпшә. *Сынган аякка жгут салу*

3) *зоол., биол.* Иң гади төзелешле организмнарның нечкә җепселсыман хәрәкәт итү әгъзасы; төкчә. *Күп кенә бактерияләр махсус хәрәкәт органоидлары – жгутлар ярдәмендә хәрәкәтләнәләр.* Гомуми биология

**ЖГУТЛА́У** *ф.* Жгут салу

**Жгутлап кую** Жгут салынган хәлгә китереп калдыру

**ЖГУТЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Хәрәкәт әгъзалары булып төкчәләр хезмәт иткән иң гади төзелешле организмнарның бер классы; *русчасы:* **жгутоносцы, жгутиковые**. *Жгутлылар жгутлары ярдәмендә йөзәләр*. Гомуми биология. *Жгутлылар җенессез үрчиләр*

**ЖЕЗЛ** *и. рус* 1) Берәр дәрәҗәгә, хакимлеккә һ.б.ш. ия булу билгесен белдерә торган махсус таяк. *Фельдмаршал жезлы*

2) Юл тәртибе саклаучының транспорт һәм җәяүлеләрнең хәрәкәт итү юнәлешләрен күрсәтү өчен кулланылган кыска таягы. *Юллар кисешкән урында басып торган милиционер, хәрәкәт сулга дәвам итә дип, жезлы белән ишарә ясады.* С.Баттал

3) *т.-юл* Бер колеялы тимер юлда машинистка юлын дәвам итү хокукы бирә торган тимер таяк. *Вокзал бинасы алдыннан үтешли машинист белән дежурный, сузылып кына, жезлларын алмашалар*. Ә.Еники

4) *т.-юл* Тимер юлда поездларның йөрешен тәртипкә салу өчен хезмәт итә торган автомат приборның металл таягы

**ЖЕЛАТИН** *и. фр. тех.* Хайван сөяге яки тиресеннән ясалып, техникада, фотографиядә, кулинариядә, медицинада кулланыла торган, җилемсыман аксым матдә; коллоид. *Бүрткән желатинны эремчеккә кушабыз, сөт өсте өстибез.* Тәмле киңәшләр

**ЖЕЛАТИНЛА́У** *ф.* Койкасыман массага әверелдерү

**ЖЕЛАТИНСЫМАН** *с.* Желатинга охшаш, желатин кебек булган

**ЖЕЛЕ** *и. фр.* 1) Җиләк-җимеш суларына, сөт, вино һ.б. продуктларга желатин өстәп әзерләнгән кесәлсыман татлы ашамлык. *Кызыл карлыган желесе белән чәй эчәбез*

2) Койкалы ит, балык һ.б. әзерләү өчен, шуның шулпасына желатин кушып ясалган дерелдәвекле масса

**ЖЕНЬШЕНЬ** *и. кыт. бот.* Аралиячәләр семьялыгыннан, Ерак Көнчыгышта үсә һәм тамырыннан дару ясала торган, үзәк тамырлы, туры озын сабаклы күпьеллык үләнчел үсемлек; тереклек тамыры (медицинада кулланыла). *Женьшень тамырыннан төнәтмә ясаган иде Оксанам*. Ә.Гадел. *Женьшень Ерак Көнчыгышта куләгәле катнаш урманнарда үсә.* Биология

**ЖЕСТ** *и. фр. кит.* 1) Хис-тойгы һәм фикерләрне белдерү өчен ясалган кул яки тән хәрәкәтләре; ым, ишарә. *Тукта, грек [нотык сөйләгәндә], кирәкмәс жестлар ясамас өчен, кулларына таш бәйләп кесәсенә тыккан бит, ә Хәлим, давылдагы җил тегермәне сыман, кулларын бутый.* И.Гази

2) *күч.* Нинди дә булса ният белән кылынган гамәл; максатка ирешү өчен ясалган адым, эш-хәрәкәт. *[Акбирдин:] Уйлашыйк әле, Габдулла әфәнде, «Йолдыз» газетасы һәм «Мәгариф» журналы өчен түгел, милләт өчен, бигрәк тә аның ярлылары өчен патшага бер дипломатик жест ясасак?* Р.Ишморат. *Бары күрәбез: кемнәрнедер урам чыгышлары белән сүгәләр, кемнәрнедер «үтерү», кемнәрнедер «тергезү» турында томанлы жестлар күрсәтәләр.* Ф.Бурнаш

**ЖЕТОН** *и. фр.* 1) Берәр оешма яки җәмгыятьнең әгъзасы булуны күрсәтеп торган металл значок. *Инспекторның күкрәгендә «ГАИ» дип язылган тимер билгесе, жетоны булмаса, документын күрсәтүне сорагыз*. Т.Галиуллин

2) Берәр вакыйга истәлеге итеп яки ярышта җиңүчегә бирелә торган металл значок. *Өчесенә дә көмешчедән монограмма яздырып, алтынланган жетон бүләк итәргә булдык.* Казан утлары

3) Берәр нәрсәгә хокук бирә торган (мәс., кассадан – акча, кибеттән ашамлыклар алу, автоматтан шалтырату һ.б.) тамгалы яки цифрлы пластмасс яисә калай кисәге. *Муса, өстәлгә юып өелгән табак-савыт арасыннан бер тирәнрәк алюмин тәлинкә алды да, жетоннарын салып, кухня тәрәзәсеннән эчкә сузды.* Ш.Маннур. --- *парк администрациясе һәр җиңүчегә бию мәйданчыгына сезон беткәнче бушлай кереп йөрү хокукы бирә торган жетон тапшыра*. Р.Мирхәйдәров

**Ж-Ж-Ж** *иярт.* Бөҗәкләр очканда яки берәр төрле механизм гөжләп эшләп торганда чыккан тавышны белдерә

**ЖИ́ГОЛО** *и. фр.* Хатыннарга интим хезмәт күрсәтеп акча эшләүче ир-ат; хатын-кыз исәбенә яшәүче ир

**ЖИКЕТ** *и. сөйл. к.* **жакет**. *Клуб урамыннан икәү янәшә кайтып барган кызларның берсе – чак кына тәбәнәгрәге, башына ак мамык шәл бәйләп кара плюш жикет кигәне – чатка җитүгә, уңга таба борылды.* Н.Хәсәнов. *Шул чакта тыкрыктан кулына ак төенчек тоткан, жикет кигән, шәльяулыкка төренгән бер кыз килеп чыкты...* М.Мәһдиев

**ЖИЛЕТ** *и. фр.* 1) Ир-атларның гадәттә пиджак астыннан кия торган җиңсез, якасыз кыска киеме. *Ашыгып, укучылар жилетларының күкрәк кесәләрен карыйлар да малайга көмеш акча сузалар.* А.Алиш. *Төсле атлас жилет кигән ике таза ир музыка уйный.* М.Мәһдиев

2) Хатын-кызларның күлмәк, блузка һ.б. өстеннән кия торган төрле озынлыктагы җиңсез киеме

3) Су яки һава транспортында яисә утлы корал куркынычы янаганда киелә торган җиңсез, эченә һава тутырылган яки пуля үткәрми торган пластинка куелган саклагыч өс киеме. *Әлбәттә, гадәти чыгышлар вакытында күлмәк эченнән пуля үткәрми торган жилет киюне бу юлы кирәк санамый.* Ә.Рәшит

**ЖИЛЕ́ТКА** *и. рус к.* **жилет**. *Укытучы пиджагын сала, жилеткадан кала.* М.Мәһдиев

**ЖИРАФ** *и. зоол. фр.* < *гар.* Партояклылар отрядыннан, гадәттән күпкә озын муенлы, озын аяклы, ала-кола төстәге кыска гәүдәле имезүче хайван. *Бер дә уен Түгел бу, Уен-муен Түгел бу: Жираф муенын Кем юа, Җитә ала Кем*

*моңа?* Ш.Галиев. *Жирафлар төркем-төркем булып яшиләр.* Биология

**ЖИРӘБӘ** *и. рус* 1) Берәр мәсьәләне хәл итү яки нәрсәнең дә булса кем өлешенә чыгасын белү өчен, билгеле кешеләр арасында уйнатылган уен (гадәттә, бер төрле предметлар арасыннан тамгаланганын тартып чыгарган яки бау (таяк) тотып, кулы өстә калган кеше җиңүче булып санала); шобага. *Чатыр корыр урын сайлап, байтак йөрделәр... Ахыр чиктә жирәбә белән хәл иттеләр.* С.Сөләйманова

2) *сөйл.* Дини карашлар буенча, Алла тарафыннан һәр кешегә алдан билгеләнеп куелган күрәчәк, язмыш, тәкъдир. *Без тартасы йөкне беркем тартмас. Безнең өлеш – безнең жирәбә.* Р.Рәхимов

◊ **Жирәбә салу** Берәр нәрсәне жирәбә (*1 мәгъ.*) белән хәл итү. *Бабаларыбыз йоласын тотып, Чияле тауда Гали белән Булат оныкларыма жирәбә салдыр.* М.Хәбибуллин. **Жирәбә тарту** *к.* **жирәбә салу**

**ЖНЕ́ЙКА** *и. а. х. рус* Ургыч, уру машинасы. *Кояш төшлеккә җиткәндә, жнейка урдырып киткән арышны көлтәләп, һәркайсыбыз өч йөз көлтә бәйлибез.* С.Сөләйманова

**ЖОКЕЙ** *и. ингл. спорт* Ат өстенә атланып, ат чабышы ярышларында катнашучы кеше; атларны сыбай йөрергә һәм төрле күнегүләр ясарга өйрәтүче белгеч. *[Белоштанның] Өстендә шәрә хатын-кыз сурәте төшкән зәңгәр нейлон күлмәк, башында козырёклы жокей картузы.* М.Юныс

**ЖОНГЛЁР** *и. фр.* 1) Берничә предметны берьюлы өскә ыргытып, аларны бер тотып, бер очыртып, күнегүләр күрсәтүче цирк артисты. *Аның башы жонглёр таягы очында әйләнеп торган шар шикелле әйләнә иде.* Ш.Камал. *Хезмәтчеләр ашамлык өелгән подносларны, жонглёр осталыгы белән тотып, җәлт иткәнче, тиешле бүлмәгә илтеп тапшыралар.* А.Расих

2) *күч.* Сүзләр, фактлар һ.б. белән оста һәм үзе теләгәнчә файдаланучы кеше. *Сүз-төшенчәләр белән шагыйрь, оста жонглёр кебек, виртуозларча җиңел эш итә.* Н.Юзиев

**ЖОНГЛЁРЛЫК** *и.* 1) Жонглёр һөнәре яки сәнгате. *Бармакларына дүртбиш гармун кия, уйнау гына түгел, жонглёрлык та итә белә иде ул [Фәйзулла Туишев].* М.Гали

2) *күч.* Берәр нәрсә (сүзләр, фактлар һ.б.) белән оста һәм үзе теләгәнчә куллану күренеше. *Яшь педагог «система», «концепция» һәм башка шуныңише сүзләр белән жонглёрлык итә башлагач, Ильяс тәрәзәгә таба ук борылып утырды.* К.Кәримов. *Сәяси жонглёрлык*

**ЖРЕЦ** *и. рус* Мәҗүсиләрдә аллалар, рухлар белән арадашлык итү йолаларын башкаручы дин башлыгы; кам, каһин. *Жрецлар һәм балыкчылар җинаятьчеләргә үлем җәзасы бирүне таләп итәләр.* М.Мәһдиев

**ЖРИ́ЦА** *и. рус* Жрец хатын, каһинә. *Явыз көчләр белән үз гомерендә гашыйк булмаска, иргә чыкмаска дип ант эчкән жрица гына сөйләшә ала.* М.Мәһдиев

**ЖУ** *иярт.* Бөҗәкләр очып йөргәндә, кешеләр үзара күмәкләп сөйләшеп, гөж килгәндә яки төрле техник механизмнар зур тизлек белән эшләп торганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *«Нәрсә бу?» дип, китте гөжләү жу да жу.* Ш.Бабич

**ЖУБАЛГЫ** *с. диал.* Үзен-үзе җыеп йөри белмәгән, җыйнаксыз. *Ә мин үзе белән кулалмашка эшләүче Фирдәс исемле әрсез егет һәм Камилә исемле жубалгы кызны, ничектер, өнәп бетерми иде.* Г.Ахунов

**ЖУ́ ИТҮ** *ф.* 1) *к.* **жулау** (*1 мәгъ.*). *Ишектән аның [Рөстәмнең] әнисе килеп чыкты, стенадагы бер төймәгә бармагы белән басты. --- шунда стена эченә качып торган бер нәрсә «жжу-у!» итте, тәрәзәләрдәге калын авыр пәрдәләр үзләреннән-үзләре ачылып киттеләр.* Р.Фәизов

2) *күч. Йөрәк, эч* сүзләре янында «сискәнү», «куркып китү» мәгънәсендә кулланыла. *Хатын: – Баскыч төбендә сине күрүгә, эчем жу итеп китте.* М.Мәһдиев. *Авылның эче жу итә.* Ә.Баянов. *Монда Буг [елгасы] шундый киң: эчем жу итте.* Ә.Галиев

**ЖУЛА́У** *ф.* 1) Очканда яки җил белән селкенгәндә, «ж-ж-ж»га охшаш аваз чыгару, «ж-ж-ж» итү, «ж-ж-ж» итеп тору (бөҗәкләр, агач яфраклары һ.б турында). --- *яшел башлы кигәвеннәргә кадәр, дөньяга үзләре генә баш булган төсле горурланып, жулап, кәефләнеп, рәхәтрәхәт очалар иде...* Г.Рәхим

2) *сөйл. к.* **жу итү** (*2 мәгъ.*)

3) Бер үк сүзне сөйләп, кат-кат әйтеп ачу китерү, ялыктыру, эч пошыру

**Жулап алу** Бераз, кыска гына жулау

**Жулап китү** 1) Ниндидер сәбәптән соң, кинәт жуылдаган тавыш чыгарып оча башлау

2) Кинәт жу итү, куркыну. *Әүвәл аның йөрәге жулап китте: мәнә, мәнә бакча җимерелер дә, мескен хәзрәт сытылып үләр төсле иде.* Ф.Әмирхан

**Жулап кую** Кыска гына кинәт жулау. *Вахтада утырганда, ишектән зифа буйлы таза берәр егет күренсә, ул түгелме икән дип, йөрәге жулап куйды, бүлмәсенә ишек тукылдатсалар, сөйгәненең куенына ташланырдай булып йөгереп барып киләне ычкындырды ---.* М.Кәбиров

**Жулап тору** Бертуктаусыз жулау. *Әйтерсең башыма ис тигән, берөзлексез гел жулап тора.* Г.Бәширов

**ЖУ́ЛИК** *и. рус* 1) Карак, бур, угры. *Жуликлар шуның [идән астында канализациягә дип казылган траншея] буйлап эргә астына үрмәләгәннәр дә инде.* З.Фәтхетдинов. *Минзәлә базарында жуликлар кесәмнән акча белән бергә алдылар.* Т.Гыйззәт

2) Алдакчы кеше; хәйләкәр, мут. *Карт (ачуланып тора, йөри). Жулик түгел! Ул бит – поплыкка укып килгән кеше.* Р.Мингалим. *[Шәмәт:] Барысы да жулик алар. Эшләгәндә эшләтә, түләгәндә – тияр тиеннәреңне басып кала.* Р.Ишморат

3) Тәртип бозучы, хулиган. *Шунда... кайсыдыр бер жулигы бер әбинең артына килде дә аяк арасындагы чиләгенә тибеп җибәрде.* М.Мәһдиев

**ЖУ́ЛИКЛАРЧА** *рәв.* Жуликларга хас булганча, жуликлар кебек.

**ЖУ́ЛИКЛЫК** *и.* 1) Жулик булу. *Бүгенге көнкүрештә чәчәк аткан караклык, жуликлык, кеше көчләү һәм үтерү, харам байлык туплауга омтылу кебек сыйфатлар комедиядә оста һәм үткен чагылдырыла.* А.Әхмәдуллин

2) Алдакчылык, мәкерлелек. *Алар эчәләр, кәеф-сафа табалар, жуликлык*

*һәм аферистлык юллары белән төрле махинацияләр коралар, халыкны алдыйлар.* Х.Хәйри

**ЖУМБА** *и. зоол.* Тәрәч балыклар семьялыгыннан, төче суларда яши торган, тимгелле тәнле, лайла белән капланган озынча шома гәүдәле ерткыч балык; шамбы; *русчасы:* **налим**. *Шулай дип әйтте дә, жумба тәрәчлеләр семьялыгына керә, дип өстәде.* Н.Хәсәнов. *Болай булгач, Кызыл яр астыннан жумбаларны эләктерәм әле.* Н.Хәсәнов

**ЖУРНАЛ** *и. фр.* 1) Гадәттә ай саен чыгып бара торган, зур форматлы, бизәлеп эшләнгән кәгазь тышлы вакытлы басма. *Самат журналлар актарып утырган арада, аның янына, поднос күтәреп, Миләүшә килеп чыкты.* Г.Гыйльманов. *Ә беркөнне кич Сөембикә әдәби журналдан «Күтәрелгән чирәм җир» әсәренең тәрҗемәсен укыды.* М.Мәһдиев. *Журналда басылып чыккан әсәрләрнең әдәби эшләнешләре төрлечә.* Казан утлары

2) Төрле вакыйгаларны, көндәлек эшләрне һ.б.ш. теркәп, язып бару өчен эшләнгән зур форматлы калын дәфтәр. *Менә звонок булды, ишек ачылды, аннан кулына класс журналы тоткан каderле остазыбыз күренде.* М.Мәһдиев. *– Таныклыкларны теркәү журналы кайда икән? – дип сорады Данишев.* З.Фәтхетдинов

**ЖУРНАЛИСТ** *и. рус* Журналистика белән шөгыльләнүче әдәби хезмәткәр. *Су астында калган җир хакында мин журналистларга күп интервьюлар биргәнем бар.* Ә.Гаффар. *Бәлки, бу – яңа гына борынлап килгән яшь журналистның беренче адымыдыр.* Г.Бәширов. *Журналист – кешеләрнең дөньяга карашын формалаштыручы шәхес.* Мәдәни җомга

**ЖУРНАЛИ́СТИКА** *и. рус* 1) Газета-журналларда, радио-телевидениедә әдәби-публицистик эшчәнлек. *Татарның гаммәви мәгълүмат чаралары, сүз сәнгате, журналистика өлкәсендә эшләүче зыялыларыбызны барлаганда, мондый күренешкә дә тап булырга туры килә: кемнәрдер сыңар әсәре, уч төбе хәтле берәр язмасы басылып чыккач та, дөнья бетереп, шау-шу күтәрә, аерым илтифат даулый, ә кемнәрдер үзенә җиде кешелек норма йөкләп тир түксә дә эндәшми.* Мәдәни җомга

2) *җый. мәгъ.* Барлык вакытлы матбугат. *Бу мәкалә ул елларда татар журналистикасында зур резонанс тудырып, шау-шу куптарды.* Мәдәни җомга

**ЖУРНАЛИСТЛА́РЧА** *рәв.* Журналистларга хас булганча, журналистлар кебек. *[Агроном:] Хуҗалыгыбыз үр менә, журналистларча әйтсәк.* Б.Камалов

**ЖУРНАЛИСТЛЫК** *и.* 1) *к.* **журналистика** (*1 мәгъ.*). *[Г.Камал] үзенең тормышын бөтенләе белән журналистлыкка бәйләде.* З.Бәшири

2) Бу эшчәнлеккә бәйле сыйфатлар. *А.Тәхәвиевнең һәм журналистлык, һәм оештыручанлык сәләте биредә бөтен тулылыгы белән ачылды.* Р.Әмирхан. *Нииндидер бер көч Матушкинның теленнән тарта иде. Нинди көч икәнлеге мәгълүм инде – журналистлык шаукымы.* Ә.Мушинский

3) Журналист эше, шөгыле. *Чыгышларында галим һәм укытучының тәрҗемәи хәленә, журналистлык һәм әдәбият белгечлеге буенча эшчәнлегенә караган яңа мәгълүмат-фактлар хәбәр иттеләр.* Мәдәни җомга

**ЖУРФИКС** *и. фр. иск.* Кунакларны атнаның алдан билгеләнгән бер көнендә генә кабул итү гадәте. *Журфиксларны сишәмбе уздыру*

**ЖУЫЛДА́У** *ф. к.* **жулау** (*1, 2 мәгъ.*). *[Ильяс] Рәгыйдә хатирәсен саклаган карт өянке жуылдаганны күңел тулганчы тыңлап, озак, озак басып һәм утырып торды.* Ә.Баянов. *Болындагы түмгәкләр дә, колак төбендә жуылдаган җил дә, бизәксез канатлы вак күбәләкләр дә – һаман да шул, тик имән генә олыгайган иде.* Н.Гыйматдинова. *Эчпошыргыч көйгә җил жуылдый, манараны тирбәтә иде.* М.Галиев

**Жуылдап алу** *к.* **жулап алу**

**Жуылдап китү** *к.* **жулап китү**. *Аның [Вәлинең] эчләре [шөбһәле фикердән] жуылдап китте.* Р.Гали

**Жуылдап кую** *к.* **жулап кую**. *Ак өй ишеген, нигәдер, каушый-каушый ачса, табиб һәм шәфкать туташының хәрәкәтсез басып торуыннан тагын эчтә нииндидер салкынлык жуылдап куйды.* Ә.Баян

**Жуылдап тору** *к.* **жулап тору**. *--- күперләр, юл кырыендагы кечкенә өйләр, сарайлар, поезд артыннан байтак вакытка кадәр тынычлана алмыйча гүләп, жуылдап торалар.* Г.Бәширов

**Жуылдый башлау** Жуылдарга тотыну

**Жуылдый бирү** Жуылдавын дәвам итү, һаман да жуылдау

**Жуылдый төшү** Бераз жуылдау

**ЖЫЙ-ЖЫЙ** *иярт.* Каты сызгырып искән җил, һаваны ярып селтәгән талчыбык, җилләнеп әйләнгән көпчәк, кисеп торган пычкы тавышын белдерә. --- *Андрәй Палич, кулындагы талчыбык белән зур-зур кизәнеп, садистларча бер дәрт белән һаман сугуын белә. Жый да жый!* Л.Толстой. *Йөк машинасы: --- «жжж-жый» дип буксовать итә.* Н.Исәнбәт

**ЖЫРА́У** *и.* Төрки халыклардан саналган казак, кыргыз һәм каракалпакларда халык җырчысы һәм шигырьләр иҗат итүче; *к. шулай ук* **акын**. *Жыраулар башкаручы гына булмаганнар, ә дидактик һәм афористик характердагы җырлар һәм шигырьләр дә иҗат иткәннәр.* Әдәбият

**ЖЮЛЬЕН** *и. фр.* Бәләкәй металл чүмечләрдә, өстенә каймак яки майонез салып, гөмбә, тел яки сирәк кенә кош итеннән әзерләнеп, өстәлгә кайнар көйгә бирелә торган ашамлык. *Жюльенның берничә төре һәрвакыт менюда була*

**ЖЮРИ** *и. фр.* 1) Төрле характердагы ярыш-конкурсларда, уеннарда җиңүчене билгеләүче һәм аңа урын, бүләк бирү мәсьәләсен хәл итүче белгечләр төркеме. *Көн кадагына сугарлык фикерең, темаң бар икән, шуны сәнгать әсәре дәрәҗәсендә үзең үк яза алгансың икән, шуны укып, үзеңне нәфис сүз осталыгында сынап карыйсың, иптәшләреңә, жюригә уңай тәэсир ясарыңа ышанасың икән, рәхим ит, мен сәхнәгә.* И.Низамов

2) Англиядә һәм Франциядә судта катнашкан присяжныйлар

3) *иск.* Спорт ярышларында судья. *Байтак очракта жюригә төп үзенчәлекләрне, ярыш кагыйдәләрен, бигрәк тә татарча көрәш кагыйдәләрен белеп җиткермәгән иптәшләр билгеләнә.* Х.Туфан

# Ж

**ҖАБЫШКАК** *и. диал.* Вак кигәвеннең бер төре. *Атны җабышкак сырып алган*

**ҖАВАБӘН** *рәв. гар. иск.* Җавап итеп, җавап йөзеннән. *Әбү Әюб, бу тәслия бәетләрен алганнан соң, дустына җавабән ошбу кыйтганы язды.* К.Насыйри. *Моңар җавабән Шәмсетдин абзый бары: – Син, Маһруй, бернәрсә белмисең; аңламыйсың син аның ләззәтен...* Г.Гобәйдуллин

**ҖАВАП** *и. гар.* 1) Бирелгән сорауга, мөрәҗәгатькә раслау яки инкярлау тәртибендә кайтарып әйтелгән сүз. *Крестьянның бу соравына Сөләйман җавапны тиз таба алмады.* К.Тинчурин. *Юк, син сорауга җавап бир: ни өчен син уенда түгел?* М.Мәһдиев. *Әтинең җавабы әзер булган, ахры, ул моны шундук әйтеп ташлады.* Р.Мөхәммәдиев

2) Дәрестә куелган бирем буенча укучының укытучы һәм сыйныф алдында сөйләве. *Хәзрәт, шәкертләрнең җавабын ишеткәч, өстәлдәге китапларның берсен алды...* М.Гафури. *Әркәшә әнә шул дәрестә танылды. Ул бер-ике сорауга дөрес җавап бирә алды.* М.Мәһдиев. *Укытучылар күреп калса, икенче көнне бөтен фәннәрдән сорап үзгәңә үтәчәкләр, җавабыңны аз гына ялгышсаң да: «Уку кайгысы качкан шул инде синнән ---», – дип, бөтен класс алдында көлкегә калдырачаклар.* М.Маликова // Дәрес барышында укытучының укучылар биргән сорауларга аңлатмасы. *Ни турында гына сорамасыннар ---, Юныс беркайчан да аларның сорауларына кул селтәми, барысына да төпле җавап бирә, җавапларым балаларга аңлаешлы булсын дип тырыша.* Г.Шәрипова

3) Эндәшү сүзенә, эндәшкәнгә кайтарып әйтелгән сүз, җөмлә, аваз, ишарәт. *Җавабында аваз: «Син рәнҗемә, – ди, – Минем исмем – ачы, карт тәҗрибә», – ди.* Г.Тукай. *Сорауны ишеткәнен белгертеп, карап алса да, берни эндәшмәде, җавап кайтармады егет.* Р.Мөхәммәдиев. *Берничә ишеккә кагып карасам да, җавап бирүче булмады.* Казан утлары

4) Әңгәмә барышында сөйләнгән мәсьәләгә карата үзеңнең фикереңне, мөнәсәбәтеңне белдереп әйтелгән сүз. *Шакир бу сүзнең җавабында төртелеп калды: аның башына берьюлы бер-берсеннән ачырак сүзле әллә ничә җавап килеп тулды.* Ф.Әмирхан. *Сөләйман бу сүзгә тиешле җавап таба алмыйча һәм шул ук вакытта эчендәге шатлыгын да яшерә алмыйча, ашыгып, кабаланып: – Мөхәммәтша агай үзе шулай дип әйтеп калдырдымыни? – дип ычкындырды.* К.Тинчурин. *Мондый сорау һәр заманда һәрбер язучыда туа. Әмма җавабын һәркем үзенчәрәк табарга тырыша.* Ә.Еники

5) Нинди дә булса сорау яки үтенечкә карата ризалык бирү-бирмәүне белдергән чара, эш-гамәл. *Тиз генә җавап бирерлек сорау түгел иде бу... Арслан әтисенең хәзер аңардан үзенең тормыш мәгънәсен хәл итә торган җавап көтеп торуын аңлады.* Г.Ахунов. *Дәшмәде Гыйлемхан. Ә хуҗа кешенең үз туксаны туксан, җавапка мохтаҗ түгел иде ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Егет, әнисенең бу гозерләренә җавап итеп, авылда торып калды.* Казан утлары

6) Табышмакның, математик мәсьәләнең чишелеш нәтиҗәсе. *Түтәлдә нинди ике нота үсә? Җавап: фа-соль.* Табышмак. *Дүрт кодагый берсен-берсе куалый. Җавабы: әвернә.* Табышмак. *Укучылар бер мисалның җавабы дөрес булмавын әйтәләр.* Ә.Хуҗиәхмәтов

7) Хатка каршы язылган хат, язу. *«--- мин сезгә Петроград адресыңыз бирлә дә, мондагы адресларыңыз бирлә дә берәр хат язган идем. Җавабы да булмады, хаты да кире кайтмады», – диде.* Г.Исхакый. *Әйтик, бүген телеграмма яздым, ә берсекөн дигәндә, җавабы килде.* Х.Туфан. *[Идрис] Иң әүвәл --- чираттагы санга ике мәкаләне редакцияләде, берничә хатка җавап язды.* А.Гыйләҗев

8) Ярышып, кара-каршы җырлап, әйтешеп бирелгән җаваплашу сүзе, тапкыр сүзләр. *Атна кич иде. Мәдрәсәдә ыгы-зыгы купты... Китте ике арада сораулар белән җаваплар чәкештерү.* Ә.Фәйзи. *Элек, кызлар аулак өй уздырганда, егетләр ишеккә килеп сорыйлар икән: «Ач!» Өй эченнән кызларның әзер җавабы ишетелә: «Ач булсаң, туеп кил!..»* Х.Мәхмүтов

9) Кылган, башкарылган эшләргә карата белдерелгән мөнәсәбәт. *Мәскәүнең исә менә шундый яхшылыкларга «җавабы» алдында Айдар алдашуы сабыйлык шуклыгы кебек кенә булып кала.* М.Гайнетдинов. *Без һәр кешене, фикер аерымлыгына карап, илдән куа башласак... Андыйларга иң көчле удар – массаларның җавабы.* Ф.Сафин. *Карательләр җавабы турында тарих дәшмәсә дә, аңлашыла: «падишаһ» Идел арьягына куылгач, «иңнәренә канат үскән» карательләр, әлбәттә, фетнәчеләр шартын кабул итми.* В.Имамов

10) Кайтаваз. *[Мәктәп] Шаулап көлсәң, яңгырап җавап бирә, Үз иткәнгә күрә баласын.* М.Җәлил

11) Сорау алу, допрос. *[Хәзрәт:] Җәмәгать, бу эш бүген генә тәмам булмас. Иртәгә шаһитлардан берәмберәм җавап алырбыз.* М.Гафури. *Хәзергә җавапка Җиһанша бабай чакырылды.* Г.Ибраһимов. *Тикшерүче аның һәр җавабын гаять бөтеркәле готик хәрефләр белән, бер дә ашыкмыйча гына язып алды.* Ш.Маннур

12) Гаеп гамәлләр, кылган җинаять өчен бирелгән җәза. *--- язарга, иллә мәгәр, бары үземә кагылганны – минеке,*

*мин беләм, җавабын да үзем бирәм.* Ә.Еники. *Кем булса да, кызганма, башын чап та өз, җавапка үзем барырмын, дип гайрәт орды.* Г.Ибраһимов

13) Берәр төрле тәэсиргә, йогынтыга мөнәсәбәтле рәвештә организмда барлыкка килгән халәт, реакция. *Дарвиннан соң кайбер галимнәр (Кеннон, Барт, Линдслей) «эмоцияләр психик механизмының төрле предметларга, күренешләргә җавабы» дигән концепцияне күтәреп чыгалар.* К.Гыйззәтов

14) *сир.* Җаваплылык, җаваплы булу хисе. *Сәфәрнең бөтен җавабы минем өстә, юлдашка җил дә, яңгыр да булмаячак.* Г.Ибраһимов. *Монда мине бригадир итеп калдырганнар икән, димәк, моның җавабы миңа да төшә.* С.Сабиров

◊ **Җавап бирерлек** Лаек, тиң, үзенә иш булырлык. --- *ул үзе дә язмыштан зурны – Галиябану белән Хәлил, Йосыф–Зөләйха мәхәббәте кебек олы, изге, --- үзенә шундый бөек дәрәҗәдәге хис белән җавап бирерлек пар эзли иде.* М.Маликова. **Җавапка күршегә (кесәгә) кермәү** Җавапка аптырамау, тапкыр телле булу. *Гөлниса белән сөйләшкәндә, «ык-мык» килеп торса да, Хөсисә кайткач, тракторчы егетнең теле яхшы ук ачылып китте, җавапка күршегә кермәде.* Ф.Хөсни. *Ул инде җавап өчен кесәгә кереп тормас, үз җавабын үзе табар.* Мирас. **Җавапка тартылу** Гаеп эш, җинаять өчен җәзага тартылу, хөкем алдына басу. *Рәис боларга шаһитлыкның бурычларын, хакларын төшендерде. Тик дөресне генә сөйләргә тиешлекләрен, юкса, җавапка тартылачакларын аңлата барды.* Г.Ибраһимов

◊ **Җавап бирү** 1) Туры килү, үтенечне, таләпне, ихтыяҗны канәгатьләндерү. *Әсәр бик түбән сыйфатлы һәм чорга җавап бирми.* М.Җәлил; 2) Нинди дә булса эш-хәлнең үтәлеше өчен җаваплылык алу, җаваплы булу. *Атлар өчен, бабай, син җавап бирәсең.* Р.Ишморат. *Урталай бүленеп, миңа юл бирделәр. Ишетеп калдым: «Әнә җитәкчеләре. И Ходаем, бу җавап бирә бит инде аңа».* М.Мәһдиев; 3) Гаебе өчен тиешле җәза алу, түләү. *Җавап бирер көнең җитте, сасы көзән!* К.Нәҗми. – *Әгәр дә боларның берсен генә качырсаң да, үз башың белән җавап бирерсең! – дип, тарантаска утырып та киттеләр.* К.Тинчурин; 4) Үзенә карата күрсәтелгән мөнәсәбәткә, эшләргә туры килерлек гамәлләр кылу. *Аны Советлар чынбарлыгы туганнарча, дусларча үз эченә алып, аңа шундый зур ышаныч күрсәтүгә Сөләйман эше белән җавап бирергә үйлады.* К.Тинчурин; 5) *дини* Шәригатькә туры килмәгән гамәлләр өчен Аллаһ алдында җаваплы булу. *[Нурый карт:] – Алда кыямәт бар, Алла каршында җавап бирәсе бар бит, – дип өстәде.* Г.Ибраһимов. **Җавапка тарту** *юр.* Нинди дә булса җинаять эшендә гаепләп судка бирү, хөкем итү. *Ул дүрт тәүлек эчендә кайнады. Илле дүрт кешене җавапка тартты.* Г.Ибраһимов. *Мәсьәләнең җитдилеген аңламаган кеше белән уртак эшкә тотынмавың артык шул, армиядә мондый гамьсез кешеләрне җавапка тарттырган булырлар иде.* М.Юныс. **Җавапка тартылу** *юр.* Кем дә булса, җинаятьчел гамәле өчен җәзага дучар булу, хөкем алдына басу. *Рәис боларга җаваплылыкның бурычларын, хакларын төшендерде. Тик дөресен генә сөйләргә тиешлекләрен, юкса җавапка тартылачакларын аңлата барды.* Г.Ибраһимов. **Җавап тоту** *к.* **җавап бирү** (3 *мәгъ.*). *Ул [укытучы] бит баланы гына түгел, шул баланың әти-әнисен дә тәрбияләүче. Барысы өчен дә ул җавап тота.* Сөембикә

**ҖАВАПЛАНУ** *ф. иск.* Сорауга туры китереп җавап бирү. --- *ул [Тукай] тагы шул үзенең: «Менә кеше сүзе белән, кешегә ияреп йөрсәң, шулай була ул, әйттем мин сезгә», – дигән сүзе белән җавапланды да, артык игътибар итмәде.* Ф.Әмирхан. *[Гөлсем:] «Юк, вакытлы гына киләмен, эшем генә бар», – дип җавапланды да, сүз киселде.* Г.Исхакый. *Берәү берәүне сыйлаганда, кунак берәр сирәк нигъмәт хакында «моны каян алдыгыз» дип төпченә башлаганда, алган урынын әйтәсе килмәгәндә, «Алла биргән» дип җаваплаңалар.* Н.Исәнбәт

**ҖАВАПЛА́У** *ф. сир.* Җавап кайтару, куелган сорауга карата җавап бирү. – *Ник алай диден әле, күрше? – диде ул, хәзрәтнең соравын сорау белән җаваплап.* М.Хәсәнов. – *Сиңа ни булды, күрше? Аралбай, аңа җаваплаудан алда тешләрен кысып, --- әкрен генә ыңгырашып куйды.* Мирас. *Ярулла егеткә күтәрелеп карамады, җаваплaмады. Камчыны да үрмәде.* Казан утлары

**Җаваплап тору** 1) Әле, хәзерге вакытта җаваплау. *Ярулла җаваплап тормады. Үрелеп, әнисенең башына ябынган иске шәленнән сыйпады да ишегалды кебек җиргә узды.* Казан утлары. *Әхмәй аңа җаваплап тормады: – Әле кайсыгыз җырлады? – дип, өтәләнеп сорады.* Мирас

2) Әле берсенә, әле икенчесенә бертуктаусыз җаваплау

**ҖАВАПЛАШУ** *ф.* 1) Үзара сөйләшү, кара-каршы бер-берсенең сорауларына җавап бирү. *Мохтар бу сүзен Шәрәфи картка юнәлтсә дә, төбендә ул Газизә белән җаваплашуны һәм Газизәнең хиссиятен сынауны күздә тота иде.* Ш.Камал

2) Ярыш төсендә кара-каршы җыр яки шигырь әйтешеп сөйләшү. *[Бу җыентыкта] Аның бер акын кыз белән тезмә табышмак әйтеше һәм кызның тезмә җаваплашуы бар.* Н.Исәнбәт

3) Ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү, каршы дәшү, карышу. *Алар белән җаваплашырга юлың юк инде. Үзеңне саткансың: бар, буйсын.* Г.Ибраһимов. *Вакыт аз булу сәбәпле, малайлар озак җаваплашмадылар.* Р.Мөхәммәдиев

**Җаваплашып алу** Кыска гына вакыт эчендә җаваплашу

**Җаваплашып тору** Әле, хәзерге вакытта җаваплашу

**ҖАВАПЛЫ** I *с.* **1.** 1) Эшкә җитди карый торган, эшенә һәм үз-үзенә таләпчән. *Бу егет – гүзәллектә Йосыф пәйгамбәр, Булсачы, кашки бер җаваплы хезмәткәр.* Ә.Исхак. *Шәхси язмаларында да ул [Сибгат Хәким] дәүләт кешесе, халык, әдәбият үсеше өчен җаваплы кеше булып кала алган.* Т.Галиуллин

2) Берәр бурыч, вазифа йөкләнгән. *Шулай күзәтә-күзәтә, Офицерлар йортына кереп киттем. Керсәм... анда*

*вак түрәләр, җиңенә кызыл бәйләгән бик күп яшьләр, җаваплы кешеләр...* М.Мәһдиев

3) Җитәкче урында эшли торган. *Аннан соң, әфәнделәр, бу номерда торучы спекулянт та, контрреволюционер да түгел. Штабның җаваплы эшчесе, иске армия полковнигы, зур белгеч!..* К.Тинчурин. *Аңа бер үк вакытта җаваплы мөхәррир вазифасы да йөкләнде.* Казан утлары

4) Җитди, бик әһәмиятле. *Аннары, бу гаять җаваплы «теманы» ерып чыга алмам, буталып бетәрмен, дип курыктым да, әллә бөтенләй язып тормаска микән дигән фикергә дә килгәндәй булдым.* Ә.Еники. *Ә иртәгә, дускай, минем особый көн булачак. Мин үз гомеремдә иң җаваплы эшкә китәм.* Ф.Яруллин. *Кыш буенча җыйналган пычрактан мәдрәсәне арындыру эшләрен Галиулла белән Камали кизүләр үзләре генә башкарып чыга алмагач, исән шәкертләрне дә бу җаваплы эшкә җиктеләр.* К.Тинчурин

5) Хәлиткеч, мөһим; бик кирәкле, актуаль. *Солдаттан калгач, Фәйзулла тормышның икенче баскычына: читен һәм җаваплы баскычына күтәрелде.* Ф.Хөсни. *Иң җаваплы һәм бик кирәкле бервакытта безнең кулга офицер «теле» эләкте.* А.Әхмәт

6) *күч.* Тәкәббер, эре кыяфәтле. *Һәм Муса Гали гаять җаваплы дәүләткүләм чырай белән документ укый башлады.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Җитди итеп, аңлап. *Гомумән, кемне дә булса туганнарга күрсәтү – бик җаваплы эш, ул яшьрәк чакта гына җиңел эшләнә, олыгайган саен, моңа җаваплырак карыйсың.* М.Маликова

**3.** *хәб. функ.* 1) Кемнеңдер өстенә нинди дә булса бурыч йөкләнгән булу, башкарып чыгарга тиеш булу. *Киләчәктә дә кешеләр борынгыдан калган хикмәтле Китаплар алдында баш иячәкләр... Шуңа күрә без узган чорлар алдында да, киләчәк буыннар каршында да җаваплы.* М.Усманов

2) Башкарылган эшнең төгәл генә кем вазифасына каравы. *Бүгенге авыр хәлдә калуыбыз өчен, без үзебез гаепле. Боларның барысына да председатель җаваплы.* М.Мәһдиев

◊ **Җаваплы урын** Хөкүмәт эшендә, югары органнар каршында яки берәр коллектив белән идарә итү вазифасы, хезмәт үтәү урыны. *Ул тарткалашып тормады. Киресенчә, җаваплы урынга куюларын ошаткан сыман күренә иде.* Г.Бәширов. *Мәсьәләнең аяныч ягы шунда ки, әлеге караш җаваплы урыннарда эшләүче кайбер абруйлы иптәшләрнең җирле һәм хәтта үзәк матбугатта басылган хезмәтләрендә --- үткәрелеп килде һәм килә.* Р.Әмирхан. *Кияве исә аның – Чакмагыш башкорты – зур, җаваплы урында утыра.* Ә.Еники. **Җаваплы хезмәт** *к.* **җаваплы урын**. *--- справка кәгазьләрен алып кайтыр өчен һәм үзенең җаваплы хезмәткә керү шатлыгын Татьяна Тарасовна белән уртаклашырга дип, Чекага китте.* К.Тинчурин

**ЖАВАПЛЫЛЫК** *и.* 1) Эшкә җитди караш, нәрсә өчен булса да җаваплы булу хисе. *Ышаныч күрсәтү, шуның өстенә әле бераз мактап та кую кайбер кешедә бары тик җаваплылыкны гына арттыра.* М.Хәсәнов. *Әйе, кем генә булсак та, әлеге [киләчәк буыннар алдындагы] җаваплылыктан без барыбер котыла алмыйбыз.* М.Усманов. *Гаять батыр һәм ихтыяр көченә ия булган Кутузов үзенең хәрби карарлары өчен дә, үз солдатларының тормышы өчен дә җаваплылыкны үз өстенә ала белде.* Н.Коробков

2) Мөстәкыйльлек; башлап йөрүче, әйдәүче йөкләмәсе. *– Ярар, ярар, балалар бу якта булыр... – дип, тәртип өчен җаваплылыкны әниләре үз өстенә алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Бөтенесен фәнгә генә кайтарып калдырма син. Игенченең тырышлыгын, үз өстенә төшкән җаваплылыкны ныграк тоюын онытма.* Ф.Яруллин. *Шуңа карамастан, ирләр бер вакытта да хатын-кызлар шикелле көчле булып, алардагы җаваплылыкны өсләренә ала алмый.* М.Юныс

3) Мөһимлек, гадәттән тыш, хәлиткеч хәл булу. *Сырга бикә белән киңәшмичә, берни эшләргә тиеш түгелләнгән белсә дә, ул, бар җаваплылыкны үз өстенә алып, кораллы кызларга боерыклар бирә башлады.* Н.Фәттах. *--- сугыш булмаячак! – дип җавап кайтарам һәм бераздан гына үземнең нинди җаваплы, җитди сүз әйткәнемне, үз өстемә нинди зур җаваплылык алганымны төшенәм.* Р.Миңнуллин. *Казан Кремле – бик үзенчәлекле урын. Монда күпсанлы музейлар да урнашкан, дәүләт оешмалары да бар. Һәм, әлбәттә, Президент Сараеның да биредә булуы җаваплылыкны икеләтә арттыра.* Мөселман календаре

◊ **Җаваплылыкка тарту** *к.* **җавапка тарту**. *Күчереп утыртылганнарның мәҗбүри билгеләгән урыннан үз белдекләре белән китеп баруында гаеплеләр җинаять җаваплылыгына тартыла.* Мирас

**ЖАВАПНАМӘ** *и. гар.-фар. дини* 1) Нинди дә булса үтенечкә, тәнкыйтькә карата язмача бирелгән рәсми җавап

2) *дини* Үлгән кешенең күкрәк турысындагы кәфенлеге арасына салына торган догалык; җавап язуы. *Мәетнең күкрәгенә җавапнамә кую*

**ЖАВАПСЫЗ** *с.* **1.** 1) Җавабы ачыкланмаган, җавабы билгесез. *Бәхет ул минем өчен һаман җавапсыз табышмак булып кала бирде.* Ә.Еники. *Кызчык та, мин дә сүзсез аңлаштык, ахрысы. Кабат җавапсыз сораулар бирешмәдек.* Р.Рахман

2) Игътибарсыз калган, илтифат күрсәтелмәгән, кабул ителмәгән. *Унҗидедә без барыбыз да кемгәдер гашыйк, ул еш кына җавапсыз мәхәббәт була, яшьлек эгоизмы белән без кемнең кемне яратканын абайлап та бетермибез.* Р.Мирхәйдәров. *Аларның тәү мәртәбә сөю газабының тамчысын татыган һәм җавапсыз мәхәббәттән канатларын өттереп, шуны зур фаҗигагә санаган иләс чаклары иде.* Н.Гыйматдинова

3) Анык түгел, ачыкланмаган. *«Ни бар икән? Сираҗи нигә чакырды икән?» Шул җавапсыз уй белән өйгә кайтты.* Г.Ибраһимов. *Яшәгән саен, җавапсыз сорауларыбыз күбәя генә бара.* Р.Шәрәфиев

4) Эшкә җиңел мөнәсәбәттәге, гамьсез, салкын. *– Кемнәрнеңдер гамьсезлеге, хезмәтенә җавапсыз каравы*

*аркасында, район экономикасына чамасыз зыян килә, – дип дәвам итте сүзен районның баш түрәсе.* Ә.Моталлапов

**2.** *рәв. мәгъ.* Игътибарсыз калдырып, илтифат итмичә. *Шаһимәрдән исә Шәкүрнең сүзләрен җавапсыз гына уздырып җибәрергә тиеш түгел иде.* Ф.Яхин

◊ **Җавапсыз калдыру** Игътибарсыз калдыру, әһәмияткә алмау, илтифат итмәү. *Габдулла бу бүлмәдә иркенләбрәк һәм теләбрәк сөйләште. Бер сорауны да ул җавапсыз калдырмады.* Ә.Фәйзи. *Кызның туры сүзен җавапсыз калдыру уңайсыз булды.* К.Тинчурин. *Хатларыңны җавапсыз калдырганым өчен гафу ит мине. Командировкаларда булдым, бер ай, авырып, больницада яттым.* Ф.Яруллин. **Җавапсыз калу** 1) Фикерен дәлилләрлек сүз таба алмау, эндәшми калу, ни дә әйтә алмау. *Фәхри бабай тагын җавапсыз калды.* М.Гафури. *Әмма дәшмәде, [Микәй] чак тыелып калды. Бик тә, бик тә кыен иде җавапсыз калу.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Әйтелгән сүз, сорау, хат һ.б.ш.га җавап булмау, җавап табылмау. *Күңелләрне тынычсызлаган бу сораулар җавапсыз кала.* Г.Ибраһимов. *Егетнең соравы җавапсыз калды.* М.Юныс; 3) Игътибарга алмау, илтифат итмәү. *Җизни безнең ярлылык астына җилкәсен куярга бик үк ашыкмаса да, шулай да җавапсыз калмаган.* Ф.Хөсни. *Ләкин мондый чакларда җавапсыз калу хәтәр икәнлеген белгәнлектән ---: – Мин, шәһәрдән, чехлардан качып, монда килдем, – диде.* К.Тинчурин; 4) *юкл. форм.* «Мин бу яхшылыкны онытмам, кайчан да булса, мин дә сезгә яхшылык белән җавап бирермен» мәгънәсендә. *Ох, Рустик, яхшылыгыңа җавапсыз калмам, мең рәхмәт сиңа!* Х.Ширмән. **Җавапсыз карау** Үтәргә дип өстеңә алган эшне юньләп үтәмәү, гамьсезлек күрсәтү. *Кызганычка, аеруча баштагы чорда мәсьәләгә өстенөстен, җавапсыз карау, күмәк киңәш тотмыйча, фәнни дәлилләүләргә нигезләнмичә, кабаланып, бер яктан икенче якка нигезсез ташланып эш итү очраклары еш булды.* И.Низамов

**ҖАВАПСЫЗЛЫК** *и.* Эшкә, үзенә йөкләнгән бурычка салкын караш, җиңел мөнәсәбәт, гамьсезлек. *[Нургали] Һәртөрле җебегәнлекне, салкынлыкны, җавапсызлыкны кызган тимер белән көйдерәчәк.* Ә.Еники. *Хәлбуки мондый аңлашылмаучылыкларның күпчелеге үзебезнең гамьсезлектән, наданлыктан, җавапсызлыктан килә.* И.Низамов. *Бу юлы инде бүтәнчә, күптәнге бәхетсез мәхәббәте хакында түгел, дөньяви мәгънәдә киңрәк, тирәнрәк уйланды: бу заман балаларының илтифатсызлыгы, җавапсызлыгы аны борчыды.* Мирас

**ҖАВАПЧАН** *с.* Җавапка оста, җавапны тиз табучан, тапкыр. *Сабир телгә чапак, пәк җавапчан, мәгәр күбрәк фахиш сүзләр иде.* Г.Камал

**ҖАВАПЧЫ** *и.* 1) Журналистикада: кара-каршы оештырылган әңгәмәдә сорауларга җавап бирүче

2) *юр.* Гаепле дип табылган, җавапка тартылган кеше. *Җавапчы туктады. Шәяхмәтнең күңелендә бу юлы да үзенчә бик үткер сөаль бар иде.* Г.Ибраһимов. *Хәзер Гайнан Ибраһимович алдында ике җавапчы: уң ягында – Комзин, сулда – Шумбутский. Икесенә дә бурыч-хокуклары аңлатылган.* М.Насыйбуллин. *– Тынлык! Җавапчыны бүлдермәгез! – диде судья.* Ә.Сафиуллин

**ҖАВАПЧЫЛЫК** *и. сир. к.* **җаваплылык**. *Фидакарь ант һәм катгый җавапчылык өчен, үз ризалыгым белән, бу солых хакына чирканыч һәм җәберле бәлаләр алырга булдым.* К.Насыйри

**ҖАГАЛА́У** *ф. иск.* Туку эшендә: озайтылган буйлык җепне станга урнаштыру (көредән, кылычтан үткәреп, сугу өчен әзер хәлгә китерү). *Нәгыймә, «аулак өй» дип, бик иркенләп утырмасын, сугуларын суксын, суга башлаганы бетсә, яңадан җагаласын.* М.Гали

**Җагалап бетерү** Барысын да җагалау; җагалау эшен төгәлләү

**Җагалап кую** Алдан җагалап әзер итү

**ҖАГЫЛМАЛЫ** *с. диал.* Ягымлы, күңелгә ятышлы. *Минем кызым кеше өчен бик җагылмалы*

**ҖАГЫЛУ** *ф. диал.* Нәрсәгәдер тию, кагылу, сораусыз, рөхсәтсез алу. *Балалар, кеше әйберенә җагыласы булмагыз!*

**ҖАДУ** *и. фар. миф.* 1) Һава торышын үзгәртә ала торган тылсымлы таш. *Юлга чыксаң, юлдаш ал, кулыңа җаду таш ал.* Мәкаль

2) Тылсым

3) Тылсымчы, сихерче, күрәзәлек итүче. *Шул хәвефеннән уйганып китте, күрде: башы өстендә Дакъянус җаду хәнҗәрен чыгарып үтерергә касд иткән, һаман йөзенә бер табанча орды, Дакъянус мәтәләнеп калды.* К.Насыйри

**ҖАДУГӘР** *и. фар.* Тылсымчы, сихерче, күрәзәлек итүче

**ҖАДУЧЫ** *и.* 1) *к.* **җадугәр**. *Гыйбадәт нуры белән мөнәүвәр булган йөз җадучы кяфер йөзенә охшамас.* К.Насыйри

2) Им-том итүче, өшкерүче

**ҖАЗИБ** *с. гар. иск.* Күңелне үзенә тарта торган, ягымлы. *Хәлаикъ калебе җалиб вә җазиб.* Г.Тукай

**ҖАЗИБӘ** *и. гар. иск.* 1) Кешенең күңелен үзенә тартып, җәлеп иттереп торган сихри көч, сыйфат; сөйкемлелек. *--- гади кием кигән вакытында, үзенә башка бер җазибә вә мәхәббәтле уладыр иде.* Р.Фәхреддин

2) *физ.* Тарту көче, гравитация көче. *Җазибә, ягъни тарту көче мәсьәләсе дә мөселманнар заманында мәгълүм түгел иде.* Г.Ибраһимов

**ҖАЗИБӘЛЕ** *с.* Үзенә җәлеп итә торган, үзенә тартып торган. *Хәнифнең яшь күңелен җазибәле Әминә үзенә бәйләгән.* Ф.Вәлиев. *Сәгыйд һичбер нәрсәдән ләззәт алмый, --- Галимәнең алсу йөзләрен, йөзенең күркен арттыра торган җазибәле керфекләрен --- үз күз алдына китереп кую гына аңа ләззәт вә кәеф бирә иде.* Г.Ибраһимов. *Син аның акылын-фигылен, җазибәле йөзен күреп җиткермәдең әле.* Ф.Хөсни

**ҖАИЗ** *с. гар.* Дөрес, ярый торган, яраклы. *Ысулы тәдрисе җаиз дәгел – укыту, дәрес бирү ысулы, методы дөрес түгел.* М.Акъегет. *Мәзһәб җәһәтеннән ислам мәмләкәтендә яһүд, нәсарага тәгәррыз җаиз булмаса, әһле*

*кыйбла булган шигыйларга тию, әлбәттә, җаиз түгел.* Гасырлар авазы

**ЖАЙ** I *и.* **1.** 1) Әйбернең, эшнең, хәрәкәтнең үзенә хас, тиешле тәртибе, билгеле бер эзлеклелеге, көе. *Мәгәр бу дөньяның бер җае әйләнмәсме, миңа да кояш карамасмы, дигән өметем юк имәс.* Г.Ибраһимов. *Кодагый – бик мәнле, бик һәйбәт кеше, эшнең җаен бик белә торган кеше.* Г.Камал. *Ат сбруеның җаен ул яхшы белә, шуңа күрә каешларны бөтенләй кисеп чыгармады.* Р.Мөхәммәдиев

2) Иплелек, уңайлылык. *Һәркем үзенә җайны карый, җәен дә лайны карый.* Мәкаль. *Тора-бара юлда утырганнарга да җае табылды: аларга, кысылып булса да, урын бирделәр.* Г.Мөхәммәтшин

3) Эш-хәлнең булу-булмавын тәэмин итә торган чара, мөмкинлек. --- *Ул иртәдән бирле шундый җайны туры китерә алмавына бик тә, бик тә гаҗиз иде.* С.Рафиков. *Инде җай килә икән, җәйнең теләсә кайсы көнендә безнең бакчаны күреп чык.* М.Мәһдиев. *Хуш, син җүләрлек эшләдең, ди. Аны төзәтерлек бернинди дә җай юк идемени соң?* Р.-Н.Гүнтәкин

4) Нәрсәдер эшләргә уңайлы момент, форсат. *Җае чыкканда, аннан көлдек.* М.Мәһдиев. *Җаныңның ваклыгын сылтама заманга, Куркырга, өркергә җай бар ул һаман да.* Р.Фәйзуллин. *Без өй буендагы эскәмиядә янәшә утырып тордык. Мин перчаткаларны бүләк итәргә җай таба алмадым.* М.Маликова

5) *сөйл.* Эш-хәлнең булуын тәэмин итәрлек шарт; матди мөмкинлек, рәт, барлык. *Эшнең җае булмаса, коймакның мае булмый.* Мәкаль. *Җае барның мае бар! Төшемле генә кәсеп.* Р.Сибат

6) Ният, план, исәп. *Әтиеңнәр ничек, күнәргә җайлары бармы?* М.Фәйзи. *Әни бераз рәтләнгәч, күчү җаен карарга кирәк.* А.Шамов

7) Яраклашкан бер көй, бер уңай, ярашкан тәртип. *Ферма эше, бер дә туктый белмәгән сәгать шикелле, үз җае белән барып кына тора.* Ә.Еники. *Кыз аның җаена туктап-туктап барды.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* 1) *к.* **җайлы**. *Хисами өчен бик җай вакыт иде бу, шуңа күрә ул карчыкның сүзләрен өзеп алгандай итеп бүлде дә әйтәсе фикерен ялгап китте.* Г.Минский

2) Үз көенә генә иплән эш итүчән, күндәм. *Матур, үткен, ачы телле, шаян дусты хәзер --- дәртсез, җай бер казак хатыны булып әверелгән.* Г.Ибраһимов

3) Яхшы, уңай, файдалы. *Җангали бичарагамы мәҗлестә болай аяк вә арка терәп сөйләшү, кем авызыннан җай сүз чыгар дип көтеп торыр-торыр иде дә, бичара, иснәп утыра башлар иде.* М.Хәбибуллин

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Салмак, тын гына, үз уңаена. *Чәч кузгатып, Җай искән Таңгы җилем, исән бул!* Дәрдемәнд. *Ник ярсый бу елга, ник шаша, ник таша? Тын акса, ни була, Җай гына, уртача?* М.Җәлил. *Елганың уртасыннан чынлап та зур боз кисәге, сал шикелле булып, җай гына агып килә иде.* Ә.Фәйзи

2) Иплән, ашыкмыйча, кабаланмыйча. *Дустыңа ат бирмә, бирсәң, җай йөр, димә.* Мәкаль. --- *анда әллә ни нәрсә күренмәгәч, җәяүләп, җай гына түбәнгә кузгалды.* Ф.Мансуров. *Аты болдыр янында ук тора иде. Сөембикә җай гына атланды һәм Хан капкасына таба кузгалды.* Мирас

3) Хәлдә, халәттә, рәвештә. *Алар да, без дә – күчмә халык, бер җайда көн күрәбез лә...* М.Хәбибуллин

4) Чиратлы белән, бер-бер артлы, эзлекле рәвештә. *Хәзер, сеңелкәем, җае белән сөйлим.* Н.Гыйматдинова

**4. җаена** *бәйл. функ.* Нәрсәнең дә булса юнәлешенә, уңаена туры китереп эшләүне белдерә. *Бик иртә тотынган ул, Кул җаена сынап караган Әүвәл үз йортыннан ул.* С.Хәким. *Дәшмәдем, ваза да, әнкәсенең кадерле рәсеме дә сүз җаена иң кулай нәрсәләр иде, югыйсә.* А.Гыйләҗев

◊ **Җае белән** Җай туры килгәндә, мөмкинлек туганда. *Әнисе белән теләсә кайсы темага гәп куертып була, тормыш күргән, зирәк хатын. Бер җае белән үз тормышын да сөйләде.* Сөембикә. **(Үз) Җаена кую** 1) Ашыктырмау, кумау. *Юлга чыкканнан соң, ул атны, юыртырга әйдәмичә, үз җаена куйды.* Ш.Камал; 2) Берәр эш эшләүдән тыймау, юл кую, рөхсәт итү; 3) Эшне үз агымына кую, эшне тәртипсез рәвештә алып бару. **Җаена сыпыру** Кемнең дә булса кәефенә ярарга тырышу, кәефенә карап эш итү. **Җаена тору** Кемнең дә булса теләгенә каршы килмәү, ул дигәнчә эшләү, кәефенә ярарга тырышып тору. *– Я, Ирек белән ничек? – Болай җаена торганда ярый.* Ш.Усманов. **Җаена төшенү** *к.* **җаена төшү** (*1 мәгъ.*). *Совхоз директоры заманында үзе дә тракторчы булган. Соңыннан, тормышының җаена төшенеп, шул ук совхозга баш була.* Н.Гариф. **Җаена төшү** 1) Тәртибен өйрәнү, белеп, аңлап алу. *Эш – миннән, мин эштән канәгать дигәндәй, җаена төшә барам.* Х.Сарьян; 2) Элекке уңайлы хәленә кайту. *Гүя үлән таш астыннан шытып чыга. Сөенәмен: Үз җаена төшә дөньям.* Ф.Солтан. **Җаена яту** 1) *к.* **җаена тору**. *«Җаена яту» дигән нәрсә кыйммәткәрәк төшә шул.* Ш.Усманов; 2) *к.* **җаена төшү** (*1 мәгъ.*). *Эшнең җаена яттым да, эшлим дә эшлим.* Н.Фәттах. **Җаен китерү** Уңай вакытын туры китерү; уңай моменттан, форсаттан файдалану. *Сүз җаен китереп, бабайдан: – Әллә сезнең үз ата-бабаларыгызга берәр ачуыгыз, үч-мазарыгыз бармы? – дип сорыйм.* М.Усманов. *– Шулай да, җаен китереп, күктән дә нык кына файдаланып алган чаклар булгалый, – дип, Нәфисә ничек эшләүләрен сөйләп китте.* Г.Бәширов. **Җаен табу** 1) *к.* **җаен китерү**; 2) Шартларга җайлашу, яраклашу. *Менә ич мин дә җаен табарга теләп йөрим.* Г.Насрый. **Җаен тартып карау** Кемнең дә булса берәр эшкә, нәрсәгә карата мөнәсәбәтен белергә тырышу. **Җаен туры китереп** Вакытына җайлашып, уңайлы моменттан, мөмкинлекләрдән файдаланып. *Җаен туры китереп, бу турыда район җитәкчеләре алдында мәсьәлә кузгатып карасак?* Ф.Хөсни. **Җае туры килеп торганда** *к.* **җай килгәндә**. *Әйе, җае туры килеп торганда, нигә аңа Өмит алдында бераз гына булса да мактанмаска!* М.Маликова. **Җае чыккан саен**

Мөмкин булган һәр очракта. *Бу «затлы» өстәл нигъмәтен тәмләгән Мөхәммәт Мәһдиев белән Фәрваз Миңнуллин, җае чыккан саен, әле хәзер дә, шаяртып, искә төшереп торалар.* Т.Галиуллин. **Җайга килү** 1) Тәртипкә килү, рәтләнү; 2) Билгеле бер эш башкарырлык хәлгә килү, җайлылану (эш кораллары һ.б. турында); 3) Яхшыга әйләнү, уңайлану, кирелеге бетү (кешенең үз-үзен тотышы, тәртибе турында). **Җайга салу (китерү)**. Эшне юлга-көйгә салып җибәрү, тәртипкә китерү. *Эшләрене җайга салгач, Дүрткә тулгач хатыны, Күңеле була, этли башлый Көн дә шәкерт халкыны.* С.Рәмиев. *Ләкин, сәүдәгәрләрнең олауларын саклау өчен, илдә иминлек кирәк иде. Җангали хан моны да җайга салды шикелле.* Мирас. **Җай гына** Ашыкмый, кабаланмый, салмак кына, үз көенә. *Елга буенда кечкенә генә аланда учак яна, ут янында утыручылар җай гына әңгәмә куерталар.* М.Усманов. *Ахырысында әңгәмә җай гына ага башлады.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Җай аккан бу сүзләрдә тормыш бизәкләре янып торалар, һәм шуңа күрә алар тормышның үзе төсле җылы, саф иделәр.* Ф.Хөсни. **Җай килгәндә** Уңай момент, форсат булганда. *Әйе, Хәдичә Галимҗан абыйсының, агроном була торып та, Заготкож арбасында чабуын бик ошатып бетерми, бу турыда, җае чыкканда, һаман шулай төрттергәли иде.* Ф.Хөсни. *Җае чыкканда, бу риясыз, баламишкинлыгы ярылып яткан, әдәбиятны ихлас яраткан якты кешегә рәхмәтемне әйтәсем килә.* А.Гыйләҗев. **Җай табу** *к.* **җаен табу.** *Урамда торган машина, пыялаларны дерелдәтеп, урыныннан кузгалып киткәч кенә дәшәр җай тапты Фатыйма апа.* Р.Мөхәммәдиев. *Барлык хатларында диярлек ул [Сибгат Хәким], Казаннан читтә яшәүчеләрне юатырга, күңелләрен күтәребрәк куяргa җай таба.* Т.Галиуллин. **Җай туры килгәндә** *к.* **җай килгәндә**. *Ләкин күзләреннән күренеп тора: --- аны бу матур өйгә китереп керткән сәбәп бөтенләй башка: Халисәне күреп, --- җае туры килсә, аны бүген кичкә клубка чакыру иде.* Ф.Хөсни. **Җай чыгу** Уңайлы момент барлыкка килү, вакыты туры килү. *Мин анда күптән барырга җыена идем. Җай чыгуы бик яхшы булды әле.* Г.Әпсәләмов. *Әмма йортны төзәтергә һаман кул тимәде, кул тисә, байлыгы җитмәде, иманаы арттырырга һаман җай чыкмады.* Ә.Фәйзи. *Аннан, бу колбасниклар артык уяу халык түгел шикелле, шаять, алдап булыр үзләрен, тик җай гына чыксын.* Ә.Еники

**ЖАЙ** II *и. фар. иск.* Урын, төш, төбәк. *Җаек каргасы – Җаек җаена, Идел каргасы Идел ибенә очар.* Мәкаль. *Болар көн киттеләр, ай киттеләр һәм бик матур җайга барып җиттеләр.* К.Насыйри. *Гадәттә, бригадирлар иң якты, иң җылы почмакны үз итәләр. Пётр исә караңгырак җайга урнашкан.* А.Гыйләҗев

**ЖАЙ-ӘМӘЛ** *җый. и.* 1) Мөмкинлек, чара, ысул, җайлы момент. *Ул вакытны авызлыклый белә: «китап» дигән кәүсәр чишмәсенә иелеп, туган телебез аһәңеннән шифа, рухи пакьләнү алырга, бәгырен йомшартып, акылзиһенен чарларга җай-әмәл таба.* Ватаным Татарстан

2) Сәбәп, форсат, уңай вакыт. *Кенәз исә, Казан ханлыгына бәйләнергә җай-әмәл тууына сөенә-сөенә, тиз арада Касыйм ханны яубаш итеп, аңа кенәз Оболенский җитәкләгән рус гаскәрен дә ияртеп, казанлылар тарафына беренче тапкыр яу оештыра.* М.Хәбибуллин

**ЖАЙДАК** I *и.* 1) *тар.* Атка атланган гарәп сугышчысы

2) Ат менгән кеше. *Рухы төшкән җайдакның аты чапмый.* Мәкаль. *Узган гасырда Англия сазлыкларының берсендә кайчандыр шул сазлыкка кереп баткан һәм, торф черегәндә череп, күмергә әйләнгән ат һәм кораллы җайдак гәүдәсен табалар.* А.Муранов. *Кинәт гаскәр икегә аерылды. Шулар арасыннан бер җайдак туп-туры безнең өйгә таба юл тотты.* Казан утлары

3) Чабыш аты, чабышкы. *Атлар барда, бәйге тотарлык җайдаклар була.* М.Рафиков

**ЖАЙДАК** II *и. зоол.* Элпәканатлылар отрядыннан, личинкасы башка бөҗәкләр тәнендә паразит булып яши торган вак бөҗәк (кәбестә күбәләге, каенлык кискече һ.б.); *русчасы:* **наездник**. *Җайдакларның ана җенесе үзенең корбанын эзләп таба да, аны иярләгән кебек (шуңа күрә исеме дә «җайдак»), өстенә менеп утыра һәм, күкәй салып, аны зарарлый.* Биология

**ЖАЙДАКЛАП** *рәв.* Ат(ка) менеп, атка атланган хәлдә. *Райүзәккә барырга чыктым мин, җайдаклап. Тауга каршы барам, атның үз көенә генә.* С.Рафиков

**ЖАЙДАКЛЫ** *с.* Җайдагы булган, җайдак катнашкан. *Җайдаклы атлар чабышында, бәйгедә беркайчан да беренче урынны бирмәгән шул йөгерек.* М.Рафиков

**ЖАЙЛАНМА** *җый. и.* 1) Берәр төрле эшне башкару өчен ярдәм итә алырлык әйбер, теләсә нинди эш кирәкярагы, махсус җиһаз, прибор. *XIX йөзнең 80 нче елларында Казанның «Касыймия» мәдрәсәсендә шәкертләрнең дәрестә астролябия, циркуль һ.б. геометрик прибор һәм җайланмалардан файдаланулары билгеле.* Р.Әмирхан. *Бер кырыйда верстак, металл кою җайланмалары, тагын әлләниләр...* Г.Галиева. *Квадрант – горизонт өстеннән күк җисемнәренең биеклеген үлчәү өчен кирәк булган почмак үлчәү җайланмасы.* Г.Дәүләтшин

2) *махс.* Тереклек ияләрендәге үзләре яшәгән шартларга яраклашудан барлыкка килгән табигый үсентеләр, саклагыч чаралар. *Күп кенә үсемлекләрнең орлыкларында су һәм хайваннар ярдәмендә таралу өчен җайланмалар була. Әгәр дә мондый җайланмалар булмаса, орлыклар, үзләрен үстергән үсемлекләр янына гына коелып, уңайсыз шартларда калырлар иде.* Е.Веселов. *Һәрбер терек зат үзе яшәгән шартларда исән калуны, үсешне һәм үрчүне тәэмин итә торган җайланмаларга ия була.* Дарвинизм нигезләре. *Балыкның яхшы үскән парлы һәм парсыз йөзгечләре бар. Бу җайланмалар суда тиз хәрәкәтне тәэмин итәләр.* Биология

**ЖАЙЛАНУ** *ф.* 1) Тәртипкә килү, рәтләнү, көйләнү, җайга салыну. *Ниһаять, барысы да җайланды, ипләнде булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Сайрар*

*кошкайларымның тормышы җайланды дип, мин дә иркен сулап куйдым.* Ә.Салах

2) Яхшыру, әйбәтләнү, канәгатьләнерлек хәлгә килү. *Чәй эчеп җибәргәч, хәлләр минем җайланды.* М.Әмир. *Сергейның бүген кәефе әйбәтрәк шикелле иде: бераз гына хәле җайланды исә, ул мәзәк кенә сөйләнә башлый.* Х.Камалов

3) Җайга килү, киреләкләр, каршылыклар бетеп, яхшыга әйләнү, карышмый башлау (кешенең үз-үзен тотышы, тәртибе турында). *[Вәли] Минем тарафтан шул яшенә җиткәнгә кадәр ата-анасыннан да ишетмәгән тәмле, татлы сүзләрне ишеткәч кенә, бераз җайланды.* Г.Камал. *Алар арасында буталырга яхшысынмады... – Хәзер аралары җайланган бит инде! – диде Зуфирә, сызланып.* М.Маликова

4) Нинди дә булса шартларга яраклашу, шул шартларда яшәргә күнегү. *Ир – җиргә, хатын иргә җайлана.* Мәкаль. *Керәшә һәм карлыгачларның канатлары озын, алар очуга яхшы җайланганнар ---, бу кошлар бөҗәкләрне һавада очкан хәлдә тоталар, аларның аяклары җирдә йөрүгә җайлашмаган.* Дарвинизм нигезләре

5) Нинди дә булса бер эш, гамәл үтәү өчен, механизм махсус көйләнү. *Әнә Илгизәр белән берничә малай, тракторга җайланган тырмалар төркеме күпергә сыймаганлыктан, кичүдән чыгып яталар.* Г.Бәширов. *Ул килгәндә, инде ферма мөдире шунда ---, сыерны махсус җайланган стойлога бәйләгәннәр.* Ф.Хөсни. *Бер читтә су эчәр өчен махсус җайланган кран тора.* Казан утлары

6) Нинди дә булса хәлгә, тирәлеккә яраклы итеп эшләнү. *Салынган чакта аларның да йорты шулай байларча иркендә, рәхәттә яшәү өчен җайланган булган.* Н.Фәттах. *Кич белән кайнар аш бирделәр, агачлар ышыгына җайланган ачык клубта «Антоша Рыбкин» дигән кино күрсәттеләр.* Х.Камалов

7) Эшләү өчен җайлы, уңайлы булу, көйләнү, ипләнү (мәс., *эш коралы*). *Башта ат белән махсус җайланган сабаннар ярдәмендә, бер метр чамасы ара калдырып, алан кәсен сөреп, ярдырып аласың ---.* Н.Гамбәр

8) Остару, нинди дә булса эшне оста итеп эшләргә, башкарырга өйрәнү. *Кайчан карама – капка төпләрендә җигүле ат торыр, ә Сәмигулланың күзе майланган, эше җайланган булыр иде.* Ф.Яруллин

**Җайлана бару** Акрынлап, аз-азлап җайлану. *Мин, эшнең әкренләп җайлана барганын күргәч, киенеп, тышка чыгып китәргә уйладым.* М.Гафури

**Җайлана башлау** Җайлануга таба үзгәрү

**Җайлана төшү** Бераз җайлану. *Отделение командиры белән аралар соңгы вакытта шактый җайлана төште.* Ә.Маликов. *1943 елның башында икмәк, ашау-эчү белән тәэмин итү мәсьәләсе бераз җайлана төште.* Г.Бәширов

**Җайланып бару** *к.* **җайлана бару**. *Эшләр үзенчә җайланып барганда, бервакыт өйгә теге кызның әнисе – авылдагы күрше апа килеп керде.* Т.Миңнуллин

**Җайланып бету** Тулысынча, бөтенләй җайлану; җайланган хәлгә килү. *Ул кайсының – кырын ятып, кайсының утырып, җайланып бетүен көтте.* Г.Бәширов

**Җайланып җиту** Тәмам, ахырга кадәр җайлану. --- *теләсә кайсы марка тракторның двигатель тавышыннан, йөрү тавышыннан кай җирдә нәрсәсе җайланып җитмәгән икәнен әйтә алам.* М.Мәһдиев. *Өстә төзелгән план үтәлә, әмма кешеләрнең тормыш-көнкүреше һаман җайланып җитмәгән.* Х.Камалов

**Җайланып калу** Җайланган хәлгә килү; нининдер бер моменттан соң җайлану

**Җайланып килү** Акрынлап җайлана башлау; аз-азлап җайлану. *Җайланып килә торган эш белән канатланган укытучыны кинәт шикләнү, курку чолгап алды.* Ә.Фәйзи. *– Мин бит сине городка алып китәм, тирес оясында күпме яшәргә була? – Юк, хәзер соң инде, безнең монда да тормыш җайланып килә.* Ә.Салах

**Җайланып киту** 1) Тиз арада яки кинәт, соңгы вакытта, нининдер шарттан соң җайлану. *Гомәрхан көн-төн эштә, тормыш ярыйсы гына җайланып китте сыман бу елда.* Ф.Сафин. *Безнең янга төшеп аралашкач, сөйләшү үзеннән-үзе җайланып китте.* М.Юныс

2) *юкл. форм.* Берничек тә килеп чыкмау, һич җае табылмау. *Сүз, әллә ничек, җайланып китми иде. Башка вакытта шулкадәр сүзчән Михаилның хәзер генә шулай сүз таба алмый утыруы Хәятка сизелми калмады.* Ф.Әмирхан. *Җыеп әйткәндә, Казан университетындагы даими археографик экспедициянең башлануы кинәт кенә дә килеп чыкмады һәм шома гына да җайланып китмәде.* М.Госманов

**Җайланып кую** 1) Көтмәгәндә, кинәт җайлану

2) Алдан ук җайланган булу

**Җайланып тору** Әле, хәзер җайланган хәлдә булу. *Ул, ничектер, үзеннән-үзе ритмик сөйләмгә ярашып, җайланып тора.* Х.Туфан

**ЖАЙЛАНЫШ** *и.* Җайлану, җайлашкан булу, яраклашканлык. *Табигый сайланыш организмнарның әйләнә-тирәлеккә төрлечә җайланышын барлыкка китерә, --- ләкин организмнарның тирәлеккә җайланышы чагыштырмача гына.* Дарвинизм нигезләре

**ЖАЙЛА́У** *ф.* **1.** 1) Кулланырга, тотарга, эшләргә җайлы хәлгә китерү, уңайлы итү. *Исән йөргән берничә малай белән хәрби формаларны көйләдек, караватлар җайладык, хуҗалык эшләренә йөрдек.* М.Мәһдиев. *Кунактан кайтышлый, бу кеше безнең колхозга янә туктала, сораша, умартаның урынын җайлый, акыл бирә...* Ф.Хөсни. *Ул урындыкта шундый җайлап, иркә мәче кебек күзләрен кысып, рәхәт итеп утыра, аркасыннан сыйпап җибәрсәң, мырлап куяр кебек тоела иде.* М.Маликова

2) Нәрсәнедер билгеле бер тәртипкә китерү, тәртипкә кертү, җайга салу, көйләү. *Сәүбән абый ат җигеп бирә, чанага солы, вика тутыра, толыпны җайлый.* М.Мәһдиев. *Равил Фәйзуллин безне ачык йөз белән каршы ала, вактөяк эшләрен җайлый да безне стадионга алып китә.* М.Галиев

3) Берәр кешенең кәефен табу, аның уңай мөнәсәбәтен булдыру. *Кемнәрне*

*җайларга, кемнәрне майларга, кемнәрне алдарга туры килгәндер дала улы Җаксыбаевка, әмма бригада картларының җанын саклап калырга чат ачылды.* А.Гыйләҗев. *Ханиевкә эшне ничек тә җайларга, карчыкның күңелен күрергә кирәк, шуңа күрә ул өй эчен яңгыратып сәлам бирде.* М.Шаһимәрдәнов

4) Үтәү, башкарып чыгу. *Шулай итеп, Исәнтәй ата кам белән дә уртак тел тапты. Уртак тел тапкач исә, Сырга бикә белән Кәринә бикәнең үтенечен җайлау бөтенләй авыр булмады.* Н.Фәттах

5) Кору, эшкә көйләү (машинаны, аппаратны һ.б.). *[«Казмаш» заводы] С-80 тракторына җайлап йөртелә торган куак кискечләр, тракторга запас частьлар эшләп чыгарган.* Г.Әпсәләмов. *Фермада салам кискеч машинаны электрга җайлау*

6) Үгетләү, үгетләп күндерү. *Хәтирә үзенең эшкә ашыгуын әйтте. Майбәдәрне юатып, аны да үзе белән бергә алып чыгып китәргә җайлады.* М.Әмир

7) *күч.* Алдау, ялган сөйләп, кешене ялгыштыру, хәйләләп күндерү. *Инде Иблис барча эшне җайлады: Оста тел берлән халыкны майлады.* Ш.Бабич

**2. җайлап** *рәв. мәгъ.* 1) Ипләп, әдәпле генә, каты бәрелмичә. *Билгеле, минем үтенүем буенча, ул башта Һаҗәрне үзләренә кич утырырга чакырган, аннары, ничектер җайлап, көйләп кенә, киногa барырга күндергән.* Ә.Еники. *Беркөнне әти җизни алдында язның күңелле күренеп торуы турында сүз башлап җибәрде, шуннан, җайлап кына күчеп, ахырында сыерны үзебезгә кайтарырга вакыт җитеп килгәнлеген сиздерде.* Ф.Хөсни

2) Кешенең кәефенә туры китереп, йомшак кына. *Күрәсең, Тимери бик тиз сүрелә торган кеше иде булса кирәк, Хәерниса җайлап әйтүгә, ул бераз йомшарды.* Г.Бәширов. *Карале, улым, җайлап кына әйт әле, тәрәзә яңаклары какшаган, бер килеп рәтләп китмәс микән?* М.Маликова

3) Ипләп, рәтен, тәртибен белеп, тиешенчә, кабаланмыйча. *Әлеге бабай белән шаян малай --- кабыктан эшләнгән тубал алып киләләр. Бабай туз кашык белән җайлап кына кортларны тубалга соса башлый.* А.Алиш

**Җайлап бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы җайлау

**Җайлап бетерү** 1) Бөтенләй, тулысынча җайлау; җайланган хәлгә китерү

2) Бөтенесен җайлау, хәл итү дәрәҗәсенә җиткерү. *Урын һәм башка якларын җайлап бетергәннән соң, эш афиша бастыруга килеп терәлде.* Ф.Хөсни

**Җайлап җибәрү** Артык озакка сузмыйча, җайланган хәлгә китерү, җайларга өлгерү. *Тормышыбызны бер көйгә җайлап җибәрсәк тә, без яңаданяңа теләкләр һәм бурычлар белән янып яшибез.* Ә.Еники

**Җайлап кую** Алдан ук җайлау, җайланган хәлгә китерү. *Кунагыңны урнаштыруны хәл иттеңме соң? Гостиница ягын алдан җайлап кую зыян итмәс.* М.Юныс. *Әтисенең костюмын элеккечә җайлап куйыйм дигәндә, нәрсәгәдер ияреп, бер бит кәгазь килеп төште.* Ф.Яруллин

**Җайлап тору** 1) Даими рәвештә җайлау, бертуктаусыз җайлау

2) Әле, хәзерге вакытта җайлау эшендә булу

**Җайлый бару** *к.* **җайлап бару**. *Каенанасының баштарак сиздергән ризасызлыгын да, ире аша җайлый барып, күндергән кебек иде.* Н.Гариф

**Җайлый башлау** Җайларга тотыну. *– Юрганыгызны ачыгыз, – диде профессор авыруга һәм фонендоскобын колагына җайлый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Печән өсте җитеп килә иде. Йортларда чалгы кайрый, чалгы сапларын җайлый башладылар.* М.Галәү

**Җайлый төшү** Тагы да бераз җайлау; бераз җайлаган хәлгә китерү. *Ул корбанын тотарга җыенган җанвардай бераз күтәрелә, кулына алган ефәк бауны җайлый төшә.* М.Хәбибуллин

**ЖАЙЛАШКАНЛЫК** *и.* Ярашканлык, туры килүчәнлек. *Гармония ул – бөтен нәрсәнең бер-берсе белән килешкәнлеге, җайлашканлыгы.* Т.Миңнуллин

**ЖАЙЛАШТЫРУ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **җайлашу**

2) Нинди дә булса шартларга яраклаштыру, шул шартларга, мөмкинлекләргә туры китерү. *Сингапурдан өйрәнеп кайткан алдынгы тәҗрибәне Татарстан мохитенә җайлаштыру өчен, Россиядә дәүләт сәясәтен һәм приоритетларын яңадан карарга кирәк.* Шәһри Казан. *III Бөтендөнья татар яшьләре форумы кысаларында татар гаиләсен төзү һәм аны бүгенге тормышка җайлаштыру мәсьәләләре турында сөйләшү үткәрелгән иде.* Ватаным Татарстан

**ЖАЙЛАШУ** *ф.* 1) Урнашу, төпләнү; җирләшү. *Саба күрсәтелгән урынга җайлашты.* К.Насыйри. *Агыйдел, Дим, Ашказарларның буенда җайлашып, Ямьле җәйне үткәрәләр җәй буена сайрашып.* М.Гафури

2) Нинди дә булса шартларга яраклашу, шул шартларда яшәргә күнегү. *Кайвакыт чыршы урманында бер үлән дә күреп булмый; бары кымызлык кына чыршылар астында үсәргә җайлашкан.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова. *Үсемлекләр бергәлеге күп мең еллар дәвамында акрынлап хасил булган. Нәтиҗәдә, бергәлектәге үсемлекләрнең төрле төрләре бергәләшеп үсүгә җайлашалар.* Биология. *Шартлы һәм шартсыз рефлекслар аркасында, хайваннар әйләнә-тирәлеккә бик яхшы җайлашалар.* Дарвинизм нигезләре

3) Ярашу, ияләшү. *Демократиядән авыз иткән кешенең реаль социализм шартларына күнегә һәм җайлаша алуына алар ышанмаганнар.* А.Тимергалин. *[Чыпчыкны] Чыгарып җибәрсәләр, минем янга очып килә, минем адымга җайлашып, йөземә якыная.* З.Зәйнуллин. *Алар [ала каргалар] тавыш-тынсыз гына ботакларга кушалар, бераз шыбырдашалар, җайлашалардыр инде.* Мирас

4) Берәр төрле хәл яки мөнәсәбәткә яраклашу. *Аңлаша алам, Җайлаша алам, Алдаша алам бик уңай; Инде синсез яшәргә дә Өйрәнеп киләм бугай...* Р.Рахмани. *Нигә, имеш, бераз җайлашмыйсыз Аркан исә торган җилләргә?* Р.Гәрәй

**Җайлаша бару** Аз-азлап, акрынлап җайлашу. *Кайсы беренчел: йомыркамы,*

*тавыкмы? Бал кортымы, чәчәкме? Мондый сорауларга бердәнбер дөрес җавап шул: тарихи үсеш процессында һәр ике сыңар бер-берсенә җайлаша барганнар һәм хәзерге хәлгә килгәннәр.* Р.Әхмәтьянов

**Җайлаша башлау** Җайлашырга тотыну. *Аңа хәзер шушы хәлендә – дөм сукыр һәм ялгыз килеш яшәргә өйрәнергә, тормышка җайлаша башларга кирәк иде.* Ф.Бәйрәмова

**Җайлаша төшү** Беркадәр, бераз җайлашу. *Бу очракта ул интернетка җайлаша төшә, компьютер клавиатурасы гадиләшә, димәк, алфавит үзе дә универсаль һәм конкуренциягә сәләтле була.* Р.Хәкимов

**Җайлашып бетү** Бөтенләй, тулысынча яки барсы да җайлашу. *Ниһаять, барысы да җайлашып беткәч: – Тыңлыйм сезне, – дип куйды.* Р.Сәгъди. *Әткәй кулына җайлашып беткән кораллар минем кулга да ип килеп тора.* Х.Сарьян

**Җайлашып җитү** Бөтенләй, тулысынча җайлашкан хәлгә килү. *Көн итешләре тәмам җайлашып җиткәндә генә, бәллүр савыт идәнгә төшеп чәлпәрәмә килмәсенме!* Т.Галиуллин

**Җайлашып калу** Җайлашкан хәлгә килү, җайлашырга өлгерү. *Кышка кадәр бу авыр эшләр җайлашып калды*

**Җайлашып китү** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң җайлашу; әкренләп җайлашу. *--- бу кечкенә песи баласы берүзе генә кырыс, кыргый тормышка җайлашып китә алырмы икән?* Ә.Сафиуллин. *Ул [ондатра] яхшы җайлашып китә, үрчи һәм хәзер затлы мехлы җәнлекләр промыселының әһәмиятле объектына әверелә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**Җайлашып тору** Әле, хәзерге вакытта җайлашу. *Биегәндә, аларга бер-берсенең аягына басудан куркып, сагаеп, җайлашып торасы булмады. Һәдия белән бию бик рәхәт, җиңел икән.* М.Маликова

**ҖАЙЛАШУЧАН** *с.* Шартларга, мөмкинлекләргә җайлаша ала торган

**ҖАЙЛАШУЧАНЛЫК** *и.* Күнегә, җайлаша алу, яраклаша алу сыйфаты

**ҖАЙЛЫ** *с.* **1**. 1) Файдалану өчен уңай, ипле. *Хәзер күгәрченнәрнең оялаlarын икенче җиргә күчердек – җайлырак та, яхшырак та булды.* Ф.Хөсни. *Әмма шәфкать туташының: «Урыгыз җайлымы, яралы?» – дигән соравына ул берни дәшмәде: барыбер түгелмени?* М.Маликова

2) Вакытлы, кулай. *Бәхеткә, аның бик җайлы вакыты туры килде.* Ф.Хөсни. *Кыш та җылы, җил дә җайлы, Һавалар да саф тышта...* Х.Туфан

3) Уңайлы шартлары булган. *Бервакыт улым миңа: – Әткәй, ялгыз кешегә кайда да ярый, бу бүлмә балалар өчен бик уңайлы, әнә синең өчен тегендә бик җайлы урын бар... – диде.* Ш.Камал. *Хатыны терелеп чыкканчы, чит күзләрдән югалып тормакчы ул. Ә аның өчен иң җайлы урын – Зуфирә квартирасы.* М.Маликова

4) Ипле, әйбәт, яхшы (холыклы), күндәм. *Нарядчик күптән түгел генә билгеләнгән, юаш, җайлы кеше иде.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Җай белән, ипләп. *Аның җыйнак, тыгыз тәненнән, --- һәрнәрсәне җайлы тота торган кулларыннан гайрәт, көч бөркелә.* М.Маликова

**ҖАЙЛЫ-ҖАЙСЫЗ** *рәв.* 1) Бик үк җайлы булмаган вакытта. *Бәхетсезлек өчен юк фасыллар, Җайлы-җайсыз вакыт, көн вә төн.* Ф.Шәехов. *Җайлы-җайсыз килеп йөрү*

2) Теләсә ничек, тәртипсез, таркау; берсе өстенә берсе өелгән хәлдә. *Җайлы-җайсыз яткан агачлар аша аланлыкка чыктык.* Казан утлары

3) Бик үк җайлы тәртиптә булмаганча, төгәл җиренә җиткермичә. *Юлда да гел шуның хакында сөйләштеләр, җайлы-җайсыз итеп булса да, Харис үзенең аңа бик тә бурычлы икәнлеген аңлатты.* Л.Гыймадиева

4) Ипсез, тәртибен белмичә. *Көпшәне җайлы-җайсызрак тотсаң, җиңсә пожарныйны селтәп атарга да күп сорамый.* Р.Кәрами

5) Хәтер сакламыйча; күңелгә тидереп, урынсыз. *Чагыштыру Вәлидигә ошап бетмәде, әлбәттә. Әмма ул сер бирмәде, җайлы-җайсыз әйтелгән сүзне йотып кына куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**ҖАЙЛЫЛАНУ** *ф.* Җайлы хәлгә килү, уңайлану. *Эшләр әкренләп җайлылана*

**Җайлылана бару** Аз-азлап, акрынлап җайлылану

**Җайлылана төшү** Беркадәр, бераз җайлылану

**Җайлыланып бетү** Бөтенләй, тулысынча җайлылану; ахырына кадәр җайлыланган хәлгә килү. *Тормышлар җайлыланып бетү*

**Җайлыланып китү** Кинәт җайлылана башлау

**ҖАЙЛЫЛЫК** *и.* Җайлы, уңай булу. *Агачлар арасында куе үләннәр ерып йөрим. Күңел юлга тарта. Чыгам, җайлылык тоеп, иркенләп китәм.* Ш.Галиев

**ҖАЙНА́У** *ф. иск.* Ялтырау, җемелдәү, ялт-йолт итеп тору. *Яугир ирләребез ничә заман Ак тирмәдә кылыч кайрады. Шалтыр-шолтыр чыңлап савыт-сайман, Өстебездә сөңге җайнады.* Ш.Бабич. *Кәрәкәүле Майра, Яшьле күзем, җайна!* Н.Арсланов

**ҖАЙСЫЗ** *с.* **1.** 1) Уңайлыгы булмаган, ипсез, җайланмаган. *Аннан Володя юынырга китә, җәйме, кышмы, билдән чишенеп, җайсыз кран астына кәрә дә бөтен идәнне су белән тутырып --- юына.* М.Мәһдиев. *Үпкәләшкәннән бирле ул, хатынына үч итеп, юри шул җайсыз, тар, биш яшьлек Халидәгә генә ярый торган урында йоклый.* М.Маликова

2) Табигый торышны сакламаган, ипсез, уңайсыз. *Буындагы җайсыз хәрәкәт сөякләрнең урыныннан күчүен – буыннар таюын китереп чыгарырга мөмкин.* Анатомия. *Җайсыз хәрәкәтләр ясау яисә бәрелү-сугылулар нәтиҗәсендә, буыннарда сөякләрне тоташтырып торган сеңерләр зарарланырга мөмкин.* Анатомия

3) Кыен, читен, мәшәкатьле. *Юллар җайсыз булып, бик туңмадыңмы?* А.Шамов. *Урамнарда таш җәелмәгәнгә, бөтен юллар, казылып, бик җайсыз һәм уңайсыз хәлгә килгәннәр.* Ш.Әхмәдиев. *Штаб ерак түгел, әмма барыр җире җайсыз: ешкын таллык, чокыр-чакыр.* Мирас

4) Үзен башкалар кебек үк тотмый торган, башкалардан аерылып торган,

ипсез; көйсез, холыксыз. *Башка мохиттән булса да, совет җәмгыяте өчен җайсыз кешене Б.Пастернак доктор Живаго образында булдырды.* Т.Галиуллин

5) Урыны яки вакыты уңайсыз булган. *Әче үч тойгысы нигә шулай соңгарып килде дә, күңелем үтә җайсыз урында шулай давылланды?* А.Гыйләҗев. *Иллә дә җайсыз вакытка билгеләнгән бу практика.* М.Мәһдиев. *[Мөхәммәт бабай:] Бик җайсыз чагыңа туры килгәнмен икән, энем, ачуланма инде.* Ф.Яруллин

6) Күңелгә ятышсыз, кәефкә начар тәэсир итә торган, урынсыз. *Бәхил булыгыз, әгәр эш вакытында берәрегезгә җайсыз сүз әйткән булсам, мине кичерегез.* М.Мәһдиев

7) Катлаулы, читен. *Иң җайсыз бер сорауга егет ике дә уйламыйча җавап бирде.* М.Мәһдиев. *Тизәйткечләр әйтелешләре ягыннан телне чәбәләндерерлек дәрәҗәдә җайсыз хәрефләр кабатламасыннан тезелгән сүзләрдән һәм җөмләләрдән торалар.* Н.Исәнбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Уңайсыз, ипсез рәвештә, табигый торышны сакламыйча. *Гөлшәһидә, җайсыз басып, аягын каймыктырган иде.* Г.Әпсәләмов. – *Колхоз председателе Ислам абый юкмы дип сугылуым иде, – дигән булды ул, ишек төбендә җайсыз тукталып.* Ф.Хөсни. *Шулай диде дә Зуфирә, мамык кебек йомшарган аякларын җайсыз басып, баскычтан төшеп китте.* М.Маликова

2) Күңелсез, ямансу. *Сездән айрылып, туганнар, җайсыз, уңайсыз тору; Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.* Г.Тукай

3) Әйбәт түгел, кыен, читен. *Башлап та очларга өлгермәсәм, җайсыз булыр.* М.Әмир. *Вакытында килеп өлгермәсәк, кунаклар алдында җайсыз булыр.* Казан утлары

**3.** *и. мәгъ. к.* **җайсызлык**. *«Балык – тирәнне, адәм яхшыны эзли» ди рус мәкале. Югыйсә адәм баласы балыкка охшарга тиеш түгел бит. Җайсызны үзенә җайлы итә белергә тиеш.* М.Маликова

◊ **Җайсызга килү** Кыен булу, авырга туры килү. *Атлар кузгалып киткәч тә, Фәтхигә бераз вакытлар эш җайсызга килде.* Ш.Камал. **Җайсыз җаный** Көйсез, тиз үпкәләүчән кешегә карата әйтелә

**ҖАЙСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Җае китү, уңайсызга әйләнү, уңайсызлану. *Балет мәктәбен Уралга күчерделәр. Кызым белән курешүләр тагын җайсызланды.* Р.Батулла. *Теге комлыкка җиткәндә, дөм караңгы булган иде инде. Комлык икәнлеген аяк асты җайсызлангач кына чамаладык.* Л.Гыймадиева

2) Кыенсыну, үзен кыен хәлдә итеп сизү, тартыну. *Сәерсенергә мәҗбүр иткәне шул иде: Зөлфия чамасыз аз сүзле булып чыкты. Чит кешедән тартынган сабый диярсең, кызара-бүртенә, җайсызлана.* Б.Камалов. *Гел хатын-кыз арасында сәгатьләп озак утыргач, мин, җайсызланып, ишегалдына чыктым.* М.Мәһдиев

**Җайсызлана бару** Торган саен ныграк җайсызлану

**Җайсызлана башлау** Җайсызлыгы күренү

**Җайсызлана төшү** Берникадәр, бераз җайсызлану

**Җайсызланып бетү** Тәмам, бик нык җайсызлану

**Җайсызланып калу** Ниндидер хәлдән соң җайсызлык барлыкка килү. *[Председатель сүзеннән] Әмәт җайсызланып калды.* Б.Камалов. *Мидхәт, гаеп эш кылганда фаш булган адәм сыман, җайсызланып калды.* Д.Гайнетдинова

**Җайсызланып китү** Кинәт җайсызлану. *Ипи ягы җайсызланып китте бит әле.* Ш.Галиев

**ҖАЙСЫЗЛА́У** *ф.* Кыенлык тудыру, комачау итү. *[Кулак:] Комсомоллар тагын поход ясыйлар: Тагын миңа җайсызлыйлар, Карт башымны ашыйлар.* М.Җәлил. *Газинур тәрәзә төбендәге тамчылы гөлне бер читкәрәк этеп куйды: ул аңа карарга җайсызлый иде.* Г.Әпсәләмов

**Җайсызлап йөрү** Әле, хәзерге вакытта җайсызлау

**Җайсызлап тору** Һәрвакыт, гел җайсызлау. *Шундук бил турысында кысып, җайсызлап торган балтамны барлап куйдым...* Г.Гыйльманов

**Җайсызлый башлау** Җайсызларга керешү

**Җайсызлый төшү** Тагы да җайсызлау

**ҖАЙСЫЗЛЫК** *и.* 1) Җайсыз шартлар; ипсезлек, уңайсызлык. *Ә менә Эльвир кебекләр, чыннан да, тирәнне эзләгән балык шикелле, җайлыны гына эзлиләр, җайсызлыкка бер дә түзә алмыйлар.* М.Маликова. *Җентекләбрәк карый башлагач, --- палаталарның, кабинетларның җайсызлыгы, җиһазларның искергәнлеге аеруча күзгә ташланды.* Г.Әпсәләмов. *Сөйләшеп, планнар корып бара торгач, автобусның җайсызлыгы да, юлның озынлыгы да сизелми башлады.* Сөембикә

2) Авыр хәл, кыенлык. *Иләнгән җир – иләнгән җир инде ул! Лагерьда түгел, Черек күлдә камерадан камерага куып йөрткәндә дә, мин җайсызлык тоя идем.* А.Гыйләҗев. *Әһә, җайсызлык килеп чыкканда, без исенә төшкән икәнбез.* М.Маликова. *Намус белән дус-тату яшәгән Бибинур әбинең җайсызлыкка, кешелексезлеккә, битарафлыкка каршы үзенчәлекле протесты – маңкорт адәмнәрнең әхлаксыз гамәлләрен намус хөкеменә тарту ул!* М.Сәхапов

**ҖАЛИБ** *с. гар. иск.* Күңелне үзенә тарта торган, ягымлы. *Хәлаикъ калебе җалиб вә җазиб.* Г.Тукай

**ҖАЛПАК** *и. диал.* Иртә яз башында күк күкрәүсез була торган яшен. *Җалпак күренсә, су җылыныр.* Әйтем. *Җалпак күренгәч, су коенырга ярый.* Әйтем

**ҖАЛПАЮ** *ф. диал.* 1) Тернәкләнү, көрәеп китү, матурлану. *Кыз яхшы җиргә төшсә – җалпая, яман җиргә төшсә – картая.* Мәкаль

2) Яшәрү, яхшырак үсә башлау. *Яңгырдан соң үләннәр бераз җалпайганнар*

3) Алга китү, эш уңу, әйбәтләнү. *Яхшыга иярсәң – җалпаерсың, яманга иярсәң – картаерсың.* Мәкаль

**Җалпаеп килү** Акрынлап җалпайган хәлгә керү

**Җалпаеп китү** Бераз җалпаю

**Җалпая бару** Акрынлап җалпаю

**Җалпая башлау** Җалпаерга тотыну

**ҖАЛПУ** *с. диал.* Уйсу, иңкүлектәге, түбән урнашкан. *Җалпу җир*

**ҖАМ** I *и. фар. иск. к.* **җамаяк**. *Әгъраби аны [Мәһдине] ашатты, эчертте. Бер җам хәмер китерде.* К.Насыйри. *Олуг кенәз аягүрә басты, кулында – агач җам, җам алтын тасмалар белән билләнгән.* М.Хәбибуллин. *Ач карынны туйдырыр бер җам ботка да.* Р.Корбан

**ҖАМ** II *и. рус диал.* Чокыр; баз. *Күмер җамы*

**ҖАМАЯК** *и.* Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү. *Ахырда түзмәде Хәдичә апа, бер җамаяк җылы сөт күтәреп, чирәм үскән ишегалдына барып керде.* М.Маликова

**ҖАМИГЪ** *и. гар.* Дин тотучыларның бергәләп җомга намазы укый торган урыны; зур мәчет. *--- кальга эчендә сигез манаралы бер җамигъ мәчет, «таҗик ермагы» дип йөртелгән урында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә була.* Ш.Мәрҗани. *Ходайның рәхмәте, хан кызы мунчадан үз аяклары белән кайта. Бу могҗизадан соң Айдар хан һәм аның халкы Аллаһыга иман китерә, җамигъ мәчете салалар.* Т.Нәбиуллин. *«Җомга намазы кыйлмак өчен җамигъ шәрифкә бардык», – дигән юллар бар.* Ф.Урманче

**ҖАН** *и. фар.* 1) *дини* Тәңгә тереклек бирә һәм аннан башка да яши ала торган мәңгелек башлангыч, кот. *Риваятькә караганда, Аллаһ кешеләрнең җанын кисәкчекләрдән яраткан.* А.Тимергалин. *[Элек] Заманында рәсем ясый башласаң: «Бу рәсем теге дөньяда синнән җан сорар, бирерлек җаның булмагач, ул синең үз җаныңны алыр...» – дип куркытканнар.* Г.Кутуй. *Алар күбесе – коммунистлар, комсомоллар ---, тәннәрендә – җаннары, беләкләрендә көч барында, аяусыз сугышалар. Тик җан белән генә, күкрәк көче ярдәмендә генә немецның аждаһадай ыжгырып килгән танкларына каршы торып буламыни?* А.Гыйләҗев

2) Кешенең эчке дөньясы: уй-фикере, хисләре, омтылышлары; күңел; рух. *Олы җаны дөресен әйтергә ирек бирми, ул теләсә кемне, йөзенә ихласлык чыгарып, чын күңелдән тыңлый.* Т.Галиуллин. *Шулай да аның җаны вакыт-вакыт үрсәләнеп куя, һәм алай үрсәләнгән минутларда малай әледән-әле тәрәзәгә күз салып ала иде.* Ф.Хөсни. *Күңеле нәрсә теләгәнен ул үзе дә белми, бөтен нәрсәсе бар да кебек, ә шулай да җаны тыныч түгел, җаны һаман нидер тели, нидер көтә.* Ә.Еники

3) Кеше, шәхес. *Дөньяда ничә җан булса, шунча йөрәк, шунча табигать бар; һәм шунча теләк вә әмәл бар.* Г.Ибраһимов. *Бала-чага – алты җан: Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан ---.* Ә.Фәйзи. *Банкетка кеше чакырганда, җан башына сигез сумнан акча кертәсе иде.* М.Мәһдиев

4) Кешенең гомере. *Җан кыйбатмы, мал кыйбатмы?* Әйтем

5) Кот, нур, ямь, матурлык. *Имән баганада имән кояш, шул кояшта ямь, җан бар.* Р.Харис

6) Нинди дә булса эшне башлап йөрүче, илһам, көч-дәрт биреп торучы зат. *Сәхнәдә – «артист» кушаматлы, идарәнең үзешчән сәнгать коллективының җаны – электрик Борис Андреев.* М.Хәсәнов

7) Нәрсәнең дә булса асылы, нигезе. *Килсә дә ул гади избач булып, Карт авылның җанын яшәрткән.* Ш.Маннур

◊ **Җан азыгы** Күңел рәхәтлеге, канәгатьлек хисе бирә торган нәрсә, рухи азык. *Яхшы сүз – җан азыгы, Яман сүз – баш казыгы.* Мәкаль. *Кирәк икән, җырлап та җибәрерсең. Хәзер шундый чак, җан азыгына сусап тормасыннар.* Г.Бәширов. *[Халык] Үзләренә җан азыгы табарга клубка төркем-төркем агыла.* Татар театры. **Җан актару** 1) Күңелнең иң нечкә хисләрен уяту. *Әллә соң чынлап та, «җан» дигән нәрсә бар микән ул, Зөлфә? Җанымны актардың бит син минем.* М.Хәбибуллин. *Мин бервакытта да бу җырны тыныч кына тыңлый алмам кебек. Йөрәгемә үтеп кереп, җанымны актара ул минем.* Сөембикә; 2) Тәмам борчу. **Җан(ын) алу** 1) Үтерү; 2) Бик нык аптыратып, йөдәтеп бетерү. *Әле дә: ни эшләп болай соңга калдың, дип, җанымны алыр.* Г.Ибраһимов. **Җан алучы** 1) Җан ала, үтерә торган зат; газраил; 2) Палач, җәллад. *Казаматның ишеге Тар ләхеттән тар икән, Казаматның эчендә Җан алучы бар икән.* Г.Тукай. **Җан асрау** Чак-чак кына тереклек итү, үләр-үлмәс яшәү. *Катыкоты... бу бит җан асрауга да җитми.* Г.Әпсәләмов. *Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Ул какланып беткән тәнендә бары җан асрый.* Ә.Еники. **Җан ачу** Кызгану һәм башка шундый хисләрдән әрнү, рухи газаплану. *Аңа бик җаным ачыды.* К.Насыйри. *Шул вакыт – яшьләр күзеңдә, җан ачып, җан сызланып Егълыйсың, Җан Зөһрә берлә Җан Таһирны кызганып.* Г.Тукай. **Җан ачуы белән** Бик каты, көчле ачу белән; ярсып, шашынып. *Гайрәт белән бер тартам, камчы белән уңга-сулга җан ачуы белән сугам.* Г.Ибраһимов. *Җан ачуы белән аның өстенә гранатаны томырдым.* Ф.Хөсни. **Җан ачуы кузгалу** Бик нык ачу килү, ачудан ярсып китү. *Мәдинәнең җан ачулары кузгалды һәм, соңгы чара итеп, кулындагы тал чыбыгы белән бар көченә селтәнде.* Г.Минский. **Җан ачуына** *к.* **җан ачуы белән**. *Камчы белән уңга-сулга җан ачуына сугам. Алмачуарым «эһ» дип суырып ала да, күз ачып йомганчы, күк биянең алдына барып чыга.* Г.Ибраһимов. **Җан ачысы белән (илә)** 1) *к.* **җан ачуы белән**. *Гәрәй, җан ачысы белән сугышса да, озак каршы тора алмады.* К.Нәҗми; 2) Өзгәләнеп, ачыргаланып. *Илсөяр, җан ачысы белән кычкырган тавышлар ишетеп, төрмәнең ватык тәрәзәләренә карады.* Г.Гобәй. *Зәйтүнә, тиз генә кулын тартып алып, Мидхәтнең яңагына чалтыратып җибәрде. Һәм үзе, җан ачысы белән кычкыра-кычкыра, авылга йөгерде.* Ф.Хөсни. *Хан кызының иң тирән, иң саф калебеннән җан ачысы илә чыккан сүзләре, ялварулары – бар да җилгә китте, шаһзадәгә һичбер әсәр кылмады.* Ш.Мөхәммәдев. **Җан ашау** Бәйләнеп йөдәтү, каныгу. *Кул-Сарай директоры, түбәмә су үтә, дип җанымны ашый.* Г.Мөхәммәтшин. **Җан аямау** Берәр максатка ирешү өчен, үзен кызганмау,

тормышын бирергә дә әзер тору. *Без сөйгән кызыбыз өчен җан аямыйбыз, әмма, көчләп сөйдерер өчен, тәлке тиресе ябынмыйбыз.* М.Фәйзи. **Җан әрнү** Ачыну, кызгану, хәтер калу һ.б.ш. хисләрдән барлыкка килгән рухи газаплану. *Бая үзе каты чәкәләшеп алган Шәяхмәтнең бу талашка җаны әрнеде.* Г.Ибраһимов. *Юк шул ул көч бу күңелдә: ул зәгыйфь, ул кечкенә, Уйласам уй, сызлый күңелем, әрни җан да эч кенә.* С.Рәмиев. *Сафура, җаны әрнеп, Мәһдине күңелсез генә чишендерде, --- чоланга урын җәеп, шунда чыгарып салды.* Казан утлары. **Җан әсәре бетү** *к.* **җан әсәре күренмәү**. *Буш авыллар очрый юлында, Тәрәзәләр япкан, кагылган: Җан әсәре беткән авылда.* Н.Арсланов. **Җан әсәре күренмәү** Тереклекнең эзе, билгесе сизелмәү, җан ияләре күренмәү, хәрәкәт беткән булу. *Балачагадан башка җан әсәре күренмәгәч, кыеклап, олы юлга чыкты.* К.Нәҗми. *Урамнарда, арыш камырыннан әвәләнгән зур сумсаларга охшашлы нәрсәләр кигән кешеләрдән башка, бер җан әсәре күренмәде.* К.Тинчурин. **Җан башына** Һәр кешегә, кеше саны буенча. *Җан башына үзенә тигән имана җирен генә чәчеп килде ул.* М.Гали. **Җан белән** Чын күңелдән, бирелеп. *Боларда җан белән, эчке кичерү белән уйлау җитешми.* М.Җәлил. **Җан биздергеч** Күңел кайтаргыч, җирәнү, нәфрәт хисе уята торган. *Табигатьнең салкын шыксызлыгы һәм боларның ямьсез эчүләре --- фәкать шулар аркасында, туган җиргә урап кайту көне җан биздергеч бер көн булып хәтердә калачак иде.* Х.Сарьян. **Җан бизү** 1) Күңел кайту, күрәсе килмәү. *Ак өемнең идәнендә Бакыр комган, җиз ләгән. Синең җаның бизгәч тәген, Минем җаным бизмәгән.* Җыр. *Кузгалмадык почмаклардан, Җаннар бик күптән бизсә дә.* Г.Тукай; 2) Гарык булу, тәмам тую. **Җан биргәнгә – җүн бирер** «Бәла-казадан ничек тә арынып булыр, берәр чарасы табылыр» дигән мәгънәдә әйтелә. *Ярар, җан биргәнгә җүнен бирер әле: ничек тә бәхилләтербез. Бар инде, алайса, Әхмәтгали абыең янына барып кара.* Казан утлары. **Җан биргәндә, авызына бер кашык су салмас** Үтә мәрхәмәтсез, миһербансыз, саран кеше турында. **Җан биреп, җан алып** Көчкә генә, очын очка ялгап, матди яктан кысанлыкта калып. *Кая мин бу хәлемдә аңа ярдәм итә алыйм? Үзем көчкә җан биреп, җан алып яшим.* М.Фәйзи. **Җан бирү** 1) Үлү. *Агыйделнең агуы, Җиңел пароход баруы; Җан бирүдән авыр икән Сөйгән ярның калуы.* Җыр. *Үз кулларымда җан бирде шул, бәгырькәем, дип, өзгәләнеп язган иде ул кыз аңа...* Ә.Еники. *Шуның белән бергә, апамның озатылган вакытта елаулары, чит авылда моңаеп җырлаулары, коры сөяккә калып, монда җан бирүләре – һәммәсе, һәммәсе күз алдымда тора.* М.Гафури. – *Җан биргәндә, баш очында ясин чыгар кешең дә булмас. Бисмилласыз-нисез туп-туры шайтан кочагына барып керерсең, – диештеләр эшчеләр.* Б.Камалов; 2) Яшәргә мөмкинлек бирү, яшәү чыганагы булу. *Тормышка җан биргән кояш нуры.* Ш.Маннур; 3) Ямь бирү, матурлык кертү. *Синең рухың гына наз гөлләргә Җан бирәдер, дустым, беләмен.* Ф.Бурнаш; 4) Илһам бирү, рух өрү. – *Җырың белән миңа җан бирүче – син үзең бит! – димәкче булган икән дә, тик кыюлыгы гына җитеп бетмәгән.* Д.Аппакова. **Җанга әсир итү** Күңелдә тирән эз калдыру, йогынты ясау. *Ул тормышны белә, күп тә яза. Ләкин әсәрләре, никтер, җанга әсир итми, җан җылысы юк.* Аң. **Җанга без булып кадалу** Авыр хисләр барлыкка китерү, күңелне әрнетү, ачындыру. *Үсмер егетнең бу саксыз соравы аның җанына без булып кадалды.* Сөембикә. **Җан газабы** 1) Үлем алды газабы; 2) Вөҗдан газаплану, үкенү белән бәйле рухи кичерешләр. *Ә мөнә җан газабына түзеп булмый.* Г.Гобәй. *Әйе, кешеләрне тасвирлаганда да, табигатьне сурәтләгәндә дә, бу катлаулы мәгънәне, җан газапларын һәм җиңү тантанасын – үз-үзеңне җиңү тантанасын! – тулысынча күрсәтә алсаң гына уңышка ирешәсең.* М.Маликова. **Җан газизем** 1) Иң якын дус; 2) Сөйгән яр. *Алмагачта биш алма, Мин алмадым, син дә алма; Җаным-бәгырем, җан газизем, Ятлар белән чуалма.* Җыр. **Җанга көч** Авырлык, кыенлык. *Аяз гына булса – айга көч, Болыт та гынай булса – көнгә көч; Кая гына барсаң, бер үк кояш: Күбәләккәй газиз җанга көч.* Җыр. **Җанга салкын яту** Ошамау, кире мөнәсәбәт барлыкка килү. *Мулла Галимҗан Баруди шул җанга бик салкын ята.* Ш.Бабич. **Җанга тию** Авыр тәэсир итү, күңелне рәнҗетү. *Җанга тия, сөяккә төшә торганы, иң куркынычы – үтәли җил түгел, ә билгесезлек, ачыклык җитмәү.* Т.Галиуллин. **Җанга тоз салу (сибү)** Туйдырып бетерү, борчу. *Эшкә осталыгы булса да, әче сүзе, каршы әрләшүе каенананың җанына тоз сала торды.* Г.Ибраһимов. **Җанга урын тапмау** Бик нык борчылу, пошыну, нишләргә дә белмәү. *Җанына урын таба алмыйча, эшнең ахырын көтүче бер кеше булса, ул Зәйтүнә иде.* Ф.Хөсни. *Бала чактан килгән бер гадәт: Күрсәм әгәр китап янганын, Төшләремә кереп уятты, Җанга урын таба алмадым.* М.Әгъләмов. *Аның хәле дә минем кебегрәк, җанына урын тапмый.* Ф.Хөсни. **Җанга якын** Җылы хисләр уята торган; кадерле, кадерләп саклана торган. *Җанга якын татар әдәбиятында, үземне Фатих Әмирхан, Әмирхан Еникиләрнең дә шәкерте санап, --- бу язмаларым фикерләремә бер һәйкәл булсын, дип эшкә тотындым.* А.Гыйләҗев. *Сөембикә манарасы – халкыбызның иң күркәм, иң мәшһүр, иң җанга якын, әмма шул ук вакытта иң серле архитектура һәйкәле.* Мирас. **Җанга яту** Күңелгә якын булу, ятышлы булу, ошау. *Әллә нишләп, шул абыйның сөйләшүләре җанга ята.* Н.Исәнбәт. **Җан дус** *к.* **җан газизем**. **Җан җылысы** Йөрәк хисе, үз итү, ярату хисе. *Ә анда, инвалидлар йортында, --- үз-үзләрен карый алмаган яралыларны, иренмичә, ялыкмыйча, җан җылысын биреп карый ала торган шәфкать туташлары бик тә кирәк икән.* М.Маликова. *Кеше туып, сөекле әнкәсе туган телендә: «Улым! Кызым!» – дип, җан җылысы белән эндәшүгә, сабыйның чиста-саф аң дәфтәренә тәүге милли сызык сызыла...* А.Гыйләҗев. *Әнкәсенең үлү кайгысыннан катып киткән күңеле*

*авылдашларының җан җылысын тоеп эреде.* Ф.Яруллин. **Җан җылыту** Дәрт бирү, дәртләндерү, күңелне үстерү; рухландыру. *Җан җылытып утырган идек, Юлы чиксез юлчылар кебек...* Х.Туфан. **Җан иясе** 1) Тереклек иясе, һәр тере нәрсә. *Җан иясен ярата белгән бала юньсез бала булмас ул.* Г.Ахунов. *Урак башлануга, авыл бушап калды. Урамда юл тузанында коенучы тавыклардан башка бер җан иясе юк.* Мирас; 2) Кем дә булса берәү, берәр кеше. *Өйдә миннән башка бер җан иясе дә юк.* Г.Камал. *Гыйльметдин әфәнденең эше беткәнче, бер генә җан иясен дә уткәрмәсеннәр.* К.Нәҗми. *Сөләйман, шашкан кеше төсле, парк буйлап йөгерә-йөгерә, кызылармеецларны эзли башлады. Паркта бер җан иясе дә күренмәде.* К.Тинчурин. **Җан кайгысы** Үлем янап торганда исән калырга тырышу, үзен үлемнән саклап калырга тырышу уе. *Итчегә – мал кайгысы, кәҗәгә – җан кайгысы.* Мәкаль. **Җан кебек күрү** Үз итү, якын итү. *И Казан, Казан... Ярый әле, җан кебек күргән син бар...* Х.Сарьян. **Җан кертү** 1) Тормыш бирү, җанландырып җибәрү. *Үстереп яшел игеннәр, үләннәр, хуш исле гөлләр, җан кертербез комлы чүлләргә.* Ә.Исхак; 2) Рух, дәрт бирү, күңелне күтәрү. *Унлап кызга – бер егет инде, аңа, ачуым килмәгәе, өшкергәләп тә җан кертербез.* Г.Бәширов. **Җан керү** 1) Сәламәт кеше төсе керү, тернәкләнү. *Сабирымның сары йөзенә җан керде.* Н.Исәнбәт. *Әнисе ирекkә чыгу әтисенә бик тә шифалы дәва булды: аякларына җан керә башлады, бармаклары кыймылдарга кереште.* Казан утлары; 2) Аптырау, курку хәленнән чыгу, тынычлану; күңелдә өмет уяну, күңел күтәрелү. *Авыл күргәч, Вилданга бераз җан керде.* Г.Толымбай. *Ләкин егетнең кем икәнен белгәч, бераз гына җан керде.* Г.Ибраһимов. *Җиденче килүемдә булса кирәк, ниһаять, кибетче хатынның үзен генә туры китердем. Эчкә җан кереп китте.* Ф.Хөсни; 3) Җанлылык арту; шау-шу, хәрәкәт көчәю. *Аягүрә катып, өнсез, аптырашта калган мәҗлес халкына бердән җан керде, бар да киң итеп сулап җибәрделәр.* Н.Исәнбәт; 4) Эшли, хәрәкәт итә башлау. *Банкрот булырга әзерләнгән Әҗимевнең бәз фабрикасына җан керде.* К.Тинчурин. *Казанга янә җан керде: алыпсатарлар ишәйде, күрше-тирәдән генә түгел, чит илләрдән дә сәүдәгәрләр агылды.* Мирас; 5) Җанланып китү; тереклек, хәрәкәт башлану (табигать күренешләре турында). *Чәчәкләргә шунда ук җан керә, яфраклары күтәрелеп, таҗлары ачыла.* М.Хуҗин. *Халыкның кәефе тәмам кырылды, тәкате бетте дигәндә генә, кургаш болытларга җан керде.* Казан утлары. **Җан көеге** 1) Эч пошыргыч кеше яки берәр нәрсә; 2) Имгәк. *Ул [ат] егылачак, аягын сындырачак яки, сукыраеп, җан көеге булып басып торачак.* М.Мәһдиев. **Җан көю** 1) Бик нык сусау. *Түгәрәк чишмә, салкын су, эчтем җаным көйгәнгә; Ерак юлны якын итеп килдем, җаным сөйгәнгә.* Җыр; 2) Кызгану һәм башка шундый хисләрдән әрнү, рухи газаплану. *Аклы ситса кем кимәс, Кем ярларын кем сөймәс; Кеше ярын кеше сөйгәч, Ничек җаннарың көймәс?* Җыр. *Кадыйр ботканы --- бер-ике капты да, табакны этеп куйды. – Әллә ни ашыйсы килми әле, – диде. – Җаным көя.* Казан утлары. **Җан кызганмау** *к.* **җан аямау. Җаннан тую** Үлем эзләү, яшәүдән өмет өзү, дөньядан тую. *Курыкмадың, монда ничек кердең кыеп? Бар икән йөргән кеше, җаннан туеп!* Г.Тукай. **Җанны айкау** Борчып тору, тынычсызлау, аптырату, кәефне төшерү. *Болай да үз-үзен кая куярга белми каңгырып йөргән Халисәне егет сулардан алып утларга салды, бәгырьләрен телде, җаннарын айкады.* М.Хәбибуллин; 2) Нинди дә булса көчле хис, тәэсир калдыру. *Гаҗәп хәл: айлар буе авырып ятса да, бите-йөзе бер дә үзгәрмәгән... Әнә шул үзгәрмәве белән ул [Хәсән Туфан] җаннарны айкап алды.* Г.Ахунов. **Җанны кая куярга белмәү** 1) Чиктән тыш борчылу, борсаланудан аптырауга төшү. *Менә шулай җанымны кая куярга белмичә, эчтән төрле шикләр белән газапланып йөргән чагым.* Ә.Еники. *Ни эшләргә белмичә, аптырап, җанны кая куярга белмичә, болай тилмереп йөргәнче, Иделгә генә ташланырлык калды бит.* К.Тинчурин; 2) Шатлыктан, куанычтан очыну. *Зөһрә, Мәрзия сүзләреннән канатланган җанын кая куярга белмичә, шәһәр урамнары буйлап әрле-бирле йөргәч, китап кибетенә барып керде.* К.Тимбикова. **Җанны кисү** Күңелдә иң тирән хис-тойгыларны кузгату, тәэсирләндерү, хисләндерү. *Бервакыт «чутчут» итеп сайрый Ходайның кошлары; Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.* Г.Тукай. **Җанны кыйнау** Аптыратып, йөдәтеп бетерү. *Мәрьям абыстай рәнҗеп еламсырый башлый: – Гомерем буена шул кирәксез сүзләре белән миңа аркылы төшеп җанымны кыйнады...* Ә.Еники. **Җанны өзгәләү** *к.* **җанны кисү**. *Аһ, шул «китмә» дип өзелеп әйткән сүзләрең белән җанымны өзәсең.* Ю.Әминев. *Бу мескен кызны якыннарының көн саен, адым саен хурлауларын ишетү Акчуринның җанын өзгәли иде.* Г.Әпсәләмов. **Җанны талку** Өзлексез борчып, йөдәтеп тору. – *Нәрсә кирәк сезгә, ә? – диде ул, чәрелдәп. – Нигә минем җанымны талкып йөрисез?* Ф.Яруллин. **Җанны тергезү** 1) Тормыш бирү, җанландырып җибәрү. *Соңыннан, килеп, үлеп барган җанны тергездегез дип, аңа рәхмәт укып киткәннәре дә бар. Югыйсә гади генә нәрсәләр хакында сөйләшә алар белән Бакый.* М.Маликова; 2) Өмет уяту, өмет барлыкка китерү. **Җанны учка йомарлап** Куркыныч янап торганда, тәвәккәлләп. *Шуңа күрә ул, менә-менә җиргә атылып төшәм дә үләм, дип, җанын учына йомарлап бара иде.* Ф.Әмирхан. **Җанны учка учлап** *к.* **җанны учка йомарлап**. *Өч юлбасар, диеп, мәшһүр җиһанда без, Йөз чытмаган миллион җанны кыйган да – без, Юкса җаның учка учлап килдеңме син? Китерербез сине дә тиз иманга без!* З.Бәшири. **Җанны фида кылу** Үзен аямау, җанын корбан итү. *Ил халкы өчен җанын фида кылып, дошман кулыннан әҗәлсез киткән Хәкимулла улы Сибгатулла мәрхүмне дә шәфәгатеңнән мәхрүм итмә.* Г.Бәширов. *Бөтен йөрәгем белән эчтән ялвардым: «Ул синең өчен салкын дәрья суларына ташланды, җанын фида кыла*

*язды, син дә кара инде бер генә!» – диде.* М.Маликова. **Җан үзгәләнү** Газаплану, кайгы-хәсрәтне авыр кичерү, ни эшләргә белми гаҗиз калу. *Көндезен үк картның эче пошып, үзалдына җаны үзгәләнде, күңеленә төрле уйлар килде.* Мирас. **Җан үзелү** 1) Үлү. *Түгелә каным, үзелә җаным, яраланып ятам мин.* Ә.Ерикәй; 2) Бик сагынып, күрәсе килеп, күңеле сызлану, ямансулау, зарыгу. *Зәйнәп, моны күргәч, җаны үзелә язып, күңелсезлек сәбәбен сорады.* М.Гафури. **Җан өрү** 1) Рух, дәрт бирү; кемнең дә булса күңелен күтәрү, дәртләндерү. *Кемдер бу станциядә озак торуыбызны әйтте. Бу хәбәр малайларга җан өрде.* М.Мәһдиев. *Батырҗанның үзе була алмасам да, аларның хәлләрен ничек тә җиңеләйтергә, бу салкын, караңгы бушлыктан үзләрен чыгарырга, җан өрергә, яңадан терелтергә кирәк дип уйлады.* Ә.Еники. *Үзләре сеңсә дә, рухлары калыккан. Әнә шулар үлеме җан өрә халыкка.* Р.Фәйзуллин; 2) Җанландырып җибәрү, ямь бирү. *– Әһә, килеп капкан икән безнең чибәр егет! Ычкындырмагыз инде үзен! – дигән булды. – Җан өрегез үзенә! Терелтеп җибәрегез, яшәртеп!* Г.Бәширов. *Артыш саплы пәке иң нечкә чигелешләргә җан өрде.* Р.Мөхәммәдиев. **Җан өшү** 1) Күңелдә авыр, ямьсез хис барлыкка килү. *Староста усал карчыкны бераз тынычландырырга теләде. Шибай тирәсендәге ызгышлардан җаны өшегәнгә, боларны килешү ягына сөрде.* Г.Ибраһимов. *Авыл урамына барып керү белән, җан өшеп, куырылып кала. Һәр йортта бөлгенлек, фәкыйрьлек, ятимлек күзне кыса.* А.Гыйләҗев. *[Сәмигулла] Ишектәге йозакны күрмичә, шактый озак дөбердәтеп торды ул. Ә йозакны күргәч, җаны кинәт өшеп китте.* Ф.Яруллин; 2) Кемнән яки нәрсәдән булса да бизү, күңел сүрелү. *[Карчык] Совхозның эчке тормышы турында ни белсә, һәммәсен ачып ташлады: – Җаным өшеде. Үтерсәгез дә яңадан бармыйм, балакаем, – диде.* Г.Ибраһимов. *Изаил Харисович күз алдыма килә дә, җаннарым өшеп китә.* М.Маликова. **Җан рәхәте** Күңеле ачылудан кичергән рәхәтлек, канәгатьлек хисе. *Эре мәрҗән, эре мәрҗән Кыз баланың муенында; Дөнья шушы җан рәхәте Әткәй-әнкәй куенында.* Җыр. *Тик Сафа әфәндегә баргагда гына җан рәхәте була иде.* Г.Тукай. **Җан саклау** Исән булу, исән калу. *– Аккошлар! – дип пышылдады Зуфирә ---. Болытлардан ишелеп төшкәндәй булып җепшек кар яуганда, аяктан егарлык ачы җилләр искәндә ничек җан саклыйсыз?* М.Маликова. **Җан сызлау** *к.* **җан әрнү**. **Җан сыкрау** *к.* **җан әрнү**. **Җан табанга төшү** Гаять зур рухи киеренкелек кичерү һәм курку. *Җаны табаннарына төшкән хәлдә, Әбүзәр абзыйның йөзен күзәтте.* Г.Әпсәләмов. **Җан талашу** Бар көченә тырышу, нәрсәнедер булдыру, башкарып чыгу өчен, бөтен көчен, сәләтен кую. **Җан тартмаса, кан тарта** Күңелгә ошамаса да, туган итү, якын итү. *«Җан тартмаса, кан тартыр, әбекәем, рәнҗетмәм», – дип, ышандырырлык итеп, ризалыгын сорый.* Мәдәни җомга. **Җан тартмау** Күңелгә ошамау, яратмау, якын күрмәү. *Матурын матур да ул, тик, нигәдер, җан тартмый.* Н.Исәнбәт. *Атасына кагылган бу авыр сүз Габдулланың йөрәгендә төер булып утырып калды. Шуннан бирле җизнәсе кушканны эшләргә аның җаны тартмады.* Ә.Фәйзи. **Җан тәнгә сыймау** Пошыну, уфтану, борчылу, рухи газаплану, ни эшләргә дә белмәү. *Уф, җаннарым тәнемә сыймый. Нишләргә дә белмим, аптырадым.* М.Гафури. **Җан тәслим кылу** Үлү, җан бирү, вафат булу. *Бер атнада Пәттәхнең хатыны җан тәслим кылды.* Г.Ахунов. *Иртәгәсен дә урыныннан тора алмады, ике тәүлек бернәрсә капмыйча, көчкә сулу алып, бик авыр хәлдә ятты да, өченче тәүлек киткәндә, кичен җан тәслим кылды.* Г.Галиев. *Бу хәлне күреп торган шаһзадә дә, төбеннән кискән агач кебек, шул торган җирендә егылып, җан тәслим кылды.* Ш.Мөхәммәдев. **Җан теләгән** Күңелгә ошаган, яраткан. *Сөйгән – сигез, теләгән – бер, диләр бит. Ә минем җан теләгәнем бирәү генә – Фәридә генә иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Җан теләгән нәрсәне алып килгән бит.* М.Фәйзи. **Җан тир белән** Бөтен көчен биреп, тырышып-тырмашып. *Син монда, үләрең белми, җан тирең белән эшлисең, җыен хөрәсән, җыен әрәмтамак анда синең каныңа тоз салып ята.* Г.Бәширов. **Җан тиргә төшеп** *к.* **җан тир белән**. *Хатын-кыз үзенең нәтиҗәсен чыгарып өлгерде: – Җан тиргә төшсә төште, кызны тегеңә бирмәде!* Ә.Фәйзи. **Җан тирләрен чыгару** Интектерү, җәфалау. *Бикмүш бабай белән Илсөярнең җан тирләрен чыгарган нәрсә череп, каралып беткән --- имән төбе иде.* Г.Гобәй. **Җан тирләре чыгу** Чамасыз көч түгү; хәлдән таю, интегеп бетү. **Җан тоемы** Ерактан торып тоемлау, эчке сизенү; телепатия. *«Җан тоемы» дип әйтикме, әллә, заман шартына китереп, «телепатия» дип җибәрикме?* Б.Камалов. **Җан түзмәү** Сабырсызлану, түземсезләнү, бик нык кызыксыну. *Ә песи яшерен генә яткан, кәтүкне күзлидер; Тукта, селкенмәсме, ди ул, бер дә җаны түзмидер.* Г.Тукай. **Җан тыну** *к.* **җан тынычлану**. *Җизнәсенең тавышыннан ул беравыкка бөтенләй диярлек котылды, һәм җаны тынып калды.* Ә.Фәйзи. **Җан тынычлану** 1) Борчулардан арыну, күңел тынычланып калу. *Кечкенә кызның җаны тынычланып ук китте.* Г.Ибраһимов; 2) Канәгатьлек хисе кичерү. *Бүген йөрәге каты сукты. Ни күрәм, дип, икеләнеп керде һәм бер күрү белән җаны тынычланып, күңеле белән кызга бирелеп үк китте.* Г.Ибраһимов. **Җан тынычлыгы** Күңелнең рухи канәгатьләнү хәле, кайгы-хәсрәттән имин булу. *Һәм бу кечкенә бүләкне бармагында йөртү аңа нindидер җан тынычлыгы бирә, аны вакланудан, шапшаклыктан, күңеле керләнүдән саклый.* Ф.Хөсни. *Кыяметдин карт та бу мәгънәсез бөтерелүдән инде туйган, арыган иде, картлык көнендә аңа җан тынычлыгы кирәк иде.* Ф.Бәйрәмова. *Ерак җирләрдә йөреп кайтса да, һаман үзенә җан тынычлыгы таба алганы юк иде.* Ф.Мансуров. **Җан уртак булмаса да, кан уртак булу** Туганлык, кардәшлек; бер нәселдән булуны аңлата. *Туганнар бит без. Җан уртак булмаса да, каныбыз уртак.* Б.Камалов. **Җан чыгу** 1) Үлү, яшәүдән туктау. *Карыйм дип,*

*муенымны сузган идем, аркама имән казык белән китереп бирделәр... Жаным чыкты, үлдем дип торам!* Г.Ибраһимов. *Хыянәт иткәндә жаның чыккан солдат! Син үзеңнең командирыңа ничаклы жәза, бәла-каза өеп китүеңне тәмуг утларында янганда аңладыңмы икән...* А.Гыйләжев; 2) Соң дәрәжәдә жәфа чигү, арып, йөдәп бетү. *Көтәкөтә, жаным чыкты: Ник килмидер паровоз, Капчык-капчык калач ташыйм, ашап тора зур авыз.* Жыр. *[Бүрәнәләр] Шулкадәр чи: шыбыр тиргә батабыз, маңгайдан тир кипкәне юк. Пычкыларны майлый-майлый жаныбыз чыга.* М.Галәү. *Айныта алмый кичә бер юанны Тәкать корды, тәмам жан чыкты.* М.Жәлил; 3) Мөлаемлану, яктыру, нурлану. *Аның күзләренә жан чыкты, килененә каршы гомер буе йөрәгендә асрап килгән әрнүләре дә таралдылар.* Г.Ибраһимов. **Жанын каезлау** Туктаусыз борчып тору, ачындыру, әрнетү. *Фәритнең соңгы елларда жанын каезлаган, үзәгенә үткән тавыш.* А.Расих. **Жанын кую** Жанын бирү, гомерен кызганмау. *Каймак – тәмле әйбер, аның өчен жанын куя бик күп песиләр.* Һ.Такташ. **Жанын уч төбенә йомарлап** *к.* **жанны учка йомарлап**. *Ул, йә үләм, йә калам, ни булса – ул, дип, жанын уч төбенә йомарлап, упкын өстендә селкенеп торган тар гына басмага басты.* Х.Сарьян. **Жанына урын таба алмыйча** Пошынып, борчылып. *Авылда, шушы ыгы-зыгы арасында --- Сәфәргали язмышы өчен чын-чынлап куркынган һәм, жанына урын таба алмыйча, эшнең ахырын көтүче бер кеше булса, ул Зәйтүнә иде.* Ф.Хөсни. **Жаныңа ни кирәк** *к.* **жаның ни тели**. *Ул кибеттә жаныңа ни кирәк – бар нәрсә дә бар.* Казан утлары. **Жаның жәһәннәмгә олаккыры** «Үлгәч тә жаның каты газап чигүдән айнымасын» дип каргау сүзе. *Биек тә сарай алдына Элеп куйдым, жаный, колакчын; Мине дә ташлап ятны сөйсәң, Жаның жәһәннәмгә олаксын!* Жыр. *Мөртәт! Муеның астыңа килгере! Жаның жәһәннәмгә олаккыры!* М.Әмир. **Жаның ни тели** «Ни теләсәң шул бар» дигән мәгънәне белдерә. *Жаның ни тели – барысы да бар. Күгәрчен сөте белән елан мөгезе генә булмаса булмастыр.* К.Тинчурин. **Жаны шикелле күрү** Бик якын итү, үз күрү, ярату. *Жаным шикелле күргән сөекле бәгырем Зәйнәпкә.* Г.Камал. **Жан эрү** Күңел йомшару, үпкә-ачулар онытылу. *Кашың кара йөртәсең, Нинди майлар сөртәсең? Татлы сүзләр сөйләп, дустым, Жаннарым эретәсең.* Жыр. *Бер сүзеннән жаннарым эреп китә.* Г.Бәширов. *Ире шулайрак диюгә жаны эресә дә, күңелгә сеңеп калган үпкә тиз генә жуелмады.* М.Хәбибуллин. **Жан яну** 1) Бик зур шатлыктан дәрт кабыну. *Бу тавыш бик ачты күңелем, шатлыгымнан жан яна; «Әйдә, чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на, на-на!»* Г.Тукай; 2) Күңелдә тынычлык бетү, борчудан көеңү. **Жан ятмау** Ошатмау, яратмау, үз итмәү. *Тик югары уку йортына жаны ятмады, вузны ташлап чыкты.* Б.Камалов. *Тимер-томырга һич кенә дә жан ятмый минем.* Г.Ахунов

**ЖАНАГА** *и. диал.* Иренең энесе, каене. *Жиңгәләренә өйләнгән жанагалар иң бәхетле ирләрдән санала.* Т.Гыйззәт

**ЖАНАГАЙ** *и. диал. к.* **жанага**. *Жан сөйгәнем – жанагай, ярты жаным аныкы.* Жыр

**ЖАНАН** *и. фар. иск. к.* **жанаш**. *Мәрхаба, и жаны жанан, мәрхаба!* Мөнәжәт. *Күз яшем сөртергә гүя назлы жананым килә.* Г.Тукай. *Үтте айлар, үтте еллар, Күзләремне басты кан... Ник торалмыйм? Ник куралмыйм? Кайда нур? Кайда жанан?* С.Сүнчәләй

**ЖАНАСИ** *и. диал.* Туй мәжлесе. *Жанаси кешеләре жырлыйлар инде алар*

**ЖАНАСЙ КЕРТҮ** *ф. этн.* Туйдагы кунакларны ашка алу; туй кертү

**ЖАНАТАР** *и.* Спорт ярышларында, һәртөрле конкурсларда жаны-тәне белән бер якның яки бер катнашучының жиңүен теләүче, шул якны дәртләндерүче кеше; *русчасы:* **болельщик**. *Озаграк чыңласа, Дима Биланның Евровидениедә жиңгән жыры жанатарларның күңелен хушландырган булыр иде.* Л.Гарифуллина. *Казанның Үзәк стадионында меңнәрчә жанатарлар жыелган.* Мәдәни жомга

**ЖАНАТУ** *ф.* 1) Үзен-үзе кызганмау, үзен аямау. *Татар бәхете өчен мин жанатармын, Татар бит мин, үзем дә – чын татармын.* Г.Тукай

2) Тырышу-тырмашу, тырышып эшләү. *Аягында – чабата, Күргәне юк киез ката; Көне-төне жаната, Һаман житми тидия.* М.Крыймов

3) Ашкыну, атлыгып тору. *Бу вакытларда Казанда, бернечә газета һәм бернечә журнал мәйданга чыккан кебек, күп кенә әдәби әсәрләр дә дөнья күргәнлектән, Габдулла Тукай Казан мәркәзенә килү өчен жаната.* Татарстан. *Татарстанны һәм аның башкаласы Казанны Фәридә Кудашева һәрчак сагынып яшәде, анда һәрчак жанатып бара иде.* Мәдәни жомга

4) Спорт ярышында кайсы да булса якны жиңүгә дәртләндерү, аның уңышларын хуплау, уңышсызлыкларына көенү

**ЖАНАШ** *и.* 1) Сөйгән яр, яраткан кеше, жанга якын зат. *Табындым, сәждә кылдым мин сөйгән жанашның алдында.* Г.Тукай. *Бер көн бәхет кошы балкыды: Горький урамындагы гастрономда очраттым мин моны. Гади сатучы булып эшли икән, жанашым.* М.Мәһдиев. *Беләм, жанашым, бу күзләрең хәсрәтне шулхәтле күп күргәннәр, минем сүзләремне дә, тойгыларымны да, шәт, төшенәләрдер алар.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) Сөекле хатын. – *Жанаш кайгысы – жан кайгысы инде ул! – диде шакмаклы күлмәклесе, авыр көрсенгән булып.* Ә.Еники

**ЖАНВАР** *и. фар.* 1) Кыргый хайван, жәнлек. *Жанварларга килгән үләт.* М.Гафури. *Нигә өрә икән ул [эт]? Нигә шулай ярсый? Кешегә ул алай ук өрмәс, бер-бер жанвар килеп чыктымы икән?* Р.Мөхәммәдиев. *Бередәге [Себердәге] табигать байлыгының, төрле жәнлекләрнең, бигрәк тә кыйммәтле кеш жанварының зур табыш китерәчәген урыс патшалары бик яхшы аңлаган.* Ә.Мәңгәр

2) Тере, жанлы зат, жан иясе. *Синең барлыгыңа таныклык бирер барча жансыз нәрсә, жанвар, очар һәм йөгерер нәрсә.* Ә.Югнәки. *Шул ук ва-*

*кытта, астан, кара су төбеннән, нинди дә булса куркыныч җанвар да, килеп, аяктан эләктереп алыр шикелле.* М.Маликова

3) *күч. сөйл. кимс.* Начар сыйфатлар туплаган кеше, адәм, бәндә. *Каенлык авызында аларны --- озын, чандыр немец офицеры каршы алды. Бу кечкенә җанвардан булмаска тиеш иде.* Ә.Еники. *Хатынның тавышына өй эченнән бер яшь ир-ат чыкты. Ул миңа, сәер җанварга карагандай, усал итеп карады да: – Акча каерырга йөрисеңме? – диде.* Ф.Яруллин

4) *күч. сөйл.* Бет, кандала кебек бөҗәкләр. *Ә юк, болай гына, менә баш кычыта, ахрысы, теге бәдбәхет җанварлар бардыр, дим.* Ш.Камал. *Ул вак җанварлар Томилинның да җилкәсен ашый иде, ләкин ул сер бирми.* Казан утлары

**ҖАНДАР** *с. фар.* **1**. Җанлы, тере

**2**. *и. мәгъ.* Гайрәтле, дәртле кеше

**ҖАНДА́У** *и. этн. диал.* Кызны кияү йортына озата баручы парлы кунаклар (гадәттә, туганнары яки якын кардәшләре)

**ҖАНҖЫЛЫЛЫ** *с. к.* **җанҗылымлы**. *Морзахан абзый әдәплерәк, йомшаграк, җанҗылылы сөйләшү ягын карады.* Б.Камалов

**ҖАНҖЫЛЫМЛЫ** *с.* Үзенә тартып, җәлеп итеп торган. *Хәзер аңа җанҗылымлы Нәфисәдән бозлы суык бәрелә төсле.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ҖАНИ** *и. гар. иск.* Җинаятьче, закон бозучы; хыянәтче. *Гөнаһлылар, җанилар дөньясы бу [байлар дөньясы].* М.Гафури. *Әй, бөтен гомре усаллык берлән үткән карт җани! Вөҗданың изсә изәр, курыкма, аның да бар җае.* Н.Думави

**ҖАНИБ** *и. гар.* Як, тараф; фланг. *Казан Идел елгасының сул җанибендәдер.* К.Насыйри

**ҖАНИСӘП** *и.* Кеше (халык) санын белү өчен, хөкүмәт тарафыннан үткәрелгән чара. *Җанисәпкә әзерлек чорында, татар милли хәрәкәте, танылган галимнәребезне җәлеп итеп, берничә фәнни-гамәли конференция уздырачак.* Казан утлары. *Башкортстан татар милли оешмалары быелгы җанисәпкә әзерлек турында фикер алыштылар.* Шәһри Казан

**ҖАНКАЙ** *и. к.* **җанаш**. *Шул җанкай белән кавышсак, корбан суяр идем келәүгә.* Җыр. *Агыйделнең аръягында калды кешнәп малкаем; Әй... калмады кешнәп малкаем, калды елап җанкаем.* Җыр

**ҖАНКАЙ-ҖАНАШ** *и. к.* **җанаш**. *Биектә генәй тауның, һәй, түбәсе, Ат чаптырып кына, әй, менәсе. Җанкай-җанаш кына сагындыра – Сагынуларга ничек түзәсе?* Җыр

**ҖАНКИСӘК** *и.* 1) *к.* **җанаш**. *Башта «татар килен» идем, кемгә – «җиңги» инде, аннары, үзең күрәсең, «Татар әби», «җанкисәк» тә булдым берәүгә.* Г.Якупова

2) Мөрәҗәгать итү сүзе. – *Ходайга шөкер, кызларны да күргәләгәнем бар. Әмма сез әйткән кызны күргәнем юк, җанкисәгем, – дип, көлә-көлә җавап кайтарды парикмахер.* Ф.Хөсни. *Мәрфуга, дим, Мәрфуга! Исән генәме, җанкисәгем. Яле, самавырыңны куеп җибәр: бик зур кунаклар алып киләм сезгә.* М.Усманов. *И-и! Кави абы-ый! Җанкисәк-кәе-ем! Теп-тере, исән-имин кайтуың белән сине!* З.Зәйнуллин

**ҖАНКИСӘР** *и.* Җан кыючы, җан кисүче, үтерүче, палач. *Бетсен канэчкеч җанкисәрләр! Яшәсен эшче-крестьян!* М.Гафури. *Атлы кеше күздән югалгач, ата бүре үзенең егылып калган батыр җанкисәре янына әйләнеп килде.* Т.Мөбарәков

**ҖАНКЫЙГЫЧ** *с.* 1) Явыз, корткыч (*кеше, ерткыч*)

2) Канкойгыч, куркыныч, дәһшәтле. *Ни дисәң дә, без – канкойгыч һәм җанкыйгыч сугыштан соң туган балалар...* Кызыл таң

**ҖАНЛАНДЫРГЫЧ** *с.* 1) Күңеллелек, җанлылык бирә торган. *Стенадагы рәсемдә җанландыргыч табигать күренешләре урын алган*

2) Дәртләндерә, илһамландыра торган. *Күңелне җанландыргыч вакыйгалар*

**ҖАНЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса тыныч хәленнән чыгару, кузгату, җанлылык кертү. *Гади сүз яки сүз тезмәсе урынына образлы фразеологик әйтелмә (мәкаль яки әйтем) куллану – сөйләмне җанландыра, аны үтемлерәк, тәэсирлерәк, тойгылырак итә.* Х.Курбатов. *Мәгарә эчен җанландырып, челтерәп, чишмә агып ята.* Ф.Бәйрәмова

2) Дәртләндерү, дәрт, илһам бирү; күңеллелек бирү. *[Галимә апа] Үзе дә чәй эчеп алды. Чәй арасында һәммәбезне җанландырды, бөтен өй эчен матурландырып, нурландырып җибәрде.* М.Гафури. *Яшьләрне үзе артыннан ияртә, җанландыра, очкыннан ялкын кабыза торган көч бар иде аңарда [Нәҗиптә].* М.Хәсәнов

3) Алга җибәрү, куәтләү. --- *Җангали хан тәхеткә утырганда, сәүдә итүне җанландыру өчен, берничә фәрман игълан итте.* Мирас. *Фикер алышуда катнашучылар поэмалар тарихын булдыру, гомумән шигърият тәнкыйтен җанландыру җәһәтеннән үзләренең уй-фикерләрен белдерәләр.* Мәдәни җомга

4) Күз алдына китерү, фикердә-уйда гәүдәләндерү. *Гүя ул әйтергә теләгән фикерен бөтен хәрәкәте белән шунда – мәйданга тулган халык алдында гәүдәләндереп, җанландырып бирмәк була.* Г.Ибраһимов. *Шәмси башыннан кызлар портреты эзләргә тотынды. Үзенең теләгәнен җанландырды, төсләндерде.* Г.Исхакый. *«Сагынып килдем... сагынып килдем...» – дип өзгәләнә аккордеон, узганнарның иң матур күренешләрен күңелдә җанландыра.* М.Маликова

5) Тормышны, чынбарлыкны әдәби әсәрләрдә сурәтләү, фикердә-уйда образлар барлыкка китерү. *Үзенең кинокадрларында авылдашларын – авыл картларын, авыл малайларын, кызларын, туган як табигатен җанландыра ул.* Р.Миңнуллин

6) Җансыз әйберләрне җанлы итеп күрсәтү; кешеләргә хас сыйфатлар бирү; антроморфизм. «*Зыр-зырбану*» *дигән сүз белән ачкыч җанландырылган, кешеләндерелгән.* Н.Исәнбәт. *Башкортлар арасында ислам диненә кадәр булган күзаллауларның эзләре озак сакланган: алар табигать һәм аның күренешләрен җанландырганнар.* Б.Хәмидуллин

**Җанландыра төшү** Бераз җанландыру, беркадәр җанлылык кертү. *Драматургия һәм театр сәнгатендә, борынгы греклар традицияләре нигезендә, комедия белән трагедия жанрлары үсә башлый. Римлылар әлеге жанрларны җанландыра төшәләр.* К.Гыйззәтов. – *Тикшерсен әле,ниләр әйтер икән? – дип, сүзне тагын да җанландыра төште.* З.Фәйзи

**Җанландырып алу** Азга гына, кыска вакытлы, бераз җанландыру. *Ара-тирә генә, кызыклырак фактлар өстәп, дәресне дә, укучыларны да бераз җанландырып алырга мөмкин.* К.Миңлебаев

**Җанландырып җибәрү** Тиз арада, җәһәттән җанланган хәлгә китерү, җанлануга этәргеч бирү. *Россия үзәгеннән килеп, Себергә чаклы узып киткән бу тимер юл моңарчы тын гына йокымсырап яткан Эткол-Дәүләкән җирләрен кинәт бик нык җанландырып җибәрә.* Ә.Еники. *Хикәянең кинәт чынга әйләнеп китүе залда утыручы тыңлаучыларны тагын да җанландырып җибәрде.* Ф.Хөсни. *«Безнең серләшкәнне ай тыңлар» дип, профессиональ җырга яңа образлар – сирень һәм шомырт образларын алып килә, җыр жанрын җанландырып җибәрә.* К.Миңнуллин

**Җанландырып тору** Әледән-әле җанландыру, бертуктаусыз җанландыру. *Аның күзләреннән нindидер күңелле, шаян яктылык агыла, һәм шул дәртле, чая яктылык аның ак, түгәрәк йөзен – бигрәк тә елмайган чагында – балкытып, җанландырып тора.* И.Гази

**ҖАНЛАНУ** *ф.* **1.** 1) Җан керү, тереклек сыйфатлары барлыкка килү, исән хәлгә килү. *Тархан, ниһаять, җанлану әсәре күрсәтте.* Н.Фәттах. *[Рәүфә:] Балам җанланган, әни.* А.Шамов

2) Тернәкләнү, хәрәкәткә килү. *Маллар, адәмнәр, үләннәр, чәчәкләр – һәммәсе җанландылар, һәммәсенең төсенә тереклек, яңа матурлык чыкты.* Г.Ибраһимов. *Монысы да бик табигый икән: туфрак җылынуга, анда курчаклардан бик күп корт ясала, курчаклар җанлана, үрчи башлый.* М.Мәһдиев

3) Хәрәкәт фазаларын эзлекле рәвештә рәсемгә төшереп, аларны экранда бер-бер артлы кабат күрсәтү юлы белән җанлылык тәэсире барлыкка китерү. *Зуфирәнең кулы астында фломастер белән сызган сызыклар җанланды, хәрәкәткә килде.* М.Маликова

4) Кинәт кенә үсеп, көчәеп китү. *Караңгылыктан тәмам һәлак була язган бичара Гөл дә Кояш нуры илә яңадан җанланды.* Г.Тукай. *Гүя гөлләр шунда җанландылар: Нурлар чәчеп җем-җем көлделәр.* М.Гафури

5) *күч.* Уйда, хыялда барлыкка килү, хәтердә яңару, күз алдына килү. *Күңел күзем алдында онытыла язган картиналар бер-бер артлы туалар, бер-бер артлы җанланалар.* Гали Рәхим. *Туган авыл! Бу сүзләрне әйтүгә, Бакыйның хәтерендә, авылның үзеннән дә бигрәк, нурлы күзләр, назлы пышылдау, җан эреткеч рәхәт биреп иркәли торган йомшак кулларның җылысы җанлана иде.* М.Маликова. *Картинага күз салу белән, хәзерге көндә беренсәрән хәрабәләре генә торып калган шәһәрнең кайчандыр шаулап-гөрләп торган чаклары гүя кабаттан җанлана, яши башлый...* К.Нәфыйков

6) *күч.* Дәрт керү, күңеллеләнеп китү. *Мондый минутларда аның күзләрендә сизелер-сизелмәс кенә нур балкый, гадәттә чытык, караңгы йөзе дә җанлангандай була иде.* С.Сабиров. *Ул аз гына калтыранган тавыш белән шыпыртлабрак: – Аталар... – ди. Рәбиганың күзләре дә бик аз гына җанлана.* Гали Рәхим. *Фәридә, егет кочагыннан ычкынгач, саф чишмә суын эчеп сусынын баскан кош кебек җанланган иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

7) *күч.* Шау-шу, эш-хәрәкәт башланып китү. *Иртә. Дөнья җанлана, Мәшрикъ ягы аллана, Кояш чыгып, нурлары, Төшеп, җиргә ялгана.* Г.Тукай. *Бердән урман җанланды. Анда да, монда да балалар кычкыра башлады.* Г.Исхакый. *Кинәт пароход борынында басып торучы пассажирлар арасында җанлану башланды, шатлыклы авазлар ишетелде.* Б.Камалов

8) *күч.* Активлашу, көчәеп китү. *1908–1910 еллар реакциясеннән соң, Россия тормышында сыйныфлар көрәшендә нык җанлану башлана.* Г.Нигъмәти

**2. җанланып** *рәв. мәгъ.* Илһамланып, күтәренке күңел белән. *Сандугач аз гына уйланып торды да җанланып эндәште Чишмәгә тын гына.* М.Җәлил. *Ул торган саен җанланыбрак сөйләде, гадәттәгедән кычкырыбрак көлде.* Ә.Еники. – *Нәрсә дидем әле мин? – диде бикә, шундук җанланып, – яшьлек шушында узды, – дидем бугай.* Н.Фәттах

**Җанлана бару** Акрынлап җанлану; торган саен ныграк җанлану. *Чалы кошы тәмам әүвәлге чалы кошына әйләнде. Давылдан соң җылы кояшта ачылган гөл кебек җанлана барды.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Көй уйнаган саен, ир кеше җанлана барды, сүзсез генә авыз эченнән шыңшып та куйды.* Р.Вәлиев

**Җанлана башлау** Җанланырга тотыну. *Аның төссез ябык чырае җанлана башлый.* Г.Бәширов

**Җанлана төшү** Беркадәр җанлану; җанланган хәлгә килү. *Бераздан ул, җанлана төшеп, Абдулга борылды: – Коедан бүтән җирдә әллә су беткәнме?* Ф.Хөсни. *Ул арада инде урам тагын да җанлана төшә.* Г.Бәширов

**Җанланып алу** Бераз, азга гына, берара җанланган хәлгә килү. *Вятские Поляны станциясендә генә халык бераз җанланып алды.* М.Мәһдиев. *Усмановның сүзен ишетеп, тарала башлаган халык, тукталып, тагын җанланып алды.* Ф.Сафин. *Көтү кайтыр алдыннан гына, авыл бер җанланып ала.* Н.Әхмәдиев

**Җанланып бару** *к.* **җанлана бару**. *Хәзер исә халкыбызның әхлакый хәзинәсен торгызу, аны яшь буынга җиткерү процессы җанланып бара.* Х.Миңнегулов

**Җанланып килү** Акрынлап, аз-азлап җанлану. *Төбәкләрдә, тирәкләрдә тормыш җанланып килә.* Г.Сәгыйров. *Бу [шәҗәрәләр белән] кызыксыну Татарстанда, Башкортстанда, Пермь, Киров, Екатеринбург, Оренбург, Ульяновск һ.б. төбәкләрдәге татарлар арасында да җанланып килә.* М.Әхмәтҗанов

**Җанланып китү** Кинәт җанлылык башлану, нинди дә булса сәбәп белән, яки билгеле бер вакыттан, гамәлдән, сүздән соң җанлану. – *Шахтёр, димәк, – дип җанланып китте хуҗа кеше, – нигә аны баштук шулай димисең?* Р.Мөхәммәдиев. – *Ай Аллам! – ди карчык, җанланып китеп, – карасана, танымый да торам ласа, Әхмәтвәли бәбкәм, син икәнсең.* Ә.Еники. *Казанга кайтып, кулъязма табышларым хакында аннан-моннан сөйләп, «Бараба иле»н табуымны да хәбәр иткәч, гыйльми җитәкчем җанланып китте.* М.Госманов

**Җанланып кую** Аз вакытка, кинәт җанлану. *Әмма аның бу соңгы кыйнавы үтә ерткычларча булып, анда ирексездән бераз кешелек сыйфатлары да җанланып куя.* Ш.Камал. *[Бари абый] Әле бер сүз әйткәнче үк, күзләре, ирен читләре белән елмаюга, халык җанланып куя.* Ш.Галиев. *Алман әсирләре, нәрсәдер әйтешеп, җанланып куйдылар.* Р.Гариф

**Җанланып тору** Әледән-әле, еш җанлану. *Яңарып тор, җанланып тор, Сердәшче бул, Бул серле.* Э.Шәрифуллина

**ҖАНЛАНЫШ** *и.* 1) Шау-шулы хәрәкәт, ыгы-зыгы. *Яңгыр тавышыннан бөтен тирә-як җанланган кебек булды, караңгылык хәрәкәткә килде, бу үзгәреш, җанланыш --- шатлык өсти иде.* А.Гыйләҗев. *Идарә әгъзалары арасында көлемсерәү җанланышы булып ала.* Р.Батулла

2) Берәр нәрсәнең, күренешнең көчле үсүе, зур үсеш алуы, күтәрелеш. *Бу дәвер иҗтимагый хәрәкәтендәге җанланыш --- әнә шулай бара.* Г.Нигъмәти. *Элегрәк туган молекуляр биология, генетика ватаныбыз фәннәре өлкәсендә яңа этәргеч көч һәм җанланыш тапты.* К.Гыйззәтов

**ҖАНЛЫ** *с.* **1**. 1) Җаны булган, тере, исән. *Аннан соң «институт» – үзе бер абстракт төшенчә, оешманың кабул ителгән атамасы булса, аның эчтәлеген җанлы, канлы, нинди генә акыллы яисә ахмак булса да, бу фани дөньяда бер генә тапкыр яши торган кешеләр билгели.* Т.Галиуллин. *Маш миңа һәрвакыт җанлы, алай гына да түгел, олы җанлы, миһербанлы, тылсымлы, бөек бер шәхес булып тоелды.* М.Мәһдиев

3) Көчле тәэсир итә, уй-фикер уята торган. *Без шагыйрьләрдән менә шул идеяләребез өчен булган көрәштә аерым бер хезмәтне үти ала торган җанлы шигырьләр сорыйбыз.* Һ.Такташ. *Гомәрне кыстау, аның ашау-эчүе турында сорашу белән җанлы сөйләшү башланды.* Ә.Еники

4) Чын; табигый. *Алар [китаплар] белән бергә бабайларның уй-фикерләре, шатлык һәм моңнары, зирәк тәҗрибәсе һәм кайгы-хәсрәтләре дә мәңгегә югала. Бабайларның җанлы авазларын, «тере сүзләрен» болай югалту гаять аяныч, әлбәттә.* М.Усманов. *Әдипнең җанлы сүзе, кәлимәсе, үткен гыйбарәсе --- укучының йөрәгенә, китап сүзенә караганда, тизрәк барып җитә.* Т.Галиуллин. *Ботаника бакчаларында сирәк очрый торган үсемлекләрнең җанлы коллекцияләре булдырыла.* Биология

5) Тасвирлы, образлы, чынбарлыкка туры килгән, тормышчан. *Шагыйрь тарихи, ярым легендар Сөембикәнең кешелекле, тормышчан, җанлы образын тудыруга ирешкән.* Т.Галиуллин. *Утыз сигез яшьлек автор --- метафора белән юмористик фикерләүгә таянып, сәхнәгә җанлы типларны, авыр сугыш шартларында үзләре булып кала алган яшьләрне күтәрә.* Идел

6) Кайбер исемнәрдән соң килеп, шул исем белән аталган әйберне яратуын белдерә. *Җылы күңелле, бала җанлы ана үзе булмагач, әйберләре күзгә күренми, өй эче ташлап чыккан өй кебек күңелсез.* Ф.Хөсни. *[Тәбриз Мөбарәков] Әдәбиятны бик ярата, белә торган татар җанлы, сәләтле укытучы үзе.* Т.Галиуллин. *[Хәсән] Сарьян абый якташ җанлы, милләт җанлы кеше иде.* Р.Миңнуллин

7) Үзеннән алдагы сүз белән килеп, шул сүз белдергән сыйфатка ия булуны аңлата. *Бары тик бер кеше генә, бары тик уйчан кыз Зәйтүнә генә, шук җанлы Сәфәргалине, ул калдырып киткән «Гөлҗиһан» сабыны белән юынган саен, сагынып искә ала иде.* Ф.Хөсни. *Лирик җанлы эчкерсез шәхес, талантлы актёр, шигырьгә, гомумән матурлыкка гашыйк иде Котдус ага Кәримов малае.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Чынбарлыктагыча, дөрес итеп, ясалмалылык кертмичә. *Шәрафи картның кызы Газизә, ягымлы кыланышы, уйчан карашлары белән Хәлимәне җанлы гәүдәләндереп, аның исенә төшерә иде.* Ш.Камал. *Катлаулы булган бу сюжетны композитор Җиһанов музыка телендә зур осталык белән җанлы һәм кызыклы итеп биргән.* М.Җәлил

◊ **Җанлы бөҗра** Кешеләр уратып алган киртә, кешеләрдән торган тоткарлык, комачау. *Тик тыгыз җанлы бөҗра аны кысканнан-кыса бара.* Х.Камалов. **Җанлы корал** Кеше ихтыярына буйсынып хәрәкәт итүче кеше турында. *Һәммә эшне солдатлардан яшереп йөрткән, тик аларны җанлы корал итеп тотарга өйрәнгән башлыклар бу юлы да бүген нәрсә буласы хакында ләм-мим сүз әйтмәделәр.* М.Гафури. **Җанлы көч** 1) Кешеләр һәм эш хайваннары; 2) Хәрби берәмлектәге гомуми сугышчы саны. *Дивизиябезнең бер полкы --- [дошманның] ут нокталарын барларга, җанлы көчләрен ачыкларга приказ алды.* Ә.Айдар. **Җанлы курчак** Бер нәрсә эшләргә дә хокукы булмаган кеше. *Шул вакыт Фәхри, кайтып, үзенең гадәтенчә, мине җанлы курчак кебек шаярта башлады.* Г.Ибраһимов. **Җанлы мал** Мал-туар, йорт хайваннары, терлек белән исәпләнгән байлык. *Бер төрле кавем иген чәчә, сукалый, тырмалый, җанлы мал көтә, җимешләр җыя һәм гайреләр.* Г.Тукай. **Җанлы мәет** 1) Үләргә хөкем ителгән, үләргә тиешле кеше. *[Кара кареталардагы кешеләрнең] Шушы төн эчендә җиргә күмеләчәк җанлы мәетләр булганын сизеп, [солдатлар] алга сикереп чыгардай булдылар.* М.Гафури; 2) Үлүгә, бетүгә йөз тоткан күренеш, хәл; 3) Дәртсез, рухы сүнгән, сүлпән кеше. *Гүрстандай гамьле авылларда Кыбырдаша җанлы мәетләр.* Ш.Бабич. **Җанлы мисал** Нинди дә булса фикерне, хәлне ачыктан-ачык исбатлый

торган факт. **Җанлы тарих** 1) *к.* **җанлы шаһит.** *Әби-бабай – җанлы тарих, Җиргә туганнар күптән; Илдә иң-иң кызык хәлләр Алар булганда үткән...* Р.Рахмани; 2) Чынбарлыкта, чынында булган хәлләрнең истәлеге, шуны хәтерләткән әйберләр. *Сабит Җумакаевич бик саклык белән генә дәфтәр битләрен актара. Дәфтәр түгел, җанлы тарих битләре.* Ә.Маликов. **Җанлы тел** Халыкның сөйләшү теле, гади сөйләш. **Җанлы хәсрәт** *тирг.* Имгәк, булдыксыз, бәлале кеше. **Җанлы шаһит** Булган вакыйганы, хәлне үз күзе белән күргән, шунда катнашкан кеше. *Шул ук вакытта без – XX гасырның бәхетсез балалары – халыклар язмышы һәм тарих белән шаяруның, бозуның җанлы шаһитлары.* Т.Галиуллин

**ҖАНЛЫ-ҖАНСЫЗ** *с.* Дөньядагы барлык тере һәм тере булмаган нәрсәләр. *Тимер юл буендагы башка җанлы-җансыз нәрсәләр аның күз алдыннан бер-бер артлы тәгәрәп, егылып киткән шикелле булалар.* Ш.Камал

**ҖАНЛЫЛЫК** *и.* 1) Тере (исән) булу; җаны булу. *Бармак, тамыр өзелүдән, иң күбесендә, алты сәгатьтән соң җанлылык төсен югалта башларга тиеш иде.* Г.Камал. *--- монда ул – җансыз әйбергә җанлылык үзенчәлеген китереп кушкан.* Х.Курбатов

2) Актив эшчәнлек, үсеш, хәрәкәт. *Әле бик иртә булуга карамастан, һәр җирдә җанлылык хөкем сөрә иде.* Р.Мирхәйдәров. *--- яңарыш бигрәк тә 1905–1907 еллардагы инкыйлаб шартлары җирлегендә, татар тормышындагы җанлылык һәм үзгәрешләр нәтиҗәсендә бигрәк тә ачык төс ала.* А.Әхмәдуллин

3) Шау-шулы хәрәкәт, ыгы-зыгы, җанланыш. *Бүген безнең өй эчендә аерым рәвештә җанлылык бара, мине гадәттәгедән артык иркәлиләр, сыйпыйлар, мөмкин кадәр хөрмәт итәләр иде.* М.Гафури. *Палубада куанычлы бер җанлылык иде.* Ә.Еники. *Кибет каршында сирәк була торган җанлылык иде.* Р.Мөхәммәдиев

4) Табигыйлек, чын тормыштагыча булу хәле. *Кая карама анда җанлылык сизелә. Һәм рәссамның шулай реалистик планда тасвирлавы безне әнә шул дөньяга алып керә...* К.Нәфыйков. *Кави Нәҗми әсәрләренә хәрәкәт тизлеге, җанлылык, конкретлык, образлылык хас иде.* Казан утлары. *Бу мисаллардагы «тамак эшенә керешү», «бөгә башлау» кебек гади сөйләм элементлары сөйләмгә җанлылык өстиләр.* Мәдәни җомга

5) Үзеннән алдагы сүз белән бергә шул сүз белдергән сыйфатка ия булуны аңлата. *Илгәзәк табигатьле, якты чырайлы бу хәрәкәтчән чандыр гәүдәле кеше [Сәид Вахиди] чын зур галимнәрнең олы җанлылыгына, юмартлыгына ия иде.* М.Госманов. *Язучы фикерләвендә татарның ат җанлылыгы, ат дөньясы шулкадәр тулы чагыла ки, кешенең үзенә, үз тәне, үз хәяты белән бәйле төшенчә, күренешләр кебек үк, аның хисләрен тулыландыра, бизи.* И.Низамов

**ҖАНСАКЧЫ** *и.* Югары дәрәҗәле кешенең (мәс. патшаның, түрәнең, бизнесменның һ.б.ш.ның) иминлеген саклап, аны озатып, аның белән бергә йөрүче кеше, шәхси сакчы; тән сакчысы; *русчасы:* **телохранитель**. *Ләкин аны каяндыр килеп чыккан җансакчысы туктатты: – Киράкмәс, әмирем!* М.Мәһдиев. *– Ташбулат, җансакчы буласың киләме? – дип сорады хан малайдан.* Р.Батулла. *Көймәгә Сөембикә берүзе төште, җансакчыларына иярмәскә кушты.* Мирас

**ҖАНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Тере түгел, вафат булган, үлгән, үле. *Тагы берничә кеше булышып, җансыз гәүдәне өйгә таба күтәреп алып киттеләр.* К.Тинчурин. *Без килеп җиткәндә, ләкләк җансыз, җирне кочкандай канатларын җәеп, хәрәкәтсез ята иде инде.* Ә.Гаффар. *Әнисе ияр өстенә аркылы яткан, чәчләре асылынып төшкән, ике кулы, ат тилпенгән уңайга җансыз нәрсәдәй атына иде.* Г.Бәширов

2) Тере булмаган; җаны юк, тереклек дөньясына карамаган. *Ул аның калфак астында чем-кара сачының кара урмандагы җансыз күл кеби томрап торуыны карарга тотынды.* Г.Исхакый. *Бары тик радиалгычның яшел күзе генә аңа текәлгән, һәм шул җансыз күз, яшь койгандай, бер киңәя, бер кысыла иде.* М.Маликова. *Чебиләр, пипелдәшеп, аның артыннан йөгерә, туктагач, сөенешеп, кабат тупка сыеналар икән... Тик ул җансыз тупта нинди җылы тапты икән ныкайлар?!* Казан утлары

3) Тереклек иясе булмаган, тереклек яшәмәгән, бернинди җан иясе дә очрамый торган. *Сицилиядәге Үлем күле иң «җансыз» күл санала: аның яр буйларында һичбер үлән заты, суында бернинди тереклек юк. Димәк, аның исеме җисеменә туры килә.* А.Муранов

4) *күч.* Рухсыз, тонык, сүрән. *[Миңнулла] Җансыз күзләрен кара, җимерек идәнгә күңелсез генә текәп, бишмәтенә төренә-төренә, туңган шикелле калтыранып, [сүзен] дәвам итте.* А.Шамов. *Гыйззәтуллин инде күзләрен өметсезлек белән бушлыкка терәгән, --- аның күзләре – җансыз пыяла.* М.Мәһдиев. *Миңнегол тагын да ваемсыз, тагын да җансыз суык тавыш белән, матәм телеграммаларын тапшыра тора.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Мәрхәмәтсез, каты бәгырьле, кызгана белми торган. *Ямьсез, салкын, җансыз пароход, сыкрап елагандай, өч кабат кычкыртты да дустым Касыймны алып та китте.* Х.Сарьян. *Наилә, Нәҗип янына килеп баскач, дулкын-дулкын озын чәчен өскә чөйде һәм коры, җансыз тавыш белән сүзгә кереште.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Хәрәкәтсез, үлгән хәлдә. *Мостовойда җансыз яткан бу егетнең йөзе Сөләйманга таныш төсле тоелды.* К.Тинчурин

2) Хәрәкәт булмаган, туктап калган. *Тайга белән сахра кул биреште, Җансыз яткан дала җанланды.* Ә.Ерикәй. *Су буе шәп-шәрә. Елга үзәне, кибеп, җансыз булып караеп ята.* М.Галәү

◊ **Җансыз атка менү** Үлеп, җеназаң күтәрелү, табутта яту. *Үлем бирде җавапны буйлә картка: Адәмне менгезәмен җансыз атка.* Г.Исхакый. **Җансыз мал** Терлектән башка булган байлык (кыйммәтле ташлар, акча, алтын җиһаз, йорт-җир һ.б.). **Җансыз тынлык** Тулы тынлык, бернинди тавыш, хәрәкәт булмау хәле. *Бөтен тирә-*

*якта сәер, ят бушлык һәм җансыз тынлык хөкем сөрә.* Ә.Еники

**ҖАНСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Яшәүдән, тереклек итүдән туктау. *Яусаңчы бер, яу, яңгыр! Шаулап торган урманнар Ямьсезләнгән, корганнар, Җансызланган, үлгәннәр. Яу, яу, димен, яу, яңгыр.* С.Рәмиев

2) *куч.* Тынып калу, хәрәкәтсез калу. *Дала бермәлгә җансызланды*

3) Сүлпәнләнү, әкренәю, пассивлану (эш-хәл, тормыш агышы турында). *Анда тормыш җансызланган*

4) *куч.* Төссезләнү, сүнү. *Кызның кайчандыр янып торган күзләре җансызланганнар*

**Җансызлана бару** Җансызлыгы акрынлап арту, көчәя бару

**Җансызланып калу** Ниндидер бер сәбәптән, вакыттан соң җансыз хәлгә килү

**ҖАНСЫЗЛЫК** *и.* 1) Тынычлык; әкренлек. *Житмәсә, аның «авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем --- шау-шу яратучылыгымны, галәбәлек, көрәш сөючәнлегемне үчекләгән кеби булды.* Г.Тукай

2) Ашыкмаучанлык, сүлпәнлек. *Недоимкалар җыюда җансызлык күрсәтәсез.* Т.Гыйззәт

**ҖАНТАК** *и. бот.* Алсу төстә вак кына чәчәк ата торган, барлык өлешләреннән дә буягыч матдә алына торган куак; *русчасы:* **жидовник**

**ҖАН-ТӘН** *җый. и.* Кешенең булган бөтен барлыгы, рухы һәм тәне. *Юк, аның бөтен җаны-тәне моңа каршы тора, болай үлүне аның акылы сыйдыра алмый иде.* Г.Бәширов. *Укытучылары һәм баянчылары да – шул ук факультетны тәмамлаган, үзешчән сәнгатькә җанын-тәнен биргән, гомерен багышлаган Радик Нотфуллин.* Т.Галиуллин

◊ **Җан-тән белән** 1) Бөтен барлыгы белән. *Элеп киптергәндәй корышып беткән, тешсез, холыксыз тиле-миле Кортка бикәне Исәнтәй җаны-тәне белән яратмады.* Н.Фәттах. *--- егет аңа яратып карады, моны Зәйтүнә җаны-тәне белән сизде.* М.Хәбибуллин. *Сәгыйть Сүнчәләй җаны-тәне белән яңа идеологиягә турылыклы булуын эш белән расларга тырыша.* Мәдәни җомга; 2) Чын йөрәктән, бирелеп, ихластан. *Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм, Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.* Г.Тукай. *Бик яхшы урта мәктәп ачыла икән, мин моңа җаным-тәнем белән шатланам.* Ф.Хөсни. *Әйе, ул гади карак кына түгел, ул – фанатик, ат хайванын җаны-тәне белән яратучы кеше.* Ә.Еники

**ҖАН-ФӘРМАН** I *и.* Сугыш хәбәре, сугышка чакыру; сугышка мобилизация фәрманы

**ҖАН-ФӘРМАН** II *рәв.* 1) Бик кызу, зур тизлек белән. *Ул арада поезд, җан-фәрман чабып, Татарстан җиренә килеп керде.* М.Мәһдиев. *Мөнирә таудан җан-фәрман чабып төшкән исәпкә, күл читенә килеп, көч-хәл белән туктады...* Ф.Хөсни

2) Бар көченә, тырышып. *Бөтен кеше җан-фәрман эштә. Мондый чакларда безнең кәеф шәп инде.* М.Маликова

**ҖАН-ФӘРМАНГА** *рәв. к.* **җанфәрман** II

**ҖАНЫЙ** *и.* 1) *к.* **җанаш**. *Китә җаныем, китә җаныем, Китә җаныем Донбасска...* Җыр. *Ничек диелә әле халык җырында: «Сөяр булсаң, сөймә, җаный, үзеңнән түбәннәрне!»* М.Маликова

2) Кешегә карата дусларча яки нәрсәгә дә булса үз итеп әйтелгән эндәшү сүзе. *Минем тиле йөрәк тагын «дөпдөп...» Ә юк, дөпелдәмә кирәкмәскә, йөрәк җаный, ишектә гүпчи Габсаттар абзаң түгел, ишектә аның кызы, минем Биби-Газзәм.* Ф.Хөсни

**ҖАНЫШАК** *с.* 1) *диал.* Елак, көйсез. *Җанышак бала*

2) Үгет-нәсыйхәтле. *Җанышак тон*

3) Үгетләргә, акыл өйрәтергә ярата торган. *Җанышак әби*

**ҖАП** *и.* Таулар арасындагы тигез иңкүлек; тау итәгендәге тигез урын; тигез җирле калкулык. *Чәчәк үскән урын җап була.* Әйтем

**ҖАП-** *кис.* «Җ» авазына башланган «җайлы» сыйфатына ялганып һәм басымны да үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Ике кат укып чыксаң, хәтердә кала, җап-җайлы әсәрләр бит.* Ф.Яруллин. *Ә болай җап-җайлы килеп чыкты.* Ә.Баян

**ҖАПСАР** *и.* 1) Тигез җирдә кинәт текә күтәрелеп торган тау

2) *диал.* Эскерт, кибән

**ҖАПТАК** *с.* Тау астыннан кинәт тигезлеккә күчкән. *Җаптак җир*

**ҖАР** *и.* 1) Бар халыкка ишетелерлек итеп игълан ителгән хәбәр, өндәмә, чакыру. *Зур князьдән килгән илчеләр артыннан тагын бер «җар» яздырырга кирәк.* А.Таһиров

2) *фольк.* Балаларның кояшка, яңгырга, болытка һ.б. табигать күренешләренә карата такмаклап әйтә торган теләк, үтенечтән гыйбарәт җыр жанры. *Яңгырга карата түбәндәге җар әйтелгән: «Яңгыр яу, яу, майлы ботка бирермен, тәти кашык бирермен, Майлы ботка казанда, тәти кашык базарда!»* Такмак

◊ **Җар салу** Бөтен халыкка ишетелерлек итеп хәбәр итү, игълан итү. *«Гаделлек бу түгел!» – дип җар салыйммы?* Котб. *Дусты – юлбашчысы үтерелгәч тә, аның давын даулап, аның максатларын яклап, бу әсәре белән тарихка, мәңгелеккә җар салып калдырган.* М.Гайнетдин

**ҖАРИЯ** *и. гар.* Хәрәм йортында яшәүче яшь тол хатын-кыз, кәнизәк. *Аның тирәсендә – кунак сыйлаучы җарияләр, сарай хадимнәре.* Ф.Бурнаш. *Кыз, чыннан да, чибәр иде. Озын муены, яшь болан шикелле нәфис гәүдәсе әллә нинди затлы җарияләрне хәтерләтә иде.* Мирас. *Бу ике кыз җарияне сакларга, ул кая барса да, гел аның белән булырга тиешләр иде.* Казан утлары

**ҖАСУС** *и. гар. иск.* Шымчы, шпик, шпион, яшерен полиция агенты. *Өч ел үткәннән соң гына, беренче хәбәре килә: аны [Әхсәнне] «халык дошманы», «сатлыкҗан», «җасус» дип тапканнар һәм Магадан төрмәсенә озатканнар, шунда шахтада эшли икән.* Т.Галиуллин. *Кулларында кылыч-мылтык, яннарында җасус, шымчы, әләкчеләр, аяк чалучылар.* Р.Батулла. *Җасусларсыз власть булмый, дип, Гөлсаф тумачи күпме әйтте.* Б.Камалов

**ҖАСУСЛЫК** *и. иск.* Шымчылык. *Ә ул замана, белгәнебезчә, илдә*

*диссидентлык хәрәкәте колач җәя башлаган, шуңа күрә шымчылык, җасуслык хөкем сөргән ---, бигрәк тә миллиятлеккә караган өлкәләрдә сатлыкҗаннар өскә чыккан замана иде.* М.Госманов

**ЖА́У** I *и. диал.* 1) Май, туңмай, терлек мае

2) *күч.* Кешенең тышкы кыяфәтендә, киемендә күзгә күренеп торган эффектлылык

**ЖА́У** II *и. иск.* Яу. *– Әгәр бу дөрес булса, җир берлеген кан белән беркетсәк, кайсы яман бу ике илгә җау чыгарыр? – диде.* Г.Ибраһимов. *– Җау килеп калды! – дип кычкыруына, кәрванчылар, йокыдан уянып җитәрҗитмәс, сикереп аякка бастылар да, атылып, тышка чыктылар.* М.Галәү

**ҖАҺИЛ** *с. гар.* **1.** 1) Надан, белемсез. *Фәкыйрь булып та галим булмак, бай булып та җаһил булмактан артыктыр.* Имам Малик. *Нә файда, Галиәкбәр агай – никадәр бай булса да, шулкадәр җаһил бер адәмдер.* Ш.Мөхәммәдев. *[Колшәриф хәзрәтләре:] «Хаклык өстен чыгар, җаһилләр, наданнар рисвай кылыныр һәм хөкем ителер», – дип, изге сүзләрне мәҗлестә янә бер тапкыр кабатлады.* М.Хәбибуллин

2) Икейөзле, монафикъ. *Бермәлне гаепле кеше төсле югалып калдым. Липатникова җитәкләгән җаһил команда каршында да болай коелып төшкәнемне хәтерләмим.* Т.Галиуллин. *– Бу хәтле җаһил дә булырсың икән!.. – Нәгыйматтәй, ярсуына буылып, шуннан да артыгын әйтә алмады.* К.Кәримов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Хыянәтче, сатлыкҗан; юньсез кеше. *Юл озын, хәвефле, юлбасарлар белән очрашу куркынычы да бар. Хәер, ул җаһилләрнең матбагачылар алып бара торган йөккә бик исләре китмәс иде дип уйларга кирәк.* Мәдәни җомга

2) Көнче, көнләшүче. *Бәгъзе җаһил серең белсә, арттан төшәр, Хасидләр бәйләнергә әзер торыр.* М.Гафури

**ҖАҺИЛИЯТ** *и. гар.* 1) Наданлык, белемсезлек. *Казан (ханлык) тар-мар ителгән көннән бирле, татар дөньясында мәктәпләр системасы юкка чыгарыла. Төбәк караңгылык, җаһилият упкынына тарый.* М.Гайнетдин

2) Мәҗүсилек, исламгача булган дәвер. *Гарәп халкы арасында җаһилият заманында бәгъзы бер гадәтләр бар иде.* К.Насыйри. *Динсезлек, мәҗүсилек безне җаһилият дәверенә кайтарса, дин, иман безне илаһият чорына илтә.* И.Әмирхан

**ҖАҺИЛЛӘНҮ** *ф.* Икейөзлеләнү, монафикъланy, ярарга тырышу. *Сәлмән карт җәмәгать җыенында, старостаны, аның салымнардан кергән акчаны үзләштерүен акларга тырышып, бик төче телләнеп, җаһилләнеп сөйли.* Ф.Хөсни. *Алар кайтса, кайнана алмаштырып куйгандай үзгәрә --- андый чакларда кырыс һәм гадел холыклы Сафура «кара нинди җаһилләнә, йомры телен тасма итеп җәя бит бу җылан» дип уйлый иде.* Гөлшәһидә

**Җаһилләнә бару** Көннән-көн җаһиллеге көчәю

**Җаһилләнә башлау** Җаһилләнергә тотыну

**Җаһилләнә төшү** Бераз җаһилләнү; беркадәр җаһиллек күрсәтү

**Җаһилләнеп калу** Берәр эш-хәлдән соң җаһилгә әйләнү

**Җаһилләнеп китү** Кинәт җаһилгә әйләнү

**ҖАҺИЛЛЕК** *и.* Җаһил, надан кешегә хас сыйфатлар. *Бу, җаһиллектә тиңе булмаган, шөкәтсез язмалардан киләчәк дәвер галимнәре безнең турыда, «болар тел, имля, гореф-гадәт һәм иманнарыннан ваз кичкән манкортлар өере булган икән» дигән нәтиҗә чыгармаслармы?* Р.Әмирхан

**ҖӘБӘ** *и. иск.* 1) *тар.* Кыргый ат; токымсыз ат

2) Ялы күпереп торган, зур озын койрыклы тәбәнәк атлар токымы

3) *диал.* Арык ат

4) *диал.* Яшь ат, ябага. *Менмәгә бирсәң, җәбә бир – Тибенгедән тир чыкмас.* Дастан

◊ **Җәбә хәере** Ачлыктан нык ябыгып, язын күтәрәмгә калган ат

**ҖӘБӘЛӘЙ** *и.* Парад яки туй аты маңгаена куелган саплы җилфердек, каурыйлардан яки кылдан ясалган бизәк; *русчасы:* **султан**

◊ **Җәбәләй кебек кенә** Бик сыек (миллек, себерке һ.б.ш. турында)

**ҖӘББАР** *и. гар. иск.* 1) Зур көч, кодрәт иясе, Аллаһ. *Аздырырмын дөньяны, бел, җәббарым.* Ш.Бабич. *Бәлкем, Ходай биргән әкә... доганың, ялваруларның бөек җәббарга ирешүен --- күрергә тырышадыр.* И.Салахов

2) Җәберләүче, изүче, залим. *--- гакылы белән тәгъбир итеп җиткерә алмаса да, ул, эчке бер сизенү белән, ире Җәләлне хаксыз рәвештә үзенә гомер буенча хуҗалык итмәктә булган бер залим, бер җәббар кебек тоя.* Г.Ибраһимов

**ҖӘБЕ** *и. иск. к.* **җәбә**. *Җәбедән айгыр куймагыз – яуга менәр ат тумас.* Мәкаль

**ҖӘБЕР** *и. гар.* **1.** Изү, кыерсыту, золым. *Мин шуңа гаҗәпләндем: тоташ акылдан торган галәмдә каян туа икән сугыш, җәбер, сәясәт тәкәбберлеге шикелле акылсызлыклар?* М.Юныс. *Женя – балачактан ук Пахомовтан җәбер күреп үскән малай.* М.Насыйбуллин. *Күпме кимсетү, күпме мәсхәрә, күпме җәбер күрде минем кечкенә халкым?!* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Изү, кыерсытуга караган, золым итә торган. *Әтием дә гомере буена Кеше малын көтеп, Җәбер сүз ишетеп, Өйдән өйгә йөреп туенган.* Ф.Кәрим

◊ **Җәбер күрсәтү** Кемне дә булса кыерсыту, кимсетү; михнәт кылу. **Җәбер күрү** Җәберләнү, изелү. *Бу кадәр җәбер күргәнче, үләргә разыймын.* Г.Коләхмәтов. *Сихер бөтиеннән җәбер күргән һәр җан иясе ирек алсын.* Р.Хафизова. **Җәбер салу** Афәт, зыян китерү. *Юньле карак үз авылына җәбер салмый, ди бит!* Г.Бәширов. *Сау җаннарга нәфрәт, җәбер салып, Хәтерләргә сеңгән шул заман.* Ф.Шәех. **Җәбер тидерү** *к.* **җәбер күрсәтү**. *[Икенчесе] Һичберәүгә җәберен тидерми, һичбер хатын-кызны, өстерәп, зыр-зыр әйләндерми.* Ф.Әмирхан. **Җәбер тиерү** *к.* **җәбер күрсәтү**

**ҖӘБЕР-ҖӘФА** *җый. и. гар.* Һәртөрле җәбер-золым һәм җәфа. *Ул кычкырышырга, низаглашырга, адәмнәргә җәбер-җәфа салырга бик остар-*

*ган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Бу сүзләрне ишеткәч, күпме җәбер-җәфа күргәннән соң да кешелек сыйфатларын саклап кала алган бу зыялы әбекәйгә Габделнур хәйран калды.* Р.Кәрами

**ҖӘБЕР-ЗОЛЫМ** *җый. и. гар.* Һәртөрле кыерсыту, кимсетү, изү. *Үги ана белән торганда да, җәбер-золымнарны күп чиктем.* Д.Аппакова. *Андый [кушканны сукырларча үтәүче] кеше үз мәнфәгатьләрен яклый һәм үзен җәбер-золымнан саклый алмый, гаделсезлекләргә түзеп яшәргә дучар була.* Ш.Җәләлиев

**ҖӘБЕ́Р ИТҮ** *ф.* Җәберләү, кыерсыту, кимсетү. *Минем беркемгә дә җәбер итәр көчем юк.* Дәрдемәнд. *Мине язмыш сыный, әйтче, сиңа нинди җәбер иттем?* М.Җәлил

**ҖӘБЕ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **җәберләү**

**ҖӘБЕРЛӘНҮ** *ф.* 1) Кем тарафыннан булса да җәбер-золым күрү, изелү. *Җәберләнгән алар алпавыттан, Төрмәләрдә алар булганнар.* Н.Баян. *Бу эшкә ул, күрше-тирәләреннән җәберләнеп, йә булмаса бөтенләй тар-мар ителеп, ил-суларыннан куылып җибәрелгән --- кыпчак ыруларын кабул иткәч керешә.* М.Хәбибуллин

2) Хурлану, кимсенү, рәнҗү. *Оят, хурлык һәм бик нык җәберләнү хисе, ут ялкыны кебек, аның йөрәгенә һөҗүм итә, яндыра иде.* Ш.Камал. *Шуннан соң әти, бик сыкранып, җәберләнеп булса да, келәтне Арчаның Иван исемле сатучысына азык-төлек кибете ачарга бирмәкче булды.* Г.Бәширов

**Җәберләнә калу** Кинәт җәберләнү, җәбер тою. – *Сез китә-китә, әле монда ике кыш чыгарга булыр,* – *диде [Хатип]. Исмәгыйль бу сүзләргә җәберләнә калды.* Ш.Усманов

**Җәберләнеп алу** Бераз, аз гына җәберләнү. *Ибраһим эченнән хәтта җәберләнеп алды, чөнки бу сорау артына, кыюсыз гына булса да, шик-шөбһә яшеренгән иде.* Г.Бәширов

**Җәберләнеп килү** Күптәннән, элек-электән, дәвамлы рәвештә җәберләнү. *Россиядә яшәүче халыкларның күпчелеге – урыслар тарафыннан яулап, басып алынган, ничәмә-ничә гасырлар изелеп, җәберләнеп килгән халыклар бит.* Р.Мирхәйдәров

**ҖӘБЕРЛӘНҮЧЕ** *и.* 1) Җәбер-золым күрүче, мәзлум, изелүче. *Яман сүз белән кычкырып сөйләүне Аллаһ сөйми, мәгәр берәүгә хаксыз золым кылынса, ягъни җәберләнүче чарасыз булып залимгә каршы яман сүз әйтсә, гөнаһ булмас.* Р.Фәхреддин

2) Рәнҗетелгән кеше, кимсетү корбаны

**ҖӘБЕРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Изү, кыерсыту, җәбер-золым күрсәтү. *Моннан 4 ел элек тә кулаклар этлек эшләп ята иде, --- хәзер дә шулай ук ярлыларны җәберлиләр.* М.Әмир. *Нәтиҗә: империя хуҗалары да үзләрен кәккүк кебек тоталар, басып алган халыкларны җәберләү сәясәте уздыралар.* М.Әхмәтҗанов. *Үзенә файда булса, Лохмачев кешене җәберли дә, кимсетә дә ала.* М.Юныс

2) Рәнҗетү, кимсетү. *Ни өчен мин аны шундый начар сүзләр белән җәберләдем?* Р.Ишморат. *Шулай да болгарлар бортасларны җәберлиләр икән, аларга да усаллык белән җавап кайтарырга кирәк.* Т.Нәбиуллин

**Җәберләп бетерү** Барысын да җәберләү; бик нык җәберләү

**Җәберләп йөрү** Һәрберсен җәберләү, рәттән һәркемне җәберләү. *Бөтен мәктәп баласын кимсетеп, җәберләп йөри иде бит ул [Әнәс Килдеков].* В.Нуруллин

**Җәберләп тору** Даими, регуляр рәвештә җәберләү. *Анда, Византиядә, ясак җыючы дәүләт чиновниклары гади халыкны бертуктаусыз кыерсытып, җәберләп торалар...* Ф.Урманче. *Үги әнисе аны гел кыйнап, җәберләп тора.* М.Хәнәфи

**Җәберләп ташлау** Кинәт, көтмәгәндә җәберләү. *Хәтта кайберәүләр үзенә хәтер калдыргыч сүзләр ычкындырганда да, хәтта берәр усалрагы кайчагында җәберләп ташлаганда да, ул [Һарун], үзен яклап, берни эшләмәде.* Н.Фәттах

**Җәберли башлау** Җәберләргә тотыну. *Фабарисов моны хатынынннан күрде, балалары булмасын белгән көннән ул аны кага, җәберли башлады.* Ф.Бәйрәмова

**ҖӘБЕРЛӘҮЧЕ** *и.* Җәбер, мәрхәмәтсезлек күрсәтүче, каты күңелле кеше, залим. *Алабуга кызын җәберләүче әлегә табылмаган ---.* Шәһри Казан

**ҖӘБЕРЛЕ** *с.* 1) Рәнҗү катыш; үпкәләүле кыерсытылганлык, изелгәнлек сизелеп торган. *Җәберле тавыш белән сөйләү*

2) *күч.* Азаплы, җәфалы. *Фидакарь ант һәм катгый җаваплылык өчен, үз ризалыгым белән бу солых хакына чирканыч һәм җәберле бәлаләр алырга булдым.* К.Насыйри. *Тормышыгыздагы иң авыр, иң җәберле көнегез нинди көн, Хәсән абый?* Р.Батулла

**ҖӘБЕРЛЕК** *и. сир. к.* **җәбер**. *«Авылдашларың фалында да син [Кара Кул Хәбри] күрсәткән җәберлекләр...» – ди аңа Сабирҗан.* Р.Шәрәфиев

**ҖӘБЕР-МИХНӘТ** *җый. и. гар.* Һәртөрле кыенлык, изү, кимсетү. *Кайбер гөман кылулар буенча, Ильдико, үз халкы күргән җәбер-михнәтләр өчен Аттилладан үч алам дип, аңа кул сала.* Ф.Урманче

**ҖӘБЕРСЕНҮ** *ф.* Үпкәләү, рәнҗү. *Газизәнең чыраена, чынлап та, кәеф китү, җәберсенү күләгәсе төшкән.* Ш.Камал. *Карчык бу сүзгә шактый җәберсенде.* Г.Гобәй. *«Әти исән булса...» дигән уй кереп чыга Идриснең башына. Элек-электән, берәрсенә җәберсенсә, шулай була торган иде.* Л.Гыймадиева

**Җәберсенеп калу** Җәберсенгән халәткә килү. *Җәберсенеп калган чакларымда Кул сузасың миңа – малайга.* Х.Әюп

**ҖӘБЕРСЕТҮ** *ф.* Үпкәләтү, кимсетү, рәнҗетү. *Бу үз һөнәре белән горурланырга яраткан картны чиксез ачуландырды һәм җәберсетте.* Г.Әпсәләмов

**Җәберсетә төшү** Беркадәр җәберсетү; тагы да җәберсетү

**Җәберсетеп бетерү** Барысын да җәберсетү; бик нык җәберсетү

**Җәберсетеп җибәрү** Кинәт җәберсетү. *«Әллә миңа ышанмый башладыңмы?» Бу сүзләр Таняны җәберсетеп җибәрде.* Г.Әпсәләмов

**Җәберсетеп килү** Даими рәвештә, электән үк җәберсетү

**Җәберсетеп тору** Һәрвакыт, гел җәберсетү. *Хәмит белән сеңлесенә әтиләре барында караңгы чырай, явызлыгын күрсәтмәскә тырышса да, Зөбәрҗәт,*

*ул юкта, аларны гел тамактан аера, һәрвакыт кимсетеп һәм җәберсетеп тора иде*. З.Фәйзи

**ҖӘБРАИЛ** *и. гар. дини* Ислам динендә: Исрафил, Микаил, Газраил белән беррәттән дүрт олуг фәрештәнең берсе: Аллаһ тарафыннан пәйгамбәрләргә вәхи китерү белән вазифалы арадашчы фәрештә; Җибрил. *Җәбраил галәйһиссәлам Адәм галәйһиссәламгә өч нәрсә китерде: гакыл, хәя, дин*. К.Насыйри. *[Туташ] Каршында сүз ачарга батырчылык итә алмаган гашыйк өчен җәбраил бул!* М.Фәйзи. *Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре фәрештәләрнең олугларыннан Җәбраил галәйһиссәлам аша әмерләрен һәм сүзләрен пәйгамбәребезгә белдерде*. С.Поварисов

**ҖӘ́БРӘН** *рәв. гар. иск.* Ирексезләп, көчләп, мәҗбүри рәвештә. *Бармасаң, җәбрән бирермез*. М.Акъегет. *Галиәсгар әфәндене, җәбрән вә каһәрән өстерәп, сәхнә эченә атып, әллә ничә кәррә кулларына күтәрделәр*. Г.Тукай

**ҖӘВЕЗ** *и. гар. диал.* Әстерхан чикләвеге

**ҖӘВЕР** *и. диал.* 1) Бер оя; бер тума (кошлар, хайваннар)

2) Туган-тумача; нәсел. *Безнекеләрне «Җәнбәт җәвере – җиде табын» дип йөртteләр*. А.Хәсәнов

**ҖӘГЪРАФИЯ** *и. гар. иск. к.* **география**. *Җитәр инде, күп җырладык «Бакырган», «Йосыф китабы»н, җәгърафиядән дәрес алыйк, укыйк тарих һәм хисабын*. Ш.Мөхәммәдев. *Анда күңелсез. Җәгърафия дә укытмыйлар, туган телне дә*. Г.Бәширов

**ҖӘДВӘЛ** *и. гар.* 1) Таблица. *«Я» хәрефенә туры килгән цифрны ачыклау өчен җәдвәл төзибез*. Р.Нуруллин. *Бу сөйләнгән аваз үзгәрешләрен түбәндәге җәдвәлгә җыеп күрсәтергә мөмкин*. Г.Алпаров. *Европада, кешеләрнең туган вакытына карап, бу вакытта аны нинди агач саклавы турындагы урман җәдвәле төзегәннәр*. Татар милли педагогикасы

2) Эш расписаниесе, план. *Үзләре чөн төзделәр иң әүвәле мәңгелек тәфсилле «шайтан җәдвәле»*. Ш.Бабич

3) Дәресләр расписаниесе. *Хәзер күз алдыбызда Мәрҗанинең төрле вакытларда ул укыткан дүрт данә җәдвәле бар*. Ш.Мәрҗани

**ҖӘДИ** *и. гар. иск.* 1) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган йолдызлык атамасы һәм шул йолдызлыкның тамгасы; кәҗәмөгез йолдызлыгы

2) Кояш календаре буенча унике айдан торган йолдызлыкның 18 гыйнвардан 15 февральгә кадәр булган унынчы ае исеме һәм шул айда туган кеше; кәҗәмөгез

**ҖӘДИТ** *с. гар. иск.* **1.** 1) Яңа, яңача булган. *Җәдит карашлар*

2) Уку-укыту эшендә яңа булган, яңа метод белән эшли торган. *Монда байбәтчән ең хәятын начар якка борып йибәргән сәбәпләрнең мөһимрәге – аның, Сәхилә карчык фикере белән җәдит мәктәбеннән алынып, ниндидер кадим, бохара бер мәхдүмгә бирелүе булып чыга*. Г.Исхакый. *Ягъни Исмәгыйль хәзрәт татарның (якташы Хөсәен Фәезхановлар планын гамәлгә ашырып) җәдит мәктәпләренә кадәр үк мәктәп системасын яңарта башлаган алдынгы мәгърифәтчеләреннән берсе булган*. М.Гайнетдин

3) Яңалыкны, җәдитчелекне яклаучы, җәдитчелек тарафдары булган. *Мин түгел, ди, абзарауни һәм түгелмен, ди, җәдит*. Г.Тукай. *[Атасы] Казандагы җәдит байларга ияреп, аны Хөсәениягә укырга җибәрде*. К.Нәҗми

**2.** *и. мәгъ.* 1) Яңалык, яңачалык. *Мөхәррирнең бу өченче дәвердәге әсәрләрендә, «Инкыйраз»гача чыкканнарындагы кебек, милли тәрәккъый пәрвәрлек, җәдит һәм кадим көрәше дә --- юк*. Г.Газиз

2) *к.* **җәдитче**. *Кемдер – кадим, кемдер – җәдит, Кемдер кызгылт көрән. Үткән белән бәхәсләшеп, Яңа чорга керәм*. Г.Афзал

**ҖӘДИТЛӘНҮ** *ф. иск.* Иске ысулга үзгәреш кертергә омтылу; яңартуга, җәдитчелеккә омтылу. *Нәтиҗәдә, яңа иҗтимагый-фикри хәрәкәтләр кузгала, төрле яктан уянулар, яңару, җәдитләнүләр, реформаторлыклар башлана*. Татар театры

**Җәдитләнеп китү** Кинәт җәдитләнү. *Бу тиречеләрнең бөтен хәсрәте кадими ыштан һәм җиләнгә күңел баглау гына булса да, ахирел-әмер, шушы соңгы елларда җәдитләнеп китүләренә хәйран итәрлек иде*. Ф.Яхин

**ҖӘДИТЛЕК** *и. иск.* Җәдит булу, җәдитчелекне яклау. *«Кәләпүшче кыз», «Ике гашыйк», «Өч хатын берлән тормыш»тан «Инкыйраз»гача – монда да ул бәхет вә сәгадәтне җәдитлектә, яңа юл белән укуда күрә*. Г.Исхакый

**ҖӘДИ́ТЧӘ** *рәв. иск.* Яңача, җәдитчелек нигезендә, җәдитчелек карашларыннан чыгып. *Тукайның поэмасындагы бу сюжетны җәдитчә аңлату ясалма булачак*. М.Җәлил

**ҖӘДИТЧЕ** *и. иск.* Җәдитчелек тарафдары. *Аннан соң, кадим белән җәдит арасында нисбәт йөртеп, бәхет вә сәгадәтне соңгыда күрә килгән милли тәрәккъый пәрвәр җәдитче Исхакыйны бөтенләй югалтасыз*. Г.Исхакый. *1917 елда Диния нәзарәтенең үзенең дә җәдитче ислам эшлеклеләре кулына күчүен онытмаска кирәк*. Д.Исхаков

**ҖӘДИТЧЕЛЕК** *и. иск.* XIX йөз азагы, XX йөз башында мәктәпләргә реформа кертүне яклап чыккан иҗтимагый агым. *Боларның җәдитчелек пәрдәсе белән капланган күзләре борынгы кадим Көнчыгыш дәверендә туган әдәби җәүһәрләрне күрә алмыйлар*. Г.Ибраһимов. *Милли азатлык, җәмгыятьне яңарту өчен барган иҗтимагый хәрәкәттә яңа юнәлешләр – болгарчылык, җәдитчелек килеп чыга*. С.Алишев

**ҖӘЕЛДЕРҮ** *ф.* 1) Үстерү, киңәйтү; эшне алга җибәрү. *Башка бер спектакльдә режиссёр, сәхнә мәйданы белән генә чикләнмичә, тамаша залыннан файдалана, тамашаны сәхнәдә һәм залда җәелдерә*. Г.Арсланов. *Бу елларда ул --- күп җырлар, шигырьләр, поэмалар, опера либреттолары иҗат итә, тәнкыйть эшчәнлеген киң җәелдерә*. Татар әдәбияты тарихы

2) Төрле хәбәр, фикер, идея һ.б.ны күп кешеләргә мәгълүм итү, пропагандалау, тарату. *Без бу көрәшкә шулкадәр күнектек ки, сизмәстән, аны үзара мөнәсәбәтләргә дә җәелдердек...* Ф.Дәүбаш. *Ислам динен җәелдерү*

**Җәелдерә бару** Көннән-көн күбрәк җәелдерү. *Шул ук вакытта ул [Һади*

*Атласи] үзенең иҗтимагый һәм публицистик эшчәнлеген дә җәелдерә бара.* С.Алишев

**Җәелдерә башлау** Җәлдерергә тотыну. *АКШ, дөньядагы террорлык актларын сылтау итеп, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләр территорияләрендә үзенең агрессив курсын җәелдерә башлады.* К.Гыйззәтов

**Җәелдерә төшү** Беркадәр, бераз җәелдерү; тагы да җәелдерү. *Кагыйдә буларак, монда да Тукай Лермонтовта гомумиләштереп бирелгән деталь һәм мотивларны җәелдерә төшә, әсәрдәге фаҗига төсмерен көчәйтә һәм шигырьдә үзенең иҗади язмышын да чагылдыра.* Н.Хисамов

**Җәелдереп җибәрү** Тиз арада, кинәт җәелдерү. *Ул эшне җәелдереп җибәрергә өлгермәде – чираттагы призыв буенча Кызыл Армия сафларына китеп барды.* Г.Иделле. *Әнә бит кыска гына арада Чаллы Язучылар оешмасында нинди эш җәелдереп җибәрде.* М.Галиев

**Җәелдереп тору** Һаман, әледән-әле җәелдерү

**ҖӘЕЛЕШ** *и.* Таралыш, үсеш киңлеге, колач. *Әлбәттә, аның [пародиянең] тоткан урыны, табигате һәм җәелеш дәрәҗәсе төрле тарихи чорларда төрлечә була.* И.Нуруллин. *2006–2008 елларда киң җәелеш алган торак төзелеше бүген, туктамыйча, уңышлы дәвам итә.* Саба таңнары

**ҖӘЕЛМӘ** *и.* **1.** *махс.* Күпкырлыкның якларына тәңгәл булган күппочмакларның бер-берсенә кайбер кырлары белән тоташкан, бер яссылык өстендә яткан тоташ өлгесе. *Куб җәелмәсе*

**2.** *с. мәгъ. к.* **җәелмәле**. *Кайберәүләр, чатыр кормыйча гына, ачык һавада җәелмә карават, өрелмә матрас яки гамаклар урнаштыра.* Ватаным Татарстан

**ҖӘЕЛМӘЛЕ** *с.* Җәелә торган, җәелергә көйләнгән. *Аптыраган ата-аналар баласын хәтта җәелмәле караватта да йоклатырга риза, түбә астына гына кертсеннәр.* Ватаным Татарстан

**ҖӘЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **җәю**. *Электр китерде, газ китерде колхоз, кешеләр әнә шифер, калай түбәле өрьяңа өйләргә – радиолары, телевизорлары булган, идәннәренә келәмнәр җәелгән өйләргә керделәр...* Ф.Хөсни. *Хәзер могҗиза ясыйм! Тылсымлы ашъяулык, җәел!* М.Маликова. *Дымны үткәрмәү өчен, шлак өстенә цемент эремәсе салына, ә аңа, битум белән сылап, өч кат рубероид җәелә.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

2) Үсеп, зураеп, тирә-якка таралу, зур урын алу. *Каһирәдә 5 миллионнан артык кеше яши, ул һаман үсә, җәелә.* М.Юныс

3) Агып, саркып чыгу, билгеле бер урынны тоташ каплау. *Менә Волжск тирәләре. Су диңгез булып җәелгән.* И.Низамов

4) Бөртекле, вак яки сыек әйберләр, юка катлам булып, тирә-якка таралып яту. *Күренеп тора: йорт борынгы, бигрәк тә аскы таш подвалы, ишегалдына җәелгән зур ак ташлары, капка төбенә яңа гына кисеп аударган йөзьяшәр тирәге...* Ф.Бәйрәмова. *--- [инешнең] язгы ташу вакытында суы күтәрелеп, ярларының ике ягына да җәелә.* К.Миңлебаев

5) Яктылык, караңгылык, төтен, ис, томан кебек күренешләр тирә-якка таралу, бөркелү. *Дөнья яктырган, күлдән күтәрелгән сыек кына ак томан һавага җәелә.* Г.Ибраһимов. *Кичке эңгер җәелгәндә, бүлмә кинәт караңгыланып китте.* Т.Әйди. *Ә шәһәр өстенә тыныч төннең зәңгәрсу кара канаты җәелгән.* М.Маликова

6) Ян-якка киң булып үсү, тармаклану. *Түбән җәелеп үскән колачларын карлар баскан чыршы төбендә, ак халатын киеп, кеше ята.* Ш.Маннур. *Лапас түбәсе төсле киң булып җәелгән карагай төбенә урнаштык.* М.Әмир

7) Йомшап, изрәп киңәю, таралып китү; җәенкеләнү. *--- мәктәп белән фатир арасында йөргәндә генә аяк өшерлек түгел, җәелгән киез итекне мич башына ыргытып, аякка биек үкчәле, яннан биш-алты төймә тезелгән, җылы эчле драп галош алып кидем...* Ф.Хөсни. *Ершовны танырлык түгел, ул симез бер урыс мужигына әйләнгән, --- чәчләр аксылга әйләнгән, иреннәр бөрелгән, бит җәелгән...* Ф.Бәйрәмова

8) Ерακларга сузылу, иркен җирне биләү. *Кара Идел буйларына кадәр җәйләүләре җәелгән.* М.Хәбибуллин. *Бүлгәләмик уртак тарихыбызны, ул – Урал таулары кебек биек, кыпчак далалары кебек киң, Татар бугазыннан Каф тауларына хәтле җәелгән иксез-чиксез Татар Иле, Нугай җире...* Ф.Бәйрәмова. *--- июль айларында Пугачёв явы гаять зур территориягә җәелә.* В.Имамов

9) *күч.* Киң таралу, активлашып китү. *Мәдрәсәләрдә тарихи төс алган вакыйгаларга карата бәетләр чыгару, китап күчереп язу эшләре җәелә.* С.Алишев

10) *күч.* Эчке хисләр, кичерешләр чырайда чагылу, йөзгә таралу. *Теге дә тәрәзә янында торган хуҗаны шәйләп алды, ахрысы, тук йөзенә елмаю җәелде, нидер кычкырып, кул изәп куйды.* Р.Зәйдулла

**2. җәелеп** *рәв. мәгъ.* 1) Иркенләп, тартынмыйча, озаклап. *Ят малай, китү түгел, киресенчә, җәелебрәк утырды.* Ф.Яруллин. *Әгәр дин башында көчле иманлы тәкъва кешеләр – әмирләр торса, ислам диненең шушылай җәелеп эшли башлавы безнең өчен куанычлы гына булыр иде, без, ниһаять, милләтебезне коткарып калырдай иң зур көчне күрер, тояр идек.* Ф.Бәйрәмова. *Кил, җәелеп, рәхәтләнеп сөйләшергә. Йөрәгеңне учка салып серләшергә.* М.Хөсәен

2) Киң булып, таралып. *Юлыбыз чәчәкле болыннар, сөзәк тау битләре, җәелеп аккан Кубань елгасы буйларыннан үтә иде...* Ф.Бәйрәмова

3) Иркенәеп, сузылып. *Ята җәелеп Шүрәле читлек эчендә.* Р.Зәйдулла

**Җәелә бару** Торган саен ныграк җәелү. *Аурышкан урманы өстеннән күтәрелгән күгелҗем калын болыт, торган саен җәелә барып, авыл өстенә агыла башлады.* Г.Бәширов. *Яктылык көчәйгәннән-көчәя барды, өскә, югарыга күтәрелә барды, як-якка җәелә барды һәм берзаман бөтен шәрекъ ягын биләп алды.* Н.Фәттах

**Җәелә башлау** Җәелергә тотыну. *Билгеле инде: мондый җирдә һәртөрле сәүдә, коммерция эшләре аеруча кызу үсә һәм җәелә башлый.* Ә.Еники

**Җәелә төшү** Беркадәр, бераз җәелү; тагы да җәелү. --- *кырыгынчы еллар башында Садри Ахунның иҗат активлыгы тагын да җәелә төшә.* Казан

**Җәелеп бетү** Бөтенләй җәелү, тулысынча җәелгән булу. *Артык киемнәрен өстеннән салып, инде җәелеп беткән түшәк өстенә сузылды.* М.Әмир. *Башка күпчелек авылларга асфальт җәелеп беткән булса да, Юлыкка аны сузып өлгермәгәннәр.* Ф.Фәтхи

**Җәелеп килү** Акрынлап, аз-азлап җәелү. *Эңгер-меңгер куерып, караңгылык пәрдәсе җай гына җәелеп килә.* Р.Мулланурова

**Җәелеп китү** 1) Кинәт җәелү. *Алардан соң шомыртлы, баланлы, миләшле урман тугае, әрәмәлекләр җәелеп китә.* С.Поварисов. *Инешкә җитәрәк, ул бөтенләй дә җәелеп китә, сулары да саега.* К.Миңлебаев. *Кинаяле елмаю бөркелгән иреннәре җәелеп китәр дә, колак төбендә шаркылдап көлгән тавыш ишетер сыман.* Р.Зәйдулла

2) Иркенләп, тартынмыйча, озын итеп сөйләү. *Шуңа күрә, артык җәелеп китмичә, ниләр булганын гына әйтәсем килә.* Ә.Еники. *Валя алардан үзен, ничектер, өстен куя, тегеләр дә аның белән уртак сүз таба алмыйлар, мәктәптә өйрәнеп тә, инде онытыла башлаган урыс сүзләре җәелеп китеп сөйләшерлек түгел иде инде.* Р.Зәйдулла. *Ширияздан Сарымсаковның кечкенә истәлеге белән таныш ул. Сак язган, җәелеп китмәгән.* Ф.Сафин

3) Иркенәю, башка эшләрне, мәшәкатьләрне хәтердән чыгару. *«Язгы кыр эшләре вакытында халыкның вакытын алмыйча, иртәрәк башлап, бик җәелеп китми генә уйнагыз», – дип, артистларны кисәтеп куя председатель.* Д.Гыйймранова

**Җәелеп тору** Әле, хәзерге вакытта як-якка җәелгән хәлдә булу. *Өстенә бөркәнгән җиңсез плащы, бөркет канатларыдай, як-якка җәелеп тора, башында кокардалы офицер фуражкасы.* Ф.Яруллин. *Яран гөлнең алсу чәчәклесе иде бу, ямь-яшел яфраклары тыгыз булып, нык булып җәелеп тора.* Р.Батулла

**Җәелеп яту** Әле, хәзер, күз алдында җәелгән хәлдә булу. *Эшкә бара колхоз батырлары, Җәелеп ята иркен басулар.* Ә.Фәйзи. *Түбәндә, киерелә биреп, очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп ята.* Ә.Еники. *Кул сузымы җирдә җәелеп яткан күл көзгедәй ялтырый, урман артында исә биек ак ташпулатлар тезелешеп киткән.* Т.Әйди

**ҖӘЕМ** *и. иск.* 1) Бер тапкыр кулдан сугу өчен җәелгән көлтәләр тезмәсенең микъдары (үлчәү берәмлеге буларак). *Борчакны ике җәем сугалар да ашарга кирәргә җыеналар болар.* Әкият. *Актык җәемне сугып бетерәбез дә, кулларга сәнәкләр алып, салам селкергә керешәбез.* М.Гали

2) *к.* **җәймә**. *Бер җәем токмач белән туй үтми.* Мәкаль. *Каяндыр ак он юнәтеп, сөттә генә изеп, өч йомырка сытып, майга баскан камырдан ике җәем токмач турады.* М.Хәсәнов

3) Кибәргә таратып салынган бөртекле ашлык. *Кояш күзенә таратылган кызгылт сары бодай җәеме янында Мәүлиха түти белән Әпипә, берәмлекләп, бодай чүплиләр.* М.Әмир

**ҖӘЕН** I *и.* Җәеннәр семьялыгыннан, шома тәнле, киң авызлы, зур башында берничә пар озын мыегы булган, төче сулыкларда яши торган тәңкәсез эре ерткыч балык; *русчасы:* **сом**. *Ул Сакмар буеның болынлыгын, таллыгын күрсәң!.. Сакмар суы терекөмештәй саф. Җәеннәре бар...* Х.Сарьян. *Чабак күп кенә ерткыч балыклар – чуртан, судак, җәен, алабуга өчен азык булып тора.* И.Рәхимов. *Алар, үзләренең озын саплы, эче куыш итеп ясалган мутавычлары белән шапы-шопы суга бәреп, тирән җирләрдә качып яткан җәеннәрне куркытып чыгаралар. Беренче булып, кара сыртлы, ишкәк койрыклы көймә хәтле җәен күзгә ташлана.* Ф.Яруллин

**ҖӘЕН** II *рәв.* Җәй көнендә, җәйге вакытта. *Җәен чана әзерлә, кышын арба әзерлә.* Мәкаль. *Капкадан кергәч, рәссам ак келәткә таба атлады. Әнисе исән чакта, анда җәен аш-су әзерлиләр иде.* Р.Зәйдулла. *Ләтчә, сезонга карап, төсен үзгәртә: җәен коңгырт җирән төстә, кышын – ак.* И.Рәхимов

**ҖӘЕНКЕ** *с.* 1) Яссы, тупыйк. *Әле аның тез буыннары калтырый, аяклары ачыган йоннан басылган җәенке киез катаны чак кына өстери иде.* Ф.Әмирхан. *Гарифулланың киң җәенке йөзендә бу юлы мескенлек чагыла иде.* А.Расих

2) Тирә-якка таралып үскән, киң ябалдашлы, тармакланып торган. --- *дежур торучылар урман авызындагы җәенке ябалдашлы карама башыннан утрау каравылына сәгать саен кесә фонаре белән якты күрсәтергә тиешләр иде.* А.Тимергалин

3) Аркылыга киң булып җәелгән, киң. *Җәенке кашлар*

4) Киңчә, яссы, җәелебрәк торган. *Василий Степанович, яшькә кырык тирәсе булуына карамастан, гәүдәгә безнең студент шикелле чандыр, тик биткә генә таза, борыны да бераз җәенке иде.* Х.Сарьян. *Әни бервакытны: «Атаңның куллары корычтыр», – дигән иде. Миңа аның кулларының корычы --- ялтырап, шомарып торган җәенке бармак битләрендәдер кебек күренә.* Г.Бәширов. *Алкаланып, колак артларына төшкән куе аксыл чәче дә, ап-ак муены да, хәтта аз гына җәенкерәк борыны да – барысы да аңа тулаем бер сөйкемле йомшаклык биреп тора кебек.* Ә.Еники

5) *лингв.* Баш кисәкләрдән тыш иярчен кисәкләре дә булган. *Иярчен кисәкләре булу-булмауга карап, җөмләләр җыйнак һәм җәенке җөмләләргә аерылалар.* Ф.Сафиуллина

6) *мат.* 90° тан 180° ка кадәрле булган. *Җәенке почмаклы өчпочмакта бер почмак җәенке, калганнары кысынкы була.* Геометрия

7) *куч.* Эчкерсез, шатлыклы. *Аларның йөзендә һәрвакыттагыча җәенке елмаю балкый иде.* Р.Зәйдулла

**ҖӘЕНКЕЛӘНДЕРҮ** *ф. лингв.* Җәенке хәлгә китерү, өстәмә җөмлә кисәкләре белән тулыландыру. *Җыйнак җөмләләрне җәенкеләндерү*

**Җәенкеләндерә төшү** Берникадәр җәенкеләндерү

**Җәенкеләндереп карау** Җәенкеләндерергә омтылу

**Җәенкеләндереп кую** Җәенкеләндергән хәлгә китерү

**ҖӘЕНКЕЛӘНҮ** *ф.* Җәелеп китү, җәенкеләнгән хәлгә килү. *Мондый ка-*

*бат ясалулардан мәгънәләре ягыннан катлаулы һәм аваз составлары ягыннан артык җәенкеләнгән сүзләр килеп чыга.* Г.Алпаров

**Җәенкеләнә бару** Торган саен ныграк җәенкеләнү. *Шунысын искәртеп узарга кирәк: төзелеше җәенкеләнә барган саен, мәкальләрдә кабатланып килгән сүзләрнең дә саны арта бара.* Г.Нәбиуллина

**Җәенкеләнә төшү** Беркадәр, бераз җәенкеләнү; тагы да җәенкеләнү

**Җәенкеләнеп бетү** Тоташ җәелеп китү; бөтенләй җәенке хәлгә килү

**Җәенкеләнеп калу** Ниндидер сәбәптән соң җәенкегә әйләнү

**Җәенкеләнеп килү** Акрынлап җәенке була бару

**Җәенкеләнеп тору** Җәенке хәлдә булу, шул торышта булу

**ҖӘЕНКЕЛӘ́Ү** *ф.* Җәю, җәенке итү, җәенке хәлгә китерү

**ҖӘЕНКЕЛЕК** *и.* 1) Җәенке булу. *Акыллы булу өчен маңгай җәенкелеге генә җитми.* Әйтем

2) Җәелеп яткан урын, киңлек. *Бу тармакның боргаланып аккан урынында берничә җәенке култык бар... Күптән инде, бик күптән бу җәенкелекләрнең берсендә ялгыз бер имән агачы утыра.* Г.Минский

**ҖӘЕН-КЫШЫН** *рәв.* Елның-ел буена; җәен дә, кышын да. *Урманнарда меңәр еллык карт наратлар, чыршылар, җәен-кышын яшәреп, шаулашып утыралар.* Г.Ибраһимов. *Җәен-кышын бергә уйнап, бергә укып үскән иптәш малайлар искә төште.* Г.Бәширов. *--- ятим шәкерт, үзенең хәлфәсенә самавыр куеп, аш пешереп, җәен-кышын шул мәдрәсәдә яши биргән.* Ә.Еники

**ҖӘЗА** *и. гар.* 1) Гаеп эш яки җинаять эшләгән кешегә карата кулланыла торган йогынты ясау чарасы. *Нәрсә ул шелтә? Үз вөҗданыңа хыянәт итүдән күп җиңел җәза бит ул.* А.Расих. *Әмир хаҗи баш күтәргән ташчыларга җәзаны үзе бирде.* М.Хәбибуллин. *Минемчә, мең чиновникның даими җәзасына дучар булып торганчы, бер гадел хөкемдарга тугрылыклы булып калу мең тапкыр артыграк.* Ф.Урманче

2) Үтерү, һәлак итү, үч алу; физик газап. *Аннан ул, үлем җәзасыннан котылган кешедәй, безгә балкып килеп керде: егетемә бронь биргәннәр, ул заводта калачак!..* Ә.Еники. *--- белешмәдә «Алкин И.С. хөкем җәзасын үтәгәндә, 1939 елның 4 маенда үлгән» дип язылган була.* Казан утлары. *Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагеренә яба һәм, газаплаулардан соң, үлем җәзасына хөкем итеп, 1944 елның 4 сентябрендә үлем карарын гамәлгә ашыра.* Казан утлары

3) Бәла-каза, тормыштагы авыр күренеш, азап, рухи газап. *Дошманның аз эшенә кайгы тартма! Һәр бәндә үз җәзасын үзе табар.* М.Гафури. *Бел, Зөһрә, бу эшеңнең иң зур җәзасы минем башыма төшәчәк. Бөтен хурлыгы миңа булачак...* Ә.Еники. *Без кылганнарның, безнең хаталарның җәзасын ала сабыйлар.* М.Маликова

◊ **Җәзага тарту** Гаеп эш өчен җавап бирергә мәҗбүр итү, йогынты ясау чарасын куллану. *Әлбәттә, кайбер каракларны тотканнар, --- аларны җәзага тартканнар һәм тарихи тыюлыкны ныграк саклый башлаганнар.* Ф.Бәйрәмова. *Бер сәгатьтән соң инде ул – әлеге кенәз – җәзага тартыла, аны аяк-кулларыннан агач тәрәгә кадаклап куялар.* Ф.Урманче. *Кыерсытучыны ничек җәзага тартырга соң?* Хайваннар дөньясы. **Җәзасын тартсын** «Җинаятенең тиешле җәзасын күрсен» дигән мәгънәдә әйтелә. *Миңа каршы килүчеләр кодрәтле Сәлим морзаның каһәре аркылы җәзасын тартсын!* М.Фәйзи

**ҖӘЗА́ БИРҮ** *ф. к.* **җәзалау**. *Табынны, ниндидер гаепләре өчен, балаларга җәза бирү урынына әйләндермәскә, бәлки, эштә, укуда булган уңышлар, борчыган мәсьәләләр турында әтиәни, апа-абыйлар белән сөйләшү-киңәшү урыны итәргә кирәк.* А.Хәсәнова

**ҖӘЗАЛАНУ** *ф.* 1) *төш юн. к.* **җәзалау**. *Җәзаланган кешеләрне тәрәгә кадакланган килеш калдырып, халыкны куып тараткач кына, Винитар король кайтыр юлга чыкты.* М.Хәбибуллин. *Бераз вакыт узганнан соң, бу кабих җанның үтерелгән, җәзаланган, яндырылган мәетен табалар.* Р.Батулла

2) Интегү, җәфалану, азаплану. *Иртәдән бирле ашамаган-эчмәгән, эшендә җәзаланган хатынның тамагына төер тыгылды ---.* Н.Көбәш

**ҖӘЗАЛА́У** *ф.* 1) Гаеп эш эшләгән өчен җәзага тарту, җәза бирү. *Сабый чактан ук төрле йолаларга --- ышанган Сәлим хан, оста Дәүран гомере – чынлап та, үзенең гомере, дип уйлап, иң алдан җәзаланырга тиеш кешене йолып калды.* М.Хәбибуллин. *– Саламны рәхәтләнеп урлыйлар, берәрсен тотып, бүтәннәргә сабак булсын өчен җәзаларга кирәк, – диде Солтан.* А.Расих

2) Физик газаплау. *Әйе, фашистлар ерткычларча җәзалаган вакытта да түзгән ул батыр кыз.* А.Әхмәт. *Аталары камышлыкта гөрес-гөрес үрдәкказ атса, бот хәтле игезәкләр эт-мәче җәзалап кул шомартты.* Н.Гыйматдинова. *Лефортово һәм Лубянкада җәзалап үтерелгәннәрдән аермалы буларак, ул урынга исән-сау – тере кешеләрне китерә торган булалар.* Казан утлары

3) Бәла-каза җибәрү, зарар китерү. *Ходай Тәгалә ни гөнаһ шомлыгыбыз аркасында болай җәзалый торгандыр инде безне?!* Ф.Әмирхан. *Ходаем, нинди генә гөнаһларым өчен җәзалыйсың икән мине?* Г.Галиева

**Җәзалап алу** Берара җәзалау; аз гына җәза бирү

**Җәзалап бетерү** Барысын да җәзалау; бик күп төрле алымнар белән җәзалау

**Җәзалап тору** Даими рәвештә, бертуктаусыз җәзалау

**Җәзалый башлау** Җәзаларга тотыну. *Хәзер дә становой пристав, окружной начальник, волостнойлар, поплар белән авылларыбызга килеп, безне төрлечә җәзалый башладылар.* С.Алишев

**Җәзалый бирү** Җәзалауны дәвам итү, һаман да җәзалау

**ҖӘЗАСЫЗ** *рәв.* Тиешле җәзасы билгеләнмичә, җәзага тартылмыйча. *Изгелекнең дә әҗере бар, җинаять тә җәзасыз калырга тиеш түгел кебек.* Сөембикә. *Әмма җәзасыз калган җитәкче тагын башкаларга да кул күтәрмәс дигән ышаныч юк.* Мәдәни җомга

**ҖӘЗАСЫЗЛЫК** *и.* Җәзасыз калу, җәза бирелмәү күренеше. *Җәзасызлык тәртипсезлек тудыра.* Ватаным Татарстан. *Ә бүген, дөнья буталып, асты өскә килгән бер чорда, гомумән дә җәзасызлык хөкем сөрә кебек.* Татарстан яшьләре

**ҖӘЗАЧЫ** *и.* Җәза бирүче яки җәзалауда катнашучы кеше. *Хәтта җәзачыларга атуны да аның [Асылгәрәй хәзрәт] нәселеннән, аның балаларыннан шикләнделәр, тик кем атканын барыбер таба алмадылар.* Ф.Бәйрәмова. *Юл уртасын олаулар алган, --- юл читеннәнрәк җәзачылар, карательләр атлый.* Казан утлары

**ҖӘЗБӘ** *и. иск.* Циркуль. *Әнвәр өстәлгә алсу кәгазен җәеп, готовальнясын ачып куйды. Кызыл бәрхет эчендә ак тимер җәзбә, каләмнәр елкылдап ята иде.* М.Маликова. *Бер шәкерт кулдан ясалган җәзбә белән шәмаил сыза.* М.Галәү. *Кунак кыз белән әни чәйгә киткән арада, мин, җәзбә белән сызып, карандашлар белән төрле төскә буяп, хат башын ясап та алдым.* Г.Бәширов

**ҖӘЗБӘР** *и. иск. к.* **җәзбә**. *Сызылыр әйләнә җәзбәр чәнечкәч, Гөләп чәчәк атар чәнечке үскәч.* Котб

**ҖӘЗИРӘ** *и. гар. иск.* Утрау, атау. *--- ахшам якын булдык вакытда, көймәм бер гәрдабка тугыры килеп, көймәм әйләнеп-әйләнеп бер тарафка ук кеби атылып, бер җәзирәгә барып чыкты.* Ф.Халиди. *Ихлас дәрьясында йөзсен безнең караб, китсен тугры гыйрфан җәзирәсен карап.* Г.Тукай

**ҖӘЙ** *и.* 1) Елның яз белән көз фасыллары арасында килә торган иң җылы вакыты; ел календаренда июнь, июль, август айлары. *Яңа күлмәк киеп, җәйләр җитә!.. Бер мин генә иске күлмәкле!* Н.Измайлова. *Мең тугыз йөз егерме өченче елның коры җәй башлары иде.* Ф.Хөсни. *Чәчәкләр алар – җәй хәбәрчесе.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Гомернең җитлеккән, өлгергән иң матур чагы. *Ә кайда соң безнең җәйләр? – Алдамы, артта микән?* Н.Измайлова. *Гомеремнең җәй уртасы, Чәчәкләре тере әле. Тик юк инде өмет гөлем, ачылмаган бөреләре.* Х.Мөдәрисова

◊ **Җәйгә чыгу** Җәй башлану, җәй җитү. *Җәйгә чыккач, буш вакытын гел шунда [бакчада] чокчынып үткәрде.* И.Гази. **Җәйдә – сусыз, кышта агачсыз калу** Елның ике сезонын да бернинди әзерлексез каршы алу. **Җәйнең җәй буена** Җәйнең башыннан алып ахырына кадәр; бөтен җәй буена. *Шулай итеп, без бабай белән җәйнең җәй буена көтүдә йөрдек.* М.Галәү

**ҖӘЙГЕ** *с.* 1) Җәй көне була торган, җәй көненә хас булган. *Җәйге төннең гадәтенчә, төн бераз салкын икән.* Г.Тукай. *Җәйге яңгыр килә төньягыннан. Вакыт-вакыт дымсу җил бәрә.* Г.Хуҗиев. *Әгәр җәйге эссе көнне, кырда яки болында йөргәннән соң, караңгы чыршы урманына килеп керсәң, шунда ук салкынча, дымлы һаваны сизәсең.* И.Рәхимов

2) Җәй көне кия торган. *Өстендә ак ефәктән җәйге костюм.* Ә.Еники. *Ләйсирә җиңел җәйге халаттан гына.* М.Вәли-Барҗылы. *Частьтагы хәрбиләр җәйге формага күчкәннәр инде.* С.Шәрипов

3) Җәй көне, җылы вакытта тору, ашарга пешерү өчен җиңелчә материалдан төзелгән. – *Китәбез инде, абый, китәр вакыт җитте... – Җәйге дачадан күчеп китүче таныш түгел кыз әйтә моны.* Ш.Галиев. *--- сугыштан соңгы бишьеллыклар чорындагы ярлы гына җәйге лагерьларда учак якканда, бергә җыелып утырган дуслар кайларда да, кайсысы кем булган, аларның язмышлары нинди...* Р.Мирхәйдәров

**ҖӘЙГЕЛЕК** *с.* **1.** Җәй өчен билгеләнгән, җәй көне файдаланыла торган. *Фатиры булмаса да, җәйгелек бакча сатып алды.* Ф.Җамалетдинова

**2.** *и. мәгъ.* Җәй вакыты, җәйге көн. *Җәйгелектә күп сәяхәт итү*

**ҖӘЙГОР** *и. диал.* Салават күпере. *Ачык дәрес бирә бүген дөнья... Чишмә чыңы күккә үрелә. Туган җирем, Мең төсмере белән, Җәйгор булып җанга чигелә.* Р.Газизов. *Ул зәңгәр һаваны күрә, төрле төсләргә буялганлыктан, җиргә төшкән җәйгорны хәтерләтеп торган йортларны күрә.* М.Кәбиров. *Күзгә урман, яфракларын манып, Агачларда җәйгор кабындыра.* Н.Әхмәдиев

**ҖӘЙЛӘВЕК** *и. диал. к.* **җәйләү**. *Әнә теге Идел буеннан күренеп торган яшел болыннар елкылар өчен менә дигән җәйләвек булганнардыр.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ҖӘ́ЙЛӘТӘ** *рәв.* Бөтен җәй буена, җәй көне. *Укучылар җәйләтә әти-әниләренә кыр эшләрендә булыштылар*

**ҖӘЙЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **җәйләү**

2) Җәен терлекләрне авылдан читтә, яшел азык мул булган җирдә тоту, шунда көтү. *Эре мөгезле терлекне җәйләтү ит-сөт продукциясен җитештерүгә сизелерлек уңай йогынты ясый*

**Җәйләтеп карау** Җәйләтү омтылышы ясау, җәйләтүне сынау. *Быел фермерның терлекне җәйләтеп карау исәбе бар*

**ҖӘЙЛӘ́Ү** I *и.* 1) Күчмә халыкларның җәйге тору урыны. *Ә бит ерак җәйләүләрдән йөреп кайтканда, йөгереп каршы чыгар иде дә: «Исән-имин кайттыңмы, Йосыф җаным!» – дияр һәм кочагына иңәр иде.* М.Хәбибуллин. *Әлбәттә, бер баруда мин аларның барысында да була алмадым, әмма кайчандыр төрки ханнарның җәйге җәйләве булган «летняя ставка»га барасы килү теләге калды...* Ф.Бәйрәмова

2) Билгеле бер кабилә кешеләре тупланып яши торган урын. *Ил-җәйләвең кай тарафта иде, баһадир?* М.Хәбибуллин

3) Җәй айларында терлекне утлату өчен, болында яки урман аланында киртәләп алынган махсус корылма. *Авылыбызның язын котлап уңыш бирде Бу ел иген кыры, печән җәйләве дә.* М.Җәлил. *Җәйләүләрдә тугай, Тугайларда тургай Канатларын җилпи җиллләрдә.* И.Юзеев. *Мөкәррәмә җәйләүдән кайтып кергәндә, кунаклар барысы да китеп беткәннәр, сыерлар көтүдән кайткан иде.* А.Расих

4) *геогр.* Өслеге тигез булган зур яссы калкулык; *русчасы:* **плато**. *Кырым җәйләве*

**ҖӘЙЛӘ́Ү** II *ф.* Җәйне табигать кочагында уздыру, шәһәрдән читтә, җәйге өйләрдә яшәү. *Тауда җәйләп, ташта үскән, агай-энедән башка үскән.* Табышмак. *Талларым, кырларым, кошларым! Мин сездә күпме җәй җәй-*

*ләдем, Мин сездә күпме кыш кышладым.* Р.Вәлиев. *Тыныч җәйли алмам җәйләрне.* Ш.Җиһангирова

2) Йорт хайваннарының болында яки урман аланында утлавы. *Ялгыз җәйләгән куй – бүрегә җим.* Мәкаль

**Җәйли башлау** Җәйләргә тотыну. *Иделнең уң ягына чыгып җәйли башладылар.* М.Хәбибуллин

**ҖӘЙЛЕК** *с.* 1) Җәй буена җитәрлек. *Җәйлек азык әзерләү*

2) *к.* **җәйгелек**. *Җәйлек өс-баш. Җәйлек өй*

**ҖӘЙЛИ** *рәв. диал. к.* **җәен**. *Җәйли печән чапмадым, Бөрлегән өзеп капмадым.* Җыр. *Аларның уенча, без бит җәйли һөҗүм итә белмибез.* И.Гази

**ҖӘЙМӘ** *и.* 1) Урын-җир өстенә җәелә торган ярма, простыня, түшәк ярмасы. *Мәгъсүм кроватенда ак җәймә өстендә чалкан ята.* З.Һади. *Анна Ивановна Динәнең өстенә җәймә япты да, баш очына килеп, битенә суккалады: – Диночка, Диночка, уян инде!* М.Маликова. *Ак мунча, зат мунча – хәтфә ярмалары, крахмалланган җәймәләре, сөлгеләре, кирәксенгән кешегә – сырасы, зильтерски куасы белән.* Ф.Хөсни

2) *күч.* Җиңел, юка ярма. *Галимҗан ай нурында аның кара толымнарын бер үрә, бер сүтә иде... Аннан аларны, җәймә итеп, Айсылуның ак тәненә каплый иде.* Ф.Бәйрәмова. *Хәтта төрле яктан калкып чыккан атлар да, ай нурына манчылып, турысы булсын, карасы булсын, юка гына көмеш җәймә бөркәнгән төсле булып күренәләр иде.* Г.Бәширов

3) Ашъяулык, өстәл ярмасы, эскәтер. *Инде минем авыздан вәгъдә ычкынгач, Нәҗип безнең өйгә иң кадерле кеше булып йөри башлады. Ак җәймә җәеп кенә каршы алмыйлар иде аны.* Ә.Еники

4) Токмач кисәр өчен, юка итеп җәелгән камыр. *Аннары токмач җәймәсе кадәр марля алып, шуңа сары ревонол агызды.* Х.Камалов. *Бер җәймә токмач кисү*

5) *диал.* Ачы яки төче камырдан юка итеп, табага җәеп пешерелгән камыр азыгы; табикмәк. *Әни җәймә пешерә, ул каймак белән бигрәк тә тәмле була.* *Кыстыбый җәймәсе*

6) *иск.* Япкыч, ярма, чаршау һ.б.ш. *Әни алып килгән модалы пальто, җәймәгә төрелгән килеш, чөйдә тик эленеп тора, иске бишмәтем өстеннән шәлемне урыйм да йөри бирәм.* Ф.Хөсни

7) Гөмбә һәм кайбер үсемлекләрдә була торган элпә. *Шампиньонның җәймәсе – алсу, аннан шәмәхә төскә керә, ә аксыл гөмбәнең җәймәсе юк, эшләпәсе өске яктан яшькелт төстә була.* И.Рәхимова. *Гади бөркет канатының [абаганың бер төре] спорангийлары яфрак җәймәсенең читендә урнаша һәм аска бөтерелеп тора.* И.Рәхимова

◊ **Җәймә итү** Җәймә кебек җәелдереп, авызны зур ачып елау. *[Кави] Урам буйлап, авызын җәймә итеп Елый-елый кайтты өенә.* Һ.Такташ

**ҖӘЙМӘЛЕК** *с.* **1.** Ярма итеп кулланырлык; җәймә тегәргә җитәрлек. *Электән гадәтләнгәнчә, бәйгедә җиңүчегә җәймәлек тукыма бүләк иткәннәр*

**2.** *и. мәгъ.* Бер җәймәгә җитәрлек тукыма

**ҖӘЙМӘН** *и. диал.* Урын-җир, ятак. *Кече улымның кәләше бар иде. Аны харап иттеләр, хәзер мескен бала тора алмый, җәймәндә ята.* Казан утлары

**ҖӘЙПӘК** I *с. сөйл.* Җәенке, яссы. *Кайсылары, су өстен салмаклатып, ярышып, җәйпәк таш аталар.* З.Ярмәки. *Шулчак йорт урыны кадәр җәйпәк боз Нәбиулла бабасын каплагандай булды.* А.Хәлим. *Шаһ илендә җәйпәк ипи пешерәләр, ипине ул анда ашарга өйрәнде, ә менә табын тутырып торган калын калачны беренче тапкыр авызына кабуы иде.* М.Хәбибуллин

**ҖӘЙПӘК** II *и. диал.* Чәй тәлинкәсе

**ҖӘЙПӘКЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Җәелеп китү; җәйгән хәлгә килү. *[Шмарь] Битен җәйпәкләндереп, борын тишекләрен дерелдәтте.* Н.Дәүли

**ҖӘЙПӘКЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Җәйпәк, яссы итү, җәю

**ҖӘЙРӘН** *и.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан, матур сынлы, җитез кыр кәҗәсе. *Бу тирәдә, күрәсең, җәйрәннәр һәм сайгаклар бар иде.* Н.Фәттах. *Фәттах җәйрәнгә генә хас җитезлеге белән нык аерылган Торсынбайны туган энесе кебек якын күрә, ярата иде.* Ф.Кәрим. *Тик бу елмаюда шундаен гаярьлек, тәкәбберлек, горурлык, бирелгәнлек күрде ки, хан кызы икенче мәлдә аучы каршына килеп чыккан җәйрән кебек сискәнеп китте.* М.Хәбибуллин

**ҖӘЙРӘТҮ** *ф.* Җәю, җәеп кую. *Ул, минем гаҗәпләнүемне күргәч, кесәсеннән чаршау хәтле бер газета чыгарып җәйрәтте.* Ш.Камал

**ҖӘЙРӘ́Ү** *ф.* 1) Җәелеп ташу, киңәеп агу. *Әнә безнең Сакмарыбыз ничек җәйрәп ага.* Г.Гомәр

2) Киң булып җәелеп яту, киңлеге, зурлыгы белән аерылып тору. *Җәйрәп йоклый кырлар-басулар, Йоклый күлләр-сулар...* М.Шабаев. *Өлгергән алмалар, хөрмәләр, күл тутырып җәйрәп чәчәк аткан төнбоеклар була.* М.Хәбибуллин. --- *авыллар, бәрәңге кишәрлекләре, алмалары тулышып килгән бакчалар, түтәлләрдәге гөлләр – һәммәсе кайнар кояш астында җәйрәп, яшәешнең һәр күзәнәктән тулып ташыган тантанасы булып, күкрәп утыралар.* М.Маликова

**Җәйрәп яту** Җәйрәгән хәлдә булу. *Тирбәндереп якты уйларымны, Җәйрәп ята данлы, киң илем.* Ә.Ерикәй. *Пароходлар йөри торган мул сулы дүрт елгасы, --- таулары һәм урманнары, тугайлары һәм чишмәләре белән, Татарстан җире илебезнең уртасында, кояшка күкрәген киереп, җәйрәп ята.* Ф.Хөсни. *Хәзер минем кулымда мәгълүмат күп иде, авыл үзе дә, аның тарихы да минем күз алдымда җәйрәп ята иде.* Ф.Бәйрәмова

**ҖӘЛӘК** *и. диал.* Хатын-кыз йөзен яшерү өчен, кием өстеннән киелә торган ябынча; бөркәнчек

2) Җиңсез өс киеме; жилет, камзул. *Зур үлчәмле җәләк*

**ҖӘЛЕ́П ИТҮ** *ф.* 1) *Дикъкать, игътибар* сүзләре янында килеп, игътибар бирергә, кызыксынырга мәҗбүр итү. *Минем игътибарымны революция вакыйгаларын һәм гражданнар сугышын чагылдырган материаллар аеруча җәлеп иттеләр.* Ә.Еники. *Шигърият иленә кергән тәнкыйтьчеләребезнең*

*теге яки бу әдипкә карата ничаклы объектив булуы, бәяләрдәге логик эзлеклелеге, стилистикасы, терминологиясе һ.б. сыйфатлары игътибарны җәлеп итә.* Р.Әхмәтҗанов. *Әйе, шәехнең игътибарын җәлеп итә алмады Сөембикә.* М.Хәбибуллин

2) Нинди дә булса эшкә тарту, үзенә карату. *Шул фикернең дөреслеген тикшерү өчен, Тухачевскийны Кронштадт фетнәсен бастырырга җәлеп ителгән көчләргә командующий итеп билгелиләр.* З.Зәйнуллин. *Шәһәрне яшелләндерү эшенә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү*

3) Үзенә тартып тору. *Суы – мәхәббәт утында янучыларга дәва биргән, башка шәһәрләрдә яшәүчеләрне дә җәлеп иткән данлыклы Мәхәббәт чишмәсе* М.Юныс. *Патша тавы бик зур булып, ераклардан үзенә җәлеп итеп тора.* Ф.Бәйрәмова

**ҖӘЛЕ́П КЫЛУ** *ф. к.* **җәлеп итү**

**ҖӘЛЛАД** *и. гар.* 1) Үлем җәзасын башкаручы; палач. *Ак патша бар, аның түрәләре бар, түрәләрнең кылычлары, камчылары, җәлладлары бар.* М.Гали. *Мин тез чүкмәм, җәллад, синең алда, Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.* М.Җәлил

2) *күч.* Бик явыз, рәхимсез, мәрхәмәтсез кеше. *Каенанасын күрә төшләрендә, җәллад булып килә каршына.* М.Укмаси. *Яшерен комиссия җәлладлары тарафыннан кыйный-кыйный сорау алынган, әмма, җәза бирелмичә, иреккә чыгарылган.* В.Имамов

**ҖӘЛЛАДЛЫК** *и.*1) Җәллад вазифасы

2) *күч.* Рәхимсезлек, миһербансызлык, мәрхәмәтсезлек. *Бигрәк тә Казан епископы миссионер Лука Канашевич үзенең ерткычлыгы, җәлладлыгы белән нык аерылып тора.* М.Сәхәпов

**ҖӘЛПӘЙТҮ** *ф.* Җәлпәк итү, җәлпәкләндерү

**Җәлпәйтеп бетерү** Барысын да җәлпәйтү; тәмам җәлпәйгән хәлгә китерү. *Бакыр чөйләрнең очларын җәлпәйтеп бетерү*

**Җәлпәйтеп кую** Җәлпәйгән хәлгә китереп калдыру. *Алюминий чыбыкның очын җәлпәйтеп кую*

**ҖӘЛПӘК** *с.* 1) Башы, очы яссыланып, бераз гына яньчелеп торган. *Янәшәдәге каравылчы өе алдында бәйгә куелган бияләйдәй җәлпәк борынлы, уклау сыйраклы, шома йонлы эт аларга усал гына ырылдап калды...* Т.Әйди

2) Биек булып очланып тормаган, җәенке формалы. *Икенче матур йортның түбәсе җәлпәк.* М.Юныс. *Фәнни-техник революция гадәти кораб архитектурасын чәлпәрәмә китереп ташлаган: корабның койрыгы – җәлпәк; корылманы түгәрәкләп, җыйнаклап азапланмаганнар...* М.Юныс

◊ **Җәлпәк авыз** 1) Ямьсез, зур авызлы кеше; 2) Сер тотмаучы кеше

**ҖӘЛПӘКЛӘНҮ** *ф.* Җәлпәк хәлгә килү, җәлпәк форма алу

**Җәлпәкләнә төшү** Беркадәр, бераз җәлпәкләнү, тагы да җәлпәккә әйләнү

**Җәлпәкләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җәлпәкләнү; барысы да җәлпәкләнү

**Җәлпәкләнеп калу** Җәлпәкләнгән хәлгә килү

**Җәлпәкләнеп тору** Җәлпәкләнгән хәлдә булу; җәлпәк булып күренү

**ҖӘЛПӘЮ** *ф. к.* **җәлпәкләнү**. *Баш арты кыйшайган, «кыяр» кебек сузылган, җәлпәйгән кешеләр бар.* Үзең нинди, көзгең шундый. *Юраның озын чәче баш артының җәлпәйгән булуын капласа, Вадимның баш арты сузынкы икәне әллә кайдан «кычкырып» торачак.* Үзең нинди, көзгең шундый

**Җәлпәеп бетү** Тәмам, бик нык җәлпәю. *[Мортаза бабайның] Өстендә озын җиңле ак күлмәк, җиңсез кыска бишмәт, башында җәлпәеп беткән түбәтәй.* Г.Әпсәләмов

**Җәлпәеп калу** Җәлпәйгән хәлгә килү

**Җәлпәеп тору** Җәлпәйгән хәлдә булу

**Җәлпәя бару** Торган саен ныграк җәлпәю

**Җәлпәя башлау** Җәлпәюгә табан үзгәрү

**Җәлпәя төшү** Бераз җәлпәю

**ҖӘЛТ** *рәв.* 1) Бик тиз, ялт кына. *Машина тагын җәлт кенә кузгалды.* А.Гыйләҗев. *Үзем язам, үзем теге кунакның миңа текәлеп утыруын да тоям. Әледән-әле җәлт кенә күз дә төшереп алгалыйм тегеңә.* Ф.Баттал. *Һич кыстатмыйча, [малай] үзе сикереп тора, беркем искә төшермичә, битен-кулын юа, табынга җәлт килеп утыра...* Ф.Хөсни

2) Җәһәт кенә; бик тиз, кызу-кызу. *Без, студия егетләре, җәлт кенә акча җыештык, яңа фатирга күченүчеләргә карават, өстәл, радиоалгыч алдык.* А.Хәсәнов

◊ **Җәлт иткәнче** Бик тиз, күз ачып йомганчы. *Хезмәтчеләр ашамлык өелгән подносларны, жонглёр осталыгы белән тотып, җәлт иткәнче тиешле бүлмәгә илтеп тапшыралар.* А.Расих.

**Җәлт итеп** *к.* **җәлт иттереп**. **Җәлт иттереп** Тиз генә. *Җәймәне бер якка алып ташлады, җәлт иттереп, идәнгә сикереп төште.* А.Гыйләҗев

**ҖӘЛТЕН-ҖӘЛТЕН** *рәв.* Тиз-тиз, әле бер ягы, әле икенче ягы белән ялтырап, җемел-җемел килеп. *Фото икесенең дә кулыннан ычкынды да, җәлтен-җәлтен әйләнгәләп, идәнгә таба очты.* М.Әмир

**ҖӘЛТЕРӘП** *рәв. диал.* Тиз генә, җәлт итеп. *[Карт] Куе куак төбеннән җәлтерәп чыкты да, ди, егетне кочаклап еларга тотынды, ди.* Әкият

**ҖӘЛТ-ҖӘЛТ** *рәв.* Бик тиз, җәһәт, кызуланып, ялт итеп. *[Стрельцов] Тротуардан җәлт-җәлт атлап бара.* И.Гази. *Шәмсия карчык, --- гөнаһлы җирдәнераграк булуың хәерле дигәндәй, урыныннан кузгалып, таякка таянып, җәлт-җәлт, автобус тукталышына атлады.* Ф.Имамов. *[Самат] Баш төзәтергә дип, «бурычка» бераз акча алды да, җәлт-җәлт атлап, үз юлы белән китеп барды.* Ватаным Татарстан

**ҖӘМАЛ** *и. гар. иск.* Матурлык, гүзәллек, чибәрлек; йөз матурлыгы, матур йөз. *Мәхәббәт җәмал теләмәс.* Мәкаль. *Аһ, җәмалыңны күрергә җан күрер күзләр кирәк; Гыйшкыңны тасвирда Коръәннән гали сүзләр кирәк.* Г.Кандалый. *Гөл җәмалы берничә көндә кичәр.* С.Сараи

**ҖӘМӘГАТЬ** *и. гар.* **1.** 1) *к.* **җәмгыять** (*1 мәгъ.*). *Колхоз-совхозлардагы партия оешмалары бүгенге авыл кешеләрендә күренә башлаган шәхси*

*мәнфәгатьне җәмәгатьнекеннән өстен кую, җиңел юллар белән яшәргә маташу, эчүчелек кебек яман чирләр белән нык көрәшергә тиешләр.* И.Низамов

2) Нинди дә булса бер максат белән берләшкән оешма, мәнфәгатьләре уртак булган кешеләр төркеме. *Шулай, эчемлек сата алмыйсыз! Җәмәгать җыены рөхсәт итми.* Г.Бәширов. *Безнең илдә һәр милләт кешесе үз телендә белем алырга, җәмәгать оешмаларында сөйләшүләр алып барырга һәм җыелышлар уздырырга хокуклы.* М.Әхмәтҗанов. *Җәмәгать урыннарында, кибеттә дә, автобуста да, урамнарда да туган телебездә сөйләшүчеләрне еш очратасың.* Мәдәни җомга

3) Бер урында бергә яшәүче халык, кешеләр төркеме. *Җәмәгать бу яңа кибеттә аракы сатмагайлары дип шикләнә.* Г.Бәширов. *– Бүген җыелышта сүз нәкъ ферма турында барачак, җәмәгать алдында ярып сал, әйтәсе сүзләрең булса, – диде.* Ф.Хөсни

4) *сир.* Аерым бер гаилә кешеләре, өй кешеләре. *[Гали] Кочегар булып хезмәт итеп, җәмәгатьләрен тәрбия кыла иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Бөтен өй җәмәгате чәй эчәргә утырды: иң түргә – йөз яшьлек Зөһрә әби, --- икенче ягына Патый карчык утырды.* М.Галәү

5) Кемнең дә булса хатыны. *Халикъ абыеңның хәләл җәмәгате булам.* Ш.Камал. *– Бүректән дә бигрәк, өйдәгеләр: инәең, җәмәгатең, бала-чагаң белән сөйләш, – дип, аның уйларын белгән кебек өстәп куйды секретарь.* Ф.Хөсни. *Элегрәк Урта Азия төрәләренең күпчелегенең җәмәгате татар милләтеннән иде.* Т.Галиуллин

6) *махс.* Кайбер термин һәм тотрыклы сүзтезмәләрдә «халык исеменнән», «халыкка мөнәсәбәтле», «халык файдасына» һ.б.ш. мәгънәләрне белдергән беренче кисәк буларак кулланыла (мәс., *җәмәгать башлангычы, җәмәгать гаепләүчесе, җәмәгать эшлеклесе*). *Бүген бит нарсудта бер «шома егет» тарафыннан көчләнгән Нәфисә эше карала. Мин анда җәмәгать гаепләүчесе булып катнашам.* Т.Гыйззәт. *Безгә мәгълүм булганча, күренекле татар галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре Шиһабетдин Мәрҗани, Мөхәммәтрәхим Юнысов, Хәсән Акчурин, Галимҗан Баруди кебек затларның бермәтекләп җыйган кульязма китаплары, сәнгать әйберләре һ.б., ияләре үлү белән үк диярлек, таралып юкка чыккан-нар.* М.Әхмәтҗанов

**2.** *энд. сүз функ.* Бер урында җыелган кешеләргә мөрәҗәгать итү сүзе буларак кулланыла. *Сәвит өе бусагасына үтә иртә килеп, озак көттерерлек булмагыз, җәмәгать.* Ф.Хөсни. *Кемнеңдер башына төплерәк уй килде: «Җәмәгать, чиләккә генә сыймый моның суы. Зуррак савыт кирәк, бидоннарны алып килик».* К.Кәримов. *Аннан соң гына сабыр, колакка ук ятышлы салмак тавыш белән: – Йә? Хәлләрегез ничек, җәмәгать? – дип сорап куяр иде.* Мирас

◊ **Җәмәгать эше** Милли, сәяси, мәдәни, һөнәри һ.б.ш. ихтыяҗларга бәйле рәвештә, төп хезмәттән тыш, түләүсез, үз ихтыяры белән алып барыла торган эш. *Мин [Галия] җәмәгать эше буенча Елга аръягы эшчеләре арасына йөрдем.* Г.Кутуй. *Ул Каргалыда һәм Кабулда дини белем ала, гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белә, атасы Ибраһим Тынкачев кебек, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша.* Ф.Бәйрәмова

**ҖӘМӘГАТЬЛӘНДЕРҮ** *ф. сир.* Кемне дә булса өйләндерү, җәмәгатьле итү. *Менә Мостафа иптәшне җәмәгатьләндерәсез булыр, мөгаен, шулай.* Ш.Камал

**ҖӘМӘГАТЬЛӘНҮ** *ф. иск.* Җәмәгатьле булу; өйләнү. *Ниһаять, мин дә җәмәгатьләндем бит, дуслар, бик озак сайлана торгач ---.* Мәдәни җомга

**ҖӘМӘГАТЬЛӘШТЕРЕЛҮ** *ф.* Җитештерү средстволары иҗтимагый милеккә әйләндерелү. *Мал-туарлар җәмәгатьләштерелгән, ләкин Мохтар бабай элек үзенеке булган атны бик нык күзәтеп йөри.* Һ.Такташ

**ҖӘМӘГАТЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Җитештерү тармакларын берләштерү, җитештерүне иҗтимагый формага кору; коллектив хуҗалык оештыру. *Вак крестьян хуҗалыкларын җәмәгатьләштерү*

2) Матди милекне, транспорт чараларын һ.б. әйберләрне, бергәләп файдалану өчен, гомумхуҗалык милкенә әверелдерү. *Урманнарны җәмәгатьләштерү. Сулыкларны җәмәгатьләштерү*

**Җәмәгатьләштерә башлау** Җәмәгатьләштерергә керешү

**Җәмәгатьләштереп бетерү** Җәмәгатьләштерүне тәгәлләү, барысын да җәмәгатьләштерү

**Җәмәгатьләштереп йөрү** Хәзерге вакытта җәмәгатьләштерү белән шөгыльләнү

**ҖӘМӘГАТЬЛӘШҮ** *ф.* Билгеле бер төр әйберләр (эш кораллары, терлек-туар, җир һ.б.) гомумхалык милкенә әйләнү

**ҖӘМӘГАТЬЛЕ** *с.* 1) Җәмәгате, хатыны булган, өйләнгән. *Арада Корбангали генә җәмәгатьле иде.* Ш.Камал. *– Сабир җәмәгатьле бит ул хәзер, безнең ишеләр белән бик сөйләшеп тә тормас, – диде шунда кызларның берсе.* Казан утлары

2) Гаиләсе булган, гаиләсендә күпмедер кеше булган. *Менә, ниһаять, сәфәр чыгар көннәр дә якынлашты. Беренче булып, аз җәмәгатьле гаиләләр кузгалырга булды.* М.Галәү

**ҖӘМӘГАТЬЛЕК** *и. сир.* Берәүнең җәмәгате, хатыны булу. *Кыз әйтә: «Әгәр кабул итсәң, мин сиңа җәмәгатьлеккә барыр идем, ал син мине», – ди.* Әкият

**ҖӘМӘГАТЬЧЕ** *и. сир.* Җәмәгать эшләрендә катнашучы, җәмәгать эшләрен башкаручы. *Мәктәп елларында ук оста җәмәгатьче булып танылган иде Мостафа.* Казан утлары

**ҖӘМӘГАТЬЧЕЛ** *с.* 1) Гаилә жанлы, үз гаиләсен кайгыртучан. *Ә менә олы улым, киресенчә, бик җәмәгатьчел булып чыкты.* Юлдаш

2) Ачык күңелле, аралашучан, җәмәгатьне, компанияне ярата торган. *Җәмәгатьчел холкы һәркемне үзенә тарта*

**ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК** *җый. и.* 1) Җәмгыятьтә иҗтимагый фикерне чагылдырган һәм җәмәгать тормышында актив катнашкан, яңалыклардан хәбәрдар булган алдынгы катлау. *Сәбәп тирәндәрәк ята: хикмәт шунда ки,*

*Әбүбәкер абзый да, Әминә апа да – тарихи шәхесләр. Татар халкының чын зыялылары, киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм кешеләр.* Ә.Еники. *1985 елда җәмәгатьчелек Тукайның йөз еллык юбилеена әзерләнә башлады.* М.Мәһдиев. *Мөхәммәд пәйгамбәр турындагы бу китап җәмәгатьчелектә киң яңгыраш ала.* Мәдәни җомга

2) Җәмгыятьнең аерым бер катлавы; уртак эшчәнлекләре, шөгыле, һөнәре яисә кызыксынулары, бердәм мәнфәгатьләре белән берләшкән кешеләр даирәсе. *Бүген Казан медицина җәмәгатьчелеге арасында шундый сүзләр ишетергә мөмкин иде.* Г.Әпсәләмов. *Синең сүзең кирәк, Нәкый... Әнә шул Мәскәү язучылар җәмәгатьчелегенең Пастернакка карата чыгарган карары белән килешәсеңме, юкмы?..* Ә.Еники. *--- әдәби җәмәгатьчелек тәнкыйтьнең торышыннан беркайчан да канәгать булмады.* М.Вәли

3) Киң катлау, бар халык, күпчелек. *Процент шаукымы үз-үзебезне генә алдау түгел, азак килеп, бөтен ил җәмәгатьчелеге алдында күз буяу икәнлеген исбатлап күрсәтегез.* Б.Камалов. *Барысы да – тәрбиядән, Хәлил абый, тәрбиядән. Ата-ана тәрбиясеннән, мәктәп тәрбиясеннән, җәмәгатьчелек тәрбиясеннән.* А.Шамов. *Төп максат, әлбәттә, Русия һәм дөнья җәмәгатьчелегендә ислам һәм мөселманнар турында дөрес, гадел фикер тудыру.* Идел

**ҖӘМӘЛӘН** *и.* Емельян Пугачёв исеменнән фонетик үзгәреп, сөйләмдә кулланылган вариант

◊ **Җәмәлән явы** 1) Исәпсез-хисапсыз, бик күп. *Ай-вай-вай-вай! Җәмәлән явы да бу төсле үк булмагандыр.* Х.Сарьян; 2) Бар нәрсәне тар-мар итәрлек көч

**ҖӘМГЫ** *и. гар.* 1) *мат.* Кушу, кушу гамәле. *Бу җиде кеше эчендә, --- гыйльме хисаптан дүрт гамәлнең җәмгыдән башкасын белүче булмаган шикелле, русчаны да адрес язу дәрәҗәсеннән артык белүче юктыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Алдыгызга китерегез: шәкерт [һәм] зыялы. Ике арасына галәмәте җәмгы куегыз [шәкерт+зыялы].* Ф.Әмирхан

2) Барысы, бөтенесе

**ҖӘМГЫ́ БУЛУ** *ф. иск.* Бергә җыйналу, җыелу, җыелышу. *Шунда картлар җәмгы улып киңәштеләр.* Г.Тукай

**ҖӘМГЫСЫ** I *а. иск.* Барысы бергә, бөтенесе. *Хатын да үзем, янә бер кәҗә. Җәмгысы өч баш.* Г.Бәширов. *Аннан соң тагы ун буын теркәлгән, җәмгысы 46 буын.* Ф.Бәйрәмова

**ҖӘМГЫСЫ** II *и. лингв. иск.* Күплек (саны)

**ҖӘМГЫЯТЬ** *и. гар.* 1) Яшәеш барышында конкрет тарихи шартларда берләшкән халык. *Тел җәмгыятькә бәйле һәм җәмгыять үсеше өчен гаять әһәмиятле.* Ф.Сафиуллина. *Гаилә – җәмгыятьнең үзе кебек үк, бик борынгы иҗтимагый институт ул.* М.Әхмәтҗанов. *--- җәмгыять тормышына хатын-кызны катнаштыру кирәклеге танылa.* Г.Исхакый

2) Билгеле уртак максатлар белән оешкан берләшмә. *1901 елда Гаяз әфәнде, якын дус-ишләре белән берлектә, «Шәкертлек җәмгыяте» дигән яшерен җәмгыять оештыра, һәм бу җәмгыять «Тәрәккъый» гәзитәсен чыгара башлый.* Ф.Әмирхан. *«Ватан» җәмгыятенең оештыру конференциясендә, чит илләрдәге татарлар белән элемтәне ныгыту өчен, алар белән яңалиф графикасында элемтә тоту кирәклеген мин күтәреп чыккан идем.* Ә.Кәримуллин. *Лингвистик җәмгыятьне без үзебезчә «И туган тел» җәмгыяте дип атый алыр идек...* Мәдәни җомга

3) Уртак эшчәнлек, билгеле бер тоткан урыны, бердәй чыгышы, мәнфәгатьләре нигезендә берләшкән кешеләр төркеме. *--- бүгенге Россия матбугатында «яңа русларның» кенәз, Россия дворяннары җәмгыяте члены булуы (дөресрәге, бу исемне сатып алуы) турында хәбәрләр күренә.* Я.Шәфыйков

4) *иск.* Җыен; митинг. *Шәкертләр тавышыннан шау-гөр килеп торган бүлмәгә керү белән, Вәли мулла, ачуланып: «Бу нинди рөхсәтсез җәмгыять тагын?!»–дип кычкырды.* Казан утлары

5) *сөйл. к.* **җәмәгать**. *Ул шулай сөйләп килде дә бөтен җәмгыять өстенә акырды.* Г.Ибраһимов

**ҖӘМГЫЯ́ТЬ КЫЛУ** *ф. иск.* Бергә җыелу, оешу, мәҗлес кору. *Мондый бәйрәм көннәрендә җәмгыять кылмак бер-бер мәхәббәт итешмәгә һәрбер мәдәни милләттә, һәр халыкта булган бер гадәт күркәмлегедер.* Ш.Мөхәммәдев

**ҖӘМГЫЯТЬЧЕ** *и. иск.* Җәмәгать эшләрендә актив катнашучы. *[Студиядә] Аларны чын җәмгыятьчеләр итеп чыгарырга тырышалар*. Татар театры

**ҖӘМИГЪ** *с. гар.* Бөтен, барлык, һәммә. *Җәмигъ авыл аны тәгъзыйм идеп...* М.Акъегет. *Адәм пәйгамбәрнең гакылы җәмигъ әүладының гакылы кадәр иде*. К.Насыйри

**ҖӘМИ́ГЪ ИТҮ** *ф.* Җыю, туплау. *[Үзбәк хан] Үз араларында сугышып, кырылышып торган вак кенәзләрне бетереп, бер ноктаны җәмигъ итте, ягъни җыйды.* Р.Әмирхан

**ҖӘМИ́ГЪ КЫЛУ** *ф. к.* **җәмигъ итү**. *Имди ул кошларныйң атларыйн җәмигъ кыйлуб, барчасыйный әйтәлик*. Дастан

**ҖӘМКЕ** *и. диал. к.* **җәмки**. *--- тукал белән киленчәк, чырайлары ачылып: «Кодай сакласын», – диешеп куйдылар да җәмке белән тизәкләрне рәтли башладылар.* А.Таһиров

**ҖӘМКИ** *и. диал.* Утлы күмер алу өчен махсус кыскыч. *Әләкчегә каты җәза: борынын җәмки белән кысабыз.* А.Гыйләҗев. *Бер җәллад шуларның аркаларына ахактай кызган җәмки китереп баса*. Х.Камалов

**ҖӘМШӘЮ** *ф. сөйл.* Ямьшәю. *Болай да бүлтәеп торган калын ираннәре җәмшәеп җәелә, күзләре кинәт кенә болыт арасыннан чыккан кояш кебек балкый.* Г.Галиев

**Җәмшәеп бетү** Тәмам, бик нык җәмшәю. *[Керүченең] Башында уңып, җәмшәеп беткән кубанка.* Ш.Маннур

**Җәмшәеп тору** Җәмшәйгән хәлдә булу

**Җәмшәя бару** Торган саен ныграк җәмшәю

**Җәмшәя башлау** Җәмшәергә тотыну

**Җәмшәя төшү** Бераз җәмшәю

**ҖӘНАП** *и. гар. кит.* Зур дәрәҗәләргә, хөрмәткә ия булган затларны олылау йөзеннән әйтелә торган сүз. *Академия әгъзасы Василий Васильевич*

*Радлов җәнаплары – иң бөек тюрколог галимнәрдән.* Р.Фәхреддин. *Инде үзләре генә түгел, тоташ дөнья үзгәргән иде: патша җәнаплары төшерелеп, алай гынамы, бөтен гаиләсе белән атып үтерелеп, илгә большевиклар хуҗа булган иде.* Г.Якупова. *Озата килүче пәһлеван, янә ишарәләп: – Падишаһыбыз Гыйфрит җәнаплары тәхеттә! – диде.* Р.Батулла

◊ **Җәнабе гали** Галиҗәнап; барыннан да өстен булган зат; өстенлек иясе. *Мән җәнәбе галиләреңездән үтенәмен, Сафа байның кызыны алсаңыз, зур туй кылмый, сараеңызга кызны китереп никах идеңез.* Ф.Халиди. **Җәнабе Хак** 1) *дини* Бөек Аллаһ (Аллаһны олылау сүзе). *Чөнки дога – бәндәләрне Җәнабе Хакка якынлаштыра торган иң гали чара*. Инсан һәм дин; 2) *к.* **җәнабе гали**. *Җиһанның бөекләрдән бөек газамәтле шагыйре – Җәнабе Хак үзе!* М.Галиев

**ҖӘНҖАЛ** *и. фар.* Зур гауга, кычкырыш-талаш, ызгыш. *Җәнҗалның зураюыннан шүрләп, төрмә башлыклары японнарны төрле камераларга таратканнар.* А.Гыйләҗев. --- *квартира җәнҗалы буенча суд карарын игълан иткәч, без кечкенә тәнәфес ясап алдык.* Ә.Еники. *Туган белән туган арасында җәнҗал, гауга чыкмады.* Р.Батулла

◊ **Җәнҗал кубару** Ызгыша, кычкырыша башлап, башкаларны да шул җәнҗалга тарту, кемгә дә булса бәйләнү, тавыш чыгару. *Яшь килен алдында җәнҗал кубарып, көлкегә калуың бар.* Җ.Рәхимов. **Җәнҗал кубу** Тавыш, гауга чыгу, ызгыш-талаш башланып китү. *Күпме җәнҗал кубачак.* Ә.Еники. **Җәнҗал куптару** *к.* **җәнҗал кубару**. *Хатыны бәбәй табар вакыт җиткәч, исенә төшкән, өенә исереп кайтып җәнҗал куптаруларын оныткан Шәрифең.* М.Хуҗин. *Айрат беренче вакытта җәнҗал куптарды, көн саен диярлек Лилиягә кычкырды, хәтта бер тапкыр кул күтәрүгә кадәр барып җитте.* Казан утлары. **Җәнҗал күтәрү** *к.* **җәнҗал кубару**. *Шулай да җәнҗал күтәрәсе килмәде [Габдел-бәрнең].* Б.Камалов

**ҖӘНҖАЛЛА́У** *ф.* Җәнҗал чыгару, тавыш-гауга кубару, ызгыша башлау, талашу. *Кәефе булмаганда, нык ачуы килгәндә, бераз җәнҗалларга ярата инде ул [Мансур] шулай.* Казан утлары

**Җәнҗаллап алу** Аз гына җәнҗаллау; кечкенә генә җәнҗал барлыкка килү

**Җәнҗаллап йөрү** Төрле урыннарда, төрле кешеләр белән җәнҗал куптару; һәрвакыт нинди дә булса җәнҗалга сәбәпче булу

**Җәнҗаллап тору** Һәрвакыт, гел җәнҗаллау

**Җәнҗаллый башлау** Җәнҗалларга керешү

**Җәнҗаллый бирү** Җәнҗаллавын дәвам итү, һаман да җәнҗаллау

**ҖӘНҖАЛЛАШУ** *ф.* Үзара талашу, ызгышу, даулашу. *Нинди җәнҗаллашу инде сезгә – гомерлек күрше, сердәш, ахирәтләргә?!* Н.Дәүли. *Ә без монда, Кузнецовлар һәм Дубцовалар белән җәнҗаллашып, ми черетергә калабыз.* Ш.Камал

**Җәнҗаллашып алу** Берара, аз гына җәнҗаллашу

**Җәнҗаллашып йөрү** Төрле урыннарда, төрле кешеләр белән җәнҗаллашу

**Җәнҗаллашып тору** 1) Хәзерге вакытта, сөйләү моментында җәнҗаллашу

2) Туктаусыз, әледән-әле җәнҗаллашу

**ҖӘНҖАЛЛЫ** *с.* 1) Ызгыш-талашлы, җәнҗалдан торган, шау-шулы, гаугалы. *Җәнҗаллы заман шул. Кыз баланың көтәргә вакыты күп булмый.* Н.Дәүли. *Арада җәнҗаллы дулкыннар үткәндә, Син дә бит еладың – түзмәдең.* Ф.Гыйззәтуллина. *Явыз Иван үлгәннән соң башланган җәнҗаллы чор кабат кайтмадымы икән?* М.Юныс

2) Җәнҗал чыгаручан

**ҖӘНҖАЛСЫЗ** *рәв.* Тавыш-гаугасыз, ызгыш-талашсыз, тыныч кына. *Әгәр булсын дисәң, бер өй эче шау-шу вә җәнҗалсыз: Ире булса сукыр, ул җитми, – булсын һәм хатын телсез.* Г.Тукай. *Сүз көрәштермичә, тавыш-гаугасыз, җәнҗалсыз гына бер-ике көн яшәп карыйсы иде...* Казан утлары

**ҖӘНҖАЛЧЫ** *и.* **1.** Җәнҗал чыгарырга, ызгышырга ярата торган, гаугачыл кеше. *Утлы табага бастырырга кирәк мондый җәнҗалчыларны!* Б.Камалов. *Беренче образ тамашачы каршына, иске җил тегермәне канатларыдай, кулларын бутый-бутый, бер җәнҗалчы булып килеп чыкса, икенчесе исә шулкадәр оялчан, хәтта гомере буе Лиза белән кавышырга дип хыяллanып йөрсә дә, мәгъшукасы янына бармас өчен, аякларын терәп баса, тешетырнагы белән бөтен нәрсәгә тотынып калырга әзер.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ. к.* **җәнҗаллы** (*2 мәгъ.*). *Надир Алкин җәнҗалчырак холыклы, шуңа күрә бер төштә генә ябышып эшли алмый.* Х.Камалов

**ҖӘНИН** *и. гар.* Ана карынындагы яралгы. *Бала җәнин мәшимә эчендә ике кулын тезенә куеп вә күзләрен ике кул аркасына куеп, туп кеби йомарлак булыр.* К.Насыйри

**ҖӘНЛЕК** *и.* 1) Тиресе, ите, йоны өчен аулана яки аерым бер урында тотып үрчетелә торган кыргый хайваннарның гомуми исеме; җанвар, киек. *Укытучы Африка саванналарында яшәүче җәнлекләр турында сөйли.* М.Юныс. *Күлдә аккошлар оя корган, тирә-юнендә бихисап җәнлек үрчегән, ди.* М.Маликова. *Ул әлеге озын көйне сузганда, аны агачлар, куаклар артына поскан барча җәнлекләр тын калып тыңлый сыман.* А.Филиппов

2) Барлык төр хайваннарның гомуми атамасы. *Әгәр күк катларыннан шундый фәрман килсә: «Бүтән планетага күченәсез, үзегез белән мең төрле җәнлек арасыннан тик берсен генә сайлый аласыз!» – диелсә, кеше, һич икеләнмичә, атның җылы муенына килеп сыеныр иде.* М.Галиев

3) *диал.* Шәхси хуҗалыкта асрала торган кош-корт. --- *мордвалар XVII гасырга кадәр борынгылык шартларында яшәгәннәр, ярым күчмә тормыш алып барганнар, хуҗалыклары җәнлек тотуга, табигать нигъмәтләрен җыючылыкка, балыкчылыкка һәм башка «борынгы» шөгыльләргә кайтып калган, дигән.* Б.Хәмидуллин

**ҖӘНЛЕК-ҖАНВАР** *җый и. төрки-фар.* Табигатьтә яши торган барлык төр кыргый хайваннарның гомуми атамасы. *Аларның һәр аткан*

*ядрәләре, могҗиза булып, кош-кортка, я җәнлек-җанварга тисә – ул чагында Җир шарында бер кош та һәм җәнлек тә калмаячагын беләсезме?* Г.Мөхәммәтшин. *Тирә-яктагы кош-корт, җәнлек-җанвар качып бетте.* Р.Батулла. *Алар [рәссамнар] кошларны, җәнлек-җанварларны сурәткә иңдергән.* Мәдәни җомга

**ҖӘНЛЕКЧЕ** *и.* 1) Кыйммәтле мех, тире, мамык бирә торган җәнлекләр үрчетүче кеше

2) Аучы, сунарчы. *Их, минәйтәм, юкка гына җәнлекче Җәмил малайларыннан чакма мылтык алып килмәдем.* Т.Гыйззәт

**ҖӘНЛЕКЧЕЛЕК** *и.* 1) Җәнлек асраучылык, җәнлек үрчетү һәм аларны аулау шөгыле. *Болгар-татарларда җәнлекчелек элек-электән үк төп шөгыльләрнең берсе булган – безгә әллә нәрсә уйлап чыгарасы юк, җиң сызганып эшлисе дә эшлисе.* Сөембикә

2) Кыйммәтле мех бирә торган җәнлек үрчетү белән шөгыльләнүче хуҗалык тармагы. *Моннан берничә ел элек --- «Җәнлекчелек» павильонында безнең борын-борыннан атаклы Баргуза кеш тиреләре Алтын медаль белән бүләкләнгәннән соң була ул хәл.* М.Хәсәнов. *Бүгенге көндә җәнлекчелектә эшләр бик үк мактанырлык түгел әле.* Казан утлары. *Барлык җитәкчеләр дә җәнлекчелек хуҗалыгының эшчәнлегеннән һәм андагы үзгәрешләрдән канәгать калды булса кирәк.* Ватаным Татарстан

**ҖӘННӘТ** *и. гар. дини* 1) Фани дөньяда гөнаһлы гамәл кылмаган, ислам дине кануннарын чын күңеленнән үтәгән хак мөселманнар өчен бакый дөньяда вәгъдә ителгән рәхәт тормыш, оҗмах. *Урыны җәннәттә булсын татарның.* А.Гыйләҗев. *Безгә – Җир йөзенә сынау өчен, җәннәткә әзерләнер өчен генә җибәрелгән бәндәләргә – бары тик Үзенең кушканнарын үтәү, тыйганнарыннан тыелу гына кирәк.* Татар мөселман календаре. *Бу ай – Котылу ае – бозыклыклардан тыелып, җәннәт насыйп иткән ай, Аллаһы Тәгаләнең ут газабыннан коткара торган ае.* Сөембикә

2) *күч.* Бәхет һәм ләззәт дөньясы, рәхәт тормыш. *Ләкин сезнең хәл – җәннәт, минеке белән чагыштырганда... Җәннәт кенә дә түгел – рай.* И.Гази. *--- Әгъләм бай узып киткән чакларда, якын-тирә авыллардагы ярлы-ябагай күзләрен ут яндырып карап кала һәм, авыр көрсенеп: «Менә, ичмасам, кешеләр дөньяның җәннәтендә яши!» – дип, үзара сөйләшә.* Г.Ахунов. *Җәннәт эзләп авылдан китүче яшьләр саны арта бара.* Ф.Садриев

3) *күч.* Рәхәт яшәү өчен бөтен мөмкинлекләре булган җир, урын. *Әле ун гына минут элек мин җәннәтне күзәтеп йөри идем.* М.Юныс. *Үземнең дә танышларым, җәннәтне күрәсең инде, дип озатып калган иде сәфәр чыкканда.* Р.Минһаҗ. *«Өебезгә» түгел – «өйләренә!» Йөрәгенә килеп тигән бу сүзне ишеткәч, апалары җәннәтенә әле һаман ияләшеп җитә алмый икән дип, Асылбикә үз кызын чын күңеленнән тагын бер мәртәбә җәлләп куйды.* Р.Вәлиев

4) *күч.* Кешенең үзе өчен кадерле булган тирәлеге, үз почмагы, өе; булган тормышыннан канәгатьлек. *Кыскасы, Аллага табынгандай табынып йөргән, минем өчен иң чибәр, иң акыллы, иң гүзәл һәм иң кадерле булган, җанымнан якын күргән сөекле кешем шуны эшләгәч, егерме ел корган җәннәтем күз ачып йомганчы җил-давыл булып очкач, зиһеннәрем таралып, башым уйламас булды.* Г.Мөхәммәтшин. *Иске генә, кечкенә генә өем – үзем өчен җәннәт минем.* Мәдәни җомга. *--- үзенә күрә бер җәннәт булган гаилә ояларының тәмен-тозын җибәреп, яшәп булмаслык шыксыз йорт хәленә, җәһәннәм хәленә китергән күпсанлы гафил яшь хатыннар --- үз хозурларына кайтсалар иде!* Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы

5) *күч.* Җанга һәм тәнгә ял, дәва бирә торган рәхәтлек. *Мунчасы – җәннәтнең үзе.* Ф.Садриев. *Их, ерак сәфәрләрдән соң тузанга батып, тирләп-пешеп, алҗып, сагынып кайткач, үз мунчаңның кап-кайнар ләүкәсенә сузылып ятулары – җәннәт, валлаһикаем!* Р.Батулла

6) *күч.* Бик матур җир. *Бөтен җирне матур җәннәт ясарбыз. Калырбыз мәңгелеккә шунда торырга.* М.Җәлил. *Табигатьнең кеше кулы тидерелмичә саклана торган бу искиткеч матур урыны – кошлар һәм балыклар өчен җәннәт.* А.Муранов. *Гөлләргә күмелеп утырган бакчаң – җәннәтнең үзе.* Мәдәни җомга

◊ **Җәннәт алмасы** *дини* 1) Җәннәт бакчасында үсә торган агачның җимеше. *Аннан: «Син соң үзеңнең алма икәнеңне беләсеңме?» – дип сорый да: «Синең исемең Төфахелҗинан – «җәннәт алмасы» дигән сүз бит», – дип, миңа аңлата иде.* З.Рәсүлева; 2) *к.* **җәннәт җимеше. Җәннәт әһеле** *дини* Җәннәткә ирешүче, җәннәткә керергә лаеклы кеше. *Инсанның иманы камилләшеп өлгерсә, үссә, ул инсан җәннәт әһеле булыр.* Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы. *Ул җәннәт әһелләре, бер-берсенә каршы килеп, бу бөек дәрәҗәгә ни сәбәп белән ирештегез, дип сорашырлар.* Коръән тәфсире. **Җәннәт бакчасы** 1) *дини* Җәннәтнең аллы-гөлле чәчәкләргә күмелеп утырган һәм күптөрле татлы җимешләр үсә торган урыны. *Аның да фәрештәгә әвереләсе, җәннәт бакчаларындагы җимешләрдән авыз итәсе килде.* А.Хәлим. *--- авыруның хәлен белергә баручы – җәннәт бакчасында йөрүче ---.* Татар мөселман календаре. *Бу [намазлыкның купшы чәчәк бәйләмнәре рәсемнәре белән тулыландырылуы] намаз укучы игътибарын башка нәрсәгә юнәлтмичә, үзен җәннәт бакчасында йөргән дип хис итү өчен эшләнелгән.* Идел; 2) Рәхәт, мул, матур тормыш. *[Закирҗанның] Җәннәт бакчасына тиң дөньяда яшәп тә, аның кадерен белмәвенә, шундый гүзәл тормышта алтындай елларын әрәмгә үткәрүенә ачуы килде.* М.Кәбиров. **Җәннәт җимеше** 1) *дини* Җәннәт бакчаларында үсә торган җиләк-җимеш. *Оҗмах бакчаларындагы алма-хөрмә, җәннәт җимешләреннән авыз итеп ята инде бу оҗмах кошы!..* А.Хәлим; 2) Үз тирәлегендә үсмәгән, чит-ят илләрдән килгән татлы, тәмле җимеш. *Хөрмә – оҗмах, җәннәт җимеше.* Мәдәни җомга. *Ул җәннәтнең җимешләре утырган вә яткан кешеләргә якындыр.* Коръән

тәфсире. **Җәннәт ишеге** 1) *дини* Җәннәт капкасы; 2) Җәннәткә керү мөмкинлеге. *Рамазан ае җитү белән, бөтен җәннәт ишекләре ачылыр, җәһәннәм ишекләре ябылыр ---.* Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы. **Җәннәт капкалары ачылу** Төрле комачаулар, тоткарлыклар юкка чыгып, яңа мөмкинлекләр барлыкка килү. *Нурҗиһан өчен җәннәт капкалары ачылгандай булды.* М.Маликова. **Җәннәткә ирешү** *дини* Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешеп, оҗмахка керү, җәннәтле булу. *Җирдәге шушы газаплар аша, бәлки, халык иманга, тәүбәгә килер, ахирәт көнендә җәннәтләргә ирешер.* Ф.Бәйрәмова. **Җәннәт күрдеңме әллә?** Сәбәпсезгә, тик торганда яисә кинәт кенә үзалдына көлеп куйган кешегә карата әйтелә. **Җәннәт нигъмәте** 1) *дини* Җәннәттәге мул ризык, сый-хөрмәт; 2) Җәннәт рәхәтлеге. *Гомере буе игелекләр эшләп, намусына тап төшерми яшәгән һәм дин юлыннан тайпылмаган адәм баласы, фани дөнья белән хушлашканда ук, җәннәт нигъмәтләрен татып карый, дип әйтүләре дөрес икән...* Ватаным Татарстан. *Әгәр бер кеше дөньяда вакытта сукыр булса, ахирәттә дә сукыр булыр, --- Коръән күрсәткән юлдан бармаса, ахирәттә, җәннәт нигъмәтләреннән мәхрүм булып, җәһәннәм газабыннан котылырга юл тапмас ---.* Коръән тәфсире; 3) *к.* **җәннәт сые**. **Җәннәт сые** Тәмле һәм мул ризык. *«Кайнар аш», «куе чәй» дигәнең җәннәт сые, фантазия иде.* Б.Камалов. *Аша, эч – алдыңда җәннәт сые, аннан тулы корсакка ят, йокла, хет тәүлек буе!* Н.Хикмәт. **Җәннәт фәрештәсе** 1) *дини* Фәрештә; 2) Әйбәт, чиста күңелле һәм бер гаебе, бер кимчелеге булмаган идеаль кеше. *Бу минутларда Мәрьям чиксез матур, офык артыннан күтәрелгән кояш аның йөзен алсу нурга күмгән, ул гүя әкият кызы, ул гүя җәннәт фәрештәсе, ул Шәүкәтне әйтеп бетергесез дулкынландыра иде...* Г.Ахунов. **Җәннәт хәяты** 1) *дини* Җәннәт тормышы. *Аллаһ ризалыгына ирешкән кешеләр дөньяда рәхәт вә хозур эчендә яшәрләр, ахирәттә дә җәннәт хәятына ирешерләр.* Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы; 2) Җәннәттәге кебек рәхәт тормыш. *Гүзәл әхлаклы кеше дөньяда да эше белән, дуслары белән, гаиләсе белән, туганнары белән җәннәт хәятында яшәр.* Вәгазьләр, әдәп-әхлак китабы; **Җәннәт хуры** 1) *дини* Оҗмахтагы хур кызы; 2) Чибәр, гүзәл кыз. *Борыннарын чөйгән кызларның [сүзләреннән] --- «син безгә тиң түгел, чөнки без – җәннәт хурлары!» – дигән мәгънә аңлашыла иде.* Р.Батулла

**ҖӘННӘТЛЕ** *с.* Җәннәткә керергә лаеклы булган, җәннәт әһеле булырдай. *Хәдичә түти! Үзем күптән җәннәтле, күршеләрне кайгыртам дигәндәй, ир белән хатын арасына килеп кысылмасаң, эшең беттемени?* Г.Бәширов. *Син [Раббыбыз] бирәүне дөньяда явызлыктан саклап та, ахирәттә җәннәтле итсәң, бу эш олуг изге теләккә ирешмәктер.* Коръән тәфсире

**ҖӘНҮБ** *и. гар. иск.* Көньяк. *Көймә якынлашканнан-якынлашты; җәнүбтән каты җил көймәнең җилкәннәрен кош канаты шикелле киергән, көймә дә, аккош шикелле, агымга каршы булса да, очадыр иде.* Г.Гобәйдуллин

**ҖӘНҮБИ** *с. гар. иск.* Көньякта урнашкан, көньяктагы. *[Зәки Вәлиди] Идел (Волга) буе, Кырым, Кавказ вә Сибириядәге татар, мишәр, нугай, типтәр, башкортлар, Урта Азиядәге сарт, үзбәк, таранчылар, казак вә кыргызлар – урта төрекләр дип; төрекмәннәр, Кавказ татарлары җәнүби дип --- аталалар, ди.* С.Алишев. *Җәнүби Африка. Җәнүби мәмләкәтләр*

**ҖӘНҮП** *и. гар. иск. к.* **җәнүб**. *– Җәнүп якларыннан бер әйләнеп килсәгез, шунда беразга Сараны да Киевтә калдырсагыз, бигрәк тә яхшы булыр, – ди.* С.Җәлал. *Җәнүптәге мазлум ком гарәбе, белми калма син дә көрәшне ---.* М.Җәлил. *«Иде» фигыле җәнүп төрекләрендә, «де»гә әйләнеп, аерым «хикәя фигыльләре» тезмәсен хасил итә. Мәсәлән: «гәлмешдем», «күрсәйде» кебек.* Г.Алпаров

**ҖӘҢ** *и. фар.* Сугыш, бәрелеш. *--- җиденче кальганың халкы, кальгаларының мәхкәмлегенә ышанып, җәң итәләр.* К.Насыйри

**ҖӘП** I *и. диал.* 1) Берничә аерчалы, очы тармакланып торган әйберләрнең (мәс., сәнәк, чәнечке, циркуль һ.б.) бер аерчасы. *[Гайфулла] Печәнне өч җәпле агач сәнәк белән алагаемга күтәреп, сәндерәгә томыра башлады.* Ф.Яруллин. *--- тере килеш җәп белән тотып, авызлык кигезеп, танавын каеш белән бәйләп, ат сыртына салганда, еш очраша иде аучы Котлый белән бүре күзләре.* Р.Батулла

2) Агачның ике яки берничә ботакка аерылып киткән өлеше, ботак аермасы һәм шулай аерылып киткән һәр ботак

3) Болан, пошиның агач ботаклары кебек тармакланып киткән мөгезе һәм аның һәр тармагы. *Боланның яшен мөгез җәпләренә карап билгелиләр*

4) Елан теле яки карлыгач койрыгының бер аерчасы

5) *күч.* Бергә берләштереп сузылып киткән әйберләрнең берсе, бер тармагы. *Трубаның бер җәбен яшелчә бакчасына сузабыз.* Ф.Шәфигуллин. *Булгач-булгач, мулдан булсын, өч җәптән катыр җебен, май эчендә йөрсен әле егетнең кулы.* Р.Төхфәтуллин

**ҖӘП** II *и. сөйл. к.* **зәп** I. *Җәпкә сөрү*

**ҖӘПЛӘКӘ** *и.* **1.** 1) *диал. к.* **җәп** I. *Сәнәге кыйбат түгел, җәпләкәсе кыйбат.* Мәкаль. *Һөҗүмгә ташланып кешеләр түгәрәге өстенә сикергән җанвар һавада ук сәнәк җәпләкәләренә эләгә, яраланып яисә куркып, качу ягын карый.* Р.Фәизов. *Мәгыйзь күреп алды: Рәхмәтнең уң кулында уртадан ике бармак юк, җәпләкә булып калган, аны кырык икедә үк кайткан дигәннәр иде шул.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Берничә ябе булган, япьле сыман аерылып торган. *Җәпләкә агач. Җәпләкә койрык*

**ҖӘПЛӘКӘЛЕ** *с.* **1.** 1) *диал.* Япьләре булган. *Һәр шалашка озын саплары ялтыраганчы шомартылган өч җәпләкәле агач сәнәкләр сөяп куелган.* Р.Фәизов

2) Тармакланып киткән; япьләргә аерылып торган. *Берәүләр аның җәпләкәле кул белән ничек итеп ашаганын карарга, икенчеләр сугыш турындагы*

*хикәяләрен тыңларга киләләр иде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Берничә тармакка бүленгән. *Җәпләкәле юл чаты*

4) *күч.* Күпләп, артык көч куймыйча гына, җиңел табыла торган, тармаклы-тармаклы. *Синең күңелеңне анда эш түгел, җәпләкәле тиеннәр өмете тарткан икән.* Р.Төхфәтуллин

**2**. *рәв. мәгъ.* Берничә тармакка бүленеп, тармакларга аерылып. *Тик минә мәктәптән чыккач инде, безнең юллар, текә җәпләкәле булып, як-якка аерылды.* Р.Фәизов

**ҖӘПЛӘНҮ** *ф. диал.* Япьләргә, тармакларга аерылу. *Болан мөгезе җәпләнү. Агач ботаклары җәпләнү*

**Җәпләнә башлау** Җәпләнү билгеләре сизелү

**Җәпләнә бару** Торган саен ныграк җәпләнү

**Җәпләнеп бетү** Нык җәпләнү, бик күп җәпләр барлыкка килү. *Агачның тамырлары җәпләнеп беткән. Шул тамырларга карап, чирәм өстендә бик озак уйланып утырды Сабир: баксаң, кеше язмышлары, гомерләре дә шулай тармаклана, боргалана, җәпләнә бит.* Казан утлары

**Җәпләнеп килү** Җәпләнүгә таба бару

**Җәпләнеп тору** Җәпләнгән хәлдә булу

**ҖӘПЛЕ** *с. диал.* 1) Япьләргә аерылган, япьләре булган. *Дөресрәге – аның өч җәпле бәләкәй пәкесе бар иде, тик ул пәке берәү генә иде шул.* Г.Ахунов. --- *Вәсилә балдыз – җылы башмаклар, Нурия кодача – бүре бүрек, Хашия кодача унҗиде җәпле пәке алып килгән.* Ф.Шәфигуллин. *Өч җәпле ботак арасына корылган ояга җиткәч, эшен бетереп, шуып та төште [Вагыйзь].* Ә.Гаффар

2) Япь сыман аерылып торган кисәкләре, өлешләре, аерчалары булган, тармакланып торган. *Миңа таба пальма буйлап елан шуып килә. Ике җәпле агулы тел маңгаема килеп тия язган.* М.Юныс. *Әйтик, җәй азакларында, спиннинг тотып, Идел өстенә чыксаң, җәпле кармагың янына, ялтыравык урынына, муштугыңны яки трубкаңны бәйләп сал, чуртан барыбер каба.* М.Әмир

◊ **Җәпле сәнәк** *сөйл.* Язу танымаган, үзенең исемен яза белмәгән грамотасыз кешенең сәнәккә охшаган кул тамгасы; имза. *[Бамбыр:] Ничә тапкырлар әйткәнем бар сиңа, энем, шул язган киягазеңнең өске өлешенә җәпле сәнәк төшереп куй, диеп.* З.Зәйнуллин

**ҖӘПТӘШ** I *с. диал.* 1) Эшне бик оста, җитез башкара торган, өлгер, булдыклы, сәләтле. *Ләкин ул барыннан да бигрәк эшкә җәптәш, эшкә уңган иде.* Н.Фәттах. *Кулы эш белде, шөгыльгә җәптәш булды.* Н.Хәсәнов

2) Нинди дә булса берәр эш-гамәлгә, һөнәргә оста, маһир, һәвәс. *Бу куллар балта-пычкы тотарга да бик җәптәш булып чыкты.* Р.Төхфәтуллин. *Сүзгә җәптәш кеше. Укуга җәптәш малай. Музыкага җәптәш кыз*

**ҖӘПТӘШ** II *с. сир.* Япьләргә аерылган, җәпләкәле, тармаклы. *Әлбидә үз наратының җәптәш тамырлары арасындагы чокыр урынны хәлсез бармаклары белән казып утырды.* Ш.Маннур

**ҖӘПТӘШЛЕК** *и.* Осталык, маһирлык; эшкә сәләтлелек. *Ул, булган җәптәшлеген куеп, тырышып укыды.* Ф.Хөсни. *Арсланда йорт җанлылык дисеңме, эшкә җәптәшлек дисеңме, артыгы белән бар иде.* Г.Ахунов

**ҖӘПШӘК** *с. диал.* Яссыланып, яньчелеп торган, киң. *Мин – җәпшәк борынлы, киң маңгайлы малай.* Ф.Шәфигуллин. *Кечкенә чагында зур авызлы, җәпшәк борынлы кечкенә генә юаш малай булган, дип, кем әйтер аны [Габдулланы]?* Юлдаш

**ҖӘРӘХӘТ** *и. гар.* 1) Тәннең яки эчке бер әгъзаның зарарланган урыны; тәндәге яра. *Георгий Фёдорович – сугыш күргән кеше, дөньяны миңа караганда күп элегрәк таныган, яраланган, маңгай читендә җәрәхәте зәңгәрләнеп тора.* А.Гыйләҗев. *Маңгай дисеңме, күз-колак тирәләрен әйтәсеңме – һәммә җирендә җәрәхәт иде.* Р.Ишморат. *Җәмилнең, шулай да була икән, ике елдан артык ут эчендә йөреп, бер генә җәрәхәте дә юк иде.* Г.Якупова

2) *күч.* Күңелдәге сызлану, борчу-сагыш, рухи газап; берәр кайгы яисә авыр кичерешнең күңелне әрнетеп торуы. *Борынгылар, сагыш җәрәхәтеннән бәндә баласы савыга алмый икән, дия торган булганнар.* М.Хәсәнов. *Абый-энекәшләрне, якын дусларны югалту да, күңелдә җәрәхәт калдырып, күңелне озак елларга телгәли икән.* Н.Гариф. *«Вакыт» дигәнең әллә нинди хәлләрне дә рәткә кертеп куя, авыр күңел җәрәхәтләрен дә төзәтә ул.* Р.Фәизов

3) *күч.* Кыр-басуларның яргалануы; җир өстендәге яра җөенә охшаган эзләр. *Басу йөзендә, төзәлмәс җәрәхәтләр булып, әрлән балчык сырлары сузылып китә, тегендә дә, монда да шыксыз шадралар ишәя бара...* Э.Касыймов. *Җир җәрәхәте, озак еллар төзәлмичә, сыкранып, хәйран ята икән.* М.Юныс

4) *күч.* Нинди дә булса өслекнең кырылган, сызгаланган, тырналган урыны. *Өстәл читен эт кимергән диярсең – буеннан-буена теш эзләренә охшаш җәрәхәт сузылып киткән. Сыра бөкесен ачудан барлыкка килгән җәрәхәтләр бу.* М.Юныс

◊ **Җәрәхәт алу** Берәр вакыйга, күңелсез хәлдән соң күңелдә ачыну хисе уяну, рәнҗү. **Җәрәхәт ачылу** Онытыла башлаган, үткәндәге аянычлы вакыйгалар кабат хәтердә яңару, аларны искә төшерерлек этәргеч ясалу. **Җәрәхәт җөе** Үткәндәге аянычлы вакыйгаларны искә төшереп торган борчу, ачыну хисе **Җәрәхәткә тоз басу** *к.* **җәрәхәткә тоз сибү**. **Җәрәхәткә тоз салу** *к.* **җәрәхәткә тоз сибү**. **Җәрәхәткә тоз сибү** Кеше күңелендәге авыр җәрәхәтне, газапборчуларны кузгату, аның кайгысын исенә төшереп, күңелен әрнетү, ярасына тоз сибү. *Инде онытылып бара дигәндә генә, тиздән, аны кабат ачтылар, ачтылар да җәрәхәтенә, учлап-учлап, тоз сиптеләр.* Р.Низамиев

**ҖӘРӘХӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **җәрәхәтләү**

2) Җәрәхәт алу. *Фронтны күреп, җәрәхәтләнеп, госпиталь аша үткән солдатлар гына торышларын үзгәртмәделәр.* З.Зәйнуллин. *Зөлфәтемнең хаты-хәбәре юк, башлары вәйран булды микән балакаемның, әллә җәрәхәтләнеп, хат язарлык та хәле юк микән?* Т.Мөбарәков

3) Билгеле бер әгъзада яисә органда яра, җәрәхәт барлыкка килү. --- *Дмитровск шәһәрен алдык. Кабыргам җәрәхәтләнде.* З.Зәйнуллин. *Бармак җәрәхәтләнү генә димәссең, авыртуына һич түзеп булмый.* Сөембикә

4) *күч.* Күңелдә, җанда зур борчу, кайгы-хәсрәт булу. *Китек күңел җәһәт җәрәхәтләнә шул!* Б.Камалов. *Аның күңеле сизгер, тиз җәрәхәтләнә, җылыга туймый.* Х.Хөснуллин

5) *күч.* Җирнең яргаланып, чокырланып бетүе. *Сугыштан калган эзләр бу. Җимерек йортлар, җәрәхәтләнгән җир, каберлекләр.* М.Юныс

6) *күч. сир.* Берәр нәрсә ватылу, җимерелү; бөтенлеген югалту. *Хатыны Җомабикә абыстай, --- җәрәхәтләнгән савыт-сабаларын җыйнап, кухняга чыгып китте.* Ш.Мөхәммәдев

**Җәрәхәтләнеп бетү** Төрле җире, тәмам, бик нык җәрәхәтләнү. *Ул Зөбәйдәне танып алды, җәрәхәтләнеп беткән беләген кысып тоткан кулының җәдәч бармагын чак-чак кына кыймылдатып, кызны үзенә чакырды.* М.Шаһимәрдән. *Өстәвенә, Хәдичәнең өс-башы, ертылып, тузанга, туфракка буялган; куллары, бите, аяклары җәрәхәтләнеп беткән иде.* А.Расих. *Бөтен гәүдәсе җәрәхәтләнеп беткән, тәнендә җан әсәре калмаган патриот комсомолецны, үлгәнгә санап, мәетләр чокырына ыргыталар.* Ш.Мостафин

**Җәрәхәтләнеп калу** Нинди дә булса сәбәп, вакыйгадан соң җәрәхәтләнгән хәлгә килү. *Кунарга урын табылыр, әмма китек күңел тагын да җәрәхәтләнеп калыр...* Ә.Моталлапов

**ҖӘРӘХӘТЛӘНҮЧӘН** *с.* 1) Тиз җәрәхәтләнә торган. *Кайбер кешеләрнең тиресе җәрәхәтләнүчән була*

2) *күч.* Күңеленә авыр ала, тиз үпкәли торган, үпкәчел. *Аларның күбесе – шигъри җанлы, нечкә күңелле, интеллектуаль һәм эмоциональ табигатьле хис кешеләре, шул ук вакытта артык кызу канлы, тиз җәрәхәтләнүчән, импульсив геройлар.* Ф.Миңнуллин. *Олыгайган саен, кешенең күңеле нечкәрә, чәрексезләнә, тиз җәрәхәтләнүчән була, диләр.* М.Маликова

**ҖӘРӘХӘТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәнне яки берәр төрле әгъзаны яралау, җәрәхәт ясау, зарарлау. *Әмма мин, ир булам дип, чак кына гүргә кермәдем: чаңгы шуганда, текә ярдан сикереп, сул аякны нык кына җәрәхәтләдем.* К.Латыйп. *Артык озын үскән тырнак һәрвакыт сынып тора һәм кул тиресен җәрәхәтли.* Биология. *Ташның бер ярчыгы әтине җәрәхәтли.* Сөембикә

2) *күч.* Кешенең күңелен, йөрәген авыр газапларга, кайгы-борчуларга дучар итү. *Өчпочмаклы, кара кайгылы хатлар авыл кешеләренең җанын бик күп җәрәхәтләде.* Г.Ахунов. *Һаҗәргә булган өметсез мәхәббәтне әйтеп тормыйм, чөнки мин (гәрчә мәхәббәт газабы кешенең җанын бик җәрәхәтләсә дә) аңа күпмедер дәрәҗәдә ияләшкән идем инде.* Ә.Еники

3) *күч.* Җимерү, хәрабә хәленә китерү, зыян итү. *Шушы гүзәл иртәдә, җирне җәрәхәтләп, кешеләрне кырып, сугыш белән килү түгел, бу хакта уйлау гына да зур җинаять тоела.* Ш.Рәкыйпов

**Җәрәхәтләп бетерү** Бик күп һәм авыр җәрәхәтләр ясау. *Ә иртәсен, ямый-ямый яңа тунымны, Инә белән чәнчеп, канга батырып, Җәрәхәтләп беттем кулымны!* Һ.Такташ. *Авыр еллар минем күңелемне телгәләп, җәрәхәтләп бетерделәр.* Э.Яһудин

**Җәрәхәтләп җибәрү** Бераз, бернихадәр җәрәхәтләү

**Җәрәхәтләп кую** Җәрәхәтләнгән хәлгә китерү

**Җәрәхәтләп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм җәрәхәтләү

**Җәрәхәтли бирү** Җәрәхәтләвен дәвам итү, һаман да җәрәхәтләү. *Түшәмнән яңгыр тама: леп-леп, леп-леп. Матур гына тамчылар. Үзләре, тамган саен, йөрәкне тишкәли, җәрәхәтли бирәләр.* Ә.Баян

**Җәрәхәтли төшү** Тагы да ныграк җәрәхәтләү

**ҖӘРӘХӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Җәрәхәте, ярасы булган. *Оркестр марш уйнап җибәрү белән, яралы матрослар, хәлдән таеп арыган кызылгвардеецлар, җәрәхәтле тәннәренең сызлаганын онытып, атакага кузгалалар.* М.Юныс. *Илсөяр аның җәрәхәтле аягына карап, кызганып куйды.* Г.Гобәй. *Башы җәрәхәтле сабый үкереп елый, ә мин нишләргә дә белмим.* К.Латыйп

2) *күч.* Күңелдә, җанда, йөрәктә кайгы-хәсрәт, сагыш-борчу булган. *Уйна, назлы җилкәй! Күпме газаплар кичергән ике хатынның җәрәхәтле җаннарын иркәлә!* М.Хуҗин. *Бу уй аның җәрәхәтле йөрәген җылы дулкын булып тибрәндереп узды.* М.Хәсәнов. *Гомер буе әрнер өчен, төнге һавада атылган йолдыз кебек, моңлы бер сәхифә генә мәңге җәрәхәтле күңелендә сызылып калыр микәнни?* Ш.Шәйдуллин

3) *күч.* Йөрәкне әрнетә, күңелгә үтеп керә, ачуны китерә торган. *Чиратдагыларның, үзенә таба борылып, пышым-пышым серләшүләрен, сүз ара: мескен, уңмады, үз башына икән, ире дә бәхетсез инде дигән җан әрнеткеч җәрәхәтле сүзләр ишеттерүен күтәрә алмады Әхмәт.* К.Кәримов

**2.** *и. мәгъ.* Яраланган, җәрәхәт алган кеше. *Җәрәхәтлеләрнең ыңгырашканы ишетелә.* Ш.Усманов

**ҖӘРӘЯН** [җәрәйан] *и. гар. иск.* 1) Агым, юнәлеш. *Бу яңа җәрәянның Төркиядә туууына безнең илдәшемез Йосыф Акчура беренче рольне уйный.* Г.Исхакый

2) Булу, агыш, процесс, барыш

**ҖӘРГӘ** *и. бор.* Хәрби тезем, саф, строй. *Менә көн җәйдагы да төште җиргә, Кара һинд явы килде, тезде җәргә.* Котб

**ҖӘРЕН** *и. диал.* Киләсе ел, алдагы ел; ярен. *Язлар килер, Сикереп агар сулар – Иген яхшы булыр җәренгә.* Г.Афзал. *Шул кечкенә нәрсәдән җәренгә бер яшьлек бозау зурлыгындагы эт үсеп, яһүднең яшелчә уңышын арттыруда төп көчкә әйләнгән.* З.Зәйнуллин. *Алай димәле, җизни! Менә тагын җәренгә бәдәл – хаҗ килешеп кайттым.* Ә.Гаффар

**ҖӘРИДӘ** *и. гар.* 1) *тар.* Электә: салым җыючыларның салым салынырга тиешле җир мәйданын яза торган дәфтәре

2) *иск.* Газета. *Өч җәридә шәп, диләр: «Йолдыз» вә «Әлислах», «Вакыт».* Г.Тукай. *Соң, алай булса, башка*

*милләтләр ничек укырга вакыт табалар, алар да сезнең кеби дөнья көтәләр, кәсеп итәләр, ләкин сезнең кеби, вакытым юк, дип тормыйлар, хәтта арбачыларына кадәр, вакыт табып, җәридәләр укыйлар, дөньядан хәбәрдар булып торалар.* М.Гафури. *Чөнки бу могътәбәр җәридә үз телемездә чыккан нәшрият әдәбиятның юлбашчысыдыр.* Р.Фәхреддин

**ЖӘРИМӘ** *и. гар. бор.* 1) Гаеп, гөнаһ. *И угыл, һәрбер җәримә вә гөнаһ өчен кешене мовахәзә итмә.* К.Насыйри

2) Штраф

**ЖӘРМУК** *и. тар.* Чи тиредән тегелгән аяк киеме

**ЖӘСАРӘТ** *и. гар. иск.* Батырлык, батырчылык, кыюлык. *Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар; Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!* Г.Тукай

**ЖӘСАРӘ́Т ИТҮ** *ф. иск.* Батырчылык итү, җөрьәт итү, кыю. --- *халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне сөйләргә җәсарәт итәм.* Г.Тукай. *Гөлнар белән ничек килешәчәгемне уйларга да җәсарәт итми идем.* Н.Гасрый

**ЖӘСАРӘ́Т КЫЛУ** *ф. иск. к.* **җәсарәт итү**. --- *фәкать бу тугърыда кыйлдым җәсарәт ---*. Г.Тукай

**ЖӘСАРӘТЛӘНҮ** *ф. иск. к.* **җәсарәт итү**. *Һичбер инсан аңа каршы торырга җәсарәтләнмәс иде.* М.Акъегетзадә

**ЖӘСӘД** *и. гар. иск.* 1) Үлгән кешенең гәүдәсе, мәет. *«Без китәбез, сез каласыз!» дип җырлармын, Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.* Г.Тукай. *Үлекләрнең җәсәде җиргә иңдерелә ләбаса!* Н.Гыйматдинова. *Борһан бабайның җәсәден зиратка тикле егетләр күтәреп алып килде.* Г.Ахунов

2) *иск. кит.* Гәүдә, тән. *Ул вакытта минем җәсәдемне уй-фикер түгел, шашкан буталчык хисләр дулкыны йөрткәндер.* А.Гыйләҗев. --- *нәфрәтең дә дәвамлы булмый, иблис котырыгы инде бөтен җаныңны, җәсәдеңне яулап ала, яман чир кебек, метастазалары бөтен әгъзаларыңа тарала.* Р.Зәйдулла

**ЖӘСҮР** *с. гар. иск.* Кыю, батыр, куркусыз, тәвәккәл. *Алар алдарлар, алдансаң; Җәсүр мөфти дә юк, дирләр ---*. Г.Тукай. *Күз яшь түкмә, җәсүр кошым, бераз сабыр бул, Офык йөзен нурга манып, ал таң атачак.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ЖӘСҮРАНӘ** *рәв. гар. иск.* Кыю рәвештә, курыкмыйча. *Әле вак һөнәрче дә капиталның ерткычлыгы илә яхшы гына вә җәсүранә генә көрәшеп торадыр.* Г.Тукай

**ЖӘСҮРЛЕК** *и. иск.* Батырлык, кыюлык. *Хан кызы үзенең каһарманлыгын, җәсүрлеген югалтмады, --- куркып, аптырап, шашып калмады.* Ш.Мөхәммәдев

**ЖӘТ** *рәв. сөйл. к.* **җәһәт** I. *Кара, җилле төн әсирлегендә үзе тоткын хәлендә калган Булат, җәт кенә, өй тәрәзәсен шакыды.* В.Нуриев. *Казан янындагы хатыннарның берсе, җәт кенә килеп, атны читкә алып китте.* Р.Батулла

**ЖӘТ-ЖӘТ** *рәв. сөйл.* Үтә тиз, бик җитез, зур җитезлек белән. *[Зәкия] Зәңгәрсу төстәге нечкә билле күлмәктән, җиңелчә ак туфлидән җәт-җәт атлый.* Г.Ахунов. *Шул мәлдә Тимерхан абыйсы, үзе дә җир «авызына» кереп баруын сизеп, аякларын җәт-җәт тартып алды.* В.Нуриев

**ЖӘТМӘ** *и. диал.* **1.** 1) Тишекле-тишекле, челтәрсыман материал. *Вак тишекле тимер җәтмәдән капчык ясадым да, рәсем пумаласы һәм кечкенә шешә белән буяу алып, урманга киттем.* З.Фәйзи. *Җәтмәне беркетү өчен, аның өске һәм аскы кырыйларына резинка үткәрәләр.* Файдалы киңәшләр. *Аны [битлекне] кара челтәр тукымадан яки буяуга манган марлядан ясарга мөмкин. Нәзек кыл җәтмәдән ясасаң, тагын да яхшырак.* Файдалы киңәшләр

2) Балык тоту, кош-корт яисә башка җәнлекләрне аулау өчен үреп ясалган тозак; ау коралы. *Ә инде, азрак буш вакытлары булса, озын җәтмә белән --- Ука елгасыннан балык сөзәләр ---*. З.Зәйнуллин. *Ходайбирде көндәгечә, кулына күбәләк аулый торган җәтмә тотып, түбән төште, йортны әйләнеп, бәләкәй күлчек янына килде.* Ф.Шәфигуллин. *Утсә унбиш-егерме минут үткәндер, Фарсил әйләнеп килеп җитте. Карасалар – кулындагы җәтмәдә, бөгәрләнеп, елан ята!* З.Фәйзи

3) Азык-төлек салу өчен, нечкә баудан үреп эшләнгән хуҗалык сумкасы; сетка. *Мин бәләкәй чакта, шәһәр хатыннары көзге һәм пудра сыя торган ридикюль генә тотып йөриләр иде. Сугыштан соң – җәтмә, соңрак хуҗалык сумкасы өстәлде.* М.Юныс. *Кулында гел ике-өч гәзит салынган сеткасы, үзе әйтмешли, «җәтмә»се булыр.* М.Госманов. *Ике ипи салынган җәтмәсен күтәреп кайтып килә әнә бабай...* Казан утлары

4) Ачык һавада ял итү, ятып тору, йоклау өчен, баудан үрелеп эшләнгән челтәрсыман махсус ятак; гамак. *Ике карт агачның урталарына гамак (ятыла торган селкенмәле җәтмә) бәйләп куелган.* Ф.Әмирхан

5) Корбаннарын эләктерү өчен, үрмәкүч корган тозак. *Җәтмәне үрмәкүч үзе үрә, ә төзелеш материалы булган сыекча исә үрмәкүчнең эчендә ясала; бу сыекча, тышкы якка чыккач, катып китә, һәм ябышкак пәрәвез җепләре барлыкка килә.* Ф.Бәйрәмова. *Үрмәкүч җәтмәсенә эләккән чебенне кызганып куйды Илдар.* Ялкын

6) *күч.* Һавада күз күремен кыенлаштыручы элпә, аралык. *Тәгәрмәч каплавычы астыннан пошкырып чыккан бу җәтмәсе астына ышыкланып, түгәрәк утлар уйныйлар.* К.Нәҗми. *Томан җәтмәсе күз күремен шактый кыенлаштырган иде.* Казан утлары

7) *күч.* Кешеләрне буйсындыру яисә алардан файдалану максатыннан корылган хәйлә, тозак. *Ләкин кем җәтмәсенә эләгүен егет, бичара, бер дә аңламаган икән шул.* Ә.Еники. *Тагын кемнәрне үз җәтмәңә төшерә алдың?* Г.Ахунов. --- *Мансурны вәсвәсәле уйларга этәрә, һәм ул Рәшидә чибәрнең җәтмәсенә эләгүен сизми дә кала.* С.Шәрипов

**2.** *с. мәгъ.* Тишекле-тишекле, челтәрсыман. *Атнабай аңа җәтмә сумка белән берничә төрле компот, консерв, папирос китергән.* Г.Ахунов

◊ **Җәтмә кору** Берәр кешегә карата начар уй белән хәйлә кору, эш-гамәлләренә тоткарлык ясау. *Моның өчен*

*иблиснең үзе булырга да, теләсәң нинди җәтмәләр корырга да ярый.* Ә.Еники. *Игътибар белән тирә-юнегезгә карагыз әле – бу тормышта кешене адаштыру, һәлак итү өчен, атлаган саен җәтмәләр корылган.* Ф.Бәйрәмова. **Җәтмә салу** *к.* **җәтмә кору**. *МГБ да йоклап ятмаган, агент арты агент җибәреп, уй сукмакларына җәтмә арты җәтмә салган.* А.Гыйләҗев. *Җәтмәне исә, аны эзләп, милиция хезмәткәрләре сала.* Мәдәни җомга. **Җәтмә үрү** *к.* **җәтмә кору**. *Сез Сөләймановны тыңлап кына карагыз! Ничек оста итеп үрә бит ул үзенең җәтмәсен, бер дә сикереп сукмый, ерактан сак кына уратып китерә.* Ә.Еники

**ҖӘТМӘ́ СОСКЫЧ** *и.* Ятьмәгә эләккән балыкларны сосып алу һәм аларны тере килеш саклау өчен ясалган җайланма. *Хәтта үзебез балыкка бармаган көннәрдә дә, иртән торуыбызга, дүрт-биш тере балык салынган җәтмә соскычын күтәреп, Мәхмүт килеп җитә.* М.Әмир

**ҖӘ́Ү** *и. диал.* 1) Туңмай, терлек мае

2) Сары май

**ҖӘҮЗА** *и. гар. иск.* 1) *астр.* Зодиак поясына туры килә торган йолдызлык һәм шул йолдызлыкның тамгасы; игезәкләр

2) Кояш календаре буенча унике айдан торган йолдызлыкның өченче ае исеме (21 майдан 23 июньгә кадәр); игезәкләр. *Кавәс тумый – кыш булмый, җәүзә тумый – җәй булмый.* Мәкаль. *Фәкать игенчелек эшләре өчен, кояш хисабы белән яз башыннан башлап, «хәмәл, сәвер, җәүзә ---» дип, гарәби исемнәр кулланалар.* Ш.Мәрҗани

3) *диал.* Май аенда әзерләнгән иң сыйфатлы ак май; эретелгән май, сары май. *Җәүзә кушып, камыр басу*

**ҖӘҮЗӘ** *и. гар. иск. к.* **җәүза**

**ҖӘ́Ү ИКМӘК** *и. диал. кулин.* Коймак

**ҖӘҮҺӘР** *и. гар.* **1.** 1) Затлы ташларның (энҗе, зөбәрҗәт, алмаз, якут, фирүзә) гомуми атамасы; асылташ; гәүһәр. *Җәүһәр җирдә ятмас.* Мәкаль. *Җәүһәр-якутларга тиңдәш вөҗүд Иелеп алмас бакыр тиенне.* Б.Рәхимова. *Ул кешеләр алтын-көмеш вә җәүһәр белән тукылган диваннарда ял итәләр.* Коръән тәфсире

2) *күч.* Халык тарафыннан яратып кабул ителгән, югары бәяләнгән әдәбият һәм сәнгать әсәре. *Армый-талмый укыды, армый-талмый, пианино уйнады Рөстәм: дөньяның музыка җәүһәрләрен белеп калырга, гомерлеккә күңеленә сеңдерергә кирәк иде.* Г.Ахунов. *Халык иҗаты җәүһәрләренең асыллары әле җыйналмаган, дәреслек китапларында урын ала алмаган.* А.Гыйләҗев. *Габдулла Тукайдан башлап, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Хөсни һәм башкаларның әсәрләренең һәркайсы дөньякүләм җәүһәр булырдай.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Оста эшләнгән, затлы, зиннәтле әйбер. *Татарстан кул эшләре палатасы Республикада яшәүчеләрнең милли бизәкләр төшереп эшләнгән җәүһәрләрен тәкъдим итте.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса иң затлы, камил үрнәге. *Автор Марат Әмирханов телебез җәүһәрләреннән мул файдалана.* М.Әхмәтҗанов. *Аның шигырьләре тел җәүһәрләреннән үрелгән асыл муенсага тиң иде.* М.Маликова. *Театр – дәүләт эчендә дәүләт, милли җәүһәрләрне җыйган сандык.* Сәхнә

5) *күч.* Кадерле, изге нәрсә; йөрәк, күңел сере. *Аның да күз карашын, яшереп хыялымда, Җәүһәр итеп саклый алмадым.* Һ.Такташ. *Сөйләрмен, колынкаем, сиңа сөйләрмен. Күңелем җәүһәрләрен тагы кемгә таратыйм да, тагы кемгә мирас итеп бирим?!* Г.Якупова

6) *күч.* Бар яктан да килгән; ихтирамга ия, хөрмәткә лаек кеше. *Авылның гүзәле, җәүһәре, авылның киләчәге иде бу кыз.* Р.Фәизов

7) *күч.* Асылташлар кебек җемелдәгән, ялтыраган нәрсә. *Кыз ак тешләренең җәүһәре белән тирә-юньне яктыртып көлде.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* Асылташлардан эшләнгән. *Юлга чыксаң, юлдаш ал, яныңа җәүһәр таш сал.* Мәкаль. *Хан Алтынчәчкә бик кыйммәтле җәүһәр муенса кидерә.* М.Җәлил

◊ **Җәүһәр бөртеге** Берәр кешенең яисә әйбернең затлы, кыйммәтле, кадерле булуын ассызыклап әйтелә. *Кем багар да кем бәһаләр асыл җәүһәр бөртеген?* Р.Фәйзуллин

**ҖӘҮҺӘРИ** *с. гар.* 1) Җәүһәр булган, җәүһәрдән торган

2) Кадерле, изге. *Җир үбеп, дидек догалар гәүһәри, һәм дәхи улсын сәналәр җәүһәри.* Г.Кандалый

**ҖӘҮҺӘРЛӘНҮ** *ф.* Кыйммәтле асылташлар белән бизәлү. *Җәүһәрләнгән тәхет өстендә гүзәл кыз ята.* К.Насыйри. *Габдулла җәүһәрләнгән кылычтан күзләрен ала алмады.* Казан утлары

**ҖӘҮҺӘРЛӘ́Ү** *ф.* Берәр әйберне кыйммәтле асылташлар, җәүһәрләр белән бизәү, зиннәтләү. *Кирәк дисәң, тешеңне дә җәүһәрлиләр безнең заманда.* Мәдәни җомга

**Җәүһәрләп бетерү** Тәмам җәүһәрләү, күп төрле җәүһәрләр белән бизәү

**Җәүһәрләп җибәрү** Бераз җәүһәрләү

**Җәүһәрләп тору** Сөйләү моментында, әле, хәзер җәүһәрләү

**Җәүһәрләп чыгу** Барысын да җәүһәрләү

**Җәүһәрли башлау** Җәүһәрләү эшенә керешү

**Җәүһәрли төшү** Тагы да бераз җәүһәрләү

**ҖӘҮҺӘРФРУШ** *и. гар.-фар.* Асылташлар белән сәүдә итүче. *Күрсәткел җәүһәрфрушкә бер йирдә хали.* Мөхәммәдьяр

**ҖӘҮҺӘРЧЕ** *и.* Асылташлар эшкәртүче, зәркәнче, ювелир. *Җәүһәр кадерен җәүһәрче белер.* Мәкаль. *Базарларда илчеләр, киезчеләр, күнчеләр, хәлвәчеләр, җәүһәрчеләр, вак-төяк сатучылар мыж килеп торырлар иде.* Р.Батулла

**ҖӘҮҺӘРЧЕЛЕК** *и.* 1) Асылташлар һәм кыйммәтле металларны эшкәртеп, затлы бизәнү әйберләре эшләүгә бәйле шөгыль; зәргәрлек эше, ювелирлык һөнәре. *Китапханәләр яна, мәчетләр җимерелә, көмешчелек, җәүһәрчелек корый...* Р.Батулла

2) Шундый әйберләр белән сату итү эше

**ҖӘФА** *и. гар.* 1) Бәла-каза, михнәт; зур сынау. *Аннары, ди әби,*

*Кәшафетдине, буыны ныгымаган килеш, сугыш җәфасын күтәрешеге, ә Әмирҗаны ускән чакта муллык килде, каравым әйбәтрәк булды, ди.* М.Хуҗин. *[Митя] Европаны гизгән, әсир калып, дөнья җәфасының иң авырын татыган җан иде.* А.Гыйләҗев. *Бу ком иле – ачы хәсрәт иле, кайгы иле, җәфа иле, улым...* Р.Батулла

2) Авырлык, кыенлык, мәшәкать. *[Мотаһар:] Мең җәфа белән урындыкны эзләп тапты ---.* А.Хәлим. *Нинди җәфа булсын! Бәлки, миңа шулай рәхәттер?* Р.Вәлиев. *[Әһлиулла:] Үз җилкәңә үзең артык җәфа аласың лабаса, Габделбәр энем.* Б.Камалов

3) *күч.* Золым, изү; башкалар тарафыннан тудырылган авыр шартлар. *Мескен, бичара хатынга --- ерткыч иренең кылган җәзаларына, җәфаларына чыдап, газап чигәргә [туры килә].* Г.Камал. *[Ханзадә:] Мин илемә кайтырга тиешмен, җәфада калган халкыма ярдәм итәргә тиешмен!* Р.Батулла

4) Кем яисә нәрсәдер тарафыннан тудырылган өстәмә мәшәкать, кыенлык, уңайсыз шарт. *Әмма бу тәбәнәк өстәлләрдән күрәсе җәфалар алда булган икән әле.* Ә.Еники. *Су җәфасын быел җәйдән калдырмыйча хәл итәргә кирәк.* Ә.Еники // Рухи халәт белән бәйле кыенлык, уңайсызлык. *Мәрьям абыстай, хәлсезлектәнме, әллә сүз таба алмау җәфасыннанмы, улына сыенып, акрын гына елый башлады.* Ә.Еники

5) *күч.* Мәшәкать, авырлык тудыручы кеше, имгәк. *– Җәфа! – Кем җәфа? Минме?* М.Хуҗин. *Сез җәфалар аркасында аталмадым [үрдәкләрне], камышлыкка шылды, каһәрләр.* Н.Гыйматдинова. *Теге җәфа әллә кайчан сорап йөри иде. Синең теләнче төпчегеңне әйтәм.* А.Гыйләҗев

◊ **Җәфа кичерү** Күп авырлык, кайгы-борчу күрү. *Әнә ата-ана күпме җәфа кичерә, ә берсен дә балаларына белгертми бит...* Х.Камалов. **Җәфа күрсәтү** Җәфалау, газаплау, интектерү; артык кырыс, таләпчән булып яисә начар гамәлләр кылып, бәгырьгә тию, борчу. *Үксез бала җәфа күрсәтмәс, дип, кем әйтә ала?!* Сөембикә. **Җәфа күрү** *к.* **җәфа кичерү**. *Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне, Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.* Г.Тукай. **Җәфа салу** *к.* **җәфа күрсәтү**. *Нурулла исемле бу адәм әшәке кулы белән бөтен тирә-якка җәфа салып торган.* М.Мәһдиев. *Кешенең хуҗалык эшчәнлеге барча җанварларга да үзенең җәфасын сала.* Кызыклар дөньясында. **Җәфа чигү** *к.* **җәфа кичерү**. *Төнге дежурларга күп йөргәч, йокы ритмы бозыла, йокысызлык белән җәфа чигәм.* З.Садыйков. *Идрисов элек үзенең русчасыз җәфа чигүен исенә төшерде дә егетләрне артык газапламады, әкренләп сугыш өйрәтер әле, диде.* Х.Камалов. *Халык ярлылыктан җәфа чиккән.* Ф.Гарипова. **Җәфа чиктерү** Кемне дә булса физик яки рухи авырлыкка, кайгы-борчуларга дучар итү, җәфалау. *Халык җыенының карары шундый булды: «хатын-кыз» дип кызганмадылар, чөнки болар Кылык кешеләренә гомер буе җәфа чиктереп яшәгән нәселләрнең берсе иде.* М.Хуҗин. *Ул исерек ир Мәрьямне гомер буе җәфа чиктергән.* Сөембикә

**ҖӘФА́ ИТҮ** *ф. к.* **җәфалау**. *Гәрчә күрсәң ата-анадан җәфалар күп заман, Син җәфа итмә аларга, бәлки, хөрмәтлә, и углан!* Дәрдемәнд

**ҖӘФА́ КЫЛУ** *ф. к.* **җәфалау**. *Шулар изде, җәфа кылды күңлемне.* Н.Исәнбәт

**ҖӘФАЛАНУ** *ф.* 1) Михнәт чигү, бәла-казага дучар булу; авыр тормышта яшәү. *Безне бу дөньяга шул кайгы, җәфалану өчен генә җибәрдең микәнни?!* М.Гали. *--- әмма [Хәлил Наильский] артык ваемсыз, пошымсыз, җиңел генә уйлаучан, шуның аркасында ул, бездә адашып калып, үзен дә, яшь хатынын да күпме җәфаланырга, күпме түбәнлекләр кичерергә мәҗбүр итте.* Ә.Еники

2) Азаплану, интегү, кыенлык күрү, мәшәкатьләнү. *Әгәр, авырып, Сәхиягә укол кадарга туры килсә, медсестралар аның тәненә энә кертә алмыйча җәфаланырлар, мөгаен.* Ф.Яруллин. *Өч көн дигәндә, мең мәшәкать чигеп, җәфаланып, шактый акча түгеп, малай-кызны, кирәк-яракларны төяп, без дә күченеп куйдык.* Җ.Мостафин. *Менә хәзер ул [Зөфәр Шәрипович] – үлеп баручы күпме авыруны терелткән кеше – егерме биш битле мескен бер мәкаләгә җан өрә алмыйча җәфалана.* Ф.Садриев

3) Золым күрү, изелүгә дучар ителү, азап чигү. *Нык изү һәм түзә алмаслык авыр хезмәттә җәфаланган коллар турында тыныч күңел белән язып булмый.* Идел

**Җәфалана башлау** Җәфаланырга тотыну. *Кызганычка, Гыйлемдар шактый иртә йөрәк сырхавы белән җәфалана башлады.* Ә.Еники

**Җәфаланып бетү** Тәмам җәфалану; озак вакыт дәвамында, соң чиккә җитеп җәфа күрү. *Бик уңайсыз, бик авыр иде болай утыруы, аяклар оеп, катып бетә, аларны кая сузарга, нишләтергә белмичә йөдәп, җәфаланып бетәсең.* Ә.Еники. *Тракторчының күңеле тасырдап, тирләп, җәфаланып бетте.* Р.Фәизов. *Өч айга якын эш эзләп җәфаланып беткәч, Мирсәет Солтангалиев әрмән капиталистлары тарафыннан рус телендә чыгарыла торган «Баку» газетасына килеп юлыга.* Р.Мөхәммәдиев

**Җәфаланып йөрү** Озак вакыт җәфалану. *1968 ел, августның соңгы яртысы, ә мин, җәй буе диярлек, яңа квартирга ордер алалмыйча җәфаланып йөрим.* Ә.Еники. *Юкка җәфаланып йөрисең, бу тирәдә нинди су булсын.* З.Фәйзи

**ҖӘФАЛА́У** *ф.* 1) Өстәмә кыенлык, борчу-мәшәкать тудыру, эшне яисә тормыш-көнкүреш хәлләрен катлауландыру. *Тик су белән генә әлегә җәфалыйлар, әмма анысы да озакламый бер юньгә киләчәк, ди.* Э.Касыймов. *Дөрес, [Сабир] яшь хатынны сыер каратып җәфаламады.* М.Мәһдиев. *Дүрт көн буена машинаның уң як ишеге җәфалады Җәүдәтне.* А.Хәлим

2) Кыйнау, җәзалау, физик газаплау. *Кыйнаулар да булды, тик, бик җәфаладылар, дип тә әйтеп булмый.* З.Зәйнуллин

3) Рухи яктан интектерү, тынгылык бирмәү, азаплау, аптырату. *Урысча сөйләндереп, кешене җәфалый.* Ф.Яруллин

**Җәфалап алу** Бераз, берара, күпмедер дәрәҗәдә җәфалау

**Җәфалап бетерү** Тәмам газаплап, интектереп, бөтенләй хәлдән тайганчы җәфалау. *Андрейны көн саен бер үк төрле сорауларга әллә ничә тапкыр җавап ала-ала җәфалап бетерделәр.* Х.Камалов. *Теге имче Мәймүнә тавышы. Тагын Хәлимне сихерләргә килгән микәнни? Тагын, өшкереп-төкереп, җәфалап бетерәләр икән...* Г.Гыйльманов

**Җәфалап йөрү** Озак вакыт, еш җәфалау. *Икенчедән, печән өстендә эт булып арган абзыйны һәм атны кара төндә җәфалап йөрисем килми иде.* А.Хәлим

**Җәфалап килү** Күптәннән, озак вакыттан бирле җәфалау

**Җәфалап тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз җәфалау

**Җәфалап чыгу** Ниндидер бер вакыт аралыгында җәфалау; һәрберсе, һәр очракта бер-бер артлы, бертуктаусыз җәфалау. *Шундыйрак сораулар мине дә төне буе җәфалап чыкты.* Ватаным Татарстан

**Җәфалый башлау** Җәфаларга керешү. *Әмма соңгы вакытта ниндидер сәер хәл җәфалый башлады үзен.* Э.Шәрифуллина. *Бу газап – шундый газаптыр, Карамый яшькә, картка. Җәфалый башлый ул сине.* Г.Афзал

**Җәфалый бирү** Җәфалауны дәвам итү, һаман да җәфалау

**ЖӘФАЛЫ** *с.* 1) Газаплы, интектерә торган, авыр. *Җәфалы булса да, татлы, ләззәтле ул гашыйк булу.* В.Нуриев. *Җәфалы, авыр урман эше йөкләмәсе бик күп йомышлы татарларны чабаталы ярлы крестьян хәленә калдырган.* С.Алишев

2) Тынычсыз, мәшәкатьле, күп көч һәм энергия таләп итә торган. *[Майпәрвәз ханым] Кияүнең райком кебек үзе бәрәкәтсез, үзе җәфалы җирдән китүе файдага гына булыр дип әйтә торды.* Ә.Еники. *Тик җиденчеләр бик тә җәфалы класс икән.* Э.Касыймов. *Юл, бигрәк тә төнге юлсыз юл, эчпошыргыч озын һәм җәфалы була.* А.Гыйләҗев

3) Интектергеч, авыр рухи һәм физик борчу-газаплар белән бәйле, үтә борчулы. *Төннәрнең берсендә, җәфалы һәм газаплы допростан соң, таң атканда гына кайтып кердем.* А.Гыйләҗев. *Балалык бәхетен сугыш урлаган бичараларны йокыда да өндәгечә җәфалы тормыш борчыйдыр.* Р.Хәбибуллина

**ЖӘХИМ** *и. гар. иск.* Тәмуг, җәһәннәм уты. *Кайсыбер фатиха вә бәддога сатучылар --- халыкны җәһәннәмнәр, җәхимнәр берлә куркытсалар да, халык, ни сәбәптәндер, җәһәннәмнән дә курыкмадылар.* Г.Тукай. *Җанына улды җәхим уты мәкам.* М.Әмин

**ЖӘҺАЛӘТ** *и. гар. иск.* Наданлык, томаналык, аң-белемсезлек. *Синең изге балаларың китапларын алдылар, Наданлык вә җәһаләтне аяк аска салдылар.* Бәет. *Шулай чорнап тора безне җәһаләт.* Г.Тукай. *Иске кабыгын салган кебек елан, Җәһаләттән чыкса кешелек, – Йөрмәс иде бәндә, мәхлук сыман, Җанварлыгын искә төшереп...* Н.Арсланов

**ЖӘҺӘННӘМ** *и. гар.* 1) Дини тәгълимат буенча: үлгәннән соң, гөнаһлы кешеләрнең җанын газаплый торган урын, утлы тәмуг. *Гөлҗиһан үкереп янган уттан бик курыкты, моның җәһәннәм икәнлеген аңлады.* Ф.Бәйрәмова. *Болытларына гына күтәрелеп кара: җәйге, июль болытларымы болар? Җәһәннәмнән кубарылган албастылар, иблисләр түгелме әллә?!* А.Гыйләҗев. *Ул явыз кеше олуг җәһәннәмгә керер.* Коръән тәфсире

2) *күч.* Түзә алмаслык авыр шартлар, газаплы, интектергеч тормыш. *Ул аларның җирдәге тормышларын җәһәннәмгә әйләндерде ---.* Ф.Бәйрәмова. *Якты көне күптән инде төнгә әверелде, әйләнә-тирәсе караңгы җәһәннәмгә охшап калды.* М.Хәсәнов. *Бер тапкыр җәһәннәмне кичеп, икенче кат төрмәгә эләккән кешенең шундый сабырлыгы, үз-үзен иркен тотышы, горурлыгы, олысымаклыгы мине сокландырды.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Үлем-кырылыш, сугыш кырындагы коточкыч хәлләр, дәһшәт. *Өч көн, өч төн бертуктаусыз сугыш җәһәннәмендә кайнаган, ахыр чиктә арыган кызылармеецлар ял итәләр.* Г.Гобәй. *Кинәт тирә-ягыңда җәһәннәм кайный башлый, блиндажлар җимерелә, яныңдагылар җен шикелле юкка чыга башлый.* М.Әмир. *Мерефа ул дәһшәтле көннәрдә җәһәннәмне хәтерләтте.* К.Латыйп

4) *күч.* Тавыш-талаш, шау-шу, чуалчык, буталчык; гаугалы вакыт. *Бер минут эчендә бөтен йорт җәһәннәм рәвешенә керде.* Г.Тукай

5) *күч.* Бик ерак, әллә кайдагы урын, билгесез җир. *Җаны үртәлгәнгә күрә генә: – Миңа димәсәң, ник җәһәннәмгә китеп олакмыйсың шунда, – дип, кызының артыннан кычкырып калган булды Мәрфуга җиңги.* М.Шабай. *Председатель Хәкимовны хет җәһәннәмнән табыгыз.* М.Хуҗин. *Икенчедән, үзең, чатан чәүкәдәй, җәһәннәмгә дә барасың юк, өйдә утырасың.* Б.Камалов

◊ **Җәһәннәм арты** *к.* **җәһәннәм асты**. *Болай эшләү төрле яклап файдалы булып чыкты. Беренчедән, җәһәннәм артына үз машинаңны кумыйсың.* Ф.Яруллин. *Менә хәзер аякка басам да әнкәйгә ярдәм итә башлыйм дигәч кенә, барысын ташлап, җәһәннәм артына китәргә кирәк.* Ватаным Татарстан. **Җәһәннәм асты** Кеше эзләп таба алмаслык бик ерак урын, яки билгесез җир. *Эзләдек, ләкин таба алмадык: җәһәннәм астына киттемени, җир күрде, су алды үзен...* К.Латыйп. *Юк, менә аның өчен җәһәннәм астына барырга, ниндидер ташландык, караңгы мәчетне күрергә, җитмәсә, шуның янында катып-туңып, тыңлап торырга кирәк.* Ә.Еники. **Җәһәннәм базы** 1) *дини* Җәһәннәмнең төбе, кешеләр газаплана торган иң куркыныч урыны. *Шәвәли, --- сират күперен чыга алмый җәһәннәм базына егылып төшүдән куркып, соңгы елларда намазын калдырмый башлады.* А.Расих; 2) Төрмә, тоткынлык; газаплы, интектергеч шартлар. *– Әйе, – диләр иптәшләрең, – җәһәннәм базын уйлап тапкан адәм актыгы җәзадан коры калырга тиеш түгел.* А.Гыйләҗев. *Үләм дигәндә, кемнәрдер җәһәннәм базына – лагерьга килеп чыккан, татарларны җыйган, үз телләрендә кешеләрчә сүзләр табып*

*эндәшкән.* А.Гыйләҗев. *Биш башак усаң – биш ел төрмә, ун башакка үрелсәң, ун елга җәһәннәм базына дөмегәсең.* Казан утлары; 3) Котсыз, шыксыз өй, бина яки урын турында. *Бу җәһәннәм базында ничек яшәмәк кирәк: түшәме дисәң – түшәме, идәне дисәң, анысы да юк...* М.Фәйзи; 4) Һәлак итәргә, начар хәлгә төшерергә мөмкин булган мохит, халәт. *Упкынга тәгәри язу бик көендерә, шулай да, кара җәһәннәм базы авызын ачып торганда, янәшәңдә кул сузучылар барлыгы – олы шатлык.* Б.Камалов. **Җәһәннәм газабы** Иң авыр газап, коточкыч шартлар, бәла-каза. *Вәли Исхаков – зыялы булганы өчен җәһәннәм газаплары күргән татар, – 60 яшендә якты дөнья белән саубуллаша.* Г.Ахунов. **Җәһәннәмгә җибәрү** Юк итү, үтерү; мәңгелек газапка салу. **Җәһәннәмгә керсә дә йөзе кызармас** Үтә явыз, әрсез, оятсыз. **Җәһәннәмгә китү** Юкка чыгу, бетү, үлү, һәлак булу. *Ярамый, мылтыклы озатучыларның күрүләре ихтимал: солдатка түгел, җәһәннәмгә китәрсең.* К.Латыйп. *«Беттек, җәһәннәмгә киттек!» – дип, син тагын укына күрмә.* К.Латыйп. **Җәһәннәмгә озату** Юк итү, үтерү. *– Китерегез баланы! – дип кабатлады Шымытыр. – Ату өерегез белән җәһәннәмгә озатам!* Р.Батулла. **Җәһәннәм дәрьясы** Бик ерак, барып җитә алмаслык җир. *Җәһәннәм дәрьясы артында нинди генә көч булмасын, бу салкын якларга берничек тә тәэсир итә алмый.* Х.Камалов. **Җәһәннәм кисәве** Гөнаһлы эш яисә начар гамәл кылудан да курыкмаган кешене ачуланып, тиргәп әйтелә; һичшиксез, җәһәннәмгә җибәреләчәк кеше. *[Каюм:] У-у, афәт, әйтергә сүз таба алмыйм! Эшкә соңга калдырасың, кит, җәһәннәм кисәве, кит, югал күземнән!* Ф.Шәфигуллин. **Җәһәннәм кочагы** Җәһәннәмнең үзәге, нәкъ үзе. *Аның, акылын җуйган карт лачын шикелле, ялгызлыктан җәһәннәм кочагына атылып очасы, алдын-артын карамыйча китеп югаласы килә башлады.* Г.Кашапов. **Җәһәннәм кызуы** Түзә алмаслык эсселек. *Елның нинди икәнен сезгә сөйләп торасы юк. Җәһәннәм кызуы.* Б.Камалов. **Җәһәннәм машинасы** Шартлаткыч; динамит. *Күпернең төбенә җәһәннәм машинасы куелган булган. Поезд шунда килеп керүгә генә – гөмберт!* Ш.Усманов. **Җәһәннәмнең җиденче катыннан** Бик еректан, әллә кайдан. *Җәһәннәмнең җиденче катыннан эзләп табарсың...* Казан утлары. **Җәһәннәмнең теге кырыенда** Бик еракта. *Һи, кояш әле, кояш җәһәннәмнең теге кырында әле.* Г.Бәширов. **Җәһәннәм оясы** Начарлык, явызлык чыганагы, әшәкелек, кабахәтлек тупланган урын. *Бу җәһәннәм оясын күптән туздырырга вакыт иде инде.* Казан утлары. **Җәһәннәм өрлеге** Олы, калын гәүдәле, көчле (кеше турында). **Җәһәннәм тәмугы** Коточкыч хәлләр, михнәтгазаплы, түзә алмаслык авыр шартлар. *Шунда ук өзелгән сүзне ялгап китә: – Сез, Сталинградта булмагач, белмисез инде, и-и андагы җәһәннәм тәмугын сөйләсәң, кеше ышанмас.* Х.Камалов. **Җәһәннәм терәве** Башкалар эшләгәндә берни эшләми, нәрсәгә дә булса терәлеп торган озын буйлы кешегә әйтәләр. **Җәһәннәм тишеге** *к.* **җәһәннәм асты**. *Җәһәннәм тишегеннән барып алган чишмә суың ---, оясына качкан елан кебек, минут эчендә юкка чыкса, телеңне генә түгел, терсәгеңне тешләрсең.* Ф.Яруллин. *«Әртис Равил Шәрәфинең ишек токкасы җыйганын җәһәннәм тишегендәге Шри-Ланка ярларында да беләләр икә-ә-ән», – дип сузды Һарун Фәррахыч.* Мәдәни җомга. **Җәһәннәм уты** *дини* 1) Теге дөньяда җәһәннәмдәге ут. *Гөнаһларымны гафу әйлә, җәһәннәм утыннан сакла, дөньяга вә ахирәткә бөтен гамәлләребезне дөресләә!..* А.Хәлим; 2) Утлы күмер кебек, күңелне, йөрәкне әрнетеп торган газаплы уйлар, тынычсызлык, бәла-каза китерер дәрәҗәдәге куркыныч көч. *Җәһәннәм уты да шушында бәреп чыгар дип, кем уйлаган.* Ф.Бәйрәмова. **Җәһәннәм утына салу** Берәр кешене кайгы-борчуга дучар итү, күңелен ярсыту, йөрәген әрнетү. *Ярдәм итәрлек булмагач, кызны җәһәннәм утына салган кебек, сөйләтеп тә тормаска иде.* З.Садыйкова. **Җәһәннәм уты төшү** Күңелне, йөрәкне сагыш-борчу, кайгыхәсрәт биләп алу. *Аның тынычлана башлаган йөрәгенә яңадан җәһәннәм уты төште.* М.Әмир. **Җәһәннәм чите** *к.* **җәһәннәм арты**. *Сиңа нәрсә, сиңа: ике дөнья – бер морҗа. Бүген монда син, иртәгә – җәһәннәм читендә.* Р.Вәлиев. *Шунда, җәһәннәм читендә, кара тайга уртасында, танышы очрап торуын күр әле син аның.* М.Хәсәнов. *Тавышың җәһәннәм читеннән килгән шикелле ишетелә.* Р.Вәлиев. **Җәһәннәм юлы** Газаплы, йончыткыч юл. *Алар, әлегә җәһәннәм юлының кайчан бетәсен дә белмичә, һаман баралар да баралар.* Г.Паушкин

**ҖӘҺӘННӘМЛЕК** *и.* **1.** 1) Җәһәннәм урнашкан урын

2) Җәһәннәмгә керерлек күп гөнаһлы кеше. *Гөнаһлы бәндә шиксез җәһәннәмлек булса кирәк.* К.Насыйри. *Хайваннарга карата рәхимсез булган кеше – җәһәннәмлек, аларга рәхимшәфкать күрсәткән кеше исә җәннәтледер.* Инсан һәм дин

**2.** *с. мәгъ. сир.* Җәһәннәмгә кертерлек, җәһәннәм газапларында яндырырлык, гафу ителмәслек, бик зур. *Хәтта мәчет урынына салынган шайтан оясының бусагасын атлап керүне җәһәннәмлек гөнаһ санаган Камыт Минһаҗ.* Т.Мөбарәков. *Җәһәннәмлек гөнаһ кылган кешеләр дә тыныч кына йоклап ята ала торган заман килде.* Казан утлары

**ҖӘҺӘТ** I. *рәв. гар.* **1.** 1) Тиз генә, бик кызу, кызулап, зур тизлек белән. *Борһан исә нәкъ сәгате, минуты җиткәч кенә, җәһәт коралланып, берүзе яуга ташланырга әзерләнгән баһадирдай, яр читенә чыгып баса.* М.Шабай. *Үзең ал. Минем буем җитми. Йә, җәһәт...* А.Хәлим. *Яшел уйсулыкны, чиста каеннарны күреп рәхәтләнергә өлгермисең, автобус аларны җәһәт үтеп китә – безнең төбәкләрдә дә юллар йөгерек икән.* М.Хуҗин

2) Җитез, өлгер. *Җәһәт иде аның хәрәкәте.* М.Хуҗин. *– Бик җәһәт икәнсең син, Халисә, – диде ул [Мәрьям], кулын аның җилкәсендә тотты. – Алай ансат кына түгел бит әле сәфәр кылу.* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Тиз, кызу. *Сөембикә, ул [Шәвәлиев] әйткәннәрнең бөтен мәгъ-*

*нәсенә төшенеп җитә алмаса да, аңа ачулы караш ташлап алгач, җәһәт адымнар белән чыгып китте...* Ф.Садриев

**ҖӘҺӘТ** II *и. гар.* **1.** *иск.* 1) Пространствода: билгеле бер як, юнәлеш, тараф. *Пенсиям – адәм көлкесе, бүтәнчә бер җәһәттән акча керми.* А.Гыйләҗев

2) Берәр эш, күренеш яки мәсьәләнең билгеле бер ягы. *Энесе Миңнеислам да бит бу җәһәттән агасына охшаган.* Ә.Еники. *Әйтәм: мин яшьлегемдә бөтен җәһәттән дә акыллы, олыларча фикер йөртә алырлык камил бала түгел идем, бар иде, шыттырган, арттырган чакларым да була торган иде.* А.Гыйләҗев. *Әлбәттә, бу җәһәттә җитди үзгәрешләр булмый торып, яшьләрне гыйльми эшчәнлеккә җәлеп итү кыен булачак.* Ватаным Татарстан

**2.** *бәйл. сүз функ.* 1) **җәһәтеннән** *тарт. чыг. кил. форм.* Ягыннан, уңаеннан, уңайдан, уңае белән, берәр нинди очрак белән. *Акыл төзелеше ягыннан да ерак алар, уй-фикер сөрелеше җәһәтеннән дә, яшәгән саен, бер-берләреннән аерыла, читләшә, ерагая баралар.* А.Гыйләҗев. *Дөрес, ул [Гали абый] аларны ашау-эчү, кием-салым җәһәтеннән бер вакытта да кысмады – мул ашатты, әйбәт киендерде.* Ә.Еники. *Конкурс, Татарстанда әдәбият һәм сәнгать елы кысаларында, композиторның 75 яшьлек юбилее җәһәтеннән үткәрелде.* Казан утлары

2) **җәһәттән** *чыг. кил. форм. к.* **җәһәтеннән**. *Вәсвәсәгә бирелүдән мин курыкмыйм, әлбәттә, ул җәһәттән нервларым таза, чыдарлык, әмма шулай да курорт тирәсендә йөргән мондый кызлардан ераграк булуың хәерлерәк...* Ә.Еники. *Чакан вариантын чувашчадан дип карау тарихи җәһәттән акланып бетми.* Р.Әхмәтьянов

3) Сәбәпле, уңае белән. *Кешелек хисләрен, игелеклелек, мәрхәмәтлелек тойгыларын югалтмас өчен моңлы булмый мөмкин түгел. Г.Рәхимнең «Елагыз!» исемле шигыре бу җәһәттән аеруча гыйбрәтле.* Р.Миңнуллин. *Шул җәһәттән караганда, генерал-майор Карның тарихы бик кызыклы.* Я.Винецкий

**ҖӘҺӘТЛӘНҮ** *ф.* Кызулану, ашыгу, тизлекне арттыру, тизрәк кылану. *– Карале, вәкил иптәш, – дип, Бикмураев каршына җәһәтләнеп барды Бәйрәмхан.* М.Хуҗин

**Җәһәтләнеп китү** Кинәт, ниндидер сәбәпләр аркасында җәһәтләнү. *Малайның сүзләре хәзрәтне элгәре буталчык, салмак, аннары кинәт җәһәтләнеп киткән уйларыннан бүлдерде: «Зур эш эшләнде бүген».* М.Хуҗин

**ҖӘҺӘТЛӘТҮ** *ф.* Кызулату, кыздыру, ашыктыру. *Барый атларны җәһәтләтеп куа башлады, ничек тә барып өлгерергә, ничек тә күреп калырга иде бит кызны.* Казан утлары

**ҖӘҺӘТЛӘ́Ү** *ф.* Кызулау, тизләтү; ашыгу, тизлекне арттыру. *Сәгыйд, урам буйлап мал йөкләткән атларны вә иптәшләрен куып җитәр өчен, җәһәтләп барганда, бер ишегалдында бер станок белән бер кешенең чүлмәкләр ясап утырганын күрде.* Г.Гобәйдуллин. *Җәһәтли дип, бер дә ашыкмадылар әле....* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Малай картны җитәкләп тә алды, җәһәтләп, урам аша алып та чыкты.* А.Хәлим

**Җәһәтләп китү** Бераз, берникадәр, кинәт җәһәтләү. *Аннан тагын җәһәтләп китеп, [Сираҗетдин] ишектән чыга башлый.* Г.Камал. *[Надир] Үзе дилбегәне кагып җибәрде, күк айгыр җәһәтләп китте.* К.Тимбикова

**ҖӘҺӘТЛЕК** *и.* Җитезлек, кызулык, тизлек, өлгерлек. *Бәйрәмхан әйткәндәй, әшәкелек кылуда җәһәтлеккә һәм үҗәтлеккә кем шушылай ныклап өйрәтте икән бу бәндәне...* М.Хуҗин. *Тегесе дә шундый ук җәһәтлек белән каршы төште: – Алай димә, кем, мелла, авызыңны да ачма берүк.* М.Хәсәнов. *Сәет, яшьләр җәһәтлеге белән урыныннан сикереп торып, уң кулының имән бармагын өскә күтәрде.* Т.Галиуллин

**ҖӘҺЕД** *и. гар. иск.* Тырышлык, иҗтиһат. *Китмәсен бушка бәнем җәһдем вә мәшгулиятем.* Г.Тукай. *Тырышма, эзләмә юкны эрәмгә, Табылмас – юк! Әрәм җәһдең, әрәм лә.* Г.Тукай

**ҖӘҺЕ́Д ИТҮ** *ф.* Тырышу, тырышлык күрсәтү. *Инде үзеңнең нәкышең юлы белән аны белмәгә җәһед ит, аның шул сурәтләр нәкъкашлегe турында фикер кыйл.* К.Насыйри

**ҖӘҺЕ́Д КЫЛУ** *ф. к.* **җәһед итү**. *Вакытның кадерене белгел, Җәһед кыйл һәр минутында.* Г.Сәмитова

**ҖӘҺЕЛ** *и. гар. иск.* Наданлык, томаналык, белемсезлек; аңгыралык. *Инде файда күзләмәк – гакылга дәлилдер; вә бу кадәр хәтәрләргә кермәк – җәһел вә наданлыкка дәлилдер.* К.Насыйри. *Җыелган кешеләрнең --- гыйлем вә җәһел мәсьәләсе хосусында язылган тау-тау кәгазьләре падишаһның башын гына чуалталар иде.* Г.Тукай. *Мин баскан «җәһел» утын Су сибеп сүндерсәнә!* Ш.Бабич

**ҖӘЮ** *ф.* 1) Җыеп яки төреп куелган берәр нәрсәне (тукыма, кәгазь һ.б. әйберләрне) сүтеп җибәрү яисә нинди дә булса өслеккә таратып салу. *Җәеп кызыл байракларны, Сафларга баса алар.* Г.Хуҗиев. *Газетасын сүтте дә яшел, кара, кызыл бизәкләр төшерелгән шәльяулыкны, селкеп җәйгәч, әбисенең башына япты.* М.Хуҗин. *Ә егет, чынлап та, бераз гына шөребе какшый башлаган кешедәй, аны-моны сизмичә, яулыгын бер җәеп карый, бер йомарлый, битенә дә куеп ала, иснәгән кебек тә итә, гүя сихерләп маташа.* Ә.Еники

2) Утыру, яту яки башка максат белән берәр өслеккә яисә җирлеккә нәрсә дә булса түшәү, салу. *Северке белән кырып-кырып юган сап-сары идәнгә ап-ак, йомшак яңа чыпта җәйде.* Ш.Шәйдуллин. *Зитта бик җитез йөренде, мех палас өстенә кәгазьләр җәеп, табын шикелле нәрсә әзерләде.* Х.Камалов. *Кече манарага җитәрәк, үлән өстенә намазлык җәеп намаз укучы 15–16 яшьлек егетне күреп, Әсфирә туктап калды.* Т.Миңнуллин // Малтуар һ.б. астына салам, печән түшәү. *[Сыер] Ашамаса, төнгелеккә астына җәярсең: җир салкын бит әле, җылынып җитмәгән.* З.Зәйнуллин

3) Йоклау өчен ятак әзерләү. *Кайткач, Рәмзия ирен җәйлап кына чишендерде, даруларын эчерде һәм урын җәеп яткырды, аннары аның караваты читенә килеп утырды.* Б.Камалов. *Малайлар беренче көннәрдә урынны идәнгә җәеп йокладылар.* Казан утлары

4) Камырдан юка җәем ясау. *Барысы да әзер булгач, Кәримә камырны җәйде, бәрәңге турап, ит белән аралаштырды да суган турап салды, эчлекне тутырды, өске камырны каплап, бөтерә-бөтерә, ефәк бау кебек ишеп китерде.* М.Хәбибуллин. – *Пилмәнебез тәмле булыр, Үзең ясап аша, – ди. Әби җәя камырын, Бабай итен салыша.* К.Булатова

5) Вак яисә бөртекле әйберләрне, киптерү өчен, юка катлам итеп тарату. *[Бригадир кыз Фәйрүзә] Орлыкларны бер савыттан Бер савытка тутыра. Әле суда чылата да Әле җәя, киптерә.* М.Җәлил. *Бер чиләк чем-кара карлыганны юды да юып үтүкләгән юрган тышлыгына җәйде Фирая, кипсеннәр шунда иркенләп!* Казан утлары

6) Төзелеш материалы белән каплау, түшәп, нәрсә дә булса ясау. *Җиңел эш түгел асфальт җәю, көн азагына таба җеп өзәрлек хәл калмый, көчкә аякта басып торасың.* М.Хәбибуллин. *--- алар фанер, пластмасса, идәнгә җәяргә паркетлар да алып килгәннәр иде.* Г.Ахунов. *Туктаусыз агым булып килгән бетонны кай арада [бетончы егетләр] җәеп, тигезләп өлгерәләр!* Казан утлары

7) Кул-аяк, бармакларны яки канатларны киң итеп як-якка җибәрү. *Мария, ике кулын җәеп, кечкенә бүлмәсенә күрсәтте.* Б.Камалов. *Басарый абзаң идән уртасына аякларын киң җәеп баскан...* М.Хуҗин. *Без килеп җиткәндә, ләкләк җансыз, җирне кочкандай, канатларын җәеп, хәрәкәтсез ята иде инде.* Ә.Гаффар

8) *күч.* Авызны, иреннәрне бик зур итеп ачу, еру. *Ул, елмайган кебек, иреннәрен җәеп, кызыл уртларын һәм очлы ап-ак тешләрен күрсәтеп, авызын яман зур итеп ачып ырылдый.* З.Зәйнуллин

9) Әйберләрне берәр өслеккә таратып, тезеп кую. *Апуш белән Мөхәммәтгариф, посылканы алып кайту белән, ашамлыкларны өстәлгә җәеп, сөенә-сөенә ашыйлар.* Г.Кайбицкая. *[Ханым] Пароходның арткы очына җиткәч, тукталып, ихтыярсыздан түбәнгә карасa, әлеге таныш яшьләрнең койрыкта, тимер идәнгә газеталардан табын җәеп, күңелле генә ашап-эчеп утыруларын күрде.* Ә.Еники

10) *күч.* Ябалдашлану, киңәеп, тармакланып китү. *Яфракларын җәйгән тирәкләр ---.* А.Әхмәт. *Рәхимә түтинең күзе яр буенда ботакларын киң җәеп, су өстенә салындырып торган бөдрә өянкеләргә төште.* З.Фәйзи. *Авыл очында, тегермән буасының ярына тезелешеп үскән һәм күксел бәскә төренгән мәһабәт тирәкләр, ботакларын киң җәеп, бөтен яр буен караңгылап торалар.* Ә.Еники

11) *күч. сөйл.* Сүз яисә хәбәр тарату, башкаларга җиткерү, ирештерү

**Җәеп алу** Тиз арада җәю

**Җәеп бару** Торган саен ныграк җәю. *Сөендекләр, Гегель Әфләтүновичлар, Псих Сәлимгәрәевичлар милләтнең бәгыренә урнашып, тамыр җәеп барган яңа мәҗүси советчыл традицияләр җирлегендә үсеп чыкмадылармы?* А.Хәлим

**Җәеп бетерү** Барысын да җәю; җәю эшен тәмамлау. *Безнең алга бу айда куелган бурычлар: су агызу каналын казып һәм тимер юл өстенә комны җәеп бетерү.* А.Алиш. *Хәтирә үзенә урын җәеп бетерде, ләкин ятарга ашыкмады, Сабираның аяк очына килеп утырды.* М.Әмир. *Йокы бүлмәсенең идәненә ламинат җәеп бетергәч, Фазыл җиңел сулап куйды.* Сөембикә

**Җәеп җибәрү** 1) Кинәт җәю. *Шәрә килеш караңгы алачыкка чыгып баскач, Габдулла, кинәнеп, кулын җәеп җибәрде, киерелеп алганда, колгадагы себеркеләргә орынды.* Ә.Гаффар. – *Кызганычка, юк! – Һәм ул, татар теле укытучысы Мөхетдин абзый кебек, кулларын җәеп җибәрде.* Г.Әпсәләмов

2) Җәю белән бәйле берәр эшне башкарып чыгу, җәяргә өлгерү. *Урамның урта бер җиренә дамба күтәрсәләр, асфальт та җәеп җибәрсәләр, йорт аллары чирәмгә күмелер иде.* Г.Ахунов

3) *күч.* Берәр эшне киң колач белән башкару һәм алып бару

**Җәеп йөрү** Әле, хәзер җәю, җәю белән мәшгуль булу. *Рәдифне алып кайтып, җитәкләп, өйләренә керткәндә, әнисе Мәсрүрә апа үзенә урып җәеп йөри иде.* В.Нуруллин

**Җәеп кую** Алдан җәю, җәйгән хәлгә китерү. *[Гафур] Аптырагач, торып, ут яндырмый гына чишенде, карчыгы җәеп куйган йомшак урынга – киң агач караватка менеп ятты.* Җ.Рәхимов. *Газаплы уйлар эчендә бөтерелеп, әнкәй җәеп куйган салкын түшәккә кайтып ятам...* Х.Ибраһим. *Ә [кыз] исенә килеп кайтырга чыкканда, төн үзенең кара җәймәсен күктән җиргә кадәр җәеп куйган булган.* Ф.Яруллин

**Җәеп салу** 1) Тиз яки тулысынча җәю, җәеп кую. *Полк командиры, шактый өлкән яшьтәге, озын буйлы, кара мыеклы кеше, өстәлгә картасын җәеп салды да безне үз янына чакырды.* Г.Галиев. *[Хөсәен] Чәй кайнап чыкканчы дип, китапларын өстәл өстенә җәеп салды, хатыны яткан якка ара-тирә караштыргалап укый башлады.* А.Расих. *Хәбип миңа тарих, география буенча ярдәм итә, идәнгә картаны җәеп салабыз да, сузылып ятып, иртәгәсен минем дәрескә кирәк булачак вулкан, тау, күлләрне эзлибез.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Барысын да яшермичә сөйләп бирү, ачыктан-ачык әйтү. *Килеп керү белән, бар хәбәрне җәеп тә салды Сәмигулла.* Юлдаш

**Җәеп ташлау** Тиз-тиз, аннан-моннан җәю. *Ябылмаган сүзлек мәрткә киткән, Китап йоклый укый башлаган. Күпме гәҗит, журнал борсалана, Әштер-өштер җәеп ташлаган.* И.Гыйләҗев

**Җәеп тору** Әле, хәзер җәйгән хәлдә булу. *Тегермәннәр канатларын җәеп торалар иде.* А.Алиш. *Юлыгызда фәрештәләр Канатларын җәеп торсын.* Л.Шагыйрьҗан. *Аңа әйтерсең лә даншөһрәт колачын җәеп тора.* Р.Миңнуллин

**Җәеп чыгу** Барысын да, башыннан ахырына кадәр җәю

**Җәеп яту** Әле, хәзер, сөйләү моментында җәю. *Авылның үзәк урамына асфальт җәеп яталар.* Т.Әйди

**Җәя бару** Тагын да ныграк җәю; торган саен күбрәк җәю. *Ул биемәскә итенде, аннары, гайрәт белән кулын селтәде дә, күзен йомып һәм башын*

*чайкап, әкрен-әкрен кулларын җәя барып, түгәрәкне кысрыклап диярлек, киң адымнар белән йөреп китте, алдагылар, аңа юл бирер өчен, чигенәрәк төште, арттагылар, күрер өчен, алгарак сузылдылар.* Ә.Гаффар. *Әхсән Баянов – безнең хәзерге әдәбиятыбызда күренекле урын алган, елдан-ел иҗади колачын киң җәя барган язучыларыбызның берсе.* Р.Даутов

**Җәя башлау** Җәяргә тотыну. *Этине күрү белән, без, атылып кереп, әнигә әйтәбез. Әни ашъяулык җәя башлый.* М.Юныс. *Югыйсә республикабызда әлеге [чирәмдәге хоккей] спорт төре 1980 елда Мәскәүдә узган Олимпия уеннарыннан соң гына чын-чынлап тамыр җәя башлады.* А.Гафиятов

**Җәя бирү** Җәюен дәвам итү. *Мәүлетдин, ике кулын ике якка җәя биреп, бөтен битен балкытып елмайды.* З.Зәйнуллин

**Җәя килү** Күптәннән, электән үк, системалы рәвештә җәю. *Табигатьтәге тигезлекне, җир-сулар әйләнешен бозуга аваздаш булып, игенчене җирдән биздерү, үткәнне инкяр итү кебек ямьсез күренешләр тамыр җәя килде.* М.Вәлиев

**Җәя төшү** Бераз җәю. *Кыз киң, озын итәген җилфердәтеп, аны ике яктан бармак очлары белән генә чеметеп җәя төшеп, иплән кенә килеп, кәнәфигә утырды.* К.Тимбикова

**ҖӘЮЛЕ** *рәв.* Җәелгән хәлдә, түшәлгән килеш. *Түгәрәк өстәл өстендә Җәймәң җәюле торсын.* Г.Тукай. *Авыр, әнигә бик авыр. Ничә барсаң, урыны җәюле, йөзе моңсу булыр.* Э.Шәрифуллина

**ҖӘЯ** *и.* **1.** 1) Укны еракка аттырып җибәрү өчен, агачны һ.б.ш. бөгеп, бау белән нык итеп тарттырып бәйләнгән борынгы сугыш һәм ау коралы. *Болар килеп туктауга, тимерләп ясалган авыр капка ачылды; ук, җәя тоткан кешеләр капка өстендәге манараның тышкы ныгытмаларына чыгып тезелеп әзерләнделәр вә аларның башлыгы кем вә ни өчен килгәнлекләрен сорады.* Г.Гобәйдуллин. *Җәяләр киереп Җиде ук атканда, Җиде ят бер уйда: – Һәлакәт – башкага!* Ф.Мөслимова. *Шул чорның иң камил сугыш кораллары, бигрәк тә ук һәм җәяләр, аларда гына була.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Иярнең җәя сыман (*1 мәгъ.*) кырые, очы,ияр кашы. *Иярнең көмеш белән уратып алынган биек җәясе ай яктылыгына каршы --- балкып китте.* Ш.Камал. *Дагалар җиргә тигән саен, күз яшьләре ияр җәясенә тамалар иде.* Р.Батулла

3) *лингв.* Җөмләдә өстәмә сүз һәм ремаркаларны башка кисәкләрдән ике яклап аеру өчен кулланыла торган дуга яки ярым квадрат формасындагы тыныш билгесе. *Җәяләр эчендә булса да әйтеп китик: гомеренең соңгы елларын түгәрәкләп килгәндә, Г.Таһиров «Шүрәле» балетының 141 битлек партитурасын композиторның энесе Мирсәет Яруллинга үз куллары белән тапшыра.* Р.Низами. *Ә инде күпнокталар һәм җәяләр эченә алынган өндәү билгесенә җиткәндә, аның йөрәге күкрәгеннән бәреп чыгарга ашкынгандай тибәргә тотына иде.* Р.Мөхәммәдиев. *«Әсәрне уку барышында җәя эчендәге сүзләргә ныграк игътибар итегез», – диде Ләйлә Камилевна.* Ялкын

4) *мат.* Үз эчендә төрле гамәлләре булган катлаулы санны берләштереп бирә торган, ярым дуга, квадрат яки фигура формасындагы математик билге. *Квадрат җәяле мисалларны укучылар бик җиңел чишәләр.* Мәгариф

5) *тех.* Йон тетү машинасында нык киереп тарттырылган баудан гыйбарәт тетү җайланмасы

6) *тех.* Пычкы, борау кебек эш коралларында җәя сыман җайланма

**2.** *с. мәгъ.* Җәя кебек; киерелгән, тартылган, җәягә охшаш булган

◊ **Җәя бавы кебек киерелү** *к.* **җәядәй киерелү**. *Һәркемнең нервлары җәя бавы кебек киерелгән.* Ш.Хөсәенов. **Җәя буе** Җәядәге бар киеренкелегенә тартылган ук белән, ул атылып, аның очы барып төшкән аралык. *Яманнан җәя буе кач.* Әйтем. **Җәядәй киерелү** Киеренке халәттә булу. *Кинәт аның бөтен йөзен, күз-кашларын, маңгаен, җәядәй киерелгән яңакларын ачып – яктыртып, ниндидер нур сызылып үтте.* А.Гыйләҗев. **Җәядәй тартылу** Киеренке халәттә булу. *Тукталып тын алыр чама юк – Заманнар җәядәй тартылган.* Х.Әюп. **Җәя җебе булып тартылу** *к.* **җәядәй киерелү**. *– Фәррахетдин улым, – дип, кискенлеккә җәя җебе булып тартылырга ирек бирмәде Сәхәрия, – ризык янына утыр әле.* М.Хуҗин. **Җәясе бушау** Сүз көрәштерүдә, бәхәстә көче бетү, җиңелә башлау. **Җәясен тарту** *к.* **җәясен тартып карау**. **Җәясен тартып карау** Кешенең уй-фикерен, мөнәсәбәтен, планнарын белү өчен, сынап яки хәйләләп сораштыру. **Җәясе тартылу** Нерв киеренкелеге булу. *Әмма Уралның җәясе нык тартылган булып чыкты.* Т.Галиуллин. **Җәя соң чиккәчә тартылу** Нервлар какшаган һәм соң чиккәчә киеренке булу. **Җәя сыман киерелү** *к.* **җәядәй киерелү**. *Минрахманның җәя сыман киерелгән авызында, әчтә, тамагының караңгы төбендә кармак сыман селкенгән кече телен күреп, Канәгать үзе телсез калды диярлек.* А.Хәлим

**ҖӘЯКЛӘ́Ү** *ф. диал.* Ияккә сугу. *Янәсе, ач тотып карарга кирәк, эшләтергә, каршы сүз әйтсә, җәякләргә!* Н.Дәүли. *[Караколак] Ачуы килсә, җәякләргә дә күп сорамый.* Н.Дәүли

**ҖӘЯЛӘНҮ** *ф.* Җәя формасын алып, дугаланып тору. *[Мотаһар] Җәяләнеп төшкән кашларын --- салкын су белән сыпырды.* А.Хәлим

**Җәяләнә төшү** Тагы да бераз җәяләнү

**Җәяләнеп бетү** Тәмам җәяләнү

**Җәяләнеп китү** Кинәт җәяләнү. *Гаҗәпләнүдән, кашлары сикереп җәяләнеп китте*

**Җәяләнеп тору** Һәрвакыт, даими җәяләнгән хәлдә булу

**ҖӘЯЛЕ** *с.* 1) Җәя (*1 мәгъ.*) белән коралланган, җәясе булган. *Айгырны бай киемле, әмма җәяле зат җитәкләгән.* Б.Рафиков

2) *мат.* Җәяләр (*4 мәгъ.*) белән бирелгән, җәя эченә алынган. *Җәяле саннар*

3) *тех.* Җәясе (*5 мәгъ.*) булган (*җайланма, эш коралы*). *[Хәмит абзый:] Иптәш! Иптәш! Миңа җәяле*

*пычкы полотносы кайтты. Нибары икәү.* М.Мәһдиев. *Ындыр капкасында дәү җәяле авыр йозак эленгән икән.* А.Гыйләҗев

**ҖӘЯ́Ү** *рәв.* **1.** 1) Үз аягы белән, атлап. *Атка атланып чыгып киттем, җәяү кайтып киләм.* М.Әмир. *Соңгы өч тиенен юл чатында утырган гарипкә биреп, үзе, трамвайга утырмыйча, җәяү китә торган кеше иде Баграт.* М.Юныс. *Басу юлыннан җәяү атлаганда, я булмаса урманда җиләк җыйганда, мин, кычкырып, шуны [Г.Тукайның «Шүрәле»сен] сөйләп чыгам.* Казан утлары

2) *күч.* Хәерче хәленә төшеп; бар булган милекне югалтып. *Тормыш беркадәр тигезләнде кебек – элеккедәй череп баючылар да, кара җәяү калучы ярлылар да күренми диярлек.* Ә.Еники

**2**. *и. мәгъ.* Үз аягы белән атлап баручы, җәяүле кеше. *Җәяүнең сукмагы тар, алай да турылыгы бар.* Мәкаль

◊ **Җәяүгә калдыру** Бөлдерү, малмөлкәтсез калдыру, тәмам фәкыйрьлеккә төшерү. **Җәяүгә калу** *иск.* 1) Атсыз калу, аттан мәхрүм булу; 2) Машинасыз, транспортсыз калу; 3) Алда барудан туктау, беренчелектән төшү, өстенлекне югалту. *И-и, балалар, атсыз, эшегез җәяүгә кала бит инде болай булгач.* З.Зәйнуллин; 4) Бар булган милекне югалтып, хәерче хәлендә калу. *Әгәр болай яуса, тагын бер кара җәяүгә калачакбыз бит.* М.Мәһдиев. *Балачагасы, мал-туары белән кемнең кычкырып янасы, йә булмаса, кара җәяү каласы килсен?* Г.Бәширов. **Җәяү йөрү** Җил яисә буран карны, җирдән күтәрми, астан себереп йөртү

**ҖӘЯҮЛӘП** *рәв.* Җәяү, җәяү килеш. *Болар машиналары белән авыл читендә кала, ә хатыннары, җәяүләп кенә, югары очка – Җантай әбинең йорты тирәсенә атлый.* Р.Зәйдулла

**ҖӘЯҮЛӘТӘ** *рәв.* Җәяү, җәяү генә. *Без күпер төбеннән җәяүләтә Бозаулыкка барырга уйлыйбыз.* Ш.Усманов. *[Хисами:] Мукловкага – җәяүләтә, аннан атта – стансага, – диде дә җылы мич башына менеп ятты.* К.Нәҗми

**ҖӘЯҮЛӘТЕП** *рәв.* Җәяү, җәяүләтә, җәяү килеш. *Тимер юл станциясеннән ике ротаны җәяүләтеп алып килгән капитан аларны штаб янында туктатты.* З.Зәйнуллин

**ҖӘЯҮЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* **1.** Җәяү атлау, җәяү хәрәкәт итү, җәяү йөрү. *Петрухлар авылына, җәяүләгәндә дә, бер тын алуга – ярты сәгатьтә барып җитәсең: ерак түгел.* М.Хуҗин. *Чаллыдан Зәйгә үк чыгып киттем. Җәяүлим!* А.Гыйләҗев. *Арыган аяклар белән биш километр җирне тәпи-тәпи җәяүләргә туры килә, диләр апайлар...* Ә.Еники

**2. җәяүләп** *рәв. мәгъ. к.* **җәяүләтеп**. *Лебедев белән Әхмәй, иске җил тегермәне янына күтәрелгәч, атларыннан төшеп, җиде җил кочагында шул таба карап тордылар, --- аннан, җәяүләп, җай гына түбәнгә кузгалдылар.* Ф.Мансуров

**Җәяүли бирү** Җәяүләвен дәвам итү

**ҖӘЯҮЛЕ** *с.* **1.** 1) Җәяү йөри торган, җәяү барган. *Иярле ат артыннан юлда җәяүле ир кеше пәйда булды.* Ш.Шәйдуллин. *Чөнки җәяүле кешенең яшен аткычы бармы-юкмы икәнен ерактан ук белеп була.* Р.Батулла. *1944 елның сентябрь башларында Шакир ташы янындагы юлда җәяүле солдат күренде.* З.Зәйнуллин

2) Җәяү узыла, йөрелә торган. *Җәяүле, эссе тузанлы егерме чакрымлы юлга чыктылар.* М.Мәһдиев

3) Атлы һ.б.дан аермалы буларак, җәяү хәрәкәт иткән. *Йөгер тиз! Әйдә, башла, и җәяүле гаскәр, атларга!* Г.Тукай. *Кырыклап олау, ике йөзләп кеше: беразы – ат өстендә, ә күпчелеге – җәяүле гаскәр...* Ә.Еники

**2.** *и. мәгъ.* 1) Гадәттә, ерак араларга җәяү йөрүче кеше. *Урамнарда, караңгылыкны ерып, җәяүлеләр йөриләр.* С.Җәлал. *Ә моннан турыга җәяүлеләр өчен сукмак барлыгын Сәгыйть белә иде, һәм ул шунда омтылды.* Ф.Гайнуллин. *Җәяүлегә янчык та авыр, дигәндәй, ике поттан артык күтәрә алмыйсыз инде.* З.Зәйнуллин

2) Пехотачы, җәяү хәрәкәт итә торган гаскәри; пехота солдаты. *Юлын бүлеп дошман танкларының, Биш җәяүле ятты чокырга.* М.Җәлил. *Иң әүвәл, машиналарга төяп, җәяүлеләрне чыгардылар, аннары – туплар, танклар, алардан соң гына «катюшалар» узды.* Г.Ахунов. *Агыла да агыла гаскәр: пулемётлар, туп таккан атлар, җайдаклар, җәяүлеләр ---, галәмәт тә зур гаскәр була бу.* Р.Батулла

3) Җәяү хәрәкәт итә торган гаскәр. *Болар арасында күпчелеге – җәяүле, калганнары исә атлылар, тупчылар, сапёрлар иде.* Г.Бәширов

4) *күч. иск.* Аерым бер өлкә буенча аз мәгълүматлы, дилетантларча фикер йөртүче кеше. *Мин җырда, көй бабында җәяүле түгелмен. Русның театрында, концертларында, опералярында булганым бар.* Г.Ибраһимов

◊ **Җәяүле буран** Карны югары күтәрми генә җирдән себерткән буран. *Кыр буйлап җәяүле буран себерелә, әйтерсең күзгә күренми чапкан ак аргамакның яллары дулкынлана.* Г.Әпсәләмов. *Болытлы күк йөзе баш өстенә ук төшеп җиткән. Җәяүле буран себертә.* Г.Ахунов. *Кышкы каникуллар җитәрәк, җәяүле буран себереп торган көннәрнең берсендә, малай мәктәпкә килми.* Ф.Шәфигуллин. **Җәяүле йокы** Аяк өсте йоклап йөрүчегә карата әйтелә

**ҖӘЯҮЛЕ́ АДВОКАТ** *и.* Берәр кеше яисә коллектив йомышы белән йөрүче, юллаучы; *русчасы:* **ходатай**

**ҖӘЯҮЛЕК** *и.* **1.** Җәяү йөрү, җәяү йөрергә калу. *Ат аягын кызганган җәяүлектән котылмас.* Мәкаль. *Җәяүлек башыңа төшкәч, якын җиргә дә җитә алмассың.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Җәяү дә барып җитәрлек, бик озын булмаган. *Җәяүлек юлга чыксаң, аш-җәймәңне калдырма.* Мәкаль

**ҖӘЯЧЕ** *и. тар.* Җәя белән коралланган сугышчы. *Моның өчен һәр җәяче ун ук әзерләп куйды. «Һа-айт» дип әмер ишетелгәч тә, йөзләгән җәяче бер очтан бик тиз генә унар укны бер урынга атарга тиеш иде.* Р.Батулла

**ҖЕБАШ** *и. диал.* Мич агарту өчен, арыш онына акбур кушып ясалган акшар. *Мичне җебаш белән агарту*

**ҖЕБӘРӘК** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, туры шома сабаклы, озынча яссы яфраклы, себеркәчкә тупланган укмаш чәчәкле, яхшы мал азыгы дип исәпләнгән күпьеллык үлән

үсемлек; *русчасы:* **мятлик.** *Болынны җебәрәк баскан*

**ҖЕБЕГӘН** *с.* 1) Сыеклык тию аркасында йомшаган, юешләнеп изрәгән. *Ашханә өстәлләре бәрелештән соңгы сугыш кырын хәтерләтә иде: майлы соуска буялган тәлинкәләр, боткага баткан кашыклар, шулпага җебегән икмәк кисәкләре...* М.Юныс. *[Үрдәкнең] Икенчесе кыргыйрак, куркаграк булып чыкты: ничек кенә чакырса да, Гадел янына килмәде, алдындагы җебегән икмәк кисәкләрен дә үрелеп кенә чүпләп бетерде.* Г.Гыйльманов

2) Йомшарган, йомшак хәлгә килгән. *Җебегән тиреләрне озын-озын колгаларга асып, кешеләр бер йорттан икенчесенә ташыйлар.* Ә.Фәйзи. *Хәзер әнә юлның кары көпшәкләнгән, чана эзләрендәге тизәк-саламнар җебегән, йомшаган.* Р.Низами

3) *күч.* Уңмаган, булмаган, булдыксыз. *Зуфирә идәндә яткан үкчәсе ачык ак туфлине – таныш туфлине! – иргә таба тибеп очырды: – Син дә йөрисең шунда «мин – ир» дип, җебегән!* М.Маликова. *Гади тормышта куркак, җебегән адәмнәр дә, сәгате суккач, каһарманлык кылып куйгалыйлар түгелме?!* А.Гыйләҗев. *– Утыр! – диде мулла, кырыс кына. – Җебегән! Шулай сугалармыни? Менә ничек кирәк! – диде дә, чалт итеп, Әхмәтзакирның яңагына ялтыратып алды.* М.Әмир

4) *күч.* Үтә йомшак табигатьле, көчсез; юкка да кәефе кырылып елый торган. *Безгә кызык, арба үрәчәсенә чытырдап ябышып, җебегән малай түгеллегебезне раслыйбыз.* Казан утлары

◊ **Җебегән авыз** 1) Уңмаган, булдыксыз кеше. *[Факиһә:] Һи аңгыра! Җебегән авыз! Мин сиңа шулай дип әйтергә куштыммыни?* Г.Камал. *Балаң булса, ут булсын, выжлап очар ук булсын; Җебегән авыз, пешкән шалкан – Бар булганчы юк булсын.* З.Бәшир. *«Яратам, шуңа кирәк» диген, җебегән авыз...* Т.Миңнуллин; 2) Ваемсыз, игътибарсыз. *Әллә кайчангы идән асты кешесе, диләр, җебегән авыз икән.* Г.Ибраһимов. **Җебегән арыш боламыгы** Булдыксыз, оешмаган, уңмаган кеше. *– Син, – диде, – мәхлук җан иясе, бердәнбер энеңә күз-колак булып тора алмадың, җебегән арыш боламыгы, черегән көпшә, – диде.* С.Поварисов. **Җебегән арыш салмасы** *к.* **җебегән арыш боламыгы**. *Җебегән арыш салмасы! Мин соң андыйларга бирешәмме?* Г.Камал. **Җебегән салма** *к.* **җебегән арыш боламыгы**. *Ни карап торасың, җебегән салма! Никахлы хатының чит ир кочагында торганын күрмисеңмени?* М.Фәйзи. *[Халидә] Үзем җебегән салма булгангамы, кыю, тәвәккәл ирләрне яратам шул.* А.Гыйләҗев

**ҖЕБЕГӘНЛЕК** *и.* 1) Җебегән булу. *Сохариның суда озак ятып җебегәнлеге күренеп тора*

2) *күч.* Җебегән булу, берәр нәрсәне эшләргә көч-сәләт җитмәү; булдыксызлык. *[Нургали] Һәртөрле җебегәнлекне, салкынлыкны, җавапсызлыкны кызган тимер белән көйдерәчәк.* Ә.Еники. *«Үлем тырнагыннан ничә тапкыр ычкынганны, грипкка бирешеп тору җебегәнлек булыр», – дип, үз-үзен әйдәкләү ягын карады Вәсим.* Ә.Моталлапов

3) Игътибарсызлык, ваемсызлык, гамьсезлек. *Йозакка кул тидергән генә иде, йозак үз-үзеннән ачылды да китте. Мондый җебегәнлекне күреп, кәефе китте Гарифулланың.* Г.Минский

**ҖЕБЕК** *с. сөйл.* **1.** 1) *к.* **җебегән**. *Ул сердәше Гөлнараны, аның әкрен-әкрен рухы сына барган җебек ирен күз алдына китерде.* А.Гыйләҗев

2) Боек, моңсу, төшенке күңелле. *Вилданның күңеле җебек булган кебек, өс-башы да җебегәндә.* Г.Толымбай. *Мин нindидер ярым йокылы, җебек халәттә идем.* Т.Кәримов

**2.** *и. мәгъ.* Булдыксыз кеше. *[Вил:] Эх, егет, егет... егет түгел син, җебек...* Р.Ишморат

**ҖЕБЕКЛӘНҮ** *ф. сир.* Җебегәнлек күрсәтү, җебеп төшү

**ҖЕБЕКТЕРҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **җепкертү**. *Күпкә китсә, майлы ботка да җебектерә.* Әйтем

2) Нинди дә булса күңелсез күренеш еш кабатланып йөдәтү, туйдыру, биздерү. *Көн дә ызгыш, ялан әр Җебектерде инде җанымны.* Я.Емельянов

**ҖЕБЕН** *с. сөйл.* **1.** *к.* **җебегән**

**2.** *и. мәгъ.* Булмаган, оешмаган кеше. *Бер тамчы суга батып, чебен үләр, бер стакан аракыга батып, җебен үләр.* Мәкаль

**ҖЕБЕНЛЕК** *и. сөйл. к.* **җебегәнлек**. *Җебенлек белән саранлык – яман холык ирләргә.* Мәкаль

**ҖЕБЕНҮ** *ф.* 1) Су яки яңгырга чылану, юешләнү. *Явымнар белән җебенеп, кояшка ашалып төсләрен югалткан палаткалар да нурны шуннан [электромагистральдән] алалар.* М.Хөсәен. *Атасына охшап, Тимерҗан бик яшьли балык тотарга, җәнлек эзәрлекләргә һәвәсләнеп киткән иде бугай... Шуңа күрә Локман карт аны кул-аягы тырналып, өс-башы җебенеп кайтса да орышмый.* Ә.Еники

2) Су, дым, җылылык тәэсирендә йомшару, изрәү. *Юллар тәмам җебенгән*

3) *күч. диал.* Йомшап, изрәп, рәхәтлеккә талу, рәхәтлек тою. *Гайбәт чүлмәкләре тула башлагач, әлеге дус дүрт хатын янә җебенергә җыеналар.* З.Хөснияр

**Җебенә төшү** Беркадәр, бераз җебенгән хәлгә килү

**Җебенеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җебенү; бөтенләй җебенгән хәлгә килү. *Өйгә кергәч тә, Мәдинә, бирге бүлмәдә генә туктап, Гатауллага җебенеп беткән саргылт конверт төртте.* К.Нәҗми

**Җебенеп тору** Әле, хәзер җебенгән хәлдә булу

**ҖЕБЕТҮ** *ф.* 1) Каткан әйберне суга яки башка сыеклыкка салып йомшарту яки изү. *Ашыйсым килсә ---, кухнядагы икмәк катыларын суда җебетәм дә шулар белән тамагымны туйдырам.* Ш.Камал. *Төрле механизмнар ярдәмендә, су көче белән балчыкны җебетәләр.* Г.Лотфи. *[Сукбайлар] Җәелеп китеп сөйләшмичә генә, каткан ипи телемнәрен җебетә-җебетә, шулпа чөмерделәр.* Г.Гыйльманов

2) *махс.* Тире, сүс, җитен һ.б.ш. нәрсәләрне эшкәртү алдыннан, билгеле бер вакытка суда яки башка сыеклыкта тотып йомшарту. *– Җәйгә чыксаң, баса җебетергә, җитен чылатырга тилмереп торасың: су табып булмый... –*

*диде бер ак сакаллы карт.* И.Гази. *[Йосыф] --- кабыкны күлдә җебетеп, мунчала каезлады.* А.Гыйләҗев

3) Чылату, юешләндерү. – *Әнә анда кыйбладан болыт кузгалды, болай зарланып утыра торгач, без арышны җебетмик, чәчрәсең аннары, – дип, кулына көрәк алып, [Сафа] арышны суыра башлады.* М.Гали. *Яңгыр бик вак ява --- вак су бөртекләре битләрне кытыкландыра, күз эчләренә керә, әмма өсне җебетми.* Ш.Камал. --- *тугызынчы класс малайлары, пискультурадан кайткач, чаңгыларын морҗа артына куйганнар. Завыч шул класста укытып ята, чаңгыдан кар эреп, морҗаны җебетә.* М.Мәһдиев

4) *з.-сыз* Аяк асты пычрак хәлгә килү, изрәтү. --- *бу араларда көннәр әйбәт тора әле, – дип куйды ул. – Кайчакларны бер җебетеп, бер туңдырып аптырата.* А.Хәсәнов

5) *з.-сыз* Көннәр җылынып, кар эри башлау турында. *Март башларында җебетә*

6) *күч.* Исерткеч эчемлек тәэсирендә изрәү, ою. *Эчемлек көчле, тамырларга тиз йөгерде. Яралыларны бик тиз җебетте.* Казан утлары

**Җебетә башлау** Җебетергә тотыну. *Кыш үтеп, көннәр җебетә башлагач, мине язгы чәчү кампаниясе буенча авылга җибәрделәр.* М.Әмир. --- *текә ярларны су инде җебетә башлаган һәм, чарасын күрмәсәң, бер-ике елдан утраудан колак кагуың да бар иде.* А.Тимергалин

**Җебетә төшү** Беркадәр (бераз) җебеткән хәлгә килү. *Иртән туң иде. Әле генә җебетә төште.* Х.Сарьян

**Җебетеп алу** Беразга, берникадәр җебетү. *1960 елларда Хрущев властька килгәч, шәхес культы чорын язучылар бераз яктырта башласа да, ул «җебетеп алу чоры» бик тиз узды.* Ф.Яруллин

**Җебетеп бетерү** Тәмам, бик нык җебетү. *Карчык, як-ягына карана-карана, иртәдән бирле учында йөртеп, тирдән җебетеп бетергән бер төргәк акчаны килененә сонды.* А.Гыйләҗев

**Җебетеп җибәрү** Тиз арада, кинәт кенә җебетү. *Көн урталары якынайдымы, аяк астын тагын җебетеп җибәрә, яшь боз эреп юк була.* Г.Бәширов. *Юл авыр: көндез җебетеп җибәргәндә, туң балчык арба көпчәкләренә ябыша.* В.Нуруллин. *Катырып та җибәрә көннәр, җебетеп тә җибәрә.* Р.Сибат

**Җебетеп кую** Алдан җебеткән хәлгә китерү. *Үзем дә сизмәстән: – Иртән керләрне дә җебетеп куярга кирәк, – дип әйтеп ташлаганмын.* Х.Сарьян. *Гөмбәләрне исә алдан ук суда җебетеп куярга кирәк.* Э.Кәлимуллина

**Җебетеп ташлау** Кинәт, бик нык җебетү. *Белә иде хатын, алдан күрә: коньяк аны җебетеп ташлаячак!..* З.Хөснияр

**Җебетеп тору** Әле, хәзер җебетү

**ҖЕБҮ** *ф.* 1) Чылану, җебенү, юешләнү. --- *бишмәт шактый җебегән; бишмәт азрак сурыга төшсен, үзем дә бераз шомарак, мәдәниятлерәк күренim дип уйладым.* Ш.Камал. *Мидхәт пугачын каргаларга төзәде. Ләкин, бая базда аунаганда, кар белән пистонnaры җебегән булганлыктан, пугачы атмады.* Ф.Хөсни. *Суда аяклар җебегәч кенә, авырту басылып, тәнгә рәхәтлек йөгерде.* Ф.Яруллин

2) Су, дым яки җылылык тәэсирендә йомшару, изрәү, сыегаю. *Яңгырлар башланса, иске чокырларга су тула, ярлары җеби, йомшара.* А.Гыйләҗев. *Өстәвенә изелгән карбызлардан машина тартмасының идәне җебегән, Әгъдия таеп та китте, гөрселдәп ауды да...* К.Кәримов

3) *күч.* Нинди дә булса хәл алдында артык юашлану, бик курку, каушау. *[Кадыйров] Пошына башласа, башын түбән исә, бетте инде, җеби дә төшә.* Г.Әпсәләмов. *Зуфирәгә ошамый малай, йомыкый, хәтта шактый җебегән булып тоела.* М.Маликова. *Менә шул сүзне Мәһди әйтергә, ике бозауга кибәкне Мәһди аерып бирергә тиеш иде дә бит, ә ул әнә утыра җебеп, авызына су кабып.* Казан утлары

4) *күч.* Йомшару, елау дәрәҗәсенә җитү, күңел тулу. *Күзләренә кинәт, ачыттырып, дару салгандай булдылар. Монсы кирәкмәс иде, бу кадәр җебемәскә иде, диде ул.* Х.Сарьян

5) *күч.* Йомшау, киеренкелек бетү. *Бер-ике сәгатьтән соң апам тәмам җебеп, тирләп-пешеп, бик канәгатьләнеп, өйдән чыкты, төшкән урынына кайтып китте.* А.Шамов

6) *күч. сөйл.* Исерү, нормаль хәрәкәт итү сәләтен югалту. *Җебүе җиткән каһәрнең, шаркылдап көлә генә.* Ф.Хөсни

◊ **Җебеп аккан** *к.* **җебегән арыш боламыгы**. *Бибинур, телгә-тешкә алай ук үткен булмаса да, бөтенләй җебеп акканнардан да түгел.* А.Гыйләҗев

**Җебеп алу** Кыска вакытлы, азга гына җебү. *Шул авыртуга күңелем җебеп алды... Ә болай барысы да әйбәт, атасы.* Г.Гыйльманов

**Җебеп бетү** Тулысынча, тәмам җебү. --- *моңга гына салынып, сагышланып ятсак, без бөтенләй йомшап, җебеп бетәрбез.* Г.Ибушев

**Җебеп җитү** Тиешенчә җебегән хәлгә килү. *Судагы җитен җебеп җиткән*

**Җебеп йөрү** *күч.* Җебегәнлек күрсәтү, булдыксызлану. *Ә сез, уҗым бозаулары, җебеп йөри торгач, муенга атландырасыз бит дию пәриен.* К.Нәҗми. *Шулай җебеп йөрү килешәмени инде шундый бөркеткә, ә?!* С.Шәрипов

**Җебеп китү** 1) Бераз, берникадәр җебү. *Кадрия чәчәкле кулъяулыгы белән күз тирәсен, аннан җебеп киткән борынын сөртеп алды.* Р.Галиуллин

2) *күч.* Кинәт, көтмәгәндә җебегәнлек күрсәтү. *Күңеле нечкәреп, җебеп китүдән ул хәтта үзе дә уңайсызланып куйды.* И.Гази

**Җебеп тору** 1) Әле, хәзер җебү хәлендә булу. *Ишетәсеңме? Кемдер шул бозлы яңгыр астында ике аягын укмаштырган да күшегеп, җебеп тора.* Г.Бәширов

2) *күч.* Артык йомшау, мәлҗерәү, куркып тору. *Ул киреләнер, нинди дә булса сылтау тапкан булыр. Кара аны, җебеп торма, ычкындырма кулыңнан.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Моннан соң мин куркак булмыйм, беркем алдында да җебеп тормыйм.* М.Мәһдиев

**Җебеп төшү** 1) Тиз арада яки кинәт кенә йомшау; йомшаган хәлгә килү. *Куркып торам, таш булып таш чыдый алмас: Эреп төшәр, җебеп төшәр – ком да калмас.* Э.Шәрифуллина

2) *күч.* Кинәт югалып калу, нишләргә белмәү, каушап калу, аптырашка төшү. – *Шулай кирәк ул... Башка хатын-кызлар җебеп төшкәннәр бит, ничек инде шулар кебек булмаганы өчен гаеплисең, – ди Гыймай абзый.* М.Гафури. *Дөрес, зинданда тәмам җебеп төшкән тоткыннарны яратмыйлар, андыйлардан тиз читләшәләр.* А.Гыйләҗев. *Ул [Хәсән Сарьян] җебеп төшмәде, татар язучылары арасында үз урынын тиз таба алды.* М.Шабаев

**Җеби төшү** Беркадәр, бераз җебегән хәлгә килү. *Житен җеби төшкән*

**ЖЕГӘР** *и. фар. сөйл.* 1) *к.* **егәр** (*1 мәгъ.*). *Аның артык яктылыктан күзләре камашты, башы әйләнде. Эсселек тәннең җегәрен суырды.* Ф.Яруллин. *Борынгы милләтләрнең берсе буларак, татар халкының, Л.Н.Гумилёв әйткәнчә, пассионарлык җегәре Болгар, Казан дәүләтләрен тотуга --- һәм үз-үзен гаять авыр шартларда саклап калуга киткән.* Т.Галиуллин. *Җыеп әйткәндә, 30–40 ел эчендә безнең халыкның интеллектуаль җегәре үзенең генетик фондын югалту дәрәҗәсендә зәгыйфьләнеп өлгергән иде.* М.Госманов

2) *күч. диал.* Берәр эш-шөгыльнең кызыгы, ләззәте, тәме. *Ринат – оста әңгәмәче, дәлилләр китереп, сүзнең җегәрен белеп сөйли.* Мәдәни җомга

**ЖЕГӘРЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **егәрләнү**. *[Яшь үрмәкүчләр] Тизрәк җегәрләнәчәк, аналарыннан өйрәнеп, агач кәүсәсе буйлап үрмәләячәк.* Г.Хәсәнов

2) Көч керү, хәл җыю. *Каты авырудан соң яңадан җегәрләнү*

3) Гайрәт керү; көч арту

4) *күч.* Тагын да куәтләнү, ныгу, яхшыру. *Совет чорында ул [татар әдәбияты] бик каты җегәрләнеп, дөньядагы алдынгы телләрдән һич калышмас дәрәҗәгә басты.* Х.Сарьян. *Р.Миңнуллинның шигыре елдан-ел җегәрләнә, елдан-ел гадирәк һәм төгәлрәк була бара.* Г.Ахунов

**Җегәрләнә бару** Көннән-көн, вакыт узган саен егәрлеге арту

**Җегәрләнә башлау** Җегәрләнүгә табан бару

**Җегәрләнә төшү** Беркадәр егәрләнү, бераз егәрлегә әйләнү. *Бара-бара, [Габделбәрнең] буыннары ныгып җиттеме шунда, җегәрләнә төште, берзаман хәтта изүләрен дә чишеп җибәрде.* М.Шабай

**Җегәрләнеп алу** Егәрле хәлгә килү. *Карт, егәрләнеп алып, курыкмыйча юлга чыккан*

**Җегәрләнеп җитү** Бөтенләй (тулысынча), ышаныч тудырырлык дәрәҗәгә җитеп егәрләнү. *Егет инде җегәрләнеп җитте*

**Җегәрләнеп калу** Егәрләнгән хәлгә килү, егәрлегә әйләнү

**Җегәрләнеп китү** Кинәт егәрләнү, тиз арада егәрләнгән хәлгә килү. *Уеннан соң балаларның күзе-йөзе кабынып, үзләре җегәрләнеп --- китәләр.* Н.Исәнбәт. *Чәең каты, сөтең куе булса, Җегәрләнеп китә буыннар.* Ш.Маннур

**ЖЕГӘРЛЕ** *с. диал. к.* **егәрле**. *Гомеренең иң җегәрле, иҗатка иң кулай өлешен китап шкафлары белән шыгырым тулган --- таш идәнле салкын бүлмәдә кульъязмалар өстенә иелгән килеш, ялгызлыкта уздырды ул.* М.Госманов. *Ташып торган җегәрле шәхес чынбарлык белән бәрелештә, конфликтта бәргәләнә.* Т.Галиуллин. *--- популяр җырлар шагыйрь сүзенең – мәгънәле, кичереше – җегәрле, иҗеге ятышлы булуы хакында сөйли.* Т.Галиуллин

**ЖЕГӘРЛЕК** *и. диал. к.* **егәрлек**. *Җир шарының теләсә кайсы ноктасына барып кайтырлык җегәрлегем бар иде әле.* Ә.Еники. *[Галимҗан Ибраһимовның туган авылы Солтанморат] Халкының эшчәнлеге-тырышлыгы, җегәрлеге белән тирә-якта шөһрәт казанган, табигатьнең оҗмахтай гүзәл урынында хозурланып утырган данлыклы авыл ул.* С.Поварисов

**ЖЕГӘРЛЕКЛЕ** *с. диал.* 1) *к.* **егәрлекле**. *Җитмеш биш ат җегәрлекле трактор*

2) Кыенлыкларны җиңеп чыга торган, нык ихтыярлы. *Җегәрлекле кеше булып күренү*

3) Нык тәэсир итә торган, көчле. *Язучылар аеруча мөһим күренешләргә тукталырга, җегәрлекле, саллы мәгънәле художество чараларын сайлап алырга --- яраталар.* Ф.Хатипов. *Җегәрлекле сәнгать чаралары*

**ЖЕГӘРЛЕЛЕК** *и. диал. к.* **егәрлелек**. *[Гасыймның] Күпне күргән булуы өстенә, җегәрлелеге, батырлыгы да бар.* Х.Садрый

**ЖЕГӘРСЕЗ** *с. диал. к.* **егәрсез**. *Җегәрсез аяклары бүген әллә нишләгән, ул йөрми, йөгерә генә.* Г.Әпсәләмов

**ЖЕГӘРСЕЗЛӘНҮ** *ф. диал. к.* **егәрсезләнү**

**Җегәрсезләнә бару** Акрынлап егәрсезләнү, акрынлап егәре кимү

**Җегәрсезләнә башлау** Җегәрсезләнергә тотыну

**Җегәрсезләнеп калу** Берәр хәлдән соң егәре бетү

**Җегәрсезләнеп тору** Егәрсезлек хәле кичерү

**ЖЕГЕРЛӘГЕЧ** *и. сөйл. иск.* Җеп эрли торган кул машинасы. *Бәләкәй бүлмәчектә йокы китерә торган тавыш белән җегерләгеч безли.* Ш.Камал

**ЖЕГЕРЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Эрләү. *Хатыннар, тезелеп, җеп җегерләп утыралар.* Ф.Бурнаш

**ЖЕГЕТ** *и. диал. к.* **егет**. *[Фатыйма] Мине бөтенләй эреткән дә череткән: бичара Сираҗи бик бәхетсез икән, бәхетле булса, ул бер дә Гөлҗиһанны ала торган җегет түгел икән, – ди икән.* Г.Камал. *Күршеләр берни дә әйтмәс. Дөрес эшләде Мәһди, акыллы җегет икән, диярләр.* Казан утлары

**ЖЕК** I *и.* 1) Такта, борыс һ.б.ш. әйберләрдә, ярык калдырмыйча, берберсенә тоташып барсын өчен, махсус ясалган уенты, ырмау. *[Пыялачы] Чалбар кесәсеннән өтерге сыман әйбер чыгарып, рам җегенә кысылышып торган пыяла кисәкләрен кырып төшерде.* А.Гыйләҗев

2) Берничә кисәкне ялгап эшләнгән әйберләрнең тоташкан урыны. *Бүрәнә җекләре ак балчык белән сыланган алтыпочмаклы өйнең зәңгәр буяулы тәрәзәләре биек һәм зур иде.* Г.Ахунов. *[Кулешов] Кирпечләрне ничек ялгарга, җекләрне ничек сыларга кирәклеген вәзенләп сөйләп бирде.* А.Гыйләҗев

3) Сөяк тоташкан урын, буын. *Аның әллә нинди тамырлары өзелеп, арка җекләре имгәнеп, аяк-кулы хәрәкәтләнмәс булган иде.* М.Галәү

4) *диал.* Тар гына ярылган ачыклык, ярык. *Койма җегеннән карау*

◊ **Җеге җеккә яту** Бернинди кимчелексез, төгәл килеп чыгу, ярашу. *Финляндиядә эшләнеп, аерым-аерым тартмаларда сәяхәт кылган йорт кисәкләрен ул, бернинди сызымсыз, күңел күзе белән чамалап җыя башлады. Сүтә, җыя, җеге җеккә ята, таслап кына куя.* А.Гыйләҗев. **Җеген җеккә китерү** Җиренә җиткереп, төгәл, пөхтә итеп эшләү. **Җеген табу** Күңеленә үтеп керә белү, йомшак җирен табу. *Бөтеркәләнеп беткән карама төбе шикелле [бу сер саклаучы картлар]. Чөй сугардай җайлы җеген һичбер табалмассың!* Ш.Маннур

**ҖЕК** II *и. иск.* Берүзе генә, ялгыз. *Юлда йөргәндә җеккә йөрмә.* Мәкаль

◊ **Җек тиен дә** Аз гына да, бөтенләй, һич тә. *Кызыл фәс кигәч тә, хәлфәи исламыңны онытып, хуҗаңнан көләргә җек тиенлек тә praваң юк синең.* К.Нәҗми

**ҖЕКЛӘНҮ** *ф.* Җек барлыкка килү, җеклегә әйләнү. *Ишек җекләнгән*

**ҖЕКЛЕ** *с.* 1) Җекләре булган, буынтыклы. *Сөяктәге җекле чыгынтылар*

2) *куч.* Көчле, таза, җегәрле, дәрманлы. *Ямьсез кеше иде ул [Җәпчәй], әмма галәмәт җегәрле, җекле кеше иде.* М.Шабаев

**ҖЕКРӘЧ** *с. диал.* Игез, игезәк (мал-туар турында)

**ҖЕКСЕНҮ** *ф. диал.* Үз-үзенә түбәнсенеп карау, кимсенү, үзен нәрсәгә дә лаеклы санамау

**ҖЕЛЕК** *и.* Сөяк куышлыгын тутырып торган йомшак тукыма. *Сөяк пластинкалары кызыл җелек белән тулган була, ул кан ясаучы орган булып тора.* Анатомия. *Көпшәсыман сөякләрнең куышлыкларында майга бай тоташтыргыч тукыма – сары җелек була.* Биология

◊ **Җелеге кибү** Эшне төгәлли алмый җәфалану, тәкате бетү. *Якасын каптыра алмый җелеге кипте, аптырагач, миңа төймәләтте.* Ш.Маннур. **Җелеге кору** *к.* **җелеге кибү**. **Җелегенә кереп утырган** Үз сыйфаты, гадәте булып әверелгән; канына сеңгән. *Әгәр нәселдән килә торган авырудан – яшь чагыннан ук канына, бөтен җелегенә кереп утырган ул комсызлык чиреннән – үзе генә котыла алмый икән, аңа Нәфисәләр ярдәм итәргә тиеш түгел идеме соң?* Г.Бәширов. **Җелегенә үтәрлек итеп** Нык сеңдереп, тәмам ышандырып. *Андый чакта сүзләрне сайлап тормый, сигезәр катлап, җелекләренә үтәрлек итеп сүгә.* Казан утлары. **Җелеген суыру** 1) Кешенең көчен файдаланып хәлдән тайдыру, җегәрен алу. *Тик тормыш үзгәрмәде, һаман үзенең җелекләрне суыра торган бертөрле төссез агымы белән ага бирде.* Ә.Фәйзи; 2) Алҗытып бетерү, теңкәсенә тию. *Хатын белән дә ара тәмам өзелеп бетмәгән иде. Ул юха елан башын иеп кенә китеп бармады бит, Яңгураның җелеген суырды.* Г.Әпсәләмов. *[Машинадан] Колхоз председателе белән эшләпәле бер егет төштеләр. Болары инде тәмам җелекне суырдылар, өстәвенә, кызларның да тавышы хәзер усалрак, таләпчәнрәк яңгырый башлады.* Э.Касыймов; 3) Талау, нигезен корыту, ярлыландыру. *Җелеген суырып бетергәннәр басуларның, җелеген!* Р.Төхфәтуллин. **Җелеккә тию** *к.* **җелеккә үтү**. *Алдыма куелган шикәр кисәген, ярты чынаякка да җиткермичә, шатыр-шотыр чәйнәп бетерәм, тагын сорап, әнкәйнең җелегенә тия башлыйм.* Ш.Маннур. **Җелеккә төшү** 1) Йөдәтеп, аптыратып бетерү, тәмам җәфалау. *Икенче районга качып китеп тә котыла алмассың. Җелегеңә төшәчәкмен әле!* Ә.Моталлапов; 2) Бик нык интектерү, газаплау. *Ялынып, ялварып тапшырган хатларның күпчелеген шофёрлар почтага илтеп йөрми, алалар да юк итәләр. Бер-берсеннән курку җелекләргә төшкән.* А.Гыйләҗев. **Җелеккә үтү** 1) Тәнгә салкын үтеп керү, суыктан калтырау. *Ачы шималь җиле һәм зәһәр суыкның куәте җелекләргә үтә китә.* Г.Ибраһимов; 2) Тәмам йөдәтү, аптыратып бетерү. *Әмма да җелеккә үттең. Бик йөдәткеч кеше икәнсең син.* Ш.Әхмәдиев. *Бу «авыру» [җирсү] еракларга киткән эмигрантларның гына түгел, үз дәүләтендә кече ватаныннан – туган-үскән җиреннән аерылганнарның да җелекләренә үтә.* Ә.Борһанов. *Заһидулла иртәнге авыр сорауларыннан, җелегенә үткән үкенүләрдән, бигрәк тә тәмам юләрләндерә язган икеләнүләрдән тәмам арынды.* Р.Сибат

**ҖЕЛЕКЛЕ** *с.* Эчендә җелеге булган. *Итләре үзләре кашыкка кереп торалар, сөякләре дә җелекле.* Г.Толымбай

**ҖЕЛТ** *рәв.* Бик тиз, бик кыска вакыт эчендә. *Яр кырыенда утырган тәбәнәк баганалар, җелт тә җелт килеп, егылышып кына калалар.* Г.Бәширов. *Егет папиросын тирән суырып: – Их, акчарлак шикелле, менә шулай җелт иттереп кенә, берәр җәенне сыртыннан эләктереп алсаң иде, – диде.* Ә.Еники

**ҖЕЛТЕР** *с.* Җелт-җелт итеп торган, бик хәрәкәтчән, тере. *Быел беренче мәртәбә мәктәпкә аяк атлаган җелтер күзле, аксыл башлы сабыйлар кинәт минем күз алдыма килеп басты.* М.Мәһдиев

**ҖЕЛТЕРӘТҮ** *ф.* 1) Җелт-җелт китерү, елтырату. *Шәмсүн, күзләрен җелтерәтеп, озак кына кызга карап торды.* А.Вергазов

2) Бик тиз генә нәрсә дә булса эшләү. *Кутәрдем, үчтекиләп сөйдем дә, аның елавын ишетмәс өчен, иңенә мукәләтеп җибәрүгә үк, чемоданнарны кабат җелтерәтеп кенә кулга алгач, инде беркемгә карамаска, борылмаска ниятләп, йортыбыз янынннан гына узган такыр басу юлына атладым.* Рифә Рахман

**Җелтерәтеп кую** Кыска вакыт эчендә, аз гына җелтерәтү

**ҖЕЛТ-ҖЕЛТ** *иярт.* **1.** Уйнап торган тере күзләр турында. *Читлектән кеше өстенә караган маймыл күк, күзләрен җелт-җелт иттереп карады.* Г.Газиз. *Тавыклары да, тибенеп йөргән җирләреннән туктап, «Нигә әле безнең әбиебез күренми?» дигәндәй, башларын кырын салып, җелт-җелт карана торганнардыр.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Вак-вак җиңел адымнар белән, җәһәт, тиз-тиз атлап. *Төсебите дисеңме, буе-сыны дисеңме, биегән шикелле җелт-җелт атлап баруы дисеңме – бары да килгән инде менә.* А.Шамов. *Салпаның ярсып килгәне*

*күренеп тора: кулларын нык селтәп, итәген җелт-җелт китереп атлый.* Г.Якупова

**ҖЕМЕЛДӘВЕК** *с.* Җем-җем иткән, җемелдәп торган. *Бу табигать балаларының үзара чебердәшүләрен тәрәзәдән җемелдәвек йолдызлар карап торды.* Г.Ахунов

**ҖЕМЕЛДӘТҮ** *ф. диал.* 1) *йөкл. юн. к.* **җемелдәү**

2) Җем-җем итеп тору, якты нур чәчү. *Бу йолдызларның барысы да бер зурлыкта, сихри-көмеш утларын җемелдәтеп, күзләрне иркәләп яналар да яналар...*Г.Гыйльманов

3) Ялтырату, ялтыратып күрсәтү. *Яланаяклап суга кердең, тешләреңне җемелдәтеп көлә-көлә, учларыңа су тутырып, миңа сиптең ---.* Ә.Гаффар

4) Яктылык нурларын чагылдыру, берәр тигез өслекне ялтырату, шунда нурлар уйнату. *Сөн, вак-вак дулкыннарын җемелдәтеп, сабыр гына ага.* Р.Миңнуллин. *Яктылык күзнең явын ала, ап-ак кар өстен җемелдәтә.* М.Яһудин. *Юлларда да тузан күтәрелде, аяз күкне җемелдәтеп, яшен камчысы уйнап алды.* Ф.Яхин

**Җемелдәтә башлау** Җемелдәү билгеләре күренү

**Җемелдәтеп алу** Берара җемелдәтү; аз гына җемелдәтү. *Күзләрен җемелдәтеп алу*

**Җемелдәтеп куюю** Бер мәртәбә җемелдәтү

**Җемелдәтеп тору** 1) Бертуктаусыз җемелдәтү

2) Әле, хәзерге вакытта, күз алдында җемелдәтү. *Егетләр Фаяз артында кара күзләрен җемелдәтеп торган чибәркәйгә күз төшерделәр ---.* Сөембикә

**ҖЕМЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Җем-җем итеп нур чәчү, нур тарату. *Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен – әйләнә-юнь моржа эчедәй каплкара.* Ә.Еники. *Ул [кар] кыш көнендәге шикелле күзләрне чагылдырмый, асылташлар сипкәндәй җемелдәми.* М.Маликова. *Анда-санда Иләк йолдызлар тоныкына җемелди.* Г.Әпсәләмов

2) Кояшта ялтырау, нурлар уйнау. *Кояш иңгән якта болытлар аллы-кызыллы җемелди.* Г.Камал. *Сагына белмәгәннәрнең дә күкрәк бозы әкренләп эри, ирләрнең күз төпләре дымланып, кичке шәфәкъ нурларында тамчылар җемелди икән, бел дә тор: ул сагына, сагына!* А.Гыйләҗев. *Еракта күгелҗем рәшә җемелди.* И.Гази // Ялтырап күренү, ятырып тору. *Диңгезче фуражкасын салгач, аның шома итеп таралган коңгырт чәчләрендә, чигә турыларында, чал бөртекләр җемелдәп күренә иде.* М.Маликова. *Зәйтүнә --- хәйран калды: карама агачы кәүсәсендә, пәке очы белән йөзек сыярлык кына итеп уелган түгәрәк мөештә ---, күз яше кебек җемелдәп, зәңгәр кашлы йөзек ялтырап тора иде.* Ф.Хөсни. *Гәүһәрнең --- элек гел бөдрәләнеп торган көлсу чәче башына сыланган, арада ак бөртекләр җемелди.* Казан утлары

3) *күч.* Яктырып, ачылып, җанланып китү. *Кадыйрның сүлпән йөзе кинәт яктырып китте, күзләрендә серле очкыннар җемелдәде.* М.Галәү

**Җемелдәп китү** Кинәт кенә җемелди башлау. *Төргәк кызыл, яшел, күк, ал һәм ак төсләр белән җемелдәп китте.* Ә.Фәйзи. *Козгын карасу куе зәңгәр төстә, --- йоннары кабарганда, асылташлар җемелдәп киткән кебек була.* Мирас

**Җемелдәп тору** Әле, хәзер җемелдәү. *Шомырт кебек кара чәчләре арасында сирәк-мирәк кеби ак төкләр дә җем-җем итеп җемелдәп тормакта, һәм битендә бер-ике җирдә бөрешә башлаган җирләре дә картая башлаганын күрсәтмәктә иде.* Ш.Мөхәммәдев

**Җемелдәп яту** Нык җемелдәү, озак вакытлардан бирле җемелдәү. *Кояш яктысында ялтырап, җемелдәп яткан тигез кар сахрасы уртасында --- түбәсенә чаклы көрт баскан кечкенә бер өй караеп күренә иде.* М.Галәү. *Алар барча утлары сүндерелгән шәһәр урамнары буйлап ай яктысында җемелдәп яткан карлы юллардан шактый озак бардылар.* М.Маликова. *Чал башы мендәр өстендә көмеш коштабактай җемелдәп ята, маңгай сырлары бөтенләй югалган, ничектер, яшәреп калган.* Ф.Хөсни

**Җемелди башлау** Җемелдәргә тотыну. *Караңгы төшеп, беренче йолдызлар җемелди башлагач, атулар туктады.* И.Гази. *Бераздан лампалар ялгыз ялтырап яткан утлы күмер кисәге төсле генә җемелди башладылар, аннары бөтенләй сүнделәр.* А.Шамов

**Җемелди төшү** Бераз җемелдәү

**ҖЕМЕЛДӘШҮ** *ф.* Төрле яктан төрле төсләргә кереп җемелдәү. *Утлар артык серле, якты җемелдәшә.* М.Маликова. *Яшел яфраклар өстендә энҗе бөртекләредәй тамчылар җемелдәшә башлады.* М.Галәү. *Камыл очларында энә очы кадәр генә чык тамчылары җемелдәшә.* Мирас

**Җемелдәшеп алу** Аз гына, кыска вакыт җемелдәшү. *Кечкенә генә бер станцияне үттеләр, ахрысы: берара утлар җемелдәшеп алды да, вагон тагын караңгылыкка чумды.* З.Хөснияр. *--- утлар сүнәм-сүнәм дип җемелдәшеп алдылар.* Г.Әпсәләмов

**Җемелдәшеп калу** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң җемелдәшкән хәлгә килү. *Җемелдәшеп калды... Горчицаның сары киңлекләре, люцернаның калын юрганы.* Ш.Мөдәррис

**Җемелдәшеп китү** Кинәт җемелдәшү. *Шул чагында бармакларындагы асыл кашлы йөзекләре ялтыр-йолтыр җемелдәшеп китте.* М.Әмирханов

**Җемелдәшеп тору** Әле, хәзер, күз алдында җемелдәшү. *Һавада болыт юк, тик йолдызлар гына җемелдәшеп торалар.* А.Таһиров. *Алар шуңа да башка тамчылардан аерылып, җемелдәшеп торалар.* Р.Хафизова

**ҖЕМЕЛДЕК** *с.* **1.** Җемелди торган, җем-җем килгән. *Алсу шәмәхә офык, җемелдек тәрәзәле карасу өйләр, моңсу гына башларын игән карасу тупыллар – барысы да аста калды бугай.* Р.Төхфәтуллин

**2.** *и. мәгъ.* Җемелдәү күренеше. *Кар өсте --- җемелди, атлаган саен як-ягында шул җемелдекнең искеләре сүнеп, яңалары кабынып тора.* Н.Исәнбәт

**ҖЕМЕЛ-ҖЕМЕЛ** *иярт. к.* **җем-җем**

**ҖЕМЕ́Л-ҖЕМЕЛ КИЛҮ** *ф.* Җемелдәү, җем-җем килү. *Ак кар өстендә әллә нинди кара күләгәләр, җемелҗемел килгән утлар күренеп китте.*

М.Гали. *Еракта, күк читендә, җемел-җемел килеп, рәшә уйный.* Ә.Фәйзи

**ҖЕМ-ҖЕМ** *иярт.* **1.** Ялтырау, нур сибү, очкынлану рәвешен белдерә. *Кышкы кояшлы иртәдә җем-җем кар бөртекләре ялтырый*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җемелдәп торган, җемелдәвек; якты. *Караңгы төнгә яктылык сирпеп, җем-җем йолдызлар кабынды*

2) Җирлегеннән якты булып аерылып торган, сибелеп киткән. *Зәңгәр күлнең буе җем-җем чәчәк, Арасында сары андыз бар.* Җыр

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Җемелдәшеп, нурлар чәчеп. *Күктән ай карап тора, йолдызлар җем-җем уйныйлар.* Г.Ибраһимов. *Гүя [гөлләр] шунда җанландылар, нурлар чәчеп, җем-җем көлделәр.* М.Гафури. *Кунычлары җем-җем ялтырап торган хром итегенең табанына ябышкан үзле балчыкны кырып интекми, туп-туры сафлар өстенә, тоткыннарга карап селки.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Дусларча, әкрен һәм басынкы гына. *Егет килә, түргә, ике тәрәзә арасына менеп утыра. Чәй эчә башлыйлар, җем-җем сөйләшеп кенә.* Әкият

**4.** *кис. функ.* «Кара» сыйфаты алдында килеп һәм басымны да үзенә алып, шул төснең артыклык дәрәҗәсен ясый (*ялтырап торган дегет кебек кара; чем кара, дөм кара, шомырт кара*). *Җем-җем кара чәчләремне Сүтсәм, үрә алмам инде.* Җыр. *Атның аласы була, Җем-җем карасы була. Сөйсәң, ярның сөй матурын, Сөйсәң, аласы була.* Җыр

**ҖЕ́М-ҖЕМ ИТҮ** *ф.* Җемелдәү. *Күрде кырда: бик матур бер әллә нәрсә ялтырый. Нурлана, җем-җем итә, йолдыз шикелле калтырый.* Г.Тукай. *Февраль ахырлары булса кирәк. Тау маңгайлары челтәрләнеп, җем-җем итеп уйный башлаган иде.* Ә.Еники. *Җем-җем итә сары гәрәбәсе; Алтын йөгертелгән урманга.* Казан утлары

**ҖЕ́М-ҖЕМ КИЛҮ** *ф.* Җемелдәү. *Бу томан эчендә исәпсез күп энҗе тузаны йөргән шикелле, җем-җем килеп, күзләрне кытыклап тибрәнә.* Ә.Еники

**ҖЕМИЕП** *рәв.* Ягымлы һәм тыйнак кына, үз итеп елмаеп. – *Узеннән сорыйлар аны! – диде Җыяншә абый да, җемиеп кенә.* Ш.Маннур

**ҖЕ́М ТОРУ** *ф.* Дәшмәү, авыз йомып калу. *[Мәрьям:] Сүзең алтын, үзең бакыр, өндәмә, җем тор.* К.Тинчурин

**ҖЕН** I *и. гар. миф.* 1) Табигатьтән өстен явыз зат. *Җеннән куркып, албастыга очраган.* Мәкаль. *«Җен-фәлән» дип сөйләшүләр – искелардән калган ул; Сөйләве яхшы, күңелле – шагыйрәнә ялган ул.* Г.Тукай. *Алар җен кагылып авырган уллары өшкертергә чакырганнар иде. Малай нишләргә белми, дулап ята.* М.Гафури

2) *күч.* Зур куәткә ия көч. *«Атом» дигән «җен»не йөгәнли белмәсәң, аз гына ялгыш җибәрсәң, ул ярты дөньяңны әйләндереп салырга мөмкин.* Р.Низами

3) *күч.* Кеше холкында өстенлек иткән сыйфат. *Утыз тиен көмешне Габдуллага сузыйм дигәндә генә, саранлык җене кабыргасына төртте булса кирәк, көмешләрне янчыгының икенче бүлегенә салып куйды да, икешәр тиенлек алты бакырын санап, шалтыратып, Габдулланың учына салды.* Ә.Фәйзи

4) *күч.* Тәэсир көче, йогынты. *Шундый бер җене бар язның: --- үзеңә дә сиздермичә, сине кинәт исертеп ташлый.* Ф.Хөсни. *Ат җене! Һәм аның күпләр аңлап та бетерми торган нинди ярем яшерен көче, сере бардыр, ахрысы. Аны, гадирәк итеп әйткәндә, атларга мәхәббәт, ат кебек асыл малның кадерен белү --- дип тә аңлатып булыр иде.* Казан утлары

5) *күч.* Күңел, рухи дөнья. --- *монда, төп герой Сәйфинең характер асылын ачар өчен, аллегорик Җен образы кертелә. Әнә шул Җен – аның икенче «мин»е – Сәйфине бар нәрсәгә каршы чыгарга котыртып тора.* Д.Гыймранова

6) *күч.* Ачулану, тиргәү сүзе. *Ах син, җен малай, качарга уйлый бит!* Мәдәни җомга

◊ **Җен алгыры** 1) Берәр нәрсә искә төшми торганда әйтелә; 2) Тиргәү, орышу сүзе. *Их, җен алгыры, кирәк чакта гына...* Р.Батулла; 3) Кайбер очракларда көч-куәт иясен җенгә тиңләп, сокланып әйтелә. *Килә бит ажгырып паровоз, җен алгыры!* Н.Исәнбәт. **Җен алмаштырган** 1) Ямьсез йөзле, начар холыклы кеше турында. *Җил бик ачы тавыш белән сызгыра, --- әле, ыжгырынып, бүре улаган тавышлар чыгара, әле җен алмаштырган бала шикелле елый да тагын үкерә.* Ф.Әмирхан. *Мин, юләр карчык, шул шайтан кыяфәтле, җен алмаштырган нәрсәгә яучы булып йөрдем.* К.Тинчурин; 2) Кешелек сыйфатларын югалткан, мәрхәмәт хисе калмаган кеше турында. *Әллә, әбиләр әйтмешли, Төнлә җен алмаштырган?! Акаеп кына карый ул Уңга да сулга гына, Гердәй авыр сүзләр белән Ора да суга гына.* Ш.Галиев. **Җен алыштырган** *к.* **җен алмаштырган**. *Зәйтүнә, аңа каршы бер сүз әйтмичә, ул ни кушса, шуны эшли, ә теге – җен алыштырган нәрсә – аңа берөзлексез кушып кына тора иде.* Ф.Хөсни. *Ходаем шаһит: Карабас мәктәбен бергә үткән юлдашларымны Актаста җен алыштырды!* А.Гыйләҗев. **Җен ачуы кузгалу** *к.* **җен ачуы чыгу**. *Ләкин Габдулланың аңа җен ачуы кузгала: – Минем апа риза түгел бит! Нигә алдыйсыз? – дип, ул еларга җитешеп кычкыра.* Ә.Фәйзи. **Җен ачуы чыгу** Ачуы эченә сыймау, бик яман ачулану. *Бер көннәрдә кызлар җыены җыйган, шунда, күршедә тора торып, мине утыртып калдырган. Бөтенләй минә җен ачуларым чыкты.* Г.Камал. *Базда, кисмәкләп, сары май, тозлаган итләр күргәч, --- шатлану урынына, аның җен ачулары чыкты.* К.Тинчурин. *Тирене төятергә кеше тапмыйча, җен ачуы чыгып кайтып килгәндә, урамда кодасы Аптулны очратты.* Ф.Хөсни. **Җен булып күренү** Тискәре мөнәсәбәт, фикер уяту. *Башта Мэлс Хәйриевич безгә җен булып күренгән иде.* Ф.Садриев. **Җен дә төшенмәс** Буталчык, аңлашылмый торган (эш һ.б. турында). **Җене белән бер күрү** Кемне дә, нәрсәне дә булса гаять дәрәҗәдә яратмау, дошман күрү. *Ул яратмый бер дә ирен, Җене белән бер күрә, Утырып-утырып, бу иренә Чыкканына үкенә.* М.Җәлил. **Җене җибәрү** Ачуы басылу, тынычлану, кирелеге бетү.

*Укырга барырга ничәмә-ничә әйтеп карадылар. Киреләндең, көең килмәде ул чакта ---. Бу юлы ничек җенең җибәрде, минәйтәм?* С.Рафиков. **Җене кагылу** Бер нәрсәгә баштанаяк бирелү, шуннан башканы белмәү, шуның белән генә мавыгу. *Машина җене кагылган инде үзенә. Сәгатькә кадәр төзәтте.* Т.Гыйззәт. *Нил [Юзиев] көн-төн укуда, аңа фән җене кагылган, лекцияләрен бер дә калдырмый, һәммәсен, кызлар кебек, түкми-чәчми язып бара...* А.Гыйләҗев. **Җене кату** Бик нык үпкәләү, ачулану, гафу итә алмау. *Тәкый абзыйның яшьләрнең, картлар киңәшен тотмыйча, астыртын гына язылышып куюларына бик җене каткан икән.* Р.Төхфәтуллин. **Җене котыру** Көчле ачу кузгалу, ачуыннан нишләргә белмәү. *Ходаем, бер җене котырса --- дигәннәре дөрес инде, алайса.* Р.Төхфәтуллин. **Җене кузгалу** *к.* **җене котыру**. *Бөтен дөньясына берьюлы җене кузгалып, шуларның барысының ачуын Зәйтүнәдән алмакчы булгандай, сикереп торды карт.* Ф.Хөсни. *Инде онытты... дип куанып кына йөри башлаганыем, тагын шул уку җенең кузгалган икән, алай булгач.* В.Нуруллин. *Картның улына карата янә бер мәртәбә бик хәтәр җене кузгалды.* Г.Ахунов. **Җененә кагылу** Ачуын китерү, ачуын кузгату. *Сез аның җененә, җенбикәсенә кагылгансыз.* Г.Әпсәләмов. **Җененә килешү** Кемгә дә булса ярау, ошау. *Башына ак яулык бәйләгән бу апа аның җененә килешә бара.* Г.Ахунов. **Җенен кузгату** *к.* **җененә кагылу**. *Монда кергәнче, Сәлмән картның кайдадыр җенен кузгатканнар иде булса кирәк, ул әле һаман исенә килә алмагандай ярсый бирде.* Ф.Хөсни. **Җене сөймәү** Һич тә яратмау; күрәлмау. *Чәчсез хатын-кызны җенем сөйми.* Г.Кутуй. *Язгач-язгач, дөресен язарга кирәк, Гарәфи энекәш, ялганны җенем сөйми минем.* А.Расих. *Дөресен беләсем килә. Җенем сөйми ялганлаган кешене, эчем актарыла.* М.Хәбибуллин. **Җене чыгу** 1) *к.* **җене котыру**. *Моның аеруча җене чыга, теленә очлы-очлы сүзләр килә, ләкин шулай да тыелып кала, әйтми.* Ф.Хөсни; 2) Тәмам интегеп, азапланып бетү. *[Закир] Битенә бөрчек-бөрчек чыккан тирне җиңе белән сөртеп алгач: – Җенем чыга язды бит, малай, – дип, үз-үзенә зарланып алды.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Җен исе** Авыр, сасы, бозык ис. *Нәрсә генә эчерәләрдер шуңа, янына килерлек түгел, җен исләре килә.* Аманулла. **Җен карчыгы** Явыз, тискәре, туйдырып бетерә торган карчык турында. *Чәй урынын тиз генә җыеп ал, теге җен карчыгы тагын килеп җитәр.* Г.Камал. *– Нәрсә, әләкләп тә өлгердемени инде?! Җен карчыгы! – дип зәһәр чәчә килен.* Н.Каштанов. **Җен көче** Гадәттән тыш көч, куәт. *Җен көчләре бар икән үзеңдә, әй.* М.Әмир. *Җен көчләре белән китереп сукты исерек баштан, «үлдем» дип торам. Ике ай урынымнан тора алмый яттым.* Ф.Шәфигуллин. **Җеннәре килешү** Ике дуамал, тискәре кешенең уртак тел табулары. *Белмим инде, әллә ул миңа дошман, әллә мин аңарга? Безнең җеннәр килешә бит.* Г.Бәширов. **Җен оргыры** *к.* **җен алгыры**. *Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампының һичбер нуры; Шул мәкаль монда дөрес шул. Ах, аны, җен оргыры!* Г.Тукай. **Җен сирпелү** *миф. к.* **җен сугу (***1 мәгъ.***)**. *Төнлә белән базга күп төшеп йөрергә ярамый, җен сирпелүе бар.* Г.Камал; **Җен сугу** 1) Авыры башлауның сәбәбе – «җен кагылу» дип ышану. *Әтинең: – Шулай уйлап торам әле, – дигән сүзенә каршы: – Йөзе кара булсын! Әле берегезне, шәригатькә каршы йөргән өчен, йөзе кара булып, җен сукты бит! – дип, бик авыр сүзләр әйткән.* М.Гафури; 2) Паралич. *Җен сукканның авызы кыеш.* Әйтем. **Җен ташы** Бөтенесенә дә җитешеп, әрсезләнеп, кызу-кызу йөрүче кеше. *– Карале, теге җен ташы бии бит. – Шәп бии, чукынмыш.* Р.Батулла. **Җен туе** *мыск.* 1) Җәнҗал, зур тәртипсезлек, ыгы-зыгы, буталыш. *Квартал-квартал булып тезелгән тәтәйләр йортларында җен туе.* К.Тинчурин; 2) *миф.* Кояш баеганнан алып кояш чыкканга кадәр, кешеләрне алдаштыра, буташтыра торган вакыт. *Таң әтәчләре кычкыра башлагач, җен туе тәмамланган, һәм егет, патша кызы утырган арбага ябышып, яңадан сарайга кайткан.* Әкият; 3) *миф.* Басу-кырларда, юлларда тузан бөтереп торган өермә. *Гөр дә гөр ком буран Килде дә, берьюлы Капланды зур урам. Купты бер җен туе.* Н.Исәнбәт. *Тергеш урамнарыннан малай чакта без «җен туе» дип йөрткән тузан өермәләре бөтерелеп узды.* Г.Сабитов. **Җен урынына күрү** *к.* **җене белән бер күрү**. *Тәмәкене җен урынына күрә торган кеше, чоланнан тәмәке табып, бөтен өйне сасытты.* А.Гыйләҗев

**ҖЕН** II *и. диал.* Үңәч, азык юлы

◊ **Җенен өзү** 1) Көче, куәте белән кемнән дә булса өстенрәк булу, җиңә алырлык булу. *Ул, җиңнәрен сызганып, нечкә генә беләкләрен малайларга күрсәтеп мактанды: – Минме? Моның белән суксаммы? Теләсә кемнең җенен өзәм!* Ә.Фәйзи. *Көрәштә дә, йөгерештә дә ул, әлбәттә, иң арттa булмады булуын, әмма шул ук вакыт берәүнең дә җенен өзә алмады.* Ә.Фәйзи; 2) Ут уйнатып эшләү. **Җен кору зәхмәте** Үңәчтә үтмәс чир (рак) авыруы. *Тамактан үтмәй, кызым. Аш үтмәй, --- җен кору зәхмәте, диләр, кызым.* Н.Фәттах

**ҖЕНАЗА** *и. гар.* 1) Мәетне ислам дине кушканча күмү йоласы. *Әтинең җеназасын укырга Хатыйп хәзрәт үзе килде.* М.Гафури. *Байтүрәнең вафаты, иртәгә булачак җеназа һәм үлем хәсрәте бу йортның тынычлыгын алган.* Г.Ибраһимов. *Керде дә, әллә саташаммы дип, артына чигенде: элек җеназага бөтен авыл кешесе җыела иде. Ә монда ике бөртек карт утыра.* Мирас

2) Шул йола вакытында, мәетне күмәр алдыннан, аның гөнаһын кичерүне Алладан сорап укыла торган намаз. *Тагын бер мәртәбә дога кылганнан соң, әтинең гәүдәсен, күтәреп, өйдән алып чыгып, мәчет янында җеназа укыдылар.* М.Гафури. *Сөләйман --- берәр таныш кешене очрату уе белән, мәйданга митингка китте. Беренче карашта Сөләйманга бу митинг җеназа намазы төсле булып күренде.* К.Тинчурин. *Башта мәчеткә илтеп, яшел чирәмдә генә җеназа укыдылар, аннары, мәет ташый торган сай,*

*озын әрҗәгә салып, яңа зиратка алып киттеләр.* Ә.Еники

3) Җансыз гәүдә, мәет. *Мин монда әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, ялан аяк, ялан баш хәлемдә капка астыннан үкереп елыйелый йөгереп чыгып: «Әнкәйне калдырыгыз, әнкәйне бирегез!» – дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә хәтерләвемне язамын.* Г.Тукай. *Шул вакыйгадан соң ике көн узгач, өч шәкертнең җеназасын төнлә шифаханәдән яшерен генә чыгарып, каберлеккә озатучылар арасында Сөләйман да бар иде.* К.Тинчурин. *Кышкы зәмһәрир суыкта Дәрдемәнднең җәсәден нибары ике кеше каберстанга алып килә: ызба хуҗасы белән аның кызы, Дәрдемәнднең җеназасын чыптага төреп, чанага салалар.* Б.Урманче

4) Мәетне озату процессиясе. *Тәкъдимебез шул: цехларда кайгы митингысы үткәрәсе иде һәм шагыйрьнең [Һади Такташның] җеназасына эшчеләрдән делегация сайлап җибәрәсе иде.* Ә.Еники. *Капкадан, җеназа күтәреп, халык керде.* К.Тинчурин

◊ **Җеназа уку** Нәрсәнең дә булса бетүенә, юкка чыгуына шаһит булу. *Мәрхүм Думаның җеназасын укырга депутат булып барган Хәйрулла исәнсау кайтты.* Ш.Мөхәммәдев

**ҖЕНАЗА́ АГАЧЫ** *и.* Мәетне, күтәреп, зиратка илтү өчен махсус җайланма. *Без кайтуга, тармакларын төрле якка җәеп торган җеназа агачы әзерләнеп, өй тирәсендә тавыш-тынсыз гына йөриләр иде.* М.Гафури. *Өйгә кереп, тәһлил әйтеп, дога кылдылар да, әнинең гәүдәсен, күтәреп, җеназа агачына чыгарып салдылар.* М.Гафури

**ҖЕНАЗА́ КАБЫГЫ** *и. к.* **җеназа агачы**

**ҖЕНАЗАХАНӘ** *и. гар.-фар.* Мәетләрне юып, дәфен кылырга әзерләү бүлмәсе

**ҖЕНЕС** *и. гар.* 1) Организмның аталык-аналыкны аеру билгеләре. *[Күбәләк] Ана җенесенең канатларында тагын икешәр карасу тап та була, ата җенестә андый таплар булмый.* Биология. *Акулаларның күпчелеге – тереләй тудыручы балыклар. Яралгы ана җенес тәнендә үсә.* Зоология. *Ата җенес күбәләкләренең кузысында ефәк, ана җенеснекенә караганда, шактый күбрәк. Шуңа күрә тут ефәкчесенең үсешен күзәтеп торалар һәм яшь күбәләкләрнең, башлыча, ата җенестән булуына ирешәләр.* Зоология

2) Теге яки бу җенескә караган кеше. *Табигать адәм баласын барлык җан ияләре шикелле үк ике җенес итеп яраткан.* Ә.Еники. *Әңгәмәнең үзәгендә, әлбәттә, хатын-кыз җенесе.* Ф.Шәфигуллин

3) Нәсел, кабилә, кавем. *Кадимнән бу җирләрдә [Себердә] ханнар булган, Төрле җенес халыклары монда тулган.* М.Гафури. *Һәрбер җан иясе җенесенә тартым [булып] туар.* М.Гафури

4) Төр, иш (хайваннарда). *[Күк:] Сез үзегезнең хәлегезне генә бәян кылыгыз, алай башка җенес хайваннарга сүз тидермәгез, рөхсәт юк.* Ш.Мөхәммәдев

5) Кеше заты, кешелек дөньясы. *Сугыш туу, нәсел калдыру, яңару мөмкинлеген туктатты: шуңа каршы җенес баш күтәрә.* М.Юныс

6) *диал.* Берәр төрле әйбер, нәрсә. *Итек җенесе күрмидер идек элек*

**ҖЕНЕСЛЕ** *с. биол.* 1) Җенескә бүленеше булган, аерым җенесләрдән торган. --- *Ирандагы бик борынгы диннең баш алласы Зурван баштан ук ике җенесле алла итеп күзалланган.* Ф.Урманче. *Моллюсклар – күбесенчә аерым җенесле хайваннар.* Биология. *[Алмагачның] Чәчәкләре эре, ике җенесле, ак яки алсу төстә, төркемгә 5–12 данә булып җыела.* Өмет

2) Аталык яки аналык билгеләре булган, билгеле җенескә караган. *Y (игрик) хромосомасы хатыннарда булмый, ул бары тик ир җенесле адәмнәрдә генә була.* Р.Батулла. *Шунысы кызыклы: каракучкыл төстәге күкәйләрдән ана кортлар гына чыга, һәм бу билге бары тик ана җенесле буынга гына күчә.* Р.Зәкиев

3) Җенес күзәнәкләре ярдәмендә барган. *Гидра җенессез һәм җенесле ысуллар белән үрчи.* Зоология

**ҖЕНЕСЛЕК** *и.* Аерым бер җенескә (*1 мәгъ.*) караган булу. *Юк, Володя! Сөю үлем түгел, ул – бары тик Җенеслекнең канда уйнавы.* Һ.Такташ

**ҖЕНЕСЛЕЛЕК** *и. биол.* 1) Биологик төрдә җенесләргә бүленеш булу күренеше; үрчү җенси ысул белән бару

2) Җенсилек; билгеле җенескә караган булу

**ҖЕНЕССЕЗ** *с. биол.* 1) Җенесләр булмаган; җенси юл белән бармаган. *Җенессез үрчүнең иң гади формасы – бүленү, бу вакытта ана организмның тәне ике бертөрле кисәккә аерыла.* Биология

2) Теге яки бу җенес билгеләре булмаган, бер җенескә дә карамаган. *Аталанган күкәй күзәнәктән кабат нарат-башның җенессез буыны – спорофит үсә.* Биология. *Клон булдыру үзенә тиңнәрне булдыруга гына, җенессез кешеләр тууга илтә.* Фән һәм тел

**ҖЕНЕССЕЗЛЕК** *и.* 1) Биологик төрдә җенесләр булмау күренеше

2) Бер җенескә дә карамау күренеше; җенси билгеләре зәгыйфь булу күренеше

**ҖЕНЕСТӘШ** *и.* 1) Бер җенестән булган кеше (яки хайван). *Инде мөгаллимәләргә килсәк, анлар кемнәр? Бу [кыз] балаларның кемнәре? Әлбәттә, бер ят кеше. Факт: бер җенестәш кенә.* Х.Сәнгатьзадә

2) Төрдәш, бер үк төрдән булган әйберләр. *Җенестәш хәтта кош-корт та, күрәмсең... Казына – каз, күгәрченгә – күгәрчен.* Котб. *[Кушма сүзләрнең] --- тагылма кисәге исә шул мәгънәне киңәйтүгә ярдәмче роль уйный һәм беренче сүз белән бергә аңа җенестәш булган, аңа охшаган нәрсәләрнең дә бергә аңланырга тиеш булуын белдерә.* Г.Алпаров

**ҖЕНЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Ачуын китерү, ярсыту, чыгырдан чыгару. *Акрынлап айгырны йөгәнләделәр, дулатып, җенләндереп иярләделәр.* Г.Ибраһимов. *Сезнең сабырлык мине җенләндерә!* А.Гыйләҗев

2) Тынычлыгын алу, ашкындыру. *Шомырт исе җенләндерә кызларны.* А.Гыйләҗев. *Шушы бай, моңсу, сихерле, шигъри табигать хозурландыра, шашындыра, җенләндерә аның күңелен.* С.Поварисов

**Җенләндерә башлау** Җенләндерергә тотыну. *Кызның Хәлимне санга сукмавы, Анатолийның гына сүзләрен җөпләп, Хәлимнекеләрне бөтенләй җавапсыз калдыруы малайны җенләндерә башлады.* И.Гази

**Җенләндерә төшү** Тагын да җенләндерү. *Малайның елап-ялварып аклана башлавын көткән Зәйнәпне бу сүзләр җенләндерә генә төште.* К.Тимбикова

**Җенләндереп бетерү** Бөтенләй, тәмам җенләндерү, җенләнгән хәлгә җиткерү

**Җенләндереп җибәрү** Кинәттән, тиз арада җенләнгән, котырган хәлгә китерү, җенләнүгә этәргеч бирү. *Аракы ул ярсулыкны мең өлеш котыртып, җенләндереп җибәрә.* С.Поварисов

**Җенләндереп тору** Бертуктаусыз җенләндерү

**ҖЕНЛӘНҮ** *ф.* 1) Артык ярсып китү, нык холыксызлану, үзен-үзе белештермәү дәрәҗәсенә җитү. *Әле хәзердән үк болай җенләнгән анасы, Шибай карт үлеп, йөгәнсез, авызлыксыз калса, зур уллары ташлап чыкса, бәйләүдән ычкынган эткә әйләнер.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Гел бер үк нәрсәне уйлау, шуның белән саташып хыяллану. *Җенләнеп ята торгач, йокыга киткәнмен.* Ф.Хөсни

3) *күч.* Нәрсә белән дә булса артык мавыгу, шуңа тулысынча бирелү. *Студент чакта бер егет Евтушенко дигән шагыйрьнең шигырьләрен укып җенләнә иде.* Л.Лерон. *[Марсель] Казан университетының юридик факультетында укый, фехтование белән җенләнә.* Р.Низами

4) *күч.* Ярсу; көчәеп китү, котырыну (табигать күренешләре һәм җансыз әйберләр турында). *– Апрель бер җенләнмичә калмый ул, – диде Хәдичә әби.* Э.Касыймов. *Давылланып ничек җенләнсә дә --- чигенде, Җиңелде Ангара!* М.Хөсәен

5) *күч.* Акылдан язу, юләрләнү, диванага әйләнү. *Бу нидән икән, дип уйлап торгач, Сабира апаның иләннән сәкегә котырган шикелле йөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның урактан җенләнеп, авырып кайтканын белдем.* Г.Тукай. *Беркөн шулай әни иртән, кайтып, Галимә апаның көннән-көн кире китүен, җенләнгән кебек кыйлануларын һәм, Фәхри бабайлар белән киңәш итеп, Коръән чыгарып өшкертергә карар бирүләрен этигә сөйләде.* М.Гафури. *Җенләнмәсәм генә ярар иде.* Г.Коләхмәтов

**Җенләнә бару** Җенләнүе торган саен көчәю. *Менә шул баян белән торган саен ныграк җенләнә бардым мин.* М.Вәли-Барҗылы

**Җенләнә башлау** Җенләнергә тотыну. *Минем әдәбият белән җенләнә башлаган чагым, шуңадыр инде Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй кебек танылган шагыйрьләрнең безнең өйдә булуы яки кереп кенә чыгулары да минем өчен, билгеле, зур бер куанычлы вакыйга булып кала иде.* Ә.Еники

**Җенләнә төшү** Тагы да ныграк җенләнү

**Җенләнеп алу** Берникадәр вакыт, бераз җенләнү. *– Нәрсә сез бүген барыгыз да! – дип җенләнеп алды Зөбәеров.* Ш.Бикчурин. *Беренче класста укыганда ук, шахмат уйнарга өйрәндем һәм аның белән чын-чынлап җенләнеп алдым.* Н.Әхмәдиев

**Җенләнеп бетү** Тәмам җенләнү; бөтенләй җенләнгән хәлгә килү. *«Ничек монда килеп чыкты икән? Ничек атылмый калды икән?» Карчык шул уйлар белән җенләнеп бетте.* Г.Ибраһимов. *[Рамилә] --- шушы баскетбол белән җенләнеп беткән.* Ч.Гобәйдуллина

**Җенләнеп йөрү** Даими рәвештә, һәрвакыт җенләнү. *Муса абзый, синең болай җенләнеп йөрүеңнән берни файда юк.* Ф.Тарханова. *Әни: – Кая болай җенләнеп йөрисез? – дип төпченмәкче булган иде дә: – Кайткач күрерсең, җыенып торыгыз, – дигәч, үзе шуннан аңлады бугай инде.* Ф.Хөсни

**Җенләнеп китү** Кинәт җенләнү. *Хәләл җефете әйткәч, ул, җенләнеп китеп, Галимҗанны чыннан да караватка атып бәрде.* С.Поварисов

**Җенләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта, бераз җенләнү

**Җенләнеп чыгу** Нинди дә булса вакыт дәвамында, шул вакытның башыннан ахырына кадәр җенләнү. *Алар төннәр буе шәмнәр яндырып, кәрт ачып, тәлинкәләр әйләндереп, рухлар, мәетләр белән җенләнеп чыгалар.* Ф.Бәйрәмова

**Җенләнеп яту** Әле, хәзер җенләнү, нәрсә белән булса да нык мавыгу. *Әле Достоевский белән җенләнеп ятам.* Ф.Яруллин. *Өйдә берүзем. Нишләргә белмим. Такташ шигырьләре белән җенләнеп ятам.* Мәгариф

**ҖЕНЛЕ** *с.* **1.** 1) *миф.* Хорафатлар буенча: җене булган, җеннәр ияләшкән. --- *әти-әнисе белән һәм башка туган-тумачалары белән күрешеп, хәл-әхвәл сорашып, чәйләр эчкәч, әбием белән җитәкләшеп, үзләренең җенле өйләренә кунарга киткәннәр.* Г.Афзал. *Һә, кем йөрсен бу җенле үләт базы тирәсендә?* Н.Гыйматдинова

2) Акылын югалткан, юләр, психик авырулы. *Без эштән кайтуга, ул, эчендәге иң каһәрле ачуларын чыгарып: – Сезнең җенле Галимәгез өчен без гаепле түгел!.. --- дип каргана.* М.Гафури

3) Кызу характерлы, юкка-барга кызып китүчән. *– Җенле, – дип әйтүдән башка чарасы калмады атаның. Ул моны эчке бер куаныч һәм горурлык белән дә әйтте бугай. – Тәмам җенле малай икән бу, хәерлегә булсын.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Холыксыз, дуамал, кызу характерлы кеше. *Җенлегә якын торма.* Мәкаль

2) Акылын югалткан кеше, юләр. *Җенледән сап сорама.* Мәкаль

**ҖЕН-ПӘРИ** *җый. и. гар.-фар. миф.* Хорафатлар буенча: җирдә яманлык, явызлык таратучы, кешеләрне, котыртып, ялгыш юлга кертүче явыз кара көчләр. *«Җен-пәри» дип сөйләшүләр – искеләрдән калган ул, Сөйләве яхшы, күңелле – Шагыйранә ялган ул.* Г.Тукай. *Болардан башка, пәриләрнең, җеннәрнең төрле төсләргә керүләре ---, кайбер кешеләргә җен-пәри ияләшүләре турысында берсеннән-берсе куркыныч нәрсәләр сөйләнде.* М.Гафури

**ҖЕНСИ** *с. гар.* Җенескә мөнәсәбәтле, женескә караган. *Эшче корт күкәйләр салмый; аның җенси органнары шул дәрәҗәдә җитлексез булалар ки, гади шартларда, эшче кортны*

*практикада «үрчемсез корт» дип санарга мөмкин.* И.Халифман. *Гидраның җенес күзәнәкләре дә бар. Алар җенси үсү чорында барлыкка килә.* Биология

**ҖЕНТЕКЛӘҮ** *ф.* **1.** 1) Тәфсилләп өйрәнү, тирәнтен тикшерү. *Вәли бабай, беләм, бик усал карт, Түбән сыйфат – аның дошманы; Ул җентекләр, үлчәр унҗиде кат, Тик шуннан соң безгә ышаныр.* М.Җәлил. *Сөйләшү генә җитми, --- иң элек ул зәһәрле чүп үләннәрнең тамырлары ничек, кайларга таралганны җентекләргә кирәк.* Ш.Камал

2) Берәр мәсьәләнең асылын белер өчен һәрьяклап, бөтен ваклыкларына кадәр кат-кат сорашу, төпчену. *Һәрбер төшкән төрек әсирен үзе сорады, аның яныннан тапкан һәрбер кәгазьне үзе җентекләде.* Г.Исхакый. *[Гөлбану] Матурмы икән, эшкә уңганмы икән, әйбәт тораламы икән, --- дип, кайта-кайта нечкәләп җентекләде.* Г.Ибраһимов

3) Игътибар белән күзәтү, кызыксынып карау. *– Кешегә ышансаң, шул инде, – дип, Әсма остабикә иренең эшен җентекләп карарга кереште.* М.Галәү. *Сыерга чыккач, ничек бозау имтекләвен тәрәзә аркылы җентекләде, камыр басканда, --- яшь киленнең бераз каушап калтыраган куллары ничек йөрүен күзәтте.* Г.Ибраһимов. *Аның хәзер инде Асиянең матур күзләренә туры карыйсы, йөзен-күзен рәтләп җентеклисе килде.* Г.Иделле

4) Анализлау, анализ ясау. *Бу җентекләү иптәшләр учагы өчен язылган иде.* Г.Шәрәф

**2. җентекләп** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеләнгән таләпләрнең барысын да үтәп, җиренә җиткереп. *Ялт итеп торган абзар, автоэчергечләр, җентекләп төзелгән рацион – һәммәсе бик ошады.* Б.Камалов. *Дару препаратларының үзләрен дә, җентекләп, пөхтә әзерләү сорала.* Е.Солодухин

2) Тәфсилләп, төпченеп, кызыксынып, игътибар белән. *Ул, бик җентекләп, алдында яткан яңа чыпталарны тикшерә, аларны берәм-берәм алып, келәт эченә ыргыта.* М.Галәү. *Өй эчендәгеләр, аның җыйган чикләвеген күреп, һичшиксез: «Каян таптың бу кадәр чикләвек?» – дип кызыксынырлар, җентекләп сорашырлар дип уйлаган иде Габдулла.* Ә.Фәйзи

3) Карап, күзәтеп, тикшереп. *Солдатлар, --- бөтен хәрәкәтләрен тикшереп, җентекләп торучы шымчыларның барлыгына карамастан, үз араларында булып үткән хәлләр хакында сөйләшергә керештеләр.* М.Гафури

**Җентекләп тору** Даими рәвештә җентекләү. *Детальләрнең эшләнешен җентекләп тору*

**Җентекли төшү** Тагы да җентекләү; җентекләүне дәвам итү

**ҖЕНТЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Бөтен ягы, нечкәлекләре тәфсилләп бирелгән, бик төгәл. *Төгәл һәм җентекле хәбәрне кичкә табарак Сәхип солдат алып кайтты.* Ә.Фәйзи. *Гомумән, Р.Мостафин шагыйрь иҗатының төп этапларын билгели торган байтак әсәрләргә җентекле анализ ясый.* Р.Фәйзуллин

2) Игътибарлы, кызыксынучан, төпченүле. *Ул йомышчыларның язу-кәгазьләрен урнаштыргалап чыкты да, аларга таба җентекле күз карашы ташлап алгач, коры гына эндәште.* М.Галәү. *Әсәрләренең барысы да авторның, шагыйрь җанлы булуы белән бергә, җентекле прозаик карашына да ия икәнлеген күрсәтәләр.* Р.Даутов

**2.** *рәв. мәгъ.* Барлык вак-төякләре белән, тәфсилләп. *Реалистик һәм аллегорик образларның үзара мөнәсәбәте җентекле эшләнгән.* А.Әхмәдуллин. *Моннан И.Нуруллин Тукай һәм Тукай чоры әдипләренең иҗатларын җентекле өйрәнүгә килде.* Р.Нуруллина

**ҖЕНТЕКЛЕЛЕК** *и.* Тәфсиллелек, үтә төгәллек; төпле булу, барлык вак-төякләрне исәпкә алу күренеше. *Бу китапта төрки телләр өчен уртак һәм татар теленә хас фонетик һәм грамматик кагыйдәләр шактый тулылык һәм җентеклелек белән яктыртылганнар.* Фән һәм тел. *Халык белән эшләү сабырлык, җентеклелек, игътибар таләп итә.* Кызыл таң

**ҖЕН-ШАЙТАН** *җый. и. гар. миф.* к. **җен-пәри**. *Пошкырынып басып торган кечкенә йөнтәс ат үзе бер җен-шайтан кыяфәтендә иде.* Г.Гыйльманов. --- *борынгы Иран телендәге «daiva» соңгырак чорларда «дев» – «див» дип языла һәм «мәҗүси алла», шул ук вакыт «җен-шайтан» дигәнне дә аңлата башлый.* Ф.Урманче. *Изге китап, тынычлык саклап, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын хәтта җен-шайтан ишеләргә дә белдереп тора.* Ф.Яхин

**ҖЕП** *и.* **1.** 1) Йон, мамык, ефәк, җитен һ.б.ның җепселләрен бер-берсенә кушып, нечкә итеп сузып, бөтереп эрләнгән эшләнмә. *Өлкән кызлары, тукыр өчен, буй сару калыбына җеп чолгый.* М.Галәү. *Әбием иренми, Көнозын җеп эрли, Орчыгы көн бии, Төн бии, келдери.* Н.Исәнбәт. *Үзебезнең сарыкның язгы йонын яздым, бик нечкә итеп, җеп эрләдем.* М.Маликова

2) Берничә җепне бергә бөтереп, катып эшләнгән нечкә бау, шнур. *Парашют җепләреннән бушануга, автоматын тотып, ул кар өстеннән йөгерә.* И.Гази. *[Хәмит] Озын җепкә тезгән ак таран белән чабак, кызылканатларны да күп алып кайта иде.* Ә.Еники. *Алайса, тротилның җебенә ут төртәсең дә – бабах!* Р.Сәгъди

3) *сөйл.* Металлдан яки сеңердән ясалган сыгылмалы нечкә бау; кыл. --- *бик зур бер җәен эләккән иде, җебем чыдамады – кармакны өзеп алып китте, ди [Фәхри малае].* Г.Ибраһимов. *Әти миңа да район кибетеннән җебение белән чын кармаклар алып кайткан.* Х.Сарьян

4) *диал.* Гомумән бау. *Җеп нечкә урыннан (җиреннән) өзелә.* Әйтем. *Егылганнарга кул бирмәс, батып барганга җеп сузмас.* Г.Тукай. *Бу – кыска буйлы, ябык гәүдәле --- азрак кылый күзле бер карт: өстендә иске җилән, аны билдән җеп белән буган.* Г.Ибраһимов

5) Үрмәкүч пәрәвезенең аерым-аерым җепселләре. *Үрмәкүчләр botak-тан-ботакка җеп сузган, пәрәвез корган.* Ш.Бикчурин. *Агачлар арасыннан үткәндә, йөзне җиңелчә кытыклап, биткә тоҗым җепләре сырышты.* Г.Әпсәләмов. *Әвернәле ана үрмәкүч, пәрәвез җепләреннән агач ботаклары арасына, койма яннарына һәм башка урыннарга вертикаль итеп тарттырып, зур ау ятьмәсе – пәрәвез үрә.* Биология

6) Гөмбә җепселләре. *Гөмбә җепләрендә кайвакытта үсентеләр хасил*

*була, һәм алар суүсем күзәнәкләренә үтеп керә.* Ботаника

7) Организмда җепсел (*2 мәгъ.*) рәвешендәге тукыма. *Скелет мускуллары аркылы-буйлы мускул тукымасыннан төзелгән, аның мускул җепселләре бәйләм-бәйләм тора. Җепселләр эченнән аксым җепләре үтә.* Биология

8) Кешедә: чәч, сакал бөртекләре. *Минем өчен ул һаман яшь, зифа иде, студент чактагыдан бөтенләй үзгәрмәгән дә шикелле иде. Тик бөдрәләрендә көмеш җепләр чагылып китә.* М.Маликова. *Кара чәчләрендә сирәк кенә ак җепләр дә күренгәли башлады, күз төпләрендә вак кына челтәр дә пәйда булды.* Ә.Еники

9) *күч.* Кешеләр арасындагы якын мөнәсәбәт, бәйләнеш. *Барчагыз Алла җебенә ныклап тотыныгыз, «Алла җебе» дигәнем – үзара якынаю, дуслашудыр, димәк, үзара каршылыктан, ызгыштан саклануды́р.* Г.Тукай. *Шул көннәрдә күңеленә хуҗа булган акылларның берсе, беренчесе шул иде: әлегә безне ислам диненең гүзәл, тирән кануннары гына берләштерә, без, белепме-белмичә дәме, күзгә күренмәгән бик күп җепләр белән аңа ялганабыз.* А.Гыйләҗев. *Ул мене аларны [балаларны] моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде.* Ә.Еники // Кан-кардәшлек бәйләнешләре. *Каргалы халкының да иң зур күпчелеге – Еникеевлар һәм Терегуловлар, һәм алар, чынлап та, үзара туганлык җепләре белән бик нык бәйләнеп, чуалып беткәннәр.* Ә.Еники

10) *күч.* Яшәү процессындагы эзлекле бәйләнеш. --- *карт крестьян хуҗалыгының һичбер җебен үз кулыннан ычкындырырга теләмәде.* Г.Ибраһимов. *Сүз болай куергач, Хәлимә түти дә чыдамады, иренә ялварып, әр җебен өзмәк булды.* Б.Камалов. *Катнаш гаиләдә милли тәрбия, нәсел җебен саклау мәсьәләсе ата-аналардан тора.* Сөембикә

11) *күч.* Күңелләрне бәйли торган хис. *Илсөя шундый хәл кичерде. Өметнең соңгы җепләре өзелер чиккә җитеп килә.* М.Госманов. *Фәнияр кырына гел барып йөргәндә, мәхәббәт җепләренә болай нык чолгангандыр, дип уйламый иде.* Ф.Яруллин. *Аннары тагын шул чаклысы да бар, тартыша торгач, ике арадагы мәхәббәт җебенең өзелеп китүе дә мөмкин ич.* Ф.Хөсни

12) *күч.* Уй, фикернең эзлекле агылышы. *Минем фикер җебемне югалтмыйсыңмы?* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җептән ишеп, үреп, бәйләп һ.б.ш. ясалган. *Ярый әле җеп баскычлар бар, алар булмаса, ничек менәр идең бу таш стенага.* И.Гази. *Җеп чабата*

2) Тар, юка, нечкә. *Кырма сакаллы, җеп мыеклы, камзул һәм бишмәт чабуларын җилбәгәй җибәреп, очынып йөрүче авыл старостасы Зариф эчү, сыйлану ягын гына кайгырта.* Г.Толымбай. *Митя озын буйлы, аксыл чырайлы, озын куллы, торна тезле, җеп иренле егет иде.* А.Гыйләҗев

◊ **Җеп бөртеге** Бик кечкенә өлеш, нәрсәнеңдер бик азы. *Яфракларга дуга тиеп киткән саен, өскә шыбырдап су коела. Ун чакрым урманны чыккančы, бер генә җеп бөртеге дә коры килеш калмаячагы көн кебек ачык иде.* Р.Батулла. **Җеп бөртекләп** Бәйнә-бәйнә, җентекләп. *«Балачак бәйрәмнәре»ндәге шигырьләр шулхәтле дә җеп бөртекләп, энҗе бөртекләп эшләнгәннәр.* Г.Ахунов. **Җеп бөртексез булып** Манма су булып, тулысынча, үтәдән-үтә, нык чыланып. *Анда исә җеп бөртексез булып чыланган бу кешеләрне җылы өйләре көтә иде.* Ф.Хөсни. **Җеп бөртексез итү** 1) Нык юешләү, манма су итү. – *Сөбханалла, әкренрәк кылан, балакаем. Күрмисеңмени, мине дә җеп бөртексез иттең бит, – дип назлап дәшкән бу тавышны да шулкадәр үз итте сабый, чыркылдап ук җибәрде.* Г.Галиева; 2) *к.* **җеп бөртексез калдыру**. **Җеп бөртексез калдыру** Кычкыртып талау, үзләштерү. **Җеп бөртексез калу** Бернәрсәсе дә калмау, бар булганны югалту. **Җеп калынлыгы** Бик нечкә. *Мәскәүле Павел Иванович Токмаков зыялы, бармаклары нәзек, озын, тавышы да неп-нечкә, җеп калынлыгы гына...* А.Гыйләҗев. **Җеп кебек** *к.* **җеп калынлыгы**. *«Кода абый» дигәне чандыр гына сары йөзле, мыегын җеп кебек калдырып кырган, күзләренә сөрмә тарткан, кырыс чырайлы берәү иде.* Ә.Фәйзи. **Җепкә тезгән кебек** *к.* **җепкә тезгәндәй**. *Кайвакытта исә вагоннар ябык була, һәм алар җепкә тезгән кебек, уенчык вагоннар төсле булып күренәләр.* Ә.Еники. **Җепкә тезелгәндәй** Бер генә эздән, бер-бер артлы, туры итеп. *Элек заманнарда авыл кызлары эзләренең җепкә тезелгәндәй тигез булуы белән мактанганнар.* М.Маликова. **Җепкә тезү** 1) Уй, фикер һ.б.ш.ны билгеле бер тәртипкә китерү, фикерне туплау. *Халидәнең кайнар тәне, татлы сулышы аның күңелен юатты, уйларын бер җепкә тезәргә көч бирде.* М.Маликова. *Сәгать буенча вакыт докладның бөтен чуалчык якларын җепкә тезде.* Г.Ибраһимов; 2) Берләштерү, бергә туплау. *Явызлык үзенә ышанган кешеләрне тәсбих дисбесе кебек бер җепкә тезә, уйланган эшнең ахырына җитмичә, аны божрадан чыгармый.* Т.Галиуллин. **Җепне нечкәдән эрләү** Сүзне, мәсьәләне бик нечкәләп төшенептөшендереп сөйләү. *Җепне нечкәдән эрли бу.* Н.Исәнбәт. **Җепне тешләгән җиреннән өзү** Икеләнергә урын калдырмыйча, катгый эш йөртү. *Җепне тешләгән җиреннән өзәргә өйрәтелгән кеше.* Ф.Хөсни. **Җеп очы күренү** Фаш булу, ачыклану, беленү, билгеле булу. *Сәрхуш турында башкаларга сүләмәдем. Күп сүләсәң, җеп очы күренә башлый.* Г.Әпсәләмов. *Сөйләшә торгач, моның җеп очы күренде.* Х.Камалов. **Җеп очын җую** *к.* **җеп очын югалту**. **Җеп очын күрсәтмәү** *к.* **җеп очын яшерү**. **Җеп очын табу** 1) Нәрсәне дә булса аңлау. – *Менә мин калага кайтам да Емельяновны күрәм. Аның аркылы җепнең очын табып булыр, – ди.* Г.Ибраһимов; 2) Җинаятьне ачу. **Җеп очын югалту** Бәйләнеш, эзлеклелекне югалту, чуалу (сүз, фикер һ.б. турында). *Ат башыдай алтын өчен тиешле акчаны санаганда, җепнең очын югалттык, саннарны саташтыра башладык.* М.Гафури. --- *Зәйтүнә тозакка эләгергә ашыкмады, кунакның*

*бу сүзләрен тиз генә уенга борып, җепнең очын югалтып өлгерде.* Ф.Хөсни. **Җеп очын яшерү** Таба алмаслык итү, яшерү, тоттырмау. *Җепнең очларын шулай нык яшерделәр. Ләкин без капчыкта ята алмады. Бу сөйләшүләр Шакирҗанның хатыны Миңленисаның колагына чалынды.* Г.Ибраһимов. **Җеп очы ычкыну** 1) *к.* **җеп очын югалту**. *Төнлә ничектер төшендем күк. Иртән тагын җеп очы ычкынган.* Ш.Галиев; 2) Нинди дә булса уңайлы моменттан, мөмкинлектән файдалана алмый калу. *Ничек кенә булмасын, күренеп кенә киткән җеп очы тагын кулдан ычкынды.* Р.Мостафин. **Җеп өзәрлек дәрман калмау** *к.* **җеп өзәрлек хәл калмау**. *– Туңып торам әле, – диде хатыны. – Җеп өзәр дәрманым калмады.* Р.Зәйдулла. *Бөтен гәүдәсе тиргә батты, куллары-аяклары тәмам изелеп, җеп өзәрлек тә дәрманы калмады.* Г.Бәширов. **Җеп өзәрлек көч калмау** *к.* **җеп өзәрлек хәл калмау**. **Җеп өзәрлек хәл калмау** Бик нык ару, хәлдән таю. *Булмый, җеп өзәрлек хәлем калмады.* Ф.Хөсни. *Заһитның өсте лачма су булды, итекләре бүртте, авырайды, үзенең җеп өзәрлек тә хәле калмады.* Мирас. **Җеп сыйрак** Нечкә балтырлы кешегә карата әйтелә. *Тирән базда үргән бәрәңге сабаклары төсле ак чырайлы, җеп сыйраклы пионеркалар, соңгы тамчы канга кадәр империалистлар белән көрәшергә чакырып, ал галстукларын җилфердәттеләр.* А.Гыйләҗев

**ҖЕПЬЕЛАН** *и. зоол. к.* **җеп суалчан**

**ҖЕПКЕР** *и. фар. махс.* Шома яки бөтерелгән алтын яисә көмеш җеп ярдәмендә челтәрләп эшләнгән яки металл җирлеккә кургаш коеп ябыштырылган бизәк (зәргәрлек сәнгатендә кулланыла торган эш алымы); *русчасы:* **скань, филигрань**

**ҖЕПКЕРТҮ** *ф. диал.* Туйдыру, биздерү, ялыктыру. *Көн дә ашасаң, майлы ботка да җепкертә.* Мәкаль. *Он булмагач, арыштан ботка пешереп карадык, тәме юк, тиз җепкертте.* Г.Тавлин

**ҖЕПКЕРҮ** *ф. диал.* 1) *махс.* Кул станында тукыганда, җепне кылыч аша үткәрү

2) Җирәнү; нәфрәтләнү

3) *күч.* Кирәгеннән артык ашап макмырлау (мал турында)

**ҖЕ́П ОЧЫ** *и.* 1) *махс.* Сугып эшләнгән әйберләрнең баш-башларындагы буй җепләр; чуклар бәйләме, чачак

2) Башы балавыз яки сумала сеңдереп ясалган калын җеп. *Югары шүрлектә әтисе аның өчен калыпка тартып куйган читек башы тора, ---. Без белән тишәсе дә, җеп очын тыгып, выжт-выжт тартып чыгарасы.* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Нинди дә булса хәлнең килеп чыгуына төп сәбәпчесе, аңа этәргеч булган нәрсә, башы, башлангычы, нигезе. *Җепнең очы волбашкармада эшләүче бер егеткә барып тоташты.* Г.Ибраһимов. *Шул Дәүләтхан гына бөтен качкынны өенә яшереп ята, бер ул гына шуңа сәләтле, бөтен угрылыкның җеп очы аңа килеп төйнәлә.* Р.Камал. *Әмма ябышырлык җеп очы күренмәде.* Х.Камалов

**ҖЕПСӘ** *и.* 1) Сосада шүрене урнаштыра торган таякчык; шүре күчәре

2) Өй яки каралты кыегында, такталарны беркетү өчен, бәпкәләргә аркылы кагылган, агач, ишек, капка такталарын беркетеп торган борыс. *Болдырга чыккач та, ул, аркылы җепсәгә терсәкләре белән таянып, бер тын уйланып торды.* Н.Хәсәнов. *Чери башлаган җепсә урталай сынып, койма такталары шапылдап җиргә коелдылар.* Ф.Сафин

3) Пыяла, такта кебек нәрсәләрне беркетү, урнаштыру өчен рамга ясалган уем (уенты), ырмау. *[Гриша эшләгән] Рамнар --- пөхтәрәк тә, ыграк та. Почмакларда, җепсәләрдә бер ярык юк, ябышып торалар.* И.Салахов

4) *диал.* Тәгәрмәч теше, киги. *Тәгәрмәчнең җепсәләре коелу*

**ҖЕПСӘЛЕК** *с.* **1.** Җепсә (*2 мәгъ.*) өчен яраклы. *Җепсәлек агач әзерләү*

**2.** *и. мәгъ.* Җепсә өчен яраклы агач, җепсәгә яраклы материал. *Бер кайтуында, ул машинасына сөян салып кайта, икенче карасаң, җепсәлеген, ишектәрәзә яңагына ярарлык агачын төяп кайта.* Казан утлары

**ҖЕПСЕЛ** *и. биол.* 1) Тере организмнарда тән тукымасын тоташтырган озынча күзәнәк; *русчасы:* **волокно**. *Физик эш, физкультура һәм спорт белән регуляр рәвештә шөгыльләнгәндә, мускул җепселләре тизрәк үсәләр.* Анатомия. *Чөгендердәге күзәнәк җепселләре эчәклектәге зарарлы токсиннарны һәм май матдәләрен үзенә йота.* Мөселман календаре. *Ул тамашачы белән шулкадәр элемтәгә керә, аларны уенга тарта, шул рәвешчә, тыңлаучысының тартылган нерв җепселләрен йомшартып, җанында тынычлык урнаштыра.* Мәдәни җомга

2) Синтетик юл белән ясалган сүс массасындагы аерым бер бөртек

3) Кайбер үсемлекләрнең сабакларыннан алына торган сүсле катлам; юкә сүсе. *Җитен, юкә һәм башка кайбер үсемлекләрнең сабакларында юкәр җепселләре аеруча яхшы үскән һәм бик нык була. Җитеннең юкәр җепселләреннән җитен тукыма, --- мунчала һәм чыпта әзерлиләр.* Биология

4) Үрмәкүч һәм башка бөҗәкләр чыгарган махсус ябышкак сыекчадан барлыкка килгән җепкә охшаш сузылмалар. *Җылы тын һавада пәрәвез җепселләре оча.* М.Хәбибуллин

5) Үсемлекләрнең яфракларында, бөҗәкләрнең канатларында тармакланып киткән, орлыкны төпсәгә тоташтыра торган бик нечкә сүсчәләр; *русчасы:* **жилка**. *Сеңерчәләрнең махсус җепселләре яфракларга ныклык һәм сыгылмалылык бирә.* Биология

6) Мүкләрнең, лишайникларның, кайбер суүсемнәр һәм гөмбәләрнең су һәм азык матдәләрен суыру өчен хезмәт итә торган, тамырга охшаш ялгылары

7) *күч.* Кешеләр арасындагы якын мөнәсәбәт, бәйләнеш. *Каенана белән килен арасы бик юка җепселгә тиң, бераз гына шелтә төсмере белән әйтелгән сүз, аз гына кыегайган караш та өзә ул җепселне.* Татарстан яшьләре

**ҖЕПСЕЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Җепселләр барлыкка килү, җепселлегә әйләнү

2) Сүсәреп бетү, чүбекләнү. *Ана, җепселләнгән яулыгы читләре белән күзләрен сөртә-сөртә, кызы Дөрриянең уң кулын аның яңа әнисенең уң кулына уң кулы белән тоттырды.* М.Хуҗин

**Җепселләнә төшү** Бераз җепселләнү, бераз җепселләнгән хәлгә килү

**Җепселләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җепселләнгән хәлгә килү

**ҖЕПСЕЛЛЕ** *с.* Җепселләрдән торган

**ҖЕПСЕЛЛЕЛЕК** *и.* Җепселле булу, җепселләрдән тору. *Җиләк-җимешнең җепселлелеге*

**ҖЕ́П СУАЛЧАН** *и. зоол.* Йомры суалчаннар классыннан, кеше һәм хайван организмында яши торган, 30 – 40 см озынлыктагы чәч бөртеген хәтерләткән паразит корт; *русчасы:* **нитчатка**, **волосатик**

**ҖЕ́ПСЫМАН** *с.* 1) Җеп кебек нәзек, җепкә охшаш. *Ризоидлар – бер яки берничә күзәнәктән торган җепсыман үсентеләр.* Биология. *Эвкалиптлардан тыш, Австралия өчен акацияләр, җепсыман сабаклы яфраксыз казуариннар хас, алар башка материкларда юк.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) Биологиядә кайбер төрчәләрнең классификацион билгесен белдерә торган сүз. *Җепсыман суалчаннар. Җепсыман тишмән*

**ҖЕПШЕК** *с.* **1.** 1) Бераз дымы булган, эри төшкән, юеш. *Яратам мин туган якларымның Бәсле таңын, җепшек буранын.* С.Урайский. *Март аеның иренеп кенә җепшек кар яуган җылымса бер көнендә авыл почтальоны Локман карт кулына сары конверт тоттырып китте.* Ә.Еники. *Авиатехник, канаттан тотып, селкеткәләп, чаңгылары белән җепшек карга ябышкан самолётны кузгатып җибәрде.* С.Баттал

2) Кары эри төшкән, лыҗырдык, пычрак. *Көн һаман соры, җепшек, аяк асты пычрак.* Г.Әпсәләмов

3) Дымык, юеш, томанланып торган (һава, көн турында). *Хәлимнәр дә бит шундый җепшек көннәрдә мәктәптән урамга йөгереп чыгалар иде дә, берәр атлы узып барганны күрсәләр, аңар кар атып калалар иде.* Г.Гобәй

**2.** *и. мәгъ. күч. к.* **җепшеклек** (*2 мәгъ.*). *Бу юлга яңа дәвердә, Хрущёв җепшегендә аягын чылата-чылата, беренчеләрдән булып, Нурихан Фәттах чыкты.* Т.Галиуллин

◊ **Җепшек борын (танау)** Уңмаган, булдыксыз, эшкә сәләтсез кеше. *Әй, җепшек борын, кеше өйрәтүдән элек, борыныңны җыярга өйрән!* Н.Исәнбәт

**ҖЕПШЕКЛӘНДЕРҮ** *ф. з.-сыз к.* **җепшекләтү**

**ҖЕПШЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Җепшеккә әйләнү (кар турында). *Урман унга бөгелсен, җил дөнья җимерсен, ә кортлекләргә берсе дә куркыныч түгел. Тик кар-фатир өсте җепшекләнеп бозланмасын гына.* М.Рәфыйков. *Юеш җил исә, ара-тирә түбәләрдән тамчылар ычкынып очып китә, кар җепшекләнеп басыла, йөргәндә кисәк-кисәк аякка ябыша...* Ә.Еники

2) Җепшү, лыҗырдау. *Апрель ае җитү белән, аяк асты җепшекләнә*

**Җепшекләнә башлау** Җепшекләнергә тотыну. *Сабан туен, язның бу шау-шулы, ыгы-зыгылы һәм шатлыклы якты бәйрәмен, без, малайлар, кар җепшекләнә башлагач ук көтәргә тотына идек.* Г.Бәширов

**Җепшекләнә төшү** Беркадәр җепшекләнү, бераз җепшекләнгән хәлгә килү. *Кар җепшекләнә төшкән*

**Җепшекләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җепшекләнү

**Җепшекләнеп китү** Нинди дә булса сәбәп аркасында, тиз арада җепшекләнгән хәлгә килү. *Көн җылыткач, кар җепшекләнеп китте*

**Җепшекләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта җепшекләнгән хәлдә булу. *Бу арада көннәр җепшекләнеп тора*

**ҖЕПШЕКЛӘТҮ** *ф. з.-сыз* Юешләнү, җир өсте җепшеккә әйләнү. *Кояш бераз карауга, аяк аслары җепшекләтә*

**Җепшекләтеп җибәрү** Тиз арада, кинәт, соңгы вакытта җепшекләнү. *[Декабрьдә] Март килгәндәй, йомшартып, җепшекләтеп җибәрде.* Г.Хәсәнов

**ҖЕПШЕКЛЕК** *и.* 1) Җепшек булу, дымлы булу хәле. *Һавада җепшеклек исе аңкып, борыннарга һәм бөтен вөҗүдкә язның якынлашканын белдерә башлады.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Җиңеллек, киеренкелек кимү хәле. --- *шул ук вакытта поэзиягә «Хрущёв җепшеклеге» чорында килгән буынның фикер төрлелеге, иҗат иреге ---, ничектер, югалып калды.* Т.Галиуллин. *Никита Сергеевич Хрущёв Сталинның һәм аның иярченнәренең илгә коточкыч фаҗигаләр китерүе турында доклад ясый. Ил вазгыяте «җепшеклек» («оттепель») кичерә. Күпмедер дәрәҗәдә халыкка иркенлек килә.* Казан утлары

**ҖЕПШЕНҮ** *ф.* 1) Бераз гына җепшү; эри, сулана башлау

2) Дым сеңеп йомшару, кабарып, көпшәкләнеп тору. *Әүвәле кара җирдә, кара җирдән соң балда һәм майда, актан-ак сөттә һәм сөзмә катыкта җепшенеп буынланган ак бармаклы кулларын тез очларына куйды.* А.Хәлим

**Җепшенә төшү** Беркадәр, бераз җепшенү. *Туң ит җылыда җепшенә төшкән*

**Җепшенеп алу** Беразга, аз гына җепшенү. *Тормышның чал диңгезендә Күпме җепшенеп алдым.* М.Сафиуллин

**Җепшенеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җепшенү. *Яңгырда җепшенеп беттек*

**ҖЕПШЕТҮ** *ф. з.-сыз* 1) Аяк асты җепшек хәлгә килү, кар эри башлау. *Ашыкмый килә яз: җепшетә, тамчылар тама башлый, анда-санда сулар тибеп чыга, җылы җилләр исә.* Р.Мирхәйдәров. *Көндез җепшетеп, кояш ашап иләкләткән юл кары, туңып, пыялага әверелгән.* В.Нуруллин

2) Җепшү, лыҗырдау, пычракка әйләнү. *Яңгыр күптән түгел генә башланган, ахры, аяк астын артык җепшетеп өлгермәгән.* Ф.Бәйрәмова

**Җепшетә башлау** Җепшетергә тотыну. *Көн урталарында җепшетә башлады шул инде.* Ш.Камал

**Җепшетә төшү** Беркадәр җепшетү, бераз җепшеткән хәлгә килү. *Март ае бит, бераз җепшетә төшкән*

**Җепшетеп алу** Кыска вакыт эчендә бераз җепшетү. *Көндез бераз җепшетеп алган аяк асты ярмаланып каткан иде.* Л.Ихсанова

**Җепшетеп җибәрү** Тиз арада яки кинәт җепшетү, җепшеткән хәлгә китерү. *Яңа ел башына кадәр ишле карлар явып, көннәр буранлап торды да, кинәт кенә җылытып, җепшетеп җибәрде.* Ф.Сафин

**Җепшетеп тору** Әле, хәзерге вакытта җепшеткән булу. *Бүген җепшетеп тора әле*

**ҖЕПШҮ** *ф.*1) Бераз эри төшү, җепшек хәлгә килү

2) Җепшек һавадан, томаннан чык төшү, дымлану

3) *күч.* Борын йомшару

**Җепшеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җепшү; бөтенләй җепшегән хәлгә килү. *Ишегалдындагы кар җепшеп беткән*

**Җепшеп китү** Бераз, берникадәр җепшү. *Иван Иванович исә шатлыгыннан елмая --- һәм, үзе дә сизмәстән, җепшеп киткән борынын халат итәгенә сөртә иде.* А.Расих

**Җепшеп тору** Әле, хәзерге вакытта җепшегән хәлдә булу. *Бүген кар бераз җепшеп тора*

**Җепши башлау** Җепшергә тотыну. *Өй түбәсеннән тамчылар тамып, карлар җепши башлады.* М.Гафури

**Җепши төшү** Беркадәр җепшү; бераз җепшегән хәлгә килү

**ҖЕТЕ** I *с.* **1.** 1) Яхшы күрүчән, үткен. *[Мәүлихә түти] Тирес өеме кебек кенә булып күренгән тәбәнәк солы чүмәләләренә күрсәтте: – Әнә, күрәсеңме аларны? Минем күзләрем ул хәтле җете түгел түгелен, алай да күрәм.* Г.Бәширов. *Һәм шулай уйлап барганда, җылы җәйләр, туячак тамаклар турында матур хыяллар эчендә атлап барганда, җете күзле Мансур кинәт кычкырып җибәрә: – Борчак!* М.Мәһдиев

2) *күч.* Үткен, көчле, куәтле. *...Пляж. Якты, җете кояш.* М.Мәһдиев. *Тузан бөртеге дә очмаган күк йөзенә җете кояш балкып менгән бер көн иде.* Х.Сарьян

3) *күч.* Үткен, елгыр. *Җете кеше җитәр җиренә җитми кайтмас.* Мәкаль

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Яхшы, нык. *Ләкин бүген, март кояшы бик җете кыздырып, тамчылар тәрәзә буенда тыптып биешеп торсалар да, Гөлниса карчык бераз ялгышты.* Ф.Хөсни. *Кояшы үтә җете бүген, күләгә бик аның төшә...* М.Хуҗин

2) Яхшы, ачык итеп. *Җете күрү*

3) Аек рәвештә, зур игътибар белән. *Фаҗигагә юлыкмыйк дисәк, Иң яхшысы: бүген үк дөньяга, тирә-юньгә җетерәк карыйк.* Р.Фәйзуллин

**ҖЕТЕ** II *с.* **1.** 1) Ачык, күзгә бәрелеп торган. *Җете кызыл тиз уңа, дип, белеп әйткәннәр икән.* В.Нуруллин. *Минем уемча, классик әдибебез булган Ф.Әмирхан әсәрләрен җиз иләктән иләүдән туктап, --- җете һәм контраст буяуларга манчымыйча чыгару – якын киләчәк эше булырга тиеш.* Р.Әмирхан. *Күк йөзе искиткеч җете йолдызлар белән тулган бу аяз апрель кичендә Зәйтүнә берьюлы --- ике ялгышын эшләде.* Ф.Хөсни

2) *сөйл.* Ачылыгы, тозлылыгы нык сизелеп торган. *Җете аш тәмләткечләр. Җете азыклар белән сыйлану*

3) *күч.* Артык бирелгән, үтә прогрессив булып күренергә тырышкан. *Андый авылларда, исемле байлар, муллла-мунтагайлар, фанатик картлар белән беррәттән, ата дәһриләр дә, җете коммунистлар да, чая комсомоллар да күп табыла.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик нык, кирәгеннән артык. *Кыяр җете тозланган*

**3.** *кис. функ.* Төп төсне аңлаткан сыйфатлардан алда килеп һәм басымны да үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый; бик ачык, үтә. *Илдарның башында кечкенә козырёклы кепка булыр, читеннән карга канаты кебек җете кара чәче чыгып торыр.* Г.Гобәй. *Габдулла кибеткә килеп җиткәндә --- кара сакаллы, җете кызыл иренле, таза гәүдәле Лотфулла абзый бер казакка ит үлчәп тора иде.* Ә.Фәйзи. *Чебен гөмбәсен ак таплар төшкән җете кызыл эшләпәсе буенча җиңел танып була.* Биология

◊ **Җете кызыллану** *к.* **җете кызыл булып кылану**. **Җете кызыл булып кылану** Артык дәрәҗәдә ихлас тәгълиматчы булып күренү. *Әлхасил бигрәк җете кызыл мөэмин булып кылана.* Г.Тукай

**ҖЕТЕЛӘНҮ** I *ф. сөйл.* Яхшы ишетә яки күрә башлау

**Җетеләнә бару** Вакыт узган саен ныграк җетеләнү, акрынлап, аз-азлап җетелеге арту. *Дәваланганнан соң, энинең күзе җетеләнә бара*

**Җетеләнә төшү** Беркадәр җетеләнү; бераз җетеләнгән хәлгә килү

**Җетеләнеп җитү** Бөтенләй, тулысынча җетеләнү; бөтенләй җетеләнгән хәлгә килү

**ҖЕТЕЛӘНҮ** II *ф.* 1) Төсе аермачык булып күренү, төсе ачыклану. *Сакал баскан бите уртасында ак тешләре җетеләнеп күренде.* Х.Камалов. *Әнә күр, ямь өстенә ямь биреп, яран гөлләр җетеләнә, һәркайсы – күңелгә ятышлы бер бәйләм.* М.Рәфыйков

2) *күч.* Ачылу, ачыклану. *--- салкынча саф һаваны күкрәк тутырып сулаудан зиһен тагы да җетеләнеп, яктырып китте.* А.Вергазов

3) *күч.* Әһәмияте арту, эчтәлеге, мәгънәсе тирәнәю. *Искә төшердеңме – ул көннәрнең төсләре җетеләнә, кешеләре – әүлияга, ә әйткән сүзләре изге догага әйләнә.* К.Кәримов

**Җетеләнә бару** Вакыт узган саен ныграк җетеләнү, акрынлап, аз-азлап җетелеге арту. *Еллар үткән саен, аның төсмерләре якыная, җетеләнә генә бара.* М.Вәлиев

**Җетеләнә төшү** Бераз җетеләнү

**Җетеләнеп китү** Нindидер этәргеч сәбәптән соң яки хәзерге вакытта җетеләнгән хәлгә килү. *[Кунак кызы] Тәмам күңеле булганчы, көзгедән үзен күзәтте. Иңбашларына төшеп торган чәчләренә, тагын да яктырып, җетеләнебрәк киткән күзләренә --- сокланып карап торды.* Р.Мөхәммәдиев. *Юкәләр күләгәсендә калган яшел сукмак, салкын су бөркеп алгандай, җетеләнеп китте.* Г.Вәлиева

**ҖЕТЕЛЕК** I *и.* Җете I (*1 мәгъ.*) булу, үткенлек. *Күзәтүчеләр, үзе яза торган аппаратлар ярдәме белән, һава температурасын, җил көчен һәм юнәлешен, атмосфера басымын, кояш яктыртуының җетелеген тәҗрибә вакытында теркәп тордылар.* И.Халифман. *Тик безнең күзләргә – җетелек, күңелләргә сизгерлек җитенкерәми шул, таңнарның балкышларын һәм болытларның агышларын төсмерләре белән аерып күрә белмибез.* М.Маликова

**ҖЕТЕЛЕК** II *и.* 1) Төсләрнең җете II (*1 мәгъ.*) булуы. *Инде яфракларда да*

*иртәнге сусыллык, җетелек, шәплек юк.* Рифә Рахман

2) Сизелеп торган тозлылык, ачылык дәрәҗәсе. *Ашның җетелеген табып карау*

**ҖЕТЕМ** *и. иск.* Бетү, юк булу; үлү. *Дөнья фани: үлеме бар, җетеме бар.* Әйтем

**ҖЕФЕТ** *и. фар. иск.* 1) Ир хатыны яки хатын ире, кемнең дә булса никахлы хатыны яки ире. *Ничә җефет тагын да кулга төшмәс, Шаһиншаһ бик ирекkән иде – пошмас.* Котб. *Мондый җефет насыйп булса, талашырга телем күтәрелер иде микән?* Ф.Баттал. *Кырык еллап гаилә тормышы киеренә карамастан, җефетем – гүяки әле дә яшь-яшь ханбикә!* З.Фәйзи

2) *иск.* Җөп, пар, куш; так түгел. *Аннан Нух галәйһиссәлам үзенең әһелен көймәгә куеп вә һәрбер хайваннан берәр җефет, ягъни аталы-аналы икешәр хайван алды.* К.Насыйри

**ҖЕФЕТЛӘНДЕРҮ** *ф. сир.* Никах укытып, ир-атны өйләндерү яки хатын-кызны кияүгә бирү. *Бу замандагы кызларга мөмкин кадәр яшьләйрәк никах укытып, җефетләндерергә кирәк иде, дип, Җаббар абзый өчен бер дә кирәкмәгән сүзләр дә сөйләде.* Х.Мөҗәй. *Качан пәйгамбәр йегерме йәшкә тиггәндә, Абу Талип Хәдичә хатунны пәйгамбәр галәйһи әс-сәламгә җефетләндерде.* Нәһҗел-Фәрадис

**ҖЕФЕТЛӘНҮ** *ф. иск.* Парлашу, өйләнү

**ҖЕФЕТЛӘ́Ү** *ф. иск.* Хатынлыкка алу, өйләнү. *Әй угыл, җефетләнергә теләсәң, шундаен хатынны җефетлә ки, дин әһеле кулында тәрбияләнгән булсын.* К.Насыйри

**ҖЕФЕТЛЕК** *и.* Җефет булу. *Сәламдин соң кәлям яздым үзеңә, Җефетлеккә өмид идәм үземә.* Г.Кандалый. *Ничек аны Казанның усал егетләре эләктермәгәннәр дә, җефетлеккә ярәшеп, бәхетләренә ирешмәгәннәр?* Ф.Яхин

**ҖИБӘЛӘЙ** *и. диал.* 1) *бот.* Маренначалар семьялыгыннан, тар яфраклы, сары яки ак төстәге вак чәчәкле үлән яисә куак үсемлек; йогырт; *русчасы:* **подмаренник**

2) *бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, озынчага бөтерелгән бераз кытыршы яфраклы, кабарынкы йомшак себеркәч чәчәкле күпьеллык дала үләне; кылган; *русчасы:* **ковыль-волосатик, тырса**

3) Кыска буйлы йөнтәс кеше (шулай ук, куе чәчле хатын-кыз)

**ҖИБӘРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **җибәрү**. *Җибәрелгән күчтәнәчләрне карамас борын ук, хатны укырга керештем. Бу хат үткән атнада ук җибәрелгән иде.* М.Гафури. *Су юклыктан, эсседән солдатлар тәмам хәлсезләнде. Тирәякка күзләү җибәрелде.* Мирас. *Кибеттә товарлар – чират белән, тик сугыш инвалидларына, чыгарылма буларак, чиратсыз җибәрелә.* Азат хатын

2) Тартылып, киерелеп торудан туктау; бушау. *Айгыр, аз гына дилбегә җибәрелү белән, яңадан алга ыргылды.* Мирас

3) Юнәлеш килешендәге кайбер абстракт исемнәр янында килеп, шул исемнән аңлашылган хәлгә дучар булу, дәвамлы рәвештә шул хәлдә калу. *Бу ишектән чыкканда, фельдшер: – Хайван кебек сырага җибәреләләр дә... Холера, имеш!... --- – дип сүгенә калды.* Ш.Камал

4) *күч.* Артык иркенәю, кызып китү; үз-үзенә контрольне югалту. *Бөтенләй җибәрелгән, кызганнар, ди...* Ш.Бабич. *Ислам Сәләхович ахырда бөтенләйгә тынды, ә Франц Фәррәхович, отыры җибәрелеп, үзенекен сөйли бирде.* Ә.Еники

**Җибәрелә бару** Вакыт узган саен күбрәк җибәрелү. *Ул нечкә тармак та (күтәреп торган бау) авырлыкка чыдамый, бушый, җибәрелә бара.* Ш.Камал

**Җибәрелә төшү** Беркадәр җибәрелү, бераз җибәрелгән хәлгә килү. *Камытның чөелдереге җибәрелә төшкән*

**Җибәрелеп алу** Берара, кыска вакыт аралыгында җибәрелү. *[Галәветдин:] Кыюлык өчен җибәрелеп алдым әле, Нурул Хәйруллович.* Аманулла

**Җибәрелеп бетү** Бөтенләй, барысы да җибәрелү. --- *әйберләр бары да җибәрелеп бетте, үзебезгә дә китәргә кирәк...* М.Фәйзи

**Җибәрелеп тору** Һәрвакыт, даими җибәрелү; әледән-әле җибәрелү. *Дөрес, Болгар да Румга бурычлы калмый, ай саен кеш, бүре, аю, болан тиреләре, бал, балавыз, агач сагызы, балык җилеме җибәрелеп тора.* М.Хәбибуллин. *Бирелә фикер мантыйгы мондый: рәсүлебезгә кадәр дә пәйгамбәрләр җибәрелеп торган ---.* Р.Сафин

**ҖИБӘРҮ** *ф.* **1.** 1) Кемнедер билгеле бер урынга ниндидер максат, эшйомыш белән озату. *Хәзрәтне шулай кунак иткәннән соң, мине шушы көннәрдә үк мәдрәсәгә җибәрергә вәгъдә биреп, әти хәзрәтне озатты.* М.Гафури. --- *Сәфәргали өчен казарма эче тагын да күңелсезрәк күренә башлады. – Тизрәк сугышка җибәрсеннәр иде, ичмасам, – дип куйды ул беркөнне.* Ф.Хөсни

2) Каядыр китәргә, юнәлергә рөхсәт итү; берәр нәрсә эшләргә мөмкинлек бирү. *Әни дә каршы төшми, мине җибәрү ягына кушылды.* М.Гафури. *[Рокыя:] Мин сорасам, әти гомер дә җибәрми.* Ф.Әмирхан. *Ләкин ул күптән түгел генә нинди ашкыну, дулкынлану белән үзләренең станциясенә якынлашкан иде, ничек, үтенеп, командирыннан, бер генә сәгатькә булса да, авылга җибәрүен сораган иде.* Ә.Еники

3) Эшкә билгеләү. --- *тәртип нигезендә инструктаж үтмәгән ул кызны әле бригадага иярттү-иярмәү дә икеле булырга тиеш. Ә аны Шәмселбану урынына ук җибәрә «былгадир» ярдәмчесе.* Л.Хәмидуллин. *Зинһар, тәҗрибәле кеше җибәрә күрегез.* Т.Гыйззәт. *Үтенечен тыңлап, аны ерак районга укытучы итеп җибәрделәр.* Азат хатын

4) Китәргә мәҗбүр итү, йорттан куу, аеру. *Хатыныңны җибәрергә кирәк түгел микән, улым? Кызлар бетмәгән...* М.Галәү. *Сираҗетдиннең хыялы – хатынын җибәреп, яшь хатын алу.* М.Гали

5) Коллективтан, илдән читләштерү, сөрү, куу. *Карак мулланы авылдан җибәрергә дип, тау хәтле тамгалар җыелды.* Г.Ибраһимов. *Патшага, алпавытларга каршы күтәрелгән кешеләрне [Бөгелмәгә] сөргенгә җибәргәннәр.* Г.Әпсәләмов

6) Нәрсәнедер икенче урындагы кешегә тапшыру өчен озату. *Әтиләргә*

*дә, Вәсиләгә дә бер хат та язмадым. Бүләсе малым булмаганнан түгел, үзем акча җибәрә алмаудан хурланып язмадым.* Ф.Хөсни. *Бухгалтер – Зарифулла исемле көләч ир – --- инде унөч кешегә ашау-эчү әйберләре җибәрү турында боерыклар тутырып утыра иде.* М.Мәһдиев

7) Печән яки саламны кибән куйган җиргә бау яки чыбык ярдәмендә ат белән өстерәп, сөйрәтеп китерү. --- *[Гөлбану] берәүгә дә ишеттермичә генә, иренә әйтте: – Син чыбыкка төя, чүмәләне мин җибәрим, кулларымның хәле бетте, – диде.* Г.Ибраһимов

8) Үз иркенә, ихтыярына кую, үз карамагына калдыру. *Басуларга җибәр акбүз атың, Курпы башкайларын чүпләсен.* Җыр. *Өмәчеләр атларын туарып, су буена утлауга җибәрделәр.* М.Галәү. *Әткәй аның [биянең] муенына зур арканны бәйләгән дә тышауламыйнитми генә җибәргән.* Г.Ибраһимов

9) Кая яки кем янына булса да кертү, уздыру. *Берсен дә яннарына җибәрмә.* Т.Гыйззәт. *Әй хан! Җибәрегез, бу ниткән эш? Хәлифәңнән килгән мин Шәриф!* Н.Исәнбәт

10) Вакытлыча торырга яки кунып чыгарга кертү. *– Ят кешеләрне кунарга җибәргән өчен, чираттан тыш ике наряд үзеңә! – ди Дәүләтшин.* И.Гази

11) Тоткарламау; хәрәкәтне туктатмау, кысмау. *Моңа [койрыкка] да якын җибәрмәдем: сөяктән түбән ягын гына кистеләр дә матурлап түгәрәкләделәр.* Г.Ибраһимов. *Седовның «Фока» исемле корабын бозлар --- бер ел буе беркая җибәрми, бер урында гына тоталар.* А.Алиш

12) Азат итү, рөхсәт бирү; иреккә чыгару, тоткынлыктан коткару. *Ул аңа бераз карап торды да солдатларга Сәгыйдәнең атасын җибәрергә кушты.* Һ.Такташ. *Мин гаепле. Штраф икән – штраф түлим, әгәр җибәрә алсагыз – җибәрегез!* А.Хәмзин

13) Хезмәтеннән бушату, эштән азат итү. *Элекке технорукны ник җибәрдең?* Ш.Камал. *Ә бераздан ул [тилгән] әнкә дусты янына да төшеп җитә һәм гүя, әнкәсе, бар, очып кил, күңел ач бераз дип, дустын җибәрә дә, озын канатларын киң җәеп, җылы күкәйләр өстенә үзе утыра.* Г.Хәсәнов

14) Киертелгән, эләктерелгән җирдән кире чыгару, ычкындыру. *[Сәлим] Урыныннан торып, бишмәт төймәләрен җибәреп, ары-бире йөргәндә, Хәдичә абыстай илә Гайшә кунактан кайттылар.* З.Һади

15) Кулны нәрсәдән дә булса алу, ычкындыру. *Маймыл онытa тауны, Кулдан җибәрә бауны.* Ф.Кәрим

16) Нәрсәне дә булса бушайта төшү, иркенәйтү. *Госман капрон җепне аз гына җибәрде.* Э.Касыймов. *Хыял, очып, кайчак күккә ашадыр, Мин дә тезгенне җибәреп барамын.* Чулпан

17) Еру, бөялеп торган суны билгеле бер юнәлештә агызу. *Председатель вакытында кешеләрне бүлеп куйган булса, күлне, җибәрми, саклап калырга мөмкин иде.* Г.Ахунов. *Минзәлә елгасындагы суны җибәреп, фетнәчеләрнең юлларын биклиләр.* В.Имамов

18) Агызу, бушату, салу. *Янәшә генә торган сулы комганнарның берсен алды да, юрганны күтәреп, Габдулланың астына су җибәрде.* Ә.Фәйзи. *Самавырдан җибәргән су, чынаяк тулып, өстәл өстеннән аягыма агып төшкәч кенә айнып киттем.* Х.Сарьян

19) Нәрсәне дә булса сыеклык өстеннән яки эченнән бер юнәлештә агып барырлык итү, хәрәкәт иттерү. *Ул канны үзегезгә җибәреп, үзегез күренмәс кеше булырсыз, дип уйлыйм.* Г.Кутуй. *Яралангач, каны күп аккан, кеше канын җибәреп кенә үлемнән йолып калганнар.* Ш.Янбаев. *Суга көймә җибәрү. Гөрләвеккә йомычкалар җибәрү*

20) Чаптыру, чабышта уздыру. *Йөри торгач, онытылып кала язганмын, ат җибәрер вакыт җиткән икән. Тизрәк мәйданга – халык арасына йөгердем.* Ф.Хөсни

21) Чыгару (тамыр, үсенте, бөре һ.б. турында). *Кайчандыр монда, пыяла түбә аркылы төшкән кояш нурлары астында, кәбестәләр беренче яфрак җибәргәннәр, чөгендерләр баш төрткәннәр, помидорлар тишелгән.* Г.Галиев. *Бу күзәнәкләрнең очлары чикләнгән үсешле, тармакланган ян җепләр җибәрә, алар, үзара чорналып, кайры хасил итәләр.* Л.Мәүлүдова. *Чыннан да, бераздан борчак, ян-якка сабаклар җибәреп, бауга сарылып, өскә үрмәләде.* Һ-К.Андерсен

22) Үстерү, үсәргә мөмкинлек бирү, нинди дә булса рәвеш бирү (чәч, сакал, мыек турында). *Йа Алла, сабый булып югалды, сакал җибәреп кайта.* М.Хәбибуллин. *Кыз кара чәчен артка җибәргән.* Казан утлары

23) Юнәлтү. *Соңгы пуляны үз күкрәгенә җибәрде*

24) Берәр механизм ярдәмендә вaклау, чыгару; тарттыру. *[Карт] – Ашлык коры булса гына бит он йомшак була; кипмәгән ашлыкны нихәтле йомшакка җибәрәм дисәң дә, булмый ул, ташка сылана, – ди.* Ш.Камал

25) Барлыкка китерү, бирү, хасил итү. *Ләкин бу урыннан-урынга куылуларны, коткы салып, эш ташлап йөрүләрне, сөргеннәрне Нәгыйм аңламый иде. Болар аңа язмышның җибәргән бәхетсезлекләре булып күренәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Галәм ни өченгә сынау арты авыр сынау җибәрә? ... Әллә ул Җирдә яралган тереклекнең үзе көткән нәтиҗәләргә ирешә алмыйча бозылуларына нәфрәтен белдерәме?* А.Гыйләҗев. *– Син шулай дисең, хатын, чыпчык балаларына Тәңребез азык җибәрә бит, – диде.* Ш.Әхмәдиев

26) *күч.* Берәр хәбәр, сүз тарату. *Фәтхулла агай аның сүзен үргә җибәрмәде, йомшак ата тавышы белән [кире какты].* Ш.Камал. *Энебез, кунакка чакырып, күптән сүз җибәрә иде.* С.Рафиков. *– Бернинди хат-хәбәр җибәрмичә, тагын әзрәк йөрер идең, – ди бу, һаман шулай күтәрелеп карамыйча гына.* Ф.Хөсни

27) *күч.* Кулдагы әйберне куәт белән кемгә яки нәрсәгә дә булса ыргыту, ату, ташлау. *Таш бөтенләй гөнаһсыз кешегә эләккән икән, чамаламыйчарак җибәргәнмен шул.* Ф.Хөсни. *Буе җитмәгәч, агачка Тәпәч белән бәрә, ди. Алай да алма төшмәгәч, Таш алып җибәрә, ди.* Г.Гыйльманов

28) *күч.* Кабызу, эшләтә башлау. *Гөлсем, җибәр машинаңны!* Г.Бәширов. *[Рәдифә] Музыка җибәрә. Бүлмә*

*тутырып, яшьләрчә дәртле хип-хоп музыкасы яңгырый.* Ә.Хәсәнов

29) *күч.* Хәрәкәтнең юнәлешен, торышын үзгәртү, элеккеге хәленнән күчерү. *Сәгать телен алга җибәрү*

30) *күч.* Сугу, кискен бәрү. *Алай-болай булса, камчы белән авызына гына җибәр.* М.Гали. *[Каһәрман:] Бәхетең, күренеп өлгердең, менә шушы таш белән җибәрә идем.* Т.Гыйззәт

31) *күч.* Пар, төтен һ.б.ш.ны ургытып чыгару, өрдертеп тору. *Коры кызу мунчага пар җибәрделәр.* Әкият

32) *күч.* Уйламыйча гына нәрсә дә булса әйтеп ташлау. *Без --- «Бәлки, безне дә сугышка алырлар әле», – дип җибәрергә дә күп сорамый идек.* М.Мәһдиев. *– Товар – синеке, җилкә – безнеке --- дип кенә җибәрә дә шунда ук борылып китә башлый.* Ф.Хөсни. *Инде [шәкертләрнең] бертөрлесе дәресләргә дә суынды ---. – Андый схоластика белән ми черетер чак түгел! – дип җибәрәләр!* Г.Ибраһимов

33) *күч.* Авырту кимү. *Беркөнне урыныннан соңланып, сөякләре ватылып уянды ул. Башы да авырта, йөрәге дә начаррак тибә төсле. Сөт салып, каты чәй эчеп карады, ләкин башы барыбер җибәрмәде.* Казан утлары

34) *күч.* Бирү, тапшыру, сату. *Тагын бер тәңкә юнәтеп өстәсәң, Шәмсия егерме биш тиен әҗәткә генә җибәрерие дә бит...* Ә.Гаффар

35) *күч. гади с.* Комсызлык белән күп итеп ашау

36) *күч. гади с.* Астын юешләү, чылату. *Түзәр чама калмады ич! Чалбар төбенә җибәреп булмый бит инде.* С.Зыялы

37) *күч. гади с.* Исерткеч эчемлек эчү. *Менә бу шәп нәрсәне берәрне җибәрик әле.* Г.Камал. *Кайчакларда Фатих, шәһәрдә якташларын очратып, кафега керә дә, сөйләшә-сөйләшә, бер-ике рюмканы җибәрә.* Я.Шәфыйков

**2. җибәреп** *рәв. мәгъ.* «Үзеннән алдагы сүз аңлаткан кадәр ара, шулкадәр әйбер аркылы» дигән мәгънәне белдерә. *Миңсылу белән Нәгыйм алардан бер эскәмия җибәреп артта урнашкан иделәр.* Ш.Камал

**3.** *ярд. ф. функ.* 1) Төзү, салу, ясау һ.б.ш. мәгънәләрне белдергән сүзләр янында килеп, эшнең, процессның төгәлләнүен белдерә. *Рәуфә, эткәң белән миңа – кечкенә самавырны, үзегезгә зур самавырны шаулатып җибәр дә дүрт көнлек каймактан май атларга тотын.* А.Шамов. *Г.Исхакый мирасының халыкка кайтуы татар әдәбиятының, иҗтимагый фикеренең офыкларын киңәйтеп җибәрде.* Т.Галиуллин

2) Кайбер фигыльләр янында килеп, эш-хәлнең тиз башлануын, кинәтлекне белдерә. *[Җамали] Киемнәрнең якаларыннан, кесә төпләреннән, күкрәкләреннән кызган үтүк белән бер ышкып җибәрә, иңеннән буена тагын бер йөреп чыга.* Г.Ибраһимов. *[Хәдичә] Бераз тынычланган кебек булса да, ындыр артында үпкәләп калган Газизе күз алдына килде дә, уйларын яңадан элекке эзгә борып җибәрде.* Г.Бәширов. *Ул кереп китми, минем янымда басып тора, үзе дерелдәгәннән-дерелди. – Кереп кит, диләр сиңа! – дип кычкырып җибәрәм.* Ф.Хөсни

3) Үзеннән алда килгән фигыль белән белдерелгән эш-хәлнең бик тиз, интенсив башкарылуын күрсәтә. *Сихерче карчык үзенең сихерле таягын бер селтәп җибәргән икән, менә дигән патша сарае пәйдә булган.* Әкият. *Орлыклары өлгергәч, тиле кыяр аларны атып җибәрә.* Ботаника

4) Фигыль белдергән эшкә соклану, канәгатьлек төсмерен өсти. *Их, минәйтәм, бу әйберләрне ак өйгә куеп җибәрсәң!* Т.Гыйззәт

**Җибәрә бару** Даими, регуляр рәвештә берсе артыннан икенчесен җибәрү. *Дустым шигырьләрен миңа җибәрә бара*

**Җибәрә башлау** Җибәрергә тотыну. *Әбелхарис, ишек төбенә сәлам ягып, бүлмә эченә төтен җибәрә башлады.* К.Насыйри. *[Гали] Шунда ук чәй китерде, вак бәлешләре белән бергә җибәрә башладым.* Г.Ибраһимов

**Җибәрә бирү** Бернәрсәгә дә карамастан җибәрү; һаман да җибәрү

**Җибәрә тору** Һәрвакыт, гел җибәрү. *Мин аның өчен үләрдәй булып тордым, авылга – авыру анама, фәкыйрь калган атама юлламыйча, бөтен тапкан барлы-юклы акчамны аңа җибәрә тордым.* Р.Батулла

**Җибәрә төшү** Беркадәр, бераз җибәрү. *Артык нык кыскан каешны җибәрә төшү*

**Җибәреп алу** Аз гына, кыска вакытлы җибәрү. *Шамил, гадәтенчә, үзенең тагын бер шаян угын җибәреп алды.* М.Вәли-Барҗылы

**Җибәреп бару** Һәрберсен, булган берсен җибәрү. *Ул [Нәүширван Яушев] үзенең юлъязмаларын «Шура», «Вакыт», «Сәмәрканд», «Сәдаи Төркестан», «Сәдаи Фирганә» газета-журналларына җибәреп бара.* Ф.Галимуллин

**Җибәреп бетерү** Кирәк күләмдә тулысынча, барысын да җибәрү; бернәрсә дә калдырмыйча, тулысы белән җибәрү. *Әйдә, иптәш Маигушев, [икмәкне] җибәреп бетерик әле.* Т.Гыйззәт. *Ул вакытта юллар начар, булган машиналарны, атларны фронтка җибәреп бетергәннәр.* У.Альмеев

**Җибәреп калу** Берәр хәл килеп чыкканчы җибәрергә өлгерү

**Җибәреп кую** Алдан җибәргән булу. *Каһәр сукканнар, сәгатьләрен юри алга җибәреп куйганнар.* Г.Камал. *Җамали бай: «Һәр җомга көнне мохтаҗ кешеләр миңа килсен, сәдака өләшәм», – дип хәбәр таратып, алар килүгә, усал этләрен җибәреп куеп, кеше кертмәгән була.* Н.Исәнбәт

**Җибәреп тору** Һәрвакыт, гел җибәрү; әледән-әле, еш җибәрү. *Тамара Сергеевна, билгеле инде, акчасын да җибәреп тора, соңгы көнгәчә озын-озын хатларын да язып тора.* Ә.Еники. *[Дәүләтов] Ул бит сезгә ара-тирә күчтәнәч җибәреп тора.* Р.Зәйдулла. *Гөлбану аулак өйләргә барырга сораганда, бик сайлап кына, кешесенә карап кына җибәрә торган булды.* Г.Ибраһимов

**ҖИБЕР** *и. сөйл. к.* **җәвер**. *Аларның җибер шикелле бер-бер артлы тупырдаган адәм актыгы кызларына кияү чыксын да, синең бердәнбер алма шикелле газиз балаңа кияү чыкмасын, имеш.* Г.Камал

**ҖИБРИЛ** *и. гар. дини к.* **Җәбраил**. *Газраилдан туйган инде, һәр кеше Җибрил көтә.* Ш.Бабич

**ҖИГЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **җигү**. *Йорт төрле пролёткаларга һәм йөк арбаларына җигелгән яки туарылып, печән ашап торган атлар белән тулы.* Ә.Фәйзи. *Туй кайткан чакта ул, төпкә җигелгән атка, йөзе белән тарантаска карап атлана икән дә кияү белән кәләшкә гармун уйнап бара икән.* Ә.Еники. *Шуны күреп кайттым: болгарлар җирне үгезгә җигелгән сабан белән сөрәләр икән.* М.Галәү

2) Файдалану, куллану. *[Баррикадалар төзегәндә] Казыклар, ташлар, тимерчыбыклар – барысы да эшкә җигелә.* СССР тарихы

3) *күч.* Ныклап эшкә тотыну. *Әтисе үлгәч, аңа ныклабрак эшкә җигелергә туры килде.* М.Гали. *Без җиде сыйныф бетерүгә эшкә җигелдек, кечке мәктәпләрдә укып йөргәндә, инде утыз яшьләр тулып узган иде.* М.Зарипов. *Юл буена уйлана-уйлана кайтты Сәфәргали. Ниһаять, үзе өчен яңа булып күренгән бер хакыйкатьне ачты: «Җигелсәң, ат урынына да җигәсе бу Сәлмән мөртәт».* Ф.Хөсни

**2. җигелеп** *рәв. мәгъ.* 1) Тулы көчкә, бик тырышып. *Инәй ягыннан кардәш тиешле, мин белгән Яңгуразларның күбесе җир эшен яратып, җигелеп эшләүче таза тормышлы агайлар иде.* Ә.Еники. *Ул бит – ир заты, дөньяны җигелеп алып барырга тиеш…* Н.Каштанов

2) Игътибар белән, кызыксынып, бирелеп. *Шулай җигелеп карый торгач, еракта, сыек рәшә аша зур каланың биек ак биналары, чиркәү гөмбәзләре күренә башлады.* Ә.Еники

**Җигелеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җигелү. *Ат җигелеп беткәннән соң, безне озатып калыр өчен, Фәхри бабай белән Хәмидә әби, алар артыннан Галимә апа да безгә керде.* М.Гафури. *Инде атлар җигелеп беткән икән. – Кайтабыз! – дип аваз салды кайсыдыр.* Мирас

**ҖИГЕМ** *и.* 1) Бергә җигелгән берничә җигү малы; *русчасы:* **упряжка**. *Чусовитин килеп җиткәч үк, бер җигем боланнарны ал да базага кайт.* И.Хуҗин

2) Җигүгә күнеккәнлек. *«Үгезгә – дуга, сыерга – дага». Атка кирәк нәрсәләр башка җигем малга кирәк булмаудан алып әйтелгән.* Н.Исәнбәт. *Атны җигемгә өйрәтү*

**ҖИГҮ** *ф.* 1) Арба, чана, сабан кебек әйберләрне атка, үгезгә махсус дирбияләр ярдәмендә беркетү. *Шул вакыт Уфа губернасы Эстәрле Тамак өязенең Югары Күл атлы бер авылына яхшы тарантаска өч ат җиккән, кыңгырау таккан бер түрә килеп төшә.* Г.Ибраһимов. *Чәйдән соң, атларны җигеп, Уфадан чыгып киттек.* М.Гафури. *Ат җиккәндә үзең җик – кешедән җиктермә. Халык кара куллы җитәкчене ярата.* М.Мәһдиев

2) Нинди дә булса көчне берәр эш башкару өчен файдалану. *Әнә, күрәсеңме, җилкәнгә җилне ничек җиккәннәр!* А.Алиш. *Бары шуннан соң гына берсеннән икенчесе нечкәрәк пычкыларны эшкә җиктек.* Р.Мөхәммәдиев. *Ямансу чакларда ул, юаныч эзләп, кәгазь, буяулар, кылкаләм ала. Сәнгать мәктәбендә өйрәнгәннәрен эшкә җигеп, кечерешләрен рәсемгә сала.* Казан утлары

3) Физик, рухи, акыл көчен туплап, алардан рациональ файдалану. *Гыймади күп еллар буена, үз авызыннан өзеп дигәндәй, бөтен булган акчасын баю эшенә җикте.* М.Галәү. *Шулай, Әбрар Кәримуллин бабайлар акылын эшкә җиккән, үз хатыны да ризыкны, үрелеп кенә, ишек артыннан биргәләп торды.* М.Мәһдиев. *Кеше алдында елап җибәрмәс өчен, ул, бөтен ихтыяр көчен җигеп, үз-үзен кулга алырга тырышты һәм еламады.* М.Әмир

4) Нинди дә булса эшне башкарырга мәҗбүр итү. *Аларга тормышны өйрәнергә вакыт тудырмавыбыз өстенә, аларны, тын да алырга вакыт калдырмаслык итеп башка эшкә җигеп, башларындагы темаларны бертөрле калыпка салуга вакытларын калдырмыйбыз.* Һ.Такташ. *Кыш буенча җыйналган пычрактан мәдрәсәне арындыру эшләрен Галиулла белән Камали кизүләр үзләре генә башкарып чыга алмагач, исән шәкертләрне дә бу җаваплы эшкә җиктеләр.* К.Тинчурин. *Халык исәбен алу башлангач, үзебезнең күзәтүчеләр төркемнәрен дә эшкә җигәчәкбез.* Казан утлары

5) *күч.* Эшкә кушу; нык эшләтү. *– Ярамый, Локман бабай, ярамый, сине дә эшкә җиксәк, оятыбызга көч килер, --- – диләр.* Ә.Еники

**Җигә башлау** Җигәргә тотыну

**Җигеп бетерү** 1) Тулысынча, бөтенләй, ахырына кадәр җигү, җигү эшен тәгәлләү. *Җигеп бетергәч, Гайния, кереп, эш кәгазьләрен алды.* Н.Әхмәдиев. *Гайнетдин бабай, чанага туры атны җигеп бетергәч, келәттәге онлык, --- өч тулы капчык һәйбәт, чүпсез богъдайны чыгарып салды.* Ак юл

2) Барысын да җигү. *Икмәк тапшыручылар төркеме атларны җигеп бетерделәр дә колонна булып юлга чыктылар*

**Җигеп йөрү** Даими рәвештә җигү. *Ул көн саен атын җигеп йөри*

**Җигеп карау** Җигәргә омтылу

**Җигеп кую** Алдан җигү, җигелгән хәлдә тоту. *Нурислам абзый әллә кайчан атны җигеп куйган иде инде.* М.Гафури. *Ул атын җигеп куйган, бишмәтен кигән һәм, кашларын җыерып, йөк өстендә утыра иде.* А.Гыйләҗев

**ҖИГҮЛЕ** *с.* 1) Арба, чана, сабан кебек хуҗалык әйберләренә җигелгән. *Базар көнне авылның барлык йортлары кунаклар, җигүле арбалар, сатып алынган әйберләр белән тулып, постоялый дворга охшап кала.* М.Галәү. *Яхшы кара айгыр җигүле тарантаска утырган ике гаскәри кеше, аларны узып, берничә сажень үткәннән соң туктадылар.* К.Тинчурин. *Минем әтинең, сыңар куллы килеш җәһәт егәрлек белән ат җиккәненә, аллы-артлы җигүле арбаларда колхоз икмәген заготзерногa ташуына исем китә торган иде.* Идел

2) Нинди дә булса эш-хәлгә әзер, җигеп куелган. *Чыксаң – атың җигүле, ятсаң – урының җәюле.* Әйтем. *Күптәннән бирле җигүле торган ат, без чанага утырып дилбегәсен кагу белән, капкадан чыгып та китте.* М.Гафури

**ҖИГҮЛЕК** *с.* Җигү өчен кирәкле. *Җигүлек кирәк-ярак*

**ҖИДА** *и.* 1) *тар.* Озын сөңге. *[Каһарман кыз:] Энә тоткан кулым җида да тотар.* Әкият

2) *диал.* Балык тоту коралы, чәнечке; *русчасы:* **острога**. *Җида белән балык тоту*

**ҖИДӘ** *и. бот.* 1) Тутчалар семьялыгыннан, озынлыгы 10–15 метрга җиткән, яфракларын ефәк корты ашый торган көньяк агачы; тут агачы

2) Шул агачның ак, кызыл яки шәмәхә төстәге баллы, ашарга яраклы җимеше; тут җиләге

**ҖИДӘ́Ү** *сан* **1.** Барысы, бөтенесе бергә җиде булуны белдергән җыю саны. *Киттек. Барыбыз җидәү: Госман, мин, калганнары – ят малайлар.* Ф.Хөсни

**2.** *рәв. мәгъ.* Җиде зат бергәләп, җидесе берьюлы. *Җидәү барып, алтау кайттык: беребезне калдырдык.* Бәет

**ҖИДӘҮЛӘП** *сан* **1.** Чама белән җиде, якынча җиде булуны белдергән чама саны; җиделәп

**2.** *рәв. мәгъ.* Җидесе бер булып, һәр төркемдә җидәү булып, җидесе бергә. *Безнең авылда Нәҗип абый дигән кеше бар иде. Аның – җиде баласы. Болар колхозда җидәүләп эшлиләр.* М.Шиһапов

**ҖИДӘҮЛӘШЕП** *рәв. к.* **җидәүләп 2.** *Төнлә белән, җидәүләшеп акырып-бакырып, елкы көтүен уралтып-уралтып чаптырып кыздыралар.* З.Зәйнуллин

**ҖИДЕ** *сан* **1.** 1) Алты белән сигез арасында килә торган бөтен сан, шул санның үзе, цифры һәм микъдары атамасы. *Склад басучылар, бердәүләр әйтүенчә – җиде, икенче сүзләргә караганда, уникe кеше булган...* Ә.Фәйзи. *Җиде чакрымдагы Зиреклебашка, караңгы төшеп, тәмам күз бәйләнгәч кайтып җиттеләр.* Ә.Еники. *Урамнан гармун уйнап уза башласалар, кызлар тәрәзә өчен пыр тузып шаярышалар… Җиде кыз – җиде бәла! Аларга җиде әйбәт кияү кирәк.* А.Гыйләҗев

2) *сөйл.* Бик күп, әллә ничә. *Алай да әле төненә җиде уяна.* А.Алиш

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **җидееллык**. *– Мин кайтканда, сез укымый идегезмени инде? – Син кайткан елны бетердек бит җидене.* Х.Сарьян. *Җыелыш беткәндә генә, директор белдерү ясады: җидене бетергән малайларга иртәгә сәгать сигездә военкоматта булырга.* М.Мәһдиев

2) **җидесе** *тарт. форм. этногр. дини* Татарларда, кеше үлеп, җиде көн үткәннән соң, аш җыеп, Коръән укытып, мәрхүмне искә алу мәҗлесе. *Шибайның өче, җидесе дә бик яхшы, бик тыныч үтте, тик менә җидесен үткәрергә дип җыелган мәҗлес таралгач, каладан бер кәгазь килеп төшүе генә бераз кытыршылык тудырды.* Г.Ибраһимов. *Аккош күлендәге дачада Сибгат абыйны искә алу мәҗлесе буласы икән. Өчесеме, җидесеме, кырыгымы? Инде хәтерләмим.* М.Мәһдиев. *Бәлкем, мәетнең өчесе, җидесе, кырыгы, илле бер көне, елы булмаса, авылларда дин дә сакланып калмас иде.* Безнең гәҗит

◊ **Җиде азан кычкырту** *дини* Авыруны кинәт авырып китеп егылганда, һушын җуйганда, җиде азан кычкырып өшкерү. *Мин әтигә җиде азан кычкыртам.* Т.Гыйззәт. *Малаеның әллә зиандаш зәхмәте микән дип, мәдрәсәдән җиде шәкерт чакырып, җиде азан да кычкырттык.* М.Гали. **Җиде бабадан (килгән)** Бик күптәнге, борынгы; борынгыдан мирас булып калган. *Чыгарма, җаный, бу серне: Безем бу муллалык җөбе Ки җиде бабадин бирле Килеп өзелмәгән бер дә.* Г.Кандалый. **Җиде бабасына җитү** 1) Ямьсез, тупас сүзләр белән бик нык сүгү. *[Назимов] Поцелуйкинның җиде бабасына җитеп сүгенеп алды.* Г.Әпсәләмов; 2) Кемнең дә булса нәселен кырып бетерү, үч алулар белән янау. **Җиде бабасын тану** Үзенең нәсел-нәсәбе, фамилиясе каян, кемнәрдән килүен төгәл өйрәнү, тарихын белү. **Җиде бабасын таныту** *к.* **арт сабагын укыту**. *Мин синең җиде бабаңны танытырмын!* **Җиде башлы аждаһа (дию)** Әкиятләрдә сурәтләнгән куркыныч, явыз мифик зат. *Агуларын чәчеп, җиде башлы аждаһа басып тора икән.* А.Әхмәт. **Җиде буынга җитү** 1) *к.* **җиде бабасына җитү** (*2 мәгъ.*). *Шундый итеп куркытырбыз, җиде буынына барып җитәрбез.* К.Тинчурин; 2) *к.* **җиде бабасын таныту**. **Җиде диңгез артында** Бик еракта. **Җиде җәһәннәм асты (арты)** Әллә кайдагы ерак ят җир, ят урыннар; яшерен урын. *Үз тирәбездә менә дигән матур җирләр булганда, ни пычагыма, «курорт» дип кенә, җиде җәһәннәм астына барырга?* Г.Әпсәләмов. **Җиде җәһәннәм төбе** *к.* **җиде җәһәннәм асты (арты)**. *Үз әниемнән калган төймәләрем дип, аларны җиде кат төеннәргә төенләп, әллә кай җиде җәһәннәм төбенә яшергән иде.* К.Нәҗми. **Җиде җил кочагы** Һәрьяклап көчле җил исә торган, бер яктан да ышыкланмаган калку урын. *Лебедев белән Әхмәй, иске җил тегермәне янына күтәрелгәч, атларыннан төшеп, җиде җил кочагында шул айга таба карап тордылар, --- аннан, җәяүләп, җай гына түбәнгә кузгалдылар.* Ф.Мансуров. **Җиде иләктән үткәрү** Бик нечкәләп, кат-кат тикшерү. **Җиде йозак астына бикләү** Бик нык саклау, яшерү, эзен тапмаслык итү. *Патша җил җитмәс җирән атны, берничек тә урлап китмәсеннәр өчен, җиде йозак астына бикләтте.* Әкият. **Җиде йозак астында тоту** *к.* **җиде йозак астына бикләү**. *Гадәттә әкиятләрдә генә шулай сезнең кебек чибәр кызларны дию пәриләре, урлап, --- җиде йозак астында тота торган булганнар.* Ф.Яруллин. **Җиде йортка – бер энә** Күршеләр арасында кулдан-кулга йөртелә торган бердәнбер корал булуга киная. **Җиде камыт кидерү** Барлык эшне бер көндәм кеше җилкәсенә күтәртү, йөкләтү. *Мокыт бит, җиде камыт кидерсәләр дә тарта торган нәмәстәкәй.* А.Гыйләҗев. **Җиде кат җир астында** Бик нык яшерелгән, әллә ничә йозак астына куелган. *Үзәк банкның «җиде кат җир астында» дип әйтелешле сейфларыннан миллион пизарралык алтын коелмалар алып чыгу үзе генә дә ни тора?* А.Тимергалин. **Җиде кат җир астыннан табу**. Берәр кешене яки нәрсәне ничек кенә булса да эзләп табу. *Кастаның кәефен бозып кара… Беттең! Җиде кат җир астыннан сине табачаклар, җаныңны кыячаклар…* А.Гыйләҗев. **Җиде кат йозак артына яшерү** *к.* **җиде йозак астына бикләү**. *Тик тойгыларын җиде кат йозак артына яшерә белмәсә, татар кызы була димени?* Мирас. **Җиде кат күккә ашу**

Куанычыннан күңеле күтәрелү, бик нык шатлану. *Рахманкулов, үзе дә сизмәстән, тагын җиденче кат күккә ашты.* М.Юныс. **Җиде кат күкләргә күтәрү (чөю)** Бик нык мактау. *Бездә шулай, кемне дә булса бер мактый башласалар, җиде кат күкләргә чөеп мактыйлар.* Казан утлары. **Җиде кат тир чыкканчы** Җан тиргә төшеп, бик нык тырышып, көчәнеп. *Чүпрәк ботинкамны ике көн кремга батырып, аннары, җиде кат тирем чыкканчы, коры сукно белән ышкып кына ялтыраткан идем.* Ф.Яруллин. *Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр җиде кат тирең чыкканчы урак урып кара син.* М.Галәү. **Җиде төн уртасында** 1) Төннең кыл уртасында, бар тереклек тирән йокыга талганлыктан бер хәрәкәт тә булмаган вакытта. *Хыялый хикәяләр реаль вакыйгалар белән аралаша... Көрәштә батыр чыгар өчен, кайсы үләннең чәчәген җиде төн уртасында барып өзәргә... һәм тагын әлләниләр.* Ә.Фәйзи. *Мөәзин бабай дөньяда бик озак торганга, җиде төн уртасында юлларда күп йөргәнгә, караңгы төннәрдә ялгызы мәчеткә барганга күрә, бу хакта аның да фикерен сорап үттеләр.* М.Гафури; 2) Вакытсыз, йоклый торган вакытта, бик соң. *Эчке бүлмәләрнең берсеннән байның: – Кем йөри анда җиде төн уртасында? – дип чәрелдәгән тавышы ишетелде.* М.Галәү. *Мәгәр син миннән сорап кара: кайда нәрсә ята – мин сиңа җиде төн уртасында күземне йомып әйтеп бирермен.* Ф.Хөсни. **Җиде юл чаты** 1) Кеше күп йөри торган урын, юл өсте. *Юк, кызык кына түгел, ниндидер сер, тылсым бар бу санда! Менә кара! «Җиде юл чаты», «җиде төн уртасы», «җиде үлчә, бер кис».* Г.Бәширов; 2) Күп юллар тоташкан урын. *Даланың җиде юл чатында үзе җил тегермәне төзеп, җыелган килемне ачларга өләшкән.* Ф.Мансуров. **Җиде ямаулы** Тузган, сәләмәләнеп беткән. *Өсләрендә җиде ямаулы күлмәк була иде.* Г.Гобәй. **Җиде ясин** *дини* Берәр нәрсәгә нәзер әйтеп, Коръәннең Ясин сүрәсен җиде кат укып, багышлау. *Ярабби, Ходаем! Сиңа нинди шөкерләр генә кылыйм! Нәзерем булсын: җиде газизләр рухына җиде Ясин укып багышлармын.* Г.Камал. **Җиде ят** Кан кардәшлеге булмаган, бөтенләй ят, чит кешеләр. *Әнә, ди-ди, менә, ди-ди, Безнең гомер шулай уза; Яшьли сөйгән яшь матурга Җиде ятлар кул суза.* Җыр. *Җиде ят каршында әйтелгән бу кыю сүзләрне ишеткәч, Гәрәй бөтенләй терелеп киткән кебек булды.* К.Нәҗми. *Зәһәр сүзләренә, кырыс холкына күнгән-өйрәнгән инде, нинди булса да, җиде ят кеше түгел, үз әбием.* Казан утлары. **Җиде ятып бер төшкә (дә) кермәү** Искә алмау, бөтенләй уйламау, хәтердә тотмау

**ҖИДЕГӘН** *с.* Җиделе; җиде өлештән, җиде кисәктән торган. *Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, Җидегән йолдыз күреп калсын дип. Җанкай-җанаш алсын да куансын, Вәгъдәләрем булып калсын дип.* Г.Бәширов

**ҖИДЕГӘ́Н ЙОЛДЫЗ** *и. астр.* Җиде йолдызы чүмечкә охшаш фигура булып тезелгән, күкнең төньягында урнашкан җиде якты йолдыздан торган йолдызлык; *диал.* чүмеч йолдыз; *русчасы:* **Большая Медведица**. *Җидегән йолдыз җиде әйләнә – Тимерказык урынында.* Әйтем. *Йокла инде. Әнә анда Җидегән йолдыз таңнарга борыла башлаган.* Г.Бәширов. *Олы җидегән. Кече җидегән*

**ҖИДЕЕЛЛЫК** *и.* **1.** Җиде сыйныф тәмамлап алган белем; элекке тулы булмаган урта белем. *Авылда мәктәп җидееллык кына иде. Өч ел район үзәге Аккүлгә йөреп укыдым.* Б.Камалов. *Ә тегеннән хәбәр дә килеп җитә: җидееллыкны гел «бишле»гә генә тәмамлаган укучы буларак, сынаусыз кабул ителдегез, --- беренче октябрь көнне сәгать сигездә укулар башлана --- дип язганнар.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Җиде сыйныф программасына нигезләнгән, тулы булмаган урта. *Күп кенә яшь кызларның җидееллык белемнәре бар.* Ә.Еники. *Әни мине бер көнгә дә бушатмый. Шуңа күрә дә ул, минем җидееллык мәктәп тәмамлаганлыкка таныклыгымны алып, үземнән гариза яздыртып, кеше аркылы гына педучилищега биреп җибәрә.* М.Мәһдиев. *Җидееллык мәктәпне бетергәч, Галимҗан абыйсы аны үзе укыган авыл хуҗалыгы техникумы каршындагы бакчачылык курсына урнаштырды.* Ф.Хөсни

**ҖИДЕКЫРЛЫ** *с. махс.* Җиде кыры булган. *Җидекырлы геометрик җисем. Җидекырлы пирамида*

**ҖИДЕКЫРЛЫК** *и. мат.* Җиде кырлы геометрик фигура; *русчасы:* **семигранник**

**ҖИДЕЛӘП** *сан* Якынча җиде, чама белән җиде булуны белдергән чама саны. *Ташбулатның сүзләре чынга аша бугай, урман буенда җиделәп ат күренде.* М.Хәбибуллин

**ҖИДЕЛӘТӘ** *рәв.* Җиде тапкыр арттырып. *Әйбер хакын җиделәтә түләтү*

**ҖИДЕЛӘТҮ** *ф.* Җиде тапкыр арттыру. *Үтмәс пычак, яман ат икеләтте җәфамны; Яман хатын, яшь бала җиделәтте җәфамны.* Мәкаль

**ҖИДЕЛЕ** *с.* 1) Җидене белдергән. *Хикмәтле бу җиделе саны.* М.Галиев

2) Күләме, номеры яки үлчәме җиде берәмлеккә тигез булган. *Тик инде мин, бала чагымда ук, озын бер пакус үләнне чабып куйганнан соң, җиделе чалгым йөзеннән – кайрагымны, аннары соң үткер кыргычымны аллы-артлы чаҗлап үткәнендәге шикелле нык итеп: – Ки! – дип кабатлыйм.* Ә.Гаффар. *Җиделе галош*

3) Лампа филтәсенең киңлеген белдергән. --- *күп вакыт мондый бәхәсләр кышның озын кичләрендә җиделе лампа тирәсендә кич утыру һәм, кычкырып, «Таһир–Зөһрә» яки «Бүз егет» уку белән тәмамлана торган иде.* Ә.Фәйзи. *Интегеп кенә башымны күтәрсәм: кучкарда ут яна – җиделе лампа кысып кына куелган.* Х.Сарьян. *«Җиделе лампа» дигәне аның җиде буй җепкә тукылган тар филтәсен аңлата.* Казан утлары

**ҖИДЕЛЕК** *и. сөйл.* 1) Җиде (7) цифры. *Җиделек белән берлегең охшаш язылган*

2) Кәрт, домино һ.б.ш. уеннарда җиде билгесе куелган уен берәмлеге. *Җиделектән йөрү*

3) Җиде катнашучыдан торган команда, кешеләр төркеме, илләр берләшмәсе һ.б.ш. *Кайчандыр без әрсезләнеп*

*кергән «Зур сигезлек» тә әнә яңадан «Жиделек»кә әйләнеп куйды.* Ватаным Татарстан. *1993 елда «зур җиделек» илләре, бездәге беренче буын реакторларын ябуны финанслау өчен, махсус счёт булдырган иде.* Татарстан яшьләре

**ҖИДЕНЧЕ** *сан* Бер-бер артлы санаганда, урыны алты белән сигез арасында булуны белдергән тәртип саны. *Безнең өйдә – без җидәү, безнең песи – җиденчесе.* Г.Тукай. *Яңадан үги әбисе кулына, зур семьялы ач өйгә, алты күгәрчен арасына җиденче чәүкә булып кайту аны шатландырмый.* Ә.Фәйзи. *Җирән бияне таба алмагач, --- җиденче басу читеннән урманга таба юыртып киттем.* Х.Сарьян

◊ **Җиденче кат күктә тою, хис итү** Үзеңне артык бәхетле дип санау, бик нык шатлану. *Әгәр Мәдинә ялгыш кына якты чырай күрсәтсә дә, Хәбир үзен күкнең җиденче катына менгән кеше кебек хис итте.* Ш.Хөсәенов

**ҖИДЕНЧЕДӘН** *кер. сүз* Нәрсәне дә булса санаганда, тәртип, эзлеклелек ягыннан җиденче урында торуны белдерә

**ҖИДЕПОЧМАК** *и. махс.* Җиде почмаклы геометрик фигура

**ҖИДЕПОЧМАКЛЫ** *с.* Җиде почмагы булган. *Җидепочмаклы геометрик фигура*

**ҖИДЕ-СИГЕЗ** *сан* Җиде яки сигез тирәсе, якынча җиде белән сигез арасында. *Башка елларда булса, җиде-сигез чакрымнан чаптыралар иде, быел, төрле илләрнең данлык атлары килгәнгә, шулай ерактан чаптыралар диләр.* Г.Ибраһимов. *Габдулла Тукай шул җиде-сигез еллы бер арада дүртбиш йөз битлек шигырь яза һәм, һичбер шагыйрьгә насыйп булмаган нәтиҗәлелек белән, шималь төркеләре тормышының яңа сәхифәләрен тасвир итә.* Г.Исхакый. *Җиде-сигез яшьлек малай инде авылның уртак кайгысы белән кайгыра, уртак шатлыгы белән шатлана.* Ә.Фәйзи

**ҖИДЕУРЫНЛЫ** *с.* 1) *мат.* Бер миллионнан алып 9 миллионга кадәр булган теләсә кайсы (сан турында)

2) Җиде урыны, җиде утыргычы булган. *Җидеурынлы автомобиль*

**ҖИДЕШӘР** *сан* Һәркемгә, һәрнәрсәгә җиде, бертигез күләмдә җиде булуны белдергән бүлем саны. *Эне белән апа озак бармадылар, асты таш, өсте агач, аслы-өсле җидешәр тәрәзәсе белән урамга караган йортның таш капкасыннан кереп --- киттеләр.* Ә.Фәйзи

**ҖИДЕШӘРЛӘП** *рәв.* 1) Җидешәргә бүлеп, һәрберсенә җидешәр-җидешәр итеп

2) Җиде зат бергәләп, җидесе берьюлы

**ҖИДЕЯФРАК** *и. бот.* Нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан, туры сабаклы, яфраклары өскә таба сирәгәеп, такыясыман җыелган, касәсе 7–9 аерчадан торган ак чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **седмичник европейский**

**ҖИЗ** *и.* **1.** Бакырга төрле металлар (цинк, кургаш, аккургаш, тимер һ.б.) кушып коелган эретмә. *Самавыр --- инде утырган җиреннән бер якка кыйшаеп төшкән, соры җиз ниндидер күкле-яшелле төскә кергән.* Ә.Фәйзи. *Ае белән гөмбәзен, чыннан да, җизенә була Мәгъдән абзый алып китәргә иткән иде дә – картлар, бик каты тавыш күтәреп, якын да җибәрмәделәр.* Х.Сарьян

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый эретмәдән эшләнгән. *Бары тик әнә шул мунчага куяр өчен генә махсус җиз ләгән белән җиз чүмеч алырга туры килде Габдулла агайга.* Ф.Хөсни. *Ул арада, комган төбе чаклы җиз медален тагып, кулына таягын тотып, зур кара сакаллы, тупас битле староста да килеп җитте.* М.Гали. *Кердем, карт ялгыз, иске китапны өстәлгә таратып салган, ак күлмәктән, чиста йөзле. Күзлеге җиз чыбыклы.* М.Мәһдиев

2) Шул эретмә төсендәге, сары, җирән. *Җил тибрәткән сары җиз башаклар җиргә яттылар.* М.Җәлил. *Җиз кәүсәле мәһабәт наратлар арасында, чынлап та, әллә нинди иркенлек, җанны иркәли торган саф тынлык иде.* М.Галиев

◊ **Җиз иләк аша үткәрү** Үтә сайлап, сайланып. *Әлеге кыйссага өлкән агай әһелләре бик сакланып һәм сирәк мөрәҗәгать итә, хрестоматияләргә дә бик нәзберекләнеп, җиз иләк аша үткәреп кенә кертәләр.* Т.Галиуллин.

**Җиз кадак** Юлчыларның ат азыгы булган кадерле солы турында башкалардан тел яшереп әйтә торган сүзләре

**ҖИЗБАШ** *и. зоол.* Тузбашлар семьялыгыннан, аркасында 2–4 рәт кара таплар булган, җиз төсендәге, чакмый торган агусыз елан; *русчасы:* **медянка**. *Җизбаш урман кисентеләрендә, киң яфраклы урманнарда, кайчак наратлыкларда очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ҖИ́З ЕЛАН** *и. к.* **җизбаш** *Җиз елан – безнең республикада иң сирәк очрый торган еланнардан берсе, шуңа күрә ул Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ҖИЗЛӘ́Ү** *ф.* Җиз йөгертү яки җиз тәңкәләр белән бизәү. *Аягымдагы кәвешемнең үкчәләре җизләгән.* Җыр. *Камытны җизләү*

**Җизләп бетерү** Бөтенләй, тулысынча җизләү; җизләү эшен башкарып чыгу

**Җизләп җибәрү** Нинди дә булса өлеккә бераз гына җиз йөгертү. *Оста беләзекне тиз генә җизләп җибәрде*

**Җизләп кую** Алдан ук җизләү, җизләгән хәлгә китерү

**Җизләп тору** 1) Гел, һәрвакыт җизләү

2) Әле, хәзерге вакытта җизләү. *Без килгәндә, конюх эшлеяне җизләп тора иде*

**ҖИЗЛЕ** *с.* Җиздән эшләнгән яки җиз белән бизәлгән. *Җизле камыт, күн эшлея безнең атларда гына.* Җыр

**ҖИЗНӘ** *и. к.* **җизни**. *Ата – җизнә, ана – казна.* Мәкаль. *Садыйк бай Хөснуллага җизнә тиешле.* Ш.Камал. *Габдулла белән җизнәсе арасындагы үзара мөнәсәбәтне беркадәр җентекләбрәк язуымның сәбәбе шул: бу хәл булачак шагыйрьнең киләчәге белән турыдан-туры бәйләнгән.* И.Нуруллин

**ҖИЗНӘЙ** *и. к.* **җизни**. *Җизнәй буласы кеше белән танышканчы, Габделнурның апасы авылның бер егете белән йөри иде.* Р.Кәрами

**ҖИЗНИ** *и.* Үзеңнән олы кыз туганыңның ире һәм аңа эндәшү сүзе. *Анаң үги булса, атаң җизни була.* Әйтем. *Җизниләргә кунакка баруыбызны, ничектер, хәтерләмим, ә минә җизни үзе безгә кунакка килергә бик яратучан булып китте.* Ф.Хөсни. *Бала чагыннан бирле кадерләп, тәрбияләп үстергән җизнәсенә шундый явызлык эшләгәнне, туган анасына да ул игелек күрсәтмәс.* Р.Ишморат

**ҖИЗНИЛЕК** *и.* Җизни булу. *Галиәсгар Габдуллага мөмкин хәтле каты кагылмаска --- теләгән иде. Булмады. Монда да аның җизнилек, олылык, байлык, дәрәҗә тойгылары җиңеп чыкты, һәм ул инде үзен тыя алмады, китте, китте.* Ә.Фәйзи

**ҖИК** *и. к.* **җык** (*2 мәгъ.*). *– Әй улым, улым, --- [исерек] әтиеңнән дә җик күреп беткән идем инде, – дип, улына бераз үпкәләп алды [әнисе].* М.Гали

**ҖИКӘН** *и.* Җикәнбашчалар семьялыгыннан, сазлык урыннарда, елганың баткак ярларында үсә торган, кара чәкән башлы, шуышма тамырчалы, камышка охшаш үсемлек һәм шуның йөнтәс башы. *Җирле – җирендә, җикән – күлендә.* Мәкаль. *Тумбочкасы өстендә --- башак-яфраклар, җәйге матурлыкны саклаган коры үләннәр тора. Арадан, кукраеп, бер генә җикән-камыш күтәрелгән.* А.Гыйләҗев

**ҖИКӘНБАШ** *и. к.* **җикән**. *Күрәнчәләр семьялыгына күрәннәргә бөтенләй охшамаган, камыш ыругына караган үсемлек төрләре дә керә. Халык аны бөтенләй башка семьялык үсемлеге булган җикәнбаш белән бутый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ҖИКӘНЛЕ** *с.* Җикән күп үскән, җикәне булган. --- *инешнең бу ягында – колхозның печән болыны, бер читендә биек камышлы, җикәнле һәм куе кыяклы түгәрәк күл җәйрәп ята ---.* Ә.Гаффар

**ҖИКӘНЛЕ́ КАМЫШ** *и. бот.* Җикән. *Әйдә, ял да булыр, дип, Тирән Кулдан әйләнеп кайттык – ерып чыкысыз җикәнле камыш, таллыкларын --- әйләндек.* Х.Сарьян

**ҖИКӘНЛЕЛӘР** *и. күпл.* Җикәнгә охшаш үсемлекләр семьялыгы атамасы

**ҖИКЕРЕНҮ** *ф. к.* **җикерү**. *[Фәхри:] Мин сиңа, аның янына кереп, аның кара йөзен күреп йөрисе булма, миннән мәңге бәхиллек юк, дип әйттем бит! – дип җикеренергә кереште.* М.Гафури. *– Без килгәнче сандыкларны ачсагыз, барыгызга да үлем! – дип җикеренде дә чыгып китте.* К.Тинчурин. *Ясәви әтәчләнепме әтәчләнә: – Калай түбәле алачыкта эш майтарамсың, каммун калдыгы? – дип җикеренә.* Б.Камалов

**Җикеренә башлау** Җикеренергә керешү. *Сөләйман, бөтен көчен, гайрәтен бер ноктага җыеп, ятып калганчы атып калу уе белән: – Син үзең кем? Син үзең кем? Кая документың? – дип, теге кеше өстенә ташланып, җикеренә башлады.* К.Тинчурин

**Җикеренә бирү** Җикеренүен дәвам итү. *Малай нинди көлке кыяфәткә керде, әмма Гыйльминең көләргә исәбе юк иде. Ул торган саен ярсыйрак төшеп җикеренә бирде.* Ф.Яруллин

**Җикеренеп алу** Бераз, кыска гына җикеренү. *Санитар, дәү капчыгын баш очында селки-селки, тагын бер җикеренеп алды: – Нинди закон тагын психка?!* Г.Бәширов

**Җикеренеп йөрү** Даими җикеренү; анда да, монда да һәр кешегә җикеренү. *Монда Исак үз алдына, кеше саен акылдан сапкан кешечә җикеренеп йөри. Кеше саен бәйләнә.* Ш.Камал

**Җикеренеп кую** Кинәт, бер тапкыр җикеренү. *Бары Вафа староста гына түзмәде: – Нәрсә сөйләнә ул малай актыгы? – дип, буыла-буыла җикеренеп куйды.* М.Галәү

**ҖИКЕРҮ** *ф.* Ачуланып, дорфа итеп кычкыру. *Становой тагы аяк тибеп нәрсәдер җикерде һәм ахырында бармагы белән ишеккә күрсәтеп: – Вон! – дип кычкырды.* М.Галәү. *Ләкин улы чыгып алмады, җитмәсә кеше алдында: «Кычкырып ятмале!» – дип җикерде.* Х.Сарьян. *Тик полицай тагын кыек авызы белән: «Молчать!» – дип җикерде.* Казан утлары

**Җикерә башлау** Җикерергә тотыну. *[Җизнәй] Алла боерса, өч метр ситсы алам да Нәҗиягә илтеп, киң итеп тектерәм, дип җикерә башлады.* Г.Мөхәммәтшин

**Җикерә бирү** Бернәрсәгә карамастан җикерү, җикерүен дәвам итү

**Җикереп алу** Кыска гына вакыт аралыгында җикерү. *Һәм [әби] тагы нидер кыстырырга җыенган иде: – Ярар!.. – дип, карт бер җикереп алды.* М.Госманов

**Җикереп җибәрү** Кинәт җикерә башлау. *Алар арасында ун адымлап ара калгач, әпәгә әллә нәрсә булды: ул, кеше аңламый торган ямьсез авазлар чыгарып, кычкырып, җикереп җибәрде.* Г.Гыйльманов

**Җикереп кую** Бер тапкыр җикерү. *Көне буе үзен тыеп, ачуын, шиген җыеп, тешен кысып түзгән Сәет җикереп куюын сизми дә калды.* Ф.Латыйфи. *Металл арасыннан чыккан шылтырау сыманрак тавыш белән җикереп куйды: – Мин сезнең эшегездән канәгать түгел, Искәндәр Исмәгыйлевич!..* Ф.Баттал

**Җикереп тору** Бертуктаусыз җикерү. *Кече кардәшенә [ул] җикереп торды, Кыланышы кырга сыймады.* Г.Афзал

**ҖИКСЕ** *с. диал.* Кешене аптыратучан, юкка-барга бимазалый торган. *Җиксе кеше*

**ҖИКСЕНҮ** *ф. диал.* 1) Тәмам тую, гарык булу. *Әти шундук сәерсенеп куйды, шөбһәгә калды. Бүтән андый сораулар бирмәскә кушты. (Сөйләшүдән җиксенеп) Булмый миннән, булмый, булмый! [диде].* З.Хәким

2) Авырсыну, нәрсәнедер эшләргә теләп җиткермәү. *Юк, үзенә мәшәкать туудан гына түгел, ә Хоршевны бәяләргә туры киләчәк булудан һәм җаңга тагы бер авыр йөк төшүдән җиксенеп әйтте.* Х.Камалов. *Мирзаян мулла, указлы мулла булса да --- йортта хуҗалык эшләреннән һич тайчынмый, кыр эшләреннән дә җиксенми.* Казан утлары

3) Өнәмәү, яратмау, тую. *Кара ипине җиксенсәң, кара көнгә калырсың.* Мәкаль. *Бер төрле аштан җиксенү*

4) *диал.* Чит күрү, ят санау. *Ана үз баласын җиксенми*

**Җиксенеп тору** Беркадәр җиксенгән хәлдә булу. *Җаек казакларының*

*сакалларын, көчләп, ирексезләп китәргәнгә күрә, бик гаҗиз булып, җиксенеп торган заманнары икән.* К.Насыйри

**ҖИКСЕТҮ** *ф. диал.* Тәмам туйдыру, биздерү, күрәсе килмәү. *Эш бәрәңге ашау түгел, кайчак бәрәңге дә җиксетә.* Әйтем. *Бер үк нәрсә күп кулланылса, ул туйдыра башлый, җиксетә.* Г.Бәширов

**Җиксетә төшү** Беркадәр, бераз җиксетү. *Бу эш безне бераз җиксетә төште*

**Җиксетеп бетерү** Тәмам җиксетү, гарык итү. *Гел кысыр аш җиксетеп бетерде*

**ҖИКСҮ** *ф. диал.* 1) Нәрсәдәндер тую, бизү. *Итле ризыктан җиксү*

2) Эч пошу, үзеңә урын тапмау. *Өзгәләнә бәгырь, телгәләнә, Аерылудан хәтәр җиксисең...* Х.Камалов

**Җиксеп йөрү** Җиксегән хәлдә булу; эч пошкан халәт кичерү. *Ябыгып, җиксеп йөргәндә, Җыр ачадыр минем күңлемне.* Җыр

**Җиксеп тору** Беркадәр җиксегән хәлдә булу. *Нигәдер эч поша, җиксеп торам*

**ҖИ́К ЧИГҮ** *ф. к.* **җык булу**. *--- әллә мәдрәсәдә ялгыз торудан җик чиккәнгәме, Хәйдәр үзе дә тизрәк өйләнергә уйлый башлады* Г.Исхакый. *Без күргәннәр бер гомергә Җитә микән, аз микән? Бәхет эзләп җик чигүләр Сагыш микән, наз микән?* И.Гыйләҗев

**ҖИЛ** *и.* 1) Атмосфера басымы үзгәрү нәтиҗәсендә, җир өстендә барлыкка килгән һава агымы хәрәкәте. *Җилләр, җилләр исәләр, Киң кырларны кичәләр. Җил назына иркәләнеп, Тук бодайлар үсәләр.* М.Җәлил. *Өстә җил, андый-мондый гына җил түгел, төрле яктан һич туктамыйча үтеп, сызгырып торган җил.* А.Гыйләҗев. *Сабыр гына искән урман җиле Айлы юлга чәчәк сибәли.* Х.Туфан

2) Нәрсәнең дә булса тиз хәрәкәте белән барлыкка килгән һава дулкыннары. – *Синең, – диде, – аяк атлап көлүеңнең җиле минем миемә сугылды...* Г.Ибраһимов. *Машина җиле аларның сүзләрен урлый, алар кычкырып-кычкырып сөйләшәләр.* А.Гыйләҗев. *Гаяз утыру белән, ул дилбегәне бушатып җибәрде. Ат җиленнән борынга тансык ис килеп бәрелде.* Х.Сарьян

3) *күч.* Нинди дә булса берәр хәл яки вакыйганың башлангыч билгеләре; үзгәреш. *Байлык алынды дип кайгырмагыз. Бу – вакытлы бер җил генә. Исәр дә китәр. Күп булса, өч көн барыр, диделәр.* Г.Ибраһимов. *Әйтерсең лә бу ике кеше үзләре белән нindидер яңа җил алып керделәр, алар кергәч, барысы да күңеллеләнә төште...* Ф.Хөсни. *Илне үзгәртеп кору җилләре кагылгач, халык, ничектер, бер омтылып алган иде.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Нинди дә булса эш, хәл, вакыйганың барышы. *Кызының үзен игътибар белән тыңламавын сизгән Сәхип әфәнде сүз җиленең барышын үзгәртергә булды.* Казан утлары

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса көчле тәэсире, шаукымы. *Дөрес, ул вакытта әле Фатих язучы түгел, ләкин инде 1905 ел җиле кагылган, гаять үткен, кыю һәм көрәшергә ярсып торган ачы телле --- яшь егет була.* Ф.Әмирхан турында истәлекләр. *Ерак пайтәхеттән көчле инкыйлап җиле, ниһаять, безнең кечкенә Дәүләкәнгә дә килеп җитте.* Ә.Еники. *Әмма замана җиле чараларга чаманы белмәде, табигатьтән дә өстен булып, шушы таулар аша авылны еш кына туздырып узды.* Мирас

◊ **Җил алгандай** Кинәт юкка чыгу турында. **Җил алу** 1) Җылылык бетү, суыну, салкынаю; 2) Юкка чыгу, бетү. **Җил ашау** Җилгә ярылу (бит, кулга карата). **Җил баш** Буш, эшлексез, мәгънәсез кеше. *Җил баш син! Күк күкрәгән өчен, болытларга бармак янап маташасың, адәм көлкесе!* Ә.Еники. **Җил белән киртәсен тоткан, һава белән япкан** Туктар-кунар җире юк, йортсыз, ихатасыз. **Җил белән симертү** Ач тоту, ашатмыйча тотарга тырышу. **Җилгә җибәрү** 1) *к.* **җилгә очыру**. *Ашлыгымны җилгә җилгәрдем. Яшьлегемне җилгә җибәрдем.* Җыр; 2) *к.* **җилбәгәй(гә) җибәрү.** *Ләкин, шул тыгыз халыкны --- ике якка сибеп, урталай ярып, берәү килә ---, «шалевый» якалы пальтосын җилгә җибәргән.* М.Мәһдиев. **Җилгә җиленләп, бозга бозаулап йөрү** 1) Теләсә кемне тыңлап, бушка мактанып гомер уздыру. *Йөрисең арбага бишенче көпчәк булып, былтыр яуган карны эзләп. Фәрештә кияве. Җилгә җиленләп, бозга бозаулап, аша да ят инде пенсияңне.* Б.Камалов; 2) Юк-бар, файдасыз эш артыннан чабу. **Җилгә йөрү** *гади. с.* Табигый йомышны үтәү. *Асаф моңа игътибар итте: кайбер сугышчыларның һөҗүм алдыннан шундый гадәтләре бар. Йә берөзлексез җилгә йөриләр, әйтерсең бер самавыр чәй эчкәннәр ---.* М.Мәһдиев. **Җилгә очу (китү)** 1) Әрәм булу. *Хан кызының иң тирән, иң саф калебеннән җан ачысы илә чыккан сүзләре, ялварулары бар да җилгә китте, шаһзадәгә һичбер әсәр кылмады.* Ш.Мөхәммәдев. *Ярый, түземсезләнеп, иңбашларыңны җыерма. Әйтәсе сүзем бик күп иде дә җилгә очты.* Г.Әпсәләмов. *Ул арада ишектән карсак кына буйлы, чүрәкәй генә бер кеше чыгып, француз яулыклы бер карчыкның муенына ташланды: – Булмады, биргән сәдакаларың җилгә очты, анакай...* Ф.Хөсни. **Җилгә очыру** Малны, дәүләтне, вакытны бушка, файдасызга уздыру, әрәм итү. *Бу бит, кимендә, биш сәгатьне җилгә очыру дигән сүз.* Г.Ахунов. *Солтан, син бу адымың белән минем тормышымны җимереп, тәмле хыялларымны җилгә очырдың.* Т.Гыйззәт. **Җил дагалап йөрү** Эшсез, тик йөрү. *Җил дагалап йөри ул.* Г.Ахунов. **Җилдәй җитез** Бик тиз; бик өлгер, уңган. *Җилдәй җитез йөртә бик тиз минем таныш автобусым.* Р.Миңнуллин. **Җилдән җиң тегеп йөрү** Корыга, бушка тик йөрү. *Бакиров җилдән җиң тегеп йөрүче зат түгел.* А.Гыйләҗев. **Җилдән килгән давылга китү** *к.* **җилдән килгән җилгә китү** *Җилдән килгән давылга китәр.* Мәкаль. **Җилдән килгән җилгә китү** Көч түкмичә генә тапкан мал бушка китү, кадерсезгә китү. **Җилдән туган (тапкан) бала** Рәсми никахы булмаган анадан туган бала. *Сиңа ни әйтер идем, шул җыен яттан, җилдән туган баланы сөймәсәң, сөяргә башка бала таба алмагансың икән.* Г.Камал. *Ә мин – җилдән туган. Минем күңел җәрәхәтле, мине мыскыл итәргә әзер*

*торучылар бар.* М.Мәһдиев. **Җиле дә килмәгән** Аз гына да охшамаган, якын да килмәгән. *Кая боларның төсләре бер-беренә охшау, ди? Җиле дә килмәгән.* А.Әхмәт. **Җил иләп йөрү** *к.* **җил куып йөрү**. *Йөри шунда җил иләп.* И.Туктар. **Җил кагылу** Нәрсәнеңдер тәэсире, йогынтысы булу. *Кооператив урынбасарына да җил кагылды.* Г.Ибраһимов. **Җил кайсы якка иссә, шунда (шул якка) авыша торган** Үз принцибы, үз тоткан юлы, тотрыклы карашлары булмаган кеше турында. *Кыз баланың язмышы егетләр кулында. Тәлиганың әле җил кайсы якка иссә, шул якка авыша торган чагы.* Ф.Яруллин. *Кырыкка җитеп тә үз хыялына ирешә алмаган ана белән җил кайсы якка иссә, шунда авыша торган аумакай атадан ничек туган диген шундый бала!* М.Маликова. **Җил (куу) куып йөрү** Юк эш артыннан йөрү, бушка йөрү, кирәксез эш белән шөгыльләнү. *Йөрмә читтә җил куып, син кайт, Гыйлемдар, кайт әле.* Ш.Бабич. *Намаздан соң ул, урыныннан торып, сүзгә кереште: – Балаларыбыз урамда бер эшсез җил куып йөриләр, дога белмиләр, укый-яза белмиләр. Мулла абзый аларны укыта алмас микән?* М.Галәү. *Фарукның җил куарга вакыты юк, хода бәндәләре. Мәшәкате муеннан.* Б.Камалов. **Җил күрде, кояш алды** *к.* **ай күрде, кояш алды** *Гүзәлне җил күрде, кояш алды. «Сау булыгыз», – дип әйтергә дә онытып китеп барды.* Т.Галиуллин. **Җилләр исү** 1) *к.* **җилләр уйнау**. *Югыйсә үз вакытында Мәскәүне шаулаткан аты һәм гайрәте булган бу мәшһүр затның тупланган байлыкларыннан күптән инде җилләр искән.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Кинәт юкка чыгу. *Бибинур тантана белән Зөһрәбану баскан урынга караган иде, сыңарыннан җилләр искән, кай арада кибеттән чыгып та шылган диген!* А.Гыйләҗев. *Выжт, җилләр исә тегендә, эрегән! Яулык күптән Исмәгыйльнең кесәсендә ята инде.* М.Фәйзи. *Тагын бер тын эзләнеп йөрдек. Киемнәребездән җилләр искән иде.* М.Юныс. **Җилләр уйнау** Бетү, юкка чыгу. *Кесәдә тагы җилләр уйнап тора иде.* Ф.Хөсни

**ҖИЛАЯК** *с. сөйл.* Бик елдам, җитез. *Җилаяк малай*

**ҖИЛӘК** *и.* 1) Кайбер үлән яки куак үсемлекләренең сусыл, татлы йомшак җимеше. *Шул чакны печән җыеп йөргән бәләкәй генә бер кыз, әллә нинди шатлыклы нәрсә күргәндәй чәрелдәп: – Җиләк! Җиләк! – дип кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Әз генә форсат чыгу белән, җиләк җыярга китүләр, агач арасына кереп, карлыган, шомырт җыюлар бигрәк күңелле иде.* М.Гафури. *Көзен зелпе, кура җиләге, эт шомырты, гөлҗимеш, кабар агачы кебек куакларның җиләк һәм сусыл җимешләре күпчелек кошлар өчен тәмле азык санала.* Ботаника

2) *күч.* Үсеп буйга җиткән, бик чибәр, сылу. *[Шәкертләр:] Ах Гайшә хурый да, их Гайшә җаный! Бигрәк тә пешеп кенә өлгергән кып-кызыл җиләк шул! Кемнең генә авызына өзелеп төшәр икән ул татлы-сусыл җиләк?!* Ш.Мөхәммәдев

3) **җиләгем** *тарт. форм.* Ярату, иркәләү һәм ихтирам хисләре белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Кил, җиләгем, кил, балам!*

◊ **Җиләк кебек (шикелле)** 1) Кып-кызыл, тулып пешкән. *Җиләк кебек иреңнән Суырып үпсәң – бал тама.* Җыр; 2) *к.* **җиләк** (*2 мәгъ*). *Бик әйбәт, бик уңган, җиләк шикелле бер кыз.* Г.Камал. --- *Хәмидә әби, бик тирәннән көрсенеп: – Аның да сезнең төсле җиләк кебек чаклары бар иде дә бит, Ходай язгач, ни эшлисең! – диде.* М.Гафури. *Димәк, җиләк кебек Фәридә ак чәчле, тумак битле, олы күсәк шушы картка насыйп булган?!* Р.-Н.Гүнтәкин

**ҖИЛӘК-ҖИМЕШ** *җый. и.* Барлык төр җиләкләр һәм җимешләр. *Авыл артында җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары тезелеп киткән иде.* М.Галәү. *Мостафа абый балаларына җиләк-җимеш үрентеләрен ничек карарга икәнен күрсәтте.* Г.Гобәй. *Чапкан печәннәрне өяр, җиләк-җимеш җыяр чак бит.* Казан утлары

**ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛЕ** *с.* Җиләк-җимешкә бай, җиләк-җимеше мул булган. *Безнең лә җирләр, әй, билгеле, Матур гөл бакчалары шикелле; Сулары ла тәмле бал-шикәрдәй, Урманнары җиләк-җимешле.* Җыр

**ҖИЛӘКЛӘНҮ** *ф.* Җиләк үсемлекләренең чәчәкләре коелып, җиләкләр барлыкка килү. *Кызыл карлыган куагы җиләкләнгән*

**Җиләкләнә төшү** Берникадәр, бераз җиләкләнү

**Җиләкләнеп килү** Акрынлап җиләкләнү. *Җир җиләге җиләкләнеп килә*

**ҖИЛӘКЛЕ** *с.* 1) Җиләк салынган, җиләге булган, җиләк тутырылган. *[Шәкүр абзый] Җиләкле чынаякларга чәй агызганнан соң, ул яңа бер дәртләнү белән сүзен дәвам итте.* Ф.Хөсни

2) Җиләк күп үсә торган, җиләккә мул. *Их, җиләкле җәйләрнең онытa алмамын ямен, Тоямын иреннәреңдә кура җиләге тәмен.* Җыр. *Җиләкле урыннарның исеме бар.* М.Мәһдиев. *Җәй буена без аның урманында мәмрәп торган җиләкле аланнарыннан чыга алмыйбыз.* Казан утлары

3) Җиләк рәсемнәре төшерелгән. *Җиләкле чынаякка чәй ясау*

**ҖИЛӘКЛЕК** *и.* Җиләк күп үсә торган урын. *[Маһи әби] Урманда йөрергә оста карчык булганга, барысы да аның белән ияреп урманга барып, ул белгән җиләклекләрне беләселәре килә.* М.Гали. *– Һай, бу Миңсылуны әйтәм! Нинди җиләклек тапкан бит! Кара син, нинди эреләр! – ди-ди, шулай ук җир өстенә чүгәләде.* М.Галәү

**ҖИЛӘ́К СУЫ** *и.* Җиләктән ясалган татлы эчемлек. *Аның өчен без җиләк суы кайнатабыз, куе итеп чәй ясап бирәбез.* Р.Мостафин

**ҖИЛӘКЧЕ** *с.* **1.** Җиләк җыярга һәвәс, җиләк җыярга оста. *Авылда бер карчык бар иде. Балалар аны җиләкче әби дип йөртәләр иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Җиләк җыярга килгән, җиләк җыеп йөрүче кеше. *Гали, әнә күрәсеңме җиләкчеләрне?* Д.Аппакова

2) Җиләк сатучы. *Әнкәй, җиләкче хатын килгән.* Т.Гыйззәт

**ҖИЛӘКЧЕЛЕК** *и.* Җиләк үстерү тармагы. *Җиләкчелек белән шөгыльләнү*

**ҖИЛӘ́К ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Миләш чыпчыгысыманнар семьялыгыннан, арка ягы коңгырт көрән, тамак

асты һәм түше җирән төстә булган кечкенә сайрар кош

**ҖИЛӘН** *и.* Эченә мамык куймыйча гына, киң, озын итәкле, кайтарма тар якалы итеп тегелгән ирләр өс киеме. *[Габдулланың] Аягында савырлы кәҗүл читек, җәен кәзәки өстеннән кара җилән, кышын төлке тун кия.* М.Галәү. *Абзый, ике таңкага төшереп, җилән тектереп бирде. «Урак урган хакымны бирмәделәр дип рәнҗемә», – дип, ул җиләнне эш хакына куйды.* М.Гафури. *Өстендә түше ачык иске күк җилән, башында ак чалма, аягында яшел башмак.* Ф.Мансуров

**ҖИЛӘС** *с.* **1.** 1) Аз гына җил исеп торган. *Җиләс бер урында гына ашап-эчеп алдык.* М.Гафури

2) Җиңелчә генә салкын булган. *Кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре, --- ромашкалар, зәңгәр кыңгыраулар белән чуарланган, әле чабылып өлгермәгән болынның хуш исле җиләс һавасына туйганчы иркәләндек.* М.Әмир. *Кичке җиләс җил исә, Йөрәкне сагыш кисә.* Ә.Исхак. *Күкрәккә мул булып ургылып кергән җиләс саф һава канны уйнатып, тәнне җиңеләйтә.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* Салкынча урын. *Чәйдән соң өйалдына – җиләскә чыгып утырдык.* С.Сабиров. *Хәйретдингә асылда берни дә булмаган, ята әнә рәхәтләнеп җиләстә.* А.Гыйләҗев

**3.** *рәв. мәгъ.* Салкынча. *Агачлар күләгәсендә җиләс иде.* Г.Бәширов. *Иртәләрем аяз иде, Җиләс иде кичләрем…* Х.Туфан. *Елга буе җиләс иде, су өстеннән, ак томан булып, бу күтәрелә.* Мирас

**ҖИЛӘСЛӘНҮ** *ф.* 1) Җиләскә әйләнү, салкынча булып китү. *Кояш түбәнгә авыша барган саен җиләсләнә, сулышлар иркенәя.* З.Фәйзи. *Сөн елгасы өстендә беленер-беленмәс кенә сыек томан күтәрелде. Җиргә дым бәрде, һава җиләсләнде.* Мирас

2) Җилләнү, җилпәзә, кульяулык һ.б.ш. кебек әйберләр белән җилпенү

**Җиләсләнә бару** Вакыт узган саен ныграк җиләсләнү

**Җиләсләнә төшү** Беркадәр, бераз җиләсләнү; тагын да җиләсләнү. *Шәһәр өстендә кичке утлар кабынган. Тагын да җиләсләнә төшкән.* Ф.Латыйфи

**Җиләсләнеп китү** Кинәт кенә бераз җиләс хәлгә килү. *Иртәдән ялтырап торган чалт аяз көн җиләсләнеп киткән.* К.Тимбикова

**Җиләсләнеп тору** Әле, хәзер бераз җиләс хәлдә булу

**ҖИЛӘСЛӘТҮ** *ф.* 1) Җил кертеп, һавасын алыштыру. *Тәрәзәне ачып, бүлмәне җиләсләтү*

2) Салкынайту, салкын хәлгә китерү. *Салкынча мәгарә утыз градуслы эсседән пешкән тәннәребезне шәраб кабул итәрлек хәлгә китереп җиләсләтә.* М.Галиев

**Җиләсләтеп алу** Бераз җиләс хәлгә китерү

**Җиләсләтеп җибәрү** Кинәт җиләсләтү

**Җиләсләтеп тору** Әле, хәзерге вакытта җиләс хәлдә тоту

**ҖИЛӘСЛӘ́Ү** *ф.* Акрын гына талгын җил исү. *Яшь торна оча алмый, Тилмерә үзәндә. Тәпие чорналган Энәле үләнгә. Матур таң сызылып, Җиләсләп атканда, Нигә соң үләннәр Әйләнде капкынга?* Ш.Гаделша

**Җиләсләп тору** Әле, хәзер бераз җиләсләү

**Җиләсли төшү** Бераз, беркадәр җиләсләү

**ҖИЛӘСЛЕК** *и.* Җиләс булу. *Кичкә рәхәт җиләслек иңде.* Ф.Әмирхан. *Юрганына чумып яткан Миңлегаязны яңадан хушбуй исе килеп торган ягымлы җиләслек иркәләп узды.* Р.Мөхәммәдиев. *Иртәнге рәхәт җиләслек. Буяу, лак, химикатлар исенә туенган бина эченә, егеткә ияреп, болын җиләслеге килеп кергәндәй булды.* Казан утлары

**ҖИЛӘТҮ** *ф. диал.* Берәр нәрсәне күп һәм еш кулланып туйдыру, тәмам биздерү. *Гел ашасаң, майлы ботка да җиләтә.* Мәкаль. *Шул чакта мин үз тиңдәшләрем белән туйганчы уйнап калам. Бара торгач, уен да җиләтә.* М.Кәрим

**ҖИЛӘ́Ү** *ф. диал.* Нәрсәдән дә булса туюю, күңел бизү, кызыксынмый башлау. *Агыйделнең аръягында үсә кура җиләге, чит җирләрдә йөри-йөри, күңелләрем җиләде.* Җыр

**ҖИЛБАШ** *с. диал.* Бик кызу, гайрәтле, ләкин таркау, эшенең ахырын, нәтиҗәсен уйлап бетерми торган. *Бер җилбаш әдәм*

**ҖИЛБӘГӘЙ** *и.* **1.** Төймәләмичә киелә торган җиңелчә өс киеме

**2.** *с. мәгъ. к.* **җилбәзәк** (*4 мәгъ.*). *Ләкин бу борчу озакка бармады, җилбәгәй егетләр болай сөйләсә дә, халык авызында үзен яратып, мактап телгә алуларын ул бик еш ишетә иде.* Г.Ибраһимов

**ҖИЛБӘГӘ́Й(ГӘ́) ҖИБӘРҮ** *ф.* Киемнең төймәләрен ычкындырып, чабуларын як-якка ачып җибәрү. *Сәлмән байның, шуннан ун көн генә элек, «тып» итеп шәһәрдән кайтып төшкән Мидхәте икенче көнне дә гимназист мундирын җилбәгәй җибәреп, --- бакча белән ишегалды тирәсендә буталып йөрде.* Ф.Хөсни. *Аңа салкынча булып китте, ул җилбәгәй җибәргән плащының чабуларын җыйды.* М.Маликова. *[Кәбир] Яшелле-кызыллы буй-буй ефәк чапанны җилбәгәй җибәреп киеп алган.* Ә.Фәйзи

**ҖИЛБӘЗ** *и. сөйл.* 1) Нәрсәнең дә булса (оешма, ярышлар һ.б.) билгесе булган, гадәттә, өч яки бишпочмаклы кечкенә төсле флаг; вымпел

2) Җилнең юнәлешен билгеләү максаты белән, колга башына урнаштырыла торган махсус җайланма; флюгер. *Өй түбәсенең почмагына җилбәз урнаштыру*

**ҖИЛБӘЗӘК** I *с.* 1) Җил уңаена күчеп йөри торган. *Бакчада – җилбәзәк яфраклар тангосы.* Ә.Рәшит. *Җилбәзәк кар*

2) Җилгә җилферди, селкенә торган. *Мәһабәт иманнәр, сылу каеннар, җилбәзәк усаклар, купшы юкәләр, сабыр өрәңгеләр – бүген барысы да, көяз яшь җилкенчәк кебек, шәл-яулыкларын төрләндереп җибәргәннәр.* Г.Әпсәләмов

3) Җиңел гәүдәле, җитез хәрәкәт итә торган. *Дуслары Лаләгә тикмәгә генә «җил кызы» дип исем бирмәгәннәр икән. Унынчы класска җитүенә карамастан, ул һаман да әле күбәләк кебек җилбәзәк.* Г.Әпсәләмов. *Зәйтүнә – ятимә бер кыз, Сәфәргали, аяк-кулларын тик тота белмәүче, җиңел гәүдәле бер җилбәзәк иде.* Ф.Хөсни

4) *күч.* Җиңел холыклы, тормышка җиңел карый торган, иләс-миләс. *Тагын шул чаклысы да бар: Биктимер минем җилбәзәк булуымны, лыгырдарга бик яратуымны яхшы белә.* Ф.Хөсни. *...Баштарак [ул] аларның бу җилбәзәк гамәлләрен башына сыйдыра алмыйча азапланып, интегеп йөрде.* Казан утлары

5) *күч.* Ашкынучан, җилкенчәк. *Гомер үткән саен, җилбәзәк яшьлек елларындагы газаплы хисләр онытыла, сүнә барды.* Шәһри Казан

6) *күч.* Җиңел, катлаулы булмаган, эчтәлегенә, мәгънәсенә игътибар ителмәгән. *Филүс Каһиров – --- татар моңын җилбәзәк эстрада такмакларына алмаштырган егет түгел.* Мәдәни җомга

**ҖИЛБӘЗӘК** II *и.* Ялтыравык тәңкәчек. *Кышкы кояш үзенең көчсез нурларын карга ташлый, Ярма кебек кар өстендә җилбәзәкләр ялтырый.* Ә.Еники

**ҖИЛБӘЗӘКЛӘНҮ** *ф.* Үзен җилбәзәк I (*4 мәгъ.*) тоту, җилбәзәк итеп күрсәтү. *Җилбәзәкләнеп, кыланып түгел, үзенең сыгылмалы билләренең, калку күкрәкләренең бәясен, дәрәҗәсен белеп кенә бии ул.* А.Гыйләҗев

**Җилбәзәкләнә бару** Көннән-көн, вакыт узган саен җилбәзәклеге көчәю

**Җилбәзәкләнә төшү** Беркадәр, бераз җилбәзәкләнү

**Җилбәзәкләнеп йөрү** Һәрвакыт, төрле урыннарда җилбәзәклек күрсәтү. *Берәү сүзендә тора алмаган икән, бу бит миңа җилбәзәкләнеп йөрү хокукы бирми.* Азат хатын

**Җилбәзәкләнеп китү** Кинәт җилбәзәккә әйләнү. *Ләйлә, үзе дә сизмәстән, «шөкер», «Алла боерса», «Ходай насыйп итсә» кебекләр белән ныгытып, әле атасы фикерен кабатлый, әле, үзенең җиткән кыз булуын онытып, яшүсмерләрчә җилбәзәкләнеп китә иде.* Г.Бәширов

**ҖИЛБӘЗӘКЛӘ́Ү** I *ф.* Җиңел генә җилфердәп очу. *Җилбәзәкләп, кар ява*

**ҖИЛБӘЗӘКЛӘ́Ү** II *ф.* Җилбәзәкләр (II) белән бизәү, шулар белән зиннәтләү. *Җилбәзәкләп теккән зәңгәр бәрхет [күлмәк] Зифа буйга бигрәк килешкән.* Ш.Бабич

**Җилбәзәкләп бетерү** Бөтенләй, тулысынча җилбәзәкләү

**Җилбәзәкләп кую** Алдан җилбәзәкләнгән хәлгә китереп тоту

**ҖИЛБӘЗӘКЛЕК** *и.* Җилбәзәк I (*4 мәгъ.*) кешегә хас сыйфатлар. *Хәер, табигатенә хас җилбәзәклек, гамьсезлек аңа бу юлы да кайгылы уйларга тирән батарга ирек бирмәде.* М.Галәү. *Вакытлар узып, яше үскән саен, Сәфәргали малай чагындагы җилбәзәклегеннән азмы-күпме арына барды.* Ф.Хөсни

**ҖИЛБӘЗӘКЛЕ́К КҮРСӘТҮ** *ф. к.* **җилбәзәкләнү**. *Алай гына да түгел, әгәр Илмира чытлыклана башласа, җилбәзәклек күрсәтсә, Мансур шунда ук аңа аркан борылыр иде.* Г.Әпсәләмов

**ҖИЛБЕГӘН** *и. миф.* 1) Кеше ашаучы, күпбашлы аждаһа, албасты

2) Җен, явыз рух. --- *комаек, койгыр, сак-сок, дию, аждаһа, юха, җилбегән кебек мифик образлар да түбән мифологиягә керә.* Татар халык иҗаты

**ҖИЛБЕРӘ́Ү** *ф. диал. к.* **җилфердәү**. *Алтын алдым, көмеш салдым Җилберәгән камышка.* Бәет

**ҖИЛБЕРДӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **җилфердәү**. *Җилбердәп җитен чәчләре, умырзая безгә елмая.* М.Җәлил. *Арыслан ялыдай сачлары җилбердәп [Гурий] Тавлин килеп чыга.* А.Гыйләҗев

**Җилбердәп тору** Бертуктаусыз җилбердәү. *[Аның] Чәче агарган, ияк очында җилбердәп торган сакалына да чал кергән.* Г.Ибраһимов

**ҖИЛБЕР-ҖИЛБЕР** *иярт. к.* **җилфер-җилфер**. *Җилбер-җилбер йөргән чакта, Җилләр ача куйнымны.* Җыр. *Йокысыннан Кояш ничек уяндисә, Җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә.* Г.Тукай. *Кайберәүләрнең [балаклары] шулчаклы киң ки, атлаганда, йә алдан, йә арттан, җилбер-җилбер, җир себереп баралар.* А.Гыйләҗев

**ҖИЛ-БУРАН** *җый. и.* 1) Җил һәм буран. *Менә бервакыт җил-буран кузгала.* Г.Ибраһимов. *Биек ярлар, агач коймалар буена җил-буран киртләч-киртләч кар көртләре өеп китте.* М.Галәү

2) *күч.* Гауга, зур ызгыш. *Менә бер вакыт җил-буран кузгала! Салахиев – бер яктан, Иванов икенче яктан давыл куптаралар.* Г.Ибраһимов

**ҖИЛБҮЛӘР** *и. махс.* Төп җил юнәлешләре аерыла торган урын; *русчасы:* **ветрораздел**

**ҖИЛГӘНУТ** *и. бот. диал.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, буе метрга кадәр җиткән, читләре сырланып торган чәнечкеле, өске өлеше өчпочмакланып килгән озынча яфраклы, ачык сары чәчәкле эре берьеллык чүп үләне; билчән; *русчасы:* **осот огородный**

**ҖИЛГӘРГЕЧ** *и.* Ашлык җилгәрә торган машина. *Күптәнме соң алар Һашим белән шул уенчык кебек зәңгәр җилгәргечне Бөгелмәдән алып кайттылар.* Г.Әпсәләмов. *Бу чүп җилгәргечтән төшми, аны, берәмләп, кул белән чүпләргә туры киләчәк.* Г.Гобәй

**ҖИЛГӘРҮ** *ф.* 1) Ашлыкны җилгәргечтән үткәрү. *Олы тешле барабан хәрәкәткә килде. Аның белән бергә ашлык сугу машинасының һәммә механизмына җан керде: кайсы бөтерелә, кайсы талкый, кайсы җилгәрә.* Мирас

2) Җилгә тоту, ашлыкны, җил белән өрдереп, чүп-чардан арындыру. *Ашлыгымны җилгә җилгәрдем, яшьлегемне җилгә җибәрдем.* Җыр

3) Туздыру, төрле якка тарату, очырту. *Кәгазь көшелен җил җилгәрә, кибән арасында ак бөртекләр генә шәйләнә.* М.Галиев

**Җилгәрә башлау** Җилгәрергә тотыну. *Яңа сугылган арышны җилгәрә башладылар.* Мирас

**Җилгәрә бару** Һәрберсен рәттән җилгәрү

**Җилгәреп алу** Берара, тиз генә җилгәрү

**Җилгәреп бетерү** Бөтенләй, тулысынча җилгәрү; ахырына кадәр җилгәрү

**Җилгәреп бирү** Кемгә булса да җилгәрү

**Җилгәреп кую** Беркадәр, бераз җилгәрү; алдан җилгәреп әзерләү

**Җилгәреп тору** 1) Даими рәвештә җилгәрү. *Аларны [чи бодай көшелләрен] сәгать саен, астын-өскә әйләндереп, җилгәреп торырга кирәк.* А.Хәсәнов

2) Хәзер җилгәрү эшен башкару. *Алар килгәндә, без ашлык җилгәреп тора идек*

**ҖИЛД** *и. гар. иск.* 1) Тире

2) Төпләнгән китапның катыргы тышлыгы

3) Китапның бер өлеше, кисәге; том. *1957–1958 елларда Ф.Әмирханның сайланма әсәрләренең калын-калын ике томы дөнья күрде. Беренче җилдне төзүче һәм текстларны әзерләүче – А.Шамов, икенчесенеке Х.Хисмәтуллин булды.* Р.Әмирхан

4) Данә, экземпляр, китап хисабының берәмлеге. *Даменла Фәриделгасриның кульязма җәвабы бар. «Эш»нең өченче җилденең дүрт йөз туксан беренче битендә.* Г.Ибраһимов

**ҖИЛ-ДАВЫЛ** *җый. и.* 1) Көчле җил, давыл. *Җил-давыл басылды, болытлар таралып, фирүзәдәй зәңгәр күк йөзендә яңадан кояш күренде.* М.Галәү. *Урман биләмәләренең күбесендә бик күп җил-давыл аударган агачлар күрәсең.* Сөембикә. --- *ару гына үскән каеннар, имәннәр җил-давылда таланып калган төсле шәп-шәрә.* Мирас

2) *күч.* Тормышның иң кыен вакыты, катлаулы чоры. *Җил очырып алып киткән дүңгәләк кебек, туган нигезебездән без артык ерак киттек. Ә җил-давыллар, иң беренче, тамырсызларны очыра.* Ф.Яруллин. *Балигъ булгач, дәү тормышның сынауларын, Дәрьяларын, җил-давылын кыю кичтем.* Ф.Дунай. *Ничәмә гасырлар буе бербөтен халык булып, җил-давылларга каршы торып, «инде бетәм» дигәндә дә сыгылып төшмәгән халкымны «татар» дигән исем саклап йөртә.* Мәдәни җомга

3) *күч.* Олы тавыш, гауга. --- *Румия больницадан чыккач, аны бәхилләтү, эшне күпертмәскә ризалату кыен булмаячак. Беренче җил-давылны гына хәвеф-хәтәрсез уздырырга иде.* М.Маликова. *Зиннур «җил-давылга» очрамыйча гына келәтенә кереп ятканда, Актүш кенә, озак каитмавына шелтәләп, --- койрыгын болгап, сыпыргаланып өлгерде.* Казан утлары

◊ **Җил-давыл булып очу** Юкка чыгу, бөтенләй бетү, эзсез югалу. *Минем өчен иң чибәр, иң акыллы, иң гүзәл һәм иң кадерле булган, җанымнан якын күргән сөекле кешем шуны эшләгәч, егерме ел корган җәннәтем күз ачып йомганчы җил-давыл булып очкач, зиһеннәрем таралып, башым үйламас булды.* Г.Мөхәммәтшин. **Җил-давыл куптарып** Җил уйнатып, җилкенеп, зур тизлек белән. *Озак та үтмәде, котчыккыч кәрван, баягы кебек җил-давыл куптарып, кире әйләнеп кайтты һәм Госмановларның капкасы алдында тукталды.* Ә.Фәйзи. **Җил-давыл өертеп** *к.* **җил-давыл куптарып**. *Менә Столыпинский чатыннан шәп тарантасларга җигелгән атлар килеп чыктылар һәм, җил-давыл өертеп, тузан туздырып, Госмановлар урамына борылдылар.* Ә.Фәйзи

**ҖИЛ-ДАВЫЛЛЫ** *с.* 1) Җиле көчле булган, давыллап торган. *Табигатьтә һава торышлары гел үзгәреп тора: кояшлы матур көннәр дә була, җил-давыллы, болытлы көннәре дә җитә.* Шәһри Казан

2) *күч.* Авыр, кыен, хәсрәт тулы. *Гомернең җил-давыллы һәм туктаусыз тулкынлы чагы үтеп, акрын, гел бертөсле һәм тынычлык сөяр дәвере кереп килә.* Г.Ибраһимов. *Кешеләр җил-давыллы, кайгы-хәсрәтле станцияләрне читләтеп үтә.* Р.Вәлиев

3) *күч.* Җитез, булдыклы. *Мине гел «җил-давыллы» диделәр. Әле дә, Екатеринбургка баргач, артистлар, Хәмдүнә – аждаһа, дигәннәр.* Ирек мәйданы

**ҖИЛДӘВЕК** *и. бот.* Үсемлекләрнең, күбрәк агачларның, вак яфраклы, кыска һәм гадәттә кысыр ботаклары, укмашып, бәйләм-бәйләм булып үсүеннән гыйбарәт гөмбә авыруы яки вируслы авыру; *русчасы:* **ведьмины мётлы**. *Җилдәвек белән зарарланган агач башларында шар сыман җисем күрергә мөмкин*

**ҖИЛДӘЙ** *рәв.* Җил кебек, бик тиз, җитез. *Әгәр шушы өермәдәй килеп, җилдәй юкка чыгучы егет --- әлеге безнең Закир Дәүләтшин булса, ни әйтерсең?* И.Гази. *Тачанка җилдәй тизлек белән авылның эченә үк килеп керде.* Г.Бәширов

**ҖИЛДӘК** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, иртә яз аксыл сары чәчәк ата торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **ветреница**. *Җилдәк үсемлегенең җир өстендәге өлеше һәр елны көзен корый.* Ботаника

**ҖИЛДЕРТҮ** *ф.* **1.** Бик кызу чабу, шәп хәрәкәт итү, элдертү. *Яз җиткән булуга карамастан, суыкта аяк асты коп-коры, айгыр җилдертә, аягы җиргә тияр-тимәс оча.* И.Гази. *Санаулы сәгатьләр тиз уза. Җилдертеп, Камага да килеп җиттек.* Сөембикә

**2.** *күч.* Эшне уңышлы, нәтиҗәле алып бару. *Тоякка да үзенең хуҗалык эшләрен җилдертеп алып барырга вакыт иде инде.* И.Салахов. *Сәүдә эшен җилдертеп алып бару*

**Җилдертә башлау** Җилдертергә тотыну. *Шофёр егет хуҗалар күрмәгәндә «тамак йомшартып» алган булгай, бик җиңел кузгалып китеп, борылмалы асфальтка алып чыгып, җилдертә башлады.* Т.Галиуллин

**Җилдертә бирү** Бернәрсәгә дә карамастан җилдертү; җилдертүне дәвам итү

**ҖИЛДЕРҮ** I *ф.* 1) *к.* **җилдертү**. *Мине утырткач, атларына чыбыркысын селтәү белән, атлар шәбәеп киттеләр. Ике туры ат җилдерәләр генә!..* М.Гафури. *Атлары да көр икән, тигез җиргә чыккач, ах, җилдерәләр генә, агай.* М.Шабай. --- *тиздән ат иясен елга буена алып чыкты һәм яр буйлап җилдерде.* М.Хәбибуллин

2) *күч. сөйл.* Берәр хәлне тасвирлаганда, үзеңнән өстәп, күпертеп сөйләү

**Җилдерә башлау** Җилдерергә тотыну. *Егетнең күңелендә өмет канат җәя, аты да аны аңлый кебек, тагын да ашкынып җилдерә башлады.* Ф.Сафин

**Җилдерә бирү** Бернәрсәгә дә карамастан җилдерү; җилдерүне дәвам итү. *Туры бия, минем өчен Әхмәтдин ни дә Мөхәммәтдин ни дигәндәй, кеше кулы сайлаучан түгел – үз җаена җилдерә бирә.* С.Поварисов

**Җилдереп алу** Берара җилдерү; кыска вакыт эчендә чабу. *Юлда без җилдереп алдык*

**ҖИЛДЕРҮ** II *ф. диал.* 1) Кайнар суда пешекләү. *Эчәкләрне җилдерү. Яшелчәләрне җилдереп тозлау. Малның эч-карынын җилдерү*

2) Итне кояшта яки җилдә тотып киптерү. *Казны җилдереп каклау. Җилдереп тозланган үрдәк ите*

**Җилдерә төшү** Тагы да бераз җилдерү

**Җилдереп алу** Берара җилдерү, аз вакыт эчендә җилдерү

**Җилдереп бетерү** Бик нык җилдерү; бөтенләй, тулысынча җилдерү

**Җилдереп кую** Алдан җилдереп әзер итү

**ҖИЛДЛӘ́Ү** *ф. иск.* Китап төпләү, китап тышлау

**ҖИЛЕ** *и. махс.* 1) Киләптәге җеп чуалмасын өчен хезмәт итә торган бау

2) Төрле максатларда кулланыла торган элмәкле, муенчаклы бау, киндерә. *Җиледән атлап узарга ярамый – аяксыз калырсың.* Әйтем. *Колыннарны тезеп бәйләү өчен җиле сузу. Бозау җилесе*

◊ **Җиледән чыккан** Гомуми тәртипкә буйсынмый торган, тыела белми торган, тәртипсез

**ҖИЛЕГҮ** *ф. диал.* 1) Тәмам тую, маемлау, үтләү. *Майлы иттән җилегү*

2) *күч.* Бик еш кабатлану сәбәпле, берәр нәрсәдән ихлас кайту, бизү, күрәсе килми башлау. *Бер алып барды бу, ике алып барды... Җилеккәндер инде, мәрхүм. [Ахырда] «Инде үзең чамала», – ди бу.* Казан утлары

**Җилегеп бетү** Бөтенләй, тәмам җилегү

**ҖИЛЕК** *и. сөйл.* 1) *к.* **җелек**

2) *күч.* Нефть. *Кырык ел вакыт аралыгында Татарстан куеныннан суырылган ике миллиард дүрт йөз миллион тонна җилекнең бәясе ике йөз илле миллиард доллар тора.* Т.Галиуллин

**ҖИЛЕКТЕРҮ** I *ф.* Җилдә, кояшта тотып киптерү, дымын бетерү. *Елга балыгын җилектерү*

**Җилектереп алу** Бераз, беркадәр җилектерү

**Җилектереп бетерү** Бөтенләй, тулысынча җилектерү; барсын да җилектерү

**Җилектереп кую** Алдан җилектереп әзер итү

**ҖИЛЕКТЕРҮ** II *ф. диал.* 1) Туйдыру, биздерү. *Кайчак майлы ботка да җилектерә*

2) *күч.* Ялыктыру, алҗыту, арыту. *Яхшы атта җиңел генә барсак та, шактый җилектерде.* Ә.Еники. *Дыңгырдык юлда арбага утырып бару җилектерде*

**ҖИЛЕМ** I *и.* 1) Әйберләр ябыштырганда кулланыла торган ябышкак куе сыекча. *Кытай, эрбет чикләвекләре, кара кузак, кызыл билле прәннек, йөзем, бизәкле кәгазьгә төргән, җилем кебек ябыша торган һәм таш кебек каты конфетларның исәбе-хисабы юк.* М.Галәү. *Ә иртәгәсен минем кулыма нарат сагызы төсле куе сары җилем белән ябыштырылган конверт тоттырды.* М.Маликова. *Дуслык бит ул ике яклы була: берең – «бөек», икенчең «көек» булса, бу дуслыкны җилем белән дә беркетә алмыйсың.* Р.Әмирхан

2) Хайван сөягеннән һәм тиресеннән ясала торган аксым матдәсе; желатин. *Бламанжилары оешмагандыр әле. Я җилемен аз салганнардыр.* Г.Камал. *Койкага җилем кушу*

3) Бал кортлары эшләп чыгарган, умарта эчендәге җекләрне һәм бал белән тулган күзәнәкләрне сылап куя торган сумаласыман матдә, тома баласы; *русчасы:* **прополис**

4) *күч.* Сөйләгәндә, сүзләрнең эзлекле агылышын тәэмин итү йөзеннән кушып җибәрелгән сүз. *Шөкер Ходайга, мин үзем алай кеше кулына калырмын дип уйламыйм, калырга язмасын Ходай. Әле тик болай, сүз җилеме итеп әйтелгән сүз.* Ф.Хөсни

**ҖИЛЕМ** II *и. диал. к.* **җилен**

**ҖИЛЕМ** III *и. диал.* Саман кирпеч сугу яки өй сылау өчен, балчыкка салам кушып ясалган измә

**ҖИЛЕМБАЛЫК** *и.* Карплар семьялыгыннан, төче сулыкларда көтү-көтү булып яши торган вак балык; *русчасы:* **уклейка**. *Җилембалыкларның Евразия елгаларында җиде төрен очратып була.* Кызыклы ихтиология

**ҖИЛЕ́М БАСМА** *и. тар.* **1.** Язма яки басма текстның күпсанлы копиясен алу җайланмасы; гектограф. *Татарчасын, мин сөргенгә киткәнче үк, җилем басмада таратырга партком тарафыннан кушылган иде.* Г.Ибраһимов. *«Әль-ислах»ның җилем басмада ничә саны чыкканы төгәл мәгълүм түгел.* Р.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* Шул җайланмада басылган. *Абыйсының ялкынлы тарафдары булган Ибраһим --- әдәби-музыкаль кичәләрдә, --- җилем басма гәзитләрдә дә катнаша.* Р.Әмирхан

**ҖИЛЕМЛӘНҮ** *ф.* Ябышкакка әйләнү. *Әйтерсең лә аның итек табаннары, җилемләнеп, күптән юылмаган, кыршылган идәнгә ябышып каткан иде.* М.Маликова

**ҖИЛЕМЛӘ́Ү** *ф.*1) Җилем сылап ябыштыру, җилем сөртү. *Җилемләү өчен, желатинлы агач җилемен яки клейстр эремәсен файдаланырга мөмкин.* Н.Верзилин

2) *күч.* Сүзләрне урынлы куллану, эзлекле сөйләү. *Сүз сорап, --- берәү алгарак чыкты. Салмак кына, сүзне сүзгә җилемләп кенә сөйләргә тотынды ул.* И.Гази

3) *күч.* Бер-берсенә бәйләү, берләштерү

**Җилемләп алу** Бераз, беркадәр җилемләү; тиз генә җилемләү

**Җилемләп кую** Алдан җилемләү

**Җилемләп тору** 1) Әле, хәзер җилемләү

2) Даими рәвештә җилемләү. *Сез икегез ике караш кешеләре булгансыз. Ахмакларча туган трагедия генә сезне вакытлыча җилемләп торган.* Б.Камалов

**Җилемли төшү** Бераз җилемләү

**ҖИЛЕМЛЕ** *с.* Җилемләнгән, җилеме булган, җилем салынган. *Сырышма җимешле үсемлекләрдән тыш, җимешләре җилемле, ябышкак үсемлекләр дә очрый. Күгәрчен күзе үләненең җимешләре нәк шундый.* Ботаника. *Җилемле кәгазь*

**ҖИЛЕМЛЕК** *и. бот. к.* **җилемсә**

**ҖИЛЕМСӘ** *и.* Кыяклы үсемлекләрнең орлыгында була торган үсемлек аксымы; *русчасы:* **клейковина**. *Җилемсә бодай онының ипи пешерү сыйфатын билгели.* Биология. *Бодай камырын марляга төреп, стакандагы суда җебетсәк, бераздан марляда сузылучан масса калыр. Бу – җилемсә, ягъни үсемлек аксымы булыр.* Ботаника

**ҖИЛЕМСЕЗ** *с.* 1) Җилеме булмаган, җилем сөртелмәгән. *Җилемсез конверт*

2) *күч.* Эзлеклелеге булмаган, бәйләнешсез, ятышсыз. *Мәгънәсез һәм дә җилемсез сүзләрем, Чөнки анда уй, фикер һәм күзләрем.* М.Гафури

◊ **Җилемсез ялгану** Үзеннән-үзе эзлекле һәм бәйләнешле бару

**ҖИЛЕН** *и.* Имезүче хайваннарда сөт бизләреннән һәм имчәкләрдән торган имезү органы. *Җиян ил булмас, җилен аш булмас.* Мәкаль. *Авызларына --- кабыктан ясап кечкенә тубал кигезгән яшь бозаулар, тиз генә килеп, аналарының имчәкләренә башларын төртәләр. Җиленнәрен чәнчүгә түзә алмаган аналары, башларын чайкап, аларны сөзеп җибәрәләр.* М.Гали

**ҖИЛЕНЛӘҮ** *ф.* Буаз хайваннарда бозаулау, колынлау, бәрәнләү алдыннан сөт бизләренең эшли башлавы; җилен тулышу. *Башмак тана җиленли башлаган*

**ҖИЛЕШ** *и.* 1) Җилдереп чабу, чабыш; кызу һәм тиз йөреш. *Җил-җил килеп, без йөрибез. Җилешебез калсын бу җирдә.* Җыр. *Сабантуй алдыннан атларның җилешен сынау*

2) Куәт, көч-дәрман. *Инде хәзер үк аякларның җилешләре юк*

**ҖИЛҖАК** *и. диал.* Мактаганны яратучан, юк-барга үсенеп китүчән кеше. *Җилҗак шәкерт*

**ҖИЛҖАКЛАНУ** *ф. диал.* Мактаганны ярату, юк-барга үсенү

**Җилҗаклана башлау** Җилҗакланырга керешү, җилҗаклану билгеләре күрсәтү

**Җилҗакланып алу** Берара җилҗаклану; аз гына җилҗаклану

**Җилҗакланып йөрү** Күпмедер вакыт җилҗаклану

**Җилҗакланып китү** Кинәт, ниндидер вакыттан яки сәбәптән соң җилҗакланырга тотыну

**ҖИЛ-ҖИЛ** *рәв. сөйл.* Бик тиз, кызу-кызу. *[Нәсимә] Шул көнне тизрәк җиткерергә ашыккандай, җил-җил атлап, фабрика тыкрыгына борылды.* К.Нәҗми. *[Черепицаны] Биш-алтыны беләгеңә аркылы саласың да авыш басмадан җил-җил менеп китәсең.* А.Гыйләҗев. *Асылбикәнең башка берәүдә дә булмаган исеме дә, гади генә бизәкле яулыкны, артка чөеп, килешле итеп бәйли белүе дә, йөргән чакта җил-җил атлап йөрүе дә – барысы да җанга якын иде.* Казан утлары

◊ **Җил-җил килеп** Кызуланып, ашыгып. *Яруллин --- кулын селтәде дә җил-җил килеп чыгып китте.* М.Хәсәнов

**ҖИЛКАПКА** *и.* Кереп-чыгып йөрү өчен, аркылы торыклардан эшләнгән ачылмалы кечкенә капка. *Мин, танавымны тартып, аяк очыма баса-баса, сыңар тәрәзәгә үрелеп, җилкапка төбендә көтеп калдым.* А.Гыйләҗев. *Мин иптәшләрем белән хушлашып калдым, тик өйгә кермәдем, җилкапка араталарына ябышып, аны көттем.* М.Маликова. *[Ул] Авыл читендәге бик начар бер йортның җилкапкасы янындагы бүрәнәгә утырып торды.* Мирас

**ҖИЛКӘ** *и.* 1) Муенның дәвамы, арткы өлеше. *Фәйзулла агайның керле, кара җилкәсе миңа тагын да сөйкемлерәк күренә.* Ш.Камал

2) Гәүдәнең муеннан кулбашына кадәрге өске өлеше. *Хәзер аның сөйләве дә, фикер йөртүе дә ипле, төпле иде. Җилкәләре киңәя төшкән, адымы салмакланган, күзләре очкынланып янып тора иде.* М.Галәү. *Егетләр, җилкәләрен җыерып, икеләнеп кенә: – Конечно, шулай инде ул, – диештеләр.* Ә.Еники. *Гәүдәсе дә түбән таба иңә төште. Җилкәләре калтыранды, ул елый иде.* Казан утлары

3) Гәүдәнең муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы ягы, арка. *Бала, өйгә ят кешеләр килеп кергәч, курка калды һәм җәһәт кенә идәннән сикереп торды да --- хатынның җилкәсе артына яшеренде.* М.Галәү. *– Тыңламаса нишли? – Тыңламаса, теге кәрлә моның җилкәсенә сикереп менә дә тукмый.* Ә.Фәйзи. *[Солтан] Элек ел буе чирдән айнымый торган йомшак кына кеше иде, хәзер, әнә, арка-җилкәгә дә киңәеп, күз карашлары да үткенләнгән кебек күренә.* Г.Бәширов // Сырт, арканың өсте (хайваннарда). *Батыр егет, атың җилкәсендә Көннәр буе инде киләсең.* Һ.Такташ

4) Гәүдәдә ике кулбаш арасы. *Мөршидә, урындык аркасында эленеп торган мамык шәлен алып, җилкәсенә сала.* Р.Ишморат

5) Өс киеменең шул урынга туры килгән өлеше. *Киемнең җилкәсе тузган*

6) *күч.* Кемнең дә булса тәрбиясендә булу. *[Хәйретдин] Тормышның авырлыгын әнисе җилкәсеннән күбрәк үз җилкәсенә күчереп, үзе төпкә җигелергә уйлый.* М.Гали

7) *күч.* Кемнеңдер хезмәте, көче. *Җыеп кына әйткәндә, дәүләткә икмәк тапшыру озын кыш буена да барды. Боларның һәммәсе дә хатыннар җилкәсенә төште.* Мәдәни җомга

8) *күч.* Таяныч, терәк. *[Майпәрвәз] Идиятне яратмаган да, яратырга тырышып та карамаган. Аңа бары Идиятнең җилкәсе кирәк булган.* Ә.Еники

◊ **Җилкәгә алу** Өскә бурыч, җаваплылык йөкләү. *Планны йөз илле процентка арттырып үтәргә дип, үзең җилкәгә йөкләмә алдың бит. Хәзер нигә чыгымлыйсың? Үтә!* Совет әдәбияты. **Җилкәгә менеп атлану (атландыру)** Кемнең дә булса көченнән файдалану; үзеңне кеше өстенә салу. *Бала-чаганы җилкәгә атландырыр хәл юк әле. Тапканнар ата-бабадан килмәгәнне.* К.Әмири. **Җилкәгә төшү** Берәр эш, җаваплылык, бурыч кемнең дә булса карамагына калу. *Әмма, көтмәгәндә, әтисе үлеп китте ---. Ярдәм итәр кешесе юк. Тормышның бөтен авырлыгы тол хатынга һәм ике өлкән кызы җилкәсенә төште.* М.Галәү. **Җилкәдән (тау) төшү** 1) Авыр, җаваплы эштән котылу; 2) Бер-бер йөкләмәне үтәү, башкарып, җиренә җиткерү; бурыч үтәлү; 3) Мәшәкатьтән котылу. *Килеп җитеп, авыр, юеш капчыкларны салып ташлагач, җилкәләреннән тау төшкән кебек, рәхәтләнеп калдылар.* И.Гази. **Җилкә(сен)дә утыру** Кемнең дә булса хисабына яшәү. **Җилкә кашу** 1) Үкенү. *[Байбәтчәләр] Яше унҗидегә җиткәч, бильярд уйный башлыйлар, бер-ике йөз сум оттыргач, җилкәсене кашыйлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Малаен башта үзе узындыра. Хәзер атасы җилкәсен бик кашый, бик үкенә дә бит...* Г.Гомәр; 2) Аптырау, нишләргә белмәү. *Бу бүре нәкъ дүрт сарыкны алды, урынына ташып, бу көтү көткән малай да калды, җилкәсен кашып.* Н.Исәнбәт.

*Беравык җилкәсен кашып тора да, артельчеләргә карап, учын-учка бәреп чапылдатып куя: – Әйдә, ярар. Сез дигәнчә булыр.* Ф.Хөсни; 3) Кыйнау, бәргәләп алу. – *Ул малай бик узынды, җилкәсен кашып алырга кирәк булыр бераз. – Ул чыккан арада, Фәтхетдин шәкерт, шүрлектән тал чыбыгы алып, шаярып утырган малайларның җилкәләрен дә кашып алды.* М.Гали. **Җилкә кимереп яту** 1) Кем исәбенә булса да яшәү. *Димәк, эш кирәк. Әти-әни җилкәсен кимереп, күпме ятарга мөмкин?* А.Гыйләҗев; 2) Кемгә дә булса баш булып алу, өстенлек итү. **Җилкә кочтыру** Җилкәгә атландырып күтәрү. **Җилкәсе калын** 1) Артында малы, дәүләте җитәрлек, хәлле, бай. *Зыян юк, аның җилкәсен кимерсәң дә ярый. Җилкәсе калын әле.* Н.Исәнбәт; 2) Һичнәрсәгә исе китми торган, ваемсыз. **Җилкәсенә (берне) тамызу (кундыру, бирү)** *к.* **җилкә тамырына тамызу**. *Яшь мөдәррис, янындагы таякны алып, тегенең җилкәсенә берне тамызып алмасынмы!* Ә.Фәйзи. **Җилкәсе чиләнү** Эшли-эшли, тәмам җәфалану. **Җилкәсе чокыр** Эштән качарга бик оста, һәрвакыт, берәр хәйлә табып, читтә кала торган. **Җилкә симертеп яту** Эшләмичә, кемнеңдер исәбенә яшәү. *Малаен карасын, җилкә симертеп ятмасын.* А.Гыйләҗев. **Җилкә тамырына тамызу (бирү, кундыру)** Бик ныгытып сугу, кыйнау

**ҖИЛКӘЛӘ́Ү** *ф. сир.* **1.** Җилкәгә куеп күтәрү, җилкәдә күтәреп алып бару. *Зур кыз көянтә белән су җилкәләгән.* М.Фәйзи. *Чишмәдән кувшин белән су җилкәләп кайтып килгән татар кызлары --- минем өчен һәммәсе ят, кызык, күңелле.* М.Фәйзи

**2. җилкәләп** *рәв. мәгъ. сөйл.* Җилкәдән тотып, җилкәдән эләктереп. *Минем юньсез, мәгънәсез, миһербансыз кызыйга чынлап ачуым кабарды ---. Әгәр очратсам, валлаһи дип әйтәм, ул кызыйны, җилкәләп, ярга кумакчы идем.* Ә.Еники

◊ **Җилкәләп чыгару (озату)** Тупас рәвештә этеп-төртеп чыгару, китәргә мәҗбүр итү. *Кунак артык узынса, җилкәләп озаталар.* Мәкаль

**ҖИЛКӘЛЕК** *и.* 1) Камыт агачын җилкә өстеннән беркеткән бау

2) Камытның эчке ягындагы киез аслык

3) *этн.* Җилкәгә чәч толымы өстеннән тага торган тәңкә, мәрҗәннәр асып, чуклап ясалган хатын-кыз бизәнчеге. *Кияүдәге хатын-кызларның баш киемнәре комплексы мәләнчек, сүрәкә, җилкәлек һәм яулык сыман бөркәнчектән торган.* Н.Максимов

**ҖИЛКӘН** *и.* 1) Көймәне, корабны җил көче белән хәрәкәткә китерү өчен, мачтага беркетелә торган махсус тукыма. *Бу кыпчак кабиләсенең урамыннан исән-сау үтеп, сәүдәгәрләр, җилкәннәрен киереп, ишкәкләрен салмак кына салып, Идел белән өскә күтәрелеп киттеләр.* Г.Гобәйдуллин. *Кораблар, җилкәннәрен җилпеп, хәерле юл теләп калды сыман.* М.Маликова. *Яр буена килеп туктаган корабларда төрле-төрле җилкәннәр күрергә була.* М.Хәбибуллин

2) Җилкәнле көймә. *Каекчы карт, тыңла сүземне, Җилкән белән озат кызымны.* М.Җәлил

3) *бот.* Борчак үсемлегендә югарыда урнашкан таҗ яфракчыгы. *[Борчактагы] Таҗ яфракчыкларының һәркайсының үзенә хас исеме бар. Югарыда таҗ яфракчыгы – җилкән, бергә тоташып үскән түбәнге ике яфракчык көймәчек --- дип атала.* Ботаника

4) *күч.* Таяныч, терәк, канат. *Дулкын ярып йөзәр өчен, Җилкән биргән ул [җир ана] миңа.* Ә.Ерикәй

**ҖИЛКӘНЛЕ** *с.* Җилкән белән хәрәкәт итә торган, җилкән куелган. *Кемнәрнең иңнәренә кулларны салырга икән? Җилкәнле ялгыз көймәмә кемне алырга икән?* Р.Фәйзуллин. *Казан янында – Адмиралтействода – рус флоты өчен җилкәнле суднолар төзегәннәр.* И.Рәхимов, К.Ибраһимова. *Яктырып килгән һавада ике биек багана өстенә куелган җилкәнле ике кораб күрде ул.* М.Маликова

**ҖИЛКӘНЛЕК** *и.***1.** Калын тупас киндер тукыма; *русчасы:* **парусина**

**2.** *с. мәгъ.* Җилкән ясарга яраклы. *Әлбәттә, әлегә көймәнең җилкәне юк, ләкин мачтасы әзер, һәм Нургали абый җилкәнлек материал да вәгъдә иткән иде.* А.Тимергалин

**ҖИЛКӘНЧЕ** *и. махс.* Җилкән белән идарә итүче кеше

**ҖИЛКӘ́ ТАМЫРЫ** *и. анат.* 1) Җилкә аша үтә торган калын нерв тамыры

2) Муен, муенның арткы ягы. *Җилкә тамырың сыекланса, язмыш һәрчак сине тар юлга кертеп сыный, аның ирегенә биреләсең икән – беттең...* А.Гыйләҗев

**ҖИЛКЕНДЕРҮ** *ф.* 1) Дәртләндерү, ашкындыру; нәрсәгә дә булса омтылу хисе тудыру. *Йөрәкләрне җилкендерсен тальянның көмеш чыңы.* Җыр. *Бөтен авылның диярлек бу спектакльне кызыксынып көтүе безнең болай да канатланган йөрәкләребезне җилкендерә.* М.Әмир. *Кызның күз очлары белән генә көлемсерәп, тып-тып басып йөрүе аның күңелен җилкендерә иде.* Мирас

2) Хис уяту, нинди дә булса эшхәрәкәткә кузгату. *Әгәр дә шушы гомеремдә үземне бәхетле итеп санаган вакытларымның хатирәләре --- йөрәкне аз гына җилкендереп, яшәртеп җибәрмәгән булса, мин гомеремдә моны язарга утырмаган булыр идем.* Гали Рәхим

**Җилкендереп алу** Бераз җилкендерү; беркадәр җилкенгән хәлгә китерү. *Шуннан соң Әхмәй, өстәл янындагы карават астыннан курай алып, кунагына күрсәтте: – Монысына да каршы килмисездер, – дип, ихлас елмайды. – Күңелләрне азрак җилкендереп алыйк.* Мирас

**Җилкендереп җибәрү** Кинәт җилкендерү, җилкенүгә этәргеч бирү. *Катя үзенең сораулары белән аның яшь күңелен җилкендереп җибәрде.* Г.Әпсәләмов. --- *яңгырга изелеп яткан күңелне бүгенге кояш тыеп булмас көч белән җилкендереп җибәрде.* Х.Сарьян

**Җилкендереп тору** Даими, һәрвакыт җилкендерү

**ҖИЛКЕНҮ** *ф.* **1.** 1) Дәртләнеп китү, ашкыну, күңел иләсләнү. *Ике ялкын бергә тоташып, Ике йөрәк бергә җилкенде.* М.Җәлил. *Ак, шома тула оеклар, шыгырдап торган яңа чаба-*

*талар киеп, чулпыларын чылтыратып урамнардан үткәндә, бер генә егетнең йөрәге җилкенмәгәндер.* М.Маликова. *Локман карт боларның барысын да күрмичә һәм, күреп, зәгыйфь йөрәге белән җилкенмичә кала алмады.* Ә.Еники

2) Бар көчкә тырышу, бирелеп эшләү. – *Юк! – диде Хәлим, ләкин үзе соңгы көче белән җилкенә иде инде.* И.Гази

3) Канат кагып очарга омтылу, җилпенү. *Бәпкәләрен саклап, ак каз Миңа таба килә, җилкенә.* М.Җәлил

4) Тынычсызлану, борчылу

5) *күч.* Нинди дә булса эшкә омтылу, берәр нәрсә эшләргә теләк барлыкка килү. *Тукта, чү, шунда якында әллә нәрсә селкенә, – Бетте уй, инде песинең ауга күңеле җилкенә.* Г.Тукай. *Аңарда көч җилкенә: Дошманын җиңгәч кенә.* Ф.Кәрим. *Корбангали абзый үзендә кинәт яңа бер җилкенү сизде, сикереп торып, чанасын янә кузгатып алып китте.* Ф.Хөсни

**2. җилкенеп** *рәв. мәгъ.* Сөенеп, күтәренке дәрт белән, күңел күтәренкелеге белән. *Җилкенеп, уйнап, сөеп эшли Миңнурый.* Г.Әпсәләмов. *Кояшны бар табигать шатланып, җилкенеп каршы алды.* Х.Сарьян

**Җилкенә бару** Торган саен күбрәк җилкенү. *Вальслар шундый инде алар: биегән саен, син тизрәк әйләнә, дәртләнә, җилкенә барасың, кәефең, рухың күтәрелә.* Ә.Салах

**Җилкенә башлау** Җилкенергә тотыну. *Өшкерүчеләр Галимә апаның битенә япкан юрганын тартып ачтылар. Шуннан соң Галимә апа тагын җилкенә башлады.* М.Гафури. *Марсельнең бу җәегетлеген күреп, Ахунов та җилкенә башлый, ул кинәт сикереп торып кычкыра ---.* Р.Батулла

**Җилкенә төшү** Бераз җилкенү; беркадәр җилкенү күрсәтү

**Җилкенеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә, бераз җилкенү. *Элегрәк тә ул шулай, дулап, бер җилкенеп алыр иде дә, әкренләп басылып, күңеле яңадан үз урынына утырыр иде.* М.Хәсәнов

**Җилкенеп йөрү** Күптәннән, озак вакытлар дәвамында җилкенү. *Күп кенә студентлар аның аэродинамика клубын оештыру өчен җилкенеп йөрүләрен дә онытмаганнар икән.* Ф.Сафин

**Җилкенеп китү** Кинәт җилкенә башлау. *Ул, хәтта, бервакытны җилкенеп китеп, Казанда басылган төркичә география китабы да алган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *[Шәйхаттар:] «Шәһәр» дигәч инде, минем үземнең дә йөрәк җилкенеп китә.* Г.Толымбай. *Ринат җилкенеп үк китте. Минем белән күптәнге танышы күк сөйләшә башлады.* Г.Бакиров

**Җилкенеп кую** Беркадәр вакыт җилкенү хисе кичерү, бераз җилкенү. *Кайбер тиз ышанучан мөһаҗирләр, чыннан да, күңелләре белән җилкенеп куйгандай булдылар.* М.Галәү. *Нәгыймә күп уйланды. Ара-тирә йөрәге җилкенеп-җилкенеп куйды.* Г.Ибраһимов

**Җилкенеп тору** Һәрвакыт, гел җилкенү

**ҖИЛКЕНЧӘК** *с.* **1.** 1) Ашкынып, дәртләнеп торган. *Миңа көрәш кирәк иде, тыныч тормышта оерга минем җилкенчәк йөрәгем риза түгел иде.* М.Максуд. *Яшь җилкенчәк чаклар бар иде*

2) Тиз кызып китүчән, ярсу. *Җилкенчәк табигатьле кеше*

**2.** *и. мәгъ.* Ярсу табигатьле яшь кеше. *[Биктимер карт:] Юк, балам, юк, безнең заманда сызгыру юк иде, аны хәзерге яшь җилкенчәк уйлап чыгарды.* Н.Исәнбәт

**ҖИЛКЕНЧӘКЛЕК** *и.* 1) Ашкынып, дәртләнеп, җилкенеп тору

2) Тиз кызып китүчәнлек

**ҖИЛКЕТҮ** *ф.* 1) *к.* **җилкендерү**. *Бу бабайның сүзләре күптән инде минем йөрәгемне җилкеткән иде.* Т.Гыйззәт. *Кайчандыр күңелне җилкеткән максатлар, омтылышлар беренче сикәлтәдә үк төшеп калдылар.* Мирас

2) Ярсыту, торгынлык хәленнән чыгару. *Мулла, сине бит сыйпап, көртлек маена манып җыйган байлык җилкетә.* Х.Кәрим

3) Кыздыру, ачуын кабарту, котырту. *Бәлки, ярлылыгыннан аптырагач, шайтан җилкеткәндер инде.* Г.Камал

**Җилкетә бару** Торган саен ныграк җилкетү

**Җилкетеп алу** Кыска вакыт эчендә җилкетү; берара җилкетү. *Үзенең арзанлы ситса күлмәге, йомшак, ягымлы карашы, татар кызларына хас мөлаем сабыр тыйнаклыгы белән ул Сабитның күңелен җилкетеп алды.* А.Гыйләҗев

**Җилкетеп җибәрү** Кинәт җилкетә башлау. *[Карт:] Һи, сез, яшьләр, минем карт йөрәкне дә җилкетеп җибәрдегез. Мин дә биим әле.* Г.Камал. *Ничек итеп халыкны кузгатырга, ничек аны җилкетеп җибәрергә?!* Г.Бәширов

**Җилкетеп тору** Даими, һәрвакыт җилкетү. *Без алар [дәрья суларының] агышын җиңеп, үзебезне җилкетеп торган күксел томанга – аръякка, аръяктан да арыракка таба йөзәбез.* Ә.Баян

**ҖИЛКУАР** *и.* 1) Төпле фикере, рәтле эше һәм яшәү урыны булмаган, һәрнәрсәгә өстән, җиңел генә карап яши торган кеше. *Без әрәмтамаклар тәрбиялибез, җилкуарлар.* Г.Ахунов. *Дөрес инде: шундый чибәр, булган хатынга дуга белән печән чабып йөрүче җилкуар ни пычагыма?* М.Мәһдиев

2) Җилбәзәк, җиңел холыклы кеше. *Ахрысы, ул безнең яхшы ниятле Сәфәргалине этләр котыртып йөрүче берәр җилкуар бәндә дип белде булса кирәк.* Ф.Хөсни

**ҖИЛКУАРЛАНУ** *ф.* Җиңел холыклыга әйләнү, үзен җилбәзәкләрчә тоту. *Башта яшь хуҗа, әтисе шикелле, базардан-базарга йөреп, алыш-биреш белән шөгыльләнергә дәртләнсә дә, нияте барып чыкмады, җилкуарланып, ярты ел чамасы йөргәч, аннары тынды...* Ф.Мансуров

**ҖИЛКҮРСӘТКЕЧ** *и.* Җилнең юнәлешен билгеле торган махсус прибор; флюгер

**ҖИЛЛӘВЕЧ** *и. сир. к.* **җилләткеч**. *Фазылның ябык паспортын җилләвеч итеп, болай да салкынча вагон эчендә үзенең янып торган бит алмасын җилләтә башлады.* К.Кәримов. *Йотайота курган тузаннарын, Җилләвечләр выжлап әйләнә.* М.Крыймов

**ҖИЛЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) *к.* **җилләтү**. *Кызу кояш астында барган эш белән арып яндылар ---. Ирләр изүләрен чишеп җибәрделәр, хатыннар минут саен йөзләреннән аккан тирләрен яулыклары белән сөртеп, күлмәкләрен җилләндерделәр.* Г.Ибраһимов

2) *к.* **җилкендерү**

**Җилләндереп утыру** Әле, хәзер җилләндерү. *Гөлшаһидә, утка салган кебек эсселәп, кулъяулыгы белән йөзен җилләндереп утырды.* Г.Әпсәләмов

**ҖИЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Җил исеп тору, җил чыгу. *Җир-күк – һәммәсе, югарыда җилләнеп, дулкынланып, тау-тау җимерелеп аккан болытлар астында караңгы төскә чумдылар.* Г.Ибраһимов. *Атна буе җилләнеп, шактый кар яуганнан соң, кинәт суытып җибәрде.* Казан утлары

2) Җилдә торып, эсселекне киметү, җилдән җиләслек алу. *Әти, бераз җилләнгәннән соң, йөгән тезгенен дугага бәйләде.* Г.Бәширов. *Ат бераз җилләнсен, суны соңыннан эчерерсез*

3) Җилпәзә, кулъяулык һ.б.ны җилпеп, җил хасил итү. *Кулъяулыкларын селкеп-селкеп җилләнәләр, һаман китәргә уйламыйлар.* Ш.Камал

4) Җил тәэсирендә чайкалып хәрәкәткә килү. *Мин урманны күптән күргәнем юк. Ул җилләнеп шаулый торгандыр.* М.Җәлил

5) Тизлекне арттыру, йөрешне тизләтү. *Үзенең җөббәсе белән җилләнеп, тагы түземсез кызу кан белән Гали хәзрәт килеп чыга да шәкерт дулкынының үзгәнә – җыелыш залы алдына ташлана.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Нинди дә булса эшне ашкынып башкару

7) *күч. сөйл.* Гайрәтләнү, гайрәт күрсәтү, кәпрәю. *Фетнәдә башлык кылган, теге күкрәге калайлы Хәйрулла староста үзалдына җилләнде, --- котырган тавыш белән: – Нәрсә катып торасыз, әйдәгез! – дип акырды.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Ашыгып, кызуланып. *Ишек ачылды, җилләнеп, һаваны хушбуйга тутырып, курсистка Разия туташ килеп керде.* Г.Ибраһимов. *[Һади Такташ] Җилләнеп килеп керде дә, җилкәгә кулын куеп: «Сиңа концертта сөйләргә бер шигырь яздым бит әле, Сәлимҗан», – диде.* Казан утлары

**Җилләнә башлау** Җилләнергә тотыну. *[Хаҗи] Күлмәк изүен чишеп, җилләнә башлый.* Ш.Камал. *Бу генерал зерә теңкәгә тиде. Ну, минәйтәм, бик җилләнәсез, генерал, без җилләнә башласак, нишләрсез икән.* Г.Әпсәләмов

**Җилләнеп алу** Беркадәр, бераз җилләнү; берара җилләнү. *[Кыз] Тәмле хушбуй исе сеңгән кулъяулыгы белән бераз җилләнеп алды.* Ф.Яруллин

**Җилләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта җилләнү

**Җилләнеп китү** Кинәт җилләнә башлау. *Талия бик җилләнергә дип килсә дә, вакыты-вакыты белән җилләнеп китәргә әзер торса да, Гәүһәр аны коралсызландыра барды.* Г.Әпсәләмов

**Җилләнеп тору** Бертуктаусыз җилләнү. *Юеш һәм бигрәк тә шыта башлаган орлыкларга караганда азрак суласалар да, коры орлыклар өчен бинаның даими җилләнеп торуы кирәк.* Ботаника

**ҖИЛЛӘТКЕЧ** *и.* 1) *сөйл. к.* **җилпәзә**

2) Һава агымы барлыкка китереп, үз күчәрендә әйләнеп торган калаклы махсус җиһаз; кондиционер. *Өстәлдә иеләсыгыла эшләп утырган җилләткеч булуга да карамастан, бүлмәдә гаять бөркү иде.* Ш.Шәйдуллин

**ҖИЛЛӘТҮ** *ф.* 1) Җил агымы белән һаваны сафландыру, һава алмаштыру. *Вакыт бетеп килә, икенче сеанс өчен залны җилләтеп өлгерәсе --- бар иде.* К.Кәримов. *Тик бүлмәне кырык кат җилләтеп, ни ашаганыңны яшерергә тырышсаң да, фатир ишеген ачып керүгә [әни]: – Тагын шул [«Доширак»] токмачын ашаган! Ашказаныңны бетерәсең инде, – дип сукрана.* А.Әхмәтгалиева

2) Җиләсләндерү, җил хасил итү. *--- әнә берсе тунын, салып, ишек башына ташлаган, әнә тагын сәнәк тоткан бер агай, бүреген күтәреп-күтәреп, башын җилләтә...* Ә.Еники

3) Җилле урынга куеп дымын бетерү яки кирәкмәгән чүпләрдән арындыру. *– Тышта матур, Сәмәрия апа. Әйдә, һава суларсың, чыгыйк. Урын-җиреңне дә җилләтеп киптерик.* Н.Гыйматдинова. *--- рәешкә асраган кием-салымын базарга илтсә дә, зәңгәр күлмәген бик кадерләп саклады. Ел саен яз да, көз дә җилләтеп алып керде.* А.Гыйләҗев. *Йөрәк аша үткән вакыйгаларның --- кирәкмәстәйләре, орлык җилләткәндә очкан кибәк кебек, барыбер онытылып бетә.* Казан утлары

4) Җилфердәтү, җилфер-җилфер китерү. *Шундый бер шатлык белән, ак беләкне сызганып, алъяпкычны җилләтеп, аш әзерләшә.* Г.Ибраһимов. *Мондый сүзләргә Сәхипҗамал карчыкның да күңеле җилкенеп китте: – Әйдә, булмаса, карт, бер җилләтеп апкайт, – дип, бишеккә менеп утырды.* Ф.Яруллин

**Җилләтә башлау** Җилләтергә тотыну. *Фазылның ябык паспортын җилләвеч итеп, болай да салкынча вагон эчендә үзенең янып торган бит алмасын җилләтә башлады.* К.Кәримов

**Җилләтә төшү** Беркадәр, бераз җилләтү. *Киемнәрне җилләтә төшү*

**Җилләтеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә җилләтү. *– Тәрәзәне ачарга иде, – диде Гаяз. – Без чыккач, ачып, җилләтеп ал әле, – диде юаны.* Х.Сарьян

**Җилләтеп тору** Һәрвакыт җилләтү. *--- ике тау арасында йөргәндә, без инде Хаҗәр анабыз кебек кояшта пешмәдек, һаваны вентиляторлар җилләтеп торды.* Ф.Мөслимова

**ҖИЛЛӘҮ** *ф.* 1) Җиле булу, җил чыгу. *Бүген дә җилли, давыллый, Һавада циклон бугай.* Х.Туфан. *Августның соңгы якшәмбесе бик матур килде: элек кичтән шактый җилләп, төнлә яңгыр ява башласа да, иртән тагын аязып җибәрде.* Ә.Еники

2) Җилдә кибү, сурыгу, дымы бетү. *Абзар артларында киртәдән үрәчәләп әвеннәр куелган, монда эт эчәгесе, билчән катыш бәрәңге сабагы җилли...* М.Мәһдиев. *[Сәфәргали] Бу хәлендә кайтып керсә, өйдә ничек каршы алачакларын чамалый, шуңа күрә, өс-башы җилләгәнче, шушы тирәдә чуалуны артыграк күрә иде. Әмма, җилләү урынына, бишмәт итәге минуттан-минутка шакаеп ката барды.* Ф.Хөсни. *Әле мин яңгырдан соң җилләп каткан сукмак белән койма буйлап кына, --- кайтып киләм.* Х.Сарьян

3) *к.* **җилләтү** (*2 мәгъ.*). *Җәйгә чыксаң, җилләр өчен, Җәй киләткә урыныңны.* Җыр

4) Җилдәй җитез булу, хәрәкәтендә көч сизелеп тору. *Җәй булса да, төннәр салкынча. Вагоннар һаваны*

*ерып, җилләп бара.* М.Маликова. *Вәли, җилләп, туп-туры ишектән үтте.* Н.Хәсәнов

5) Җилгә җилфердәү, җилдә тирбәлү. *Җилләп кибә керләр кер бауларда.* Р.Мингалим

6) *куч.* Күңел ачу, иркенгә, хозурга чыгу

**Җилләп алу** Бераз җилләү. *Әз генә явып алды да Әз генә җилләп алды. Өстән коеп тормаса да, Эшләр бүленеп калды.* К.Булатова

**Җилләп бетү** Ахыргача, тәмам җилләү. *Көек исенең әле һаман җилләп беткәне юк.* Р.Шәрипова

**Җилләп йөрү** Әле, хәзерге вакытта җилләү. *Яңгыр җиле!.. Җилләп йөрсен иде, Дер селкетсен иде дөньясын!* Э.Шәрифуллина

**Җилләп тору** 1) Һәрвакыт, бертуктаусыз җилләү. *Кичтән үк давыллап, җилләп торды.* Ф.Бәйрәмова

2) Бераз, берникадәр җилләү. *Тышта яңгыр сибәли, җилләп тора иде.* Р.Гаффар

**Җилләп утыру** Җил эчендә калу. *Бакча артындагы тау башында Җилләп утыра ап-ак кылганнар.* Г.Рәхим

**Җилли бару** Артыннан ук җилләү. *Җылы кояш нурлары астында [бәрәңгенең] шундук җилли барганнарын хатыны Сәрия талчыбыктан матур итеп Газинур үзе үргән кәрҗиннәргә җыя бара.* А.Хәсәнов

**Җилли башлау** Җилләргә тотыну. *Бик хәтәр җилли башлаган, һәм кояш баешы ягыннан, ярты күкне иңләп, каракучкыл, аксыл болытлар күтәрелеп килә.* В.Нуруллин

**Җилли төшү** 1) Беркадәр, бераз җилләү. *Аяк асты да җилли төшкән.* Н.Әхмәдиев

2) Җилдә бераз кибү

**ҖИЛЛЕ** *с.* **1.** 1) Җил исеп торган, җиле көчле булган. *Көз үзенә алмашка кышны чакырды. Октябрь азагында ук чамасыз җилле, өметсез салкыннар башланды.* А.Гыйләҗев. *Бүген беренче мәртәбә көн язгыча түгел: ямьсез, нәкъ көзге төн төсле, җилле, вак кына яңгыр явар-яумас маташа иде.* Гали Рәхим. *Разведчик кортлар көннең җилле булуын һәм турыдан-туры очарга мөмкин түгеллеген умартага килеп хәбәр итәләр...* И.Халифман

2) Җил белән аралаш, катнаш булган. *Таулар, яланнар, урманнар аша-сыннан шәһәр өстенә таба каты давыллы, җилле яңгырлар ишерелеп киләләр.* Г.Ибраһимов

3) Үтәли җил йөргән. *Җилле урын*

4) *куч.* Тынгысыз, ярсу йөрәкле, ашкынып торган. *Тормыш никадәр җилле, дулкынлы булса, аның көзгесе булган әдәбият та шулкадәр рухлы, шулкадәр күренешле була.* Җ.Вәлиди. *Поэзиягә җилле, давыллы, дәртле романтик буларак бәреп кергән --- Илдар Юзеев халыкны нәкъ шуның киресенә үгетләү юлына баса...* Т.Галиуллин

5) *куч.* Житез, булдыклы, эшлекле. *Шулай да мин әлеге фикер алышуда читтән, --- башка шәһәрдән килгән кеше идем һәм бу җилле, туфанлы, киеренке бәхәсләргә елмаеп-көлеп бәя бирә алдым.* Т.Галиуллин. *Сугышка кадәр, җилле атлар, җилле ирләр барда, урманны да бик ерактан кисеп кайтаралар иде.* Х.Сарьян. *Заһидуллин абый, бик җилле, эшлекле кеше булуы өстенә, бик кыю-куркусыз да булып чыкты.* Казан утлары

6) *куч.* Менә дигән, шәп. *Өченче бер стражник, идәнгә бөгелеп, шомарак, сыгылмалырак һәм суккан чакта сызгырып төшәрлегрәк җилле чыбык сайлый иде.* М.Галәү. *Рәйсәләрнең бик җилле магнитофоннары бар иде, бергәләп, шуны уйнаттылар.* Ф.Яруллин. *Казакның кымызы җилле иде.* А.Расих

7) *куч.* Әдәп кагыйдәләренә сыймый торган, оятсыз. *Командир чын диңгезчеләрчә җилле генә сүгенеп алды.* М.Юныс. *Безнең халыкның, машина тәрәзәсен ачып, «җилле» җөмләләр белән сөйләшергә маһирлыгын исәпкә алганда, юл төзекләндерүчеләрнең мәшәкатьле эше тулаем күз алдына килеп баса.* Шәһри Казан

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Яхшы итеп, шәп итеп. *Шундый җилле тибә ки, теге әзмәвер өйалды баскычыннан мәтәлеп төшә...* Р.Фәизов. *Кара, кара, нинди җилле кундырды!* М.Фәйзи

2) Тиз, шәп. *Әмиргә атын китерделәр, ул җилле генә, сикереп, атына атланды.* М.Хәбибуллин. *Кабан күле буенда чатырлар күренгәч, Сөембикә атын җилле генә юрттырып алып китте.* Мирас

**3.** *хәб. функ.* Нинди дә булса эшкә кулы ятыш булу. *Балта эшенә аның кулы җилле*

**ҖИЛЛЕ-БУРАНЛЫ** *с.* 1) Җиле һәм бураны булган. *Һади Такташның туган авылына барган көнне җилле-буранлы кыш иде.* И.Юзеев

2) *куч.* Ялкынлы, кайнар, көчле. *Тора-бара, аларның яшь йөрәкләрендәге ялкынлы, дәртле һәм берникадәр җилле-буранлы мәхәббәтләре бер-берсенә гадәтләнү көче белән гадиләшкәч, тормышлары көйләнде.* Г.Минский

**ҖИЛЛЕ-ДАВЫЛЛЫ** *с. к.* **җилдавыллы**. *Ә кем белә, бәлки, сизгәннәрдер дә, күргәннәрдер дә, тик соңыннан онытканнардыр, җилле-давыллы, канлы өермәле хәтәр заман иде бит.* М.Кәбиров

**ҖИЛЛЕК** *и.* 1) Җил йөрсен өчен махсус ясалган тишек. *Зәйнәгытдин бичара, теше-тешкә бәрелеп, өй астының җиллек тишегеннән моны тыңлап ята һәм белә: бетте, мәсьәлә хәл ителде.* М.Мәһдиев

2) Чормадагы уемтык. *Җиллектән карау*

3) *диал. к.* **җилгәргеч**. *Ашлыкны җиллек белән җилләтеп амбарга салалар*

**ҖИЛЛЕ-КОЯШЛЫ** *с.* Җиле һәм кояшы булган. --- *түшәк-ястыкларны җилле-кояшлы көннәрдә киптереп кенә торырлар иде.* А.Гыйләҗев

**ҖИЛЛЕЛЕК** *и.* Җилле булу, җил исеп тору; җилнең көчлелек дәрәҗәсе. *Көннең җиллелеге*

**ҖИЛМАЯ** *и.* 1) Тиз йөрешле, чапкыр дөя

2) *миф.* Канатлы ат

**ҖИЛПӘВЕЧ** *и.* 1) *к.* **җилпәзә** (*1 мәгъ.*). *[Ата көртлек] Зәңгәрсу кара койрыкларын җилпәвечтәй тырпайтып, өскә тарттыра.* Г.Хәсәнов. *Кинәт тимер юл буенда көчле шартлау гөрселдәде. Күккә, җилпәвеч канатларын хәтерләтеп, ялкын бөркелде.* Ш.Рәкыйпов

2) *к.* **җилләткеч**. *Типография залы уртасында басу машинасыннан бер-*

*бер артлы, җилпәвеч канатларыдай булып, яңа елның беренче көне газеталары чыгып тора.* Г.Минский

**ҖИЛПӘГЕЧ** *и. к.* **җилпәзә** (*1 мәгъ.*). *[Кешеләр] Еш-еш сулыйлар, кульяулыкларын җилпәгеч итеп, кызарган йөзләренә һава «сибәләр».* М.Шәрифуллин

**ҖИЛПӘЗӘ** *и.* 1) Ясалма җил булдыру өчен кулланыла торган ярым түгәрәк формасындагы зиннәтле әйбер; *русчасы:* **веер**, **опахало**. *Татарстан Сынлы сәнгать музеенда җилпәзәләр күргәзмәсе оештырылды.* Мәдәни җомга

2) Кошларда: каурый сабының бер ягына рәттән урнашкан йоннар. *Контур каурый тар гына каты үзәктән – саптан һәм аның як-ягындагы киң, йомшак җилпәзәдән тора. Каурыйның җилпәзәсен саптан үсеп чыккан бик нечкә, куе мөгезчел йон бөртекләре челтәре тәшкил итә.* Биология

3) *бот.* Кайбер үсемлек орлыкларының очып таралуына ярдәм итә торган җиңел канатчыклар. *Ике саплы җилпәзәсенә ябышып, өрәңге орлыклары очып йөри.* М.Мәһдиев

**ҖИЛПӘЗӘЛЕ** *с.* Җилпәзә формасындагы, җилпәзәгә охшаган. *Тагын да эчтәрәк, өч-дүрт метр озынлыкка сикереп, җилпәзәле камыш җәелә.* М.Хәсәнов. *Кояш бераз кызурак итеп карый башлау белән, Көмешле күлнең сайрак урыннарында җилпәзәле камыш баш калкыта башлый.* Г.Галиев

**ҖИЛПЕНҮ** *ф.* 1) Канат кагу; талпыну, очып китәргә омтылу. *Чыпчык шундук җилпенеп очып киткән.* Әкият. *Канатлары ныгый башлауга, кошчыклар да җилпенәләр, тар оядан иркен, очсыз-кырыйсыз күккә талпыналар.* И.Салахов

2) Нәрсә дә булса эшләргә тырышу, берәр хәрәкәт ясау. *Сәлим, биек кузлага салган юан бүрәнә өстендә, канатларын җәйгән бөркет шикелле, җилпенеп-җилпенеп, пычкыны салмак кына йөрткәндә, Вәли астан әтисенә булыша.* М.Галәү. *Кулындагы каурый каләм дә, очарга җыенган кош кебек, бер талпынып ала. Берара туктап кала, шунда ук, җилпенеп, тагын кузгала.* М.Госманов

3) Җиңелчә генә җилфердәп, селкенеп тору; тибрәнү. *[Ул] Җилдә җилпенеп шытырдаган зәңгәр брезент куышы эчендә, тәбәнәк, тар прилавкасы артында басып тора.* М.Маликова. *Абзыйның кара калын кашлары сикерешеп, борын яфраклары җилпенеп, күзләре очкынланып китте.* Г.Гомәр. *Мич каршында өелгән саламда мәтәлчек атабыз, ялкын телләренең талпына-талпына җилпенүен карап, ләззәт кичерәбез.* Казан утлары

4) Кемгә яки нәрсәгә дә булса юнәлтеп, кискен кул хәрәкәте ясау. *Оркестр каршында җилпенү*

5) *күч.* Талпынып алу, күңел ашкыну, иләсләнү, хискә бирелү. *Шигырь дә бит каләм белән түгел, күңел түрендә җилпенгән былбылларның канат очы белән языла.* Казан утлары

**Җилпенә башлау** Җилпенергә тотыну. *Анда, оркестр артындагы бөтен диварны иңләп-буйлап, гүяки салават күпере калыкты, һәм ул, музыка тирбәлешенә буйсынып, җилпенә башлады.* М.Маликова

**Җилпенеп алу** Бераз, кыска вакыт эчендә җилпенү. *Белә ул, шатлыкның бик кыска вакытлы икәнен дә, икенче көн тагын дөнья куласасының басасын да белә, әмма шатланып ала, селкенеп, җилпенеп ала.* Т.Миңнуллин. *Сагышлы көйләр көйләп, Кошлар күк канат кагынып, Бер җилпенеп аласың.* Х.Касыйм

**Җилпенеп китү** Кинәт җилпенә башлау. *Мөнәвәрә аккош кебек назлана, тургайлар кебек җилпенеп китә, аңардан нәфислек, садәлек, хатын-кыз мөлаемлыгы ташый иде.* Г.Ахунов

**Җилпенеп кую** Кыска вакыт эчендә, бер тапкыр җилпенү. --- *иске бүрегенең бер колакчыны үрә катып тора; икенчесе, шиңгән әрекмән яфрагы шикелле, шәлперәеп төшкән. Атлаган саен, канат каккандай җилпенеп куя.* М.Хәсәнов

**Җилпенеп тору** Бертуктаусыз җилпенү. *Кыска пәлтәсенең төймәләре ычкынган, ул селтәнгән җайга, кыпкызыл галстугының ике очы җилпенеп тора.* Ф.Сафин

**ҖИЛПЕТҮ** *ф.* 1) Талпыну, кагыну. *Кыр казлары җылы яктан Кайтып килә тезелеп. --- Йөгерешеп, сәлам биреп, Каршылыйбыз һәр казны, Канатларында җилпетеп, Китерә алар язны.* Н.Гайсин

2) *к.* **җилфердәтү**. *Туй күлмәген җилләр җилпетә.* Т.Низами

**ҖИЛПУЧ** *и.* **1.** 1) Он салу һәм иләү өчен хезмәт итә торган, уртасы бераз колашаландырып эшләнгән җәенке агач савыт. *Бервакыт, әнигә ипи изәргә, җилпуч тутырып, он иләп куйганымны да хәтерлим.* Ф.Хөсни. *Зур җилпучы белән, йөгереп, келәткә барды, өсәктән, тутырып, арыш оны алды да аш өенә керде.* Г.Ибраһимов. *[Ир кеше] Бераздан, дәшмичә генә, чиләк белән он алып кереп, аны җилпучка сала, тау итеп, матур итеп сала.* М.Мәһдиев

2) Тегермәндә ташларны әйләндереп алган стена

**2.** *с. мәгъ.* Җилпучка охшаган, җилпуч формасындагы, зур. *Казык башы саен – кара карга, без килә башлагач, җилпуч-җилпуч канатлары белән җиргә кара күләгә коеп, каргалар төркеме кузгалды.* А.Гыйләҗев

**ҖИЛПУЧЛАНУ** *ф.* Җилпуч рәвешенә кереп, бераз чокыраю, уртасы калҗаю. *Яңгыр астында калып, куна тактасы җилпучланган*

**Җилпучлана төшү** Бераз җилпучлану

**Җилпучланып бетү** Бөтенләй, тәмам җилпучлану

**Җилпучланып калу** Җилпучланган хәлгә килү

**Җилпучланып тору** Җилпуч рәвешен алу, җилпучланган хәлдә булу

**ҖИЛПҮ** *ф.* 1) Канатны очу өчен хәрәкәтләндерү, селкү. *Әллә ничек ак каз, каң-каң --- итеп, канатларын җилпеп кагына.* М.Гафури. *Әләм уртасына канатларын зәһәр җилпеп очкан шоңкар сурәте төшерелгән.* В.Имамов

2) Талпыну, кагыну, селкеп җибәрү. *Ак тулпар, озын ялын җилпеп, муенын алга сузып, борын тишекләрен киңәйтеп очып бара...* М.Маликова. *[Кошлар] Канатларын җилпеп-җилпеп карый. Сирәгәйгән чылгыйларын саный.* Казан утлары

3) Кулга тоткан әйберне селкү, чайкау. *– Нәрсәм белән алыйм мин аларны*

*[билетларны]? – Биктимер чалбар кесәләрен җилпеп күрсәтте.* Г.Галиев. *Җилпәзәне җилпү*

4) Кискен хәрәкәт белән болгау, селтәү. *Клара, кыргыйлык һәм нәфислек кушылган хәрәкәт белән, кулларын соңгы тапкыр җилпеде.* Ә.Еники. *Бакый, кулларын җилпеп, утны сүндерергә азапланды.* М.Маликова. *Зур оя янына киләсең дә, өстенә кагылмыйча гына, кулыңны җилписең.* М.Мәһдиев

5) Җилгәрү, чүп-чарны җилгә очыру. *Җил бераз көчәюгә, Һадия әби олы капкасын ачып куйды да, җиргә ак җәймәсен җәеп, чиләктәге бодаен җилпеп җилгәрергә тотынды.* Г.Галиев

6) *күч. сөйл.* Ташлау, тондыру. *[Шәкүр] Өелеп яткан тимерләр эченнән берсен эләктереп алды да, күз иярмәслек җитезлек белән, дуңгыз тарафына җилпеде.* М.Әмир

**Җилпеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә җилпү; тиз һәм аз гына җилпү. *[Ул] Кочакларга җыенган кеше сыман, бер ихласлык белән, колачларын җилпеп алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Мәҗит, Саттарның һөҗүмен кире каккандай, сыңар кулын канат сыман җилпеп алды*. Ф.Сафин

**Җилпеп бетерү** Барысын да, тулысынча җилпү

**Җилпеп җибәрү** Кинәт җилпи башлау. *Җилпеп җибәрә кичке җил Ал чылтәр пәрдәләрне*. Ф.Кәрим

**Җилпеп кую** 1) Нәрсәне дә булса, җилпеп, әзер хәлгә китерү. *Җәймәләрне, ишегалдына алып чыгып, җилпеп куйдык*

2) Бер тапкыр җилпү хәрәкәте ясау. *Кайбер чәчәкләргә кубәләкләр ябышып сеңгәннәр дә, аерылырга теләмичә, бары канатларын гына җилпеп куялар.* Ә.Еники. *Ана казым канат җилпеп куя...* А.Хәлим

**Җилпеп тору** Бертуктаусыз җилпү. --- *көчек, шып туктап, кәкрәйгән койрыгын өскә күтәреп, әле бер якка, әле икенче якка җилпеп тора инә.* Ф.Сафин. *Җәйге челләдә, кирәкле төймәгә басуга, җиләс җил битеңә өрә. Әйтерсең сөйкемле япон кызлары синең каршыңда җилпәзәләрен җилпеп тора*. Ф.Абдуллин

**Җилпи башлау** Җилпергә тотыну. *Төшеп җитәрәк, аккошлар муеннарын аска бөктеләр, гәүдәләрен турайтып, канатларын җилгә каршы җилпи башладылар*. Г.Хәсәнов

**Җилпи төшү** Тагын да бераз җилпү

**ҖИЛСЕЗ** *с.* 1) Җил булмаган, җил исми торган, тын, тыныч. *Җилсез җылы сәгатьләрдә яшь умарта кортлары, масса күләмдә чыгып, очыш уены уздыралар.* И.Халифман. *Күк, көндезге зәңгәрлеген җуеп, карасу төскә кергән. Кич җилсез, болытсыз иде.* Х.Сарьян. *Җилсез көндә серкәләр еш кына, авызчыкларга эләкмичә, җиргә коела. Шулай итеп, җимешлекле чәчәкләрнең күбесе серкәләнмичә кала.* Ботаника

2) Җил йөрми торган, ышык. *Алмагач җилсез урынны ярата.* Г.Әпсәләмов. *Бездә сабантуйлар табигатьнең оҗмах бакчасында үтә. Авылның бер иңкү, җилсез, үтә тыныч урыны ул.* Казан утлары

**ҖИЛСЕЗЛЕК** *и.* 1) Җилсез, тыныч һава; штиль. *Көннең эссе булачагына чалт аяз күк, җилсезлек, кошларның инде хәзердән агач күләгәсендә мәш килүләре хәбәр вә дәлил иде.* Ф.Яхин

2) Җил йөрмәү, ышык булу

3) *күч.* Тынлык; тыныч вакыт. *Гаскәри-хәрби лирикадан соң «шигърият» дигән дәрьяда тынлык, салмаклык, җилсезлек чоры башланды.* Р.Батулла

**ҖИЛСЕНДЕРҮ** *ф. диал. к.* **җилләтү**. *[Хәйри] Бераз тынычлана, изүен чишеп, җилсендерә, маңгай тирләрен сөртә.* Г.Ибраһимов

**ҖИЛСЕНҮ** *ф.* Суык җил тәэсирендә аз гына шешенү, кызару. *Каты җилдән сугышчыларның битләре, куллары ярылып бетте, күз кабаклары җилсенде.* Г.Бәширов. *Кыза төшкәч, олаучының чумар кебек җилсенгән күз кабаклары ачылып китте.* Казан утлары

2) *мед.* Ялкынсынып шешү, кабару. *Бүген төндә әтиегез дөнья куйган. Үпкәсе җилсенүеннән.* Д.Вәлиев

**Җилсенә башлау** Җилсенү билгеләре күренү. *Йокысы туймаган, бите җилсенә башлаган Тотыш би, алар кергәндә, йомшак урында ята иде.* Н.Фәттах

**Җилсенә төшү** Беркадәр, бераз җилсенү; аз гына шешенеп китү. *Бите җилсенә төшкән*

**Җилсенеп тору** Һаман, еш җилсенү

**ҖИЛСЕТҮ** *ф.* 1) Җилдән аз гына шешенү. *Каршы искән җил битне җилсеткән*

2) *күч.* Җилкендерү, дәртләндерү, нәрсәгә дә булса омтылу хисе тудыру. *Ләкин аның тавышы шундый матур, моңлы, йөрәкне җилсетеп, дулкынлатып үтә.* Ә.Еники

**Җилсетә төшү** Беркадәр, бераз җилсетү; бераз җилсенгән хәлгә китерү

**Җилсетеп кую** Беркадәр җилсетү, аз гына, кыска вакытка җилсетү. *Аннан Петя еш кына аның фермасына тегене-моны төзәтергә барып йөри, ихтимал, шул чакларда карап торырга болай зарарсыз, тыйнак кына күренгән аз сүзле чибәр егет яшь ханымның күңелен җилсетеп куйгандыр.* Ә.Еники

**ҖИ́Л ТЕГЕРМӘНЕ** *и.* Җил көче белән эшли торган тегермән. *Еракта, кара җир белән зәңгәр күк тоташкан урында, җил тегермәненең канатлары әкрен генә әйләнә.* И.Гази. *Арырак, канатларын селкеп, җил тегермәне эшләп тора.* Ф.Хөсни

**ҖИЛТЕР** *с.* 1) Кискен, ашкынулы. *Җилтер хәрәкәтләр*

2) Бик тиз, җәһәт. *Җилтер егет*

3) Кызу, тиз мавыгып китүчән. *Кечкенәдән җилтер табигатьле булды*

**ҖИЛТЕРӘТҮ** *ф.* **1.** 1) Этеп-төртеп, кабаландырып, нәрсәдер эшләргә мәҗбүр итү; капылт кузгату. *Аны әле аңа, әле моңа җилтерәтте, ашыктырды, кабаландырды, примуста доктор әйткәннәрне әзерләп тә алды.* Г.Ибраһимов. *Габдулла авыз ачып сүз әйтергә өлгермәде, Аннушка аны, җилтерәтеп алып, чанага күтәреп салды.* Ә.Фәйзи. *Каравыл өенең ишеген тибеп җибәрде дә коты очкан Шәмсетдинне, җилтерәтеп, ай яктысына чыгарып бастырды.* Г.Бәширов

2) Тотып, нык кына селкү. *– Нинди врач? Син нәрсә сөйлисең? – дип җилтерәтергә тотынды аны Әзһәр.* Ф.Яруллин. *Аннары нишләргә белмичә чыбыкка тотынып торган Томилинны,*

*иңеннән җилтерәтеп, арба артына төртте.* Казан утлары

3) Сикертеп-дыңгырдатып, дөбердәтеп алып бару. *Җилтерәтеп чыбык тарантасны, Җирән кашка алга ашкына.* Ш.Мөдәррис

**2. җилтерәтеп** *рәв. мәгъ.* 1) Бик тиз, тиз арада, җәһәтләп. *Әнә бер ак җиңсәлесе, башын калкытмыйча гына, учмаларын җилтерәтеп күтәреп сала.* И.Гази. *Әби белән Рифгать чананы җилтерәтеп алып киттеләр. Бары тик үргә менеп җиткәч кенә туктадылар.* А.Әхмәт. *Кемнәрдер аның чемоданын җилтерәтеп алып китте.* Г.Әпсәләмов

2) Шау-гөр килеп. *Җилтерәтеп кенә бер кул чабып алдылар.* Г.Бәширов

**Җилтерәтә бару** Торган саен ныграк җилтерәтү, җилтерәтүне аз-азлап көчәйтү

**Җилтерәтә башлау** Җилтерәтергә тотыну. *Күп вакыт үтмәде --- үзлегеннән җыйналган халык төркеме Фәйзулла куштан өенә барып, ни эшләргә белмичә аптырап торган карт куштанны җилтерәтә башлады.* М.Галәү

**Җилтерәтеп алу** Бераз, аз гына җилтерәтү. *Заһидәнең халәтен аңлаган Гайшә кызның җилкәсеннән тотып җилтерәтеп алды: – Исеңә кил, ахирәтем, – диде ул.* Ф.Сафин

**Җилтерәтеп җибәрү** Кинәт җилтерәтә башлау. *«Һәй-й, атка арт ягыннан камыт кидергән нәстә», – дип, малайны җилтерәтеп җибәрде.* М.Хәсәнов

**Җилтерәтеп кую** Кинәт бер тапкыр җилтерәтү. *– Ахмак! – дип кычкырып җибәрде Мәле һәм аны иңбашларыннан тотып җилтерәтеп куйды.* Ф.Садриев. *– Без сабыйлар түгел ләбаса! – диде ул һәм, кызуланып, Шаһназарның туныннан тотып алган килеш җилтерәтеп куйды.* Ә.Фәйзи

**Җилтерәтеп тору** Бертуктаусыз җилтерәтү. *Музыка ялганны кабул итми. Концерт беткәнче, шушы сораулар тойгыларымны тетрәтеп, җилтерәтеп торды.* М.Юныс

**Җилтерәтеп чыгару** Куып чыгару, җилкәләп озату

**ҖИЛТЕРӘҮ** *ф.* **1.** Тиз бару, җил кебек очу. *Аягым тоялмый ничек тә, Үзеннән атлады ишеккә; Мин очам, мин барам, җилтерим, Колакта бер аваз – тим-трим.* Н.Исәнбәт

**2. җилтерәп** *рәв. мәгъ.* Ашкынып, ашыгып; җәһәтлек белән. *Ул яңадан коридорга борылып чыкты һәм җилтерәп кереп килүче Васильев белән кара-каршы очрашты.* И.Гази. *Кыз, җилтерәп, икенче бүлмәгә чыгып китте.* Ә.Фәйзи. *Ул, җилтерәп кенә чыгып, сыерны ябып, юынып керде...* Г.Бәширов

**ҖИЛТЕР-ҖИЛТЕР** *рәв. к.* **җилт-җилт**. *Тик карт һич тә калырга тырышмый кичкә, Арттан куган кебек кемдер, Ашыга ул, җилтер-җилтер.* Р.Әхмәтҗанов

**ҖИЛТ-ҖИЛТ** *рәв.* Бик тиз, кызу-кызу. *Мортаза боларның сөйләшүләрен ишетеп алды бугай, җилт-җилт атлап килде дә Гыйззәтулла бабайны үзенә таба сөйри башлады.* Г.Иделле

**ҖИЛҮ** *ф. к.* **җилдертү** (*1 мәгъ.*). *Кабан күле өстендә Җилеп килә җил кимә; Уртак ярым түгел, дустым, Син ул кызга һич тимә.* Җыр. *Хәтердәдер, бәлки, сезнең Казан аша узган чаклар? Пугачёвлар эзен иснәп, Кешнәп җилгән аргамаклар...* Х.Туфан. *Туры айгыр, җилүдән туктап, акрын адымга күчте.* И.Салахов

**Җилеп калу** Форсаттан файдаланып, мөмкинлек булганда җилергә өлгерү. *Егет кенә чакта бер җилеп кал, Аркалардан үткән боландай.* Җыр

**ҖИ́Л ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан, күбесенчә, комлы урыннарда үсә, орлыгы өлгереп җиткәч, тамырыннан аерылып, җил уңаена тәгәрәп йөри торган, көчле тармакланган, бик вак чәчәкле үлән яки ярымкуак; пәри уты; *русчасы:* **качим высочайший**. *Сызгыра кырда җил үлән, Каргалар каркылдаша.* Х.Туфан. *Җил үләненең тамыры сапонинга бай, йон һәм ефәк юу өчен кулланыла.* Биология

**ҖИЛФЕРДӘТҮ** *ф.* 1) Җилфер-җилфер китерү, тибрәндерү. *Җилләр! Җилфердәтеп кара чәчләремне, Нигә мине шулай сөясез?!* Ф.Кәрим. *Якубның уң ягыннан, буш җиңен җилфердәтеп, Серебряков бара, сул ягыннан җиңел сөякле Васильев атлый.* И.Гази. *Ефәк ялларын җилфердәтеп җил белән ярышучы атлар ярсуы...* Казан утлары

2) Болгау, селтәү, селкү. *Минәйтәм, --- миңа Хәмит Ярми кия торган кара плащ кирәк, менә акча, дип, долларларымны җилфердәтәм.* М.Мәһдиев. *Иң алдан Тәкъвә Сәхәү килеп керде һәм, башын югары күтәреп, киң җилән җиңен җилфердәтә-җилфердәтә кычкырып җибәрде.* М.Әмир

**Җилфердәтә башлау** Җилфердәтергә тотыну. *Яулыкны йомшак җил эләктереп алды, флаг шикелле җилфердәтә башлады.* Г.Мөхәммәтшин

**Җилфердәтә төшү** Тагын да бераз җилфердәтү

**Җилфердәтеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә җилфердәтү. *Рәйсә, реверанс ясагандай итеп, күлмәк итәген җилфердәтеп ала да кызу-кызу атлап чыгып китә.* Л.Лерон

**Җилфердәтеп җибәрү** Кинәт җилфердәтә башлау

**Җилфердәтеп тору** Туктаусыз җилфердәтү. *Өстендәге күлмәген кичнең салкын җиле бер яктан – тәненә сылап, икенче яктан әллә нинди кайгы флагы төсле җилфердәтеп тора иде.* Ш.Камал. *Җил байракны җилфердәтеп тора*

**ҖИЛФЕРДӘ́Ү** *ф.* Җил искәнгә селкенү, җилфер-җилфер килү. *Бик күп кеше аның кем икәне белән кызыксынмады да, бары тик җилфердәгән юка плащны гына күрде аларның күзләре.* М.Мәһдиев. *Асылынып калган кәгазь кисәкләре җилдә акрын гына җилфердиләр.* Б.Камалов. *Яулык, нәкъ тавис койрыгыдай, әллә ничә төрле төсләр уйнатып, аның кулында җилферди иде.* Ә.Еники

**Җилфердәп алу** Берара, кыска вакыт эчендә җилфердәү. *Яфраклар җилфердәп алгач кына, мин янымдагы ботакта мәче башлы ябалак утырганын абайладым.* Ә.Хәсәнов. *Җилсакал көрсенеп куйды, ефәк сакалы җилфердәп алды.* Р.Хафизова. *Тылсымлы агач, ишеткәнен белдереп, җилфердәп ала да тынып кала.* Л.Лерон

**Җилфердәп йөрү** Һәрвакыт, гел, озак вакыт җилфердәү. *Менә шушы җиңем атна буе җилфердәп йөрде.* Н.Гаетбай

**Җилфердәп китү** Кинәт, кыска вакытлы гына җилфердәү. *Берни аңла-*

*маган яшь килен каенанасыныкына охшаш алсу алъяпкычның җилфердәп китүен тәрәзә аша гына күреп калды.* К.Тимбикова

**Җилфердәп кую** Кинәт кенә бер тапкыр җилфердәү. *Кинәт кергән һавадан өй түрендәге агач караватның ак чыбылдыгы җилфердәп куйды.* Ә.Еники. *Муенына салган җиңелчә шарфы чыккан уңайга җилфердәп куйды.* Х.Ширмән

**Җилфердәп тору** 1) Туктаусыз җилфердәү. *Сугыш гөрелтесе якынайганнан-якынайды. Аның өермәсеннән палаткалар җилфердәп торды.* М.Хәсәнов. *Беләкләренә дә шундый ук тасмалар эленгән. Ул әкрен генә селкенеп, җилфердәп тора.* Р.Вәлиева

2) Әле, хәзерге вакытта җилфердәү. *--- җен карты сакалын өзеп качкан, бары каенга бәйләнгән сакалы гына җилфердәп тора, ди.* Әкият. *Аның [Гөлҗиһанның] ике бите ут булып яна, артка чөеп бәйләгән ак яулыгы астыннан ак чәчләре җилфердәп тора иде.* Ф.Бәйрәмова

**Җилферди башлау** Җилфердәргә тотыну. *Гөлҗимеш куакларында, төсе уңган иске чүпрәк шикелле, сарык йоннары гына җилферди башлады.* Г.Мөхәммәтшин

**ҖИЛФЕРДЕК** *с.* Җилфердәп торган. *Әллә инде яшьлек аланнарында, җилфердек күбәләк булып, иркәләнеп оча-оча адашып калырмы дип уйлый идем элек.* М.Галиев. *Җилфердек байрак*

**ҖИЛФЕР-ҖИЛФЕР** *иярт.* **1.** Тибрәнүле хәрәкәтне, җил белән селкенеп торуны белдерә. *Вакыт-вакыт җәнүп тарафыннан искән җилгә агач яфраклары иренгән сыман гына җилфер-җилфер селкенмәктә иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Тирәдәге агач яфраклары акрын искән җил белән ни-нәрсә хакындадыр җилфер-җилфер сөйләшәләр.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз-тиз, җәһәт-җәһәт. *Ике баласын иярткән Миңзифа, җилфер-җилфер атлап, ирен каршы алырга килә иде.* И.Гази

**ҖИЛЬЯК** *с. сөйл.* 1) Җиңел табигатьле, төптән уйламый торган. *Рухи җитлеккәнлек җитенкерәми иде миңа, җильяк егет идем шикелле, юк-бар кешеләргә өстенлек биреп, аларга ияреп китеп, байтак хаталар ясаганымны хәзер аңлыйм да...* А.Гыйләҗев

2) Аумакай, үзенең төпле фикере булмаган. *Майлы коймак, җылы түр башыннан башканы уйламый торган җильяк тегүчегә аның аты турында лыгырдап баруы пычагыма кирәкмени?!* Ф.Хөсни. *Җитмәсә тагын, теге юлда ияргән җильяк кеше: – Кайда кызың? Алып китәбезме? – дигән сораулар белән, ачу китереп, һаман бәйләнеп тора.* Ф.Хөсни

3) Җитез, йөгерек. *Болай үзе тире белән сөяктән генә оешкан кебек күренсә дә, аты да, хуҗасы кебек, җильяк хайван икән, бер көй алгач, чибәр генә элдертә башлады.* Ф.Хөсни

**ҖИЛЬЯКЛАНУ** *ф.* Җиңел холыклыга әйләнү, җилбәзәклек күрсәтү. *Шулай хәвефләнү катнаш җильякланып чабып йөргәндә, «хоп» әлеге вакыйга.* Ф.Хөсни

**Җильяклана бару** Торган саен ныграк җильяклану

**Җильяклана башлау** Җильякланырга тотыну

**Җильяклана төшү** Тагын да җильяклану

**Җильякланып йөрү** Һәрвакыт, туктаусыз җильяклану

**Җильякланып китү** Кинәт җильяклана башлау

**Җильякланып кую** Беркадәр, бераз җильяклану, җильяклык күрсәтү

**ҖИЛ-ЯҢГЫР** *җый. и.* Җил һәм яңгыр; җилләп яуган көчле яңгыр. *– Ии ... Билләрем сызлап тора. Җил-яңгыр булыр, ахры.* К.Әмири. *Елның теләсә кай вакытында, җил-яңгырда, буранда да, нәкъ тиешле вакытында, мәчет манарасыннан сузып-сузып азан әйткән тавыш ишетелә.* М.Галәү

◊ **Җил-яңгыр тидермәү (тигезмәү)** Кемне дә булса рәнҗетергә, кимсетергә ирек бирмәү, кадерләп саклау. *Заһит өстеннән шикаятьләр болай да килгәләп тора. Ләкин ул дустына җил-яңгыр тигезмәде.* Мирас. **Җил-яңгырдан саклау** Яклау, рәнҗетергә ирек бирмәү

**ҖИЛ-ЯҢГЫРЛЫ** *җый. с.* Җил һәм яңгыр явып торган. *Җил-яңгырлы пычрак юллары, чебен-черки газаплаган төннәре, машина ватылып, чарасыз калган чаклары – барысы да баштан кичә...* М.Госманов

**ҖИМ** *и.* 1) Кош-корт өчен, көрпә, ярма кебек ризык катнаштырып, махсус әзерләнгән азык. *Балалы казга җим тимәс.* Әйтем. *Бу җәйне Хәтирә --- ярдәмгә мохтаҗ әби-карчыкларның йорт эшләрен эшләште, бәрәңге әрчеде. Кош-кортларына җим-азык бирде.* М.Галәү. *Ул ишегалдын себерде, кош-кортка җим болгатып бирде.* Ә.Фәйзи

2) Кош-кортка сибә торган ярма, бөртек. *Кошны – җим белән, кешене сүз белән алдыйлар.* Әйтем. *Амбар алдында җим чүпләгән башка тавыклар арасында кыртлап йөрүче чуар тавык күренде.* А.Алиш. *Әнә безнең өйдә дә бер тубал чебиләр черелдәшә. Миңа да эш артты: су эчерәм, җим сибәм аларга.* Казан утлары

3) *сөйл.* Азык, ашыйсы ризык. *Аерылган каз тупланган каргага җим булыр.* Әйтем. *Зонада һәркем иртәдән кичкә кадәр җим эзли. Чынлап җыласаң, юк җирдән дә әз-мәз табыла ризык.* А.Гыйләҗев. *Әтәч йөри җим эзләп, Аяк белән типкәләп.* М.Гали

4) *диал.* Каты кабыклы орлыкның төше. *Кабак җиме. Көнбагыш җиме*

5) Балык тотканда кармакка кидерелә торган чебен-черки кебек алдавыч. *Бернинди җимгә дә чиртмәгәч, балыкчылар күренми башладылар.* Г.Гобәй

6) Гарәп алфавитында «җ» хәрефенең исеме

7) *күч.* Кемне дә булса кулга төшерү максаты белән оештырылган хәйлә. *Шушы яшь кыз белән сөйләшү шәкертләр өчен Ефим поп йортына тарта торган бер җим иде.* М.Галәү. *Әлтафи ыргыткан кармакка шул арада хәйләкәр, мут Баязитова җим кертте.* М.Мәһдиев. *Шагыйрь күңелен нәрсә белән аулыйсын тәгаен чамалый, сылана, куенга керә белә, җимнәрне туктаусыз өсти, куерта тора ---.* Т.Галиуллин

8) *күч.* Күңелне, җанны рухи канәгатьләндерә торган нәрсә. *Сусаганда су юк, җанга җим юк: Кул сузалмый шунда Алласы.* Ф.Бурнаш

9) *күч.* Нәрсәнең дә булса асылы, нигезе, төп мәгънәсе. *[Нәфүш] Сүзнең җимен чамалап алып, көлеп куйды.* Г.Ахунов

**ҖИМБАЛЫК** *и. махс.* Балык тотканда, җим урынына кулланыла торган вак тере балык

**ҖИМЕРГЕЧ** *с.* 1) Җимерә торган, юкка чыгара торган, тар-мар итә торган. *Җимергеч көчләр котырганда, шәһәр-калалар ахыргача җансызланмыйлар, яшәүләрен дәвам итәләр.* М.Юныс. *Бу хәл каядыр барып җиткән. Каядыр гына түгел, тагы да хәтәррәк урынга ---. Мә сиңа комиссия ---, мә сиңа җимергеч чыгыш.* М.Мәһдиев. *Әдип үз дәверенең җимергеч, кешелексез сәясәтенә, тоталитар хакимияткә, аның икейөзлелегенә үтергеч бәя бирә...* Р.Әмирхан

2) Зарарлы, зыян китерә торган. *Дару чималын һава коры торганда ---, ә кояш нурларының җимергеч тәэсиренә юл куймау максатында – болытлы сүрән көннәрдә җыярга кирәк.* Е.Солодухин

**ҖИМЕРЕК** *с.* **1.** 1) Җимерелгән, авып төшкән, ишелеп беткән. *Җимерек капка төбендә яхшы күк аргамак, башын чайкап, аякларын сугып тора.* Г.Ибраһимов. *Атын җимерек капканың Ходай ярдәме белән исән калган баганасындагы күгәргән боҗрага йөгән тезгененнән бәйли дә йортка керә.* М.Мәһдиев. *Больницаның җимерек коймаларын, чалшаеп беткән урам утыргычларын, таш, ком, тимер-томыр белән тулы ишегалдын күргән кешенең һич кенә дә чирлисе килмәс!* Т.Галиуллин

2) Хәрабә хәленә килгән. *Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады.* Ә.Еники. *Җимерек шәһәрләрнең ташлары арасында әрвахларның үлмәс җаннары адашып йөри.* М.Юныс

3) Ватык, бозык, эшкә яраксыз хәлгә килгән. *Ватык, җимерек, иске әйберләрнең барсы да Сафага булды, яхшы, төзек, яңа әйберләр Вафага калды.* М.Галәү. *Ул җимерек һәм пычрак пыялалар эчендә тетрәп-тетрәп янып торган кызгылт шәүләләрдән яктылык түгел, гүя караңгылык, кайгы, хәсрәт ага иде.* Ш.Камал. *Мин, баладай буйсынып, җимерек ящик өстенә утырдым.* А.Шамов

4) Күп йөрүдән чокырланган; җимерелгән. *Салкын көз, елгалар аша чыгасы бар, күперләр җимерек.* Татарстан

5) Таркалган, бетүгә йөз тоткан. *Җимерек илдә зур-зур калаларны Алар исеме белән төзедек без.* Ә.Ерикәй

6) *күч. сөйл.* Чытык, сытылган, җыерылып килгән. *[Старшинаның] Чырае бик җимерек иде.* Х.Камалов. *--- йөзеннән нур качкан, кашлары җимерек иде.* В.Имамов

7) *күч.* Боек, төшенке, моңсу. *Менә мин шулай, эшкә яраксыз бер әйбер төсле, почмакта ташланып торам. Вөҗүдемнән дә бигрәк минем күңелем җимерек, җәрәхәтле.* Ш.Камал

**2.** *и. мәгъ. к.* **җимереклек**. *Союзда ел эчендә төзелгән, иң әйбәт саналган биналарның барысын бергә алганда да, алар Эфес шәһәрендәге фәхешханә җимерекләренә дә тормыйлар.* Р.Мирхәйдәров. *Урта диңгез төбендә аквалангистлар ярга якын гына урында борынгы шәһәр җимерекләре таптылар.* Физик география. *Бу йортта яшәүчеләр: – Йортыбыз таркала, көннәрдән бер көнне бина ишелеп, җимерекләр арасында калмасак ярар иде, – диләр.* Шәһри Казан

**ҖИМЕРЕКЛЕК** *и.* 1) Җимерелеп бара торган корылма калдыклары, хәрабәләр. *Ничек кенә дәлилләргә тырышмасыннар, монда кеше яшәмәгәне һәркемгә дә аңлашыла. Идән юк, чүпчар, җимереклек.* Шәһри Казан. *Болгар шәһәре җимереклекләре*

2) Хуҗалыктагы бөлгенлек, икътисади мохтаҗлык хәле. *Беренче бөтендөнья һәм гражданнар сугышы елларында җимереклеккә, ачлыкка --- дучар ителгән Россия чиксез зур авырлыклар кичерде.* Д.Вәлиев. *Җимереклек, тәртипсезлек, үзара низаглар урындагы иптәшләрнең җелегенә үткән.* Р.Мөхәммәдиев

3) *күч.* Эштә уңышсызлык, житешсезлек. *Чын дус алга киткән якны күрсә, Йөзе китә айдай ачылып, Җитешсезлек, җимереклек күрсә, Тәнкыйть итә, эчтән ачынып.* М.Гафури

**ҖИМЕРЕЛМӘС** *с. к.* **җимерелмәслек**. *Ялкынланып бердәм хис белән, Җимерелмәс ныклы көч белән... Саклый алар шулай үзләренең Ерактагы туган илләрен.* Ә.Исхак

**ҖИМЕРЕЛМӘСЛЕК** *с.* 1) Нык, таза эшләнгән. *Бөтен көнбатыш инженерлары кулы белән салынган җимерелмәслек тимер-бетон ныгытмалар көлгә әйләнеп күккә очалар.* Т.Гыйззәт

2) Какшамас, нык. *Җимерелмәслек ныклы көч белән саклый алар анда Испаниянең хезмәт яңгырап торган җирләрен.* Ә.Исхак

**ҖИМЕРЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) Оешкан, корылган нәрсә ишелү, ватылу, таралып китү. *Малайлар: «Багор кирәк! Багор! Күпер җимерелде!» – дип кычкыракычкыра, урам буйлап йөгерештеләр.* М.Галәү. *Сигез балалы Рабига карчыкларның өе җимерелгәч, бурасын урманнан туры шуларга кайтартты.* Ф.Яруллин. *Тәрәзәләр ватылган, чиләкләр яньчелгән, утыннар җимерелгән, сулар түгелгән, арбалар ауган.* М.Фәйзи

2) Хәрабә хәленә килү, җимереклеккә әйләнү. *Кавдивизиянең йөгерек атлары баскан җирдә дошманның --- ватылган, җимерелгән станцияләре генә калды.* А.Шамов. *Бу шәһәрдә каты сугышлар булган. Йортлар җимерелгән, урамнарда йөрерлек түгел: таш, кирпеч кисәкләре өелеп ята.* Г.Бакиров. *Үчен алды халык улы, үчен алды изге җирләрнең, Җимерелгән шәһәр, авылларның, Үтерелгән хатын, ирләрнең.* Ә.Исхак

3) Убылу; уелып, ишелеп төшү. *Шахтаның җимерелүен хәбәр иттеләр.* М.Гафури. *Таулар җимерелү нәтиҗәсендә, тау илләрендә дә тигезлекләр барлыкка килүе мөмкин.* Физик география. *Җимерелгән тау токымнарын елгалар яңадан диңгез һәм океаннарга алып китә, шулай итеп, таулар җимерелә, һәм процесс туктаусыз дәвам итә.* Физик география

4) Ватылу, сыну; эшләргә, файдаланырга яраксыз хәлгә килү. *Алар ут-*

*лыгы җимерелгән --- самавырдан --- гадәттә эчелә торган чәйне эчтеләр.* Ф.Хөсни

5) Яшәүдән туктау, юкка чыгу, бетү. *Дөнья җимерелде, яисә шуңа охшашлырак бер хәл булды, дип уйладылар бугай.* Ш.Камал. *Ләкин Ш.Мәрҗани Болгар шәһәренең, тәмам җимерелеп, юкка чыгуының сәбәпләрен күрсәтми. «Болгар шәһәренең кайчан һәм ни сәбәпле җимерелгәнлеген һичбер китапта күргәнебез юк», – дип яза ул.* Ә.Хәйри. *Чилидагы җир тетрәү нәтиҗәсендә, уннарча шәһәр бөтенләй җимерелде, йөзләрчә торак җир өстеннән юкка чыкты.* Физик география

6) Гамәлгә ашмау, үтәлмәү, юкка чыгу. *Җайланып килә торган эш белән канатланган укытучыны кинәт шикләнү, курку чолгап алды: әллә тагын җимереләме минем эш?* Ә.Фәйзи. *Гадәттә, хыял белән яшәүчеләр, планнары җимерелсә, ни эшләргә белмичә, каушап калалар.* М.Юныс

7) Нигездән үзгәрү, бетү. *Ләкин беребез дә: «Ә менә мин белмим», --- дип әйтергә батырчылык итмәде. Ул кемгә кирәк? Әйдә, ындырдагы апаларның «укыган кеше – укыган кеше инде» дигән уйлары җимерелмәсен...* Х.Сарьян

8) Тормыш агышының, эшнең һ.б.ның урнашкан тәртибе бозылу, үзгәрү. *Аның бар кебек шатлык вә өметләре җимерелгән, бигрәк тә Газизә өчен кайгыра, аны кызгана иде.* Ш.Камал

9) Берәр әгъзага зарар килү, зарарлану, саулыгын, бөтенлеген югалту. *Аның йөзе, изелеп, канга баткан, баш сөяге ватылган, маңгае, чигәләре буй-буй җимерелгән, --- сул як кулбашы канлы туфрак белән укмашып беткән иде.* Г.Ибраһимов. *[Тоткынны] Нык кыйнаганнар, күз-каш җимерелгән, яңаклар кутырлап каткан, күзләр йомык...* А.Гыйләҗев. *...Борыны җимерелгән бер малай, читкәрәк китеп, зур гына кар кисәге белән борыныннан килгән канны туктатырга тырыша.* Ә.Фәйзи

10) *күч.* Какшау, таркалу; бетү, юкка чыгу хәленә килү. *Ул үзенең бәхете җимерелмәгәнен, якты күккә тик вакытлы кара болыт кына сарылганын сизенде.* Г.Ибраһимов. *Билалның мәхәббәте кире кагылгач, ул тагын шиккә төште: бу – нәрсә, Гәүһәрнең бик эредән сайлануымы, әллә тормышы бер җимерелгәч, икенче тапкыр үтә сак кылануымы?* Г.Әпсәләмов. *Гайбәте бер хәл, минем язмышым җимерелде әле монда.* Казан утлары

11) *күч.* Кәефсезләнү. *Аларның авыз-борын салынган, каш-күз җимерелгән, [эчтән] көеп йөриләр.* Ф.Әмирхан. *Анкетаны караганнан соң, начальникның кашы җимерелде.* М.Юныс

12) *күч.* Ару, йончу, хәлсезләнү. *Җир астыннан җимерелеп чыгасың да, чакчак тамак ялгап, сигез-тугыз сәгать изелеп йоклыйсың.* Ш.Камал. *Бер ел эчендә ул бетеренгән, җимерелгән*

**2. җимерелеп** *рәв. мәгъ.* 1) Бик күп булып, берсе өстенә икенчесе өелеп. *Язгы ташуда бозлар җимерелеп килә*

2) Үз-үзеңне аямыйча, күп көч түгеп. *Бросьте, пожалуйста, әллә мин каторжникмы, җимерелеп эшләргә!* Ш.Камал

◊ **Җимерелеп агу** Актарылып, ярсып, көчле ташкын булып агу. *Җир, күк – һәммәсе, югарыда җилләнеп, дулкынланып, тау-тау җимерелеп аккан болытлар белән караңгы төскә чумдылар.* Г.Ибраһимов. **Җимерелеп уңу (үсү)** Бик яхшы уңу, мул булып үсү. *Зур-зур болытлар күк йөзен каплап килә, тау-тау булып, Җимерелеп үскән игеннәргә карап, зур яу булып.* М.Гафури

**Җимерелә бару** Вакыт узган саен ныграк җимерелү, җимерелүе акрынлап арту. *Аяклана алмаслык хәлгә җитеп җимерелә барган тормыш, нәтиҗәсез эшчәнлек заманы килә.* М.Гайнетдин. *Бу хәлләр [рухи кризис] күбрәк аның аттестатка имтиханнар тапшырып, университетка укырга керү хыялы җимерелә баруы белән бәйләнгән булса кирәк.* Р.Әмирханов

**Җимерелә башлау** Җимерелергә тотыну. *Ми эшчәнлеге тукталса, бу процесслар куелган чикләрдән чыгып, барлык әгъзалар таркала, ә кеше система буларак җимерелә башлый.* И.Әмирхан

**Җимерелә төшү** Беркадәр, бераз җимерелү; тагы да җимерелү. *Завучның болай да сытык чырае тагын да җимерелә төште.* Р.Батулла

**Җимерелеп бару** Көннән-көн ныграк җимерелү, акрынлап, аз-азлап җимерелү. *Алар искереп, җимерелеп барган агач баскычтан тиз-тиз генә өскә күтәрелделәр.* А.Шамов

**Җимерелеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җимерелү. *Юл буендагы машина калдыклары, унар, уникешәр йортлы кечерәк, күбесе җимерелеп беткән авыллар – барысы да кар астында калганнар.* Г.Әпсәләмов. *Таш түшәлгән бу юл да --- казылып, җимерелеп беткән иде.* А.Шамов. *Казанның бик күп биналары җимерелеп бетте.* Р.Батулла

**Җимерелеп китү** Кинәт җимерелү. *Җимерелеп китте чергән диварлар, матчалар. Тумырылып китте югартын төрле ерткыч патшалар...* Ш.Бабич

**Җимерелеп төшү** Ишелеп җимерелү. *Әлеге тирес яккан зур боз кисәге иске күпергә барып бәрелде дә, күпер, шатыр-шотыр килеп, җимерелеп төште.* М.Галәү. *Бу бушлык зурайгач, үз өстендәге өс катын күтәрә алмаганлыктан, каты җимерелеп төшә.* Ф.Әмирхан. *Ии, илаһи! Җиз моржалардан кычкыртуларын ишетсәң, күк җимерелеп төшә, диярсең.* К.Нәҗми

**Җимерелеп яту** Әле, хәзер җимерелгән хәлдә булу

**ҖИМЕРТТЕРҮ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **җимерү 1.** (*1–2 мәгъ.*). *--- авыл советы башлыгы, авылдашларының хисләре белән исәпләшеп тормыйча, 50 елга якын торган хәтер һәйкәлен җимерттереп, ташларын пычрак су аккан каналга ташлаттырган.* Шәһри Казан

2) *күч.* Бернәрсәдән дә тартынмыйча, теләп, күп һәм җиренә җиткереп эшләү, булдыру

**2. җимерттереп** *рәв. мәгъ.* Көч-куәт, булдыклылык күрсәтеп, теләп

◊ **Җимерттереп йөрү** *к.* **җир(не) җимерттереп (җимертеп) йөрү**. **Җимерттереп тору** *к.* **җимерттереп яшәү**. *[Фатыйма:] Кайт әле менә, атасы. Җимерттереп торырбыз, валлаһи.* А.Алиш. **Җимерттереп эшләү** *к.* **җир җимерттереп эшләү**. *Билләһи, үземә тапшырыгыз, үзем җимерттереп*

*эшлим моны.* Г.Минский. **Җимерттереп яту** Ни дә булса эшләү, майтару. *Нәрсә җимерттереп ятасың?* Ф.Бурнаш. **Җимерттереп яшәү** Тормышның түмен татып, рәхәтен күреп, күңелле итеп яшәү, эшләү. *Болай булгач яшибез әле, җимерттереп яшибез, шулаймы?* Г.Гыйльманов

**ҖИМЕРТҮ** *ф.* **1.** 1) *к.* **җимерү** (*1 мәгъ.*). --- *белгечләр аның мөмкинлекләрен, көчләп, шытып, асфальтны җимертеп чыккан яшел үсенте сымак, тишеп, бәреп чыкмыйча күрмиләр.* Г.Каюмов. *Ул, Амударьясындагы буаны җимертеп, Үргәнечне коточкыч су ташкыны астында калдырган, ди.* В.Имамов

2) *сөйл.* Берәр эш артыннан йөрү, нәрсәнедер майтару

**2. җимертеп** *рәв. мәгъ. күч.* Бернинди эштән дә тайчанмыйча, яхшы итеп башкарып. *Хәзер совхозда --- аяклы мал йөз башка җитте. Болар эчендә җимертеп җигәрлек унике баш ат бар.* Г.Ибраһимов. *Ирләр белән бергә, җимертеп, печән дә чапты, көлтә дә кертте ул.* Н.Фәттах

**Җимертә башлау** Җимертергә тотыну. *Холык-фигыльләре үзгәрмәде. Карарга иренеп, машина, механизмнарны җимертә башлады.* Х.Камалов

**Җимертеп йөрү** 1) Бөтен нәрсәне рәттән җимертү

2) *күч.* Сау-сәламәт булып эшләп тору; нәрсәнедер булдыру. *Я, ни эш җимертеп йөрисең, Егор кордаш?* Г.Гобәй

**ҖИМЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Вату, төзеклеген бозу, яраксыз хәлгә китерү. *Таҗи үзенең бу «карашын» бик тырышып тормышка ашыра башлады. Яшьтәшләренең борынын сугып канатты, уйный торган уенчыкларын ватты, җимерде.* М.Галәү. *Әйе, ат хәзер киртә почмакларын җимереп чапмый, башын җай гына чайкап, атлап-атлап кына килә иде.* Ф.Хөсни

2) Ватып, кырып, хәрабәләр хәленә китерү. *Талаучылар бандасы юлда бөтен нәрсәне талый, җимерә, вата.* Ш.Усманов. *Ярсып аккан елга ярындагы Ак шәһәрне төнге караңгыда җимергәннәр, утка салганнар.* Ф.Кәрим. *Кайсы якка гына колак салма, «гөрс» тә «гөрс» җир селкетеп, [дошман] химаясез шәһәрләрне җимерде.* Ә.Еники

3) Су ташкыны белән юлдагы нәрсәләрне юып, ерып үтү. *И яуды, и яуды [яңгыр], күперләрне агызды, буаларны җимерде.* Казан утлары

4) *күч.* Нинди дә булса хәләтне, уйны, планны юкка чыгару, бетерү. *Ләкин Гәүһәрнең кинәт кайтып төшеп, ачыктан-ачык Булат белән бәйланып китүе – Разияның хыялларын җимерде.* Г.Ибраһимов

5) *күч.* Йөздә ризасызлык, ачулану төсмере чагылу. *Гаяз каты итеп тешен кысты, кашларын җимерде дә, кулын каты йодрыклап, һавага кизәнеп куйды.* М.Әмир

6) *күч.* Җиңү, юк итү, юкка чыгару. *Бүген безнең актык киртәне дә җимереп үткән көнебез.* М.Фәйзи. *Тоткын – уе белән генә бикләрне җимереп, ишек-тәрәзәләрне үтеп чыга.* А.Гыйләҗев

7) *күч.* Бетерү, юк итү. *Барны җимергән юкны бар итмәс.* Мәкаль. *Тирә-якта, авыл саен диярлек, кулаклар баш күтәрәләр, арттан җимерергә маташалар.* Г.Ибраһимов

8) *күч.* Нинди дә булса идарә системасын нигездән юкка чыгару яки бөтенләй үзгәртеп кору. *Дошман кулында гаскәр, дошман кулында зindan, суд, палач ---. Мондый дошманны җимерү өчен, революция алдында бер генә чара бар: ул да булса, кораллы сугыш.* Г.Ибраһимов. *Өч йөз еллык династияле патша монархиясен җимерү өчен, революция җиленең бер исүе җитте иҗ.* К.Нәҗми

9) *күч.* Үзара мөнәсәбәтләрне, яшәп килгән хәләтне юкка чыгару, тормыш агышын чуалту, тәртипсезлек кертү, таркату. *Әнә шул шомлы туй, көчләп укылган никах Сафия апамның бөтен өметләрен җимерде: ул туйдан соң бөтенләй күңелсезләнде...* М.Гафури. *Мин семьяны ватарга, җимерергә теләмим, Шәриф Гыйльманович. Шул ук вакытта минем өметем дә калмаган.* Г.Әпсәләмов. *Фәридә нык, адәм ышанмаслык нык ул. Ләкин, ни дисәң дә, хатын-кыз бит. Син – аның тормышын җимергән кеше, шуның өчен дә аның каршында җаваплысың!* Р.-Н. Гүнтәкин

10) *күч.* Таркату, бөлгенлеккә төшерү, юк итү. *Хәер, ул, безнең арага кереп, тыштан – колхоз яклы булган булып, эчтән бөтен көче белән колхозны җимерергә маташа.* Г.Әпсәләмов

**2. җимереп** *рәв. мәгъ. к.* **җимертеп**. *Ул бөтен кышын, язын җимереп эш эшләсә дә, йортның барлык мәшәкатьләрен җилкәсендә алып барса да, күңеле белән һаман Нурый карт йортында иде.* Г.Ибраһимов

**Җимерә бару** *к.* **җимереп бару** (*1 мәгъ.*)

**Җимерә башлау** Җимерергә тотыну. *Ислам дине белән көрәшү өчен, чукынган татарлар яшәгән җирләрдә (ә кайвакыт андыйлар булмаганда да) мәчетләрне җимерә башлыйлар.* И.Гафаров

**Җимерә төшү** Тагын да җимерү

**Җимерә язу** Чак кына җимерми калу. *Сәрвиназны рәхимсез җәберләп, гаиләмне җимерә язган тар күңелле әнигә ни әйтергә белмичә сүзсез калдым.* С.Сабиров

**Җимереп ату** Тиз арада җимерү. *Ватан өчен безнең йөрәкләрдә Диңгез ярындагы таш тауларын Җимереп аткан вулкан көче бар.* Ф.Кәрим

**Җимереп бару** 1) Рәттән, барысын да тоташ җимерү. *Мәчетләрне тулаем җимереп бару дөрес түгел, кайбер авылларда исән калдырсак та, революциягә зыян килмәячәк, дип язылган монда.* Ә.Баян

2) *күч.* Барысын да рәттән эшләү, бер эштән дә тайчанмау. *Зурысы Миңниса ялан эшләрен батырып эшләде. Утауда, печәндә, ашлык сукканда, ирләр белән бер уңайдан җимереп барды.* Г.Ибраһимов

**Җимереп бетерү** Бөтенләй, тулысынча җимерү. *Хәмбәл әмере буенча, кыпчаклар Әбүбәкер йортындагы барча байлыкны талап алды, остаһың чуен, бакыр җиһазлар коюга көйләнгән мич һәм казаннарын җимереп бетерде.* В.Имамов

**Җимереп килү** Нинди дә булса бер вакыттан башлап, даими рәвештә җимерү, эзлекле рәвештә юкка чыгару

**Җимереп ташлау** Кинәт җимерү. *Меңгә якын ирдән торган ташкын каланың берьюлы өч капкасын җимереп ташлады.* В.Имамов. *Зур фактлар килеп чыгарлар. Миңлебаев, өстенә авып барган гаепне җимереп ташларлар, дип өметләнә.* Г.Ибраһимов

**ҖИМЕТ** *и. иск.* Азык, ашау ризыгы. *Җиметенә карама, җәгетенә кара.* Мәкаль

**ҖИМЕШ** *и.* 1) Үсемлекнең чәчәк җимшәненнән үсеп киткән орлыгы. *Эт тигәнәгенең чәчәк төркеме – сары төстәге кечкенә кәрзин, ә җимеше – ике үткен чәнечкеле орлык.* Ботаника

2) Кайбер куак һәм үсемлекләрдәге ашарга яраклы итләч сусыл орлык тышчасы. *Тик болар артыннан Фәтхия карчыкның көяз кодалар, кодагыйлар алдында мактанычлы җимеш суы биреледе...* Г.Ибраһимов. *Сусыл җимешләрнең җимеш тирәлеге сусыл, йомшак була... Алмагач, груша, слива, чия агачлары, помидор, кыяр үсемлекләре кешегә тәмле, сусыл җимешләр бирә.* Ботаника

3) Кайбер шундый җимешләрнең атамасы составында килә. *Өрек җимеше. Кара җимеш*

4) *күч.* Нинди дә булса тирәлек, шартлар китереп чыгарган күренеш, иҗтимагый нәтиҗә. *Кеше бит әле, иҗтимагый тормыш җимеше дә. Менә шул шартларда да Сибгат Хәким --- бер төрле сөйләп тә икенче төрле эшләүгә каршы көрәште.* Т.Галиуллин. *Үз чорының җимеше буларак, кадими мәдрәсә татар милләте өчен бик күп зыялылар, галимнәр, әдипләр җитештергән, халыкны аң-белемле иткән.* Р.Әмирхан

5) *күч.* Нинди дә булса тәрбия нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән күренеш. *Олылар сүзен тыңлый белмәсәгез, менә хәзер мыскыл иткәнне күтәрә белегез... Менә хәзер түзегез инде! Әнә ул шуның җимеше инде.* М.Галәү. *Хәсәншә башка бай балаларыннан артык та түгел, ким дә түгел, ягъни ысул кадим хәлфәләренең бакчасында үскән җимешләрдән бер җимеш, бигрәк тә тугырысы – утын кебек тәрбиясез бер егет иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Саниянең әнисе, тормышта меңгә берсе дә табылмастай хатын булып, баласына «ызгыш җимеше» дип кенә карады.* Б.Камалов

6) *күч.* Эшнең нәтиҗәсе, казаныш, уңыш. *Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.* Г.Тукай. *Бакчы, дошман үлмәгән, ул кузгала, Хөррият җимешен халыктан кызгана; Акрын-акрын канлы кылычын кулга ала.* М.Гафури. «*Нәфисә», «Бибисара» кебек популяр җырлар, «Шәрык балеты» кебек гаҗәеп сюитасы – әнә шул иҗади элемтәнең безгә калган җимешләре.* Ә.Еники

**ҖИМЕШЛӘНҮ** *ф.* 1) Җимеш ясалу, җимеш барлыкка килү; җимеш булып өлгереп җитү, ашарлык хәлгә килү. *Зөфәр бакчасының көннән-көн көчлерәк җимешләнә, пешә, аңкый торган чагы җиткән хәзер.* Ә.Еники. *Әнә бака яфрагы чәчкә сабагы чыгарган хәтта. Җимешләнә алыр микән?* М.Маликова. *Җирдәге бөтен гөлләрнең шашынып-шашынып чәчәк аткан, язгы чәчәкләрнең мөлдерәп-мөлдерәп җимешләнгән чагы.* К.Тимбикова

2) *күч.* Үсешнең югары стадиясендә булу. *Сугарылып халкым назы белән, Җимешләнеп җырым җитеште.* М.Җәлил

**Җимешләнә башлау** Җимешләнү билгеләре күренү

**Җимешләнә төшү** Беркадәр, бераз җимешләнү

**Җимешләнеп бетү** Тәмам, ахыргача җимешләнү. *Алмагач – үзенең алмасын, чикләвек агачы – чикләвеген, шомырт, балан, миләшләр – бар да үз җимешләрен алып, җимешләнеп беткәннәр.* Тәмле сүз

**Җимешләнеп җитү** Бөтенләй, тулысынча җимешләнү

**Җимешләнеп килү** Акрынлап җимешләр барлыкка килә башлау. *Язның соңгы ае, ихата саен бакча, агачларның шау чәчәктә чагы артта калган, алар җимешләнеп киләләр иде.* Ф.Сафин

**ҖИМЕШЛЕ** *с.* 1) Җимеше булган. *Субтропик районнарда мандарин, апельсин, хөрмә, инҗир --- һәм тәмле җимешле башка үсемлекләр үстерәләр.* Дөнья кисәкләре географиясе. *Карга борыны (күзе) – паслёнчалар семьялыгыннан вак кара җимешле үлән.* Ботаника

2) Җимешкә бай, мул уңыш бирә торган. *Язлар чәчәкле булсалар, Көзләр җимешле була.* М.Җәлил

3) *күч.* Нәтиҗәсе уңышлы булган, продуктив. *Үтелгән юл ерак булмаса да, Эшләнгән эш безнең җимешле.* М.Крыймов. *Озын һәм бәрәкәтле, бик тә җимешле иҗат гомере белән яшәде Фәридә Кудашева.* Ф.Фәтхи. *1950 еллар ахыры – 1980 еллар башы – Наҗар Нәҗми иҗатының иң «җимешле» чоры.* Р.Миңнуллин

4) *күч. сөйл.* Күп әсәрләр иҗат итүче. *Энҗе Мөэминова озын иҗат гомерендә олылар өчен дә, балалар өчен дә бердәй актив язган, мул җимешле шагыйрьләр җөмләсеннән.* Әдипләребез

**ҖИМЕШЛЕК** I *и. бот.* Чәчәкнең аналык органы; җимшән; *русчасы:* **пестик**. *Бөртекчә – коры җимеш, аның элпәсыман җимешлек тирәлеге орлык кабыгына тоташып үсә, һәм шуңа күрә аны орлыктан аерып алып булмый.* Ботаника

**ҖИМЕШЛЕК** II *и.* Җимеш бакчасы; җимеш агачлары үскән урын. *Аска караса, гаҗәеп матур күренеш: гөлбакча, җимешлек, кәүсәр күле, хур кызлары... «Син, акыллы зат, оҗмах өстеннән үтәсең», – дип кычкыра әлеге фәрештә.* С.Поварисов

**ҖИМЕШЛЕКЛЕ** *с.* Җимеш бирә торган, җимеш барлыкка килә торган. *Җимешләр бары тик җимешлекле чәчәкләрдән, ягъни җимшәне булган чәчәкләрдән генә барлыкка килә.* Ботаника

**ҖИМЕШЛЕЛЕК** *и.* Агач яки куакның уңыш бирү сәләте. *Слива агачының җимешлелеген тикшерү*

**ҖИМЕШЧЕ** *и.* 1) Җимеш үстерүче, җимеш үстерү остасы

2) Җимеш белән сату итүче

**ҖИМЕШЧЕЛЕК** *и.* Җимеш үстерү белән шөгыльләнү, җимеш үстерү хуҗалыгы. *Ә ул [Искәндәр] ташландык авылны арендага алырга, бетүгә дучар ителгән яшелчә-җимешчелек тармагын тергезергә карар биргән.* А.Әхмәдуллин

**ҖИМЛӘ́Ү** *ф.* Кармак очына җим беркетү. *Карача бинең ике углы бар икән, икәве дә мәргән икән. Алар, сәелдән кайтканда, Ярмакның ар якта кармак җимләп утырганын күрәләр икән, аны мәзәк кылып атарлар икән: башына тидермичә, башыннан картузын атып төшерәләр.* Риваять

**Җимләп бетерү** Барысын да җимләү; ахыргача җимләү. *Кармакларны җимләп бетерү*

**Җимләп җибәрү** Тиз генә җимләү, җимләргә өлгерү

**Җимләп кую** Җимләп, әзер хәлгә китерү

**Җимләп тору** 1) Даими рәвештә җимләү. *Балык чирткән саен, кармакларны җимләп тору*

2) Әле, хәзер җимләү

**ҖИМЛЕ** *с.* 1) Җим куелган, җим салынган. *Бауларны тартып, көймәмне агымга аркылы куйдым; балыкларны үз тирәмә чакырырга җимле капчыкларны суга батыргач, кармак җепләрен сүттем.* А.Гыйләҗев. *Синең җимле кармагыңа балык капмавының бар хикмәте – боларның уылдык, маймычлардан башлап һәммәсен кыдырып ялмап кына баруында.* Ә.Гаффар

2) Җиме, азыгы булган. *Җимле ат армас.* Мәкаль. *Урманда кошлар юк, ни сәбәп микән? Мөгаен, җылы, җимле шәһәргә елышкан алар: каланың ала каргаларына өйдәш-кышташ булып кергәннәр.* Ш.Галиев

3) Калориясе күп булган, туклыклы. *Киндер орлыгы бик җимле ризыклардан санала*

**ҖИМЛЕК** *и.* 1) Кош-кортларга җим салу өчен ясалган махсус җайланма; *русчасы:* **кормушка**. *[Кошлар өчен] Агач җимлекләр ясадым, өй буендагы агачларга элә башладым.* Г.Хәсәнов

2) Бал кортлары өчен махсус ясалган кечкенә тагарак. *Иртәгәсен умарта кортларына ике җимлекнең берсен сайлап алу тәкъдим ителде: аларның берсеннән – шул ук әнис исе, икенчесеннән камфара исе аңкый иде.* Умарта кортлары

**ҖИМЛЕЛЕК** *и.* Туклыклы булу сыйфаты, калориялелек. *Борчак онының җимлелеге*

**ҖИМСӘ** *и. диал.* Үңәчнең киңәеп киткән өлеше; бүксә (кошлар турында). *Кошның җимсәсе тулган*

**ҖИМЧӘЧӘК** *и.* 1) *бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, тармакланып үскән туры сабаклы, пәрәвезсыман йончалар белән капланган күксел яшел яфраклы, чәчәкләре кайчандыр тукыма ману максаты белән, лимон сары буяу ясау өчен кулланылган, үзенчәлекле исле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **пупавка красильная**

2) *этногр.* Чәчәк бәйләмен суга корбан итеп китерү бәйрәме; апрель азагында үткәрелә торган байчәчәк, ягъни беренче чәчәк белән котлау бәйрәменнән соң шуның дәвамы буларак үткәрелгән; эргәзымбай

**ҖИМШӘН** *и. бот.* Җимешлекнең орлык ярала торган аскы өлеше. *Бодай, арпа, арыш, чия һәм күп кенә башка үсемлекләрнең җимшәнендә бары бер генә орлык бөре була.* Ботаника. *Орлык бөреләр җимшәннең эчке стенасында үсә һәм, үсемлекләрнең барлык башка өлешләре шикелле үк, күзәнәкләрдән тора.* Ботаника

**ҖИМШӘНЛЕК** *и. сир. к.* **җимешлек** I

**ҖИМШӘ́Ү** *ф. диал.* Чәчәктән җимеш төймәләнү

**Җимши башлау** Җимшәү билгеләре күренү

**Җимши бару** Аз-азлап, эзлекле рәвештә саны артып җимшәү

**ҖИНАЯТЬ** *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә кешеләрнең яшәвенә куркыныч тудыру белән бәйләнгән, закон тарафыннан тыелган куркыныч гамәл. *Җинаять белән табылган мал тәүбәсенә китәр.* Әйтем. *Иң ахырдан [гаепләүче], Вәли Хәсәновка килеп, аның җинаятен 57 нче матдәгә салып, иҗтимагый саклануның иң югары чарасы бирелергә: атылырга тиешле, диде.* Г.Ибраһимов. *Участковый мәсьәләне тиз аңлатты. – Бу хәл буенча җинаять эше кузгатып булмый, – диде ул, тыныч кына.* М.Мәһдиев

2) *сөйл.* Ярамаган эш, әдәп-әхлак кагыйдәләрен бозу. *Мондый яхшы иртәдә йоклап яту – җинаять, Гаяз, тор!* М.Әмир. *Шундый мәлдә Казанны калдырып китү зур җинаять булыр иде.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Җинаять өстендә тоту** Җинаять, тыелган эш эшләгән вакытта өстенә, янына килеп чыгу, җинаять эшләгәнен күрү

**ҖИНАЯ́ТЬ ИТҮ** *ф.* Җинаять эшләү

**ҖИНАЯ́ТЬ КЫЛУ** *ф. к.* **җинаять итү**. *Тоталитар режим, булмаган җинаятьләр кылуда гаепләп, әдипне [Мәхмүт Галәүне] зинданга яба һәм шунда гомерен кисә.* Әдипләребез

**ҖИНАЯТЬЛЕ** *с.* Җинаять белән бәйләнгән, җинаятьтән гыйбарәт. *Прошениедә мин, имеш-мимешләр буенча, нииндидер шикле адәмнәр белән аралашкан, алар белән бергә җинаятьле эшләрдә катнашкан бер кеше итеп сурәтләнәм.* М.Галәү

**ҖИНАЯТЬТӘШ** *и.* Икенче берәүләр белән җинаять кылуда катнашкан кеше. *[Ул] Үзенә җинаятьтәш итеп бергә училищеда укыган Романны алган.* Чистай хәбәрләре

**ҖИНАЯТЬТӘШЛЕК** *и.* Икенче берәүләр белән җинаять кылуда катнашу. *Закон нигезендә җинаятьтәшлек өчен кырыс җаваплылык каралган*

**ҖИНАЯТЬЧЕ** *и.* Җинаять кылган кеше, җинаять эшләүче; закон бозучы. *Җинаятьче бер кан койган җиренә өч килер.* Әйтем. *– Җинаятьчене шулай саклыйлармы? – диюгә, солдатлар, Сөләйманның җилкәсеннән эләктереп, Әсфәндияров яныннан тартып алдылар...* К.Тинчурин. *Потенциаль җинаятьче булуы аның бөтен кыяфәтенә чыккан.* А.Гыйләҗев

**ҖИНАЯТЬЧЕЛ** *с.* Җинаятькә бәйле, җинаятькә нигезләнгән. *Наркобизнес – җинаятьчел эшчәнлекнең иң керемле өлкәсе ---. Җинаятьчел дөнья яшүсмерләрне дә үз мәнфәгатьләрендә файдалана.* Сөембикә. *Розаның ир туганнары --- җинаятьчел дөньяда зур абруй казанган «авторитет» егетләр булып чыкты.* Казан утлары

**ҖИНАЯТЬЧЕЛЕК** *и.* 1) Закон тарафыннан тыелган эшчәнлек, законсыз гамәлләр, җинаять эшләре. *Бөтен җирдә җинаятьчелек, йогышлы чирдәй, көннән-көн күбрәк тарала.*

Ә.Еники. *Алман халкын ут эченә куар алдыннан, Гитлер немесләрнең тамагын туйдырды, --- җәмгыятьнең котын алып торган җинаятьчелекне юкка чыгарды.* М.Юныс. *Төрле республикалардан, илләрдән кергән чуар халык массасы җинаятьчелекнең үсеп китүенә сәбәпче булды.* Мәдәни җомга

2) Җинаятьче булу. *Җинаятьчелеген фаш итү*

**ЖИҢ** *и.* Өс киеменең беләкне каплап торган өлеше. *– Зөһрә, – диде ул, минем җиңемнән сак кына сыйпап.* Ә.Еники. *Әллә акылдан язам инде? Җиңемне күтәрә төшеп, беләгемне чеметтем.* М.Юныс. *Алдагы өйдән кыска җиңле, тезләренә тияр-тимәс итәгенә ак челтәр йөгерткән кызыл күлмәген җилфердәтеп, --- бер яшь кызыйның йөгереп чыгып китүе Фазылны сискәндереп куйды...* К.Кәримов

◊ **Җиңсез күлмәк кидерү** Кәфенгә төрү. **Җиң сызгану** Нинди дә булса эшне башларга әзер булып тору. *Җитәр инде, җитәр инде; Давайте, сызганыйк җиңне; Салып ташлыйк киемне; Һич өмид юк җиңне сызганмай.* Г.Тукай. **Җиң сызганып** Бөтен көчне биреп, ихлас күңел белән. *Авыр кара эштән тайчанмыйча, җиң сызганып эшләргә!* А.Расих. *Родос халкы җиң сызганып эшли, җимерелгән хуҗалыгын аякка бастырырга тырыша.* М.Юныс. *Җиң сызганып, бу инешне Буып куярга булдык.* Г.Зәйнашева. **Җиң эченнән йодрык күрсәтү** Яшерен төстә янау, эчтән үч алу теләге белән йөрү

**ЖИҢӘЧИ** *и. сөйл. к.* **җиңгәчи**. *Җиңәчи, өстәлгә йомырканы куеп, почмак якка кереп киткәч, абый, колагыма гына пышылдап: «Мендәр астыңа куям. Җиңәчәң юк чагында алып ашарсың», – диде.* Ә.Рәшит

**ЖИҢГӘ** *и.* 1) *к.* **җиңги**. *Әйе шул, мин синең җиңгәң булам, Камил!* Һ.Такташ. *Без, Рабига җиңгәнең хикәясе тәэсиреннән айный алмыйча, зур бер шөһрәт иясенә караган төсле сокланып, Артыкбикәгә карап тора идек.* М.Әмир. *Нәфыйк кергә. Әнисе белән җиңгәсенең кочаклашып торганын күреп, бик азга гына аптырап карап тора.* А.Әхмәт

2) *этн.* Туйдан соң, кызны кияү куенына кертергә әзерләүче хатын-кыз. *Йомагыл, ачуланып, кыз җиңгәләре аркылы кызга ишеттерергә кушып, каты-каты сүзләр әйтеп карады – берсенең дә файдасы булмады.* М.Әмир

**ЖИҢГӘЙ** *и. к.* **җиңги**. *Ай, Гөлсылу җиңгәйнең ядкаре!* М.Фәйзи. *Җиңгәй безгә ачу белән эндәште...* М.Гафури. *Ә Фәрхия җиңгәй күңеле балкый, Яз төненең тулган аедай.* Ш.Маннур

**ЖИҢГӘЛӘ́Ү** *ф. этн.* Кәләшнең битен ачып күрсәтү

◊ **Җиңгәли килү** *этн.* Җиңгә булып, кызны озата килү, кызны туйга әзерләү хезмәтен башкару. *Анда җиңгәли килгән хатыннар чыбылдыкны корып, киленнең урын-җирен җәеп куялар.* С.Сүнчәләй. **Җиңгәли бару** *этн. к.* **җиңгәли килү**

**ЖИҢГӘЧӘЙ** *и. сөйл. к.* **җиңги**. *Син дә, комитет булдым, диң, җиңгәчәй, ә?* Т.Гыйззәт

**ЖИҢГӘЧИ** *и.* 1) *к.* **җиңги**. *– Хатыныңны бикләп тотарга итәсеңме әллә? – Бикләр идем, җиңгәчи, бик бикләр идем, мин бит аны бик яратам.* Г.Ибраһимов. *Җиңгәчи, үзегез дә барып чыгыгыз.* Ш.Камал

2) *иск.* Фәхешханә тотучы хатын. *Аның өчен аларның үзләре тарафыннан ук Троицкий фәхешханәләрендә, Оренбург притоннарында, Казан җиңгәчиләрендә җитештерелгән фәхишәләр дә җитәрлек.* Г.Теләчи. *Аның борынгы халык музыкасы байлыгына өстәгән «яңа» музыкасы – «Баламишкин», «Дүдәк», «Ижбулдин» төсле җиңел жанрлы төче җиңгәчи көйләреннән ерак үтмәде.* М.Җәлил

◊ **Җиңгәчиләр йорты** Фәхешханә. *Шундый бичаралар, ник туганнарына ләгънәт укый-укый, елый-елый, җиңгәчиләр йортына барырга яки үз-үзләренә кул салырга мәҗбүр була бит.* Г.Әпсәләмов

**ЖИҢГИ** *и.* 1) Яше буенча өлкән ир туганның хатыны һәм аңа эндәшү сүзе. *Тумачи җиңгине кайда утыртыйм?* Г.Камал. *Безнең Вәли абый хатыны, кечерәк кенә гәүдәле, аксыл чырайлы Миңзифа җиңги, һәммәсеннән дә күбрәк яшь түгә иде.* Г.Бәширов. *Сиңа – җиңги, миңа – килен.* А.Әхмәт

2) *сөйл.* Үзеңнән өлкәнрәк яшьтәге хатын-кыз һәм аңа эндәшү сүзе. *Аны капка төбендә әңгәмә корып утыручы агайлар белән бабайлар да, сыер савып керүче апайлар, җиңгиләр дә – һәммәсе дә сүзләрен бүлеп, эшләреннән туктап тыңлыйлар.* Г.Бәширов. *Җиңги кеше өстәлләргә тәлинкәләр тезгән арада, без, урыныбыздан торып, идән буенча йөри башладык.* М.Әмир. *Ләкин инде монда бөтен кеше җыелгач, аш-су тирәсендә берәү дә калмагач, ашчы җиңгиләргә җәнҗаллашудан башка юл юк иде.* Ш.Камал

**ЖИҢДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **җиңү**. *[Николай патша] Харап иткән Рәсәйне. Сугышта да шул җиңдергән, халыкны да шул ач-ялангач калдырган.* Г.Бәширов

2) Кемнән дә булса җиңелү. *Кемнән җиңдергәнсең бит әле, бот буе малайдан бит.* Г.Гобәй

**ЖИҢЕЛ** *с.* **1.** 1) Авыр булмаган, аз үлчәүле. *Аның кечерәк кенә чикләвек агачыннан эшләнгән гаять таза, ләкин бик җиңел көпчәкләре дә бар иде.* Ф.Әмирхан. *Аның озын табанлы, куыш эчле, җиңел тимераяк аласы килгән иде.* А.Шамов

2) Җитез, тиз хәрәкәт итә торган. *Ул миңа елмаеп карады --- һәм җиңел адымнар белән китеп тә барды.* Ә.Еники. *Аны озатканда да, киенеп, урамга чыкканда да, Җәмилә Закированың йөзе шат, адымнары җиңел иде.* М.Маликова

3) Күп физик көч сорамый торган, ансат. *Бәлки, җиңелрәк эш табарга туры килер?* И.Гази. *Гасырлар буе фәкать төрле ялгыш яки җитешсез мәгълүматлар белән миңгерәтелгән башларга халыкның соравын тиешенчә җавапландыру һич тә җиңел эш булмады.* Н.Дәүләт. *–Эшең җиңел икән, – диде Нәфисә. – Адәм көлкесе. Ботак кисеп ала да шуңа исем ябыштыра. Шуның өчен акча да бирәләрме?* Р.Зәйдулла

4) Катлаулы яки четерекле булмаган, гади, тиз аңлаешлы. *Мәҗит Гафуриның мәсәлләре җиңел тел белән матур итеп язылганнар.* М.Җәлил.

*Телевизорда хатын-кызлар каналы бар монда – 38 нче канал, аны халык телендә «уайт траш чәнел» дип тә атыйлар, ягъни ак тәнлеләрнең иң түбән катламы карый торган канал, мин карыйм аны, теле җиңелрәк минем өчен.* Н.Измайлова

5) Көчле булмаган, сизелер-сизелмәс, җылы. *Каршыга искән җиңел су җиле Хөршитнең ап-ак ефәк шарфик астыннан, яңаклары турысыннан чыгып торган бөдрә чәчләре белән уйный башлады.* Ф.Әмирхан

6) Куе, тыгыз булмаган, йомшак. *Күк йөзе чиста, зәңгәр һәм Миңнурыйның косынкасы кебек җиңел иде.* Г.Әпсәләмов. *Бөтен икмәктәй түгәрәк ай вак җиңел болытлар арасыннан карап көлә.* А.Шамов. *Сөт пары сыман гына җиңел томан төшкәндә, иртәнге елга шулай якты, ак була.* И.Низамов

7) Юка, нәфис итеп эшләнгән. *Шул үтә юка һәм үтә җиңел зәңгәрсу пәрдә астыннан анда-санда иләк йолдызлар тонык кына җемелди.* Г.Әпсәләмов. *Ап-ак эшләпә, Тасмасы – кара, Җиңел бөркәнчек Җилфердәп бара.* З.Мансур

8) Артык куркыныч булмаган, тиз үтә, тиз төзәлә торган (авыру, яра, психик халәт). *Үзенең авыруы җиңел икәнен, тиздән йөриячәген бер-ике сүздә аңлатты.* Г.Ибраһимов

9) Хәрәкәтләнергә комачауламый торган, җайлы. *Билгеле инде: ял итүчеләр барысы да, иртәнге аштан соң, җиңел киемнәрдән генә --- диңгез буена ашыгалар.* Ә.Еники. *Джинса чалбардан, җиңел курткадан, аякларында кроссовка.* З.Хәким

10) Аз санлы пассажирлар йөртә торган, кечкенә. *Җиңел машинаның таныш тавышы Сискәндерде кинәт Шакирны.* М.Җәлил. *Кәҗә бәтиләрен кое өстеннән куркытып, җиңел автомобиль үтеп китте.* Г.Әпсәләмов. *Эшкә җиңел машинага гына утырып йөрисең.* М.Юныс

11) Житди мәсьәләләр күтәрмичә, көлдерүне, күңел ачуны максат итеп куйган (матур әдәбият, сәнгать әсәрләре турында). *Комедиягә тамашачы җиңел жанр итеп карарга күнеккән.* Д.Гыйймранова

12) Юка, эчтән җылытылмаган, язкөз кия торган. *Өстендә җиңел пальто*

13) Көнкүреш кулланылышындагы товарлар җитештерә торган. *Җиңел сәнәгать*

14) Җиңеллек һәм ныклык бирү өчен, башка металларга кушып коела торган. *Алюминий, магний, кальций, натрий һ.б.ш. – җиңел металлар санала*

15) *күч.* Градусы, куәте зур булмаган. *Әгъдәс кайвакыт, ресторанга кереп, шампанское кебек җиңел эчемлекләр эчеп утыра.* З.Хәким

16) *күч.* Мәшәкатьсез, борчусыз. *Җиңел тормышны ничек кенә яратмасын, рәхәтлеккә ничек кенә күнмәсен, кеше инде үзе дә моның артык икәнен сизә, табигать кушканнан читләшүен аңлый.* Н.Измайлова

17) *күч.* Табигатен кысмый торган, тыныч, күтәренке. *Ничектер, җиңел, рәхәт иде аның белән сөйләшүе.* Ә.Еники. *Ләкин андый җиңел кәеф миңа килмәде.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бернинди авырлыксыз, каршылыксыз, җайлы гына. *Яңа түгел түгелен дә, тик гөрелтесе шәп, чыбык белән бәйләнгән җирләре юк, пускачы җиңел кабына...* К.Кәримов. *Җисемнәр бүлеп чыгара торган, төрле тиз очып бетүчән матдәләр аның аша җиңел үтеп чыгалар.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү. *Алкалоидлар нигездә чәчәкле үсемлекләрдә булалар һәм, башлыча, тозлар, --- органик кислоталар хәлендә аларның төрле өлешләрендә тупланалар, кристаллар булып, җиңел бүленеп чыгалар.* Урман аптекасы

2) Ансат, җайлы, уңай. *Аңа да җиңел түгелдер инде. Шундый фаҗигадән соң, кешегә җан тынычлыгы бик кирәк шул.* Г.Әпсәләмов

3) Тиз, кызу, шәп. *Бүлмәдәге киеренкелек кимеде, барысы да үз эшләрен җиңел итеп, күңел күтәренкелеге белән башкардылар.* М.Маликова. *Кешенең хәлен белү җип-җиңел, аның йөрешенә бер карау җитә: бәхетле кеше җиңел басып, очып диярлек йөри, ә бичара авыр хәрәкәт итә.* Ф.Дәүбаш. *Аты болай җиңел күренә, тояклары да түгәрәк... бәлки, нәрсә булса да чыгар.* Ф.Хөсни

4) Сулыш алырга иркен, рәхәт. *Күл буендагы карлыганнарга --- әз генә кагылдыңмы, ниндидер әчкелтем ис тарала. Суларга җиңел, рәхәт.* Ф.Яруллин

5) Мәшәкатьсез, борчусыз, күп көч куймыйча, рәхәт. *Элек-электән түрәләрне майлап-җайлап җиңел көн итәргә күнеккән чибәр тормышлы кешеләр хәзер дә җаен таптылар.* Г.Бәширов

6) Аз гына, сизелер-сизелмәс. *Кыз җиңел генә көлемсерәде. Ә, дип, нидер исенә төшкәндәй, җиңел генә көлеп алды Сәфәр.* Ә.Фәйзи

7) Бик тиз, шундук. – *Кеше сүзенә җиңел ышана, имеш! – диде Һидият, җәберләнгән тавыш белән. – Азрак уйлап сөйләшергә кирәк!* Ш.Камал. *Җиңел кабынучан матдә*

8) Тиз; артык күп көч куюны сорамый. *Әйе, кешене елатуы гына җиңел, елмайтуы авыр икән.* Ф.Яруллин. *Ә биредә, Һун илендә, барысы да бик җиңел хәл ителә.* Ф.Урманче

9) Авырсынмыйча, каршылыксыз. *Ул, ни сәбәптәндер, җиңел генә риза булды.* Ә.Еники. *Ул тормыштагы һәртөрле көйсезлекләрне җиңел үткәрә.* М.Маликова. --- *мондагы халык күп хәлләрне шушы әйтемдәгечә кабул итә: җиңел итеп, көлке итеп, күңелгә алмыйча гына.* Н.Измайлова

10) Җайлы, уңайлы, хәрәкәткә комачауламаган. *Пристаньда --- юка җәйге күлмәкләр кигән кызлар, дамалар, җиңел генә, матур гына киенгән егетләр --- бер-берсен сәер вә тамаша итәләр.* Ф.Әмирхан

**3.** *хәб. функ.* 1) Зур көч, акыл таләп итми, ансат. *Дусны табу җиңел, саклавы авыр.* Мәкаль. *Мин бәхетсез дип зарланып яту җиңел.* Ф.Дәүбаш. *Бу түрәнең эше җиңел.* Н.Исәнбәт

2) Бик кулай, җайлы, уңай. *Бу аяк киеме белән йөрергә җиңел*

3) Тиз, кызу, шундук. *Ул [Ш.Усманов] Бу мәҗлескә ничек җиңел кергән булса, шундый ук җиңеллек белән шинелен киеп, башына шлемын элеп, чыгып китте.* А.Шамов

**4.** *и. мәгъ. сөйл. эвф.* Акылсыз, юләр кеше. *Ул аны әллә ничек «җиңелләрдән» саный иде.* Г.Иделле

◊ **Җиңел акыллы** 1) Өстән-өстән генә фикер йөртүчән, җилбәзәк; 2) Акылсыз, юләр, ахмак. *[Кызлары] Әллә нинди --- шаркылдык, җиңел акыллы бер нәрсә шунда.* Г.Ибраһимов. **Җиңел аягың белән** Бәхет, шатлык, уңыш, муллык алып. *Башкорт биясе безнең йортка җиңел аягы белән килде һәм безнең йортка бәрәкәт китерде.* Г.Ибраһимов. **Җиңел аяклы** 1) Эшне алга җибәрә торган, эшләгән эше уңышлы тәмамлана торган. *– Аягың да җиңел, яшьтән үк шулай иде, – дип, әтисе үгетләвен дәвам итте.* Р.Зәйдулла. *Кичтән йорт хуҗасы үзе «җиңел аяклы» дип санаган берәр ир кешене яисә ир баланы иртүк үзенә «бусагадан керү» йоласын үтәргә чакырып куя.* Р.Уразманова; 2) Берәр кеше килгәннән соң, эш уңса, әйтелә торган сүз. *– Аягың җиңел булсын, тавык-чебеш мул булсын! – дип теләк телиләр.* Р.Уразманова; 3) Тиз хәрәкәтләнә, җитез эшли торган кеше турында. **Җиңел баштан** Исерек килеш, бераз эчкән хәлдә; төптән уйламыйча. **Җиңел булып китү** Рухи киеренкелек бетү, күңел тынычлану. **Җиңелгә җигү** *к.* **җиңелчәгә җигү**. *[Алмачуарны] җиксәк тә, бик җиңелгә, якынга гына җигәбез.* Г.Ибраһимов. **Җиңел карау (уйлау)** Өстән-өстән генә фикер йөртү, житди мөнәсәбәт күрсәтмәү турында. *Түшләрен киереп, үрә катып йөргән бу кешеләр хатын-кызларга бик җиңел карыйлардыр төсле тоела иде миңа.* Ә.Еники. *Син гел шулай инде, Миңлегөл, җиңел уйлыйсың.* Ф.Хөсни. **Җиңел кәсеп** Көч куймыйча гына зур табыш бирә торган кәсеп. *Каяндыр дуслары да килеп чыкты, җиңел генә кәсебе дә табылды.* А.Расих. **Җиңел котылу** Хәвефле, хәтәр эштән зур зыян күрмичә котылу. **Җиңел көекле** Бик тиз борчылучан, паникага бирелүчән. *Безнең Хафиз – бик җиңел көекле кеше.* **Җиңел кузгалышлы** Тиз карар кабул итеп, иренмичә эшкә керешүчән. *Бу [Азымбай] – ябык, чандыр гәүдәле, эчкә баткан хәйләкәр күзле, җиңел кузгалышлы бер карт иде.* Г.Ибраһимов. **Җиңел кулдан** Эшне уңышлы итеп башлап җибәрү турында. **Җиңел мәҗлесле** Киң күңелле, ачык чырайлы. *Фәүзия апаның хәтерендә остазбикә гаять юмарт, киң күңелле, җиңел мәҗлесле, ягъни матур холыклы бер кеше булып уелып калган.* Р.Әмирхан. **Җиңелнең астыннан, авырның өстеннән** Оста, шома итеп эшли ала торган, авырлыктан кача белгән. **Җиңел пар белән** Мунчадан парланып чыккан кешегә әйтелә торган теләк. **Җиңел сөякле** Җитез хәрәкәт итә торган. *Шул [зоотехник] җиңел сөякле нәрсә икән, сыер фермасына да барып чыккан.* А.Расих. *«Җиңел сөякле малай» дип, гел мине эзләп йөриләр. Рәхәт тә соң ат өстендә килү.* Ф.Хөсни. **Җиңел сулап җибәрү (кую)** Киеренкелек кимеп, иркенләп, тынычлап калу. *Аның хәзер генә чыкмасын белгәч, Мөһимә, җиңел сулап, саубуллашырга ашыкты.* М.Маликова. *Мөдәррис абзый, аның бидоны, банкалары юклыгын күргәч, ничектер, җиңел сулап куйды.* Ф.Яруллин. *Тулаем алганда, республика укытучылары җиңел сулап куйды: «Ниһаять, без дә БДИның ни-нәрсә икәнен аңладык», – диде алар.* Мәдәни җомга. **Җиңел табигатьле** Җилкуар, җилбәзәк. **Җиңел якка ятып йөзү** Эшнең агышын, кая таба барышын сизеп, шул якка яраклашу, үз фикере булмау

**ЖИҢЕ́Л АРБА** *и.* Кеше утыртып йөрү өчен генә кулланыла торган арба, ике көпчәкле арба. *[Гыйбадәтханәнең] Түбәсенә дүрт ат җигелгән (латинча – «квадрига») җиңел арба – колесница куелган.* М.Юныс

**ЖИҢЕ́Л АТЛЕТИКА** *и. спорт* Йөгерү, сикерү, йөзү, ыргыту кебек спорт төрләре. *Чөнки Мөнип җәй буе җиңел атлетика белән шөгыльләнә, ә кышын – чаңгыда.* Р.Кәрами

**ЖИҢЕЛӘЙТҮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса авырлыгын басу, тәэсир итү көчен киметү, җиңел итү. *Син киткәч, мин бу кешенең сихерен җиңеләйттем.* Г.Гыйлманов. *Йөкне җиңеләйтү*

2) Газап, борчуларны киметү. *Сүземне бүлмичә, хәсрәтемне җиңеләйтергә ашыкмыйча, ничектер, үзалдына тирән уйга калып тыңлады ул мине.* Ә.Еники. *Ләкин алар башкаларны яратканнар, башкаларны күңел җылысы белән җылытканнар, башкаларның сызлануларын җиңеләйткәннәр.* М.Маликова. *Күрше палатада көннәр буе баш күтәрми яткан кешене әллә җәлләп, әллә бераз хәлен җиңеләйтергә теләп, бу яшь хатын-кыз елмаеп килеп керә дә: «Марат абый, берәр нәрсә кирәк түгелме?» – дип сорый.* Д.Гыйсметдин

3) Ансатлаштыру. *Савытлар аларны механик җәрәхәтләнүләрдән саклап кына калмый, --- вентиляция ролен үти һәм суынуны җиңеләйтә.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү. *Дәүләт семья турында зур кайгыртучанлык күрсәтә. Балалар учреждениеләре челтәре киң җәелдерелә, күп нәрсәдә өй эшләрен җиңеләйтергә тиешле көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм җәмәгать туклануы камилләшә.* Тигез гомер итегез!

4) Җиңел итү, түзәрлек хәлгә китерү. *Белмим әле, кемнең ихтыяҗыннан чыгып эшләнәдер бу – караларның тормышын җиңеләйтү өченме, әллә байлар яшәгән җирдә хакларны югары тотып, анда ярлыларны якын җибәрмәс өченме?..* Н.Измайлова. *Минкаура фиргавен халыкка хуҗалык эшләре белән шөгыльләнергә рөхсәт итә, яңа гыйбадәтханәләр ача, салымнарны җиңеләйтә.* М.Юныс

5) Кыенлыктан чыгарга ярдәм итү, коткару. *[егетләр] --- бер-берсеннән оялышып, күпме утырырлар иде, белмим, шулчак әни кешенең тавышы хәлне җиңеләйтте.* К.Кәримов

**Җиңеләйтә бару** Торган саен ныграк җиңеләйтү

**Җиңеләйтә башлау** Җиңеләйтергә тотыну. *--- кичләрен дәрескә әзерләнү, дәфтәр тикшерү, җәмәгать эшләренә бирелеп китү, тагын шуларга охшаш башка шөгыльләр аның авыр кайгысын берникадәр җиңеләйтә башлады.* С.Поварисов

**Җиңеләйтә төшү** Тагын да, бераз, берникадәр җиңеләйтү. *Үкенечне бераз гына булса да җиңеләйтә төшкән бер фикер шул: аның сәнгатен, хезмәтләрен бөтенләй үк юкка чыгара алмаганнар икән.* Ә.Баян. *Хәлне авыл хуҗалыгында эшләүче җитәкче татарларның*

*төп массасын берьеллык, икееллык мәктәпләрдә, төрле курсларда укыту азмы-күпме җиңеләйтә төшә.* Татарстан тарихы

**Җиңеләйтеп алу** Бераз, аз гына җиңеләйтү. *Судьяның хәлне бераз җиңеләйтеп аласы килде, ахры, ул сүзен шаяруга борды.* Ф.Бәйрәмова

**Җиңеләйтеп җибәрү** Бераз җиңеләйтү, җиңеллеккә этәргеч бирү. *Гади генә сүзләр Мидхәтнең күңелендәге авыр ташны кузгатып, җиңеләйтеп җибәргәндәй итте.* М.Маликова. *Бу кечкенә сер аларның икесенең дә йөрәкләренә куәт биреп, гәүдәләрен җиңеләйтеп җибәрә.* Ә.Дусайлы

**Җиңеләйтеп тору** 1) Һәрвакыт, гел җиңеләйтү. *Бала урынына иркәләп, бар сызлауларын җиңеләйтеп тордылар.* Х.Камалов

2) Хәзергә, вакытлыча җиңеләйтү. *Кемнәрдер, түшәмгә күзен терәп, күңелсез төн якынлашуына борчыла-борчыла, авыруын аз гына булса да җиңеләйтеп торырга тырыша.* Г.Бәширов

**ҖИҢЕЛӘЮ** *ф.* 1) Авырлыгы кимеп, җиңел булып калу. *Бораулаучылар кәрваны чыгып киткәч, паром җиңеләеп, сикереп куйды.* К.Кәримов

2) Җиңелрәк булу, кыенлыклар кимү. *Хаҗга бару хәзер җиңеләйде, «Юл газабы» дигән газап юк.* Ф.Яруллин. *Ике мәртәбә кабатлады, ике мәртәбә сузды, ләкин аңа карап кына хәле җиңеләймәде.* Ф.Хөсни

3) Рухи күтәренкелек тою, җиңеллек сизү. *Рухым үзенә яңа бер куәт, яңа бер дәрт алып, һәммә нәрсәнең төсе матурга таба үзгәрде, кулларым да, бөтен торышым да җиңеләеп, эшкә гайрәтем тәмам башкаланды.* Г.Ибраһимов. *Менә хәзер дә ул, җиңеләеп, бер сулады шикелле, һәрхәлдә, тәмам үзгәргән тавыш белән җылы итеп: – Сез – яхшы кеше, – диде.* Ә.Еники. *Җиңеләйгән кебек була хәлем, Янда басып Алсу торганда.* М.Хөсәен

4) Терелә башлау, хәл керү, сәламәтләнү; кәеф әйбәтләнү. *Авыруның хәле җиңеләю*

5) *эвф.* Акылдан язу, юләрләнү. *[Галимә апа] --- җиңеләйде. Ул, башын түбән иеп, бик нык исәпләгән кеше кебек утыра да, соңра, шатланган булып, кирәкмәс сүзләр әйтә.* М.Гафури. *Кайчан әмиребез акылы җиңеләя башлаган Сәлим ханга баш июдән туктар икән...* М.Хәбибуллин

**Җиңеләеп алу** Бераз вакытка, аз гына җиңеләю. *Ни бит, малай, сез киләбез дигәч, хатын бераз җиңеләеп алган иде...* Ф.Яруллин. *--- аерым мизгелләрдә һәммә хатын-кызның да холкы җиңеләеп алучан...* Р.Зәйдулла

**Җиңеләеп бару** Вакыт үткән саен ныграк җиңеләю. *Еларсың да, көләрсең дә. Әллә, Ходаем, бу җиңеләя башлаган кешеләр арасында ятып, чынлап җиңеләеп барам инде.* Ф.Хөсни

**Җиңеләеп йөрү** Әле, хәзер җиңеллек сизелү. *Ире кайткан көннәрдә Маһирә, зәңгәр күлмәген киеп, яшәреп, җиңеләеп йөрде.* А.Гыйләҗев

**Җиңеләеп калу** 1) Кинәт җиңеләю, кинәт җиңеллек килү. *Су, барыбер, көткәнчә салкын ук булып килмәде, шулай да, әйбәтләп юынгач, бераз хәл кереп, җиңеләеп калды.* Ә.Еники. *--- аның тәне мамык кебек җиңеләеп калган.* Г.Гыйльманов

2) Киеренкелек кимү. *Кеше, күңелен бушатса, җиңеләеп кала, диләр.* Ә.Еники. *Син шуның белән күңелеңне бушатасың, җиңеләеп каласың.* Ф.Яруллин. *Соңгы сүзләрен ул елый-елый әйтте һәм, кинәт җиңеләеп калгандай, ишектән атылып чыгып китте.* Ф.Хөсни

**Җиңеләеп китү** Кинәт җиңел булу; беркадәр җиңеллек сизү. *Басуда эш җиңеләеп китте.* Г.Гыйльманов. *Ул сиздерми генә үпкәләргә тула, җылы дулкын булып, эчкә тарала, тән үзеннән-үзе җиңеләеп китә.* Ф.Яруллин. *Маңгайларына тир бәреп чыкты, бит очларына алсулык йөгерде ---. Бераз җиңеләеп киткәндәй булды бит әле.* Р.Мөхәммәдиев

**Җиңеләеп тору** Әле, хәзер, кыска вакытка җиңеләйгән булу. *Әле менә бары кичәге көннән бирле генә бераз салкынча булып, һавалар җиңеләеп тора.* Г.Камал. *[Талип:] Ха-ха-ха! Тәннәрем җиңеләеп тора. Әллә нинди көн булды әле бу...* А.Гыйләҗев. *Быел чыгачак китабымны тапшырдым. Инде бераз җиңеләеп торам...* Х.Сарьян

**Җиңеләя бару** Аз-азлап, акрынлап җиңеләю, җиңеллеге арта бару. *Сандыгыннан яңа чүпрәк алып элгән саен, аның йөзе тагы да көләчләнә, хәрәкәтләре җиңеләя барды.* Ә.Дусайлы

**Җиңеләя башлау** Җиңеләергә тотыну. *Искәндәр кинәт кенә үзенең гәүдәсе җиңеләя башлаганны тойды.* Р.Вәлиев

**Җиңеләя төшү** Бераз җиңеләю, авыр тәэсирләрдән арына башлау. *Колынсыз калу хәсрәте бераз гына җиңеләя төште.* Г.Бәширов. *Хаклык шунда: илдә байлар күбрәк булган саен, халыкның тормышы җиңеләя төшә.* М.Әхмәтҗанов

**ҖИҢЕЛ-ҖИЛПЕ** *с.* Вак-төяк, әһәмияте булмаган. *Буш вакытларыңда ара-тирә кергәләрсең, җиңел-җилпе йомышларыбызны үтәштергәләрсең.* Ш.Камал

**ҖИҢЕ́Л КАВАЛЕРИЯ** *и.* 1) Махсус сайланган йөгерек атларда йөрүче, җиңел коралланган солдатлардан гыйбарәт гаскәр

2) *күч.* Эшен төгәл, җитез башкара торган, ашыгыч ярдәм күрсәтә алырлык кеше яки кешеләр төркеме. *Бездә «җиңел кавалерия» бик шәп иде. Бу – өч комсомолец-активисттан торган, эшне тиз башкара торган группа.* Х.Камалов

**ҖИҢЕЛЛӘНҮ** *ф.* 1) *к.* **җиңеләю** (*1 мәгъ.*)

2) *күч.* Кызып китү. *Сөйләшкәндә кычкырмагыз, җиңелләнеп вә кызып китмәгез, тавышыгызны бозмагыз, үзегез аңламаслык сүзләрне катыштырып сөйләмәгез.* Р.Фәхреддинов

**Җиңелләнә бару** Аз-азлап, акрынлап җиңелләнү

**Җиңелләнеп китү** Нindидер сәбәптән, вакыйгадан соң җиңеллек килү. *Гания [кияүгә чыккач] тиз арада тагы чибәрләнеп, нурланып, җиңелләнеп китте.* Г.Ибраһимов

**ҖИҢЕЛЛӘШТЕРҮ** *ф. сөйл. к.* **җиңеләйтү**. *Яңа заман техникасы җир кешесенең эшен шактый җиңеләштергән.* Ватаным Татарстан

**Җиңелләштерә бару** Торган саен күбрәк җиңелләштерү

**Җиңелләштерә башлау** Җиңелләштерүгә табан бару

**Җиңелләштерә төшү** Берникадәр җиңелләштерү; тагын да җиңелләштерү

**Җиңелләштереп җибәрү** Аз гына җиңелләштерү

**ҖИҢЕЛЛӘШҮ** *ф.* Җиңелгә әйләнү, җайланып китү, уңайлырак булу. *Шуның нәтиҗәсендә татар мәктәпләре, гимназияләре ачу җиңелләште, ул инде дәүләт сәясәтенә әйләнер дигән өмет туды.* Т.Миңнуллин

**Җиңелләшә бару** Торган саен ныграк җиңелләшү

**Җиңелләшә башлау** Җиңелләшү билгеләре күренү

**Җиңелләшә төшү** Бераз җиңелләшү. *Гаиләдә берничә бала булганда, тәрбия җиңелләшә төшә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**Җиңелләшеп алу** Берара, кыска вакытлы җиңелләшү

**Җиңелләшеп бетү** Тәмам, бик нык җиңелләшү

**Җиңелләшеп калу** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң җиңеллек килү

**ҖИҢЕЛЛЕК** *и.* 1) Авырлыгы аз булу; *киресе:* **авырлык**. *Җисми кагылу түгел Мамык җиңеллеге белән Ачылып китте күгем.* Б.Рәхимова

2) Уңайлы, җиңел булу: *киресе:* **кыенлык**. *Һәр авырлыкның бер җиңеллеге бар.* Мәкаль. *[Яңа, яхшы дөнья] Безгә нинди җиңеллек бирәсе, бу ачлыктан, хәерчелектән ничек коткарасы?* Г.Бәширов. *Әгәр кайбер ата-аналар, бу җиңеллек үзеннән-үзе барлыкка килә, дип уйласалар да, монда үз кыенлыклары килеп чыгуын күздән ычкындырмаска кирәк...* Тигез гомер итегез!

3) Канәгатьлек хисе, күңел күтәренкелеге; яхшы кәеф. *Семья фаҗигасен фаш итү миңа бернинди дә җиңеллек бирмәгән булыр иде...* Ә.Еники. *Ул [Ш.Усманов] бу мәҗлескә ничек җиңел килеп кергән булса, шундый ук җиңеллек белән --- чыгып китте.* А.Шамов

4) Көч, куәт, энергия. *Ул, бөтен гәүдәсендә гаҗәеп бер җиңеллек сизеп, Нәсимәгә эшләрен тәгәлләште.* К.Нәҗми

5) Җитезлек, җайлылык, иплелек. *Ул барында, палата, ничектер, үзгәреп киткәндәй була, аның пөхтә кыяфәтеннән, --- җирән бөдрәләреннән, нечкә үкчәле туфлиләреннән үзенә бер җиңеллек сирпелә...* М.Маликова

6) *күч.* Акылдан шашу, юләрлек, акылга зәгыйфьлек. *[Хәлим] Йөри инде шунда. Башына җиңеллек килмәсен дип куркам.* Г.Гыйльманов

◊ **Җиңеллек итү** Кемгә дә булса ярдәмләшү, авыр хәлен җиңеләйтү. **Җиңеллек ясау** *к.* **җиңеллек итү**

**ҖИҢЕЛМӘС** *с.* Сугышта, ярышта, көрәштә беркемнән дә җиңдерми торган, рухи һәм физик яктан барысыннан да көчле, өстен булган. *Атилла --- һәрвакыт үз-үзен бик тә горур тота белгән; үзенең ил-халкы алдындагы сәяси дәрәҗәсен, җиңелмәс көчкуәткә ия илнең хөкемдары булуын аңлап эш иткән.* Ф.Урманче

**ҖИҢЕ́Л ТАРАНТАС** *и.* Ике кеше утырып йөрерлек, терәлеп утырырга аркасы булган кечкенә арба. *Сарай астында җиңел тарантаска бәйләнгән зур кара айгыр гына солы сораган тавыш белән әкрен генә кешнәп куйды.* М.Әмир

**ҖИҢЕ́Л ТУФРАК** *и.* Комга, торфка бай туфрак. *Әгәр дә туфрак --- җиңел туфрак булса, орлыкларны тирәнгәрәк чәчәргә кирәк.* Ботаника

**ҖИҢЕЛҮ** *ф.* 1) Дошманга буйсынырга мәҗбүр булу. *Урыс солдаты беркайчан да җиңелми.* Р.Зәйдулла. *Византиянең ялкау, талантсыз яу башлыклары бик күп очракта җиңеләләр, меңнәрчә гаскәр бер дә юкка яу кырында ятып кала.* Ф.Урманче. *Кария армиясе җиңелгән илгә ясак салып кайтып киткәч, Родос шәһәрендә мәсхәрәле һәйкәл кала.* М.Юныс

2) Көрәштә, ярышта көндәшеннән оттыру, өстенлекне бирү. *Бар булсаң, биргәнеңне әйтмә, ир булсаң, җиңелгәнеңне әйтмә.* Мәкаль. *Ватан өчен утка төшсәң – үлмисең, гарең өчен сугышсаң – җиңелмисең.* Мәкаль. *Сугышканда Арнольдның җиңелмәве аны бермәбер шатландырды, әлбәттә.* З.Хәким

3) Карышмый башлау, бирешү, үз уеннан кире кайту, нинди дә булса көчкә, хискә каршы тора алмау. *Вак дулкыннар, бәрелә-бәрелә, биек каты ярларны ишә, Равиләнең күңеле алай каты түгел иде, җиңелде, заводтан чыгып, ательега урнашты.* Ф.Яруллин. *Син бирешмә, кызым, башың имә, Гел алга бар, көрәш, җиңелмә!* Ш.Җиһангирова

**Җиңелә бару** *к.* **җиңелеп бару**. *Тик хәзер инде үлем, кан коюю юк. Ачлык та җиңелә бара.* М.Мәһдиев

**Җиңелә башлау** Җиңелергә тотыну. *Ситдыйк абзый үзе ярый торган кеше булса да, хатынына чыдар әмәл юк иде, күрмәгән булып йөрсәм дә, җиңелә башладым.* Г.-Халикъ Садри

**Җиңелә төшү** Бераз җиңелү. *Баштарак аны кусам да, Соңнан җиңелә төштем. Әллә ничек бик тиз генә Язмыш белән килештем.* Ф.Яруллин

**Җиңелеп бару** Акрынлап, аз-азлап җиңелү. *Фашистлар, үзләренең котылгысыз үлемнәрен сизеп, Көнчыгыш фронтында җиңелеп барган чакта, тагын бер җинаять эшлиләр.* М.Җәлил

**Җиңелеп бетү** 1) Барысы да җиңелү. *Бар җәнлекләр җиңелеп беткәч, Кәҗә урыныннан кузгалган да итагатьле генә сүз каткан: – Фил әфәнде, миңа да рөхсәт итсәгезче.* Әкият

2) Тәмам, бөтенләй җиңелү. *Җиңелеп бетә яза, әмма бирешми. Җиңелүләрдән көч ала.* Х.Камалов

**Җиңелеп калу** Җиңелүгә дучар булу, җиңелгән хәлгә килү. *Әти-әнисе каршында да, шактый зур шәхесләр белән сөйләшкәндә дә, Галимҗан җиңелеп калуны яратмый.* С.Поварисов. *Шулай да җиңелеп каласы килми иде аның.* З.Фәйзи

**Җиңелеп килү** Һаман, системалы җиңелү. *Елан патшасының малаена әйтә: «Мин баядан бирле карап торам, сезнең гаскәр җиңелеп килә, булышыйм әле», – ди.* Әкият. *Моңарчы җиңелеп килгән әтәчтә агрессивлык сыйфаты кузгаткач, ул үзеннән көчлерәк әтәчләрне дә җиңә, талый башлый...* Ә.Баян

**Җиңелеп куюю** Кинәт җиңелү. *Тик «Пламя революции»дән җиңелеп куймасак ярар иде.* Т.Гыйззәт

**Җиңелеп тору** Һәрвакыт җиңелү. *Безнең алда барсы җиңелеп тора.* М.Әгъләмов

**ҖИҢЕЛҮЧЕ** *и.* **1.** 1) Сугышта яки сыйнфый көрәштә буйсындырылган, ярышта җиңелгән як; үзара ызгыш-

талашта, бәрелештә жиңелгән кеше. *– Син – әсир зат, ханбикә, жиңелүче як буларак, безнең таләпләрне үтәргә бурычлысың, – дип, вәкарь белән генә тезеп китә, – орышның кагыйдәсе шундый.* М.Әмирханов. *Бернича кабилә нидер бүлеп ызгышканнар. Җир бүлешкәннәрдер, күрәсең, жиңелүче як буш яткан урыннарга күченеп китә.* Р.Сәгъди

2) Ярышта алдынгылыктан төшеп калган төркем яки аерым бер кеше

3) Бәхәс вакытында каршы як фикере белән килешкән, фикеренең дөрес түгеллеге дәлилләнгән кеше; буйсындырылган, карышудан туктаган хайван. *Хәзер, менә хәзер су кызы җир егетен үзенә алып, жиңү тантанасын тирәюньгә белдереп бөтерелер. Башкалар да моны аңлар, аларның күз карашларында жиңелүчегә нәфрәт чагылыр.* М.Маликова. *Жиңелүчеләр, дуслашып, буйдаклар төркеменә берләшә, ә жиңүче болан белән ана боланнар көтү булып китә.* Хайваннар дөньясы

**2.** *и мәгъ.* Жиңелгән кеше. *Юра белән нык кына бәргәләшергә туры килде безгә. Жиңелүче дә, жиңүче дә булмады... Иртәгәсен күз төпләрем күгәргән килеш эшкә бардым.* Ф.Шәфигуллин

**ЖИҢЕ́Л ЧАНА** *и.* Ат яки башка төр хайваннарга җигеп, кешеләр утыртып йөрү өчен көйләнгән, ике табанга утыртылган җайланма. *Жиңел чанага җигелгән бер пар болан сәгатенә 10 км тизлек белән чаба һәм 100 кг йөк тарта ала.* Хайваннар дөньясы

**ЖИҢЕЛЧӘ** *с.* **1.** Жиңелнең уртача дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган кимлек дәрәҗәсен белдерә. *Якты кояштан кар җемелди, күз чагыла. Атлар өстендә жиңелчә бәс.* М.Хәбибуллин. *Элек Гыймай тозы жиңелчәрәк итеп пешерелгән ашларны ярата иде, хәзер кыркурак итеп пешерелгәнне хуп күрә.* Ф.Яруллин. *--- андый бала бер минут та урынында утырып тора алмый кебек; бертуктаусыз башка балалар белән жиңелчә конфликтка кереп тора...* Тигез гомер итегез!

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Артык куркыныч түгел, тиз төзәлердәй. *Әүхәдие соңгы хатында, жиңелчә яраланып, госпитальгә кердем дигән.* Ф.Яруллин

2) Сизелер-сизелмәс кенә, аз гына. *Минем тез буыннарым жиңелчә генә калтырап киттеләр, алар әллә ничек кенә, бик аз гына исергәннәр шикелле иде.* Ф.Әмирхан. *Ерактa яңгыр тоҗымнары аша жиңелчә өрфияләнеп торган урманнар тәбәнәгәеп калган сыман.* Р.Зәйдулла. *Суалчансыман амфибияләрнең тәннәре цилиндр формасында, арка-корсак юнәлешендә жиңелчә генә кысылган.* Хайваннар дөньясы

3) Йомшак кына, көчле басым ясамыйча. *Карт белән карчык үзара жиңелчә генә әйткәләшеп алалар.* Ф.Яруллин. *Әнисенең мондый жиңелчә тонга күчүе, болай караганда, Гөлчирәне дә чак-чак кына бушатып җибәрергә тиеш иде кебек...* Ф.Хөсни

4) Хәрәкәтләнергә комачауламый торган, юка һәм уңайлы киемнән. *Ямьле җәйге юл буенча җәяүләү жиңелчә киенгән яшьләр өчен авыр булмаса да, авылга кайтып житү белән, буыннарыбызда авырлык сизелде.* М.Әмир. *Жиңелчә киенеп, уйнап-көлеп йөрүче җилбәзәкләрне хәзер күрмәссең, барысы да тизрәк җылыга кереп посарга ашыга.* Г.Әпсәләмов

5) Тәэсире сизелер-сизелмәслек булган. *Кыргый житен үләне ялкынсынуга каршы, тирләткеч, үт куучы, сидерткеч һәм жиңелчә генә эч йомшарткыч буларак тәэсир итә.* Урман аптекасы

◊ **Жиңелчәгә җигү** Атны жиңел йөк тарту яки кешеләр утыртып йөрү өчен генә җигү

**ЖИҢЕЛЧӘЛӘП** *рәв.* Жиңелчәгә җигеп. *Өченче яшькә житкәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр. Акрынлап, жиңелчәләп җигә башлыйлар.* Г.Ибраһимов

**ЖИҢЕШ** *и. сир.* Жиңү, уңыш. *Яңа елда яңа жиңүләргә ирешкәч, ул жиңешен сөйләр.* Ш.Маннур. *Озатканда, халык комиссары миңа әйтә: колхоз тормышы – крестьяннарны бөлгенлектән, караңгылыктан шатлыклы якты тормышка чыгаручы иң зур жиңешебез, ди.* Ф.Бурнаш. *Хәзер инде миңа бу җырның менә дигән социаль мәгънәсе дә ачылып житте. Минем өчен жиңеш иде бу.* М.Әмир

**ЖИҢЕШЛЕ** *с. сир.* Уңышлы. *Язлар күп эшле булсалар, Көзләр жиңешле була.* М.Җәлил

**ЖИҢЕШҮ** *ф. сөйл.* Әрепләшү; бәхәсләшү, сүз көрәштерү. *Балтикада хезмәт иткән кеше белән кем генә жиңешә алыр безнең авылда!* М.Мәһдиев. *Настя әледән-әле Иван белән бәхәсләшә, жиңешә, аны үрти, котырта, шулай да ул малайны ярата.* Казан утлары

**ЖИ́Ң КАЙТАРМАСЫ** *и. к.* **жиң очы** (*1 мәгъ.*)

**ЖИ́Ң ОЧЫ** *и.* 1) Жиңнең беләзеккә таба тарайтыбрак тегелгән өлеше, манжет. *Шмит, сүзләренең тәэсирен белү өчен, сырмасының жиң очларын төймәләп торган Фатыйманы дикъкать белән күзәтте.* А.Расих. *Аклы күлмәкнең жиңе тар, Жиң очында хаты бар.* Татар халык җыры

2) Жиңнең кул чуклары чыга торган өлеше. *Ул әледән-әле жиң очын тарткалап, чыра шикелле юка беләкләрен яшерергә тырыша иде.* Г.Бәширов. *Ул майлы жиң очы белән әледән-әле маңгай тирен сөртеп ала.* Г.Иделле

**ЖИҢСӘ** *и.* 1) Киемнең жиңе тузмасын, каралмасын, беләкне камыл сыздырмасын һ.б. өчен, беләккә киелә торган махсус өстәмә жиң. *Минем белән янәшә торып битен чылатканда, Сәлимә, бүтәннәр күрмәслек итеп кенә, чигүле жиңсәсеннән алып, миңа кәгазьгә төргән бер кечкенә әйбер сузды.* Г.Бәширов. *Зәңгәр жиңсәләр кигән почта кызларының прессны печатьне, шапылдатып, конверт өстенә сугулары ишетелә.* Г.Ахунов

2) Сугылган бөртекне бушатканда, кирәкле юнәлештә кою өчен җайлаштырып, ныклы, чыдам тукымадан жиң сыман итеп тегелгән җайланма; шланг формасындагы улак-торба. *Төрле жиңсәләр ясаганда, мамык җебеннән эшләнгән тукымалар файдаланыла иде. Хәзер заводта синтетик җеп тукымаларын куллану технологиясен үзләштерү бара.* Б.Камалов

3) *кулин.* Мичтә азык-төлек пешергәндә кулланыла торган, кургашын кәгазеннән я булмаса кызуга чыдам башка берәр материалдан ясалган, жиң сыман капчык. *Үрдәкне жиңсәгә тыгып пешерү*

4) *анат.* Ашказанының зур булмаган бүлеге; *русчасы:* **рукав**

5) *анат.* Хатын-кызда һәм теше хайваннарда аналыктан килә торган канал; *русчасы:* **влагалище**. *Бозау салырга булса, сыер борчыла, аналык җиңсәсеннән канлы сыекча килә башлый.* Сөт терлекчелеге

6) *бот.* Кайбер үсемлекләрдә яфракның сабакны әйләндереп төреп алган түбәнге өлеше. *Җиңсә сабакны тагын да ныграк һәм чыдамлырак итә, буын араларының үсә торган яшь, йомшак өлешләрен зарарланудан саклый.* Ботаника. *Яфраклары алмаш торышлы, кыяксыман, пластинкасының җиңсәгә күчү урынында keче телле, өске ягы кытыршы.* Урман аптекасы

**ҖИҢСЕЗ** *с.* Җиңе булмаган яки җиңе бик кыска итеп тегелгән. *Башында кырпулы бәрхет бүрек, ак күлмәк өстеннән җиңсез казаки кигән.* Г.Гобәй. *[Килен] Иелгәндә ташып чыккан күкрәкләрен каплап, кабалана-кабалана, җиңсез, кыска күлмәгенең итәкләрен тарткалап ала һәм, тиз генә борылып, --- бакча капкасына таба йөзеп китә.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Җиңсез күлмәк кидерү** Үтерү, җанын кыю

**ҖИҢҮ** I *ф.* 1) Сугышта, яуда дошман гаскәрен буйсынырга мәҗбүр итү; тар-мар итү, таркату. *Дәрман бирдең, яшьлек, Давылларны, ябырылган яуны җиңәргә.* М.Хөсәен. *Аларның җиңеп кайтулары күзгә ташланып тора.* М.Юныс

2) Ярышта, көрәштә өстен чыгу, беренчелекне алу, уңыш казану. *Мин [кыйммәтле кәгазьне] тиз генә эләктердем дә, зур көрәштә җиңгән батырның бүләге сынлы тотып, әнигә китердем.* Г.Ибраһимов. *Җиңү бит ул – мәхәббәт кебек үк татлы нәрсә. Ә мәхәббәттә җиңү икеләтә татлы.* Ф.Яруллин

3) Кемне яки нәрсәне дә булса үзенә буйсындыру, анынча эшләргә, яшәргә мәҗбүр итү. *Халыкны хан да җиңмәс.* Мәкаль. *Мәүсәл сәләтле шәхес булган. --- ул хәйлә, акыл, тәҗрибә таләп итә торган дипломатия юлы белән җиңәргә яраткан.* М.Юныс. *1917 елда Февраль революциясе җиңгәч, татар-башкорт халкының күптәнге хыялы – Россия составында киң хокукларга ия булган автономия төзү теләген тормышка ашыру өчен уңай шартлар туа...* М.Әхмәтҗанов

4) Нинди дә булса халәттән чыгарга көч табу, үз-үзең белән идарә итә алу, ихтыяр көчеңне туплау. *Дөрес, баштарак тыелырга, йөрәгемне тынычландырырга, мәхәббәтне акыл белән җиңәргә чамалап карадым...* Ә.Еники. *Ялгызлыклар басты иңнәремә – Җиңәрменме язмыш сынавын?!* Ш.Җиһангирова

**Җиңә бару** Бер-бер артлы барысын да җиңү, даими рәвештә җиңү. *Кимчелекләрне әкренләп җиңә бару гына зур гыйльми ачышларга китерә.* М.Зәкиев. *Кайберләре исә, тормыштагы кыенлыкларны җиңә барып, реаль эшләргә юл табалар, ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**Җиңә килү** Дәвамлы рәвештә, электән үк, һәрвакыт җиңү

**Җиңеп ату** Тиз арада зур өстенлек белән җиңү, пыр туздырып ташлау

**Җиңеп бару** *к.* **җиңә бару**. *Гомер юлында очраган кыенлыкларны җиңеп бару, нинди генә газап булса да, татлы газап!* Н.Хәсәнов

**Җиңеп бетерү** Тәмам җиңү; барысын да җиңү

**Җиңеп кую** Уйламаганда кемне булса да җиңү

**Җиңеп ташлау** *к.* **җиңеп ату**

**Җиңеп тору** Бик еш җиңү. *Ә инде Атилла яуларына килсәк, ул һәрбер сугышта җиңеп тора.* Ф.Урманче

**Җиңеп чыгу** Көрәштә, сугышта өстен булу; тулысынча җиңү. *Биючеләр биегәндә, Идәннәре бөгелә. Ярышларда җиңеп чыктык, Безнең биисе килә.* Такмак. *Родос Алыбы селкенеп куя һәм турая, аның тирәсенә тупланган родослылар Кояш алласының җир тетрәүне җиңеп чыга алуына тәмам инаналар.* М.Юныс. *Бу көрәштә кайсы җиңеп чыгар – мин үзем әйтә алмыйм.* Н.Измайлова

**ҖИҢҮ** II *и.* Сугышта, көрәштә, эш-хезмәттә яуланган уңыш. *Көрәшсез – җиңү көтмә.* Мәкаль. *Без гел алга бардык, Җиңүгә юл ярдык, Карамыйча, әйе, бернигә!* М.Хөсәен. *Мәүсәлнең хатыны, --- бу зур һәм кодрәтле җиңүне тарихта калдыру өчен, Родос каласының үзәк мәйданына һәйкәл куйдыра.* М.Юныс

**ҖИҢҮЛЕ** *с.* Җиңүне белдергән, җиңү билгесе, тантанасы чагылган. *Корбангали бу сүзләрне тыныч һәм җиңүле тон белән сөйләде.* Ш.Камал

**ҖИҢҮЧЕ** *и.* 1) Сугышта, көрәштә дошманны җиңгән, үзенә буйсындырган кеше; җиңеп чыккан як. *Солдатлар, үзләрен җиңүче итеп тойсалар да, элекке дошман җирләрендә иканлекләрен онытмыйлар.* Х.Мөдәррисова

2) Ярышта алдынгылыкны алган, беренчелеккә ия булган зат. *Ул җыелышта җиңүчеләргә вымпеллар, байраклар тапшырылачак.* А.Расих. *Ярышларның иң мөһиме һәм кызыклысы булып көрәш санала, бүләкнең дә иң зурысы ат чабышында җиңүчегә һәм сабан туе батырына саклана.* Р.Уразманова

3) Башкалардан өстен чыгучы; үзе белән килешергә, аңа буйсынырга мәҗбүр итүче. *Җиңүчеләргә хас тавыш белән гәпләшергә тотындылар.* К.Кәримов. *Көз көне ата боланнар үз яннарына 2–5 ана боланны җыялар. Бу вакытта алар бик ярсу булалар... Ана боланнар, тезелешеп басып, җиңүчене көтәләр.* Хайваннар дөньясы

**ҖИП** *и. диал.* Зур кесә

**ҖИП-** *кис.* «Җ» авазына башланган «җиңел» сыйфатына ялганып һәм басымны үзенә алып, шул сыйфатның артыклык дәрәҗәсен ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Иш булачак кызны табуы да, «Әп» итү дә хәзер җипҗиңел.* Х.Туфан. *Югыйсә, ана карынныннан төшү, кендек киселү, имчәктән аерылу, сизмәвең, белмәвең аркасында, җип-җиңел ул.* Ә.Гаффар. *Их, иңнәреңә йоп-йомшак, җып-җылы, җип-җиңел тун элеп кенә менә шушы урам буйлап үтсәң иде дә, барлык тәрәзәләрдән барча хатын-кыз көнләшеп карап калса иде.* З.Мурсиев

**ҖИР** *и.* **1.** 1) Үз күчәрендә һәм Кояш тирәсендә әйләнә торган, тереклек дөньясы булган планета. *Җирдә нихәтле кеше булса, шулхәтле гомер*

*дә бар.* Г.Әпсәләмов. *Миллион еллар чамасы элек безнең Җир бөтенләй хәзерге кебек булмаган. Климат дымлы, җылы һәм ел буена бертөрле торган.* Биология

2) Җир өсте; аның атмосфера белән чикләнгән өлеше. *Кырга ак кардан Юрган ябылган; Җир язга чаклы Уйкуга талган.* Г.Тукай. *И кояш! Тизрәк җылыт җирне, терелдер дөньяны.* З.Ярмәки. *Ындырларда, таулар кебек булып, Салынганнар зур-зур кибәннәр. Болыннарда, каз бәпкәләредәй, җирне япкан яшел чирәмнәр.* Ә.Ерикәй

3) Аяк асты, йөри торган урын. *Бөтен җирдә кар эреп бетте.* М.Галәү. *Мулла, таяк очы белән бозлавык җиргә нык кына бәреп-бәреп, урам аркылы чыгып бара иде.* Ш.Камал. *Эшче, тәмәке төпчеген җиргә ташлап, итек башы белән аны сүндерә-сүндерә: – Габделхакны күптәннән беләсеңме соң син? – диде.* К.Тинчурин

4) Җирнең өске катлавы, туфрак; грунт. *Каяндыр атылган туп ядрәсе, атлы чех солдаты чабып барган ярга төшеп, юеш җирне һавага ыргытты.* К.Тинчурин. *Өйдә озак утырганга, саф тау һавасыннан, җир исеннән минем башым әйләнеп тора иде.* М.Маликова. *Әгәр суганчаны җиргә утыртсаң, төпчәдән аска таба – чуксыман өстәмә тамыр системасы, ә бөреләрдән яфраклар, чәчәк сабаклары үсеп чыга.* Ботаника

5) Хуҗалыкның ашлык чәчә һәм башка максатларда файдаланыла торган мәйданы. – *Мөселманнар! – дип кычкырды оратор. – Менә Учредительный собрание җыелыр, җир дә булыр, урман да бирерләр.* И.Гази. *Монда аларның борчак җирләре булган, безнең бабайларның. Шунда борчак җыярга килгәндә, әни утырткан бу агачны.* Ф.Хөсни. *Тиресле җирләрдә, кашлак урыннарда җирләре булган кешеләр аратирә ургалый да башладылар.* М.Гали

6) Басуда эшкәртергә бүлеп алынган кишәрлек, участок. *Хәзер инде аларның үз җирләре бар, тик алар уракны үзләре урмый, бәлки, өмә ясап урдыралар иде.* М.Галәү. *Җиребез башыннан узган кайсы кеше, сүз кушмый үтмәс өчен, Фәйзулла агайга: – Малайны арытма! – дип кычкыра.* Ш.Камал. *[Әткәй] Мәңге сабан-сука кермәгән бер җир – каты чирәм сатып алган.* Г.Ибраһимов

7) Диңгезләр, океаннар белән чолгап алынган зур мәйданлы коры урын; утрау, континент. *1912 елны ук Франс-Иосиф җире Россиянең котып тикшерүчесе Седовны үзенә тарта.* А.Алиш

8) Билгеле бер халыкның, илнең биләмәсе булган территория. *Рус җирендә без әсәрле, эзле без.* Г.Тукай *Кореяда һаман сугыш бара, кореялыларның үзара түгел, алар җирендә Рәсәй һәм Америка сугышып ятканын бөтен кеше аңлый...* А.Гыйләҗев // Аерым кеше кулындагы биләмә. *Ирем әйтеп тора: атай фатиха бирсә, җиреннән әзрәк өлеш чыгарса, бик кайтыр идек, ди.* Г.Ибраһимов

9) Торак пункт урнашкан урын. *Аларның өйләре каланың иң матур җирендә иде.* К.Тинчурин. *[Түбән оч Хәмит] Шул, ярлыланып бетеп, авылдан өмет өзеп, үзенең эшләп йөргән җиренә – агач заводына бөтенләй күчеп китте.* Г.Ибраһимов. *Гомумән, Клара, чын шәһәр кызы булганлыктан, авыл җирен өнәп бетерми иде. Нәрсә ул авыл? Азрак күрергә туры килде аңа мактаулы авыл җирен.* Ә.Еники

10) Туып-үскән урын, туган ил. *Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән.* Ә.Еники. *Кинәт Вәсиләләрнең чабыш атлары исемә төшә. Их, атланыр ием дә туган-үскән җиремә кайтып китәр ием.* Ф.Хөсни. *Тик патша аны [авылны], халыкның ай-ваена карамастан, генерал Останковка биргән. Һәм әлеге генерал Бәшенде авылындагы татарларны авылдан, җирләреннән куган.* Мирас

11) Җан башына тигән җир участогы, имана. *Кыз тапса, минем өлешкә тигән сыңар иманалык җирне дә тартып алырлар.* К.Нәҗми. *Җаны бугазына килсә, яртылай гүргә керсә, анда да ул Нурый эттән бер адым җир ала алмассың!* Г.Ибраһимов. *Яңадан җир өләшкәнче, аннан калган шул бер иманабызны, шәт, тартып алмаслар.* И.Гази

12) Аерым кеше яки оешмага караган биләмә. *Волостьтагы алпавыт, чиркәү, монастырь җирләрен бүгеннән «бөтен халыкныкы» дип игълан итәбез.* Т.Гыйззәт

13) Ара, ераклык. *Фатыйма бикәнең туган-үскән каласы болардан илле генә чакрым җирдә.* Г.Ибраһимов. *Ә хәзер [Дим күпере] шактый еракка күчкән икән. Шул сәбәпле, күп кенә җир әйләнеп, урап барырга туры килде.* Ә.Еники. *Бераз җир сүзсез барабыз. Бу сүзсезлек Госманга ошамый, ул, атын сикертеп, алгарак китә.* Ф.Хөсни

14) Нәрсәнең дә булса үзенчәлекле аерым өлеше, кисәге, урыны. *Яшьлек бит үзе дә иң матур җирендә Вакытлыча туктаган бер төш кебек.* Җыр. *[Сабирҗан мәзин:] Безнең Гыймади кызының кай җире килмәгән? Үзем яучы булырмын... Бирми калмас, Алла боерса.* М.Галәү. *Кай җире матур иде ул малайның, дип сорасалар, аңлатып бирә алмас идем, мөгаен: түгәрәк ак йөз, кара чәч, буйга кечерәк кенә.* М.Маликова

15) Кеше гәүдәсенең, тәненең бер өлеше. *Сәетгали, килеп, сәке кырыена гына утырды. – Кай җирең авырта соң? – Авырткан җирем дә юк кебек... Тыным кысыла, сулавы авыр... – диде Акъәби, бугазын һәм күкрәген сыйпап.* Ә.Еники. *Хәмидә әби: – Кай җирең авырта, балам? – дип сораугa каршы: – Юк, бер җирем дә авыртмый, тик менә йөрәгем кага... башым авырта.* М.Гафури. *Сезнең госпитальдә дәваланучы фәлән кызның кай җире яралы: кулымы, аягымы, башымы, күземе яисә башка берәр җиреме?* И.Гази

16) Урнашкан урын, булган, торган мәйдан. *[Егетләрнең] Күбесе яткан җирләрендә йокыга киткән.* Ш.Усманов. *Карт, авылга кергәч, йөрешен кызулатты. Билгеле бер барып керә торган җире бар кеше шикелле, бер дә икеләнүсез, эре-эре атлап бара, кайбер җирләрдә кар өемнәренә дә сөртенә иде.* Ш.Камал. *Урамның урта бер җиреннән көн эссесендә берәү бара...* М.Мәһдиев

17) Аерым бер хуҗалык, йорт, гаилә. *Кыз яхшы җиргә төшсә – җалпая,*

*яман җиргә төшсә – картая.* Мәкаль. *Яше җитүен җитсә, ару гына җирдән кыз бирерләр иде үзенә.* М.Фәйзи

18) *иск.* Чәчүлек мәйданының үлчәү берәмлеге: ике дисәтинә, ягъни буе – 80, иңе 60 сажиннан гыйбарәт мәйдан. *Безнең ярты җир солы бар, --- инде саргаеп килә.* Г.Ибраһимов. *Бер ир башына бер таяк җир – җирмени ул?! Хатын-кыз бөтенләй өлешсез иде.* Казан утлары

19) *к.* **җирлек** (*3 мәгъ.*). *Быел теккән күлмәгемнең безгә күк, җире ак.* Җыр

20) Хезмәт итү урыны, хезмәт вазифасы. *Бәйрәмнең өченчесе ни дисәк, ул – Илфарның ташчылар бригадасы башлыгы булган җиреннән прораб итеп билгеләнүе.* Б.Камалов

21) Кирәк, хаҗәт. *Ал, берәр җиреңә ярап куяр.* Т.Гыйззәт

22) Чара, мөмкинлек; хәл. *Бер дә кабар җирем юк*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) **җиргә** *юн. кил. форм.* Аска таба, түбәнгә. *Башны җиргә ию*

2) **җирдә** *у.-вак. кил. форм.* Тапкыр, мәртәбә, саннарны тапкырлаганда, кушканда. *Ике җирдә икең дүрт була, дүрт җирдә дүртең уналты була*

3) **җирендә** *тартымлы у.-вак. кил. форм.* Тиешенчә, үз урынында, кирәгенчә, нормаль. *Җирле – җирендә, җикән – күлендә.* Мәкаль. *Һәрбер гәүдәм җирендә, ләкин хәзер башым гына урынында түгел.* Г.Камал. *Иртә белән, торып, лампаны тикшерәләр, аның бөтен нәрсәсе җирендә табыла. Керосины да ярты савыттан артыграк булып чыга.* К.Тинчурин

**3.** *бәйл. функ. чыг. кил. форм.* **җирдән, җиреннән** 1) Үзеннән алда килгән сүз белән кемнең яки нәрсәнең нинди хәлдә булуын аңлата: хәлдә, килеш, рәвештә. *Тешләгән җиреннән өзеп чыгармыйча туктый белми торган, авыр табигатьле бу кешегә карата Арысланда ихтирам хисе уяна башлады.* Г.Ахунов. *Ул бик кызу канлы, башына уй кердеме – чыгар димә. Тоткан җиреннән сындыра.* Г.Мөхәммәтшин. *[Илсөяр] Түгәм дип, чиләккә үрелгән җиреннән туктап калды: аның күзләре соры шинельлегә төште.* Г.Гобәй

2) Үткән заман сыйфат фигыль янында килеп, вакыт төшенчәсен аңлата. *Уйламаган җирдән син килдең дә Ут салдың йөрәгемә.* Ә.Ерикәй

3) Каршы кую өчен кулланыла; «теләмәсә дә» мәгънәсен аңлата. *Карамас җиреннән карады кызың.* Ф.Хөсни

**4.** *хәб. функ.* Нәрсәнең дә булса капма-каршысын белдергәндә кулланыла. *Дәшми каласы җирдә кычкырып утыра. Киңәш бирәсе җирдә көлеп утыра*

◊ **Җир акырып** Яман, ямьсез тавыш белән. *Лачкылдатып битемә төкерде дә җир акырып еларга тотынды.* В.Нуруллин. **Җир астыннан калыккандай** Кинәт, көтмәгәндә алга килеп басу турында. *Мәнә көтмәгәндә, җир астыннан калыккандай, алда Шәрәфи калкып чыкты.* Ш.Камал. **Җир белән күк аермасы** Бер-беренә берниндиi дә охшашлыгы булмаган ике нәрсә турында. *Надан белән галим арасы – җир белән күк аермасы*. **Җир белән күк арасы** 1) *к.* **җир белән күк аермасы**; 2) Билгесезлек. **Җир белән тигез итү (тигезләү)** Җимерү, вату, кыру, юк итү. *Шулай була кала икән, үзеңне генә түгел, бөтен нәсел-нәсәбеңне җиде буынга кадәр корытырмын, алачыгыңны җир белән тигезләрмен.* М.Хәбибуллин. *Аксак Тимер Болгар, Биләр шәһәрләрен җир белән тигез итте.* Мирас. **Җир бете** Тәбәнәк, карсак буйлы кеше турында. **Җир бит** Оятсызның оятсызы, гарьсез. *– Ялганлыйсың, җир бит! – диде.* Г.Бәширов. *Ике-өч карчык, --- ул кайтуга, аңа ябырылдылар: – Кара син моны, денсез нәмәстәкәйне! Җир бит икәнсең, оятсыз, затсыз...* Казан утлары. **Җиргә салу** Үтенечне тыңламау, үтәмәү. *Сөйлә инде, ни хәбәр бар, иптәшем, назланмыйча, Әллә нидә бер соравымны да җиргә салмачы.* Г.Тукай. *Мансуровның теләген җиргә саласы килмәде.* Г.Бәширов. *– Мәнә рәхмәт, кода, чакыруымны җиргә салмыйча керүеңә, – диде Касыйм, өстен чишенәчишенә.* Р.Төхфәтуллин. **Җиргә сеңгәндәй булу** Тавыш-тынсыз югалу, юкка чыгу, юк булу, күренми башлау. **Җирдән көткәнне [Алла] күктән бирү** Көтелмәгән җирдән берәр табыш килгәндә әйтелә. *Ай Аллам, мәнә син тамаша, мәнә син рәхмәт яугыры, җирдән көткәнне күктән бирде.* Г.Ахунов. **Җирдә ятмау** Сирәк очрау, кадерле булу. *Ал, ал, мондый мал җирдә ятмый.* Н.Исәнбәт. **Җиренә җиткереп (җиткерелеп, җиткезеп)** Шартын китереп, тиешенчә башкарып, төгәл, пөхтә итеп; аңлаешлы итеп. *Киленем эшкә килгәндә дә үзен сынатмый. Шушы йортта дүрт-биш ел гомер иткән кебек, --- җиренә җиткереп эшли.* Г.Толымбай. *Иртәгә җыен бәйрәме башланасы дигән көнне инде бөтен әзерлек җиренә җиткерелгән, өй эчләре бизәкле ашъяулык, чүпләмле сөлгеләр белән бизәлгән.* М.Галәү. *[Сибгат Хәким] Кемнеңдер шәхси үтенече булса, ул аны җиренә җиткереп үти, таш атканга да аш ата.* Т.Галиуллин. **Җир җимерттереп** Гайрәт, җегәрлек белән, актив эшчәнлек күрсәтеп. *[Шәвәли абзый] Инде әүвәлгечә җир җимерттереп эшли алмый – эшли алмавы өчен үрсәләнә.* Г.Ахунов. *Эштән курыкмаган һәм җир җимерттереп эшлисе килгән кешегә эш бар!* Татарстан яшьләре. **Җир(не) җимерттереп (җимертеп) йөрү** Сау-сәламәт, рухланып, гайрәтләнеп йөрү; эштә, гомумән, тормышта активлык күрсәтү, оптимист булу. *Бер --- әмиркән кәвеш алырбыз. Шуны киеп, кодагыйлар алдында җирне җимертеп йөрерсең*. М.Фәйзи. **Җир җимеше булып яту** Каты авыру, үлем чигендә яту. *Мәнә инде Бохара берлән Оринбур арасында кәрван йөрткән гайрәтле ир бүген түшәктә җир җимеше булып ята.* Н.Исәнбәт. **Җир йоту** 1) Дини ышану буенча: гөнаһлы кешеләргә Алла тарафыннан бирелгән җәза. *--- ул чынлап та күренмәс булды. Ары карадым, бире карадым – җир йотты диярсең, юкка чыкты.* Ф.Яруллин. *Икмәк шундый кирәк чагында, сугыш вакытында, җирне кысыр калдырсаң, җир йотар үзеңне, белдеңме шуны, җир йотар!* Г.Бәширов; 2) Сизмәстән кинәт юкка чыгу, бетү, юк булу. *Җир йотамы аның игеннәрен, Әллә җеннәр урлап качамы?* М.Гафури; 3) Ант итү, ышандыру сүзе. *– Каенатайга әйтәм, җир йотсын әгәр, барам да әйтәм, –*

*дип, усал сүзләренә карамастан --- бөтен бер чирек акны алып кайтты.* Г.Ибрагимов. **Җир йөзеннән себереп түгү** Бөтенләй дөньядан юк итү, халкын, нәселен калдырмау, кырып бетерү. *Вакыт килер: безгә үлем, хәсрәт алып килгән фашист ерткычларын Җир йөзеннән себереп түгәрбез.* Р.Ишморат. **Җир куенына керү** Үлеп, җирләнү. *Ул җәйнең иң җылы, иң матур вакытында җир куенына керде.* М.Мәһдиев. *Ул, эшне аңлагач, карусыз гына гариза язды, китеп барды һәм ...коллективтан аерылгач, озак та үтми, җир куенына кереп ятты.* М.Мәһдиев. **Җир куенына салу** Җирләү. *Ай-һай дөнья, вай дөнья, кемгә вафа кылдың сән? Искәндәрдәй падишаны җир куенына салдың сән.* Бәет. **Җир куенына тапшыру** *к.* **җир куенына салу**. **Җир күтәрмәс (күтәрмәстәй)** Гаять зур, авыр (җинаять, гөнаһ һ.б. турында). *Җир күтәрмәстәй бозык кеше ни сөйләнә, ишетсәң, колак пәрдәләрең ярылырлык.* Ә.Баянов. *Бу нинди җир күтәрмәс кабахәтлек? Мин сорыйм синнән!* Н.Исәнбәт. **Җир кыры** *к.* **җир чите**. **Җирнең ертыгын ямау** *ирон.* Юк-бар сәбәп, кимчелек табып, шуның белән бик каты мәшгуль булу. **Җир селкетеп** Нык итеп, ышанычлы адымнар белән. *Элеккечә җир селкетеп атлый.* Р.Төхфәтуллин. **Җир тарткан** *ирон.* Тәбәнәк, кыска буйлы кеше турында. **Җир тишегенә керерлек булу** Бик нык оялу. *Җир тишегенә керерлек булдым.* Г.Камал. *Теге вакытта Такташ тәнкыйтьләгәннән соң, җир тишекләренә керердәй булдым.* Ф.Хөсни. **Җир тырмашып** 1) Чамадан тыш көч түгеп, бар хәленә азапланып. *Яшьли тол калып, ике ирдән тапкан ике баласын җир тырмашып үстергән.* М.Маликова; 2) Өзгәләнеп, ачыргаланып. *Мәгыйшә, өшәнчеге яшерелгән җиргә ятып, менә шушында гына иде, шушы төштә генә иде ич, дип, җир тырмашып елады.* Г.Ахунов. **Җир убу** *к.* **җир йоту**. **Җир убылгандай** *к.* **җир упкан кебек**. *Әле бүген генә янызызда йөгереп йөргән сабыегыз яки якын кешегез җир убылгандай юкка чыксын әле.* Шәһри Казан. **Җир упкан кебек** Көтмәгәндә, кинәт юк булу, юкка чыгу. *Мулла, биргәнне дә санап тормыйча, кесәсенә салды да, --- Сәфәргалине эзләргә тотынды. Ләкин малай, җир упкан кебек, каядыр юкка чыккан иде.* Казан утлары. **Җир упсын әгәр** Әгәр сүзем ялган булса, үземне җир упсын, дигән мәгънәдәге ант сүзе. **Җир үкереп** Кычкырып, үкереп; ыңгырашып. *Ниемә дип җир үкереп елый шул бала?* Ш.Камал. **Җир үтә (аша) китәрдәй булу** Бик нык оятлы булу, кая качар урын тапмаслык хәлгә килү. *Оятымнан җир үтә китәрдәй булдым, кайда аяк басып торганымны белмәдем.* **Җир чите (кыры)** 1) Горизонт, җир белән күк тоташкан урын. *Акрынлап кына кояш та җир читенә якынлашып бара.* Ә.Еники; 2) Бик ерак җир, ерак урын. *Бер кайтмасак, бер кайтырбыз, Киттек җирнең читенә.* Җыр

**ҖИРАЛМА** *и. диал.* Бәрәңге. *Чуваш авылында да сөйләп тордылар бит әле: көчләп җиралмасын утырттырган өчен, ничә авыл бунт күтәрде, дип.* М.Галәү

**ҖИ́Р АНА** *и. шигъ.* Җирне иң кадерле, иң изге кешегә – анага тиңләү. *Шундый кояшлы, борчаклы, тилгәнле моңсу бер көндә межага утырган гына идек ... кинәт авыл ягыннан җир ананың тешен суыргандай шөбһәле бер шыгырдау ишетелде.* М.Мәһдиев. *Нигә кыен бүген? Ни булды? Җиргә кичте Әллә бер ананың бер улы, Әллә Җир ананың бер улы?* Р.Гаташ. *Җир ананың әлеге өч һиммәте [таулары] --- авылны як-яктан ышанычлы камап тора, елның һәр мизгелендә дә аны җил-давыллардан саклый.* Мирас

**ҖИРАСТЫ** *с.* Җир астындагы, җир астына урнашкан; җир астына бәйле. *Узкөчәнеше булган тимербетон басымлы торбаларда, монолит һәм җыелма су чаннарында, спорт һәм җирасты корылмаларында кулланыла.* Төзү материаллары. *Кулланылыш сыйфатына карап, эчәргә яраклы, техник, минераль һәм сәнәгати җирасты сулары була.* Физик география

**ҖИ́РАСТЫ ЕЛАНЫ** *и. зоол.* Тропик якларда туфрак астында яши торган зур булмаган елан; *русчасы:* **слепун**

**ҖИ́РАСТЫ КУЫШЫ** *и.* 1) Тау куышы, мәгарә. *Бу вакытта Галиең җирасты куышында китап язып утырган Әбүгалисина рәвешеннән, нәрсәдер сизенгән кебек, тора да кибет алдына чыгып баса.* Н.Исәнбәт

2) Землянка

**ҖИ́Р АТМОСФЕРАСЫ** *и. геогр.* Җир шарын урап алган һава сүрүе. *Җир атмосферасы, Җирдән аерылмыйча, аның белән бергә бербөтен буларак әйләнә.* Физик география

**ҖИРӘ** *и. бот. диал.* Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан ике яки күпьеллык үлән үсемлек һәм аның аш тәмләткеч буларак кулланыла торган хуш исле төчкелт орлыгы; әнис, әнеч; *русчасы:* **тмин**

**ҖИРӘН** *с.* 1) Кызгылт сары. *Урыннан кузгалуга, без өч ат – мин, күк бия, тагын бер җирән чабышкы – бер-беребезгә бәрелә язып, янәшә оча идек.* Г.Ибраһимов. --- *үләндә йөргән җирән алаша да әледән-әле башын селкеп куя.* Ә.Еники. *Ат төсе, без уйлаганча, ике-өч төрле генә булмый икән. Аның коласы да, җирәне дә, алмачуары да, бурлысы да була икән! Каян белеп бетергән боларны Мәскәү кешесе?* М.Мәһдиев

2) Чәче, сакалы, кашы, мыегы шундый төстә булган. *Кызлары да, суеп каплагандай, әниләренә охшаганнар, әниләре кебек барысы да эре сөякле, җирән чәчле, зур соры күзлеләр...* Ә.Еники. *Беренче булып зур гына борынлы, җирән мыеклы кеше дәште.* Ә.Фәйзи. *Җирән чәчле, җирән кашлы, урта буйлы кеше – кырчылык бригадасы бригадиры Сәлмән Галләмов кайтырга җыена башлады.* Х.Сарьян

**ҖИРӘНГЕЧ** *с.* **1.** 1) Пакь булмаган, пычрак, җирәндерә торган. *Күз алдында әлерәк кенә үзе илтеп түккән җирәнгеч сыекча җәелеп ятты, борынына шундагы ачы, тәмсез исләр килеп бәрелгәндәй булды.*Н.Фәттах. *Арттан килеп юеш куллар белән күзен каплауга, борынына җирәнгеч аракы исе бәрелде.* Г.Бәширов

2) Күңелдә җирәнү хисе уята торган, күңел кайтаргыч, әхлакка сыймый торган. *Боларның бу кадәр җирән-*

*геч кыяфәтләренә карап, ничек итеп түзеп торырга кирәк.* Г.Камал. *Шулай да Хасиятнең начар ниятле, майлы, елгыр күзләре, елан сызгыруыдай гыжылдап чыккан әшәке сүзләре күңелдә --- жирәнгеч бер тойгы калдырды.* А.Шамов. *Чөнки ул белә: синең, үз гомереңне саклап калу өчен генә, үз илеңне сатканыңны һәм шул ук немецларны да җиңел генә сатачак җирәнгеч бәндә икәнеңне.* Мирас

**2**. *и. мәгъ.* Тиргәү сүзе. *Тьфу, җирәнгеч, әле ярый, башка киткән вакыт булмады.* Г.Камал

**ҖИРӘ́Н ГӨМБӘ** *и.* Сөтчел гөмбәләр ыругына караган, ылыслы урманнарда үсә торган, кызгылт җирән эшләпәле, ашарга яраклы гөмбә; *русчасы:* **рыжик**. *Җирән гөмбә Россиядә барлык урман зоналарында үсә.* Е.Солодухин

**ҖИРӘНДЕРГЕЧ** *с. к.* **җирәнгеч**. *Күзләренең борын почмагына җирәндергеч ак эрен җыелган.* Р.Сибат. *Кол Шәриф, тетрәнеп, дисбе әйләнешен күзәтә, аны туктатасы, бу дәһшәттән, җирәндергеч канлы суешлардан, колагында яңгыраган елаш-каргышлардан арынасы, ял итәсе килә.* Ф.Латыйфи

**ҖИРӘНДЕРҮ** *ф.* Җирәнү хисе тудыру. *Күргәнең бардыр, артык төчеләнгән ирләр җирәндерә, артык тупас хатыннар үзләреннән биздерә.* Т.Миңнуллин. *Әшәке сүз мине җирәндерә!* Ә.Баян

**Җирәндерә төшү** Беркадәр, бераз җирәндерү

**Җирәндереп бетерү** Җирәнү дәрәҗәсенә җиткерү; бик нык җирәндерү

**Җирәндереп тору** Даими рәвештә җирәндерү; җирәнү хисе кичерергә мәҗбүр итү

**ҖИРӘНЕЧ** *с. к.* **җирәнгеч**. *Боларның бу кадәр җирәнеч кыяфәтләренә карап, ничек итеп түзеп торырга кирәк?* Г.Камал

**ҖИРӘ́Н КАШКА** *и.* Маңгаенда ак табы (кашкасы) булган җирән төстәге ат яки сыер. *Җирән кашка, яшь булса да, көчле икән: шулчаклы печән белән биш кешене йөгертә.* Г.Ибраһимов. *Әйдә, кызым, үз күзең белән барып күр әле җирән кашканы.* Р.Ишморат

**ҖИРӘНКЕЛ** *с. диал. к.* **җирәнсу**. *[Бригадир] Карасу көрән чәчен ниндидер әмәлләр белән җирәнкел төскә кертә алган чибәр кыз Асиягә күз атаата, көлешкән эшчеләр янынннан әйләнеп килде.* Э.Касыймов

**ҖИРӘНЛӘНҮ** *ф.* Җирән төскә керү, җирән төс алу

**Җирәнләнә бару** Торган саен ныграк җирәнләнү; җирәнләнүе көчәю

**Җирәнләнә төшү** Беркадәр, бераз җирәнләнү; тагы да ныграк җирәнләнү. *Диңгез кояшында Дәнис чүлмәктәй каралды, болай да җирән сакалы тагы да җирәнләнә төште.* М.Хәбибуллин

**Җирәнләнеп бетү** Тулысынча җирәнләнү; тулысы белән җирән төс алу

**Җирәнләнеп җитү** Тулысынча җирән төскә керү

**Җирәнләнеп калу** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң җирәнләнгән хәлгә килү; җирән төс алу. *Көз көне кырлар, урманнар җирәнләнеп калды*

**Җирәнләнеп килү** Акрынлап, азазлап җирәнләнү. *Тайның төсе җирәнләнеп килә*

**Җирәнләнеп китү** Кинәттән, тиз арада җирәнләнү; җирән төскә керә башлау

**Җирәнләнеп тору** Җирән булып күренү; җирән төстә булу

**ҖИРӘНЛӘТҮ** *ф.* Җирән төскә кертү; җирән төс бирү. *Абзый, тәмәке төтене җирәнләткән мыек очларын чәйнәштергәләп, хатны йөз дә беренче мәртәбә укып калды.* Б.Камалов

**Җирәнләтә төшү** Беркадәр җирәнләтү; бераз җирән төскә кертү

**Җирәнләтеп бетерү** Тулысынча җирәнләтү; бөтенләй җирән төскә кертү

**Җирәнләтеп җибәрү** Кинәт җирәнләтү; бераз җирән төс бирү

**Җирәнләтеп чыгу** Барысын да рәттән җирәнләтү

**ҖИРӘНСУ** *с.* Җирән төскә тартым. *Кызның җирәнсу чәче, чыланып, башына сыланган, чырае турсайган.* М.Маликова. *Менә бит, хәере белән булсын, җирәнсу малкай, үзеңнән соң токым калдыру кирәк.* Р.Низами

**ҖИРӘН ТАРАКАН** *и. зоол.* Таракансыманнар отрядыннан җирән төсле 13–16 мм озынлыктагы бөҗәк. *Беркөнне җирән таракан күреп шаккаттым.* Татарстан яшьләре

**ҖИРӘНҮ** *ф.* 1) Пычрак, сасы һ.б.ш. әйберләрне күрүдән күңел болгану, косасы килү хисе уяну. *Карыннары ачкан булса да, аларның күбесе, дуңгыз итеннән җирәнеп, ашамыйча, тик авызга сыймаслык кашыклар белән борчак боткасын гына ашадылар.* М.Гали. *[Кыз] Чыланды, күшекте, тыгыз өйләрдә тараканнардан җирәнә-җирәнә кунып ятты, өс-башы – тузып, үзе керләнеп бетте.* Ә.Еники. *Кайбер дәфтәрне, почмагыннан чеметеп, җирәнеп кенә кулына ала, авызы кыйшаеп китә, йөзе чытыла.* М.Мәһдиев

2) Кемне дә булса яратмау, тайчану, дошман күрү. *Егет, җирәнеп һәм мыскыллап, кинәт аның битенә төкерде.* А.Шамов

**Җирәнә башлау** Җирәнү хисе барлыкка килү. *Маврдан күңеле бизәр, тора-бара аннан җирәнә башлар, һәм ахырында аның күңелендә маврга карата нәфрәт уяныр.* У.Шекспир

**Җирәнә төшү** Беркадәр җирәнү, бераз җирәнү хисе туу

**Җирәнеп кую** Кинәт кенә җирәнү хисе кичерү. *Үз-үзләреннән канәгать, төрле оятсыз анекдотлар сөйләшеп кенә көн уздырган бу адәмнәрдән җирәнеп куйды.* Р.Сәгъди

**Җирәнеп тору** Әле, хәзер җирәнү хисе кичерү

**ҖИРӘНҮЧӘН** *с.* Нәрсәдән яки кемнән дә булса җирәнә, чиркана торган. *Дару эчүгә килгәндә, күп кенә авырулар җирәнүчән була*

**ҖИРӘНҮЧӘНЛЕК** *и.* Җирәнүчән булу; җирәнә торган гадәте булу. *Җирәнүчәнлек хисе*

**ҖИРӘНЧӘ** I *с. к.* **җирәнсу.** *Җирәнчә чәчән, син – акыл иясе дә кеше, кешегә җитеш тормыш кына нигә җитми икән ул?* Г.Хөсәенов

**ҖИРӘНЧӘ** II *и. диал.* Җиңелчә генә кызарып, чабырткылар хасил булудан гыйбарәт тире авыруы; бүре уы; *русчасы:* **крапивница**

**ҖИРӘНЧӘК** *с.* **1**. Юк кына нәрсәдән дә җирәнә торган. *Кави Нәҗми, Шәйхи Маннурның җирәнчәк кеше икәнен белеп, юри: – Кичә бу балык*

*койрыгын мин ишегалдындагы чүплектә күргән идем, аны этләр тарткалап йөрделәр-йөрделәр дә ташлап киттеләр, ашчылар тагын шуны казанга кертеп салдылар, – дип зарланган була.* Р.Батулла

**2**. *и. мәгъ.* Җирәнүчән кеше. *Күңелчәк белән җирәнчәк көн күрә алмас.* Мәкаль

**ҖИРӘНЧЕК** *с. к.* **җирәнсу**. *Җирәнчеккәй атның, ай, ялларын, Кыйблалардан искән җил тарый; Үз бәхеткәйләрең, ай, булмагач, Байга хезмәт итеп кем ярый?* Җыр

**ҖИ́Р БИЛӘҮЧЕ** *и.* 1) *тар.* Алпавыт. *Патшаның олуг князьләрдән, эре җир биләүчеләрдән, миллионерлардан сайлап кына куйган хакимнәренә нигә ул чаклы итагать итәргә?* М.Гафури

2) Җиргә хосусый милекче

**ҖИ́Р БУЕ** *и.* 1) *иск.* 80 сажинга (якынча 170 м, 1 сажин – 2,13 м) тигез озынлык, җир үлчәү берәмлеге. *Госман бездән, бер җир буе дип әйтерлек, алда бара, тик шулай да мине ул түгел, арттан уйнаклап килгән теге кашка байтал шикләндерә.* Ф.Хөсни

2) Күз күреме ара, ераклык арасы. *Шуннан Һәдиямне юл кырыена утыртып калдырдым да төенемне бер җир буе алга илтеп куйдым.* Ә.Еники

**ҖИРГИЗӘР** *и.* Яңа җирләр ачучы; *русчасы:* **землепроходец**

**ҖИ́Р ГРУШАСЫ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгына караган, ашарга яраклы бүлбеле, озын эре сабаклы, көнбагышка охшаган кечерәк чәчәкле күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **земляная груша**, **топинамбур**. *Җир грушасының туган җире – Төньяк Америка.* Биология

**ҖИРДӘШ** *и.* 1) Бер якта туып үскән, яшәгән кеше; якташ. *Инде Гыйлаҗетдин булып Гыйлаҗетдин – --- җирдәшләренә гелән изгелек теләгән зат та – Мыек Яруллага шундый тамга салган икән, монда уйланырлык урын бар.* А.Гыйләҗев

2) Ватандаш, илдәш. *Шуның өчен бөтен җирдәшләрдән рәхмәтем дә сиңа.* М.Җәлил

3) Ызандаш кеше. *Башкортларның --- авыл башлары, юк бәһага сатып, кем, чакырып, бер кәррә сыйласа, аңа җир биреп, типтәрләрне вә Казан татарларыны үзләренә җирдәш итеп, --- җирләрен үзләренә дә аз калдырмышлардыр.* З.Һади

**ҖИРДӘШЛЕК** *и.* Ызандаш кеше булу. *– Я Рабби, ярты җире – ярты гомере дигәндәй, шул иде бит инде коданың, инде нишләр? – Әсәт белән кода булыр. Җирдәшлек – кардәшлек.* Ә.Фәйзи

**ҖИ́Р ҖИЛӘГЕ** *и.* 1) Розачалар семьялыгыннан, мыекчалар ярдәмендә үрчи һәм вак орлыклар белән капланган татлы сусыл кызыл җимеш бирә торган үлән үсемлек һәм шуның җимеше; *русчасы:* **клубника**. *Җир җиләге ачы була, үз вакытында пешмәсә...* Җыр

2) **җир җиләгем** Яратып, иркәләп эндәшкәндә кулланыла. *– Җир җиләгем, – дип кабатлады егет.* Р.Мөхәммәдиев

**ҖИ́Р ИЯРЧЕНЕ** *и.* Орбита буйлап Җир тирәсендә әйләнеп хәрәкәт итә торган күк җисеме, ясалма аппарат

**ҖИ́Р ЙӨЗЕ** *и.* 1) Җир өстендәге терек һәм терек булмаган нәрсәләрнең барысы; дөнья. *Җир йөзендә һичбер җан иясе йөзен ябып йөрми, йөрмәде.* М.Гафури. *Әнә шул югарыдагы кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый.* Ә.Еники

2) Җирнең өске катлавы, аның офык белән чикләнгән өлеше. *Җир йөзе йомшак аклык белән капланды.* Г.Ибраһимов. *Җир йөзе тәмам бизәнгән Чәчкәләр, гөлләр белән.* М.Гафури

**ҖИ́Р КАБЫГЫ** *и.* Җирнең өске катлавы, литосфера. *Җирнең [өске] кабыгы, эчендәге матдәгә караганда тыгызрак булганга күрә, акрынрак кысыла.* Ф.Әмирхан. *Текә ярлар пычак белән телеп төшергән төсле. Җир кабыгы катлы-катлы.* Г.Ахунов. *Көчле җир тетрәү нәтиҗәсендә, җир кабыгы берничә урында ярылып, кыялар җимерелә башлады.* Физик география

**ҖИР-КӨН** *җый. и.* Биләмәсендә булган җир һәм мал-мөлкәт. *Капитализм тормышы кысрыклавы белән имениеләрен сатып бөлгенлеккә барган алпавытлар [«Чия бакчасы»], җиркөннән аерылган крестьяннар, тагын --- бик күпләр --- Чехов әсәрләрендә --- очрыйлар.* Г.Нигъмәти

**ҖИР-КҮК** *җый. и.* Җир йөзе; бөтен дөнья; барча табигать. *Гөлләр елмайган, кырлар нурланган. Бөтен җире-күге нурга чорналган.* Ш.Бабич. *Ятсынып карап торам: җирне-күкне, тирә-ягымны, заводны танымыйм.* А.Гыйләҗев. *Җирне-күкне тоташ кара болыт, яшен камчылары урап алган.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Җире-күге белән шатлану** Исkиткеч нык, чын күңелдән шатлану. **Җирен-күген онытып** Бөтен дөньясын онытып, бар нәрсәгә кул селтәп. *Ләкин хатын җирен-күген онытты, өенә, авыру баласы янына очты.* Г.Ибраһимов. **Җир-күк бетереп эзләү** Бик нык эзләү, карамаган җирне калдырмау. **Җир-күк җимерелү** Нәрсәнең дә булса бөтенләй һәм эзсез бетүе; бөтенләй һәлак булуы, юкка чыгуы. *Өч бөртек кыл өзелгән икән – аннан җир-күк җимерелерме?* Г.Ибраһимов. **Җирне-күкне бер итеп** Бөтен дөньясын тоташтан каплап. *Бу хәл әти үлеменә берниндн дә ачыклык кертмәде. Киресенчә, төшсә, тиз генә күтәрелми торган кышкы томандай, җирне-күкне бер итеп каплады да куйды.* Х.Сарьян. *Ә җил җирне-күкне бер итеп котырына.* М.Маликова

**ҖИ́Р КҮЧӘРЕ** *и. геогр.* Җирнең үзәге аша ике полюсны тоташтырган уйланма туры сызык

**ҖИРЛӘҮ** *ф.* 1) Үлгәч, кешене җиргә күмү, гүргә иңдерү. *Без бит бәхетле, Нуриәсмакаем, безне үзебезнең авылга җирлиләр, ата-бабаларыбыз белән янәшә ятабыз.* Ф.Садриев. *Рәшит абыйсын ул яңадан, бик күп еллар үткәч, үзенең үги әтисен җирләгәндә күрде.* Казан утлары. *Мәҗүси бабаларыбызның үз җирләү йолалары булган. Гомер иткән өлкәннәр, картлар, яшьләр, хатын-кызлар, балаларның һәркайсы дөньялыкта тоткан роленә карап җирләгәннәр.* Мәдәни җомга // Мавзолейга урнаштыру. *Тарихтан беләбез: Ленинны Горкадан китергәннән соң, Мәскәүнең Кызыл мәйданында*

*җирләү (вакытлыча мавзолейга кую) 27 январьда булды.* Ә.Еники

2) Электр тогыннан саклау өчен, электр үткәргечләрен җиргә тоташтыру; *русчасы:* **заземление**. *Антеннаны беренче мәртәбә А.С.Попов уйлап тапкан. Радиотапшыру һәм радиолау эшендә җирләүне беренче мәртәбә ул кулланган.* Физика

**Җирләп бетерү** Барысын да җирләү; җирләү процессын тәмамлау. *Сугыш кырында һәлак булганнарны көнендә җирләп бетерделәр*

**Җирләп йөрү** Җирләү эше белән шөгыльләнү; шул шөгыльне башкару. *Әлфияне җирләп йөреп, бәрәңге утыртырга да кайта алмады Баязиты.* З.Мәхмүди

**Җирләп кую** Җирләгән хәлгә китерү; җирләү эшен башкарып чыгу. *Әбине икенче көнне шау-шусыз гына җирләп куйдылар.* Ф.Яруллин. *Бабай белән әбиләре, кырык өчтә үк аллыартлы вафат булып, икесен дә рус авылы зиратына җирләп куйдылар.* Х.Сарьян

**Җирләп яту** Әле, хәзерге вакытта җирләү. *Ләкин миңа аны сөендерергә насыйп булмады, мин кайткан көнне аны җирләп яталар иде.* Ф.Яруллин

**ҖИРЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) *к.* **җирләшү**. *Бер заманнар бу буйлар, җәелеп яткан зур күлләре, яшеллек вә төрле агачлары белән, борынгы бабайларны кызыктырып, монда җирләштерсәләр дә, заман үткән саен, --- хәзер бу җирләр бик ялангач вә төсмерсез булып калган иде.* Ш.Камал

2) Урнаштыру, урын бирү. *Өйдә әллә никадәр буш бүлмә булса да, аны егетнең күрше бүлмәсенә – Чарлакка җирләштерде.* Г.Исхакый

**ҖИРЛӘШҮ** *ф.* 1) Кая да булса бер урынга урнашу, шуннан урын алу. *Поезд кузгалды: сикереп мендек тә, кондукторны күреп, ярты хакны түләп өчен, вагон ишеге төбенә җирләштек.* Г.Ибраһимов. *Пәһлеван вагонга җирләште кереп, Алды «пересадка» берлән бер билет.* Г.Тукай

2) Яшәү өчен билгеле бер урынга төпләнү. *Кайчан да булса бер илгә кайтып җирләшү*

3) Эшкә керү, нинди дә булса хезмәткә урнашу. *Йөри торгач, кечкенә генә бер мөселман кибетенә приказчик булып җирләште.* Г.Исхакый

4) *сир.* Югарыдан җиргә төшү, җир өстенә төшеп утыру

5) *күч.* Урнашу, биләп алу, тамыр җәю. *Ул шөбһәне тиздән бетерә алмаганга, --- күңелендә әллә нинди бер исемсез эчпошыргыч нәрсә җирләште, әллә нинди күрелмәгән бер көя аның тынычлыгын ашый башлады.* Г.Исхакый. *Борынгы ыручылык һәм күчмә патриархальлектән чыгып, болгар бабайлар да акрынлап утрак тормышка күчә, феодальлек тәртипләре җирләшә, кабиләләр берләшү, халыклар төзелүгә юл ачыла.* Н.Исәнбәт

**Җирләшә бару** Торган саен ныграк җирләшү. *Әдәбият-сәнгатьнең матурлыкка хезмәт итү функциясе торган саен җирләшә бара.* Ә.Закирҗанов

**Җирләшә башлау** Җирләшергә тотыну. *Көнчыгыш Кытай тимер юлы Русия тарафыннан салына башланган көннәрдән алып (1900–1902) сәүдәгәр милләттәшләребез бу тирәләргә җирләшә башлыйлар.* Г.Исхакый

**Җирләшә төшү** Бераз җирләшү. *--- яшь шагыйрьләр күп вакыт «тәүге адымнарын», «үз-үзләрен ачу-табуны» «күкләргә» тыелгысыз алгысулардан, күпмедер дәрәҗәдә «абстракт», «хыялый» дөньяларга «сәяхәттән» башлыйлар, әмма соңыннан, кызганычка яки бәхеткә, төрле метаморфозалар аша узып «җирләшә» төшәләр.* И.Вәлиулла

**Җирләшеп алу** Җирләшкән хәлгә килү; җирләшүгә ирешү

**Җирләшеп җитү** Бөтенләй җирләшү; тулысынча җирләшкән хәлгә килү

**Җирләшеп калу** Җирләшеп, бер урынга урнашу, төпләнү. *Биредә урын әйбәт дип, авылдашлар җирләшеп калырга булдылар*

**Җирләшеп китү** Күпмедер вакыт узу белән җирләшү. *Читтән килгән кешеләр биредә әйбәт кенә җирләшеп киттеләр*

**ҖИРЛЕ** I *с.* 1) Җире булган, чәчүлек җирләргә ия булган. *Җиһан, ире белән киңәшмичә, күп җирле күршеләренә урак урырга ялланды.* М.Галәү

2) Шул җирдә туып үскән, читтән килмәгән. *Семидәге беренче мәчетне, җирле казак байлары белән берләшеп, Урта Азия сәүдәгәрләре салган ---.* М.Госманов. *--- мондый класс ачарга ашкынып тормаган Барудига татар искеләре дә, җирле урыс – православие әһелләре дә һаман саен аяк чалалар.* Р.Әмирхан. *1890 елның мартында җирле рәссам Ф.Т.Травкин, профессор Н.А.Осокин күзәтүендә, бу каретага бердәнбер реставрация ясый.* Мирас

3) Билгеле бер урынга, төбәккә караган. *Барабада, әлбәттә, иң элек җирле сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнү белән мәш килдек.* М.Госманов. *1883 елда Казанда Хөсәен бине Әмирханның «Тәварихе Болгария»се дөнья күрә. Ул күп кенә җирле чыганакларга таянып язылган булуы белән әһәмиятле.* Р.Әмирхан. *Читтән китерелгән кеше җирле тормыш кагыйдәләрен кабул итсә, үзара аңлашу әйбәт, яшәү күңеллерәк була.* Мәдәни җомга

4) Читтән кертелмәгән, кырыйдан китерелмәгән, шул урында эшләнгән, шунда барлыкка килгән. *Ш.Мәрҗани, җирле педагогика тарихында беренче булып, үз мәдрәсәсендә эчке тәртип кагыйдәләре кертә.* Р.Әмирхан

**ҖИРЛЕ** II *кер. сүз сөйл.* Күбесенчә *әйтәм* сүзе янында килеп, нәрсәнең дә булса асылына, сәбәбенә төшенүне аңлата. *Әйтәм җирле, Хәсән чирле – Гайшә эшкә бармаган.* Әйтем. *Теге кеше артык кызыксынып, сорашып тормады. Бары: – Җирле, бик үскән күренәсең... – дип, күз кысып куйды.* Җ.Фәйзи. *Гомер аты алга чаба дисең, Күзләреңдә җирле сагышы...* Казан утлары

**ҖИРЛЕ-ҖИРСЕЗ** *с.* **1.** Төгәл урыны булмаган, күчеп йөргән. *[Картәтәй] «Кемнәр соң ул болгарлар?» дигәнгә җавап бирә алмый иде. «Әллә тагы? Башкорт белән типтәр кебек җирлеҗирсез халык булды микән?» – дип, үзе дә аптырап утыра иде.* Х.Сарьян

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Урынлы-урынсыз, тиешсез урында яки вакытта. *Җирлеҗирсез сүз кату*

**ҖИРЛЕК** *и.* 1) Җирнең мул уңыш бирә алу сыйфаты; туфракның

уңдырышлылык дәрәҗәсе. *Бакчаның җирлегә югалу*

2) Үсеп утырган яки басып торган кеше, әйбер астындагы җир. *[Әлеге түбәдә үскән үләннең] Җирлеге бик бәләкәй: бер учка сыярлык туфрак кына.* Г.Галиев. *Зуфирә кинәт үзендә бер җиңеллек сизде, аның җаны канатланган-дай булды, ул канатлар аны моңарчы басып торган җирлегеннән күтәреп алып киттеләр...* М.Маликова

3) Башка төсләрдән, бизәкләрдән аерылып торган төп төс, фон. *Бу [шәл] инде үзенең аллы-кызыллы чуклары, сорылы-зәңгәрле җирлеге белән бөтен бүлмәне нурлы төсләр дулкынына тутырды.* Г.Ибраһимов. – *Дәфтәрнең тышына да нәрсәдер язылган. Ләкин зәңгәр җирлектә аермачык беленми генә, – диде.* Р.-Н. Гүнтәкин

4) Нинди дә булса бер әйбер яки күренешнең тирә-ягы. *Җиһанның шушы затлы бизәкләренә карый-карый, хисләрең яңара, гаҗәеп бер соклану белән җирлегә җете йолдызларны күз алдына китерә башлыйсың.* М.Рәфыйков

5) Нинди дә булса күренешнең барлыкка килүенә сәбәп булган чыганак; нигез. *Колач җитмәстәй бу бай мирасыбызны, җентекләп, фәнни җирлектә өйрәнәсе иде.* Р.Әмирхан. *Әдәби мирасыбызны ярлыландыруга, аның алтын фондыннан иң талантлы әдипләрне, шагыйрьләрне, аларның иҗатларын сызып ташлауга алып барган бу зарарлы карар бер төркем студентлар арасында да җирлек таба башлады.* А.Шамов. *Тереклек, дөньяга барлыкка килү белән, табигатьнең объектив кануннары нигезендә, үзе өчен яшәргә омтылыш тудырырдай җирлек әзерли башлый.* Мирас // Берәр нәрсә эшләүне аклый торган сылтау, сәбәп. *Биюгә чакыруының җирлеге дә бар иде кебек. Бервакыт, яныннан узып барганда, Артур аңа елмаеп карагандай тоелган иде.* Казан утлары

6) Кешенең туып үскән җире, чыгышы. *Мулла, бу юлы бераз йомшаган төсле күренергә тырышып: – Син кай җирлек? – дип сорады.* Ф.Хөсни. *Авылда туганмы, шәһәрдә туганмы сез, дигәндәй, җирлегегез кайдан?* Г.Галиев

7) *физ.* Соңыннан өслегенә нәрсә дә булса йөгертелергә тиешле материалның ябышуын яхшырту, ныклыгын яки коррозиягә чыдамлылыгын арттыру өчен, металл, агач яки башка материаллар өстенә сылана торган буяусыман матдә

**ҖИРЛЕ́ СӨЙЛӘШ** *и* Тел үзенчәлекләре белән аерылып торган, билгеле бер территориядә таралган сөйләш. *Җирле сөйләш үзенчәлекләрен иске язмалардан эзләү мөмкинлеге юк.* Р.Сибгатов

**ҖИРЛЕ-СУЛЫ** *с.* Җире һәм суы булган; җиргә, суга хуҗа булган. *Чыннан да, дәрвиш яшь чагында ярлы кешеләрне комсыз байлардан яклаган, аларны җирле-сулы итәргә тырышкан.* Ф.Мансуров

**ҖИРЛЕ́ ХАЛЫК** *и.* 1) Колониаль илләрнең төп халкы. *Ислам динендәге җирле халык шәфкатьсез кырыла.* М.Гайнетдин

2) Билгеле бер урында борынгыдан яшәгән халык. *Талауның алымнары да, нәтиҗәсе дә шул ук. Җирле халык [Татарстан] янәдән тишек көймәгә утыртып калдырылды.* Т.Галиуллин

**ҖИ́Р МАЕ** *и.* 1) *бот.* Сасы исле, эчендә майлы сыекчасы булган, йомшагы юка элпә белән капланган гөмбәнең бер төре; *русчасы:* **мутинус собачий.** *Җир маеның лайласы җиде төрле сызлауга шифа.* Әйтем

2) *сөйл.* Нефть; аңардан җитештерелгән ягулык. *Сугыштан соңгы еллар. Тегесе юк, монысы җитешми. Илгә машина кирәк, аларны йөртергә җир мае кирәк.* Ш.Рәкыйпов

**ҖИ́Р ӨЙ** *и.* Җирасты куышы, землянка. – *Аларның бит мунча кебек җир өйләреннән башка бернәрсәләре дә юк, – дибез.* Г.Гали

**ҖИРСЕЗ** *с.* **1.** Җире булмаган яки җире аз булган. *Иректне биргәннәр, җирне алып калганнар, ди. Җирсез крестьян нәрсә ул?* Г.Ибраһимов. *Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр, Ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар...* Г.Тукай. *Чабаталы морзалар җирсез крестьян хәленә калдырылдылар, бу, әлбәттә, дворянлык дәвере татар мәдәниятен бик нык түбәнләштерде.* Г.Газиз

**2.** *рәв. мәгъ.* Җир бирмичә. *1803 елда алпавытларга үзләренең крепостнойларын җирсез генә ирекка җибәрергә рөхсәт итүче указ чыга.* Татарстан тарихы

**ҖИРСЕЗЛЕК** *и.* Үз җире, чәчүлеге булмау яки бик аз булу. *Тимерша чыкмаган җаны белән гырылдап җавап бирә: – Кем котыртсын, җирсезлек котыртты, – ди.* Г.Ибраһимов. *Саргылт җирән мыегына һәм кашларына карап, аны авылда «Сары Җаббар» дип йөрттеләр. Гомер буена ул җирсезлек һәм атсызлык белән интекте.* Ә.Фәйзи

**ҖИРСЕЗ-СУСЫЗ** *с.* Җире-суы булмаган. *Залим Россия хөкүмәте, кан эчүче бюрократия, юан корсаклы буржуазия, бичара җирсез-сусыз, ачялангач авыл халкын талап, казаклардан суктырып, аттырып каһәрләгән.* Ш.Мөхәммәдев

**ҖИРСЕНҮ** *ф. к.* **җирсү**. *Аңа, бу ят шәһәрдәге ялгыз кешегә, бик-бик ямансу булып китте. Ул, җирсенеп, ихтыярсыз бер көрсенеп куйды.* Ә.Фәйзи

**Җирсенеп бетү** Тәмам, бик нык җирсенү

**Җирсенеп кую** Кинәт җирсенү. *Күңелем җирсенеп куйды. Әни мәрхүмә исемә төште.* Г.Сабитов

**ҖИРСЕТҮ** *ф.* 1) *з.-сыз к.* **җирсү** (*1 мәгъ.*). *Монда калсам җирсетә, илемә кайтсам – кем көтә?!* Җыр. *Яшәгәннәр чит җирләрдә, Туган якларны уйлап. И газиз җир – Идел – Урал, Җирсетеп сагындыра.* Р.Гарифуллина

2) Ярсыту. *Соңра көттереп халыкны, җирсетеп, [Иблис сөйләде] кулда шәрабен күрсәтеп.* Ш.Бабич

**Җирсетеп алу** Берара вакыт җирсетү, кинәт кыска вакытка гына җирсетү

**Җирсетеп бетерү** Тәмам җирсетү; нык җирсеткән халәт кичерү

**Җирсетеп кую** Кинәт кенә һәм беркадәр җирсеткән халәт кичерү

**ҖИР-СУ** *җый. и.* 1) Яшәү чыганагы буларак чәчүлек җирләр һәм шул җирләр янындагы сулыклар. *Монда, минәйтәм, аның җир-суыннан, машиналарыннан --- безнең фәкыйрь мөселманнар файдаланалар бит.* Г.Ибраһимов

2) Ил, халык биләп яшәгән, җире һәм суы булган урын. *Садыйкны беләләр, ярats: Авылның кияве итеп тә, җир-су алып бирешүдә юл күрсәтүче итеп тә ---, бу Байрак авылына күчү эшендә каладан Фәхригә булышлык кылучы итеп тә яраталар иде.* Г.Ибраһимов. *Үзе кара җирдә утырып калган бу кеше ---, күбесенчә, көнкүрешнең гомумән кысанлыгы, җирсуның җитәрлек булмавы турында сөйли.* Ф.Хөсни

**ҖИ́Р-СУ ХАЙВАННАРЫ** *и.* Җирдә дә, суда да яши алган умырткалы хайваннар; *русчасы:* **земноводные**

**ҖИРСҮ** *ф.* 1) Туган илне сагыну, аны юксыну. *Чит җирдә мал да җирси.* Мәкаль. *Безнең заманда шундый «йогышлы авыру» бар, ул – ностальгия – җирсү дип атала. Бу «авыру» еракларга киткән эмигрантларның гына түгел, үз дәүләтендә кече ватаныннан – туган-үскән җиреннән аерылганнарның да җелекләренә үтә.* Ә.Борһанов. *Чит илләрдә яшәүче татарлар арасында татарлыкны югалтучылар күбрәк, ләкин үз тамырларын уйлап, җирсеп яшәүчеләр дә күп.* М.Зәкиев

2) Җилкенү, ярсу; дәртләнү. *[Кызларның язга таба] Күңелләре җирси, йөрәкләре кымырҗый, күзләрендә ут көчлерәк яна.* А.Гыйләҗев. *Дөм караңгы авыл башында әсәрләнеп басып торган солдат кинәт ишетә: җирсегән күңелне ут сулышлы толпар итәрдәй җыр --- урамның аргы очыннан бар тарафларга тарала.* Ф.Мансуров

**Җирсеп алу** Берара җирсү; күпмедер вакыт җирсү халәте кичерү

**Җирсеп йөрү** Даими рәвештә җирсү; һәрвакыт туган якларны сагынып яшәү. *Шәүкәт абый – ана телендә бер утырып сөйләшергә зар булып, чит җирләрдә җирсеп йөргән илдәшләребезнең тере шаһиты.* Э.Шәрифуллина

**Җирсеп кую** *к.* Кинәт кенә, кыска вакыт аралыгында җирсү тойгысы кичерү. *Син хат язмасаң, кайтмаган да булыр идем әле. Хатыңны алгач, кинәт җирсеп куйдым. Авыл искә төште.* Р.Батулла

**Җирсеп тору** Бертуктаусыз җирсү, сагыну хисе кичерү. *Аккашканың колыны бар: Бармас инде чабышка. Үзе исә, атлар күргәч, Җирсеп тора ярышка.* Х.Халиков

**ҖИ́Р ТАМЫРЫ** *и. бот.* Ароидчалар семьялыгыннан, юан, шуышма тамырчалы, кыяк яфраклы, яшькелт сары чәчәкле, сазлыклы урыннарда, су буйларында үсә торган күпьеллык үсемлек: *русчасы:* **ирный корень, аир обыкновенный.** *Җир тамырының туган җире – Һиндстан һәм Кытай.* Е.Солодухин

**ҖИ́Р ТӘКӘСЕ** *и. диал.* Бәрәңге. *Яңа гына узган мичтә җир тәкәсе тәгәрәтеп алганда да бик тәмле була*

**ҖИ́Р ТЕТРӘҮ** *ф. геол.* Җир эчендә барган процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килгән көчле селкенү. *Бабасының татар булуын белдерде дә, казак, сорамасам да, үзе белән таныштыра башлады. Алма-Атада тора икән, --- соңгы җир тетрәгәндә, ата-анасы йорт-җирсез калган...* А.Гыйләҗев

**ҖИ́РЧӘ** *рәв. сөйл.* Җир кешесе кебек. *Чын бәхет бит кешегә җирдә яшәп, Җирчә яшәп кенә бирелә.* Г.Зәйнашева

**ҖИ́Р ЧИКЛӘВЕГЕ** *и.* 1) Кузаклылар семьялыгыннан, сабаклары җиргә ятып үсә, кузагы туфрак астында өлгерә торган көньяк үсемлеге; арахис. *Бүлбесыман тамырлары ашарга яраклы, шуңа күрә бу үсемлекне «җир чикләвеге» дип тә атыйлар.* Л.Мәүлүдова. *Җир чикләвеге азык һәм май алу өчен игелә.* Биология

2) Шул үсемлекнең ашарга яраклы чикләвеге. *Фәйзерахман оныгы кулыннан шоколадны алып сындырып карады: – Ие шул, җир чикләвеге кушып ясаганнар. Арахистан. Татлы булырга охшый.* М.Рәфыйков

**ҖИ́Р ШАРЫ** 1) *к.* **Җир** (*1 мәгъ.*). *Җир шарының кайсы ноктасында икәнлегебезне, секстант ярдәмендә, кояш һәм йолдызларга карап билгелибез.* Р.Мостафин. *География дәреслегендә шундый бер рәсем бар: түгәрәк Җир шарының ике ягында ике кеше басып тора.* М.Маликова. *Җир шарының кайбер урыннарында гранитлар җир өстенә чыгып ук тора.* Физик география

2) Кешелек дөньясы. *Җир шарын дер селкетеп, туктаусыз җиңеп торучы империяләрнең язмышлары кызганыч.* М.Юныс

**ҖИСЕМ** *и. гар.* 1) Пространствоның билгеле бер өлешен биләп торган матдә; пространстводагы аерым бер предмет. *Үз җисемнәрен төзү өчен, яшел үсемлекләр углекислый газдан, судан һәм минераль тозлардан төрле-төрле органик матдәләр синтезлыйлар.* Е.Солодухин. *Ут, су, җир һәм һава, һәркемгә мәгълүм булганча – җисемнәр. Ә бит һәрбер җисем, гадәттә, билгеле сандагы яссылыклар белән чикләнә.* Җ.Тәрҗеманов. *Җисемнең чиге өслек була.* Геометрия

2) Аерым планета яки галәмдә билгеле бер юнәлештә хәрәкәт итә торган объект. *Якты нурларга уранган бу күк җисеменең нәрсәсен күзәтә ул...* Ф.Мансуров. *Сунүче йолдызлар бар. Әмма нурлары галәмнең башка җисемнәренә, шул исәптән Җиргә килеп торалар.* С.Поварисов. *Квадрант – горизонт өстеннән күк җисемнәренең биеклеген үлчәү өчен кирәк булган почмак үлчәү җайланмасы.* Г.Дәүләтшин

3) Гадәттә, каты яки сыек халәттәге материя. *Сабын куыгы – геометрик җисемнең бик шәп моделе.* Җ.Тәрҗеманов

4) Әйберне яки күренешне шул әйбер итеп таныткан төп сыйфаты; шул әйбернең яки күренешнең үзенчәлеге, асылы. *Исеме бар, җисеме юк.* Мәкаль. *«Нур» дип аталуы да бит бик урынлы, Шулай ук исеменә җисеме дә килә туры.* Г.Тукай. *Әсәрләрдә геройларның җисеме төрле-төрле булган кебек, исемнәре дә үзенчәлекле булсын иде.* Х.Сарьян

5) *Җан* сүзенә капма-каршы мәгънәдә: тән, барлык, җисми хәл. *Сәгать, көн вә төн үткән саен, Галимәнең күңелендә Сәгыйдкә каршы гыйшык уты кызулана, ялкынлана, рухлары вә күңелләре һаман якыная бара иде. Ә җисемнәре бик ерак иде.* Г.Ибраһимов

**ҖИСЕМЛЕ** *с.* 1) Конкрет җисеме булган. *Җисемле почмак*

2) Предметлар, әйберләр дөньясы белән бәйләнешле булган. *Шагыйрь*

*[Ә.Фәйзи] табигать сурәте, тирәлек сыны аша кешене, аның нечкә хисләрен җисемле тасвирлау юлына чыга.* Т.Галиуллин

**ҖИСМАНИ** *с. гар. иск. к.* **җисми**. *Минемчә, сиңа аны җисмани һәм рухани тарафларыннан тәрбия итәргә кирәк.* Г.Тукай

**ҖИСМИ** *с. гар.* **1.** 1) Җисемгә, предметка мөнәсәбәтле. *Җисми зурлык*

2) *филос.* Аң, фикерләүдән тыш яши торган, пространствоның билгеле бер өлешен биләгән, материаль

3) Җисемгә, тәнгә, барлыкка караган. *[Тукай – Әмирхан] Җисми һәм рухи дуслыклары белән бик күпләргә өлге булырдай олуг, могтәбәр шәхесләр.* Р.Әмирхан

**2.** *рәв. мәгъ.* Тән ягыннан, тәне, гәүдәсе белән. *Беренчесе [тиран] җәйрәп яткан, башка халыклар байлыгына кызыкмаган илебезне, ыру-нәселебезне җисми юкка чыгара.* Т.Галиуллин

**ҖИСМИЛЕК** *и.* Җисемгә (*1 мәгъ.*) хас үзлек. *Исемендә үк җисмилеге чагылыш тапкан әлеге әсәр татар халкының миллилеген тирәнрәк ачып биргән, күрәсең, шул чор нәширләре аны бастырудан баш тарталар.* Р.Бәдретдинов

**ҖИТӘК** *и.* 1) Кешене – кулыннан, терлек-туарны тезгененнән, муенчагыннан тотып әйдәкләү. *Баланың берсе итәктән җитәккә күчкәнче, икенчесе итәккә менеп утыра.* Мәкаль. *Җитәктә йөргән ат*

2) *күч.* Кеше ярдәменә салынганлык, кешедән файдаланып яшәү. *Бала җитмештә дә җитәктә.* Мәкаль

◊ **Җитәгендә йөрү** 1) Кемнең дә булса әйдәве астында, тезгенендә йөрү; 2) Кемнән булса да файдалану, кемнеңдер ярдәменә салыну. **Җитәк белән тотак** Һәрвакыт бергә йөрүче кешеләр. **Җитәккә калу** Авыру яки картлык сәбәпле, мөстәкыйль яшәү сәләтен югалту

**ҖИТӘКЛӘТҮ** *ф.* 1) Җитәкләргә ирек, мөмкинлек бирү

2) Салыну, үзе көч куймау, кемгә дә булса ышанып тору, эшләп биргәнне көтеп тору

**ҖИТӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кемне дә булса кулыннан тотып алып бару. *Өч яшьлек энем бар минем, Бер минут та тик тормый. Җитәкләп урамга чыкса, Әбине интектерә.* Г.Зәйнашева. *Монда кеше-кара ишетеп торуы бар, әйдә читкәрәк китик, дип, ул мине, кулымнан җитәкләп, тау астына алып төшеп китте.* Ф.Хөсни. *Кадер кичне, ястү вакыты җитү белән, мин аны, җитәкләп, мәчет янына алып мендем.* Г.Бәширов

2) Хайванны тезгененнән, муенчагыннан яки башка җайланмадан тотып әйдәп бару. *Иртән иртүк торган да, сыерын җитәкләп, базарга киткән.* Ф.Яруллин. *Атын җитәкләп, --- бара яшь юлчы. Зур уйлар уйлап.* З.Мансур

3) Нинди дә булса коллективның, оешманың эшенә җитәкчелек итү. *Пермь – Казан – Горький газүткәргечендә Илсур Шәйхетдинов җитәкләгән агым коллективы 116 километр торба сузды.* М.Хөснимәрдәнов. *И.Н.Надиров 10 ел дәвамында Институтның гыйльми сәркатибе, директор урынбасары булып эшләде... 1972–1990 елларда халык иҗаты бүлеген җитәкләде.* Ш.Асылгәрәев. *Екатеринбург шәһәрендә дистәләгән татар оешмасы бар, өлкәнең иң бай татары милли-мәдәни автономияне җитәкли, шәһәрнең иң купшы ире Татарстан вәкиллеген җитәкли...* Ф.Бәйрәмова

4) *күч.* Алга, үсешкә алып бару, әйдәп бару, үзенә ияртү. *Дәүләтне җитәкләр өчен кеше, акыллы кеше кирәкме? Кирәк!* Ф.Яруллин. *Ул район яшьләрен тәрбияләргә дә, җитәкләргә дә куелган шәхес түгел.* Б.Камалов

**Җитәкләп алу** Тиз генә җитәкләү. *Айсылу баланы җитәкләп алды да ишеккә таба атлады.* Нурзилә. *Хәдичә апа өйрәткәнчә, Асияне кулыннан җитәкләп алды, гәүдәсен туп-туры тотып, үкчәләрен бер-бер артлы ике якка ыргытып бии башлады.* Ф.Латыйпов

**Җитәкләп бару** Озак вакытлар, дәвамлы рәвештә җитәкләү. *Шулай атын җитәкләп барганда, кемдер Алып Бәргәннең җиңеннән тартты.* Р.Батулла. *Дәүләтне җитәкләп бару ул сезгә сука тоткасына ябышып бару гына түгел.* Г.Бәширов

**Җитәкләп йөрү** Һәрвакыт, бөтен җирдә җитәкләү. *Башта ана баланы җитәкләп йөри, аннары – бала ананы.* Ш.Галиев

**Җитәкләп килү** Электән үк, күптәннән җитәкләү. *Октябрьск шәһәрендә Федераль казначылыкның төбәк идарәсен оештыра һәм менә җиде ел инде аны уңышлы җитәкләп килә.* Ф.Фәтхи

**Җитәкләп чыгару** Кулыннан тотып китереп кую. *Кем җитәкләп чыгарды сине минем юлыма?* Ә.Еники

**Җитәкләп чыгу** 1) Кулыннан яки тезгененнән тотып китереп кую. *Ызанга чүгәләп карасам, ындырдан бер-берсенең койрыгына тагылган дүрт ат җитәкләп чыгалар.* Г.Бәширов

2) *күч.* Идарә итү, оештыру эшен башкарып, уңышка ирешү, әйдәп бара алу

**Җитәкли башлау** Җитәкләргә керешү. *XX гасыр башында хәрәкәтне Гайнан Вәисев җитәкли башлый.* Рәмзи Вәлиев

**Җитәкли төшү** Беркадәр җитәкләү; җитәкчелекне бераз ныгыту, көчәйтү

**ҖИТӘКЛӘШҮ** *ф.* **1.** 1) Бер-берсенең кулларына тотынышып бару, бер-берсен җитәкләп тору. *Алар, җитәкләшеп, бик кәефле төстә үз бакчаларына таба киттеләр.* Т.Әйди

2) Үзара ярдәмләшү, бер-берсенә булышу. *Җирдә тынычлыкны саклау өчен җитәкләшү*

**2. җитәкләшеп** *рәв. мәгъ.* Бергәләп, бергәләшеп, бергә-бергә. *Ә анда исә апа, үзенең кунагы белән җитәкләшеп, юкәләр күләгәсеннән бакча түренә таба китеп бара.* Р.Зәйдулла. *Әби белән җитәкләшеп, Чыктык шәһәр карарга.* Г.Зәйнашева

**Җитәкләшеп йөрү** Һәрвакыт, гел җитәкләшкән булу. *Телем ташламадым, ташлар атсалар да, Мин сакладым аны, ул – мине. Җитәкләшеп йөрдек. Тән сакчым да, җан сакчым да минем шул иде.* Л.Шагыйрьҗан

**ҖИТӘКЛЕ** *с.* Тезген яки муенчагыннан тотып йөртелә торган (хайван турында). *Җитәкле ат*

**ҖИТӘКЧЕ** *и.* **1.** 1) Нинди дә булса оешманың яки коллективның билгеләнеп куелган башлыгы, идарә итүче-

се. *Шул ук елның 1 мартында Г.Дәүләтшин урынына җитәкче итеп филология фәннәре кандидаты М.И.Әхмәтҗанов билгеләнде.* М.Әхмәтҗанов. *Моңа ирешү юлын да бик ачык сызып куйган: башта ул үз заводында күтәрелергә, ничек кенә булса да, заводның җитәкчеләреннән берсе – йә баш инженеры, йә баш конструкторы булырга тиеш.* Ә.Еники. *Безнең белән Омскидан килгән милли хәрәкәт җитәкчеләре --- бу авыл турында Омск, Новосибирск эшмәкәрләренә дә сөйләргә, ярдәм итү юлларын эзләргә булдылар.* Ф.Бәйрәмова

2) Нинди дә булса вакыйгада төп роль уйнаучы, әйдәүче, юнәлеш бирүче; лидер. *Алдыңда җитәкчең булсын, артыңда таянычың булсын.* Мәкаль

3) Фәнни хезмәт язганда юнәлеш бирүче, ярдәм итүче галим, җаваплы кеше, остаз

**2.** *с. мәгъ.* Җитәкли торган, җитәкләп барган. *Тәҗрибәле авиаторны, авиациядә җитәкче кадрлар җитешмәү сәбәпле, беренче чиратта чакырылган булырлар иде, ләкин аңа мөрәҗәгать итмиләр.* Р.Ибраһимов. *Дәүләт башында торучы җитәкче органнар кризис алды ситуациясен төрле реформалар белән юк итәргә тырышып карадылар.* К.Гыйззәтов

**ҖИТӘКЧЕЛ** *с.* Җитәкчеләргә хас, җитәкчеләр кебек. *Әтисе, сүзенең бәясен яхшы белгән җитәкчел тонда, өстәлгә киң учын куеп, мөһер сукты: – Шәп булыр!* Э.Касыймов

**ҖИТӘКЧЕЛЕК** *и.* 1) Оештыру, юнәлеш бирү эшчәнлеге. *Җитәкчелек нәтиҗәле булды, күптомлык басма 1976–1988 елларда дөнья күрде.* Ш.Асылгәрәев // **җитәкчелегендә** *тарт. форм. у-вак. кил.* Үзеннән алда килгән шәхес яки оешманың оештыручы роль уйнавын белдерә. *Шушы сүзләрне гамәлгә ашыру нияте белән, Татарстан хөкүмәтенең вице-премьеры С.Когогин җитәкчелегендәге бер төркем белгечләр Уфага юл тотты.* М.Әхмәтҗанов

2) Идарә итү органы; җитәкче орган. *Тәбриз Сабантуенда исә Омск өлкәсенең һәм районның җитәкчелеге бик теләп катнаштылар, татарлар адресына күп җылы сүзләр әйттеләр.* Ф.Бәйрәмова. *Шуңа күрә институт җитәкчелеге аспирантураның эшчәнлеген камилләштерү, анда укучыларның санын арттыру, укуның сыйфатын яхшырту, күп профильле бүлек базасында мөстәкыйль бүлекләр булдыру бурычын алга куйды.* Ш.Асылгәрәев

3) Ил, дәүләт белән идарә итүче орган; хөкүмәт башлыгы. *СССР җитәкчелегенең югары катлам вәкилләрен өйрәткәндә шулай дигәннәр: фәлсәфә фәннәре гомумиләштерә, ә фәлсәфәне дин очлый.* Р.Сафин // **җитәкчелеге астында** ...җитәкчелегендә, ... җитәкчелек белән. *Татар хезмәт ияләре, фәкать безнең большевиклар партиясе җитәкчелеге астында гына, башка изелгән милләтләр белән берлектә, үзенең милли автономияле республикасын төзиячәк.* Т.Гыйззәт

**ҖИТӘКЧЕЛЕ́К ИТҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса эшне оештыру, аның җитәкчесе булу, юнәлеш бирү, әйдәп бару. *Алар хатын-кызның сугыш гыйлеменә, гаскәр белән җитәкчелек итә белүенә ышанмыйлар.* М.Юныс. *[Ул] Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли, матур әдәбият редакциясенә җитәкчелек итә.* М.Гайнуллин

2) Идарә итү, җитәкләү. *Борынгы греклар арасында даннары таралган мәшһүр архитекторлар Пифий белән Сатир проект төзергә һәм төзелеш белән җитәкчелек итәргә чакырылган.* М.Юныс. *Аларда сугыштан соңгы авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек итү мәсьәләсе үзәккә куела...* Ф.Мусин

**ҖИТӘРӘК** *рәв.* Билгеле бер урынга килеп җиткәндә. *Нурый, җилтерәп барып, каударланып, ишектән чыгып китте. Әмма капкага җитәрәк борылып керде дә ишекне ачып: – Дөрес түгел! – дип кычкырды.* Г.Бәширов. *Кирмәнгә җитәрәк, Зәйтүнә янә бер аулыгын болгады, янә Нугай капкасы ягыннан туптан аттылар.* М.Хәбибуллин

**ҖИТӘР-ҖИТМӘС** *рәв.* 1) Аз, тиешле күләмдә түгел. *Икмәк үзебезгә дә җитәр-җитмәс кенә [калды].* Ш.Камал

2) Нинди дә булса вакыт чигенә якынаеп; нинди дә булса процесс тәмамланыр алдыннан. *Кояш Бишнә урманына төшеп җитәр-җитмәс чагында, югары очтан көтү кайткан тавыш ишетелде.* Г.Бәширов. *Җирләр кибеп җитәр-җитмәс, халык арыш басуына чыкты.* Г.Бәширов

3) Билгеле бер урынга җиткәндә, якынайгач. *Килеп җитәр-җитмәс, алар взводка ата башладылар.* М.Гали. *– Һәй, әмир, яңәшәңнән урын бир! – дип кычкырды ул, килеп җитәр-җитмәс.* М.Хәбибуллин. *Чишмәнең кайнап торган урынына җитәр-җитмәс туктап калдым, аяклар атламас булып тоелды.* Р.Мөхәммәдиев

**ҖИТӘРЛЕК** *рәв.* **1.** 1) Тиешле күләмдә, тиешенчә, канәгатьләнерлек. *Тик мин генә китаптагыга каршы торырга үземдә җитәрлек көч тапмадым.* З.Хәким. *Фитотерапияне киң куллануга әле һаман да үсемлектәге тәэсир итүче (биологик актив) матдәләрнең хәзерге биохимик методлар ярдәмендә җитәрлек өйрәнелмәве комачаулый.* Урман аптекасы. *Ләкин күп кенә колхозларда һәм совхозларда умартачылык әле җитәрлек үстерелмәгән, һәм бал аз җитештерелә.* Умартачыга ярдәмлек

2) Күп тапкырлар, бик еш кабатлану турында. *Мин алданасын алданган инде, җитәрлек алданган.* Г.Камал. *--- шул бер генә гомер эчендә кеше дөньяның рәхәтен дә, михнәтен дә җитәрлек татый.* А.Расих

3) Мул, бай. *Монда сый-хөрмәт җитәрлек күренә.* Р.Ишморат

**2**. *хәб. функ.* 1) Кирәгенчә, тиешенчә, кирәк күләмдә, санда. *Оябыз зур булмаса да, biләгән җирләребез җитәрлек иде, мал-туарга бай идек...* М.Хәбибуллин. *– Парта икегезгә дә җитәрлек, сезнең кебек малайлар дус, тату һәм иңдәш булып утырсыннар өчен ике кешелек итеп ясаганнар аны,* – диде ул. Ф.Яруллин. *Куяны да, бүресе дә җитәрлек.* Т.Әйди

2) Шактый, байтак. *Кыскасы, кызыксынып карар нәрсә җитәрлек иде монда...* Ә.Еники. *Тәҗрибәгез җитәрлек, кулыгыз бу эшкә ятып тора.* М.Маликова

**ҖИТДИ** *с.* **1.** 1) Уйлап эш итүчән, төпле, үзен тота белә торган. *Күп кенә язучыларның рухи теләктәшлеге менә шул авыр чорларны үтеп чыгарга ярдәм итте. Сибгат Хәким иң олы, җитди әхлакый таянычларның берсе булды.* Т.Галиуллин

2) Җаваплы, мөһим, әһәмиятле. *– Карарбыз, күрербез, – ди Аллаяров. Бу аның үтә җитди очракларда әйтә торган сүзе.* С.Сөләйманова. *Белделәр ... һәм хәйран калдылар. Ләкин көтелмәгән яңалык булганы өчен генә түгел... Мәсьәлә җитдирәк тора.* Ә.Еники. *Язучылык үреннән ансат кына күтәрелә башлаган шәкертне алда җитди тормыш сынаулары көтә.* Р.Әмирхан

3) Куркыныч, авыр. *Күрәсең, авыруы аның болай бер-ике көн генә ятып үткәреп җибәрерлек түгел иде. Ниндидер җитди чиргә охшый.* Ә.Еники. *Азыкта* $B_1$ *витамины булмау «бéри-бéри» дигән җитди авыруга китерә.* Биология. *Санитарлар җитди яралыларны лазаретка урнаштырдылар.* Мирас

4) Кискен, хәтәр. *Әле шул чорда --- Солтангалиевнең Татарстан республикасы оештыру хакында барган бәхәсләрдә кайбер җитәкчеләр белән җитди конфликтка керүе мәгълүм.* Р.Мөхәммәдиев

5) Акыллы, эшлекле, файдалы. *Алар җитди сөйләшүгә күчтеләр.* М.Маликова. *Җитди киңәшләре, ярдәме өчен, Галимҗан Ибраһимовны «әдәби укытучым» дип атады Садри Җәләл.* С.Поварисов. *Дунай елгасы буендагы Кече Кайнарҗа авылында төзелгән солых килешүендә Төркия хөкүмәте мөселманнарның Россиядәге язмышына карата җитди тәкъдимнәр кертә.* Л.Хәмидуллин

6) Уйчанлык чагылып торган, мәгънәле. *Бабай, чүгәләп, җитди, моңсу кыяфәт белән дога укырга кереште.* Ә.Еники. *Сүзсез йөрәгендә күпме сагыш, борчылу таш булып ятканлыгын аның җитди, моңсу кара күзләре үк әйтеп тора иде.* Ә.Еники

7) Саллы, төпле, авторитетлы. *«Этимологический словарь русского языка», «Современный толковый словарь русского языка» кебек җитди басмаларда --- «бельмес»не дә белми» кебек тәгъбирләр урын алган.* Мәдәни җомга

8) Уйланырга мәҗбүр итә торган, шактый зур булган. *Либреттоны тыңлаган вакытта, берничә җитди кимчелеге сизелде.* М.Җәлил

9) Чын, табигый, ясалма түгел. *Язган хатлары, сугышның авыр һәм хәвефле айлары тәэсиренә бирелүдәндер инде, җитди һәм кыска булдылар.* Г.Минский. *...Куен сәгатенең юан, озын чылбыры кыршау күк салынып тора, кыяфәт бик җитди.* Г.Лотфи

10) Җентекле, тәфсилле. *Минем әйтергә теләгәнем бигрәк тә әдәбиятны җитди тикшерүдә нинди ысул тоту мәсьәләсендәдер.* Г.Ибраһимов

11) Ышанычлы, нигезле, уңай нәтиҗәсе булган. *Ә асылда, бу – минеке, дип, горурланып, кулыңа тотарлык бер җитди, төпле хезмәтең дә юк синең!* Ә.Еники. *Бу йортта үзенә хас басынкы бер киеренкелек, җитди бер эшчәнлек сизелеп тора иде.* Г.Бәширов. *Тукай турындагы фән алтмышынчы-җитмешенче елларда җитди казанышларга ирешә.* Т.Галиуллин

12) Эшкә җаваплы карый торган, булдыклы, эшлекле. *Мамадыш ягы, кайчак, бик тә җитди як, яшәеше, халкы белән дә, башкарган эшләре белән дә шактый ук җитди бер төбәк булып тоела.* Мәдәни җомга

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Таләпләре кушканча, бөтен шартын китереп. *Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна каенанасы белән ике куллап, бик җитди итеп күреште.* Ә.Еники

2) Тормыштагыча, асылда, чынлап. *Ул, --- бөтен көче белән чын, җитди күренергә тырышкан чагында да, кәҗә күзләренә охшашлы түгәрәк яшькелт күзләреннән кешене мыскыллау, кешеләрдән шаярып көлү чәчкән төсле күренә иде.* Ш.Камал. *Җаббар, хәйләкәр генә елмаеп, күзен кысып куйды. Аннан соң җитди генә итеп нәтиҗә ясады.* Ә.Фәйзи. *Ләкин Вәсим җитди сөйләшә, алдый торган гадәте дә юк.* Ә.Моталлапов

3) Чыннан, дөрестән дә. *Ләкин Хәмит агай чынлап, җитди итеп авырый. Аның янында бу вакытта юмор була алмый.* М.Мәһдиев

◊ **Җитди төс алу** Киеренкегә әйләнү, четерекләнү, катлаулану. *Мәсьәләнең җитди төс алуын күреп, ул да җитдиләнде, аның каш араларына калын гына ике җыерчык чыкты.* Ә.Фәйзи. *Кыскасы, дошманнар җиңеп, мәсьәлә минем өчен бик җитди төс алды. Минем өчен, димен, чөнки мөдирнең куркасы юк: аның утыз еллык стажы бар...* Х.Сарьян

**ҖИТДИЛӘНҮ** *ф.* 1) Җитдигә әйләнү, уйлап эш итәрлек дәрәҗәгә җитү. --- *Гөлчәчәк кинәт кенә әллә нишләде: җитдиләнде, уйчанланды, хәтта йөзеннән тылсымлы елмаюы качты.* Ф.Яруллин. *Көтмәгәндә, уйламаганда, Г.Афзал сатирадан читләшә. Темасы бетәме, каләме чарланмыймы? Юк, шагыйрь җитдиләнә.* Т.Галиуллин. *Элек тегенди-мондый мәзәк хәлләр сөйләнеп йөрергә яраткан карт кинәт кенә бик җитдиләнде.* М.Мәһдиев

2) Күз, караш, чырай һ.б.ш.да җитдилек (*1 мәгъ.*) сизелү. *Пётр җитдиләнде, үрелеп, гитарасын алды.* А.Гыйләҗев. *Илгизәр, сер сөйләгәндәй, сагая төште, зур күзләре җитдиләнделәр.* Г.Бәширов

3) Кискенләшү, катлаулану, кыенлашу. *Фронтның алгы сызыгында хәлләр җитдиләнде*

**Җитдиләнә бару** Вакыт узган саен ныграк җитдиләнү; җитдиләнүе акрынлап көчәю. *Мин бит бу тормышны тазартырга Чакырылган кеше дөньяга, Шуңа һаман җитдиләнә барам.* Г.Рәхим. *Юкса, үпкәгә тигән салкын торган саен җитдиләнә бара иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Җитдиләнә башлау** Җитдиләнергә керешү. *Кичке мәктәптә --- укучылар – егетләр-кызлар – инде җитдиләнә башлаган халык – артык шаяртып бимазаламыйлар.* Э.Касыймов

**Җитдиләнә төшү** Беркадәр, бераз җитдиләнү, җитдилеге тагы да арту. *Карт беравык хәрәкәтсез утыра. Аның күзләре тагын да җитдиләнә төшә.* М.Госманов. *– Икегез дә милициядәнме? – Юк, – дидем, елмая төшеп. ---*

*– Интерпол алайса? – диде ул, тагы да җитдиләнә төшеп.* Р.Мөхәммәдиев

**Җитдиләнеп алу** Кыска вакыт эчендә җитдиләнү; аз гына вакытка җитдилек күрсәтү

**Җитдиләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җитдиләнү; бөтенләй җитдиләнгән халәткә килү

**Җитдиләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта җитди булу

**Җитдиләнеп калу** Билгеле бер моменттан, вакыттан соң кинәт җитдиләнү. *– Әйттем бит инде, офицерлыкка укырга тәкъдим итәләр, – диде кинәт җитдиләнеп калган Сирин.* Ф.Латыйпов. *Моңарчы бөтен гамәлләре, сүзләре белән барын да көлкегә генә борып торган буйдак Андрей да җитдиләнеп калды.* К.Тимбикова

**Җитдиләнеп килү** Акрынлап, азазлап җитди була башлау

**Җитдиләнеп китү** Кинәт кенә җитдигә әйләнү. *Җиңгәсенең җитдиләнеп киткән чыраена, кызык булып җыерылган кашларына күзе төште дә Нәфисә ихтыярсыз көлеп җибәрде.* Г.Бәширов. *Газыйм да, Разия да бу минутларда үзләрен, ничектер, бердән үсеп, җитдидәнеп киткән төсле сизделәр.* Г.Минский. *Ләкин докторларны озаткannan соң янына кергән кызының бик җитдиләнеп киткән йөзенә карап, ул эшнең серен сизенгәндәй булды.* Ә.Еники

**Җитдиләнеп кую** Кинәт җитдиләнү. *Бу вакытта Илдар да уянды, башын мендәреннән күтәрә төшеп, тыңлап ята иде, көлде һәм, ахрысы, энесенең сүзләре тәэсир иткәндер, җитдиләнеп куйды, уйчанланды.* Г.Гобәй. *--- һәм кинәт кенә җитдиләнеп куйды генерал. Аның күз алдына Чернобыль вакыйгалары килде булса кирәк.* Т.Нәҗмиев

**ҖИТДИЛӘТҮ** *ф. к.* **җитдиләштерү**. *Ниһаять, директор үзен кулга алды, тавышын яңадан җитдиләтте.* М.Әмир. *Кинәттән, кулларын аның муеныннан алып, тавышын җитдиләтеп: – Әйе, егет, көрәш юлында йөргән кешеләр һичбер вакыт тойгы корбаны булырга тиеш түгелләр [диде]!* Ш.Усманов

**ҖИТДИЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Җитди төс бирү, кырыслату, артык җитдигә әйләндерү. *Доктор йөзен җитдиләштерде, сугыш турында сөйләшмәскә киңәш бирә башлады.* Ә.Таһиров

2) Җитди, уйлап эш итәргә мәҗбүр итү

**Җитдиләштерә төшү** Беркадәр, беразазлап җитдиләштерү; тагы да җитди хәлгә китерү

**Җитдиләштереп тору** Даими рәвештә җитдиләштерү

**ҖИТДИЛӘШҮ** *ф.* 1) Җитди (*1 мәгъ.*) төс алу, җитдигә әйләнү. *Чынлап сөйләргә яраткан олы кеше янында, ягъни минем янымда, ул кыз да җитдиләшеп, миңа эшне кыскача гына аңлатып бирде.* С.Баттал

2) Кискенләшү, кыенлашу, читенләшү. *Кара аны, Әптерәшит, тагын бер кат әйтәм: мәсьәлә җитдиләшеп, җинаятең катлауланып бара.* Т.Гыйззәт. *Зөһрә ханымга бик авыр тәэсир калдыра булырга кирәк, ул, килен булып төшкәч тә, озакламаенча хасталана, авырый, хәле бик җитдиләшә.* А.Мәхмүтова

**Җитдиләшә бару** Вакыт узган саен ныграк җитдиләшү. *Илдә хәлләр җитдиләшә бара*

**Җитдиләшеп бетү** Бөтенләй, тулысынча җитдиләшү

**Җитдиләшеп килү** Акрынлап, азазлап җитдигә әйләнә башлау, катлауланып килү, кыенлаша бару

**Җитдиләшеп китү** Кинәт җитдиләшү; кинәт җитдигә әйләнү. *Соңгы вакытта хәлләр җитдиләшеп китте*

**ҖИТДИЛЕК** *и.* 1) Уйлап эш итүчәнлек, төплелек. *Хәмдиевнең бөтен барлыгыннан, үз-үзен тотышыннан --- катгыйлык һәм җитдилек бөркелеп тора иде.* Р.Төхфәтуллин. *[Малайлар] Шәвәли абзыйның йөзендәге гаять эшлекле җитдилекне һәм аяусызлыкны күреп, авызларын кире яптылар.* Ә.Фәйзи

2) Олысымаклык, акыллылык. *Элекке иркә, матур йөздә хәзер бик аз гына җитдилек күренә.* Г.Ибраһимов. *Зәвык белән тегелгән костюмның күкрәк турысыннан, ак кофточка өстеннән сузылып төшкән кызыл галстук кызның күрекле йөзенә матур җитдилек биргән.* К.Тинчурин. *Ул бу вакытта көлеп маташмый. Йөзендәге тынлык белән бик нык җитдилек аңлата иде.* Ш.Камал

3) Җитди мөнәсәбәт, җитди караш. *Ул бераз ябыга, суырыла төште, --- ә акыллы йөзендә аның нидер көтүне чагылдырган, бер дә югалмас җитдилек күренә иде.* Ә.Еники

4) Кырыслык; киеренкелек. *Аның ниндидер бер җансыз җитдилек белән катып калган йөзе аз гына сагыш белән өртелгән.* Ә.Еники. *Әмма кешеләрнең йөзләрендә шатлык юк, уен-көлке юк, бары тик ниндидер – яшьләргә әлегә билгесез киеренкелек, гадәттән тыш җитдилек, сүзсез җитдилек бар иде.* М.Мәһдиев

5) Мөһимлек, әһәмиятлелек, җаваплылык. *Хәлнең җитдилеген күз алдына тәгаен китереп бетерә алмаса да, --- бүтәнчә дә хәл ителү мөмкинлегеннән күпмедер шөлли төште.* Ә.Моталлапов. *Кайчагында алар [малайлар] мәсьәләнең җитдилеген зурларга караганда да тизрәк аңлый беләләр иде.* Ә.Еники. *Һади Такташ иҗатка һәрвакыт зур җитдилек һәм ышаныч белән карый, шулай ук башкаларның да аңа тиешле җитдилек белән карауларын таләп итә иде.* Мәдәни җомга

**ҖИТДИЯТ** *и. гар. иск. к.* **җитдилек**. *[Ул] Нотык сөйләгәндәге бер җитдият һәм күтәренкелек белән сөйләргә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Аның йөзенә тагын да җитдият һәм ачу галәмәтләре чыкты...* М.Гафури

**ҖИТЕЗ** *с.* **1.** 1) Өлгер, уңган, булдыклы, тиз башкаручан. *Җитез кеше җитәм дигән җиренә җитми кайтмас.* Әйтем. *Һәм дә киләчәктә кайчан да булса бик эшлекле вә җитез бер егетнең аңар: – Әткәй, син күп эшләдең, хәзер инде синә ял итәргә вакыт... – диячәген уйлап, күңеле янә күтәрелә вә гайрәте янә арта иде.* Ш.Камал. *Миңа яшь, үткер күзле, җитез куллы мөселман бригадир кирәк иде, моңарчы заводта андыйлар булмады.* А.Гыйләҗев

2) Хәрәкәтчән, елгыр, тиз йөрешле. *Анда да бит шушындый ук бер кара урманда агач төбеннән ике кеше җиде сандык алтын казып алалар. Аларның*

*да бит берсе нәкъ шундый: үзе бөкре, үзе җитез карт була.* Г.Гобәй. *Күлмәк итәкләрен кыстырган, ябык гәүдәле, әрлән кебек җитез яшь кенә хатын иде ул.* Ә.Фәйзи. *Озын таяклар белән коралланган җитез, чая үсмерләр тамашаны тагын да ямьлерәк, кызыклырак итү чараларын күрә.* Мәдәни җомга

3) Тизлеге белән аерылып торган; омтылышлы, кискен. *Хөршит җәһәт кенә йөзен күтәрде, турайды, йомшак, ләкин җитез генә хәрәкәт белән кулын минем учымнан котылдырды.* Ф.Әмирхан. *Фәйрушин җитез егет булып, әкрен йөрүне белми иде – шотыр-шотыр юынып, киенеп тә алды.* Х.Сарьян. *Вафин Харис – «Ялкын» колхозының тырыш, җитез, зирәк хуҗасы.* Ш.Маннур

4) Тиз, кызу хәрәкәтләнә торган. *Хәзер аның күзләрен кан баскан, гәүдәсен кан түгел, ниндидер җитез машина хәрәкәтләндерә кебек иде.* Г.Гобәй

5) *күч.* Яхшы ишетә яки күрә торган, җете. *Сафа, сүзгә саран булса да, колакка бик җитез иде.* А.Шамов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик тиз һәм оста итеп. *Карыйм, кызыйның кулы җитез йөри.* Р.Ишморат. *Бу кызның бөтен зифа торышыннан, кабаланмыйча, ләкин җитез генә ясаган хәрәкәтләреннән оялчан тыйнаклык, сөйкемле садәлек сизелеп тора иде.* Ә.Еники

2) Тиз арада, шәп, җәһәт итеп. *Бу вакытта инде Мәрдән абзый, арысландай җитез борылып, старостаның якасыннан эләктереп алган иде.* Г.Гобәй

◊ **Җитез тоту** Эшне уйлаганнан кыскарак вакытта эшләп чыгу, тиз арада башкару

**ҖИТЕЗ-ҖӘҺӘТ** *рәв. к.* **җитез-җитез**. *[Кызчык] Җитез-җәһәт хәрәкәтләнеп, шунда дебаркадерда торган ике хатын-кыз янына килеп, көлеп-елмаеп, палубада калган әтисенә кул болгый башлады.* М.Хәсәнов

**ҖИТЕЗ-ҖИТЕЗ** *рәв.* Тиз-тиз, зур тизлек белән, җәһәт кенә. *Тик аннары гына [хатыннар] чиләктәге керләрен чыгарып, үзара эндәшкәләп ала-ала, җитез-җитез чайкарга һәм, су буен яңгыратып, бәләк белән чабарга тотындылар.* А.Шамов

**ҖИТЕЗЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Җитезрәк хәрәкәт итә башлау, тизлекне арттыру. *Кайтыр юлга чыккач, ат та җитезләнде*

2) Уйнаклау, җитез хәрәкәтләр ясау. *Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә, Җитезләнә, уйный һаман, йөгерә, өрә.* Г.Тукай

**2**. **җитезләнеп** *рәв. мәгъ.* Җәһәт кенә, ашыгыч рәвештә, тиз генә. *Ул [ана] яшәрде кебек шатлыгыннан, Җитезләнеп, чәен яңартты.* Н.Баян

**Җитезләнә бару** Торган саен җитезлеген арттыру. *Үскән саен, малай җитезләнә бара*

**Җитезләнә башлау** Җитезлеген арттырырга тотыну

**Җитезләнә төшү** Беркадәр җитезләнү; җитезлеге бераз арту

**Җитезләнеп алу** Кыска вакыт эчендә җитезләнү. *Кызлар, берара җитезләнеп алып, эшне төгәлләп тә куйдылар*

**Җитезләнеп китү** Кинәт кенә җитезгә әйләнү. *Ачык диңгезгә чыккач, кораб җитезләнеп китте, дулкын кузгатып, алга омтылды.* М.Юныс

**ҖИТЕЗЛЕК** *и.* 1) Тизлек, кызулык, өлгерлек. *Инде ук җитезлеге белән читәнгә табан атылам дигәндә генә, кыяр түтәлләрен әйләндергән куе кабак яфраклары арасыннан атылып, Ибрай үзе килеп чыкты.* М.Әмир. *Кылычлылар кергән җитезлек белән үк чыгып та киттеләр.* Ә.Фәйзи. *Берзаман остазым --- уңнан сулга таба теләсә нинди сүзләрне күз аермас җитезлек белән – яшен яшьнәве тизлеге белән – кара тактага шул тиклем дә языплар күрсәтте ки, миннән калган һәркем аһ итте.* Ә.Гаффар

2) Җитез булу сыйфатлары. *Айсылу! Кая синең ялкынлы сүзең, кая җитезлегең?!* Г.Бәширов

3) Нинди дә булса эшне башкаргандагы хәрәкәт тизлеге. *Атлар туктамыйча-тукталмас, Закир көймәдән сикереп төште, җитезлек белән яшь хатынын култыклады…* Г.Ибраһимов. *Күзләрем яшен җитезлеге белән ишеккә төбәлде.* М.Әмир. *Ләкин кашыкларның җитезлеге кимемәде, «әһ» дигәнче, шактый зур агач табак белән куелган талкан яртыга калды.* Ә.Фәйзи

**ҖИТЕН** *и.* **1.** 1) Җитенчәләр семьялыгыннан, сабагыннан – сүс, орлыгыннан май алу өчен үстерелә торган берьеллык үсемлек. *Болынга җитенне сүсләнергә таратканнар.* Г.Толымбай. *Инде колхоз басуларына көнбагыш, киндер һәм җитен кебек соң өлгерә торган культуралар да чәчелеп бетте.* Г.Галиев

2) Шул үсемлек сабагыннан алынган сүс. *Зәйнәпнең апайлары, кичләр утырып, җитенне кабага элеп, орчык әйләндерә, җеп эрли башладылар.* Дәрдемәнд

3) Шул сүстән эрләп тукылган материя. *Нурый үзе дә --- һәр базарда диярлек төпчек кызның тегү-чигүләре өчен --- кирәк җепне, җитенне --- алып бирә барды.* Г.Ибраһимов

**2**. *с. мәгъ.* 1) Җитен сүсеннән эрләнгән. *Кар агарткан җитен җебен кызлар, Җыеп алып, киләп киләпләп, Чайкадылар көмеш чишмәләрдә, Ак бәләкләр белән бәләкләп.* Ш.Маннур

2) Шул сүстән эрләп тукылган. *Җитен күлмәкне җил ала, Илтеп, дәрьяга сала.* Җыр

3) Җитен **1.** (*2 мәгъ.*) төсендәге. *Минем уң ягымда утыручы җитен сакаллы, күк күзле бабай шапылдатып тезенә сукты.* Г.Мөхәммәтшин

4) *күч.* Чаларган, ак төскә кергән, агарган. *Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе, --- Җитеп килә инде аның җитмеш яше, җем-җем итә җитен сакал, көмеш чәче.* Г.Тукай

**ҖИТЕНКЕ** *с.* Үсеп озынайган, җиткән, житү. *Арнаутовның сакалмыек – җитенке.* Ф.Хөсни

**ҖИТЕНКЕРӘ́Ү** *ф. гадәттә, юкл. форм.*1) Тулысынча диярлек җитү, җитәрлек кадәрле булу. *Бер уйлаганда, аксакал хаклы иде, дружина яңа оешып килә, корал җитенкерәми, сугышчыларның күбесе агач сөңге белән коралланган.* М.Хәбибуллин. *Әмма кызыксынуы җитенкерәмәдеме, әллә төбәлеп җиткерә алмадымы, күзләрен Габдулланың җиңендәге --- сүтегенә күчерде.* Ә.Фәйзи. *Аллага шөкер, товарлар исән… Менә… Акча гына җитенкерәмәде.* Ә.Моталлапов

2) Тиешле дәрәҗәдә булу. *Саулык җитенкерәмәү*

3) *эфм. юкл. форм.* Акылга сай булу, юләр булу. *Аңа бераз җитенкерәми*

**ҖИТЕН МАЕ** *и.* Җитен орлыгыннан сыгып алынган май. *Иртән, җитен маена манып, бәрәңге ашап килгән идек.* Г.Мөхәммәтшин

**ҖИТЕНЧЕ** *и.* Җитен үстерүче, җитенчелек белән шөгыльләнүче. *Уңган җитенчеләр бу юлы да сынатмадылар*

**ҖИТЕНЧЕЛЕК** *и.* Җитен үстерү эше. *Җитенчелек алга киткән районнар*

**ҖИТЕШ** *с.* **1.** 1) Яшәү өчен кирәкле бар әйбере дә булган, мал-мөлкәтле, барлыклы. *Соң, бар җирегез җитеш. Өй, дисәң – менә дигән, ашарга бар...* Р.Мөхәммәдиев. *--- бар дөньясы җитеш, тормышы түгәрәк, тәне сәламәт хатынына башкалар кайгысы гына шатлык китерә алганын яхшы төшенде ул.* Ф.Яруллин. *Бөтен килеш-килбәтеннән, торыш-кыланышыннан, шулай ук шактый фасонча киенгән өс-башыннан аның җитеш тормышта, оста кулда пешеп җиткән кыз булуы әллә каян күзгә бәрелеп тора иде.* Ә.Еники

2) Кирәк кадәр булган, җитешле, мул. *Әле беркөн генә, һәммә нәрсәң җитеш инде, дип торадыр идең.* М.Фәйзи

3) Хуплауга лаек, һәр яктан өлгергән, әйбәт. *Һади Такташ үз иҗатының җитеш һәм уңышсыз якларын масса хөкеме алдына куярга ярата иде.* Мәдәни җомга

4) Нәрсәгә дә булса охшаш, шуннан аергысыз, тиң. *Җир йөзендә моңа җитеш булырлык байлык һичкемдә дә юктыр.* Әкият

**2.** *рәв. мәгъ.* Мул, хәлле тормыш белән, бай булып. *Җитеш яшәү*

**3.** *хәб. функ.* Кирәк әйберләрнең барысы да булу. *--- бөтен нәрсә җитеш. Йорт-җир – байларча, мал-туар абзар тулы.* А.Гыйләҗев

**ҖИТЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) *к.* **җитеш 1.** (*2 мәгъ.*). *Сезнең хакта, һәр яктан җитешле районыгыз хакында күп ишеткәнем бар.* Р.Мирхәйдәров. *Бу малтуар, йорт-җир – кайсы ягы җитешле түгел?* Ф.Яхин. *Мин ышанам: андый вакыт җитәр, авыл укытучысы гаиләсенә җитешле хезмәт хакы алыр, үз өстендә эшләргә мөмкинлек табар.* Ватаным Татарстан

2) Җиңел аңлашыла торган, ачык, гади. *Җитешле сөйләм. Җитешле уен*

3) Билгеле бер күрсәткечләре, сыйфаты белән тиң булган, охшаш. *Фатыймага бүген буй җитешле түгел иде, Айбикә инәйнең тырышлыгы бушка китмәде.* З.Кадыйрова

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **җитеш 2.** *Яугирләре дә бу дәүләтнең халкы ни дәрәҗәдә бай һәм җитешле яшәвен үз күзләре белән күрделәр.* М.Хәбибуллин. *Җитешле генә яшәп, дүрт бала үстергән сыйныфташым – элек аеклар исемлегендә йөргән тырыш ир-егет – хәзер хатыны белән бергәләп эчә.* Ватаным Татарстан

**3.** *хәб. функ.* Кирәк кадәр булу, җитү. *Биредә тормыш өчен кирәк булган бөтен нәрсә дә җитешле*

**ҖИТЕШЛЕ-ҖИТЕШСЕЗ** *с.* Тиешле дәрәҗәдә булмаган, кимчелекле, ярты-йорты. *Шуның өчен аларны әйбәтләп укып, җитешле-җитешсез якларын аңлатып баручы махсус укымышлылар – тәнкыйтьчеләр кирәк.* Татар әдәбияты

**ҖИТЕШЛЕК** *и.* Мул тормыш, муллык, барлык. *Бик җитешлек һәм пөхтәлек белән эшләнгәнлеге күренеп торган бу йортның хәзерге кыяфәте --- минем эчемне пошыра иде.* Ф.Әмирхан. *Ул эре-эре ташлардан җитешлек белән салынган таш амбарлар, биек кыеклы лапаслар, кар базы, келәтләр...* А.Гыйләҗев. *Андый җитешлеккә барча «яңа татар»лар да, «яңа урыс»лар да әрсезлек белән генә ирешкәннәрдер дип әйтүем түгел.* Мәдәни җомга

**ҖИТЕШСЕЗ** *с.* 1) Яшәү өчен кирәкле бар әйбере дә булып бетмәгән, мохтаҗ, ярлы, фәкыйрь. *Кысан, җитешсез тормыштан кинәт иреккә чыккан хатын-кызның күңеле әйле-шәйле яңа фикерләр белән тула.* А.Гыйләҗев

2) Кирәкле күләмнән ким, саны җитеп бетми торган

3) Тиешле сыйфаттан түбән, йомшак, кимчелекле, җитешсезлеге булган. *Тәдбирле һәм сәләтле Галимҗан Галиев яшь чагыннан ук иске мәдрәсәнең җитешсез якларын күргән...* Р.Әмирхан

**ҖИТЕШСЕЗЛЕК** *и.* 1) Нәрсәнеңдер булмавы, җитмәүчелек, мохтаҗлык. *Байлыкка табыну хисен уятучы төп сәбәп ярлылык, җитешсезлек үзе булса, аны байларга хөрмәт хисенә әверелдерүдә ислам дине һәм аның руханилары зур урын тоткан.* М.Әмир

2) Тиешле сыйфатка, таләпкә, дәрәҗәгә туры килмәү. *Алар [кадими конфессиональ мәктәпләр], үзләренең бөтен җитешсезлекләренә карамастан, үз шәкертләренә мәгълүм микъдарда белем биргәннәр, аларны фикри яктан үстергәннәр...* Р.Әмирхан. *Инспектор белән механик, зур фонарь тотып, машина тирәсендә йөриләр ---. Бик тырышып эзләгәч, «Волга»ның җитешсезлекләрен табып булыр дип уйлый Нияз.* М.Маликова

3) Кешедә яки берәр нәрсәдә булган җитешсез як; килешмәгән җир, кимчелек. *Телен тыюы бик авыр аңарга ---. Шул җитешсезлеге янында Яруллинның бик тә зур тәвәккәллеге дә бар.* З.Зәйнуллин. *Аның көчле, үзен хәйран калдырган сыйфатларын белгән кебек, җитешсезлекләрен дә аңларга, гафу итәргә гадәтләнгән иде Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев. *Автор аны артык вакласа, җиргә төшерсә, характерының җитешсезлекләрен тәфсилләсә, халык андый Сөембикәне кабул итмәс, күңеленә үткәрмәс иде шикелле.* Т.Галиуллин

4) Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсендәге уңышсызлык; җимереклек, зарар, зыян. *Чын дус алга киткән якны күрсә, Йөзе китә айдай ачылып, Җитешсезлек, җимереклекне күрсә, Тәнкыйть итә, эчтән ачынып.* М.Гафури. *Ревизия ачкан җитешсезлекләр турында без аңа нык кына кисәтү ясарга тиешбез.* Ә.Еники

**ҖИТЕШТЕРҮ** I *ф.* 1) Яшәеш өчен кирәк булган матди әйберләр барлыкка китерү, нәрсә булса да эшләп чыгару. *Инстинктив хезмәт нәтиҗәсендә табигатьтән әзер предметлар алынган, хезмәт кораллары, яңа продуктлар җитештерелгән.* Ф.Сафиуллина. *Ак чыршы, гадәттә, кәгазь җитештерүдә кулланыла.* И.Рәхимов. *Кайчакта аларны дару препаратлары*

*җитештергәндә файдаланалар.* Урман аптекасы

2) Нәрсәне булса да ясау, әзерләү, барлыкка китерү. *Цехларга чимал җитештерү эше ифрат читенләшкән.* Ш.Камал. *Бары тик Әхмәт алачыгында гына корал эшләп, хуҗалыктагы оста мактанырдай барлык кирәк-яракларны җитештерәләр иде.* М.Хәбибуллин. *Авыл хуҗалыгы культураларын серкәләндерү өчен умарта кортларыннан киң файдаланып, аларның уңышын шактый арттырырга һәм бер үк вакытта кыйммәтле туклану продукты булган бал һәм балавыз җитештерүне арттырырга мөмкин.* Умартачыга ярдәмлек

3) Ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш үстерү. *Колхоздан киткән яшьләр, әллә кайда читтә түгел, шушында, борын төбендә генә эшлиләр: кайсы – нефтьтә, кайсы – төзелештә, кайсы – тегүдә, кайсы – эти-әни җитештергән азык-төлекне сатуда.* Ф.Яруллин. *Шундый күләмдә көнбагыш җитештерү өчен, аның чәчүлекләрен 1 млн. гектарга киңәйтергә кирәк булыр иде.* Умартачыга ярдәмлек

4) Азык-төлекне кулланырга яраклы итү; ризыкны ашарлык хәлгә китерү. *Сый җитештердем, бик күп пешердем.* А.Алиш

5) Төрле профессия белгечләре, кадрлар әзерләү, өйрәтү, укытып чыгару. *Театр җитәкчелегенең һәм Сәнгать эшләре идарәсенең төп бурычларыннан берсе опера өчен милли художество кадрларын җитештерүдән гыйбарәт.* М.Җәлил

6) *күч.* Сәяси эш өчен өлгертү, рухи, әхлакый яктан үстерү, чыныктыру. *Шулай, көрәш һәм сынаулар юлы Хабулны аңлы көрәшче итеп җитештерә, революциягә алып килә.* М.Гайнетдинов

7) Нәрсә дә булса кору, төзү; эшне төгәлләү. *Колхозга яхшы каралтылар җитештерделәр.* Г.Бәширов. *Митри дәдәй, Хәлимнең сүзен тыңлап, үз тормышын, карчыгын калдырып, йорт җитештерергә килеп җитте.* Г.Гыйльманов. *Кайтсын гына, яңа йорт җитештерер әле Габдерахман.* Ф.Яхин

8) *күч. диал.* Ирештерү, кемгә дә булса барып әйтү, җиткерү. *Без бу эшләрне никадәр яшерен итәргә тырышсак та, барыбер аңа моны җитештерерләр.* Ф.Бурнаш

**Җитештерә бару** Аз-азлап, эзлекле рәвештә җитештерү

**Җитештерә башлау** Җитештерергә тотыну

**Җитештерә килү** Электән үк, даими рәвештә җитештерү

**Җитештерә тору** Даими рәвештә, һәрвакыт җитештерү. *Үзебез колхоз турында, ул җитештерә торган ашлык, ит, сөт турында --- сөйләшәбез, ә үзебез ике сүзнең берендә, «кәеф», «өмет», «рухи халәт», дибез.* И.Низамов

**Җитештерә төшү** Тагы да бераз җитештерү

**Җитештереп алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә җитештерү

**Җитештереп кую** Җитештерелгән хәлгә китерү, алдан җитештерү

**Җитештереп тору** Һәрвакыт, гел, даими рәвештә җитештерү. *Су көче белән эшли торган бу такта яргычы колхозның бөтен төзү эшләренә кирәкле тактаны җитештереп тора икән.* М.Гали

**ҖИТЕШТЕРҮ** II *и.* Матди байлыкларны барлыкка китерү белән бәйле эшчәнлек. *Алга китеш тукталу, җитештерү кыскару сәбәпле, эшчехезмәткәрләргә ихтыяҗ нык кимеде ---.* З.Мифтахов

**ҖИТЕШТЕРҮЧӘН** *с.* 1) Матди байлык эшләп чыгара торган. *Халык хуҗалыгының җитештерүчән тармаклары*

2) Нәтиҗәле, продуктив. *Җитештерүчән хезмәт*

**ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕК** *и.* Башкарган эшнең нәтиҗәлелеге, эшләп чыгару дәрәҗәсе. *Машина-аппаратларның җитештерүчәнлеге. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү*

**ҖИТЕШТЕРҮЧЕ** *и.* Матди байлыклар җитештерү эшендә катнашучы кеше, кешеләр төркеме, предприятие. *Сөттән керем күп, ләкин җитештерүче үзенә тиешле өлешеннән мәхрүм кала.* Ватаным Татарстан. *Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче*

**ҖИТЕШҮ** *ф.***1.** 1) Кызарып пешү, өлгерү, үсеп җитү. *Алар артыннан кыяр, кишер, кавын шикелле кадерлерәк яшелчәләр җитешә.* М.Әмир. *Августа әле үләннәр ямь-яшел, чәчәкләр дә керфек кагалар, бакчаларда чия, алма җитешә.* Д.Каюмова

2) Үсеп җитү, балигъ булу. *Шул заман эчендә егетем камил ир булып җитешкән.* Г.Ибраһимов. *Гаиләсе бөтен, балалары бер дигән үсеп җитеште, күз тимәсен.* З.Мифтахов

3) *күч.* Белгеч, профессионал булып өлгерү, үз эшенең остасына әйләнү. *Ниһаять, төрк халыкларыннан да тарихка керерлек галимнәр җитешә...* М.Зәкиев. *Акрынлап Зәйнәп үз-үзен тотышындагы индивидуалистик моментлардан арынган, коллективчыл тойгылар белән янучы кеше булып җитешә.* З.Рәмиев

4) Вакытына килеп өлгерү, кичекмәү. *Мин үземне кая куярга белмәдем, Хәбибуллин җитешер микән?* З.Хәким. *--- эшемдә утырыш булачагын, сәгать дүртләрдә икәнлеген әйттеләр. Ярар, ярар, җитешермен, килми калмам дип уйладым.* Ф.Яхин

5) Өлгерү, әзер булу. *Яккан мунчам да җитешергә тора, мактап кына йөрүегез икән.* Р.Низами

6) Барысына да өлгерү, кул җитү. *Эш бик кызу. Ничек җитешәсең?* Ш.Мөдәррис. *– Җитәкчеләрнең эшләре күп була, җитешә алмыйлардыр, – диде ул.* М.Маликова. *Абзар тулы малың, казың, үрдәгең! Мин каян барысына да җитешим?* Ф.Яхин

7) Барып ирешү, тапшырылу. *Үзеңә хәер-догасы булып җитешер. Дин, дөнья өйрәтергә безгә мәктәп ачып бир.* Г.Ибраһимов

8) Нинди дә булса халәткә, хәлгә җитү. *Бер-беребезнең күкрәкләренә мылтык төзәп атышу дәрәҗәсенә җитештек.* Г.Ибраһимов. *Һәркемнең йөзендә кулы белән тотып, кармагына каптыру мәртәбәсенә җитешкән бер теләк балкый.* Г.Ибраһимов

9) Куып җитү, артыннан өлгерү. *Артыннан юлдашлары җитешкәндә, ул инде ашкынган хис атын авызлыкларга өлгергән иде.* Ф.Яхин

10) **житешмәү** *юкл. форм.* Сан, күләм, сыйфат ягыннан канәгатьләнерлек булмау, кирәк кадәр, җитәрлек дәрәҗәдә булмау. *Әти-әниләр ташысалар да, дачада һаман савыт-саба җитешми икән әле.* Т.Әйди. *Организмда Е витамины җитешмәве матдәләр алмашуның бозылуына һәм төрле органнарның шуңа бәйле зарарлануына, җенси функциянең көчсезләнүенә китерә.* Урман аптекасы

11) Өскә чыгу, барлау, хисабын алу вакытында, акча яки нинди дә булса продукция исәптәге белән чагышмау, исәптәгедән кимрәк булу. *Кайчак анда егерме мичкәләп спирт җитешми.* Т.Гыйззәт. *Май заводында ревизор, Санап бакса – җитешмәү зур.* Ш.Галиев

12) *сөйл.* Фикерләү сәләте зәгыйфьрәк булу. *Аңа бераз җитешми*

13) **житеш(егез)** *боерык ф. форм.* Табында кемне дә булса ашарга-эчәргә өндәү, кунакны кыстау сүзе буларак әйтелә. *Җитешегез әле, кода, бары белән!* Ә.Фәйзи. *– Кыстатмагыз, җитешегез әйдә, – диде Сабира апа, өстәлдә яткан бизәкле кашыкларга ишарәләп.* Р.Низами

**2.** *ярд. ф. функ. -рга/-ргә кушымчалы фигыль янында*: 1) Шул фигыль белдергән эшне үтәргә, башкарып чыгарга өлгерү-өлгермәүне аңлата. *Алар [мишәрләр] җавап бирергә җитешми, ул кабат сорауларын тезә.* Ф.Яхин

2) Алдында килгән фигыль белдергән дәрәҗәгә җитүне ачыклый. *Мин туктадым, актык көчемне җыеп дигәндәй, беләгемне тартып алдым да, еларга җитешеп, көчкә-көчкә генә: «Нишлисез сез?» – дидем.* Ә.Еники. *Еларга җитешеп, атка ялынырга тотындым: – Баһ-баһ, җаным, харап итәсең бит.* Г.Бәширов. *Сабир уртада бөтерелә, ә аны шартларга җитешкән кып-кызыл битләр, күлүдән яшьләре чыккан күзләр --- уратып алган.* З.Зәйнуллин

◊ **Җитешмәгән җир (як, урын)** 1) Җитешмәүчелек, мохтаҗлык. *Хәтта инде ул вакытта бер дә җитешмәгән җир булмый, бар сәгадәт безне каршы алырга гына көтә.* Ш.Камал; 2) Кемнең дә булса кимчелеге, йомшак ягы. *Җитешмәгән ягыңны фаш итеп «өйрәтә» дигәннән...* Н.Исәнбәт

**Җитешеп бару** Даими рәвештә, һәрвакыт житешү

**Җитешеп килү** 1) Һәрвакыт, гел җитешү, нәрсәне булса да вакытында эшләргә өлгерә бару

2) Акрынлап килеп җитү, якынаю. *Агыйделнең аръягына җитешеп килгәндә, таң аткан --- .* Ф.Яхин

**Җитешеп тору** Һәрвакыт, гел җитешү

**ҖИТКӘН** *с.* 1) Өлгергән, балигъ булган. *Һәрбер җиткән кыз кияүгә чыгарга тиеш. Бу – табигый нәрсә.* Ә.Еники. *Җиткән кызлар алъяпкыч итәгенә җыйган җиләкләрен табын янына китереп салалар.* Ф.Яруллин

2) Зур үскән, кирәгеннән артык озын. *Чәчләр җиткән, буй үскән, беләкләргә тагын да күбрәк куәт өстәлгән.* Ф.Яруллин

**ҖИТКЕЗҮ** *ф.* 1) *сөйл. к.* **җиткерү**. *Күз җиткезер, күз җиткезмәсә – сүз җиткезер.* Мәкаль. *Әйткән җиткезер, чаккан үтерер.* Мәкаль

2) Төгәл итеп, шартын китереп башкару. *Әллә җиткезеп яза белмиләр шунда.* Г.Коләхмәтов

3) Төзеп чыгу, ясап кую. *Каралтыкура җиткезү*

**Җиткезә тору** 1) Һәрвакыт җиткезү, һәрберсен, булган берсен җиткезү

2) Җиткезерлек булу. *Нагиев, булдыра алганча, эшем кешесечә күренергә тырышып, кыска, ләкин җиткезә торган итеп сөйләшергә тырыша иде.* Ф.Хөсни

**Җиткезеп кую** Әзер итү, җиткезгән хәлгә китерү. *[Сәлимов] Быел гына Идел буенда менә дигән бер дача да җиткезеп куйган.* С.Сабиров

**Җиткезеп тору** Әле, хәзерге вакытта җиткезү

**ҖИТКЕЛЕКЛЕ** *с.* **1.** Бар яктан да житеш; мул, бай. *Ике-өч балалы булса, ир-атлы, җиткелекле тормыштан бөтенләй өмет өзеп, бөтен гомеренә михнәт чигәр өчен, тол хатын булып кала да мал-туарны киметергә, бөтен хуҗалыгын кысарга тотына.* Г.Бәширов. *Безнең халык әйткәндәй, «артык күп бервакытта да җиткелекле булмый».* Н.Измайлова. *Җиткелекле монда барсы да: телевизор, затлы шифоньер, Биек көзге тора каршыда.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Җитәрлек итеп, тиешенчә. *Материалны җиткелекле җибәрмиләр.* Ә.Баян

**ҖИТКЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Акча, азыктөлек һ.б.ш. кирәк- яракны җитәрлек итү, җитәрлек күләмдә булдыру. *Аңа, көннекен көнгә җиткерер өчен, әллә ниләр уйлап табарга, тормышны хәйләләргә туры килде.* Ә.Фәйзи. *Мөгаен, аны тормыш авырлыгы куркытадыр: фатир өчен түләү көн саен диярлек арта, балаларга чыгымнар үсә, әйберләр кыйммәтләнә, акчаны җиткерү кыенлаша.* Ф.Дәүбаш

2) Билгеле бер вакытка, срокка кадәр бетермәү, сак тоту. *Солдат башына яртышар кадак сохари бирделәр, иртә беләнгә кадәр шуны җиткерегез.* М.Гали. *[Гасыйм Сәләхович:] – Менә сиңа акча, шуны җиткерергә тырыш, әйбәт кенә йөр ---, – диде.* Ә.Еники

3) Нинди дә булса әйбернең бер башын икенче бер чиккә туры китереп сузу, озынайту. *Хәлим Нәҗипнең --- хәтсез үскән, аяк йөзләренә җиткереп тегелгән шинеле белән тагын да озынрак булып күренгән гәүдәсенә карап тыңлап торды.* Г.Гобәй

4) Билгеле бер күләмгә тутыру. *Заданиемне бүген йөз иллегә җиткермен, аны белеп тор!* М.Җәлил

5) Билгеле бер срокны көтеп алу, вакытны аның килеп җитүен санап үткәрү. *Ашауга киткән вакытка «перекур» минутларын өстәп, ярты сәгатькә җиткерәсең дә килгән бураз-наның читеннән кире кайтып китәсең.* К.Кәримов. *Бәлки, алар, менә тагын бер язны исән-сау җиткердек, дип сөенәләрдер.* Ф.Яруллин

6) Билгеле бер вакытка кадәр сузу, югалтмый саклап калу. *Җир йөзендәге башка барлык һәйкәлләрне дә узып китеп, данын мәңгелеккә җиткерергә тиеш була бу корылма.* М.Юныс. *Хисләрне ничек итеп саклап калырга, ничек итеп аларны, түкми-чәчми, бөтен гомер буена җиткерергә соң?* Тигез гомер итегез!

7) Тапшыру, ирештерү, кемнеңдер хис-тойгыларын, фикерен, карашларын сөйләп, язып бирү. *Алайса, зинһар өчен, сез аңа минем сәламемне җиткерегез!* Ә.Еники. – *Инде йомышыңны җиткер, морза, кем Йосыфҗан, – диде.* М.Хәбибуллин. *Миңа җиткерделәр, углан, Шайтан каласы нигезенә Болгар Ата үз-үзен корбан иткән, имеш.* М.Хәбибуллин

8) Әләкләү; берәр начар эш турында кемгә дә булса хәбәр итү, әйтү. *Ә кнәгинә, башы яшь булса да, Исмәгыйльне яратмый иде, илчеләре җиткерделәр бу хакта.* М.Хәбибуллин. *Хәйри үзе ул чакта яшьләр арасында булмаса да, аңа мактанчык байбәтчәнең сүзләрен бик тиз җиткергәннәр.* Г.Минский. *Зәкия җиткергән хәбәрдән бер генә мизгелгә күңелне тутырып, бөтерелеп алган сөенеч өермәсе, нишләптер, бик тиз сүнде.* И.Низамов

9) Төзү, салу, кору, нәрсә дә булса булдыру, ясап кую. *Су, җитмимен, диме – яр җиткерми. Ир, җитмимен, диме – мал җиткерми.* Мәкаль. *Дөнья куып, тегесен җиткерим, бусын булдырыйм, дип йөри-йөри, гомер үткәнен дә сизми яшибез.* Ф.Яруллин. *Хәзер үзе монда тормый, кайда да булса яңаны җиткереп кергән.* Г.Гобәй

10) Тиешле дәрәҗәгә ирештерү. *Кайвакыт маташасың-маташасың, нәрсәсендер җиткереп кенә булмый.* Ф.Яруллин

11) Туган фикерләр белән уртаклашу, башкаларга да белдерү. *М.Зәкиевнең «Төрки-татар этногенезы» китабы төркология фәненең зур бер казанышы булачак, аны, һичшиксез, басып чыгарырга, дөнья галимнәренә җиткерергә кирәк.* Ф.Төркмән. *Һәр ташында мәңгегә татар эзләре уелып калган Уралтаудан мин әнә шундый уйлар белән кайттым һәм болар турында милләтебезгә дә җиткерергә булдым.* Ф.Бәйрәмова

12) *сөйл.* Әзерләү, әзерләп өлгертү. *Малай кече якта аш җиткереп йөргән әбисе янына сыенды.* Л.Ихсанова

13) Үстерү. *Бай мужик кыяфәтендә киенгән, сакалын җиткереп, мыегын кыскарткан адәмне күрүгә, ул бер секунд кына аптырап калды.* Г.Ибраһимов. *Директор, сугыштан кулсыз кайткан Гәрәй абый, мәктәптә чәч җиткереп йөрүчеләрне бер дә яратмый.* Ф.Яруллин

14) Артыннан куып тотарга ирек бирү. *Болай иткәндә, Фәрит хәтта дөньяда иң яхшы шуучы малайга да җиткермәс.* А.Шамов

**2.** *ярд. ф. функ. хәзерге заман хәл фигыль янында*: 1) Билгеле бер урынга, чиккә, ноктага китерүне аңлата. *Юлы каян булса да булсын, тик Казанга илтеп җиткерсен.* Мәкаль

2) Өлгертү, билгеле бер срокка үтәү. *Шимбәгә китереп җиткерер дип, сүз алдылар.* Г.Ибраһимов

3) Билгеле бер сүз янында килеп, шул сүз белдергән эшнең тулысынча үтәлүен белдерә. *Мин пароходны яр янына китереп җиткердем.* Ф.Әмирхан

**Җиткерә алу** 1) Җиткерергә мөмкинлек табылу. *Никтер, аны әни авызыннан ишетәсе килә, ни дип тә әйтеп җиткерә алмаган бер якынлык белән бәйләнгән анамның аны укуын тыңлыйсы килә.* Г.Ибраһимов

2) Аңларлык, күңелгә үтеп керерлек итеп җиткерү; тиешенчә төшендерү. *Әгәр мин укучыга әйтергә теләгән фикеремне кыска шигырь яки хикәя белән җиткерә алам икән, минемчә, моның бер дә ояты юк.* Ф.Яруллин

**Җиткерә бару** Даими рәвештә җиткереп тору, һәрберсен, булган берсен җиткерү. *Хезмәт хакын айныкын-айга җиткерә бару*

**Җиткерә тору** Даими рәвештә, һәрвакыт җиткерү, һәрберсен, булган берсен тапшырып тору. *Туган бер яңалыкны, килгән бер хәбәрне шулар, каравыл өендә вак иләктән иләп, халыкка җиткерә торалар.* Г.Бәширов

**Җиткерә төшү** 1) Беркадәр, тагы да, бераз вакытка җиткерү

2) Беркадәр сузу, озынрак итү, тагы да озынайту

**Җиткереп бару** Һәрберсен, булган берсен җиткерү, системалы тапшырып тору. *Кайсы Германиягә хезмәт иткән, кайсы – Япониягә, илдәге иң яшерен хәрби серләрне җиткереп барганнар.* Ф.Бәйрәмова

**Җиткереп килү** 1) Күптәннән, элек-электән, эзлекле рәвештә җиткерү

2) Аз-азлап, акрынлап тиешле дәрәҗәгә, санга, күләмгә җиткерү. *Акча җыюны тиешле суммага җиткереп киләбез*

**Җиткереп тору** Даими рәвештә, һәрвакыт җиткерү. *Сталинград тирәсендәге җиңүләр бер канатландырса, киткән шәһәрләребезнең яңадан үзебезгә кайтуы турында Совинформбюро, көн саен булмаса да, әледән-әле җиткереп тора.* Ф.Хөсни. *Кайсы --- тегү машинасын әйләндерә белүче хәллерәкләр сугышка тун җиткереп торучы Казан байларына ялланды.* Г.Бәширов. *Йосыф бәкнең Мәскәүдәге озын колаклары да, Аллага шөкер, булган хәлләрне төкми-чәчми җиткереп торалар.* М.Хәбибуллин

**Җиткереп яту** Җиткерү алдында тору, әле, хәзерге вакытта, якын көннәрдә җиткереп бетерү. *Әхәт абыйның күп еллар буш торып, әрем белән алабута баскан йорт урынында, күршеләре белән туганнары, өмә ясап, өй җиткереп яталар иде.* Г.Бәширов

**ҖИТЛЕГҮ** *ф.* 1) Балигъ булу, өлгереп җиту; үсеп, мөстәкыйль яши алырлык хәлгә килү. *Бары тик нәрсәгәдер омтылган балалар гына актив шәхес булып җитлегәләр.* Тигез гомер итегез! *Акчарлакның балалары бик тиз җитлегеп, мөстәкыйль яши башлый, бер атнадан инде кыю рәвештә суга керәләр.* Кошлар. *Тычкан баласы 2–2,5 ай эчендә җитлегә.* И.Рәхимов

2) Пешү, өлгереп җиту, формалашып бетү. *Спора шытудан башлап, үсемлекнең тулысынча җитлегүенә кадәр күп еллар уза.* И.Рәхимов

3) Тиешле үсеш дәрәҗәсенә җиту; срогын тутырып туу. *Әйе, шундый җитлеккән, хәрәкәтчән булыр, томрап торыр аның баласы.* М.Җәлил. *Ана карынында тиешенчә яткан, җитлеккән балалар гына каш-керфек, куе чәч белән туа.* М.Маликова. *Куян балалары җитлегеп туа: күзләре ачык, тәннәре йон белән капланган була.* Хайваннар дөньясы

4) Тиешле дәрәҗәдә формалашу, үсү. *[Ике канатлыларның] Барысының*

*да бер пар канаты бар, икенче пары, җитлекмичә, бызылдагычка әверелгән.* И.Рәхимов. *Сөләйман балыксыманнар күбрәк диңгезләрдә яшиләр, шунда үсәләр, җитлегәләр, тукланалар, ә уылдык чәчү өчен елгаларга керәләр.* Хайваннар дөньясы

5) *күч.* Берәр төрле план, идея формалашу. *Бу атна эчендә Хисаминың башында бер мәкерле фикер --- җитлеккән иде.* Г.Минский

6) *күч.* Нинди дә булса сәяси, иҗтимагый, фәнни һ.б.ш. эш өчен өлгереп җитү, әзерлек алу, җитешү. --- *авылдан төзелешкә килеп, квалификацияле эшчегә әверелгән бу егет үз чорының лаеклы улы, аңлы гражданины, тормышны үзгәртеп коручы булып җитлегә.* Ф.Мусин

7) *күч.* Тиешенчә эшләнеп бетү, әзер хәлгә килү, камиллеккә ирешү. *Җитлекмәгән әйберләр газета-журнал редакцияләренә торган саен күбрәк килә, редакция хезмәткәрләре, аларны дөньяга чыгару өчен, торган саен күбрәк көч, вакыт сарыф итәләр.* С.Шәмси

◊ **Җитлекми туган** Тиешле үсү срогын тутырмыйча, тиешле үсеш дәрәҗәсенә җитмичә туган, кимчелекле. *– Алар иртәрәк туган, – диде кыз, йомшак кына итеп... «Җитлекми туган» димәде «иртәрәк туган», дип, матурлап әйтте.* М.Маликова; 2) Тиешле тәҗрибә алып өлгермәгән, әзерлексез; 3) *хурл.* Җебегән, булдыксыз

**Җитлегә бару** Торган саен җитлегүе арту

**Җитлегә төшү** Вакыт үткән саен ныграк җитлегү, тагы да бераз җитлегү. *Соңрак, шәхес һәм әдип буларак җитлегә төшкәч, А.Расих тормышта юморның гына теше үтмәслек хәлләр белән очраша башлый.* Ф.Мусин

**Җитлегеп бетү** Тәмам, тулысынча җитлегү

**Җитлегеп килү** Аз-азлап, акрынлап җитлегү. *Саматов җитлегеп килгән бодай басуларына --- карап тора.* Г.Минский

**ҖИТЛЕККӘН** *с.* 1) Үсеп, мөстәкыйль яши алырлык хәлгә килгән, балигъ булган. --- *хәзерге заманның җитлеккән шәхесенә еш кына гадәти мәхәббәт җитеп бетми, --- ул, үзе дә аңлап җиткермәстән, универсаль хиskә, ничектер, «икеләтелгән» --- хискә омтыла.* Тигез гомер итегез!

2) Нинди дә булса эш өчен өлгергән, тулысынча әзер булган, тиешенчә белем, тәҗрибә туплаган. *Институтның фольклор бүлеге югары дәрәҗәдә җитлеккән кадрлар үстерүче мәктәпкә әйләнеп бара.* Н.Хисамов. *Инде сугышта ике ел йөреп, бер аяксыз кайткач, --- аның холкы ныгыган, кыскасы, җитлеккән ир иде.* А.Расих

**ҖИТЛЕККӘНЛЕК** *и.* 1) Карында, йомыркада нормаль үсеп җитү; өлгерү. --- *икенче яктан, ай – җитлеккәнлек, өлгергәнлек символы.* Э.Галиева. *Кош балаларының борынлап чыккан вакытка физиологик җитлеккәнлек дәрәҗәсе буенча, кошларны ике төркемгә бүләләр: йомырка эчендә җитлегүче кошлар һәм ояда җитлегүче кошлар.* Биология

2) Аңлы, киң карашлы, белемле булу. *Бу очракта башка закон: әхлакый дорфалык тудырган колонизаторлар телен өстен кую, алар телендә сөйләшүне үзенә күрә җитлеккәнлек, культурага ирешү дип санау идарә итә башлый.* М.Юныс. *Өлгергән мәсьәләләрне тиешле әзерлек белән рәсми органнар алдына кую Язучылар берлеге җитәкчелегеннән зур активлык, җитлеккәнлек һәм интеллект сорый.* Ватаным Татарстан

3) Мөстәкыйль яши, эшли алырлык дәрәҗәдә үсеп җитү; балигъ булу

4) *күч.* Нык үсеш алу, алга китү. *Яшь буынның җитлеккәнлеге*

5) *күч.* Нинди дә булса эш-шөгыль өчен тулысынча әзерлекле булу, профессиональ осталык, өлгергәнлек. «*Театраль җитлеккәнлек» шәхеснең яшенә бәйле.* Ватаным Татарстан

**ҖИТЛЕКЛЕ** *с. диал. к.* **җитеш**. *Безне җитлекле табын көтә иде. Җитлекле терлек азыгы булганда, кыш куркыныч түгел. Җитлекле тормышта яшәү*

**ҖИТЛЕКЛЕ́ БАЛАЛЫЛАР** *и. зоол.* Йомырка эчендә үк җитлегеп бетеп, тугач та мөстәкыйль рәвештә яши алырлык кошлар (мәс., тавыксыманнар, казсыманнар, торнасыманнар); *русчасы:* **выводковые птицы**

**ҖИТЛЕКСЕЗ** *с. биол.* Җитлекми туган, йомыркадан чыкканда зәгыйфь, йонсыз, хәрәкәтләнү мөмкинлекләре чикле булган. *Җитлексез балалы кошлар*

**ҖИТЛЕКСЕ́З БАЛАЛЫЛАР** *и. зоол.* Балалары йомыркадан чыкканда зәгыйфь, шәрә туган, шактый вакыт аналары җим ташып ашата торган кошлар (мәс., сыерчык, чыпчык, күгәрчен, сандугач һ.б.); *русчасы:* **птенцовые птицы**

**ҖИТМӘС** *с. сөйл. к.* **җитмәслек**. *Ә мин ышанам, Аң җитмәс тирән Серләр барга да, – Юкса, җәй ничек Миңа хат яза!* Н.Измайлова

**ҖИ́ТМӘСӘ** *кер. сүз* Болай да ярамаган бер эш-хәлгә тагын нәрсәдер өстәлгәнне белдерә; шуның өстенә, өстәвенә, шуңа өстәп. *Җитмәсә, карап торучылар җыелды: сугышны тамаша кылырга, залдан берничә кеше, поварлар һәм официантлар чыккан иде.* З.Хәким. *Җитмәсә, теленә салынып маташкан булмаса икән!* Ф.Хөсни. *Җитмәсә тагы, киртә арасыннан күрше малайлары – Тәлгатьнең иптәшләре – күзләрен яндырып карап торалар.* Ф.Хөсни

**ҖИТМӘСЛЕК** *с.* Үзеннән алдагы исем белән килеп, предметның теге яки бу сыйфатка ирешергә мөмкин булмавын аңлата. *Акчаң җитмәслек әйбергә кызыкма.* Мәкаль. *Көчем җитмәслек бәлагә тарсам, Хәбәр итеп, көмеш угымны атармын.* М.Җәлил. *Алдыбызда күз күреме җитмәслек дала җәйрәп ята*

**ҖИТМӘСТӘЙ** *с. к.* **җитмәслек**. *Акчаң җитмәстәй әйбергә ымсынып, хәлеңне бетермә.* Мәкаль. *Көчең җитмәстәй эшне башламавың хәерле*

**ҖИТМӘ́Ү** *и. к.* **җитмәүчелек**. *Каяндыр, нindидер документлар, актлар табып чыгардылар, шуның белән өсләренә чыккан җитмәүне киметә алдылар.* Ә.Еники

**ҖИТМӘҮЧЕЛЕК** *и.* 1) Сату-алу эшендә, сәүдә өлкәсендә керемгә караганда чыгымның артып китүе, ялгышлык я булмаса урлау сәбәпле, акча яки товарның исәптәгедән кимрәк булуы. *Әлбәттә, вак-төяк растрата,*

*җитмәүчелекләр генә аны куркытмый.* Ә.Еники

2) *сөйл.* Тормыш өчен кирәк-ярак әйберләрнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, мохтаҗлык. *Алар, артык кабаланмыйча, тормыш җитмәүчелекләренә, язмыш кыерсытуларына бәрелепсугылмыйча, дөнья көтәләр, кызлар үстерәләр.* Ф.Яруллин

**ҖИТМЕШ** *сан* **1.** Җиде дистәдән гыйбарәт сан; шул санны, аның микъдарын, цифрын белдергән атама. *Ай, әле бик еракта идек без, Җитмеш чакрым җирдән килдек без.* Җыр. *Без җитмеш елга якын йорт салудан мәхрүм яшәдек, авыл җирендә төзү материалы, акча җитми иде.* М.Юныс. *Адам Олеарий язмасының беренче вариантында татар җиһангиры Мамон --- җитмеш татар патшасы белән дөньяны яулап алырга килгән диелә...* Ф.Бәйрәмова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кат-кат, кабат-кабат, бик күп. *Җитмеш тапкыр аңлатсаң да төшенми*

2) Күп төрле, төрле-төрле. *Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.* Мәкаль. *Җитмеш кабат күлмәк аркылы тәннәре күренеп тора, ди бит.* Ш.Камал. *Бал – җитмеш авырудан сихәт*

◊ **Җитмеш җиде төрле** Бер карасаң – бер төрле, икенче карасаң – икенче төрле; әллә ничә төрле. *Син купшы, тик тузган йөрәгеңнең Җитмеш җиде төрле ялгавы.* Г.Тукай. **Җитмеш яшәр** Карт, өлкән. *Чынлап та, ник кирәктер җитмеш яшәр ул бабайга тегермән?* Ф.Хөсни

**ҖИТМЕШӘР** *сан* Һәркемгә, һәрнәрсәгә җитмеш, бертигез күләмдә җитмеш булуны белдергән бүлү саны. *Район җитәкчеләре һәр мәктәпкә җитмешәр мең акча бүлеп бирделәр.* Ф.Бәйрәмова

**ҖИТМЕШЕНЧЕ** *сан* Рәт, тәртип белән санаганда җитмеш урынында килә торган тәртип санын белдерә. *Утызынчы елда да шулай иде Ф.Хөсни, илленче елда да, җитмешенчедә дә...* М.Мәһдиев. *Алтмышынчы-җитмешенче еллар әдәби хәрәкәтендә Ш.Маннур ничәмә еллар буе поэзия белән яшәгән иҗатчы барыннан да бигрәк прозаик буларак катнаша.* З.Рәмиев. *Егерменче гасырда кешелек кавеменең, өлешчә, шактый зур тизлек белән түбәнлеккә төшә баруы утызынчы елларда герман рухының фашистлануы, җитмешенче елларда Чили феномены --- белән бәйләнмәгәнме?* Д.Вәлиев

**ҖИТМЕШЛӘП** *сан* Чама белән җитмеш; якынча җитмеш булуны белдергән чама саны. *Паровоз --- җитмешләп вагонлы составны --- туктата алмыйча узып китте.* Ш.Усманов. *Татарстанда үрмәкүчләрнең җитмешләп төре исәпләнә, аларның күпчелеге аз санлы һәм сирәк очрый.* И.Рәхимов

**ҖИТРИ** *с. диал.* Җитез. *Бу егет бик җитри, ни кушсаң да булдыра*

**ҖИТҮ** I *ф.* **1.** 1) Пространствода билгеле бер урынга килү, нәрсә белән булса да тигезләнү, якын ук килү. *Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман. Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит – Казан!* Г.Тукай. *Кызу-кызу атлап, бер чатка җиткәч тә, ул үзе башлап туктатты.* Ә.Еники. *Өйгә җиткәндә, күңел сизенде: ул подъезда көтеп торадыр.* З.Хәким

2) Нәрсәнең дә булса озынлыгы, киңлеге белән тәңгәл булу, башка берәр нәрсә белән тигез булу. *Дулкынланып иңбашына төшкән аксыл чәчләре һәм аяк йөзенә җиткән эре чәчәкле күк атлас халаты белән ул әллә каян ук балкып күренә...* Ә.Еники. *Казышыр иде – чокыры тирән, буй җитмәс шул.* Т.Әйди. *Бригадир: «Борыныңа җиткән корсагың белән урак уруы кыендыр...» – дип, күпме үгетләсә дә, Динә кулындагы урагын бирмәде.* К.Кәримов

3) Хәрәкәттәге кешене яки транспортны куып килеп, аның белән тигезләнү. *Әтисен куып җиттем дигәндә генә, малай абынып егылды*

4) Билгеле бер вакыйга, ел фасылы, көн дәвамындагы иртә, кич, таң һ.б.ш. кебек вакыт аралыгы якынлашу, башланып китү. *Көз җиткәч, кердем бакчага, көнбагыш җыярга дип.* Г.Зәйнашева. *Өйлә җиткәч, Мәскәү елгасына төшереп, су эчереп кайтыр идем.* М.Юныс. *Ә инде кыш җитеп, тыкрыкларга җилләр, тырышып, кар ташый башласа, Әүхәди үз өенә терәп үк тау ясарга тотына...* Ф.Яруллин

5) Нәрсә дә булса билгеле бер чиккә кадәр үсү, күтәрелү, арту, югары ноктага менү. *Бу балыклар елгаларда көтүләре белән йөзеп йөриләр, зурлыгы сирәк кенә 30 см га кадәр җитә.* И.Рәхимов. *Кайбер агачлар 10 метрга җиткән була.* М.Юныс. *Нектар составында су 20 %ка кадәр кимегәч, умарта кортлары кәрәз күзәнәкләрен өскә кадәр җиткәнче тутыралар һәм аларны нечкә балавыз капкач белән томалап куялар.* Умартачыга ярдәмлек

6) Сан, күләм ягыннан канәгатьләнерлек булу, кирәк кадәр булу. *Йорт салырга уртача берничә дистә мең кирпеч җитә.* М.Юныс. *Шушы күләмдәге азык умарта кортларын кышын тукландыру өчен генә түгел, бәлки, язгы чорга да (10 – 15 әр кг) җитә, бу исә умарта кортлары семьяларының үсеше өчен бик мөһим.* Умартачыга ярдәмлек

7) Билгеле бер яшькә якынлашу, билгеле бер яшьне тутыру. *Кайсыбыз җитәр сиксәнгә? Менә бит сорау кайда! ...Ә шулай да барыгыз да Сиксәнгә җитсен иде.* Г.Рәхим. *Син дә кырык бишкә җитәсең.* Ф.Яруллин. *Нәтиҗә буларак, хатын-кыз ялгызлыкка дучар, бик бәхетлеләре генә, кырыкка җиткәндә ничек кирәк алай кияүгә чыгып, иллегә кадәр бала таба...* Н.Измайлова

8) Нәрсәнең дә булса югары стадиясенә якынлашу, соң чиккә кадәр киеренкеләнү. *Ул законнарның язылганы да, язылмаганы да кайчак көлке дәрәҗәсенә җитеп, ахыр чиктә бичара хатын-кызның үзенә каршы бер явызлыкка әйләнә бара.* Н.Измайлова. *Эчке спазма бөтен гәүдәмне шартлап өзелерлек дәрәҗәгә җиткән бер нерв җепселенә әверелдерде.* З.Хәким

9) Билгеле бер вакытка кадәр сузылу, бетмәү. *Алар мәңгегә җитәр дип өметләнә идек.* М.Юныс. *Гомумән, әйберләрнең сыйфаты «ах» итәрлек түгел монда, бездә бер таба утыз елга җитә иде, монда ел саен алыштырырга кирәк, 20–30 доллар әле ул.* Н.Измайлова

10) Кемгә дә булса барып ирешү, әйтелү, тапшырылу. *Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе Җитсен иде һәрбер*

*күңелгә, Җилләр, сулар тавышы шикелле үк, Үзләренең асыл телендә.* Х.Туфан. *Мин бу манараны яңабаштан үзгәртеп кордым, яшерен ишекләр куйдым, аулак бүлмәләр ясадым, --- берәү белгәнен икенче белер, өченчегә җитәр, анысы илгә таратыр, манарага үзегез генә керсәгез иде, Ханиян.* М.Хәбибуллин

11) Кирәк хәтле, кирәкле күләмдә булу. *Аз да җитә, күп тә бетә, бергә торганга ни җитә.* Мәкаль. *Америка кебек илдә, нинди генә аз хезмәт хакы алсалар да, тамак туйдырырга һәм киенергә барыбер акчасы җитә.* Н.Измайлова. *Ә иң кыены: акча җитми башлады.* Ф.Яруллин

12) Балигъ булу, өлгерү. *Мин туташ булып җиткән идем инде һәм аңа ихтыярсыздан кызыксынып карый идем.* Ә.Еники

13) Озын булып үсү. *Малайның тырнаклары җиткән, тәннәренә кисеп кергән.* Ә.Фәйзи

14) Берәр төрле гозер, үтенеч белән, түбәннән башлап иң югары органнарга кадәр мөрәҗәгать итүне белдерә. *Монда сөйләп кенә туктап калмам, министрга кадәр җитәрмен.* З.Мансур

15) Нинди дә булса дәрәҗәгә ирешү, вазифа буенча югары күтәрелү. *Дөрес, Галия Гафаровна – уңган һәм кешелекле врач, югалып калмады, абруй казанды, Республиканың баш акушер-гинекологы дәрәҗәсенә җитте.* М.Маликова

16) **җитмәү** *юкл. форм.* Кирәкле сыйфатта, тиешле дәрәҗәдә булмау. *Угрының урларга кулы җитәр, урладым дияргә йөрәге җитмәс.* Мәкаль. *Мин беләгемне ычкындырмакчы булып карадым – көчем җитмәде, телем белән дә берни әйтә алмадым.* Ә.Еники. *Картаю торгынлыгы, яңалыкны аңларга көч җитмәү менә шушыдыр инде, дип уйлап алгач, корабның каюталарын --- тикшерергә керештем.* М.Юныс // Кирәк хәтле, кирәкле күләмдә булмау. *Җир аз булганлыктан, үз икмәгебез бервакытта да яңага хәтле җитми торган иде.* Г.Бәширов. *Суларга һава җитми, урамга чыгасы килә.* М.Маликова. --- *хезмәт хакы очынчка ялгарга җитмәгәч, ул өенә аракы алып кайтып куя, аны төнлә тугарылып киткән егетләргә кыйбатрак бәягә сата иде.* Р.Зәйдулла

17) *сөйл. юкл. форм. к.* **җитешмәү** (*12 мәгъ.*). *Әллә моның җитми микән?*

18) **җитмәгән** *юкл. форм.* Алда атап үтелгән берәр ярамаган нинди дә булса эшкә яки хәлгә тагын нәрсәдер өстәлгәнне белдерә (гадәттә ризасызлык төсмере белән әйтелә). *Ә ир дигәне, карт булуы, эчкече булуы гына җитмәгән, эшләргә дә теләми – эшләр өчен өйләнгәнмени ул бай хатынга!* Н.Измайлова. *Ашатып-эчертүе генә җитмәгән, көчли-көчли, күчтәнәчен тыгып җибәрә.* Ф.Яруллин

**2.** *хәб. сүз функ.* Канәгатьлекне белдергәндә кулланыла, аннан артыгы кирәкмәүне аңлата. *Бәхетгәрәй исән, Бәхетгәрәй мине онытмый – миңа шул җиткән!* Ә.Еники. *Ул минеке булса, шул җиткән.* З.Хәким. *Хәер, тегеләргә аның эше кирәкми дә, үз вазифасын үтәсә, шул бик җиткән бу авыр заманада.* Н.Измайлова

**3.** *ярд. ф. функ.* 1) Эшнең төгәлләнүен белдерә. *И күңелле әби белән! Килеп җиттек базарга.* Г.Зәйнашева. --- *айгыр кушаяклап алга ыргылды. Иллә оста Әхмәт Әмирнең атын бик тиз куып җитте һәм йөгәненә ябышты.* М.Хәбибуллин. *Куян, ау этләрен күрсә, озын-озын итеп сикереп чаба да, этләрне алдау өчен, --- җиргә поса, ә этләр аны куып җитеп узып китәләр.* Хайваннар дөньясы

2) *-рга/-ргә ф. форм.* белән килеп, эшнең чак эшләнми калуын белдерә. *Еларга җитү. Ташланырга җитү*

**4. җитте, җитәр** *ы. функ.* Нәрсә дә булса эшләүдән яки нindидер сүз әйтүдән тыюны, туктатып калуны белдерә. *[Хәсән:] Җитте, узынма. Бар, кереп, чәй эч.* Т.Миңнуллин. *Җитте, бертуктаусыз киреләнүеңне ташла!*

◊ **Җитеп арткан (ашкан)** «Артыгы белән» дигән мәгънәдә. *Телгә бик оста, дөнья хәлләре белән бик кызыксынып бара торган тынгысыз кыз иде ул. Шуның өстенә кыюлыгы да җитеп ашкан иде.* В.Нуруллин. **Җитмәгән җире юк** 1) Һәр яктан да камил. *Буе зифа, акылы камил, бер җитмәгән җире юк аның;* 2) Теләсә кая тыгылучы, күпне белүче кешегә карата әйтелә

**Җитә калу** Берәр эшкә сәбәпче булу. *Боларга җитә калды.* З.Хәким. *Мондый сүзләр яңа күзе ачылып килгән, хыялланырга яраткан яшь күңел өчен җитә кала иде.* Ә.Еники

**Җитә тору** Даими рәвештә җитү, вакытында, кирәк кадәр булу. *Килә тора, китә тора, кирәгенә җитә тора.* Мәкаль. *Акча бездә күп түгел, кирәгенә юк түгел, Килә тора, китә тора, кирәгенә җитә тора.* Н.Исәнбәт

**Җитеп бетү** Тулысынча җитү. *Капитанның имзасы гына җитеп бетмәс шикелле тоелды безгә.* М.Юныс. --- *хәзерге заманның җитлеккән шәхесенә еш кына гадәти мәхәббәт җитеп бетми, --- ул, үзе дә аңлап җиткермәстән, универсаль хискә, ничектер, «икеләтелгән» --- хискә омтыла.* Тигез гомер итегез!

**Җитеп килү** 1) Акрынлап якынлашу, килеп җитә язу. *Җитеп килә инде аның җитмеш яше. Җем-җем итә җитен сакал, көмеш чәче.* Г.Тукай. *Пароходларга алмашка теплоходлар килде. Хәзер теплоходларның үзләренә үлем чираты җитеп килә.* М.Юныс. *Вәгъдә көне дә җитеп килә, түземлек тә төкәнә башлады.* Г.Бәширов

2) Акрынлап җитлегү, балигъ булу. *Хәзер инде әнә үзләре угланнар үстерәләр, моның янына Назлыгөле җитеп килә.* М.Хәбибуллин. *Аннары ул үзе дә мине җитеп килгән кыз итеп күрми иде шикелле.* Ә.Еники. *Нәфисә – инде җитеп килгән кыз, күкрәкләре дә бөреләнгән, сыны уйнап тора...* Р.Зәйдулла

**Җитеп тору** 1) Әлегә җитү, хәзерге вакыт өчен канәгатьләнерлек булу

2) Һәрвакыт җитү; җиткән хәлдә булу. *Хезмәт хакы аның һәрвакытта зур булды, иркен, мул гына яшәр өчен җитеп торды.* Ә.Еники. *Менә ул матур күзләрнең иясе – бик вак бөдрәләре тузгынып, күперенеп, иңнәренә җитеп торган кыска гына кап-кара чәчле 17–18 яшьлек кыз.* Ф.Әмирхан

3) Артыгы белән җитү, бу кадәресе дә җиткән булу. *Коръән укытырга ике сум да җитеп торыр.* Ш.Камал

**ҖИТҮ** II *с.* 1) Җиткән, өлгергән, балигъ булган. *Ак җиңсәләр кигән җитү кызлар --- ак тырмалар белән печән җыялар.* Г.Ибраһимов

2) Зур үскән, озынайган. *Җитү чәчле малай аларны күреп алды да: – Әлфия ---, кара, әнә безгә кемнәр килгән, – диде.* Т.Әйди. --- *асылмалы лампа яктысында урта яшьләр тирәсе кеше ап-ачык булып күзгә ташланды: аның өстендә өр-яңа яшькелт сырма, яланбаш, җитү чәчле.* А.Расих. *Иван Ивановичның йомшак җитү чәчләре җилдә чуалды, күзләре дымланып китте.* А.Расих

**ҖИҺАД** *и. гар.* 1) Изге сугыш; дин хакына сугыш; изге көрәш. --- *тышкы яктан боларның барысын «ислам дине хакына җиһад» байрагы белән каплап, үтә «изге» төскә кертәләр.* З.Мифтахов. *Татар халкының, милләт буларак сакланып калу өчен, җиһадтан иҗтиһадка, мәгърифәтчелеккә күчү чоры башлана.* Ф.Бәйрәмова

2) Сугыш, кырылыш. *Кычкырыйк без берьюлы: Бетсен сугыш... Бетсен җиһад.* М.Гафури

**ҖИҺАДЧЫ** *и.* Изге сугыш каһарманы, дин хакына сугышчы. --- *үз халкының милли азатлыгы, социаль тигезлек, нормаль яшәү шартлары өчен көрәшкән кешеләр шул глобаль пропаганда тәэсирендә, бүген үзләрен «җиһадчы», «потенциаль шәһит» дип хис итә башлыйлар.* З.Мифтахов

**ҖИҺАЗ** *и. гар.* 1) Көндәлек тормышта кулланыла торган һәртөрле мебель; йорт кирәк-яраклары һ.б. әсбаплар. *Чыннан да, бу җиде могҗизаның берсен төзүчеләр һәр мәрмәр кисәгенә, аның күләменә, һәр җиһазга гаҗәп зур әһәмият биргәннәр.* М.Юныс. *«Кешене киеменә карап кабул итәләр» дигән сүз бар. Җиһаз – өйнең киеме бит ул.* Ф.Яруллин. *«Болгар» номерында – Тукай бүлмәсе. Бик гади җиһаз – өстәл, ике урындык.* Р.Ишморат

2) Берәр төрле эшкә, эшчәнлеккә кирәкле әйберләр, хезмәт кораллары, радио-электрон приборлар, техник әсбаплар һ.б.ш. *Теплоход уртача зурлыктагы заводның барлык җиһазларын берьюлы сыйдыра ала.* М.Юныс. --- *чолан сыманрак җирдә өелеп яткан химия җиһазларын һәм реактивларны тәртипкә китереп, --- лаборатор эшләрнең һәрберсен җиренә җиткереп үткәрергә тырышам.* З.Мифтахов. *[Аның] Үз бригадасына алган бораулау җиһазларын запас итеп җиргә күмеп куюы --- герой характерының каршылыклы яклары.* С.Сафуанов

**ҖИҺАЗЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Йортны, кабинетны, офис, сәүдә павильоны һ.б.ш.ны кирәкле җиһаз белән тәэмин итү. *Мәчетне җиһазландыруны Башкортстан хөкүмәте өлешчә үз өстенә ала, хәтта мәчет өчен бәллүр шәмдәлләрне дә Мортаза Рәхимов үзе бүләк итә.* Ф.Бәйрәмова

2) Уку-укыту процессы яки эш өчен кирәк булган приборлар, станоклар, әсбаплар белән тәэмин итү. *Физика һәм химия кабинетларын җиһазландыру*

**Җиһазландыра бару** Аз-азлап җиһазландыру

**Җиһазландыра башлау** Җиһазландырырга тотыну

**Җиһазландыра төшү** Бераз җиһазландыру

**Җиһазландырып алу** Тиз арада җиһазландыру

**Җиһазландырып бетерү** Тулысынча җиһазландыру

**Җиһазландырып кую** Җиһазландырылган хәлгә китерү

**Җиһазландырып тору** Даими, һәрвакыт җиһазландыру

**ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛГАН** *с.* Мебель, эш кораллары һәм һәртөрле кирәк-ярак белән тәэмин ителгән. *Чит илдән кайткан ялтыравык мебель белән җиһазландырылган залның бер почмагында --- зур гәүдәле ир кеше ята иде.* Ф.Хөсни

**ҖИҺАЗЛА́У** *ф. к.* **җиһазландыру**. *Подвалларны җиләк-җимеш өчен төрле стеллажлар, яшелчәләр өчен буралар белән җиһазларга мөмкин.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү. *Нәүрәпләр казыганда, җылытылган сарайлар төзегәндә, җимеш һәм яшелчәне саклау өчен, подваллар һәм башка биналар җиһазлаганда, аларны төп яклары белән төньякка каратып урнаштыралар.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

**Җиһазлап кую** Тиз арада җиһазлау; җиһазланган хәлгә китерү. *Бүлмәне җиһазлап кую*

**Җиһазлап тору** Һәрвакыт, гел җиһаз белән тәэмин итү

**Җиһазлап чыгу** Барысын да җиһазлау; һәрберсен җиһазлау; башыннан ахырына кадәр җиһазлау

**Җиһазлый башлау** Җиһазларга керешү

**ҖИҺАЗЛЫ** *с.* 1) Йорт кирәк-яраклары җитәрлек булган. --- *Гайшәләрне өйле, җиһазлы итеп куйдылар.* Г.Ибраһимов

2) Берәр төрле эшчәнлек өчен кирәкле приборлар, әсбаплар белән тәэмин ителгән. *Тулы җиһазлы физика кабинеты*

**ҖИҺАН** *и. фар.* 1) Дөнья, җир өсте. *Мин тәмам гиздем җиһанны, кайда-кайда йөрмәдем, Тик шул алтыннан бәла, шайтан-фәлән һич күрмәдем.* Г.Тукай. --- *аның татар тормышына багышланган язмаларын укыганда да бөтен дөньяны күргәндәй һәм җиһанның яңадан-яңа серләрен ачкандай буласың.* Ф.Баттал

2) Галәм, космос. *Әй син, телем, туган телем, тамыр телем. Җиһандагы һәрбер җисем, һәрбер матдә, исемем бар дип, гүя сиңа рәхмәт әйтә.* Л.Шагыйрьҗан. --- *Җирдә, адәм баласының яшәү ареалында, төгәл, бәхетле тормыш кору өчен күпме эшлисе, күпме көч түгәсе бар, ә без һаман күккә – җиһанга омтылабыз.* М.Юныс. *Романда әлеге артий кабиләләренең барысы да – җиһандагы иң югары дәрәҗәле затлар, расалар дигән фикер ярылып ята.* Ф.Урманче

◊ **Җиһан корткыч** Астыртын рәвештә кемнең дә булса хисабына яшәүче, хәйлә белән көн күрүче. *Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар, Юк түгел аю, бүре; төлке – җиһан корткыч та бар.* Г.Тукай. **Җиһан сарае** Җир өсте, җир йөзе. --- *кояш чыгуы җиһан сараена әллә нинди тылсымлы матурлык бирә ---.* Ш.Камал

**ҖИҺАНГИР** *и. фар.* **1.** Дөньяны яулап алучы, буйсындыручы, дөньяны тотучы кеше яки дәүләт. *Дәһшәтле җиһангир һәм талантлы*

*гаскәр башы Атилла 453 елда үлгән.* Р.Фәхретдинов

**2.** *с. мәгъ.* Басып алучы, буйсындыручы. *Бөтен дөньяның сәяси һәм икътисади власте, берничә олуг җиһангир дәүләтләр арасында бүленеп, --- албасты булып басып өлгергән иде.* Ф.Әмирхан

**ҖИҺАНДАР** *и. фар. иск.* Хөкемдар, дөньяның иясе, патшасы, идарә итүчесе. *Һәм эндәште Мөһибану: «Җиһандар, Кирәк булса, минем әйбәт урын бар».* Котб

**ҖИЮ** *ф. иск.* Ашау. *Хәрәм малны эт җияр.* Мәкаль. *Аз җисәң дә хәләл җи, карның ачмас үлгәнче.* Мәкаль

**ҖИЯК** *и.* 1) *иск.* Киемнәргә, тегеп, бизәк төшерер өчен кулланыла торган тар ефәк шнур. *[Чапан] Җилән шикелле, эчле-тышлы була һәм әдепле була: әйләнәсенә җияк тоталар ефәктән, ул җияк шнур кебек нәрсәдер.* К.Насыйри

2) Кече хәрби составның җиңенә яки погонына аркылы тегеп куелган тар тасмадан гыйбарәт аеру билгесе: *русчасы:* **лычки**. *Бар солдатның да погоны андый булмый икән, «яфрәтил» погонына гына шундый аркылы җияк тегәләр икән. Димәк, әтиебез ефрейтор булган.* М.Әмир

**ҖИЯН** *и. иск.* Хатын ягы туганнары, «үз кеше түгел», «ир нәселеннән түгел» мәгънәсендә. *Җиңги хатын җияннеке.* Мәкаль. *Җиян ил булмас, җилен аш булмас.* Мәкаль

**ҖОБАНУ** *ф. диал.* Ялыгу, иренү. *Мин сөйлим, тыңларга гына җобанмагыз.* М.Әмир

**ҖОБЫРГАН** *и. диал.* Юрган

**ҖОЛА** *и. диал. к.* **йола**. *Ил җоласыз булмас.* Мәкаль. *Су буйсыныр буага, ил буйсыныр җолага.* Мәкаль. *Йортның җоласы, тәкъдирнең язганы шул икән, дип, куеныма алдым...* Г.Ибраһимов

**ҖОМ** *и. сөйл.* Шикәр чөгендерен эшкәрткәндә калган сыгынты, чөгендер түбе. *Хайван симертергә, ашлыктан тыш, комбиазык, җом --- бар бит әле.* Г.Бәширов. *Көзен кайтарган җом җәйгә кадәр җитте*

**ҖОМАК** *и. диал.* Табышмак; башваткыч; йомак. *Чит илләрдә булган, күпне күргән кешеләрнең --- сүзен җомак тыңлаган кебек берелеп тыңлыйсың.* Н.Фәттах. *Апай, шкафка сөялеп, табышмак әйтергә тотынды: – Җомак әйтәм, җөмен тап! – диде.* Г.Бәширов

**ҖОМГА** *и. гар.* 1) Атнаның пәнҗешәмбе белән шимбә арасындагы бишенче көне. *Җомгасын да җомга, кайтуын да бер генә көнгә кайткан. Шулай да көн буе сөрән сугып тик йөрисе түгел әле.* Г.Бәширов // Җыелып, намаз укый торган изге көн. *Бер җомгада, карт-корыны җыеп, Коръән укытып алды.* Г.Гыйльманов

2) *дини* Җомга көнне җыелып укыла торган төшке намаз. *Бу мажаралардан ике җомга мөкаддәм.* К.Насыйри. *Икенче көнне җомга алдыннан, вәгъдә иткән хезмәт хакын алырга дип --- киттем.* Г.Бәширов

**ҖОМГА́ НАМАЗЫ** *и. дини к.* **җомга** (*2 мәгъ.*). *Җомга намазына азан әйткәч, Хәмдүнәне дә, җиңгәсен дә --- ияртеп, безгә кайтасыз.* Г.Бәширов. *Картларның җомга намазына киткән чагы икән, карчык каядыр биләмгә киткән, өй аулак.* Г.Бәширов. *Иртәгә, җомга намазыннан соң, никах ашына җыялар икән.* Г.Гыйльманов

**ҖОМЛА́У** *ф. диал.* Юк итү, ашау, кабып йоту

**Җомлап бару** Һәрберсен, берсе артыннан икенчесен җомлау. *Ташланган перәннекләрнең барысын да һәйбәт кенә җомлап бара башлады.* Т.Әйди

**ҖОМЫКЫЙ** *с. диал.* 1) Кеше белән аралашмый торган, үз эченә бикләнгән; йомыкый

2) Тиз генә аңлап ала алмый торган. *Бигрәк җомыкый бала икән бу*

**ҖОМЫР** *и. диал. к.* **йомры** II. *Алар җомырга чәй салдылар*

**ҖОР** I *с.* 1) Сүзгә тапкыр; шук, шаян телле. --- *Сабан туе шау-шуы басыла төшкәч, телдән-телгә күчеп һәм җор телле кешеләр тарафыннан бераз куертылып өлгергәннән соң гына, Ахуновка бер хәбәр килеп җитте...* Ф.Хөсни. *Нияз – җор сүзле, шаян табигатьле, шат күңелле малай.* Д.Каюмова. *Җырыклының җор күңелле, пычак телле, мәзәккә бай һәм сугышчан халкы арасында капитан Миңлебаев нигез салып урнаша алмады.* З.Хәким

2) Шаян, шаяртулы. --- *аңардан чак кына өркебрәк йөрүче авыл агайлары – җор сүзгә җаннарын бирергә әзер Мәтәскә кешеләре – Сәфәргалинең кыска, үтемле --- «йомгаклау речендә» үтә дә ачылып киттеләр.* Ф.Хөсни. *Яшьләр, капчык тулы машиналар белән килеп туктап, җор сүзләрне юмарт әйтә-әйтә, килен-кызларның шаян җавапларыннан көлә-көлә, аерым ташыдылар.* И.Низамов

**ҖОР** II *и.* Далада яши торган мөгезле кыргый хайван; антилопаның бер төре. *Җордай җуртак, җыландай җылдам бул.* Әйтем

**ҖОРЛАНУ** *ф.* Мәзәк, көлке сүзләр кушып сөйләргә, шаяртырга остару. *Улың белән җорланма, җорлансаң, улың сине елатыр.* Мәкаль

**ҖОРЛЫК** *и.* Җор булу; шаяртып сөйләшү осталыгы. *Тик ул моңарчы очраган йорт ияләренә охшамаган, карашында – ниндидер җорлык, хәйләкәрлек.* Р.Зәйдулла. *«Казан сөлгесе»ндәге шаянлык, җорлык белән «Зәңгәр шәл»дәге трагизм – ут белән су бит инде ул.* Ф.Яруллин. *Ул шактый ук җор телле карт булып чыкты, җорлыгы вакыт-вакыт ирония белән дә аралашкалый иде.* Ф.Хөсни

**ҖОРНАЙ** *и. зоол. диал.* 1) Карпсыманнар отрядыннан, озын гәүдәле, тәне вак тәңкәләр белән капланган, елан кебек боргаланып йөзә торган балык; этләч; *русчасы:* **вьюн**

2) *күч.* Елгыр, житез. *Җорнай егет*

**ҖОРНАЙЛАНУ** *ф. диал.* Сырпалану; чуалу, куштанланып йөрү. *Максатка җорнайланып ирешү*

**Җорнайлана бирү** Бернәрсәгә карамастан, җорнайлануны дәвам итү

**Җорнайланып йөрү** Әле, хәзер җорнайлану

**ҖОТ** *и.* 1) Җир кинәт туңып яки кар белән капланып, малларга ашарга үлән калмау сәбәпле, аларның күпләп кырылуы, хайваннарның ачлыктан күпләп үлеме. *Гидай казакларның ялгыз-ярым маллары җотның беренче көннәрендә үк аякларын суздылар.* И.Салахов. --- *яман бозлы бер көздә аның күп хайванын җот һәлак кылды.* Г.Ибраһимов. *Илгә җот килде, тибеп*

*ашарга мөмкин булмаганга, малның бик күбе һәлак булды.* Г.Ибраһимов

2) *диал.* Илгә килгән ачлык

3) *диал.* Ашауга комсыз кеше. *Жот – йортсыз калыр.* Мәкаль. *Жот кешегә хәт кунмас.* Мәкаль

**ЖО́Т КИЛҮ** *ф.* Ачлыктан, маллар күпләп үлү

**ЖОФАР** *и.* **1.** Бөҗәк ашаучылар отрядыннан, озын борынлы, хуш исле сыекча бүлеп чыгара торган, ялтыравык мехлы су җәнлеге; *русчасы:* **выхухоль**. *Жофарны яшерсәң – исеннән беленер, белемне яшерсәң – телдән беленер.* Мәкаль. *[Дошман җиңсә] Җиребездән качар коланнар, Күлебездән китәр җофарлар, безнең өстән китмәс томаннар.* Н.Исәнбәт. *1983 елдан башлап, бөҗәк ашаучыларның тагын бер вәкиле – җофарның очравы турында бер мәгълүмат та юк. Жофар Татарстанның, Россиянең --- Кызыл китабына кертелгән.* Н.Рәхимов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Жофар сыекчасы кушып эшләнгән. *Менә әйбәт гатырша май, менә җофар сабыны.* Т.Гыйззәт

2) Хуш исле. *Түргә үтте, кереп, Ак кояшлы язның Сирень исле җофар җилләре.* М.Җәлил

**ЖОФА́Р ГӨЛЕ** *и. бот. диал.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, ятма яки туры сабаклы, ак яки алсу чәчәк ата торган хуш исле үсемлек; чабыр үләне; *русчасы:* **тимьян, чабрец**

**ЖӨББӘ** *и. гар.* Мөселманнарда ирләр өс киеме, җиләннең бер төре. *Өстенә – җөббә, башка – зәңгәр фәс, күзгә – күзлек, аякка ботинка кигән, авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкерт.* Г.Тукай. *Кинәт [Тимер] кылычын чишеп ташлый, җөббәсен сала.* Р.Батулла. *Аның [Тәхтәһү Мансурның] өстендә яхшы постаудан тегелгән озын җөббә, башында җәйге каракүл бүрек, аякларында ялтыравыклы әмерхан читек-кәвеш.* Г.Лотфи

**ЖӨГӘРӘ** *и.* Кыяклылар семьялыгыннан, тарыга охшаш, игеп үстерелә торган көньяк үсемлеге; *русчасы:* **сорго**

**ЖӨДА** *с. фар.* Аерылган, аерылуга дучар булган

**ЖӨДА́ БУЛУ** *ф. иск.* Берәр нәрсәдән мәхрүм калу, нәрсәне дә булса җую, югалту. *Барча иркеңнән вә циркыңнан җөда булдың, инде бәс сиңа миннән дога.* Г.Тукай

**ЖӨДА́ ИТҮ** *ф. иск.* Нәрсәдән дә булса мәхрүм итү

**ЖӨДА́ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **җөда итү**

**ЖӨДӘ** *рәв. фар.* Бик, гаять, ифрат. *Нәрсәдә соң мондый җөдә куркыныч хәлнең сәбәбе?* Ә.Еники

**ЖӨЙ** *и.* 1) Тукыма, тире һ.б. нәрсәләрнең кисәкләрен бер-берсенә тегеп беркеткән эз. *Ямавы бар, җөе юк.* Табышмак. *Биредәге керләр тышкы ягы белән, җөйләре эчтә калдырылып эленгән иде.* А.Хәлим. *Кыйгач тукыманы уң яктан каеп, тискәре якка әйләндерәләр дә, каеган җөйне каплатып, күренми торган итеп тегеп куялар яки уң яктан элеккеге җөй эзеннән кайыйлар.* Йорт эшләре

2) Тегүдә энә атламы, энәне бер чәнчеп алу белән икенче чәнчеп алу арасы. *Тегү эшен дөньяда иң җаваплы һөнәр дип санаучы, һәр җөен уйлапнечкәләп ясый торган Насибә өстәле янында тураеп басты, энәсен чәнчеп куйды ---.* М.Маликова

3) Тегү яки чигүдә тукыма өстендә энә йөртү; җөй салу ысулы. *Сабак сыман җөй белән, гадәттә, чәчәк сабакларын чигәләр.* Йорт эшләре. *Болар [чәчәкләр] барысы да тамбур җөе белән яшел, сары, чия кызыл кебек ачык төсле тукымаларда башкарыла.* Идел. *Тамбур җөе. Кузла җөе*

4) Берничә кисәктән ялгап эшләнгән әйберләрнең тоташкан урыны; җек. *Үзең беләсең бит, Зәйтүнә, торбаларның бер җөе генә ярылса да, күпме хезмәт юкка чыгачак.* М.Маликова. *Бер эшсез кеше кебек, түшәмдәге ярыкларга, җөйләргә, почмактагы обой җыерчыкларына, шкаф җекләренә, идән ярыкларына кадәр күздән кичерде.* Р.Вәлиев. *Идәннең җөйләрен кысу – нык түземлек һәм осталык сорый торган эш ул.* Йорт эшләре

5) Операциядән яки ярадан соң тәндә калган эз. *Карар күзгә сөйкемле ул [Кәримә], буе-сыны килешле, йөзе чиста, дөрес, нәкъ чигә сөяге өстендә битен нәрсәгәдер эләктереп ертудан калган җөй эзе бар, ләкин ул зарарсыз, аз гына беленеп тора...* Ә.Еники. *Күрәсен күргән икән бу тән, хәтта артыгын да, дип уйлады Шәйдулла, Мирзаның күкрәгендәге һәм аркасындагы яра җөйләрен сыпыргалады.* М.Хуҗин. *– Күптән түгел генә кызы кайтып китте бугай аның, – диде Разыя, сөрмәле күзләрен врачның яңагындагы зур җөйгә төбәп.* М.Шаһимәрдән

6) Нинди дә булса бер җирлекнең ярылган, ергаланган, җәрәхәтләнгән урыны. *Аксый-аксый, «җөй» буйлап атлыйм. Шушы кечкенә генә яра да басуны шактый зарарлап өлгергән: ике яклап та әллә ничә адым җирдә бодай бөтенләй кәрлә, ә беткән төшендә – зур бер пеләш мәйдан.* И.Низамов

7) *лингв. неол.* Ике сүз, нигез белән аффикс (морфемалар) тоташкан урын. *Өченче синтагмада исә беренче җөйдә [п] һәм [б] фонемалары чиратлашса, икенче җөйдә -лы комплексы нуль фонема белән алышынды.* М.Зәкиев

◊ **Жөенә чөй кагу** Эшне бозу, эшгамәлләренә аркылы төшү. **Жөен җөйгә китерү** 1) Тигез атламнар белән, тигез җөй салып тегү; 2) Бөтен төр эшләрне дә, шартларын китереп, пөхтә, оста итеп эшләү. *Әнисе тирәүне дә җөен җөйгә китереп обойлаган булган да ---.* Ф.Шәфигуллин; 3) Оста, матур итеп, тәмен белеп сөйләү. *Жөен җөйгә китереп, сәлам бирдем.* Т.Галиуллин. **Жөй сүтә башлау** Бөлә, ярлылана, бирешә башлау. *Гаделша гаиләсе дә җөй сүтә башлады.* Р.Ишморатова

**ЖӨЙДӘ** *и. к.* **җидә**

**ЖӨЙЛӘНҮ** *ф.* 1) Яра, җәрәхәт төзәлеп, эзе генә калу. *Тездән аста балтырда уч төбе хәтле җир алсу төстә җөйләнеп, тартылып калган иде.* Х.Камалов. *Берничә минуттан Ирек аның танкта янып җөйләнгән кулын кыса иде инде.* Ф.Садриев

2) *күч.* Рухи җәрәхәт төзәлү, онытылу

3) *күч.* Берәр сәбәп белән бозылган, начарланган эш-хәл, үзара мөнәсәбәт җайлану, төзәлү

4) Берәр тишек яисә ярыкның нәрсәдер ярдәмендә ябылуы, ягъни аның

урынына җөй хасил булу. *Кем белә, бәлки, кеше кереп-чыгып йөргән ярык сагыз белән шулай «җөйләнергә» өлгергәндер?..* М.Хәсәнов

5) Нинди дә булса тукымага, киемгә бизәкләр яки хәреф-тамгалар чигелгән яки тегелгән булу. *Җентекләп карарга керештем: «Х.З.» дип, ак җеп белән җөйләнгән ике баш хәрефне укыгач: «Хәмидулла!» – дип бар тавышка кычкырып җибәрдем.* К.Латыйп

**Җөйләнә башлау** Җөй барлыкка килү, җөйләнергә керешү. *Күптәнге, инде чак кына җөйләнә башлаган йөрәк җәрәхәте кабаттан ачылдымыни?* М.Хәсәнов

**Җөйләнә төшү** Бераз җөйләнү

**Җөйләнеп бару** Җәрәхәт төзәлә барып, аның урынына акрынлап җөй барлыкка килә башлау, акрынлап җөйләнү. *Яра урыны җөйләнеп бара, бернинди куркыныч юк кебек.* Х.Камалов. *Кирәкми бу хәл аңа [Бәхтияргә], җөйләнеп барган җәрәхәтләрен генә кузгатып җибәрмәсме?..* М.Хәбибуллин

**Җөйләнеп бетү** 1) Тәмам җөйләнү, җөе генә калу

2) Бик күп җөйләрдән тору, җөй баскан булу. *Тән җөйләнеп беткән – яра баскан...* Н.Арсланов

**Җөйләнеп калу** Җөй барлыкка килү

**Җөйләнеп килү** Акрынлап җөйләнү

**ҖӨЙЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тегү; тегү белән шөгыльләнү. *Аның урак ургандагы шаянлыкларын, Сара белән булган дуслыкларын, бергә-бергә күлмәк җөйләүләрен, киндер сугуларын сөйлим.* З.Бәшири. *Анда, бер якны биләп торган, зур гәүдәле кеше аунарлык иркен өстәл янында, тегүче Насибә нәрсәдер җөйләп азаплана иде.* М.Маликова. *...Җиңне минем урман ерткан иде, Ул шул төшкә күзен төшерде, «Җөйли белэм... изүемдә менә Инәм дә бар...» дигән шикелле.* Х.Туфан

2) Киемнең аерым бер өлешен тегү яисә ертык-сүтеген ямау. *Аклы ситсы күлмәгемнең Якасын җөйләмиләр ---.* Җыр

3) Аерым бер ысул белән энәне йөртеп җөй ясау. *Юллап җөйләү. Чылбыр ясап җөйләү. Элмәкләп җөйләү*

**Җөйләп алу** Тиз арада җөйләү

**Җөйләп бетерү** Җөйләүне төгәлләү

**Җөйләп кую** Җөйләнгән хәлгә китерү

**Җөйләп тору** Сөйләү моментында җөйләү

**Җөйләп чыгу** Барысын да берәмберәм җөйләү; башыннан ахырына кадәр җөйләү

**Җөйли башлау** Җөйләргә керешү

**Җөйли төшү** Бераз җөйләү

**ҖӨЙЛЕ** *с.* 1) Җөе булган, тегелгән. *Татар хатыннары кием-салымның эчен тышка әйләндереп, җөйле ягын тышта калдырып, чайкаганда да шул уңайга чайкап элэләр, ә марҗалар исә, әйләндереп-нитеп тормыйча, тышкы ягы белән юалар да шул килеш эләләр.* А.Хәлим. *Җөйле ягын тышка каратып элгәндә, кояш нуры киемнең сабын да алып бетермәгән керен ашый...* А.Хәлим. *Күлмәгенең җөйле урыннарын кабат-кабат сыйпады Камилә, тик, барыбер, берни исенә төшерә алмады.* Юлдаш

2) Яра җөе, җәрәхәт эзе булган. *Турганов сул җиңен сызганды, терсәк буыныннан астарак бияләй чаклы кызгылт җөйле яра эзе әллә каян беленеп тора иде.* Х.Камалов. *Әлеге җөйле маңгайлы егет кемнедер хәтерләтте Габдуллага.* Казан утлары

**ҖӨЙЛЕ́ ЧИГҮ** *ф.* Тукыманың җепләрен тартып чыгарып, шул җирлектә тишекләр ясап чигү

**ҖӨ́Й МАШИНАСЫ** *и.* Тегү машинасы. *Әнисе, җөй машинасы янында утырып, кызына күлмәк тегә.* Р.Ишморатова. *Арзанлы гына ситсы алып, бер-ике ыштан тегеп җибәргәндә дә ярар иде дә, җөй машинасы да байтактан юк инде Бибинурның...* А.Гыйләҗев

**ҖӨ́Й САЛУ** *ф.* Тегү, җөйләү. *Олег Михайлович, үзен бик тыныч тотып, зур осталык белән җөй салды.* Р.Ишморатова. *Зәйтүнә соңгы җөйләрне пөхтә, тигез итеп салырга тырышты.* М.Маликова

**ҖӨЙСЕЗ** *с.* 1) Җөе булмаган (гадәттә, бәйләнгән, тегелгән әйберләр турында). *– Ярар, бабай, без, әти белән сөйләшеп, туйны чигерәбез, син андый һөнәрле оста булгач, безнең өчебезгә өч җөйсез күлмәк тегеп бир, күлмәкләр иртәгә өлгергән булсын, – диләр [патша кызлары].* Әкият

2) *тех.* Җөе булмаган, тоташ, бербөтен итеп эшләнгән. *Полимерның судагы дисперсиясе җөйсез идәннәр ясаганда, бетон һәм изменең сууткәрүчәнлеген һәм химик тотрыклылыгын арттыру өчен кулланыла.* Төзү материаллары. *Кайнар килеш прокатлап эшләнгән җөйсез торбалар*

**ҖӨЙ ТАРТУ** *ф.* Яра эзе төзәлеп, җөе калу, җөйләнү

**ҖӨ́Й ТЕГҮ** *ф.* 1) Тегүчелек эше белән шөгыльләнү, тегү. *Әбиләрнең үз гомерендә бик күп эш башкарган, бик күп бала сөеп үстергән, җөй тегеп, бөтен семьяны киендергән эшчән куллары үзләре йон эрләп, үзләре бәйләгән йомшак перчатка һәм бияләйләрне сыйпап куя.* Г.Бәширов

2) *к.* **җөй салу**

**ҖӨЙЧЕ** *и. сөйл.* Тегүче. *Әнием оста җөйче иде.* А.Гыйләҗев

**ҖӨ́Й ЭШЕ** *и.* Тегүчелек эше, тегүчигү. *Җөй эшен аеруча яратып башкара идем, ди әбием.* Юлдаш

**ҖӨМ** *и.* Эчтәлек, мәгънә, асыл; җавап. *Йомак әйтәм – җөмен тап!* Әйтем

**ҖӨМА́ДИӘЛАХИР** *и. гар. иск.* Һиҗри тәкъвимнең алтынчы ае; мөселман календаре буенча ай елының алтынчы ае атамасы

**ҖӨМА́ДИӘЛӘҮВӘЛ** *и. гар. иск.* Һиҗри тәкъвимнең бишенче ае; мөселман календаре буенча ай елының бишенче ае атамасы

**ҖӨМИ́ ӘБӘТЕ** *и. диал.* Төшке аш белән кичке ашау арасында җиңелчә генә ашап алу һәм шул ашау вакыты (элек кыр эшендә вакытта ярты көнлек ашауны шулай дип атаганнар) // Җиңелчә ашап, тамак ялгап алу

**ҖӨМЛӘ** I. *и. гар.* 1) *лингв.* Тәмамланган фикерне белдерә торган сүз яки сүзләр тезмәсе. *Күзе һаман бер җөмләгә тукталды: «Фотонның күкрәк кесәмдә генә йөртер идем...»* А.Юнысова. *Шундый аяусыз чынбарлыкта пьесаның персонажлары да кырыс телдә, өзек-өзек җөмләләр белән аңлашалар иде.* М.Маликова. *Теленең сафлыгы, матурлыгы, җөмләләрнең төгәллеге,*

*гадилеге, әсәрнең мавыктыргыч вакыйгаларга бай булып, үрелеп кенә баруы күңелемне әсир итте.* Казан утлары. *Өндәү җөмлә. Сорау җөмлә. Хикәя җөмлә*

2) *сөйл.* Сөйләм барышында сүз һәм сүзтезмәләр белән белдерелгән уй, фикер. *Соңгы җөмләсен әйтмәсә, Илфатның кәефе кырыласы икән.* Б.Камалов. *Алар, бер-берсеннән кыенсынган кешеләр кебек, ачылып китә алмыйча, өзек-өзек җөмләләр белән генә сөйләшәләр, бер-берсенең күзенә күтәрелеп карарга кыймыйлар иде.* Р.Вәлиев. *Кыз җөмләсен тәмамлый алмады, тамагына кайнар төер утырды.* Ф.Яруллин

**ҖӨМЛӘ** II *а.* **1.** *иск.* 1) Барча, барлык, бар. *Җөмлә гөлнең нуры китә Сачәк вакытлары үткәч...* Г.Кандалый. *Бер сөеп арган вә җөмлә нәрсәдән бизгән кеше – күңле бозланган кешедер ---.* Г.Тукай. *Мин аның алдында чакта җөмлә хәсрәттән азат.* М.Гафури

2) Барысы, барчасы, бөтенесе. *Таш пулатлар җөмлә дер-дер селкенә ---.* Г.Тукай

3) Һәркайсы, һәрберсе. *Угрылар бонларны Җөмләләрене багълап, Хайван кеби яткыздылар.* Ф.Халиди

**2.** *и. мәгъ.* 1) Аерым бер даирә яисә нинди дә булса зат, шәхесләр төркеме. *Чөнки Әсман карт, менә дигән дүрт ул һәм өч кыз үстергән кеше буларак, соңгы елларда җылы түр һәм каты чәй яратучы бабайлар җөмләсеннән исәпләнә башлаган иде.* М.Әмир. *Кешесе бүтән, һәр кич ресторанга эчәр өчен генә тула торган клиентлар җөмләсеннән түгел.* Ә.Еники

2) **җөмләдән** *чыг. кил. форм.* «Шул исәптән, шул сәбәпле, шулар арасыннан, шулардан» дигән мәгънәне белдерә. *Мин инде дөньяда күп нәрсә күрдем, җөмләдән бер-ике эшне сөйләп үтим әле.* М.Гафури. *Сугыш бетү һәркемнең, шул җөмләдән Зөфәрнең дә язмышын кинәт яшендәй урталай ярып узды.* Ә.Еники

**3. җөмләдән** *кер. сүз функ.* 1) Шул уңайдан, сүз уңаеннан. *Җөмләдән, шул тарихның сәхифәләрен вакыт төпкелләреннән актарып алыйк булмаса...* Р.Низами. *Җөмләдән, шул булсын, Анатолий агай җәһәннәмнең түреннән бу юлы да исән кайтты.* А.Гыйләҗев

2) Беррәттән, шунда ук. *Укуны тәмамлап, университетта эшкә калуга ук, җитәкчем оештырылачак экспедициянең хәстәрен күрә башларга, җөмләдән, маршрутны да билгеләргә кушты.* М.Госманов

**ҖӨМЛӘТӘН** *рәв. гар. иск.* Һәммәсе, барысы да, һәр нәрсә. *Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың.* Г.Тукай

**ҖӨМҺҮР** *и. гар. иск.* 1) Җәмәгать, халык

2) Җәмгыять, төркем

**ҖӨМҺҮРИЯТ** *и. гар.* Республика. *Монда инде сәясәт аңкый: әйтерсең җөмһүриятгә «татар» дигән зур халык, аның мәгыйшәте юк.* С.Хафизов. *Шул моңнарга тәңгәл генә агыла Җөмһүриятнең имин еллары.* Р.Әхмәтҗан. *Җөмһүриятебез башлыгы, гомумән, бу вазгыятьне корылтайдагыларның һәммәсеннән яхшырак белә булып чыкты.* Ватаным Татарстан

**ҖӨНТӘС** *с. диал. к.* **йөнтәс**. *– Кем ул анда йөри, эт өрдереп?! – диде Сакалбай һәм җөнтәс кашлары астыннан килүчегә төбәлде.* Г.Ахунов. *Йөзе дә җитдиләнде, хәтта бакыр төсендәге сакал-мыегы, җөнтәс кашлары да, ничектер, җыелып киткәндәй булды.* М.Әмирханов

**ҖӨНҮН** *и. гар. иск.* **1.** 1) Акылдан язганлык, җиңел акыллылык, тилелек

2) Ярсу

**2.** *с. мәгъ.* Акылдан язган, җиңел акыллы, тиле. *Җөнүн адәм*

**ҖӨНҮНХАНӘ** *и. гар. иск.* Юләрләр йорты

**ҖӨП** *с. фар.* 1) Икегә калдыксыз бүленә торган; *киресе:* **так**. *Җөпне «җөп» дип һәм шулай ук такны «так» дип яз.* Г.Тукай. *Саннар төрле-төрле бит ул, Җөпләре бар, таклары бар.* М.Каюмов. *Май ахырында инде, бер метр киңлектәге түтәлдә өчәр рәт калдырып, җөп рәтләрдәге салатны азык өчен алырга мөмкин.* Яшелчәчелек. *Хәзер тригонометрик функцияләрнең җөп һәм так булуы мәсьәләсен тикшерәбез.* Алгебра

2) *иск.* Пар, ике. *Иң ахырга ике-өч җөп көрәшче кала.* Ф.Әмирхан. *Безнең халыкның «дөньяның җәфасы – җөп, вафасы-тугрылыгы – так» дигән мәкале хайваннарга бөтенләй дә кагылмый...* М.Хуҗин

◊ **Җөп китерү** Туры китерү, шуның кебек итеп ясау, ике әйберне пар итү, парлау. **Җөп табу** Хуплау, җөпләү, әйбәт кабул итү. *Хаклы дип, безнең теләкне җөп табып, Вәгъдә биргән ирде Тәңре күптән ук.* Ш.Бабич

**ҖӨПЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кемнең дә булса сүзен, фикерен хуплау, аның белән килешү. *Күк гөмбәзен күзләгән хәлдә, Хәнәфи хатыны сүзен әнә шулай җөпләде, үзе күңеленнән улы Вәсимнең өйдән чыгуын көтүдә булды.* Э.Касыймов. *Хатыны аның [Харисның] сүзен җөпли, башын сыйпый, алдына аш китереп куя.* М.Маликова. *– Кешене алай эчерү – хөрмәт күрсәтү түгел, ямանлык кылу ул. – Әлбәттә! – дип, картны җөпләде Илдар.* З.Фәйзи

2) Берәр сүз яисә вакыйганы, эшхәлне раслау һәм сөйләүченең сүзләрен ым, сүз белән хуплап бару. *Һәм ул, Рифнең «әйе!»сен дә көтмичә, үзенекен җөпләде: – Вәт, сөйләш минем белән.* К.Кәримов. *Бередә [утырышта] инде, карулашып, үз фикереңне җөпләү мөмкин түгел иде.* Х.Камалов. *– Әйе, әйе! Шулай булмасам, мондый сөйләшүгә мине җибәрер идемени Радик Хафизович! – дип җөпләргә тотынды тегесе.* З.Фәйзи

**Җөпләп бару** Һәр сүзне, фикерне җөпләү, барысы белән дә килешү. *Койрыксыз, әйтмә дә инде дигән сыман баш кагып, Әнкә куянның сүзләрен җөпләп бара иде.* Р.Батулла

**Җөпләп кую** Сөйләүченең фикерләрен нәрсә дә булса әйтеп хуплау белдерү. *– Әлбәттә, шулай, – дип, тыныч, әмма көр тавыш белән аның сүзен җөпләп куйды Җиһангир.* М.Маликова. *Янындагы улы аның сүзен җөпләп куйды: – Бар, ахфицер әфәнде, бар.* К.Латыйп. *– Дөрес, – дип җөпләп куйды Вахитов. – Әмма мин Солтангалиев сүзләре белән килешәм.* Р.Мөхәммәдиев

**Җөпләп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта берәр кешенең сүзен, фикерен яисә эш-гамәлләрен хуплауны ниндидер хәрәкәт яки сүзләр белән белдерү. *Кыз, аңа бар күңеле белән ышанып,*

*аның сүзләрен ияк кагып, йөзен яктыртып-сүндереп җөпләп торды.* Б.Камалов. *Һәм аның һәрбер сүзен диярлек хуплап, ияк кагып җөпләп тордылар.* М.Хәсәнов

2) Һәрвакыт, даими җөпләү. *Ә үзләре [вәзирләр]: – Сөңгеләр кояргa! Угланнар тудырырга! Егетләрне өйрәтергә! – дип, ханның сүзләрен җөпләп торганнар.* Р.Батулла

**Җөпләп утыру** *к.* **җөпләп тору** (*1 мәгъ.*). *– Ә бит ул чакта сыер саткан акчасын барыбер алып кайтмаганые ул! – диде шунда, моңарчы гел «ы-ы, ы-ы» дип, Фатыйх абзыйның сүзен җөпләп утырган Хафиз карт.* В.Нуруллин. *Теләсә нәрсә эшләтегез, әмма аның сүзен җөпләп утыра алмыйм.* Р.Вәлиев. *Председательнең, әйеме дигән сүзенә баш кагып, әйе дип җөпләп кенә утырырга туры килде Фәндиләгә.* Г.Ахунов

**ҖӨРЬӘТ** *и. гар.* 1) Тәвәккәллек, кыюлык, батырлык. *Яшерен эшләрне ачарга кемдә җөрьәт бар иде.* Г.Тукай

2) Көч-дәрман, гайрәт

**ҖӨРЬӘТ ИТҮ** *ф.* Батырчылык итү, тәвәккәлләү. *Аяк очларына басып, поса-курка гына почмактан-почмакка килә, өй тирәсен карап чыга, әмма бакчага керергә җөрьәт итми.* М.Галиев. *Ягъни син, кеше, кая килеп кергәнеңне белеп кер һәм лаек булсаң гына атлап үтәргә җөрьәт ит!* Ә.Еники. *– Җәмил бабай кайда, өйдә күренми? – дип, беренче соравын бирергә җөрьәт итте Тимерхан.* Г.Ахунов

**ҖӨРЬӘТЛӘНҮ** *ф. к.* **җөрьәт итү**

**ҖӨРЬӘТЛЕ** *с.* Кыю, тәвәккәл, батыр

**ҖӨРЬӘТЛЕЛЕК** *и.* Тәвәккәллек, кыюлык, йөрәклелек, батырлык

**ҖӨЯ** *и. гар. иск.* Мантыйк

◊ **Җөясен белү** *к.* **җөен җөйгә китерү**

**ҖӨЯЛЕ** *с.* Мантыйгы булган, эзлекле, урынлы, дәлилләнгән. *Җөяле сүз җөясен табар, җөясез сүз иясен табар.* Мәкаль

**ҖӨЯСЕЗ** *с.* Мантыйгы булмаган, нигезсез. *Җөясез дәлил*

**ҖУА** *и. диал.* Юа; кыргый суган. *Бер көтү бала болыннан җуа җыеп кайтып килә иде.* Г.Гобәй

**ҖУАЧА** *и. диал.* Ваграк итеп ясалган бавырсак. *Ул кунакларны җуача пешереп каршы алды*

**ҖУБАЛГЫ** *с. диал.* Таркау, шапшак; үзен-үзе пөхтә йөртмәүче, җыйнаксыз кеше. *Хатын бик шапшак булып чыкты минем, тфү! Җубалгы! Бернәрсә карамый.* Г.Бәширов

**ҖУЕЛУ** *ф. сөйл.* 1) Нәрсәдер төшеп калу, югалу, юкка чыгу. *Ялгызның җәясе калса – җуелыр, ырулының угы калса да табылыр.* Мәкаль

2) Сакланмау, тәмам таушалып, танымаслык хәлгә килү. *Ул кәгазьләрдә хәрефләр борынгы, алары да җуелган, укырлык түгел дип сөйләделәр.* Р.Зәйдулла. *Аның бу чор иҗатында документаль фактларга нигезләнгән очерк белән художество фантазиясенә корылган хикәяләр арасында еш кына чик тә җуела...* С.Сафуанов

3) *сөйл.* Юк булу, юкка чыгу. *Сандугач --- гөл чәчәгеннән башка, үзен чолгаган бөтен дөньяны оныткан шикелле, үз тавышында үзе җуела иде.* Ф.Әмирхан. *Юаш, но шешә күрсә – бетте, тыела алмый. Акылы җуелганчы чөмерә.* М.Юныс. *Ә яшьлек гомергә җуелган, Чәчкәсе коелган үләндәй.* Ә.Ерикәй

4) *сөйл.* Бетү, вакытлар узу белән онытылу, хәтердән югалу. *Ишленең мең хатасы җуелыр, ялгызның бер хатасы мең булыр.* Мәкаль. *Үткәндә кичергән кайгылар, газаплар Барсы да онытыла, барсы да җуела.* М.Җәлил. *Хәтердән җуелып, йөрәктән уелып, Онытылып калган күп җирләр бар.* М.Мазунов

**Җуела бару** Акрынлап, бер-бер артлы җуелу, вакыт узган саен ныграк җуелу. *Уйлашкан саен, бармау ягын куәтли торган сәбәпләр берәм-берәм җуела баралар иде.* Ф.Әмирхан

**Җуела башлау** Җуелырга тотыну

**Җуела төшү** Бераз җуелу

**Җуела тору** Һәрвакыт яки бер-бер артлы җуелу. *Өстәлдәге кәгазьләр бер-бер артлы җуела тора*

**Җуелып бетү** Тәмам җуелу, бөтенләйгә җуелу. *Әле һаман һавадан җуелып бетмәгән яз җиле кояш батышы ягыннан аерым бер акрынлык һәм тынычлык белән исә ---.* Ф.Әмирхан

**Җуелып тору** 1) Әле берсе, әле икенчесе җуелу

2) Әлегә, вакытлыча җуелу. *Бу ялварулардан соң теге «кяфер» сурәтләр җуелып торган шикелле булдылар.* Ф.Әмирхан

**ҖУЕН БУЛУ** *ф. диал.* Бетү, һәлак булу; үлү. *--- син бит – ата, бала җуен булмасын, никах укыт!* Шура

**ҖУЮ** *ф.* 1) Кулында, милкендә булган әйберне, янында булган кешене югалту, нәрсәне дә булса төшереп калдыру яки урлату. *Тапканыңа да куанма, җуйганыңа да елама.* Мәкаль. *Дәрьяларга төшкән энҗе кебек, җуйдым бугай сине, җуйдым сине.* Ш.Җиһангирова

2) Берәр төрле сыйфат, рухи халәт тигезлеге юкка чыгу, кимү. *Нәтиҗәдә, тормышның ямен җуйдык, җиргә нык берекмек һәм... балаларча көнләшеп: «Очынмагыз», – дидек.* Ф.Дәүбаш. *Әниемнең йөзе үзгәреп китте, курыкты булса кирәк, ләкин тынычлыгын җуймады.* Ә.Еники. *--- чирмешләрне урыслар тәмам йоттылар, илтабарлары, горурлыкларын җуеп, муеннарына тавык тәпие тактылар.* М.Хәбибуллин

3) Тәмам оныту, истән чыгару. *Үткәннәрне бүгенгеләр белән тоташтыра кеше хәтере: Мәңгелеккә хәтерен җуйса әгәр, кешелекнең Бетә кадере.* Ф.Яруллин. *Түзем тел ул [Татар теле] Окопларда, төрмәләрдә, лагерьларда атылса да, ысланса да, асылса да, Җиңү рухын җуймаган ул.* Р.Фәйзуллин

**Җуеп бетерү** Барысын да, бөтенесен дә җую

**Җуеп тору** 1) Даими рәвештә, әледән-әле җую

2) Вакытлыча, кыска вакытка җую. *Секундның күпмедер өлешендә булды бу акылымны җуеп тору, аннары, исемә килеп, бөтен гәүдәм белән майорга таба атылдым.* Ә.Еники

**Җуя бару** Аз-азлап, акрынлап җую; бер-бер артлы җую. *Олыгайган саен, кеше үзенә бирелгән җиңеллек, рәхәтлек хисен җуя бара.* Ф.Дәүбаш

**Җуя башлау** Җуярга керешү

**Җуя төшү** Бераз җую

**ҖУЯЛТУ** *ф. сөйл.* Югалту. *Ул үзүзенә кайчандыр бер вакытта бик бәхетле булып та, аннан соң бәхетен*

*җуялткан шикелле тоелып китә иде.* Ф.Әмирхан

**ҖҮЗ** *и. тар.* Казакларда кабиләләр бергәлеге

**ҖҮЛӘР** *с. диал.* **1.** 1) Акылга зәгыйфь, тиле; юләр. *Ә ул, минем Якутым, җүләр ире артыннан әнә шулай илле ел йөри, белдегезме?* Г.Мөхәммәтшин

2) Җиңел уйлаучан, эшнең яки хәлнең асылына төшенмичә генә фикер йөртә торган. *Әлеге материал белән шөгыльләнгән кешеләрне дә «җүләр» дип булмый. Тәҗрибәле юристлар.* З.Фәтхетдинов. *Хәзерге тормышын ташлап, җүләр кеше генә китсә китәр авылдан...* Ф.Шәфигуллин. *Дөресен әйткәндә, безнең заманда бераз җүләррәк булсаң, яхшырак та әле ул.* Сәхнә

3) *куч.* Беркатлы, гади. *Батальонда миндәй «җүләр» егет табылырмы*? К.Латыйп. *Әйе, мин уйлаганча ук җүләр түгел икән шул Сәлим хан.* М.Хәбибуллин

4) *куч.* Үз ихтыяры, фикере булмаган, нәрсә әйтсәләр дә риза була торган, ни кушсаң да үти торган

5) *куч.* Мәгънәсез, мантыйксыз, бернәрсәгә дә нигезләнмәгән. *Рәхәтлектә йөзәм мин, шуңа күрә башка җыен җүләр уй килә.* М.Шабаев. *Япон исә бу җүләр кагыйдәгә буйсынмый, ул дүрт сәгать эшләгәч туктый, ял итә, хәл җыя, бер сәгатьтән тагын җиңен сызгана, тагын дүрт сәгать дәвамында эшли, ут уйната.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Тиле, дивана кеше. *Җүләргә кызык – кемнең кем белән ничек кочаклашуын күреп, шуннан рәхәт табып көлә.* В.Шугаев. *Ә мин бит җүләр түгел, мин бары тик башкаларга охшамаган гына.* Ф.Бәйрәмова. *Борынгылар: «Адәм баласы акыллы янында – акыллы, җүләр янында – җүләр, исәр янында – исәр, дивана янында – дивана булыр», – ди.* М.Хәбибуллин

2) Төпле фикер йөртми, уйлап эш итми торган кеше. *Буш басуны сакларга кайсы җүләре кушты сиңа?* Р.Батулла

3) Кемгә дә булса ачуланып яки үз итеп, яратып эндәшү сүзе. *Кыз башта аңа таба ташланды, аннары исенә килде бугай, әйләнеп, сабакташларына карады, сабыррак атлап китте һәм килеп җитүгә: – Барый, җүләрем, туңгансың бит! – диде.* М.Хәбибуллин. *Берәр җирең авыртыр, нишләвең бу, Габбани, чү, җүләрем!* Ә.Галиев. *– Җүләр! – диде икенче бала. – Дию түгел бит ул, Бәргән абый үзе шулай аркылы ятып кайтты.* Р.Батулла

◊ **Җүләр балык** Әйтер сүз таба алмыйча, ык-мык килеп, аптырап, миңгерәп торучы кеше хакында. *Тик җүләр балык шикелле торам. Читтән караган кеше Саламторханның патша сарае янында торуын искә төшергәндер.* Г.Тукай. *Җүләр балык, юка баш.* К.Тинчурин. **Җүләр нәрсә** Башсыз, акылсыз кеше. *Анасы тагын, җүләр нәрсә, ышана калган.* Г.Камал. **Җүләр сату** 1) Дөреслеккә туры килмәгән, урынсыз сүзләр сөйләү, үзен юләрләрчә тоту. *Кайберәүләр шундый мәсьүл вакытта җүләр сатуы өчен Дөлдел Харисны ачуландылар.* К.Тинчурин. *Укыган кешеләрне «китап кушаучелар» дип, ә үзен «эш кешесе» дигән булып, җүләр сатып йөрде.* Ә.Еники. *[Диләрә:] Җүләр сатма, Гаян!* Н.Гыйматдинова; 2) Юк-бар, кирәкмәс эш белән вакыт үткәрү. *Мотоциклыңны бикләп куясы бар, тыр-пыр җүләр сатып йөри алмас идең!* Б.Камалов. **Җүләр сөяк** Буйга үсеп тә, акылга үсми калган кеше. *Җүләр сөяк дип йөртсәләр дә, Гали һич үпкәләмәде авылдашларына ---.* Казан утлары. **Җүләр чир** Кирәкмәгән уй, начар гадәт. *Ходаем саклагандыр, тиз арындым җүләр чирдән.* Ф.Шәфигуллин

**ҖҮЛӘРБАШ** *и. диал.* Акылсыз кеше; юләрбаш. *Җүләрбаш, кирә дә чыга, имеш.* А.Гыйләҗев

**ҖҮЛӘРЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Акылдан язу, исәрләнү; юләрләнү. *Гөлйөзем апа җүләрләнгән, димә.* Н.Гыйматдинова. *[Гөлфия:] Ишеткәнсеңдер инде, Заһитың җүләрләнде.* Ф.Яруллин

2) Җитдилеген югалту, юләргә сабышу. *Әйе, һәркем үзенчә җүләрләнә шул.* З.Фәйзи. *[Миңлеасия:] Кит әле, җүләрләнмә. Картаеп беткәч, юкны тагын?!* Г.Ахунов. *Ул хәтта куян, кыр тавыгы ише нәрсәләргә безнең шикелле, җүләрләнеп, мылтык күтәреп йөрми, аларны артларыннан куып, коры кулы белән генә эләктереп ала, диләр.* Г.Мөхәммәтшин

3) Кызып китеп, уйламыйча, аңышмыйча эш итү. *– Җүләрләнмә! – дип, ике кулын берьюлы селтәде ул [мадам Элизабет].* Э.Касыймов. *Гөлниса апаның: «Җүләрләнмә, Гөлүсә! Нишләвең бу?..» – дигән сүзләре дә ярдәм итмәде.* М.Хәсәнов. *Син, җүләрләнеп, Карасазда йөргәндә, мин «ул үз акылында» дип исбатлар өчен, сиңа өйләндем.* Н.Гыйматдинова

**Җүләрләнә бару** Торган саен җүләрлеге арту

**Җүләрләнә башлау** Җүләрләнү билгеләре барлыкка килү. *Әллә урманда йөри-йөри җүләрләнә башладым инде?!* Аманулла

**Җүләрләнә язу** Җүләрләнү дәрәҗәсенә җитү. *Җүләрләнә язып сөйгән җанны Синнән биздерергә тырышам.* Ш.Җиһангирова

**Җүләрләнеп алу** Беркадәр, аз гына вакытка җүләрләнү. *Апа кеше, әллә ни булмагандай гына: – Әй, җизнәң бераз җүләрләнеп алды.* Р.Сәгъди

**Җүләрләнеп бетү** Тәмам җүләрләнү, төрле җүләрлекләр эшләп ташлау

**Җүләрләнеп йөрү** Әле, хәзер җүләрлек күрсәтү. *[Хәмдия:]. Йөрде инде, җүләрләнеп йөрде!* А.Гыйләҗев. *Чәчәкләремне күргәч, кычкырып көлде дә: «Бүтән болай җүләрләнеп йөрмә, яме», – диде.* Г.Галиев

**Җүләрләнеп калу** Нинди дә булса сәбәптән җүләрләнү

**Җүләрләнеп утыру** Әле, хәзер җүләрлек эшләү. *Бар, кайт, җүләрләнеп утырма.* Г.Мөхәммәтшин

**ҖҮЛӘРЛЕК** *и. диал.* 1) Үз акылында булмау; юләрлек. *Җүләрлек төрле була ул, үзалдына сөйләшеп йөрүчеләр бар, җүләрлек белән зур эшләр майтарып атучылар бар.* Сәхнә

2) Җилбәзәклек. *Унынчыны бетергәч үк, яшьлек җүләрлегә беләндер инде, бер электрикка кияүгә чыккан.* Б.Камалов. *Асия, әлбәттә, егеткә бу хакта әйтеп тормады. Оялып, кызарды: – Кичерегез мине, Нәҗип абый --- Җүләрлегем өчен ---, – диде.* З.Фәтхетдинов. *Мәхәббәт җүләрлегенә акыллылар көнләшә.* Г.Мөхәммәтшин

3) Кирәкмәгән гамәл; ялгышлык. *Әни: – И балам, нишләп мондый җүләрлек эшләдең соң? – дип өзгәләнде. – Шәһәрдә, бер белмәгән җирдә ничек яшәрсең?* Ф.Яруллин. *[Таҗи:] Нишлисез сез? Җүләрлек бит бу! Ичмасам, [балыкларның] бер-икесен калдырыр идегез.* М.Әмир. *Дөресрәге, батальон командиры капитан Непейвоның җүләрлеге аркасында [Мотаһар] күзсез калды.* А.Хәлим

**ҖҮЛӘРСЕТҮ** *ф. диал.* Кемне дә булса юләргә санау, санламау; юләрсетү. *Кара, кара, монысы да каршы түгел икән бит! Мине генә җүләрсетеп йөртәләр.* А.Хәсәнов

**Җүләрсетеп йөрү** Һәрвакыт, гел җүләрсетү. *Исән чакта җүләрсетеп йөрсәләр дә, Бәхтияр бабайны озатырга бик күп кеше килгән иде.* Р.Батулла

**ҖҮН** I *и. диал.* Көч, хәл, мөмкинлек; юнь

◊ **Җүн бирү** Мөмкинлек, ярдәм бирү; җае чыгу. *Исән булсаң, тазалыгың булса, җүн бирер.* Р.Вәлиев. *– Менә вәт, җан биргәнгә җүн бирә бит, карчык! – диде Мирхәтим, шаяртып.* З.Фәйзи. *Фронтка киткән чагында, әти миңа: «Улым, дөнья хәлен белеп булмый, кире әйләнеп кайтмасам, төсем итеп киярсең, исән-сау кайта алсам, җан биргәнгә җүн бирер, баш киеме бетмәс, рәхәтен күреп ки», – дип, үзенең өр-яңа бүреген биреп калдырган иде.* А.Хәсәнов. **Җүн кылу** *к.* **җүн бирү.** *– Алла җүн кылса, ничек тә сыешырбыз, – дип, ул [Газизә] сәке читенә утырды да яулык очын күзенә тидереп-тидереп алды.* Ә.Гаффар

**ҖҮН** II *с. диал. сөйл.* Кыйммәт булмаган, арзан, түбән бәяле; юнь. *Җүнгә генә ашлама, чәчү орлыгы теләнәм!* Н.Гыйматдинова. *Сездә азык-төлек бигрәк җүн икән, кызым.* Казан утлары

**ҖҮНӘТҮ** *ф. диал.* Тырышып, җаен табып булдыру, бар итү, табу; юнәтү. *Бик телисез икән, намаз уку урыны җүнәтү ягын да карарбыз.* М.Хәсәнов. *– Кем тапкан, кем җүнәткән нәрсәләр бу? – Ул [Сәкинә], кулларын җәеп, өй эче җиһазларына ишарә ясады.* Н.Хәсәнов

**Җүнәтеп бетерү** Барысын да, тулысынча җүнәтү

**Җүнәтеп кую** Алдан җүнәтү

**Җүнәтеп тору** Һәрвакыт, даими җүнәтү

**ҖҮНӘЮ** *ф. диал.* 1) Сатыласы әйбернең бәясе төшү, арзанаю; юнәю. *Бензин җүнәя, дип сөйлиләр, дөрес микән, кода?* Юлдаш

2) Сәламәтләнү, савыгу; тернәкләнү. *Балалары бәхетенә җүнәйсен иде*

3) Яхшыру, бөтенәю. *Тормышлары шактый җүнәйгән*

**Җүнәеп бетү** Бөтенләй җүнәю

**Җүнәеп китү** Тагын да бераз җүнәю. *Без җүнле милләт түгелме, әллә артык җүнәеп киттекме, безнең андый вак-төякләргә вакытыбыз юкмы, әллә без шул эшләрне майтарырдай кешеләргә мохтаҗмы?* Р.Батулла

**Җүнәя бару** Торган саен ныграк җүнәю

**Җүнәя башлау** Җүнәюгә таба бару

**Җүнәя төшү** Бераз җүнәю

**ҖҮНЛӘП** *рәв. диал.* 1) Әйбәтләп, җиренә җиткереп; юньләп. *Аларны укыткан укытучыны да бит үзе дә русча җүнләп белми дип алыштырдылар.* М.Әмир. *Икенчедән, ул яңа килгән, үзе җүнләп белмәгән кешегә бал сыламакчы булып хурлыкка калды.* Г.Ахунов. *[Дилбәр:] Һи, җүнләп яумаган карың белән.* Җ.Рәхимов

2) Ихластан, саф күңелдән, эчкерсез. *Бер бүлмәдә яшәп тә җүнләп, кеше төсле сөйләшмәгәч.* М.Вәлиев

3) Яхшылап, төшендереп, җентекләп. *Җүнләп аңлатырга да өлгермәдем*

**ҖҮНЛЕ** *с. диал.* **1.** 1) Яхшы; әйбәт күңелле, инсафлы; юньле. *Җүнле карчык төннәр буе урман сукмагы таптамый.* Н.Гыйматдинова. *Тышта җүнле кешенең эте дә йөрмәгән көндә син дә үзеңне йортлы, дәүләтле итеп тоясың.* Ф.Җамалетдинова. *[Хәмзә:] Безгә каршы сугыш башлагач, җүнле халык түгел инде алар [немесләр]* Ф.Яруллин

2) Әйбәт, яхшы сыйфатлы, затлы. *«Актырнакка җүнлерәк әйбер ашатырга кирәк! Ашатырга кирәк!» – ничектер, шушы уй, хәсрәтемне кысрыклап, күңелемә оялады.* Н.Гыйматдинова. *«Аш» дигәннән, Бәйрутта ашарга җүнле аш таба алмый аптырадык.* А.Расих. *Утырып язарга җүнле язу өстәле, кием эләргә җүнле шкафы да юк.* Идел

3) Булдыклы, белемле, оста. *[Хисмәтулла:] Духтырларның җүнлерәгенә күренергә кирәк. Калада белдекелеләре күптер бит аларның...* Ә.Моталлапов. *– Җүнлерәк балыкчыгыз да юкмыни соң? – ди Мәхмүт.* М.Әмир

4) Уңайлы; мөмкинлекләре булган; сыйфатлы, затлы. *Монда минем балаларымны үз вакытында ашатасым, җүнле фатирда яшәтәсем килә.* М.Хәсәнов. *Бишенче бала булганлыктан, сәкедәге җүнле урыннарны миңа кадәр алып бетергәннәр иде.* Ф.Яруллин

5) Мәгънәле, нәтиҗәле, яхшы, файдалы. *Гайбәт тыңларга яратмыйм, күрше. Сөйләсәң, җүнлерәк сүз сөйлә. Сөйләмәсәң ---, миңа ятарга вакыт.* М.Әмир

**2.** *и. мәгъ.* Нәтиҗәле, яхшы, файдалы эш, гамәл. *Ул тирәгә чакыруның җүнлегә түгеллеген без инде белә идек.* М.Хәсәнов

**ҖҮНЛЕ-БАШЛЫ** *с. диал.* **1.** Әйбәт, таләпләргә җавап бирерлек; юньле-башлы. *Тик минем монда җүнлебашлы кәгазь беткән икән әле, Рәҗибә, синең җырлар дәфтәреңдә буш битләр юкмы?* Ф.Яруллин

**2.** *рәв.* Яхшылап, җентекләп, игътибар белән. *Аны-моны тикшереп торып чак түгел, кемнең кемдә эше бар дигәндәй, җүнле-башлы карамыйча җибәреп куюлары да ихтимал.* Г.Ахунов

**ҖҮНЛЕЛЕК** *и. диал.* Юньлелек

◊ **Җүнлелеккә булу** Хәерлегә булу, ахыры әйбәт тәмамлану. *Ачулансаң – мунчага барып уйный. Җүнлелеккә булыр микән ул, Солтан?* Г.Ахунов. *Җүнлелеккә булсын! Сугышлар бетәргә язсын!* Г.Ахунов

**ҖҮНЛЕ-РӘТЛЕ** *с. сөйл. диал.* Юньле-рәтле. *[Тимерхан] Җүнле-рәтле җавап бирә алмады Хуҗа абыйсына.* Г.Ахунов

**ҖҮНСЕЗ** *с. диал.* **1.** 1) Тискәре сыйфатлы, начар эш-гамәлләр кылучы; акылсыз, уйлап эш итми торган; юньсез. *Квартира якларын җайлагач, үз яныма алырмын дип уйлаган идем, җүнсез малай качып китте.*

Ф.Яруллин. *Башыңнан чыгарып ат син аны, җүнсез кызый.* Р.Батулла

2) Явыз, әшәке. *Һай-ла, тәмам җүнсез, денсез кеше икәнсез!* М.Хәсәнов. *Йөзе кара көйгән җүнсез җан бу юлы да җавапсыз калмады: – Акыл сатма, яме! Мин сиңа киңәшкә түгел, ярдәм сорарга килдем, – дип кенә җибәрде.* М.Хәсәнов

3) Начар, мәгънәсез. *Җыен җүнсез сүзләр сөйләп, балаларны куркытма, дим...* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* 1) Начар, тискәре сыйфатларга ия булган кеше; юньсез. *Җүнсез белән тапма да, бүлешмә дә, дигән халык.* Р.Мөхәммәдиев. *Җүнсез, дигәннәрдер, игелексез, дигәннәрдер, кыз баланы нинди бәхетсезлекләргә дучар иткән бит, дигәннәрдер.* М.Хәсәнов. *Минем утын абзарының капкасына бер җүнсезе оятсыз сүз язып киткән.* Р.Батулла

2) Кемгә дә булса ризасызлык белдереп ачулану, әрләү сүзе. *Нурсөя саташкан дигән яманатымны таратасың, җүнсез.* Н.Гыйматдинова

**ҖҮНСЕЗЛӘНҮ** *ф. диал.* Юньсезлек кылу, юньсезлек күрсәтү, юньсезгә әверелү; юньсезләнү. *Тик Советта җүнсезләнгән бер халык бар, һәммә эштә теңкәгә дә тигән шулар...* М.Җәлил

**Җүнсезләнә бару** Торган саен ныграк җүнсезләнү

**Җүнсезләнә башлау** Җүнсезләнү юлына басу. *Син бигрәк җүнсезләнә башладың әле, малай ---.* Казан утлары

**Җүнсезләнә төшү** Бераз җүнсезләнү

**Җүнсезләнеп бетү** Тәмам җүнсезләнү. *Ул малайлар белән дуслашкач җүнсезләнеп беттем, урлаша, сугыша башладым.* Г.Галиев

**Җүнсезләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында җүнсезләнү. *Җүнсезләнеп йөрүеңне туктатмасаң, берәр чарасын күрербез.* Сөембикә

**Җүнсезләнеп китү** Кинәт җүнсезләнү

**ҖҮР** *и. диал.* Каты материалларны эшкәртү, гадәттә, таш юну өчен махсус эшләнгән пычак

**ҖҮРМӘ** *и. диал.* Үреп эшләнгән кыска камчы. *Җүрмә белән сугу*

**ҖҮРМӘ́Ү** *ф. иск.* Тегү; кул белән тегү

**ҖҮРМӘП ТЕГҮ** *ф.* 1) Тукыманың кырыеннан алдырып тегү

2) Сүтелмәсен өчен, энәне җебен атлатып, чалмаштырып, тукыманың кырыен читләү

**ҖЫБЫРДА́У** *ф.* Кыймылдашу, кайнашу, мыж килү; боргалану (гадәттә, бөҗәкләр турында). *Тирес өеме торган урында бөҗәкләр җыбырдый*

**Җыбырдап тору** Бертуктаусыз җыбырдау

**Җыбырдый башлау** Җыбырдарга керешү

**ҖЫБЫ́Р-ҖЫБЫР КИЛҮ** *ф. к.* **җыбырдау**

**ҖЫБЫТКЫ** *и. сөйл.* 1) Сыек ботка, боламык. *Ботка түгел, җыбыткы.* Әйтем

2) *күч.* Булдыксыз, эш рәтен белми торган кеше. *Җыбыткының эше дә җыбыткы.* Мәкаль. *Хатының җыбыткы булса, энә-җебеңне үзең тотарсың.* Мәкаль. *Әй җыбыткы, ачуым да бер килмәгәе. Җиләк кебек егетне Титарай кулына калдырып кайтыр идемме мин!* Ә.Камал

**ҖЫДА** *и. к.* **җида**

**ҖЫЕЛМА** *и.* **1.** 1) Бердәй кулланылышлы, бер өлкәгә, бер темага караган әйберләр, материаллар тупланмасы. *Иң башлап әдәби телне аерып чыгаралар... Аның мәҗбүри, ныклы бер кагыйдәләр җыелмасы бар.* Ф.Сафиуллина. *Балның үзлекләре аның составы күптөрле булу белән аңлатыла: аның составында иң гади шикәрләр – глюкоза, фруктоза, ферментлар, органик кислоталар һәм кеше организмы өчен бик кирәк булган микроэлементларның зур җыелмасы бар.* Умартачыга ярдәмлек

2) Әйберләрдәге яки кешеләрдәге бербөтенне тәшкил иткән сыйфатлар тупланмасы. *Аң – беренчедән, психик эшчәнлекнең җыелмасы, икенчедән, теоретик һәм практик эшчәнлекнең нәтиҗәсе...* Ф.Сафиуллина. *Кешенең явызлык яки, киресенчә, яхшылык хакына кылган һәр гамәле, эше күптөрле сәбәпләр һәм шартлар җыелмасыннан гыйбарәт.* Д.Вәлиев

3) Җыентык; әдәби әсәрләр тупланмасы. *«Г.Ибраһимов әсәрләре» тулы җыелмасының икенче томына «Казакъ кызы» романы кертелгән.* Г.Нигъмәти. *Шагыйрь Шәехзадә Бабичның Академик Үзәк карамагына тапшырылган архив материаллары буенча әсәрләр җыелмасы басылып чыга.* М.Әхмәтҗанов

4) Бердәй булган күпсанлы әйберләрнең кушылмасы. *Аркан – ул җепләр җыелмасы*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Барысын бергә тупланган. *Халык массаларының җыелма социаль портретын тудыруда И.Гази зур осталыкка ирешә.* С.Сафуанов. *Әйткәнемчә, Урал – ул җыелма исем. Шул ук вакытта биредә һәр тау сыртының үз борынгы исеме, үз тарихы бар.* Ф.Бәйрәмова

2) *к.* **җыелмалы**. *Җыелма өстәл*

**ҖЫЕЛМАЛЫ** *с.* Күләмен үзгәртеп була торган; зурайтыла һәм җыелып куела торган. *Җыелмалы диван. Җыелмалы өстәл*

**ҖЫЕЛУ** *ф.* 1) Кеше, хайван, кошкорт, бөҗәкләр һ.б.ш. бер урынга килү; бер тирәгә туплану. *Шәһәргә данлыклы сынчылар, рәссамнар, төрле осталар, галимнәр җыелганнар.* М.Юныс. *Яңа дача өендә беренче мәртәбә түгәрәк табын янына җыелдылар.* Т.Әйди. *Ул мең татар Чиләбе Сабантуенда күңел ачып калды, без, мөселман-татарлар, шушы авыл өенә җыелып булса да, динебезнең, милләтебезнең хәлләре турында сөйләшеп алырга булдык.* Ф.Бәйрәмова

2) Су, май, нефть кебек сыек матдәләрнең, агып, бер урынга тулуы, туплануы. *Менә шушы олы дәрьяда Чишмәле инешнең дә суы бар ич, Идел нәкъ менә шундыйлардан җыела да ич инде.* И.Низамов. *Башта су бозлык иңкүлегенә җыелган, аннары, бозлыкны ерып, Нарсай елгасы тарлавыгына чыккан.* Могҗизалар энциклопедиясе

3) Әкренләп, тора-бара туплану (тәҗрибә, белем, фикер, эш, мал һ.б.). *Мал бөртекләп җыела.* Мәкаль. *Ял көненә мең эш җыелган була.* М.Маликова

4) Аз-азлап билгеле бер күләм туплану. *Тәхет ягына кереп, гәүһәр ташлардан җыелган дисбесен кулына алгач*

*кына, Йосыф бәк, --- Исмәгыйль энем белән киңәшергә кирәк булыр дигән фикергә килде.* М.Хәбибуллин. *Мондагы уртача хезмәт хакының алтмыш проценты ике ел буе, җыелып, сине көтеп тора.* К.Кәримов. *Димәк, көзен суднолардан җыелган акча контрольдән чыга.* И.Низамов

5) Җәелә, сузыла торган нәрсәнең, җыйнакланып, кечерәеп калуы. *Эшче кортларның аркага җыелган канатлары, алар тыныч хәлдә чакта, корсакларын тулысынча диярлек каплый.* Умартачыга ярдәмлек

6) Җыеп алган булу. *Җыелган чәчәкләрне мөмкин кадәр тизрәк киптерергә кирәк.* Урман аптекасы. *Җиләкләрен яңа җыелган килеш ашыйлар, алардан варенье кайнаталар...* Урман аптекасы

7) Бергә кушып исәпләү. *Кызык, синең белән күрешкән минутларны бергә кушып санасаң, ярты көнгә җыелыр микән?* К.Кәримов. *Буровойдагы эш стажы биш елга җыела!* К.Кәримов

8) Тәртип белән урнаштырылган булу. *Пөхтә итеп җыелган кроватьларда, авылда кич утырганнардагыча, ыспай киенгән урманчы кызлар бәйләү бәйләп, чигү чигеп утыралар.* Г.Гобәй. *Җыелган урын өстендәге мендәрләрне сытып кырын яткан Суфияттәй, эч пошуын тавышына сеңдереп, бәя биреп торды.* К.Кәримов

9) Таралып, чәчелеп, тузып торган нәрсәләрне бергә туплап, пөхтәләп кую. *Сары җирән толымнары баш түбәсенә божра булып җыелган.* Р.Зәйдулла

10) Полиграфия хәрефләреннән текст төзү. *Гәрәй эре хәрефләр белән җыелган юлларны ерактан ук аермачык күрде.* К.Нәҗми

11) *сөйл.* Ябыгу, җыйнаклану

12) Берсе өстенә берсе өстәлү, күбәю. *Һәрьяклап җыелган ачуы, югалтулары, түләмәле тирене түләмәсез тиредән аера алмавы өчен, тәмам эчне киптерү дәрәҗәсенә җиткән үте хатын кыйнау белән генә басылмагач, көннәрдән бер көнне Хәмзә --- Кабанның теге ягына – Суконный бистәсенә юл тотты.* Ф.Хөсни. *Шул авырлык аны җиргә таба тарта, һәм ул, бөтен җыелган хис-тойгыларын туфракка тапшырыр өчен, фани дөньядан китеп бара.* Р.Зәйдулла

13) Берләшү. *Кардәш җыелса – кавем булыр, Сыер җыелса – савым булыр.* Мәкаль. *Инде нәүбәт без бичараларга җитә, – Җыйлып-җыйлып депутатлар сайлыйк имди.* Г.Тукай. *Йөз кеше җыелсак, кеше башыннан алтышар сум гына чыгачак.* Ф.Хөсни

**Җыела бару** *к.* **җыелып бару**

**Җыела башлау** Җыелырга тотыну

**Җыела килү** Электән үк, акрынлап, аз-азлап җыелу, өсте-өстенә артып ишәю. *Ул ачу акрын-акрын эчкә җыела килде.* Р.Зәйдулла

**Җыела тору** 1) Әлегә, хәзергә җыелу; торган саен күбрәк җыелу

2) Һәрвакыт, гел җыелу. *Җәйге ял вакытында иллешәр миллион су коенучы җыела торган Франция пляжлары дигет эшләпәсе белән каплана.* М.Юныс

**Җыела төшү** Тагы да бераз җыелу. *Җыелышны башламый, кешеләр җыела төшкәнне көтәләр*

**Җыелып бару** Аз-азлап, акрынлап җыелу, ишәйгәннән-ишәю. *Аларга чи йомырка бирәләр, ул йомыркалар бер савытка җыелып бара.* Р.Уразманова. *Әгәр андый матдәләр капчык эченә җыелып барсалар, җимешләр бик тиз көрән төскә керерләр иде.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

**Җыелып бетү** 1) Барысы да җыелу. *Кунаклар, эш кешесе буларак, төгәл үз вакытында җыелып беттеләр.* Ф.Хөсни. *Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар.* Ә.Еники

2) Бөтенләй, тулысынча җыелу; тәмам җыелу. *Шул исе китмәгәнлекне күрсәтү өчен, җыеласы акча җыелып беткәннән соң да, ул, кабаланып, акчага ташланмады...* Ф.Хөсни. *Аннары, табын җыелып беткәч, олылар йокларга яттылар.* Ф.Хөсни

**Җыелып җитү** Барысы да җыелу; кирәк булганча җыелу. *Малайлар җыелып җиткәч, шәкертләрнең олысынкечесен ястү намазына йөртә башладылар.* Г.Бәширов

**Җыелып калу** Ниндидер вакыттан, вакыйгадан соң берәр төрле сәбәп белән җыелу; җыелырга өлгерү. *Кәрван озатучыларның барысы да, килеп, ишанның догасын алып, кулын үбеп китәләр. --- ниндидер махсус теккән чапан астындагы тирән кесәсенә алтын тәңкәләр шактый ук җыелып кала.* Ә.Еники. *Юкә ботакларында, түбә кыегында җыелып калган тамчылар биткә бөркелеп чиркандыра.* И.Низамов

**Җыелып килү** Озак вакытлар дәвамында җыелу; аз-азлап җыелу. *Римнең меңеллар буена җыелып килгән коточкыч әхлаксызлыгы үч алуны таләп итә.* Ф.Урманче. *Бу --- авыл кешеләрендә бөртекләп җыелып килгән белем, осталык, тәҗрибәнең әкренләп гамәлгә аша башлавы түгелмени?!* И.Низамов. *Мәхәббәтемне аклау йөзеннән түгел, юк, ә озак еллардан бирле эчемә җыелып килгән газаплы уйларны бушатыр өчен сөйләр идем.* Ә.Еники

**Җыелып тору** 1) Һәрвакыт, даими рәвештә җыелу. *Ел да җыелып торабыз*

2) Әле, хәзер, күз алдында төркем-төркем булып җыелу. *Йөгереп барды да арба янында җыелып торган кызларга бер чиләк су тондырмасынмы!* Г.Бәширов. *Күпер төбендә җыелып торган егетләр кунак кызларын күрүгә --- тынып калдылар.* Г.Бәширов

**Җыелып яту** Бер урынга күп булып җыелу. *Өйдә калганнарның барысына да яшертен үпкә белән әйтте: «Барыбыз да җылы өйдә җыелып ята башласак...» – диде.* Ф.Хөсни

**ҖЫЕЛУЧАНЛЫК** *и. мат.* Җыела ала торган булу, шундый үзлеккә ия булу; *русчасы*: **сходимость**. *Җыелучанлык ноктасы*

**ҖЫЕЛЫШ** *и.* 1) Нинди дә булса оешмада, коллективта эшләүчеләрнең килеп туган мәсьәләләрне хәл итү өчен уздырыла торган утырыш яки киңәшмә. *– Кисәткәнегез, шелтә биргәнегез яисә җыелышка куйганыгыз булдымы соң? – дип сорыйм.* М.Юныс. *Ялгышмасам, сез мине җыелыш саен тәнкыйтьләп чыга идегез шикелле.* Ф.Яруллин. *Кияү кеше ашыга иде, аңа ниндидер бер кечке җыелышка кайтып җитәргә кирәк икән.* Ә.Еники

2) *сир.* Бергә җыелу, туплану. *Вәхши кешеләрне бер җиргә җыелып, куәт*

*беректереп торырга мәҗбүр итүче – [ихтыяҗ] һәм чарасызлык икән. Аларның бу җыелышлары дошманнардан котылырга да уңайлы, азык табарга да бик җайлы.* Г.Тукай

**ҖЫЕЛЫШУ** *ф* **1.** Бер урынга күпләп җыелу; бергә туплану. *Тимур, уен картасын чыгарып, берәмләп таратты, башкалар да өстәл янына җыелыштылар.* Ф.Яхин

**2. җыелышып** *рәв. мәгъ.* Бергәләп, җыйнаулап, күмәкләшеп. *Хәзер бөтенебез дә, җыелышып, ашханәгә төшәбез.* К.Кәримов. *Врач чыгып киткәч, палатадагы дүрт хатын бергә җыелышып, больница хәлләрен, дөресрәге, гайбәт сөйләшә башладылар.* М.Маликова

**Җыелыша бару** Акрынлап җыелышу

**Җыелыша башлау** Җыелышырга тотыну

**Җыелыша төшү** Тагы да бераз җыелышу

**Җыелышып алу** Кыска вакытка, тиз арага җыелышу

**Җыелышып бетү** Барысы да җыелышу

**Җыелышып калу** Җыелышкан хәлгә килү

**Җыелышып килү** Аз-азлап, акрынлап җыелышу

**Җыелышып тору** 1) Вакыт-вакыт җыелышу, һәрвакыт, даими җыелышу

2) Әле, хәзер, күз алдында җыелган булу. *Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар.* Ә.Еники. *Шулар тирәсендә зур төркем булып, бергәрәк җыелышып торган татар хатын-кызлары да, төрле сүзләр әйтеп, аларга куәт биреп торалар.* Г.Бәширов

**Җыелышып утыру** 1) Күмәкләп, бергәләп ял итү, кәеф-сафа кору. *Әнә, кичләрен, коридорда җыелышып утырганда, хатыннарниләр генә сөйләми.* М.Маликова

2) Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен бергә җыелу

**Җыелышып яту** Еш һәм озаклап бергә булу

**ҖЫЕМ** *и.* 1) *иск.* Мәҗбүри салым. *Әмир Хаҗи, гомумән, тимерчеләр, һөнәрчеләр белән кызыксынмады, казнабашы җыем һәм салымнарны төгәл үти, кул астындагы җиде-сигез кеше белән барысына да өлгерә.* М.Хәбибуллин

2) Нинди дә булса максат белән тотып калына торган акча, әйбер

3) Җыеп алынган уңышның яки башка төрле берәр нәрсәнең тулы күләме. *Бал кортлары, җыемны һәм кышка азык запасын тәэмин итү өчен, йөзләгән үсемлеккә очып кунарга тиеш булалар.* И.Рәхимов. *Арышның тулай җыемы. Савылган сөтнең җыемы ике йөз литр булыр*

**ҖЫЕМТА** *и.* 1) Гомуми сумма; барысы бергә тупланган күләм. *Житештерү мөнәсәбәтләренең җыемтасы*

2) Барлык җыем, табыш. *Эшче үзенең эш көчен теге яки бу предпринимательгә сатканчы ук инде, җыемта капиталист карамагында була.* Политэкономия

**ҖЫЕ́Н** *и.* 1) Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен җыйналган җәмәгать җыелышы. *Уенда узган – җыенда узар.* Мәкаль. *Мәмләкәткә нинди генә хан килмәсен, аның уң кулында һәрчак Булат бәк Ширин утырды – мәҗлесендә дә, табын җыенында да.* М.Хәбибуллин. *Анысы, җәмәгать җыены җыеп, түләмәүчеләрнең исемнәрен укырга тотынды.* Г.Бәширов

2) *этн.* Авылларда сабан эшләре тәмамлангач, ел саен үткәрелә торган бәйрәм. *Җыенда ят кеше булмас.* Мәкаль. *Ә кечерәкләре исә, җыен иртәсендә иң алдан торып, йомырка, чикләвек, кәнфит-прәннекләрне күбрәк җыйнау хыялы белән яна.* Г.Галиева

3) Яшьләрнең җәен авылларда, табигать кочагында бергә җыелып үткәрә торган күңел ачу кичәсе. *Син безнең җыенны әүвәлге замандагы авыл кызларының аулак өйләре дип белдеңмени?* Ф.Әмирхан

**ҖЫ́ЕН** *а.* 1) Предметларның җыелмасына бербөтен итеп күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; бар, барча. *Җыен кяфер арасында ялгызы боегып килгән бабайга бер мөселман очрату бик зур ганимәт булды бугай.* Г.Ибраһимов. *Докторлар җыен шифалы үләннәрне барысын бергә җыеп кайнаталар да теге кешене шуның суына чумдыралар.* Г.Бәширов

2) Предметларга, затларга яки аларның төркемнәренә аерып, аерым-аерым күрсәтә торган билгеләү алмашлыгы; һәрбер, һәртөрле. *– Районда сәләтеңне ачарлык эш юк, Равилә, җыен ыбыр-чыбырга очсызлы кием тегеп вакыт үткәрмә, – диде Илгизәр.* Ф.Яруллин

3) Кимсетү, ышанмау төсмере белән санап киткәндә кулланыла торган билгеләү алмашлыгы; барысы да, һәммәсе дә. *Җыен ялганчы, җыен җебегән! Сезгә ышанган мин дурак!* Г.Бәширов. *Җыен алкашны, җыен эшлексезне туйдырып ятар өчен эшләмим мин.* Ф.Яруллин

**ҖЫЕНКЫ** *с. сөйл. к.* **җыйнак**

**ҖЫЕНТЫК** *и.* 1) Әдәби әсәрләрне, аерым текстларны бергә җыеп бастырган китап. *Бу җыентыкка бөек шагыйрьнең сайланма тезмә әсәрләре – лирикасы, поэмалары, балалар өчен шигырьләре һәм әкиятләре урнаштырылды.* Р.Даутов. *Татар укучысын төрек әдәбияты җәүһәрләре белән таныштыру максатыннан чыгып төзелгән бу җыентыкта танылган язучыларның хикәяләре, романнан өзекләр туплап бирелде.* А.Рәхимова. *Мин моны аның берничә җыентыгына, мәсәлән, «Еллар эзе», «Низаглы йорт» исемле китапларына бәяләмә язучы буларак әйтәм.* М.Әхмәтҗанов

2) Музыкаль язмалардан, музыкаль әсәрләрдән торган тупланма; билгеле бер авторның пластинка, кассета, дискка яздырылган иҗат җыелмасы яки аерым бер темага багышланган язмалар тупланмасы. *М.Хөсәеннең халык арасында киң яңгыраш тапкан һәм заман сынавын үткән сайланма җырлары «Толымнарың» исемле музыкаль җыентыкка тупланган.* М.Гайнуллин

3) Бергә тупланып, аерым китап булып басылган фәнни китаплар җыелмасы. *Теоретик мәгълүматлар һәм күнегүләр җыентыгы.* Ф.Сафиуллина

4) *диал.* Нәрсә дә булса җыелып торган урын. *Парадный баскычыннан сикереп үк киткән идем – ике аяклап --- нәкъ су җыентыгының күзенә төшкәнмен.* Ш.Камал

5) Төрле урыннан җыйналган төркем. *Моннан алты ай элек [Жилинскийны] ниндидер җыентык сапёр командасына начальник ярдәмчесе итеп куйганнар.* А.Таһиров

**ҖЫЕНУ** *ф.* 1) Билгеле бер максат белән кая да булса барырга әзерләнү, әзерлек чаралары күрү. *Без кунакка җыенабыз бүген.* Т.Әйди. *Ә хәзер, бар, туганнарың көтә әнә, далага чыгарга җыеналар бугай, бар...* М.Хәбибуллин

2) Нәрсә дә булса эшләргә ниятләү, уйлау, планлаштыру. *Әхәт сикереп торды да, сөзәргә җыенган үгез сыман муенын сузып, Сәлимгә таба килә башлады.* Г.Бәширов. *Бер кешеләрне беләм, инде ничә ел «әнтик» йортларын сатарга җыеналар, тик сата алмыйлар, чөнки кыйбатка алганнар.* Н.Измайлова

3) Үзеннән алдагы фигыль белдергән эш өлгереп килү, нинди дә булса хәл, вакыйга алдында тору. *Зөһрә ханымның күрәләтә торып хата адым ясарга җыенуы, әлбәттә, мине гаҗәпләндерде.* Ә.Еники. *«Кайсы университетта?» – дип сорарга җыенган иде дә Нагаев, тыелып калды.* Р.Зәйдулла. *Көн болытлады, яңгырга җыена*

**Җыена башлау** Җыенырга тотыну. *Һич икеләнмичә юлга җыена башлый торган хыялый күңелле хатынының бүген шулай дип торуы Зөлфәтне тагын гаҗәпләндерде.* Ф.Яруллин. *Кояшлы июнь уртасында, ниһаять, түземсезләнеп көткән сәфәргә җыена башладылар.* Т.Әйди

**Җыена тору** Нәрсә булса да эшләргә яки кая да булса китәргә алдан әзерлек күрү, башкалардан алданрак җыену. *Безгә җыена торырга куштылар*

**Җыена төшү** Беркадәр, бераз җыену

**Җыенып бетү** Тулысынча җыену; тәмам җыенган хәлгә килү. *Әнисе әйләнеп кергәндә, ул инде җыенып беткән иде.* Р.Зәйдулла. *Турысын гына әйткәндә, әни мине узган ел ук өйләндерергә җыенып беткән иде.* Г.Бәширов

**Җыенып җитү** Тулысынча җыенып, әзер хәлгә килү. *Без җыенып җиткәч кенә яңгыр яварга тотынды*

**Җыенып йөрү** Әле, хәзерге вакытта нинди дә булса әзерлек эшләре белән шөгыльләнү. *Сыерлар көтүдән кайткан, ә кызлар сыер саварга җыенып йөриләр иде.* А.Расих

**Җыенып кую** Алдан җыенып, әзер хәлдә тору

**Җыенып тору** Әзер тору, әзер хәлдә булу. *[Әни] Төпченмәкче булган иде дә, кайткач күрерсең, җыеныбрак торыгыз, дигәч, үзе шуннан аңлады бугай инде.* Ф.Хөсни

**Җыенып яту** Җыену эше белән шөгыльләнү; җыену эшендә булу

**ҖЫЕ́Н УТЫРУ** *и. этн.* Элекке вакытта яшьләрнең, җыелышып, кышын өйдә үткәрә торган күңел ачу кичәсе. *Мәхәлләдә җыен утырулар башлана...* Г.Минский

**ҖЫЕНЧЫ** *и.* Җыенда катнашучы кеше; җыенга йөрүче. *Ябалак-ябалак кар яуган кышкы кичләрнең берсендә җыенчылар, кыңгыраулы саратский гармун гөрләтеп, Хәйдәрләр өенә дә килеп керәләр.* Г.Минский

**ҖЫЕНЫ** *а. к.* **җыенысы**

**ҖЫ́ЕНЫСЫ** *а.* Бөтенесе, барысы бергә, һәммәсе

**ҖЫЕРУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса сырландырып җыю, җыерчыклар ясау; пәрдә, чаршау кебек әйберне бер якка тартып кую

2) Йөз, каш, чырай, борынны бөрештерү, иңбашны кысу хәрәкәте ясау. *Зөһрә ханым, нечкә кашларын җыерып, иреннәрен кысып, беравык тынып торды.* Ә.Еники. *Ул, көтелмәгән сораудан гаҗәпләнгән сыман, миңа карап алды да иңбашын җыерыбрак: – Нишләргә уйлыйм? – диде.* Ә.Еники. *Фатыйма, кашларын җыерып, бер ноктага караган хәлдә уйга чумды.* А.Расих

**Җыера бару** Торган саен ныграк җыеру

**Җыера башлау** Җыерырга тотыну

**Җыера төшү** Тагын да бераз җыеру. *Сөембикә кашларын җыера төште, тураебрак басты, атасының күзләренә карады.* М.Хәбибуллин

**Җыерып алу** Кыска вакыт эчендә, кинәт җыеру. *Ул, Цызганов ягына карап, иңбашын җыерып алды.* Г.Бәширов

**Җыерып бетерү** Ахыр чиккә җиткереп җыеру

**Җыерып җибәрү** Кинәт җыеру; җыерылган хәлгә китерү

**Җыерып кую** Кинәт, бер тапкыр җыеру. *Зөһрә ханым, сәерләнеп, иңбашларын җыерып куйды...* Ә.Еники. *Менә килеп керде. Елмайды. Маңгаен җыерып куйды.* Р.Зәйдулла

**Җыерып тору** Әле, хәзерге вакытта җыеру; бераз вакыт җыерган хәлдә тоту

**ҖЫЕРЧА** *и.* Бик вак буразналар, җыерчыклар. *[Әкәм-төкәм] Стенкалары мантиядән ясалган киң үпкә куышлыгына һава ала. Мантия юка тиречел җыерчадан гыйбарәт.* И.Рәхимов. *Ми җыерчалары*

**ҖЫЕРЧАЛЫ** *с.* Җыерчыклары булган. *Конуссыман җыерчалы гөмбәләр берәрләп яки төркем булып үсә.* Биология

**ҖЫЕРЧЫК** *и.* 1) Олыгайган саен, кешенең тәнендә, йөзендә барлыкка килгән сырлар. *Күңеле нечкәреп киткән мизгелләрен хатынына күрсәтергә яратмый иде Идрис, Гөлчәчәк тугач кына бераз үзгәрде, йомшарды, вакытсыз җыерчыклар төшкән яңагына елмаю кунды.* Ф.Бәйрәмова. *Аның йөзе дә ачык, ишеге дә көне-төне биксез. Килгән бер кешегә елмаерга тырышып, күз төпләренә җыерчык чыккан.* К.Кәримов. *Батырып караучан коңгырт күзләр, хәрәкәтчән куе кара кашлар, яңак буйлапияккә таба сузылган эре-эре җыерчыклар...* А.Расих

2) *к.* **җыерча**

3) Тирбәлү нәтиҗәсендә су өслегендә барлыкка килгән шадралар

**ҖЫЕРЧЫКЛАНДЫРУ** *ф.* Җыерчыклар барлыкка китерү. *Көнчыгыштан искән йомшак кына җил диңгезнең өс катын азрак җыерчыкландырып бизи, матурландыра һәм диңгезнең чит буйларында вак-вак дулкыннар ясап, кырый ташлары белән ачусыз гына бәрештерә тора иде.* Ш.Камал. *[Үгез] Мүкләккә ялкау гына бер борылып карады да, борынын җыерчыкландырып, «мыш фу-у» дип авыр сулагач, --- күшәнеп торуын дәвам итте.* Җ.Юныс

**Җыерчыкландыра төшү** Беркадәр, бераз җыерчыкландыру

**Жыерчыкландырып бетерү** Бөтенләй, тулысынча жыерчыкландыру

**Жыерчыкландырып тору** Һаман, һәрвакыт жыерчыкландыру

**ЖЫЕРЧЫКЛАНУ** *ф.* Жыерчыклар хасил булу. *А витаминының җитешмәве күзнең үткенлеге югалуга, холестерин алмашының һәм бавыр функцияләренең бозылуына, тиренең кибүенә, җыерчыклануына китерә.* Урман аптекасы. *Мондый вакытларда аның тәне бик нык җыерчыклана, киңәепзураеп китә, һәм елан кабырчыгыннан алда барган шикелле күренә.* Хайваннар дөньясы

**Җыерчыклана бару** Торган саен ныграк җыерчыклану

**Җыерчыклана башлау** Җыерчыкланырга тотыну

**Җыерчыклана төшү** Беркадәр, бераз җыерчыклану

**Җыерчыкланып бетү** Бөтенләй җыерчыклану, күп булып җыерчыклар басу

**Җыерчыкланып китү** Кинәт, кыска гына вакыт эчендә җыерчыклану

**Җыерчыкланып чыгу** Кинәт җыерчыклар хасил булу. *Ире өчен борчуы кимегәч, ул үз тәненең сызлауларын сизә башлады, ахрысы, маңгае җыерчыкланып чыкты.* М.Маликова

**ҖЫЕРЧЫКЛЫ** *с.* 1) Җыерчыклары булган, җыерчыклар белән капланган. *Бераздан син түшәккә дә егылдың; Җыерчыклы йөзенә карчыгыңның Карарсың тилмереп, мәэюс булып син; Еларсың мөлдерәп, мәхзүп булып син.* Г.Тукай. *Әбинең җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде.* Ә.Еники

2) Сырлы, җыерылып-җыерылып торган. *Юан эчәкнең стенасы җыерчыклы, шуңа күрә аның сыйдырышы берничә мәртәбә зурая ала.* Урман аптекасы

**ҖЫЕРЧЫКЛЫЛЫК** *и.* 1) Җыерчыклар белән капланган булу, җыерчыклары күп булу

2) Җыерчыклардан тору. *Тауларның җыерчыклары*

**ҖЫЕРЫК** *и. диал. к.* **җыерчык**. *Тордык. Гимнастёрка җыерыкларын төзәттек.* А.Таһиров

**ҖЫЕРЫЛМАЛЫ** *с.* Җыерып, вак-вак сырлар ясалган. *Карточка шунда гына – җыерылмалы кызыл кәгазь белән уралган гөл чүлмәгенә сөяп бастырган килеш, өстәлдә тора икән.* М.Галәү

**ҖЫЕРЫЛУ** *ф.* 1) Җыерчыклар хасил булу, җыерчыклану, сырлар ясалу. *Чәчәкләрне күрмәгән әтинең кашлары җыерылды.* Г.Бәширов. *Үзсүзле Алсуның кашлары җыерылган, саргылт чәчләре маңгаена төшкән, почык борыны түшәмгә караган.* Т.Әйди. --- *бо такта килеш көзге кырауларга калган алма төсле җыерылган бите язылып, күз төпләренә кадәр сүрән кызыллык йөгерде.* М.Әхмәтҗанов

2) Гәүдәне җыю; җыеру, йомарланып килү. *Оятыннан кая керер урын тапмый җыерылу*

3) Куырылу, кечерәеп бөрешү (картлыктан, ябыгудан)

4) Бөгәрләнү, бер якка җыелу. *Хатынның ачык таза беләкләре, җыерылган итәге астыннан ялтырап күренгән шома ботлары күз карашын өстери дә китерә, өстери дә китерә.* Р.Зәйдулла

**Җыерыла бару** Тагы да ныграк җыерылу

**Җыерыла төшү** Бераз җыерылу

**Җыерылып бетү** Тәмам, бик нык җыерылу

**Җыерылып килү** Кинәт җыерылган торыш алу. *Ул, үзенең шаяртуыннан куенсынып, кинәт тынып калды, иңбашлары җыерылып килде...* Р.Зәйдулла

**Җыерылып тору** Җыерылган хәлдә булу

**ҖЫЕРЫНКЫ** *с.* Җыерылып, бөрешеп, куырылып торган

**ҖЫЕШТЫРУ** *ф.* 1) Таралып, чәчелеп яткан әйберләрне, җыеп, үз урынына кую, җыю. *Ахырда, әнием, торып, миңа акрын гына: «Бар, ят инде булмаса», – диде дә үзе өстәл өстен җыештырырга кереште.* Ә.Еники

2) Тәртипкә китерү, юып, чистартып чыгару, матурлау. *Эшендә ару гына хезмәт хакы алган кеше, әлбәттә, ярты көн эшләп, калган ярты көнен өй җыештырып, ашарга әзерләп, бала карап үткәрергә теләми...* Н.Измайлова. *Өй бик матур итеп җыештырылган. Бөтен нәрсә өр-яңа, ялт итеп тора.* Ф.Яруллин. *Ләкин иң гаҗәбе шунда: бу йортларның күпчелегендә балалар өчен махсус бүлмә күрмәссең, ә менә пөхтә, матур итеп җыештырылган кунак бүлмәсе була.* Өегез ямьле булсын

3) Мәетне күмәргә әзерләү (юу, киендерү, кәфенләү). *Аннары мәетне юу бар, җыештыру бар, озату бар, ә алар үзләре бу эшләрнең тәртипләрен һич тә белмиләр.* Ә.Еники. *Рәүфәнең гәүдәсен авыл хатыннары күз яшьләре белән югандай итеп җыештырдылар, яңа күлмәк кидерделәр, табутын мәктәпкә куйдылар.* Г.Минский

4) Бер урынга җыйнау, бөрештереп яки бөкләп җыю. *Менә арбага, кара җиләненең чабуларын җыештырып, күкрәгенә көмеш тәре аскан зур сакаллы поп менеп утырды.* Г.Бәширов

5) Төрле урыннан аз-азлап җыеп, үзеңдә булдыру, туплау. *Өй салырга дип, акча җыештыру*

6) *күч. сөйл.* Урлау, үзләштерү. *Ахрысы, тегендә, чынлап та, уңга-сулга карамыйча, «койрыклар»ны җыештыралар иде булса кирәк.* Ф.Хөсни

7) *күч.* Үтерү, юк итү, һәлак итү. *[Кулакларның] Арслановка бик ачулары килә. Аны җыештырмасыннар, карагыз.* Г.Толымбай

**Җыештыра бару** Әзлекле рәвештә, һәрберсен, булган берсен, бер-бер артлы җыештыру

**Җыештыра башлау** Җыештырырга тотыну

**Җыештыра төшү** Бераз җыештыру

**Җыештырып алу** Тиз арада җыештыру, җыештырылган хәлгә китерү. *Нагиев, олы кунакларны озата чыгышлый, --- этажга хезмәт күрсәтүче хадимә ханымга җыештырып алырга боерык бирә киткән иде.* Ф.Хөсни. *Кызлар ни арададыр табынны җыештырып алганнар да хәзер әнә кич утырырга әзерләнәләр.* Г.Бәширов

**Җыештырып ату** Тиз-тиз, аннан-моннан җыештыру

**Җыештырып бетерү** Бөтенләй, тулысынча җыештыру; барысын да җыештыру. *Җыештырып бетергәч, бары унитаз белән туалетны чистарту өчен генә кулланыла торган щётка һәм*

*чүпрәкне, сабынлап юып, кадакка элеп куярга кирәк.* Өегез ямьле булсын

**Жыештырып калу** Нинди дә булса бер вакыйгага кадәр жыештыру эшен тәмамлау, жыештырырга өлгерү

**Жыештырып кую** Жыештырылган хәлгә китерү, алдан жыеп алып, тәртипкә салу. *Әти эш коралларын кайраганда, кайрак әйләндереп торам, йә, ул туктаган арада, верстагын жыештырып куям.* Г.Бәширов

**Жыештырып тору** 1) Һәрвакыт, даими рәвештә жыештыру

2) Әле, хәзер жыештыру белән шөгыльләнү

**Жыештырып йөрү** Әле, хәзерге вакытта жыештыру эше белән шөгыльләнү; жыештыру эшендә булу. *Клубта бер кеше калмады, официантлар гына өстәлләрне жыештырып йөри...* Р.Зәйдулла

**Жыештырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр жыештыру; барысын да берәм-берәм жыештыру. *Бөтен өйне ялт итеп жыештырып чыкты, кара көз булса да, әллә кайдан бер кочак чәчәген күтәреп алып кайтты.* Ф.Бәйрәмова. *Башта бу якны жыештырып чыгарды, аннан балалар йоклаган бүлмәгә керде.* И.Низамов

**ЖЫЕШТЫРУЧЫ** *и.* Жыештыру эшен башкаручы; идән юучы. *Әтисе үлгәч, ул бер мәктәпкә жыештыручы булып эшкә кергән.* Х.Сарьян. *Ишектән, озынча ак шәүлә булып, жыештыручы килеп керде дә, таяк башына уралган чүпрәк белән идәнне сөртә башлады.* М.Маликова

**ЖЫЕШТЫРЫНУ** *ф.* 1) Өйне, бүлмәне жыештыру; тәртипкә китерү. *Чисталыкка, пөхтәлеккә исем китте. Әллә, кайткач, Надя шулай жыештырынды микән?* Р.Төхфәтуллин

2) Аз-маз жыештыру, анысын-монысын алгалап кую

**Жыештырына башлау** Жыештырынырга тотыну

**Жыештырына төшү** Беркадәр, бераз жыештырыну

**Жыештырынып алу** Кыска бер вакыт арасында жыештырыну

**Жыештырынып йөрү** Жыештыру эше белән мәшгуль булу

**Жыештырынып кую** Алдан ук жыештырыну

**Жыештырынып тору** Әле, хәзерге вакытта жыештырыну

**ЖЫЙГЫЧ** *и. тех.* 1) Үзеннән алда килгән сүз белдерә торган нәрсәне жыю өчен тәгаенләнгән, гадәттә, трактор яки комбайнга беркетелә яисә тагыла торган техник жайланманы, механизмны аңлата; кушма сүзләрдә икенче компонент булып килергә мөмкин (мәс., *бәрәңге жыйгыч, мамык жыйгыч, печән жыйгыч, су жыйгыч*). *Зур болыннардагы печәнне атлы жыйгыч белән жыялар.* Ф.Төхфәтуллин. *Узган елда рулоннарга печән жыйгыч, быел МТЗ-82 тракторы һәм югары житештерүчәнле тагылмалы чапкыч сатып алганнар.* Кызыл таң

2) Нәрсәне дә булса жыеп туплау, саклау өчен билгеләнгән жайланма; *русчасы:* **накопитель**. *Кыш көне кырда кар тотарга, ә язда басу тирәләренә күп итеп су жыйгыч буалар эшләп куярга кирәк.* Татарстан яшьләре. *Энергия жыйгыч*

3) *полигр.* Текст юлларын кулдан жыю өчен, өч яны калкулы металл пластинадан гыйбарәт жайланма; *русчасы:* **верстатка**

**ЖЫЙДЫРМАС** *и. бот. диал.* Кыначалар семьялыгыннан, сусыл сабаклы, гадәттә үтә күренмәле, тоташ эллипссыман яфраклы, тартмачыкны хәтерләткән жимешле бер яки күпьеллык үлән үсемлек; өлгергән жимеше, аңа кагылу белән, капкачлары спираль формасында ачылып, орлыкларын чәчеп жибәрү үзлегенә ия; бохар кынасы, кына гөле; *русчасы:* **недотрога обыкновенная**. *Жыйдырмас, гадәттә, күләгәле урыннарда үсә*

**ЖЫЙМА** *с. лингв.* Бер төрдән булган предметларның, затларның жыелмасын, гомумилеген белдерә торган. --- *өченче төрле исемнәр предметларның жыелмасын бербөтен итеп белдерәләр. Ләкин жыйма исемнәрнең семантик төркемчәсе бик тар: агачлык, сазлык, ташлык һ.б.ш.* Д.Тумашева

**ЖЫЙНАК** *с.* 1) Зур булмаган, уртача зурлыктагы, пропорциональ үлчәмле. *Юл бирдем, янымнан гына жыйнак, сылу гәүдәле ханым үтте, нәфис бер хуш ис сизелер-сизелмәс кенә борыныма бәрелеп үткәндәй булды...* Ә.Еники. *Ул урта буйлы, киң генә жилкәле, сыны нәкъ хәрбиләрнекечә төз, жыйнак, йөзе шома, кара тутлы, башкортныкына тартым киңчәтүгәрәк, ләкин борыны бик туры...* Ә.Еники. *Алар арасында юка гына булып кара мыек чыгып килә торган, жыйнак кына гәүдәле безнең абый да бар.* Г.Бәширов

2) Һәрнәрсәсе урынында, пөхтә, матур һәм зәвыклы булган. *Минә, ичмасам, гомергә үзгәрмәс өй, гел шулай жыйнак, жанга рәхәт монда.* И.Низамов. *Берәү жыйнак, матур итеп салынган йорты каршына, искиткеч шөкәтсез итеп, гараж салып куйган.* М.Юныс. *Әнвәр күзен ачканда, өстәлдән кәгазь алынган, жыйнак кына табынның өсте ачылган иде.* М.Маликова

3) Пөхтә, төгәл, таман. *Жыйнак костюм-чалбарлы, галстук таккан «милый» малайлар шактый күренә.* Р.Зәйдулла. *Ул өстенә жыйнак пальто кигән*

4) Күләме, саны ягыннан зур булмаган; уртача күләмле. *Арада авыл йортларын хәтерләткән бәләкәй, жыйнак өйләр бар.* М.Юныс. *Бүлмә кечкенә, жыйнак: икенче катка менә торган баскыч астына урнашкан, мондагы барлык жиһаз – карават та өстәл, бер урындык.* Р.Зәйдулла

5) Эшне төгәл, пөхтә башкара торган, жиренә житкереп эшләүчән. *Ул бик эшчән, бик жыйнак, мине бик ярата.* Г.Ибраһимов

6) Эчтәлеге, сюжеты катлаулы булмаган, уртача күләмле. *Ул сюжет-композицияне жыйнаграк һәм эзлеклерәк төзи...* З.Рәмиев

**ЖЫЙНА́К ЖӨМЛӘ** *и. лингв.* Баш кисәкләрдән (ия белән хәбәрдән) генә торган жөмлә. *Жыйнак жөмлә модельләрен билгеләгәндә, үзеннән-үзе аңлашыла: бары ия һәм хәбәр белән генә эш итәргә туры килә.* М.Зәкиев

**ЖЫЙНАКЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Жыйнак хәлгә китерү, кыскарту. *Дәреслекне бераз үзгәртеп, жыйнакландырып нәшер итү*

2) Җыйнак, төз күрсәтү. *Яңа кием егетнең гәүдәсен берникадәр җыйнакландырды*

3) Оешканрак, игътибарлырак итү. *Шулай план төзү үзеңне җыйнакландыра, ялкауланырга ирек бирми, максатка ирешергә булыша.* Сәхнә

4) Чистарту, пөхтә итү; төзекләндерү, уңайлыклар булдыру. *Язын шәһәрне җыйнакландыру*

**Җыйнакландыра бару** Бер-бер артлы, торган саен күбрәк җыйнакландыру

**Җыйнакландыра төшү** Беркадәр җыйнак хәлгә китерү

**Җыйнакландырып бетерү** Тәмам, тулысынча җыйнакландыру. *Паркны җыйнакландырып бетердек, ниһаять*

**Җыйнакландырып җибәрү** 1) Җыйнак итеп күрсәтү. *Яңа костюм егетнең гәүдәсен җыйнакландырып җибәрде*

2) Бераз җыйнакландыру

**Җыйнакландырып йөрү** Хәзерге вакытта җыйнакландыру эше белән мәшгуль булу; җыйнакландыру эшен башкару. *Йорт тирәсен җыйнакландырып йөрү*

**Җыйнакландырып кую** Җыйнак хәлгә китерү

**Җыйнакландырып тору** Әледән-әле, еш җыйнакландыру. *Мәктәп ишегалдын җыйнакландырып тору*

**ҖЫЙНАКЛАНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **җыйнаклау**

2) Пөхтәләнү, тәртипләнү, һәрнәрсә үз урынында булу

3) Җыйнак хәлгә килү, бераз кечерәеп, ябыгып китү

**Җыйнаклана бару** Торган саен ныграк җыйнаклану

**Җыйнаклана төшү** Бераз, беркадәр җыйнаклану, җыйнак хәлгә килү. *Егетнең килеш-килбәте дә бераз җыйнаклана төшкән.* Г.Бәширов

**Җыйнакланып калу** Берәр вакыйгадан соң җыйнакланган хәлгә килү

**Җыйнакланып китү** Беркадәр, бераз җыйнакланып күренү. *Җыештыргач, өй җыйнакланып китте*

**ҖЫЙНАКЛА́У** *ф.* Җыйнак, пөхтә хәлгә китерү. *Сестра утырган урынында калган чәчәкләрне барып алды һәм, тигезләп, җыйнаклап, күкрәгенә кысып тотты.* А.Шамов

**Җыйнаклап бетерү** Ахыргача, тулысынча җыйнаклау

**Җыйнаклап кую** Җыйнак хәлгә китереп калдыру

**Җыйнаклап тору** Һәрвакыт, гел җыйнаклау

**Җыйнаклап чыгу** Барысын да, бөтенесен дә җыйнакланган хәлгә китерү; башыннан ахырына кадәр җыйнаклау

**Җыйнаклый башлау** Җыйнакларга тотыну

**Җыйнаклый төшү** Беркадәр, бераз җыйнаграк итү. *Ул өс-башын җыйнаклый төшкән*

**ҖЫЙНАКЛЫ** *с. сир. к.* **җыйнак** (*1 мәгъ.*)

**ҖЫЙНАКЛЫК** *и.* 1) Җыйнак, пөхтә булу

2) Уртача күләмдә булу, зур булмау. *«Әхмәт бабай» хикәясе исә әдәби тәнкыйть тарафыннан сүз кадерен белүнең, җыйнаклыкның матур үрнәге дип бәяләнде.* Ф.Хөсни

**ҖЫЙНАКСЫЗ** *с.* 1) Таркау, булдыксыз, оешмаган. *[Сара] Бик җыйнаксыз булган, ди. Бер минутта бер нәрсә эшләсә, икенче минутта аны оныта икән.* Д.Аппакова

2) Шапшак, пөхтәлекне сакламаучан. *Җыйнаксыз киленнең себеркесе чүп астында булыр.* Мәкаль

3) Шөкәтсез, килбәтсез, ямьсез. *Җыйнаксыз зур гәүдә*

**ҖЫЙНАКСЫЗЛЫК** *и.* 1) Җыйнак (*2 мәгъ.*) булмау, таркаулык; тәртипсезлек. *[Рокыяның] Хәтта кимчелекләре – чытлыкылана белүе, иренчәклеге һәм җыйнаксызлыгы да – ничектер килешеп тора.* И.Нуруллин. *Мөлкәт хуҗаларының үз байлыкларына карата ваемсызлыгы, җыйнаксызлыгы*

2) Чисталык, пөхтәлек булмау, шапшаклык (эшләү, киенү һ.б.ш. турында). *Чоланда без кеше кулы тимәгәндәй тәртипсезлек һәм җыйнаксызлык күрдек.* Л-Х.Таналин. *Ашларының тәмсезлегенә, салатларының искелегенә, эчке якта буталып йөрүче пешерүчеләренең дә, аш бүлүчеләрнең дә, кассирның да яланбашлыгы, җыйнаксызлыгы өстәлгәч, тәмам күңел болгаткыч, укшытырлык күренешне күзаллыйсыздыр*. Татарстан яшьләре

**ҖЫЙНАЛУ** *ф.* 1) Бер урынга җыелу, җыелышу. *Җыйналып, мәҗлес ясыйк, Бер-беремездән качмыйк; Наданлыкка юл ачмыйк, – Бик күп изде, бәдәвам.* Г.Тукай. *– Бүген кичкә җыйналыгыз да килегез әле, кунып, әзрәк сый-хөрмәт күреп китәрсез, – диде.* Ф.Яруллин

2) Туплану. *Сакалың үскән, дип, яңагыннан сөйсә, ханымның өч көн буена җыйналган энергиясе аңа күчә.* К.Кәримов. *Шулай ук аерым архивлардан фото-күчермә рәвешендә җыйналган материаллар да аз түгел.* М.Әхмәтҗанов

3) *диал.* Нәрсәдер эшләргә җыену. *Чөнки, чыкса-чыкмаса, мин Ык буенда яшәүче кешеләр турында сөйләргә җыйналдым.* Ф.Хөсни. *Нәкъ менә кызу мичкә илтеп тыгарга җыйналабыз да без сезне, иптәш Ахунҗанов.* Ф.Хөсни

4) *диал.* Җыештырылу, җиһазлану. *Шәһәрчә җыйналган бүлмә.* Т.Гыйззәт

**ҖЫЙНАЛЫШУ** *ф. диал. к.* **җыелышу**. *Шушылай бергә-бергә җыйналышмасак, мин әле синең җырлаганыңны да белми яшәр идем.* Ф.Яруллин

**ҖЫЙНА́У** I *ф.* **1.** *к.* **җыю**. *Чәчү җиңел, җыйнау кыен.* Мәкаль. *Бәләкәй чакта чәчәкле пыяла ватыклары җыйнап, өй бизәшле уйный идек без.* К.Кәримов. *Ул берничә гасыр дәвамында шарсыман яшенне күргән кешеләр сөйләгән сүзләрне бергә җыйнаган һәм тикшергән.* Могҗизалар энциклопедиясе

**2. җыйнап** *рәв. мәгъ.* Берләштереп, җыеп. *Карт, бар көчен җыйнап, аягына басты*

**3. җыйнап әйткәндә** *кер. сүз функ.* Гомумән алганда, тулаем әйткәндә. *Алай гына да түгел, тургай канаты астында калган болыннарга, утлы чишмәләрдән бәреп чыккан су ташкынына сөенеп каңгылдашкан казлар авазына, Әлфинәле кичләргә, җыйнап кына әйткәндә, яшьлекнең үзенә сәяхәткә чыгарга өнди, алгысыта һәм ашыктыра иде.* К.Кәримов

**ҖЫЙНА́У** II *рәв. сөйл.* **1.** *к.* **җыйнаулашып.** *Җыйнау кайтып кердeләр*

**2.** *а. мәгъ.* Барлык, һәммә, бөтен. *Җыйнавыгыз да мондамы?*

**ҖЫЙНАУЛАП** *рәв. к.* **җыйнаулашып**. *Әпрәй: Беләм инде, җыйнаулап, бер сүзле булдыгыз да каныктыгыз инде миңа.* А.Алиш. *Җыйнаулап көлешеп алдылар шунда.* Р.Мөхәммәдиев

**ҖЫЙНАУЛАШЫП** *рәв.* Барысы бергә җыелып, бергәләп, дәррәү. *Шәледә укыганда, эче яна торган двигательләрне өйрәнеп, кулга «авыл механизаторы» дигән катыргы биреп чыгаргач, әй көлгән иде малайлар, җыйнаулашып.* К.Кәримов. *Җыйнаулашып җыештырабыз, Бер Диләк туздырганны, Әйткәнне дә һич тыңламый – Көтә ул «кыздырганны».* Ф.Тарханова. *Ә беркөнне, җыйнаулашып, бакчаны кат-кат урадылар да каядыр очып киттеләр.* Ф.Яруллин

**ҖЫЙНАШТЫРУ** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **җыйнау** I. *Август аена акча алсам, бөтенесен җыйнаштырып салырмын.* Ватаным Татарстан

2) Тиз-тиз генә җыеп алу; аннан-моннан гына җыйнау. *Хатын, Мирвәлинең саубуллашуын да көтмичә, малаеның газонда таралып яткан әйберләрен җыйнаштырды да, вак-вак атлап, машинасы янына китеп барды.* Г.Гыйльманов

3) Ашыкмыйча, ипләп әзерләү; төрле урыннан алып туплау, хәстәрләү (акча, җылы кием, ашамлык һ.б. турында). *Ризван абыйсы акрын гына сүзләрне җыйнаштырып сөйли бирде.* Ф.Яхин. *Фатир алу өчен, акча җыйнаштыру*

**Җыйнаштырып бару** Даими, гел җыйнаштыру. *Бакчачылыкка кагылышлы мәкаләләрне җыйнаштырып бару*

**Җыйнаштырып йөрү** Хәзер җыйнаштыру, шуның белән мәшгуль булу. *Өй буйлап таралган уенчыкларны җыйнаштырып йөрү*

**Җыйнаштырып кую** Алдан җыйналган, әзерләнгән хәлгә китерү. *Кышкы киемнәрне җыйнаштырып кую*

**Җыйнаштырып чыгу** Бер-бер артлы, барысын да җыйнаштыру

**ҖЫК** *и.* Атларда була торган авыру

2) *күч.* Авырлык, газап, иза

◊ **Җык кергере! (булгыры, тигере, суккыры!)** Тиргәү, каргау сүзе; көйсез, иркә, баш бирмәс, телчән кешегә яки хайванга карата әйтелә. *Нә-ә сәнә, үләт тигере, кара, кара, гел йоклады бит баскан җирендә, җык суккыры нәмәстәкәй!* Ш.Маннур. *Әле үзе һаман да трантастан төшми бит менә, җык тигере.* Г.Газиз. **Җык булу** Тәмам туеп бетү, гарык булу; йөдәүгә төшү, гаҗиз булу. *Синең укытучыларыңны әйтәм, җык булганчы эшләгәннәре дә билгеле, ә менә нәрсә ашадылар икән?* Г.Гобәй. *Тагын шул бандалар, --- тагын кан, туйдырды, тәмам җык булдым.* Казан утлары. **Җыкка сабышу** Йөдәүгә төшү, тәмам азап чигү, гаҗиз булу. *Уф, тәмам җыкка сабыштым мин синең бу үзсүзлелегең белән, туктыйсыңмы-юкмы син?* Ш.Камал. *Без инде монда ике елдан бирле аның белән җыкка сабышкан.* Н.Исәнбәт. **Җык кебек** Әзмәвердәй, зур гәүдәле, таза. *Счетовод урындыгында чалбар туздырып утыручы җык кебек өч егетне күрергә туры килде безгә.* Совет әдәбияты. **Җык күрү** *к.* **җык булу.** *Соңрак ул сеңел белән җык күргәннәре Фәниянең... Еладылар кызганып.* Р.Зәйдулла. **Җык чыгу** Хәлдән таю, тәмам йөдәп бетү. *Майланмаган арбага төялгән чи көлтәләрне пычрак басуда сөйри-сөйри, атларның җыгы чыкты.* А.Гыйләҗев

**ҖЫКЛАНУ** *ф.* Җык булу; интегү, җәфалану. *[Зарифлар] Сугыш башлангач, әүвәлгедән дә яхшырак тора башладылар, шулай ук ат белән дә җыкланмыйлар.* Г.Гобәй

**ҖЫЛБЫР** *с.* Шома, ялтырап торган. *[Гөлшәһидә] Караса, җылбыр әнчек, ыргылып-ыргылып, Гөлчәчәк өстенә ташланмакчы була.* Г.Әпсәләмов

**ҖЫЛБЫР-ҖЫЛБЫР** *иярт.* Ялтырау, җемелдәү рәвешен белдерә

**ҖЫЛБЫ́Р-ҖЫЛБЫР ИТҮ** *ф.* Ялт-йолт килү; яктылык нурларын кайтарып, ялтырап, җемелдәп тору. *Иртәнге якта күл өсте җылбыр-җылбыр итеп тора*

**ҖЫЛБЫ́Р-ҖЫЛБЫР КИЛҮ** *ф. к.* **җылбыр-җылбыр итү**. *Чәчүлек җирләренең шактый өлеше җылбыр-җылбыр килеп торган яңгыр сулары астында ята.* Г.Әпсәләмов

**ҖЫЛДЫРЫМ** *и. диал.* 1) *к.* **елдырым**. *Җылдырым яшьнәде*

2) Аҗаган, арыш камчылау; *русчасы:* **зарница**

**ҖЫЛУ** I *и.* 1) Елга яки күлнең кышын туңмый калган ачык өлеше. *Җылуга, су эчәргә дип, кошлар төшкәли*

2) *диал.* Су ашаганлыктан, ярның чокырланып кергән урыны; култык. *Җылуда балык шәп чиртә*

**ҖЫЛУ** II *ф. диал.* 1) Агып төшү (су турында). *Улаклар шактый киң, су җылып төшәрлек итеп эшләнгән*

2) Таудан шуу

**ҖЫЛЫ** I *с.* 1) Кояшта торып яки ут ягып җылытылган, температурасы югары булган. *Башка вакытларда Мәрьямбикә, аркам туңа дип, көне буе өйдә утыра, безгә кергәндә дә тизрәк җылы мичкә барып сөяләлә.* Г.Бәширов. *Кичләрен су май кебек җылы, йомшак.* Ф.Яруллин. *Тазга җылы су агызды, чалбарны батырды.* И.Низамов

2) Җылылык энергиясе бирә торган. *Дюк Ришелье һәйкәле янындагы эскәмиядә аркасын җылы кояш нурларына тәрәбрәк утырган җиреннән, ул сәяхәткә китүче корабларны төтеннәре офык эченә кереп эрегәнче карап, озатып кала.* М.Юныс

3) Һава торышы нульдән (С°) югары булган. *Җәйге төн өй эченә караганда җылырак булса да, Мәрхәбә әби ачык тәрәзә белән йокларга рөхсәт итмәде.* К.Кәримов. *Иртән торып чыксаң, ялт итеп торган кояш, дымсу җылы, йомшак һава, зәп-зәңгәр күк --- һәм... тирән тынлык.* Н.Измайлова. *Көзге җылы көннәрдә саклана торган продуктлар өчен салкынча, кояшта җылынмаган һава кирәк.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

4) Салкыннан, җил-яңгырдан саклый торган, салкынны үткәрми торган. *Хайванына җылы такта абзар салды, Хайваннары таза торды – Бик көр булды.* М.Җәлил. *Ишек ачылганы ишетелде, җылы курткасының изүен ачып җибәргән Әнвәр килеп керде.* М.Маликова. ...*Әни кешегә, җылы урыннан кузгалып, балаларга әледән-әле күз салырга, өсләренә ябарга туры килә.* Ф.Хөсни

5) Ягып җылытылган, салкын көннәрдә дә суынмый торган. – *Кем сиңа анда җылы урын әзерләп куйган да,*

*кем ертык-тишегеңне ямар! – дип, үзенчә өзгәләнде Асылбикәсе. – Жылы өеңдә, кадер-хөрмәттә генә ятасы, – дип карады килен дә.* Ф.Хөсни. *Югыйсә аларның барысының да төп эш урыннары бар бит: кем табиб, кем журналист, кем инженер, кем студент, ә «милләт» дигәндә, жылы өйләрен дә, гаиләләрен дә калдырып торып, ял көннәрендә булса да ерак юлга чыгып китәләр.* Ф.Бәйрәмова. *Аның яралы күңеле үзенең жылы куышында, тыныч, тәрбияле тормышта гына савыгыр кебек иде.* Г.Бәширов

6) Үзеннән жылылык бәреп торган, кайнар. --- *янымда жылы беләге белән минем беләгемә терәлеп утырган Зөһрә ханым бу минутта миңа аеруча кадерле, аеруча якын булып тоелды.* Ә.Еники. *Нәфисә жылы учын рәссамның беләгенә куйды.* Р.Зәйдулла

7) Кайнар, әле яңа пешеп чыккан яки кайнатылган. – *Тукта, чү, – дип, кунакның чабуына ябышты карт, – әле нинди дә булса жылы ризык бирелергә тиеш... Кунак тагын аякка басты, «жылы ризык»ны көтә алмаганлыгын әйтте...* Ф.Хөсни

8) *күч.* Якын итү, үз итү, ярату, дуслык хисе сизелеп торган. *Иптәшләрнең шундый жылы карашы һәм чын күңелдән әйтелгән теләкләре мине бик дулкынландырды.* М.Жәлил. *Гаиләдә ничек итеп яхшы, жылы атмосфера тудырырга?* Тигез гомер итегез!

**2.** *рәв. мәгъ.* Үз итеп, чын күңелдән; якын итеп. *Әгәр мин аның салкынтәкәббер булуы, чамасыз мин-минлеге, шуның аркасында мине кешечә жылы, матур итеп ярата белмәве дип әйтсәм, бу гына аз, бу гына жавап була алмый.* Ә.Еники. *Аны әйтмичә калдырырга ярамый, чөнки бик тә жылы булып хәтергә сеңеп калган.* Ф.Хөсни

◊ **Жылы авызыңнан чыгып, жылы куеныңа керсен** Каргыш сүзләре әйткән кешегә жавап буларак, «миңа әйткән сүзләрең үзеңә әйләнеп кайтсын» дигән мәгънәдә әйтелә. **Жылы йөз (чырай) күрсәтү** Дусларча якын итү; йомшак, яхшы мөгамәләдә булу; үз итеп карау, читкә какмау. **Жылы канат астында** Ата-анасы яки кемнең дә булса яклавында булу. *Машина аларга берникадәр дәрәжәдә Алланы алыштыра бугай, машина ишеген шартлатып ябып кую Ходай Тәгаләнең жылы канаты астына кереп утыру белән бердер боларга...* Н.Измайлова. **Жылы канлы** Ихлас күңелле, кешелекле, аралашучан, илтифатлы. *Үсәр яхшылыгың, син яхшы булсаң; Жылы канлы итәр ул, вәхши булсаң.* Г.Тукай. **Жылы кочак** 1) Жылылык бөркелеп торган, кайнар, дәртле. *Ул тылсымлы, жылы кочагында Кемне телгән, кемне назлаган... Сихри көчен татып мәхәббәтнең, Кемнәр генә һуштан язмаган?!* М.Хөсәен; 2) Йөрәккә, күңелгә тынычлык, рәхәтлек хисләре бирә торган. *Зөһрә ханым исә, галәмне, иркәләп, жылы кочагына алган шушы юаш, хәвефсез тынлык аша, гүя узып киткән сугышның еракагы дәһшәтле гөрелтесен тыңлый иде.* Ә.Еники. **Жылы кулдан** Бер уңайдан, бер эш артыннан ук икенчесенә күчеп. **Жылы сүз** Кешегә йомшак, илтифат күрсәтеп эндәшеп әйтелгән ягымлы сүз. *Салкын йөзледән жылы сүз көтмә.* Мәкаль. *Тиз, сиздерми гомер үтә, Бер жылы сүз көтә-көтә.* Ф.Кадыйрова. *Сез гаеп итмәгез, мин Зәйтүнә Мәжитовна хөрмәтенә тост күтәрәм! Анда дәваланган, аның жылы сүзеннән үк шифа алган йөзләгән хатын-кызлар исеменнән рәхмәт әйтәм мин аңа!* М.Маликова. **Жылы тәнеңдә тузсын** Яңа киемне котлап, «үзең киеп туздырырга язсын» дигән мәгънәне белдереп әйтелә торган теләк сүзе. **Жылы тәнкыйть** Үз итеп, кимчелекләрне кабартмыйча, дусларча ясалган тәнкыйть. **Жылы урын (жир)** Артык көч куймыйча хезмәт итә торган, табышлы һәм уңайлы эш урыны. *Жылы жиргә урнаштым, диген, ә, --- матур гына итеп.* Р.Зәйдулла. *Ләкин андый жылы, хәвеф-хәтәрсез урынга эләгү өчен, күпмедер сарык кирәк, тана кирәк була.* Г.Бәширов. *Анасы шундагы колхозга завхоз булып урнашкан. Жылы урынны ярата торган адәм иде ул.* В.Нуруллин. **Жылы хәбәр** Шатлыклы хәбәр; яхшы, күңелне тынычландыра торган хәбәр

**ЖЫЛЫ** II *и.* 1) Кояш нурларыннан, ягулык янганда аерылып чыга торган энергия, жылылык. *Жир жылысын тоеп юандың, Ил сулышын тоеп куандың.* М.Хөсәен. – *Пешә-пешә эчәргә кирәк, жылысы бөтен тамырларга китсен, – дип кыстый торды.* Ә.Еники. *Саман йортның үз уңайлыгы бар: ул жәй көне салкынча була, кыш көне жылы тота икән.* Ф.Бәйрәмова

2) Һава торышы жылы булган вакыт; жәй айлары; кояш туры карый торган көннәр. *Жылылар житте*

3) Тере организмнарда матдәләр алмашу процессында барлыкка килгән энергия; тәннең уртача температурасы. *Бераздан аякларым жылы тойды, чәнчеп авырту бетте.* Ә.Еники. *Төньяк боланының йон бөртекләре һава белән тулган, ә һава тән жылысын яхшы саклый.* Хайваннар дөньясы

4) Жылы урын, жылытыла торган өй, бүлмә һ.б.ш.ны белдерә. *Хәзер үк жылыга керергә кирәк.* Ә.Еники

5) *күч.* Башкаларга карата булган наз; ярату, якын итү, үз итү хисе; яхшы мөнәсәбәт. *Кеше дөрес тәрбия алмаган, дибез, моны ничек аңларга соң? Иң беренче шул: балага ана жылысы, мөлаем карашы, сөюләре-үбүләре житмәгән.* М.Әхмәтжанов. *Кил, ишектән күз алмыйча Көтәрмен мин. Күңел жылым белән кунак Итәрмен мин.* М.Хөсәен

6) *күч.* Дәрт, рух бирә торган күңел көче. *Нәжип килсә дә, мине юатса да, минем белән бик жылы, якын булса да, ихтимал, барыбер коткарып кала алмаган булыр иде.* Ә.Еники

◊ **Жылы алмау** Жылынмау. **Жылы башлау** Ягылган мунчага, башлап, беренче булып бару; иң эссе, парлы вакытында керү. *Әнкәсе күршедәге Сәрби карчыкларга мунча яккан икән, Жиһангәрәйне жылы башларга жибәрдек.* Г.Толымбай. **Жылы бирү** 1) Мунчаның кызган ташына су сибеп, пар чыгару; 2) Көч, дәрт бирү; рухландыру. **Жылы керү (йөгерү)** *Йөрәккә, күңелгә, эчкә* сүзләре янында килеп, «өмет кабыну, тынычлану, ышаныч уяну» кебек мәгънәләрне белдерә. – *Хәзер кайда эшлисең соң? – дип сорыйм, эчемә жылы керә башлаганын сизеп.* М.Юныс. **Жылы тотмау** Эчтәге жылылыкны саклый алмый торган, жылы-

ны тышка тиз чыгара, тиз суына торган итеп эшләнгән булу

**ҖЫЛЫ́ КАНЛЫЛАР** *и. күпл.* Кан җылылыгы чагыштырмача югары булган һәм бер дәрәҗәдә торган, җылы тәнле тереклек ияләре. *[Озынборыннарның] Аналары җылы канлы хайваннар канын суыра.* И.Рәхимов. *Имезүчеләр – гәүдәләре йон белән капланган җылы канлы хайваннар.* Хайваннар дөньясы. *Имезүчеләр – умырткалыларның иң югары төзелешле классы. Бу – югары нерв системасының көчле үсеш алуында, тереләй бала тудыруда һәм балаларын сөт белән туендыруда, җылы канлы булуларында чагыла.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ҖЫЛЫЛЫК** *и.* 1) Җисемдә атом, молекулаларның тәртипсез кызу хәрәкәтеннән барлыкка килгән энергия төре. *Көндез кояш кыздырган җир, хәзер, ягылган мич кебек, рәхәт җылылык бөрки.* Г.Әпсәләмов. *Физика профессоры Ганс Эрстед Копенгаген университеты студентларына электр тогының җылылык тәэсире турында лекция укый.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Саклагычлар төзү өчен, җылылыкны начар үткәрә торган материаллардан файдаланырга киңәш ителә.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

2) Температура 0ºС градустан югары булган халәт. *Ык суы үзенең йомшаклыгы, җылылыгы белән тәнеңдәге арыганлыкны юа.* Ф.Яруллин. *Диңгез суының җылылыгы 20 градус*

3) *күч.* Ягымлы, кайгыртучан мөнәсәбәт, җылы хис, якын итү, үз итү. *Әмма шулай да аның якты соры күзләрендә нинди дер бер җылылык барлыгын сизми калмадым.* Ә.Еники. *Нәҗип, елап җибәрүдән чак-чак тыелып, ниндидер җылылык, наз көтеп, әнисенә карый.* Ф.Яруллин. *Барысы да тәртиптә кебек, тик бу тәртипнең җаны юк, җылылык юк. Җылылык, җан Сабира җырлый башласа гына керә бу өйгә.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Җылылык белән** Яратып, үз итеп; якын итеп. *Аеруча бер җылылык белән алар миңа: «Киленебез түгел, кызыбыз булырсың», – дип кенә торалар иде.* Ә.Еники

**ҖЫЛЫЛЫКЛЫ** *с.* Җылылык бирә торган, җылы чыгара торган. *Җылылыклы яктылык чишмәләре белән беррәттән, техникага һәм көндәлек тормышка торган саен киңрәк кергә барган яңа төр яктылык чишмәләре дә бар.* Физика

**ҖЫЛЫЛЫ́К МИКЪДАРЫ** *и. физ.* Җылылык күчү процессында җисемнең алган яки биргән эчке энергиясе микъдары. *Әмма җылылыкның микъдары бөтенләй, мөгаен, гадәд [сан] белән тәгаен ителә алмыйдыр.* Ф.Әмирхан

**ҖЫЛЫЛЫ́К ПОЯСЛАРЫ** *и. геогр. күпл.* Җир өстенең, җылыну дәрәҗәсенә карап, якынча бүленгән поярлары; *русчасы:* **тепловые пояса**. *Җирдә төрле җылылык поясларының булуы Җир шарының төрле урыннарында Кояшның биеклеге төрлечә булу белән аңлатыла.* Астрономия

**ҖЫЛЫМ** *и. диал. к.* **ятьмә**. *Җырлап тартыйк әле җылымны, Авыр җылым җиңел тоелсын.* М.Җәлил. *Алар елганы иңләгән җылымны тартып баралар. Ярның сөзәгрәк, ташлырак урынын сайлап, җылымны тартып чыгаралар.* Ф.Яруллин. *Балыкчылар җәтмә, җылым карый. Кузгалалар ишкәк, көймәләр.* Г.Хуҗиев

**ҖЫЛЫМСА** *с.* Суык булмаган һәм шул ук вакытта кайнар да түгел, җылысы сизелеп торган. *Агачлар куелыгыннан чыгуга, биткә --- аланның җылымса коры сулышы, мең төрле чәчәкләр хуш исе белән төнәтелгән җылы һәм коры алан һавасы килеп бәрелде.* Г.Бәширов. *Минем ботыларымны алып, җылымса батарея өстенә бастырды, шуннан соң гына шинелен салды, гадәтләнгән җитезлек белән гимнастёркасын киң каешы буйлап ике якка сыпыргалады...* Ә.Еники. *Табак төбендәге җылымса суда күзне, иренне чылатып алдым да Минзук янына ашыктым.* Р.Зәйдулла

**ҖЫЛЫМЧЫ** *и. диал.* Елым белән балык тотучы. *Ул көннәрдә Идел яры буйларында йөзләрчә җылымчыларның билдән су эчендә, муен тамырлары шартларга җитеп бүрткәнче, көчәнә-көчәнә, җылым тарту тавышлары ишетелеп тора иде.* Г.Минский

**ҖЫЛЫНУ** *ф.* 1) Кояш, янган ут, электр һ.б.ш. тәэсирендә җылы хәлгә килү. *Яшен үткән урында һава бик нык җылына, аның басымы, күз ачып йомганчы, берничә мең атмосферага кадәр күтәрелә.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Кәлтә иртән кояшта җылынырга ярата һәм актив була, ә төнлә сүлпәнләнә.* Хайваннар дөньясы

2) Җылы урында торып туңган, күшеккән тәнне җылы хәлгә китерү. *– Йә, җылындыңмы инде? – дип сорады ул миннән. – Юк, юк, җылындым, – дидем мин...* Ә.Еники. *Туңып беткәнсең бит, йолдызым! Җылынырга кирәк сиңа.* М.Маликова. *Гадәттә, көтүдә берничә мең болан була. Көчле бураннарга юлыккан очракта, җылыну өчен, [алар] тыгыз өер булып тупланалар.* Хайваннар дөньясы

3) Суыктан җылыга әйләнү, җылы хәлгә килү. *Тритоннарның үрчүе һәм үсеше безнең регион шартларында апрель-майда яхшы җылынган сулыкларда уза.* И.Рәхимов. *Аш җылынды. Өй җылынды*

4) Һава торышы үзгәреп, көннәр җылыга әйләнү. *Кышкы көннең җылынуына ышанма, дошманның көлүенә ышанма.* Мәкаль

5) *күч.* Кайнар хисләрдән дәрт туу, энергия, илһам барлыкка килү; өмет уяну. *Ялгыз утын янмас, ялгыз куен җылынмас.* Мәкаль. *Күшеккән күңелем җылынсын – Кулларым учыңа алсана! Күшеккән күңелем җылынсын – Җанымны учыңа салсана!* Ш.Җиһангирова. *Аралар да бераз җылынмасмы, югыйсә, балаларга сиздермәс өчен генә курчак уйнап кыланалар.* И.Низамов

6) *күч.* Кемнең дә булса канаты астында рәхәт яшәү, аңардан файдалану. *Тик, әнә теге мошенник Хәсән аны харап итә: без – социалист-революционер, без фәлән, без төгән дигән булып, Сафин тирәсендә җылына, нәгъләт.* Ш.Камал

**Җылына бару** Әкренләп җылыну, вакыт узган саен җылылыгы арту

**Җылына башлау** Җылынганы сизелү

**Җылына төшү** Бераз, берникадәр җылыну; беркадәр җылынган хәлгә килү

**Җылынып алу** Кыска вакыт эчендә, берникадәр җылыну

**Җылынып бетү** Тәмам, ахырынача җылыну

**Җылынып җитү** Тиешле дәрәҗәгә килеп җылыну. *Кояш югары менеп киткәч, һава җылынып җиткәч, көтүләре белән бергәләшеп, җиң сызганып, күмәкләшеп [умарта кортлары] эшкә ашыгалар.* А.Алиш. – *Китәсез дәмени инде? – диде ул. – Җылынып та җитмәгәнсездер...* Ә.Еники

**Җылынып китү** Тиз арада җылыну; кинәт җылынган хәлгә килү. *Чынлап та, мин әле бер дә җылынып китә алмый идем.* Ә.Еники. *Кечкенә Хәлилне үз араларына алып салдылар. Балаларыннан да бигрәк, үзләре җылынып киткән кебек булдылар.* Ф.Хөсни

**Җылынып тору** Әле, хәзерге вакытта җылыну

**Җылынып чыгу** Тулысынча җылы хәлгә килү

**ҖЫЛЫСЫЕШЛЫК** *и. физ.* Җисемнең температурасын бер градуска күтәрү өчен киткән җылылык микъдары. *Әйбернең массасы никадәр зур булса, аның җылысыешлыгы да шулкадәр зур була.* Физика

**ҖЫЛЫТКЫЧ** *и.* 1) Җылыта торган прибор. *Тышта бик түбән температуралар булганда, биналарда төрле җылыткыч приборлардан файдаланырга мөмкин.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү

2) Тәннең аерым бер өлешен җылыту өчен, эченә кайнар су салып файдаланыла торган резин капчык; *русчасы:* **грелка**. *Фельдшер, ниндидер дарулар биреп, җылыткыч куярга кушты.* Э.Касыймов

**ҖЫЛЫТУ** *ф.* 1) Җылылык энергиясе чыгарып, тирә-якны, һаваны яки әйберләрне җылы хәлгә китерү. *Шулай байтак икеләнеп утырганнан соң, шактый ук күтәрелеп җылыта башлаган кояшка күз салды, күрше-тирәдәге чәчүчеләргә карап алды да аягүрә басып: – Аллага тапшырдык! – диде.* Г.Бәширов. *Җиләк-җимеш һәм яшелчәне саклау өчен, тәрәзә янында аз гына мәйданчыкны бүлеп куярга һәм аны я өстәмә рәвештә җылытырга, я анда суыргыч вентиляция җайлап куярга кирәк.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү. *Ток белән җылытылган тимерчыбык янында ук магнит угы торган.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Үз җылыңны биреп, кочып, тәнне ышкып, өреп җылыту. *Ни өчен дәштең, үзеңә алып кердең, тезләнеп, аякларымны җылыттың, онытылып, күзләремә карадың?* Ә.Еники. *Җәмилә Закировна, җылытырга теләгәндәй итеп, кулларын угалады.* М.Маликова

3) Җылыну өчен, җылы чыганак янында тору. *Хәзер үк берәр җиргә кереп, аякларыгызны җылытырга кирәк.* Ә.Еники

4) Учакка, мичкә яки башка җылылык чыганагына куеп, аш-суны җылы хәлгә китерү. *Ботка җылыту. Аш җылыту*

5) Өй, торак, бинаны салкын үткәрми торган итеп эшләү; җылы сакланырлык итү. *Өйнең түбәсен туфрак, пычкы чүбе белән җылыту. Өйне тышкы яктан күбектән эшләнгән пластиналар белән җылыту*

6) *з.-сыз* Һава температурасы күтәрелү. *Көн кичкә таба шактый җылытты*

7) *куч.* Җылы тойгы уяту, дәрт, илһам, рәхәтлек бирү. *Кайда соң син, җан җылытыр кешем? Туңа җаным янда син юкка.* Ш.Җиһангирова. *Ничек кенә булса да, начальникның чыраенда изге кеше чалымнары күрү күңелне бик нык җылыта...* Н.Измайлова

**Җылыта бару** Вакыт узган саен, җылылык арту, торган саен ныграк җылыту

**Җылыта башлау** Җылытырга тотыну. *Язгы кояш җирне җылыта башлагач, ул [бака] уяна һәм тагын бөҗәкләрне аулый башлый.* Хайваннар дөньясы

**Җылыта төшү** Беркадәр, бераз җылыту; тагы да җылырак итү

**Җылытып алу** Тиз арада җылыту, җылынган хәлгә җиткерү

**Җылытып бетерү** Барысын да, бөтенесен дә җылыту

**Җылытып җибәрү** 1) Кинәт җылыту. *Аяк астын туңдыруны, кырпак төшүне көтеп торганда, ноябрь урталарында, һич күренмәгән хәл, кинәт аязып, җылытып җибәрде.* Ф.Хөсни. *Алай гына да түгел, бу кешенең мине үзенә көчләп алып керүе минем өчен яхшы булды кебек, аякларымны гына түгел, ул хәтта йөрәгемне җылытып җибәрде кебек...* Ә.Еники

2) Бераз җылыту. *Бүген үк чәчкәндә, тишелә алмыйча, сөтләнеп ятмагае, бозылып. Ярый ла җылытып җибәрсә!* Г.Бәширов

**Җылытып җиткерү** Тиешле дәрәҗәгә җиткәнче җылыту

**Җылытып кую** Алдан җылытып, әзер хәлгә китерү. *Ашны җылытып кую*

**Җылытып тору** 1) Һәрвакыт, бертуктаусыз җылыту. *Әнә шул еракта балкыган якты нур – өмет чаткылары белән күңелләребезне җылытып тора иде.* Г.Бәширов. *Ярты республика җирләрендә газ, айлар-еллар буе янып, һаваны җылытып торса да, бер генә авылга да газ кертелмәде.* М.Әхмәтҗанов

2) Әледән-әле, еш җылыту

**ҖЫЛЫТУДЫРУЧЫЛЫК** *и. физ.* Бер килограмм ягулык янганда чыккан җылылык микъдары. *[Хәзерге ракеталарда] Җылытудыручылыгы кечкенә булган дары урынына зур җылытудыручылыклы башка ягулыклар кулланыла.* Физика

**ҖЫЛЫУЗДЫРГЫЧ** *и. махс.* Җылылык станциясеннән кайнар су яки пар җибәрү өчен хезмәт итә торган торбалар; *русчасы:* **теплопровод**. *Чакрымнарга сузылган җылыуздыргычлар шәһәр читенә тикле җир өстеннән килә икән дә, кала сызыгына җитүгә, җир астына кереп, бихисап тармакларга аерыла икән.* Б.Камалов

**ҖЫЛЫ́ ЯК** *и.* Салкын кышлар булмый, кар яумый торган җирләр, көньяк. *Җылы якның бик күп нәрсәсе онытылса да, шушы кара кипарисы белән зәңгәр күге беркайчан да онытылмас кебек...* Ә.Еники. *Җылы якта дым җитәрлек булса, агач бик тиз үсә...* М.Юныс. *Крокодилларның 26 төре бар, алар күбрәк җылы яклардагы*

*төче сулыкларда яши.* Хайваннар дөньясы

**ЖЫП-** *кис.* «Ж» авазына башланган «жылы» сыйфатына ялганып һәм һәрвакыт басымны үзенә алып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Кояш та жып-жылы нурлар сачадыр, Күңелсез җир йөзе күңелен ачадыр.* Г.Тукай. *Безнең тормыш кебек матур булып, Жып-жылы яз килде тагын да.* Ә.Ерикәй. *Баздан чыккач, беркавым жып-жылы йомшак бәпкә үләне өстенә капланып ятып тордым.* Ф.Шәфигуллин

**ЖЫПКЫ** *и. диал.* Агым сулы елгаларда суның тирән, агымы көчле булган урын, су юлы. *Пароход йөри торган жыпкыга, маяклар белән билгеләнгән юнәлешкә керергә кирәк.* Ә.Баянов

**ЖЫПТЫ** *с. диал.* Уйсу; иңеп, чокыраеп торган. *Жыпты җирләрдә әле кар тирән иде, шуңа күрә су, күрәсең, кар астыннан үзенә юл алып китә алмаган иде.* Н.Фәттах

**ЖЫР** *и.* 1) Көйгә салынган шигъри әсәр. *Жыр – күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч.* Мәкаль. *Хөрия жырлап туктаганнан соң да, жыр тәэсиреннән озак айный алмыйча утыралар.* Ф.Яруллин. *Жыр сәнгатен тирәннән белүче классик композиторыбыз Жәүдәт Фәйзи әйткәнчә, М.Хөсәен халык йөрәгенә иң элек жыр аша үтеп керде.* М.Гайнуллин

2) Шагыйрь күңелендә туган хисләрне сурәтләгән шигъри әсәр, жырга салырлык текст. *Мин кабыздым жырда, ялкын итеп, Йөрәгем һәм халык кушканны. Жырым белән дусны иркәләдем, Жырым белән җиңдем дошманны.* М.Җәлил. *Берәүләре диңгезләрдә кораб йөртә, Берәүләре алар исемен жырга кертә.* Ф.Яруллин. *Якташларым, йөрәк аша үтеп, Жырларыма кучә түгелме?!* М.Хөсәен

3) Шигъри текстларга язылган музыка, көй. *Шагыйрьләрнең текстларына жырлар язу буенча М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Ж.Фәйзи һ.б. эшләп килделәр.* М.Җәлил

4) *күч.* Кошлар сайравы, сызгыруы. *Миләш чыпчыгы – жырчы кош. Алар иртән кояш чыкканда да, көндез дә, бер-берләреннән уздырырга тырышып, гаҗәп матур жырларын сузалар.* Т.Шакирова. *Ул сандугач – дус сандугач! Көн дә бездә кунакта. Минем өчен жырлар жырлый Бакчабызда – куакта.* Р.Миңнуллин

◊ **Жыр башлаучы** Нинди дә булса эшне башлап, оештырып йөрүче, житәкчелек итүче кеше. *Уннарча, йөзләрчә башка энтузиастларны «сыйфат өчен көрәшнең алгы сафында атлаучылар» дип, зур горурлык белән әйтергә мөмкин. Әйе, алар – сафта жыр башлаучылар.* Б.Камалов. **Жыр сузу** Моңлы итеп жырлау, жыр башкару. *[Кызлар] Идел буен яңгыратып, батыр егетләр турындагы жырларын сузалар.* К.Нәҗми. **Жыры жырланган** 1) Вакыты узган, яшь, күрекле, дәрәҗәле чагы узган; 2) Язмышы, киләчәге хәл ителгән. **Жырын жырлау** 1) Кемдер файдасына эшләү, аның белән бер сүздә булу, аның мәнфәгатьләренә туры китереп сүз сөйләү. *Кемнең жырын жырласаң, шуның көен көйләрсең.* Мәкаль. *Әмма аракы монополистлары массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы бөтенләй башка «жырны жырлыйлар».* М.Әхмәтҗанов. *Аксак энесе Исмәгыйль бәк Мәскәү кенәзе жырын жырлый башлады бугай, Иделнең сул як далаларын, шул исәптән Әстерхан ханлыгын да үз биләмәсе итмәкче.* М.Хәбибуллин; 2) Башкаларга иярү; үзеңне башкалар кебек тоту. *Сандугач жырын жырлыйм дип, үз жырыңны онытма.* Жыр. *Кемнең арбасына утырсаң, шуның жырын жырларсың, дигән халык.* М.Хәбибуллин

**ЖЫР-БИЮ** *җый. и.* Жырлар һәм биюләр. *Башкортларның беренче урында һаман жыр-бию, күңел ачу, ягъни кымыз һәм кубыз тора...* Ф.Бәйрәмова

**ЖЫРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **жырлау**. *Бишек жырын утыз балага берьюлы жырлап булмый, ул һәр балага аерым жырланырга тиеш.* М.Маликова. *«Һәр эштә мактаулылар» дип, жырланмый юкка гына; – Аңларсың моның мәгънәсен Баулыда тусаң гына.* Ш.Жиһангирова

2) Тормыштагы аерым хәлләрне шигырьгә салу, жырда чагылдыру. *Ул тугрылык жырда жырланырлык, Меңнәр табынырга торырлык!* Ш.Жиһангирова

3) *сир.* Әкрен генә үзалдына көйләү, үз-үзенә жырлау. *Араларыннан бер студент жырлана-жырлана керә.* Ф.Әмирхан

**ЖЫРЛАТУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **жырлау**. *Әтиләрдән курыкмасам, кешедән оялмасам, [Хәлилне] тәрәзә төбендә, жырлатып, төн буе утырыр идем.* М.Фәйзи. *Әмма шунсы начар: гел русча жырлар жырлаталар.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Самавыр шаулату, кайнату. *Самавырны жырлатып, чәй эчтек*

**2. жырлатып**. *рәв. мәгъ.* Менә дигән итеп, шәп итеп. *Гыймазовның --- жырлатып эшләвенә сокланган Борһан, хәл жыярга, тәмәке көйрәтергә утыргач, гаҗәпләнүен тышка чыгармый түзә алмады.* С.Рафиков

**Жырлатып жибәрү** Бераз жырлату, жырлата башлау. *Мин бит-кул юып, чистарынып кергән арада, самавырыңны жырлатып жибәрмисеңме?* И.Гази

**ЖЫРЛА́У** *ф.* **1.** 1) Тавыш ярылары ярдәмендә көй чыгару, жыр башкару. *Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын, Жырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!* Г.Тукай. *Ул жырласа, никтер, күңел тула, Никтер каушыйм, аңа карасам.* М.Хөсәен. *Әтием мандолинада уйнаган, матур гына жырлаган да...* Ә.Еники

2) *күч.* Тормыштагы хис-тойгыларны жырда чагылдыру, шигырьгә салу, сурәтләп бирү. *Жырлый-жырлый үләрмен мин үлгәндә дә, Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә, «Без китәрбез, сез каласыз!» – дип жырлармын, Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.* Г.Тукай. *Бу шагыйрь производствоның үз теле белән жырлый.* М.Гайнетдинов. *Мәхәббәт – изге, бөек хис, барча халыкларның даһи шагыйрьләре аны юкка гына жырламаган.* М.Маликова

3) *күч.* Сайрау. *Ә инде ана сыерчык кайткач, алар бергәләшеп, илһамланып жырлыйлар. Сыерчык хәтта башка кош булып та жырлый ала.* Т.Шакирова. *Шатлыгы сыймый эченә, Сайрый ул сузып-сузып. Йә әйләнә*

*бытбылдыкка, Йә җырлый тургай булып.* И.Мадьяров

4) *күч.* Машина аппаратлары ритмлы тавыш чыгарып эшләү

5) *күч.* Табигый тавышлар, шат, дәртле җанлылык барлыкка килү. *Анда җырлый җирдә һәр кош, Анда җырлый һәр агач. Анда кайтсам, мин дә башка: Анда мин дә сандугач.* Н.Исәнбәт. *Дуслар рәтенә ул шушы төбәкнең җирен, күген, күктә йөзгән яшенле болытларын, урманда мәш килгән кырмыскаларын, җырлый-җырлый бал ташучы умарта кортларын – һәммәсен кертә иде.* Ф.Яруллин

**2. җырлап** *рәв. мәгъ.*1) Шәп итеп, менә дигән итеп. *Җырлап яшәргә, Гөрләп яшәргә язсын дөньяда, язсын дөньяда. Гел бергә-бергә.* Г.Латыйп

2) Көйләп, сузып. *Алар саф татарча, бераз җырлап сөйләшә, кайберләрендә мишәр акценты да сизелә, алар инде Пенза, Сембер, Волгоград якларыннан күчеп килүчеләр булырга тиеш.* Ф.Бәйрәмова

**Җырлап алу** Берара, кыска вакыт аралыгында җырлау. *«Сарман» белән «Шахта»ның бер-ике куплетын җырлап алдылар да тагын тынып калдылар.* М.Маликова

**Җырлап бетерү** 1) Җырны тәмамлау, ахырына кадәр җырлап чыгу. *Ул, җырлап бетерер-бетермәс, миннән борчылып сорады: – Сезгә ни булды?* Ә.Еники

2) Барлык җырларны җырлап чыгу. *Белгән җырларыбызны җырлап бетердек*

**Җырлап бирү** Сораган җырны җырлау. *Менә ул йөзен күтәреп, тешләрен җемелдәтеп, ялынгандай елмайды: – Зәйтүнә, җырлап бир әле безнең хөрмәткә.* М.Маликова

**Җырлап җибәрү** Кинәт җыр башлау, җырларга керешү. *Шуннан без күмәк булып, солдатларча тигез атлап кузгалырбыз. Җырлыйсы килгәнгә, җырлап җибәрү дә рөхсәт ителә...* Ф.Хөсни. *Сәлмән кунак кызлар хөрмәтенә бүтән җыр җырлап җибәрде.* Г.Бәширов. *Гөлзада ханым: «Бездә биек таулар бар, тау астында таллар бар», – дип җырлап җибәрүгә, аңа залдан халык та кушылды: «Талда – яфрак, бездә – сагыну, сездә нинди хәлләр бар?» – дип, җырлап җавап бирде.* Ф.Бәйрәмова

**Җырлап йөрү** Төрле урыннарда, һәрвакыт җырлау; якында, әйләнә-тирәдә җырлау. *Яшь кызлар, муеннарына чәчәктән үрелгән такыя киеп, кунаклар хөрмәтенә җырлап, биеп йөриләр.* М.Юныс. *Гастроль башланды гына, Азалия нинди кәеф белән җырлап йөрер – син шуны уйлыйсыңмы?* Х.Сарьян

**Җырлап карау** Җырларга омтылу, җырларга тырышу

**Җырлап тору** 1) Сөйләүче күргән вакытта җырлау; әле, хәзер ритмлы тавыш чыгару. *Пропеллер, тыр-тыр итеп, һаман җырлап торды.* М.Җәлил

2) *күч.* Үтә яхшы, шәп булу

**Җырлый башлау** Җырларга тотыну. *Менә болар берзаман сикерешеп тордылар да, күккә карап, гөр-гөр килеп, үзләренчә көйли, җырлый башладылар, болар шулай күктән көч ала икән.* Ф.Бәйрәмова

**Җырлый бирү** Җырлавын дәвам итү, һаман да җырлау

**ҖЫРЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **җырлау**. *Кошлар бит сайрашып табыша, Их, без дә җырлашып табышсак.* Г.Зәйнашева

2) Кара-каршы җыр әйтешү. *Туй йоласы буенча, татарларда кодаларны каршы алу җырлашу белән барган*

**Җырлаша башлау** Җырлашырга тотыну. *Музыка буенча тәрбияче пианинода уйнап җибәрүгә, төрле тавышлар белән --- җырлаша башлыйлар.* Ф.Яруллин

**Җырлашып утыру** Бергә-бергә, күмәкләп җырлашу. *Әнисе йортында мондый җырлашып утыруларны, кунакка йөрүләрне бөтенләй күрмәде ул.* Ф.Яруллин

**ҖЫРЛЫ** *с.* Җыр белән башкарыла торган. *Татар халкының җырлы уеннары*

**ҖЫРЛЫ-БИЮЛЕ** *с.* 1) Җырдан һәм биюдән торган; җыры да, биюе дә булган. *Шулай да галимнәр тәңречелек күзаллаулы төркиләрнең язга – җирнең яңадан тууына корбан бирү йоласы булуы һәм бу йола кысаларында ат чабышлары, кылычлар белән сынашлар, җырлы-биюле уеннар, бәйгеләр үткәрелүе турында мәгълүматларга юлыгып торалар.* Фольклористика. *Халыкка күбрәк җырлы-биюле әсәрләр ошый.* Шәһри Казан. *Җиңүчеләр ачыклануга, халык мәйдан тутырып чыгыш ясаган җырлы-биюле музыкаль хореография күзәтте.* Татарстан яшьләре

2) Җыр-биюгә оста, шат күңелле. *К.Тинчуринның җырлы-биюле «Назлы кияү»ендә Рәшит, Батулланың «Сөйгән ярым ятка кала»сында Харамша – шулай ук актёрның [Зөфәр Харисовның] иҗат биографиясен баеткан образлар.* Мәдәни җомга

**ҖЫРЧАН** *с.* Җырга һәвәс, җырларга ярата торган. *[Гайшә] Яшь чагыннан ук бик моңаючан һәм бик җырчан булган.* Г.Ибраһимов

**ҖЫРЧЫ** *и.* **1.** 1) Җырларны оста башкаручы; профессиональ җыр остасы. *Залда татар моңы тантана итә: әле Гөлзада ханымның дәртле җырлары яңгырый, әле яшь җырчы Сәүбән Закировның көчле тавышы клуб диварларын дерелдәтә...* Ф.Бәйрәмова

2) Шагыйрь. *Кайттым... «Җырчы» исемен йөкләү Җиңел түгел икән, малайлар: Шагыйрьлектә үткән бернichә ел Җыерчыклар салды маңгайга!* Х.Туфан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җыр текстлары яза торган. *Җырчы шагыйрь буларак та Мәхмүт Хөсәенне укучылар бик яхшы беләләр.* М.Гайнуллин

2) Табигатьтә җырга, көйгә охшаш ритмлы тавыш чыгарган, җырчан, сайраучан. *Кешеләргә сөйләмәгән уйхыялларын җырчы усакларга, иркә юкәләргә сөйләде.* Ф.Яруллин. *Рәхәт, сулышка иркен, дөнья мәшәкатьләре урманның аргы ягында – авылда, кысан өйләрдә торып калды, монда – гамьсез мужиклар да җырчы кошлар гына.* Ф.Хөсни

**ҖЫРЧЫЛЫК** *и.* Җырчы булу сәләте, һөнәре. *[Галия:] Докторлыгыма караганда, җырчылыгыма тизрәк ышанырлар дип уйлаган идем.* Г.Кутуй

**ҖЫЮ** *ф.* 1) Куып яки чакырып, билгеле бер урынга китерү, туплау. *Төзелеп яткан төрбә янына шагыйрьләр-*

*не жыеп, ярыш оештыралар.* М.Юныс. --- *төрле яктан туган-тумачаларын жыялар ---.* Н.Измайлова. *[Халисә] Жыя безнең һәммәбезне Чәй өстәле артына, Җан җылысы җитә аның Яшенә дә картына.* Ш.Җиһангирова

2) Чәчелеп, таралып яткан нәрсәләрне җыйнау, бер җиргә туплау, тәртипләп кую. *Ачуланган сүзләргә дә Артык исе китмидер, Аның артыннан жыярга Ун әни дә җитмидер.* Ф.Тарханова. *Ашап туйгач, Гыймай үз алдындагы валчыкларны, җыеп, авызына каба иде.* Ф.Яруллин

3) Аерым өлешләрне бер бөтенгә әйләндерү, берләштерү. *Үз тырышлыгы белән җыйган машина рулена утырганнан бирле, бераз борынын да күтәргән...* Ф.Хөсни. *Әнә ничек ялыкйолык итә. Әйтерсең кояшның бөтен нурларын үзенә җыйган.* Ф.Яруллин

4) Яшелчә, җиләк-җимешне, иген уңышын һ.б.ны чүпләп, урып-сугып, җыеп алу; урнаштыру. *Әйе, балны вакытында җыярга, кызны вакытында кияүгә бирергә кирәк.* М.Хәбибуллин. *Ямь-яшел килеш өлгерә, Яшь килеш тәмле кыяр. Иң оста бакчачы аны Нәкъ вакытында җыяр!..* Г.Зәйнашева. *Кайбер үсемлекләрнең чәчәк бөреләрен генә җыялар.* Урман аптекасы

5) Нәрсәнедер әкренләп туплау, булдыру, күбәйтү, ишәйтә бару. *Дөньяда мал җыймак – олы ташны биек тауга мендермәк.* Мәкаль. *Хәзинәдә бары инде, махсус җыйган мал түгел.* М.Маликова. *Ә үзләре һаман да җыялар, экономия ясыйлар, акча салып баралар. Җыю, гап-гади итеп әйткәндә, гадәткә кергән, табигатьләренә сеңгән...* Тигез гомер итегез

6) Киңәшмә, бәйрәм, концерт-театр уңае белән, халыкны билгеле бер урынга чакыру, өндәү; дәшеп китерү. *Гадәттә, кунак җыйганда, бәлеш табынга башта ук куелмый, аштан соң гына китерелә.* М.Маликова

7) Мәҗбүри түләнергә тиешле салымны, түләүләрне һ.б.ш.ны халыктан алу, түләтү. *Иртәдән бирле авылда салым җыялар.* Ф.Кәрим. *Җыен таралды, староста белән дисәтникләр, ат җигеп, имана түләмәүчеләрнең йорт әйберләрен җыярга чыктылар.* Г.Бәширов

8) Ирекле рәвештә бирелә торган нәрсәләрне халыктан алу. *Үзара акча җыеп, өр-яңа Европа картасы сатып алдылар – үзләре хуҗа картага.* Ф.Хөсни

9) Мобилизацияләү, запастагыларны хәрби хезмәткә чакыртып алу. *Германия безгә каршы сугыш башлап, безнең границага басып кергән бит. Менә хәзер приказ бар. Фәлән-фәлән елгыларны җыялар.* Ф.Кәрим. *Родос патшасы тиз генә хәрби флотын җыя, аны коралландыра һәм Карияне яулап алырга җибәрә.* М.Юныс

10) Аерым кисәкләрне бер-берсенә беркетеп, ялгап, бербөтен әйбер, механизм, корылма хасил итү. *Җепне җыйсаң, аркан була.* Мәкаль

11) Җыештыру, тәртипкә китерү. *Ярый әле эш күп: кер юарга, өйне җыярга, кибеткә барырга --- кирәк!* М.Маликова

12) Таралып, чәчелеп, кабарып торган нәрсәләрне тәртипкә китерү, җыйнак-пөхтә итү. *Нәҗия кыска жакетын киеп, матур бизәкле ефәк косынкасын башына, чәч бөртекләрен юри җыймыйча калдырып, саксыз гына бәйләгән.* Ә.Еники. *Бер дә булмаса, [чәчен] артка – бантигына җыеп, резинка белән каптырып җибәрер, тәрбиячесе үрер.* И.Низамов

13) Яшереп кую; күренмәслек, беленмәслек урынга урнаштыру; ышанычлы, яшерен урынга алып кую, яшерү. *Артык-портык кәгазьләреңне һәм бу кенәгәне ераграк җыярга кирәк.* Ш.Мөхәммәдев. *Өйдә булган артык әйберләрне җыю*

14) Бер урынга туплау; коллекция барлыкка китерү. *«Дендрарий» дип, бик күп агачларны бер җиргә җыеп үстергән зур бакчага әйтәләр икән.* Ә.Еники. *Маркалар җыю*

15) *махс.* Текстны махсус техникада басып, басмага әзерләү. *Мәкаләне компьютерда җыю*

16) Чәчәктән-чәчәккә, үсемлектән-үсемлеккә кунып, нектар, серкә һ.б.ш.ны туплау. *Билгеле булганча, күп кенә авыл хуҗалыгы культуралары, нектар җыйганда, бер үсемлектән икенчесенә серкәләр күчерә торган бөҗәкләр аларның чәчәкләренә кунган очракта гына, мул уңыш бирә алалар.* Умартачыга ярдәмлек

17) Аерылып чыккан умарта күчен бергә туплап, савытка тутыру. *Ә бер көнне Дамир Гыйлемдар бабай белән күч җыйды. Ул көнне берьюлы берничә умарта аерды.* Ф.Яруллин

18) Кош-корт, җәнлекләр азык табу, чукып ашау, кышлыкка туплау. *Урмаган арышың – Бер еллык табышың; Аны җил коядыр, Чыпчыклар җыядыр.* Г.Тукай

19) Үзенә сеңдерү. *Дым җыю*

20) Үлекләү, эрен туплау, шешү. *Бармагы, шешеп, үлек җыйган*

21) *күч.* Көч, хәл туплау, тын алу. --- *Зөһрә ханым, тын җыйгандай, бер сулап куйды.* Ә.Еники. --- *тел ачып үртәшүче булмады – белмим, әллә татулашудан, әллә якын киләчәктә тагын бер бәргәләшү өчен көч җыюларыннан...* Ф.Хөсни. *Кәүсәрия, аңын җыя алмыйча, аңа карап утырды.* М.Маликова

22) *күч.* Акыл, фикер, белем туплау. *Ил гамен җыйган ир ил агасы булыр.* Мәкаль. --- *бөтен белемемне җыеп, әлеге шигырьнең соңгы ике юлын шатлыкка, бәхеткә борып үзгәртергә теләдем.* Г.Кутуй. *Мисырны килеп күргән кеше безнең ерак бабаларыбыз турындагы мәгълүматларга баеп, файдалы белем җыеп, туган ягына кайтып китә.* М.Юныс

23) *күч.* Мәетне йола шартларына туры китереп җирләргә әзерләү. *Менә минем дә Әнвәрҗан бәпкәем кайсы патшалыкта гүр иясе булып ята торгандыр. Бәлки, гәүдәсен дә җыеп җирләүче булмагандыр.* Г.Мөхәммәтшин

24) *күч.* Барлыкка китерү, арттыру, ишәйтү. *Көчем күп, дип, башыңа дошман җыйма, күмәк кырмыска атны үтерер.* Мәкаль. *Нинди хаталар? Каян җыйдың аларны?* Г.Бәширов. *Һич уйламаган-көтмәгән җирдән улы Дамир үлеп китте дә, бөртекләп җыйган бәхет орлыклары читкә тарала башлады.* Ф.Яруллин

25) *күч.* Имтихан, сынау, конкурслар вакытында балл, очко туплау. *Без имтиханда тиешле баллны җыя алмаганбыз, имеш. Минем контроль эшнең бер бите югалган.* Ф.Яруллин

◊ **Җыеп алмаслык** Бик вак кисәкләргә таркатып, тетеп бетереп. *Мин сине --- аяк-кулларыңны җыеп алмаслык итәм әле...* Р.Зәйдулла. **Җыеп тоту** Таратмыйча, таркатмыйча, сакчыл тоту. *Малны ансат табасы, мәшәкать – аны җыеп тотасы.* Мәкаль

**Җыеп алу** 1) Тиз арада җыелган, җыештырылган хәлгә китерү. --- *хәдимнәр табынны җыеп алалар.* Ә.Еники

2) Кыска вакыт эчендә, тулысынча җыю; тәмам җыю. *Алларыма җыеп алдым Карурман миләүшәсен.* Җыр. *Җимеш вә җиләкләрне җыеп алу турында берничә сүз.* Яшелчә һәм җиләк-җимешне саклау, эшкәртү. *Барлык мәйданда мамыкның чәчәкләрен умарта кортлары белән серкәләндерү нәтиҗәсендә --- илебездә елына өстәмә рәвештә 8–10 млн центнерга кадәр югары сыйфатлы мамык җыеп алырга була.* Умартачыга ярдәмлек

3) Берсен дә калдырмый җыю. *Күрше авылда бригада активына хәтле җыеп алып чыгып киттеләр.* Ф.Бәйрәмова. *Нишләгән көнбагышлар?.. Барысы да пеләш калган!.. Кемдер, бик оста иттереп, Мин юкта җыеп алган.* Г.Зәйнашева. *Йорт саен кереп, әйберләрен җыеп алырга!* Г.Бәширов

**Җыеп ату** Тиз-тиз, аннан моннан җыю. *Бик нәни булса да, Дилә Чисталыкны ярата: Үрмәләп кенә йөрсә дә, Бар чүпне җыеп ата.* Ф.Тарханова

**Җыеп бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы җыю. *Кайберәүләр газета-журналларны, килгән көнне укымыйча, «вакыт булгач укырмын» дип җыеп баралар.* А.Хәсәнова. *Булмаган андый хатын-кыз! Авырган чакларда аны тәрбияләүче, аның иҗатына илһам бирүче, язганнарын бөртекләп җыеп баручы, аны мәхәббәте белән җылытучы...* М.Маликова

**Җыеп бетерү** Ахырынача, барысын да җыю; җыю эшен тәмамлау. *Бу җәйдә, яңгыр яумаганлыктан, өрекләре өлгермәгән, аның каравы чия агачлары мул уңыштан җиргә кадәр иелгән, җыеп бетерерлек түгел...* Ф.Бәйрәмова. *Линатипта эшләүче кызлар бу китапны бик тиз җыеп бетерделәр.* Яңарыш

**Җыеп йөрү** Дәвамлы рәвештә җыю, кабат-кабат җыю. *Әйтәм аны, әни бүген көне буе печәнлектә йомырка җыеп йөрде.* Г.Бәширов. --- *кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри.* Ә.Еники. --- *начар үзгәреш булмаска тиеш бу «куратор» дигәне, һәрхәлдә, табыннан кеше калдыгын җыеп йөрү булмас.* И.Низамов

**Җыеп калу** Берәр вакыйгага кадәр җыеп өлгерү. *Печәнне яңгырга кадәр җыеп калу*

**Җыеп килү** Элек-электән, күптәннән бирле җыю. *Аның кыз чагыннан ук җыеп килгән бай гына китапханәсе бар иде...* Ә.Еники. *Сәүдәгәрләр әйтүенә ышансак, мәнгелләр бүген, күрше-тирәдәге ыруларны буйсындырып, көчгайрәт җыеп киләләр.* М.Хәбибуллин

**Җыеп кую** 1) Җыйган, җыелган хәлгә китерү; тәртипләп, бер өемгә туплау. *Сары чәчен баш артына зур төен итеп җыеп куйган, чигәләрендә җиңел бөдрәләр бөтерелгән Зәйтүнә бүген --- кичке уенга чыккан авыл кызын хәтерләтә иде.* М.Маликова

2) Алдан җыю. *Газизҗан сыерга кичтән карчыгы җыеп куйган әрекмәнне салып маташа иде.* И.Низамов

3) Күрмәслек, башкалар белмәслек итеп җыю; яшерү. *Мондый семьяларда күңел кызыгырлык бөтен нәрсә тыела: эш хакы алуга, дөнья рәхәтләреннән ваз кичкән ир белән хатын, җентекләп, акчаны саныйлар да, хуҗалык өчен бик аз калдырып, ераграк җыеп куялар.* Өегез ямьле булсын

4) Җыеп, кая да булса урнаштыру. *Аның каравы, бала, рәхәтләнеп, бөтен фантазиясен җигеп уйнар, уйнап туйгач, әйберләрен билгеле урынга җыеп куярга, пөхтәлеккә өйрәнер.* А.Хәсәнова

**Җыеп тору** Һәрвакыт, даими рәвештә җыю. *Өйне көн саен җыеп торганда, кунак-фәлән чакыру да башны әйләндерерлек вакыйгага әйләнмәячәк.* Өегез ямьле булсын

**Җыеп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм яки башыннан ахырына кадәр җыю

**Җыеп яту** 1) Күп итеп җыю, күптәннән җыю. *Кайдадыр шүрлек почмагында озак вакытлар кузгалмый тузан җыеп яткан Коръәннең ике як тышлыгын да, сабак баласыдай тырышлык күрсәтеп, ялап-ялап алды.* Ф.Хөсни

2) Әле хәзер җыю эшен башкару. *Без килеп җиткәндә, печәнчеләр печән җыеп яталар иде*

**Җыя башлау** Җыярга тотыну. *Яз җитте исә, Фазыл ишеләр Сабан туе өчен алдан ук акча җыя башлыйлар.* К.Кәримов. *Чәйләр эчеп, инде эш беткәч, Мөһимә, тыр-тыр йөреп, табын җыя башлагач... Алтынчәч, сөйләшер өчен, шуннан да җайлырак вакытның булмасын аңлады.* М.Маликова

**Җыя бирү** Җыюны һаман да дәвам итү

**Җыя төшү** Бераз, беркадәр, җыю. *Сәетгали, килеп, сәке кырыена гына утырды, карчыгы юрганын үзенә таба җыя төште.* Ә.Еники

**ЖЫЮ́ САНЫ** *лингв.* Бер төрдәге предметларның аерым берәмлекләрен төркемнәргә туплауны белдерә торган саннар: берәү, икәү, өчәү. *Җыю саннары исемне ачыкламыйлар һәм аергыч булмыйлар.* Д.Тумашева

**ЖЫЮЧЫ** *и.* 1) Гадәттә, үзеннән алда килгән сүз белдерә торган нәрсәне җыю (*3 мәгъ.*) белән мәшгуль кеше (мәс., *бирнә җыючылар, мамык җыючы, ит җыючы* һ.б.). *Бүләк җыючы аны [сөлгене] рәхмәт укып алды да колганың очына, яшел яулык белән бергә бәйләп куйды һәм ары китте.* Ә.Фәйзи. *Халыкка йон җыючы ярдәмгә килгән.* Ватаным Татарстан

2) Детальләрдән нинди дә булса техник җайланма җыя торган (*4 мәгъ.*) эшче, хезмәткәр. *Машина моторлары җыючы. Компьютер җыючы*

3) Бер урынга туплап саклау, өйрәнү һ.б. максатларда нәрсәдер җыю белән шөгыльләнүче кеше. *Коръән басмаларын җыючы. Халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыючы*

4) *махс.* Махсус техника, гадәттә, компьютер ярдәмендә текст җыя торган белгеч. *Хәреф җыючы*

# З

**ЗАБАСТО́ВКА** *и. рус* 1) Нинди дә булса икътисади яки сәяси таләпләрне дәгъвалап, оешкан төстә эш ташлау. *Приказчиклар хәрәкәте, Кадыйр бай приказчикларының забастовкасы – болар әсәргә эпизодлар рәвешендә кертелгән вакыйгалар, аз урын алганнар.* Г.Нигъмәти. *Әгерс мастерскоенда исә забастовканы чынлап торып башларга да өлгермәделәр.* К.Нәҗми. *Февраль аенда миллион ярым шәкерт забастовка ясады, шулай булгач, татар яшьләренең хәлен кайгыртмый калмаслар.* З.Хәким

2) *күч.* Ризасызлык, канәгатьсезлек, килешмәүчәнлек. *Дамирның күңелендә забастовка! «Әйтмәсә, артык бер адым атламыйм!»* И.Гази. *Сүз кайтармаса да, эчтән генә забастовка ясый ул: үзе тик тормагандай булса да, эше тик тора...* Ш.Галиев

**ЗАБАСТО́ВКАЧЫ** *и.* Забастовкада катнашучы кеше. *Забастовкачылар хәрәкәте башлану*

**ЗАБАСТО́ВЩИК** *и. рус к.* **забастовкачы**. *Забастовщикларның барысына да расчёт бирәбез.* К.Нәҗми

**ЗАБИТ** *и. гар. иск.* 1) Буйсындыручы, биләүче, кулга төшерүче

2) Басып алучы, сугышып алып буйсындыручы

3) Үзләштерүче (дәресне)

4) Офицер. *Капкачын ябып, забит үзе ул табакны әмиргә китергәндә, хадимнәрнең мәҗлесенә очрап, Әхмәд ятимгә бирде*. К.Насыйри. *Саф-саф тезелгән гаскәрләр, ат өстендә команданнар, забитлар хан өенең ишеге төбенә дәрәҗә-дәрәҗә тезелгәннәр.* Г.Исхакый. *Янымызда бер забит, даим безнең илә бергә гизеп, безгә күп тәфсыйлатлар бирде*. Г.Камал

**ЗАБИ́Т КЫЛУ** *ф.* Кулга кертү, үз милкенә әверелдерү, җыю. *Сөхбәт, вә туй, вә уенны – Җүчигә, хөкем итмәк вә тоттырмакны – Чыгтайга, мәмләкәт малын саклап забит кылмакны – Үгедәйгә, вә гаскәр тәртибен Тулигә тапшырган иде*. Ә.Баһадир

**ЗАБОЙ** *и. рус* Шахтада күмер чабу яки руда чыгару урыны. *Забойлар янында эшчеләр вагонеткаларга күмер төяп, магистраль буйлап этеп алып китәләр.* Ш.Камал. *Син юк инде, Ләкин әле дә тора Син эшләгән барча забойлар, Әле дә шунда күмер казыйлар Безнең күрше Гобәй абзыйлар.* Ш.Маннур. *Крестьяннарны рудниклардан, забойлардан айлар буена җир өстенә чыгармыйлар.* Р.Әмирхан

**ЗАБО́Й КИСҮ** *ф. к.* **забой чабу**. *Илле тиен өчен кан гыжлап забой кисәм лә мин.* Ш.Камал

**ЗАБО́Й ЧАБУ** *ф.* Забойда күмер чабу, руда казу

**ЗАБОЙЧЫ** *и.* Забойда эшләүче, забой чабучы, күмер яки руда чыгаручы кеше

**ЗАБОЙЧЫЛЫК** *и.* Забойчы һөнәре; забойда эшләү, күмер яки руда чабу белән шөгыльләнү

**ЗАБО́ЙЩИК** *и. рус к.* **забойчы**. *Гәрәй аңа расчёт бирә икән, аның бер дә исе китми, менә дигән забойщик ич ул.* Ш.Камал. *Алар урынына техник һәм берничә забойщик кереп, югары китәләр.* Һ.Такташ

**ЗАБЫТ** *и. гар. иск.* 1) Биләү

2) Үзләштерү, кулга төшерү

3) Кулга алу

4) Басып алу, сугышып алу

5) Буйсындыру. *Каләмне забыт итеп вирдем, ниһаять.* Г.Тукай

6) Беркетмәгә теркәү, язып кую

**ЗАБЫ́Т КЫЛУ** *ф.* Басып алу, сугышып алу. *Вакыты илә бөтен дөньяны забыт кылган Искәндәрләр, Наполеоннар, --- телеграф, телефоннарны иҗат иткән Эдиссоннар, философ Шекспирлар, Вольтерлар --- анадан туганда ук мәгълүматлы булып тудылармы?* Ш.Мөхәммәдев. – *Вә миңа еллык хираҗ күндереп, минем хәзинәмә тәслим итмәк кирәксең. Әгәр «юк» дисәң, барып, илеңне, мәмләкәтеңне забыт кыйлып, үзеңне мәгъдүм итәрмен, – диде.* К.Насыйри

**ЗАБЫТНАМӘ** *и. гар.-фар. кит. иск.* Беркетмә

**ЗАВ** *и. рус сөйл.* Мөдир. *Әй... юкка талашасыз, зав абый бер олау киез итек алып кайтты.* А.Алиш. – *Сабитов үзе бирედә. Хәзер. – Гарипов трубкасын куйды да, – әйдәгез әле, зав чакыра, – диде.* Ф.Садриев. *[Шәкүр:] Зав та бәладән котылды, мин дә...* М.Әмир

**ЗАВКОМ** *и. рус тар.* 1) Профсоюзларның завод комитеты. *Безнең завком һәм цех ячейкалары бик әкрен кыймылдыйлар.* Ш.Камал. *Ячейкага чаба, завкомга да, Өенә кайта Хисмәт кич кенә.* Ш.Маннур. *Аннары сиңа ничек тә эшлибез, завком аркылы булса да, дип тынычландыралар.* Н.Хәсәнов

2) *сөйл.* Завод комитеты белән җитәкчелек итүче, завод комитеты җитәкчесе. *Мин завком белән сөйләшеп алыйм.* Ш.Камал

**ЗАВОД** *и. рус* 1) Эре сәнәгать һәм һөнәрчелек предприятиесе. *Нәгыймә һәр шимбә саен, башка хатыннар кебек, завод капкасына баруны үзенә гадәт итте.* Г.Ибраһимов. *Ул ит комбинатын, сабын заводын, әзерләүчеләр конторасын йөк атлары белән тәэмин итте.* Р.Вәлиев. *Сигез ел эшләп, ияләшеп беткән заводны ташлап чыгасы килми иде аның.* И.Гази

2) Яхшы токымлы, нәселле хайваннар үрчетә һәм үстерә торган хуҗалык. *Гөлчәчәк бәхетенә, урман буенда иң яхшы юртаклардан гына торган ат заводы да ачылган иде.* З.Хөснияр

**ЗАВОДЧЫ** *и.* 1) Завод хуҗасы; завод тотучы кеше. *Урыс дворяннарына, сәүдәгәрләренә һәм заводчыларына башкорт далаларында үзләре телләгән урында һәм кирәк кадәр җирне үзләштерергә ирек бирә.* Р.Әмирхан.

*--- заводчылар, үзләренең соңгы маллларын сатар өчен базар эзлиләр.* Урал

2) Заводта эшләүче кеше

**ЗА́ВУЧ** *и. рус* Мәктәп, училище, техникумда уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары. *Хәзергә Наилгә әллә ни кисәтү ясамый, ә завучка чакыртырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килә.* А.Әхмәт. *Озын буйлы, киң җилкәле, бераз алга сөрлегеп атлый торган өлкән завуч мине сыйныфым янына озатып куйды.* Р.Хәбибуллина. *Мин сезнең өстән завуч Кадыйр абыйга керәчәкмен. Мәсьәләне мин дөрес чишкән идем.* В.Нуруллин

**ЗА́ВУЧЛЫК** *и.* Завуч хезмәте, завуч вазифасы, завуч булу

**ЗАВХОЗ** *и. рус* Нинди дә булса предприятие, оешма, учреждениедә хуҗалык бүлеге мөдире. *Шушы путёвка буенча завхоз машина частьларын эзләргә чыгып, район буенча колхоздан колхозга чабу эшенә керешкән иде.* М.Әмир. *Җитмәсә, мәктәпнең завхозы авырып китте, завхоз – карт кына бер абзый.* Г.Әпсәләмов. *Әхмәт балалар йортының контора сыман бүлмәсендә үзенең завхозы белән хуҗалык исәп-хисаплары тикшереп утырган чагында, Фәтих килеп керде.* Ш.Камал

**ЗАВХОЗЛЫК** *и.* Завхоз хезмәте, завхоз вазифасы, завхоз булу. *[Рәдиф] Колхозда эшләп карарга кирәк бераз, дигән булып, шыпырт кына завхозлыкка урнашты.* В.Нуруллин. *– Председатель өстеннән йөри, юньсез, – дип сүгенде Әхмәт. – ...Завхозлыктан төшергәннәр, шуңа үчегеп йөри.* А.Гыйләҗев

**ЗА́ГОВОР** *и. рус* 1) Билгеле бер (гадәттә сәяси) максатка ирешү өчен, берничә кешенең бергәләп эш итү турында яшерен килешүе; фетнә. *Чит илләрнең шушы провокациясе нәтиҗәсендә, Тухачевский, Якир һәм башкаларның хәрби заговоры барлыкка килә.* Д.Шәрәфетдинов

2) *күч. сөйл.* Кемгә дә булса дошманлык йөзеннән, үч итү өчен сүз куешу, сүз беркетү. *--- күзгә-күз очрашу вакытында, [ул] заговорда катнашкан башка иптәшләрен дә фаш итте.* Д.Шәрәфетдинов

**ЗА́ГОВОРЧЫ** *и.* Заговор оештыручы яки шунда катнашучы кеше. *Заговорчы булмаганга һәм шуңа күрә алар белән заговорга кагылышлы бернинди элемтә булуы мөмкин булмаганга, минем советка каршы хәрби заговорда катнашуым хакында күрсәтүләрем – үземә-үзем яла ягу.* Д.Шәрәфетдинов

**ЗА́ГОВОРЧЫЛЫК** *и.* Яшерен рәвештә оештырылган фетнә, фетнәчелек

**ЗАГОТ-** *рус Заготовительный* сүзеннән, «авыл хуҗалыгы продуктларын әзерләү» мәгънәсен аңлата торган кушма сүзләрдәге беренче кисәк (мәс., *заготзерно, заготпункт*). *Нәрсә, конфликт килеп чыктымы әллә? Заготзерно сезне тыңларга теләмиме?* Г.Ахунов. *Заготзерно белән җир бүлегендә эшен бетереп, озакламый кайтачагын язган иде.* Г.Бәширов. *Язын ипиең бетсә, Ташлытауга барып, я заготзернода, я типографиядә төнге сменада эшләргә мөмкин.* М.Мәһдиев

**ЗАГОТО́ВКАЧЫ** *и. сөйл.* 1) Авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алу эшен оештыру һәм урнаштыру белән шөгыльләнүче кеше

2) Эш өчен материал әзерләп бирүче кеше

**ЗАГС** *и. рус* Гражданлык хәлендә булган үзгәрешләрне (туу, үлү, өйләнү, аерылу) теркәү идарәсе (*русчадан кыскартылма:* **запись актов гражданского состояния**). *Ә биш көннән загс белән тормыш башланды...* Һ.Такташ. *Ә «Мәдинә иптәш» белән загста язылырлык та, бергә кайтырлык та һәм шулай ук аерым-аерым кайтырлык та эш булганы юк ич әле.* Ш.Камал. *Баштан театрга, ди, киногa барыйк, ди, аннан, загска, ди башлый.* Р.Ишморат

**ЗАДА́НИЕ** *и. рус сөйл.* Алдан ук билгеләнеп куелган, тапшырылган эш. *Өстәвенә, ул эшли башлаган елны ук табигать шартларының да туры килүе, дәүләткә ашлык сату заданиесен дә төгәл башкарып чыгарга мөмкинлек бирде.* Г.Ахунов. *Минем пионер ул заданиене ударникларча башкарып чыккан.* М.Әмир. *Мин – бу районга обком заданиесе белән җибәрелгән кеше.* Н.Акмалов

**ЗАДА́ТКА** *и. рус сөйл.* Сатып алына торган әйбер, мөлкәт өчен түләнәчәк тулаем акчаның алдан бирелә торган өлеше; аванс. *Задатка акчамны сорый башлагач, теге ике марҗа, задатканы кайтармау юлында булырга кирәк, шул кадәр колак төбемдә чиреләп кычкырырга тотындылар.* Г.Тукай. *– Күпме задатка алган идең? – дип сорады Һидият.* Ш.Камал. *Бай, алардан задатка алмыйча, чәйне төшерергә кушмады.* Г.Камал

**ЗАДӘ** *и. фар. иск.* Ир бала, ул, углан; патша улы. *Мисыр шаһзадәсе хан кызын күрергә өмид кисте.* Р.Гали. *Үтәмеш ханзадә Сөембикәнең күптәннән көтеп алган бердәнбер углы була.* Р.Батулла

**ЗАЕГЪ** *рәв. гар. к.* **заигъ.** *Һавада йолдыз ничәдер, Ничә генә баксаң, күчәдер; Ничә айлар, ничә еллар Гомерләрем заегъ кичәдер.* Җыр

**ЗАЕ́ГЪ БУЛУ** *ф. к.* **заигъ булу**. *--- кадер белмәгән кешегә изгелек итмә, тозлавык җирдә орлык заегъ булган кебек, изгелек кадерен белмәгән кешегә изгелек кыйлсаң, изгелек заегъ булыр.* К.Насыйри

**ЗАЕ́ГЪ ИТҮ** *ф. к.* **заигъ итү**. *«Бәдәвам», «Йосыф китаплары» белән балаларның газиз гомерләрен бушка заегъ итәбез.* Ш.Мөхәммәдев. *Мин үлгәннән соң, вакыт заегъ итми, басуыбызга барыгыз, һәр җирен яхшылап казып актарыгыз.* Дәрдемәнд

**ЗАЁМ** *и. рус* Кире кайтару шарты белән дәүләт бюджетына башка илдән яки халыктан бурычка акча җыюның бер төре. *Иптәшләр, монда ашлык әзерләү, заём тарату турында базарга килгән крестьяннарга кыска гына доклад булачак, озак тотмабыз, сезне ялыктырмабыз.* М.Гафури. *Иртән әнисе, орден-медальләр саклана торган шул сандыктан, мең тугыз йөз кырык җиденче елгы бер төргәк заём облигацияләре тартып чыгарды.* Р.Мирхәйдәров. *Сабир, Фәрхуннардан, салым-ясак, заёмнардан качып, Донбасс ягында шахтёр булып, Исламнур әйбәт тә эшләгәндер, ни әйтсәң дә, ул ялгыз калган әнисенә гел акчалата да --- ярдәм итеп килде.* Р.Батулла

**ЗАЖИГА́ЛКА** *и. рус сөйл.* Ут алу, ут кабызу әсбабы. *Яндырырга шәм дә, лампа да булмагач, чиратлап зажи-*

*галка яндырып, ярты төнгә кадәр уйнадылар.* М.Гали. *Зажигалкасын аның кулына тоттырды: – Иртәгә кертерсең, бүләккә дип алган әйбер бу, – диде.* Н.Акмалов. *Абайламый батып китү куркынычы булганлыктан, лейтенант зажигалкасын кабызды.* Г.Әпсәләмов

**ЗАИГЪ** *рәв. гар. иск.* Әрәмгә, бушка, файдасызга, кирәксезгә; зая

**ЗАИГЪ БУЛУ** *ф.* Югалу, юкка чыгу, юк булу. *Аюга чәнчи торган сөңгесе, нәселеннән Габдулла дигән кешедә күп еллар сакланып, соңыннан кайдадыр заигъ булган.* Гасырлар авазы

**ЗАИГЪ ИТҮ** *ф.* Әрәм итү, бушка үткәрү; мәгънәсез сарыф итү (гомер, вакыт һ.б. турында). *[Миңлебай] Унҗиде яшенә кадәр мәдрәсәдә укыса да, --- әтәч сугыштыру шикелле уеннар берлә мәшгуль булып, «Кисекбаш китабы» шикелле гомер заигъ итә торган китаплар укып, һөнәр вә мәгърифәттән мәхрүм калган.* Ш.Мөхәммәдев. *Калган бер-ике елында «Кисекбаш», «Бәдәвам», «Кызыл алма», «Фәзаилеш-шөһүр» кеби һич файдасыз китаплар укытылып, гомерләре заигъ ителәдер.* Ф.Кәрими

**ЗАИГЪ КЫЛУ** *ф. к.* **заигъ итү**. *[Ата-ананың] Хезмәтләрен заигъ кылма, надан булып.* М.Колый

**ЗАКАЗ** *и. рус* 1) Берәр төрле эшне башкару турында сорап, телдән яки язма рәвештә махсус мөрәҗәгать. *Ләкин без, бу сәяхәттән кайту белән шул социаль заказларны үтәрлек материаллар алып кайта алдык, дип әйтә алмыйбыз.* Һ.Такташ. *Әнисе хаты ялга китеп барыр алдыннан гына килеп төште, юллама Рушанның кулында, һәм билетка заказ да бирелгән инде.* Р.Мирхәйдәров. *Ул якын араларда «Казмаш»ка яңа зур заказ бирелү мөмкинлеген --- әйтте.* Г.Әпсәләмов

2) *сөйл.* Махсус сорау, мөрәҗәгать буенча эшләнгән, алынган әйбер, кушылган эш. *Фәхрия апа безнең Гыйлаҗ байның кибетенә заказлар биргән икән, шуларны китердем.* Т.Гыйззәт

**ЗАКАЗЛЫ** *с.* Нәрсә дә булса яки нинди дә булса эш сорау, кушу буенча эшләнгән. *Заказлы үтерүләрдән бушаган арада – ә ул үз «эше» өчен йөз меңнән дә ким алмаган – «яшь бүреләр» арасындагы низагларны-бәхәсләрне хәл итү юлы белән акча эшли.* Казан утлары

**ЗАКАЗНОЙ** *с. рус сөйл.* Адресатның үз кулына тапшырылу, барып ирештерү өчен җаваплылыгы арттырылган. *Тиешле хакын бирерсез һәм безгә почта илә --- кечерәк посылка кылып --- заказной хат булса да җибәрерсез.* Ш.Мөхәммәдев. *Кара аны, заказной итеп җибәрсеннәр, юлда югалырлык булмасын.* В.Нуруллин

**ЗАКАЗЧЫ** *и.* Берәр төрле эшне эшләргә заказ бирүче, заказга эшләтүче кеше. *Әгәр бу эш иптәшлек нигезендә башкарылса, ягъни бүрек заказчы материалыннан тегелсә, монысын закон тыймый.* Р.Вәлиев. *Заказчыны табасың, килешү төзисең, аннан бераз аванс акчасы аласың ---.* Ә.Сафиуллин. *Ул бит, түләүле үтерүчеләрнең байтагы турында сөйләп бирсә дә, бер генә заказчысының да исемен әйтмәгән.* Казан утлары

**ЗАКЛАД** *и. рус* Бурычка акча, әйбер алганда яки бәхәсләшкәндә, кире кайтарып бирергә ышандырып калдыра торган акча яки берәр әйбер, мөлкәт. *Япон бурычка акча аладыр, Җирләрен заклад саладыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Бер дә заклад алмыйча гына биш тиен чыгарып бирде һәм дә бурыч итеп бирмәгәнлеген аңлатты.* Ш.Камал. *Беребез ләй анда, беребез ләй монда, Закладларга гына салган, Абау, бәгърем, мал кебек.* К.Тинчурин

**ЗАКЛАДЧЫ** *и.* Закладка салып торучы, закладка акча, берәр әйбер яки мөлкәт бирүче кеше

**ЗАКЛЁПКА** *и. рус тех.* Ике металл кисәген беркетү өчен кулланылган, бер башы җәлпәк, эшләпәле, икенче башы чүкеп җәелә торган очсыз металл кадак. *Кирәкле инструментларны алып киләсең, баржа корпусларын җыйганда, табаклы тимерләр җилкәңнән үтә, заклёпка вакытында чүкеч сугасың, чүкечне кувалда алыштыра, бик тирләсәң, мастер күзеннән шыгаеп, тиз генә чумып аласың.* Ф.Хөсни

**ЗАКЛЁПКАЛАУ** *ф. тех.* Заклёпка салу, заклёпка ярдәмендә беркетү. *Тимер көрәкне заклёпкалау*

**Заклёпкалап кую** Тиз арада яки алдан заклёпкалау

**ЗАКОН** *и. рус* 1) Югары дәүләт хакимияте тарафыннан кабул ителеп, юридик көчкә ия булган, үтәлүе һәркем өчен мәҗбүри саналган норматив акт, канун. *Совет законнары суд залында Һава ярып яңгырап китәләр, Аны бүген хөкем итәләр.* Һ.Такташ. *Суд юлында йөргән кешеләр закон – ерак, йодрык – якын икәнен үзләре күреп, татып белә.* Татарстан яшьләре. *Республика законы нигезендә, дәүләт экология экспертизасы үткәрү тәртибен Татарстан Министрлар Кабинеты билгели.* Мәдәни җомга

2) Үтәлүе мәҗбүри, катгый булган боерык яки тапшырылган эш. *Аның сүзе закон, авторитеты тиңдәшсез, даны күзләрне чагылдыра иде.* Г.Әпсәләмов. *Аның законнары минем яки синең кәеф белән генә исәпләшеп тора алмый.* Ф.Хөсни

3) Җәмгыятьнең аерым кешеләре арасында, коллективта гомум кабул ителгән үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; карашлар, зәвык, гадәт, традиция. *«Акчарлаклар»ның бәхет теләргә хаклы ике яшь, матур һәм эшчән эшче каһарманы әнә шулай тойгысыз тормыш законнары алдында көчсез калалар.* Г.Нигъмәти

4) Тормышта, табигатьтә төрле күренешләр, предметлар арасындагы зарури, эчке объектив бәйләнеш. *Тик табигать законнары буенча өзлексез хәрәкәт итү аркасында, аның формалары гел алмашынып, үзгәреп тора.* Ш.Камал. *Ләкин ничек кенә булмасын, командирның хәзер генә әйткәннәре чынмы-ялганмы, физика законнарына туры киләме ул, юкмы, әмма Федько юлыккан бу гаять сәер хәлне берникадәр аңлаткан кебек булды.* Ә.Еники

◊ **Законга керү** Закон көчен алу, закон булып кабул ителү. **Законнан тыш** Законга буйсынмый торган, законны исәпкә алмый торган. *Билгеле булганча, 1917 елгы июль көннәреннән соң, Вакытлы хөкүмәт Ленинны «законнан тыш кеше» дип белдерә.* Т.Нәҗмиев. **Закон юк** *к.* **закон язылмаган. Закон язылмаган** Бернинди кагыйдә, мәҗбүри нормалар, чикләүләр юк. *Җүләргә закон язылмаган.* Мәкаль

**ЗАКОНЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Закон нигезендә раслау, рәсмиләштерү; закон

көче бирү, закон белән ныгыту, законлы итү. *Авыл халкы тарафыннан үз исеменә бирелгән вәкаләтнамә морзага вексельдәге Әкрәм карый имзасын законлаштыру, тасдыйк итү өчен кирәк булыр, дигән уй бу минутта аның башына да кереп карамады.* М.Галәү. *Нигезне законлаштырырга килгәч, сельсовет Мөхлис сораган моңардан: «Сәрви сеңел, безнең Чәтрән нәрсәсе белән тартты соң сине?»* С.Хафизов. *Бу төркемнәрнең кешегә хисапсыз хәсрәт китерүен, явызлык, көчләүне законлаштыруын --- без әле һаман да ахыргача аңлап бетермибез.* Идел

2) Гадәткә кертү, традициягә әйләндерү

3) Гражданлык мөнәсәбәтләрен закон нигезендә теркәү, рәсмиләштерү; язылышу. *Никах – татар халкында өйләнешүне дини яктан законлаштыру процессын, ягъни дини йоланы белдерә торган сүз, һәм ул якынча руслардагы «венчание» сүзенә туры килә.* Р.Юсупов

**Законлаштыра бару** Һәр очракны берәм-берәм законлаштыру

**Законлаштырып алу** Тиз арада закон көченә кертү

**Законлаштырып бетерү** Тулысынча, ахырга кадәр законлаштыру; барысын да законлаштыру

**Законлаштырып килү** Электән үк, системалы законлаштыру. *Искәндәр нәкъ шул вакытта үз шартларын куеп, тәртипсезлеген законлаштырып килгән, диләр.* М.Кәбиров

**Законлаштырып кую** Нәрсәне дә булса алдан законлы итү, аңа алдан ук закон көче бирү. *Ләкин инде эшне бар яктан да законлаштырып куйганнан соң, бу машина алай ук торамы дип, калганының бик азын гына бирмәкче булган.* Ә.Сафиуллин

**ЗАКОНЛАШУ** *ф.* 1) Закон көчен алу, законга әйләнү, рәсмиләшү. *Кагыйдә законлашкан*

2) *сөйл.* Ныклап урнашып, гадәт булып китү; кагыйдәгә әйләнү

**Законлаша бару** Торган саен ныграк закон көче алу. *Тагын да аянычрагы шул: бу гамәл [«спонсорлык» исеме алган шикле шөгыль], бу омтылыш көчәя һәм ныклап законлаша бармакчы.* Ә.Баянов

**Законлашып килү** Акрынлап, аз-азлап закон көчен алу

**ЗАКОНЛЫ** *с.* 1) Законга нигезләнгән, закон белән ныгытылган, законга туры килгән. *Европалыларның гыйлем хәзинәсенә үтеп кереп, андагы җәүһәрләрне эләктерү – законлы чәлмеш, законлы урлау бу.* Т.Нурмөхәммәтов. *Чиксез кыйммәтле бу байлыклар, Дрезден галереясының бинасы торгызылгач та, законлы хуҗасына – ГДРга кайтарылган.* Ш.Рәкыйпов. *Әгәр Мәдәният министрлыгы китапханәләрне ябарга карар итсә, үзебездән акча табачакбыз --- дип әйткән, ди, Р.Вәлиев. Район җитәкчеләренең моңа законлы хакы бар.* Татарстан яшьләре

2) Гадел, дөрес, нигезле, урынлы. *Бу урында законлы һәм бик принципиаль сорау туа: сәнгатьнең һәм поэзиянең беренче нигезе булган мифологиянең башлангыч-генетик җирлеге нинди булган соң?* М.Бакиров

3) Объектив канунnarга буйсынган, килеп чыгышына, табигатенә туры килгән. *Барлык телләрдә дә һәр сүз диярлек күп мәгънәле. Полисемия – ул законлы күренеш.* И.Низамов

4) *сөйл.* Закон нигезендә рәсмиләштерелгән, рәсми теркәлгән. *Аннары, беренче эш итеп, үз кешеләренә һич көтелмәгән хәбәр салды: бүгеннән башлап мәңге-бакыйга Тося Скавронская аның законлы хатыны булачак.* З.Фәтхетдинов. *Һәр биш гаиләнең нибары берсе генә «нормаль», ягъни законлы никахтан туган балаларын тәрбияләүче гаилә.* Сөембикә

**ЗАКОНЛЫЛЫК** *и.* Законлы (*1 мәгъ.*) булу, законга нигезләнгәнлек. *Әмма, безнең уйлавыбызча, хокук тәртибе һәм законлылык --- баштан ук социаль-сәяси, дәүләт күләмендәге мәсьәлә булып каралырга тиештер.* Казан утлары. *Федераль законның 15 нче маддәсе буенча иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеге тигез хокуклылык һәм законлылык принципларына нигезләнә.* Мәдәни җомга

**ЗАКОНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Законлаштырылмаган, законга каршы килгән, законга туры килми торган. *[Зөлфәт] Законсыз корал тотканы һәм шуның белән җинаять кылганы өчен хөкем алдына басты.* Г.Галиев. *Ләкин ул Казан мәчетләрен, мәктәпләрен яндырып бетерә, бистәнең икегә бүленүенә ирешә һәм башка бик күп законсыз гамәлләр кылып, татарларны изә, эзәрлекли, кыйнап үтерүләргә кадәр барып җитә.* С.Алишев

2) Юридик яктан рәсмиләштерелмәгән, закон белән ныгытылмаган; никахсыз. *Мин инде сабый түгел бит. Төшенәм. Әллә?.. Әллә мин законсыз туган ташландык баламы?..* И.Салахов. *Гадәттә «җилдән туган» законсыз балага гына анасы исемен фамилия итеп куялар бит!* Г.Бәширов. *Ул үзенең законлы ирен түгел, законсыз сөяркәсен көтә ләбаса!* Ә.Баян

3) *сөйл.* Урлап алынган, алдау юлы белән үзләштерелгән. *Чит сәүдә маркасын законсыз кулланучыга 400 минималь хезмәт хакына кадәр штраф салу --- күздә тотылган.* М.Вәлиев. *--- бу квартираның Татьяна Якимова һәм ире Чепчиков тарафыннан бөтенләй законсыз, алдау юлы белән үзләштерелгән икәне ачылган.* С.Баттал

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Законга каршы килеп, закон таләпләрен үтәмичә. *--- үзебезнең законлы оешмаларда кеше исемен законсыз бозып утырабыз икән!..* Х.Сарьян. *Ләкин ипи белән законсыз сәүдә иткән өчен аңа – Елтыр Кашапка, Сабирҗан муллага, башкаларга караганда, җәзаның зурысын бирделәр.* М.Маликова. *Боларга кеше үтерү, кеше сәламәтлегенә аңлы рәвештә җитди зыян салу, --- законсыз автомобиль белән идарә итү, кеше әйберенә аңлы рәвештә зыян салу --- керә.* Ә.Сафина

2) Законлаштырылмыйча, юридик яктан рәсмиләштермичә. *--- әби сезнең хатыныгыз түгел, сез аның ире түгел. Илле җиде ел буе законсыз яшәгәнсез.* Т.Миңнуллин

**ЗАКОНСЫЗЛЫК** *и.* Законны бозу күренеше, законнарга каршы килү, законга буйсынмау. *Һәрхәлдә, хәзерге җәмгыятьтә урнашкан бу кадәр тәртипсезлеккә, тигезсезлеккә, законсызлыкка, вәхшәткә чик куелырга тиеш!*

Р.Фәизов. *Бу турыда бәхәс күтәрүчеләр булмады, бары тик шул кадәр озак вакыт бу законсызлыкның яшәвенә һәм аны күрмәүләренә генә гаҗәпләнделәр.* А.Шамов. *Эстәрлетамак сәүдәгәрләр җәмгыяте, С.Рәмиевне яклап, мөфтине законсызлыкта гаепләп – губернаторга, аннан җавап алмагач, юстиция министрына гариза язалар.* Татар әдәбияты тарихы

**ЗАКО́НЧА** *рәв.* Законга нигезләнеп, законга туры китереп, законда каралганча. *Сабирҗан, язылышыйк, дигәч, каршы килмәдем. Закончa булсын, ди торгандыр.* Т.Гыйззәт. *Законча эшлим, дигән булып «хаталана» да, хокук сагындагы юньлерәкләрнең һәркайсы кебек, кагылырга ярамаган затка юлыга.* Р.Шәрәфиев

**ЗАКОНЧАЛЫ** *с.* **1.** Табигать, җәмгыять законнарына, кануннарга туры килгән, табигый, нигезле. *Димәк, нинди генә формада булмасын, традициялелек – стилистик яктан да үзен сиздерүче закончалы күренеш.* М.Җәләлиева

**2.** *рәв. мәгъ.* Табигать, җәмгыять законнарына, кануннарга туры китереп. *Безнең борынгы бабаларыбызга әйләнә-тирәләрендәге барлык үзгәрешләр очраклы хәл, буталчык алмашыну булып тоелган. Чынлыкта исә, табигатьтә бөтенесе закончалы корылган.* Серләр пәрдәсен ачсак

**ЗАКОНЧАЛЫК** *и.* 1) Законлы булу, законга нигезләнгән булу. *Закон, закончалык, кагыйдә, йола, гадәтләр системасы булганда, ничек абсолют ирек була алсын?* Р.Батулла

2) Объектив законнарга бәйләнгән булу. *Билгеле ки, дөньяда һәр нәрсә мәгълүм закончалыкларга, кануннарга буйсынып яши.* С.Шәмси. *Дөньяның, тарихи үсешнең чын барышын аның эчке закончалыклары хәрәкәте ягыннан тану – бу үзе бер сөенеч, шатлык, кешенең чын мәгънәсен, чын вазифасын аңлауда бер бөек ачыш иде.* Х.Госман

3) Кагыйдә, логик эзлеклелек; үзара тыгыз бәйләнештә булу. --- *ораторлык прозасының мондый табигате һәм специфик ритмга ия булуы грек-латин телле текстлар өчен дә, шулай ук урыс матур сөйләме өчен дә уртак һәм гомуми закончалык буларак характерлана.* М.Бакиров. *Монда нинди дер бер явыз закончалык эш итә...* М.Мәһдиев

**ЗАКОНЧАЛЫКЛЫ** *с.* Объектив законнарга нигезләнгән, законлы булган, үзгәртеп булмый торган. *Әгәр моны закончалыклы күренеш, табигый халәт итеп кабул итсәк, бернинди аңлашылмаучылыкка урын калмый.* Р.Әмирхан. *Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын игълан итү татар халкының милли тәрәзелүгә таба барышында закончалыклы этап булды.* М.Хәсәнов. *Урта гасыр әдәби әсәрләренең фольклор белән бәйләнеше – закончалыклы күренеш.* Татар әдәбияты

**ЗАКОНЧАЛЫЛЫК** *и.* Закончалыклы булу. *Фәнни фикерләүнең нигезендә закончалылыкны, ягъни даими рәвештә кабатланып торган сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу процессы ята.* Кызыклы психология

**ЗАКОНЧЫ** *и. сөйл.* 1) Законнар чыгаручы юридик зат. --- *Сатылмаган нәрсә калмады. Судья – хөкем, Патша халкын сата, Закончылар закон саталар. Ораторлар ялган пафос сата, Министрлар портфель саталар.* Г.Афзал

2) Гомумән, закон кагыйдәләрен тирән белгән, аларны тормышта куллана белгән зат. – *Үзең дә беләсең, – диде Сәгыйт абзый минем бу соравыма каршы, – Әхмәтҗан Сәйдәшев элек-электән --- дипломсыз аблакат (адвокат), закончы булып килгән.* С.Рәмиев. *Хәзерге байлар төзегән йортка карасаң исең китә. Һәрберсе безнең авылның клубы хәтле. Кая карый закончылар?!* З.Дәүләтов

3) Тормыш-көнкүрештә закон таләп-күрсәтмәләрен саклаган, законга хилафлык китерми яши торган кеше

4) *куч.* Кайда да булса читтә, үзе булган җирдә үз тәртипләрен урнаштырырга теләүче кеше. – *Син, килүең белән, монда закончы булма! – дип кычкырып салды.* А.Таһиров

**ЗАКОНЧЫЛ** *с. к.* **законлы**. --- *боларның барысын да без, бәрелми-сугылмый, кеше өлешенә керми, тыныч, закончыл демократик формаларда тормышка ашырырга ниятлибез.* Р.Әмиров

**ЗАКУ́СКА** *и. рус* Аппетитны ачу яки эчемлек артыннан кабып кую өчен әзерләнгән салкын ашамлык; кабымлык. *Анда һәрвакытта закускага тозлы кәбестә, тозлы кыяр, торма, балык – шундый нәрсәләр генә китерәләр.* Г.Камал. --- *получка көннәрендә аракы белән арзанлы закускалар ташу --- аңа йөкләнде.* К.Нәҗми. *Без өстәл өстен тутырган күп төрле закускаларны капкалаган арада, Низами тагын берәрне салып куйды.* М.Әмир

**ЗАЛ** *и. рус* 1) Җыелыш, лекция, концерт һ.б. шуның кебек күмәк чараларны уздыру өчен билгеләнгән, күп кеше сыешлы зур бүлмә. *Рабфак кичәсендә, Зал эчендә ул да бар, Әүвәл авыл улы иде, Хәзер – комиссар.* Һ.Такташ. *Бөтен зал, сулыш алмастан, үлем тынлыгы эчендә аны тыңлый иде.* Г.Ибраһимов. *Миндәге ярсулы халәт зал тутырып биегән яшьләргә дә күчә.* К.Булатова

2) Берничә бүлмәле шәхси торакта ял һәм кунаклар кабул итү өчен билгеләнгән зур бүлмә, кунак бүлмәсе. *Әминә Хәятны залда озак тотмады, үз бүлмәсенә алып чыкты.* Ф.Әмирхан. *Алар өчәүләшеп залга кергәндә, Әбүзәр абзый башын салындырып, иңенә шакмаклы җылы шәл салып диванда утыра иде.* Г.Әпсәләмов. *Кунак хатын, тынгысызланып, бер залга, бер Айсылу белән Тимергә карап алды, муенсасына кагылып куйды да урыныннан торды.* Г.Ахунов

**ЗАЛИМ** *с. гар.* **1.** Изүче, җәберләүче; явыз. *Җитәр инде, күп йокладык, Уяныгыз, туташлар! Залим ирләр аркасында Ни күрмәде бу башлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Хан мәшһүр шәехнең сүзен игътибарсыз калдырмый, гаскәр туплап, залим хөкемдар өстенә яу чаба.* С.Шәмси

**2.** *и. мәгъ.* Мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, каты күңелле кеше, тиран. *Зәгыйфь, корбан булу артык, Ходаем, Булудан андый көчле һәм дә залим.* Г.Тукай. *Кан итәргә синең суларыңны Сиңа таба үрелә залимнәр.* Ә.Ерикәй. *Залимнең золымы берничә кешегә тия.* Г.Хөсәенов

**ЗАЛИ́МАНӘ** *рәв. фар. иск.* **1.** Залимнәрчә, мыскыллап, мәсхәрәләп. *Мәңге хәсрәткә салып, Язмышым белән нигәдер Залиманә уйный ул.* Һ.Такташ

**2.** *с. мәгъ.* Үтә явыз, мәрхәмәтсез. *Ул – Касыймның соңгы солтан-ханбикәсе... Булалганмы үз халкының җанбикәсе? Ханкирмәнгә, мөлкәтенә читләр хуҗа, Залиманә бу дөньядан ни көтәсең?* С.Әхмәтҗанова

**ЗАЛИМӘ** *и. гар.* Залим хатын-кыз. *Әй нәфсеңезгә золымлык кыйлучы егетләр! Вай, явыз вә залимә хатыннар! Бу гыйсъяныңыз белән мөселман исемен күтәрәсез. Мөхәммәд галәйһиссәламнән оялмайсызмы?* К.Насыйри

**ЗАЛИМЛЕК** *и.* Залим булу; явызлык, үтә мәрхәмәтсезлек. *Дөньяны залимлек белән тулган дип, үземне исә шул залимлек каршында сыгылып төшкән бер мәхлук итеп исәпләгән көннәремдә сез минем химаячем булдыгыз.* Т.Нурмөхәммәтов. *Лотфи җизнәмнең рәхимсезлеген, залимлеген шуннан да күреп була иде: ул үзенең яшь хатынын --- балалар алдында хурлый иде.* А.Расих. *Әсәрләрендә алар семинариядәге тәртипләрне, --- кимсетү практикасын, укытучыларның наданлыгын, залимлеген фаш итәләр.* Татар әдәбияты тарихы

**ЗАЛИМНӘ́РЧӘ** *рәв.* **1.** Залимнәр кебек, явызларча, үтә мәрхәмәтсез, шәфкатьсез рәвештә. *Үзен залимнәрчә тоту*

**2.** *с. мәгъ.* Аяусыз, рәхимсез, кешелексез. *Ул чорда, иссез һәм төтенсез яна торган майлары өчен, китларга залимнәрчә ау киң җәелдерелгән булган, шуның аркасында китлар төр буларак аздан гына Җир йөзеннән юкка чыкмый калган.*Шәһри Казан

**ЗАЛИМЧЕ** *и. ялг. к.* **залим 2.** *Аллаһы Тәгалә Гафира улларына рәхмәтле булсын, алар өммәтнең фиргавенен, кяферләрнең атаклы залимчесен үтерделәр, мөселманнарны шул мәлгуньнән коткардылар.* Ф.Яхин

**ЗАЛОГ** *и. рус* 1) Алынган бурыч яки ссуданың ышанычлылыгын тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт. *Мухинның җәй көне --- түләргә акчасы җитмәгәнен, официанткага кул сәгатен залог салып, соңыннан барып алмаганлыгын белә иде Идрис.* Ә.Айдар. *Кан ялкынлы туй көненә кадәр Көрәш залогы без.* Х.Туфан

2) *икът.* Йөкләмәнең үтәлешен тәэмин итү өчен, кредиторга бирелгән мөлкәт. *Залогка төрле әйберләр – күчемле һәм күчемсез мөлкәт, әйләнештәге һәм эшкәртүдәге әйберләр һәм мөлкәткә ия булу хокукы салынырга мөмкин. Күчемсез милекне залогка салу аерым кагыйдәләр нигезендә башкарыла.* Мирас

3) Тоткындагы кешене (тоткынны) билгеле бер шартлар нигезендә вакытлыча азат итү өчен бирелә торган акча. *Атагыз хөрмәтенә менә анда ректә калган танышларыгыз сезнең өчен залог салмакчылар.* Г.Ибраһимов

**ЗАЛО́ЖНИК** *и. рус* Билгеле бер таләп, йөкләмәләр үтәлгәнгә кадәр ирексезләп тотылган кеше; тотык. *Надзирательләр, бу сигналны аңлап, заложник калдырмыйча, берьюлы коридорга ташландылар.* Г.Гобәй

**ЗАЛП** *и. нем.* Берьюлы берничә утлы коралдан (мылтыктан, туптан) ату. *Качу бетмәс борын ук, бик еш туп ату, аңа кушылган залп, сугышчы гаскәр тавышы бик каты, бик якыннан ишетелә.* Г.Ибраһимов. *Ындыр тирәсендәге канауларга яткан мадьяр роталары аны залп белән каршы алдылар.* Ш.Усманов. *Әйе, патша дворецы буена тезелгән солдатлар, патша приказы буенча, шушы коралсыз халыкка төзәп, өч рәт залп биргәннәр.* К.Нәҗми

**ЗА́ЛПЛАП** *рәв. хәрби* Залп белән, бердән, берьюлы атып. *[Австриялеләр] --- тау кабыргасына залплап атылган шрапнельләр яудыра башладылар.* А.Таһиров

**ЗАЛЯЛЬ** *и. гар. иск.* Туры юлдан язу, ялгыш юлга кереп китү, хата; азгынлык. *Хосусән, голямалар: «Әйе, шәргы шәриф хатын-кызны укыту заляль диеп әйтә инде», – дигән сүзләре белән бик каты могарәзәләр кылсалар да, аларның арасында рәтләп игътибарлары юккамы, әллә замана шуны үзе теләгәнгәме, хатын-кызда уку көннән-көн арта иде.* Г.Исхакый

**ЗАМА́ЗКА** *и. рус* Ярык, тишекләрне томалау өчен кулланыла торган, сыланучан үзле матдә. *Ишек катында бүлмәдә шактый биек, әтинең замазка баса торган сәкесе [урнашкан].* А.Расих. *Рамнарының ак буяулары һәм замазкалары купшакланып коелган.* Г.Исхакый. *Олиф урынына кайнатылмаган җитен мае алырга мөмкин, ләкин бу очракта, замазка тизрәк кипсен өчен, циклы яки аккургашлы ак буяу салырга кирәк.* Йорт эшләре

**ЗАМА́ЗКАЛАУ** *ф.* Замазка сылап томалау, замазка ябыштыру. *20 ләп тәрәзә рамын яңадан ясарга, 50 ләп рам төзәтергә, 100 күздән артык пыяла куярга, 500 күз пыяланы замазкаларга кирәк.* М.Гафури

**Замазкалап чыгу** Башыннан ахырына кадәр барысын да бер-бер артлы замазкалау

**Замазкалап кую** Алдан ук замазкалау

**ЗАМАН** *и. гар.* 1) Җәмгыять яшәешендә билгеле бер вакыт, чор, дәвер. *Әйтик, «Кара халык – кара сарык» мәкале капитализм чорында чыккан, дигәнгә каршы шунда ук кайтарып мондый сорау биреп була: ни өчен капитализм чорында? Ни өчен аның феодализм заманында яки тагын да элегрәк чыгуы мөмкин түгел?* Н.Исәнбәт. *«Татар идеясе» исә Бөек Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы заманнарында татарларның мөстәкыйль һәм көчле булуы турындагы хатирәләр белән бәйле.* Р.Хәкимов

2) Берәр күренекле шәхес (шәхесләр) яшәгән, аның эшчәнлеге белән аерылып торган чор. *Пётр Беренче заманыннан ук татарларга, «тимерче булмаска, матрос булмаска» дигән закон чыккан.* И.Низамов. *Күпме яшәтер икән ул аны Сталин заманында салынган биек түшәмле, киң тәрәзәле иркен фатирында?* Т.Галиуллин. *--- бу чор театр елъязмасына «Даутов заманы» булып кереп калды.* Ф.Сафиуллина

3) Кеше тормышында билгеле бер дәвер. *Студент заманыннан калган*

4) Нинди дә булса күренеш, эшчәнлек белән бәйле, нindидер хәрәкәт өстенлек иткән чор, вакыт. *Кискен үзгәрешләр, алмашынулар заманында кыйбласын югалтып, ышанычы какшап, каушап калучылар бар.* Ш.Галиев. *Эчкечелеккә каршы көрәш заманы*

5) Шәхескә бәрабәр дәвер, үзе яшәгән чорда, вакытта. *Аның бабала-*

*ры – чынлап та заманының зурлары.* Г.Ибраһимов

6) Вакыт, ара, мәл. *Бер заман сәгатьне чыгарып карасам, уникене узып киткән.* М.Әмир. *Үтә күренмәле, юка чынаяк китегенең нәфис бизәкләре өстенә оста куллар, бик килештереп, алтын белән нәрсәдер язган булган, ләкин, заман үтү белән, сүзләре ашалып беткән иде.* Г.Гобәй

7) *лингв.* Эш яки хәлнең сөйләү моментына карата вакыт мөнәсәбәтен белдерә торган фигыль формасы. *Дарвин һәм Павлов очраклы рәвештә генә: «хөкем итә алмыйбыз», «ышанычлы рәвештә белә алмыйбыз» дип, хәзерге заман фигыльләре белән язмаганнар.* Кызыклы психология. *Үткән заман эш яки хәлнең сөйләү моментыннан алда үтәлүен белдерә.* Татар теле грамматикасы

◊ **Заман җиле** Заманга хас вазгыять, тормыш шартлары. *Бер үк кояш һаман караса да, бер үк булмый заман җилләре.* Н.Нәҗми. *Заман җилләре аның тормышына да килеп кагылды*

**ЗАМАНА** *и. гар.* Хәзерге вакыт, яшәешнең хәзерге чоры. *Заманалар тыныч булса, иртәгә уянып китүеңә, кроватың тулы бүләк булыр иде.* Г.Гобәй. *Заманалар авыр чагында бер-беребезгә булышыйк, фронтка икмәкне күбрәк бирик, ди.* Г.Бәширов. *Безнең герой бер үк вакытта замана кешесе дә: телефоны, телевизоры бар, берничә радиоалгычы дөньяның барлык дулкыннарын тота ала…* Мирас

◊ **Замана кушканча** Хәзерге чор таләпләренә туры китереп, чор таләп иткәнчә. *Мин исә хатыныма бөтенләй булыша алмадым диярлек, чөнки бөтен көчемне, замана кушканча, илгә хезмәт итүгә бирдем.* Сөембикә

**ЗАМАНАЛАШТЫРУ** *ф. к.* **заманчалаштыру**

**Заманалаштыра бару** Акрынлап заманага яраклаштыру, җайлаштыру

**ЗАМАНАСЫНДА** *рәв.* 1) Ул заманда, ул чакларда, шул дәвердә; кайчандыр, элек. *Шибай карт заманасында кантон булып, башкортны күп талаган.* Г.Нигъмәти. *Ул заманасында казна урманы исәпләнгән.* Ф.Гарипова

2) *к.* **заман** (*2 мәгъ.*). *Сөембикә заманасында гыймарәт кыйлынып та, урыс архитектурасына охшаса, гаҗәп түгел: Казанның соңгы ханнары, әлбәттә, урыс калаларына барып йөреп, урыс гыймарәтләрен күргәннәре бардыр.* К.Насыйри

**ЗАМА́Н АХЫРЫ** *и. дини к.* **ахырзаман**. *Моңа кадәр Иртәштә әле бишегендә сөйләшә башлаган баланың туганы юк иде. Кемдер моны заман ахыры белән бәйләде, кемдер радиациянең кире мутациясеннән күрде.* Ф.Бәйрәмова

**ЗАМАНА́ЧА** *рәв. к.* **заманча**. *Яшьлек бит ул туктау белми, Кодрәтен һаман ача. Заманча эшлиләр алар, Ял итә заманача.* Х.Хөснуллин

**ЗАМАНДАШ** *и.* Бер-берсенә карата: бер чорда, бер вакытта яшәгән яки яшәүче кешеләрнең берсе, чордаш. *Шамил замандашның әтисенә бәйле хатирә-хикәятләре дә туган туфрак, туган җир, хәләл ризык һәм аның кадере төшенчәләре белән тыгыз үрелеп язылган.* Р.Шәрәфиев. *Замандашлары арасында, зур укымышлылыгы белән аерылып торган өчен, аны Мязгилдин дип тә йөртәләр.* Р.Әмирхан. *Коръән, тәфсир, фикһе гыйльмен искиткеч яхшы белүе белән замандашларының ихтирамын казанган.* Р.Ганиева

**ЗАМА́НЧА** *рәв.* **1.** Үз заманында кабул ителгәнчә, заманга хас рәвештә, үз заманы таләпләренә туры китереп. *Жуковский романтикасына сугылудан соң, бусы инде икенче чиккә тайпылып, үтә «кызыл», үтә заманча булырга тырышып ясалган бер селтәнү иде.* Ф.Хөсни. *Заманча итеп әйткәндә, бу – югары культуралы яшәешкә омтылыш.* Мирас. *Әйтергә кирәк, заманча сатып алу системасы – кредит карточкаларыннан файдалану – товар белән мавыгып китүне арттыра гына: акча янчыгы бушаганны «маньяк» абайламый да кала.* Мәгариф

**2.** *с. мәгъ.* 1) Хәзерге заман зәвыгына туры килгән. --- *һәйбәт, заманча алты почмаклы биек-биек йортлар салып җибәрделәр.* А.Гыйләҗев

2) Хәзерге заманга хас булган, хәзерге заманда актуаль булган. *Заманча җиһазларыбыз да бар: өр-яңа өч компьютер классы бар, барлык студентларыбыз да анда тулы әзерлек үтәләр.* Мирас. *Әсәрдә заманча эгоизмның башка яклары да сурәтләнә.* Мирас

**ЗАМАНЧАЛАШТЫРУ** *ф.* Замана таләпләренә туры китереп, яраклаштырып үзгәртү, яңарту, яңартып кору. *Хәтта халык җырларын заманчалаштыру, эстрадага яраклаштыру да халыкка файда китерми, дип саныйм.* Ватаным Татарстан

**Заманчалаштыра бару** Акрынлап заманага яраклаштыру, җайлаштыру

**ЗАМАНЧАЛЫК** *и.* Заманча булу, хәзерге заман таләпләренә туры килү. *Заманчалык, новаторлык тойгылары белән әсәрләнгән яшь шагыйрьләр дә, тәнкыйтьчеләребез дә лирика маршын алкышлап, традицион поэма, баллада --- кебек лиро-эпик жанрларны мәйданнан кысрыклау сәясәтен үткәрә башладылар.* С.Хафизов. *Заманчалык рухы тормыштагы яңалыкны күрсәтә белү белән билгеләнә.* Казан утлары

**ЗАМАНЫНДА** *рәв.* Кайчандыр, элек бер вакытта, бервакытны, күптән. *Миргазиян ага, заманында, акваланг маскасы киеп, диңгез төпләренә төшкән.* М.Галиев. *Бу авылда заманында гөр итеп йорт сырасы, сало ясап, гөмбә тозлап, --- әйләнә-тирәдәге татар белән әвәрә килеп яшәгәннәр дә, Бөек Ватан сугышыннан соң, кинәт җәгәрсезләнеп калып бушаганнар.* М.Мәһдиев

**ЗАМАТ** *рәв. гар. диал.* Бик тиз, күз ачып йомганчы. – *Без аны [бөти яздыруны] замат эшләп кайтабыз! – ди [Гәләвetдин].* С.Җәләл

**ЗАМЕ́ТКА** *и. рус сөйл.* Яңа мәгълүмат бирә торган кечкенә мәкалә, газета мәкаләсе. *Беренчедән, минем завод газетасында басылып чыккан заметкам буенча клуб рәтләнде.* М.Әмир

**ЗАМИН** *и. гар.* Бер кешенең бурычын түләүне үз өстенә алучы, түләүче кеше; *русчасы*: **поручитель**

**ЗАМИНЛЕК** *и.* Ышаныч язуы. *Шул ук вакытта бәгъзесе дә: «Мин Сакмановтан фәлән-фәлән сум сәмән алдым, шуның өчен Мисхәт иптәш[не] --- төрмәдән чыгаруны үз өстемә алам» дигән язма заминлек кулына тоттырмаячак.* Т.Галиуллин

**ЗАМИР** *и. гар. иск.* 1) Эч, һәр әйбернең эчке ягы

2) Эчтәлек, мәгънә. *Тарих көпчәгенең әйләнүе алдымызда нинди генә мәсьәлә ачмасын, тормышымызның барышы алдымызда нинди генә милли, дини, мәдәни сөальләр куймасын, һәммәсенең дә җавабы бер замиргә кайта.* Г.Исхакый

**ЗА́МОК** *и. нем.* 1) *тар.* Урта гасырларда феодалның крепость сыман торак йорты. *Шул трагедия дөньяга чыккannan бирле, Фамагустадагы замок әдәби геройның исеме [Отелло] белән йөртелә. Традиция буенча киприотлар ел саен бу замок хәрабәләрендә Шекспир трагедияләрен сәхнәгә куялар...* М.Мәһдиев

2) *тар.* Сарай, зур алпавыт йорты. *Кимәкләрдән ирригацион корылмалар калдыклары, феодаль замоклар хәрабәләре калган.* Г.Фәйзрахманов

3) Революциягә кадәр кайбер сарайларның яки кайбер төрмәләрнең исеме. *1879 елда Мәскәүдә, Бутырка заставасы янында, Екатерина II тарафыннан төзелгән төрмә замогы урынында Бутырка төрмәсе төзелә.* Г.Исхакый. *Искәндәр, борынгы замок башнясының әйләнмәле баскычыннан менеп барганда, әнә шул уйларыннан арына алмады.* Г.Үзиле

**ЗАМО́К** *и. рус* 1) *сөйл.* Йозак, бик, бикләгеч. *Ишек эчтән замокка бикләнгән*

2) Утлы коралдагы деталь. *Менә алда, җиргә сибелгән чәүкәләр төсле, кара нокталар пәйда булды, безгә таба хәрәкәт итә башладылар. Замокка лентаны да үзем тыгып, «чәүкә»ләргә озын гына очередь бирдем.* Л.Гыймадиева

3) *сөйл.* Кара-каршы китереп, бикләгечен шудырып йөртеп ача яки яба торган, киемгә тегелгән тасма сыман җайланма; молния. *Киемнәрен кабат-кабат тоткалап чыкты, күлмәгенең берәр төймәсе ычкынгандыр йә булмаса чалбарының замогы эләкмәгәндер кебек тоелды.* М.Кәбиров. *Итәкнең замогы чынлап та ватылган. Ни өскә менми, ни аска төшми.* Ф.Яруллин. *Зур сумканың замогы каптырылмаган иде.* Н.Гыйматдинова

**ЗАМОКЛЫ** *с.* Замогы (*2 мәгъ.*) булган, замок куелган. *Һәр кечкенә күлне көзге итеп, үз-үземә сокланып, фасонлы замоклы вельветны карап үтәм.* Ш.Шәйдуллин

**ЗАМШ** *и. нем.* **1.** Хайван (поши, болан, сарык) тиреләреннән эшләнгән, уң ягы бәрхет сыман йомшак юка күн. *Хәзер замштан тегелгән әйбер [күп], тора-бара тирегә күчәчәкләр.* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* Шул күннән эшләнгән, ясалган, тегелгән. --- *ашыкмыйча гына пальтосын, котелогын, замш перчаткаларын киде, көмеш ябалдашлы кул таягын эләктерде дә: – Рекс! Рекс! – дип, этен чакырды.* М.Галәү. *Ул, кызгылт мыекларындагы кар бөртекләрен замш перчаткасы белән сыпыргалап, түп-түгәрәк битле асрауның әле һаман почмакта торуына карамастан, бер кулы белән Суфиянның нечкә бармакларын кысты.* К.Нәҗми

**ЗА́МША** *и. нем. к.* **замш**. *Дизайнерлар фикеренчә, 70 нче еллар стилендәге фасоннар, бигрәк тә җирән һәм аксыл көрән төстәге табигый яки ясалма замшадан тегелгән пәлтәләр модага керәчәк.* Шәһри Казан. *Ләкин безне замша куртка, замша туфли яки итекләр белән шаккатырып булмый инде хәзер.* Кәеф ничек?

**ЗАН** *и. гар.* 1) Анык ачык булмаган, якынча гына булган уй. *Фәйләсуф әйтте: «Бер кешенең өе түбәсендә ябалак кычкырса, ул кешенең үлмәкенә дәләләт кыйла, дип, заннары хак булса, бу мөганнинең тавышы ябалакның үлмәкенә дәләләт кыйлыр иде», – димештер.* К.Насыйри. *Зан идәрсәм, бу хикәя бервакыт «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган иде шикелле.* Г.Камал

2) Берәр нәрсә турында туган шикле уй

**ЗАНЯ́ТИЕ** *и. рус сөйл.* Уку, нәрсәгә дә булса өйрәтү дәресе. *Әнә анда инде бүтән взводлар, строй занятиесен бетереп, казармаларына да тарала башладылар.* К.Нәҗми. *Эшләсәм дә, занятие ахырына кадәр барыбер эшемнең рәте булмаячак.* Ш.Камал. *– Җәмәгать, – диде Скоморохов. – Әйдәгез, занятиене ташлыйбыз да барыбыз да Иван Ивановичка барабыз.* Ф.Садриев

**ЗАҢ** *и. иск.* Гореф-гадәт, әхлак кагыйдәләре. *Заманына күрә заңы, урманына күрә авы.* Мәкаль. *Ил илнең заңы башка, этләре кара кашка.* Мәкаль

**ЗАҢГЫЛДА́У** *ф.* Заң-заң иткән авазлар, тавышлар чыгару

**Заңгылдап кую** Бер тапкыр, кыска гына заңгылдаган тавыш чыгару

**Заңгылдап тору** Бертуктаусыз заңгылдау

**Заңгылдый бирү** Һаман да заңгылдау, заңгылдавын дәвам итү

**ЗАҢ-ЗОҢ** *иярт.* Тимернең тимергә бәрелүеннән яки чаң сукканда чыккан тавышларны белдерә. *Назимовның колаклары чаң кебек заң-зоң шаулый, --- күз алларында яшелле-сарылы түгәрәкләр очып йөри.* Г.Әпсәләмов

**ЗАПАЛ** *и. рус хәрби* Шартлаучан матдәләрне кабызып җибәрү өчен махсус җайланма. *Сумкасында гранаталар, Запаллар түгел бүген, – Ә китаплар.* Г.Хуҗиев. *– Хәзер, хәзер, – дип сөйләнде Җиһангир, гранатасына запал куеп.* Г.Әпсәләмов

**ЗАПАС** *и. рус* **1.** 1) Киләчәктә куллану, файдалану өчен, билгеле бер күләмдә алдан әзерләп куелган азык, әйбер, материал. *– Ә синең кул тидерми торган запасың нинди хәлдә? – диде майор, зәңгәр күзләре белән елмаеп.* А.Шамов. *Бу җирләр чәчелми калса, быел халык тагын ачыгыр: менә синең күпме запасың бар?* И.Гази. *Өч пот он запасым бар әле.* Ш.Камал

2) Теге яки бу әйбернең кирәк кадәр күләмнән артыгы. *Тамырчада кышын алдагы елда яфраклар һәм чәчәкләр үсеше өчен кирәкле туклыклы матдәләр запасы саклана.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

3) Җир асты байлыклары, казылма байлыклар, чимал. *Игенче, җиләккә карап, туфрактагы дым запасын чамалаган.* Н.Максимов. *«Нью-Йорк Таймс» газетасы АКШтагы нефть һәм газ ятмаларының картасын бастырып чыгарды. Бу ятмаларда нефть һәм газ запасы биниһая.* Р.Вәлиев

4) Киләчәктә зурайту өчен, киемнең тегкән вакытта артыграк итеп махсус калдырылган җөй өлеше; тиешледән зуррак размер. --- *безнең авылда бала-*

*чагага киемне бер-ике размерга запас белән алалар.* В.Нуриев

5) Аерым шәхес, коллектив яки дәүләт карамагындагы байлык. --- *өемдә бер ел кайгысыз яшәрлек акча запасы торачак!* Х.Ширмән. --- *һәр дәүләтнең кәгазь акчалар массасы шушы дәүләтнең алтын запасы белән тәэмин ителергә тиеш.* К.Гыйззәтов

6) *күч. сөйл.* Аерым шәхеснең эрудициясен, белемен, культурасын, сөйләүаңлату дәрәҗәсен билгеле торган тел байлыгы. *Фәриднең сүз запасы бетте, аның теле дә әйләнерлек түгел иде.* Г.Әпсәләмов

7) *хәрби* Сугыш булган очракта хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле, тыныч вакытта хәрби учётта торган гражданнар. *Запастан чакырылганнарны җибәрәләр.* М.Җәлил. *Мин, запаста торган яшь командир, Уйларымның белми тынгысын, Әзерләнеп һәркөн әмер көтәм*... С.Хәким. *Эшсез калган 400 дән артык кеше һәм запаска чыккан хәрби хезмәткәр өстәмә белем бирү факультетында яңадан әзерлек узды.* Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Алмашка, кирәге чыкса, дип өстәп алынган. *Безгә, бу арыш әзерлекләрен күргәндә, әүвәлдә әзерләнгән запас азыкларыбыздан берازын тотарга туры килде.* Ф.Әмирхан. *Әй Семён Семёнович, өченче путьтагы запас вагоннарга төягез, ... нче эшелонга тагарсыз.* Г.Гобәй. *Начхоз аларны тиз генә йортка алып керде, тезелеп торган запас винтовкаларны күрсәтте.* А.Шамов

2) *хәрби* Сугыш вакытында: алгы фронттан ерак торган, резервтагы. *Запас полкның бер ротасы солдаткаларга каршы ут ачудан баш тартты.* К.Нәҗми

3) **запастагы** *хәрби* Тыныч вакытта учётта торган, сугыш булган очракта хәрби хезмәткә чакырылырга тиеш булган. *Аларның һәрберсенең үз тормышы, әмма запастагы хәрбиләрнең мәнфәгатен кайгырту мөһим.* Ватаным Татарстан. *Бер танышым, запастагы офицер, күптән түгел генә Казакстанга барып кайтты.* Татарстан яшьләре

**ЗАПАСЛЫ** *с. сөйл.* Запасы (*1 мәгъ.*) булган, запас тотучан. *Запаслы ат армас, ди торган иде безнең әткәй.* Д.Гайнетдинова. *Запаслы кешеләр хәтта окрошкага кадәр алып килгәннәр.* Г.Мөхәммәтшин

**ЗАПАСЛЫЛЫК** *и.* Запаслы булу, запас белән яшәү. *Запаслылык беркайчан да комачау итми*

**ЗАПА́СНИК** *и. рус* Запастагы (*7 мәгъ.*) кеше. *Эшелоннар, күптән буялмаган көрән теплушка ишекләреннән обмоткалы арык аякларын салындырып утыручы олы яшьтәге запасникларны төяп, бер-бер артлы көнбатышка йөгерәләр.* К.Нәҗми

**ЗАПАССЫЗ** *с.* **1.** Запасы булмаган, запас әзерләмәгән. *Мартта шартлата – хуҗалык ягыннан да шартлата, запассыз игенчене бөлдерә, дигәннән.* Н.Исәнбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* Запас тотмыйча, запасы булмаган хәлдә. *Мин запассыз йөрмим. Минем ризык һәрвакыт үзем белән.* Д.Салихов. *Меңләгән бөҗәкләрдән һәм бик күп санлы личинкалардан торган зур семьяда запассыз ярамый.* Кызыклы физиология

**ЗАПА́ШНИК** *и. махс. рус* Рәт араларын йомшарту өчен кулланыла торган сай сабан; күмгеч, күмдергеч

**ЗАПЕКА́НКА** *и. рус* Бәрәңге, эремчек кебек ризыкларга сөт һәм йомырка кушып, мичкә яки духовкага куеп, өсте кызарганчы пешереп әзерләнгән ашамлык. --- *гарнир белән ит котлеты, берәр төрле ярма запеканкасы, өченчегә кесәл, компот, җимеш бирелә.* Йорт эшләре. *Суынган ризыкларны шулай кайнарлап алырга була (микродулкынлы мичтә). Ботка, запеканкалар турында әйтеп торасы да юк.* Серле сандык

**ЗАПИ́СКА** *и. рус* Берәр төрле хәбәрне, үтенеч-теләкне белдереп язылган язу; кечкенә хат, намә. *Кулымны карады, култык астына градусник куйды да ридикюленнән кечкенә бер записка чыгарды.* Г.Ибраһимов. *Миңа биргән запискаларында «иртәгә» дип язылган. Гыймади муллаларга биргән запискаларында «бүген» дип язылган, дип әйтә, ди.* Г.Камал. *Комендант исә калын кәгазьгә эре почерк белән язылган запискаdebeнең беренче сүзләренә күз төшерү белән үк кондукторга кычкырды.* К.Нәҗми

**ЗАПОВЕ́ДНИК** *и. рус* Сирәк очрый торган яки табигатьтә югалып, кимеп барган, аз калган үсемлекләрне яки җәнлекләрне, кошларны үрчетү һәм саклау урыны; саклаулык. *Барыр алдыннан, заповедникны яр буеннан башлап планлы рәвештә тоташ карап чыгармын, дип уйлаган идем.* М.Юныс. *Заповедник хезмәткәрләре фламинголарның һава үзгәрешләренә бик сизгер булуларын күргәннәр.* А.Муранов

**ЗА́ПОНКА** *и. рус* Күлмәк җиңнәрен, яканы каптыру өчен кулланыла торган парлы сәдәфләр яки галстукны күлмәккә беркетү өчен каптырма, эләктергеч. *Бу нечкә, озын бармаклар ислемай, паста, запонка, тасма кебекләрне күз иярмәстәй тизлек белән бик җитез төргәннәрдер.* Г.Бәширов. *Ул киемнәр! Габардин костюм, затлы күлмәк, затлы галстук, запонкалар, ә аныкы төсле ботинкаларның бу авыл урамында әле гомумән күренгәне юк.* М.Мәһдиев

**ЗАПРА́ВКА** *и. сөйл. рус* 1) Машинага ягулык, май, су салу эше. *Баш тракторчылар бәхәсләшә, ә ярдәмчеләре заправка белән йөгерешә, солярка, су ташыйлар иде.* Х.Камалов

2) Шул эшләрне башкару урыны. *Стационар заправка постларын үзәк һәм бригада складларына, ә кайчакта машина-трактор агрегатларына техник хезмәт күрсәтү пунктлары янына урнаштыралар.* Механизаторлар белешмәсе

**ЗАПРА́ВЩИК** *и. рус* 1) Заправкада эшләүче, машинага ягулык салучы кеше. *Әхмәт бабай заправщик бит ул. Майлы мичкәләр төяп йөри.* Ф.Гыйльми. *Заправка вакытында бирелгән нефть продуктларын заправщик тракторның лимит-забор картасына язып бара.* Механизаторлар белешмәсе

2) *сөйл.* Ягулык белән тәэмин итү машинасы

**ЗАПРОС** *и. рус* Нинди дә булса мәгълүмат бирүне сорап язылган рәсми мөрәҗәгать. --- *ямьле көннең ямен җибәрмик, сезне мин чакырттым, Совмин аркылы депутатлык запросы җибәреп, – диде ул.* Г.Ахунов. *Олы кенәз, йомшара төшеп,--- запрос ясарга риза булды.* Мирас

**ЗАПЧАСТЬ** *и. рус* Машиналар, төрле җиһазлар өчен запас детальләр. – *Әгәр инде машина алам дисең икән, запчасть турында алданрак кайгырта башла, – диде.* Ф.Яруллин. *Зоотехник анда запчастьлар табуда ярдәм сорап барган иде.* А.Расих. *Берәр файдасы булмас микән дип, запчасть шудырган иде дә... Барып кына чыкмады.* Р.Зәйни

**ЗАР** *и. фар.* 1) Кемгә дә булса сөйләп бирелгән үз тормышыннан канәгатьсезлек. *Минем дә нәкъ шулай, авылга кайтканыма дүрт көн, нинди генә зарлар ишетмәдем, нинди генә теләкләр әйтмәделәр миңа ярлылар.* М.Әмир. *Газизов берәр яңа нәрсә сөйләр һәм безне майор зарларын тыңлаудан коткарыр, дип уйладык без.* А.Шамов

2) Кайгы-хәсрәт, борчу, моң-зар. *Чайпалышып, шатлык дулкыннары Чәп-чеп бәрелә күңелем ярына; Шул шатлыклар белән каршы торам Бу дөньяның барлык зарына.* Ш.Бабич. *Нурихан Фәттах теге чакта шактый зар күрсә дә, бүген үч алам дип вакланмый.* Т.Миңнуллин. *Синең зарың аларның һәммәсен капларлык көчле иде, моңлы егет.* М.Фәйзи

3) Мохтаҗлык, җитешмәүчелек, интегү. *Йөзеңне бер күрергә зар халыклар.* Котб. *Түшәкләрең алтын, юктыр зарың, Балаларың көмеш кукәйдә; Кукәйләрне тишеп чыгуларын тыныч кына утырып көт әйдә.* Ш.Бабич. *Илен ташлап киткәннәр Бер кайтырга зар икән.* Г.Афзал

4) Үпкә, рәнҗү, ризасызлык. *Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый, һәммәсеннән риза-канәгать.* Ә.Еники. *Бер зарым юк сезгә, и кешеләр! Бер үпкәм юк сиңа, и дөнья!* С.Якупова

◊ **Зар елау** 1) Елый-елый, бик нык зарлану. *Зар елый безнең мәче: «Сез туйдыгыз, ди, мин ач ич!»* Г.Тукай; 2) Ачыну, рухи газаплану. *Күпме бәндә күзне текқән Кыйбла якка күз терәп: «Ник яраттың, әй Ходай?» – дип, Зар елыйлар тинтерәп!* Н.Исәнбәт. *«Минем падишаһ булуыма карамаңыз. Бәлки, Аллаһы Тәгалә каршында миннән хур-хәкыйрь адәм юктыр?» – дип, зарзар егълады.* К.Насыйри; 3) Мескенләнү. --- *болар барысы да – җиңелгән, буйсындырылган халык өчен табигый вакыйгалар, алар турында куертып, зар елап, нигәдер сөйләп торасы да килми...*Ә.Еники. **Зари елау** *к.* **зар елау**. **Зар калу** Мәхрүм калу, мохтаҗ булу

**ЗАРАР** *и. гар.* 1) Предмет, күренешкә, аларның яшәеше, үсүенә комачаулый, аларны тоткарлый, боза, тарката яки өлешчә җимерә торган күренеш; тискәре йогынты, зыян; *кирессе:* **файда**. *Кавидә дә, иске тормышны, ямьсез күренешләрне язганда, искегә нәфрәт, аннан көлү, аның зарарына агитация ясау юк түгел.* Г.Гобәй. *Әйтегез, пожалуйста, ничек итеп исерек эчүнең зарары, аеклыкның файдасы турында кешене ышандырырлык нәрсә яза алсын?* Г.Бәширов

2) Кимчелек, төгәлсезлек; зәгыйфьлек, саусызлык китерә торган тәэсир. --- *сәламәтлекләренә зарар китереп булса да, күбесенчә ирләренең кушуы белән, гомер буена баласыз яшәгән хатын-кызларны беләм мин.* Г.Кутуй. *Баш мие кузгалып, аң-зиһененә зарар килмәсен тагын, дип шикләнделәр.* Г.Гыйльманов. --- *кайчакта, сөйләм интонациясенә зарар китермәс өчен дә, кушымчаларны кыскартмаска кирәк була.* Р.Юсупов

3) Бәла-каза; зыян, матди югалту. *Әгәр кадимлек мәсләге хан булса, дөньяма зарар килмәс иде.* Г.Тукай. *Болар, ул якта баскынлык итеп, урысларга шактый зарар китерделәр.* Һ.Атласи. *Бу сугыш китергән корбан һәм зарарны исәпләп бетерерлек түгел.* Ә.Еники

◊ **Зарар булмас** *к.* **зарар итмәс**. – *Дөрес тә, – диде карт, – азрак арттагы сабакларын тыңлатканда зарар булмас иде булуын, юк шул инде, картаям, егетләр!* Ш.Камал. **Зарар күрү** 1) Бәла-казага дучар булу, зыян килү. *Бу гәзитне чыгарудан Шакир һәм Закир Рәмиевләр һәр ел саен 7–8 мең сумлык зарар күрә, диелә.* М.Гайнетдинов. *Бозлы яңгырдан басулар зур зарар күрде;* 2) Билгеле бер предмет, күренешнең начар тәэсиренә эләгү, тискәре йогынты алу. *1346 елны Кытайдан килгән чума чире ярты Европа халкын кырып сала, бу афәттән шулай ук Дәште Кыпчак далалары, Кырым, Идел буе да зур зарар күрә.* Ф.Бәйрәмова. **Зарар юк** *кер. сүз* Борчылырлык түгел, борчылырга урын юк, зыянсыз. – *Зарар юк, табарбыз, – диде Гаяз, – авылдан чыгып китмәгәннәрдер әле.* М.Әмир. *Зарар юк, дускай, минем өчен борчылма син...* Р.Ишморат. – *Хәер, зарар юк, егете чибәр, – диделәр.* Г.Кутуй

**ЗАРАР-ЗӘХМӘТ** *җый. и. гар.* Төрле бәла-каза, зыян, бәхетсезлекләр. *Төрле зарар-зәхмәттән саклану*

**ЗАРАР-ЗЫЯН** *җый. и. гар.-фар.* Төрле зыян, каза, һәртөрле материаль югалту. *Көчле янгын аркасында зарар-зыян килү*

**ЗАРА́Р ИТҮ** *ф.* Зыян китерү, зыян салу; югалтуларга дучар итү. *Техниканы начар белү аркасында, күп кенә зарар иткәнбез.* Ш.Камал. *Кешеләргә зарар иткән кешеләрне Тыныч таптым кара җиргә күмелдереп.* М.Гафури

◊ **Зарар итмәс** Яхшы булыр, файдага гына булыр, файдасы тияр; яхшыга юрау. – *Әллә, минәйтәм, – диде бригадир сак кына, – калага хәбәр итикме? Суфиян агай, йә булмаса, Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...* Ә.Еники. *Яхшырак характеристика язып бирсәгез дә, зарар итмәс.* Т.Миңнуллин

**ЗАРАРЛАГЫЧ** *с. сир.* Нәрсәгә дә булса зарар китерә торган. *Зарарлагыч матдәләр*

**ЗАРАРЛАНУ** *ф.* Нәрсәнеңдер зарары, зыяны тию, үзенең бөтенлеген, сыйфатын яки саулыгын югалту, кимчелек килү. --- *тәрәзәдән сикергәндә, аның бер сыйрак сөяге чатнаган, икенче аягының тез капкачы зарарланган булган.* Г.Гобәй. *Нагасаки – Кюсюның төп порты; сугыш вакытында Американың атом бомбасыннан зарарланды.* И.Мамаев. *Белмим, нәрсә, күпме эшли алганнардыр, шул керүдә иллешәр радиоктив нурлар белән зарарланып чыкты мескен таҗиклар.* Ә.Салах

**Зарарлана бару** Торган саен ныграк зарарлану

**Зарарланып бетү** Тәмам зарарлану, бөтенләй зәгыйфьләнү. *Үсемлекнең тамырлары зарарланып беткән, алып ташлаудан ары бернәрсә эшләп булмый*

**Зарарланып тору** Еш, әледән-әле зарарлану, бертуктаусыз зарар күрү

**ЗАРАРЛА́У** *ф.* 1) Зарар, зыян салу, каза китерү. *Урманнарның, елга-чишмәләрнең, күлләрнең, болын-тугайларның кадерен без үзебез дә белмибез, аларны төрлечә зарарлыйбыз, корытабыз.* Ф.Мусин. *1920 елда, бер көзен аклар пулясы зарарлагач, Хәбибулла солдат авылына кайтып төшкән.* М.Мәһдиев

2) *диал.* Үлү, үлеп китү. *Поп агайның еш кына көтүдән сарыгы кайтмый кала йә таналары зарарлый.* Г.Бәширов

**Зарарлап бару** Зарарлауны акрынлап дәвам итү, эзлекле рәвештә зарар салу

**Зарарлап бетерү** Тәмам зарарлау, бөтенләй зарарлау

**Зарарлап килү** Элек-электән, даими зарарлау

**Зарарлап кую** Алдан ук зарар салу, зарар салырга өлгерү

**Зарарлап ташлау** Кинәт, ахырын уйламыйча зарарлау

**Зарарлап тору** Әледән-әле, еш яки бертуктаусыз зарарлау. *Корткычлар игенне зарарлап торалар, аларга каршы кискен чаралар күрергә кирәк*

**Зарарлап чыгу** Нәрсәнедер башыннан ахырынача зарарлау, һәрберсен, булган берсен зарарлау

**ЗАРАРЛЫ** *с.* 1) Зарар, зыян китерә торган; зыян сала торган; зыянлы, куркыныч. *Халык үзенә ни-нәрсә файдалы, ни-нәрсә зарарлы, үзенә кемнәр дус, кемнәр дошман идекне бик яхшы белде, аңлады.* Ш.Мөхәммәдев. – *Төзәлүгә таба бара, зарарлы әйбер юк, – диде, фельдшерга ниндидер мазь сөртергә һәм яңадан урарга кушты.* Ш.Камал. *Шамгун язу танымаучы кешеләрнең нинди файдалы икәнен чын мәгънәсе белән аңлады һәм укый-яза белүнең зарарлы икәнен бик ачык төшенде.* А.Шамов

2) Җәмгыятькә зыян китерә, аны какшата торган. *Шагыйрь [Яков Емельянов] анда үз-үзеңне генә яратуга, тәкәбберлеккә каршы чыга, аларны социаль зарарлы күренешләр дип бәяли.* М.Гайнуллин

3) Боза, тарката торган; корткыч, корткычлык эшли торган. *Зарарлы шеш төсле каядыр эчтә утырып калган.* Т.Галиуллин. *Коелган яфраклар белән бергә үсемлекләрдәге зарарлы матдәләр дә ташлана.* Ботаника. *Уңай ионнарның зарарлы тәэсире тәҗрибәләр белән тикшерелде.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ЗАРАРЛЫЛЫК** *и.* Зарарлы булу, зыянлылык. *[Батырхан:] --- дәүләт Думасына булачак сайлауларда --- минем кандидатураны куймакчы булалар. Платформага килгәндә, мин сезгә якынрак торам. [Сөнгать:] Зарарлылык ягыннанмы?* К.Тинчурин

**ЗАРА́Р САЛУ** *ф.* Аңлы рәвештә начарлык, явызлык эшләү, казалы итү. *Атасының байлыгына һаваланып, шушы Мирза, егет чагында да, бик күп кешеләргә үзенең зарарын салды.* Г.Толымбай. *Чулак Абдул үз гомерендә беркемгә дә зарар салмады. Ул тынычлап үлә ала иде.* М.Мәһдиев

**ЗАРАРСЫЗ** *с.* **1.** Зарары тими торган, зарар китерми торган, зыянсыз. *Ярый, минәйтәм, агаңның дус-ишләре булуы сиңа да ярдәм итсен, дидем, сыйнфый чыгышыбыз да зарарсыз, минәйтәм, тоттым да кыш уртасында рабфакка кучердем.* Г.Гали. *Витаминнар, сез уйлаганча ук, зарарсыз түгел әле ул.* Идел

**2.** *рәв. мәгъ.* Ярыйсы, канәгатьләнерлек; зарланырлык түгел. *Әсәрегезне зарарсыз дип таптык.* Г.Ибраһимов

**3.** *хәб. функ.* Түзәрлек, алай ук куркыныч түгел. – *Хәлләр зарарсыз, – дигән булды ул, – тик менә савыгып кына булмый.* И.Гази

**ЗАРАРСЫЗЛАНДЫРУ** *ф.* Зарар итү тәэсирен бетерү, зыян китерү мөмкинлеген чикләү, зарарсыз иттерү, зарарлы матдәләрдән арындыру. *Ул мәлгуньне ничек кенә булса да эзләп табарга кирәк. Чын йөзен ачарга, фаш итәргә, зарарсызландырырга кирәк аны.* Р.Фәизов. *---164 нче инженер-сапёр батальоны, килешкә эшкә керешеп, штольня авызына оста итеп яшереп калдырылган немец миналарын зарарсызландырган иде инде.* Ш.Рәкыйпов. *[Егет] Аны [төргәкне] саклык белән генә чишә башлады. Әйтерсең шартлаткычны зарарсызландыра.* Р.Сәгъди

**Зарарсызландырып бару** Һәрберсен, булган берсен зарарсызландыру

**Зарарсызландырып бетерү** 1) Барысын да зарарсызландыру

2) Зарарсызландыру эшен төгәлләү

**Зарарсызландырып тору** Һәрвакыт, даими рәвештә зарарсызландыру. *Минёр тикшереп чыкканнан соң, бу күңелсез фикер расланды: немецлар миналарны зарарсызландырып та тормаганнар.* З.Фәтхетдинов

**ЗАРАРСЫЗЛАНУ** *ф.* Зарар тимәслек булу, зарар булу мөмкинлеге бетү. *Туфрак корткычлардан зарарсызлана, чистара.* Акчарлак

**Зарарсызлана башлау** Зарарсызлануга табан йөз тоту

**Зарарсызланып бетү** Тулысынча зарарсызлану

**ЗАРАРСЫЗЛЫК** *и. сир.* Зыяны, зарары булмау

**ЗАРӘБӘ** *и. гар. иск.* Зыян. --- *«җиңәлмәслек» исеменә зарәбә бирелгәч, егетлек дөньясыннан аерылырга карар биреп, фабрикадагы иң усал кызлардан берсенә өйләнгән иде.* Ш.Усманов

**ЗА́Р БУЛУ** *ф.* 1) Мохтаҗ булу, тилмерү. *Чакырганда бармасаң, чакырганга зар булырсың.* Мәкаль. *Бер йотым суга зар булып яткандыр…* М.Гафури. *Мин уйлыйм: ышык җир табалмый Егылган юлчыларны, Зар булып кояш нурына Саргайган җырчыларны.* Ә.Исхак

2) Сагыну-сагыштан түзә алмаслык хәлгә килү, тилмерү. --- *бер күрергә зар булып [Гөлйөзем] Акканатны [зәңгәр күзле яшь пәһлеванны] сагына иде.* Ф.Латыйфи

**ЗАРИ́ ЕЛАУ** *ф. к.* **зари кылу**

**ЗАРИ́ КЫЛУ** *ф.* 1) *к.* **зарлану**. *Атакайга зари кылма, Күккә сыгын, туганым.* Г.Морат

2) Кычкырып елау. *Йөзен орды [кисек баш] туфракка, кыйлды зари.* Г.Тукай. *[Хәзрәтнең] Күзләреннән яшьләре мөлдер-мөлдер булып сакалы буенча актылар. Намазлыгы өстенә утырып, бик озак зари кылып дога кылды.* Һ.Такташ

**ЗАР-ИНТИЗАР** *рәв. гар.-фар.* **1.** Зарыгып, түземсезләнеп, тилмереп. *Атна саен «бер күрергә зар-интизар...» дип, хатлар алышкан вакыт.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ. к.* **зар** (*1 мәгъ.*). *Хәзер инде күңелемдә җилкендергеч татлы хыял түгел, бу дөньядан сусауларым басмый үтәм инде, дигән зар-интизар гына чайкала.* Ш.Янбаев

**ЗА́Р-ИНТИЗАР БУЛУ** *ф.* Зарыгу, түземсезлек белән көтү, сагынып тилмерү. *Бәлки, ике бертуган Сак белән Сок --- түзә алмаслык сагынудан зар-интизар булып, аһ-зарлардан күп күз яшьләре түккәннән соң көрешә алган булсалар, нәкъ менә шулай исәнләшерләр иде.* М.Маликова

**ЗА́Р ИТҮ** *ф. к.* **зарыктыру**

**ЗАРЛАНУ** *ф.* 1) Теге яки бу нәрсәгә ризасызлык белдереп сөйләү. *Туровец янында йоклаган солдат: «Түшәмнән яңгыр үткән, плащ-палатка юеш», – дип зарлана.* Ф.Вәлиев. *Бүлмәнең сул почмагын урталай бүлеп торучы җәенке мич артыннан хәреф җыючы Шакирның көйләр-көйләмәс зарлануы ишетелә.* К.Нәҗми. *Һәрнәрсәң җитеш, зарланырга – зарың, уфылдарга хәсрәтең юк.* Н.Гыйматдинова

2) Кешенең кимчелекле, тискәре яклары турында сөйләү. *Андый вакытларда алар ирләреннән зарланалар, аларны судка бирәләр, җавапка тарттыралар.* М.Әмир

**Зарлана башлау** Зарланырга тотыну. *Күңелле көннәрне мәңгегә оныткан кебек зарлана башлады.* М.Әмир. *Килеп керде дә --- колхоз рәисенең бөтенләй игътибар күрсәтмәвеннән зарлана башлады.* Г.Әпсәләмов

**Зарлана бирү** Һаман зарлану, зарлануын дәвам итү

**Зарлана тору** Бертуктаусыз, гел зарлану. *Зарлана торгач, «җыен җыяргамы әллә» дигәләнеп, тәкъдим кертә.* Г.Толымбай. *Гомумән, зарлана торган, аһ-зарлы заманалар килде безгә.* Р.Миңнуллин

**Зарлана төшү** Бераз зарлану

**Зарланып алу** Беркадәр, бераз гына зар белдерү. --- *эшнең күплегеннән, үзенең өлгерә алмавыннан зарланып алды.* А.Шамов. *– Гафу итегез, Татьяна Макаровна, суык тигән. Теге көнне машина белән бик озак буранда утырдым, – дип зарланып алды карлыккан тавыш белән мастер.* Ш.Бикчурин. *«Эчем поша, башымда уем күп, тынгысызмын», – дип зарланып алырга теләсәң, сине ялгыш аңлаячаклар.* Казан утлары

**Зарланып йөрү** Барысына да бертуктаусыз зарлану, һаман да канәгатьсезлек белдерү. *Үзең бертөрле дә чара күрмичә, коры зарланып йөрүнең --- файдасы юклыгын әйттек.* М.Әмир. --- *торакның аскы катына урам ягыннан ишек уеп, «Бистро» ачтылар, үзалдыңа зарланып йөргәндә, күңел юатыр өчен телевизор бар.* К.Кәримов

**Зарланып килү** Озак вакытлар дәвамында зарлану, күптәннән бирле зарлану. *Әй шулай да, тормыш төрле яклап яхшырса да, ул Билал абзыйга һәрвакыт зарланып килгән, колхоз тормышын эттән алып этә салган.* Г.Толымбай

**Зарланып китү** Нәрсәнеңдер соңында, билгеле бер вакыттан соң дәвам итеп зарланырга тотыну. *Җәйләүнең начарлыгыннан зарланып китте.* Г.Ибраһимов. *Шул турыда Бибиковның исенә төшермәкче булып торган иде, ләкин теле әйләнмәде, башкалар кебек үк зарланып китте: – Мин үзем аңлый алмый интегәм. Безнең промыселларда, иптәш Бибиков, болай эшләмиләр.* Ш.Бикчурин

**Зарланып кую** Нәрсәдәндер кинәт кенә берәр төрле зар белдерү. *Марат пароход дөпелдәгән якка карады да зарланып куйды.* Г.Гобәй. *Яртылаш бөкрәйгән хәлдә казан астын рәтләп маташучы Раушана зарланып куйды: «Тамак» ди-ди, тәмугка кереп баттык бугай».* К.Нәҗми

**Зарланып тору** 1) Гел, һәрвакыт зарлану

2) Әле, хәзерге вакытта зарлану. *Башы авырганлыктан зарланып торды.* Ш.Камал

**Зарланып утыру** Әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда зарлану. *– Әнә анда кыйбладан болыт кузгалды, болай зарланып утырып, без арышны җыебетмик, чәчәрсең аннары, – дип, кулына көрәк алып арышны суыра башлады.* М.Гафури. *Хәтердә шул калган: бер очрашканда, Хәсән абый кызыннан зарланып утырды.* Казан утлары

**Зарланып яту** *к.* **зарланып утыру**. *Узган кыш урманда артыграк тырышып ташлаган, ахрысы, кайткач, берчак биленә зарланып ятты, ышандырганынча, Фәсхи кордашы белән урманга кабат бара алмады.* Г.Гобәй

**ЗАРЛАНУЛЫ** *с. к.* **зарлы**. *Минҗан --- колүдән бигрәк, зарланулы тавыш белән: «Әй юк... Чебенне артык кысарга ярамый --- сытылып китүе бар...»* М.Хәсәнов

**ЗАРЛАНУЧАН** *с.* Зарланырга яратучан, еш зарлана торган. *Сеңлем кызының холкын кайнанасыныкына охшата: гел зарланучан, шөкер итә белмәүче карчык иде, мәрхүмә.* Сөембикә. *Әй менә үз эченә йомылган, сытык, елак, гел зарланучан кеше, гадәттә, бәхетсез була.* Ватаным Татарстан

**ЗАРЛАНЫРЛЫК** *с.* Кимчелекле; ризасызлык, канәгатьсезлек белдерердәй. *Хәзер аңа язмыштан зарланырлык сәбәп юк.* М.Галәү. --- *пароходлар тәүлек буе туктаусыз йөри бирде, без дә зарланырлык бәла-каза күрмәдек.* С.Сабиров

**ЗАРЛАНЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **зарлану**. *Алар, уйнап-көлеп, шаярышып, әкиятләр сөйләп, көннең эсселегеннән зарланышып, чәй эчәргә тотындылар.* М.Галәү

2) Һәрберсе үз зарын сөйләү, зарлану

**Зарланышып алу** Бераз, җиңелчә генә зарланышу. *[Өлкәннәр] Заманнан, яшьләрдән зарланышып алалар.* Р.Габделхакова

**Зарланышып йөрү** Барысы да бердән зарланышу. *Без байтак еллар «эшчеләр тормышына багышланган хикәя-романнар аз языла» дип зарланышып йөрдек.* М.Вәли-Барҗылы

**Зарланышып китү** Нәрсәгә дә булса кинәт барысы берьюлы зар белдерү

**Зарланышып кую** Бер тапкыр зар белдерү

**Зарланышып тору** 1) Бик еш, әледән-әле зарланышу

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләгән вакытта үзара зарланышу. *Мөдәррис Әгъләм белән Ркаил Зәйдулла очрашып, шигырь язып яшәүнең бүгенгесе көндә матди яктан никадәр кыен булуы турында сөйләшеп, зарланышып торалар.* Ш.Маннапов

**ЗАРЛЫ** *с.* **1.** 1) Зары булган, тынычсыз, борчулы. --- *үземнең исә, зарлы тормыш үткән ата-бабаларым кебек, һич илемнән аерылмый «мин каракалпакмын...» дип тәкрарлап торасым килә.* Казан утлары

2) Моңлы; зар тулы. *Хәсрәтле әнисенең зарлы җыры аша Әхмәт тагын да арырак күренгән Бантырай түбәсенә карашын төбәде.* Мирас

**2.** *и. мәгъ.* Зары булган кеше. *Очрый калса сезгә шундый ярлылар, яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар…* Г.Тукай

**ЗАРЛЫК КЫЛУ** *ф.* Зарлану, ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү. *– Дәүләтем юк, бәхетем ким дип зарлык кылма, кыямәтнең оҗмахында тәхетең бар, – диде.* Г.Ибраһимов

**ЗАРЛЫЛЫК** *и.* Зарлы булу. *Ярлылык – зарлылык.* Мәкаль

**ЗАР-МОҢ** *и.* Моң-зар. --- *илаһи миссия үтәп (Аллаһ колы булып) яшәүчеләр психологиясе --- мескенлек кичерешләреннән, зар-моңнан арына, аларның күңелләрендә хозурлык һәм җан рәхәте хисләре өстенлек итә.* Р.Сафин

**ЗАРПЛА́ТА** *и. рус сөйл.* Эш хакы; хезмәт иткән, эшләгән өчен түләү. *Ул, беләсең килсә, үзенең түш кесәсендә генә дә синең еллык зарплатаң хәтле акча йөртә.* Н.Акмалов. *Өч ай акчасыз утырып кара әле! Берьюлы томтыргач, кадерлерәк була икән ул «зарплата» дигәннәре!* Д.Гыйсметдин

**ЗАРУР** *с. гар.* **1.** 1) Кирәк булган, бик әһәмиятле, мөһим. *[Хуҗа] Ике мәртәбә конторага кереп, бик зарур кәгазьләргә кул куеп чыгадыр.* Ш.Мөхәммәдев. *[Зөбәйдә:] Юк, Сөләйман, раст, ул көнне минем өйдә бик зарур эшем бар иде.* С.Рәмиев

2) Котылгысыз, аннан башка мөмкин булмаган, чарасыз, мәҗбүри; җитди. *Кайбер тикшерүчеләр мафияне тарихның билгеле бер этабында Сицилия өчен зарур күренеш булганлыгын да расларга тырышалар.* Р.Фәйзуллин. --- *башка бер телдән ихтыяҗ белән, кирәккәнгә сүз алу әдәби телебез өчен гаять тә зарур бер хәл икән.* Х.Сарьян

**2.** *хәб. сүз функ.* Аерым күрсәтелгән шартларда нәрсәгә дә булса туган ихтыяҗны белдерә; кирәклек таләп итәлә. *Ә яшәргә кирәк, кыш көне укырга мөмкин булсын өчен, җәйләрен кайдадыр хезмәт кылу зарур.* Ф.Бәшәр. *Ташләрдә таш хасил ителсә, ташны эретә торганнарын куллану зарур.* Идел

**ЗАРУРӘТ** *и. гар.* Чарасызлык, котылгысызлык, мәҗбүрилек, үтә кирәклек, тиешлек. *Һәрбер сүзе аның өчен кызыл фонарьга кору, җан вә табигате илә кирәксенә торган бер ихтыяҗ, бер зарурәт кабиленнән иканен белдереп тора.* Г.Ибраһимов

**ЗАРУРИ** *с. гар.* **1.** 1) *к.* **зарур** (**1.**). *Салих элеккеге танышы белән «латыш укчыларына» тәмле-томлы ризыклар ясау өчен зарури коры сөт озатып ятканда очрашты.* Т.Галиуллин. *Бер яктан, мохит анда зарури шарт булырак кына түгел, бәлки баланың үсеш чыганагы буларак та чагылыш таба…* Могҗизалар энциклопедиясе

2) *филос.* Очраклы гына булмаган, закончалыклы, әйбернең үз табигатеннән чыгып барлыкка килә торган. *Автор, кешенең начар сыйфатларын күргәндә дә, аның турында начар фикердә калмаска, берәр зарури сәбәп булгандыр, дип уйларга киңәш бирә.* Татар әдәбияты тарихы

**2.** *хәб. сүз мәгъ. к.* **зарур** (**2.**). --- *халкыбызның дөнья мәмләкәтләре арасындагы элеккеге абруен, урынын даулау өчен, иң әүвәл, тарихи дөреслекне кайтару зарури.* Т.Галиуллин

**ЗАРУРИЛЫК** *и. к.* **зарурлык** (*2 мәгъ.*). *Дөрес, хәзер ул үз эшенә бәя бирә алмый иде әле, аның эшендә белем белән осталык өстенлек иттеме, әллә тәвәккәллек белән зарурилык аркасында гына башкарып чыктымы, анысын да хәзергә әйтә алмый иде ул.* Г.Әпсәләмов. *«Хәзер дә аһәңле нотага куелган тавышлар кирәк», – дип, Баттал акыллы, төпле тәнкыйть зарурилыгын әйтә.* Казан утлары

**ЗАРУРИЯТ** *и. гар. к.* **зарурлык**. *Хезмәт ул байлык чишмәсе һәм зарурият кына түгел, ул – кеше тормышының төп шарты: эшләгән савыккан, эшләмәгән кабыккан.* Н.Исәнбәт. *Телебездәге күчеш чоры өчен хас зарурiятләр гарәп-фарсы алынмаларына мөнәсәбәттә аеруча үзенчәлекле гәүдәләнә.* Р.Ганиева. *Димәк, аның күңелендә алга, киләчәккә ышаныч, өмет, үз хезмәтенең милләт яшәешендәге зарурiятен тирәнтен аңлау, төшенү хисе яши.* Х.Миңнегулов

**ЗАРУРЛЫК** *и.* 1) Кирәклелек, кирәк булу, мөһимлек, әһәмиятлелек. *Үзең белгән гыйбрәтләрне сөйләп һәм язып, кем каршындагыдыр бурычны үтәү зарурлыгы Шамил Маннапов кына ачкан әдәби алым түгел, билгеле.* Р.Шәрәфиев. *Тик ул үзе генә моның мөһимлеген, зарурлыгын аңлап бетерми: озак утыра яки киреләнә, кәҗәләнә башлый.* М.Госманов. *Татар әдәбиятының бөтен тарихына, бигрәк тә XX йөз башындагы әдәбиятына бөтенләй яңа күзлектән карау зарурлыгы сорала.* Казан утлары

2) *филос.* Әйберләрнең яки күренеш, вакыйгаларның эчке бәйләнешләренең асылларыннан килеп чыга торган котылгысыз, закончалыклы хәл. *Һәрхәлдә, заман күчеше өчен урынны дөрес сайлау зарурлыгы турында әйткәндә, мин нәкъ менә шушы төрбәрәсадханәне күздә тоттым.* А.Тимергалин

**ЗА́Р ЧИГҮ** *ф. к.* **зар булу**. *Яңа совет гаиләсе төзим дип, тормыш зинданында зар чиккән меңләгән үзбәк хатынкызларына үрнәк булырлык яшим дип, ашкынып чыктым кияүгә.* Ф.Сафин

**ЗАРЫГУ** *ф.* 1) Көтә-көтә ару, йөдәү, талчыгу. *Язны Таулы Төбәк райкомында зарыгып көтеп алдылар.* Г.Ахунов. *Поездның станциягә килеп җиткәнен зарыгып көтеп алам.* Т.Миңнуллин

2) Түземсезләнү (озак көтүдән, нинди дер эшне башлап җибәрә алмаудан һ.б.дан), тую, ару. *Зарыгып көткән сөйкемле төн килү белән, тагын күңел рәхәтләнә.* М.Әмир. *Кызыклы әкиятнең ахырын түземсезләнеп көткән кебек, матур чабатаның да калыптан тизрәк төшүен көтеп зарыга ул.* Н.Максимов

3) Ачыну, үрсәләнү, өзгәләнү кебек хис кичерү. *Бу шулай бик озак өерелә торгач, зарыгудан, ачыргаланып, кыя ташка ташлана.* Г.Гыйльманов. --- *чит җирләрдә Хәялинең бер авыз татарча сүз, бер куплет милли җыр ишетергә зарыгып яшәгән булуы ихтимал.* Ф.Хатипов

4) Сагынып көтү, тилмерү. *Таң кошын юксынып, Чишмә дә зарыга.* М.Җәлил. *Җыен, бергә китәбез. Анда әниең зарыга.* Х.Камалов

**Зарыга башлау** Зарыгырга тотыну. *Чөнки малай атны керсез күңелдән ярата, ә безне кулыбыздагы шикәребез, печеньебыз беткәнче генә ярата да, беткәч, зарыга башлый.* И.Гази

**Зарыга төшү** Бераз зарыгу

**Зарыгып бетү** Тәмам, бик нык зарыгу. *– Көтә-көтә зарыгып беттем, чәем дә суынды инде, ни эшләп бу кадәр соңладыгыз? – диде.* Һ.Такташ. *Хәлим, ачык тәрәзә төбенә утырып аларны көтә-көтә, тәмам зарыгып бетә.* И.Гази. *Атым көткәндер инде, Зарыгып беткәндер инде.* Р.Вәлиева

**Зарыгып йөрү** Озак вакытлар дәвамында зарыгу. *Калды Казан, киттем Себергә. Озаккамы? Бәлки, гомергә. Ишетеп кенә белгән ят җирләрдә Ристан булып, зарыгып йөрергә.* Ф.Кәрим

**Зарыгып тору** 1) Гел, һәрвакыт зарыгу. *Яз җитә дип, мин дә бер куанам, Бер җырлыймын өзелеп сагынып. Торырсыңмы, былбыл, син зарыгып, Читлегеңдә һаман ябылып.* Ш.Бабич. *Эх, бу томанны!.. Хәтерләтте синең, шәл бөркәнеп, Мине көтеп, зарыгып торганны.* Х.Камалов

2) Әле, хәзерге вакытта зарыккан булу. *Һәрбер сыйныфның хәзергә хәтле үз өстендә хөкем сөреп килгән тәртип вә аны иҗра итүчеләргә булган мөнәсәбәтләрен күрергә вә вәкилләре васитасы белән кылган дәгъваларын ишетергә зарыгып тора иде.* Ф.Әмирхан. *Капканың ачылып китүе булды, халык ике якка тайпылып кына өлгерде, зарыгып торган айгыр атылып чыгып та китте.* Г.Бәширов

**Зарыгып яту** Күп вакытлардан бирле, озак вакытлар зарыгу. *Гасырлар буе тырыш хезмәтне, батыр кулларны көтеп, тудырырга, үстерергә зарыгып яткан бу шәфкатьле җирдә бик күп игеннәр, җимеш агачлары үстерәсе --- килә иде.* Г.Бәширов

**ЗАРЫКТЫРГЫЧ** *с.* 1) Зарыгырга мәҗбүр иткән, зарыктыра торган, түземсезләнеп көтеп алынган. *Зарыктыргыч ике-өч минут үтеп китүгә, авыру беренче сулышын ала, аннары икенче, өченче…* Кызыклы физиология

2) Ардырта, талчыктыра торган, ялыктыргыч. *Ниһаять, дәресләрнең зарыктыргыч бертөрлелеге шәкертләрне дә, Габдулланы да тәмам ялыктырды.* Ә.Фәйзи

**ЗАРЫКТЫРУ** *ф.* Бик нык көттереп арыту, тилмертү. *Еллар буе кызны зарыктырды Шул атаның йөрәк сагышы.* М.Җәлил. *--- көттереп, зарыктырып дөньяга килде Вася.* Ф.Латыйфи. *– Я, сөйлә инде, зарыктырма? – дип, Габдулла иптәшен куыра башлады.* Ә.Фәйзи

**Зарыктырып бетерү** Тәмам зарыктыру, көттереп тилмертү. *– Зарыктырып бетермәгез, кайтып торыгыз, – дип калды артларыннан әниләре.* Казан утлары

**Зарыктырып тору** 1) Гел, һәрвакыт зарыктыру

2) Бик озак зарыктыру. *Көттереп, зарыктырып торганнан соң, гап-гадәти кар яуса да шатлык.* Ш.Галиев

**ЗАРЯД** *и. рус* 1) *хәрби* Утлы коралда (снаряд гильзасында, патронда һ.б.ш.да) тиз кабынып китүчән шартлагыч матдә. *--- Габдрахман Галиев, авыл яшьләре арасында физкультура-спорт эшләрен җәеп җибәрү өчен, волейбол җәтмәседер, туплар, әллә ниткән герләр, һәртөрле сикерү, суга чуму, муен сындыру әсбаплары алган, хәтта тартма-тартма зарядлары белән кече калибрлы мылтык алырга да онытмаган.* Ф.Хөсни

2) *физ.* Электр корылмасы. *А.Бугорский алган нурланыш заряды 200 мең рентген белән исәпләнә.* Татарстан яшьләре

**ЗАРЯ́ДКА** *и. рус спорт* Организмны чыныктыру максатында, даими ясала торган физик күнегүләр; гимнастика. *Иртән ул беркайчан да калдырмый торган зарядкасын бүген ясамады.* Ф.Садриев

**ЗАСА́ДА** *и. рус хәрби* 1) Яшерен урыннан дошманга көтмәгәндә һөҗүм итү ысулы; поскын. *Мөгаен, алар безнең полк батареяләренең засадада торуын абайламый калды булса кирәк.* Ә.Галиев. *Засадага эләккән бер байгура, егетләр сизмәгәндә генә, кесәсеннән бер йомарлам кипкән кызыл балчык алып, канауга ташлады.* З.Фәтхетдинов. *Кауровның немец засадасы белән бәрелешүе бик мөмкин.* Г.Әпсәләмов

2) Шундый һөҗүм өчен әзер торган отряд, төркем. *Яна башлаган танк, арттагы танкларга юл бирү өченме, әллә засададагы бутылкачыларны сытып ташлау нияте беләнме, кинәт уңга борыла.* И.Гази

3) Засада отряды урнашкан урын. *Кичкә кырын засадада ята иде ул, шунда бөтен җирдә аңламаслык бер тынлык иде.* Ә.Исхак

**ЗАСЛОН** *и. рус* 1) Саклану киртәсе; нәрсәдән дә булса саклану өчен куела торган әйбер. *Район территориясендә терроризмга һәм экстремизмга ышанычлы заслон кую, гражданнарның шәхси хокукын һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү беренчел бурыч булып кала.* Туган як

2) *хәрби* Хәрби операция вакытында дошманның төп көчен үзенә юнәлдереп, һөҗүмне уңышлы башкаруга ярдәм итә торган сугышчан отряд. *Аның приказы буенча роталар дошманның сафлары хәлсезрәк булган бер юнәлешкә удар ясыйлар, ә заслонда калдырылган Х.Сабиров взводы дошманны калган участокларда тоткарлап тора.* Г.Мөхәммәтшин

**ЗАСТА́ВА** *и. рус хәрби* 1) Дәүләт чиген саклый торган хәрби подразделение. *Этләргә акыллы, җитди булу килешәрәк төшә (чик буе заставасындагы овчаркаларны нәкъ менә шуның өчен яраттым да инде мин).* Р.Низамиев. *Башта аны комсомол секретаре итеп сайлыйлар, аннары застава командирының политбүлек урынбасары итеп билгелиләр.* Х.Бәдигый. *Мин аны, Сосновка авылына бара торган юл дип, заставага бара торган юлга җибәрдем.* А.Әхмәт

2) Шул подразделение урнашкан урын. *Җиһангир, элек әтисе белән заставада торганлыктан һәм хәрби тормышка берникадәр күнеккән булганлыктан, Опанас Грайның сүзләрен тиз төшенә барды.* Г.Әпсәләмов

3) Каравыл отряды, подразделениесе

**ЗАСТА́ВКА** *и. рус махс.* 1) Китапта текст, бүлек башланган битнең өске өлешендәге бизәк, орнамент, рәсем. *Китапның җыйнак калыбы да, сәнгати яктан бизәлеше дә күңелгә хуш килә. Аның тышлыгы, форзацлары, заставкалары һәм нәфис миниатюралар дәрәҗәсендәге иллюстрацияләре Надия Фәхретдинова тарафыннан эшләнгән.* Р.Әмирхан

2) Телевидение, радио тапшыруларының башында кабатлана торган музыка, рәсем, эфирда паузаларны тутырган композиция. --- *радиоалгычны кабыздым да соңгы мәртәбә эфирга чыктым. Һәрвакыттагыча алхәбәр – заставка сыйфатында «Космическая фабрика», «Гастролирующий ансамбль» альбомыннан Криденсларның ике минутлык боевигын куйдым.* Т.Кәримов

3) *сөйл.* Компьютер, кәрәзле телефон экранына куелган рәсем

**ЗАТ** *и. гар.* **1.** 1) Төп билгеләре гомуми булган предметлар, җан ияләре төркеме. *Һәм [ул], тамагы ач булуга карамастан, ашарга да сорап тормыйча, төендә азык заты юклыгын истә тотты булса кирәк, эшкә кереште.* М.Әмир. *Җылы канлы хайваннарның күкәй күзәнәкләре, сазлыкта тереклек итүче җир-су затларыныкына караганда, йөзләрчә тапкыр кечкенәрәк.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Җенес. *Аның сул ягына хатын-кызлар, уң ягына ир затындагы кешеләр утырды.* Н.Фәттах

3) Кеше, адәм баласы, шәхес. *Дөньяда тагын бер гадәттән тыш зат – Мөхәммәт Тулеевның әрвахы пәйда булу, әйткәнебезчә, вакыйгалар барышын үзгәртеп җибәрсә дә, лаборатория өчен артык киеклык тудырмады.* А.Тимергалин. *Кеше – биологик һәм социаль зат.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Чөнки Әни заты берни дә доллар, фунт-стерлинглар белән дә бәяли алмаслык олы Бәхет ул!* Сөембикә

4) *миф.* Адәм балалары яки табигатьтән өстен көчләр. *Нишләттең малкайны, пәри заты?!* Н.Гыйматдинова. *Язмыш – илаһи зат, сихри көч, тылсым иясе, дигәнне белдерә.* Г.Гыйльманов. *Бер генә зат та, хәтта Күк Иясе дә Ана каргышына каршы килә алмаган.* Р.Батулла

5) Нинди дә булса әйбер, нәрсә, предмет. *Әдилбәк челем тартмый торган кеше була. Тәмәке заты тотмыйм бит, дип җавап бирә.* Г.Ахунов. *Җирдә ник бер үлән заты булсын, аяк астындагы кызыл туфрак кыштырдап тора.* Ф.Бәйрәмова. *Бүгенге көндә өйдә өреп очырырлык ризык заты юк...* М.Хәсәнов

6) Чыгыш, нәсел, ыру, токым. --- *күркәм дә, батыр да, кыю да шәхесләр булып, юк, изге затлардай булып күз алдына килә алар.* Мирас

7) Нинди дә булса уртак сыйфатлары, башкарган эше, профессиясе белән аерымланган төркем. – *Син – Ибрашка заты! Зимаг-гур! – Ә син – Бур Дәүләтхан каны!..* Р.Камалов. *Күпме текә затлар машинада гына йөри хәзер.* Ф.Баттал. *Яшьлек ике бирелми, хәтта укытучы затка да.* Т.Галиуллин

8) Кеше арасына чыкканда гына, яхшыга кия торган кием турында; кешелеккә, рәешкә. *Алай да мунча кереп, затка кия торган күлмәген киеп, чәчәкле ефәк яулыгын бәйләгәч, нур кереп киткәндәй булды үзенә.* Б.Камалов

9) *лингв.* Эш-хәрәкәтнең сөйләүчегә мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категория. *Аналитик иярчен җөмләләр баш җөмләдә һәрвакыт пауза белән аерылалар, һәм, кагыйдә буларак, аларның иясе белән хәбәре затта ярашалар.* М.Зәкиев

**2.** *с. мәгъ. сөйл.* Гүзәл сыйфатлы, бәһале; дәрәҗәле. *Зат җиһаз. Зат кием-салым*

**ЗА́ТӘН** *рәв. гар.* **1.** Асылда, нигездә, чынында, дөресендә. *Затән безнең ашын ашаган, яшен яшәгән картларыбызны, корган агачтан дуга ясарга мөмкин булмаган кеби, тугры юлга көндерүе мөмкин түгелдер.* Г.Тукай. *Затән моның Зыяга кирәге дә юк; анда бар музыка, шул аңа җитә.* Г.Ибраһимов

**2.** *кер. сүз мәгъ.* Гомумән алганда. *Затән, Гаяз әфәнденең һәммә пьесаларында да сәхнә өчен авырлыклар, кирәкмәс дәрәҗәдә озын монологлар бар.* С.Рәмиев. *Затән, бу тармакларны татарлар арасында социализм хәрәкәтенең тарихын язучы берәм-берәм тикшерергә тиеш.* Казан утлары

**ЗАТВОР** *и. рус хәрби* Ату коралында көпшәнең түбән башын ачу яки ябу өчен махсус эшләнгән механизм. – *Сөйләшмәскә! – Мылтык затворы тавышы чыңлап куйды.* Ф.Сафин. *Тегене затворны бик озак кулында әйләндерде, алай борды, болай борды ---, шулай да затворны сүтә алмады.* Г.Әпсәләмов

**ЗАТ-КАВЕМ** *җый. и.* Кардәш-ыру, нәсел-нәсәп, чыгыш. *Зат-кавем бергә җыелу*

**ЗАТЛАНДЫРУ** *ф. махс.* Затлы төс бирү, сыйфатын, тышкы күренешен яхшырту. *Ул мех эшкәртүнең һәм мехны затландыруның фәнни методларын тикшерә, эзләнә, яңа юллар ача.* М.Максуд

**Затландыра төшү** Бераз затландыру

**Затландырып бетерү** Тәмам затландыру, затландыру эшен төгәлләү

**Затландырып җибәрү** Бераз, берникадәр затландыру

**ЗАТЛАНЫШЛЫ** *с. лингв.* Зат белән төрләнә торган. *Икенче төрле чаралар ияртүче җөмләнең хәбәре составында килмиләр, бәлки аннан аерым торалар, шуңа күрә хәбәр үзенең затланышлы, тулы формасын югалтмый.* М.Зәкиев

**ЗАТЛАНЫШСЫЗ** *с. лингв.* Зат белән төрләнми торган. *Синтетик чаралар ярдәмендә бәйләнгән җөмлә язма әдәби телдә һәрвакыт баш җөмләдән алда килергә тиеш, чөнки ул, хәбәре затланышсыз булганлыктан, ахырдан килеп, гомумән, кушма җөмләне тәмамлап куя алмый.* М.Зәкиев

**ЗАТЛЫ** *с.* **1.** 1) Яхшы нәселдән булган, асыл зат нәселеннән яки чыгышы морза һ.б.ш.лар нәселеннән килә торган. *Бигрәк тә затлы нәселдән килүче дворяннарга, патша түрәләренә, офицер халкына көн бетте.* З.Фәтхетдинов. *Ул [Фатыйма] морзалык, затлы нәсел белән мактануны, башкаларга түбәнсетеп карауны кире кага.* Әдәбият

2) Тәрбияле, яхшы тәрбия алган, югары эчке культуралы; зыялы. *Мин ул затлы кешеләрне күреп беләм.* Татарстан яшьләре

3) Яхшы токымлы, нәселле. *Ә хәзер һәр колхоз өстендә дөньядагы бу иң гүзәл, иң затлы, иң зыянсыз кошлар төркем-төркем очалар, түбә кыекларында, сарай түбәләрендә гөрлиләр.* Г.Әпсәләмов

4) Югары сыйфатлы, сыйфаты һәм материалы яхшы булган, кыйммәтле, асыл, югары бәядәге. *Бик әйбәт затлы сатин икән, рәхмәт инде үзеңә.* Ш.Камал. *Еракларден балкып тора Яңа бистә утлары, Ефәк кебек асыл затлы Казан фабрик мехлары.* Р.Ишморат. *Кодагыйга бирергә дә бер затлырак нәрсә алмый килешмәс.* М.Фәйзи

5) Тәмле, хуш исле. *Шәрык илләрендә әле дә кунакханәләрдә искә зур игътибар бирәләр: сандал агачы исе, арахис исе һ.б. затлы исләр чыгарып бүлмә әзерләү кунакка ихтирам билгесе булып санала.* М.Мәһдиев

6) Матур, күркәм. *Ресторанның иң затлы бүлмәсендә йөз кешелек табын әзерләнде.* Н.Гыйматдинова

7). Дәрәҗәле, күренекле; бөек. *Һәм бу затлы исемнең Мөхәммәт ага Мәһдиевкә рәсми рәвештә бирелгәнен ишетү чын әдәбиятка мөкиббән меңнәргә --- сөенечле бер вакыйга булганына иманым камил.* М.Галиев

8) Зур, саллы, лаеклы. – *Шагыйрә Жанна Баянова әдәбиятка бик матур, затлы өлеш кертте, – диде абзый. – Аның шигырьләре тел җәүһәрләреннән үрелгән асыл муенсага тиң иде.* М.Маликова

9) Югары зәвыклы, рухи ләззәт бирә торган. --- *затлы бер фикер тугандыр, шул затлы фикерен ул үзенең сүз тыңлаучан энесе Фатыйх белән ирләрчә, икәүдән-икәү генә бизмән тәлинкәсендә үлчәп карарга ният кыладыр.* Г.Ахунов. *[Рәшит Ваһаповның] Хәрәкәтләре дә бик табигый, сәхнә культурасы да югары, затлы иде.* Мәдәни җомга

**2.** *рәв. мәгъ.* Матур, яхшы, әйбәт итеп. *Затлы киенгәннәр, ат дирбияләре дә ялт-йолт итә.* М.Хәбибуллин

◊ **Затлы агач** Гадәттә мебель ясау өчен кулланыла торган кыйммәтле агач (мәс., *чикләвек агачы, кызыл агач*). *Бу – затлы агачтан матур сырлап, чын сәдәпләр белән бизәкләп эшләнгән бик нәфис язу өстәле иде.* Г.Гобәй. **Затлы металлар** Алтын-көмеш һәм башка кыйммәтле, тутыкмый торган металлар. *Казан көмеш осталарының эшләре аларның затлы металлардан ясалган әйберләр эшкәртү һәм бизәү техникасын бик әйбәт белүләрен күрсәтә.* Д.Рамазанова. *Зәңгәрсу асылташлы алтын алкалар таккан, ачык муенында нечкә чылбырга беркетелгән, затлы металлдан коелган арыслан башы ыржаеп тора.* Ш.Рәкыйпов

**ЗАТЛЫЛЫК** *и.* 1) Затлы булу, күркәм холыклылык, югары эчке культурага ия булганлык. *«Затлылык» дигән сыйфат та чамалы икән Сәүдә Сафинада: улын бер күрергә тилмергән әтисен ул Рафаэль янына якын да җибәрмәде.* Г.Ахунов. *Синең затлылыгың алдында гына түгел, зирәклегең алдында да баш иям.* З.Фәтхетдинов. *Конисская зыялы булуы белән бик күпләрдән аерылып тора, һәм аның шушы югары сыйфатын, затлылыгын немецның затлы офицерлары, солдатлары да бәяли беләләр.* А.Гыйләҗев

2) Матур, күркәм булу. *Янә бер баруында алиһәнең күлмәк якалары, үзенә күрә челтәр кыяфәте алып, бертөрле затлылык өстәгән иде.* К.Миңлебаев

**ЗАТОН** *и. рус* 1) Ярдан эчкә кереп торган елга култыгы. *Затон ярлары арасында йөри торган паром эзенең көмеш тимгелләре дә озакка бармыйлар, шомаралар.* К.Нәҗми

2) Пароходларга агымдагы ремонт ясау, елгаларда сезон ябылгач, кышын аларны саклау өчен махсус җиһазландырылган урын. *Көннәрдән бер көнне Казанның Балык базарыннан үзе кебек бер эшчене затонга илтеп куя.* Ф.Галимуллин. *Гаңгылдашып аккош-пароходлар Затоннардан юлга чыгалар.* Х.Туфан

**ЗАТСЫЗ** *с.* **1.** 1) Нәсел-нәсәбе, чыгышы белән затлы, асыл нәселдән булмаган. --- *морзалар үзләрен өстен санаганнар, «түбәннәр» белән аралашмаска тырышканнар, --- борын еш кына ишетелә торган «затлы» яки «затсыз» дигән төшенчә дә әнә шуннан килеп чыккан булса кирәк.* Ә.Еники

2) *сөйл.* Әдәпсез, тәртипсез, тәрбиясез; начар холыклы. *Бу мулланың һәр әгъзасы моның бик затсыз бер татар мулласы икәнлеген белдереп торалар иде.* Г.Тукай. *Сөннәтче бабайның әллә ничә еллардан бирле өйрәнгән гадәтләренә илтифат итмәенчә, үзе теләгәнчә кылана торган шул затсыз карчык аны җирәндерде.* Г.Исхакый. *Әлбәттә, тыштан күрсәтмәсә дә, эчтән затсыз Туктамышка җирәнеп караган, --- Тимер бәк бу яуны тегенең тар-мар ителүе белән тәмамларга теләгәндер.* С.Шәмси

3) Түбән сыйфатлы, начар эшләнгән, сыйфатсыз. *Алтын акыл затсыз малга кызыкмый ул.* У.Шекспир. *Затлы күлмәк киясе килгән хатын-кыз затсыз күлмәген сала белергә тиеш.* Р.Батулла. *Затсыз тәмәкедән саргайган тешләре генә артык эре.* Т.Галиуллин

4) *сөйл.* Начар, эшәке, оятсыз; тыелган. *Гадәттәгечә затсыз сүзләр әйтергә тотынганчы дип, Хәйруллаһ бәй яныннан тиз генә йөгереп чыгып киттем.* Р.-Н.Гүнтәкин. *Күңел ярасына тәмсез телләрдән затсыз сүзләр сибелүен теләми иде ул [Мидхәт].* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Сыйфатсыз, начар итеп. *Бу мәкаль, икенчеләй миңа эш кушмасыннар дигән кебек, формаль һәм затсыз эшләргә мисал итеп.* Ш.Хөсәенов

**ЗАТСЫЗЛАНУ** *ф. сөйл.* Әдәпсез кылану, үзен әдәпсез, тәрбиясез, оятсыз тоту. *Шул бит инде [Нуриасма], затсызланып, яңагына миң ясап йөри, сул яңактагы миң егетләргә мәхәббәтле күрсәтә, дип сөйләнә иде.* Ш.Хөсәенов. *Өстәл янына утыралар да, аракы эчә-эчә, ничек итеп тегенең белән булуларын затсызланып сөйли башлыйлар.* Ш.Галиев

**Затсызлана бару** Торган саен ныграк затсызлану

**Затсызланып бетү** Тәмам, бик нык затсызлану

**Затсызланып китү** Кинәт, көтмәгәндә затсызлык күрсәтү

**Затсызланып тору** Вакыт-вакыт, еш яки хәзерге вакытта затсызлык күрсәтү. *Килененең затсызланып торуына Гайшә әбинең йөрәге әрнеде.* Казан утлары

**ЗАТСЫЗЛЫК** *и. сөйл.* Әдәпсезлек, әдәп кагыйдәләреннән читкә китү,

тәртипсезлек. *Андый-мондый тупас сүз әйтеп затсызлыгыңны белдермә!* Г.Исхакый. *Галәм фасылларының билгеле бер агышында адәм балаларына курку иңә, затсызлык, комсызлык арта.* Ф.Латыйфи. *Ихтимал, җитәкчеләрнең затлылыгы яки затсызлыгы хатыннарыннан да киләдер.* Г.Ахунов

**ЗАТ-ЫРУ** *җый. и.* Туган-тумача, туганнар, кардәшләр; нәсел-нәсәп. *Бөтен зат-ыруын белү. Аларның зат-ыруы бик ишле. Зат-ыру белән киңәш кору*

**ЗАТ-ЫРУСЫЗ** *с.* Туган-тумачасыз, нәсел-нәсәпсез. *Зат-ырусыз кеше*

**ЗАФӘР** *и. гар. иск.* Өстенлек, уңыш, җиңү, максатка ирешү. *Газат әһлегә бу бер хөсне ләтафәт бар: зафәр тапса – ганимәт, гәр шәһадәт тапса, җәннәт бар.* Кол Шәриф. *Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыйлып, сабыр ит ки, сабыр иткәннәр тиз заман зафәр таптылар.* К.Насыйри

**ЗАҺИД** *и. гар. иск. кит.* Суфи; дини, тәкъва, изге кеше; монах. *Поэмада каһарманнарның яшьләрен бирүдә дә шартлылык, әкияти традицияләргә иярү күзгә ташлана. Мәсәлән, Кәнган пьесасындагы заһидка – 1200 яшь.* Х.Миңнегулов

**ЗАҺИДЛЕК** *и.* Заһид булу. *Караңгы бер мәгарәңне йортың итеп, Габидлеккә, заһидлеккә башыңны сал.* Мирас

**ЗАҺИР** *с. гар.* **1.** Тышкы, күренеп торган. *Гайбе заһир улса улсын, гайбе мәзъһәр улмасын.* Акмулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Аермачык, ачык, анык. *Имамлыкның рәсүлулла урынына калу икәнлегеннән хәбәре булмаганлыгы кояш шикелле заһир иде.* Г.Тукай. *--- аның кояштай балкып яшәргә тиешлеге заһир имди.* С.Поварисов

**ЗА́ҺИРӘН** *рәв. гар. иск. кит.* 1) Тыштан, тышкы яктан караганда. *Ул заһирән шулай кебек күренсә дә, руслар әмире Бохарага илтифатларыннан гына шулай иткәннәр.* Г.Исхакый

2) Ачыктан-ачык. *Заһирән, хәлвәмезне хуш күрмәгәнеңездән төкереп ташладыңыз бугай.* К.Насыйри

**ЗАҺИ́Р БУЛУ** *ф.* Барлыкка килү, күзгә күренү. *Теләсә кайда гына булсын, йөрәгенә үтәрлек бер музыка ишетү белән, шул күренеш аның хыялында заһир була иде.* Г.Ибраһимов. *Башкаларның йөзендә хәят вә шатлык әсәре заһир булды.* М.Гафури. *Мәгәр ул чокыр эчендә бер арыслан заһир булып, ничә адәмнәрне һәлак тиеш иде.* К.Насыйри

**ЗАҺИРИ** *с. гар. иск. кит.* **1.** Тышкы, тыштагы, күренеп торган, тышкы якка караган. *Бу, икенчедән, мәйданга заһири шатлык бирә.* Г.Ибраһимов. *Газизә Хәнифә, сәнең ялгыз заһири кыяфәтеңә дәгел, хөсне әхлакыңа кәзалик гашыйк улдым.* М.Акъегет

**2.** *и. мәгъ.* Тышкы күренеш, кыяфәт, килеш-килбәт. *«Карама беләккә, кара йөрәккә» [мәкале] кешенең сурәт заһирисенә вә кыяфәтенә игътибар итмә, мәгърифәтенә кара, димәк.* К.Насыйри

**ЗАЧЁТ** *и. рус* 1) Югары уку йортларында яки махсус урта мәктәпләрдә укучыларның теоретик һәм практик белемнәрен, билге куймыйча, гомуми планда тикшерү, сынауның бер төре. *Зачётлар бетү белән, акка-карага карамый, өйгә ашкындым.* Ш.Камал. *Үзе зачётларын башкалардан Алдан бирә, алдан котыла.* Һ.Такташ

2) Шундый сынау үтүне раслый торган билге

**ЗАЧЁТКА** *и. рус сөйл. к.* **зачёт кенәгәсе**

**ЗАЧЁТ КЕНӘГӘСЕ** *и.* Уку процессында студентка бирелгән, аның өлгерешен исәпкә алып, тикшереп, нәтиҗәләрен терки торган документ

**ЗАЧЁТ КНИЖКАСЫ** *и. сөйл. к.* **зачёт кенәгәсе**. *Дәүләт имтиханнарын биреп бетергәч, мин Даутов иптәшкә барып, зачёт книжкамны күрсәтеп, аңа һәм аның аша партиягә, хөкүмәткә рәхмәтемне белдердем.* Г.Кутуй

**ЗАЧЁТЛЫ** *с.* Зачёт тапшырган, зачёт биргән, имтиханын уңышлы тапшырган. *Теге зачётлы кыз, тау башларына яшел чирәм чыккач, кояшлы, матур язгы көндә саф һавага исереп, уйный, бик сикерә торган кәҗә бәрәне кеби кылана.* Г.Исхакый

**ЗАЯ** *с. гар.* 1) Әрәм, файдасыз. *Карусыз кешенең гайрәте зая, гайрәтсез кешенең һәйбәте зая.* Мәкаль. *Җәйләр тату насыйп булмаса да, Гомер юлкайларың түгел зая.* М.Вафин

2) Югалган, юкка чыккан, һәлак булган. *Немец теле грамматикасы ятлауга киткән зая вакытларымны кызганып куйдым.* М.Юныс

**ЗАЯ́ВКА** *и. рус* Нәрсә дә булса сорап җибәрелгән рәсми кәгазь, рәсми заказ, үтенеч. *Уйлап карыйк: эксперт-лар фикеренчә, заявка биргән 11 эшмәкәрнең, иң әйбәт дигәндә, берсе генә кредит алырга мөмкин.* Татарстан. *--- хуҗалыкларның заявкалары буенча кәзле авыр туфраклар өчен ярым винт сыман эшче өслеге булган корпуслар комплекты --- бирелә.* Механизаторлар белешмәсе

**ЗАЯВЛЕ́НИЕ** *и. рус сөйл. к.* **гариза**. *Гимназиянең берничә классыннан да имтихан тоткан кызы, кирәк урында аңа русча заявлениеләр, татарча хатлар да язып бирә.* Ф.Әмирхан. *Агымдагы эшләрдә партиягә кабул итүне сораган биш заявление каралды.* Ш.Камал

**ЗАЯ́(ГА́) КИТҮ** *ф.* Әрәм булу, бушка китү, кирәксезгә сарыф ителү, юкка тотылу; заегъ булу. *Хәзинә эзләдем, таптым, дидем, шат! Югалды ул – зая китте бу михнәт.* Котб

**ЗАЯ́(ГА́) УЗУ** *ф.* Бушка, әрәмгә китү, мәгънәсезгә сарыф ителү, югалту. *Минем җавапны көтеп, вакытын заяга уздырып тормастан, ул «мин бернәрсә белмим...»ен халык көенә шыңшыйшыңшый китеп барды.* Т.Галиуллин. *Акмал, чуен юл стансаларында вагон бушатып, Идел баржаларына утындыр, тоздыр ише нәрсәләр төяп, бер ел чамасы гомерен заяга диярлек уздырып җибәрде.* Г.Ахунов

**ЗАЯ́(ГА́) ҮТҮ** *ф. к.* **зая(га) узу**. *Үтсә дә гомере заяга, Ул да көлә, шаяра.* М.Җәлил

**ЗӘБУР** *и. гар.* Дауд пәйгамбәргә бирелгән китап; Псалмнар Китабы, Псалтырь, догалар җыентыгы. *Исламның төп кануны Коръән булса, башка дини китапларны да инкяр итми. Гайса пәйгамбәр дәверендәге Инҗил (Евангелие – Иисус Христос), Дауд дәверендәге Зәбур (Псалма – Давид), Муса пәйгамбәрнең Тәураты (Библия – Моисей) китапларын кабул итә.* Т.Нәбиуллин

**ЗӘВАЛ** *и. гар. иск. кит.* 1) Китү, бетү, юкка чыгу, югалу. *Күрмәсәң дә*

*син һичбер зәвал да, югалгандыр шунда күп атсыз.* М.Җәлил

2) Кояшның төшлектән баюга таба авышуы. --- *бу ел рамазан шәрифтә пәнҗешәмбе көн зәвал вакытында мәгърибъ тарафындин бер койрыклы йолдыз пәйда булды.* М.Госманов. *Авык ул дәм күзен текәп күккә бакар, Күккә бакып зәвал вакыт булмыш күрер.* Дастан

3) Чик, кульминацион нокта, үсү яки кимүнең иң соңгы, ахыргы чиге. *Һәр кәмальнең бер зәвалы бар.* Мәкаль

4) *күч.* Үлем. *Әбү Ләһәб анда иде, әйтте: «Зәвал сиңа ки, бу кадәр халыкны тугры юлдан яздырдың! Янә аздырмак эстәрсең!» – диде.* К.Насыйри

**ЗӘВАЛЛЫ** *с.* Кызганыч, бичара; бетүгә, югалуга йөз тоткан. *Ләкин зәваллы сәяхәтнамәнең һичбер җирендә: «Бу мөселман ирләренең эшләре кая, йортлары кая, кәсепләре кая?» мәсьәләләрен карамаган да, уйламаган да иде.* Г.Исхакый

**ЗӘВЫК** *и. гар.* **1.** 1) Матурлыкны, гүзәллекне тоя белү, әйбер, күренешләргә эстетик бәя бирә белү сәләте. *Гомернең күп елларын Мәскәү консерваториясендә уку, Мәскәүдә яшәү, гомеренең күп елларын Мәскәүнең күренекле сәнгать осталары белән аралашып үткәрүләре берсе дә эзсез калмаган, әнкәйнең зәвыгын формалаштырган.* Ә.Айдарская. *Теге яки бу халыкның борынгылыгын, зәвыгының камиллек дәрәҗәсен белергә теләсәң, аның хатын-кызларына, аларның да кием-салымына, үз-үзен тотышына игътибар ит.* Ф.Латыйфи. *Зәвык белән эшләнгән йомшак утыргычлар!* Мирас

2) Эчке сиземләү сәләте. *Ата-баба, йорт салганда, тәрәзә наличнигын үз зәвыгына туры китереп эшләгән.* М.Мәһдиев. *Алмабикәнең күңел зәвыгы тупас ак офицер табигатен һич кабул итә алмый.* С.Поварисов

3) Ләззәт, рухи канәгатьлек, хозур. --- *минем белүемчә, моңа кадәр берәүнең дә үз файдасы, үз зәвыгы өчен генә музыкант яисә артист булганы юк әле.* Г.Бәширов

4) Кызыксыну, мавыгу. *[Ибрай сабан сөрүгә] Файдалы эш итеп түгел, бер зәвык итеп кенә карый.* Г.Гобәй

**2.** *рәв. мәгъ.* Сүзгә оста, һәвәс. *Егет сүзгә бик зәвык, чая булып чыкты.* А.Шамов

◊ **Зәвык ачу** Табигатьтә яки башка җирдә җыр-музыка белән күңел ачу, ләззәт алу. *Гадәттә, берничә кеше үзара зиһен-хыял җитезлеген сынашып зәвык ачу өчен, халык телендә күчерелмә мәгънәдә йөргән кыска гына шигъри сөйләм белән ике нәрсәдән берсенең охшашын әйтеп икенчесен табуга, шулай ук тапкыр җавап алу, кара исәп белән мәсьәлә чишү өчен, телебездә әйтелеп йөргән четерекле сорауларга, башваткычларга «табышмак» диләр.* Н.Исәнбәт. **Зәвык ачып утыру** *к.* **зәвык ачу**

**ЗӘВЫКЛАНУ** *ф.* Зәвык, ләззәт алу, тәм табу, рухи рәхәтлек, канәгатьлек кичерү. *Мин, җәйге табигатьнең кояш баткандагы аһәңенә зәвыкланып, яшел печән белән ябылган куыш буендагы бүтәкә үләннәре өстендә утырам.* М.Мостафин

**ЗӘВЫКЛЫ** *с.* **1.** 1) Сиземләү сәләте зур булган, матурлыкны, гүзәллекне тоя белгән. --- *тирән зәвыклы язучы яисә тәнкыйтьче күзе генә тотып ала алырлык кайбер үзгәрешүсеш чалымнарын, йә булмаса, прозаның котылгысыз рәвештә зәгыйфьләнә баруын тоябызмы, сиземлибезме?* Ф.Латыйфи

2) Зәвык белән эшләнгән, матур, нәфис. *Йортлар бизәлешендә ул бер дә зәвыклы төсмерләр таба алмады.* Г.Үзиле. *Агач, салам, бамбуктан ясалган юан балдак, авыл өстәле яисә, киресенчә, бик зәвыклы япон сервировкасы өчен кулай санала.* Сөембикә

**2.** *и. мәгъ.* Матурлыкка, гүзәллеккә эстетик бәя бирүче кеше. --- *бүгенге заман тамашачысының коллектив портретында билгеле бер төркем обывательләрне, арзан зәвыклыларны да табып булсын, ди, ләкин бит иң түбән обывательнең дә эчендә кеше җаны бар.* Г.Ахунов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Зәвык белән, пөхтә, матур итеп. *Бүлмәләр генә түгел, хәтта кухня да күзләреңне иркәләп, җанга рәхәт бирә торган итеп зәвыклы җыештырылган.* М.Максуд

2) Чын күңелдән, рәхәтләнеп, тәм табып. *Зәвыклы итеп көлде Җәмил, мәзәкчел малайларга хас булганча.* Г.Гобәй

**ЗӘВЫКЛЫЛЫК** *и.* Гүзәллек, матурлык, зәвыклы булу, зәвык белән эшләнгәнлек. *Бер читтә, ул кадәре зәвыклылык белән салынмаса да, шактый зур йорт, рәшәткәле терраса, кечкенә беседка, --- җимеш бакчасы ---.* А.Каһһар. *Бүген республиканың социаль хезмәтендә үз эшенә бирелгән --- инициативалы 10 меңнән артык социаль хезмәткәр эшли. Тармагыбызның киләчәге, абруе һәм зәвыклылыгы нәкъ менә шул кешеләргә бәйле.* Татарстан

**ЗӘВЫК-САФА** *җый. и. гар.* Хозур, ләззәт, рәхәтлек

**ЗӘВЫК-САФА́ КЫЛУ** *ф.* Хозурлану, ләззәт, рәхәтлек кичерү. *Намуслы фамилияләр үз йортларында --- әдәп берлә зәвык-сафа кылалар.* Ш.Мөхәммәдев

**ЗӘВЫКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Зәвыгы, гүзәллекне тою сәләте булмаган; рухи ләззәт бирми торган. *Зәвыксыз да түгел: теләгәндә киенә белә, вакытында матур сүзләр белән синең күңелеңне ача ала!..* Г.Ибраһимов. *Күргәнегезчә, мин [Жан] чирек минутта куркыныч үч алучыдан зәвыксыз бай сәүдәгәргә охшап калдым.* Ш.Рәкыйпов. *Маркиан исә аның өчен комган тотучы гына иде – ни акылы, ни ирлеге юк, тупас һәм зәвыксыз бер бәндә.* М.Хәбибуллин

2) Зәвык белән эшләнмәгән (ясалмаган). *Борынгы урыннары рәхимсез җимертелгән, кайбер урыннары зәвыксыз төзелгән башкалама сыкранып карыйм.* М.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Зәвыгы түбән хәлдә, матурлыгы исәпкә алынмыйча. *Күп җирләрдә, тирә-юньгә ямь биреп, манаралы мәчетләр калкып чыкты (дөрес, аларның күбесе ашык-пошык, зәвыксыз һәм фәкыйрь салынды ---).* Р.Фәйзуллин. *Нәрсә генә маташтырмаганнар: чыршы бизи торган ялтыравык укалар, зәвыксыз гына ясалган рәсемле, еш алышынып торган сәхнә дисеңме, сәхнәдә дә, залда да түшәмнән асылынып төшкән, ялык-йолык килеп әйләнә торган көзгеле шарлар дисеңме – берсе дә калмаган.* Казан утлары

**ЗӘВЫКСЫЗЛЫК** *и.* Зәвыксыз булу, зәвыгы булмау. *Оҗмахның гадәттән тыш матурлыгын сурәтләгәннән соң, сюжет башланганчы ук, бу матурлыкның җансызлыгын, зәвыксызлыгын, ямьсезлеген искәртә.* Р.Харрасова

**ЗӘГЪФРАН** *и. гар.* 1) Сусынчалар семьялыгыннан, яфраклары тамыр яны таралгысы ясап үсә торган, сары буяу матдәсенә бай булган хуш исле шәмәхә чәчәкле, бүлбе-суганчалы көньяк үсемлеге; *русчасы:* **шафран**. *--- тәрәзәдән чыгып барганда, зәгъфран гөле чүлмәген челпәрәмә китерүем һәм аны мәчебезгә сылтаганым исемә килеп төште дә, үз-үземне белештермичә, үксеп елап җибәрдем...* Ж.Тәрҗеманов

2) Шул үсемлекне киптереп әзерләнгән аш тәмләткеч. *Шуннан соң сөзелгән шулпага пешкән сарык итен, он белән кыздырылган суганны салырга, зәгъфран (шафран), тоз, борыч сибеп, тагы кайнатып чыгарырга кирәк.* Йорт эшләре

3) Шул үсемлекнең киптерелгән чәчәге серкәсеннән алынган буяу. *Өйлә тәһарәте берлән хәзрәт тарелкага зәгъфран берлән аяте шифа да язып җибәрде.* Г.Исхакый. *--- каурый каләмне зәгъфран карасына манган арада, сыңар куллы кешенең йөзендә ниндидер таныш чырай күреп, акырып җибәрә.* К.Нәҗми

4) Зәгъфраннан алынган буяу төсенә туры килгән кызгылт сары төс. *Зәһәрләнә, төсе зәңгәрләнә, Гыйфритләнә килен өстенә; Бичара килен – яшь кызга Зәгъфрандай сары төс иңә.* Г.Тукай. *Капка уентыгында зәгъфран сарылары иңгән чибәр йөз күренде.* Ф.Латыйфи

**ЗӘГЪФРАНЛЫ** *с.* 1) Зәгъфран (*1 мәгъ.*) салынган, зәгъфран кушылган. *Зәгъфранлы су*

2) Зәгъфраннан ясалган. *Зәгъфранлы буяу. Зәгъфранлы төнәтмә*

**ЗӘГЫЙФӘ** *и. гар.* Зәгыйфь хатын-кыз. *Үрия әйтте: «Мин – бер зәгыйфә, гаҗизмен, ничек итеп мин падишаһлык итим?» – диде.* Борынгы татар әдәбияты

**ЗӘГЫЙФЬ** *с. гар.* **1.** 1) Физик яктан кимчелекле, тәненең берәр әгъзасы имгәнгән, авыру, гарип. *Заһидулла агай үз вакытында гаскәргә дә алынмады, соңрак сугышка да бармады: бер аягы зәгыйфь аның.* М.Кәрим. *Сәламәт йөрәк мондый катлаулануны шактый ансат җиңә, ә зәгыйфь йөрәк өчен ул авыр көрәшкә әверелә.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Көчсез, хәлсез, теге яки бу эшне башкаруга сәләтсез, башкалар ярдәменә мохтаҗ. *Хәзер инде ул ашыкмый, кабаланмый, саф һава сулап кирәргә чыккан зәгыйфь карт кебек, аягын атлар-атламас кына бара бирә.* М.Насыйбуллин. *Кайчагында көчле ирләр эшли алмаганны зәгыйфь кенә хатын-кыз менә дигән иттереп башкарып чыга бит.* Г.Әпсәләмов

3) Начар үскән; үсеп, өлгереп җитмәгән, җитлекмәгән. *Мыекчалар үсемлекнең зәгыйфь сабагын ныгыту хезмәтен үти.* Ботаника

4) Көчсез, ишетелер-ишетелмәс; сизелер-сизелмәс (кенә) булган. *Гөлшәһидә тамыр тибешен капшады: һаман бик зәгыйфь.* Г.Әпсәләмов. *Төтен эчендә бишле лампаның зәгыйфь яктысы тагы да зәгыйфьрәк булып күренә.* Г.Гобәй

5) Сыйфаты ягыннан тиешле дәрәҗәдә булмаган, сыйфатсыз. *Мөхәррирнең драмалары комедияләренә караганда да зәгыйфьрәк вә төссезрәк.* Г.Кәрам. *Шагыйрь --- беренче зәгыйфь шигырьләре белән --- динчелек мирасына каршы ачыктан-ачык сугыш ачты.* А.Гыйләҗев. *Кулына бәяләү өчен йомшак, зәгыйфь әсәр килеп керсә дә, Гариф абый --- күтәрелеп бәрелмәс ---.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Начар гына булып, көчсез булып. *Матвей Иванович каршында илаһи көчен җуйган бакыр кисәге, агач тамырына туры килеп, зәгыйфь зыңлап алды да, юл тузанына батып, күздән югалды.* Г.Гобәй

2) Эшләнеше түбән; начар, тиешле дәрәҗәгә җиткермичә. *--- бу әсәрләр берсе дә әдәби вакыйга була алмыйлар һәм әдәби эшләнешләре ягыннан шактый ук зәгыйфь булып туалар.* Мирас

**ЗӘГЫЙФЬ-ЗОГАФА** *җый. и. гар.* Һәртөрле авыру, гарип-гораба. *Нуретдин --- һәртөрле зәгыйфь-зогафага дарулар белән ярдәм итүне, бигрәк тә үз кулы белән дару сөртүләрне бик ярата иде.* Г.Тукай

**ЗӘГЫЙФЬЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Зәгыйфь хәлгә китерү, гарипләү, имгәтү. *Фигурасының бик күп татар хатыннарыныкы ишкелле зәгыйфьләндерелгән булмавы --- миндә яхшы хис калдырды.* Ф.Әмирхан

2) Көчсезләндерү, көчен бетерү, хәлен алу. *Болар [дәүләт ягыннан ярдәмне азайту] һәм башка сәбәпләр татар авылларын зәгыйфьләндерә генә.* Рәмзи Вәлиев. *Аксак Тимер, Алтын Урданы тәмам зәгыйфьләндерү максатында, иң беренче нәүбәттә икътисад, мәдәният, һөнәрчелек, сәүдә үзәкләре булган шәһәрләргә һөҗүм итте.* Мирас

**Зәгыйфьләндерә төшү** Бераз зәгыйфләндерү, шундый хәлгә китерү

**Зәгыйфьләндереп бетерү** Тәмам, бик нык зәгыйфьләндерү

**ЗӘГЫЙФЬЛӘНҮ** *ф.* 1) Имгәнеп, авырып, картаеп зәгыйфь хәлгә килү, зәгыйфькә әйләнү. *Тешәгәндә таш чәчрәп, сул күзе дә зәгыйфьләнгән иде.* А.Гыйләҗев. *Клиникага исә Вафина бөерләренең эшчәнлеге бөтенләй зәгыйфьләнгәч кенә килеп эләккән.* М.Маликова. *Тын су өстендә миңгерәгән, сәламәтлеге зәгыйфьләнгән корбан балыклары шулай өскә чыга, болганып йөри башлый.* М.Рәфыйков

2) Начар үсү; нинди дә булса сәбәп аркасында үсеше тоткарлану, тиешенчә үсә алмау, җитлекмәү. *Урыны-урыны белән караеп торган, зәгыйфьләнгән иген камылларын да «Арыш анасының эзләре» дип уйлаганнар.* Г.Гыйльманов. *Яфраклары саргайган, таплы-таплы чәчәкләре зәгыйфьләнгән; үрчемлелеге кимегән.* Р.Зәкиев

3) Көчсезләнү, куәте кимү, хәлсезләнү, көче югалу. *Менә ярлылык башланып, хәзинә ярлылангач, мәмләкәттә башбаштаклык туды. Шуның аркасында Алтын Урда зәгыйфьләнде.* Г.Гобәйдуллин. *Саный башлаганда шактый көр яңгыраган тавыш егермеләр тирәсендә зәгыйфьләнә, сүнә башлады.* М.Юныс. *Ышанычлырак булсын дип, снайпер тагын бер тапкыр мылтык тәтесенә басты, икенче пуля*

*да шул ук юлны узды, көче кимеп, зәгыйфьләнә башлаган йөрәк янынннан гына үтте.* А.Гыйләҗев

4) Интенсивлыгы кимү, киеренкелеге юкка чыгу. *Җир астындагы пар бер куәтләнсә, бер зәгыйфьләнсә, ул вакытта җир бер күтәрелә вә бер төшә дә, зилзилә хасил була.* Ф.Әмирхан

5) Нормаль уйлау, фикер йөртә алу сәләтенә зыян килү. *Ләкин ул, теге телсез әпә кебек, аң-зиһене зәгыйфьләнгән бер мескен зат та түгел.* Г.Гыйльманов. *Кешенең тиресе саргая, сөякләре сынучан була, чәче коела, акылы зәгыйфьләнә, элекке тойгылары һәм кызыксынулары югала, ул тиз картая.* Мәгариф

6) *күч.* Төшенкелеккә бирелү, бар нәрсәне начар итеп күрү, бары начарлык эзләү. *Бөтен җире дә исән-сау аның. Әмма рухы зәгыйфьләнгән, күңел ярлары какшаган...* Г.Гыйльманов

**Зәгыйфьләнә бару** Акрынлап, азазлап зәгыйфьлегә көчәю. *Ифрат зиһенле, зирәк үлчәмле күренгән агаебыз акылга зәгыйфьләнә бара түгелме?* Т.Галиуллин. --- *тирән зәвыклы язучы яисә тәнкыйтьче күзе генә тотып ала алырлык кайбер үзгәреш-үсеш чалымнарын, йә булмаса, прозаның котылгысыз рәвештә зәгыйфьләнә баруын тоябызмы, сиземлибезме?* Ф.Латыйфи

**Зәгыйфьләнә башлау** Зәгыйфьлек билгеләре күренү. *Ләкин кыпчак иленең Монголиядә булган мәркәзгә бәйлануы акрынлап зәгыйфьләнә башлап, Мәнги ханнан соң бөтенләй бетте.* Г.Гобәйдуллин. *Балигъ булып, иблис эшчәнлеге нәтиҗәсендә иман савыты зәгыйфьләнә башлагач кына, диннең кирәге чыга.* И.Әмирханов

**Зәгыйфьләнә төшү** Тагы да зәгыйфьләнү. *Ә инде картлык килеп зәгыйфьләнә төшкәч, комсыз булу бер дә килешми.* А.Ганиев

**Зәгыйфьләнеп бетү** Бик нык, тәмам зәгыйфьләнү. *Әмма ул көннәрнең салкын һавасы әтиебезнең зәгыйфьләнеп беткән үпкәләрен барыбер куырып алган булып чыкты.* Р.Фәизов. *Бозлы су --- җиргә агып төште, тапталып, зәгыйфьләнеп беткән үлән бөртекләренә яшәү бүләк итте...* Г.Гыйльманов

**Зәгыйфьләнеп калу** Билгеле бер сәбәп, хәл, вакыйгадан соң зәгыйфьләнү. *Таш белән бастырсаң, үлән дә сытыла, төссезләнеп, зәгыйфьләнеп кала, үзенең асыл сыйфатларын җуеп, шәкелен танымаслык итеп үзгәртә.* Ф.Галимуллин

**Зәгыйфьләнеп китү** Кинәт, бераз, беркадәр зәгыйфьләнү. *Аксак Тимер тарафыннан Алтын Урда шәһәрләре җимерелгәч, Түбән Идел – Җаек төбәгендә утрак тормыш шактый дәрәҗәдә зәгыйфьләнеп китә.* Әдәбият

**ЗӘГЫЙФЬЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәнгә, берәр әгъзага зыян китерү, имгәтү, гарипләү. *Жуанжуаннар (жужаннарның икенче исеме), янәсе, үз әсирләренең башына дөянең балтырыннан яңа тунап алынган тире кисәге кидерәләр, ул кояшта кибеп кечерәя, баш сөяген кысып, мине зәгыйфьли.* Г.Фәйзрахманов. *Мәрхәбә сугыш зәгыйфьләгән егетнең күзләрендә мөлдерәмә тулы сөю җылысын тойды.* Ш.Янбаев

2) *күч.* Акыл, уйлау сәләтенә зыян китерү

3) *күч.* Кеше аңында җәмгыятькә һәм үзара мөнәсәбәтләрдә әдәп-әхлак нормаларын, яшәеш принципларын бозу, идеалларны юкка чыгару, яшь буында тискәре сыйфатлар барлыкка китерү. *Алар [Кутузовлар] булмаганга күрә дә Сириннәребез өстеннән тәкәббер лейтенант Майорчуклар гына командалык итә, буын-буын яшьләребезне әнә шулар әхлакый зәгыйфьли.* Р.Шәрәфиев

**Зәгыйфьләп бетерү** Тәмам, бик нык зәгыйфьләү

**Зәгыйфьли бару** Торган саен ныграк зәгыйфьләү

**ЗӘГЫЙФЬЛЕК** *и.* 1) Тәндәге физик кимчелек; гариплек. *Минә шунда инде мин үземнең көчсезлегемне, зәгыйфьлегемне бик ачык сизәм.* А.Шамов. *Картлык зәгыйфьлеге аңа берәр юаныч, эш табып, аз вакытка онытылып торырга да ирек бирми.* Ф.Хатипов

2) Көчсезлек, хәлсезлек, көчен, сәләтен югалткан булу; кимчелек. --- *сәргаскәр сәламәт булса, гаскәрнең куәте урыныңдадыр. Әмма гаскәрдә зәгыйфьлек пәйда булып, сугышка үзең кермәк лязим булса, ул вакытта нәүбәт сиңа төшеп, сугышка кергәйсең.* К.Насыйри. --- *падишаһның гаскәр башлыгын вә көчле гаскәрләр олугын юкка чыгардың һәм моның аркылы падишаһның гаскәренә зәгыйфьлек китердең.* Ибн әл-Мөкаффаг

3) *күч.* Аң, акыл кимчелеге. *Аның гакылына зәгыйфьлек килгән булыр.* М.Фәйзи. *[Мөстәкыйм] Башына зәгыйфьлек килсә дә, аның сүзендә дөреслек бар.* Д.Салихов

4) *күч.* Түбәнлек, кимлек. *Болай сөйләшеп утырганда, аның [М.Горький] турындагы фикерләрдә – шундый ваклык, шундый зәгыйфьлек. Хәтта минем ул язучының, бу бөек исем турында сөйләгәнә өчен, авызына сугасым килде.* Г.Бәширов

**ЗӘЙТҮН** *и. гар.* 1) Зәйтүнчәләр семьялыгыннан, вак аксыл чәчәкле, җимеше майга бай булган мәңге яшел көньяк агачы; *русчасы:* **маслина, олива.** *Апеннин ярымутравында һәм утрауларда, бөртекле ашлыклардан һәм виноградтан тыш, цитрус һәм зәйтүн агачлары утырту бик киң таралган.* И.Манаев. *Субтропик районнарда мандарин, апельсин, хөрмә, анар, зәйтүн, бадам, әстерхан чикләвеге һәм тәмле җимешле башка үсемлекләр үстерәләр.* Ботаника

2) Шул үсемлекнең җимеше. *Борис Яковлевич зәйтүн җимешенә охшаш күзләрен тутырып миңа карап алды.* М.Юныс. --- *бер көнне хәзрәте Пәйгамбәр (с.г.в.), Сәгыд бине Убадә хәзрәтләре янына баргач, тегесе бер телем икмәк һәм зәйтүн чыгара.* Х.Алгөл

3) *к.* **зәйтүн гөле**

**ЗӘЙТҮ́Н ГӨЛЕ** *и.* Киндерчәләр семьялыгыннан, киң кыяксыман яфраклы, эре саргылт кызыл, кып-кызыл яки куе сары чәчәкле декоратив куак үсемлек; *русчасы*: **олеандр**. *Җилпәзәләр тоткан сылу хурлар кебек, Зәйтүн гөлләр таңга калган хозур күреп.* Г.Афзал

**ЗӘЙТҮ́Н МАЕ** *и.* Зәйтүн җимешеннән сыгып алына торган сортлы май. *Бик яхшы ит эләкте, гомергә күрмәгән зәйтүн мае алдым, сөтен-катыгын, ярмасын, яшелчәсен сала башлагач, сумкам да, букчам да тулды.* Ф.Садриев. *Бит ул Иерусалимдә христиан*

*динен кабул итте, ниндидер тау кушларында анадан тума шәрә, зәйтүн майларына буялып, --- кылган гонаһларымны кичерә күр, дип ялынды.* М.Хәбибуллин

**ЗӘКЪКУМ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Җәһәннәмдә үсә дип фараз ителгән агулы агач. *Бу яшьләр --- унтугызынчы-егерменче гасыр голямасының утырткан агачларының йемеше иде – зәкъкум йемеше иде.* Г.Исхакый

2) *күч.* Көчле агу, зәһәр. *Дөнья бутый, илне ярлыландыра, кешене эт коненә калдыра торган бер зәкъкум бар, ул да булса – аракы, имеш.* С.Поварисов

**2.** *с. мәгъ. к.* **зәкъкумле.** *Күңлемә утлар яга, Яндырып кан юлларымны, Нәкъ зәкъкум утлар ага…* Һ.Такташ

**ЗӘКЪКУМЛЕ** *с. иск. кит.* 1) Агулы, агу салган

2) *күч.* Ачы, үзәкне өзә торган, мәңге онытылмаслык авыр. *Нишлим соң? Зәкъкумле хәсрәтләр белән күңелем яна, нишлим соң?.. Мәлгунь иблисләр төкергән дөньяга.* Ш.Бабич

**ЗӘКЯТ** *и. гар.* 1) *дини* Ислам дине буенча, байлык, мал-мөлкәтең хисабыннан чыгып, ярлыларга һәм дин файдасына бирелергә тиешле еллык керемнең кырыктан бер өлеше (елына бер бирелә торган салым, сәдака). *Теге көзне зәкятыннан китереп аударткан чи утыны белән иске җиләнен дә исәпкә тыга.* Ә.Фәйзи. *«Алла ризасы өчен зәкяттан бирелде Файзуллага 25 сум акча, бер кадак чәй – 3 сум, сигез аршин шведски – 12 сум, мәҗмугы – 40 сум».* Г.Исхакый. *Кәрим абзыйлар укырга дип зәкят акчасын биргәч, Хәлимнең шатлык белән тулган җаны шулай ук табигать тасвирлары ярдәмендә сурәтләнә…* Р.Ганиева

2) *тар.* Ханлыклар чорында буйсындырылган халыкка хан тарафыннан салына торган салым

**ЗӘКЯТЛЫ** *с.* Шәригать таләпләренә туры килгән, зәкятны искә алып эшләнгән. *Әлхәмделилла, сезнең малыгыз – зәкятлы мал, һич югалмас.* Ш.Мөхәммәдев

**ЗӘКЯТЧЫ** *и. тар.* Зәкят (*2 мәгъ.*) җыючы кеше. *--- болардан Мансур берлә Габдулла, Сәгадәтнең аз гына да эзенә төшәрлек мәгълүмат ала алмасалар да, зәкятчыларның кайда күплеге хакында шактый ачык мәгълүмат алып китәргә әзерләнделәр.* Г.Исхакый

**ЗӘМ** *и. гар. иск.* Әр, шелтә; хурлау, яманлау, сүгү; гаепләү. *Мәҗлестә дөньяны зәм кыйлдылар.* К.Насыйри

**ЗӘМЗӘМ** *и. гар.* 1) Мәккә шәһәрендә Кәгъбә янындагы изге кое. *Зәмзәм күзләдем еллар буе.* Дәрдемәнд. *Оҗмах түреннән агып чыгып, безнең фани дөньябызга нур өстәгән Зәмзәм һәм Кәүсәр чишмәләренең бер генә йотым булса да суын авыз иту – һәр мөселманның хыялыдыр.* Татарстан чишмәләре

2) Шул коеның суы. *Зәмзәм сулары белән юынып, изге җирләрдә дөньялык гонаһларыннан ваз кичәр вакыт җитте.* Ф.Латыйфи

◊ **Зәмзәм суы** Хәмер, исерткеч эчемлек. *Соңгы вакытта муллаларның әлеге каһәр төшкән «зәмзәм суы» белән авыз пычратулары шәйләнә башлады.* С.Поварисов. *Ул бит Казан каласында ике ел яшәп, унҗиде яшен тутырып та ресторан-мазарны белмәде, грузчик булып эшләп тә авызына «зәмзәм суы» капмады, аны үгетләп тә, көчләп тә эчерергә тырышып карадылар.* Г.Ахунов. *Спиртлы «зәмзәм суы» алтын бәясенә әйләнде.* Х.Ибраһимов

**ЗӘМИН** *и. фар. иск.* 1) Җир, туфрак, ил. *Ул ялт-йолт итте, һәм руе зәмин яктырып китте.* Г.Тукай

2) *күч.* Җирлек, нигез, төп. *--- күңел тынычлыгына зәмин әзерләнгәч, Абу, киресенчә, көрсенә, үзенә урын тапмый башлады һәм, башка уку йортында конкурста катнашырга ниятләп, бәяләмә сорап керде.* Т.Галиуллин. *Барыннан да бигрәк, кабер өстенә ташлар эшләтеп куйдырту өчен, матди чыгымнар кирәк. Алтын Урда дәүләтендә XIII гасыр ахырында моңа зәмин тупланган булган инде.* М.Әхмәтҗанов. *Драманың зәмине безнең тормышыбызда яңа дияргә мөмкин.* Г.Кәрам

3) Мөмкинлек. *Мөселман халыкларының төрле мәмләкәтләрдә таралып яшәве ---, төрле икътисади һәм сәяси зәминнәр тәэсире белән барлыкка килгән гореф-гадәтләрендәге кискен каршылыклар бу мәсьәләне бик нык катлауландырачагы ачыктыр.* М.Галәү. *«Мөселман иттифакы» сәяси партия булып яшәрлек Русия мөселманнары арасында зәмин юк иде.* Г.Исхакый

**ЗӘ́М КЫЛУ** *ф.* Хурлау, яманлау, гаепләп сөйләү. *Тик минә биш гасыр – зар заман Зәнкигә саныйлар татарны, Зәм кыла һәр сәрхүш славян, Татарга сылтыйлар юк-барны.* Ф.Дунай

**ЗӘМРУД** *и. фар.* Изумруд, зөбәрҗәт. *Кичәге тузан берлә буялып беткән яфраклар бүген зәмруд кеби ямь-яшел торалар.* Г.Исхакый

**ЗӘМҺӘРИР** *и. гар.* **1.** Көчле суык, кышкы әче салкыннар. *Суыкның зәмһәрире, зәһре кискен, Тагы туктар, тагы атлар ул мескен.* Г.Тукай. *--- син мине кара буранда, кышкы зәмһәрирдә далага куасың.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Үтә салкын, әче суык. *--- бәлеш ашап яшәвенә, «мөкаддәс идеалын» югалтуга рухи җәзалана, үзен зәмһәрирдәй салкын, «уты сүнгән җәһәннәмгә» ыргытылгандай тоя.* Р.Ганиева. *Җанын зынҗырлап һәм өшетеп торган зәмһәрир салкын боз эри башлагандай булды ---.* Г.Әпсәләмов. *Әле минә иртән уяныып китсәм – мәхшәр: котырыныпы-давыллап, төньяктан зәмһәрир җилләр исә ---.* К.Миңлебаев

**ЗӘНБИЛ** *и. фар. кит.* Камыштан үрелгән сумка. *Исхак сучи зәнбиленә азык куйды.* Кол Гали. *Бу урында туктап, бер агач астында ял итеп, бераз тәгам ашамага ният кыйлды. Үзе белән бер зәнбил инҗир вә бер савыт белән сөт бар иде.* К.Насыйри

**ЗӘНҖӘБИЛ** *и. фар. к.* **имбир**. *Зәнҗәбил эчке катуларга, чәнчешүләргә, бармак буыннары сызлаганга файдалы.* К.Насыйри. *Зәнҗәбилнең туган ватаны – Һиндстан*

**ЗӘНҖИ** *и. гар. иск. к.* **зәнки** (*1 мәгъ.*). *Каршыдан бик зур гәүдәле --- бер зәнҗи килеп чыкты.* К.Насыйри

**ЗӘНКИ** *и. фар.* **1.** 1) Кара тәнле кеше, негр. *Болар күчмә гарәп кабиләләреннән булып, араларында зәнкиләр дә бар иде.* А.Хәлим. *Фарсы теленнән кергән «зәнки» сүзе – негр, эфиоп, кара тәнле кеше.* А.Тимергалин

2) *күч.* Караңгы чырайлы, явыз, усал кеше. *Чемоданга теге зәнки үзләре*

*белән алып китәргә тиешле китап, кәгазьләрне тутырырга кирәште.* С.Поварисов

**2.** *с. мәгъ.* Кара эчле, явыз, оятсыз, карун. *Һе, зәнки карчык!.. Күргәнеңкүрмәгәнең шул булсын...* Т.Гыйззәт

**ЗӘНКИБИКӘ** *и. сөйл.* Кара тәнле негр хатын-кызы, негритянка. *Исеменә караганда, бу туташ борынгы француз колонияләреннән каракучкыл зәнкибикә булса кирәк.* А.Тимергалин

**ЗӘНКИЛӘНҮ** *ф.* **1.** Явызлану, зәһәрләнү, усаллану. *Муллагали аның якасыннан эләктереп алгач та, ул [Мөрем], зәнкиләнеп, тырнашырга керешτе.* А.Расих

**2. зәнкиләнеп** *рәв. мәгъ.* Төкселәнеп, караңгы чырай күрсәтеп; астыртын явызлык белән. *Зәнкиләнеп кенә сөйләшү*

**Зәнкиләнә бару** Торган саен зәнкилеге акрынлап арту. *Йөзе торган саен зәнкиләнә бара, ерткыч хайванныкы кебек күзләренә карагач, күңеле, җаны тайчана иде.* Казан утлары

**Зәнкиләнеп китү** Көтмәгәндә, кинәт зәнкиләнү

**Зәнкиләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта зәнкиләнү. *Бар, зәнкиләнеп торма, эшлә кушканны.* Татарстан яшьләре

**ЗӘНКИЛЕК** *и. сөйл.* Зәнки булу, караңгы чырайлы, астыртын булу. *Зәнкилеге йөзенә чыккан*

**ЗӘҢГӘР** *с.* **1.** 1) Спектрда яшел белән күк арасындагы төп төсләрнең берсе – күк йөзенең аяз көндәге ачык төсе, диңгез төсе. *Сыек зәңгәр төс аяз күк йөзен, әле һаман да хәтеремнән китми азаплаткан Айнан күзләрен хәтерләтә.* Н.Гыйматдинова. *Анда сирәк-сирәк кенә ак болытлар, якты зәңгәр күкне чуарлап, сибелеп торалар.* Ә.Фәйзи

2) *күч.* Ачы, югары тондагы; көчле, чәрелдәп торган. *Зәңгәр тавыш колак пәрдәсен зеңгелдәтә иде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Зәңгәр төс, зәңгәр буяу. *Гөлчәһрә белән Гөлзәһрәнең алъяпкычлары сары ефәк җепләр белән чигелгән, кофталары – зәңгәр белән, Гөлсинәнең дә шундый белән, ә Галимәнең бернәрсәсе дә чигеп эшләнмәгән иде.* Г.Гобәй. *Шөн авылының шактый зур иканен күрдем: зәңгәргә, сарыга, кызылга, көрәнгә һәм башка төсләргә буялган өч йөзләп йорт, үлән арасына чәчелеп яткан төрле төсләрдәге агач шакмаклар кебек, ямь-яшел агачларга күмелеп утыра иде.* Р.Сибат

2) *күч.* Гомосексуаль ориентацияле кеше. *Дәрига телсез калды. «Зәңгәр» икән ич бу, хайван. Ә ул аңа кайсы ягы беләндер ошый башлаган иде инде.* М.Әмирханов. *Баласы аныкы микән соң? «Зәңгәр» ләбаса ул.* Ф.Садриев. *Күз карашы әллә нинди: әллә наркотиктан, әллә нииндидер тыелгысыз теләктән тонган. Әллә «зәңгәр», әллә наркоман, әллә икесе бергә.* Ә.Дусайлы

◊ **Зәңгәр көю** Кешегә ачу-нәфрәт белән, йөз чытып карау. **Зәңгәр күзлек аша карау** Тормышны, кешене идеаллаштыру, аның кимчелекләренә, җитешсезлекләренә игътибар итмәү. **Зәңгәр хыял** Тормышка ашмаслык хыял. *Балачакның зәңгәр хыялларын җыеп учка, Тарттым аска стоп-кранны...* Р.Рахмани

**ЗӘҢГӘРӘЮ** *ф. диал. к.* **зәңгәрләнү**

**ЗӘҢГӘРБАШ** *и. бот. диал.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, яфрак читләре чәнечкеле, чәчәге зәңгәрсу күк төстә булган күпьеллык (сирәк кенә ике яки берьеллык) үлән үсемлек; чәнчү үләне; *русчасы:* **синеголовник**

**ЗӘҢГӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) Зәңгәр төскә керү, зәңгәр булып күренү. *Диңгез сулары кебек зәңгәрләнеп уйный торган зур, матур күл буена утырганга, бу авылны Зәңгәр Чишмә дип атыйлар.* Г.Ибраһимов. *Әкияттәге күлләр күк, Бар бик матур зәңгәр күл. Әйтерсең лә күк шәүләсе Төшеп зәңгәрләнгән күк.* Б.Рәхмәт. *Ә ул яктан, нәкъ үзләренә каршы, әле зәңгәрләнеп, әле алтынланып, әле яшелләнеп, утлы бер таш тәгәрәп, юк, очып килә иде.* Ә.Гаффар

2) *күч.* Салкыннан, авырудан йөзнең, тәннең төсе үзгәрү, табигый төсен югалту; күгәрү. *Аннан, иреннәре зәңгәрләнеп, матрасы алынган такта караватына килеп ауды.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Ачудан агарыну, ярсудан күгәренү, зәңгәр төскә керү. *Зәһәрләнә, төсе зәңгәрләнә, Гыйфритләнә килен өстенә; Бичара килен – яп-яшь кызга Зәгъфрандай сары төс иңә.* Г.Тукай

**Зәңгәрләнә бару** Торган саен зәңгәрлеге ныграк арту, зәңгәр төсе ачыграк күренү. *Күкнең Зәңгәрләнә барган гөмбәзендә Сулыш кебек сизелер-сизелмәс Ай шәүләсе тибрәнде...* Р.Акъегет. *Күк йөзе дә көннән-көн зәңгәрләнә бара, болытлар да инде соры түгел, аксыл өемнәр булып йөзәләр.* Ф.Ибраһимова

**Зәңгәрләнә башлау** Зәңгәрлек иңәргә керешү. *Учак җылысы төнге салкынны бөтенләй куып җибәрә алмады, суык, сырышкан көчек баласы кебек, резина итек эчендә зәңгәрләнә башлаган аякларга урала.* Р.Сибат. *Җәйге төн – күз ачып йому арасы гына, үтә дә китә, офык зәңгәрләнә башлый.* З.Дәүләтов

**Зәңгәрләнә төшү** Тагы да зәңгәрләнү, бераз зәңгәр төсе арту. *Ул [Хәлисә] хәле киткәнен, күз алларының сары уттай янганын, аннары зәңгәрләнә төшкәнен һәм караңгыланганын тойды.* Ә.Гадел. *Күләгәгә кергәч, аның [Любашаның] күзләре тагын да зәңгәрләнә төште.* М.Хуҗин

**Зәңгәрләнеп бетү** 1) Тәмам зәңгәр төскә керү, зәңгәрләнү дәрәҗәсенә җитү

2) Тән, табигый төсен югалтып, күгәргән төскә керү. *Кунак кода [тартa-тарта] зәңгәрләнеп бетә.* М.Мәһдиев. *Сәхнәгә, эчке күлмәктән генә, туңып, зәңгәрләнеп беткән бер кыз керә.* Г.Каюмов. *Малайның зәңгәрләнеп беткән тәненә кызу-кызу массаж ясадылар, аның исән булуына ышанмаган ананы тынычландырдылар.* Казан утлары

**Зәңгәрләнеп калу** Нинди дә булса сәбәп, вакыйгадан соң зәңгәр төс алу. *Тау битләрен яңгыр яңа юган, юллар зәңгәрләнеп калган хәтта.* Р.Әхмәтҗан

**Зәңгәрләнеп килү** 1) Нинди дә булса сәбәп, вакыйга белән аз-азлап, акрынлап зәңгәр төс алу. *Зәңгәрләнеп килгән салкын иртәдә ботакларын ак бәс сарган каен киемнәре асылташ белән бизәлгән матур кызга охшый иде.* Г.Әпсәләмов

2) Кинәт, күзгә күренеп төсе үзгәрү, йөзе зәңгәр төс алу. *Маркин ачудан зәңгәрләнеп килде.* И.Низамов

**Зәңгәрләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә зәңгәрләнү. *Без хәзер инде бик яхшы аңлыйбыз: сөмсере коелган ке-*

*шенең йөзе караебрак, ягъни зәңгәрләнебрәк китә.* Г.Гыйльманов. *Кичке эңгер-меңгердә аның йөзе таш кебек каткан, зәңгәрләнеп киткәндәй күренде.* Л.Ихсанова. *Мич яккач, иртәрәк япканмын – ис чыккан. Котларым алынды: зәңгәрләнеп киттең, үләсең дип торам.* Ш.Галиев

**Зәңгәрләнеп тору** 1) Һаман, һәрвакыт зәңгәрләнгән хәлдә булу. *Әле үткән елларда гына эшкә килгәч, еракта зәңгәрләнеп торган урманнарга, җәелеп яткан кырларга карап алу белән, --- кычкырып җырлап җибәрә торган иде.* М.Хәсәнов. *[Нәфисә] Иделнең түбән ягында зәңгәрләнеп торган калын болытларга күз салды.* Г.Бәширов. *Георгий Фёдорович – сугыш күргән кеше, дөньяны миңа караганда күп элегрәк таныган, яраланган, маңгай читендә җәрәхәте зәңгәрләнеп тора.* А.Гыйләҗев

2) Әле, хәзерге вакытта зәңгәр булып күренү. *Болай да ак йөзле Фатыйма ачлыктан үтә күренмәлегә әйләнгән: йөзендә кан әсәре юк, зәңгәрләнеп тора.* Р.Хәбибуллина. *Тамырлары да күпереп, зәңгәрләнеп тормый.* А.Тимергалин

**Зәңгәрләнеп чыгу** Бөтенләй дә, тәмам зәңгәрләнү. *Ка-а-атып беттем! Зәңгәрләнеп чыктым!* Х.Ибраһимов

**ЗӘҢГӘРЛӘТҮ** *ф.* 1) Зәңгәр төс бирү, зәңгәрләндерү, зәңгәр төскә буяу. *Капка төбенә чыкканда да иренен, керфекләрен буйый, күз төпләрен зәңгәрләтә, кашын сыза, пудра яга, исле май сөртә...* Т.Миңнуллин

2) Зәңгәр итеп күрсәтү, зәңгәр булып күренү. *Зәңгәр һава, зәңгәр болыт зәңгәрләтә диңгезне.* Җыр

3) Төссезләндерү, күгәртү

**ЗӘҢГӘРЛӘ́Ү** *ф.* Зәңгәргә буяу, зәңгәр төскә кертү, зәңгәр төс бирү. *Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр, Ничек зәңгәрләгәннәр?* Җыр

**Зәңгәрләп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә зәңгәр төскә кертү. *Апасы ялга кайткач, капкаларны зәңгәрләп алдылар, өйләрен сарыга буядылар*

**Зәңгәрләп чыгу** Нәрсәне дә булса башыннан ахырына кадәр яки барысын да бер-бер артлы зәңгәр төскә кертү. *Укучылар мәктәп коймаларын зәңгәрләп чыгып, үз эшләренә сокланып тордылар*

**Зәңгәрли төшү** Бераз зәңгәрләү

**ЗӘҢГӘРЛЕ** *с.* 1) Зәңгәр төсе булган, зәңгәргә буялган, зәңгәр төс кергән. *Көндезен авыл өстендә чуар юрган төсле зәңгәрле, сарылы әләм эленеп торса, төнлә аны Махноның баш сөяге төшерелгән шомлы кара әләме алмаштыра.* Г.Бәширов

2) Ике яки берничә төс арасына зәңгәр төс кушылуны, зәңгәр төс катышкан булуны белдерә (мәс., *зәңгәрле-сарылы, зәңгәрле-кызыллы* һ.б.)

3) *күч. к.* **зәңгәрле-яшелле** (*2 мәгъ.*). *– Әйтәм! – диде ул [Нургали], зәңгәрле тавыш белән яман кычкырып.* Ә.Еники

**ЗӘҢГӘРЛЕК** *и.* 1) Зәңгәр төс. *Күзләрендәге элекке җете зәңгәрлек сыекланып калды.* Н.Хәсәнов. *Күк, көндезге зәңгәрлеген җуеп, карасу төскә кергән.* Х.Сарьян. *Коңгырт кара күзләрнең пәрдәсе артына яшеренеп, сизелер-сизелмәс кенә булып, бертөрле саф зәңгәрлек саркып тора кебек.* М.Хәсәнов

2) Зәңгәр фон, әйләнә-тирә, ерак горизонт. *--- агач очлары арасыннан кечке алсу уклар белән бизәлгән күкнең сыек зәңгәрлеге күренеп китә.* Г.Галиев. *Бу зәңгәрлек шулкадәр көчле иде ки, ул яңадан ап-ак халатларга төренеп өлгергән наратларга да, нәфис тюль бөркәнгән зифа каеннарга да, ап-ак мамык юрган ябынган аланнарга, күлләргә, сазлыкларга да йокты.* Г.Әпсәләмов

**ЗӘҢГӘРЛЕ-ЯШЕЛЛЕ** *с.* 1) Зәңгәр, яшел төсләр катыш, ике төс катнашкан, кушылган. *– Башым әйләнә, Идрис, --- күңелем болгана, – ди Лида зәгыйфь тавыш белән, – күз алларында – зәңгәрле-яшелле очкыннар...* Ә.Айдар. *Биредә эре, матур зәңгәрле-яшелле геотруп коңгызларны, ат чебене һәм башка бөҗәкләрне очратырга мөмкин.* Ә.Халидов

2) *күч.* Ямьсез; куркыныч, колакка ятышсыз. *Әле Шәңгәрәй, борынын салып, судтан кайтып килгәндә, минем янга килеп туктады да зәңгәрле-яшелле тавыш белән зарланды.* Г.Толымбай. *– Туктагыз! – Миләүшә зәңгәрле-яшелле тавыш белән чырылдап җибәрде.* Ф.Яруллин

**ЗӘҢГӘ́Р СӨТ** *и.* Өсте җыеп алынган, каймагы аертылган сөт, сыек сөт. *Башта берсе, аннары икенчесе сепаратның «зәңгәр» сөт агыза торган кранына чокырларын тоттылар.* Р.Гариф

**ЗӘҢГӘРСУ** *с.* 1) Аксыл зәңгәр, сыек зәңгәр. *Кулъязма такта тышлы китап рәвешендә XIX гасырның 20 нче елларында зәңгәрсу һәм саргылт ак кәгазьләргә языла башлаган.* М.Әхмәтҗанов. *Нәфисә --- зәңгәрсу кыска бишмәтенең эчке кесәсеннән коңгырт тышлы кечерәк кенә куен дәфтәрен чыгарды.* Г.Бәширов

2) Зәңгәргә тартым, зәңгәр төсмерле. *Йокысыз күзләре кызарып яшьләнгән, күз төпләреннән зәңгәрсу капчыклар асылынып төшкән.* Р.Вәлиев. *Хәдичә апа, батыраеп, зәңгәрсу тамырлары бүртеп чыккан шул зур, кызыл кулны сыйпады.* М.Маликова

3) Төп төскә зәңгәргә тартым төс кушылуны, шундый төсмере булуны белдерә (мәс., *зәңгәрсу ак, зәңгәрсу кара, зәңгәрсу кызыл* һ.б.)

**ЗӘҢГӘРСУЛАНУ** *ф.* Зәңгәрсу төскә керү, зәңгәрсу төс алу. *Юл зәңгәрсуланган, әлегә калын кар юрганына бөркәнгән түбәләрдән сузынкы тамчы бозлары күренгәли.* А.Расих. *Төшеп баручы кар бөртекләрен аралап, әллә кайлардан адаша-адаша килгән кояш нурларыннан ак дөнья зәңгәрсуланып җем-җем итә.* Р.Зарипов

**Зәңгәрсулана бару** Торган саен ныграк зәңгәрсулану. *Шуннан да ары гүя диңгез башланып китәдер кебек, яшел кырлар, зәңгәрсулана барып, офыкка кушылалар.* Г.Бәширов

**Зәңгәрсулана башлау** Зәңгәрсулык сизелү

**Зәңгәрсулана төшү** Тагын да зәңгәрсулану

**Зәңгәрсуланып бетү** Тәмам, бик нык зәңгәрсулану

**Зәңгәрсуланып китү** Бераз зәңгәрсулану

**Зәңгәрсуланып тору** Әле, хәзер зәңгәрсу булу, зәңгәрсуланып күренү. *Хаҗи алдында яткан кәгазь өстендә прокурорның, мәетнекенә охшап,*

*тырнагы зәңгәрсуланып торган имән бармагын күрде.* М.Хәсәнов. *Шопшома иттереп кырылган сакал-мыек урыннары бераз зәңгәрсуланып тора.* Ф.Яруллин

**ЗӘҢГӘ́РЧӘ** *рәв.* Зәңгәр төс белән, зәңгәр төскә кертеп; зәңгәр төсләр фонында. *Бөтен җиһазы зәңгәрчә ясалган бүлмә яктысында һәммәмезгә дә әллә нинди зәңгәр сыманрак төс бирә.* Г.Исхакый

**ЗӘҢГЕЛӘ** *и.* «С» витамины җитмәүдән була торган урт шешү авыруы; *русчасы*: **цинга**. *Кузгалак, кыяклы суган борын төртәләр. Аяз аларны чүпли --- аннары: – Зәңгелә кач, Идел кич; иске авызга яңа аш! – дип, догасын укый...* Г.Шәрәфетдинов. *Зәңгеләдән какшап бетте тешләрем, Сагыштан агарды сакал-чәчләрем.* Совет әдәбияты

**ЗӘП** I *и. рус сөйл.* **1.** Туңга сөрелгән җир, сабан ашлыгы өчен көздән сөреп калдырылган җир. – *Узган көз зәптә мин аларны [бүреләрне] шәйләдем,* – *дип башлады ул [Варис].* Х.Камалов

**2.** *с. мәгъ.* Туңга сөрелгән яки сөреләә торган. *Зәп җирләре*

**ЗӘП-** II *кис.* «З» авазына башланган «зәңгәр» сыйфатына ялганып һәм басымны үзенә алып, шул төснең артыклык дәрәҗәсен ясый торган индивидуаль алкисәкчә. *Күзләрең синең күк кебек: Ап-ачык һәм зәп-зәңгәр.* Ә.Ерикәй. *Аптырап өскә карадым – күк зәп-зәңгәр, боз яварга һич ошамаган.* Д.Булатова

**ЗӘПКӘ́ СӨРҮ** *ф.* Туңга сөрү, сабан ашлыгы өчен җирне көздән сөреп калдыру

**ЗӘР** *и. фар. кит.* Алтын. *Зәр кадерен зәркән белер.* Мәкаль

**ЗӘРГӘР** *и. фар.* Алтынчы, алтын-көмештән әйберләр эшләүче кеше. *Шәҗәрә очы Казан һәм Болгар мәмләкәтенең иң оста алтынчыларына барып тоташкан, аларның һөнәр серләрен саклап килгән зәргәрнең эше күзгә күренеп алга бара, һәр көн аңа бәрәкәт, мал китерә.* Ф.Латыйфи

**ЗӘРДӘ** *и. фар. бот. диал.* Сәрдә; *русчасы:* **снытъ.** *Безнең буа буенда үсә микән ак зәрдә?* Җыр. *Зәрдәнең яшь яфраклары ашарга ярый.* Ботаника

**ЗӘРДӨШТЛЕК** *и. к.* **зороастризм**. *Зәрдөштлектә ут табыну объекты булса, борынгы төркиләрдә ул тәэсир итә торган магик корал ролен үтәгән.* Г.Дәүләтшин. *Зәрдөштлектә (б.э.к. XV–X гасырлар), учакны һәм шул бер учак белән бәйләнгән гаиләне махсус саклап торучы Алла бар, дип уйланылган.* Ф.Урманче

**ЗӘРЕҺ** *и. фар. к.* **зирәһ**

**ЗӘРЕҺЛЕ** *с. иск. к.* **зирәһле**. *Бу зәреһле поездның командиры Фёдоров иде.* Ш.Усманов

**ЗӘРКӘН** *и. фар.* 1) Ювелир әйберләр, алтын-көмеш әйберләр. *Зәркән кибетләре эшләп торганда, ломбардлар бизәнү әйберләрен залогка җыеп акча таратканда, --- чынны ялганнан аерып, алдакчыларны фәкать алар гына фаш итә ала.* Х.Бәдретдинов. *Саный китсәң, бизәнү әйберләре, чокып-уеп язылган зәркән сәнгате әсәрләре күп инде алар. Баш хәситәсе, каеш аеллары, --- чулпылар...* С.Сәүбәнова. *--- Идел, Кама һәм аларга коючы елгаларда күпләп балык, шул исәптән кыйммәтле мәрсин балыклары тоту, һөнәрчелекнең төзелеш-архитектура, зәркән сәнгате, корал эшләү --- – боларның һәммәсенең Болгар һәм Алтын Урда чорларыннан килгән төпле нигезе, тотрыклы традициясе бар.* Мирас

2) *к.* **зәркәнче**. *Зәр кадерен зәркән белер.* Мәкаль

**ЗӘРКӘНЧЕ** *и.* Алтын-көмештән һәм асылташлардан бизәнү әйберләре ясаучы оста, ювелир. *Зәркәнчеләр һәм бакырчылар искиткеч гүзәл бизәнү әйберләре үрнәкләре тудыралар.* Һ.Такташ. *Татар зәркәнчеләренә хас сәрке, каралтып бизәк төшерү алымнары белән таныштыру.* Р.Әхмәтҗанова

**ЗӘРКӘНЧЕЛЕК** *и.* Зәркәнче хезмәте, зәркәнче эшчәнлеге; зәркәнче булу. *Тимерчелек, зәркәнчелек һәм башка һөнәрләр камилләшә.* Б.Хәмидуллин

**ЗӘРРӘ** *и. гар.* 1) Атом төшчәсе. *Моның өчен бик киң карашлы, хакыйкатькә карата түбәнчелекле булу сорала: без белгән дөнья белмәгәнебезнең бер зәррәсе генә бит.* Р.Сафин

2) Бөртек, тузан, иң кечкенә кисәкчек. *Зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау.* Г.Тукай. *Хәтта, татар халкының мөстәкыйльлек өчен күп гасырлык көрәшендә минем дә бер зәррә өлешем бар, дип әйтү дә күп булыр.* Җ.Дәрзаман

◊ **Зәррә кадәр (дә)** Бөртек тә, тузан кадәр дә (юк). --- *гомердә бер кешегә зәррә кадәр хәер күрсәтмәгәнеңне бердән чыгарсаң да гаҗәп түгел.* Г.Тукай. *Шулай да сиңа зәррә кадәр дә үпкә сакламыйм.* Ф.Хөсни. *Юк, ышанмадым, карчык, аның [Минтукның] күз яшенә, зәррә кадәр дә ышанмадым.* К.Миңлебаев

**ЗӘҮҖӘ** *и. гар.* Хатын, кәләш, ир хатыны. *Хәлим әфәнденең зәүҗәсе Фатыйма ханым кырык яшьләрендә бер хатындыр.* Ф.Бәширов. *Тик синең зәүҗәң булулар миңа насыйп түгел икән шул. Язмыш миннән сине күпсенде.* Г.Бәширов. *Зәүҗә башым белән йөрмәс идем тәхет тирәсендә ышкылып.* З.Мансуров

**ЗӘҮҖӘ́ЕН** *и. гар.* Ир белән хатын бергә, ирле-хатынлы. *Әгәр инде зәүҗәеннең берсе, йомшарып, бер сүз эндәшсә, --- ике арада татулык та булачак иде.* Г.Тукай

**ЗӘҮҖӘЛЕК** *и.* Зәүҗә булу, хатын булу; хатынлык. *Сез, атам илә бер мәслихәттә булып, ялгыз үз файдагызны күзләп, вәгъдә кылмыш сары алтыннарына, ялтыравыклы алмазларына алданып, мине картаеп,--- кабер исе килә торган Әфган ханына зәүҗәлеккә бирмәк булдыгыз!* Ш.Мөхәммәдев

**ЗӘҮКЪ** *и. гар.* 1) *к.* **зәвык**. *Әдәбиятның эчке ягы бик тирән. --- аларның бөтен артыклыкларын ачып кую, бөтен йитешмәгән җирләрен күрсәтеп бирү өчен дә шулкадәр нечкә сизеш, шулкадәр үткен хис вә шулкадәр тугры зәүкъ кирәктер.* Җ.Вәлиди. *Укытучы бит үзенең зәүкы турында гына уйламый, аның классы бар, классында – ничәмә-ничә бала.* Г.Әпсәләмов

2) Исем янында килеп, «стиль, мода, манера, рәвеш» кебек мәгънәләрне белдерә. *Башкалар бар да авыл зәүкында киенгәннәр.* М.Фәйзи. *Ярым татар, ярым Европа зәүкында тегелгән күлмәктән Һаҗәр керә.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ЗӘХМӘТ** *и. гар.* 1) Газап, борчу, мәшәкать; авырлык-кыенлык белән, җәфа

чигеп башкарыла торган эш. *Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа.* Г.Тукай

2) Зарар, зыян, начар тәэсир; уңайсызлыклар, кысанлыклар. *Күзге салкын яңгырның зәхмәтен онытып та өлгерә алмаган үләннәрне таптап, изеп, бер атлы арба каберлеккә таба бара.* Г.Иделле

3) *миф.* Мифологик көчләр тудыра, дип фараз ителә торган авыру, чир, сырхау. --- *елга ярында яки берәр таулыкта бу аллага атап корбан чалганнар, аңардан кешеләрне һәм малларны төрле зәһәр авырулардан, зәхмәттән саклауны үтенгәннәр.* Татар мифлары

4) *сөйл.* Ачулану, тиргәү, мәсхәрәләү, сүгү сүзе. *Зәхмәт, ничек зәһәр тешли.* Н.Хәсәнов. *«Барысын да каян белеп тора бу зәхмәт!» – дип сукранды Хәмит.* Казан утлары

◊ **Зәхмәт кагылу** 1) Мифик ышанулар буенча, җен, шайтан кебек ят көчләрдән чир кагылу, төзәлмәс чиргә, дәвага бирелми торган авыруга дучар булу. *Җирдән тиенү дисеңме, зәхмәт кагылу дисеңме – барысы да шулар кәсафәте.* К.Нәҗми; 2) Нәрсә белән дә булса артык мавыгу, берәр нәрсәгә мөкиббән китү. **Зәхмәт сугу** *к.* **зәхмәт кагылу**. **Зәхмәт тию** *к.* **зәхмәт кагылу**. *Киселгән чәч-сакал, черемичә, озак саклана, шуңа күрә ул аяк астына эләксә, тапталып ятса, хуҗасының башына зәхмәт тия.* М.Госманов. *Сиңа, минем уемча, калкавыч зәхмәте тигән булыр.* Ш.Камал. **Зәхмәт угы** Усаллык, явызлык, зәһәр. *Әгәр дә мин әйткәнлекне белсәләр, минем күземне дә ачырмаслар, бөтен зәхмәт укларын миңа кадый башларлар.* Г.Камал. **Зәхмәт чигү** Интегү, газаплану, җәфалану, зур мәшәкатькә, хәсрәткә дучар булу. *Без дә, безнең иптәшләремез дә шул юлда әллә никадәр зәхмәт чиктеләр.* Г.Исхакый

**ЗӘХМӘТИ** *с. гар. к.* **зәхмәтле**. *Монда да җил тәңресенең шаукымы, зәхмәти тәэсире хакында ишарә бар.* Г.Гыйльманов

**ЗӘХМӘТЛЕ** *с.* 1) Зәхмәте, михнәте булган; газаплы, мәшәкатьле, борчулы. *«Фест дисбесе» дигән хезмәте аңа дан, бөеклек китерергә һәм алсыз-ялсыз үткән зәхмәтле еллары өчен җан тынычлыгы бүләк итәргә тиеш иде.* А.Гыйләҗев. *Әнисен үтә зәхмәтле узган елны җирләгәннәр.* М.Хәсәнов

2) Зәхмәт чире, зәхмәт авыруы булган, зәхмәт кагылган. *Биби әби, минем сүзем бер булыр: кайттым, дигәч кайттым, кирәкми, юк, миңа зыяндашлы, янә череп сасып беткән төче зәхмәтле кыз. Кирәкми.* Ф.Халиди

3) *сөйл.* Зәхмәт китерә, авыру, чир йоктыра торган, сихерле. *Адәм сөякләре өстенә корылган зәхмәтле йорт бит бу.* К.Нәҗми. *Кыш котырынган саен, Хәлимнең уйлары да, буранга ияреп, кабат теге зәхмәтле урман аланлыгына, албастылар утарына исә башлый.* Г.Гыйльманов. *Ул зәхмәтле төштә икмәк тә бармак буыны тигентен генә үсепката ие, олан.* Н.Гыйматдинова

**ЗӘҺӘР** *и. фар.* **1.** 1) Агу; агулы эчемлек. *Дустың өчен зәһәр эч.* Мәкаль. *Син гыйлемле вә мәдәниятле тормышның зәһәре белән бер мәртәбә агулангансың.* Г.Ибраһимов. *Вә ни сан ягъмурының тамчысы еланга төшсә, зәһәр вә агу булыр, сәдәф үзәренә төшсә, энҗү булыр.* К.Насыйри

2) *күч.* Явызлык, әшәкелек, усаллык; көчле нәфрәт, ачу. *Ә ишан эченә зәһәр йотып йөрде.* А.Каһһар. *Тентүнең көтелгән нәтиҗәне бирмәвенә зәһәрләре чыккан ротмистр белән Камали ишекне шар ачык калдырып чыгып киттеләр.* К.Нәҗми. *Дөньяда ике явыз булса, шуның берсе Васфикамалдыр… Ни әйтсә – зәһәр чыга, ни сөйләсә – ярага нашатырь сибә.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Агу белән катнаш, агу кушылган, агулы. *Ачы зәһәр төтен җиргә сылана, тамакларны, борыннарны ачыттыра, күзләрне ашый иде.* Казан утлары

2) Куәтле, градусы зур булган. *Варис, тамакларны көйдереп төшеп киткән зәһәр эчемлекнең нәрсә икәнлеген белү өчен, ирексездән шешәгә күз салды.* М.Хәсәнов. *Эчемлек бик зәһәр һәм затлы иде, беренче стаканнан ук Ляшковның башына китте.* Х.Камалов

3) *хим.* Ашый, кисә торган, химик тарката торган. *Селте суы белән юа ул ак әйберләрен, кулын да жәлләми – кисә бит ул селте, яман зәһәр.* Г.Якупова

4) *күч.* Бик каты, көчле, үзәккә үтә торган. *Кайчан гына әле кышкы зәһәр салкыннар битләрне яндыра иде.* М.Хәсәнов. *Әлфия белән булган сөйләшү дә кышның зәһәр җиледәй сөягендә утыра.* Т.Галиуллин. *Миф-риваятьләргә караганда, бик зәһәр корылык елында шундый хәл була.* Г.Гыйльманов

5) *күч. сөйл.* Шәп, оста, менә дигән (сөйләмгә артыклык төсмерен бирә). *Ә теге чегән малае чыннан да зәһәр икән. Бию генәме!.. Гидрат цехының эстрада оркестрында да катнаша икән, иблис әвәләп чыгарган нәрсә.* Э.Касыймов. *Финдә яраланып кайтканчы, бик зәһәр тимерче иде ул.* Г.Гобәй. *Атның исеме дә зәһәр: күптәнге әбиләр әкиятен искә төшереп тора, күз алдына кылыч таккан баһадирлар, җиде башлы аждаһалар килә.* Р.Зәйдулла

6) *күч.* Явыз, усал, ачулы, явызлыгы сизелеп торган. *Саматов Гөлшәһидәгә зәһәр караш ташлады да – әйтерсең ул гаепле – тагын кыза, яный, куркыта башлады.* Г.Әпсәләмов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Ачу белән; ачуланып. *Төлкегә каршы ул китте, арка-муенналарын кабартып, томшыгын зәһәр сузып, төлкене таламакчы!* Ә.Баянов. *Пулемёт зәһәр тырылдый башлаган иде дә, безнекеләрнең берсе граната тондырды, аның борын төбендә үк тузантуфрак көлтәсе күтәрелеп, беразга томалап торды.* И.Низамов. *Аларның зәһәр килүләрен күреп, Җилбегән куркуыннан дәрьяга кереп чума.* Г.Гыйльманов

2) Шәп, оста итеп. *Күрше квартал командасы, аерата бер-ике малай бик җитез, бик зәһәр уйный иде.* Э.Касыймов

3) Бик, чиктән тыш. *Зәһәр усал иде Давыл [Миңлекамал].* Н.Гыйматдинова. *Мал суя торган зәһәр үткен пычак!* Ф.Абдуллин

**ЗӘҺӘ́Р ГӨМБӘ** *и.* Агулы, ашарга яраксыз гөмбә; *русчасы*: **желчный гриб**. *Ак гөмбәдән ул шуның белән аерыла: зәһәр гөмбә төбенең югары өлеше кара яки кара-соры төстәге челтәр кебек бизәк белән капланган, ә аның йомшагы исә сындырган урыннан кызарып чыга.* Ботаника

**ЗӘҺӘ́Р ЕЛАН** *и.* 1) *зоол.* Чага торган, агулы елан; *русчасы*: **гадюка**. *Бередә ерткыч җанварлар, монда зәһәр еланнар сызгыра.* Р.Батулла

2) *күч.* Явыз, мәкерле, кара эчле кеше. *Сез дә мине бер зәһәр елан иттереп уйлыйсыз инде...* Р.Гали

**ЗӘҺӘРЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Агулану. *Кара инде бу бакчага, әйтерсең лә чума белән зәһәрләнгән.* К.Тинчурин

2) *күч.* Нык ачулану, эчтә, күңелдә ачу кайнау, шул ачудан үрсәләнү, ни эшләргә белмәү. *«Барыбер котелогыңны ватам мин синең, иптәш директор!» – дип зәһәрләнсә, бернигә дә исе китмәскә өйрәтелгән кеше дә тынычсызлана, --- борчыла икән.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Усаллану, кырыслану, явыз кешегә әйләнү. *Элек мин бөтенләй башка кеше идем. Күңелем йомшак иде минем. Хәзер зәһәрләндем.* Г.Әпсәләмов. *Безнең ачу моңа каршы тагын да зәһәрләнде.* Г.Минский

4) *күч.* Көчәю, куәтләнү, арту. *Кайбер көннәрне [җил] зәһәрләнеп, үтереп, күз ачкысыз буран кузгатты.* Казан утлары

5) *сөйл.* Куәтләнү, градусы арту (эчемлек турында)

**2. зәһәрләнеп** *рәв. мәгъ.* Ачу, нәфрәт белән, явызланып. *Губернатор күн утыргычны зәһәрләнеп кырыйга этәрде: – Килеп җитте, ахры, шомлы давыл.* К.Нәҗми. *– Сезне алар табада кыздырып ашаячаклар! – диде бала Чун, зәһәрләнеп, ярсый башлап.* Н.Фәттах

**Зәһәрләнә бару** Торган саен көче артып, зәһәррәк булу. *Вәзир торган саен зәһәрләнә бара, аның һәр боерыгына ихласлык төсмере өстәлә иде.* М.Хәбибуллин. *Сизде Гази: көчле агымга, торган саен зәһәрләнә барган җилгә эләккән көймә, ифрат зур тизлек белән, һаман тирәнгә, елга уртасынарак йөзә.* М.Хәсәнов

**Зәһәрләнә башлау** Зәһәрләнергә тотыну. *Филатов зәһәрләнә башлаган хатынның күзләренә туры карамыйча гына сорап куя: «Ул сине дә мәҗбүр иттемени?»* З.Мәхмүди. *Күгәреп чыккан экскурсовод марҗа урысныкына әйләнеп бетә язган элекке татар каласы Казанда үзен хуҗабикә итеп өйрәнгән, зәһәрләнә башлый һәм усалланып телгә килә.* З.Зәйнуллин

**Зәһәрләнә төшү** Тагы да зәһәррәк булу. *Ә Галләм хаҗи исә, соңгы козырьларыннан берсе итеп саклап килгән бу хатны китереп тапшыру белән тынычлана алмады гына түгел, киресенчә, бу өметенең дә файдасы тимәстәйлекне сизенеп, тагын да зәһәрләнә төшебрәк хәрәкәт итә башлады.* Ф.Хөсни. *Кайчак бу сызланулар атналар буена сузыла һәм бары тик тагын да зәһәрләнә төшеп яңадан башланыр өчен генә беразга басылып тора.* Г.Әпсәләмов

**Зәһәрләнеп алу** Бераз, аз гына зәһәрлек күрсәтү. *– Аларның авылга әйләнеп кайтасылары, күрше булып яшиселәре дә бар әле! – дип, янарга теләп әйтсәләр, бүтәннәре, арттырып җибәреп: – Кирәкләрен бирербез! – диярәк зәһәрләнеп тә алдылар.* Ф.Яхин

**Зәһәрләнеп бетү** Тәмам зәһәрләнү. *Кайбер укытучылар эшләү дәверендә зәһәрләнеп беткәннәр, хәтта ки үч алудан да тайчынмыйлар иде.* Мәгърифәт

**Зәһәрләнеп йөрү** Күптәннән, озак вакыт дәвамында зәһәрләнү. *Урамда январь абыегыз зәһәрләнеп йөри.* И.Гази

**Зәһәрләнеп киту** Көтмәгәндә явызлану, зәһәрлеге арту. *Тәкъдиреме, әллә еллары шулай зәһәрләнеп киттеме, бер яктан булмаса, икенче яктан китереп ора.* Казан утлары

**Зәһәрләнеп кую** Берара, кыска вакыт арасында зәһәрләнү, кинәт зәһәрлек күрсәтү. *Сирәк булса да, Сәйдәш абыйлары зәһәрләнеп куя, һәм бу чакта аңа якын да килеп булмый иде.* Казан утлары

**Зәһәрләнеп тору** 1) Һаман, һәрвакыт зәһәрлек күрсәтү

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында зәһәрләнү. *Зәһәрләнеп торган каенанасына Гайшә бер сүз дә әйтмәде, тыныч кына үз эшен эшли бирде.* Казан утлары

**ЗӘҺӘРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Агулау, агу катнаштыру, агу салу. *Ул төтен, бормаланып-бормаланып, әтрафка тарала, үзе күргән күзләрне зәһәрли, ачыттыра, аңардан ихтыярсыз яшь агыза.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Агулау, томалау, бозу. *Шул фәннәрне, шул гыйлемнәрне беләсем килгәндә, калдык-постык берлә башымны тутырырга, дөрестлеге шөбһәле мәгълүматлар берлә миемне зәһәрләргә тиешмен.* Г.Исхакый. *Боларга карап, Җәгъфәр әфәнде: «Безнең голямамызның кальбләрен зәһәрләүгә болар кадәр хезмәт иткән нәрсә булмаган ---» диде дә тагы башка китаплар янына китте.* Г.Исхакый

3) Зәһәрен, ачуын китерү, үртәү, ярсыту. *Агулады шәүләң бу атаны, зәһәрләде исемен ананың.* Ф.Бурнаш

**Зәһәрләп бетерү** Тәмам, бик нык зәһәрләү. *Аның эшен редакциядә тәмам зәһәрләп бетергәннәр, язганының өчтән бер өлеше дә калдырылмыйча сызып бетерелгән.* Казан утлары

**Зәһәрләп кую** Вакыт-вакыт, сирәк кенә зәһәрләү. *– Анда-санда зәһәрләп кую ярый аны, – дип, әнисе малаеның башыннан сыйпады. – Күр, әнә ничек эшләп чыккан.* Казан утлары

**Зәһәрләп тору** Һаман, һәрвакыт зәһәрләү. *Хәтта тәнкыйтьчеләр дә аны [Г.Тукайны] урынсызга зәһәрләп тордылар.* С.Сүнчәләй. *Кызны, нигәдер, гел зәһәрләп торалар, яралы күңеленә тоз салалар, кубәләктәй җанын һаман борчыйлар иде.* Казан утлары

**Зәһәрли төшү** Тагын да зәһәрләү

**ЗӘҺӘРЛЕ** *с.* 1) Агулы, агулый торган, агуы булган. *Үкенечкә, намуслы кешегә саражнар алдына барып сәдака сораудан елан авызындагы зәһәрле агуны йоту җиңелрәктер.* Ибн әл-Мөкаффаг. *--- аның [шагыйрьнең] түрәләргә-чиновникларга булган мөнәсәбәте дә ачык. Ул аларны зәһәрле еланга охшата.* Татар әдәбияты тарихы

2) Явыз, усал, зәһәр тулы. *Сәгыйдә, шуны аңлаган кебек, шул тирән күзләре белән хәзрәтнең йөрәгенә кадалган укны, зәһәрле укны күргән кебек, йомшак кына көлеп: – Хәзрәт, синең әллә ник кәефең юк... – диде.* Г.Исхакый. *Әмма күкрәген яндырып зәһәрле ачу купты, нәфрәт өермәсе купты...* Э.Касыймов. *Үткен күзле бөркетнең куянны – куркак озын колакны күрә алмавына Тинәй ачулана, зәһәрле күзләрен елтыратып сүгенә.* М.Госманов

3) *күч.* Бик каты, көчле, кискен ачы. *Кайда сөеклем, алтыным Уздыра бу*

*куркыныч Төннең зәһәрле салкынын?* Һ.Такташ. *Колакларыңда җил уйный, битеңә зәһәрле салкын бәрә.* Г.Бәширов

**2.** *рәв. мәгъ.* Ачу белән, нәфрәт катыш. *Мәгариф мөдире янә күзлеген киеп алды да зәһәрле генә әйтте: «Анысы инде – сезнең эш. Безнең мәшәкатьләребез болай да күп».* Т.Нурмөхәммәтов. *Карчык, зәһәрле йөткеренә-йөткеренә, авыр таш капканы сыкрандырып, минем арттан бикләп калды.* Ф.Әмирхан

**ЗӘҺӘРЛЕК** *и.* 1) Зәһәр (*2 мәгъ.*) булу; усаллык, явызлык. *Тегесе [Фәтхия], картының ашалган, сирәк тешле авызын ерып утыруын бер генә дә килештермичә, карашына зәһәрлек кертеп, уенны чынга алды да, кеше бар дими, ни дими, кабынып, чәпченеп китте.* Э.Касыймов. *Суларында күпме янау, гайбәт, бөек мәмләкәтчел зәһәрлек, ә шулай да су чиста.* М.Юныс. *--- әмма, гади халыкны буйсындыру өчен, барыбер, зәһәрләгән йөзенә чыгара торган байбичә итеп сурәтли.* Казан утлары

2) Бик нык салкынлык яки эсселек. *Гәрчә Гыйнвар көнне калтырата, Зәһәрләгән гәрчә арттыра, Юккамы тик көннәр озыная, Юккамыни көннәр яктыра?* Ә.Баян

3) *сөйл.* Күгү көче, җетелек, үткенлек. *Күзнең зәһәрлеге бетте.* М.Хәсәнов

**ЗӘҺР** *и. фар. к.* **зәһәр**. *Таш йотам икмәк белеп, һәм зәһр эчәм, саф су дисәм.* Г.Тукай. *Суыкның зәмһәрире, зәһре кискен, Тагы туктар, тагы атлар ул мескен.* Г.Тукай

**ЗВА́НИЕ** *и. рус хәрби* Махсус белеменә, әзерлек дәрәҗәсенә, хезмәт стажына карап бирелә торган дәрәҗә; чин. *Берәр ай үткәч, хәрби званиең күтәрелер.* Ф.Вәлиев. *Ә аннары, арада өлкән званиедәге кешеләр булса да, адъютант Бикбаевны бертавыштан отряд командиры итеп сайлаганнар.* Ш.Рәкыйпов

**ЗВЕНО** *и. рус* 1) Нинди дә булса берләшмә, оешма, төркемдә зур булмаган бүлекчә. *Механик, самолётлар звеносы очарга әзерләнгәндә, двигательләрнең эшен тикшерә һәм «яхшы» дип таба.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) *тар.* Совет чорында колхозларда бригаданың бер бүлеге, ячейка. *Алар звеносы көлтә бәйли башлаган иде. Бу звено начар звено түгел.* Г.Толымбай. *--- звено, бригада җитәкчеләре өчен оештырылган политик уку түгәргәген алып баруны да яңадан аңа [Гөлшәһидәгә] йөкләделәр.* Г.Әпсәләмов

3) *тар.* Совет чорында: пионер отряды яки дружинасының аерым бер бүлеге

**ЗВОНАРЬ** *и. рус* Чиркәүдә чаң кагучы кеше. *Вакытсыз азан әйткән мәзиннәр яисә вакытсыз чиркәү каккан звонарьлар була инде.* Г.Тукай

**ЗВОНОК** *и. рус* 1) Тавыш сигналлары бирү өчен махсус җайланган прибор яки зур булмаган кыңгырау. *Кыз, урындыкка күчкән вакытта, ишек читендәге звонокка бармагы белән басып алды.* К.Тинчурин. *Шуның өчен, иң әүвәл, Исхак әфәнде звонок биреп керергә, хуҗаларга, кайтсалар, үзем ачармын, дип әйтеп, тышка чыгарга вә шул вакытта без керергә план кордык.* Г.Исхакый. *Габделнасыйр капкадан чыгуга уңга борылып, --- Московский урамы чатына җиткәч тә, ике катлы таш өйнең баскычына тукталып, озын баулы звонокны каты гына итеп тартты.* М.Гафури

2) Кыңгырау яки башка берәр нәрсә ярдәмендә бирелгән тавыш сигналы. *Ул, бумажник хуҗасы өчен билгеләнгән сәгатьләрдә, коридордагы звонок шалтыраган саен, ашкынып, үзе йөгереп чыкты.* А.Шамов. *Тәнәфескә звонок булу белән, бөтенебез залга ашыга.* Г.Нәбиуллин. *Сменага һәрвакыт яшьләрдән алда киләләр һәм, звонок булганын да көтмичә, аерылып торган китапларына --- ябышалар иде.* Мирас

**ЗЕ́БРА** *и. фр. зоол.* 1) Атсыманнар семьялыгыннан, Африкада яшәүче, так тояклы, утырып торган кыска яллы, аклы-каралы буй-буй сызыклары булган тиреле кыргый хайван. *Африка далаларында көтү-көтү булып йөргән зебра, антилопа, кабаннар арасыннан [арыслан] корбанын шундый итеп эләктереп ала – исләрең китәрлек.* Т.Миңнуллин

2) *күч. махс.* Юлның, җәяүлеләр чыгып йөрү өчен, аклы-каралы буйлар төшерелгән урыны. *Урамда «зебра» булган җирләрдә күпме генә машина җыелса да, җәяүлеләрне үткәреп җибәрәләр...* Мәдәни җомга

**ЗЕ́БУ** *и. фр. зоол.* Африкада һәм Көньяк Азиядә яши торган, өркәчле, чыгышы белән сыерларга якын булган мөгезле эре терлек. *Зебу Һиндстанда тиярга, рәнҗетергә ярамый торган изге хайваннардан санала*

**ЗЕК** *и. рус сөйл.* 1) Кылган җинаяте өчен ирегеннән мәхрүм ителгән, төрмәгә ябылган кеше; тоткын

2) Төрмәдә, лагерьларда утырып чыккан кеше. *Егетнең --- тавышы киселде: – Сез нәрсә? «Магаданнан» дигәч тә, анда зеклар, хайваннар гына яши, дип уйлыйсызмы?* Т.Галиуллин

**ЗЕКЕР** *и. гар. сөйл. к.* **зикер**. *Зекер – утырткан агачыңның һәр яфрагы дога укып, җәннәткә керүеңне теләп торыр, ди.* Э.Шәрифуллина. *Апалар шыпырт кына мәет тирәли тезелеп утырдылар, авыл өенә моңлы һәм бераз шомлы зекер һәм тәхлил авазлары таралды.* Ф.Бәйрәмова

**ЗЕКЕ́Р ӘЙТҮ** *ф. дини сөйл. к.* **зикер әйтү**. *Кайбер кеше кыйблага каршы утырып зекер әйтә, ягъни тәсбих тарта, капыл гына: «Һу шәйхем мәдәт!» – дип кычкырып җибәрә.* М.Гафури. *Ятсалар да, торсалар да, аллаларга, изгеләргә зекер әйткәннәр.* Н.Фәттах

**ЗЕКЕ́Р ИТҮ** *ф. сөйл. к.* **зикер итү**. *[Мулла:] Анысы кем, Сабирҗан, риясыз дога булса, кайда зекер ителсә дә, кабул әйләрмен, дигән Хак Тәгалә.* Г.Сабитов

**ЗЕКЕ́Р КЫЛУ** *ф. сөйл. к.* **зикер кылу**. *Рәхмәтулла ибн Әмирхан әфәнде һәм 41 нче елда тәбыг кыйлдырмыш горрәнамәсендә зекер кыйлгандыр.* К.Насыйри

**ЗЕЛПЕ** *и. бот.* Зелпечәләр семьялыгыннан, парлап урнашкан вак яфраклы, хуш исле алсу һәм ак чәчәк ата, кара коңгырт төстәге җимеш бирә торган куак үсемлек, *русчасы:* **жимолость**. *Ямь-яшел чирәм белән капланган бәләкәй генә бик матур тугайчыкта Мәдинә зелпе куагы башына юеш яулыклар җәеп маташа иде.* Ш.Камал. *Матур иртәгә көлеп ачылган гөлҗимеш, зелпе чәчәкләреннән чыккан хуш исләр ---.* М.Әмир. *Сырма кигән, кырынмаган,*

*шуңа зелпе каерысыдай кара яңаклы кеше [үзе килеп чыкты].* Х.Камалов

**ЗЕЛПЕЛЕ** *с.* Зелпесе булган, зелпе үскән. *Ә мәнә быел без, унбер җан, зелпе чыгарырга барабыз! Зелпеле булу – бүрәнәле, өйле булу дигән сүз ул.* Ф.Гыйльми

**ЗЕЛПЕЛЕК** *и.* Зелпеләр күп үскән урын

**ЗЕМЛЕМЕР** *и. рус* Җирдән файдалану, җир бүлү эшләрен тәртипкә салучы белгеч. *Алпавытның җавабы бик кыска булган: «Соңга калдыгыз: землемер килде, багана какты, эш бетте».* И.Гази

**ЗЕМЛЯ́НКА** *и. рус* 1) Җирне казып эшләнгән торак урын (ныгытма). *Землянкалар, сукмаклар, күпер алды дотлары, зенит батареяларының позицияләре, --- – барысы да исәпкә алынган булырга тиеш.* Г.Әпсәләмов. *Уң кул якта, ерак түгел, ак кар яктысында землянка, блиндаж түбәләренә охшаган калкулар күренә.* Ф.Кәрим. *Транспортчылар землянкасында унбишләп кеше тора иде.* Ә.Еники

2) Яшелчә һ.б. әйберләр саклау өчен махсус урын. *Быел колхоз яңадан ике зур амбар салдыра, бәрәңге, яшелчә саклар өчен, өч землянка казыта.* Г.Әпсәләмов

**ЗЕ́МСКИЙ** *с. рус тар.* **1.** Земствога караган, земство карамагындагы. *Иван Георгиевич бу җирләрдә беренче земский больницалар, телеграф бүлекләре ачылганда ук дөньяга килгән кеше икән.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ. к.* **земский начальник**

**ЗЕ́МСКИЙ НАЧА́ЛЬНИК** *и. рус тар.* Авылларда җирле идарә һәм суд эшен башкаручы өяз чиновнигы. *Шул сәбәптән ул, старосталар китергән хәбәрләргә үз белгәннәрен өстәп, земский начальник белән становойга белдерде.* М.Галәү

**ЗЕМСНАРЯД** *и. рус тех.* Гидротехник эшләр башкару өчен, су асты грунтыннан балчык, вак таш, ком суырта, соса торган махсус җайланма. *Ә земснаряд юдырып, комы алынган иркен колакта балыкчылар санап бетергесез һәм көтү кебек кайсы кая сибелгән.* З.Фәйзи

**ЗЕМСНАРЯДЧЫ** *и.* Земснарядта эшләүче

**ЗЕ́МСТВО** *и. рус тар.* Революциягә кадәр Россиянең үзәк губерналарындагы җирле үзидарә. --- *шифаханә күрше авылда, ә сеңлесе гади генә кеше түгел – врач, земство врачы, могтәбәрле кеше.* Г.Шәрипова. *Һәм Мирсәетне --- Оренбург губернасының земствосы әлеге яңа оешкан «мөселман мәгарифе» бүлегенә җитәкче итеп чакыралар.* Ф.Дунай. *Земствоның шул ук елгы рәсми басмасында мондый юллар бар: «грамота тарату буенча татар халкы бик алга киткән...».* Р.Әмирхан

**ЗЕНИТ** I *и. фр.* Күк гөмбәзенең җирдәге күзәтүчегә карата иң югары, иң ерак ноктасы; төшлек, зәвал (*2 мәгъ.*)

**ЗЕНИТ** II *и. фр. сөйл. к.* **зенит артиллерия (пулемёт, туп).** *Беренче мәртәбә Тухачевский белән 1932 елда, ул, Оборона халык комиссариаты комиссиясе җитәкчесе сыйфатында, зенит җайланмаларын һәм орудияләрне сынау максатында уздырылган үрнәк өйрәнүләрдә катнашу өчен, дивизиягә килгәч очраштым.* Д.Шәрәфетдинов

**ЗЕНИТ АРТИЛЛЕ́РИЯ (ПУЛЕМЁТ, ТУП)** *и.* Һавадагы дошман самолётларына ата торган артиллерия (пулемёт, туп). *Кичүгә җитәрәк бер танкетка күренде. Аннан ерак түгел машина кузовына беркетелгән зенит пулемёт тора.* Ә.Галиев. *Шуның өстенә фашистларның алтмыш өч зенит тубы, алтмыш сигез эре калибрлы орудиясе, мең дә дүрт йөз туксан ике автомашинасы, сигез танкы сафтан чыгарылды.* Р.Ибраһимов. *Тышта зенит туплары телгә килде, тиздән исә бомбалар шартлавы да ишетелә башлады.* Т.Әйди

**ЗЕНИ́ТКА** *и. рус сөйл.* Зенит артиллериянең бер пулемёты яки бер тубы. *Шәһәр читләрендә, завод-фабрика ишегалларында озын көпшәләре күккә сузылган зениткалар урман булып үсте.* Г.Гобәй. *Авыл өстендә тагы өзлексез шартлау, күк күкрәгән кебек дөбердәү, зениткалар тавышы, пулемёт шатырдавы һәм тузан, тузан, тузан...* И.Гази. *Яна торган самолёттан, Атылган йолдыз сыман, Бик биектән, зәңгәр күктән Ташланды безнең Шәкүрев Дошман зениткасына.* Ф.Кәрим

**ЗЕНИ́Т СНАРЯД** *и.* Зенит артиллериясе яки тубыннан аткан снаряд. *Фронт сызыгы аша үткәндә, зенит снаряды кыйпылчыгы тиеп, шассилары ватылу сәбәпле, самолёт җиргә төшә алмаган, йөкне парашютлар белән ташлаганнар.* З.Фәтхетдинов

**ЗЕНИТЧЫ** *и.* Зениткадан атучы кеше. *Имеш, зенитчылардан нык куркуга төшкәннәре хәтта постларын ташлап киткән, икенче бер җирдә посып ятучылары да булган икән.* Р.Ибраһимов

**ЗЕҢ, ЗЕҢ-ЗЕҢ** *иярт.* Юка металл, пыяла, бәллүр һ.б.ш. нәрсәләр берберсенә тигәндә, орынганда барлыкка килгән калтыраулы нәфис нечкә тавышны белдерә. *Колак тынлыктан нидер эзли, табарга азаплана һәм күпмедер вакыттан соң таба да: – Зең, зең, зең.* Ә.Баянов. *Миләшләр бер-беренә җиңелчә бәрелеп, бары «зең-зең» дигән нечкә аваз чыгардылар.* Р.Низамиев

**ЗЕҢГЕЛДӘТҮ** *ф.* Зеңгелдәү тавышы чыгару. *Колак төбеңнән генә юка, нәфис канатларын зеңгелдәтеп узган энәкараклары арасыннан чупырдат та чупырдат суны.* Ф.Шәфигуллин. *Авыл ирләре чүкечне дә, мастерокны да суккалап, зеңгелдәтеп, кулларында әйләндергәләп караганнан соң, болар гайре махсус металлдан эшләнгән, дигән фикергә киләләр.* Мирас

**Зеңгелдәтә башлау** Зеңгелдәтергә тотыну

**Зеңгелдәтә бирү** Зеңгелдәтүен дәвам итү; һаман да зеңгелдәтү

**Зеңгелдәтеп алу** Кыска гына зеңгелдәгән тавыш чыгару

**Зеңгелдәтеп кую** Бер яки берничә тапкыр өзек-өзек зеңгелдәтү

**Зеңгелдәтеп тору** Бертуктаусыз зеңгелдәтү

**ЗЕҢГЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) «Зең», «зеңгел» иткән тавыш чыгу. *Марат белән Әлфия, өнсез калып, зал уртасында басып торганда, ишек кыңгыравы зеңгелдәде.* З.Хәким. --- *зал артындагы оркестр уйнап җибәрде – җиз тәлинкәләр зеңгелдәп бер-берсенә бәрелде ---.* М.Маликова. *Иртәнчәк нindидер нәни кыңгыраулар зеңгелдәвен ишеттем.* Г.Хәсәнов

2) Баш авыртып шаулау. *Чигәләр зеңгелдәп шаулады. Юк шул, сезгә бернинди дә хөкем юк.* Н.Гыйматдинова

**Зеңгелдәп алу** Кыска вакытлы «зең» иткән тавыш чыгу

**Зеңгелдәп кую** Кыска гына бер тапкыр зеңгелдәү. *Тик көтү-көтү очкан сыерчыкларның чирелдәшүләре һәм уракларның бодайга ышкылган саен зеңгелдәп куюлары ишетелгәләп китә.* Г.Гобәй. *Шул чак стеналар музыкаль шкатулка сыман зеңгелдәп куя да, буш бүлмәгә бөтен җирдән: тәрәзәләрдән, ишекләрдән музыка агыла башлый.* Р.Вәлиев. *Күк күкрәүдән өйнең тәрәзә пыялалары зеңгелдәп куйды.* Р.Батулла

**Зеңгелдәп китү** Кинәттән, көтмәгәндә зеңгелди башлау. --- *башым, калун балта белән китереп суккандай, зеңгелдәп китте.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Зеңгелдәп тору** Бертуктаусыз зеңгелдәү. *Җәйге коры һава чыңлап, зеңгелдәп тора.* А.Гыйләҗев. *Пычкы зеңгелдәп тора, гүя аның тешләреннән дә чүп түгел, очкын сибелә.* Р.Мөхәммәдиев. *Урамда исә җәйге эссе зеңгелдәп тора иде...* Ф.Бәйрәмова

**Зеңгелди башлау** Зеңгелдәргә тотыну. *Фабарисовның хәвефле сорауларына җавап биргәндәй, кесә телефоны зеңгелди башлады.* Ф.Бәйрәмова

**Зеңгелди бирү** Зеңгелдәвен һаман да дәвам итү

**Зеңгелди төшү** Бераз зеңгелдәү

**ЗЕҢГЕЛ-ЗЕҢГЕЛ** *иярт.* Нәрсәләрдер орынганнан, бәрелгәннән килеп чыккан, озаккарак сузылган калтыраулы зең авазына охшаш нәфис нечкә тавышларны белдерә. *Әйтерсең лә бу матур чыңлау кечкенә кыңгыраудан түгел, ә болын чәчәкләреннән сибелә. Зеңгел-зеңгел, зеңгел-зеңгел!* Ф.Яруллин

**ЗЕҢГЕРДӘ́Ү** *ф. к.* **зеңгелдәү**

**ЗЕҢЛӘВЕК** *с.* «Зең» иткәнгә охшаган, зеңли торган, бик нечкә. *Меңләгән черкичекләр бөтен дөньяны зеңләвек тавыш белән тутыра икән.* Р.Батулла

**ЗЕҢЛӘ́Ү** *ф.* «Зең» иткән тавыш чыгару. *Сыер мөгрәве, кәҗә-сарык тавышы, каз-үрдәк һәм әтәчләр кычкыруы, --- чалгы зеңләве, балта-пычкы җыры --- – шуларның барысын да үзендә туплап, түкми-чәчми мөлдерәмә саклап тора авыл.* Р.Низамиев. *Кояш өскә менә, өскә менгән саен, челлә зеңли.* Р.Батулла. *Сөт акканда зеңләп чиләккә, Аклык, сафлык тула йөрәккә.* Ә.Баян

**Зеңләп алу** Аз гына, кыска вакыт эчендә зеңләү. *Рюмкалар чәкеште, калак-чәнечкеләр җиңелчә зеңләп алды.* Р.Низами

**Зеңләп китү** Кинәт зеңли башлау

**Зеңләп кую** Бер тапкыр «зең» иткән тавыш чыгару. *Тикшерүченең кычкыруыннан, йодрыгы белән өстәлгә сугуыннан тәрәзә пыялалары зеңләп куйды.* С.Зыялы

**Зеңләп тору** Бертуктаусыз зеңләү. *Юкә агачы, үзенә күрә бер көй чыгарып, бертуктаусыз зеңләп тора.* Д.Каюмова. *Утә күренмәле чиста, саф һава зеңләп тора.* Р.Мулланурова

**Зеңли башлау** Зеңләргә тотыну. *Яшелле-зәңгәрле салкынча җил колакка кереп зеңли башлый.* Ә.Баянов

**ЗЕРӘ́** *рәв. рус сөйл.* 1) Юкка, бер сәбәпсезгә, нигезсез; тиктомалга. *Рәхим бабайның аты бер заманны, урактан кайткач, зерәдән генә үлде китте.* Г.Толымбай. *Без аны зерә генә «матур» дип йөргәнбез икән.* А.Шамов

2) Бушка, юкка, кирәкмәстән, максатсыз. *– Зерә... – диде Сәүбәнов. – Зерә каршы киләсез, Фәһим Сабирҗанович. Без сезгә ярдәм итәргә теләгән идек.* Г.Ахунов. *Көлмәс идем зерәгә, ди, Булмас идем бүрәнә, Әнә килде, катыша бит Минем эшкә, Катыша!* Н.Исәнбәт

**ЗЕ́РӘ** *рәв. сөйл.* Бик, артык, нык. *Әнисе, диген, минем башта зерә шәп бер уй туып тора бит әле.* Г.Бәширов. *Ай, күлмәгең дә күлмәгең. Кемнән тектердең? Зерә дә килешә, ярабби, өстеңдә туза күрсен.* М.Хәбибуллин. *Инде кузгалдык дигәндә, башыма зерә акыллы уй килде.* М.Кәрим

**ЗЕРЕЛДӘ́Ү** *ф.* Әйләнү, ышкылу, хәрәкәтләнү вакытында өзлексез рәвештә «зер-зер» иткән нечкә аваз чыгарып тору

**Зерелдәп алу** Тиз генә, берара зерелдәү, бик аз вакыт зерелдәү

**Зерелдәп кую** Аз гына, бер тапкыр зерелдәгән аваз чыгару; кинәт һәм бераз гына зерелдәү

**Зерелдәп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта зерелдәү

2) Бертуктаусыз, гел, һәрвакыт зерелдәү

**Зерелди башлау** Зерелдәргә тотыну

**ЗЕР-ЗЕР** *иярт.* Нәрсә дә булса әйләнүдән, ышкылудан, хәрәкәтләнүдән чыккан нечкә генә тавышны белдерә. *Зер-зер орчык әйләнә*

**ЗЕФИР** I *и. гр. иск. шигъ.* Йомшак кына искән җил; саба җиле

**ЗЕФИР** II *и. фр.* Киҗе-мамык тукыманың бик юка бер төре. *Сирәк-сирәк буйлы ак күлмәк. Ул вакытта мин «зефир» дип аталган материя барлыгын белми идем әле.* М.Әмир

**ЗЕФИР** III *и. фр.* Җиләк-җимеш согына шикәр, йомырка агы кушып, күбек сыман күпертеп әзерләнгән кондитер ризык. *Чәйләр сатабыз, шикәр, зефир – бөтенесе дефицит.* А.Хәмзин. *Өстәл торт, шоколадлы конфет, пирожный, лимонад, зефир ише татлы әйберләрдән сыгылып төшәргә әзер кебек иде.* Ф.Латыйфи

**ЗИГЗАГ** *и. фр.* 1) Сынык сызык. *Бу текә тауга менү өчен, поезд зигзаглар ясарга мәҗбүр, бер алга китә, бер атка чигенгәндәй була.* А.Расих. *Кинәт магнитометрның каләме кискен генә сикереп куя, --- кәгазь өстендә зигзаг рәвешендәге сынык сызык барлыкка килә.* Могҗизалар дөньясы

2) *күч.* Тормышта килеп чыккан кинәт, көтелмәгән катлаулы үзгәрешләр. --- *диаматтан лекция бара, профессор җәмгыять үсешенең, туры сызык белән генә бармыйча, үз юлында төрле әйләнмәле борылышлар, зигзаглар ясаганлыгын исбат итә.* Ф.Хөсни. *Хәлнең кинәт зигзаг ясавына әзер булмаган Мизин исә, таяныч эзләгәндәй, як-ягына каранып торды.* Х.Камалов

3) *махс.* Тегү эшендә әйбернең җөйләрен сынык сызыкча сыман адымнар ясап эшкәртү ысулы; шул ысул өчен махсус җайланма

4) *а. х.* Туфрак йомарламнарын вату, җирнең өстен йомшарту өчен җир эшкәртү коралы, тешләре сынык сызык рәвешендә урнаштырылган тырма. *Тракторлар, культиваторлар, сабаннар, зигзаг тырмалар үзләренә*

*билгеләнгән участокларга якынлашып туктадылар.* И.Салахов

**ЗИГЗАГЛЫ** *с.* Зигзаг формасында булган, борылмалы. *Зигзаглы тау сукмаклары*

**ЗИГО́ТА** *и. гр.* Үсемлек һәм хайваннардагы аталанган күкәй күзәнәк. *Тынлык чорыннан соң зигота шыта, редукцион бүленү нәтиҗәсендә 4 зооспора барлыкка килә.* Л.Мәүлүдова

**ЗИҖ** *и. гар. иск.* Астрономия календаре. *Зиҗ гыйлеме белән шөгыльләнгән иң мәшһүр мөселман галимнәреннән Ибне Юнысның, Әбү Хәнифә әл-Динуриның --- дәвер, заман сикәлтәләрендә язып калдырган китаплары бүген дә астрономия, география, математика белгечләренең игътибарына лаек.* К.Салихҗан

**ЗИКЕР** *и. гар. дини* Аллаһы Тәгаләне олылап, аның шәрәфенә күмәкләп яки эчтән генә укыла торган мактау догасы (ля илаһы иллә-л-лаһ); шуны укып тәсбих тарту. *Бабай, шуны күреп, шатланып китте, агачның зикерене ишеткән кеби, моңаеп тыңлап утырды.* Г.Исхакый

**ЗИКЕ́Р ӘЙТҮ** *ф.* Аллаһы Тәгаләне олылап мактаган махсус доганы (ля илаһы иллә-л-лаһ) күмәкләп яки эчтән генә уку, шуны укып тәсбих тарту. *И Кол Шәриф, тынма син, төннәрен ятып йоклама, Аллаһка зикер әйтүне ташлама, белми йөрмә, «Аллаһу» диген.* Газәл. *Коллык димәктән, көнозын намаз уку вә зикер әйтү --- дип аңламыйча, бәлки, Аллаһы Тәгаләнең боерган юлы белән өстендә булган бурычларны үтәү --- һәм гөнаһлардан саклану дип аңлагыз вә шулай гамәл итегез!* Р.Фәхреддин

**ЗИКЕ́Р ИТҮ** *ф.* 1) *дини к.* **зикер әйтү**. *Мәчеткә барганда ашыгып атламаска, салмак кына, вәкарь белән бару мәслихәт. Юлда Аллаһны зикер итеп, тәкбир әйтеп бару тиешле.* Инсан һәм дин

2) Искә алу, искә төшерү. *Үткәннәргә карап зикер итмә, алдагыга карап фикер ит.* Мәкаль

3) Телгә алу, әйтеп узу, телгә алып узу. *--- кайсыбер урыс мөәррихләренең, шушы вакыйганы язганда, «Казан» сүзенең иң элек зикер ителә башлавы шул елдан башланадыр» диюләре дә дөрес булып чыкмыйдыр.* Һ.Атласи

**ЗИКЕ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **зикер итү**. *Узган эштән төш яхшы ---, ягъни үткән эш зикер кыйлынмас.* К.Насыйри. *Шул вәгънәне сөйләгән вакытта, сары атларны, җиз камытларны, саз буйларын зикер кылуы гаять килешсездер.* Г.Тукай

**ЗИЛЗИЛӘ** *и. гар.* 1) Көчле җир селкенү, җир тетрәү. *Әйтерсең лә диңгез басып килә, Яисә тиздән була зилзилә.* М.Гафури. *Камый башлауның икенче көнендәге зилзилә, гарасатлы давыл исләренә төшкән саен, һәркемнең йөрәге калтырап куя иде.* Ф.Латыйфи. *Урманда үсеп утырган бәләкәй агачлар һәм уртача зурлыктагы агачлар җилдавылның тәэсирен дә сизмичә калганда, зур агачлар, иелеп-сыгылып, шул зилзиләләргә каршы торалар*... Мирас

2) *күч.* Җәмгыять тормышында, кеше язмышында булган хәлиткеч вакыйгалар, тетрәндергеч күренешләр. *Күк йөзендә тын гына йөзмәктә йолдыз, ай, кояш, Җир йөзендә – зилзилә, дәһшәт, газап, кан, канлы яшь.* Ш.Бабич. --- *«сугыш» дигән зилзиләнең безнең халкыбызга китергән зарарларын искә төшерде.* Ф.Хөсни. *Болганчык заман зилзиләләренең негатив йогынтысы нәтиҗәсендә, соңгы вакытта шигъри сүзнең көче һәм әһәмияте шактый кимеде.* Мирас

3) *күч.* Кешенең үз-үзен тотышындагы тынгысызлык, тынычсызлык, башкаларга уңайсызлык тудырырдай ыгы-зыгы, әрле-бирле йөренү. *Ишекнетүрне бер итеп, зилзилә килеп йөри.* Т.Галиуллин

**ЗИЛЗИЛӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Давыл күтәрелү; көчле җил-давыл белән җир тетрәнү

2) *күч.* Җәмгыятьтәге, яшәештәге көтелмәгән вакыйгалар нәтиҗәсендә кешеләр язмышында тетрәнүләр килеп чыгу, аянычлы гамәлләр башкарылу. *Зилзиләләп чыга дәһшәт җирдән, Дүнәрләрдәй килә, әйләнеп.* Б.Рәхимова

3) *күч.* Тынгысызлык, ыгы-зыгылык кичерү, тынычлык тапмау (кешенең үзүзен тотышында, халәтендә һ.б.). *Юккамыни безнең күңелләрдә зилзиләләп куба ярсулар.* Э.Мостафин

**Зилзиләләп алу** Вакыт-вакыт, кыска вакытлы зилзиләләү

**Зилзиләләп тору** Бик еш, бертуктаусыз зилзиләләү

**ЗИЛЗИЛӘЛЕ** *с.* 1) Зилзилә еш була торган, зилзилә булып үткән

2) *күч.* Тынычсыз, тотрыксыз. *Син дөньяга килгән гасыр башы Утлы, зилзиләле чор иде.* Х.Бәдигый. *Бүгенге көндә безнең республика зилзиләле, давыллы Россия уртасында сабырлык, тыйнаклык, тынычлык утравы булып кала бирә.* Мирас

**ЗИЛКАГДӘ** *и. гар. к.* **зөлкагдә**

**ЗИЛЛӘТ** *и. гар.* Хурлык, мәсхәрә; кадерсезлек. *Торалар мескенәт, зилләт эчендә.* М.Гафури

**ЗИЛХИҖҖӘ** *и. гар. к.* **зөлхиҗҗә**

**ЗИМ** *и.* 1) Көзен яки язын су өстендә ага торган бозлы куерык. *Ык катканнан соң, безнең агайлар Идел ягыннан кайтучылардан гел сораштырып торалар: «Иделдә зим ага башламаганмы әле?»* Г.Бәширов. *--- су өстендә, ярдан ярга тоташ җәелеп, итле аш өресе төсле зим ага.* С.Сабиров. *Безнеке ише вак елгалар туңып, Агыйделгә зим чыкты.* Х.Сарьян

2) *диал.* Бузаның өсте, күбеге

**ЗИМАГУР** *и. фар. иск. сөйл.* Төрле промыселларга китеп эш эзләп йөрүче крестьян, даими эше булмаган сезонлы эшче. *Зимагур да зимагур, Халәф тә зимагур инде менә*... Ф.Яхин. *Зимагур Хабул агай ул: Җырлавы шулай аның. Җырлары аша гүя ул, Караул сала-сала, Үзенең сыйныфы янына Яклауны сорап бара.* Х.Туфан. *Дворникка да ышаныч аз, әнә нинди зимагур чырайлы бит ул.* Г.Шәрипова

**ЗИМАГУРЛЫК** *и. иск.* Зимагур булу, сезонлы эшче булу. *Зимагурлык белән юанырга, ташлар ватып, җирләр чукып, авыр эшләр белән сине онытырга тырыштым.* М.Фәйзи. *– Зимагурлыкта чакта, заводта, шахталарда эшләгәндә, ниләр кыйрата алдыгыз соң сез, егетләр? – диеп сорады.* С.Поварисов. *Әллә инде зимагурлык мишәр малаеның канына сеңгән, милләтебезгә хас әлеге сыйфат әллә инде гомер юлдашы – белмәссең.* К.Миңлебаев

**ЗИМЛЕ** *с. диал.* 1) Туклыклы, калорияле (ашамлык, азык турында). *Зимле аш*

2) Уңдырышлы, югары уңыш бирә торган. *Зимле җир*

**ЗИМНӘ́Ү** I *ф. диал.* Ачыган балга шикәр өстәп кую

**Зимнәп җибәрү** Бераз зимнәү, шикәр өстәү

**Зимнәп тору** Гел, еш зимнәү

**ЗИМНӘ́Ү** II *ф.* Ямау салу. *Күлмәкне зимнәү*

**Зимнәп кую** Тиз арада зимнәү

**Зимнәп тору** Гел, еш зимнәү

**ЗИНА** *и. гар.* Фәхешлек, уйнаш, җенси бозыклык. --- *зина, фәхешлекләр илә башлары әйләнеп, дөнья-ахирәт бәхетләреннән коры калганнар.* Г.Тукай. *Китап әйткән: аларның туенда җитмеш мең ир, җитмеш мең хатын зина кыла, дигән.* Г.Исхакый. *Авыл халкы аның энисенең яшьлек гөнаһысын гафу итмәде, малайның да исеме бик ямьсез сыйфат белән йөртелде: зинадан туган.* М.Мәһдиев

**ЗИНАР** *и. фар.* Нечкә билбау. *Сөләйман итәкләре каюлы ак күлмәк киеп, өстеннән зәңгәр зинар баглаган.* Ф.Әмирхан. *Кайтарылып төшкән кыек якалы, зәңгәр ефәк белән чиккән ак күлмәге дә, очлы башлы сары штиблет өстен каплап торган озын балаклы соры чалбары да, биленә бәйләнгән зәңгәр ефәк зинары да, аның йөзендәге шул көләч сызыкларны тулыландырган, сайлап җыелган бизәкләр төсле генә булып, икенче планга калалар.* М.Әмир

**ЗИНАХУР** *и. фар.* Зина кылучы, җенси бозыклык юлына баскан кеше; уйнашчы ир яки хатын

**ЗИНАЧЫ** *и.* **1.** Зина кылучы; җенси бозыклык юлына баскан кеше. *Әле генә алар алдында зиначы, көчләүче тора иде, ә хәзер... Бу бит үзе фәрештә икән, моңа канатлар гына үсмәгән.* Р.Сибат

**2.** *с. мәгъ.* Җенси бозыклык юлына баскан, фахиш. *Зиначы кызлар белән аларны да хөкем итәбез.* Т.Гыйззәт

**ЗИНАЧЫЛ** *с. сир.* Зина кылучан, уйнаш итүчән

**ЗИНАЧЫЛЫК** *и.* Зина, зина кылу, уйнаш итү, фәхешлек. *Яшьләрне үз иркенә куйдылар. Наркоманнар – яшьләр! Зиначылык белән шөгыльләнүчеләр – шулай ук яшьләр!* В.Нуруллин

**ЗИНДАН** *и. фар.* 1) Төрмә. *Мин, зинданда кан косып яткан иптәшемне коткарыр өчен, бер тиен акча да тота алмыйммы?* Г.Ибраһимов. --- *сине тәләсәм ни кыла алам: Әстерханда коллар базарында сине сатып җибәрә алам, үтерә алам, үземдә кол сыйфатында тота алам. Зинданга сала алам.* Р.Батулла. --- *үлү мотивы әсәрдә геройның коега ташлануы, зинданга ябылуы кебек эпизодлар аша бирелсә, терелү мотивы аның яңадан күтәрелүе --- рәвешендә гәүдәләнә.* Мирас

2) *күч.* Кысынкы, тар урын, кысынкылык, тарлык. *Кошка алтын читлек – зиндан.* Мәкаль. *Дөнья зинданында кылган Иң соңгы догам шушы.* И.Юзеев

**ЗИНДАНЧЫ** *и.* Зинданда, төрмәдә хезмәт итүче. *Кызының бу әллә нинди бер ят ир белән тотылуыннан хурланган, ачуыннан ярсыган хан җәлладка тоткыннарны китерергә куша. Зинданчы аларны тиз генә хан катына алып килә.* Казан утлары

**ЗИНДИКЪ** *с. гар. дини* Иманы дөрес булмаган, бозык; диненә хыянәт иткән, еретик. *Юк исә мөнкир вә зиндикъ дәһриләр: «Аллагыз гафләттә калган бит!» – дияр!..* Ш.Бабич. --- *йөз карасы ягучы зиндикъ башлыклары бу урында бөтен вөҗүдләрене истиля иткән шатлык вә бәшашәтләрене изһар идәрәк хәрәкәт иттеләр.* Г.Камал

**ЗИН-ЗИН** *иярт.* Тартылган кылларны чиртүдән, нәфис савыт-саба бербәрсенә орынудан барлыкка килгән тавышны белдерә. *Карурманда әйтерсең лә кемдер скрипканың нечкә кылларын тарта: «Зин-зин...»* М.Рәфыйков

**ЗИННӘТ** *и. гар.* 1) Затлы, кыйммәтле әйбер; алтын-көмеш, ука һ.б.ш. кебек кыйбатлы, затлы яки шулардан эшләнгән әйбер. *Сәрандибтан килгән кодагыйларга һәм кодачаларга төрле зиннәтләр: беләзекләр, йөзекләр, алкалар, бау-бау чәчәкләр, сөрмәләр һәм ислемайлар, каптырмалар, тараклар, сәгатьләр тәкъдим итеп торалар.* К.Насыйри. *Торып, көзгегә карап, зиннәт тагынды.* Дәрдемәнд

2) *күч.* Байлык, муллык. *Гыйлем – галимнәрнең зиннәте, адәмнәрнең хөрмәте булып, караклардан куркусыз дәүләт вә һич бетми торган байлыктыр.* Р.Фәхреддин. --- *кешегә бирелә торган ак бәхетнең иң-иң зурысы алар кулында инде – дөньяның бөтен байлыклары, зиннәтләре, рәхәтләре бер якта торсын!* Г.Әпсәләмов

3) Матурлык, нәфислек, ямь, бизәк. *Кыз бала – өй зиннәте.* Мәкаль. *Кар беткән урыннарга зиннәт бирер, Вак-вак кына төрле-төрле үлән үсеп.* М.Гафури

**ЗИННӘТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Зиннәтле әйберләр белән бизәү, зиннәтле итү. *Һәммә җирне электр һәм патша рәсемнәре белән зиннәтләгәннәр.* А.Расих. *Менә шуның өчен дә татар күчермәләре арасында алтынлап язылып, миниатюрлар белән бизәлеп, хәтфә тышлары көмеш белән зиннәтләнгән купшы фолиантлар бөтенләй юк дип әйтерлек.* М.Госманов

2) *күч.* Ямь бирү, бизәү, матурлау, купшыландыру. *Кипте җир, чыкты үлән дә, җир түшәлде хәтфәдәй, Бар агачка бирде яфрак, җирне зиннәтләп Ходай.* М.Фәйзи

**Зиннәтләп бетерү** Тәмам, бик нык зиннәтләү; зиннәтләү эшен төгәлләү

**Зиннәтләп җибәрү** Зиннәтләргә өлгерү, зиннәт булып өстәлү. *1980–2000 елларны үз эченә алган дәвердә безнең китап киштәләребезне Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, Ә.-З.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, Һ.Атласи, Г.Баттал, Х.Әмирхан, Г.Әхмәров һ.б. олпат галимнәрнең хезмәтләре зиннәтләп җибәрде.* Р.Мостафин

**Зиннәтләп килү** Дәвамлы рәвештә, электән, күптәннән зиннәтләү

**Зиннәтләп кую** Алдан зиннәтләү, зиннәтле итеп калдыру

**Зиннәтләп тору** Һәрвакыт, гел зиннәтләү, өсте-өстенә зиннәтләү

**Зиннәтләп чыгу** Нәрсәнедер башыннан ахырынача тулаем яки барысын да бер-бер артлы зиннәтләү

**Зиннәтли төшү** Тагы да зиннәтләү

**ЗИННӘТЛЕ** *с.* 1) Затлы, кыйммәтле. *Шкаф эчендә – зиннәтле савыт-саба.* Г.Әпсәләмов. *Зиннәтле язу өстәле каршысына куелган озын агач эскәмиягә Сөләйман, рөхсәтсез, үзе утырды.*

К.Тинчурин. – *Син кая алып кайттың мине, Наилә? – диде Фәләх, фатирдагы җиһазларның һәм зиннәтле әйберләрнең күплегенә шаккатып.* В.Нуруллин

2) Затлы, яхшы нәрсәләр, зиннәт әйберләр белән бизәлгән. *Яхшы зиннәтле дача кадерен беләме --- ул, дип әйтсәм, бәлки гөнаһлы да булырмын: әмма ләкин шуннан артык түгелләр.* Ш.Камал. *Башындагы чит-чите зиннәтле кеш мехы белән камалып алынган күн бүреге дә сакал-мыегының дәвамы кебек күренә.* М.Әмирханов. *Зиннәтле, биек тәрәзәле бай йортында дөньяга килмәде Акмал.* Г.Ахунов

3) Бай, җитеш. – *Син дөньяга тар һәм сукырларча карыйсың. Зиннәтле тормыш болай гына килми. Аның өчен түлисе була, – диде, катгый бер карарга килеп, Вильсур.* Т.Галиуллин

4) Нәфис; бизәкле, матур орнаментлы. --- *тора-бара, Фәтхулла хәзрәт башына йомшак һәм җиңел берет киеп йөрергә күнекте, фәкать мәчеткә барганда гына, зиннәтле кәләпүш кия башлады.* А.Тимергалин

**ЗИННӘТЛЕЛЕК** *и.* Зиннәтле булу; зиннәтләнгән булу. *Кая карама, күзләр гүзәллек, зәвык, зиннәтлелек, муллык вә купшылык белән очраша.* М.Әмирханов. *Чишмә тирәсендәге матурлык, зиннәтлелек кеше кулы белән эшләнгән.* Т.Миңнуллин

**ЗИНҺАР** *кер. сүз* 1) Үтенүне, ялваруны белдерә. *Уйнасын күңлен ачып, гаеп итмә, зинһар, и күңел.* Дәрдемәнд. *Бик озын бер хат язгыз әле, зинһар.* Г.Тукай. *«Нихәл, Гыйльметдин туган, миңа көтәчәккә биш сум биреп тор әле, зинһар...»* М.Әмир

2) Кереш сүз тезмәсе составында кулланыла: *зинһар дип әйтәм, зинһар дип сорыйм (үтенәм), зинһар өчен* һ.б. *Хәсән, зинһар дип әйтәм, мине газиз баламнан бөтенләйгә аера күрмә.* М.Гафури. *Зинһар өчен, әллә ниткән сәбәпләр табып барма.* Н.Гыйматдинова

**ЗИНҺАРЛА́У** *ф. сир.* **1.** Нәрсәне дә булса эшләргә ялыну, ялварып сорау, бик нык үтенү. *Бу кадәр зинһарлауга таш та түзмәс иде*

**2. зинһарлап** *рәв. мәгъ.* Ялынып-ялварып, бик үтенеп. *Якубҗан, җитәр, кит бу эшеңнән. Зинһарлап сорыйм, кит.* М.Хәбибуллин. *Гөлшәһидә шофёр белән янәшә утыручы кешедән зинһарлап үтенергә дип килсә, доцент Яңгураз ни әйтергә белмичә аптырап калды.* Г.Әпсәләмов

**ЗИҢ-ЗИҢ** *иярт.* Юка тимергә тимер бәрелгәндә, кыл тартылганда чыккан яңгыравыклы авазны белдерә. *Колын, колын, колынкай, Аяклары озынкай, Өсте җирән мамыклы, Зиң-зиң алтын тавышлы.* Табышмак. *Сәгать җырлый: «Диң, диң!..» – Мин бит туктый белмим. Моннан ары: «Зиң-зиң!» – Миңа карап йөр син!..* М.Җәлил

**ЗИҢКЕТҮ** *ф. диал.* Алҗыту, интектерү. *Теш сызлап зиңкетә*

**Зиңкетә башлау** Зиңкетергә тотыну

**Зиңкетеп тору** Гел, еш зиңкетү

**ЗИҢКҮ** *ф. диал.* Арып бетү, алҗу; көчсезләнү. *Гөлдәр икеме-өчме сәгать ятып алды да, отыры зиңкеп, дәресенә китте.* Х.Сарьян

**ЗИРАГ** *и. гар.* 1) Кул, терсәк

2) Терсәк буена тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге (якынча 58 см). *Бу кешенең буе җиде зираг --- кадәрле иде.* Риваять

**ЗИРАГАТЬ** *и. гар. иск.* Игенчелек, авыл хуҗалыгы. *Менә зур шәһәрләрдә сәнәгать вә һөнәр мәктәпләре, зирагать, тиҗарәт вә багчаванлык мәктәпләре, гимназияләр бар.* Ф.Кәрими

**ЗИРАГЫЙ** *с. гар. иск.* Игенчелеккә караган, авыл хуҗалыгына караган, аграр

**ЗИРАТ** *и. гар.* Вафат булган кешеләрне җирләү урыны, каберлек. *Мәчеткә барыр идең, картлардан дога алыр идең, зиратка менәр идең, кайтасың да китәсең, ике елдан бирле әрвахларга Коръән укыганың да юк.* Г.Ибраһимов. *Кешеләргә генә түгел, йортларга һәм капкаларга, хәтта зиратта үсеп утыра торган агачларга да бәйрәм төсе иңгән!* Ә.Фәйзи. *Тимери үзенең капкасыннан чыкканда, Шәмсетдиннең тавышы зират очында ук яңгырый иде.* Г.Бәширов

**ЗИРА́Т КЫЛУ** *ф. к.* **зиярәт кылу**. *Кече чагында ук, хаҗга барып, Мөхәммәд галәйһиссәламе вәссәламнең каберен зират кылдык.* Г.Толымбай

**ЗИРАТЛЫК** *и.* Зират, каберлек. *Зиратлыкка карап юнәлделәр.* М.Гафури. *Картлар догага чыгалар да, догадан соң су коендырышалар, корбан чалалар иде су буенда йә зиратлыкта.* Г.Гыйльманов

**ЗИРАТЧЫ** *и.* Зиратта җирләү эшләрен алып баручы, зират эшләре (коймаларның төзеклеге, зиратның чисталыгы, җирләү өчен кирәк-яракларны саклау һәм барлау һ.б.) буенча җаваплы кеше

**ЗИРӘ** *терк. гар.* Чөнки, алай дисәң, алайса. *Кулыңда форсат бар вакытта уйна да көл, зирә озакламый шундый бер хезмәтләр, мәшәкатьләр уртасында калырсың ки...* Г.Тукай

**ЗИРӘК** *с.* 1) Зиһенле, белем алуга сәләтле, тиз төшенүчән. *Шунлыктан ул үзе шикелле зирәк булуына ачык ышанган кызын, бала чагыннан ук, теге каладагы мирза балаларынча тәрбия итәргә хыяллый...* Г.Ибраһимов. *Ул укытучы бу кешегә язган хатында, Хәйретдин бик ярлы семьядан чыкса да, аның укырга бик зирәк, басынкы һәм акыллы булуын мактап, ничек булса да аны урнаштыруда ярдәм күрсәтүен үтенә.* М.Гафури. *Чыннан да, менә шул кызлар кебек зирәк, кыю булсаң икән дә гыйлем укырга омтылсаң икән.* Т.Гыйззәт

2) Төпле акыллы, һәр нәрсәне акыл белән, уйлап эш итә торган. *Бөек көрәштә корбан булучыларның каннары буялган байракны җилфердәтеп, алгы җиңүләргә өндәде, ди, яңа хуҗаларның зирәк юлбашчысы.* А.Алиш. *Алар каршында укытучы абыйлары табигатьнең бөтен серләрен һәм бөтен тереклекнең телен белә торган ниндидер кодрәтле, зирәк кеше булып гәүдәләнә.* Г.Бәширов

3) Үткен, өлгер, елдам, кыю. *Нураеваны өлкән оператор итеп күтәрдек. Бик зирәк кыз булып чыкты ул.* А.Әхмәт

4) Сизгер, уяу, һәрнәрсәгә игътибарлы. *Ярый әле, килене – бик зирәк нәрсә. Хәдичә түти иснәнә башлауга, ялт итеп торды да нәрсәнедер минут эчендә сүндереп тә куйды.* Г.Бәширов

**2.** *рәв. мәгъ.* Төпле, нигезле, дәлилле итеп. *К.Бикколов «Сука, җир, мужик» шигырендә крестьянның гомерлек эш коралы сука турында чичәннәрчә зирәк сөйли.* Татар әдәбияты тарихы

**ЗИРӘКЛӘНҮ** *ф.* Тиз аңлаучан, төшенүчән булып китү, зирәккә әйләнү

**Зирәкләнә бару** Торган саен ныграк зирәкләнү. *Белеме арткан саен, бала зирәкләнә бара*

**Зирәкләнә төшү** Бераз зирәкләнү

**ЗИРӘКЛЕК** *и.* Зирәк булу. *Аның бу кыска җавабында, бигрәк тә акыллы күз карашында теләк тә, кыюлык һәм нииндидер зирәклек тә бар иде.* Г.Әпсәләмов. *Мин иртән тауларга, кичен суларга карыйм. Шул чакта күңелгә яшьлек дәрте, зирәклек иңә.* Ф.Садриев. *Күп мәсьәләдә артык зирәклек күрсәтә алмаса да, Җәмилә бу ымлауга шунда ук төшенде.* А.Расих

**ЗИРӘҺ** *и. фар. иск.* 1) Сугышта уктан, кылычтан саклану өчен киелә торган кием; көбә

2) Броня

**ЗИРӘҺЛЕ** *с. иск.* Бронялы

**ЗИРЕК** *и.* Каенчалар семьялыгыннан, үзагачы бераз кызгылт төсле, тиз сынучан, иртә яз чәчәк ата, дымлы урыннарда үсә торган агач. *Бераздан, зирекләр генә түгел, өянкеләр белән каен куаклары да очрый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Аның бөреләре махсус сапларда утыра, әнә шул билгесе, шулай ук алкалары һәм кечкенә төерчекләре буенча зирекне башка агачлардан җиңел аерырга мөмкин.* Ботаника

◊ **Зирек тәртә(ле)** Тиз үпкәләүчән кешегә карата әйтелә; үпкәчел кеше

**ЗИРЕКЛЕК** *и.* Зирек агачлары күп үскән урын. *Алабуганың күл зиреклеген танып тыным ачылды.* М.Кәрим. *Зиреклек төбеннән чыккан аерым чишмәгә Минһаҗ абзый төпсез кисмәк утырткан иде.* Г.Бәширов

**ЗИР-ЗӘБӘР** *и. гар. к.* **зир-зөбәр**

**ЗИ́Р-ЗӘБӘР ИТҮ** *ф. к.* **зир-зөбәр китерү**. *Әмма шул ук елның көзендә Вәли әле яңарак кына бөреләнеп килгән гаилә тормышын зир-зәбәр итте дә ташлады.* М.Хәсәнов

**ЗИ́Р-ЗӘБӘР КИЛҮ** *ф. к.* **зир-зөбәр килү**. *Ал чүкечне, бәр тимерне! Дөнья килсен зир-зәбәр!* Н.Исәнбәт. *Бәр барабанны, ныграк бәр, бәр! Иске дөньялар килсен зир-зәбәр!* Г.Бәширов. --- *бомба төшми калган цехларда да машиналар зир-зәбәр килде.* Г.Әпсәләмов

**ЗИР-ЗӨБӘР** *и. гар.* Асты өскә килгән торыш. *Мин үзем тыныч холыклы һәм басынкы кеше бугай, ә менә шундый зилзилә, зир-зөбәр һәм башкаларны нигәдер бик яратам, ул минем җаныма азык була.* Г.Бәширов

**ЗИ́Р-ЗӨБӘР КИЛҮ** *ф.* Җимерелү, актарылу, туздырылу, асты-өскә килү, буталу. *Бар залимнәр зир-зөбәр килгән, имеш.* М.Гафури

**ЗИ́Р-ЗӨБӘР КИТЕРҮ** *ф.* Җимерү, актару, туздыру, астын-өскә китерү, бутау. *Алар күктән бомбалар ыргытып, окопларны зир-зөбәр китерәләр.* Г.Бәширов. *Хәзер уйлавымча, әтием, гаилә тормышының барышын зир-зөбәр китереп мулла булырга ризалык биргәч, тәгаен, әнием аның каршында ультиматум шартлар куйган.* А.Расих. *Дөньясын зир-зөбәр китерер идек.* Г.Иделле

**ЗИФА** *с. фар.* 1) Сылу, ыспай гәүдәле; матур буйлы, нәфис төзелешле. *Сөрмәле күз, зифа буең Әйләндерде башларым.* Җыр. *Зифа иде Кәримәнең сыны, җиденче класста укыганда, аны һәм классташы Зөбәрҗәтне гимнастика секциясенә язганнар иде.* М.Хәбибуллин

2) Төз, туры, кәкрәймәгән. *Зифа каеннар тирәсендә тузан-туфрак, җил чыкканны сизми дә калгандай, җирдә ята бирә.* Сөембикә

**ЗИФАЛАНУ** *ф.* Сылулану, ыспай гәүдәлегә әйләнү, матурлану. *Йөкле чагында ямьсезләнгән Гөлшаһидә хәзер яңадан гаҗәеп матурланган, буй-сыны зифаланган, йөзенә алсу сафлык йөгергән.* Г.Әпсәләмов. *Хатын-кыз сөйгән саен йомшара, яраткан саен зифалана ул.* М.Хәбибуллин

**Зифалана бару** Аз-азлап, акрынлап зифалыгы арту

**Зифаланып җитү** Тәмам зифалану

**Зифаланып китү** Кинәт бераз зифалану. *Монда килгәч, ябыгып, зифаланып киттең.* Г.Каюмов

**ЗИФАЛЫК** *и.* Зифа булу. *Озын коңгырт толымнары ике якка салынып төшкән, сылу нечкә буйлы, зур моңсу күзле, ябык булуына карамастан, матурлыгын, зифалыгын югалтмаган.* А.Шамов. *Бу хатынга Ходай Тәгалә барысын да мул итеп биргән иде: гүзәллекне дә, сылулыкны да, зифалыкны да.* М.Хәбибуллин. *Мин, аның уйнап торган зифалыгына, күзләрне камаштырырлык чисталыгына, кайнар яшьлегенә, тиңсез матурлыгына сокланып, онытылып калдым.* М.Әмир

**ЗИҺЕН** *и. гар.* 1) Кешенең уйлау сәләте, акыл, аң. *Яшь хатынның күзләре ачылып, зиһене яктырып китте…* Н.Гыйматдинова. *Әмма... ялгызлык барыннан да усалрак иде, зиһенне гел миңгерәтә торды.* Ә.Баян

2) Уй, фикер. *Серле тирәнлеккә төшеп китә торган челтәрле тимер баскычлар, антик скульптуралар – болар бар да синең кан тибешеңне, зиһен агышыңны үзгә бер халәткә көйли.* М.Галиев

3) *к.* **хәтер**. *Докторлар үз эшләрен эшли торганда, хәзрәт, зиһененең бөтен көчен җыеп, күз алдындагы мәетне танырга тырышты.* Ф.Әмирхан. *Ләкин бер-берсен таптап зиһененә тулган әрнүле, ачы, зәһәрле вакыйгалар аның иркен алдылар.* Г.Ибраһимов

◊ **Зиһен таралу** *к.* **зиһен чуалу**. *Хәмдиягә сүз кушмагыз, Зиһене таралган чагы.* М.Фәйзи. **Зиһен чуалу** Уйлау сәләтен югалту, фикерен туплый алмау. *Аның зиһене чуалмаса да, буын һәм әгъзаларында ул шактый какшау һәм калтыранганлык сизә иде.* Ш.Камал. *– Зиһенем чуалган, башым каткан, әйдә, укыганны Алла кабул итсен инде… – дип, битен сыйпап, урыныннан торды.* Г.Бәширов

**ЗИҺЕНЛӘ́Ү** *ф.* Уйлау, башны, акылны эшләтү, фикер йөртү. *Серафим карт башын чайкап куйды һәм, мин зиһенләп өлгергәнче: – Гомеремдә аюга мылтык асып йөргәнем юк иде, бүген килеп кенә үз дәрәҗәмне төшермәм инде, – дип өстәде.* М.Шабай. *– Юк шул менә! – дип, Фарукка беренче тапкыр каршы төште Фәрхәнә, тик зиһенләүдә өлгер кызның инде шаяртуга кучүе анык сизелде.* М.Хуҗин

**ЗИҺЕНЛЕ** *с.* 1) Зиһене (*1 мәгъ.*) яхшы булган; зирәк, акыллы. *Шулай итеп, башка хәллерәк кешеләрне күреп үсмәсә дә, бик зиһенле кыз булып чыкты.* Г.Минский. *Тик үткен зиһенле малай да үз сүзен бирми, тегеләрне аптыратып, гел бер үк сүзләрне кабатлый: «Йортка мин хуҗа түгел! Бабайлар мин*

*мәктәптә вакытта киләләр! Минем аларны күргәнем юк!» – дип, сүзен кырт кисә.* Х.Бәдигый. *Коръән укыган бабасыннанмы, җыр яраткан, мәзәк телле, үткен зиһенле атасыннанмы?..* Мирас

2) Яхшы хәтерле. *Балладаны сөйләтеп, зиһенле энем белән мактанасым килде.* М.Кәрим

**ЗИҺЕНЛЕЛЕК** *и.* Зиһенле булу, акыллы, аңлы, зирәк булу. *Уен шарты буенча һәр ике як, алдан әзерләнеп тормыйча, җыр чыгарырга --- тиеш. Шул рәвештә уен җыр чыгару осталыгына, тапкырлыкка, зиһенлелеккә корылган.* С.Сәүбәнова. *Белем, зиһенлелек кешегә иң кирәкле сыйфат булып кала.* Татар әдәбияты тарихы

**ЗИҺЕНСЕЗ** *с.* 1) Зиһене булмаган, зиһене начар, фикер йөртү сәләте йомшак. *Нәгыймә зиһенсез кыз түгел ул, алай дауламас, ул минем хәлне белер.* Г.Камал. *Сөембикәнең беренче ире Җан Гали хан Касыйм каласында 1516 елда туа. Эшлексез, буынсыз, мәсләксез, зиһенсез бер адәм була.* Р.Батулла

2) Хәтерсез, хәтерләми торган, начар хәтерле. *– Синең зиһенсез икәнеңә без гаеплеме? – ди директор.* Р.Батулла

**ЗИҺЕНСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Аңсызлану, фикер йөртү сәләте начараю, аңгымиңгеләнү

2) Хәтерсезгә әйләнү, хәтер начарлану

**Зиһенсезләнә бару** Торган саен ныграк зиһенсезләнү

**Зиһенсезләнә башлау** Зиһенсезлек билгеләре күренү

**Зиһенсезләнә төшү** Бераз зиһенсезләнү. *Авыруы сәбәпле зиһенсезләнә төште*

**Зиһенсезләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй зиһенсезләнү

**ЗИҺЕНСЕЗЛЕК** *и.* Зиһенсез булу. *– Һы, – диде Гарифулла, илле ике ел зур юлларга чыкмаган карчыгының зиһенсезлегенә чын-чынлап аптыраган булып. Аннан куллары белән ишарәләде. – Монда – Уфа, тегендә – Кинәче!..* А.Хәлим

**ЗИЯДӘ** *рәв. гар.* Күп, артык, артыграк итеп. *Рәхмәт, Алла разый булсын, гомерегез озын булсын, дәүләтегез вә бәхетегез көндин-көнгә зиядә улсын.* Г.Тукай. *Ул егерме яшьтән зиядә улмас.* З.Бигишев

**ЗИЯРАТ** *и. гар. к.* **зират**. *Бүген бу, бер зур әүлия зияраты кебек, кешелегеН югалтмаган һәр татарның килә торган урыны булды.* Г.Исхакый

**ЗИЯРӘТ** *и. гар.* 1) *к.* **зират**. *Зиярәт иясе шулай ук кабер чардуганнарын, кабер ташларын ватып-җимереп йөргән кешеләрне сөйми.* Г.Гыйльманов

2) Күрергә, күрешергә, хәл белергә бару; визит. *Бер генә сәгатькә зиярәткә кергән иптәшем хәтеремә төште...* Ф.Әмирхан

3) *дини* Изге дип саналган урыннарга, әүлияләрнең каберләре, төрбәләре янына барып дога кылу. --- *Бәйтелмөкаддәсне зиярәткә бару, әллә кайдагы телсезләр мәктәбендә укыту, --- матур язу өйрәтү ысулы, байлыкның юлы, тагы белмим, ниләр-ниләр укыдым.* Г.Исхакый

**ЗИЯРӘ́Т ИТҮ** *ф.* 1) Үлгән кешенең кабере янына барып гыйбадәт кылу, мәрхүмнәр рухына багышлап дога уку. *Иртәгәсен безнең юлчылар Хәлилрахманга баралар, юлда байтак каберләр зиярәт итәләр.* А.Расих

2) *күч.* Кемнең дә булса янына керү, хәл белергә бару. *Мәкәрҗәгә барышлый, безне зиярәт итәрсең дип, апай берлә икебез дә Гурьев тарафына дүрт күз берлә карамакбыз.* Г.Тукай

3) Кая да булса барып карау, дөнья гизеп йөрү, тамаша кылу. *[Эйфель манарасы] – Парижга читтән баручыларның сөеп зиярәт итә торган җирләреннән берсе.* Г.Гали

**ЗИЯРӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **зиярәт итү**. *Килеп туктагач та, Хөсәен, агач дәрвишне зиярәт кылырга, өскә менеп китте.* М.Кәрим. *Тагы Хәрәм шәрифнең башка тарафдарларында зиярәт кылгач, Бабрәхмән капкасыннан чыгып киттек.* А.Расих. *Зиярәт кылганда уянган изге тойгылар җаныбызны тарихка, ата-баба васыятенә тоташтыра.* М.Юныс

**ЗИЯРӘТЧЕ** *и.* Зиярәт итүче кеше. *Әсма ул вакытта, зиярәтчеләр кабул итәлә торган вакытның иң башыннан кереп, иң ахыргы минуты узганчы утырган иде.* Ф.Әмирхан

**ЗИЯФӘТ** *и. гар.* Банкет. *Банкетны да белмәскә, оят бит. Безнеңчә – зияфәт, Европача – банкет дип, бер кешенең шәрәфенә багышлап ясалган мәҗлескә әйтәләр.* К.Тинчурин

**ЗНАЧОК** *и. рус* Кешенең берәр төрле күрсәткән хезмәтен, уңышын яки кайсы да булса оешмага каравын билгеләп, күкрәккә кадап йөртелә торган металл билге. *Тимергалиев аның күкрәгенә күз төшерде: депутатлык значогы, ипле генә булып, аның пиджак якасында ятып тора иде инде.* Г.Ахунов. *Ә нигә депутат значогын такмадыгыз?* Г.Ахунов. *Мыегын сыйпап куя бәби аның, Значогына сузыла аннары.* Х.Туфан

**ЗНАЧОКЛЫ** *с.* Значогы булган, значок тагылган. *Уполномоченный ниндидер хәл буланын сизенде булса кирәк: ак значоклы кара башлыгын арткарак шудырып, тәмәке кабызды.* М.Мәһдиев

**ЗОБ** *и. рус мед.* Эчке секреция системасындагы калкансыман бизнең эшчәнлеге бозылу нәтиҗәсендә килеп чыккан авыруның халык телендәге атамасы. *Аның муенында зоб бүлтәймәсе зурая бара иде. Шуңа йодалы таблеткалар белән юана.* Х.Камалов. *Бүксә тәре, имеш. Әнинең муенында зоб авыруы булганга, шулай мыскыл итә.* Ш.Маннапов

**ЗОБАНИ** *и. гар.* 1) *дини* Җәһәннәмдә, тәмугта гөнаһлыларны җәзалаучы; газап фәрештәсе. *Зобанилар үз куллары илә казаннар астына ут яктылар.* Г.Тукай. *Җиргә иблисне сөрү булды кызык: хур вә гыйлманнар йөриләр пыртузып... Килде шунда бар фәрештә күктәге, Килде һәм барлык зобани уттагы.* Ш.Бабич

2) *күч.* Кансыз, рәхимсез кеше, палач. *Безем шәһәремездә Гәзитчеләр заһир булды, Ул кяферләр, зобанилар Язган саен азалар.* Г.Тукай. *Бөркет кебек ике сугышчыны Зобанилар алып баралар.* Ә.Ерикәй. --- *зобаниларга ник бер чара тапмыйлар икән?* И.Юзеев

**ЗОБАНИЛА́РЧА** *рәв.* Явызларча, рәхимсез рәвештә. *Зобаниларча кылану*

**ЗОБАНИЛЫК** *и.* Зобани булу; явызлык. *«Янгура» драмасында Нугай Урдасы әмире Исмәгыйль морзаның,*

*Явыз Иван зобанилыкларына кушылып, үз халкын кыруына протест йөзеннән көрәшкә чыккан Янгура батырның тормышы тасвирлана.* Мәдәни җомга

**ЗОГЫФ** *и. гар.* Физик зәгыйфьлек, көчсезлек, хәлсезлек. ---*Петербургның дарелфөнүн табибын, зогфем сәбәпле, минем номерыма китерттек.* Г.Тукай

**ЗОДИАК** *и. гр. астр.* **1.** Эклиптика буенча урнашкан 12 йолдызлык җыелмасы; Кояшның еллык күренмә хәрәкәте шул йолдызлыклар аша үтә, һәм бу юл «зодиак» – хайваннар түгәрәге дип атала. *Шунысы кызык, Ай зодиагында 21 нче йорт гарәп астрологиясендә әл-Балда дип атала.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ. к.* **зодиакаль**. *Бу бәйрәм шул ук шумер-аккадлардан башлангыч ала торган һәм Пётр Беренче заманында Юлиан календаре кертелгәнгә кадәр кулланышта йөргән зодиак календарь буенча уздырылган.* М.Бакиров. --- *Пётр I заманында кертелгән Юлиан календарена кадәр, көньяктан килгән зодиак календарь кулланылган һәм август ахырына, башлыча, сентябрьгә туры килә торган сигезенче ай Сөмбелә дип йөртелгән.* С.Сәүбәнова

**ЗОДИАКАЛЬ** *с. астр.* Зодиакка мөнәсәбәтле, зодиакка бәйле. *Күк йөзе 12 зодиакаль билгегә бүленеп карала.* Р.Сафин

**ЗОЛОТНИК** *и. рус тех.* Кайбер машиналарда пар, газ яки сыеклык йөрешен автоматик хәрәкәтләндерә торган махсус механизм, пар бүлгеч. *Туплагычка салам һәм кибәк тулган чагында, гидросистеманың золотнигы «агызу» хәлендә тора.* Механизатор белешмәсе. *Әгәр чүмәлә тулысынча бушатылмаса яки салам туплагычны буш килеш ачсалар, ул чагында золотникны комбайнчы мәйданчыгыннан бәҗралы тарткыч --- ярдәмендә күчерергә мөмкин.* Хәзерге авыл хуҗалыгы машиналары һәм алардан файдалану

**ЗОЛЫМ** *и. гар.* Җәбер, изү, кысу. *Күрсәтә һәрбер җәһил милләткә золым вә җәберне.* Г.Тукай. *Бичара хатын, иренең золымына чыдый алмыйча, янә хәзрәткә бара.* Г.Камал. *Г.Исхакыйның югары эчке культуралылыгы хакында сөйли торган тагын бер асыл сыйфаты – ул аның «кечкенә генә золымга да чыдый алмый торган, кешене мыскыл итүнең һәркайсы өчен эчтән хурлана торган күңеле»...* Мирас

**ЗОЛЫ́М ИТҮ** *ф.* Җәберләү, изү. *Шуның чөн золым итә безгә залимнәр, Шуның чөн җәбер итә безгә хакимнәр.* Бәет. *Инде ул кызны берегезгә алып бирсәм, калган икегезгә золым иткән булыр идем.* Әкият

**ЗОЛЫ́М КЫЛУ** *ф. к.* **золым итү**. *Шулай золым кылалармы, бар, дип, көчем!* М.Гафури. *Толстой бу тасвирында кешенең хәяты илә һәркемнең үзенең хәяты бер идеке, гайрегә золым кыйлу үзеңә золым кыйлу илә бәрабәр бер эш идекене аңлатадыр.* Г.Камал. *Ничек вөҗданыңыз җитте шулкадәр золым кылырга?..* Г.Исхакый

**ЗОЛЫМЛЫ** *с.* Золымга нигезләнгән; җәбер, изү хөкем сөргән

**ЗОЛЫМЛЫК** *и. к.* **золым**. *Уйласаң, әнә шуларның һәрберсендә Батуның золымлыгы, ай-һай, бәләкәйдән булмады.* Ф.Мансуров

**ЗОЛЫМЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **золым итү**. --- *гаделлек кыйлсаң да, золымлык кыйлсаң да, үзеңә кайта, гамәлеңә күрә җәза күрәсең.* К.Насыйри. --- *үз ригаясе берлә уйнаган, үз кул астында золымлык кыйлган йорт уңмас булыр.* С.Алишев

**ЗОЛЫМЛЫЛЫК** *и.* Явызлык, усаллык

**ЗОЛЬМӘТ** *и. гар. иск.* Караңгылык. *Басты зольмәт Җир йөзенә шул заман.* Г.Тукай. *Үзеңне син изеп янган белән, Уйлама син, вакыт үтәр, дип, Кара төндә кара болыт булып Җирне баскан зольмәт китәр, дип.* Ш.Бабич. *Инсаният күкләрен каплаган зольмәт вә афәт болытлары таралып, инсаният сафлана вә нурлана башлады.* Мирас

**ЗОЛЬМӘТЛЕ** *с. иск.* Караңгы. *Аерыламын синнән изге нурым, Киң зольмәтле төндә, йолдызым.* Мирас

**ЗО́МБИ** *и. индонез.* 1) *миф.* Африка халыклары ышануларында: җанын чакырып алган кеше ихтыярына буйсынып, шул кеше теләгән гамәлләрне кыла торган әрвах

2) *куч.* Уйлау сәләте югалган, үзенең эш-хәрәкәтләренә җавап бирә алмый, башкалар ихтыярына тиз буйсына торган кеше. *Телевидение аша халыкның психикасын бозып, зомбига әйләндерергә керештеләр.* Р.Фәтхерахманов. *Мин бит зомби, робот белән сөйләшергә кермәдем.* Идел

**ЗО́МБИЛАШТЫРУ** *ф.* Зомбига әйләндерү, зомби ясау. *Зомбилаштыруга каршы көрәш хәрәкәтендә катнашкан татар галиме Илһам Саттарны хөкем иттеләр.* Р.Фәтхерахманов

**ЗО́МБИЛЫК** *и.* Зомби булу, зомби халәте кичерү. *Әдәбиятта да киң фронт булып һәм бер үк стильдә фаталь мохит идеясен тәкрарлап торсалар һәм ул катгый формула рәвешендә мигә сеңдерелеп торса, ай-һай, мондый аң зомбилыктан котылырмы?* Казан утлары

**ЗО́НА** *и. гр.* 1) Җир шарының аерым табигый шартлары белән характерлана торган территория, полоса. *Мәсәлән, тундра зонасыннан көньякка --- таба туфрак төрләре «картая» яки бик борынгы туфрак рәтенә керә бара.* А.Фаткуллин. *Чүлләр зонасы суга бик ярлы. Кайбер урыннарда явымтөшемнең күләме ел әйләнәсендә 100–200 мм дан артмый.* Ботаника. *Тарихи чыганакларда Урта Идел, Урал буе географик зонасында Казан ханлыгы чорында христиан динендә булган татарлар турында мәгълүмат юк.* Мирас

2) Нинди дә булса билгеле бер сыйфат, аерма, үзенчәлек белән характерлана торган төбәк, район, урын, җир. *Дүрт йөз метр киңлектәге ачык коридор – нейтраль зона буйлап күпме шуышканбыздыр, әйтүе кыен.* Ә.Маликов

3) *куч.* Төрмә, тоткынлык. *Зонадан чыккан кеше башкача фикерли алмый.* Т.Галиуллин. *Зонадан кайткач, участковый интектерде мине. Атнага өч тапкыр өйгә килә.* Н.Акмалов

**ЗО́НАЛАП** *рәв.* Зона-зона итеп, зоналарга бүлеп яки урнаштырып. *Зоналап тикшерү. Зоналап урнаштыру. Зоналап бүлү*

**ЗО́НАЛЫК** *и. сир.* Зоналарга бүленеш. *Туфракның зоналыгын билгеләү. Урман-дала зоналыгы*

**ЗОНАЛЬ** *с.* Нинди дә булса берәр зонага (*1 мәгъ.*) караган, аерым бер зона өчен характерлы. *Шулай итеп, [Фәһим] 1973 елдан Сәнгать фондының*

*Татарстан иҗади производство комбинатында эшли башлый һәм, 1974 елдан башлап, Бөтенсоюз, республика, «Зур Идел» зональ күргәзмәләрендә катнаша*. Н.Гамбәр

**ЗОНД** *и. гр.* 1) *мед.* Авыруга диагноз кую яки дәвалау максаты белән (мәс., дару җибәрү өчен) берәр әгъзага кертелә торган көпшә сыман яки башка төрле медицина коралы. – *Әйе. Менә йөрәкнең зонд ярдәме белән алынган снимогы. – Профессор негатоскопны кабызды.* Г.Әпсәләмов. – *Үпкәсен көнбагыш маенда эретелгән прополис белән юдырып карарга. Начар имгән көннәрдә зонд аша тукландырырга, кан алыштыруны дәвам итәргә, – ди ул [профессор] синең турыда*. Э.Шәрифуллина

2) *геол.* Җир асты катлауларын тикшерә торган борау яки көпшә формасындагы корал

3) *махс.* Метеорологик күзәтүләр алып бару өчен автомат язу приборы урнаштырылган, зур булмаган һава шары

**ЗОНТ** *и. фр. к.* **зонтик**. *Сара эшләпәсен генә ала да киемен һәм зонтын Газиз кулында калдыра.* Ф.Әмирхан

**ЗО́НТИК** *и. фр.* 1) Тимерчыбыктан ясалган гөмбәз формасындагы каркаска материя тарттырып эшләнгән, кояш кызуыннан яки яңгырдан саклагыч җайланма; кулчатыр. *Мәликә апа --- аптырап торган арада, ак бүрекле татар, кояшлы көн булса да, зонтигын баш өстенә корып җибәреп, мишәргә янап үтеп китә.* К.Нәҗми. *Монда нәрсә генә юк: биегән төсле арт аякларын күтәреп торган атлар, башына эшләпә кигән, таяк тоткан күзлекле малайлар, нәзек кенә бау өстендә зонтик тотып атлап барган нечкә генә аяклы кызлар...* Ә.Фәйзи. *Зонтикны һич кенә дә тиз җәеп баш өстенә күтәрә алмый.* М.Мәһдиев

2) *бот.* Чәчәкләре бер яссылыкта урнашып, зонт чыбыкларыдай, бер ноктадан як-якка таралып торган оешма чәчәк төре. --- *чия белән суганның чәчәк төркеме гади зонтик формасында, чөнки чәчәкләрнең чәчәк саплары һәммәсе дә диярлек тигез озынлыкта һәм, зонт чыбыкларыдай, бер ноктадан якякка таралып торалар.* Ботаника

**ЗО́НТИКЛАНУ** *ф.* Зонтик рәвешен алу, гөмбәзләнү. --- *тармаклары берлән дөньяга җәелгән миләше дә, үзенең яфрагы ваклыгыннан, чын зифа түгеллегеннән, ботаклары түгәрәкләнеп килеп, зонтикланып, ак тәнен кояштан саклый алмавыннан оялып-хурланып, кечерәеп кенә агач арасына яшеренгән каенда да күз кабагы тарткан кадәре дә селкенү --- күрә алмады.* Г.Исхакый

**ЗО́НТСЫМАН** *с.* Зонтка охшаш, зонт формалы. *Циркның зонтсыман түбәсе. Зонтсыман корылма*

**ЗООВЕТЕРИНАР** *и. рус* Зооветеринария белгече

**ЗООВЕТЕРИНА́РИЯ** *и. гр.* Хайваннарның яшәү шартларын һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган фән. *Таня үзе шәһәрдә туып үскән, быел зооветеринария институтының соңгы курсын бетерә.* Р.Төхфәтуллин. *Зооветеринария укулары нәтиҗәле булсын дип үткәрелә, турыдан-туры бүгенге бурычларга бәйләп алып барыла.* Б.Камалов

**ЗООГЕО́ГРАФ** *и. рус* Хайваннар дөньясының таралышын өйрәнүче география белгече. *Зоогеографлар киңәшмәсе*

**ЗООГЕОГРА́ФИК** *с.* Зоогеографиягә караган. *Зоогеографик тикшеренүләр. Зоогеографик карта*

**ЗООГЕОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Җир шарында яки нинди дә булса төбәктә хайваннарның таралу рәвешен өйрәнә торган фән; хайваннар географиясе. *Зоогеография өлкәсендәге тикшеренүләр. Зоогеография проблемасы*

**ЗООГИГИЕ́НА** *и. гр.* Тирә-юньнең хайваннар организмына тәэсир итүен һәм аларның сәламәтлеген саклау чараларын өйрәнә торган фән. *Зоогигиена кагыйдәләрен төгәл үтәү. Зоогигиена проблемалары*

**ЗООИНЖЕНЕР** *и. гр.-фр. к.* **зоотехник** (I)

**ЗОО́ЛОГ** *и. рус* Зоология белгече. *Поляк профессоры зоолог Фильдингның соңгы хезмәте турында сөйләгәндә, машина авылга килеп керде.* М.Мәһдиев. --- *саламандраларның әйләнеп кайтуын нәрсә белән аңлата аласыз, дигән соравына, зоолог: «Монда нининдидер мистика!» – дип куя.* Могҗизалар кыры

**ЗООЛО́ГИК** *с.* Зоологиягә бәйле, зоологиягә мөнәсәбәтле. *Зоологик тикшеренүләр. Зоологик тәҗрибәләр үткәрү. Зоологик инстинкт*

**ЗООЛО́ГИЯ** *и. гр.* Хайваннар дөньясын, аларның төзелешен һәм тереклеген өйрәнә торган фән. *Училищеның хуҗалык мөдире Исмәгыйль агай безгә зоология дә укыта бит әле.* М.Мәһдиев. *Биредә ул үзенең өлкән замандашы Карл Линнейның ботаника һәм зоология өчен эшләгән эшләрен кабатлады.* Кызыклы психология

**ЗООПАРК** *и. рус* Җәнлекләрне һәм хайваннарны ясалма шартларда, күргәзмә өчен асрый торган урын; зоология паркы; хайваннар бакчасы. *Ул туган чакта, аның әтисе Зиятдин абзый Казанның Болак буендагы зоопаркында балта остасы, ремонтчы булып эшли, ә гаиләсе, шул зоопарктан бер-ике генә йорт аркылы, тәбәнәк бер йортның подвалында яши иде.* Г.Ахунов. *Киләчәктә аның урыны – рәшәткәле читлек эчендә, зоопаркта.* З.Фәтхетдинов

**ЗООПЛАНКТОН** *и. гр.* Су төбендәге тереклек ияләренең гомуми атамасы

**ЗООПСИХО́ЛОГ** *и. рус* Хайваннарның үз-үзен тотышларын өйрәнүче белгеч. *Мин, зоопсихолог Надежда Николаевна Ладыгина, Коте үз баласы кебек итеп үстергән шимпанзе Иони турында сөйләдем.* Кызыклы психология

**ЗООСПО́РА** *и. гр.* Кайбер суүсемнәрнең һәм гөмбәләрнең женессез үрчүе өчен хезмәт итә торган хәрәкәтчел күзәнәк. *Улотрикснның зооспоралары үзенең төзелеше һәм формасы буенча бер күзәнәкле хламидомонаданы хәтерләтә.* Ботаника

**ЗООСПОРА́НГИЙ** *и. гр.* Суүсемнәрнең һәм кайбер түбән төзелешле гөмбәләрнең женессез үрчү органы. *Суүсемнәр, үрчегәндә дә, чәчәкле үсемлекләр кебек орлыклардан түгел, ә махсус күзәнәкләрдән – зооспорангийлардан барлыкка килә торган зооспоралардан үрчи.* Ботаника

**ЗООТЕ́ХНИК** I *и. гр.* Терлекчелек белгече. *Райзога кердек, зоотехник Алексеев дигән кеше безне сыер абзарына алып китте.* Ә.Айдар. *Нургали, районда гы зоотехниклар курсын таш-*

*лап, күрше-тирә авылларга кино куеп йөри башлаган иде.* М.Мәһдиев. *Үзенә хатынлыкка тәгаенләнгән укытучы Әсманы ул, зоотехник абыйсына кунакка кайткач, мәктәп йортында бер очраткан иде.* Т.Галиуллин

**ЗООТЕ́ХНИК** II *с.* Зоотехникага мөнәсәбәтле, шуңа бәйле. *Зоотехник күрсәтмәләр*

**ЗООТЕ́ХНИКА** *и. гр.* Терлекләрне дөрес асрау, үрчетү һәм файдалану турындагы фән. *Мәнә мин [Солтан], сезнең белән зоотехника буенча беседалар уздырырга кирәк булыр, дип уйлап утыра идем әле.* А.Расих

**ЗООТЕХНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Терлекчелектә җитештерү методлары һәм процессларының гомуми җыелмасы. *Вәлиәхмәт әле студент елларында ук агрономия һәм зоотехнология белән мавыккан һәм ул вакытта үзенең белеме белән әти-әнисенә нәселле сыерлар булдыруда --- һәм башка хуҗалык эшләрендә ярдәм иткән була.* Мирас

**ЗООФЕ́РМА** *и. гр.-лат* 1) Авыл хуҗалыгында терлекләрне, кош-кортларны, җәнлекләрне аерым туплап үстерү, үрчетү урыны. *Зоофермаларда кеш үрчетү*

2) Хосусый яки арендага алынган җирдә аерым авыл хуҗалыгы предприятиесе. *Зоофермада тәвә кошы үрчетү*

**ЗООЦИРК** *и. гр.-лат.* Өйрәтелгән хайваннарның уены күрсәтелә торган цирк

**ЗОРОАСТРИЗМ** *и.* Заратуштра исеме белән аталган, Урта Азия, Азәрбайҗан, Иран, Якын һәм Урта Көнчыгышта яшәгән борынгы халыкларның дине (бу дингә хас сыйфатлар: ике башлангыч – изгелек һәм явызлык көрәше; утка табыну; үлекләрне җирләүне тыю: аларны кыргый кошларга, ерткыч җәнлекләргә ташлаганнар). *Бу атамаларның иң борынгылары Урта Азиянең Туран төбәклегендә яшәгән һәм иранпарның, зороастризм диненең даими дошманнары булган сакларга карый.* М.Бакиров

**ЗОҺЕР** *и. гар.* Төш вакыты, көн уртасы; өйлә намазы

**ЗӨБӘ КАБЫРГАЛАРЫ** *и.* 7 пар чын кабыргадан соң урнашкан һәм түш сөягенә тоташмыйча, янәшәсендәге кабыргаларга кимерчәкләр ярдәмендә тоташкан 3 пар иң кыска һәм нечкә кабырга; ялган кабыргалар

◊ **Зөбә кабыргаларын санау** Бик нык кыйнау, тукмау, дөмбәсләү. *Хафиз мулла белән мәзин килеп араламасалар, становойны бөтереп алганнар иде. Чигә тамырларын кашыганнармы, зөбә кабыргаларын санаганнармы – аларын мин күрә алмадым.* К.Кәримов

**ЗӨБӘРҖӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Зәңгәрсу яшел төстәге үтә күренмәле, кыйммәтле асылташ; *русчасы*: **изумруд**. *Тау башында төрле-төрле кыйммәтле ташлар: зөбәрҗәтләр, якутлар, ахаклар һәм башка эре-эре матур ташлар бик күп икән.* А.Алиш

2) *күч.* Кадерле, кыйммәтле, бәһасез нәрсәләр, күренешләр. *Язучы гомумкешелек әхлагы зөбәрҗәтләрен сүзсурәтләр тукымасына чигеп барырга омтыла.* Т.Галиуллин

3) **зөбәрҗәтем** *тарт. форм.* Назлап, иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Кил яныма, кил, чибәрем, Кил алтын, зөбәрҗәтем.* Ә.Ерикәй

**2.** *с. мәгъ.* 1) Зөбәрҗәт ташыннан ясалган. --- *императорга кияүгә чыккан туташның кул бармакларында – зөбәрҗәт кашлы балдаклар, муенында – затлы ташлардан тезгән хәситә.* М.Хәбибуллин. *Ир хатынына зөбәрҗәт кашлы йөзек яисә алка бирсә, иренә нинди бүләк бирү хатын-кыз ихтыярына куела.* С.Сәүбәнова. *Кем баш имәс гүзәл гөлнең алларында, Асылташлар тоныклана ул барында, Зөбәрҗәт каш Сафа-Гәрәй билбавында.* Ф.Гатина

2) Зөбәрҗәт кебек, зөбәрҗәт төсендәге. *Соргылт ташлар, кызгылт көрән сукмак, алсу куаклар, зөбәрҗәт чирәмлек – менә кем тәрбияли япон зәвыгын.* М.Юныс. *Фатыйма үзе дә сизмәстән туктап калды, уйнаучыга борылып карады, шул чагында чиләге чайпалып куйды, зөбәрҗәт су тамчылары итәгенә тамды.* М.Хәбибуллин. *Суда йөзеп йөри торган бик күп яшел шарчыклар һәм пластинкалар аны [елганы] зөбәрҗәт төсенә кертә.* Ботаника

**ЗӨБӘРҖӘ́Т ТУЙ** *и.* Өйләнешеп утыз ел үткәч билгеләп үтелә торган туй

**ЗӨЛКАГДӘ** *и. гар.* Һиҗри тәкъвимнең унберенче ае, мөселман календаре буенча ай елының унберенче ае атамасы. *Ниһаять, бик озын газапланганнан соң, мең тугыз йөз унбишенче сәнә миладп, мең өч йөз утыз өч һиҗри, уналтынчы сентябрь, егерме зөлкагдә, чәршәмбе көн төнлә сәгать ун ярымда бала дөньяга килде.* А.Расих

**ЗӨЛФӨКАР** *и. гар.* Легендаларда: Гали хәлифәнең кылычына бирелгән исем; «арка умырткасын кисүче» бик үткен кылыч. *Үткенлеге хәзер дә зөлфөкар кылычыдай: теләсәң, сабынсыз кырынырлык.* Н.Әхмәдиев. --- *Гали батырны Дию белән сугышырга озатканда, аның тугрылыклы аты Дөлдөл генә түгел, сугыш коралы – зөлфөкары да елый.* Татар әдәбияты

**ЗӨЛХИҖҖӘ** *и. гар.* Һиҗри тәкъвимнең уникенче ае, мөселман календаре буенча ай елының уникенче ае атамасы. *Зөлкагдәнең 20 сендә Зәйнулла Мәдинәдән дөядә Мәккәгә китә һәм зөлхиҗҗәнең икенче көнендә анда була.* А.Расих

**ЗӨМРӘ** *и. гар. иск.* 1) Төркем, җәмгыять. *Имде ушбу халык зөмрәсеннән ишеткән сән бер хәбәр.* К.Насыйри

2) Сыйныф, класс. *Шәриф шул көннән башлап хәерчеләр зөмрәсенә керде.* М.Гафури

**ЗӨМРЕД** *и. гар. к.* **зөбәрҗәт**. *Зөмредне күрсә, еланның күзе сукыр булыр, димешләр.* К.Насыйри. *Агач яфраклары, агач ботаклары булып челтәрләнеп күренә торган күлнең төсе зөмред төсен алган иде.* Г.Исхакый

**ЗӨФАФ** *и. гар.* Кияү белән кәләшнең никахтан соң беренче төне. *Зөфаф кичәсендә шундый хәл булыр дип кем уйлар?* К.Нәҗми. *Никах укытып, зөфаф кичәсен үткәреп тә куялар.* Ф.Латыйфи. *Зөфаф киченнән үк утлы хәнҗәр булып кадалган бу сорауны ул күңеленең иң төбенә яшереп куйган һәм аны шушы көнгә кадәр бер мәртәбә дә кузгатмаска, чыгармаска көче җиткән иде.* Ф.Садриев

**ЗӨҺЕД** *и. гар.* Дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнү; заһидлык. *Дөнья малыннан ваз кичеп, зөһед булып яшәү дини*

*өйрәтмәләрдә элек тә киң җәелгән булган һәм бу тәсаувыфчылык әдәбиятында тагын да югары баскычка күтәрелә.* Г.Дәүләтшин

**ЗӨҺЕДЛЕК** *и.* Зөһед булу, заһидка әйләнү. *Ул [Туда-Мәнгү], суфига әйләнеп, әз белән канәгатьләнеп, зөһедлеккә күчә һәм тәмам тәхеттән баш тарта.* Г.Дәүләтшин

**ЗРА́ЗА** *и. пол. кулин.* Уртасына дөге, бәрәңге һ.б.ш. кыстырып әзерләнгән ит котлеты. *Бар икән күрәселәр... Тефтели. Лангет. Солянка. Пудинг. Зразы... Бусы инде бигрәк иләмсез сүз. Ферма мөдире Гыйльмуш абзар ишеген ватып чыгып качкан үгезне бервакыт шулай дип сүккән иде ...* М.Мәһдиев

**ЗУБИ́ЛО** *и. рус махс.* Металл кисү, таш чокып эшкәртү һ.б. максатлар өчен кулланыла торган, өтергегә охшаган инструмент. *Аның күкрәгендәге юлбашчы профилен, ямьсез генә итеп, тимер кискеч зубилолар белән умырып, кисеп алганнар.* Р.Мирхәйдәров

**ЗУБР** *и. рус* 1) Кыргый үгез. *Сирәк кенә аерым йөрүче зубрларны күрергә мөмкин булса да, алар гадәттә төркемнәргә берләшеп яшиләр.* Хайваннар дөньясы: имезүчеләр. *XX гасыр башларында Россиядә сакланып калган зубрларның саны 2000 нән артмаган.* Биология

2) *күч. кит.* Яңалыкка каршы торган, үзенең иске карашларына ябышып ята торган үтә консерватор кеше. *Әй, байлар, карагыз инде бу шәкертләрне, әй мөхтәрәм татар зубрлары, рәхим итеп, авызларын җимерегез инде бу әдәпсезләрнең.* Ф.Әмирхан

**ЗУ́БР КЫЯГЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, озын шуышма тамырчалы, себеркәч чәчәк төркемле, хуш исле күпьеллык үләнчел үсемлек. *--- тугай болыннары су астында калу сәбәпле, биек сабаклы кыяклы үләннәр – гади сарут, хуш исле зубр кыягы, болын канәфере – бик сирәк очрый башлады.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ЗУ́ММЕР** *и. нем.* Радиотелеграф хезмәтендә тавыш сигналларын тапшыру приборы. *Линиянең буш түгеллеген белдергән зуммер. Электромагнитлы зуммер*

**ЗУР** *с.* **1.** 1) Күләме, микъдары белән гадәтидән олы, дәү булган; *киресе:* **кечкенә.** *Өстенә җылы күн тужурка, башына зур йонлач малахай кигән Гафур ишекне хуҗаларча киң ачып кайтып керә.* Р.Ишморат. *Теләгән кешегә ике чиләк су сыешлы зур самавырда чәй дә кайнап тора иде.* Г.Ахунов. *--- ул зур гәүдәле, үтә көчле куллары бүрәнә юанлыгы, дию пәриләреннән дә курыкмый, өй хәтле ташны сыңар кул белән генә ала да һавага чөеп җибәрә...* Ә.Фәйзи

2) Сан ягыннан гадәтидән артык, күп. *--- әмма ни үтенсәләр дә, зур-зур бәһаләр вәгъдә итсәләр дә, Винитар король Бож кенәз кызларын аларга сатмады.* М.Хәбибуллин. *Кырык-илле адым әллә ни зур ара булмаса да, аны түш белән шуып узу миңа бик җиңел булмады.* М.Госманов. *Ул цехка зур хезмәт хакына кызыгып та беркем дә бармый, шуңа күрә, кешеләрне ымсындырыр өчен, анда эшләүчеләргә күпмедер кишәрлек җир һәм йорт салыр өчен зур гына кредит бирә торган булганнар.* Р.Мирхәйдәров

3) Әһәмияте, файдалылыгы ягыннан аерылып торган, мөһим. *Уйлап баксаң әгәр үткәннәрне, Күзең салсаң әгәр бүгенгә, Бөеклеге безнең зур эшләрнең Шулкадәрле ачык күренә!* Ә.Исхак

4) Көче, барышы яки тәэсире белән гадәттәгедән артык, куәтле. *Тау башыннан зур өермәләр куба... Аждаһалар өерелеп күккә менә... Күктә бик ямьсез болытлар агыла, әлләниләр шартлый, ташлар ярыла.* Ш.Бабич

5) Ишле, күп кешеле. *Бу саннар үзләре генә дә әлеге зур гаиләдә балаларга булган мәхәббәтнең буыннан буынга, каннан канга күчүе турында сөйләмимени?* Э.Шәрифуллина

6) Масштаблы. *Зур яу алдыннан, атасы тархан белән очрашыр алдыннан аңа бер иркенләп сөйләшергә кирәк иде.* Н.Фәттах. *--- сиңа хәзер, шундый зур тәҗрибәң белән, бораулаучы гына түгел, мастер булырга да күптән вакыт.* М.Хәсәнов

7) Нык нигезле, тирән эчтәлекле, әһәмиятле. *«Идел» картинасы үзенең камиллеге вә гүзәллеге белән бөтендөнья сынлы сәнгатендә зур урын биләгән мәшһүр әсәрләргә тиңләшерлек дәрәҗәдә килеп чыкты.* К.Миңлебаев. *Әбүзәр абзыйны зуррак мәсьәлә борчыды: озынга сузмыйча, шушы араларда кафедра җитәкчелеген икенче бер кеше кулына тапшырырга кирәк, дип уйлады.* Г.Әпсәләмов. *Шул язда бугай, аның шәһәр-авылларны яшелләндерү һәм урман полосалары утырту буенча галәмәт зур программасы тормышка ашырыла башлады – бөек һәм изге эшгамәл иде ул...* Р.Мирхәйдәров

8) Мөһим, җитди, хәлиткеч. *Зур хәбәр, сөенеч бирергә халкына, Китте алдан илче Каф-тау артына.* Ш.Бабич. *Шул кәгазьнең бик зур кәгазь икәнене белә, әллә нидә бер зур кунак-фәләнгә күрсәтергә тугры килсә, ул шәҗәрәнең бер җирендәге исемгә бармагы берлән төртеп: – Менә монысы – Сәлман Фарси разый аллаһе ганһе, менә монысы – мин, – дия иде.* Г.Исхакый. *--- ул 1950 елның мартыннан алып 1955 елның августына кадәр Сталин концлагерьларында сәяси мәхбүс буларак тормышның рәхимсез кырыслыгы белән күзгә-күз очраша, анда зур сәяси һәм рухи тәҗрибә туплап зур сынау аша үтә.* Ә.Сәхапов

9) Дәрәҗәсе, чины белән югары; югары дәрәҗәле; билгеле, танылган. *Университетыбызның мактанычы булырлык зур галим дәрәҗәсенә ирешү өчен аңарда барлык сыйфатлар бар.* Р.Ишморат. *Аның турында «башлы мужик», кайчандыр зур начальник та булган бугай, дип сөйлиләр иде.* Р.Мирхәйдәров. *--- кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да – зур кешеләр ...* Ә.Еники

10) Яшь ягыннан олы булган, өлкән. *– Кара нинди зур булган, – Якуб малайның матур, түгәрәк йөзенә, энисенеке төсле кара күзләренә карап торды, – мин киткәндә, әле бишектә генә иде.* И.Гази. *Зур уллары Төхфәтнең хатыны Мәрфуга килен бик явыз телле, үзсүзле иде.* Г.Ибраһимов. *Рәшит аннан соң да әле гаиләсен ташлап китеп йөргәләде, ераккарак, хәтта Ташкентка кадәр үк кыяклады – анда ул*

*зур апасында бер елдан артык торды.* Р.Мирхәйдәров

11) Балигъ булган, балалыктан чыккан, җитү. *Син хәзер зур кыз инде. Дүрт-биш елдан кияүгә бирергә вакыт үзеңне, эшкә өйрән!* Г.Әпсәләмов

12) *күч.* Зурлар белән бертигез булган, өлкәннәр дәрәҗәсендәге. *Соңгы звонок булсын беренчесе, Син каршыла безне, зур тормыш.* Ш.Галиев

13) *күч.* Көчле, тирән, истә калырлык. --- *мин еш кына синең сүзләреңне кабатлый идем: зур мәхәббәт зур бәхет кенә түгел, ул – зур газап та…* Р.Мирхәйдәров

14) *күч.* Батыр, курыкмас. *…Зәңгәр күзле, йомшак сары чәчле, өстенә ямаулы күлмәк, киндер чалбар кигән яланаяклы Петя – кечкенә гәүдәле, зур йөрәкле баһадир Петя – үзе ташлаган гранатадан үзе дә һәлак булды.* Г.Гобәй

**2. зурлар** *и. мәгъ. күпл.* 1) Өлкәннәр, өлкән кешеләр. --- *кичке сабаклар ясарга, зур вә кечкенәләр өчен һөнәр өйрәтергә юл ачачак, һәм дә кирәкле китаплар бастырырга тырышачак.* Г.Исхакый. *Малайлар шактый урамнарны үтеп ярга җиткәндә, анда боз карарга килгән балалар, үсмерләр, зурлар төркем-төркем булып торалар иде инде.* Ә.Фәйзи

2) Җәмгыятьнең дәрәҗәле, мөхтәрәм, йогынтылы кешесе. *Аның бабалары – чынлап та заманының зурлары.* Г.Ибраһимов

◊ **Зурга җибәрү** Ниндидер эшне, мәсьәләне катлауландыру, аңа җитди төс кертү. *Хәмит энем, зинһар дип әйтәм, эшне алай зурга җибәрмә.* Р.Ишморат. *Ярый әле төркемдә ике хәрби кеше бар иде, алар гауганы зурга җибәрмәделәр.* Ф.Яруллин. **Зурга китү** Эш, мәсьәлә һ.б. катлаулану, җитди төс алу. *Шау-шу зурга китә башлагач, Тауиле Гыйлаҗи малаена каршы озын ак киндер күлмәктән, чабата-оектан, биленә кызыл пута бәйләгән тәбәнәк кенә юан бер егетне чыгардылар.* М.Гафури. *Йомышчы малай, эшнең бик зурга китүен сизенеп, икеләнә башлады.* Г.Бәширов. *Ярый әле, эш алай ук зурга китмәгән икән!* Н.Фәттах. **Зурдан кубу** 1) Нинди дә булса эш, вакыйгага артык зур әһәмият бирү. *Ә нигә алайса, зурдан кубып, терлекчеләр каласы дип, авыз суыңны корыттырды.* Г.Ахунов; 2) Нәрсәнедер үз мөмкинлегенә, чамага карамыйча, артык чыгымнар тотып купшы үткәрү. **Зурлар мәктәбе** *тар.* Ликбез елларында өлкән яшьтәге кешеләр өчен ачылган кичке мәктәп

**ЗУРАЙТКЫЧ** *с.* **1.** 1) *махс.* Зурайта торган, зур итеп күрсәтә торган. *Ул, әлеге фотоны зурайткыч пыяла аша карап, аерым билгеләрен чамаларга тырышып утырганда, рөхсәт сорап, Ирек Габдуллов килеп керде.* М.Насыйбуллин. *Пир атадан да куркып торасы юк. Озакламый ул үзенең биек манарасына менәр, зурайткыч пыяла аша йолдызларны күзәтер.* Н.Фәттах. --- *яктылык микроскобының төп өлеше – карау көпшәсенә куелган зурайткыч пыялалар.* Ботаника

**2.** *и. мәгъ.* Фоторәсемне зурайтып төшерү приборы

**ЗУРАЙТУ** *ф.* 1) Зур итү, күләмен, микъдарын арттыру, үстерү. *Саимә шәһәргә барган җиреннән әтисенең һәм сугышта үлгән абыйсының карточкаларын зурайтырга бирде.* М.Мәһдиев

2) Эреләндерү, киңәйтү. *Җирнең тарту көче утыз тапкырга кимегәндәй булды: атлаганда, очып-очып, адымнарын зурайтты ---.* К.Кәримов. --- *һәр малай, күршесенең җиренә кадатып, шул кадалган урыннан сызып, үз «биләмәсен» зурайта.* Р.Ягъфәров

3) Көчен, куәтен, интенсивлыгын арттыру. *Педальгә ныграк баскач, пружина кысыла башлый, ул электродлар арасындагы басымны зурайта.* Электр контактлы эретеп ябыштыру

4) Әһәмиятен, дәрәҗәсен, колачын һ.б.ны арттыру, киңәйтү, көчәйтү, җәелдерү. *Баеп, малы күбәйгәч, Казанда, Мәскәүдә вә гайре шәһәрләрдә кибетләр --- ачып, йортлар, җир-сулар алып, эшне елдан-ел зурайтып, приказчик һәм конторщиклары күп иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Өченчесендә, солдат әйтүе буенча, күрше авылдан да берничә егет кушылды, алар эшне зурайтмакчылар, үз авылларында да мондый яшерен түгәрәкләр ясамакчылар.* Г.Ибраһимов

5) *сөйл.* Исемен, хезмәтен, әһәмиятен башкаларга билгеле итү; зурлау, олылау. *Зур дөнья белән аралашу безне зурайта иде, хәзер исә бәләкәйләнә барабыз шикелле.* Р.Миңнуллин

6) *күч. к.* **зурга җибәрү**. *«Чуан» дисәң, ул һаман «чыгам» дияр; «Бетчә» дисәң, «бетәм» дип әйтә, имеш. Начарлыкны зурайтып әйтмәскә, аздырмаска, дигәннән.* Н.Исәнбәт

**Зурайта бару** Акрынлап, аз-азлап зурайту, торган саен киңрәк җәелдерү. *Хәзер гел шулай, көньякка таба үстереп, зиратны зурайта баралар.* М.Мәһдиев. --- *музыканың тилереп үкерүе, төсләр чатнавы әлеге явызлык төенен зурайта барды.* А.Вергазов

**Зурайта башлау** Зурайтырга керешү. *Казан үсә бара. Яңадан-яңа эшче бистәләре туалар да, зур шәһәргә тоташып, аны зурайта башлыйлар.* А.Алиш

**Зурайта килү** Һәрвакыт, даими зурайту. *Туган якларым һәрвакыт мине зурайта килде.* Р.Харис

**Зурайта төшү** Тагы да бераз зурайту. *Стадионны зурайта төшеп, овал түбә дә коргач, бу ансамбль аеруча чибәрләнгән.* А.Тимергалин. *Буйтур тишекне тагы да зурайта төште.* М.Хәбибуллин

**Зурайтып алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә нәрсәнедер зурайту. *Аның бу рәсемен ул үзе зурайтып алган иде.* Н.Хәсәнов

**Зурайтып бетерү** Зурайту эшен тәмам итү; бик зур итү. *Хәер, аны бер көн эчендә зурайтып бетерергә кирәк дигән сүз юк ич!* Р.Хафизова

**Зурайтып җибәрү** Кинәт зурайту; артыгын зурайту. *Тик бу караңгы өлгене куертып, зурайтып җибәргән бер хәл булды.* А.Вергазов. *Мавыгып китеп, артык нык зурайтып җибәрмибезме аның әһәмиятен?* М.Вәли-Барҗылы

**Зурайтып килү** Даими рәвештә аз-азлап зурайту. *Сату-алу, сәүдә эшләре бик яхшы бара, масштабларны да акрынлап зурайтып киләләр.* Мирас

**Зурайтып кую** Зурайган хәлгә китереп калдыру. *Ул яшәгән якның өстәлен зурайтып куйдым да бер башына Юрмыч елгасыннан алып кайткан сызымнарны, диаграммаларны, язмаларны җәеп салдым.* Л.Ихсанова.

*Умарталыктагы иске йортка янкорма бурап, зурайтып куйды*. Г.Якупова

**Зурайтып тору** Гел, һәрвакыт зурайту эше белән шөгыльләнү; әле, хәзер, күз алдында зурайту. *Кичә сез килгәндә, бер фоторәсемне зурайтып тора идем*

**ЗУРАТ** *и. рус* Басуда ашлык көлтәләреннән торган озынча зур өем. *Бөтен ил чыгар басуга, Бөтен ил зурат куяр.* Ә.Ерикәй. *Бу ни гаҗәп, ни хәйран, ди, Урак урган кеше юк, Зурат куйган кеше юк.* Н.Исәнбәт. *Зуратлар арасыннан, бар көченә йөгереп, Саҗидә килеп чыкты.* Ә.Салах

**ЗУРАЮ** *ф.* 1) Зур булу, үсү, яше арту. *Зураерсың, зиһенең арта барыр.* С.Хәким

2) Гадәти хәленнән зуррак хәлгә килү, ишәю, күләме арту. *Сентябрь кояшы кызарып, зураеп, урман артына төшеп китте.* И.Гази. *Болай да зур, чәркә хәтле соры күзләре тагын да зураеп, калайланып чыга.* В.Нуруллин. *Каланың эченәрәк кергән саен, йортлар ишәя, зурая һәм бер-берсенә ныграк елыша бардылар.* Ә.Фәйзи

3) Эш, мәсьәлә, хәл һ.б. катлаулылану, җитди төс алу, зурга китү. *Картның йортында башланган әзерлекләр белән бергә, Гөлбануның бирелү хәбәре тиз арада күршеләргә ирешә, аннан чыгып, өйдән-өйгә, урамнан-урамга китте, --- зураеп, гайбәтләр дә кушылып, кызның үзенә дә килеп җитте.* Г.Ибраһимов

4) Үсеп җитү, балигъ булу. *Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, Зурайгач җайсыз ул, Картаеп каткач буыннар Эш белү уңайсыз ул!* Г.Тукай. *Әмма инде шуны [мәкальдә китерелгән туры мәгънәне] кешегә карата киная итеп алсаң, гаиләдә бала нәрсә күреп үссә, зурайгач та шул була, дигән мәгънә [барлыкка килә]*. Н.Исәнбәт

5) Масаю, эреләнү, санламау, баш имәү. *Коръәндә һәм пәйгамбәребез хәдисендә бик ачык кисәтелә. 17 нче сүрәнең 37 нче аятендә мондый сүзләр бар: «Җир өстендә зураеп, күкрәк киереп йөрмә! Чөнки син никадәр зурайсаң да, җирне ертырга хәлеңнән килмәс һәм никадәр зурайсаң да, таулар хәтле зурая алмассың»*. Ш.Җәләлиев

**Зураеп бетү** Тәмам зураю, тиешле зурлыкка җитү. *Таныш түгел апа Ләйсәнне кулларына күтәрде дә: – Бәпкәчем, алтыным, инде зураеп та беткән, – дип, күкрәгенә кысты*. Г.Якупова

**Зураеп җитү** Яшәешнең билгеле бер стадиясенә, гадәттә мөстәкыйльлек чорына басу (кеше турында); тәмам өлгерү. *Балалары үсеп, зураеп җиттеләр, кул арасына керә башладылар, өчесе дә әниләренә гел булышып торалар*. Л.Ихсанова

**Зураеп калу** Зурайган хәлгә килү. *--- ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора кебек...* Ә.Еники. *Өй бушап, зураеп калды.* Г.Гыйльманов

**Зураеп китү** Тиз арада, көтелмәгәндә, кинәт зураю. *Тагын да зураеп киткән кайгыларыбызны уртаклашырга, зарыбызны аңа сөйләргә теләгән идек.* А.Шамов. *Картлары яшәрде, бала-чагалары кинәт үсеп, зураеп киттеләр.* Р.Ишморат. *--- алдында майор басып торганын күргәч, күз аклары зураеп китте.* Х.Камалов

**Зураеп тору** Күз алдында зур булып аерылып тору, башкалардан калку булып күренү. *Мәнә аларның каршында, биек булып, капкалары зураеп тора, мәнә, тонык кына булып, тимер тотка ялтырый.* Г.Бәширов

**Зурая бару** Акрынлап, аз-азлап зураю. *Шунда, болында, үләннәр арасында төрле кошчыклар, хәшәрәтләр шаулашалар: еракта, минут саен зурая барып, минут саен кызара барып кояш баерга җыена.* Г.Коләхмәтов. *--- бүлмәсе көннән-көн зурая барган сыман тоелды, ә тирә-юньдәге түгәрәк дөнья күзгә күренеп кечерәйде.* Р.Вәлиев. *Ялкын минут үткән саен көчәя, зурая барды*. Р.Батулла

**Зурая башлау** Зураерга тотыну. *Кинәт теге бала күз алдында үсә һәм зурая башлады*. Р.Гали. *Чәчәк касәләре кинәт зурая башлады*. Р.Батулла

**Зурая бирү** Һаман да зураю, зураюын дәвам итү. *--- буй җиткән кызлары бар, монысы бераз борынын күтәребрәк йөри, мактанчыграк. Әмма кызларына ул кадәр исем китеп тормый әле, зурая бирсен шунда*. Г.Гомәр

**Зурая төшү** Тагы да бераз зураю. *Зур кара күзләре тагын да зурая төшкән.* М.Гафури. *Бу изге картны да ул бераз зурая төшкәч үк эзли башлады.* Г.Бәширов. *Минем бәрәннәргә исем китә: алар өч-дүрт көннән инде бөтен өйне бетереп чаба башлыйлар, зурая төшкәч, мич башына хәтле сикереп мендәләр*. Ә.Еники

**ЗУРЛАНУ** *ф.* Эреләнү, масаю, тәкәбберләнү; баш имәү, үзен зур, югары тоту. *Кышка баскач, торды ул мәгърурланып, «Мин хәзер кайда!» дигәндәй зурланып.* Ш.Бабич. *Зурланып, тамак кырып бирде җавап: «Көн буе сабан сөреп арып киләм – Вакытсыз йөрмә әле бимазалап»*. Мәсәл

**ЗУРЛА́РЧА** *рәв.* Зурларга охшап, олылар, өлкән кешеләр кебек. *Аны әнисенең үзе белән зурларча сөйләшә башлавы кызыксындырды.* В.Нуруллин. *Гани аңа, ничектер, зурларча карап алды да кистереп әйтте: «Безнең акчалар түгел ул. Яхшысы: син ул хакта онып, яме!»* Р.Мирхәйдәров. *Кыз зурларча кул биреп исәнләште.* А.Расих

**ЗУРЛА́У** *ф.* **1.** Олылау, ихтирам итү, хөрмәт күрсәтү. *Килене тел яшергәнне Айдаш карт бик ошата, --- «биатасын зурлый» дигән яшерен уй картны гомере буе куандыра килде.* Р.Батулла

**2. зурлап** *рәв. мәгъ.* Тантаналы төстә, бәйрәмчә; күп кешеләр катнашында. *Шул уңайдан элек Бөек Литва кенәзлегенә кергән Польша, Белоруссия, Балтия илләрендә бу датаны зурлап билгеләп үттеләр.* Мирас

**Зурлап тору** Гел, һәрвакыт зурлау. *Ана балаларына карап шатланып бетә алмый: игелекле, ярдәмчел, туган җанлы алар, бер-берсен хөрмәт итеп, зурлап торалар.* Заман

**ЗУРЛЫК** *и.* **1.** 1) Зур булу, башка нәрсә белән чагыштырганда, күләме артык булу. *Каршы як стенадагы башкалардан үзенең зурлыгы белән аерылып торган бер панорамага күзе төшүгә, Хәйдәр гаҗәпләнеп аягүрә басты*. Г.Бәширов. *Мин сиңа ул җырләрнең бай-*

*лыгы турында да, Урал шәһәрләренең матурлыгы һәм заводларының зурлыгы турында да – барысын да дөресен сөйләдем.* Г.Әпсәләмов

2) Күләм; әйбернең иңе, буе, биеклеге белән үлчәнгән күләме. *Бүлмәнең бөтен җиһазы 137 нчегә охшашлы булса да, зурлыкта бу бүлмә аның кадәр 10–15 өлеш бар иде.* Ф.Әмирхан. *Ерактан алар авылындагы пожар каланчасы төсле булып күренеп торган бу вышкаларның зурлыгы Инсафны аеруча гаҗәпләндерде.* М.Хәсәнов. *Бу ике тәрәзәсе белән – ишегалдына, бер тәрәзәсе белән урамга караган уртача зурлыктагы бер бүлмә булып, түрдәге сәкесе белән, бераз Кырлайдагы сабак абыстаеның кызлар укыта торган бүлмәсен хәтерләтә иде.* Ә.Фәйзи

3) *мат. физ.* Үлчәнә һәм исәпләнә ала торган, исәпләргә мөмкин булган нәрсә. *Батареяның бушану дәрәҗәсен шулай ук көчәнеш зурлыгы буенча нагрузка сәнәге белән дә белеп була.* Механизаторлар белешмәсе. *Чикле зурлык. Даими зурлык*

4) Бөеклек, өстенлек, сыйфат, дәрәҗә һ.б. белән башкалардан артык булу. *Үлем берни түгел, тик начар аның хурлыгы, Беленмәү халыкка аның хезмәтенең зурлыгы.* Г.Камал. *Ил йөкләгән эшнең зурлыгы, мөһимлеге Әкрам карый белән Сафаны юл буе җилкендереп, горурландырып килгән иде.* М.Галәү

5) Дәрәҗә, чин. --- *аның хыялында бабалары, чыннан да, дан һәм зурлыкта булып урнашалар.* Г.Ибраһимов

6) Абруй, авторитет. *Чөнки барыбер алар – Җәләлнең угыллары, барыбер Җәләлгә угыллары аша зурлык килә.* Г.Ибраһимов

7) Яше зур булу, олы, өлкән яшьтә булу. *Кышкы айларда иртә-кич ут белән дә эшли һәм, кечкенәлегенә, зурлыгына карамастан, кул астындагы кешене дә шулай эшләтә.* М.Галәү

**2. зурлыгы, зурлыгында** *бәйл. мәгъ. тарт. форм.* Бер әйберне икенчесе белән микъдар, күләм ягыннан чагыштырганда кулланыла: кадәр, кадәрле, чаклы; тикле, тиклем; хәтле. *Әхмәтнең кушуы буенча, хәзрәткә иске нәрсәләр саклана торган бүлмәдән бозау зурлыгы бер җиз комган чыгарып бирделәр.* Ф.Әмирхан. *Шахмат тактасы зурлыгында гына бер хөкүмәт министры булуга карамастан, ул рус эмигрантлары алдында рияланып тормаган, тоткан да: «Мин моннан соң русча сөйләшмим», – дип, приказ чыгарган.* Г.Гобәй

**ЗУРЛЫ-КЕЧЕЛЕ** *с. сөйл.* Өлкәннәре дә, кечеләре дә булган. *Шул казаннарның янында һәммәсе кулларын сызганып, зурлы-кечеле бик күп шәкертләр кайнаша: кем бәрәңге турый, кем токмач сала, кем ашының тозын карый…* Г.Ибраһимов

**ЗУРЛЫ-КЕЧКЕНӘЛЕ** *с.* Зурысы да, кечкенәсе дә булган, төрле зурлыктагы. *Алар арасында ераклы-якынлы, зурлы-кечкенәле, әкиятләрдәге тылсымлы көзгеләр төсле матур күлләр ялтырап ята.* Ш.Камал. *Зурлы-кечкенәле оешмаларыннан туктаусыз кәгазьләр, карарлар явалар.* Г.Ибраһимов

**ЗУ́Р ЮЛ** *и.* 1) Транспорт күп йөри торган шәһәрара магистраль юл. *Аларның [Күлбаш авылының] җирләре Царевококшайск шәһәреннән Казанга килә торган зур юл буйлап урнашкан, дип языла анда [документларда].* Ф.Гарипова

2) *куч.* Күп һәм озак алып барылган эшчәнлек, тупланган тәҗрибә. *Шул рәвешле, сугышка кадәрге чорда татар режиссурасы бик зур юл үтә.* М.Арсланов

3) *куч.* Тормыш, яшәеш агымы. *[Мәктәп] Зур юлларга безне чыгардың син, Күңелләргә бирдең омтылыш.* Ш.Галиев

**ЗУ́Р ЯК** *и.* Йортның (өй, фатирның), гадәттә, кунаклар кабул итә торган зур бүлмәсе; түр як; зал. --- *өйнең зур як түрендә, агач кәнәфидә өч авыл карты һәм алар янында шәльяулык ябынган, укалы камзул кигән әбекәй утыра.* Ә.Еники

**ЗЫБАН** *и. гар. иск.* Җиләннең бер төре; җөббә. *Шул чак өстенә буй-буй зыбан, башына кара кәпәч, аякларына күн итекләр кигән базык гәүдәле берәү, төркемнән аерылып, кунаклар янына ташланды.* Җ.Рәхимов

**ЗЫЙҢ-ЗЫЙҢ** *иярт. к.* **зың**. *Чалгы янаган тавыш, күңелләрне җирсетеп, агач араларында зыйң-зыйң яңгырый.* А.Гыйләҗев

**ЗЫ́К БУЛУ** *ф.* Тәмам туя, күрәсе килмәслек хәлгә җиту. *Авыр эштә эшләүдән зык булу*

**ЗЫ́К КИЛҮ** *ф. к.* **зык кубу**. *Беребез дә күрмәгән машина өчен зык килеп, төн йокысын калдырмасалар, башка эшләре юктыр шул…* К.Нәҗми

**ЗЫ́К КУБУ** *ф.* Шаулашу, шау-гөр килү, ыгы-зыгы килеп йөгерешү. *Өй эчендә шулай зык кубып, туйга әзерләнгән кебек әзерлек баруга карамастан, Галимә апа бу эшләргә әйләнеп тә карамаган кебек тора.* М.Гафури. *Алар башта зык кубып, Раузаны сырып алды.* М.Кәрим. *Урман һәм кырларны, алан һәм болыннарны калдырып, инде өй яки келәт кәрнизендә кыш чыгарга җыенган бу кошлар, гүя, кара каргаларны озатып, үзләре моңаеп калалар, шуңа зык кубалар иде.* Г.Хәсәнов

**ЗЫ́К КУПТАРУ** *ф.* Шаулату, шаушу, ыгы-зыгы, чуалыш барлыкка китерү, төрле якка йөгерешү. *Бу ник болай соң, бу эш нигә бөтен авылны зык куптара? Әйбер урлап тотылган кешеләргә дә болай кызмыйлар, --- урам буйлап, битләренә кара ягып йөртмиләр.* М.Гафури

**ЗЫ́К ЧИКТЕРҮ** *ф.* Җәфалау, интектерү. *Теге төше эшләнеп бетмәгән, бу төшенә ремонт кирәк дип, шул өйләренә күчмичә тәмам зык чиктерделәр.* Татарстан яшьләре

**ЗЫКЫ** *и.* **1.** Кыш көнендә була торган кар сыман вак бәс, томан. *Төнге зыкы күгелҗем урманны алыштыргандай иткән иде.* М.Рәфыйков. *Көннәр суытты, төннәрен кешеләрнең киемнәренә зыкы куна торган булды.* Т.Нәбиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Томанлы һәм кырыс. *Зыкы суыкларда урманнан ач-ялангач килеш утын тартып ташулар, тирләп-пешеп кар күмеп киткән эскертне ачулар һәм ялан кул салам йолкулар --- бердәнбер көнне Маһиянең үпкәсен кабартып, аны түшәккә екты.* Н.Хәсәнов. *Ничек кенә сәер тоелмасын, зыкы салкын булуга да карамастан, каберне тиз һәм җиңел казып куйдылар.* Р.Мирхәйдәров

◊ **Зыкысын чыгару** 1) Бер эшне көч түгеп, тырышып эшләү; 2) Бер сүзне

кат-кат сөйләү, гайбәт итеп сөйләү.

**Зыкы чыкканчы** Артыгы белән, артык күп, артык тырышып. *Әйтик, бүгенге көндә дә «зыкы чыкканчы ашады», ягъни артык күп ашаган; «зыкы чыкканчы кыйнаганнар», ягъни артыграк кыйнап ташлаганнар; «зыкы чыкканчы эшләү» дә бар. Димәк ки, чамадан тыш, артыкка киткән нәрсәне татар «зыкы» сүзе белән аңлаткан.* Р.Батулла

**ЗЫКЫЛЫ** *с.* Томанлы салкын, дымлы салкын, сыкы барлыкка китерә торган. --- *авыр йөкне сөйрәп, зыкылы юлны шыгырдатып һәм чана табаннарыннан тешкә тия торган ышкылу тавышлары чыгартып, бер көйгә генә Сөнгә якынлашып килгәне ап-ачык ишетелә иде инде.* З.Фәйзи. *Зыкылы төн. Чана авыр бара, Атлар пошкыралар талчыгып.* Р.Гатауллин

**ЗЫКЫМ** *и.* Көчле тәэсир, йогынты, шаукым. *Шаяруларның зыкымы, кайчак, минем кебек яңа кергәннәргә генә түгел, хәзрәтләргә дә барып тия.* Г.Гобәй. *Ә минем шомырт чәчәкләремнең исе, палатага гына түгел, бөтен коридорга таралып, дару исләрен хәйран баскан икән. Ул чәчәкләрнең зыкымы озакка барды.* Т.Нәҗмиев. *Берсе, хәрәмләшеп, бабай сырасына аракы куша. Ул кыза төшә, аракы зыкымы баса башлагач, кайтырга чыга.* Н.Хәсәнов

**ЗЫНҖЫР** *и. фар. иск. кит.* 1) Озынча, түгәрәк яки башка шәкелдәге металл боҗраларны бер-берсенә кидереп ясалган чылбыр. --- *калын зынҗырлар илә асылган ике зур казаннарга икесен дә салдылар.* Г.Тукай

2) Коллар яки тоткыннарның кул яки аякларына салынган чылбырлы богау. *Кыенлыкка калып бара көннәребез, Зынҗыр берлән беркетелде телләребез, Аһ-ваһ илә үтәдер һәм төннәребез.* Ш.Мөхәммәдев. *Без кол идек бай кулында, Богау, зынҗырлар муенда, Зинданнарда чери идек Хак сүз, тугрылык юлында.* Г.Камал. *Болгарларның кулларында зынҗыр, муеннарына озын бау тагылган.* В.Имамов

3) Бизәнү әйберсе буларак затлы металлдан эшләнгән чылбыр. *Таһир ул җәүһәрләрне этләрнең муенына затлы зынҗырлар илә тагып йөртә.* Р.Батулла

**ЗЫНҖЫРЛА́У** *ф. иск.* 1) Богаулау, зынҗыр салу, иректән мәхрүм итү

2) *күч.* Чикләү, иреген кысу, ирексез итү. *Яраусыз Җир җанны кысса, сүзебез – кыска: Җирдән олы булмасын җан – җанны зынҗырла!* Г.Сәлим

**Зынҗырлап алу** Тиз арада зынҗырлау. *Әсирләрнең һәрберсен зынҗырлап алып, кыйный-кыйный, тар камерага куып керттеләр.* Мирас

**Зынҗырлап ату** Ашыгыч рәвештә зынҗырлау. *Иясез этне зур авырлык белән зынҗырлап атып, машинага ыргыттылар.* Казан утлары

**Зынҗырлап бетерү** Бернинди хәрәкәтләнү ирекгә калдырмыйча, тәмам зынҗырлау; зынҗырлауны ахыргача җиткерү

**Зынҗырлап кую** Алдан зынҗырлау, зынҗырланган хәлгә китереп калдыру. *[Намаз] Укыр вакыт җиттеме, башыңда әллә нинди кара уйлар зырзыр әйләнеп торса да, аларны, миеңнән куып чыгарып, бер почмакка зынҗырлап куясың.* С.Поварисов. *Кызык бу дөнья: богау белән караватка зынҗырлап куелган, әле үз йомышына да йөри алмаган авыру мәхбүсне пистолет һәм автомат белән коралланган өчәү саклый.* Н.Әхмәдиев

**Зынҗырлап тору** Әле, хәзерге вакытта зынҗырлаган булу. *Җанын зынҗырлап торган зәмһәрир салкын боз эри башлагандай булды.* Г.Әпсәләмов

**Зынҗырлап ташлау** Тиз арада, ашык-пошык зынҗырлау

**ЗЫНҖЫРЛЫ** *с.* 1) Зынҗырланган, чылбыр салынган, богаулы, богауланган. *Алтын – утта, адәм михнәттә сынала, дигәне дә бар. Михнәт күрәкүрә чыныксыннар. Утырган таш шикелле мүкләнүдән ни файда? Зынҗырлы аю түгел лә инде алар.* С.Поварисов

2) Ирегә чикләнгән. *Халыкларның уртак төрмәсендә Шагыйрьләр дә тоткын, зынҗырлы.* Г.Морат

**ЗЫҢ** *иярт.* Җиңелчә вибрация (калтырау) бирердәй нәрсәләргә орынганда барлыкка килгән калтыраулы тавышны белдерә. *Француз туфлиенең очлы үкчәсендә «зың» итеп әйләнеп, борылып китеп кенә барасы иде дә, хатын-кызлык табигате җиңде.* Т.Галиуллин. *Күчәрдәге алкалар чыңлавын, үрәчә шыгырдавын, чикерткәләр зыңын, тургай сайравын тыңлады [Чаныш].* Ә.Гаффар

**ЗЫҢГЫЛДАВЫК** *с.* **1.** «Зың-зың», «зыңгыл-зыңгыл» итеп тавыш чыгара торган. *Зыңгылдавык уенчыклар*

**2.** *и. мәгъ.* Зыңгылдый торган нәрсә. *Синең зыңгылдавыгың нәрсәгә кирәк?*

**ЗЫҢГЫЛДАТУ** *ф.* Нәрсәгәдер орынганда, үзара бәрелешкәндә шуңа охшаш калтыраулы тавыш чыгару. *Иртә белән ишек ачуга ул тагын зыңгылдатып җиде тапкыр суга ---.* К.Нәҗми. *Өлге-пыялаларны зыңгылдатып, кемдер тәрәзә кага.* Р.Муллануров. *Балык уңай гына килә-килә дә кинәт кире чигенә, юан җепне зыңгылдата, як-якка бәргәләнә.* С.Шәрипов

**Зыңгылдата башлау** Зыңгылдатырга тотыну

**Зыңгылдата бирү** Һаман да зыңгылдату, зыңгылдатуын дәвам итү

**Зыңгылдата төшү** Бераз зыңгылдату

**Зыңгылдатып алу** Кыска вакыт эчендә зыңгылдату. *Кайчак ул әйбер тулы шкаф һәм тартмаларны дер селкетеп, зыңгылдатып алу белән генә дә чикләнә.* Идел

**Зыңгылдатып кую** Кинәт бер тапкыр «зың» иткән тавыш чыгару. *Минә мин ачык капкадан эчкә узам һәм, тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып куйган үзәк өзгеч тавыш ишетеп, тораташ булып катып калам.* Р.Гыйззәтуллин

**Зыңгылдатып тору** Бертуктаусыз зыңгылдату. *Асфальт салучы машиналар көнозын тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып торды.* Казан утлары

**ЗЫҢГЫЛДА́У** *ф.* 1) Калтыраулы «зыңк-зыңк» иткән тавыш чыгару. *Тәрәзә пыялалары зыңгылдады.* М.Мәһдиев. *Кинәт зыңгылдаган ишек кыңгыравы тавышыннан сискәнеп китте, гәзитләрне, кабаланып, диван астына шудырды.* М.Маликова. *Җиде төн уртасында --- мылтык аткан тавышка йортның барча тәрәзә пыялалары зыңгылдады.* Мирас

2) Кинәт, кискен авырту барлыкка килү. *Кыз куркудан җайсыз сикерде, үкчәсе зыңгылдады, йөзен чытып*

*өскә караса, тәрәзәдә айдай балкып Мөзәкир тора.* А.Гыйләҗев

**Зыңгылдап алу** Кыска гына, аз гына вакыт зыңгылдау. *Матвей Иванович каршында илаһи көчен җуйган бакыр кисәге, агач тамырына туры килеп, зәгыйфь зыңгылдап алды да, юл тузанына батып, күздән югалды.* Г.Гобәй. *Тәрәзә пыялалары зыңгылдап алды.* М.Мәһдиев

**Зыңгылдап йөрү** Даими, һәрвакыт зыңгылдаган тавыш чыгару. *Ат дугасында зыңгылдап йөргән кыңгырауларга караган саен, балачагым күз алдыма килә.* Казан утлары

**Зыңгылдап кую** Бер тапкыр «зың» иткән тавыш чыгару. *Балта түтәсе белән сугып карады, гәрәбә төсле сапсары озын нарат, скрипка кылыдай, зыңгылдап куйды.* И.Гази. *Туң тәрәзә зыңгылдап куйды, ишегалдындагылар бер-берсенә карашып алдылар.* Ф.Хөсни. *Тәрәзә пыялары зыңгылдап куйды: «Шапки снять!»* М.Мәһдиев

**Зыңгылдап тору** Бертуктаусыз зыңгылдау. *Ләкин нәкъ менә шул аңлаешсызлыклары белән алар Газзәгә тылсымлы, кызык тоелалар. «Рабби әнзилни мөнзәлин...» Ничек зыңгылдап тора.* М.Маликова. *Зыңгылдап торган машина тавышына башы авырта башлады, күз аллары караңгыланды.* Казан утлары

**ЗЫҢГЫЛ-ЗЫҢГЫЛ** *иярт.* Әйбер нәрсәгә дә булса орынганда, бәрелгәндә, зыңгылдаганда чыккан авазны белдерә

**ЗЫҢГЫРА́У** *ф. к.* **зыңгылдау**. *Пар атлар да күп иде. Һәммәсе матур итеп бизәлгән, дугаларында, тәртә башларында сөлге-тастымаллар җилферди, җиз кыңгыраулар зыңгырый.* Мирас

**ЗЫҢК** *иярт.* Бер генә тапкыр нык һәм кинәт бәрелүдән чыккан калтыраулы тавыш. *Әйе, кайтып төшәсе иде дә әни каршысына «зыңк» иттереп килеп басасы иде: – Әни! Мин бит бу! Шәмси!* Г.Бәширов

**ЗЫҢКУ** *ф. диал.* 1) «Зыңк» иткән тавыш чыгару, кинәт шундый тавыш чыгарып бәрелү

2) Ару, авыру сәбәпле баш, колаклар шаулап тору

3) *куч.* Җиргә каты итеп бәрелеп килеп төшү, кинәт барып төшү

**ЗЫҢКЫТУ** *ф.* 1) *к.* **зыңлату**

2) *куч.* Көч белән җиргә бәрү, «зыңк» иткән тавыш чыгарлык итеп ыргыту

**ЗЫҢЛАТУ** *ф.* Колакта зыңлаган тавыш чыгару. *Көчле шартлау тавышы колакларны зыңлатты*

**Зыңлатып җибәрү** Кинәт зыңлату

**Зыңлатып тору** Һәрвакыт «зыңзың» килгән тавышлар чыгару

**ЗЫҢЛА́У** *ф.* «Зың-зың» иткән тавыш чыгару. *Без – еллар һәм урын алыштырып Яшьлегеннән киткән качаклар; Өзелгәндер дисәң, сагындырып, Таныш кыллар зыңлый кайчакта.* Ш.Галиев. *Пуля тиеп, корпус каты зыңлый.* И.Низамов. *Биек булып, уңып күтәрелгән арышның талгын гына дулкынлануына сокланып, ул башакларның бер-берсенә иркә генә бәрелеп зыңлавына колак салып торды.* Ә.Фәйзи

**Зыңлап алу** Бик кыска вакыт арагында зыңлау. *Уенчыкның зыңлап алганына бала сискәнеп куйды һәм әнисенә сыенды.* Казан утлары

**Зыңлап йөрү** Һаман да, бертуктаусыз зыңлау. *Ат дугасында зыңлап йөргән кыңгыраучыклар белән чагыштыра ул бүген үзен: тавышы матур, үзе матур, ләкин ирекле түгел.* Казан утлары

**Зыңлап кую** Бер тапкыр, кинәт зыңлау. *Муса кулына алган кырык алтылы сандалиен баскычка ташлады, аның калай каптырмасы зыңлап куйды.* Ә.Гаффар. --- *зур бау тартылудан зыңлап куя һәм Рифкать аска, упкын төбенә оча.* Р.Вәлиев

**Зыңлап тору** Бертуктаусыз зыңлау. *Зыңлап тора чылбыр... Өзелергә һич ярамый аңа, ярамый.* Л.Шагыйрьҗан. *Төннәр ни тикле җиләс булмасын, иртәнчәк кар, пыяладай, ни тикле зыңлап тормасын, кояш үзенекен итә: кырлардан карны качыра.* Г.Хәсәнов

**ЗЫҢЛЫ** *с.* Зыңлап торган тавышлы. *Тирә-якка мандолинаның зыңлы моңы сибелде*

**ЗЫР** I *и. диал.* 1) Сыр, бизәк. *Тәрәзә капкачларындагы зырлар. Капкадагы зырлар*

2) Буяу

**ЗЫР** II *рәв.* Зур тизлек белән бөтерелеп. *Зыр әйләнү*

**ЗЫР-ЗЫР** *иярт.* Әйбер бөтерелгәндә яки тиз хәрәкәт иткәндә, бөтерелеп очканда һавага ышкылудан килеп чыккан тавышны белдерә. *Нинди елгыр әйләнә чылбыр хәзер. Бөтерелә чылбырда Иблис зыр да зыр!* Ш.Бабич. *Малайлар – Илшатны, кызлар Миләүшәне бер урында зыр-зыр әйләндереп, аркаларыннан этеп җибәрделәр.* Ф.Яруллин. *Тиле кыз, билемнән алып, зыр-зыр әйләндерде мине.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЗЫ́Р-ЗЫР КИЛҮ** *ф. к.* **зырлау**. *Җирдән өермә суырып алган тузан бөртекләредәй зыр-зыр килеп әйләнергә, бөтерелергә тотынды.* Ф.Латыйфи

**ЗЫРЛАТУ** *ф.* Зыр-зыр иттерү, зырылдаган тавыш чыгарып тору. *Көчле җил зырылдавыкны зырлата*

**Зырлата башлау** Зырлатырга тотыну

**Зырлатып җибәрү** Кинәт зырлату

**Зырлатып тору** Әледән-әле яки берөзлексез зырлату

**ЗЫРЛА́У** *ф.* **1.** 1) Зыр итү, «зырзыр» килгән тавыш чыгару. *Өй түбәсендә флюгер туктаусыз зырлый*

2) Бик тиз бөтерелү, зур тизлек белән әйләнү. *Калкулыкның иң текә тәңгәленә җиткән төшендә көпчәкләр бер урында чын-чынлап, хәтта киргәннән артык зырлап әйләнә башлады.* А.Хәлим

**2.** *рәв. мәгъ.* Бер урында кинәт әйләнеп, борылып. *Трактор бер урында зырлап борылды да югары очка таба китте.* Р.Батулла

**Зырлап алу** Аз вакыт эчендә, беразга гына зырлау. *Кыргычлары бераз зырлап алды да янәдән сүнде.* К.Нәҗми

**Зырлап китү** Кинәт зырлый башлау. *Моторның зырлап китүенә куанып, балалары шаулашып сикереп куйдылар.* К.Нәҗми

**Зырлап кую** Бер тапкыр зырлаган тавыш чыгару

**Зырлап тору** Бертуктаусыз зырлау. *Иң мөһиме: җил тегермәнедәй зырлап торыгыз.* Р.Зарипов. *Зырлап торган уенчыкка карап, нәни кыз сөенә, кулларын чәбәкләп, чырык-чырык көлә иде.* Казан утлары

**ЗЫРЫЛДАВЫК** *с.* **1.** Зырылдап әйләнеп торган, зырылдаган тавыш

чыгарып торган. *Зырылдавык уенчык. Зырылдавык очыргыч*

**2.** *и. мәгъ.* Җилдә җитез әйләнеп, җил юнәлешен һәм җил көчен күрсәтә торган әйбер; флюгер. *Аннан кайткач, зырылдавык ясап, аны сарай кыегына меңгереп кадаклый да сокланып карап тора; җил чыктымы, зырылдавык әйләнергә, зырылдарга тотына.* М.Галәү

**ЗЫРЫЛДАВЫКЛЫ** *с.* «Зыр-зыр» иткән тавыш чыгара торган

**ЗЫРЫЛДАТУ** *ф.* **1.** 1) «Зыр-зыр» иткән тавыш чыгару, зыр-зыр китерү, көчле тавышлар чыгару. *Алар артыннан, ташларны зырылдатып, авыр туплар иярде.* К.Нәҗми. *Очыргыч җибәрсә, аның очыргычы болытлар эчендә уйнаклап йөрергә тиеш; --- кәтүк агачын зырылдатып тартып әйләндергәч тә пырылдап очып киткән выжвыжагы иң ерак араны үтәргә тиеш.* Ш.Рәкыйпов

2) *күч.* Үз ихтыярына буйсындыру, үзенчә генә эшләргә мәҗбүр итү. *Бөтен шәһәрне учымда зырылдатам, ә син!..* А.Гыйләҗев

**2. зырылдатып** *рәв. мәгъ.* 1) Бер урында кинәт әйләндереп. *Күкчәчәк аның, бу якка чыгып җитәр алдыннан, көймәне, зырылдатып борып, яр кырыена койрыгы белән оста итеп китереп туктатканын күрә.* Ә.Хәсәнов. *Чанасын зырылдатып борып җибәрүем булды – Сөмбел багана төбендәге көрткә чумды.* В.Нуриев

2) Җитез, шәп, җәһәт. *Кулыннан тотып, зырылдатып тартып китереп, кочаклап аласы иде дә бит...* М.Маликова

3) Бик тиз арада, җилтерәтеп. *Әгәр кушсалар, ул теләсә кайсы җитәкчене көннең йә төннең теләсә кайсы вакытында хәтта җир читеннән дә эзләтеп таптыра, кирәк булса, аны --- тере яисә үле хәлендә, зырылдатып, райкомга китереп җиткерә.* Ф.Садриев

**Зырылдата башлау** Зырылдатырга тотыну

**Зырылдата бирү** Һаман да зырылдату, зырылдатуын дәвам итү

**Зырылдата төшү** Бераз зырылдату

**Зырылдатып алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында зырылдату. *Әни орчыгын берничә мәртәбә зырылдатып алуга, апай аңа әллә ничек кенә итеп ым какты.* Г.Бәширов

**Зырылдатып җибәрү** Кинәт зырылдата башлау. *Ул [әби] орчыгын зырылдатып җибәрә.* Р.Хафизова

**Зырылдатып тору** Бертуктаусыз зырылдату

**ЗЫРЫЛДА́У** *ф.* **1.** Зыр-зыр иткән калтыраулы тавыш чыгару. *Ябык ындыр эчендә, тирә-яктагы бөтен әйберләрне селкетеп, сугу машинасы үкерә, җилгәргеч зырылдый, кешеләр кайнаша.* Г.Әпсәләмов. *Колак тирәсендә нәрсәдер зырылдап очкан кебек.* З.Мәхмүди

**2. зырылдап** *рәв. мәгъ.* 1) Бер урында кинәт әйләнеп, бөтерчек кебек. *Менә Галәү уң аягын читкә сузып җибәрде һәм идәнгә сул аягының үкчәсе белән генә тиеп торган көе, зырылдап әйләнергә тотынды.* Н.Фәттах. *Танк урынында зырылдап, бер якка түңкәйде.* Х.Камалов

2) Бик тиз арада, җитезлек белән. *--- [ат] ипи күреп, шуны китергәнеңне көтеп тора да, танавын сузып эләктереп алса, колакларын яткызып, күз ачып йомганчы, зырылдап, арты белән әйләнә, һич үзенә якын барырмын димә.* К.Миңлебаев

3) Үпкә белдереп, канәгатьсезлек белән

**Зырылдап алу** Өзек-өзек, кыска яки вакыты-вакыты белән зырылдау

**Зырылдап китү** Тик торганнан зырлый башлау яки кинәт кенә, көтмәгәндә зырларга тотыну

**Зырылдап кую** Бер мәртәбә, кыска вакытлы зырылдау

**Зырылдап тору** Гел, һәрвакыт, бертуктамый зырылдау. *Казан элеваторы бүген дә һәрвакыттагыча яхшы эшли, пневматик бушаткычлар туктаусыз зырылдап тора.* С.Сабиров. *Карасам, уч төбемнән югарырак, буын өстендә, тәнемне кисеп кергән юка лезвие зырылдап тора.* Г.Сабитов

**ЗЫРЫЛ-ЗЫРЫЛ** *иярт.* Әйберләр бөтерелгәндә, ышкылганда чыккан авазны белдерә. *Зырыл-зырыл такта яргыч эшли*

**ЗЫРЯН** *и. тар.* Коми халкының элекке атамасы

**ЗЫЯ** *и. гар. иск. кит.* 1) Нур, яктылык. *Нигә булды зыя сөйгән азат баш Монафикълар караңгысында хәффаш?!* Г.Тукай

2) *күч.* Белем, мәгърифәт. *Бичара караңгыда калган Уральск мөселманнарына шактый зыя сачмакчы икәнсез.* Г.Тукай

**ЗЫЯЛАНУ** *ф.* Белемле, мәгърифәтле булу, мәдәнияткә ирешү. *Безнең дә әдәбият галәмебезгә зыялану вә нурлануны шул таулар кадәр матбуг рисаләләр өелүдән гыйбарәт дип белеп, максаты аслыйдан мәхрүм калу куркусы бардыр.* Г.Тукай

**ЗЫЯЛЫ** *и.* **1.** Интеллигент, интеллигенция вәкиле. *Бу зыялылар хезмәтләре вә гамәлләре белән дөнья капиталын үз тирәләренә җыярлар.* Ф.Әмирхан. *Сәнгатьлелек сыйфатлары, Солтангалиев идеяләренең мөстәкыйльлек юлына чыккан «өченче дөнья» зыялылары омтылышларына муафыйк булуы төрек һәм башка милләт укучылары күңеленә хуш килде.* Т.Галиуллин. *Үзебезнең тарихыбызда, татар зыялылары арасында азмыни шундый хикмәт ияләребез?* Мирас

**2.** *с. мәгъ.* 1) Укымышлы, мәдәниятле; мәгърифәтле, интеллигентларга хас. *Киләчәктә зыялы, зур культуралы, гыйлем иясе кеше булачаксың инде син.* Р.Фәизов. *Зыялы татарлар чыга торган мәктәп вә мәдрәсә тәртибе.* Мирас

2) Күркәм, интеллигент. *--- халык аның [Таһир Якуповның] иң элек татарның асыл затларына гына хас зыялы тышкы кыяфәтенә таң кала иде.* Г.Галиева

3) *иск.* Нурлы, нур чәчеп торган. *Зыялы дөнья*

**ЗЫЯЛЫЛЫК** *и.* 1) Зыялы булу. *Ләкин пролетар шагыйрьгә әле моны аңлау дәрәҗәсендәге зыялылык җитми.* Ф.Галимуллин. *Ш.Галиев --- чор вакыйгаларына объектив бәя бирә. Сабырлык һәм иплелеккә таянып, зыялылыкны онытмыйча, шәфкатьле күңеле кушканча [яши].* Мирас

2) Мәдәниятлелек, тәрбиялелек. *--- ах-ух килеп, «ур-ра» кычкырып утыру өчен белем дә, зыялылык та кирәкми.* Т.Миңнуллин

**ЗЫЯН** *и. фар.* 1) Матди югалту, каза; чыгым. *Болай эшләүнең нәтиҗәсе ахыр чиктә Рухиягә файдага түгел, киресенчә, зыянга әйләнергә мөмкинлеген дә бик белә.* В.Нуруллин. *Күпсанлы мал көтүләре кешеләрнең иген басуларына, йорт-кураларына зур зыян китереп торганнар.* Г.Гыйльманов

2) Сату, җитештерү, бизнес өлкәсендә чыгымның керемгә караганда артыклыгы; *кире*: **файда**. *Дәреслек --- ул заман акчасы белән 1 миллион сум саф табыш алып эшләүче нәшриятка һәр елны шул кадәр үк зыян сала иде.* Казан утлары

3) *к.* **зарар** (*1 мәгъ.*). *Моңарчы бу ташның колхоз тормышына бер зыяны да юк иде кебек.* М.Мәһдиев. *--- персонажларның күбесе бер үк позада булып, бер-берсен кабатлый, шуңа аларны тегеләй үзгәртсәң дә, болай үзгәртсәң дә, әсәргә бернинди зыян яки файда килми.* К.Миңлебаев

◊ **Зыян итмәс** *к.* **зарар итмәс**. **Зыян күрү** Матди югалтуга юлыгу. **Зыян салу** Астыртын корткычлык эшләү, зарар китерү. *Кави Ишмурыйга мин зыян салмаслык дәрәҗәдә генә җавап бирергә тырыштым.* А.Гыйләҗев

**ЗЫЯНДАШ** *и.* Вакыт-вакыт көзән җыеру һәм аң югалту рәвешендәге өянәкле нерв авыруы, үзбума чир, бума чире, үзчире. *Хәле бик авыраеп киткәч, мәдрәсәдән өйгә алып кайттык без малаеңны, Гайфетдин суфидан чакырып өшкертеп карадык, саташа башлагач, әллә зыяндаш зәхмәте микән дип, мәдрәсәдән җиде шәкерт чакырып --- азан да кычкырттык.* М.Гафури. *Зыяндаш булган кешенең һәрбер киеменнән берәр чүпрәк алып, бергә бәйләп, күпер башына ташлыйлар.* Г.Гыйльманов

**ЗЫЯНДАШЛЫ** *с.* Зыяндаш авыруы булган, үзчирле. *--- кирәкми, юк, миңа зыяндашлы, янә череп сасып беткән төче зәхмәтле кыз.* Ф.Халиди. *Ә карчык һаман саен: – Кузгатмагыз, узар... Зыяндашлы бала ул... һәр ел шулай була торган иде, – ди.* Г.Кутуй

**ЗЫЯНДА́Ш ТОТУ** *ф.* Зыяндаш өянәгә башлану. *Тәне бер җыерылып, бер киерелеп, зыяндаш тоткан кебек булды.* Г.Исхакый

**ЗЫЯН-ЗАРАР** *җый. и. фар.-гар.* Һәртөрле зыяннар һәм зарарлар. *Тормыш үзе, гомумән, малай өчен зур бер табышмак иде. Аның берәүгә дә зыян-зарар эшләгәне юк.* Р.Низамиев. *Шул ук микроорганизмнар анда бернинди зыян-зарар күрмичә яшәп һәм үрчеп яталар.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ЗЫЯН-ЗӘВЕР** *җый. и. фар. к.* **зыян-зәүрәт**. *Күзең-башың аларган! Әллә зыян-зәвер күрдеңме? Юлда берәрсе талап кайтардымы әллә?* Гөлшәһидә. *Ярабби, бу йортка иминлек бирсен, авыру-сырхау, бәла-каза, зыян-зәвер китермәсен.* М.Хәсәнов

**ЗЫЯН-ЗӘҮРӘТ** *җый. и. фар.* Зыян һәм зарар. *Күзгә күренми торган җан иясенең бистә халкына ияләшеп, кемнәргәдер – игелек, ә кемнәргәдер зыян-зәүрәтләр кылуы турында иде бу хәбәрләр.* Р.Фәизов. *Моның күрәзәлеккә бер-бер зыян-зәүраты булмасмы?* Ф.Латыйфи

**ЗЫЯН-ЗӘХМӘТ** *җый. и.* Һәртөрле зыян, начар тәэсир иткән нәрсә. *Шулай ул «җен-пәри» дигән нәрсәләр адәм балаларына зыян-зәхмәт китерергә касд итеп кенә торалар.* М.Гафури

**ЗЫЯНЛА́У** *ф. сир.* Имгәнү, яралану, үлү (мал, терлек турында). *Безнең быел сыер зыянлады*

**ЗЫЯНЛЫ** *с.* 1) *к.* **зарарлы**. *Уң аягы соңрак, Равил уяныр алдыннанрак кына, куыштан тышка чыккан булса кирәк – анысының өшүе артык зыянлы булмады.* В.Нуруллин. *Икенче дәүләт телен – татар телен белмәгән һәм хөрмәт итмәгән дәүләт хезмәткәрләренең шундый зыянлы тәкъдиме киләчәктә кабат калкып чыкмасын өчен, милли матбугатны яклау турында Татарстан канунын парламент аша кабул итәргә --- кирәк.* Мирас. *Дөрес, аларның һәммәсе дә физик бәйлелек тудырмый, әмма барысы да, аз гына кулланганда да, шәхескә зыянлы тәэсир итә.* Мәгариф

2) Начар, яман. *Шуннан соңгы елларда аны туктаусыз әзәрлекләгәннәр: яңа заманга син ят зат, үтә дә куркыныч булмасаң да, хосусый милекчелек карашларың белән зыянлы бәндә син, янәсе.* Р.Вәлиев

**ЗЫЯНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Зыян-зарар, каза китерми торган. *Әһе, Гаян Алиев та синең герой икән. Зыянсыз кеше иде, мәрхүм.* Н.Гыйматдинова

2) Әдәплелек кысаларына туры килгән, әдәп, тәрбия киртәсеннән чыкмаган. *Бераздан, сүз иярә сүз чыгып, Хәмзә зыянсыз гына бер мәзәк сөйләп көлдерде.* Ж.Дәрзаман

**2.** *рәв. мәгъ.* Зарарсыз, зыян китермичә. *Шулай да, давыл афәт калдырып китмәдеме дип, басуларны карарга ары чаптык. Гарасат зыянсыз диярлек узган.* Ә.Баянов

**ЗЫЯНЧЫ** *и. сир.* **1.** Зыян эшләүче

**2.** *с. мәгъ.* Зыян, зарар китерүчән. *Зыянчы песи күзен ялтыратыр.* Мәкаль

**ЗЫЯРӘТ** *и. гар. к.* **зиярәт**. *Хәзер бөтен йөкләрне ал да, авылны әйләнеп, зыярат янына чык.* Ю.Әминов. *Т.Галиуллин да, үзе әйтмешли, шушы «рәхәт һәм михнәтле фарыз» гамәле турында «Хаҗга зыярәт шәхси эшме?» дигән юлъязма белән чыкты.* Ф.Галимуллин

**ЗЫЯРӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **зиярәт кылу.** *--- җәмгысе 170 кә якын кеше Согуд Гарәбстанына – ислам дине бишекләре Мәккә белән Мәдинә шәһәрләренә зыярәт кылды.* Т.Галиуллин

**ЗЫЯФӘТ** *и. гар.* Кунак итү, сыйлау, хөрмәтләү мәҗлесе; кунакчыллык. *[Сәгыйд бин Гобәдәнең] --- һәр зыяфәтендә 380 ләп адәм булыр иде.* К.Насыйри. *Баскынлыкка җибәрелгән гаскәр табыш белән кайтса, падишага моннан өлеш чыга, туй яки зыяфәт булса, мәҗлеснең зурлыгына карап, нигъмәттән падишага бүләк бирәләр.* Г.Дәүләтшин. *--- башка эшләрне Ислим Барласка тапшырды да, кул ишарәсе белән утырышны ябып, бөтен мәҗлесне үзенең зыяфәтенә чакырды.* Я.Шәмсетдинов

**ЗӘК** *и. рус к.* **зек**. *Тәҗрибәле зәк яткан җиреннән ялантәпиле аякларын берсе өстенә икенчесен атландырып куйды да кара тырнаклы бармагын уйнатып алды.* Н.Хәсәнов

# И

**И** I *ы.* **1.** 1) Гадәттә, эндәш сүзләр янында килеп, сүзнең кемгә төбәлүен белдерә яки игътибарны үзенә тарту өчен кулланыла. *Исәнме, и туган җирем минем, Мәрхәмәтле анам, исәнме!* Ш.Маннур. *И абыйлар, и агайлар, ап-ак сакаллы бабайлар, Бераз инсафка килегез, җитәдер шәриф айлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Фида җаным синең юлыңда, и яр, Берүк сау бул, берүк уйланма.* Дәрдемәнд

2) Контекстка карап, төрле кичерешхиссиятләрне белдерә. *И сеңлем, җирегез бигрәк тә нурсыз күренә.* Д.Аппакова. *[Галиябану:] И җаным, мине Исмәгыйльгә барырга көндерер өчен күрсәтмәгәннәре калмады.* М.Фәйзи

3) Интонация ярдәмендә ярату, иркәләү, гаҗәпләнү, аптырау, кызгану, әр-шелтә, ризасызлык, канәгатьсезлек һ.б.ш. кебек төрле хис-кичерешләрне көчәйтә. *Әллә шуңа ышандылар инде, и-и малайларның күзе янды, төлке тоталар, имеш. Тоттырыр пычагым!* Н.Әхмәдиев. *Хәдичә ханым да моннан бик канәгать булды. Тора-тора: – И-и, колакларым тынды бит, рәхмәт төшкересе, кызым!.. – дип әйтә башлады.* Т.Нурмөхәммәтов. *И-и-и, ни генә күрми икән адәм башлары!* З.Зәйнуллин

**2.** *иярт.* Газапланып ыңгырашканда, физик яки рухи авыр халәт кичергәндә, елаганда чыккан тавышны белдерә. *Ишетәм! Чынлап та: «И-и-и» дип, бик нечкә генә сузып, әкрен генә елаган тавыш!.. Бала елавына охшаган.* Ә.Еники

**3.** *кис.* 1) Кабатланып килә торган бер үк сүзләр яки синонимнар алдында тәэсирлелекне арттыру өчен кабатлап әйтелә. *Син [Гайнан] бит безнең бердәнберебез, күз өстендә каш шикелле карап кына торганыбыз! И борчылам, и кайгырам синең өчен!* Г.Бәширов

2) *сир.* Шигырьдә иҗек саны тутыру, рифманы саклау, җырны сузып җырлау өчен кертелә. *Быел кискән и утыным, Бар да ярый и казыкка.* Бәет

**И** II Борынгы телдә *ир-* формасында булып, хәзер *иде, икән, имеш, исә* ярдәмче фигыльләре һәм сүзләре составында калган тамыр кисәк

**И-А (И-А-А-А)** *иярт.* Ишәк кычкырган тавышны белдерә. *Ишәк (бакырып). И-а! (кире чигенә).* Н.Исәнбәт

**ИБЕ́-ҖЕБЕ БУЛМАУ** *ф. к.* **ибе-җебе күренмәү**

**ИБЕ́-ҖЕБЕ КҮРЕНМӘҮ** *ф.* Эшнең тәртибе булмау, оешмаганлык, таркаулык хөкем сөрү. *Үзегез, бүген кайтам, дисез, ә үзегезнең бер генә эшегезнең ибе-җебе күренми.* К.Тинчурин

**ИБЕ́-ЯБЕ БУЛМАУ** *ф. сөйл. к.* **ибе-җебе күренмәү**

**И́БИС** *и. гр.* Ләкләксыманнар отрядыннан, муен һәм баш өлешләре урыны-урыны белән йонсыз булган, озын кәкре томшыклы кош. *Ибислар колонияләр булып урта һәм тропик зоналарда киң таралганнар.* Биология

**ИБЛИС** *и. гар.* 1) *дини* Алла каһәренә дучар булып, күктән җиргә сөрелгән, кешеләрне station азьдыру белән шөгыльләнә торган мифик зат. --- *шуннан соң Алланың бер «мордар» бәндәләре, иблис вәсвәсәсеннән котылып, «изге» православие иманына иңгәннәр икән.* Р.Әмирхан. *Төште Иблис җиргә акрын, баш иде: «Менә, менә сезләргә Иблис баш!» – диде.* Ш.Бабич. *Бер абзый көн саен кич курка төннән, Кара төн шайтаны – иблис вә җеннән.* Н.Исәнбәт

2) *куч. тирг.* Башкаларны алдап, котыртып юлдан яздыручы, аздыручы явыз кеше. *Әйтерсең лә яза башлаган повестеннан нindидер иблис аңа таба тискәре импульслар җибәрә, һәм ул кулына тоткан ручкасын атып бәрә.* Ф.Садриев. *Аяк басып каршы алуыгызны сорыйм, хөрмәтле иблис кавемнәре.* Н.Әхмәдиев

◊ **Иблис көчеге** *гади с.* Кешеләрне, бигрәк тә, үзеннән кечеләрне юлдан яздыручы яшь кешегә карата тиргәп әйтелә. *[Әхмәт:] Кайда ул иблис көчеге? [Гөлшаян:] Әнә сандыкта.* М.Әмир. **Иблис ләгыйнь** *сөйл. иск.* Каргалган иблис, явыз зат (тиргәү, әр сүзе). *[Хәнифә:] Нәрсә күңелгә вәсвәсә салып йөри соң бу, иблис ләгыйнь.* Р.Ишморат. **Иблис өмәсе** Җәнҗал, ыгы-зыгы, зур тәртипсезлек. *[Шәйхезаман:] Бу нинди шайтан туе? Бу нинди иблис өмәсе? [Байтирәк:] Менә хәзрәткәем, күр: әчеп кайтканнар.* Т.Гыйззәт. **Иблис өшкергән нәрсә** *гади с. тирг.* Ачы, усал телле кеше; берничек тә игә-юньгә килми торган, начарлыкка чыккан кеше. *Тукта! Тукта, дим, иблис өшкергән нәрсә!* Э.Касыймов. **Иблистән иман сорау** Юк җирдән, булмастайны өмет итү. *Шулай ук һәм гакылсыздан гакыл сорау – иблистән иман сорау – буштан бушка.* З.Бәшири. **Иблис токымы** 1) Иблис нәселеннән булган чибәр, гүзәл зат. *Хатын-кыз гына түгелдер син! Иблис токымыннандыр! Ир-атны гына түгел, фәрештәңне дә юлдан яздырырсың.* М.Хәсәнов; 2) Тыңлаусыз бала-чаганы, я азган, мәгънәсез яшь-җилкенчәкне, явыз, хәйләкәр кешеләрне тиргәү сүзе. *Сезне хәйләгә өйрәтәсе юк инде, иблис токымы бит сез.* Ә.Фәйзи. **Иблис төкереге** *гади с.* 1) Усал, шук-шаян балага ачуланып әйтелә. *– Син, иблис төкереге, чәнчелеп төшмичә, нишләп анда койма өстендә утырасың? – диде мулла.* Ф.Хөсни; 2) Яман, тискәре кеше, үҗәт (ачулану сүзе). *Җанын җәһәннәмгә җибәрәсе карт шайтан, иблис төкереге.* Ш.Усманов

**ИБЛИСЛӘНҮ** *ф.* Азгынлану, бозылу, явызлану

**Иблисләнә бару** Торган саен иблислеге, явызлыгы көчәю

**Иблисләнә бирү** Иблисләнүен дәвам итү

**Иблисләнә төшү** Тагын да иблисләнү

**Иблисләнеп китү** Кинәт иблисләнә башлау

**ИБЛИСЛӘ́Ү** *ф.* Бозыклык, мәкер эшләү, зыян салу. *Мин төкердем дә моны иблисләдем, Пакь шәрапны саф исерткеч эшләдем!..* Ш.Бабич

**ИБЛИСЛЕ** *с.* Иблискә хас сыйфатлардан торган, бозык, явыз, икейөзле. *«Эт кояшы»н язган яшь каләм иясе Достоевский юнәлешен сайлап, адәми затның эчке хасиятендәге караңгы тарлавыкларга, иблисле чоңгылларына кадәр төшәргә сәләтле икәнен раслаячак иде.* Р.Вәлиев

**ИБЛИСЛЕК** *и.* Иблискә хас булган явызлык, икейөзлелек, монафикълык, кара эчлелек. *Аякларың инде җиргә тими Көн ягына таба атларга. «Горур» көчең, «Даның», иблислегең Танк асларында таптала.* Х.Мөҗәй

**ИБЛИ́СЧӘ** *рәв.* 1) Иблискә (*2 мәгъ.*) хас булганча, иблисләр кебек

2) *күч.* Хәйләкәр, мут кыланып, икейөзлеләнеп. *«Шулай да без Газизә белән икәү кайтабыз!..» Гариф, бу сүзләрне әйткәндә, Газизәгә туп-туры һәм дә иблисчәрәк карый иде.* Ш.Камал

**И́БНЕ** *и. гар.* Ул, ир бала. *Мөхәммәт Фатих ибне мелла Зариф әл-Әмирханның юл истәлеге.* Ф.Әмирхан // Гомумән бала. *Ибне адәм кисә торыр – урман халкы үсә торыр.* Мәкаль

◊ **Ибне сәбил** *иск. кит.* Юлчы, мөсафир

**ИБРАҺИМИ ДИННӘР** *и. дини* Борынгы семит халыкларының уртак дини йолалары нигезендә барлыкка килгән, бер илаһны таныган һәм Ибраһим пәйгамбәрнең нәселеннән чыккан пәйгамбәрләргә нисбәт ителгән диннәр (яһүдилек, христианлык, ислам)

**ИБТИДА** *и. гар. иск.* Башланыш. *Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы [шушыдыр].* К.Насыйри

**ИБТИДАИ** *с. гар. иск.* Башлангыч. *Бу икенче дәвер татар теленең сарыфыннан гыйбарәт улып, моның иң садә кагыйдәләреннән беразын ибтидаи өченчедә башлау мөмкин...* Г.Ибраһимов. *Башлангыч мәктәп курсына бәрабәр ибтидаия сыйныфында балалар, гадәттә, 4 ел укый торган булганнар.* Р.Әмирхан

**ИБТИДАЙ МӘКТӘП** *и. иск.* Революциягә кадәр: беренче баскыч мәктәп. *Әхмәт атасын теге әфәнде янынннан алып китте дә, аңар пошыныбрак карап: – Сине, әти, әдәпкә өйрәтер өчен, ибтидаи мәктәпкә бирми ярамый, – диде.* Ф.Әмирхан. *Менә мине мәдрәсә рөшдиен бетереп, русча ибтидаи мәктәпне генә тәмам иттерделәр дә эшкә куштылар.* Ф.Әмирхан

**И́ БУЛУ** *ф.* Җайлы, файдалы, кулай, кирәкле булу. *Су тирегә и булмас.* Мәкаль

**ИГАНӘ** *и. гар.* Фән, сәнгать, дин үсеше өчен һәм мохтаҗларга җәмәгать оешмалары, дәүләт учреждениеләре, шулай ук аерым затлар тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм, булышлык. *Безнең тарихның бу икенче дәверенең, башлыча, матди тәрәге – зур, урта татар байларының иганәләре, һимматләре, юмартлыклары иде.* Г.Ибраһимов

**ИГАНӘ́ ИТҮ** *ф.* Иганә бирү. *Бөтен яшьләр, мөгаллимнәр, шәкертләрне кулларыннан килгән кадәр матди вә мәгънәви иганә итешергә чакырабыз!* Ф.Әмирхан

**ИГАНӘ́ КЕРТҮ** *ф. к.* **иганә итү**. *Иганәне кертмиме соң! Мортаза бай моны бик канәгатьләнеп һәм арттырып эшләде.* Ә.Фәйзи

**ИГАНӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **иганә итү**. *Оренбург байбәтчәләре һәр көн Беловкада, Топольдә җырчы кызларга милләт өчен йөзәр сумлап иганә кылалар.* Ш.Мөхәммәдев

**ИГАНӘЧЕ** *и.* Иганә бирүче кеше

**ИГАНӘЧЕЛЕК** *и.* Иганә эше белән шөгыльләнү. *Мисал – 3 миллион 755 мең сум. Узган елда хәйриячелек, иганәчелек юнәлешендә шушы кадәр акча тотканбыз.* Р.Фәйзуллин. *Иганәчелек хәрәкәте элек-электән татар байлары арасында киң таралган.* Мәдәни җомга

**ИГӘ́-ҖҮНГӘ КЕРТҮ** *ф. к.* **игә китерү** (*1 мәгъ*). *Берничек игә-җүнгә кертә алмагач, көннәрдән бер көнне мин: «Бар, матурым, үзеңнең партияң белән яшә. Минем бүтән чыдар хәлем юк», – дип, өйдән куып чыгардым.* Ф.Яруллин

**ИГӘ́ КЕРТҮ** *ф.* 1) *к.* **игә китерү** (*1 мәгъ*). *Күрше авыллардан яхшы түгел, бөтен колхозлары белән бер юньсезне дә игә кертә алмадылар, диярләр.* Г.Сәгыйдуллин. *Хәсбулыч, кызыл тышлы блокнотын селки-селки: – Әйтергә туры килә. Син киребеткәнне шунсыз игә кертеп булмас, – дип, өскә таба атлады.* Р.Бәшәр

2) Көйләү, рәтләү, төзәтү. *Камера шартлаган. --- әгәр җилем булса, берике сәгать эчендә игә кертеп булыр иде.* А.Шамов

**ИГӘ́ КЕРҮ** *к.* **игә килү** (*1 мәгъ*). *– Иремне әти-әнисе үз вакытында ныграк тотмады, ни эшләсә дә, үзләре ирек бирделәр. Бәлки, игә дә кергән булыр иде, каты тоткан булсалар, – диде Гөлия ханым, уфтанып.* Ф.Тарханова

**ИГӘ́ КИЛҮ** *ф.* 1) Кешеләр киңәшенә, үгет-нәсыйхәтенә колак салып, аны кабул итеп, холык-фигыльне уңай якка үзгәртү, яхшырту, җайлау, яраклашу, тыңлаучанга әйләнү. *Үзе нинди таза, нинди көчле, нинди матур җыру җырлый инде югыйсә, үзе шул җырларыннан соң һич игә килә алмый.* К.Миңлебаев. *Әгәр сөю гөнаһ булса, гөнаһларым әз түгел. Гөнаһ, дими, тәүбә белми, Игә килми бу күңел.* К.Булатова. *Улының игә килүе, инсафлылык саклап сөйләшүе, ниһаять, бу фани дөнья хәятының буразнасына дөрес кереп китүе бик шатландырды аны.* С.Поварисов

2) Ипкә, җайга килү, җайлылану. *Югыйсә ирләр алар, бер тайпылса, ике елсыз игә килми.* М.Маликова. *Шуннан соң туксан килолы хатыным игә килеп калыбына утырмасынмы, майлап куйган кебек!* З.Фәйзуллин

3) Хәл яхшыру, терелү, сихәтләнү. *Арба кендеге белән башына сукканнар. Шуннан игә килә алмады инде ул...* Ә.Хәсәнов. *– Имче баба, мин кайда? – Менә игә килдең, углан. --- Тиздән аякка басарсың. Син безне, атаң Әтрәк бәкне шактый хафага салдың.* Т.Нәбиуллин

4) Рәткә килү, рәтләнү, уңайлану, көйләнү (җансыз әйберләр турында).

**ИГӘ́ КИТЕРҮ** *ф.* 1) Кемнең дә булса холык-фигылен яхшырту, үзара

мөнәсәбәттә ипле итү, күндерү, җайлап, тәртипкә кертү. *Монда хәзерге хәлләр шәптән түгел әле. Саматны, уртак күршебезне әйтәм, һич игә китерә алмыйбыз шуны.* З.Фәтхетдинов. --- *балаларына-оныкларына тырнак белән дә чиртмичә, сүз белән игә китереп үстерде.* Рифә Рахман. *Табиблар белән шәфкать туташлары, --- баласын алырга теләмәгән ананы игә китерер өчен, кулларыннан килгәннең бөтенесен эшлиләр.* Сөембикә

2) Берәр нәрсәне рәтләп төзәтү, яхшырту, әйбәт, уңайлы итү. *Алабута карабодайны баскан әле анда. Аны шыгырдап кына игә китерә алмассың.* Ф.Бурнаш. *Әтисе исә әнә шул буйсынмас көчләрне җиңеп, игә китереп, асыл бизәкләр, асыл сурәтләр тудыручы гали бер зат булып тоела Гөлйөземгә.* Ф.Латыйфи. *Биш-ун ел буена уртакул тәрҗемә кулъязмаларын игә китерергә тырыштым.* Казан утлары

3) Терелтү, хәлен яхшырту. *«Инде син мөртәтне ашатып-ашатып та игә китерә алмасам, мин сине чынлап та мөфтинең мәргәненнән укка алдырачакмын», – диде Айбиби каракошка, якын кешесен орышкандай итеп.* М.Хәбибуллин

**ИГӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **игәү** I

2) *күч.* Борчылу, интегү, йөдәү. *Каршылыклы уйлардан игәлү*

**Игәлеп бетү** Бөтенләй игәлү; тәмам игәлү

**ИГӘР** *и. диал.* 1) Ау эте

2) *күч.* Ялкау кеше

**ИГӘРЕШҮ** *ф. диал.* 1) Талашу, ызгышу, әрләшү. *Яман белән игәрешкәнче, яхшы белән киңәш.* Мәкаль

2) *күч.* Шаяру, тик тормау

3) *күч.* Киреләнү, карышу

**ИГӘРЧЕ** *и. диал.* 1) Күәс төбеннән кырып алынган камырдан ясалган кечкенә ипи; кырындык. *Арыш икмәге пешергәндә, икмәкләрне әвәләп бетергәч, күәс чиләгенең төбендә, кырыйларында ябышып калган камырларны җыештырып, оештырып, бер кечкенә икмәк ясыйлар. Шул кечкенә икмәк «игәрче» аталадыр.* Г.Сәгъди

2) Хәерчегә бирер өчен, кечкенә итеп әвәләнә торган ипи, вак ипи

**ИГӘРЧЕЛЕК** *с. диал.* Игәрче пешерү өчен калган, шуңа гына җитәрлек. *Игәчем өенә барганчы, игәрчелек он тартырмын.* Мәкаль. *Бер игәрчелек арыш камыры*

**ИГӘТ** *и. диал.* Кызга ата-анасы ягыннан кияү йортына алып барырга бирелә торган мал

**ИГӘ́Ү** I *и.* Нәрсәнеңдер өслеген кырып шомарту, үткерләү яисә кисеп чыгару өчен, тешәлгән сырлы металл кисәгеннән гыйбарәт эш коралы. *Сөякләре сызлап, җаны сыкрап, Игәү белән кыргандай була.* М.Гафури. *Мич өстенә һәрбер кара мунчадагыча гади таш өелгән, таш араларында сынык кендек, ватык йозак, шомарган игәү кебек тимер-томыр күп иде.* Г.Гобәй

**ИГӘ́Ү** II *ф. к.* **игәүләү**. *Әти пычакларны үзенә бер көйгә җырлатып иги, чарлый, кайрый.* М.Галиев. *Тагын шикшөбһә җанны иги.* Н.Хәсәнов. *Бичә көн дә аның өчен мине иги. Имеш, бала тәрбияләү белән шөгыльләнмим, ата-аналар җыелышына йөрмим.* М.Сәлимов

**Игәп тору** Бертуктаусыз игәү. *Үскән саен, кеше булган саен Игәп тора бала күңелеңне.* Ә.Ерикәй. *Әнисе, әшсез ятма, дип, гел игәп тора, диләр.* Х.Камалов. *Ә инде көн саен игәп торуга тиреӊ җиде катлы булса да түзмәячәксең, үзеңнең дә ир кеше икәнлегеңне күрсәтергә тырышачаксың.* Ф.Яруллин

**Иги башлау** *к.* **игәүли башлау**. *Әмма беләм: шушы минуттан минем бәгырьне билгесезлек иги башлаячак.* Ә.Еники

**ИГӘҮЛӘ́Ү** *ф.* 1) Игәү белән ышкып, нәрсәнең дә булса өслеген шомарту, кайрау, тигезләү. *Мохтар өйдән чыгып барганда, Гыйльмулла кухня ягында иске әчкечләр игәүләп утыра иде.* Ш.Камал. *Аннары, трюмо алдына утырып, тырнакларын игәүләп лакладЫ, чәчләрен тарап матурлап куйды.* З.Фәйзуллин. *Алар янына, кулына кыскарак кына саплы җиңел чалгы тотып, Зәйтүнә килеп туктады. – Игәүләп кенә бир әле, Барис абый? – диде ул.* Н.Фәттах

2) *күч. сөйл.* Кемне дә булса туктаусыз әрләү, шелтәләп тору. *Йөрәк булып та тибә, Сабый булып та имә. Булмый аны йөгәнләп, Игә килми игәүләп.* Х.Бәдигый

3) *күч.* Борчып тору, тынгылык бирмәү

**Игәүләп алу** Тиз генә игәүләү. *Балам гариплеген яшерергә, Ипләп маташканда икәүләп, Оста, аның үткен тешен күреп, Җәһәт кенә ала игәүләп.* Ф.Шәехов

**Игәүләп бетерү** 1) Игәүләү эшен тәмам итү

2) *күч.* Тәмам игәүләү, теңкәсенә тиеп бетү

**Игәүләп кую** Игәүләп әзер хәлдә тоту. *Җитмәсә, пычкыны алдан бик нык үткерләп-игәүләп куйган иде әти кеше.* С.Поварисов

**Игәүләп тору** Әле, күз алдында игәүләү; бертуктаусыз игәүләү. *Күңелен игәүләп торган галәмәтнең Зөлфия икәнен танырга теләмәде.* Т.Галиуллин. *Хатыны бертуктаусыз игәүләп торуыннан бичара Әбелгәрәйнең колаклары шаулый башлады.* И.Хәйруллин. *Җәмилә әби генә Касыйм бабайны адым саен игәүләп торды.* Д.Гайнетдинова

**Игәүләп үтү** *к.* **игәүләп алу**. *«Бәлки, башым белән бәрелеп, бу туташка берәр нәрсә вәгъдә иткәнмен. Мин аның белән йокламадыммы икән?» – дигән ямьсез уй миен игәүләп үтте.* Т.Галиуллин

**Игәүли башлау** Игәүләргә тотыну. *Тимергалиев председательгә урын-мазар тәкъдим итмәде, аны «келәмгә бастырып», тып-тын калган бүлмәдә игәүли башлады.* Г.Ахунов

**ИГӘЧ** *и. диал.* 1) Бертуган апа, үзеңнән олы кыз туган. *Игәчем өенә барганчы, игәрчелек он тартырмын.* Мәкаль

2) Бертуган апа яки сеңел. *Кайнишләрем – кан кыйгычларым, үз игәчләрем – сер белгечләрем.* Җыр

3) Туганнан туган кызлар

**ИГӘЧЛЕ-СЕҢЕЛЛЕ** *с. диал.* Апалы-сеңелле. *Игәчле-сеңелле туганнар белән кунакка йөрешү*

**ИГӘ-ЧӨЙГӘ КИЛҮ** *ф. к.* **игә килү**. *Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә-чөйгә китерер хәл юк.* Г.Камал

**ИГӘ́-ЮНЬГӘ КИЛҮ** *ф.* Тәртипкә күнү, холык-фигылен уңай якка үз-

гәртү, йомшару, әйбәткә әйләнү. *Шул бәдбәхет Шөҗәчка катнашканнан бирле, --- [Әхмәтнең] һичбер игә-юньгә килгәне юк.* Г.Камал

**ИГЕ** *с. иск.* Яхшы. *Атадан ул туса иге, ата юлын куса иге, биленә садак буса иге, битенә килер оятны үзе белән юса иге; шушыларны кылмаса, барыннан да югы иге.* Мәкаль

**ИГЕЗ** *с.* 1) Бер анадан бер үк вакытта туган. *Ана сөтен аера имә Бала игез булмаса.* Дәрдемәнд

2) *күч.* Тигез, бертөрле, бердәй. *Якты бирдең һәр кешене игез күреп.* М.Гафури

**ИГЕЗӘК** *и.* **1**. 1) Игез туган балаларның берсе. *Надрюков уйнаган Осип, Шамуков уйнаган Хлестаковка игезәкләрдәй охшаган: чиләгенә күрә капкачы инде, әйтәсе дә юк.* Татар совет театры. *Ибрай кул астына туры килгән беренче кызны – игезәкләрнең берсен этеп җибәрде.* Г.Гобәй

2) Зодиак йолдызлыгының 21 май – 23 июньгә туры килгән вакыт аралыгы һәм шул арада туган кешеләр; җәүза

**2.** *с. мәгъ. к.* **игез** (*1 мәгъ.*). *Игезәк бала үстерү авыр, диләр иде, болар икесе бер бала караган шикелле дә булмады.* Р.Вәлиев

**ИГЕЛЕК** *и.* 1) Яхшылык, миһербанлылык, киң күңеллелек. *[Ләлә:] Игелек күр! Бер ятим баланы карашуың өчен рәхмәт яусын үзеңә! Ходай теләкләреңә ирештереп, бәхетеңне яр итсен!* М.Фәйзи. *Алдаш карт өскә калыкты: «Килен! Факиһә кызым, ашыгыз бик тәмле булган. Бик рәхмәт, кулларыгызның игелеген күрегез».* Р.Батулла

2) *күч.* Рәхәтлек, тыныч тормыш. *[Мәзин:] Игелек күрер җире калмаган инде аның, хәзрәт, үзем күрдем кичә.* Н.Исәнбәт. *Хода Тәгалә биргән дәүләтеңнең игелеген күреп, кинәнеп яшәргә язсын.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Файда, мәнфәгать. – *Сиңа игелеккә әйтәләр, ә синең үз туксаның туксан, – диде кыз.* М.Хуҗин

◊ **Игелек кайтару** Яхшылыкка каршы яхшылык эшләү. --- *сезнең игелегегезне кайтарырга кулымнан килмәгәнлектән, мин оялам.* Ш.Камал. **Игелек(ген) күр** 1) Алган әйбереңнең, бирелгән бүләкнең рәхәтен күрергә язсын, дип әйтелгән теләк сүзе; 2) Яхшылык күрсәткән, ярдәм иткән кешегә, бу яхшылыгың сиңа да яхшылык булып кайтсын, дигән мәгънәдә рәхмәт әйтү сүзе. **Игелек күргере** 1) Яхшы тормыш, рәхәтлек теләп әйтелгән теләк сүзе; 2) Кешеләргә, балаларга, хайваннарга, ачу килгән вакытта, начар сүз әйтүдән тыелып, үзеңнең канәгатьсезлегеңне, үпкәңне яхшы теләк белән белдерү сүзләренең берсе. *[Крестьян атка:] Әйдә, әйдә, рәхмәт төшкере! Тарт инде, игелек күргере.* К.Тинчурин. **Игелек күрсәтү** 1) Яхшылык итү, рәхәт тормышта тоту. *Бала чагыннан бирле кадерләп, тәрбияләп үстергән җизнәсенә шундый явызлык эшләгәнне, туган анасына да ул игелек күрсәтмәс.* Р.Ишморат; 2) Файда китерү. *[Бодайларның] Кайсы яньчелгән, кайсы сынган, кайсы-берсе бик чирләшкә. Андыйларның күбесе тишелсә дә, игелек күрсәтмәс иде.* Г.Бәширов

**ИГЕЛЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Файда күрү. *Мин ул җирне саруттан арындыра алмыйча, өч сука калагы сындырдым. Ул [Аптул] игелекләнсен, дип сындырдыммыни мин ул калакларны?* Ф.Хөсни

2) Рәхәт күрү, рәхәтләнү. *Гомере буе ат җигеп игелекләнмәгән, ул тайның тиздән тәртә арасына керерлек булуын уйлап куана.* С.Рафиков

**Игелекләнеп калу** Мөмкинлек булганда игелеген күрергә өлгерү

**ИГЕЛЕКЛЕ** *с.* 1) Игелек китерә торган, киң күңелле, яхшы, миһербанлы. *Кыен, чөнки бу фидакяр, олпат затның кылган игелекле гамәлләрен санап кына чыгу да байтак урын алыр иде.* Р.Әмирхан. *Балаларына йомшак, ягымлы, кирәгенчә таләпчән һәм каты куллы, иренә игелекле һәм тугры хатын була белде.* Ф.Латыйфи

2) Файдалы, изге. *...К.Мотыйгый-Төхфәтуллин татар дөньясында беренче булган әдәби-иҗтимагый журнал «Әлгасрел-җәдид»не мәйданга кую буенча игелекле эш башкара.* Р.Әмирхан. --- *бу игелекле кешеләрнең (Мотыйгулла, Гыйззинас) һәр ике малайга да җылы йон оекбаш җибәргәннәре мәгълүм.* Ф.Галимуллин. *Игелекле гамәлләрнең асылы да – мәхәббәт.* Сөембикә

3) Бәрәкәтле. *Көзге-карлы яңгырлар башлану белән, Украинаның игелекле җире дә үзенең матурлыгын югалта.* Ә.Айдар

**ИГЕЛЕКЛЕК** *и.* Файда. *Бик арык нәрсә икән ләбаса бу. Сәвабы өчен генә алмасаң, бүтән игелеклеге юк моның.* М.Шабай

**ИГЕЛЕКЛЕЛЕК** *и.* Игелекле булу; игелек. *Бу вакытта инде без тәмам таркалып, бер-беребезнең язмышына тәмам битараф булып, өзеп кенә әйткәндә, чын новаторлык, игелеклелек, киң күңеллелек кебек сыйфатларыбызны тәмам югалтып бетергән идек...* Г.Рәхим. *Бертуганыгыз сезгә үз ирке белән биргәнне алыгыз. Һичкем дә башка берәүдән өстен түгел, эш фәкать игелеклелектә генә.* Идел

**ИГЕЛЕКСЕЗ** *с.* 1) Яхшылыкка яманлык белән җавап бирүче. *Бәлки, балалары игелексездер, дип уйлар идең, үзенең әйтүенә караганда, алар аның өчен үлеп торалар, имеш.* М.Шабай

2) Булдыксыз, юньсез, тәрбиясез. *Игелексез кеше син, Борһан. Кешеләр әнә тиздән уянып, эшкә тотынырлар, ә син адәм җанын үртәп яшәвеңне генә беләсең.* М.Шабай

3) Файдасыз, бәрәкәтсез. *Тик былтыр нигәдер игелексез ел булды.* Г.Бәширов. *Игелексез хезмәт. Игелексез җир*

**ИГЕЛЕКСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Игелексез булып китү, игелек китерми торган кешегә әверелү

**Игелексезләнә бару** Торган саен ныграк игелексезләнү

**Игелексезләнеп алу** Берара игелексезләнү

**Игелексезләнеп бетү** Бөтенләй игелексезгә әйләнү

**Игелексезләнеп йөрү** Соңгы вакытта игелексезгә әйләнү

**ИГЕН** *и.* 1) Орлыкларыннан он, ярма әзерләнелә торган бөртекле, кузаклы яки техник культура. *Яз көннәре чәчкән игеннәрең Үскәч, көзен рәхәт ашарсез.* М.Гафури. *Бу алтын игеннәр табигать мәрхәмәте буенча гына үсмәгән бит, аларны кеше үстергән.* Г.Әпсәләмов

2) Шул үсемлекнең орлыгы; ашлык. --- *күмгән җирдән аның күп игенен табып, шуның өчен аның үзен төрмәгә ябып, йорт-җирләрен, бөтен нәрсәләрен конфисковать иттеләр.* М.Гафури. *Иң ахырдан, караңгы төшә башлагач, шыгыр-шыгыр итеп, озын-озын кәрваннар кебек, иген төягән, ат, сыер таккан чувашлар, руслар, типтәрләр килә башлыйлар.* Г.Ибраһимов. *Мәүлиха түти әле сугылмаган, бер өлеше ындырга да керэп җитмәгән игенне алай алдан-ала бүлгәләп ташлауны ошатмый иде булса кирәк.* Г.Бәширов

3) Шундый культура үсеп утыра торган басу. *Кайдадыр игеннәр арасында өзеп-өзеп бер тартар кычкыра, уң яктагы куаклыкта мәче башлы ябалак, нәкъ эт баласы кебек чыелдап, әллә елый, әллә сайрый.* А.Шамов. *Киң кырларда үсә шул игеннәр! Шаулап ага чиксез елгалар.* Ә.Исхак

4) Иген үстерү эше, игенчелек. *Чөнки, ни әйтсәң дә, иген игеп көн күрә торган вакыт түгел ич, сөрә башласаң – аты, чәчә башласаң орлыгы юк.* М.Шабай. *Бабайлар әйтмешли, иген эшенең кайбер көне елга җавап бирә.* Ш.Камал. *Тимери «Ничек булыр икән соң, килеп, иген эшенең тәмен белерсеңме икән син?» дигән сыман, сүзсез генә Нәфисәгә карап торды.* Г.Бәширов

◊ **Игенгә бәрәкәт, җанга саулык** Яңа ашлык-иген өлгергәндә, шулай ук Сабантуй, җыеннарда авыл кешеләренең бер-берсен котлау әйтеме. **Иген чүмәләсе** *гади с. шелт.* Рухи тормышы ярлы, мәгърифәтсез, культурасыз кеше. *Безнең сеңелләр дә, энеләр дә бар. Аларны да карарга кирәк. Ә картларга гына калдырсаң, алар үзләре кебек иген чүмәләсе итеп үстерәләр дә, бетте.* Ф.Бурнаш

**ИГЕН-АШЛЫК** *җый. и.* Ашлык, игеп үстерелгән һәртөрле икмәк. *Мин иген-ашлык сукканда, көлтәләр ярсып сикерәләр.* З.Бәшири

**ИГЕ́Н ГӨМБӘСЕ** *и. а.х.* Ашлык бөртекләрен зарарлап, кара тузанга яки кибәккә әйләндерә торган гөмбә авыруы; корымбаш; *русчасы:* **головня**

**ИГЕН-ИКМӘК** *җый. и. к.* **иген-ашлык**

**ИГЕ́Н КОҢГЫЗЫ** *и. а.х.* Икмәк культураларына зур зыян сала торган корткыч коңгыз; *русчасы:* **кузька**

**ИГЕНЛӘТӘ** *рәв.* Иген белән, иген биреп. *Эш хакын игенләтә түләү*

**ИГЕНЛЕ** *с.* 1) Икмәкле; игене булган, игенгә мул, бай. *Игенле байның исе бар, игенсез байның нисе бар?* Мәкаль

2) Иген уңа торган, уңдырышлы. *Актаныш – игенле як.* Н.Дәүли

**ИГЕНЛЕК** *и.* **1.** Иген чәчелгән яки чәчелә торган җир; кыр, басу. *Бу атаанасыз балаларга игенлекләрдән, кырлардан бер-ике бөртек орлык булса да китереп бир.* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* Иген чәчелгән яки чәчелә торган. *[Аның] Өч йөз дисәтинәгә якын игенлек кырлары бар.* Г.Ибраһимов

**ИГЕНЛЕКЛЕ** *с. сир. к.* **игүле**. *Су кырыйларындагы игенлекле җирләрдән аерылдык.* Г.Сәгъди

**ИГЕ́Н ТАРАКАНЫ** *и. а.х. к.* **иген коңгызы**

**ИГЕН-ТАРУ** *җый. и. к.* **иген-ашлык**. *Татар сөйләшләрендә «язы» һәм «уй» сүзләре бер үк вакытта уйсулыкны да, иген-тару басуын да белдерәләр.* Р.Әхмәтьянов. *Иген-тару җыелып беткәч, бөтен авылны шаулатып туй иттек.* Г.Ибраһимов. *Кичкырын, көн кызуы сүрелгәннән соң, башка карткортлар кебек Тимери агай да, капка төбенә чыгып, көтү кайтканчы, узганбарган белән иген-тару, явым-чәчем, --- Кытайдагы хәлләр турында картларча вәземләп әңгәмә корырга ярата.* Г.Бәширов

**ИГЕН-ТИГЕН** *җый. и.* Игеп үстерелә торган һәртөрле культуралар, икмәк. *Быел иген-тиген бик уңды. Иген-тигенне югалтуларсыз җыеп алу*

**ИГЕН-ҮЛӘН** *җый. и.* Игүле культуралар һәм үлән үсемлекләрнең барчасы. *Иген-үлән көйгән кытлык елларда, тамак ялгарлык урын эзләп, шәһәргә килгән --- сала кызларының хәле тагы да авыррак булган.* К.Нәҗми

**ИГЕН-ЧӘЧЕМ** *җый. и.* Кырларга, басуларга чәчелгән иген. *Тары чәчегез быел. Башка иген-чәчем, белмим, уңмастыр.* Р.Төхфәтуллин

**ИГЕНЧЕ** *и.* **1.** Төп кәсебе иген, икмәк үстерү булган кеше. *Тәҗрибә күргән гакыллы игенче, үзенең уллары алдында тырышып эшләүнең төкәнмәс бер хәзинә хөкемендә икәнлеген балаларына киная белән аңлаткан иде.* Дәрдемәнд. *Шатланыр безнең игенчебез Матур, җылы яңгыр яуды исә.* М.Гафури. *Күкнең эссе кояшы, бөтен дөньяны, бөтен табигатьне чолгап алган яз шатлыклары игенченең өметләренә, дәртләренә куәт бирәләр.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Иген игү белән шөгыльләнә торган. *Гарәп сәяхәтчеләре шул чорда Дон һәм Идел буйларында, Болгар биләмәләрендә күпсанлы игенче кыпчак авыллары барлыгын хәбәр итәләр.* Р.Әхмәтьянов

**ИГЕНЧЕЛЕК** *и.* Авыл хуҗалыгының иген үстерү, җир эшкәртү белән шөгыльләнә торган тармагы. *– Иптәш Дунаев, без менә авыл хуҗалыгы коммунасы оештырдык, – диде Әхмәт, – игенчелек, бакчачылык, мал асраучылык...* Ш.Камал. --- *корбан-келәү йола бәйрәмнәре, шулай ук җир эшкәртүгә һәм игенчелеккә кагылышлы ритуалбәйрәмнәр – барысы да халык календареның состав өлешен тәшкил иткәннәр.* М.Бакиров. *Төркиләр арасындагы сугышлар бераз басылгач, X–XIII гасырларда күп кенә кыпчак кабиләләре һәм ырулары игенчелек белән шөгыльләнә башлый.* Фән һәм тел

**ИГЕ́-ЧИГЕ БУЛМАУ** *ф.* 1) Очсыз-кырыйсыз, чиксез булу. *Гүя илаһи бер кул белән Җир йөзендәге һәммә биналар, ташлар каядыр алынды да анларның урынында иге-чиге булмаган бакча хасил булды.* Г.Ибраһимов

2) Гаять күп, исәпләп бетергесез, исәпсез булу. *Бер елдан соң җиләкҗимешнең иге-чиге булмаячак бездә.* И.Гази

**ИГЕ́-ЧИГЕ КҮРЕНМӘҮ** *ф.* 1) Очы-кырые булмау. *Монда зур диңгез: иге-чиге күренмәгән ак кар диңгезе иде.* Г.Ибраһимов

2) Күпсанлы, исәбенә чыга алмаслык булу. *Далада кышлаган мал-туарның иге-чиге күренми*

**ИГЕ́-ЧИГЕ ЮК** *к.* **иге-чиге булмау**. *Бу кытыршы салкын тимерне тизрәк «дошман» өстенә ыргытасы, тизрәк аннан котыласы, бу иге-чиге*

*юк төсле тоела башлаган мәхшәрле көнгә чик куясы килә.* Р.Вәлиев. *Унынчы классны алар бергә, бер мәктәптә, бер класста тәмамладылар. Яратышуларының иге-чиге юк иде.* Г.Рәхим

**И́ГРЕК** *и. лат.* Латин алфавитында «у» хәрефенең исеме. *Әлбәттә, бу борынгы [латин] хәрефләрнең шактыен танып белә идек инде: эпсилон, игрек...* Э. Касыймов

2) Билгесез зурлыкның шартлы билгесе. *[Сәгыйдә:] Шул икслар белән төн буе сөйләшеп утырдыңмы? [Камил:] Юк. Игреклары белән дә ара-тирә сүз көрәштердем.* Һ.Такташ

**ИГУА́НА** *и. исп. зоол.* Җылы якларда яши торган озын койрыклы елан

**ИГУ́МЕН** *и. гр.* Ирләр монастыреның башлыгы. *Һичбер [кеше] ул күлләрдән игумен рөхсәтеннән башка балык тота алмый.* К.Нәҗми

**ИГҮ** *ф.* 1) Бөртекле культураларны чәчеп үстерү. *Ул [Нурҗиһан] анда чөгендер игү эшләрен машинага көйләү турында сөйләүчеләрне аеруча әһәмият биреп тыңлады.* М.Ханнанов. *[Сәләхетдин] Җимертеп эшли, нәкъ шахтадагыча: җирен сөрә, игенен игә.* К.Миңлебаев. *Башка яшәү урыннарындагы шикелле үк биредә дә халык гомер-гомергә иген игә ---.* Т.Галиуллин // Яшелчә үсемлекләре чәчеп үстерү. *Менә бернинчә ел инде җиде кешелек звеноны җитәкләп, Голландия технологиясе белән мөстәкыйль рәвештә бәрәңге игә Азат.* Т.Нәҗмиев. *Татар хатыннары йорт башыннан кеше исәбендәге ният белән чөгендер игә.* Ә.Гаффар

2) Үстерү, булдыру, барлыкка китерү. *Киттек, әйдә, кырлар буйлап, киләчәк көннәрнең шатлыгын игәргә!* К.Нәҗми

**Игә башлау** Игәргә тотыну. *Беренче елларда шалкан чәчеп үстергәннәр, ә соңга таба бөртекләләр игә башлаганнар.* Р.Юсупов. *Дәрте очындырып-очындырып йөртә. Кияүгә чыккач, балалар игә башлагач, ул да салмакланыр.* Ш.Галиев

**Игеп килү** Элек-электән, борынгыдан, даими игү. *Ничә йөз еллар буена җир сөреп, иген игеп килгән бит безнең бабайлар.* В.Нуруллин

**Игеп тору** Һәрвакыт, гел игү

**ИГҮЛЕ** *с.* Игелә торган. *Игүле үсемлекләр*

**ИГҮЛЕК** *и.* Иген игелә торган җир, кыр, басу. *Халык, игүлек җирләрен, өйләрен ташлап, ә балаларын исә залог калдырып, туган якларыннан качып китәргә мәҗбүр була.* М.Гайнетдин

**ИГҮЧЕЛЕК** *и.* Иген игеп көн күрү, иген үстерү эше

**ИГЪДАДИ** *с. гар. иск. пед.* Революциягә кадәрге чорда татар мәдрәсәләрендә урта белем алган шәкертләрне югары уку йортына әзерли торган. --- *тел вә әдәбиятның гүзәл нәмунәләреннән җыелып ясалган әдәби хрестоматияләр һич өзлексез рөшди вә игъдади буена сузылып баралар.* Г.Ибраһимов. *Урта белем мәсьәләсенә килгәндә, аны алу, кагыйдә буларак, ике-өч, кайвакытларда хәтта дүрт баскычтан торган мәдрәсәләрдә уку белән бәйләнгән: 1) башлангыч (ибтидаия), --- 3) урта (игъдадия) ---.* Р.Әмирханов

**ИГЪЛАН** *и. гар.* Берәр нәрсә турында газета-журналга, сайтка урнаштырылган яки стенага эленеп куелган белдерү. *«Идел»дә Тукайның «Җан азыклары» исемле китабы басылып чыгып сатыла башлавы турында игълан бирелгән.* Г.Камал. *Игълан – мәшруг. Һәрбер сатучы үзенең малын дөньяга теләгәнчә фаш итәргә, маһиятне тәгъриф кыйлырга хаклы.* Г.Ибраһимов

**ИГЪЛА́Н ИТҮ** *ф.* 1) Хәбәр итү, белдерү. *Кич белән ячейка җыелышы буласын Мостафа иртәдән үк һәммә членнарга игълан итте.* Ш.Камал

2) Рәсми рәвештә белдерү. *Кичә безнең сөйләүләр өлеше бетеп, тәнәфес игълан иткән вакытта, безнең күңелләр артык күтәренке иде.* М.Әмир. *Әти анда, ачыктан-ачык игълан итеп, үзенең муллалыгын ташлавы турында яза.* А.Расих. *Ә хәзер, бу төр җитештермәне безгә җибәрүче заводлар урнашкан дәүләтләр бәйсезлек игълан иткәч, эш бөтенләй дә мөшкелләнде.* Мирас

3) Дөньяга чыгару, бастыру

**ИГЪЛА́Н КЫЛУ** *ф. к.* **игълан итү**. *Эстетика фәне сәнгать өчен мәңгелек кануннар сызып игълан кыйлмый, бәлки сәнгатьнең тарихи үзгәрешләрен тудыра торган мәңгелек кануннарны эзләргә, өйрәнергә генә тырыша.* Г.Ибраһимов. *Берәр төрле эш хакында гаепләнүче һәм өсләренә түләүләр төшкән мөселманнар чукынсалар, гаепләреннән коткару, түләүдән азат итү хакында кануннар игълан кылынды.* Р.Әмирхан

**ИГЪЛАННАМӘ** *и. гар.-фар.* Белдерү кәгазе

**ИГЪЛАНЧЫ** *и.* 1) *тар.* Борынгырак заманнарда: берәр вакыйга булачагын яки югары дәрәҗәдәге кешенең килүен алдан хәбәр итеп йөрүче кеше. *Игъланчы керә: «Әрчелегез юлдан, квиритлар! Бөек диктатор Сулла хатыны – Валерия Мессала килә!»* Н.Исәнбәт

2) Игълан, афишалар бастырып таратучы. *Матбугат дөньясы вәкилләреннән игъланчы, календарьчы Шәрәфетдин Шәһидуллин беренче була.* И.Рәмиев // Игъланнар, афишалар язучы, ясаучы кеше. *Г.Тукай, Казанга килгәч, --- игъланчы булып та эшли.* Н.Исәнбәт

**ИГЪТИБАР** *и. гар.* 1) Фикерләү, күрү, ишетү сәләтенең бер ноктага төбәлүе; дикъкать. *Равил, күзләрен радиоалгычтан алмаса да, бабасының сүзләрен игътибар белән тыңлады.* А.Әхмәт. *Секретарь, Хәйдәрнең җанлана барган йөзенә ара-тирә күз салгалап, зур игътибар белән тыңлый иде.* Г.Бәширов. *Нургали дә Нуретдин абзыйның йон уңаена сыйпагандай итеп кенә сөйләвеннән бераз тынычлангандай булды һәм аның гыйбрәтле сүзләрен бик игътибар белән тыңлап утырды.* Ә.Еники

2) Ихтирамлы мөнәсәбәт, хөрмәт. *Нуруллин, аның игътибарыннан, аның җылы йомшак мөгамәләсеннән --- ничек тынычланып, авыруын, сызлануын онытып ята.* А.Шамов

3) Абруй, дәрәҗә. *Башка казармаларның халыклары арасында боларның игътибары юк. Һәммәсе «ташландыклар» дип хисапланалар.* Ш.Камал

◊ **Игътибар бирү** 1) Әһәмиятле саналу, илтифат итү. *Гасыр башы әдәбиятын этрафлы өйрәнгән күренекле галим И.Нуруллин әлеге мәсьәләгә махсус игътибар биреп, шул рәвешле фикер*

*йөртә...* Ф.Бәширов. *Әдип-публицист М.Гафури иҗатына зур игътибар бирә, аны [Г.Тукай] 1905 елгы революция ташкынында күтәрелеп чыккан бөек шагыйрьләрнең берсе дип саный.* Ф.Әгъзамов. *Алда торган максатлар турында сөйләгәндә, ПИЧ рәисе быелгы халык санын алу кампаниясенә татар милли хәрәкәтләренең әзерлегенә һәм аны оешкан төстә үткәрүгә бәйле мәсьәләләргә аеруча игътибар бирде.* Мәдәни җомга; 2) Хөрмәтләү, кайгыртучанлык күрсәтү. **Игътибарга алу** 1) Әһәмият бирү, кабул итү. *Анасының караңгы торачагын белгән хәлдә, анасының күз яшьләрен игътибарга алып, аз көнгә булса да, өйгә кайтып китүне тиеш тапты.* Г.Ибраһимов; 2) Исәпкә алу, истә тоту. *Сез, безнең элекке иң актив членыбыз булуны игътибарга алып, безнең соравыбызны кире какмассыз, дип ышанабыз.* Ш.Камал. **Игътибар иясе** Хөрмәткә лаек кеше. **Игътибар үзәгендә тотылу** *к.* **игътибар бирү**. *Аннары шул проблеманың, шул идеянең гәүдәләнеш чаралары (формасы, теле, стиле һ.б.) игътибар үзәгендә тотыла.* Ф.Әгъзамов

**ИГЪТИБАРӘН** *рәв. гар. иск. кит.* 1) Башлап, шуннан башлап. *Менә шул вакыттан игътибарән безнең тормышыбызда бертөрле үзгәрү сизелә башлады.* Ш.Камал

2) Игътибар итеп, искә алып, илтифат күрсәтеп. *Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем игътибарән, --- һәр йорт иясе дә буялган кукәй бирәләр иде.* Г.Тукай

**ИГЪТИБАРЛЫ** *с.* 1) Дикъкатьле, игътибар белән карый торган, кызыксынучан. *Ул яшь натуралистларга юлда очраган һәммә нәрсәгә игътибарлы булырга куша иде.* М.Кәримов. *С.Баязидов квартирасында булуын канәгатьләнү хисе белән искә ала Тукай. С.Баязидов аңа игътибарлы була.* Ф.Әгъзамов

2) Кайгыртучан, кеше хәлен аңлаучан, ярдәмчел. *Янында чакта аңа карата игътибарлы була алдымы, юк-бар белән теңкәсенә тиеп рәнҗетмәдеме?* Г.Ибраһимов. *Аның ягымлы, игътибарлы булуы һәм сәләте турында хәтта легендалар йөри.* Г.Әпсәләмов. *«Ялган революционерлар»дан Мирвәли йомшак күңелле, кешеләргә игътибарлы булуы, үз халкына, гореф-гадәтләренә мәхәббәте белән аерылып тора.* Татар совет театры

3) Әһәмиятле, игътибарга алынырлык, игътибарга лаек

4) Абруйлы, ихтирам ителүче. *Ул авылның игътибарлы һәм хөрмәтле карты [иде].* А.Шамов

**ИГЪТИБАРЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Игътибары арту, дикъкатьлерәк булып китү, кызыксынучанга әйләнү

2) Игътибарлы булып китү, игътибарлылык, кайгыртучанлык күрсәтү

**Игътибарлылана бару** Акрынлап игътибары арту

**Игътибарлылана төшү** Бераз игътибары арту, игътибарлыга әйләнү

**ИГЪТИБАРЛЫЛЫК** *и.* Игътибарлы (*1, 2, 4 мәгъ.*) булу. *Монда инде ялгыз әниләрдән [кияүгә чыкканда] зур игътибарлылык сорала.* Сөембикә

**ИГЪТИБАРСЫЗ** *с.* **1.** 1) Дикъкатьсез, күңел бирми торган. *Ул [Абульханов] кешеләргә игътибарсыз, минминлекне алга сөрә, урынсызга масая.* Татар совет театры

**2.** *рәв. мәгъ.* Әһәмият бирмичә, илтифат итмичә. *Бу фикерләр тәнкыйтьчеләр вазифасы булса да, соңгы вакытта вакытлы матбугатта әдәби әсәрләр тәнкыйтенә бик аз урын бирелү сәбәпле, бик күп хосусиятләр тәнкыйтьчеләр тарафыннан игътибарсыз калуын искә алып, без бу хосусиятләргә тукталуны кирәк таптык.* Г.Тукай. *Гөлнур профессорның сүзләрен игътибарсыз тыңлады.* Г.Ахунов. *Хәлимгә җиңелчә генә күз ташлап алып, игътибарсыз гына, гамьсез генә, хәтта ничектер тәкәббер генә шикелле булып, аның янынннан узып китте.* А.Шамов

**ИГЪТИБАРСЫЗЛАНУ** *ф.* Игътибарсызлык күрсәтү, кайгыртмау. *Игътибарсызланды, дип сукранып йөргән улы да: «Әни, син авырмыйсыңдыр бит? Бер дә төсең юк», – дип куйды.* Ш.Хөсәенов

**Игътибарсызлана бару** Игътибарсызлыгы акрынлап арту, көннән-көн игътибары кимү. *Озак кына хат язмый тордым, сәбәбе бардыр, дип уйлый күрмә. Пычак та юк, кешеләргә игътибарсызлана барам, шуның бәласе.* А.Гыйләҗев

**Игътибарсызлана башлау** Бераз игътибар кимү

**Игътибарсызлана төшү** Бераз, соңгы вакытта игътибары кимү

**Игътибарсызланып бетү** Тәмам игътибарсызлану

**Игътибарсызланып китү** Кинәт игътибарсызлану, ниндидер моменттан соң игътибары бетү

**Игътибарсызланып тору** Әле, хәзер игътибарсызлык күрсәтү

**ИГЪТИБАРСЫЗЛЫК** *и.* Игътибарсыз булу сыйфаты. *Мондый игътибарсызлыктан Сарбайның хәтере калды булса кирәк, ул, төнлә бик сәер елтыраган күзләрен бер ачып, бер йомып, кызга: «Кунакка кайтканда да безне бар дип санамыйсың, ичмасам... Оныткансың бит...» – диган шикелле карый иде.* Г.Әпсәләмов. *Әллә игътибарсызлык, әллә икенчесенең йөрәге зәгыйфьрәк эшләгәнме, кем белсен...* Г.Галиева

◊ **Игътибарсызлык күрсәтү** 1) Дикъкать итмәү, гамьсез булу. *Шулай да мин ул көнне үземнең иң яраткан әйберемә – табигатькә карата зур игътибарсызлык күрсәттем.* Г.Рәхим; 2) Кайгыртучанлык күрсәтмәү, ярдәм итмәү; 3) Хөрмәт итмәү, санлашмау. *Ул кисәк кенә Баһавига арты белән борылды, кителмәгән игътибарсызлык күрсәтеп, кунакка сүз дәшмәстән, башта лампаның филтәсен чеметеп тазартты.* А.Расих

**ИГЪТИДАЛ** *и. гар. иск. кит.* Урталык, урта сызыкта булу, урта фикердә булу. *Бу хакта ифрат, тәфрыйт, игътидал кеби рамкалар һичбер тәкъдирдә куелырга мөмкин түгел.* Г.Ибраһимов

**ИГЪТИЗАР** *и. гар. иск. кит.* 1) Үтенеч; гафу сорау. *Бу кадәр моңлы зар берлән. Бу кадәр игътизар берлән --- сорыйм сез[дән].* Г.Кандалый

2) Берәр төрле эшне эшләү яки эшләмәүнең сәбәбе күрсәтелгән аклану. *Мин моны аңлый алмадым. Моңа мең төрле җавап, игътизар табарга мөмкин.* Г.Ибраһимов

**ИГЪТИЗАР КЫЛУ** *ф. иск. кит.* Гафу үтенү. *Инде бу вакыйганы кешегә*

*сөйләмә, --- дип игътизар кылды.* К.Насыйри

**ИГЪТИКАДӘН** *рәв. гар.* Ышану, инану нигезендә. *Докторның һичбер сүзенә гамәлән һәм игътикадән карыша алмый иде.* Ф.Әмирхан

**ИГЪТИКАДЫ́НЧА** *рәв.* Ышануынча, инануынча. *Галиәкбәр агайның игътикадынча, бу эшләрдә хыянәтчелек юк, бу эш – сәүдәгәрнең осталыгы гына.* Ш.Мөхәммәдев

**ИГЪТИКАТ** *и. гар. иск. кит.* 1) Ышаныч. *Гыйлем вә матбугат белән яктыртылган гавам өчен болар игътикад та вә тәгълимат та буладыр.* Г.Ибраһимов. *Тәрҗемәи хәле, дөнья вә тормышка карашы, әхлак вә игътикады һәм дә кай вакытларда вә нинди нәрсәләр тәэсире астында язуы хакында да мәгълүматым юк.* Г.Ибраһимов. *«Аңа каршы килү гөнаһ булыр» дигән ныклы игътикат аның башын, аягын чылбырлаган.* Г.Нигъмәти

2) Берәр нәрсәгә инану; мәсләк. *Башкалар, адәм ышанмасны сөйләмә, дисәләр дә, Сабир үзенең «ул кайтмый» игътикатында нык торды һәм анасын-фәләнен бераз юаткач, инде утырырга вакыт дип, сызганып эшкә тотынды.* Г.Ибраһимов

**ИГЪТИКА́Т ИТҮ** *ф.* Ышану. *--- мин аларны хәзерге мәгыйшәтне яңартырга тырышучы вә яңартучылар дип беләм вә, алар юлы белән бөтен киләчәктәге татарлар да китәрләр, дип игътикат итәм.* Ф.Әмирхан. *Бәдри ул Шәрифкә итагатьле генә һәм аның тормышына өйрәнгән, Шәрифне «эшлекле» дип игътикат итә торган иде.* М.Гафури

**ИГЪТИКА́Т КЫЛУ** *ф. к.* **игътикат итү**. *--- ул үзене һәртөрле хатадан минза дип игътикад кылганга, әлбәттә, пар түгел-фәлән, Хәдичә сөйми торгандыр дип уйлап та карамады.* Г.Исхакый

**ИГЪТИКАТЛЫ** *с. иск.* Ышанычлы. *Хәзергә кадәр «Иттифак» сайлау вакытларында да бер генә төрле сәяси игътикатлы кешеләрне үз тарафыннан сайлату урынына, кайда нинди кешене сайлату мөмкин булса, шуны үз кандидаты санады.* Ф.Әмирхан. *Шул накизәлек вә шушы хулиганлык юклыкны вә, бильахирдә, авылга иңгән шушы вәкарьле тынычлыкны саклаучының торышы, шушы игътикатлы вә тәртипкә өйрәтелгән көтүне күзәтә торган хаким көтүченең торышы төсле тоела иде.* Ф.Әмирхан

**ИГЪТИРАЗ** *и. гар. иск. кит.* Берәр төрле фикер, карар, карашка каршы төшү, бәхәс. *«Вакыт», «Йолдыз», «Ил» – болар уен түгел, бу өч гәзитәнең бер юлда игътиразы халык йөрәгендә бер эз калдырмый булмас.* Г.Ибраһимов. *Шигырь өчен вәзен вә кафия лазем, дип белгән адәмнәрнең игътиразы минем каршымда һичбер тиеш тормыйдыр.* Г.Ибраһимов

**ИГЪТИРА́З ИТҮ** *ф.* Каршы төшү. *Мин аңа, «ни эшлим соң» дип, бик йомшак кына игътираз иткән идем, ул тагын йомшарып, сүзен бетерде.* Г.Ибраһимов. *Бай малаеның кәефен бозмас өчен, мин аңар игътираз итмәдем, фәкать: – Минем йөрәгем таза түгел, – дидем.* Ф.Әмирхан

**ИГЪТИРА́З КЫЛУ** *ф. к.* **игътираз итү**. *Мөгаллим һәм аларга игътираз кылмады, иске генә чемоданы белән мендәр, юрганын кертеп урнаштырды.* Ф.Әмирхан. *Өч-дүрт ел әүвәл сурәтнең яравын ачык әйтергә батырлыгы җитмәгән «Шура» хәзер үзе рәсем тарата, һәм шуңа һичкем гаҗәпләнми, һичкем игътираз кыйлмый.* Г.Ибраһимов

**ИГЪТИРАЗСЫЗ** *рәв.* Бәхәссез; карусыз. *«Әхбар» газетасы коры бер газета гына булса, аның бу фикерен игътиразсыз калдырырга да мөмкин булыр иде.* Ф.Әмирхан

**ИГЪТИРАФ** *и. гар. иск. кит.* Тану, икърар. *Шәкертнең күңелендә үзенең чынлап та шәм һәм дә халыкны яктырту өчен булган шәм икәнлеген икътираф, аңлау туа.* Г.Тукай

**ИГЪТИРА́Ф ИТҮ** *ф.* Икърар итү, яшерми әйтеп бирү, тану. *Сәгыйть шигырьләрен тикшергәндә, аның артык мөстәкыйльлеген, һич тугрыда дөньяда үзенә башка бер адәм, бер мода барлыгын игътираф итмәвен --- әйтми узып булмый.* Г.Ибраһимов

**ИГЪТИРА́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **игътираф итү**. *Фәнни вә фәлсәфи әсәрләрнең тәмәдден өчен зарури бурычлыгы игътираф кыйлынса да, --- мондый әсәрләрне тупас рәвештә фәлсәфә саткан китаплардан түбән күрәләр.* Г.Ибраһимов

**ИДАРӘ** *и. гар.* 1) Хакимлек, власть. *Кадет вә аларга якыннар --- мәмләкәт идарәсендә иң зур роль алырга тиеш икәнчелеген --- дәгъва итәләр.* Ф.Әмирхан

2) Оешма, учреждение эшләре белән җитәкчелек итү өчен сайланып куелган, билгеләнгән административ орган һәм шул орган урнашкан бина, бүлмә. *Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы провокаторның 26 июльдәге җыелыш турындагы доносын Идел буе охранкасы башлыгына җибәрә.* Г.Тукай. *[Галинур:] Ашап-эчкәч, идарәгә барып, сөйләшеп килермен, күрәсен күреп, танышасы белән танышырмын дигән идем.* М.Хуҗин

3) Административ орган җыелышы. *Идарәнең карары шундый: бүгенгесе көннән син монда ындыр бригадиры буласың.* Г.Бәширов

4) Кеше организмының үз эшчәнлегенә, хәрәкәтләренә җитәкчелек. *[Мостафа] --- идарә көче йомшармасын дип, һәр көн иртә-кич бозлы су белән тәнен ышкыды.* Г.Ибраһимов

5) Хәрәкәт итә торган машина, приборлар һ.б.ны йөртү, алып бару // Машина, механизм һ.б. конструкцияләрнең эшләре белән җитәкчелек итү өчен кирәкле приборлар җыелмасы. *Кабинетына кереп өстенә ак халатын киде, компьютерының ерактан идарә ителешле пультын кулына алды да йомшак көрсигә чумды.* Р.Фәтхерахманов

6) *иск.* Газета-журнал редакциясе. *«Шура» идарәсенең, 75 әр тиен генә бәһа куеп, «Басылмаган шигырьләр мәҗмугасе» вә «Тил ярышы» кеби чүпләр таратуына милләт сабыр итә...* Г.Тукай. *«Шура» идарәсенә күндерелеп, төрле сәбәпләр аркасында журналда нәшер ителмәгән шигырьләр дә «Басылмаган шигырьләр мәҗмугасе» исемендә җыентык хәлендә басылган.* Р.Мәрданов

◊ **Идарә дилбегәсе** Баш булу, җитәкчелек. *Әти, картаеп, кулдан идарә*

*дилбегәсе ычкынганнан соң да – ахры, элекке хакимдар чакларын сагынып булса кирәк – зур тавыш күтәрде.* Ф.Хөсни. **Идарә җебе** *к.* **идарә дилбегәсе**

**ИДАРӘ́ ИТҮ** *ф.* 1) Идарә эшен алып бару, җитәкчелек итү. *Алтын Урданың мәҗүси мәрһәбендәге ханнар тарафыннан идарә ителгән чорын әлегә калдырып торыйк.* Р.Әмирхан. *Әмма, күп кенә тарихи һәм экономик сәбәпләр аркасында, гарәп хәлифәлегендә --- идарә итү дәүләт органнарына күчә бара.* Ислам

2) Прибор, руль һ.б. ярдәмендә механизмнар йөрешенә, эшенә юнәлеш бирү; эшләтү. --- *алар идарә итә торган йолдызлар да мәңге очрашмый: бер йолдыз көнчыгышта калыккан чакта, икенчесе көнбатышта батып өлгерә.* М.Бакиров

3) Сүз, фикер сөрешен билгеле юнәлештә алып бару. *Исмаев әңгәмә белән тагын да кыюрак идарә итә башлады.* Г.Бәширов

4) Үзе теләгәнчә эш йөртү. *Ул, миллионнар белән идарә итеп, тәм һәм рухи азык таба иде.* Г.Әпсәләмов

**ИДАРӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **идарә итү**

**ИДАРӘХАНӘ** *и. гар.-фар.* 1) Административ учреждение урнашкан бина. *Шагыйрь кайсы вакытта идарәханәгә кесәсенә кузна тутырып килә дә, йорт хуҗаларының балаларын алып чыгып, ишегалдында бик кәефләнеп кузна уйный иде.* Ф.Әмирхан

2) *иск.* Китап, газета-журнал чыгару, аны редакцияләү белән шөгыльләнгән орган, редакция урнашкан йорт, бүлмә. *«Әл-ислах» газетасы мөхәррире В.Бәхтияров иртән «Әл-ислах» идарәханәсендә Г.Тукай белән таныша.* Г.Камал

**ИДАРӘЧЕ** *с.* Дәүләт, ил, өлкә белән җитәкчелек итә торган, хакимлек итә торган. *...Годуновны бөтен урыс һәм урыс булмаган халыкларның уртак атасы-патшасы итеп күрсәтергә тырыша һәм, аны гаҗәеп акыллы, куәтле, гадел идарәче хөкемдар итеп тасвирлау өчен, буяулар кызганмый.* М.Бакиров. *Басып алынган җирләр мөселман общинасы, ягъни гарәп дәүләте милке дип игълан ителсә дә, идарәче югары катлау «ганимәт мал»ны һәм шактый җирне үзенә ала.* Ислам

◊ **Идарәче даирәләр** Дәүләт идарәсенең төп вәкилләре. *Г.Тукай дин урнаштырган һәм җәмгыятьнең идарәче даирәләре яклаган шушы кыргый законга каршы чыга.* Ф.Әгъзамов. *Бу чорда ислам дине өйрәтүләре идарәче даирәләр мәнфәгатьләренә яраклаштырыла.* Ислам

**ИДАРӘЧЕЛЕК** *и.* Дәүләт, ил, өлкә белән җитәкчелек, хакимлек итә торган система. *Башта яңа идарәчелекнең элекке колхоз нормативыннан берние белән дә аерылмаган устав-уклады, карар, кул күтәртелеп, бертавыштан кабул ителде.* Н.Хәмитов

**ИДӘН** *и.* Теләсә нинди корылманың, йөрер өчен, тактадан яки башка материалдан тигез итеп тоташ түшәлгән түбәнге өлеше. *Рабига босоножкиларын салды да, сырланып балчык каткан идәнгә басарга чирканып, кире киде.* Н.Гыйматдинова. *Аяклар паркет идәнгә тиеп-тиеп кенә алалар.* Т.Миңнуллин. *Буялган тар такталы агач идәндә чүп-чар, чүпрәк-чапрак аунап ята.* Т.Галиуллин

◊ **Идән себеркесе** Чит ирләр белән чуаларга яратучы хатын-кыз. *[Әмирхан:] Әминә апа хурланадыр? [Бәдриҗамал:] Сине идән себеркесенә алыштырсыннар әле! Хурланмыйча!* А.Гыйләҗев. **Идән чүпрәге** Ихтыярсыз, булдыксыз кеше турында. *[Малай] Кемгә карап идән чүпрәге булсын, --- этисеннән түрләр дерелди [ич аның].* Г.Әпсәләмов

**ИДӘН АСТЫ** *и.* 1) Өй эченнән идәндәге капкач белән ябылган тишек аша төшә торган итеп, өй астына казылган баз. *Идән асларын, кар базларын онытырга вакыт инде, Газинур.* Г.Әпсәләмов. *Бәрәңгеңне генә идән астында калдыра күрмә. Ягылмаган өйдә өшер ату, базыңа тутырып куй.* В.Нуруллин. *Авыл советында күмәк хуҗалыкка кодалау дәвам итә иде... Кемнедер акыртып кыйныйлар, кемнедер идән астына тибеп төшерәләр, кемнедер аяк-кулларыннан асып куеп газаплыйлар.* Ф.Бәйрәмова

2) *күч.* Хакимияткә каршы яшерен алып барыла торган эшчәнлек, яшерен сәяси хәрәкәт; шул хәрәкәттә катнашучыларның яшерен тормышы. *1929 елда ук Әхмәров Шиһаб белән Буа кантонына барган һәм анда кулак авторитетлары белән «идән асты» җыелышларында катнашып, аларга Совет хакимиятенә каршы булган директивалар биргән.* Р.Вәлиев. *Мәскәү хакимияте диссидент шагыйрьләрне ачуланган, орышкан, «Метрополь» исемле «идән асты» журналын тыйган, юкка чыгарган булып кылана.* Т.Галиуллин. *Сәясәтне белмиләр, ди, Ул яктан һич зыянсыз, ди. «Идән асты» монда юк, ди, Чөнки диңгез идәнсез, ди.* Ә.Фәйзи

3) *күч.* Тыелган, законнан тыш эшләнгән эш. *Күпләр шулай уйлады: «идән асты» бизнесын законлаштырасың да, капитализм безне социализм сазлыгыннан колакларыбыздан тартып та чыгара. Әмма... тот капчыгыңны!* Р.Мирхәйдәров. *Идел буе районында ялган аракылар җитештерүче «идән асты цехы» табылган.* Ватаным Татарстан

◊ **Идән асты кошы** *эвф.* Тычкан, күсе. **Идән астына китү** Эшне легаль булмаган, яшерен рәвештә алып бару. *Ни өчен ул, чын ирек сөюченең хыялы булган профессиональ революционерга әверелеп, идән астына китмәгән?* А.Расих. *Бишенче елның декабрь күтәрелеше бастырылып, Россия буйлап җәза отрядлары чаба башлаган заман иде. Революцияче партияләр идән астына киттеләр.* Г.Нигъмәти. **Идән астыннан** Яшертен рәвештә. *[Рәхимҗанның] Яңарак вафат булган бер хәзрәтнең егерме яшьлек матур хатыны белән мөнәсәбәт саклавы хакында бөтен шәһәрдә идән астыннан бер хәбәр йөри башлады.* Г.Ибраһимов. **Идән астыннан ут йөртү** Интрига, астыртын эш алып бару; котырту. **Идән астыннан чыгу** Легаль хәлгә кайту. **Идән асты халкы** *эвф. к.* **идән асты кошы**

**ИДӘ́Н БАЛАВЫЗЫ** *и.* Паркет идәнне ялтырату өчен, балавыз һәм буяу кушылмасыннан торган сыекча; *русчасы:* **мастика**

**ИДӘНЛЕК** *с.* Идәнгә җәю өчен махсус әзерләнгән, идән итеп түшәргә яраклы. *Авылда идәнлек такталар бар.* Р.Төхфәтуллин

**ИДЕ** *ярд. ф.* 1) Исем, сыйфат, сан, алмашлык һәм хәбәрлек сүз булып килә торган мөнәсәбәтлек белән бергә тезмә хәбәр ясый һәм аларның үткәнгә караганын белдерә. – *Өч каен иде, икесен кая куйдың? – дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Гыйлемхан. Җаныннан саркып чыккан иң авыр сорау иде бу.* Р.Мөхәммәдиев. *Зур иде аның күзләре, куркыныч иде.* Г.Гобәй. *Ул элек тә төрле мәзәкләр, кызыклы әкиятләр уйлап чыгарырга оста иде.* Ф.Яруллин

2) Хикәя һәм ният фигыльләрнең тәмамланмаган үткән заман аналитик формасын ясау өчен кулланыла. *Кибет тәрәзәләренә, ишекләренә аркылы-торкылы такта кадакланган, вывескалары җирдә аунап ята иде.* Г.Гобәй. *Көнчыгыштан ачыкланып, таң яралып килә иде.* Н.Фәттах. *Хәлиманең, сөтле чиләген күтәреп, иртә таңнан сепаратка Айсылу апаларына барышы иде.* Н.Хәсәнов

3) Хикәя һәм ният фигыльләрнең күптән үткән заман аналитик формасын ясый. *Фәниярның бу зур шагыйрьне элек тә укыганы бар иде.* Ф.Яруллин. *Төркиядәге консуллыкка эшкә җибәргәннәр иде мине.* Т.Әйди. *Беренче тапкыр алар сабан туена кайтканнар иде.* Н.Хәсәнов

4) Киләчәк үткән заман хикәя фигыль ясауда катнаша. *Әгәр мөмкин булса, мин укучыларга берничә сүз әйтер идем.* Ф.Яруллин. *Күз күрмәгән, хыял ирешмәгән йөзлекләр ясарга иде үзләренә. Башка берәүнекен дә кабатламаган, авылда тиңе булмаган йөзлекләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Солдат һаман ерагая бара, хәзер аны куып җитү кыен булачак иде.* Г.Бәширов

5) Теләк фигыль ясауда кулланыла. *Тәрәзә пәрдәләрен ачасы да якты көнне күрәсе иде.* М.Хәбибуллин. *И-их, авыл өендә мич каршында утырырга иде хәзер ә?!* Р.Вәлиев. *Тигез гомер иткән, чөкердәшеп яшәгән әби белән бабайны күргәч: «Бәхетле картлык безгә шушылай килсен иде ул!» – дисең...* Н.Хәсәнов

6) Контекстта икенче бер фигыль белдергән эш-шөгыль өчен фон булып килә. *Цехта реконструкция башланган, ул аяк-кулны богаулап куйган иде.* Н.Хәсәнов. *Зәйтүнә өенә кайтканда, картлар кичке ашны ашап утыралар иде.* Ф.Хөсни

7) Хәзерге заман хикәя фигыльнең күплек санында килеп, реаль мөмкинлек була торып та эш-хәрәкәтнең үтәлмәвенә ризасызлык белдерү өчен кулланыла. *Алданрак уйлыйлар иде аны*

8) Үткән заман сыйфат фигыль белән килеп, икенче бер эш-хәрәкәт белән кинәт бүлдерелгән, тукталып калган, каршы куелган эш-хәрәкәтне белдерә. *Поезд астына ташланмакчы булган идем. Курыктым, туры сикерә алмам да үлми калырмын дип курыктым.* Р.Вәлиев. *Шатлыктан бер мәтәлчек тә атынып китәсе килгән иде – тыелып калды: аргы яктан берәрсе карап торса, ни уйламас.* Н.Хәсәнов

9) Киләчәк заман сыйфат фигыль янында килеп, тиешлек мәгънәсен белдерүдә катнаша. *Бу [февральдәге] революциядән әллә ниләр көткән идек: янәсе, сугыш та бетәсе иде, эш сәгате дә кимисе иде, крестьянга җир дә биреләсе иде.* И.Гази

10) Кабатлаулы эш-хәрәкәтне белдерә. *Куйбышев ТЭСы төзелгәнгә кадәр, шәһәрне әледән-әле су баса торган иде.* Р.Мостафин. *Эштән бушадымы, кулына балта-пычкы ала торган иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Эшкә дә социалистик шәһәрчектән парк аша җәяүләп кенә йөриләр иде.* Н.Хәсәнов

**ИДЕАЛ** *и. фр.* 1) Җәмгыять яки аерым шәхеснең куйган, шуңа омтылган иң югары максаты. *Бу мәсьәләне ул Шәрык дөньясында озак гасырлар буе шәкелләшеп килгән олуг идеаллар югарылыгында торып яктыртырга омтыла.* Х.Миңнегулов. *Мөселман хокук белеме күзлегеннән караганда, дәүләт төзелешен теократик нигезгә кору – Ислам диненең идеалы ул.* Ислам

2) Кеше омтылышының, теләк һәм максатының иң югары ноктасы. *Татар халкында гасырлар дәвамында урнашып килгән иҗтимагый һәм әдәби-әхлакый идеаллар үзгәрә, Шәрекътән Гаребкә йөз тоту көчәя.* Р.Мәрданов

**ИДЕАЛИЗМ** *и. фр. 1) Рухны, аңны, идеяне беренчел һәм бөтен барлыкның нигезе дип, ә материяне икенчел, шулардан чыгарылма дип саный торган фәлсәфи юнәлеш. Субъектив идеализм бердәнбер нигез итеп «субъектның» (кешенең) аңын ала.* М.Абдрахманов. *Идеализм кеше аңын нindidер абстракт гамәли идеяләр яисә илаһи көчләр продукты дип кенә саный.* К.Гыйззәтов. *Циклның өченче мәкаләсе идеализм фәлсәфәсе тарафдарлары – Ксенофонт, Парменид, Зенон өйрәтүләрен шактый тулы яктырта.* Д.Заһидуллина

2) сөйл. Үз-үзен аямыйча, үз мәнфәгатьләрен күздә тотмыйча, теге яки бу эшкә, хезмәт итүгә омтылыш, һәвәслек

3) сөйл. Реаль чынбарлыкны уңай яктан гына күпертеп сурәтләү, идеаллаштырып күрсәтү алымы. *Алар, латин хәрефен алсак, Европа, Америка кебек бай да, көчле дә, гаҗәп шәп мәдәниятле дә булып китәбез, дигән идеализм белән хыялланалар.* Г.Алпаров. *Чынлап торып уйлаганда, тәнкыйтьне тыныч кына кабул итүне көтү – бу үзе идеализм түгелме икән соң?* М.Вәлиев. *[Гүзәлия:] «Суд» дигәннән, миңа калса, бүгенге хөкемнән дә зуррагы юк аның өчен. Бер югла, бәлки, җитеп торадыр? [Хәмит:] Анысы идеализм, Гүзәлия. [Гүзәлия:] Беләм инде, син идеализмны яратмыйсың. Син балта белән эш итәргә яратасың.* Т.Миңнуллин

**ИДЕАЛИСТ** *и. фр.* 1) Идеалистик фәлсәфәне яклаучы, шуның тарафдары. *Без --- идеалистлар түгел, без – материалистлар.* Ә.Фәйзи. *Ул Г.Тукайның якын дусты С.Сүнчәләйне «милләтче, соңыннан контрреволюционер солтангалиевче, череп барган идеалист» дип атый.* Ф.Галимуллин. *Профессор Мөхәммәт Гайнуллин әдипне «дөньяга карашы белән идеалист» дип атаса да, бу – бары галим үзе яшәгән чор өчен генә кулай фикер.* М.Җәләлиева

2) Теге яки бу эшкә үз-үзен аямый, үз мәнфәгатьләрен, үз файдасын кайгыртмыйча хезмәт итүче кеше. *Бу егетнең [эчке, рухи сыйфаты] миңа һәрвакыт рус идеалистлары арасында «народник» (---) [исеме] белән мәгърур 60–70 нче еллар зыялыларының хөрмәтле [рухи сыйфатларын] хәтерләтә.* Ф.Әмирхан

3) *сөйл.* Чынбарлыкны идеаллаштырып, матурлап күрсәтергә яратучы кеше; хыялый, фантазёр. *Шулай да хыялый сезнең ул картыгыз, идеалист!* Г.Бәширов. *Тагын бер кат рәхмәт төшсен оныкларыма, син фәлән дип, йөзгә бәреп әйтмиләр. «Син – идеалист, синең дөньяны матур итеп күрәсең килә», – диләр.* Т.Миңнуллин. *– Бу, минемчә, бәхет буладыр инде. Әллә, тагы нәрсә?.. – Натела, күзләрен кыса төшеп, көлемсерәде. Аннары, җитдиләнеп: – Сез – ике идеалист! Бөтен нәрсәне бер бизмәнгә салып үлчисез, – диде.* Г.Мөхәммәтшин

**ИДЕАЛИ́СТИК** *с. Идеализмга (1 мәгъ.) хас. Ә аларга беренче булып фәнни билгеләмәләр бирүче марксист та, хәтта материалист та түгел, бәлки, заманында идеалистик юнәлештә иҗат иткән немец философы Фридрих Шлегель --- була.* К.Гыйззәтов. *Классик идеалистик эстетика, хәятка чын матурлыкны сәнгать кенә бирә, ул тудырган гүзәллек тормыштагы матурлыктан югарырак дип саный.* Ф.Хатипов. *Ләкин Гыйльфан – инженер, ул – төгәл фәннәр буенча әзерлекле кеше, әлеге беренче карашка идеалистик булып күренгән «туган туфрак» төшенчәсенә материалистик аңлатма бирә.* М.Мәһдиев

**ИДЕАЛИСТЛӘ́РЧА** *рәв.* Идеалистлар кебек, шуларга охшатып. *Идеалистларча фикер йөртү. Фактларны идеалистларча бәяләү*

**ИДЕАЛИСТЛЫК** *и.* Идеализм белән сугарылганлык. *--- гел үзебезнең авылдан көньякка –کояшка таба чыгып китәргә кызыктым. Хыял гел шул якка тарта иде. Моның сәбәбен (мине идеалистлыкта гаепләмәсеннәр) мин илле яшемә җиткәндә генә белдем.* М.Мәһдиев. *Ләкин узган ике ел вакыт безнең Рәшидне тамчы да үзгәртмәгәннәр, ул һаман элеккеге Рәшид икән. Шул ук идеалистлык, шул ук шат күңел, дөньяга ачык караш аның йөзенә үк чыгып тора иде.* Р.Гали

**ИДЕАЛЛАШТЫРУ** *ф.* Кемне яки нәрсәне дә булса реаль чынбарлыктан яхшырак итеп, уңай яктан гына күрү, кабул итү, яхшы якларын күпертеп күрсәтү, сурәтләү. *Китапта Сталинның эш-гамәлләрен аклау, шәхесен идеаллаштыру өстенлек итә, Америка тәнкыйтьләнә.* Х.Миңнегулов. *М.Г.Худяков --- Олуг Мөхәммәдне Казан ханлыгының нигез салучысы буларак идеаллаштыру юлына баса.* Б.Хәмидуллин. *Әдәбиятка буй җитмәслек изге нәрсә итеп карауда минем халкыма хас бер йомшак як та кабатланды: хискә бирелеп, чамасыз идеаллаштыру да булды шикелле.* Г.Бәширов

**Идеаллаштыра бару** Торган саен ныграк идеаллаштыру

**Идеаллаштыра төшү** Бераз идеаллаштыру

**Идеаллаштырып бетерү** Тулысынча, бөтенләй идеаллаштыру

**Идеаллаштырып килү** Эзлекле рәвештә, системалы идеаллаштыру. *Без, Сталин чорыннан башлап бүгенге көнгә кадәр, «халык» дигәндә гавамны күз алдында тотып идеаллаштырып килдек.* Т.Миңнуллин

**ИДЕАЛЛЫ** *с.* Идеал (*1 мәгъ.*) белән сугарылган. *Әлбәттә, бу олы бурычларны үтәргә талант кирәк, идеаллы максат кирәк, йөрәк кирәк.* Р.Фәйзуллин. *Без килдек, Испания, сиңа – Дон Кихотлы бөек илгә, Синең хаклык рыцарьларың, Зур идеаллы ирләрең, Ышаныйк, яши бүген дә!* Р.Гаташ. *Шул ук вакытта ул [Н.Фәттах] – тәнкыйтьче Һ.Мәхмүтов билгеләгәнчә, дошманга каршы берләшеп көрәшү кирәклеген вакытында аңлаган «уңай идеаллы шәхес» тә.* А.Нәҗипова-Зиннәтуллина

**ИДЕА́ЛЧА** *рәв. сир.* Идеалдагы кебек. *Бу соңгы рюмканы мин сезнең өчен күтәрәм: сезнең гади тормышта идеалча матур итеп, бәхетле итеп яши белүегез өчен!* Н.Исәнбәт

**ИДЕАЛЬ** *с.* 1) Хыялда гына яши торган; абстракт; *киресе:* **чын, реаль, хакыйкый**. *Фатих Әмирхан, «Фәтхулла хәзрәт» сурәтен биреп, искелекне тәнкыйть[ләп] кенә калмый, буржуа яңа тормышының идеаль үрнәге турында да хыял итә.* Г.Нигъмәти

2) *сөйл.* Камил, үрнәк булырлык, бик яхшы. *Язмаларда идеаль кешегә хас сыйфатларны билгеләү омтылышы ясала ---.* Д.Заһидуллина. *Дөрес, закон проекты әле бөтен яктан да эшләнеп бетмәгән. Бу хакта әйтелде. Андый идеаль закон проектларын без әле, гомумән, күргәнебез юк.* Т.Миңнуллин. *Урамда гына түгел, цехларда, складларда да һәрчак идеаль тәртип саклана.* Р.Кәрами

3) *физ.* Матдәләрнең физик күрсәткечләре идеалга якынлаштырып кабул ителгән фараздагы моделенә караган. *Барлык реаль газларның үзлеге шактый югары температураларда һәм түбән басымнарда гына идеаль газ үзлекләренә якын була.* Идеаль газның халәте. *Классик физикада үткәргечтәге электрон газы идеаль газ кануннарына буйсына дип фаразлана.* Физика

**ИДЕЛ** *и. иск. сир.* Зур елга. *Идел күрми, итек салмыйлар.* Мәкаль. *Пароходта без барабыз Вятка иделе буйлап.* Бәет. *Исмәгыйль ханның меңе Туктамыш хан гаскәренә үз җәйләүләре тирәсендә, Чулман иделе белән Зәй елгасы арасында гына кушылды.* Т.Нәбиуллин

◊ **Идел суы илле батман** Ите аз, шулпасы күп; сыек шулпа, сыек чәй; тозсыз, татсыз аш. **Идел уртасында калу** к. **ике ут арасында калу**

**ИДЕЛ-ЙӨРТ** *җый. и. фольк.* Идел буена урнашкан борынгы Болгар һәм Кыпчак дәүләтләре. *Элекке Болгар һәм соңыннан Кыпчак йөртын фольклорда --- «Идел-йөрт» дип йөртү еш очрый.* Н.Исәнбәт. *--- татар әдәбиятында Идел-йөртның күз алдында бары тик үз шәхси мәнфәгатьләре белән генә яшәгән тар маңгайлыларның --- юкка чыгуын үзәккә алган бер олы әсәр – «Идегәй» дастаны иҗат ителә.* Т.Галиуллин. *Әмма баш имә Син, Идел-йөрт кызы Син, Сәкинә!* Р.Закиров

**ИДЕ́Л КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Бер генә көн яши һәм күбрәк су өстендә очып йөри торган күбәләк; бер көнлек күбәләк

**ИДЕОГРА́ММА** *и. гр. лингв.* Язуда нинди дә булса бер төшенчәне белдерә торган шартлы тамга (мәс., саннар, тапкырлау, кушу, алу билгеләре). *Абстракт төшенчәләр ике идеограмма комплексы белән белдерелгән.* Ф.Сафиуллина

**ИДЕОГРА́ФИК** *с. лингв.* Идеографиягә мөнәсәбәтле. *«Семантик синоним» төшенчәсе, гадәттә, идеографик синонимга тиңләп карала.* Ф.Сафиуллина. *Соңгы елларда активлашкан алынмаларның бер төре исә, телдә булган сүзләрнең идеографик синонимнары буларак, ягъни төшенчәгә яңа мәгънә төсмере өстәп, конкретлаштыру максаты белән кулланыла.* Р.Мөхиярова. *Идеографик синонимнар – мәгънә төсмерләре белән аерылып торган синонимнар.* Г.Галиуллина

**ИДЕОГРА́ФИЯ** *и. гр. лингв.* Идеограммалар ярдәмендә язу

**ИДЕО́ЛОГ** *и. гр.* Теге яки бу сыйныфның, иҗтимагый-сәяси стройның һәм аның идеологиясенең яисә берәр юнәлешенең тарафдары, әйдәүчесе. *--- бу чор йола фольклоры турында сөйләгәндә дә, галимнәр тик ясалма, совет идеологлары уйлап чыгарган стереотипларга гына таянырга мәҗбүр булганнар.* Ф.Урманче. *Әлбәттә, империячел идарә идеологы өчен халыкларның конгресслары ошап бетмидер.* Т.Миңнуллин. *Батырша – --- Абдулла Галиев – 1755 елгы халык күтәрелешенең җитәкчесе һәм идеологы, рухи таянычы.* М.Гайнетдин

**ИДЕОЛО́ГИК** *с.* Идеологиягә бәйле, идеологияне чагылдырган. *Оешма XX гасырның байтак дистә елларында язучыларның иҗади хезмәтен оештыруда һәм бәяләүдә үзгә бер идеологик үзәк ролен үтәп килде.* Р.Фәйзуллин. *Хаким партия һәм яңа власть милли мәдәният эшлеклеләреннән идеологик активлык, агитацион күргәзмәлелек таләп итә.* М.Арсланов. *--- теләсә кайсы иҗтимагый эшне оештыру өчен, башта аның идеологик нигезен булдырырга кирәк.* Ф.Галимуллин

**ИДЕОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Билгеле бер җәмгыятьтә сәяси, хокукый, әхлакый, эстетик, дини төркемнәрнең мәнфәгатьләрен гәүдәләндерә торган фәлсәфи карашлар, идеяләр системасы. *Коммунистик идеология юкка чыгу белән, халык күңелендә, аңында бушлык хасил булды.* Ә.Закирҗанов. *Ислам – Урта гасыр татар тормышында төп идеология.* Х.Миңнегулов. *Моның төп сәбәбе илдә хөкем сөргән большевистик идеология кануннары белән бәйләнгән иде.* Ф.Урманче

**ИДЕ́Я** *и. гр.* 1) Кеше аңында реаль яшәешне чагылдыра, шул яшәешкә мөнәсәбәтне белдерә торган төшенчә, күзаллау. *Социализм – хәзер ул коры идея генә түгел, ә – факт.* М.Җәлил

2) Кешенең дөньяга карашында нигез принцип булган төп фикер; рухи кыйбла, юнәлеш. *Төрки телдәге әсәрләр суфыйчылык идеяләре белән сугарылган була.* К.Гыйззәтов. *Әмма иң аптыратканы: шулар һәммәсе дә, әйткәнебезчә, кичәге большевиклар. Кайчандыр бер сафта торып бер үк идея өчен көрәшүчеләр, бүген исә, берберсенең бугазын чәйнәргә торучы дошманнар!* Ә.Еники. *Шуңа гаҗәпләнергә кала: идея ныклыгы булмаган, аумакай үзәкле кеше ничек партия җитәкчесе итеп куелган?* Х.Камалов

3) Сәнгать әсәренең, әдәби жанрның эчтәлегенә салынган төп фикер. *«Болын» повестенда язучы, Җан һәм Тән гармониясенең бозылуы нәтиҗәсендә, адәм баласы үзен ялгыз итеп тоя дигән матур идея үткәрә.* А.Шәмсутова. *Әлеге әсәрләрнең идея юнәлеше бик ачык: ул ислам диненең изгелеген исбат итүгә юнәлдерелгән.* Ф.Урманче. *Тик [картинаны] кабул итмәгәннәр, идея эчтәлеге сай, дигәннәр. Аитов, шул комиссиягә ачу итеп, картинасын кискәләгән.* М.Маликова

4) Фикер, уй. *Миңа бер идея килде. Беләсезме нәрсә, ханым. Алып китегез сез бу баланы үзегез белән.* Г.Гобәй. *Юри генә: – Ботинка ботинка инде ул, үзйөрешле итек түгел! – дип ычкындырган идем, Йөгертдиновка җитә калды. – Үзйөрешле итек?! Шәп идея бит бу! – дип эләктереп тә алды.* М.Сәлим. *Сүзне Нәсимә башлап җибәрде: – Ә нигә? Начар идея түгел бу. Хуҗаңның яшь хатыны булып, карт хатынга приказ гына биреп ятасың.* Ф.Яруллин

5) *күч. Теләк, ният. Пароход капитаны булырга теләү коры бер җилкенү булып кына калмады, бу идеяне мин байтакка кадәр үземдә саклап, җайлы форсат чыкканны көтеп йөрдем.* *Ф.Хөсни. Ә минем идея? Минем теләк?.. Бөтен дөньяның хезмәт ияләрен, кешелек дөньясының иң бөек акылларын сокландыра торган якты теләк!* М.Әмир

**ИДЕ́ЯЛЕ** *с.* 1) Нинди дә булса бер идеягә нигезләнгән, аны пропагандалаган, шуның белән сугарылган. *Образлы, матур тел белән язылган, ачык идеяле кыска хикәя – ул бер стакан куе ширбәт белән бер.* Г.Галиев. *1934 елдан --- соң --- үзәктә коммунистик идеяле уңай герой торырга тиешлеге ачыкланды.* Ф.Галимуллин. *Безгә идеяле, акыллы, үзен һәм үз сыйныфының теләген төшенгән әдәбият кирәк.* Х.Туфан

2) Алдынгы фикер белән сугарылган. *Поэма, минем карашка, Байрон, Лермонтов, Такташлардан килә торган мәңгелек мәсьәләләрне заман рухында оста чишүне күрсәтә. Ул – тирән идеяле әсәр.* Р.Гаташ. *Ә.Еникинең, ул чактагыча әйтсәк, югары идеяле мондый әсәрләре күп.* Ә.Баян. *Бу исә үткәрелгән чараларның оешкан һәм югары идеяле булуын, политик хезмәт һәм әхлак тәрбиясенең бер-берсе белән тыгыз бәйләнүен тәэмин итте.* Г.Шакиров

3) *сөйл.* Шәхси мәнфәгатьләрне күздә тотмаган; нинди дә булса идеягә чын күңелennән бирелгән. *– Бу дөньяда хәләл көчем белән эшләп тапканга гына яшәргә күнеккәнмен. Катгый рәвештә! Бу – тайпылмас кыйблам, – дидем мин. – Син... шундый идеяле зат инде ---, – диде ул, кәефе бик тә кырылып.* Р.Фәизов

**ИДЕ́ЯЛЕЛЕК** *и.* Идеяле булу. *Чиратның мәгънәсе бик түбәнлектән алып бик югары идеялелеккә кадәр була ала.* М.Мәһдиев. *Илһамның әдиптән югары идеялелек, олы максатлар таләп итүе турында язучы Аяз Гыйләҗев «Урталыкта» повестенда менә нәрсәләр ди ---.* Р.Фәтхрахманов. *--- аларда [әсәрләрдә] социалистик реализм методы таләп иткән коммунистик идеялелек алгы планга чыга, бөтен сюжет шуңа буйсындырыла.* Ф.Галимуллин

**ИДЕ́ЯСЕЗ** *с.* Идеясе булмаган, тирән эчтәлекле фикерләре, принцибы булмаган. *Идеясез әсәр*

**ИДЕ́ЯСЕЗЛЕК** *и.* Идеясе булмау, рухи кыйбласызлык. *Бу идеясезлек бүгенге тормыш куйган тематикадан читкә китүдә генә түгел, бәлки бүгенге тематиканы алып та, аны тирәнәйтми бирүдә, «пафослы» терминнар белән генә канәгатьләнеп өстән йөзүдә, укучы массага бер яңа фикер дә бирмәүдә.* Һ.Такташ. *Элек безнең дәүләттә «идеология» дигән нәрсә бар иде. Идеясезлек булмасын, идея алгы планга күчсен, дип өйрәтәләр иде.* Р.Заһидуллина. *Казан телевидение тапшыруларының күпчелегендә хөкем сөргән идеясезлек, кыйбла булмау тапшырулар сериясен берсен башлау, икенчесен ташлау кебек күренешләрдән килә.* М.Шиһапов

**ИДЕ́ЯЧЕЛ** *с. сир.* Нинди дә булса бер идеягә (*2 мәгъ.*) чын күңеленнән бирелгән. *[Г.Ибраһимовның] иң идеячел һәм, әдипчә, үзен-үзе онытып революция эшенә чумган дип бирелгән революционерлары да көрәшә, сөя, иҗтимагый эш рәтеннән тагын шәхес тормышы белән дә яши белә.* Г.Нигъмәти

**ИДИ́ЛЛИК** *с.* 1) Идиллиягә (*1 мәгъ.)* караган, гамьсез тормышны сурәтләгән. *Яңа, азат хезмәт эстетикасына каршы бер күренеш буларак, мещанлык поэзиясе, идиллик романтика дөньяга чыкты.* Г.Халит. *Марс Шабаевның Ык елгасы – ямена сокланып, тук күңелгә бераз хәл алдырып кына үткән идиллик бер образ түгел.* Х.Сарьян

2) Тыныч, гаугасыз, борчылусыз. *Сәгадәт үскән авыл өе һәм мулла йорты идиллик йорт буларак сурәтләнсә, Габдулла йорты консерватив җәмгыять символы кебек ачыклана.* А.Батталова. *Күрәсең, идиллик җәмгыять хыялда гына кала, һәр (хәтта камил) җәмгыятьтә дә игелек белән яманлык арасында көрәш барачак.* К.Гыйззәтов. *Табигатьнең нинди дә булса бер гүзәл, идиллик күренеше бар.* Г.Бәширов

**ИДИ́ЛЛИЯ** *и. гр.* 1) Табигать кочагындагы тыныч, борчылусыз, гамьсез тормышны идеаллаштырып сурәтләгән шигъри әсәр. *XVII һәм XVIII йөзләрдә француз шагыйрьләре, Россиядә Сумароков, Херасков һәм башкалар «көтүчеләр» турында идиллияләр иҗат иткәннәр.* Н.Гыйззәтуллин. *Г.Газиз исә үзенең кечкенә күләмле бу --- әсәрен, аның төче бер лирик характерда булуы һәм вакыйганың бакчада, алмагачлар чәчәк аткан җирдә – «табигать кочагында» баруыннан чыгып, «идиллия» дип атаган.* Р.Гайнанов

2) *күч. ирон.* Тыныч, гаугасыз, идеаль тормыш. *Тынлык. Идиллия! Тирә-якта җаннарга тынычлык иңдерә торган яшеллек җәйрәп ята.* Ә.Сафиуллин. *Кая гына барма, кайда гына торма, сине чакыручылар, үзләренчә яхшылык теләүчеләр, сиңа җәннәт, идиллия вәгъдә итүчеләр тулып ята.* Р.Фәйзуллин. *--- мин Соломон Моисеевич белән Улечка арасында шундый сөйләшү ишетеп калдым: – Авыл чиста, Саша, – диде Улечка. – Әйе, идиллия, романтика! – диде Соломон Моисеевич, ирония белән.* Н.Фәттах // Тыныч, гамьсез тормыш картинасы турында. *Нинди матур, нинди идиллия: Пар аккошлар күккә талпына. Ут, су, һава бергә хезмәт итә Бу җирдәге тормыш хакына.* Р.Гарифуллина. *Ачудан шашкан апа килер дә ялган идиллия пәрдәсен бер селтәнү белән һәм бер алама сүз белән йолкып ыргытыр.* Ә.Баян. *Алда туктаусыз көрәшләр – кешелекне яңадан эшләү кебек озын үзгәрешләр торганда, тормышта идиллия көтәргә ярамый.* Х.Туфан

**ИДИ́ЛЛИЯЛЕ** *с.* Гамьсез, тыныч, борчылусыз. *Вафинның моннан бер сәгать-сәгать ярым элек кенә кичергән идиллияле рухи халәте яңадан шикшөбһәләр, җавабы табылмаган --- сораулар белән алышынды.* Ф.Хөсни

**ИДИО́МА** *и. гр. лингв.* Составындагы сүзләренең эчтәлегенә туры килмәгән, кинаяле мәгънә белдергән һәм билгеле бер телгә генә хас булган әйтелмә, тотрыклы сүзтезмә. *Идиомаларда аерым сүзләрнең урыннарын алмаштырып яки --- берәр компонентын төшереп һәм өстәп булмый диярлек.* Ш.Рамазанов. *--- кайчак, үзләрен генә алганда, хәзерге телдә бөтенләй аңлашылмый да, кулланылмый да торган, нык береккән әйтелмәләр (идиомалар) тәрҗемә ителә. Мәсәлән: зла на зло не воздавай – таш атканга аш ат ---.* Р.Юсупов. *Сүзлекләрдә теркәлмәгән булса да, «гафләт йокысы» гыйбарәсен дә соңгы елларда активлашкан идиомалар исәбенә кертергә була ---.* Р.Мөхиярова

**ИДИОМА́ТИК** *с. лингв.* Идиоматикага бәйле, идиоматикага хас. *--- ул болай дип язды: «Әгәр дә без телебезгә игътибар беләнрәк карасак, бәетләребезнең, җырларыбызның, мәкальләребезнең, идиоматик әйләнмәләребезнең бик матур рифмалашкан һәм ритмиклашкан булуын күрәбез».* К.Миңнуллин. *Идиоматик әйтелмәләр рус телендә дә, татар телендә дә күп.* Р.Юсупов

**ИДИОМА́ТИКА** *и. рус лингв.* 1) Тел белеменең идиомаларны өйрәнү тармагы. *Бүгенге көн өчен --- идиоматиканың лексикологиягә параллель фән тармагы икәнлеге ачыкланды. Г.Ахунҗанов*

2) Билгеле бер телдәге идиомалар җыелмасы. *Идиоматика – телнең идиомалар җыелмасы.* Г.Галиуллина

**ИДИОТ** и. *гр. сөйл.* 1) Тумыштан акылга зәгыйфь кеше; дивана. *[Врачлар] аның --- тумыштан яки контузиядән идиот булмавын да расладылар.* Ш.Маннур

2) *сөйл.* Аңгыра, ахмак, тинтәк, юләр кеше. *– Син оештырдыңмы бу тамашаны? – диде Ихлас, ризасызлыгын яшермичә. – Мин! – диде Морат. – Идиот! – дип пышылдады Ихлас.* Р.Батулла. *Минем җиремдә мине мыскыл итүчене яратырга идиот түгел ич мин.* Т.Миңнуллин. *Бөек империядәге тәртипне нинди дер идиот боза.* А.Расих

**ИДИОТЛЫК** *и.* 1) Идиот булу, акылга зәгыйфьлек. *Башыңны идиотлыкка салып торма. Исеңә төшер: Чистополь шәһәрендә, базарный площадьта кул болгый-болгый кычкырып политика сатучы кеше син булгансың ич?!* Ф.Хөсни. *Караклар арасында яшәп намуслы булып калырга тырышу – идиотлык билгесе.* Т.Миңнуллин

2) *күч.* Ахмаклык, томаналык; мәгънәсезлек. *– Юкны сөйлисез, Гасыйм Мәмәдович, – дидем мин. – Андый күрсәтмәне, минемчә, беркем дә бирә алмый. Идиотлык бит.* М.Юныс

**ИЕ I** *кис. сөйл.* Әйе. *– Хәтерем ялгышмаса, исеме – Вафа, фамилиясе Аб-*

*дуллин бугай? – Ие, Абдуллин.* А.Алиш. *– Әтисе янында егет булып кайтыр. Ие бит, улым? – Рамил елмаеп баш какты.* М.Рәфыйков. *Безнең арада кечкенә генә ыгы-зыгы булып алды. Сүзне Зарифуллин башлады: – Нәрсә бу, бигрәк тагын, мыскыл итәм дигәч тә! – Ие! Кызлар белән түгәрәк уен уйнарга, бигрәк тагы!* М.Мәһдиев

**ИЕ II** *ярд. ф. сөйл. к.* **иде**. *Синең казларың уңа ие бит.* Р.Мулланурова. *Атка утырып йөрергә ярата торган ие Хәниф.* Т.Миңнуллин. *Рәхмәт, вакытым бик тыгыз. Рәүфкә йомыш бар ие.* М.Маликова

**ИЕЗУИТ** *и. лат. дини* 1) XVI гасырда барлыкка килеп, Рим папасының һәм реакциянең терәге булган католик монахлар ордены (сугышчан дини оешма) әгъзасы. *Иезуит Саккери (1667–1733) --- геометриядәге «караңгы тапны» яктыртырга тырышкан.* Җ.Тәрҗеманов. *Иезуитлар монастыре*

2) *күч.* Икейөзле, мәкерле, явыз кеше

**ИЕЗУИТЛЫК** *и. кит.* Икейөзлелек, явызлык, мәкерлелек

**ИЕК, ИЕКК** *иярт.* Укшыганда, очкылык тотканда чыга торган тавышны белдерә. *Эчегез, Шакир ага... И-иекк... Пажалыста... Миңа ярамый... Иекк... Бөерем... И-иекк... Җәфалый, иек!!!* Г.Мөхәммәтшин

**ИЕ́ КИЛҮ** *ф.* Җае, урыны, вакыты һ.б. туры килү, җайлану. *Ие килсә, көе килми.* Әйтем

**ИЕЛӘ-БАСА** *рәв. к.* **иелә-тора**. *Иелә-баса, мәче кебек кача-поса, урман эченә кереп барган кыздан ничек тә калмаска кирәк иде.* Г.Гыйльманов

**ИЕЛӘ-БӨГЕЛӘ** *рәв.* 1) Бер иелеп, бер тураеп. *Ул иелә-бөгелә үләннәрдән, чәчкә керфекләреннән чык бөртекләре җыеп ала ---.* Г.Сабитов. *Ир артымнан иярмәде, иелә-бөгелә, «Волга»-сына кереп чумды.* Н.Гыйматдинова. *Ул керүгә, ресторан ишекләрен ачык тоткан кызыл формалы мыеклы швейцар карт, иелә-бөгелә, киң елмая ---.* Х.Ширмән

2) Җилдән, давылдан як-якка чайкалып, сыгылмалы хәрәкәтләр ясап. *Аркылы-торкылы егылган кабыксыз имәннәр --- үзләренең баш очларында иелә-бөгелә шаулашкан ыругдашларын тын калып тыңлыйлар сыман.* Н.Хәсәнов. *Алсу гөлләр һаман иелә-бөгелә Салкын кабер ташын үптеләр.* Р.Вәлиева

**ИЕЛӘ-СЫГЫЛА** *рәв.* 1) Гәүдә белән сыгылмалы хәрәкәтләр ясап, гәүдәне ия-ия. *--- әллә әтине күрмичә, әллә юри күрмәгәнгә салынып: – Өммикамал җаным! Атаң матур кияүгә бирсен! – дип кычкырды. Аннан иелә-сыгыла көлделәр.* Г.Бәширов. *«Эчемә кату чыга бит инде, Шәүкәт!» – дип, иелә-сыгыла, күз яшьләрен сөртә-сөртә көлүче Гөлйөзем түгел ул.* Р.Бәшәр. *Әнә бер хатын көянтә белән, иелә-сыгыла, су алып кайта ---.* Г.Әпсәләмов

2) *к.* **иелә-бөгелә** (*2 мәгъ.*). *Ә яшь таллар Җилләр дулкынында, Иелә-сыгыла, җиргә авалар.* Х.Туфан. *Өянке агачлары, сизелер-сизелмәс кенә иелә-сыгыла, күләгәләр бирә.* Ш.Камал

**ИЕЛӘ-ТОРА** *рәв.* Гәүдәне бер иеп, бер турайтып. *Үз окопларыннан, иелә-тора, немец окоплары ягына китеп баручы ике шәүләне күреп, Сәфәргали Арнаутовка эндәште.* Ф.Хөсни

**ИЕЛЕНКЕРӘ́Ү** *ф. сир.* Гәүдәнең өске өлешен бераз гына бөгә, ия төшү. *[Аның] гәүдәсе дә борынгы кебек бик үк туры түгел, бәлки, эче яки биле авырткан кеше кебек алга таба иеленкерәп йөри.* М.Гафури

**ИЕЛҮ** *ф.* 1) Басып торган хәлдә башны яки гәүдәнең билдән югары өлешен аска таба бөгү. *Ана кеше баласы өстенә иелә: – Ни кирәк, балам? – дип сорый.* Р.Батулла. *Ак колын ераккарак китә башласа, бия, сискәнеп, башын өскә чөя һәм, колынның арлы-бирле чабуы шаяру гына икәнен күргәч, тагын чирәмгә иелә.* М.Хуҗин. *Куркырга ярамый, дип уйлый Алексей, шартлау булган саен, окоп төбенә иелә.* Х.Камалов

2) Агач-куакларның, үсемлекләрнең ботаклары аска салынып төшү. *Су өсләрен аксыл томан сарган, Моңсу гына таллар иелә.* Д.Сирай. *Мин йөрим бакчабыз түрендә, Алмалар көткәннәр, билгеле, Ботаклар иңсәмә иелә ---.* Г.Афзал. *Янәшәмдәге карт каен Бер турая, бер иелә.* Р.Хисмәт

3) Янтаю, кыйшаю, авышу. *Әнә шул [элекке] авылның баштанаяк иске вә черегән, саламга күмелгән, мескеннәрчә иелеп, җиргә сеңгән аяныч биналары!* Г.Ибраһимов. *Иске дә иске, һай, түбәсе, Еллар үтеп, кыеклар иелгән.* Н.Исәнбәт

4) *күч.* Буйсыну, буйсынуны белдереп, билне яки башны ию. *Халык өстенә төшкән авырлык шулкадәр зур: билләр чыдый алмый, чытырдап бөгеләләр, муеннар иелә, иелмәс муеннар чабыла тора.* Р.Батулла. *Хөрмәт итәм өлкәннәрне, Тик теләмим баш ияргә; Баш болай да иелә ул Баш ирдәй кешеләргә.* М.Әгъләм. *Иелә белдек, бөгелә белдек, Бер тәкәббер гөл булмадык. Мәхәббәткә тезләнсәк тә, Горурлардан ким булмадык ---.* Ф.Яруллин

**Иелә бару** Торган саен ныграк иелү. *Иң гаҗәбе шунда: Хөсәеннең горур башы иелә барды, иелә барды һәм, ниһаять, тәмам бөгелеп, Ларисаның иңенә терәлде ---.* М.Маликова. *Авыр уйлардан башы түбән иелгәннән-иелә барды.* Ф.Яруллин. *Ул сөйләгән саен, Арслановның башы аска иелә барды.* Ф.Садриев

**Иелә башлау** Иелү хәрәкәтенә керешү. *Шулчак нидер булды, Айбиби: – Ah! – диде дә җиргә таба иелә башлады.* М.Хәбибуллин. *Ул үз караваты янына килде, тегे төргәген култык астыннан алды, тумбочка ишеген ачты һәм төргәген куярга дип иелә башлады.* Җ.Дәрзаман. *– Ә, беләм, беләм, – диде Шәфыйк, лампа алып, сәке астына иелә башлады.* М.Әмир

**Иелә бирү** Бераз иелү. *Ул арада ишектән, иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, --- капчыкланып беткән зәңгәр пинҗәктән Сәетгали үзе керде.* Ә.Еники. *Ул дулкынлана иде. Акрын гына Фрунзега иелә биреп, пышылдауга җитә язган тавыш белән сөйли башлады ---.* З.Зәйнуллин. *«Ишетсен» дигәндәй, иелә биреп, ул, борылып, мәет тарафына кычкырды: – Иптәш Кәримов, сиңа кабер дә казып булмый!* А.Хәлим

**Иелә төшү** Бераз иелү; тагын да ныграк иелү. *Ул, иелә төшеп, сарайның тәбәнәк капкасыннан чыгып китте.* З.Гыйниятова. *Сәйфи, иелә төшеп, Мәүлиха белән Әпипә арасында торган*

*юкә кисмәктән бер уч бодай алды ---.* Г.Бәширов. *Борһан, әйтәсе сүзләрен оныткан кеше сыман, тотлыгып калды. Башы тагын да иелә төште.* М.Хәсәнов

**Иелеп алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында иелү. *Әби дәшми. Калкына. Нидер пышылдый, янә иелеп ала, янә тезләнеп башын ора.* Р.Батулла

**Иелеп бетү** Аска кадәр иелү. *Сез барыгыз да иелеп беткәнсез инде. Сыртыгызда йөгереп йөриләр.* Ф.Садриев

**Иелеп тору** 1) Һәрберсенә, бертуктаусыз иелү

2) Иелгән хәлдә булу. *Гамь агачын бик тиз танып алган ул, чөнки, бөтен агачлар төп-төз утырганда, моның башы түбәнрәк иелеп тора икән.* Ф.Яруллин

**ИЕЛҮ-БӨГЕЛҮ** *ф.* Җилдән, давылдан төрле якка чайкалу, бөгелү. *Җил көчәя, күл читендәге тирәкләрнең ботаклары иелә-бөгелә, камышлар яман кыштырдый башлауга, мин күккә карадым ---.* М.Ибраһимов

**ИЕ́НА** *и. яп.* Япониядә акча берәмлеге. *Япониядә билгесез калырга теләгән бер химаяче җәмәгать бәдрәфләрендә 10 ар мең иена (60 евро) салынган конвертлар калдырып йөри.* Мәдәни җомга

**ИЕНКЕ** *с.* 1) Иелгән, бөкрәеп торган. *[Вульфның] Иенке гәүдәсе, күтәренке җилкәләре миндә тирән нәфрәт уятканнар иде инде.* А.Расих

*2) күч.* Буйсынган, буйсынуны белдереп бөгелгән. *Бу җил, бу туфанны каршы алыр капитан Иенке баш, бөгелгән бил белән.* Г.Камал

*3) күч. сөйл.* Сүз тыңлый торган, күндәм. *Бик иенке бала*

4) *сир.* Уйсуланып торган. *Ярдан чыгам-чыгам дип торган елга суы әйтерсең шуны гына көтеп торган: иенке җирләрне елга ясап чыгарга да тотынды.* А.Алиш

**ИЕНКЕ́ КАЕН** *и. бот.* Каенның ачык җирдә, корырак урыннарда үсә торган төре; *русчасы:* **берёза повислая**. *Иенке каен – Россия символы, бөек җиребезнең иң үзенчәлекле агачы.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Татарстан территориясендә иенке каеннар һәм бөдрә каеннар – урман барлыкка китерүче төп токымнар.* Татарстан яшьләре

**ИЕРАРХ** *и. гр. дини кит.* Изге җитәкче, дин әһеле; христиан динендә иң югары рухани (патриарх, митрополит, архиепископ, епископ)

**ИЕРА́РХИК** *с. кит.* Иерархиягә бәйләнешле, эзлекле. *Каһиннәр төркеме бердәм булмаган, иерархик принципка нигезләнеп төзелгән.* Б.Хәмидуллин. *Төркиләр дәүләтендә һәм җәмгыятендә катгый иерархик система хөкем сөрә.* Г.Фәйзрахманов

**ИЕРА́РХИЯ** *и. гр. кит.* 1) Иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасының югарыдан түбәнгә таба тезелгән тәртибе. *Сез түбәндә, пычракта болганып ятасыз, ә без, югарыга күтәрелеп, иркен яшибез, басмалар иерархиясен табигать үзе шулай куйган.* Г.Нигъмәти. *--- системаны тәшкил итә торган элементлар буйсыну-буйсындыру (иерархия) мөнәсәбәтендә яшиләр һәм хәрәкәт итәләр.* К.Гыйззәтов

2) Сыйнфый яктан түбәнге катлауның югарыдагыларга буйсыну тәртибе. *1445 елдан алып Казан дәүләтенең феодаль иерархия баскычы түбәндәгечә булган: илдә югары хакимият хан кулында була, һәм дәүләтнең барлык җирләре хан милке булып санала ---.* Б.Хәмидуллин. *Лев Толстой болай дип язган: «Безнең иерархия үзе дә тота һәм халыкка да сеңдерә торган дин – алдау гына да түгел, әхлаксыз ялган да ул».* Р.Хәким. *--- җанварлар арасында күселәрдә генә тәгаен хакимият вертикале икән. --- Аларда бик төгәл иерархия, имеш.* Р.Зәйдулла

**ИЕРО́ГЛИФ** *и. гр. лингв.* Алфавитсыз язулы кытай, япон, корея телләрендә һәм борынгы мисырлылар язу системасында шартлы рәвештә тулы бер төшенчәне, иҗек яки аерым авазны белдерә торган рәсемгә охшаш билге. *Кытай язуында утыз биш «та» иероглифы бар.* Р.Әхмәтьянов. *Бу вакыйгалар турында б.э.к. 1300 – 1200 елларда хайван сөякләренә төшерелгән иероглиф язулар да хәбәр итә.* Г.Фәйзрахманов. *Илленче елларда Корея телен өйрәнгәндә, мин Кытай иероглифларын да бераз караштырган идем, тик, соңыннан, кулланмагач, онытылган: ун-унбишләп иероглиф кына ачык истә калган.* Татар теле. Хрестоматия

**ИЕРО́ГЛИФИК** *с. лингв.* Иероглифларга бәйләнешле, иероглифларга нигезләнгән. *Мисыр иероглифик язуында «җәя» сурәте «М» хәрефе рәвешендә.* Н.Фәттах. *Россиядәге дунганнарда – башта иероглифик (кытай) язуы, аннан – --- рус графикасына нигезләнгән язу кулланыла.* Ф.Сафиуллина

**ИЕРОМОНАХ** *и. гр. дини* Рухани дәрәҗәсендәге монах. *Зөядәге Богородицкий монастыре архимандриты итеп, миссионерлык эшендә зур тәҗрибә туплаган иеромонах Алексий Раифский билгеләнә, һәм ул урыс булмаган халыкларны чукындыру эшен оештырырга тиеш була.* Ф.Ислаев. *750 елның 29 июнендә, Изге Пётр һәм Павел бәйрәмендә, иеромонах Патрикий мондый эшләре өчен аларга чиркәү мөнбәреннән ләгънәтләр яудыра, аларны «диннән язган кешеләр» дип игълан итә.* М.Гайнетдин

**ИЗА** *и.* Җәфа, газап, кыенлык. *Курорттан кайтышка тагын дүрт-биш көн иза: тегендә тынлыкка өйрәнгән газиз башкаең янәдән хатынның --- музыкасына ипләшергә тиеш. Ф.Хөсни. Изасы бар, хафасы бар, Барырым – чытыр юллы.* Р.Фәйзулин. *Әнә бит алдымда, Сөзәклек артында, Мин иза кичергән Таш кала калкына.* Б.Рәфиков

**ИЗАЛАНУ** *ф.* Җәфалану, газаплану, интегү. *– Ә син боларны каян беләсең? – дип сорады Хәнәфи, бераз баргач. --- – Шундый гыйлемлегең булгач, нигә колхозда изаланасың?* А.Гыйләҗев. *Эчпошыргыч тынлык сиңа ни дип җавап бирсен? Ул синең ялгызлыктан тырмашып изалануыңнан дәшми генә авыз ерып көлә дә кебек.* Н.Хәсәнов. *Бу Иркә сихерче булды, ахры. Күпме изалана – күз алдыннан китми.* Ф.Яруллин

**Изаланып бетү** Бик нык изалану. *Бакча артларыннан, койма буйларыннан кура җыеп алып кайталар, туң курага ныклап ут эленгәнче тәмам изаланып бетәргә кирәк, бөтен төтен өй эченә чыга.* Ф.Сафин. *Җырланмаган*

*җырым, Көйләнмәгән көем син минем. Ничек башларга да белми торам, Изаланып бетәм инде мин.* Х.Әюп

**Изаланып тору** Изаланган хәлдә булу. *Андыйлар, гадәттә, халык язмышы, милли идея, иҗади миссия кебек «вак» нәрсәләр белән изаланып тормый: яздым – бетте!* Р.Фәйзуллин. *Ничек чыгарга белмичә, тилмереп, изаланып торганда, тыштан Нурисламның кычкырганы ишетелде* ---. Р.Вәлиев

**ИЗАЛА́У** *ф.* Кемне яки нәрсәне дә булса җәфалау, газаплау, интектерү. *Пычагыма кирәкмени буранда халык изалап, ат азаплап йөрергә! А.Расих. Еллар үткәч, үземне изалап, борчып йөргән сорауны мин --- Аяз агага бирермен* ---. М.Галиев. *Ирләре югы – юк дип әрнесә, ирләре барының кайберләре, мәңге исерек булулары белән, хатынкызны бары тик изалап кына яши.* Э.Шәрифуллина

**Изалап бетерү** Бик нык изалау

**Изалап тору** Бертуктасыз, һәрвакыт изалау; әледән-әле изалау. *Тагын ике көннән факультетның партия комитеты утырышы булды. Бу юлы инде мине әллә ни изалап тормадылар, партия җыелышының карарын раслап, мәсьәләгә үзләренчә нокта куйдылар.* З.Зәйнуллин

**Изалый башлау** Изаларга тотыну. *Ләкин бераздан ук аны [Гайнанны] коточкыч саташулар, куркыныч төшләр изалый башлады.* Г.Бәширов

**ИЗАЛЫ** *с.* Интектергеч, җәфалы, газаплы. *Көннәр түгел, авыр еллары, Заманабыз зарлы, изалы.* Ф.Чанышева. *Шундый ярлылык, шундый изалы тормыш өстенә, тугызынчы бала булып, шушы кыз туды, бахыр.* М.Әмир. *Авторның каршылыклы кыйбласы, ярсу хисләренә җавап тапмыйча изалы эзләнүләре «Үтерелгән пәйгамбәр» (1918) шигырендә дә дәвамлы килә.* М.Җәләлиева

**ИЗАР** *и. гар. сир.* 1) Гәүдәне билдән түбән каплау өчен билгә бәйли торган алъяпкыч (гадәттә мунчада бәйләнә). *Мәликнең табуты төрбәгә җитте, Үзе керде Ширин, Хөсрәүне кертте. Изар бәйләп каравышлыкка, шунда: – Чыгыгыз, – диде, – калыйм мин шушында.* Котб. *Быел яз көне ул хатыныннан --- бер изар [тектерде].* Г.Газиз. *[Мунчада кунакларның] икесен ике хезмәтче чишендерде. Үзләренә дә, кунакларга да изар бәйләделәр.* М.Галәү

2) Скульптурада ялангач кеше сыннарының җенес әгъзаларын каплап торган яфрак сурәте; фига яфрагы

**ИЗАФӘ** *и. гар. лингв.* Аергыч һәм аерылмыш мөнәсәбәтендә торган исемнәрдән гыйбарәт булган, сүз тезмәләрендә затның яки предметның билгеле бер затка яки предметка нисбәт ителүен белдергән грамматик категория. *Ул чын татарча «Яр Чаллысы» булырга тиеш. Чөнки бу тезмә сүзнең компонентлары тел законы буенча изафә бәйләнеше нигезендә бәйләнешә: тау башы, яр буе --- һ.б.* Р.Юсупов. *Революциягә хәтле шактый актив кулланылышта булган гарәп изафәсе рәвешендә йөргән тезмәләр дә --- татар, рус сүзләре белән алышындылар* ---. Ф.Сафиуллина. *Фарсы теленә хас булган изафә бәйләнеше кайвакыт язуда күрсәтелми кала* ---. Х.Миңнегулов

**ИЗАФӘТ** *и. гар. лингв. к.* **изафә**

**ИЗАХ** *и. гар. кит.* Аңлатма, ачыклама. *Кулланган ишарәтләрем хакында изах биреп китүне тиешсенәм.* М.Фәйзи. *Мәсьәләгә изах кертеп, аңлатып бирсәгез икән?* К.Тинчурин

**ИЗА́Х ИТҮ** *ф. к.* **изах кылу**. *Күп кешеләр бу шигырьдән морад нәрсә икәнен бөтенләй аңлап җитмәгәнгә, азрак изах иттем.* Г.Тукай. *[Моңарчы] Байлык «Ходай биргәннән», «казна тапканнан», «очраклы рәвештә байлыкка юлыгудан» кебек җаваплар белән изах ител[гән була].* Г.Нигъмәти. *Син, Хөснимәрдән агай, изах ит, аңлат: уйларың, фикерләрең кай якка ага?* Р.Сибат

**ИЗА́Х КЫЛУ** *ф.* Аңлату, төшендерү, ачыклау. *Әдәбиятның да матди тормышка бәйләнгән бер тармак икәнен башта изах кылып үтү кирәк.* Г.Ибраһимов

**ИЗА́ ЧИГҮ** *ф.* Газаплану, җәфалану, интегү. *Бибигайшә иртәдән кичкә кадәр аяк өстендә, көнозын бетмәс-төкәнмәс йорт эшләреннән иза чигә.* Т.Мөбарәков. *Минем «Тәфтиләү», «Гөлҗамал»ларга җайлашкан колак Бетховен, Чайковский, Яруллиннарга ияләшә алмыйча иза чикте.* Р.Вәлиев. *Кәшфи яңа эш урынына ияләнә алмыйча иза чикте* ---. М.Мәһдиев

**ИЗБАЧ** *и. рус тар.* 1) Утызынчы елларда, укырга-язарга өйрәнү өчен, халык җыела торган өй

2) Шул эшне оештырып, укырга-язарга өйрәтүче кеше. *Утызынчы елларда бернichә авылда избач булып эшләп йөргән иде.* М.Мәһдиев. --- *Себер татарларының рухи дөньясында якты эз калдырган мулла улы – хезмәт юлын комсомол активы һәм избач булып Төмән җирендә башлап җибәргән Хәмит Ярмөхәммәтов – Казанга юл тотканда, инде татар халык җырларына, халык иҗаты җәүһәрләренә гашыйк булып өлгергән булган.* Б.Сабирова

**И́ЗВЕСТЬ** *и. рус* Составында кальций оксиды булган, тау токымын яндырып табыла торган ак минераль матдә. *Яту белән, бөтен сөяк-санаклары сызларга тотынды, известь базына егылып төшкәннән соң кичергән әрнүләре, ике-өч ел узгач, үзен тагын сиздерә башлады.* К.Миңлебаев. *[Айрат:] – Бу якларда кырлар ачы туфраклы, – диде ул. – Әгәр бу балчык известь булып чыкса, беләсеңме нинди олы хәзинәбез булачак!* А.Вергазов. *Биш елга бер йөк тирес китермәделәр, бер чиләк торф, бер көрәк известь кертмәделәр.* Г.Мөхәммәтшин

**И́ЗВЕСТЬЛӘНҮ** *ф.* Известькә әйләнү, известь утыру. *Йөткергән вакытта, Галимҗанның үпкәсендәге күптән известьләнеп каткан туберкулёз учагындагы кан тамыры ярылган.* Г.Мөхәммәдова

**И́ЗВЕСТЬЛӘҮ** ф. 1) Әчелеген киметү өчен, туфракны известь белән ашлау. *Сезгә, ничек кенә булса да, бу урынны быел яз известьләргә кирәк.* Г.Галиев

2) Берәр нәрсәгә известь сеңдерү, известь катнаштыру. *Менә известьләү ысулының бер төре. Башта туралган саламны әле генә сүндерелгән известьнең бер процентлы эремәсендә манчыйлар. А.Расих*

**Известьләп бетерү** Ахырга кадәр, тулысынча известьләү

**Известьләп тору** Даими известьләү. Туфракны әледән-әле известьләү

**Известьли башлау** Известьләргә тотыну

**И́ЗВЕСТЬЛЕ** *с.* Составында известь булган, известь катнаштырылган. *Бүлмә эче буп-буш иде, тып-тын иде. Известьле киң табан эзләре белән чуарланган тузанлы идәндә кәгазь кисәкләре, буш шешәләр аунап ята ---.* Н.Фәттах. *Ә менә абага гөл – известьле кыя ярыкларында, гади елан абагасы дымлы болыннарда үсә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИЗВЕСТЬТАШ** *и.* Составында известь (кальций оксиды) булган утырма тау токымы (мәс., *доломит, акбур, мрамор). Бу скважинаны бораулаган чорда, токымнарның төрле үрнәкләрен күреп үтте Камил. Ком чыкты, известьташ, балчыклы ком, комлы балчык – барысы да чыкты.* Ш.Бикчурин. *Алат янындагы известьташ катламында мәгарә бар.* Ф.Гарипова. *Известьле ашламалардан еш кулланыла торганнары – известьле туфрак, доломит оны, известьташлар, акбур.* Х.Байчурова

**ИЗВЕСТЬТАШЛЫ** *с.* Составында известьташ булган, известьташ катнашкан. *Известьташлы көньяк тау битләрендә кылган үләннәре зур урын алганнар.* А.Фаткуллин

**И́ЗВЕСТЬ ШПАТЫ** *и. махс.* Кальцит

**ИҖА́БЕ КАБУЛ** *и. гар. иск. этн.* Кыз ярәшкәндә никахка кадәр булган килешү; алдым-бирдем. *Кирәк булса, хәзер үк берегезгә «алдым-бирдем» ясап, яучылык кылып, иҗабена кабулын кушып, туй ясап алырга була.* Ф.Бурнаш

**ИҖАБИ** *с. гар. иск. кит.* Уңай; *киресе:* **тискәре**. *Бу шигырьләр капиталистик системадагы эксплуатация, хаксызлык, изү һәм вәхшәтне фаш иткән, революцион хәрәкәтнең үсешендә иҗаби роль уйнаган әсәрләр булдылар.* М.Җәлил. *Матурлыкны күреп, кешенең эстетика тойгысы шуңа омтыла, шуннан ләззәт таба, бу – иҗаби як.* Г.Нигъмәти

**ИҖАДИ** *с. гар.* 1) Иҗат итү сәләте белән бәйле булган. --- *болар барысы да – бары тик егерме җиде яшькә кадәр генә дәвам иткән гомер юлында ирешелгән иҗади һәм рухи-әхлакый биеклекләр!* М.Вәлиев. --- *әкиятне сөйләве генә ансат. Моның өчен никадәр ихтыяр көче, ничаклы иҗади эзләнүләр таләп ителгәнлеген мастерның чал башы, маңгаендагы тирән җыерчыклары бик ачык сөйли дә, иҗади фикернең өзлексез дәвам итүен әнә шулай күз иярмәслек тизлек белән шырпылар уйнаклатучы куллары күрсәтеп тора.* Р.Төхфәтуллин. *В.Имамовка зур гына күләмле бу әсәрне һәр яктан камил итеп эшләп бетерергә иҗади көч һәм тәҗрибә җитмәгән.* Казан утлары

2) Төзүгә, барлыкка китерүгә, иҗат итүгә юнәлдерелгән. *Ирек, самолёттан төшкәч тә, үзе белән бер курста укучы Әхмәткә шылтыратты. Ләкин ул редакциядә туры килмәде, бер атнага иҗади ял алган, диделәр.* Ф.Садриев. *Гөлшат Зәйнашева күренекле шагыйрьләр, композиторлар, җырчылар --- белән аеруча дус булып яшәде. Бу җитди, иҗади дуслык булган.* Мәдәни җомга

3) Үзендә иҗат яңалыгы, яңача эшкәртү, иҗат итү сыйфаты булган. *Радиодагы эш Шәмсир күзаллаганча ук җанлы һәм иҗади шөгыль булып чыкмады ---.* Т.Әйди. *Ә ирекле кеше һәрвакыт иҗади фантазиягә бай.* З.Фәйзи

4) *пед.* Нинди дә булса кагыйдәне үзләштерү максаты белән махсус сайлап алынган сүзләрдән, телдән җөмләләр төзеп, аларны тикшереп һәм соңыннан хәтердә калганча яки укытучы әйтүе буенча язудан гыйбарәт диктант. *Иҗади диктант укучыларның сөйләм телен үстерүгә дә ярдәм итә.* М.Вәлидова

**ИҖАДИ-ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ** *с.* Иҗат һәм акыл эшчәнлегенә бәйле, иҗат һәм акыл эшчәнлегенә караган. *«Алиш бәйгегә чакыра» дип исемләнгән бу иҗади-интеллектуаль ярыш укучыларыбызда гаҗәеп дәрәҗәдә кызыксыну уятты.* Мәгърифәт

**ИҖАДИЛЫК** *и.* Уйлап чыгаруга, яңалыкка омтылу сыйфаты. *Иҗадилык аның һәр эш-гамәлендә, һәр шигъри юлында сизелеп тора.* Х.Миңнегулов. *Бу каршылыкны җиңеп чыгу ике тел белән эш итүче каләм иясеннән зур осталык, иҗадилык таләп итә.* Р.Юсупов. *Тора-бара мәкаль-әйтемнәрнең сүз байлыгын үстерүе, аның аһәңлелегенә, --- образлылыгына өстәмә көч бирүче булып әверелүе сөйләмнең иҗадилыгын тәэмин иткән.* Әдәбият

**ИҖАДИЯТ** *и. гар. кит.* Иҗат эшчәнлеге. *Мин тик иҗадиятемнең нигезенә куелган түбәндәге матдәләрне әйтеп үтәм.* Һ.Такташ. *Тоташ тетрәнүләрдән торган бу хәят һәм иҗадият әле кайчан да булса чын трагизмы, чын бөеклеге белән ачылыр...* Р.Даутов

**ИҖА́П КАБУЛ** *и. гар. иск. этн. к.* **иҗабе кабул**. *Әни иҗап кабул турында әйтеп караган иде.* А.Шамов

**ИҖАРӘ** *и. гар.* Аренда. --- *1750 елда татарлар Сенатка --- печәнлекләре булмагач, күршеләреннән иҗарәгә алып чәчүләрен бәян итеп шикаятьнамә бирделәр.* Г.Гобәйдуллин

**ИҖАТ** *и. гар.* 1) Кешенең рухи, матди байлыклар, мәдәният хәзинәләрен барлыкка китерүгә юнәлдерелгән мөстәкыйль эшчәнлеге. *Карт доктор – үзенең табип гыйлемендәге яңа иҗатлары белән дан тоткан профессор – озак карады Зәйнуллинны ---.* С.Җәлал. *Ирек алып кергәч, ул аның титул битенә: «Ирек Хәйриевичка тагын да зуррак иҗат уңышлары теләп, Арсланов» дип язды һәм, Ирекнең кулын кысып, китапны кабат бирде.* Ф.Садриев. --- *Башкортстан язучылары берлеге аксакалларының сиксән проценты татар булган иҗат оешмасына 34 яшемдә әгъза булып кабул ител[дем].* А.Хәлим

2) Шул иҗади эшчәнлек нәтиҗәсе; берәр кеше яки кешеләр коллективы тарафыннан барлыкка китерелгән хезмәт җыелмасы. *Халык иҗаты җәүһәрләренең асыллары әле җыелмаган, дәреслек китапларында урын ала алмаган.* А.Гыйләҗев. *А.Алиш танылган драматург һәм фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең татар халык авыз иҗатын җыюын зур шатлык белән каршы ала ---.* С.Шакир. *Шулай әйле-шәйле болгана торгач, ахыр чиктә, уң яктагы остаханәдә ут чыгарып, Карнаков*

*дигән рәссамның күп еллык иҗат җимешләрен төтен иттеләр.* М.Маликова

**ИҖА́Т ИТҮ** *ф.* Нинди дә булса өлкәдә матди яки рухи байлыклар барлыкка китерү. *Әллә син редактор эшен бездәгедән дә тынгысызрак дип уйлыйсыңмы? Рәхәтләнеп эшләү, иҗат итү өчен мөмкинлекләр анда инде ул.* Ф.Садриев. *Хәсән ага һәр дәресен үзенчә иҗат итә.* М.Галиев. *Дүртләр тирәсендә Ирек Сөембикәне дәште һәм ике хатын-кыз кичкә кадәр үзләренең аш-суга маһирлыкларын берләштереп, уртак табын иҗат иттеләр.* Ф.Садриев

**ИҖА́Т КЫЛУ** *ф. к.* **иҗат итү**

**ИҖАТКЯР** *и. к.* **иҗатчы**. *Була тагын икенче төр иҗаткярлар, иҗатларының беренчел кисемендә алар башкалардан әллә ни аерылып тормыйлар ---.* Н.Гамбәр

**ИҖАТТАШ** *и.* Бергәләшеп, күмәкләп иҗат итүчеләр. *Юбилейдан соң, күңелле итеп, районлаш-авылдашлар, туганнар, иҗатташлар белән --- аш-су мәҗлесе корып утырдык...* Л.Шагыйрьҗан. *Остаханәдә генә ул бөтен рәссам ни эшләгәнеңне белеп тора. Иҗатташ дусты Галиеч килгәч тә эш бүлмәсен ачмады.* Д.Гайнетдинова. *Башкортстанда яшәп иҗат итүче танылган татар композиторы Урал Рәшитов бик күп иҗатташ дуслары катнашында зур сәнгать бәйрәме әзерли.* Мәдәни җомга

**ИҖАТТАШЛЫК** *и.* Бергәләшеп, күмәкләп иҗат итү эшчәнлеге. *Соңгы елларда фәнни әдәбиятта сәнгать әсәрен зиһенгә алу үзенә күрә ул «иҗат итү» дә, «иҗатташлык» та дигән фикерләр куерып китте.* К.Гыйззәтов. *Бу этапларда педагогның төп эшчәнлеге – үсмерләр арасындагы үзара йогынтыларны бу уен кысаларындагы хезмәттәшлек һәм иҗатташлыктан чыгып көйләү.* А.Хуҗиәхмәтов

**ИҖАТХАНӘ** *и.* Рәссам, скульптор, архитекторлар эшли торган бүлмә; мастерской. *--- соңгы өч ел эчендә генә дә рәссамнарыбыз Дзержинский урамындагы сәнгать салонын, халык рәссамы Әмир Мәҗитовның иҗатханәсен югалтты.* Шәһри Казан

**ИҖАТЧАН** *с.* Иҗат итәргә сәләтле, иҗат итәргә һәвәс, иҗат итү белән мавыгучан. *[Балаларның] Иҗатчан булулары белән оригинальлеккә, яңалыкка омтылулары билгеле.* Н.Исәнбәт

**ИҖАТЧАНЛЫК** *и.* Иҗатчан булу

**ИҖАТЧЫ** *и.* **1.** 1) Иҗат эше белән шөгыльләнүче кеше. *Ул вакытта университетта яшь иҗатчылар күп һәм көчле иде.* Р.Фәйзуллин. *Колхоз идарәсенең ике катлы кирпеч бинасы һәртөрле шәһәр иҗатчыларының зәвыгы белән ярышырлык ---.* Казан утлары. *--- гомер юлының шулай аянычлы башлануы булачак иҗатчыда тирән эз калдыра.* Мәдәни җомга

2) Үз акыл сәләте белән уйлап яңалык кертүче, һәрнәрсәгә иҗади якын килүче кеше. *Бөек кешеләр, бөек иҗатчылар рәтенә театр галәмендә үзенең режиссёрлыгы белән танылган --- Станиславский да керә.* Г.Кутуй. *XXI гасырга хатын-кызлар, ир-атлар белән янәшә торып, цивилизацияне алга этәрүчеләр, иҗатчылар булып керергә тиеш, дип әйтелде.* С.Ибраһимова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Иҗат итүче. *Өметле иҗатчы И.Салахов күренекле әдип Г.Ибраһимовның фатихасын алган ---.* Әдәбият

2) Үз акыл сәләте белән уйлап яңалык кертүче, һәр нәрсәгә, һәр эшкә иҗади килүче. *Секретарь эштә дә, тормышта да стандартны сөйми, ул кешенең иҗатчы булуын, кечкенә генә эшкә дә ни дә булса үзенекен, үз белдеген өстәвен тели.* Г.Бәширов

**ИҖАТЧЫЛ** *с.* **1.** Иҗат итү сыйфатларына ия булган, яңа уй-фикерләр тудыра торган. *Тик бу шөгыль максатчыл, иҗатчыл булырга тиеш.* И.Низамов. *Дискуссиянең иҗатчыл методы*

**2.** *рәв. мәгъ.* Яңача якын килеп, яңа фикерләргә нигезләнеп, яңа фикерләр кулланып

**ИҖАТЧЫЛЫК** *и.* Иҗат эше, иҗади эш белән шөгыльләнү. *--- безнең өчен аулак өй йоласының иң мөһим ноктасы да аның үткен, шаян иҗади тел, --- җыр-бию, көй-музыка иҗатчылыгы, төрле кызыклы халык уеннары һәм фольклор мәйданы булып килүендә.* Н.Исәнбәт

**ИҖЕК** *и.* 1) *лингв.* Бер һава этәрелеше белән әйтелә торган, бер сузык авазлан гына яки бер сузык янында килгән бер яисә берничә тартыктан торган иң кечкенә сөйләм берәмлеге. *Татарчада ике яки күп иҗекле сүзләрнең бер иҗеге басылыбрак, ачыграк итеп әйтеләдер. Без мондый иҗекне «басымлы» дип, шуннан башкаларын «басымсыз» иҗек дип атыйбыз.* Җ.Вәлиди. *Аның [Рәйләнең] татарча сөйләшүен тыңлау үзе үк рәхәт. Сүзләрнең һәр иҗегенә басым ясап, тырышып кабатлый.* Ф.Мәснәвиева. *Хәрефләрне кушып укыту ысулы кулланылган: балалар әүвәл хәрефләрнең исемнәрен өйрәнгәннәр, аннары алардан иҗекләр, сүзләр ясаганнар.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) *пед. иск.* Иске ысул белән укытуда: гарәп сүзләрен иҗеккә (*1 мәгъ.*) аерып, нинди хәрәкә белән булуын әйтеп уку (мәс., *кәп өсте кә, ләм асты ли, мим өсте мә* дип уку). *Ул вакытта иҗек танып, Коръән укый башлау хәзерге көндәге беренче баскыч мәктәптән икенчегә күчү белән бер исәпләнә.* М.Гафури

◊ **Иҗеген иҗеккә китерү** Матурлап, стиль ягыннан шома, дөрес итеп, җиренә җиткереп уку, сөйләү, язу. *Иҗеген иҗеккә китереп оештырып утырырга минем вакыт бармыни?* Р.Ишморат

**ИҖЕКЛӘ́Ү** *ф.* **1**. 1) Иҗекләргә бүлү. *– Аң-ла-шы-ла, – диде Хантимер, сүзен иҗекләп. – Бер тапкыр хыянәт иткән ир үлгәнче әлеге гадәтен куа.* Н.Гыйматдинова. *Шәп яңгырады бу сүз. --- Корбангали абзый малаеның болай өздереп әйтә белүен ошатты. Хәтта «кулына туры килмәгән»е аның үзенә кагылса да, моны иҗекләмәскә тырышты.* Ф.Хөсни. *– Ничек инде булмасын. Бар. Тик алар тагын да күбрәк калым таләп итәләр. – Серадов ыржаеп көлде. – Гыйффәтле кыз әләктерәсең киләме? Ба-рып чыкмас! – дип, иҗекләп әйтте ул.* З.Фәтхетдинов

2) *иск. пед.* Иҗек (*2 мәгъ.*) белән уку. *Кечерәк кызлар: «Әбсен ә, бигә сәкен, әб...» дип иҗекләргә керешәләр.* К.Нәҗми

3) *күч.* Җентекләп, тәфсилләп аңлату, төшендереп бирү. *Шулай диген син: савытларыгызны, диген. Безнең шикелле наданнарга иҗекләбрәк әйтмәсәң, әллә ни калага барып укыган гыйлемлек юк.* М.Фәйзи

**2. иҗекләп** *рәв. мәгъ.* Авырлык белән, сүзләрнең иҗекләрен, хәрефләрен берәм-берәм оештырып. *Әмирнең тез өстендә углакы Җаббар утыра, һәм углан иҗекләп китап укый иде.* М.Хәбибуллин. --- *бер гаиләдә өч язу үрнәген танып белеп тә, телдән бер-берсен аңлап та, язмада бер-берсен аңлый алмыйлар, укыганда да бик җәфаланып, иҗекләп укыйлар ---.* А.Хәлим. – *Син күрер-гә бир-мә-гән-сең-дер шул. – Бу кадәр озын җөмләне Гөлкәй көч-хәл белән иҗекләп-иҗекләп әйтте.* Х.Ширмән

**Иҗекли башлау** Иҗекләргә тотыну

**Иҗекли тору** Шактый вакыт дәвамында иҗекләү. *Камали русча ташка басканны кыенлык белән аера иде. Күп иҗекли торгач, ул кәгазьләрдән «заградительный отряд» дигәнне генә таный алды.* Г.Ибраһимов

**Иҗекли төшү** Бераз иҗекләү. *Матбаганы күрмәгән кешеләргә болар һәммәсе сүз генә булганга, моны иҗекли төшик әле.* Г.Исхакый

**ИҖЕКЧЕ** *и. пед.* Иҗекләп (*2 мәгъ.*) укыту алымын яклаучы, шул алым белән эшләүче. *Әлифба укыту мәсьәләсендә Каюм --- иҗекче (слоговой метод белән баручы) иде.* Г.Сәгъди

**ИҖЕК ЯЗУЫ** *и. лингв.* Бер билге бер авазны түгел, ә аерым иҗекне белдергән язу, силлабик язу (мәс., хәзерге һинд язуы шул принципка нигезләнгән). *Иҗек язуын уку өчен, фикерләүнең аналитик сәләте югары булу кирәк, чөнки иҗек белән билге арасында күренеп торган бәйләнеш юк.* Тел гыйлеменә кереш

**ИҖТИМАГЫЙ** *с. гар.* 1) Җәмгыятькә караган, җәмгыятькә бәйләнешле. *Тарихи үсеш нәтиҗәсендә борынгы община строе яңа иҗтимагый формация – колбиләүчелек строе белән алышына.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Җәмгыятьнең иҗтимагый үсеш законнары*

2) Күпсанлы кешеләр катнашында, күмәкләп, бергәләп тудырыла, үтәлә, эшләнә торган. --- *Сара Садыйкованың вафатыннан соң, сөекле композиторыбызның иҗтимагый фонды оештырылды.* Л.Шагыйрьҗан. *1909–1913 еллар Россиядә 1905 ел революциясеннән соң туган реакциянең дәвамы һәм ахырга таба иҗтимагый кузгалыш, эшчеләр хәрәкәте, --- революция идеяләренең җанлана башлаган вакыты иде.* Г.Нигъмәти

3) Бөтен җәмгыятьнеке, җәмгыятьнең барлык кешеләренә дә караган; күмәк. *Сөйләм иясеннән башлыйк. Төрләренә килгәндә, ул шәхси дә, күмәк тә (иҗтимагый да) була ала.* И.Низамов. *Бөек Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты һәм театр сәнгате, вакытлы матбугаты --- бу исемнән, аның [Г.Исхакыйның] әдәби һәм иҗтимагый мирасыннан башка тулы була алмый ---.* Казан утлары

4) *Зарур, әһәмият* сүзләре белән килгәндә: бөтен җәмгыять өчен. *Хезмәт, гаять зур иҗтимагый әһәмияткә ия булу белән бергә, кешенең шәхси тормышында гаять зур роль уйный ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Иҗтимагый зарур эш вакыты*

5) Җәмгыятьнең сәяси, мәдәни һ.б. ихтыяҗларын үтәү белән бәйләнгән. *Дин – иҗтимагый аңның чынбарлыкны хыялый күзаллау, хыялый төшенчәләрдә чагылдыра торган бер формасы, ---.* Т.Әйди. *Җәмәгатьчелек тәртибен саклау буенча, халык дружиналарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, --- оешмаларның эшчәнлеген бер максатка юнәлдерү өчен иҗтимагый пунктлар оештырыла.* Мәдәни җомга

6) Җәмгыятьтәге кешеләрнең тормышына, тоткан урыннарына, үзара мөнәсәбәтләренә бәйле булган; социаль. *Бу әңгәмә миңа героемның аз гына булса да иҗтимагый йөзен ачыкларга ярдәм итте.* Г.Бәширов. *Сезгә анда, үзегезнең институтта, иҗтимагый фәннәрне, кешелекнең тарихын укытканнардыр бит?* М.Маликова. *Концепция дәүләтхокук өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру, --- республика иҗтимагый тормышында барлык милләт вәкилләренең катнашуы өчен шартлар тудыруны үз эченә ала.* Мәдәни җомга

7) Җәмгыятьтәге җитештерү мөнәсәбәтләрен үзгәртүне максат итеп куя торган; социаль. *Минем үземә --- Алабуга районының кайбер татар авылларында, халыкның үзаңын уятып, иҗтимагый хәрәкәткә ияртү өчен, шактый зур тырышлык куярга туры килде.* Мәдәни җомга. *Иҗтимагый борылыш. Татар буржуазиясенең иҗтимагый программасы*

**ИҖТИМАГЫЙ-ӘДӘБИ** *с.* Җәмгыятькә һәм әдәбиятка бәйләнешле. *Бәйге бүгенге көндә республика мәктәпләрендә «Алиш варислары» дигән иҗтимагый-әдәби хәрәкәт тууына китерде.* Мәгърифәт

**ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ** *с.* Җәмгыятькә һәм сәясәткә караган, җәмгыятькә һәм сәясәткә бәйләнешле. *Татар халык әкиятләрендә иҗтимагыйсәяси әһәмиятле булган мәсьәләләрне хәл иткәндә, дәүләт идарәчеләренең халыкка мөрәҗәгать итүе очраклы гына түгел.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Иҗтимагыйсәяси массакүләм мәгълүмат чараларына андый материаллар үтеп керүгә президиум әгъзалары ризасызлык белдерде.* Мәдәни җомга

**ИҖТИМАГЫЙ-ЭСТЕТИК** *с.* Җәмгыятькә һәм эстетикага мөнәсәбәтле, җәмгыятькә һәм эстетика караган. *Алты бертуганның --- бер гаепсез суелуларының нигезендә ялган, сәяси, иҗтимагый-эстетик тәгълиматлар һәм кануннар ятуын һич кенә дә алдан искәртми һәм искәртә дә алмый иде сабый!..* А.Хәлим

**ИҖТИМАГЫЯ** *и. гар. иск.* Иҗтимагый фәннәр. *Голүм иҗтимагыя галимнәре, адәмнәре үзләре тарихта фагыйль була алалар ---.* Г.Гобәйдуллин

**ИҖТИҺАТ** *и. гар. кит.* 1) Тырышлык. --- *көн кичкә авышканда --- башына бүреген батырып кигән, аның колакчыннарын исә ияк астына төшереп, аерым бер иҗтиһат белән томалап бәйләгән Ямалетдин килеп керде.* А.Хәлим. *Һичкемнән: «Алгы сафка элэгеп буламы? Күпме төшәр?» – дигәннән башка һични ишетелми, соң дәрәҗә иҗтиһат берлән, бөтен дөньяны ут алса да, тукталу ихтималлары юк кеби хәрәкәттәләр иде.* Г.Ибраһимов.

*Солтанда булдыклылык, иҗтиһат бар.* Казан утлары

2) Дини хакыйкатьне ачу өчен дин белеме тикшеренүләре барышында мөстәкыйль фикри нәтиҗә чыгаруга һәм чагыштырып карап (охшашлык юлы белән) хөкем йөртүгә нигезләнгән, акыл белән эш итү турындагы теория (IX гасырда барлыкка килгән)

**ИҖТИҺА́Т ИТҮ** *ф.* Тырышу, тырышып эшләү, тырышлык күрсәтү. *Мондый үҗәтлек белән башка берәр өлкәдә иҗтиһат итсә: галим булып ачыш ясаса, --- эшләнгән эшен беркем дә юкка чыгара алмас иде.* М.Маликова. *Рушан Дасаев әчке бер тоем белән сизенә: кешенең җирдәге бурычы – --- үзең кемдер булу, иҗтиһат итү, бар итү ---.* Р.Мирхәйдәров. *Инде килеп, кемнәрнеңдер баштан ашкан хәерчелегенә үзләренең ялкаулыгы, коточкыч мәнсезлеге, үз-үзләрен иҗтиһат итмәүләре сәбәп.* М.Хәсәнов

**ИҖТИҺА́Т КЫЛУ** *ф. к.* **иҗтиһат итү**. *Иҗтиһад кыл, эшкә башла, Гомер узып барадыр.* Җыр. *Бонларның сахирлары бу әһрамнарны ачарга бик иҗтиһат кылдылар.* Ф.Халиди. *Утыз ел буена --- ирен калага күчәргә көндерә алмагач, ичмаса, балам бу җәһәннәмнән котылсын, дип, Мәрьямне гимназиягә бирергә иҗтиһат кылган иде.* Г.Ибраһимов

**ИҖТИҺАТЛЫ** *с. иск. кит.* Тырыш. *Рифа үзе дә эшкә бик иҗтиһатлы иде.* Х.Камалов. *Шәкертләр бигрәк иҗтиһатлы булганнар ---.* Г.Ибраһимов. *Гыйрфанны ул тырыш, тәртипле, иҗтиһатлы, низамлы, оста мөдәррис булганы өчен яратты.* С.Поварисов. *Замандашлары Зәбиригә иҗтиһатлы, эш сөючән, тынгысыз кеше итеп бәя бирәләр.* Ф.Ибраһимова

**ИҖТИҺАТЛЫК** *и. иск. кит.* Тырышлык. *Бу иҗтиһатлык аңа Алла тарафыннан бирелгән, ди.* С.Поварисов. *Иҗатында үз Мәккәсен тапкан, гомумән, әдәбиятка гомерлек яры итеп, изге гамәл итеп карауда югары кимәлдәге иҗтиһатлык – аның гадел яшәү-иҗат алымы.* М.Галиев

**ИЗӘ́Ү** *ф.* 1) Чакыру яисә саубуллашу һ.б.ш.ны белдереп, кулны бераз күтәреп, нинди дә булса ишарә ясап селтәү, болгау. *Алга карап-карап та берни күрә алмагач, --- ак һәм туңган халатлы иптәшләренә кул изәде.* Г.Әпсәләмов. *Эшелон тулы ход алгач, туктап, кул изәргә керештеләр.* Г.Гобәй

2) Кул селтәп яки башны хәрәкәтләндереп кемгә яки нәрсәгә дә булса күрсәтү; нәрсәгә дә булса игътибар иттерү, игътибар итәргә чакыру. *Ул уң ягында утырган кызга башы белән изәде...* Г.Әпсәләмов. *--- карт кулларын уңга таба да, сулга таба да киң итеп изәде.* А.Шамов. *Хәлим кулы белән сул якка изәп күрсәтте.* Ә.Еники

**Изәп алу** Изәгән хәрәкәт ясау. *Верещагин кулын изәп алды, катып беткән разведчиклар яшереп калдырылган чаңгылары янына шуышып киттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Әнә кулын да изәп алды!* Н.Хәсәнов

**Изәп кую** Кинәт кенә бер тапкыр изәү. *Теге дә тәрәзә янында торган хуҗаны шәйләп алды, ахрысы, тук йөзенә елмаю җәелде, нидер кычкырып кул изәп куйды.* Р.Зәйдулла. *Шушы сүзләрдән соң әби, кузгалып, таулар арасына изәп куйды.* Д.Бүләков. *Мөкәррәмә, яулык бәйләгәндәй итеп, кулын изәп куйды.* К.Тимбикова

**Изәп тору** 1) Бертуктаусыз изәү

2) Әле, хәзер, сөйләгән вакытта изәү. *Абзый, дирижёрны күреп: «Бу адәмгә, шушы рәвешле орчык изәп торган өчен, күпме түлиләр?» – дип сораган.* М.Маликова. *Бераздан ул юл читендә кул изәп торган ике хатынкыз турында машинасын туктата ---.* М.Галиев

**Изи башлау** Изәргә тотыну. *--- бер төркем хатын-кызлар, үзләренә якынлашучы тракторны күргәч, кычкыракычкыра, кул изи башладылар.* А.Вергазов

**ИЗВО́ЗЧИК** *и. рус тар. сөйл.* 1) Олау, экипаж, көймәле арба яки чананың ялланган кучеры; олаучы, арбачы, ям чабучы. *Нәгыймә карчык Фазылҗан извозчик семьясын белгән хәлдә хәзерге вакытта Мохтарның Фазылҗан улы икәнлеген белми торган булыр.* Ш.Камал. *Әхтәм извозчикка юри озак түләде, вакны тапмый азапланды.* Г.Ибраһимов. *Салкында зур күн бияләйләре белән үз-үзләрен кыйнап торган извозчиклар, чыгып килүче Дәүләтьяровны күрүгә каршысына ташландылар.* И.Гази

2) Кучеры белән бергә ялланган экипаж. *Сәгать өчләрдә Черек күл буйлап крепостька таба бер извозчик узып китте.* К.Насыйри. *Бер извозчикка әйберләр төяләп, икенчесенә яшь хатын утырды.* Ш.Камал. *Алар, ресторіаннан чыккач, извозчикка утырдылар.* Ш.Рәкыйпов

**ИЗВО́ЗЧИКЛЫК** *и.* Извозчик булу, извозчик эшен башкару. *Гомерен извозчиклыкта үткәргән атамның исеме арбага яки чекушкага бәйле булуы гаҗәп түгел.* К.Басыйров

**ИЗГЕ** *с.* **1.** 1) *дини* Бар гомерен Аллага багышлаган һәм, үзе вафатыннан соң, дингә ышанучыларның яклаучысы дип игълан ителгән, тормышы дин тотучылар өчен үрнәк булып торган, Аллага якын (зат, әүлия, пәйгамбәр турында). *Изге Иван, бүреген эзләп, тау арасына барды.* М.Җәлил. *Шушында сурәтләнгән Изге Мария сине ялгыш адымнардан, кызулыктан, дошманнарың үченнән сакласын.* В.Имамов. *Инде минем бер шигем дә калмады, тәкъсир, син чын мәгънәсендә изге зат, олы акыл иясе икәнсең!* Ә.Еники // Бик динле, диндар, тәкъва; суфи. *Патша сараенда бер изге Аллаяр карт торган.* Т.Гыйззәт

2) *дини* Бар нәрсәдән дә өстен көчкә ия булган, илаһи. *Аның изге фатихасына сәдакаларын бирделәр.* М.Гафури. *Гөнаһсыз йөзләрең иртәнге таң шәүләләредәй нурлы, әйткән сүзләрең изге догалардай шифалы бит синең.* Г.Бәширов. *Татьяна әби күп еллар буена беркатлы һәм ышанучан кешеләрне үзенең ишегалдындагы коедан чиләк белән алган «изге» су белән «терелтеп» килгән.* Дин һәм көнкүреш

3) Гыйбадәтләр, табынулар белән бәйләнгән (гадәттә гыйбадәт кылу урыннары һәм кайбер дини бәйрәмнәр алдында даими эпитет булып йөри). *Нур балкышын җырлап килгән изге гает.* Ш.Бабич. *Ә син, вечерга барып, --- кулакларга да изге бәйрәм алдында*

*тел тидерәсе булма.* Ш.Камал. *Безнең җиребез өстендә изге гает көнендә --- кояш карап тора.* М.Әмир

4) Башкаларга һәрвакыт ярдәм кулы суза торган, яхшы, киң күңелле. *Әйе, ул бу минутта безне аңлап, безне бер-беребезгә димләүче изге күңелле яучыбыз иде.* Ә.Еники. *Ул бу вакытта --- 7 бала алып үстергән изге хатын – Порлаумер ханым турында уйлады.* Г.Гобәй. *Үз тирәсендә нинди мәрхәмәтле, изге җанлы кешеләр барын белмидер дә әле…* Г.Бәширов

5) Яхшы теләктә булып, чын күңелдән эшләнгән, башкаларга яхшылык китерә торган. *Сарьян абыйсы Нәфисәнең тормыш күгендә үзенең изге эшләре белән гел яхшылыкка өнди.* Г.Бәширов. *Агач, куаклар утырту элек-электән иң изге гамәлләрдән саналган.* А.Хәсәнов. *Изге юлда җаным фида: мин сезнең калканыгыз булыр идем.* Ә.Еники

6) Үз-үзен тотышында һәм тормышта тел-теш тидермәслек, пакь, саф күңелле. *Аның әдәплелеге, тыйнаклыгы, үзен тота белүе алдында иң изге кешеләр дә тез чүгәрләр иде.* А.Шамов. *Шундый изге хатыннарның пычрак кеше булуларына мин дә ышанмыйм.* Т.Гыйззәт. *Хаҗи әфәнде – ул әүлия шикелле изге кеше.* Ш.Камал

7) *күч.* Бөек, гүзәл, саф. *Аларның уйлары үзләренчә изге булган кеби, үлүләре дә изгеләрчә иде.* Һ.Атласи. *Аның күңелендә гомер буе кулы эштән бушамаган, ару-талуны белмәгән --- зур изге мәхәббәт – уллык мәхәббәтеташый иде.* Г.Әпсәләмов. *Без бу изге халык гадәтен үтәү өчен урындыкларга утырдык.* Г.Минский

8) *күч.* Җанга якын, газиз, хөрмәтле, кадерле. *Безнең татар халкы гомергомергә икмәкне изге нәрсә дип санаган.* Н.Дәүли. *Алар өчен изге бернәрсә дә юк.* М.Маликова. *Изгеләрдән дә изге иманга кизәнәсез икән, бик нык ялгышасыз, ай-һай нык ялгышасыз…* Ф.Сафин

9) *күч.* Хаклык, гаделлек, бәйсезлек өчен алып барыла торган (сугыш, көрәш турында). *Шатландыра язмыш күңелне, кавыштырып ирек-сердәшкә, багышлармын калган гомерне ирек өчен изге көрәшкә.* М.Җәлил. *Азатлык һәм хаклык өчен булган иң гадел һәм иң изге сугыш бу.* Ә.Исхак. *Бу изге сугышта бөтен халык катнашырга тиеш.* Г.Гобәй

10) *күч.* Кул сузарга ярамый торган, кагылгысыз. *Колхоз милке ул – җәмәгать милке, изге милек, аны әрәм-шәрәм итү һич тә ярамый.* А.Шамов. *47 нче размерлы гигант аякларына киеп йөргән ау итекләре – һәммәсе изге реликвия сыман саклана.* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *и. мәгъ. дини* Бөтен гомерен Аллага багышлап, үлгәннән соң дингә ышанучыларның яклаучысы дип игълан ителгән, тормышы дин тотучылар өчен үрнәк булып торган, Аллага якын зат. *Ул изгеләрне вә аларның тормышларын иң зур максат итеп күрә --- торган булды.* Ф.Әмирхан. *Әгәр үлчәүнең бер ягына бөтен пәйгамбәрләрне, бөтен изгеләрне салсак… Мөхәммәд ягы тартачак.* Г.Гобәй. *Изгеләр тормышы тасвирланган күп риваятьләрдә изгеләрнең түземлелек, сабырлыгы мактала.* Л.Шәйдуллина

◊ **Изгедән явыз туган** *сөйл. тирг.* Ачулану, тиргәү сүзе. **Изгедән явыз туган нәрсә** *сөйл. тирг. к.* **изгедән явыз туган**. **Изге киселү** Яхшы күңелле, изге булып күренергә тырышу, дингә мөкиббән булып кылану. *Ачыктан-ачык фәхешханә тотып та, [Миһри җиңгинең] изге киселеп утыруына ачу килеп китте.* Ә.Фәйзи. **Изге сәгать** Күптән, бик озак көтелгән мөкатдәс вакыт, бөек мизгел. *Сукты безнең изге сәгать – Бөек җиңү сәгате.* Ә.Ерикәй. **Изге сәгатьтә (сәгатьләрдә)** Эшлисе эш алдыннан эшнең уңышлы килеп чыгуын теләп әйтелә; хәерле сәгатьтә. *– Никахыгыз изге сәгатьләрдә укылган булган. Дөньяда вә ахирәттә бәхетле булыгыз, – диештеләр.* Г.Бәширов. *Аның: «Изге сәгатьләрдә, Ходаем», – дип пышылдавыннан, --- мин барысын да аңлап алдым.* Н.Гыйматдинова. *Изге сәгатьтә, кенәз, Ходай Тәгалә бирүк сине хәер-фатихасыннан гына ташламасын.* В.Имамов

**ИЗГЕ́ АТА** *и. дини* Христиан динендә руханины атау сүзе. *Дин әһеле, сезнеңчә, изге ата, безнеңчә, мулла була инде ул.* К.Латыйп. *Хан кызы күргән төшне Изге ата юрый, һәм ул, күрәзәчелек белән, Болгар дәүләтенең зур үзгәрешләр алдында торуын әйтә.* А.Гыйләҗев

**ИЗГЕЛӘНДЕРҮ** *ф. дини* Православие динендә нәрсәне дә булса су сибеп, чукындырып аруландыру йоласы. *Космик ракеталар, су асты көймәләре, зур кораблар, хәтта олимпия уеннарына китүчеләр, су бөркеп, тәре белән билгеле хәрәкәтләр ясап, «изгеләндереп» озатыла.* Татарстан яшьләре. *Изгеләндерелгән суда коенып чыкканнан соң, кешеләр, үзләренең тораклары изгеләндерү, авырып киткәндә, берәр йотым кабып кую өчен, ашыкмыйча гына чишмә суын савытларга тутырып алдылар.* Туганайлар

**Изгеләндереп тору** Һәрвакыт, гел яки әледән-әле изгеләндерү

**Изгеләндереп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы изгеләндерү

**ИЗГЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Изгегә әверелү

2) Изге булып кылану, изге булып күренергә тырышу

**Изгеләнә бару** Вакыт узган саен ныграк изгеләнү

**Изгеләнә башлау** Изгелек сыйфатлары беленү

**Изгеләнеп китү** Кинәт кенә изгегә әйләнү, изге булып күренә башлау

**ИЗГЕЛЕК** *и.* 1) Изге булу сыйфатлары. *Мине «ишан» дигәннәр һәрберсе – синдәй ишәк, Минем изгелегемә һичберсе китерми шәк.* Г.Тукай

2) Изге эш, чын күңелдән эшләнгән эш, саваплы эш. *Ләкин син эшләгән яхшылык, син эшләгән изгелек һәркем эшли ала торган гади бер эштән узмый.* А.Шамов. *Изгелеккә балта белән кизәнсәң, бәхетең генә түгел, кулың да корыр.* А.Хәсәнов

3) Игелек, яхшылык, киң күңеллелек. *Ата-анасына изгелеге тияр дип өмет итеп, баланы үстер инде.* Г.Камал. *Сөт кебек ап-ак сакал-мыегы аңа илаһилык, ирлек, изгелек төсмере ягып тора.* Г.Гыйльманов. *Гөнаһларны күбрәк язалар да изгелекне оныта баралар.* Ә.Баянов

4) Югары әхлаклылык, эчкерсезлек, саф күңеллелек. *Бу сәгатькә кадәр синең изгелегең, синең тугрылыгың*

*мисалларда сөйләнә иде.* Г.Тукай. *Бу – аның дөнья бәясе торырдай изгелеге бәрабәренә йөрәген мәңгегә ачы яралап калдыруы була түгелме соң?* Г.Гобәй

5) *күч.* Кул сузарга ярамау, кагылгысызлык. *Социлизм системасы капитализм нигезен җимерде, --- хосусый милек хакимлеге урынына социализм милкенең «изгелеге» мәсьәләсен куйды.* М.Җәлил

**ИЗГЕЛЕ́К ИТҮ** *ф.* 1) Динлелек, диндарлык, тәкъвалык күрсәтү

2) Файда китерү, яхшы эш күрсәтү, яхшылык эшләү. *Бу кешедә, болай караганда, һичкемгә изгелек итү, кешенең әхвале рухиясенә төшенү, башкаларның положениесенә керү ихтималы юк кебек күренә иде.* М.Гафури. *Синең сөюең көрәштә Изгелек итсен диеп.* Ә.Ерикәй

**ИЗГЕЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **изгелек итү**. *Ул бичара, вакыты җитеп, гыйбадәтен кылып, намазлыгы өстендә үлде дип әйтерлек, һаман изгелек кылып үлде.* М.Гафури

**ИЗГЕЛЕКЛЕ** *с.* Киң күңелле, мәрхәмәтле, шәфкатьле. *Фәтхия болай йомшак күңелле, изгелекле кеше булып танылса да, көндәшенең баласын ярата алмады.* Г.Ибраһимов. *Гомере буе кешегә ярдәмчел һәм изгелекле Зариф абзыйны хөрмәт итмәгән кеше юк иде.* З.Фәйзи

**ИЗГЕЧ** *с.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса сыта, изә торган

2) *күч. сөйл.* Бер үк сүзне кат-кат сөйләп, кабатлап торган, туйдырып бетергән сүзне кабат-кабат сөйләгән. *Кирәгеннән артык изгеч нәрсә инде*

3) *күч. сир.* Рухи яктан газаплый, рухи авырлык китерә, җанга баса торган. *Хаста иренең тәненнән килгән ис, аннан саркыган күңелне изгеч хис бөтенләй башка – бүтән төрле шул!* М.Маликова

**2.** *и. мәгъ.* Йорт хайваннарына азыкны изеп, изгәнне болгата торган, башы япьле таяк; арлау. *Бушату шнегы пешекләнгән бәрәңгене, изү өчен, чаннан изгечкә бирә.* Терлекче-механизатор өчен белешмә

**ИЗЕЛДЕК** *с. сөйл. шелт.* Бик йомшак, акрын селкенеп йөрүчән, җебегән, мәлҗерек. *Изелдек бер кеше шунда*

**ИЗЕЛҮ** *ф.* **1.** 1) *кайт. төш. юн. к.* **изү** (*1–6 мәгъ.*). *Бервакыт әллә кайсы шахта җимерелгән, уналты кеше аста калып изелгән, утыз кеше имгәнгән, имеш, дип сөйләделәр, шуны ишеткәч, ашаганым – аш, эчкәнем су булмады.* Г.Ибраһимов. *Гасырлар буе изелү сәбәпле, татарларда дәүләт эше белән идарә итәрлек укымышлы кешеләр бик аз.* И.Гази. *Сынган ботак, аяк астында изелгән коры-сары тавышы, гомумән, ат ишарәте сизелми.* А.Хәлим

2) Сыеклык, юешлек яки температураның төшүе-күтәрелүе нәтиҗәсендә җебү, сыегаю, йомшару. *Ул бит аны шул ук өч кешегә дигән әйбердән пешерде, --- изелгәнче кайнатып, бутка булса, сыек итте.* Г.Гобәй // Төзелештә ком, балчык, цемент һ.б. материалларга су кушып, үзле масса барлыкка китерү, үзләтү. *Су белән изелгән кызыл балчык, аякларга сыланып, аларны рәхәтләндерә иде.* Ф.Әмирхан

3) Басылу, тапталу, кысылу нәтиҗәсендә сытылу. *Хирург беренче сүзендә үк авыруның хәле бик авыр булуы, коткарып калу өмете юклыгы турында ачыктан-ачык әйтте. – Умыртка һәм оча сөякләренә кадәр... изелгән, – диде хатын.* М.Хәсәнов

4) *күч. сөйл.* Төрле сәбәпләр аркасында организм хәлсезләнү, көчсезләнү, хәл булмау, мәлҗерәү. *Төрмәдә торганда, Гариф абзыйның гомеренең күбесе авыру берлән үтте. Аның нервалары бик изелде.* Г.Исхакый. *Ну, әйдәгез, теге тәмам изелде, барыгыз, култыклап алып чыгыгыз да ямщик белән өенә илтеп ташлагыз.* Г.Камал. *Карчыкларның чәенә йоклата торган дару салдык та, алар изелеп, без – өч кыз – төш тә кал төнлә поезддан!* Г.Бәширов

5) *гади. с.* Көчсезлек, гаҗизлек тойгысына бирелү, нишләргә дә белмәү, югалып калу. *Ул көнене-төнене шул уй астында изелде, ләкин шул бәладән котылырга юл таба алмады.* Г.Исхакый

6) *күч. сөйл.* Бер үк сүз кат-кат сөйләнү, күп кабатланып, үткерлеген, кызыгын югалтканчы һәркем тарафыннан телгә алыну, чәйнәлү. *Бу фразалар изелгән инде, кабатламасаң да була*

**2. изелеп** *рәв. мәгъ.* 1) Гомумән йомшарып, тулып. *Чияләр изелеп пештеләр.* М.Җәлил

2) Тәмләп, изрәп. *Икенче әйләнеп кергәндә, Мифтах инде изелеп, хәлсезләнеп йоклый иде.* А.Шамов. *Иренеп кенә шыбырдый торган ягмурдагы басынкы һавадан изелеп йоклый торган авыл бер җавап та бирмәде.* Г.Исхакый

3) Нәрсәгә дә булса тулысынча бирелеп, онытылып. *Шулай да тәмам изелеп, җебеп утыралар.* Г.Камал. *Хәзер инде карчыгы бу җырны электәгечә итеп суза алмый, озын бөгелешләрендә тавышы өзелеп тә калгалый, ә барыбер аны Моратбакый изелеп тыңлый, килеп җитмәгән җирләренә хәтерендә уелып калган моңын ялгап җибәрә иде.* М.Галиев

**3.** *и. мәгъ.* Сәяси, икътисади хокуксызлыктан файдаланып, кеше хезмәтен үзләштерү, эксплуатация. *Бу көндә бай булмаган милләт бай булган милләтләрнең хезмәтләрене үтәүгә вә шунлар аяклары астында изелүгә мәхкүмдер...* Р.Фәхреддин. *Тагы шуны белүдән дә тора: Изелү ул – түгел тигезләнү.* Н.Сафина. *Үткән чордагы барлык социаль изелүләр, диннең аңны бикләгән кара сөреме – һәммәсе дә --- хатын-кызның авыр язмышында күренә.* Х.Сарьян

◊ **Изелгән арыш боламыгы** *гади с. тирг.* Бик булдыксыз, уңмаган, җебегән яки үтә кыюсыз кешегә карата әйтелә. *Ул да шул бер изелгән арыш боламыгыдыр әле, бер дә артык җирләре булмас.* Г.Камал. **Изелгән арыш салмасы** *гади с. тирг. к.* **изелгән арыш боламыгы**. **Изелгән салма** *гади с. тирг. к.* **изелгән арыш боламыгы**. *– У-у-у, пешмәгәннәр! – диде Гарипов, тешен кысып. – --- уятырбыз без ул изелгән салмаларны йокымсыраудан, исләренә төшерербез шанлы чакларын ---.* Т.Әйди. **Изелеп аккан** *сөйл. хурл.* 1) Булдыксыз, эш белмәгән; 2) Елак, бертуктаусыз зарланучан

**Изелә бару** Вакыт узган саен ныграк изелү. *--- кояш кызуында Фәрит торган саен изелә барды, аның битеннән шыбырдап тир акты.* Г.Бәширов

**Изелә башлау** Бераз изелү. *Җыйган җиләкләре изелә башлаган.* Ватаным Татарстан

**Изелә төшү** Тагын да ныграк изелү, изелгәнрәк була бару. *Аяк асты да көндезгегә караганда тайгакланган, изелә төшкән.* А.Шамов

**Изелеп бетү** Тулысынча, бөтенләй изелү. *Мулла, чапан итәген башына бөркәнеп, катырак урыннарны сайлыйсайлый, былчыранып, изелеп беткән сукмак буйлап китте.* А.Шамов. *Дөньялыкның яме – байларның мәрхәмәтеннән, дип күнеккән әби, йөзе-тәне изелеп беткәч, исән калуына шөкрана кылып, аяк өстенә басарга тырышып карады.* Ф.Яхин. *Урам Эзи юлы шикелле үк изелеп, җебеп, чокырланып беткән.* А.Гыйләҗев

**Изелеп җитү** Тиешле дәрәҗәгә җитеп изелү

**Изелеп китү** Бераз, беркадәр кинәт изелү

**Изелеп төшү** Кинәт изелү; тәмам, бөтенләй изелү. *Изелеп төшеп музыка тавышына ---.* Ф.Кәрим. *Каптым, дип уйлады ул һәм тәмам изелеп төште, тик шунда гына үзен кулга алып, күз ачып йомганчы, дошманына ташланды.* Г.Гобәй. *Әллә, теге хәйләкәр, астыртын эш йөртеп, күпчелекне үз ягына аударып куйганмы, бусы, шуны сизеп, бөтенләй изелеп төшкәнме?* Г.Бәширов

**ИЗЕН** *и. гар. кит. иск.* Рөхсәт, фатиха, ризалык. *Габбас июнь ахырында атасыннан Мәкәрҗәгә кәсепкә барырга дип рөхсәт вә паспорт сорап хат язгач, атасы изен бирде һәм паспорт та җибәрде.* З.Һади

**ИЗЕ́Н ЯСАУ** *ф.* Рөхсәт бирү, фатиха бирү. *Шаһмара бер еланга кушты: «Бар, чыгар моны», – ди, койрыгы белән изен ясый үзенчә.* Әкият

**ИЗЛОЖЕ́НИЕ** *и. рус к.* **инша**. *Изложение язганда, укучы, текстның эчтәлеген эзлекле һәм дөрес бирү белән бергә, тиешле урында тыныш билгеләрен куярга, сүзләрнең ясалыш, язылыш, төрләнеш һәм бер-берсе белән ялгану үзенчәлекләрен, җөмлә төзелеше турындагы кагыйдәләрне истән чыгармаска тиеш.* Татар теле. *Изложение язу өчен, гадәттә, укучыга аңлаешлы телдә язылган хикәяләү характерындагы текст яки өзек алына.* Мәгърифәт

**ИЗМӘ** *и.* 1) Известь, цемент, алебастр, гипсны су белән катыштырып ясалган һәм төзелештә кулланыла торган боламык сыман үзле катнашма. *Дүрткел кирпечләрне беркеткән измәне аерым тикшерергә туры киләчәк, чөнки ул моңарчы очраган измәләрдән күп тапкыр ныграк.* К.Тимбикова. *Коеның өске өлешенә якынайган саен, эшләр катлаулана, баскычларга басып измә ыргыту кыенлаша, кызларның да көче җитми иде.* Р.Вәлиев. *Казанлылар шактый зур, таш белән түшәлеп, төзү измәсе белән сыланган бассейн ясаганнар.* Ватаным Татарстан

2) *диал.* Ботка, пюре. *Бәрәңге измәсе*

3) *диал.* Он, су, сөт һ.б.ш. кушып ясалган үзле масса. – *Тәрәзәләрне он белән судан измә ясап, кәгазь белән сыларга кирәк, – диде Фатыйма.* М.Әмир // Нәрсәләрнең дә булса сыланып торган ярым сыек катнашмасы, камыр сыман формасыз матдә. *Арба тәгәрмәчләре сыек измәгә әйләнгән юл пычрагын ера-ера әкрен генә әйләнәләр.* Г.Галиев. *Йомыркасы ярар инде, ә менә ул заманда балчык измәсенә шулкадәр дә сирәк, затлы азык булган шикәр кушу белән авыл халкының тәмам исен китерә иде.* Г.Рәхим. *Измәне сепарат сөте, шулпа, сыворотка, ылыс оны төнәтмәсе, сыегайтылган чүпрә яки су белән кушып әзерлиләр.* Терлекчелекне интенсив үстерү

◊ **Измәне изү** *гади с. к.* **измәсен изү**. **Измәсен изеп арыш кабартмасы ясау** *гади с. к.* **измәсен изү**. *Дөрес эшләде Зөфәр каланчага ук качып, Вәзилә Хәйретдин агайны да, Минниса карчыкны да күреп узды, әгәр малай да алар янында булса, оятлы итә иде атаклы футболчыны, измәсен изеп арыш кабартмасы ясый иде!* А.Гыйләҗев. **Измәсен изү** *гади с.* Аякта тора алмаслык итеп, бик каты кыйнау. *Ә бу юлы алай итмәде, Фәритне бер читкә этеп җибәреп, Илдарның измәсен изү өчен, алга омтылды.* Г.Гобәй. *Бакчи, кара инде, измәсен изгән бит, тын да тартмый ята.* Ф.Сафин. *Әгәр алар аңа бәйләнсәләр, --- ул аларның икесенең дә измәләрен изәчәк иде.* Р.Сибат

**ИЗМӘЧЕ** *и.* Измә ясаучы кеше. *[Исәнмесез] Бетончы һәм измәче дуслар!* З.Нури

**ИЗНИГАМ** *и. гар. иск. кит.* Рөхсәт, ирек. *Бездән изнигам! Әнә үзегезгә кирәк фәннәрне урамнарда котырынып йөргән бозык зимагурлардан, сукбайлардан [өйрәнерсез]!* К.Тинчурин

**ИЗО-** *гр.* Европа телләреннән кергән кушма сүзләрнең «охшаш», «бертигез», «бертөрле», «бер үк» мәгънәсендәге беренче кисәге

**ИЗОБА́Р(А)** *и. гр. геогр.* 1) Географик картада бертөрле атмосфера басымы булган урыннарны тоташтыра торган сызык

2) Графикта тигез басым сызыгы

**ИЗОБА́РИК** *с. геогр.* Изобар(а)га бәйләнешле

**ИЗОБА́РИК ПРОЦЕСС** *и. физ.* Даими басым астында бара торган процесс (мәс., химик реакцияләр, эчке ягулы двигательләрдә ягулыкның януы һ.б.)

**ИЗОБА́ТА** *и. гр. геогр.* Географик картада сулыклар (диңгез, елга, күл һ.б.) төбенең бер үк тирәнлектә булган урыннарын тоташтыра торган сызык

**ИЗОБУТАН** *и. гр. хим.* Составы белән бутанга якын булган углеводород кушылмасы. *Газны эшкәртеп, изобутан --- алыначак, ә алардан полиэтилен синтетик сумалалар җитештерәчәк.* М.Бахитов. *Бутаннан аермалы буларак, бу матдә «изобутан» дигән исем алды.* Химия

**ИЗОГЛО́ССА** *и. гр. лингв.* Нинди дә булса тел күренеше таралышының чикләрен географик картада күрсәткән сызык. *Теге яки бу фонетик, лексик һәм грамматик күренешләр шартлы билгеләр ярдәмендә картага төшерелә. Бер үк күренеш булган пунктлар сызык белән тоташтырыла. Шул рәвешле «изоглоссалар» --- дип аталган сызыклар барлыкка килә.* Тел гыйлеменә кереш

**ИЗОЛЯ́ТОР** *и. гр.* 1) Электр тогын үткәрми торган, электрүткәрүчәнлеге бик кечкенә булган матдә; диэлектрик. *Чыбыкның икенче очын капка баганасындагы изолятор чыбыгы белән тоташтыралар.* Терлекче-механизатор

белешмәсе. *Изоляторларны җылытканда, аларның электр үткәрүчәнлеге яхшыра.* Серле кристаллар

2) Электр чыбыкларын изоляцияләү, беркетү өчен кулланыла торган фарфор яки пыяладан ясалган җайланма. *Берәүләре ап-ак чәйнүкләрне* (*без изоляторларны шулай атый идек*) *багана башына менгереп боралар, икенчеләре өйгә шнур кадаклый, лампа эленә.* Ф.Яруллин. *Электриклар, баганаларның нәзек башларына тишекләр тишеп, ак тәтәйләр – изоляторлар борырга керештеләр.* Р.Кәрами

3) *кит.* Җылылыкны аз үткәрә торган әйбер. *Лупаларны, пробиркаларны, изоляторларны һәм барлык кирәк-ярак нәрсәләрне Мичурин --- кыштан ук әзерләп куя иде.* А.Бахарев, П.Яковлев. *Һава катламы – яхшы изолятор*

4) Йогышлы авыруга дучар булганнарны, акыл зәгыйфьлеге белән әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыручыларны, кулга алынганнарны һ.б.ш.ны аерым тоту өчен көйләнгән махсус бүлмә яки бина. *Иң яхшысы: авыруны изоляторда калдырыгыз.* Р.Мирхәйдәров. *Изолятордагы чебиләрнең исә йомыркага да, эремчеккә дә һәм сөткә дә исләре китмәде.* Ә.Дибаев. *27 гыйнварга каршы төндә, кызын югалткан ана милициягә килгәнгә нәкъ 20 тәүлек тулганда, аның каршында изоляторның калын ишеге ачыла.* Мәдәни җомга

**ИЗОЛЯЦИОН** *с.* 1) Изоляция (*1 мәгъ.*) белән бәйле

2) Изоляция өчен кулланыла торган. *Йөртү винты буенча изоляцион цилиндрлары белән траверса күчеп йөри.* Терлекче-механизатор белешмәсе. *[Кабельгә] снаряд төшеп өзгән урынны барып таптым. Шуннан гына өзекне әйбәтләп ялгап, изоляцион тасма белән урап куйдым.* М.Кәрим

**ИЗОЛЯ́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Ток яки җылылыкны үзе аша үткәрми яки аз үткәрә торган материал. *Һәммәсе дә тавыш йотучан махсус тышча белән каплатылган, атмосферадагы электр тирбәнешләрен үткәрмәслек изоляция салынгын иде.* Ф.Латыйфи. *Электродлы казан җылылык изоляциясе булган кожухка урнаштырылган корыч цилиндрдан гыйбарәт.* Терлекче-механизатор белешмәсе. *Үткәргечләрнең үзәген тоташтыруга (ялгауга) аеруча әһәмият бирергә, --- ялгаган урынга изоляция тасмасын тыгыз катлау итеп чорнарга кирәк.* Көнкүреш хезмәте

2) Кемне дә булса тирә-юньдәге кешеләрдән, берәр илне, сыйныфны икенче илләр, сыйныфлар белән аралашудан, бәйләнештән аеру, бүлеп алу. *Төп бурычыгыз – режимны саклау. Мәскәүдән килгән, исемнәрен беркем дә белмәгән зур СССРның атаклы галимнәрен саклау, аларны теләсә кем белән аралаштырмыйча, изоляция ясау.* З.Зәйнуллин

**ИЗОЛЯ́ЦИЯЛӘНГӘНЛЕК** *и.* 1) Изоляцияләнгән хәлдә булу. *Чыбыкларның изоляцияләнгәнлеге*

2) Аерымлык, аерымланган булу, ялгызлык

**ИЗОЛЯ́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **изоляцияләү**. *Дәреслектә образ-персонажлар күп очракта изоляцияләнгән хәлдә, аерым-аерым түгел, бәлки башка образ-персонажлар, тирә-юнь (җәмгыять, табигать) чолганышында карала.* Ш.Асылгәрәев. *Ялгызлык, психоген факторлардан берсе буларак, кешенең эмоциональ халәтләренә тәэсир итүче фактор, аның башка кешеләрдән изоляцияләнүе, читләшүе.* Фән һәм тел. *Морфологик изоляцияләнү юлы белән ясалган рәвешләр арасында хәл фигыль формаларыннан күчкәннәре еш очрый ---.* Татар теле морфологиясе

**Изоляцияләнеп бетү** Тәмам изоляцияләнгән хәлгә килү; бөтенләй, тәмам изоляцияләнү

**ИЗОЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Изоляция материалы белән каплау, чорнау. *Әлеге конструкцияләрне изоляцияләгәндә, кимендә 30 см ара сакланган булырга тиеш.* Терлекче-механизатор белешмәсе. *Үткәргечләрнең үзәген тоташтыруга (ялгауга) аеруча әһәмият бирергә, берсен икенчесеннән ышанычлы итеп изоляцияләргә --- кирәк.* Көнкүреш хезмәте

2) Әйләнә-тирә белән аралашудан, бәйләнештән мәхрүм итү. *Шуңа күрә бу эзләнүләрне туктаталар, ә теге биоҗинаятьчеләрне изоляцияләр.* Т.Нәбиуллин. *Пролетариат бүтән сыйныфлардан изоляцияләнгән.* СССР тарихы. *Бер генә халык та башкалардан изоляцияләнгән хәлдә тереклек итә алмый.* Казан утлары

**Изоляцияләп алу** Кыска вакыт арасында тоташ изоляцияләү

**Изоляцияләп бетерү** Барысын да тулысынча изоляцияләү; изоляцияләү эшен тәгәлләү

**Изоляцияләп кую** Изоляцияләнгән хәлдә тоту

**Изоляцияли башлау** Изоляцияләү эшенә керешү

**ИЗОЛЯ́ЦИЯЛЕ** *с.* 1) Изоляция материалы белән каплаулы, чорнаулы. *Изоляцияле торбалар җитештерү. Полиэтилен изоляцияле кабельдән файдалану. Урам баганаларына изоляцияле чыбык үткәрү*

2) Тирә-як белән аралашудан, бәйләнештән мәхрүм ителгән

**ИЗОМЕР** *и. гр. хим.* Химик составы һәм молекуляр авырлыгы бертөрле, молекула төзелеше төрле булган кушылмаларның берсе. *Бутлеровның күпме изомер мөмкин булачагын алдан әйтүе --- химик төзелеш теориясенең дөреслеген раслаучы ышанычлы дәлил булып тора.* Химия

**ИЗОМЕРИ́Я** *и. гр. хим.* Составы һәм молекуляр авырлыгы бертөрле химик кушылмаларның физик һәм химик сыйфатлары, төзелешләре белән аерылу күренеше

**ИЗОМОРФ** *с. гр. хим.* Кристалларының формалары һәм үзлекләре бертөрле булган. *Яшел суүсемнәрдә изоморф һәм гетероморф буын чиратлашуы күзәтелә.* Л.Мәүлүдова

**ИЗОМОРФИЗМ** *и. гр. хим. к.* **изоморфлык**

**ИЗОМОРФЛЫК** *и. хим.* Составы ягыннан охшаш матдәләрнең каты эремә хәлендәге катнаш кристаллар барлыкка китерү сәләте

**ИЗОПРЕН** *и. гр. хим.* Синтетик каучук җитештерүдә чимал буларак кулланыла торган, туендырылмаган углеводород. *Соңрак галимнәр «изопрен» дигән янучан төссез сыеклыкның һавада торганда куерырга сәләтле икәнен белделәр.* М.Бахитов. *Табигый каучукны изопрен тудыра дип исәпли башладылар.* Химия

**ИЗОТЕ́РМА** *и. гр.* 1) *геогр.* Географик картада билгеле бер вакыт аралыгында уртача бердәй температура булган урыннарны тоташтыра торган сызык. *Биредә гыйнварның 0°лы изотермасы Туран түбәнлегенең көньяк кырые буйлап бара.* География

2) *физ.* Җылылык процессы диаграммасында даими температураны күрсәткән нокталарны тоташтырган сызык

**ИЗОТЕ́РМИК** *с.* 1) *геогр.* Изотермага бәйләнешле (*1 мәгъ.*)

2) *физ.* Матдәнең, җисемнең күләм ягыннан үзгәрешсез җылыну сыйфаты. *В.Г.Иноземцевның икенче мавыгуы – изотермик кузовлар.* Татарстан. *Изотермик процесс. Изотермик вагон*

**ИЗОТОП** *и. гр. хим.* Бер үк химик элементның атомнары арасында (нейтроннар саны буенча) үзенең авырлыгы белән аерылып торган атом. *Менделеевның периодик системасында бер үк урында торучы элементлар – изотоплар барлыгын ачу атом физикасының үсешендә бик зур роль уйнады.* А.Пёрышкин. *Никель һәм кобальтның атом авырлыклары бертөрлерәк булса, ул аларны, изотоплардан санап, бер клеткага куйган.* В.Курбатов. *Ашламалар составына радиоактив изотоплар кертүнең дә әһәмияте бик зур.* М.Зарипов, С.Салихов

**ИЗОТРОП** *с. гр. физ. махс.* Төп физик (үткәрүчәнлек, эластиклык һ.б.) үзлекләре бар яктан охшаш булган. *Изотроп мохит. Изотроп кристалл*

**ИЗОХРОМА́ТИК** *с. гр. физ.* Бар төсләрне охшаш итеп күрсәтә торган. *Изохроматик негатив материалларга күренә торган төсләр барысы да тәэсир итә. Шуңа күрә аларны караңгыда гына эшләргә ярый.* Ф.Акчурин

**ИЗОХРОН** *с. гр. махс.* Бер үк дәвамлылыктагы. *Тавыш дулкыннарының изохрон тирбәнүләре*

**ИЗОХРОНЛЫК** *с. махс.* Теге яки бу күренешнең, процессның бер эзлеклелектә булуы. *Маятникның бу үзлеге изохронлык дип атала.* Физика курсы

**ИЗРӘТКЕЧ** *с.* Йомшак, рәхәт. *Ярминкәдән соң була торган изрәткеч рәхәтлектән, бурычларын үтәгән кешеләрдәге канәгать тынычлыктан беркемнең дә чыгасы килми иде ахры.* Ф.Латыйфи. *Ул, күзләрен йомып, тәнен чолгаган изрәткеч рәхәтлеккә бирелде.* Ф.Яхин

**ИЗРӘТҮ** *ф.* 1) Берәр каты нәрсәне йомшарту, җебетү. *Хәер, яңгырлар явып юлларны изрәтү белән, машиналарның бу юлдан йөрмичә, --- таш җәелгән зур юлдан китүләре турында ул инде белә иде.* М.Хәсәнов. *Беркөнне юынтык сулар сала торган чиләк тулып аккан да кәрзиндәге китапларны изрәткән.* М.Галәү. *Алар яз изрәткән юлда кара-каршы басып торалар.* Ирек мәйданы

2) Рәхәтлеккә талдыру. *Сәер рәхәтлек... Кеше үзен алдый алса да ала икән. Эчкән нәрсәм бик тиз изрәтте мине.* А.Вергазов. *Аяк астындагы дымык яшел үлән исе талгын изрәтеп, йокыны китерә.* Г.Галиев. *Бәрхеттәй йомшак, ефәктәй шома, тау бәллүредәй чиста яңгыраш колакны иркәли, йөрәкне рәхәтлектә изрәтеп талпынырга мәҗбүр итә.* Ф.Латыйфи

3) *күч. диал.* Изү, сыту; җимерү, вату. *Карагыз, кара, Хава анабыз, аю анасы бара... Аяк астына эләгә күрмәгез, --- изрәтеп ташлар.* Ш.Камал

**Изрәтә башлау** Изрәтергә тотыну. *Хуҗабикә кебек кунакчыл пар, гәүдәсен чолмап, изрәтә үк башлады.* Н.Гыйматдинова. *Ике тәүлеккә сузылган йокысызлык изрәтә башласа да түзәргә туры килә.* Н.Гариф

**Изрәтә бирү** Бернәрсәгә дә игътибар итмичә изрәтүне дәвам итү

**Изрәтә төшү** Беркадәр изрәгән хәлгә китерү; бераз изрәтү

**Изрәтеп алу** Тиз генә изрәтү

**Изрәтеп бетерү** Бик нык изрәгән хәлгә китерү; тулысынча, бөтенләй изрәтү

**Изрәтеп җибәрү** Кинәттән бераз изрәтү; көтмәгәндә изрәтү. *Ачык тәрәзәдән кергән авыл һавасы аны [Илусәне] тәмам изрәтеп җибәргән иде.* Г.Гыйльманов. *Башта бөтен тәнне изрәтеп, йомшартып җибәрә торган кайнар парлы саунага керделәр.* Р.Вәли

**Изрәтеп тору** 1) Әледән-әле, еш изрәтү

2) Әле, хәзер бераз изрәткән булу

**ИЗРӘ́Ү** *ф.* 1) Су, дым яки җылылык тәэсирендә йомшару, сыегаю, җебү, изелү. *«Газик» тирә-якка изрәгән пычрак чәчрәтеп китеп тә барды...* М.Хәсәнов. *Ләкин ул, боларга игътибар итмичә, бер кызган килеш, сындырып ташланган ботакларның очын өскә каратып, аскы өлешен изрәгән җиргә кадый-кадый, шалаш ясый башлады.* А.Вергазов

2) *диал.* Күп кулланылудан таушалу, җепләре юкарып, искереп өзелә башлау, сүсәрү, искерү (тукыма турында). *Әни өстәл сөртергә дә ярамаслык тишек, ертык, саргаеп, сүтелеп, изрәп, тузып беткән майка, күлмәкләр --- тартып чыгарды.* Э.Шәрифуллина

3) Таралып тору, йомшак булу; тәмам өлгерү, җитлегү. *Миңа бернинди тәм-том кирәкми, мин унсигез яшьлек кыз чагымдагы аның һәр әйткән сүзеннән буыла-буыла көлеп, тончыга-тончыга, изрәп пешкән бәрәңге ашавымны сагынам.* З.Хәким. *Менә бүген иртән торуга инҗир агачында өч изрәп пешкән җимеш күрдем дә шуларны, өзеп, сезгә бүләк итәргә булдым.* Әкият. *Саба җиле әкрен исә, йомшак үләнне тарап. Мәмрәп, изрәп пешә җиләк.* Р.Бәшәр

4) *күч.* Тән рәхәтлеккә талу, рәхәт тою. *Аның аяк-куллары, бөтен тәне ял рәхәтеннән таралырдай булып, изрәп яталар, бармаклары сулык-сулык килә иде.* Г.Бәширов. *Ул ике арада урнашкан татулыктан рәхәт чигеп, изрәп, мендәргә таянды.* Ф.Латыйфи. *Моңарчы татылмаган рәхәттән исергән Кәлимә, ул ни әйтсә, шуңа буйсына барды, тәмам йомшарды, изрәде, эреде...* К.Тимбикова

5) *күч.* Тәмле, татлы, тыныч һәм тирән йокыга талу. *Баладан соң җиңеләйгән ана кебек, ул онытылып, изрәп йоклый җир өстендә.* Ш.Маннур. *Аларның тигез сулыш алулары, кислород исе, озон исе мине дә изрәтә башлый, һәм мин, йөзтүбән яткан килеш кенә, изрәп йоклап китәм.* Г.Рәхим. *Таң нурлары аның керфекләренә килеп кагылгач кына, күзләренә йокы рәшәсе кереп тулды һәм, ниһаять, изрәп йоклап китте.* Г.Галиева

6) *күч.* Йокы басу, ярым йокылы хәлгә килү. *Әнә ич, изрәп йокымсыравымнан уятмас өчен, йомшак кына басып, үзе мине сөяргә килә.* М.Хуҗин. *Бары тик урман артыннан күтәрелеп килгән кояш өй эчен идәнгә төшкән энәне дә табарлык итеп яктырткач кына, күз кабаклары авыраеп, изри башлады.* З.Хөснияр. *Хәлим дә аның күңелле гырылдавы астында изри башлады.* М.Хәсәнов

7) *күч.* Бик курку, каушап, югалып калу, артык басынкылану, юашлану, җебү. *– Изрәдең әле син, карындаш?! – диде аңа Мәксим. – Чәпчим изрәдең... – Изрәмәдем, авыр уйлар басты мине...* Р.Сибат

8) *күч.* Ару, талчыгу. *Илүзә белән Фәрдәнә көне буе эшләп изрәгән, инде йокыга да китәргә өлгергән кызларны өй саен кереп уятып йөрделәр.* А.Вергазов

9) *күч.* Иренү, ялкаулану. *Хатыны белән малае өйдә булса, уянгач, болай караватъ читендә изрәп, иренеп утырыр идемени?!* Ә.Еники

10) *күч.* Аңгыраю, миңгерәү. *Зур тираж белән таралып, аңы йокымсырап, акылы изрәгән халыкның кулына барып җитә.* М.Галиев. *Бераздан мин аңгыраеп китәрмен, исәнгерәрмен һәм тәмам изрәрмен.* Г.Рәхим

11) *күч.* Картаю, чирләү һ.б. сәбәпле сәлперәю, зәгыйфьләнү. *Ул олыгайган, ләкин Исмәт кебек юанаймаган, апара корсак булмаган, изрәмәгән, нык, бирешергә уйламый әле.* Г.Әпсәләмов

12) *күч.* Дым җитмәүдән шиңеп төшү, сулу. *Борынгы тын Идел ярларында Эсселектән изри яшь үлән.* Зөлфәт

◊ **Изрәгән арыш боламыгы** *гади с. тирг.* Бик булдыксыз, җебегән яки үтә кыюсыз кешегә карата әйтелә. **Изрәгән кабак бәлеше** *гади с. мыск.* Уңмаган, мәлҗерәгән, пошмас җанлы кеше турында. *[Гөлҗамал:] Ә без чәчрәп торган физкультурный комсомолка булган булыр идек... [Локман:] Ай, изрәгән кабак бәлеше.* Ш.Камал

**Изрәп алу** Бераз, аз гына изрәү

**Изрәп бетү** Бөтенләй, тулысынча изрәү. *Кулмәкләрең изрәп беткән, җеп тотарлык җирләре дә калмаган!* М.Гафури. *Тир тозы белән көмешләнгән киндер күлмәктә, кыршылып, изрәп беткән малюскин чалбар-пинжәктә, --- [ул] үзен һич кенә дә бәхетсез санамый иде.* А.Хәлим

**Изрәп китү** Кинәт, тиз арада изрәү. *Мин изрәп киткәнгәдер, тавышы бик ерактан-ерактан, әллә кайлардан урап килеп ишетелә.* М.Хуҗин. *Яки печән куышында, я булмаса, такыр юлдан келтерәп кенә барган арба тавышына изрәп китеп йокыга талган минутларын нәрсә белән алыштырырга мөмкин соң?* Н.Гамбәр

**Изрәп тору** Изрәгән хәлдә булу. *Сыерлар кояшка сыртларын куеп изрәп торды.* И.Галимов

**Изрәп төшү** Ниндидер бер эш-хәлдән соң изрәгән хәлгә килү. *Теге көнне солдатта танышкан нәрсәңнән хат алгач, яңадан изрәп төштең, бала. Яшермә, әллә аның белән бер-бер хәл булганмы?* Г.Галиева. *Әмма безгә изрәп төшәргә һич ярамый.* Татарстан. *Бер кичне туп-туры кибәнгә алып китте. И бәйләнде, и кыстады үзе: изрәп төштем...* Идел

**Изрәп яту** *к.* **изрәп тору**. *Күзгә кояш талгын гына җылыта, йөзенә аз гына сарылык иңгән табигать изрәп ята.* Г.Хөсәенов. *Аның түбәсенә басып, алсу шәфәкъ нурлары астында изрәп яткан иген басуларына күз салды.* Ф.Садриев. *Кояш астында изрәп яткан тугайда бер генә дә серле зат күренми.* М.Галиев

**Изри башлау** Изрәргә тотыну. *Бертуктаусыз чаптырудан арыган һәм адымнарны акрынайтуга изри башлаган укчыларның бердән йокысы качты.* Ф.Латыйфи. *Тора-бара изри башлаган акылында Шамил дә онытылды, әмма йокы үзе бик еракта иде әле.* Рифә Рахман. *Тагы күзен ача алмыйча изри башлады.* Х.Камалов

**Изри төшү** Бераз, берникадәр изрәү

**ИЗҮ** I *ф.* **1.** 1) Каты яки порошок шикелле нәрсәне сыеклык кушып болгатып, йомшак, сыек яки боламык хәленә китерү. *Иртәгә икмәк изеп куясы бар, шикәр иртәгәлек кенә калды.* Ә.Фәйзи. *Хәлим белән Ибраһим бер өлеш сыер тизәгенә 5 өлеш су кушып изделәр.* Г.Гобәй. *Малай: «Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде шул!» – дип җавап биргән.* Ә.Еники

2) Нәрсәне дә булса зур авырлык астында калдырып бастыру, таптау, сыту, формасын җимерү. *Зур, мәһабәт гәүдәсе белән бер өйгә таба ыргыла һәм өйне сытып, изеп, бакчалар эченә кереп китә.* И.Гази. *Малайлар, әүмәкләшә торгач, ике карлыган куагын изделәр, ---.* А.Гыйләҗев. *Аның хәзер алар артыннан борыласы, килгән шәпкә кырдан китереп бәреп, --- аркылы-торкылы йөреп таптыйсы, изәсе килде.* Ф.Садриев // Шул рәвешле үтерү, бетерү, юкка чыгару. *Соңыннан Васильконы, күкрәгенә такта салып, шуның өстендә бии-бии изеп үтерәләр.* В.Имамов. *Әсир төшкән урыс кенәзләрен һәм атаклы кыпчак бәкләрен монголлар аяк-кулларын бәйләп җиргә тезеп салганнар да, өсләренә агачлар тезеп, шулар өстенә киезләр җәеп, үзләре шунда менеп утырып тантана иткәннәр, тегеләрне изеп үтергәннәр.* З.Зәйнуллин

3) *күч. сөйл.* Бик каты кыйнау, хәлдән тайдырганчы кыйнау. *Винтовка инде аларның икесенең дә кулыннан ычкынган, алар бер-берсен аста калдырырга, буарга, изәргә тырышалар иде.* А.Шамов. *Бикмәмәтне изеп ыргыту белән бергә, авылда бөтен ярлыларны кыйнау башланды.* Г.Толымбай. *«Әлфред тереләе микәнни? Кичә нык изгәннәр иде бит. Чибәр кызлар өчен кыйммәт түләргә туры килә шул», – дип уйлады Миләүшә, янә көзгегә күз салып.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Күңелгә авыр булып, борчып, газаплап тору. *Галинең эче пошарга, аны вөҗданы изәргә, борчырга кереште.* М.Гафури. *Җанны изә торган авыр моң һәм тойгылар белән мин ишегалдына чыктым.* Ф.Әмирхан. *Бигрәк тә блокадада калган Ленинградтан бер хәбәр дә килмәү, иренең язмышы билгесез булу аны бик изә иде шикелле.* Ә.Еники

5) *күч.* Төрле авырлыклар, дөнья мәшәкатьләре басу; газап чиктерү, хәлдән тайдыру, эштән чыгару. *Кич берлән һаман ялгыз йокларга өйрәнмәде. Шул ялгызлыкның изүенә хәйлә таба*

*алмады.* Г.Исхакый. *Шул вә, гомумән, тормыш агымы мине бик изгән, бик эштән чыгарып, йөрәгем әллә нинди ачу, ләгънәт белән тулган.* Г.Ибраһимов. *Ике елга якын халык миен изгәннән соң тайды ул моннан.* А.Хәлим // Организм физик һәм психик яктан таушалу. *Мин нервлы кеше, фронтлар мине изде.* Ш.Камал. *Мин, кире борылып, буш аллеялар буйлап киттем. Йокысызлык, йокысызлык изә.* Ә.Еники

6) *күч.* Икътисади, сәяси һәм рухи яктан кысынкылыкта тоту, җәберләү, эксплуатацияләү. *Ярлыларны изгән байларга каршы баскынчылык итсәм, менә минем өчен шул күңелле...* М.Фәйзи. *Расаларның бертигез булмаулары турындагы ялган теория буржуазиягә империалистик сугышларны, колониаль политиканы, бер халыкның икенче халыкны изүен --- аклар өчен кирәк булды.* Дарвинизм нигезләре

7) *күч.* Нәрсәне дә булса аңлашылмаслык хәлгә китереп бозу, танымаслык хәлгә җиткерү. *Ахун бу Коръән аятьләрен шулкадәр сындыра, шулкадәр изә иде.* Г.Тукай. *Һәммәсе [килешле] уйнадылар, тик чегән хатыны Алмазова гына изде: татар сүзен дә [әйтә] алмагач, сәхнәгә аяк басмау кирәк иде.* Ш.Әхмәдиев

8) *күч. гади с.* Кирәкмәгән, зарарлы эш эшләү; җайга салынып беткән, көйләнгән эшне бозу. *Бу арада Газиз үзе генә эшне изеп ташлады әле.* Ф.Әмирхан. *Шул радионы юкка чыгарасы, изеп ташлыйсы килде.* Х.Камалов

9) *күч. гади с.* Бер сүзне күп тапкыр кабатлап сөйләү; нинди дә булса эшне яки хәлне кирәгеннән артык тикшерү. *Сез – зирәк егет, сездән зур кеше чыга ---. Халкыгызга зур хезмәт күрсәтә алырсыз ---, – дип, [ул] картларча озак изеп килә.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Икътисади, сәяси һәм рухи кысынлык, җәбер; эксплуатация. *Фашистлар изүе астында калган совет кешеләре каршында, немецлар изүе астында интегүче Европа каршында җинаять булыр иде.* Г.Әпсәләмов. *Иребезне югалтып, урыс изүендә дүрт йөз елдан артык җәфаланып яшәп, --- югалтуларны моңга салырга өйрәнгән халык без, татарлар.* З.Зәйнуллин. *Ул Үзәк һәм Көньяк-Көнчыгыш Европа халыкларын фашизм изүеннән азат итүче булды.* И.Мамаев

**Изә бару** Торган саен ныграк изү

**Изә башлау** Изәргә керешү. *--- ялгызлык хисе яңадан талкый, җанын баса, җанын изә башлады.* М.Хәсәнов. *– Берәүне дә күрәсем, яшисем килми, – дип, йодрыклары белән печәнне изә башлады.* Т.Нәбиуллин. *Башы белән буразна катысына барып төшкән корбанын шундук котырган эт кебек талый, таптый, изә башлады: – Менә сиңа! Менә сиңа! Безнең авылда бүтән җырламассың!* А.Хәлим

**Изә бирү** Бернәрсәгә дә игътибар итмичә изүне дәвам итү. *«Ниемә кирәк соң сез миңа?» – дип, Таптамыш [аю баласы] аларны [бака яфрагын] тәпие белән таптый, изә бирә.* Әкият

**Изә төшү** Тагы да ныграк изү

**Изеп алу** Кыска вакыт арасында, берара изү эшен башкару

**Изеп ату** Тиз генә изү; изелгән хәлгә китерү

**Изеп бетерү** Барысын да, бөтенесен дә изү; барысын да изелгән хәлгә китерү. *Без авылга барып кергәндә, инде аны таптап, изеп бетергәннәр иде.* А.Шамов. *Тирә-юньдәге бөтен бакчаларны таптап, изеп бетерделәр.* А.Гыймадиев. *Дару йотмыйча йокларга ятса, мендәрен изеп, эчен чыгарып бетерә.* А.Гыйләҗев

**Изеп җибәрү** Теләп, рәхәтләнеп изү. *[Хәсби:] Бераз бодай оным бар, иртә беләнгә коймак изеп җибәрербез.* К.Тинчурин

**Изеп килү** Электән, күптәннән дәвамлы рәвештә изү. *Рөстәм үзенең алдында туасы таңның яктылыгын сизеп уянырга хәзерләнгән кешене – үзен гомере буе изеп килгән караңгылыктан чыгарырга юл эзләүче Садрыйны күрде.* Һ.Такташ. *Ләкин үз халкын изеп килгән ак патшага (Россия хакимлегенә) каршы хәрәкәтләр хакында язарга базмый.* Ф.Галимуллин

**Изеп кую** Алдан изеп әзер итү яки тиешле хәлгә китерү. *Нәфисә апасы аларны ишек төбендә озатып калды: – Галимҗан, бик озак йөрмәгез, яме. Югыйсә, пилмәнем суынып бетәр. Камыр да изеп куярмын, Алла боерса.* Ф.Зариф. *Мөнәвәрә апаң бер пот он китереп китте. Төш вакытында ук изеп куйган идем.* Ф.Шәфигуллин

**Изеп ташлау** 1) Аннан-моннан, тизтиз генә изү

2) Уйламаганда, көтмәгәндә, бик каты итеп изү. *Кеше-фәлән күреп, үзенә әйтсәләр, җанымны чыгарганчы кыйнап, изеп ташлар бит.* Г.Камал

**Изеп тору** Һаман, бертуктаусыз изү. *Күк йөзен иртәдән бирле соры болыт баскан, түбәнәеп калган гөмбәз җанны изеп тора сыман.* Р.Зәйдулла. *Авылны урап кайткач күңеле булды, иртәдән бирле үзен басып, изеп торган моңсу уйлары таралып китте кебек.* Ф.Латыйфи. *Аңлап та, аңлатып та булмаган, бөтен аңны-зиһенне томалап, албастыдай изеп торган бу курку тойгысыннан аның йөрәге сулкылдап тибәргә тотынды ---.* Н.Фәттах

**ИЗҮ** II *и.* 1) Киемдә муеннан аска таба ачыла торган итеп эшләнгән уемты. *Гафият абзагыз да бүген иртәдән бирле кырда эшли: беләкләрен сызганган, изүләрен ычкындырган, маңгаеннан гөрләп тир ага.* И.Гази. *Хәмдия тиз генә әнисенең изүен, яулыгын чишеп җибәрде, биленә буган капчыгын чиште.* Н.Фәттах. *Аннары ул, изүеннән энәсен алып, яңа җеп саплады да командирга эндәште.* А.Шамов

2) *этн.* Татар хатын-кызларының тукымага төрле төстәге тасмаларны дуга сыман беркетеп тегелгән, укалар белән чигелгән һәм тәңкәләр белән бизәлгән, күлмәк өстеннән кия торган, күкрәкчәгә охшаш бизәнү әйбере. *Анау кәшимир күлмәгем белән изү тәңкәмне дә калдырмадылар бит. Ашка-суга йөрергә бернәрсәсез калдым.* Х.Кәрим

**ИЗҮЛӘШҮ** *ф. сөйл.* Кыйнашу, берберсенең изүләреннән алып сугышу

**Изүләшә башлау** Изүләшергә тотыну

**Изүләшеп алу** Кыска вакыт арасында сугышу, изүләшү. *Җыелыш кайнап торган казанга әйләнде. Кемнәрдер изүләшеп алдылар. Кемнәрдер бер-берсенең нәсел-нәсәбен тикшереп алды.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ИЗҮЧӘ** *и. диал.* 1) Күкрәкчә

2) Кием өстеннән киелә торган җиңсез камзул

**ИЗҮЧЕ** *и.* Сәяси, икътисади, рухи яктан җәберләүче, кысучы; эксплуататор. *Ул җирләрдә элек изүчеләр, Паразитлар хөкем сөрделәр, Илебезнең бөтен матурлыгын Алар гына йотып килделәр.* Ә.Исхак. *Эчемдәге янган ачу белән безне изүчеләргә каргыш-ләгънәт яудырам.* А.Алиш. *– Бай белән ярлы бер сулыш алырмы икән? – диде ул, ниһаять. – Изүче белән изелүче бер сафка басармы?* Т.Әйди

**ИЗҺА́Р ИТҮ** *ф. иск. кит.* Нинди дә булса хәбәрне, уйны кешеләргә ачып салу, белдерү, сөйләү. *Уйчан дәрт вә шул ук вакытта әллә никадәр хәтлелек изһар итәләр иде.* Ф.Әмирхан. *Бу «җир» гали диеп тик тормаслар, вакльжларын изһар итәрләр.* М.Гафури

**ИЗҺА́Р КЫЛУ** *ф. иск. кит. к.* **изһар итү**. *Мин ачык, көләч йөз белән аңа үз шатлыгымны изһар кылырга тырышам.* Ш.Әхмәдиев. *Телләре белән болар изһар кыла шатлыкларын.* М.Гафури

**ИЗЮБР(Ь)** *и. зоол.* Болансыманнар семьялыгыннан, Көнчыгыш Себердә яши торган эре болан; затлы боланның бер төре. *Аларда тайга ерткычлары – аю, боланнар, изюбрлар яши.* Дөнья кисәкләре географиясе

**ИКАМӘТ** *и. гар. дини* Намазга керешүдән элек аягүрә торып укыла торган дога

**ИКӘМ** *сан иск.* **1.** *к.* **икәү** (санамышларда сакланган). *Берәм, икәм, өчәм, дүртәм, бишәм, алтам – кайры балтам.* Н.Исәнбәт

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Янәшә куелган ике ташны сыпырып алудан гыйбарәт булган бишташ уенының беренче баскычы. *Фәридә икәмдә генә, мин дүртәмгә җиттем инде*

**ИКӘН** *ярд. ф.* 1) Фигыльдән башка сүз төркеменә караган сүзләр янында килеп, аларга фигыль төсмере бирә. *Тел ил белән икән, аерым түгел икән. Ил язмышы тел язмышы икән.* С.Хәким. *«Ә ник үзең шалтыратмыйсың?» – дип әйтүдән чак кына тыелып калдым. Билгеле инде ник икәне.* М.Маликова

2) Хәбәр составында килеп, җөмләдә белдерелгән фикергә раслау, дөресләү төсмере кертә. *Шунда тәрәзәгә күзе төште. Нәкъ манара өстендә генә тулган ай эленеп тора икән.* Г.Бәширов. *Тулы чүмечне ул тын да алмыйча эчеп бетерде дә, ат кебек пошкырапошкыра, эчен угалап алды. – У-ух, бик эчәсе килгән икән.* Н.Фәттах. *Баксаң, ике ел эчендә авылда ике оя кызлар өлгергән икән. Ике елда малайлар үсеп җиткән икән...* М.Мәһдиев

3) Сорау җөмләдәге икеләнү, шикләнү, шөбһәләнү, фараз кылу төшенчәләрен көчәйтеп килә. *Бу ни эш икән?.. Гөлбануның элекке йөргән егете булдымы икән? Миңа дигән кызны алды, дип, үч итеп, кисәргә маташтымы икән? Ул кем икән?* Г.Ибраһимов. *Менә шушы минутларда, кай җирләрдә, ниләр эшли икән ул [Госман]?* Л.Ихсанова. *Дөньяда «бәхет», «мәхәббәт» дигәнең кешенең кай ягына карап бирелә икән?* М.Маликова

4) Сөйләүче тарафыннан тормыш тәҗрибәсенә, күргән-белгәннәргә нигезләнеп ясалган нәтиҗәне белдереп килә. *Дөньяда иң авыр газап сөйләшмәү икән.* И.Салахов. *Фаҗига башларны яргач, зиһенне ача икән. Җиңгәннәр итеге белән күзеңә баса икән ---.* Р.Фәйзуллин. *Кайбер илләрдә шосседан егерме биш метр киңлегендәге арада печәнне терлеккә бөтенләй бирмиләр икән.* М.Мәһдиев

5) Шарт җөмләне баш җөмләгә бәйләп килә. *– Кирәк икән, кызлар бар! – Нәсим кеткелдәп көлеп куйды.* Н.Фәттах

6) «Белмәгән идем, инде белдем» дигән мәгънәне аңлата. *Булган икән. Күп укыгансыз икән. Алай икән*

7) «Имеш» мәгънәсендә килә. *Сәрвиназ төш күргән төндә әнисе Хәйриягә дә төш керде. Шушманың көмеш суы ярларыннан чыгарга җиткән, елга тын гына ага икән.* Ирек мәйданы. *Төшемдә күп акча тапканмын икән*

**ИКӘН-МИКӘН** *и. сөйл. к.* **имешмимеш**

**ИКӘ́Ү** *сан* **1.** 1) Барысы, бар булганы, бөтенесе бергә ике булуны белдергән җыю саны. *Без дә Фәннур белән икәү берәр чит илгә барырга, дип уйлап кына торадырыек!* Л.Лерон // Санаганда «ике» мәгънәсендә кулланыла. *Аннан кыз --- чут төймәләрен шудыра-шудыра санарга кереште: – Берәү, икәү, өчәү ... кырык алты...* М.Маликова. *Иркәләнеп елмаю. Тагын берәү, икәү --- тулы бер атлама-обойма. Мә, ал, барысы да сиңа... Кинәт килгән бүләк кадерлерәк була.* Т.Галиуллин. *Үзем үлчәү таягын атлатып барам, үзем кычкырып метрлар саныйм: берәү, икәү, өчәү... унау... кырык...* Л.Ихсанова

2) Икесе бергәләп, икәүләшеп. *Сәгыйть Зәйтүнәне үзенә табарак елыштырды. – Нәрсәдән куркырга?.. Икәү булгач...* Н.Фәттах. *Рафисның җыр белән миңа мәхәббәтен аңлатканын, аккошларга тиң итеп мине атаганын без икәү генә белә идек шул.* М.Маликова

3) **икәве, икәвесе** *тарт. форм.* Тегесе дә, бусы да; икесе дә. *– Ә ничек сөйләмисең, ди? – Сабир башын күтәрә төште, күз аклары елтырап китте. – Икәвесен берьюлы әнә шулай әпенчәпен туздырып ташласын да сиңа!* Э.Касыймов. *Әллә инде --- дип җырлагандай булды берәү. Әллә Зәйтүнә, әллә Гөлүсә шунда. Аларның икәвенең арасы шулкадәр еракмы соң?* Н.Гыйматдинова

**2.** *а. функ.* Нindидер, гомуми фараз ителгән ике кеше. *Әгәр икәүнең күңелендә тыелгысыз сөю уты кабынган икән, аларның юлына аркылы басарга беркемнең дә хакы юк.* М.Маликова

**ИКӘҮДӘН-ИКӘ́Ү** *рәв.* 1) Икәүләп кенә, икәү генә, бары тик икәү генә. *Әкрен генә тирбәлгән нарат ябалдашлары арасында, яр буендагы чәчәкләр өстеннән очкан күбәләк, су кырыена сикереп чыккан бака малае янында – шушы гүзәллек, сафлык эчендә – алар гүяки улы белән икәүдән-икәү генә калдылар.* М.Маликова

2) Башка кешеләрне катнаштырмыйча, башкалар юк чакта, күзгә-күз. *Бердәнбер сөйләшкән кешесе – әнием, әтием белән икәүдән-икәү генә үз бүлмәләрендә кичләрен шыпырт кына сөйләшәләр.* Ә.Еники. *Мин инде аның [Җәүдәт Харисович] белән кичә күргәннәр, бүгенгәчә уйлаганнар турында икәүдән-икәү генә сөйләшербез, төрле*

*версияләр корырбыз, дип уйлаган идем.* М.Маликова. *Улы белән икәүдән-икәү генә калгач, ана аңа үз янынарак күчеп утырырга кушты.* Н.Фәттах

**ИКӘҮЛӘП** *рәв.* 1) Икәү бергәләп, икәү бергә, парлап. – *Иртәгә өмә була. Хатының белән икәүләп барыгыз! – дип кычкырып калды Низамый алар артыннан.* Н.Фәттах. *Парашютны икәүләп җыйгач, алар, велосипедка утырып, чирәмлек буйлап киттеләр.* М.Маликова. *Боламык ашалып, чәй эчелгәч, алар икәүләп өй буена чыгалар.* А.Гыйләҗев

2) Икәү берьюлы, икесе бервакытта. --- *үзең дә беркая чыкмассың! Икәүләп карарсыз баланы, икәүләп өйдә ятарсыз!* Н.Фәттах

3) *сөйл. сир.* Ике чамасы, ике тирәсе. *Икәүләп кенә калган*

**ИКӘҮЛӘШЕП** *рәв.* Икесе бергә, икесе бергәләп, икесе дә. *Һәм, икәүләшеп, шарт та шарт газ пистолетыннан атарга керештеләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Алар, икәүләшеп, бураны рәтләп куйдылар, кулларын кызартып, туңдырып, чишмә юлын тазарттылар.* М.Маликова. *Тик алдан ук кисәтәм: ул буш, тузга язмаган өметләреңне оныт... Рәисең Хөсәен Моратшин да яшь, икәүләшеп, каш ясыйм дип, күз чыгармагыз!..* А.Гыйләҗев

**ИКӘҮЛЕК** *и.* Икәү булу, парлылык. *Без икәүлектән, ул безнең янга килергә базмаган.* Ш.Камал

**ИКЕ** *сан* **1.** 1) Бер белән өч арасындагы бөтен сан, шул санның микъдарын һәм цифрын белдергән берәмлек атамасы

2) Шул санча микъдар. *Әби --- ике кулына ике чиләк белән бал күтәреп керә.* Г.Камал. *Һәрбер эшне җитез эшли торган, корыч кебек ике улым бар.* А.Алиш. *Гафиятулла бабайның тавышы калтырый, һәм ике күзеннән мөлдерәп яшь ага.* Г.Әпсәләмов

**2.** *и. мәгъ. сөйл. к.* **«икеле» 2.** (*1 мәгъ.*). *Начар малайга, билгеле, «ике»не куялар. Юк, Зиннәтнең бер дә «ике» билгесен аласы килми.* А.Шамов

◊ **Ике авыз җөмлә оештыра алмау** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике авыз җөмлә сөйли алмау** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике авыз сүз** *сөйл.* Кыскача гына берничә сүз; кыска, җыйнак кына җөмлә. *Ике авыз сүз белән хәлен аңлатып бирде Әдһәм абый: моннан ике ел элек аның хәләл җефете дөнья куйган.* М.Маликова. **Ике авыз сүз белмәү** *сөйл.* Нинди дә булса берәр телдә сөйләшә, аралаша алмау. *Аның әтисе русча ике авыз сүз белми.* И.Гази. **Ике авыз сүз җыеп әйтә алмау** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике авыз сүз җыеп әйтә белмәү** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике авыз сүз кайтарып әйтә алмау** *сөйл.* Каршы җавап бирә алмаучы бик юаш, куркак кешегә карата әйтелә. *Гадәттә ике авыз сүз дә кайтарып әйтә алмый торган мескен, йомыкый кешенең кинәт кенә кабынып китүенә, әллә нинди аңлаешсыз, бәйләнешсез сүзләр сөйләп ташлавына Садыйк абзый чынчынлап гаҗәпкә калды.* Н.Фәттах. **Ике авыз сүз оештыра алмау** 1) Төрле сәбәпләр аркасында тел бәйләнү, тел көрмәкләнү, юньләп сөйләшә алмаслык хәлгә төшү. *Мидхәт үзе ике авыз сүзне дә оештырып әйтә алмаслык исерек иде.* Ф.Хөсни; 2) Кеше белән юньләп сөйләшергә өйрәнмәгән, тел культурасы түбән булган яки надан кешегә карата әйтелә; 3) *к.* **ике авыз сүз белмәү**. **Ике авыз сүз оештыра белмәү** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике авыз сүз сөйли алмау** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике авыз сүз сөйли белмәү** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике агач арасында адашу** Үтә гади мәсьәләләрнең дә очына чыга алмый буталып (аптырап) калу. **Ике адым да атларга өлгермәү** *к.* **ике адым да атлый алмау**. **Ике адым да атлый алмау** Нинди дә булса эшнең яки вакыйганың тиз арада башланып китүе турында әйтелә. **Ике адым да китә алмау** *к.* **ике адым да атлый алмау**. **Ике адым еракта** Бик якын, яп-якын, янда гына. *Хәзер «Пыяный шап» Болак елгасыннан ике генә адым еракта булганга, --- Болакка җимерелеп төшеп, алдыбыздагы кышта шунда ятачак.* Г.Тукай. **Ике адым җирдә, ике адымда гына** Бик якын, бик якында; яп-якын, яп-якында. **Ике адымлык җир** Бик якын(да), яп-якында. *Аның ни мәшәкате бар? Ике адымлык җир ул.* Г.Ибраһимов. **Ике адымны бер итү** Кая да булса кабаланып йөгерү, ашыгу, бик тиз бару. **Ике адымның берендә** *к.* **ике сүзнең берендә**. *Хатыны Фатыйма беренче тапкыр балага узгач, икесе дә сөенештеләр. Галиулла ике адымның берендә: «Кара аны, Фатыйма, авыр күтәреп, өзлегә күрмә», – дип, гел хатыны тирәсендә бөтерелеп йөрде.* И.Гази. **Ике азан әйтмиләр** Берәр нәрсә турында кабат сөйлисе килмәгәндә әйтелә. *Ярар, ишетмәсәң шул, чукракка ике азан әйтмиләр. Моннан соң яхшылабрак тыңларсың.* Ш.Камал. **Ике алъяпкыч бәйләү** Икеләтә хезмәтче яисә асрау булу. **Ике алъяпкыч ябу** *к.* **ике алъяпкыч бәйләү**. **Ике ара** Үзара бәйләнеш, үзара мөнәсәбәт. – *Харрас белән ике арагыз ничек соң сезнең? – Бу сорауны Кәримә алдан ук әзерләп килгән иде.* К.Тимбикова. **Ике арага кара елан керү** Үзара якын мөнәсәбәттәге ике кешенең аралары бозылу, үзара дошманлашу. *Элеккеге заман булса, Сөнгать белән ике арагызга кара елан булып кереп сызгырып торыр идем әле.* М.Фәйзи. **Ике арага кара мәче керү** Ике якын кешенең үзара мөнәсәбәтләре бозылу. *Әллә сезнең дә ике арагызга кара мәче кердеме?* Г.Ибраһимов. **Ике арага керү** 1) Берәр максат белән ике кешенең үзара мөнәсәбәтләренә катнашу, тыгылу; 2) Бер-берсен яраткан яки дус булган ике кешенең арасын бозу. *Айрүзә: – Син, син ничек безнең ике арага килеп кердең соң әле? Ни хакың бар? – Бу – вакытлы гына. Аңлыйсыңмы, вакытлы гына!* М.Галиев. *Аның уенча, Харрас белән ике арага ят хатын кергән, мөгаен.* К.Тимбикова. **Ике арага күпер салу** Ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салу. *Шул гомер дәшми йөрдейөрде дә, хәзер исенә төшкән: ике арага күпер салмакчы була.* Р.Габделхакова. **Ике арага суык җил үтеп керү** *к.* **ике арага кара мәче керү**. *Аптырашта калды Әхмәтсафа, һаман-һаман сузып йөрсә, ике арага суык җилләр үтеп кермәсме?* Ф.Сафин. **Ике арага тирән упкын яту** Бер-берсен яраткан яки дус булган ике кешенең арасында аңла-

шылмаучанлык килеп чыгу. *Күрәсең, Наташа моны узгынчы бер нәрсә дип санаган, аңа артык әһәмият бирмәгән – әллә мәхәббәтнең күзе сукыр буламы? – Ә ул, тора-бара, ике арага тирән упкын булып яткан.* Г.Әпсәләмов. **Ике арага төшү** *к.* **ике арага керү**. *Галләм абзый, ике арага төшеп: «Көчләмәгез инде, хәзер Вахит ничек кирәк икәнен үзе белә торгандыр ---», – дип көлеп куйды.* М.Гафури. **Ике арада – бер турыда** Уртача, бер чама гына; алга да китмәгән, артка да калмаган. **Ике арада – бер турыда йөрү** Бер рәтле эш эшләмичә, әрле-бирле буталу, болганып йөрү. **Ике арада – бер турыда калу** Кая барырга да мөмкинлек булмау, күңелсез, уңайсыз хәлдә калу. **Ике арада бетү** Сөйләшенгән, эшләнгән эшләр ике кеше яки ике төркем кешеләр арасында гына калып, башкаларга мәгълүм булмау, сер итеп саклану. **Ике арада булган сүз** Ике кеше арасында гына сөйләшенгән, башкаларга мәгълүм булмаска тиешле сүз. **Ике арада йөрү** 1) Бер якка да кушылмыйча, ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләргә йогынты ясарга тырышу; 2) Төрле учреждениеләр арасындагы эшчәнлеккә, сәүдә эшендә арадашлык итү. *Шулай ук, елдагы гадәтләренчә, ике арада йөрүче маклерлар, алучы белән сатучыны килештереп, --- кулыннан килгәнчә ялган сөйләүдән курыкмыйлар иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Ялкау ятар, ризык артыр, дигәндәй, музей белән ике арада көн узсынга йөрүче Кәримә шул рәвешле бөтен мәсьәләләрне шома гына хәл итте дә куйды.* К.Тимбикова. **Ике арада кала күрсен** *к.* **ике арада калсын**. *Самат: – Без болай килешик: әлегә бу сөйләшу ике арада гына кала күрсен.* Г.Галиева. **Ике арада калсын** «Сер итеп кенә әйтелгән сүз, бу сүзне башка кешеләргә сөйләргә ярамый» мәгънәсендә. *Белмим, торып китә алырмынмы-юкмы, ике арада калсын, Сафия һаман элекке ирен ташламый бугай.* Н.Исәнбәт. **Ике арада калу** Ике якның кайсысына кушылырга белми икеләнү, аптырау. *Кәримәнең ике арада калуына гаепле саналган агай, телефон аша сөйләшеп, тагын бер урын тапты.* Р.Мөхәммәдиев. **Ике арада киләп сару** 1) Бер бүлмәдән икенчесенә, өйнең бер башыннан икенче башына бертуктаусыз йөреп тору. *Егетләр тәмәке тарткаларга чыккаладылар. Мин аш-су ягы белән ике арада киләп сардым.* К.Тимбикова; 2) Бюрократия, волокита аркасында бер кабинеттан, учреждениедән икенчесенә кабат-кабат йөреп, кирәкле документлар туплау; 3) Ике җирдә тормыш алып бару яки ике гаиләле булу сәбәпле, бер йорттан икенчесенә йөреп, ике гаилә турында да кайгырту. *Ике җирдә ике семья асрагач, нихәл итәсең, шул инде, ике арада киләп сарып йөрергә калдык.* Н.Исәнбәт. **Ике арадан буш калу** Ике якка да карамау, ни тегеләй, ни болай булмау. *Чалпы – авыл дисәң, зур, посёлок дисәң, кечкенәрәк, кыскасы, ике арадан буш калган бер авыл иде.* Социалистик Татарстан. **Ике араны бозу** Ике дусны, сөйгән ярларны бер-бере белән ызгыштыру, бозылыштыру. *Гомерлеккә иде бу аерылу. Ул күзләрен тутырып карады. Гүя миңа шушы усал карчык бутап йөри ике араны.* С.Хәким. *Абый белән эненең татулашуын Наилә үзе тели түгелме? Хәзер, киреләнеп, ике араны бозып ташласа?* А.Гыйләҗев. **Ике араны бутау** *к.* **ике араны бозу**. *Ничек кенә эшләмәсен, – Каландаров тәкъдимен искә алмыйча, райком аркылы басым ясатамы, яисә коммунистларны үз ягына аударып, Каландаровны япа-ялгыз калдырамы – барысы да ике араны бозуга илтә.* А.Каһһар. **Ике араны өзү** Үзара мөнәсәбәтләрне бетерү, аралашудан, очрашудан туктау. – *Мин синең яраткәнең түгелмени? – Ике араны өзәргә туры килер, ахрысы. Шул сүзләрне сөйләмәгәнемне беләсез бит инде!* Р.-Н. Гүнтәкин. *Димәк, ничек кенә авыр булмасын, йөрәк ничек кенә сызламасын, Тәбрия белән ике араны өзәргә кирәк, дигән нәтиҗәгә килде Гадил.* М.Маликова. **Ике араны шомарту** Ике арада еш йөрү, күп йөрү. *Аларга ныгытып әйткәли тормасаң, менә көт тә тор, кызу эш вакытларында алар, төрле сылтаулар табып, авылдан – шәһәргә, шәһәрдән авылга ике араны шомартачаклар.* Ш.Камал. **Ике аршын җир** Кабер, гүр. **Ике ат башы бер казанга сыймый** *к.* **ике тәкә башы бер казанга сыймый**. *Ике ат башы бер казанга сыймый, Ике патша башы бер мәмләкәткә сыймый.* К.Насыйри. **Ике ат бер тиен** Гамьсез, тормыш мәшәкатеннән хәбәрсез булу, дөньяга сабыйларча өстән һәм җиңел карау. *Бәхетле нарасыйдә! Тар бишек тә киң әле аңгар! Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңгар!* Г.Тукай. *Безнең кечкенә малай чак, безгә пешкән дә көйгән, ике ат бер тиен, диңгез тубыктан: без яңгыр яумауны да, игеннәр, үләннәр көюне дә, ачлыкны да белмибез.* М.Гали. **Ике ат бер тиен, ике чабата бер кием** *к.* **ике ат бер тиен**. **Ике атлам җир** Бик якын җир, янда гына. *[Варламов:] Барып җитә алдыгызмы соң сез? [Рабига:] Җитмәскә әллә, ике атлам җиргә.* Р.Ишморат. **Ике атлыйсын бер атлап** *к.* **ике адымны бер итү**. **Ике ашык бер тиен** *к.* **ике ат бер тиен**. **Ике аю бер өңгә сыймый** *к.* **ике тәкә башы бер казанга сыймый**. **Ике аягымның берсе дә тартмый** Каядыр барасы, китәсе килмәү. – *Их! – дип пышылдады ул Ирекнең колагына. – Шулкадәр китәсем килми! Ике аягымның берсе дә тартмый...* Ф.Садриев. **Ике аягымның берсен дә атламам** Нәрсәдән булса да туеп, башкача килеп йөрүдән баш тартуны яки ике кеше ачуланышып, берсенең мөнәсәбәтләрне тәмам өзүне белдерә; «башка бервакытта да бармам» мәгънәсендә. --- *фермада эшләгән кешедән бер чакрымнан тирес исе аңкый, силос исе килә. Юк, юк, ике аягыңның берсен дә атламыйсың фермага!* Н.Әхмәдиев. *Иртән Гөлниса, көндәгечә, Гыйлаҗны уятты. – Атасы, торырга вакыт. Эшкә соңга калмагаең. Гыйлаҗ, зырылдап, икенче якка әйләнеп ятты. – Ике аягымның берсен дә атламыйм мин моннан ары.* Р.Төхфәтуллин. *Иртәгә ике аягымның берен дә атламыйм, дип яткан идем. Булмады.* Н.Хәсәнов. **Ике аягымның берсен дә басмам** *к.* **ике аягымның берсен дә атламам**. **Ике аягына бастыру** Хуҗалыкны, эшне һ.б.ш.ларны кабат торгызу, ныгыту, көчле итү. *Бөлгенлек белән*

*тәмам йончыган авылны ике аягына да бастыру бик авыр иде.* Г.Галиева. **Ике аягын бер балакка тыгу** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. *Тәуфыйк Идрис янына килеп: – Ахмак Бишбалта батырын моңарчы кешегә чутлап йөри идем, ике аягын бер балакка тыгам хәзер! – дип, бик каты янады.* А.Гыйләҗев. **Ике аягын бер итеккә кидерү** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. *Әти-әнисенең ике аягын бер итеккә кидереп, Шәмсениса кияүгә чыкканда шулай дип кул селтәгән ләбаса.* М.Насыйбуллин. **Ике аягын бер итеккә тыгу** 1) Кешене теге яки бу гаебе өчен эзәрлекләп үч алу, гаеп эше өчен җәза бирү; 2) Берәр эшкә кыстап аптырату. *Ике аякны бер итеккә тыкмагыз әле, доктор, кырыкка ярылырга җиткән чакта* ---. Г.Әпсәләмов; 3) Кешене кыен хәлдә калдыру; 4) Кемне дә булса үз ихтыярына буйсындыру. **Ике аягын бер кунычка кидерү** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике аягын бер кунычка тыгу** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. *Ә барыбер утырттылар, каһәр. Ике аякны бер кунычка тыктылар, «халык дошманы», диделәр.* Р.Кәрами. *Ни булсын, мәшһүр Казан каласының йөз яшәр институтыннан кызның ике аягын бер кунычка тыгып җибәргәннәр.* К.Тимбикова. *Килен бик үткен минем: иренең ике аягын бер кунычка тыга ала торган.* Г.Ахунов. **Ике аягын бер чалбар балагына кидерү** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике аягын бер чалбар балагына тыгу** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике аяк, бер таяк** Кулга таяк тотып җәяү барырга калу. **Ике аяк идәндә** *сөйл.* Йомыш, эш үтәү өчен һәрвакыт әзер икәнне аңлата. *«Киңәш» дигәндә шәкертнең ике аягы идәндә.* Г.Әпсәләмов. **Ике аякка берьюлы аксау** Эш тормыш бөтен яклап артка китү, начарлану. *Саттар Хәбирәсе, кем әйтмешли, ике аягына берьюлы аксый башлады. Кулыннан эш төште. Савымы бермәбер кимеде.* М.Хәсәнов. **Ике аякка да аксау** *к.* **ике аякка берьюлы аксау**. **Ике аяклы афәт** *гади с. мыск. к.* **ике аяклы хәсрәт**. **Ике аяклы бәла** *гади с. мыск. к.* **ике аяклы хәсрәт**. *Әтиеннән мирас булып калган бу ике аяклы бәла аны минә ярты гомере буе эзәрлекли инде.* М.Хәсәнов. **Ике аяклы бүкән** Уңмаган, булдыксыз; мыштыр. *[Кызыйның авазы] --- исә тагын да зәһәррәк төсмердә чатнап ала: – Тиктомалга бөтерелергә мин кем сезгә? Үзегез җитезрәк кыланыгыз, ике аяклы бүкәннәр!* Э.Касыймов. **Ике аяклы бүре (хайван, хәшәрәт, эт, елан, күсе** һ.б.**)** *гади с. тирг.* Шул хайваннардагы тискәре сыйфатларга ия булган кеше турында. *Алар [талаучылар] бары каршылык күрсәтүчеләрне генә, я булмаса өстендә бай киеме булган яралыларны гына үтерделәр. Ике аяклы бүреләрдән читтәрәк дүрт аяклы чын бүреләр йөрделәр.* Н.Фәттах. *Ике аяклы елан ул: күзләре белән синең йөрәгеңне бораулый.* И.Туктар. --- *ике аяклы ерткычларның икесе пошиларны бер бозҗрага алган...* М.Насыйбуллин. **Ике аяклы, ике куллы** *сөйл.* Бүтәннәрдән берни белән дә аерылмаган, гадәти. *Терелткән дә хатын, үтергән дә хатын, дип белми әйтмәгәннәр борынгылар. [Сәҗидә апасы] Әлфия кебек үк ике аяклы, ике куллы кеше югыйсә.* Ж.Рәхимов. *Бәхти кинәт перчаткаларын берберсенә шапылдатып куйды. – Һа! Нинди асыл кош! Ике аяклы, ике куллы. Син дә Казанда, университетта укыйсың түгелме соң?* Н.Фәттах. *Безнең кебек үк ике аяклы, ике куллы, уйларга башы, сөйләргә теле булган кешеләр бер гөнаһсыз сабыйларны ничек итеп үтерә алдылар икән?* Л.Ихсанова. **Ике аяклы ишәк** *мыск.* Аңгыра, томана кешене, ишәк белән чагыштырып, мыскыллап әйтелә. **Ике аяклы хәсрәт** *гади с. мыск.* Ышанычсыз, таяныч булырга яраксыз кеше турында. **Ике аякның бер(с)ен басмау** *к.* **ике аякның бер(с)ен дә атламау**. **Ике аякның бер(с)ен дә атламау** 1) *к.* **ике аягымның берсен дә атламам**. *Салиха апа исә: «Җибәрмим! Ике аягының берсен дә атлатмыйм!» – дип, бөтен дөньяны яңгыратып кычкырудан чак кына тыелып калды.* М.Маликова; 2) Берәр эшне эшләүдән, берәр җиргә барудан катгый рәвештә баш тарту. *Ярар инде, чәкүшкәгә булгач йөгертеп кенә барып килермен, ди, ә башка җиргә ике аягымның берсен дә атламас идем, ди.* В.Распутин. – *«Сабан туе» дигәч тә, әллә ни булмас инде ул, Галимулла абзый, – диде бригадир, үзалдына сөйләнеп. --- мин әле үзем дә ике аягымның берсен дә атламас идем.* Н.Фәттах. *Алты ел интегеп, заочныйның өч курсын тәмамлады да шуннан соң институтка ике аягының берсен дә атламады.* Ф.Яруллин. **Ике әйтеп бер төшкә кермәү** Уйламау, искә дә алмау. *Ике әйтеп бер төшенә керми шул, сыңар төймәне дә тагып куймаска инде...* Н.Хәсәнов. **Ике әйттермәү** 1) Кушкач ук башкару, хәзер үк эшләү. *Күндәм ике әйттермәс.* Мәкаль; 2) Үз сүзенә каршы сүз әйтергә ирек бирмәү. **Ике әйтү** Кабатлау. *Краюшкинга ике әйтеп торуның кирәге юк, ул командирның боерыгын күз карашыннан ук аңлап ала иде.* Казан утлары. **Ике бармак арасына ит үсмәү** Ике дус, ике туган арасын бозып булмау турында. – *Ике бармак арасына ит үсми, анысы хак, – диде абзый кеше. – Тик, әйткәнем шул! Энекәш белән безнең Аллабыз гына бер ие.* З.Фәтхетдинов. *Брат братның көтү көткәненә рат... Ике бармак арасына ит үсми... Шушы сүзнең кайсы дөрес икәнен белсә, кеше чыгар малаеңнан.* Р.Вәлиев. **Ике бармак арасыннан чыгару** Саранлану, чиктән тыш аз бирү. **Ике бармак кебек** Аерылмас дуслар, гел бергә йөрүчеләр турында. **Ике бармак кебек аерылмас** *к.* **ике бармак кебек**. **Ике бармакта тоту** Үзенә буйсындыру, бәйле итү, үз сүзен тыңлату. *Мин – бөтен авылны ике бармагымда тоткан кеше.* С.Шәкүров. **Ике башлы булу** Үтә кыю, тәвәккәл булу. *Ике башлы булмаса, андый җиргә күтәрелә ме соң кеше?* Г.Әпсәләмов. **Ике башлы каракош (сәмруг кош)** Россиянең дәүләт гербында ике башлы сәмруг кош геральдик рәсеме һәм герб үзе. *Юк, егетләр, Сөембикә манарасы башына ике башлы каракош бервакытта да яңадан кунмас, кундырмабыз.* Н.Исәнбәт. *Идел күпереннән ике башлы сәмруг кош сурәте мәтәлеп төшә, көчләп тагылган исем шундук телдән югала, халык аны Кызыл күпер дип атый башлый* ---. И.Низамов. **Ике баштан, дүрт куллап**

Ике як та бер киңәштән булып, эшне бергә һәм бик теләп башкарырга әзер торуны белдергәндә әйтелә. **Ике бәрән башы бер казанга сыймау** *к.* **ике тәкә башы бер казанга сыймау**. *Ике бәрән башы бер казанга сыймый, ди безнең вожатый.* К.Нәҗми. **Ике бәһа** *к.* **ике бәя**. **Ике бәя** Икеләтә бәя, ике тапкыр югары бәя, бик кыйммәт. *[Ул] Ярты-лай тирескә әйләнгән саламын, --- тагын шуның шикелле җыен чүп-чарын җыеп, бергә ике бәя куеп бирә.* М.Гали. **Ике битле ком икмәк** Икейөзле, монафикъ, алдакчы кеше. **Ике бозауга башак аера алмаган** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. **Ике бозауга башак аера белмәгән** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. **Ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән** Бик гади нәрсәне дә аңлый алмаган; кулыннан эш килми торган, булдыксыз, надан, уңмаган, җебегән, ахмак. *Балалар укыту түгел, ике бозауга кибәк тә аерып бирә алмыйсың ич син ---.* Р.Хафизова. *Идрисовның болай әтәчләнүе Вафинны куркытмады гына түгел, киресенчә, бары тик зәһәрен генә чыгарды. – Ике бозауга кибәк аера белмәгән малай белән сөйләшмисең.* Ф.Хөсни. *--- гуманитар галимнәр арасында --- ни рус телендә, ни Европа телендә, ни ... хәтта үз телендә ике бозауга кибәк аера алмый торган «өреп кабартылган» күркә галимнәр барлыкка килде.* М.Мәһдиев. **Ике бозауга кибәк аера алмаган** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. **Ике ботын бер итеккә кидерү** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике ботын бер итеккә тыгу** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике ботын бер кунычка кидерү** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике ботын бер кунычка тыгу** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике ботын бер чалбар балагына кидерү** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. **Ике ботын бер чалбар балагына тыгу** *к.* **ике аягын бер итеккә тыгу**. *– Үлмәснекеләр: «Бездән куркып кына милициягә чапкан ул, юкса ике ботын бер чалбар балагына тыга идек Ташкәйнең!» дип сөйләнәләр икән, – дип куйды.* Я.Зәнкиев. **Икегә ярылу** Эш бик күп булу, ике кеше булып эшләсәң дә бетмәслек булу. **Ике генә сүз әйтү** *к.* **ике сүз**. *Мин аңгыра бәрән кебек чыгып китмәкче идем дә, кинәт ач яңаклы ир кеше почмактан тавыш бирде: – Галиҗәнаб бай әфәнде, рөхсәт итсәгез, ике генә сүз әйтмәкче идем.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Икедән берсез калу** Ике нәрсә артыннан йөреп, берсе дә булмау, икенең берсе дә барып чыкмау. **Ике дә өч, алты** *жарг.* Татар сәүдәгәрләренең ашханәләрдә чәй, пәрәмәч заказы әйтеме: ике порция чәй, өч чынаяк, алты пәрәмәч. *Базар әһелләренең (чәйханәдә) дә үз жаргоны. ... Кереп утыра да: «Ике дә өч, алты», – ди. Бу сүзләрне кеше теленә күчереп әйтсәк, --- ике порция чәй-шикәр, өч стакан, алты пәрәмәч, дигән сүз була.* И.Рәми. **Ике дә уйламастан** *к.* **ике дә уйламый**. *Хәзер ике дә уйламастан, ул [Харрас] газраил каршына барыр, әмма Солтания өенә аяк басмас иде.* К.Тимбикова. **Ике дә уйламый** Икеләнеп, уйлап тормыйча; тәвәккәл, кыю рәвештә; тиз арада бер карарга килеп. *Быел җәй үзем теләгән эшкә урнашсам, ике дә уйламыйм – өйләнәм.* К.Тимбикова. *Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: Фарукҗан, ике дә уйламый, иптәшен ияртеп керде дә нәкъ шулар артындагы урынга утырды.* Т.Әйди. **Ике дә уйламыйча** *к.* **ике дә уйламый**. *Ни хикмәт: авылдагы йөзләгән кыз белән ике дә уйламыйча сүз сөйләшә алган егетең Хәерниса белән очраштымы – каушый, тыннары буыла.* М.Мәһдиев. *Кыз, булачак кайнанасын бу хәлдә күрсә, ике дә уйламыйча тәртәгә тибәчәк иде.* Н.Гыйматдинова. **«Ике» дигәнче** Бик кыска, бик аз вакыт эчендә: санаган хәлдә, «бер» дип әйтеп, «ике» дияргә өлгергәнче. *Гани абзый исә кайсы әйбернең кайда саклануын, җиде төн уртасында йокысыннан уятып сорасыннар, «әһ» тә итми әйтеп бирә, күзләрен бәйләп җибәрсеннәр – «ике» дигәнче таба.* Ш.Рәкыйпов. **Ике дога, бер җыр** Гамьсез, ваемсыз кеше турында. **Ике дога, бер хәер** «Килүеңнән китүең хәерле, артыңнан, китүеңә сөенеп, дога укып, хәер биреп калырбыз» дигән мәгънәдә әйтелә. **Ике дөнья – бер кәнди** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. *Эчкән кешегә аңа Коръәнең ни дә, аңа ике дөнья – бер кәнди.* Х.Камалов. *Ул салпы колаклар беләмени чын дуслар арасындагы язылмаган законнарны! Аларга ике дөнья – бер кәнди.* Ш.Рәкыйпов. *[Илһам хан] Хатыннарын бар дип тә белмәде, ике дөнья бер кәнди иде аңа.* М.Әмирханов. **Ике дөнья – бер кыяр** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. **Ике дөнья – бер морҗа** Дөнья хәлен, тормыш кайгысын уйламый, уйлый белми торган ваемсыз, гамьсез кешегә карата әйтелә. *Нишләптер, сезгә теш кайраганнары күп аларның. Әллә инде сүзегездә тормагансыз шунда. Күбесе гаиләсез: аларга ике дөнья – бер морҗа.* Ф.Садриев. *Сиңа нәрсә, сиңа ике дөнья – бер морҗа. Бүген монда син, иртәгә – җәһәннәм читендә.* Р.Вәлиев. *Ата кеше тагын сүзсез калды, ыңгырашкандай авыр сулап куйды: – Барыгыз, алайса, барыгыз... Ике дөнья – бер морҗа ла сезгә...* Э.Касыймов. **Ике дөнья – бер морҗа, төтене кайтмаса ярый** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. **Ике дөнья – бер морҗа, уртасында бер тишек** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. **Ике дөнья – бер мунча** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. *Яшьләргә ни, ике дөнья – бер мунча, дигәндәй, без, без сакларга тиеш аларны, без әйдәргә тиеш яхшы юлга!* Ш.Рәкыйпов. **Ике дөнья – бер тиен** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. **Ике дөнья бер, уртасы (чи) камыр** *к.* **ике дөнья – бер морҗа**. *Шыр тилегә ике дөнья бер, уртасы чи камыр.* Мәкаль. *Акчаның кадерен бик беләбез, тиенен тиенгә чутлап торабыз. Ирләргә нәрсә аларга, ике дөнья бер, уртасы камыр.* Г.Зәйнашева. *Мондый җыелышларга «Ярар Борһан» йөрми, ул фермада каравылда була, үги әнисе Бибисарага ике дөнья бер, уртасы камыр.* Г.Ахунов. **Ике дөньядан буш калган** 1) *сөйл.* Ваемсызрак яки акылга зәгыйфьрәк кеше хакында; 2) Бушка яшәгән, дөньяга килеп яшәвеннән бер эз дә калдырмаган кешегә карата әйтелә. *Ишан, атасының васыятен тотып, «түрдән урын җитмичә, бусагада чәй эләкмичә» ике дөньядан буш калган. Тормышта, тегендә

*бәрелеп тә, монда бәрелеп тә, үзенә урын таба алмаган.* А.Кәһһар. **Ике җанлы** *эвф.* Авырлы, йөкле, көмәнле, корсаклы. **Ике җиңен яшенә манчыганчы елау** Бик озак, күп күз яшьләре агызып (гадәттә, юкка яки юри) елау. **Ике җиңне сызганып** Бик ныклап, тырышып (эшкә тотыну турында). **Ике җирдә ике(ң) – дүрт** Үтә аңлаешлы, бик гади нәрсәләр. *Менә эшләр шул чиккә терәлгәч, гомерендә бер аршин тотмаган, сатуның ни икәнен белмәгән, ике җирдә икенең дүрт икәнен аңламаган байның каенагалары --- сатуга китәләр.* Ш.Мөхәммәдев. *Озын сүзнең кыскасы, алдан ук кисәтеп куям: ике җирдә ике – дүрт икәнлеген дә белмәгән работникларның безгә кирәге шулчаклы гына.* М.Хәсәнов. **Ике җөмлә җыеп әйтә алмау** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике җөмлә җыеп әйтә белмәү** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике җөмлә оештыра алмау** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. *Әгәр безнең мәдрәсәләребез һаман шул көе ике җөмлә дә оештыра алмый торган шәкертләр чыгаруында дәвам итсәләр, --- һичбер вакытта бездә, үз әдәбиятыбыз булыр, яхшы да булыр, дип өмит итәргә юл юктыр.* Ф.Әмирхан. **Ике җөмлә сөйли белмәү** *к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. **Ике икең – дүрт** *к.* **ике җирдә ике(ң) – дүрт**. *Тозлы суны «йотып» җибәрергә өлгергән, алмалары алгарак чыгып торган соры күзләрдә Сәет гаҗәпләнү, аптырау укыды: «Аяз, якты көн кебек ачык, ике икең дүрт төсле мәгълүм хакыйкатьне белми утырасың, янәсе».* Т.Галиуллин. **Ике инә бер җептә, ике имән (каен) бер төптә (булу)** *к.* **ике тирәк бер төптә, ике төймә бер җептә (булу)** *Гомерен минем белән палаткаларда, баракларда үткәрде. Без гомер буе ике инә бер җептә, ике имән бер төптә.* Г.Мөхәммәтшин. **Ике иңем бер түбәле** 1) Әйткәнегезне үтәргә әзермен, баш өсте; 2) Ялгыз башымнан башка торыр җирем дә, беркемем дә, бернием дә юк. **Ике исәп – бер хисап** 1) Барыбер, тегеләй дә, болай да ярый. *Димәк, монда койрык бутап маташудан бернәрсә дә чыкмый, барыбер ике исәп – бер хисап булып чыга.* Ш.Камал; 2) Икеләнүсез тәвәккәлләү. *Ярый, ике исәп – бер хисап, быел шәһәргә күчәбез.* Н.Исәнбәт. *– Соң, тот та үзгәрт син аны [исемеңне]! Ике исәп – бер хисап, Хәйбулла тәвәккәлләде.* К.Тимбикова. **Ике йортка бер кисәү** 1) Ике кешегә берьюлы хезмәт күрсәтүче кеше; 2) Бер йорттан икенчесенә йөрергә мәҗбүр булу (гадәттә, карт ата-анасын карап тору турында). **Ике кабып, бер йоту** Тиз арада, күз ачып йомганчы башкарып чыгу (ашап бетерү яки эшләп чыгу). *Барып керсәм йортка, анда утыра бер кортка, пешергән ботка, ике каба да бер йота.* Н.Исәнбәт. – *Мәдинә кайтканчы мин аны [аракыны] ике кабам, бер йотам, – [диде Мортаза].* М.Хәсәнов. *Бу арысланнарым [атларым] белән синең ул бер иманаңны ике кабып бер йотам мин аны! Җиреңне генә күрсәт. Берсекөнгә ялт иттерермен!* Г.Бәширов. **Ике каен арасында адашу** *кит.* Бик гади әйберләрне дә хәл итә алмый аптырау. *Автор үз героен ике каен арасында адаштырып йөртә башлый, кояшлы көнне яшен суктыра. Мондый әсәрләрдә чынбарлык уйдырма вакыйгалар белән конфликтка керә.* Л.Ихсанова. **Ике калач – бер тиен**; **ике калач – бер тиен, ике чабата – бер кием** *к.* **ике ат – бер тиен**. **Ике камыт кию** Берьюлы ике эш алып бару, берьюлы ике вазифа үтәү. **Ике канат, бер койрык** Илсез, йортсыз, гаиләсез, бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүче кеше турында әйтелә. **Ике карама арасында адашып калу** *к.* **ике агач арасында адашу**. **Ике карбыз бер култыкка сыймау** Ике эшне берьюлы башкарып булмау (мөмкин булмаслык эш турында әйтелә). *Ике кылыч – бер кынга, ике карбыз бер култыкка сыймас.* Мәкаль. **Ике каш арасына энә кадау** Комачаулау, тоткарлык ясау. *Хурландыра, Гөлфия. Ат кебек җигелеп тартканда, ике каш арасына энә кадыйлар.* Н.Гыйматдинова. **Ике кашык – бер тиен** *к.* **ике ат – бер тиен**. **Ике килмәү** Бер генә кат булу, кабатланмау, кире кайтмау. *Яшь гомерләр ике килми, белегез кадерләрен.* Җыр. **Ике койрыклы** Ике якка да, ике хуҗага да хезмәт итүче, куштан, ялагай. **Ике колагың үзеңә булсын** Сөенечкә бернәрсә дә бирмәүне белдерә. **Ике колагыңны дүрт җирдән тыгу** Озак тыңлаудан туеп бетү. *Минем җитмәгән җирләрне, минем кирәгемне санап китсәң, иптәшкәем, ике колагыңны дүрт җирдән тыгарсың.* М.Әмир. **Ике көймәнең (куянның) койрыгын (берьюлы) тоту** *к.* **ике куянны берьюлы ату** – *Юкка борчылма, атасы, аңа карап ачка үлмәбез әле, сине бит быел дисәтник тә итеп билгеләгәннәр, ике көймәнең койрыгын берьюлы тота алмассың, – ди.* М.Галәү. *Шулай инде, картлар белми әйтмәгәннәр, чынлап та, ике көймәнең койрыгын тотып булмый, күрәсең.* Ш.Камал. *Тимәгез, ике куянның койрыгын тотам, дип, Нәсимәсеннән колак какмасын!* Г.Бәширов. **Ике көндә бер**; **ике көннең берендә** Бик еш, көн аралаш. **Ике кул баглау** Борынгы вакытта ике кулны күкрәккә баглап, ихлас хезмәткә әзер булуны аңлаткан коллык билгесе. **Ике кул белән** *к.* **ике куллап**. *Урыс байлары ике кул белән ярдәм биреп торганда, без мөселманнарга читтә калу һич килешмәс.* И.Гази. **Ике кул белән җил аулаучы** *шелт.* Җилкуар, булдыксыз, үзен эшчән итеп күрсәтергә теләсә дә, бернинди эше дә булмаган, эшсез кешегә карата әйтелә. *Ике кул белән җил аулаучы, бөтен шәһәрләр буенча шарлатанлык итүче --- әфәнде хәзрәтләре белән Шаляпин лакееның дуэле булды.* Г.Тукай. **Ике кулга бер эш** Бер генә төрле шөгыль, төрлегә бүленеп эшләнми торган, махсус бер генә белгечлек таләп ителә торган эш; нинди дә булса билгеле бер шөгыль. *Монда, ичмасам, ике кулыңа бер эш, ватылмый эшлисең. Шул эшеңә генә җавап бирәсең.* Н.Исәнбәт. *Ә Кәримнең ике кулына бер эш. Эше туйдырса, күңел ача ала, типтереп йөри ала.* Г.Ахунов. *«Тегендә, ичмасам, ике кулыма бер эш иде. Юкка килештем, – дип уйлады ул [Барый] үзалдына. – Менә монда иректә башыңнан ирексез булып, нинди дер Исламнар, нинди дер башкисәрләр турында кайгырып ят икән!»* Н.Фәттах. **Ике кулга дүрт эш** Эшнең күплеге турында. *Крестьян хуҗалы-*

*гында ике кулына дүрт эш булыр, котырып йөрергә вакыт калмас.* И.Гази. **Ике кулга шәм тотып (яктыртып) эзләү** Бик тырышып эзләсәң дә, башка бер җирдә ише табылмый торган яки бик сирәк очрый торган (әйбер яки кеше турында). *Җир җиләкләре пешкән чакта, Син сөясең, җаный, ниндәйне? Ике кулларыңа шәм яктыртып эзләсәң дә, Син тапмассың, җанкай, миндәйне.* Җыр. **Ике куллап** 1) Бик теләп, шатланып (риза булу, алу, каршы алу һ.б.). *Аларга башкалар кушылды, шулай итеп, гаеткә каршы кичтә яшьләр җыены үткәрергә карар кылдылар. Губком әлеге адымны ике куллап каршылады.* Ф.Сафин. *Имтиханнарын яхшы билгеләренә генә тапшыра икән, ике куллап алачакбыз.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Ныгытып, бөтен игътибарны туплап. *Миңа бу яңалык җепнең очы булып тоелды. Мин аңа ике куллап ябыштым.* М.Насыйбуллин. **Ике кулны баглау (бәйләү)** 1) Бернәрсә дә эшләмичә тик тору; 2) *к.* **ике кулсыз итү** (*1 мәгъ.*). **Ике кулны (да) богаулау** Берәр мәшәкать чыгып, үзеңнең төп эшеңә бушый алмау. *Кызының бала табуы Сәгыйдә апаның ике кулын да богаулады.* Н.Исәнбәт. **Ике кулны да кую** Берәр эшне хуп күрү, тулысынча, хәтта шатланып риза булу. *Бик хак, бик дөрес, ике кулымны берьюлы куям бу эшкә. У-ра!* Н.Исәнбәт. **Ике кулны кесәгә тыгып** Эреләнеп, тәкәбберләнеп; эре, тәкәббер кыяфәттә. **Ике кулны кисәргә бирү** Сүзенең дөреслегенә, вәгъдәсенең үтәләчәгенә ышандыру өчен әйтелә. *Әгәр дә мәгәр инде минем тәкъдим кабул ителмичә, бу эшне шушы көе калдырабыз икән, ике кулымны кисәргә бирәм, озакламый, безнең укучы кызларыбыз мәктәпкә бала алып кайта башлаячаклар.* Г.Рәхим. **Ике кулсыз** *к.* **ике кулсыз итү**; **ике кулсыз калу** *Гаиләсез-нисез, кола, дөресрәге, бүгенге алакола яланда, урманнар төпкелендә инде эшсез – ике кулсыз да торып калган ир-ат халкына вакытны, бигрәк тә алдагы төнне газапсызрак үткәрергә кирәк иде.* А.Хәлим. *– Юк, иптәш военврач, – диде Турганов иплe генә, ничектер, шатлыклы елмая-елмая. – Мин үз частема кайтам, әле замполит килгән иде, синнән башка без ике кулсыз, ди.* Х.Камалов. *Мин менә сездән башка ике кулсыз.* К.Тимбикова. **Ике кулсыз итү** 1) Вакытында кирәк ярдәмне күрсәтмәү, эшне бүлдерү; эшләү, хәрәкәт итү мөмкинлегеннән мәхрүм итү. *Билгәсәпитсез калдырып, син мине ике кулсыз итмәк буласың бит.* В.Нуруллин. *– Их, Сәет! – диде ул, Бикташ әтисенең сәламен дә алмыйча. – Ике кулсыз иттегез бит сез безне, ә! Көннәр буе газап чигәбез бит сезнең аркада!* М.Маликова. *Сиңа иң кирәк чагында гына тегермәнгә китеп бара да ике кулсыз итә.* В.Нуруллин; 2) Кыен, уңайсыз хәлгә калдыру, аптыраштa калдыру. *Тапты үләр вакыт, ярамаганмыни җәй өне, корырак, җыылырак вакытта. Ике кулсыз итте бит, шыгырдавык...* М.Мәһдиев. *Хәер, «профессор» димәктән.... Ул әле бүген дә Харрасны ике кулсыз итә язды бит.* К.Тимбикова. **Ике кулсыз калу** *сөйл.* Булышыр кешесез, ярдәмчесез калу; чарасыз калу. *Менә әле ике кулсыз калдым. Хатын үлеп китте бит. Былтыр – атсыз, быел – хатынсыз.* Н.Исәнбәт. *– Алып куйыйк, [чарыкның] кирәге чыгар дип, Рәдифкә әйтеп тә караганыем. Тыңламады бит, аксак шайтан. Менә хәзер ике кулсыз калдык инде! – дип җавап бирде.* В.Нуруллин. *Әле дә менә бу җебегән аркасында ике кулсыз калдык.* Н.Фәттах. **Ике кулы кесәсендә** Эшсез, булдыксыз, булышырга теләге булмаган кеше турында. **Ике кулым якасында** «Аның өстендәге хакымның тиешлесен алганчы дәгъвалыйм» дигән мәгънәдә. **Ике кулын артына куеп** *к.* **ике кулы кесәсендә**. **Ике кулының берсе** Берәүнең эшендә иң ышанычлысы, төп ярдәмче. **Ике куян артыннан куу** Берьюлы ике максатка, ике теләккә ирешергә омтылу. *Ике куян артыннан куып, берсеннән коры калма.* Ш.Хөсәенов. **Ике куян артыннан чабып, берсеннән дә коры калган** Берьюлы берничә эш алып бару, бүлгәләнү бернинди нәтиҗә китермәячәгенә киная. **Ике куянны бер атуда егу** *к.* **ике куянны берьюлы ату**. *Әткәй белән дә күрешербез, укырга да кереп кайтырмын. Ике куянны бер атуда егарбыз.* Э.Касыймов. **Ике куянны берьюлы ату (куу, тоту)** Бер башкарган эш белән ике максатка ирешү, бер эш башкарып, икенче мәсьәләне дә хәл итү. *Үргәнеч, ни хикмәт, Сарайдан читләшә бара. Сөһәйлнең анда булуы ике якны якынлаштырыр, фикерләрне берләштерер. Аны Үргәнечкә тәрбия өчен җибәрүем белән ике куянга берьюлы атармын, ике сунарны бергә алырмын!* Ф.Яхин. *Ул үзе сөйли торган сүз белән үзе үк мавыгып китте: – Дөресен генә әйткәндә, ике куянны берьюлы тотмакчы булган идем мин. Синнән дә үч алмакчы идем, кызда да өмет юк түгел.* Ф.Хөсни. **Ике күз алмам** *к.* **ике күзем карасы (нуры)**. **Ике күз арасында юк булу** Хәзер генә күз алдында булган кеше яки әйбер кинәт югалу. **Ике күзе генә калу** Бик каты ябыгу. **Ике күзе дүрт булу** 1) Хәйран калу, шаккату, бик нык аптырау, гаҗәпләнү. *[Маннур] Сөт тутырган бидон янына килде дә, «тратайка»ны бераз кыйшайтып, бер ыргак белән бидонның сабыннан эләктереп, үзенә таба тартуы булды, авыр бидон җиңел генә «тратайка» өстенә менеп тә утырды. Хәбирәнең ике күзе дүрт булды.* М.Хәсәнов. *Исәнтәй --- арадагы барлык бүләкләрен өйгә алып керде, барысын да идәнгә --- ташлады да: – Сиңа, олуг бикә! – диде. Кәринә бикәнең ике күзе дүрт булды.* Н.Фәттах. *--- бабай пычкының бер башын скрипка кебек ияк астына кыстырып, икенчесеннән шундый тибрәтеп җибәрде: гади пычкы сандугач кебек сайрый башламасынмы? --- Асиянең ике күзе дүрт булды.* Г.Әпсәләмов; 2) Тилмереп, түземсезләнеп, зарыгып көтү турында. *Сине көтеп, ике күзем дүрт булды.* **Ике күзе кебек** Бик көткән, бик кадерле, теләгән; бик кадерләп саклаган. *Мостафинның ике күз кебек теләгән нәрсәсе – бала.* Ә.Еники. **Ике күзе кебек (төсле) саклау** Бик кадерләп саклау. **Ике күзем (карасы, нуры)** Сөеп, иркәләп әйтү сүзе («кадерлем», «бәгърем» мәгънәсенә туры килә). *– Әйдүк, әйдүк, ике күзем, түребездә бул! [– диде Сәйфетдин абзый].* Ә.Еники. *Дәү, бик дәү үс, ике күзем.* Г.Гобәй.

*Ике күзем карасы, йөрәгемнең парәсе.* Н.Исәнбәт. **Ике күзем кояшы** *к.* **ике күзем (карасы, нуры)**. **Ике күзем чәчрәсен (чәчрәп чыксын)**! Берәр нәрсәгә ышандырырга кирәк булганда әйтелә торган ант-каргыш сүзе. *Гайния --- әкрен генә сөйләнә иде: – Ике күзем чәчрәп чыксын әгәр! --- инде, зинһар, кешегә генә чыга күрмәсен.* Ф.Хөсни. *Әйдәле, әйдә, синең бу әтәч тиресеннән эшләнгән портфелеңне суга салып карыйк әле! Ике күзем чәчрәп чыксын, таш кебек төпкә китәчәк ул!* З.Хөснияр. *– Чынлапмы, Гөлфия? – Балачакта без «ике күзем чәчрәсен» дип каргана идек.* Н.Гыйматдинова. **Ике күзен дүрт итеп** 1) Зур игътибар белән, бик яхшылап. *Буранбай ике күзен дүрт итеп баянга карап тора иде.* Г.Әпсәләмов. *Яңгура Гөлшәһидәгә ике күзен дүрт итеп карады. Измәгә буялып беткән кием белән дә нинди матур ул!* Г.Әпсәләмов; 2) Тилмереп, зарыгып. *Мин әнә шулай ни эшләргә белмичә, ике күземне дүрт итеп, Сәкинәдән хат көтеп йөргән чакта, --- теге Гөлүсә дигән укытучы тагын калкып чыкты бит, туган.* В.Нуруллин. *Хатыны инде чәйне кайнатып өлгергән, ике күзен дүрт итеп, иренең кайтуын көтә.* Э.Касыймов. --- *Айчибәрнең авылда ике күземне дүрт итеп көткән хаты тулай торакның вахтёр янындагы өстәлендә кояш нурларыннан саргаеп өлгергән иде инде.* Н.Әхмәдиев. **Ике күзен дүрт итү** Бик нык гаҗәпкә калдыру, шаккатыру. *«Ярый, исән булсак, бер күрешербез әле без ул чибәр белән. Ике күзен дүрт итәрбез әле без аның!» – дип, үзен-үзе юатып, Равил мотоциклын кайтыр якка борды.* В.Нуруллин. *Әмма аңа [Сәкинәгә] күңеле төшкән кеше бер мин генә булмаганмын, башка егетләрнең дә ике күзен дүрт иткән икән ул.* Г.Галиева. **Ике күзе тиң чыксын**! Кешегә яманлык теләү, каргау сүзе. **Ике күзе төсле** Иң кадерле әйбер турында. *Өзелеп сорыйм: ике күзең төсле, Спартакны сакла, аппагым.* М.Җәлил. **Ике күзе ут булу** 1) Дәртле, гайрәтле, көчле, йөрәкле, энергияле булу. *Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын.* М.Җәлил; 2) Бик каты кызыгу, үзенеке итәсе килү; берәр нәрсәгә зур теләк уяну, йөрәк җилкенсенү. *Егет матур кызлар күрсә, Ике күзе ут булыр.* Җыр. *Гармуныңны тартып уйна, Җырлаучыга хут булсын! Җыр тыңлаучы яшь кызларның ике күзе ут булсын!* Н.Исәнбәт. **Ике күзе шар булу** *к.* **ике күзе дүрт булу**. *Башка вакытта абыйсыннан мондый каты сүз ишетмәгән Адайның ике күзе шар булды.* Н.Фәттах. **Ике күзе юлда булу** Кемнең (яки нәрсәнең) дә булса килүен юлдан күз алмыйча көтү. **Ике кырда ике куян куу** Бер үк вакытта ике җирдәге ике хатын (ир) белән яшәү. *Мин сине коткарам, тиле! Ике кырда ике куян куган ир сәләмәсе нәстәмә сиңа?!* Н.Гыйматдинова. **Ике мәгънәле** Нәрсәгә дә булса ишарә иткән; кинаяле, иронияле, ике төрле аңларлык. *Кайсы, шаяртып, Ләләгә ике мәгънәле сүзләр әйткәли.* М.Фәйзи. **Икенең берсе** 1) Ике юлның, ике мөмкинлекнең берсен сайлау зарурлыгын аңлатканда әйтелә; я берсе, я икенчесе; я теге, я бу. *Бер аулакта мин аңа кырт кисеп куйдым: «Чыгасыңмы, Нәфисә, юкмы? Туп-туры әйт, икенең берсе», – дидем.* А.Шамов; 2) «Ике мөмкинлекнең, ихтималның берсе булмый калмый» дигән мәгънәдә әйтелә. *Монда хәзер икенең берсе: я хәзер [бүре] безгә ябыша, я без аны бетерәбез!..* Н.Исәнбәт. **Ике рәхәт бергә килми** Һәр яктан да көйләп бетерү, бөтен уңайлыкларга да ирешү мөмкин булмау турында. **Ике рәхәт җәннәттә генә була** *к.* **ике рәхәт бергә килми**. **Ике сарылы** Ачык билгеле түгел, шикле, шөбһәле. *Инде айга якын Шумский тубдиспансерда ята: үпкәсендә кара таплар тапканнар. Идарә буенча план үтәлеше исә – ике сарылы.* Җ.Рәхимов. *– Миңа, – Фәнзия егетнең колыгына бер укытучының фамилиясен әйтте, – бәйләнә. Чистый сагыз булды. – Ничек? – Зачёт куймады. Экзаменга керүем дә ике сарылы.* Р.Кәрами. **Икесе бер иш** Икесе дә бер төсле, бер-беренә охшаган. *– Икең бер иш бит сез. Апа күк йөрсәң, үзең дә кияүсез калырсың әле менә, – диде Зәйнәп.* Л.Ихсанова. **Икесе бер кашыктан ашау** Ике кешенең, булган әйберләрен уртаклашып, бик тату яшәүләренә карата әйтелә. **Икесе бер кием** *к.* **икесе бер иш**. *Габделбәр дә саран, Әхтәм дә саран ---. Күрәсез, ике әсәрдәге ике пар герой икесе бер киемгә әйләнә.* Х.Сарьян. **Икесе бер табаннан** Бер эздән, бер юлдан йөргән, бер үк төрле фикерле торган аерылмас дуслар. **Икесе дә бер багана төбен таптау** 1) Бер үк сүз сөйләү турында әйтелә. *Сабиров аңа каршы бер генә сүз әйтмәде, дисәм дә, хата булмастыр. Алар икесе бер багана төбен таптыйлар.* С.Рафиков; 2) Бер тирәдә йөрү. **Икесе дә бер калыптан сугылган** *к.* **икесе дә бер очтан кискән**. **Икесе дә бер очтан кискән** Бер-беренә охшаш, бертөрле (кешеләр турында). **Икесе – ике нәрсә** Бер-беренә бәйләнешләре булмаган, бер-береннән аерыла торган нәрсәләр турында. *Ул «берләшү» белән Разия туташ кузгаткан «берләшү» – икесе ике нәрсә ич.* Г.Ибраһимов. **Икесе кешенеке, өчесе күршенеке** *сөйл.* Ярлылыкны, хәерчелекне, юклыкны аңлата. *– Алты пар чынаягыбыз бар, кунаклар, – диде ул. – Гаеп итмәгез инде. Аның да икесе кешенеке, өчесе күршенеке дигәндәй, өч пары гына үземнеке.* М.Әмир. **Икесен бер идән тактасына куеп карау** Икесе ике холыклы, ике төрле тәрбия алган кешеләрне чагыштыру турында. **Ике сикер, бер атла** «Бик якын»; «аралары якын, монда гына» мәгънәсендә ...*Мәрәк Хисмәт «Казанны калдырабыз!» дигән хәбәргә колагын ялт торгызды. Ничек алай? Казанны алсалар, Әтнәгә дә «ике сикер, бер атла» ич.* И.Низамов. **Ике сөйләмәү (сөйләп тормау, сөйләшмәү)** *сөйл.* 1) Әйткәнне эшләү, вәгъдәдә тору. *Әткәй, син минем ике сөйләмәгәнне беләсең бит, нигә юк өчен кан бозасың...* Г.Ибраһимов. *– Син Каһарманов абыеңны белмисең әле. Ике сөйләшми ул, --- диде пациент.* М.Маликова. *Патша ике сөйләми ул, аның кулына бер эләксәң...* Г.Әпсәләмов; 2) Сүзне катгый һәм бер әйтү, кабатламау. *Минем киңәшем шул: шушы атнада ук чираттагы ялыгызны алыгыз да стационарда дәваланыгыз. Ике сөйләшмибез. Хушыгыз!* Б.Камалов. *Грасис*

*кулга алыначак. Ильяс Алкин ике сөйләшми.* Р.Мөхәммәдиев. **Ике сөяк – сандырак** *шелт.* Икесеннән бер кеше чыкмаслык; икесе дә чирле яки гарип. *Бу Ханнан карт белән карчыгы да ике сөяк – сандырак, башлары чирдән чыкмый, балалары да юньсез, карашмыйлар.* Н.Исәнбәт. **Ике сүз** Артык киң җәелмичә, кыска; берничә сүз. *Шуңа күрә Париж урамнарының һавасы турында ике сүз артык булмас.* Г.Гобәй. **Ике сүз арасында** Сүз җае килгәндә, сүз уңаенда; гәп, әңгәмә вакытында. *Шунда, ике сүз арасында, аның күңеленнән бу юлы сүзне әйткән саен исенә төшә торган бер вакыйга сирпелеп узды.* Г.Бәширов. **Ике сүз әйттермәү** Күп сөйләшмәү. *Алтынчәч бу эшләрне иреннән дә нечкәрәк аңлый иде. Ике сүз әйттермәде: «Берсекөнгә каланың базар көне гуй – Җылкычы атаны чакырыйк».* Г.Ибраһимов. **Ике сүз булмау** Ике төрле сүз, фикер яки бәхәс булмау, булырга ярамау, булуы мөмкин түгел. *«Димәк, син риза, алайса, бир кулыңны!» Туташ урыныннан торды: «Ул турыда ике сүз булырга ярамый!» – дип, кулларын Фазыйлга сузды.* Г.Ибраһимов. **Ике сүзгә урын калдырмау** *к.* **ике сүз булмау**. *Варис үзе генә озата бармакчы иде, Кави Салихович ике сүзгә урын калдырмады, такси туктатып, --- больницага килеп җитте.* Б.Камалов. **Ике сүзгә урын юк** Башка фикер яки бәхәс булырга да мөмкин түгел. **Ике сүздә, ике сүз белән** Берничә сүз белән, кыскача гына. *Синеке кып-кыска чыга, ике сүз белән бетерәсең дә куясың, ди.* Г.Ибраһимов. *Күк күзле хатын ике сүз белән хәлемне аңлатып бирде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Ике сүздән аңлау** Бик тиз аңлау, тиз төшенү. *Мәсьәләнең асылын карт ике сүздән аңлады.* М.Маликова. **Ике сүзле** 1) Ике урында ике төрле (капма-каршы) сөйләүче (кеше); 2) Әйткән сүзендә, вәгъдәсендә тормаучы (кеше). *Мине ике сүзле ясыйсың, атам.* Н.Исәнбәт. **Ике сүзне кушып бер җөмлә тәртип итә белмәү** *иск. кит. к.* **ике авыз сүз оештыра алмау**. *Бездә ике сүзне кушып бер җөмлә тәртип итә белмәгән кешеләр --- газета чыгаралар.* Г.Тукай. **Ике сүзнең бере(ндә)** Бик еш, туктаусыз; сүз саен. *Шул [Котдус] бит инде ике сүзнең берендә «Илсөя» дип тора.* Ф.Яруллин. *Гыймадетдин ике сүзнең берен «ызнамы шулай» дип җүпләп барды да офицер килбәтле кешегә карап куйды.* К.Нәҗми. *Гайнулла карт, ике сүзнең берендә корык-карык йөткерә-йөткерә, нидер сөйли, бүтәннәр тавышсыз гына тыңлап утыралар иде.* Н.Фәттах. **Ике сүз сөйләү** Бер урында (вакытта) бер төрле, икенче урында (вакытта) икенче төрле сөйләү, төрлечә фикер йөртү. **Ике сыерга башак аера алмаган** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. **Ике сыерга башак аера белмәгән** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. **Ике сыерга кибәк аера алмаган** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. – *Әшнәлек, кода-кодагыйлык аркасында, ике сыерга кибәк аера алмаслык кешеләр югары урыннарга менеп утыралар ---, – диде Талип.* Ә.Ибраһимова. **Ике сыерга кибәк аера белмәгән** *мыск. к.* **ике бозауга кибәк аера (аерып бирә) белмәгән**. **Ике сыңар – бер кием (пар)** Бер-берсенә торырлык, берсе икенчесенә тиң булырлык. *Җаббар белән Саттар – ике сыңар, бер пар. Икесе бер-береннән башка йөрмиләр дә, була да алмыйлар. Менә шул.* Н.Исәнбәт. --- *Тураев искәрткәнчә, ике сыңар – бер кием булган Мөхетдинов белән Хуҗаевның соңгысын ялгыш та телгә алмавы белән сәерсендерде Гарипов.* Т.Әйди. **Ике табып, бер югалткан** Бик кадерле кеше яки әйбер турында. **Ике такта арасында калу** *к.* **ике ут арасында (уртасында, эчендә) калу**. **Ике тамчы судай** *к.* **ике тамчы су кебек (шикелле)**. *Ул, ни хикмәт, шушы берсе икенчесенә ике тамчы судай охшаган кошларның күбесен таный ---.* Р.Фәизов. **Ике тамчы су кебек (шикелле)** Аерып алгысыз, бер-берсенә охшаш. *Әгәр дә Зояның ике тамчы су кебек анасына охшавы дөрес булса, бәлки, аны бер күрүдә үк таныйрлар, «сеңлем!» дип, кочаклап алырлар?* Г.Бәширов. *[Гобәевләр һәм Апанаевлар] Үзара киңәшмиләр-нитмиләр, хәтта бер-берсе турында да ишетеп кенә беләләр, ә менә үзләренең тәкәббер киленнәренә ике тамчы су кебек охшаш шарт куялар.* Г.Шәрипова. *Энекәшләр күз алдымда диярлек үссәләр дә, аерып бетерә алмыйм: ике тамчы су кебек охшаш алар.* Н.Әхмәдиев. **Ике тәйле** *диал. к.* **ике сарылы** *Хәзер патша туй ясый, кызлар, кием булгач, бармакчы булалар булуын, шулай да бару әле ике тәйлерәк.* Әкият. **Ике тәкә башы бер казанга сыймау** Бер гаилә, коллектив кешеләренең, җитәкчеләрнең үзара тыныша, килешә алмаулары турында. – *Әле ул [Хәмит] монда куна калырга да тиешме? Ике тәкә башын бер казанга сыйдырмакчы буласыңмыни? Ай-һа-а-й... – дип, Касыйм Кадыйрович түш кесәсеннән телефонын тартып чыгарды.* Г.Галиева. *Ләйләгә күз генә атты да Фәһим кинәт ишеккә таба борылды: – Ни, алайса... алай бик ышангач, син аны көтәсеңдер инде. ...Беләсең ич, ике тәкә башы бер казанга сыймый, берсе артык. Мин китим, алайса.* Г.Бәширов. *Мин бик гаҗәпләндем: Ленаны бөтен авыл халкы ярата, Сибгат абый ярата, якын итә. Гадәттә, ике тәкә башы бер казанга сыймый бит инде.* М.Мәһдиев. **Ике теләйле** *к.* **ике сарылы**. – *Солычаны бетерәм дип, чәчүне соңарту – ике теләйле, – дип зарын түкте Вәзыйх. – Я пан, я пропал!* Х.Камалов. **Ике телле** Алда – бер, артта икенче төрле сөйләүче; ике төрле, икейөзле. **Ике тиен – бер акча** 1) Мөһим түгел, кирәксез, әһәмиятсез, бернигә дә тормый, берни түгел. *Хәзер синең муллаңның бәясе, күп булса, ике тиен – бер акча.* К.Әмири. *Гомәр әйбәт укырга сүз бирде, тырышсам, әйбәт уку миңа ике тиен – бер акча, диде.* Г.Рәхим. *Сезнең авыл нигә асты өскә килми, аларга ике тиен – бер акча бит.* Ш.Камал; 2) Арзан. *Нәрсә син, Илһам углан, болгар кызларын ике тиен – бер акчага сатып торган сыман...* М.Хәбибуллин. *Өлкән язучыга 60 – 70 яшьлегендә 3–4 меңне чыгарып салу нәрсә ул! Ике тиен – бер акча ул ---.* М.Мәһдиев; 3) Барыбер, ничек булса шулай ярый. *Фәридә артка чикте дә, күзләрен алартып: – Ни диюегез бу, җизни? – диде.*

*Газиз бәй, Кәмранга күрсәтеп: – Менә ирең шулай куша, миңа нәрсә, ике тиен – бер акча, – диде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Ике тиен – бер акча тормый** *к.* **ике тиен тормас(лык)**. **Ике тиен тормас(лык)** *мыск.* Яраксыз, әһәмиятсез. *Тегеләй ике тиен тормас кеше бит.* Ш.Камал. *Ике тиен дә тормаслык җәлладларга башын сатып, тамак туйдырмак була.* М.Галәү. **Ике тиенгә исәпләнмәү (күрмәү)** Әһәмиятсез, яраксыз, кирәксез саналу. *Аның өчен матәм тотучылар йөзләр, меңнәр белән чикләнә, Ләкин дөнья эшчәннәре өчен исәпләнми ике тиенгә дә.* М.Гафури. **Ике тиенгә дә тормау (кирәкмәү)** *к.* **ике тиенгә исәпләнмәү (күрмәү)**. *Рүзәл --- безнең сөйләшүнең эшлекле эзгә төшә алмаганын аңлагач, ачуланырга ук тотынды: – Шулайдыр дип уйлаган идем әле аны. Ике тиенгә кирәкмәгәнне лыкылдап утыргансыздыр.* К.Тимбикова. **Ике тиенлек** 1) Бер дә, аз гына да, бөтенләй. *Кем дә кем, төшендә мөселманнарга мөфти булып, елга өч мең жалованье алып, мөселманнар файдасына ике тиенлек эш кылмаса – хәвефледер.* Ш.Мөхәммәдев. *Сабантуй мәйданында йөргәндә, моны кесәдән алып чырт-кырт китереп ватасы, ашыйсы, шунсыз – кеше алдында ике тиенлек тә дәрәҗәң булмаячак.* М.Мәһдиев. *Урядникның акырынуы мине ике тиенлек тә куркытмый.* Ф.Хөсни; 2) Әһәмиятсез, кирәксез, бернигә ярамаган, юк-бар. *Имеш, сары чикмәнле мужик егетләре белән китеп, анда бәрәңге ашап, ике тиенлек «ефрейтор»ларның итеген тазартып йөргән бер бичараны, аңа кияүгә барам дип, ничә ел көт!* Г.Ибраһимов. **Ике тиен тормау** «Юк дәрәҗәсендә, әһәмиятсез» мәгънәсендә. – *Күңел матурлыгы алдында бит матурлыгы ике тиен дә тормый бит ул! – дидем.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Ике тирәк бер төптә, ике төймә бер җептә (булу)** Бик якын, берберennән аерылмас дуслар (булу). **Ике тишек – бер морҗа** Яхшы белән начарны аера белмәү. **Ике тишекле бер тиен акча** Тәмам кадерсезгә калган, бәясен югалткан кеше турында. **Ике тишекле бер тиен дә тормау** Кешеләр арасында кадерсез, бәясез булу. **Ике төрле сөйләү** *к.* **ике сүз сөйләү** *Ринатның ачуы чыкты: – Менә нәрсә, брат, без план үтәлешен синең «кәеф»еңә генә көйләсәк, нәрсә булачагын беләсеңме син?.. Эшләр тагын да мондыйга китә калса, үпкәләштән булмасын, ике төрле сөйләшү булмаячак...* Н.Хәсәнов. *Бу кеше ике төрле сөйләргә яратмый, агын – акка, карасын карага аерып кына куя иде.* Г.Ахунов. **Ике төрле телдә сөйләшү** Бер үк турыда сөйләшеп тә, икенче нәрсәне күздә тоту. *Миңнулла стаканын учы белән каплады да --- әйтте: – Кичерегез, Кошкарев әфәнде, ләкин без икебез ике төрле телдә сөйләшәбез булып чыкты бит әле! Мин тостымны үзем көткән, үзем ышанган якты киләчәкне --- күздә тотып әйткән идем.* В.Нуруллин. **Ике туйдан калган** Дәрәҗәсе төшкән, кадерсезгә калган. **Ике уйлап тормау, ике дә уйлап тормау** *к.* **ике дә уйламау**. *Мунчалар янына килеп җиткәч, Гомәр ике дә уйлап тормады, Фәлинәнең беләгеннән нык кына итеп эләктерде дә теге ике кыздан йолкып та алды.* Г.Рәхим. **Ике уйларга урын калдырмау (калдырмаслык итү)** Катгый итеп, икеләнүгә урын калдырмыйча. *--- пашаның олы кызы миңа картиналарны күрсәтеп йөргәндә, ике уйларга урын калдырмыйча, каян килеп картиналар булсын болар, сыздым-боздым гына ич алар, дидем.* Р.-Н.Гүнтәкин. *– Ә без очрашырга телибез, – дидем мин, ике уйларга урын калдырмаслык итеп.* Р.Мөхәммәдиев. **Ике уртада (тору)** 1) Яхшы да, начар да түгел, ярыйсы гына булу. *Хатыннар арасында иң нык тырышып эшләүче – Мәдинә, ә иң ялкавы – Миңсылу, башкалары – ике уртада.* Ш.Камал; 2) Ике фикер яки ике төркем кешеләренең кайсысына кушылырга белми икеләнү, аптырауда калу. *Бу ике төркем арасында икеләнүче, ике уртада торучы, күп төрле каршылыклы язучылар бар.* М.Җәлил. **Ике урындык арасында утыру** Берьюлы бер-берсе белән сыеша алмаслык ике фикер, караштa тору һәм шуларга таянып эш итү. **Ике ут арасында (уртасында, эчендә) калу** 1) Капма-каршы ике фикер яки ике якның кайсысына кушылырга белмәүдән барлыкка килгән куркынычлы хәлдә калу. *Ул, әйтерсең, ике ут арасында. Берсе – кайчандыр аңа җылы, якты биргән ут инде суынып-сүнеп бара. Икенчесе – аның бүгенгесе, кем белә, бәлки, киләчәгедер дә...* М.Галиев. *Ул [Гадил] Тәбриягә баланы «тап» та дия алмый, «тапма» да дия алмый, ул ике ут арасында иде.* М.Маликова. *Ул чагында ул үзен ике ут арасында калган төсле хис итте һәм төне буе йоклый алмады.* Ш.Камал; 2) Берьюлы ике мәшәкать яки ике бәхетсезлек арасында калып, кайсына җитешергә дә белмәү. *Абыйсының борчулы һәм уйчан күзләренә игътибар итте кыз. Ул ике ут арасында калган.* Р.Мөхәммәдиев. *Шул минутта ул язмышының ике ут уртасында калуын, икенең берсен сайлап алырга тиешлеген тойды.* К.Тимбикова. **Ике ут белән уйнау (шаяру)** Берьюлы ике хәтәр эш белән шөгыльләнү. *– Миңнурый, син ике ут белән шаярасың, – диде ул, кызның мәрҗәннәр кебек ялтырап торган кечкенә күзләренә текәлеп карап.* Г.Әпсәләмов. **Ике ут эчендә калу** *к.* **ике ут арасында (уртасында, эчендә) калу** (*2 мәгъ.*). *Наилә ике ут эчендә калды. Сабитның: «Мин сине ашарга телим!» – дигән сүзе, шаяру булмыйча, шушы көтелмәгән сәяхәткә барып тоташса, ни кылырсың?!* А.Гыйләҗев. **Ике ут ялкынында өтелү** *к.* **ике ут арасында (уртасында, эчендә) калу** (*2 мәгъ.*). *Ләкин ир ике ут ялкынында өтелде. Бер якта – васыять, икенче якта – Шәрифә....* Н.Гыйматдинова. **Ике утыргыч арасында калу** 1) Капма-каршы фикердә, караштa эш итеп, уңышсызлыкка дучар ителү; 2) Кыен хәлдә калу. **Ике үгез башы бер култыкка сыймау** *к.* **ике карбыз бер култыкка сыймау** *Бер култыкка ике үгез башы сыймавы, бер көймәче ике көймәнең койрыгын тота алмаганы һәркемгә мәгълүм була торып, бер муллага --- 20 төрле эш биргәннәр.* Г.Тукай. **Ике фронтта** Берьюлы ике юнәлештә, ике тармакта эш итү турында. **Ике хак** *к.* **ике бәя**. **Ике чабата – бер кием** *сөйл.* 1) Бернәрсәгә дә артык

игътибар итмәү, әһәмият бирмәү, ничек булса шуңа риза булу. *Хәзер кусаң ни дә кумасаң ни! Ике чабата – бер кием!..* А.Гыйләҗев; 2) Бер-беренә охшаш, бер төсле, бер иш. *Мулла белән кулак дус булса да булыр, ике чабата – бер кием инде.* Г.Толымбай. *Алар [татар-монголлар] ни дә, Гитлер ни – ике чабата бер кием.* Ә.Ибраһимова. *Мин дә халык укытучысы... Син дә... Бер сукмактан йөрибез, ике чабата – бер кием икәнбез ләбаса...* Р.Мөхәммәдиев. **Ике чабата бер кием, ике дөнья бер тиен** *сөйл. к.* **ике чабата – бер кием**. *Буран элеккечә яман котырынса да, аларга, әллә кем әйтмешли, хәзер «ике чабата – бер кием, ике дөнья – бер тиен» иде инде.* Г.Бәширов. **Ике шалкан – бер тиен** Икесе дә бер, барыбер. *Татар бае газет сөйми. Ике чабата – бер кием, ике шалкан – бер тиен.* Г.Тукай. **Ике шалкан – бер тиен, ике чабата – бер кием** *к.* **ике шалкан – бер тиен**. *Ваемсызның халәте җиңел аның: ике шалкан – бер тиен, ике чабата – бер кием.* М.Насыйбуллин. **Ике эткә бер сөяк** Ике арада ризасызлык, бәхәс китереп чыгарган әйбер. **Ике юл уртасы (чаты)** Кеше яки җәмгыять тормышында берәр эшне, карарны үтәү, юнәлешне билгеләү алдыннан әһәмиятле, бик мөһим момент. *Ул кичне мин ике юл чатында баскан идем. Гарәфи лотошникның сөйләгәннәре минем алдагы язмышны теге яки бу юлдан җибәрергә тиеш иде.* Э.Касыймов. **Ике якка да кушылмау** Бер якка да кушылмыйча, нейтральлек саклау, битараф булу. *Алар ике якка да кушылмый торырга мөмкин түгеллеген сизәләр, аңаралар. Шунлыктан алар сыйнфый дошманга артык аңсыз корал булмыйлар, киресенчә, кулакны фаш итү юлы белән китәләр.* М.Җәлил. **Ике якка да юк** Булдыксыз, мәнфәгатьсез, бер эш тә булдыра алмый торган. *Ни заводта куандырмый, ни өйдә: ике якка да юк.* Н.Исәнбәт. **Ике яклы** 1) Киләчәге, нәтиҗәсе ничек буласы анык түгел; томанлы, билгесез. *1917 елның Октябрь давылы әнә шундый ике яклы эш эшләде.* Г.Нигъмәти; 2) *к.* **икейөзле**. *--- миңа шикләнүнең, шикнең көчен, аның кеше күңеленә тәэсирен күп мәртәбәләр күзәтергә туры килде. Ике йөзле пычак кебек ике яклы ул.* М.Маликова. **Ике яклылык** Икейөзлелек, турылыксызлык. **Ике яклы (йөзле) пычак (пәке)** *тирг. к.* **икейөзле**. *Хәер, кешеләр бөтен җирдә дә Сәлмән карт кебек ике яклы пычак түгел лә!* Ф.Хөсни. *Мәрфуга иренең аны гомер буена алдап, аңа хыянәт итеп яшәвенә бәгырьләреңне көйдереп алырлык итеп рәнҗеде: – Ике йөзле пычак! – дип тиргәнде.* Г.Бәширов. – *Кичә телләрендә Ленин иде, Бүген – Алла. Тфү, ике яклы пәкеләр! – Ир, җиргә төкергәч, җиң очы белән иренен сөртте.* Н.Гыйматдинова. **Ике яклы уен уйнау** Һәр ике якны да алдау, һәр ике як белән дә тыштан – бер, эчтән икенче эш алып бару. **Ике якны да су кебек эчү** Ике телне дә бик яхшы белү. **Ике ятып бер төшкә кермәү (уйламау)** 1) Искә алмау, уйлап та карамау. *Ә менә Нәфисә өчен Халидә әллә бар, әллә юк дөньяда: ике ятып бер төшенә керми иде, ичмаса.* М.Шабай. *Ул [Рәүф] мине ике ятып, бер төшендә дә күрмидер, миннән җиңел генә котылуына куанып йөридер әле...* Н.Мусин. *Башка егетләр Гөлнараның ике ятып бер төшенә дә керми.* Ә.Сафиуллин; 2) Һич көтелмәгән, уйга да килмәгән булу. *Шактый иркә үскән, яшьли акчалы тормышка өйрәнгән Мисхәт-Мишаның чит-ят шәһәр төрмәсендә алты айга якын кандала симертәсе ике ятып бер төшенә керә алмаслык хәл иде.* Т.Галиуллин

**ИКЕ-** Кайбер кушма сүзләрдә (урын, вакыт, озынлык ягыннан) «ике өлеш» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк (мәс., *икеурынлы, икеellык, икеатналык*)

**ИКЕ́ АВЫЗЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Ике имгечлеләр отрядыннан кеше яки хайван тәнендә паразит булып яши торган яссы суалчаннар; *русчасы:* **двуротые**. *Ике авызлылар арасында хайваннар һәм кеше тәнендә яшәүче паразитлар барлыгы да билгеле.* Биология

**ИКЕАТНАЛЫК** *с.* **1.** 1) Ике атнага бер чыга торган (вакытлы матбугат турында)

2) Ике атнага сузылган. *Икеатналык ял. Икеатналык сәяхәт. Икеатналык юллама*

**2.** *и. мәгъ.* Нинди дә булса иҗтимагый-сәяси, хуҗалык кампаниясенә багышланылган ике атна вакыт

**ИКЕАТОМЛЫ** *с. хим.* Ике атомнан торган, ике атомнан хасил булган. *Аннары атомнар икешәрләп кушылалар, һәм ике су молекуласыннан бер икеатомлы кислород молекуласы һәм икеатомлы водород молекуласы хасил була.* Химия

**ИКЕБА́НА** *и. яп.* 1) Тере һәм киптерелгән үсемлекләрдән букет ясау сәнгате. *Хәзер Сахалинда икебананың чәчәк аткан чагы, бездән японнар да көнләшә башлар әле.* Р.Мирхәйдәров

2) Шушы сәнгать кагыйдәләре буенча эшләнгән букет. *Әкрәм абзый, кыюланып китеп, букетың нишләп шулай сәер күренә, дип сорарга җөрьәт итте. – «Икебана» диләр аны, – диде Наталья Сергеевна.* Р.Мирхәйдәров. *Аның [мәктәптә уздырыла торган хезмәт дәресләренең] беренчесендә – кызларны бала карарга, --- алтынчысында икебана ясарга өйрәтәләр, җырларга, биергә, төрле музыка инструментларында уйнарга,--- өйрәтә торганнары да бар.* Сөембикә

**ИКЕ́ БАСУЛЫ** *с. а. х.* Чәчүлек җиренең уңдырышлылыгын кайтару өчен, бер өлешен чәчеп, икенче өлешен парга калдырып чиратлаштырудан гыйбарәт чәчү әйләнеше. *[Казан ханлыгы чорында] Ике яки өч басулы чәчү әйләнеше булган пар системасы өстенлек иткән.* Б.Хәмидуллин

**ИКЕ́ БАШЛЫ МУСКУЛ** *и. анат.* Кулбашындагы кулны терсәктән бөгә яки күтәрә торган ике башлы мускул; бицепс

**ИКЕБУЫН** *и. мат.* Ике бербуын суммасы яки аермасыннан торган алгебраик аңлатма; бином (мәс., $a – b$)

**ИКЕ́ ВЛАСТЬЛЫЛЫК** *и.* Илдә, шәһәрдә, оешмада һ.б.ш.ларда бер-береннән нык аермалы ике властьның бер үк вакытта, берьюлы яшәве. *Шәһәрдә ике властьлылык башланды. Арзамас халкы кайсы гаскәр башлыгының күңелен табарга, ярарга белмәделәр.*

В.Имамов. --- *илдә Вакытлы хөкүмәт белән эшче һәм солдат депутатлары Советы йөзендә ике властьлылык урнашты.* ССКП тарихы

**ИКЕЕЛЛЫК** *с.* 1) Ике ел вакыт эчендә бара торган, ике ел буена дәвам итә, эшләнә торган. *Безнең филармониядә быел бию ансамбленә биючеләр әзерләү өчен икееллык студия ачыла.* Н.Мусин. *Хәлне авыл хуҗалыгында эшләүче җитәкче татарларның төп массасын берьеллык, икееллык мәктәпләрдә, төрле курсларда укыту азмы-күпме җиңеләйтә төшә.* Татарстан тарихы. *Организмга тәэсир итә торган башка ритмнар да бар. Хатын-кызларда бу – организм эшчәнлеге күтәрелешенең һәм сүлпәнләнүенең икееллык циклы.* Тигез гомер итегез!

2) Үсеше ике вегетацион чорга сузыла торган. *Икееллык үсемлекләр беренче елда тамырларында яки сабакларында туклыклы матдәләр туплыйлар ---.* Ботаника. *Икееллык кыргый үсемлекләр әллә ни күп түгел. Болында икееллык ак әнис, буынлы үлән үсә.* Биология. *Даруга керәннең бер яки икееллык тамырларын файдаланалар.* Сәламәт булыйк!

**ИКЕЕЛЛЫКЛАР** *и. күпл. бот.* Үсеше ике вегетация чорына сузыла һәм чәчкәннең, утыртканның икенче елында орлык бирә торган, шул исемдәге класс барлыкка китергән үсемлекләр. *Ике вегетация чорын яши торган үсемлекләр «икееллыклар» дип атала. Безгә таныш яшелчә үсемлекләре: кәбестә, кишер, чөгендер – икееллыклар.* Биология

**ИКЕ́ ҖЕНЕСЛЕ** *с.* 1) *анат.* Бер үк организмда ата һәм ана органнары булган; гермофродит (кеше турында). *Бик сирәк кенә ике җенесле җан иясе – гермофродит туа икән, ул яшәүгә, тормышка сәләтле булмый.* Ф.Хатипов

2) *зоол.* Бер үк организмда ата һәм ана җенес бизләре булган (хайваннар турында). *Күп кенә башка яссы суалчаннар кебек, тасма суалчан да ике җенесле.* Биология

3) *бот.* Бер үк вакытта серкәчләре һәм җимешлекләре дә булган (чәчәкләр турында). *Бер үк вакытта серкәчләре дә, җимешлекләре дә булган чәчәкләр күбрәк очрый. Андый чәчәкләрне «ике җенесле» дип йөртәләр.* Ботаника

**ИКЕЙӨЗЛЕ** *с.* **1.** Тыштан яхшы булып күренеп, чынлыкта начарлык эшләүче, бер кеше алдында бер төрле, икенче кеше алдында икенче төрле сөйләүче; эчкерле, усал, мәкерле. *Карт мулла тыштан ягымлы, тәмле телле, ләкин эчтән мәкерле, икейөзле бер кеше иде.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* Эчкерле, хәйләкәр, усал кеше, тышкы яктан яхшы булып күренеп, асылда начарлык эшләүче, ике төрле сөйләүче кеше. *Көнчедән саклан, икейөзледән сак бул.* Г.Хөсәенов. *Икейөзленең бер бите яна, бер бите туңа. Аның теле майдай, күзе тоздай, күңеле боздай.* Сөембикә

◊ **Икейөзле Янус** *кит.* Борынгы Рим Алласы исеменнән барлыкка килгән, бер як йөзе яшь, икенче ягы карт итеп сурәтләнгән икейөзлелек символы. *Юк, Миләүшә, син мине аңламадың. Мин аның безгә карашы, мөгамәләсе турында әйтмим. Ә үзе турында. Ул икейөзле Янус кебек.* Р.Кәрами. *Алты ел эчендә Гапонин үткән юл – баглангаН ышанычка хыянәт иткән хаин юлы. Йөкләнгән хезмәтеннән тайпылып, аны астыртын гына хәйлә, яман ният белән үзенең мин-минлек мәнфәгатьләренә буйсындырып, җиңел кәсепкә әйләндермәкче булган икейөзле Янус юлы.* М.Насыйбуллин

**ИКЕЙӨЗЛЕЛӘНҮ** *ф.* Икейөзлелек күрсәтү, сөйләгән сүзләренең нәкъ киресен эшләү. *Савыгуга Гыйльфан үзе дә ышанырга тиеш, икейөзләләнүне авыру шундук сизә.* С.Сөләйманова. *Кешенең икейөзләләнүе нидән килә? Куркаклыктанмы, әллә хөсетлектәнме?* Г.Хөсәенов. *Бүген ул [Настёна] монда шунысын аңлады: аңа боларның берсен дә эшләргә ярамый... Ул нәрсә генә эшләсә дә, икейөзләләнү, ялган булып чыгар кебек иде.* В.Распутин

**Икейөзләләнә бару** Торган саен күбрәк икейөзләләнү

**Икейөзләләнә башлау** Характерда икейөзлелек барлыкка килү

**Икейөзләләнә төшү** Тагын да ныграк икейөзләләнү

**Икейөзләләнеп алу** Кыска гына вакыт дәвамында икейөзләләнү

**Икейөзләләнеп китү** Кинәт кенә икейөзләләнә башлау

**Икейөзләләнеп кую** Кыска гына вакыт эчендә икейөзләләнү

**Икейөзләләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта икейөзләләнү. – *Сырга бикә түгел микән? – диде Кәринә бикә. – Ник алай уйлыйсың?– диде Исәнтәй. – Мин аны яратмыйм. Шуңа, – диде бикә, икейөзләләнеп тормыйча.* Н.Фәттах

**ИКЕЙӨЗЛЕЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Монафикъларча, хәйләкәрләрчә. *Икейөзлеләрчә кылану*

**ИКЕЙӨЗЛЕЛЕК** *и.* Икейөзле булу, икейөзле кешегә хас билге, сыйфат; монафикълык, мәкерлелек. *Шул чордагы әдәбият, «иске тормыш күренеше», «капитализм калдыгы» дип раслап килгән гарип күренешләрнең (икейөзлелек, әхлаксызлык, имансызлык, эчкечелек ---) байтагын совет чынбарлыгы үзе тудырды, дип барды.* А.Гыйләҗев. --- *Фәниярның мондый ук икейөзлелек белән очрашканы юк иде, җаны әрнеде.* Ф.Яруллин. *Бу бөек затлар үзләренә табынучы һәвәскәрләре алдында эч серләрен бер дә яшереп тормаганнар, истәлекләрдә һәм әсәрләрендә хакыйкатьне икейөзлелектән, монафикълыктан өстенрәк күргәннәр.* Юлдаш

**ИКЕКАБЫРЧЫКЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Башлары булмаган, тәннәре ян яктан кысылган гәүдәдән һәм аяктан торган моллюсклар классы; *русчасы:* **двустворчатые**

**ИКЕКАНАТЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Бер пар канатлары булган бөҗәкләр отряды (чебен, черки, кигәвен һ.б.); *русчасы:* **двукрылые**. *Озынборыннар һәм чебеннәр ике канатлылар отрядына керә, аларның үзенчәлекле билгесе – алгы пар канатларының булуы.* Биология

**ИКЕ́ КАПКАЧЛЫ ҖИМЕШ** *и. бот.* Өлгереп җиткәндә каты кабыгы икегә аерылып китә торган җимеш

**ИКЕКАПКАЧЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Уң һәм сул капкачлардан торган кабырчык (бака кашыклары) эчендә яшәүче умырткасыз, йомшак тәнле, җәенке саңаклы моллюсклар классы; *русчасы:* **двустворчатые**. *Ике капкачлы*

*моллюсклар суда эленеп торган бик вак организмнарны һәм кисәкчекләрне эләктерәләр ---.* Биология

**ИКЕ́ КАРДӘШ КАНЫ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгына кергән һәм таҗларыннан май, буяу ясала торган үсемлек; ялган зәгъфран; *русчасы:* **сафлор красильный**

**ИКЕ́КЫРЛЫ ПОЧМАК** *и. мат.* Ике яссылык кисешүеннән хасил булган почмак

**ИКЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* Икеләнергә, шөбһәләнергә мәҗбүр итү, шөбһәләндерү. *Ләкин бер нәрсә икеләндерә иде: хатның асыл мәгънәсе нидә, чынлап та, Ватан өчен ихлас гамь, борчылумы анда, әллә кемдер дәүләт кулы белән көндәшләрен юк итәргә алынганмы*? Р.Мирхәйдәров. *Барлык ишеткән-белгәннәре нигәдер аны икеләндерә иде.* М.Насыйбуллин. *Ә замананың шул яман чире үзеңә килеп төртелсә сагайта, икеләндерә, тәмам хафаландыра икән, зәхмәт төшкере!* Ф.Дәүләтбаев

**Икеләндереп җибәрү** Кинәттән, көтмәгәндә генә икеләндерә башлау

**Икеләндереп куйю** Кинәт икеләндерү. *Әнисенең авыр хәлдә булуы гына Зөлфияне бераз икеләндереп куя иде.* Безнең гәҗит

**ИКЕЛӘ́НМӘСТӘН** *рәв.* Ике дә уйламыйча, шикләнмичә. *Шул өч кешенең берсе итеп, капитан, һич тә икеләнмәстән, сержант Гафиятуллинны билгеләде.* Г.Әпсәләмов

**ИКЕЛӘ́НМИ** *рәв. к.* **икеләнмәстән**. *Бер икеләнми күчеп китәр иде дә бит... Гомерлек сердәшең, «тормыш» дигән сикәлтәле озын юлда иң ышанычлы юлдашың булырга тиешле кеше гел сиңа аркылы килсен, имеш.* Ж.Рәхимов. *Дипломы «кызыл» булгач, ректоратта: «Кая теләсәң, шунда җибәрәбез», – диделәр. «Әлбәттә, Башкортстанга», – диде ул [Әхмәр], икеләнми.* И.Абдуллин. *Мәгъфиянең һич икеләнми үз-үзенә кул салуын, туар баласын харап итүен акыл берничек тә кабул итә алмый.* Сәламәт булыйк!

**ИКЕЛӘ́НМИЧӘ** *рәв.* Шикләнмичә, шөбһәләнмичә, хаклыгына ышанып. *Икеләнмичә әйтәбез, яман шеш вакытында сытылыр иде.* М.Насыйбуллин. *Кәримә, үзенең хаклы булуына һич икеләнмичә, башлаган сүзне ахырынача илтеп җиткерергә, капчыкны төбенәчә селкеп салырга карар кылды.* К.Тимбикова. *Элек ул шушы ук сүзләрне кистереп, һич тә икеләнмичә, кисәткән кебек әйткән иде.* М.Галиев

**ИКЕЛӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Икегә әйләнү, икегә аерылу, икегә бүленү

2) Ачык бер фикергә килә алмыйча тору, төрлечә уйлау, шикләнү. *Ни эшләсә – көлсә, ачуланса да, хисләрен сөйләсә яисә еласа да – ышандыра, икеләнергә урын калдырмый торган иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Рәхмәтуллинның урманны башкаларга караганда да яхшы белүенә ул [Павлов] һич икеләнми иде.* Г.Галиев. *Әмма Алмаз үзе икеләнә иде әле.* Шәһри Казан

**2.** *и. мәгъ.* Анык, ачык бер карарга килә алмыйча тору халәте. *Мин сине әнә шундый курку, икеләнүләр белән көттем, Айгөл.* Ф.Яруллин. *– Аңлый башладым да кебек, – дип, ярарга тырышып, авызын ача төште Алмаз. Әмма икеләнү дә бар иде булса кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Квартирсыз интегүләр, акча җиткерә алмыйча җәфаланулар,: икеләнүләр, борчылулар моңарчы гел уртак булды.* А.Гыйләҗев

**Икеләнә башлау** Икеләнү билгеләре барлыкка килү, сизелү. *– Юк ул! – Хәят, шулай дип кычкырып, ингаляторына тотынды. Миңзаһит соңгы вакытларда икеләнә башлады: әллә бар микән?* Ф.Садриев

**Икеләнә калу** Кинәт кенә аптырап калу, икеләнә башлау. *Ректорның икеләнә калуын күргән кыз һөҗүмгә үк күчәргә әзер иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Бу сөйләшүгә чаклы ул [Гайзулла], алтынны Талибуллага илтеп дөрес эшләдем, дип йөри иде, ә менә хәзер, барыр юнәлешен югалткан мосафирдай, икеләнә калды.* М.Хәбибуллин. *Уннарча еллар үткәч, барып чыкты Варис ул якларга. Икеләнә калды: туган авылына керергәме, кермәскәме?* М.Хәсәнов

**Икеләнә төшү** Аз гына, бераз икеләнү. *– Өй ягына килгәндә, теләгең әйбәт тә, тик кулыңнан килерме? Рәт чыгара алырбызмы? – диде ана, икеләнә төшеп.* Ә.Моталлапов

**Икеләнеп калу** Кинәт икеләнеп тукталып калу; нindидер бер фикергә килә алмыйча тору. *– Ояты да юк кешенең, шундый вакытта да калхузга ярдәм итмәгәч... Киттекме? – Сәгыйть икеләнеп калды.* Н.Фәттах. *Капитан бераз икеләнеп калды. Казанда алар бер-берсенә бөтенләй чит кешеләр булсалар, монда, ят җирдә, --- якташлар иде.* М.Маликова

**Икеләнеп куйю** Кыска вакыт эчендә икеләнү тою, кинәт икеләнү. *Аның каршысында --- күрше авыл егете басып тора. Олыгаеп китсә дә, гәүдәгә юка --- иде. Әллә ул түгелме, дип, Бибиса икеләнеп куйды.* С.Сөләйманова

**Икеләнеп тору** Икеләнү халәтендә булу; анык бер карарга килә алмыйча тоткарланып тору. *Яшь ана, нәрсәдер төшенгәндәй булса да, икеләнеп торды.* М.Хәсәнов. *Хатынның фикерен Гайфулла да хуплады. Икеләнеп торсаң, Зөһрә авырткан сөяленә бик тиз китереп басар.* Ф.Яруллин. *Аны [Сәгыйтьне], икеләнеп торуына да карамастан, урыныннан тартып торгыздылар да --- үзләре белән ияртеп киттеләр.* Н.Фәттах

**ИКЕЛӘНҮЛЕ** *с.* Нәрсә эшләргә, нинди дә булса бирәр проблеманы, мәсьәләне ничек хәл итәргә белмәгән, аптыраулы. *Уразов буш чынаякларны бер кырыйгарак этәреп куйды, баядан бирле калкавыч сыман бер батып, бер калкып торган икеләнүле уйларына чик куярга кирәк иде.* М.Галиев. *Ихтыяр, күңеленә оялый башлаган икеләнүле хисләрдән котылырга теләп, савыт-саба җыештырырга тотынды.* Р.Вәлиев. *Икеләнүле, тирән эчке каршылыклы геройлары белән мондый пьесалар табигый рәвештә драматик төсмерләр алалар.* Татар әдәбияты тарихы

**ИКЕЛӘНҮ-МИКЕЛӘНҮ** *ф.* Ачык бер карарга килә алмыйча тору, төрлечә уйлау

**Икеләнеп-микеләнеп тору** Икеләнү-микеләнү халәтендә булу; анык бер карарга килә алмау. *Башкалар икеләнеп-микеләнеп торган арада яки каршы әйтер сүз эзләп маташканда, дустың тора да ярып сала: «Дөрес! –*

*ди, – Иптәш Фәлән Фәләнев искиткеч ачыш ясаган!» --- ди.* К.Тимбикова

**ИКЕЛӘНҮСЕЗ** *рәв. к.* **икеләнмәстән**. --- *алар [Идрисләр], үзләре шикелле үк сакал-мыек баскан, ябыккан соры шинельле кешеләр белән бергәләп, берниндиикеләнүсез, берниндишикләнүсез --- большевиклар ягына чыктылар.* Н.Фәттах

**ИКЕЛӘНҮЧӘН** *с.* Аумакай, принципсыз, ачык фикергә килә алмый торган. *Бәндә – икеләнүчән, шикләнүчән һәм шомланучан җан.* Г.Хөсәенов

**ИКЕЛӘНҮЧӘНЛЕК** *и.* Икеләнүчән булу, аумакайлык. *Андый хәлләр кайбер кешеләрдә нәфрәт уяталар, бәгырьләрен туңдыралар, ә икенчеләрен куркуга төшерәләр, тормышка һәм, гомумән, кешеләргә саграк карарга өйрәтәләр. Икеләнүчәнлек тойгылары хасил итәләр.* Р.Кәрами

**ИКЕЛӘТӘ** *рәв.* Ике кат, ике өлеш, ике мәртәбә (тапкыр). *Улының Илсөясез яши алмавын, көннән-көн сула баруын күреп, борчылуы икеләтә артты.* Ф.Яруллин. *Инде икеләтә «тугрылыклы» булып уйнарга кереште Мәхмүт.* Р.Мөхәммәдиев. *Э.Эрленмейер углерод атомнары арасында икеләтә бәйләнеш барлыгын раслый.* Фән һәм тел

◊ **Икеләтә шах** Берьюлы ике һөҗүм астында калу, ризасызлыкларга, кыенлыкларга тап булу

**ИКЕЛӘТӘ-ӨЧЛӘТӘ** *рәв.* Ике-өч өлеш, ике-өч тапкыр (мәртәбә). *Ә яңгыр коя, университет түбәсеннән әле дә икеләтә-өчләтә артык коя.* М.Мәһдиев. *Бүтән вакытта дүрт-биш минут чамасы йөри торган араны ул хәзер икеләтә-өчләтә озаграк кайтты.* Н.Фәттах. *Фаҗиган үзең өчен генә түгел, иң якын кешеләрең өчен дә, күзгә кергән чүптәй, һәрвакыт борчып торгач, икеләтә-өчләтә газаплы.* Ф.Яруллин

**ИКЕЛӘТҮ** *ф.* Ике итү, пар итү. *– Син энекәшне күр-рмәдең, ул үлек, – диде Сыңар күз, «р» хәрефен икеләтеп. – Бер-рәр-рсенә сүләсәң – үтер-рәм!* Н.Гыйматдинова

**Икеләтә башлау** Икеләтергә тотыну

**Икеләтеп бетерү** Тулысынча, барысын да икеләтү

**Икеләтеп чыгу** Берәр нәрсәне яки арифметик гамәлне башыннан ахырына кадәр икеләтү

**ИКЕЛӘЧ** *с. диал.* Бер анадан бер үк вакытта туган. *Икеләч бала табу*

**ИКЕЛЕ** *с.* **1.** 1) Ике компоненттан торган. *Кершенштейнер, чынында исә, халык мәгарифенең икеле системасы ягында булган.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) *хим.* Ике өлеш, икеләтә. *Этилен молекуласында икеле бәйләнеш хасил булды; углерод дүрт валентлы булып калды.* Химия

3) Ике төрле аңлау мөмкинлеге булган. *Ул картның соравына икеле җавап кайтарды: – Күңелебез пакь, ниятебез ак, ясаган иясе безгә ярдәм кылса кирәк... Мәгәр бәндәнең үз тырышлыгы да кирәк имәсме?* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Шикле, шөбһәле, ачык билгеле түгел. *Мулланың сүзләре икеле генә түгел, бөтенләй шөбһәле күренде.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Укучыларның өлгерешен бәяләү өчен кертелгән биш баллы системада «начар» билгесе. *Начар укырга, «икеле» алырга ярамый.* Ф.Яруллин. *Искәндәр, дәресен әзерләп килмичә «икеле» алган малай кебек, башын аска иеп чыгып китте.* Р.Вәлиев. *– Аларның икесенә дә «икеле» билгесе куям мин! – диде ул, зәһәрләнеп ---.* Р.Фәизов

2) Ике цифрын, күләмен, билгесен белдергән сан атамасы. *Сәгать теле икеле өстеннән узган булса да, кем дә күренми әле.* К.Нәҗми. *Күкеле сәгать теле икеле санына үрмәли иде.* Н.Гыйматдинова

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Ике төрле, берберсенә туры килмәгән, охшамаган; капма-каршы булган. *Фома тибы икеле күрсәтелгән: бер яктан, ул купец дөньясыннан эшкә яраксызланып ташланган төзәлмәс эчкече булса, икенче яктан, сүзләре, фәлсәфә сатулары белән, ул әдипнең беренче әдәби дәверендәге бераз идеаллаштырган босякларын хәтерләтә.* Г.Нигъмәти

2) Анык билгеле булмаган, шикле, ышанычсыз. *Икеле булыр, ди шул, җанкисәгем, врачлар, сул кулының бармаклары язылыр, дип кистереп әйтә алмыйлар, ди.* Г.Бәширов. *Урта полосада көзге ревизияне сентябрь-октябрьдә уздырырга киңәш итәләр. Әмма бу вакытта җылы, коры көн булуы икеле.* Файдалы киңәшләр. *Сигездәге электричкага өлгерүләр икеле!* Сөембикә

**ИКЕЛЕК** *с.* **1.** 1) Ике берәмлекне эченә алган, икегә йөри торган. *Икелек цифр*

2) Икегә (ике кешегә) җитәрлек. *Тиз арада Әхмәди каяндыр икелек тәмәке эләктереп килде.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Икеле цифры. *Берәмлекләр һәм нульләр белән күрсәтелә торган санның бары тик икелекләр һәм бишлекләргә генә таркалуын күрәбез.* Арифметика

2) *иск.* Ике тиенлек яки ике сумлык акча. *Биргәнне яхшылап саклыем дип, Янчыкка икелек салдым.* Я.Емельянов

**ИКЕЛЕКЛЕ** *с.* 1) *сир.* Ике төрле аңлашыла торган. *«Туктаусыз», «чалыш кына» һәм «басып» сүзләре [әсәрдә] --- үз урыннарына куелмаганнар һәм шуның аркасында буталчык, икелекле мәгънәдә чыкканнар.* Л.Җәләй

2) Икеләнүчән, тотрыксыз, принципсыз. *Икелекле яшьләр*

**ИКЕЛЕКЛЕЛЕК** *и. сир.* Икелекле булу; принципсызлык, аумакайлык. *Яңа сыйфатлар арасында иң әһәмиятлесе – икелеклелек. Геройның бу сыйфаты ике өлкәдә – фән өлкәсендә һәм интим тормышта, хатын-кызга мөнәсәбәттә ачыла.* Татар әдәбияты тарихы

**ИКЕЛЕ́К САНЫ** *и. лингв.* Борынгы рус, грек, гарәп һ.б. телләрдә ике предмет яки ике затны белдергән сан категориясе. *Рус телендә, мәсәлән, икелек саны булганда, күплек саны «икедән артык» мәгънәсен белдергән: один стол – два стола – три стола. Икелек саны югалгач, күплек саны «бердән күп» мәгънәсен белдерә башлый.* Ф.Сафиуллина

**ИКЕЛЕ-МИКЕЛЕ** *с.* **1.** 1) Ачык түгел, билгесез, хәл ителмәгән. *Ырсытдин шулай уйлап, икеле-микеле фикерләр белән саташып йөргәндә, беркөн иртәнге чәйдән соң, Йомабикә --- сыгылып сәкегә ятты да уфылдарга тотынды.* Я.Зәнкиев. *Иданың агитбригада турында шундый оятсыз рәвештә*

*ялганлавын ишетеп, ул [Сәгыйть], моңарчы үзендә беркайчан булмаган кыюлык белән, бөтен икеле-микеле уйларын бер читкә сыпырып ташлады да урынынан сикереп торды.* Н.Фәттах. *Иң гаҗәбе: Мөхәммәт Уразаевның үз күңеленә дә икеле-микеле уйлар килеп киткәли иде...* Сөембикә

2) Икеләнүчән, аумакай. *Мәгънәсез кеше лә ул Хәлил. Куркак бит ул, икелемикеле.* Ш.Камал

3) Күңел бер якка да утырып җитмәгән, ничек буласы билгеле түгел

**2.** *рәв. мәгъ.* Анык булмыйча, хәл ителмичә яисә хәл итмичә. *Болай икеле-микеле яшәп ятканда, ничек бала булдырасың!* М.Маликова. *Мәҗит сүзне кыска тотты: – Әти кайтканчы, мин – баш көтүче, син – баш көтүче ярдәмчесе. Әтинең әйткәнен үзең дә ишеттең. Икеле-микеле йөрисе түгел!* Н.Хәсәнов

**ИКЕЛЕ́-МИКЕЛЕ КИЛҮ** *ф.* Кисеп кенә ачык бер җавап бирмәү

**ИКЕНДЕ** *и.* 1) Һәрнәрсәнең төш вакытындагы күләгәсе ике өлеш озайганнан башлап, кояш тәмам батып беткәнче булган ара; төш вакыты белән кояш баеган араның нәкъ уртасы. *Икендедә ил ташлама* («кичкә каршы сәфәргә чыкма» мәгънәсендә). Мәкаль. *Тик Сәлимәм мине юату җаен тиз тапты: – Рөстәм, ни булды? Эш өчен хафага төштеңме? Дәү әтием әйтә торган иде: «Өйләдән икендегә кадәр кылган фигыльнең бәрәкәте булмый, зәхмәте генә бар!» – дип.* Ф.Яхин. *Көннең иң ямансу чагы – икенде белән ахшам арасы, ди торган иде Динәнең әбисе.* М.Маликова

2) *дини* Биш вакыт намазның өченчесе – шул вакытта үтәлә торган намаз. *– Намаз да укыйсыңмы? – дип сорады ул [Мотаһир], куркып кына. – Укыйм. Иртәнге, икенде һәм ахшам намазларын.* А.Хәлим. *Пәрдәләр арасыннан хуҗабикәнең ак өендә икенде намазын укуын күргәч, Хәйруллин янә борчылып алды.* Г.Бәширов. *Иртәнге намаз бер генә, ә кичкеләр өчәү: икенде, ахшам, ясту.* М.Маликова

◊ **Икендедән ятып йоклау** Кояш баеганчы, бик иртә яту (ялкаулыкка киная). **Икенде күләгәсе** *гади с. мыск.* Буйга бик озын кеше. *Алга икенде күләгәсе хәтле бер адәм килеп басты. Аның аркасы аша мин --- экранны күрә алмый башладым.* Н.Исәнбәт. *Өченчесе – икенде күләгәседәй шыксыз озын гәүдәлесе – сүзгә кушылып, нәрсәдер әйтергә авыз ачкан иде, аяклары таеп китте ---.* Ф.Баттал

**ИКЕНДЕ-АХШАМ** *и. фар.* 1) Икенде белән ахшам арасы (кояш баер алды һәм баю арасындагы эңгер-меңгер чак). *Икенде-ахшам вакыты булганга, анда хәзер әһле иман гыйбадәт кылалар.* Г.Ибраһимов. *Бишенче ноябрьдә кич берлән, икенде-ахшам арасында, сәгать дүртләрдә Яуширмәгә илеп кердем.* Г.Исхакый. *Икенде-ахшам вакыты үткәч юлга чыктык.* Х.Кәрим

2) *дини* Икенде (өченче) һәм ахшам (дүртенче) намазлары. *Кая, тәһарәт алып, икенде-ахшам укырга кирәк.* Ш.Камал

**ИКЕНИГЕЗЛЕ** *с. хим.* Үзеннән кала тагын ике химик элемент атомнары белән кушыла алырга сәләтле. *А.Кекуле «нигезлек» (валентлык) турындагы фундаменталь карашларны киңәйтә, валентлыкны атом ия булырдай тулы сан итеп күз алдына китерергә тәкъдим итә, күкерт һәм кислородны «икенигезле» (икевалентлы) дип күрсәтә.* Фән һәм тел

**ИКЕ́ НОКТА** *и. лингв.* Аслы-өсле ике ноктадан гыйбарәт тыныш билгесе (:). *[К.Насыйри] 90 нчы еллардан соң басылган әсәрләрендә --- сызык (–) һәм ике нокта (:) кулланугa күчә.* Л.Җәләй

**ИКЕНЧЕ** *сан* **1.** Бер-бер артлы санаганда, урыны бердән соң, өч алдыннан булуны белдергән тәртип саны. *Ә ишегалды түрендә дүрт этажлы аерым бер йортның икенче этажында Муса яши.* М.Максуд. *Икенче клиника Казан каласының --- ике катлы борынгы бинасында урнашкан иде.* Г.Галиева

**2.** *с. мәгъ.* 1) Вакыт турында – алдагы, киләсе, булачак, моннан соңгы. *Икенче көн тоташ кар ява.* Җыр. *Икенче көнне клиникага эшкә килү белән, ул алтынчы палата врачы Фидая Галимовнадан Динә хакында сорады.* М.Маликова. *Икенче көннедерме, Тукай клубында иптәшләрчә кичке мәҗлес үткәрелде.* М.Максуд

2) *Бер – икенче, берсе – икенчесе, берәүләр – икенчеләр* кебек тезмәләрдә санап киткәндә, каршы куйганда кулланыла. *[Ибрай] Әле бер әйберен күрсәтә, әле икенчесен күрсәтә, бакчасының тәртиплелеген, яшелчәләренең шәплеген мактап бетергәнебезне дә көтми, яңа әйберләргә күчә.* М.Әмир. *Бу дөм сукыр адәмдә гади кешеләрдә булмыйча, аларны хәйран калдыра торган ике гаҗәеп сәләт бар иде: берсе – аның сизгерлеге, икенчесе – хәтере.* М.Маликова. *Авторларның кайберләре исә, дошман белән батырларча көрәшеп, яу кырында ятып калган. Икенчеләре, сугыштан кайтып, дөнья куйдылар, исәннәре дә шактый өлкәнәйде.* Казан утлары

3) Кемнең яки нәрсәнең дә булса беренчесен, чынын алмаштырган. *Әйе шул, Салиха апаның икенче ире, Бикташның үги әтисе Әгъзам дигән кеше бар иде бит әле дөньяда.* М.Маликова. *Җитмеш тугыз яшенә кадәр яшәп тә, үзенә «әни» дип эндәшкәнне бер генә тапкыр да ишетмәгән, ләкин безнең өчен икенче әниебез булган кеше турында язасым килә сезгә.* Сөембикә

4) Кемгә дә булса бик охшаш булуны белдерә; нәкъ, тулысынча. *Техника шигырьне, әдәбиятны, йомшак күңелле кешеләрне кысрыклап чыгара. Беләсезме, ни өчен Пушкиннар, Тукайлар юк? Икенче Пушкиннар, икенче Тукайлар --- менә шуның өчен.* Н.Фәттах

5) Кирәклеге, мөһимлеге ягыннан беренчесеннән ким яки әһәмиятсез, ярдәмче, өстәмә. *Хәзер инде ул [Фәлях] икенче секретарь белән санлашып тормый, турыдан-туры «беренче» тирәсендә генә бөтерелә.* Р.Мөхәммәдиев. *Моннан ун еллар элек, әле Брежнев заманында, --- дәрәҗәсе буенча илдә икенче кеше, СССР Министрлар Советы рәисе Алексей Николаевич Косыгин вафат булды.* Р.Мирхәйдәрев

6) *муз.* Ярдәмче партияне башкаручы. *Икенче тавыш. Икенче скрипка*

7) Сыйфаты ягыннан беренчесеннән түбән булган. *Әхмәтсафа агам илә Хәсәнша шул пароходта икенче класска*

*утырып киттеләр.* Ш.Мөхәммәдев. *Әгәр орлык көздән үк чәчү стандартына җиткерелмәгән икән, язгы җылы көннәр башлану белән, аны сортларга аерырга һәм сыйфатын беренче, икенче класс таләпләренә җиткерергә кирәк.* Юлдаш

8) Башка, үзгә, бүтән. – *Синең белән берәр хәл булса, хатының ташламас иде бит?..– Валя беркатлы бала-чагадан мәзәк сүз ишеткәндәй елмайды: – Без – икенче мәсьәлә...* М.Маликова. --- *Җәмилә Закировнаның башына һич кителмәгән бер уй килде: икенче кафедрага күчкәннән бирле, доцент Дәүләтшинның бер генә мәртәбә дә, ярдәм сорап, профессор Ильясовага мөрәҗәгать иткәне булмаган икән.* М.Маликова

9) Әүвәлгегә охшамаган, бүтән төрле, башка. *Бәлки, аның [Зәйниянең] атасы да Кызыл Армия сафларыннан бөтенләй икенче кеше булып, яхшырып кайткандыр?* Г.Бәширов. *Таштугайдан кайтканнан бирле күзгә-башка күренгәне юк, өеннән чыкмый. Алыштырган кебек, икенче кешегә әйләнде куйды.* Н.Фәттах. *Бүгенге очрашулардан, сөйләшүләрдән соң, аны [Ниазны] күргәч, Зөлфә бөтенләй икенче дөнья кешесе белән очрашкандай булды.* М.Маликова

10) Теге, каршы, аргы. *Юан, төз бүрәнәләрдән салынган бу өйнең бер ягында – хатын-кызлар, икенче ягында ир-ат куна торган иде.* М.Маликова. *Бу зур завод ерак, каланың бөтенләй икенче читендә иде.* Ф.Яхин

11) *хәрби* Дошман белән турыдан-туры сугыш алып барган хәрби берләшмәләрнең, алгы сызыктан соң, азык-төлек, корал, кием-салым, резерв көчләр белән тәэмин итә торган, санитария һ.б.ш. бүлекләр урнашкан өлеше. *Әтисе исенә төшкән саен, Рифаның йөрәге әрнеп куя. Бер дә булмаса, аны алгы сызыктан әз генә арткарак – икенче эшелонга күчерергә иде.* Х.Камалов. *Гәрчә, аларның икенче эшелон белән фронтка килгәнлекләрен ишетеп белсәм дә, аны күрә алудан өметемне өзгән идем.* Г.Галиев. --- *беркөнне кичкә каршы рота командиры шалтыратты: – Икенче эшелонга, дивизия тылына, Уралдан делегация килгән.* Т.Таһиров

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Кабат, яңадан, тагын. *Лотфулла абый, җаныкаем, җибәр, валлай, билләй, таллай икенче урламам, җибәр, дим.* Ә.Айдар. *Кечкенәләргә килгәндә – эш җиңел, башын ике аяк арасына кыстыра да: – Икенче усал булма! Икенче итмә! Тавышыңны чыгарма... – дип бирепме бирә.* К.Нәҗми. *Заһидә апаң белән икенче тавышланасы булма!* Н.Фәттах

2) *Икенче бер, икенче кат (мәртәбә, тапкыр), икенче төрле (төстә)* тезмәләре белән килеп: «башка», «бүтән», «башка вакытта», «кайчан да булса бер», «кабат», «тагы», «башкача» мәгънәләрен белдерә. *Киресенчә, икенче кат эшләмәслек итеп үзәкләренә үткәреп сугарга иде, ләкин, күрәсең, гырылдап йокыга киттеләр.* Т.Гыйззәт. *Әгәр без шул эшне булдыра алсак, ул вакытта алар безнең мал төягән көймәләребезне талап тора алмаслар, алар икенче мәртәбә безнең атавыбыз өстенә килә алмаслар, алар да, безнең шикелле, үзләре эшләп көн итә башларга өйрәнерләр.* Ф.Әмирхан. *Бүген ул [бикә] әнә бөтенләй икенче төрле сүзләр сөйли.* Н.Фәттах

**4.** *кер. сүз функ. к.* **икенчедән**. *Бердән, көннең эсселеге, икенче, һич йокысыз юл зәхмәте хан кызы илә шаһзадәне тәмам хәлдән тайдырган, арыткан иде.* Ш.Мөхәммәдев. – *Сезгә бик зур үтенечем бар, – диде [тикшерүче]. – Бер генә түгел, ике. Сезнең ял йортында күмәкләшеп төшкән фоторәсемегез бардыр. Шуны миңа вакытлыча биреп торыгыз. Икенчесе – безнең белән очрашып сөйләшү турында берәүгә дә әйтмәгез, яме?* М.Маликова

**5.** *и. мәгъ.* 1) Беренчедән (кайнар сыек ашамлык – аш – борщ, щи һ.б.ш.дан) соң бирелә торган кайнар ашамлык; аштан соңгы ризык. *Икенчегә, күбрәк, шулпада пешкән, яссы кисәкләргә туралган, кайчагында кишер, суган турап, борыч сибеп, томалап пешергән ит бирәләр.* Р.Мөхәммәдова. *Икенчегә бәрән, бозау, дуңгыз итеннән кәбестәле ризыклар, котлетлар, люля-кебаб, бифштекс, --- фарш тутырылган помидорлар һәм ташкабаклар, йомырка тәбәсе куела.* Юлдаш

2) *сөйл. тар.* Совет чорында партия оешмаларында җитәкче (беренче секретарьнең) ярдәмчеләреннән берсе. *Хәзер инде ул [Фәлях], икенче секретарь белән санлашып тормый, турыдан-туры «беренче» тирәсендә генә бөтерелә. «Икенче»нең аның эше күп: иген иктерәсе бар, печән чаптырасы һәм сыер саудырасы.* Р.Мөхәммәдиев

3) **икенчеләр** *күпл.* Башкалар, бүтәннәр. *Берәүләрне тормыш гомергә бер тапкыр сыный ---. Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный.* Ф.Яруллин. *Берәүләре, йортны ремонтлагыз, юкса сайламыйбыз, дип куркыта. Икенчеләрнең лифты эшләми икән, өченчеләренә җылылык килми.* Р.Мөхәммәдиев. *Шушы минутларда берәүләр, өенә кайтып кереп, балаларын сөя, икенчеләр каядыр ашыга ---.* М.Маликова

◊ **Икенче әтәч** Төннең әтәч икенче тапкыр кычкырганнан соңгы вакыты. *Ләйлә ни дә булса әйтергә өлгермәде, тышта әтәч яңадан аваз салды. – Абау, икенче әтәч! – диде Ләйлә. – Ходаем, күргән шикелле дә булмадым! Нигә шул тиклеләр кыска икән бу төннәр?..* Г.Бәширов. *Әйе, икенче әтәчтән соң кызлар янына кертермен.* Т.Гыйззәт. --- *шул төнне Вафин, икенче әтәчләргә кадәр, йокыга китә алмыйча якякка әйләнгәләп ятты.* Ф.Хөсни. **Икенче икмәк** Бәрәңге. *Бәрәңгене озакка сузмадылар – бер атна-ун көн дигәндә, утыз студент --- колхозның утыз гектарга утыртылган икенче икмәген җыеп та бирде.* Х.Ширмән. **Икенче кулдан (белү, ишетү)** Нинди дә булса хәл-хәбәр турында кеше аркылы ишетеп белү турында. **Икенче күз белән** Бүтәнчә, элеккедән үзгә рәвештә. *Шул вакыйгадан соң әти «тар балаклар» язган китапларга икенче күз беләнрәк карый башлады.* Г.Гобәй. **Икенче сүз белән әйткәндә** Шул ук фикерне башкача, башка сүзләр белән белдергәндә. **Икенче төрле (итеп) әйткәндә** *к.* **икенче сүз белән әйткәндә**. *Боларның сүзләренә колак салмаска, икенче төрле әйткәндә, сер бирмәскә тырышып, үземнең урыныма барып, --- са-*

*бакларымны кулыма алып утырдым.* М.Гафури. **Икенче яшьлек** Кешенең 35–40 яшьләр тирәсендә яшьләрчә дәртләнеп, яшәргәндәй булып киткән чагы

**ИКЕНЧЕДӘН** *кер. сүз* Нәрсәне дә булса санап киткәндә, беренчедән соң килгән пунктны белдереп әйтелә. *Беренчедән, Фидаил – армия хезмәте үткән егет. --- Икенчедән, Фидаил сүзендә нык торучан иде.* М.Маликова. *– Куанырга кирәк, беренчедән, – диде [ректор]. --- Икенчедән, инструменталь ансамбльнең дә чыгышын өзеп булмый бит.* Р.Мөхәммәдиев

**ИКЕНЧЕЛ** *с.* Башлангыч булмаган, үсештә икенче баскычта торган яисә нәрсәнең дә булса нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән. *Җирдә һәр җан иясенең, һәр үсемлекнең икенчел варианты бар.* М.Галиев. *Уртадагы икенче эре күзәнәк «үзәк» яки «икенчел күзәнәк» дип йөртелә.* Ботаника. *«Акча» сүзе – борынгы һун-төрки чорларыннан сакланган атама. Ул VIII йөзгә караган Кытай тәңкәсендәге икенчел язуда очрый.* Сөембикә

**ИКЕНЧЕЛӘЙ** *рәв.* **1.** Икенче кат, тагын, кабат, кабаттан. – *Каян алсаң, шунда илтеп куй, – диде [әтисе]. – Икенчеләй кеше әйберенә кагылсаң, кулыңны шартлатып сындырырмын.* Р.Кәрами. *Мөнәвәрә качмады, ыжгырып килгән җиңгәсенең кулын эләктереп артка каерды, Гайфәрәнең бармаклары сынган төсле шытырдап куйды. – Икенчеләй үрелмә, җиңги.* Н.Гыйматдинова. «*Икенчеләй бакчага кермәм, кермәм, кермәм!» дип ант иттереп җибәрә торган иде.* М.Әмир

2) Башкача, бүтәнчә, үзгә. *Әгәр дә кеше каядыр барып кайтса, үз тирәлегеннән читтәрәк булган кешеләр белән аралашса, ул инде уйлана башлый. Янәсе, нигә ул болай да, бүтәннәр икенчеләй яши.* Р.Кәрами

**2.** *кер. сүз функ. сөйл. к.* **икенчедән**. *Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.* Г.Камал

**ИКЕНЧЕЛӘНҮ** *ф.* Үзгәрү, башкалану, икенче төскә, икенче рәвешкә керү. *Ания, синең белән Казанга барып кайткач, бөтенләй икенчеләнгән.* Г.Галиева. *Ана быел кадерле кызкаеның бөтенләй икенчеләнеп кайтуын күрде.* Н.Фәттах

**Икенчеләнә бару** Торган саен ныграк үзгәрү, икенчеләнү

**Икенчеләнә башлау** Икенчеләнү билгеләре күренү

**Икенчеләнә төшү** Беркадәр, бераз икенчеләнү

**Икенчеләнеп бару** *к.* **икенчеләнә бару**. *Заман икенчеләнеп бара шул хәзер.* М.Маликова

**Икенчеләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй икенчеләнү

**Икенчеләнеп калу** Билгеле бер вакыт арасында, төрле сәбәпләрдән соң, тәэсирләрдән соң үзгәрү, икенчеләнү. *Бүген Зөһрә --- бөтенләй икенчеләнеп калган. Тагын да нечкәргән, җыйнакланган.* Н.Фәттах

**Икенчеләнеп китү** Кинәт кенә үзгәрү, нindидер сәбәптән, вакыттан соң икенчеләнү. *Ул үзен бөтенләй яңарып, үзгәреп, икенчеләнеп киткән шикелле сизде.* Н.Фәттах. *Кыз бала тәмам икенчеләнеп китте. Хәзер инде аның йөзендә алсулык, иреннәрендә бәхетле елмаюы сүнми, чәчләрен гел тарап, матур киенеп йөри башлады*. Р.Фәизов

**ИКЕНЧЕЛӘП** *рәв. диал. к.* **икенчеләй** (*1 мәгъ.*). *Ул, бер караганда, бик биек вә зур, икенчеләп, бик кечкенә, чак кына күзгә чалынырлык була.* Ш.Камал

**ИКЕНЧЕЛИ** *рәв. сир. к.* **икенчеләй**. *Шундый итеп бирегез --- икенчели Мәкәрҗәгә якын да килә алмаслык булып китсеннәр.* Н.Исәнбәт

**ИКЕ́ ОКСИДЛЫ** *с. хим.* Кислородның ике атомы белән теге яки бу элемент атомының кушылмасы

**ИКЕӨЙЛЕЛӘР** *и. бот. күпл.* Серкәчләре бер чәчәктә, җимешлекләре икенче чәчәктә урнашкан үсемлекләр; *русчасы:* **двудомные**. *Киндер, тирәк, тал агачларының серкәчле һәм җимешлекле чәчәкләре икесе ике үсемлектә урнашкан, андый үсемлекләр «икеөйле» дип йөртелә.* Ботаника. *Киндер, тополь һәм тал агачларын «икеөйле» дип йөртәләр, аларда серкәчле чәчәкләр – бер үсемлектә, җимешәнле чәчәкләр икенчесендә урнашкан була.* Биология. *Серкәчле һәм җимшәнле чәчәкләре төрле үсемлекләрдә урнашкан шундый үсемлекләрне «икеөйле» дип атыйлар.* Фән һәм тел

**ИКЕӨЛЕШЛЕЛӘР** *и. бот. күпл.* Яралгылары ике өлештән торган чәчәкле үсемлекләрнең бер классы; *русчасы:* **двудольные**. *Чәчәкле үсемлекләрнең иң зур төркемнәре булып класслар санала. Андый класслар ике – бер өлешле үсемлекләр классы һәм икеөлешлеләр классы.* Ботаника. *Икеөлешлеләр классына барлык яфраклы агачлар һәм куакларны диярлек --- кертәләр.* Биология. *Безнең республикада чәчәкле үсемлекләр киң таралган, ---. Икеөлешлеләр классыннан – 1199 төр: алар 432 ыругка һәм 84 семьялыкка керә; берөлешлеләр классыннан – 368 төр: алар 119 ыругка һәм 24 семьялыкка керә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИКЕ-ӨЧ** *сан* 1) Ике яисә өч, берничә. *Ике-өч атнадан артык сузылмас, дип уйлыйм.* С.Сөләйманова. *Үзе алга кереп утырды хатын, артка ике-өч ирдә булып та рәт чыгара алмаган сеңлесен утыртты.* Р.Мөхәммәдиев

2) Аз гына. *Көнләшкәннәрдер инде, Әкълимә апа алардан нибары ике-өч яшькә өлкән булып, безгә педучилище тәмамлап кына килгән иде бит.* М.Маликова

◊ **Ике-өч авыз сүз** Берничә, аз гына сүз (әйтү яки язу). *Ул бары ике-өч авыз сүз генә әйтә алды: «Ташларга... мәҗбүр иттеләр... Югыйсә ташлар идемме соң?!»* М.Хәсәнов. **Ике-өч сүз (белән)** Берәр нәрсә хакында бик кыска гына итеп (сөйләп бирү яки язу). *Күзен хатынына текәп, ике-өч сүз әйтү җитә калды: – Кара аны, мөгез чыгарып маташасы булма!* М.Насыйбуллин. *[Ишьегет:] Республика халкы фронтка хат язган, шуңа балигъ булган бөтен кеше кул куя. [Гариф:] Ике-өч сүз белән эчтәлеген әйт.* М.Гыйләҗев. *Өстәлдә – хат кисәге. Һәм анда да нибарысы ике-өч сүз: «Хәнифә, гафу ит, мин китәм. Бераз дөнья гизеп кайтырга исәп...»* М.Хәбибуллин

**ИКЕ́ ПАРАЯКЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Пар аяклы, озынча гәүдәле бөҗәкләрдән торган күпаяклыларның бер классы; *русчасы:* **двупарноногие**

**ИКЕ́ САҢАКЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Моллюсклар классыннан баш һәм авызлары янында капшавычлары булган диңгез хайваннары (каракатица, спрут); *русчасы:* **двужаберные**

**ИКЕ́ СОСТАВЛЫ** *с. лингв.* Ике баш кисәге дә (ия һәм хәбәре) аерым сүзләр белән белдерелгән. *Җөмлә төзелсен өчен, я ике сүзнең (ия белән хәбәрнең) хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе, я бер генә сүзнең (баш кисәкнең) хәбәр итү интонациясе белән әйтелүе кирәк. Беренче очракта – ике составлы җөмлә, икенче очракта бер составлы җөмлә барлыкка килә.* М.Зәкиев

**ИКЕ́ СТОПАЛЫ** *с. әд.* Ике стопадан (буыннан) гыйбарәт. *Г.Тукайның «Кичке азан», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырьләре ике стопалы ямблар белән язылганнар.* Г.Нигъмәти

**ИКЕ́ ТАКТЛЫ** *с. тех.* Пешкәкнең ике йөреше бер тулы цикл ясый торган. *Бу аппарат ике тактлы (суыру һәм кысу тактлары) цикл белән эшли, ял такты бирелә юк.* Терлекче-механизатор белешмәсе

**ИКЕТЕЛЛЕ** *с. лингв.* 1) Бер тел сүзе икенче тел сүзе белән тәрҗемә итеп бирелгән. *Иң күп таралган икетелле сүзлекләрдән татарча-русча, русча-татарча сүзлекләрне күрсәтергә кирәк.* Ф.Сафиуллина. *Эрзә халкы белән мукшы икесе икетелле газета чыгара, радиолары ике телдә сөйли, алар бер-берсен аңламый, әмма «мордва» дигән бер халык.* Р.Батулла. *Монда математика, сызма геометрия, механика, физика, --- һәм башка фәннәрдән дә саллы-саллы икетелле һәм аңлатмалы сүзлекләр бар.* Фән һәм тел

2) Берьюлы ике телдән дә файдалана, шул телләрдә яза һәм сөйләшә ала торган. *XII йөз урталарына таба Донның түбән агымында, Азов буенда икетелле руслардан, дөресрәге, рускыпчак телле метислардан торган, «бродниклар» дип аталган байтак санда авыллар яшәп килә.* Т.Кәримов. *Бала икетелле мохиткә күпме иртәрәк чумса, ике телне дә шулкадәр тизрәк һәм уңышлы итеп үзләштерә.* Шәһри Казан

**ИКЕТЕЛЛЕК** *и. сир. к.* **икетеллелек**. *Гәзит-журналларның исемнәре --- – барысы да русчага тәрҗемәдә бирелер. Ягъни күрсәткечтә икетеллек тәэмин ителер.* Казан утлары

**ИКЕТЕЛЛЕЛЕК** *и.* 1) Берьюлы ике телне камил белү һәм ике телдә камил сөйләшү күренеше. *Яшь буын бала чактан ук икетеллелек мохитендә үсә...* Мирас

2) Аралашу шартларына карап, бер үк халыкның берьюлы ике телне куллануы; билингвизм. *Безнең республикада һәм татарлар яшәгән башка өлкәләрдә элек-электән татар-рус икетеллелеге хөкем сөрә, ягъни татар халкы, үз теле белән бергә, рус телен дә куллана.* Р.Йосыпов. *XX гасыр шартларында билингвизм – икетеллелек – --- милли телләрне саклау һәм үстерү һәм, бер үк вакытта, провинциаль бикләнгәнлектән һәм тончыктыргыч ялгызлыктан котылу чарасы булып тора.* Ч.Айтматов. *Хәзерге татар-рус икетеллелеге шартларында, туган тел сүзләрен дөрес куллану өчен, үзара мөнәсәбәттәге бу ике телнең лексик-семантик системасындагы үзенчәлекләрне белү бик әһәмиятле.* Фән һәм тел

**ИКЕ́ ТЕРЕКЛЕКЛЕ** *и. зоол. иск.* Суда да, коры җирдә дә яши торган тереклек иясе; җир-су хайваны. *Ике тереклеклеләр – коры җирдә һәм суда яшәүгә җайлашкан салкын канлы хайваннар.* Биология

**ИКЕТЕШ** *и. зоол.* Икетешлеләр семьялыгыннан, тәне энәләр белән капланган, тропик диңгезләрдә яши торган балык; керпе балык; *русчасы:* **двузубка**. *Куркыныч туганда, икетеш дигән балыклар да нәкъ шулай эшлиләр: бергә җыелып, чәнечкеле зур бер балыкка охшап калалар.* Кызыклы ихтиология

**ИКЕУРЫНЛЫ** *с.* 1) Ике урыны булган, ике урыннан торган. *Икеурынлы автомобиль*

2) *мат.* 10 нан башлап 100 гә хәтле булган. *13 – икеурынлы сан. Икеурынлы саннар суммасы*

**ИКЕШӘР** *сан* 1) Һәркемгә (һәрнәрсәгә) ике, бертигез күләмдә ике булуны белдергән бүлем саны. --- *икешәр катлы таш йортларның стеналары сабын белән югандай чиста күренә, урман ягына караган тәрәзәләр, ут капкандай, күзләрне чагылдырып янып тора.* М.Маликова. *Икешәр, дүртәр, алтышар үгез җигелгән авыр арбалар, озын койрык булып, көтүләр артыннан бардылар.* Н.Фәттах. *Башкалардан кимхур булмас өчен, бер класста икешәр ел утырса утырды, кичке мәктәпне тәмамлап чыкты иң элек.* Р.Мөхәммәдиев

2) Аерым басым һәм интонация белән әйткәндә «ике» мәгънәсен көчәйтә. *Һәр бүлек өчен бездән икешәр кеше җавап бирәчәк.* Р.Мөхәммәдиев

**ИКЕШӘР-ИКЕШӘР** *рәв. к.* **икешәрләп**. *Шәһәр бюджетыннан тагы берәр миллиард өстәмә акча да ала алса, кирәк-яракларын да табачак, икешәр-икешәр кешене дөньяның Казино үзәкләре булган Лас-Вегаста һәм Монте-Карлода укытып кайтарачак.* Р.Мөхәммәдиев. *Таудай биек өй ишегенең ике ягында да – эчтә дә, тышта да – икешәр-икешәр кораллы ирләр тора иде.* Н.Фәттах

**ИКЕШӘРЛӘНҮ** *ф.* Икешәр-икешәр булу, пар булу. *Менә еракта гына «бык-бык» иткән үрдәк тавышлары ишетелде. --- «Бык-бык» итү икешәрләнде, өчәрләнде.* Г.Исхакый

**ИКЕШӘРЛӘП** *рәв.* Парлап, икешәр-икешәр итеп, икәү-икәү булып. *– Икешәрләп, өчәрләп укмашкан сарыкларда инде ашау кайгысы беткән ---.* М.Галиев. *Урамда гайре табигый җанлылык: авыл кешеләре икешәрләп, өчәрләп капка төпләренә җыелып, нидер сөйләшеп торалар.* В.Нуруллин. *Директор Илдар Ханович коридорда чабып йөрүчеләрне кабинетына берьюлы икешәрләп, ике кулы белән колакларыннан тотып алып кертә торган иде ---.* Л.Гыймадиева

**ИКЕШӘРЛЕ** *с.* Һәрберсендә, һәркайсында икешәр булган, икедән торган. *Әнә Гыйльми дә өч бүлмәлегә күчкән, Санияләр дә, Федькалар да икешәрлене алдылар.* Г.Мөхәммәтшин

**ИКЕШӘР-ӨЧӘР** *сан* Якынча икешәр яки өчәр булуны белдергән чама саны; берничәшәр. *Хәзрәт, вакыты булганда, мәдрәсәгә икешәр-өчәр мәртәбә керәдер.* Ф.Кәрими. *Эчке*

*шәһәрдә – хан сарае, биек манаралы мәһабәт мәчетләр, икешәр-өчәр катлы ташпулатлар, манаралар белән узышып күккә үрелгән юан тирәк агачлары.* Ф.Латыйфи. *Надзирательләр һәр сафны икешәр-өчәр тапкыр санап чыктылар ---.* И.Салахов

**ИКЕЮЛЛЫК** *и. әд.* **1.** Ике юлдан торган шигырь тезмәсе. *Һәр икеюллык монда [бу шигырьдә] йөзәр ел буе халык күңелендә эшкәртелгән, халык сүзендә шомарган мәкаль булып яңгырый.* Татар әдәбияты тарихы. *Дәрдемәнд иҗатында өметкә урын калдырган шигырьләр дә аз түгел. «Илдә бер дуст булмаса гәр, Ил бөтен – дошман түгел!» дигән икеюллык – шуның бер үрнәге.* Әдәбият. *Әдип Алмыш хан чорындагы көмеш акчага сугылган икеюллыктан алып (930 ел) 1992 елга кадәрге вакыт аралыгындагы барлык шагыйрьләрне барлап, алар иҗатындагы иң яхшы үрнәкләрне татар укучысына тәкъдим итә.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Ике юлдан торган, ике юлдан гыйбарәт. *«Диван»да борынгы төрки поэзиядән 170 дүртьюллык һәм 54 икеюллык шигъри строфа теркәлгән.* Мирас

**ИКМӘК** *и.* **1.** 1) Ачытылган камырдан мичтә пешерелгән ризык; ипи. *Икмәк – гомер, тазалык, мәхәббәт чыганагы, бәхет китерә торган өстәлдәге кояш ул.* А.Гыйләҗев. *Кара авыл икмәге, тоз, яшел суган һәм бәрәңгедән дә тәмлерәк бер генә ризык та юктыр төсле тоелды.* Ф.Яхин. *Икмәк комбинатында дүрт йөз кырык кешенең һәр өченчесенә директорның приказы белән җәза бирелгән...* М.Насыйбуллин

2) Ашлык. *Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалык күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды.* М.Мәһдиев. *Кешеләр икмәк үстерергә өйрәнгәнче үк бер-берләрен дәваларга өйрәнгәннәр.* Ф.Яруллин. *Ниләр генә юк иде ул хатларда: авылда беренче булып «похоронный» алган семьяның ачы кайгысы да, комсомолларның кызыл обоз белән икмәк илтүләре дә, ---.* Л.Ихсанова

3) Кырда үсеп утырган иген. *Башакларын дулкынлатып җил йөгергән бодай басуы ызанына дүрт-биш адым кала – сусыл үләнлек. Димәк, монда көтүне берәү дә якын китермәгән. «Сарык» дигәнең икмәккә бер башын тыкса, аерып кара аннары...* М.Галиев. *Болгарларның җырләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән.* Г.Гобәйдуллин. *Алар --- кызыл бозауны, --- икмәккә кермәсен өчен, казыкка бәйләп калдыралар.* Н.Әхмәдиев

4) *диал.* Бал кортлары тарафыннан үсемлекләрдән кәрәзләргә күчерелгән серкәләр; бал кортлары азыгы; чыршын; *русчасы:* **перга**, **хлебина**. *Умарта кортлары бит – табигать яраткан иң тырыш һәм файдалы җан ияләре. Алар биргән продукция: бал, балавыз, прополис, корт серкәсе, бал икмәге --- йөз төрле чирне дәвалый.* И.Абдуллин. *[Кешеләр] Азыкка дигән балны шикәр белән алмаштыралар. Кортка фәкать бал белән чыршын, ягъни бал икмәге, перга кирәк.* Б.Камалов. *Кортлар бал гына түгел, бик кыйммәтле дару чималы – корт икмәге дә җитештерәләр бит.* Г.Тавлин

5) *күч.* Гомумән ашамлык, ризык, азык. *Кеше икмәге белән озак яшәмәссең; кеше акылы белән ерак бара алмассың.* Мәкаль. *Апам сезнең икмәгегезне ашап, сезнең кул астыгызда кабер күрде... Үзем дә менә --- бар гомеремне сезнең икмәгегез белән үткәрдем.* Г.Ибраһимов

6) *күч. сөйл.* Хезмәт хакы; яшәү, көн күрү чыганагы. *Мин күптәннән балачага түгел инде. Үз икмәгемне үзем эшләп ашый башлаган көннән бирле.* А.Гыйләҗев. *Ә балалар йортында, ихтимал, егеткә һөнәр биреп, киләчәк тормышында ышанычлы икмәге булсын дип тырышканнардыр: ул елларда тимерьюлчы иң отышлы һөнәр санала иде бит.* Р.Мирхәйдәров. – *Безнең үзебезнең филармониябез бар, әллә каян килгән әтрәк-әләмнәрдән тамашачыбызның зәвыгын боздыра алмыйбыз,* – *диделәр. – Сез инде безнең артистларыбыз икмәгенә сузылмагыз.* Ф.Яруллин

7) *күч.* Кәсеп, шөгыль, эш. – *Сезнең эш түгел бу, Аллаяр, тимә минем икмәккә. – Морг докторы операциянең файдасыз икәнлегенә ишарәли.* С.Сөләйманова. *«Адәм сөяге» дигән басудагы сөякләр Алкаб би туздырган дошман чирүенең калдыклары --- түгелме? Кем белә, кем белә! Моны тикшерү – галимнәр эше, алар икмәгенә тимик.* Мирас. – *Ә менә гайбәтнең турыдан-туры үзегезгә кагылуына карашыгыз ничек? – Сүз йөри инде ул... Кайчан көлеп кенә карыйм, ачуым да килә. Бер карасаң, кемнеңдер икмәге бит инде ул.* Юлдаш

8) *күч. сөйл.* Тормышның, хуҗалыкның бергәлеге яки аерымлыгы турында. *Каената белән бер икмәктә булу*

**2.** *ы. мәгъ. сөйл. к.* **икмәктер**. *Конкурста мин беренче урынны алам, Гөлүсә. Чын, икмәк!* Н.Гыймматдинова. *Әнисенең күзләренә туры карап, икмәк белән, аның үз исеме белән антлар бирә-бирә ялган сөйләде кыз.* Р.Мөхәммәдиев

◊ **Икмәгем орсын** *карг.* Яхшылыкка каршы яманлык эшләгән кешене каргап әйтелә. **Икмәк алды** *карг. к.* **икмәктер**. *Сиңа ялган, безгә чын, менә икмәк алды, моңарчы нәселебездә эчкече булмады, йортыбызга аракы заты кермәде.* Г.Бәширов. **Икмәк бүсере** *гади с.* Әрәмтамак, бушка ашап ятучы. **Икмәк йөзе** Пешкән икмәкнең өске ягы. **Икмәк йөзен (чыраен) күрмим** *карг.* Үзенең хаклыгына ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе. **Икмәк каргышы**; **икмәк орыр** *карг.* Ризыкны ташлап, таптап һ.б. исраф итүләр ярамавын кисәтү. **Икмәк киселү** Кайту юлы ябылу, яшәргә мөмкинлек булмау. *[Хәерниса түти:] Гөлсем кызым, алдың-артың нык уйла, ну чтубыты кайтып җыларлык булмасын. Куам да чыгарам. Монда икмәгең киселә.* Р.Кәрами. **Икмәк көясе** *к.* **икмәк бүсере**. **Икмәк кызавы** *диал. шелт.* Эшлексез, сәләтсез, уңмаган кеше. **Икмәк өсте** *карг. к.* **икмәктер**. *Сорокин озак уйланып торды да сорап куйды: «Сатмассыңмы безне?» Чырык сикереп торды: «Менә, икмәк өсте, сезнең хакта сыңар сүз ычкындырсам, Ходай орсын».* Я.Зәнкиев. – *Шуннан мин, агаемны үчекләп, җыр чыгардым. Кешегә сөйләмәс булсаң, сиңа да әйтәм. – Икмәк өсте, ант.* К.Мостай. **Икмәк өстендә әйтү** Ант итү. – *Билләһи менә, икмәк*

*өстендә әйтәм! Менә шул, ә-ә! – диде.* Г.Бәширов. **Икмәк салу** Мич ягып, ипи пешерү. **Икмәк суы** *эвф.* Аракы. *Икмәк суын эчкән өчен, Җанкай мине ташлады.* Җыр. **Икмәктән бизим** *карг. к.* **икмәктер**. *Икмәктән бизим, барысы да ышандылар шул озын телле адәмнең сүзенә.* Н.Мадьяров. **Икмәк тегермәне** *мыск.* 1) Авыз. *Инде икмәк тегермәненнән [түрәләр] кызыл су агызалар дип торабыз.* Х.Кәрим; 2) Икмәкне күп ашаучы. **Икмәк тотып ант итү** *к.* **икмәктер**. *Болай яшәп булмый ич, аңлыйсыңмы? Бер гаебем юк, икмәк тотып ант итәм.* Н.Әхмәдиев. **Икмәк тотып сөйләү** *к.* **икмәктер**. *Үзенең каениш тиешле кешесе минем үземә икмәк тотып сөйләде.* Ш.Камал. **Икмәк төсен күрмим** *карг. к.* **икмәктер**. *Сүзебезнең энә очы кадәресе генә ялган булса да, икмәк төсен күрмик, менә табын өстендә әйтәм.* А.Шамов. **Икмәк төю** Бертуктаусыз, күп итеп икмәк ашау. **Икмәк убыры** *гади с.* 1) *к.* **икмәк бүсере**. *Быелдан болай шул икмәк убырларыңны асрыйсы булма.* Т.Гыйззәт; 2) Икмәкне күп, нык ашаучы; бушка ашаучы. *Габбас мулла җиренә килгән имам да – икмәк убыры.* Р.Фәхреддинов. **Икмәк череткеч** *к.* **икмәк бүсере**. **Икмәк черетү (черетеп яту)** *сөйл.* Бушка азык исраф итү, дөньяда файдасызга яшәү. *Юкка икмәкне череткән бәндә мин.* Ш.Бабич. *[Ана:] Ул инде минем өчен күптән мәет. Аналар өчен балалар шулай. Кайберләре вафат булсалар да, мәңге исән, --- кайберләре икмәк черетеп яшәсәләр дә – мәет!* Ш.Хөсәенов. **Икмәк шүрлеге** *гади с.* Авыз. *Сиңа, чатан туганый, картлар алдында икмәк шүрлегеңне бераз ябып торасы иде. Бераз уйлап кычкырырга кирәк.* А.Шамов. **Икмәк шүрлегенә менеп төшү** *гади с.* Авызга сугу, сугып җибәрү. *Хурлама мине алай. Югыйсә икмәк шүрлегеңә менеп төшәргә дә күп алмам.* Р.Ишморат

**ИКМӘ́К АГАЧЫ** *и. бот.* Тут агачлары семьялыгыннан, җимешләре пешереп, кыздырып ашала торган, крахмалга бай тропик агач; *русчасы:* **хлебное дерево**. *Цейлонда бер балыкны җирле балыкчылар икмәк агачының яфрагы – косколайя дип йөртәләр.* Кызыклы ихтиология. *Тропик илләрдә киң таралган үсемлекләрдән банан, кокос пальмасы, икмәк агачы, манго һәм авокадо җирле халыкка икмәк һәм башка шундый продуктларны алмаштыра.* Ботаника. *Андагы [тропик илләрдә] халыклар банан, кокос пальмасы, икмәк агачы, манго һәм авокадо җимешләре белән тукланалар.* Биология

**ИКМӘ́К БАШЫ** *и.* Ачыткы, камыр башы

**ИКМӘ́К ЙОМШАГЫ** *и.* Икмәкнең тышкы катысы арасындагы йомшак өлеше, ипи йомшагы

**ИКМӘК-КҮМӘЧ** *җый. и.* Икмәк, күмәч кебек ашамлыклар. *Без бүген республика халкы икмәк-күмәч әйберләре, бәрәңге, яшелчә продукциясе, ит, сөт һәм йомырка белән 1995 елгы дәрәҗәдән дә кимрәк тәэмин ителмәс дип әйтә алабыз.* Мирас. *Икмәк-күмәч әйберләре никадәр югарак булса (кабартма, ләвәш һ.б.), бактерияләрнең юкка чыгу ихтималы шулкадәр зуррак була.* Юлдаш. *1995 елда икмәк-күмәч пешерү өчен югары сыйфатлы бодай 430 мең тонна күләмендә әзерләнде.* Ватаным Татарстан

**ИКМӘКЛӘП** *рәв.* Ипи белән, икмәк белән бергә. *Аның җыйган җиләген икмәкләп сөт белән ашадылар.* М.Гали

**ИКМӘКЛӘТӘ** *рәв.* Икмәк белән, ашлык хәлендә. *Җәләл белән янәшә утырган мулла, вәкарь белән: – Ике йөз пот тапшырам мин, җәмәгать, әмма бөтен башкарган эшем өчен, --- икмәкләтә алачакмын.* Х.Сафина. *Хезмәт көненә хәзер икмәкләтә дә, акчалата да мул гына түли башлаганнар.* Э.Касыймов. *Алар [крестьяннар] сеньор һәм дәүләт файдасына бурыч түләгәннәр (икмәкләтә оброк, юл, күпер пошлиналары --- һ.б.).* Бөтендөнья тарихы

**ИКМӘКЛЕ** *с.* 1) Икмәкка (*2 мәгъ.*) бай, икмәге (*2 мәгъ.*) мул булган. *Яңгыр ява, җылы, шифалы ләйсән яңгыры, күңелләргә рәхәт биреп, тавышсыз гына сибәли, калган карны эретә, чыккан җирне пешерә, тук, икмәкле, имин җәй вәгъдә итә иде.* М.Мәһдиев. *«Хатын-кызның байтагысы ачлыктан үлде, аннан да күбрәге икмәкле якка чыгып таралды», – дидем.* Г.Бәширов. *Алар да [әтрәк-әләм], Раушанның үги әтисе шикелле үк, вагон түбәләренә утырып киләләр, --- әмма аларның төп максаты ерактагы икмәкле Ташкент каласы була иде.* Р.Мирхәйдәров

2) *күч.* Мал-мөлкәтле, бай тормышлы кеше турында әйтелә

3) *күч.* Хезмәт хакы булган, яшәү чыганагы булган. *Энекәшне үземнең группага алырга уйладым. Биш маркадан алса да, ичмасам, икмәкле булыр.* Ш.Камал

4) *күч.* Файда, табыш китерә торган; төшемле. --- *шуны инстинктив тойган демократларның беренче дулкыныннан «үзгәртеп коруны башлаган» кайбер күренеклеләре актив сәяси эшчәнлектән бөтенләй киттеләр, кайберләре исә шактый «икмәкле» урыннарыннан да отставкага чыктылар.* Казан утлары. *Икмәкле эш. Икмәкле кәсеп*

**ИКМӘКЛЕК 1.** *и.* 1) Азык, икмәк булу, туклыклылык. *Бу нәрсәнең икмәклеге шулкадәр генә, ләкин тамак алдарга ярап тора.* Н.Дәүли

2) Ашауга китә торган чыгым (акча һ.б.). *Оланнарның һәркайсы кул арасына кирә, яшьтән үк икмәклек эшли...* М.Рафиков

**2.** *с. мәгъ.* 1) Икмәк өчен, ипи өчен әзерләнгән. *Байның бура төбендә дә бер икмәклек он була.* Әкият. *Әнә бер мич икмәклек камырың күпереп ташыган, тавыклар шуны ашаган.* Г.Якупова

2) *күч.* Ашарлык, тукланырлык, азык алырлык. *Икмәклек акча да табылып тора.* С.Кудаш. *Ул рәсем ясап алган акчасын, һичшиксез, шунда оттырган дыр. Ә баласы белән хатыны кан-яшь белән аның икмәклек акча алып кайтуын көтә торганнардыр.* Һ.Такташ. *Алайга китсә, студенткаларның барысы да диярлек гыйшык-мыйшыкка баткан. Кем икмәклек акча өчен, кем бер зачёт куйдырыр өчен бирелә!* М.Кәбиров

**ИКМӘКЛЕК-ТОЗЛЫК** *рәв.* 1) Ашарга-эчәргә, тамак туйдырырга җитәрлек. *Получка саен кесәдә икмәклек-тозлык, чәйлек-шикәрлек калдырам да, калганын әйбәтләп кенә тө-*

*реп, бүрек түбәсенә, эчкә тегеп барам.* Ф.Хөсни

2) *күч.* Аз-маз аңлашырлык, ашарга сорарлык кына (телне белү турында). *– Русча беләсеңме? – Икмәклек-тозлык кына бар инде шунда.* Г.Бәширов

**ИКМӘКЛЕ-ТОЗЛЫ** *с.* 1) Азыкка мул, бай, киң тормышлы кешегә карата әйтелә. *Икмәкле-тозлы гаилә*

2) *күч.* Яхшы табыш китерә торган, файдалы. *Икмәкле-тозлы кәсеп*

**ИКМӘ́К МИЧЕ** *и.* Ипи, камыр ашлары, азык һ.б.ш.ны пешерү, өйне җылыту өчен эшләнгән киң авызлы мич; урыс миче. *[Ул] Үзенә дә яхшы кызыл кирпечтән икмәк миче чыгарды.* Г.Толымбай

**ИКМӘКСЕЗЛЕК** *и.* Икмәк булмау, ашарга булмау. *Кулаклар, икмәк яшереп һәм икмәк белән спекуляция ясап, илдә, аеруча үзәктә, икмәксезлек кыенлыгын көчәйтәләр.* М.Җәлил

**ИКМӘК-СУ** *җый. и.* 1) Икмәк һәм су, гомумән ризык, ашамлык

2) Икмәк һәм судан гына торган, ачтан үлмәслек кенә күләмдәге ризык

◊ **Икмәк-су белән яшәү** Ашау ягы тиешенчә булмау, такы-токы булу. *[Җиһангирның] Тамак ягы начар, күп вакыт икмәк-су белән яши иде.* Г.Ибраһимов. **Икмәк-суга утырту (ябу)** *сөйл.* Ярым ач тоту, ашарына икмәк һәм судан башка берни бирмәү

**ИКМӘ́КТЕР** *ы.* Сүзенең дөреслегенә яки вәгъдәсенең үтәләчәгенә ышандыру өчен, ант сүзе буларак кулланыла; билләһи, валлаһи, кояштыр. *– Шушы дукамент булмаса әгәренки, Сөләйман абзый, кайту тәтеми иде. Да, дөнья бездән кәмит ясады, икмәктер! – [диде Шәкүр].* А.Гыйләҗев. *«Үзем эшләп алдым!» – дигәч, Ышанмыйлар нишләптер. Карганып әйтүем түгел: Үзем алдым, икмәктер...* Ш.Галиев. *– Кайтабыз, һичшиксез, Хәбирә түти. – Икмәктер, диген, – диде җитди итеп Зада апа.* Г.Тавлин

◊ **Икмәктер газыйм** *карг.* Икмәкне иң олы нигъмәткә санап, «бөек икмәк исеме белән ант итәм» дигәнне аңлата. *Икмәктер газыйм, мин алай түгел!* К.Әмири. **Икмәктер менә** *карг. к.* **икмәктер**. *– Аргы елганың Бөҗралы*гында... Өч мәртәбә күрдем, үз күзләрем белән. Җәйге чилләдә Хәлилрахман абый шунда намазлык җәеп тезләнеп утыра иде. Икмәктер менә!.. – дип ант эчте Шәрифулла.* Р.Фәизов. *Ләкин Мәсрүрә сүз тыңлаудан узган иде. – Или мин шул завычны эшеннән кудыртам, или мин үзем китәм, ---. Икмәктер менә, кояштыр газыйм...* М.Мәһдиев. *Әле менә хәзер дә, үзеңә сиздерми генә, башыңнан иснәп алдым. Икмәктер менә, икегездә дә бер үк ис.* Г.Галиева

**ИКМӘК-ТОЗ** *җый. и.* 1) Икмәк һәм тоз

2) *күч.* Азык-төлек, ашамлык әйберләре. *Икмәк-тоз онытылмый.* Н.Исәнбәт. *Мирза үзе дәүләтле, --- йомшак сүзле, икмәк-тозга юмарт, гыйлем һәм дәрәҗә иясе бер кеше булган.* С.Җәлал

3) *күч.* Сый-хөрмәт. *Бу – Галим, мулланың авылдашы булып, яшь вакытында анда укыганда, ятимлеге сәбәпле, икмәк-тозыннан да файдаланган икән.* Г.Ибраһимов

◊ **Икмәк-тоз белән (каршылау)** Хөрмәтләп, олылап каршылау. *Безне икмәк-тоз белән каршы алырсыз, малай.* М.Фәйзи. **Икмәк-тоз хакы** Кемнәндер күргән сый-хөрмәт хакы (кемнеңдер ихтирамына, яхшылыгына, хөрмәтенә каршы яманлык эшләргә ярамау, өстеңә салынган бурычны намус белән кайтара алу турында)

**ИКМӘК-ТОЗЛЫК** *рәв. к.* **икмәклек-тозлык**. *Электән икмәк-тозлык та русча белмәгән --- крестьян балалары өчен бу нәрсәне аңлау, белү чиксез авыр булды.* М.Гафури

**ИКМӘКЧЕ** *и.* 1) Икмәк белән сәүдә итүче кеше. *Бәхеткә, икмәкче күнде, итекчегә кирәге кадәр икмәк бирде.* Г.Тукай

2) Икмәк пешерү остасы, икмәк пешерүче. *Шулай бервакыт икмәкче белән шәрабчыны, патшаны агуларга җыенуда гаепләп, Йосыф янына зинданга ябалар.* Дастан. *Тегүче тегү хәлен сөйләгәндә, икмәкче бүген салган нанын сөйләр.* М.Гафури

**ИКМӘ́К ЧЫРТЛАКАСЫ** *и. зоол.* Авыл хуҗалыгы культураларына зыян китерә торган нечкә, цилиндрик формадагы бөҗәк; *русчасы:* **щелкун**

**ИКО́НА** *и. гр. дини* Православие һәм католицизмда Гайсә пәйгамбәр, Мәрьям ана кебек изгеләрнең тактага, тукымага, калайга ясалган сурәте. --- *Бүлмәдә җиһаз күп түгел иде. Түр почмакта – икона.* Р.Кәрами. *Кипр утравында Свен Игелстром дигән бер швед туристын чиркәүдән икона урлаганы өчен кулга алалар.* Шәһри Казан. *Совет хөкүмәте 20 нче еллар ахырында Казан Мәрьям ана иконасын, чиркәүләрнең башка кыйммәтләре белән бергә, чит илгә сатып җибәрә.* Юлдаш

**ИКО́НАЧЫ** *и.* 1) Иконалар ясаучы рәссам

2) Иконалар белән сату итүче

**ИКОНОГРА́ФИЯ** *и. гр. махс.* 1) Фотографиядә, скульптурада, графикада һ.б.ш.ларда билгеле бер кеше яки сюжетның төрлечә төшерелгән сурәтләрен (рәсемнәрен) тасвирлау һәм өйрәнү. *Пушкин иконографиясе*

2) Дини һәм мифологик сюжетларны яки изгеләрне сурәтләү кагыйдәләре җыелмасы. *Натураны артык җентекләп тормыйча, шартлы рәвештә генә сурәтләү – рус иконографиясе өчен типик күренеш икәнлеге мәгълүм нәрсә.* Г.Шамуков

**ИКОНОСКОП** *и. гр. физ.* Оптик сурәтне электр сигналына әйләндереп тапшыра торган телевизион трубка. *Көчле иконоскоп*

**ИКОНОСТАС** *и. гр. дини* Православиедә: чиркәүдә алтарьны аерып торган, иконалар урнаштырылган җиһәл стена. --- *А.С.Пушкин: «Шәһәр фетнәчеләр табышына әверелә, – дип яза. – Алар йортларны һәм сәүдәгәр кибетләрен талыйлар; чиркәүләргә һәм монастырьларга бәреп кереп, иконостасларны кубаралар ---».* Татарстан тарихы. *Николай алты яшьтән, әтисенә ияреп, иконостас кирәк булган авылларга йөргәндә үк, рус халкының борынгы бу һөнәрен табигый рәвештә күңеленә сеңдерә.* Сөембикә. *Рәссамның әтисе Казан губернасындагы чиркәүләр өчен иконостаслар кисеп, алтынга мана торган остаханә тоткан.* Асылъяр

**ИКОСА́ЭДР** *и. гр. мат.* Егерме тигезьяклы өчпочмак белән чикләнгән, унике түбәсе һәм утыз кабыргасы

булган төзек геометрик фигура, күпкырлык. *Һаваның геометрик формасы төзек октаэдр, суныкы – төзек икосаэдр, Җирнеке исә иң тотрыклы геометрик фигура, ягъни куб булырга тиеш.* Җ.Тәрҗеманов. *Икосаэдрның параметрлары. Икосаэдр мәйданы*

**ИКРА** *и. рус сөйл.* 1) Балыкның ашамлык итеп әзерләнгән уылдыклары. *Берзаман ришвәт китерделәр аңа! Балык, икра, тагын кайбер нәрсәләр.* А.Гыйләҗев. *Минем башта гап-гади нәрсәләр: кызыл икра, кызыл балык, кыздырылган тана ите, коньяк... кебек чүп-чар.* Т.Галиуллин. *Юк, икраның бүген карасы юк. Кызылы ярыймы?* М.Мәһдиев

2) Бик вак итеп туралган гөмбәләрдән яки яшелчәләрдән ясалган ашамлык. *Каен гөмбәсенең икрасы --- тәмле дә [инде]!* Г.Хәсәнов. *Баклажан икрасын салкын кабымлык яки ит һәм балык янына салкын гарнир итеп тә биреп була.* Юлдаш

**ИКРАМ** *и. гар. иск.* 1) Хөрмәт

2) Олылау, хөрмәтләү, ихтирам күрсәтү. *Бу кызлар шаһы әйтте: – Мән, бу шәйхны икрам итеп озаткач, --- егетемне төшемдә күрдем.* Ф.Халиди. *Ут кабызмый ул төтен эчкәндә дә синнән элек, әүвәле синә суза: икрам вә хөрмәт күрсәтә.* Г.Тукай

**ИКС** *и. гр.* 1) Латин алфавитында арттан өченче хәреф (x) исеме

2) *мат.* Гадәттә билгесез санны яки бәйсез үзгәрмә зурлыкны (аргументны) билгеләү өчен кулланыла. *Тамыр алу да онытылган, кушма җөмләләр турында әллә ни белмим... Икс, игрекларның барысы да «икс» миңа хәзер.* А.Гыйләҗев. *Тигезләмә кору бәхәссез: «икс» табылмаячак...* Н.Хәсәнов. *Тәкъдирдә язылган нәрсәне «тигезләмә» дип атасаң, яңа күчкән җирең «икс» булса, димәк, язмыш ул «икс»ның кыйммәтен табып бирә.* А.Мифтахетдинов

3) *күч.* Билгесез кешегә карата әйтелә. *Кем соң ул «икс»? Бармы ул өченче кеше чынлыкта, юкмы?* А.Гыйләҗев. *Аның чын исемен бик беләсе иде дә бит, ләкин ничек? Шуңа күрә мин аны «гражданин икс» дип кенә атадым.* Н.Дәүли. *Тикшерүче, «икс»ны табу өчен, тагы да катлаулырак юлны сайларга мәҗбүр булды.* М.Насыйбуллин

**ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ** *с.* 1) Артык зур, киң, озын, чиге күренмәгән яки булмаган, очсыз-кырыйсыз. *Бихисап, иксез-чиксез Рәсәй җирләре, тегеләре-болары да барсы бергә каләм тибрәтүчеләр телендә «ил» исемен йөртсә дә, халык «ил» дигән чагында үз төбәген генә күз алдында тота...* Ф.Яхин. *Иксез-чиксез диңгез эчендә, шаулы дулкыннар арасында Фәнияр үзенең авыру икәнлеген онытты.* Ф.Яруллин. *Ана кешене бу сүз, кире урындыгыннан суырып алып, иксез-чиксез биеклеккә, чагыштыргысыз бәхет дөньясына очыргандай итте.* М.Насыйбуллин

2) *күч.* Бик күп, әйтеп, санап бетергесез. --- *Симаков шәһәрдән 120 километр ераклыкта яшәгән бер танышында ике көн буе ятты. Башында – иксез-чиксез борчу.* Р.Сәгъди. --- *мендәр урынына башын салып яткан түмгәк өстендә, сәйләнгә яки саф мәрҗәнгә охшап, иксез-чиксез мүк җиләге чәчелгән иде.* М.Хәсәнов. *Күрәсең, без әле --- яңа гына тәпи басарга өйрәнгән чакта, табигать үзе дә безгә үзенең иксез-чиксез хәзинәләрен ачарга ярдәм итәдер...* Н.Фәттах

**ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗЛЕК** *и.* Иксез-чиксез булу. *Яктыртып кырмысканың өен, Иксез-чиксезлектә йолдыз яна!..* Зөлфәт

**ИКСЕК** *с. иск.* Ким, аз. *И дәрига, дикмә кемсә дөземәде, Фәһме иксек кемсәләре язумады.* Кол Гали

**ИКСЕЛМӘС** *с. бор.* Кимемәс. *Алда сезгә икселмәс байлык, өзелмәс озын гомерләр бирсен.* Н.Исәнбәт

**ИКСЕЛҮ** *ф. бор.* Кимү, азаю. *Хисләр икселү*

**ИКСЕТҮ** *ф. бор.* Киметү, азайту

**И́КС НУРЛАР** *и. күпл. иск. физ.* Рентген нурларының элеккеге исеме (кыска электромагнит дулкыннардан гыйбарәт булган, күзгә күренми торган нурлар)

**ИК-ЧИК** *җый. и.* Нинди дә булса киңлекнең чите-кырые, күзгә күренгән өслек, офык. *Ә ул иге-чиге күренмәгән, бары тик бер якка гына сузылган түтәлләр арасыннан каядыр алга, кояш чыккан якка таба атлый, имеш.* М.Хәсәнов. --- *иге-чиге күренмәгән дала эчендә, чыннан да, мәхшәр купкан, әйтерсең анда хәрби өйрәнүләр түгел, ә чын сугыш бара.* Р.Вәлиев. *Океан өстенән очканда, бу суның иге-чиге юктыр кебек тоелды.* Г.Афзал

◊ **Иге-чиге булмау** 1) Чиксез, чиге булмаган, очсыз-кырыйсыз. *Сәйдәш үзендә иге-чиге булмаган иҗат мөмкинлекләре сизә!* Р.Низами. *Мондый сүзләрнең иге-чиге булмады.* Ф.Яхин. *Аны иге-чиге булмаган куаныч белән алды.* Г.Бәширов; 2) Бихисап, санап бетергесез, күпсанлы. *Алар артыннан килгән иге-чиге булмаган кала халкы: – Бөтен дөньяның иң матуры, иң гүзәле ул! – дип кычкырдылар.* Ш.Әхмәдиев. *Кыш буе ындыр сугылды, икмәкнең иге-чиге булмады.* М.Мәһдиев. **Иге-чиге юк** *к.* **иге-чиге булмау**. *Базарда берәр потлы осетрлар саталар, әй ул алманың иге-чиге юк иде!* Х.Камалов. *Сөйгәненең матур, ихлас җырлавыннан күңеле тулды. Яратуының иге-чиге юк иде.* Ф.Тарханова. *Ә печәннең күл буенда иге-чиге юк.* Р.Сәгъди

**ИКЪЛИМ** *и. гар.* 1) Климат. *Кызым бер көн мәннән сөаль кылды: «Әй пәдәре газизем, Кошталә шәһәре еракмы, кайу икълимендә?» – диде.* Ф.Халиди. *Син иң төньяк кәрвансарай – Мәңге кырыс икълимдә!* Р.Рахман

2) Борынгы бүленештә Җирнең экватордан төньяк котыпка кадәр булган җиде бүленешенең һәркайсы

**ИКЪРАР** *и. гар. кит.* Берәр нәрсәнең булганлыгын раслау, әйтү; *киресе:* **инкяр**. *Үз кылганың үзеңә кайта, Икърар юктыр телеңнән!* Дастан. *Тырышма нафилә җиргә вакты гаҗзеңне икърарга: Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга!* Г.Тукай

**ИКЪРА́Р ИТҮ** *ф.* Берәр нәрсәнең булганлыгын, кирәклеген телдән раслау, нәрсәне дә булса тану, яшермәү. *[Кәүсәрия:] Әһә, ишеттегезме, ишеттегезме, үзе икърар итте. Мин күргәч, чыгарганын үзе әйтеп бирде.* Х.Вахит. *Үз гаебегезне тулысынча икърар итүегез, китерелгән зыянны түләвегез, һичшиксез, судта искә алыныр.* М.Насыйбуллин. *Ләкин берсе гаебен икърар иткәндә, икенчесе инкяр итүе аларның*

*үзара сөйләшмәүләрен, --- күрсәтә иде.* А.Каhhар

**ИКЪРА́Р КЫЛУ** *ф. к.* **икърар итү**. *Үз кул астындагы тубы белән татарларга бирелмәкче булган теге башлык сорау вакытында гаебен икърар кылган ---.* Һ.Атласи. *Гаебең юк икән – икърар кыл.* М.Насыйбуллин. *Егерме дүртен тутырып килә. Үз-үзенә икърар кыласы килмәсә дә, сазаган кызлар сафына күчеп баруын бик чамалый һәм шуңа күрә тымызык бер көенү белән көенә иде.* Д.Гайнетдинова

**ИКЪРАРЛА́У** *ф.* Икърар итү, икърар кылу. *Бик озак вакытлар үткәч, Искәндәр мирза Газизә абыстайдан гафу үтенде, Гамбәрне каенанасы өендә туктарга ул үгетләвен икърарлады.* Г.Шәрипова. *Үзенең 1966 елны язылган поэмасында (23 яшьтә!) ул болай дип икърарлап язган иде ---.* И.Вәлиуллин

**ИКЪТИБАС** *и. гар. иск. кит.* Берәр язучының әсәрен үрнәк итеп файдалану яки кемнең дә булса әйткән сүзләренә иярү. *Кайвакыт Тукай икътибаслары оригиналларын хәтергә китермәслек дәрәҗәдә үзгә әһәмияткә ия булалар.* Г.Нигъмәти. *Тукайда аннан [Пушкиннан] тәрҗемәләр дә, икътибаслар да күп.* Р.Гаташ

**ИКЪТИБА́С ИТҮ** *ф.* Файдалану, файдаланып язу; иярү. *Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр кояш булса, Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән бу баш.* Г.Тукай. *Мәнә мин укыган кызларның, ана булгач, ни рәвештә хат язышканнарын мисал өчен русчадан икътибас итеп язамын.* Г.Тукай

**ИКЪТИБА́С КЫЛУ** *ф. к.* **икътибас итү**

**ИКЪТИСАД** *и. гар.* 1) Нинди дә булса иҗтимагый стройның җитештерү мөнәсәбәтләре җыелмасы; экономика. *--- базар икътисады хатын-кызларның күпчелеген сәүдәгәр итте, алыпсатар ясады.* Сөембикә. *Чит ил басмаларында бу көннәрдә, көнүзәк мәсьәлә буларак, дөнья икътисадындагы хәлләр, Гыйрактагы бәрелешләр түгел, ә нәкъ менә бездәге күңелсез вакыйгалар яктыртылды.* Юлдаш

2) Аерым бер өлкә, ил, район һ.б.ш.ларның хуҗалык тормышы, финанска бәйле мөмкинлеге, матди хәле. *Ул чагында без Татарстанда, икътисадыбызны һәм социаль проблемаларыбызны хәл кылу нигезендә үсү белән берррәттән, рухи һәм әхлакый яктан яңгыраш өлкәсендә дә җитди нәтиҗәләргә ирешәчәкбез.* Сөембикә. *--- Рәсәйдә август, гадәттә, төрле һәлакәтләр, фетнәләр һәм матавыклар ае. 1998 нең августы – дефолт, долларның һәм бәяләрнең үсүе, ил икътисадының чак кына бөтенләй җимерелми калуы.* Юлдаш

3) Берәр хуҗалык эшчәнлеге тармагының эчке төзелеше һәм финанс-матди хәле

4) Хуҗалык һәм аны алып бару ысулларын, җитештерү һәм товар алмашу процессында кешеләр арасында туган мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган фәннәр җыелмасы. *...Дәлия авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укырга теләвен әйткәч, Биктимер, кашларын сикертеп, башын янтайтты да: – Кем булырга инде? – Икътисад бүлегенә. Үз эшем буенча, – диде.* М.Хуҗин. *Фән, мәдәният, мәгърифәт һәм җитештерүне үстерүнең яңа социаль-икътисади шартларын исәпкә алып, соңгы елларда журналистика, социология һәм психология, экология, икътисад факультетлары, бизнес мәктәп ачылды.* Сөембикә. *Икътисад фәннәре кандидаты исеменә лаек булу*

5) *иск.* Әйберне, малны сак тоту; экономия; *киресе:* **исрафчылык**

**ИКЪТИСАДИ** *с. гар.* 1) Икътисадка мөнәсәбәтле; экономикага бәйләнешле. *Конференция алдында торган эшләр арасында ике зур икътисади мәсьәлә бар.* Г.Ибраһимов. *Мәнә шул мөһим сәяси һәм икътисади сәбәпләр Екатерина II хөкүмәтен мөселман төркиләргә карата дин өлкәсендә бераз килешүчәнлеккә барырга мәҗбүр итә.* Г.Баттал. *Дөньяның ямен җибәргән һәм катастрофа алдына куйган золымнар шулардыр: ач-ялангачлык, авыру, үләтләр, СПИД вируслары, икътисади кризислар, сугышлар, җинаятьчелек, наркомания, экологик хәвефләр һ.б.* Г.Хөсәенов

2) Матди хәлгә караган, хуҗалыкны идарә итү белән бәйле булган. *Ләкин Мулланурның икътисади яклары шаптән түгел, Хөсәен абый.* А.Расих. *1905–1907 елларда Казан төркиләренең икътисади хәле шактый яхшыра.* Г.Баттал. *--- әдәбиятның язмышын бирәүгә дә тапшырып булмый, әдәбият хәтта синең иктисади хәлеңә дә бәйле түгел, ул алай мескен була алмый ---.* М.Мәһдиев

3) Икътисадны, хуҗалыкны оештыру һәм алып баруга бәйле булган. *Анда ике сүзнең берендә «хәрби коммунизм», «яңа икътисади сәясәт» дигән серле һәм ымсындыргыч гыйбарәләр еш яңгырый.* Ф.Сафин. *Икътисади сәясәт комитеты рәисе урынбасары Владимир Мединский, сыра рекламасын телетрансляцияләр вакытында күрсәтергә, --- рөхсәт итәргә, дигән төзәтмәләр әзерләргә җыена.* Юлдаш

4) Икътисад фәнен өйрәнүгә бәйле. *Икътисади география. Икътисади стастистика. Икътисади журнал*

**ИКЪТИСАДИ-СӘЯСИ** *с.* Икътисад һәм сәясәткә бәйләнешле. *Югарыда башкорт баш күтәрүләренең икътисади-сәяси сәбәпләрен күрсәтергә тырыштык...* Г.Баттал. *Ничек кенә димик, икътисади-сәяси проблемалар гаилә мәсьәләләрен гел артка куйдыра килде.* Сөембикә

**ИКЪТИСАДЛЫ** *с.* 1) Экономияле, сакчыл; малын әрәм-шәрәм итми торган. *Эшчән, тырышучан вә икътисадлы кеше рәхәт тора.* Г.Тукай. *Исраф иң хөрмәтле гаиләләрне дә бозар ---. Шуның өчен исраф итүдән бик саклаңыгыз һәм һәр эшегездә икътисадлы булыгыз!* Ирек мәйданы

2) Икътисады алга киткән, финанс-матди хәле ныклы. *Сугыш алды елларында төзелгән куәтле икътисадлы Татарстан тылдагы иң мөһим базаларның берсенә әверелә.* Татарстан тарихы. *--- дөньяда иң көчле икътисадлы АКШның акча берәмлегенә һичбер куркыныч, тирән кризис янамый дип әйтеп була.* Юлдаш

**ИКЪТИСАДЛЫК** *и.* Экономияле булу, икътисадлы булу; экономиялелек. *[Аның] Үзенең тырышлыгы һәм икътисадлыгы белән бергә, шулай һаман «кечкенә» булып калуында да ---*

*йомшак табигатьле булуының катнашмасы юк түгелдер.* Ш.Камал

**ИКЪТИСАДСЫЗ** *с.* Исрафчыл, әрәм-шәрәм итүчән. *Икътисадсыз җитәкче*

**ИКЪТИСАДСЫЗЛЫК** *и.* Экономиясезлек, исрафчыллык. *Бер тәңкә кирәк, ди. Ни эшлим? Бирдем. ...«Икътисад» мөхәрриренә барганда, шундый икътисадсызлык эшләдем бит! Соңыннан таксаның 25 тиен генә икәнен белдем.* Г.Тукай

**ИКЪТИСАДЧЫ** *и.* 1) Предприятиеләрнең, оешмаларның һәм дәүләт органнарының хуҗалык эшчәгәнлеге мәсьәләләре буенча белеме булган дипломлы (яки аттестацияләнгән) белгеч. *Ул – югары белемле икътисадчы.* Ә.Моталлапов. *Кыз аның икътисадчы булырга әзерләнүен генә түгел, бер компаниядә менеджер булып эшләвеннән алып, мәктәптә укыганда нинди лагерьда ял итүенә кадәр белде.* Асылъяр. *Икътисадчы, финансист һөнәрләрем дә бар бит әле минем.* Сөембикә

2) Предприятиеләрнең, оешмаларның хуҗалык-финанс эшчәнлегендәге хәле буенча нәтиҗәләр ясаучы эксперт (аудитор, ревизор)

3) Матди байлыклар җитештерүдә ресурслардан нәтиҗәле файдалану мәсьәләләрен өйрәнүче фәнни хезмәткәр

4) Югары яки урта белем бирә торган уку йортларында икътисади фәннәр укытучысы

5) *тар.* Экономизм (эшчеләр сыйныфы бары тик үзенең икътисади хәлен яхшырту өчен генә көрәшергә тиеш, дип өйрәтә торган оппортунистик агым) тарафдары. *Швейцария икътисадчысы С.Сисмонди (1773 –1842), техник прогресс казанышларын инкяр итмәсә дә, промышленность перевороты җәмгыять өчен җимергеч нәтиҗәләргә китерәчәк, дип исәпли.* Бөтендөнья тарихы. *--- профессор П.С.Кондырев инглиз икътисадчысы А.Смитның «Халыклар байлыгының асылын һәм сәбәпләрен өйрәнү» дигән хезмәтен бик аңлаешлы итеп рус теленә тәрҗемә итә ---.* Татарстан тарихы. *Америка икътисадчылары, сәясәтчеләре һәм социологлары (Дж.Гэлбрейт, У.Рестоу, Д.Белл, Э.Тоффлер) тарихны хәрәкәткә китерүче көчне гыйлемлектә күрәләр ---.* Фән һәм тел

**ИКЫЙ-МИКЫЙ** *с. сөйл. сир.* Кыланчык, чытлык

**ИКЫ́Й-МИКЫЙ КИЛҮ** *ф. сөйл.* Кыланчыклану, чытлыклану

**ИКЫ-ЧИКЫ** *с. сөйл. сир. к.* **икыймикый**

**ИКЫ́-ЧИКЫ КИЛҮ** *ф.* Үзара чытлыкланып, көлә-көлә сөйләшү; чикылдашу. *Кызлар кирәкмәс сүз ычкынганын аңладылар, икы-чикы килеп көлештеләр дә, сүзне уенга борып, аланның икенче кырына таба китеп бардылар.* М.Мәһдиев

**ИЛ** I *и.* 1) Билгеле бер идарә органы, хөкүмәте булган дәүләт, мәмләкәт. *--- ил азатлыгы өчен көрәштә башларын салганнарны халкыбыз бервакытта да онытмый.* М.Насыйбуллин. *– Бу төзелеш, һичшиксез, җиңү белән тәгалләнәчәк, ил ышанычын аклау символы булып әвереләчәк, – дип башлаган ул [Рәхми] чыгышын.* М.Хәсәнов. *Гаҗәпләнерлек нәрсә түгел: профессор чит илләрдә булгалый, моннан ике ел гына элек ул, мәсәлән, Вьетнамда йөреп кайткан.* М.Маликова

2) Өлкә, край, республика, җөмһүрият. *Шешәгә бөке белән хат тыгып суга ыргыта идек: «Без – нефтьле Совет Татарстаны иленнән!..»* Н.Хәсәнов

3) *диал.* Як, җир. *Сибай абый кебек өздереп гармунда уйнаучы илдә юк, үзе тагы терекөмеш кебек җитез иде.* Р.Хафизова. *Узган җәй, турист булып, Казан иленә сәяхәт кылган идек.* М.Мәһдиев. *Төн илләренә үтәргә хан кулыннан ярлык алган Хәрәзем шаһ илчесе Садакның үтерелү хәбәре Бөек Калага җитүгә, --- Сәлим хан Исхакны сарайга чакыртып алды.* М.Хәбибуллин

4) Туган-үскән җир, Ватан. *Бар белгәне шул булды: «Илгә кайтам, күрәсе, сөйләшәсе кешеләрем бар, бу фани дөнья белән өзәсе исәпләрем бар, ---» шулай ди торгание мәрхүмкәй.* Ф.Хөсни. *Әйе, «Алтын-көмеш чыккан җирдән туган-үскән ил якын» дип, тикмәгә генә җырламыйлар.* Ф.Шәфигуллин // *диал.* Туган як

5) *диал.* Авыл. *– Безнең авылның мәкамы шушы иде, – ди, карт әйтә, – бер көнне яу килеп, илемне чапкан, – ди. – Мин ауда идем, кайтып килсәм – илем юк. Авылымның урынын ташлап китәсем килмәде, – ди.* Әкият. *Вәлиулла үзе --- язның иң матур чагында, май уртасында, илгә кайтып төште. «Ил» дигәне туган авылы иде.* Ф.Яхин. *Шуннан соң бу карт: «Кызым, авылыгызда, өй буенча йөреп, бер кабарлык икмәк таба алмаган идем, тик син генә бирдең. Инде син, кызым, илдә бер шәфкатьле хатын икәнсең, мин синең аркаңда илегезгә шәфкать итим», – дип әйткән, ди.* М.Гали

6) Халык, бер төбәк халкы. *Эчмәгән иргә тормыш алып баруы да авыр, чөнки беркем булышмый, беркем ярдәм итми. Тормыш бит ул ил белән бергә булганда гына әйбәт бара.* Г.Рәхим. *--- Фагыйлә түти әрнеп карганды: – Шул зимагурың белән рәхәт күрмәсәң иде, ил алдындагы кадеремне бетердең, --- атаң да бәхиллеген бирмәде үзеңә...* Ф.Яхин. *– Халыкка башны иеп барырга туры килә. – Ил төкерсә, күл була, – дидем мин.* Ф.Яруллин

7) *күч. сир.* Солых, тынычлык; татулык, дуслык. *--- борынгы төрекчәдә «ил» «солых» мәгънәсендә, әмма «яу» «дошман» һәм «сугыш» мәгънәсендә булган.* Җ.Вәлиди. *Төрекчә белгән Сәгыйд тә кораб өстеннән боларга: – Яу түгел, ил! (Дошман түгел, дус!), – дип кычкырды.* Г.Гобәйдуллин. *--- син, минем колым Күрән би, өч җыл миңа калан түләмәдең. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм, ыруыңны юк итәм. Ил белән бирәсеңме, яу беләнме?* Н.Фәттах

8) *күч.* Кешенең эчке кичерешләре белән тудырылган дөньясы. *Мин гел язлар илендә генә яшәр идем!* А.Гыйләҗев. *Ә ул [Гөлсирин], һаман шулай төз басып, минем хәтер урамыннан самими матурлык иленә таба атлый.* М.Галиев. *Вакыт атының ялларына ябышып, без хыял иленә, мәхәббәт иленә томырылдык.* Ф.Яруллин

◊ **Ил авызы** Халык телендә йөргән сүз, ил теле. *Ил авызы капчык түгел, бәйли алмассың.* Мәкаль. *Илнең авызы*

*илле батман.* Н.Исәнбәт. *И-и-и, ил авызыннан ни ишетелми диң, бусын да әйткәннәр.* Ә.Мохтар. **Ил авызына иләк каплау (ябу)** *к.* **ил авызын тыгу (иләк белән ябу, каплау).** *Читен дип... башта читен булыр, әлбәттә. Авыл ни сөйләр тагы. Ил авызына иләк капламассың: телләре кычыта икән – сөйләсеннәр.* Н.Гыйматдинова. *«Орденнары күбәйгәч, ирен ташлады», – дип сөйләүләреннән куркам. Ил авызына иләк ябып булмый бит...* А.Каһһар. *Әгәр инде мине калдырабыз дисез икән, әйдә, шулай булсын, ил авызын иләк белән каплап булмас.* Я.Зәнкиев. **Ил авызын илле яулык томалау** *к.* **ил авызын тыгу (иләк белән ябу, каплау).** *– Телисеңме, хәзер үк Мидхәтне табып, ипи шүрлеген җимерәм. Моны гына булдыра алам. – Аныкын җимерерсең дә... Алар күп шул. Ил авызын илле яулык томалый алмас. Бер тайпылма икән юлыңнан.* Р.Мулланурова. *Гайбәт таралуы яман. Ил авызын томаларга илле яулык кирәк, дигәннәр.* Р.Ишморатова. **Ил авызын тыгу (иләк белән ябу, каплау)** «Халык теленә кергән сүзне туктатырга омтылу» мәгънәсендә. *– Күрекле киленгә дә телен тыя төшәргә кирәк иде, – диде Исмәтулла астыртын гына, – ил авызын иләк белән япмассың ---.* Г.Әпсәләмов. **Ил авызын чүпрәк тыгып каплау** *к.* **ил авызын тыгу (иләк белән ябу, каплау).** *Ә бер айдан Рәшит суга батты. Китте чыш-пыш, сүз-гайбәт. --- Ил авызын чүпрәк тыгып каплый алмыйсың ---.* Р.Камалетдинова. **Ил агасы** 1) Авыл (ил) башы; староста яки старшина; 2) Аксакал; авылның, илнең олы, хөрмәтле, могтәбәр кешесе. *– Я, хуш, – диде, ил агаларына охшатып.* Р.Мөхәммәдиев. *– Әссәламегаләйкүм барчагызга, мөхтәрәм ил агалары! – дип, кенәз Дмитрий Ураковның --- сәламләве күпләр күңеленә хуш килде...* В.Имамов. *Хәерле булсын, яши-яши, Дәүләтша әкә авыл арасында яхшы ат казанды, ил агасы булды.* Я.Зәнкиев. **Ил аралау** Ил гизү, сәяхәт итү, төрле кешеләр белән аралашу. *Мин дә бер ил аралап йөргән идем, ил авызыннан ил казнасы сүзләр җыеп, аркама капчык тагып гизгән идем.* Н.Исәнбәт. **Ил арасына керү** Халык тарафыннан бәяләнү; халыкка үзен теге яки бу яктан күрсәтү. *Ул – бу көндә ил арасына керә, халык арасында сүзе дә үтә башлаган бер кеше.* М.Гафури. **Ил аягы шил булгач (шилгәч)** Төн җитеп, кеше йөрүдән туктагач, кеше аягы басылгач. **Ил белән** Үз иле-җире, андагы гореф-гадәтләр белән бер булып яшәгән халыкның шатлыкта да, кайгыда да бергә булуын белдерә. *– Сугышта гына озаграк йөреп кайтты мескенем... – Карчык мышык-мышык елап ала. – Кулымнан килсә, анда да җибәрмәс идем, ил белән килгән кайгы булды бит.* Ф.Сафин. **Ил бөлдергеч** Илгә, халыкка зур бәлаләр китерүче, ил хуҗалыгын бөлгенлеккә төшерүче җитәкче турында әйтелә. **Ил булу** *тар.* Тынычлыкта яшәү, тату яшәү. **Илгә барса – илгәзәк, өенә барсаң – бик мәзәк** *кимс.* Кеше арасында үзен якты чырайлы, юмарт кеше итеп күрсәтеп тә, үз өендә шуның киресен эшләүче кеше турында әйтелә. **Илгә чыгу** 1) Ил буйлап сәяхәт итү. *Малайлар илгә чыгарга исәпләп йөриләр.* Әкият; 2) Халык арасына чыгу. *Ризык эзләп, әнкәй илгә чыкты.* З.Байчурина; 3) *күч.* Кешедән кешегә күчеп, бик күпләргә мәгълүм булу, таралу (сүз, хәбәр һ.б. турында). **Ил гизү** Ил буйлап сәяхәт итү, чит җирләрдә, чит илләрдә йөрү. *Лариса – дөньяны күп күргән кеше, офицер гаиләсендә үскәнгә, илне аркылыга-буйга күп гизгән, акыл җыйган ---.* М.Маликова. *Габделхәй илләр гизгән, Монголиянең кырыс табигатендә төзелешләр алып барган көчле рухлы ир булып чыкты.* Сөембикә. **Илдә бер (кеше)** Тирә-якта, илдә иң абруйлы, иң хөрмәтле (кеше). – *Монда сорап торучылар кемнәр? – Илдә бер кешеләр.* Ф.Хөсни. **Илдә илле, берсеннән-берсе җилле** 1) Тирәге, иптәше булган; 2) Күмәк. *Илдә илле, берсеннән-берсе җилле, дигәндәй, аларның һәркайсының җитәкчеләре бар, һәр җитәкченең үзенә күрә характеры бар.* М.Хәсәнов. **Илдән бизгән, җиһан гизгән** Бәхет, мажара эзләп яисә иленнән китеп йөрүче кеше турында. **Ил дөресенчә** *иск.* Халыктагыча, халыкта булганча; гореф-гадәт кушканны төгәл үтәп. **Ил иләге, чүп чиләге** *тирг.* Гайбәт таратучы, кеше турында начар сүз сөйләүче кеше. *Шунда гына Таҗылбанат --- кәҗәне каргый-каргый җибәрде һәм койма аша шушы тамашаны карап торучы күршесе Хәмдияне күрде. – И-и илаһым, ил иләге, чүп чиләге, ни күрмәдең, нәмәрсәмә күзең тондырдың?!* М.Хәбибуллин. **Ил йомышы** Ил, җәмәгать эше. **Ил казасы** *к.* **ил фетнәсе**. **Ил карты** *к.* **ил агасы**. *Юк, бу ил карты үлмәсен, бик-бик озак яшәсен иде.* Н.Гыйматдинова. *Юк, теге ил карты ялгыш әйткән: юньсезләр, әшәкеләр янында яшәп, әйбәтлеккә өйрәнеп булмый.* М.Мәһдиев. **Ил кeләве** *диал.* Озак вакыт яңгыр яумый торса, өй саен йөреп, йомырка, ярма, сөт һ.б.ш. ризыклар җыеп, су буенда яңгыр теләп пешергән яңгыр боткасы. **Ил кеше(се)** 1) Үзен, тормышын илгә, халыкка багышлаган җәмәгать эшлеклесе; 2) Халык тарафыннан хөрмәт ителә торган, халыкка билгеле кеше. *Минәйтәм, врач – ил кешесе, Казанга барып җитсәм, ничек тә табармын әле.* Г.Әпсәләмов. **Ил козгыны** *тирг. к.* **ил корткыч**. *Ил козгыннарыннан йолкып алырбыз җирне!* Р.Төхфәтуллин. **Ил корабы** Бер ил, бер милләт булып яшәгән халыкның үз билгеләнешен, үз юнәлешен, язмышын шаулы диңгездә барган кораб белән чагыштырып биргән образлы әйтем. **Ил корткыч** *тирг.* Халык малын үзләштерүче, халыкны фәкыйрьлеккә, хәерчелеккә төшерүче (кеше). *Кайда ул, ил корткыч, карак баш?!* К.Тинчурин. **Ил корыту** Халыкны талау, бөлгенлеккә, хәерчелеккә төшерү. *Бу байлык, әкренләп, Малик кебек ил корытучыларның төпсез кесәсенә кереп тулмасмы?* И.Гази. **Ил күзендә** Халык алдында. *Син, якташкаем, госел коенып, тәһарәт яңарттым да эш бетте, фәрештәгә әйләндем, ил күзендә абруйлыларның да абруйлысы булдым, дип фикер йөртәмсең?* Б.Камалов. **Ил кыдыру** *диал.* Авылдан авылга, өйдән өйгә йөрү; ил гизү. *Кыз урлану хәбәре, ил кыдырып, кымыз эчеп, кызык эзләп, кыз күзләп йөргән бүз балалар --- аркылы бөтен далага*

*шул көн эчендә таралып өлгерде.* Г.Ибраһимов. **Ил кызы** Һөнәре, сәнгате яки күрсәткән батырлыгы белән дан тоткан хатын-кыз. **Илне авызына карату** Акылы, тапкырлыгы, оста теллелеге белән ил, халык алдында хөрмәткә ия, абруйлы булу. **Илнекеннән ике илле артык** *кимс.* 1) Арттырып сөйләргә яратучы, мактанчык; 2) Үзенә башкалардан артыграк таләп итүче кешегә карата әйтелә. **Ил очыру** *к.* **ил аеру**. *Бабай, ерак умартаны карарга кирәк, Ил очырмадымы икән?* К.Тинчурин. **Ил өстендә** Кеше хисабыннан, кешенекен. *Мөхсиновның, --- кеше табынына утырып, моңарчы локма ризык капканы юк. Андый эшне күңеле күтәрми. --- үзенә-үзе биргән шелтәдән – «Әһә! Ил өстендә ашап йөри башладыңмы син дә» дигән шелтәдән курка иде.* Ф.Хөсни. **Ил өстендә иләмән** Илнең кадерле, абруйлы, хөрмәтле кешесе. *Ил өстендә иләмән, дигәндәй, халык ташламады үзен: тамагы тук, өсте бөтен булды аның.* М.Хәсәнов. **Ил өстендә иләмән йомыркасы** 1) *к.* **ил өстендә иләмән**. *Такканнар икән, аны синнән ала да белерләр, ил өстендә иләмән йомыркасы бер син генә түгел.* Ф.Хөсни; 2) Ясалма дан чыгарып, илнең кадерлесе, абруйлысы булып, акыл сатып утыручы түрә. **Ил өстендә каш булу** Дәрәҗәле, данлыклы булу. *Баеп китеп, ил өстендә каш булырбыз.* Х.Сафина. **Ил талар** Халыкны талап, халык өстендә яшәүче. **Ил теленә керү** Халык теленә керү. *Барыгыз, моннан соң ил теленә керәсе булмагыз.* В.Шекспир. *Ләкин егет аның [Әкълиманең] янында әз генә утырып чыкса да, аларның исеме ил теленә керер --- иде.* М.Маликова. *Ил теленә керерлек булмасын, Уразай яки Дәүләтша ишетеп калсалар, көн күрсәтмәсләр...* Я.Зәнкиев. **Ил тоткасы** Мөһим, хәлиткеч фактор; бик кирәкле, аеруча кирәкле әйбер. *Анда бер карашка гадәти генә, хәтта кырысрак та тоелган табигать шартларында ил тоткасы – иген өчен көрәш дәвам итә.* Р.Мөхәммәдиев. **Ил тоту** Умарта кортларының яңа күчен (илен) читкә җибәрмичә, тубалга җыеп алу. *Умартаны карарга кирәк. Әйдә, егет, ил тотканны күрәсең киләме?* К.Тинчурин. **Ил уртасында тору (булу)** Халык арасында, кешеләр арасында булу. *Сезгә, ил уртасында торгач, күренә торгандыр.* А.Расих. **Ил фәрештәсе** 1) Илгә игелек, изгелек китерүче зат; 2) *иск.* Октябрь инкыйлабына кадәр мөгаллимәләргә карата әйтелгән. **Ил фетнәсе** *тирг.* Халык арасына вәсвәсә салучы, коткы таратучы, җәнҗалчы, гаугачыл кеше. *Төркиядә бер теләнче, сукбай булган Мостафа; Монда кайтып ил фетнәсе булган Мостафа.* Г.Тукай. *Патша ялчысы, доносчы Ишми ишан, яшьләр хәрәкәтенә аяк чалып, яңа ысул мәктәпләребезне яптырып, ил фетнәсе булды.* Н.Исәнбәт. **Ил эше** Җәмәгать эше; җәмәгатьчелек, халык ышанып тапшырган эш. *Я, ярар, Зәйнулла, исән бул, гаеплəп калма, ил эше бит.* З.Зәйнуллин

**ИЛ** II *и.* 1) Ана кортка ияреп аерылып чыккан бал кортлары семьясы. *Анасыз корт ил булмас, ил булса да җим булмас.* Мәкаль. *[Самат] Миендә умарта иледәй гөжләгән уйларыннан байтак кына арына алмый утырды.* Р.Ишморатова. *Әйтерсең лә умарта иле ачуланып, гүләп тора иде.* А.Тимергалин

2) *к.* **иләү** III. *Кырмыска оясына кулны суздым. Кырмыскалар учым буйлап йөгереп узды. Гөжләп куйды бөтен бер ил!* Р.Зәйдулла. --- *умарта кортлары иле гөжләгәнен ишеткәнем бар, кырмыска иленең гөжләгәнен ишеткәнем юк.* Казан утлары

◊ **Ил аеру** Яшь корт анасы белән эшче кортларның бер өлеше аерылып, яңа күч булып оешу. *Ел яңгырлы, кортлар, бал җыясы урынга, еш кына өйдә ызгыш-талаш чыгарганнар, гел ил аерганнар.* М.Мәһдиев. **Ил булып** Күп булып, төркем булып, төркемләп. *Аккош очар ил булып, Шаулап искән җил булып.* Ә.Фәйзи. **Ил очырган умарта төсле** Ыгы-зыгылы, кайнашып йөрү турында әйтелә

**ИЛ-АНА** *җый. и. шигъ.* Туган ил, Ватан. *Алар – барысы да корал кардәшләре, бер үк ил-ананың, Совет Ватанының уллары.* К.Нәҗми

**ИЛ-АТ** *җый. и. сир.* Туган ил, тугандаш, илдә яшәүчеләр, халык; бер кардәш булып яшәүче җирле халык. *Ул хуҗа хатыннан аның ничек көн күргән, ил-атның ничек торуын сораштырып, сөйләшеп утырды.* Ф.Хөсни

**ИЛА́У** *и.* Күңелгә авыр авазлар чыгарып кычкырыш, елаш

**ИЛАУЛА́У** *ф.* Үзәк өзгеч авазлар белән каты кычкырып, үз-үзен белештермичә илереп елау. *Хәтта өрәкләрнең илаулаганнары аръякка хәтле яңгырап торган, имеш.* Р.Батулла. *Суфия тагын илаулап елады. – Ай Аллам, нахакка сине каргыйм икән лә!* Н.Гыйматдинова

**Илаулап алу** Кыска гына вакыт аралыгында илаулау

**Илаулап җибәрү** Кинәттән, кисәк илаулый башлау

**Илаулый башлау** Илауларга тотыну. *– Мин фәкыйрь бер көтүче-чабан буламын, и олуг падишаһ! – дип илаулый башлый карт.* Р.Батулла

**Илаулый бирү** Бернигә дә карамый илаулавын дәвам итү

**ИЛА́У САЛУ** *ф. к.* **илаулау**. *Иртән көлгән бала кичен илау сала.* Әйтем

**ИЛАҺ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Алла, Ходай, Тәңре. *Әле кендек каны җиргә тамганчы, анасының карынында чакта ук Илаһ аңа [адәми затка] яшәү рухын, әҗәлгә җиңел генә бирешмәү кодрәтен өрә.* Т.Галиуллин. *«Бердәнберем» дип, миңа син табынма: Мин Илаһ түгел.* Р.Гаташ. *Бишенче шарт – «ихлас», ягъни «Аллаһы Тәгалә бер Үзе генә Илаһтыр. Аңардан башка бер генә Илаһ та юк», – дип чын күңелдән иман кәлимәсен әйтүдер.* Юлдаш

2) Мәҗүсиләр табына торган пот

3) **Илаһым, Илаһем** *тарт. форм.* Ходаем, Аллам, Тәңрем. *Җиясы ризыкларыбыз, эчәсе суларыбыз бетмәсен, Илаһым!* Н.Фәттах. *Кулым да селкенми, башымны да бора алмыйм, валлаһи! Илаһым, дим, җанымны ал шушы минутта, коткар мине тәмуг җәзаларыннан, дип ялварам.* Я.Зәнкиев. *И Тәңрем, зинданнарның адәм баласын гарипләткәнен күрмисеңмени син, Илаһым?..* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Башкаларга үрнәк булырлык, өлге була алырлык зат. *Сүбәдәй еш кына: «Ошбу хатын – миңа Тәңре тарафыннан җибәрелгән Илаһ», – дияр иде.* М.Хәбибуллин

5) *күч.* Башлык, хуҗа, түрә. *Кем көчле, шул илаһ.* Мәкаль

**2. Илаһым, Илаһем** *ы. мәгъ.* Берәр нәрсәгә гаҗәпләнгәндә, ачынганда, аптыраганда, карганганда һ.б. очракларда кулланыла. «*Сытык кукәй, – диде олы килен, – илаһым, авызыннан гына түгел, күтеннән дә чыгадыр моның тавышы!»* А.Гыйләҗев. *Бер кургдә кызый башларын әйләндереп тә өлгергән ---. Берсенә берсе, икенчесенә монысы – пар да килгәнсез инде үзегез дә, илаһым.* Н.Фәттах

**ИЛАҺӘ** *и. гар. иск. кит.* 1) Хатынкыз алла, алиһә; гыйшык, мәхәббәт Алласы. *Венера – борынгы галәмнең матурлык Илаһәсе.* Ф.Әмирхан

2) Алла, Тәңре. *Әмма кеше күңелендә «илаһи очкын» яши, һәм кеше «мин»е үзен бар кылган Илаһә белән бәйләнешен ахыргача югалта алмый иде...* И.Вәлиулла

**ИЛАҺИ** *с. гар. иск.* **1.** 1) *дини* Аллага бәйләнешле, Аллага мөнәсәбәтле, Алланыкы. *[Карт хәзрәт] Иман шартымны идәнгә ачып салды да --- изге, илаһи сүзләрне тезеп китте: «Әлеппи, тисси, җимхи, ыхы ыгы, далзәл...»* Г.Гобәй. *Туран дөньясында олуг дан тоткан, илаһи әмерләр биреп халкы вә илен бәхетле иткән, --- ошбу хатны Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт юллый.* М.Хәбибуллин. *Соңгы сәгате җиткәч, ниндидер бер илаһи көчкә буйсынып, аның [Андрейның] әлеге иң ахыргы үтенече атасына барып ирешәчәк...* В.Распутин

2) Алла тарафыннан булдырылган; рухи. *Күңелнең илаһи бернәрсә түгеллеге, бәлки реаль физиологик күренеш булуы --- һәрберебезгә билгеле.* Г.Әпсәләмов

3) Изге. *Илаһи зат*

4) *күч.* Тылсымлы, сихри, серле; табигатьтән өстен. *Бала тудыру йортында өч сәгать саен кабатланып торган илаһи тынлык урнашты.* М.Маликова. *Алда бары Идел, чиксезлеккә кадәр җәелгән, билгесез бер илаһи көч – Идел.* Р.Вәлиев. *Театр минем өчен хыял иде, театр режиссёрлары, актёрлары гына түгел, кая ул, әнә шул җыештыручы апалар да илаһи затлар --- булып тоела иде.* А.Гыйләҗев

5) *күч. юг.* Искиткеч, сокландыргыч, гаҗәеп, тиңләштергесез. *[Камилә туташ] Аяк астыгызда туфрак булыйм. Мин сезнең илаһи матурлыгыгызга җанымны бирергә әзер.* Ш.Камал. *И, күреп сокланып туеп булмас, серләреңне белеп төкәнмәс илаһи дөнья!* Г.Хөсәенов. *Коңгырт чәчләре тузгып як-якка таралган, кашлары, очарга җыенган кош канаты сыман, өскә талпынган, күзләре – чиксез моң һәм дәрт тулы күзләре – кешеләргә түгел, ә эчкә, үзенең эчке илаһи дөньясына төбәлгән кебек.* Р.Вәлиев

**2.** *и. мәгъ. дини* Алла, Тәңре, Ходай. *Бәндәчелек белән чирләсәң дә, Бер сыйфатың өчен мең гафу: Хатынкызны, бер Илаһи, дисең, Матурлыктан түгел шул гафил.* Б.Рәхимова. *Фәрештә: Кешем – син саф, Илаһига тиңләшер олы җан.* Г.Хөсәенов. *Дөнья оешуның башлангыч ноктасы итеп, ул [христиан дине] аның Илаһи, ягъни Алла ихтыяры буенча яралу фактын таный.* Бөтендөнья тарихы

**3.** *ы. мәгъ.* Нәрсәгә булса да гаҗәпләнгәндә, аптыраганда, аны яратмаганда, каһәрләгәндә, карганганда һ.б. очракларда кулланыла. *Булсаң да булырсың икән, илаһи бер шарлатан инде үзең.* Татар иле

**4.** *энд. сүз к.* **Илаһ** (*3 мәгъ.*). *– Ярабби, Ходаем, шул азгын бәндәне, никахлы зәүҗәсенә хыянәт иткән өчен, иң мәрхәмәтсез җәзаларыңа дучар ит! Илаһи, мәңге оҗмах чырайлары күрмәсен! – дип каргады [Мәрфуга].* Г.Бәширов. *Ул арада Мәфти, --- куанычыннан, дога укып, битен сыйпарга ук кереште. – Ай, рәхмәтләр генә яусын! Илаһи, кодрәтең чиксез. Минем өчен кылган догаларны кабул итә күр!* Г.Бәширов

◊ **Илаһи кадир** «Әй кодрәтләр иясе Аллаһ» мәгънәсендә Аллаһка сыену сүзе. **Илаһи мәгәр** Берәр төрле тойгыны белдерү сүзе буларак әйтелә; бик тә, бигрәк тә. **Илаһи уптык, кирәгеннән артык зурдан куптык** Нинди дә булса бер эшкә тотынганда, алдан шаулап, зурдан кубып та, эшкә килгәч – сынату, эшне тиешенчә итеп башкарып чыга алмау. **Илаһи уптым** *сөйл.* Барысын бергә, берьюлы; берсен дә калдырмыйча; бернәрсә дә уйламыйча. *--- әнисе Рәсүлә кайта-кайта әйтте аңа [Рәмзигә:] – Үпкә-рәнҗүләребезне аермачык сиздер, улым, әмма берүк илаһи уптым кубып бәреләсе итмә!* Э.Касыймов. *Динә тавышы ич бу! Булды, илаһи уптым барысы искә төште.* Б.Камалов. *Инде менә «сугару» дигәнендә азрак сабыр итмичә, уңгасулга карангаламыйча, ничек инде илаһи уптым гына ябышасың, ди.* Сөембикә. **Илаһи ярабби** Берәр нәрсәнең чамасыз матурлыгын, зурлыгын сөйләгәндә көчәйткеч әйтем

**ИЛАҺИ́ БӘЕТ** *и. иск.* Чын, реаль күренешләргә һәм фактларга мөнәсәбәтле мотивлар белән сугарылган җыр яки шигырь. *Шул ук кичне кияү кулларына да кына ягалар. Аннары «кына догасы» укыла, илаһи бәетләр әйтелә.* Юлдаш

**ИЛАҺИЛАНУ** *ф. сир.* Искиткеч, сокландыргыч, гаҗәеп, тиңләштергесез булу. *«Сөям» дигән сүзне әйткәндә, җан нигә илаһилана?* И.Юзеев

**Илаһилана бару** Торган саен күбрәк илаһилану, илаһилыгы акрынлап көчәю. *--- көннән-көн чибәрләнгән, шуңа күрә, үз бәясен белеп, чаялана төшкән Миләүшә Самат алдында илаһилана гына барды...* Г.Гыйльманов

**ИЛАҺИЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Табынырлык дәрәҗәдә олылау. *Сез мине, чынлап та, фәрештәгә әверелдердегез. Алай илаһилаштырмагыз, соңыннан кыен булыр.* Ф.Яруллин. *Масайлар белән янәшә яшәүче ватусен кабиләсе кешеләре сыерларның кайбер токымнарын илаһилаштыралар.* Юлдаш

2) Искиткеч яхшы, соклангыч итеп күрү. *Рәссамнар кеше тәнен матур диләр, гүзәл затларны илаһилаштыралар.* Ф.Яруллин

**ИЛАҺИЛЫК** *и.* Илаһи булу. *Кызның зифа тәненнән чәчәкләргә хас илаһилык бөркелә.* Г.Гыйльманов. *Рухи культурасының байлыгы Европага аналитизмны, психологизмны Көнчыгыш сәнгатенең илаһилыгы белән кушарга мөмкинлек бирә.* Д.Вәлиева. *Татар халкы да үз рухи-мәдәни тормышында табигатькә ияреп, Илаһилыкка һәм аның*

*белән бәйләнешле Мәңгелек Тормышка тугры калырга омтыла.* И.Вәлиулла

**ИЛАҺИЯ** *и. к.* **Илаһә** (*1 мәгъ.*). *Борынгы грекларда гашыйкларны яклаучы, аларны хәвеф-хәтәрдән саклаучы Афродита исемле Илаһия булган.* М.Кәрим

**ИЛАҺИЯТ** *и. гар.* 1) *к.* **Илаһилык**. *Матдиятлелек бит Алланы танымаса да, Чиксезлек һәм Мәңгелекне танымыйча булдыра алмый!.. Алар бар. Шулай булгач, аларны танудан Алланың барлыгын тануга да ерак түгелдер... Вакыттан һәм пространстводан өстен булган Илаһият һәрвакыт кала.* И.Вәлиулла. *Бирелгән корбаннар, түгелгән каннарны ул [Кадерҗан] шуңа күрә Ватан халкына кылынган бөек бер илаһият, бөек бер зарурият, бөек бер бурыч дип кенә кабул итә...* А.Хәлим. *Әсәрнең лексикасына игътибар итсәң, рус вариантында Илаһиятка нисбәтле төшенчәләр түбәндәгечә бирелә. Алла исеме 21 кабатланса, --- татар вариантында исә 45 мәртәбә искә алына.* Мәйдан

2) Дини фәлсәфә гыйлеме, теология. *Илаһият галимнәре фикеренчә, «Лука тарафыннан язылган Евангелие» иң төгәл санала.* Мәдәни җомга

3) *күч. юг.* Гүзәллек, матурлык, гаҗәпләнерлек, сокландырырлык нәрсә. *Әдәби иҗат сферасына кайчандыр «илаһият», «рухият» концепцияләре кертеп тутырылган...* Х.Госман. *Чорга хас Илаһиятне эзләү рухы иҗатка яңа килгән буыннан алдагы елларда үзенчәлекле ачышлар юлына алып чыга.* Т.Галиуллин. *Бер күрүдә якын иттерә, үзенә тарта, беректерә торган әллә нинди генә серле бер ягымлылык бар иде бу кешенең йөз чалымнарында, әйтеп бетергесез илаһият, моң бар иде күзләрендә.* Ш.Җиһангирова

**ИЛАҺИЯТЛЫК** *и. юг.* Илаһи булу (*5 мәгъ.*). *--- татар фольклорының – халык иҗатының нигезендә өч сыйфат күрсәткече ята: 1) мелизм – моң; 2) пентатоника; 3) илаһиятлык.* Мәдәни җомга

**ИЛАҺИЯТЧЫ** *и.* Динче галим, теология белгече. *Ләкин Барудиның ислам дөньясында танылган бер шәхес, илаһиятчы булуын истә тотып, [чекистлар] кылынган чиксез җинаятьләренә тагын бер җинаятьне өстәргә курыктылар, әлбәттә.* Г.Баттал

**ИЛ-АЯК** *җый. и. сөйл. к.* **ил-күз** (*2 мәгъ.*). *Ялан авылына кайтырга вакыт безгә. Ил-аяк тынды, хәзер без картайдык, кызыбыз анда, улыбызны өйләндерер чак җитә...* Я.Зәнкиев

**ИЛӘ** *бәйл. кит.* Белән. *Һәм әйтә алам: хәзер мин – мәсгуд, мин бәхетле, моңарчы хәятны аңламаганмын; аның, яшь йөрәкнең, мәңгелек сәгадәт илә тутырып, дөнья вә каинәткә бөтенләй икенче төс бирә торган ноктасы кайда икәнен белә алмаганмын икән.* Г.Ибраһимов. *[Хафиз] «Кол кызлары илә уйнауны пәйгамбәрләр дә ят итмәгәннәр әле», – дияргә ниятләнеп, җай чамаларга кирәклеген фикеренә кыртләп куйды.* Ф.Яхин. *Карга илә козгын, гадәттә, кан исенә җыела инде ул, җәмәгать.* В.Имамов

**ИЛӘГЕЧ** *и.* **1**. Или торган, иләү өчен кулланыла торган җайланма

**2.** *с. мәгъ.* Тире или торган, тире иләү өчен махсус. *Иләгеч матдәләр*

**ИЛӘК** I *и.* 1) Он яки ярманы, орлыкларны эрерәк катышмалардан аеру җайланмасы. *Солы оны иләгәндә, җиз иләктә учы-учы белән әрсез кылчык бөялеп кала торган иде...* А.Гыйләҗев. *Шуннан соң ул [Торымтай] кыл иләктә тары ярмасы юды*. Н.Фәттах

2) Ашлык чистарту, җилгәрү, суыру машиналарында иләү өчен челтәр җайланма. *Өннә апа җилгәргечкә беренче чиләк чүпле бодайны китереп салды. Кибәкләр тузып бер якка очтылар, ә яп-якты эре бодай бөртекләре, куанышып, иләк өстендә биибии, мөшкә аша капчыкларга коелды.* Я.Зәнкиев. *--- ыштан балакларын бот тиңентен сызганган сипкелле малайлар, агач дөмбе белән комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып, җилгәргеч иләгеннән бозып ясалган бәләкәй җәтмәләр белән балык сөзәләр...* А.Гыйләҗев

3) Балчык, вак таш, комны һ.б.ш.ларны үткәрү, иләү, сөзү өчен зур җайланма. *Аларның машиналашкан куллары --- таш катнаш балчыкларны тимер иләкнең бер ягыннан икенче ягына йөгерт[әләр].* М.Гафури

◊ **Иләге су тотмау** Сер саклый алмау, авызында сүз тормау. *Бу вакыйганы кеше-фәләнгә ишеттермик инде, дип сүз куешкан булсак та, иләкләре су тотмады, кардәшләрем табын янында еш кына минем якка карангалап, пырх-пырх көлеп куялар иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Иләк авыз** *гади с.* 1) Зур авыз. *Җанашым, аһ, иләк авызыңны үпсәм! Ни кайгы, инде шул чакта үлсәм.* Г.Тукай. *Шушы кичне Миләүшә өйдәгеләргә сиздерми генә көзге тирәсендә күбрәк уралды. Күз-каш, ияк-танау тирәләре болай ярыйсы гына төсле, әмма авызы зуррак шул: «иләк авыз», җитмәсә, итләч битле...* Г.Байбурин. *Кая инде ул «Баламишкин» җырлап үскән безнең иләк авызга мондый хикмәтле «шлюпкалы» җырларның җаен белергә...* М.Мәһдиев; 2) Түгеп-чәчеп ашаучы кеше; 3) Авызында сүз тормаган, сер тотмас кеше. – *Ә ничек сөйләмисең, ди? --- – Ишкәнсең икән, иләк авыз! – Бу минутта Рәмилә үзе дә малайның җилкә тамырына берне кундырмыйча чак кына тыелып калды.* Э.Касыймов. *Тешең-тырнагың белән тырыш, мәгәр иләк авыз, буш сүз булып каласы түгел...* Б.Камалов. **Иләк авызлы** *гади с.* Зур авызлы. *[Рамиз] Әхмәтсафа абзыйның иләк авызлы Кадриясен кичә төн буе каравыллап чыкты...* М.Хәбибуллин. **Иләк аша караган** Артык күп сипкелле битле кеше турында. **Иләк аша үткәрү (уздыру, сөзү)** Җентекләп тикшерү, нык тикшереп, сайлап алу. *Минә кайчан башланды ул кешене, үзенә сиздермичә генә, зурайткыч пыяла аша карау, эреле-ваклы иләк аша уздыру!* М.Насыйбуллин. *Ләкин ул алай итмәде, инде һәрбер җөмләсе күңелгә сеңгән, кабат-кабат укылган газета материалын яңадан тәнкыйть иләге аша сөзеп укый башлады.* А.Расих. *Хәзер сүзне үлчәп, әллә ничә тапкыр иләк аша үткәреп кенә сөйләргә ярый...* А.Гыйләҗев. **Иләк баш** *гади с. тирг.* 1) Тиз онытучан, хәтерсез кеше; 2) Ахмак, аңгыра, надан кеше. **Иләк белән җил тотып маташу** *к.* **иләк белән су ташу**. **Иләк белән**

**иләп карау** Җентекләп, төрле яктан тикшерү; бик нык тикшереп, сайлап алу. *Миңа акыл бигрәк иртә керде, һәр нәрсәне иләк белән иләп карыйм.* Н.Гыйматдинова. **Иләк белән кояш (якты) ташу** *к.* **иләк белән су ташу**. **Иләк белән су сөзү** *к.* **иләк белән су ташу** *Иләк белән су сөзгән кебек булды ла аларны (жуликларны) тотарга тырышу.* З.Фәтхетдинов. **Иләк белән су ташу** Юк эшкә, файдасызга, бушка көч түгү, кирәкмәгән эш белән шөгыльләнү. *--- коммунистлар режимыннан яхшылык көтү – иләк белән су ташу ул, ниятләре явызлыкта, бу юлы явызлыклары кая кадәр барып җитәр?* А.Гыйләҗев. *Хатын белән бәхәсләшү, аны төзәтергә тырышу, Мәһди исемле язучы әйткәндәй, иләк белән су ташыгандай файдасыз.* Н.Әхмәдиев. *Дөньяда иң буш эш нәрсә? Иләк белән су ташумы? Юк! Хатынның «холык» дигәнен үзгәртергә маташу.* М.Мәһдиев. **Иләк бит** *гади с. мыск.* Шадра битле кешегә карата әйтелә. *Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит, Синең кебек иләк битләр сирәк бит.* Г.Тукай. **Иләк булу** Сизерәп, тишкәләнеп бетү. *[Ат] Бөтенләй тишкәләнеп иләк булган, --- төз атканнар, --- тишкәләп бетергәннәр.* Ш.Усманов. **Иләк итү** Тишкәләп бетерү, иләкләү. *--- бер җирән чәчлесе, башкаларның сүзенә каршы төшеп, миңа ярсып-ярсып штык белән кадарга тотынды. Гәүдәне агач саклады, ә менә аяк-кулларны иләк итте, явыз.* Ф.Яруллин. *Сугыш талкысы адәм баласын ниләр генә эшләтмәгән?! Кайсының тәнен ярчыклар иләк итеп тишкәләп бетергән, әмма йөрәгә тибә әле, җаны чыгып җитмәгән, күзе йомык, аңы юк.* Х.Камалов. *Гәрәй, ак кульъяулыгын тишеп, вак иләк ясап бетерде.* А.Гыйләҗев. **Иләкнекен чиләккә бушату** 1) Мәгънәсез, файдасыз эш белән шөгыльләнү. *Каландаров бераз уйлап торгач: – Үзегез, эштә кимчелекләр бар, дисез. Ә үзегез кискен чара кулланырга каршы киләсез. --- Юкса, ни өчен монда иләкнекен чиләккә бушатып утырабыз?..* А.Каһһар; 2) Сүз йөртү, гайбәт сөйләү. *Председатель киткәч тә, сыер савучылар урыннарыннан кузгалырга ашыкмады: әйтелеп бетмәгән сүзләре байтак калган, иләктәген чиләккә бушатып, тагын бераз тел чарлап алдылар.* Г.Байбурин. **Иләкнекен чиләккә, чиләкнекен иләккә бушату** *к.* **иләкнекен чиләккә бушату**. *– Әгәр мин барысын да дөресен генә сөйләп бирсәм, сез аны кешегә әйтмәссезме соң? – дип сорады ул [Гомәр], икеләнеп. – Мин иләкнекен чиләккә, чиләкнекен иләккә бушатучылардан түгел, – диде директор, коры гына.* Г.Рәхим. **Иләк сораганга чиләк бирү (тоттыру)** Кеше үтенеченә формаль килеп, ул сораган эш урынына башка эш эшләү. **Иләк сораганга – чиләк, чиләк сораганга чүлмәк тоттыру** *к.* **иләк сораганга чиләк бирү (тоттыру)**. **Иләктәген чиләккә авыштыру** *к.* **иләкнекен чиләккә бушату**. **Иләктән уздыру (иләү, үткәрү, үткәзү, сөзү, чыгару)** 1) *к.* **иләк аша үткәрү (уздыру, сөзү)**. *Рәмзия Зөбәйдә сөйләгәннәрне илтифатлы тыңлый, үзенең фикер иләгеннән үткәрә ---.* Б.Камалов. *Кадрларны күреп алу, сайлап иләктән үткәрү, талантлыларны вакытында үстерү бик мөһим бурычлардан санала иде.* Сөембикә; 2) Күз алдына китерү, узганнарны, үткәннәрне искә төшерү; аң аша уздыру. *Монда [станциядә] озак утырсаң, бөтен гомереңне иләктән уздырырга мөмкин.* М.Мәһдиев. *Өлкәннәрдән күргән, ишеткән һәрнәрсәне үз иләгеннән чыгарып, шулардан үзе өчен дә сөземтә табарга яраткан бу хыялый малай үзенең иманы бармы-юкмы икәнлеге турында баш ватты.* З.Хөснияр; 3) Кабат-кабат сөйләү. *--- «Куам» дигән сүзеңне бүтән иләктән иләмә, безләр монда таш, --- безләрнең өстә... (хатын бармагы белән түшәмгә төртте) дус түрә әфәндебез корсак симертә.* Н.Гыйматдинова. **Иләк ясау** *к.* **иләк итү**

**ИЛӘК** II *и. сөйл.* Металл акчаның бәясен күрсәткән цифрлы ягы; *киресе:* **күн**. *[Акча] Ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.* Г.Тукай. *Иләк – акчаның сан ягы, акчасы иләк ягы белән төшкән кеше оттыра.* Р.Батулла

**ИЛӘ́К АСТЫ** *и.* 1) Иләк белән иләгәндә аралап алынган чүп. *Көне буе иләдем, иләдем дә, иләк өстен, иләк астын бергә кушып, тегермәнгә киттем --- .* Г.Шәрәфи

2) *күч.* Эшкә ярамаган, яраксызга чыккан нәрсәләр; вак-төяк халык. *Тик ул гәзитләргә бирә торган белдерүләр буенча хатын эзләп табан туздырма: андагы хатыннар – аптыраганнан акча туздыручы иләк аслары гына.* М.Фәйзи

**ИЛӘК БИТЛЕК** *и.* Умарта кортлары чагудан саклану өчен биткә киелә торган, кыл яки нечкә тимерчыбыктан үрелгән япма. *Оныгы килүенә шатлана да соң ул: әнә үзенең иләк битлеген алмагач ботагыннан алып, тизрәк Кәримгә суза.* Р.Низамиев

**ИЛӘК ЙОЛДЫЗ** *и. астр.* Иләк йолдызлар төркемендәге бер йолдызның халык телендәге атамасы; *русчасы:* **стожары**. *Күзен ачкач, ул иң беренче булып күк йөзендәге Иләк йолдызны таныды.* М.Мәһдиев. *«Менә бусы – Иләк йолдыз, тегесе булыр Арктур!..» – ди бу [Якуб абый], һаман йолдызларны күрсәтеп ---.* А.Гыйләҗев. *[Әткәй] Ишегалдына алып чыгып тезәр иде дә йолдызларны күрсәтеп сөйләп торыр иде: «Менә бусы – Иләк йолдыз, тегесе – Тимер казык».* А.Гыйләҗев

**ИЛӘКЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Тузып, тишкәләнеп бетү. *Очкын тиеп иләкләнгән кием-салымнарыннан ыс исе, төтен исе килә иде.* А.Гыйләҗев. *Университетта укыган белемнәрнең күбесе җилгә очкан, хәтер казаны да иләкләнгән.* Ф.Яруллин

**Иләкләнә бару** Торган саен ныграк иләкләнү

**Иләкләнеп бетү** Бик нык иләкләнү

**ИЛӘКЛӘП-ЧИЛӘКЛӘП** *рәв.* Бик көчле, бик күп итеп, мул итеп (яңгыр яву турында). *Атнадан артык әле иләкләп-чиләкләп койган, әле пыскып кына сибәләгән яңгырлардан соң чалт аяз көннәр башланды.* Р.Төхфәтуллин

**ИЛӘКЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Тишкәләү, чәрдәкләү. *Вагоннарның түшәм-идәннәрен пулемётлардан иләкләп узганнар.* М.Рафиков

**Иләкләп бетерү** Бик нык иләкләү. *Беренче патронның төбен тишеп, иләкләп бетердек, эчендәге дарысы агып чыкты ---.* А.Гыйләҗев

**Иләкләп чыгу** Һәрберсен берәмберәм иләкләү; башыннан ахырына кадәр иләкләү

**Иләкли башлау** Иләкләргә тотыну

**Иләкли төшү** Бераз иләкләү

**ИЛӘ́К ӨСТЕ** *и.* Ашлык иләгәндә, иләк челтәре өстендә кала торган башак, кибәк, эре чүпләр. *Көне буе иләдем, иләдем дә, иләк өстен, иләк астын бергә кушып, тегермәнгә киттем ---.* Г.Шәрәфи

**ИЛӘКСЫМАН** *с.* Иләк кебек, иләккә охшаган. *Яфракның сеңерчәләрендә шулай ук иләксыман көпшәләр бар.* Ботаника. *Иләксыман көпшәләр, каналлардан аермалы буларак, озын тере күзәнәкләрдән төзелгән.* Биология

**ИЛӘКЧЕ** *и.* Иләк ясау остасы, иләк ясаучы кеше. *Иләкченең – иләге, чиләкченең чиләге юк.* Мәкаль. *Иләк ясау осталыгын өйрәнеп, алдагы көннәрдә галимнәр, бәлки, китаплар язарлар, --- кинолар төшерерләр әле. Иләкчеләрне эзләп йөрерләр, әмма XXI гасырда Түбән Мактамада иләк ясаучылар, мөгаен, беткән булыр инде.* Казан утлары. *Тирә-якта башка иләкче булмаганлыктан, иләккә руста да, мукшыда да, чувашта да зур ихтыяҗ булган.* Сөембикә

**ИЛӘК-ЧИЛӘК** *җый. и.* 1) Йорт хуҗалыгындагы барлык савыт-саба. *Әнисенең, таң атмас борын торып, почмак якта савыт-саба, иләк-чиләкләрне шалтыратуын ишетү белән, Фирдәвес тә сикереп торды.* М.Хәсәнов. *Чоланнан түшәк-ястыкны, өйдән иләк-чиләкне шунда ташып бетерәннәр.* А.Гыйләҗев. *Бөтен урам буеннан-буена өй җиһазлары, --- савыт-саба, иләк-чиләк белән тулган.* Р.Вәлиев

2) *күч.* Вак-төяк, әһәмиятсез нәрсәләр. *Таушалган адәм баласының януы юктан – иләк-чиләктән, әтрәкүтрәктән башлана.* Т.Галиуллин

**ИЛӘК-ЧҮМЕЧ** *җый. и. к.* **иләк-чиләк**

**ИЛӘМ** *и. диал.* Ямь, матурлык. *Мин телем белән алдасам да, иләмем белән алдарга өйрәнмәгән.* Һ.Такташ. *Синнән башка өйнең иләме юк*

**ИЛӘМӘН** *и.* 1) Ил башы, ил башлыгы, ил хуҗасы. *Ил иле иләмән белән булганда, иләмән үзе иле белән була.* Мәкаль

2) Гомумән хуҗа. *Бүген һәр төбәкнең, һәр авылның үз лидеры кирәк! Башкаларны әйди белүче атаман кирәк бүген. Безнең Таукашта син иләмән булырсың дип көттем мин, Галияр абыйкаем!* М.Хуҗин

**ИЛӘМЛӘНҮ** *ф. диал.* Ямьләнү, матурлану

**Иләмләнә бару** Торган саен күбрәк иләмләнү, иләмлеге акрынлап арту

**Иләмләнә башлау** Ямь барлыкка килү

**Иләмләнә төшү** Тагын да иләмләнү; бераз иләмләнү

**Иләмләнеп калу** Нинди дә булса вакыттан, сәбәптән соң иләмләнү

**Иләмләнеп китү** Кинәт кенә иләмләнү

**ИЛӘМЛЕ** *с. диал.* Матур, ямьле. *Карыйсыңмы, Әнвәр, зелпе белән кочаклашып үскән имәнне! Тегендәрәк булыр. Искитәргеч – Әллә ничек, матур, иләмле.* Ш.Мөдәррис

**ИЛӘМСЕЗ** *с. диал.* **1.** 1) Төсе-бите, тышкы килеш-килбәте куркыныч, күрексез, шыксыз. *Хатын, бераздан гына аңына килеп, аяк астындагы балтаны күрә һәм Рәхмәтулланы изеп-сытып яткан иләмсез аюның умырткасын чабып өзә...* Я.Зәнкиев. *Минҗан карт тышкы кыяфәте белән бик ямьсез кеше иде: яньчек борынлы, йөнтәс кашлы, черек тешле, чыгынты яңакларына төк үскән, чепи күзле мондый иләмсез адәм якын-тирә авылларда берәү генә --- иде.* М.Мәһдиев

2) Әшәке, яман; күңелгә ятышсыз. *Бу тынгысыз, ямьсез, иләмсез уеннан ул --- котылырга тырышып караса да, кара сакаллы фикер зиһенен тишә, игәүли, бораулый...* Т.Галиуллин. *Дөнья тәмам караңгыланып, яшен камчылары ачыкланганнан-ачыкланды, зәңгәр яктылык культбудка эченә үтеп-үтеп керде. Җитмәсә, иләмсез тавыш туктаусыз баш өстендә дөбердәде.* Ж.Рәхимов

3) Артык зур, бик эре, дәү. *Өстеңә шундый авыр, иләмсез ташлар явып торганда, бәхет турында уйлый, өметләнә аласыңмыни?..* Я.Зәнкиев. *Шунда гына күреп ала Фариз абый иләмсез шкафны.* К.Миңлебаев

**2.** *кис.* Гадәттән тыш, бик, гаять. *Артларыннан әз генә дә калышмыйча, иләмсез зур күләгәләре сөйрәлеп барды.* Н.Фәттах. *Уянып чыккач та Уразаев бәрәңге бакчасына күз сала торган иде, бүген карашы офыкларны басып торган иләмсез кара болытларга --- төште.* Я.Зәнкиев. *Арабызда бер малай да бар. Буйга иләмсез озын, кушаматы – «Баганай».* С.Сөләйманова

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Ямьсез хәлдә, кыяфәтсез булып. *Кеше күзенә иләмсез күренү*

2) Каты итеп, бик нык. *Егет тегене хайван килеш бик иләмсез акыртаакырта кыйнады.* Әкият. *Кояш иләмсез кыздыруын белә.* А.Тимергалин

**ИЛӘМСЕЗЛӘНҮ** *ф. диал.* Матурлыгын, ямен югалту, иләмсезгә әйләнү. *Бераздан инешкә кулын каты итеп селтәде, таянсадагы кар эреп, иләмсезләнеп төшкән учы эзен сөртеп җибәрмәкче булды, ләкин кулын кинәт кире алды.* М.Хуҗин

**Иләмсезләнә бару** Торган саен ныграк иләмсезләнү

**Иләмсезләнә башлау** Ямьсезлек билгеләре күренү

**Иләмсезләнеп бетү** Тәмам, бик нык иләмсезләнү

**Иләмсезләнеп калу** Нинди дә булса вакыттан, сәбәптән соң иләмсезләнү

**Иләмсезләнеп китү** Кинәт, бераз иләмсезләнү. *Уылдык чәчү өчен океан киңлекләрен ташлап елгага кергәч, ана балыкларның гәүдәсе иләмсезләнеп китә ---.* Кызыклы ихтиология

**ИЛӘМСЕЗЛЕК** *и. диал.* 1) Шыксызлык, ямьсезлек, тупаслык. *Иңбашына зур кызыл йолдыз кадаган берәү, бөеренә таянып: – Җырлаудан туктарга! – дип боерды. Шуңадыр, күрәсең, бу юлы резин күсәкләрнең гайрәте чикте, иләмсезлекләре эчкәре үтеп керергә кыймады.* Ә.Гаффар. *Иләмсезлек белән тулы кибет – Ни сайларга монда кызларга?* Ә.Баян

2) Җыйнаксызлык, таркаулык, пөхтәлек житмәү. *Өс-башының иләмсезлеге. Бүлмәнең иләмсезлеге*

**ИЛӘМСЕРӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Төшенке, боек кыяфәттә булу. *Төрбә ташын соңгы тапкыр сыйпап сыктый ирдән калган, илдән калган тол җаный. Иләмсерәп тулгый-тулгый еглауларның кайтавазы ишетелә дүрт яктан.* З.Мансуров

2) Курку, хәвефләнү. *Иләмсерәп уяну*

**ИЛӘМТЕК** *и.* Иләгәннән соң, иләк төбендә калган чүп-чар

**ИЛӘН** *бәйл. иск. кит. к.* **илә**. *Кич белән бозау тиресенең бер читенә: «Сәне христианнарча – алты йөз дә кырыгынчы, безнеңчә тычкан елында Тәңре Илаһи илән Өске Кирмәннән Чалбай хан алае куылды», – дип язып куйды [Илбарис баһадир].* М.Хәбибуллин. *[Хиссәт] Ике ел микъдам бер кешегә мең ике йөз тәңкә акча биргән икән, шул кеше акчаны интереслары илән бергә китергән.* Г.Фаикъ. *Илчеләр күп төрле һәдияләр илән, ничә көннәр юл йөргәннән соң, Һушәң шаһ падишаһка барып җиттеләр.* Дастан

**ИЛӘНҮ** *ф.* 1) *тош. юн. к.* **иләү** I (*1 мәгъ.*). *Килеп җитте бит бу «яз» дигәннәре, ә минем әле чәчүлегем дә иләнмәгән.* И.Гази

2) *күч.* Нинди дә булса әйберне, эшне яки нинди дә булса хезмәткә кешеләрне сайлап алу өчен, аларны каткат, төрле яклап җентекләп тикшерү аша уздыру. *Бу революция безнең иптәшләребезгә имтихан булды. Революционерлар иләнделәр. Без хәзер кем безнең дус, кем дошман икәнлеген ачык аңладык.* Ш.Әхмәдиев

3) *күч. сөйл.* Күп файдаланудан, озак кулланудан таушалу, тузу. *Безнең машина исә, киресенчә, һич тә энәдәнҗептән чыккан гына машина түгел иде, ул инде кимендә бер-ике ел иләнгән машина иде.* Н.Фәттах

4) *күч. сөйл.* Күп авыр мәшәкатьләр күрү, азаплану, михнәт чигү, җәфалану. *Әхмәтсафа килеп кергән вакыт – ир белән хатынның тормыш иләгендә аяусыз иләнеп тә, исән-имин кавышырга насыйп булуына тәмам ышанып бетеп барган чаклары, еллар үтеп тә сүрелмәгән мәхәббәтнең кабат дөрләп кабынган мәле...* Ф.Сафин

5) *күч. сөйл.* Эшсез, шөгыльсез яшәү. *Гыймранның ике малае я авылда, я бистәдә. Ике арада иләнәләр. Башкисәрләр алар.* Н.Гыйматдинова

**Иләнә тору** 1) Бертуктаусыз кабаткабат иләнү. *Вакыты җитүгә, сакчы, тимер капкасын ачып, безне ишегалдына кертеп җибәрде. --- иләнә торгач, ниндидер кабул итү бүлмәсенә килеп эләктек.* М.Әмирханов

**Иләнеп бетү** Бөтенесе дә иләнү; беткәнче иләнү

**ИЛӘНҮ-ЧИЛӘНҮ** *ф.* 1) Берәр мәшәкатьле эштә җәфалану. *Шахтада эшләп иләнү-чиләнү*

2) Күп еллар кагылып-сугылып, гаепсезгә ээзәрлекләнеп, кат-кат тикшерелеп, бер урыннан икенче урынга тибәрелеп йөрү

**ИЛӘРЛЕК** *с.* 1) Иләргә җитәрлек. *Бер иләрлек он*

2) *күч.* Көндәлек кияргә яраклы. *Без җыйган кием-салымнарның берсе дә яңа түгел, барысы да киелгән, ләкин бөтен-таза, «рәхәтләнеп» иләрлек әле...* Ә.Еники

**ИЛӘС** *с.* **1.** 1) Җилкенчәк, ашкынып, дәртләнеп торган, шашкын. *[Тәнкәбикә:] Иләс күңел дулар да янә басылыр.* М.Кәрим. *Күрәсең, «бу як» тиешле тәрбияне биреп җиткермәгән, «тегe як» исә малайның иләс күңелен җилкетүдән туктамаган.* Ф.Хөсни

2) Җилкенүчән, күңеле урыныннан купкан. *Укымыйча гына «лётчик булырга» хыялланучы иләс малай, сумкасын кая җитте шунда ыргытып, уенга чапкан.* Ф.Хөсни

3) Җиңел акыллы, юләр; сәер яклары булган. *[Ул] Юри бераз иләсрәк булып кылана иде.* Г.Әпсәләмов. *Әгәр дә бүтән бер кеше, ягъни мәсәлән, шөкәтсез Сабираның иләс Хәкимҗаны шулай өйләнеп кайтса, кеше ни дә әйтмәс иде әле.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Ашкынучан, ярсу йөрәкле яки җиңел акыллы кеше. *Иләс илле ел илдә йөрсә, илен танымас.* Мәкаль. *Иләс илдән китәр.* Мәкаль. – *Хәзер, анасы, хәзер, Гаязтиннарга гына барып кайтам. – Әй карт иләс!.. – диде Миңҗамал әби.* Г.Шәрәфи

◊ **Иләс йөрәк** Хискә бирелеп китүчән, ашкынып йөрүчән кеше турында. *Җырындагы тирән хисләр белән Сөеп-сыйпап иләс йөрәкне, Кешелекнең – дуслык, дөреслекнең Гүзәллеген безгә өйрәтте.* Х.Туфан

**ИЛӘСЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Җилкенү, ашкыну. *Аның да күпләрне кызыктырып, күпләрне иләсләндереп, күпләрне көнләштереп йөргән яшь чаклары бар иде лә!* Ә.Гаффар. *Җәйге җылы кеше күңелен иләсләндерә, аны бераз бушатып, туарып җибәрә, хөрлеккә, иреккә өнди, матурлыкка ымсындыра.* Г.Гыйльманов

2) Ни кылганын уйламас дәрәҗәгә җиткерү. *Чынында исә мине шәрә хатын-кыз аягын күрү иләсләндерде.* З.Мәхмүди

**Иләсләндерә башлау** Иләсләндерергә тотыну

**Иләсләндереп җибәрү** Кинәттән, көтмәгәндә генә иләсләндерә башлау

**Иләсләндереп кую** Кинәт иләсләндерү

**Иләсләндереп тору** Әледән-әле яки озак вакытлар дәвамында иләсләндерү. *Баягы сәер тавышлар аның зиһенен һаман иләсләндереп тора иде.* Г.Гыйльманов

**ИЛӘСЛӘНҮ** *ф.* 1) Җилкенү, ашкыну, очыну, талпыну, ярсыну. *Улым, балам, кайтасыңны белмәдем шул. Күңелем нидер сизде мәгәр, иләсләнде.* Я.Зәнкиев. *Хатынның кайнар тәне, җылы сулышы аны тәмам гаҗизләндерде, иләсләнер хәлгә китерде.* М.Хәбибуллин. *Сугышта һөҗүмгә барыр алдыннан безнең дә күңел шулай иләсләнә торган иде.* Р.Вәлиев

2) Ни кылганын уйламау, шашыну. *--- байлык туплау, киенү-ясану белән иләсләнгән хатынга тулы ирек кирәк иде.* М.Насыйбуллин

3) Мәсьәләне аек акыл белән хәл итмәү; юләрләнү. – *Су анасы?! – дип кайтарып сорады Камай. – Нинди су анасы, иләсләндеңме әллә?* М.Хәбибуллин. *Шундый буталчык уйлар белән иләсләнүе нәтиҗәсендәдер, бер көнне Саимә әнисе алдында болай дип сүз ачты ---.* Ф.Хөсни

**Иләсләнә бару** Вакыт узган саен иләслеге арту. *--- чибәр хатын-кыз картая барган саен иләсләнә бара ---.* М.Хәбибуллин

**Иләсләнә башлау** Иләсләнү билгеләре күренү. *Ләкин йокы шаукымына иләсләнә башлаган Газиз картны мыштыр-мыштыр ишектән кереп килүче Зәйтүнә кортка кабат теге сәер балыклы дөньяга кайтарды.* Г.Гыйльманов

**Иләсләнә төшү** Бераз, берникадәр иләсләнү. *Назланудан тагын да иләсләнә төшкән Сәфәргали абзый, моны ишетүгә, кесәсендәге акчасын чамалап алды ---.* З.Фәйзи

**Иләсләнеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә, азрак иләсләнү. *Шулай итеп, Фәләх беркемгә дә алай дөньясын онытып гашыйк булып йөрмәде. Дөрес, бер иләсләнеп алды алуын.* В.Нуруллин

**Иләсләнеп бетү** 1) Тәмам иләсләнү; иләсләнү дәрәҗәсенә җитү. *Инде Сара апа да иләсләнеп беткән, Мостафадан текст көтә.* М.Мәһдиев

2) Бөтенләй акылсызлану, юләрләнү

**Иләсләнеп китү** 1) Кинәттән, көтмәгәндә иләсләнү. *Эшли суыткыч, бик тыныч эшли. --- Мин тагын дәртләнеп, иләсләнеп киттем.* Г.Шәрәфи. *Шушы мизгелдән Настёна әйтерсең иләсләнеп китте: аның җанын ниндидер бәхетле, ахмак бер хәлсезлек чолгап алды.* В.Распутин

2) Ниндидер этәргеч сәбәп белән иләсләнү. *Сәфәргали абзый, беренче гыйшык утында янгандагы кебек халәттә булмаса да, Әминәнең җылы карашы белән күңелне эретә торган ягымлы сүзләреннән хәйран гына иләсләнеп киткән иде.* З.Фәйзи

**Иләсләнеп куюю** Кинәт иләсләнү. *Безнең күңел җиләккә барырга иләсләнеп куйды.* Н.Хәсәнов

**Иләсләнеп тору** Иләсләнгән хәлдә булу

**ИЛӘСЛЕК** *и.* Җилкенүчән, иләс булу. *[Тәнкәбикә:] Балам! ...Күңел иләслеге өчен акыл гомер буе җәфа чигә.* М.Кәрим. *Аңа ничек тә ике яшь арасына салкынлык кертергә кирәк, Санькаының күңеленә иләслек саласы бар, ә моның өчен дин кануннары иң кулай нәрсә иде.* Ф.Латыйфи. *Әллә ни тирәннән уйлап түгел, исерек бер иләслеккә бирелеп, --- «Минем колхоз!» дип мактанырга яратудан туган бу мәгънәсез сорау Галләм хаҗи өчен шактый мәгънәле булып чыкты.* Ф.Хөсни

**ИЛӘС-МИЛӘС** *с.* **1.** 1) Ашкынучан, җилкенүчән, шашкын, хыялый. *Чак кына берәр нәрсә булдымы, --- Равилнең болай да иләс-миләс күңеленә вәсвәсә салырга тотына.* А.Гыйләҗев. *Карашларың – сер ташкыны. Хисләрем иләс-миләс.* Г.Морат. *Андрейның берничә мәртәбә искәргәне булды: биредә, югары кышлауда, аның кинәт йөрәге җилкенә башлый, күңелен иләс-миләс уйлар чолгап ала.* В.Распутин

2) Акылга утырып җитмәгән, акылга җиңелрәк. *[Хәсби:] Сорашмадыңмы, нишләп алай алданган? [Тимай:] Иләс-миләс чагы бит. Хатынлыкка алам, дигән тасма теленә ышанган.* Т.Гыйззәт

3) Акылсыз, тилемсә, юләрсыман. *Ул [Савелий Кузьмич] Санькаының барлы-юклы бер атна эчендә кулдан ычкынуын, иләс-миләскә әйләнүен, тамагыннан аш үтмәвен аңлый алмый.* Ф.Латыйфи. *Өянәге тоткан авыру кебек, түшәгендә калтыранып утырган Газинурның иләс-миләс хәлгә төшүен чамалап, Гөлнәзирә үзе дә исен-акылын җуя язды.* Г.Гыйльманов

4) Ярым уяу, ярым исерек хәлдә булу. *Локман карт баядан бирле ике кулы белән сәке йөзлегенә таянып, авызын ача төшеп, йокыдан айный алмаган төсле иләс-миләс бер кыяфәттә утыра иде.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Акылга җиңеләйгән сыман кыяфәттә. *«Дару»ларның, имтомнарның һичбер файдасы тими, ул һаман... иләс-миләс тора. Куркынып, сискәнеп китә, я булмаса, шатлык күрсәтеп, әллә нәрсә сөйләп ташлый.* М.Гафури. *Болай да иләс-миләс утыра иде, кулыннан эш төште. Бар ихтыярын җыеп, мәкаләсен язып бетерергә теләде – барып чыкмады.* А.Гыйләҗев. *Елама, бәгърем, йокыдан уянуга, иләс-миләс баштан, пәри-җен дип торам...* Г.Рәхим

2) Үз-үзен белештермичә, ярым исерек кыяфәттә. *Синең ордым-бәрдем сүзләреңә, җен алыштырган кеше кебек иләс-миләс йөрүләреңә күп түздек, күрмәмешкә салыштык.* Р.Вәлиев. *Кайчакны ул, бара торгач, үзенең болай иләс-миләс йөрүен үзе үк ошатмый.* Г.Бәширов

**3.** *и. мәгъ.* Акылсыз, тилемсә, юләр кеше. *Иләс-миләс игә килмәс.* Мәкаль. *Тәнзилә яшьле күз керфекләре аша ак пәрдәле тәрәзә шәйләде. «Үз өйләренә алып кайткан ич бу иләс-миләс. Әни, ди бит әнә».* Р.Төхфәтуллин. *Хәзер ул, хатыны чит шәһәрләргә китеп сату иткәндә, өй каравылчысы да. Шуннан артыгы ул иләс-миләскә кирәкми дә иде.* Р.Сәгъди

**ИЛӘ́С-МИЛӘС КИЛҮ** *ф.* 1) Күңел ашкыну, шашыну, талпыну, дулкынлану; күңел тынычлыгын югалту. *Бәлки, бүген аның урынына башка берәү килгәндер? Менә яхшы булыр иде! Стрельцовның йөрәге болай сикермәс, күңеле болай иләс-миләс килмәс иде.* И.Гази. *Буш вакытта күбрәк укырга, имтиханнарга әзерләнергә --- кирәк. Ә син (инде ничә көн!) иләс-миләс килеп йөрисең.* Т.Таһиров. *Хәер, ул җыр тәэсиренә бирелгәнче, мин әле бу авылда беренче мәхәббәт хисенә дучар булып иләс-миләс килеп йөрдем.* М.Мәһдиев

2) Юләрсымак, аңгы-миңге булу. *Үзем йокылы кучер төсле, Иләс-миләс килеп утырдым.* М.Җәлил

3) Аңгыралану, миңгерәүләнү. *Иләс-миләс килә башым, Әллә гомерем аз микән?* Җыр

**ИЛӘС-МИЛӘСЛӘНҮ** *ф. к.* **иләс-миләс килү**. *[Хәдичәнең] Күзләре, ничектер, танымаган кешесенә карагандай иләс-миләсләнгән.* М.Хәсәнов. *Күңел ниндидер билгесез, ләкин татлы бер талпыну белән талпынып, иләс-миләсләнеп очына башлый.* И.Гази. *Теге шабашкыларга ияреп, күңелең иләс-миләсләнде, ахры.* А.Гыйләҗев

**Иләс-миләсләнә башлау** Иләс-миләслек билгеләре беленү

**Иләс-миләсләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй иләс-миләсләнү

**Иләс-миләсләнеп китү** Кинәт кенә иләс-миләсләнү. *Гөлчирәттәйнең күңеле иләс-миләсләнеп китте...* С.Сөләйманова. *Бу мәгълүматлар өнсез итте баш врачны. Иләс-миләсләнеп китте, башында берьюлы мең төрле сораулар туды.* М.Хәсәнов. *[Мәүлия:]*

*Эчмә! Синең иләс-миләсләнеп китә торган гадәтең бар.* Х.Ибраһим

**ИЛӘС-МИЛӘСЛӘ́Ү** *ф.* Күңел тынычлыгын алу, дулкынландыру. *Аракы пары, хатын-кыз тәненең исе Мөнирҗанның күңелен иләс-миләсли ---.* Н.Әхмәдиев

**ИЛӘС-МИЛӘСЛЕ́К** *и.* Ашкынучан, иләс-миләс булу. *Күңел һаман иләс-миләс. Чынлап та, кайсысына күбрәк тартылам соң әле? Шушы иләс-миләслегем киләчәктә үз башыма гына булмаса ярый инде.* З.Хөснияр. *Аның да күңелендә иләс-миләслек, ярларына сыешмаслык яшьлеге тулышып ага иде бугай...* А.Гыйләҗев. *Шәкерт абзыйның иләс-миләслеге халык күңелендә матур бер истәлек сыман гына яши иде.* М.Мәһдиев

**ИЛӘТ** *и. бор.* Халык, ил-ат. *Әнә келәттә кисмәк-кисмәк бал ята, бөтен иләтне җыеп ашат: җитә.* Н.Гыйматдинова. *...Бу акканатлы җайдак, тау өстендәге ялангач өмет кебек, гасырлар дәвамында изелгән иләт уйларының йөрәген алгысытып торыр.* Р.Зәйдулла

**ИЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Онны, көрпәдән аерып алу өчен, иләк аша үткәрү. *Зөләйха, амбар ишеген киң ачып, җилпучын яктыга таба тартып, онны иләргә кереште.* А.Гыйләҗев. *[Мөсәпбиха апа] Савыт-сабаларны юып, мыштыр-мыштыр он иләп, камыр басып азапланды.* М.Маликова

2) Бөртекле ашлык, ком яки вак ташны иләк аша үткәреп, чит нәрсәләрдән, чүп-чардан арындыру. *Машина өчен орлыкны аеруча нык иләргә кирәк.* М.Җәлил. *Ком тауларын илиили, кемдер Эзләп ала алтын бөртеген.* Ә.Ситдыйкова

3) *күч.* Вак яңгыр, кар яву, сибәләп тору. *Баш өсләп үтә болытлар, вак кына яңгыр иләп.* Р.Харис. *Ак болытны иләп, карлар ява...* Л.Фәтхетдинова

4) *күч. сөйл.* Берәр эшне, мәсьәләне яки әйберне, кешене һәрьяклап, катkat, җентекләп тикшерү, сынау; сайлап алу. *Егерме өч кеше урынына 203 гариза бирелгән. Бер урынга – унлап кеше. Аяусыз иләделәр безне.* А.Гыйләҗев. *С.Хәким алда әйтелеп узган шигырендә Дәрдемәнднең һәр сүзен «Урал тауларыннан... арчып алган алтын» бөртекләре кебек «иләгеннән иләп йөз кабат» чыгаруына, таләпчәнлегенә сокlануын яшерми.* Т.Галиуллин. *Сөйләүләренә карагaнда, бу иләү процессында беркемгә тырнак белән дә чиртмәгәннәр, һәм, гомумән, бу кыйнау бөтенләй булмаган...* М.Мәһдиев

5) *күч. сөйл.* Озак киеп таушалдыру, туздырып бетерү; артык кадерләп сакламыйча көн дә кию, әрсезгә кию. *Бу туфли нык булды, күптәннән илим*

6) *күч. сөйл.* Эшсез, сәбәпсез, шөгыльсез йөрү, файдасызга йөрү. *Ә Рәхимҗан, үскән саен, әнкәдән читләшә барды. Кая ул үкерә-үкерә хатын тукмаган атаның кулына сугу, өйдә кара тавыш тынганчы, багана хәтле гәүдәсен иләп тышта йөри иде малай.* Н.Гыйматдинова

7) *күч. гади. с.* Кыйнау, тукмау

8) *күч.* Бик каты тиргәү, ачулану. *Миңа, башка председательләрне «иләгәндә», мисал итеп күрсәтү өчен факт, пример кирәк.* М.Хәсәнов. *Аннары, өйгә кайткач, хатын иләде, малай: «Ярый әле, пәлтә урынында мин булмаганмын, мине калдырып, Мәрүскәне алып киткән булыр идең», – ди.* М.Шаһимәрдәнов

9) *күч.* Талау, бөлгенлеккә, хәерчелеккә төшерү. *Без сезгә ышанып харап була яздык. Иләдегез инде, Нигъмәт әфәнде, иләдегез. Алла хәерле кылсын инде.* К.Тинчурин

10) *күч.* Кайгы-хәсрәт күрү, газаплану, җәфа чигү; сыналу. *Следователь Бикчәнтәев алдында үрә катып торганда, бу шомлы шобага миңа гына төшкәндер, ниндидер бер аңлашылмаучылык белән бары тик мине генә «или» торгандыр, дип пошына идем.* И.Салахов. *Туганда алар (кешеләр) барысы да сабый булып туалар. Сабыйларның һәркайсы тигез. Бары язмыш кына кешене төрлечә бүлгәли, таркатa, или.* Юлдаш

11) *күч.* Бер сүз, хәбәрне кат-кат сөйләү, кабат-кабат әйтү. *Әби белән озак сөйләшеп торасы килми, чөнки пароходның зурлыгына тамчы да исе китми. Икенче хәл, әйтик, иптәш малайлар арасында. Менә, ичмасам, алар иләпме илиләр.* Ф.Хөсни. *Чыннан да, төн буе сүз шул турыда гына була иде, или, или иде Валя ирен, мыш-мыш сулап, бер сүз эндәшми ята иде Ахияр!* Р.Зәйдулла

12) *күч.* Киметү, азайту, сирәгәйтү. *Сугыш, --- ирләр сафын нык иләде.* Н.Әхмәдиев

13) *күч.* Кирәкле үзенчәлекләрне, сыйфатларны булдырыр өчен нәрсә белән дә булса тәэсир итү. *[Зөлкафил:] Шәһәр һәр ел саен үзенә меңәрләгән яшь егет-кызны авылдан алып, йотып тора. Һәм ул аны эшкәртә башлый. Шәһәр кешене или, селкетә, калибрлый.* М.Мәһдиев

14) *күч.* Бер яктан икенче якка бәргәләү, селкетү. *Ә машина чайкый да или. Һай, бу сикәлтәле юлларны!..* М.Хәсәнов

**Иләп алу** Кыска гына вакыт эчендә, тиз арада иләү

**Иләп бетерү** 1) Тулысынча, беткәнче иләү. *Мин сөйләп бетергәнче, әнием онны иләп тә бетерде.* Г.Якупова. *Габделнур су алып кергәндә, әнисе өстәлдәге җилпучка он иләп бетергән дә, аның урынына куна тактасы куеп, камыр басарга әзерләнә иде.* Р.Кәрами

2) Тәмам, бик нык иләү. *Тәмам иләп бетергәч кенә, ниндидер бер шәфкатьлесе ишекнең килəсен күтәрә. Изелгән, тукмалган малайлар уенчык мылтыктан аткан борчак кебек салкын кар өстенә сибеләләр.* М.Мәһдиев

**Иләп җибәрү** Тиз арада иләү. *Сөенә-сөенә ашханәдән иләк алып чыгып, җәймәдәге онны әйбәтләп иләп җибәрде.* Ф.Сафин

**Иләп кую** Алдан иләп әзер тоту. *[Хәсби:] Бераз бодай оным бар, иртә беләнгә коймак изеп җибәрербез. Кыл иләктән иләп куярсың.* К.Тинчурин

**Иләп ташлау** 1) Аннан-моннан, тиз-тиз иләү

2) Тиз арада иләү (*7 мәгъ.*), дөмбәсләп ыргыту. *Теге егет шактый таза булып чыкты, берүзе өч егетне күз ачып йомганчы иләп ташлады.* М.Мәһдиев

**Иләп тору** Әле, хәзерге вакытта иләү. *Әнкәй эре иләк белән Он иләп тора кебек.* Н.Акмалов

**Иләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, беткәнче иләү. *Әйе, иң беренче нәүбәттә, нәкъ менә автор үз хезмәтенең теленә тәнкыйть күзе белән карап, аны «нечкә иләктән иләп» чыгарга, турысын әйткәндә, редакцияләү ләззәтен татырга тиеш.* М.Вәлиев

**Иләп яту** Озак вакытлар, бертуктаусыз иләү. *[Шәүкәт:] «Булыш, кырыкмаса кырык кыз дустыңны иләп ята!» – дип, иптәшенә кычкыра.* Я.Зәнкиев

**Иләп тору** Әле, хәзерге вакытта иләү

**Иләп чыгу** Һәрберсен, булган берсен иләү

**Или төшү** Тагын да әйбәтрәк иләү

**ИЛӘ́Ү** III *и.* 1) Төрле чүп-чар, туфрак, агач һ.б.ларны өеп ясалган кырмыска оясы. *Аһ, аякларның сызлаулары! Кырмыска иләвенә түгел, утка тыгасы килгән көннәре вә төннәре күп була иде.* А.Хәлим. *Кырмыскалар учым буйлап йөгереп узды. Гөжләп куйды бөтен бер иләү.* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Берәр нәрсә күпләп җыелган урын

**ИЛӘШЕНҮ** *ф. диал.* Ияләшү, ияләнү. *Климатка иләшенү*

**ИЛӘШТЕРҮ** I *ф. диал.* Ияләндерү. *Аю баласын кулга иләштерү*

**ИЛӘШТЕРҮ** II *ф. лингв.* «Өй» дифтонгын «и»гә әйләндереп әйтү (мәс., *көйләү – киләү, сөйләү – силәү*)

**ИЛӘШҮ** I *ф. диал. к.* **ияләшү**. *Бу – алтын-көмешкә җен иләшкән җир.* М.Гафури. *Тимерләргә күңел иләшкән.* Х.Туфан

**Иләшеп бетү** Берәр кешегә, нәрсәгә, эшкә тәмам күнегү, гадәтләнү, тулысынча ияләшү. *Фәрит абый Римма апага иләшеп бетте инде*

**Иләшеп китү** Берәр әйбергә, эшкә, кешегә күнегә, өйрәнә, гадәтләнә башлау, кыска вакыт эчендә ияләшергә өлгерү. *Лексикография бүлегендә эшли башлагач, янымдагы өстәлдә утырып эшләүче Венерага тиз иләшеп киттем*

**ИЛӘШҮ** II *ф. лингв.* «Өй» дифтонгы «и»гә әйләнеп әйтелү

**ИЛБАСАР** *и.* **1.** Башка халыкларның мөстәкыйльлеген бетереп, алар яшәгән территорияне яулап алган дәүләт, ил яки аерым кеше җитәкчелегендәге төркем. *Гасырлардан калган бәясез истәлекләрне немец илбасарлары хәрабә хәленә китергән булганнар.* С.Сөләйманова. *Ермак илбасарлары Искерне талыйлар, хан казнасыннан калган алтын-көмешләрне, бизәнү әйберләрен, кеш туннарны, кыйммәтле тиреләрне чинаша-чинаша бүлешәләр...* Я.Зәнкиев. *Котылып торыйк илбасардан, дибез. Ләкин язмаган икән: немец тимер юл күперен шартлаткан булып чыкты.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Башка халыклар яши торган территорияне яулап алучы. *Илбасар дәүләтләр һөҗүменнән имин булырга кирәк.* Г.Гобәй. *Хан салымнарны халык күтәрәлгәнчә салырга, угры түрәләрне җәзаларга, илбасар сугышлар алып бармаска тиеш.* Р.Зәйнуллин

**ИЛБАСАРЛА́РЧА** *рәв.* Илбасарларга хас, илбасарлар кебек, илбасарлар төсле. *Фашистларның илбасарларча һөҗүме*

**ИЛБАСАРЛЫК** *и.* Илбасар (2*мәгъ.*) булу, баскынчылык. *Болгар иле ярты Азияне яулап алган рәхимсез һәм дәһшәтле дошман һөҗүмен үз күкрәге белән каршылап, --- илбасарлык гайрәтен шиңдереп тора...* М.Мәхмүтов

**ИЛБАСКЫН** *и. сир. к.* **илбасар**. *Чылтырап аккан салкын чишмә өстенә Илбаскыннар зиндан кормасын.* М.Хөсәен

**ИЛБАШ** *и. неол.* Ил хуҗасы, ил башлыгы, ил белән идарә итүче; ил, дәүләт, республика, өлкә һ.б.ның җитәкчесе; президент. *Ире үлгәч, улы яшь булу сәбәпле, Таңана атлы хатыны илбашына әйләнә.* М.Хәбибуллин. *Ректор доктор, профессор була. Аннан, ректорларны бит бездә илбашы үзе тәкъдим итә, диләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Борын-борыннан килгән гадәт буенча, Алтын Урда ханы янына килгән һәр чит ил кешесен – илчеме ул яки илбашы үземе – төрле гөнаһлардан, начар ниятләрдән арынырга ярдәм итә дип саналган учак аша үткәргәннәр.* Мирас

**ИЛБӘК** *с. диал.* 1) Булган әйберләрен кешедән кызганмый торган, юмарт. *Күршебез илбәк: сораган әйберне бирә*

2) Кече күңелле, кунакчыл, якты чырайлы, ачык йөзле, илгәзәк

**ИЛБИК** *и. бор.* 1) Борынгы татарларда ил җитәкчесе

2) Баш кеше, башлык

**ИЛГӘЗӘК** *с.* **1.** 1) Кешегә карата ачык, мөлаем карашлы, тиз аралашучан. *Кемнәрдер – коткыга ышанып, кайберәүләр – илгәзәк күңеллеләр – туган төякләрен җирсеп-сагынып кайтканнар...* А.Гыйләҗев. *Бу хатынның илгәзәк күңелле булуына сокланды.* Казан утлары

2) Йөремсәк, бер урында гына торырга яратмаучан, җилбәзәк. *Зәкия дә аның кызыл яулыгын күреп калды, ул да, исе китмичә генә: «Һай, илгәзәк тә инде бу Бибинур! Кичкә безгә ашка керәсе бар, тагын каядыр чыгып китте әле», – дип уйлап алды.* А.Гыйләҗев

3) *сир.* Юаш, яхшы холыклы. *«Коба сыер» дигәне – безнең абзарда минем иң яраткан малым. Юаш ул. Тыңлаучан, илгәзәк.* М.Кәрим

4) *куч.* Чамадан тыш мут, уйнак күңелле, юма телле. *Синең ул чактагы кайнар хисләрең сүнгән (әгәр булсалар), синең илгәзәк күңелеңне инде читятлар җилкендергән иде.* Юлдаш

**2.** *рәв. мәгъ.* Ачык йөз белән, үз итеп, якын күреп. *Мине күргәч, кәефе килгәндәй булды, бик ачык, бик илгәзәк каршылады.* Б.Камалов

**ИЛГӘЗӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Үзен илгәзәк тоту, илгәзәккә әйләнү, илгәзәк булу

2) *куч.* Артык мутлану, кылану; уйнаклау. *Иртән ара-тирә япа-ялгыз очып килгән кар бөртекләренең инде мутланып, илгәзәкләнеп, төрле яктан бөтерелгәләнүләре дә кешеләрнең кәефен тырный алмый.* А.Гыйләҗев

**Илгәзәкләнә башлау** Илгәзәклек билгеләре барлыкка килү

**Илгәзәкләнә бару** Вакыт узган саен ныграк илгәзәкләнү

**Илгәзәкләнеп китү** Кинәт кенә илгәзәкләнү

**ИЛГӘЗӘКЛЕК** *и.* 1) Киң күңеллелек, ягымлылык, кунакчыллык, ачык йөзлелек. *Хатыны – бер учлап тотарлык кына нечкә билле, гел елмаеп сөйләшә торган апа – үзенең илгәзәклеге белән мине әсир итте дә куйды.* Н.Мусин. *Мөлаем йөзендә кешегә карата илгәзәклек чаткысы һич тә сүнми иде.* Х.Камалов

2) *куч.* Мутлык, кыланчыклык

**ИЛГӘСӘК** *с. диал.* 1) Кеше белән тиз аралашучан, ачык йөзле. *Диләрә кызыбызны илгәсәк булганы өчен яраттык*

2) Үз туган җирен, Ватанын сөюче

**ИЛГӘСӘР** *и. диал.* Бөтен тирәякка билгеле тиле; илнең тилесе, исәр. *Ә шагыйрен танымаган түрәләрдә өмет юк... диде [Ихсан]. Шундыйлар, илнең түренә басу өчен, бүтәннәрне гаепкә күмеп черчек эзлиләр, --- диде. Илгәсәрләр андыйлар, ил тиләләренең тиләләре, дип бәя кылды.* М.Хуҗин

**ИЛГИЗӘК** *с.* Ил гизәргә яратучы. *Корыч коючылар, шахтёрлар арасында еш очрый торган үзебезнең Минһәхмәтләр, Габдуллалар – әнә шул Татарстан туфрагында туып тернәкләнгән илгизәкләрнең балалары алар.* А.Гыйләҗев. *Илгизәк җанлы кеше ул [Р.Мостафин]: БАМын да төзешә, ерак Чукоткада Билибино атом электр станциясен төзүдә дә катнаша, Якутиядә дә эшләп кайта.* Казан утлары

**ИЛГИЗӘР** *и.* **1.** Сәяхәттә йөрүче, дөнья гизүче, сәяхәт итүче, сәяхәтче. *Бервакыт мин аның явыз башын сугып ярырмын да... илгизәр булып китәрмен.* М.Фәйзи. *Тимофеевна илгизәрләргә үзенең кимсетелү һәм нужа тулы тормышын сөйләп бирә.* М.Максуд

**2.** *с. мәгъ.* Сәяхәт итәргә, дөнья гизәргә яратучан. *Бу елгыр малайлардан бөтенесен дә көтәргә була, болар инде – илгизәр халык.* Р.Габделхакова. *Көнбатыш илләрендә илгизәр гарәп купецлары йөри башлаганнар.* Урта гасырлар тарихы

**ИЛГИЗӘРЛЕК** *и.* Сәяхәтче, илгизәр булу, сәяхәтчелек. *Кызның илгизәрлеге әтисенең әнә шул кайгылы хикәятләрен тыңлаган елларда тугандыр, бәлки.* Л.Ихсанова. *Белмәгән, таныш түгел җир, бер караганда, куркыта. Икенче яктан, – үзенә тарта. Илгизәрлек, сәяхәтләргә хирыслык адәм баласының холкында шул.* Р.Мулланурова. *Тегермәнгә ияләшкән эт он яламыйча түзә алмаган шикелле, илгизәрлек гадәте канга сеңгәч, бер урында утыру өянәкле чир кичерү белән бер икән шул.* Ә.Моталлапов

**ИЛДӘТНӘ** *и. диал.* Өйдән өйгә кереп, бер эшсез, вакытны бушка уздырып йөрүче, бիлөмче хатын. *[Оекбаш] Башын су итеп, Авыл арасын ду итеп, Ул йөрер юртаклап, Илдән кайтмас илдәтнә.* Дастан

**ИЛДӘШ** *и.* 1) Кем белән дә булса ватаннары уртак булган, бер илдә туып үскән кеше; ватандаш. *Сезнең янытызга килдек, илдәшләр.* Б.Камалов. *Болардан тыш безнең илдәшебез, газетачы Мөхәррәм Фәйзи Тугайның да бу мәшһүр хатынга багышланган зур бер хезмәте чыккан иде.* Г.Баттал. *Шәркый Төркестан халыкларының мәгарифен үстерү, югары күтәрү юлында фидакарьләрчә тырышып эшләгән илдәшләребезнең исемнәрен тагын да бик күпләп санап булыр иде.* М.Госманов

2) *сөйл.* Бер якта, бер урында туып үскән яки яшәгән кеше; якташ. *Мәйдан уртасында ялгызы калган сөрәнче егет --- сузып-сузып оран салды: – Газиз кардәшләр, куркусыз илдәшләр, --- батыр җирдәшләр!* М.Латыйфи. *Рашатның шигырьләре конкрет җирлектә туа – аларда безгә кадерле замандашлар язмышы, нык рухлы, иманы камил илдәшләр.* Казан утлары

3) Билгеле бер дәүләт гражданлыгындагы кеше. *Ул [Янгураз] әле бу вакыт киләчәктә Һамбург университетының юрфагын тәмамлаячагын, АКШ илдәшенә әверелеп, «Америка тавышы» радиосында татарча тапшыруларны башлап җибәрәчәген, --- белми иде.* Т.Әйди

**ИЛЕ** *с. диал.* Ие булган, уңайлы, җайлы, рәтле. *Әле синдә мужик тупаслыгы, Тыңла, яшьтәш, бераз иле бул. Булса булыр, булмаса юк, дию – Колхоз өчен кул сүз түгел ул.* Ф.Кәрим

**ИЛЕГҮ** *ф. диал.* Берәр мохиткә, кешеләргә ияләнү, күнегү, үзләшү. *Бутачыктай булганмын, Җим бирсәң дә илекмәм.* Дастан. – *Таңга чаклы күңел ачабыз, дигән идең, нишләп иртәләдең? – дип каршылады бабай. – Илекмәс җандыр син, кызым.* Н.Гыйматдинова. – *Их-ма, хәсрәте! Ни апаң, ни абыең авылга илекмәде, – диде әтисе, көрсенеп.* Н.Гыйматдинова

**Илегә башлау** Бераз илегү

**Илегә бару** Акрынлап илегү

**Илегә төшү** Бераз илегү

**Илегеп бетү** Берәр мохиткә тәмам күнегү, тулысынча ияләшү, илегү

**Илегеп килү** Аз-азлап, акрынлап илегү

**Илегеп китү** Бераз, берникадәр ияләнү, илегү

**ИЛЕК** *и. диал. зоол.* Боланнар семьялыгыннан, кырда, урманда яши торган күшәүче хайван, кыр кәҗәсе,

урман кәҗәсе; *русчасы:* **косуля**. *Көз дә бер айга коммуна егетләре печән чабарга киләләр, --- Рөстәм аларга илек атып бирә.* Сөембикә

**ИЛЕМ** *и. тар.* Сугышчы; гадәттән тыш зур гәүдәле көчле кеше, алып

**ИЛЕРЕК** *и. диал.* Йоклаган вакытта, урыннан торып, аңсыз рәвештә, саташып, нәрсә дә булса эшләп йөри торган кеше; лунатизм белән авыручы кеше

**ИЛЕРЕКЛЕК** *и. диал.* Илерек булу

**ИЛЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Ямьсез итеп, күңелгә борчу сала торган ачы тавыш белән кычкыру, акыру. *– Ничек... үлде?.. – дип, ачыргаланып кычкырды ул үзен белештермичә... – Сез... Сез... нигә әнием янына кертмәдегез?! – дип илерде ул [Гөлҗиһан].* Ф.Сафин. *Әнисенең илерүләре, Борьканың үксүләре малайның күңелендә ачы нәфрәт уята.* В.Шурлыгин // Үкереп елау. *Уразаев үзенең кемлеген белдергәч, яшь хатын кулындагы бәбәйне әнкәсенә бирде дә Уразаевны кочаклап алды. «Папа, папочка!» – дип илерде ул.* Я.Зәнкиев. *– Нинди гөнаһларым өчен адәм күтәрә алмаслык сынаулар бирдең син миңа картлык көннәремдә? – дип, шашынашашына илерде карчык.* Ә.Сафиуллин

2) Йокы аралаш саташып йөрү

**2. илереп, илереп-илереп** *рәв. мәгъ.* 1) Үкереп, кычкырып, үз-үзен белештермичә. *Ике апамның сәке өстендә, башларын чәнчеп куйган тезләренә салып, илереп елаулары күз алдымнан китәсе дә түгел.* Х.Сарьян. *Үлем-дәһшәт арасында мин илереп-илереп бәргәләнәм, өч ягымдагы өч улымны кая куярга белмичә, --- кыл буанакка нәфис аягы чуалган сары песнәк төсле чәбәләнәм.* А.Гыйләҗев. *– Ул чаклы илереп елама, Зөһрә, анаңның җаны тынгылык тапмас, – диде берсе.* М.Маликова

2) Аптырап, ни эшләргә белмичә, каушап калып. *Кояшлы, салкынча иртәнге һаваны тетрәтеп ишетелгән сугыш быргысының канлы тавышы --- тыныч халыкны өркетеп җибәрде. Намаздан әле кузгалган мөэминнәр илереп йөгерешә башладылар.* Ф.Яхин

**Илерә башлау** Илерергә тотыну. *Егетләрнең буш кул белән кайтканлыгын күргәч, янә илерә башлады.* Р.Батулла

**Илереп җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә илерә башлау. *--- колак төбендә үк чәрелдәвек тавыш белән берәүнең ачыргаланып илереп җибәрүенә күзен ачса, тычканмы, күсеме дигәне – сыек кына гәүдәле бер үсмернең кулы булып чыкты.* К.Миңлебаев

**ИЛ-ҖИЛ** *җый. и. к.* **ил-җир** (*1 мәгъ.*). *Анда аның апасының улы, гаярь егет, ил-җил күргән Фәтхулла яши икән.* М.Мәһдиев

**ИЛ-ҖИР** *җый. и.* 1) Төрле илләр, җирләр. *Малай вакытта бөтен кызыкканым: ил-җир күрү, дөнья гизү, авылга кайтып, беренче чиратта, аны шаккатыру иде.* М.Мәһдиев. *Илләр-җирләр болгана, ярлы халыкның күзе тонган, бер-бер хәл чыкмагае, дидем.* Н.Гыйматдинова. *Ә менә Әлфия --- ил-җирләргә сибелгән барча татарларның да мәркәзе булган Казанын ташлап, шыксыз, салкын Магаданда – җәһәннәм астында яшәп ята.* Ә.Сафиуллин

2) Туган ил. *Яуга чыккан илен-җирен саклап, Үлсә үлгән, башын имәгән.* К.Мостафин. *Сугыш түгел, тормыш өчен Ил-җир кирәк халкыма!* Р.Рахман

**ИЛ-ЙОРТ** *җый. и.* 1) Туган ил, туган як, туган авыл, йорт-җир. *Мин – Казан кешесе. Казан җире – минем өчен газиз туфрак, газиз ил-йорт...* Ф.Латыйфи. *Анда төрле ырулар җыйналып, мәйдан ачып, башкорт ил-йорт хәлләре хакында киңәшләшкән, карарлар чыгарган...* Г.Хөсәенов

2) Туган як халкы; җирле халык. *Әйткәндәй, кызлар уены, яшьләр җыены дигән матур йолаларның олысы борын заман, зур җыен рәвешендә, башкортларның ил-йорт бәйрәме булган.* Г.Хөсәенов. *Илең-йортың, күзләрен мөлдерәтеп, безгә карый, без – тылдагылар – аның ышанычы, таянычы...* Н.Гыйматдинова

**ИЛ-КӨН** *җый. и.* 1) Ил һәм аның халкы, илдәге барлык кешеләр. *Шәмсиягә үрелеп азапланучылар аз булмады булуын, Мостафа җир белән күк арасында йөрүчеләрдән түгел, барысын да ишетеп, күреп яши – чибәркәй нык холыклы булды, илгә-көнгә яманатын чыгармады.* Ф.Сафин. *Илдә-көндә йөреп, дөнья күргән ир-атның яңадан шушы салам түбә астына керәсе килмәс.* Ф.Яруллин. *Үзегез беләсез: моңарчы илгә-көнгә зыян-зәрәт салган кеше түгел ләбаса!* М.Хәсәнов

2) Тормыш, көнкүреш, хуҗалык. *Халык, арба басып киткән түмгәкне яңадан өяргә керешкән кырмыска күчедәй, мәш килеп, үзенең илен-көнен торгызырга, рәткә кертергә тотынды.* Ә.Еники

◊ **Илдә-көндә бер** Тирә-якта, халык арасында абруйлы, хөрмәткә ия кеше. **Ил-көн алдында** Халык, тирә-күрше күз алдында, кеше арасында. **Ил-көн арасында** *к.* **ил-көн алдында**. **Ил-көн белән бау ишү** Халык белән бергә булу. *Синең аркада бөтенесе белән дә әчелешле булып бетсә, ничекләр торыр Арыслан. Ир-ат ил-көн белән бау ишә, диләр.* Н.Гыйматдинова. **Ил-көн итү** Өйләнеп, гаилә корып, төпләнеп тормыш итү

**ИЛ-КҮЗ** *җый. и.* 1) *тар.* Илдәге барча эшче көч, салым түләүчеләр

2) Туган як, туган авыл халкы. *– Сез монда нишләп йөрисез, әти кайтса?.. – Әткәгез хәзрәткә чакырулы, ---. – Шулай да анысы... Әмма көпә-көндез, ил-күз аек чакта, дигәнем...* Ф.Яхин. *– Гомеремне беләсең, – дип дәвам итте ул [Хәбибрахман], ара-тирә Рәхимҗан бабайның йөзенә төбәп карап. – Бар да ил-күз алдында узды.* А.Гыйләҗев. *Ил-күз алларында рисвайлар итү өчен үстердеммени соң мин сине!* М.Хәсәнов

◊ **Ил-күз тынгач** Кич булып, халык йоклагач, кешеләр йөрүдән туктагач, башкалар сизмәслек аулак вакыт җиткәч. *– Бүген, караңгы төшеп, ил-күз тынгач та, абзарга өйгән печән буена килсен – көтәрмен, – дип әйттерде.* Г.Ибраһимов

**ИЛКҮЛӘМ** *с.* Бөтен ил өчен гомуми, бөтен ил күләмендә мөһим, әһәмиятле. *Бу укучы мәктәбебезнең генә горурлыгы түгел, илкүләм шәхес булачак әле.* Ф.Яхин. *Илкүләм олы эшләр башкаручы нефтехимикларга бик кирәк бит сез.* Р.Хисмәтуллин. *Әнә шул илкүләм олы вакыйгада мин комитет члены – делегат булып катнаштым.* И.Юзеев

**ИЛ-КҮРШЕ** *җый. и.* Тирә-як, күрше-тирә халкы, туган авыл халкы. *Үз авылларына, күрше авылларга сүз салганнар, ләкин кияү чыкмаган. Шуннан соң алар, ил-күршедән өмет өзеп, алтмыш чакрымдагы чит авылга киткәннәр.* Әкият. *Бик исән-сау, дигән, ил-күршегә бик күп сәлам әйткән.* Г.Бәширов

◊ **Ил-күрше булып** Йорт корып, үзара күршеләр булып (яшәү турында)

**И́ЛЛА** *кис. гар.* **1.** *к.* **иллә 1.** *– Илла да, апасы, көттерергә яратасың икән! – ди бу, бөтен бүлмәгә шаулап.* Н.Фәттах. *Рашатка да, аның тарафына керфек тә сирпемичә, «выжт» итеп үтеп кенә китәргә кирәк иде. Шулай итсә, илла да яхшы булыр иде лә!* М.Маликова

**2.** *терк. мәгъ. к.* **иллә 2.** *Алай-болай курыксагыз, үзем җавап бирермен, илла алар акчаны алдан бирә барырлар, дидем.* С.Рәмиев

**И́ЛЛАЛЛА** (**ИЛЛА АЛЛА**) *рәв. сөйл.* Көчкә-көчкә, көч-хәл белән; ах-вах килеп. --- *Шәмси илла алла гына Мәкәрҗәгә килмәенчә калып, беренче августсыз бушый алмады.* Г.Исхакый. *Көчкә, иллалла белән бер юан түтәй табып бирделәр.* Х.Сарьян

◊ **Иллалла, биш мулла белән** Көчхәл белән, көчкә-көчкә, бик читенлек белән; ах-вах килеп. *Шарлап аккан инеш буеннан барганда, кунакларыбызның берсе, суның каршы якасында алтын чәчәк күреп: – Нинди гүзәл! Үрелеп кенә ала торган булса икән! – дип кычкырып җибәрде. – Телисезме, мин сезгә ул чәчәкне бүләк итәм, – дидем мин ---. Иллалла, биш мулла белән теге якка чыгуын чыктым, әмма алтын чәчәкне өзеп ала алмадым.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Иллалла, кырык мулла белән** *к.* **иллалла, биш мулла белән** *Әле генә иллалла, кырык мулла белән хан казнасына биш йөз алтын салым китереп салдым.* Н.Исәнбәт. **Иллалла, кырык хәйлә белән** Бик интегеп, көч җитмәгән җирдә хәйлә белән (нинди дә булса эш эшләү турында)

**И́ЛЛӘ** *кис.* **1.** Берәр төрле тойгыны, хисне белдерү чарасы буларак кулланыла; бик тә, бигрәк тә, аеруча. *– Иллә әйбәт иткәнсез, иптәш инспектор, күптән шулай кирәк иде, --- – дип килеп керде Мөршидә ханым өлкән инспектор Мәүлетов кабинетына.* Ф.Яруллин. *– Иллә дә матур икән чәчәкләрегез! – диде хатын, әкрен тавыш белән...* М.Маликова. *– Уңган хатын кар өстендә казан кайната, дип сөйлиләр иде, иллә дөрес икән, – диде Газинур һәм, Миңнурый янына килеп, аның уң битеннән үбеп алды.* Г.Әпсәләмов

**2.** *терк. мәгъ.* Ләкин, әмма, тик, әгәр. *[Ул] Нидер әйтмәкче булды, иреннәре кыймыл да кыймыл килде, иллә сүзен әвәләп чыгара алмады.* Ф.Хөсни. *Син урла, сугыш, кыйна, җимер – халык, ахыр чутта, боларны оныта, гафу итә ала. Иллә дә инде кияүгә чыкмаган көе генә юаная башлыйсың икән – авылда яшәргә сиңа урын юк.* М.Мәһдиев

**И́ЛЛӘ ДӘ МӘГӘР** *кис. к.* **иллә-мәгәр** (*1 мәгъ.*). *Шунысын гына тойдым: иллә дә мәгәр маршалның кулындагы куәт!* М.Мәһдиев

**И́ЛЛӘМ** *кис. к.* **иллә 1.** *Кыз җитез, елгыр гына, элеккеге фильмнардагы тәрбияле курсисткалар төсле, тезләрен чүккәндәй итте. Илләм килешле чыкты.* Т.Галиуллин

**И́ЛЛӘМӘ** *кис. к.* **иллә 1.** *[Мирсәет] Сикереп, Хәйрулланың өстенә кунды да муеныннан борып көрткә екты. Өстенә менеп атланды да акыртырга тотынды тегене. Илләмә биргәләде инде.* З.Зәйнуллин

**И́ЛЛӘ-МӘГӘР** *кис. сөйл.* 1) Аеруча, бик тә, бигрәк тә. *Иллә-мәгәр, шыксыз, тынгысыз бу тирәдәге юллар.* М.Хәсәнов

2) Көчәйтү төсмере белән ачуланып яки чын йөрәктән ышандырып әйтелә; әмма ләкин. *Иллә-мәгәр, җепнең очы күренмәсен һәм судка эләгерлек булмасын.* Ш.Камал. --- *кызларның моңарчы да тимерчыбык киртәләр белән тыгыз чолганган зоналарны күргәннәре бар иде, иллә-мәгәр, ят, куркыныч бер капка төбенә барып туктагач, зонага куркып, шикләнеп карадылар.* Я.Зәнкиев. *Үләрмен, иллә-мәгәр, үз сүземне итәрмен.* Ш.Камал

**ИЛЛӘРАРА** *с.* Илләр арасында була торган, яшәп килгән, гамәлдә була, эшләнелә торган. *Русь илен дә, Болгар йортны да арка терәкле иткән Килешү – илләрара татулыкның кадерен арттырачак Килешү төзелде.* Р.Харис

**ИЛЛЕ** I *сан* 1) Кырык тугыздан соң килгән бөтен сан, шул санның микъдарын һәм цифрын белдергән берәмлек атамасы. *Илленең теге ягына үрмәләгән Галләм өчен хәтер елның һәр фасылына хас.* Н.Гыйматдинова. *Хәер, сәгатьнең кирәге дә юк, Тәбриянең секундлары төгәл иде: – Кырык биш... илле... илле алты...* М.Маликова. *Атна саен банкет. Кемгә илле, кемгә алтмыш, кемгә җитмеш.* М.Мәһдиев

2) Шул санның микъдары. *– Зөләйхәттәйне шулхәтле сарандыр дип белми идем, илле тиен акчасын җәлләп, билетсыз кереп китте, – диде Нәсимә...* Л.Ихсанова. *Хәйрүшнең кулында – илле сум акча. Илле сум!* М.Хәсәнов. *Ә Дәүләтшинның баш өстендә, икенче кафедрада, илле яшендәге кеше утыра, ул әле тиз генә китмәячәк, шулай итеп, Дәүләтшинның бөтен өмете профессор Ильясова урындыгында иде.* М.Маликова

◊ **Илле батман Идел суы** *сөйл.* Тәмсез аш, сыек чәй турында. *Бу ни бу, илле батман Идел суы? Кеше төсле, рәтләп, аш та пешерә белмисең.* Т.Гыйззәт. **Илле иләктән уздыру** Каткат тикшерү. *Диссертацияне илле иләктән уздыру*

**ИЛЛЕ** II *и.* 6 арпа киңлегенә яки якынча 18 мм га туры килгән, бармак киңлегенә тигез озынлыктагы борынгы үлчәү берәмлеге. *Кичен мыгырдап кына утырган юан, усал марҗалар, нәзек билле, битләренә бер илле кершән яккан апалар да төн җиткәнче камыр кебек йомшарып, бәби-балага мәрхәмәтле сүзләр белән багалар иде.* Я.Зәнкиев. *Өч тәлинкәне ашап бетергәч, марҗа апаның сирәк кашлары бер илле өскә күтәрелгәч, --- ул [марҗа] чуеннан кушйодрык хәтле ит калҗасын --- тәлинкәмә китереп салды.* А.Гыйләҗев. *Кыш салкын булса да, җир җылы, туфрак ике илледән дә тирәнрәк туңмаган булып чыкты.* А.Хәлим

**ИЛЛЕ-АЛТМЫШ** *сан* Илле белән алтмыш арасында, якынча илле белән алтмыш тирәсе. --- *җир асты*

*магистральләре буенча тәүлегенә илле-алтмыш тимер юл составы булырлык нефтьне кудыру установкалары булган Казнакай --- ничектер, ятим калдырылгандай тоелды Вариска.* М.Хәсәнов. *Әллә син илле-алтмыш сумнан кибеткә зыян килер дип уйлыйсыңмы?* Д.Гайнетдинова

**ИЛЛЕК** *и. сир.* Ил, дәүләт булу. *Илнең иллеге иреннән танылыр, илнең байлыгы – җиреннән.* Мәкаль

**ИЛЛЕЛӘП** *сан* Якынча илле, илле тирәсе булуны белдергән чама саны. *Авылны бөтенләй йөреп чыга алмадык – иллеләп йортта гына булдык та кайту ягына борылдык.* Н.Фәттах. *Кәҗә тәкәсе хәтле генә автобуска иллеләп кеше кереп тулгач, сулар һава калмады.* А.Гыйләҗев. *Төрлесеннән өч йөз тире, иллеләп чүлмәк, --- ярты батман кипкән балык алды.* М.Хәбибуллин

**ИЛЛЕЛЕ** *с.* 1) Илленче размерлы. *Ботинкасы, ботинкасы, Ботинкасы иллеле, Авторитетлы егетләрнең Гәүдәсеннән билгеле*. Җыр

2) *сөйл*. Илленче номерлы. *Иллеле кәтүк*

**ИЛЛЕЛЕК** I *и.* Илле сумлык кәгазь акча. *Сумкасына иллелекләр тутырып кайткан кассирны баш бухгалтер бусага төбендә үк каршылый.* М.Насыйбуллин. *Туй бүләген әйтеп, иллелекне дә бирдем...* М.Галиев. *Акча кесәгә сыймый. Иллелекләр әтәч булып кычкыра башлады.* М.Юныс

**ИЛЛЕЛЕК** II *и.* Бармак киңлеге. *Бу юлы коньякны Вәсилә салды. Аз гына, бармак иллелеге генә итеп салды.* М.Хәсәнов

**ИЛЛЕНЧЕ** *сан* Бер-бер артлы санаганда урын тәртибе иллегә туры килгән тәртип саны. *Егерменче гасырның илленче еллары иде бу.* Г.Галиева. *Илленче еллардагы җан җәзасы авырлык ягыннан тән җәзасыннан бер дә ким түгел иде.* А.Гыйләҗев. *Шуңа күрә аларның җәһәннәм артындагы тын шәһәрчекләрендә дә илленче еллар азагында джаз оркестрлары, үз эстрада җырчылары пәйда булды ---*. Р.Мирхәйдәров

**ИЛЛЕШӘР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) илле, бертигез күләмдә илле булуны белдергән бүлем саны. *Никах өчен муллага ике як иллешәр тиен табып бирергә булдылар.* Г.Ибраһимов. *Үземне иллешәр чакрымнан килеп алалар, минсиңайтим, яшерен-батырын түгел.* Г.Гыйльманов. *– Дус кеше, тиз бул! Чират безнеке... – дип, сәгатенә иллешәр тиен түләп алган билетларын күрсәтте.* М.Хәсәнов

**ИЛЛЕШӘРЛӘП** *рәв.* Иллешәргә бүлеп, иллешәр-иллешәр итеп (булып). *Белү генә түгел, бу аның канына сеңгән иде, шуңа күрә ул [Һарун] бер дә юкка акча туздырырга, сораган бер кешегә «Аллаһу әкбәр» өчен иллешәрләп акча чыгарып бирергә күнекмәгән иде.* Н.Фәттах

**ИЛЛЕШӘРЛЕК** *и. к.* **иллелек** I. *Ике данә иллешәрлекне күрсәтү*

**ИЛЛЮЗИОНИЗМ** *и. фр.* 1) *филос.* Тышкы дөньяны күз буяу, тойгыларны алдау, хыял гына (иллюзия) дип саный торган фәлсәфи юнәлеш

2) Күз буу, алдауга корылган цирк һәм эстрада сәнгатенең бер төре. *Күз буу (иллюзионизм), төрле фокуслар күрсәтү һәм цирк уеннары уйнау иң элек борынгы Мисырда барлыкка килә.* Н.Фәттах

**ИЛЛЮЗИОНИСТ** *и. фр.* 1) Иллюзионизм (*1 мәгъ.*) тарафдары

2) Катлаулы һәм күпкырлы җайланмалар ярдәмендә фокуслар күрсәтүче цирк артисты. *[Харис:] Чумак әфсенләгән суны эчеп кенә хәл алдым, дигәннәрен үземнең ишеткәнем бар. Дөрес, мин үзем ышанмыйм, андыйларны шарлатанга саныйм. – Алай дип кенә булмый... Иллюзионистлар бар бит. Гипнозны инде фән дә таный.* М.Маликова. *Коръәннең ахыргы битләренең берсендә иде ул сүрә. Мин аны циркта фокус күрсәтүче иллюзионист кебек тиз таптым.* А.Шамов

**ИЛЛЮЗИОНИСТЛЫК** *и.* Иллюзионист булу

**ИЛЛЮ́ЗИЯ** *и. фр. кит.* 1) Тойгыларның алдавы нигезендә чынбарлыкны бозып, ялгыш күз алдына китерү; уйдырмаларны, чынлыкта булмаганны чынбарлык сыман кабул итү. *«Аталар» сүзе строфаны ничек көчле тәмамлый: ул бөтен фикерне йомгаклап килә, ---. Шуның белән шигырь ахырында ату тавышы да яңгырагандай бер иллюзия туа.* Н.Юзиев. *КамАЗ талоннары бездә даими рәвештә туклыкка, иминлеккә чыгу иллюзиясен сакларга тиеш.* А.Хәлим. *--- әйләнә-тирәдәгеләр өчен, болар бер-бер мәзәк сөйләшә икән дигән иллюзия тудыру максаты белән, кычкырып көлеп тә алган булды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Тормышка ашмаслык хыял, өмет, булмастай эш. *Ләкин аның социализм турында коры фразалар һәм иллюзияләр белән исереп йөрүе озак дәвам итми.* М.Җәлил. *Ахыр чиктә ул «мәхәббәт – кеше канындагы ут», «мәхәббәт хыял гына», «мәхәббәт – кешене бәхетле итә торган хыял, иллюзия» дигән нәтиҗәгә китерә.* Р.Гали. *Кирәк түгел безгә иллюзияләр. Җилгә каршы хыял киртәсе.* Ш.Маннур

3) Берәр нәрсә турында дөрес булмаган караш. *Социал-демократ бу буржуаз иллюзияне, --- һәркайда һәм һәркайчан аяусыз фаш итә.* В.Ленин

4) Фокус күрсәтүче иллюзионист номеры

**ИЛЛЮ́ЗИЯЛЕ** *с.* Иллюзия тудырган, чын булмаган, хыялый

**ИЛЛЮ́ЗИЯЛЕЛЕК** *и.* Иллюзиягә бирелү, иллюзияле булу; ялгыш карашка, хыялга бирелү. *Кайбер эшләрдә артык төчелек, иллюзиялелек һәм рәсем сәнгатенең начар үрнәкләренә иярү тенденциясе сизелә.* Х.Якупов

**ИЛЛЮЗОР** *с. лат.* Иллюзиягә нигезләнгән; ялган, уйдырма, буш; хыялда гына була торган, чынбарлык белән бәйләнеше булмаган. *Ә Мотаһир өчен вакыт, гәрчә ул бер символик, иллюзор төшенчә булса да, аның бүгенге яшәешен билгеләүче, аның әле исән икәнлеген күрсәтеп торучы бердәнбер реаль төшенчә.* Ә.Дусайлы. *--- биредә строфа күләмендә генә шигырь – рифмасыз, ә контекстта, башка строфалар белән бәйләнештә караганда, ул рифмалы булып китә... Боларны ерагайтылган (ераклашкан) иллюзор дип атарга мөмкин.* Н.Юзиев. *Сафура үз бәхетен гомерен кәеф-сафа корып уздыруда күрергә тели. Автор исә мондый бәхет идеалының бик иллюзор булуын күрсәтә.* Татар әдәбияты тарихы

**ИЛЛЮЗОРЛЫК** *и.* Иллюзор булу

**ИЛЛЮМИНАТ** *и. лат.* XVIII гасырның икенче яртысында Европада (нигездә Бавариядә) оештырылган яшерен дини-сәяси җәмгыять әгъзасы. *Дини китаплар инде аны кызыксындырмый. Һәм ул, монахлыктан баш тартып, иллюминатлар орденына керә.* Җ.Тәрҗеманов. --- *хөкүмәт --- 1785 елда ул орденны тар-мар итә. Иллюминатларны эзәрлекләү башлана.* Бөтендөнья тарихы

**ИЛЛЮМИНА́ТОР** I *и. лат.* Судноларда, очу аппаратларында калын пыялалы, герметик ябыла торган түгәрәк яки турыпочмаклы тәрәзә. *Иллюминатордан текә яр, очлаеп күтәрелгән таулар, алар арасында агачлар һәм нефть вышкалары, кызыл яулык кебек җилфердәп янган факел, зур-зур нефть чаннары, посёлоклар күренә.* Р.Кәрами. *Бу вакытта Коля самолётта иде инде. Ул, иллюминатор янындагы креслога утыргач та, каш астыннан гына салондагы пассажирларга күз йөртеп чыкты.* М.Насыйбуллин. *Мин иллюминатор аркылы аэродромны күзәтәм.* М.Мәһдиев

**ИЛЛЮМИНА́ТОР** II *и. лат.* 1) Гравюраларны, рәсемнәрне кулдан буяу остасы

2) Иллюминацияләр ясаучы белгеч; пиротехник

**ИЛЛЮМИНА́ЦИЯ** *и. лат.* Берәр тантана, бәйрәм уңае белән урамнарны, йортларны төрле төстәге утлар белән яктырту. *Хисапсыз иллюминацияләр белән бизәлгән йортлар, парадныйлар, зур капкалар күрерсез.* Г.Гобәй. --- *ниһаять, тегермән буасы ягыннан ут җибәрделәр. – Менә, – диде Рушад, – карап калыгыз: безнең як халкының гасырлардан бирле килә торган күңелле бер уены. Боз киткән көнне ел саен бер кич шундый иллюминация була...* М.Мәһдиев. *Капитан электрик лампочкаларны, төрле төскә буяп, чыбыкка тезде дә корылма өстенә матур гына иллюминация ясады.* М.Юныс

**ИЛЛЮМИНА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Утлар белән бизәлү, яктыртылу. *Яңа елга шәһәр урамнары иллюминацияләнгән иде*

**Иллюминацияләнеп бетү** Тулысынча бизәлү, иллюминацияләнү

**ИЛЛЮМИНА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Иллюминация ясау; төрле төстәге утлар белән бизәү

**Иллюминацияләп бетерү** Тулысынча бизәү, иллюминацияләү

**Иллюминацияли башлау** Иллюминацияләргә керешү

**ИЛЛЮСТРАТИВ** *с.* Иллюстрацияләре булган; күрсәтмәле. *Ул --- акыл эшенең әһәмиятен киметкән, «гамәли мәктәпне» иллюстратив мәктәпкә әверелдергән.* Ә.Хуҗиәхмәтов. --- *тарихи-теоретик хезмәттә иллюстратив материал аналитик башлангычны басып китмәскә тиеш.* Казан утлары

**ИЛЛЮСТРА́ТОР** *и. лат. махс.* 1) Текстның эчтәлегенә ярашлы рәсемнәр ясаучы рәссам. *Чынлыкта, ул анда рәссам-ретушер һәм иллюстратор булып эшли, чөнки әдәби мөхәррирлек турында берни дә белми диярлек.* Р.Мостафин. *Шундыйлар рәтенә китап һәм газета-журнал иллюстраторлары М.Галиев белән Г.Гомәров керә.* Мәдәни җомга

2) Сәхнәдәге берәр күренешкә нинди дә булса музыка коралы белән кушылып уйнаучы кеше; аккомпаниатор. *Ул вакытта кинолар тавышсыз була, һәм фильм барышында иллюстраторлар пионинода уйнап торалар.* Ч.Бәхтиярова

**ИЛЛЮСТРА́ТОРЛЫК** *и. махс.* Иллюстратор һөнәре, эше

**ИЛЛЮСТРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Китапта, газета-журналларда басылып чыккан әсәрләрне, текстларны җанландыру һәм басманы сәнгати бизәү өчен бирелгән рәсем. *Язам гына түгел, рәсемнәр дә ясыйм, дигән идем. Кичләрен исә, ни дә булса язмаган чакларымда, басарга алынган хикәяләремә иллюстрацияләр ясыйм.* М.Әмир. *Тукай бит шул чорның алдынгы экономик карашлары ачылган фәнни-публицистик хезмәт белән таныш булса да, үзе аны татарчага тәрҗемә итсә дә, турыдан-туры шул карашларга иллюстрация ясап шигырьләр язмый.* Н.Юзиев

2) Берәр төшенчәне яки фикерне, сүзне анык итеп күз алдына китерү, аңлату яки исбатлау өчен мисал итеп китерелгән образ яки предмет. *Аның күз алдына Карип Ишбулдин яңадан килеп басты. Шәфи Алмаз сөйләгәннәрнең җанлы иллюстрациясе кебек тора иде ул.* Ш.Маннур

3) *әд.* Кешенең эчке дөньясын, рухи халәтен, вакыйгаларның асылын гомумиләштереп сурәтләү чарасы, алымы. *Бу әсәрләрдә каләм осталарына хас югары сәнгатьлелек белән иҗат ителгән сәхифәләр булса да, конфликтның ясалмалылыгы, эчтәлекнең сәяси вакыйгаларны аңлатуга иллюстрация рәвешендә корылган булуы әдипләрнең үзләре ирешкән казанышларыннан чигенүләре иде.* Әдәбият. *Авторның революция алды, революция елларында язылган хикәяләрендә идея, сюжеттан аерылып, публицист фикере итеп бирелә иде. Сюжет шул идеяләргә иллюстрация кебек бер нәрсә генә булып кала иде.* Казан утлары

4) Нинди дә булса сәхнә әсәренә бирелә торган музыкаль кушымта, өстәмә. *«Качкын» операсы – чын мәгънәсе белән опера. Ул музыкаль иллюстрация ролен генә үти торган музыкаль пьеса түгел.* М.Җәлил

**ИЛЛЮСТРА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Иллюстрацияләр белән бирелү. *«Татмедиа» холдингы мәдәният турында иллюстрацияләнгән журнал чыгарачак.* Казан утлары. *Утыз өч мең сүзне эченә алган, --- фразеологик берәмлекләр белән иллюстрацияләнгән «Уйгырча-русча сүзлек» (1968) – аның тарафыннан зур көч куеп, унбиш ел дәвамында алып барылган эшнең бәрәкәтле нәтиҗәсе.* Гасырлар авазы

**ИЛЛЮСТРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Язманың эчтәлеген тулырак күз алдына китерү максатыннан, текстка рәсемнәр бирү. *Теге вакытта юкка җәберләгәнмен үземне, яшь күңел белеп сизенгән икән: Мансуров иллюстрацияләргә алынган хикәя, чынлап та, менеке булган.* М.Әмир. *Рәссамнар Пушкин шигырьләрен иллюстрациялиләр*

2) Фикерне һ.б.ш.ны күз алдына китерү, аңлату яки исбатлау өчен мисаллар куллану. *Ә.Баянов прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануларга бай. Ул*

*җитди проблемалар кузгатырга ярата. Әзер тезисларны иллюстрацияләүдән баш тартып, үзенчә яңалыкка омтылып яши.* Казан утлары

3) Нинди дә булса сәхнә әсәренең тәэсир көчен арттыру өчен, аңа музыкаль бизәлеш өстәү, аккомпонементлык итү. *Кинофильмда геройларның күңел үзгәрешләрен һәм драматик бәрелешләрне [музыкант] музыка теле белән иллюстрацияли.* Җ.Фәйзи

4) *әд.* Кешенең эчке рухи халәтен, вакыйгаларның асылын әдәби таләпләрдән чыгып түгел, өстән генә сурәтләү. *Соңгы елларда эшче темасына язылган әсәрләрнең сәнгать ягыннан йомшак булуы – әдәбиятка журналистларча килү, аны иллюстрацияләү чарасы итеп кенә карауның бер нәтиҗәсе.* С.Шәмси

**Иллюстрацияләп бару** Һәрберсен, булган берсен даими рәвештә иллюстрацияләү

**Иллюстрацияләп бетерү** Иллюстрацияләүне төгәлләү, ахырга кадәр иллюстрацияләү; барысын да иллюстрацияләү

**Иллюстрацияләп килү** Электән, күптәннән даими иллюстрацияләү

**Иллюстрацияләп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм иллюстрацияләү

**Иллюстрацияли башлау** Иллюстрацияләргә тотыну

**ИЛЛЮСТРА́ЦИЯЛӘҮЧЕ** *и. к.* **иллюстратор**. *Яшереп-нитеп торасы юк, аерым елларда безнең поэзиядә тормыш күренешләрен салкын кан белән генә иллюстрацияләүчеләр саны үсте.* Казан утлары

**ИЛЛЮСТРА́ЦИЯЛЕ** *с.* Иллюстрацияләре (*1 мәгъ.*) булган, рәсемле. *Аның ике терсәге арасында иллюстрацияле ниндидер журнал җәелеп ята, битләрендә – зур-зур портретлар.* Ш.Маннур. *Мин алган китаплар сәнгатькә кагылышлы иллюстрацияле дәреслекләр, күренекле рәссамнарның альбомнары, музей каталоглары иде.* Р.Вәлиев. *«Шаһнамә» поэмасының иллюстрацияле төрки тәрҗемәләре.* Мирас

**ИЛЛЮСТРА́ЦИЯЧЕЛЕК** *и.* Әдәби әсәрләрдә күтәрелгән хәл-күренешләрне, вакыйгаларны сурәтләүдә кирәгеннән артык ваклану, иллюстрация (*4 мәгъ.*) белән мавыгу. *Язучы әсәрендәге һәр кечкенә эпизодны да мотивлаштырырга, аның тарихи һәм социаль сәбәпләрен ачыклап, аңлатып бирергә тырышты. Шушы нигездә әдәбиятта тасвирчылык һәм иллюстрациячелек тенденцияләре көчәйде.* Татар әдәбияты тарихы

**ИЛСАТАР** *и. сир.* **1.** Ватанына, туган иленә хыянәт итүче, ил өстенә килгән афәтле, сынаулы көннәрдә, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, дошман ягына авышучы, аңа ярдәм итүче кеше. *Илсатарлар кулыннан үлү*

**2.** *с. мәгъ.* Туган илен, Ватанын сатучы, үз мәнфәгатьләрен кайгыртучы. *Ник дисәк, Русиянең юан муенлы икътисадчылары, илсатар вак вә эре капкорсаклы буржуйлары шыплап тулган вагоны, артыннан күпме чапсак та, безне утыртмый.* Р.Әхмәтҗан

**ИЛСЕЗ-ЙОРТСЫЗ** *с.* Нәсел-нәсәпсез. *Шулай килеп чыкты инде: Таһир – бомж. Иң гадәти бомж – илсез-йортсыз, эшсез, паспортсыз, хыялсыз бер дөнья бәндәсе.* Г.Гыйльманов

**ИЛСӨЯР** *с.* **1.** 1) Ватанына, туган иленә, туган җиренә, туган халкына мәхәббәт һәм тугрылык белән сугарылган; патриотик. *Башкортлар сугышчан һәм илсөяр бер кавем булу белән бергә, --- кайбер вакыт үз халкына зарарлы хәрәкәтләрдән дә саклана алмаганнар.* Г.Баттал. *Хикмәт җәлилчеләрнең батырлыгына дан җырлау гына түгел, төп максат – киләчәк буыннарда Җәлил кебек ватанчыл, илсөяр тойгылар тәрбияләү, аларны чын кешеләр итеп үстерү.* Р.Фәйзуллин. *Кискен, ярсулы көрәш барган бүгенге заманда, капмакаршы идеологияләр бәрелеше кызган бер чорда илсөяр җанлы Ир дә, ягъни лирик герой да, замандашлары белән бергә, алгы сафта атлый.* Казан утлары

2) Туган илне яратуны һәм аңа бирелгәнлекне белдергән, патриотик хисләр белән сугарылган. *Илсөяр хикәяләр*

**2.** *и. мәгъ.* Үз Ватанын, туган илен, үз халкын яратучы, үз Ватанына, үз халкына тугры кеше; Ватанпәрвәр, патриот. *Илсөяр булу – һәрберебезнең изге бурычы*

**ИЛСӨЯРЛЕК** *и.* Ватанга, туган илгә, туган халкына мәхәббәт, тугрылык, ватанчылык. *М.Җәлилнең күп шигырьләре илсөярлек, туган илгә мәхәббәт белән сугарылган*

**ИЛ-СУ** *җый. и. сөйл.* 1) Туган як, туган төбәк, йорт-җир. *Бу эшкә ул [Сәлим хан], күрше-тирәләреннән җәберләнеп, я булмаса бөтенләй тар-мар ителеп, ил-суларыннан куылып җибәрелгән, туган ил-җирләрен ташлап, Болгарга килеп сыенырга мәҗбүр булган кыпчак ыруларын кабул иткәч керешә.* М.Хәбибуллин

2) Авыл халкы, халык. *Ул, дөрестән дә, кызын әнә шундый баерак кешегә биреп, байлар белән аралашып, картайган көнендә, улыннан булмаса, кызының игелеген күреп, ил-су алдында дәрәҗәгә менеп калырга омтыла иде.* Ф.Хөсни

**ИЛТАБАР** *и. бор.* Ыру башы. *Алар барысы да затлы би, илтабар, тархан угланнары иде, озын, зифа буйлылар --- иде.* Р.Зәйдулла. *Әйтик, борын-борын заманда төркиләр, андый-мондый афәт тоташтан килә башласа, илтабарлар гаиләсендәге иң таза, иң чибәр ир баланы Тәңрегә корбан итә торган булганнар.* М.Хәбибуллин

**ИЛТӘБӘР** *и. тар. к.* **илтибәр**

**ИЛТӘБИР** *и. бор.* **1.** Сәяси һәм икътисади яктан көчлерәк дәүләткә буйсынган ил яки дәүләт башлыгы; вассал. *[Алмыш хан] – Хазар йортының, изге каганның колы --- илтәбире.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Икътисади һәм сәяси яктан бәйле, буйсынган. *Илтәбир ил*

**ИЛТЕР** *и.* **1.** 1) Бөдрә йонлы бәрән тиресе. *Кулына бер дистә илтер тотып --- йөрүче Касыйм маклерлары да килде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Каракүлнең бер төре: бөдрә йонлы бәрән тиресен махсус эшкәртеп ясалган мех. *Биш-ун ел әүвәлге кебек бу ел да --- мех, илтер белән сәүдә кылучы Кирман (Касыйм) мөселманнары да буялган илтерне буялмаган дип саталар иде.* Ш.Мөхәммәдев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый мехтан тегелгән. *Илтер бүрекләрне ирләр кияр, мамык эшләпәне кем кияр.* Жыр. *Баскычта ил-*

*тер кырыйлы кубанка һәм пөхтә генә шинель кигән, --- бер кеше басып тора иде.* Х.Камалов. *Кышын да, җәен дә --- зәңгәр чалбар, башына бөлгән алпавыт сәрхүш чагында бүләк иткән илтер бүреген киеп йөрер.* И.Тургенев

**ИЛТЕРЧЕ** *и.* 1) Бәрән тиресен эшкәртүче, илтер эшкәртү остасы

2) Илтер сатучы

**ИЛТИБӘР** *и. тар.* Борынгы Идел Болгарында хөкемдар титулы

**ИЛТИЗАМ** *и. гар. иск.* 1) Үз өстенә йөкләү, үзенә тиешле дип табу, өстенә алу

2) Йөкләү, мәҗбүр итү. *Икенче комиссиягә исә Габдулла Тукаевка кабер урыны сайлау, мәдрәсәләргә, аны җыячак руханиларга хәбәр бирү, аны күмәргә акча җыю вә аның нәрсәләрен җыеп саклау хәле илтизам ителде.* С.Исәнбаев

**ИЛТИМАС** *и. гар. иск. кит.* Үтенеч, сорау. *Илтимас илә сәвальләр тук авызлы, шат кешеләргә артык тәэсир итми иде.* М.Гафури

**ИЛТИМА́С ИТҮ** *ф.* Үтенү, берәр эш башкаруны сорап мөрәҗәгать итү. *Дус-ишләр шул матур вә мөкатдәс хезмәтне хосусый миннән илтимас иткәнгә, --- ушбу «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабыны тәртип иттем.* Г.Тукай

**ИЛТИМА́С КЫЛУ** *ф. к.* **илтимас итү**. *Вә һәм бу мәдрәсәне вөҗүдкә чыгарырга илтимас кылды ки, зинһар, бу эш гайренең кулыннан киләчәк түгел, әлбәттә, син башласаң кирәк, дип, бу эшне аңар, ягъни бер мөгаллим адәмгә хәвилә кылды.* Ә.Фәйзи

**ИЛТИФАТ** *и. гар.* 1) Игътибарлылык, ягымлылык, ихтирамлылык. *Дасаев, --- бу сәер юлдашлары аның һәр хәрәкәтен хәтерләрендә калдырырга тырышып, үзенә сокланып карап торганнарын күрә иде. Мондый илтифатны ул әле беркайчан да тоймаган иде.* Р.Мирхәйдәров. *– Илтифатыгыз өчен рәхмәт, дәвам итсәгез, хәерлерәк булыр, – дисә дә, Комзинаның күңелен һаман кибет хәлләре кытыклап тора иде.* М.Насыйбуллин

2) Кадер-хөрмәт, зурлау, олылау. *Кызның миңа кылган илтифатына күңелиләр...* М.Гафури. *Кабык өстенә корама юрган, корама юрган өстенә мәетне аягы белән ишеккә таба каратып салды һәм, җил-буран керерлек урын калдырмыйча, илтифат белән төрде...* А.Хәлим. *Популярлашып киткәч, эшләр җайлана төшкәндер: кая гына барсаң да танныйлар, сиңа хөрмәт, илтифат күрсәтәләр...* Юлдаш

◊ **Илтифатка алу** Игътибар итү, исәпкә алу, кирәкле, зарури дип санау. *Мин сөйләгәндә сызгырсалар да, һич илтифатка алмадым.* Ш.Мөхәммәдев. **Илтифат ясау** Хөрмәтләү, олылау, зурлау. *[Көтүче] Кунакка илтифат ясады.* Г.Ибраһимов

**ИЛТИФА́Т БИРҮ** *ф. к.* **илтифат итү**. *Илтифат биреп тыңласаң, --- гөҗләп янган газ мөшкәләренә төшеп, черт-черт куырылган эре таракан, симез кыргаяк яуларының фаҗигале шәйләре шәйләнә.* А.Хәлим

**ИЛТИФА́Т ИТҮ** *ф.* Игътибар итү, дикъкать итү. *Әенең башын тимер белән яптыру, буяу вә башка җирләрен матурлау кебекләрнең һичберенә илтифат итмиләр иде.* Г.Ибраһимов. *Ирләрнең кулларында тәсбих. Шуны тартып, бернигә дә илтифат итмичә, тыныч кына баралар.* Сөембикә

2) Игътибарга алу; кирәкле, зарури дип санау, әһәмият бирү. *[Зәйнәп] Боларның бу сүзләрен әһәмияткә алмый, халык сүзенә илтифат итми.* М.Гафури. *--- икенче бер сәбәп карак мулланы бу сүзгә илтифат итәргә мәҗбүр итте.* Г.Ибраһимов

3) Олылау, ихтирам итү, ихтирам белән карау. *Рәхмәт, һәрберегез илтифат итеп килгәнсез.* Ш.Маннур

**ИЛТИФА́Т КЫЛУ** *ф. к.* **илтифат итү**. *Ләкин минем боларның берсенә дә ис китми иде, боларның берсенә дә илтифат кылмый идем.* Г.Исхакый

**ИЛТИФАТЛЫ** *с.* **1**. 1) Хөрмәт итүчән, олылаучан, ихтирам күрсәтүчән. *Башка берәүләр булса, су чәчрәтеп, кызларның җелекләренә үтәләр. Ә Җантимер алай итми: бөтен кешеләргә илтифатлы иде.* Ф.Яхин. *Алар янына пөхтә киенгән бер егет килеп, илтифатлы гына гафу үтенде.* М.Хәсәнов. *Хатыннарына карата нәзакәтлерәк һәм илтифатлырак булсалар, --- хатын-кызда хатын булу хисе тизрәк уяныр иде.* Юлдаш

2) Игътибарлы, дикъкатьле. *Корректура укуда илтифатлы булырга кирәк*

**2**. *рәв. мәгъ.* Игътибар белән, дикъкать белән. *Рәмзия Зөбәйдә сөйләгәннәрне илтифатлы тыңлый, үзенең фикер иләгеннән үткәрә ---.* Б.Камалов

**ИЛТИФАТЛЫЛЫК** *и.* Илтифатлы булу сыйфатлары. *Илтифатлылыкның да чиге булырга тиеш бугай. Нәрсә әле, Гәүһәрия җиңел машина ишеген үзе ачып чыга алмаслык нечкәргән җанмыни?!* Д.Гайнетдинова. *--- авыл кешеләренең капка төбендә яисә шәһәр кешеләренең самавыр янында гәпләшеп утыруы безнең халыкта җан тынычлыгын һәм илтифатлылыкны --- үстерде...* Тигез гомер итегез!

**ИЛТИФАТСЫЗ** *с.* **1.** 1) Игътибарсыз; игътибарга алмаучан, дикъкать итмәүчән, әһәмият бирмәүчән. *Мин, гадәтемчә, башкалада ишеткән мәзәкләрне сибәм, ә ул никтер илтифатсыз.* Р.Кәрами. *Авыруларның кайберләре өс-башка илтифатсыз булып китә ---.* Юлдаш

2) Ихтирамсыз, хөрмәт итмәүчән. *Бәлки, шәһәр транспортындагы кондуктор сурәтемә игътибар белән карамас та, әмма бу миңа илтифатсыз мөнәсәбәт күрсәтергә ярый дигән сүз түгел бит әле.* Сөембикә

3) Ис китми, гаҗәпләнми торган. *Ул илтифатсыз, бераз караңгы йөз белән синең язмаларыңны алып кала.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әһәмият бирмичә, игътибар итмичә. *Шамил аның бу кыланышларына илтифатсыз калды, актан да, карадан да җавап кайтармады.* З.Фәтхетдинов. *Зәвилә кунакны өрмәгән җиргә утыртмаска тырышса да, Гегель Әфләтүнович, аны илтифатсыз гына эчкә үткәреп, аңа дүрт бүлмәле фатирын күрсәтергә ашыкты.* А.Хәлим. *Шәһәрнең үзәк урамыннан, гадәтемчә, каршыга агылып килгән кешеләргә күз салмыйча, илтифатсыз гына бара идем...* М.Галиев

2) Ис китмичә, артык гаҗәпләнмичә. *– Син нәрсә әйтерсең икән? –*

*дигән соравына да, илтифатсыз гына: – Ярар, – диде.* Г.Галиева. *– Ә сез – тел бүлегендә укучы студентка! – диде ул [Атлас], илтифатсыз гына.* Г.Рәхим. *Телеграф тасмалары китергән сүзләр тикшеренүчене йомшартмадылар. Ул, илтифатсыз гына: – Аттан ала да туа, кола да туа, диләр, – дип нәтиҗә ясады.* Ш.Рәкыйпов

**ИЛТИФАТСЫЗЛАНУ** *ф.* Илтифатсыз, игътибарсыз булып китү, илтифатсызлык, игътибарсызлык күрсәтү. *Үзенең унҗиде ел бергә гомер сөргән ирен танымый иде ул [Гөлйөзем]. Игътибарсызланды, илтифатсызланды.* Ф.Латыйфи

**ИЛТИФАТСЫЗЛЫК** *и.* 1) Игътибарсызлык, игътибар итмәүчәнлек. *Өлкәннәр сүзенә илтифатсызлыкның олы гөнаһ икәнен белгән Санька үзе белән берни дә эшли алмый ---.* Ф.Латыйфи. *Тукайның бу сәер карары ике сәбәп белән аңлатылса кирәк. Беренчесе – Габдулланың үз шәхси тормышын үзгәртү мәсьәләсендә илтифатсызлыгы дип әйтергәме, әллә иренчәклек яисә карарсызлыкмы, ---.* И.Нуруллин. *Кызлар бу кадәр илтифатсызлыкка рәнҗеп чыгып китәрләрме дисәм, дәррәү миңа ябырылдылар ---.* Н.Әхмәдиев

2) Ихтирамсызлык, хөрмәт итмәүчәнлек. *Үз кайгысына карата, үз теләкләренең җимерелүенә, гомумән, үз шәхесенә карата аның шундый илтифатсызлыгын күреп, Исламның чынчынлап хәтере калды.* Н.Фәттах. *Тактсыз мөгамәлә, --- әти-әнисенең әбиләренә карата илтифатсызлыгы, кагыйдә буларак, балаларына да «йога» ---.* Юлдаш

3) Ис китмәүчәнлек. *Матурлыкка илтифатсызлык күрсәтү*

**ИЛТОТМЫШ** *с.* Тормышны тиешле дәрәҗәдә алып баручы. *--- бары тик ул дигәнчә генә булырга тиеш дип уйлаган илтотмыш Җомабикәгә шул җитә калды, --- юлга чыгарга катгый әмер бирде.* М.Хәсәнов. *Әле генә шундый ягымлы, юмарт күңелле хатын күз алдында илтотмыш бикәгә әверелде.* Н.Фәттах

**ИЛ-ТӨЯК** *җый. и. диал. к.* **ил-су** (*1 мәгъ.*). *Күз алмас дәрәҗәдә гүзәллек ташый иде акка төренгән алмагачлардан. Тыныч иртәгә, ил-төякнең кабатланмас бизәкле манзарасына адарынып шактый торды ул.* Ф.Сафин

**ЙЛ ТУБАЛЫ** *и.* Бал кортлары күчен җыю өчен, кабыктан ясалган киң, түгәрәк савыт

**ИЛТҮ** *ф.* 1) Кулыннан тотып, күтәреп яки утыртып кая да булса алып бару. *Ахияр идарә членнарына аерымаерым эш йөкләде: берәүләр – ашханә ягын хәл итәргә, икенчеләр – вагонеткалар китерергә, өченчеләр күчмә ремонт машинасын шунда илтү өчен җаваплы булдылар.* М.Мәһдиев. *Алдан бата-калка энем бара, аның артыннан – мин... Ләкин таш шикелле төпкә китмибез әле, чөнки көчле агым үзе безне күтәреп, уйнатып кына илтә дә илтә.* Ә.Еники. *Сөембикә белән улын илтеп биргәндә, Казан шәһәре һәм ханлыкның Болынлык ягы* (*Идел елгасының сул ягындагы җирләр*) *әлегә Мәскәү хакимияте астына төшмәгән иде.* Г.Баттал

2) Билгеле бер җиргә алып бару. *--- Шәмси никадәр авылга – әтиләренә генә кайтырга теләсә дә, Анна Васильевна бөтен көчен-куәтен кымызга илтергә сарыф итте.* Г.Исхакый. *Шәһәр үзәгенә илтә торган троллейбуста Зөлфә чал чәчле апаны күздән ычкындырмаска тырышты.* М.Маликова. *Җәннәтнең үзендә булудан да бигрәк, аңа илтә торган юллардан бару рәхәттер.* Сөембикә

3) *кит.* Берәр нәрсәгә сәбәп булу, шуның аркасында килеп чыгу; берәр хәлгә китерү, авырлыкка дучар итү. *Яшь чагында Гөлфия дә беркатлы кыз бала иде. Әнә шул сыйфаты аны упкынга илтте бугай.* Н.Гыйматдинова. *Ә нилектән сула, кибә соң ул [Наил]? Һәлакәткә илткән сәбәп нидә?* Д.Гайнетдинова. *Ул юлларның һәммәсе матур, һәммәсе мавыктыргыч. Тик кайсының бәхеткә илткәне генә билгесез.* Ф.Яруллин

4) *күч.* Көрәштә, эштә юл күрсәтеп, юнәлеш биреп, артыннан ияртеп бару, әйдәү, җитәкләү. *Батыр егет! --- Илт син безнең егетләрне яуга!* М.Җәлил

5) *күч.* Нәрсәгә булса да ирешү, берәр теләкне, уйны тормышка ашыру, эшне башкарып чыгу. *Ләкин бу сыйлаулар, бүләкләр һәм өстенлекләр максатка бик тиз генә илтеп җиткермиләр.* Г.Баттал

**Илтеп бетерү** Барысын да илтү

**Илтеп җиткерү** 1) Вакытында, соңга калмыйча, билгеләнгән урынга кадәр илтү. *[Мөдәррис] Юл буе дәшмәде, баранка өстеннән башын алгарак сузып, тизрәк Зәйтүнәне илтеп җиткерергә тырышты.* М.Маликова

2) *күч.* Берәр кеше өстеннән әләкләп өлгерү, берәр кеше турында кемгә дә булса барып әйтү, сөйләү. *Кайсыдыр каһәре аларга минем урларга теләвемне илтеп җиткергән.* А.Шамов

**Илтеп кую** Тиешле урынга, билгеләнгән җиргә кадәр илтү. *Теге таксиның шофёры да шунда тора. «Туган, – дим, – Һади Такташ урамына илтеп куй әле».* М.Маликова

**Илтеп ташлау** 1) Кемне дә булса үз теләгеннән, ризалыгыннан башка, каядыр илтеп шунда калдыру. *Әмма ләкин бер атнадан соң ук кулга алындым, элекке сәүдәгәр Набков фатирында урнашкан ЧЕКА подвалына илтеп ташладылар.* Г.Баттал. *Беренче курсны тәмамлагач, сезне бик еракларга илтеп ташларга була, сез инде адашып йөрмәячәксез, ачтан үлмәячәксез.* М.Маликова

2) Тиз арада илтеп ыргыту

**ИЛ-УМАЧ** *рәв.* 1) Бик дус булып, якыннан аралашып. *--- ә теге кызый зур калада әллә ниткән шәп егетләр белән ил-умач килеп, аудиторияләрдә бергә утыра, чыркылдаша, уйнаша, көлешә иде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Бәргәләп, суккалап, тукмап, кыйнап. *Малмыж төрмәсендә утырганда, мин аларның өчесен дә ил-умач итеп бәргәләп ташлаган идем.* Р.Сибат. *Хәйрулла абзыйның үз малае белән Бибиҗамалга ияреп килгән малай көннәрдән бер көнне ике яшьлек Гафурны --- чирәмне ник юешлисең, дип, ил-умач китереп кыйнап ташлыйлар.* М.Мәһдиев

**ИЛҮ** *и. бор.* 1) Халык

2) Волость. *Сылтау гына көткән Барды илүе старшинасы Туктамыш Ишбулат углы тупланган халыкны*

*үз гаскәре белән уратып, коралларын тапшырырга, ә үзләрен таралышырга мәҗбүр итә.* М.Гайнетдин

◊ **Илүдә йөрү** *сөйл.* Үз эшен карамыйча, өйдән-өйгә кереп йөрү, эшсез йөреп вакытны бушка уздыру; биләмдә йөрү

**ИЛҮМӘ́ КИЛҮ** *ф. сөйл.* Үзара аралашып, шаулашып әвәрә килү; буталу, кайнашу. *Анасы әүвәл татарга, аннан соң кызга, аннан соң дәхи татарга бик дикъкатьләп карады: – Хәзер татар егетләренең эте-бете – һәммәсе марҗа белән илүмә киләләр, – диде.* Ф.Әмирхан. *Ул заманда ире-хатыны бергә илүмә килеп бетәләр иде.* М.Фәйзи

**ИЛХАН** *и. бор.* 1) Хан улы. *Истәлекче, яз. Эт елында мин, Бөек Болгар ханы Кубрат, үземнең җәйләүләремне илханнарга бүлеп бирергә булдым.* М.Хәбибуллин. *Манарада Кубрат ханның тамгасы бар. Ә инде угланы илхан Кодрак, бу төбәкләргә күчеп килгәч, манара янына кәрвансарай салдырган.* М.Хәбибуллин

2) Падишаһ, хөкемдар. *Илхан булырга теләүче Пугачёвны --- генерал Михельсон Казаннан тотып кайткан, имеш.* Борынгы татар әдәбияты. *Алтын Урда илханнары*

**ИЛХАНИЯ** *и. бор.* Хан кызы. *Кодрак илхан сеңлесенең күзләренә карады. – Әйтмә алай, Чәчкә. Син – илхания, каравыш кыз түгел, хакың юк алай дияргә.* М.Хәбибуллин. *Ханша дөрес әйтә, олуг хан. Илхания – бер хан кызы гына түгел хәзер, илнеке дә.* М.Хәбибуллин

**ИЛҺАМ** *и. гар.* 1) Күңелгә салынган чиктән тыш дәрт, ашкыну, рухланыш, күңел күтәренкелеге. *Кулга – көч, йөрәккә илһам саласың. Сихерле, серле нур – синең карашың.* Л.Ихсанова. *Илһам – ул күңелдә бара торган көрәшнең дәвамы... Илһам – ул үз янәшәңдә халкыңны тою... Илһам – ул син хезмәт итә торган халыкның җылы кулы, назы...* А.Гыйләҗев. *Уйнау да илһам эше. Бер дәртләнгәч, бер, ничек дим, иң кирәк кылын тотып алгач, музыка үзеннән-үзе бик табигый, бик җиңел уйнала.* Ә.Еники

2) *күч.* Эшкә, иҗатка көч, дәрт, рух чыганагы. *Син аңа илһам булырсың. Аның каләменнән тагы да матуррак юллар түгелер.* М.Фәйзи. *Туган як шагыйрьгә бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы, лирик тойгылар чыганагы булып хезмәт итә.* Н.Юзиев. *«Алсуланган Әлмәт төннәре»ннән, «Ак куаклар күләгәсе»ннән Туфан җанындагы романтик Янарҗан Искәндәрне көненә берничә шигырь – җыр тудырыр дәрәҗәдә үзенә табындырган, --- һәр сулышын илһам чыганагы итеп бәяләгән Тәнәкә...* Сөембикә

◊ **Илһам ачылу** Кинәт дәрт килү, рухлану. *Көлке рәсемнәр ясыйм. Барыйның да илһамы ачылып китте.* М.Әмир. **Илһам килү** Көтмәгәндә, кинәттән рухлану, илһамлану. *Бу сүзләрдә ул [Дәрдемәнд] соңыннан бер бөтен шигырь булып үсәчәк шигырь орлыклары күргән. Ихтимал, илһамы килгәндә табигый рәвештә табылып торган сүзләрне соңыннан тулыландыру нияте белән язып куйгандыр.* Н.Юзиев. *Күз алдыңа китер: сиңа илһам килгән вакыт, хыялыңа чумып, ялгызлыкның кадерен белеп кенә утырасың, шул вакыт кухнядан гап-гади тавыш ишетелә.* М.Галиев. *Илһам килүнең сере дә, ачунәфрәт хисенең, үз-үзен туендырып, кинәт кабарып китүе дә нәкъ шуның белән аңлатыла.* Э.Баркер. **Илһам ташу** Дәрт, күңел күтәренкелеге чиктән тыш булу. *Шагыйрь, илһамы ташып торганда, иң әүвәлге караламаларына әле тулысынча шигырь булып ук оешып бетмәгән беренче фикерләрен һәм шул фикерләрне йөртүче рифмадаш сүзләрне теркәгән.* Н.Юзиев. **Илһам чишмәсе** *шигъ. кит.* Иҗат дәрте, иҗатка омтылыш; көч, рух бирә торган чыганак. *Чакырылмаган кунаклар китеп, бүлмәсендә тынычлык урнашкач та, Тукай эшкә кереште. Бу көннәрдә аның илһам чишмәсе челтерәп кенә түгел, гөрләп, ургылып ага иде.* А.Расих

**ИЛҺА́М АЛУ** *ф.* Илһамлану, рухлану. *Спортчы Муса, Мәскәү янында чаңгы шуганда, Мәскәү табигатеннән илһам алып, «Кышкы шигырь»ен язды.* М.Максуд

**ИЛҺА́М БИРҮ** *ф.* Рухландыру, илһамландыру. *Мәхәббәт хисе аңа [Гөлчәһрәгә] көч, илһам бирә.* Казан утлары. *Тукайга Кырлай илһам биргән, Такташ Тамбов урманнарын сагынган ---.* М.Максуд

**ИЛҺАМИ** *с.* 1) Илһам белән сугарылган. *Шул --- әрнүләр эчендә күңелгә илһами бер уй килә.* Г.Ибраһимов

2) Импровизация ясарга сәләтле, импровизация ясаучы. *Мондый тоткарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтүче илһами (импровизатор) шагыйрьләр Урта йөзләрдә Идел – Җаекта күп булганнар.* Н.Исәнбәт

**ИЛҺАМИЯТ** *и.* Илһамлылык, иҗат күтәренкелеге

**ИЛҺАМИЯТЛЕ** *с.* Илһамияткә ия булган. *«Шәһри Казан» – Татарстан башкаласында чыга торган иң яшь, иң дәртле, вөҗданиятле вә илһамиятле, иҗтимагый вә сәяси, чын милли газета!* Казан утлары

**ИЛҺАМЛАНДЫРУ** *ф.* Илһам бирү, рухландыру. *Җанын сулкылдатып торган очу-йөзү дәрте, адәми затның акыл-зиһен эшчәнлеген котыртып, илһамландырып, җилкәнле кораблар, очкычлар ясауга китергән.* М.Галиев. *Алар – безнең күкләргә чөелгән идеалыбыз, безне ымсындырып, төшләргә кереп чакырып, илһамландырып, өндә батырлыклар кылдырып ир-егет иткән хыялыбыз!* Р.Харис. *Замананың күз уңында торган бу ике шәхес аркадаш булмасалар да, бер-берсен илһамландырып, --- бер-берсенең сулышын тоеп яшәделәр.* Н.Нәҗми

**Илһамландыра бару** Торган саен ныграк илһамландыру

**Илһамландыра килү** Элек-электән, даими, һәрвакыт илһамландыру. *И.Юзеев поэзиясенең халыкчан сыйфатлары – тирән моң, лиризм, фикер-хис бөтенлеге, форма төгәллеге – композиторларны да даими илһамландыра килә.* Р.Даутов

**Илһамландырып җибәрү** Кинәт илһамлану хәленә китерү. *Хәтта соңгы вакытта авырган Газизне дә кодрәтле музыка әнә илһамландырып җибәрде ---.* Ә.Салах. *Киресенчә, һәрчак инсафлы, түбәнчелекле, әдәпле булырга*

*тырыша. Бу сыйфатлары аны тагы да илһамландырып кына җибәрә.* Д.Бүләков

**Илһамландырып тору** Әледән-әле яки даими илһамландыру. *Хәзер менә авыр сугыш елларында да дәрт биреп, илһамландырып торган якты өмет --- сүнә барган кебек сизелә иде.* Г.Бәширов. *Мондый көрәш романтикасы драматургияне дә илһамландырып торды ---.* А.Әхмәдуллин. *Миңа атап җибәргән җылы, ягымлы сүзләрдән торган шигъри хаты әле дә булса җылытып, илһамландырып тора.* Ф.Чанышева

**ИЛҺАМЛАНДЫРУЧЫ** *и.* Рухландыручы, дәртләндерүче кеше. *Янында илһамландыручың булганда гына эшең уңа, күңелең күтәренке була.* М.Маликова. *Хатын-кыз – яратыр һәм яратылыр өчен туган зат ул. Аны илһамландыручы, сөендерүче, ләззәтләндерүче – ир-ат мәхәббәте ---.* М.Галиев

**ИЛҺАМЛАНУ** *ф.* **1.** Эшкә, иҗатка теләк, дәрт тою, илһам алу, рухлану. *Мин гашыйкмын сиңа – серем ачык, Илһамландым синең яктыдан.* Г.Габдулла. *Һәм ул [мәхәббәт] башка хисләр арасында аерым бер хис кенә түгел, --- әйтерсең лә ул барлык хисләрнең сүнмәс илһамлануы, аларның дөрләп януы ---.* Тигез гомер итегез!

**2. илһамланып** *рәв. мәгъ.* Күтәренке күңел белән, рухланып, дәртләнеп. --- *мөдирнең күңеле булды, көлеп җибәрде: – Эш шуңа терәлеп калса, без сезгә ярдәм кулы сузабыз, барыгыз, ял итеп, илһамланып кайтыгыз.* С.Сөләйманова. *Кыз илһамланып сөйли башлады.* М.Маликова. *Илһамланып кул болгаучы дирижёрның таягын тартып алды да, залга таба борылып, нәзакәтле генә баш игәч, шашынып, бөтен гәүдәсе белән калтырап, ике кулын да селтәргә тотынды.* Р.Вәлиев

**Илһамланып алу** Кыска гына вакытка, аз гына илһамлану

**Илһамланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта илһамланган халәт кичерү

**Илһамланып килү** Озак вакытлар дәвамында илһамлану, даими илһамланган халәт кичерү. *Бу кечкенә мәкаләмне язар алдыннан, мин, Гомәр ага Бәширов һәм аның иҗаты турында бик күп кенә уйланып, ничектер илһамланып килдем-килдем дә, кәгазь-каләм алып язарга гына утыргач, кинәт куркып икеләнә калдым.* Х.Сарьян

**Илһамланып китү** Ниндидер бер этәргечтән кинәт кенә дәртләнү, рухлану, илһамлану. – *Менә болай! – Гамил, ихласланып вә илһамланып китеп, куллары белән тубыкларына кадәр төшеп күрсәтте.* Ф.Яхин. *Шигырьләр күп укылды бу арада. Алар йогынтысында үзем дә илһамланып киттем, ---.* М.Маликова. *Сәетҗан бабай бу вәгазьләрне Искәндәр белән Улинәгә ихлас күңеленнән сөйли. Аның тирән җыерчыклар баскан йөзе тәмам илһамланып, яктырып китә.* Р.Фәизов

**Илһамланып кую** Кинәт илһамлану

**ИЛҺАМЛЫ** *с.* 1) Илһам белән сугарылган, җанлы, дәртле, күтәренке рухлы. *Ул [яшь каен] йомшак кына искән җилдән дә тәрәзәгә таба иелә, әйтерсең лә аның да шаулап торган кара урман турындагы илһамлы җырны ишетәсе килә.* М.Хәсәнов. *Матур йөз – табигать рәссамның иң гүзәл казанышы. Ни өчен адәм баласы гүзәл сыннарны, илһамлы илаһи йөзләрне музейларга гына барып карарга тиеш?!* А.Гыйләҗев. *Бөек шигърият мине яшәргә рухландырды, илһамлы иҗатка этәрде.* Юлдаш

2) Илһам уяткан, илһам биргән. *Илһамлы кич*

**ИЛҺАМЛЫК** *и.* Чиктән тыш дәрт, ашкыну, күңел күтәренкелеге. *Рания: [Синдә] Бүген ниндидер сәер илһамлык бар. Әсәдеңнән хат килдеме әллә?* З.Хәким. --- *исеп-исеп куйган талгын җил белән бакаларның бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт җырлары агылып килә дә моңлы авазларда тирбәлгән бу болынга үзенә бер илһамлык, сихрилек һәм мәгънә өсти иде.* Р.Зарипов

**ИЛҺАМСЫЗ** *с.* **1.** Рухсыз, дәртсез. – *Иптәшләр, – диде Ольга Матвеевна, илһамсыз һәм ялкынсыз коры тавыш белән, – бу урында --- Лермонтов белән --- отставкадагы майор Мартынов арасында дуэль булган.* Г.Мөхәммәтшин. *Иҗатның илһамлы, канатлы чагы турында сөйләргә яратабыз. Илһамсыз вакытны сиздермәскә тырышабыз.* Ш.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Дәртләнмичә, рухланмыйча. *Илһамсыз һәм рухсыз гына шигырь язу Яратмаган хатын белән тору кебек.* Г.Афзал. *[Тукай:] --- Бу чәчәккә карасам, авыру чагым булса, савыгам... Илһамсыз каңгырып йөргәндә, иҗат дәртем уяна.* Р.Батулла. *Илһамсыз, ягъни теләгең булмаганда язарга утырып, бервакытта да күңел газабы кичергәнеңне хәтерләмим.* Э.Шәфигуллина

**ИЛҺАМЧЫ** *и.* 1) Илһам бирүче кеше. *Чөнки Рухия – аның якты маягы, илһамчысы, шатлыгы, бәхете ләбаса!* В.Нуруллин. *Кем лирикка илһамчы, кем – сатирикка...* Ш.Галиев. *Шагыйрьләргә тик илһамчы син, Татар кызы?! Күпме ярасын Бәйләдең илнең!* Р.Батулла

2) Көчле хисләргә этәргеч бирүче, дулкынландыручы. *Моннан соң, «нәфрәт» дисәләр, хәтеремә кара күләгә булып шушы көн, шушы көннең илһамчысы булып Мәүлиха апа иңәр!..* А.Гыйләҗев. *Кит син дә, илһамчы ярым! Кит! Кирәкми беркем дә, берни дә!* Р.Фәйзуллин

**ИЛЧЕ** *и.* 1) Мөһим йомыш белән яки нинди дә булса эшкә арадашлык итү өчен кая да булса җибәрелгән кеше, арадашчы. *[Маһисәрвәр:] Шундый ачлыктан җәфа чиккән михнәтле елларда кызыбызны дәрәҗәле мәктәпкә --- Фәһим мөгаллим илтеп урнаштырды инде, рәхмәт төшкере! Фәһим, уңайсызланып, кузгалып куйды. – Мин илче генә булдым, Маһисәрвәр апа.* Г.Бәширов. – *Илчегә үлем юк, – дип башлады Ниса сүзен, – мин, Дилә туганым, синең белән бик ныклап сөйләшергә телим!..* А.Гыйләҗев. – *Һай, бу Хәсәнне ничек кире сүрелдерергә инде, – диде Гомәр агай, --- Нәкый агайны илче итеп карыйк, бәлки ул күндерә алыр...* М.Мәһдиев // Ике арада йөрүче, йомышчы; курьер. *Еш кына редакция белән типография арасында илче дә (гади тел белән әйтсәң, курьер да) үзем.* М.Максуд. *Бүген инде менә шул укучы үзе балигъ булган яшьләр арасында илче сыман...* Б.Камалов. *Шулай да син минем иң якын, иң кадерле ке-*

*шем булганлыктан, ике арада илче йөртәсем килмәде.* Г.Бәширов

2) Капма-каршы юнәлешле якларның берсе тарафыннан икенчесенә сөйләшүләр алып бару өчен җибәрелгән вәкил; парламентёр. *Урыслардан илчеләр килгән. «Ханыгызны, карачы, морзаларыгызны, бәйләп, безгә китерегез, сезгә берни дә булмас», – дип әйткәннәр, ди.* Ф.Латыйфи. – *Илчегә үлем юк! – дигәннәр борынгы төркиләр. ...Ә бит моңа кадәр Төрки Болгарына килгән илче һәрчак исән-имин кайтып китәр иде.* М.Хәбибуллин. – *Күрән бине «башлы, белекле» дип сөйләгәннәрие, чын булмады бу, – диде илче карт. – Илчегә үлем юк. Без сиңа әйтергә кушылганны гына әйттек.* Н.Фәттах

3) Югары дәрәҗәле дипломатик вәкил; илнең мәнфәгатьләрен яклаучы дәүләт хезмәткәре. *Илчеләр хисләрен яшерә белергә тиеш. Алар ил, дәүләт файдасы хакына шәхси мәнфәгатьләреннән баш тарта.* Ф.Латыйфи. *Илчеләргә дә бит үлем килә, Һәлакәткә очрый яучылар...* С.Сөләйманова. *Үзәк разведка идарәсенең техник җиһазларе инде 1945 елда ук, Ялта конференциясе вакытында --- башланган.* Юлдаш

4) *диал.* Димче. *Егет белән кызның ата-аналары арасында илче булу*

5) *иск. дини* Алла теләгән, Алла ихтыярын кешеләргә алдан хәбәр итүче, төшендерүче; рәсүл; пәйгамбәр. *Җир йөзендәге бар кавемнәрне яраткан, юктан бар иткән Аллаһы Тәгалә бер булса да, аңа табыну, инану, үзеңне рәхимле һәм мәрхәмәтле шәфкать иясе Бөек Алланың җирдәге бәндәсе һәм илчесе итеп тою, --- – бөтенләй башка нәрсә.* Ф.Латыйфи. *Алмыш хан ислам динен дәүләт дине итеп кабул иткәч, ыру-кардәш субашларны: «Алла биргән кодрәт белән мин сезне юк иттерәм!» – дип яный. Ягъни үзен Аллаһы Тәгалә илчесе итеп күрсәтмәкче була.* М.Хәбибуллин. *Тәүбә, диген! Тиңләмә мине Алла илчеләренә, әй кем, исемеңне дә әйтмәдең бугай?* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Билгеле бер кешеләр төркеме, кешеләр эшчәнлегенең берәр тармагы исеменнән эш йөртүче вәкил

7) *күч.* Кайсы да булса халык вәкиле буларак чыгыш ясарга лаеклы әдәби-мәдәни иҗат әсәрләре. *Бөек Кытай илендә һәм халык демократиясе илләрендә, Франциядә һәм тагын бик күп илләрдә Муса Җәлил шигырьләрен татар совет культурасының лаеклы илчесе дип --- каршы алдылар.* М.Максуд

8) *күч.* Хәбәр китерүче, хәбәрче. *Ләкин кырыслык арасында ул [Такташ] лиризм чишмәсен кертеп җибәрә: әсәрнең кереш өлешендә без шагыйрьне төнлә өстәл янында, шәм яндырып, «таң илчесе» булган «зур төн хакында», ягъни Октябрь төне хакында язып утырган хәлдә күрәбез.* Х.Госман. --- *йомры таш яныннан җиләк ага иде! Теге бичара мөсафир үзеп-өзеп суга ташлый иде аларны... Әллә мәмрәп пешкән җиләкләрне каргышының илчеләре итеп аска озатып каламы?* А.Гыйләҗев. *Җәй иленә көздән илче булып, Җил әфәнде килде.* Х.Ширмән

**ИЛЧЕБАШЫ** *и. бор.* Илчелек (*2–3 мәгъ.*) җитәкчесе. *Вакытлыча илчебашы вазифаларын башкару*

**ИЛЧЕЛЕК** *и.* 1) Илче вазифасы, илче булу. *Һәм, күп тә үтми, мине казыйлыктан алдылар, бабаң илче итте. Мәгәр илчелектә дә озак тора алмадым, ---.* М.Хәбибуллин. *Иллә бабаң барыбер ханбикәсенә каршы сүз әйтә алмады, яңадан илчелеккә җибәрмәде.* Н.Фәттах

2) Бер дәүләтнең икенче дәүләттә тышкы һәм халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшләүче илче (*3 мәгъ.*) җитәкчелегендәге дипломатик вәкиллеге. *Хәлифә, бу төньяк төркиләр хөкемдарының гозеренә колак салып, Болгар иленә бер илчелек җибәргән, ә илчелекнең сәркатибе Әхмәт бине Фазлан исемле кеше булган.* Г.Баттал. *Лондонда вакытта ук безнең илчелек вәкиле әйткән иде – без аның белән тиз дуслаштык, әйбәт кеше ---.* М.Мәһдиев. *Аларда [документларда] шулай ук татар ханнары, дәүләт эшлеклеләренең дөньякүләм контекстта мәмләкәт белән идарә итү ысуллары: ярлыклар, --- аша чит ил хөкемдарларына үзләрен таныту, --- илчелек, сәүдә-икътисади вазифаларын үтәргә омтылулары ярылып ята.* Сөембикә // Шул вәкиллек урнашкан бина. *Аннары туристларны Совет илчелегенә алып керделәр.* С.Сөләйманова. *Беслан фаҗигасе, балалар рухы өчен, Россия илчелеге бинасына кочак-кочак чәчәкләр, уенчыклар китерәләр, пластик шешәләрдә су алып киләләр.* Йолдыз

3) Нindидер бер максат белән җибәрелгән вәкилләр төркеме. *Нығытма диварлар янына Аксак Тимер гаскәрләренең илчелеге тиранnan солых хаты китергән иделәр. --- илчелек Үргәнечнең сугышсыз бирелүен таләп итте....* Ф.Яхин. *Казанлылар, корылтайның үз дәүләтләре өчен һәлакәтле карарын гамәлдән чыгарырга дип, Мәскәүгә илчелек җибәрә.* Татарстан тарихы

**ИЛЧЕХАНӘ** *и. иск. к.* **илчелек** (*2 мәгъ.*). *Рус патшалыгы илчеханәсе чит илләр белән бары тик рус, латин һәм татар телләрендә генә язышa.* И.Рәмиев

**ЙЛЬЯС** (**ПӘЙГАМБӘР**) **КАМЧЫСЫ** *и. иск. миф.* Халык ышануларыбуенча, кар эри башлап, яз башланыр өчен, Ильяс пәйгамбәр селтәргә тиешле камчы. *Гел изгелекләр генә кылучы, мәңге яшәүче Хозыр бабай, Ильяс пәйгамбәр камчысы күңел язын башладымы?* М.Хуҗин

**ИМ** *и.* 1) Ырым, им-том. *Шуннан беркөнне базарда имче карчыкны очраттым. Бер такта чәй алып бирдем, бер тәңкә акча бирдем. Ходайның хикмәте, шул карчыкның име шифалы булып чыкты.* М.Мәһдиев. *Ул чагында ул яшьрәк иде һәм аңа бернинди яшәрткеч им сулары кирәкми иде.* Н.Фәттах. *Имеш, анда [аптекада] «сукырайта торган, баш авырттыра торган, эч күптерә торган, сару кайната торган вә башка төрле дарулар сатыладыр. Шунда ук сөйдергеч имнәре, боздыргыч тылсымнары ---» [сатыла].* Казан утлары

2) Төрле авырудан арындыра торган дәва, шифа; дару. *Миңа көче җитмәгәч, гөнаһсыз балаларга алынган Сәрбия. Йорт саен кереп, им биреп йөрдем үзләренә.* Н.Гыйматдинова. *Шунда Зөләйха кулына Вишневский мазеның*

*име килде, кулы төзәлде, җөйләнеп торган эз генә калды...* А.Гыйләҗев. *Монысы Чишмәгә авылдан гына да түгел, мари ягыннан ук килгән иде, чире дә хәтәррәк, шуңа им эзләве икән.* К.Тимбикова

3) Мөмкинлек, җай; әмәл, чара. *Ике дус дошман булмас, булса, аңа им табылмас.* Мәкаль

4) *күч.* Кирәкле, мөһим, зарури, әһәмиятле, мәҗбүри нәрсә. – *Сез таутау өеп куйган ук, сөңге сапларына ярый ла тимер җиткереп булса! – диде Тәгин углан. – Тимер генә им түгел! Тимер җитмәсә, таш, сөяк куярлар, – диде --- оста.* Н.Фәттах. *Моннан 5 ел элек казчылык бик отышлы иде әле. Бәяләр дә тәмам бәйдән ычкынмаган, катнаш азык заводлары да яхшы эшли. Хәзер акчага – им, казларга җим җитми башлады.* Идел

5) *күч.* Дәва, котылу юлы. *Ялкауның име – тырышлык.* Мәкаль

◊ **Имгә дә, имгә дисәң дә** *к.* **им өчен (дә).** *Безнең бу якларда ләкләк дигән ул сәер кошны имгә дисәң дә таба алмассың, белмим, берәр адашканы ялгышып килеп чыкмаса.* Ф.Хөсни. *Монда бит имгә дә юк ул сандугач кошчыгы.* Г.Әпсәләмов. **Имгә калган** Им-том белән дәваланып кына яшәп торган, саулыгы булмаган. *Имгә калган – имгәкле.* Мәкаль. **Имгә килү** Холык-фигыле яхшыру, әйбәтләнү, рәтләнү. *Чирттеме, юкмы, шулай да Зөлкаршин имгә килә башлаган шикелле иде.* Х.Камалов. **Имгә эзләсәң дә** *к.* **им өчен (дә)**. **Имгә яраклы (ярарлык)** 1) Нинди дә булса үзгәлеге белән аерылып торган, башкаларга охшамаган; нинди дә булса эш өчен файдалана алырлык. *Төрле тип вагоннарны, --- таккан чуар составта кемнәр генә юк: --- коралы үзендә, аш кашыгы итек кунычында булган «бөтенесенә әзер» гвардеецлар – имгә яраклы халык без монда.* Ф.Хөсни; 2) *к.* **им өчен (дә)**. *Бөтен тарафтан хуш ис – алма, чәчкә исләре аңкый, фирүзә күктә имгә ярарлык бер болыт әсәре күренми.* Т.Әйди. **Имгә яраксыз** Бернәрсәгә дә ярамый торган. **Имен бирү** *сөйл. сир.* 1) Тиргәү, шелтәләү. *Мин ул юньсезләрнең имен бирим әле, менә битсезләр.* М.Фәйзи; 2) Кыйнау, җәзалау. **Имен табу** 1) Дәвасын, шифасын булдыру; 2) Чарасын, әмәлен, хәйләсен табу. *Берәр имен тапты ахры, тәмәкегә акча сорамый башлады, дип, Фатыйма сөенечен уртаклашты.* Заман. **Им өчен (дә)** «Бик аз гына», «бөтенләй», «бернинди дә», «бернигә дә» дигән мәгънәләрне белдерә. *Әнә табып карасыннар хәзер им өчен хет бер генә төнбоек чәчәген. Табарсың бар.* Г.Шәрәфи. *Безне Чепья сыйлый: өстәлдә тезелеп киткән «Боржоми». Шәһәрдә аны им өчен дә таба алмыйсың.* М.Мәһдиев

**ИМАЖИНИЗМ** *и. фр.* Россиядә 1920 еллардан соң футуризм поэтикасына нигезләнеп барлыкка килгән, образны – мәгънәдән, сүзне эчтәлектән өстен санаган, рифма, сүз уйнатып, чынбарлык белән бәйләнеше булмаган образ, метафорага корылган сурәт тудыруны максат итеп куйган әдәби агым. *Син әйтәсе фикерләреңне ачык итеп, башкалар аңларлык итеп әйтергә тиешле. «Имажинизм» дип, модага ияреп, үз талантыңны үзең бозып йөрү килешми.* Г.Мөхәммәдова. *Кави Нәҗминең имажинизм лозунгысын күтәреп чыккан вакытлары бар иде.* Г.Нигъмәти. *Егерменче елларда татар поэзиясе өлкәсендә футуризм, имажинизм күренеп үтте...* Х.Госман

**ИМАЖИНИСТ** *и. рус* Әдәби агымда имажинизм юнәлешен яклаучы, имажинизм тарафдары. *Такташ, шигырьнең ритмик төзелешен бетерергә, димәсә дә, аны сөйләүгә җайлаштыру, стиль ягыннан яңарту турында гына сүз йөртсә дә, футуристлар, имажинистлар моны башкача аңладылар, алар, гомумән, ритмик төзелеш бетәргә тиеш, дип чыктылар.* Х.Госман. --- *ул [К.Нәҗми] татар әдәбиятында туып җитмәгән имажинизмны бетерелгән дип игълан кыла, татарның дөньяда булмаган имажинистлары исеменнән берүзе манифест яза.* Г.Нигъмәти

**ИМАЖИНИСТИК** *с.* Имажинизм юнәлешенә караган, имажинизмга нигезләнгән. *Гадел Кутуйның, Кави Нәҗминең һ.б.ның «гаять нечкә аһәңле, гали гармонияле иреклe шигырь» дип тәкъдим ителгән имажинистик яки футурустик «тәҗрибә»ләрендә демократик әдәбиятның реалистик стиленә бөтенләй ят күренешләр тулып ятты.* Г.Халит

**ИМАЖИНИСТЛЫК** *и.* 1) *к.* **имажинизм**. *Кави, революция елларында имажинистлык манифесты белән, футурист язучыларга гына хас булган әз генә арттырылган, кечкенә генә ямьсезләтелгән кыю чыгышлары белән, башта читтән нык кына сүгешләргә дә очрады.* Г.Нигъмәти

2) Имажинист булу

**ИМАМ** *и. гар.* 1) Мәхәллә башлыгы, өлкән мулла. *Бу авылның имамының тырышып кына мәктәп өстерәп барганын да вә халкын да рухани тәрбия итәргә тырышканын мин иптәшләремнән ишетеп белә идем.* Ф.Әмирхан. *Ул авылга керү белән мәхәллә имамының йортын сорады да, атларны шул муллаларның йортына туктатып, авыл халкын җыярга әмер бирде.* Г.Ибраһимов. *Ул кеше шул мәхәлләнең имамы икән. Имам күпне күргән кеше икән, безгә күп яхшы киңәшләр бирде.* Сөембикә

2) Җәмәгатьне үзенә ияртеп намаз укытучы. *Әгәр һәр намазны, җыелып, имам белән бергә укысаң, Биш вакыт – имамны, биш вакыт кыйбланы хәтереңә ал син, ---.* Г.Утыз Имәни. *Ире хатынына имам булып намаз укыта ала*

3) Исламда: берәр дини мәзһәп, юнәлеш оештырган кеше. *Мәзһәп имамнары. Хәдис имамнары*

4) Ислам дәүләтендә дөньяви һәм дини хакимиятне үз кулында тоткан хөкүмәт башлыгы. *1948 елда [Мисырда] алдынгы офицерлар имамга каршы баш күтәрәләр.* Казан утлары

5) *иск.* Зур җитәкче, юлбашчы. *Анда аны мәңгегә Иблис диләр. Газазил дип эндәшергә кушмыйлар. Билгеле, оҗмахта торды ул элек, Бар мәләкләргә имам булган булып.* Ш.Бабич

**ИМАМӘТ** *и. иск. гар. к.* **имамлык**

**ИМАМӘТЛЕК** *и. иск. к.* **имамлык** (*1 мәгъ*). *Тагын бер елдан --- имамәтлек хезмәтендә исә ихлас, гадел*

*кеше сыйфатында танылып өлгергән Р.Фәхреддиневкә --- казыйлык дәрәҗәсен тәкъдим итәләр.* Казан утлары

**ИМАМӘТЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Имамлык вазифасын үтәү

**ИМАМӘТЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **имамәтлек итү**. *Башка аталарның, угыллары алынган хәбәрне ишеткәч, иң әүвәл хис иткән нәрсәләре кызгану була, «мулла булыр, имамәтлек кылыр» дип йөргән шәкерт углы алынган кешеләр дә берьюлы өмет өзмиләр.* Г.Ибраһимов

**ИМАМГА́ ОЮ** *ф. дини* Намаз вакытында, үзең укымыйча, имамны тыңлап, аның хәрәкәтләрен кабатлап бару. *Мин дәшмим, имамга оеп утырам.* Н.Гыйматдинова. *Китапта --- имамнарның, --- мәзиннәрнең таш кыяларга менеп азан әйтүләре, йөзләрчә мөритләрнең имамга оеп, яшел болын өстендә намаз укулары тасвирлана.* М.Әмир. *Ни гаҗәп, һич көтмәгәндә, Ибраһим, имамга оеган кебек, баскан урынында оеп калды да ихлас күңелдән азан тыңлый башлады.* Г.Бәширов

**ИМАМЛЫК** *и.* 1) Имам булу, мәхәллә башлыгы вазифасы. *Әгәр һәр намазны, җыелып, имам белән бергә укысаң, Биш вакыт – имамны, биш вакыт кыйбланы хәтереңә ал син, Имамлык шартын белсәң, белмәсәң – булма имам!* Г.Утыз Имәни. *Мәгъсүм хәлфә --- имамлык вазифасын үти.* Р.Ишморат. *Г.Баруди 1882 елда Казанга кайта һәм анда 5 нче мәчеттә имамлык һәм дәрес бирү өчен --- указ ала.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Башында имам торган дәүләт, имамәт. *Төньяк Кавказда XIX йөзнең 30 нчы елларына кадәр дәүләтләр дөньяви булсалар, хәзер алар теократик (руханилар җитәкчелек итә торган) феодаль дәүләткә – имамлыкка (дәүләт башында имам торган) әвереләләр.* Россия тарихы

**ИМАМЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Имам вазифаларын үтәү. *Ул вакытта Г.Баруди Казан шәһәренең мәшһүр Печән базарыннан ерак түгел, үзе имамлык иткән мәчет белән мәдрәсә янәшәсендәге яртылашы агач буралы бер йортта яши иде.* Г.Баттал. *Архив вәсикаларында Закир ишан имамлык иткән мәчетнең һәм мәхәлләнең кайчан салынуы яки оешу вакыты анык күрсәтелмәгән ---.* Р.Әмирхан

**ИМАМЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **имамлык итү**. --- *1854 елда янган мәчет урынына 1859 елда яңасы төзелгән, һәм биредә Мөхәммәд-Закир Камалов, гомеренең соңынача диярлек, имамлык кылган.* Р.Әмирхан. *Гадәттә, кадим мәдрәсәләренең башында мөдәррис булып, ул шул ук мәхәлләдә имамлык кыла иде.* Казан утлары

**ИМА́М МӨГАЛЛИМ** *и. гар. тар.* Мәдрәсәдә шәкертләр укыту хокукы алган хәлфә белән имам мөдәррис арасындагы урта дәрәҗәдәге мулла. *Мәдрәсәдән имам-мөгаллим исеме белән чыккан Идрис хәлфә заманына күрә хөр фикерле укытучы була ---.* М.Әмир

**ИМА́М МӨДӘРРИС** *и. гар. тар.* Күп санлы шәкертләрне мәдрәсәдә укыту хокукына (өлкән укытучылык дәрәҗәсенә) ия иң югары дәрәҗәдәге мулла. *XVIII гасырның 30–50 нче елларында Тайсуган авылы имам мөдәррисе Габдрахман иң күренекле кеше булган.* Татарстан тарихы. *Мәдрәсәнең бер еллык галия (югары) бүлегендә укучылар, дин гыйлемен үзләштереп, имам мөдәррислеккә әзерләнделәр.* Казан утлары

**ИМА́М МӨХТӘСИП** *и. гар.* Мөхтәсибәт башлыгы. *Тавыш бирүдә Татарстанның имам мөхтәсибләре, казыйлар, дини уку йортлары ректорлары, --- катнашкан.* Ирек мәйданы. *Пленум алдыннан һәрбер имам мөхтәсибкә гыйнвар – февраль ае өчен 13 мең сум күләмендә эш хакы язылган иде.* Ирек мәйданы

**ИМА́М ТОРУ** *ф.* Имам булып, башкаларны үзенә ияртеп намаз укыту. *Бер мулла биш вакыт намазда, җомгаларда, гаетләрдә имам тора.* Г.Тукай. *Мунча яккан көнне аны мунчага чакыра идек, мунчадан соң ул имам торып әтигә намаз укыта иде.* Г.Исхакый

**ИМА́М ХАТИП** *и. гар.* Җомга, гает намазларын укыту (хөтбә) хокукына ия дин әһеле. *Шул сөйләшүдән атнаун көн үттеме-юкмы, Казан халкы, кан-яшь түгеп, имам хатипның җеназасын озатты.* Ф.Латыйфи. *[Фәрид Хәйдәр улы] 1992 елда Татарстан Диния нәзарәтендә мөфти Габдулла хәзрәтнең икенче урынбасары вазифасын башкара, Печән базары мәчетендә имам хатип булып тора.* Юлдаш. *– Мөселманнар бер-берсен бәладә ялгыз калдырмый. Барысы да җайланыр, – ди аңа имам хатип.* Ислам вә хәят

**ИМА́М ХАТИП МӨГАЛЛИМ** *и. гар. к.* **имам мөгаллим**

**ИМА́М ХАТИП МӨДӘРРИС** *и. гар. к.* **имам мөдәррис**. *Биек мәчетнең карт имамы – имам хатип мөдәррис Фәхреддин хәзрәт --- мәдрәсәдә авыл балаларын да укыта иде.* З.Һади. *Лотфи үзе дә рәхмәт укып, үз кулы белән «имам хатип вә мөдәррис» дип куйган.* Г.Ибраһимов. *Йөзьяшәр имам хатип мөдәррис Каюм ага, нишләптер, Шәрифне якын итә, башкалардан аралап үз хозурына чакыра торган иде.* Ф.Латыйфи

**ИМАН** *и. гар.* 1) Ышану, ышаныч, инану. *– Шулкадәр өметсезлек белән яшәргә синең нигезең юк. Алай яшәп булмый! – диде ул. Әхәт күзләре йомык килеш башын чайкады. – Күпләр шушы иман белән яши.* А.Гыйләҗев. *Мәхәббәт, соңарып килгән мәхәббәт, ярсу бикә өчен иманга әверелде.* М.Хәбибуллин. *– Нинди иман кирәк сиңа тагын? – Бригадир Ибрайның Сәгыйдулла агайга ачуы чыкты. – Иманыбыз – коммунизм безнең.* Р.Вәлиев

2) Ислам динендә: дин куйган тәгълиматларга чын күңелдән ышану, игътикат. --- *бала атасыннан ана кеше баш тарта аламы?.. Намусы юкның иманы да булмый икән шул, – дип, беравыкка кадәр уфтанды Ялан кешеләре.* Я.Зәнкиев. *– Казанга баш булу кая, сез аны якыннан күрергә дә лаек түгел. Чөнки җаныгызда – иман, динегездә нур юк, – дигәннәр.* Ф.Латыйфи. *– Җәйсәң – җәймә, бөксәң бөккән булырлык бала иде. Аллаһы Тәгалә иман байлыгы бирә күрсен үзенә, – [диде Хөпбелниса җиңги].* М.Хәсәнов

3) Мөселман икәнлекне исбатлау, раслау, Аллага инануны белдерә торган дога сүзләре. *Икенче егет дәшмитынмый Идел бозларына карап торатора да, авыз эченнән иман укып, ярдан берничә сажень Иделгә керә.*

Г.Ибраһимов. *Куркуыннан --- мич артына сыенган карчык иманын, догасын да әйтә алмады, револьвер тавышына һушыннан язып, идәнгә егылды.* Г.Ибраһимов. *Иманны яхшы өйрәнеп, намаз ниятләрен белсәң, кирәкле догаларны ятласаң, шул җиткән сезгә, ди торган иде карт абыстай.* М.Галәү

◊ **Иман алыштыру** Динен алыштыру, башка дингә күчү яки идеологик юнәлешен үзгәртү. *Халыкның бер өлеше ничарадан-бичара урыслашкан, милләтнең аңлы өлеше урыстан мәрхәмәт көтүнең өметсезлеген белеп урыслашкан, чукынган, иманын алыштырган, чит илләргә таралган.* А.Гыйләҗев. **Иманга зәгыйфь** Дингә, Аллага ышанычы аз. *Бу нинди диниятсезлек! Күрдегезме, хуҗагыз иманга зәгыйфь.* Н.Исәнбәт. **Иманга килү** 1) Ышанмыйча йөргән нәрсәгә ышана башлау. *--- соңгы дәвердә ул иренең хикмәтләренә күнекте, исе китми башлады, чит хатыннар белән юргалавына бармак аша карады, «бөкрене кабер генә төзәтер» дигән иманга килде.* А.Гыйләҗев; 2) *к.* **иман китерү** (*2 мәгъ.*). *Иманга кил, адәм тәганәсе! Кабер якасында булса да, бер Аллаһуга инан!* А.Хәлим; 3) Сабак алу, уйлабрак, акыл белән эш итә башлау. *Әле Рәсәйдәге бер халык та бүгенгедән гыйбрәт алып, киләчәккә терәк булырлык иманга килмәгән!* А.Гыйләҗев. **Иманга китерү** *сөйл. к.* **иман(ын) укыту**. *Женя нык урды аны. --- Кобраны иманга китергән көнне яралган хис торган саен көчлерәк тернәкләнә барды.* Б.Камалов. *Җир алды мужик, хөррият алды мужик, алпут талады мужик, инде хәзер үзебезне талатыргамы? Торып тор, мин аларны болай да иманга китерәчәкмен.* Ф.Хөсни. **Иманга утыру** Акылга килү, акыл белән эш итә башлау. *--- ана кеше үз баласына үч саклый белми ич ул. Кыз да иманга утырып кайтып килә...* Р.Мөхәммәдиев. **Иман җәяү качкан** Имансыз, шәфкатьсез, кешелексез. *Бу нәсел бәндәләреннән иман җәяү качкан, бу нәсел бәндәләренә чебен ни дә, кеше ни.* Н.Гыйматдинова. **Иман жую** *к.* **иман сату**. *Берәүләр, чыдый алмыйча качып китеп, төрмәгә эләгәләр, икенчеләр, урыс исерекләренә баш биреп, иманнарын җуялар, ---.* Я.Зәнкиев. *Аяусыз тәре походларының соңгысы асып-кисеп, яндырып-көйдереп узган безне. Тик шул хәлдә дә безнең халык иманын җуймаган.* Т.Әйди. **Иман заты көтмәү** *к.* **иман көтмәү** *Алай-болай мин әйтте дип әйтә калсаң, иман заты көтмә, бүгенге шикелле генә итмәм, бер бирүдә тынсыз ясармын.* В.Нуруллин. **Иман йорты** Мәчет. *Күрше авыллардан көнләшеп торгызалар иман йортын каратайлылар.* Н.Гыйматдинова. *Әгәр иман йорты, кемнәрдер тәкъдим иткәнчә, намаз картлары барып җитә алмаслык ерак бистәдә салынса, һәркем үзен түбәнсетелгән итеп тояр --- иде.* Сөембикә. **Иман кайту** Үзенең элек ышанган идеалына, фикеренә, принципларына яңадан ышана башлау. *– Илле алтыга тикле утырдым... Унтугыз ел! Әйләнеп кайткач --- монда урнаштым – иманым кайтты, кешеләргә ышанырга өйрәндем...* Р.Мөхәммәдиев. **Иман какшау** Моңарчы ышанып йөргән нәрсәгә ышаныч кимү, ышаныч бетә башлау. *Директорга, мәктәпкә, укытучыларга булган ышанычның мондый юнәлеш алуыннан аның [Гомәрнең] җаны катты, ләкин мәхәббәткә иманы какшамады.* Г.Рәхим. *– Менә безгә ачыкларга кирәк: кем гаделлекне аяк астына салып таптаган, кем Хөснетдин абзыйның иманын какшаткан?.. – Фәһим --- Сәлимҗанга текәлде.* Г.Бәширов. *Хәзер язмыйм, кулым бармый. Үз дәлилләремә ышанычым кимеде. Иманым какшады.* А.Гыйләҗев. **Иман качу (качыру)** Диннән язу, диннән ваз кичү. *Галләм үзе иҗат итәргә теләде. Аек баштан, аек фикер белән язылган көйләр таләп итте заман. Галләмнең «иман качырып» йөрүенә әнисе бәхиллеген бирмәде.* Н.Гыйматдинова. *Карт, хәлсезләнеп, ятагына утыра. – Ул чакта сине борчуым тикмәгә түгел иде, балакай. Шәрук – иманы качкан бәндә – Галимәне харап итеп ташлаган иде шул...* Н.Гыйматдинова. **Иман(ын) кикертү** *сөйл. к.* **иман(ын) укыту**. *--- Сталинградка баргач, ну, немецларның иманнарын кикерттек инде...* Х.Камалов. **Иман китерү** 1) Инану, ышану, ышаныч белдерү. *Кишәрлекләрнең почмакларындагы чөйләрнең төгәллегенә иман китереп, ике арага сүс бау тарттырып куйгач, үз ягыннан Галимҗан тавыш бирде.* Ф.Баттал. *[Немецлар] --- безне кол итү, кырып бетерү хокукына иман китергәннәр иде.* Р.Фәизов. *Сүзне Сәхәрия дәвам итте: – Оныгым Фәрахетдиннең дә өйләнүе адәм рәтле булыр, боерган булса. Монысына иман китерәм.* М.Хуҗин; 2) Мөселманлыкка, христианлыкка һ.б.га чыгу, нинди дә булса дин кабул итү. *[Шәех Игънәй] Мин башта ике динне дә тотып карыйм, кайсы камилрәк, шуңа иман китерәчәкмен, дип әйтеп әйткән, диләр.* М.Хәбибуллин. *Яшь мулла гарьлегеннән җыенган да авылдан киткән. Арыслан аңа күпме өмет баглаган иде! Имеш, бергәләшеп, Каратайны иманга китерәләр.* Н.Гыйматдинова. *Аллаһка иман китергәннән соң, тагын бер гамәл-сыйфатларның күркәме: адәмнәргә сөекле булып күренү.* Сөембикә; 3) *к.* **иман яңарту**. *Бик кыска дөнья тормышының вакытлы сынау гына икәнлеген аңлау, моңа кире какмаслык дәлилләр белән иман китерү хак мөселманның тормышын мәгънәле итә.* Р.Фәтхрахманов. *Җәлилчеләр үлемгә барганда да җырлап барганнар һәм... иң-иң гаҗәбе шул: алар кулларына Коръән тотып, иман китереп үлемгә киткәннәр.* Сөембикә; 4) Ышанмыйча йөргән нәрсәнең дөреслегенә ышану, раслыгын тану, тәүбәгә килү. *Ул [Шәмсир] инде әсирләр лагерена килеп эләккәч үк, адәм баласының бөҗәктән аерылмавын, ихтыярсызлыгын һәм зәгыйфьлеген яхшы төшенде, Хак Тәгаләгә баш имәү, аңа гозерләнеп дога укымауның мәгънәсез тәкәбберлек, тинтәклек икәнлегенә дә иман китерде.* Т.Әйди. **Иман китерүче** Алланың барлыгына, берлегенә, Мөхәммәд пәйгамбәргә инанучы кеше, хак мөселман. **Иман корыту** Берәр нәрсәгә булган ышанычны юкка чыгару. *Эттә түгел хикмәт, этеңә кадәр үк иманыңны корытканнар. Шуңа --- ялгыз каңгырап йөрисең син шәһәр җирендә.* Р.Мөхәммәдиев. **Иман көтмәү** Кемгә дә булса

ышанычны җую, аңардан яхшылык, изгелек, гадел мөнәсәбәт көтмәү. *Син аның «тәүбә иттем» дигән сүзенә карап алданма, аннан иман көтмә, ышанычка керер өчен генә тырыша ул.* Н.Исәнбәт. *«Баксаң, минем карчыкның аш пешерү турында уенда да юктыр әле, – дип уйлый иде Фатыйх. – Бер авызын турсайтса, тиз генә иман көтмә инде син аңардан».* Р.Төхфәтуллин. **Иман нуры** *дини* 1) Динле кешеләр ышануынча, Аллага иман китергән, динле, иманлы кешеләрдә генә була торган йөз күркәмлеге, йөз нуры. *--- Аллаһуга инан! Шунда гына гөнаһларың ярлыканыр, шунда гына мәҗүсиләнеп саргайган йөзеңә алсулык, иман нуры калкыр!...* А.Хәлим. *Ничек кенә булмасын, Магаданда туып үскән мөһаҗир энесеннән милли пәрвәр чыгуга ул [Сәет] ышанмый. Алар – телләрен, диннәрен югалткан, бөтенләй башка мохиттә тәрбия алган халык. Күбесендә иман нуры калмаган.* Т.Галиуллин. *Күзләрендә иман нуры юк, кыланмышларында мөрәүвәт беткән.* А.Гыйләҗев; 2) Эчтәге өметнең, күңел сафлыгының йөзгә чыгуы. *--- иман нуры таратып утыручы, яныннан үткәндә сабырланырга, дөньяның фани икәнен искә төшерергә мәҗбүр итүче гыйбадәтханәләр юк икән бу яңа калаларда.* А.Гыйләҗев. *Бүген авылның уртасында Мәүлет мәчете тирә-якка иман нуры чәчеп, балкып утыра.* Сөембикә. **Иман ныгыту** *к.* **иман китерү** (*1 мәгъ.*). *Зөләйханың мең сынаганы, йөз ялгышканы булды, яши-яши, ул бер иманны ныгытты: --- «вакытсыз чакта аяк астында уралмаска», «артыгын белмәскә», «түзем һәм чыдам булырга».* А.Гыйләҗев. *Һәм, шул көчкә таянып, үзенең тагын Казанга кайтуына иманы ныгый бара иде аның.* К.Нәҗми. *Утызлап җинаять эшләп, үзләренең тотылмаслыкларына иманнарын ныгыткач, кәкре куллар тагын да аза төшәләр.* Ф.Вәлиәхмәтов. **Иман саклау** Үзенең элек ышанган идеалына, фикеренә, принципларына хыянәт итмәү. *Әгәр дә без мондыйларны йомып калдырсак, киләчәк буын безгә нәләт укыр: «Революция ясый белгәннәр, әмма кешенең иманын сакларга көчләре җитмәгән!» – диярләр.* Г.Бәширов. **Иман сату** 1) Үзенең элек ышанган идеалына, фикеренә, принципларына хыянәт итү; бүтәнчә уйлый яки эшли башлау. *[Татарлар] Фаҗигале шартларда да, кол хәленә килеп җиткәндә дә теленнән, диненнән качмаган, иманын сатмаган.* Ә.Кәримуллин. *Иман сатуны (димәк, иман яңартуны да) төрле кеше төрлечә аңлый. Геосәясәт күзлегеннән исә ул – үзеңнең табигый асылыңа хыянәт.* Р.Сафин. *Сәлимҗан – акларның «максимка»ларына каршы атакага ташланган кеше! Штык сугышына күтәрелгән кеше! Мин аңа ышанам, ул дөресен әйтер! Ул да иманын сатса, кемгә ышанырга аннары?* Г.Бәширов; 2) Намус югалту; хыянәткә бару. *– Тор! – диде аңа Гайзулла ачу белән. – Шайтан суы эчеп иманыңны сатма, иблис коткысына бирелмә.* М.Хәбибуллин. *Акча ул бакчада үсми. Без аңа байтак иман сатабыз.* М.Галәү. *--- сезнең тарафлардагы берсеннән-берсе шаккатыргычрак хәлләр, иманын сатып яшәүче бәндәләр кабаттан фельетон язарга кызыктыра башлады.* К.Тимбикова**. Иман тактасы** Авыз. *Тегесе, килеп, Тәүгизне төртеп җибәрде. – Иман тактасына кундыр берне, --- дип, бер-берсеннән уздырып көлештеләр.* Х.Камалов. **Иманым камил** Үз эшенә, максатына бик нык ышануны белдергәндә әйтелә: «ышанычым нык, бөтен» дигән мәгънәдә. *Иманым камил, ул бу минутта берни дә күрми, бары тик беләкләре буйлап типкән кан тамырлары аша кызга үзенең җылы күңел хисләрен белдерә иде...* Г.Гыйльманов. *--- бу җырны сезнең кебек болай тирән мәгънәле итеп өздереп җырлаучыны ишеткәнем юк шикелле. Иманым камил, зур җырчы булырсыз.* Р.Гариф. *Ай-һай, Иван төшереп калдырамы? Кемнеңдер шакшы кулы уйнаган, иманым камил...* Ф.Латыйфи. **Иманым кяфер (көфер) булсын** Каргану, ант итү сүзләре («икмәктер, җир йотсын» кебек). **Иманым кяфер (көфер) китсен** *к.* **иманым кяфер (көфер) булсын**. *Йосыф абый әсәрләнеп киткән иде дә: – Әгәр дә теге патифун пластинкасында уйный торган Мохтар Әхмәдиев белән ярышып карарга туры килсә, иманым кяфер китсен, дип әйтәм, җиңә үк алмасаң да, аннан бер тамчы да калышмас идең! – дип кычкырып әйтеп куйган иде.* В.Нуруллин. **Иманым шаһит** *к.* **иманым камил**. *Син, давай, мине алай кыйбласызлар чутына тыкма, парин! Пука мин берегезнең җырын да җырламыйм әле. Иманым шаһит, шушы көнгәчә нә сезгә, нә тегеләргә кушылганым юк!* В.Нуруллин. **Иманын алу** *сөйл. к.* **иманын укыту**. *– Дәүлиев Рифкат! Флүрәнең җегете армия сафларында – бөтерелмә ул тирәдә. Кайткач иманыңны алыр, бел аны, – [диде Хәкимҗанов].* Ә.Гаффар. **Иманын көю** *к.* **иманын укыту**. *Тукта, Бакый кайгысын юдыртсын. Аннан иманыгызны көячәк ул.* Н.Гыйматдинова. **Иманын өшкерү** *к.* **иманын укыту**. *«Көлегез, көл! Елар чакларыгыз алда әле! Иманыгызны өшкерәм әле мин сезнең!» – ди иде Фирдүс эченнән генә.* М.Маликова. *Менә хәзер үк барырга да өйләренә, Мәрзиәне чакырып чыгарырга, усал итеп, өздереп әйтергә үзенә: «Гайбәт сатуыңны туктатмасаң, җаныңны суырам, иманыңны өшкерәм мин синең, бел!»* Р.Төхфәтуллин. *Әниең --- чит-ят егетләр, ирләр белән чуалмасын, аң бул! Юкса, Алла сакласын, кайтырмын да иманнарын өшкереп китәрмен.* Г.Мөхәммәтшин. **Иманын укыту** *сөйл.* Тиешле җәза бирү; акылга утырту; тәүбә иттерү. *Күрсеннәр, Абдулла, алтын егет син! Әгәр синнән йөз чөерсәләр, иманнарын укыт.* А.Гыйләҗев. *Мөнәвәрә, сагайган итенеп: – Әллә берәр җүнсезе иялəшкәнме, берәр качкыны өркетәме халыкны? – диде. – Чуртым да иялəшмәгән! Сәфәрең, кайтып, иманнарын укытудан куркалар.* Н.Гыйматдинова. *Атларны төнге көтүгә алып чыкмый кара, колхоз председателе Фәйрүзә апа иманыңны укытыр.* В.Нуруллин. **Иманын үтүкләү** *к.* **иманын укыту**. *– Белгәч, нигә милициягә шылтыратмадың? – Сәлимә түрдәге диванга җәелде. – Хәзер үк шылтырат! Кулын боргычлап, иманын үтүкләсеннәр ул бандитның!* Н.Гыйматдинова. **Иман югалту**

Нәрсәгә дә булса ышаныч бетү. *Хатыным әбигә күз карашы белән чат ябышты. Мин дә иманымны югалткандай торам.* Н.Гыйматдинова. --- *Кировның үтерелүе һәм башкалар илнең астын өскә китереп кенә калмады, кешеләрдә бер-берсенә карата шик-шөбһә тудырды, борын-борыннан килгән ышаныч-таянычны какшатты... Халык иманын югалта башлады.* Р.Кәрами. **Иман юлына басу** *к.* **иманга килү**. *Иман юлына баскан карттан көлсәләр, авызлары чалшаер, әти.* Н.Гыйматдинова. **Иман юлына кайту** *к.* **иманга килү**. *Ике ел ярым Чечняда йөргән, тау-ташлар арасында яшәгән, кеше үлеменнән башканы белмәгән, күрмәгән бер бәндә, шулай ук, Фәүзия апага килеп, иман юлына кайткан.* Юлдаш. **Иман яңарту** 1) Аллага ышануга кимчелек китерә торган эш эшләгәннән соң тәүбә итү, яңадан иман китерү, иманлы кеше хәленә кайту. *Ә мин, ачлы-туклы торган килеш ураза тотып, иман яңартмакчы, аз булса да акча янга калдырмакчы булам...* З.Фәйзи; 2) Иске ышануларны, тәгълиматларны кире кайтарып яңадан кабул итү, ышанычны ныгыту. *Син бирешмә, нык тор, батыр бул, иманыңны яңарт! Яле, әйтеп кара: ля илаһә иллә аллаһ!..* Г.Бәширов. *Ленинградтан мин Ленин башлаган эшнең бөеклегенә иман яңартып кайттым.* Г.Ахунов. *Үзе себерде, үзе эчтән генә, моннан ары беркемнән бер нәрсә сорамаска, --- дип иман яңартты.* Р.Вәлиев

**ИМАНА** *и. рус тар.* 1) Элек авыл җирендә җир алырга хокуклы ир җенесендәге кешеләрнең исемлеге, җан исәбе. *Минем җирем юк бит. Соңрак туып, иманага керми калганмын.* Г.Бәширов

2) Җир бүлгәндә җан башына тигән җир участогы, кишәрлек. *Ике имана җирен сөрдерү өчен яз саен байлар алдында бишкә бөгелгәнен белеп торам бит мин аның.* Ф.Хөсни. *Өйдә хәзер җиде кашык булдык, ә имана һаман бер генә.* Ш.Маннур. *Әмма аның [мужикның] иң беренче уе җир турында. Күбесенең имана җире ташка үлчим инде: бер чабата белән бассаң, бөтен җир күмелә, икенче чабатаң белән басар урын да юк.* Г.Шәрипова

3) Җан башына бүлеп бирелгән җир өчен дәүләт казнасына түләнә торган салым; җир рентасы. *Үткән көз, мин лашманда казна хезмәтендә йөргән вакытта, имана түләргә юне булмаганга, минем хатынның актык кәҗәсен саттыргансыз.* М.Галәү. *Ибраһим абзый: – Имананы да бик арттырдылар, менә мин мунчам өчен генә елына бер тәңкә салым бирәм, – диде.* Г.Гобәйдулин. *Җыен таралды, староста белән дисәтникләр, ат җигеп, имана түләмәүчеләрнең йорт әйберләрен җыярга чыктылар.* Г.Бәширов

**ИМАНАЛЫК** *с.* Бер иманага (*1 мәгъ.*) тиешле. *Кыз тапса, минем өлешкә тигән сыңар иманалык җирне дә тартып алырлар.* К.Нәҗми

**ИМА́Н ИТҮ** *ф.* Бик нык ышану. *Докторлар никадәр генә, син таза, дисәләр дә, үзенә ютәл зәхмәте булганына иман иткән, шуңа күрә --- ул көн саен дүрт чи йомырка эчми калмый.* Г.Газиз

**ИМАНЛЫ** *с.* 1) Билгеле бер нәрсәгә нык ышанган, инанган, үз фикерендә, карашларында нык торган. *Драматург сынмас-сыгылмас рухлы һәм нык иманлы герой образларын иҗат итү юнәлешендәге эзләнүләрендә яңаданяңа уңышларга ирешә.* Т.Галиуллин. *Шуның өчен дә безнең чын иманлы, горур иптәшләребезнең берсе сатлык иман колларының меңен каушата ала.* М.Фәйзи. *Әгәр динле, иманлы, көчле рухлы Рейган, Тэтчерлар булмаса, явыз Брежнев урынына алмашка нәкъ аның төсле үк бушкуык тиран менеп утырачак иде бит!* А.Гыйләҗев

2) *дини* Дингә ышанган, дин тота торган, динле, диндар. *...Галләм, бераз җайлана төшеп, яңадан тотынды: – Барыгыз да – яхшы ата балалары, иманлы авызым белән әйткәнне төшенергә тиешсез, бәпкәләрем...* Ф.Хөсни. *Безнең күңел икегә ярылды. Бер яртысы – денсез, икенчесе һаман пакь һәм иманлы хәлендә иде.* Ф.Яхин. *«Улым, – диде ул шунда, – син дә кояш шикелле иманлы нурларың белән teләсә нинди болыт аша үтәрсең, гомерең озын булыр...»* Ф.Мансуров

3) Ышанычлы; ныклы. *Ана сөте имеп үскән балалар сезне ташламас, картайган көнегезнең иманлы терәге булыр.* Н.Гыйматдинова. *Һәм тагын арада – якты ут кебек балкучылар, таза, нык иманлылар, үз юлын тапкан һәм шуннан ышанып атлаучы кешеләр.* Казан утлары

**ИМАНЛЫ́ БҮРЕК** *и. иск.* Тирәсенә кама мехы тоткан җылы, милли бүрек

**ИМАНЛЫЛЫК** *и.* Иманлы булу, динлелек. *Мин моны [эчүчелекне] үзем иманлылыкның гамәлгә туры килмәгәнлегеннән күрәм.* Сөембикә

**ИМАНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Һичбер нәрсәгә ышанмый һәм һичбер изге нәрсәне танымый торган; шәфкатьсез, мәрхәмәтсез, кешелексез. *Һәм [Мәрьям апай] япь-яшь килеш имансыз көчләргә каршы чыккан, бөтен авыл халкын яклаган, ә, бәлки, кемнәрнедер һәлакәттән дә саклап калган фәрештә.* Р.Фәизов. *Имансыз калудан саклан, олан!.. Имансыз калудан... Адәм баласы ышанырга тиешле...* Р.Мөхәммәдиев

2) Аллага, дингә ышанмаучы, дин тотмаучы, динсез

3) Сүзендә тормаучан, ышанычсыз, вәгъдәсез. *Әй кызлар, бу егет халкы коточкыч инде. Бүген сиңа бер төрле сөйли, иртәгә икенче кызга барып, шул ук сүзләрне кабатлый! Имансызлар, валлаһи!* Х.Ширмәт

**2.** *и. мәгъ.* 1) *тирг.* Динсез, кешелексез, юньсез кеше. *Шуннан соң мулла тагын да кыза төште: – Дин дошманы кяфер мәлгунь дә ил имамына бу кадәр шәфкатьсез булмас... Имансызлар сез!.. Җиде тәмуг зобаныйлары!..* А.Шамов. *Шул безнең илдән «акча эшлим» дип киткән имансызлардыр инде алары да.* М.Маликова. *[Беренче ир:] Мөселман башы белән гөнаһ кылып йөри. Үтерергә кирәк имансызны!..* Н.Әсәнбаев

2) *куч.* Яратып, үз итеп әйтү сүзе. *Хәмит шул Мөхетдин Чәүкә янында ясаган фурманны. Кулы бик оста имансыз малайның.* З.Зәйнуллин

3) *куч.* Ризасызлык белдерү сүзе. *Ә ботинкам, имансыз, аягымны кырырга керешә.* М.Юныс. *Аларның сөзгәге – авылда бер сөзгәк, мин Аланы*

*кире Атауга борам. Күршем дә калышмый, чыбыркысын шартлата-шартлата артыбыздан куа. – Имансыз, кая чаптырасың ашаган хайванны!* Н.Гыйматдинова. *Әйе, сөенеч, ә син, ятраткмыйм дип, керә-керешкә куркытып куйган буласың, имансыз малай.* Сөембикә

**3.** *рәв. мәгъ.* Оятсызларча, күзгә карап. – *Күперне кем сала? – Хөкүмәт. Шушы көннәрдә генә карары чыкты, – дип, имансыз алдашты Вәлетдин.* М.Кәрим

◊ **Имансыз китү** *дини* Үлгәндә, мөселманлыкны дәлилләгән доганы («ләиллаһә илла Алла, Мөхәммәд рәсүлулла» дип) әйтмәү. – *Нурмый, синең үлем исереклегең көчәя бара, – диде Галекәй, бик җитди төстә. – Имансыз китә күрмә, белгәннәреңне укы.* Х.Камалов. **Имансыз үтү** *дини к.* **имансыз китү**. *...Аладин, Седельников кебек, эшче вә җирсез авыл халкы файдасына сүз сөйләүче бозык фикердәге членнарга кушылмый, --- эшче һәм авыл халкы ачтан кырылса да, инша алла, үзе өчен гакыйбәте хәерле булып, дөньядан имансыз үтәр.* Ш.Мөхәммәдев

**ИМАНСЫ́З БҮРЕК** *и. иск.* Эче мехлы, тышы камасыз, кырпусыз тирән бүрек. *Әбелмәнихның башында – һаман шул авылдагы имансыз бүрек, алъяпкычы гына ак.* Г.Әпсәләмов

**ИМАНСЫЗЛАНУ** *ф.* Имансызга әйләнү, явызлану, шәфкатьсезләнү. *Ә имансызлар исә бу кризистан тагы да имансызланырга, рәхимсезләнергә мөмкиннәр, шуңа күрә бүгеннән үк җинаятьләр саны, талаулар артканлыгы күренә.* Безнең гәҗит

**Имансызлана бару** Торган саен ныграк имансызлану. *Аның ата-анасы да имансызлана бара бит.* М.Маликова. *Илне басып киткән динсезлек, бик күп дин әһелләренең хаксызга төрмәләргә утыртылулары һәм юк ителүләре, кешеләрнең һаман имансызлана баруы аны бик нык тетрәндерә.* Гасырлар авазы

**Имансызлана башлау** Имансызлык сыйфатлары күренү, имансызлануга таба юл тоту

**Имансызланып бетү** Тәмам, бөтенләй имансызлану

**Имансызланып йөрү** Озак вакытлар дәвамында имансызлык күрсәтү

**Имансызланып китү** Кинәт кенә ниндидер сәбәптән, вакыттан соң имансызлану

**ИМАНСЫЗЛЫК** *и.* 1) Һичбер нәрсәгә ышанмаучанлык, изгелекне танымаучанлык; мәкерлелек, астыртынлык, явызлык. *Халкыбызга тупаслык, җаһиллек, караклык-бурлык, имансызлык каян килә дип, бүген баш ватабыз.* А.Гыйләҗев. *Социализм теориясен тормышка ашыруда ялгышлар җибәргән коммунистлар партиясе, иң беренче, аның җитәкчеләре диктаторлык иткән совет дәүләте шартларында күп кенә закон бозулар булды, кешелексезлек, имансызлык хөкем сөрде.* Т.Галиуллин. *Алар [башкорт галимнәре], гөнаһ-язык турында уйлап тормыйча, татар халкын эчтән таркату нияте белән зур «ачыш»лар ясау юлына бастылар. Мондый имансызлыкның бер мисалы итеп, Рим Янгузинның кайбер «гыйльми фикерләрен» укучыларга җиткерәсе килә.* Казан утлары // Оятсызлык, үтә әдәпсезлек. *Имансызлык белән сыный дөнья, Миражлары юлдан яздыра – Тәмнәр-тәмнәр белән ымсындырып, Рәхәт биреп алдап аздыра.* Ш.Галиев

2) Динсезлек, Аллага, дингә ышанмаучанлык. *Әшәкелек башы – имансызлык, Инанулар төбе – игелек!* И.Гыйләҗев. *Мин барганда гел намазлыкта утырыр иде мәрхүмә. Шаярыша башласак: «Имансызлык караңгылыгында үсмәгез, калебегезне үтерерсез», – диеп ачуланыр иде безне.* Сөембикә. *Авыр вакытларны безнең халыклар – татар, башкорт – элегрәк тә күп кичерде, ләкин шуңа карап кына имансызлыкка бирелмәде.* Юлдаш

3) Вәгъдәсезлек. *Без барыбыз да халык җырчылары булырга тиеш идек. Буралмадык. Гаеп бездә дә түгел. Гаеп безне изгән дәүләтсезлектә, ипсезлектә, телсезлектә, имансызлыкта.* Мирас

**ИМА́Н ШАРТЫ** *и.* Элекке мәдрәсәләрдә дин нигезләрен өйрәтә торган иң беренче китап. *Габделкаюм һәрбер язган хәрефен һәм сүзен әбисенә күрсәтә-күрсәтә яза да букчасыннан «Иман шарты» алып укырга керешә.* М.Галәү. *Тәтеш шәех Болгарда, балалар укыту өчен, «Иман шарты»н язып ята иде.* М.Хәбибуллин. *Аңа, мәзин баласына, ислам кануннары ана сөте, бишек җыры белән сеңдерелгән, Иман шартын, Коръән Кәрим сүрәләрен, догалыкларны да яхшы хәтерли...* А.Хәлим

◊ **Иман шартын укыту** *к.* **иман(ын) укыту**. *Өйдә хатыны иман шартын укытты ахры, ник ул җүнсез синең хакта бүтән авыз ачсын --- [диде Дүсәлим].* Г.Рәхим. *Шундый куркыныч төнне Шәкерт абзыкай да әллә кайда озак йөреп кайтты, кәҗәнкәдәге кисәү агачы белән, әни аңа иман шартын укытты...* Ф.Мансуров

**ИМА́Н ЯСАГЫ** *и. тар.* Мөселман булып калган, ягъни христиан диненә күчмәгән өчен, казнага түләнә торган ясак. *Шуның өстенә әле мөселманнар «иман ясагы»н яки «мөселман булып калу түләве»н дә түләргә тиешләр иде.* Г.Баттал

**ИМӘЗӘ** *и.* Кичен һәм таң аткан-да булган ярым караңгы вакыт, эңгер. *Имәзәдә юлга чыгу*

**ИМӘН** *и.* **1.** Бүкчәләр семьялыгыннан, яфраклары челтәр кырыйлы, каты үзагачлы, зур юан агач; *русчасы:* **дуб**. *Камил мунчаның каен, имән себеркеләре, йомшак сөлгеләр эленгән алгы бүлмәсендә үзалдына җыр көйләп чишенде дә, ишекне кинәт ачып, --- әчкелтем кайнарлыкка чумды.* М.Галиев. *Үсмер имәннәрне иркәләргә Нәзек билле җилләр килгәннәр.* Ә.Ерикәй. *Шул вакыт икенче бер агачтан, ялгыз күбәләккә охшап, имән яфрагы ычкынды...* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Шул агачтан ясалган. *Имән тактадан эшләнгән таш сарай ишеге төбенә бер су чиләге каплап куелган.* Н.Хәсәнов. *Шунда ук Шәрәфи, җиңнәре сызганган кулына зур имән күсәк тотып, читән буена килеп басты...* Г.Галиев. *«Пес! Пес! Пес!» дигән чакыруга, имән ишекне уң тәпие белән каерып ачып, теге кара песи килеп керде.* К.Кәримов

◊ **Имән агачында алма үсмәс** Булдыра алмаслык эшне булдырырга

тырышудан файда яки начар гаиләдән яхшы кеше чыгуга шик белдереп әйтелә. **Имән баганам** Төп таяныч, ярдәмче, терәк. *Акчалата булышып торгач, кая барсам да, нишләсәм дә, артымда имән баганам барлыгын тоеп яшәгәч, миңа нәрсә кирәк?* Сөембикә. **Имәндә икән чикләвек** 1) Нәрсәнедер ачыклап, серен аңлап шаккатуны, гаҗәпләнүне, аптырауны белдерә. *– Сез язган «Тукай маршы»н мин бит сабый чактан ук беләм. – Имәндә икән чикләвек! Ул көйне мин дә сабый чагымнан беләм.* Х.Кумысников. *Ә безнекеләрнең тәрәзәләрендә ут юк. Ятканнар, дисәң... Имәндә икән чикләвек! Мөгаен, ваннада юынып кайтырбыз дип, безгә кунакка киткән болар.* Р.Камалетдинова; 2) Һәркемгә мәгълүм нәрсәне үзенә бик зур яңалык ачкан кебек кабул итүчедән көлеп әйтелә. *Табибә --- студентларын җыя да мәктәп-гимназияләрдә лекцияләр уздырырга үйлаганын сөйли. Бергәләп тотынсалар, шактый зур көчкә әвереләчәкләр бит. Алкоголизм, наркомания «җимешләре» хакында фильм исә аеруча тәэсирле – имәндә икән бит чикләвек!* Сөембикә. **Имән кебек** Нык, таза, саусәламәт кешегә карата әйтелә. *Ул яшь чакта имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле булган, дип сөйлиләр.* Г.Ибраһимов. **Имән кискәдәй** *к.* **имән кебек**. *Сугышта җиде тапкыр җәрәхәт алган булса да, имән кискәдәй нык, юан майор әнә шул чорга аяк басты.* Ш.Рәкыйпов. **Имән үзәкле** *к.* **имән кебек**. *– Әгәр теге чак имгәнеп калмаган булсаң, шул бармак очыдай юньсез тимер ярчыгына гына бирешер идемени синең үпкәң? Затың андый түгел синең. Сезнең затны юкка гына «имән үзәкле» дип йөртмиләр бит ---, – дип көрсенде ул.* М.Кәрим

**ИМӘ́Н АЛМАСЫ** *и. бот.* Имән яфрагындагы аклы-кызыллы кечкенә шар сыман паразит үсенте

**ИМӘ́Н ӘКӘЛӘСЕ** *и. диал. к.* **имән чикләвеге**. *Тиеннәр имән әкәләсе, нарат күркәсе, чикләвек белән туклана.* Кызыклар дөньясында

**ИМӘ́Н БАРМАК** *и.* Баш һәм урта бармаклар арасындагы бармак; икенче бармак, шәһадәт бармагы. *Хәзрәт, пистолет төзәгәндәй төбәп, Хөсәенгә имән бармагын сузды.* А.Расих. *Мәдинә, аңар ташланып, якасыннан эләктергән иде, ләкин сул кулының имән бармагы каерылган булганга күрә, бандит аның бер кулын чыдатмады.* Ш.Камал. *Ишектән килеп кергән бала, – --- икенче кулының имән бармагы белән аскы иренен тоткан кыз – тып-тып басып, Ахияр янына килде.* М.Мәһдиев

**ИМӘ́Н БОРЫН** *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан, зур томшыгы белән каты җимеш орлыкларын ватып ашый торган кечкенә урман кошы; *русчасы:* **дубонос**

**ИМӘНГЕЧ** *с. диал. к.* **имәнеч**. *Имәнгеч бер тойгы кичерде бу вакытта Ярмөхәммәт.* Р.Батулла. *Тыйнак кына кыз иде яшьлегендә, бригадирга кияүгә чыгып куйгач, тәмам узынды, авызы тулы алтын теш, үзе аркылыга-буйга җәелде, имәнгеч.* А.Гыйләҗев

**ИМӘ́Н ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Болетчалар семьялыгына караган, кызылсу яки саргылт көрән эшләпәле, ашарга яраклы гөмбә; *русчасы:* **дубовик**

**ИМӘНДЕРГЕЧ** *с. к.* **имәнеч**. *Аны [Г.Бәшировны] «имәндергеч тормыш сазлыгында яшәп тә, рухын гарипләндермичә, күңел сафлыгын саклап калучылар» сокландыра...* Казан утлары

**ИМӘНДЕРҮ** *ф.* Куркыту, сискәндерү. *Аларда милләт, мәхәббәт темасы кузгатыла, үзара мөнәсәбәтләр сурәтләнә, кайберләре гыйбрәтле, икенчеләре имәндерә, әмма һәрберсендә юмор, «төртмә» сүз бар*. Татарстан яшьләре

**Имәндереп җибәрү** Кинәттән, көтмәгәндә генә бераз имәндерү

**Имәндереп куюю** Кинәт, аз гына вакыт имәндерү

**Имәндереп тору** Даими яки әледәнәле имәндерү

**ИМӘНЕЧ** *с.* **1.** 1) Күңелгә шом, курку сала торган; шомлы, куркыныч. *Имәнеч җәзалар һәм үтерүләрдән коты алынган халыкның байтак өлеше «ак патшага» итагать итү (буйсыну) турында бигать бирергә (ант итәргә) һәм илбасарларга салым түләргә мәҗбүр итегә.* Р.Әмирхан. *Авыл күрке булган Гыйззәт мулланың имәнеч хәбәр китерүе мөмкин түгел.* Г.Әдһәмова

2) Карап торуга котсыз, җирәнгеч, чиркангыч. *Иртәнге якта алар крокодил фермасына килгәннәр иде. Зур, иркен читлекләр эчендәге имәнеч, чиркангыч җанварларга озак-озак карап тордылар.* М.Маликова. *--- табылдыклар өстәлендә хөсетлек бар, кеше, намус, ил, тән сатып тамак туйдыручы имәнеч затлар бар.* Казан утлары

3) Чиркангыч, чиркандыра торган, тәнне чымырдата торган. *Имәнгеч суык*

**2.** *кис. мәгъ. диал.* Сыйфатлар һәм рәвешләр алдында килеп, артыклык дәрәҗәсен бирә. *Имәнеч ямьсез күренеш. Имәнеч зур урман*

**ИМӘНКИСКӘЛЕЛӘР** *и. күпл. тар.* VI–VII гасырларда Татарстанның Лаеш районы территориясендә яшәгән, үзенә хас культурасы белән аерылып торган кабилә. *Имәнкискәлеләрдә игенчелек нык үсеш алган.* Татарстан тарихы. *--- имәнкискәлеләр дә, башка кабиләләр кебек үк, үз вакытында Төрки каһанлыкның яулап алу сугышлары аркасында, яшәгән җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булганнар.* Татарстан тарихы

**ИМӘНЛЕК** *и.* Имән урманы, имәннәр күп үскән урын; имәнсәр. *Имәнлектә ни тупыл үсми, ни карга заты күренми.* Н.Гыйматдинова. *Картның күз алдына Кара кош артындагы имәнлек килеп баса.* Г.Галиев. *Казан таулык имәнлекләреннән хәзерге вакытта республикабызның Апас һәм Кайбыч районнарында зур булмаган участоклар гына сакланып калган, ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИМӘНЛЕ́К ҖИЛДӘГЕ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, кар эреп бетәр-бетмәс үсеп чыга, зәңгәр, шәмәхә, сары, ак чәчәк ата торган үлән үсемлек; *русчасы:* **ветреница дубравная**

**ИМӘНЛЕ́К ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Солы чыпчыклары семьялыгыннан, кызгылт сары төстәге зур булмаган күчмә кош; *русчасы:* **дубравник**

**ИМӘ́Н САРЫМСАГЫ** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан, сарымсак исле, йөнтәс, аксыл яшел төстәге күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **дубровник чесночный**

**ИМӘНСӘР** *и. диал. к.* **имәнлек**. *Атымны җибәрдем имәнсәргә, Кайтмам, җаным-бәгърем, ирексәң дә.* Җыр. *Калкулыкта урман шаулаганда, Имәнсәрдә ялгыз имәннең Нигә шулай моңсу-тын торуын Беләм инде хәзер, беләм мин...* Ш.Маннапов

**ИМӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Куркудан тетрәнү, сискәнү; курку, куркыну. *«Тәннән шул кадәр ит качты микәнни минем?» – дип имәнде Илфат.* Б.Камалов

2) *диал.* Тартыну, оялу

**2.** *и. мәгъ.* Курку, сискәнү тойгысы. *Халыкның ул җырында шик бар, Әмир. Ниндидер курку, имәнү бар.* Р.Ишморатова

**Имәнеп калу** Көтелмәгән вакыйгалардан, эш-хәлләрдән, күренештән кинәт курку, имәнү кичереп, хәрәкәтсез тору. *Каршы як көзгедә үзенең берьюлы суырылып өлгергән сынын күреп, [ул] имәнеп калды. Бигрәк тә аны муенындагы яра эзе тетрәтте.* Ф.Хөсни. *Ул өйгә килеп керүгә имәнеп калды; әнисе бу дымлы базда бөрешкән көе сәкедә ята.* Х.Камалов. *Ногманов сискәнеп китте, хәтта имәнә калды, ләкин сер бирмәде*. Д.Гайнетдинова

**Имәнеп киту** Кинәт имәнү. *Иртәгәсен ул шат, бәхетле Әлфия урынына, бөтенләй өшәнеп, хәтта картая төшкән кызын күреп имәнеп китте.* А.Расих. *Кайчагында яшәвемнән Имәнепләр китәм. Яшәү – оҗмах. Аңардан соң Инде тәмуг көтәм.* М.Әгъләм. *Харис аның плащ җиңеннән тырпаеп чыккан кулларына карады да имәнеп китте: йодрыклары күгелҗем кызыл тукмак кебек, тырнаксыз бармаклары кәкрәеп каткан.* М.Маликова

**Имәнеп кую** Кинәт, аз гына вакыт имәнү кичерү. *Ул сискәнеп, хәтта имәнеп куйды.* Ирек мәйданы

**ИМӘ́Н ЧИКЛӘВЕГЕ** *и. бот.* Имәннең коры, ачылмый торган бер орлыклы җимеше, имән әкәләсе; *русчасы:* **жёлудь**. *Хәтердә әле: бервакыт шулай безне, мәктәп укучыларын, урманга имән чикләвеге җыярга алып бардылар.* Ф.Яруллин. *Ул хәзер, байлардан алып кайтып, потлап-потлап кер юа, якын авылларга кечкенә чана белән барып, имән чикләвеге кушып тарткан он алып кайта...* Ә.Фәйзи. *...Мөби өчен иң авыр вакыт – көз көне агач яфрагы, имән чикләвеге коелган атналар.* М.Мәһдиев

**ИМӘН ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол. к.* **имәнлек чыпчыгы**

**ИМӘС** *кис. диал. Имәк* фигыленең кире кагу формасы; түгел. *Сүзем хактыр, имәс бер зәррә ялган.* Г.Утыз Имәни. *Азым әкәнең сүзен бетермәстән бирәү кычкырды: – Найманнарның исеме симез булса да, тоткан юллары тигез имәс! – диде.* Г.Ибраһимов. *Ул картның сүзенә икеле җавап кайтарды: – Күңелебез пакь, ниятебез ак, ясаган иям безгә ярдәм кылса кирәк ---. Мәгәр бәндәнең үз тырышлыгы да кирәк имәсме?* Г.Ибраһимов

**ИМБИР** *и. нем. бот.* 1) Имбирчәләр семьялыгыннан, коры тамырчасы эфир майларына бай булган, кулинариядә һәм азык сәнәгатендә аш тәмләткеч итеп кулланыла торган күпьеллык үләнчел үсемлек; зәнҗәбил. *Кыргый имбир ризыкны яхшы сеңдерә, олы йомышын үти алмаган кешегә кайнатып эчерсәң, файда бирә.* Идел

2) Шул үсемлекнең тамырчасыннан ясалган аш тәмләткеч. *Абыстай да, тагы бераз зәм-зәм, кипкән инҗир, имбир алып, аның артыннан калмады.* Г.Исхакый

**ИМГӘК** *и.* **1.** 1) Бәла, борчу, мәшәкать, җәфа. *[Шәмси:] Теләк – ул тели белсәң теләк, тели белмәсәң, имгәк.* М.Фәйзи. *[Түләкәй:] Минем сиңа имгәк буласым килми, менә нәрсә. Авыру мин, Зиләйлүк.* Р.Сафин. *Яшь укытучы аны [Мәрьямне] драмтүгәрәккә чакырырга уйлады. – Группаңда имгәк арттырма, – дип, кайбер укытучылар яшь коллегаларының изге ниятен хупламады.* Н.Гыйматдинова

2) Интектергеч хезмәт; күңелдә мәшәкатьле, борчулы эш тәэсиреннән барлыкка килгән авырлык, кыенлык. *Актардылар, эзләделәр – хәзинә юк! Басуның өсте тоташ казылган, тупраклары тетелеп ватылган иде. Ике кардәш, бу кадәр имгәкләре бушка калмасын өчен, богдай чәчтеләр.* Дәрдемәнд

3) *сөйл. тирг.* Булдыксыз, эшлексез, борчылуга сәбәп китереп чыгаручы мәшәкатьле кеше. *Әнисе исә, «өшегән бәрәңге» дип, улын сүгә, аннары үзен битәрләргә тотына: – Үзем гаепле, үзем. Нәселләрендә шундый имгәкләре барын белә торып, аңа чыктым. Тышкы кыяфәте алдады. Кем уйлаган аюдай ирдән бер имгәк туар дип...* Ф.Яруллин. *Безнең авылның Шәмгун Сафасы дигән бер имгәге Рәуфә исемле таза, матур бер кызга өйләнгән иде.* А.Шамов.*– Әткәң аптыраганнан китте, брат... – Юл буе сөйләнеп барды Нәҗип председатель. – Үпкәсе черегән иде бит аның. Сулый да алмый иде. Кал, дидем. Җан имгәге булып йөрмим, ди.* Н.Гыйматдинова

4) Нинди дә булса бер әгъзасы яки әгъзалары зәгыйфь яисә имгәнгән, гарипләнгән кеше. *Казачий пулясын йөрәк астында асрар хәлем юк! Гомер буенча елап-сыкрап яшәгәнче, гарип имгәк булып кеше күзенә карап көн иткәнче, үлгәнең мең мәртәбә артык!* Г.Ибраһимов. *[Галәви:] Аксак күп йөрер, диләр дә бит. Син – шул фронт аксагы... [Шәмгун:] Әй син, тыл имгәге...* Г.Әхмәтшин. *Мин бер имгәк кенә бит инде хәзер. Дөрес, савыгып киләм килүен, ләкин күңелем сынгач, моннан ни файда? Җегәрле чагым, хуш күңелле чагым әйләнеп кайтмастыр инде.* Р.-Н.Гүнтәкин

5) *сөйл. тирг.* Кеше өстендә йөк булып, бушка, бер файдасыз ашап ятучы кеше. *Минбәдәр апа сулкылдап елап җибәрде. – Биш баланы ничек туйдырыйм? Бишәү бит, биш имгәк!* Н.Гыйматдинова. *Йомычкалар арасында ялгыз Утырам уйнап, кермим мин эчкә, Көндезге чәй, мин бит артык тамак, Бүтәннәргә бары мин имгәк...* С.Хәким. *«Имгәкләр» дия торган иде әтиләре балаларына. Ә шул «имгәкләр» белән дөнья барды*. Сөембикә

6) *диал.* Балага узгач, аш талымлау; нәзбереклек. *Киленнең имгәге белән бизгәге бергә булды*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Зәгыйфь, гарип. *Мин зәгыйфь, имгәк кешеме әллә?* Ш.Камал

2) *куч.* Бозык, нормага туры килми торган, кимчелекле. --- *ул татар теленә Европаның модалы язучыларыннан өйрәнмәгән, «яңа стиль» дигән*

*булып, аларның татарчага әйләндерелгән имгәк телле һәйбәт попугае булмаган, ---.* Х.Сарьян

◊ **Имгәккә калу** Кеше ярдәме таләп ителгән авырлыклар алдында калу яисә гариплеккә дучар булу. **Имгәккә тару** *к.* **имгәккә калу**. **Имгәк тарту** Күп авырлыклар, михнәтләр, кыенлыклар күрү, җәфа чигү, михнәт кичерү. **Имгәк чигү** Газаплану, интегү, зәгыйфьлек кичерү. *Ничә ел ятты Әюб, чигеп имгәк, Сабыр итте озак ятса да чирләп.* Г.Утыз Имәни

**ИМГӘКЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Кыенлык, мәшәкать тудыру

2) Мүкәйләү, дүрт аяклап йөрү. *Бала имгәкләргә өйрәнде*

**Имгәкләп яту** Озак вакыт имгәкләү. *Кояшны иләмсез болыт каплап китсә дә, машинабыз гелләгәй юлда имгәкләп ятса да, берәрсе караңгы чырай күрсәтсә дә, шуңа сылтый идек.* Х.Сарьян

**ИМГӘКЛЕ** *с.* 1) Борчулы, бәлале, мәшәкатьле. *Уен төбе – имгәкле.* Мәкаль

2) Булдыксыз, эшлексез, кулыннан эш килми торган. --- *имамыбыз бик тешләк кеше иде, илгә калган бер имгәкле шунда!* М.Әмирханов

**ИМГӘКЛЕК** *и.* Имгәк булу. *Имгә калган имгәклек.* Әйтем

**ИМГӘНҮ** *ф.* **1.** 1) Берәр әгъза яки әгъзаларның табигый торышы бозылып зәгыйфьлек алу, гарипләнү. *– Бу Ильясованың көтелмәгәндә авариягә юлыгуын әйт... Хәзер кайта алмаячак инде ул. – Кайта алмас микәнни? – Кая инде, андый имгәнүдән соң.* М.Маликова. --- *шушы арада гына Максим кайтып төште. Кулы бик нык имгәнгән, ди, әле һаман асып йөри.* В.Распутин // Үсемлекләр, җансыз әйберләргә карата да шул ук мәгънәне белдерә; гарипләнү бозылу, җимерелү. *Ай-һай, алай да барып чыкмас бит, [бодайның] тамыры имгәнер, үзе тапталып бетәр.* Г.Бәширов. *Кич гаражына чыгып караса, «Волга»сы, елыкелык килеп, үз урынында тора. Бер җире имгәнмәгән, сыдырылмаган, ---.* Р.Вәлиев. *Җиһангир ---, тамырлары имгәнмәсен өчен, нәзек, зифа каеннарны бәби билгән төсле генә күтәреп йөртүләрен үтенде.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Рухи халәткә кимчелек, зәгыйфьлек килү. --- *рухым имгәнгән, күңелем төшкән, хәтта Акъәнинең сүзләре дә юатмый, өмет өстәми башлады.* Н.Гыйматдинова. *– Бәхетле шул алар, – диде Тәбрия, аның сүзен бүлеп. – Ә менә минем бөтен язмышым имгәнде, тик кемгә зарланыйм?* М.Маликова. *Имгәнгән җанның төн йокламый язган хаты шәфкатьле кешеләр кулына эләгә...* Сөембикә

3) *күч.* Көч җитмәслек авыр хезмәттән сәламәтлек югалу, зәгыйфьләнү, гарипләнү. *Кечкенәдән эшләп имгәнү*

4) *күч. сөйл.* Икътисади яктан көчсезләнү, фәкыйрьләнү. *Сугыш елларында колхозлар имгәнде*

5) *күч. бор.* Зур тырышлык, энергия сарыф итеп эшләү, мәшәкатьләр күрү. *Яз имгәнсәң, көз кинәнерсең.* Мәкаль

6) *күч.* Югалтуларга дучар булу, зыян-зәүрәт күрү. --- *татар гаскәренең сул канаты бик нык имгәнде, әйтелгәнчә, анда кучерелгән Яглыбай баһадир орышта һәлак булды. Сул канатның имгәнүен күреп торган уң кул, ни өчендер ярдәмгә ашыкмады.* С.Шәмси

**2.** *и. мәгъ.* Берәр әгъзаның яки әгъзаларның гариплеге, зәгыйфьлеге. *Сәбәбе: әлеге дә баягы эчкечелек, наркомания, имгәнү һәм башкалар, һәм башкалар.* Сөембикә. --- *медицина өлкәсендә халыкның сәламәтлеген саклауга, --- яман шеш, йогышлы авыруларны, имгәнүләрне, диабет һәм башка авыруларны кисәтү --- бурычы тора.* Фәнни Татарстан

**Имгәнә тору** Даими, әледән-әле имгәнү; әле берсе, әле икенчесе имгәнү

**Имгәнеп бетү** Тәмам, бик нык имгәнү. *Фермада --- терлекчеләр --- имгәнеп бетәбез инде авыр эштән, диләр.* М.Маликова. *Өлкән инженер-механик булсам да, --- чүкеч тотып тимер кыйныйм. Менә шунда имгәнеп беткән куллар бу.* З.Фәйзи. *Кулы имгәнеп беткән булса да, аны ничектер саклап калырга кирәк иде.* Г.Әпсәләмов

**Имгәнеп калу** Нинди дер бер сәбәптән соң имгәнү. *– Син үзеңнең авторитетың төшүдән куркасың, ә хатыныңның имгәнеп калуыннан курыкмыйсың, – диде, кыза башлап, фельдшер.* Ф.Яруллин. *Сугыштан имгәнеп калды кайбер кешеләр, тәннәре белән генә түгел, җаннары белән дә.* Ф.Хөсни. *Ул [Мәрьям апай] үзе матур да түгел: --- бер аягы аксак, бала вакытында Гарифә әби аны бишегеннән ялгыш егып төшергән дә, аягы имгәнеп калган.* Р.Фәизов

**Имгәнеп кую** Кинәт имгәнү. *Җитәр, Галимә, имгәнеп куярсың.* М.Гафури

**ИМГӘТКЕЧ** *с.* Имгәтә, гарипләндерә торган. *Күңел имгәткеч эш. Җан имгәткеч сүз*

**ИМГӘТҮ** *ф.* 1) Кайсы да булса әгъзаны гарип, зәгыйфь хәлгә китерү, гарипләндерү, зәгыйфьләтү. *Ашау-эчүеңне онытып, берүзең кырыкка ярылырдай булып йөргәндә, энем, арба башыннан егылып төшеп, уң кулын имгәтте.* Г.Ибраһимов. *Ләкин ул [Шуктуган] ике метр ара да уза алмаган, каршыда очраган беренче агачка бәрелеп, җиргә егылып төшкән; канатын имгәткән, маңгаен тишкән.* Җ.Тәрҗеманов. *Аркадий белән Александрның киемендәге, кул һәм йөзләрендәге кан таплары теге ирне кыйнап имгәтү алар эше икәнлекне әйтеп тора.* Дулкын // Үсемлекләргә, җансыз әйберләргә карата да шул ук мәгънәне белдерә; гарипләндерү, бозу, җимерү. --- *әллә инде йорттагы кешеләребез, малайларыбыз үзләре әйбәт, ник бер чәчәк өсеннәр дә ник бер куакны имгәтсеннәр.* Г.Шәрәфи. *[Суны] Бик югарыдан сиптермә! Түбәнрәк тот. Кыярларны имгәтәсең.* Ш.Хөсәенов. *– Аның хәзер нәрсәсен карыйсың? Үзегез гаепле икән, ачык төшләренә быел ук агач үсентеләре утыртырга кирәк. Югыйсә, сез имгәткән агачлар тора-бара барыбер корыячак, – диде [Коләхмәт карт].* Г.Рәхим

2) *күч.* Рухи яктан зыян, кимчелек, зәгыйфьлек китерү; тормыш ямен китәрү, табигый агышын бозу. *Хосусый милекчелек җәмгыяте хезмәт ияләре арасыннан чыккан шәхесне баса, изә, аны физик яктан да, рухи яктан да яньчи, имгәтә...* Х.Госман. *Меңнәр-миллионнарның җаннарын айкап, тормыш-мәгыйшәтен җимереп, бар дөньяның астын-өскә әйләндереп таш-*

*лаган сугыш имгәтте аларның язмышларын.* Р.Мулланурова. *Дүрт гасырга сузылган коллык безне (татарларны) нык имгәткән.* Мирас

3) *күч. сөйл.* Вату, җимерү, эшләргә яраксыз итү. *Насосны бөтенләй имгәткәннәр.* Ш.Камал. *Бу бәрү бик мач булды ахры, немец танкының моторы кинәт тынып калды. Димәк, моторны имгәткәннәр.* Х.Камалов. *Тирә-юньдә җир катламын имгәтеп, таш түшәлгән юлдан төрле йөк төялгән машиналар агыла.* С.Шәрипов

4) *күч.* Куәтне, сәламәтлекне зәгыйфьләндерү. *Авыр тормыш кешене имгәтә*

5) *күч. сөйл.* Икътисади яктан көчсезләнү; фәкыйрьләнү

6) *күч.* Кыргыйларча файдалану. *Күп имгәттек җирне. Имәсен имдек ---.* Ә.Гаффар

**Имгәтеп бетерү** Бөтенләй имгәтү; барысын да имгәтү. *Без киңәшкәнче, ярты авылны имгәтеп бетерәләр инде анда.* И.Гази. *Ләкин әнинең авыруын тәгаен генә ачыклый да, терелтә дә алмадылар. Шул әти имгәтеп бетергәндер инде бичараны.* В.Нуруллин. *Бердәнбер көнне тота да бу [Гомәр] чишмә кырыендагы таудан таш чыгара башлый. «Үзен имгәтеп бетерер инде, мескен», – дип, моны бик кызганалар.* А.Ганиев

**Имгәтеп калдыру** Ниндидер сәбәп аркасында озак вакытка имгәккә әйләндерү. *Миндә бернинди рак булмаган, сез миңа операцияне ялгышып ясадыгыз, мине гомерлеккә имгәтеп калдырдыгыз.* М.Маликова

**Имгәтеп кую** Кинәт имгәтү. *Әгәр, мәйтәм, авыр әйбер күтәреп, безнең бәләкәчебез берәр җирен имгәтеп куйса, ә?* Ф.Яруллин

**Имгәтеп ташлау** Бер эшкә дә ярамаслык итеп имгәтү. *Шәрук, ишекне ныграк ябып, ярым пышылдап тагын өстәде: – Галимәне имгәтеп ташлады, юньсез. Тегесе авыру бала тапты.* Н.Гыйматдинова. – *Яраткан колымны тартып алды, имгәтеп ташлады! Инде бердәнбер таянычымны да тартып алмакчы, – диде ул [Күрекле бикә] яшь аралаш.* Н.Фәттах. – *Биреләм, аю, биреләм... Җибәр генә... Имгәтеп ташлыйсың бит хәзер, – дип гыжылдады укучысы кочагында тыннары беткән укытучы.* Р.Фәизов

**ИМГЕЧ** I *и.* Үләннәргә һәм кайбер тере организмнарга кадалып, тәннән – кан, үсемлектән сүл суыра торган махсус әгъза. *Аның каравы [суалчанның] берегү органнары – имгечләре бар: гәүдәсенең алгы очында – алгы яки авыз имгече, корсак ягында – корсак имгече.* Зоология. *Аның [тасма суалчанның] башында мускуллы дүрт түгәрәк имгеч урнашкан, шулар ярдәмендә олы паразит үз хуҗасының эчәклек стеналарына берегә.* Биология

**ИМГЕЧ** II *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан сары яки шәмәхә чәчәкле күпьеллык үләнчел үсемлек; баллы чәчәк; *русчасы:* **льнянка**

**ИМГЕЧ** III *и. диал. к.* **имезлек**

**ИМГЕ́Ч СУАЛЧАН** *и. зоол.* Умырткалы һәм умырткасыз хайваннарның һәм кешенең эчке әгъзаларында паразит булып яшәп, трематодоз дигән авыру китереп чыгара торган яссы суалчан; *русчасы:* **сосальщик**. *Имгеч суалчаннар саңакка, тирегә ябышалар һәм балыкларның каннарын суыралар.* Кызыклы ихтиология. *Аларның [паразитларның] берсе – бавыр имгеч суалчан.* Биология. *--- кешенең үт юлларында – имгеч суалчаннар, лямблияләр, --- яши.* Мәдәни җомга

**ИМДЕ, ИМДИ** *кис. иск. кит.* 1) *к.* **инде** *(1 мәгъ.). Имди бу «хисаплык» дигән китабымызда истилак сүзләре өчен мөмкин кадәр үз телемездәге сүзләрне сайладык.* К.Насыйри. *Имди Туктамыш хан һәм Гәлсәрах икесе торып намаз кылырга килделәр.* Ф.Халиди. *Бүз атым, кешнәп кара; Башың чиш, сачың тара; Имди мән китеп барам, Исән кал, кашың кара.* Казан утлары

2) Элеккеге шагыйрьләр язган 11–12 шәр иҗекле (үлчәмле), дүрт юллы шигырьләрнең (теземнәрнең) ахырында иҗек санын тутыру өчен кулланыла (соңгы чор шагыйрьләрдә борынгыча стильләштерү өчен алына). *Алда синең нәкъ алтмыш ел гомерең калды; Шуңа лаек эшләреңне эшлә имди.* К.Гали. *Газраилга карагандай карый аңа, эчкә баткан күзләре дә уттай яна, Тәрҗемәче узган чакта посып кала, Җанымны да алыр ахры, дидер имди.* З.Мансур. *Бюрократ һәм байларның карны туктыр. Алар кулында төрле-төрле корал күптер, Бичара эшче халыкка икмәк юктыр, авыл халкы җирсезлектән кырылыр имди.* Ш.Мөхәммәдев

**ИМЕГҮ** *ф. сир.* Имәсе, ашыйсы килү, ачыгу (имчәк баласы турында). *Әлли-бәлли бишеге, бал ялаган кашыгы, Имеккәндә имезе, Сусаганда кымызы.* Такмак

**Имегеп бетү** Тәмам ашыйсы килү, бик нык имегү

**Имегеп тору** Бертуктаусыз имегү. *Гел имегеп кенә торасың син, кызый. Имүдән туктамас та идең инде, әй.* М.Хуҗин

**ИМЕЗӘК** *с.* **1.** Сауган чорда да бозавын яки бәтиен имезүдән туктамаган. *Имезәк сыер да бурабзарда, кечкенә бозавы янында.* Р.Сибат

**2.** *и. мәгъ.* Имчәкнең имә торган җире, имчәк башы

**ИМЕЗЛЕК** *и.* 1) Элек имчәк балага каптыру өчен (гадәттә, шикәр кушып) чәйнәп әзерләнгән һәм чүпрәк яки марляга салынган ипи йомшагы. *Үз өлешен ашамады әни, Безгә имезлеккә чәйнәде.* Р.Газизов. *Әнием мине имезеп, үзе арыш ура-ура, җирнең аргы башына ук китеп югала торган булган, мин ул каптырып киткән имезлегемне суырып, аякларымны югары күтәреп, арыш күләгәсендә ятканмын.* Г.Галиев

2) Шундый ашамлык төрелгән марля яки чүпрәк. *Имезлек киндердән иде.* С.Баттал. *Әнием арыш урганда, айман күләгәсендә чүпрәк имезлек имеп ятканда, күзем төшмәгәнме?* Г.Сабитов

3) Имчәк балага, яшь бәрәнгә, бозауга һ.б.ларга имезү өчен, имчәк формасында эшләнгән җайланма; имезгеч; *русчасы:* **соска**. *Айтуганны алып кайтуга, Суфия сабыйның чүпрәк-чапракларын, имезлекләрен сабыйлар йортына илтеп тапшырды.* М.Маликова. *Имезлек суыруларыңны күргән саен, йөрәгем рәхәт кысылып куя.* Р.Низамиев. *Ул сәдәфләр савытынданиләр генә юк: булавкалар, төсле төймәләр,*

*алтын кармаклар дисеңме, хәтта Зөлфиянең имезлек боҗрасы да шунда ята – аларның барысы да кадерле иде Гөлбикәгә.* М.Хәбибуллин

4) Имчәк башы

5) *күч.* Бик әһәмиятле, мөһим, кирәкле нәрсә урынына юаныч итеп бирелгән алдавыч әйбер, вак ташлама. *Татарны Россиянең кече баласы дисез, бөтен татарларга имезлек сорыйсыз, имезлек каптырганда, бармагың белән кулыңны тешләп өзәрлек татар агайлар бездә юкмыни?* И.Гази

**ИМЕЗЛЕКЛӘНДЕРҮ** *ф.* Яңа туган бәрәнгә, бозауга һ.б.га беренче мәртәбә анасы имчәген каптыру; имәргә өйрәтү, авызлыкландыру. --- *шуңа бозау-бәрәннәрен имчәкләренә якын китерергә дә теләмәгән сыер-сарыкларның бозау-бәрәннәрен имезләкләндерү өчен, фермада төнге дежурда тору – барысы да алар вазифасына керә иде.* В.Нуруллин

**ИМЕЗҮ** *ф.* **1.** Имчәктән, җиленнән, шешәдән ирен, тел ярдәме белән сөт, чәй, сыек ботка, сок һ.б.ларны суырту, имчәк бирү. *Римне күргән кеше хәтерли торгандыр: Форум янындагы Капитолий калкулыгына күтәрелер алдыннан, игезәк балаларны имезеп торучы таш бүрегә кадәр, читлектә тотылган тере бүрегә юлыгасың.* М.Юныс. *Элек хатыннар, беләсезме, ничек яшәгән: корсак күтәрә, бала имезә, бала күмә, тагын бала таба, имезә, күмә...* М.Маликова. *Диңгез күселәренең йөклелекләре ике ай дәвам итә, ә сөтләрен нибары 10–12 көн генә имезәләр.* Кызыклы физиология

**2.** *и. мәгъ.* Хатын-кызларда һәм имезүче хайваннарда бала тудырганнан соң сөт барлыкка килүдән башлап, сөт белән тукландыруны туктату вакытына кадәрге ара. *Имезү чоры*

◊ **Имезгән сөтем харам булсын** *карг.* Игелексез баласыннан авыр хәсрәт күргән аналар каргышы

**Имезә башлау** Имезергә тотыну. *...Динә, сөт тулган күкрәген ачып, улын имезә башлады.* Р.Хәбибуллина. *Шулай, сабый суырганнан Мәрхәбә карчыкның күкрәгенә сөт төште, һәм ул да бер баланы имезә башлады.* Ф.Дәүләтгәрәева

**Имезеп алу** Тиз генә имезү. *Майя, Гөләшине имезеп алгач, куак ботакларыннан бишек ясап, бер агач төбенә салды, ---.* Г.Гыйльманов. *Әни сеңлемне кечкенә арбасына сала да, янына тезләнеп, йокыга киткәнче имезеп ала.* Г.Бәширов. *Тәмәке төтене баскан тынчу бүлмәдә Фәтхия, арты белән генә борылып, бала имезеп ала.* М.Мәһдиев

**Имезеп бетерү** Ахыргача, беткәнче имезү

**Имезеп карау** Имезергә тырышу. *Кәҗә бәтиләренә шешәдән сөт имезеп карадылар.* Татарстан яшьләре

**Имезеп кую** Нинди дә булса эшкә кадәр имезү, алдан имезү

**Имезеп тору** 1) Һәрвакыт, даими имезү

2) Әле, хәзер имезү

**ИМЕЗҮЧЕЛӘР** *и. күпл. зоол.* Балаларын үз сөтләре белән имезеп туендыручы югары төзелешле умырткалылар астибының бер классы; сөтимәрләр; *русчасы:* **млекопитающие**. *Мезолит эрасында имезүчеләр арасында үткен тешләре, тырнаклары да, канатлары, тояклары да булмаган хайваннар группасы аерылып чыга.* Биология. *Имезүчеләр классына кергән ата һәм ана хайваннарның сөт бизләре башлангыч хәлдә бер-беренә тәңгәл.* Кызыклы физиология. *Умырткалы организмнарга балыкларны, җир-су хайваннарын, сөйрәлүчеләр, кошлар һәм имезүчеләрне кертканнәр.* Табигать белеме

**ИМЕКДӘШ** *и. бор.* Имчәктәш; бер ананы имгән ир туган

**ИМЕЙЛ** *и. ингл. информ.* Хатлар интернет ярдәмендә килеп ирешә торган электрон почта; электрон элемтә чарасы. *Аннан миңа университетның дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе эшләмәячәге турында хәбәр итеп имейл җибәрделәр.* Безнең гәҗит

**ИМЕШ** *мод. сүз* **1.** 1) Ишеткән хәбәрнең дөреслегенә шикләнгәндә, аның хакмы-түгелме икәнлеген кистереп кенә әйтә алмаганда кулланыла. *Ышандырмакчы булды ул, юләр! – безне; имеш, Тәңре аның аузы белән сөйли, аңа килгән, имеш, әмре.* Г.Тукай. *Шулай көйләнер төсле тоелганда, озын телләр, кайсы көнләп, кайберләре үч итеп, карчыкның күңел ярасына тоз сибә башладылар. Имеш, Нәфисә Зиннәттән бизгән икән инде. «Ачуым ачу, кибектерәм әле мин аны», – дип әйтеп әйтәдер, ди.* Г.Бәширов. *Мин дә ишеткән идем аны ишетүен, тик «күңел» дигәнең әллә ничек ышанып бетми: бер тиенсез ике йөз дисәтинә җир бирсеннәр, имеш.* И.Гази

2) Кеше эшен, кеше сүзен ошатмаганда, яратмаганда ирония белән әйтелә; ышанмау, шул ук вакытта башкалар ышанган фикердән көлү, аны инкяр итү өчен кулланыла. *Шигырь белән болай диеп язып куйды бер читкә: «Хат ташучы эшен кара, Шул да эш була, имеш! Үзе язган хатларны да Үзе ташырга тиеш».* М.Җәлил. *Ах, бу фән кешеләре! Кара син аларны, халык өчен бары тик «җир» дигән сүз генә бар иде, болар нишләтеп ваклап бетергәннәр! Кәзле-корбанатлы, имеш.* М.Мәһдиев. *Янәсе, минем бригадада олы кешеләр дә ярый була, яшьләр бүтән бригадаларда сабан сөрергә кирәк имеш...* Г.Бәширов

3) Кемнең дә булса эш-гамәлләре турында зәһәрле, чәнечкеле, ачы көлү тонында әйтүне белдерә. *Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган; Кибән чалма кигән башта: Ишан булган, имеш, хайван.* Г.Тукай. *«Шайтан аздырган», имеш, «Юлдан яздырган», имеш! Кире татар, иң элек Вөҗданың берлән килеш!* Г.Тукай. *Акча күбрәк төшерә, имеш. Төшерден!* И.Гази

4) «Белми дә торам» дигән мәгънәдә кулланыла

5) Берәр эшнең, күренешнең реаль булмаганын, бәлки хыялда, уйда, төштә генә булуын белдергәндә әйтелә. *Яңа гына шундый төш кереп газапладьы... Нидидер, чыгарга мөмкин булмаслык тирән базга салганнар, имеш, аны.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Төрле хәбәр, гайбәт, дөреслеге ачыкланмаган юк-бар сүз. *Тагын шундый бик күп имешләр, гайбәтләр чәчелде.* Г.Ибраһимов

**3.** *с. мәгъ.* Дөреслеге, хаклыгы ачыкланмаган, төгәл билгеле булмаган. *Тирә-юньдә төрле имеш сүзләр йөри.* Г.Ибраһимов

**4.** *кер. сүз мәгъ.* Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү өчен кулланыла. *Имеш, мин терәүләрне дөрес салмаганмын.* Ф.Хөсни. *Имеш, мин дөрес сөйләмәгәнмен.* Идел

**ИМЕШ-ДИМЕШ** *җый. и. сөйл. к.* **имеш-мимеш**. *Имеш-димеш хәбәрләргә караганда, Петербургта әфәнделәргә сый-хөрмәт бик шәп, имеш.* Ф.Әмирхан

**ИМЕШ-МАНИШ** *җый. и. сөйл. к.* **имеш-мимеш**. *Мин аларның тарихларын шәкерт чагымда ук яза башлаган идем, мәгәр күбрәк имеш-манииштан иде.* «Шура»ның тел ярышы

**ИМЕШ-МИМЕШ** *җый. и.* **1.** Дөреслеге ачыкланмаган, төгәл билгеле булмаган хәбәрләр. *Авылда имеш-мимешләр таралды: «Үзенекеләрдер әле. Башка кем булсын!..»* М.Насыйбуллин. *Хәтта 1918 елның 25 гыйнварында кемнәрдер мөселман солдатларын кызылгвардиячеләр белән берләштерергә дә ниятли. Шәһәр имеш-мимеш белән тула.* Мирас. *Исемен әйтеп сөйләшмәделәр. Карт турында йөргән имешмимешләрне алар [әбиләр] ишетеп белә иде.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Төрле юрауларга нигезләнгән, дөреслеге ачыкланмаган. *Авыл советы рәисе белән Шәмсуаровның өязгә киткән җирдән өч тәүлек инде хәбәрсез югалулары, төрле имеш-мимеш хәбәрләр килгән.* М.Галиев. *Ә инде, Казнакайда яңадан район булдырыла икән, дип, халык арасында имеш-мимеш кебек сүзләр башлангач, аларның арасы тагын бозыла башлады.* М.Хәсәнов. *Шундый имеш-мимеш хәбәрләр белән авыл күмелгән иде.* Х.Кәрим

**ИМЕШ-МИМЕШЛЕ** *с.* Имеш-мимешләрдән гыйбарәт, имеш-мимешләрдән торган. *Имеш-мимешле чорлардан егерме буынга сикереп, инде аждаһалар, җен-пәриләргә ышанмастай кыю малай булып үскән Ирис өчен ырым-шырымнар буш әкият кенә.* К.Кәримов

**ИМЕ́ШТЕР** *мод. сүз* 1) *к.* **имеш** (*1 мәгъ.*). *Имештер, Мирсәет абый, менә шушы Фәттах, укытучы Зөлфия һәм тагын кемнәрдер, бергәләп, Гафур җизнигә каршы кампания алып баралар, ди.* Р.Ишморат. *Имештер, бер дарумы, нәрсәдер салып әчеткән сөт файда итә икән дә, тик аның шул даруы юк, ди.* Ә.Еники. *Имештер, ул [Муса Җәлил] герой да, батыр да түгел. Имештер, ул фашистларга хезмәт иткән, илен саткан...* Сөембикә

2) Нинди дә булса берәр эшнең, күренешнең реаль булмаганын, бәлки хыялда, уйда, төштә генә булуын күрсәткәндә кулланыла. *Төшемдә, имештер, директорны эшеннән азат иттеләр.* Татар иле

3) Кыек сөйләмдә: әйтелгән сүзләрнең икенче берәүнеке икәнен белдергәндә кулланыла. *Җае килгән саен чыпчык мактана бирде, әй мактады чыпчыкларны, әй мактады: күкләргә чөйде. Имештер, дөньяда алардан батыррак бар микән, имештер, хәтта сандугач та аларның сайравына хәйран кала, ---.* А.Алиш

**ИМЗА** *и. гар.* 1) Нинди дә булса текст, рәсем, картина астына авторның (гадәттә кыскартып) үз кулы белән язылган култамгасы. *Сәхип солдат, йорт хуҗаларының имзаларын җыеп, шәһәр думасына ике тапкыр прошение язды...* Ә.Фәйзи. *Ә аның өчен оешма җитәкчесен --- ишек төбендә сагалап утырырга, кадерле имзасын, ниһаять, алгач, тулай торакта яшәр өчен комендантнан кабат рөхсәт сорарга --- кирәк.* Сөембикә

2) Әдәби, музыкаль, сәнгать әсәрләренең авторын күрсәткән уйланма исем; псевдоним. *«Мусульманин» имзасы һәм «Н.К.» инициаллары белән язылган некрологларның гранкалары архив фондларында гына теркәлеп калган.* Р.Әмирхан. *[Г.Камалның] Җитдирәк мәкаләләре 1906 елда «Саип», «Г.К.» имзалары белән һәм имзасыз да «Азат», «Азат халык» газеталарында басылалар.* М.Гали. *Бер сәгатьтән соң экспромтларны укып карыйлар, һәм шулар арасыннан дүрт кыска шигырьне сайлап алырга да, «Студент» имзасы куеп, аларны Гурий Плетнев аша «Волжский вестник» газетасына җибәрергә карар кылына.* Казан утлары

3) Нәрсәнең дә булса астына язылган язу, аңлатма, искәрмә. *Хәзергәчә чыккан --- китапларның [сәнгать турындагы] битләрен актарып, иллюстрацияләренә күз ташлау белән, «бу әсәр Лувр музеенда саклана» дигән имзалар бик күп очрыйлар.* М.Гали

4) Әдәби әсәрнең авторын күрсәткән язу. *Ә Җәлил үзе биредә күбрәк журналист, тәнкыйтьче буларак танылa, мәкаләләрен «Муса Җәлил», «М.Җәлил», «Муса», «М.Мостафин», «Җәлил Табын», «М.З.», «М» имзалары белән бастыра.* Ш.Хамматов. *Мин шигыремнең астына «Мөхәммәтфатих Хөснетдинов» дип имза куйган идем, Гомәр Галигә бу ошамаган.* Казан утлары

**ИМЗА́ ИТҮ** *ф. иск. кит. к.* **имза кую**. *[Тукай] «Ялт-йолт»тагы мәкаләләрен «Шүрәле» һәм «Гөмберт» дип имза итә иде.* С.Исәнбаев

**ИМЗА́ КУЮ** *ф.* Берәр рәсем, текст, документ астына кем дә булса үз исемфамилиясен язу, кул кую. *Икәүләшеп, сырлый-сырлый имзаларын куйдылар.* Ф.Яруллин. *[Профессорга] Кырын карауның сәбәбе: 1919 елда, большевиклар фәнне харап итәләр, дип, Америка галимнәренә күмәк язылган хатка ул, имеш, имза куйган.* М.Мәһдиев. *Имзасын куеп, Волынкин, үзенең беренче язма аңлатмасын капитан Билаловка сузды.* М.Насыйбуллин

**ИМЗАЛА́У** *ф. иск. к.* **имза кую**. *Хәмидә әйтә: «Җаваплы секретарь соңгы вакытта нервныйга әйләнде, игътибарсызланды, кайчак хаталы битләрне дә «басарга ярый» дип имзалап җибәрә», – ди.* К.Тимбикова. *Татарстан ягыннан килешүне Президент М.Шәймиев имзалады.* Ватаным Татарстан. *Русия Президенты Д.Медведев күптән түгел, илнең Тышкы эшләр министрлыгында җыелган 250 илчесе алдында алдагы елларга программа чыгышы ясаганда, Русиянең тышкы сәясәт концепциясен имзалавы турында белдергән.* Мәдәни җомга

**ИМЗАЛЫ** *с.* Имзасы булган, имза куелган. *Карыйм, Разиягә биргән китапның имзалы бите кисеп алынган. – Разия, кая киткән мин язган сүзләр? – дидем.* Р.Батулла

**ИМЗАЛЫК** *и. сир.* Ышаныч язуы. *[Ясәви:] --- «Кара аны, Гафур күрше,*

*суд бусагасын таптарлык ясама», – дип калды. Акча биргәндә, юкка гына имзалык сорамаган икән.* Җ.Рәхимов. *Мин укый да, яза да белмим, энем. Имзалык өч кенә хәреф белеп калдым.* Х.Сарьян

**ИМЗА́ САЛУ** *ф. к.* **имза кую**. *Паспортыңа имза кую, хәләл көчең белән эшләгән акчаңны алганда имза салу күңелле.* Б.Камалов. *Менә мин әле генә документка имза салдым: симертүгә куелган унсигез баш тана иртәгә шәһәргә иткә озатылырга тиеш.* М.Мәһдиев. *[Баш архитектор:] Үз вакытында яхшылап үлчәргә иде. Имзаларыгызны салганчы.* М.Маликова

**ИМЗАСЫЗ** *с.* **1.** Авторы күрсәтелмәгән, кем язганы билгесез, кул куелмаган, аноним. *Имзасыз ул хатта: «Зинадан корсак күтәргән укытучы яшь буынны чын совет рухында, тотнаклы итеп тәрбияли аламы?» – дип язылган.* М.Маликова. *[Анна] Тикшерүне ялгыш юлга юнәлтү өчен, имзасыз хатлар язып җибәргән.* М.Насыйбуллин. *Гасыр башында татарлар яшәгән төбәкләрдә чыккан күпсанлы гәзит-журналларда ачык, яшерен һәм имзасыз әсәрләр еш очрый.* Ә.Закирҗанов

**2.** *рәв. мәгъ.* Имзасы куелмыйча, авторы күрсәтелмичә. *Шигырь «Фикер»нең 1906 елгы 1 гыйнвар санында «Төрле хәбәрләр» бүлегендә имзасыз басылган.* Х.Миңнегулов. --- *«Яшен» журналының 1908 ел дүртенче санында имзасыз гына шаяру катыш язылган «Профессиональный татар артисты булырга шартлар» исемле мәкалә басылып чыга.* Г.Арсланов

**ИМИ** *и. сөйл. к.* **имчәк** (күбесенчә, балалар телендә кулланыла). *Түбәнгә таба да мактанырлыгы юк икән кызыкайның, имиләренең кечкенә вә ләпшердек икәнен ул күлмәк киңлеге белән яшерергә тырышкан.* А.Гыйләҗев. *«Инде терелдем» дигәндә генә, аны дәвалаган табиб: «Күкрәгеңдәге шешне кисәбез, имезмәгәч, ул суырылмый», – дип өркетте. Операция ясату алма кебек имиләрне бозу дигән сүз иде.* Н.Гыймадинова. – *Кызык бит ә... Имиләре унике генә, – диде ул [колхоз җитәкчесе], мундир төймәләре шикелле тезелгән чучка имчәкләренә ишарәләп.* Ф.Латыйфи

**ИМИ́ БАШЫ** *и. к.* **имчәк башы**. *[Рәмисәнең] Чәчләре сүтелеп таралган, халаты иңеннән шуган, бюстгальтерыннан ими башлары төрткән...* Х.Камалов

**ИМИДӘШ** *и. иск. сөйл. к.* **имчәктәш**. *Карачылар, әмирләр, Касыймнар Шаһгалинең үзе белән килгән --- имидәшләре аның өстенә алтын тәңкәләр сибә башладылар.* М.Хәбибуллин

**И́МИДЖ** *и. ингл.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса урнашкан яки махсус формалаштырылган образы; эчке һәм тышкы йөзе. *Беренче кат сәхнәгә чыкканда да имидж дип тә, күлмәгемнең итәге кыскамы, озынмы дип тә уйламадым: үзем булып килдем дә чыктым.* Сөембикә. *Япь-яшь җырчыларның үз йөзләре, үз имиджлары юк.* Мирас. *Имидж – минем өчен эчке халәтнең тышкы чагылышы.* Мәдәни җомга

2) *сөйл.* Тышкы кыяфәт. *Быел исә уңышлы имидж өчен караңгы төсмерле шома киемнәр кияргә, төрле ялтыравык әйберләр белән бизәнергә киңәш ителә.* Сөембикә. *Ул [В.Ганиева] язның беренче көнендә үк, чәчтарашханәгә барып, имиджын үзгәрткән.* Юлдаш

**ИМИДЖМЕ́ЙКЕР** *и. ингл.* Нинди дә булса сәнгать әһеле, сәясәт эшлеклесе һ.б.ш.ларны билгеле бер даирәдә таныту, җәмәгатьчелектә уңай образын булдыру, авторитетын күтәрү чараларын, ысулларын өйрәнүче белгеч-психолог. *Татарстанда матур, үзенчәлекле, көчле тавышлар күп. Тик бездә эстрада индустриясе юк: продюсерлар, имиджмейкерлар, реклама осталары...* Асылъяр

**ИМИЛЕК** *и.* Хатын-кызларның күкрәкне каплап һәм күтәртеп торган эчке киеме, бюстгальтер. *Карачәч кергә. Шаровар белән имилек кенә кигән. Күлмәген, салып, утынына ураган.* Н.Исәнбәт

**И́М ИМЛӘҮ** *ф.* Авыруга каршы берәр ырым эшләү, өшкерү, ырым белән им-том итү

**ИМИН** *с. гар.* **1.** 1) Тыныч, сугышсыз, хәвеф-хәтәрсез. *Сабан туе – елга бер көн, Илләр имин, күңел иркен, Дуслык йорты, муллык йорты, Тыныч булсын безнең ил-көн.* Н.Исәнбәт. *Әйдәгез, бу көнне үзебез өчен бик тә кадерле булган бәйрәм белән – Республика көне белән – бер-беребезне чын күңелдән котлыйк һәм ватандашларыбызга тату, имин тормыш телик!* Мирас

2) Сәламәт, көр. *Өй эченнән имин, бәхетле тавыш ишетелә.* М.Мәһдиев

3) Куркынычтан, зыян-зарардан, төрле күңелсезлекләрдән азат, гарантияләнгән. *Бу көн үз ихтыярында йөргән кеше иртәгә төрмәгә кермәвеннән, Якутскига җибәрелмәвеннән, --- һич имин түгел.* Ш.Маннур. *Аның кулында булган көтү югалу, урлану бәлаләреннән бөтенләй имин санала иде.* Г.Ибраһимов. --- *химия өлкәсендә органик, фосфор-күкертле органик кушылмалар, энергия чыгымнарын киметү белән бер үк вакытта җитештерүне арттыручы экологик яктан имин яңа химик технологияләр эшләү --- бурычы тора.* Фәнни Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Сау-сәламәт, зыян-зарарсыз, хәвефсез. *Йөри идем җиһанда шатланып мин, Яши идем исән-сау һәм дә имин.* Г.Утыз Имәни. *[Тәңкәбикә:] Я, имин йөреп кайттыңмы?* М.Кәрим // Каерылмаган, сынмаган, җимерелмәгән, бозылмаган. *Юкәләр... Барысы да бердәй төзек, имин генә түгелләр шул. Кайсыныңдыр очы кырылган, кайсыныңдыр – ботаклары.* Г.Шәрәфи

**ИМИНИЯТ** *и. гар.* 1) Иминлеккә, саулыкка зыян килгән очракта, физик һәм юридик затлар тарафыннан махсус оешмаларга даими түләнгән взнослар хисабына, килешү (шартнамә) нигезендә гарантияләнгән матди тәэмин итүнең бер төре. --- *иминият кертемнәре эш хакына бердәм социаль салым составында өстән түләнә, керем салымындагы кебек кире алынмый.* Татарстан. *Хөкүмәт кабул иткән карар нигезендә 1 апрельдән хезмәт пенсиясенең иминият өлеше 9,2 процентка артты.* Шәһри Казан. *Акча янчыгын шактый саеткан икенче гамәл – иминият, ягъни страховка.* Ватаным Татарстан

2) Физик һәм юридик затларның взнослары хисабына акча фонды бул-

дыру чаралары системасы һәм шул эшләр белән шөгыльләнә торган махсус оешма. *Ташламалардан файдаланучылар, поликлиникада үзләренә тиешле хезмәт күрсәтелгәннән соң, «Ак Барс-мед» иминият компаниясенә мөрәҗәгать итәргә тиеш булачаклар.* Юлдаш. *Мондый өстенлек кредит һәм иминият оешмаларына, инвестиция һәм дәүләткә карамаган пенсия фондларына --- кагылмый.* Мәдәни җомга

3) *сир.* Иминлек. *Янгураз янәшәсендә утырган Эва ханым иренә: – Иминият, бәхет! – дип өстәде.* Т.Әйди

**ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ** *ф.* Милеккә, шәхси иминлеккә, саулыкка зыян килгән очракта гарантияләнгән матди тәэмин итүне күздә тотып, махсус оешмалар белән килешү, шартнамә төзү. *Пенсионерларны, балалар, инвалидлар, студентлар һ.б.ларны, ягъни эшләмәүче күпчелекне төбәк һәм җирле хакимиятләр чыганагы салымнар булган тиешле бюджетлардан иминиятләштерәләр.* Татарстан. *Үземнең төп эшем (иминиятләштерү өлкәсендә) һәм яраткан һөнәрем бар.* Юлдаш. *Анда [конкурста] катнашучылар арасында сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре, иминиятләштерү һәм инвестиция компанияләре һәм башка эшчәнлек өлкәләре җитәкчеләре бар иде.* Ватаным Татарстан

**ИМИНИЯ́Т ФОНДЫ** *и.* Физик һәм юридик затларның табигый бәла-казалардан һ.б.ш. шәхси иминлеккә, саулыкка зыян килергә мөмкин булган казаны кайтаруны гарантияләп түләнгән кертемнәрдән (взнослардан) тупланган акча фонды. *Пособиене элеккечә Социаль иминият фонды бирә.* Юлдаш

**ИМИНЛӘНҮ** *ф.* Тынычлану, куркынычсыз хәлгә килү. *Хәзер генә дөньялар иминләнгәч тә! Әллә нинди вакытлар бар иде.* М.Шабай

**Иминләнә төшү** Берникадәр, бераз иминләнү

**Иминләнеп бетү** Бөтенләйгә, тулысынча тынычлану, иминләнү

**Иминләнеп җитү** Тәмам тынычлану, иминләнү

**Иминләнеп калу** Ниндидер этәргечтән соң, сәбәптән соң иминләнү

**Иминләнеп китү** Кыска вакыт аралыгында яки кинәт иминләнү. *Бу тавышлар атларыннан төшеп басып торган бәндәләрнең киләчәккә өметләрен кузгата иде: «Ходай кушып, бары да иминләнеп китәр, йортлы-җирле булырбыз, иншалла!»* З.Зәйнуллин

**ИМИНЛӘ́Ү** *ф.* Төрле хәвеф-хәтәрдән, куркынычлардан саклау. *Сул флангны көтелмәгән хәлләрдән иминләү өчен, ашыгыч рәвештә көрше шәһәргә атлы батальон җибәрелгән иде.* И.Гази. *Табигый бәла-казалардан иминләү*

**ИМИНЛЕК** *и.* 1) Тынычлык, куркынычсызлык. *Сезнең гаиләгезнең иминлеген чагарга угын чыгарган елан шуыша, Зәйтүнә Мәҗитовна!* М.Маликова. *Ә бит хатын-кыз – үзенең табигате белән семья иминлеген төп саклаучы ---.* Тигез гомер итегез! *Бу чорда һәр кабиләнең иминлеген, мөстәкыйльлеген саклаучы үз гаскәре була.* Мирас

2) Исән-саулык, хәвеф-хәтәрсезлек. *Шулвакыт --- Хәлим абый чыгып баса, бөтен битеннән җылылык, туклык, иминлек бәреп тора.* М.Мәһдиев. *Халык төркеме өстеннән йомры башы шактый ук күтәрелеп торган таза гәүдәле ир кеше, чемоданын болгап, боларга таба атлады: – Саумысез, Мөһимә апа, иминлекме!* М.Маликова. *Якын кешеләренең мәхәббәтен даими рәвештә тоючы балалар иминлеккә ышанып үсәләр, алар үзләре турында кайгыртучылар барлыгын, аларны яклаучылар барлыгын беләләр.* Тигез гомер итегез!

3) Закон тарафыннан сакланганлык, кагылгысызлык, гарантия. *Ул [Сабир] халык язмышы турында борчылмый, аны газаплы тормыштан коткару хакында уйланмый. Аңа шәхси иминлек кирәк.* Әдәбият. *Шәхес иминлеге, сүз, вөҗдан иреге, кайбер башка демократик хокуклар игълан ителә.* Татарстан тарихы. *Ул [эш урыннары] – республиканың тотрыклы азык-төлек иминлеге.* Мирас

**ИМИНЛЕ́К ТЕХНИКАСЫ** *и.* Техника белән, шулай ук аның янында хәвеф-хәтәрсез эшләү алымнары һәм кагыйдәләре. *Монда лозунглар да, плакатлар да җитәрлек, иминлек техникасын төгәл сакларга өндәгән плакатларны аслы-өсле ябыштырганнар.* Б.Камалов

**ИМИНЧЕЛЕК** *и. к.* **иминлек**. *Һәр бусагадан иңсен бәрәкәт, Тусын иртәләр иминчелектә.* Н.Арсланов

**ИМИТА́ТОР** *и.* 1) Берәр кеше, хайван, кош тавышын имитацияли алучы кеше

2) *сәнг.* Имитация белән шөгыльләнүче профессиональ актёр, җырчы, музыкант һ.б. *Тавышларны охшатып сөйләүче махсус эстрада жанры вәкилләре – имитаторлар була. Алар теләсә кайсы артист булып сөйли һәм җырлый алалар.* Ф.Сафиуллина

**ИМИТА́ТОРЛЫК** *и.* Имитатор шөгыле, эше һәм сәнгате

**ИМИТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса мөмкин кадәр төгәл итеп охшатып кабатлау, кылану, сөйләү, кычкыру, сайрау һ.б.ш. --- *концерт номерының берсе – шул елларда телеэкраннардан төшмәгән сәхнә йолдызы Алла Пугачёвага имитация.* М.Мәһдиев. *Тавыш сигналларының гаять төрлелеге һәм, шуның белән бергә, җитди үзенчәлекләргә ия булуы имитация күренешен дә тудырган.* Кызыклы физиология

2) Ясалма, ялган охшашлык; охшатып ясалган әйбер. *– Күрәм: сез көзге бизәкләргә хәйран, – дип елмайды профессор. – Ләкин көзнең матурлыгыннан ләззәт аласыгыз килсә, урманда йөрегез, Гөлшәһидә. Монда имитация генә...* Г.Әпсәләмов. *Эчтәлексез, башка китапларга имитация ясап кына язылган әсәрләрне укыганда, авторның ни сәбәпле тормыш дөреслегеннән тайпылганын, ни өчен чит тормыш урынына ясалма бер схема гына биргәнлеген аңлый алсаң, вакытың бушка үтмәячәк.* М.Юныс

3) *муз.* Музыкаль көйне, темаларны икенче аһәң белән төгәл яки бераз үзгәртеп кабатлау

**ИМИТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Имитация ясау. *Кырау да, чир дә алмый торган бу чәчәкләр тере түгел, бәлки чын тереклекне имитацияләү генә.* А.Тимергалин. *Хәтта энә белән чәнчү дә сперматозоид тәэсирен тулысынча имитацияләми...* Кызыклы физиология.

*Хор циклның төрле кисәкләрендә гармоник фонны имитацияли, һәм бу алым аерым драматургик функция башкара.* Казан утлары

**Имитацияләп карау** Имитацияләргә тырышу

**ИМИТА́ЦИЯЛЕ** *с.* Ясалма, охшатып ясалган. *Быел безнең вузда «Икътисади процессларны имитацияле модельләштерү» дигән яңа кафедра ачыла.* Татарстан

**ИМИ́ ТӨБЕ** *и. к.* **имчәк төбе**. *[Сөткә] Су кушу закон белән тыела, Алла бәндәсе! Ими төбен савып бетермисеңме әллә, диюем ---.* Х.Камалов. *– Ә менә болай: авыл халкында, сыер сауган халыкта, «ими төбе» дигән сүз бар. Сөтнең иң куесы, иң сыйфатлысы – шул, – [диде Ахияр].* М.Мәһдиев

**И́М ИТҮ** *ф.* 1) Үләннәр, төрле имтомнар белән дәвалау, им-том белән шөгыльләнү

2) Имгә әйләндерү, им буларак куллану. *Кызылча авыруына кызыл әйберләрне им итәләр*

**ИМКЯН** *и. гар. иск. кит.* Мөмкинлек, мөмкинчелек. *Шунлыктан әүвәлге вакытлардагы кебек төнге күренешләргә һичбер төрле имкян табып булмый иде.* Г.Ибраһимов. *Алар һәр икесе --- моны сизәләр, ләкин --- шул мөнәсәбәт вә дуслыкны бер-беренә белдерергә юлын да, имкянын да белмиләр.* Г.Исхакый

**ИМЛА** *и. гар. лингв. иск.* 1) Сүзләрне дөрес язуда кабул ителгән кагыйдәләр; орфография. *Бездә имла мәсьәләсе утыз елдан бирле тикшерелә.* Г.Ибраһимов. *[Хәят] Рус имласы, арифметика гамәлләре һәм француз телен өйрәнергә керешә.* Ф.Әмирхан. *Бу хатларда да [кайбер бәйләнешсезлекләр] булыр, ләкин минем аларны төзәтергә хакым булмаганга, шул көйләренчә күчерәм. Әмма имла, иншa мәсьәләләрендә төзәтергә мәҗбүр буламын.* Ш.Әхмәдиев

2) Әйтеп яздыру; диктант

**ИМЛА́ ИТҮ** *ф. иск.* Тыңлаучыларга кычкырып әйтеп торып яздыру

**ИМЛАСЫЗ** *с. иск.* Кабул ителгән имла кагыйдәләрен сакламыйча, аңа буйсынмыйча язылган яки язучы. *Имласыз иншa. Имласыз шәкерт*

**ИМЛАСЫЗЛЫК** *и.* 1) Имла кагыйдәсе булмау. *Вакытлы матбугатта еш кына имласызлык хөкем итә*

2) Имла кагыйдәләренә буйсынмыйча язу

**ИМЛАЧЫ** *и. иск.* Имла мәсьәләләре, имла проблемалары белән шөгыльләнүче кеше. *1915 елның җәендә Уфа земствосы, бөтен Россия татарларының педагогларыннан, язучыларыннан, имлачы телчеләреннән кешеләр чакырып, гыйльми бер киңәш, конференция ясаган иде.* Г.Ибраһимов

**ИМЛӘВЕЧ** *и. этн.* Им-том әйберләре, дәвалау өчен кулланыла торган әйбер (тырнак, чәч, тоз, туфрак һ.б.)

**ИМЛӘ́ГЕЧ** *и. этн. к.* **имләвеч**

**ИМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Хорафатлар, ышанулар буенча: һәртөрле әфсеннәр әйтеп, тылсымлы догалар укып, кешене савыктырырга, дәваларга тырышу яки, киресенчә, бозу, ырымлау. *Аның авыруын бетерү – имләү турысында Гыйльми карчык төрле әмәлләр өйрәтә иде.* М.Галәү. *Аларда [Һадиларда] гына, бары тик аларда гына, корт чаккач «бүре уы» була торган кешеләрне имләр өчен, бүре койрыгы бар иде.* М.Мәһдиев. *Кырык бер бөртек арпа белән имләсәң, арпа аеруча тиз бетә, имеш.* Юлдаш

2) Гомумән дарулау, дәвалау. *Өч ай авырдым. Имләмәгән им калмады, алмаган дару калмады.* Г.Толымбай

**Имләп алу** Кыска вакыт эчендә тиз генә имләү

**Имләп бетерү** Ахырга кадәр, тулысынча имләү; барысын да имләү

**Имләп карау** Имләргә омтылу, имләргә тырышу. *Йокыга китә алмый озак елаган баланы әбисе күз тиюдән дә имләп карады*

**Имләп тору** 1) Даими, һәрвакыт имләү

2) Әле, хәзерге вакытта имләү. *Биккол белән Турат килеп җиткәндә, бер карт каза күрүчене чалпу ырымы белән имләп тора иде.* Т.Нәбиуллин

**Имли башлау** Имләргә тотыну

**ИМЛЯ** *и. гар. лингв. иск.* 1) *к.* **имла**. *Миңа бары тик урыс имлясы белән генә укырга рөхсәт ителгән.* А.Хәлим. *Алтын Урданың бу шәһәрләрендәге рәсем ясаучы, бизәкләр төшерүче осталарның имлялары бик нәзек булып, матурлыкны бик яратканнар.* Г.Гобәйдуллин. *--- тулыр-тулмас бер гасыр эчендә татар теле ике тапкыр имлясын үзгәртте һәм һәр икесендә дә зур югалтуларга дучар булды.* Мирас

2) Язу рәвеше. *Гарәп язуын куллануны тәртипкә салу барышында, татарларда бер-берсеннән зур аермасы булмаган иске имля алфавиты һәм 1920 елда яңа имля алфавиты кабул ителгән.* Татар теле

**ИМЛЯЧЫ** *и. иск. к.* **имлачы**. *Татар имлячыларының соңгы елларда һаман шул юл белән барганлыклары күренә.* Ж.Вәлиди

**ИММАНЕНТ** *с. лат. филос.* Теге яки бу күренешнең, предметның табигатенә хас, шул табигатеннән килеп чыккан; эчтә томаланып яткан, эчке. *Ләкин һәр халыкның нәфасәти фикерләвендә һәм зәвыкларында, күрәсең, имманент зур мөмкинлекләр ята.* К.Гыйззәтов

**ИММИГРАНТ** *и. лат.* Даими яки озак яшәү өчен берәр илгә күчеп килгән чит ил кешесе. *Чит җирдә тел белмәгән кешегә җиңел түгел. [Сиэтлда] Колледж – иммигрантларны махсус укыта торган уку йорты бар.* Сөембикә. *Шул ук вакытта мин Австралиядә яшәүче бер эстон врачын беләм: ул, үзенә йөрүче авырулар – яңа күчеп килгән иммигрантлар белән җиңелрәк аралашу өчен, грек һәм гарәп телләрен үзләштергән.* Идел. *Мондагы ташландык индустриаль зонадагы тимер юл күперләре астында Бөекбританиягә күчеп китәргә теләүче меңләгән иммигрант яши.* Мәдәни җомга

**ИММИГРА́ЦИЯ** *и. лат* Даими яки озак яшәү өчен бер илдән икенче илгә күчеп килү. *Бу вакытта Ерак Көнчыгышта иммиграциягә киткән Идел – Урал төрек-татарлары күп була.* Мирас

**ИММУНИЗА́ЦИЯ** *и. лат. мед.* Организмның йогышлы авыруларга, генетик чит матдәләргә каршы тору сәләтен арттыру чаралары; ясалма иммунитет булдыру. *--- йогышлы авырулар тудыручы көчсезләндерелгән яки үтерелгән микроорганизмнардан ясалган*

*медицина препараты кеше һәм хайваннарга иммунизация ясау өчен кулланыла.* Сәламәтлек нигезләре

**ИММУНИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Иммунизация үткәрү

**Иммунизацияләп бетерү** Тулысынча, ахыргача иммунизацияләү

**ИММУНИТЕТ** *и. лат.* 1) *мед., биол.* Организмның йогышлы авыруларга һәм генетик чит матдәләргә каршы тора алучанлыгы. *Бу айларда --- организмның нерв-биологик системалары начаррак эшли, иммунитет көчсезләнә, кешеләр ешрак авырыйлар ---.* Тигез гомер итегез! --- *актинияләр һәм синофорлар арасында яши торган балыкларда агуга каршы иммунитет туган, шул сәбәпле алар өчен агу куркыныч түгел ---.* Кызыклы ихтиология. *Ул [гипноз] кешенең хасталарга каршы торучанлыгын – иммунитетын ныгытырга ярдәм итә.* Сөембикә

2) *юр.* Аерым кешеләргә, бигрәк тә дипломатларга һәм депутатларга рөхсәт ителгән кайбер законнарга буйсынмау хокукы; иминлек (*3 мәгъ.*). *Депутат иммунитеты. Дипломатик иммунитет*

3) Берләшкән милләтләр оешмасы Уставы нигезендә бер дәүләтнең икенче бер дәүләт белән идарә итә алмавы турындагы халыкара хокук принцибы

**ИММУНЛАШТЫРУ** *ф. мед. к.* **иммунизация**. --- *котыру чиренә каршы вакцинация үткәрү, һәрбер шикләнгән очракта да иммунлаштыру мөһим.* Сәламәт булыйк!

**ИММУНОГЕНЕ́ТИКА** *и. лат.-гр.* Иммунитетның нәселдәнлек закончалыкларын, антигеннарның төр эчендәге үзгәрүчәнлекләрен өйрәнә торган фән. *Кеше генетикасының һәр тармагы күзәнәкләр генетикасы (цитогенетика), биохимик генетика, иммуногенетика, физиологик генетика, югары нерв эшчәнлеге генетикасы һ.б. кайбер гыйльми проблемалар нигезендә гамәл итә.* К.Гыйззәтов

**ИММУНОГЛОБУЛИН** *и. мед. лат.* Гликопротеидлар төркеменнән кеше һәм умырткалы хайваннарның кан сыекчасындагы актив антитәнчекләргә ия булган һәм иммунитет барлыкка китерүдә катнаша торган катлаулы аксым; йогышлы авыруларны дәвалау һәм профилактика өчен шул каннан ясалган препарат. --- *әгәр таныш булмаган хайван тешләп --- алса, яраны хирург эшкәртүе, авыруга каршы вакцинация үткәрү һәм иммуноглобулин кабул итү кирәк.* Сәламәт булыйк!

**ИММУНОДИАГНО́СТИКА** *и. лат.-гр.* Йогышлы авыруларны иммунитетлы сыек ярдәмендә ачыклау ысулы

**ИММУНОДЕФИЦИТ** *и. лат.* Организмның йогышлы авыруларга һәм генетик чит матдәләргә каршы тору сәләте бозылу; иммунитет кимү. *[Соя] Шулай ук атеросклероз, матдәләр алмашы бозылу, иммунодефицит, --- онкологик һәм йөрәк-кан тамырлары авыруына дучар булучыларга бик файдалы.* Юлдаш. *Җәрәхәт – элпәле ангина, кагыйдә буларак, организмны саклаучы көчләр С һәм В группасы гиповитаминозыннан интеккән иммунодефицит булган очракларда күзәтелә.* Мәйдан

**ИММУНО́ЛОГ** *и. рус* Иммунология белгече. --- *кызлары икесе дә әниләре юлын сайлаган: Фәридә ханым – медицина фәннәре кандидаты, балалар табибәсе, иммунолог; Рәйсә ханым – --- маммолог.* Сөембикә

**ИММУНОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Кеше һәм хайваннарның йогышлы авыруларга бирешмәвен, биологик үзенчәлекләрен саклап кала алуын өйрәнә торган фән. *Аның докторлык диссертациясе ветеринар микробиология, вирусология һәм иммунология өлкәсенә карый.* Кызыл таң

**ИМНӘ́Ү** *ф. диал. к.* **имләү**. *Угы күренмиме? Уһу... Бик усал корт икән... (Имнәргә керешә). Өшкертен, төшкертен, калма качып яшертен. Азмасын, тузмасын, үз турыннан узмасын.* Т.Гыйззәт

**Имнәп алу** Тиз генә имнәү

**Имнәп бетерү** Тулысынча имнәү; барысын да имнәү

**Имнәп тору** Даими, һәрвакыт имнәү

**Имни башлау** Имнәргә тотыну

**ИМПЕРАТИВ** *и. лат. лингв.* **1.** Боерык фигыль. *Бу очракта Вундт, Маутнер, Бреаль, Пос һ.б. күтәреп чыккан, императивның беренче булуы теориясе мәсьәләгә ачыклык кертә.* Ф.Ганиев

**2.** *с. мәгъ.* Боеруны, таләп итүне, кушуны белдерә торган. *Императив ымлыклар --- кешенең ихтыярын, теләген белдерәләр. Аларга боеру, тыю, чакыру, эндәшү, әйдәү, таләп итү кебек мәгънәләр белдерү хас.* Д.Тумашева

**ИМПЕРА́ТОР** *и. лат.* 1) Кайбер илләрдә монархистик дәүләт башлыгының иң югары титулы һәм шул титулга ия кеше (монарх). *Бер елдан соң 1852 елның 2 декабрендә Сенат Луи Наполеонга французлар императоры титулын бирә.* Бөтендөнья тарихы. *Музейның экспозициясен дә нәкъ менә ул – алтын җепләр белән чигелгән шул футлярдагы Грамота ачып җибәрә. Аны асылмалы дәүләт мөһере һәм императорның тулы титулы бизи.* Сөембикә. *Бу кешенең барлыгы турында кояш чыгышы илендә бары тик дүрт кеше: император, премьер-министр, Генштаб начальнигы һәм --- 98 яшьлек карт кына белгән.* Юлдаш

2) *тар.* Борынгы Римда гаскәр башлыгының (полководецның) почётлы титулы. *[Римда] Армиядә теләктәшлеккә, ярдәмгә ирешү өчен, «солдат императорлары» ветеран легионерларга җирләр бүлеп бирәләр.* Бөтендөнья тарихы

**ИМПЕРА́ТОРЛЫК** *и.* Император дәрәҗәсе, титулы. *Екатерина алга таба: «Минем императорлык ихтыярыма каршыларның гомерен алырга, ягъни аларны үлем җәзасына тартырга, ---» боера.* Россия тарихы. *Бер илнең, императорлыкның баш шәһәре «пайтәхет» дип йөртелә.* Ж.Зарифоглу. *[Бронзадан ясалган сында] Карл императорлык билгеләре белән сурәтләнгән: башында таҗ һәм сул кулында держава. Уң кулына озын кылыч тоткан.* Урта гасырлар тарихы

**ИМПЕРАТРИ́ЦА** *и. рус* 1) Император хатыны. *VIII гасыр азагында Кытай императоры Ю-Ван-Әның Бао-Сы исемле кәнизәге императрицага әверелә.* Юлдаш

2) Хатын-кыз император, монарх титулы. *Императрица Елизавета Петровна вакытында рәсми историограф*

*вазифасы кертелә.* Бөтендөнья тарихы. *Ләкин Әби патша белән Казанның мөнәсәбәте җылы, тирән, дәвамлы, тикмәгә генә императрица үзен «Казан алпавыты» дип атамый.* Сөембикә

**ИМПЕРИАЛ** *и. лат. тар.* Россиядә сугылган (1755 елдан 10 сумлык, 1897 елдан 15 сумлык) алтын тәңкә. *Иске вакытта [аның] елга бер өч тапкыр кәгазь екатеринкаларны алтын империалларга әйләндерү өчен станицага илткәне хутор кешеләренә ачык билгеле иде.* Ш.Камал

**ИМПЕРИАЛЬ** *с. к.* **империалистик**. *Шул ук вакытта мин үз халкы азатлыгы өчен гадел көрәштә оккупантлар танкларын яндырган ун-унике яшьлек чечен сабыйларының колак яфракларын кисеп алып, аларны аерым бер империаль горурлык белән кесәләрендә йөрткән урыс башкисәрләрен аңламыйм ---.* А.Хәлим

**ИМПЕРИАЛИЗМ** *и. лат.* 1) Эре монополияләрнең хакимлек итүе, эре дәүләтләрнең чимал чыганакларын, дөнья базарларын үз карамакларында тоту өчен, чит халыкларны буйсындыру сәясәте алып баруы белән характерлы капитализмның югары стадиясе. *Әгәр дә хәзер бөтендөнья күләмендә танылган партия белән кулга-кул тотынып һәм бердәм элемтәдә эшләмәсә, Көнчыгыштагы бер генә революцион оешма да Европа империализмына җитди йогынты ясый алмаячак.* Р.Хәйретдинов. *Империализм сугышы вакытында бер рота һәм бер взводта булулары һәм бер елга якын Германиядә әсирлек, ачлык җәфаларын бергә үткәрүләре аларны бик нык якынлаштырган иде.* Ш.Камал. *1923 елда ук аңар [М.Солтангалиевкә] «дөнья империализмы вәкиле» дигән исем тагылып, ул эш урыныннан алына, партиядән чыгарыла.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) Капитализмның шушы стадиясендәге илләр. *Ул [Гафури] «Чит җирдәге мөселманнарның хәле» дигән шигырендә Европа империализмы тарафыннан талanучы Көнчыгыш колония халыкларының хәлләрен сурәтли.* М.Җәлил

**ИМПЕРИАЛИСТ** *и. рус* Империализм сәясәтен яклаучы сәяси эшлекле; эре капиталист. *Шагыйрь империалистларның безнең илгә карата корган юлбасарлык, ерткычлык планнарына бөтен дөнья хезмәт ияләренең --- революцион бердәмлеген каршы куя.* Х.Госман. *Англия-Америка империалистлары оештырган чех офицерлары фетнәсе, Колчак ак бандалары Бөгелмәне ике тапкыр канга батырдылар.* Г.Әпсәләмов. *Үзләренә яңа җирләр басып алып, ул илләрне талар өчен сугышалар империалистлар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ИМПЕРИАЛИ́СТИК** *с.* Империализм принципларына нигезләнгән; империализмга хас; империализм сыйфатларына ия булган. *Бу партиягә эшкә урнашуның тагын бер уңай ягы була: округның кайбер службалары ярым хәрби саналганлыктан, кайбер категория инженер-техник хезмәткәрләрне империалистик сугышка җибәрми тору мөмкинлеге кала.* И.Низамов. *[Хәдичә] Империалистик сугыш елларында – 1914 елдан шәфкать туташы сыйфатында Кавказ фронтына җибәрелә.* Сөембикә

**ИМПЕ́РИЯ** *и. лат.* 1) Башында император торган монархистик дәүләт. *Ә Византия империясенең дине – символы гына түгел, империя идеологиясе дә Русиягә күчә.* М.Насыйбуллин. *Казан үз вакыты өчен Россия империясенең иң алдынгы мәдәниятле шәһәрләреннән саналган.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Әмма хазарлар, империя тоткан халык буларак, башка диннәргә карата да зур түземлелек күрсәткәннәр.* Сөембикә

2) Сәяси һәм икътисади мөстәкыйльлекләре булмаган территорияләрне берләштергән, бер үзәктән идарә ителә торган эре колониаль дәүләт. *Трибунага кара чәчле, куе кашлы яшь егет күтәрелде. «Халкымның канын эчүчеләргә үлем!» Оратор куеныннан Британия империясенең байрагы «Юнион джек»ны суырып чыгарды, сүтте һәм шырпы сызып шуңа ут төртте.* М.Юныс. *XX гасыр башында Англиянең колониаль империясендә Җир шары халкының чирек өлешеннән күбрәге яши.* Бөтендөнья тарихы. *[Наполеон] Ярты Европаны биләгән, 83 миллион халкы булган империя белән идарә итә башлый.* Кызыклар дөньясында

**ИМПЕ́РИЯЧЕ** *и.* Башка илне корал көче белән басып алучы, бәйсез илне колониаль дәүләткә әверелдерүче. «*Без империячеләр түгел, без федераллар», – дия-дия, [генераллар] Чечен җирләрен утка тоталар, халкын кыралар.* Казан утлары

**ИМПЕ́РИЯЧЕЛ** *с.* Империягә хас, империя (*2 мәгъ.*) принципларына нигезләнгән. *Патша заманыннан килгән империячел гадәтләрне онытырга вакыт.* Р.Мөхәммәдиев. *Әлеге нәзари фикерләрне хакыйкый дип кабул итәбез икән, ихтыярсыз: Рәсәй дигән мәмләкәт федерацияме, әллә империячел унитар дәүләтме? – дигән сорау туа.* Мирас. *З.Вәлидине куркыткан «бергәлек» идеясен ясалма башкортлаштыру идеясенә алыштырып, империячел көчләр ике тугандаш халык арасына әле җәрәхәте озак гасырлар буена сызлап торачак зур чөй кактылар.* Казан утлары

**ИМПЕ́РИЯЧЕЛЕК** *с. к.* **империячел**. *Башка халыкларга карата булган империячелек дәгъвасыннан алар [милләттәшләребез] тиз генә котыла алмастыр әле.* Ә.Кәримуллин. --- *«Рәсәй Федерациясе» дигәндә бернинди дә чын демократик федерация турында сүз бармый, «федерация» төшенчәсе империячелек сәясәтен «матурландыру-илаһиландыру» өчен генә кулланыла.* Мирас

**ИМПИ́ЧМЕНТ** *и. ингл. юр.* Дәүләттә югары пост биләүче затларны, аеруча ил башлыгын, законнарны тупас бозганы өчен, үз вәкаләтләреннән вакытыннан алда читләштерү максаты белән, парламент судына тарту процедурасы, тәртибе. *Американың Арлен Спoктер исемле абруйлы сенаторы бу гамәле өчен президент Джордж Бушны импичмент ысулы ярдәмендә хакимияттән алу мөмкинлеге барын белдерде.* Юлдаш. --- *вакытыннан алда Президент сайлавын үткәрүнең срогы элеккеге Президент Пәрвәз Мөшәррәф 18 августта отставкага киткәч* (*чөнки аңа импичмент куркынычы яный иде*) *билгеләнде.* Мәдәни җомга

**ИМПЛАНТАТ** *и. лат.* Күчереп утыртыла, имплантацияләнә торган әгъза яки протез. *Француз галимнәре чын йөрәкне алыштырырга сәләтле ясалма әгъза булдырган. Русия Медицина фәннәре академиясе академигы Ренат Акчурин сүзләренчә, имплантат йөрәкне тулысынча алмаштыра ала һәм еллар буе донор әгъзасы күчереп утыртуны көткән авыруларга бик зур өмет бирә.* Мәдәни җомга

**ИМПЛАНТА́ЦИЯ** *и. лат. мед.* 1) Кеше яки югары төзелешле имезүчеләрнең аналыгына яралгы кертү

2) Организмга ят материаллар кертеп ясалган операция // Гомумән әгъза һәм тукымаларны күчереп утырту операциясе

**ИМПЛАНТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. мед.* 1) Кеше яки югары төзелешле имезүчеләрнең яралгысын аналыкның лайлалы ярысына урнаштыру

2) Организмга ят чит материаллар урнаштыру. *Табибларга күгәрмәс тимердән ясалган штырьны актёрның аягына имплантацияләргә кирәк була.* Дулкын // Әгъза һәм тукымаларны күчереп утырту операциясе ясау

**И́МПОРТ** *и. лат.* **1.** *икът.* 1) Эчке базарда сату һәм куллану өчен чит илләрдән товар, технология кертү эше

2) Эчке базарда сату һәм куллану өчен, чит илләрдән (бу илгә бирелгән заём, кредит, чит ил компанияләре тарафыннан урындагы предприятиеләрне сатып алу формасында) кертелгән капитал, әйберләр һәм технология. *Республикабыз экономикасы предприятиеләр арасында хуҗалык элемтәләре өзелүе дәвам иткән шартларда, финанс-кредит системасының бозылуы, --- импорт буенча чимал, материаллар һәм комплектлау әйберләре белән тәэмин ителүнең кимүе, инфляциянең көчәюе шартларында эшләргә мәҗбүр.* Мирас

3) Чит илләрдән кертелгән товарларның гомуми саны яки бәясе

**2.** *с. мәгъ.* Чит илдән кертелгән. *Инде менә шулай чират-миратларны читләтеп үтеп, импорт киемнәр кимичә генә гомер кибәнемне очлармын дип, больницага кергән идем ---.* Ф.Яруллин. *Ул мебельләре! Безнеке шикелле сырлы-мырлы тузан оясы түгел, бар да бер очтан, бар да импорт ---.* Г.Әпсәләмов. *Импорт гарнитур һәм келәмнәр белән җиһазландырылган биек түшәмле иркен бүлмәдә укалы чүәкләр киеп басып торган Венера әйтерсең ханбикә!* З.Фәйзи

**ИМПОРТЁР** *и. лат. к.* **импортчы**

**ИМПОРТЧЫ** *и.* Чит илләрдән товар кертүче физик яки юридик зат

**ИМПОТЕНТ** *и. лат. мед.* **1.** Җенси көчсезлек белән авыручы, импотенциядән интегүче ир кеше. – *Син! Син! Ялганчы, аферист! --- Хәзер аңлашылды инде нинди импотент икәнлегең! – дип чернлдәргә керешә.* З.Хөснияр. *Ул дөньяда бердәнбер гүзәлгә өйләнгән импотент хәлендә иде.* М.Кәбиров

**2.** *с. мәгъ.* Җенси көчсезлек белән чирле, авырый торган

**ИМПОТЕ́НЦИЯ** *и. лат.* Ирләрдә булган җенси көчсезлек һәм шуңа бәйләнгән авыру. – *Импотенциядән дәваланам дип, бер ел буе мине алдап, өйләнмичә йөрисең! – дип черелдәргә керешә.* З.Хөснияр. *Сөлекнең түбәндә саналган авырулар вакытында файдасы бар: --- инфаркт, мигрень, сидек тотмау, импотенция, --- һ.б.* Сәламәт булыйк! *Клиника практикасында гадәттән тыш күп тартучы кешеләрдәге импотенция очраклары белән очрашырга туры килә.* Тигез гомер итегез!

**ИМПРЕССА́РИО** *и. ит.* Концертлар, спектакльләр оештыручы профессиональ артист яки артист исеменнән эш итүче агент. – *Ю-а райт! – диде импрессарио Ренги.* Р.Батулла

**ИМПРЕССИОНИЗМ** *и. фр. сәнг.* 1) XIX йөзнең икенче яртысында Франциядә сәнгатьтә, әдәбиятта барлыкка килгән һәм язучының яки рәссамның чынбарлыктан алган тәэсирләрен, кәефен, кичерешләрен турыдантуры үзе кабул иткәнчә сурәтләүне алга сөргән агым. --- *Ш.Камал хикәяләрендә һәм «Акчарлаклар» повестенда импрессионизм (французча «тәэсир» дигән сүздән) урыны-урыны белән уңышлы гына кулланыла.* Әдәбият. *Импрессионизм, формализм, кубизм ---. Алар барысы да яшәүгә хокуклы. Чөнки һәр рәссам тирә-як мохитне үзенчә күрә, үзенчә гомумиләштерә, үзенчә сурәтли.* Сөембикә

2) Музыкада: тавышларны, академик сыйфатындагы шартлы кагыйдәләрдән читкә китеп, яңа алымнар белән иҗат итү

**ИМПРЕССИОНИСТ** *и. фр.* Импрессионизм тарафдары. *Монда [Люксембург музеенда] импрессионизм агымында башлап картиналар язучы Моне картиналарын, французларның иң соңгы импрессионистларыннан булган Грозе картиналарын --- [күрдем].* Г.Гали. *Борынгы осталар һәм импрессионистлар, бөек Сезанн, XX гасыр рәссамнарының казанышларын өлге һәм үрнәк итү чоры ---.* Сөембикә

**ИМПРЕССИОНИ́СТИК** *с.* Импрессионизмга хас, импрессионизмга нигезләнгән. *Композиторның музыкаль телендә --- кешеләрнең эчке кичерешләрен реаль тасвирлап бирү, бик уңышлы итеп, романтик дулкынлану, саф күңеллелек һәм импрессионистик матурлык белән алып барыла.* Ч.Бәхтиярова

**ИМПРОВИЗА́ТОР** *и. лат.* Импровизация ясарга сәләтле, импровизация ясаучы кеше; чичән. *Күп кенә вакыт халык шагыйрьләре – җырчылары – импровизаторлар булалар.* Н.Гыйззәтуллин

**ИМПРОВИЗА́ТОРЛЫК** *и.* Импровизация ясарга сәләтлелек, импровизация ясаучылык; чичәнлек. *Кариев бик оста пародияче һәм импровизаторлык талантына ия иде.* И.Рәми

**ИМПРОВИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Бирелгән темага алдан әзерлексез килеш поэтик әсәр язу; нинди дә булса бер вакыйгага алдан әзерләнмичә, башкару мизгелендә генә уйлап, шигырь белән җавап бирү, көй чыгару. *Талантлы импровизация шагыйрьнең бай тормыш тәҗрибәсен, тормышны күзәтеп баруын, шигырь техникасы белән иркенле эш итә алуын һәм сүз остасы булуын, сәләтен күрсәтә.* Н.Гыйззәтуллин. *Башка халыклар иҗатында махсус эпик кануннар, импровизацияләр һ.б. иҗади факторлар көчле булса, татар дастаннарының йөзен күбесенчә китаби традицияләр билгеләгән.* Казан утлары

2) Шул сәнгать әсәре (шигырь, көй) үзе. *Көй белән илһамланып уйнау – импровизация – әлбәттә, музыкаль сиземләүнең, музыкаль хыялның көчле булуын таләп итә.* Казан утлары. *Мәкамле җырлау тамырлары борынгы чорлардан ук килә. Бу төр җырулар, нигездә, Шәрык халыкларына хас булып, төрле импровизацияләргә киң ирек бирелгән.* Мәдәни җомга

3) *к.* **имитация** (*1 мәгъ.*). *Әгәр җырлау, бию, импровизация (башка кеше булып сөйләшеп яки хәрәкәтләнеп күрсәтү) бик күп кешеләр өчен --- мөмкин булса, --- рәсем ясау – аерым шәхесләргә генә бирелгән табигать бүләге.* М.Мәһдиев

**ИМПРОВИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* **1**. 1) Тамашачылар алдында, алдан әзерләнмичә, башкару мизгелендә генә уйлап, яңа шигырь уку яки яңа көй чыгару. *Нәтиҗәдә, татар фольклоры импровизацияләүнең, эчке омтылышның, алдан әйтеп булмауның көчле йогынтысын саклый.* Фәнни Татарстан

2) Уйлап чыгару; телгә нәрсә килсә, шуны сөйләү

3) *күч. сөйл.* Нәрсәне дә булса алдан әзерлексез оештыру

**2**. *и. мәгъ.* Тамашачылар алдында алдан әзерләнмичә яңа шигырь уку яки яңа көй көйләү белән бәйләнешле чыгыш

**Импровизацияләп алу** Әзерлексез, тиз генә импровизацияләү

**Импровизацияләп кую** Кинәт, көтмәгәндә импровизацияләү

**Импровизацияли башлау** Импровизацияләргә тотыну

**И́МПУЛЬС** *и. лат.* 1) *физиол.* Нерв ярсыткычларының тәэсире белән барлыкка килеп, ирексездән эшләнә торган хәрәкәт. *Күңелеңнән бертуктаусыз йөрергә омтылырга, безнеңчә әйтсәк, баш миеннән импульслар җибәреп торырга кирәк.* Ф.Яруллин. *Синең һәр сүзеңнән-шөгылеңнән әлеге күңелдәге сурәткә төркем-төркем эмоциональ импульслар бара, алар аны һәрдаим үзгәртеп торалар ---.* Тигез гомер итегез! *Ул [глютамин кислотасы] җитмәгәнлектән, аммиак нерв күзәнәкләрен зарарлый, бу, үз чиратында, импульс тапшыруларның, хәтернең начараюын, психиканың какшавын китереп чыгара.* Юлдаш

2) *физ.* Җисем массасын аның тизлегенә тапкырлаудан килеп чыккан санга тигез хәрәкәт микъдары

3) *физ.* Электр чылбырындагы токның яки көчәнешнең бик кыска вакыт эчендәге сикереше. *Телевизор сурәте секунд саен җемелдәгән меңләгән импульслардан тора ---.* Тигез гомер итегез! *Әгәр шундый телефон челтәренең эше белән инженер кызыксынса, аны, барыннан да бигрәк, электр импульсларының гадәттән тыш акрын таралуы гаҗәпсендерер иде...* Кызыклы физиология. *Югары вольтлы импульс дошманның техникасына төбәп җибәрелә дә, аның электрон җайланмалары сафтан чыгарыла.* Юлдаш

4) *күч.* Нинди дә булса эшкә этәрә торган эчке теләк, омтылыш. *Килде андый вакыт: балалар әдәбиятына, үсешенә көчле импульс бирде, тынынсулышын, офыкларын ачып җибәрде, табигый геройлар, җанлы тормыш килеп керде.* Ш.Галиев. --- *яшьләр тулы кыйммәтле дәүләт теле була барган татар телен дә кызыксынып өйрәнәләр. Дөньядагы теләсә кайсы башкаланы бизи ала торган концерт залыбызны реконструкцияләү төгәлләнгәч, бу процесска яңа импульс биреләчәк.* Мирас

**ИМПУЛЬСИВ** *с.* 1) Кинәт туган теләк һәм импульслар тәэсирендә эш итәргә һәвәс; артык хәрәкәтчән, ашкынучан. *Шагыйрьнең тынгысыз уе, үз тормышы, үз язмышы турында ачыктан-ачык, яшермичә сөйләве, импульсив, хәрәкәтчән, интеллектуаль фикере, --- сокландыра, уйландыра, гаҗәпләндерә.* Т.Галиуллин. *Импульсив кеше тигез һәм тыныч кына эшли белми.* Кызыклар дөньясында

2) *физиол.* Ирексездән ясалган, ирексездән барлыкка килгән. *Импульсив хәрәкәт*

**ИМПУЛЬСИВЛЫК** *и.* Импульсив булу. *Аль Пачино авыруы, ягъни игътибарсызлык, бер урында утырып тора алмау, импульсивлык һәм гиперактивлыкның ми эшчәнлеге зарарланудан килеп чыгуы ачыкланган.* Сәламәт булыйк! *Артык кискен булуыгыз һәм импульсивлыгыгыз якыннарыгыз белән бәхәскә китерергә мөмкин.* Юлдаш

**И́МПУЛЬСЛЫ** *с. махс.* Электр импульслары белән бәйле. *Импульслы радиоэлемтә*

**ИМРА** *и. миф.* Кешеләргә яхшылык эшләүче, шәфкатьле, мәрхәмәтле мифик зат. *Әй имра, имра, Имра сөяк кимерә.* Такмак

**ИМРӘНҮ** *ф. диал.* 1) Бераз куркып, шикләнеп китү, куркыну

2) Сызлану, кәефсезләнү. *Убырны кыйнасаң, бу Убырның иясе йокысыннан уянгач сызлана, имрәнә, ди.* Хикәят

**ИМРӘТКЕЧ** *с.* 1) Йокымсырата, йоклата торган

2) Миңгерәтә, исәнгерәтә торган. *Имрәткеч дару*

**ИМРӘТҮ** *ф. диал.* 1) Бераз куркыту, шикләндерү, шомландыру

2) Дулкынланып, йотлыгып, игътибар белән, дикъкать белән тыңларга мәҗбүр итү; берәр тәэсиргә дучар итү

3) Йокымсырату, изрәтү, йоклату, оету

4) *күч.* Күңелне йомшарту, нечкәртү. *Адәмнең татлы сүзләре төяне бөтенләй имрәттеләр. Төя эшне озакка сузарга теләмәде, тизрәк адәм алдында бөтен серләрне ачып бирергә булды.* Ф.Агиев

**Имрәтеп җибәрү** Кинәт имрәтү; бераз имрәтү. *Җирән бияне алырга тотылган егерме биш сум турында ләммим сүз катмавы Ишмайны тагын шатландырды, аның күңелен имрәтеп җибәрде.* Ш.Камал

**ИМРӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Бераз курку, шомлану, шикләнү. *Нурһадә, тыкрыктан борылуга Байназарны күргәч, имрәп сискәнде.* М.Хуҗин

2) Йотлыгып, игътибар, дикъкать белән тыңлау, нииндидер тәэсиргә бирелү

3) Йокымсырау, изрәү, йокыга оюю

4) *күч.* Күңел йомшару, нечкәрү. *Хәлемне белмисең, ак беләк, Ничек имрәмисең, таш йөрәк!* Җыр. *Бу сайрауга иң каты күңелләр имрәгәннәр, Элеккеләр моңайганнар, изрәгәннәр.* Г.Нугайбәк

**Имрәп китү** 1) Кинәт имрәү; йокымсырый башлау, имри башлау. *Тик бераздан [Илдус] изрәп китә – Калгып китә, имрәп китә.* Рәф.Әхмәтҗанов

**ИМСЕЗ** *с.* Дәвалап, савыктырып булмый торган. *Имгәк имсез авыру таптырыр.* Мәкаль. *[Хәдичә:] Ай улым, сүнмәс ут белән уйныйсың! Фәррах абзый, бер тәвәккәлләгәч, Шәмсегаянны озату ягын карар, әмма имсез җиргә яфрак япма.* А.Гыйләҗев. *Әмма имсез бер яра бар – Хыянәтнең ярасыдыр... Әмма хыянәткә гафу – Мең вә меңнең арасыдыр!* Зөлфәт

◊ **Имсез имгәк** 1) Берничек тә дәвалап булмый торган яисә тумыштан гарип; 2) Бәлале, мәшәкатьле, булдыксыз кеше турында. *Әчми исереп дулый торган имсез имгәк бит ул Шәйхенур.* Татар иле

**ИМТЕКЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Бозау яки бәрәннең имчәккә борынын төртә-төртә аз гына имүе

2) Сөт тизрәк төшсен өчен, сава башлаганчы, сыерның, кәҗәнең имчәк башын әледән-әле тарткалап тору

**2.** *и. мәгъ.* Бозау яки бәрәннең имчәккә борынын төртә-төртә имү күренеше. *[Хәернисә] Сыерга чыккач, ничек бозау имтекләвен тәрәзә аркылы җентекләде.* Г.Ибраһимов

**Имтекләп алу** Тиз генә имү, имтекләү

**Имтекләп тору** Даими, һәрвакыт имтекләү

**Имтекли башлау** Имтекләргә тотыну

**Имтекли бирү** Бернәрсәгә карамый имтекләү, имтекләвен дәвам итү

**ИМТИХАН** *и. гар.* 1) Уку йортларында: берәр төрле уку фәне буенча белем дәрәҗәсен тикшереп, рәсми бәяләү эше; сынау. *Җәүдәт (аңа унбиш яшь), мәктәптә имтихан көннәре булуга карамастан, көндәлеген кулга алырга вакыт тапты...* М.Фәйзуллин. *Харис арткы утыргычта тын гына бара. Имтиханнар пешекләдеме, Машасы сагындырып сагышка саламы, суырылып калды малай.* Б.Камалов. *Имтиханнар башлангач, июнь таңнарының берсе сызылып атар алдыннан, тулай торак бүлмәсенә кайтып яткач, ул Камилгә зарын сөйләде.* Г.Әдһәмова

2) Тиешле рәсми хокуклар алыр өчен яки берәр белгечлек буенча үткәрелгән сынау. *Бай сатучы, --- указ алып мулла булырга авыл табылып та, приговоры җыелып, имтиханы гына кирәк муллаларны ай саен --- күреп торды ---.* Г.Исхакый. *Студентларның дәүләт имтиханнары башланыр алдыннан, Люция миңа шалтыратты.* М.Маликова. *Университетка керү имтиханнарын больницада тапшырырга туры килер дип ята иде Фәнияр.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Тормышта, эштә, яшәештә булдыклылык, яраклылык дәрәҗәсен, каршы тора алу сәләтен таләп иткән кыенлык, авырлык; тормыш авырлыкларын җиңү сәләте. *[Гөлчирә:] Шулай, абый! Язмыш, синең кешелегеңне сынар өчен, тагын бер имтихан куя...* Ш.Хөсәенов. *Батальонга беренче имтиханнарны озак көтәргә туры килмәде. Март азакларында Казанда «Болак арты» милләтчеләре Советка каршы корал һәм гаскәр белән чынлап торып баш күтәрделәр.* И.Низамов. *--- хуҗа «зилзилә» алдыннан әнә шулай рәхимсез карашы белән тикшерә, сыный. Ленарга бу төр имтихан вакытында үзен ничек тотарга кирәклеге дә билгеле...* Р.Айзатуллин

**ИМТИХА́Н АЛУ** *ф.* Нинди дә булса уку фәне буенча белем дәрәҗәсен тикшерү, сынау үткәрү; имтиханлау

**ИМТИХА́Н БИРҮ** *ф.* 1) Билгеләнгән фәннәр буенча укытучы яки комиссия куйган сорауларга яки таләпләргә җавап бирү, сынау үтү. *Ырым-хорафатларга ышанмый Илнур. Әмма имтихан биргәндә, юлга, сәхнәгә чыкканда, догасыз чыкмый икән.* Асылъяр

2) *күч.* Нинди дә булса эше яки сыйфатлары белән нәрсәгә дә булса яраклылыкка сынау үтү, тиешле югарылыкта тору

**ИМТИХА́Н ИТҮ** *ф. иск. к.* **имтихан алу**

**ИМТИХА́Н КЫЛУ** *ф. иск. к.* **имтихан алу**. *Имтиханга кердем. [Инспектор] Сине инде, ди, имтихан кылмыйча да беләбез, ди.* Ф.Әмирхан. *Әхмәт бай, каршы төшеп: «Юк, ул надан, аны мулла куймыйбыз, башканы куябыз, моны имтихан кылабыз, шунда кем булса, шуны куябыз», – дип --- йөрде.* Ш.Мөхәммәдев. *Мин бисмилланы гына түгел, әгузыны да беләм. Сабагын яхшы белүче малай кебек һич тотлыкмыйча әйтеп бирдем. Хуҗа шулай да тынычланмады, мине имтихан кылуында дәвам итте.* А.Шамов

**ИМТИХАНЛА́У** *ф. сир. к.* **имтихан алу**. *Төгәл фәннәрдән имтиханлау*

**ИМТИЯЗ** *и. гар. иск. кит.* 1) Өстенлек, өстен хокук, привилегия. *--- урамнарда --- кичке сату белән шөгыльләнгән Париж «кыз»лары арасында кара гарәп «кыз»лары һәм Шәрык белән чиктәш булган җирләрдә татар буржуазиясендә зур имтиязлар биреп, сәүдәдә истигъмаль кыла башлады.* Г.Гобәйдуллин. *--- ә менә народникларның демократлыгы шунда ки, алар хәзерге вакытта җир биләүчелектәге бөтен имтиязларны һәм сәясәттәге бөтен имтиязларны бетерергә омтылалар.* Г.Нигъмәти. *Парижның ак ирләре тарафыннан зур имтияз белән файдаланган негритянкалар очрыйлар.* Г.Гобәй

2) Укучыга бирелә торган мактау кәгазе. *Ни кушсаң да укый алды; ни әйтсәң, шуны язалды; Балаларның арасында үзенә «имтияз» алды.* Г.Тукай. *Сюар пансионын имтияз белән тәмамлап чыккач, конкурссыз гына прокурор ярдәмчесе итеп билгеләнә.* А.Тимергалин

3) Нинди дә булса хуҗалык эшен алып бару өчен, аерым шәхескә дәүләт тарафыннан бирелгән рөхсәт, хокук. *Россия хөкүмәте --- Сибирия тимер юлын Маньчжурия кыйтгасыннан үткәрмәк өчен, Чин (Кытай) хөкүмәтеннән туксан тугыз елга имтияз (рөхсәт) ал[ды].* Ш.Мөхәммәдев

**ИМТИЯ́З КАЗАНУ** *ф.* Танылу, билгеле булу, киң таралу. *Иске юл белән хөкүмәтне идарә итү[дә] [Германия] дөньядагы бөтен дәүләтләр арасында имтияз казанган.* С.Җәлал

**ИМТИЯЗЛЫ** *с. иск. кит.* 1) Берәр сыйфаты белән бүтәннәрдән аерылып торган. *Хосусан аның бик өлкән ике көмеш чулпысы, беләгенә тулган беләзекләре, муенындагы төрле төймә һәм тәңкәләренең күплеге аны башкалардан имтиязлы итеп күрсәтә иде.* Г.Ибраһимов

2) Мактауга лаек, мактаулы, өстен. *XVIII гасырның ахырына кадәрле*

*морзалар үз халкы арасында имтиязлы булып кил[әләр]---.* Г.Гобәйдуллин. *Ул шундый имтиязлы эшендә дәвам кылып, угылларын мәдрәсәгә җибәрү, кайтару --- гадәтен куймады.* Г.Ибраһимов

**ИМ-ТОМ** *җый. и.* 1) Авыруга, чиргә каршы төрле имнәр, догалар, ырымнар (авыруларны дәвалауның борынгы ысуллары). *– Йөрмә, – дип борды әбисе. – Йөрмә, канатым, ят, йокла. Бәлагә тарырсың. Бу юлысы минем дәваларым, им-томнарым да шифа бирмәс үзеңә.* Н.Гыйматдинова. *Аны өшкертеп тә карадылар, догалы су да эчерделәр. Им-том белән шактый тилмерттеләр кызыйны.* Р.Вәлиев. *Тик кырык бишкә җиткән хатынның: «Йөгемне югалтырга булыш», – дип, им-том белән көн күрүче Суфия карчык янына килүе, чынлап та, көтелмәгән хәл иде.* К.Кәримов

2) Дару, дәва. --- *«дару»ларның, имтомнарның һичбер файдасы тими.* М.Гафури. *Егерме беренче елның көзендә балалар арасында тамак чире чыкты, минем дә бер балама йокты. Укымаган дога, ясатмаган им-том калмады.* Ш.Хөсәенов

3) *күч.* **им-томга** «Бик аз гына күләмдә» яки «бик сирәк очрый торган» мәгънәсендә кулланыла. *[Хөсния] Имгә-томга саклаган шикелле саклап торган бер бит чиста кәгазен эзләп тапты.* Р.Ишморатова. *Бәхетемә, Хатирә дөнья бәясе кеше булып чыкты. Кая ул! Хәтирәләр һәр түтәлдә үсми. Имгә-томга гына алар...* Б.Камалов

◊ **Имгә-томга да очратмау** Бөтенләй булмау, табылмау

**ИМ-ТО́М ИТҮ** *ф.* Имләү, ырымлау, дәвалау. *Бала тәрбияләү белән бәйләнешле борынгы ырымлау, имтом итүләр, йолалар татар традицияләрендә дә байтак сакланып калган.* Р.Ягъфәров. *Г.Исхакый әсәрнең беренче битләрендә үк гыйлемнең өстенлеген раслый, төш юраудан, төрле им-том итүләрдән ары уза алмаган карчыкларны тәнкыйть итә.* Әдәбият. *Бу им-том итү, ырымлау, такмазаларның фәнни әһәмияте зур.* Казан утлары

**ИМ-ТОМЛА́У** *ф. сир. к.* **имләү**

**ИМ-ТОМЧЫ** *и. к.* **имче**. *– Син нәрсә анда им-томчылар белән буталып йөрисең, – дип каршылады райздрав мөдире.* Ф.Яруллин. *Тик [баланы] ананың күз яшьләре дә, йокысыз төннәр дә, тәҗрибәле им-томчыларның «терекләк суы» да коткарып кала алмады.* Г.Шәрипова. *«Халык медицинасы» дигән төшенчә әле тиешенчә гамәлгә кермәгән, аның урынына, «им-томчы», «өшкерүче-төкерүче» дигән сүзләр өстенлек итә иде шул әле ул елларда.* Р.Төхфәтуллин

**ИМ-ТОМЧЫЛЫК** *и.* Им-том итү кәсебе. *[Ул] «Медицинадагы соңгы яңалыклар, дин һәм им-томчылык» дигән темага мәкалә язарга утырды.* Г.Әпсәләмов

**ИМҮ** *ф.* 1) Иренне, телне эчкә таба хәрәкәт иттереп, имчәктән, имгечтән сөт суыру. *Ә бәрәннәрнең ояты юк; инде үзләре сарык булып килүгә карамастан, сәгать саен диярлек, әниләрен чөя-чөя имәләр иде.* В.Нуруллин. *Әниләрегезнең күкрәгенә башыгызны салып ими имеп ятулар, имеп, иреннәрегездәге сөт тамчысын ялап алырга да хәлегез калмыйча, изрәп йоклап китүләр, --- – берсен-берсен дә күрмәгәнсез шул сез.* Ф.Яруллин. --- *үрдәкборынның бәпкәләре нибары 13–14 көн эчендә чыга, ә сөтне алар 3–4 ай имәләр.* Кызыклы физиология

2) Тере организмдагы яки берәр әйбердәге кан, сүл һ.б.ш. сыекчаны үзенә җыю, суыру. --- *Күбәләк һәм умарта корты чәчәкләрдән бал имәләр.* Г.Тукай. *Күрәзәче әйткән: – Синең килеНең – юха җылан, шул йоклаганда сиздерми генә синең угылларыңның канын имә, кибектерә, үтерә бара! – дигән.* Р.Батулла. *Томаланып беткән болытлы көн, пыскак яңгыр, буш урамнар, һәр ягыннан тараеп кысылган буш дөнья – һәркайсы йөрәгемне кысып, канымны имгән кебек.* Табигать белеме

3) Шешә, фляжка һ.б.ш. нәрсә авызыннан сыекчаны йоту, эчү. *Шешә имеп торучы егет мәлҗерәгән күзләрен акайтып Нәҗипкә текәлде.* З.Фәтхетдинов. *– Әй, шайтаннар! – дип, көчкә кычкырып җибәрә алды. Хәнҗәров --- шундук пружинадай өскә калкынды. Самакат тыныч, кымшанмады: баклашканы имә иде.* Х.Камалов

4) *диал.* Каты нәрсәне авызга кабып, төкерек белән юешләп суыргандай итү. *Карандашымны да авызыма кабып суыра-суыра имдем.* Н.Дәүли. *Ул [Лена] үзенең камыт кебек кәкре аякларын кулы белән авызына кадәр тартып китереп, аяк бармакларын имеп ята.* Ф.Яруллин

5) *диал.* Тел һәм иреннәрне эчкә таба хәрәкәтләндереп, конфет, шикәр һ.б.ш. нәрсәләрне суырып ашау. *Өстәлдә яткан пычакны алып, Хәйрүш тә үзе китергән шпикны кисеп салды. Лыч-лыч итеп дуңгыз маен имделәр.* Я.Зәнкиев

6) Тәмәке, сигарет һ.б.лардан төтен суыру. *Тәмәкене күп имүдән хыр-хыр килгән тавыш исә һаман үзенекен тукый ---.* З.Фәтхетдинов. *Тартырга юк, энем, үләм, билләһи. Төтен имү бәхетләренә ирешә алмыйча дөньялардан китте Низами, диярләр инде...* Б.Камалов

7) *күч., гади с.* Алдашу, хәйлә юлы белән (яшертен) кеше акчасыннан, байлыгыннан файдалану. *[Мөгълифә:] Минә Әптерәшит белән дә белешләнсәң ---, ике яктан да имеп ятырсың.* Г.Камал. *[Күзлекле:] Әтиең, Хафиз бай, дөньяны күп имгән инде.* Н.Әсәнбаев. *Имә белсәң, җир астын таларга гына өйрәнгән нефтьчеләрдән ун имчәк таба аласың!* А.Гыйләҗев

8) *күч., гади с.* Кеше хезмәтеннән файдалану, кеше исәбенә байлык туплау, баю. *– Ай нәзберек безнең җизни-түрәләр! Халыкны имеп тешләре бозыла бугай ---, – диде Лена.* Н.Гыйматдинова. *Шакир белән озак сүз киткәч, Шәңгәрәй аны имеп калырга, үзенең комга төртелгән көймәсен секретарьдән кузгалттырырга чамалады.* Г.Ибраһимов. *[Ул] Әпипәнең бөтен маен имеп бетергәннән соң, Чистай пристаненда, кара җәяү калдырып, ташлап киткән, ди, тагын.* Г.Бәширов // Гомумән, кемдер яки нәрсәдер хисабына баю. *Күп имгәттек җирне. Имәсен имдек ---.* Ә.Гаффар. *Авыл нигә хәерче? Чөнки аны шәһәр имә. --- Аны Ленин бабай да имде, Сталин да, Хрущёв та.* З.Мәхмүди

**Имә башлау** Имәргә тотыну

**Имә бирү** Бернәрсәгә карамастан имүне дәвам итү

**Имә тору** Шактый вакыт имү. *Бала бераз киреләнеп маташканнан соң, имчәкне дә алды. Имә торгач, йоклап ук китте.* Г.Галиева

**Имеп алу** Тиз арада, аз гына имү

**Имеп бару** Һәрдаим, системалы имеп бетерергә өлгерү

**Имеп бетерү** Ахыргача, беткәнче имү. *Әтәчләнмә, Шадра! Мин түгел, алар үзләре сыйлаячак безне. Тимә! Бар, тереклек суыңны имеп бетер.* Җ.Рәхимов. *Ул үзе – әнә нинди дәү кәҗә, ә бәтие бәрәү генә. Димәк ки, ул аның җиленена төшкән сөтне имеп бетерә алмый.* Р.Фәизов. *Туйганчы имезмәделәрме, әллә бозау үзе, туеп, анасының сөтен имеп бетерә алмый туктадымы, аны бер читкә алдылар да, Хәтирә сыерны иркәләп кенә саварга утырды.* М.Әмир

**Имеп калу** Мөмкинлектән файдаланып күбрәк имәргә омтылу. *Кулыңа төшкәндә имеп кал, мине дә буш калдырмассың.* Г.Камал

**Имеп карау** Имәргә тырышу. *Ну колхозларны имеп тә карыйлар инде, сөлектән бер дә ким түгелләр!* З.Фәйзи

**Имеп килү** Озак вакытлардан бирле имү

**Имеп китү** Кинәт имә башлау. *Озынча ак төргәктән кечкенә генә бит күренә. Күзләре йомык, ә менә иреннәре әле бер, әле икенче якка кыйшая иде. Ашыйсы килә. Әмма тиз генә имеп китә алмады.* М.Маликова

**Имеп кую** 1) Алдан имү. *Үги инәнең кызы күрә дә моны инәсенә әйтә: «Әй инәй, безнең кара сыерның сөтен үги кыз имеп куя икән, шуңа күрә аның сөте юк», – ди.* Әкият

2) Бер тапкыр имү, суыру хәрәкәте ясау. *Янә, күкрәк тутырып, трубкасын имеп куйды Сталин.* Р.Мөхәммәдиев

**Имеп тору** 1) Һәрвакыт, бертуктаусыз имү. *Миен-йөрәген сызлавык сыман имеп торган авыр уйларыннан арынып өчен, кат-кат дога укып та карады, юк шул, йокы алмады.* Ә.Хәсәнов

2) Әле, хәзерге вакытта имү. – *Тучно күрдем, бозау әнисен имеп тора иде, – диде Әдәс ---.* Х.Камалов

**Имеп яту** *сөйл.* Күптәннән, озак вакытлар дәвамында имү. *[Хурия:] Кайберәүләрнең, балалары барлыгын яшереп, хөкүмәтне бер яктан, уллярын икенче яктан мыштым гына имеп ятканын ачыкларбыз.* А.Гыйләҗев. *Аның [йортның] иң соңгы хуҗасы бу тирәләрнең канын имеп яткан эшкуар булган.* З.Фәтхетдинов. *Әмир белән Мисхәт сөйләшкәнне тыңлап торган диярсең, Шаһи-Морат боларның сүзен элеп алып китте: – Сезне еллар буе талап-имеп яткан Җантуриннар Себер ягына качты.* В.Имамов

**ИМ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел үсемлек (медицинада кулланыла); *русчасы:* **володушка золотистая**

**ИМЧӘК** *и.* 1) Хатын-кыз күкрәгендәге калкып торган сөт бизе. *Яман бәндә имчәк имгәндә ук тешләк була, диләр, чыннан да, дөрес икән.* Ф.Мансуров. *Балакаем, бик ачыгып туган, күрәсең, әнкәсенең сөт белән тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.* Г.Ибраһимов. --- *имчәк очын гына имәрлек иреннәренең кыймылдавы рәхәт кытыклый ---.* Ә.Галиев

2) Имезүче хайван җиленендәге сөт каналларына тоташкан, очлаеп чыгып торган чөмәк. *Бия, бер-ике тарткач та, рәхәтләнеп аякларын ике якка аерды, имчәкләрдән сөт агып китте.* Г.Ибраһимов. *Гөлнур исә сөйли дә сөйли: – [Сыер] Сауганда, имчәкне баш һәм имән бармаклар белән мөмкин кадәр өстәнрәк тотарга кирәк.* М.Хәсәнов. *Бозауларны – бирәүләр, таналарны икенчеләр, кысыр сыерларны өченчеләр карый, савымчылар, эшкә ак халаттан гына килеп, сыерларның имчәкләренә саугыч машиналарны тоташтыралар.* Казан утлары

◊ **Имчәк бозау** Балигъ яшенә җиткәч тә әти-әнисе ярдәменә өметләнеп яшәүче бала. *Әти-әниләр ярдәм итәр иде, «имчәк бозау» дип әйтерләр кебек.* Ф.Яруллин

**ИМЧӘК АНАСЫ** *и.* Башка анадан туган балага үз сөтен имезгән хатын-кыз. *Фатыйма мине имезде, бар булган күңел җылысын – ана мәхәббәтен миңа багышлады. Имчәк анамның килен булган көне --- бүгенгедәй күз алдымда.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИМЧӘК АСТЫ** *и. диал.* Имү дәверендәге, бер яше тулмаган тай

**ИМЧӘК БАЛАСЫ** *и.* Имчәк имеп туклану яшендәге бала, бәби. *Хәтта имчәк балалары да, аналарының күкрәкләреннән аерылып, чак кына башларын күтәрә төшеп, гармунчыга төбәлделәр.* А.Хәсәнов. *Аның [миллионерның] имчәк баласыныкы шикелле гөнаһсыз күзе минем алдымда, болганчык ике зур су тамчысы кебек, тоныклык кына ялтырап алды, һәм мин анда бер генә ялган чаткысы да күрмәдем.* М.Горький. *Имчәк баласы өчен иң төп гигиеник, косметик һәм чыныктыручы процедура – коендыру.* Тигез гомер итегез!

**ИМЧӘК БАШЫ** *и.* Хатын-кызларның сөт бизендә сөт чыга торган чөмәк. *Гөлбикә ояла-тартына гына күкрәген чыгарды һәм балага имчәк башын каптырды.* М.Хәсәнов. *Хәзерге имезүче хайваннарның борынгы элгәрләрендә күпсанлы кечкенә генә сөт бизләре һәркайсы тышкы якка таба ачылган, бернинди дә имчәк башы булмаган әле.* Кызыклы физиология. *Имчәк башларында үзгәреш булу, аларның эчкә батып торулары шулай ук яман шеш барлыкка килү симптомнары булып тора.* Юлдаш

**ИМЧӘКЛЕЛӘР** *и. зоол. иск. к.* **имезүчеләр**

**ИМЧӘК СӨТЕ** *и.* Ана сөте

**ИМЧӘК ТАЙ** *и. диал.* Колын

**ИМЧӘК ТАШЛАТУ** *ф. к.* **имчәктән аеру**

**ИМЧӘКТӘН АЕРУ** *ф.* Кеше һәм имезүче хайваннарның баласын имезүдән бөтенләйгә туктату. *Алар ат тугарган арада, капкадан, инде имчәктән аерылган биш-алты бәти ияртеп, ике кәҗә кайтып керде.* Г.Галиев

**ИМЧӘКТӘШ** *и.* **1.** 1) Бер ана имезгән балаларның, бертуганнарның берсе. *Туганнарым-имчәктәшләрем янына барам.* К.Насыйри

2) Төрле анадан туып, бер хатын имезгән балаларның берсе

**2.** *с. мәгъ.* Бер имчәктән имгән. *Имчәктәш туган. Имчәктәш бала*

**ИМЧӘ́К ТӨБЕ** *и.* 1) Сөтнең иң ахырдан савыла торган куе өлеше. *Карт бия дә, угылының яратканын [сизеп], --- кыргыз абыстай килеп сауанда, урлап, имчәк төбен алып кала иде.* Шура

2) *күч.* Тәмәкенең тартылганнан калган өлеше; тәмәке төпчеге

**ИМЧЕ** *и.* Төрле ырымнар, өшкерүләр, үләннәр, төнәтмәләр белән дәвалаучы кеше; им-том итүче. *Шуннан беркөн базарда имче карчыкны очраттым.* М.Мәһдиев. *Александроваларга кергәч, ике имче икәүләшеп тозлы су ясаганнар, аны сыер абзарына алып кергәннәр.* М.Насыйбуллин. *Имче карт, антын бозган кешенең кул-аягы корыша, күзе сукырая, --- кайчан да булса ул барыбер корып-кибеп үләчәк, дип ышанып яши.* Ф.Ганиева

**ИМЧЕЛЕК** *и.* Имче кәсебе, имче шөгыле. *Теориясез педагогик тәҗрибәне Ушинский медицинадагы имчелеккә тиңләгән.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИМЧЕЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Им-том белән, ырым белән көн күрү, им-том белән шөгыльләнү

**ИМЧЕ-ТОМЧЫ** *и. к.* **имче**. *– Берберсе белән кавышып бала чыгарыр алдыннан, кошлар да башта оя кора, – дип аңлата моны аларга --- ыру карчыгы, бәетче һәм мөнәҗәтче, имче-томчы Асылбикә.* М.Маликова. *Әлегә исән, шулай булгач, барлык камнар, күрәзәчеләр, имче-томчылар аның сүзенә колак салачаклар.* Н.Фәттах. *Имче-томчы Хәбирә карчык, надан кешеләрне алдап, үз көнен күрү, ялганын яшерер өчен, томанлы, кинаяле сөйләмгә мөрәҗәгать итә.* Т.Галиуллин

**ИН** *и.* Хайван колагындагы тамга, билге. *Яшь бәрәннәргә ин салу*

**ИНАБӘТ** *и. гар. иск. кит.* Ышану; ышаныч, таяныч; вәгъдәсендә, сүзендә торучанлык. --- *Сәгыйд сүзне кире иске мәсьәләгә күчерде: – Кара син, Рахманкол ага, халыкта һичбер инабәт калмады ---.* Г.Гобәйдуллин. *Әй-й, инабәт тагын аларга, егетләргә. Ышанычсыз ич алар.* М.Хуҗин. *Юк, кемнәндер куркудан түгел, ахирәтләрендә чүпрәк хакына кешелек инабәте какшанудан, вакланудан шикләнде [Миңсылу].* А.Хәлим

**ИНАБӘ́Т ИТҮ** *ф.* Ышану. *Чит мәмләкәттә безнең кәгазьләргә бик күп инабәт итмиләр.* Г.Тукай

**ИНАБӘТЛЕ** *с. иск. кит.* Ышанычлы; сүзендә, вәгъдәсендә торучан. *Әгәр бер инабәтле һәм безне алдамаслык бер кеше табылса, без бу алтыннарны [сатабыз].* Г.Камал

**ИНАБӘТСЕЗ** *с. иск. кит.* Ышанычсыз, вәгъдәсез. *Әй-й, егет халкы инабәтсез лә алар, егетләргә ышанырга ярамый, мәңге-мәңге ышанычсыз алар.* М.Хуҗин

**ИНАНДЫРУ** *ф.* Берәр нәрсәгә ышаныч тудыру, ышандыру. *Үзенең көчле булуына ул безне шулкадәр дә инандырды ки, дөньяда юклыгына һаман ышанып җитеп булмый әле.* Казан утлары. *Сабира әбинең инандырып дәва итүгә дә маһирлыгы көчле иде.* Фән һәм тел. *Быелгы җәй су тамчысының да никадәр кадерле булуына инандырды.* Ватаным Татарстан

**Инандырып бетерү** Тәмам, бөтенләй инандыру

**Инандырып карау** Инандырырга тырышу

**ИНАНУ** *ф.* **1.** Берәр нәрсәнең хаклыгына, раслыгына, дөреслегенә чын күңелдән ышану. *Ул аны гомеренә кызганды һәм инанды: кызгану белән дә кешене яратып була икән.* М.Хәбибуллин. --- *күп кенә партияләр һәм хәрәкәтләр үз тәҗрибәләрендә Татарстан җәмгыятенең, республика халкының мондый формаларны кабул итмәвенә инандылар лабаса.* Мирас. *Күпсанлы балаларының, үз алларына зур максатлар куеп, байлык белән түгел, нәкъ менә үз сәләтләре нигезендә шул максатларга ирешүен күргәч, бу гаиләнең талантлы нәселдән булуына инанасың.* Сөембикә

**2.** *и. мәгъ.* Берәр нәрсәнең дөреслегенә, хаклыгына, раслыгына чын күңелдән ышанганлык. *Ул [судья] гына: «Мин намусыма колак салыйм, үземнең шәхси инануларым белән киңәшләшим, мин формаль яктан барысының да җиренә җиткерелүен генә күзәтәм», – дип фикер йөрткән.* М.Насыйбуллин

**Инана башлау** Инану, ышану барлыкка килү. *Тамашачы, акрынлап, Мәрьямнең куркусызлыгына, батырлыгына инана башлый.* М.Арсланов. *Мәгәр соңгы елда бу йоланың кеше күңеленә якынрак торуына инана башлады кебек философ.* М.Хәбибуллин

**Инана бару** Торган саен инануы көчәю. *...Мин әйтеп бетергесез олы бер хакыйкатькә чын күңелдән ныграк, тирәнрәк инана барам.* М.Рафиков. *Ринат тормышта шундый каршылыклы принциплар барына күбрәк инана барды.* Н.Хәсәнов

**Инана бирү** Тагын да, алга таба да инану. *Талип дәшмәде, эче-әчкә ябышкан кузакны авызына кабып җибәрде. – Яшисен яшәгән инде ул картлар, Әдһәм абый, инаналар икән Аллаһы Тәгаләгә, инана бирсеннәр.* М.Хәбибуллин

**Инана төшү** Бераз, беркадәр инану

**Инанып алу** Инанырга өлгерү, инде инанган булу. *Ялган вәгъдәләрнең хакыйкатькә караганда күп мәртәбә шифалырак икәнлегенә инанып алган кыз бала, теленә ни килсә, шуны сөйләде.* Р.Мөхәммәдиев

**Инанып бетү** Нәрсәнең дә булса дөреслегенә тулысынча инану. *Ул ничек кирәк дип тапса, шулай дөрес икәнлеген алар өч-дүрт ел эчендә күреп, белеп, бу хакыйкатькә инанып беткән иделәр.* Ф.Яхин. *Әллә күпләр, гомумән, бу кешегә ышана алмый, аның чынлыгына, ихласлыгына инанып бетми микән соң?* М.Вәли-Баржылы

**Инанып җитү** Тиешле дәрәҗәдә инану. *[Ярулла] Үзенә килгәндә исә, ул элек тә, бүген дә Хәнифәне яратуының ихласлыгына инанып җитмәгән иде.* М.Хәбибуллин. *– Малайны үстерәсе бар бит. Иске гадәтне онытырга туры килә. Граммын да авызга кабу исәбендә түгел инде. – Инанып җитә алмыйм.* Ә.Моталлапов

**Инанып йөрү** Озак вакыт дәвамында инанган булу. *Мин сезнең шартыгызны кабул итә алмыйм! Үзем чын күңелемнән инанып йөргән эшкә хыянәт итәргә намусым кушмый.* В.Нуруллин

**Инанып калу** Ниндидер хәлдән соң инанган хәлгә килү. *Һәркем тынычланып, күңеленнән инанып калды: бәла урап узар әле, иншалла...* Г.Гыйльманов

**Инанып килү** Озак вакытлардан бирле инану. *Моңа кадәр без әдә-*

*биятны кеше аңын формалаштыруда иң төп факторларның берсе дип инанып килдек.* Ә.Закирҗанов

**Инанып китү** *к.* **инанып калу**. *Зәйнәп үзе дә «Фатыйма килене» дигән дәрәҗәле титул аласына инанып китәр, Аллаһы боерса.* Р.Юсупова

**Инанып кую** Берәр нәрсәнең дөреслегенә кинәт инану

**ИНАУГУРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда – кемгә дә булса югары дәрәҗәдәге хезмәт урыны бирү, вазифа тапшыру тантанасы

2) АКШта, Россиядә һ.б. кайбер илләрдә яңа сайлап куелган дәүләт башлыгының үз вазифаларына керешү тантанасы. *Инаугурация тантанасында Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.* Сөембикә. *Дмитрий Медведев инаугурация тантанасына беренче вице-премьер булып эшләгән дәвердә танышкан дусларын да чакырган.* Ватаным Татарстан. *Инаугурация көнне генә Медведевның хөрмәтенә артиллерия коралларыннан салют оештырылды ---.* Шәһри Казан

**ИНӘ** I *и. диал.* 1) Бер башы очлы, икенче башында җеп киертү өчен тишеге (күзе) булган кыска, шома, нәзек корыч чыбык (тегү, чигү эшләрендә кулланыла). *Капчык төпләреннән пәке, кайчы, бритва шикелле солдат кирәк-яраклары чыкты, фуражка кырыена кадалган инәләр эшкә кушылды.* Г.Бәширов. *Укытучының урындыгына да инәне үчегеп куймады кыз, бары тик кызык ясыйм, сыйныфташларымны көлдерәм дип кенә тырышты, ә сыйныф көлмәде, чөнки ботына инә кадалган укытучы әллә куркудан, әллә авыртудан аңын җуйды.* Н.Гыйматдинова. *Ниһаять, Ягъфәр эзләгән нәрсәсен табып алды: кулында күгәрә төшкән корыч инә иде.* Р.Фәтхрахманов

2) Ике очы да шома тупыйк башлы ике яки биш данә нәзек корыч чыбык (бәйләү өчен кулланыла). *[Бәдрикамал] Мунча кергәндә, үзенең эченә икеөч тапкыр бияләй инәсе тыгып ала.* М.Мәһдиев. *Галимә апа миңа оекбаш бәйли. Кулы кулга йокмый. Биш инәне ничек тиз йөртә.* Н.Гыйматдинова. *Хатын, ялт-йолт итеп торган инәләрне тиз-тиз йөртеп, оекбаш бәйли.* Х.Камалов

3) Бер башы ыргак сыман итеп эшләнгән нечкә корыч яки пластмасса чыбык (бәйләү, үрү, чигү эшләрендә файдаланыла) // Очлы башында җеп үткәрү тишеге, кинәт калынаеп киткән икенче яртысында махсус кыскычлар белән эләктереп ныгытырга җайланган киртләче булган кыска корыч чыбык (тегү машинасында)

4) Гадәттә, очлаеп килгән башлы, төрле максатларда кулланыла торган төрле формадагы нәзек металл чыбык. *Патефон инәсе белән саксыз кылану аркасында булса кирәк, пластинкалар бик тиз туза башлаганнар.* Г.Галиев // Тән тукымасы арасына дару җибәргәндә, венадан кан алганда, тирене тишеп үтә торган очлы башлы, эче куыш нечкә корыч чыбык. *– Укол ясармын, аннан рәхәтләнеп йокларсың, – [диде онык]. – Тимер инәләрең берлә тәнемне тишмәк буласыңмы? Кит, югал, явыз зат! [диде Карачутыр].* Н.Гыйматдинова. *--- госпитальгә килеп кергәч, [әзмәвер егетләр] әнә шул чебен --- юанлыгындагы инәдән куркып кала. Бер сержант артына укол кадар алдыннан аклы-күкле булды...* М.Мәһдиев. *Пинжәк һәм күлмәкләрен бер читкә салып ыргыткан да шәрә беләгенә кәкрәеп сынган укол инәсе тыгып маташа...* Р.Мөхәммәдиев

5) Ылыслы агачларның инә сыман яфрагы, ылыс. *Христианнар йоласы буенча, Яңа ел бәйрәменә куелган чыршы хуҗаларының өендә яисә һич булмаса бакчаларында, һәркемнең күз алдында саргаеп бетәргә, инәләрен коярга тиеш икән.* Ф.Фәтхелислам. *Ә чыршының яшел инәләре астында утлар, кечкенә генә утлар яналар.* Ж.Тәрҗеманов. *Кырыйлары кителгән гөмбәнең каракучкыл чынаяк астына охшап торган эшләпәсе өстендә аркылы-торкылы булып ылыс инәләре генә яталар.* М.Хәсәнов

6) Кайбер үсемлек сабагындагы үткен очлы үсенте, чәнечке, шырпы. *Гөл кипте, Сабагында --- бер бөртек инә калды.* Дәрдемәнд. *Гөлҗимеш инәсе*

7) Кайбер хайваннарның тиресендә үскән чәнечкеле, каты кыл. *--- яфракларны инәләремә эләктерәм, аннан соң аларны ояма китерәм, – [диде керпе].* Ж.Тәрҗеманов. *Николай озын буйлы, --- кыска, сары чәчләре керпе инәсе кебек тырпаеп торалар.* Р.Кәрами

8) *күч.* Очлы башлы нәзек кристалл. *Җиле биткә инә очы булып кадала.* Г.Гобәй. *Ишек бусагасына менеп баскач, ул борыла, чәче бәс инәләредәй балкып, нурланыш белән каймалана, бер генә мәлгә йөзе танымаслык була.* Ә.Гаффар

9) *күч.* Киная белән әйтелгән усал, мәкерле сүз. *Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар, Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.* Дәрдемәнд. *Алар һаман шулай итәләр, Алар кайда булсаң да инә кадыйлар.* М.Җәлил

10) *күч.* Очлаеп торган нәзек әйбергә карата әйтелә. *Адмиралтейство инәсе*

◊ **Инә белән баз казу** *к.* **инә белән кое казу**. *– Син шул гамәлне бик ансатка саныйсыңмы инде? Китапларга, газитләргә язып «инә белән баз казу»ны? – дидем мин.* Р.Фәизов. **Инә белән кое казу** Бик вак, бик озак, авырлык, түземлелек белән эшләнә торган эш (эшнең үтә авырлыгын күрсәтергә теләгәндә әйтелә). *Укуны «инә белән кое казу» дип юкка гына әйтмиләрдер, шулай булмаса, типсә тимер өзәрлек ир зарланып ятмас иде!* Ф.Сафин. *Кеше ялкау, эзләргә иренә шул. Ә эзләнүләрнең юлы – гыйлем. Ул сиңа көрәк белән матди байлык көрәү түгел инде. «Инә белән кое казу» диләр аны.* Н.Гыйматдинова. *Ул --- Закирҗанның башыннан ниләр үткәнен сорашып та өлгерде. Күргән икән бичара. Юкка гына белем алуны «инә белән кое казу» димәгәннәр бит.* Г.Әпсәләмов. **Инә буе җир китү** Акрын барып, бик аз гына юл үтү. *Миңлебикәнең --- килененә зарланып, бушанасы килә: «И килен, --- көне буе мыштырдап инә буе җир китәм, ә кич сызламаган буын, шыгырдамаган сөяк юк...»* А.Гыйләҗев. **Инәгә (инәсенә) дә тимәү (кагылмау)** Сораусыз бер әйберне дә алмау, урлашмау. *Үз гомеремдә кешенең инәсенә дә тигәнем юк.*

Т.Гыйззәт. **Инәгә кадалып утыру** *к.* **инә (инәләр) өстендә утыру**. *...Рамил фарасын Салабаш урманы ягына борган, юл якты иде. – Йокламадым, күзләрем шар да шар, инәгә кадалып утырдым, – диде егет.* Н.Гыйматдинова. **Инәгә тагылган җеп кебек (төсле)** Һәрвакыт бергә, бер-берсен ияртеп йөрү турында. *Шакир белән Сылу да инәгә тагылган җеп төсле миннән калмаска сөйләшкәннәр икән, ---.* Н.Гыйматдинова. **Инәгә утырту** Кемне дә булса наркотикка ияләштерү; наркоманга әйләндерү. *Артурның абыйсы Айрат «утырткан» аны [Ританы] инәгә.* Асылъяр. **Инәгә утыру** Даими рәвештә наркотик кабул итү; наркоманга әйләнү. *[Илдус] --- моны [анашаны] любой вакытта ташлап була. Менә Ислам кебек инәгә утырырга язмасын.* Д.Салихов. **Инә дә бүләк, дөя дә бүләк** «Бүләкнең теләсә ниндиен дә зур итеп кабул итәргә, канәгать булырга кирәк» мәгънәсендә. *«Инә дә бүләк, дөя дә бүләк» дигәндәй, булган кадәре дә Якуп Сәйфине сөендерергә җитә иде.* Э.Касыймов. **Инәдән дөя (фил) ясау** *к.* **инә күзеннән дөя ясау**. *[Әсрар:] --- Әллә инәдән дөя ясамакчы буласызмы? Печтек кенә ялгышымны бөтен кан кардәшләренә фаш итеп...* Ю.Әминев. **Инәдән куркып, лом йоту** Кечкенә чыгымнан куркып, зуррак чыгымга бату. *И бичаралар, инәдән куркып лом йоткан халыклар!* Г.Камал. **Инәдән (генә) төшкән** Яңа тегелгән, тегелеп кенә беткән (кием); өр-яңа (әйбер). **Инәдән (генә) чыккан** *к.* **инәдән (генә) төшкән**. *Ул: – Ниемә дип шул тикле чабасың? Хәтта ки, инәдән генә чыккан өр-яңа әфтәмәбиленең яшенеге төшеп калганын да күрмәскә! – дип кычкыра-кычкыра, өскә таба йөгереп менә башлады.* Р.Вәлиев. **Инәдә утырту** Кемне дә булса уңайсызланырга, борчылырга мәҗбүр итү. *Секретарь, көлемсерәгәндә, бу турыда түгел, Каюмны инәдә утырткан вакыйга турында уйлады һәм шуны малайларның исләренә төшерде.* Г.Гобәй. **Инәдә утыру** *к.* **инә (инәләр) өстендә утыру**. **Инә йоткан** Бик ябык кеше. **Инә калынлыгы ут, җеп калынлыгы төтен** 1) Дәртсез, ялкынсыз, үрчемсез эш; 2) Таланты, сәләте чамалы кешегә карата әйтелә. **Инә кебек төртелеп тора** Төртмә телле кеше турында аның бу гадәтен өнәмичә әйтелә. **Инә кебек ялангач** Ач-ялангач, ярлы, фәкыйрь. *Ничә еллар һаман байга эшлим, үзем инә кебек ялангач.* М.Гафури. **Инә күзәдәй** Көзгә таба томан сыман булып томалап ява торган вак яңгыр тамчысын чагыштыру өчен кулланыла; гөмбә яңгыры тамчысы. **Инә күзе кебек (хәтле, кадәрле, чаклы, шикелле)** 1) Бик аз күләмдә; бик кечкенә. *Аның [Зәйнәпнең] тузанлы балтырына инә күзе кадәрле генә кан тамчысы саркып чыккан иде.* Ә.Гаффар; 2) Бик аз гына, чак кына (мәс., яхшылык эшләмәү). **Инә күзеннән дөя күрү** Кечкенә хәлне дә бик зур итеп күрсәтү, арттыру, күпертү, зурга җибәрү. *Аның карты – шулай ук инә күзеннән дөя күрергә ярата торган кеше. Әллә нәрсәләр дип күпертеп бетерер.* Ф.Хөсни. *Каландаров, хәзер Сәидәнең һәрбер эшенә бәйләнеп, инә күзеннән дөя күрде ---.* А.Каһһар. **Инә күзеннән дөя ясау** *к.* **инә күзеннән дөя күрү**. **Инә күзеннән карау** *к.* **инә күзеннән үткәрү**. **Инә күзеннән кичерү** *к.* **инә күзеннән үткәрү**. **Инә күзеннән нечкә** Бик нечкә, четерекле мәсьәлә турында. **Инә күзеннән тамызу** Аз гына бирү; саранлану. *Цилиндр головкаларын да инә күзеннән генә тамызып торасыз.* Г.Әпсәләмов. **Инә күзеннән төшкән кадәр** Бик аз гына, тонык, сыек (яктылык, нурлар турында). *Мәгарә эчендә инә күзеннән төшкән кадәр дә яктылык юк иде.* Мәгърифәт. **Инә күзеннән үткәрү** Бик нечкәләп, жентекләп тикшерү; нык игътибар белән сынап күзәтү. *Шәрук медпунктка биленнән зарланып керде дә Рәмзиянең һәр хәрәкәтен инә күзеннән үткәреп утыра башлады.* Н.Гыйматдинова. *Калган ике пар кунакны инә күзеннән үткәрүче булмады.* Г.Әпсәләмов. *Ул, бөтен эш кәгазьләрен тагын бер кат барлап, инә күзеннән үткәреп кую өчен, үз бүлмәсендә утырып калды.* Г.Мөхәммәтшин. **Инәне бүрәнә итү** *к.* **инә күзеннән дөя ясау**. *Син инәне бүрәнә итәсең, ул тикле куркыныч түгел, син юкка безне өркетәсең!* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Инәне дөядән зуррак итү** *к.* **инәдән дөя (фил) ясау**. *Тик, ни сәбәпледер, инәне дөядән зуррак итеп күрсәтергә омтыла.* Юлдаш. **Инә очы кадәр** Бик кечкенә, бәләкәй; аз гына. *Инә очы кадәр генә хәтта Намусыңа таплар төшмәсен.* Г.Латыйп. *Инә очы кадәр дә бер гаебем юк.* Я.Вәли. *Сүзебезнең инә очы кадәресе генә ялган булса, икмәк төсен күрмик, менә табын өстендә әйтәм.* А.Шамов. *– Анысы шулай, безгә харамның инә очы кадәресе дә кергәне юк, Аллага шөкер, – [диде Маһинур].* Г.Рәхим. **Инә очы хәтле** *к.* **инә очы кадәр**. *Ил-көндәге кайгы-хәсрәтләрне ишеткән саен, күргән саен, минем җилкәмне басып торган олуг хәсрәтем кечерәя барып, инә очы хәтлем генә калды.* Н.Гыйматдинова. **Инә очы чаклы** *к.* **инә очы кадәр**. **Инә өстендә бию** 1) Яшьлек хисләре уйнау, дәртләнү, җилпенү; 2) Бик кызу, бик тыгыз эш белән кайнашу; 3) *к.* **инә (инәләр) өстендә утыру**. *Ярты көн инә өстендә биедем. Күз алдымда Равил белән Гаян иде. Күр: кочаклашалар, күр.* Н.Гыйматдинова. **Инә (инәләр) өстендә утыру** Үз-үзеңне уңайсыз хис итү, борчылу. *Юл, юл, юл! Янәшәмдәге кешеләрдән гел сорашып, белешеп барам, алар минем инәләр өстендә утыруымны --- сизмиләр булыр, гади генә: «Әйтербез, әйтербез!» – дип тынычландыралар.* А.Гыйләҗев. *Директор абый --- мактаудан миңа бер куаныч та юк. Инәләр өстендә утырам мин.* Н.Хәсәнов. *Шулай да дүрт сәгатькә сузылган бу киңәшмәдә инәләр өстендә утырган күк тойды үзен.* Р.Айзатуллин. **Инәсе белән кинәсе тел очында булган** Үчегә торган, ачы телле. *Редакциядә шаян табигатьле, тапкыр сүзле, инәсе белән кинәсе тел очында булган бер егет күренә башлады.* И.Рәми. **Инәсеннән җебенә кадәр(ле)** 1) Җентекләп, нечкәләп, барын да, бер дә калдырмыйча, бәйнәбәйнә. *Мәскәүдә укый торган малае кайтса-нитсә, инәсеннән җебенә кадәрле сорашырмын дип торам әле.* А.Шамов. *--- натуралист язучы үзе яза торган даирәне, күренешне, укучы*

*өчен кызыклымы ул, юкмы – инәсеннән җебенә кадәр бөртекләп сурәтли.* Әдәбият; 2) Бөтен кием, бер коры җире калмыйча, яңгырдан һ.б. сыеклыктан үтәли чылану. **Инәсеннән җебенә тиклем** *к.* **инәсеннән җебенә кадәр(ле)**. *Куышыбызга яңгыр үтә башлады. Көт тә тор: инәсеннән җебенә тиклем лычма су булачакбыз.* Ә.Гаффар. **Инәсеннән җебенә хәтле** *к.* **инәсеннән җебенә кадәр(ле)**. **Инәсеннән җебенә чаклы** *к.* **инәсеннән җебенә кадәр(ле)**. *Ярты сәгать эчендә алар безнең кемнәр икәнебезне --- инәсеннән җебенә чаклы сорашып беттеләр.* М.Гафури. *Инәсеннән җебенә чаклы бер чыланмаган җире юк.* Н.Исәнбәт. **Инәсеннән җебенәчә** *к.* **инәсеннән җебенә кадәр(ле)**. **Инә табарлык** Бик якты. **Инә ташлар (төшәр) урын юк (булмау, калмау)** *к.* **инә төртерлек (чәнчерлек) тә урын юк (булмау, калмау)**. **Инә ташласаң (атсаң, ыргытсаң), җиргә төшмәс** *к.* **инә төртерлек (чәнчерлек) тә урын юк (булмау, калмау)**. **Инә төртерлек (чәнчерлек) тә урын юк (булмау, калмау)** Кеше яки башка җан ияләре, я булмаса, әйберләр күпләп җыелып, гадәттән тыш тыгызлык урнашу. *Беренче класс залында инә төртерлек тә урын юк, тыгызлык иде.* С.Җәлал. **Инә төртерлек түгел** *к.* **инә тыгарлык (ташларлык) түгел**. **Инә (дә) төшмәслек** *к.* **инә тыгарлык (ташларлык) түгел**. *Халык инә дә төшмәслек күп, шуңа карамастан, кешеләрнең йөзләре аермачык күренеп тора.* Ә.Гаффар. **Инә түгел** «Кечкенә әйбер түгел, югалса табылыр» мәгънәсендә кулланыла. *– Кичәге бодай табылмаган бит әле! – Анысына пошынма. Табылыр, инә түгел.* Г.Бәширов. **Инә тыгарлык (ташларлык) түгел** Бик тыгыз, кысан булган (урын, җир һ.б.ш.). *Монда инә ташларлык урын калмады.* Г.Ибраһимов. **Инә эзләп табарлык итеп** Бик нык яктыртып. *Мең шәмле электр лампалары --- чуерташтан түшәлгән урыннарны инә эзләп табарлык итеп яктырталар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ИНӘ** II *и. диал.* Ана. *Тамагын кыргалап, Сәлимҗан үз сүзен әйтте: – Хәлдән килгәнчә инәңә булышырбыз, ташламабыз ---.* С.Сөләйманова. *Көннәрдән бер көнне инәләре, лар төбен себергәләштереп, --- аш ишарәте пешерде.* А.Хәлим. *Шул ук граф Толстойның бер хикәясендәге бер көчекнең төнлә белән авылга килгән инә бүрегә ияреп, аның белән урманга киткәнен укып та, сөйләп тә бирде.* З.Зәйнуллин

**ИНӘ́ БУКЧАСЫ** *и.* Инәләрне кадап куяр өчен, чүпрәктән тегелгән мендәрчек

**ИНӘ-ҖЕП** *җый. и.* Инә, җеп кебек әйберләр. *Гөлбануның әнисе алардан караваt, диван өстенә япмалар, мендәр тышлары, инә-җеп кебек әйберләр алып калгалый иде.* С.Зартдинов. *Аерылыштык. --- Судсыз гына бүләбез әйберләрне. Кадак-чүкеч – миңа, инә-җеп – хатынга.* Ф.Шәфигуллин. *Өммегөлсем сандыгыннан --- актанак чүпрәк кисәкләре, --- инә-җеп алды.* А.Хәлим

◊ **Инәдән-җептән киендерү** Баштанаяк яңа кием киендерү. *Солдатлар арасында тегүчеләр табыла, һәм алар бер көн эчендә Җиһангирне инәдән-җептән киендерәләр.* Г.Әпсәләмов. **Инәдән-җептән киенү** Баштанаяк өр-яңа кием киенү. *[Азиат] Инә-җептән киенгән, ыспайлыгы хәйран!* Т.Әйди. **Инәдән-җептән (генә) төшкән** *к.* **инәдән (генә) төшкән**. **Инәдән-җептән (генә) чыккан** *к.* **инәдән (генә) төшкән**. *Өстендә инәдән-җептән генә чыккан өряңа киемнәр иде.* Г.Ахунов

**ИНӘЙ** *и. диал.* Әни. *– Апа, аны өйгә кертеп, сәкегә яткырырга кирәк. Инәй аны ашатты инде, – диде кыз бала.* Р.Хафизова. *Кайтып барганда, үч иткәндәй, кыз анасыннан сорап куйды: – Инәй, бу оста егетнең аты ничек икән?* М.Хәбибуллин. *Авыл советы сарыкларның хакын сугыш ятимәсе булган инәебездән түләтергә дигән карар чыгарды.* Мирас

**ИНӘК** *и. зоол.* **1.** 1) Хайваннарда: ана җенес һәм шул җенестәге хайван. *Көчек тагын йомшак тавыш бирде... – Кем соң әле син – иркәкме, инәкме? Җенесең нинди, дим, – диде Габдияр.* М.Хуҗин. *Ихтимал, табигать тәкәнең чакыру тавышын инәкне үзенә җәлеп итәрдәй, ә башка хайваннар куркырдай итеп планлаштыргандыр.* Кызыклы физиология

2) *диал.* Сыер

**2.** *с. мәгъ.* Ана җенестән булган. *Үзенең нәсел-ыруын дәвам иттерү өчен, хайваннарның теләсә кайсы төре тереклек итүгә яхшы җайлашкан балаларга мохтаҗ. Ә балалар саны, башлыча, үсеп җиткән инәк затлар санына бәйле.* Кызыклы физиология

**ИНӘКӘ** *и. диал.* 1) Дәү әни, әби. *Минем кулым түгел, Әйшә-Батманың кулы; Минем телем түгел, Идел кичкән инәкәләр теле.* Такмак. *Балаларны караучы инәкә өйдә юк иде.* Н.Фәттах

2) Үги ана, үги әни

3) Лилипут, кәрлә; бик кечкенә буйлы хатын-кыз

**ИНӘ́ КҮЗЕ** *и.* Инәнең җеп үткәрә торган тишеге. *Инә күзе аша җеп үткәрү дә аның өчен зур эш бит.* Мәдәни җомга

**ИНӘЛӘНҮ** *ф.* Инә рәвешен алу, инә кебек тырпаю; инәләр белән каплану

**Инәләнә бару** Торган саен арта барып, тагын да күбрәк инәләнү

**Инәләнә башлау** Инәләр күренү

**Инәләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча, тоташ инәләнү

**Инәләнеп кую** Кинәт инәләнү, инәләнгән хәлгә килү

**Инәләнеп тору** Әле, хәзер тырпайган хәлдә булу. *Мәче ябыккан, кабыргалары ерактан ук беленә, йоннары кыл кебек инәләнеп тора.* Н.Дәүли

**ИНӘЛГЕЧ** *с. диал.* Ялварулы, ялынулы; ялваруны, ялынуны белдергән. *[Тәкәрлекнең] Тавышы шундый зарлы, шундый инәлгеч булып ишетелә, әйтерсең ул: «Зинһар таптый күрмәгез!» --- дип кычкыра.* Ш.Маннур

**ИНӘЛЕ** *с.* 1) Инәләре булган. *Җәүдәт кассетага сузылган кызның кулыннан эләктерде: – Син гел шундыймы? – Нинди, Әюпов? – Инәле керпе төсле, дим?* Н.Гыйматдинова. *Инәле чыршыны күреп Аптырады балалар: «Бик зур керпе килгән», – диеп, Әй куандылар алар.* К.Закирова. *Аручанлыктан инәле элеутерококк төнәтмәсе файдалы.* Сөембикә

2) *күч.* Кеше күңеленә тия торган, чәнечкеле, усал, төртмә итеп әйтелгән.

*Инәле җыр Тусын өчен кирәктер Иң нечкә, Иң якты чагы күңелнең.* Е.Уткин

**ИНӘЛҮ** *ф. диал.* 1) Түбәнчелек белән үтенү, сорау, ялыну, ялвару. *Кордаш булсаң, әйдәле, кырдаш та бул, ал да күрәгеңне, киттек. Килеп тепәлмәсә, безгә инәлмәсләр иде.* Г.Шәрәфи. – *Берүк Шәрәфкә әйт, Газзә күрше. Гыйлемдарга үч тотмасын. Ачу-киная җүнлегә илтми адәмне, – дип инәлде Акъәни.* Н.Гыйматдинова. *Оятыма, сизмәстән акырып җибәрдем, авырта, --- дип аңлатып карыйм, инәләм, берәүсе ышанмый, икмәктер...* А.Гыйләҗев

2) Шаккату, аптырау

**Инәлеп китү** Кинәт инәлү. *Кызларны чишәргә дип тезләнгән Гаяделхәмит кинәт инәлеп китте: үз күзләренә ышанмыйча торды.* С.Зыялы

**ИНӘЛҮЛЕ** *с. диал. к.* **инәлгеч**. *--- әнисе, инәлүле күзләрен яшел түбәле йортның бу яктагы сыңар тәрәзәсенә төбәп, хәрәкәтсез калган.* Р.Вәлиев. *Ютәле тукталып торган арада, әнисенең инәлүле тавышы ишетелде.* М.Галиев

**ИНӘ́ ТАШЫ** *и. иск.* Магнит

**ИНӘТӘНЛЕЛӘР** *и. күпл. зоол. иск. к.* **инәтирелеләр**

**ИНӘТИРЕЛЕЛӘР** *и. күпл. зоол.* Су төбендә хәрәкәтләнә торган, тиреләре известь инәләр, чәнечкеләр белән капланган умырткасыз хайваннарның бер тибы (мәс., диңгез йолдызлары); *русчасы:* **иглокожие**. *Диңгезләрдә бик күп төрле умырткасызлар, бигрәк тә борынгы мәрҗәннәр, моллюсклар, кысласыманнар, инәтирелеләр яши.* Дарвинизм нигезләре

**ИНӘ́Ү** *ф. диал.* Хайваннарны яки кош-кортларны тамгалау; берберсеннән аерылып торсын, буташмасын өчен тамга салу

**Инәп бетерү** Барысын да инәү

**Инәп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм, берсе артыннан берсен инәү

**ИНӘЧЕ** *и.* Инәләр белән сату итүче кеше. *Җәлләдем бу Хода бәндәсен, алдым инәләрен. Тик инәчене җәлләп торганда гына, тагын бер телсезчукрак килеп чыкмасынмы.* Р.Фәизов

**ИНВАЛИД** *и. лат.* **1.** Авыру, имгәнү яки тумыштан зәгыйфь булу сәбәпле, хезмәткә яраклылыкны өлешчә яки тулысынча югалткан гарип кеше. *--- министрлык инвалидларга колясканы илтеп бирми, аны шул гарипнең якыннары барып алырга тиеш икән.* М.Маликова. *Аларның Гөлҗиһан белән туйлары булырга тиеш иде. Бүгенге көндә ул – дөм сукыр инвалид, кирәк булырмы ул Гөлҗиһанга?* Ф.Бәйрәмова. *Ватан сугышы инвалидларына кадерхөрмәт әнә шулай минуты-сәгате белән күрсәтелгән ул чакларда.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Имгәнгән, гарип. – *Ныграк тотын, – диде хатын һәм болдырдан төшүгә инвалид ирне тизрәк арбасына утыртты.* М.Хәбибуллин. *Инвалид ананы балалары чиратлашып караса әйбәтрәк була, диләр бит...* М.Маликова. *Инвалид бала нинди дә булса сәбәпләр аркасында санаторийга бара алмый кала икән, аңа --- акчалата компенсация бирелми.* Юлдаш

**ИНВАЛИДЛЫК** *и.* Хезмәткә, эшкә өлешчә яки тулысынча яраксызлык; инвалид булу. *Операция ясадылар, егет барыбер гомерлек инвалид булып калды. Инвалидлыкны законлаштырырга кирәк булгач, аларны яллаган кешеләр --- ярдәм итүдән баш тарттылар.* С.Шәмси. – *Колхозда аның кадәр пенсия буламыни? – Ә мин инвалидлыкка алам. – Ничек инвалидлыкка? – Шулай, яраларым бар.* М.Мәһдиев. --- *Гарәф Сәхабетдин улы Сәхаповка 1943 елның февраль азагында икенче группа инвалидлык биреп, шәфкать туташы Мария Журавлёвага өенә кадәр озатырга куштылар.* Р.Камалетдинова

**ИНВЕНТАРИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Инвентаризацияләү эше. *Финагент Сәмигуллин мәктәптә инвентаризация ясаган да гамәлдән чыгарылган инвентарьны акт белән уздырып ята икән.* М.Мәһдиев. *Инвентаризация комиссиясе шул микроскоп аркасында үзенең эшен тәмам итә алмый.* Г.Галиев

2) Милекне инвентарь дәфтәре, инвентарь кенәгәсенә кертү эше. *Миллионер Хөсәеновларның мал-мөлкәтен, терлек-туарын конфискацияләгәндә, пони, инвентаризация кенәгәсенә теркәлмәгәнлектән, тапшырылмый калган.* М.Фәйзуллин. *Шаяз, баш механик итеп билгеләнгәндә, инвентаризациягә кул куеп алган.* Х.Камалов. *«Татарстанда Алтай тракторы» җаваплылыгы чикләнгән ширкәт директоры Ф.Җиһангиров, бу оешманы ябу максатында, Биектау районы техник инвентаризация бюросына мөрәҗәгать итә.* Ватаным Татарстан

**ИНВЕНТАРИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Матди кыйммәтләрнең, акча һәм башка средстволарның гамәлдәге калдыклары исәп-хисаптагы мәгълүматларга тәңгәл килүен тикшерү, барлау

**Инвентаризацияләп алу** Кыска вакыт эчендә, тиз арада милекне инвентаризацияләү

**Инвентаризацияләп бетерү** Милекне тулысынча, барысын да инвентаризацияләү; инвентаризация эшен төгәлләү

**Инвентаризацияләп чыгу** Булган әйберләрнең һәрберсен берәм-берәм, башыннан ахырына кадәр инвентаризацияләү

**Инвентаризацияли башлау** Инвентаризацияләү эшенә тотыну

**ИНВЕНТАРЬ** *и. лат.* 1) Берәр оешманың барлык булган эш кораллары, эш көчләре, җиһазлары, гомумән, җитештерү средстволары; дирбия. *Ә кичектергесез хәл итәсе мәсьәләләр күп иде. Атларны, инвентарьларны кая җыярга? Фураж каян алырга?* М.Маликова. *Кулларында пожар инвентаре: лом, балта, көрәк.* М.Юныс. --- *берәттән умарталык инвентаре турында кайгыртырга онытма. Юкса, бездә бер ертык битлек белән бер төтәсләгечтән башка нәрсә юк.* Ф.Яруллин

2) Милектә булган җиһазлар, эш кораллары һ.б. *Кайчандыр колхоз инвентарена кергән китаплар турында әйтә булыр Әмирҗан.* М.Хуҗин. *Буфет мөлкәтен барлап чыккач, дүрт нөсхәдә акт төзедек. Беренче нөсхәне инвентарь кенәгәсенә теркәдек.* М.Юныс

**ИНВЕНТАРЬЛА́У** *ф. к.* **инвентаризацияләү**

**Инвентарьлап алу** Кыска вакыт эчендә инвентарьлау

**ИНВЕРСИОН** *с. лингв. к.* **инверсияле**. *Инверсион кисәкләр (кире тәр-*

*типтә килгән кисәкләр), әгәр дә алар җөмлә ахырында торсалар, өстәмәләргә бик якын булалар.* Татар грамматикасы. *Инверсион кисәк җөмлә тәмамлангач әйтелми, бәлки җөмлә тәмамланганчы әйтелә. Мондый инверсион кисәк күбрәк шигъри әсәрләрдә һәм гади сөйләмдә кулланыла.* Тел гыйлеменә кереш

**ИНВЕ́РСИЯ** *и. лат.* 1) *лингв., әд.* Нинди дә булса берәр сүзгә аеруча басым ясау максаты белән, җөмлә эчендәге сүзләрнең гадәттәге грамматик тәртибе үзгәртелгән сүз әйләнмәсе; җөмләнең аерым бер кисәгенең гадәттәге тәртибеннән алмашынып килү күренеше. *Ләкин проза сөйләмендә дә билгеле бер максатларда берникадәр дәрәҗәдә кире сүз тәртибе (инверсия) кулланыла.* Р.Юсупов. *Өстәмәләр аерым җөмләләр арасында була торган интонация ясалмаса, өстәмә барлыкка килмичә, җөмлә кисәкләренең инверсиясе күзәтелә.* Татар грамматикасы. *Модальлек шулай ук кисәкчәләр, ымлыклар, интонациянең төрле типлары, кабатлаулар, инверсия һ.б. аша да белдерелә.* Тел гыйлеменә кереш

2) *хим.* Кислоталар, су, ферментлар тәэсирендә шикәрнең глюкозага һәм фруктозага таркалуы. *Немец физигы һәм химигы Людвиг Фердинанд Вильгельм (1812–1864) когезия күренешен, химик процесслар тизлеген, кислоталар тәэсирендә камыш шикәренең инверсиясен (таркалуын) өйрәнә, шушы реакция тизлегенең математик тасвирламасын бирә.* Фән һәм тел

**ИНВЕ́РСИЯЛӘҮ** *ф. лингв.* Сүз тәртибен үзгәртү, инверсия ясау. «*Мин торам кырларда, Болында, урманда; Уйныймын, очамын Якты көн булганда», – дип, Г.Тукай урын хәлләрен матур итеп инверсияли.* Л.Җәләй. *Хәлбуки без туры сөйләмнәрдәге автор сүзеннән соң килгән мондый оборотларны нәкъ русчадагыча инверсиялибез.* Х.Сарьян

**ИНВЕ́РСИЯЛЕ** *с. лингв.* Җөмләдә гадәти сүз тәртибе үзгәртелгән, сүзләрнең урыннары алмаштырылган

**ИНВЕ́РТОР** *и. лат.* 1) *физ.* Электротехникада – даими электр тогын алмаш токка күчерә торган җайланма

2) *информ.* Компьютерның бер билгене икенчегә (мәс., *1 не 0 гә*) үзгәртә торган элементы

3) *биол.* Геннарның тәртибе үзгәрүгә китергән хромосомалар мутациясенең бер төре

**ИНВЕСТИ́ТОР** *и. лат. икът. к.* **инвестор**. *Казанда «Универсиада – 2013 авылы» төзеләчәк. Бу инвеститорларга 300 млн. долларга төшәчәк.* Юлдаш

**ИНВЕСТИЦИОН** *с.* Инвестициягә, капитал салуга мөнәсәбәтле. *Әгәр дә Казан Универсиада башкаласы булса, проектның инвестицион җәлеп итүчәнлеге 450 миллионга кадәр җитәргә мөмкин.* Юлдаш

**ИНВЕСТИ́ЦИЯ** *и. лат. икът.* Табыш алу максатыннан чыгып, иҗтимагый яисә хосусый капиталны ил эчендә дә, чит илләрдә дә халык хуҗалыгының төрле тармакларына салу. *Без чит ил инвесторлары өчен уңайлы закон актлары булдырдык һәм инвестицияләр күләме ягыннан Россиядә өченче урынга чыктык.* Мирас. *Әлеге программа дүрт «И»не: институтларны, инфраструктураны, инновация һәм инвестицияләрне үстерүгә корылган.* Татарстан

**ИНВЕСТИ́ЦИЯЛӘҮ** *ф. икът.* Табыш алу максатыннан озак срокка чит ил һәм ил эчендәге предприятиеләргә капитал салу. *Инвестицияләү эшчәнлеге*

**Инвестицияләп тору** Даими инвестицияләү

**Инвестицияли башлау** Инвестицияләргә керешү

**ИНВЕ́СТОР** *и. лат. икът.* Инвестиция салучы, инвестицияләүче юридик яки физик зат; инвеститор. *Акча кертүче кешеләрне, ягъни инвесторларны алар үзләре табарга тиеш булачак.* Сөембикә. *Чит ил инвесторлары Татарстанга «прагматизм утравы» дигән исем куштылар һәм аны капитал салу өчен «табигый магнит» дип атадылар.* Мирас. *--- инвесторлар шәхси авыл хуҗалыгы предприятиеләре сыйфатында дәүләттән --- гектар җир сатып алганнар.* Ватаным Татарстан

**ИНВОЛЮ́ЦИЯ** *и. лат. физиол.* 1) Нинди дә булса сәбәп аркасында зурайган органның элекке хәленә кайтуы. *Бала тудырганнан соң аналык инволюциясе*

2) Эволюция барышында кайбер органнарның югалуы

**ИНГАЛЯ́ТОР** *и. рус тех.* Ингаляция аппараты. *Ирем астма чире белән авырый иде. Кесәсендә гел ингалятор йөртте.* Сәламәт булыйк!

**ИНГАЛЯ́ЦИЯ** *и. лат. мед.* Сулыш органнарын даруларга баетылган һава яки пар сулатып дәвалау. *Томау төшүдән иң шифалысы теге ни... ингаляция булыр. Ягъни болай: бик әйбәтләп кайнар бәрәңге парын сулыйсы.* Э.Касыймов. *Сулыш юллары ачылсын һәм пневмония авыруы барлыкка килмәсен өчен, ингаляция үткәрергә: бәрәңге парын суларга кирәк.* Сәламәт булыйк! *Ул [лаванда] шулай ук грипптан, бронхиттан һәм башка төрле салкын тиюләрдән ингаляция ясау өчен дә файдалы санала.* Сөембикә

**ИНГАМ** *и. гар.* 1) Ашамлык, ризык, нигъмәт; сый. *Ул алты углына күп вәгазь вә нәсыйхәтләр әйтеп, вә шәһәрләр, вә илләр, вә ингамнар бирде ---.* Дастан

2) Яхшылык. *Асрады шаһ үз ингамы белән.* Мөхәммәдьяр

**ИНГЛИЗ** *и.* Бөекбританиядә яшәүче, күпчелеге протестант динендәге, инглиз телендә сөйләшүче халык һәм шуның бер вәкиле. *Ул да түгел урамда башларына карт хатыннар кебек итеп кара берет кигән инглиз солдатлары күренә башлый.* Г.Гобәй. *Әмелә, әйтик, инглиз врачы Дженнер кешеләргә чәчәк салу йоласын керткән, --- ләкин аны күпме кеше белә?* И.Гази. *Моның өчен институт китапханәсендә, тезе белән шуышып, шактый күп йөрде, чөнки инглиз телендәге химия китаплары аскы киштәләргә тезелгән иде.* М.Маликова

**ИНГЛИ́З АВЫРУЫ** *и. иск. мед.* Бала организмында D витамины җитешмәгәнлектән, матдәләр алмашы, бигрәк тә кальций һәм фосфор алмашуы бозылу сәбәпле, сөякләрнең йомшак, зәгыйфь, тигезсез үсүеннән гыйбарәт авыру; рахит

**ИНГЛИ́З ЙОЗАГЫ** *и.* Ишеккә уеп куела һәм үзеннән-үзе бикләнә торган

йозак. *Саубуллашып, ишектән чыккач, инглиз йозагының «чык» иткәнен ишеткәч тә әле Рәшидә туктап, тыңланып торды...* М.Маликова. *–[Ачкычларны] Нина Георгиевнага тапшыр, зинһар, – диде [Шурик]. – Минә монысы инглиз йозагыныкы, тышкы ишекнеке...* А.Алексин

**ИНГЛИ́З ТОЗЫ** *и. мед.* Эч йомшарта торган дару, магний оксиды

**ИНГЛИ́ЗЧӘ** *рәв.* **1.** Инглиз телендә. *Тел өйрәнүгә сәләтем булган, күрәсең: ике ел дигәндә, апам белән инглизчә ярыйсы гына сукалый идек инде.* Ф.Яруллин. *– Инглизчә язылган булса кирәк монда, – диде Ибраһим, капны күрер-күрмәс күзләренә якын ук китереп.* Ф.Хөсни. *– Ну инде, без егермедән узган кешеләрне дә җәмгыять җилкәсендә асрый башласак, – дип, ватаҗимерә инглизчә каршы төште Алтынчәч.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* Инглизләрнеке кебек. *Аның [Вәлиднең] матур диярлек, тазалыктан кызарып янып торган йөзе, бераз майлырак кара күзләре, кызыл иреннәре өстендәге инглизчә кечкенә генә итеп калдырып кыркылган кара мыегы, әллә нишләп, миңа ошамадылар.* Г.Рәхим

**3.** *и. мәгъ.* Инглиз теле. *Ә мин бардым. Үзем генә дә түгел, ә инглизчәне су кебек эчә торган хатыным белән бардым.* Ф.Яруллин

**ИНГРЕДИЕНТ** *и. лат. хим.* Нинди дә булса бер катлаулы кушылманың яки катнашманың состав өлеше; тәшкиләт. *Пирог, катлама һәм күмәчләр өчен камыр басканда, ингредиентларга он кушыла.* Татар ашлары. *Нью-Йорк рестораннарының берсендә шундый коктейль әзерлиләр. Бармен анда өч ингредиентны бергә куша.* Юлдаш

**ИНГУШ** *и.* Ингушетиядә һәм Ичкериядә яшәүче, ислам динен тотучы һәм ингуш телендә сөйләшүче халык һәм шуның бер вәкиле. *1943–1944 елларда үз ватаннарыннан куылган халыкларга (балкарлар, карачайлар, ингушлар, чеченнар, калмыклар, кырым татарлары, Идел буе немецлары) 1957 елда туган якларына кайтырга рөхсәт ителсә дә, --- милли мәктәпләрен ачу рөхсәт ителми.* Идел. *Дивизия командиры генерал Багратион аеруча исәп баглаган ингуш солдатларын нейтральләштерүдә алар [мөселман оешмалары] хәлиткеч роль уйный.* Мирас

**ИНДЕ** *кис.* **1.** 1) Төрле сүз төркемнәре янында килеп, эш яки хәлнең тәмамлануына, бетүенә ишарә итә. *Чын румнар кайда хәзер? Аулаган биләмәләрдән «мәңгелек калага» агылган чуар халык арасында алар әллә кайчан эреп беткән инде.* Р.Зәйдулла. --- *Фәния Шәвәлиевна олы юлга чыгып килгәндә, кулына чәчәк бәйләме тоткан Гөлгенә Чишмә үрен менгән иде инде.* С.Зыялы. *Рәхилә уянганда, көн яктырган иде инде.* Ф.Сафин

2) Боерык фигыльләрдән соң килеп, үтенү, ялыну яки сабырсызлану, таләп итү төсмере өсти. *Әни аның күлмәген, башыннан алып, яңгырга сузды, тик энекәш: – Яп, яп инде әйткәч, – дип, кире какты.* Ә.Гаффар. *Моны күргәч, язылучы, ялынган сыман тавыш белән: – Сез, абзыйлар, зинһар өчен дип әйтәм, ала күрегез инде.* Ш.Усманов. *Алсу тагын ялынып чакыра: «Кил, уйнамыйм, бетте... Кил инде!»* Һ.Такташ

3) Исем яки алмашлыклар янында килеп, көчәйтү төсмерен белдерә. *Бу инде үзенең аллы-кызыллы чуклары белән бөтен бүлмәне нурлы төсләр дулкынына тутырды. Бу инде нинди генә киң хыяллы кеше өчен дә бик күп.* А.Шамов. *Менә шундый инде ул адәм баласы: нинди генә авыр хәлдә калмасын, үзен юатырлык сылтау эзләп таба.* И.Гази. *Сугыш булгач, сугыш инде ул, шар сугу түгел.* Ф.Хөсни

4) Хикәя фигыльләр янында килгәндә вакыт төсмерен белдерә. *Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби.* Г.Тукай. *Язгы сандугачлы яшьлек таңым үтте инде...* Һ.Такташ

5) *сөйл.* Әңгәмәдәш әйткән сүзне, эш-гамәлне ошатмау, яратмау, дөрес дип тапмауны аңлата. *Әмма Сабира түтинең чаршавын күргән кеше юк иде әле. Инде! Сабира түти шундый хәйләкәр елмаю белән сандык төбеннән бер чаршау чыгарып тоттырды Сөембикәгә...* М.Мәһдиев. *Шоферларның берсе: – Я ин-де-е!.. – диде, сузып, иптәшенең бу эшен килештереп бетермичә.* М.Хәсәнов. *– Чү, чү инде, зинһар, ул кадәр тавышланма, – диде ул, ялынып.* А.Шамов

6) Эш-хәрәкәтнең эзлеклелеген, күренешләрнең бер-бер артлы алмашынуын күз алдында булып торган кебек итеп сурәтләгәндә кулланыла; менә. *Инде упкын читенә килеп җитәм дигәндә, инде ап-ак томан арасына соңгы тапкыр ташланам дигәндә, кинәт яр буенда мин аны күрәм.* Ф.Бәйрәмова

**2.** 1) *рәв. мәгъ.* Берәр эш башкарырга вакыт җиткәнен, эшнең башланып китүен белдерә; хәзер. *Нәкъ шуның күк бер заманны дөньясын типкән халык, Инде алҗып, тик йөридер, сызгырып, айхай салып!* Ш.Бабич. *– Бик күңелсез йортта очрашсак та, Илфат энем, көннәрне ярыйсы гына уздырдык. Инде тизрәк савыгып чыгуыгызны телимен, – [диде Хәбиб].* Б.Камалов. *Син Хак Тәгалә боермаган җирдән тамгы итәсең, моның җәзасын ул гайрәтле Падишаһ сиңа бирер, инде тәүбә кыл.* Борынгы татар прозасы

2) *диал.* Күптән түгел, әле генә. *Әле ул чакта «чәй» дигән нәрсә юк иде, --- инде генә чыкты.* М.Галәү

**3.** *и. мәгъ. диал.* Бүгенге, хәзерге көн, шушы мизгел. *Мирза индедән соң Фәридә белән Кәримәне укудан туктатырга исәпли, шуңар күрә мадам Лиза, яз җитүгә, үзенең Уфасына кайтып китә.* С.Җәлал

**4.** *терк. мәгъ. сөйл.* Нинди дә булса эшнең шартын белдергәндә, шарт җөмләләрне баш җөмләгә бәйләгәндә кулланыла; әгәр. *Инде килми икән – калмакчы икән – закон бар.* М.Мәһдиев. *Саимәне күрүгә, ул [Самат] --- җәйлы гына култыклап алды: – Инде килмисең икән, дип курыккан идем, тагын биш минуттан килеп җитмәсәң, өегезгә барып алырга иде исәп, – дип, дулкынлануын яшермәде егет.* Г.Галиева. *Инде алай-болай кемдер чынлап та килеп чыга икән, ул чакта да искитәрлек берни дә юк монда...* В.Распутин

◊ **Инде бер дә булмый икән** Һич булмаса, бер дә булмаса, ахыр чиктә.

**Инде дә** Таң калуны, ис китүне, гаҗәпләнүне, соклануны белдергәндә кулланыла; шулкадәр. *Ә Айдар, кош тотканмыни, әтисе каршында бертуктаусыз тәтелдәп этне мактый: – Менә әти, боксёр бу, боксёр. Матур бит, әти, әйеме?! – Инде дә, улым, инде дә...* Г.Шәрәфи. *– Яшьрәк чагым булса, мин сине үзем үк ялгызың яшәтмәс идем дә бит кана... – [диде Мөбәрәкша]. – Инде дә телең!..* Ә.Гаффар. **Инде дә җитмәгән (җитмәсә)** Мәшәкать яки бер бәла өстенә икенчеләре өстәлгәндә әйтелә. **Индедән ары** Моннан ары, тагын. *Бусы булган, индедән ары була күрмәсен.* Ватаным Татарстан. **Индедән соң** *к.* **индедән ары**. *Рөстәм: – Мин бит, атакай, әлегә кадәр сезгә үземне начар яктан күрсәткәнем юк, индедән соң да күрсәтмәм дип уйлыйм, – дип җавап бирә.* С.Җәлал. *Индедән соң бу эш булмас.* Ирек мәйданы. **Инде килеп** Шулай итеп; шулай булгач; тагын, өстәвенә, җитмәсә. *Талиянең тавышы ике ирне дә ипкә китерде... – Инде килеп, Хәмит дус, сез дә таныш булыгыз: бу әфәнде безнең фирманың генераль директоры Касыйм Кадыйрович ---.* Г.Галиева. *– Моңа бары тик мин генә гаепле, иптәшләр, – дип, шактый ышанычсыз хәлдә башлап җибәрде ул. – Инде килеп, шушы эш процессында... күңелсез картиналар чыккан икән, моңа как директор мин генә гаепле ---.* М.Мәһдиев. *Инде килеп, республикабызда ел саен өч йөз илле меңнән артык кешенең ГТО нормалары тапшыруын, шул кадәр үк разрядлы спортчылар әзерләнүен әйтик.* Казан утлары

**ИНДЕГЕ** *с. бор.* Хәзерге. *– Борынгының бере юк, Индегенең коны юк, – [дип сөйләгәннәр].* Н.Исәнбәт

**ИНДЕ́ЕЦЛАР** *җый. и. рус күпл.* Төньяк һәм Көньяк Америкада европалылар килеп утырганга кадәр яшәгән җирле борынгы кабиләләрнең һәм халыкларның (эскимослардан һәм алеутлардан башка) гомуми атамасы; хәзерге вакытта әлеге континентның аерым районнарында гына сакланып калган шул халыкларның вәкилләре. *--- төрки телнең бик ачык, ышанычлы эзләре Америка индеецларының телендә дә, шумер телендә дә, Европа топонимнарында да бик яхшы сакланган.* Мирас. *Әле унҗиденче гасырда ук Америка континентын үзләштерүче испаннар тарафыннан нигез салынган Таос шәһәрчеге --- гүзәллеге белән дә, испан, инглиз һәм җирле индеецларның бергә укмашкан мәдәнияте белән дә рәссамнарның игътибарын үзенә җәлеп итә.* Сөембикә

**И́НДЕКС** *и. лат.* 1) Нинди дә булса исемлек, реестр, берәр нәрсә турында белешмә, белешмә кенәгәсе. *Китаплар индексы*

2) Нинди дә булса зурлыкның, белешмәнең хәрефле, цифрлы шартлы билгеләре системасы. *Шунысын да искәртәбез: Татарстаннан читтә яшәүчеләр «Юлдаш»ка 2 төрле индекс буенча языла алалар.* Юлдаш. *--- су составын $H_2O$ химик формуласы белән күрсәтергә мөмкин. Водород элементы билгесеннән уңда аста торучы 2 цифры «индекс» дип атала.* Химия. *Почта индексы*

3) *икът., фин.* Нинди дә булса икъдисади күренешнең (җитештерү, бәяләр, тышкы сәүдә һ.б.ның) эзлекле үзгәрүен (гадәттә процентларда) чагылдыра торган сан. *Әлеге затлар пенсиясенә өстәмә дәүләт хезмәткәрләренең вазифаи окладын арттыру индексын исәпкә алып билгеләнә.* Мәдәни җомга. *Бәяләр индексы*

4) *мат.* Бер үк символлар белән күрсәтелгән аңлатмаларны аеру өчен кулланыла торган санлы, хәрефле яисә башка төрле тамга (мәс., $x_2$, $x_3$, $y_0$, $y_1$, $T^0$, $T^2$ һ.б.ш.)

5) *махс.* Китапханә классификациясендә китапның кайсы бүлеккә караганлыгын һәм алфавит тәртибе буенча тору, саклану урынын билгели торган цифрлар яки хәрефләрдән гыйбарәт күрсәткеч, шартлы билге

**ИНДЕКСА́ЦИЯ** *и. лат. икът.* Инфляция чорында акча һәм керемнәрнең реаль зурлыгын эзлекле арттырып бару хисабына саклап калу чарасы. *Сентябрь аеннан, бюджет хезмәткәрләренең хезмәт хаклары белән бергә, федераль казнадан ярдәм алучы ташламага ия кешеләрнең акчаларына индексация булды.* Юлдаш

**ИНДЕКСА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. икът.* Контракт, кредит суммаларын, хезмәт хакын, пенсияләрне кулланыштагы бәяләрнең индексы үзгәрүенә карап арттыру яки киметү. *Русиядә телеграф элемтәсе хезмәтенә --- бәяләр артты. Монополиягә каршы сәясәт министрлыгы телефон элемтәсе хезмәтенә тарифларны кабаттан индексацияләде.* Дулкын. *Әлеге түләүләр инфляцияне исәпкә алып индексацияләнәчәк.* Юлдаш. *2007 елның марты өчен түләнгән хезмәт пенсияләренең һәр өлеше күләмен тапкырлау юлы белән индексацияләнәчәк.* Шәһри Казан

**Индексацияләп бару** Һәр очракны исәпкә алып, даими индексацияләү

**Индексацияләп тору** Әледән-әле, еш индексацияләү

**Индексацияли башлау** Индексацияләү эшенә керешү

**ИНДЕТЕРМИНИЗМ** *и. лат. филос.* Табигатьтәге һәм җәмгыятьтәге күренешләр арасында сәбәп бәйләнешләре һәм гомуми закончалык барлыгын инкяр итә, дөньяда очраклылык, башбаштаклык хөкем сөрә, дип саный торган фәлсәфи концепция

**ИНДИВИД** *и. лат. кит. к.* **индивидиум**. *Акыл шәхеснең үз-үзен тикшерә, үзен индивид буларак анализлый.* Н.Юзиев. *Җайдак бөҗәкләрнең кайбер төрләрендә һәр күкәй 1000–1500 индивид бирергә мөмкин!* Кызыклы физиология. *Үзенең социаль һәм сәяси гамәлләре логикасын формалаштыруда индивид психикасының социал-психологик компонентлары ролен өйрәнү даими игътибар үзәгендә тора.* Фәнни Татарстан

**ИНДИВИДУАЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* Кайсы да булса шәхесне яки нинди дә булса әйберне (күренешне) индивидуаль, үзенә генә хас үзенчәлекләре, билгеләре буенча аерып сурәтләү, аерып алу. *Образларда һәм ситуацияләрдә дә бер-берсенә охшашлык, индивидуализациянең җитәрлек булмавы күзгә ташлана.* Т.Гыйззәт

**ИНДИВИДУАЛИЗМ** *и. гр.* 1) *филос.* Иҗтимагый күренешләрне халыкның, массаның, сыйныфларның эшчәнлеге нәтиҗәсе түгел, бары аерым

шәхесләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсе дип аңлата торган фәлсәфи концепция. *Әгәр [Алсу] социалистик коллектив белән конфликтка керсә, аның бу сыйфатлары ихтыярсыздан буржуаз индивидуализм белән сугарылырлар --- иде.* Х.Госман. *Шул романтиканы индивидуализм белән бергә бутап, безнең поэзиябездә егерменче елларның беренче яртысында романтик индивидуалистлык киң таралган күренеш иде, дип раслау --- поэзиябезнең данлы тарихын бозып күрсәтү була ---.* М.Максуд

2) Аерым шәхеснең мәнфәгатьләрен җәмгыять мәнфәгатьләреннән өстен куйган әхлакый принцип; шәхси мәнфәгатьләрне җәмгыять мәнфәгатьләреннән өстен күрү. *Индивидуализм белән коллективизмның кайсын сайларга тәвәккәллек итә алмыйча, ике арада чайкалучы крестьяннарга Такташ бу сүзләре белән ярдәм итәргә, дөрес юл сайлауда булышырга тели.* Х.Госман

3) Индивидуальлеген, шәхескә хас үзенчәлекләрне, билгеләрне күрсәтүгә омтылыш. *Сез класс белән урманга барасыз... Дирекция дә, коллектив та бу турыда берни белми. Коллективтан аерылу, индивидуализм түгелме бу?* Р.Хафизова. *[С.Рәмиев] А.Пушкинның «Пәйгамбәр» шигырен татарчалаштырганда, пәйгамбәр образына романтик буяулар өстәде, аның индивидуализмын көчәйтә төште.* Әдәбият. *Индивидуализм – бәлки, эстон кешесенә хас кимчелектер дә, тик бу еш кына аның көченә әверелә.* Идел

**ИНДИВИДУАЛИСТ** *и. рус. кит.* 1) Эштә, фикер йөртүдә индивидуальлек күрсәткән, карашлары, мөнәсәбәтләре белән башкалардан аерылып торган кеше. – *Безнең көннәрдә кеше, – диде ул [Горький], – ашкынып давылланган чынбарлыкның гаять дәрәҗәдә төрле-төрле тәэсирләре астына эләгә, ул үз эчендә индивидуалист белән социалист көрәшен кичерә...* Х.Госман

2) Эштә дә, фикер йөртүдә дә үз шәхесен җәмгыятьтән, коллективтан өстен куючы кеше (тискәре мөнәсәбәттә). *Әсәрдә без үзен җәмгыятькә, аның прогрессив көчләренә, халыкка каршы куйган индивидуалистның тупикка барып терәлүен, рухи яктан үлә башлагач кына үзе йөз чөереп йөргән халык алдына килеп тезләнүен күрәбез.* С.Шәмси. *Җиһанша, яшьтән үк, нәкъ Ницше философиясендәге индивидуалист кебек, эгоист, «сверхчеловек» буларак формалаша.* Казан утлары

**ИНДИВИДУАЛИ́СТИК** *с.* 1) Индивидуализм юнәлешенә хас, шуңа бәйләнешле. --- *аның [Кол Галинең] гуманизмы индивидуалистик, стихиячел, күбрәк даирә әһелләренең омтылышларын, ниятләрен чагылдыра.* Т.Галиуллин

2) Бары бер шәхескә генә хас, аны башкалардан аера торган. *Акрынлап Зәйнәп үз-үзен тотышындагы индивидуалистик моментлардан арынган коллективчыл тойгылар белән янучы кеше булып җитешә.* З.Рәмиев

**ИНДИВИДУАЛИСТЛЫК** *и.* Индивидуалистларга хас, индивидуалистларда була торган сыйфат. --- *28 юллык бу шигырьнең башыннан ахырынача «мин» күкрәп тора. Бу шигырьне «романтик индивидуалистлык»ның иң күперенке бер үрнәге дип әйтергә мөмкиндер төсле.* М.Максуд. --- *«Сихерче тамчылар» исемле хикәясендә ул [Думави] Платон, --- кебек борынгы һәм яңа заман философлары хезмәтләре һәм «пессимистлык, оптимистлык, индивидуалистлыктан гыйбарәт булып кала торган бу фәлсәфәләр»нең аның аңында фикер сугышы кузгалтуы турында әйтеп үтә.* Казан утлары

**ИНДИВИДУАЛЬ** *с.* **1.** 1) Бары тик бер шәхескә генә хас һәм аны башкалардан үзгә итә торган. *Автор аларның һәммәсенең тормыш юлын күзәтә, укучыларга индивидуаль язмышларын күрсәтеп бирә.* Ф.Галимуллин. *Бу нәселдәнлек аркасында ата-аналардан киләчәк буынга төр, сорт яки токым үзенчәлекләре генә түгел, бәлки индивидуаль үзлекләр дә күчәләр.* Дарвинизм нигезләре. *Әдип стилендә кеше холкының индивидуаль чагылышын сурәтләгән картиналар белән гомумиләштерү рәвешендәге сөземтәләр аралашып баралар.* Казан утлары

2) Бер генә кеше карамагында булган; хосусый; *киресе:* **гомуми**. *Укучыларның эшләре күпкырлы булырга тиеш һәм бакчада, ашау бүлмәсендә, ашханәдә, хәзерге машиналар белән җиһазланган төрле индивидуаль эшханәләрдә башкарылырга тиеш.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Индивидуаль хуҗалык. Индивидуаль милек*

3) Аерым кешеләр башкара торган. *Индивидуаль җитештерү*

4) Һәр кешегә аерым бәйләнешле; һәркемгә, һәр очракка аерым. *Идарә комсомолецларының тулаем алган бу йөкләмәсе белән беррәттән, --- башка бик күп цехларда эшләүче яшьләрнең индивидуаль йөкләмәләре дә бар икән.* М.Хәсәнов. *Шушында һәр шагыйрьнең индивидуаль стиле мәсьәләсе бик хаклы рәвештә үткен төс алды. Индивидуаль стильләр елга-елга аерылып чыга башладылар.* Х.Госман. *Билгеле, һәркемнең дә кулыннан килердәй гади ысуллар гына ярдәм итмәгән, индивидуаль киңәш сорап врачка мөрәҗәгать итәргә кирәк булган очраклар да килеп чыккалый.* Тигез гомер итегез!

5) Аерым, ялгыз. *«Эх, индивидуаль проектлар төзергә мөмкинлек булса, мин биредә мондыйрак биналар, әмене монда тегендирәкләрне салыр идем!» – дип, кәгазьгә сызгалый торгач, --- микрорайонның эскизы ясалды.* М.Маликова. --- *мәктәпләрнең иң төп, иң әһәмиятле принципларының берсе һәр кешегә индивидуаль йогынты ясау методы икән.* М.Хәсәнов

6) Шәхси гигиенага караган, шәхси кулланыштагы. *Ул --- әүвәл сумкадан шәхси кулланыш өчен берничә индивидуаль пакет, аннары хатынкызларның елкылдап торган чем кара күн букчасын чыгарды.* Мәдәни җомга

**2.** *рәв. мәгъ.* Һәр кешегә, һәр нәрсәгә, һәр очракка аерым. *Чөнки җинаятьчелек белән көрәштә каты булу да, кешелекле булу да, һәркемне индивидуаль аңлый белү дә кирәк.* М.Насыйбуллин. *Классиклар, күбесенчә, индивидуаль алынган бер кеше характерында бу ике каршылыкның ничек хәрәкәт итүен һәм кешенең үзен, аның белән бәйләнгән башка кешеләрне нинди язмышка дучар итүен ачып салалар.* Х.Госман. *Кыйммәтле әйберләрне*

*һәм башка төрле зиннәтле әйберләрне исәпкә алмаганда, индивидуаль файдаланудагы әйберләр (кием-салым, аяк киеме һ.б.ш.) --- ир яки хатынның шәхси милке дип танылa.* Тигез гомер итегез!

**ИНДИВИДУАЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф. кит.* **1.** 1) Шәхесне яки аерым бер предметны үзенә генә хас, үзенә генә характерлы индивидуаль үзенчәлекләре, билгеләре буенча аерып бирү; һәр шәхесне, һәр очракны индивидуаль яктан ачыклау. *Дөрес, аерым персонажны индивидуальләштергәндә, бигрәк тә аның сөйләмендә ул [Такташ] халык теленең бик борынгыдан килә торган элементларын саклый.* Х.Госман. *Минем әдәби образларны характер итеп индивидуальләштерү, сюжет төзү үзенчәлекләре турындагы фикерләремне ул рәхмәтләр әйтеп кабул итте.* Ә.Нигъмәтуллин

2) Нәрсәне дә булса гамәлгә куюда, куллануда һәр очракка, һәр шәхескә индивидуаль якын килү. *Белем бирү системасында, бигрәк тә башлангыч сыйныфларда, дәресләрдә индивидуальләштерү аеруча әһәмияткә ия*

**2.** *и. мәгъ.* Шәхес яки аерым бер предметның үзенә генә хас, индивидуаль үзенчәлекләре буенча аерымлануы. *Авторны мондый артык гомуми тиңләү дә канәгатьләндереп җиткерми. Индивидуальләштерү юк.* Т.Галиуллин. *Исәнбәт: «Таш урамнардан үтәләр дә үтәләр», – ди, шәһәр урамы картинасын индивидуальләштерүдә уңышлы эпитет таба.* Х.Госман

**Индивидуальләштереп бару** Һәрберсен аерым-аерым индивидуальләштерү. *Героеның шушы сыйфатын Такташ үз шигыренең интонациясе, төзелеше, паузалары белән дә сиземләндереп, индивидуальләштереп бара.* Х.Госман

**Индивидуальләштереп бетерү** Тулысы белән индивидуальләштерү; барысын да индивидуальләштерү

**Индивидуальләштереп бирү** Махсус рәвештә индивидуальләштерү

**ИНДИВИДУАЛЬЛӘШҮ** *ф.* Индивидуальгә әйләнү

**Индивидуальләшеп китү** Кинәт кенә нииндидер сәбәптән, вакыттан соң индивидуальләшү

**ИНДИВИДУАЛЬЛЕК** *и. кит.* Кайсы да булса бер шәхесне яки нинди дә булса күренешне, предметны башкалардан аерып торган үзенчәлекләр, сыйфатлар. *Шуңа да бу шагыйрьләрнең индивидуальлекләре ничек үсүен аларның лирик геройлары үсешендә дә күзәтеп карарга тиеш булабыз.* Х.Госман. *Кешенең табигате үзгәргәч, ул үзенең индивидуальлеген югалтса, --- кешегә яшәүдән кызык калмый.* З.Садыйков. --- *ләкин безнең хисләребез беркадәр төссезләнәләр, үзләренең индивидуальлекләрен югалталар.* Тигез гомер итегез!

**ИНДИВИДУАЛЬЧЕ** *и. к.* **индивидуалист**. *Буржуа әдәбияты әнә шул милек иясе – эксплуататор катлауларның геройларын, индивидуальче геройларны җырлады.* К.Нәҗми

**ИНДИВИ́ДУУМ** *и. лат. кит.* 1) *биол.* Мөстәкыйль яши торган һәрбер тере организм

2) Аерым кеше, шәхес, зат. *Хатынкыз, --- индивидуумда яшәүдән бигрәк, кавем эчендә яши, һәм аның өчен кавем тормышы индивидуаль тормыштан якынрак.* З.Хөснияр. *Сезнең күзәткәнегез бардыр: образлы фикер йөртүче индивидуумнарның күз карашы моңсу, тәэсирле була.* А.Вергазов. *Укучы булarak, аны [Хафизовны] яратып булмый (үзе ярата белмәгәнгәдер...), сокланырга сәбәп юк, ошарга тырышырлык сыйфатлар табылмый: кешегә охшаган кеше генә. Уртача статистик индивидуум.* Казан утлары

3) Үзенә генә хас үзенчәлекле сыйфатларга, холыкка, аерым талантка ия булган кеше; шәхес. *Индивидуумнарның образлы яисә логик фикерләү өстенлек итү белән аерылып торганын сез дә беләсез.* А.Вергазов. *Әйтерсең бездә һәрбер иҗади шәхес үзенә бер индивидуум түгел, әйтерсең шагыйрьләр төркемләп, «детсадлап» үсә!* Сөембикә

**ИНДИ́ГО** *и. лат.* **1.** 1) *бот.* Кузаклылар семьялыгыннан чәчәкләре ал, җете кызыл, ак төсле куакчыл үсемлек (исеме Һиндстан белән бәйле, беренче башлап шунда кулланылган). *[Тирәюньдә] --- коелып калган ашамлык бөртекләре, кокос чикләвеге, хна, индиго, өем-өем сүс, мамык, такталар.* М.Юныс

2) Шул үсемлек сүленнән ясалган куе зәңгәр төстәге буяу матдәсе. *1842 елга кадәр туку промышленностенда кулланыла торган буяуны чит илдән кертелә торган үсемлек – индигодан гына алганнар.* Россия тарихы. *Моңа кадәр бу буяу матдәсен индиго дигән үсемлектән ала торган булганнар.* Татарстан тарихы

3) Куе зәңгәр төстәге синтетик буяу

**2.** *с. мәгъ.* 1) Куе зәңгәр. *Индиго төс*

2) *күч.* Искиткеч сәләтле, уйлау, фикерләү сәләте белән гадәти кешеләрдән бик нык аерылып торган, гадәттән тыш сизгерлеккә, телепатиягә ия булган (экстрасенслар әйтүенчә, аларның ауралары индиго төсендә, һәм алар – Җиргә киләчәк яңа раса кешеләр). *Франциядә аларга «тефлон» дигән кушамат такканнар, чөнки индиго балаларга без күнеккән стереотиплар бөтенләй «ябышмый», үзләренең эшгамәлләрендә йөрәк белән түгел, баш белән уйлап фикер йөртергә күнеккәнгә, Англиядә аларны «киборглар» дип атыйлар.* Мәдәни җомга

**И́НДИЙ** *и. лат. хим.* Сирәк табыла торган, көмешсыман төстәге, җиңел эрүчән металл; периодик системаның III төркеме химик элементы. *Кремний һәм германий дүрт валентлы элементлар булганлыктан, аларга өч валентлы бирәр элемент (алюминий, индий һ.б.) кушалар.* Р.Шаһморатова. *Индий атомына күчкән электрон германий атомының тышкы электрон сүрүендә буш урын калдырып китә.* Химия

**ИНДИКАТИВ** *с.* Индекслауга нигезләнгән; индексланган. *Соңгы вакытта республика хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән идарә итүнең индикатив системасын кертү, --- һәм башка республика программалары әлеге тенденцияләрнең тотрыклы камилләшүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән.* Мирас

**ИНДИКА́ТОР** *и. лат.* 1) *тех.* Нинди дә булса күренешне (басым, авырлык һ.б.ш. физик зурлыкларны) үлчи, күрсәтә, терки торган прибор, җайланма. *[Зәй] --- кинәт насос*

*басымының кимүен сизеп алды. Үзе, ышанмыйча, индекатор шкаласына күз төшерде – әйе, дөрес шул.* Х.Камалов. --- *радиопост төрле төстәге индикаторлар белән җемелдәгән, эфирдагы сызгыру, морзянка тавышлары белән тулган иде.* М.Мәһдиев. --- *конструкторлар --- исләрне нәкъ чебен кебек сизеп ала торган индикатор ясамакчы булалар.* Кызыклар дөньясында

2) *хим.* Нинди дә булса матдә белән тәэсир итешкәндә, төсен үзгәртә һәм шуның белән аның микъдарын яки сыйфатын билгеләргә ярдәм итә торган матдә (мәс., лакмус, метилоранж, фенолфтамин һ.б.). *Алар карыннан алынган пробаларны --- индикатор салып селте белән титрладылар.* А.Расих

3) *махс.* Китапханәдә, уку залында китапның кемгә бирелүен күрсәтә торган картотека

4) *күч.* Гомумән күрсәткеч, ишарәләгән билге, галәмәт. *Болар – үзләренә күрә И.Ефремовның «Андромеда томанлыгы» повестындагы идеяне гәүдәләндерүче «төсле музыка индикаторлары» дигән нәрсәләр.* Г.Галиев. *Бер үк вакытта тикшеренүдә бу чагыштыруның кирәкле барлык индикаторларын билгеләүнең ахыргача хәл ителмәгәнлеге дә күрсәтеп узыла.* Фәнни Татарстан. *Экологлар фикеренчә, тәвә абага – тирән булмаган җир асты грунт суларының индикаторы.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИНДИФФЕРЕНТ** *с. ингл. кит.* Ваемсыз, гамьсез, кызыксынмый торган; салкын

**ИНДИФФЕРЕНТЛЫК** *и. кит.* Ваемсызлык, гамьсезлек, кызыксынмаучылык; салкынлык

**ИНДОНЕ́ЗИЯЛЕ** *и.* Индонезия кешесе, Индонезиядә яшәүче җирле халыкның, кабиләләрнең гомуми атамасы; аның бер вәкиле

**ИНДУИЗМ** *и. санскр.* Илаһ, игелекле эшләрен һәм кимчелекләрен исәпкә алып, җанны төрле гәүдәләнештә фани дөньяга кире кайтара, дигән ышануга нигезләнгән дөнья диннәренең берсе; Һиндстанда иң киң таралган дин. *Индуизмның төп үзенчәлеге – күп нәрсәдә бердәнбер нәрсәне күрергә, һаман үзгәреп, агып торган фани дөньядан нииндидер үзгәрми торган мәңгелек нәрсә табарга омтылудан гыйбарәт.* Д.Вәлиев. *Индуизм тарафдарлары өчен хас булган һәм Һиндстан халкы тугрылык саклаган язмышка буйсынучанлык һәм җәбер-золым кылмау принципларын сикхлар өлешчә генә таныганнар.* Бөтендөнья тарихы. --- *«бинду» дип аталучы әлеге [ике каш арасындагы] нокта индуизм динен тотуны билдерә.* Дин вә йола

**ИНДУКТИВ** *с.* 1) *лог.* Индукциягә (*1 мәгъ.*) нигезләнгән. --- *әлеге инглиз философы кеше акылын үткәннең ялгышларыннан һәм хорафатларыннан коткарган, беренче тапкыр, башка фәннәр кебек үк, философиянең дә нигезен тәҗрибә тәшкил итә, дип күрсәткән һәм фикерләүнең индуктив методын тәкъдим иткән фикер иясе дип атала.* Я.Абдуллин. *Бэконның индуктив методында Коменский «табигать серләренә үтеп керү» юлын күрә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Индукция (*2 мәгъ.*) барлыкка китергән. *Индуктив каршылык*

**ИНДУКТИВЛЫК** *и.* 1) *лог.* Фикерләүдә индукция (*1 мәгъ.*) методын өстен куюю күренеше. *Исбатлауның индуктивлыгы*

2) *физ.* Индукция (*2 мәгъ.*) күренеше. *Электр чылбырының индуктивлыгы*

**ИНДУ́КТОР** *и. лат. тех.* 1) Алмаш ток алу өчен кул белән әйләндерә торган электр машинасы. *Индуктор аппаратына куелган кечкенә звонок шалтырый.* Х.Садри. *Аннан соң үткәргечләр яңадан индуктор ярдәмендә корылалар, чаткы пәйда була, һәм процесс кабатлана.* Физика

2) *физ.* Даими ток генераторында (динамомашинада) магнит кыры, индукцион токлар тудыра торган магнит

**ИНДУКЦИОН** *с. физ.* Индукция (*2 мәгъ.*) нәтиҗәсендә барлыкка килгән яки индукциягә (*2 мәгъ.*) нигезләнгән. *[Прибор] Эчендә көпчәкләр, индукцион кәтүкләр [күренә].* А.Тимергалин

**ИНДУ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) *лог.* Аерым, нигезсез, сәбәпсез барлыкка килгән, очраклы дип саналган фактларга һәм положениеләргә таянып гомуми нәтиҗәләр чыгару; хосусыйдан гомумигә илтә торган танып белү методы; *каршы:* **дедукция**

2) *физ.* Нинди дә булса үткәргечне магнит кырында хәрәкәт иттергәндә яки магнит кырын үзгәрткәндә, шул үткәргечтә барлыкка килгән электр тогы. *Аларның идеяләрен үстерә барып, инглиз физигы М.Фарадей (1791–1867) электромагнит индукция күренешен (магнит сызыклары белән ябык үткәргеч кисешкәндә электр тогы барлыкка килүне) ача.* Бөтендөнья тарихы

**ИНДУЛЬГЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Католикларда: гөнаһларны ярлыкау һәм шул турыда Рим папасы исеменнән чиркәү бирә торган түләүле грамота

2) *күч. кит.* Нинди дә булса эшгамәлгә, эшчәнлеккә бирелгән рөхсәт

**ИНДУС** *и. ингл.* 1) Һиндстанда яшәүче төп халыкның бер вәкиле; һинд. *Хәбир, төшендә энҗе күргән, кулына тотарга өлгергәнче уянып киткән индус кебек басып калды.* Ш.Хөсәенов. *Урта Азиянең сәнгатенә гарәпләргә кадәр фарсылар һәм индуслар тәэсир итеп торганнар.* Мирас. *Алар арасында төрки, рус, сүрияле, индус, кытай, монгол, поляк, болгар, румын һәм австралияле кәнизәкләр дә булган.* Юлдаш

2) Индуизм тарафдары. *Әлеге винтовкаларны кору өчен, май сеңдерелгән патрон төргәкләрен теш белән ертырга туры килгән. Бу исә индуизм һәм мөселман динендәге индусларның дини хисләрен мыскыллау буларак кабул ителгән, чөнки алар өчен сарык һәм дуңгыз мае тыелган продукт булып исәпләнә.* Бөтендөнья тарихы. --- *индуслар, өйләренә кергәндә дә, аяк киемнәрен салалар.* Дин вә йола

**ИНДУСТРИАЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* Индустрияләштерү процессы. *1920 елларның ахырында коллективизация һәм индустриализация башлана.* Тарих. *Илне аякка бастыру, индустриализация, коллективлаштыру чорларында язучы җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара.* Фән һәм тел

**ИНДУСТРИАЛЬ** *с.* Сәнәгате (промышленносте) булган; индустриягә бәйләнешле. *Мари Республика-*

*сы – хәзер индустриаль республика, 1909 елда Казанда халыкара күргәзмәдә ул яклардан киез итек, чабата, --- һәм башка экспонатлар күрсәтелгән.* И.Низамов. *Бигрәк тә индустриаль хезмәт белән бәйләнгән әйберләрне сынландыру аңарда [Туфанда] күп очрый.* Х.Госман. *Ә август урталарында, [Варис] үзенең тугыз класс бетергән таныклыгын алып барып, индустриаль техникумның студенты булды.* М.Хәсәнов

**ИНДУСТРИ́Я** *и. лат.* 1) Эре машина техникасына нигезләнгән фабрика-завод сәнәгате. *Нефть индустриясе үсеше республика көньяк-көнчыгышының йөзен һәм бу типик аграр төбәктә яшәүчеләрнең язмышын тамырдан үзгәртә.* Татарстан тарихы. *Әйе, Алсуның хәтерендә: аларга шәһәр образын язарга куштылар. Яңа индустрия эрасын күрсәтергә, шулар фонында иске каралты-кураларны да сурәтләргә кирәк иде.* Сөембикә

2) *күч.* Нинди дә булса эшчәнлекнең нык алга киткән тармагы. --- *сексуаль белем бирә торган китап индустриясе үскән илләрдәге кебек кризисны никах институты башка беркайда да кичерми.* Тигез гомер итегез! *Туризм индустриясе*

**ИНДУСТРИ́ЯЛӘШТЕРҮ** *ф.* **1.** Халык хуҗалыгының барлык өлкәләрен индустриаль машина техникасына күчерү. *Бу – илне индустрияләштерү, яңа завод-фабрикалар --- һ.б. салу, коллективлашу һәм кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү чоры иде.* С.Шакир. *1929 елдан илне чын-чынлап индустрияләштерү башлана.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Бу чорда илне индустрияләштерү һәм, партиянең XV съезды карарлары нигезендә, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү өчен киеренке көрәш бара.* Казан утлары

**2**. *и. мәгъ.* Халык хуҗалыгын индустриаль машина техникасына күчерү процессы. *Инде илне индустрияләштерү турында сөйли башласа, Мәдинә апа үзебезнең колхоз хисапчысы Фатыйх абыйны бу бөек эшләрнең җанлы бер вәкиле итеп китерергә ярата.* Р.Фәизов. *Язучылар республиканы индустриальләштерү процессының яңалык һәм искелек көрәшен көчәйтеп җибәрүенә игътибар иттеләр.* Татар әдәбияты тарихы. --- *зур төзелешләр тирәсендәге авылларны эреләндерү, андагы көнкүрешне шәһәрнекенә якынайту һәм хуҗалык итү ысулларын индустрияләштерү өчен [автоматлаштыру] этәргеч ролен үти ала.* Казан утлары

**Индустрияләштерә башлау** Индустрияләштерү эшенә тотыну

**Индустрияләштереп бетерү** Тулысынча, тулаем индустрияләштерү

**ИНДУСТРИ́ЯЛӘШҮ** *ф.* **1.** Халык хуҗалыгының барлык өлкәләре индустриаль машина техникасы нигезенә күчү

**2.** *и. мәгъ.* Халык хуҗалыгының индустриаль машина техникасы нигезенә күчү процессы. *Бераүләр социалистик индустрияләшү чоры поэзиясенең бурычын гадиләштерү юлына тайпылалар...* Х.Госман

**Индустрияләшә бару** Эзлекле рәвештә индустриальләшүне дәвам итү

**Индустрияләшеп бетү** Тулысынча индустрияләшү

**ИНДУСТРИ́ЯЛЕ** *с. к.* **индустриаль**. *Илебездә социализм төзелешенең зур бер шарты авыл белән шәһәр элемтәсен ныгыту, индустрияле каланы колхозлы авылга бәйләү иде.* Идел. *Республиканы бүген чын мәгънәсендә югары индустрияле һәм югары инновацияле үзәк дип атарга була.* Шәһри Казан

**ИНЕРТ** *с. нем.* 1) *махс.* Башка матдәләр белән кушылмый торган, тотрыклы электрон төзелешле; реакциягә начар керүчән. *Гелий, неон, оргон, криптон, кинон, радон – атмосферада аз күләмдә очрый торган инерт газлар. Болардан тыш һавада «инерт газлар» (0,94 %) дип аталган газлар да бар.* Химия. *Ионлы кристаллар --- электроннарын я биреп, я кабул итеп, инерт газларның конфигурацияләрен алырга омтылалар*. Физика

2) *тех.* Измә, бетон һ.б.ш.ларның күләмен арттыру, үзкыйммәтен киметү максатында составына кушып җибәрелә торган (ком, вак таш, гравий һ.б. төзелеш материаллары турында)

3) *күч.* Пассив, дәртсез, сүлпән, инициативасыз. *Кайбер талантлы кешеләр иҗатларында фидакяр хезмәт күрсәтсәләр дә, шәхси яшәешләрендә беркадәр инертрак булучан ---.* Р.Фәйзуллин

**ИНЕРТЛЫК** *и.* Сүлпәнлек, пассивлык, эшлексез булу, инициативасызлык. *Гамьсезлек, битарафлык хөкем сөргән җирдә чикләнгәнлек, инертлык, үшәнлек чәчәк атучан була*. М.Сәхапов. *Авыл кешесенә еш кына инертлык хас.* Казан утлары

**ИНЕРЦИОН** *с. физ.* Инерциягә (*1 мәгъ.*) нигезләнгән, инерциядән (*1 мәгъ.*) файдалана торган. *Инерцион система*

2) *күч.* Инерция көче белән генә дәвам иткән, инициативасыз. *Якын киләчәк бүгенге геосәяси тенденцияләрнең инерцион дәвамы итеп карала ала, ә, гамәли яктан, бүген күзалларлык ерак киләчәк инсаниятнең цивилизацион күчеш чорына туры килер дип фаразларга була.* Р.Сафин

**ИНЕ́РЦИЯ** *и. лат.* **1.** ) *физ.* Тышкы тәэсир булмаганда җисемнең хәрәкәт итү юнәлешен яки тикторыш хәлен саклау үзлеге. *Караянов очкычны сулга таба аудара башлады. Инерция мине уң як бортка китереп сылады.* М.Юныс. *Еланнар бик оста һәм шактый еракка --- төкерә алалар. Мондый ату ераклыгына алар агу капчыгындагы басым көче белән хәрәкәт инерциясен берләштерү нәтиҗәсендә ирешәләр...* Кызыклы физиология. *«Кояш күктә шулай мәңге йөзәр» шигырендә (1923) ул [Һ.Такташ] җир, кояш, планеталарның хәрәкәте, аларның, кайчан да булса бер вакыт, инерция көче бетү аркасында, башка хәлгә күчәчәкләрен сурәтли.* Әдәбият

2) *күч.* Дәртсезлек, сүлпәнлек, инициативасызлык. *Бу шундый халәт, үзенчә бер «үле нокта» иде: үз көчең белән генә алга таба кузгалып китәрлек түгел, ә инерция көче ахыргача сарыф ителгән.* З.Фәтхетдинов

3) *күч.* Электән килгән, элек булган тәртипләрнең, хәлләрнең, күнегелгән гадәтләрнең үзгәрешсез дәвам итү хәле. *Ә бит, югыйсә, офицерның эшенә бәя*

*подразделениенең сугышчан әзерлегеннән чыгып бирелергә тиеш. Ни кызганыч, тиз генә үзгәреп булмый шул, инерция бик көчле, әле һаман да электрелмәгән каптырмаларга һәм каршы дәшүләргә бәйләнәбез, төймәләр һәм каешлар белән сугышып ятабыз.* Идел

**2.** *рәв. мәгъ.* Күнегелгән, иялэнгән гадәт буенча, белештермичә, механик рәвештә. *Инерция белән һаман кукурузга ябышып ятуны сизә алган икән инде, ул, Әдилә, начар җитәкче түгел, [диде Гариф].* М.Хәбибуллин. *Гаграда алган шул инерция белән мин, күп тә үтмичә, --- повесть та язып ташладым.* М.Мәһдиев. *Менә шуннан соң инде кайбер тәнкыйтьчеләребезнең татар әдәбиятын һаман да инерция белән «авыл әдәбияты» дип исәпләүләре үзеннәнүзе юкка чыга.* Х.Сарьян

**ИНЕЧ** *и.* 1) Күлмәкнең (киемнең) эчке ягыннан арка һәм күкрәк турысына тегелгән тукыма // Киемнең эчке ягына тегелгән тукыма. *Марат Саниягә дигән «мыеклы бодайны» кепка инечен кыстырды.* Г.Гобәй. *Кайткач кара: күлмәгеңнең инечендә яны буйлап кечкенә тар бер чүпрәк тегелгән булыр.* Г.Ибраһимов

2) Портфель яки башка нәрсә эченә тегелгән тукыма. *Илдар антны --- портфель инеченә тегеп куйды.* Г.Гобәй

**ИНЕЧЛӘ́Ү** *ф.* Инечләп тегү, инеч салу. *Күлмәкне инечләү*

**Инечләп бетерү** Тулысынча, ахырга кадәр инечләү, инечләү эшен тәмамлау

**Инечләп кую** Инечләнгән хәлгә китереп калдыру

**Инечләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, барысын да инечләү

**Инечли башлау** Инечләргә тотыну

**ИНЕШ** *и.* 1) Кечкенә, тар һәм сай елгачык. *Сөйләделәр: Кәримов, үз авылларына кайткач, я сазлыкка, я күлгә кереп, я чишмә инешендә тәгәрәп елый икән.* М.Мәһдиев. *Саба инеше өстеннән салынган асылмалы басма аша киттек мәдәният йортына.* Т.Нәҗмиев. *Кияүгә чыкканның икенче көнендә инеш буена суга төштем.* Сөембикә

2) *диал.* Елга. *Ә аста Тирән елга дип аталган киң инеш сузылып ята иде.* Г.Галиев

**ИНЕШ-ЧИШМӘ** *җый. и.* Инешләр һәм чишмәләр. *Рәттән тальян гармун чаклы гына туган авылы Таузар да, илгә нидер вәгъдә итеп, инеш-чишмәләргә сыенып утыра...* Р.Хисмәтуллин. *Кешеләр, иртүк торып, сукмак ердылар, абзар-сарай ишекләрен күмеп киткән карны көрәделәр, инеш-чишмәләрдәге бәкеләрне ачтылар.* К.Тәхау

**ИНЖЕ́КТОР** *и. лат. тех.* Газ һәм парларны кысу-тыгызлау, шулай ук газны яки сыеклыкны, тыгызлап, төрле аппаратларга һәм резервуарларга тутыру өчен көйләнгән агынтылы насос

**ИНЖЕНЕР** *и. фр.* Фән-техниканың берәр тармагы буенча югары техник белемле белгеч. *Бөтен Көнбатыш инженерлары кулы белән салынган тимер, бетон ныгытмалары көлгә әйләнеп күккә очалар.* Т.Гыйззәт. *Партияле яшь инженер Габбас югары сыйфатлы мех эшләүнең химик ысулларын табуы өчен бүләкләнергә тиеш.* Г.Нигъмәти. *Анда [газетада], авыл хуҗалыгы институтында машина-трактор станцияләре өчен баш инженерлар әзерли торган механика факультеты ачылды, диелгән.* Мирас

**ИНЖЕНЕ́РИЯ** *и. фр.* 1) Иҗади техник эшчәнлек, инженерлык эше

2) Кайбер сүзтезмәләрдә: табигатьтә моңарчы булмаган, конструкцияләнгән яңа органик берәмлекләр. *Сөтендә кыйммәтле үсеш гормоны булган беренче сыер моннан ике ел элек бу лабораториядә ген инженериясе ярдәмендә чыгарылган булган.* Сәламәт булыйк! *Бәлки, киләчәктә геннар инженериясе кайбер генетик хаталарны төзәтүне тәэмин итә алыр, ләкин --- хәзер бер нәселдән килгән авырулардан да дәвалауга кыенрак бирелә торганнары юк, дип әйтергә тиешбез.* Тигез гомер итегез! --- *биология өлкәсендә --- ген, аксым һәм күзәнәк инженериясен үстерү --- бурычы тора.* Фәнни Татарстан

3) *җый. и. сөйл.* Инженерлар

**ИНЖЕНЕР-КОНСТРУ́КТОР** *и. рус* Нинди дә булса конструкцияләр төзүче югары белемле инженер. *Аны [авиация институтын] кызыл диплом белән тәмамлагач, заводта инженер-конструктор булып эшли башладым.* З.Фәйзи. *[Хәмзә] 1946–1976 елларда Казанда Горбунов исемендәге авиация заводында инженер-конструктор булып эшләп, лаеклы ялга чыкты.* Сөембикә

**ИНЖЕНЕРЛА́РЧА** *рәв.* Инженерларга хас булганча; инженерлар кебек. *Иптәшләр, монда ИТРлар тарафыннан инженерларча фикерләү әз булды.* Р.Кәрами

**ИНЖЕНЕРЛЫК** *и.* 1) Инженер хезмәте, инженер һөнәре. *Тимерханнар батальоны командиры капитан Косюченко армия штабына вакытлыча инженерлык хезмәте начальнигы итеп билгеләнде.* Г.Ахунов. *Мәктәпне тәмамлау белән үк, Казанга – ул заманнарда бик абруйлы саналган инженерлыкка укырга китеп барды.* С.Шәмси. *Нинди генә җаваплы участокны алма, җитәкчелек эшеме ул, инженерлык яисә культура-масса эшеме, һәркайда хатын-кызны очратырга була.* И.Низамов

2) Инженерлар әзерли торган уку йорты. *Белеме зурдан: – Мәскәүдәге Дзержинский исемендәге инженерлык академиясен тәмамлаган.* З.Зәйнуллин

**ИНЖЕНЕР-МЕТАЛЛУРГ** *и. рус* Металлург белгечлегенә ия булган югары белемле инженер. *Әлеге киң полотнолы әсәрдә [И.Баһманов] инженер-металлург Ипполит образын тудырды.* Казан утлары

**ИНЖЕНЕР-МЕХА́НИК** *и. рус* Машиналарның дөрес һәм системалы эшләвен, аларны эксплуатацияләүне тәэмин итәрлек механик белгечлеге булган югары белемле инженер. *Өлкән инженер-механик булсам да, --- чүкеч тотып тимер кыйныйм, ---. Менә шунда имгәнеп беткән куллар бу.* З.Фәйзи. *Ә Хәсән шушы елны Казан авиация институтын тәмамлый. Ул – инженер-механик.* Сөембикә. *Тиздән авылга инженер-механиклар, агроном, ветфельдшерлар, бухгалтерлар һәм... рәссам кайтачак.* Казан утлары

**ИНЖЕНЕР-ТЕ́ХНИК** *и. рус* Техника буенча югары белемле инженер. *Разведканың инженер-техник эшчеләре таулардан кайтарылган җиһазларның иң кыйммәтлеләрен түбәнгә*

*озаталар.* Ә.Айдар. *Инженер-техниклар исеменнән котлаучы Булатов сүзен кыска тотты ---.* Мирас

**ИНЖЕНЕР-ТӨЗҮЧЕ** *и.* Төрле корылмалар, объектлар төзү буенча югары белемле инженер. *Төзелештә – инженер-төзүче, мастерскойда инженер-техник баш, яшелчәчелек – үзенә, һәм аларның барысы да председательгә буйсыналар.* Х.Сарьян

**ИНЖЕНЕР-ЭНЕРГЕ́ТИК** *и. рус* Энергия ресурслары, аларны эшкәртү, үзгәртү, тапшыру, файдалану белән шөгыльләнүче югары белемле белгеч, инженер. *Ул чакта инженер-энергетик һөнәре әле күпләргә «буй җитәрлек» түгел иде.* Мирас

**ИНЖИНИ́РИНГ** *и. махс. ингл.* Коммерция нигезендә сәнәгать, авыл хуҗалыгы һәм башка тармак объектларын икътисади-техник яктан нигезләү һәм проектлау, җитештерү процессын һәм җитештерелгән продукцияне сатубүлүне җайга салу буенча инженерлык хезмәте

**ИНҖИЛ** *и. гар.* Иисус Христосның (Гайсә Мәсихнең) тормышы һәм тәгълиматы турындагы хикәяләрдән торган һәм христиан дине өйрәтмәләренең нигезен тәшкил иткән дини китап атамасы; Библиянең бер өлеше; Евангелие. *Ак һәм алсу чәчкәгә төренгән биек, куе олеандр куаклары, --- Яңа Афонны оҗмахка тиң итә. Инҗилдә тасвирланган оҗмах шушы якка охшаган, диләр.* М.Маликова. *Г.Ибраһимов, М.Гафури, К.Тинчурин тасвирлаган татар мәдрәсәләре Н.Г.Помяловский сурәтләгән бурсалардан (рус дини мәктәпләреннән) Инҗил урынына Коръән укытылу белән генә аерылса аерылгандыр.* И.Абдуллин. *Һ.Такташның гыйсъянчы герое яһүдләрнең «Тәүрат»ын да, русларның «Инҗил»ен дә «себереп түгә», бер уңайдан «Коръән»не утка якканлыгын әйтә.* Әдәбият

**ИНҖИЛЧЕ** *и.* 1) Христиан динендә «изге» дип кабул ителгән дүрт Инҗилнең авторларыннан һәрберсе

2) Инҗил тәгълиматын таратучы

**ИНҖИР** *и. фар.* Тут агачлары семьялыгының фикус ыругыннан, кышын коела торган каты, кытыршы эре яфраклы, татлы җимешле, кипкән тамырлары тәмләткеч итеп кулланыла торган күпьеллык тропик агач; *русчасы:* **инжир, фига, смоковница**. *Хәтта текә таш кыяларга, борынгы корылмаларның диварларына да эре, сусыл яфраклы инҗир агачлары тамыр җәйгән, үрмәле гөлләр сарылган.* М.Маликова. *[Маймыл] Бер көнне шулай инҗир куагында аның җимешләрен берәм-берәм өзеп ашап утырганда, бер җимеше кулыннан суга төшеп китте.* Җ.Зәйнуллин. *Әнә шундый җирдә ике йөзләп адымга сузылган рәтләр булып зәйтүн агачлары үсә. Инҗир, шәфталу, гранат, аскединья, йөзем, затар, шалфейга да урын табылган.* Сөембикә

2) Шул агачның татлы җимеше (гадәттә, киптереп әзерләнә); салма җимеше; *русчасы:* **смоква**. *Бу инҗир җимешенең чапылдап суга төшүе маймыл күңеленә хуш килде, һәм ул тагын да бер-бер артлы җимешләрне суга ташлый башлады.* Җ.Зәйнуллин

**ИНИЦИАЛ** *и. лат.* 1) Исем-фамилиянең яки исем һәм атасы исеменең баш хәрефләре. *Резеда Фәритовна дәшми-тынмый гына чыгып китте дә, кесәсенә «А.Р.Ф.» дип үз инициаллары чигелгән халат кертеп бирде.* М.Маликова

2) Китапның, бүлекнең яки кызыл юлның башында зурайтып һәм бизәп бирелгән хәреф. *Бер кульязма китапны озак вакыт дәвамында күп кеше эшли: берәүләр текстны каллиграфик хәрефләр белән яза; икенчеләре кызыл юл башындагы баш хәрефләрне – инициалларны – бормалы-сырмалы итеп бизи ---.* Урта гасырлар тарихы

**ИНИЦИАТИВ** *с.* Берәр эшне башлап җибәрергә этәреш бирә торган. *Миңа Князев, тантаналы тавыш белән: – Инициатив группа морякларның 1 нче Казан социалистик батальонын оештырырга тәкъдим кертте, --- – диде.* И.Низамов

**ИНИЦИАТИ́ВА** *и. лат.* 1) Берәр яңа эшне үз теләгең белән башлап җибәрү, шул эштә башкаларга этәргеч булу, башлап йөрү. *Ишмаковның инициативасы буенча республикада хезмәт ияләренең гаризаларын карау, колхозларда пенсия турындагы законны үтәү --- кебек мәсьәләләргә анализ ясалды.* М.Насыйбуллин. *Ул [флотилия] большевик-революционер Лев Ефимович Берлин инициативасы белән Губком председателе С.Я.Шейнкман булышлыгында төзелә.* И.Низамов. *Лаешлылар Казан Кремлендәге Кол Шәриф мәчетен торгызу һәм Благовещение соборын яңарту фондына --- яхшы инициатива белән чыктылар.* Мирас

2) Нинди дә булса берәр эштә җитәкче роль, вазифа. *[Җәмгыяте хәйрияне] Башлап җибәрү җәдитчеләр кулында булса да, инициатива кадимчеләргә күчкәнлеге күренеп тора.* М.Гали. *Талип агрономга өнәми генә карап алды: – Тәк, әйт әле, Мидхәт, урман полосаларын кем кушуы буенча кистердең? Әйтик, үзеңнең башың җиттеме, әллә булмаса, башка берәүнең киңәше белән эшләдеңме? – Үз инициативам.* М.Хәбибуллин

3) Мөстәкыйль, үз көче белән эшли алу сәләте, булдыклылык. *Опера язуда бик күп нәрсә композиторның инициативасына бәйләнгән.* М.Җәлил. *Бары тик ирекле, инициативага ия булган иҗади рухлы халык кына гадел дәүләтчелек төзи һәм бөтен мәсьәләне дә хәл итә ала.* Р.Вәлиев

**ИНИЦИАТИ́ВАЛЫ** *с.* Мөстәкыйль, үз көче белән эш йөртүгә сәләтле, булдыклы; эшлекле. *Шулай булгач, әгәр дә синең кул астында кискен чакта инициативалы, белемле, колхозчыларны хәлиткеч көрәшкә күтәрердәй тагын бер җитәкче эшли башлаган икән, аның белән килешмәгән кичәге көн кешесенең әләгенә колак саласың икән... Син үзең дә кичәге көн җитәкчесенә әверелмисеңме икән?..* Г.Кашапов. *Алар арасыннан күбрәк элек Буа районында колхоз председателе булып эшләгән Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов белән аралаша идем. Белемле, инициативалы, төпле кеше.* Т.Миңнуллин. *Әтисе, терелгәч тә, һаман шул РИКта эшләде. Иң инициативалы, нык куллы активист булып, абруе бик зур иде.* Х.Камалов

**ИНИЦИАТИ́ВАСЫЗ** *с.* Мөстәкыйль (үзбашка) эш йөртүгә сәләтсез, булдыксыз, эшлексез. *Әнә шулай үзләренең урталыкта баруларына ияләнеп*

*беткән, алга үрмәләргә теләкләре сүнгән, инициативасыз, сүлпән кешеләр тәрбияләмибезме соң?* Л.Ихсанова

**ИНИЦИАТИ́ВАСЫЗЛЫК** *и.* Мөстәкыйль эш йөртүгә сәләтсез булу, булдыксызлык. *Җыелышта аны инициативасызлыкта, үз фикере, фантазиясе булмауда гаепләп сөйләгән сүзләрне искә төшерде.* Р.Вәлиев. *Мөстәкыйльлеге кимү халыкның инициативасына да кире йогынты ясаган. Инициативасызлык әкренләп милли холыкка сеңгән.* Ш.Җәләлиев

**ИНИЦИА́ТОР** *и. фр.* Берәр яңа эшне башлап җибәрүче, иң элек кузгатучы кеше; инициатива күрсәтүче кеше. --- *Заһир алдында ул үзен гаепле саный иде: теге язгы төндә тау башына ясаган экскурсиянең инициаторы, ни әйтсәң дә, Рушад үзе бит!* М.Мәһдиев. *1988 елның җәендә сәяси оппозиция республикада халык фронты инициаторлары үзәген төзи.* Татарстан тарихы. *Гадәттә, аерылышуның инициаторы – башлап йөрүчесе – хатынкыз үзе була.* Асылъяр

**ИНИЦИА́ТОРЛЫК** *и.* Инициатор булу; инициатива күрсәтү

**ИНИЦИА́ЦИЯ** *и. лат.* Нинди дә булса социаль төркем эчендә, дини җәмгыятьтә яки мистик оешмада шәхеснең яңа үсеш баскычына күчүенә багышланган, борынгыдан килә торган йола. *Андый ябык дини оешмага керү процедурасы – инициация – каты тикшерү һәм куркыныч ритуаллар аркылы башкарылган.* Р.Сафин

**ИНК** *и.* Хәзерге Перу дәүләте территориясендә (Көньяк Американың Амазонка елгасы бассейнында) яшәгән югары мәдәниятле борынгы индиан кабиләсе халкы һәм аның бер вәкиле. *Анда [журналда] борынгы майя һәм инк халыкларының гаҗәеп сәнгать әсәрләре, манаралары, калалары турында язылган иде.* М.Маликова. *Инклар цивилизациясе иң серле, табышмак цивилизацияләрнең берсе булып кала. Инкларда металлургия, һөнәрчелек алга киткән, туку станоклары файдаланылган ---.* Бөтендөнья тарихы. *Урта гасыр инклар дәүләтендә мондый мәктәпләр «Сайланган гүзәлләр» («Акльа-васи») исеме белән аталган һәм тора-бара дәүләт карамагына күчкән.* Юлдаш

**ИНКАССА́ТОР** *и. ит. фин.* Төрле оешма, предприятие һ.б.ш.лардан банкка тапшыру өчен акча кабул итүче кеше. *27 октябрьдә Казанның Восстание урамындагы Дәүләт банкы бүлеге янынннан 19–14 ТТК номерлы «Волга» кузгалып киткәндә, шәһәрдә инде кичке караңгылык төшкән була. Арткы утыргычта – өлкән инкассатор Маннур Әхмәдуллович Нигъмәтуллин, акча җыючы инкассатор Георгий Ашотович Григорян.* М.Насыйбуллин. *Американың Кливленд шәһәрендә яшәүче Марк Морант атлы бер кеше инкассатор машинасыннан төшеп калган 640 мең доллар акчаны, табып, банкка илтеп тапшырган.* Юлдаш

**ИНКАССА́ТОР ПУНКТЫ** *и.* Түләнергә тиешле документлар буенча акча кабул итү эше белән шөгыльләнә торган банк бүлеге

**ИНКАССА́ЦИЯ** *и. ит. фин.* 1) Инкассаторларның предприятиеләр һәм оешмалар кассаларындагы акчаларны җыюы һәм банкларга тапшыруы. --- *кулына пистолет тоткан 33 яшьләр чамасындагы ир-ат төзелеш материаллары сатыла торган кибеткә кереп, акчаны инкассациягә тапшырырга җыенган ике хатын-кыздан барлык сумманы үзенә бирүләрен таләп итә.* Ирек мәйданы

2) Түләү документлары (мәс., чек, вексель) буенча банклардан акча алу

**ИНКА́ССО** *и. ит. фин.* Клиентлар таләбе белән акча средстволарын берсе исәбеннән (түләүчедән) икенчесе исәбенә (алучыга) күчерү буенча арадашлык операциясе

**ИНКВИЗИ́ТОР** *и. лат.* 1) Инквизиция (*1 мәгъ.*) хөкемдары, инквизиция карарларын тормышка ашыручы кеше. *Инквизиторлар тарафыннан тәмам эштән чыгарылып, аяк-кулларына кадәр сындырылып, Неаполь төрмәсенә ташланган Кампанелла --- турында да сөйләде ул [Маннур].* М.Хәсәнов. *Папа --- Изге Доминик ордены монахларына еретикларны эзәрлекләү бурычын йөкли. Инквизиторларга аларны табып җәзалау һәм хөкем итү хокукы бирелә.* Бөтендөнья тарихы. *Галилео Галилей: «Җир шар формасында һәм үз күчәре тирәсендә әйләнә», – дип белдергәч, аны инквизиторлар гына түгел, шул чорда яшәгән башка галимнәр дә аңламаган.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Салкын кан белән рәхимсез газаплаучы, җәзалаучы; үтә явыз кеше. *– Бүрегең яна, бүрегең, инквизитор, Нахак каннар яна бүрегеңдә! – дип эндәшә Х.Туфан вәхшәт иясенә. Аны турыдан-туры «егерменче гасыр формасына җайлаштырган маска кигән инквизитор» дип атый.* Ф.Ганиева

**ИНКВИЗИ́ТОРЛЫК** *и.* Чиктән тыш рәхимсезлек, явызлык

**ИНКВИЗИ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *тар.* Еретикларга каршы көрәштә католиклар чиркәве тарафыннан XIII–XIX гасырларда оештырылган һәм үзенең аяусызлыгы, шәфкатьсезлеге белән танылган хөкем итү һәм җәзалау оешмасы. *Чиркәү догматларына каршы килә торган еретик фикер белдерүдә гаепләнүчеләр, сихерчелек, бозым белән эш итүдә шик астына алынучылар, чиркәү тарафыннан гаепләнә торган актларга керүчеләр инквизиция хөкеменә дучар ителә.* Бөтендөнья тарихы. *Инквизиция хөкем сөргән вакыт эчендә җәзалап үтерелгән корбаннарның саны --- берничә йөз мең кешегә җиткән.* Мирас. *Бу язмада Тәүратны бозучы җөмләләрнең дә күплеген искә алганда, аның инквизиция хөкеменә тартылмый калуы хәтта аңлашылмый да.* Юлдаш

2) *күч.* Газаплау, рәхимсез җәзалау. *Ник дигәндә, Хрущёв – талантларны куралмаган совет инквизициясе, дөресрәге, НКВД инквизициясе канат җәйгән чорда формалашкан кеше.* Идел

**ИНКО́ГНИТО** *рәв. лат.* **1.** Яшертен, яшерен исем астында, үз исемен атамыйча. *Инкогнито бара торган 3 нче класс пассажиры йөзләгән башка пассажирлар арасында эреп югалырга мөмкин.* И.Нуруллин. *Әйе, кайчагында инкогнито йөрү файдалырак була шул.* Ф.Яруллин

**2.** *и. мәгъ.* Үзен чит исем белән атап, билгесез булып калырга теләүче кеше

**ИНКОРПОРА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Үз составына кушу

2) *юр.* Төрле вакытларда чыккан законнарны һәм закон актларын нигездә үзгәртүләрсез генә гамәлдәге законнар белән бербөтен итеп берләштерү

**ИНКРУСТА́ТОР** *и. лат.* Инкрустация белән шөгыльләнүче художник

**ИНКРУСТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Металлдан, таштан, агачтан яисә сөяктән ясалган әйберләрне уеп, аларның өслегенә икенче бер затлырак металл, таш кисәкләре һ.б.ш.ларны урнаштырып ясалган рәсем, орнамент, бизәк. *Инкыт күле гүя күл дә түгел, гүя табигать үзе, ак чалмалы мәгърур тауларның әмерен үтәү йөзеннән, инкрустация хикмәтләрен күрсәтә ---.* К.Миңлебаев. *Бу кеше портретның үзенә карамый, ә аның бай инкрустация белән эшләнгән рамындагы алтын бизәкләрен өйрәнә иде.* Ш.Маннур. *Төсле пыяладан инкрустацияләр, скань һәм филигрань куллану – болар һәммәсе дә аларның сәнгатендә татар халык ювелирлык иҗаты нигезендә үсә.* Татарстан яшьләре

2) Берәр әйбергә уеп рәсемнәр, бизәкләр, орнаментлар ясау эше

**ИНКРУСТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Нәрсәне дә булса уеп, аның өслеген мәрмәр, керамика, асылташлар, металл, сөяк, перламутр рәсемнәр белән бизәкләү, инкрустация белән бизәү. *Аның кармак таягы бамбуктан, мельхиор һәм җиз белән инкрустацияләп эшләнгән.* М.Юныс. *Салават күперенең җиде төрле төсен балкытып янган бәллүр люстраны, инкрустацияләп эшләнгән затлы шкафның бер бүлемен, идәндәге һәм стенадагы чәчәкле зур келәмнәрне исе китеп карап торды.* Л.Ихсанова. *Аның астындагы юка гына алтын кисәгендә ниндидер саннар һәм кызыл эмаль белән инкрустацияләп ясалган тәре тирәсенә тезелеп киткән кечкенә-кечкенә рәсемнәр бар иде.* З.Фәтхетдинов

**Инкрустацияли башлау** Инкрустацияләү эшенә керешү

**ИНКУБА́ТОР** *и. лат.* 1) Тавык, үрдәк һәм башка кошларның йомыркаларыннан чебешләр, уылдыктан маймычлар һ.б. җан ияләреннән яшь үрчем алу өчен, электр белән җылытыла торган аппарат. *Әгъдия килеп кергәндә, Нәгыймә инкубатордан алып кайткан чебиләр белән чүкердәшеп йөри иде.* К.Кәримов. *Үзебезнең инкубатор бар. Бәбкәләрне өч районга сибелгән фермаларыбызга таратабыз.* Идел. *Аңа кадәр Апас инкубаторында эшли иде ул. Колхозлар өчен һәм халыкка чебиләр чыгаралар.* Казан утлары

2) *махс.* Вакытыннан алда туган баланы кирәкле температурада тотып җитлектерү аппараты

3) *күч.* Иҗади эшчәнлек өлкәсе. *Яшь бер язучының иҗат инкубаторыннан чыккан, хәтта әле чыгып кына килә торган зур башлы, бәләкәй гәүдәле чебичегенә минем кебек сәлтерәвек картның корышып беткән дорфа кулын сузу оят булыр иде.* Л.Җәләй

**ИНКУБАЦИОН** *с.* 1) *мед.* Йогышлы авыру микробларының үрчи башлаган вакытыннан алып клиник билгеләре күренә башлаганчыга кадәрге ара; авыруның яшерен барган вакыты. *Грипның инкубацион чоры 5–7 көн*

2) Инкубаторда (*1 мәгъ.*) кулланыла торган. *Фабрика зурайгач, инкубацион йомырка мәсьәләсе җитдиләнгәннән-җитдиләнә барды.* Казан утлары

**ИНКУБА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Инкубаторда (*1 мәгъ.*) чебеш, маймыч, ефәк кортлары һ.б. чыгару. *Инкубация чорында йомырка эчендә барган процессны ул үзенең биш бармагы кебек белә.* Казан утлары

2) *мед.* Йогышлы авыруның йоккан моментыннан алып беренче билгеләре күренә башлаганга кадәр үткән вакыт. *ВИЧ вирусының организмда инкубация чоры берничә елга сузыла, һәм бердәнбер тышкы билге булып лимфа төеннәре зурая.* Мәйдан. *Кайбер очракларда тышкы кыяфәте белән мәчеләр сау-сәламәт шикелле күренсәләр дә, чынлыкта, чир яшертен рәвештә көчәя генә бара. Чөнки инкубация чоры кайбер очракларда берничә көннән алып берничә айга чаклы дәвам итә.* Юлдаш

**ИНКУНА́БУЛА** *и. лат. махс.* Китап басу эшенең башлангыч этабында (1450–1500 еллар) Иоган Гутенберг металл литералар уйлап тапканнан соң, басмаханә хәрефләре белән җыелып, шул чорда басылган һәр китап

**ИНКЫЙЛАБИ** *с. гар.* 1) Инкыйлапка (*2 мәгъ.*) бәйләнешле. *Матур әдәбият, шул җөмләдән татар әдәбияты, илдә бара торган инкыйлаби үзгәрешләрне чагылдыруга җиң сызганып керешә.* А.Әхмәдуллин. *[XX гасыр башында] Инкыйлаби рухлы шигъярият барлыкка килә, прозада һәм драматургиядә эшчеләр образларын үзәккә куйган әсәрләр языла.* Әдәбият. *Инкыйлаби җиңүдәге күтәренке рух аның кайбер юлбашчыларыннан кайберәүләренә хәл-әхвәлне аек бәяләп, хурлыклы шартларда башкалардан аермалы (сепаратлы) солых булырга тиешлеген тануга комачау итми.* Мирас

2) Инкыйлап (*1 мәгъ.*) идеяләрен алга сөргән; инкыйлап рухы белән сугарылган; инкыйлап таләпләренә, ихтыяҗларына туры килә торган; инкыйлапны яклаган. *Совет чоры әдәбият белеме XX гасыр башы татар әдәбиятын башлыча социаль тигезлек, сыйнфый мотивларга бәйле рәвештә яктыртуны кулай күрде, язучылар әсәрләрендәге иҗтимагый гаделлек, инкыйлаби тартышларны өйрәнүгә басым ясады.* Сөембикә. *--- дип башлана торган инкыйлаби яки «Марсельеза» исемле җырны да бик дәртләнеп җырлый идек.* Казан утлары

3) Инкыйлап тарафыннан, инкыйлап нәтиҗәсендә булдырылган, урнаштырылган. *Мин --- бер китап укып чыктым. Ул егерменче гасыр инкыйлаби тарихы иде.* С.Җәлал. *[К.Нәҗми] Икенче мәкаләсендә: «Инкыйлаби агымнардан берсе --- имажинизм вакытлы рәвештә татар әдәбиятын ташлый», – ди...* Х.Госман. *Инкыйлаби яңарыш, хәбәрдарлык һәм ачыктан-ачык сөйләү ирегә иске тәртипләргә ияләнгән күп кешенең акылын чуалтты.* А.Әхмәдуллин

4) *күч.* Нинди дә булса бер өлкәгә кискен үзгәреш кертә торган; нәрсәне дә булса тамырыннан үзгәртеп кора торган. *Мәдәният өлкәсендә инкыйлаби үзгәреш*

**ИНКЫЙЛАП** *и. гар.* 1) Әйләнү, асты-өскә килү, буталчыклык

2) Җәмгыять строен көч куллану юлы белән бәреп төшереп, аның урынына яңа строй урнаштыру, җәмгыять тормышын тамырыннан үзгәртеп кору эше; революция; алмашыну, үзгәрү. *Объектив сәбәпләрнең тулы бер катнаш сәбәпләре нәтиҗәсендә, әле инкыйлапка кадәр үк, нәкъ менә татар милли хәрәкәте Россиядәге мөселман халыклары арасында күп кенә интеграция процесслары һәм акцияләренең башлап йөрүчесенә әйләнә дә.* Мирас. *1905 елгы һәм 1917 елгы ике инкыйлап арасындагы чор татар журналистикасының гөрләп үскән чоры була.* Казан утлары. --- *университет стеналары эчендә Октябрь инкыйлабына кадәрге 112 ел дәвамында күренекле татар мәгърифәтчеләре, җәмгыять эшлеклеләре үсә.* Сөембикә

3) *күч.* Фәннең, сәнгатьнең, техниканың һ.б.ш.ларның берәр өлкәсендә төпле үзгәреш, кискен алмашыну. --- *аз вакытта вә бер кешенең тәэсире илә генә, һичбер җирдә булган кебек, телдә дә зур бер инкыйлап (үзгәреш) вөҗүдкә килми.* Җ.Вәлиди

4) *күч.* Уй-фикердә үзгәреш. --- *татлы сүзләр сөйләшү өмиде белән акчага килгән Галимәгә ялгыз бер хат белән кайтып китү бик авыр иде. Бу Галимәнең башына бик зур инкыйлап ясаган иде.* Г.Ибраһимов

5) *иск. грам.* Бер авазның икенче авазга әйләнүе, күчүе; чиратлашу. *«Л»нең «н»гә инкыйлабы.* К.Насыйри

**ИНКЫЙЛАПЧЫ** *и. иск.* 1) Инкыйлап хәрәкәтендә катнашучы көрәшче. *Балкый анда күп корбан, күпме эшче каннары, Без татарның инкыйлапчы хәрби гаскәр даннары.* Н.Исәнбәт. *Тарих истәлеге булып калган әлеге әсәрләрдә 1917 ел борылышын оештыручы инкыйлапчы [Ленин] татар халкын бәхет һәм мәгърифәт юлына алып чыккан, аңа зур изгелекләр эшләгән кеше буларак бәяләнә.* Т.Галиуллин

2) *күч. сир.* Фәннең, техниканың, сәнгатьнең һ.б.ш.ның берәр өлкәсендә тамырыннан үзгәреш кертүче кеше. *Каннар бозылу галәмәте – төрле милләтләрнең буталуы – аның хезмәтендә, дөресрәге, бөек ачышларында шулай үк әһәмиятле фактор буларак өйрәнелергә тиеш ләбаса, дип фикер йөртте инкыйлапчы галим.* З.Хөснияр

**ИНКЫЙРАЗ** *и. гар.* 1) Бетү, юкка чыгу, сүнү, үлеп бетү процессы. *«Особый лагерьларда»--- большевизмның --- кешелек дөньясына деспотизм, җәберҗәфалар, кыенлыклар, рухи инкыйраз алып килгәнен ачыклаган кешеләр утыра иде.* А.Гыйләҗев. *Ул [Таһиров] җитәкләгән халыкара оешма милли хәрәкәтнең генераль штабына әйләнде һәм халкыбызның инкыйразга каршы актив көрәшенә стратегик юнәлеш ачып җибәрде. Шул вакытта игътибарән Алтын Урда дәүләте инкыйразга (бетүгә) йөз тотты.* Г.Гобәйдуллин. *Әгәр дә һәркайсыбыз, чит илләргә чыгып, монда да татарлар яши әле, дип сөенеп йөрүдән артык китә алмасак, инкыйраз көннәре озак көттермәс шул.* Казан утлары

2) Үсештә артка китеш, артка чигенеш; регресс. *1950–1970 елларда татар терминологиясе чын мәгънәсендә инкыйраз дәверен кичерә, дип әйтү һич арттыру булмас.* С.Шәмси

**ИНКЯ́Р** *и. гар.* Нәрсәне дә булса кире кагу, кабул итмәү. *Фигыль иярченнәреннән инкярны аңлата торган «түгел» дә үзенә кушылып әйтелә торган сүз белән берлектә кушма хөкем буладыр.* Җ.Вәлиди

**ИНКЯ́Р ИТҮ** *ф. гар. кит.* Нәрсәне дә булса кире кагу. *Футуристлар да культура мирасын, әдәби традицияләрне инкяр иттеләр...* Х.Госман. *Ул [Петя] бөтен этик кагыйдәләрне инкяр итеп, шаркылдап көлә башласа, бөтен борчуларыңны онытып, ирексездән аңа кушыла идең.* М.Галиев

**ИНКЯ́Р КЫЛУ** *ф. гар. кит. к.* **инкяр итү**

**ИНКЯРЛА́У** *ф. к.* **инкяр итү**. --- *шартлар белән чагыштырганда, сылтауның роле шактый кимрәк. Шулай да аның үзгәрешләр процессындагы ролен бөтенләй инкярлап булмый.* К.Гыйззәтов

**Инкярлап бару** Һәрберсен, булган берсен даими инкярлау

**Инкярлап килү** Күптәннән, электән үк һәрвакыт инкярлау

**ИННЕК** I *и.* Иренне һәм битне алсуландыру өчен кулланыла торган алсу, алсу кызыл, шәмәхә кызыл төстәге яки төссез косметик буяу. *Мәрьям, трюмо каршына басып, алканы киеп карады. Килешә. Иреннәргә шундый иннек яксаң, кара күлмәк кисәң, искиткеч буласы.* М.Маликова. *Әгәр дә Сөмбелнең иренә иннек сөртелмәгән булса, Аит аның агарып калуын күрер иде.* Ә.Гаффар. *Алай да апа йөзен каплаганчы күреп өлгердем, күрәсең, чырайсызлыгын яшерү өчендер инде, битенә иннек яккан.* А.Расих

**ИННЕК** II *и. диал.* **1.** 1) Киртә. *Иннеген төшереп, ишегалдына узсам, аның лапас почмагындагы баз чоланында маташуы күземә чалынды.* Ш.Маннур

2) Кергәндә-чыкканда алына торган итеп эшләнгән капка. *[Матрослар] Басмаларны тартып алдылар, --- иннек ябылды...* Н.Фәттах

3) Хайваннарны бер урынга җыю, туплау өчен, киртәләр белән уратып алынган урын. *Маллар кереп-чыгып йөрергә иннек-киртә, ә кешеләргә аерым бәләкәй капка ясаучы Айдаш баба булды.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Буйга сузылган киртәләрдән эшләнгән. *Агай йөгән тезгенен, дуга бөҗрасыннан ашыкмыйча чыгарып, иннек капканың тәбәнәк баганасына чалды.* М.Хуҗин. *Иннек капкасы да төтен булып күккә очты.* А.Гыйләҗев

◊ **Иннеге тыгылмаган** Теленә ни килсә, шуны сөйләүче кеше турында

**ИННЕК-КЕРШӘН** *җый. и.* Гомумән бизәнү-төзәнү әйберләре. *Син җибәргән киемнәрне әйбәтләп киенде, иннек-кершән салып бизәнде. Чынчыннан кияү көткән кызга әйләнде.* Т.Гыйззәт. *Лена аның кулына косметика савыты төртте: – Бар әле, битеңә, иреннәреңә әз-мәз иннек-кершән як.* Н.Гыйматдинова. --- *[бинаның] коймасын эчтән сарыга, тыштан зәңгәргә --- буяганнар. Әмма бу буяулар сиксән яшьлек карчык битенә ягылган иннеккершән кебек кенә.* М.Маликова

**ИННОВА́ЦИЯ** *и. ингл. икът.* 1) Базар таләпләренә җавап бирә алырлык

эшчәнлекнең яки продукциянең саны һәм сыйфаты үсешенә кискен этәргеч ясаган, кулланышка кертелгән яңалык. *Әлеге программа дүрт «И»не: институтларны, инфраструктураны, инновация һәм инвестицияләрне үстерүгә корылган.* Татарстан

2) Техниканы һәм технологияне нигездән яңарту максатыннан чыгып, средстволарны икътисадка юнәлтү. *Мәгариф системасындагы инновацияләр – яңа белгечлекләр һәм яңа мәгариф технологияләре ул.* Татарстан

3) *лингв.* Телдә эчке үзгәреш

**ИННОВАЦИОН** *с. к.* **инновацияле**. *Казанның 146 нчы мәктәбен үстерүнең инновацион программасы белән аның директоры Диләрә Кәримова --- таныштырган.* Мәдәни җомга

**ИННОВА́ЦИЯЛЕ** *с. икът.* Инновациягә нигезләнгән. *Инновацияле үсеш мәсьәләләре һәм мәгариф системасы проблемалары үзара нык бәйләнгән.* Татарстан

**ИНОМА́РКА** *и. рус сөйл.* Чит илдә җитештерелгән автомобиль. *Шәһәр урамнарында көннән-көн ишәя барган иномаркалар арасында «Ниссан»нар еш очрамый.* М.Маликова. – *Карале, икебезгә бер бизнесмен карата алмыйбыз. Авыл гыйбатлары, – дип, кайткач, дустының тетмәсен тетә Гөлфирә. – Хәер, безнең сыман җәяү йөрми шул алар, иномаркада элдертә.* Р.Мулланурова. *Илдәге һәр дүртенче автомашина – иномарка.* Юлдаш

**ИНСАН** *и. гар. кит.* Кеше, адәм. *Шул вакытта әллә кайдан чыга инсан, Кулларына балта берлән чүкеч тоткан.* Г.Тукай. *Азат иткәч, өйләнергә марҗа кызы таптылар, инсанны, ихлас җанны, Ядгәр ханны, мәкерле җаннар еландай чактылар.* К.Латыйп. --- *[ата кешенең] --- акылы ачык бер фикергә килмәсә дә, йөрәге сизенә, аңына дәшә: – Бу улың буш кеше булмаячак, аннан илгә күренекле инсан чыгачак!* Р.Сибат

**ИНСАНИ** *с. гар. кит.* Кешегә бәйләнешле, кагылышлы, кешеләргә хас. *Әти-әниләрнең гомер буе шул «дәүләт» исемле бирән алпавытка бил бөккәннәре дә җиткән... Паспортсыз, барлык инсани хакларыннан мәхрүм ителеп яшәделәр.* Ф.Фәтхелислам

**ИНСАНИЯТ** *и. гар. кит.* 1) Кешелек дөньясы, кешеләр җәмгыяте, кешеләр. *Кешелек тулы Гармониягә ирешкәч кенә чын Бәхеткә тап булачак. Хакыйкатьне табып бетереп булмаган кебек, инсаният бервакытта да тулы Гармониягә ия булачак түгел...* Р.Сибат

2) Кешеләрдә генә була торган яхшы сыйфатлар, кеше сөючәнлек. *Инсаният хисләренең иң киң мәгънәсе – --- өмид кәгъбәләредер.* Г.Тукай. – *Яз, – диде Төхфәт, – әйбәт итеп, ачык итеп яз. Менә болай диген: «Хөрмәтле Хөсәен әфәнде, гафу үтенәм, әмма сезне кисәтүне үземнең инсаният бурычым дип саныйм».* А.Расих

3) Кешелеклелек, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек. *Залим ир хатынының актык тамчы канын эчеп бетереп, гүргә керткәнчегә кадәр бара. Я, әйт инде, --- шушы булдымы инсаният?* Г.Камал

**ИНСАНИЯТЛЕ** *с. кит.* Шәфкатьле, мәрхәмәтле, кешегә ярдәм итәргә әзер булган. *Болай да бик мәрхәмәтле, бик үк инсаниятле вә йомшак күңелле булмаган төрекмән ханы үзенең дошманнарыны, үзенең әсирләрене --- газап кыла.* Ш.Мөхәммәдев

**ИНСАНИЯТ(ЛЕ)ЛЕК** *и. кит.* Кешелекле булу сыйфатлары. *Сара Рөстәмгә үзенең рәхмәтләрен укып бетерә алмый: «Мин сезнең инсаниятлелегезне гомеремдә дә онытмам ---!»– ди.* С.Җәлал

**ИНСАНИЯТСЕЗЛЕК** *и.* Кешелексезлек, кешелексез булу сыйфатлары. *Бу күз яшьләренә --- шул һәяте иҗтимагыяләрнең һиммәтсезлеге вә инсаниятсезлеге сәбәптер.* Г.Тукай. *Гөнаһсыз кызны бөтен рәхәтеннән мәхрүм иткәнсез... Мескенәнең бөтен гомерен харап иткәнсез... Зур инсаниятсезлек!* Г.Исхакый

**ИНСАНИЯТЧЕ** *и. кит.* Кешелеклелек төшенчәләрен, идеяләрен алга сөрүче. *Сәлим, тар «милләтчелек» даирәсеннән чыгып, «инсаният даирәсенә» күчкән; милләтчелекне ташлап, инсаниятче булган ---.* Г.Ибраһимов

**ИНСАНИЯТЧЕЛЕК** *и. кит.* Кешелеклелек (мәрхәмәтлелек) идеяләрен алга сөрү, гуманизм. *Үзенең инсаниятчелеген ул [Сәлим] шул нәзарияләр илә мөдафәгә кыйла иде.* Г.Ибраһимов

**ИНСАНЛЫК** *и. кит.* 1) Кешелекле булу, кеше булу сыйфатлары. *Яхшы аңла: юк сафа инсанлыгыңны җуймыйча. И шуны җуймау юлында күп газапланган күңел!* Г.Тукай. *Һич булмаса, инсанлыгымны, абруемны коткара идем.* Ф.Фәтхелислам. *Иманым камил, күзаллаулар төрлечә булса да, иң соңгы нәтиҗә уртактыр: безнең өчен Тукай шагыйрь генә түгел, аның инсанлыгына изгелек сыйфатлары да салынган ---.* Сөембикә

2) Кешелеклелек, мәрхәмәтлелек. *Туар дөньяга дуслыклар – Менә шунда чын инсанлык.* М.Гафури

**ИНСАФ** *и. гар.* Үз-үзеңне тота белү сыйфаты; әдәп; тыйнаклык. *Намус, хәя, инсаф, мәрхәмәт кебек нәрсәләр бу залимдә һич юк иде.* Ш.Мөхәммәдев. *[Дәрвиш] Раббым! Акъегет илә Зөбәрҗәт атлы колларыңа гомерлек инсаф вә итагатьлелек бир, татулык вә мөлкәт бир.* М.Кәрим. *[Борһан] Хатыны үлгәч, инсаф саклап булса кирәк, бик күп айлар буе тол яшәде.* М.Хәсәнов

◊ **Инсафка кайту** *к.* **инсафка килү**. *Бер [кат] инсафка кайтып, яхшылап уйлап карыйк: ике йөз мең адәм төрмәдә ятсын!* Ш.Мөхәммәдев. **Инсафка килү** Инсафлану, тәүфыйклылану, әдәплеләнү. *Мин инде аның инсафка килүен өмет итмим.* Ш.Камал. *Җылкычы ата иң элек үзе инсафка килде: булдым, биргәнеңә шөкер, дип, майлы кулларын итек кунычларына сөртә башлады.* Г.Ибраһимов. *И абзыйлар, и агайлар, ап-ак сакаллы бабайлар, Бераз инсафка килегез, җитәдер шәриф айлар.* Ш.Мөхәммәдев. **Инсафка утыру** *к.* **инсафка килү**

**ИНСА́Ф ИТҮ** *ф. иск.* Инсафлану, тыйнаклану, әдәпләнү. *Җитәр, инсаф итең, --- [оятсызлар]!* Г.Тукай

**ИНСА́Ф КЫЛУ** *ф. иск. к.* **инсаф итү**. *[Күңелемдә] Ялгыз синең сурәтең бар, Шуның өчен мине кызган, кыйлгыл инсаф!* М.Гафури

**ИНСАФЛАНУ** *ф.* Тыйнаклану, тотнаклылану, тәртипләнү, әдәпләнү, тәүфыйклылану. *Карт мирза аңар әллә*

*ничә мәртәбә ачуланып хат та язып карый. Касыйм да шуннан соң вакытлы рәвештә азрак инсафланган төсле була.* С.Җәлал. *Җитмешкә җиткәндә генә акыл керде... Инсафландым.* Э.Касыймов

**Инсафлана бару** Торган саен ныграк инсафлану

**Инсафлана башлау** Инсафлану юлына басу

**Инсафлана төшү** Берникадәр, бераз инсафлану

**Инсафланып бетү** Тәмам инсафлану

**Инсафланып китү** Берәр этәргеч бирерлек вакыйгадан, билгеле бер вакыттан соң инсафлану. *Хәкимҗан ага соңгы вакытларда бик инсафланып киткән, хәтта челем тартуын да ташлаган.* Э.Касыймов

**ИНСАФЛЫ** *с.* **1.** Тотнаклы, тыйнак, әдәпле, тәүфыйклы, тәрбияле. *Шәкерт вакытта бик юньле, инсафлы бала иде, хәзер инде тәмам урыс булып беткән, эштән чыккан, ди.* Ф.Әмирхан. *Иреннәрендә аның тыйнак, яшерен бер елмаю уйный. Менә ул кызның инсафлы булуы --- турында сөйли.* М.Хәсәнов // Гади, тыйнак. *Ул заманда әле нинди инсафлы татар авылларында халык дошманнары яшәп ятуына кешеләр ышана да, бик ышанмый да.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* Әдәпле, тыйнак, тәүфыйклы итеп. *Ул – әйбәт яңа костюм кигән, чиста-пакь йөзле егет. Инсафлы сөйләшә.* Ш.Рәкыйпов. *Үзен инсафлы тоту. Инсафлы гына йөрү*

**ИНСАФЛЫК** *и.* Әдәпле, тыйнак, инсафлы булу. *– Шулаймы? – диде Хәдичә, тыйнаклык, инсафлык саклагандай итеп, шул ук вакытта күзләре белән генә көлеп өстәде: – Без инде хәзер, Мәдинә, сугылган көлтә, өребез киткән...* М.Хәсәнов. *Әүвәл ирен мәсхәрәләп, татар хатыннарында борын-борыннан килгән инсафлыкка хилафлык кылган Сәрия бүген тикшерүче алдында җавап тота.* М.Насыйбуллин. *Син сусаган, мин сусаган... Яз китерә сафлыкны. Сафлык тулган иреннәрдән Эчәбез... инсафлыкны.* Б.Рәхимова

**ИНСАФЛЫЛЫК** *и.* Тыйнаклык, әдәплелек, тәрбиялелек сыйфатлары. *--- кискән икмәк яңадан ябышмаган кебек, әхлаклылык сыйфатларын, инсафлылыкны югалткан хатыннар, гадәттә, үткәнне кире кайтара алмый...* М.Насыйбуллин. *Гыйлем мәсьәләсе дә әхлак, инсафлылык, кешелеклелек кебек проблемалар белән тыгыз бәйле булуын Утыз Имәни ассызыклап билгеләп үтә.* Ә.Мәхмүдев

**ИНСАФСЫЗ** *с.* **1.** Тәрбиясез, тотнаксыз, әдәпсез. *– Әллә эчмисез дәме сез, Алла бәндәсе?– дип гаҗәпләнде туташ. Ул үз чәркәсенә тагын коньяк салды. – Сез, бу – нинди инсафсыз чәчби? Тарта, эчә, ди торгансыз.* Г.Тавлин

**2.** *рәв. мәгъ.* Әдәпсез, тыйнаксыз, оятсыз рәвештә. *Егет үзен инсафсыз тотты*

**ИНСАФСЫЗЛАНУ** *ф.* Әдәпсезләнү, тәрбиясезләнү, тотнаксызлану

**Инсафсызлана бару** Торган саен ныграк инсафсызлану

**Инсафсызлана башлау** Инсафсызлану юлына басу

**Инсафсызлана төшү** Бераз, беркадәр инсафсызлану

**Инсафсызланып бетү** Тәмам инсафсызлану

**Инсафсызланып китү** Кинәт инсафсызлык күрсәтү

**ИНСАФСЫЗЛЫК** *и.* Тәрбиясезлек, тотнаксызлык, әдәпсезлек. *Нәрсә бу, иң якын кешеләрем миңа ерак булып калды? Ә бит бу, иң киме – инсафсызлык!* Х.Камалов. *Менә ул шуларны – үзен якын күрүемне белеп, әлбәттә, тәфсилле генә миңа яза, кешеләрнең инсафсызлыгыннан зарлана.* Ш.Камал. *Пьесаларда җаһиллек һәм саранлык, мәрхәмәтсезлек, наданлык, инсафсызлык фаш ителә.* Әдәбият

**ИНСЕКТИЦИДЛАР** *и. күпл. лат. хим.* Көнкүрештә, йортта очрый торган зарарлы бөҗәкләрне юкка чыгару өчен кулланыла торган химикатлар. *--- корткылар өй тирәсенә оя ясамасын дисәгез, түбә кайчыларын, такталарның өске өлешен инсектицидлар белән эшкәртергә киңәш ителә.* Сәламәт булыйк! *Сазанакны инсектицид сыйфатында да файдаланырга мөмкин, ул тире дуплау өчен дә кулланылган.* Урман аптекасы. *Үсемлек корткычларына һәм авыруларына каршы көрәштә кулланыла торган матдәләр --- ике группага бүленәләр: 1) инсектицидлар һәм 2) фунгицидлар.* Яшелчәчелек

**ИНСПЕ́КТОР** *и. лат.* 1) Үз карамагындагы оешмаларның, учреждениеләрнең һәм кешеләрнең үзләренә йөкләнгән эшне дөрес алып баруларын, канун тәртипләренең дөрес үтәлешен тикшереп, күзәтеп торучы дәүләт хезмәтендәге кеше; назир. *Мәдрәсәгә инспектор төшә икән дип, кыш буе шәкертләрнең котларын алып куркыттылар.* К.Тинчурин. *– Килешмәсәгез, югары инстанциягә мөрәҗәгать итегез, дип үзегез әйтәсез бит, – диде инспектор, үпкәле тавыш белән.* М.Насыйбуллин. *Инспектор белән механик, зур фонарь тотып, машина тирәсендә йөриләр, чүгәләп, тәгәрмәчләрне карыйлар. Бик тырышып эзләгәч, «Волга»ның җитешсезлекләрен табып булыр, дип уйлый Ниаз.* М.Маликова

2) *тар.* Россиядә Октябрь инкыйлабына кадәр ир балалар уку йортларында директорның тәрбия һәм уку-укыту эшләре буенча ярдәмчесе. *XIX йөзнең 70 нче елларына кадәр патша хөкүмәте --- укыту эшенә турыдан-туры катнашмый. --- Мәктәп һәм мәдрәсәләр янындагы рус классларын күзәтеп тору халык училищелары инспекторларына йөкләнә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИНСПЕ́КТОРЛЫК** *и.* Инспектор вазифасы, инспектор эше. *Егет болай матур-матурын, әмма ләкин инспекторлыкка яраксыз.* Ю.Әминов

**ИНСПЕ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) Эшнең дөрес барышын күзәтү һәм тикшерү вазифасы йөкләнгән оешма. *Һич уйламаганда, дивизиягә генштабтан инспекция килүе беленде.* Ф.Яруллин

2) Инспекторлык эшләрен алып баручы оешма, учреждение; нәзарәт. *Әле пенсия фондыннан, әле салым инспекциясенең төрле бүлекләреннән ике айга бер килеп торган тикшерүчеләр аның өстеннән акт язганнар.* М.Маликова

3) Инспекторлык эшләре өчен махсус оештырылган кешеләр төркеме. *Икенче көнне җиде кешедән төзелгән сыйфат инспекциясе килде.* М.Әмир

**ИНСТА́НЦИЯ** *и. лат.* Берсе икенчесенә буйсынган дәүләт органнары системасындагы бер баскыч (суд яки административ эшләрне карау вакытында чагыла). *Ә инде берәрсе начальник яки түрә булып алгач, утырган креслосын, портфелен югалта башласа, бетте! Разбой салып кына калмый, жалоба артыннан жалоба яза, дус-ишләрен пычратудан да җирәнми, мең төрле инстанциягә җитә...* М.Хәсәнов. *Эшкә урнаштыру, санаторийга юллама бирү, субсидия, стипендия, туу-күмү мәсьәләләре, бер инстанциядән икенчесенә кагыла-сугыла, әйләнгеч юллар аша шушы кабинетка барып тоташа.* Сөембикә. --- *ниһаять, иртәнгә язып бетерде, аны инстанция буенча җибәрде һәм ике ел дәвамында җавап көтте.* Ватаным Татарстан

**ИНСТИНКТ** *и. лат* 1) *биол.* Тере организмның, эчке яки тышкы мохиттәге үзгәрешкә карап, кирәкле, яшәү өчен әһәмиятле эш-хәрәкәтне аңсыз рәвештә башкаруга тумыштан килгән җайлашу реакциясе, сәләте. *Туганнан алып һәлакәтенә кадәр Микәй табигать белән бәйле, табигый инстинктлар коралы.* Әдәбият. *Охшарга тырышу, ияреү инстинкты – төп психологик механизмнарның берсе, аның аркылы балалар үзләренең характерларын булдыра.* Тигез гомер итегез! *Югыйсә, сугыш кебек хәтәр нәрсә инстинкт белән эш итүче ерткыч хайваннар арасында гына булырга тиеш иде дә бит.* Мирас

2) Нәрсәгә дә булса аңсыз рәвештә, белештермичә, ихтыярсыз ясалган омтылыш; хис. *Мин, сүзем, гакылым белән генә түгел, үземнең инстинктым белән үк авыл ягына карыйм.* Г.Ибраһимов. *Сөмбел дөрес әйтә ул: без – җирнең үги баласы. Инстинкт буенча омтылабыз без күккә.* Р.Вәлиев. *Бу – бик оста алынган деталь, бу безгә чекистның революцион инстинктын гаять ачык ярыртып җибәрә...* Х.Госман

3) Эчке сизем, табигый тойгы. --- *Марат бу сугуның көчлеләрнең көчсезләрне җәберләү, кимсетү икәнен инстинкт буенча аңлады һәм Саниягә сыенып елап җибәрде.* Г.Гобәй

**ИНСТИНКТИВ** *с.* **1.** *биол.* Инстинктка бәйле, инстинктка нигезләнгән. *Дөньяда битараф рәвештә көнетөне Җир шарының яшәү бәгырен кимерүчеләр генә түгел, ә вөҗданын тормыш ваклыклары йотып бетерә алмаслык, табигать турында туктаусыз инстинктив борчылу кичерүчеләр дә күп ич!* Р.Хисмәтуллин

**2.** *рәв. мәгъ.*Үзе дә сизмәстән, белештермичә. *«Күп куйганда да дүртбиш минуттан су төбенә китәчәкмен!» дигән коточкыч уй ярып үтте миемне. Һәм шунда, ахыры ни белән бетәрен дә уйлап тормастан, дөресрәге, инстинктив рәвештә, икенче чаңгымны ычкындырырга үрелдем.* В.Нуруллин. *Таеп егылганда кеше, кагыйдә буларак, инстинктив рәвештә куллары белән таяныч эзли.* Сәламәт булыйк! *Илмир шушы бәрелүләр алдыннан инстинктив рәвештә санын җыярга һәм дивардан этелергә күнеккән.* Юлдаш

**ИНСТИТУТ** *и. лат.* 1) Кайбер югары уку йортлары һәм фәнни учреждениеләрнең исеме. --- *Ләйлә үз язмышын әнисенең башына да килмәгәнчә хәл итте: мәктәпне тәмамлагач, педагогия институтының чит телләр факультетына керде.* М.Маликова. *Ә минем педагогия институтының аспирантурасында укып йөргән чак.* Идел. *Комплекслы социаль тикшеренүләр институты мәгълүматларына караганда, күпчелек гаиләләрдә килеп чыга торган --- низагларның төп сәбәбе – шул матди авырлык икән...* Сөембикә

2) *тар.* Россиядә Октябрь инкыйлабына кадәр югары катлау кызлары өчен ябык типтагы урта уку йорты. *Бецкой беренче хатын-кызлар тәрбияләү-укыту учреженисе – Асылзат кызлар институты (Смольный институты) ачуда зур роль уйнаган.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Алты елдан соң, алпавыт А.Н.Родионова акчасына Казанда затлы нәселдән булган кызлар институты ачыла.* Татарстан тарихы. *Безнең шәһәргә Мәскәүдән тагын берничә учреждение – архивлары белән Сенат департаменты, Мәскәү опекун советы, хатын-кызлар институтлары да күчеп килә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

3) *махс.* Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнеңниндидер бер өлкәсендә билгеләнгән хокуклар нормасының җыелмасы. *Татар авылларында «кеше нәрсә әйтер», «кеше ничек кабул итәр», «кеше күзенә ничек күренербез» кебек әдәп-әхлак институтының абруе бик зур.* Т.Галиуллин. --- *сексуаль белем бирүче китап индустриясе үскән илләрдәге кебек кризисны никах институты башка беркайда да кичерми.* Тигез гомер итегез! *Бу саннар бүген гаилә институтының торыксыз булуы хакында сөйли.* Сөембикә

4) Җәмгыять органнарының үзара мөнәсәбәтләрен, эш тәртибен фәнни нигезгә таянып камилләштерү өстендә эшләүче оешма. *Объектив рәвештә аның [Изге союзның] төзелүе, барыннан да бигрәк, Россия мәнфәгатьләренә туры килгән, чөнки ул аңа каршы юнәлдерелгән коалиция тууны булдырмый калган. Нәкъ менә Александр I Изге союзны даими эшләүче институтка әверелдерергә омтылган.* Бөтендөнья тарихы. *1722 елда, хакимият институтларының нәтиҗәлелеген күтәрү чарасы буларак, «Рангләр турындагы табельләр» гамәлгә кертелә.* Татарстан тарихы. *Ә бездә [Татарстанда], ни кызганыч, демократик институтларның күп гасырлык тарихлары юк, алар бай иҗтимагый традицияләргә таянмыйлар.* Мирас

**ИНСТИТУТТАШ** *и.* Бергә, бер институтта укыган кешеләрнең һәрберсе (бер-берсенә карата). *Институтташ дусым белән очрашу*

**ИНСТРУКТАЖ** *и. лат.* 1) Җитәкче күрсәтмәләр, инструкцияләр. *Врачка тулы инструктаж бирелде.* А.Тимергалин. *Таң вакытында Гыйльфан картада күрсәтелгән әйләнәгә килеп җитте. «Башы сынык нарат» диелгән иде инструктажда.* М.Мәһдиев. *Фарукшин, яшь иптәшкә инструктаж бирү, коллектив белән таныштыру сиңа йөкләнә.* Р.Вәлиев

2) Күрсәтмәләр, инструкцияләр бирү эше. *Пропуск алганда, инструктажда әйттеләр бит: рөхсәт язуы булмаса, ут якмаска, --- дип.* Р.Кәрами. *Рәфис башта берничә көн цех*

*белән таныштты, инструктаж укып, куркынычсызлык техникасы буенча кагыйдәләр өйрәнеп йөрде.* Н.Әхмәдиев. *Очуга катнашкан экипажларны эскадрилья командирының самолёты янына җыйдылар. Инструктаж башланды.* М.Юныс

**ИНСТРУКТИВ** *с.* Җитәкче күрсәтмәләре булган; инструктаж булып хезмәт итә торган. *Казначылык департаментының төп функцияләре – республика бюджетын төзү, гамәлгә ашыру, --- департамент компетенциясе чикләрендә методологик һәм инструктив материаллар булдыру.* Фәнни Татарстан

**ИНСТРУ́КТОР** *и. лат.* 1) Дәүләт, җәмәгать органнарында шунда эшләүче кешеләрнең һәм шул органнарга буйсынулы оешмаларның эшләрен тикшерүче һәм күрсәтмәләр бирүче хезмәткәр. *Әле кайчан гына, иң яхшы саналган эш алымын башкаларга күчерергә дип, сайлап алу өчен, комиссияләр төзеп, инструкторлар билгеләп, мәш килеп яталар иде.* М.Хәсәнов

2) Берәр һөнәргә, белгечлеккә өйрәтүче, шул һөнәр, белгечлекне үзләштерергә ярдәм итүче кеше. *Әле яңа гына самолётларга утырган, һәр хәрәкәтне, һәр эшне инструктор күзәтүе астында эшләгән яшь курсантлар инде космоска очу турында хыялланалар.* Ф.Яруллин. *Парашют белән сикерү өчен, алдан өч ай укырга кирәк икән. Укытучысы «инструктор» дип атала, ---.* М.Маликова. *Хәрби җитәкчелек Җәннәткә Гданьск шәһәрендә яшьләр белән эшләү буенча инструктор урынын тәкъдим итә.* Сөембикә

**ИНСТРУ́КТОРЛЫК** *и.* Инструктор хезмәте, вазифасы. *Тиздән Рәсим инструкторлыктан секретарь кәнәфиенә утырды.* Ф.Фәтхелислам

**ИНСТРУ́КЦИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса берәр эшне үтәү юлларын һәм тәртибен билгели торган, рәсми кабул ителгән кагыйдәләр, җитәкче күрсәтмәләр җыелмасы. *Стенага атаклы чекист Дзержинскийның җитди карашлы рәсеме, дружиначылар эмблемасы һәм инструкция эленгән...* Р.Кәрами. *Урыннардагы кассир-контролёрлар еш кына кассадагы акчаны, алып, үз кирәк-яракларына да тоталар. Бу – турыдан-туры инструкцияне бозу.* Р.Фәизов. *1920 елның май аенда республикадан 1919 елгы килешүләрдә вәгъдә ителгән кайбер хокукларны тартып алган яңа инструкцияләр һәм канунчыл актларның тулы бер пакеты кабул ителә.* Мирас

2) Нинди дә булса җайланманы, җиһазны җыю, көйләү тәртибен өйрәткән күрсәтмә

3) Пакетлы ризыкларны яки даруларны куллану тәртибе язылган текст. *Шнуры юк икән ләбаса суыткычның... Аптырагач, инструкциясенә, ягъни ничек кулланырга кирәклеген аңлаткан дәфтәренә күз салдым.* Г.Шәрәфи. *Беренчедән, даруны сатып алганчы ук, игътибар белән, куллану инструкциясен укып чыгарга кирәк.* Сөембикә

**ИНСТРУМЕНТ** *и. лат.* 1) Берәр эш башкарганда файдаланыла торган җайланма, корал. *Камилә стерилизаторда кисү инструментларын кайнаткан арада, Әминә картның бармакларын --- чистартты.* Г.Минский. *Хәзер республика предприятиеләрендә җитештерелгән электр-автомат приборлар, суыткычлар, аммиак ташыгычлар, ясалма күн, радио детальләре, металл кисү инструментлары һәм башка продукция илебездә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы билгеле.* И.Низамов. *«Наша Лора будет лором», – дип шаярталар иде. Маңгаена елкылдап торган түгәрәк көзге беркетеп, кешеләрнең ачылган авызына инструментлар белән генә үрелеп утыру аңа, чыннан да, бик килешәчәк иде.* М.Маликова

2) Аһәң, көйләр чыгару, башкару өчен махсус эшләнгән музыкаль корал. *Белгәнеңчә, оркестрдагы барлык инструментларда да симфония өчен кирәк ритмда уйнамасалар, музыка бозылыр иде.* М.Хәсәнов. – *Музыкант күрсәм, колагым чыңлый минем, – диде Нияз. – Мин әле, кайсы колагым чыңлаганына карап, сезнең нинди инструментта уйнавыгызны да әйтә алам.* М.Маликова. *Скрипка, мандолина, гармун халык арасында иң популяр музыка инструментлары була.* Татарстан тарихы

**ИНСТРУМЕНТАЛЬ** *с. муз.* 1) Музыка коралында башкарыла торган. *Сүзле музыкалардан тыш, җыентык ахырында фортепианода башкару өчен өч инструменталь әсәр бирелде.* М.Җәлил. *Мирсәет, үзенең җырларын, инструменталь әсәрләрен иҗат итү алдыннан, --- абыйсының бу сүзләрен истә тотадыр ---.* И.Юзеев. *Инструменталь әсәр язганда, гади нота гына белү җитми, теоретик белем дә кирәк.* Юлдаш

2) Музыка коралларын үз эченә алган, музыка коралларын берләштергән. *Менә бәйрәмнең башлануын хәбәр итеп, залның бер почмагына ясалган сәхнәчектә мәктәпнең инструменталь ансамбле уйнап җибәрде.* А.Гыйматдинев. *Залны тутырып, сиксәненче еллар көе агыла: әле Юрий Антонов яшьлек турында моңлана, --- әле төрле инструменталь ансамбль көйләре яңгырый.* Х.Ширмәт. *Зәвык тәрбияләү әти-әнидән тора: күпме вокаль, инструменталь һәм бию студияләре бар – сайлыйсы гына.* Сөембикә

**ИНСТРУМЕНТЧЫ** *и. тех.* Инструментлар (*1 мәгъ.*) ясаучы оста; белгеч. *Инструментчылар бригадасы бригадиры*

**ИНСУЛИН** *и. лат. мед.* Ашказаны асты бизе эшләп чыгара торган гормон (канда шикәр күләмен киметә, бавырда гликоген таркалуны тоткарлый). *Инсулин, канга эләгеп, үз эшен башкара: шикәр күләмен киметә.* Сәламәт булыйк! *Сезгә хәзер иң мөһиме – ач тормаска, --- инсулин яки шикәр алыштыргычлар дозасын билгеләргә, калорияләрне санарга туры киләчәк.* Ирек мәйданы. *Суыткычта антибиотикларны, витаминнар, глюкоза, сироп һәм шулай ук үлән төнәтмәләрен, гормональ препаратларны, инсулин, сыворотка, вакцина ишеләрне саклыйлар.* Юлдаш

**ИНСУЛЬТ** *и. лат. мед.* Баш миендә кан йөрешенең кискен бозылуы (ми зарарлануга, аның функцияләре бозылуга, параличка китерә). *Башта «инсульт» диделәр. Ныклабрак карагач, инфаркт булмагае, дип шикләнделәр.* А.Гыйләҗев. *Организм һәрчак җылы алмашын көчәйтергә тырыша, һәм без*

*тирлибез, ә организм сусызлана, нәтиҗәдә, кан куера. Вакытында берәр чара күрелмәсә, мондый хәлдә инфаркт яисә инсульт булу мөмкинлеге дә арта.* Сәламәт булыйк! *Югары кан басымы йөрәк-кан тамырлары, бөер авыруларын, миокард инфарктын, баш мие инсультын китереп чыгаручы төп сәбәп булып санала.* Сөембикә

**ИНСЦЕНИРО́ВКА** *и. лат.* 1) *әд.* Сәхнәләштерелгән әдәби әсәр. *Драма труппасы зур күләмле әсәрләргә дә кыю алына, татар һәм рус язучыларының әсәрләре буенча әзерләнгән инсценировкалар уйнала башлый.* Ш.Рахманкулов. --- *җыелышта баш режиссёрыбыз Гали ага Хөсәенов Галимҗан Ибраһимовның «Казак кызы» романы буенча алты сериягә исәпләнгән инсценировканың эшләнеп бетүен --- хәбәр итте.* Казан утлары. *Быел җиңүчеләр ике номинациядә билгеләнәчәк. Беренчесе – «Иң яхшы татар пьесасы», икенчесе – «Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романдилогиясенә иң яхшы инсценировка».* Сөембикә

2) *күч.* Кемне дә булса ялгыштыру, алдау өчен эшләнгән эш, гамәл. *Бу вакыйга, ничектер, алдан әзерләп куйган инсценировканы хәтерләтте.* И.Юзеев. *Шушы хыянәтче кабахәт, кораллы өч кеше белән бергә төрмә больницасына барып, тегене, чекага допроска илтәбез, дип алып чыккан, һәм шунда юк булганнар. --- Оешулы инсценировка ясалган.* Ш.Камал

**ИНТЕГРАЛ** *и. лат. мат.* Чиксез кечкенә саннар суммасы булган бөтен зурлык. *Карт профессор Бартельс математиканы акрынлап аңа тапшырып бетерде диярлек: башта тригонометрияне бирде, --- тора-бара, дифференциал һәм интеграл хисаплауны тапшырды.* Ж.Тәрҗеманов. *Безнең гасыр башында «интеграл» төшенчәсенең төрлечә гомумиләштерелүе француз математиклары А.Лебег (1875 – 1974), --- тарафыннан башкарыла.* Алгебра һәм анализ башлангычлары. *Даими тапкырлаучыны интеграл тамгасы тышына чыгарырга мөмкин.* Югары математика нигезләре

**ИНТЕГРАЛЛА́У** *ф. мат.* Алмаш зурлык интегралын табу. *И.Кеплер үзенең атаклы планеталар хәрәкәте законнарын чыгарганда, асылда, якынча интеграллау идеясенә таяна.* Алгебра һәм анализ башлангычлары. *Интеграллау гамәле – дифференциаллауга кире гамәл.* Югары математика нигезләре. *Ньютонның укытучысы И.Барроу (1630–1677) интеграллау һәм дифференциаллау арасындагы бәйләнешне аңлауга якынрак килә.* Фән һәм тел

**Интеграллап бетерү** Башыннан ахырынача интеграллау, барысын да интеграллау

**Интеграллап чыгу** Башыннан ахырынача интеграллау

**Интеграллый башлау** Интегралларга керешү

**ИНТЕГРАЛЬ** *с.* Интегралга бәйле, интегралга бәйләнешле, табигате белән интеграл булган. *Интеграль исәпләү физикада, механикада һ.б. фәннәрдә киң кулланыла.* Югары математика нигезләре. --- *1696 елда математиканың яңа тармагының исеме – интеграль исәпләү --- барлыкка килә, аны И.Бернулли кертә.* Фән һәм тел. *Линияләр кайчагында «авыш» дулкыннардан, интеграль спиральләрдән, каймалардан торган.* Казан утлары

**ИНТЕГРАЦИОН** *с.* Киңәю, кушылу, берләшү процессы белән бәйле. *Интеграцион күренешләр тормышның икътисади, иҗтимагый, шулай ук милләт-тел сфераларында да чагылыш таба: телләрдә уртак, гомуми лексик-терминологик фонд барлыкка килә ---.* Төрки телләрдә сүзьясалышы проблемалары

**ИНТЕГРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *мат.* Алмаш зурлык интегралын табу алымы

2) *кит.* Нәрсәнең дә булса өлешләрен, кисәкләрен бер бөтенгә җыю. *XIX–XX гасырларда Казан татарларының милли мәгарифе шактый зур ресурс туплый. Европа стандартларын үзләштерә, актив интеграция чоры кичерә.* Сөембикә

3) *икът.* Икътисади хезмәттәшлекнең киңәю, үзара яраклашу процессы; ике яки берничә дәүләтнең милли хуҗалыгын берләштерү, кушу; интернационализацияләү формасы. *Халыкара аренада мөһим үзгәрешләр була, державалар арасындагы көндәшлек хезмәттәшлек белән алышына. Интеграция процесслары үсә, бердәм икътисади киңлекләр (Көнбатыш Европа, Төньяк Америка һ.б.) барлыкка килә.* Бөтендөнья тарихы. *Глобаль интеграция процесслары шартларында мәдәниятара диалог мөнәсәбәтләрен ныгыту торган саен зуррак әһәмияткә ия була бара.* Мирас // Гомумән нинди дә булса өлешләрне, элементларны бергә берләштерү

**ИНТЕГРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* **1.** Интеграция ясау

**2.** *и. мәгъ. к.* **интеграция** (*3 мәгъ.*). *Аерым технологик чылбырларны, сәүдәне, банк структураларын интеграцияләүнең бу формалары продукцияне арттыруга, җитештерү потенциалыннан нәтиҗәле файдалануга стимул бирә.* Мирас. *Бу максатка исә хуҗалыкара кооперацияләр булдыру, авыл хуҗалыгы эшләрен интеграцияләү аша колхоз-совхозларны специальләштереп кенә ирешергә мөмкин.* Казан утлары

**Интеграцияләп бетерү** Тулысынча интеграцияләү

**Интеграцияләп тору** Һәрвакыт, даими интеграцияләү

**ИНТЕГҮ** *ф.* **1.** 1) Рухи һәм физик газаплар кичерү, җәфалану, газаплану. *Интегә иде Гөлзәйнәп, җаны кыйнала иде аның: ул чишенгән кешегә карарга ояла, пляжларны «шүрәле оясы» дип атый, шәһәр халкының бу кыланышын кыргыйлык дип саный иде.* М.Маликова. *Әмма Хәйрүш үз гомерендә бары тик иза чикте, җәфаланды, интекте генә...* М.Хәсәнов. *Соңгы көннәрдә холкы бозылып бетте Шәрәфнең, --- җитмәсә, йокысызлык чире белән интегә.* Л.Ихсанова

2) Нәрсәне дә булса эшли, башкара алмыйча, нинди дә булса мәсьәләне хәл итә алмыйча йөдәп бетү, аптырау. *Фәнияр аның [Балалайкинның] лекцияләрен тапмый интекте.* Ф.Яруллин. *Үз якларындагы нindидер бер авыл егетенә булган мәхәббәтен онытa алмый интегә ул мескен.* М.Фәйзи. *Анда --- сәяхәтчеләр белән тулы теплоход*

*һәм эреле-ваклы баржалар хәрәкәтсезлектән интегә иде.* Г.Кашапов

3) Көч түгү, мәшәкатьләнү, тырышу

4) Зарыгу, тилмерү, көтә-көтә ару. *Ялгыз торучылар --- җәйне җиткерә алмыйча интегәләр.* М.Галәү. *[Дәрвиш:] Моннан ерак җирләрдә, җәйләүләрнең берсендә яшәгән матур яшь бер киленнең ире яуга киткән. Бик сагынган, бик интеккән бу башта.* М.Кәрим. *Егет «кыз» дип интеккән, кыз «егет» дип интеккән...* М.Фәйзи

5) *сөйл.* Нәрсәгә дә булса мохтаҗ булу. *Күрше әби гел акчага интегә*

**2.** *и. мәгъ.* Рухи һәм физик газаплар; мәшәкать. *Ә юлда күпме интегүләр булды: әле вагон бukслары янып чыга, әле сатлык чиновниклар ялгыш юлга кертеп җибәргән була, әле паровоз сусыз, күмерсез кала: кая карама, корткычлык.* И.Низамов

**Интегеп бетү** 1) Тәмам, бик нык интегү. *[Әюп] Өч ел гомерен патша окопларында бурсып, немецларга каршы сугыша-сугыша бетләп, интегеп беткәч, бер изге бәндә аның күзен ачкан...* М.Хәбибуллин. *Ә менә яңа фатирга күчеп, үзбаш яшәргә калгач, кечкенәләре белән интегеп бетә язды Фәндилә.* Г.Ахунов. *Тәмам аптырап беттем бүген мин алар белән. Сырып алдылар да һаман, отрядыңа яз да отрядыңа яз, диләр.* В.Нуруллин

2) Тәмам зарыгу, тилмерү. *Көтә-көтә интегү*

**Интегеп йөрү** Озак вакытлар дәвамында интегү

**Интегеп тору** Һәрвакыт, даими интегү. *Һәрвакыт акчага интегеп тор[ам].* Ш.Камал

**Интегеп яту** Әле, хәзер интегү

**ИНТЕГҮЛЕ** *с.* Рухи яки физик газаплануны чагылдырган, рухи яки физик газаплардан, җәзалардан торган. *Г.Исхакый тормышның интегүле язмышлы Камәрләрен («Кәләпүшче кыз») әдәбият түренә китереп кертә.* М.Гайнетдин. *Үзеннән-үзе чәчрәп чыгарга кыҗраган сүзләрен ирене белән кысып, интегүле кыяфәттә тора.* М.Галиев

**ИНТЕКТЕРГЕЧ** *с.* Газаплый, җәзалый торган. *Актасның балчык карьеры! Илле беренче, илле икенче еллар! Иң авыр, иң газаплы интектергеч дәверем.* А.Гыйләҗев. *--- бәйсезлек аны [Хәбирне] туйдырды. Күңелендә бушлык, авыр һәм интектергеч бушлык хасил булды.* Ш.Хөсәенов. *Балаларга уку өчен булган китапларның үзләренә хас сыйфатлары: реаль нигезен югалткан фантазия, интектергеч әхлак, тел ярлылыгы.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИНТЕКТЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Рухи һәм тән газаплары кичерергә дучар итү, газаплау. *Йокым бик килсә дә, торып, әбиемне уяттым. – Мине йокысызлык чире интектерә, – дидем мин аңа.* А.Алексин. *Аякларым бик яман сызлап интектерә.* Л.Лерон

2) Зарыктыру, тилмертү. *Рушана! Көттереп, интектереп булса да хат яздың тәки.* А.Гыйләҗев

3) Җәфалау, азаплау, кыенлык күрсәтү. *Ичмасам, ботинкам чаңгыдан чыгып интектерә.* К.Кәримов. *Хәзер бәрәңге бакчаларын су басып интектерә!* З.Хөснияр

4) Нәрсәгә дә булса мохтаҗлыкка дучар итү. *Безгә бик аңлашылып бетмәгән су проблемасы интектерә.* Д.Гыйсметдин

**2.** *и. мәгъ.* Газаплар, физик интегүләр, авырлыклар. *Сугыш. Әсирлек. Газаплар, интектерүләр.* Ф.Галимуллин. *[М.Солтангалиевне] 1923 елның май аенда кулга алалар, бик озак интектерүләрдән соң, 1940 елның 28 маенда төрмәдә атып үтерәләр.* Әдәбият

**Интектерә башлау** Интектерергә тотыну. *Монголия бөлгенлегендәге көндәлек тормыш кыенлыклары инде күпләрне интектерә башлаган.* М.Гайнетдин

**Интектерә килү** Күптәннән, электән даими интектерү. *Әмма кайберләре, онытылмау гына түгел, хәтта онытылуларын бик теләгәндә дә, кабат-кабат искә төшеп интектерә килде.* Ә.Баян

**Интектереп бетерү** Бик нык, тәмам интектерү. *Эшләр яманга китте, акча да кызганмадым, Матрёнаны да яшердем – юк! Йөдәтеп, тинтерәтеп бетерделәр. Интектереп бетерделәр.* И.Тургенев

**ИНТЕКТЕРҮЛЕ** *с. к.* **интегүле**. *Фашистлар аларны [җәлилчеләрне] озак интектерүле үлем белән генә түгел, рухларын сындырып үтерергә теләделәр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ИНТЕЛЛЕКТ** *и. лат.* Аң, акыл, зиһен; кешенең уйлау, фикерләү сәләте, акыл үсеше дәрәҗәсе. *Үз-үзеңнән, бигрәк тә хаксызлыгыңны аңлагач, ихлас күңелдән көлә алу сәләтен «интеллектның югары формасы» диләр.* Тигез гомер итегез! *Безгә кеше организмының ясалма интеллект белән – робот белән кушылмасы бүген коточкыч бер азман булып тоелса да, иртәгә андый кибернетик организмнарның («киборг»ларның) чынга ашуы мөмкин түгелмени?* Мирас. *Ул [телевидение] интеллектка һәм талантка хезмәт итми, ә кешеләрне аңгырайту, кешелексезлекне пропагандалау коралына әверелә.* Казан утлары

**ИНТЕЛЛЕ́КТЛЫ** *с.* Фикерләү сәләте, акыл үсеше югары дәрәҗәдә булган. «*Бүгенге заманның югары интеллектлы укучысы сүз художнигының акыл һәм хис көчен чагылдырган кыска шигырьләрен юксына башлады», – дип яза, мәсәлән, «Сүзне олылау» мәкаләсендә Зиннур Мансуров.* А.Яхин

**ИНТЕЛЛЕКТУАЛ** *и. нем.* 1) Акыл яки рухи хезмәт белән шөгыльләнүче кеше. *Россиядә реалистик әдәбият аеруча зур масштабларда үсеш кичерә. Самодержавие интеллектуалларның һәм укымышлы кешеләрнең иҗади энергиясен сәяси эшчәнлектә гамәлгә ашыруын чикләгән ил, рухи тормышның дөньякүләм үзәге булып әверелә.* Бөтендөнья тарихы. *КПСС өлкә комитетының составы үзгәртеп кору елларында актив гражданлык позициясе белән танылган һәм элек номенклатурада тормаган яшь интеллектуаллар белән тулыландырыла.* Татарстан тарихы

2) Югары интеллектка ия кеше

**ИНТЕЛЛЕКТУАЛИЗМ** *и. лат.* 1) *филос.* Чынбарлыкны танып белү процессында акыл, интеллектка төп рольне биреп, аны реаль тою, тәҗрибәпрактикадан аерып карау

2) *к.* **интеллект**. *Әсәрләребезнең бөтенсоюз аренасында яңгыраш тапмавының бер сәбәбен мин нәкъ менә шул интеллектуализм җитмәүдән дип*

*уйлыйм.* С.Шәмси. --- *шәһәр материалы язучыдан, Р.Мостафин сүзләре белән әйтсәк, «гасырыбызның әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләре югарылыгында хәрәкәт итү»не таләп итәчәк. Моның өчен язучыдан да бик күп нәрсә сорала. Беренче чиратта, әлбәттә, интеллектуализм.* С.Шәмси

**ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ** *с. кит.* Акыл эшчәнлегенә бәйле; рухи. --- *интеллетуаль тормыш өчен бер бүлмә кысанрак шул.* М.Галиев. *Садри Максуди белән Индус Таһиров сәяси гамәлләре һәм интеллектуаль дәрәҗәләре буенча бер-берсенә бик тә охшаганнар.* Мирас. *Халыкның интеллектуаль, оештыру мөмкинлекләренә һәм үз язмышын үзе хәл итә алуына чын күңелдән ышанып, без үзебезне үзебез сынадык.* Фәнни Татарстан

**ИНТЕЛЛЕКТУА́ЛЬЛЕК** *и.* Интеллектуаль булу. *Безгә, аеруча яшьләргә, интеллектуальлек җитми, ди С.Шәмси.* И.Нуруллин. *Интеллектуальлектән минем күңелем бозыла хәзер.* М.Мәһдиев. *Гомәр ага башкаларның да фикерләү дәрәҗәсе югарылыгына, ягъни интеллектуальлегенә ышана, шуңа күрә яшәеш һәм үлем, яхшылык һәм начарлык, --- мөнәсәбәтләрен табуны укучының үзенә тапшыра.* А.Яхин

**ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ МИЛЕК** *и.* Закон тарафыннан саклана торган, акыл хезмәте белән тудырылган милек (әдәбият, сәнгать әсәрләре, фәнни хезмәт)

**ИНТЕЛЛИГЕНТ** *и. лат.* **1.** Интеллигенция катламыннан булган кеше; зыялы. *Бездә исә, хәтта университетлар коридорларында да, «зыялы», интеллигент адәмнәр сүзләрен тәмсезлиләр, кайчакта ачусыз, болай гына, «пар чыгару» өчен генә әшәке сүгенеп алалар ---.* М.Мәхмүтов. *Торабара, [Фәкыйбә әби] русча ярыйсы ук сукалый башлады. Хәтта шомарган интеллигентлар телендә генә йөри торган «автономно», «элементарно» кебек сүзләрне дә сүз сөрешенә кушып җибәргәли иде.* М.Галиев. *Коллык һәм эксплуатация законнарына буйсынган бер интеллигент та ирекле була алмый.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Укымышлы, культуралы, зыялы. *Гәрчә шундый дәрәҗәле, матур, интеллигент хатынның аны тиң итүенә борынын күтәрсә дә, бары --- мактанудан гына гыйбарәт иде.* Ә.Еники. *Шунда ишектән ялт кына урта яшьләрдәге интеллигент кыяфәтле бер ир-ат килеп керде.* Ф.Яруллин. *Джованни Джерманетто ифрат якты чырайлы, иркен күңелле, чын мәгънәсендә интеллигент кеше иде.* Казан утлары

**ИНТЕЛЛИГЕНТЛАНУ** *ф.* Культуралы, тәрбияле булу; зыялылык, интеллигент сыйфатлары күрсәтү

**Интеллигентланып йөрү** Әле, хәзерге вакытта интеллигентлык күрсәтү. *Аның шушы эше белән сүзләре бер Нугайбәкне генә түгел, коры манжетлар, ак якалар белән интеллигентланып йөргән башка берәүләрне дә шактый кызартты.* З.Бәшири

**ИНТЕЛЛИГЕНТЛЫК** *и.* 1) Интеллигент, зыялы булу. *Вафин, --- ирониясе көлү белән кабынып китте. – Менә ул гнилой интеллигентлык кайда. Имеш, кеше әйберенә кагылырга кулы бармый.* Ф.Хөсни. *Егетнең бусы чибәр дә түгел, тупасрак та, интеллигентлык та чамалы аңарда.* Ф.Галимуллин. *Зыяы кешегә санайсың үзеңне. Авырткан сөялгә гел басып тору «интеллигентлык» төшенчәсенә сыеп бетми түгелме соң?* Ф.Садриев

2) Укымышлылык, тәрбиялелек. *Сөләйман көмеш җепләр белән аралаша башлаган чем-кара куе чәчләрен сул кулы белән артка сыпырып куйды да торып басты. Аның кояшта янган тулы түгәрәк йөзендә интеллигентлык нуры яктыра.* Г.Әдһәмова. *Геройларның эрудициясенә, рухи байлыгына, интеллигентлылыгына кызыгасың.* Л.Ихсанова. *Мәһабәт гәүдәле, интеллигентлык манераларына ия булган, үзе эшли торган өлкәне яхшы гына белүче кеше итеп гәүдәләнә ул.* Казан утлары

3) *кимс.* Зыялыларга, интеллигентларга хас тискәре сыйфатлар (ихтыяр көче, тәвәккәллек җитмәү; йомшаклык, икеләнүчәнлек һ.б.). *Киресенчә, хәзер бу [җебегәнлек] интеллигентлыкны күрсәтә торган бер сыйфат итеп кенә карала бугай.* З.Фәтхетдинов

**ИНТЕЛЛИГЕ́НТЧА** *рәв.* **1.** Интеллигентларга, зыялыларга охшатып, интеллигентлыгын күрсәтергә тырышып. *Интеллигентча кылану*

**2.** *с. мәгъ.* Зыялыларга, интеллигентларга хас. *Соңыннан, торакка кайтып койкасына яткач, бу интеллигентча йомшаклыгы, сентиментальлегеге өчен [ул] үзен тиргәп ятты.* Г.Ахунов

**ИНТЕЛЛИГЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Фән, техника һәм мәдәниятнең төрле өлкәсенә караган махсус югары белемле һәм шул өлкәдә даими рәвештә акыл хезмәте белән шөгыльләнүче кешеләрдән торган иҗтимагый катлау. *[Күзлекле:] --- Үмеркәй тавышын ишетеп, хөрмәләр иленә башка әдипләр дә, җырчылар да, композиторлар да, кыскасы, бөтен татар интеллигенциясе агылачак.* Н.Әсәнбаев. *Халыкның мохтаҗлыкта яшәвенә, аның да иң ярлы катламы – интеллигенция булуына үзәкләрең өзелде.* Сөембикә. *Ул [университет] татар милли интеллигенциясенең киң катлавы формалашуга зур ярдәм итә.* Казан утлары

2) Шул социаль катлау кешеләре. *Иҗат интеллигенциясе вәкиле. Шагыйрә [диде күршесе].* М.Маликова. *Язучының «Казан каласы – таш кала» (1967), --- «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл интеллигенциясе – инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, врачлар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.* Татарстан язучылар берлеге белешмәсе

**ИНТЕНДАНТ** *и. фр.* 1) Армиядә хуҗалык эшләрен алып баручы һәм кирәк-ярак белән тәэмин итүче хәрби хезмәткәр. *Тупчы батареяларның корал-ярак белән тәэмин ителеше мәсьәләсе буенча Мостафинны полк штабына чакырдылар. Төрле бүлек интендантлары җыелган иде.* Х.Камалов. *[Шамил:] Сугыш чорында минем сыман интендантлар булмаса, ач карын белән кем атакага күтәрелә алыр иде!* Г.Әхмәтшин. *Печәнлек исәбен алмый ярамый, чөнки ул мөлкәтне дивизиянең интендант бүлегенә тапшырырга кирәк.* Г.Ахунов

2) Армиядә хуҗалыкны алып бару һәм кирәк-ярак белән тәэмин итү эше;

интендантлык хезмәте. *[Сидоров] капитан иде, ләкин интендант хезмәте буенча, ягъни хәрби тәэминат кешесе.* Ә.Еники

**ИНТЕНДАНТЛЫК** *и.* Армияне кирәк-ярак белән тәэмин итә һәм хуҗалыкны алып бара торган хәрби оешма. *Немецларның алгы кырыйдан качкан солдат ташкыны һәм бөтен индендантлык эшелоны шушы юлдан ашыгыч рәвештә Минскига таба агылган.* Ш.Маннур. *Вакытлыча өйдәш булып кергән квартираның хуҗасы Черноусов, --- күчмә госпитальләрнең берсендә интендантлык хезмәтен башкара.* Г.Ахунов

**ИНТЕНСИВ** *с. фр. кит.* **1.** 1) Көчле, киеренке, куәтле. *Макиндер раславынча, «эчке ярымай» иң интенсив үсеш алучы цивилизация зонасы булып тора.* Р.Сафин. *Патша хөкүмәтен бәреп төшерү, Бөек Октябрь казанышларын саклап калу --- өчен татар халкын көрәшкә тартуда вакытлы матбугатны масштаблы һәм интенсив файдалану Т.Насыйровның монографиясендә --- яктыртыла.* Казан утлары

2) Күп көч куелган, күп энергия сарыф ителгән. *Кызчыкны туу белән имезергә бирмәделәр, «интенсив терапия» бүлегенә салабыз, диделәр дә алып киттеләр.* А.Әхмәтгалиева. *Интенсив хезмәт*

3) Җитештерүчәнлеге югары булган, файдалы. *Икътисадны башлыча интенсив юлдан үстерүгә күчү бурычы үтәлми.* Татарстан тарихы. *1987 елдан башлап авыл хуҗалыгында гаилә подряды, интенсив хезмәт коллективлары пәйда була.* Татарстан тарихыннан хикәяләр. *Авыл хуҗалыгының интенсив системасы*

4) *күч.* Ачык, якты. *Балалар бүлмәсен җылы, шатлыклы, интенсив төсләр – алтынсу яки ачык кызгылт сарыга буяу әйбәтрәк.* Тигез гомер итегез!

**2.** *рәв. мәгъ.* Көчле, киеренке итеп. *Безнең көннәрдә милли стиль интенсив рәвештә үзгәрә, байый.* Татар әдәбияты тарихы. *Казан ханлыгы яулап алынгач башланган күченү Октябрь революциясенә кадәр интенсив рәвештә дәвам итә.* Идел. *Шәрык телләрендәге, шул җөмләдән иске татарча кулъязмаларны Россиядә интенсив рәвештә җыю, өйрәнү эше, мәгълүм булганча, Казан университетында ориенталистика белеменең барлыкка килүе, тернәкләнеп аякка басуы белән бәйле.* Фәнни Татарстан

**ИНТЕНСИВЛАШТЫРУ** *ф.* **1.** Интенсивлыгын арттыру, үсешен тагын да көчәйтү, интенсиврак итү. *Авыл хуҗалыгын химияләштермичә һәм интенсивлаштырмыйча, иген уңышын да, терлекчелекне дә үстереп булмый.* Казан утлары. *Сөт күп булсын өчен, терлекчелекне интенсивлаштыруга бәйле бик күп яңа кагыйдәләрне өйрәнергә кирәк иде.* Ватаным Татарстан

**2.** *и. мәгъ. к.* **интенсивлык**

**ИНТЕНСИВЛЫК** *и.* 1) Интенсив эшчәнлек, хезмәт киеренкелеге. *Химия куллану технологик процессларны гаять тизләтә, җитештерүнең интенсивлыгын шактый күтәрергә мөмкинлек бирә.* Бөтендөнья тарихы

2) Югары җитештерүчәнлек, тизлек. *Җылытканда, металл үткәргечнең электрүткәрүчәнлеге кими, чөнки температура күтәрелү электроннарның һәм металл атомнарының тәртипсез хәрәкәт интенсивлыгын арттыра ---.* Р.Шаһморатова. *Шунысы кызык: тән тиресенең арка һәм корсак өлешләре сулау интенсивлыгы ягыннан хәтта үпкәдән дә өстенрәк.* Кызыклы физиология

**ИНТЕНСИФИКА́ЦИЯ** *и. лат.* Нинди дә булса ресурсның һәр берәмлегеннән тулы файдалану юлы белән җитештерүчәнлекне күтәрү. *Егерме беренче еллар тирәсендә безнең авылда Әптел абзый --- сигез сыер асраган. Барысы да ябык, ди, җәй үзгендә өчәр литр сөт бирәләр, ди. Ләкин кеше арасында теге абзый «минем сыерым гына сигез баш» дип мактана торган булган. Интенсификациянең нәрсә икәнен белдегезме инде?* М.Мәһдиев

**ИНТЕНСИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. сир.* **1.** *к.* **интенсивлаштыру**. *Авыл хуҗалыгын интенсификацияләү*

**2.** *и. мәгъ. к.* **интенсивлык**. *Яруллин тегеңәр әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде. – Тем более! Хәзер колхозлар киң профильле. Шуның өстенә әле интенсификацияләү чоры...* М.Хәсәнов

**ИНТЕРАКТИВ** *с. ингл. информ.* Мәгълүматларны компьютер челтәре буенча тапшыруга һәм кабул итүгә нигезләнгән. *ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты укыту методикасы кафедрасы белгечләре тарафыннан «Мин татарча сөйләшергә телим» дигән интерактив кулланма чыгарылды.* Мәгърифәт. *Без музейларның барысын да заманча итеп эшләргә планлаштырабыз. Биредә интерактив экспозицияләр булдыру күз алдында тотыла.* Мәдәни җомга. *Барлыгы 5 кисәктән торачак интерактив кулланма ярдәмендә нибары 72 сәгать эчендә 200 сүз өйрәнергә мөмкин икән.* Ватаным Татарстан

**ИНТЕРӘТҮ** *ф. диал.* Тинтерәтү, йөдәтү

**Интерәтеп бетерү** Тәмам, бик нык интерәтү

**Интерәтеп тору** Һәрвакыт, гел интерәтү

**ИНТЕРВАЛ** *и. лат.* 1) Ике предметны, ике пунктны аерып торган ара. *Бу мәйданга керер алдыннан гына, ике колонна арасына интервал ясала ---.* М.Мәһдиев. *Хәситәнең урта рәтендә бизәкле челтәр рама эченә алынган дүртпочмаклы һәм түгәрәк шома фирәзә ташлар билгеле бер интервал аша тезелеп куелган.* Казан утлары

2) Типографиядә, машинкада, компьютерда җыелган басма тексттагы юлларны аерып торган, билгеле бер үлчәмдәге ара. *Беренче бүлек илле битләр чамасы иде. Икенчесе утыз биттән артып китте. Бер интервал аша җәмгысе сиксән биттән артык текст яздым.* А.Гыйләҗев

3) Ике эш арасындагы вакыт, ара. *Бу җырлар арасындагы интервал да әллә ни зур түгел, ике-өч тапкыр шикәр белән тәмләп чәй йотып куярлык кына вакыт иде.* М.Мәһдиев. *Төлке тавыш чыганагын кешегә караганда шактый төгәл билгели, аның ике колак арасы 10 сантиметр, ягъни тавыш бер колакка, күп дигәндә, 0,0003 секундка соңарып ишетелергә мөмкин.*

*Гадәттә, бу интервал шактый азрак.* Кызыклы физиология

4) *муз.* Бер үк вакытта яки бер-бер артлы яңгыраган ике авазның югарылыгы белән түбәнлеге арасындагы аерма. *Интервалларның төрлечә чиратлашуы нәтиҗәсендә яңа көйләр барлыкка килгән.* Ә.Бакиров

**ИНТЕРВЕНТ** *и. лат.* Интервенцияне оештыручы яки интервенциядә катнашучы кеше. *Шушы туганнар кабериндә интервентлар тарафыннан ерткычларча үтерелгән кешеләрнең мәетләре ята.* Г.Әпсәләмов. --- *иске тәртипләрне кире кайтарырга теләгән контрреволюция һәрьяклап һөҗүм итә, бу кара көчләргә илгә басып кергән Англия, Америка, Япония интервентлары булыша.* Ш.Рәкыйпов. *1918 елның 10 сентябрендә Казан акгвардиячеләрдән һәм интервентлардан азат ителә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ИНТЕРВЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Бер яки берничә дәүләтнең, коралы көч кулланып, икенче дәүләтнең эчке эшләренә тыкшынуы. *[Күзлекле:] Мөселман кардәшләребез булган басмачыларга ярдәм йөзеннән Франциядәге безнең генераллар гаскәр туплыйлар. Англия дә нидер вәгъдә итә. Интервенция башлану белән, без монда баш күтәрәчәкбез.* Н.Асанбаев. *Беренче бөтендөнья, аннары гражданнар сугышы һәм чит илләрнең хәрби интервенциясе, 1921 елгы ачлык аркасында Татарстан да авыр газаплар кичерә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

2) *фин.* Үзәк банкның теге яки бу валютаны сату һәм алу буенча биржа курсын саклауга юнәлдерелгән операциясе

**ИНТЕРВЕ́НЦИЯЧЕ** *и.* Интервенция ясаучы, илбасар

**ИНТЕРВИ́ДЕНИЕ** *и. лат. гр.-рус* Халыкара телевизион тапшырулар системасы һәм тапшыруның үзе

**ИНТЕРВОКАЛЬ** *с. лат. лингв.* Ике сузык арасындагы. *Болгар-татарларга гарәп һәм фарсы телләреннән кергән (Хәсән, Хәсәнә, Халисә һ.б.) кеше исемнәрендә интервокаль позициядәге саңгырау «с» тартыгының «з»га күчү очраклары юк.* Г.Саттаров

**ИНТЕРВЬЮ** *и. ингл.* 1) Матбугатта бастыру, радио яки телевидение тапшырулары өчен, корреспондентның кем белән булса да сорау-җавап формасында үткәргән әңгәмәсе. *Көяз журналист алган интервьюны мәркәз гәзитләре бик нык кыскартып һәм йомшартып баса ---.* Мирас. *95 яшь тулган көннәрдә ул [Г.Бәширов] газеталарга интервью биреп, мин һич тә үземне таякка таянып йөрүче карт дип уйламыйм, телләгем – берәр һәйбәт хикәя язу, дигән иде.* Сөембикә

2) Кайсы да булса матбугат басмасында урын алган, әңгәмә формасындагы мәкалә. *Баягынак язган интервьюларымны укып чыгыйм үзегезгә...* С.Баттал

◊ **Интервью биреп йөрү** Җенси тотнаксыз булу. *Мин бит турылыклы хатын. Минем матурлык икенче бер юньсезгә эләксә, ул хатын почмак саен интервью биреп йөрер иде.* М.Мәһдиев

**ИНТЕРВЬЮЕР** *и. рус кит.* Интервью алучы кеше

**ИНТЕРДЕНТАЛЬ** *с. лингв.* Телне аскы һәм өске тешләр арасына куеп әйтелә торган; теш арасы (тартык аваз) (мәс., Минзәлә сөйләшендәге «сакау» «з»). *Башка урындагы «с» авазы --- интерденталь (сакау) «ҫ» авызына алмашынып әйтелә.* Г.Алпаров

**ИНТЕРЕС** *и. рус сөйл.* 1) Аерым кеше яки җәмгыять файдасы, ихтыяҗы; мәнфәгать, кирәклек, сорау. *Бу вакытта алар [ир белән хатын], беренче чиратта, тулаем семья интересларыннан, бигрәк тә балигъ булмаган балалар интересларыннан чыгып эш итәргә тиешләр.* Тигез гомер итегез! *Без бит – дәүләт кешеләре, иң башлап, эшкә дәүләт интересы күзлегеннән чыгып карарга тиешбез.* Р.Ишморат. *Шуны истә тоту мөһим: бергә яши башлагач, аерым-аерым хатын һәм ир интереслары юк, сезнең уртак интересларыгыз гына бар!* Сөембикә

2) Файда, керем, табыш; кызыксынганлык. *Бары тик капиталистлар интересы өчен генә башланган бу канлы сугышның тизрәк бетүе кирәк.* М.Гали

3) *тар. икът.* Бурычка бирелгән акча өчен процент. *[Хиссәт] Ике ел микъдам бер кешегә мең ике йөз тәңкә акча биргән икән, шул кеше акчаны интереслары илән бергә китергән.* Г.Фаикъ

4) Берәр кешенең бөтен эчке дөньясын, уй-фикерен, тормышын биләгән, аның тормыш эчтәлеген тәшкил иткән күренеш. *[Гафифә] Үзенең бик вак: күлмәк-күнчек, кершән-иннек интереслары белән --- көлке халәттә күрсәтелә.* Ф.Әмирхан

**ИНТЕРМЕ́ДИЯ** *и. лат.* 1) *әд.* Спектакльнең актлары арасында башкарыла торган көлкеле кечкенә сәхнә әсәре, комик пьеса. *«Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасында --- пролог, эпилог һәм интермедиядән башка барлык күренешләр дә Әлмәндәр катнашында бара.* А.Әхмәдуллин. *Әдәби-драматик тапшыруларда кече формадагы әсәрләр, нәни инсценировкалар, интермедияләр зур урын ала.* Ш.Рахманкулов. *XVII–XVIII йөзләрдә интермедияләр бик еш күрсәтелгән.* Н.Гыйззәтуллин

2) *муз.* Музыкаль әсәрнең ике өлешен бәйли торган кечкенә пьеса. *1972 елда композиторның бер-бер артлы ике китабы дөнья күрде: берсе – «Безнең илләр» исемле җырлар җыентыгы, икенчесе – скрипка һәм фортепиано өчен язылган ике интермедия һәм бию.* Мирас. *Р.Абдикеев һәм З.Мостафиннар клоунлык жанрында искерә башлаган әзер юлдан китмиләр. Киресенчә, алар үз юлларын табарга, реприз һәм интермедияләрдә үз темаларын булдырырга омтылалар.* Казан утлары

**ИНТЕРМЕ́ЦЦО** *и. лат.* Фортепьяно, оркестр өчен иркле формада язылган кечкенә музыкаль әсәр

**ИНТЕРНАТ** *и. лат.* 1) Укучылар өчен тулай торак. *Мәктәп каршында авылдан килеп укучылар өчен интернат та ачылырга тиеш иде.* Ф.Хөсни. *Безне алырга колхоз машинасы килде, һәм без авылдагы мәктәп интернатына урнашуга, урамга белдерү элдек.* М.Мәһдиев

2) Картлар яки инвалидлар яши торган йорт. *Рәшидә әбинең өч улы да исән-сау, типтереп, шәһәрдә яшиләр. Кечесе Әдһәм интернатка килгәләп тора: әнисенең пенсиясен алып китә.*

Татар әдәбияты тарихы. *Тик менә 9 мең сумлык келәмнәр генә карт-корылар интернатына барып җитми ---.* Юлдаш

3) Ятим балалар даими тора һәм шунда тәрбияләнә торган урын. *Хак булса, ятим кызлар элек Дәрвишләр бистәсендәге интернатта тәрбияләнгәннәр икән.* Р.Камалетдинова. *Шушы көннәрнең берендә район газетасында үзебезнең Казнакай интернаты балаларының ачык хаты күзгә чалынды.* М.Хәсәнев. *Мин утыз ел буена ятим балалар интернатында эшләдем.* Ватаным Татарстан

4) *к.* **интернат мәктәп**. *Балаларны интернатка, атналык мәктәпкә урнаштырырга кирәк.* А.Расих. *Ачлык үткәч, Габделкәрим абзыйлар яңадан авылга кайткан, кызлар «Үрнәк тәҗрибә» мәктәбенең интернатына күчерелеп, шунда укырга калганнар.* М.Әмир. *1959 елда Азнакайда да интернат мәктәп ачылды. Бу интернатка балалар республиканың төрле почмакларыннан җыелды.* Ватаным Татарстан

**ИНТЕРНА́Т ЙОРТ** *и. к.* **интернат** (*2 мәгъ.*). *Арча районының Яңа Чүриле бистәсендә төзелеп бетмәгән интернат йортны күргәнсездер? Ул бит картлар йорты булачак.* Г.Ахунов. *Борһановка интернат йортларны ремонтлау, яңаларын төзүне тапшырсак, ничек булыр икән?* Г.Ахунов

**ИНТЕРНА́Т МӘКТӘП** *и.* Уку һәм яшәү өчен шартлары булган, укучылар торып укый торган, дәүләт дотациясендәге мәктәп. *--- апа, бер дә хафаланмагыз, малайны Акчишмәгә интернат мәктәпкә илтеп урнаштырабыз.* Ф.Сафин. *Моңарчы тугыз яшьлек улы өйдә булган. Хәзер ул интернат мәктәптә укый икән.* М.Хәсәнов. *--- кайчандыр Казанның 10 нчы интернат мәктәбендә тәрбияләнүчеләр бу язманың герое укытучы-тәрбияче Ләлә Әлмиевна Галиева икәнен әллә кайчан таныганнардыр инде.* Сөембикә

**ИНТЕРНАТУ́РА** *и. лат.* Белгечлек буенча диплом яклаган яшь табибның клиника яки хастаханә каршында шул белгечлеккә хокук бирә торган стажировка (гадәттә бер ел) үтү формасы. *Институтны тәмамлагач, кызны интернатурага калдырдылар.* Г.Әдһәмова

**ИНТЕРНАЦИОНАЛ** *и. лат.* 1) Халыкара оешма. *Маркс Беренче Интернационалның нигезен салган.* М.Максуд. *Самарада Мостафа Сөбхи РКП(б) Үзәк Комитеты һәм Коммунистик Интернационалның Башкарма комитеты җибәрүе буенча Төркестанга барышлый туктый.* Казан утлары

2) Башта – большевиклар, соңыннан Коммунистлар партиясенең гимны. *Машина килә пар белән, эче тулы мал белән; Капиталга каршы барыйк Интернационал белән.* Җыр. *Бөтендөнья пролетариатының сугышчан көрәш гимны булган «Интернационал» авторы Эжен Потьеның иҗаты турындагы «Коммунар һәм шагыйрь», --- кебек мәкаләләре әнә шундый максатны күз алдында тотып язылган.* Ш.Хамматов. *Корылтай әгъзалары «Интернационал»ны җырлыйлар һәм таралалар.* Татарстан тарихы

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯ** *и. рус к.* **интернациональләштерү**

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМ** *и. лат.* Расасына, милләтенә карамыйча, барлык халыкларның азатлыгы һәм тигез хокуклылыгы, дуслыгы һәм хезмәттәшлеге, шулай ук милләтчелеккә һәм шовинизмга каршы көрәштә халыкара бердәмлеге. *Бу – хезмәт ияләренең туганлык, интернационализм сыйфатлары иде.* Х.Госман. *Милли мәдәниятеңне ташлап, ана телеңне белмичә, гел русныкына күчү ул һич кенә дә интернационализм түгел.* Идел. *--- интернационализмны күкләргә чөеп мактаган бер философ хәзер инде Бәйрәмованы «татарның Жанна д'Арк»ы итеп күрсәтә башлады.* Фәнни Татарстан

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТ** *и. рус* Интернационализм идеяләрен яклаучы, интернационализм тарафдары. *Әнә хәзер минем кебек интернационалистлар Чечняда кеше үтерә.* З.Мәхмүди. *Казан сагында --- интернационалистлар отряды, 1 нче мөселман социалистик полкы, 1 нче татар-башкорт батальоны, --- һәм башка көчләр тора.* Татарстан тарихы. *Халыкара революцион хәрәкәттә бердәмлек кирәклеген күренекле интернационалист әнә шулай кискен куя һәм бу юлда Коммунистлар партиясенең тоткан урынын югары бәяли.* Казан утлары

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТИК** *с.* Интернационализм белән сугарылган; интернационализм принципларына нигезләнгән. *[Оешма] --- революциядә пролетариатның җитәкчелеген тәэмин итүгә булышты, хезмәт ияләрен революцион һәм интернационалистик рухта тәрбияләүдә зур эш башкарды.* Казан утлары

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЧЫ** *и. к.* **интернационалист**. *Горькийның без халыклар дуслыгының аваз салучысы, төрле халыкларның үзара мөнәсәбәтендәге бу изге юнәлешне революциягә кадәр үк фидакарьләрчә тырышлык белән алга сөрүче интернационалчы булarак та ихтирам итәбез.* Г.Бәширов

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ** *с.* 1) Халыкара. *--- революционер төрек, фарсы, һинд һәм башка көнчыгыш халыкларыннан төзелгән интернациональ отрядларда политик тәрбия алып баруны оештыра...* И.Низамов. *Бу вакытта Самарада Төркестан халыкларына интернациональ ярдәм күрсәтү өчен татар һәм башкортлардан формалашкан хәрби частьлар да күп була.* Казан утлары

2) Барлык милләтләр өчен уртак, гомуми. *Монда шуны искәртеп китү кирәк: аларның күбесе – интернациональ фәнни-техник терминнар яки Россия халыклары өчен гомуми сүзләрне алмаштыру өчен ясалган лексик берәмлекләр.* Р.Йосыпов. – *Әстәгъфирулла! – диде Халисә. – Ике татардан туган малай ни өчен әле ниндидер интернациональ исем йөртергә тиеш?!* Ф.Яруллин. *Татар поэзиясенең яңа элементларында милли белән интернациональ сыйфатлар бер булып тудылар.* Х.Госман

3) Интернационализм принципларына туры килгән, шуңа нигезләнгән, интернационализм рухында булган. *Сугышка кадәрге елларда партия һәм хөкүмәт органнары, --- совет халкын интернациональ рухта тәрбияләү буенча зур эш алып бардылар.* Г.Сабирҗанов. *--- партия активының бер җыелы-*

*шында Ф.Ә.Табеев болай ди: «Республикада интернациональ тәрбия өчен яхшы нигез бар. Бездә һәр җитештерү коллективы күпмилләтле».* Татарстан тарихы

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф.* Интернациональ, халыкара итү

**Интернациональләштереп бетерү** Тулысынча, бөтенләй интернациональләштерү

**ИНТЕРНАЦИОНА́ЛЬЛӘШҮ** *ф.* **1.** Интернациональ, халыкара булу. *Милли культураларның аерым-аерым үсешен һәм яшәвен хәзер күз алдына китерүе дә кыен. Тормышның интернациональләшүе гаять кызу бара, культураларның үзара якын килүе, тоташуы – күз алдында.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* Гомумилек, уртаклык; интернациональ, халыкара булу. *Рәсми пропаганда интернациональләшүне бары тик уңай күренеш дип расларга тырыша.* Татарстан тарихы

**Интернациональләшә бару** Тагы да интернациональләшү, торган саен ныграк интернациональләшү. *Моңлы татар көйләре язучы композиторларыбыз кимегәннән-кими, алар ауруналаша, ягъни интернациональләшә баралар.* Т.Миңнуллин. *Бу, иң элек, интернациональләшә барып, нигездә, инглиз телендә үскән фәнгә кагыла ---.* Идел

**Интернациональләшеп бетү** Тулысынча, тәмам интернациональләшү

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛЕК** *и.* 1) Бөтен милләтләр өчен гомуми, уртак булу сыйфатлары. *А.Мостафинның байтак чыгышлары әдәбиятта миллилек һәм интернациональлек, милли әдәбиятларның үзара йогынтысы һәм бер-берләрен баетулары --- кебек бөтен совет әдәбияты һәм әдәбият белеме өчен уртак мәсьәләләргә багышланган.* Ф.Миңнуллин. *--- төрле милләт яшьләре мәхәббәт тойгысы нигезендә өйләнешәләр. Ир белән хатын мөнәсәбәте милләтара мөнәсәбәт түгел. Интернациональлек – катлаулырак, җаваплырак нәрсә.* Идел. *Моңа аеруча характерлы мисаллар булган М.Гафури һәм Ш.Бабич иҗатлары, социализм заманы әдәбиятларында миллилек белән интернациональлек арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекле якларын өйрәнү өчен, кызыклы материал да бирәләр.* Казан утлары

2) Интернационализм принциплары белән сугарылганлык, аңа нигезләнгәнлек. *Азатның сабыры ычкынды: – Ул интернациональлек бурычын үтәү безгә бик кыйммәткә төште. Берәүләргә – баш бәясенә, икенче берәүләргә – аяк-кул бәрабәренә.* Н.Хәсәнов

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЧЕ** *и. к.* **интернационалист**

**ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЧЕЛЕК** *и. к.* **интернационализм**

**ИНТЕРНЕТ** *и. ингл. информ.* Дөньяның теләсә кайсы почмагыннан торып, файдаланучыларга шәхси компьютер ярдәмендә мәгълүматларны кабул итү һәм тапшыру, гомумән, бер-берсе белән аралашу мөмкинлеге тудыра торган халыкара электрон челтәр. *Ит җыючы әрмәннәргә абзардагы бөтен мал-туарын тапшырса тапшырды, барыбер шул «компьютер» дигән уенчыкны сатып алу бәхетенә ирешге. Әле, интернетка тоташтырып бирсәләр, Регина әбинең оҗмах белән элемтәгә кереп карарга да исәбе бар...* К.Кәримов. *Латин хәрефләреннән торган GPRS һәм WAP кебек сәер комбинацияләр телефонның интернет белән эшләү мөмкинлеге барлыгын күрсәтәләр.* Асылъяр. *Гәрчә инде хәзер кешелек тә бик белемлегә әйләнеп, компьютерлар, интернет пәйдә булып, аның аша аралашу өчен дөнья киңлеге ачылды.* Сөембикә

**ИНТЕРНЕТЛАШТЫРУ** *ф. информ.* Интернет челтәрен киңәйтү

**Интернетлаштыра башлау** Интернетлаштыру эшенә керешү

**ИНТЕРНЕТЧЫ** *и. сөйл.* Интернет челтәреннән файдаланучы. *--- мин --- татар интернет сөйләменең дә аңа гына хас --- асыл сыйфатларын истә тотарга, беренче чиратта, үземнең интернетчы буларак бурыч-максатларыма җаваплы килеп, истә тотып, төгәл үтәргә тырышам.* И.Низамов. *Шул ук вакытта интернетчыларга яңа иҗади эзләнүләрендә, омтылышларында азмы-күпме файдасы тимәсме дип, социолингвистик күзәтүләребезне бастыруны дәвам иттерәбез.* Мәдәни җомга

**ИНТЕРПОЛ** *и. ингл.* Җинаятьчелеккә каршы көрәштә халыкара полиция оешмасының кыскартылган исеме (җинаятьчеләрне теркәүнең халыкара үзәге буларак, җинаятьчелектә гаепләнүчеләрне, хәбәрсез югалганнарны, урланган кыйммәтле әйберләрне эзләүне координацияләү белән шөгыльләнә). *– Икегез дә милициядәнме? – Юк, – дидем, елмая төшеп. --- – Интерпол алайса? – диде ул, тагы да җитдиләнеп.* Р.Мөхәммәдиев. *--- Булатовны җинаять җаваплылыгына тарту турында карар чыгарылды, һәм ул халыкара эзләүгә тапшырылды. Узган елның 12 февралендә җинаятьче Интерполның Испания милли бюросы тарафыннан тоткарланды.* Ирек мәйданы. *Иртән кызым белән Интерполга киттек. Эзләтеп караган идек, шикләребез расланды: «Улыгыз Порту шәһәрендә бер үтерешнең корбаны булды ---», – дигән язу килде.* Юлдаш

**ИНТЕРПОЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *мат.* Билгеле булган ике зурлык арасындагы аерманы билгеләү. *Хикмәт шунда: 1959 елда СССРда халык санын алу мәгълүматларын интерполяция ысулы белән тикшерсәң, сугыш елларында Татарстан халкы --- Белоруссия халкына караганда да күбрәк процентка кимегән булып чыга...* Мирас

2) *лингв.* Нинди дә булса әсәрне күчереп язганда, күчереп язучы тарафыннан өстәлгән сүзләр һәм җөмләләр

**ИНТЕРПРЕТА́ТОР** *и. лат. кит.* Интерпретация ясаучы. *Совет җырларын башкару өлкәсендә ул [А.Аббасов] үзенчәлекле интерпретатор буларак танылды.* Казан утлары

**ИНТЕРПРЕТА́ЦИЯ** *и. лат. кит.* 1) Нәрсәне дә булса аңлату, аның эчтәлеген, асылын ачып бирү, күрсәтү. *Болар арасыннан бары тик Йосыф кына (биредә без тагын дини риваятьләрдәге Йосыф образының үзенчәлекле интерпретациясе белән очрашабыз) олы максат өчен дә, аерым бер кешенең язмышы өчен дә көрәшергә әзер, һәм көтелмәгән бер очраклылык аркасында гына ул Зөләйханы бәладән*

*коткара алмый кала.* Д.Вәлиев. *Комплекслы саннарның тригонометрик интерпретациясе*

2) Нинди дә булса музыкаль әсәрне яки берәр образны музыкант, режиссёр, актёр һ.б. тарафыннан иҗади рәвештә гәүдәләндерү

**ИНТЕРФЕЙС** *и. ингл. информ.* Хисаплау системаларын үзара тоташтыра торган бердәм элемтә һәм сигналлар системасы. *«Яндекс» интернет-компаниясе мәгълүматларны татар телендә дә бирә башлый, ягъни ул татар телендәге сорауларга да җавап бирәчәк. Порталның төп бите, эзләү интерфейсы һәм «Яндекс. Почта» интерфейсы ике дәүләт телендә – урыс яки татар телендә эшли.* Мәдәни җомга

**ИНТЕРФЕРЕНЦИОН** *с.* Интерференция күренешләренә бәйле. *«До» предлогының татар теленә интерференцион йогынтысы бар.* Р.Йосыпов. *Күплек формасында гына кулланыла торган рус исемнәре татар теленә интерференцион йогынты ясыйлар.* Р.Йосыпов

**ИНТЕРФЕРЕ́НЦИЯ** *и. лат. физ.* 1) Когерент (тавыш, яктылык, электр һ.б.) дулкыннарның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә, аларның көчәюе яки кимүе. *Интерференция күренеше су өстендәге дулкыннарда гына түгел, һәртөрле дулкыннарда да: тавыш дулкыннарында да, электромагнитик дулкыннарда да һәм башкаларда да булырга мөмкин.* А.Перышкин

2) *лингв.* Билингвизм (икетеллелек) шартларында ике тел системасының үзара бер-берсенә йогынтысы, тәэсире; кисешүе. *Татар әдәби теле, шулай итеп, язма «төрки»нең «халык теле» белән интерференциясе нәтиҗәсендә үскән.* Р.Әхмәтьянов. *--- морфологик интерференциягә, лексика-фразеологиядәге кебек, ике телнең бер-берсенә якын категория һәм формалары дучар була.* Р.Йосыпов

**ИНТЕРЬЕР** *и. фр.* 1) *архит.* Бинаның эчке ягы, аның эчтән архитектура һәм сәнгать чаралары белән бизәлеше. *«Интерьер» «эчке» дигәнне аңлата. Хәзерге заман квартирасына куллансак, интерьер – кешенең планировка, җиһазлау, буяу-бизәү, зиннәтләү кебек чаралар белән барлыкка китерелгән торагы ул.* Тигез гомер итегез! *Агачтан ясалган җиһаз һәм архитектура элементлары гаҗәп күп булса да, алар интерьерны тыгызламый.* Сөембикә. *Алар – зур булмаган интерьерларны бизәүче яктылык музыкасы җайланмалары.* Казан утлары

2) *сәнг.* Бинаның эчке күренеше сурәтләнгән картина, рәсем. *60–70 нче елларда Татарстанда декоратив сәнгать белән интерьерны берләштерергә омтылган бер төркем рәссамнар барлыкка килә.* Г.Вәлиева. *--- интерьер революциягә кадәр үк сырлап-бизәп салынган бинаның тышкы күренешенә, зур көзгеле, сырлы кәрнизле, мәрмәр баскычлы вестибюленә һич туры килми иде.* М.Маликова

3) *анат.* Хайваннарның эчке төзелеше, аларның продуктлылыгы һәм нәсел сыйфатлары белән бәйле биохимик һәм физиологик үзенчәлекләре

**ИНТИЗАМ** *и. гар. иск. кит.* 1) Тәртип, кагыйдә буенча эш йөртү. *Йорт эчендә дә элгәреге низам вә интизам бетте.* Г.Исхакый. *Шул кадәре үзгәлеге булды: Анна Васильевна театрга йөрү мәсьәләсен бер интизамгарак куйды.* Г.Исхакый

2) Дөрес, даими, регуляр. *Сөйләгән вакытта исә сулауның бу интизамы бетә.* Җ.Вәлиди

**ИНТИЗАР** *и. гар. иск. кит.* **1.** Зарыгу, зарыгып көтү, күз текәп көтеп тору. *Шулай бик интизар берлә көтә торгач, берничә минуттан соң максутым хасыйль булды.* Г.Тукай

**2.** *хәб. функ. к.* **интизар булу**

**ИНТИЗА́Р БУЛУ** *ф.* Зарыгу, зарыгып көтү; зарыктыру, зарыктырып көттерү. *--- падишаһ бу күңелсез хәбәрдән, Мәҗнүн Ләйләсенең аерылуыннан аһ-ваһ иткән кеби, зар вә интизар булып, тәмам һушыннан язды.* Дастан. *Зариманы бер күрергә интизар булган Бакый аның «үзем чакырырмын»ын көтеп ята алмады, инде ничә рәт килеп китте...* М.Галиев

**ИНТИЗА́Р ИТҮ** *ф. к.* **интизар булу**. *Тиз килерме, ди-ди интизар иттем.* Г.Кандалый

**ИНТИКАД** *и. гар. иск. кит.* Тәнкыйть. *Яки уйга калдырадыр интикад, итмәсәм дә мин аңа күп илтифат.* Г.Тукай

**ИНТИМ** *с. фр. кит.* 1) Үтә шәхси, яшерен. *Югары патриотик тойгылар, идеяләр бик табигый рәвештә интим сөйләшү темасына әйләнеп китәләр.* Ф.Галимуллин. *Биредә [әсәрдә] үтә шәхси, интим, туганлык мөнәсәбәтләре белән ил, дәүләт, йола, сәүдә мәсьәләләре гаҗәп катлаулы, тыгыз булып үрелгән.* Мирас

2) Мәхәббәт, гыйшык, хис белән бәйле; җенси. *Хәтта кызлар арасында бер көнне укытучылар: «Егетләр белән интим мөнәсәбәткә кергәнегез бармы?» – дип, яшерен анкета уздырдылар.* Ф.Яруллин. *Ирләр белән хатыннарның күпчелеге интим тормышның иң гади кагыйдәләрен дә белми.* Тигез гомер итегез! *Интим тормышның җайга салынмавы турында хәзер иптәш хатынга түгел, сексопатологка --- зарланалар.* Сөембикә

**ИНТИМЛЫК** *и.* Уйларның, хисләрнең яшеренлеге. *Нәркәс, Илдархан һәм Исәнбәк Әнис алдына йөрәк серләрен ачып салалар, ---. Менә шушы ачыклык, интимлык һәм серләрне сөйләгәндәге ышанычлылык әсәрнең үзенә бертөрле ягымлы стилен барлыкка китерә.* Татар әдәбияты тарихы

**ИНТОКСИКА́ЦИЯ** *и. лат.-гр. биол.* Организмның үзендә барлыкка килгән яки тышкы тирәлектән эләккән агулы матдәләр белән зарарлануы, агулануы

**ИНТОНАЦИОН** *с. лингв.* Интонацияле, интонациягә кагылышлы, интонациягә хас. *Телне тел итеп тоткан, аны башка күп төрле телләрдән аерып торган төп нәрсә, төп билге – аерым сүзләрнең сөйләм тәшкил итү, җөмләләр, әйтелмәләр булып берләшү, шул берәмлекләр эчендә үзара мәгънәви, интонацион мөнәсәбәтләргә керү тәртибе дә.* Р.Йосыпов. *Мелодик стиль, лад, интонацион башкарылу рәвеше һәм хәтта тембр ягыннан аерылып торган көйләр бер үк кеше тарафыннан һәркайсы табигый рәвештә --- башкарыла.* Казан утлары

**ИНТОНАЦИО́Н ШИГЫРЬ** *и. әд.* Төрле ритмик үлчәмдә язылган шигырь. *Такташ татарларның борынгыдан ук килгән --- интонацион шигырьнең классик үрнәген бирде.* Х.Госман

**ИНТОНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *кит.* Сөйләүченең эчке тойгысын, кичерешләрен чагылдырган тавыш үзенчәлеге; сөйләү манерасы. *Китапны яшен тизлеге белән кулыма алдым һәм, Сәйфи абзыйга да, башкаларга да ярарга тырышып, диалогларны үземә күрә интонация белән укырга тотындым.* Г.Галиев. *Һәркемнең сөйләшүендә үзенә бер үзенчәлек, башкалардан аерма була бит. Сез аның белән берничә тапкыр сөйләшкәнсез, бәлки, үзенә генә хас сүзе, интонациясе исегездә калгандыр?* М.Маликова. *Тавыш интонациясенә, сөйләшү алымына карап, шалтыратучының синең түрәңнән зурракмы, кечерәкме кеше икәнлеген аерасың.* Ф.Яруллин

2) *лингв.* Югары һәм түбән тавышларның телдә чиратлашуы, кеше сөйләменең ритмик-мелодик төзелеше. *Әсәрнең бөтен сюжеты, композициясе, интонациясе, тел-тасвир чаралары – һәммәсе дә антитезага корылган.* Х.Госман. *[Балага] «Яхшы» һәм «начар» дигән иң беренче бәяләү сүзләре интонация белән, кайчагында мимика һәм ишарәләр белән әйтелә, һәм алар әлеге сүзләрнең тәэсирен көчәйтә.* Тигез гомер итегез! *Татар шигыренең традицион көйле интонациясеннән сөйләү интонациясенә таба борылыш ясавы да С.Рәмиев исеме белән бәйле.* Әдәбият

3) *муз.* Җырлаганда яки музыка коралында уйнаганда, тавышның, тонның күтәрелү-төшү ягыннан дөреслеге; яңгыраш югарылыгының төгәллеге. *Насретдиновның лирик теноры, чынлап та, интонациягә искиткеч бай, көмеш чишмә челтерәведәй саф; татар халкының күңел түрендәге моңын үзенә алган тавышын тибрәндереп җырлап җибәрсә, үзәкләргә үтәрлек моң тарала торган иде.* Х.Кумысников

4) *күч.* Әдәби әсәрдә, сәнгатьтә, иҗатта үзенә генә хас эш алымнары, шәхси характерлы үзенчәлекләр җыелмасы. *В.Ганиевнең үз тәрҗемәләрендә ачыклык, интонация чисталыгы хас, алар чуарлыктан, ялган пафостан азат.* Ә.Гаффар. *Әсәрдә – татар язмышы интонациясе. Сәхнәдә – Марсель Сәлимҗанов интонациясе. Эчке кичерешләрнең сыннардагы Бакый Урманче интонациясе*

**ИНТРИ́ГА** *и. лат.* 1) Берәр максатка ирешү өчен астыртын алып барылган мәкерле эш, начар якны күпертеп күрсәтү. *Өстәвенә, әлеге Исәнтәй-Банхуа, астыртын эш йөртеп, интригалар коруны дәвам иттерә, тархан бикәләре арасында гына түгел, ырулар һәм дәүләт арасында да конфликтлар китереп чыгаруга ирешә.* Мирас. *Ни генә булмасын, [Нурихан Фәттах] кыек-мыек эшләр белән, интригалар белән шөгыльләнмәде, монысы шиксез.* Сөембикә. *Ә инде мин «Советская Татария» газетасының мөхәррире булгач, ул [Хамматов] --- җаваплы кешеләр белән таныштырды, сәяси интригаларның механизмнарын «үзләштерергә» ярдәм итте.* Казан утлары

2) *әд.* Әдәби әсәрдәге образларның кискен көрәшен чагылдырган рухи бәрелешләрдән гыйбарәт сызыгы. *Әсәрдә комик интрига, һәртөрле аңлашылмаучылыклар оста корылган.* Г.Рамазанов

3) *иск.* Гыйшык, мәхәббәт бәйләнеше

**ИНТРИГАН** *и. фр.* **1.** Интрига (*1 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче, мәкерле, астыртын кеше. *Кыек авызлы, кыек уйлы бу интриган һәрчак иснәнеп кенә йөри, уенда – гел мәкерле ниятләр.* Мирас

**2.** *с. мәгъ.* Интрига (*1 мәгъ.*) белән шөгыльләнүчән, мәкерле, астыртын. *Зәки Вәлиди белән аларның үзара аңлаша алмаулары да шул нигездә килеп чыга. ...Интриган Сталинга нәкъ менә шул кирәк.* Г.Ахунов

**ИНТРИГАНЛЫК** *и.* Интриган булу

**ИНТРИ́ГАЧЫ** *и. к.* **интриган**

**ИНТРИ́ГАЧЫЛЫК** *и.* Кешеләр арасын бозу өчен мәкерле, астыртын эш итү белән шөгыльләнү

**ИНТРОСКОП** *и. лат.-гр.* Ультратавыш яки радиодулкыннар, рентген нурлары яки ультракызыл нурланыш ярдәмендә җисемнәрнең составларын яисә әйләнә-тирәдәге объектларның эчендә барган процессларны, күренешләрне күзәтү, тикшерү әсбабы. *Интроскоп ярдәмендә телевизорны тикшерә башлагач, аның эчендә шартлый торган корылма барлыгы ачыклана.* Юлдаш

**ИНТРОСКОПИ́Я** *и. лат.-гр.* Үтәли күренмәгән әйберләрнең, бөтенлеген бозмыйча, интроскоп ярдәмендә эчке төзелешен күзәтеп тикшерү

**ИНТУИТИВ** *с.* **1.** Интуициягә, сиземләүгә нигезләнгән. *Иҗат процессында интуитив башлангыч өстенлек итми.* К.Гыйззәтов. *Беренче тәҗрибәдә үк кешенең интуитив фикерләве --- ярдәмгә килде.* А.Тимергалин. *Интуитив караш. Интуитив танып белү*

**2.** *рәв. мәгъ.* Интуициягә нигезләнеп. *Төрле журналлардан диеталар турында укыйм да, мин үзеннән-үзе, интуитив рәвештә шуңа киләм икән, дип уйлыйм.* Сөембикә

**ИНТУИТИВИЗМ** *и. лат. филос.* Дөньяны акылдан, фикерләүдән башка, бары интуитив кына танып белү мөмкинлеген раслаган фәлсәфи агым. *Әлеге [«Сәнгать – сәнгать өчен»] концепция[се]нең реалистик сәнгатькә каршы юнәлдерелгәнлеге Франция философы Анри Бергсон тарафыннан (1859–1941) интуитивизм теориясен эшкәртү өчен файдаланыла.* К.Гыйззәтов. *Н. Бердяев сәнгать теориясендә интуитивизм вәкиле булып санала.* К.Гыйззәтов

**ИНТУИ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Тәҗрибәгә таянып, дәлилләргә нигезләнмичә генә хакыйкатьне аңлау сәләте; эчке сизем, зирәклек. *Махсус юридик белеме өстенә, аның [прокурорның] хәзинәсендә «интуиция» дигән икенче бер корал да бар бит әле. Дәлилләргә дөрес юридик анализ-бәя бирүгә нигезләнгән төпле интуиция.* М.Насыйбуллин. *Яза башлаганда, рифма-ритм ишеләрне дә белмичә, бары интуициягә генә таянып каләмгә тотынучы кеше өчен бу фәннәрнең никадәр кыйммәтле байлык икәнен әйтеп тә торасы юк.* Ф.Яруллин. *Ата-ана интуициясенең ролен дә (ихтимал, ул аларның үз балачагына нигезләнәдер) инкяр итмик.* Тигез гомер итегез!

2) *филос.* Фәлсәфәдә: чынбарлыкны фәнни анализдан, фикерләп нәтиҗә чыгарудан башка сизү юлы белән танып белү

**ИНТУИЦИЯЛЕ** *с.* Нәрсәне дә булса алдан тою, сиземләү сәләте югары булган. *[Нәгыймә ханым Таҗдарова] Үткер, айнык акыллы, тирән интуицияле, индивидуаль сыйфатларга бай булган, чын мәгънәсе белән олы талантлы һәм киң диапазонлы сәхнә остасы.* Ә.Еники

**ИНҮ** *ф. диал. иск.* 1) *к.* **иңү**. *1156 сәнә эт елы, һава йөзендә бер койрыклы йолдыз пәйда булды, койрыгы кояш инеше тарафында иде, төн бер анча узганнан соң, мәгърибтә инәр иде.* Г.Гобәйдуллин. *Аның миңа төбәлеп уйчанлана башлаган чыраена яктылык инә, калын йомшак иреннәре елмая, күзләре чаткыланып нур бөрки.* Г.Ахунов

2) Төшү. *Әбүгалисина тәхетеннән инеп, бер кулына чыбык, бер кулына кабак алып, мәйданга килде.* К.Насыйри. *Беренче көннәрдә Шәмси, бигрәк Анна, шул һавада исерделәр, шаштылар. Иртәнге сандугачларның сайравы бетмәенчә тау башыннан инмәделәр.* Г.Исхакый

**Инә башлау** *к.* **иңә башлау**

**Инә төшү** *к.* **иңә төшү**

**Инеп бетү** *к.* **иңеп бетү**

**ИНФАНТИЛИЗМ** *и. лат. мед.* Организмның физик һәм психик үсешендә тоткарлык, җитлекмәү күренеше; балалык яшендәге физик яки психик сыйфатларның олыгайгач та сакланган булуы. *Җиңел формадагы инфантилизм дөрес дәвалаганда бетәргә һәм барлык функцияләр нормальләшергә мөмкин.* Азат хатын

**ИНФАНТИЛЬ** *с. кит.* 1) Җитлекмәгән. *[Гафил] --- җегәрле Одик белән чагыштырганда, хатын-кызларча матур иде. Кыяфәтендә инфантиль чалымнар да бар.* Р.Сибат. *Хәзерге көндә, заманыбызның рухын аңламыйча, аның бөек омтылышларын һәм таләпләрен искә алмыйча, әти-әни тапканга киенеп-ясанып, ресторан ашларын гына ашап, гитара чиртеп, рәхәт чигеп йөрүдән бүтәнне белмәүче инфантиль егетләребезнең берсе түгелмени?..* М.Әмир. --- *фикер йөртүе һәм үз-үзен тотуы буенча балалар яки өлгереп җитмәгән яшүсмерләр дәрәҗәсендә калган кешеләрне «инфантиль кешеләр» дип атыйлар.* Мораль нигезләре

2) Балалык яшенә хас. *Инфантиль тон. Инфантиль кыланыш*

**ИНФАНТИЛЬЛЕК** *и.* Инфантиль булу; җитлекмәгәнлек. *Инфантильлек, бала-чагалык --- үткен каләм ияләрен дә читләтеп үтмәде.* Мәгърифәт

**ИНФАРКТ** *и. лат. мед.* Артериянең кысылуы яки тыгылуы сәбәпле, кан әйләнеше кинәт бозылу нәтиҗәсендә орган яисә тукыманың аерым өлеше таркалу, үле хәлгә килү. *Сугыш беткәннән бирле колхозда председатель булып эшләгән Ибраһимны инфаркт бәреп екты.* Ф.Яруллин. *Башта «инсульт» диделәр. Ныклабрак карагач, инфаркт булмагае, дип шикләнделәр.* А.Гыйләҗев. *Булачак кандидатлар, докторлар больницаларга ятты, инфарктлар, инсультлар көндәлек хәбәргә әйләнде.* М.Мәһдиев

**ИНФЕКЦИОН** *с. мед.* 1) Йогышлы, йога торган, көчә торган. *Аның [Гашигуллинның] тырышлыгы аркасында үзәк больницаның яңа кирпеч бинасы салынды, аңа өстәп 35 урынлы инфекцион больница да булдырылды.* Казан утлары. *Ангина – күп очракта аңкау миндальсыман бизе үзгәрү нәтиҗәсендә туган инфекцион авыру.* Мәйдан

2) Инфекциягә бәйле, инфекция эләгү нәтиҗәсендә булган. *Фермада сөт планы тулмый, --- сыерларда инфекцион аборт.* Т.Гыйззәт

**ИНФЕКЦИОНИСТ** *и. рус* Йогышлы авырулар буенча белгеч; табиб. *Берәрсе эче авыртып килсә, ул [участок врачы] аның өчен үзе баш ватып утырмый, хирургка, инфекционистка я башка берәрсенә җибәрә.* М.Маликова. *Медицина җәмәгатьчелеге арасында хирурглар А.В.Вишневский, И.В.Домрачев, --- инфекционист А.Ф.Агафонов исемнәре югары абруй казана.* Татарстан тарихы

**ИНФЕ́КЦИЯ** *и. лат. мед.* 1) Авыру йоктыра торган микробларның организмга эләгүе һәм үрчүе. *Кызганыч, чөнки инфекция кичергәннән соң, балага уза алмау һәм бала төшү кебек аяныч хәлләр күзәтелә.* Сөембикә

2) Йогыш, йогышлы микроорганизмнар. *Тегендә – больницада чакта, врачлар, сестралар: «Инфекция эләкмәсен», – дип, ярага яба торган салфеткаларны пинцет белән генә тотып маташалар иде.* Ф.Яруллин. *Пешкән урыннарга һәм яраларга тозлы коньякта чылаткан тампон куйганнар: ярага инфекция эләкмәгән, ул тизрәк төзәлә торган булган.* Файдалы киңәшләр. *Грипп һәм вируслы инфекцияләрдән кала, ангина белән авыру очраклары үзенең ешлыгы буенча беренче урынны алып тора.* Мәйдан

**ИНФИЛЬТРАТ** *и. лат. биол., мед.* Организмның кайсы да булса өлешендә биологик сыекчалар һәм күзәнәк элементлары тупланып, шул урынның шешеп китүе. *Авыруның сәламәтләнә башлавына карамастан, 1928 елның ноябрендә тамакта туберкулёз инфильтраты башлана.* Г.Кутуй

**ИНФИЛЬТРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *биол., мед.* Организмда ялкынсыну продуктларының, шеш күзәнәкләренең тукымаларга үтеп керүе һәм туплануы

2) Сарку, үтү, саркып үтү (сыеклыклар турында). *Казан университеты хезмәткәрләре --- кар суларының саркып үтүе (инфильтрациясе) сәбәпле, җир асты сулары кимәленең үзгәрүе нәтиҗәсендә ызан агымнары кимүгә күбрәк игътибар бирәләр.* Фәнни Татарстан

**ИНФИНИТИВ** *и. лат. лингв.* Зат, сан һәм заман белән төрләнми торган (татар телендә *-ырга/-ергә, -рга/-рғә* кушымчалы) фигыль формасы. *Рус һәм татар телләрендәге күп кенә фигыль сүтезмәләрендә бәйләү чарасы булып инфинитив хезмәт итә.* Р.Йосыпов. *Чит тел, ни генә дисәң дә, чит бит инде ул! Дәресләрдә утырганда, «инфинитив», «перфект», «герундий»лар кемнең генә үзгенә үтмәгән...* М.Маликова. *Инфинитив – җөмләдә мөстәкыйль кулланылырга да, икенче фигыльгә ияреп килергә дә мөмкин.* Хәзерге татар әдәби теле

**ИНФЛЮЭ́НЦА** *и. ит. мед. иск.* Сулыш органнарының лайлалы тышчасы ялкынсыну, хәл бетү, баш авырту һәм

тән температурасының кинәт үзгәрүе белән характерланган йогышлы авыру. *Куркынычлы әйбер юк, [ул] салкын тидергән, инфлюэнца.* М.Гали

**ИНФЛЯ́ЦИЯ** *и. лат. икът.* Чамадан тыш күп бастырып чыгару һәм алтын белән гарантияләнмәү сәбәпле, кәгазь акчаның бәясе төшү. *Салымнар арткан, кирпеч-бетонга хаклар шашып күтәрелгән, йортка заказ биргән оешма акча түләми, ул арада инфляция син аласы акчаны чүпкә әйләндергән...* М.Маликова. *1654 елдан башлап, хөкүмәт, көмеш тәңкәләр урынына, бакыр тәңкәләр суга башлый, бу – инфляция (акчаларның очсызлануы) китереп чыгара.* Бөтендөнья тарихы. *РФ Дәүләт статистика комитеты мәгълүматларына караганда, Русиядә 2003 елда инфляция 12 процент тәшкил иткән.* Шәһри Казан

**ИНФОРМАНТ** *и. лат.* Тикшеренүчегә, сорауларга җавап бирү формасында, нинди дә булса мәгълүмат бирүче кеше. *Анна апа таба ашлары пешерде, мунча якты, ә мин үз эшемдә булдым, информантлар белән сөйләштем.* Ф.Гарипова

**ИНФОРМА́ТИКА** *и. лат.* 1) Фәнни информациянең гомуми сыйфатларын һәм төзелешен, аларны туплау, тапшыру, файдалану юлларын өйрәнә торган фән. --- *Татарстан алдында, бигрәк тә информатика һәм компьютер техникасы өлкәсендә, фәннең матдитехник базасын ныгытуга булышлык күрсәтү, аны алга таба үстерү, глобаль мәгълүмати системаларга керү бурычы тора.* Фәнни Татарстан. *Менә шул --- дәүләт ---, кыска гына вакыт эчендә аякка басып, иң алдынгы капиталистик илләрне куып җитте һәм электроника, информатика технологияләре буенча иң беренче урынга чыкты.* Сөембикә. *24 май көнне биология, урыс әдәбияты, информатика фәннәреннән беренче имтихан булып үтте.* Мәдәни җомга

2) Фәнни информацияне үзгәртү, туплау, тапшыру кануннары һәм кагыйдәләре

**ИНФОРМА́ТОР** *и. лат.* Информация ясаучы, мәгълүмат биреп торучы, хәбәр бирүче. *...Бакли болай дип белдерә: «Мюнхендагы «информаторлар»ның эшчәнлеге «журналистиканың гадәти булмаган төре» икән, аларның бурычы «тимер пәрдә» артындагы халыкларны «агарту» икән.* Казан утлары

**ИНФОРМАЦИОН** *с.* Мәгълүмати, информация бирә торган. *ЭВМны да, үзеңне дә, информацион эзләү системасы тарафыннан сезгә тәкъдим ителгән кешене дә ялгыштырмас өчен, мәгълүматлар никадәр ихлас күңелдән бирелсә, шулкадәр яхшырак.* Тигез гомер итегез! *Узган ел гына ЮНЕСКО тарафыннан Парижда чыгарыла торган «Яңалыклар» информацион бюллетенендә Миркасыйм Госмановның --- Кол Галигә багышланган мәкаләсе басылып чыкты.* Казан утлары. *Дөньядагы татар авыллары һәм мәктәпләре турында информацион база оештыруны күздә тотабыз.* Идел

**ИНФОРМА́ЦИЯ** *и. лат.* Берәр өлкәдәге эшләрнең торышы, барышы, берәр кеше яки нәрсәнең эшчәнлеге турында хәбәр, белдерү; нәрсә турында булса да мәгълүмат. --- *Камиләне күргәч, редактор Әсгать гомер булмаганча сөенде: – Хәзер үк телефонга утыр да бернichә районнан комсомол оешмаларының республика бәйрәменә нинди уңышлар белән килүе турында информация ал.* М.Маликова. *Көн тәртибендә төп мәсьәлә булып, чирек йомгаклары буенча класс җитәкчеләренең һәм предметникларның информацияләре тора.* М.Мәһдиев. *Тел – аң, фикерне белдерү чарасы бит ул. Информация кыры.* Сөембикә

**ИНФОРМА́ЦИЯЛЕ** *с.* Берәр өлкәдә мәгълүматлы, хәбәрдар. *Моның иң информацияле шаһиты – председательне йөрткән шофёр.* М.Мәһдиев

**ИНФО́РМБЮРО** *и. лат.-фр.* Информацион бюро (мәгълүматлар туплау һәм аны халыкка җиткерү белән шөгыльләнә торган бюро). *Намаз укыган чагында, радиодан Совет информбюросының белдерүен сөйли башласалар, Хәдичә түти --- учы белән битен сыйпый да тизрәк олы якка чыгарга ашыга иде.* Г.Әпсәләмов. *Совет информбюросы сугыш гарасатының, Гитлер Германиясе безгә көчләп таккан сугышның илгә нинди вату-җимерүләр, нинди үлем-һәлакәтләр китергәнен көн саен хәбәр итеп тора.* Г.Ахунов

**И́НФРАКЫЗЫЛ НУРЛАНЫШ (НУРЛАР)** *и. лат. физ.* Тоташ спектрның күзгә күренә торган кызыл очыннан башлап сузылган күзгә күренмәс электромагнит нурлары. *Инфракызыл нурларның иң характерлы үзлекләре – җылыту тәэсире.* А.Перышкин. *Эритрогегомометр – селеннан ясалган вентильле фотоэлементтан, лампочкадан, инфракызыл нурларны гына уздыручы яктылык фильтрыннан, --- гальванометрдан тора.* Р.Шаһморатова. *Дайсон фикеренчә, мондый тышча, термодинамик ташландыклар рәвешендә, күзгә күренми торган инфракызыл нурлар гына тарата.* А.Тимергалин

**ИНФРАМИКРОБИОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Вирусларны өйрәнә торган фән; вирусология

**ИНФРАСТРУКТУ́РА** *и. лат.* Матди җитештерүне һәм коммерция эшчәнлеген, шулай ук кешеләрнең яшәү шартларын тәэмин итә торган тармакларның һәм эшчәнлек төрләренең (транспорт, элемтә, электр энергиясен тапшыру линияләре, күперләр, юллар, коммуналь-торак хуҗалыгы, авыл хуҗалыгы продуктларын эзерләү, банклар, биржалар, капитал салу фондлары, иминият компанияләре, реклама һәм патент хезмәтләре, фән һәм фәнни хезмәт күрсәтү һ.б.) җыелмасы. --- *җирнең уңдырышлылыгын күтәрү, нәсел эше һәм элита орлыкчылыгы, фәнне үстерү, авылларда социаль инфраструктура объектлары кору, агропромышленность комплексын үстерүнең башка максатчан программалары һәрдаим игътибар үзәгендә.* Мирас. *Әлеге программа дүрт «И»не: институтларны, инфраструктураны, инновация һәм инвестицияләрне үстерүгә корылган.* Татарстан. --- *ул [Европа дәрәҗәсендәге регион] – күптармаклы инфраструктурасы --- булган, --- инвестиция өчен уңай шартларга ия икътисади үскән регион.* Ватаным Татарстан

**ИНФРАТАВЫШ** *и. физ.* Кеше колагы кабул итә алмый торган, ешлыгы

1 секундка 16–25 тирбәнүдән түбән булган тавыш дулкыннары. --- *балык секундка 5 тән алып 16 га кадәр булган ешлык механик һәм инфратавыш тибрәнешләрен «алтынчы сизү органы» белән ишетә ---.* Кызыклы ихтиология. *--- медузалар --- булачак тавыш хакында хәтта 8–13 герц ешлыгындагы инфратавышларны да ишетергә сәләтле.* Кызыклар дөньясында. *Инфратавыш өлкәсендә дә шактый тәҗрибәләр үткәрелгән. Аны кеше ишетми, ләкин организмы сизә.* Юлдаш

**ИНФУЗО́РИЯ** *и. лат. зоол.* Күпсанлы вак кына керфекчекләр белән капланган, суда яши торган бер күзәнәкле иң гади тереклек иясе. *Күп сандагы керфекчекләр ярдәмендә хәрәкәтләнә торган иң гади төзелешлеләрне инфузорияләр классына кертәләр.* Биология. *Җенси юл белән үрчергә ниятләгән ике инфузория, корсаклары белән бер-берсенә сыенып, авызларын бергә туры китерәләр.* Кызыклы физиология. *Инфузориянең бөтен тәне рәт-рәт булып урнашкан күп сандагы кыска керфекчекләр белән капланган.* Зоология

**ИНЦИДЕНТ** *и. лат.* Көтелмәгән, кинәт килеп чыккан күңелсез вакыйга, аңлашылмаучылык, бәрелеш. *Грузия коммунистлары, алар артыннан Украина коммунистлары да, Россия Федерациясенә автономияле республика хокуклары белән керүдән баш тарталар. Бу инцидент Ленинны бик нык борчуга сала, ---.* Р.Хәкимов. *Хәер, вакытлыча, бу инцидент арткы планга күчте, чөнки алгы планга принципиаль әһәмияте булган гаять мөһим мәсьәләләр --- калкып чыкты.* Н.Крупская. *--- Керенский 11 майда, Алкин әлеге инцидентларны провокация дип саный, --- дип, Кавказ фронтының баш командалыгына ашыгыч телеграмма җибәрә.* Мирас

**ИНЧЕ** *и. этн.* 1) Хатынның үз ата-анасыннан бирелгән һәм гомер буе аның милкендә исәпләнгән аяклы малы. *Ала алмаячаксыз, чөнки Кара биябез – инче.* М.Хуҗин

2) Кызга ата-анасы тарафыннан бирелгән әйберләр. *Элек кызны мал, бирнә, инче, өшәнчекләр белән озата торган булганнар.* Н.Исәнбәт

3) *диал.* Элек: киленгә кияү ягыннан бирелә торган аяклы мал

4) *бор.* Нәсел башы итеп калдырылган аяклы мал. *Малчының инчесе булыр, патшаның илчесе булыр.* Мәкаль. *[Сарсымбай:] Җылкычыдан үзеңә барып сайларсың, дөядән, сыердан яхшы инче алырсың, диде.* Г.Ибраһимов

**ИНЧЕК** *с. этн. к.* **инче** *(2 мәгъ.) Ирләр менгән инчек бүз ир менәргә туп булсын.* Мәкаль

**ИНЧЕЛӘ́Ү** *ф. диал.* Электә киленгә кияү ягыннан бирелә торган аяклы малны тапшыру

**ИНША** *и. гар.* 1) Берәр булган хәлне, вакыйганы, фикерне үз сүзләрең белән сөйләү, хикәяләү формасы. *Бу хатларда [кайбер бәйләнешсезлекләр] дә булыр, ләкин минем аларны төзәтергә хакым булмаганга, шул көйләренчә күчерәм. Әмма имла, инша мәсьәләләрендә төзәтергә мәҗбүр буламын.* Ш.Әхмәдиев

2) *пед.* Укыган текстны үз сүзләрең белән язу; изложение. *Ничек булса булды, рус теленнән «бишле»гә белүебез белән иншадагы утызар хатабызны бергә кушып, безгә «өчле» чыгардылар.* Г.Ахунов. *Казан университетының кабул итү имтиханнары расписаниесендә «татар мәктәбен тәмамлаучылар һәр факультетка кергәндә дә иншаны татар телендә яза алалар» дип белдерелгән иде.* Идел

3) *пед.* Укучыны фикер йөртергә өйрәтү максатында, билгеле бер темага язылган язма эш; сочинение. *Бер көнне ул [Фатих Әмирхан] безгә «Тукай һәм Сәгыйть Рәми» дигән темага инша яздырды.* Р.Ишморат. *Дүртенче класста яңа укытучы иде, беренче сентябрь көнне үк инша язарга кушты. «Мин җәйне ничек үткәрдем».* М.Мәһдиев. *Аерым әсәргә багышланган иншаның эчтәлеге анализ нәтиҗәләреннән һәм шул нәтиҗәләрне исбатлаучы анализ алымнарыннан гыйбарәт.* Әдәбият

**ИНША́ ИТҮ** *ф.* 1) Берәр мәсьәлә турында язу, берәр вакыйганы, булган хәлне үз сүзләрең белән хикәяләп язу. *Менә бу – шигырь. --- Ләкин кем моны инша иткән? Һич билгеле түгел.* Г.Тукай

2) Барлыкка китерү, кору, төзү, салу. *[Ул] Коелар казытты, күп мәдрәсәләр, мәктәпләр, мәсҗед җамигълар инша итте.* Г.Ибраһимов

**ИНША́ КЫЛУ** *ф. к.* **инша итү**. *Зиттаның төгәл мәгълүматлары юк, шуңа күрә, чарасыздан, алар утары тирәсенә урнашкан частьлар турында инша кылырга тотынды.* Х.Камалов

**ИНШАЛА́У** *ф. к.* **инша итү**. *Халык өчен мәктәпләрне төзүдә кем хокуклы һәм тиешле булуы, --- турындагы үзенең күзалламаларын Толстой 1859–1862 елларда «Ясная Поляна» журналында үзенең беренче мәкаләләрендә иншалаган.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Түбәндәге кереш сүзләр, мәсәлән, безнең карашыбызча, модаль сүзләргә карамыйлар: а) фикерне иншалау тәртибен белдерүче кереш сүзләр ---.* Татар грамматикасы. *Тәнкыйть материалларының эчтәлек (социаль-эстетик анализның көчәюе) ягыннан да, форма (иншалауны диалог яки уйланулар, түгәрәк өстәл янында сөйләшү рәвешендә кору) ягыннан да сыйфаты күтәрелүе сизелә.* Казан утлары

**И́НШАЛЛА** *мод. сүз гар.* 1) *дини* Алла боерса, Алла теләсә, Алла язган булса (берәр нәрсәнең үтәлүенә ышанып әйтелә). *– Юлда булуың әйбәт, – диде Гөлсәйдә. – Урыны җәелсә дә, йокы алдырып булмас. Иншалла, аяк өсте дә барып җитәрбез.* Ф.Яруллин. *...Зөләйха бугазына килеп тыгылган ачы төерне йотып җибәрә дә елмайгандай итә: – Әнә ич, кайтып-табылып торалар, иншалла, безнекенең дә ризыгы киселмәгәндер әле, – дип куйгалый.* А.Гыйләҗев. *Ихластан үкенгән, тормышын яңадан «бисмилла» белән башлаган кешегә Аллаһ Тәгаләнең чиксез ярдәме ирешер, иншалла.* Асылъяр

2) Ихтимал, бәлки, мөгаен, минем уемча. *Бәлкем әле, Сафаны солдатка алмаслар да, сугыш-орышы да алай кисәк кенә килеп чыкмас, иншалла.* М.Галәү. *Кыз-хатын – ул туганнар сүзенә караучан халык, син ныгытып әйтсәң, иншалла, күнәр ул.* Ш.Камал. *Синең улларың дөнья күрмәгән егетләр түгел, иншалла, җаен табарлар әле.* Т.Гыйззәт

**ИНШАЛЫК** *и. кит.* Рәсми кәгазьләр, хатлар язу өчен ярдәмлек, үрнәкләр тупланмасы

**ИНЪЕ́КЦИЯ** *и. лат. мед.* Сыек даруларны шприц ярдәмендә тән тукымаларына, куышлыкларга җибәрү. *Сестра! Бу авыруга спазган белән димедрол инъекциясе бирегез!* М.Маликова. *Папаверин яисә каверджект инъекцияләрен җенес органына ясап, җенес органында кан әйләнешен көчәйтәләр.* Юлдаш

**ИҢ** I *и.* 1) Нәрсәнеңдер бер читеннән икенче читенә кадәр булган ара; киңлек. *Рушад иңе бер генә метр булган тыкрыктан килә.* М.Мәһдиев. *Анда урын да иркен. Каралты-кураларың белән теләсәң – буйга, теләсәң иңгә таба җәел.* Н.Гыйматдинова

2) Әйбернең киңлеге, аркылы үлчәме. *Бар да искечә. Капкалар чүгеп, ишегалды бераз тарайган сыман, --- алмагачлар иңгә киңәйгән, миләшләр буйга күтәрелгән.* К.Кәримов. *Иңен җөйләргә инә сапласам да, буен җөйләргә инә сапласам да, шатлык-куанычлар теләп, үзем генә башкарыймсана.* Н.Гыйматдинова. *Нәкъ ишек турында, түрдә көмешкә алтын белән йөгертеп эшләнгән зур өстәл тора, кеше гәүдәсе биеклегендә, иңе өч терсәк булыр.* Мәдәни җомга

3) Арканың калак сөякләре турысындагы киңәеп киткән өлеше; иңбаш, ике кулбаш арасы. *Арслан тирән уйга бирелгән атлы булып, чалбарын киде, күлмәген иңенә салды...* Р.Мөхәммәдиев. *Капкадан кызның ата-анасы чыкты, сулкылдаудан иңнәре калтыраган кызны җитәкләп, ишегалдына таба әйдәделәр.* М.Хәбибуллин. *--- төсле утлар балкышында дәртле музыкага иң уйнатып биегән ярым шәрә кызлары белән кафелар рәте артта кала.* М.Галиев

4) *күч.* Өс; буй; җилкә. *Ил язмышы ир иңендә.* Әйтем. *Кулың белән эшләгәнне иңең белән күтәр.* Әйтем. *– Тссс! – диде Шәвәлиев, имән бармагын тырпайтып. – Әнә кара Әминәгә, Нуриевка, Гомәровка, миңа... Һәрберебезнең иңенә мең төрле вазифа йөкләнгән.* Ф.Садриев

◊ **Иң бирү** Бер башы яки бер очы белән бер-берсенә янәшә, берсе икенчесенә терәлеп урнашкан булу. *Колхоз идарәсе йортына иң биреп торган ашханә янына берничә машина килеп туктады.* Ялкын. **Иңгә басу** *к.* **иңгә төшү**. *Монда һәр өй, һәр тыкрык, һәр капка сиздермичә дә үз тарихы белән синең хәтереңә кагыла. Әллә соң шул хәтер иңнәргә басамы?* М.Галиев. *Урамга чыккач, саф һава җанга җиңеллек өрде, иңгә баскан мәшәкатьләрдән тугарылгандай иркенәеп кителде.* Н.Хәсәнов. **Иңгә берегү** Кемнең яки нәрсәнең дә булса башка берәүләр исәбенә ашавы, яшәве. *Ул бала хәзер Халитовлар иңенә гомерлеккә береккән инде.* Б.Камалов. **Иңгә салу** *к.* **иңнәргә күтәрү**. *Хәзер, ярты мең ел узгач, гаеплеләрне эзләү, җаваплылык йөген теге яки бу халык иңенә салу ахмаклык булыр иде.* Р.Мостафин. **Иңгә терәлеп** *к.* **иңгә-иң** (*1 мәгъ.*). *– Яшь чагында бик фырт булгансыңдыр, иеме? – Иңемә терәлеп үк утырган баягы кортка күңел кылларын тарткалый.* Р.Мулланурова. **Иңгә (ишелеп) төшү** 1) *к.* **иңнәргә күтәрү**. *Йортны тоту унҗиде яшен тутырып кына узган Илһамия иңнәренә төште.* Б.Камалов. *Хатынының йөрәк өянәге соңгы елда ешаеп китүгә йорт башының гомумән кәефе кырыла. Чөнки өйдәге бөтен эш үз иңенә төшә.* Б.Камалов; 2) Кайгы-хәсрәт, борчу-хафа, бәхет-шатлык килү. *Кинәт кенә иңенә ишелеп төшкән тау хәтле кайгысыннан нишләргә белмичә, Мәрзия әби тәмам катып калды.* Ә.Сафиуллин. *Искәрмәстән иңенә ишелеп төшкән бу бәхеттән Гөлнисаның аңына зыян-зарат килмәсә генә ярар иде.* М.Хәсәнов. **Иңен иңләү** Берәр җирне аркылыга үтү. *Хәйрулла абзый, киң Россиянең буен буйлап, иңен иңләгәннән соң, 1925 еллар тирәсендә --- шушы шәһәрчеккә тукталган иде.* Г.Әпсәләмов. **Иңеннән алу** Кешенең иңбашына кул салу, иңбашыннан кочаклау. *Елап утырганда, Тәскирәнең иңеннән ала.* Г.Зәйнашева. **Иңеннән буена** Берәр әйбернең бөтен өслеген кертеп (карау, томалау, йөрү һ.б. турында). *Җамали [үтүк белән] --- киемнәрнең иңеннән буена тагын бер йөреп чыга.* Г.Ибраһимов. **Иңеннән буена айкау** 1) Бер җирен дә калдырмыйча йөреп чыгу; 2) Берәр нәрсәне барлык ваклыкларына кадәр җентекләп, яхшылап, җиренә җиткереп тикшерү. *Каенана белән килен арасындагы бу талашлар һәр икесенең үткән тормышларын иңеннән буена айкап чыгалар.* Г.Ибраһимов. **Иңнән иңгә** 1) Бер кырыйдан икенче кырыйга кадәр; бөтен киңлегенә. *Урамны иңнән иңгә тутырып килүче тыгыз колонналарның алгы сафында тынлы оркестр булган икән.* К.Нәҗми; 2) Бер яктан икенче якка һәм кирегә (йөреп, йөзеп чыгу турында). *Кандыр иңен йөзеп буйлаганда, Уртасына басып тын алдым, Иңнән иңгә сине айкаганда, Синең өчен, Кандыр, оялдым.* К.Тинчурин. **Иңнән тау ташлану** Бик авыр, җаваплы, зур эштән арыну. **Иңнән таш төшү** *к.* **иңнән тау ташлану**. *Егетләрне сыйладым, иңемнән таш төште.* Б.Камалов. *Тикшерүченең соңгы сүзләренә Рузия ышанып бетмәгән кебек калды. Аның иңеннән тау төшкәндәй булды.* С.Зыялы. *Аларның йөзенә күз салуга, Виленның иңеннән тау төшкәндәй булды: ул Заһидәнең исән икәнлеген аңлап алды.* М.Маликова. **Иңнәргә канат үсү** Рух күтәрелү, дәртләнү. *Мансур Ибраһимович --- Гөлкәйгә кайчакта «Бик яхшы! Молодец!» дип куйгалады. Мондый көннәрне Гөлкәйнең үзүзе белән горурланудан күңеле тула, иңнәренә канатлар үскәндәй була.* Х.Ширмәт. *Шул караш аның монда берьялгызы гына түгел икәнлеген искәртеп, Микәйнең оеп барган канына кайнар учак якты. --- Иңнәренә тагы канат үсте.* Р.Мөхәммәдиев. **Иңнәргә күтәрү** Авыр, мәшәкатьле, күп көч сорый торган эшләрне үз өстенә алу. *Берәү дә --- сугыш вакыты кырыслыгы белән күреләсе чараны үз иңенә күтәрергә теләмәгән.* Б.Камалов. *--- тормыш авырлыгын әле ныгып җитмәгән иңнәренә күтәргән яшь геройларын тасвирлаганда, язучы әлеге бурычны шактый уңышлы хәл иткән ---.* В.Нуруллин. **Иңнәре белән күтәрү** *к.* **иңнәргә күтәрү**. *Әти тагын*

*өстәлгә сукты. – Юк, беркая җибәрмибез. Әгәр ирең гаепле икән, үз гаебен иңнәре белән күтәрсен.* Ф.Яруллин. **Иңнәрне җыеру** *к.* **иңбашларын җыеру**. *Мин иңнәремне җыердым. Әйләшәйле торуымны чамалаган артистка апа мине район клубына, театр директоры Исхак Дасаев янына җитәкләп китте.* Б.Камалов. *– Ә мин һич аңлый алмыйм, – диде Флора, йомры иңнәрен җыерып, – нигә дип аларның үзләренә түгел, ирләренә таяк төшә?* З.Фәтхетдинов. **Иңнәрне сикертү** *к.* **иңбашларын сикертү**. *Кыерсытылучының берәрсе минем өстән шикаять кылса: «Нишләмәк кирәк, Чалы кошыннан бүтәнне көтеп тә булмый инде аңардан», – дигән сымак, иңнәремне сикертеп кенә куя торган идем.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Иңне иңгә куеп** *к.* **иңгә-иң** (*1 мәгъ.*). *Сугыш гарасаты дөньяларын әйләндереп ташламаса, шулай ипле-тыныч кына, кара гүргәчә бергә, иңне иңгә куеп, матур яшәрләр иде ---.* Р.Мулланурова. *Бакчада иңне иңгә куеп пар-пар йөргән чакларында, дусларымның ни турында пышылдашуларын мин әллә каян белеп торам.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Иңне иңгә терәп** *к.* **иңгә-иң** (*1 мәгъ.*). *Ары таба егет белән кыз, иңне иңгә терәп, кулларындагы сәнәкләрен алга сузып, үзләрен төрле көтелмәгән хәлләргә әзер тотып атладылар.* Р.Фәизов. *– Шулай итәрбез, Зәкия, барысы да син дигәнчә булыр, – дип килешә әти. Шунда алар, иңне иңгә терәп, бүрәнә өстендә янәшә утыралар, бер-берсенә карап елмаялар.* Р.Фәизов. **Иң салыну** Төшенкелеккә бирелү. *Кем әйтмешли, ярык тагарак янында калгач, минем иңнәрем салынды, эштән күңел бизде...* Р.Мирхәйдәров

**ИҢ** II *кис.* 1) Асыл сыйфат алдында килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый; чиктән тыш, гадәттән тыш, үтә, бик. *Үзе аклы, үзе каралы бу, кыскасы, песиләрнең иң дә, иң дә, иң дәсе икән бу.* Г.Шәрәфи. *Ул бүләк өчен саклык белән генә капшанып һәм сыйпанып, иң матур, иң бөдрә, иң йомшак, иң елкылдык, иң сыгылмалы, иң купшы, иң көмеш зәркәнле, тагын да әллә нинди иң-иңнәрне өзеп карады.* А.Хәлим. *Америка галимнәре фикеренчә, Сатурнның иң зур иярчене булган Титанда нефть, газ һәм ташкүмер запаслары Җирдәгедән йөзләрчә тапкырга күбрәк.* Мәдәни җомга

2) Асыл сыйфатлар өченче зат тартым формасында килгәндә: «бигрәк тә, аеруча» мәгънәләрен бирә. *Мөдәррис өчен иң авыры шушы гинекология бүлегенә килү иде.* М.Маликова. *Гөлзадә – безнең арабызда иң озын буйлысы, иң матуры.* Р.Фәизов. *Нәни дусларымның иң кечкенәсе җиде-сигез яшьлек малай иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

3) *сир.* Нәкъ. *Хәсән иң урта җиргә --- ачык хат кадап куйды*. Ф.Әмирхан

◊ **Иң аз дигәндә** *к.* **иң азында**. **Иң азы** *к.* **иң азында**. **Иң азында** 1) Бик аз дип исәпләгәндә. *Мансур иң азында биш ел [хезмәт итәргә] җыена*. Ш.Усманов. *Яхшы һавада һәр көн, иң азында, сәгать ярым булырга кирәк.* Г.Тукай; 2) *кер. сүз мәгъ.* Ахыр чиктә, бер дә булмаса; һич югында. *Аның бу ямьсез кыяфәтен күргән кеше куркыр, иң азында, соң дәрәҗәдә авыр хәлгә калыр*. М.Гафури. **Иң әүвәл** *к.* **иң башлап**. *Иң әүвәл, әлбәттә, хуҗабикәләре Зәйтүнәнең җир биләмәсен, бакчасын сөреп, --- бирде.* М.Хәсәнов. *--- мин Мишаның колагына: – Иң әүвәл икенче катка кызлар янына меник ---, – дип пышылдарга өлгердем.* Э.Касыймов. **Иң башлап** Беренче булып. *Иң башлап, Миңлегөл сүз ачты*. Ш.Камал. **Иң башта** *к.* **иң башлап**. *Иң башта тәрәзәдән урманнарны, кырларны карарга тотынды.* Г.Тукай. *Иң башта «йөз процент»ны Хушият абзый бирде.* М.Мәһдиев. **Иң киме** *к.* **иң кимендә**. *Иң киме --- ун мең сумнар акча кирәк булыр.* Г.Ибраһимов. **Иң кимендә** *к.* **иң азында**. *Иң кимендә берәр машина уйлап табарга иде аның исәбе.* Ф.Яруллин. **Иң күбе(се), иң күбендә, иң күп дигәндә** Берәр нәрсә, берәр эш өчен кирәкле әйберләрнең зур саны; «күп булса», «күп дип санаганда» мәгънәсендә кулланыла. *Иң күп дигәндә, гектарына 15 центнер алырбыз, дип уйлыйбыз.* Н.Исәнбәт. **Иң күпкә киткәндә** *к.* **иң күбе(се)**. *Безне аерачак заман алты, җиде ай булыр. Иң күпкә киткәндә, бер елга сузылыр.* Г.Ибраһимов

**ИҢБАШ** *и.* 1) Гәүдәнең муеннан кулбашына кадәр булган өске өлеше. *Үз-үзен белештермичә, Сәхауның иңбашына төртелеп, --- дөньясын каргап, ике ятим баланың анасы яшь койды.* Р.Кәрами. *--- Исхак ата, угылының --- иңбашына кулын салып, күзләренә карады.* М.Хәбибуллин. *Гөлсемнең бит урталары аз гына чокырланып торган йөзе, түгәрәк иңбашыннан аккошныкы кебек талгын гына нәзегәеп менгән озынча муены, --- – бөтенесе дә күз алдында!* З.Фәйзи

2) Киемнең яка уентысыннан алып кулбашына кадәрге өлеше. *Иңбашлары күпертмәле итеп тегелгән ак алъяпкычы --- бу сылу хатынның җыйнаклык сөюен күрсәтә.* Г.Бәширов

◊ **Иңбашка иңбаш терәп** *к.* **иңгә-иң** (*1 мәгъ.*). *Гражданнар сугышында без – аның белән иңбашка иңбаш терәп, бер окопта ятып сугышкан кешеләр.* Н.Исәнбәт. **Иңбашларын җыеру** Аптырау, гаҗәпләнү, ни эшләргә белмәү, нәрсәне дә булса төшенмәү һ.б.ш. очракларда иңбашларны хәрәкәтләндереп ишарә ясау. *– Кайчанрак өйдә була соң ул? Асрауга охшаган хатын кабат иңбашын җыерды.* М.Хәсәнов. *Потатов, мин уйлап чыгармадым дигәндәй, иңбашын җыерды.* Н.Хәсәнов. **Иңбашларын кагу** *к.* **иңбашларын җыеру**. *[Инсаф] --- Дилбәреннән сорады: – Кем бу, беләсеңме? Кызый иңбашларын какты.* Г.Нурлы. **Иңбашларын сикертү** *к.* **иңбашларын җыеру**. *[Хәйруллин] Балалар шикелле борынын тартып, җиңелчә генә иңбашларын сикертеп куйды.* М.Маликова. *– Атам, мин иртәгәгә үк Өргәнечкә китәм. Сәлим хан иңбашын гына сикертеп куйды, бер сүз дә әйтмәде, бары тик угланы әмир хаҗи ягына сирпелеп кенә алды.* М.Хәбибуллин. *Сибгатулла, ашыгып: – Ничек? – диде. Рәхимҗан иңбашын сикертте: – Бусы – синең хәсрәт. Теләсәң – ас, теләсәң – кис ---.* Н.Гыйматдинова. **Иңбашларын тарту** *к.* **иңбашларын җыеру**

**ИҢ-БУЙ** *җый. и.* 1) Нинди дә булса әйбернең, урынның иңе белән буе, барлык мәйданы. *Күз бераз күнеккәч, аердым: каршыбызда – биек-биек кап-*

*ка, ул бөтен иңенә-буена чәнечкеле чыбыклардан ясалган бизәкләр таккан иде.* А.Гыйләҗев. *Иңе-буе утыз сантиметрлы чүпрәк капчыгым, күңелне җылытып, яртылаш тула иде.* Н.Гыйматдинова

2) Кемнең дә булса килеш-килбәте, гәүдәсе, буй-сыны. --- *кыз --- иңбашы аша тар каешлы кечкенә фотоаппарат таккан Искәндәревкә, аның иңен-буен үлчәгәндәй, күз кырые белән җитди генә карап ала.* Ә.Еники

◊ **Иң-буй үлчәү** Кемне дә булса башыннан аягына кадәр карап алу. *Ул яратмыйча гына күтәрелеп карады, икесенең дә иң-буйларын үлчәде.* А.Гыйләҗев. **Иңгә-буйга айкау** Барлык юнәлешләрдә эш итү; бөтен урыннарын йөреп чыгу. *Татарстанны мин иңгә-буйга айкап чыккан кеше.* Н.Исәнбәт. **Иңе-буе үлчәнгән (үлчәнеп киселгән)** Бер үк төсле, бер үк төрдәге, бер-берсенә охшап торган. *Боларның һәммәсен --- иңе-буе үлчәнеп киселгән бер шаблон буенча язалар.* Г.Ибраһимов. **Иңен-буен белеп (үлчәп) калу** Кешенең килеш-килбәтен, ничек киенгәнен тикшерү; гайбәтен сату. *Мөһәндис барлыгын мөнкир «Кофер почмагы»на барсын; Күрер шунда: иңен-буен белеп калганымыз бардыр.* Г.Тукай. **Иңен-буен иңләү** Берәр җирнең бар урыннарында да булып чыгу. *Без моннан соң да әле бик күп техникум, училищеның иңен-буен иңләдек.* Х.Сарьян. **Иңен-буен таптау** *к.* **иңен-буен иңләү**. *Бу тирәләрнең иңен-буен таптаган кешеләр без.* Ә.Ибраһимова. **Иңне-буйны абайлау** Барысын да алдан күреп, тикшереп эш итү. *Иңне-буйны абайлый торганга охшамый [ул]. Юк, мин болай гына, яманлавым түгел.* К.Тинчурин

**ИҢГӘ-ИҢ** *рәв.* 1) Бик якын, янәшә, бер адым да калышмыйча, рәттән, бергә. *Ә Каһир Сафин белән без бу тормышның коточкыч кыска юлында һәрвакыт иңгә-иң барганбыз лабаса.* Ә.Гаффар. *Иңгә-иң терәлешеп, дымлы рәхәтлектән мәһабәт булып үскән өянкеләр өстеннән, --- талгын җил исә.* М.Галиев. *Баһаветдин исә аны күрмәде дә: бер чибәркәй белән инеш ярына иңгә-иң утырган да --- йөгерек агымга чәчәк таҗларын өзеп ата-ата уйный иде.* Т.Әйди

2) Янәшә, бергә кушылып. *Янәшә, иңгә-иң ышыкланып үскән куш карама[ның] --- ябалдашлары моңсу аерылып, җиргә таба иелә төшкән.* М.Галиев

3) *күч.* Тыгыз бәйләнештә; бергә. *--- без хәзер русча күп әйбер укып, русча күп ишетеп, рус иптәшләр белән генә түгел, башка милләт вәкилләре белән дә русча сөйләшеп, иңгә-иң эшлибез.* Х.Сарьян. *Без кырык алты ел аның белән иңгә-иң яшәдек, якты истәлеге исә мәңге яшәр.* Казан утлары. *Мондый эштә җәмәгатеңнең дә иңгә-иң куюы авырлыкларны бермә-бер җиңеләйтә шул.* Юлдаш

**ИҢГЕРӘ́Ү** *ф. диал. к.* **иңрәү**. *Себерелә карлар коточкыч, Ишетелә бер иңгерәү.* Н.Исәнбәт

**ИҢДӘШ** *и. сир.* Иптәш, якын дус. *Бер туфракта үскән иңдәшләрен Сагынадыр ул, сагына, мөгаен.* Ш.Маннапов

**ИҢДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **иңү** *(1, 3, 5 мәгъ.).* *Начтый бераз алгарак иелде дә, --- ике кулы белән ике җилкәмә басып, мине җиргә иңдерде.* И.Сирматов

2) Тарату, күңелгә сеңдерү. --- *тагын бер мәртәбә аның тавышын ишетү Гөлсинәнең җанына ләззәт, күңеленә тынычлык иңдерә.* Ә.Сафиуллин. *Ул [Хәбир], балалар аңына ничек тә бер якты нур иңдереп калдырырга тырышып, көн дими, төн дими казгана иде.* Х.Камалов. *Аңа кинәт рәхәт булып китте. Гыйлем иңдереп, савап алды.* Ә.Гаффар

3) Мәетне гүргә кертү, җирләү. *Наҗияне гүргә иңдерәсе минутлар, савыттагы ком кебек, ихтыярсыздан кими, һаман азая торды.* Ш.Шәйдуллин. *Сөем тутай мәет өстендә бузлаучылар җылаганга да түзде, анасының гәүдәсен кабергә иңдереп, балчыктан тау хасил булгач та җыламады...* Р.Батулла

4) Югарыдан түбәнгә төшү, төшерү. *Атыннан кызны иңдереп, Кул очыннан җитәкләп, Акбеләкне Идегәй Шаһ Тимергә кулдан биргәндә, Әмир Бырлас Шаһ Тимер Иләкләп алтын чәчтерде.* Дастан

5) *диал.* Югарыдан башка сугу. *Түбәңә иңдерермен!*

**Иңдереп бетерү** Тулысынча, тәмам иңдерү. *[Мачаклы үгезе көтүче малайны] Аягы белән таптап сазлыкка ук иңдереп бетергән иде бичаракайны...* М.Хәсәнов

**Иңдереп җиткерү** Тәмам иңдерү, тулысынча иңдерү. *Балаларга --- белем һәм тәрбияне иңдереп җиткерү буенча да зур тырышлык куярга туры килә.* Казан утлары

**Иңдереп кую** Иңдергән хәлдә калдыру. *Хәтереңә иңдереп куй, кем: Мәдинә вәкилләре сүрәләренең йөз егерме бишенче аятеннән булыр бу гыйбрәтле сүзләр...* М.Хәсәнов

**Иңдереп тору** Даими рәвештә иңдерү. *Югарыдан әле дә шундыйрак рухтагы әмерләрне иңдереп кенә торалар.* Т.Әйди. *Ул [зәңгәрсу нур] үзенең серле зәңгәрлеге белән Айсылуның йөзенә, күзләренә өстәмә ямь иңдереп тора сыман.* Ә.Сафиуллин

**ИҢЕЛӘЙ** *рәв. диал.* Бөтенләй, бөтен иңенә; тулысынча. *Ул урам ягындагы тәрәзәне иңеләй ачып җибәрде.* Н.Фәттах

**ИҢЕЛҮ** *ф.* Батып, чокырланып керү

**ИҢЕШ** *и. диал.* Батыш. *Кояш иңешендә биек вә калын агачлар арасыннан гына кызыллы-сарылы офык күренә.* Ш.Камал

**ИҢ ЗУР УРТАК БҮЛҮЧЕ** *и. мат.* Бирелгән саннарның барысын да калдыксыз бүлә торган иң зур сан (мәс., 36 һәм 48 саннарының иң зур уртак бүлүчесе – 12)

**ИҢКӘЙТҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне түбәнгә ию, кыйшайту, янтайту. *Ишек төбендә зур самавырны бер колагыннан иңкәйтеп тоткан Һәдия түти басып тора.* К.Нәҗми. *Аркасына биштәрләгән авыр капчыгын җиргә иңкәйтә, сөйрәгән йөгенең артыннан эз сузылып кала.* Г.Якупова

2) Башны ию, алга таба бөгү, салындыру. *Яхшы адәм алтын башын иңкәйтсә, яман адәм артын туңкайтыр.* Мәкаль. *Поса-поса баргалап, Туктамышны тапкан соң, Ул миңа да мин аңа Күп сүзләрне әйткән соң,*

*Иңкәйтеп башын алганмын, Алдыңа китереп салганмын!* Дастан

**Иңкәйтә башлау** Иңкәйтергә тотыну

**Иңкәйтә төшү** Бераз иңкәйтү. *Ольга Ивановна башына күпертелеп җыйналган һәм чал керә башлаган чәчен җитез генә төзәтеп алды һәм кунакларның икесенә дә бер төсле үк ягымлылык белән башын бер якка иңкәйтә төшеп карап алды.* Ә.Фәйзи

**Иңкәйтеп алу** Тиз генә, кыска вакыт дәвамында иңкәйтү

**Иңкәйтеп бетерү** Тәмам, ахыргача иңкәйтү

**Иңкәйтеп тору** Һәрвакыт яки даими рәвештә иңкәйтү

**ИҢКӘЛ** *и. диал.* Ит һәм бәрәңге белән пешерелгән токмач ашына салынган киң камыр кисәкләре

**ИҢКӘЮ** *ф.* 1) Туры хәлдән бераз авыша төшү; янтаю, кыегаю, аву (җансыз әйберләр турында). *Анда иңкәйгән, кыйшайган иске кабер ташлары күп.* Ә.Еники

2) Иелү, алга таба бөгелү, салыну (баш, гәүдә турында). *Кешеләр Герман җиреннән чүпрәк-чапрак төяп кайтсалар, мин, иңкәеп, орлык төяп кайттым.* Р.Төхфәтуллин. *[Галиулла картның] Иңкәеп атлавына караганда, капчыгы саллы гына булырга охшый.* Ф.Шәфигуллин. *Көндезге сүз саранлыгыннан аптыраган Маһибәдәр, карт бөркет кебек иңкәеп, яны белән тәрәзә төбенә таянып утырды.* А.Гыйләҗев

**Иңкәеп бетү** Тәмам иңкәю

**Иңкәеп китү** Кинәт, уйламаганда иңкәю

**Иңкәя башлау** Иңкәергә керешү

**ИҢКЕ-ЗИҢКЕ** *рәв. к.* **иңке-миңке**. *Тагын ике көн аңыма килә алмыйча иңке-зиңке килеп йөрдем.* Р.Ишморат

**ИҢКЕЛ** *с.* **1.** *к.* **иңкү** I. *Авылны урталай ярып, Актай елгасы ага, карга оялары белән тулган өянкеләр яшәреп утыра, язгы ташудан соң иңкел урыннарга дәрья кебек булып су җәелә.* С.Шакир

**2.** *и. мәгъ.* Иңкеллек, уйсу җир. *Алар читләре чирәм белән капланган иңкелгә җыелдылар.* Г.Мөхәммәтшин. --- *бер ял көнебездә --- Минзәлә инешенең ипле генә бер иңкеленә дә барып чыктык.* К.Миңлебаев. *Кайчандыр Байтирәк куштаннары, землемерга бер тәпән бал, ике сарык ришвәт биреп, Алабашның Яурышкан иңкелен үзләренә кистереп алганнар.* Г.Бәширов

**ИҢКЕЛЛЕК** *и. к.* **иңкүлек**. *Бу иңкеллек, бу тар гына батынкы җир елганың кайчандыр иске эзе булган.* Н.Фәттах

**ИҢКЕ-МИҢКЕ** *рәв.* Аңгы-миңге. *Ә менә бүген әйтерсең колагымнан тартып уяттылар, төн урталарында торып утырдым. Башта иңке-миңке берни аңламый тордым.* З.Вәли. --- *Сәүбән йокысыннан бөтенләй икенче кеше булып уянды да --- иңке-миңке баштан янә бер чыбыркы шартлатуны кирәк тапты.* Ф.Хөсни. --- *бәйрәм җиле атнага сузыла ---. Күбесенең атна буе башы авыртып, иңке-миңке килеп йөри.* Р.Ишморат

**ИҢКЕ-ТИҢКЕ** *рәв. к.* **иңке-миңке**. – *Әни, тынычлан әле, яме. Болай син агу ашаган таракан шикелле иңке-тиңке киләсең, --- диде --- Талия.* Г.Галиева. *Түшәмдәге бала бишеге тага торган боҗрага кер бавы ташлап, абыстай асылынган иде. Моны күреп күрше хатыны, --- иңке-тиңке килә-килә, өйдән чыгып йөгерде...* М.Хәбибуллин. *Көне буе иңке-тиңке йөрде. Киңәшмәләрне иртәгәгә күчерде, сәркятипләренә үзен юк дип әйтергә кушты.* Ф.Җамалетдинова

**И́Ң КЕЧКЕНӘ УРТАК КАБАТЛЫ** *и. мат.* Бирелгән берничә санның һәрберсенә калдыксыз бүленә торган иң кечкенә сан (мәс., 3 һәм 4 санnарының иң кечкенә уртак кабатлысы – 12)

**ИҢКЕШ** *и. диал. к.* **иңкүлек**. *Чокыр-чакырларда, иңкешләрдә эреп бетәргә өлгермәгән кар, күмер тузанына капланып, саргайган былтыргы үләннәрдән каралыгы белән аерылып тора ---.* Ирек мәйданы

**ИҢКҮ** I *с.* **1.** Әйләнә-тирәдәге тигез җирдән түбәнрәк, батыбрак, чокыраебрак торган; уйсу. *Шулай итеп, кайчандыр гөрләп торган өй урынында, ташландык кабер кебек, иңкү җир генә калган.* М.Хәсәнов. --- *иңкү җиргә су тулдымы – шуннан күл барлыкка килә.* А.Муранов. *Кызның күз яшьләре инеш булып түбәнгә агалар, иңкү җирдә кайнар күз яшьләреннән тозлы күл барлыкка килә.* А.Муранов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый урын; иңкүлек. *Бу күл зур тектоник диңгез иңкүенең ерак, буш бер почмагына урнашкан ---.* А.Муранов. *Инеш буендагы иңкүләргә зәңгәрсу сыек томан җәелә башлаган иде.* Г.Бәширов. *Урта диңгезнең көнчыгыш ярыннан ерак түгел урында, Гхор иңкүе төбендә Үле диңгез дип аталган озынча бер күл ята.* Физик география

**ИҢКҮ** II *ф. диал.* Аңгыраю, аңгымиңге килү, иңке-миңке килү. *Сафура карчыкның сыкрануларын изеп, Мөхәммәт бер генә эндәште: – Җитәр сиңа, мырлама. Болай да баш иңкегән.* А.Гыйләҗев

**Иңкеп бетү** Тәмам иңкү

**Иңкеп китү** Кинәт иңкү. *Хәбәр бик хәтәр иде. Нәҗипнең зиһене томаланып, башы иңкеп китте.* А.Гыйләҗев

**ИҢКҮЛЕК** *и.* 1) Әйләнә-тирәдәге тигез җирдән чокырланып, батып торган урын, иңкү җир; уйсулык. *Каен төбенә җәелгән табынга көлдә пешкән бәрәңге дә килгәч, шат авазлар тау битеннән төшеп киткән урман иңкүлекләренә генә сыя алмады ---.* М.Галиев. *Тик... авыл белән кыр арасында элек шактый киң иңкүлек бар иде.* Ә.Баянов. *Алар алан уртасындагы чишмә янәшәсендәге иңкүлеккә киң итеп чокыр казыдылар ---.* Р.Фәизов

2) *геогр.* Диңгез өсте тигезлегеннән 200 метрдан югары булмаган тигезлек; түбәнлек. *Совет экспедицияләре моңа кадәр билгеле булмаган су асты тау сыртларын, тирән су асты иңкүлекләрен һәм утрауларын табып, географик карталарга төшерделәр.* А.Муранов. *Планетабызда нинди океан һәм материклар, диңгез, күл һәм елгалар, иңкүлек, калкулык һәм таулар бар, география шуны тасвирлый.* Табигать белеме. --- *«Витязь» кораблендәге экспедиция 1957 елда Тын океандагы иң тирән иңкүлекне – Мариан иңкүлеген үлчәде.* Физик география

**ИҢЛӘП-БУЙЛАП** *рәв.* 1) Бөтен киңлеге һәм озынлыгы буенча; иңен-

буен биләп. *Ләкин күлне иңләп-буйлап рәхәтләнеп йөзәм дигәндә генә, кемдер: – Эчкә үк кермә, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Сталин һәм аның сүзсез баш ияргә гадәтләнгән канлы яраннары СССРны иңләп-буйлап тагын бер мәртәбә җәза дулкынын үткәрүне планлаштыралар.* А.Гыйләҗев. *Зәлия, җанына урын таба алмыйча, тизрәк суга ташланды һәм бар көченә иңләп-буйлап йөзә башлады.* Казан утлары

2) Бөтен җирне, урынны аркылыга-буйга. *Сары тавык --- бөҗәкләр чүпли, бакчаны иңләп-буйлап йөри.* Н.Фәттах

**ИҢЛӘТЕП** *рәв. к.* **иңләп**. *[Паласны] Бөтен түрне иңләтеп җәеп җибәрер идек.* Т.Гыйззәт. *Студентлар безне урам иңләтеп кунакханәгә хәтле озатып куйдылар.* Х.Сарьян

**ИҢЛӘҮ** *ф.* **1.** 1) Берәр урынны биләү, алып тору. *Тыкрыкны чыгуга, таң күренеше тагын да ачыла төште. Кояш, гаҗәеп зур ут шары төсенә кереп, ярты офыкны иңләгән.* З.Фәйзи. *Бөтен дөньяны июнь кояшы иңләгән ---.* М.Мәһдиев. *Иң элек түргә як сәкене тоташтан иңләгән ап-ак тула киез өстенә ак-кызыл шакмак бизәкләр төшереп сугылган киндер ашъяулык җәйде.* М.Хәсәнов

2) Берәр җирне, урынны һ.б.ш.ларны аркылыга-буйга йөреп чыгу. *Рекрут яшьләр, Пычрак димиләр, Тальян белән урам иңлиләр.* Н.Баян. *5–6 ай ярга чыкмыйча, океаннар иңләгәннән соң, 40 яшьлек әбекәйләр дә матур кыз булып күренә башлый.* Ф.Яруллин. *Файдалы казылмалар эзләүче геологлар партиясе белән Себернең аркылысын буена иңләде.* Ә.Моталлапов

3) *күч.* Дәвам итү, вакыт узу. *Бу тапшыруларның икесе дә татар иленең күп гасырларны иңләгән тормыш хәрәкәтен тасвирлап, зиһенебезне яңалыклар белән баета.* И.Низамов

4) *күч.* Карау, баштан-аяк карап чыгу. *Зөлфия, бөтен гәүдәсе белән борылып, Сәетнең чиста кырынган йөзен, алгарак чыгып торган ияген, киң җилкәләрен тәүге кат күргәндәй иңләде.* Т.Галиуллин

**2. иңләп** *рәв. мәгъ.* 1) Бөтен киңлекне биләп, колачлап. *Әнисенең ишегалдын иңләп гөрләвек ага.* М.Мәһдиев. *--- ул Гөлсемнең олы юл киңлеге җирне иңләп барган культиваторының, аның артыннан ияргән бик күп тырмаларга ---, тырмачы кызларга куанып карап торды.* Г.Бәширов. *Урамны иңләп килгән хан азатларын күрде дә халык качарга кереште.* М.Хәбибуллин

2) Иркенләп, бар киңлекне биләп. *Шәһәрнең аркылысын-буен иңләп эзли торгач, ул кылларны тапты, ниһаять.* З.Фәйзи. *Хәзер рәхәтләнеп болын иңләп көтү куып йөрүләр булмас, ахры...* Казан утлары

3) Күп итеп, кочак-кочак. *Байлар бирде [акларга] ярдәмнәрне меңләп-меңләп, Кызыл маллар, ситсыларны иңләп-иңләп.* Г.Камал

4) *күч.* Берәр нәрсәне тулысынча, бөтен күләменә күздән үткәреп. *Директорның йөгерек карашлары Иңләп чаба совхоз аланын.* М.Җәлил

5) *күч.* Колачлау, бөтенләй чолгап, уратып алу. *Җил бит безнең Ташлытау басуыннан гына узмый. Ул бит әллә ничә мең чакрымны иңләп килә.* М.Мәһдиев

**Иңләп алу** Тулысы белән, тулысынча иңләү, тулысынча томалап иңләү. *Олы күлләр – Төньяк Америкадагы Изге Лаврентий – елга бассейнының югары һәм урта өлешләрен иңләп алган зур күл-елга системасындагы соңгы буын.* А.Муранов

**Иңләп чыгу** Башыннан ахырынача иңләү

**Иңли бару** Тагын да күбрәк иңләү. *Диңгез өстендә таң сызылып килә. Гүя ул томан белән бергә күтәрелә, офыкны иңләгәннән-иңли бара.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Иңли башлау** Иңләргә тотыну

**ИҢЛЕ** *с.* 1) Иңе киң булган. *Берзаман Габделнур күзен ачты. Саргылт түшәм. Такталары нарат, иңле.* Р.Кәрами. *И Телем син, иңле Иделем син, синдә – назым, синдә – ярсуым.* Л.Шагыйрьҗан

2) Киң җилкәле. *Анда монгол йөзле, тәбәнәк буйлы, ләкин калын иңле бер солдат бар иде.* Х.Камалов. *Мин өч үги әти кулы аша үттем дияргә була. Беренчесе – аю кебек таза иңле, зур башлы, юан беләкле, кәкре аяклы.* Х.Камалов. *Унтер-офицер --- бүген, көн яктысында, иңлерәк тә, буйлырак та күренә.* Ф.Хөсни

3) *к.* **илле** II. *Кулларга ике иңле сөял үстереп әйткән сүз бервакытта да контр булмый ул.* Р.Төхфәтуллин. *Ак тасма бәйләгәннәр диярсең – муенында бер бармак иңле генә ак хәтфә бөҗра!* Т.Мөбарәков

4) *күч.* Күпьяклы, киң, зур. *[Әхмәтебез] Тормышны тирәнрәк, иңлерәк колачлый.* Ф.Хөсни

**ИҢЛЕК** *и.* Киңлек. *Көзгедән карыйм да җиде бармак иңлеге текә маңгаема ачуым килә.* М.Галиев

**ИҢӨС** *и. к.* **иңбаш** (*1 мәгъ.*). *Миңгали абыйсының --- иңөсләре басылган, кая куярга белмәгән озын куллары салынып төшкән --- иде.* Р.Мөхәммәдиев

**ИҢРӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Каты авыртудан, кайгы-хәсрәттән һ.б.ш.лардан сызланып зар елау, сыктау. *Латыш кызы җылый-җылый үкси, иңри һәм үз телендә нидер дәшә.* А.Гыйләҗев. *– Әхмәтемә ни булган, Саҗидә, әйт! – диде Рәхимә түти, авыр иңрәп.* З.Фәйзи. *Ул, үлемен сизеп, җан ачысы белән иңри...* Н.Хәсәнов

2) Олы хәсрәттән, кайгылы хәбәрдән бик нык әрнү, рухи газаплану, тетрәү. *«Йосыфҗанымның карынын тук ит, тап әмәлен, берүк адәм көлкесенә калдыра күрмә», – дип иңрәде ана.* А.Гыйләҗев. *Кылынган явызлыклардан җан иңри ---.* М.Хәбибуллин. *Җанда да татлы сыкрау иңри сыман... Барысы да үлде-бетте, дигәндә...* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Шомлы, ачы яки каты тавышка кайтаваз булып гүелдәү (җансыз әйберләр турында). *Көзге салкын җил исә, Атлашкино ягыннан кара болытлар килә, камышлар иңри.* М.Мәһдиев. *Кыз «аһ» диде, йөрәктән бәргән бу аваздан тып-тын урман да иңрәде, куактагы яфраклар җил кузгаткан сыман лепердәшеп алды ---.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Тилмерү, зар елау, газаплану, интегү. *– Ә такта яру заводы? Такта яру заводы? – Мәгыйзь, тәмәке тартасы килүдән иңрәп, озын сүзле Хәсән картка ачу катыш карады.*

М.Мәһдиев. *Уен эшмени, гасырлар буе иренең олтаны астында, шәригать богаулары эчендә иңрәгән, --- татар хатыннарының хөрриятькә чыгуларына биш ел тула бит.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Йөрәк әрнеткеч ыңгырашу, үзәк өзгеч аваз. *Халык башта, --- өнсез калды. Аннары шаулау, --- елаусыктау белән дөнья тулды. Болын тугайлары, --- менә шушы халык иңрәвен ишетте.* Г.Ахунов. *Газиның чыраенда тән сызлануының гына түгел, җан иңрәвенең дә чалымнары бар иде кебек.* М.Хәсәнов. *Үз-үзен белештермичә, Сәхауның иңбашына төртелеп, җан тетрәндергеч ачыргалану, иңрәү белән, әрнеп, --- ике ятим баланың анасы яшь койды.* Р.Кәрами

**Иңрәп алу** Бер тапкыр иңрәгән тавыш чыгару. --- *эре-эре атлап бүлмә буйлап тагын бер әйләнде дә моңарчы җанында йөргән авыр уйларын берьюлы тышка бәреп чыгаргандай иңрәп алды: – Бармы дөньяда бәхет, егеткәйләрем?* Ф.Сафин

**Иңрәп калу** Нинди дә булса сәбәптән, вакыйгадан иңрәгән хәлгә килү. *Безнең белән, синең белән мондый хәлләр булыр дип, бервакытта уйламаган идем. --- әни әйткәч, ышанасым килмәде. Тетрәнеп, иңрәп калдым.* Н.Хәсәнов

**Иңрәп китү** Кинәт иңрәү. *Әтисенең кәфенгә төренгән гәүдәсен җир куенына тапшырганда, ләхеткә куйган чакта, [Тимерханның] кинәт күңеле тетрәнде, җаны иңрәп китте.* Г.Ахунов. *Шул мизгелдә --- яраланган меңнәрчә ат һәм адәмнәрнең җан өзгеч аваз белән кычкыруыннан тирә-юнь гөрселдәп, иңрәп китә ---.* С.Шәмси

**Иңрәп кую** Бер тапкыр иңрәгән аваз чыгару. *Хатыны аның кровате янына тезләнеп иңрәп куйды.* Г.Бәширов. *Фәйрүзә тыны кысылгандай иңрәп куйды.* Р.Мулланурова. *«Шулкадәр астыртын кеше булыр икән», – дип иңрәп куйды Венера, Хафизовның Чабакса күле янындагы төче сүзләрен исенә төшереп.* З.Фәйзи

**Иңрәп тору** Әле, хәзер, нининдидер вакыт дәвамында иңрәү. *Пианино, мин назлы зат, миңа тупас кагылырга ярамый дигәндәй, шактый вакыт иңрәп торды.* Р.Вәлиев. *Атлар кешнәгән, кешеләр ачыргаланып кычкырган авазлардан елганың ике як яры да иңрәп тора.* В.Имамов

**Иңри башлау** Иңрәргә тотыну. *Урман тоташ бер гүләү белән иңри башлады.* Г.Әпсәләмов

**ИҢРӘҮЛЕ** *с.* Үзәк өзгеч, әрнеткеч. *Иргалинең болай да чайпалырга торган күңелен пыран-заран китерү өчен җитә калды әлеге иңрәүле авазлар.* М.Хәсәнов. *Аның тавышына кыргый бер ялвару аһәңе үтеп кергән иде. Әйе, әйе, кыргый ялвару. Иңрәүле аваз.* Б.Камалов. *Сәгыйдәнең теле көрмәкләнде. Ул: «Алайса ник миннән йөз чөерәсең, нәрсә булды сиңа?» – дип, ачыктан-ачык сорамакчы иде, Хәкимҗанның иңрәүле тавышын ишеткәч, уеннан кире кайтты ---.* Н.Хәсәнов

**ИҢСӘ** *и.* 1) Арканың иңбаштан һәм җилкәдән торган югары өлеше, ике иңбаш арасы. *Шунда Фарсил: – Кеше ялгышмый тормый, Сәмәт. Хатаңны аңлагансың икән, молодец! – дип, Сәмәтнең иңсәсен кагып алды.* З.Фәйзи. *Безнең --- авылдашыбызның киң иңсәләрен киереп, бөркет карашларын еракларга текәп төшкән рәсемнәрен газеталарга басып чыгарганнар.* Р.Фәизов

2) Киемнең шул турыдагы өлеше

3) *к.* **иңбаш**. *Бик җаваплы заказлар гына кабул итә торган кисүчеләр иңсәләренә үлчәүләрен салды ---.* Р.Мөхәммәдиев. *Бервакыт алданрак барган Кәримнең иңсәсенә ике чәүкә килеп кунды.* З.Фәйзи. *Диләрә көзгә каршына басып бөтерелеп алды да иңсәсенә сумкасын асты.* Асылъяр

4) *диал.* Башның арткы йомры өлеше, баш чүмече. *Ике көн иңсәләрем чатнап, хәтта намазга да чыга алмадым.* Ш.Камал

5) Кием элгеч, киергеч. *Алинә, --- кыюлыгын җыеп пәрдәне ачып җибәрсә, иңсәгә эленеп куелган үз күлмәген күреп шаккатты.* Х.Ширмәт

6) *тех.* Рычагның (көянтәнең) терәк ноктасыннан алып, көч кую ноктасына кадәр булган өлеше. *Бораулау иңсәләре, олеин кислотасы, модификатор, --- кебек продукцияләр илебездә бары тик Татарстан предприятиеләрендә генә җитештерелә.* Казан утлары

◊ **Иңсәләрен җыеру** *к.* **иңбашларын җыеру**. **Иңсәләрен сикертү** *к.* **иңбашларын сикертү**. *– Син миңа бу хакта бер дә сөйләмәгән идең, – дип ризасызлык белдереп, Наталья иңсәләрен сикертте ---.* Р.Мирхәйдәров. *– Сәер кеше бугай син, – дип, иңсәләрен сикертеп алды егет.* Р.Мөхәммәдиев. *Казембек башын килешле итеп бер уңга, бер сулга ташлый-ташлый, иңсәләрен сикертеп, Сәидәгә таба килә иде.* А.Каһһар

**ИҢСӘЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Иңсәсеннән (*1–3 мәгъ.*) тоту, иңсәсеннән әләктерү

2) *сөйл.* Баш артына, баш чүмеченә сугу. *– Төнлә йокламыйча гулять итеп йөрисез! – дип, шәкертләрне иңсәләп, үз казармаларына хәтле озатып куйдылар.* К.Тинчурин

**ИҢСӘЮ** *ф. диал.* Аска таба салыну, салынып тору. *Балык аулый торган үрмәкүчләр суга иңсәеп төшкән агач ботаклары өстенә урнаш[алар].* Яңалиф

**ИҢСЕРӘ́Ү** *ф. диал.* Әлсерәү. *Ул башка картлар шикелле иңсерәгән, йөдәгән, сөйкемсез түгел: тулы гәүдәле, тулы битле, --- киң күкрәкле карт иде.* Ак юл

**Иңсерәп бетү** Тәмам иңсерәү

**ИҢСҮ** *с. диал. к.* **иңкү** I. *Газиз --- яр буйлап шактый баргач, тәбәнәк тал куаклары үскән иңсү җиргә утырды, Идел-суга текәлде.* Ш.Җиһангирова

**ИҢСҮЛЕК** *и.* Чокырланып, батып торган урын; иңкүлек. *Дулкын иңсүлеге*

**ИҢҮ** *ф.* **1.** 1) Чокырланып җиргә батып керү, батып китү, бераз, берникадәр сеңеп тору. *Әмма йорт, келәт, абзар-лапаслар бик тә иңгәннәр иде.* М.Хуҗин. *Аскы каттагы тәрәзәләре җиргә иңә башлаган, --- мунча, тыштан караганда, бер кешене дә җәлеп итәрлек түгел.* Ф.Латыйфи. *Йорт, кояш ягына таба кыйшаеп, җиргә иңгән.* Н.Хәсәнов

2) Уелып керү, чокырланып тору, чокыр хасил булу. *Комбинезон кигән, тешләре төшүдән яңаклары иңгән ябык ир куркып калды.* М.Мәһдиев. *Алинә, туктап, Айсылуны кабер янына алып керә, дәшми генә утыргычка иңәләр.*

Х.Ширмәт. *Бу тирәләрнең җире, бозлык чорында калын боз катлавы басып торганлыктан, аска иңгән булган ---.* А.Муранов // Чокыр сыман урын хасил итү. *Шунда, абзарның караңгы почмагында, сыер таптый алмый торган корырак урында мин нindидер батынкылык күреп алдым. Бу ни хәл тагын? Әллә гасыр буе торган абзар астында җир иңә башлаганмы?* Р.Фәизов // Аска таба сеңү, басылу. *Иргали, җиргә иңеп керергә теләгәндәй, окоп кырыена тагын да ныграк елыша төште.* М.Хәсәнов // Авырлык көче белән өслектән төпкә төшеп китү. *Вышка артыннан ук, лебедка, ротор, трослар һәм культбудка урнаштырылган тимер чаналарын өстерәп, өч-дүрт трактор да баржага керде. Гаять зур баржа күзгә күренеп суга иңде.* М.Хәсәнов

3) *сөйл.* Офык артына төшеп күмелү, баю. *Кояш иңгән, тышта караңгы төшеп килә.* Ш.Камал // Килү, җитү, башлану. *...Яз килде, өстенә тынгысыз төн иңде.* А.Гыйләҗев

4) Күктән төшү. *– Әйе шул, – диде фрау Берна. – Кайчак мин «Тәүрат»ны ачам дә Раббыбыздан иңгән васыятьләрне укыйм.* Т.Әйди. *– Сез, райком инструкторы була торып, ничек мондый фикерләргә килә алдыгыз соң? – Алар, ничектер, үзләреннән-үзләре иңә миңа. Гел көтмәгәндә югарыдан әйтәләр.* Ф.Садриев. *– Син сизәсеңме өстән иңгән нурны? – дип, аның [Ленизаның] башын сыйпады Герман. – Ул [Илаһи] безне хуплый!* М.Маликова

5) *диал.* Билгеле бер күренеш, төс алу, билгеле бер рәвешкә керү; берәр нәрсәгә икенче нәрсә кушылу, йогу (төс, буяу турында). --- *бөтен тау битен каплап киткән урман да, инде карасу яшел төс иңеп, ап-ачык күренә иде.* Х.Сарьян. *Йөзенә зәгъфран сарысы иңгән Зөлхия бер иртәне, ничектер, җиңеләеп, яшәреп киткәндәй, Надыйр белән Айзирәне үз янына дәшүләрен үтенде.* Р.Мулланурова. *Бернichә минуттан аның --- мәетнеке төсле ак чыраена сизелер-сизелмәс кызыллык иңгән иде.* Ф.Садриев

6) *күч.* Ишетелү, барып җитү. *– Иптәш өлкән лейтенант, сезне штабка чакыралар, – диде кинәт иңгән ирләр тавышы.* М.Юныс. *Зөһрә бакча уртасында туктап кала да, күктән иңгән тавышларны ишеткән сымак, бәбәкләрен күккә терәп тыңлап тора.* Р.-Н.Гүнтәкин

7) *күч.* Билгеле бер кыяфәткә керү. *Гөлниса апа Гөлүсәгә кул күтәрде... Коелыплар иңде бичара кыз, үкси-үкси, буылып еларга кереште.* М.Хәсәнов. *Канат иңде егеткә. Җегәр, гайрәт ташкыны килде.* Р.Мөхәммәдиев

8) *күч.* Курку, көтү кебек киеренке хәлдән чыгу, тынычлану. *Яралы баласы янында булгач, аңа җан иңде.* Я.Зәнкиев. *Габдрахман абый белән сөйләшкәннән соң, минем күңелгә тынычлык иңгән иде инде.* Г.Ахунов. *[Ананың] Күзләренә йокы кайтты, өйгә янә иминлек иңде.* Р.Мөхәммәдиев

9) *күч.* Акыл керү, аңлылану. *Йа Ходаем, күпме гомерләр күргәнем юк бит инде сине, Илдархан... Үзгәргәнсең, әзрәк буйга да үскәнсең бугай. Акыл иңгән сиңа.* М.Хуҗин

10) *күч.* Берәр нәрсәнең тулысынча эченә үтеп керү; беләп алу, үзенә буйсындыру. *Кар бөртекләре белән җиргә моңсу яктылык, талгын рәхәтлек тә иңә иде кебек.* Р.Вәлиев. *Бәхетсезлек чыккан йортка бәхет иңмәскә дигәндер инде...* М.Галиев. *Ирексездән, күзләре яңадан кысыла башлады Микәйнең. Күзләре кысылды, ә йокы иңмәде.* Р.Мөхәммәдиев // Кешенең эчке дөньясына нindидер борчу керү. *Иргалинең йөрәге янә дөрселдәргә керешә, күңеленә янә шик, икеләнүләр иңде.* М.Хәсәнов. *Таң атса да, кояш баеса да, күңелгә тынычлык иңмәде, эзгә бастырып милиция килер сыман иде.* Н.Гыйматдинова. *Табын янындагы сүзләр азая, зират турысында сөйләшә башлауга, күңелләргә курку иңә.* А.Гыйләҗев

**2. иңеп** *рәв. мәгъ. күч. диал.* Бик тирән. *Башымны кую белән мин иңеп йокыга китәм.* Ш.Әхмәдиев

**Иңә бару** Торган саен ныграк, тагы да арта барып иңү. *Ә үзе, никадәр тырышса да, күзләренә иңә барган моңсулыкның торган саен тирәнәя генә баруын яшерә алмады.* Г.Галиева. *Кояш урман өстенә иңеп бара.* М.Галиев. *Гармун телләрендә, йөрергә яңа өйрәнгән мәче баласы кебек, чалый-болый атлаган бармакларга һаман саен ышаныч, ныклык иңә барды.* Н.Әхмәдиев

**Иңә башлау** Иңәргә тотыну. *Урманда кар иңә башлаган, чаңгы юлы калкып чыккан.* Н.Каштанов. *Ә мин аны көз төсе иңә башлаган агачларның сафлыгы дип уйлыйм.* Ш.Галиев. *Торабара аның күңеленә битарафлык иңә башлады ---.* Р.Вәлиев

**Иңә төшү** Тагын да бераз, берникадәр иңү. *Мин күрмәгән тугыз-ун ай эчендә, картаеп, җиргә иңә төшкән бу йорт.* Н.Әхмәдиев. *Яшеллек эчендә җиргә иңә төшкән борынгы йортларның тарихын сөйләп бара.* М.Галиев

**Иңеп бару** Торган саен ныграк иңү. *Кояш иңеп бара ---.* Б.Камалов. *Мин чүкечне кысыбрак тоттым, һәм без эшләп киттек. Клепкалар, титан калайлары беркетелеп, иңеп бара.* Н.Хәсәнов

**Иңеп бетү** Бөтенләй, тулысынча иңү. *Марҗаның куены нигә шундый да тирән, шундый да кайнар ул? Ахияр да баш-аягы белән йотылды, иңеп бетте анда.* Р.Зәйдулла. *Бер, ике, өч, дүрт, биш... алтынчы өй безнеке. Түбә саламы каралып, иңеп беткән инде ---.* М.Галиев

**Иңеп калу** Нindидер сәбәпләр аркасында иңү. *Урамда башын игән кое сиртмәләре моңаеп утыра. Иңеп калган кое бураларының өстен каплап, таш бастырып куйганнар.* М.Галиев

**Иңеп килү** Аз-азлап, акрынлап иңә башлау. --- *җәй буе кояш нуры һәм яңгыр тамчылары белән иркәләнгән яфракларга анда-санда саргылт төс иңеп килә.* Р.Мөхәммәдиев. *Ерактан шавы-гүләве ишетелмәгән дулкын булып, бөтен үзәнлекләрне колачлап эңгер иңеп килә.* М.Галиев. *Кояш баеган, караңгылык иңеп килә иде инде.* Ф.Садриев

**Иңеп тору** Әледән-әле, ара-тирә иңү. --- *мәҗүси гарәпләрнең аңына бер һәм бердәнбер Аллаһ турындагы идеяне сеңдерү пәйгамбәребезгә җиңел булмаган, шуңа күрә ара-тирә иңеп*

*торган сүрәләр ярдәмендә аңа даими аңлату эше алып барырга туры килгән.* С.Шәмси

**Иңеп төшү** Кинәт иңү. *Кар таулары кайнар кояш нуры астында шул көнне үк иңеп төште.* И.Гази. *Мотыйк һаман кузгалмады. Аннары «лып» итеп утыргычка иңеп төште.* Р.Вәлиев

**ЙҢ ЯХШЫСЫ** *кер. сүз* Барлык гамәлләрдән дөресрәге, кулайрагы, файдалырагы. *Иң яхшысы: эшне ул дәрәҗәгә җиткермәскә кирәк.* Р.Ишморат

**ИОД** *и. гр.* 1) *хим.* Кара соры төстә металлик ялтыравыклы кристаллар рәвешендәге химик элемент, йод. *Иод эремәсе яфракның төсен үзгәртми.* Биология. *Диңгез суүсемнәреннән иод, калий тозлары, --- һ.б. алалар.* Ботаника. *Әлеге минераль суның составында биологик актив матдәләр – бром, иод, хлор, кальций, күкерт, микроэлементлар бар.* Мирас

2) Медицинада куллану өчен шул кристалларның спирттагы эремәсе. *Ярага иод сөртү*

**ИОДИД** *и. гр. хим.* Иодның башка химик элементлары белән кушылмалары (медицинада, фотографиядә, металлургиядә һ.б.ш. тармакларда кулланыла)

**ИО́Н** *и. гр. физ.* Уңай яки тискәре корылган атом яки атомнар төркеме. *Индий атомы, германий атомнары белән бәйләнешкә кергәндә, дүрт валентлы элементка әверелергә омтыла һәм германий атомының бер электронын үзенә алып, тискәре ионга әверелә.* Р.Шаһморатова. *Ионнар – атомнарның электроннарны бирү яки аларны үзләренә китереп кушу нәтиҗәсендә барлыкка килгән корылмалы кисәкчекләр ул.* Химия. *Гадәттә, тышчаның ике ягында ионнар концентрациясе бертигез булмый: җепсел эчендә натрий һәм хлор ионнары тукыма сыекчасындагыга караганда 10 тапкыр азрак, аның каравы калий ионнары 20 тапкыр күбрәк.* Кызыклы физиология

**ИОНИЗА́ТОР** *и. рус* Медицинада яки көнкүрештә һаваны ионлаштыру өчен махсус эшләнгән электр приборы

**ИОНЛАШТЫРУ** *ф. физ.* Ионнар барлыкка китерү. *Ә телевизор өйнең һавасын боза, өй һавасын ионлаштыра бит ул.* А.Ганиев

**Ионлаштырып бетерү** Күп итеп, бик күп ионнар барлыкка китерү, нык ионлаштыру

**ИОНЛАШУ** *ф. физ.* Нейтраль атомнардан яки молекулалардан ионнар барлыкка килү. *Икенчел ионлашу. Ионлашу потенциалы. Ионлашу энергиясе*

**Ионлашып бетү** Нык ионлашу

**ИОНЛЫ** *с. физ.* Ионнар ярдәмендә ясалган, ионнарга бәйле булган. *Электростатик тартылу көчләре йогынтысы нәтиҗәсендә ионнар арасында ясала торган химик бәйләнешне «ионлы бәйләнеш» дип атыйлар.* Химия. *Ылыслы урманнардан таралган кислородка бай һава тау һәм диңгезнең ионлы һавасы белән туендырыла.* А.Муранов

**ИОНОСФЕ́РА** *и. гр.* Җир атмосферасының ионнар һәм ирекле электроннарга бай булган иң югарыгы катламы. *Ионосфера Кояшта бара торган процесс белән тыгыз бәйләнгән.* А.Фаткуллин. *Хәзер без ионосферада радиодулкыннар тарaлуны практик яктан бәяли алырбыз.* Галәмгә юл. *800 км биеклектә әле ионосфераның чиге сизелми.* Фән һәм тел

**ИОРДА́НИЯЛЕ** *и.* 1) Көнбатыш Азиядәге зур булмаган мөселман дәүләте Иорданиядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Өлкән яшьтәге иорданияле Уим Хәтим ире белән «теге дөньяда очрашмас өчен» аерылышырга карар кыла.* Юлдаш

2) Чыгышы белән Иорданиядән булган, Иорданиягә бәйле. *Күчмә кабиләләрдән чыккан иорданияле гарәпләр һәм палестиналы гарәпләр – Иордан елгасының Көнбатыш ярыннан килгән эмигрантлар.* Сөембикә

**ИП** *и.* **1.** 1) Нәрсәнеңдер җае, уңае, көе, рәте. *Илдә ип бар чакта әйбәт кенә яшәгән ул [Семён]: заводта слесарь булып эшләгән, өйләнгән, квартир алган.* М.Маликова

2) *сөйл.* Як, тараф, юнәлеш. *Идел каргасы – Идел ибенә, Җаек каргасы Җаек җаена очар.* Мәкаль

3) *иск.* Нәрсә дә булса эшләү уе, теләк; шул уй-теләкне тормышка ашыру максатында эшчәнлек. *Красноярдагы ошбу дүрт-биш татар-төрек балалары үзләренең алдагы көннәрен яхшырту ибенә кереш[әләр].* Шура

**2.** *рәв. мәгъ.* Җай белән, уңайлап, тәртипләп. *Шәйдулланың фикерен җайлап-сайлап кына Галләмгали агай куәтли. Монысы җай белән, ип белән.* М.Мәһдиев. *«Бишек» менә һавага Талгын гына, ип кенә...* Ә.Маликов. *Әткәй кулына җайлашып беткән кораллар минем кулга да ип килеп тора.* Х.Сарьян

**3.** *с. мәгъ. сир.* Җайлы, уңайлы, ипле. *Бу әйбер бик ип. Ип кеше*

◊ **Ибен китереп** Бөтен нечкәлекләрен, үзенчәлекләрен тиешенчә исәпкә алып, тәртибен белеп, ипләп, җайлап (эшләү турында). **Ипкә керү** *к.* **ипкә килү**. *Башына тай типмәгән булса, өйләнгәч ипкә керер әле.* Г.Камал. **Ипкә килү** 1) Җайлану, уңайлану, тәртипкә салыну, рәтләнү. *[Искәндәр:] Эшләр бер дә ипкә килми. Ни эшләтергә инде бу кызны...* М.Фәйзи. *Минем хәлем бу сукыр карт хәле түгел ләбаса. Аяк, быел булмаса, яренгә ипкә килер.* Б.Камалов; 2) Холык яхшы якка үзгәрү, көйләнү, җайлану. *Бер ипкә килмәссеңме дип, әле дә биш ай кадерләп йөрттем [сине].* М.Фәйзи. *Әмма Андрейның әкренләп җайга, ипкә килә башлавын Настёна күреп-сизеп торды...* В.Распутин; 3) Сүз тыңлау, берәр нәрсәгә күнү. *Коммуна төзү мәсьәләсенә килгәч, Хәйбулла киреләнде дә китте. Һич ипкә килми. Артель, ди, вәссәлам!* Ш.Камал. **Ипкә китерү** 1) Ватылган, бозылган нәрсәне төзәтү, ипләү; 2) Берәр эшне юлга салу, рәтләү. *Ниһаять, Талиянең әле рәсми, әле ипле-ягымлы яңгыраган тавышы ике ирне дә ипкә китерде, тын калдырды.* Г.Галиева; 3) Кемне дә булса үз ягына күндерү, көйләү, күңелен табу, җайлау. --- *Әнәс аны нык иярләгән иде, ике яктан касыгына үкчәләре белән тибеп, Зәйтүнне бик тиз ипкә китерде.* А.Гыйләҗев. *Ипкә китерүдән өмет өзеп һәм Йосыф белән Зәйнәпне тәмам «юлдан яздыруыннан» куркып, Хөсәен олы улы Газизне өеннән куып чыгара.* Әдәбият. **Ипкә салу** Берәр эшне көйләү, рәтләү. **Ипкә утыру** *к.* **ипкә килү** (*2 мәгъ.*) *Педагогия нормаларына сыйдымы, сыймадымы*

*бу, ләкин «чыбыркы» телендә шушы сөйләшүдән соң, малай сизелерлек ипкә утырды.* Ф.Хөсни

**ИПИ** *и. сөйл. к.* **икмәк**. *Дусларча гына әйтәм: бөтенләй үк бушлай куя алмыйбыз, үзебез дә ипи белән тозда гына торабыз.* Г.Шәрипова. *Әти белән әни, безнең ипи сорап тилмергән күзләребезне күрмәс өчен, читкә борылалар.* Ф.Яруллин. *Бал корты «ипие»нең могҗизалы дип әйтерлек дәвалау сәләте турында халык табиплары искитмәле хәлләр сөйлиләр.* Файдалы киңәшләр

◊ **Ипи ашатма** Кемнең дә булса берәр нәрсәгә бик нык бирелүе, берәр эш белән ихластан мавыгуы турында («шул әйберсе яки эше булса, ашамый да тора ала» мәгънәсендә). *Коптилов миңа пышылдый: – Федоренкога куш! Ипи ашатма – илләмә чыгыш ясарга ярата инде.* З.Зәйнуллин. **Ипи әгәр** «Изге ипи белән ант итәм» мәгънәсендә кулланыла. *Карыйм декабрь кичендә, Үпкәм зур декабрьга, Юк, ипи әгәр, онытмам Кергәнче шул кабергә.* С.Хәким. **Ипидер, ипиемдер** *сөйл. к.* **ипи орып үтерсен**. *Егетләр, оттым менә, ипидер, оттым!* А.Расих. – *Үзең яраткан кешеңнең балалары да минем өчен газиз булыр. Ышан. Ипидер, – диде егет.* Р.Кәрами. *Рәхимҗанның эчтән кайнап бәрелгән сулышы иренен пешерде. – Ипидер, әйтмәде. Ул кеше бу дөньяда рәхәт күрмәс, кенә диде.* Н.Гыйматдинова. **Ипидер газим** *к.* **ипи әгәр**. *Садыйк агаегыз, әгәренки исән калса, ипидер газим, менә дигән рәссам булачак егетнең әйберләренә карап, аны ихлас күңелдән исенә төшерәчәк.* Ш.Рәкыйпов. **Ипидер менә** *к.* **ипи әгәр**. *Кичәге «шуклыкларын» онытам --- һәм дустыма үтә мөһим хәбәр җиткерәм: – Бүген төнлә гел синең тавыш колакта, малай, ипидер менә!* Н.Гыйматдинова. *Сыңар бөртек ярмага да кагылмам, ипидер менә, кояштыр!* Р.Ишморатова. **Ипиенә май сөртеп тору** Куштанлану, ялагайлану. **Ипи йөзе(н) (чыраен) күрмим** *к.* **икмәк чыраен күрмим**. *Синең алда намусым чиста, Алмаз Борисович, шөкер! Менә шушы ипинең чыраен күрмим...* Х.Камалов. – *Беркемгә дә әйтмәдем. Беркем дә белми. Кичер мине, Зөфәр, кичер. Ипи йөзен күрмим менә... Кәнзел, елар дәрәҗәгә җитеп, ант артыннан ант итте.* М.Хәбибуллин. **Ипи орып үтерсен** Сүзнең дөреслегенә, вәгъдәсенең үтәләчәгенә ышандыру өчен ант итеп әйткәндә кулланыла. *Ипи орып үтерсен, әгәр алмыйча китсәм.* Ф.Хөсни. **Ипи өсте** *к.* **икмәктер**. **Ипи савыты** *гади с. к.* **ипи шүрлеге**. – *Нәрсә дип ипи савытыңны кыегайтасың? – диде Сәхи, үпкә белән. Кыз аны аңлап җиткермәде бугай, аптыраулы караш ташлады. – Шушы ак чырайлар кешечә сөйләгәнне аңламаслар инде. Нигә авыз ерасың, дип әйтәм мин сиңа.* Ф.Яруллин. **Ипи салган көнне ачтан үлгән** 1) Үтә саран, хәтта үзеннән дә кызгана торган кеше турында әйтелә; 2) Соң дәрәҗәдә булдыксыз кеше турында көлеп әйтелә. **Ипи салу** Ипи пешерү. *Ипи салу – хатын-кызның бер тәүлеккә сузылган эше.* М.Мәһдиев. --- *авыр елларда халык телендә шундый зур хәбәр йөри иде: – Хәбирнекеләр ипи салып яши...* М.Мәһдиев. **Ипи тотып ант итү** *к.* **ипи орып үтерсен**. – *Зинһар, гафу ит, брат, гомер ишетмәссең, каберемә керсәм дә ишетмәссең андый сүзне. Ипи тотып ант итәм менә, ике күзем чәчрәп чыксын! – диде Кәнзел.* М.Хәбибуллин. *Гөлзада ипи тотып ант иткән: «Сәйфикәем, бу хакта авыз ачып сүз әйткәнем юк, әле Аллага шөкер, яшьләрдән ким кыланмыйсың», – дигән.* Ф.Сафин. **Ипи черетеп яту** Вакытны, акчаны әрәм итү. *Юкка ипи черетеп ятасыз сез, егетләр.* Ф.Кәрим. **Ипи черетү** *к.* **ипи черетеп яту**. **Ипи черетүче** *кимс.* Вакытны, акчаны әрәмшәрәм итүче, кулыннан эш килмәүче булдыксыз кеше. **Ипи чырае күрмәү** 1) Ач булу, ачлыктан тилмерү. *Моңарчы ипи чырае күрмәгәннәр җитеш тормыш белән яшәячәк!* Х.Камалов; 2) Сүзнең дөреслегенә ышандыру өчен ант итеп әйткәндә кулланыла; кояштыр, валлаһи. **Ипи шүрлеге** *гади с.* Авыз. – *Азман --- анаңны эт ялагыры!.. Яп инде шул ипи шүрлегеңне! – дип кычкырып җибәрде Мунча Миче.* З.Фәтхетдинов. *Күрсәләр – ипи шүрлегенә эләгә, күрмәсәләр – бөтен көн минеке.* Ф.Хөсни. **Ипи шүрлегенә менеп төшү** *гади с.* Авызга сугу. *Шул арада Хираҗның ипи шүрлегенә дә менеп төшәргә өлгерде ул [Гыйльметдин].* Ф.Сафин. *Закировта ул мактанчыкның ипи шүрлегенә менеп төшү теләге уянды.* З.Фәтхетдинов. *Син, тилекәй, сүзеңне үлчәбрәк сөйлә. Икенче берәү әйтсәме, момент – мин аның ипи шүрлегенә менеп төшәр идем.* Ф.Сафин. **Ипи шүрлегенә тамызу** *к.* **ипи шүрлегенә менеп төшү**. **Ипи шүрлеген җимерү** *гади с.* Авызын сугып җәрәхәтләү. --- *бернинә егет Тәүфикъны ике яктан тотып торалар, ә ул алар кулыннан читкә талпына иде: «Ипи шүрлеген җимерәм әле мин аның!»* М.Маликова. – *Печелгән ул. Печелгән тәкә! – дип көләләр. Шундыйлардан бер-икесенең ипи шүрлеген җимергәч, тындылар тагын.* Р.Сибат. **Ипи шүрлеген талкан ясау** *гади с. к.* **ипи шүрлеген җимерү**

**ИПИ́ АГАЧЫ** *и. к.* **икмәк агачы**. *Тын океан утрауларында ипи агачы үсә. Ул бик матур, киң ябалдашлы, яфраклары зур, кытыршы һәм яртышар метрга җитә.* Юлдаш

**ИПИ-КОНДИТЕР** *җый. и.* Ипи һәм кондитер ризыклары. *Чәк-чәкне шушы чара өчен махсус «Биләр» рестораннар челтәре, --- һәм ипи-кондитер комбинаты пешереп бирде.* Мәдәни җомга

**ИПИ́ КӨРӘГЕ** *и.* Юкә агачыннан ясалган почмаксыз көрәк. *Ачы камырны әни шуларга [ипи савытларына] сала да күпереп маташканда гына әйләндереп, ипи көрәгенә куя һәм мич төбенә озата.* М.Мәһдиев

**ИПИЛЕ** *с.* 1) Азык-төлеккә бай. *Бер көнне балаларга: – Без сезне ипиле якка, Украина дигән җиргә озатабыз, – дип игълан иттеләр.* М.Маликова. *Запаслы кешеләр искене чәчте. Коры басуга. Шулар егерме икенче елны ипиле булды.* М.Мәһдиев

2) *күч. к.* **икмәкле** (*3 мәгъ.*)

**ИПИЛЕК** *с.* **1.** 1) Ипи өчен әзерләнгән. – *Аның кадәр ипилек ашлыкны урлар өчен, бик олы кесәләр кирәк булыр, – дип, энем Хәйдәр сүзгә кушыла.* Ф.Яруллин

2) Ипи, азык сатып алырга җитәрлек. *Аннары халыктан «ваучер» дигән кәгазьләрне ипилек акчага яисә бер ярты хакына җыеп, шулар бәрабәренә зур-зур завод-фабрикаларга хуҗа булу җае чыкты.* М.Маликова. *Бу рольне башкару миңа --- үземә һәм гаиләмә ипилек акча юнәтергә, шушы хәләл ипиемә, бик үк калын булмаса да, май ягып ашарга мөмкинлек бирә.* З.Дәүлитов. *[Хәмидә] Күз яшьләрен, әрнүен басып, теләнче сыман хурлана-хурлана, кемнәргә күпме бирәчәге барын, балага сөтлек, ипилек акчаны тагын кемнән сорап торырга мөмкин икәнен барларга тотынды.* Асылъяр

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ипи алырлык, ашарга алырлык чыгым. *Мәнәх карт тагын көлде. Кәефе әйбәт иде, ахрысы: – Хә-әх, хә-әх, хәх! Өстәвенә, бай түләп җибәрсә ипилек, тозлык.* З.Зәйнуллин. *Спиридонычтан ун көн ашханәдә түләүсез ашарга дигән язу алып бирде, Купцовтан ике кило ипилек талон алып чыгып тоттырды.* Т.Мөбарәков. *Күпләр, өеннән бер тиен ярдәм алмыйча, стипендиягә яши, вокзалда йөк бушатып ипилек юнәтә.* Казан утлары

2) Ипи пешерергә җитәрлек ашлык, он һ.б.ш. *Без – бер төркем мәктәп балалары – --- коелып калган башакларны җыябыз. – Карагыз әле, малайлар, өчебезнекен кушсак, бер бөтен ипилек булыр бит, ә? – ди Өлфәт, кулындагы капчыкны селеккәләп.* Г.Сабитов

**3.** *рәв. мәгъ.* Ашарга-эчәргә, тамак туйдырырга җитәрлек. *Монда кайтарсалар да, аларны [колбаса, кызыл, кара уылдыкны] кем генә алып ашар икән. Ипилек тә рәтләре юк.* Н.Әхмәдиев. *Ул пенсия акчасы нәрсәгә җитсен, утына, газына, суына түләгәч, ипилек һәм тозлык кына кала шул.* Мәгърифәт

**ИПИЛЕК-СӨТЛЕК** *рәв. к.* **икмәклек-тозлык** (*1 мәгъ.*). *Элек, мәсәлән, ничегрәкләр итеп ипилек-сөтлек өстәмә акча табу турында уйлый идем.* Ф.Баттал

**ИПИЛЕК-ТОЗЛЫК** *рәв. к.* **икмәклек-тозлык** (*2 мәгъ.*). *Таһир ага русча ипилек-тозлык кына сөйләшә ала, Григорий шулай ук берничә авыз гына татарча сүз белә.* Г.Галиев. *Без «балаларны ипилек-тозлык кына булса да ничек итеп татар телендә сөйләшергә өйрәтергә икән соң» дигән борчулар белән яши идек.* Н.Гыйләҗева. *Отто исә телгә бик сәләтле, бик тиз отып ала, инде ипилек-тозлык немецча сөйләшә башлады.* Х.Камалов

◊ **Ипилек-тозлык (кына) белү** Икенче бер телне төпле рәвештә өйрәнмичә, бераз аңлашырлык кына сөйләшә белү. *Караңгы авылдан соң зур калага эләккән, русча ипилек-тозлык та белмәгән «татарчонок»ның хәле нинди икәнен язмасам да чамалыйсыздыр инде.* Г.Әпсәләмов. *Бу татар, әйткәнемчә, урысча ипилек-тозлык та белми иде.* А.Гыйләҗев. *--- татарчаны бөтенләй белмәгән яки ипилек-тозлык кына белгән персонажларыбыз кайвакыт язучыларыбызны да кызыктырырлык тел белән сөйләшеп, безне хәйран итәләр.* Х.Сарьян. **Ипилек-тозлык (кына) сукалау** *к.* **ипилек-тозлык (кына) белү**

**ИПИЛЕК-ЧӘЙЛЕК** *рәв. к.* **икмәклек-тозлык** (*1 мәгъ.*). *Ипилек-чәйлек кенә акчаны үзем дә калдырам мин!* Рифә Рахман

**ИПИСЕЗЛЕК** *и.* Ипи булмау, ачлык. *Балачакта иписезлекне кичергән кеше генә искә аеруча сизгер була.* М.Мәһдиев

**ИПИ-СӨТ** *җый. и.* Ипи һәм сөт азыклары; көндәлек ашау-эчү ризыклары. *Күршеләре кибеттән ипи-сөтен кайтарып бирәләр, тик менә юындыру ягы читен.* М.Маликова. *Ибрайның үз гомерендә чабатадан чыкканы, ямаусыз кием күргәне юк, ипи-сөт күргәне юк.* М.Мәһдиев. *Әле бит безнең ипи-сөт алырга да акчасы җитмәгән пенсионерларыбыз да бар.* Сөембикә

**ИПИ-ТОЗ** *җый. и. к.* **икмәк-тоз**. *Аклар килүен ишетү белән, Рәхим бай капканы ачарга әмер бирде, --- казаклар белән исәнләшеп, ипи-тоз чыгарттырды...* М.Хәбибуллин. *Ләйлә беренче тапкыр очрашканда ук үз укучыларына шулай аңлатып куя: – Беренче курсны тәмамлагач, сезне бик еракларга илтеп ташларга була, сез инде адашып йөрмәячәксез, ачтан үлмәячәксез. Ипи-тоз сорап алырлык, юл сорарлык сүзләр беләчәксез...* М.Маликова. *Чигүле сөлге өстенә салып ипи-тоз китергән Хәбра картны гына кибитка янына җибәрделәр.* К.Нәҗми

◊ **Ипи-тоз белән (каршылау)** *к.* **икмәк-тоз белән (каршылау)**. *[Мансур Хуҗиевич:] Ташла, ипи-тоз белән каршы алмасларын чамалагансыңдыр.* М.Маликова. *Кара туфраклы, куе калын чирәмле аэропортта безне чәчәкләр, җыр, милли кием, ипи-тоз белән каршы алдылар.* М.Мәһдиев. *Халкыбыз гомер-гомергә кунакларны ипи-тоз, якты йөз белән каршылаган.* Мәдәни җомга. **Ипи-тоз, матур кыз** «Сый-хөрмәт, күркәмлек – бар да бар» дигән мәгънәдә кулланыла. **Ипи-тоз, якты (ачык) йөз** Кадерле кунакларны, хөрмәткә ия кешеләрне барынча сый-хөрмәт, ихтирам белән каршылап әйтү. *...Җәлүк бабай кунакларны, ипи-тоз, якты йөз дигәндәй, җылы гына каршылады ---.* Э.Касыймов. *Дөрес, киленебездән зарлана алмыйбыз. – Ипи-тозы, ачык йөзе өчен хуҗага рәхмәтләребезне әйтик тә өйләргә таралышыйк, – [диде Каюм].* Г.Шәрипова. *Ипи-тозын, якты йөзен кызганмый, кулыннан килгәнчә сый-хөрмәтен күрсәтә.* Сөембикә

**ИПИ-ТОЗЛЫ** *с.* 1) Ипие-тозы булган, хәлле, мул тормышлы. *Ипи-тозлы гаилә*

2) *күч.* Юмарт, киң күңелле, илгәзәк. *Ипи-тозлы хуҗабикә*

**ИПИ-ТОЗЛЫК** *рәв. сөйл.* **1.** 1) Ашарга-эчәргә генә җитәрлек. *Күрше Мотыйгулла аена йөз иллене каерып ята, ә миңа ипи-тозлык: нибары сиксән тәңкә.* З.Вәли

2) Аз-маз гына. *Араларыннан ничә кеше татарча белә дип уйлыйсың? Алтысы... Калганнары ипи-тозлык кына сукалый.* Р.Вәлиев. *--- кайберләре үзләре дуслык визиты белән барасы халыкның телен ипи-тозлык кына түгел, хәтта үзара шаярышырлык дәрәҗәдә үзләштерергә өлгерделәр.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ. күч.* 1) Аз-маз булган. *Бүгенге көндә җәмгыятебезнең барлык катламнарында ипи-тозлык белемнең дә --- бик түбән дәрәҗәдә булуы очраклы күренешме?* Идел

2) *күч.* Бик аз, ачтан үлмәслек. *Ярлыларда исә тәрбия бирүгә ихтыяҗ «үзенә ипи-тозлык эшли алса ярый» дигән гади генә ихтыяҗга кайтып кала.* Сөембикә

◊ **Ипи-тозлык белү** *сөйл. к.* **ипилек-тозлык белү**. *Манкорт татар туган телен белми, Урысчаны белә ипи-тозлык.* Г.Афзал. **Ипи-тозлык сукалау** *сөйл. к.* **ипилек-тозлык белү**. *– Таштимер әкә, сез таҗикча беләсезме? – Ипи-тозлык сукалыйм.* Т.Әйди

**ИПИ́ ЧӘЧӘГЕ** *и. бот. диал.* Кузаклылар семьялыгына караган, өч яфрагы да бер сабактан чыккан һәм чәчәкләре шарсыман чәчәк төркеменә берләшкән үләнчел үсемлек; *русчасы:* **клевер**

**ИПИЧЕ** *и. к.* **икмәкче** (*1 мәгъ.*). *– Өйдә ипи беткән, – диде Сәмигуллла беркөнне. – Без нәрсә, суган суы суырырга тиешме? – Анысы да юк аның, – диде бер ипиче.* Ф.Баттал

**ИПЛӘМӘ** *и. сир.* Маһирлык, осталык, эшкә сәләт. *[Аның] Балта тотарга да ипләмәсе бар.* Г.Бәширов

**ИПЛӘНҮ** *ф.* 1) Ипле итеп урнашу, үз урынын табу. *Суыткычлар да гади түгел, берсе – финнардан, икенчесе Алжирдан килгән. Шешәләр тартма-тартма кереп ипләнәләр.* А.Гыйләҗев

2) Нәрсәгә дә булса күнегү, ияләшү, җайлашу, яраклашу. *Әминем, ичмасам, һич кенә дә исем китми. Юк, дөрес сүз түгел бу. Шулай ук, кемгәдер ошарга тырышып, тормышка ипләнергә азаплану да түгел.* Ф.Хөсни. *Әкрен-әкрен ул [Рауза] күнегә барды, куркулары басыла төште, йөрәге ипләнде, --- үз-үзенә ышаныч беләнрәк яши башлады.* Г.Мопассан

3) Үзен-үзе рәтләү; ясану, төзәтенү. *Матур итеп киенү, ипләнү*

4) *күч.* Уңайланып китү, характеры әйбәтләнү; җайлылану

**Ипләнә башлау** Ипләнү юлына басу

**Ипләнә бару** Торган саен ныграк ипләнү

**Ипләнә төшү** Бераз ипләнү, иплегә әйләнү. *Батареядагы мөнәсәбәтләр әкренләп тигезләнә, ипләнә төште.* Х.Камалов

**Ипләнеп бару** Акрынлап, аз-азлап ипләнү. *Тормышыбыз ипләнеп бара.* Т.Галиуллин

**Ипләнеп бетү** Тәмам, тулысынча ипләнү. *Менә бу фикерләргә дә игътибар итсәк, бу кушымчаларның килешләр арасында күрсәтелүләренә, аларның анда ипләнеп бетмәүләренә гаҗәпләнергә бер дә урын калмый.* Г.Алпаров

**Ипләнеп килү** Әкренләп, аз-азлап ипләнү, ибен таба бару. *– Ничегрәк соң? – дип, Мостафин замполит хакында нидер белергә теләгәндәй сорады. – Ярыйсы. Солдатлар белән дә ипләнеп килә.* Х.Камалов

**Ипләнеп китү** Кинәт ипләнү, ниндидер сәбәп, этәргечтән соң ипләнү. *Балабыз да көпә-көндез, илдән качып, читләрдә себерелеп йөрми. Отыры ипләнеп, акыллыланып кына китте.* М.Фәйзи. --- *этисе малай көткән, әмма кыз тугач, әнисеннән суынып йөргән. Аннары, әнисе малай тапкач, ипләнеп киткән, шатлыгыннан нишләргә белмәгән.* Х.Камалов

**Ипләнеп кую** *к.* **ипләнеп китү**. --- *тәти бирәм, дигәч, ипләнде дә куйды егет.* М.Маликова

**ИПЛӘП-СИПЛӘП** *рәв.* Ашыкмыйча, җайлап кына, сиздермичә. *Ипләп-сипләп сораштыру*

**ИПЛӘП-ЧАКЛАП** *рәв. сир.* Җайлап, уйлап, билгеле бер тәртип белән. *Ипләп-чаклап, үлчәп-кисеп кенә сөйлим.* З.Бәшири

**ИПЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Ипле итү, уңайлау, җайлау; тәртипкә китерү, рәтләү. *[Атаян] Кәгазьләрен катыргы эченә ипләде дә, бәләге белән кочаклап, бухгалтерлар бүлмәсенә кереп китте.* Х.Камалов. *Дима чалкан ятты, озынча бармаклы арык кулларын баш астына ипләде һәм усал, төпсез кара күлдәй күзләрен түшәмгә төбәп, үзе сөйләшә башлады.* А.Гыйләҗев. *Үзе [немец малае] сумкасын ипләде.* С.Шакир

2) Урыныннан кузгалган яки тәртибе чуалган нәрсәне билгеле бер тәртипкә китерү, төзәтү. *Исәнлегенә өмет юкмы дигән кебек, яңа гына җан биргән Шәңгәрәйнең кулларын, күкрәкләрен карыйлар, ике үлекне дә иплиләр...* Г.Ибраһимов

3) Ватылган, җимерелгән нәрсәне төзәтү, көйләү, төзек хәлгә китерү. *Арт тәгәрмәченең чыгып китүен һәм аны ипләп байтак кына вакыт уздыруны исәпкә алмаганда, Тирәкле авылына нәкъ вакытында --- килеп җитте[к].* Ф.Хөсни

4) Берәр үлчәүгә, формага, калыпка яраклаштыру. *Стиль кытыршылыкларын ипләү*

5) *күч. сөйл.* Нинди дә булса уңайсыз хәлдән, халәттән арыну. *Кунаклар озак юл кылә-килә бик ачыкканнар һәм көйгәннәр иде. Шуңа күрә дә алар чәй янына утыруга бигрәк тә тамак ягын ипләргә керештеләр.* С.Җәлал

6) *күч. сөйл.* Нинди дә булса максат белән берәр кешене үз ягына карату; ике арада уңай мөнәсәбәт урнаштыру. *Нишлисең бит, сүзең үтмәгәч, Йөз баш сарык белән нәпман чөйләп ипләгәч!* М.Җәлил

**2. ипләп** *рәв. мәгъ.* 1) Иркенләп, ашыкмыйча, җиренә җиткереп. *Зыя, яткан җиреннән баш калкытып, дивардагы сәгатьне карады да, --- киенеп, юынып, кичә бетерә алмаган эшенә үзе белән алачак әйберләрне сумкасына ипләп тутырырга тотынды.* Г.Ибраһимов. *Безнекеләр, рәхмәт әйтеп тормыйча, алларына төшкәнне бик эшлекле кыяфәт белән ипләп кенә сыпыра бирделәр.* Ә.Еники

2) Сак кына, саклык белән. *[Хәйри:] Кеше күрмәсен, ындыр артыннан ипләп йөрегез.* Г.Ибраһимов. *Башта бер арбага палас җәйделәр, мендәр куйдылар, аннары әбинең иске юрганга ураган гәүдәсен өч кеше ипләп кенә күтәреп чыгарып салдылар.* Ә.Еники. *...Харис Җәүһәрияне үзе генә күтәреп чыгармакчы иде. Ләкин ул бик авыр тоелды. Тезе астыннан Саша тотып алды. – Җайлап... Ипләп... – диде Харис.* М.Маликова

3) Җайлап, йомшак кына; илтифат белән. *Без, картлар, ипләп сөйләгәнне яратабыз.* Ш.Камал // Аңлаешлы итеп, әйбәтләп, рәтләп. *Ипләп әйт, җиңги: кем харап булды?* Г.Ибраһимов. *Тукта әле, агай-эне, ипләп кенә сөйләш!* Ш.Камал

4) Игътибар белән; яхшылабрак. *Менә Насыйп иптәш калсын, ул сабыр кеше, ипләп карар, тикшерер.* Г.Ибраһимов

5) Тәртипле генә, акыллы гына; сакланып. *Бик чибәрсең, ипләп йөри күр инде, туганкаем, арттан иярергә генә торган ир-ат күп ул!* В.Җиһаншин

**Ипли төшү** Бераз, берникадәр ипләү, иплерәк итү. *[Ул] Баланы кулында ипли төшеп, йөгерә-йөгерә станциягә таба китеп барды.* Ә.Еники

**ИПЛӘШҮ** *ф.* **1.** 1) Нинди дә булса шартларда уңайлы, җайлы итеп урнашу. *Барысы да, Хәйдәрне уртага алып ипләшеп утыргач, тынып калдылар.* Г.Минский

2) Нинди дә булса мохиткә, берәр нәрсәгә җайлашу, яраклашу. *Юк, куркаклык бүтәннәрнекеннән артык түгелдер, ә менә яраша, ипләшә алмау миндә артыгы белән иде.* Х.Камалов. *Монда төп конфликтлар – бер-берсенә охшамаган ике кешенең бер-берсенә ияләшү, ипләшү конфликтлары, ике төрле «мин»нән «без» дигән бер система оешу авырлыклары.* Тигез гомер итегез!

**2.** *и. мәгъ.* Берәр нәрсәгә, мохиткә җайлашканлык, яраклашканлык. *[Бу] Шаяру да, ипләшү дә, коры тәкәбберлек тә түгел.* Ф.Хөсни

**Ипләшә башлау** Ипләшү хәле сизелү

**Ипләшә бару** Акрынлап, аз-азлап ипләшү

**Ипләшә төшү** Берникадәр ипләшү

**Ипләшеп бетү** Барысы да, тулысынча ипләшү

**ИПЛЕ** *с.* **1.** 1) Файдалану, куллану өчен җайлы, уңайлы булган. *Яр буенда ак көймәләр, комлыкта ипле ятаклар...* М.Маликова. *Телебез өлкәсендәге уяныш хакында дөрес әйттегез. Аның ипле сүзләрен, күптәннән килгән терминнарын кайтару – яшәү көчен үстерү дигән сүз.* Мәйдан. *Ипле кроссовкалар кигән егетләр җитез булалар.* Ирек мәйданы

2) Кулай, җайлы, уңайлы; яраклы. *Узган ел табыш зур булды, җәй ипле килде.* М.Мәһдиев. *Көн буе механизаторларны ашатып йөреп, ул үзе дә, аты да өшәнгәннәр, талчыкканнар. Ә монда – имән ышыгында – ипле иде.* Ә.Гаффар

3) Әйбәт, яхшы мөгамәләле; җайлы, күндәм, эш итәргә җиңел. *Хуҗалары да бик тыныч холыклы, иплеләр.* Х.Камалов. – *Мондый чакта бик файдалы бер дәвасы бар аның, – диде Кәүсәрия. – ...Әйбәт кенә, ипле генә, сөйкемле генә бер кеше белән сөйләшкәләп йөрү яхшы.* М.Маликова. *Иң мөһиме, әлбәттә, Даянның ипле холык-фигыле. Күндәм, сүз тыңлаучан.* Х.Камалов // Яхшы, әйбәт мөгамәләле, ихтирамлы. *Даладан миһербан көтеп булмый, иң башлап ипле мөнәсәбәт кирәк аңа...* М.Хуҗин

4) Тормыш өчен кулай, файдасы тиярлек, төшемле. *Ипле урынга урнашу*

5) *күч.* Булдыклы, һөнәрле. *Авыл ипле, эшчән, гыйлемле, --- аяклы мал кадерен белүче татар ирләре һәм ашсуга оста, --- чибәр татар хатыннары белән дан ала башлады.* З.Зәйнуллин

6) *күч.* Төз, зифа; матур. *Буйга озын булганга, Филизәнең --- костюм кигән нык, ипле сыны Фидая янында шактый калкып тора ---.* М.Маликова

7) *күч.* Матур яңгырашлы, аһәңле. *Мөхәммәтхан өч ел буе концертларда катнашып килде, аны, ни өчендер, әллә тавышы моңлы, әллә үзе тыйнак булганга, өчпочмаклап тезелгән хорның башына --- чыгарып бастыралар, һәм ул --- салмак, ипле тавыш белән башлап җырлый иде.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиешле хәлгә китереп, уңайлы итеп. *Кичтән ятып, иртәнгә кадәр шулай ипле ял итүне күптән онытканые инде.* Р.Вәлиев. *Чәчләре ипле ятсын өчен, иртәләрен башына челтәр дә бәйләп куя торган иде ич ул [әти] ---.* А.Алексин

2) Җайлап, яхшылап; әйбәт кенә. *Безнең «әңгәмә» ни белән беткән булыр иде, билгесез, ләкин каяндыр килеп чыккан сакчы: – Ипле генә сөйләшегез – дип, икебезне ике якка аерды.* Ф.Яруллин. *Илле яшьләрдәге бу агайның минем белән бик җайлап, ипле иттереп сөйләшүенә хәйран калып, дөньямны онытып утырам.* Г.Ахунов. – *Моннан күп еллар элек, – дип башлады Саниятти, арбадагы йомшак печән өстенә ипле генә менеп утыргач.* Р.Мөхәммәдиев

3) *күч.* Каты итеп. *[Матрос] Надзирательнең кабыргасына шундый ипле итеп утыртты: теге тынын да ала алмыйча, бөгәрләнеп, коридор идәненә ауды.* Г.Гобәй

4) Әйбәт, яхшы. – *«Ашлы семья» дип тә әйтәләр, – ди Аркадий Владимирович, миңа кушылып. – Таза эшлиләр, ипле ашыйлардыр.* М.Рафиков

**3.** *и. мәгъ.* Уңган, һөнәрле кеше. *Эш иплене ярата.* Мәкаль. *[Нәүширван абзый] Кырынмаган караңгы чыраен күтәреп кычкырып җибәрде: – А-ай, ипледән ипсез туган! Телләшә тагын!* М.Галиев

**ИПЛЕЛЕК** *и.* Ипле (*1 – 4 мәгъ.*) булу. *Картны озаткач, өйдә ямь калмады. Элек --- өйдә нинди дер иплелек, пөхтәлек, бөтенлек сизелеп тора иде.* М.Мәһдиев.– *Менә бәрәңге дә өлгерде, җитешегез, – диде [Заһидулла абый]. Һәм өстәл янына ничек тыйнак килгән булса, шундый ук иплелек белән китеп тә барды.* Р.Мөхәммәдиев. *Тотнаклылыгы, иплелеге өчен өлкәннәр аны һәрдаим мактадылар.* Ә.Моталлапов

**ИПОТЕ́КА** *и. гр. икът.* 1) Ссуда алу өчен күчемсез мөлкәткә (җиргә, корылмаларга һ.б.) салынган заклад

2) Закладка салынган күчемсез мөлкәт бәрабәренә банк тарафыннан бирелгән акча (ссуда, кредит). *Бүген хөкүмәт тәккә фатир өләшми, бүген ипотека заманы, кызчык.* Н.Гыйматдинова. *Дәүләт социаль ипотекада катнашучыларга торакны бурычка еллыкның җиде проценты күләмендә түләү шарты белән бирә.* Юлдаш. *«Татнефть» ипотека кредиты буенча республика торак төзү программасында катнашучылар арасында төп урынны биләп торучыларның берсе булып санала.* Мәдәни җомга

**ИПОХО́НДРИК** *с. мед.* **1.** Ипохондриягә хас

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Ипохондриягә бирелгән кеше

**ИПОХО́НДРИЯ** *и. гр. мед.* Дәвалап булмый торган авырулардан курку, үзенең саулыгына артык игътибарлы булу, төрле нәрсәләрдән сәбәпсезгә шикләнү, күңел төшенкелегенә бирелү. *--- профессор Чибәркәева --- турында Маһирә ханымга менә нәрсәләр әйт-*

*те. – Чибәркәева ипохондрия белән авырый.* Г.Әпсәләмов

**ИППОДРОМ** *и. гр.* Ат чабышлары үткәрә торган махсус урын. *Башкалабызның иске аэропорт урынында Казанның 1000 еллыгына төзелеп бетәчәк ипподром халыкара таләпләргә җавап бирәчәк. Казан халкы --- дөнья ипподромнарын шаулаткан атаклы атларны да күрәчәк.* Юлдаш. *Франциядә ипподромда атлар ярышы гына булмый икән ---.* Ватаным Татарстан

**ИППОТЕРАПИ́Я** *и. гр.* Атлар ярдәмендә (нигездә умыртка баганасын) дәвалау. --- *баланы даими рәвештә неврология бүлегендә дәвалыйлар, халыкара клиникада тернәкләндерү курслары узалар, йөзү һәм иппотерапия белән шөгыльләнәләр һ.б.* Шәһри Казан. *Иппотерапия --- бигрәк тә терәк-хәрәкәт аппараты чирләре булган кешеләргә файдалы.* Ирек мәйданы

**ИПРИТ** *и. лат. хим.* Тәндә шеш, җәрәхәт барлыкка китерә торган агулы газ; горчица газы (сугыш максатларында кулланыла). --- *шул беренче бүлектәге бер лаборант кыз кул аркасына иприт тамызган булган.* М.Маликова. *Бер ел булыр инде менә, кызыл урда басты... Миче – гүя кандала инкубаторы. Хет иприт газы сиптер.* А.Хәлим

**ИП-САП** *җый. и.* Җай, рәт, уңай, көй

◊ **Ипкә-сапка кермәгән** Рәткә кермәгән, җайга салынмаган, тотрыксыз. **Ипкә-сапга килү** Рәткә килү, җайга салыну, көйләнү. *Иллесе тулганда гына ипкә-сапка килде ул [Айгөл].* Ә.Моталлапов. **Ипкә-сапка китерү** Рәткә китерү, җайлау, көйләү. --- *вак-төяк корылмаларны, уч төбедәй механизмнарны үзләре дә ипкә-сапка китерә ала бит инде...* С.Шәрипов

**ИПСЕЗ** *с.* **1.** 1) Файдалану өчен уңайсыз, җайсыз. *Иркен, якты һәм бай залда үткәргән шатлыклы сәгатьләрдән соң, үзеңнең кысан, күңелсез һәм ипсез бүлмәңә кайткач, бу иләшкән торагың ошамый башлый.* Р.Төхфәтуллин. *Кызны палатага кертеп, ипсез тар караватка күтәреп салдылар.* М.Маликова. *Авылга кайтып җитәргә биш-алты чакрым калганда, юлның бер ипсез урыны бар.* С.Зыялы

2) *күч.* Эш рәте белми торган, булдыксыз; көйсез, холыксыз. *Минеке дә китте әнә, бер ипсез катынга йортка керде.* М.Хәбибуллин. *Теге ипсез бала урындык аягына кармак җебе бәйләгән дә укытучысы утырам дигәндә генә тартып аударган.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Җайсыз, уңайсыз итеп. *Егет аның ипсез утырганын карап торды да: – Бир әле сумкаңны, менә монда бәйлик, --- диде.* Ф.Яруллин. *Ул коры сөяккә калган карчыкны --- кочаклаган итте, тик бу кочу нигәдер җайсыз, ипсез килеп чыкты.* Х.Ибраһимов

2) *күч.* Көйсезләнеп, капризланып. *Югыйсә йомшак кына кагыла ул аңа, җайлап кына эндәшә. Ә төшенә әнә ничек ипсез булып керә.* Л.Гыймадиева

**ИПСЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф. к.* **ипсезләү**. *Малай чалгы сабын тәмам ипсезләндергән*

**Ипсезләндереп бетерү** Тәмам, бөтенләй ипсезләндерү

**ИПСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Ипсез хәлгә килү; җайсызлану

**Ипсезләнә бару** Торган саен ныграк ипсезләнү

**Ипсезләнә башлау** Ипсезләнү күренеше сизелү

**Ипсезләнә төшү** Бераз, берникадәр ипсезләнү

**Ипсезләнеп калу** Нинди дер эш, сәбәптән ипсезләнү

**Ипсезләнеп китү** Кинәт ипсезләнү

**Ипсезләнеп тору** Әледән-әле, гел, һәрвакыт ипсезләнү

**ИПСЕЗЛӘ́Ү** *ф.* Ипсез хәлгә китерү; җаен җибәрү

**Ипсезләп бетерү** Бөтенләй, тулысынча ипсезләү

**Ипсезләп кую** 1) Көтмәгәндә, уйламаганда яки кинәт ипсезләү

2) Алдан ипсезләү, алдан җаен җибәрү

**Ипсезләп ташлау** Кинәттән яки көтмәстән ипсезләү

**Ипсезләп тору** Һәрвакыт, даими ипсезләү; сөйләү моментында ипсезләү

**Ипсезли башлау** Ипсезләргә тотыну

**Ипсезли бирү** Бернигә дә карамыйча ипсезләвен дәвам итү

**Ипсезли төшү** Бераз, берникадәр ипсезләү

**ИПСЕЗЛЕК** *и.* 1) Ипсез булу, җайсызлык

2) *күч.* Эш җаен белмәү; көйсезлек, холыксызлык. *Варис, Бибисага булышмакчы булып, ике кулын аның аркасы астына шудырып кертте. --- Бибиса врачның ипсезлегеннән көлеп куйды.* С.Сөләйманова. *Телсезлек белән ипсезлекне аерым-аерым карап булмый.* Г.Афзал

**ИПТӘШ** *и.* 1) Эштә, тормышта, дөньяга карашта һ.б.ш. уртак сыйфат булудан якынайган, бергә аралашып яшәгән кеше. *Март аенда имтиханга әзерләнеп иптәш кызлары яныннан кайтканда, Ләйләгөл шул таллар янынннан уза иде.* М.Мәһдиев. *Балачакта кеше ялгызлыкка бигрәк чыдамсыз була, аңа иптәш, уендаш, дус кирәк.* М.Маликова. *Минем иптәшләремнең дә төрлесе төрле төркемгә кушылып, уртак эшләргә, уртак тормышка катышып киттеләр.* Ф.Әмирхан

2) Бер партия (фирка), бер хезмәт коллективы әгъзасы. *Хуш, большевик, --- якын, бөек иптәш.* Ш.Маннур

3) Шул ук мәгънәдә рәсми рәвештә эндәшү сүзе буларак кулланыла. *Иптәшләр, бер тәкъдим бар: колхозны Рөстәм абый исеме белән атарга!* Һ.Такташ. *Алтын каләм белән көмеш шигырь, Көмеш төсле шигырь яз, иптәш.* Г.Афзал

4) *тар.* Совет җәмгыяте члены, гражданы. *Совет председателе нишләп «әфәнде» булсын! «Иптәш» диген!* И.Гази

5) Шундый кешенең исем-фамилиясе, профессиясе, дәрәҗәсе алдыннан шул ук мәгънәдә килә. *– Иптәш замполит, ул мине өнәп бетерми, – дип, Каракүз сүз кыстырды.* Х.Камалов. *– Соңгарак калдык, Ильяс иптәш, ачуланмыйсызмы? – диде Артыкбикә.* М.Әмир. *Штаб башлыгы бүлмәгә кереп: – Атлы элемтәчеләр чыгып китте, иптәш командующий! – диде.* Г.Бәширов

6) *иск.* Рәсми булышчы, урынбасар. *«Кармак»ның иптәш нашире З.Дәминов дигән егет тә килде.* Ш.Бабич

7) **иптәшкә** *юн. кил. форм.* Берәр төрле эш эшләр яки нинди дә булса бер процессны җиңеләйтер өчен дип сайлап алынган дус, иш, компаньон. *Фәнүзә, кыш чыгу җиңелрәк булсын дип, иптәшкә Сәрияне кертте.* Мәдәни җомга

8) Бер-берсен тулыландырып торган ике әйбер; иш, пар. *Ул өстенә --- керләнеп беткән сары майка һәм аңа иптәшкә ике балагының да тез күзләре тишек иске чалбар кигән.* Г.Мөхәммәтшин

9) *сөйл.* Гаиләдә ир яки хатын.. *Тормыш иптәше бар, ә менә чын-чыннан «ир» дигәне... анысы инде байтактан юк, дияргә була.* М.Маликова. – *«Иптәш»еӊ бармы, дип сорыйм мин синнән. Егет көлеп җибәрде: – Ә-ә, син аны әйтәсеӊ икән! Юк әле, агай, өйләнмәгән әле мин.* Н.Әхмәдиев. *Минем иптәшем сезнеӊ хатыныгыз белән дус.* Г.Галиева

**ИПТӘШЛӘНҮ** *ф. сөйл. сир.* Өйләнү. *Көзгә иптәшләнергә исәп*

**ИПТӘШЛӘ́Р СУДЫ** *и. тар.* Совет чорында, дәүләт судыннан аермалы буларак, коллективта аерым кешеләр арасындагы вак бәхәсләрне, низагларны тикшерә торган һәм җәмәгать шелтәсе бирүгә хокукы булган суд. *Иптәшләр судына үзенеӊ йөрәктәге барлык нәрсәләрен ачып салырга, ә менә болай һаман сер саклап йөрергә теләмәде.* А.Алиш. *Партия оешмасы секретаренеӊ тырышлыгы нәтиҗәсендә, иптәшләр суды, бөтен халыкка гыйбрәт булсын дип, авыл клубында оештырылган иде.* Ф.Сафин. *--- бездән куылган Мортаза, өстерәп диярлек, өенә алып керде. --- Менә иптәшләр суды белән кудырткан идеӊ. Аӊар карап әллә ни югалтмадым, --- ди.* М.Хәсәнов

**ИПТӘШЛӘ́РЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Иптәш итеп, үз итеп, якын итеп. *Яшьләр, үзләренеӊ беренче командирларын иптәшләрчә олылап, Тарасовныӊ кулын авырттырганчы кыстылар.* К.Нәҗми. *Бригада членнары төрлесе төрлечә сыный. Берәүләр дусларча, иптәшләрчә якын итеп, икенчеләр астан гына...* Р.Кәрами. *Мостафин алдында үзен иркен сизә Идрисов. Чөнки командир үзе сиӊа иптәшләрчә тиӊ итеп карый...* Х.Камалов

2) Дус, иптәш кешеләргә хас булганча. *Шәүкәтнеӊ нибары бер хаты килде. Ул иптәшләрчә коры гына язылган иде.* М.Маликова. – *Мужикныӊ бармагы үзенә кәкре булмаганын кайдан табарбыз икән? – дип, иптәшләрчә шаяртып калды Мөхсинов.* Ф.Хөсни. *Байкучатов үзен чын командирларча таләпчән, ләкин иптәшләрчә гади тоткан Шиһабетдиновка карата күӊелендә ниндидер үз итү тойгысы яралуын тойды ---.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* Иптәш, дус кешеләргә хас. *Күбесе гыйшык белдергән, шуныӊ белән бергә, иптәшләрчә сәлам юллап, --- кызыклы хәбәрләр белән таныштырган --- ул хатларда --- заман рухы чәчрәп тора.* М.Әмир. *Сезгә уӊыш теләп, иптәшләрчә сәлам яза Такташ агагыз.* Һ.Такташ

**ИПТӘШЛЕК** *и.* 1) Иптәшләрчә булган мөнәсәбәт. *Егет булып җиткәч, аныӊ шигырьләре кызлар альбомында истәлек булып калды. Чөнки болар иптәшлек, дуслык, мәхәббәт хакында язылган беренче каләм тибрәтү генә --- иде.* Р.Кәрами. *Икенче милләт кешесе белән якыннан танышу һәрвакыт мине рухи яктан баетып җибәргәндәй була, күӊелдә иптәшлек, туганлык, уртак гражданлык хисләре кузгалуын тоясыӊ.* М.Әмир. *Дуслык, иптәшлек турында күптән түгел пионер сборында да сөйләшкәннәр иде.* Р.Хафизова

2) **иптәшлеккә** *юн. кил. форм.* Бергә булу, бергә йөрү; башка кешегә иш, пар. *Иренә тугры яшь хатынныӊ ялгызы гына күккә ашасы килми иде. Ул монда да иптәшлеккә ирен сайлады.* А.Гыйләҗев

**ИПТӘШЛЕККӘ́ АЛУ** *ф. сөйл.* Өйләнү. – *Әгәр мин сине шушыннан коткарсам, син мине иптәшлеккә алырсыӊмы? – ди кыз.* Әкият

**ИПТӘШЛЕККӘ́ КИЛҮ** *ф. сөйл.* Кияүгә чыгу. *Кыз да бер дә оялып тормый: «Мин Җиһангәрәйгә иптәшлеккә килдем. Сез хәзер миӊа да әти, әни буласыз», – ди.* Г.Толымбай

**ИПТӘШЛЕКЛЕ** *с.* 1) Үз иптәшләренә булыша торган, тугры; иптәшчән

2) Кешеләр белән тиз аралашучан, тиз дуслашучан; компаниячел. *Кыз бик иптәшлекле кеше булып чыкты*

**ИПТӘ́ШЧӘ** *рәв. иск. к.* **иптәшләрчә**. *Кыз башта, иптәшчә якын елмаеп, кулларын каты кысмакчы булган иде.* Г.Ибраһимов. *Ул гына түгел, каләм юлында хезмәт иткән мөхәррирләр тарафыннан җылы сүз, дустча әйткән бер фикер, иптәшчә бер кул кысу очрамады.* М.Исхаков

**ИПТӘШЧӘН** *с.* Иптәшлек, дуслык мөнәсәбәте, хисе көчле булган

**ИПТӘШЧӘНЛЕК** *и.* Иптәшчән булу. *Ихласлылык, иптәшчәнлек – матур сыйфатлар*

**ИР** *и.* **1.** 1) Аерым бер сыйфатларга, табигый үзенчәлекләргә ия буларак, хатын-кыз затына капма-каршы җенестәге кеше. *Хәзер Мансуров каршында канлы сугыш юлларын, --- үткән егерме дүрт яшьлек ир кеше – фронт офицеры утыра иде.* Г.Бәширов. *Ир гайрәтне тәвәккәлдән ала: я башын сала, я батыр кала.* Н.Арсланов. *Кәрим абзагыз – иллеләр өстендәге буй-сыны бик төз, бик егәрлекле, чын ир кеше, ир солтаны!* Ә.Еники

2) Шул җенеснеӊ малай, үсмер яшеннән үткән кешесе. *…Чабаталы ирләр, итекле егетләр, ак --- яулыклы хатыннар, киленнәр, малайлар җыелып, --- карап торалар.* Г.Ибраһимов. *Арсландай ирләреннән башлап, мыексыз малайларга, буй җиткән кызларга хәтле --- Аланбашны ду китерәләр иде.* Г.Бәширов. *Алар йорт каршындагы эскәмиягә чыгып утырдылар, ир кесәсеннән тәмәке алып кабызды, тирән итеп суырды.* М.Маликова

3) Батыр, гайрәтле, булдыклы, тугры һ.б. уӊай сыйфатларга ия булган кеше. *Илнеӊ эше ир муенында.* Мәкаль. *Син чын ир икәнсеӊ*

4) Хатынына карата: хатын белән никахта булган, өйләнгән кеше. *Иренә сүзсез буйсынырга күнеккән Хәдичә апа урыныннан кузгалды. – Дөнья хәле, дисеӊ... – диде ул әрнеп, иренә карамыйча. – Минем хәлне белмисеӊ. Әнә кешеләр ничек матур торалар. Кешенеӊ хатыны да кадерле...* М.Маликова. *Гөлбикә самавырын, ашъяулыгын алып*

*бетеп кенә тора иде, ава-түнә ире Җомагыл кайтып керде.* Г.Ибраһимов. *Иренең ярату-яратмавын хатын-кыз белми булмый.* Р.Хафизова

5) **ирләр** *күпл.* Ир-ат өчен билгеләнгән, ирләргә (*1 мәгъ.*) хас нәрсәләр. *Ул аз гына вакыт эчендә --- ирләр мәктәбе, кызлар мәктәбе ачып бетергән, кайберләрен ачарга әзерлекләр күргән.* Г.Ибраһимов. *1812 елдан гарәп-фарсы кафедрасында 1 нче Казан ирләр гимназиясенең татар теле укытучысы Ибраһим Исхак улы Хәлфин эшли башлый.* Татарстан тарихы // Ир-ат өчен тәгаенләнгән нәрсәләр. *Ирләр күлмәге. Ирләр хезмәте*

5) **ирдә** *у.-в. кил.* Кияүгә чыккан хатын-кызга карата кулланыла. *Мине сөяргә ярамый, Рәшат! Мин ирле; мин кыз кеше түгел, мин ирдә.* Ф.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ. куч.* Батыр, гайрәтле, кыю йөрәкле; уңган, булдыклы. *Ир йөрәкле безнең кызларыбыз*

◊ **Ир бөлдергеч (бөлдергән)** Гаять исрафчан, акча туздыручан, хуҗалыксыз хатын. – *Ирне көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын! – дип әйтергә ярата торган иде.* Ә.Еники. **Ир йөрәк** Батыр, кыю, һиммәтле, ирләрчә сабыр холыклы кеше. *Үсте ак тормыш белән ул, илдә бер ал гөл булып, Уктай үткен, зур күңелле, ир йөрәк, алгыр булып.* М.Фәйзи. **Ирләр тастымалы** *гади с. хур.* Төрле ирләр белән чуалырга яратучы хатын. *Менә хәзер ирләр тастымалы Гөлсемне алып кайтып куярсың.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Ирләр якасын иснәмәгән** 1) Гыйффәтле кыз; 2) Төрле ирләр белән чуалмаган, никахлы иренә тугры, намуслы хатын. *Бәлки, [Эрнаның] ирләр якасын яшьли исни башлавын каплап калу өчен уйлап табылган уйдырма гынадыр әлеге тамаша?* Ф.Әмирханов. **Ир өстеннән ир тоту** *к.* **ир өстеннән йөрү**. *Нәрсә дисең? Әллә, оялмыйча, югыйсә, миңа ир өстеннән ир тотарга кушасыңмы?* Г.Камал. *Бүтәннәр ир өстенә ир тота, безнеке кебек кыңгыраулары чылтырамый тагы.* Н.Гыйматдинова. **Ир өстеннән йөрү** Ире була торып, башка ир белән якын мөнәсәбәттә яшәү. **Ир талашып, җир талашып** Кычкырышып, даулашып, көч-хәл белән (эш башкару турында). **Ир уртасы** Утыз биш-илле яшьләр арасындагы, урта яшьләрдәге. *Төп кода – озын, җирән кеше – ир уртасы гына икән әле.* Ә.Еники. *Гыйлфанны үзе белмәгән, танымаган кешеләр – кызлар, егетләр, ир уртасы кешеләр уратып алган ---.* М.Мәһдиев. *Татарлардан чибәр генә егетләр һәм дә ир уртасы кешеләр бар иде.* Ш.Камал. **Ир хакы** Ир кешенең хатыны алдында булган хокукы. *«Ә мин – томана. Шуның өстенә йомшаклык. Ир хакы дип, аны җәллим...» – дип уфтанды Сәрдә.* Х.Камалов. *Ир хакы белән ата хакы нәрсә, беләсеңме шуны?* Ә.Фәйзи. *Сүзләре йөрәккә яра булса да, ир хакы дип түзде [Зөлфия].* Н.Хәсәнов

**ИРАВЫЛ** *и. бор.* Хәрәкәттәге армия алдыннан баручы гаскәри берләшмә; авангард. *Акбүре җиреннән кузгалып китүләренә бер ай чамасы булды дигәндә, болгарларның мең кешелек иравылы Ямгырчы би җиренә барып керде.* Н.Фәттах

**ИРАДӘ** *и. гар. иск. кит.* 1) Теләк, омтылыш. --- *катай башкортларыннан Сабит Габделбасыйр углы Яхшыбаев исемендә егерме ике яшьлек яшь бер башкорт Казанга килеп чыкты һәм үзенең сәнаигы нәфисә мәктәбенә керергә ирадәсе барлыгын игълан итте.* Г.Камал

2) Ихтыяр. *Адәмнәр табигатьләре, куәтләре буенча берничәгә бүленәләр: бертөрлесе үзенең тимер кулы, куәтле ирадәсе белән әхвальне үзе теләгән якка бора ---.* Г.Ибраһимов

**ИРАН** *и. к.* **иранлы**. *Болгар йорты иран, таҗик, гарәп, әрмән, хазар, яһүд, Рим, рус сәүдәгәрләре белән алыш-биреш итә.* Татар тарихы әдәбияты

**ИРАНАЙ** *и. диал. к.* **ирдәүкә**

**ИРАНАЙЛЫК** *и. диал.* Ирдәүкәлек. *Шук күңелле иде бүген Гайния һәм шуның өстенә тагын беләкләрендә көче ташып торганын сизә иде ул. Хәер, киенүендә, килеше-килбәтендә үк ниндидер бер иранайлык бар иде.* Ф.Хөсни

**ИРАНИСТ** *и. рус* Иран телләре (пушту, көрд, фарсы, таҗик һ.б.), әдәбияты һәм мәдәнияте белгече

**ИРАНИ́СТИКА** *и. рус* Иран группасына кергән халыкларның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнә торган фәннәр җыелмасы; иран филологиясе

**ИРАНЛЫ** *и.* **1.** Иранда яши торган төп халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Икенче бер җирдә каракүл өчлы бүрек кигән озын иранлы алдына тезеп куйган бик матур паласлар сата ---.* Г.Гобәйдуллин. *Япон-кытай, мадьяр-немец, румын-поляк тоткыннары, иранлылар, әфганлылар – үз илләреннән хәбәр ала алмаган коллар – Акташ зонасыннан терек суы – хатлар салып торган хатын-кызларга үлгәнче рәхмәтле булганнардыр, дип уйлыйм.* А.Гыйләҗев. *Г.Гобәйдуллин татарлар, --- иранлылыр, --- болгарлар тарихы буенча күп хезмәт язды.* С.Алишев

**2.** *с. мәгъ.* Чыгышы белән Иран халкыннан булган. *Иранлы шагыйрь*

**ИР-АТ** *җый. и.* Гомумән ирләр, ир җенесендәге кешеләр. *Ир-атның күзеннән кача белергә кирәк.* К.Нәҗми. --- *сугышчан манёврны бөтен нечкәлекләренә кадәр алдан ук уйлап килгән шома егет – ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләр фронтында Луциустан чагыштыргысыз зирәгрәк.* М.Маликова. *Урам уртасына чыгарып куелган кечкенә ялангач өстәл тирәсен бик күп халык сырып алган: ир-ат, хатын-кыз, карт-коры, яшь-җилкенчәк, бала-чага – һәммәсе дә шул тирәдә урала.* М.Әмир

**ИР-АТСЫЗ** *с.* **1.** 1) Ир кешесез, ир-ат булмаган. *Шуның өстенә, акча күреп өйрәнмәгән авыл хатынын акчасы да кызыктыра, ир-атсыз өйдә кирәк-ярак төпсез кое кебек.* Ф.Хөсни. *Ир-атсыз өйдә кояшлы көндә дә эңгер булыр.* М.Хәсәнов

2) Ире (*3 мәгъ.*) булмаган. --- *әни мине иңбашымнан кочып алды да: «Тагын ат булмады бит, улым! Ир-атсыз кешене шулай мыскыл итәләр инде аны», – дип, үксеп җылап җибәрде.* Г.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Ирләрдән башка, ираттан башка. *Түбән очлар, аңлый идек: Мәүлиха түтиләр ир-атсыз яши алачак түгел, кыш уртасында суыкка ябышып катачаклар.* А.Гыйләҗев

**ИРАУЛА́У** *ф. сир.* Бик каты кычкырып елау, ай-вайлау. *Юләр, шулкадәр ираулап еларга ярыймыни?* Ф.Әмирхан

**ИРӘБӘ** *с. диал.* Эре сөякле, зур гәүдәле. *Ирәбә кыз*

**ИРӘГЕШҮ** *ф. иск.* Бәхәсләшү, сүз көрәштерү, каршы сүз әйтү. *Аңдышкан авыл булмас, ирәгешкән ил булмас.* Мәкаль

**ИРӘК** *и. бор.* Кремль. *Ярлык Кремльдә – Ирәктә бирелгән.* С.Алишев

**ИРӘ́М БАГЫ** *и. иск.* Кыйссаларда мәшһүр мифик Шәтдад патшаның җирдә ясаган оҗмагы. *Бонлар хуш күреп, багы Ирәм кеби яхшы, хуш һавалы, былбыллары сайрар, сазчылары уйнар бакчага барып, --- Әсгадь әфәндедең угыллары әйттеләр ---.* Ф.Халиди

**ИРӘМ БАКЧАСЫ** *и. иск. к.* **ирәм багы**. --- *бер бакчада бу кыз берлән бәндәңезне куеп, безләрдә Ирәм бакчасында Шәтдадың җарияләре хозур кылыр кеби --- иде.* Ф.Халиди

**ИРӘМСҮ** *с. диал.* Тәкәббер, масаючан, эре. *Ирәмсү хатын*

**ИРӘН** *и. иск.* 1) *дини* Аллага якын, изге кеше. *Изге ирәннәрнең сөякләре өстендә кәҗә йөртү һичбер килешә торган эш түгел.* К.Нәҗми // Күзгә әледәнәле күренеп, бәхетсезлеккә очраганнарга ярдәм итүче изге рух. *Йотты офык тамагы Тәпиләгән ирәнне.* Г.Сәлим

2) Сугышчы ир-ат. *Инде лә тәүлек, әй сугыш булды, Чаңгы өчен каты орыш булды. Күп ирәнләр йауда үлеп калды...* Дастан. *Ниһаять, утырып беттеләр. Түргә, ханга якын булып, дәүләтнең иң шөһрәтле, дәрәҗәле ирәннәре урнашты.* Р.Зәйдулла

3) *күч.* Ил башы. *Туры әйткән ил алдында ирән булган.* Мәкаль

**ИРӘНМӘН** *и. иск. к.* **ирән** (*2 мәгъ.*). *Тимер лә батыр хәйлә корды, йөз ирәнмән Соңгир суын кичте.* Дастан

**ИРӘЮ** *ф. диал.* 1) Зур булып үсү, зураю. *Иртә ирәймәсен икән бу малайлар.* Б.Камалов. *Малайларның язмышларын үз кулларына төшерүгә куанган җилләр һәм дулкыннар тагын да ирәйделәр, көчәйделәр.* Г.Мөхәммәтшин

2) *күч.* Масаю, үзен зурга кую, эреләнү; мактану. *– Минем трактор шәбрәк, – дип ирәйде кинәт Хәйдәр.* А.Гыйләҗев. *Башта кызкай оланны яшьсенде, баласынды, шуңа күрә бераз ирәйде, ---.* М.Хәбибуллин. *– Кызма, – диде эчтән генә үз-үзенә. – Сабыр бул. --- [Ирләр] дөрес сүз сөйләп киңәнсеннәр, үзләрен хатын-кыздан өстен куеп ирәйсеннәр.* М.Маликова

**Ирәеп алу** Кыска гына вакытка, аз гына ирәю

**Ирәеп китү** Нинди дер бер сәбәптән, эш-хәлдән яки кинәт ирәю. *Отряд җыелышына укытучылар керми башлагач, кайсыбер малайлар ирәеп китте.* Г.Мөхәммәтшин. --- *Түри бабай салмак кына ялгап китте: – Дөрес эшлисең, Кәрим энем, карабрак торырга кирәк малайларны, бик ирәеп китеп, ат каралары кебек бозылып китмәсеннәр.* З.Зәйнуллин. *Яшьләй ирәеп китүенә ояла Рәхми.* Ирек мәйданы

**Ирәеп кую** Кинәт бераз ирәю. *– Сәлам сезгә, каләм әһелләре! Бу игътибарга мин хәтта бераз ирәеп куйдым.* А.Тимергалин

**Ирәя бару** Торган саен ныграк ирәю

**Ирәя башлау** Ирәергә тотыну

**Ирәя төшү** Бераз, берникадәр ирәю. *– Ә мин бабаларымнан, Чирмешәннән утырмадан кайтып киләм, – диде кыз, ирәя төшеп.* М.Хәбибуллин

**И́РБИС** *и. монг. зоол.* Мәчеләр семьялыгыннан, Урта Азия тауларында яшәүче имезүче ерткыч хайван

**ИРГА** *и. монг. бот.* Роза чәчәкләләр семьялыгыннан, шомыртка охшаш тәлгәшле, каракучкыл зәңгәр куныклы баллы җимеш бирә торган үсемлек; ыргай; дүңкәл. *Алмагачлар, чия, груша, ирга, сливалар шау чәчәктә утырганда, төньяктан салкын җил исә, төнен кырау төшкәли.* К.Тәхау. *Татарстан Республикасында груша, шулай ук ирга да кыргый хәлдә очрамый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИРГӘ** *и. иск. кит.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса арасы, станы. *Ирәннәре булган мең батырмән Урыс иргәсенә барып керде.* Дастан

**ИРГӘЛӘШҮ** *ф. диал.* Бәхәсләшү, сүз көрәштерү, карулашу

**ИРГӘСӘР** *с.* Ирләр белән чуалырга яратучы, бозык, азгын. *Иргәсәр хатын. Иргәсәр кыз*

**ИРДАР** *с.* Тәвәккәл, батыр, чын ир. *Авторлар, күрәсең, кыю һәм ирдар кеше портретын сурәтләүләренә ихлас күңелдән ышаналар.* Тигез гомер итегез!

**ИРДАРЛЫК** *и.* Ирләрнең тәвәккәллек, батырлык, гайрәтлелек, булдыклылык, тугрылык һ.б. уңай сыйфатлары. *Адәмнәр арасында ирдарлык бетеп килә. Ир-ат арасында феминизация – «катыншаклану» процессы бара.* А.Тимергалин

**ИРДӘҮКӘ** *и. шелт.* **1.** 1) Үзен ирләр кебек тотарга, ирләр арасында булырга яратучы, ир табигатьле хатын. *Андый хатыннар, заманга иярүне ялгыш аңлап, аякларына итек киеп, тәмәке тартып, ирдәүкә булырга тырышалар.* Г.Кутуй. *«Ах явыз! Ах ыштансыз марҗа! Ирдәүкә! Әләкче! Саескан!» – дип тиргәде Наиләне Сабит.* А.Гыйләҗев. *Ирдәүкәсен ирдәүкә, ә бит ул – хатын-кыз, җитмәсә, бер тапкыр да, берәүдән дә сөелмәгән, --- кыз бала.* М.Хәбибуллин

2) *гади с.* Ике җенесле; кызтәкә; гермафродит. *– Ирдәүкә? Моны ничек аңларга кушасың, Оксана? Оксана Женяга үтергеч караш ташлады: – Ирдәүкәнең кем икәнен белмисеңмени? Ни егет түгел, ни кыз түгел ---.* Ф.Яруллин

**2.** 1) *с. мәгъ.* Үзен ирләр кебек тотарга, ирләр арасында булырга яратучы, ир табигатьле. *Ә картлык көнендә нинди дер ирдәүкә кызга [серне] ачып бирә язды.* М.Хәбибуллин. *Авылда карунның бәбәгән чукырлык бердәнбер кыю хатын-кыз – ирдәүкә Һашия генә, аның кушаматы да Кара Карга иде.* Н.Гыйматдинова. *Кешегә кирәккәндә, Ташлыярның ирдәүкә кызы ярдәмен кызганмый иде.* Д.Гайнетдинова

2) *к.* **иргәсәр**. *Хатын-кызлар --- Мәдинәне яратмыйлар: «Шадра шайтан, ирдәүкә, кыланчык, ир-ат күңелен аздырып кайнаша...» – дип, аның гайбәтен саталар иде.* Ш.Камал

**ИРДӘҮКӘЛӘНҮ** *ф.* Үз-үзен ирләр кебек тота башлау; тупаслану. *– Ничек... шундый булды соң ул хатын? – дип сорады Рамилә ---. – Ирдәүкәләнгән, дисеңме? Үзе шулай тели. Егет булу – иң зур дәрәҗә бит ул.* М.Ма-

ликова. *Ни гомер тату яшәгән ир белән хатынның, минем ат белән мавыгуым аркасында, ничә тапкыр сүзгә килгәннәрен хәтерлим. Әни, кып-кыска итеп: «Ирдәүкәләнмә!» – ди торган иде.* Д.Гайнетдинова

**Ирдәүкәләнә бару** Торган саен ныграк ирдәүкәләнү; ирдәүкәләнүе акрынлап арту

**Ирдәүкәләнә башлау** Ирдәүкәлек билгеләре сизелү

**Ирдәүкәләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй ирдәүкәләнү

**ИРДӘҮКӘЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Ирдәүкәләргә хас булганча. *Үз-үзләрен әллә кемгә куеп тыз-быз йөрүче малайларга, алар янында ирдәүкәләрчә кыланып маташкан кызларга --- күз аткан саен, Фәриснең эчендә ниндидер зәһәр дулкын куера барды.* А.Вергазов

**ИРДЕ** *ф. бор.* Иде. *Урысның ла батыры – Йармак батыр Йаман ла эттән йаман булды. Кулына эләккән кешеләрнең Кулларын ла кисеп куя ирде.* Дастан. *Мең дә туксан бердә башкорт арасында бер мөселман пәйда булды, бик олылап, кадерле хуҗа итеп, аны Сәедҗагфар хан дип әйтер ирделәр.* Г.Гобәйдуллин. *Фирдәвеснең энҗе, мәрҗән алмасы Берлә зиннәтләнмеш ирде чалмасы, Чын ефәктән ирде тәсбих баулары ---.* Ш.Бабич

**ИР-ЕГЕТ** *и.* 1) *к.* **ир-ат**. *Моңарчы Сәхиянең ир-егетләр йөзенә күтәрелеп караганы юк, аның өчен ир-ат һәммәсе бер төсле булып күренә иде ---.* Ф.Яруллин. *Алар яшендә инде мин, буй җиткән генә түгел, акыл җыйган ир-егет идем.* Х.Сарьян. *Бер ир-егет читтән генә мине күзәтә иде.* М.Кәбиров. *Авылдан ир-егетләр китеп бетте.* М.Хуҗин

2) Булдыклы, батыр, зур эшләргә сәләтле, гайрәтле ирләр. *Ир-егетнең асылы ил эшендә танылыр.* Мәкаль. *Утта янмас, суга батмас Ир-егетнең сөяге.* Җыр

**ИР-ЕГЕТЛЕК** *и.* Ир булу, егет булу, ир-егет булу. *Ничек дип әйтим, мин күргәннәремдә, белгәннәремдә мөстәкыйльлек, ир-егетлек җитеп бетми, «кызның егете» дип түгел, үземне «егетнең кызы» дип әйттерәсем килә.* Р.Гаташ. *Ир-егетлек – ул сөюнең тәмен татуда һәм аның өчен җаваплылыкны үз җилкәңә алуда да.* М.Маликова. *Иптәшләрем йокыга киткәч, юыну бүлмәсенә кереп, комбинезонны кидем. Көзгегә карыйм. Ир-егетлек билгеләре җитеп бетми.* М.Юныс

**ИР-ЕГЕ́ТЧӘ** Батыр, кыю кешегә хас булганча. *Әнә аның салмак, төз йөреше, Ир-егетчә басып килеше.* Н.Исәнбәт

**ИРЕГҮ** *ф.* 1) Гел бер нәрсә эшләүдән, бертөрле торудан, бертөрлелектән яки эшсезлектән тую, ялыгу, бизү. --- *бөтен күңел ачу һәм күңелгә мәгънәви азык бирү теләкләре шушы мәҗлесләрдә үтәлә; җүләрләр бер Мортаза байга гына түгел, бәлки, бөтен ирекkән байларга күңел ачу өчен корал хезмәтен үтиләр: кәмит булалар ---.* М.Галәү

2) Иренү, ялкаулану. *Мин сөяменирекне, ирекне, Хезмәт итәм ирекми, ирекми.* Г.Камал

3) *диал.* Сагыну, юксыну. *Атымны җибәрдем имәнсәргә, Кайтммам, җаным-бәгърем, ирексәң дә.* Җыр. *Урам капкасын ачып, ишегалларына керүгә, аның күкрәгенә эте Тарзан сикерде. – Һе, дускай, иректеңмени? – диде Абдулла, этнең сыртыннан сыйпап.* Э.Касыймов

**Ирегә башлау** Ирегү хәле сизелү

**Иреген бетү** Бик нык ирегү, тәмам, бөтенләй ирегү. *Ул бит инде айдан артык ятып тәмам ирегеп беткән, шифаханәдән күптән чыгасы килә башлаган.* Г.Бәширов

**Иреген яту** Озак вакытлар дәвамында ирегү. --- *кышын җылы абзарда ирегеп яткан яшь бозауны ишегалдына беренче чыгарганда сак булырга кирәк ---.* М.Мәһдиев

**ИРЕК** *и.* 1) Шәхси азатлык, бәйсезлек, хөрлек. *[Кәҗәләр] Кыргыйлыгына, үз ирегенә хыянәт итмәгән йорт җанварлары.* М.Галиев. *Миңлегалим ил өчен, ирек өчен хәленнән килгән бөтен нәрсәне биргән, хәтта ул шушы зур көрәштә аягыннан да мәхрүм калган иде инде.* Г.Галиев. *Халыкның ирекkә сусаганлыгын, әллә кайсы кара заманнарда да азатлык хыялы белән яшәвен --- «Хәйләкәр Дәлилә», --- һ.б. әсәрләрдә дә күрергә мөмкин.* Әдәбият

2) Тоткынлыкта, сак астында булмау хәле. *Шыксыз нәрсә икән ул «төрмә» дигәннәре... Нигә соң ирекtә вакытта монда эләкмәү чарасын күрмәдем икән, дип уфтана, үкенә башладым.* М.Хәсәнов. *Анастасия белән яшь башлагач, яшь патша --- киң күңеллелек күрсәтергә теләпме, зинданга япкан кайбер кенәзләргә ирек бирде...* М.Хәбибуллин. *«Кошчык ---, – дип уйлап куйды Гуськов һич көтмәгәндә. – Мин бит үзем дә биредә кош кебек ирекtә яшәдем».* В.Распутин

3) Дәүләт кануннары, карарлары тарафыннан илдә шәхескә бирелгән хокук, мөмкинлек. *Славянофиллар Уваров триадасын якларга әзер булалар, ләкин алар «халыкчанлык» төшенчәсенә земский собор, шәхес һәм вөҗдан ирегeн --- дә кертеп карыйлар.* Россия тарихы. *Ирек турындагы манифесттан соң поместьеларда төпләнеп калган дворяннар, --- барлык мәсьәләләрне дә өязләрдә генә хәл итү мөмкинлеге алганнар.* Бөтендөнья тарихы

4) Билгеле бер сыйныф яки җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси тормышында сәяси яки икътисади изелү, чикләүләр булмау хәле; бәйсезлек, азатлык, хөррият. *Кол булырга теләмәгән, Ирек сөйгән халык Күтәрелгән, сәнәкләрен, Балталарын алып.* Ә.Исхак

5) *тар.* Крепостное праводан һәм коллыктан бәйсезлек. *Оста Дәүран – хан колы, гәрчә әмир Хаҗи остага ирек бирсә дә, хан бирмәгән икән әле.* М.Хәбибуллин. *1803 елда алпавытларга үзләренең крепостнойларын җирсез генә ирекkә җибәрергә рөхсәт итә торган --- указ чыга.* Татарстан тарихы. *Крепостной крестьяннар күңелендә ярсыган ачу аларга вәгъдә ителгән ирек язмышы белән дә бәйле була.* Россия тарихы

6) Иркен; беркемгә дә буйсынмыйча, беркемнән дә курыкмыйча яши торган тормыш. *Кыр төлкене! Ирек булсын үрдәк-казга!* Ш.Бабич

7) Нәрсә дә булса үзенчә эшләргә, хәл итәргә мөмкинлек. *Разведчиклар ишкәкләрне үз ирекләренә калдырдылар*

*һәм, берничә минут үтүгә, ярга килеп туктадылар.* Г.Галиев

8) Теләк. *Юкса мин, мин, үз иркем, үз саулыгым бар чагында, мондый хәлгә төшмәс идем!* Г.Ибраһимов. *--- ничек инде үз ирегең белән буран кочагына, ялан кырга чыгып китәргә кирәк?* Р.Мөхәммәдиев. *Ополчение составына үз ирке белән 3 мең җәяүле һәм 300 атлы сугышчы керә.* Татарстан тарихы

9) Ихтыяр; көч. *Уй иркенә бирелгән Тимер, сискәнеп, беркавым телгә килә алмыйча торды.* М.Хәсәнов. *Көннәрнең көз иркенә бирешкән мәле.* Ф.Сафин. *Авыр сагыш баса аны [Локман картны], күңелендә аның моңсу тынлык урнаша, ялкау гына уйлана ул, уйлана... Һәм, ихтыярсыздан, татлы-газаплы истәлекләр иркенә бирелә...* Ә.Еники

10) **иркегез, иркең** *тарт. форм.* «Ничек телисез, шулай эшли аласыз, сезнең карамакта, сезнең ихтыярда» дигән мәгънәдә

11) **иркендә** *форм.* Буйсынуда, карамагында, хакимлегендә. *Яз янгыны җиргә кабынганчы, Җил иркендә калды урамнар.* Һ.Такташ

12) *куч.* Саф, ачык һава, ачык җир. *– Уф... үземнең иреккә чыгып һава сулыйсы киләдерие --- уф --- Таш капчыкта көн буе --- Тын алыр хәл юк... – диде әти.* М.Маликова

◊ **Ирек азаны** Инкыйлап башланганын хәбәр итә торган аваз, тавыш. **Ирек алу** 1) Бәйлелектән, буйсынудан котылу; мөстәкыйль булу. *XI гасырдан алып әле немец рыцарьлары, әле швед боярлары, --- тарафыннан тапталган, таланган бу илләр һаман да ирек ала алмаганнар икән!* Г.Гобәй; 2) Иркенләү, рәхәтләнү, ләззәтләнү. *Боларककач, Кәҗә белән безнең Сарык Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып. Утыралар аяк бөкләп каршы утка, Болар инде тәмләп кенә ашый бутка.* Г.Тукай; 3) Ял итеп алу, көч җыю. *Балакаем, инде кавырсының яңа гына ката башлаган икән, тагы берничә айлар ирек алсаң, үзеңә бераз көч керер.* Әкият; 4) Бирәү белән дә, һичбер нәрсә белән дә хисаплашмыйча, үзенчә эшләү; берәр нәрсәдә арттырып җибәрү, артыгын кылану. **Ирек ачу** Вакытны күңелле үткәрү, ял итү, иреккә чыгып хозурлану, рәхәтләнү. *--- бай балалары, һич булмаса, аталары Эрбет яки Минзәлә ярминкәсенә киткәч, ирек ачалар яисә үзләре --- дус-ишләре белән очрашып күңел ачалар...* Ш.Мөхәммәдев. **Ирек бирү** Нәрсә булса да эшләргә мөмкинлек бирү, рөхсәт итү, нәрсә булса да эшләүдән тыймау. *Бөтен палатаны берьюлы кочаклап алырга җыенган күк, үзенең хисләренә ирек биргән кыз ананы малаеннан читкәрәк кысрыклады.* Ф.Яруллин. *Кузьма Клаваны төрле сүзләр белән мыскыл итеп, кулына ирек бирә башлагач, араларына кердем.* М.Хәсәнов. **Иреккә чыгу** 1) Авыр, кысан тормыштан котылу. *Кысан, җитешсез тормыштан кинәт иреккә чыккан хатын-кызның күңеле әйлешәйле яңа фикерләр белән тула.* А.Гыйләҗев; 2) Теләсә ни эшләргә мөмкинлек алу. **Ирек кую** *к.* **ирек бирү**. *Хәер, ирек куйсаң сөйри дә сөйри бирә инде ул андый көчекләр...* Р.Төхфәтуллин. *--- ат еш-еш сулу ала, ара-тирә хәлсез генә пошкырып куя, --- Хөҗҗәт аны куаламый, атка ирек куя.* Г.Галиев

**ИРЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Беркемгә дә буйсынмыйча үз ихтыяры белән яши торган, азат. *Элек мин хөр фикер йөртергә, үз акылым, үз теләгем белән яшәргә хаксыз бер сәясәтче идем, бүген – идеологик богаулардан арынган ирекле кеше.* Ф.Яруллин. *Егет – ирекле рухта тәрбия алган, күңелендәге уйларын кеше алдында кычкырып әйтергә дә тартынмый, теләгәнен эшләргә оялмый торган табигать сөючән кеше.* М.Әмир. *«Йолкыш булсам да, мин – ирекле җан. Ә син – Брежнев һәм аның яраннарының колы», – диде Нәҗип.* А.Гыйләҗев

2) Теләгән нәрсәне эшләргә мөмкинлеге яки хокукы булган; бәйсез; мөстәкыйль. *Алашалар арасына килеп эләккән тай кебек иде Каләмгөл. Йөгәнне дә, тәртәне дә белмәгән. Ирекле!* М.Маликова. *Кәрим... Наилә юк инде. Син хәзер – кош кебек ирекле. Сине бернәрсә дә бәйләми…* М.Хәсәнов. *--- Руссо, тәрбия эшен бозык җәмгыятьтән читтә алып барырга, аны җәмгыятькә бәйсез (ирекле) итәргә кирәк, дип саный иде.* Ә.Хуҗиәхмәтов

3) Нәрсәне дә булса эшләргә үз теләге белән алынучы, үз ихтыяры белән тотынучы. *Әгәр сугыш башланса, елеккечә барлык ирекле франклардан ополчение җыела.* Урта гасырлар тарихы

4) Кемнәрнең дә булса үз теләкләре белән оештырыла торган яки оештырылган. *Икенче көнне Зиннәт «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең авыр атлетлар командасы белән Түбән Камага китте.* Р.Кәрами. *Учреждениедән учреждениегә чабып йөрүләребез шуның белән тәмамланды: кайдадыр безне хәрбигә тартым ирекле оешмага язып кайтардылар.* М.Әмир

5) Төрле изүләрдән, коллыктан азат ителгән, хөр. *Давылларда туган утлы йөрәкләр без, Без – ирекле илнең батыр яшьләре.* Җыр. *--- идарә хөкеменнән азат, ирекле булырга теләгән шәхеснең омтылышлары өчен әле реаль мөмкинлекләр юк.* Г.Нигъмәти. *Татар эшмәкәрләре хуҗа булган мануфактураларның күбесе ирекле ялланган эшчеләр хезмәтенә нигезләнә.* Татарстан тарихы

6) Крепостнойлыктан азат булган. *--- 1781 елгы дүртенче ревизия мәгълүматы буенча «типтәр» дип аталган ирекле крестьяннарның саны 43656 ир булган.* Г.Гобәйдуллин. *1861 елның 19 февраль манифесты игълан ителгәннән соң, крепостной крестьяннар ирекле авыл кешесенә әверелә һәм гражданлык хокукы ала.* Татарстан тарихы. *1861 елның 19 февралендә Александр II крепостной хокукны бетерү турындагы манифестка кул куя. Россия коллар иле, хуҗалар иле булудан туктый: аның барлык халкы иреклегә әйләнә.* Россия тарихы

7) Әсирлек яки тоткынлык хәлендә, сак астында булмаган; азат. *...Кенәри – читлек кошы. Ә сез – ирекләләр. Ирекле затлар...* Р.Мөхәммәдиев

8) Бернинди чикләр куелмаган, закон тарафыннан һәртөрле тоткарлыклар куелмаган, тыелмаган. *Тынгысыз еллар бер көе уңайга салынып, ирекле сәүдәгә юл куелгач, ул тагын да иркенрәк тын ала башлаган.* М.Әмир.

*Герценның община социализмын --- тормышка ашыру социалистик тәртипләргә түгел, нәкъ менә капиталистик тәртипләрнең ирекле үсешенә юл ачар иде.* Россия тарихы

9) Билгеле кагыйдәләр, калыплар, нормалар белән чикләнмәгән, мәҗбүри булмаган. *Бер-ике атна тыныч, ирекле иҗат эше булса, мин бер унлап әсәрне өлгертеп тапшыра алам.* М.Җәлил

10) Бернинди чикләрне, киртәләрне белмәгән, кешенең үз иркенә нигезләнгән. *«Мәхәббәт физиологиясе»се шигырендә шул ук фикерне үстереп, ирекле мәхәббәт мәсьәләләренә карашын да әйтеп үтәргә ашыга.* Г.Нигъмәти. *Син дә бит, мәхәббәт ирекле булырга, семьяга бәйләнмәгән булырга тиеш, ди идең...* Р.Ишморат. *Безнең мәмләкәттә бөтен власть патша кулында, ул – нишләсә дә ирекле.* М.Мәһдиев

11) Мөстәкыйль, хөр. *Кафелар --- тарихның мәгълүм бер вакыт[ында] ирекле фикер учагы булып яшәгәннәр ---.* Г.Гали

12) Теләсә ничек. *Аның ирекле рәвештә тузгып дулкынланган чәчләре чем-кара.* М.Әмир

13) *хим.* Икенче бер элемент белән химик кушылмага кермәгән. *Ирекле углерод*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Сугыш вакытында, үзе теләп, хәрәкәттәге армиягә кушылучы. *Билгеләнгән көнгә рота төзелеп бетә. Ә аңа ирекледәрне язу туктатылмый.* Ш.Рәкыйпов. *Французлар, немец, инглизләр, эшче-социалистлар, коммунистлар һәм башкалар бик күп илләрдән ирекледәр булып килгәннәр.* Ә.Исхак. *Айдаровны фронтка алырлармы? Чакырырлар микән? Чакырмасалар, үз теләге белән, ирекле булып китәр ул.* Г.Ахунов

2) Нинди дә булса эшкә үз теләге белән алынучы; волонтёр

3) Әсирлек яки тоткынлык хәлендә булмаган; азат кеше. *Кемнең соң ирекледән башын тоткынлыкка саласы килсен.* М.Әмир. – *Көнбатыштан монда килүләренә бер ел тулгач, кызлар да ирекле эшче саналачак. – Хәзер үк ирекләне табарга мөмкиндер ич?* Т.Әйди

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) *сир.* Җиңел, ансат, кыенсынмыйча. *Үзен ирекле тоту*

2) Үзе теләп, үз ирке белән. *Көнбатыш илләреннән ирекле килеп эшләүчеләр, сүз дә юк, сөйкемлерәк, хәвефсезрәк тоела Янгуразга, тик аларга сукмак салуы уңайсыз әлегә.* Т.Әйди. *Урта мәктәпләрдә, кайбер мәҗбүри уку фәннәре белән беррәттән, күп итеп, ирекле сайланган уку курсларын өйрәнәләр.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Латыш ирекледәре отряды сугышчысы --- фашистлар кулына эләккәч, --- болай дип язып калдырган ---.* Р.Ишморатова

◊ **Ирекле баштан** Үз ирегe, үз теләге белән, кеше мәҗбүр итмичә. *Җәйнең шундый матур вакытында иртәдән кичкә кадәр тузан эчендә бөкреңне чыгарып киндер сугып утыру җиңел эш түгел. Апай да ирекле баштан утырмый.* Г.Бәширов. – *Ничекләр итеп ирекле баштан газиз баламны үги ана кулына җибәрим соң? – диде Салиха апа.* М.Маликова. *Әллә син генә ирeңне үлеп яратасың да, әллә син генә шулай өзелеп көткәнсең дип уйлыйсыңмы? Әллә без ирекле баштан ирләребезне югалтканбызмы?* В.Распутин. **Ирекле казак** *к.* **ирекле кош**. **Ирекле кош** Беркемгә дә буйсынмаган, нинди дә булса чикләүләргә дучар ителмәгән, бәйсез (кеше турында). **Ирекле көн** Һәртөрле җәбер, көчләүләрдән, коллыктан азат, хөр яшәеш; ирекле тормыш. **Ирекле көннән** *к.* **ирекле баштан**. *Көлә генә сөеклем: – Ирекле көннән мин дә кермәс идем дә бит, әнә теге чибәркәйгә кәрт уйнаганда оттырдым... – дигән була.* К.Миңлебаев. *Разин бөтен Россиядә «ирекле казак» тормышы ясаячагын игълан итә.* Г.Гобәйдуллин. **Ирекле кую** Берәр нәрсә эшләргә юл кую, мөмкинлек бирү, берәр эш эшләүдән тыймау. *Мин аны да ике тәүлек буенча шәһәрдә теләгәнчә йөрергә ирекле куйдым.* Г.Ибраһимов

**ИРЕКЛЕДӘН** *рәв.* Үз теләге, үз ихтыяры белән, ирекле баштан. *Гарип көенчә ирекледән йөримени ул ---?* З.Зәйнуллин. *Сугыш барган якка үз теләге белән Сугышырга ирекледәр бара... Ирекледәр? Сугышырга бара? Ирекледән сугышалармыни? Качалармыни соң үз төяктән?* Н.Сафина. *Сәер тынлык. Карап торсаң, гүя терексез. Туфан анда, сөрген тозагында, Ирекледән һаман ирексез.* Р.Шиһапов

**ИРЕКЛЕ́ ДИКТАНТ** *и. пед.* Диктантның укытучы укып чыккан тулы текстын хәтердә калганча язудан гыйбарәт төре. *Татар теленнән ирекле диктант язу*

**ИРЕКЛЕ́ ДИПЛОМ** *и.* Совет чорында: югары уку йортын тәмамлаганнан соң, мәҗбүри эшкә билгеләми генә бирелгән диплом. *Остазына тулы өмет баглаган Нәҗип Йосыф улы Нургалиев ирекле диплом алып чыккан иде.* А.Гыйләҗев. *Ирекле диплом алу өчен, син аларга язылышу турында белешмә китереп бирергә тиеш ---.* Р.Вәлиев

**ИРЕКЛЕ-ИРЕКСЕЗ** *рәв.* 1) Үзе дә сизмәстән, ирексездән (күбесенчә кешенең үз ихтыярына буйсынмаган хисләре турында әйтелә). *Кайчагында Рөстәм ирекле-ирексез «ялгышлык иттем бугай» дип куя ---.* С.Җәлал. *Кайберәүләрнең бугазларыннан ирекле-ирексез: – Улым бәгърем... Нишләдең син?.. Шулай ук безне ялгыз калдырасыңмыни? – дигән тавышлар яңгыравы сулкылдау, үксү өннәренә күмелде.* К.Нәҗми

2) Үз теләгеннән башка; мәҗбүри рәвештә. *Ирекле-ирексез алар шунда төн уздырырга карар бирделәр.* М.Галәү. --- *кешеләр дә көндәгечә бар дөньясын онытып көлми, ә ирекле-ирексез генә елмая, Ихтыярның хәленә кергәндәй, тавышсыз гына көлә иде.* Р.Вәлиев

**ИРЕКЛЕ-ИРЕКСЕЗДӘН** *рәв. к.* **ирекле-ирексез**. --- *рәсем караган кичне, Искәндәр, мин сине уйламаска тырыштым. Ирекле-ирексездән гел Вәли Сафиуллин тирәсендә әйләндем.* Г.Кутуй

**ИРЕКЛЕК** *и. сир.* Хөрлек, бәйсезлек, азатлык. *Ireклек ул – канат күңелгә, Ирек яулау – бару үлемгә.* Н.Нәҗми. *Макаренко тәрбия эшендә --- ireклек һәм зарурлык, бурыч һәм хокук, --- таләпчәнлек һәм мәхәббәт кебек каршылыкларны чишү юлларын эзли һәм таба.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Хөкүмәт, ireклек өчен көрәшә торган халыкны басарга акчасы беткәч, --- думаны чакырды.* Урал

**ИРЕКЛЕЛЕК** *и. кит.* 1) Эшне бары тик үз ихтыяры, үз теләге белән эшләргә мөмкинлек. *Крестьяннарны кооперативларга берләштерү иреклелек нигезләрендә үткәрелергә тиеш ---.* Советлар Союзы Коммунистлар партиясе тарихы. *1815 елда барлык крестьяннарга да «иреклелек эзләп табу»ны тыю турында указ чыгарыла.* Россия тарихы

2) Гомуми кагыйдәләрдән, нормалардан, төп нөсхәдән тайпылыш, аларга буйсынмаучанлык. *Бу мәсьәләдә аның [Г.Ибраһимовның] «Тәрбия эшендә иреклелек һәм гуманлылык нигезләре» дигән хезмәте игътибарга лаек.* Ә.Хуҗиәхмәтов

3) Төрле чикләүләр куелмаган, азат хәл; ни теләсә, шуны эшләргә мөмкинлек. *Минем, шушы минуттагы иреклелектән файдаланып, --- сиңа әйтәчәк серләремне --- чишәсем килә.* Аң

4) *филос.* Табигать һәм җәмгыятьнең үсеш кануннарын танып белү нигезендә кешенең үз теләкләрен һәм максатларын тормышка ашыра алу мөмкинлеге. *Чын иреклелек ул – танып беленгән зарурлык.* М.Абдрахманов

**ИРЕКЛЕЛЕК ҺӘМ ЗАРУРЛЫК** *и. филос.* Табигать һәм җәмгыятьнең объектив кануннары белән кешеләрнең эшчәнлеге арасындагы мөнәсәбәтләрне белдергән фәлсәфи категорияләр. *Иреклелек һәм зарурлык нисбәте*

**ИРЕКЛЕ́ СҮЗТЕЗМӘ (СҮЗ ТЕЗМӘСЕ)** *и. лингв.* Сүзләрнең лексик берәмлек тәшкил итмәгән синтаксик бәйләнеш төре. *Ирекле сүзтезмәләр нинди дә булса бер төшенчәне белдерү өчен ныгып калган булмыйлар, чагыштырмача ирекле булалар.* Татар грамматикасы. *Сөйләм барышында кирәк вакытта гына төзелгән сүзтезмәләр ирекле сүзтезмәләр булалар.* Хәзерге татар әдәби теле. *Ирекле сүзтезмәләр телнең грамматик законнары нигезендә һәрвакыт яңадан ясалалар, алар составындагы сүзләрне алыштырып була ---.* Тел гыйлеменә кереш

**ИРЕКЛЕ́ ТӘРҖЕМӘ** *и.* Төп нөсхә (оригинал) белән төгәл туры килми торган, якынча тәрҗемә. *--- татар әдәбиятын рус телендә чыгару --- эшенең сыйфатына зыян китерә торган төп факторларның берсе – ирекле тәрҗемә белән мавыгу.* Татар әдәбияты тарихы. *Тукай ирекле тәрҗемә итте. Ләкин Тукай үзе тәрҗемә иткән шагыйрь алдында беркайчан да бурычлы булып калмады.* Казан утлары. *Инглиз, француз, алман шагыйрьләреннән ирекле тәрҗемәләр биргән Жуковский кебек, Тукай да Европа һәм рус шигъриятенең аерым үрнәкләрен татар укучысына җиткерә килде.* Мәйдан

**ИРЕКЛЕ́ ТЫҢЛАУЧЫ** *и.* Югары уку йортында лекцияләр тыңларга, практик дәресләрдә катнашырга рөхсәт алган, әмма студентлар исемлегенә кертелмәгән һәм аларның хокукларына ия булмаган зат. *Ирекле тыңлаучылар? Теләсәләр киләләр дәрескә, теләмәсәләр – юк. Алардан имтихан да таләп ителми.* М.Әмир. *--- сабакташым, тырай тибеп йөрмәс өчен генә, ирекле тыңлаучы сыйфатында «укып» йөргән.* К.Миңлебаев. *Шул ук 1874 елны И.Терегулов Казан университетының тарих факультеты лекцияләренә ирекле тыңлаучы булып йөри.* Мирас

**ИРЕКЛЕ́ ХӘРӘКӘТЛӘР** *и. спорт* Спорт инвентарьларын кулланмый гына эшләнә торган гимнастик күнегүләр

**ИРЕКЛЕ́ ШӘҺӘР** *и.* Мөстәкыйль дәүләт хокукына ия булган шәһәр. *Ватикан ирекле шәһәр булып санала*

**ИРЕКЛЕ́ ШИГЫРЬ** *и. әд.* Буыннар, иҗекләр саны төрлечә булган шигырь юлларының аралашып, ритмика һәм интонация ягыннан үзара ярашып, бербөтен ритмик берәмлек тәшкил итүгә нигезләнгән тезмә юллар. *Көнбатышта ирекле шигырьне яклап, шуның буенча язып чыгучыларның күпчелеге революциончыл бунтарь, вак буржуа шагыйрьләре булды.* Г.Нигъмәти. *Ак шигырь дә, ирекле шигырь дә татар әдәбиятында соңгы елларда юктан бар булган, күктән төшкән нәрсәләр түгел. Ирекле шигырьне С.Рәмиевтән, Һ.Такташтан, Ә.Давыдовтан теләсәң күпме табып була.* Татар әдәбияты тарихы. *Берәүләр Р.Фәйзуллинны татар поэзиясенең шигырь калыпларын җимерүдә --- гаепләргә ашыкса, икенчеләре --- ирекле, ак шигырь үрнәкләре татар поэзиясе өчен чит-ят күренеш түгел, дип, яшь шагыйрьнең кыю эзләнүләрен яклап чыкты.* Әдәбият

**ИРЕКЛЕ́ ЭЛЕКТРОННАР** *и. физ.* Атом төше белән бәйләнеше аз яки бәйләнешсез бөтенләй өзгән электроннар; бәйсез электроннар (металларда күп була)

**ИРЕКСЕЗ** *с.* **1.** 1) Тормышы, эшчәнлеге берәр кешегә яки берәр илгә бәйле, буйсынган; мөстәкыйль булмаган. *Ир икәнен оныткан ир ирексез булыр.* Мәкаль. *Мин кол монда, йортсыз-ирексез, Ирексез һәм илсез – мин үксез.* М.Җәлил. *Иренең --- таш капчыкта – биек койма, чәнечкеле тимер чыбык артында зинданда калуына, читлектәге кош кебек ирексез булуына ул әле һаман ышанып җитми.* Р.Кәрами

2) Мәҗбүр; үз теләгеннән, ихтыярыннан башка эшләргә яки яшәргә тиеш булган. *Хәят, теләсә дә, теләмәсә дә, аш ашарга вә намаз укырга ирексез иде.* Ф.Әмирхан. *Россиядә металлургия --- технология алымнары ягыннан --- артта кала. Аның төп бәласе – теркәлгән крестьяннарның ирексез, мәҗбүри хезмәтеннән файдалану.* Россия тарихы. *Николай I хакимияте, ирексез кешеләр хезмәтенә таянып, көчле икътисад булдырырга --- өметләнә.* Татарстан тарихы

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бәйле, буйсынган хәлдә. *Үзалдына уйлаганда ул алгы көнне бик оста сурәтли иде, ләкин аның теле сүзгә бай түгел иде, аеруча матурлап бирә алмады, ирексез үткән тормышның, кара крестьянның --- ачлы-туклы яшәве моментларына тукталды.* Г.Ибраһимов. *Күрәбез: бу хыянәт татар халкына бик кыйммәткә төште, аның берничә гасыр буена ирексез яшәвенә китерде.* Әдәбият

2) Теләмәсә дә, үз теләгеннән башка, мәҗбүри рәвештә. *Башлыгыбыз Үтәмеш әфәнде бервакыт, безнең барыбызны җыеп, коралландырып, өсләренә барырга уйласа да, аларның күпме икәнен, үзебезнең көчебез аларны җиңәргә җитәрме икәнлеген ачык белмәгәнгә күрә, ирексез тукталып калырга туры килде.* Ф.Әмирхан

3) Үзе дә сизмәстән, аңсыз рәвештә; үзе дә теләмичә, ихтыярсыздан.

*Тыңладым да мин ирексез яшьлегемне уйладым.* Н.Исәнбәт. *Бу вакытта аның бер генә минут элек очкынланып торган шомырт кара күзләре ирексез йомылганнар, озынча, алсу йөзе сулып, агарып киткән иде инде.* Г.Гобәй

◊ **Ирексез баштан** *к.* **ирексез көннән**. – *Ирексез баштан күчмә, – диде ир, сүз юктан сүз ясап.* Н.Гыйматдинова. **Ирексез көннән** Аптыраганнан, һич башка чара булмаудан, мәҗбүри рәвештә

**ИРЕКСЕЗДӘН** *рәв.* 1) Теләсә-теләмәсә дә, мәҗбүри рәвештә. *Ул белмәде кемгә сөйләргә дә Йөрәгенең әрнеп янганын, Һәм үзенең канлы һөҗүмнәргә Ирексездән генә барганын.* Ә.Исхак. *Күңелемә аеруча авыр тәэсир калдырганы шул булды: монда һәрнәрсәгә номер сугылган. Ирексездән, хәтеремә киноларда күргән әсирләр килде.* Ф.Яруллин. *Күренеп тора: Бәһиҗә түтәй артыгын кызмаска, тыелырга тырыша иде, ләкин Әхсәннең кайнарлануы аны ирексездән чыгырыннан чыгара иде.* М.Маликова

2) Нәрсә эшләвен үзе дә сизмичә, аңсыз рәвештә; үзе дә теләмичә. *Хәйрүш, ирексездән, шушы машина астында калып һәлак булган Дмитрий белән Әхмәтне --- исенә төшерде.* М.Хәсәнов. *Шулчак аның колагында кемнеңдер көлгән тавышы ишетелгән кебек булды. Нурзидә күңелендә, ирексездән, инде онытылып баручы хатирәләр яңарды...* Р.Гыйззәтуллин. *Ирексездән, янә кызыксыну белән алды аны: «Кем икән бу кеше?»* Р.Мөхәммәдиев

**ИРЕКСЕЗДӘН-ИРЕКСЕЗ** *рәв. к.* **ирексездән** (*2 мәгъ.*). *Аңа баккач, күңелдә ирексездән-ирексез (кәефнең нindiлегенә карап, әлбәттә) я кызгану, яисә чиркану хисе туарга мөмкин: икенең берсе...* М.Шаһимәрданов

**ИРЕКСЕ́З ИТҮ** *ф.* Ирексезләү, ирексезләп эшләтү, мәҗбүр итү. *Газизә абыстайны --- рөхсәт бирергә ирексез итте.* Ф.Әмирхан

**ИРЕКСЕЗЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Үз ихтыярына куймау; көчләү; ирексезләп эшләтү, мәҗбүр итү. – *Шофёрлар риза була икән, барсыннар. Гафу итәсез, Каюм абый, ирексезли алмыйм. Аннары техник кагыйдәләрне үзем үк бозарга кушкан булам ич, – [диде Мансур].* М.Хәбибуллин. – *Мин сине алырга дип кайтканыем, – диде Сәетҗан. – Барырсың, карарсың, дигәнием. Ошаса, кала мәктәбенә керерсең, ошамаса, мин сине ирексезләмәм.* М.Маликова. *Гөлгенәнең дәресен дә әзерлисе килмәгән чаклары бар иде. Ләкин аны ирексезләргә ярамаганын, --- вакытында аңлый алдым...* Ә.Сафиуллин

**2. ирексезләп** *рәв. мәгъ.* Үз теләгеннән башка, мәҗбүр итеп, көчләп. *Юк, егет Гөлбануның колагына «яратам» кебек сүзләр дә пышылдамады, ирексезләп көчләмәде дә.* С.Зартдинов. *...Яратмаган ирне көчләп, ирексезләп тотуның үзенә дә, семьяга да газаптан башка берни дә китермәгәнлеген ул [хатын], ниһаять, аңлаган.* Ә.Еники. *Кемгә өйләнәсен яки кемгә кияүгә чыгасын һәркем үзе хәл итә. Һәм бербересенә гашыйк кешеләргә үз фикерен ирексезләп тагарга берәүнең дә хакы юк.* Тигез гомер итегез!

**Ирексезләп тору** Гел, һәрвакыт ирексезләү

**ИРЕКСЕЗЛЕК** *и.* Ирексез (*1 мәгъ.*) булу хәле; бәйлелек; хокуксызлык. *Буржуаз стройдагы бөтен ирексезлек, хокуксызлыкны аяусыз фаш итәргә керешә.* М.Җәлил. *Татар баласына кайчак бөтен дөньясы зиндан кебек тоела башлый. Күпме чыдарга мөмкин ирексезлеккә?* Т.Әйди. *--- язучыны, шагыйрьне бары тик төрмә генә, ирексезлек кенә әдип итә ала.* Х.Ибраһим

**ИРЕН** *и.* Авыз куышлыгын астан һәм өстән җыеп торган, хәрәкәтчән, итләч мускуллы тукыма (авызны ачу, ябу өчен хезмәт итә). *Хәйдәр аның ничектер үзалдына балкып, елмаеп торган күзләреннән, кан тамырыдай алсу иреннәреннән күзен ала алмыйча, тыгыз кечкенә кулын бик рәхәтләнеп кысты.* Г.Бәширов. *--- берданка атуга ярылып китеп, Илдарның уч төбен чәрдәкләде, Фәритнең өске иренәнә мәңгелек җөй ясап калдырды.* Г.Гобәй. *Максимов аңа каты гына бәрелеп алды да, иренен кысып, өстәл өстенә текәлеп туктады.* Х.Сарьян

◊ **Иренгә ирен** Бер-берең бик якын утырып, яшерен (серләшү, сөйләшү турында). **Иренгә сөртерлек** Бик аз күләмдә, җитәрлек түгел. – *Сезнең бу тирес җирнең иренәнә сөртергә дә җитми, – диделәр.* Г.Гобәй. **Ирен генә тидерү** Татып карау. **Ирен дә кыймылдатмау** Бернәрсә дә әйтмәү, эндәшмәү; җавап кайтармау. **Ирененда (ирененнән) ана (ими) сөте кипмәгән** *кимс.* Дөнья күрмәгән, ана куенынннан чыкмаган; яшь, тәҗрибәсез. *Ат азгыны тайга иярә, дигәндәй, Фәхри дә, җитмәсә тагын, сакаллы башы белән шул иреннәреннән сөте кипмәгән малайны яклап тора.* Г.Ибраһимов. *Өйләнешкәндә унсигез дә тулмаган иде әле үзләренә. Нурдидә бер дә өнәмәде бу эшне. – Торалырсыз микән, ай-һай?.. Ир буласы кешенең ирененнән ими сөте дә кипмәгән ---, – дигән иде.* С.Сөләйманова. **Ирен тешләү** 1) Дәшмәү, дәшмәс булу, бер сүз дә әйтмәү. *Ул, аскы иренен тешләп, калын кашларын җыерып, бер сүз дә әйтмичә басып тора иде.* А.Шамов; 2) Үз гаебе белән берәр нәрсәдән мәрхүм калганда яки берәр бәхәстә җавапсыз калганда әйтелә. – *Әлләки нишләтте? Иреннәрне тешләтте.* М.Фәйзи. **Ирен турсайту** Үпкәләү, ачулану; ризасызлык, канәгатьсезлек яки үпкә белдереп йөз чыту. *Мөнирәгә инде бигрәк тә иренен турсайтыбрак йөри иде.* Ф.Хөсни. – *Шул гынамы? – диде Зиннәт, иренен турсайткан булып. – Минемчә, безгә җитдирәк сөйләшергә дә вакыттыр.* Р.Кәрами. *Диңгез буенда ике атна бергә ял иткән чор эчендә иркенлеккә өйрәнгән Эльвираның ирене турсайган иде...* М.Маликова. **Ирен чылату** Бераз гына исерткеч эчемлек эчү. *Бөтен гомере буена – очрашу вакытларында, бергә утырып ирен чылаткан чакларда, --- һәрвакыт, һәр урында, очынып, дөньяның катлаулылыгына хәйран калып яши белә иде ул.* Ф.Хөсни

**ИРЕ́Н АВАЗЛАРЫ** *и. лингв.* Иреннәр катнашы белән әйтелә торган авазлар (*б, п, в, ф, о, ө, у, ү*). *Авазларның бәгъзеләрен әйткән вакытта фәкать иреннәр генә хәрәкәтләнә ---. Мондый авазлар «ирен авазлары» дип атала.* Җ.Вәлиди

**ИРЕНАЯКЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Баш һәм буынтыклы өлешләрдән торган яссы һәм озынча гәүдәле хайваннарның буынтыкаяклылар тибыннан күпаяклыларның бер классы; *русчасы:* **губоногие**

**ИРЕНДЕРГЕЧ** *с.* Ирендерә, ялыктыра торган. *Бик ирендергеч эш*

**ИРЕНДЕРҮ** *ф. з-сыз* Нинди дә булса эшне башлыйсы яки башкарасы килмәү, эшкә теләге булмау, ялкаулану. *Ләкин безнең турыда гына бәке юк, кая да булса ераграк барып йөрергә ирендерә.* Н.Әхмәдиев. *Эшләсәң, эш бар инде дә, ирендерә.* Т.Миңнуллин

**Ирендерә башлау** Ирендерергә тотыну

**Ирендереп җибәрү** Кинәттән, бераз ирендерү

**ИРЕ́Н-ИРЕН АВАЗЛАРЫ** *и. лингв. к.* **ирен-ирен тартыклары**. *Бала аңында тик кайбер авазлар гына дөрес кабул ителми. Мәсәлән, ирен-ирен һәм борын авазлары* (*б, н, п һ.б.*) *әйтелешендә дефект булырга мөмкин, ә ирен-теш авазларын әйтүдә бөтенләй диярлек хата күзәтелми* (*в – ф һ.б.*). Юлдаш

**ИРЕ́Н-ИРЕН ТАРТЫКЛАРЫ** *и. лингв.* Аскы һәм өске иреннәрнең берберсенә якынаюы яки тиюе белән ясала торган тартыклар (*б, п, м, w*). *Бу яктан [ясалу] урыны буенча тартык авазлар түбәндәге группаларга бүленәләр: ирен-ирен тартыклары ---.* Татар грамматикасы

**ИРЕНЛӘ́Ч БАЛЫК** *и. зоол.* Алабугасыманнар отряды, иренләчләр семьялыгыннан, тропик һәм субтропик суларда яши торган чиктән тыш ачык төстәге балык; *русчасы:* **губан**

**ИРЕНЛӘЧЛӘР** *и. зоол. күпл.* Алабугасыманнар отрядыннан, тропик һәм субтропик суларда яши торган бик ачык төстәге балыклар семьялыгы; *русчасы:* **губаны**

**ИРЕНЛӘ́Ч УТ** *и. бот.* Сәхләбчәләр семьялыгыннан, бик сирәк очрый торган, биеклеге 5–10 см булган үләнчел үсемлек; урман үләне; *русчасы:* **надбородник**

**ИРЕНЛӘШТЕРҮ** *ф. лингв.* Кайбер авазларны әйткәндә, иреннәрне алга таба сузып түгәрәкләү, бөрештерү, иреннәрне түгәрәкләп авазлар әйтү, лабиальләштерү. *Аның буенча сүзнең беренче иҗегендәге [о], [ө] авазлары калган иҗекләрдәге кыска сузыкларны иренләштерәләр, һәм алар [о], [ө] булып әйтеләләр һәм ишетеләләр.* Ш.Асылгәрәев. *Барлык бу иренләштерү очракларын бер кагыйдәгә берләштерү уңайлы.* Фән һәм тел

**ИРЕНЛӘШҮ** *ф. лингв.* **1.** Кайбер авазларны әйткәндә, иреннәр алга таба сузылып бөрешү. *[ы] сузыгы [о], [у], [ы] сузыкларыннан соң килә ала, ә [о] сузыгыннан соң кулланылса, ул иренләшә.* Җ.Вәлиди. *Сузыклар рәт (телнең горизонталь хәрәкәте буенча), күтәрелеш (телнең вертикаль хәрәкәте буенча), иренләшү буенча аерылалар.* Х.Сәлимов. *Ирен гармониясе булганда, беренче иҗектәге иренләшкән авазларга ярашып, калган иҗекләрдәге сузыклар да иренләшәләр.* Тел гыйлеменә кереш

**2. иренләшкән** *с. мәгъ.* Иреннәр алга таба сузылып һәм бөрешеп әйтелә торган. *Иренләшкән сузыклар*

**ИРЕ́НМӘҮЧӘН** *с.* Иренми торган, эшчән. *«Нинди ягымлы, гүзәл кыз бу Гөлсинә! Үзе иренмәүчән дә икән тагын, – дип уйлап алды ул. – Бер егетнең бәхете инде!»* Ә.Сафиуллин

**ИРЕ́НМИЧӘ** *рәв.* Авырыксынмыйча, ялкауланмыйча; теләп. *Әмир кулындагы зәңгәр тышлы калын дәфтәрнең калган битләрен актарып карады: айһай, бигрәк күп икән әле, иренмичә язган Шәфика.* М.Маликова. *Бөтен шартын китереп әгузебисмилласын әйткәннән соң, бер дә иренмичә, аз гына да авырсынмыйча, чын күңелдән әлхәмен дә укып, --- йокыга киткән кичләрем аз булдымыни?..* М.Әмир. *Мин аптырап: «Ничек алай була ул?» – дип куям, Теодор Августович, иренмичә, мине завод бинасы янына ук алып килә.* А.Гыйләҗев

**ИРЕ́Н ТАРТЫКЛАРЫ** *и. лингв.* Иреннәр катнашы белән әйтелә торган тартык авазлар (*б, п, в, ф*). *Ирен тартыкларының күршесендәге сузыкларның иренләшүе – күп телләргә хас күренеш.* Татар грамматикасы. *--- ирен тартыкларыннан соң килгән сузыклар иренләшебрәк әйтеләләр.* Тел гыйлеменә кереш

**ИРЕ́Н-ТЕШ АВАЗЛАРЫ** *и. лингв. к.* **ирен-теш тартыклары**. *--- [балада] ирен-теш авазларын әйтүдә бөтенләй диярлек хата күзәтелми* (*в – ф һ.б.*). Юлдаш

**ИРЕ́Н-ТЕШ ТАРТЫКЛАРЫ** *и. лингв.* Аскы ирен һәм өске тешләрнең бер-берсенә якынаюы белән ясала торган тартыклар (*ф, в*). *Бу яктан [ясалу] урыны буенча тартык авазлар түбәндәге группаларга бүленәләр: ирен-ирен тартыклары ---; ирен-теш тартыклары ---.* Татар грамматикасы

**ИРЕНҮ** *ф.* **1.** 1) Нинди дә булса эшне үтәргә теләге, омтылышы булмау; нидер башкарырга авырсыну, ялкаулану. *[Сәгыйдә остазбикә белән Вахид мулла] Эштән иренмиләр, хезмәттән тартынмыйлар.* Г.Исхакый. *Сүз уңае чыга калганда, Гайния җиңги шул «сабакның» ничек булуын энәсеннән алып җебенә кадәр бәйнә-бәйнә хикәяләргә бер дә иренми.* Г.Ибраһимов. *Бер төнне, ничектер, сискәнеп уянып китеп: «Аерым үткәргән төннәрем өчен үкенмәм микән?» – дип уйлап куйдым. Тик урынымнан кузгалырга ирендем.* М.Маликова

2) *диал.* Ялыгу, ару, тую

**2.** *и. мәгъ.* Ялкау, иренчәк кеше. *Иренгән – авырган, тырышкан – савыккан.* Әйтем. *Иренгәнне ир алмас.* Мәкаль. *Иренгән ике эшләр.* Әйтем

**3. иренеп** *рәв. мәгъ.* 1) Акрын, ялкау, теләр-теләмәс. *Ниһаять, автобусның тузган ишекләре иренеп кенә шыгырдап ачылды ---.* М.Галиев. *Гөрләтеп кул чабулар кая ул! Кемнәрдер, ярар инде, дигән кебек, иренеп кенә чәбәкәй итеп куйдылар.* М.Әмир. *Тәрәзәдән ашыкмыйча, иренеп кенә кар яуганы күренә.* Ә.Сафиуллин

2) Салмак кына, үз көенә, җай гына. *Кояшның зураеп, бик әкрен генә байый торган чагы. Әнә ул, җир өстенә сузылып яткандай, иренеп кенә сырт читенә төшеп бара…* Ә.Еники. *Иренеп кенә кышкы таң ата.* Казан утлары

◊ **Иренмәс җан** Бик хәрәкәтчән, эшкә бер дә иренмәүче, тырыш кеше

**Иренә башлау** Иренүе сизелү, ирengәнлеге күренү. *Тора-бара Малик үзе әллә курыкты, әллә йөрергә иренә башлады*. Г.Бәширов

**Иренеп йөрү** Озак вакытлардан бирле нидер эшләргә иренү

**Иренеп китү** Кинәт иренә башлау. *Хисмәт, бик иренеп китмәсә, эш рәтен белә, әлбәттә*. Л.Хәмидуллин

**Иренеп тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында иренү, нәрсәне булса да эшләргә, башлап җибәрергә иренеп тоткарлану. *Авырып торам, димә, иренеп торам, диген*. Н.Исәнбәт

**Иренеп яту** Һаман, һәрвакыт, гел иренү

**ИРЕНҮЛЕ** *с.* Иренүе сизелеп торган, ялкау, теләр-теләмәс. *Иренүле хәрәкәт. Иренүле аваз*

**ИРЕНҮЧӘН** *с.* Эшкә омтылышы булмаган, иренә, ялкаулана торган. *Иренүчән бала*

**ИРЕНЧӘК** *с.* **1.** 1) Эшкә ихлассыз, иренә торган, ялкау. *Ул үзе бик иркә дә бик иренчәк, өстәвенә, бик үпкәчән дә бик итенчәк икән*. Н.Исәнбәт. --- *өйдә артык байлык күзгә ташланмый. Шулай да бар булган кадәресеннән чисталык, пөхтәлек бөркелә. Күрәсең, хуҗа хатын иренчәк түгел*. Р.Кәрами. *Дөньяда бары тик бер имезүче генә --- тумыштан йөзә дә белми --- һәм --- бик иренчәк тә*. Кызыклар дөньясында

2) Иренгәнлеге, ялкаулыгы күренеп торган; ихлассыз. *Кояш ялындыргандай чыкты. Шулай да вакытында өлгерде, иренчәк томанны төшә башлаганда ук таратты*. М.Хуҗин. *– Монда без барыбыз да үз кешеләр, яшерепнитеп маташма, дөресен генә әйт әле: тагын кайчан җир тетрәячәк? – дип сорады аннан, сузып кына, иренчәк тавыш белән Лена*. М.Маликова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Эшкә ихлассыз, ялкау кеше. *[Шәмсир] Ике яктан ерым ясарга өндәде авылдашларын, тик һәр капка төбеннән ерым аша күперчек түшәү хаҗәтлеге кайбер иренчәкләрне бу эштән суытты*. Т.Әйди

2) *зоол.* Тулы булмаган тешлеләр (тешсезләр) отрядыннан, Көньяк һәм Үзәк Америкада агачларда үрмәләп яшәүгә җайлашкан, хәрәкәтләре бик салмак булган имезүче хайван

**ИРЕНЧӘКЛЕК** *и.* Иренчәк булу, ялкаулык. *Тукайның бу сәер карары ике сәбәп белән аңлатылса кирәк. Беренчесе – Габдулланың үз шәхси тормышын үзгәртү мәсьәләсендә илтифатсызлыгы, дип әйтергәме, әллә иренчәклек яисә карарсызлыкмы ---?* И.Нуруллин

**ИРЕНЧӘЧӘКЛЕЛӘР** *и. бот. күпл.* Таҗ яфраклары тоташ, еш кына ике җенесле булган, ике өлешле, бер, ике, күпьеллык үләннәр семьялыгы (сукыр кычыткан, бөтнек, лаванда, розмарин, шалфей һ.б.); *русчасы*: **губоцветные**. *Иренчәчәклеләр арасында дару үләннәре, аш тәмләткеч үләннәр, --- күп*. Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Иренчәчәклеләрдән иң билгелеләре – кыр бөтнеге, озын яфраклы бөтнек һәм гади мәтрүшкә*. Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИРЕ́Н ЯРГЫЧ** *и. бот. диал.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, яшь чагында сабагы ашарга яраклы булган һәм иренне яра торган үсемлек; *русчасы*: **пастернак дикий**. *Җир яшәргәч, кызарып борнаган кычыткан, аннары ирен яргыч белән какы, соңрак балтырганга керешәсең*. Ә.Гаффар

**ИРЕШТЕРҮ** I *ф.* 1) Нәрсәне дә булса кирәкле урынга алып килү, тиешле җиргә китереп җиткерү. *Икенче көнне аның бер дусты, һәммә нәрсәләрен китереп, хәзрәт тарафыннан рәсми тапшырылган ушбу игъланны ирештерде*. Г.Ибраһимов

2) Берәр хәбәрне яки сүзне кемгә дә булса килеп әйтү, барып тапшыру, җиткерү. *Мин аның сәламен ирештерергә илче ителдем*. М.Фәйзи. *Кайту белән, иң беренче эшем итеп Николаевны эзләп табам, барыбер Җир йөзендә яшәтмим, дигән сүзләрен китереп ирештерделәр инде*. М.Маликова. *Яңалыкларның иң ачысын, фаҗигалесен дә, сөенечлесен дә халыкка хат ташучы Галиулла ирештерә*. Т.Галиуллин

3) Берәр нәрсәне (теләкне, уйларны һ.б.ш.ларны) тормышка ашыру. *– Җәйге урманда тәнемне шулай рәхәтләндерергә кызыга идем мин. Рәхмәт сиңа, Ихсан, син мине шуңа ирештердең, – диде [Акчулпан]*. М.Хуҗин

4) Берәр эштә, өлкәдә билгеле бер югарылыкка, дәрәҗәгә күтәрелү (осталык, камиллек һ.б.ш.лар турында). *Сүзлекне камиллеккә ирештерү*

5) *сөйл.* Берәр нәрсәгә ия итү, берәр нәрсә белән тәэмин итү. *«Бу дөньяда зур дәүләткә ирештерә торган юлларның иң турысы, иң хәләле – сәүдә кылу», – ди торган иде аның әтисе исән чагында*. М.Әмир

6) *иск. күч.* Берәр нәрсәгә (бәла, каза һ.б.ш.ларга) дучар итү. *Бәла-казага ирештерү. Афәткә ирештерү*

**Ирештерә бару** Даими рәвештә, һәр булган берсен ирештерү. *Ничә мәртәбәләр акыллылыгы аркасында аның шундый хәлләрдә калганы бар. Һәммәсен әнисенә ирештерә баралар. Бу әләкчеләр булмасын иде ул*. Ә.Гаффар

**Ирештерә башлау** Ирештерергә тотыну. *Ир белән хатынның сүзләре беттеме-юкмы, ишектән --- Рамил килеп чыкты, әтисенә яңалыклар ирештерә башлады: – Беләсеңме, әти, мүкләгебез поши бозавына тими инде*. М.Рәфыйков

**Ирештерә килү** Күптәннән бирле, системалы рәвештә һәрвакыт ирештереп тору. *Нинди генә кимчелеген күрсәм дә, кемнән генә аның хакында начар сүз ишетсәм дә, иремә ирештерә килдем*. М.Маликова

**Ирештерә тору** Һәрвакыт, берсе артыннан икенчесен ирештерү. *Хәлил көне буенча, килгән-киткән кеше белән гәпләшеп, телефоннан кирәкле хәбәрләр җыеп, Сәет колагына ирештерә тора*. Т.Галиуллин. *Чәнечкеле сүзләрен ирештерә тордылар*. Л.Гыймадиева

**Ирештереп тору** Әледән-әле, еш ирештерү. *Кангуровлар гаиләсенә кагылышлы мәсьәләләрне сезгә ирештереп тору тиеш дип саныйм*. М.Маликова. *Акбүренең төп вазифасыннан берсе: урманга якын авыллар, шәһәрләрдәге хәлләрне белеп, бүреләргә хәбәр ирештереп тору иде*. Р.Батулла

**ИРЕШТЕРҮ** II *ф. диал.* Кемне дә булса үчекләү, үртәү, котырту. *[Чәчне] Кайчы белән кыркытасы*

*килми, чөнки урамга чыгу белән «кәҗә» дип ирештерәләр.* Ф.Яруллин. *Син уйныйсың, юри ирештерәсең кебек мине.* Р.Мөхәммәдиев. *– Елга суын күбрәк чөмергәнсең, ахры, каенсеңел. Миең сыегайган, – диде сәркятип хатын. – Сине юри ирештерәләр, юри!* Н.Гыйматдинова

**Ирештерә бару** Торган саен ныграк ирештерү. *Ул [Мотаһир] чалгы сабын чатырдатып торткан, күзләре отыры усаллана бара. Әллә шуны күреп, әлеге дә баягы уголовник аны һаман ирештерә бара.* Р.Кәрами

**Ирештерә башлау** Ирештерергә тотыну

**Ирештерә килү** Күптәннән бирле, даими, һәрвакыт ирештерү. *Өстәвенә, [Имаметдин] булышчылары авызыннан: «Мәчетнең мулласы итеп әбәзәтелни аны сайлап, мәчеткә исемен дә бирергә кирәк даже!» – дигән сүзләрне мәхәллә кешеләренең колагына ирештерә килә.* З.Фәйзи

**Ирештереп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә ирештерү. *Бибиса кузгалганда, күзгә күренмәгән адәмнәрне ирештереп алды: – Кайгырмагыз, көймәне мин кирәгенә файдаланырмын!* С.Сөләйманова. *Чыгып китәм дигәндә генә, ишек катына җиткән Камилә тагын бер мәртәбә дәү әтисен ирештереп алды. – Бүген иске клуб каршында дискотека була, әйдә, минем белән чыгасыңмы?* Г.Гыйльманов

**Ирештереп йөрү** Һәрвакыт, даими ирештерү

**Ирештереп тору** 1) Сөйләү моментында ирештерү

2) Һәрвакыт ирештерү. *Түбәнлекләрен, тупаслыкларын сиздерәсем килеп, гел-гел ирештереп тордым үзләрен [хуҗаларны].* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИРЕШҮ** *ф.* 1) Хәбәр, сүз, гайбәт кемгә дә булса ишетелү, билгеле булу. *– Сезгә сер сыяр, сездән чыкмас, дип кенә сөйләшүем, шуңа гына иң эчке уйларымны ачуым. Әгәр кызыма ирешсә, күңеле тагын рәнҗер, ярамас, – [диде карт].* М.Маликова. *– Төшлек салган идем, изгеләрдән шул килеп иреште. Пакьләнеп-аруланып, «кылган кара эшемә тәүбә итәм, йа Аллаһы Тәгалә, ---» дип, җитмеш мәртәбә кабатласын, --- диделәр.* Н.Гыйматдинова. *Ә Өч Наратка хәбәрләр әллә нидә бер, соңарып кына ирешәләр иде.* Х.Сафина

2) *сөйл.* Берәр җиргә, билгеле чиккә килеп җитү. *...Уралның безгә караган итәгенең тармаклары сырт-сырт булып тезелеп китәләр дә, бара-бара каядыр еракта, күккә терәлгән җирдә, күгелҗем кара урманнар белән капланган биек тауларга барып ирешәләр.* Г.Ибраһимов

3) Хат, посылка һ.б.ш.ларның билгеләнгән урынга барып җитүе, тапшырылуы. *Йөрәгем сизә: минем сәламем аңа иреште, бигрәк тә «көтсен, бүген кич аның янына барам» дигән сүзем иреште.* Г.Ибраһимов

4) Гомернең кайсы булса бер чигенә килеп җитү. *Йөз яшькә ирешү*

5) *күч.* Нинди дә булса бер теләк яки ният тормышка ашу, алга куелган максатка ия булу. *– Мин инде бу җирдә үкенерлеген калдырмадым, – диде Степан Петрович. – Мәхәббәтен дә, бәхетен дә татыдым. Дөрес, аларга мин уравыч, авыр юллар белән барып ирештем, ләкин барыбер ирештем.* М.Маликова. *Үз вакытында һәркайсы күңелемдә матур эз калдырган яшьлек дусларымның шундый бәхеткә ирешүләренә куанып бетәргә өлгермәдем, Биктаһировның фаҗигале үлеме турында хәбәр китерделәр.* М.Әмир. *Балачакта кыерсыту-кагулардан гаҗиз җаны данга-шөһрәткә ашкынды Замановның. Ул моңа иреште...* Ф.Сафин

6) *күч.* Кайсы да булса берәр өлкәдә билгеле бер югарылыкка күтәрелү, аңа ия булу. *--- без бүген, бүләк һәм теләкләребезне яңа хөкүмәткә тапшыру өчен, үзебезнең вәкилләрне тантаналы рәвештә, тыныч күңел белән озату шәрәфенә ирештек.* К.Нәҗми. *Әни, вакыт-вакыт зарланса да, әтинең хезмәте, аның шундый дәрәҗәгә ирешүе белән горурлана.* Ф.Яруллин. *Мөвакыйф уенда гаҗәпкә калды, әйтте: – Бу ни шәрәфкә ирештем: олуг казый үзе мин колыгызга мондый хөрмәтләр күрсәтә, – диде.* Борынгы татар прозасы

7) *күч.* Берәр нәрсәнең мәгънәсен, эчке табигатен, эчтәлеген аңлар хәлгә җитү; төшенү. *Каршыбызда, акыл ирешә алмаслык сер булып, бөтенләй диярлек ялангач кыз басып тора иде.* М.Әмир. *Биредәге рәхәтнең дә китек җире табылды: урыннар иң кадерсез, караңгы төштә икәнлеге аңга килеп иреште.* М.Маликова. *--- Капкаев та үзләре арасында нindидер җитди сөйләшү көтелгәнлекне аңлауга иреште.* Р.Мөхәммәдиев

8) *иск. күч.* Бәла, каза һ.б.ш күңелсез хәлләргә юлыгу. *Болар шунда яхшы гына эшләп йөргән вакытта, шырпы фабрикасына да каза ирешеп, ут чыгып, баганаларына кадәр янып бетте.* М.Гафури

**Ирешә бару** Акрынлап, даими, берсе артыннан берсенә ирешү. *Моңа чаклы теләгенә ирешеп килде.* Ә.Моталлапов. *--- илебезнең алдынгы галимнәре һәм мәгърифәтчеләре, Ломоносов юлы белән барып, югары белем учакларын күбәйтү өчен көрәшәләр һәм әкренәкрен булса да үз максатларына ирешә баралар иде.* Җ.Тәрҗеманов

**Ирешә башлау** Нәрсәгә дә булса ирешү сизелү. *Г.Исхакыйның мөһаҗәрәттә язылган әсәрләре, --- илдәге татар укучыларына бары тик 90 нчы елларда гына ирешә башлады.* Х.Миңнегулов

**Ирешеп килү** Әкренләп, аз-азлап бер-бер артлы ирешү. *«Теләкләреңнең барысына да ирештеңме соң?» – дип --- сорады Наилә. «Ирешеп киләм», – диде Гөлнара.* А.Гыйләҗев. *– Мин бу көнне күптән көтә идем, Венера, бәхетемә ирешеп киләм, ниһаять! – Хафизов, кайнарланып, камыр кебек йомшап чыккан Венераны кысып алды.* З.Фәйзи

**Ирешеп тору** Һәрвакыт, һәрдаим, булганы берсе ирешү. *Сәяси вакыйгаларның һәммәсе турында хәбәрләр, алай-болаймы, ничек тә базарга агайэне арасына ирешеп тора.* Ш.Камал

**ИРҖӘНКӘ** *и. диал.* **1.** *к.* **ирдәүкә**. *– Әбәү, әбәү, – диде күрше хатыны. – Харап икән. Күлмәк киеп кенә кеше рәвешенә кермәкче булганыңдыр. Күлмәк кенә түгел, алтынга манчылсаң да сиңа егетләр әйләнеп карамаячак. Ирҗәнкә!* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* Үзен ирләр кебек тотарга, ирләр арасында булырга яратучан. *Алты-җиде аппаратчик – тук, шома битле, утыз-кырык яшендәге ирләр, кырыс-җитди киенгән ирҗәнкә хатын-нар ыгы-зыгы килделәр.* М.Мәһдиев

**ИРЗАТ** *и.* Ир кеше, ир җенесендәге кеше. *Яшерен-батырын түгел, кайбер ирзат җиңел генә: «Әй, бу хатын-кыздан нәрсә чыксын инде, хатын-кызның бөтенесе бер чыбыктан «сөрелгән», – дип, тиз генә тигезлек билгесе куярга тырыша.* С.Ибраһимова

**ИРИ́ДИЙ** *и. гр. хим.* Агалтын төркемендәге уалучан ак төстәге көмешсыман металл (органик синтезда катализатор сыйфатында, радиотерапиядә (яман шешләрне диагнозлауда) кулланыла)

**ИРИДОДИАГНО́СТИКА** *и. гр. мед.* Авыруны күзнең төсенә карап диагнозлау ысулы

**ИРИДОЛО́ГИЯ** *и. гр. мед.* Медицинада нинди дә булса авыруның күзнең төсе үзгәрү белән бәйләнешен өйрәнә торган бүлеге

**И́РИС** *и. гр. бот.* Сусынчалар семьялыгыннан, кылыч сыман эре кыяклы һәм шәмәхә, күк яки сары төстәге эре чәчәкле күпьеллык үсемлек; күк сусын; кылыч уты. *Ирис – тармакланучан тамыр-сабаклы, яхшы кышлый торган үсемлек.* Йорт эшләре. *Анна-ры хуш исле шомырт чәчәккә төренә, бераз соңрак нәүрүз, күгәрченкүз, ала миләүшә һәм сусын (ирис) чәчәкләре күренә ---.* Ботаника. *Халык медицинасы, сөялләрне бетерү өчен, ирис яфракларын сөял өстенә ябып бәйләргә киңәш итә.* Юлдаш

**ИРИ́С** *и. гр.* Шикәр һәм бәрәңге балын сөттә изеп, кайнатып әзерләнгән озынча шакмак формасындагы кызыл көрән төстәге конфет. *Авызының тәме юк иде, гастрономга кереп ирис алды, шуны суырды.* А.Гыйләҗев

**ИР-КАНАТ** *и. иск. к.* **ир** (*3 мәгъ.*). *Багучым, Кандыр ата минем ирем түгел, бары тик кан кардәшем. Киләр бер көн, ир-канатны үзем сайлармын.* М.Хәбибуллин. *Әй, ир-канатым күрсә икән бу бәхетле көннәрне!* Н.Гыйматдинова

**ИРКӘ** *с.* **1.** 1) Сөюне, иркәләүне, назлауны ярата торган. *Артыкбикә иркә балалар төсле шат һәм җил шикелле җитез кыз булып чыкты.* М.Әмир. --- *иңгә менеп кунакларга гына торган бәйләнчек, симез һәм иркә Тимошаны бөтенләй җене сөйми иде Мәрьямнең.* М.Маликова. *Әлегә мин – кадерле, иркә малай. Әбинең, әти белән әнинең бердәнбере.* Р.Хафизова

2) Сөекле, кадерле, яраткан. *Шаһзадәнең иркә сөяркәсе әйтте бер көн, назлап сөйгәнен.* М.Җәлил

3) Артык иркәләү, яратудан узынган, көйсез; назлы. *Ул арада назлы, иркә килен Гыйззелбанат үзенең каенсеңлесе Гөлбануны тиге өйдән --- бу өйгә китереп тә җиткерде.* Г.Ибраһимов. *...Әйтерсең лә [Җәүдәт] --- кызларның кирәгеннән артык иркә, үзсүзле булып үсүен --- хәтерләми.* Т.Галиуллин. *Ул [Фирзан] – кап-кара чәчле, нәзек сөякле, тугыз апасы куенында гына үскән иркә малай.* М.Галиев

4) Ягымлы, назлы, назлаучан, иркәләүчән, йомшак. *Зиләйлә иркә хәрәкәт белән аның керфекләрен сыйпаштырды.* М.Маликова. *– Нәҗип! – диде Наилә, кыз чагындагы көмеш, иркә тавышы белән.* А.Гыйләҗев. *Гөлгенә ирен таң калып тыңлады һәм: «Баш бар икән үзеңдә!» – дип, Хәйригә иркә караш ташлады.* Ф.Яруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Артык иркәләнеп, назланып. --- *аның кулыннан бер эш килми: ул хәлле ата-ананың бик көтеп алган, кадерләп үстергән ялгыз баласы иде, иркә үсте.* Г.Ибраһимов. *Фатыйма баланың иркә үсүен яратып бетермәсә дә, иренең шатлыгын уртаклаша.* И.Гази. *[Галя] Гаиләдә иркә үскән, ни кыланса, шуны килештергәннәр, ни әйтсә, шуны үтәп торганнар.* М.Насыйбуллин

2) Ягымлы итеп, назлы итеп, йомшак итеп. *Башкалар да гел мактап тора иде бу сестраны, ләкин, минем ышануымча, ул бары тик миңа гына шулай назлы, иркә итеп орына иде шикелле.* М.Маликова. --- *сабыйның үзәк өзгеч моңы --- әрем, эт эчәгесе, каз катламасы, пәйгамбәр сагызының хуш исләре белән бергә кушылып, сулыш юлларын иркә кытыклый ---.* А.Хәлим // Наз, сөю күрмичә. --- *ата-анамның иртә үлүенә бик кайгыра идем. Назсыз, иркәсез үскән сабый чагымны хәтерләп, баламны әнкәем өчен дә иркәләргә, сөяргә тырыша идем.* Г.Кутуй

**3.** *и. мәгъ.* 1) Сөйгән, яраткан кеше (гадәттә, хатын-кыз). *Әйтсәгез лә минем иркәмә, Зәңгәр күлгә барсын иртәгә!..* М.Җәлил. *Бик ярата торган кеше генә Сагына шулай үзенең иркәсен.* Р.Ишморат. *[Сәет] Иркәсен коткарса, аны башкача сөяр, --- гел матур сүзләрдән тәсбих төймәләре тезәр иде.* Т.Галиуллин

2) Иркәләү, яратып карау; яхшы мөнәсәбәт, наз. *Ирнең каны уяна, ачуы югала, Һаҗәрнең иркәләре ялкынында күңеленең барлык вәсвәсәләре юкка чыгалар.* Г.Ибраһимов

3) **иркәм** Яратып, иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Аерылабыз, иркәм, мин китәмен Ватан сугышлары кырына ---.* Ф.Кәрим. *Әби, ике арадагы читән буена килеп, яңадан дәште: – Эшең ашыгыч булмаса, кереп чыкчы, иркәм.* Г.Галиев. *– Я, әйдә керик, иркәм! – диде Мөнирә.* Ә.Еники

◊ **Иркә песи** Гел иркәләнеп, назланып торучы (күбесенчә бала-чагага карата әйтелә). *Үзенә игътибарны алмыйча, мыштым гына чишенеп, юрган астына иркә песи баласыдай чума белгән Зөлфиясе сихерләдеме.* Т.Галиуллин. **Иркә тай** Ярату, наз көтеп сырпаланып йөрүче яшүсмер балага яратып әйтелә. *Карлыгач түзмәде: – Ут эчендә калдым гуй мин дә, иркә таем! – дип, үзенең фаҗигасен сөйләп бирде.* Г.Ибраһимов

**ИРКӘК** *с.* **1.** *иск.* 1) Ата җенестәге. *Көчек тагын йомшак тавыш бирде... – Кем соң әле син – иркәкме, инәкме? Җенесең нинди, дим? – диде Габдияр.* М.Хуҗин. *Иркәк зат бик күп инәк затлар белән парлана ала.* Кызыклы физиология. *Баксаң, инәкләр түгел, бәлки, иркәк затлар көчсез җенес булып чыга икән.* Кызыклы ихтиология

2) Ирләргә генә хас, ирләрнеке кебек, ирләргә охшаган. *Сабир хәзрәт --- иркәк йөзле, киң иңсәле, сәламәт адәмдер.* Г.Камал

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Ир җенесендәге кеше, ир; ата җенестәге җан иясе. *Хатынның иркәккә рәхмәте кичке затлы аш, йомшак урын, назлы кочак, --- булып кайта.* Т.Галиуллин. *Бу эшкә яшьли җигелгән кызлар тиз картая, ике-өч елда кырыкилле яшьлек хатын-кыз кыяфәтенә керә. Чөнки төрле иркәк белән мөнәсәбәттә була.* Ф.Фәтхелислам. *Дөя баласы – иркәк, әтисе – Чыңгыз, әнисе Люси исемле.* Ирек мәйданы

**ИРКӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Назлану, сыйпалану. *Итне ашап, кымызны эчеп чыкканда, төн килгән --- маллар ятканнар, тик сөякләрне көтеп, этләр генә койрык селкеп, һәр очраганга иркәләнеп йөриләр иде.* Г.Ибраһимов. *Сәлимәм бар дөньясын онытып мине иркәләде һәм иркәләнде.* Ф.Яхин. *Әле күптән түгел генә үзе дә бала кебек аның куенында иркәләнә иде, ә хәзер нинди җитди.* З.Кадыйрова

2) Аркалану, салыну. *Абыйсына иркәләнү*

**Иркәләнә бирү** Бернигә дә карамыйча иркәләнүен дәвам итү

**Иркәләнеп алу** Бер тапкыр, аз гына иркәләнү

**Иркәләнеп тору** Һәрвакыт, гел иркәләнү

**ИРКӘЛӘНҮЧӘН** *с.* Иркәләнергә, назланырга ярата торган. *Иркәләнүчән холкыңа Тап ярлар табалдыңмы?* Җыр

**ИРКӘЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Кадерләп, назлап ярату; сөю, ярату хисен белдерү; назлау. *Рәимә дә Гүзәлне иркәләде, сөйде, тузгыган чәчләреннән үбеп, йокларга яткырды.* М.Хәсәнов. *Ә «яратам» дигәнеңне, иркәләүләреңне ничек аңларга?* Р.Мөхәммәдиев

2) Кешегә яки берәр нәрсәгә ягымлы күз карашы, йомшак итеп дәшү яки ниндидер җиңелчә хәрәкәт һ.б.ш.лар белән рәхәтлек, рухи ләззәт бирү. *Җырым белән дусны иркәләдем, Җырым белән җиңдем дошманны.* М.Җәлил. *Үсмер иманнәрне иркәләргә Нәзек билле җилләр килгәннәр.* Ә.Ерикәй. *Кояш, --- тауларны, яшеллеккә төренгән болын-тугайларны, --- сулыкларны иркәли.* Н.Әхмәдиев

3) Кирәгеннән артык уңайлы яшәү, җиңел тормыш шартлары тудырып, рәхәттә яшәтеп, теләсә нәрсә эшләргә юл куеп узындыру, бозу (гадәттә балалар турында әйтелә). *[Баланы] Артык иркәлибез, сүзен итәбез дип, үзебез бозып ташлыйбыз.* М.Фәйзи. *Сабыйның теләсә нинди уңышын назлы елмаеп, кызыксынып, җылы сүз әйтеп хуплау яхшырак нәтиҗә бирә. Артык иркәләү белән моның берниНди уртаклыгы юк.* Тигез гомер итегез!

**2.** *и. мәгъ.* Ярату хисе, наз. *Ягымлы елмаеп торган балага наз, иркәләү һәрвакыт күбрәк эләгә.* Ф.Яруллин. *Сәхап киткәннән бирле иркәләү күрмәгән тән назга сусаудан йомшый, изри башлады.* С.Зыялы. *Ул минутларда Шакирның күңелендә хатынына рәхмәт хисе, аны кызгану, хөрмәтләү, иркәләү теләге уянган иде.* М.Маликова

**Иркәләп алу** Кыска вакыт арасында, аз гына иркәләү. *– Юк, юк, Самат, бик вакытлы килдең, рәхмәт, – дип, [Сәлимә] ягымлы карашы белән егетне иркәләп алды.* Г.Галиева. *Сәет [Зөлфияне] карашы белән иркәләп алды да култыклау өчен кулын җәйлап куйды.* Т.Галиуллин. *--- Айсылуның җилдән сибелеп, таралып торган чәче кайчак Марсның йөзен иркәләп, кытыклап ала.* Р.Хәбибуллина

**Иркәләп бетерү** Артык иркәләп узындыру, бик нык иркәләү. *Бозылды хатын-кыз. Хөкүмәт иркәләп бетерде.* Ф.Яруллин. *– Син иркәләп бетердең баланы, кыюсыз иттең, – диде Хәбир.* Х.Камалов. *Төпчек кызым, бәхетле кызым, дип, үзем иркәләп бетердем, үзем...* Ф.Бурнаш

**Иркәләп тору** Һәрвакыт, гел иркәләү, әледән-әле иркәләү. *Тик инде, кызым, берүзеңә бер өй биреп иркәләп торуның кадерен белмәдең.* М.Фәйзи. *Бервакыт өстәл башында утырганда, Вәзыйх Ленизаның кулын тотып алды һәм ике учында озак кына иркәләп торды.* Х.Камалов. *Мишәр кызы --- Зәйнине иркәләп кенә тора, күзенең карасы кебек саклый.* М.Хуҗин

**Иркәли башлау** Иркәләргә тотыну. *Кызның сулышы ешайды, бөтенләй өзелде, ап-ак беләкләре ирнең муенын, чәчләрен иркәли башлады.* Т.Галиуллин. *Гайфулла балдызын иркәли башлады.* Ф.Яруллин. *Үсә төшкәч, гармунчы егет дип, кызлар иркәли башлады.* Г.Бәширов

**Иркәли бирү** Бернигә дә карамый иркәләүне дәвам итү

**Иркәли төшү** Тагын да күбрәк иркәләү. *Атасы да, төпчек малай дип, иркәли төшә иде җитмәсә.* З.Фәйзи

**ИРКӘЛӘҮЛЕ** *с.* Иркәләү, назлау, ярату хисен белдергән. *Шунда яр башыннан әнкәйнең иркәләүле тавышы ишетелә...* Г.Гыйльманов

**ИРКӘЛӘҮЧӘН** *с.* 1) Ярату, сөю, наз белдергән, күңелгә ятышлы, ягымлы, йомшак, рухи канәгатьлек бирә торган. *Әхмәтшасын күргәч, яшь килен сөенеп, эчтән-тыштан балкып китте. Аннары иркәләүчән бер тавыш белән сорап куйды...* Г.Шәрәфи. *Заһид иркәләүчән һәм көр күңелле егет кенә түгел, бик игътибарлы ир, йорт тотар хуҗа да булып чыкты.* Р.Төхфәтуллин. *Анда Муса ягымлы, иркәләүчән, йомшак тавышы белән бәхәскә катнаша иде ---.* М.Максуд

2) Рәхәтлек бирә торган. *Иртәнге кояшның иркәләүчән җылылыгында һәрнәрсәдән иренчәк пар күтәрелә.* Ә.Камал

3) Иркәләнергә яратучан. *– Хатының үзеңне бик иркәли бугай. Хатыннары иркәләгәннәр шулай иркәләнүчән булалар, әмма без, җәмәгатьчелек, сине иркәли алмыйбыз, – диде Актанов.* Х.Камалов. *Харис башын күтәрә. Аның йөзе ачулы, әмма күзләре астыртын гына, иркәләүчән елмая.* Р.Төхфәтуллин

**ИРКӘЛЕ** *с.* Иркә, сөю белдерә торган, йомшак, ягымлы. *Нәсимә иркәле генә тавыш белән: – Ярар инде, икенче озаграк сөйләшеп утырырсың, минем бик йоклыйсы килә башлады, – диде.* Ш.Камал. *Остазбикә озын, озын бураннар, --- каты суыклардан соң кинәт кенә май аеның иркәле кояшы алдына барып чыккан адәм кебек --- иде.* Г.Ибраһимов

**ИРКӘЛЕК** *и.* 1) Иркә (*1–2 мәгъ.*) булу, назлану, сөелү, иркәләнү. *--- җиңеллек чәчә торган күзләрендә дә хәзер элекке нурлар, элекке иркәлекләр өстенә ниндидер бер уй катнаш акыл пәрдәсе капланып тора.* Г.Ибраһимов.

*Аның һәртөрле иркәлекләренә өйрәнгән атасы һәм абзаларына да аның болай һаман яшь балаларча кылануы кызык тоела...* Ш.Камал. *Хәнифәнең иркәлеге, назлылыгы да ясалма кебек, аның чамасыз әрсезлеге, --- ачуын китерә иде.* Р.Хафизова

2) Иркәләү, назлау, сөю хисе. *Җәй буе дачаларда, гомеремдә күрмәгән, хәтта хыялына да китерә алмаган иркәлек һәм наз эчендә яшәтер.* Г.Бәширов. *«Тормыш турындагы җыр»га мин үземдә булган бөтен иркәлегемне бирергә тырыштым.* Г.Кутуй. *Ятим үскән, балачак иркәлеген татымаган, --- бу яшь егеттә кайдан шулкадәр көр күңеллелек, кайдан шулхәтле үз-үзенә ышану?!* Г.Әпсәләмов

**ИРКӘЧ** *и. диал.* Үзен яратканны, сөйгәнне, иркәләгәнне яраткан кеше; иркә (*1 мәгъ.*). *Һи-һи икән бикәчем, кая китте иркәчем?* Н.Исәнбәт

**ИРКЕН** *с.* **1.** 1) Иңе, буе зур; киң, кысынкы булмаган, рәхәтләнеп сыярлык. *Театрның ишегалды шактый иркен: түрдә – гараж, аның каршында кечкенә автобус тора.* М.Маликова. *Алар Рудольфны түр яктагы иркен һәм йомшак ятакка урнаштырдылар.* Р.Вәли. *Нефтьче шефлар салып биргән зур, иркен яңа мәктәптә дәрес бара иде.* А.Әхмәт

2) Кысып тормаган, киң. *Иркен туфли. Иркен күлмәк. Иркен чалбар*

3) Киң җәелгән, зур урын биләгән. *Өч баламны, очар кош итеп, Мин очырдым иркен далага ---.* М.Җәлил. *Свайлар арасында ватылган боз кисәкләре буадан агып чыгалар да, иркен болында мәһабәт кыяфәттә борыла-борыла, еракка юл алалар.* М.Мәһдиев. *Автобус, урамнарның әле берсеннән, әле икенчесеннән чаба торгач, ниһаять, шәһәрне артта калдырып, киң, иркен юлга чыкты ---.* Р.Гыйззәтуллин

4) *сир.* Азат, ирекле, бәйсез. *Казан! Фахиш шәһәр, синең урамыңа Мин, гыйсъянчы, кереп адаштым. Череп беткән мещан баткагында Иркен уйларымнан саташтым...* Һ.Такташ

5) Җайлы, уңайлы, киеренке түгел. *Һәр хәрәкәтем төгәл, иркен, нык, һәр адымым ышанычлы булып китте.* М.Маликова. *Куллары белән иркен хәрәкәтләр ясап куя.* Ә.Фәйзи. *--- замандасы бик иркен иде бит: 1956–1958 елларда --- Казанның теләгән ресторанында --- 5 – 6 тәңкәгә ашап-эчеп утырырга була иде.* М.Мәһдиев

6) Тышкы, тыштагы. *--- кортка урын тар, кызыксыз күренде булса кирәк, өй эчен бер әйләнде дә кире иркен һавага чыгып очты.* Ә.Еники

7) *күч.* Бернинди дә матди кыенлыклар кичерми торган, бай, хәлле. *Җир йөзендә шундый тук, Шундый иркен тормышлы, --- Тагын берәр ил бармы?* М.Җәлил. *--- улыбыздан уңмадык. «Этне чылбырга бәйләгән кебек, мине гаилә белән богауларга тырышасыз», – диде. Ул иркен, матур тормыш өчен яралган, имеш.* М.Насыйбуллин. *--- мәдәни казанышлардан, нигездә, җәмгыятьнең укымышлы, иркен тормышлы өлеше генә тулысынча файдалана ала.* Татарстан тарихы

8) *күч.* Берәр нәрсәне чама белән әйткәндә «бер дә ким түгел, әле артык та булыр» мәгънәсендә

9) *күч.* Эш, шөгыль белән мәшгуль булмаган, буш. *Кайтып төшкән көннәрдә ячейка белән, яшьләр белән кайнашып, ничектер иркен бер вакыт таба алмадым.* Г.Ибраһимов. *– Сезнең театрда җиңел көнегез, иркен вакытыгыз булганы бармы соң? – Низам, сулышына йотылып, сүз таба алмый торды.* М.Маликова. *Наилә үтә мөлаем, изгелекле тавыш белән аны бүлдерде: «Нигә ярамасын, ди? Алан киң, ризык мул, вакыт иркен. Рәхәтләнеп ял итик!» – диде.* А.Гыйләҗев

10) *күч.* Җитәрлек, табып, алып булырлык (берәр нәрсәнең дефицит булмавы турында). *Люся бүген иртән җыенды да чыгып китте. Билеты да юк иде бугай. Хәер, хәзер самолётка билет иркен бит.* М.Маликова

11) *күч.* Аһәңле, матур, саф, киң. *Әмма җырчының иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.* Ә.Еники. *Болын киңлекләренә иркен музыка агыла башлады.* Р.Сибат

**2.** *и. мәгъ.* 1) Пространствосы зур булган киң урын; ачыклык, ачык һава. *Бу һава, бу яз галәмәте кешеләрне урамга тарта, кысрыктан иркенгә өстери.* Ф.Әмирхан. *Тизрәк урамга – яктыга, иркенгә чыгарга ашыкты Харис.* М.Маликова

2) Азатлык, бәйсезлек, хөрлек; ирек (*2 мәгъ.*). *--- кол булып тору белән иркендә торуның аермасы бик зур бит.* Г.Коләхмәтов. *Әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин?!* Г.Тукай. *Камерада салкынча. --- Нигәдер бу минутта Хәяткә үз йөрәге дә тимер читлек эчендә тибә сыман тоелды. Тик җаны гына иркендә.* М.Насыйбуллин

3) *күч.* Җитеш, мул, хәлле тормыш. *Үзен монда китерүләренә гаепләми ул оныкларын. – Без инде яшен яшәгән, ашын ашаган. Алар иркендә, рәхәттә торсын, – ди.* С.Зыялы

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) *сөйл.* Бәйсез, азат булып. *Кайда без иркен яшәрбез, хөр, азат җилләр кебек.* Һ.Такташ. *Туган илдә ничек сыйланулар, коштай иркен йөргән вакытлар ---.* А.Алиш

2) Җиңел генә, ансат кына. *Җидесигез телдә бик иркен сөйләшкән бабам кышлакта балалар укыта.* Ә.Хәсәнов. *«Урыс» дигән кушамат аның урысча яхшы белгәне, урыс галимнәре белән иркен аралашканы, татарларны урысча өйрәтергә тырышканлыгы аркасында бирелгән.* Р.Батулла. *--- русча-татарча иркен сөйләшә һәм яза алган дәрәҗәле Р.Мостафинның бу чыгышы партия түрәләре өчен һич тә көтелмәгән хәл булды.* Р.Фәйзуллин

3) Тартынмыйча, уңайсызланмыйча, бәйсез, табигый рәвештә. *Шәхтазый үзе һәм Әхтәм абый безгә --- кырын карамыйлар, шуңа күрә әбиләрдә без үз өебездәге кебек иркен кылана идек.* М.Әмир. *Клава үзен иркен тотты. Хәтта Тимернең уң як кашы өстендәге яра белән кызыксынды.* М.Хәсәнов. *Юк, бу ханым, нинди генә асыл кош булмасын, «түбәндәгеләр» компаниясенә алырлык икән. Үзен әнә ничек иркен, кыю, гади тота ул!* Ә.Еники

4) Берәр нәрсәне тартылып, киерелеп торудан туктатып, бушайтып, киеренке итмичә. *Берүк тезгенеңне иркен куй!* Г.Ибраһимов. *Башчы иркен торырга әмер бирде. Солдатлар*

*тирләрен сөртергә, тәмәке тартырга керештеләр.* С.Җәлал

5) Мөлаем, ягымлы итеп. *Баш механикның тулы битле итләч йөзендә хәзер баягы иркен елмаю түгел, ә мыскыллы караш иде.* Р.Кәрами. *Хәлим тагын чигенеп куйды, әтисе аның нәрсәдән курыкканын аңлады бугай: иркен елмайды.* Г.Гобәй

6) Матди кыенлыклар кичермичә. *Һәр икәвесенең тавышында Исхакның күп акча эшләвенә, иркен яшәвенә кызыгу, хәтта соклану сизелә иде.* М.Маликова. *Ә тормышлары бер дә начар булмаган. Иркен, мул яшәгәннәр.* Ә.Еники

7) *сөйл.* Комачаулаусыз, чикләүсез, тоткарлыксыз гына

8) *күч.* Җитәрлек, күп, мул. – *Бәрәңге пешерәбез. Шәп балыгым бар минем. Мин бит эшлим – акчам иркен, [– диде Мөби].* М.Мәһдиев

9) *күч.* Берәр эшнең билгеле бер вакыт эчендә һичшиксез үтәлү мөмкинлеге барлыгын белдерү өчен кулланыла

10) *күч.* Тулысынча, бөтен киңлегенә, киң итеп. *Мең елларга бөтен намуслылар Хыялланган бәхет, кешелек Беренче кат менә безнең илдә Иркен итеп ачты ишеген.* М.Җәлил. *Кешене гәүдәләндерүдә традицион алымнар һәм чаралар иркен кулланыла.* Х.Миңнегулов. *Автор уен алымыннан да иркен файдалана.* Ә.Закирҗанов

11) *күч.* Яхшы, әйбәт, шәп

12) *күч.* Тәкәллефсез, әдәпсез, масаючан. *Хәйрүш үзен бик иркен тота. Кесәсеннән алып кабызган затлы папиросын ләззәтләнеп суыра да озаклап төтенен өрә.* Я.Зәнкиев. *Әгәр вакыйгаларга район югарылыганда гына берәр Шатманов килеп кушылса, һәм ул, билгеле инде, авыл рәисенә терәктаяныч булса, Баттал абзаң Мансурларга, Канәфиләргә үзенә каршы авыз да ачтырмас, авылдагы Катифә белән үзен ат караучы Шамилә янындагыдай «иркен» тотар иде.* Казан утлары

◊ **Иркен куллы** Хәлле тормышлы, дәүләтле, байлыгы җитеш. *«Хәерче» дип йөртә идең безне, Үзеңә кайта бу сүз, хәерсез, Батмый инде безгә синең бу сүз: Иркен куллы халык хәзер без!* Х.Туфан. **Иркен күңелле** Киң күңелле, юмарт табигатьле; сер, сүз сыя торган. *Бу сөйкемле таза хатынның ачык чыраенда иркен күңелле ягымлылык, түбәнчелекле ихтирам сизелә иде.* Г.Бәширов. **Иркен сулау, иркен сулу (сулыш, тын) алу** 1) Бөтен күкрәк белән, тирән итеп тын алу, сулау. *Бүлмәгә әле кояш төшмәгән, эссе, тузанлы урамнан кергәч, яңа гына юып чыгарган өйдә тын алу иркен иде.* М.Маликова; 2) Төрле мәшәкатьләрдән, куркынычтан котылып, җиңеләеп, тынычланып китү; үзеңне җиңел хис итү. *Урак өсте җиткәндә, халык шактый иркен сулый башлаган иде инде.* М.Әмир. *Җинаятьче табылмый торып, авыл иркен сулый алачак түгел иде.* М.Маликова. *Шәхес культы – явызлык, дип бәяләнгәннән соң, сәяси тоткыннарның күбесе гаепсез табылды һәм азат ителде. Ил аз булса да иркен сулыш алды.* Әдәбият; 3) Котылу, иреккә, азатлыкка чыгу: икътисади, сәяси һәм рухи яктан җиңеллекләр сизү. *Әле бернечә генә ай элек капитализм богавыннан котылып, иркен сулу ала башлаган Агыйдел крестьяннарының яңадан тыннары кысылды.* Г.Гобәй

**ИРКЕНӘЙТҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне күләм ягыннан зурайту (киңәйтү), иркен итү. *Трамвай юллары әлеге «бөкеләрне» бетерү, машиналарга юлны иркенәйтү максатыннан сүтелә.* Татарстан яшьләре

2) Сулышны, тынны җиңеләйтү. *Ана кеше, буын ныгытып, сулышын иркенәйтеп, өй эшләренә чат ябышты, күрше-тирәдәге кибетләргә дә чыккалап йөри башлады.* Г.Гыйльманов. *Һәр тарафтагы иртәнге саф һава сулышларны иркенәйтә, бөтен җанны иркәли.* Г.Галиева

3) *күч.* Эшне киметеп, буш вакыт калдыру. *Бала үстергәндә аларны бер минут та күз уңыннан ычкындырырга, иркенәйтергә ярамый.* Шәһри Казан *Вакытны иркенәйтү*

**Иркенәйтә бару** Торган саен күбрәк, ныграк иркенәйтү

**Иркенәйтә башлау** Иркенәйтергә тотыну

**Иркенәйтә бирү** Бернигә дә карамастан иркенәйтүне дәвам итү, һаман да иркенәйтү

**Иркенәйтә килү** Күптәннән, аз-азлап, акрынлап арттыра барып иркенәйтү

**Иркенәйтә тору** Даими яисә әледән-әле иркенәйтү

**Иркенәйтә төшү** Берникадәр, бераз иркенәйтү

**Иркенәйтеп җибәрү** Кинәт иркенәйтү. *Дәһшәтле 1937 ел, сугыш афәте, илленче ел башларындагы төрле яңа процесслар шаукымының (шул исәптән «врачлар эше»нең) артта калуы аның да сулышын беркадәр иркенәйтеп җибәрә.* Р.Әмирхан

**Иркенәйтеп карау** Иркенәйтергә тырышу

**ИРКЕНӘЮ** *ф.* **1.** 1) Күләме ягыннан зураю, киңәю; тыгызлыгы кимү. *Олы абыйлары, хатынын, бала-чагасын төяп, Әлмәткә, нефтькә чыгып китте. Өй чак кына иркенәйде.* А.Гыйләҗев. *Өй иркенәйде. Суфия артык әйберне яратмый иде, әллә нәрсәләр алып, өен тыгызламады.* Ф.Яруллин. *Күк йөзе ачылып китте, дөнья иркенәйде, һәм тапталмаган каты юл да кинәт тураеп, киңәеп калгандай булды.* Н.Фәттах

2) Тулы мөмкинлек алып җиңеләю. *Гыйлфанның кинәт кенә күкрәк куышы иркенәйде, тамакны тотып торган төен ычкынды, кинәт бакча, туган нигез исе бугазга бәреп керде ---.* М.Мәһдиев. *Соңрак, спектакль план буенча бер-бер артлы уйнала башлагач, --- сулышлар иркәнәя, дәрт өстәлә, илһам килә.* М.Маликова. *--- ишекне ачып, бүлмәне җилләтеп алырга булдылар. Сулыш алу иркенәйде, баш бераз җиңеләйде кебек.* Ф.Сафин

3) *күч.* Үзе теләгәнчә яши башлау; иркенлек алу. – *Эшендә ничек җайларга чамалый соң бу кыз, көннәр буе югала башлагач ---. – Больничный таптыртты, каһәр. Шуңа иркенәя --- – [диде Саматов].* Ф.Сафин. *Аланда яшәүчеләр дә тәмам иркенәйделәр, кышкы авыр киемнәрен салып ташладылар, билгә кадәр яланөс калдылар.* Р.Фәизов

4) *күч.* Рухи һәм физик газаплардан, авырлыклардан соң җиңеләю. *Халык*

*җиңеләеп китте, зал буйлап йомшак җил искәндәй булды. Даутов аның саен иркенәйде.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Мулга, җитешкә әйләнү; рәхәт яши башлау. *Дөньялар иркенәеп бер җыелсак, бу көннәрнең истәлеге итеп күрсәтерсең үзләренә.* К.Нәҗми

6) *күч.* Эш кимү, эштән бушану. *Кыр эшләре бетеп, азрак иркенәю*

7) *күч.* Вакыт арту, күбәю. --- *[Ихтыярның] мәшәкатьләре дә кимеде, вакыты, киресенчә, иркенәйде.* Р.Вәлиев

**2. иркенәеп** *рәв. мәгъ.* Иркен һәм җайлы итеп. *Резеда Фәритовна Нәҗия Нәкыйповна белән хушлашкан арада, Изаил Харисович, тунын салып, кәнәфигә иркенәеп утырды.* М.Маликова

**Иркенәеп алу** Азга гына, кыска вакытка иркенәю. *Нигә анда әллә кем булмый, туктамагыз, Яваска барып кергәч кенә, хәрби комендатура каршында иркенәеп алырсыз.* Ф.Сафин. *Теге гасырның бишенче елларында иркенәеп алгач та, бераз вакыт үткәч, татар өчен бозлы җилләр исә башлый.* Р.Зәйдулла

**Иркенәеп бетү** Бөтенләй киң, иркен булып калу. *Дөньялары чиксез, Җире йомры икән, Гомер сәкесе дә иркенәеп беткән.* Р.Харис

**Иркенәеп җитү** Тулы иркенлеккә ирешү. --- *Бибинур янында өч сыер савучы гына калгач, кунаклар сизелерлек җәйландылар. Бигрәк тә Шәмсеҗиһан иркенәеп җитте.* А.Гыйләҗев

**Иркенәеп калу** Нindидер бер эш, сәбәптән соң киңәю, күләме ягыннан зураю. *[Парикмахерскаяга] Кергәндә, бүрегем баш очында гына тора иде, чыкканда, күзләремә чаклы батты, --- бүрек эче иркенәеп калды.* Ф.Хөсни. *Бу тетрәткеч тойгылар узгач, аның күңеле яңгырдан соң саф һава бөркелгәндәй иркенәеп, рәхәтләнеп кала иде.* Г.Бәширов. *[Фаикъ] Ябыккан ахыры: яңаклары суырылып, өстендәге күк күлмәге иркенәеп калган.* А.Вергазов

**Иркенәеп китү** Бераз, берникадәр иркенәю. *Шау-шу басыла төшкән, баш та иркенәеп киткән кебек булды.* Ф.Әмирхан. *Фәрхананең шаярып әйткән сүзеннән соң операция бүлмәсендә һава иркенәеп киткәндәй булды.* С.Сөләйманова. – *Гали, – диде Гарәфи, хатирәләр кузгалткан күңел дулкынлануын басарга тырышып, – сәфәр чыгар алдыннан, күңелләр иркенәеп китә.* Г.Әпсәләмов

**Иркенәеп кую** Кинәт иркенәю. *Син, дедуля, кара аны, кайтыр алдыннан пилоткаң иркенәеп куймасын.* С.Шәрипов

**Иркенәя бару** Торган саен күбрәк иркенәю. --- *яңа җыр башлаган саен үзе ул ничектер рухлана, дәртләнә, ә тавышы отыры көчәя, иркенәя барды.* Ә.Еники. *Менә күр инде: өебезне оҗмах почмагы иттең бит. Яңа әйбер алган саен иркенәя бара.* Ф.Яруллин. *Янгураз тузанлы юлдан атлаганда: «Әйе, ил мәйдан ягыннан һаман иркенәя бара», – дип уйлады.* Т.Әйди

**Иркенәя башлау** Иркенәю сизелү

**Иркенәя төшү** Берникадәр, бераз иркенәю. *Урып җыю эшләре бераз иркенәя төшкәч тә, аларның туйлары булды.* Г.Әпсәләмов. *Икенче милләт кешесе белән --- танышу мине һәрвакыт рухи яктан баетып җибәргәндәй була, күңелдә иптәшлек, туганлык --- хисләре кузгалуын тоясың, эчке дөньяң киңәя, иркенәя төшә.* М.Әмир

**ИРКЕНЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Ашыкмау, үз җае белән эш итү. --- *Гадилнең: «Иркенләп утырыйк әле, Яңа елны бер көн алдан каршы алыйк», – дигән сүзләрен ишеткәч, Тәбриянең түбәсе күккә тиде...* М.Маликова. *Гасыйм Сәлахович, эше бик тыгыз булмаса, гәзитләрне шунда ук караштырып чыга, инде вакыты юк икән, барысын бөкләп портфеленә тыга да, өенә кайткач, ашыкмыйча иркенләп карый.* Ә.Еники. *Мәрвән ---, исереклек юлына кереп киткән Әхтәмне авылына алып кайтып, үз язмышы турында, --- иркенләп уйланырга мөмкинлек бирә.* Татар әдәбияты тарихы

2) Тарлык, кысынкы торыштан котылу; иркен урнашкан булу. *Бил каешым да гел кысмый, Иркенләп, җыйнак тора.* Ш.Галиев

3) Газап, авырлык һәм мәшәкатьләрдән котылу, җиңеллек сизү, җәелеп китү. *Авылда ул иркенләгән кебек булды. Авыл мәчетенең җомгалардагы сасысы да аңарга мөкаддәс сыман тоелды.* Г.Исхакый

4) Иркенлек, җиңеллек сизү, рәхәтләнү. *Аңар бирдем азатлык мин, Үзем дә шул вакыт күрдем: Тынычланып калды, никтер, Һәм тәмам иркенләде күңлем.* Г.Тукай. *Бүтән көндәгечә аны өстәл кирәк дип ашыктыручы Ринаты да булмагач иркенләде.* Н.Хәсәнов

5) *күч.* Вакытны бушка, әрәмгә уздыру. *Нәгыймә аулак өй дип бик иркенләп утырмасын, сугуларын суксын.* М.Гали

6) *күч. сир.* Үзе теләгәнчә яшәү; тулы ирек, мөмкинлек сизү, иркенлек алу. *Йомшак урынга чишендереп яткырган бала, бераз шулай иркенләгәч тә, яңадан йокыга китә.* Г.Минский. *Шулай итеп, китә калса, Кәүсәриянең артык иркенләвеннән Гамирга көн бетәсен уйлап, түзә бирде.* З.Фәйзуллин

**2. иркенләп** *рәв. мәгъ.* 1) Бернинди каршылыксыз, өстәмә мәшәкать кичермичә. *Дәүләт учреждениесендә эшләгән һәр кытай белән иркенләп, рәхәтләнеп инглизчә сөйләшә аласың.* В.Юныс

2) Бушрак вакыт сайлап, озаккарак. *Бераздан иркенләп килермен әле.* Т.Гыйззәт

3) Борчылмыйча, һичбер нәрсәгә илтифат бирмичә. *[Соры Бүре] Ни күрсен, көтүче йокыга киткән, ә сарыкбәрәннәр иркенләп утлап йөри икән.* Әкият. *«--- сез иркенләп, тыныч кына йоклагыз», – диде әби, чыгып китәр алдыннан.* Ә.Еники

4) Иркен һәм җайлы итеп, үз уңаена. *Ничек килеп кергән соң ул шома егет Люциянең тормышына, ничек анда шулай иркенләп урнаша алган?* М.Маликова. *Әйдә, иркенләп урнаш, иртәгә, бәлки, бусы да булмас, ачык окопта кунарга туры килер.* Г.Әпсәләмов

◊ **Иркенләп сулыш (тын) алу** *к.* **иркен сулау, иркен сулу (сулыш, тын) алу**. *Аның мине яклап чыгуы минем өчен бик зур җиңеллек булып төште, иркенләп тын алдым.* М.Гафури. --- *бөтен халыкларга тигез яшәү хокукы бирелгәч – менә шул чакта гына без иркенләп тын ала башладык, шуннан соң гына безгә кеше төсле тормыш*

*төзергә, алга барырга киң юл ачылды.* Г.Алпаров

**Иркенләп алу** Бераз, вакытлы, берара, кыска вакытка иркенләү

**Иркенләп җибәрү** Берникадәр, бераз иркенләү

**Иркенләп йөрү** Һәрвакыт, гел иркенләү. *Кояшсыз булса дөнья, мин ул чакта иркенләп йөрер идем төрле якта.* М.Гафури

**Иркенләп калу** Борчып, ирексезләп торган сәбәп беткәннән соң иркенләү. *Ире ни өчен алай: «Эчемне пошырып лыгырдап йөрмә! Мин киткәч иркенләп калырсыз», – диеп әйтте икән?* Ш.Мөхәммәдев. *Өстән кия торган күлмәк вә зинарым янына алып барсагыз, мин, бу калыпларымны салып, иркенләп калыр идем.* Ф.Әмирхан. *Әлеге бөтиле кәләпүшне киеп печтик кенә дә әйләнергә өлгермәдем, син күр дә мин күр, башымның сызлавы бетте дә китте. Үзем дә иркенләп калдым.* С.Җәлал

**Иркенләп килү** Сөйләү моментына эшнең тыгызлыгы кими бару

**Иркенләп китү** Кинәт иркенләү. *Авылны чыккач та, бөтен хатыннар, карчыклар, иркенләп киткән кебек, башларындагы кызыл яулыкларын кулларындагы савытларына салып, үзара сөйләшә башладылар.* М.Галәү. *Рәсүл кода иркенләп китте, чөнки бу билгесезлек аны нык борчый иде.* С.Җәлал. *Мәктәп ишегалдыннан ат чанасы чыгып барганын күргәч, барысы да иркенләп киттеләр.* М.Мәһдиев

**Иркенләп яту** Тулысынча, тәмам иркенәю

**Иркенли башлау** Иркенлек сизелү. *Күзгә күренеп картая, тиресе бәлҗери, көпшәкләнә төшкән шул ук табак бит, шул ук, әмма әле генә аракыда җепшеп, үз абруен белеп иркенли, йомшара башлаган бәрәңге танау, шул ук, әмма алсулыклары уңган калын иреннәр – барысы да мин килгән шатлыктан куана иде.* А.Хәлим

**ИРКЕНЛЕК** *и.* 1) Кысынкылык, тарлык сизелмәгән киң урын; киң, иркен булу. *Ун-унбиш минуттан алар басу читенә чыгып басканнар иде инде. Монда дөньяның иркенлеге аерата нык сизелде.* М.Маликова. *Гыйлфанның кинәт кенә күкрәк куышы иркенәйде, --- кинәт бакча, туган нигез исе бугазга бәреп керде, һәм, дөньяда башкача беркемдә булмаган сыман, иркенлек сизелде.* М.Мәһдиев. *--- йа дөнья, нинди киң, нинди иркен син! Әмма шушы чиксез, нурлы иркенлектә, шушы иркә, назлы, йомшак табигать кочагында мин үземне, нигәдер, бик ялгыз тоям.* Ә.Еники

2) *күч. иск.* Ирек, азатлык, хөрлек, иркенчелек. *Аһ Әминәм! Булмадың ник бер су. Иркенлектә уйнап йөрүче.* Һ.Такташ. *Иң мөһиме: XX гасырда әдипләргә иҗатта иркенлек җуелып, алар тар идеология кысаларына кысрыклап кертелде.* Т.Галиуллин. *--- үз даирәсендә күнеккән киеренкелек, һәр сүз үлчәме, гәүдә тотышына кадәр эчке бер кагыйдәгә буйсынганлыгы монда бөтенләй кирәксез булып калган. Табигый иркенлек.* М.Галиев

3) *күч.* Киңлек. *Бар яктан да сине нидер чолгап алган кебек, шулай ук монда үзенә бер төрле киңлек, иркенлек сизелә. Кырлар, басулар иркенлеге түгел, күңел иркенлеге.* Н.Фәттах

4) *күч.* Рәхәт, җиңел тормыш. *Диңгез буенда ике атна бергә ял иткән чор эчендә иркенлеккә өйрәнгән Эльвираның ирене турсайган иде ---.* М.Маликова

5) *күч.* Муллык; иркенчелек. *Су астында --- азык иркенлеге – чабаклар, сазаннар, корбаннар, кызылканатлар --- һәм ташбашлар.* Ә.Баянов. *Алтышар ай өйдә булмый ул. Кайтып, атна-ун көн тора да, монда миңа иркенлек юк, дип, янә сәфәргә әзерләнә башлый.* Г.Тавлин. *Бер үк әсәрдә без еш кына төгәл тәрҗемә үрнәкләрен дә, --- йөгәннән ычкынган иҗади иркенлекне дә очратабыз.* Казан утлары

**ИРКЕНЧЕЛЕК** *и.* 1) Теләгәнчә эш итәргә мөмкинлек. *Дәресләр дә бакчаларда үтә, рәсем ясау да искиткеч куелган, кул эшләре дә кертелгән, балаларның үзешчән сәнгате өчен дә иркенчелек бар ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) *иск.* Хөррият, ирек, азатлык. *Мөселманнарга да дин җәһәтеннән иркенчелек булыр дип, газеталар язалар.* Ш.Мөхәммәдев. *«Сабыр савытлары» китабында урын алган --- тыгыз эчтәлекле поэмаларында, күңел байлыгын, фикер иркенчелеген эченә алган лирик шигырьләрендә Х.Әюпов --- тормыш киеренкелеген --- төгәл һәм ягымлы итеп ачып сала.* Әдәбият

3) *күч.* Муллык, җитешлек. *Без үскәндә кәстрүл кырые кимерә идек. --- Хәзер барысына да иркенчелек. Ипие дә теләсә кайда аунап ята.* Н.Хәсәнов

**ИРЛАНД** *и. к.* **ирландияле**. *Тел белгече булмаган кешегә рус, хетт, әрмән, прусс, литва, инглиз, албан, көрд, таҗик, ирланд телләре генетик яктан туган телләр дисәң, һич ышанмас.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Бәрәңге – ирландларның иң күп ашала торган ризыгы.* Файдалы киңәшләр. *Итле рагу ирланд халкының милли ризыгы санала һәм бөтен дөньяга атаклы.* Сөембикә

**ИРЛА́НДИЯЛЕ** *и.* 1) Ирландиянең төп халкы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Инглиз теле британлылар теле генә түгел, бәлки, ирландиялеләр, австралиялеләр теле [дә].* В.Хаков

2) Чыгышы белән Ирландиядән булган, шуннан күчеп килгән кеше

**ИРЛӘ́Р РИФМАСЫ** *и. әд.* Шигырьдә басымлы иҗеккә тәмамлана торган рифма. *Татар шигырьләрендә ирләр рифмасы өстенлек алып тора.* А.Сайганов

**ИРЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Ирләр кебек, ирләргә хас булганча. *Вәлиуллина – калын тавышлы, зәңгәр күзлекле, тәмәке тарта торган шадра хатын, ирләрчә сөйләшә.* М.Мәһдиев. *«Әтием, – дип язасың син, – бу хатны үзеңә генә атап җибәрәм. Синең белән ирләрчә күзгә-күз карап сөйләшәсе килә...»* Ф.Яруллин. *Әтисе белән сүз ирләрчәрәк барды.* Н.Әхмәдиев

**ИРЛЕ** *с.* Кияүгә чыккан, ире булган, ирдәге. *Юк, Нинаның да ире бар, ул да бүтәннәр рәтеннән ирле хатынга исәпләнеп йөри.* Ә.Еники. *Ирсез тормыш та шикәр түгел, ирлесе дә бәхет түгел икән.* Ә.Сафиуллин. *Ни гаҗәп, Байтирәктә яшәп, кайнана-кайнатага килен булып хезмәт иткән, инде ерак калган ирле гомерен, --- искә төшерде Нурсөя.* Р.Мулланурова

**ИРЛЕК** *и.* 1) Ир кеше булу. *Тәбриянең өзгәләнүе, бәргәләнүе, тилме-*

*реп каравы Гадилнең ирлек дәрәҗәсен күтәрә, кәефен яхшырта, тормышын ямьли иде.* М.Маликова. *Корбангали карт моны ачык белми һәм килененең карынындагы туасы җан иясе китерәчәк акчаны көтеп ятуны ирлек абруе да «рөхсәт итми» ---.* Ф.Хөсни

2) Ир кеше булу куәте. – *Көн-төн эчүдән башы чыкмаган, булдыксыз, --- бу адәм затының ирлеге дә корыган, күрәсең, – дип фикер йөртте авыл хатыннары, – югыйсә, үзе теләп кияүгә чыккан кеше бер кич куну белән тавышсыз качып китмәс иде.* Я.Зәнкиев. *Ярулла күңелсез генә елмайды да җавап бирде: – Миннән олырак булса да, ул хатынга дәртле ир кирәктер бит инде. Соңгы тапкыр кыйналганнан соң, минем ирлегем юк... Тибеп, изеп... кыйнадылар... җенси җирне...* З.Зәйнуллин. *– Болай булганчы, үләсе калган... Ир-ат өчен ирлеген югалтудан да зур кайгы юк, күрәмсең.* Ә.Галиев

3) *сөйл.* Ир кешенең җенес әгъзасы. *[Кавын башлы татарның] Юлда ике төймәгә чак эләгеп торган чалбарының күселегеннән мылт итеп ирлеге бүлтәеп чыккан.* А.Гыйләҗев. *Ах, «ирлекләрен» түмәргә кадаклап, адәм хуры итәсе иде дә... Вәт булыр иде җәза!..* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Батырлык, кыюлык, егетлек. *Балаларда ирлек, егетлек сыйфатлары тәрбияләү – белем бирү белән бер дәрәҗәдәге бурыч.* М.Мәһдиев. *--- ирлек җирдә ятмый, илле еллар узгач та әйләнеп кайта, каһарман батырлыгы телдән телгә күчеп, исеме ташка яисә китап битләренә языла, легендага әверелә.* М.Хәбибуллин. *Халыкны коткару өчен азыктыр, дарудыр эзләп табып йөргән бу ике солдат никадәр көч, никадәр ирлек күрсәткәннәр.* Э.Касыймов

**ИРЛЕКЛЕ** *с.* Ирлек сыйфатына ия булган. *Ир булу гына җитми, ирекле һәм ирлекле ир булырга кирәк.* Н.Исәнбәт

**ИРЛЕ-ХАТЫНЛЫ** *с.* **1.** Ир белән хатын мөнәсәбәтендәге, парлы. *Бары тик бишенче катта торучы гаилә турында гына сүзләре кыска булды: ирле-хатынлы, ике балалы ул кешеләр кич караңгыда чыгып йөрмиләр, чөнки кечкенә сабыйлары бар икән.* М.Маликова. *--- рәхәтләнеп сөйләшә алмыйсың, әледән-әле кабатлап сорарга туры килә, чөнки янәшәдә тагын ирле-хатынлы бер пар өзгәләнә.* Р.Кәрами. *Бер көнне шулай каршыбызга егет белән кызмы, ирле-хатынлы яшьләрме килә.* М.Әмир

**2.** *рәв. мәгъ.* Ир белән хатын бергә; парлап. *Күпме гомерләр ирле-хатынлы яшәп, моңарчы куйган бөтен тырышлыклары, --- бөтен хыяллары җимерелде дигәндә, ул --- йөккә калдымы?* В.Распутин. *Ирле-хатынлы яшәү кешеләрдә яңа көчләр уята, аларда элек булмаган сыйфатлар барлыкка китерә.* Тигез гомер итегез! *Ирле-хатынлы булып яшәү – ул гаилә өчен җаваплылыкны уртаклашу, төрле характерлы ике кешенең бер тормыш сукмагына басуы.* Юлдаш

**ИРЛЕ́-ХАТЫНЛЫ БУЛУ** *ф.* Өйләнешү, никахлашу. *Лида ирле-хатынлы булырга үтереп кыстый: «Бала булса, миңа шул җиткән», – дип ялына.* Х.Камалов. *Безнең бүлмә кызларының --- берсе бүлмәдә егете белән куна. Ирле-хатынлы булып яшиләр.* Х.Ширмәт

**ИРМӘК** *и. диал.* **1.** Уен, кызык, шаяру; юаныч. *--- бу кадәр битабигый вакыйганы сурәтләү өчен тел ачкычларыбыз җитәр микән? --- Ярый, илаһи ният кыйлдым ирмәккә, сезләргә сөйләп бирмәккә...* А.Хәлим. *Уку һәм язу белән ирмәк табам.* М.Фәйзи

**2.** *с. мәгъ.* Кызыклы, күңелле

**3.** *рәв. мәгъ.* Кызык, күңелле итеп

**ИРМӘКЛӘНҮ** *ф. диал.* Кызык, юаныч табу, юану. *Мин сине күпер төбендә күргәннән соң, йомышка йөртү сылтавы белән яныма ияләштереп, ямең белән ирмәкләндем.* М.Фәйзи

**ИРНӘ́Ү** *и.* **1.** Чүлмәк, чиләк, кисмәк, шешә кебек савытларның авыз тирәсендәге салынып, кайтарылып торган кырые. *Кисмәк ирнәве. Шешә ирнәве. Чүлмәк ирнәве*

**2. ирнәвеннән** *чыг. кил. рәв. мәгъ.* Мөлдерәмә. *Чүлмәк ирнәвеннән тулган*

**ИРНӘҮЛӘ́Ү** *ф.* Ирнәү ясау

**Ирнәүләп бетерү** Ахыргача, тулысынча ирнәүләү

**Ирнәүләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр ирнәүләү

**Ирнәүли башлау** Ирнәүләргә тотыну

**ИРНӘҮЛЕ** *с.* Ирнәве булган

**ИРО́НИК** *с. к.* **ironияле**. *Билгеле, авторның Солтан төзегән яшәү рәвешенә ироник карашы сизелә.* Ә.Закирҗанов. *Шул каршылыкның гаҗәп җиңел чишелүе, хәл ителүе ироник тон бирә.* Д.Заһидуллина. *Биредә ироник мәгънә бөтен бер сүз сөреше аша бирелә.* Х.Курбатов

**ИРО́НИЯ** *и. кит. гр.* 1) Астыртын гына мыскыллап көлү, читләтеп әйтү. *«Гел-гел буйга аркаланып яшәргәме исәп?» Ихлас Сабитның бертуган энесеннән ирония көтмәде, сорауны чынга алды.* А.Гыйләҗев. *«Что ты ржёшь, мой конь ретивый…» – Нәркис бу җөмләне Галәвиевтән кычкырып укытты. Галәвиев, әлбәттә, моның ирониясен аңламады.* М.Мәһдиев. *Көлемсерәп куйды егет. Кыз исә аның соңгы сүзләрендәге ирониянe аңламады.* Р.Мөхәммәдиев

2) *әд.* Берәр кешене яки әйберне мактаган булып, алардан яшертен, нечкәләп, оста итеп көлүдән гыйбарәт стилистик әйләнмә яки сүз. *Мактаган булып мыскыллауның, ягъни иониянең иң көчле үрнәге [Г.Тукайның] «Мөнтәкыйть» («Тәнкыйтьче») шигырендә бирелгән.* Ә.Исхак

**ИРО́НИЯЛЕ** *с.* Ирония белдергән, ирония белән сугарылган. *Хәлимә аның ирониялe төрттерүен бөтенләй ишетмәгәндәй дәвам итте ---.* Т.Әйди. *– Әллә Цепилов айгырына хәер-фатиха бирергәме исәп, әти? – дип, ирониялe сорау куйды Сәфәргали.* Ф.Хөсни

**ИРРАЦИОНАЛИЗМ** *и. лат. филос.* Чынбарлыкны тоеп танып белү генә мөмкин, ул закончалыкларга нигезләнмәгән, һәм шуңа күрә дә аны танып белүгә кеше акылы ирешә алмый, дип раслаган, фәнни логик танып белүне инкяр иткән фәлсәфи юнәлеш. *Модернизм, асылда, ул – антиреализм, эстетлык. Бу юнәлешкә мистика, иррационализм, абсурдлык, алогизм хас.* К.Гыйззәтов

**ИРРАЦИОНАЛЬ** *с. лат.* 1) *филос.* Фәлсәфәдә: логик төшенчә белән әйтеп бирү мөмкин булмаган, акыл ирешә

алмый торган; мистик. *Бездә исламга рациональ һәм иррациональ караш бар.* Р.Сафин. *Алар [дөнья әдәбиятының гүзәл үрнәкләре], XX гасырда популярлык казанган иррациональ карашлардан чыгып, дәүләт һәм чиновниклар йөзендә кешеләрне шәхес буларак юк итүче шайтан башлангычларының гамәлгә ашырылуын күргән язучылар өчен илһам бирделәр.* Бөтендөнья тарихы

2) *мат.* Берәмлек белән үлчәнми, шуңа күрә бөтен һәм вакланмалы сан белән төгәл бирелми торган. *Төгәл алынмый торган тамырлар гына иррациональ саннар булалар, дип чикләнергә ярамый, чөнки тамыр алуны таләп итмәгән иррациональ саннар да бар.* Югары математика нигезләре. *Геометриядә кисемтәләрне чагыштырганда, еш кына иррациональ саннар килеп чыга.* Фән һәм тел

3) *лингв.* Бик кыскартылган. *Иррациональ сузыклар*

**ИРРЕАЛЬ** *с.* 1) Реаль булмаган, чынбарлыкта булмый торган. *Бүген иҗат итүче татар әдипләренең миф тудыруга мөрәҗәгать итүләре, ягъни әсәрләрендә ирреаль дөнья моделен торгызулары ике яклы, ике планда бара.* А.Шәмсутова

2) *лингв.* Үтәлеше реаль хәбәр ителми торган. *--- реаль наклонение барлык башка ирреаль --- наклонениягә каршы куела.* Татар грамматикасы

**ИРРЕГУЛЯР** *с.* 1) *кит.* Бернинди тәртипкә буйсынмый торган. *Иррегуляр сугышларның формалары күптөрле: терроризм, психологик йогынты, тәрбия, дипломатия һәм разведка органнарының дошманга каршы оештырылган гамәлләре һ.б.* Р.Сафин

2) *хәрби* Регуляр булмаган, регуляр армия составына керми торган. *--- Пётр заманында мөнтәзам гаскәр килеп чыккач, әүвәлдәгечә иррегуляр гаскәр ул кадәр күп кирәк түгел иде ---.* Г.Гобәйдуллин

**ИРРИГА́ТОР** *и. рус* 1) *а. х.* Ирригация белгече, сугару белгече

2) *мед.* Организмдагы яраларны, куышлыкларны юдыру приборы

**ИРРИГА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* 1) *а. х.* Коры яки дым аз булган җирләрне арык, каналлар ярдәмендә сугару (мелиорациянең төп төрләреннән берсе). *Ирригация белгече. Ирригация корылмасы*

2) *мед.* Сыеклык сиптереп, яраны, тәндәге куышлыкларны юдыру

**ИРРР** *иярт.* Гөберле бака кычкырганда чыккан нечкә тавышны белдерә. *Яшел гөберле бакалар --- нечкә тавышлы: «Иррр... иррр... иррр...». Шушы калтыраулы тавышлары аларның кавышу җырлары инде.* Г.Хәсәнов

**ИРСӘК** *с. сөйл. шелт.* 1) Ирләрне яратучы, ирләр артыннан йөрүче (хатын-кыз турында). *Ирсәкнең җиде чикмәне булыр, алтысы кешедә булыр.* Әйтем

2) *диал.* Азгын, бозык

**ИРСӘКЛЕК** *и.* Ирсәк булу

**ИРСӘ́Ү** *ф.* Ирләргә чиктән тыш омтылу (хатын-кыз турында)

**ИРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Ире булмаган. *Кая барсаң, нишләсәң дә ир кирәк шул. Ирсез хатынга сан юк инде, юк.* М.Маликова. *--- мондый тормыш тәртибе ирсез хатынга ярыйдыр, дип тынычландыра иде ул үзен ---.* М.Хуҗин. *«Ирсез хатын» исемен күтәрүнең таш йоту белән бер икәнен бик белсә дә, Рәмзия, --- прорабтан китәргә мәҗбүр булды.* Б.Камалов // Гомумән ир заты булмаган. *Ирсез йортта какмаган җир һаман табылып тора*… М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Ирдән башка. *Эш хакы түбән, бригадада тәртип юк: әле кемдер авырып киткән, әле берсе ирсез генә декретка чыккан ---.* Р.Вәлиев. *Әй Аллам! Яшь килеш ирсез калуым гына җитмәгән идеме?* Ә.Сафиуллин. *Ирсез яши торган ханымнарга да тартмаганнар.* Ә.Моталлапов

**ИРСЕЗ-КУШСЫЗ** *с. сөйл.* **1.** Ирсез, ирдән башка, ялгыз. *Ирсез-кушсыз тормыш*

**2.** *рәв. мәгъ.* Ирдән башка. *Ирсез-кушсыз көн итү*

**ИРСЕЗЛЕК** *и.* Ир булмау. *Кешене бетергән тагын бер нәрсә бар: ирсезлеккә буйсынып яшәү.* З.Фәйзи

**ИРСЕТҮ** *ф. диал.* 1) Масайту, кәпрәйтү, узындыру. *Кешене акча ирсетә*

2) Ярсыту. *--- сугыш өрәге белән күзгә-күз очрашу еларга өлгермәгән малайларны да ирсетә.* Казан утлары

**ИРСҮ** *ф. диал.* 1) Масаю, кәпрәю

2) Көйсезләнү

3) Ярсу

**Ирсеп китү** Кинәт, кирәгеннән артык ирсү. *Ирләргә ул сүзне бик әйтергә ярамый, ирсеп китәр. «Сагындым»ны башта ул әйтсен.* Н.Исәнбәт

**Й́Р ТАМЫРЫ** *и. бот.* 1) Ароидчалар семьялыгыннан, ак тамырлы, кылыч сыман озын яфраклары дару ясауга китә торган күпьеллык саз үләне, кылыч үлән, *русчасы:* **аир**

2) *сөйл. к.* **ирлек** (*3 мәгъ.*)

**ИРТӘ** *и.* **1.** 1) Көннең башы, көннең беренче сәгатьләре. *Ни өчендер бик сөям мин җәйге көннең иртәсен.* М.Гафури. *Ахрысы, анда әле таш стена аркылы чиертеп сөйләшү һөнәренә өйрәнеп өлгермәгән берәр яңа кеше утырадыр: иртә, кич, көндез кат-кат шакылдатып карый, җавап юк.* Г.Ибраһимов. *Февраль азагының аяз, җилсез иртәсе иде.* М.Маликова. *Иртә килде, кояш чыкты.* М.Мәһдиев

2) Иртән (гадәттә балалар бакчаларында) үткәрелә торган спектакль, тамаша; *русчасы*: **утренник**. *Шәмсетдиннәрнең кибет хуҗасына фәкыйрь балалар тәрбияләр өчен ясалган балалар иртәсенә ике билет көчләп саттылар.* Г.Исхакый

3) *күч. шигъ.* Берәр нәрсәнең башлангыч чоры, тәүге мәле. *Җыр булып калыр елларга яшьлек иртәсе, Яшьлекнең канат җилпегән Романтикасы.* Ф.Кәрим. *Төне буе Ләйләгөл керфек какмады. Таң атты. Кичә ул балалыгы белән саубуллашты. Бүген кызлык дәверенең беренче иртәсе.* М.Мәһдиев. *--- яшерәсем килми, иртә яшьлегемдә чын күңелдән теләп танышулар, «мин сөям!» дип, үз-үземне ышандырып йөрүләр аз булмады.* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* 1) Башкалардан элек, алда өлгерә торган. *Вакытында шыта алмый калган иртә культуралар өстенә тары чәчүчеләр байтак булган икән.* М.Әмир. *Иртә өлгерешле кәбестә өчен их яхшы элгәр – кыяр, бәрәңге, суган, борчак.* Яшелчәчелек. *Иртә өлгерүче ак башлы һәм чәчәкле кәбестәне --- апрель азагында – май башында ачык грунтка утыртырга мөмкин.* Юлдаш

2) Гадәттәгедән алда, билгеле бер вакыттан элек булган. *Ул елның маенда да күк йөзен атналар буе каплап торган салынкы болытлар вакыты җиткәч таралды, үз нәүбәтендә җәй, аннары иртә кыраулы көз килде.* М.Маликова

3) Вакытыннан алда булган. *Иртә үлем*

4) Иртәнге, иртә беләнге. *Иртә сәгать уннарда, иртә чәйне эчеп, пароход өстенә чыктым.* Ф.Әмирхан. *Бaрактагыларга иртә чәйне, гадәттәгечә, каткан чәйнекләрдән, иске-москкы кружкалар белән эчәргә туры килсә дә, бәйрәм әсәре бөтенләй үк юк түгел иде.* Ш.Камал

5) *а. х.* Сезоннан алда, баласын үстерү өчен уңайсыз булган (кыш башында яки гыйнвар, февраль айларында бала китерергә тиеш булган сыер, сарык һәм кәҗәләр турында). *Үзләренең сыеры, иртә буаз булганлыктан, инде күптән ташласа да, Гайнижамал апа, каяндыр табып, сөтен-каймагын да, мәтрүшкәсен дә --- кайнатып эчертә.* В.Нуруллин

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Иртә белән, иртәнге сәгатьләрдә. *Иртә сәгать бишләрдә уяндым.* Ф.Әмирхан. *Моңарчы спорт белән әллә ни кызыксынмаган, иртәләрен киерелеп-сузылып гәүдәсен язудан узмаган Харис, ул җәйне --- мускулларын ныгыту белән шөгыльләнде.* М.Маликова. *Вахит абзыйлар иртә торып, бит-кул юып, киенеп чәйгә утыргач, шыгырдап капка ачылды да, --- атлар капкадан килеп тә керделәр.* М.Гали

2) Гадәти, билгеләнгән вакытка кадәр; вакытыннан элек. *Күрәм, ишетәм сезнең сызланганны. Сизәм: сездән иртә аерылам.* Ш.Бабич. *Башмакова бүген эштән иртә кайтты.* М.Насыйбуллин. *– Балаларны алып чыгарга ниятем бар да уятырга жәллим. Соң яталар, йокылары туймый торгандыр, – диде Сәнифә. – Бер тәртипкә салгач, үзләре үк иртә ята башларлар, – диде Шәмсениса әби.* Э.Шәрифуллина

3) Алдан, вакытыннан алдарак. *Иртән килгән – урын өчен, соң килгән – тамак өчен.* Әйтем. *Иртәгә гает, дигәндә, кешеләр башка көннәрдәгегә караганда эштән бик күп иртә кайттылар.* Ш.Камал. *Ул елны корылык үзенең аянычлы нәтиҗәләрен бик иртә сиздерә башлады.* М.Әмир

4) Бүгенге артыннан ук килгән көнгә; икенче көнгә. *Иртәдән калмый язарга тотынырга да бик вакыт җитте инде.* Ф.Әмирхан. *Иртәдән калмый кунакларны алырга барырга кирәк булыр.* М.Гали

**4.** *хәб. функ.* Тиешле вакытның килеп җитмәве турында. *Әле вакыт иртә булса да, юлда бетон, измә --- төягән машиналар, --- бульдозерлар күренә башлады.* Р.Кәрами. *Минемчә, безгә философ булырга бик иртә әле, аның өчен безнең авызыбыздан ана сөте кипмәгән.* М.Әмир

◊ **Иртә дә мыштыр, кич тә мыштыр** Эшне бик акрын, озак башкаручы кеше турында. **Иртә исемдә, кич төшемдә** Һәрчак исемдә, бер дә онытмыйм. *Беләзегем Филисә, Арасыннан җил исә; Иртә исемдә, кич төшемдә – Насыйп мәллә, югыйсә.* Җыр. **Иртә кырау төшү (куну)** Чәчләргә яшьтән чал керү. *Нәҗип Корбановның чигә чәчләренә мул булып кунган иртә кырауга күз салды.* Г.Ахунов. **Иртәсен кичкә катып** Иртә таңнан кичке караңгыга кадәр (көн-төн эшләү турында). **Иртә таңнан** Бик иртә, иртән үк. *– Шул кирәк сезгә! – диде теге адәм. – Иртә таңнан парлашып бодай арасында йөрмәссез!* М.Маликова. *Кояш исә күлне үзенең көлтә-көлтә нурларына иртә таңнан кичке эңгергәчә коендыра ---.* К.Миңлебаев. *Фани дөнья белән алышбиреше беткәндәй, Рамазан бабай иртә таңнан бирле карчыгының аягы очында бөкрәеп утыра...* Ә.Еники. **Иртә таңнан кара төнгә кадәр (хәтле, чаклы)** Көнозын, көн буе. *Иртә таңнан кара төнгәчә эштә булган кешене бимазалау, ничектер, уңайсыз бит.* З.Вәли. **Иртә юк, кич юк** Кешеләрне вакытсыз, туктаусыз борчып тору. *Иртә юк, кич юк, киләләр дә керәләр, бер тынычлык калмады.* Н.Исәнбәт

**ИРТӘГӘ** *рәв.* **1.** Бүгенгедән соң килгән көнгә; икенче көнгә. *Иртәгә сабан туе, дигән кичне кем генә тыныч йоклый алды икән!* Г.Бәширов. *Камәретдин иртәгә китәсе көнне алар печәнлектә кундылар.* М.Әмир. *Иртәгә ни буласын белү бары тик пәйгамбәрләргә генә хас сыйфаттыр, ханым.* М.Хәбибуллин

**2.** *и. мәгъ. күч.* Киләчәк. *Тарихыбыз коллыкта... Коткарырга! ---Үткәнебез тоткын икән, иректер – иртәгәбез?* Ф.Габдрәхим

◊ **Иртәгә өчен ишәк кайгырсын** Киләчәк, алдагы көн өчен борчылмау, кайгырмау. *– Иртәгә өчен ишәк кайгырган, – дип сүгенде Иван Мөхәммәтович, кырыс рәвештә. – Иртәгә ситуация үзгәрә.* Х.Камалов. **Иртәгә шулпасын эчерү** Иртәгә дә иртәгә, дип, эшне тартып-сузып, алдап йөрүгә ризасызлык белдереп әйтелә

**ИРТӘГӘ-БЕРСЕКӨНГӘ** *рәв.* Якын арада, якын көннәрдә, тиздән. *«Эш бик тыгыз бит Каюм абзый, – диде ул, – чәчүне бетерергә, водокачканың насосын рәтләп, иртәгә-берсекөнгә ходка җибәрергә кирәк».* Ш.Камал. *Батый хан көлемсерәп: – Баһадир, --- иртәгә-берсекөнгә таран арбалар, грек утын китерүче олау, белгечләр килеп җитәр, шуннан бергәләп уйлашырбыз, – диде.* М.Хәбибуллин

**ИРТӘГӘГЕ** *с.* 1) Бүгенге артыннан килгән, алдагы. *Без бераз сөйләшкәннән соң, иртәгәге газитәгә мәкаләләр әзерлеклеген белгәннән соң --- урыннарга яттык.* Г.Исхакый. *Иртәгәге көнгә аның [Миңлегөлнең] уе ачык һәм әзер булырга тиеш.* А.Гыйләҗев. *Ибраһим Гази, хәйләкәр елмаеп: «Бүгенге шагыйрь – иртәгәге прозаик ул», – ди торган иде.* Ш.Галиев

2) Бүгенге артыннан ук килгән көнге, алдагы көнге. *Әнә Төхфәт кабергә күмелергә иртәгәге көн туганын көтеп ята.* Ш.Камал. *Иртәгәге дәресне караштырасы да бар. Иртәгә – физика.* А.Гыйләҗев. *Иртәгә кабинетыма чакыртып гафу үтендерергә теләгән идем дә, иртәгәге көнгә хәтле ничек түзәсең.* Т.Миңнуллин

◊ **Иртәгәге көн** Якын киләчәк. *Инде кем, Сәйфулла туган, --- иртәгәге көнне кайгыртмаганга күрә дә әнә шулай кырда калды безнең быелгы игеннәр.* Г.Бәширов. *Иртәгәге көн кешеләрен*

*кичәгеләр бүген укыта.* Ш.Галиев. --- *фәкыйрь елларда аның җырлары әнә шулай халык күңеленә якты нур булып иңделәр, мохтаҗлыкларны оныттырдылар, иртәгәге көнгә ышаныч уяттылар.* Р.Хәбибуллина. **Иртәгәге өчен ишәк кайгырсын** *к.* **иртәгә өчен ишәк кайгырсын** (**кайгырткан**). *Миңа бүгенге көнем кадерле. Иртәгәге өчен ишәк кайгырсын.* Г.Бәширов. *Иванушка, сөеклем! --- Кайгырма. Һәммәсе дә үтәр, һәммәсе үзгәрер. Син яшь, син көчле... Иртәгәге көнне ишәк кайгырткан.* Ш.Рәкыйпов

**ИРТӘГӘДӘН** *рәв.* Иртәгәгедән башлап, иртәгәсе көннән. *Вакыт буенча иртә иртәлеген. Әмма, җир кибү сәбәпле, иртәгәдән калу ярамый.* Ш.Камал. *Гыйльман абзый аны яңадан чалгы саплары янына әйдәде: – Менә шулай, Зиннур туган. Иртәгәдән дә калмассыз, борчак чабарга төшәрсез инде.* Г.Галиев. *Иртәгәдән мин һәр килгән кешегә хезмәтче түгел.* М.Юныс

**ИРТӘГӘДӘ́Н СОҢГА** *рәв. диал.* Берсекөнгә. *Кино булмаган көннәрдә мин Таняны беркая җибәрмәдем. --- Усал бианалар кебек, тегене уч төбендә йомарлап тоттым. Ә бүген... иртәгә... иртәгәдән соңга без икәүләп барачакбыз!* Н.Фәттах

**ИРТӘГӘЛЕ-БҮГЕНЛЕ** *рәв.* Я иртәгә, я бүген; тиз арада, шушы көннәрдә. *План эшен иртәгәле-бүгенле тапшырырга кирәк*

**ИРТӘГӘЛЕК** *с.* Иртәгәге көнгә җитәрлек. *Ислам Бакирович, миңа такта җитми, иртәгәлек кенә калды.* Р.Кәрами

**ИРТӘГӘСЕ** *с. к.* **иртәгесе**. *Илһам хан белә иде: иртәгәге һөҗүм бүгенгедән дә хәтәррәк булачак; шул турыда уйлады ул, иртәгәсе турында.* М.Хәбибуллин. *Иртәгәсе хәлләр турында уйламаска тырышып, ир дә баш төртте.* Н.Гыйматдинова. *Иртәгәсе Сабантуйның мәзәкләре, кем әйтмешли, иртәгә булса да, маза-кәҗәләре, гадәттә, бүген булучан.* А.Хәлим

**ИРТӘГӘСЕН** *рәв. к.* **иртәгесен**. *Иртәгәсен көн болытлады, игеннәр өчен бик шифалы, талгын яңгыр ява башлады.* М.Маликова. *Хатыным иртәгәсен бик иртә Фәрдәнәләргә китте һәм бу юлы тиз кайтты.* Г.Галиев. *Ул кичтә иртәгә кадәр төпсез уйда булдым. Иртәгәсен карарсыз булып, янә баягы җиргә барып тордым.* Борынгы татар прозасы

**ИРТӘГӘЧ** *рәв. диал.* Икенче көнне иртә белән. *Иртәгәч шул хәлне көтүчеләр үзләре кайтып әйттеләр.* Г.Толымбай

**ИРТӘГЕ** *с.* **1.** 1) Бүгенге көннән соң киләчәк, алдагы, нәүбәттәге, туачак. --- *тышта Айдарның аты тынычсызлана, ә правление йортында иртәге көнгә наряд алырга дип килгән бригадирлар тирләп утыралар иде.* Ф.Хөсни. *Бәлкейс, мәктәпкә кереп, кәгазьләр арасыннан иртәге көннең расписаниесен күрсәтте.* М.Мәһдиев. *Бир әле кулыңны, тәбрик итәм! Иртәге көннән, дустым, син – укытучы!* Г.Галиев

2) Киләсе, алдагы көндә булачак, иртәгәсе. *Бүгенлек ризыгыгыз булса, иртәге өчен кайгырмагыз ---.* Ш.Мөхәммәдев. *Әйе, Әлфия җиткән кыз инде, иртәге язмышы хакында Садыйк Сираевич үзе уйларга тиеш, һәм хәл иткән сүз дә анык булачак.* З.Хөснияр

3) *иск.* Иртә беләнге. --- *малай килеп чакыргач, иртәге чәйгә коймак ашарга чакыргандыр диеп, хәзрәт, --- ашыгып барган иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Кичке табын иртәгесенә караганда мулрак иде.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Бүгенге көн артыннан киләчәк көн, алдагы көн; киләчәк. *Ә шулай да бүген үтәр-үтмәс, Иртәгене килә күрәсе.* Ш.Маннур

◊ **Иртәге көн** Якын киләчәк. *Бүгенге көн [буржуазия] өчен канәгатьләнерлек булса да, иртәге көн инде аның өчен үлем әзерли.* М.Җәлил. *Иргалиме, Иргали – ул иртәге көнне бүген кайгыртып яши торган кеше.* М.Хәсәнов. *Әйе, барыбызны да иртәге көнгә булган ышаныч яшәтә.* Н.Гариф

**ИРТӘГЕГЕ** *с. сир. к.* **иртәгәге**. *Бу сүзләрне бүгенге яшьләр – иртәгеге картлар кабатлаганда, бүтән буын килгән булыр.* Г.Галиев. --- *гаилә, мәктәп һәм дәүләтнең максатлары уртак: иртәгеге көн кешесен тәрбияләү.* Татар иле

**ИРТӘГЕДӘН** *рәв.* Иртәгесе көннән, иртәге көннән башлап. *Иртәгедән язгы каникул башлана!* М.Мәһдиев. *Я иртәгедән башлап эшкә йөри башлыйсың, я без сиңа, Устав нигезендә, кискен чара күрәбез.* Р.Ишморат. *Тимернең гаепсезлеге турында тиешле документлар тупларга кирәк. Иртәгедән, берсекөннән дә калырга ярамас.* М.Хәсәнов

**ИРТӘГЕДӘ́Н СОҢ** *рәв. диал.* Берсекөнгә, алдагы бер көннән соң

**ИРТӘГЕ́ ИМӘЗӘ** *и. иск. гади с.* Күренер-күренмәс кенә булып, офык чите агарып яктылык сизелә башлаган вакыт, чак кына таң сызылып килә башлаган вакыт; шайтан таңы, ялган таң

**ИРТӘГЕСЕ** *с.* 1) Бүгенге көн артыннан киләчәк, алдагы, туачак. *Сабир өчен иртәгесе көнне җиткерү авыр.* А.Алиш. *Ташкент поезды белән иртәнге сәгать алтыда үтәбез, дигән Таһиры. Иртәгесе числоны куйган.* М.Галиев

2) Иртә беләнге. *Өебез мәчеткә якын булганга, безгә азанның иртәгесе дә, төшкесе дә, кичкесе дә ишетелеп тора иде.* М.Әмир

**ИРТӘГЕСЕН** *рәв.* **1.** Берәр хәл, вакыйганың икенче көнендә, бер көн узгач. *Иртәгесен миңа Карамалыга кайтып китәргә кирәк иде.* М.Әмир. *Иртәгесен кояш чыгар-чыкмас уяттылар.* М.Гафури. *Ә бу хыял – иртәгесен Чын тормышына әйләнер: Зур Иделнең дулкыннары Итәгендә тирбәлер.* Ш.Маннур

**2.** *и. мәгъ.* Бүгенге көннән соң киләчәк, туачак көн; алдагы чираттагы көн. *Хәлим гармонен сузып җибәрде. Иртәгесен дә сузды. Аның иртәгесен дә...* Г.Гобәй

**ИРТӘДӘГЕ** *с. диал.* Алдагы көндә булачак, иртәгесе. *Әүвәле иртәдәге лекцияләргә әзерләндем: укыдым, конспектлар яздым.* И.Салахов

**ИРТӘДӘН** *рәв.* Иртәнге сәгатьләрдән, иртә беләннән (башлап). *Күк йөзендә кояш иртәдән бирле әйтерсең лә кунакка дәшә иде.* В.Имамов. *Иртәдән бирле карлыгачлар да түбән очалар.* Т.Гыйззәт. *Иртәдән бирле кызык карап йөргән без малайларга да ничектер дөньяның яме бетеп, аны хәвеф,*

*шом каплап алгандай булып калды.* В.Нуруллин

◊ **Иртәдән башлап караңгыга (кичкә) кадәр**; **иртәдән башлап кичке караңгыга кадәр** *к.* **иртәдән кичкә кадәр**. **Иртәдән кичкә кадәр (кадәрле, хәтле, чаклы)** Көнозын, көн буе. *Колхозның тимерчелегендә, амбарларында, ат абзарларында, бригадаларның хуҗалык лапасларында иртәдән кичкә кадәр халык кайнаша ---.* Ә.Еники. *Дачада иртәдән кичкә хәтле тышта йөртермен.* Ш.Янбаев. *Иртәдән кичкә чаклы җиңнәре сызганулы.* М.Әмирханов. **Иртәдән кичкәчә** *к.* **иртәдән кичкә кадәр (хәтле, чаклы)**. *Иртәдән кичкәчә шулар [укучылар] белән әвәрә булабыз.* М.Маликова

**ИРТӘДӘ́Н СОҢ** *рәв.* Берсекөнгә. *Мин ике генә көнгә кайттым. Иртәдән соң китәм...* Г.Ибраһимов

**ИРТӘК** *и. бор.* Әкият. *Бер патша бар иде. Туркан иртәкләрендә аты Зитун дирләр.* Дастан. *Әбием иртәкләре*

**ИРТӘ-КИЧ** *рәв.* 1) Иртә дә, кич тә; иртән һәм кичен. *Куна-төнә, отыры салкыная барган су өстеннән, иртә-кич тагын да куера төшкән томан эченнән, --- озын юл үткәч, баржа сулга борыла башлады...* Р.Кәрами. *Үзе, гадәтенчә, өстәлемә иртә-кич бер стакан кәҗә сөте куя.* Н.Хәсәнов. *Көн саен иртә-кич менә шушы рецепт белән алган даруны тамызырсыз.* А.Тимергалин

2) Иртән дә, кич тә, һәрвакыт, бертуктаусыз. *Ике өй картлары иртә-кич Зиннурны көтте.* Я.Зәнкиев. *--- иртә-кич, өзелмичә, шау-гөр килгән авыл җыенныннан дулкынланып кайткач, Батырҗан бишегенә иелеп сөйләнә торган иде.* Ә.Еники. *Солтанның һәр мизгелдә Хак Тәгаләгә үтенече бар иде: иртә-кич Тәңредән сорар, бер бала өмет итәр иде.* Борынгы татар прозасы

3) Көнозын, көне буе. *Иртә-кич кабинетыннан чыкмыйча, ул райкомның агымдагы эшләре белән шөгыльләнде.* Ә.Еники

**ИРТӘ-КИЧЕН** *рәв. к.* **иртә-кич**. *Иртә-кичен халык арасында булса да, Хәйрүш үзен ялгыз хис итте.* М.Хәсәнов. *Кайтасымны әйтеп хат язганыма атна узган иде инде. Әнием, мөгаен, көн саен иртә-кичен тегермән кашына менеп күзәтә булыр.* З.Вәли. *Иртә-кичен, баш өсте дип, койрык болгап торды, Түбән карап, сыртын ялап, мактау уйлап торды.* Г.Афзал

**ИРТӘКЧЕ** *и. бор.* Әкият сөйләүче кеше. *Иртәкче бабай*

**ИРТӘЛӘЙ** *рәв. диал.* Вакытыннан элек, билгеләнгән вакытка кадәр, иртә. *Күкрәк киң, беләкләр таза, муен нык, диңгездә үскәне, бик иртәләй ишкәк ишә башлаганы әллә каян күренеп тора.* Н.Фәттах. *Йөрәк чире әнине бик иртәләй гүргә алып киткән.* Э.Касыймов

**ИРТӘЛӘРЕН** *рәв.* Һәр көн иртә белән, һәр көн иртән диярлек. *Наҗия иртәләрен башы авыртып уяна.* Р.Хафизова. *--- яшьтән үк «йокы чүлмәге» идем лә мин. Иртәләрен, аеруча печән өстендә, урак вакытында уята алмый гаҗиз булалар иде.* З.Вәли. *[Рәшидә] Иртәләрен сәгать алтыда радионың һәр сүзен йотылып тыңлый.* М.Маликова

**ИРТӘЛӘРЕН-КИЧЛӘРЕН** *рәв. сир. к.* **иртә-кич**. *Чишмәгә суга барганда да, инеш болынына каз-үрдәк куа төшкәндә дә, --- иртәләрен-кичләрен менә шушы урам чатларында гел очраша иделәр.* Н.Хәсәнов

**ИРТӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Иртән иртүк берәр кая кузгалу (килү, бару һ.б.ш.). *Бераздан картның көр тавыш белән: «О-о, иртәләгән сез бүген», – дип, кемнәрнедер каршы алганы ишетелде.* М.Хәсәнов. *[Илгиз Хәбриев] --- туктады, башын ия төшеп исәнләште. – Иртәләгәнсез, – диде.* М.Маликова. *Ә, хөрмәтле Тата! Әйдә, түргә уз. Нишләп әле иртәләдең болай?* Ә.Баян

2) Берәр эшне вакытыннан алда эшләү. *Таз тау итәгендәге кырда ике трактор кар тота. «Иртәләгәннәр егетләр бүген», – дип уйлады Талип.* М.Хәбибуллин. *Берсекөнгә дә шулай соң килермен. Кара аны, бик иртәли күрмә, беркем сизенерлек булмасын.* В.Распутин

3) Нинди дә булса берәр эш яки хәл-вакыйга көтелмәгәндә булу. *Бик иртәләде дустыбыз, егермесе тулартулмас дөнья куйды.* Р.Хафизова. *Калай түбәгә дәү алмагачтан тып-тып алма коела иде. – Көз иртәләде, – диде Җәүһәр һәм сабыр гына тәрәзәне япты.* Ф.Җамалетдинова. *Иртәләде кары белән ак Кыш, Ел фасылын бозып.* С.Гәрәева

**ИРТӘЛЕК** *и.* Иртә булу. *Былтыр Габдулла русча укырга йөрүне үзе сораган иде. «Сиңа иртәрәк әле!» – дип, аның соравын кире кактылар. Иртәлектә түгел иде хикмәт.* Ә.Фәйзи

**ИРТӘЛЕ-КИЧЛЕ** *рәв. к.* **иртә-кич**. *– Менә, – диде ул, – иртәле-кичле салкыннарда кияр өчен, җылы әйберләрем юк.* Г.Ибраһимов. *Карусыз, тырыш иде малайлары, сөт машинасында иртәле-кичле район үзәгенә, кырык чакрым пычрак, ләм ярып, сөт ташыды.* Р.Мулланурова. *Сиринә иртәле-кичле аның янында булды.* Л.Гыймадиева

**ИРТӘМЕ-СОҢМЫ** *рәв.* Киләчәктә, кайчан да булса бер (һичшиксез булачагы турында). *Шуның өстенә хәвефле бер караш соңгы вакытларда үзен ачык сиздерә башлады: янәсе, татар теленең киләчәге юк, иртәмесоңмы ул йотылырга тиеш...* Ә.Еники. *Мөбаракша – Галия апаның беренче һәм соңгы мәхәббәте, Сәрия аларның берденбер җимеше иде. Шуңа күрә ул Мөбаракша иртәме-соңмы үзенә кайтыр дип өметләнә, көтә иде.* С.Зартдинов. *Яшерен мәхәббәт озак билгесез булып кала алмый, иртәме-соңмы барыбер беленә ул.* Ф.Яхин

**ИРТӘН** *рәв.* **1.** 1) Иртә белән, иртәнге вакытта. *Икенче көн иртән сәгать уннарда Әхмәт һәм Фәтхулла хәзрәт университетка килделәр һәм бер аудиториягә керделәр.* Ф.Әмирхан. *Иртән Гали абзыйның ак рәшәткәле йорты алдына җигүле ат килеп туктады.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин иртәгә иртән, хатыныгыз эшкә киткәнче, шалтыратып әйтергә кирәк булыр.* В.Нуруллин

2) *сир.* Икенче көнне, иртәгәсе көнне, алдагы көндә, иртәгә. *Бүген бездә баш күтәрсә, иртән – сездә, Һәр җирдә дә кузгалыр, калмас көзгә.* Ә.Камал

**2.** *и. мәгъ.* Тәүлекнең бер өлеше, көннең башы. *Сәрвәр туташ! Алсу йөзең, күзең күркәм, Тудыңмы әллә алсу нурлы җәйге иртән?* Ш.Бабич

**ИРТӘ́ НАМАЗ** *и. дини* Таң яктылыгы җәелгәннән башлап, кояш чыга

башлаганчы укыла торган намаз; биш вакыт намазның беренчесе. *Иртә белән Шакир мөәззин иртә намазга керде.* Г.Исхакый. *Әнкәй, җиңнәрен сызганып, иртә намазына тәһарәт алып йөри.* Г.Ибраһимов. *Бервакыт уяндым: өй хуҗасының бер озынайтып, бер кыскартып, моңлы гына мәкам белән иртә намазы укыганлыгы ишетелеп тора.* Ш.Камал

**ИРТӘНГӘ** *рәв. сир. к.* **иртәгә** (*1 мәгъ.*). *Иртәнгә таң атканда кем кайда булыр, кем кырылып бетәр, кем җиңәр?* Г.Бәширов. *Ә Сафуан абый (аның исемен иртәнгә бөтен оч белеп өлгергән иде) ак күлмәктән, иңенә --- күн пинжәк салган.* М.Галиев. *Ул үзебезнең Фәйзигә эшен тапшырды да, икенче көнне иртәнгә авылдан әзләре суынган иде инде.* Х.Сарьян

**ИРТӘНГӘ́ЧӘ** *рәв.* Иртәнгә кадәр. *Егетләр чыгып, белеп керделәр: кайдадыр кабель өзелгән, ут иртәнгәчә булмаячак, имеш.* М.Маликова. *Сүз иярә сүз чыгып, шактый гомерләр узгач кына, инде батыраеп алгач, иртәнгәчә бозау һәм сарыкларын көтүләп ашатасы иттеләр.* Ф.Яхин. *Апа аңа бармак яный: – Түз инде, – ди, – иртәнгәчә.* Г.Юнысова

**ИРТӘНГЕ** *с.* 1) Иртә беләнге. *Әнә сырма өстеннән ак халат кигән өч хатын киң авызлы, өсте ябык чиләкләрдә иртәнге сөтләрен ферма өенә китерәләр.* Ә.Еники. *Шул шомлы төндә, иртәнге өчләр тирәсендә, Нигъмәтләр өе ишегенә шакыйлар.* И.Салахов. *Иртәнге сәгатьләр генә булса да, кояш инде шәп кенә кыздыра иде.* З.Вәли

2) Иртә белән, иртән була торган. *Иртәнге салкын һәм дымсулык, мөгаен, кичәге яңгырның сулышы гынадыр.* И.Салахов. *Зәңгәр күктә йолдызлар җемелди. Идел ягыннан искән талгын җил Казан урамнарына иртәнге салкынлык тарата.* М.Насыйбуллин. *Иртәнге ашны бик соң бирделәр.* Шәһри Казан

3) Иртән эшләнә, иртән оештырыла, иртән чыга, иртән була торган. *Малайның: «Иртәнге газета --- яңа хәбәрләр --- Рейхстагны яндыручылар тотылды», – дигән сүзләре Урал тавышына кушылып югала.* А.Алиш. *Хәрби госпитальдә врачларның иртәнге обход вакыты иде.* А.Шамов. *Профессор һәр чәршәмбе көнне иртәнге рапорттан соң ярты сәгатьлек әңгәмә үткәрә иде.* М.Маликова

4) *сир. к.* **иртәгеге**. *Аерым хуҗалык булып яшәгән чактагы өзлексез борчылулары, үзенең дә теңкәсенә тиеп беткән икеләнүләре, йоклаган чагында да җанны тындырмый торган, иртәнге көнгә булган ышанычсызлыгы бөтенләй юкка чыга.* Г.Әпсәләмов. *Иртәнге көнне, иртәнге чәйдән соң, Рәхмәй абыйсы --- бәләкәй атта ишегалдына кызу гына юырттырып килеп керде.* Ә.Еники. *Иртәнге көн дә безнеке ич.* Казан утлары

**ИРТӘНГЕ́ АШ** *и.* 1) Иртә беләнге ашау-эчү. *--- иртәнге аштан соң, онлы капчыгымны алып һәм барысы өчен дә рәхмәт әйтеп, Пүчинкәгә кайтырга кузгалгач, хуҗабикә мине туктатты ---.* С.Сабиров. *Җиңги мичкә яга, иртәнге аш әзерли торган арада, мин юырттырып кына су алып кайтам ---.* В.Нуруллин. *Ә иртәнге ашы бутерброд, каһвәдән торган кешеләр бик тиз кызып китүчән булалар.* Сәламәт булыйк!

2) Иртә белән ашар өчен әзерләнгән ашамлык, азык

**ИРТӘНГЕ́ КАВЫМ** *и. к.* **иртәнге күлем**

**ИРТӘНГЕ́ КҮЛЕМ** *и.* Иртәнге аштан төшке ашка кадәр булган вакыт

**ИРТӘНГЕЛЕК** *и. диал. к.* **иртәнге аш**. *Тиз генә иртәнгелекне капкалап алу*

**ИРТӘНГЕ́ НАМАЗ** *и. к.* **иртә намаз**. *--- көя тишкәләп бетергән михраб келәмендә, иртәнге намазга картлар җыелганны көтеп утыручы ап-ак сакаллы Заһидулла хәзрәт бүген мәчет капкасы төбендә басып тора --- иде.* К.Нәҗми. *Иртәнге намазга азан әйтергә баручы Мотыйгулла мәзин, Мостафа картның үле гәүдәсен күреп, барлык авылны аякка бастырды.* Г.Минский. *--- таң аткач, Алла боерса, тагын да парлап иртәнге намазны укырбыз ---.* С.Поварисов

**ИРТӘНГЕ́ЧӘ** *рәв.* Иртәнге кебек. *Ул иртәнгечә үзенең бөтен тарихын сөйләп бирде.* Г.Ибраһимов

**ИРТӘНГЕ́ ЯК** *рәв.* Иртәдән башлап төшкә кадәрле вакыт аралыгы. *Иртәнге якта бераз салкынча кебек тоелса да, көндез тагы кыздыра башлады ---.* Ф.Бәйрәмова. *Ә иртәнге якта Роберт яшькелт күзле Томочка Солохоны озата китте дә... үзен милиционер китерде.* Р.Мирхәйдәров. *Иртәнге якта фермага барып йөрмәсен.* Г.Насрый

**ИРТӘН-КИЧЕН** *рәв. к.* **иртә-кич**. *Суык иртән-кичен.* Ш.Маннур

**ИРТӘННӘН** *рәв. диал. к.* **иртәдән**. *Баламның инде иртәннән бирле җаны юк.* Ф.Яхин. *Ул иртәннән бирле табигать белән хушлашып йөрде.* С.Поварисов. *Рәзиләнең иртәннән бирле бер сәбәпсезгә йөрәге сикерде ---.* Нурзилә. *Иртәннән үк елак яңгыр башланды.* А.Әхмәтгалиева

**ИРТӘНЧӘК** *рәв. диал.* Көн башланганнан соң, бераз вакыт эчендә; иртә белән, иртән. *Аннары Гаффаров абый --- өч сугыш чукмарына күзләрен күчерде. – Я егетләр, алайса, инде сезне тыңлап карыйк: ничек аңлатабыз бүген иртәнчәк купкан җәнҗалны?* Ф.Хөсни. *Иртәнчәк Диләрә ханым палубада кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкән-көлешкән тавышларыннан уянып китте.* Ә.Еники. *Иртәнчәк алдавычы һава тын тора, караганник яфракларында чык җемелди.* А.Гыйләҗев

**ИРТӘ́ ПАР** *и. а. х.* Яздан сөреп, көзгә кадәр берни дә чәчелмәгән җир. *[Алар] иртә парларын сөрергә, печәнгә чыгарга эшче көчләре сорап миңа килгәннәр иде.* Т.Гыйззәт

**ИРТӘСЕ** *с. сир.* Иртәгәсе, алдагы. *Иртәсе көн якшәмбе иде. Иртәсе көн Әхмәт Дунаевны бөтенләй очрата алмады.* Ш.Камал

**ИРТӘСЕН** *рәв.* 1) Икенче көнне, иртәгәсен, бер көн узгач. *Ә иртәсен инде урам тулып, Үткәрдек без бәйрәм парадын.* Ш.Маннур

2) Иртә белән, иртән. *Кыйналган кичнең иртәсендә, башкалар турында хәбәр сөйләр дип, безнең Галиләр Гыйлаҗины арбага салганнар да монда җибәргәннәр.* Г.Ибраһимов. *Яшәгән саен яшисе килә, һәр кичнең иртәсен, һәр төннең таңын күргән саен күрәсе килә, ди, алар илендә.* А.Алиш. *Сәрия апа-*

*сының чат токмач ашларын иртәсен дә, кичен дә берәр чуен шупырып, апаларының прәннек-печеньеләре белән генә сыйланып, Чатан берәр айдан танымаслык булып матурайды.* Ә.Хәсәнов

**ИРТӘСЕН-КИЧЕН** *рәв.* Иртә дә, кич тә, иртән һәм кичен. *Инде кияү буласы кеше Зиннәт шикелле бик бетәшеп кайтса, иртәсен-кичен җылы сөт эчерәсе булыр дип әйтеп, --- бер кәҗә дә алдылар.* Г.Бәширов. *Үзем дә сизәм инде: баланы теләсә кемгә ташлап, иртәсен-кичен өйдән чыгып китүләре бик читен...* М.Маликова. *Алар, көлешә-көлешә сөйләшеп, урамнан атлыйлар, йөзләрендә – канәгатьлек билгесе, алар иртәсен-кичен дә, бүген-иртәгә дә гел бергә.* Ф.Садриев

**ИРТӘСЕНҮ** *ф.* Берәр нәрсә эшләү вакытын бик иртә дип санау, эшне башлау өчен вакыт җитмәгән, дип уйлау

**ИРТӘЧЕЛ** *с.* 1) Иртә торуны гадәт итеп алган, иртә торучан. *Кызларымның сиңа охшап иртәчел булуларына, йоклап ятмауларына шатланам.* Э.Шәфигуллина

2) Эшне вакытыннан элек үти торган, артык ашыгучан. *Иртәчел безнең кешеләр, бөтен хикмәт тә шунда! Көзге чәчүне иртә чәчтек. Туңга сөрүне беренчеләрдән бетердек.* С.Рафиков

**ИРТӘЧЕЛЕК** *и.* Иртәчел булу, иртәчел булу сыйфаты. *Иртәчеллек – уңай сыйфат*

**ИРТӘ́ ЯЗ** *и. иск.* Апрель ае. *Иртә яздан шушы көнгә хәтле Рәшит эштән кайтып кермәде.* С.Зыялы. *Елгачылар --- иртә яздан кышка кергәнче су өстендә алар.* Р.Мөхәммәдиев

**ИРТЛӘЧ-ИРТЛӘЧ** *с. диал.* Вак-вак чокырчыклы. *Ул хатынның үз кызы иртләч-иртләч шадралы, ямьсез булганлыктан, ул үги кызының матурлыгыннан янып-көеп көнләшә икән.* Ф.Әмирхан

**ИРТҮК** *рәв. сөйл.* Иртән үк, бик иртә. *Бүген иртүк Виктор Нателланың күршеләре белән сөйләште.* М.Маликова. --- *мондый кызу урак өстендә Заһидулла агай иртүк басуда булуны үзе өчен беркайчан да бозылмый торган закон итеп алган иде.* Г.Галиев. *Без иртүк торабыз да атларыбыз янына --- тау битләренә юл тотабыз.* М.Әмир

**ИР-УЛАК** *җый. и. к.* **ирләр** (*1 мәгъ.*). *Кызым буй җитте инде, ир-улакка карана башлаган чагы, ул-бу булмагае дип исенә кертеп чыгармый.* К.Нәҗми. *Ирен өйләндергән кыз-хатынны беренче очратуым, бәрәкалла. Хаталанмыйсыңмы, кызым? Икегезне дә тиң күрерме ул ир-улак?* Н.Гыйматдинова

**ИРҮ** I *ярд. ф. бор. кит.* Булу. *Балшикәр тик датлу ирер сүзләрең.* Г.Кандалый

**ИРҮ** II *и. бор.* Ял итү өчен туктаlыш; *русчасы:* **привал**

**ИРҮЛЕ** *с. бор.* **1.** Ял итәр өчен туктаган

**2.** *и. мәгъ.* Ял итәр өчен туктаган кеше. *Ирүлегә – карулы.* Мәкаль

**ИР-ХАТЫН** *җый. и.* 1) Ир белән хатын. *Шул көннән алар ир-хатын кебек тора башладылар.* Г.Ибраһимов. *Бөек Ватан сугышы афәтләре нәтиҗәсендә җәфаланган, ялгыз калган карт-карчыклар, ир-хатыннар, ятим балалар, олыгайган, --- кызлар образлары күбәйде ---.* А.Әхмәдуллин

2) **ире-хатыны** *тарт. форм.* Ирләр дә, хатыннар да. *Бик сусаганнар булса кирәк, авылның бөтен халкы диярлек: ире-хатыны, карты-карчыгы, егет-җиләне, баласы-чагасы – һәммәсе Гыйрфан байның йорты эченә тулган иде.* Г.Ибраһимов

**ИР-ХАТЫ́Н БУЛУ** *ф. к.* **ирле-хатынлы булу**. *Ир-хатын булып торуларына өченче елында Садыйк тагын эшсез калды.* Г.Ибраһимов

**И́Р ЧЫРАЙЛЫ** *с.* Йөзе, кыяфәте ирләргә охшаган (гадәттә, хатыннар яки яшүсмерләр турында)

**ИР-ШАҺБАЗ** *и. иск. кит.* Батыр, кыю егет; ир-егет. *Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы, Назы белән яулап ала ир-шаһбазны.* Ш.Бабич

**ИС** I *и.* 1) Җисемнәрнең, әйберләрнең борын белән тоеп, белеп була торган үзенчәлекле сыйфаты. *Эчтә җылы гына түгел, шулпа исе, кызган май исләре дә җанга рәхәт бирә иде. Акча түләп иснәрлек тәмле исләр!..* М.Әмир. *Ә тышның салкын һавасы әчкелтем татлы һәм исерткеч куәтле икән. Яз исе, яз тәме иде бу.* М.Маликова. *Сәхия әнисен сагынган чакларда шушы сандыкны ача, сабын исләре аңа әнкәсенең исе булып тоела.* Ф.Яруллин

2) Углерод янып бетмәү сәбәпле чыккан агулы сөрем газы. --- *кичтән мич яккан булганнарие дә --- морҗаны иртәрәк томалаганнар, башка ис тиде.* Ф.Хөсни. *Мунча эче әле коры ---. Ләкин сизәм: нәрсәдер күңелгә ошамый. Ахрысы, ис бардыр, дигән уй килде башыма.* М.Әмир

3) *күч.* Берәр нәрсәнең булу ишарәсе, башлангыч билгесе, галәмәте, әсәре; алдан белгертә, сиздертә торган күренеше. *[Сәгыйдә абыстай] Беренче мәртәбә шул урыннан үгилек исе тойды.* Г.Исхакый. *[Ул] Теләсәгез ни әйтегез, җәмәгать, милләтчелек исен сизәм мин бу шигырьдән, кебек сүзләрне ычкындыра башлагач, аптырап, Шәрәфкә карадым.* Л.Ихсанова

4) *күч. сөйл.* Берәр нәрсәнең якын арада булу ихтималы билгесе. *Хөкем исе аңкый*

◊ **Исе дә калмау** Кем яки нәрсә дә булса бөтенләй бетү, юкка чыгу; эзе дә, әсәре дә калмау. --- *бу Сабирда Җәләлнең көткәне, булачак мөдәррисенең исе дә калмаган иде.* Г.Ибраһимов. *Хатын --- буылып кычкыра башлады. Шул арада яшь мәгъшуканы ай күрде, кояш алды. Минут эчендә исе дә калмады.* Х.Камалов. **Исе дә чыкмасын** Ул хакта беркем дә белмәскә тиешлеге турында. *Карагыз аны, курортта ничек бергә очрашкан булуыбызның исе дә чыкмасын.* Н.Исәнбәт. **Исе дә чыкмау** Бөтенләй булмау, күренмәү, ишетелмәү. *Алтыннарның эзенә төшәргә никадәр генә тырышып карамадык, ни аланда, ни яланда, дигәндәй, һич исе дә чыкмый!.. Я ул нәрсәләр монда бөтенләй килмәгәннәр, яисә шундый оста итеп яшерелгәннәр.* Ш.Камал. **Исе дә юк** *к.* **исе дә калмау**. *[Мисбах] Туры сарайга килде, әмма монда да тайларның исе дә юк иде.* Х.Камалов. **Исе килү** Берәр нәрсәнең билгеләре сизелү. *– Нәгыйм, – диде ул, – аның бу сүзләреннән безнең иптәшләр арасына дошманлык орлыгы салырга теләү исе килә.* Ш.Камал. **Исен иснәп кенә**

**калу** Нәрсәгә дә булса өметләнеп торганда, аннан бөтенләй өлешсез калу. **Исен (дә) иснәтмәү** Барлыгын да белгертмәү, бөтенләй күрсәтмәү. – *Сез хәлнең тышкы ягын гына күрәсез шул! – дип, үпкәләгән тавыш белән Вил каршы төште. – Хәлнең эчке ягы да бар. Кечкенә бер шишка-мишкага ярамасаң, ул сиңа запчастьнең, ашламаның исен дә иснәтми.* Х.Камалов. **Исен иснәү** Берәр нәрсә белән өлешчә, беркадәр таныш, аннан хәбәрдар булу. *Без бит әле, Аллага шөкер, аз булса да мәдрәсә исен, гыйлем исен иснәгән кеше.* Н.Исәнбәт. **Исе чыкты** Гаеп эше беленү, кешегә сизелү турында

**ИС** II *и.* 1) Элек булган истәлекләрне, тәэсирләрне, баштан узганнарны аңда саклау һәм яңарту сәләте; хәтер. *Минем кечкенә чагымда Иске Абзанда булганым бар иде. Мин аны белмим, хәтерләмим, тик зур кара тараканнан куркып елавым гына истә калган.* Ә.Еники. *Исегездә микән, иптәш директор, моннан өч ел элек сезне минем бүлеккә фәнни хезмәткәр итеп куйганнар иде.* Ф.Яруллин. – *Хәтерегездәме, Рахман Галимович, өченче класста укыганда, миннән, тавык алдан барлыкка килгәнме, әллә йомыркамы, дип сораган идегез? – Исемдә, исемдә, Рәхилә апа.* Н.Әхмәдиев

2) **исемдә** *тарт. форм. у.-в. кил.* Ядәч аерганда: уенда катнашучыларның берсе икенчесенең кулыннан әйберне алганда, уенны онытмавын белдереп әйтелә торган сүз. *Әйе, ханым отарга ашыкмады, ләкин егет берәр әйбер сузган саен, ул, сөйкемле елмаеп кына: «Исемдә!» – дип әйтергә дә онытмады.* Ә.Еники

3) *диал.* Акыл, зиһен, аң. *Картның әле бер-ике ел яшәренә өмет бар: йомышына үзе йөри, исе дөрес.* Н.Исәнбәт. *Бичараның үләр вакытына кадәре исе дөрес булган ---.* М.Гафури

◊ **Ис аву** 1) Һуштан язу, аң югалту, һуш китү. *Исем авып китте.* Х.Сарьян. *--- күкертле водород күбрәк булса, аңны җуярга мөмкин, плеврит, көзән җыеру, ис аву кебек авыруларга китерә.* Р.Мостафин; 2) Кемгә яки нәрсәдә булса бик нык соклануны белдергәндә әйтелә. **Ис алу** 1) Һушка килү, аңга килү, зиһен җыю. *Бер сүз әйтә алмыйча, миңа текәлеп калды. Ис алырга мөмкинлек бирергә кирәкми иде. «Мөмкинлек биргәндә танып кал: син үтердеңме?» – дидем мин.* Х.Сарьян. *Мөгаен, Денис Иванович та бераз каушаган булгандыр. Менә бит бераз ис алгач кузгалды, торып басты.* Ә.Баян; 2) Һуштан яздыру, аңны югалттыру. *Ул кычкыра башлаган иде, Таһир аның башына сугып исен алды.* М.Әмир; 3) *к.* **ис җибәрү**. *Әле дөньяны яңа гына таный, аңлый башлаган Рузалиянең шундый тирән уйлар, шигъри хисләр эчендә бәргәләнүе Әнсарның исен алды.* Х.Ибраһим; 4) *диал.* Физик зәгыйфьлектән яки матди кысынкылыктан соң хәл яхшыга үзгәрү; берәр төрле киеренке хәлдән соң тынычлану. *Мал-туар бер атна арасында ис алды, хәтта сөт тә артты.* Б.Камалов; 5) *диал.* Тәҗрибә туплау, чынбарлыкны тирән аңлау. **Исе дә китми** Уйлап та карамый, бернинди әһәмият бирми. *Сөһәйлнең исе дә китмәде: – Йа Илаһи, амин! – дип, дога япты да шуның белән бетте.* Ф.Яхин. **Исемә дә кереп чыкмый** Уйлап та карамыйм, бар дип тә белмим. **Исемә дә керми** *к.* **исемә дә кереп чыкмый**. *Сөям сине, сөям сине, белмисең; Әллә яратып сөйгәнгә, Исемә дә кермисең.* Җыр. **Исемә ике кереп бер чыгасың** *к.* **исемә дә кереп чыкмый**; **исемә дә керми**. **Исем китте (бик)** Илтифат та итмим, игътибарга алмыйм. *Исем китте, ди, язмагаең!* К.Нәҗми. *–Уф! – дип куйды Фәрит. – Бу чаклы көнчедер дип уйламый идем. – Ха! Көнләште, ди, бик исем китте ---.* Ф.Яруллин. **Исенә дә кереп чыкмый**; **исенә дә керми** Уйлап та карамый, бар дип тә белми. **Исенә дә кертеп карамау** *к.* **исенә дә кереп чыкмый**, **исенә дә керми** *Нәрсә уйлый икән Зитта минем турында? Әллә исенә дә кертеп карамыймы?* Х.Камалов. **Исенә төшкәч, исе киткән** 1) Гамьсез, ваемсыз кешегә карата әйтелә. *Исләремә төшсә, исем китә, Исемә керсә, башым әйләнә.* Г.Тукай. *Ялан җирләрдә генә үсә ай кушкаен, Яфраклары ла җилгә бәйләнә. Исләремә төшсә, исем китә, Төшләремдә башым әйләнә.* Җыр; 2) Ишеткәнен, күргәнен соңарып аңлаган кешегә карата әйтелә. *Безнең абыйның шулай исенә төшсә, исе китә торган гадәте бар.* Ф.Яруллин. **Исендә дә юк** 1) Бөтенләй оныткан. *Әнә минем әти кайтмады. Беләсең килсә, кайту түгел, хат та язмый. Исендә дә юк.* З.Хөснияр. *--- баланы таза, нык, күндәм итәр өчен, аны җилгә, яңгырга --- алып чыгарга кирәк имеш. Шулай уйлаган иде шикелле ул – хәзер исендә дә юк инде.* Ә.Еники; 2) Берәр кеше яки нәрсә турында бөтенләй уйламау, игътибарга алмау. *Югалып калу хатынның исендә дә юк иде.* М.Хуҗин. *Язучы чакырып китергәч, юри тавышланып эшлим мин, --- ә язучының исендә дә юк, өстәлдән башын да күтәрми.* Ф.Шәфигуллин. – *Менә моны күрдеңме? – диде [Фая], ике йодрыгын Идрисов йөзенә китереп. Лейтенант тәмам каушап калды, ни әйтергә белмәде, начар ният исендә дә юк иде бит.* Х.Камалов. **Исеңә дә кертәсе булма** Нәрсәне дә булса эшләргә кирәк түгеллеген искәртеп әйтелә. *Ничек инде ул «төкерергә»? Исеңә дә кертәсе булма, сердәшем. Сора, бирмиләр икән, судка бир.* А.Шамов. **Исеңә төшәр** Ялгышканың, хаталанганың өчен соңыннан үкенерсең, дип кисәтү. *Алмалары, хөрмәләре кызарып пешәр әле, Бүген исеңә төшмәсә, иртәгә төшәр әле.* Җыр. **Исең дә китәр**, **акылың (гакылың) да бетәр** *к.* **исеңакылың китәр** *Каршы чыксам, исем дә китте, гакылым да бетте.* Г.Ибраһимов. **Исең киткән (икән)** 1) Юкка аптырыйсың, игътибар итмә. – *Әй сеңелкәш, – диде Хөснетдин, – исең киткән икән!* Ш.Камал; 2) Аптырама, курыкма (берәр яңа хәлгә аның гади һәм мәгълүм эш икәнен аныклап әйтелә). *Һи! Исең киткән икән, алар көлмәсәләр, илтифат итмәсәләр, малаеңның икенче бер һөнәре юкмыни!* Г.Камал. *Янгураз кыенсынып: – Мин алай бии белмим шул, – диде. – Исең киткән икән, мондый буталышта сине кем күрә? Өйрәнерсең!* Т.Әйди. **Исең киткән иске чикмәнгә** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса бик нык сокланунның, гаҗәпләнүнең нигезсез, урынсыз икәнлеге турын-

да. *Мине елап җибәрер дип уйлагандыр әле. Исем китте иске чикмәнгә, сер биреп торам, ди, шул кәгазь кортларына.* Р.Вәлиев. *--- минем Шәрәфкә үпкәләп йөргән көннәрем. Шуны Җәмиләгә сиздерсәм, белеп торам, авыз ерып көләр генә: – Исең киткән иске чикмәнгә. Менә күрерсең, итекләрен шакылдатып килеп җитәр әле, – дип әйтер.* Л.Ихсанова. *Вәзыйх ялынмый, эчтән генә үзен батырайта: сиңа теләнеп барырга тагы, тот менә. Бик исем китә иске чикмәнгә.* Х.Камалов; 2) Нинди дә булса искергән әйбергә яки көне кадерсезгә калган кешегә карата әйтелә. **Исең китәр** Кемгә яки нәрсәгә дә булса сокланып яки гаҗәпләнеп әйтелә. *Кызлары бик чибәр, исең китәр.* Г.Камал. *– Шулхәтле үчле, эчле кешеләр бар, исең китәр! – диде Каләмгөл.* М.Маликова. *Иңемә һөд-һөд кошы килеп кунды да: «--- бәхетең алда!» – дип сайрап җибәрде. Исләрең китәр!* Т.Әйди. **Исең китмәсен** «Бер дә гаҗәпләнмә; аптырарлык ни дә юк» мәгънәсендә. *– Хәйбулланы яратучылар дөнья тулы, бер дә исең китмәсен, – диде.* Ш.Камал. **Исе таралу** Гайбәт, сүз таралу. *Бу очракта тимерне кызуында сугарга кирәк иде, чөнки озакка сузган саен, районда сүз күбрәк үрчи, тәмсез исе ныграк тарала.* М.Маликова. **Исе чыгу** Берәр эш-гамәл турында сүз чыгу, сүз таралу. *Психушкага учётка алдылар сине... Әгәр андый-мондый эшең беленсә, исе чыкса, шундук юк итәләр, белеп тор.* А.Гыйләҗев. **Ис җибәрү** Гаҗәпләндерү, шаккатыру, таң калдыру. *Закир Челлит, айга фәлән таңкә генә алса да, --- малаена самокат алырга җыена икән, ди. Һи! Исне җибәрде! Самокат, имеш.* Ф.Шәфигуллин. *Халыкның исен җибәрерлек итеп эшләргә иде исәбе Зөбәрҗәтнең.* З.Вәли. *--- бу мөһергә швейцарның әз генә дә исе китмәде: – Аның белән генә безнең исне җибәрә алмассың! – диде.* С.Җәлал. **Ис җую** 1) Һуштан язу, аң югалту. *Әлеге исләрдәнме, әллә икенче берәр нәрсәдәнме, Гуськов исен җуярдай хәлгә килде.* В.Распутин. *Айгырның аягы шартлап сынды, --- моны --- ират халкы күреп, әүвәл исләрен җуеп тордылар.* Ф.Сафин. *Күз аллары караңгыланып, исен җуяр хәлгә җиткәч, Шаманның гәүдәсенә кемдер кагылды.* Р.Зәйдулла; 2) Аңлый алмау, төшенмәү. *Шәрәф ---, тыныч күл өстенә төшкән таш кебек, авыр-авыр сүзләр ыргыта башлады. Бүлмәдә бомба ярылдымыни?! Исен җуйган халык аңына килгәнче, Игнатьев авыр гына урыныннан кузгалды.* Л.Ихсанова. **Ис җыю** 1) Хәл җыю, көч җыю, ял итеп алу. *Кара канлы тереклек диңгезендә Исен җыйды батыр ауган җирендә.* Н.Исәнбәт; 2) Зиһенне, уй-фикерне бер ноктага туплау, берәр мәсьәләнең серенә төшенерлек, берәр нәрсәне аңларлык хәлгә килү. *Беркөнне кинәт авыл уртасында безнең танклар күренде. Немецлар арасында буталыш, ыгы-зыгы купты, --- ләкин алар бик тиз ис җыйдылар.* Х.Камалов. *--- безнең егетләр күпер астыннан чыгарга ашыкмадылар. Исләрен җыеп, үзалларына уйланып, сүзсез генә утыра бирделәр.* Ә.Еники. *Куркуыннан карга сеңгән карт, күзен йомган килеш, көпшәсен карачкыга юнәлтеп, мылтык тәтесенә басты. Шул килеш исен җыя алмыйча, байтак вакыт үтте.* Я.Зәнкиев. **Ис итмәстән (итмәгәндә)** Кинәт, көтмәгәндә, уйламаганда. *Ис итмәгәндә генә берсе, уч итеп, биленә сугып җибәрдеме әллә, дип уйладым.* Ш.Камал. *Аны күңеле белән яратулары, шуннан соң аерылышып бернечә еллар үткәч, ис итмәгән чакта аның яңадан килеп чыгуы Газизәне уйландыра.* Ш.Камал. **Ис кайту** *к.* **искә килү**. *Исем кайтканда, иң әүвәл ерактан бик әкрен генә, «мунча кергәнмен икән...» дигән уй килде.* Х.Сарьян. **Ис капчыгы** Акыл, зиһен. *Кабер якасына баскан бу бабай ни сөйли алсын? Ис капчыгы аның күптән тишектер инде.* Р.Зәйдулла. **Искә алу** 1) Берәр нәрсәне исәпкә, игътибарга алу, истә тоту. *Тик бер кешенең уй-кичерешләре искә алынмый, ул да булса Зиләйлә иде.* М.Маликова. *Ә ак патша Александр, башкорт-татарларның батырлыгын искә алып, шул походта катнашучыларга Урал даласыннан күп җир бүлеп бирә.* Х.Камалов; 2) Санлау. *Ярлыны берәү дә исе китеп искә алмый.* Ш.Камал. *Безне искә алып, кешегә санап килүеңә бик рәхмәт.* А.Шамов; 3) Хәтергә төшерү, күңелдә яңарту. *Хәтереңә яхшы сеңдер, бүген булмаса, иртәгә искә алырсың дигәндәй, әледәнәле үзенең, чәй урынына кайнар су белән ипи ашап булса да, укуын ташламавын искә алып сөйли.* З.Вәли. *[Мәсрүрә апа] Рәдиф аерып җибәргән киленнен искә алды.* В.Нуруллин. *Кыз бала иң хәлиткеч минутларда энесен исенә ала.* Н.Әхмәдиев; 4) Хәтергә төшереп сөйләү. *Бабайның, борынгы вакытларны искә алып, ниләр сөйләгәне Исмәгыйльнең хәтерендә дә сакланмаган.* Г.Гобәй. *Авылда шулай бит ул: бер ялгышың гомереңә җитә, үзең үлгәч тә һаман иң беренче итеп шуны искә алалар.* М.Маликова. *Биюш белән Фирәвия яшьлекләрен рәхәтләнеп искә алдылар.* М.Хуҗин; 5) Берәр кешене яки нәрсәне атау, исемен әйтү, исемен күрсәтү. *Нәгыйм үзенең гаризасын Фәтхи сораганнан соң гына бирергә дип уйлап куйган иде. Ләкин аны искә алучы да булмады.* Ш.Камал; 6) Кемне яки нәрсәне дә булса аерып күрсәтү. *Болар арасында Татар дәүләт опера театрының художество җитәкчесе һәм баш дирижёры С.С.Бергольцны аерым искә алып үтәргә кирәк.* М.Җәлил; 7) Кемнең дә булса хөрмәтенә бәйрәм, тантана үткәрү. *Әллә соң Каләмгөлне үзебезчә искә алыйк микән? Әйтик, аның истәлегенә багышлап матур гына бер кичә үткәреп алырга булыр иде.* М.Маликова. **Искә алынган** Берәр чыгышта, мәкаләдә һ.б.ш.ларда әйтеп үтелгән. **Искә алып куй** Нәрсәне дә булса онытырга ярамавын искәртү. *Син моны исеңә алып куй. Кирәк булыр, акыл бу сиңа.* Н.Исәнбәт. **Искә дә төшми** Уйга да, хәтергә дә килми. **Искә (дә) кертмә** Ул хакта, ул турыда уеңа да китермә, уйлап та карама. *[Фашистның] Маңгаена атып, Миен чәчрәтмичә, Котылуны кертмә исеңә.* Ф.Кәрим. **Искә кертеп чыгармау** 1) Берәр нәрсә турында бөтенләй уйламау, хәтергә дә алмау. *Ник «хәер-дога» дигән нәрсәләрне исегезгә кертеп чыгармыйсыз?* Ф.Әмирхан; 2) Нәрсәнедер үтәргә җыенмау. *Кош халкы чигенүне исенә дә*

*кертмәде.* Г.Хәсәнов. **Искә кертмәү (кереп чыкмау)** Кемдер яки нәрсәдер турында бөтенләй уйламау. *Менә аның исенә дә кереп чыкмый, өч ятып, бер төшенә дә керми, ичмасам!* М.Гафури. *[Зифа:] Әйтү түгел, Галләм исемә кереп тә чыкканы юк.* М.Фәйзи. **Искә керү** *к.* **искә төшү** (*1 мәгъ.*). *Аның, Газизен исенә дә кертмичә, яшь кияү белән тагын да матуррак гомер итү мөмкинлеге каенананың көнчелеген янә күпертеп узды.* Г.Бәширов. *– Улым, биш ел буена бер дә хатың-хәбәрең килмәде, – дип әйтергә җөрьәт итте Миңҗамал карчык. – Бер дә исеңә кермәдекмени соң?* Ф.Яхин. *Тормыш йөген тарту, хатынга ярдәм итү, бала тәрбияләү кайгысы аның исенә кермәде.* Ә.Моталлапов. **Искә (дә) килмәгән, төшкә (дә) кермәгән** 1) Көтелмәгән, уйланмаган; 2) Бик сирәк, ят, сәер хәлләр яки күренеш турында. *Патша кызын тазга бирделәр, ди, кырык көн, кырык төн туй булды, ди, ул анда кунаклар, ди, аш-су, ди, әллә нинди искә дә килмәгән, төшкә дә кермәгән тәмлетәмле сыйлар, ди.* Әкият. **Искә килү** 1) *к.* **искә төшү** (*1 мәгъ.*). *Әсма белән танышкан мәҗлеснең кадерле хатирәләре искә килделәр.* Ф.Әмирхан. *[Зиттаның] Шунда ук күпме вакыттан бирле җанын төрле борчулар кимергәне исенә килде.* Х.Камалов; 2) Һушка килү, үз-үзеңне һәм тирә-якны сиземләү, аңлау хәленә кайту. *Исенә килгәч, үзенең нишләп болай бусага төбенә чалкан ятуын тиз генә аңлый алмыйча азапланды Майкап.* К.Миңлебаев. *...Нәкъ шушы урында Кәрим абзый --- бертын сыны катып ятты, аннары кинәт исенә килде.* Ә.Еники. *Берничә көн һушсыз яткан баланың мие селкенгән икән. Суырылып, күз төпләре күгәреп чыккан бала, исенә килгәч, тәрәзәгә карап тора...* Я.Зәнкиев; 3) Тирән уйга бирелүдән, тәэсирләнүдән айну. *– Настя, без тагын очрашырбыз микән?! – дип каушабрак кычкырды Әхмәт, кинәт кенә исенә килеп.* М.Хуҗин. *[Рәхилә] Кинәт исенә килеп, идәндә таралып яткан киемнәрен җыеп алды һәм күз яшьләренә тыгылып киенә башлады.* Ф.Сафин. *Кино белән мавыгып киткән Алтынчәч сизми дә калган, берзаман исенә килсә, аның иңбашы егетнең беләгенә терәлгән һәм үзен бу хәлендә бик рәхәт хис итә икән.* М.Маликова; 4) Аңлап алу, төшенү, абайлау. *Директорның җиңеннән тартырга өлгерә алмый калдым, ---. Исемә килеп, кире йөгердем.* Н.Әхмәдиев. *...Хәбир, үзе дә сизмәстән, Тәүгизнең яңагына чалтыратып җибәрде. Малай кинәт кызарды, исенә килә алмыйча, бертын аптырап, --- әтисенә текәлеп торды.* Х.Камалов; 5) Хисләрдән, теләк-омтылышлардан баш тарту, аек акыл белән уйлау. *– Фаяз абый, үләм, мин сине яратам! – дип, уттай сулыш белән пышылдады. – Зөмәрә, Зөмәрә, исеңә кил! – дип тәкърарлады Фаяз.* Х.Камалов; 6) Берәр төрле башкарылган эшнең яки ниятнең ялгышлыгын аңлау, аны төзәтергә омтылу. **Искә китерү** 1) Берәр нәрсә турында уйлау, хәтергә алу. *--- Әнвәр үз хәленең болай яшь коюдан яхшырмаячагын, хәзер болай өзгәләнү берни дә бирмәячәген исенә китерде.* Х.Камалов; 2) Һушка китерү, аңга китерү. *Зиттаның чыңлап көлүе ишетелде, шул тавыш Мостафинны исенә китерде.* Х.Камалов; 3) Үз-үзен тотышын, холкын үзгәртергә, төзәтергә мәҗбүр итү. *– Мәйданга! – дип кычкырды Гыйльметдин, һаман үзен кулга алырга өлгермәгән Мәхмүтне исенә китерергә тырышып.* Ф.Сафин. **Искә төшерү** 1) Элек күргән яки белгән нәрсәләрне, кешеләрне, булган вакыйгаларны хәтердә, күңелдә яңарту, шул турыда искә төшереп уйлау. *Әнисе әле улларына сукранып та алды: – Әтиегезнең йөрәгенә тоз салып, һаман-һаман сугышны исенә төшереп утырмасагыз да ярар иде инде, – диде.* М.Маликова. *Үзеннән алда эшләгән шофёрны, бер кыек сүз ычкындырганы өчен, дүрт ел ярымга төрмәгә тыгуларын ул бик еш исенә төшерә!* А.Гыйләҗев. *Әниемнең әйтергә ярата торган, күңел таптамак – бер калҗа, дигән сүзләрен ник кенә исемә төшермәдем икән.* Л.Ихсанова; 2) Кайчандыр күргән-белгәннәрне хәтердә яңартып сөйләү. *Шулчак лейтенант күрше «Хоттабыч»ның хикәятен исенә төшерде.* З.Фәтхетдинов. *Баграков Мостафин белән төне буе сөйләшеп утырдылар. Баштан кичкән хәлләрнең бөтенесен тәфсилләп искә төшерделәр.* Х.Камалов; 3) Берәр нәрсә, вакыйга, кеше турында онытмаска, хәтердә тотарга кирәклек турында кисәтү. *Кәефе киткән ана, тавышын күтәрә төшеп: – Кәстүмеңне ясатыр булсаң, мастерскойга барып кайт, – дип исенә төшерде.* З.Вәли. *– Кайчан туган соң ул? – дип сорады Фидая. – Моны мин сиңа түгел, син минем искә төшерергә тиеш идең, – диде Җәгъфәр Латыйпович.* М.Маликова. *Ул туйда да шулай әледән-әле үзенең комсомол секретаре икәнен исенә төшерә ---.* Р.Кәрами; 4) *сөйл.* Кемне дә булса кылган явызлыгы өчен үч алачагын кисәтү. *Мин моны онытa алмам! Гомер булса, бер аның исенә төшерермен!* Г.Ибраһимов; 5) Берәр нәрсә яки кеше булып күренү, берәр нәрсәне яки кешене хәтерләтү. *Караңгы бүлмәләр, агач орнаменты белән эшләнгән иконалар, гравюралар урта гасыр монахларының тормышларын искә төшерәләр.* Г.Гобәй. **Искә төшү** 1) Үткәннәр хәтергә килү, хәтердә яңару. *Шул хакта сорарга дип авызын да ачкан иде, Рамиләнең яңарак кына: «Безнең кайсыбыз оялырга тиештер бит!» – дигән сүзе исенә төшеп, тыелып калды.* Н.Әхмәдиев. *Зәйнәп әби исенә төшкәч, Сәхиянең күңеленә якты нур бөркелгәндәй булды.* Ф.Яруллин. *Тагын Фарукшин әйткән сүзләр исенә төште: кешенең бөеклеген аның бөек эшләре билгели.* З.Фәтхетдинов; 2) Берәр нәрсә эшләү фикере туу. *Синең шул булыр инде. Бернәрсә исеңә төшсә, тынгы бирмәссең.* Т.Гыйззәт; 3) Эшләгән эшенең ялгышлыгын аңлап, соңыннан шуның өчен үкенү. *Фидаил озак тормады, тиз арада әйләнеп керде һәм, нидер әйтергә кирәк тапкандай: – Исенә төшкән! – дип, гаҗәпләнгән кыяфәт белән башын чайкады.* М.Маликова. **Ис керү** 1) Нинди дә булса уңышсызлыктан, ачы тәҗрибәдән соң аңлы, уяу булу, нәрсәнең ни өчен икәнлеген аңлый башлау; 2) Үсү, өлгерү, дәрт керә башлау. *Зөфидә хакында Женядан сорарга оялды Тәүгиз, көләр генә, әһә, ис керә*

*башладымы, дип, күзеңне дә ачырмас.* Х.Камалов. *Гыйбадулла абзый хәвефтә: әллә егет кисәгенең борынына кызлар исе кергәнме?* Г.Ахунов. --- *Рәдиф тә, мин дә ул чакта борыннарыбызга кызлар исе кергән, «кызлар» дигәндә җәһәннәмнең аргы ягына барып чыгарга әзер торган егетләр идек инде.* В.Нуруллин. **Ис китәрү** 1) Бик нык гаҗәпләндерү, шаккатыру. --- *аның сүзләре шома булып, берсенә-берсе җилемсез ялганып, Рахмановның исен китәрерлек акыллы булып чыга иде.* М.Әмир. *– Балаларның исен китәрү тәрбиячеңең сәләтенә кайтып кала, – дип, Нияз аңа каршы төште.* А.Вергазов. *Бервакыт авылның бик диндар кешесе Садыйк абзыйның исен китәргән эти.* Р.Фәизов; 2) Сокландыру, таң калдыру, хәйран калдыру. --- *буй-сыны, килеш-килбәте, үзен тотуы, сөйләшүе белән шәкертләр һәм хәлфәләрнең исен китәрде.* Ә.Фәйзи. *Скрипкачы кыз үзенең уйнавы белән бөтен кешенең исен китәрде.* К.Бәкер. **Ис китмәстән** Артык гаҗәпләнмичә яки сер бирмичә. **Ис китү** 1) Бик нык гаҗәпләнү, аптырау. *Бер иртәдә кыз чәчәкләрнең тәрәзәләргә бизәк булып сыкыланып төшүләрен күреп, исе китә.* М.Хуҗин. --- *марҗа түтәйләрнең берсе дә дуңгыз карарга дәртсенмәде. Кул гына селтәделәр! Исем китте.* М.Маликова. *Икебезне янәшә бастырып куйдылар. Яныбызга хатын-кыз, бала-чага җыелды. Бары да исләре китеп безгә карап торалар.* М.Әмир; 2) Таң калу, соклану. *Бу вакытта Ләйлә шулкадәр матур иде ки, аңа бөтен кешенең исе китә иде.* И.Гази. *Шул ук минутта мин аны кыз дип тә күрдем. Чибәрлегенә исең китәр.* Г.Кутуй. *Ул күзләрдә нindидер хәйран калу, ис китү, хәтта бераз миңгерәүләнеп калу да сизелә кебек.* Ә.Еники; 3) Артык игътибар итү, әһәмият бирү. *«Луциусның андыйларга гына исе китми лә, тыштан гына ялтырый иде бит ул егет», – дип сөйләштек без – группадаш кызлар.* М.Маликова. *Киленнәре белән икенче уллары арасындагы мөнәсәбәтләрнең тирәнгә кереп китүен сизенгән кайната белән кайнана телләрен тешләделәр. Авыл халкы исләре китеп берәр атна авыз чайкадылар да туктадылар.* Я.Зәнкиев. *[Апа] Бу хәлне, әти кайткач, аңа да сөйләп бирде. Әтинең аңа әллә ни исе китмәде: – Барысы кырылып бетмәсә, шөкер инде, – диде ул.* Ф.Яруллин. **Исләренә дә алмау** Уйлап та карамау, хәбәрләрендә дә булмау. **Истә дә юк** Бөтенләй хәтердән чыккан. **Истә калдыру** Хәтердә саклау, онытмау. *– Аның хәтере яхшы, – диде Зөлфә. – Теләсә нинди әйберне бер күрүдә исендә калдыра.* М.Маликова. **Истән аву** *к.* **ис аву**. *Зәйтүнә истән авып барган чырай белән җиргә чүгәләп кычкырды.* К.Нәҗми. *Истән авып яттым ун сәгать.* М.Җәлил. **Истән җибәрү** 1) Кемнең дә булса аңын югалттыру. *Беренче сугуым белән аны истән җибәрсәм, икенчесе белән аяктан ектым.* Т.Гыйззәт; 2) Оныту. **Истән салу** *диал. к.* **истән чыгару**. *Җаным син, алтын алмам ла, Исемдин бер дә салмам ла!..* Г.Кандалый. **Истән тайдыру** Һуштан язарлык, акылны югалтырлык итеп бик нык гаҗәпләндерү, әсәрләндерү. *Ник мине бу хәтле истән тайдыра тик бер кеше?* С.Рәмиев. **Истән чыгару** Оныту, хәтердән чыгару. *Группа җитәкчесе Яхъя Каюмович институтның чыгарылыш кичәсендә: «Укытучы икәнегезне бер минутка да истән чыгармагыз», – дигән иде.* Н.Әхмәдиев. *Хатынын исеннән чыгара алмады ир.* Я.Зәнкиев. *Ямгырчы бине, нишләптер, барысы да исләреннән чыгарып ташладылар.* Н.Фәттах. **Истән чыгу (китү)** Онытылу, хәтердә калмау. *Кайберәүләр, үлсә, еллар үтү белән истән чыга: онытыла.* М.Гафури. *Гришаның устав та исеннән чыга, ике-өч минуттан тәмле төш тә күрә башлый.* Н.Әхмәдиев. *Картаясы да, үләсе дә исеннән чыкмады Зөлхәбирәнең.* С.Зыялы. **Истән чыккан** Нәрсәнең дә булса берара онытылып торуын аңлата. *– Истән чыккан, дигән булып акланып маташма, барыбер хәйләңне аңладым, – диде Фәтхи.* Ш.Камал. *– Әсләх бүләге... Кулыңны да, күңелеңне дә тагын да нурландырсын шушы йөзек, дигән иде, бәгырькәем... Исемнән дә чыккан --- диде --- Саура.* М.Хуҗин. **Истән язу (таю)** 1) Һуш китү, аңны югалту. *Ятрылаш ул тайган исеннән, Шулай да яшәве өметле.* М.Җәлил. *Тик саташу һәм истән язулардан бөтенләй арынып савыга төшкәндә, ул инде таш калада, зур врачлар карамагында дәвалана иде.* Г.Бәширов; 2) Һуштан язарлык, акылны югалтырлык дәрәҗәдә әсәрләнү, тәэсиргә бирелү. *Казый әйтте: – Бу үзеңдәге киемнәрне – җөббә белән чалманы салып бир, – диде. Фазыл бу хәрәкәтне күреп, исеннән язды.* Борынгы татар прозасы. **Истә тору** Хәтердән чыгармау, онытмау. --- *бер баганага сөялеп торуым, күземә нindидер кан күренүе, шуңардан куркуым әле дә төшемдә кебек кенә исемдә тора.* Г.Ибраһимов. **Истә тоту** 1) Онытмау, хәтердә тоту. *Габдулланың да бу очрашудан күңеле шактый йомшарды, әмма ул үзенең инде «зур үскәнен» истә тотып, сынатмас өчен, күз яше чыгармаска тырышты.* Ә.Фәйзи. *Ахырдан мин, Зәбидә чәчен тартуын истә тотып, аңа: «Ленар! Сиңа хәрәмләшү килешми икән», – дип, юри төрттереп куйдым.* Н.Хәсәнов. *Шәһәр урамында бик сакланып йөрергә кирәклеген Гасыйм Сәлахович һәрвакытта исендә тота торган иде.* Ә.Еники; 2) Теге яки бу эшне башкарганда, берәр нәрсәне игътибарга алу. *– Нәни генә борчуыгыз булса да, врачка барыгыз, – [диде Эльза Бруновна]. – Әлбәттә, әлбәттә ---, – диде Мортаза, ашыгып. – Исемдә тотармын... Барырмын, каралырмын.* М.Маликова. *Исегездә тотыгыз: барысы өчен дә берүзе эшләргә тырышкан начальник ике җинаять ясый.* Р.Кәрами. **Ис югалту** *к.* **ис җую**

**ИСАБӘТ** *и. гар. иск.* Тәңгәллек, туры килү. *Заһидулла Заһидәгә ачылды: – Дөрес юл түгел бу. Боларда исабәт юк. Болар бер сүз сөйлиләр, икенче эш эшлиләр.* Р.Сибат

**ИСАГУҖИ ХАН** *и. гар.-фар. иск.* Иске мәдрәсәнең икенче баскычында укучы шәкерт. *Бу хәл аның исагуҗи хан заманында, «тәүзыйх» мәсьәләләренә катнашып, көлкегә калуларына да сәбәп була иде.* Г.Ибраһимов

**ИС-АКЫЛ** *җый. и.* Зиһен, аң, хәтер. *Татарда – сизгерлек, татарда – ис-акыл ---.* Ә.Мәхмүдов

◊ **Ис-акыл бетү** Нык курку, аптырау нәтиҗәсендә нәрсә эшләгәнен аңлый алмау хәленә килү. *Сукмак аркылы бер кеше сузылып ята, карыйм – Фәхри! --- Тәне бөтенләй суынган. Исем-акылым бетте.* Г.Ибраһимов. **Ис-акылга килү** *к.* **ис-акылны җыю**. *«Ризыкка туйгач кына китеп барды бит!» – дип, әтиләре, әниләре үлгәч, бик озак ис-акылга килә алмыйча тинтерәп йөрде.* Р.Мулланурова. **Ис-акыл китәрү (җибәрү)** Бик нык гаҗәпләндерү, хәйран калдыру, шаккатыру. *Ифрат шәп исле духилар сөртенеп, шатырдаган ефәк чапан, матур чалмадан килеп кереп, хатын-кызларның исен-акылын китәрә икән ул...* Ш.Камал. *Шул мәлне Тимерханның исен-акылын китәрерлек тагын бер хикмәт булды.* Г.Ахунов. **Ис-акыл китмәле (ис тә, акыл да китмәле)** *диал.* Искиткеч, гаҗәпкә калырлык, хәйран калырлык, шаккатарлык (шәп, бай, матур һ.б.ш.). *Ис тә, акыл да китмәле! Ничек чыдый бу ир-ат?* К.Нәҗми. **Ис-акыл китү** Бик нык гаҗәпләнү, хәйран калу, шаккату. *Ул яңалыкларны ишеткәч, Миңкамал абыстайның тагын бер тапкыр исе-акылы китте.* А.Шамов. *Бу тамашага бөтен сарай әһеле ис-акыллары китеп, тәмам хәйран вә вәйран булып калалар.* Ә.Еники. *Бала туганнан бирле бианасы кулында, дигәч, ис-акыллары китте, малакаем.* Ф.Сафин. **Ис-акылны алу (исен дә, акылын да алу)** Гаять дәрәҗәдә гаҗәпләндерү, хәйран калдыру, сокландыру. *Һәм шул тынлыкта Университет урамы белән Уңъяк Болак чатында кинәт пәйда булган хәрби патруль анархистларның ис-акылын алды ---.* З.Фәтхетдинов. **Ис-акылны алырлык** Гаҗәеп, бик матур. *Гади ишегалды гына түгел, тигез-матур аллеялары, аллы-гөлле чәчәк түтәлләре, --- белән ис-акылны алырлык гаҗәеп парк-бакча иде бу.* З.Фәтхетдинов. **Ис-акылны җыю** Зиһенне, уй-фикерне туплау, берәр нәрсәне аңларлык хәлгә килү. *– Безнең юллар бер тарафка икән, – диде, ниһаять, исен-акылын җыеп өлгереп Сабадырев.* З.Фәтхетдинов. *Рәхимҗан ис-акылын җыеп өлгергәнче, халык ташкыны аны гайрәтләнеп коймага таба кысрыклады ---.* Н.Гыйматдинова. **Ис-акылны югалту (җую)** Гадәти психик халәтне югалту, нәрсә эшләгәнне аңлый алмау. *--- һич көтелмәгән бу очрашу, бу сәер охшашлык аны шундый тәэсирләндерде ки, Чыңгыз хәтта исен-акылын җуеп торды ---.* З.Садыйков. *Менә Муллагали күргәне исең-акылыңны җуярлык.* И.Сирматов. *Исе-акылын җуяр дәрәҗәгә җитеп, булган мәхшәргә карап торганда, беренче булып, Ислам сүз катты.* М.Хәбибуллин. **Исең-акылың китәр (киткән)** Кемнең яки нәрсәнең дә булса гадәттән тыш яхшырак яки, киресенчә, начаррак икәнлеген белдергәндә әйтелә. *Адәм баласы, эшләмичә яшәр өчен, ниләр генә кыланмый. Исең-акылың китәр!* Х.Камалов. *Фәриснең [Фираяга] җан ачуы чыкты. «Шул тимер җене кагылган сары пышлакка исең-акылың киткән икән!»* А.Вергазов. **Искә-акылга килмәгән** Бөтенләй уйда, күңелдә булмаган, һич уйламаган. *Авыргач, сәламәт чакта искә-акылга килми торган нәрсәләр турында уйлыйсың.* Г.Әпсәләмов. **Искә-акылга килү** Аңга килү, һушны җыю; нинди дә булса яхшы яки начар тәэсирләр йогынтысыннан айну

**ИС-АҢ** *и. к.* **ис-акыл**

◊ **Ис-аңны җыю** *к.* **ис-акылны җыю**. *Малай ис-аңын җыеп торып басты. Авызын каплап, чайкала-чайкала кире урман эченә атлады.* Н.Гыйматдинова. **Ис-аңны югалту (җую)** *к.* **ис-акылны югалту (җую)**. *Алла исемне-аңымны югалтырга ирек бирмәгәндер, күрәмсең ---.* З.Фәйзи. *Нигә ис-аң җуеп Нәзергә барды икән?* Н.Гыйматдинова. **Искә-аңга килү** Аңлап алу, төшенү. *Ул [Кәшифә әби], --- иртәнгә кадәр йоклап, күңелсез уйлардан арына, искә-аңга килә алмаммы дип, одеялын башыннан ук бөркәнеп куйды.* З.Фәйзи. **Истә-аңда булмау** (Берәр нәрсә) хәтердә бөтенләй булмау, ул турыда уйламау. **Истә-аңда юк** Бөтенләй хәтердә булмаган, бөтенләй уйламаган кешегә яки аның турында әйтелә. *Кара син аны, юньсезне, гомерендә исендә-аңында юкны. Каян бүген генә уена килде икән?* М.Шабай

**ИСӘ** *ф.* **1.** 1) *бор.* Хәзерге телдәге *булса* мәгънәсенә туры килгән борынгы *ир* тамырыннан ясалган ярдәмче фигыль. *Җәйнең туктаусыз хәзмәте бик ардырмыш исә дә, халыкның күңеле күтәренке, йөзе шат иде.* Г.Ибраһимов // Борынгы мәгънәсе хәзерге телдә *алай исә (алайса), юк исә (югыйсә), я исә (яисә), әйттем исә кайттым* тезмәләренең состав өлешендә сакланып калган. *Бәхетең бар икән инде, бәхетең юк исә, Әнвәр шикелле егеткә гомердә бара алмас идең.* Г.Камал. *Самат!.. Кычкырма инде. Әйттем исә кайттым. Әнә кешеләр борылып карый башлады.* Г.Гыйльманов

2) Үткән заман хикәя фигыльгә кушылып шарт фигыль ясый (баш җөмләдә белдерелгән эшнең иярчен җөмләдә белдерелгән эштән соң тиз арада башкарылуын аңлата). *Исенә бернәрсә килеп төште исә, хәзер шул минут ук эшли дә ала.* Г.Камал. *Күктә болыт әсәре күренә башлады исә, шул әтәч чатән өстенә очып менә дә канатларын җилпеп кычкырырга тотына.* М.Галәү

3) *диал.* Сүзнең яки фикернең дөреслегенә бик үк ышанып җитмәгәндә, чамалап кына әйтүне белдерә. *Берәр юләрдән килгән хаттыр шунда, юк исә, юләр булмаса, мондый сүзләр язар идемени?* Г.Камал

**2.** *терк. функ.* Әйтелә торган сүзләрне алдагы фикергә каршы кую өчен кулланыла; әмма, э. *Кичке кояш пыяла заводы посёлогын алсу нурга коендырган. --- Малайның исә кояшта хәбәре юк.* М.Маликова. *[Ваня] Ашханәгә барып йөрми, иртән чәй куеп эчә, --- кичен исә кара ипигә тоз сибеп ашый иде.* М.Галиев. *[Хәбир] Хәтмулла картка текәлеп карап тора башлады. Ә карт исә, малайның туры карашыннанмы, башлаган уй очын төйнәп бетереп-ме, кулларын халат итәгенә сөртә-сөртә, атлар янына кереп китте.* Г.Гыйльманов

**ИСӘВӘН** *с. диал.* Тиз онытучан; хәтере начар, хәтерсез. *– Карале, ни, Нурһадә, ялгыш сүз ычкындырдым бугай. Ни әйткәнемне дә оныттым. Исәвән бәндә мин. Начар сүзне тиз онытам, – диде Байназар.* М.Хуҗин

**ИСӘКӘЙ** *и. этн.* Каз өмәләре вакытында егет һәм кызларның, төрле кыяфәттә киенеп, биеп-уйнап, су буена төшү йоласы

**ИСӘН** *с.* **1.** 1) Тере; *киресе:* **үлгән**. *Бибиәсма җиңгәчәй дә исән чагында миңа гел шулай ди торган иде. Син тач әниең, коеп куйган Шәмсемаһи ди ие.* Р.Ишморат. *Әгәр атаң мәрхүм исән булса, ул да сиңа шундый ук сорауларны бирер иде.* А.Шамов. *[Иремнең] Тугызынчы майда язган хаты Берлиннан килгән иде. Җиңдек, мин исән, дип балаларча сөенеп язган иде. Бер атнадан чех җирендә харап булган, мәрхүм.* М.Галиев

2) Сау-сәламәт, таза; авыру булмаган. *– Исәнме, Баязит абый? – ди Мирзанур. – Бик исән, энем, хуш киләсең, – ди бу.* Р.Ишморат

3) Зарарланмаган. *«Бүген кич туры монда килимме?» – дип сорады Линар гади генә. Ничек кенә текәлеп караса да, Алтынчәч аның исән сул күзендә дә, үз-үзен тотышында да дулкынлану сизмәде.* М.Маликова. *[Фәйрүзә] Сызлаган кулын юрган астыннан алды да уралган ак чүпрәккә аптырап карады. Исән кулы белән йөзен, чәчләрен сыпырды.* М.Галиев

4) Зыян-зарарсыз, бөтен, җимерелмәгән, ватылмаган. *Аушева автовокзал ягыннан кайтып килгән. Койманың нәкъ менә бөтен такталары да исән турысыннан үтеп барганда атканнар аңа.* З.Фәтхетдинов

5) Югалмаган, юкка чыкмаган, үз урынында сакланган. *Чишеп карый Сәфәргали [капчыкны], комсомол билетлары исән.* М.Әмир.– *Әле син минем портретны ясау фикереннән ваз кичмәдеңмени? – Ю-у-ук! Син үзең вакыт тапмадың ич. Кая әле, теге киндер исән булырга тиеш!* М.Маликова. *– --- ә берсекөнгә --- мунчага минем мылтыкны китер. Исәнме ул? – Исән.* В.Распутин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тере килеш. *Госпитальләрнең берсендә беренче мәртәбә күзен ачканда, Зиннәт үзенең исән калуына бик гаҗәпләнде.* Г.Бәширов. *Хәлбуки һәлакәттән соң кыргый җанварларның да бик азы гына исән калды.* Р.Фәизов

2) Сәламәт, таза килеш. *Өскә алдым туган ил каршында Аның исән, таза үсүен.* М.Җәлил

3) Зарарланмыйча, җимерелмичә. *Янып кара көйгән йортлар арасында, ничектер, берьялгызы исән калган чүлмәк башлы өйнең капкасыннан кергәндә, зениткалар якын гына дөпелдәтә башлады.* И.Гази. *Беркөн ул, янган өйгә барып, сәләтле куллары белән Мәүлиха әбинең исән калган ярты өен тәмам тораклык хәленә китерде.* Ә.Фәйзи. *Цивилизацияле Европа вәкилләре – инглизләр әнә Һиндстанны талдырганда, Таҗ мәхәлне җимереп китмәкче булалар. --- шулай да исән калган бит Таҗ мәхәл.* М.Галиев

4) *куч.* Гамәлдә, яшәештә, законлы нигездә. *Совет исән булса, аты да булыр, сыеры да булыр.* М.Гали

**3.** *и. мәгъ.* Тереклек иткән, дөньялыкта булган дәвер, яшәгән чак. *[Бакыйга] Исәннәрнең бар мәшәкате, ыгы-зыгысы чүп кенә булып тоела ---.* М.Маликова. *Исәннәргә зират тирәсендә тору авыр.* М.Галиев

**4.** *хәб. сүз. функ.* Берәр нәрсәнең хәзерге вакытта та булганлыгын яки барлыгын белдерә. *Бензин белән эшли торган моторлы беренче автомобильләр әле дә исәннәр ---.* М.Хәсәнов

◊ **Исән генә торасыңмы** *сөйл.* Күптән билгеле хәлне яңалык итеп сөйләгәндә, гаҗәпләнүне, ризасызлыкны белдереп әйтелә торган җавап сүзе

**ИСӘН-АМАН** *рәв. к.* **исән-имин**. *Бу күренешләр барысы да аның --- туган-үскән иленә исән-аман кайтып җитәчәгенә ышандыралар иде.* А.Хәлим. *Районның киләчәге нинди булуда бу хатынның хәбәре юк, ул бары тик четерекле хәлдән исән-аман котылу --- турында гына хыяллана --- иде.* М.Маликова. *Бибисаның әнисе, икесенең берсенә чык, ди. Аңа кем дә бер, димәк, кеше теленә кергән кызыннан исән-аман котылырга гына кирәк.* С.Сөләйманова

**ИСӘН-ӘМАН** *рәв. к.* **исән-имин**. *Хәерелбанатлар Нурулла янына исән-әман барып та җитә алмаганнар. Юлда ук алар утырган поездга немец самолётлары бомба ташлаган. Сания шунда һәлак булган.* А.Гыйләҗев

**ИСӘН-ӘМАНЛЫК** *и.* Исән-әман, исән-сау булу. *Килеп керде, --- миңа сәлам бирде, исән-әманлыкны сорады: «Кәеф начар мәллә, абзыем?» – ди. Мин әйтәм: – «[Әйе] Сырхап торамын».* Ш.Маннур

**ИСӘ́Н БУЛ(ЫГЫЗ)** *ы.* Саубуллашканда, кемнең дә булса саулыгына атап тост әйткәндә яисә берәрсе төчкергәндә сәламәтлек, исәнлек теләү. *Юл читендә кар кисәкләре торалар тезелешеп. Барысы да иелеп калалар: «Хуш, исән бул!» – диешеп.* Ш.Бабич. *Тәһарәтен яңартып керде дә, күрешмәсәк, исән булыгыз, дип, мәҗлескә китте.* Г.Ибраһимов. *Фатыйма старшинага кулын сузды: – Сез дә, иптәш Зәбиров, исән булыгыз.* Г.Әпсәләмов

**ИСӘНГЕРӘ́Ү** *ф.* **1.** Аптырап калу; зиһен таралу. *Табышмаклардан башы каткан Нәҗип, абыйсының сүз сөрешен, фикеренең очын югалтканга, тәмам исәнгерәде.* А.Гыйләҗев. *– Исәнме, Мотаһир. – Исәнгерәп утырам, яшьти, – диде Мотаһир, көлеп.* Р.Кәрами. *Әмма Нәсимә аны ишетми дә, аңламый да. Аркасы белән ташка сөялгән хәлдә исәнгерәп тик тора һәм әледән-әле сискәнеп куя иде.* С.Сабиров

**2.** *и. мәгъ.* Ярым уяу, йокымсырау хәле, халәте. *Килеп бәрелгәч, йокымнан исәнгерәүләрем юкка чыкты.* Юлдаш

**Исәнгерәп калу** Төрле сәбәптән, ниндидер тәэсирдән соң кинәт исәнгерәү. *Бер читтәрәк арзанлы тәмәке тартып торучы музей хезмәткәре дә, боларның исәнгерәп калуын күреп, кабер кырынарак килде.* Р.Зәйдулла. *Дөреслек Кәрам ягында, Кәрам алдашмый иде ---. [Шуңа күрә дә Җәмил] Исәнгерәп, миңгерәп калды.* Н.Әхмәдиев. *Күрсәгез иде ул затсызларның исәнгерәп калуларын! Суга баткан чебеш кебек иде кыяфәтләре.* Р.-Н.Гүнтәкин

**Исәнгерәп китү** Кинәт, уйламаганда исәнгерәү. *Гомеремдә бер дә төш-мөш, ырым-шырымга ышанмый торган Газиз әлеге төштән исәнгерәп китте ---.* Ә.Салах

**Исәнгерәп тору** Ниндидер вакыт дәвамында исәнгерәгән хәлдә булу. *Шаһгали исә, ни уйларга да белмичә, бик озак исәнгерәп торды.* Р.Зәйдулла.

*Гөлсара каз бәпкәсе шикелле пипелдәгән трубканы тоткан килеш бермәл исәнгерәп торды*. Л.Лерон

**Исәнгерәп яту** Озак вакыт дәвамында исәнгерәгән булу. *Күпмедер вакыт исәнгерәп яткач, урамга чыккалый башладым.* Ф.Яруллин

**Исәнгери төшү** Тагын да ныграк исәнгерәү. *Балалар бакчасына килеп, елап, күзләре шешенеп беткән кызын күргәч, Венера тагын да исәнгери төште.* З.Фәйзи

**ИСӘН-ИМИН** *рәв.* 1) Тере, саусәламәт хәлендә. *Минзакир абзый ике куллап күрешеп кенә калмады, Хәйрүшне, җилтерәтеп, җилкәләренә кадәр каккалап-суккалап алды. – Исән-сау гына тордыгызмы?.. – Исән-имин яшәп ятам шунда.* М.Хәсәнов. – *Бәхетле син, – диде Нәфисә апа, Фәйрүзәнең аркасыннан сөйде. – Исән-имин йөр.* М.Галиев. *Исән-имин кайтып, кушылыр көнне көтәм.* Я.Зәнкиев

2) Зарарламыйча, зарарланмаган хәлдә, бөтен көенчә. *Нина гаҗәпләнеп миңа карады: – Нинди могҗиза турында әйтәсең? – Моңарчы кассагызга бирәүнең дә кермәвен, акчаның исәнимин ятуын әйтәм.* М.Насыйбуллин

3) *күч.* Гамәлдә, яшәештә. *Беренче рус революциясеннән соң йөз ел үткәч, социализм җирлегендә шытып чыккан, бүгенгәчә исән-имин яшәп калган сатирик журналыбыз --- «Чаян» дәфтәре генә.* Казан утлары

**ИСӘНКЕРӘ́Ү** *ф. диал. к.* **исәнгерәү**. *Яңа гына йокыларыннан уянган солдатлар исәнкерәгән кебек бар[алар].* М.Гафури

**ИСӘНЛӘШҮ** *ф.* 1) Очрашканда, бер-береңне сәламләү. *[Якуб абзый] Ул Зиннәт белән баш иеп исәнләште дә сүзсез генә стена буена килеп утырды.* Г.Бәширов. *Шул арада Бибиҗамал, тавыш-тынсыз гына чыгып, Әмирҗан белән исәнләште дә арт як өйгә чыгып китте.* Ш.Камал. *Кыз йомшак кына исәнләште дә, матур аяклары белән йөзеп баргандай җиңел атлап, кухняга үтеп китте.* З.Фәтхетдинов

2) Саубуллашу, хушлашу; исән бул (тор), исән булыгыз (торыгыз) һ.б.ш. сүзләр әйтеп аерылу. *Кыз --- яңадан бер күлмәклек ситса ала да, исәнләшеп, чыгып китә бу.* Әкият. – *Тфү, мөртәт! – диде дә «лачт» итеп Госманга таба төкерде, үзе, ашыгыч атлап, ишеккә барды, тиз-тиз киемнәрен киде дә һичкемгә бер сүз әйтми, исәнләшми чыгып китте.* Г.Ибраһимов. *Малайлар, үзләренең капчыкларыннан поездда ашап барырга билгеләнгән каз итләрен, атланмайларын, кабартмаларын чыгарып, Нәҗип алдына куйдылар да исәнләшеп чыгып киттеләр.* Г.Гобәй

**Исәнләшә башлау** Исәнләшергә тотыну. *Ахырдан гел елмаешып исәнләшә башладык.* Р.Миңнуллин. *Мине очраткан чакларда да ай буе дәшми кара коелып йөрде, аннары, ничектер, яктырып исәнләшә башлады*. З.Гыйниятова

**Исәнләшеп алу** Тиз генә исәнләшү. *[Булат:] Җиһанша агай, синең белән исәнләшкән дә юк бит әле. Хаҗиларча бер исәнләшеп алыйк булмаса*. К.Тинчурин

**Исәнләшеп йөрү** Даими рәвештә, һәрвакыт исәнләшү. *Аз сөйләш, күп тыңла. Кеше белән исәнләшеп йөр*. Н.Гариф. *Ә хәзер һәркөнне диярлек мин алар белән очрашам, исәнләшеп йөрим*. Р.Әхмәтҗан

**Исәнләшеп кую** Кинәт, бер тапкыр исәнләшү. --- *хатынга ишеттерү максаты белән, ул юри гадәттәгедән катырак кычкырып исәнләшеп куйды: – Исәнмесез!* М.Хәсәнов

**Исәнләшеп узу** Узып барышлый, кем белән дә булса исәнләшү. *Без, төрле тарафлардан җыелган авыл гыйбадлары, алар белән исәнләшеп узуны да зур бәхеткә саный идек*. Ә.Рәшит

**Исәнләшеп үтү** *к.* **исәнләшеп узу**. *Урамда очраган һәр кеше иң якын танышына эндәшкән кебек исәнләшеп үтә.* Ә.Баян

**Исәнләшеп чыгу** Һәрберсе белән аерым-аерым исәнләшү. *Кул биреп, Васильев белән, Егоров белән, Серебряков белән исәнләшеп чыкты.* М.Хәсәнов. *Егетләр үзе белән бер-бер артлы кул биреп исәнләшеп чыкты.* Р.Мөхәммәдиев. --- *Абдуллин телефоннан редакция һәм типография хатын-кызларын чакырды, һәм, озакламый, алар килеп, чәйләп, исәнләшеп чыктылар.* Ф.Садриев

**ИСӘНЛЕК** *и.* Исән булу. *Тимерхан әтисе белән әнисен искә төшерергә дә курка иде. Киттеләр дә югалдылар. Ни исәнлекләрен белгертеп, ни «үлде» дип хәбәрләре килмәде.* Ф.Сафин. *Туган ил өстенә шундый куркыныч ябырылган бер вакытта үз башымның исәнлеге, үз бәхетем турында гына уйларга минем хакым юк.* Г.Бәширов. *Озын мыеклы абый, бумажнигы эчендәге әйберләрнең исәнлеген күргәч, кинәт дулкынланып, әнисенең кулын кысты.* А.Шамов

2) Организмның дөрес, нормаль эшчәнлеге, аның физик һәм психик иминлеге, камиллеге. *Дөресен генә әйткәндә, [Дугласның] исәнлеге дә какшады соңгы вакытта. Кайчак күкрәге дә гыжлый сыман.* Р.Ишморат. *Соңгы елларда әтиәнисе дә бик бирешкәннәр иде, исәнлеккә дә туеп бетмиләр.* Я.Зәнкиев

3) Сәлам, исәнләшү. *Айсылу аның исәнлеген дә алмады, борылып та карамады*. Ә.Моталлапов

4) **исәнлегенә, исәнлегеңә** *юн. кил. тарт. форм.* Шәраб эчкәндә берәр кешенең сау-сәламәт булуына теләк йөзеннән әйтелә. *[Илфат] Хуҗаларча кыю гына торып басты да рюмкаларны тутырды. – Яңа шәһәр өчен! Һәрберебезнең исәнлеге өчен!* Р.Вәлиев. *Дөресен әйткәндә, без инде кичә аның исәнлегенә Ногман белән төшереп тә алдык.* Г.Гобәй. *Иптәшләр, бу бокалымны мин авылыбызның мәдәни көчләре исәнлегенә күтәрәм.* М.Әмир // **исәнлеккә** *юн. кил.* Шәраб эчкәндә бер-береңә саулык, сәламәтлек теләп әйтелә торган сүз. *Хәтерләдек җырлап исәнлеккә күтәрелгән тулы тостларны.* А.Алиш. – *Егетләр, кызлар! – диде Нателла, бокал күтәреп. – Әйдәгез, күтәрегез әле, минем исәнлеккә!* М.Маликова

**ИСӘНЛЕ́К АЛУ** *ф. сир.* Исәнләшү сүзенә җавап кайтару; бирелгән сәламне кабул итү. *[Әүхәтнең] --- нәрсәдер мыгырданганы ишетелә – исәнлек алганы шулдыр инде, бирмәсәләр, үзе эндәшмәс.* Ф.Сафин

**ИСӘНЛЕ́К БИРҮ** *ф. сир.* Исәнләшү сүзләрен әйтеп мөрәҗәгать итү, күрешү; сәламләү. *[Әүхәт] Очраган кешеләргә күтәрелеп карамас, исәнлек*

*бирсәләр, нәрсәдер мыгырдаганы ишетелә ---.* Ф.Сафин

**ИСӘНЛЕ́КМЕ** *ы. сөйл. к.* **исәнме(сез)**, **исәннәрмесез**. *Туңган тавыш, өшегән авыз белән: – Әссәламегаләйкүм! Әткәй, исәнлекме? – дип, калын җиң эченнән ике кулын сузды.* Г.Ибраһимов

**ИСӘН(ЛЕК)-САУЛЫК** *җый. и.* 1) Сәламәтлек, тазалык; авыру булмау. *Бу кызыйдан, билгеле инде, мин исәнсаулык сорашып тормадым...* Ф.Әмирхан. *Мин, Мөнәвир Закиров белән танышып, аңа, шулай ук гаиләсенә исәнлек-саулык теләдем.* Р.Ишморат. *Килеп күрешкәч, исән-саулык сорашкач, кайберләре тормыш кайгыларын сөйләргә тотыналар.* А.Шамов

2) Исәнләшү, сәлам бирү. – *Исәнсаулыкмы? – диде Нәсимә, шәлен сәке кырыена салып куйды.* Ш.Камал

3) Иминлек; тереклек; гомер. *Ул сугышта чакта аңа исәнлек-саулык теләдек, --- ә ул безнең бәхетебезне көнли.* Р.Ишморат

4) **исәнлеккә-саулыкка** *юн. кил.* Шәраб эчкәндә, бер-береңә саулык, сәламәтлек теләп әйтелә. *Ирләр, исәнлеккә-саулыкка дип чәкешеп, чокырларын бушаткан арада, Миләүшә аш бүлде.* М.Хәсәнов

**ИСӘНЛЕК-САУЛЫ́К СОРАШУ** *ф.* Исәнләшү, сәлам бирү; саулык, хәлэхвәлләр турында сорап белү. *Исәнлек-саулык сорашкач, Гөлҗамал белән Сөембикә табын әзерли башлады.* Ф.Садриев. *Хатыннар исәнлек-саулык сорашкан арада, әлеге дә баягы апа тракторчы егеткә хәлне аңлатты.* Н.Әхмәдиев. *Гадәттәгечә, шау-гөр килеп, хәл-әхвәл, исәнлек-саулык сорашулар башланды.* М.Хәсәнов

**ИСӘ́НМЕ(СЕЗ), ИСӘННӘ́РМЕСЕЗ** *ы.* Очрашканда исәнләшү сүзе буларак әйтелә. --- *таза гәүдәле ир кеше, чемоданын болгап, боларга таба атлады. – Саумысыз, Мөһимә апа, иминлекме? – Исәнме, җанашым, саумы?* М.Маликова. *Кирәмәт тау башына менеп җиткәч тә: – Исәнме, яшьлек дустым! – дидем. «Бик исәнсау әле», – диде каен, яшел яфракларын җилфердәтеп.* Р.Ишморат. *Класс җитәкчесе Сания Салимовнаның йомшак тавышы җылы нур булып рәт арасыннан үтте. – Исәнмесез, укучылар! – Исәнмесез!* М.Галиев

**ИСӘНМЕСЕЗЛӘ́Ү** *ф. сир.* Исәнләшү, «исәнмесез» дип дәшү. *Авылда, нигәдер, «исәнмесез»ләп мәшәкатьләнми кеше.* Р.Зәйдулла

**ИСӘН-САУ** *с. к.* **исән**. *[Ләбибә:] Исән-сау кешеләрнең дә кайчак йөрәге сызлый, Разия апа, бик нык сызлый.* Р.Ишморат. *Бер укол – бары бер укол ясарга кирәк булды, һәм бала исәнсау туды.* М.Маликова. *Кыз «исәнмесаумы?»дан, салкын гына елмаеп, горур рәвештә баш чайкап узудан артыкны сиздермәде ---.* Ф.Хөсни

**ИСӘН-САУЛЫ́КМЫ** *ы. к.* **исәнме(сез)**, **исәннәрмесез**

**ИСӘҢГЕРӘ́Ү** *ф. диал.* Зиһен чуалу, фикер таркалу. *Шактый бардык шикелле, кызның сәер, шомлы мөнәсәбәтеннән исәңгерәп, вакыт чамасын да онытып җибәргәнмен.* А.Гыйләҗев. *Туган-тумачалары Фәрдәнә апаны кайгыдан исәңгерәгән һәм акылы җиңеләя башлаган итеп күрәләр ---.* Х.Камалов

**Исәңгерәп йөрү** Шактый вакыт дәвамында исәңгерәгән хәлдә булу. *...Менә шушы җирдән маңгай сөяген немец пулясы бораулап үткәч, мин байтак заман исәңгерәп йөрдем.* М.Кәрим. *[Сәет] Көне буе исәңгерәп йөргәннән соң, Әнисәдән башка яши алмасын әйтеп салды.* Т.Галиуллин

**Исәңгерәп калу** Ниндидер сәбәптән соң исәңгерәгән хәлгә килү; кинәт исәңгерәү. *Рөстәм, кинәт һавадан бәреп төшерелгән кош сыман, исәңгерәп калды.* М.Кәбиров

**Исәңгерәп киту** Кинәт, беркадәр вакытка исәңгерәү. *[Кыяр башлының] Аягыннан эләктереп алдым да торып бастым, болгап, монысының башы белән тегесенең башына шаңкыдым. Беразга икесе дә исәңгерәп киттеләр.* Ф.Баттал

**Исәңгерәп тору** Бераз, берникадәр исәнгерәү. *Ишектә кызлар күренүгә, беркавым исәңгерәп торды да, очкылык тоткандай нечкә аваз чыгарып, башын мендәр астына яшерде.* Э.Шәрифуллина

**ИСӘП** I *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең гомуми саны, микъдары. *Әнә Инкубатор Фәридә, чебиләрнең исәбен көзен алырсыз, ди.* К.Тинчурин. – *Картлар исәбенә язылдыңмы әллә, кер әйдә, Тәнзил, сине көтәбез, – дип, ул [Нәзифә апа] мине култыклап ук алды.* М.Галиев

2) Билгеле сандагы нәрсәләр арасында, составында (арасыннан, составыннан) булуны белдерә. *Командующий гарнизондагы барлык частьларны, шул исәптән юнкерларны да, казармаларына таратты.* К.Нәҗми. *Һичшиксез, без барыбыз да, шул исәптән егетләр дә, Люцияне ихтирам итә идек ---.* М.Маликова. --- *берәү дә, шул исәптән Матвейның җан дуслары да, моңа ышанмадылар.* Г.Әпсәләмов

3) Нәрсәнең дә булса санын, микъдарын билгеләү нәтиҗәсе. *Шахтёр егет күмер кисә, Кемнәр ала исәбен.* Җыр. --- *офицерларның барысы да зур мәгълүматлы, --- чөнки аларга һәртөрле исәпләр ясарга, --- кирәк бит.* Г.Ахунов. *Ерак, чакрым исәбенә дә тиз генә чыгарлык түгел, санарга тотынсаң, меңнәрдән узып китәр.* Г.Бәширов // Спорт уеннары нәтиҗәсе. --- *«Металлург» соңгы очрашуда «Авангард» командасын 4:3 исәбе белән җиңеп, гомуми исәпне үз файдасына 2:1 ясады.* Шәһри Казан. *17 сентябрьдә «Акбарс» Магнитогорскида «Металлургны» 3:1 исәбе белән отты.* Ватаным Татарстан. *А.Стук шәкертләре Ульян шәһәренең «Волга» хоккейчыларын 10:3 исәбе белән тар-мар итте.* Мәдәни җомга

4) Берәр нәрсәне игътибарга алып, истә тотып билгеләнгән сан, норма. *Каймакны бер кило шикәргә ике йөз грамм исәбеннән салу*

5) Эшләнгән эш өчен түләү, түләнгән хак. *Иртән алырга уйлаган исәпне кичкырын гына алдылар. Исәптән вак-тияк әйбер һәм акчалата алганнары чигелдереп, һәммәсенә йөз ун сумлык акча бирелде.* Ш.Камал. *Тулы исәп ясау*

6) Алдан ясалган хисап, экономия. *[Мостафин] Бабасының исәп белән тора белүенә чын-чынлап гаҗәпләнә.* М.Әмир

7) **исәпкә** *юн. кил.* Кемнең дә булса акчасына, хисабына. *Безнең ашау-эчү үз исәбебезгә, әлбәттә.* М.Җәлил

8) **исәбенә** *юн. кил.* Берәр нәрсә урынына, бәрабәренә. *Акча исәбенә он белән бәрәңге бирделәр.* Г.Ибраһимов. *Күптәннән үк инде Әхтәм морза имениесенең яртысын да вексельләр исәбенә алырга ниятләнеп йөргән Юныс бай өчен, сугыш елларында капиталы бермә-бер үскән фабрикант өчен, хәзерге хәлләр, чынлап та, ут йоттырырлык иде!* К.Нәҗми

9) *сөйл. күч.* Эшләгән эш өчен хисап, отчёт. *Санап ал да расписка яз! Иптәшләргә исәбен бирергә туры киләчәк.* К.Нәҗми

10) **исәптә** *күч. у.-вак. кил.* Яхшылар яки начарлар рәтендә исәпләнү турында. *Мәктәптә минем бала начар исәптә йөрми*

11) **исәптә** *у.-вак. кил.* Берәр нәрсәнең исәпле, санаулы булуы турында. *Акчаның һәр тиене исәптә*

12) *күч.* Бер-берәңә кара-каршы әйтелгән үткен сүз, астыртын эш, үчегүле гамәл. *[Хатынның] Җилкәсенә кулларымны куеп көлеп җибәрдем: – Исәп тигезләнде: 1:1, – дидем. – Уенны туктатырга вакыт.* Ф.Баттал

**2**. *рәв. мәгъ. диал.* Артык, күп. *Инде бишәү булдык, кашык саны ишәйде. Ирең-атың янында булмагач, анысы да исәп.* Г.Бәширов

◊ **Исәбе күренмәү** Гаять күп булу, исәпсез-хисапсыз булу. *Сүзнең, гәп-әңгәмәнең исәбе күренми, ачылып китәләр дә хәйран калып сорашалар.* Г.Ибраһимов. *Ул башка приданнарының исәбе дә юк, ди.* Г.Камал. **Исәбенә чыга алмау** *к.* **исәбен җую**. *Аның салдырган мәчетләренең исәбенә чыга алмассың бит!* Г.Ибраһимов. **Исәбен җую** Исәптә саташу, ялгышу. *Тик ул хәзер намазлык өстендә, күбесенчә, Газизе турында уйлап уздыра, кайвакытларны бөтенләй онытылып, рөкугь урынына сәҗдәгә китеп бара, дүрт фарыз урынына ике белән генә дә очлап куйгалый, исәбен җуеп, арттырып та җибәргәли торган иде.* Г.Бәширов. **Исәбен югалту** *к.* **исәбен җую**. **Исәбе (дә), хисабы (да) юк**. Бик күп, санап бетерерлек түгел. *[Байтирәк:] Халык бармы? [Исәнбай:] Исәбе дә, хисабы да юк. Күрше авыллардан да килгәннәр.* Т.Гыйззәт. **Исәбе, чуты юк** *к.* **исәбе (дә), хисабы (да) юк**. *Ә [өйдәге] мәшәкатьнең исәбе, чуты юк.* Б.Камалов. **Исәбе (дә) юк** *к.* **исәбе (дә), хисабы (да) юк**. *Туздырган акчаның исәбе юк.* Г.Ибраһимов. **Исәпкә бар, санга юк** *шелт.* Исемлектә исәптә йөрсә дә, фактта эшкә яраксыз кеше яки әйбер турында. *[Хәмәтшин] Сүзен дәвам итмәкче идеме, юкмы, кемдер кычкырып өлгерде: – Бер культиватор Нарат чокырында җиргә сеңеп бара. Исәпкә бар, санга юк*... Ф.Баттал. *Штат тулы, ә эшләргә кеше юк. Сәбәбе нәрсәдә? Кадрларыбызның исәпкә бар, санга юк булуында.* М.Хәсәнов. *Кешеләр исәпкә генә бар бездә, санга юк.* Р.Ишморат. **Исәпкә сан тутырыр өчен** Билгеле бер төркемгә, категориягә кертелеп тә, үз сыйфатлары белән шул төркемгә керергә лаек булмаган кешегә яки әйбергә карата әйтелә. *Ничек итеп теге юлбасарлар үзләренең шайкаларына керткәннәр? --- Исәпкә сан тутырыр өчен, минемчә.* Ш.Камал. **Исәпне ачу** 1) Спорт уенында үз файдасына беренче очко алу. *Казанлылар беренче минутлардан ук өстенлекне үз кулларына алып, дүрт минут та үтмәде, исәпне Алексей Терещенко ачты.* Шәһри Казан; 2) Саклык кассасына, банкка беренче тапкыр акча салу; счёт ачу. **Исәпне өзү (бетерү)** 1) Үтәлгән, башкарылган эш өчен тиешле хакын түләп бетерү. *Газиз бәй: – Әй, чиямне урлаган Чалы кошы! Кая, чиямне кайтарып бир дә, шуның белән исәпне өзик, – диде ---.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) Үч алу, үч кайтару. *Бар белгәне шул булды: «Илгә кайтам, күрәсе, сөйләшәсе кешеләрем бар, бу фани дөнья белән өзәсе исәпләрем бар», шулай ди торгание мәхрүмкәй.* Ф.Хөсни. **Исәпне хисапка китерү** *к.* **исәпне хисапка чыгару**. **Исәпне хисапка чыгару** Матди мөмкинлекләрдән чыгып, аларны исәпкә алып эш итү. *Болай да әле очын очка ялгап, исәпне хисапка чыгарып булмый.* А.Әхмәт. **Исәптән төшеп калган** *мыск.* Булдыксыз, ихтыяр көче нык булмаган, йомшак кеше турында. **Исәптән төшерү** *к.* **исәптән чыгарып ташлау**. *Ә Гуля-Гөлсинә «Түгәрәк»нең ирененнән үк үбеп алды: «Монда мин дә бар әле, мине дә исәптән төшермәгез...» – дия иде ул гүя.* Р.Мөхәммәдиев. **Исәптән чыгарып ташлау** Игътибарсыз калдыру, әһәмият бирми башлау, бар дип тә белмәү. *Без көндәлек тормышыбызда --- һәртөрле эгоистлык, мещанлык, хезмәткә җиңел карау элементларын да, әлбәттә, исәптән чыгарып ташлый алмыйбыз.* Ф.Хөсни. **Исәптә тору** Исемлектә булу, исәптә саналу. *Аларга барыбер түгелмени, исәптә торгач, кешеме – кеше.* И.Гази. *Без сугышка киткәндә, магазинда фактически ул сату итә, Шәйсолтан бабай исәптә генә тора иде.* Х.Сарьян. **Исәп тулмаганга яралган** *шелт. к.* **исәпкә бар, санга юк**. **Исәп юк** *к.* **исәбе юк**

**ИСӘП** II *и.* 1) Уй, фикер. --- *минем исәп тизрәк машинадан чыгып ычкынырга иде.* М.Маликова. *Мәҗлес соңында --- Айдар учак сүндерү нияте белән берьялгызы торып калды. Хәер, артларыннан тиз генә куып җитәргә иде исәбе.* М.Галиев. --- *минем үз өстемә мәшәкать алырга исәбем юк, дип, турыдан ярып әйтегез.* Р.Вәлиев

2) Нәрсә булса да эшләргә ният, план. – *Рәсимә апа иптәшләремнең лекцияләрен алып килеп тора. Караштырып барам, – диде Гөлгенә, тумбочка өстендә яткан дәфтәрләргә күрсәтеп. – Артка калырга исәп юк.* Ә.Сафиуллин. *Еракка төбәлгән бик мәкерле исәп иде бу.* Ә.Еники. --- *Нәфисәнең исәбе, Габдрахман турында сүз куертып, Давытның үзеннән актык нәрсәне әйттерү иде, шуңа күрә ул һаман шикле якны каерды.* Г.Ибраһимов

3) Сагышлы, кайгылы уй. *Настёна --- төпченүендә булды: – Шуннан соң мине беркайчан да бала белән күрмәдеңме? Әйбәтләп уйла әле. – Юк, күрмәдем. – Бәлки, хәтереңнән генә җуелгандыр. Башка исәпләр кысрыклап чыгармадымы икән?* В.Распутин. *Ирне эш картайтмый, исәп картайта.* Әйтем

◊ **Исәбе күренмәү** Кемнең дә булса нияте, уе сизелмәү. *Әмма халыкның таралыр исәбе күренми, киресенчә, кызыксынып килүчеләр һаман арта бара иде.* Ф.Хөсни. --- *[карт] тәмам*

*зәһәрләнгән, нәрсә булса шул, дип бара һәм икеле-микеле җавап белән генә юанып калырга һич исәбе күренми иде.* Ф.Хөсни. **Исәбенә керү** Берәр нәрсә эшләргә уйлау, ниятләү. *Әти-әнисе белән киңәшләшеп алу өчен, Айсылу туган ягына кайтып килү исәбенә керде.* Ә.Моталлапов. **Исәбендә дә юк** Кемнең дә булса ниятендә, уенда булмау, сизелмәү. *Хатын көтмәгәндә мыскыллы төчеләнеп: – Ә-ә, Атласны эзләп килдеңмени? – диде. Зөлфәне өенә кертергә аның исәбендә дә юк иде...* М.Маликова. **Исәп баглау** *к.* **исәп тоту**. *Кайбер эшлекләләр тамашачылар арасыннан иң таләпсезенең, зәвыксызының ихтирамын казануга исәп баглый...* Ә.Гаффар. **Исәп белән** 1) Берәр төрле файданы күздә тотып, нәрсәгә дә булса исәп итеп. *Бәк Бәкич, өйләнгәндә, хатынны исәп белән алган.* Х.Кәрим; 2) Өмет баглап, өмет итеп. **Исәп итү (йөртү)** 1) Берәр эш эшләргә ниятләү; нәрсәне булса да күздә тоту. *Нишләргә соң, каравыл кычкырырга микәнни, дип куркынды йорт хуҗасы, ләкин җебеп төшмәскә исәп итте.* М.Хуҗин. *Быел да ярышырга исәп итәрләрме сезнең белән, әллә юкмы, анысы инде алар эше.* Г.Бәширов. *Ринат бәхәсне туктатырга исәп итте.* Н.Хәсәнов; 2) Өмет баглау, өмет итү. *Бала [тормышны] авыз ачып һава сулау кебек ансат күреп үссә, тормыш үз башына калгач та шуларга исәп итә торган була.* Г.Гобәй. **Исәпкә алу** 1) Билгеле бер исемлеккә кертү, санау. *Котдус Вафин озатылырга тиешле кешеләрне озатышып, алардан калган мал-мөлкәтне, иген коралларын исәпкә алышып, --- фатирына кич кенә һәм бик арып-талып кайтты.* Ф.Хөсни. *Исәпкә алынган малны уттан, талаудан, әрәм-шәрәмнән саклау өчен, чаралар күрелде.* И.Гази. *Ханлыкта яшәгән һәрбер кеше исәпкә алынып, бер яки берничә төрле салым түләргә тиеш булган.* Р.Мостафин; 2) Игътибарга алу, истә тоту. *– Акыл белән уйласаң, сез хаклы кебек, – диде Харис. – Ләкин сез Җәүһәриянең холкын исәпкә алмыйсыз.* М.Маликова. *Хәзер Нәгыйм, ике арада булган шушы мөнәсәбәтне исәпкә алып, Мостафа белән сөйләшергә дип, аның янына барган иде.* Ш.Камал. *Күп уйлап тормыйча, ул аяк астындагы баткакны да исәпкә алмый, турыдан юл ярып, янгынга ташланды.* Ә.Фәйзи. **Исәпкә бату** Бик нык уйлану. *Бервакыт ул авыз эченнән генә көйли, моңая башлады. Бу аның исәпкә баткан чагы иде.* Г.Галиев. *– Нәрсә, бик исәпкә баттың, Кәбиров, ә? – диде замполит – төртмәле тел.* Х.Камалов. **Исәпкә калу** Берәр нәрсә турында уйлану, бер уй белән мавыгу. *Ул, мөгаен, кулына умырзая чәчәге тотып, исәпкә калган Газинурны ерактан ук күргәндер – ерактан ул чыннан да шәп күрә – хәзер, ничектер, хәйләле дә, шаян да, мөлаем да елмаеп килә иде.* Г.Әпсәләмов. *Шушылай тиз үкмени, дип, бераз исәпкә калып сорады Газинур.* Г.Әпсәләмов. **Исәпкә кертү** *к.* **исәпкә алу**. **Исәп кору** 1) Берәр нәрсә эшләргә җыену, план кору, ниятләү. *Фәхри исән чагында зур улын фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбенә бирергә исәп корып йөргәнен сөйләде.* Г.Ибраһимов; 2) Алдан уйлау. *Хәзер лейтенантның колагына бер сүз дә керми, әлеге эзне ничек төшереп алырга, дип кенә исәп кора башлады.* З.Фәтхетдинов. **Исәп тоту** 1) Берәр нәрсә эшләргә ниятләү, җыену. *«Ватан» пионерлары орлыкны шулардан сорарга исәп тоттылар, ләкин телләре тик тормау аркасында, эшне харап итеп ташладылар.* Г.Гобәй. *Буранлы төн уртасында мунча кереп йөрергә ни азаплары калган аларның? Димәк, җинаять эзләрен юарга исәп тоткан.* М.Маликова; 2) *к.* **исәп итү (йөртү)** (*2 мәгъ.*). *Украинаның шактый өлешенә капкын һәм ятьмәләрен куеп чыккан Махно нәкъ менә шуңа исәп тотты да.* З.Фәтхетдинов. *--- калган гомерен Сәүбән канаты астында кырын ятып үткәрергә исәп тотучы Миңнулла чәчрәп чыкты.* Ф.Хөсни. *Квартирына, байлыгына исәп тотып чыктым.* Д.Вәлиев. **Исәп төшү** Башка уй төшү; план, ният туу. *Әллә, юкса, минәйтәм, башыңа берәр исәп төшеп, шуны сагышлап утырасыңмы, дим?* Ф.Бурнаш. *Башларыңа исәп төшсә, качып кына котылам димә икән!* М.Маликова

**ИСӘ́П АЛУ** *ф.* Эштән азат ителеп, расчёт алу. *Заводтан исәп алу*

**ИСӘ́П БИРҮ** *ф.* 1) Хезмәт хакын түләп, эштән азат итү. *Артык эш юк дип, безгә исәп бирделәр.* Ш.Камал

2) Кемдер каршында кылган гамәлләрең турында яки ниндидер әйберләрнең сакланышы буенча хисап тоту

**ИСӘ́П КЫЛУ** *ф.* Берәр кеше яки нәрсә турында нинди дә булса фикердә булу. *– Миңа ни сан, ди, син үзеңне картка исәп кылгач? – [диде Шәйдулла агай].* М.Хуҗин

**ИСӘПЛӘНҮ** *ф.* 1) Исәпләп чыгарылу. *Корбаннарның саны йөзләр белән исәпләнде.* Казан утлары. *Беренче декабрьдән бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы яңа система нигезендә исәпләнеләчәк.* Ватаным Татарстан. *Чыннан да, бу шимбәдә су юлы буенча да, коры җирдән дә Изге Болгар җиренә агылучылар меңнәр белән исәпләнер.* Татарстан яшьләре

2) Саналу. *...Болар нәселләре белән үткен кешеләр исәпләнәләр иде.* М.Мәһдиев. *Алар тагын шунысы белән дә кызыклы, чөнки һуннар тарихта мәгълүм беренче төрки кабиләләр булып исәпләнәләр.* Р.Фәхретдинов

3) Исәпкә алыну, исәпкә кертү. *Бу акчалар бурычны түләүгә исәпләнсен*

4) Кемгә яки нәрсәгә булса да яраклы булыр дип исәп тоту. *Сүзлек укытучыларга һәм укычыларга исәпләнгән*

**Исәпләнеп бетү** Тулысынча, бөтенесе, булган берсе исәпләнү

**Исәпләнеп йөрү** Һәрвакыт, гел исәпләнү. *Авылның хөрмәтле кешеләреннән исәпләнеп йөргән көтүче Степан исә сүзен ерактан йөртеп тормый, бераз мишәрчәләтеп әйтә дә сала ---.* Г.Гыйльманов

**ИСӘПЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса исәбен, санын билгеләү (алу); исәбенә чыгу; санау, хисаплау. *Баш инженерның төп вазифаларына объектив килеп, эш хакын шуннан чыгып исәпләсәк, миңа чиста көмеш белән бары тик бер сум илле тиенләп акча түләнергә тиеш.* Р.Вәлиев. *[Кәримә] Иреннәрен бөрештереп авыз эченнән нидер исәпләде.* А.Вергазов. *--- ул максатыма гомерем буе (үндүрт яшьтән*

*алып исәпләсәң, хәзер – егерме сигез, нәкъ ундүрт ел килеп чыга икән) барам бугай инде.* З.Хөснияр // Нинди дә булса санаулар, хисаплаулар ясау. *Аңа аяклы мал симертеп суюның, базардан ит сатып алуга караганда, никадәр арзанга төшүен исәпләп күрсәтә.* Ә.Еники. *[Зәйнәпбануның] --- бармаклары өстәл астында бөгеләязыла, өстәмә итеп алачак бодаеннан йорттаниләр җиткерәсен --- исәпли иде.* Г.Бәширов. *Сез чишенеп урнашып беткәч кенә, мин дәресне башланган дип саныйм һәм кырык биш минутны шуннан исәплим.* М.Мәһдиев

2) Саннар белән арифметик гамәлләр (кушу, алу, бүлү, тапкырлар һ.б.ш.) башкару. – *Миллион сәгатьтә ничә ел булганны да, үлгән чакта бабайга ничә яшь булганны да укучылар үзләре исәпләп чыгарырлар, – ди.* Г.Гали. *Язарга һәм санарга өйрәткәндә, кайбер укытуны җиңеләйтүче ысуллар, мәсәлән, төрле төстәге ташлар ярдәмендә санау, исәпләүнең гадиләштерелгән алымнары һ.б. кулланыла.* Ә.Хуҗиәхмәтов

3) Берәр нәрсәне күздә тоту, игътибарга алу. *Бина җимерелмәсен, нык булсын, үз-үзен тотсын өчен, --- бик төгәл исәпләү кирәк.* М.Маликова

4) Кеше турында билгеле бер фикердә булу, аңа билгеле бер бәя бирү; кем яки нәрсә дип карау, санау. *Күрше бабайны чукракка исәпләү. Дус итеп исәпләү. Үзеңне бәхетле дип исәпләү*

**Исәпләп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә исәпләү. *Бер ишек ачылган арада, Алмаз әллә никадәр мөмкинчелекләрне исәпләп алды.* И.Сираҗи. *Инспектор, кесәсеннән калькулятор чыгарып, тиз генә исәпләп алды: – Сезгә тугыз мең өч йөз егерме дүрт сум туксан тугыз тиен салым салынырга тиеш.* М.Сәлим

**Исәпләп бару** 1) Һәрвакыт, даими исәпләү. *Болгар илендә туган, үлгән һәр кешене мин исәпләп барам.* Н.Фәттах

2) Һәр очракны исәпкә алу, һәрберсен исәптә тоту

**Исәпләп бетерү** Тулысынча, ахырга кадәр исәпләү. *Ул карандашын кәгазь өстендә тиз-тиз уйнатып исәпләп бетерде ---.* Г.Бәширов. *Кыска гына вакыт эчендә нинди генә исем белән нинди генә партияләр тумады?! Аларны белеп тә, исәпләп тә бетерерлек түгел.* Ә.Еники

**Исәпләп карау** Исәпләргә тырышу. *Кулыңдагы бармакларыңны мең тапкыр санасаң яки күктәге йолдызларның санын исәпләп карасаң, бәлки, аларның очына чыгарсың.* А.Алиш. *Ә бер умартада унбиш меңләп эшче корт була. Шуларны исәпләп карасаң, бер семья корт кына да никадәр эш башкара.* Ф.Яруллин. *Яшерен тавыш биргәч, исәпләп карасалар, ни күрсеннәр: бөтенесе дә каршы тавыш биргән, бары тик кара шарлар гына ташланган булып чыга.* Г.Хөсәенов

**Исәпләп килү** Алдан, электән үк, даими рәвештә исәпләү

**Исәпләп кую** Алдан исәпләү. *Сөмбелә әнә шул ике сәгать вакытны алдан ук исәпләп куярга тиеш.* К.Кәрами. *Әби аларны тирләгән бармаклары белән берничә тапкыр санады, әмма акча ул исәпләп куйганча чыкмады ---.* Р.Зәйдулла. *Кунаклар килгәч, аны-моны аңышмыйча бозып ташлавы бар. Ташы кызган. Мондый очракта һәр нәрсәне алдан исәпләп куйган яхшы.* А.Гыйләҗев

**Исәпләп тору** Сөйләү моментында яки даими исәпләү, исәпләү эше белән мәшгуль булу

**Исәпләп чыгару** *к.* **исәпләп бетерү**. *Шуларның барысын бөртеген бөртегенә китереп исәпләп чыгаргannan соң гына, бер гектар җиргә күпме орлык кирәге билгеле буласы.* Х.Сарьян. *Гел үзләре җыйган азыкны гына ашаган очракта, өч айга җитәрлек азык алырга кирәк. Моны Шамил исәпләп чыгарды.* Р.Мөхәммәдиев. *Күңеленнән Андрейның алгы сызыкка киткән вакытын исәпләп чыгарды.* Х.Камалов

**Исәпләп чыгу** Һәрберсен берәмберәм (аерым-аерым) башыннан ахырына кадәр исәпләү. *Төннең төн буе йокламыйча акчамны исәпләп чыктым – мин дигәнчә түгел.* Ф.Хөсни. *Акча, сәмән, дим, күктән яумый. --- Кичә кич, өйгә кайтып аугач та, күзгә йокы керми, төне буе исәпләп чыктым.* Ф.Сафин

**Исәпли бару** *к.* **исәпләп бару**

**Исәпли башлау** Исәпләргә тотыну. *Уйга калды милләттәшем. Башы түгәрәк: исәпли-саный башлады. Мində дә өмет уянды. Акча колы, байлык колы булмасын иде егетләребез.* Т.Миңнуллин. *Бигрәк тә Хөриянең апасы бала ияртеп иреннән кайткач кырысланып китте аларның әниләре. Ашауэчүне бик исәпли башлады.* Ф.Яруллин. *Ирләреннән башка гомер кичерүләренә күпме еллар узган. Исәпли башласаң, очына да чыга алмассың...* Ф.Җамалетдинова

**Исәпли бирү** Бернигә карамыйча исәпләүне дәвам итү

**Исәпли китү** Исәпләп карау. *Кешелекнең борынгы, зур һәлакәткә кадәрге тарихы, технологик үсеш юлы да, исәпли китсәң, вакыт исәбе белән бик кыска булмаган.* Р.Фәизов

**ИСӘПЛӘҮ** II *ф.* 1) Уйлау, фикер йөртү. *Мин елмаеп куйдым! Мөгыйн абзый үзеннән башка бер эш тә бармас дип исәпли иде, ахрысы.* М.Маликова. *Тагын очрашкач, Фәүрия: – Мине тәрбияләмәкче буласыз бит, бүген дә миңа лекция укырга җыенасызмы? – дип, зәһәрен чәчәргә исәпләде.* М.Хуҗин

2) Берәр нәрсә эшләргә ниятләү, җыену. --- *мин, вузга кергәнгә кадәр, бер ел (ике җәй, бер кыш) ял итәргә исәплим.* М.Җәлил. – *Бергә-бер яшәргә исәп әле. Карт --- иреннәрен бөрештереп әйтә куйды: – Әһә. Исәплисез, димәк. Ә кайчан исәпләүдән туктыйсыз?* З.Фәтхетдинов. *Шулай да татарлар өчәвебез бер сүздә булып, кышны монда үткәрергә исәпләдек.* Ш.Камал

3) *сир.* Кайгыру; кайгылы, хәсрәтле уйлар уйлау. *Үз язмышын каргый-каргый Елый ул, исәпли ул.* М.Җәлил

**Исәпләп алу** Тиз арада, тиз генә уйлау. *Хөсниҗамал Мохтарны бөтенләй тиле, аңгыра кешеме әллә дип тә исәпләп алды.* Ш.Камал. --- *безнең әбибабаларыбыз ул җәмгыятьне гадел итеп төземәгәннәр. Бөтен якларын да уйлап, исәпләп бетерә алмаган алар.* Р.Фәизов

**Исәпләп бетерү** Тулысынча, ахырынача, һәр ягын җентекләп исәпләү. *Һәр ягын исәпләп бетергәч, Кәримә ирекле-ирексез Мифтах белә тормак-*

*чы, авыр булса да, гомерен бергә үткәрмәкче булган иде.* Г.Исхакый

**Исәпләп житкерү** Ахырга кадәр исәпләү. *Уңай герой Гаязга да көрәшче тәҗрибәсе җитеп бетми, анда тәвәккәллек белән башсызлык аралаша, акыл белән уйлап, исәпләп җиткермәү аны фаҗигагә китерә.* Ф.Хатипов

**Исәпләп йөрү** Озак вакыт уйлап, планлаштырган булу. *Күршедә генә үскән бу акыллы, тыйнак, хәтта бераз юаш Нәзирне ул күңеленнән үзенең кияве дип исәпләп йөри иде.* Ф.Яруллин

**Исәпләп карау** Исәпләргә тырышу. *Исәпләп карагач, бу кыланышның гап-гади дуамаллык, башсызлык булганлыгын соңга калып булса да аңладым.* М.Юныс

**Исәпләп килү** Күптәннән, электән үк исәпләү. --- *йөрәкне бар халыклар да диярлек, традицион рәвештә, кешенең хисләнү әгъзасы дип исәпләп килгәннәр ---.* Т.Гыйззәт

**Исәпләп кую** Алдан исәпләү. --- *шул вакыт, директорны тәмам аяктан егарлык итеп, берничә зәһәр сүз әйтергә исәпләп куйган иде.* М.Шаһимәрдәнов. *Ләкин алдан никадәр барысын да уйлап, исәпләп куймасын, тарлавык авызындагы бу очрашу Марис теләгәнчә барып чыкмады.* Н.Фәттах

**Исәпләп тору** 1) Ниндидер бер фикергә, уйга килү. *Шуңа карамастан Сәлим хан илчеләре сүзенә ышанды һәм бу хакта кенәз белән әңгәмә тотарга исәпләп тора иде.* М.Хәбибуллин

2) Берәр нәрсә эшләргә ният итү, планлаштыру. *Закирның күз кабаклары ачылды, зәңгәр күзләре нәрсәдер исәпләп торган кебек итәләр.* Х.Камалов. *Камага алып барып кайтырга исәпләп торабыз.* М.Гафури. --- *ләкин болай селкенеп йөрүдән туйдым, ди, колхозыбызның хәзер үз машиналары булачак, берәр комбайнга басарга исәпләп торам, ди.* Ә.Еники

**Исәпли башлау** Исәпләргә тотыну. *Беләм мин аны, Зәбидә! Алар – узганбеткән нәрсә ич. Барысын исәпли башласаң...* Н.Хәсәнов. *Иң мөһиме – ул аны үзе белән тиң итеп, алай гына да түгел, үзеннән бераз өстенрәк тә итеп исәпли башлады.* Н.Фәттах

**Исәпли тору** Билгеле бер вакыт эчендә уйлау халәтендә булу. *Исәпли торгач, Фәнзаман Баттал татар халкында көлүнең йөздән артык төре барлыгын ачыклаган.* Ф.Баттал

**ИСӘПЛӘШҮ** *ф.* 1) Тиешле акчаны, малны тулысынча түләп, үзара исәп-хисап ясау; исәп-хисап эшләрен өзү; алыш-биреш ясау. *Илле тәңкә акча да алып килгән идем. Җитмәслек булса, тагы үз яныннан бераз кушып булса да алып кайта күрсен. Кайткач исәпләшербез.* Г.Камал

2) *күч. сөйл.* Үч алу, үч кайтару. *Изаил Харисович елмайды, ләкин аның бу елмаюы ачы иде. «Бурычлы булып калмам, исәпләшербез» дигәнне аңлата иде аның карашы.* М.Маликова

3) *күч.* Ниндидер шартларны, хәлләрне, тәртипләрне игътибарга алу, шулар белән хисаплашу. *Кәбир әфәнде үзе дә реформаларга каршы түгел, һәм аның мөдәррис атасы да улының фикере белән бик исәпләшә иде.* Ә.Фәйзи. *Шулай да егет балыкларның каршы торулары белән исәпләшмәгән: әрҗәсен үрә биргән.* Г.Гобәй. *Дөнья кайгысы көчлерәк булганга күрә, Сәхәү алар белән исәпләшмәгән, теше-тырнагы белән атасыннан калган дөньягаябышкан.* М.Әмир

4) *күч.* Берәүнең әйткәнен, кушканын игътибарга алу, аның белән санлашу. *Син мине авыр чакта ташлап киттең, минем белән тамчы да исәпләшмәдең.* М.Маликова. *Райком секретарьлары аның белән исәпләшәләр, киңәшәләр, күзенә карап «Миргаяз ага» дип кенә сөйләшәләр.* М.Мәһдиев. *Хәзер ул үз каласында иң дәрәҗәле, иң тәҗрибәле врач санала. Аны хөрмәт итәләр, аның белән исәпләшәләр.* Г.Әдһәмова

**Исәпләшә башлау** Исәпләшергә тотыну. *Безнең нәшрият оешмаларыбызга яңа туып килгән эшче-крәстиян укучысы белән исәпләшә башларга, әсәрне шулар эчендә тарата белү чараларын карарга бик вакыт җитте инде.* Г.Ибраһимов. --- *һәр бишьеллык саен рәиснең күкрәгенә орден тагылды, районда чын-чынлап исәпләшә башладылар.* Казан утлары

**Исәпләшеп алу** Тиз генә исәпләшү, үзара исәпләшеп нәтиҗә ясау. *Карт белән карчык, шулай киңәшләшеп, исәпләшеп алганнан соң, тынычлап йокларга яттылар.* З.Фәйзи

**Исәпләшеп бетерү** Тулысынча, ахыргача исәпләшү

**Исәпләшеп килү** Һәрвакыт, даими рәвештә исәпләшү

**Исәпләшеп кую** Алдан исәпләшү. *Ләкин акчасы түләнгән инде аның. Хәйдәр исән чагында ук исәпләшеп куйды.* М.Кәбиров

**ИСӘПЛЕ** I *с.* 1) Исәпләнгән; санаулы; хисапка алынган. *Бабайлардан калган сүз бар: «Исәпле көн тиз үтә», – диләр.* Әкият. *– Сине чакырдым! – диде дә санап чыгарылган кебек өзек, исәпле сүзләр вә кискен тавыш илә ялчыга әмерләр бирә башлады.* Г.Ибраһимов. *Кисәтеп әйтәм: һәр минут исәпле чакта билгеләнгән юнәлештән читкә тайпылып, вакытны әрәм итәсе булмагыз!* З.Фәйзи

2) Чикле, аз; кадерле. *Әнә шул иң кирәкле әйбер (гомер) бик исәпле бит бу фани дөньяда.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Һәр нәрсәне исәпли торган, хәйләкәр. *Холыклары шактый үзгә: Мәхмүт бик исәпле, астыртын, үзаңлы, ә Мәдинәсе исә беркатлы, садә, ачык йөзле, киң күңелле ---.* Р.Фәизов. *Әмма Минсадыйк буйга Мәрфугадан шактый кайтыш бер карсак, җитмәсә, бик исәпле, саран, хәйләле иде.* Р.Фәизов

**ИСӘПЛЕ** II *с.* Кайгылы, хәсрәтле, сагышлы. *Лариса Сөнгатовнаның чырае караңгы, күз төпләре күгәреп чыккан, төн йокламаган, исәпле кеше кебек күренә иде ул бүген.* М.Маликова. *Аның болай да исәпле башына бүген өч уй төште.* Р.Батулла. *Ниндидер исәпле уйларга чумганлыгы кыяфәтенә чыккан иде.* Х.Камалов

**ИСӘП-САН** *җый. и.* Төрле исәпләүләр, саннар. *Без беравык исәпләрсаннар, чагыштырмалар теле белән сөйләшеп алыйк.* Г.Бәширов

◊ **Исәбен-санын югалту** *к.* **исәбен җую**. **Исәбе-саны булмау** *к.* **исәбе-хисабы булмау**. *Йорттагы малның, байлыкның исәбе-саны булмау.* **Исәбе-саны юк** Бик күп. *Тамбукан күлендә дәваланып, сәламәтләнеп кайтып*

*китүчеләрнең исәбе-саны юк.* А.Муранов. **Исәп-санын алып бетергесез** *к.* **исәбе-саны юк**. *Сез [милиционерларның] исәп-саныгызны алып бетергесез бит хәзер.* З.Фәйзи

**ИСӘПСЕЗ** I *с.* **1.** Исәбе, хисабы алынмаган, исәпләп бетергесез, бик күп, чиксез күп. *Фәйрүзә перрондагы ыгы-зыгы, исәпсез халык арасыннан Таһирны эзләвен күз алдына китерде.* М.Галиев. *Иң соңгы очрашу. Хәзер бу очрашуның һәр детале зур мәгънәгә ия булып калды, һәр төсмер исәпсез күп сораулар уята.* Х.Камалов. *Безгә бары риваятьләр генә килеп җитте: көнетөне дөрләгән учаклар ---, шешенгән-күбенгән, кара көйгән мәетләр, кара киемле монахлар озатып барган исәпсез җеназалар...* Р.Мостафин

2) *күч.* Исәп белән эш итми торган, исраф итүчән. *Исәпсез хуҗабикә*

**2.** *кис. функ. күч.* Бик күп, чамадан тыш, гаять, ифрат. *«Ир» дигән исемне күтәреп йөргән хәлдә үзләренең никадәр түбән җанлы икәнлекләрен аңламаучылар исәпсез бит.* С.Зыялы. *[Әни] Иоланта өйдә чагында мине ачуланмады, ул югында төртке сүзләрен исәпсез сипте.* М.Хуҗин. *Ул, колагындагы исәпсез күп чыңнар арасыннан, кинәт теге, аңа таныш булган, кайчандыр якын, соңыннан эчке дошманлык тудыра башлаган, хәтфә кебек йомшак тавышның яңгырап киткәнен ишетте.* А.Шамов

**ИСӘПСЕЗ** II *с.* Уйсыз, гамьсез, ваемсыз. *Мин әлегә хәтле чыдадым-чыдадым да, хәзер инде син мине чыдамнан чыгардың; ай акылсыз, исәпсез!..* Ш.Камал. *Алай да юләр булды Нурислам, үз тормышында исәпсез булды.* Р.Фәизов. *Хәзергә әле Настёна бер исәпсез тик кенә ята бирә, ә тормыш тәгәрмәче һаман тәгәри дә тәгәри.* В.Распутин

**ИСӘПСЕЗЛЕК** I *и.* Бик күп булу, бихисап булу

**ИСӘПСЕЗЛЕК** II *и.* 1) Уйсыз, гамьсез, ваемсыз булу. *Исәпсезлек матур кызлар башына җитә*

2) *күч.* Уйлап, исәп белән эш итмәү. *Исәпсезлек аркасында финанслауда хата җибәрелгән*

**ИСӘПСЕЗ-САНСЫЗ** *с. к.* **исәпсез-хисапсыз**. *[Камалиевның] Күңелен исәпсез-сансыз сораулар бимазалый.* М.Насыйбуллин. *Исәпсез-сансыз бормаларда янтаеп, --- Массандра тауларына күтәрелгәч тә уңнан диңгезнең хыялый зәңгәр манзарасы ачылды.* А.Хәлим. *Мансуров, барып җиткәч, бик еракларга кадәр сузылып киткән исәпсез-сансыз тырма эзләрен рәхәтләнеп карап торды.* Г.Бәширов

**ИСӘПСЕЗ-ХИСАПСЫЗ** *с.* Исәбе, хисабы булмаган, бик күп, чиксез күп. *Һәр ике як та исәпсез-хисапсыз исәнләшүләр, шаулашулар, хәл сорашулар белән капланды.* Г.Ибраһимов. *Кызның үз гомерендә беренче мәртәбә кибет киштәсенә тәртип белән тезелгән исәпсез-хисапсыз уенчыкларны --- себереп төшерәсе килде.* З.Хөснияр. *Миңа ул һич онытылмас яшел урман эчендәге җиләкле алан!.. Исәпсез-хисапсыз чәчәкләре күңелләрне хозурлый.* Н.Хәсәнов

**ИСӘП-ХИСАП** I *җый. и.* 1) **исәбе-хисабы** *тарт. форм.* Берәр нәрсәнең саны, исәбе, хисабы, күплеге. *Болар белән бергә өйгә әллә ничаклы суык һава керде, исәбе-хисабы булмаган «әссәламегаләйкүм», «исәнмесез», «саумысыз», «исәнмесез», «саумысыз»лап кодалар керде.* Г.Ибраһимов. *Авыл агайлары, шул елганы бөяп, маймычлар җибәргәннәр. Хәзер андагы сазан, кызылканат, алабуга, кәрәкә балыкларның исәбе-хисабы юк.* С.Зыялы

2) Исәпләү, хисаплау, санау эшләре. *Бераз үсә төшеп, мәктәптә исәп-хисап таный башлагач белде Тимерхан: бер дилбегә алты метрлы булса, биш дилбегә утыз метр була ич.* Г.Ахунов. *--- Җәүһәрия өчәр айлык исәп-хисап эшен бер утыруда башкарып чыгарга тырышкан.* М.Маликова. *Председатель белән счетовод исәп-хисап эшләре белән утыралар.* А.Әхмәт. *Сүзләрен, исәп-хисапларын түгәрәкләп бетергәннән соң, Хәйрулла абзый --- Заһидулланы шушында хезмәткә калдыра.* Р.Низамиев

3) Хуҗалыкта, кибеттә, складта һ.б.ш. урыннарда сакланган товарларның күләмен барлау эше. --- *тикшерүче Камалиев бүлмәсендәге шкаф шүрлекләре --- төрле-төрле исемлекләр, --- исәп-хисап кәгазьләре ---, кинотасмалар ише бихисап дәлилләр белән тулды.* М.Насыйбуллин. *Әхмәт балалар йортының контора сыман бүлмәсендә үзенең завхозы белән хуҗалык исәп-хисаплары тикшереп утырган чагында, Фәтхи килеп керде.* Ш.Камал. *Әхмәтсафа агай илә Тимергали кичкә кадәр исәп-хисапта, язу-сызуда булдылар.* Ш.Мөхәммәдев

4) Үзара акчалата яки әйберләтә алыш-биреш. *Интендантлык белән элекке исәп-хисапка 20 процент өстәргә [кирәк].* К.Нәҗми

5) Эшләнгән эш өчен түләү, түләнгән хак. – *Торбаны томалаганнар, – диде Җәүһәрия. – Ә күпме алдылар? – Соңыннан сөйләшербез, диделәр. – Вакытында исәп-хисап ясау яхшырак булмас микән?* М.Маликова

6) *күч.* Ике арадагы киеренке мөнәсәбәт, ачу, үпкә. *Димәк, ярату тойгысы күп кенә исәп-хисапларны читкә ташлый, андый-мондый шартлар белән һич тә хисаплашмый булып чыга.* Ш.Камал // *сөйл.* Үч алу, үч кайтару. *Ну Акбирдин, исәп-хисап көне бер килер. --- Сөйгән кызымның күңелен суындырдың. --- Бәхилли алмам.* К.Тинчурин

7) *күч. сөйл.* Файда. *Хәзерге кеше дә, исәп-хисап корып, яратмаган кешесе белән өйләнешә, эшләгән җирендә түрәләргә ярарга тырышып ялагайлана.* Ф.Фәтхелислам

◊ **Исәбе-хисабы булмау** Санап бетергесез күп булу, бик күп булу. *Шулай булса да бу урманның гөрләп утыруы, бигрәк тә аның язгы кузгалагы, көпшәсе, җәйге чәчәкләре, исәбе-хисабы булмаган җир җиләге, кура җиләкләре, карлыганнары, бигрәк тә күзгә чикләвекләре минем күңелемне тарталар.* Г.Ибраһимов. **Исәбе-хисабы юк** Бик күп. *Тегеләй дә минем танышларның исәбе-хисабы юк.* Ш.Камал. *Анда татарча --- хикәяләр, кыйссалар өстенә, бик тәмләп --- язылган төрек романнарының да исәбе-хисабы юк иде.* Г.Ибраһимов. *Анда винтовкалар гына түгел, тупларның да исәбе-хисабы юк.* Ш.Камал. **Исәп-хисапны**

**коры тоту** Нинди дә булса хезмәт өчен түләү-түләтүне яки бурычны кайтаруны, үзара алыш-бирешне вакытында төгәлләү. *Бирәчәге булса – түләр, алачагы булса – түләтер. Исәп-хисапны коры тота ул безнең бабай.* К.Нәҗми. **Исәп-хисапны өзү (алу)** 1) Үзара акчалата алыш-бирешне ясау; тиешле хезмәт хакы алу яисә түләү. *Эшне бераз җыйгач, ул ялчының исәп-хисабын өзеп чыгарып җибәрде.* А.Шамов. *Балалар икесе дә Нурия белән китәләр, Солтан үз җае белән, ягъни Наркомзем белән исәп-хисапны өзгәч килә.* Г.Ахунов. *Нух белән дә исәп-хисапны тиз өзә ул.* Ф.Галимуллин; 2) *күч.* Үч кайтару, үч алу. *Сугыш башлангач, миңа немец илбасарлары белән исәп-хисапны өзү мөмкинлеге туды, һәм мин аны өзәргә кирәк таптым.* А.Шамов. *Гитлерчылар белән исәп-хисапны өзгәч тә, кече абыемны япон самурайларын тукмарга җибәрделәр.* З.Вәли. *[Миңнулла] Минем анда Кошкарев, Шишков, Соколовлар кебек контрлар белән исәп-хисапны өзәсем бар, дияргә теләсә дә, ул аларны белми бит дип, кире түнде.* В.Нуруллин

**ИСӘП-ХИСАП** II *җый. и.* Уй-фикерләр, ниятләр, планнар. *Ә Галләм хаҗи исә --- тагын да зәһәрләнә төшебрәк хәрәкәт итә башлады. Чөнки барлык бүтән исәп-хисаплары сабын күбеге булып һавага очкан, тик бер генә исәбе сакланып калган*... Ф.Хөсни

◊ **Исәп-хисап белән** Исәп белән. **Исәп-хисап буенча** *к.* **исәп-хисап белән**. *Ихтимал, акыл һәм исәп-хисап буенча өйләнешкән кешеләр рухи яктан талымсызрактыр ---.* Тигез гомер итегез! **Исәп-хисап йөртү** Исәпләү, уйлау, ниятләү, план кору. *Әле кичә дә, булачак уңыш турында исәп-хисап йөртеп, төн йокысы бирмәдең.* М.Шабай

**ИСӘП-ХИСА́П ИТҮ** *ф.* Исәпләү, санау. *Яхшылап исәп-хисап итеп карагач, галимнәр, әгәр канал казылса, ул тагын да зуррак зыян китерәчәк, --- дигән нәтиҗәгә киләләр.* А.Муранов

**ИСӘП-ХИСА́П КЫЛУ** *ф. к.* **исәп-хисап итү**. *[Рәхим] Үзенең бүлмәсендә байтак вакыт исәп-хисап кылып утырды.* А.Расих

**ИСӘП-ХИСАПСЫЗ** *с. к.* **исәпсез-хисапсыз**. *Тимерчегә исәп-хисапсыз әйберләр җибәрелә, дип ишеттем.* Т.Гыйззәт

**ИСӘП-ХИСАПЧЫ** *и.* Хисапчы. *Шаһбаз --- ферманы ташлады, җиңел эшкә күчте. Исәп-хисапчы булып йөрде.* Х.Ибраһим

**ИСӘП-ХИСА́П ЯСАУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса алдан исәпләү. *Карчык үзенең килене --- белән мәҗлескә нәрсәләр әзерләү турында исәп-хисап ясарга керешә.* Ш.Камал

2) Үтәлгән эш өчен тиешле хезмәт хакын түләү. *Икенче көнне эшкә чыкмадылар. Исәп-хисап ясар өчен, бер ай буе, үзләре килер, дип көттек.* Юлдаш

**ИСӘПЧЕ** *и. сир.* Исәпкә алып торучы, исәпләп баручы кеше. --- *минем яхшы кеше икәнемә ничектер ышандырып, үз гәҗитенә учётчик, исәпче итеп эшкә алды.* Р.Зәйдулла

**ИСӘПЧЕЛ** *с.* Исәпләп тота торган; исәп (экономия) белән эшләргә өйрәнгән. *Котдус аның тел төбен бик аңлады: техниканың рәтен белгән һәм исәпчел председатель мондый куәтле машинаның инвалид кулында булуыннан бигүк риза түгел иде.* Г.Фәизов. *Мин исәпчел, сак, аяусыз җәллад идем.* М.Кәбиров

**ИСӘР** *с. диал.* **1.** 1) Юләр, дивана, акылга зәгыйфь, ахмак. *Авылда чакта кызының шулай кинәт алмашынуына әнисе гаҗәпләнә, бераз исәррәктер син, дия иде.* С.Сөләйманова. *Тел белән әйтмәсәң дә аңлашыла, мин шыр исәр түгел.* Ф.Яруллин. *Хәнәфи --- кире миңа карап: – Исәр кеше кебек сорыйм әле, сез кайчан китәсез, абый?* Х.Сарьян

2) Акылсыз, акылга ятышсыз, мәгънәсез. *Малай чакның исәр истәлеге.* И.Киньябулатов

**2.** *и. мәгъ.* Юләр, дивана, акылсыз, ахмак кеше. *Ничек, үпкә-ачуың сыендымы әле? Яле, битләреңне юып алыйк... Исәрем минем, диванам. Үзем дә инде тиле.* Г.Гыйльманов. *«Юләр белән исәрләрне җиргә чәчеп маташмагыз. Үзләре дә үсәрләр», – дип, белеп әйткән шул бабайлар.* Т.Гыйззәт. *Баштарак Әхнәфнең кыланмышларына гаҗәпләнеп караган классташлары --- малайдан көлә --- башладылар. Еш кына «җүләрләнгән», «исәр» кебегрәк сүзләр дә ычкындыралар икән.* Ф.Сафин

◊ **Исәр әйтмешли** Кем яки нәрсә турындадыр турыдан-туры үз исеменнән әйтергә килештермәгәндә кулланыла. *Инде бераз әкренрәк барсаң да була иде, чөнки без, исәр әйтмешли, әллә егерме, әллә утыз машинаны артта калдырган идек.* Н.Фәттах. **Исәр баш** Җиңел акыллы, иләс-миләс кеше, бер төпле акылга килә алмаган кеше. *Мин, исәр баш, шәһәр буйлап чабып кайттым, ә ул мине «чүпрәкбаш» дип тиргәде.* Д.Вәлиев. *Суң, исәр баш, үзең уйлап кара, әнием белән бергәләп, терек-терек кенә фабрикка барып, --- киңәш-табыш итеп кенә яшисе урында...* Г.Ахунов. *Теге исәр баш мине күзәтмиме икән, апай?* Н.Гыйматдинова

**ИСӘРӘН** *с. диал. к.* **исәр**. *Каладан кайтышлый гына кереп ал, дип әйтергә онытканмын аны. Исәрән булгач ни...* М.Фәйзи

**ИСӘРЕНҮ** *ф. диал.* Куркынып, аптырап китү, берәр төрле тәэсиргә бирелү. *Очрашу шатлыгыннан исәренү*

**ИСӘРЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Юләрләнү. *Кызны алмаштырып куйдылармыни! Ул инде көлә-елмая, исәрләнә иде.* Г.Гыйльманов. *– Я инде, Юматша, исәрләнмә, – диде Диләфрүз кызарып һәм иренә күз кысты.* Г.Әпсәләмов. *Илфатның --- җырлап утырганын күреп, авылдашларының: «Я Хода, бу бала әллә исәрләнәме инде?» – дигән чаклары да булды.* Б.Камалов

2) Зиһен таркалу, фикер чуалу. *Күземә кеше күренмәс, колагыма аваз ишетелмәс булды. Исәрләндем тәмам...* Э.Касыймов

3) *күч.* Ашкыну, җилкенү. *Минем сине яратасым килә Яшь чактагы кебек, тилереп, һәм йөрисем килә исәрләнеп ---.* Р.Миңнуллин. *Таныш өянкегә сөялеп хәл алмакчы иде. Йөрәге нишләптер бик нык ярсып, исәрләнеп кага.* Р.Мулланурова. *Галиәхмәт исәрләнеп ашкынды, кабалануы сәбәпле, маңгаена тир бәреп чыкты.* Ф.Яхин

**Исәрләнә бару** Торган саен, вакыт узган саен ныграк исәрләнү

**Исәрләнә башлау** Исәрлек билгеләре сизелү, күренү

**Исәрләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй исәрләнү. *Юкса әллә нинди исләр чыгарып, үзең исәрләнеп беткән идең бит инде!* Л.Гыймадиева

**Исәрләнеп йөрү** Озак вакыт исәрләнү. *Байтак вакыт шулай исәрләнеп йөргәннән соң, ул, кич утырып, Шәүрәгә хат язды.* Г.Бәширов

**Исәрләнеп калу** Кинәттән генә исәрләнү. *Аз була, бик аз була Викториянең болай исәрләнеп калган минутлары.* Ш.Рәкыйпов

**Исәрләнеп китү** Кинәт, уйламаганда исәрләнү. *[Ымсынай әби] Бертуктаусыз сөйләнә, ястыкны әле улларының берсенең исемен, әле икенчесенекен әйтеп сөя, күкрәгенә кыса иде. Исәрләнеп киткән хатынга ни диярга дә белмәде Әминә.* Я.Зәнкиев. – *Безнең Кырмыскай бик карт, үз гомерендә күпне кичергән зат иде. Исәрләнеп китеп, ул сезнең юлга эләккәндер, – диде чит кырмыскаларның төркем башлыгы.* К.Тәхау

**Исәрләнеп тору** Сөйләү моментында ниндидер тәэсир астында булу. *Кухняда өстәл әзерләп йөргән Әлфия, нидер эзләп, бу якка чыкты һәм өстәл янында исәрләнеп торган Хафизга елмаеп, кире кереп китте.* С.Шәмси

**ИСӘРЛЕК** *и. диал.* 1) Юләрлек, диваналык, ахмаклык, акылсызлык. *[Кызның] Патроннары да бетте бугай, тынды. Мине куркыту өчен уйлап чыгарган идеме әлеге исәрлекне, әллә үзен-үзе тынычландыруы идеме?* Х.Камалов. *Башын әз-мәз исәрлеккә салып, беркайчан да зонада эшкә чыгып йөрмәгән матрос Попов, түшенә газитләрдән кисеп алынган Ленин ордены сурәтләрен тезеп, --- түш киереп йөрде.* А.Гыйләҗев

2) Уйламый эш итү гадәте, кызулык. *Акыллы кыз ул Миләүшә, бераз исәрлеге генә бар.* Г.Гыйльманов. *Исәрлегемә караганда акылым өстенлек иткәнгә, ялгышларымны, --- уйлап үкенсәм дә, --- үз-үземне акларга да көчем җитә!* А.Гыйләҗев

**ИСӘРҮ** *ф. диал.* Берәр нәрсәдән, күренештән нык тәэсирләнү; куркынып, аптырап китү, әсәрләнү. *Мотоциклда икәү баралар. Артка атланганы тизлектән исәреп, аякларын кагып, на-на, дип әйдәп бара.* Ш.Галиев. *Айдар белән Вәсилә язмышын белгәч, барча кеше исәрде.* Мәдәни җомга

**ИСӘЮ** *ф. диал.* 1) Бераз үсеп, акыл, аң керү, фикер йөртә башлау. *Дөрес, медицина бу очракта безгә ярдәмгә килде, бераз исәймичә, баланы биреп җибәрергә ашыкмадылар.* Ф.Хөсни. *Гали дә исәйде, мәктәпкә барыр яшькә җитте.* Рифә Рахман

2) Ныгу, физик яктан көчәю. *Мин аны, тукта, бераз исәйсен, тукта, бераз буыннары ныгысын дип, --- яше җитсә дә, армиягә җибәрмичә асрадым.* Ф.Шәфигуллин. *Баштарак бала исәйгән кебек тә күренә башлаган иде.* Ф.Хөсни. --- *үрдәк балалары инде шактый исәйгәннәр.* Г.Галиев

3) Арту, үсү. *Атаклы профессорның шәкерте булып йөргәндә, дошманнарның шактый булачагын акылы исәйгән Нәҗип хәзер белә иде инде.* А.Гыйләҗев

**Исәеп килү** Акрынлап, аз-азлап исәю. – *Васфиянең балалары исәеп килә, – дип сүз кыстырды әнисе.* М.Хуҗин. *Ярыйсы гына исәеп киләдер иде улыбыз, бәхетсезлеккә, юк кына чирдән әтиебез үлеп китте.* Ф.Хөсни. *Ә бу якта... кысрыкта, аның газиз хатыны – балаларының әнкәсе... Исәеп килгән ике улы!* А.Гыйләҗев

**Исәя бару** Торган саен ныграк исәю. *Армасын өчен, Актырнакны күтәреп бара идем хәтта. Шулай йөртә торгач, көннән-көн исәя, елгырлана барды бу.* З.Фәйзи. *Балалар исәя барган саен, борчылу-мәшәкатьләре дә арта.* Юлдаш

**Исәя башлау** Исәергә тотыну

**Исәя төшү** Бераз, берникадәр исәю. *Бәләкәй генә исәя төшкәч, мин, ныгып та җитмәгән бала, җилкәләремә авыр тубал асып чәчү чәчтем.* Г.Бәширов. *Ул чагында Илдар да, исәя төшеп, кул астына керә башлаган иде.* З.Фәйзи. *Исәя төшү белән, ул аталы малайлардан калышмаска, алардан ким яшәмәскә ант итте.* Ә.Моталлапов

**ИСБАТ** *и. гар.* Берәр нәрсәнең дөреслеген, хаклыгын, реальлеген, булганлыгын раслаган дәлил, факт. *«Бу» бәйлеге әдәби җөмләдән соң, шуның киресен исбат өчен китерелгән җөмләнең башында килә.* Җ.Вәлиди

**ИСБА́Т ИТҮ** *ф.* Берәр нәрсәнең, күренешнең, эшнең дөреслеген, чынлыгын, булганлыгын фактлар белән дәлилләү, раслау. *Казнакай нефтьчеләренең, төзүчеләренең яхшы эшчеләр булуын гына түгел, ә менә дигән культуралы, сәхнә талантлары икәнлеген дә исбат итәргә тиешсез.* М.Хәсәнов. *Зәйтүнә бары тик үз ихтыярын чыныктыру, Әнвәр каршында ныклыгын исбат итү турында гына уйлый иде.* М.Маликова. *Ә Румовский нәрсә ди? Ачыкланмаган яки исбат ителмәгән бер нәрсә дә нигез итеп алынмый, дип яза бит.* Җ.Тәрҗеманов

**ИСБА́Т КЫЛУ** *ф. к.* **исбат итү**. *Ул тегe соңгы сүзенең дөрес түгеллеген --- бик үткен вә озын исбат кылды.* Ш.Камал

**ИСБАТЛА́У** *ф.* **1.** Исбат итү, раслау, дәлилләү. *Сүзнең көченә ышанмыйм мин. Аны бөтен гомерең белән исбатларга кирәк.* М.Галиев. *Монда бит сәеррәк килеп чыга: булган хәлнең булмаганлыгын исбатларга, ягъни Мәдинәнең ялганын фаш итәргә кирәк.* Н.Вахитов. *Митрополит Филарет закон проектын якламый, ул, христианлык тән җәзасы бирүне гаепләми, дип исбатлый.* Россия тарихы

**2.** *и. мәгъ.* «Дәлил, факт, мисаллар» мәгънәсендә әйтелә. *Фактлар кинәт аның алдына тау булып өеләләр, һәм аңарга яңадан-яңа исбатлаулар эзләргә, --- туры килә.* Җ.Тәрҗеманов. --- *исбатлау чылбырында җитмәгән төенне ачыклау юнәлешендә галимнәргә зур уңыш елмайды.* Казан утлары

**Исбатлап карау** Исбатларга тырышу. – *Бу җинаять бит, – диде Фалия, аның томса күзләре зур булып ачылды, һәм таң калудан тырпайган керфекләре дерелдәп-дерелдәп алдылар. – Исбатлап кара, ир белән хатын арасына милиция дә керергә курка.* Х.Камалов. *Мәгәр авыл акны кара дип бара икән, исбатлап кара җилдән туган бала түгелен!* Р.Мулланурова. *Әгәр эш судка барып җитсә, мин әйтәчәкмен: Шамбасов*

*кушуы буенча эшләдем, диячәкмен. Сез исбатлап карагыз.* Т.Миңнуллин

**Исбатлап килү** Күптәннән, электән үк даими исбатлау. *Үзенең директор булуы белән Нәфисә Мәлска мөстәкыйль яши алуын, хәтта үзенең аннан югарырак та икәнен исбатлап килде.* Ф.Садриев. *Без моны үзебезнең яшәү рәвешебез белән, кылган гамәлләребез, тугандаш халыкларга, Ватаныбызга күрсәткән игелекләребез белән гасырлар дәвамында исбатлап киләбез.* Р.Миңнуллин

**Исбатлап тору** 1) Даими рәвештә яки туктаусыз исбатлау. *Хәер, һәр империянең таркалырга тиешлеген тарих исбатлап тора.* Р.Фәйзуллин. *Ефетов кешеләргә гаять игътибарлы, эчке культурага ия булган чын интеллигент иде. Тышкы кыяфәте дә шуны исбатлап тора.* Т.Гыйззәт

2) Сөйләү моментында, әле, хәзер исбатлау. *Әдәс һаман: «Мин лаборатория бүлмәсенә кереп чыккан арада, бозау юк булды», – ди-ди, дәлилләп, исбатлап тора.* Х.Камалов. *Сүзләрен дәлилләп, исбатлап торуны кирәк тапмады.* Т.Галиуллин

**Исбатлап үтү** Эш барышында, сүз уңаенда исбатлау. *Монысын да фән югарылыгында исбатлап үтәм мин үз хезмәтемдә.* Ф.Баттал

**Исбатлап чыгу** Һәрберсен, берәмберәм исбатлау; башыннан ахырына кадәр исбатлау. *Тарихи съездда яңыраган «развитой» сүзенең аңы үскән кешегә генә түгел, җәмгыятькә карата да әйтелгәнен, борын-борынгыдан ук халык арасында, бигрәк тә Касыйм татарлары арасында кулланылганын исбатлап чыкты Сабуров.* М.Галиев

**Исбатлый бару** Һәрберсен, бер-бер артлы исбатлау. *Гаеп ташлыйсыз икән, дәлилләр илә исбатлый бару кирәк.* Р.Мөхәммәдиев

**Исбатлый башлау** Исбатларга тотыну. *Маһ-Гушнасп Алланың төрле рәвешкә керә алуын, ләкин кеше кыяфәтендә генә сурәтләүнең асылда адәм дәрәҗәсенә төшерү икәнен исбатлый башлаган иде – бүлдерделәр.* Б.Рафиков

**Исбатлый тору** Бер-бер артлы исбатлау

**Исбатлый төшү** Тагын да дәлилләрәк, нигезлерәк итеп исбатлау

**ИС ГАЗЫ** *и. хим.* Углеродның өлешчә генә окисьлашуыннан барлыкка килгән төссез агулы газ; углерод окисе. *Язып куя аласыз: ул хатын-кыз ис газы белән агуланып үлгән.* Ф.Галиев

**ИС-ДӘРТ** *җый. и.* Акыл, аң, ис һәм дәрт. *Кызга ис-дәрт кергән чак, егетләр турында уйлый башлаган.* Татар иле

◊ **Исем-дәртем Искәндәр** *сөйл.* Бары үз уе белән генә мәшгуль булып яшәү яки кемдер, нәрсәдер турында гына уйлау (карашларның чиклелеге турында)

**ИСЕ-ҖИЛЕ** *и. к.* **ис** I (*3 мәгъ.*)

◊ **Исе-җиле калмаган (юк)** Юкка чыккан, бөтенләй калмаган, бөтенләй беткән, беркем дә белми

**ИСЕМ** *и. гар.* **1.** 1) Кешегә тугач та бирелә торган шәхси атама; ат. *Кайчандыр Сәлимәнең исеме мәктәп стена газетасында еш кына мактап телгә алына, --- иде.* Г.Гобәй. *Тәбрия Гадилнең үзенә текәлеп караганын сизде, уңайсызлануын яшерү өчен сүз башларга ашыкты: – Бу кеше дөньяда шактый яши инде, ә исеме юк әле.* М.Маликова. *Баланың исеме, табигый ки, бала туууны теркәргә килгән кеше әйткәнчә язылып куела.* Тигез гомер итегез!

2) *сир.* Кешенең шәхси атамасы һәм фамилиясе. *Аргы баштагы ишеккә яңа язу кадаклаганнар: «Нурханова Фидая Госмановна». Сирәк исем, телгә дә бик үк җайлы түгел сыман.* М.Маликова. *--- мине Губин исеме белән якындагы концлагерьга китерделәр, аннан өчәү качтык.* З.Фәтхетдинов. *Азат Вергазов исеме олы әдәбиятта ныклап 1975 елда гына күренә башласа да, ул инде сигез китап чыгарырга өлгерде.* Р.Сверигин

3) Кеше яисә хайван кушаматы. *Килгән көнне үк, тиктормас аюга матрослар, сүз куешкандай, Михаил Топтыгин дип исем куштылар.* Н.Әхмәдиев. *Кушаматын да үзем бирдем: «Шаман». Яңгырап тора, шомлы да үзе. Малайларга шундый исем кирәк.* М.Насыйбуллин

4) Төрле предмет, күренеш, әйбер һ.б.лар атамасы. *Зур бер табак кәгазьне дүрт битле газета итеп яздым. Иң башта – газетаның исеме: «Сәлам».* М.Әмир. *--- дүрт битле район газетасының ике подвалын тутырып, «Батырлар үлми» дигән исем белән, Тәүгиз турында очерк басылып чыкты.* Х.Камалов. – *Мин ул парник хуҗалыгының исемен үк үзгәрттерәчәкмен әле! – ди Әнвәр, кайнарланып. – Совхоз итәчәкмен мин аны!* М.Маликова

5) Күрсәткән хезмәте өчен кешегә бирелә торган мактаулы атама. *Баш рольне уйнатсалар, миңа «РСФСРның атказанган артисты» исемен бирергә туры киләчәк. Шуңа куркалар. Исемне бирәселәре килми, җәллиләр.* М.Маликова. *Партбюроның һәм төзелеш комитетының берләштерелгән утырышы үзенең кичәге карары белән сезнең коллективка «Коммунистик хезмәт бригадасы» дигән мактаулы исем бирде.* Р.Кәрами. *«Герой» исеме турында сүз тимер юл күперен бомбага тотып кайтканнан соң кузгалган иде.* М.Юныс

6) Кешенең бер өлкәдә квалификациясен яки эш-хезмәттә токкан урынын рәсми билгели торган атама; дәрәҗә. *--- Хрущёвка тәлинкә тоткан һәм шуның белән тамак туйдырган, фән кандидаты, докторы дигән исемнәр алу өчен ниләр генә кыйланмаган галим-голәмә хәзер Никита Сергеевич Хрущёвны сүгә.* Н.Әхмәдиев. *--- профессор-фәлән дигән зур исемнәрне алгач, шул дәрәҗәләренә күрә урыннар --- биләгәч, боларны рус, яһүд, чуваш галимнәре алдында күрсәтергә оят була башлады.* М.Мәһдиев. *1759 елның январенда Петербург Фәннәр академиясендә «член-корреспондент» дигән яңа фәнни исем кертелә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

7) Нинди дә булса бер эшчәнлек өлкәсе атамасы. *«Рәссам» дигән зур исемең бар, дәрәҗәң бар ---.* З.Хөсния

8) Кайбер кешеләрнең үзенә алган уйдырма исеме яки фамилиясе. – *Ә минем исемем – Андрей. – «Андрей» үз исемегезме? – Кыз Зәкинең икеләнеп торуын күргәч дәвам итте: – Димәк, кушамат? – Әйе, бу – минем кушаматым.* З.Фәтхетдинов

9) *лингв.* Предметны, затларны, күренешләрне белдерә, атый һәм килеш,

тартым, сан белән төрләнә торган сүз төркеме. --- *татарда бернәрсәнең үзен, затын аңлаткан сүзләр исем --- була, дигән әсасны кабул итәргә туры килә.* Җ.Вәлиди. *Исем --- җөмләдә, күбесенчә, фигыль белән бәйләнешкә кереп, ия, тәмамлык, икенче бер исемне ачыклап, аергыч булып та килә.* Татар грамматикасы. *Җөмләдә исем теләсә нинди җөмлә кисәге булып килә ала.* Татар теле

10) *күч.* Танылганлык, дан, шөһрәт. *Аннары исемнәр турында... Мин егерме ел эшлим, ләкин минем исемем дә, наградаларым да юк.* Г.Әпсәләмов

11) *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса уңай яки кире сыйфатлары турында туган гомуми фикер; дан. *«Саран» дигән исемеңне чыгартмас өчен, кеше алдында хур булмаслык яшим дип, үзеңә күбрәк тота башлыйсың...* Г.Ибраһимов

12) *күч.* Абруй, авторитет; дәрәҗә. *Ә авылда аның тормышы азмы-күпме көйләнгән, эшендә дә «Гөлшәһидәбез» дип кенә торалар, халык алдында да исеме бар.* Г.Әпсәләмов

13) Нинди дә булса төркемгә яки оешмага карауны күрсәтә торган атама. *– Үз-үзеңне, дәрәҗәңне җиңәргә өйрән! – диде Зәйнанов. – Ни өчен «коммунист» исемен йөртәсең?* Х.Камалов. *– Сез, иптәш Вәзыйхов, эчеп-исереп, семьяда тавыш, җәнҗал куптарып йөрүегезне, хатыныгызны рәнҗетүегезне акларга уйлыйсызмы? «Коммунист» исемен пычратырга ирек бирмәбез! – диде Кадыйров.* Н.Әхмәдиев. *Сез дә Ленин төзегән партия члены исемен йөртәсез ләбаса!..* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ* 1) **исемендәге** Берәр кеше хөрмәтенә яки берәр вакыйга уңаеннан аталган. *Мине язу машиналары эшли торган заводның Вахитов исемендәге пионерлар отрядына вожатый итеп күчерделәр.* А.Алиш. *Бу хатны мин язам сезгә. Мин – Сөмбел Булатова, Советлар Союзы Герое Сәфәр Имашев исемендәге пионер дружинасының дружина советы председателе.* Г.Сабитов. *Менә Жан, мәсәлән, «Кара» дигән берәү җитәкләгән отрядны белә. Суворов, Невский, Ленин комсомолы исемендәгеләре дә шушы тирәләрдә генә югыйсә.* Ш.Рәкыйпов

2) **исеменә** *юн. кил.* Кемгәдер адресланган, билгеләнгән, юнәлтелгән. *Кичә Мортаза Шәрипов дирекция исеменә --- аңлатма язып бирүне тәкъдим итте ---.* Р.Ишморат. *– Тагын бер кәгазь кирәк булыр, – диде полковник. – Хатын-кызлар төрмәсендәге баш табиб исеменә.* М.Маликова

**3. исеменнән** *рәв. мәгъ. чыг. кил.* 1) Берәр кеше, оешма яки коллектив кушуы, әйтүе, соравы, теләге, үтенече буенча; аларның вәкиле буларак. *Раушания күчеп киткән елны ук үлеп киткән икән. Аның исеменнән сеңлесе Румия хат язып яткан.* З.Мәхмүди. *– Шәп эшләдегез бит, егетләр, көтмәгән идек, – ди совхоз директоры. – Сезгә әнә совхоз идарәсе исеменнән бүләк китердем.* Г.Сабитов. *Комсорг җәмәгатьчелек исеменнән кыскача гына речь белән туйны ачып җибәрде.* Х.Камалов

2) Берәр кешегә яки оешмага, коллективка бирелгән хокукларга таянып. *Әкрен кыймылдый торган булсалар, Совет исеменнән кыздыр үзләрен.* И.Гази

◊ **Исем алу** Теге яки бу эшләре, холкы белән уңай яки тискәре яктан билгеле булу; дан, шөһрәт, ат казану. *Һәм шул эштә эшли торгач, Мактаулы бер исем алырсың.* З.Маннур. *«Бурсык» исемен алган Альберт Галиков – мафиянең тәэминатчысы, вак кибетләр хуҗасы, каракның да бик комсызы, конарсызы.* Г.Гомәр. *Нәтиҗәдә, артта сөйрәлгән коллектив бөтен юллар төзү идарәсендә, иң беренчеләрдән булып, «Коммунистик хезмәт коллективы» дигән мактаулы исем алуга иреште.* М.Хәсәнов. **Исем буяу** *к.* **исеменә тап төшерү**. *Аларын үзе дә җиренә җиткереп эшләргә тырышыр инде. Исемен буярлык итмәс. Кем бүләкләре, дигәндә, Исмәгыйль бүләкләре, дип кычкырып торырлык итәр.* М.Фәйзи. *– Ул ирнең исемен буяма, Сәрия. – Абау ла, хараплар икән! Әллә синең Арысланың ап-ак оекбаштан гына болытлардан сикергән фәрештәме?* Н.Гыйматдинова. **Исемгә чыгу** Уңай яки тискәре яктан билгеле булу, дан таралу. *Авыл хатыны булса да үткен нәрсә икән: шул җырлаудан исемгә чыгып, үзен шәһәргә алдырганнар.* Г.Ибраһимов. *Яратмасам да, әби, бу – бик зур оят эш бит, кеше күзенә нихәл итеп күренерсең. Кеше арасына исемем чыкса нишләрмен?* Г.Камал. **Исемдә генә** 1) Элеккечә аталып та, үзенең элеккеге төп асылын, сыйфатларын югалткан әйберләр, күренешләр һ.б.лар турында. *Меньшевиклар белән эсерлар --- үзләренең чын йөзләрен ачтылар, --- исемдә генә эшчеләр партиясендә йөргәнлекләрен күрсәттеләр!* М.Гафури; 2) Сүздә берне әйтеп, чынбарлыкта шуның киресен эшләү, икейөзлеләнү, монафикълану турында. **Исеме аклану** Күрсәткән эше белән үзен аклап, элеккеге яки уйланылган тискәре фикерне юкка чыгару. **Исеме (исемнәре) алтын хәрефләр белән язылу** Ватанга, халыкка зур хезмәт күрсәтеп, тарихта исемнәре хөрмәт, ихтирам белән искә алына торган затлар турында әйтелә. **Исеме астында** Берәр кеше яисә оешма исеме белән, шул исем астында яшеренеп. **Исеме бар, җисеме юк** Исемлектә саналып йөреп тә, гамәлдә булмау. – *Үсмерләр клубының исеме генә бар әле, җисеме юк, – диде капитан чыраен сытып.* А.Вергазов. **Исеме белән атау** Хакыйкатьне, дөреслекне яшермичә ачыктан-ачык әйтү. **Исеме генә калу (булу)** 1) *к.* **исемдә генә** (*1 мәгъ.*). *Россия өстендәге кара болытлар көннән-көн куера, --- хөррият союзлар тәмам бетте, хөррият матбугатның да исеме генә калып бара.* Ш.Мөхәммәдев; 2) Юкка чыккан, беткән, үлгән, югалган булу. **Исеме дә ишетелмәү** Бөтенләй булмау, күренмәү, югалу. **Исеме дә калмау** Бөтенләй бетү, югалу, тарихтан, халык хәтереннән бөтенләй төшеп калу, онытылу. *Шул золымнар тәмам бетеп, [реакциянең] исеме калмас җир йөзендә.* М.Гафури. **Исеме дә юк** Бөтенләй юк; бөтенләй күренмәү, булмау. **Исеме җәелү** Уңай яки кире яктан билгеле булу. *[Себер бае:] Сезнең монда бөтен дөньяга исеме җәелгән «Көфер почмагы» дигән чатыгыз кайда?* Г.Камал. **Исеме җисеменә муафыйк** *к.* **исеме җисеменә туры килү**. *Исеме җисеме-*

*нә муафыйк һәм Камилә, Мөршидә; Булмыйдыр түзеп куралмый көн дә барып күршегә.* Жыр. **Исеме җисеменә туры килү** Тышкы күренеше эчтәлегенә яраклы, муафыйк булу; нинди булып күренсә, асылы белән нәкъ шундый булып чыгу. *«Машиналар каберлеге». Исеме җисеменә бик туры килә аның. Язгы-көзге пычракларда гына түгел, җәй урталарында да машиналар батып, ватылып ята монда.* М.Хәсәнов. *…Касә-күл! Исеме җисеменә туры килә икән. Тирән яшел касә төбендә, ялтырап, күзге кебек кечкенә генә, түп-түгәрәк күл [ята].* Г.Сабитов. *Җамбулның теле болай да сөяксез. Исеме җисеменә бик туры килә.* М.Әмирханов. **Исеме китү** Дан, шөһрәт таралу. *Исеме киткән аның Зәй буена...* С.Хәким. **Исеме(н) күтәреп йөрү** Кылган эше кешенең исеменә, дәрәҗәсенә, һөнәренә һ.б.ларга туры килмәү, лаек булмау. *Җитәр инде, кәрәкә балыклары тотып, чалбар төпләребезне юешләп, «балыкчы» исемен байтак күтәреп йөрдек.* Ф.Хөсни. *Динчелек исеме күтәреп, суфыйлык сатып, яңа фикерләрне сүгеп, үзеңнең шәригать буенча йөрүең шушымыни?* М.Фәйзи. *Үч иткәндәй, «инженер» дигән исем күтәреп йөргән буласың ич, адәм мәсхәрәсе!* М.Хәсәнов. **Исемем (фәлән) булмасын** Берәр нәрсәне һичшиксез эшләячәген ант итеп әйткән сүз. *Шул… шул сарыктан синнән күбрәк акча чыгармасам, исемем Хәяли булмасын!* А.Вергазов. *Шушы беркатлы шагыйрьне дә хәйләләп отмасам, исемем хатын-кыз булмасын!* М.Маликова. *Мин, дип әйтә икән, ди, ни эшләсәм дә эшләрмен, шул Хафизаны Хафиз кулыннан тартып алмасам, дөньяда исемем Кәрим дә булмасын, дөньяда йөрмим, дип әйтә икән, ди.* Г.Камал. **Исемен аклау** Кемнең дә булса гаепсезлеген раслау. *Аңламассың бу ирләрне! --- Кичә, исемен акларга кушып, бөтен редакциягә шаулады, ә бүген «кирәге юк» имеш.* Н.Гыйматдинова. **Исеменә күләгә төшерү** *к.* **исеменә тап төшерү**. Исемен пычрату. *Мәгънәсез бер очрак аркасында, яшьләр минем яхшы исемемә шактый ямьсез күләгә төшерделәр.* Г.Әпсәләмов. **Исеменә кучерү** Теге яки бу әйбергә, милеккә икенче кешене хуҗа, ия итү. *Атасы уналтынчы елны ук --- хәзинәдән бер өлешен Швецария банкына, Әнвәр исеменә күчереп куйды.* З.Фәтхетдинов. *Ә йорт-җир – һәммәсе Сәйдә исемендә. Ялгыш итте Кәрим: үз исеменә күчерергә башы җитмәде.* Ә.Галиев. *Бер нәрсәне онытмагыз: мирас малын үз исемеңә күчерү, бер яктан караганда, һич тә мәҗбүри эш түгел.* Юлдаш. **Исеменә тап төшерү** Кемнеңдер исемен пычрату, яманатын чыгару. *Бу юньсез дә этисенең исеменә тап төшерүдән тайчынмаган!* М.Хуҗин. *Җыр тынгач, укытучы сорау бирде: – Муса Җәлил исеменә тап төшермәскә, аны лаек йөртергә кирәк. Булдыра алырбызмы икән соң?* Р.Хафизова. *Без шәһәребезне чиста куллар белән төзергә тиешбез, ә менә Закирова кебек әхлаксыз кешеләр «архитектор» исеменә тап төшерәләр.* М.Маликова. **Исеменә язу** 1) Теге яки бу әйбернең, милекнең, мирасның хуҗасы, иясе итеп рәсми билгеләнү. *Ул йортның Апанаевларныкы икәнлеген белмиләр дә: чыбык очы кардәшләре исеменә язылган.* З.Фәтхетдинов; 2) Кемне дә булса баланың этисе итеп яздыру, балага аның фамилиясен бирү. *Аның әйткәннәренә карап, районда баланы минем исемгә яздылар ---.* Ә.Моталлапов. **Исемендә булу** Теге яки бу әйбернең кемнең дә булса милкендә саналуы яки исеме белән аталып йөртелүе. *Монда бәләкәйрәк фирмалар мәзин исемендә булалар.* Г.Тукай. **Исемен селкү** Кемне дә булса күп мәртәбә начар яктан искә алу. *--- минем исемне болай да җитәрлек селкеделәр ул көнне.* Ф.Хөсни. **Исемен таплау** *к.* **исеменә тап төшерү**. *Кешеләр Нисадан Моназыйрның хәлен белешмәделәр, Моназыйр алдында Нисаның исемен телгә алсалар, бу аларга Таукашка ерак Пенза якларыннан килен булып төшкән Хәйрелбәрәшнең исемен таплау булыр кебек иде.* М.Хуҗин. **Исемен телгә алмау** Берәр кеше яки нәрсә турында сөйләмәү, оныту. *Летучкада профессор кеше күзенә күренмәслек итеп әрләр, дип көтте Гөлшәһидә. Ләкин летучкада профессор аның исемен дә телгә алмады.* Г.Әпсәләмов. *[Миләүшә] --- яңадан Әлфреднең исемен телгә алырмын димәгән иде.* Ф.Яруллин. **Исемен чәйнәү** Кемнең дә булса кат-кат гайбәтен, яманатын сату. **Исемен чыгару** Кемгәдер начар исем тагып хур итү. **Исеме телгә кермәү** Кемне яки нәрсәне дә булса берәүнең дә исенә төшермәве, бөтенләй онытылуы. *Нишләптер, Заһир абыйның исеме бөтенләй телгә кермәде ---.* М.Маликова. **Исеме телдән төшмәү** 1) Кемне яки нәрсәне дә булса гел искә төшереп тору, һәрвакыт истә тоту. *Шул кеше дә газетада эшли бит әле, дигән уй килде башыма. --- Летучкаларда исеме телдән төшми.* Л.Ихсанова. *Аның исеме телдән төшмәде. Кеше күзенә күренерлеге калмады Варисның.* М.Хәсәнов. *Хатыннар, кузгалып киткәч тә, Җәмит исемен телдән төшермәделәр.* Н.Хәсәнов; 2) Исеме киң таралу. *Партиянең егерменче съездыннан соң исеме телдән, --- төшми башлаган генераль секретарь Мәскәү язучылары --- белән очрашулар үткәрә икән, дип ишетәбез.* Л.Ихсанова. **(Фәлән) Исеме харам булсын** *к.* **исемем (фәлән) булмасын**. *Әгәр шушы Хәлилнең кулыннан Галиябануны тартып ала алмасам, Исмәгыйль исеме миңа харам булсын!* М.Фәйзи. **Исеме чыгу** Яхшы яки яман яктан даны таралу. *Кеше арасына исемем чыкса, нишләрмен? Бер исемең чыккач, кая барасың?* Г.Камал. *Авылда «кияүгә барып кайткан» исеме чыккач, Бибисада бала булдыру теләге туды.* С.Сөләйманова. *Исеме чыгудан куркып, күләгәдә шыпырт яшәргә теләгәннәр кулдан-кулга күчә китте.* А.Гыйләҗев. **Исем җәю** Даны, шөһрәте таралу, дан казану. *Шәкертләр, Җиһанша хәзрәт мәдрәсәсенә килеп, еллар үтеп, хәлфә булып исем җәйделәр.* З.Һади. **Исем казану** *к.* **исем алу**. *Асыл сөяк чабышкы атлар, үз тирәсендә исем казанган көрәшчеләр, шәп йөгерүче егетләр бу җыенга йөзәр чакрымнан киләләр ---.* Г.Ибраһимов. *Хәзер исә Камилә мәгълүм дәрәҗәдә исем казанган журналист булып үсеп җитте ---.* М.Маликова. **Исем**

**китү** Дан казану, дәрәҗәгә ирешү. *Иseме киткән аның Зәй буена...* С.Хәким. **Исем күтәрү** *сөйл.* 1) Берәр дәрәҗәгә ирешү яки хаксызга кимсетелү, җәберләнү турында. *Син абзыеңны сәүдәгәр булмаска үгетләгәндә дә, үзең өчен куркып кына, «сәүдәгәр энесе» исемен күтәрү ихтималлыгыннан шикләнеп кенә үгетлисең.* М.Әмир. --- *«ирдән кайткан» исеме күтәреп, сезне дә оятлы итәсем килми.* Р.Мулланурова. *Иртәгә берәүсенең хәләле буласы ят ирдән җылы урлаган угры хатынга охшаган иде ул. Андый хурлыклы исемне күтәрүгә караганда, туңып үлүең мең өлеш артык иде.* Н.Гыйматдинова; 2) Ниндидер исемгә лаек булу. *«Архитектор» исеме күтәреп йөрүче кеше мин.* М.Маликова. *Кешеләр... дип уйланып калды Нургаяз. Кем белә, ә, бәлки, «кеше» исемен күтәрерлекләре булмагандыр.* Р.Мөхәммәдиев. **Исем өчен (генә) (булса да)** 1) Бөтенләй, бер дә (табып булмау, очратмау һ.б.ш.лар турында); 2) Аз гына булса да. *Комик актёр каптырган биш балыктан, исем өчен булса да, уха пешерделәр.* С.Сөләйманова. *Минсафның әле моңа тикле шушы сәнгатькә юри дә караганы, Зөбәрҗәтен исем өчен дә мактаганы булмады бит!..* Х.Сарьян; 3) Кечкенә генә. *Укуны тәмамлаганчы, аннан да бигрәк, ата-анадан әдәп өчен генә булса да ризалык сорап, исем өчен генә булса да туй ясаганчы, мондый хәлне булдырмаска кирәк иде.* М.Маликова; 4) Бер дә булмаганчы. – *Минем урынбасар бар бит инде, тик эшләми генә, – диде Җәүһәрия көлеп. – Алай да торсын әле ул үз урынында. Исем өчен генә булса да.* М.Маликова. **Исем пычрату** *к.* **исеменә тап төшерү**. --- *милиция килеп эзләсен, каракның эзенә төшсен, абый! Ул чакта минем исемне берәү дә пычрата алмый.* С.Зыялы. *Гайбәтчеләр теленә кереп, берәүнең дә исемен пычратасы килми.* Л.Ихсанова. *Башка берәү булса, эшне аннан-моннан оформить итәр иде дә судка тапшырыр иде. Ә без, күрәсең, алай итмәдек. Ничек кенә булса да синең исемеңне пычратмыйча саклап калып булмасмы дип тырышу иде.* М.Хәсәнов. **Исем сату** 1) Абруй, дәрәҗә төшерү, яхшы исемен пычрату. *Сугыш миннән хыянәтче ясады. Юк, юк, мин исемемне дә, ватанымны да, халкымны да сатмадым.* М.Әмирханов; 2) Берәр кеше турында гайбәт сөйләп, аның яманатын чыгару. *Кыз баланың исемен сатарга оялмадылар инде [алар].* Н.Исәнбәт. **Исем тагу** Кемгә дә булса ниндидер сыйфаты яки гамәленнән чыгып хурлап, мәсхәрәләп атау. *«Сатлыкҗан» исемен кешегә такканчы энәсеннән-җебенә кадәр тикшерергә --- кирәк.* Я.Зәнкиев. *Ә сез, тәти егетләр, аның шундый бәя биреп бетергесез хезмәтләре өчен, тоткансыз да аңар кимсетү исеме таккансыз.* Г.Гобәй. *Ә мине... «балта остасы» дигән исем тагып, мыскыл итеп, җыен хатын-кыз янына – корректорскийга күчерделәр.* Х.Сарьян. **Исем таралу** *к.* **исем җәю**. *Ә Әгъләм дигәннәре Минзәлә якларының бик тә хәлле, исеме тирә-яктагы авылларга таралган кеше була.* Г.Ахунов. **Исем тоту** Берәр исем күтәрү, берәр исемгә, дәрәҗәгә лаек булу яки лаек дип саналу. **Исем чәчү** *к.* **исем сату** (*2 мәгъ.*). *Эчерми булмый, беркөн ул мине тегендә күргән иде, эчертмәсәң, ул аннары бөтен дөньяга исемеңне чәчеп йөри.* Г.Камал. **Исем чыгару** 1) Берәр кеше турында, гадәттә, начар хәбәр тарату, яман исем тагу. *Ул бит Зиннәт турында «начар малай» дигән исем чыгарды.* А.Шамов; 2) Нинди дә булса сыйфатлары белән үзен таныту, билгеле, атаклы, данлыклы итү. *Ул инде исем чыгару өчен ниләр генә эшләми.* Н.Исәнбәт. *Ул – авылда атларының яхшылыгы белән исем чыгарган кеше.* Г.Ибраһимов; 3) Шикләнүләргә, имеш-мимеш таралуга нигез булу, начар ат чыгуга сәбәп булу. *Сафа абый, ташла син мине, зинһар, йөрмә, исемемне чыгарма! Күңелем шикләнә минем.* А.Шамов

**ИСЕ́М ӘНИСЕ** *и. этн.* Христианнарда, керәшеннәрдә, баланы чукындырып, исем кушканда рәсми шаһит булып катнашкан хатын-кыз

**ИСЕ́М ӘТИСЕ** *и. этн.* Христианнарда, керәшеннәрдә, баланы чукындырып, исем кушканда рәсми шаһит булып катнашкан ир кеше

**ИСЕ́М БИРҮ** *ф.* 1) *к.* **исем кушу**. *Балалар йортыннан бер ятимне тәрбиягә алды һәм балага Фәрит исемен бирде.* Г.Мөхәммәтшин

2) Кемне яки нәрсәне булса дә исем белән атау. *Шунда ук без команда төзедек. Аңа «Өянке командасы» дигән исем бирдек.* Г.Сабитов. – *Балаларны «вак җеннәр» дип ирештерәләр, – дип еламсырады Җәмлиев. – Елап керәләр. Ул чокырдан минем исемне, зинһар, алыгыз. Башка исем бирегез.* Х.Камалов

3) Кемгә булса да кушамат тагу. *Шатлык чәчеп йөрүеңә синең «ирдәүкә» дип исем бирделәр.* Ш.Маннур. *Безнең Әзизгә, шулай ук машина маркасына охшатып, «А-ЗИС» дип исем бирделәр.* Г.Сабитов

**ИСЕМДӘШ** *и.* Бер үк, бер төрле исем белән аталучыларның берсе; адаш. Солтан әйтте: «Ул кеше минем белән исемдәш, имеш, шул сәбәпле азат кыйлдым», – диде. Әкият. *Алай булгач, «адаш» сүзе (ад – фарсыча «исем», ад-даш, ягъни исемдәш) каян килеп чыккан соң?* Х.Сарьян

**ИСЕМДӘШЛЕК** *и.* Исемдәш булу. *Шәйләнәләр сансыз йөзләр – исемдәшлектә игезләр: Йонас, Йон, Джон, Иван.* Рәф. Әхмәтҗанов

**ИСЕ́М ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Хәбәре булмаган, бер составлы җөмлә. *Бер составлы җөмләнең баш кисәге исем яки исемләшкән башка сүзләр белән бирелсә, исем җөмлә барлыкка килә. Бер составлы исем җөмләләрне, мәгънәләреннән чыгып, «атау җөмлә» дип исемләү гадәткә кергән.* Татар грамматикасы

**ИСЕ́М ЙӨРТҮ** *ф.* Аталу. *«Яшь гвардия» исемен йөрткәч, сез инде сынатырга тормагыз.* Р.Ишморат. *Бүгеннән башлап --- үзенең туган ягында аның исемен йөртәчәк мәктәптә дә, аның исемен йөртәчәк урамда да яшәячәкләр.* Р.Хәйри

**ИСЕ́М КАРТОЧКАСЫ** *и.* Визит карточкасы, визитка. – *Нинди ил, нинди җир бу, әфәндем! – диде ул. – Акчаны суга сала беләләр, ә үзләренә менә исем карточкасын да бастырып ала алмыйлар.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИСЕ́М КУШУ** *ф.* 1) Кеше тугач, аңа билгеле бер шәхси атама беркетеп кую. *Балага исем кушарга кирәк булгач, син теш арасыннан әче көлү белән: – Дездемона, Розалия, Луиза, Офелия кушыйк, – дип, йөрәккә тоз салдың.* Г.Кутуй. *Бездән соң да бала-чагага исем кушасы, --- үлем-җитем булса, йоласын китереп җирлисе булыр.* Р.Кәрами. *Күп тә үтми Айгөл аңа ир бала таба, аңа Сөябел дип исем кушалар.* М.Хәбибуллин

2) Кушамат тагу

3) Атама бирү, атау. --- *әбинең каршы килүенә карамастан, «Изге Гөлзәйнәп» дип исем куштылар атауга.* М.Маликова

**ИСЕ́М КУЮ** *ф. к.* **исем кушу** (*1 мәгъ.*). *Кем дип башлыйм, Кем дип исем куйыйм, Кем дип атап сиңа эндәшим?* Һ.Такташ. *Үзегез гомер биргән, үзегез исем куйган кызыгызның --- нинди олы гөнаһлары бар иде соң?* Г.Мөхәммәтшин

**ИСЕМЛӘНҮ** *ф.* Исем бирелү, исем алу, аталу. *Дәреслекләрнең соңгысы «Мохтасар химия» дип исемләнеп, 1912 елда «Вакыт» нәшриятында дөнья күрә.* Гасырлар авазы. *Шәһәрнең яңарак сафка баскан «Икмәк – тиңсез хикмәт» дип исемләнгән монументаль композициясе үзенең --- архитектура һәм техник үтәлеше буенча дөньякүләм танылган галимнәрне дә таң калдырган.* Ватаным Татарстан

**ИСЕМЛӘ́Ү** *ф.* **1.** Берәр кешегә яки нәрсәгә исем кушу; атама бирү, ниндидер исем белән атау. *Юкка ышанучы крестьяннар элек, «җен» дигән күзгә күренми торган нәрсә бар дип, шул җенне хурлау өчен, «иске чабата», «сыңар тәрәзә» дип исемлиләр иде.* Х.Кәрим. *Ничек булса булсын, безнең Хәсән дә шул көннән бу исемне эләктереп алган һәм рус арасында үзен Хәсән Абдрахимович дип атауга караганда, «Евгений Петрович» дип исемләүне артык күрә башлаган иде.* М.Әмир. *Бер составлы исем җөмләләрне, мәгънәләреннән чыгып, «атау җөмлә» дип исемләү гадәткә кергән.* Татар грамматикасы

**2. исемләп** *рәв. мәгъ.* Исеме белән атап, исеме белән әйтеп. *Кызга исемләп дәшү*

**ИСЕМЛӘШҮ** *и. лингв.* Башка сүз төркемнәреннән исем сүз төркеменә күчеп, аңа хас грамматик категорияләр алу, исемгә әверелү; субстантивация. *Өстәвенә, төрки телләрнең типологик үзенчәлеге буларак, күпчелек фигыль формалары контекстта еш исемләшәләр.* Татар теле морфологиясе. --- *исем фигыльләр үзләренең грамматик билгеләре буенча күбрәк исемнәргә тартылалар, шуның өчен дә күпчелек очракта исем функциясендә киләләр яисә еш кына исемләшәләр.* Татар грамматикасы

**ИСЕМЛЕ** *с.* 1) Нинди дә булса исеме булган, нинди дә булса исем белән аталган. *Дуся түтәй гомерен Тимоша исемле ата мәчене тәрбияләп үткәрә.* М.Маликова. *Йөрәкне «үкенеч» исемле корт кимерә, кайтканда ук күңелгә килгән уйлар тынгы бирми.* Н.Әхмәдиев. *Әнисенең мондый акыллы сүзләренә Гүзәлия исемле гүзәл кыз каршы куярлык дәлилләр таба алмады.* Ф.Яруллин

2) Исеме, даны киң таралган, күренекле, атаклы, данлыклы. *Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчы.* Г.Ибраһимов. *Профессор Ильясова янында дежур торырга бик тәҗрибәле һәм исемле врачларны гына билгеләгәннәр ---.* М.Маликова. --- *карт --- язын-җәен нәрәтә белән балык аулап, кышын җәнлеккә капкын куеп, авылының исемле сунарчысы да булып яшәде.* Ә.Еники

3) Берәр кеше исеменә атап бирелгән; иясенең, хуҗасының исеме язылган яки куелган. *Кыз «солдатка» исемле балдагын бирә.* Әкият. *Исемле маузер. Исемле яулык. Исемле сәгать*

4) Берәр кеше исеме белән бәйләнгән, аталган; махсус, гадәттәгедән югарырак. *– Ректор исеменә җибәргәннәр [фоторәсемнәрне], – диде секретарь. – Хурлык, бөтен университет өчен зур хурлык бу! Күкрәгеңдәге комсомол значогыңны алып ташларга онытткансың, икейөзле Алла колы... Минә сиңа исемле стипендиат, комитет әгъзасы!* Җ.Тәрҗеманов

**ИСЕМЛЕК** *и.* 1) Җанлы яки җансыз нәрсәләрне исемләп тезеп, билгеле бер тәртип белән санап чыккан язу. *Ванда шуңа барып җиткән ки, Германиягә коллыкка озату өчен исемлекләр төзеп йөргән.* М.Маликова. *Кайчандыр Сәлимнең исеме стена газетасында еш кына телгә алына, ата-аналар җыелышында мактаулы балалар исемлеге Сәлим белән башлана иде.* Г.Гобәй. *Август урталарында Асия институтка кабул ителүчеләр исемлегендә иде инде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Исем (*9 мәгъ.*) булу. *Татар телендә кулланылган һәм кулланыла торган андый исем фигыльләрнең дә исемлек дәрәҗәсе бердәй үк түгел.* В.Хангилдин

◊ **Исемлектән сызу** 1) Кемне дә булса оныту, хәтердән чыгару; 2) Үтерү, юк итү. --- *әнә Газыйм Дардиевны бандитлар үзләре үк «исемлектән сыздылар».* З.Фәтхетдинов

**ИСЕМЛЕ́ КАРТОЧКА** *и. к.* **исем карточкасы**. *– Әгәр [Гариф әфәнде] кайткан булса, менә бу карточканы бирерсең, – дип, исемле карточкамны бирдем.* Ф.Әмирхан

**ИСЕМСЕЗ** *с.* **1.** 1) Исеме билгесез; исем бирелмәгән. *Әгәр шулай икән, исемсез бандит --- үзенә сыенып урын эзләячәк.* З.Фәтхетдинов. *Тиздән без диңгездәге бер исемсез утрауга киттек.* Ә.Гадел. *Тарихтан беләбез: дөньяда бер халык та океан эчендәге исемсез атау кебек үзенә генә аерым яшәмәгән ---.* Х.Сарьян

2) Кем язганы билгесез, авторы күрсәтелмәгән, имза куелмаган. *Боларга, урамга чыксалар, «шпион!» дип кычкыралар, --- өйләренә кайтсалар, исемсез хатлар берлән боларның котларын алалар иде.* Г.Исхакый. *Мөдәррисов үзенең героен, ягъни мине, исемсез хатлар язуда гаепли.* Л.Ихсанова

3) Билгесез, халыкка танылмаган. *Теплоход хезмәткәрләре дә артистлар белән танышып, дуслашып, бергә күңел ачып баралар икән. Исемсез яшь артистлар матрослар белән табындаш булганнар.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Исеме булмаган килеш, исем алмаган килеш. *Малай бер ай исемсез яшәде.* М.Мәһдиев

**ИСЕМСЕ́З БАРМАК** *и. иск.* Кулда урта һәм чәнчә бармаклар арасындагы

бармак, атсыз бармак. *Балдакны үзенең чибәрлегенә яшертен бүләк төсендә кабул кылган кыз, аны ара-тирә сул кулының исемсез бармагына киеп йөрергә дә җөрьәт итә башлады.* Ә.Гаффар. *Гамирның --- сул кулының исемсез бармагында зур кашлы алтын балдак.* З.Фәйзуллин. *Уң кулымның исемсез һәм чәнти бармаклары шундук әрнетеп сызларга керештеләр.* Г.Тавлин

**ИСЕМСЕЗЛЕК** *и.* Кешеләр арасында билгеле булмау, танылмау. *[Ул] Исемсезлек кайгысы белән яна, көя.* Ә.Фәйзи

**ИСЕ́М ТУЕ** *и. этн.* Исем кушу мәҗлесе. *Бу фаҗигагә тарыганнан соң, дәү әнисе, мулла бабайны чакыртып, аңа яңа исем куштырган. Исем туе үткәргәннәр.* А.Хәлим. *Әнисе иренә кыз бүләк итте. Аңа Жанна дип исем куштылар. Исем туена авылдан кодагыйны чакырып тормадылар.* Кызыл таң

**ИСЕМ-ФАМИ́ЛИЯ** *җый. и.* Исеме һәм фамилиясе. *Кичәнең программасы һәм катнашучыларның исем-фамилияләре афишаның яртысыннан күбрәк урынын алып [тора].* Ш.Камал. *Наҗия, уку елы башланганчы ук, күпчелек укучыларын йөреп чыккан, күбесенең исем-фамилияләрен дә хәтерендә калдырган кебек иде.* Р.Хафизова. *Мин сезгә үз исемемне әйтмим. Сез мине исемем-фамилиям белән хәтерләмисез дә, ә чалымым белән хәтерләргә тиеш кебек.* Г.Әпсәләмов

**ИСЕ́М ФИГЫЛЬ** *и. лингв.* Эш яки хәлнең исемен белдерә торган фигыль формасы. *Исем фигыль, исем кебек ук, килеш, тартым, зат-сан белән төрләнә ---.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев. *Исем фигыльләр наклонениягә һәм заманга бәйләнмәгән эш-хәрәкәтне (халәтне, процессны һ.б.) белдерәләр.* Татар грамматикасы. *Хәзерге әдәби телдә исем фигыль -у/-ү кушымчасы белән ясала ---.* Татар теле морфологиясе

**ИСЕМ-ЧАП** *җый. и.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса яхшы яки начар сыйфатлары турында туган гомуми фикер; дан, танылганлык

◊ **Исем-чабы таралу** Яхшы яки начар яктан даны чыгу, таралу; шөһрәт казану. *Берсе – олуг юлларны кисүче ---, икенчесе бик данлыклы, бөтен дөньяга исеме-чабы таралган мөхәррир – китап язучы.* Г.Тукай. **Исем-чабы чыгу** *к.* **исем-чабы таралу**. *Бу арада Газиз үзе генә эшне изеп ташлады әле. Кафер кызы белән йөри, дип, исеме-чабы чыгып тора.* Ф.Әмирхан. --- *Гыйльфан агайның буйга артык калку булмасалар да, төскә-биткә күркәм, исемнәре-чабы чыкмаган төпчекләре егерме бердә дә ата йортында иделәр.* А.Гыйләҗев

**ИСЕ́М ШӘРИФ** *и.* Кадерле, хөрмәтле исем. *Исемнәрең Шәриф, йөзең күркәм, Исем шәрифләрең кем куйган?* Г.Тукай. *Ир баланың исем шәрифләре шундый булсын: анда корыч чыңласын, акыл һәм зирәклек гәүдәләнсен…* М.Насыйбуллин. *Ял көннәрендә, каникулларда яки олы журнал күтәреп безнең исем шәрифләрне билгеләп торучы группа староcталарына «күпне күрмәскә» боерып, лекцияләрдән таябыз ---.* Казан утлары

**ИСЕНГЕРӘ́Ү** *ф. к.* **исәңгерәү**

**Исенгерәп бетү** Тәмам, бөтенләй исенгерәү. --- *Нәҗипне тәмам исенгерәп беткәнче кыса-коча, аркасыннан чәбәкли-чәбәкли хушлаштылар алар.* Җ.Рәхимов

**ИСЕРГӘ́Ү** *ф. бор.* 1) Яклау, саклау, кайгырту, канат астына алу. *И яхшы вә яманнарны исергәүче! Без[не] үзең исергә!* Шура

2) Кемне дә булса кызгану, кемнең дә булса хәленә керү. *Бәнем кеби [ярдәмчесез фәкыйрьне] Исергәп, дәр[темә] кыйлгыл дәва.* Г.Сәмитова

**ИСЕРГӘҮЧЕ** *и.* Яклаучы, саклаучы, кайгыртучы. *И яхшы вә яманнарны исергәүче! Без[не] үзең исергә!* Шура

**ИСЕРЕК** *с.* **1.** 1) Исерткеч эчемлек кулланудан аек халәтен җуйган, исерткеч эчемлек эчеп исергән. *Хәер, көткәнгә генә озак тоелгандыр, әнә чаттан бер исерек бәндә алпан-тилпән атлап килеп чыкты.* Ф.Яруллин. *Гомерендә беренче тапкыр Гадилгә исерек хатын янында утырырга, аны юатырга, тынычландырырга туры килде.* М.Маликова. *Соңгы вакытта ул баракка, гомумән, бик соң кайта һәм еш кына исерек тә була иде.* Г.Әпсәләмов

2) Исергән яки ярымаек хәлендә булган кешеләргә хас. *Кемдер, егетләрдән берсе, гармун тартып җибәрде, кемнәрдер бераз исерек, шулай да матур, моңлы, кайгылы тавыш белән озын көйгә сузды.* Г.Ибраһимов. *Аларның тавышлары исерек, гармуннары бозык иде.* А.Шамов. *Кыз юк сәбәптән дә көлә башлады. Табында яңгыраган һәр исерек сүз үткен, зирәк булып тоела иде.* Л.Ихсанова

3) *күч.* Шатлык, мәхәббәт, бәхет һ.б.ш.лар тәэсире астында башы әйләнгән, әсәрләнгән. *Мин бүген болай да исерек: һаваның сафлыгы, табигатьнең матурлыгы, дөньяның гүзәллеге, яшәүнең күңеллелеге исертте мине.* А.Шамов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Исерткеч эчемлек эчеп исергән кеше. *Мәдинә, шул томанлы әчкелтем-төчкелтем һава эченнән өстәл кырыендагы иске урындыкларга, тәрәзә төбенә утырган исерекләргә тагын бер тапкыр күз йөгертеп, зур сандык өстендәге ике хатынга таба атлады.* К.Нәҗми. *Аек кешенең зиһенендә йөргәннәр һәммәсе дә исерекнең теленә килә, диләр бит.* К.Миңлебаев

2) Исереклек. *Шуңа күрә Гаязның мине исереккә исәпләп, Низамыйлардан араларга тырышуы миңа бераз тынычлык бирде, һәм мин юри башымны исереккә салдым.* М.Әмир

◊ **Исерек баштан** Исерек хәлдә, исерек көенчә, исереклек белән. *Исерек баштан шайтан котырткандыр инде. Пошины Харис белән мин аттым.* М.Насыйбуллин. *Исерек баштан әйтелгән бу сүзләр, утыз ел үткәч тә онытылмаслык булып, Хәдичә апаның күңеленә сеңеп калган.* М.Маликова. *Бер кичне Илфир үзен ятим иткән әтисен – Мөхетдиновны кыйнап ташлады. Билгеле, исерек баштан.* Х.Камалов

**ИСЕРЕКБАШ** *и. кимс.* Һәрвакыт исерек кеше. *Үз-үзен дөрес бәяли алмый торган кеше тәмам бозылган исерекбашны яисә акылыннан мәхрүм ителгән тилемсәне хәтерләтә.* З.Фәтхетдинов. *– Шул исерекбашның ипи шүрлегенә минем исемнән менеп төшегез әле, – ди.* С.Зыялы. *– Алдыйсың, алкаш тәре! – ди-ди, Сәрия урыныннан*

*сикереп торды. – Мин моны болай гына калдырмыйм! Исерекбаш!* Х.Камалов

**ИСЕРЕКЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Исерекләргә хас булганча; исерекләр кебек. – *Малай, тор әле, тайлар югалды бит, – диде Мирхас. Тик Гыйльмеяр дөм исерекләрчә авыз эченнән нидер мыгырдады да тынды.* Х.Камалов. *Шуннан соң [Гамир белән Руслан] тагын исерекләрчә кылануларын дәвам иттеләр.* З.Фәйзуллин

**ИСЕРЕКЛЕК** *и.* 1) Исерек (*1 мәгъ.*) булу, сәрхуш булу. *«Исереклек белән, әти-әнинең үгетләве аркасында өйләндем мин Ләйләгә», – дип антлар итә Вәгыйзь.* М.Насыйбуллин. *Әбүсогыт исереклек җитезлеге белән Сөмбеләнең башын төйде.* М.Хуҗин. *Өстәлләрендә буш шешә аунап ята, ипи катылары, үзләре, икесе ике яры авып, исереклек йокысына талган.* К.Тимбикова

2) *күч.* Айнык фикер йөртә алмау хәле, йокылы-уяулы халәт. *Ольга йокы исереклегеннән һаман арына алмаса да, --- яткан урыннан кузгалырга мәҗбүр булды.* Р.Сибат. *Хәйрүшләр очыннан «Галиябану сылуым, иркәм» җырын исереклек катнаш йокы көенә сузган тавышлар ишетелсә дә, авылның таң алдында гына була торган сихри тынлыгын бозарга җөрьәт итүчеләр башка юк иде…* Я.Зәнкиев

3) *күч.* Шатлыктан, мәхәббәттән, бәхеттән һ.б.ш.лардан үз-үзен онытырлык булып әсәрләнү, тәэсирләнү халәте. – *Әти! Чабышка бардык! Беренче килдем! – дип, әле һаман бәйге исереклегеннән айнып җитә алмастан, кычкырып җибәрде Солтан.* Г.Ахунов. *Нәркисне ул [Нәсимә] киләчәктә бары тик шәһәрнең зур, якты сарайларында, көяз өрәңгеләр тезелгән паркларда, баш әйләндергеч исереклек бирә торган театр залларында гына күз алдына китерә ала иде.* М.Мәһдиев. *Фәтхи исә: «Закир миңа бәхиллеген бирде инде, хәзер үлем исереклеге аңын томалады», – дип сөйләнә-сөйләнә, үзенекен тукыды.* Х.Камалов

**ИСЕРТКЕЧ** *с.* **1.** 1) Составында спирт, алкоголь булган, исертә торган. *Женяның бар белгәне – исерткеч эчемлек. Ул, хәмер белән агуланып, кешелек сыйфатларын көннән-көн югалта бара.* М.Насыйбуллин

2) *күч.* Тәэсирләндерә, хисләндерә, әсәрләндерә торган. *Бу киеме аның [Ларисаның] буй-сынының исерткеч сылулыгын аеруча күзгә ташландырып күрсәтә иде.* М.Маликова. *Яшьлекнең бу исерткеч тойгысына бирелеп, сүзсез генә карашып торганда, безне шул ук Сәхипҗамал уятты.* Г.Бәширов. *Җәй үзенә хас зәвыклы бизәкләре, исерткеч җылылыгы, тынгысыз эшчәнлеге белән кешеләрне тулаем йотты ---.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Составында спирт, алкоголь булган эчемлек. *Исерткечнең зарарлы булуы турында бөтен дөньяның акыллы кешеләре әйтеп килә.* М.Әмир. *--- кырмыска личинкасы ашаучы бөҗәкнең тәне исерткеч бүлеп чыгара. Кырмыскалар шуны ялыйлар да исерәләр.* Х.Камалов. *Печән чабарга чәйнек белән исерткеч алып килгән, абаланып йөрүче бу абзыйлардан нинди эш, нинди киңәш, нинди акыл көтәргә мөмкин!* Татар әдәбияты тарихы

**ИСЕРТҮ** *ф.* 1) Спиртлы, алкогольле эчемлекләр эчертеп, исереклек халәтенә кертү. *Бу элек җәннәттәге ширбәт иде. Һушны алмый һәм исертми – пакь иде.* Ш.Бабич. *Аның иптәшләре ишегалдында --- көтеп торалар да аны үзләре белән бергә алып китеп эчертәләр, исертәләр ---.* Г.Камал. Әле күптәнме иң зур бокалларны егет белән кызга биреп, яшьләрне беренче кичтә үк исертеп, туган-тумачасын аяктан екканчы сыйлыйлар иде. Э.Шәрифуллина

2) Агулау (гадәттә газ белән). *--- малмөлкәтне үзенә генә калдырырга теләгән комсыз яшь хатыны мунча мичен тавык тизәге белән кушып яккан да шул исле мунчада [Сәлмән сәүдәгәрне] исертеп үтергән, имеш.* Ф.Хөсни

3) *күч.* Шатлык, матурлык һ.б.ш.лар тәэсире белән әсәрләндерү, үз-үзен онытыр хәлгә китерү. *Хәнифәнең елтыр күзләре егетнең уйларын чуалтты, исертте.* Р.Хафизова. *Аның бөдрә чәчләреннән, ефәк күлмәгеннән, нәфис тәненнән аңкыган хуш ис Дәүләтшинны тәмам исертә.* И.Гази. *Без йоклаган арба төбендәге кичә генә чабып кайтарылган печән исе дә мине исертә.* М.Әмир

**Исертә башлау** 1) Үзенең исерүен аңлап алу

2) Исерткеч эчемлекнең тәэсире сизелү

**Исертә төшү** Тагын да көчлерәк исертү. *--- нинди дер бер кыздан аңкып калган бик куәтле ислемай исе, тәмәке һәм сигара төтеннәренә кушылып, кар исенә буталып, Хәсәннең борынына керде дә тагы да исертә төште.* Ф.Әмирхан

**Исертеп алу** Бер тапкыр исертү. Кайчандыр Хрущёв: «1980 елда коммунизм була», – дип, беркатлыларны исертеп алган иде. Г.Галиев

**Исертеп бетерү** Тәмам, бөтенләй исертү, бөтенләй исергән хәлгә китерү. *Гыйлемдар бабайны --- алар ул көнне исертеп бетерә яздылар.* Ф.Яруллин

**Исертеп җибәрү** Кинәт исертү; бераз, җиңелчә генә исертү. *Печәннең хуш исе аны исертеп җибәрә.* Р.Кәрами. *Мәсрүрәнең чәчләреннән арзанлы одеколон исе килә иде, ул ис Рушадны исертеп җибәрде.* М.Мәһдиев. *Өметгали белән бу рәвештә беренче утыруым иде. Аркадаш сүзе әйтерсең лә исертеп җибәрде мине.* М.Юныс

**Исертеп җиткерү** Исереклек дәрәҗәсенә җиткерү

**Исертеп кую** Исерек хәлгә китерү. *Җәйге көн, кыр һавасы үзенекен иткән: малайны тәмам иләсләндереп, исертеп куйган.* Г.Гыйльманов

**Исертеп ташлау** Кинәт исертү. *--- һич тә көтмәгәндә Вәсилә исеме яңгырап китү бераз исертеп ташлады мине…* Ф.Хөсни

**Исертеп тору** Озак вакытка исертү. *Мәхәббәт белән исертеп торырга кирәк сезне.* Ф.Яруллин

**ИСЕРҮ** *ф.* 1) Аракы, шәраб һ.б.ш.лар исерткеч эчүдән, әфьюн, героин яки башка наркотик тәэсиреннән аек фикер йөртү һәм нормаль хәрәкәт итү сәләтен югалту, исереккә әйләнү. *Акчасы түләнгән нигъмәтләр әрәм калмасын дип, бетерергә тырыша торгач, итекче белән тегүче бик нык*

*исерделәр.* Г.Ибраһимов. *Фәнүзә шунда: «Фу, тәмам исергәнсең!» – дип, Даянны эткәндәй итте.* Х.Камалов. *Гаяз, урыныннан торып, минем яныма ашыкты: – Җитте аңа, ул исерде, аның бит беренче эчүе, – диде ул.* М.Әмир

2) Гадәттә, ис, газ белән агулану. *Тимерче шул ялкын эчендә торып исергән инде.* Г.Тукай. *Ходаем! Исерә ич ул! Ис тия ич аңа! Әнә башы әйләнә!* Р.Муллануровa

3) *күч.* Берәр нәрсә тәэсирендә зиһен чуалу, фикер таркалу. --- *кырмыска личинкасы ашаучы бөҗәкнең тәне исерткеч бүлеп чыгара. Кырмыскалар шуны ялыйлар да исерәләр.* Х.Камалов. *Гали, йокысына исергән килеш мышмыш килә-килә, чалбарын башына киярго тотынды.* Р.Төхфәтуллин. *Бистә таң йокысы белән исергән.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Ниндидер хис-тойгыдан, хуш истән, яхшы мөгамәлә һ.б.ш.лар тәэсирендә әсәрләнү, рәхәтлек тойгысы кичерү. *Тау битенең --- чирәменә ятып аунийсы, чәчәкләрен иснәп исерәсе килә.* К.Тимбикова. *Исерде ул язның саф исеннән, Гашыйк егет кебек сөйләнде…* Ш.Маннур. *Аларның [күзләренең] тылсымлы нурыннан Хәбир исерә, тәкатен җуя, көне буе тел очында йөрткән, --- сүзләрен оныта.* Ш.Хөсәенов // Берәр нәрсә тәэсиренә бик нык бирелү. *Мәһабәтлегенә урманнарның, тирән тынлыкта утыруларына карап исердем.* М.Гафури. *Әйе, бәгърем, эчми исердем, тормыш матурлыгыннан исердем.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Ниндидер эш белән гадәттән тыш мавыгып йөрү. *Ирек мәкалә белән тәмам исереп бетте һәм көн ярымда эшен төгәлләде.* Ф.Садриев

**Исерә бару** Исереклеге торган саен ныграк арта бару. --- *ул исә, моңа кадәр беркайчан да танымаган билгеләр, серле сөю ләззәте тоеп исерә барды.* Г.Гыйльманов. *Ул Миләүшәнең исерә баруын күреп, аулаккарак сөйрәмәкче иде, тик авыл егетләре сизгер булып чыкты.* Ф.Яруллин. *Ул күзгә күренеп исерә бара иде.* Р.Батулла

**Исерә башлау** Исерү билгеләре күренү, сизелү. *Айрат, бик сирәк эчкәнгәме, бер рюмкадан ук исерә башлавын сизде.* Ф.Яруллин. *Ул тагын һәм тагын эчте, исерә башлавын бик ачык сизсә дә, юри тыелырга теләмәде.* Ә.Еники. *– Кенәз илчесен эчер, – диде исерә башлаган атаман.* М.Хәбибуллин

**Исерә калу** Кинәт, тиз арада исерү. *Ахыр чиктә йончыган иде, бик ябыккан иде ул бу вакытта, бер рюмка эчүгә исерә калды.* А.Вергазов

**Исерә төшү** Беркадәр (бераз) исерү, кызмача хәлгә килү. *Җәвит вино китертте. Эчте, исерә төште, теле язылды.* М.Хәбибуллин. *– Җәмил туган, сеңелгә күз-колак бул, – беренче рюмкадан соң исерә төшкән Гата фәлсәфә сатарга кереште.* М.Маликова. *Бераз исерә төшкәч, Гөлүс гаҗәпләнеп Альбертка карап торды.* Р.Кәрами

**Исереп алу** Исереклек хәлендә булу, исереклек дәрәҗәсенә җитү. *Кешеләр монда речьләр, тәбрикләр белән шөгыльләнгәндә, алар форсатны ганимәт белеп, инде шактый исереп алганнар ---.* С.Җәлал. *Тагын өстәмәсә генә ярар иде балакаем. Исереп алып, яралы аягын авырттыруы бар.* Б.Камалов. *Битарафлык күрсәтергә күпме генә тырышса да, исереп алган милиционерның һәр сүзе аның бәгырен өзгәли, җанын изә --- иде бит.* Р.Мөхәммәдиев

**Исереп бару** *к.* **исерә бару**. *Юри кылана түгелме соң бу Мортазин? Исереп киткәнме? Шулай шул, табын белән бергә исереп бара.* Н.Акмалов

**Исереп бетү** Тәмам, бөтенләй исерү, исергән хәлгә килү. *Буксирның капитаны һәм башка диңгезчеләр, солдатлар белән эчеп, тәмам исереп беткәннәр.* М.Юныс. *Бөтен кеше берьюлы тиз-тиз эчсә, исереп бетәләр дә, мәҗлеснең рәте чуала.* Р.Батулла. --- *Сергей иптәшенә аракыны кызганмый. Тегесе тәмам исереп бетеп, яр кырыена егыла.* Законлы газета

**Исереп җитү** *к.* **исереп бетү**. *Тәмам исереп җиткән Туктар үзен кинәт кенә сугыш кырындагы бер ялгыз батыр кебек хис итә башлады.* Х.Ибраһим

**Исереп йөрү** 1) Берәр төрле исерткеч эчемлек эчеп, шуның тәэсирендә булу

2) Һәрвакыт, гел исерек хәлдә булу. *Әле дә булса хәтеремдә: яз исенә, яз шатлыгы белән ярым исереп йөргән көннәр иде.* М.Хәсәнов. *Сиңа булган мәхәббәтемнән исереп йөрим мин…* Ә.Сафиуллин

**Исереп китү** Бераз, берникадәр исерү; кинәт исерү. *Вәлиулла, ахырга таба исереп китеп, үзенең аһ-зарларын сөйләп ташлады.* Ф.Яхин. *[Әни] Ирен эчертә, сыйлый. Үзе дә еш кына исереп китә иде.* Х.Камалов. *Миләүшә үзенең бераз гына исереп китүен тойды, ләкин бу тәнне оета, зиһенгә ачыклык бирә торган гүзәл бер мизгел иде.* Р.Кәрами

**ИСЕШ** *и. сир.* Исү хәрәкәте, исү юнәлеше. *Җилнең исеше үзгәрү*

**ИСКӘ АЛУ МӘҖЛЕСЕ** *и.* Үлгән кешене күмгәннән соң, аның истәлегенә уздырыла торган мәҗлес. *Зиратка чәчәкләр салып кайткач, искә алу мәҗлесе булырга тиеш ---.* М.Маликова. *Аккош күлендәге дачада Сибгат абыйны искә алу мәҗлесе буласы икән.* М.Мәһдиев. *Настёнаны җирләгәннән соң, хатыннар --- Надьканың өенә, мәрхүмәне искә алу мәҗлесенә җыелдылар ---.* В.Распутин

**ИСКӘНҮ** *ф. диал. к.* **иснәнү** (*3 мәгъ.*). --- *бүген иртәдән алып бу урамда, бу йорт тирәсендә филёрларның туктаусыз искәнүләрен Галимов сизеп калды.* Г.Ибраһимов

**Искәнеп йөрү** Күптәннән иснәнү, искәнү. *Кайдан кредит ачыйм, дип йөридер ул искәнеп, Төшендә банкы повесткасы күрсә уянадыр йокыдан сискәнеп.* Ш.Мөхәммәдев. *Теге Фәхри, Зыя алынгач, бу тирәдә искәнеп йөренгәләвен бигрәк арттырды ---.* Г.Ибраһимов

**Искәнеп тору** Һәрвакыт, гел иснәнү, искәнү. *Башка чакта Мөкәргә кем кергән, кем чыкканны искәнеп кенә торган Хөршид тә, Мөкәрнең кая таба атлаганын күзәтеп торучы Мәгъри балалары да хәбәр итәргә өлгермәдемени?* К.Булатова

**ИСКӘРМӘ** *и.* 1) Төп фикергә карата бирелгән аерым бер аңлатма, ачыклама (мәс., текстагы берәр кагыйдәгә, закон пунктларына һәм аларның кайбер сүзләренә). --- *мин ашыгыч җибәре-*

*ләргә тиешле сызымның соңгы штрихларын үткәрә башладым. Астагы искәрмәгә дә бер-ике сүз өстәргә ниятләп кенә уйга калган идем…* Ф.Баттал. *--- идарәнең парткомы, стройкомы исеменнән район прокуратурасына язып, Тимерне каталажкадан чыгардылар. Әммә «судка кадәр» дигән искәрмә белән.* М.Хәсәнов. *Хатны ике кат укып чыктым, --- соңгы искәрмәсе үзе генә ни тора!* Р.Ишморат

2) Теге яки бу нәрсәгә карата әйтелгән, язылган кыска фикер. *Документлар барсы да әзер бит, янгын сүндерүчеләрнең, санэпидстанциянең искәрмәләрен күздә тотып, тагын төзәтмәләр кертелде.* М.Маликова. *Минә шул турыда бер искәрмә бирү артык булмас, иншалла.* И.Салахов

3) Нинди дә булса хезмәткә карата бирелгән фәнни характердагы тәнкыйть фикере. *Рецензентның бер киңәшен дә кабул итмәде ул [Варин]. Бит кырыйларына карандаш белән язылган искәрмә, күрсәтмәләрне бетергеч белән --- чистарткалады.* М.Хәсәнов

4) Гомуми кагыйдәләрдән тайпылган очрак, төп кагыйдәләргә туры килеп бетмәгән фикер. *Гомерендә бер тапкыр булса да хаталанмый калган хатын-кыз юк Җир шарында. Бу яктан Зөлфия генә искәрмә була алмый ич инде.* Т.Галиуллин. *«Иплән кенә, искәрмә рәвешендә генә фикереңне әйтеп кара», – диде акыл.* М.Маликова

5) Кисәтү, шелтә. *Икенче юлы әткәй дә ирләрнең берсенә шулай ук каты бәрелмичә генә искәрмә ясаган иде.* Ә.Баян. *Ялгыз яшәүгә тәмам күнекте ул. Нәрсә, өйдә тынычлык, чисталык, сиңа беркем дә, беркайчан да комачавын салмый, искәрмә ясамый, син – тулы хокуклы гидай, ирекле хуҗа.* Р.Фәизов

**ИСКӘ́РМӘГӘНДӘ** *рәв.* Көтмәгәндә, уйламаганда. *Ә мин шулай дуамалланып, искәрмәгәндә мөгез чыгарып куюларыгыз үтерә, суя.* М.Хәсәнов. *Аннан соң «хәтер» дигәнең синнән сорап-нитеп тормый бит ул: искәрмәгәндә генә әллә кайчангы үткәннәрне искә төшереп җаныңны айкапайкап ала.* Ә.Сафиуллин. *Аңа каршы килүче дошман искәрмәгәндә сикереп иярәнә басты, сөңгесен күтәрде.* М.Хәбибуллин

**ИСКӘ́РМӘС** *с.* 1) Көтелмәгән, очраклы. *Взвод сугышчылары дошман искәрмәс урында караңгы сентябрь төнендә елганы көймәләрдә һәм аннанмоннан укмаштырылган кечкенә салларда мыштым гына кичә башлыйлар.* Г.Тавлин. *Тәрәзә пәрдәләрен яңартмакчы идем. Болары бик искергән. Искәрмәс акча керми безгә... Башкача ничек акча җиткезәсең?* А.Гыйләҗев

2) Күренмәгән, көтелмәгән. *Искәрмәс түмгәк чана аудара.* Мәкаль

3) *күч.* Астыртын. *Искәрмәс эт каты тешли.* Мәкаль

**ИСКӘ́РМӘСТӘН** *рәв. к.* **искәртмәстән**. *Тотыш искәрмәстән аның эченә тибеп җибәрде – Алмыш ханның мактаган алыбы «гөрс» итеп арты белән җиргә барып төште.* Н.Фәттах. *Нәсимә аның бу сагышлы тынлыгын атасы өчен көенүгә юрап йөргән көннәрнең берендә, Саимә аны, урамнан узып барышлый, искәрмәстән куып җитеп кочаклап алды.* К.Нәҗми. *Варис дәррәү кабынып китә торганнардан түгел. Әмма, искәрмәстән «забастовка» сүзен ишеткәч, түзмәде, кинәт усалланып әйтә салды.* М.Хәсәнов

**ИСКӘ́РМИЧӘ** *рәв. к.* **искәртмәстән**. *Бер кичне Зөлхиҗә аны-моны искәрмичә: – Карап торуга җыйнак кына гәүдәле, малайлык та чыгып бетмәгән үзеннән ---, – диде.* Ф.Сафин. *[Рәфис] Уйга бирелеп, искәрмичәрәк калган икән, маңгае белән «шап» бетонга!* Н.Әхмәдиев. *Шикле бәндәләр ул арада берни искәрмичә атлавын дәвам иткән Шәяхмәткә ябырылалар.* К.Миңлебаев

**ИСКӘРТКЕЧ** *и. сир.* 1) Язма ядкәр, истәлек

2) Нәрсәне дә булса онытмас өчен билгеләнгән әйбер яки тамга

**ИСКӘРТМӘ** *и. к.* **искәрмә**. *--- ул, һичшиксез, үз искәртмәләре турында уйлар һәм төзәтер.* М.Җәлил

**ИСКӘРТМӘЛЕ** *с.* Алдан аңлатыла, искәртелә торган. *Шундыйлардан диктантларның төрле төрләре кулланыла: сүзлек диктантлары, аңлатмалы, искәртмәле, иремле, тикшерү, контроль диктант һ.б.* Фән һәм тел

**ИСКӘ́РТМӘСТӘН** *рәв.* Кинәттән, уйламаганда, көтмәгәндә; кисәтеп тормыйча. *Гильотинмы кисәр газиз башны, Искәртмәстән яки атарлар, Ачлык белән буып үтерерләрме? Яки биек дарга асарлар?* А.Алиш. *Шулай көннәр үтә, шулай айлар үтә, һәм кинәт, искәртмәстән генә, тормышның зәгыйфь кенә яңа җиле син көтмәгән яктан исеп куя.* Ф.Хөсни. *Арт яктан килеп җиткән бер фриц, искәртмәстән, Шәяхмәткә кизәнде.* А.Әхмәт

**ИСКӘ́РТМИ** *рәв. сир.* Сиздермичә, алдан хәбәр бирмичә, белдермичә, алдан кисәтмичә. *Менә шулай, һичбер чакырусыз-нисез, искәртми-нитми генә чит кешегә барып керү килешмәгәнлеген бик яхшы аңласам да, Ф.Әмирханның кайда торуын, өй адресын белү өчен, тәвәккәлләп, Яңа бистәгә киттем.* М.Бөдәйли. *«Тел» кирәк дошман планын Яхшырак ачар өчен; Искәртми барып, фашистның Оясын басар өчен!* М.Җәлил

**ИСКӘ́РТМИЧӘ** *рәв.* 1) *к.* **искәртмәстән**

2) Искә төшермичә, хәтергә алмыйча. *Шунысын искәртмичә узарга ярамый: Ильяс Шәриповның озын, дәвамлы педагогик хезмәте әле тиешле хөрмәт белән искә алынмады.* М.Макаров

**ИСКӘРТҮ** *ф.* **1.** 1) Искә төшерү; хәтердә, күңелдә яңарту. *Монда бытбылдык, тургай тавышлары аның кыз вакытларын, үзенең тиңдәшләре белән урак урып, печән җыйнап йөргән заманнарын искәртә иделәр.* Ш.Камал. *Кешелекле эчке бер тойгы гына аларны [Сәмигулланың] кан туганы икәнен искәртә.* М.Галиев

2) Берәр эш турында алдан хәбәр итү, әйтеп кую, алдан кисәтеп кую. *Уяу дустым, искәрт байларыңа: Бу сөякләр бер көн үлчәнер.* М.Җәлил. *Аны Нина алдан искәртмәгән, ахры, искәртеп тә, бәлки, үз сүзен итәсе килгәндер: ничек булса булган, Нина, беребезне дә зур тәнәфескә чыгармыйча, бик коры гына итеп, Максимовка класс алдында Сәрвидән гафу үтенергә кушты.* Х.Сарьян. *Көннәрдән бер көнне, аһ-уһ итеп, Елена Мачтакова*

*райкомга кайтып керде һәм, без аулакта икәүдән-икәү генә калгач: «Аяз, бел, мине МГБга чакырдылар, синең хакта бик җентекләп сораштылар», – диде. Кисәтү иде бу, искәртү.* А.Гыйләҗев // Әйткәнне, кушканны, үтәргә тиеш булганны үтәмәгәндә, тыңламаганда кисәтү ясау. *Бәби йоклый, дип, ничә тапкыр искәрттем инде мин сезне!*

3) Алдан күрү, аңлап алу, сиземләп кисәтү. *Ә.Баянов беренчеләрдән булып яңа шәһәрләр, ясалма диңгезләр төзүнең, тирәлекне пычратуның киләчәк өчен нинди куркыныч алып килүен искәртте.* Әдәбият // Алдан күренү, аңлатып тору, сиземләнү. *Әле бит югыйсә бернәрсә дә Хрущёвның шулай тиз чөеләсен искәртми иде.* Р.Кәрами

4) Игътибар итү, күреп алу, абайлау. *Касыймның бала туганга шатланып балкымавын, сүзенең сүрәнлеген искәртте Зәйтүнә.* С.Зыялы

5) *әд.* Текстка карата кыскача аңлатма, ачыклама, искәрмә ясау. *Әсәрнең матбугатта басылып чыккан өзекләре дә «Гарнизон» романыннан» дип искәртәләр иде.* Н.Гыйззәтуллин

6) Ничек эш итәргә кирәклеген аңлату, күрсәтү, юнәлеш бирү. *Чабудан да тарта социализм, Иң хак юлны миңа искәртә.* Х.Туфан

**2.** *и. мәгъ.* 1) Әйткәнне, кушканны, үтәргә тиеш булганны үтәмәгән өчен кисәтү, шелтә. *Конференциядә катнашмаган фәнни хезмәткәрләргә искәртү ясалачак*

2) Текстка карата кыскача аңлатма, искәрмә. *Җитәкче күрсәткән искәртүләрне төзәтеп, мәкаләмне басмага тапшырырга җыенам*

3) Аерым игътибар, дикъкать. *Туфан шигырьләрендә пешеп җиткән эшчеләр турында искәртүләр булса да, бу типлар үтешле-китешле генә алына ---.* Г.Нигъмәти

**Искәртә бару** Һәр очракны аерым-аерым искәртү, искә төшерү

**Искәртә килү** Электән үк, даими рәвештә яки әледән-әле, еш кына искәртү. *[Марсель Сәлимҗановның] Алдан күрә белүчәнлеге, зирәк зиһене, кешелеклелеге, абруе ваемсызлык чиреннән күпләрне искәртә килде.* Т.Мөбарәков

**Искәртеп алу** Сүз уңаенда әйтеп узу, кыскача искәртү. *Башта берничә сүз белән ни өчен җыелуларын, тикшерелә торган мәсьәләнең әһәмиятен искәртеп алды ---.* Р.Кәрами. – *Каударланма, кабаланма! Мондый вакытта хирурглар кебек тыныч, салкын канлы булырга кирәк, – дип искәртеп алды аны күзәтеп торган Фарсил.* Р.Фәизов

**Искәртеп калу** Ниндидер бер мизгелдә, кыска вакыт арасында берәр вакыйганы, эш-хәлне искә төшерү, тиз арада искәртү, искәртергә өлгерү. *Ибрай, аны-моны тоеп алганчы, фәкать бер генә нәрсәне искәртеп калды: әйтерсең лә ул үзе шаркылдап көлде, ә аның бирге ярдан аргы ярга сузылып яткан күләгәсе үксеп-үксеп елады шунда.* Ә.Гаффар

**Искәртеп килү** Озак вакытлардан бирле, күптәннән һәм күп тапкырлар искәртү. --- *укырга теләге барлыгын Мәхмүт гел искәртә килде.* С.Зыялы

**Искәртеп китү** Сүз уңаенда әйтеп узу, кыскача искәртү. *Тик шуны гына искәртеп китәм: картлар әйтмешли, чәчләребез чәчкә бәйләнеп үк туган булганбыз, күрәмсең, Сәкинә белән шул ук кичтә аңлашып, сөешеп киттек.* В.Нуруллин. *Әмма шунысын искәртеп китик: һәрбер хыялый әсәр --- ул әле фәнни фантастика жанрына карый дигән сүз түгел.* А.Тимергалин. *Беренчедән, шуны искәртеп китәсем килә: миңа иптәшләрнең принципиаль чыгышлары ошады.* Шатлыклы кайгы

**Искәртеп кую** Нәрсә турында булса да алдан ук искәртү. *Колхоз рәисе Шәкүр дә халыкны җыеп, шул турыда тагын бер тапкыр искәртеп куйды.* Я.Зәнкиев. *Моны аңа хәзер үк әйтү, һич булмаса искәртеп, сиздереп кую хәерле.* Р.Кәрами. --- *Суфия апа аның борсалануын күреп: – Мин синең өчен дә сөйлим, Нәҗметдинов! – дип искәртеп куйгач, тынып калырга мәҗбүр булды.* В.Нуруллин

**Искәртеп тору** 1) Һәрвакыт, гел, даими искәртү. *Шул буран, кар-яңгырлар буласын алдан белеп, искәртеп тора да инде безне, Ходай бәндәләрен, Ак Чагылкай дигән тау.* З.Зәйнуллин. *Хәеровны анда яхшы беләләр, форсат чыккан саен, аның нык куллы җитәкче икәнен искәртеп торалар иде.* Ф.Сафин. *Балалар, минемчә, өлкәннәргә сафлык, матурлык, ихласлык хакында искәртеп тору өчен кирәк.* Г.Гыйльманов

2) Әле, хәзерге вакытта искәртү. *Яшьләрне ярдәмеңнән ташлама. Хәер, нигә монысын искәртеп торам соң әле?* М.Хуҗин

**Искәртеп узу** Сүз уңаенда искәртү. *Шунысын искәртеп узу да артык булмас: мәҗлестә катнашучыларның берсе дә ата-бабаларының туган җиренә аяк баса алганнары юк икән.* В.Нуруллин. *Безнең белән дә таныштылар. Берочтан минем татар язучысы булуымны искәртеп узалар.* Р.Мөхәммәдиев. *Соңыннан күпме эзләсәләр дә, рогатканың табылмавын, бары тик көзен, --- бер сабакка уралган, --- резинка чыкканын искәртеп узыйк.* А.Гыйләҗев

**Искәртеп үтү** *к.* **искәртеп узу**. *Әмма кайткан мәлләрдә генә түгел, хәзерен дә кемнәрнеңдер ук атып, --- шул мәлдә үзләрен күккә чөяргә маташкан салам сыйраклар барлыгын да искәртеп үтәм!..* А.Гыйләҗев. *Ул чакта шунысы бик гаҗәп тоелды Равилгә: монда да аңа Укмас клубында булган күңелсез хәлне искәртеп үттеләр.* В.Нуруллин. *Аннан соң моңарчы бронзадан коелган һәйкәлләрнең тора-тора яшел төскә кереп, өстәвенә, тузан белән аралашып ямьсезләнгәннәрен дә искәртеп үттем.* Г.Галиева

**ИСКӘРТҮЛЕ** *с. к.* Кисәтүле, кисәтү белдергән. *Әни як-ягына искәртүле каранып, тавышын акрынайта төште.* С.Сабиров. *Җүләрләнеп, ашкынып капкага таба йөгергән карчыкны Зәйнәпнең кискен, искәртүле тавышы туктатты ---.* Х.Ибраһим

**ИСКӘРҮ** *ф.* 1) Искә төшерү, хәтергә килү, онытылган әйбер хәтердә яңару. *Солдат нәрсәдер искәргәндәй булып, Сәгыйтовка карап торды да: «Бу шул түгелме икән?..» – дигән уйга калып, сөйләүченең янына барды.* М.Гафури

2) Кисәтү, исенә төшерү. *Әни Казанда берәрсендә тотып укыту ягын карады, әти кыз балага алай кыен булганын искәрде.* К.Миңлебаев

3) Күрү; абайлау; белеп, аңлап алу; сизү. *Кош-корт тирәсендә иртәнге эшләрне бетергәч, Җәмил киемнәре керләнгәнен искәрде.* Н.Әхмәдиев. *Ул баскычтан ничек менгәннәрен дә искәрмәде.* М.Маликова. *Фәрдәнә биек баскычтан ничек төшкәнен, урам аша чыгып, ничек бакчага килеп кергәнен үзе дә искәрмәде.* С.Сөләйманова

4) Игътибар итү, дикъкать итү. *Зилә, чырыйлап, кайнар бәрәңгене төшереп җибәрде. Айдар читкә караган булып утырса да, барысын да искәрә.* М.Галиев. *Әйтерсең ул --- үзенең толлыгын, җилкәсенә төшкән тормыш авырлыкларын, мәшәкатьләрен искәрми ---.* Н.Хәсәнов

**Искәрә башлау** Абайлап алу; игътибар итү. *Шуннан соң искәрә башладым: ашханәдән чыккач, кыргый урман хозурлыгында, кышкы кояшның нурларын сеңдереп, төркем-төркем язучылар гәп коралар иде.* М.Галиев. *Аннан соң байтак кына егетләребезнең сакланып, үзләрен бик тә тыярга тырыша-тырыша гына сөйләүләрен дә искәрә башладым.* М.Вәлиев. *Бераздан мин Сафинның авызы ерылып та күзләренең бер дә көлмәвен искәрә башладым.* Р.Вәлиев

**Искәрә килү** Күптәннән үк, һәрдаим искәрү. *Сәлим абый Хәмитне иң авыр вакытларда да җебеп төшми торган тәвәккәл, кирәк чакта нык куллы җитәкче буларак ихтирам итә, әмма аның тагын кайбер якларын да искәрә килә иде.* Р.Фәизов

**Искәрә тору** Даими, һәрвакыт искәрү. *Мисхәт --- соңыннан санарга өйрәнгәч, аларның [китапларның] төптөгәл унбиш данә икәнен һәм шуннан кимемәүләрен дә, артмауларын да искәрә торды.* М.Шаһимәрдәнов

**Искәреп алу** Кыска гына вакыт арасында күреп абайлау, тиз арада искәрү. *Бервакыт, география картасыннан бергәләшеп Изге Елена утравын эзләгәндә, Илгиз аны [миңне] искәреп алган иде.* Г.Галиев. *Ничә якшәмбе булган икән, дип искәреп алды Бибиса, врачларның озак күренми торуларын хәтеренә төшереп.* С.Сөләйманова. *Егылган җирдә Әнвәр үзенең җыелып торган бозлы суда ятканлыгын тәне өшүдән искәреп алды.* Х.Камалов

**Искәреп бару** Берсе артыннан берсен искә төшерү, бер-бер артлы искәрү

**Искәреп йөрү** Күптәннән сизенү, әллә кайчаннан искәрү

**Искәреп калу** Искәрергә өлгерү, тиз арада искәрү. *Алай да авылга бу юлдан менмәскә әле. Кешеләр күреп, искәреп калмасын...* Р.Фәизов. *Бу ыгы-зыгыда Әмир дә, Динис тә Аппакның каядыр югалуын искәрми калдылар.* Р.Зәйдулла

**Искәреп тору** Әледән-әле яки даими искәрү, исенә төшерү. *Ә лобогрейка алдына утырган малайга Мостафа әледән-әле искәреп тора.* Ш.Камал

**ИСКӘРҮЛЕ** *с.* Кисәтүле, нәрсәнедер кисәтергә теләгән. *Искәрүле караш*

**ИСКӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Иснәү. *Файда юк искәсә дә, яласа да, Кирәк кай җиренә куеп караса да.* М.Гафури. *Терекҗан уянды. Уянды да авызын ачып искәде, киерелеп алды.* Р.Батулла

2) *күч.* Берәр нәрсәне, эшне сизенеп, аңлап, белеп алу. *Җилнең кай тарафтан искәнен искәү*

**ИСКЕ** *с.* **1.** 1) Озак вакытлар буена яки еш куллану нәтиҗәсендә сүсәргән, искереп җимерелү алдында торган, кулланышка яраксыз хәлгә килгән; тузган, таушалган. --- *колхозның уңышы елдан-ел арта барганга, иске келәтләр, иске базлар гына аны канәгатьләндерә алмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Радиолада иске пластинка бер ноктада әйләнепме әйләнде ---.* Р.Хафизова. *Иске, кыршылган гына тун кисә дә, аның астында әзмәвердәй таза гәүдә йөрткән өлкән яшьләрдәге бер ир телгә килде.* В.Имамов

2) Хәзерге таләпләргә, чорга туры килми торган, заман таләпләренә җавап бирми торган; заманнан артта калган; модадан чыккан. *Сафый Насыйбуллин – кыскарак буйлы, ак кергән чәчле, искерәк модада европача киенә торган Казан сәүдәгәре.* Ф.Әмирхан. *Атасы никадәр иске фикерле борынгы кеше булса да, анасы бик сөеп иркәләгәнлек сәбәпле, байбәтчә бара-бара атасының сүзенә күп колак салмыйча, үз теләгәнчә --- киенә башлады.* Ш.Мөхәммәдев. *Заманалар үзгәргән, таләпләр үскән, ә архитекторлар иске традицияләрдә тәрбияләнеп үскән кешеләр булып калганнар.* М.Маликова

3) Үткәндәге иҗтимагый, сәяси, икътисади төзелешкә караган. *Иске татарларыбыз аяклары белән уйларга өйрәнеп, башларына бөтенләй ихтыяҗлары беткән.* Ф.Әмирхан. *Унҗиденче елның октябрь җилләре Казан губернасын да урап-урап исте: тарих юлында черегән яфраклар төсле аунап яткан иске хакимиятне себереп түкте.* З.Фәтхетдинов. *Хәзер адәм балалары «намус» ише иске режим калдыгы белән санашмый ---.* Х.Камалов

4) Күптәннән бирле яшәп килгән; күптәнге, әллә кайчангы. *Шул иске җир-суның, таш пулатларның, шул иске магазиннарның кире тагы үзләренә кайтуы турында, дөньяның иске эзгә төшүе турында саташа.* Г.Ибраһимов. *Биредә, иске Әлмәттә, урамнар караңгырак, ә өске якта – яңа Әлмәттә – бик күп гирляндалар балкып торалар.* Х.Камалов. *Һәр адымын атлаган саен, ул үзенең иске дусларына якынлаша, йөрәге очрашу шатлыгыннан дулкынланып тибә.* Г.Әпсәләмов

5) Булып үткән, элек булган. *Шуларны күргәч, кире иске тормышыма кайтасым килми.* М.Гафури

6) Күптәнге, электә булган, элеккеге. *Пешмәгән җырларның байтагы иске җырларны бик ятышсыз, механик рәвештә яңача үзгәртеп ясаган җырлардан тора.* М.Җәлил. *Флегант авыр итеп сулыш алды: ахры, хатирәләр белән бергә иске яралары да кузгалды.* З.Фәтхетдинов

7) Бик күптәнге, борынгы, элекке замандагы. *Үләсе елларында Ибраһим, мәрхүм, Казан тарихы турында китап язам, дип, берничә тапкыр минем өйгә килеп, иске Казан һәм Пугач явы турында --- сорашты.* М.Гали. *Болар бар да – иске заман тәрбиясеннән, хатын-кызга курчак, чәчәк итеп караудан килгән нәрсә.* Г.Кутуй. *Бабай, без иске китапларны, кульъязмаларны яңадан бастырып чыгарырга исәпләп йөрибез...* Г.Галиев

8) Былтыргы, узган. *Син китәсең, безне базга бикләп, хуш, иске ел, көмеш сакаллы.* М.Җәлил // Былтыргы, узган ел уңышыннан калган. *Казып чыгарган бәрәңгеләрне, сабакларыннан кага-кага, бер кучкәрәк өяргә керештем. Миңа карап, син үз фикереңне белдерәсең: – Иске «ана» бәрәңге беркемгә дә кирәк түгел.* Н.Хәсәнов. *Июль аенда аларның базында киселгән ярты чиләк бәрәңге дә калмады. Яңасы өлгермәгән, искесе беткән чак.* С.Зыялы. *Туфракта иске орлыктан яңа бәрәңге үрчетү аңа күктә яңа йолдыз үстерү белән бердер кебек.* А.Хәлим

9) Моңа кадәр булган, моңа кадәрге. --- *Гөлгенә яңа йортны иске урынга эшләтмичә, икенче урынга салдыра.* М.Җәлил. *Иске председатель, җыенга үз кешеләре генә килүне күреп булырга кирәк, шат йөри.* Һ.Такташ. *Бу иңкеллек, бу тар гына батынкы җир елганың кайчандыр иске эзе булган.* Н.Фәттах

10) Срогы чыккан, хәзер гамәлдә булмаган, кулланылып ташланган. *Трамвай тукталышларында бер тәмәке төпчеге, иске билет әсәре күрмәссең.* С.Зыялы. *Иске абонемент*

11) Күптәннән мәгълүм, күп тапкырлар кабатланган. *Таныш, иске сораулар өр-яңадан алга килеп басты: үтерүнең сәбәбе нәрсәдә?* З.Фәтхетдинов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Күп кулланудан тузган, таушалган әйбер. *Бар, әнә баскыч астына чык та өс-башыңны алыштыр, искеләреңне чүплек савытына ташлап китәрсең.* М.Маликова. *Энемнең өстендә – әтидән калган, искедән бозып тегелгән кыска бишмәт.* М.Әмир. *Әти белән әни каршы торып караганнар иде дә, авызларын тиз томаладым. Җилкәм үсте, синең искеңнән бозып теккән камзулга сыймый башладым, дидем.* Ф.Хөсни

2) Яшь балаларның астына салына торган чүпрәк; бәби чүпрәге. *Чынлап та, хатынның идәнгә сузылган сул беләге өстендә искегә төргән бер сабый да ята иде.* Ә.Еники. *Фәтхерахман --- бәби искеләренә хәтле юа.* Б.Камалов. *Озак та үтми сандык янәшәсенә --- япмалар, күкрәкчәләр, бала искеләре – тагын да әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр өелә барды...* А.Хәлим

3) Тормышта элекке заманга хас, хәзерге вакыт өчен искергән нәрсә, күренеш. *Савымчыларның күпчелеге бу яңа ысулга ышанып бетмәделәр, һаман да шул ике куллап искегә ябышып яту ягын карадылар.* М.Хәсәнов

4) Элекке, үткән заманга хас, хәзерге вакыт өчен яраксыз фикерләр иясе; иске лекне яклаучы, консерватор. *Җен-фәлән дип сөйләнүләр искеләрдән калган ул.* Г.Тукай. *Барысы да – иске тип сәүдәгәр, «без – мөселман» дип, үзләренең кадимлегенә шөкер итеп утыручы искеләр.* М.Мәһдиев. – *Башта алар шулай кыйлананалар, – ди, – аннан соң үз калыпларына төшеп утыралар, – ди, – искесе дә башта кыйланган иде, төште, – ди* ---. Х.Сарьян

5) Элеккеге, борынгы чор, заман. --- *савыт-саба, кирәк-ярак искедән, борынгыдан калган булса да, һәммәсе үз урынында --- иде.* М.Маликова. *«Бу иске дөньяны җимерәбез. Искене җимермичә, яңаны корып булмый», – дип сөйләнде ул.* Ф.Яруллин // Элек булган, кайчандыр кулланылган әйбер. *Мәүлә абый үзе: – Аю күлендәге машина тагын ватылган, – дип зарланып куйды. – Искедән генә җыйган машина бит, – дидем мин аңа каршы.* Л.Ихсанова. *Чыннан да, каян табылган бу әйбер? Борынгымы ул, әллә шушы заманның оста куллы берәрсе юри искегә охшатып койганмы?* Ф.Сафин

6) Элек булган хәлләр, вакыйгалар. – *Гөлшәй, – диде Гайса бераздан: – Гафу ит инде, Гөлшәй. Искеләрне онытыйк та яңадан бергә кушылыйк.* Г.Әпсәләмов. – *Инде мең ел җир куенында яткан мәетләрне кузгатып, --- [салынган] шәһәрнең нигезе бәрәкәтле булыр дип уйлыйсыңмы? – Искене җимермичә, яңаны салып булмый.* Р.Вәлиев

7) Элек кулланышта булып та, хәзер гамәлдән чыккан нәрсә. *[Сыерны] Тугыз йөзгә килештек. --- Иске белән тугыз мең бит ул.* М.Галиев

◊ **Иске авыздан яңа сүз** Берәр кешедән көтелмәгән, урынсыз, дөрес булмаган яки гаҗәп сүз ишеткәндә әйтелә. – *Кайсы станциядә төшәсең син, Мотыйк абый? – Менә сиңа иске авыздан яңа сүз, киләсе станциядә, дип торам ич.* Р.Вәлиев. – *Менә иске авыздан яңа сүз! Ничек инде сөйләшер кеше юк?! – дип гаҗәпләнде Рәсимә апасы. – Яныңда әнией бар иде ич синең!* Ә.Сафиуллин. – *«Өйләндем» дип, улым. Алдан хәбәр итү юк, киңәшләшү юк. Иске авыздан яңа сүз, ишетмәгән колагым ишет.* Ф.Сафин. **Иске бер тиен** *кимс.* 1) Шомарган, әрсез кешегә карата әйтелә; 2) Кыйммәте, файдасы, кирәге юк дәрәҗәдә аз булган нәрсә турында әйтелә. **Иске бер тиен кебек** Кайтуы яки сөйләве кирәксез булып та, кайткан яки сүз сөйләгән кеше турында. *Атна-ун көннәр үтте микән, баш агроном иске бер тиен кебек тагы күренде.* Х.Камалов. **Иске бер тиен төсле** *к.* **иске бер тиен кебек**. *Чыннан да, сәер кеше булып чыкты ул. Үзенә тиешле ике атнасын эшли дә больницага кереп ята. Ә буровойга барыр көн җитү белән, иске бер тиен төсле кайтып җитә.* М.Зарипов. *Кем белә, может, тагын да иске бер тиен төсле ялтырап кайтып килербез әле.* Ф.Бурнаш. **Иске бистә асравы** *кимс.* 1) Үз-үзенә шаккатып, эшләмичә йөрүче кеше турында; 2) Җыйнаксыз кеше турында әйтелә. **Иске бишмәтне кузгату** Булган, онытылган эшне, үпкә-хатирәләрне яңадан кузгату, искә алу. *Я, ярый, иске бишмәтне кузгатмыйк – тузаны чыкмасын. Үткән-беткән, өстенә үлән үскән.* Г.Мөхәммәтшин. **Иске җыр җырлау** Күп мәртәбә ишетелгән, сөйләнгән сүзне кабатлау. – *Улым, тап син Гөлнарага вакыт, тап. Ычкындырма алтын балыкны ятмәдән! – Әни, син тагы иске җырыңны җырлыйсың!* Н.Гыйматдинова. **Иске искедән** Бик күптәннән, борынгыдан. *Иске искедән калган йолаларны онытырга ярамый.* **Иске колакчын кидерү** Бөлдерү, матди яктан авыр хәлгә калдыру. **Иске корсак – яңа аш** Күчтәнәч ашамлык алып авыз иткәндә әйтелә. *[Бибкәй:] Менә күчтәнәч. [Гөлбикә:] Я, иртәдән бирле иренем кычыта иде, иске корсак – яңа аш!* Н.Исәнбәт. **Иске күз** Күптәннән, электән таныш кеше, элекке дус.

**Иске мунча, иске таз** Бер үзгәреш тә, яңалык та булмау турында. **Иске мунча, иске таш** *к.* **иске мунча, иске таз**. *[Харис] Бераз уйланып торгач тыныч кына: – Безгә институтта ук эш киеме белән китәргә куштылар, ә син ефәк күлмәк белән. Ике-өч атнага махсус эш киеме бирсеннәрме әллә? Кыймматкә төшәсең... совхоз өчен. – Э-э, иске мунча, иске таш!..* З.Вәли. **Иске мунча себерксе чәйнәү** Файдасызга, бушка сөйләү, йөрү. *Бу заманда юк сүз сөйләп, иске мунча себерксе чәйнәп тормагыз.* Н.Исәнбәт. **Иске мунча фәрештәсе** *кимс. к.* **иске чабата олтаны**. *Анда Вәли мулла һәм Ф.Сәймани кебек иске мунча фәрештәләре адәмиләрнең көфер вә иманын язарга вә печать басып торырга [боерылганнардыр].* Г.Тукай. **Иске тунны кузгату** *к.* **иске бишмәтне кузгату**. **Иске чабата** *эвф.* 1) Бизгәк авыруы, малярия; 2) *миф. хур.* Җен, пәри. *Юкка ышанучы крестьяннар элек җенне, хурлау өчен, «иске чабата», «сыңар тәрәзә» дип исемлиләр иде.* Х.Кәрим. **Иске чабата белән куу** Хурлап, мәсхәрәләп, мыскыллап куу. *Син, Фәсхи абзый, үзең дә йомшаграк. Мин синең урыныңда булсам, [аны] иске чабата белән совхоздан куар идем.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Иске чабата олтаны** Ямьсез яки кирәксез кешегә карата мыскыллап, мәсхәрәләп әйтелә. *Шул чепи күзле нәрсә гүзәлләр солтаны буласы, имеш. «Иске чабата олтаны» дисә, бер хәер иде.* Г.Камал. **Иске читек олтаны** *к.* **иске чабата олтаны**

**ИСКЕ́ ЕЛГА** *и.* Елганың элеккеге юлы; *русчасы*: **старица**. *Язгы ташу вакытларында үзәннең күп өлешен су баса, һәм --- елга үзенә яңа юл сала, ә элекке юлы урынында «иске елга күле» дип атала торган күлләр калдыра.* География

**ИСКЕДӘН** *рәв.* 1) Борын-борыннан; элек-электән. *Искедән бирле аш-су күреп килгән дус-ишләр бөтенләй үк хәтерләреннән чыгарып бетермиләр әле.* Г.Камал

2) *иск.* Күптәннән. *Шуның өчен Сәгыйдә: «Хәзрәт, сәфәр ае кергәнче, әллә эшне тәмамлыйкмы?» – дигән сөальгә дә хәзрәт, искедән сөйләнеп беткән кебек: «Үзең кара, остазбикә!» – диде.* Г.Исхакый. *Ул кибетче малайларга, читекче, кәвешчеләргә ак яка киертте, искедән киеп килгән казакиларын искечегә саттырып, һәйбәт бумажный материядән «пинжәк» тектертте ---.* Р.Гали.

◊ **Искедән калган** Борынгыдан килгән, электән калган. *Минем күземдә искедән калган бер пәрдә булган икән.* Г.Ибраһимов. *Сездә дә, бабай, искедән калган язмалар юкмы дип килгән идек.* М.Галиев. *Кешегә кунакка йөрү, үзеңә кунаклар чакыру – искедән калган начар гадәт ул.* Т.Гыйззәт

**ИСКЕ́ ДИНЧЕ** *и. иск. дини* Россиядә XVII гасырда христианнарда дини таркалыш сәбәпле барлыкка килгән һәм иске чиркәү кануннарын (иске динне), элеккеге тәртипләрне саклап яшәргә омтылган дини агым тарафдары; *русчасы:* **старовер**. *Пугачёв Алаттагы бер иске динче рус купецы белән --- каравылчы солдатларны эчертеп --- качкан.* Г.Гобәйдуллин

**ИСКЕ́ ИМЛЯ** *и. лингв.* Татарларда XX гасыр башларына кадәр кулланылып килгән һәм тулысынча гарәп графикасына нигезләнеп төзелгән орфография. --- *ысул җәдидә дәверенә кадәр дәвам иткән бу имляны без «иске имля» дип атыйбыз ---.* Җ.Вәлиди. *Гарәп язуын куллануны тәртипкә салу барышында, татарларда бер-берсеннән зур аермасы булмаган иске имля алфавиты --- кабул ителгән.* Татар теле

**ИСКЕ́ КЕРӘШЕННӘР** *и. этн.* XVI–XVII гасырларда ук чукындырылган татарлар. *Галимнәр керәшеннәрне, христиан диненә күчерелү вакытларына мөнәсәбәтле рәвештә, «иске» һәм «яңа» керәшеннәргә бүлеп йөрткәннәр.* Ф.Гарипова. *Иске керәшеннәрнең телендә дә, җырларында да, киемнәрендә дә борынгылык күбрәк сакланган, дип язалар.* Х.Сарьян. *Казан ханлыгы рус дәүләте тарафыннан буйсындырылганнан соң, ягъни XVI урталарыннан башлап 1741 елга кадәр христиан диненә күчерелгән татарлар «иске керәшеннәр» дип йөртелгәннәр.* Ф.Гарипова

**ИСКЕЛЕК** *и.* 1) Тормышта, көнкүрештә элеккеге, ата-бабалар вакытындагы тәртип, гореф-гадәт, зәвык. – *Минемчә, градирняның шахтасын монолит бетоннан күтәрергә кирәк. – Бу кире искелеккә кайту була түгелме соң?* Р.Кәрами. *Мәктәпнең яңа яшь директоры Илгиз Туктаров ныклы гына тамыр җибәреп өлгергән иске тәртипләргә каршы сугыш ача. Ләкин күнегелгән гадәтләр һәм искелек, күз буяу шактый көчле ---.* Әдәбият. *Ә менә авыл карты Шәвәли, үз хуҗалыгы турында гына кайгыртканы өчен «вак милекче» мөһире сугылып һәм искелек тарафдары рәвешендә --- уңай геройларга каршы куела.* Татар әдәбияты тарихы

2) *куч.* Һәртөрле яңалыкка каршы булу; фикер торгынлыгы. *Совет чоры тәрбиясе яңача фикер йөртергә, искелектән чыгарга һаман да комачаулап килә*

**ИСКЕ-МОСКЫ** *с.* **1.** Күп һәм еш кулланудан таушалган, тузган. *Искемоскы сәләмәнең җөенә яшеренгән вак җанварлар шатор-шотыр килә башлады.* Р.Кәрами. *Салкын өйдә, иске-москы чүпрәк арасында бөгәрләнеп яткан малайны күршеләре Бәйрәмгали бабай --- үзләренә алып чыкты.* Ф.Сафин. *Иске-москы әрҗәдән калган фанер кисәкләре җыйдым.* М.Әмир

**2.** *и. мәгъ.* Киелеп тузган, таушалган, искергән әйберләр. *Әллә кайчан тезеп куелган, ни икәне өстенә язылган иске-москылар янына кил дә кеше әзерләп биргән сүзләрне сөйләп көн уздыр, имеш.* К.Тимбикова. *Күпмедер вакыт үткәч, --- безне иске-москыга төреп, өебездән алып чыктылар да, Шәкерт абый белән Мулла җиңгәй үз өйләренә алып керделәр.* Ә.Афзалова. *Кич белән Сабир эштән кайтканда, иске-москыга төргән ике нарасыйны Зөһрә алыш-тилеш имезеп азаплана иде.* С.Зыялы

**ИСКЕ-МОСКЫЧЫ** *и. тар.* Иске, тузган, тотылган әйберләрне җыючы һәм алар белән сату итүче кеше; искече (*1 мәгъ.*). *Болак артының бу иске бистәсендә, күбесенчә, һөнәрчеләр, читек-кәвешчеләр, --- иске-москычылар, хәерчеләр [яшәгән].* Ә.Камал

**ИСКЕ-ПОСКЫ** *с. сир. к.* **иске-москы**. *Иске-поскы киемнәр. Иске-поскы җиһазлар*

**ИС КЕРҮ** *ф.* 1) Ашамлык бозылу, тәмсезләнү. *Җылыда торып ашка ис кергән*

2) *сөйл.* Берәр нәрсәгә бик аз гына күләмдә икенче бер нәрсә кушылу. *Бу өчпочмак итенә бераз үрдәк исе дә кергән*

3) *күч.* Яшүсмерләрдә каршы җенестәгеләргә карата кызыксыну уяну, игътибар итә башлау. *Кыз тәмам өлгергән, сылуланган, үзенә егетләр исе дә кергән*

**ИСКЕРҮ** *ф.* 1) Вакыт үтү белән яки еш, күп кулланудан тузу, яраксыз хәлгә килү. *Бу ботинкам искергән, тагын бер ботинкам бар-барын да, анысын яратмыйм.* Г.Камал. *Кичә Нәфисә янына кереп, ул: – Өстәмәгә тигән бодаең белән өйне сипләтербез, бик искергән! – дип кисәтеп куйган иде.* Г.Бәширов. *Пальтом искерде, яңаны тектерергә булдым.* И.Гази

2) Куәте кимү яки бөтенләй айну. *Сыра искерү. Камыр башы искерү*

3) Яңалыгын, йомшаклыгын югалту; кибү, кату. *Анда да ашарга искергән арыш икмәге белән күгәргән ярмадан башка әйбер җибәрмәде.* Г.Ибраһимов. *Ул икмәк тагы бик тиз искерә бит, мал багучы ул кадәр искергән икмәкләрне кая куйсын?* Г.Тукай

4) *физ.* Вакыт үтү белән яки җылылык тәэсирендә материалларның (металларның, полимерларның) үзлекләре үзгәрү

5) Хәзерге көн, хәзерге заман таләпләренә җавап бирми торганга әйләнү; яраксызга чыгу. *Без, бу китаптагы ысулны искергән санаганлыгыбыздан, мөгаллимнәргә [тәкъдим] итәргә җөрьәт итмибез.* Ф.Әмирхан. *Янәсе, Нәфисәләр чоры узды, ул романнар искерде.* Р.Миңнуллин. *«Ярык» сүзенең беренче мәгънәсе искерде: ул «яктылык» мәгънәсен инде белдерми, бәлки, агач әйберләрдәге аралыкны – ачыклыкны белдерә.* Ф.Сафиуллина

6) Беренче әһәмиятен, актуальлеген, кирәклеген югалткан. *Газета искергән хәбәрне яратмый.* И.Гази. *Бу чорда безнең поэзиябез дә, шагыйрьләребез дә бик нык үсте, үзгәрде. Яңа шагыйрьләр килде, күп шагыйрьләр искерде.* Р.Миңнуллин. *– Атаңнар сүзен сөйлисең. – Минем атамнар сине начарлыкка өйрәтәмени? – Аларның фикере искерде инде.* Ф.Яруллин

7) *күч.* Тормыштан артта калу. *– Ну, монда дөнья һаман шул килеш икән, – диде Линар. – Искергәнсең икән син дә, апа. Радиолаң да кадими заманныкы, җырларың да.* М.Маликова

8) *күч.* Олыгаеп таушалу, көчсезләнү. *– Кайтып дөрес иткәнсең, – диде карт, Ихтыярның уйларын белгән кебек. – Картайдык без, искердек.* Р.Вәлиев

**Искерә бару** Торган саен, көннән-көн ныграк искерү. *--- кар базы өстендәге куыш, хәтта мунча да елдан-ел искерә, иңә бара.* М.Маликова. *Былтыр болай түгел идем, Быел әллә нишләдем... Искерә бара елларым, Искерә барам үзем.* Р.Корбан. *--- мондый үзгәрүнең икенче сәбәпләре дә булуы ихтимал. Мәсәлән, «кытай татары кайту» хәбәренең искерә баруы, күзләрнең дә «ят чырайга» күнегә төшүе.* Казан утлары

**Искерә башлау** Искерү билгеләре күренү, беленү. *Мунча ташы искерә башлагандыр, чак кына төтен әчесе бар.* Ш.Янбаев. *Август аена кереп, искерә башлаган җәйне яңартып ала торган яңгыр бу.* М.Хуҗин. *Ә менә саклау ягы кыенрак ул ризыкларны, казылыкны саклап булса да, калганнары айлык юлда искерә башлый.* М.Хәбибуллин

**Искерә төшү** Тагын да бераз, беркадәр искерү; беркадәр искергән хәлгә килү. *Киеменең искерә төшкән булуына карамыйча, керсез, тузансыз булуы бу татарны миңа сөекле күрсәтә иде.* Ф.Әмирхан. *Ак өй идәненә, бераз искерә төшкән Бохар паласы өстенә табын әзерләнгән иде.* А.Шамов. *[Салихҗан] Капкадан керә-керешкә, бик эшлекле кыяфәттә, искерә төшкән йортны --- караган була.* А.Вергазов

**Искереп бару** Акрынлап, аз-азлап искерү. *Теге башкорт егете – усал солдат Закир – үзенең дүрт иптәше белән, искереп бара торган, шулай булса да әле таза бер йортка барып керделәр.* С.Җәлал. *Алар искереп, җимерелеп барган агач баскычтан тиз-тиз генә өскә күтәрелделәр.* А.Шамов

**Искереп бетү** Тулысынча искерү. *[Бүлмәнең] Обойлары каралып, искереп беткән, урыны-урыны белән ертылган да.* Г.Әпсәләмов. *Искереп беткән пальтомның өтек якасын күтәреп, ашыга-ашыга, Чернышевский буйлап --- киттем.* Ә.Еники. *--- эчпошыргыч тынлыкка өйдәге һәрнәрсәнең соң дәрәҗәдә искереп, какшап, төссезләнеп беткән булуы да сәбәпче иде…* М.Маликова

**Искереп калу** 1) Нindидер сәбәптән соң, тәэсирдән соң искерү; кинәт искерү

2) *күч.* Актуальлеген, хәзерге вакыт өчен әһәмиятен, кирәклеген югалту. *Бая цех начальнигыннан һәм витриналардан күчереп алган мәгълүматлар берьюлы искереп калган төсле булып күренделәр аңар.* Г.Минский

**Искереп килү** Искерүгә таба бару; акрынлап, аз-азлап искерү хәленә якынаю. *Әтидән калган өй дә, абыйлар үзләре тергезеп киткән каралты-кура да, сипләп торуга карамастан, искереп килә.* Х.Сарьян

**Искереп китү** Бераз, берникадәр искерү. *Күмәчләр алып килгән идем. Күп булгач, искереп китәр инде.* М.Фәйзи

**ИСКЕ́ СТИЛЬ** *и.* Хәзерге вакыттагы Григориан календаре белән исәпләнә торган ел исәбеннән 13 көнгә соңарып йөргән Юлиан календарена нигезләнгән ел исәбе. *[1918 ел, апрельнең] Икесендә (иске стиль) Габдулла Тукайның вафатына биш ел тулды.* Ф.Әмирхан. *Бу гәзитәнең 3 майда (иске стиль белән) 20 еллык юбилее булды.* М.Гафури

**ИСКЕ́ЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Иске заманга, иске тәртипләргә, иске карашларга туры китереп. *Ул, кыз вакытында искечә генә тәрбияләнеп, аннан соң иске бер тегүче Ибраһим байга «хәләл җефет» булган.* Ф.Әмирхан. *Сез артыгын искечә фикер йөртәсез.* Ф.Яруллин

2) Үзгәрешсез, элеккечә. *Тик җавап һаман искечә, бердәнбер кырыс сүздән тора иде.* М.Насыйбуллин. *Өй эчендә бар нәрсә искечә, бөтен әйбер үз урынында --- иде.* Ә.Еники. *Зәйтүнә, кырыена утырып, хатынның нечкә беләзеген кулына алды: – Хәлебез ничек безнең бүген, Рәзилә? – Искечә инде.* М.Маликова

3) Гарәп шрифтында, гарәпчә. *Милашкин бер биткә гарәп хәрефләре*

*сызгалап та бирде. Гыйльманов искечә беләү иде --- күзләре шар булып маңгаена менде.* Х.Камалов. *Борынгы язмалар эзсез югалалар. --- Искечә белгән укымышлылар да сирәгәя бара.* М.Галиев. *Әһә, исәп-хисап эшләре искечә, гарәпчә язылa икән.* А.Әхмәт

**2.** *с. мәгъ.* 1) Иске стиль белән исәпләнгән. *Яз бик алдаучан ул. Искечә март бетмәгән бит әле.* М.Маликова. *Бүген төнлә, Алланың рәхмәте белән, искечә февральгә керәбез.* М.Хуҗин. *Атна буена шушылай холыксызлану кышның үзен дә туйдырды-ардырды бугай, искечә елның соңгы көнендә, ниһаять, һава торышы тиз генә үзгәрмәскә урнашты кебек.* М.Хуҗин

2) Гарәп шрифтында язылган. *Дин китабы түгел бу, искечә хәрефләр белән язылган гына.* М.Хуҗин. *--- өйнең иң түр почмагында, искечә язулы рамнарны ышыклап, таныш читлек эленгән.* Г.Гыйльманов

**ИСКЕЧЕ** *и. тар.* 1) Искергән, тузган әйберләр белән сату итүче кеше; иске-москычы. *Күршесе искече карт та килеп керде.* Ш.Камал. *Ул кибетче малайларга, читекче, кәвешчеләргә ак яка киертте, искедән киеп килгән казакиларын искечегә саттырып, һәйбәт бумажный материядән «пинжәк» тектертте ---.* Р.Гали

2) Консерватив, реакцион, иске карашлы кеше. *Коткарылды Оренбург, искечеләр булды хур.* Г.Камал

**ИСКЕЧЕЛЕК** *и.* 1) Искече (*1 мәгъ.*) булу, искече кәсебе

2) Фикердә, тормышта консервативлык, реакционлык, кадимчелек. *Безгә һәрбер искечелек дошман булып тоелды, әгәр кайберендә алмаз, бриллиант булса да, чөнки без бриллиантка да дошман идек.* Т.Миңнуллин. *Искечелекне тәнкыйтьләү*

**И́СКИТӘРГЕЧ** *с. сөйл. к.* **искиткеч**. *Миңа бәхәс кирәкми: мин бу фәннең барлыкка киләчәгенә, искитәргеч ачышлар китерәчәгенә ул чакта Фәһимәмне күрәчәгемә ышанган кебек ышанам.* Ә.Баян. *Искитәргеч тамаша. Искитәргеч яхшы фикер. Искитәргеч көч*

**И́СКИТӘРДӘЙ** *с. сөйл.* 1) *к.* **искиткеч**

2) Артык гаҗәпләнерлек, гадәти булмаган. *Галимҗан абзый да улының ашыкмыйча, сабыр гына сөйләвен, сүзләренә искитәрдәй төс бирмәвен --- күргәч: «Малай башка-а!» – дип уйлап куйды.* Ә.Еники

**И́СКИТӘРЛЕК** *с.* 1) *к.* **искиткеч**. *Режиссёр ханым искитәрлек чибәр. Аның матурлыгын Бибиса тел белән сөйләп аңлата алмас иде.* С.Сөләйманова. *Урам аша каршыда гына диярлек таш мәчет. Таш! Бу инде үзе минем өчен искитәрлек күренеш.* М.Әмир. *[Варис] Бер дә искитәрлек нәрсә булмаган кыяфәт белән сүзен башлады.* М.Хәсәнов

2) *к.* **искитәрдәй** (*2 мәгъ.*). *Фәхретдинов өчен бу хәбәр әллә ни искитәрлек яңалык булмаса да, Зиннәт өчен көтелмәгән нәрсә иде.* Р.Кәрами

**И́СКИТКЕЧ** *с.* **1.** Гаҗәеп, сокландыргыч, хәйран калдырырлык; шаккатарлык. *Табигатьнең искиткеч серлелеге аңарда табигатьнең көченә ихтирам уята, аны дулкынландыра, хәтта көнләштерә иде.* Г.Бәширов. *Хәтерегездә микән: мине укырга озаткан-да, искиткеч табын әзерләгән идегез.* Ф.Яруллин. *Бодай оныннан алабута-мазар кушмыйча гына пешерелгән умач искиткеч тәмле аш икән ул.* М.Әмир

**2.** *рәв. мәгъ.* Чамадан тыш, чиктән тыш, хәйран калдырырлык итеп. *Безнең дустыбыз, совет сугышчысы старшина Шәйхетдинов, искиткеч әрнеп, гаzапланып һәлак булган.* А.Шамов. *Ни гаҗәпләнгән булсам да, мин Люциянең күлмәге бик кыйбат тукымадан, искиткеч оста тегелгән икәнен күрми кала алмадым.* М.Маликова. *[Ул] Гаязның яр башыннан егылып төшү моментларын бөтенләй хыялый әкиятләргә охшатып, искиткеч итеп сөйләде.* М.Әмир

**И́СКИТМӘЛЕ** *с. диал. к.* **искиткеч**. *Көмешлесу авылы халкы арасында да имеш-мимешләр арта барды, алар берсеннән-берсе артыграк, искитмәлерәк була башлады.* Я.Зәнкиев. *Әбинең кечерәк кенә түгәрәк бөкресе дә чыккан инде, тешләре дә берән-сәрән генә калган. Шулай да аның кодрәте белән дәрәҗәсе искитмәле.* Г.Бәширов. *– Быел минем классымда кырык ике бала укыячак. Искитмәле хәл, – [диде Хәнифә].* М.Хәбибуллин

**ИСКИ́ТМӘҮЛЕ** *с. сир. к.* **искитмәүчән**. *Аның җил каклаган озынча битенә, тоташкан куе кашларына, язмыштан узмыш юк инде, дигән искитмәүле сызыклар чыккан иде.* Х.Камалов. *Егетнең ул, бәлки, горурлыгыннан гына киләдер? Тыштан искитмәүле салкынрак булып тоелса да, бәлки, аның күңеле әйбәттер?* Х.Камалов

**ИСКИ́ТМӘҮЧӘН** *с.* Бернәрсәгә дә гаҗәпләнми, борчылмый, хәсрәтләнми торган, бернәрсә белән дә кызыксынмаучан. *Искитмәүчән чырай. Искитмәүчән кыяфәт*

**ИСКИТМӘҮЧӘНЛЕК** *и.* Искитмәүчән, гаҗәпләнмәүчән булу. *Бөтен эрелеге, бөтен искитмәүчәнлеге кинәт каядыр югалган [аның].* Н.Фәттах. *Пауза озаккарак киткәч, чыраена ваемсызлык, искитмәүчәнлек тамгасы чыгарып: – Соң, шуннан? – дигән булды.* Т.Нәбиуллин. *Ул ясалма бер искитмәүчәнлек белән көлгәндәй итеп куйды да нидер эзләп кесәсенә тыгылды.* Н.Фәттах

**ИС-КОН** *җый. и.* Төрле-төрле исләр, һәртөрле исләр

◊ **Исе-коны(сы) да булмау** *к.* **исе-коны(сы) да юк**. **Исе-коны(сы) килмәү** *к.* **исе-коны(сы) да юк**. **Исе-коны(сы) да юк** 1) Исе, төтене һ.б.ш.лар булмау, бер нәрсә дә сизелмәү; 2) Берәр кеше яки берәр нәрсәнең бөтенләй булмавы яисә юкка чыгуы турында; эзе дә, хәбәре дә булмау. *Нәсимә качкан... Исе дә, коны да юк киленнең.* К.Нәҗми

**ИС-КОҢ** *җый. и. к.* **ис-кон**

**ИС-КОС** *җый. и. к.* **ис-кон**. *[Бриллиант] Сулы шешәне алдан хәстәрли, анда бармак эзләрен булдырмау, хәтта ис-кос калдырмау чараларын күрә.* Ф.Сафин. *Башка өянкеләр чегән таборы сыман кара карга оялары белән караеп, карга тавышлары белән каркылдап торса, Сәгъдәтнекенә, нишләптер, оя кормыйлар. Яратмыйлармы? Әллә башка берәр ырымы-сырымы, исе-косы, таты-заты бармы тагын?* А.Хәлим

**ИС-КӨЧ** *җый и.* Акыл, зиһен һәм физик энергия

◊ **Ис-көч җыю** Хәл җыю, көч туплау. *Дошманлыгы канына сеңгән дошманны яхшылык белән генә игә китереп булмый, вакыты җитү, исен-көчен җыю белән тагын үз юлына баса.* Н.Исәнбәт

**И́СКРАЧЫ** *и. тар.* 1900 елда В.И.Ульянов (Ленин) тарафыннан нигез салынган «Искра» газетасы тирәсенә тупланган революционерларның бер вәкиле. *Искрачылар оппортунистларның барлык атакаларын кире кактылар.* Советлар Союзы коммунистлар партиясе тарихы

**ИС-КҮЗ** *җый. и.* Акыл, зиһен; игътибар, дикъкать

◊ **Ис-күздә тоту** Истә тоту, онытмау; һәрвакыт игътибар үзәгендә тоту. *Истә-күздә тотылмаган эшләр*

**ИСЛАМ** *и. гар.* VII гасырда Гарәбстанда барлыкка килеп, тарафдарлары «мөселман» дип аталган, Аллаһның барлыгын һәм берлеген, Мөхәммәд пәйгамбәрнең аның илчесе булуын тануга нигезләнгән, дөньякүләм таралган өч диннең (христиан һәм будда диннәре белән беррәттән) берсе; мөселман дине, мөселманлык. *Байракны күргәч, даменла хәйранга калды: шулай икән, ди, дөрес икән, ди, бу урыннарда, ди, кәләпүшле мөселман балалары, яулыклы ислам хатыннары күземә рәхәт бирделәр, ди.* Г.Ибраһимов. *Ислам – иң демократик дин: ул кешенең рухын түрәләргә яки башка затларга буйсынудан арындырып, аңа үз акылы белән яшәргә тулы хокук бирә.* Р.Сафин. *Гарәпләр, ислам динен кабул иткәнче үк, ай һәм кояш еллары арасындагы аермалыкны белгәннәр ---.* Мирас

**ИСЛА́М ДИНЕ** *и.* Мөселман дине, ислам. *Заманы өчен яхшы ук укымышлы, гарәп телен чынлап та ярыйсы белүче, ислам динен ахирәт белән генә түгел, күбрәк бу дөнья хәлләре белән бәйләргә омтылучы яшь имамны, --- гадәттә, Сәгыйтҗан хәлфә дип сөйлиләр иде.* М.Әмир. *Идел буена күчеп килгән Кодрак илхан ыруы ислам динен кабул итте.* М.Хәбибуллин. *Ислам динендә, татар халкының язылмаган әхлакый кануннарында җиде буын бабаңны белү изге гамәл --- санала.* Казан утлары

**ИСЛАМИ** *с. гар.* Ислам диненә кагылышлы; ислам диненә нигезләнгән. *Бүген иҗтимагый фикерләүдә ислами татар фәлсәфәсе юк дәрәҗәсендә, гәрчә аны тудырган татар укымышлылары мирасының югарылыгы дөньякүләм танылган факт булса да.* Ф.Сафин

**ИСЛАМИЗМ** *и. рус сәяси* Ислам фундаментализмы (соңгы чик ортодоксальлеккә, башка диннәр белән килешмәүчәнлеккә нигезләнгән, үз сәясәтендә радикаль алымнар куллана торган кайбер мөселман оешмаларының дини-сәяси агымы)

**ИСЛАМИСТ** *и. рус сәяси* Исламизм тарафдары

**ИСЛАМИЯ** *с. гар. к.* **ислами**. *Әгәр дә сез ---, Оренбург җәмгыяте исламиясенең собраниесендә председательгә ачу илә – җәмгыятьне ифтира кылып, --- тиешсез хәрәкәттә булсагыз, ул вакытта сез, миннән бигрәк, эшебезгә зарар китерәчәксез.* Ш.Мөхәммәдев

**ИСЛАМИЯТ** *и. гар. кит. к.* **ислам**. *Исмәгыйль абзый һәр мөселманның исламияткә кире эшләр эшләргә мәҗбүр булуын күрә.* Г.Тукай. *Аңламагансыз: минем углым Ходаяр дингә ислах кереп, исламиятне үз җиребездә ныгытырга тырыша.* Т.Гыйззәт. *Дөньялыкның соңгы көне һәм мәңгелек яңа тормышның башлану вакыты исламияттә Кыямәт дип атала.* Р.Фәтхерахманов

**ИСЛАМЛАШТЫРУ** *ф. сәяси* Ислам динен тарату, ислам динен пропагандалау, аның тәэсирен көчәйтү. *Биредә гарәпләрнең башка территорияләрне яулап алу, андагы халыкларны гарәпләштерү, исламлаштыру сәясәтен дә искә алырга кирәк.* К.Гыйззәтов. *--- русның танылган кешеләре А.Солженицын, И.Шафаревич һаман да, Россияне исламлаштыру куркынычы яный дип, армый-талмый кабатлыйлар.* Я.Шәфыйков. *Аерым очракларда исламлаштыру көчләү, мәҗбүр итү юлы белән дә барган.* Татар милли педагогикасы

**ИСЛАМЛАШУ** *ф. сәяси* Ислам динен кабул итү, ислам диненә күчү. *Җучи Олысында күпсанлы шәһәрләр барлыкка килә. Исламлашу белән шәһәрләр үсү тыгыз бәйләнештә була.* Татар милли педагогикасы

**ИСЛАМОФО́БИЯ** *и. рус кит.* Исламга карата дошманлык мөнәсәбәте, ислам динен күралмаучылык. *Әйе, Русиядә ксенофобия, исламофобия, милли җирлектәге җәнҗаллар арткан саен, мәдәниятара диалог белән толерант мөнәсәбәтнең актуальлеге --- арта төшә.* Мәдәни җомга // Исламнан курку (хәзерге вакытта Көнбатыш илләрендә таралган термин)

**ИСЛА́М ХОКУКЫ** *и.* Дини хөкемнәргә нигезләнгән хокук; фикъһ

**ИСЛА́МЧА** *рәв.* Ислам дине кануннарына туры китереп; ислам диненә хас булганча. *--- Асылгәрәй карт, биредә торган бер генә сәгатен дә әрәмгә уздырмыйча, аларга дин-ислам турында сөйләде, исламча яшәү үрнәген күрсәтте.* Ф.Бәйрәмова. *Мөселман кешесе һәм исламга өндәүче буларак, Ибне Фадлан исламча яшәү рәвеше турында сокланып яза ---.* Ватаныбыз тарихы. *Мәрхүмне монда китергәч, исламча юу, кәфенләү буенча белгеч бөтен йоланы җиренә җиткереп башкарачак.* Юлдаш

**ИСЛАМЧЫ** *и.* 1) Ислам диненең кануннарын, идеяләрен алга сөрүче кеше. *Мәрҗани хәзрәтләре, төрекче булудан бигрәк, исламчы, аннан да бигрәк татарчыдыр ---.* Г.Гобәйдуллин. *Соң, шулай икән, нигә ул большевикларның бар булышканы милләтчеләр әле? Исламчы да ярамый үзләренә, төрекче дә...* Р.Мөхәммәдиев

2) *к.* **исламист**. *Татарстан прокуратурасы, «Республика урманнарында исламчыларның хәрби күнегүләр лагеры урнашкан», «Татарстанда радикал ислам җәелә» ише ялган хәбәр тарата, --- дип, --- Рәис Сөләймановка кисәтү ясады ---.* Ирек мәйданы

**ИСЛАМЧЫЛЫК** *и. тар.* 1) Исламчы (*1 мәгъ.*) булу. *Исламчылыкта төрки-гарәби исламны яклаучылар (таррак алганда, кадимчеләр) – болгарчылар, татар исламы яклылар (җәдитчеләр) – татарчылар.* Р.Сафин. *Татар милли идеясен эзләгәндә, күпләр, бигрәк тә соңгы вакытта, ислам-*

*чылыкка мөрәҗәгать итә.* Р.Сафин. *Минемчә, безнең рухи нигезләребез, идеологиябез татарчылык, исламчылык һәм заманчалаштыру* (*модернизация*) *кебек өлешләрдән торырга тиеш.* Мәдәни җомга

2) *к.* **исламизм**

**ИСЛАНД** *и. к.* **исландияле**. *Исландия ярлары буенда Сертсей дигән бер утрау бар. Ул исланд халкының Ут Алласы хөрмәтенә шулай дип аталган.* Җил каян исә? *Исланд теле. Исланд әдәбияты. Исланд сәнгате*

**ИСЛА́НДИЯЛЕ** *и.* 1) Исландиянең төп халкы һәм шул халыкның бер вәкиле

2) Чыгышы белән Исландиядән булган, шуннан күчеп килгән кеше

**ИСЛА́НДЧА** *рәв.* Исланд телендә. *Исландча укый белү*

**ИСЛАХ** *и. гар. иск. кит.* 1) Килештерү, дуслаштыру, яраштыру, араны төзәтү. *Кайчакларда мин күз алдыма бер мәгъсүм кыз белән очрашуыбызны, --- аның мине көннән-көн ислах итүләрен --- фараз итә идем.* С.Җәлал

2) Нәрсәне дә булса төзәтү, яхшыга үзгәртү, яхшырту, үзгәртеп кору; реформа ясау; төзәтмә, үзгәреш; яңарыш. *Аңламагансыз: минем улым Ходаяр дингә ислах кертеп, исламиятне үз җиребездә ныгытырга тырыша.* Т.Гыйззәт. *--- бу әфәнде --- ислах, ягъни яңарыш җилләре исә башлагач, --- шушында ук эшкә калган яшь хәзрәт иде.* А.Хәлим

3) Җәмгыятьтә иҗтимагый, сәяси, икътисади, мәдәни һ.б.ш. яңалыкка таба үзгәреш; реформа. *--- ислах таләп иткән өчен, «Галия» мәдрәсәсеннән куылган алтмыш биш шәкертнең берсе Заһид Миравалов Бәргәрдә белем тарата башлый.* Т.Әйди. *– Яшәсен ислах! Яшәсен каһарман татар шәкерте! Яшәсен милләтнең яшь көрәшче каһарманнары! – дип гөрләп, тавыш күтәрелде.* Г.Ибраһимов. *Аның урынына «Шәкертләрнең чын ислах сорау вакыты килде» дигән, зур таләпләр куеп язган исемсез мәкалә чыкты.* Ә.Фәйзи

**ИСЛА́Х ИТҮ** *ф.* 1) Төзәтү, үзгәртү, төзәтмәләр кертү. *Сәлим үзен-үзе ислах итеп --- әүвәлге шикелле мөкаддәс мәсләк өчен хезмәт итүгә бирелсә, зур сәгадәткә ирешкән булыр иде кебек хис кылды.* Г.Ибраһимов

2) Яңалык, үзгәрешләр кертү, реформалар ясау. *Без мәдрәсәне ничек ислах итү турында программа бирдек.* Г.Ибраһимов. *Башлангыч мәктәпне яңа нигездә тәртипкә китереп, Галимҗан хәзрәт әкренлек белән рәшти (урта) сыйныфны ислах итә, 1899 елда яңартылган рәшдия бүлеген ача.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИСЛА́Х КЫЛУ** *ф. к.* **ислах итү**. *Бераз башында фикере барлары, мәктәпләрне, мәдрәсәләрне ислах кылу кирәк, дисәләр дә, фанатик муллалар, үзләренә иярткән юан корсак надан байлар илә, һәмишә каршы төшәләр дә торалар.* Ш.Мөхәммәдев. *Безнең хәрефләребез (гарәп хәрефләре) никадәр генә ислах кылынмасын, һәнүз фонетика таләпләрен үтәүдән ерак торалар.* Җ.Вәлиди. *Динне ислах кылу хакында сүз булмаган кебек, шул диннең бер кисәге, коралы дип танылган хәрефләрне төзәтү хакында да уйлаучы, әлбәттә, булмаган.* Җ.Вәлиди

**ИСЛАХЧЫ** *и. иск.* 1) Берәр өлкәгә үзгәрешләр кертүче, үзгәртеп коручы; реформатор. *2 гыйнвар корбан гаетенең икенче көнендә ислахчылар тарафыннан Купеческое собрание залында әдәбият кичәсе ясалды.* Ф.Әмирхан

2) *тар.* Татар мәдрәсәләрендә үзгәрешләр кертү тарафдары. *Тугрырак фикерле һәм вөҗданнары югалмаган шәкертләр арасында үзара бер «иттифак» та ясалды. Кыскасы гына, кечкенә ислахчылар партиясе туды.* Г.Ибраһимов. *--- мөтәзилилек, мөселман ислахчылары, шул исәптән татар дин белгечләре тарафыннан үзләренең гаклый фикерләрен раслау өчен кулланылган.* Мәдәни җомга

3) *тар.* 1905 – 1907 елларда татар мәдрәсәләрен реформалау мәсьәләсен күтәреп, шул юнәлештә эшләгән «Әльислах» газетасын чыгаручыларның берсе. *Г.Камалның «Бүләк өчен» исемле комедиясен --- карар өчен, ислахчылар Тукайны да алып баралар.* В.Бәхтияров

**ИСЛАХЧЫЛЫК** *и. иск. кит.* Билгеле бер өлкәдә яңарышлар, үзгәрешләр, реформалар кертүне күтәреп чыккан хәрәкәт. *Мөселман ислахчылыгы – иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә, танып белүнең кайбер традицион ысулларын һәм ислам дине күрсәтмәләрен аңлатуны яңабаштан тикшереп чыгуга юнәлтелгән дини-иҗтимагый агым.* Татар энциклопедиясе. *Камали Зыя дин гыйлеменә, фәлсәфәгә караган хезмәтләрендә ислам ислахчылыгы идеяләренә таяна.* Мәдәни җомга

**ИСЛӘНҮ** *ф.* 1) Хуш ис белән аңку. *Тәрәз төбем исле гөл, Исләнәмен исеннән.* Җыр

2) Матдәләр, азык-төлек чери башлап, сасы ис чыгу, бозылу. *Кичә Кәлҗемановларда исләнгән бавыр ашаган идек, шуның исе килә булыр.* Х.Вахит. *Карт шуңа бераз исләнгән ит кисәген утыртты да, җепнең икенче очын тал ботагына бәйләп, кармакны суга ыргытты.* З.Фәйзи

3) Озак юынмыйча йөрүдән, тән һәм киемнәр керләнүдән ис килә башлау. *Юан корсаклы, калын бүксәле баш табиб, көчәнеп, картның аягындагы носкиен салдыра башлады. Аяк та, носки да исләнгән.* Х.Ибраһим. *Урыс --- итекләрен салды. Борынга исләнгән аяк исе килеп бәрелде.* З.Зәйнуллин

4) *диал.* Ислемай сөртенү. *Хушбуй сөртеп исләнү*

**Исләнә башлау** Ис хасил булу. *Матрасы исләнә башлаган кебек тоелгач, икенче матрас җәеп, тегесен тышка чыгарып элеп куйды.* Ф.Ярullин. *Мәетне озак тотудан мәгънә юк. Җәй көнендә бигрәк тә. Карала, исләнә башлаганчы, матур чагында урнаштыру мәслихәт.* Н.Әхмәдиев. *Тавыкның калганын икенче көнне хәтта Агыйдел балыкларына да ташладык (кыздырылмаганга күрә исләнә башлаган иде).* Ә.Еники

**Исләнә төшү** Бераз исләнү, берникадәр исләнү

**Исләнеп бетү** Тәмам бозылып, яраксыз хәлгә килеп исләнү, бөтенләй исләнгән хәлгә килү. *Юрганга төрелгән [үле] сабый гәүдәсе дүрт тәүлек эчендә нишләр? Исләнеп, муртаеп бетмәсме?* А.Хәлим. *Адәм авазы ишетеп, әллә кай караңгылыктан, тупылдап,*

*Кәшифә балакаем килеп чыкты. Юешләнеп, исләнеп беткән.* К.Тимбикова

**Исләнеп китү** Кинәт ис таралу, исләнү. *Һава да хуш җофар, сирень, канәфер исләре берлә исләнеп китте.* Г.Тукай

**Исләнеп тору** Сөйләү моментында исләнгән булу; һаман, әледән-әле исләнү

**ИСЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Игътибар итеп, хәтердә, истә калдыру; искә, хәтергә төшерү. *Чәй янында егетнең туктаусыз сөеп каравы аз гына хәтерендә калды. Аңа елмаерга тырышуын да бик аз гына исләде.* Г.Ибраһимов

2) Онытмау, хәтердә тоту. *Балачак хатирәләрен исләү*

**ИСЛЕ** I *с.* 1) Теге яки бу җисемнәрнең, матдәләрнең борынга тәэсир итү сыйфатына ия булган; үзенә генә хас ис аңкытып торган. *Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый.* Г.Камал. *Болыннары елның елында тирә-якны җәй көне яшел үлән белән, кышкы суыкта солыдан кадерле санала торган хуш исле коры печәннәр белән хәйран итәләр.* Г.Ибраһимов. *Хуш исле чәчәкләр арасына кысылган әрем исе дә кыйммәтле хушбуйлар исеннән тәмлерәк булып тоела.* М.Әмир

2) Исе (*2 мәгъ.*) бар, ис тидерә торган. --- *мунчаны исле килеш томалаганнар да, комиссия җитәкчесенә, главканың бүлек мөдире урынбасарына ис тигән.* Р.Вәлиев. *Өстәвенә, исле мунчага барып, якты дөнья белән бәхилләшә язып калуымны да күргәч, Мәдинә апа бөтенләй тынычлыгын югалткан* ---. М.Әмир. --- *мал-мөлкәтне үзенә генә калдырырга теләгән комсыз яшь хатыны мунча мичен тавык тизәге белән кушып яккан да шул исле мунчада [Сәлмән сәүдәгәрне] исертеп үтергән, имеш.* Ф.Хөсни

**ИСЛЕ** II *с. диал.* 1) Аңлы, зиһенле, акыллы. *Исле кеше уйламый эш итмәс.* Мәкаль. *Инәкәй мине ташлап киткән чакта, мин инде шактый исле идем.* Н.Фәттах

2) Балалыктан чыккан, балигъ булган (яшүсмер турында)

**ИСЛЕ́ БОРЧАК** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, терлек азыгы буларак игелә торган баллы үсемлек; *русчасы:* **душистый горошек**

**ИСЛЕ́ ГӨЛ** *и. бот.* 1) Иренчәчәкләләр семьялыгыннан, бик вак яфраклы, хуш исле үсемлек (яфраклары медицинада, парфюмериядә, азык-төлек сәнәгатендә кулланыла); *русчасы*: **тимьян**. *Тәрәзә төбем исле гөл. Мин яратам кынаны…* Җыр. *Тәрәзә төбем исле гөл, Иснә, дустым, исле ул.* Җыр. *Исле гөлләрне күргәндә, Исенә исерәм төсле…* Ә.Ерикәй

2) *диал.* Иренчәчәкләләр семьялыгыннан, сыек шәмәхә төстәге хуш исле чәчәк ата торган күпьеллык үсемлек; мәтрүшкә; *русчасы:* **душица**

**ИСЛЕКӘЙ** *и. бот. диал.* Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан, икееллык агулы үлән. *Клара үләнне алып борынына китерде һәм хәйран калды:* ---. *– Нәрсә бу? – Ислекәй* ---. Ә.Еники

**ИСЛЕЛЕК** *и.* Исле I булу

**ИСЛЕ́ МАЙ** *и. бот. к.* **исле үлән**

**ИСЛЕМАЙ** *и.* Хуш исле матдәләрнең спирттагы яки төрле майлардагы эремәсе (парфюмерия әйбере буларак кулланыла). *Болын бүген тыныч, хуш исле, ислемай сипкәннәр диярсең.* Г.Әпсәләмов. *Бүләкләрнең иге-чиге булмас иде. Берсеннән-берсе затлы француз ислемайлары, кыйммәтле кремнар дисеңме, чүпрәк-чапракның очы-кырые юк.* С.Зыялы. --- *хатын --- көзге алдына килеп төнге күлмәген кия, битенә әллә ниткән ислемайлар сөртә…* М.Мәһдиев

**ИСЛЕМА́Й ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **исле үлән**. *Клара үләнне алып борынына китерде һәм хәйран калды: үлән искиткеч хуш исле иде. – Нәрсә бу? – Ислекәй... Ислемай үләне, – диде Сания.* Ә.Еники

**ИСЛЕ́ САБЫН** *и.* Бит-кулны юу өчен файдаланыла торган хуш исле сабын. *Сандыктагы сабыннарны Сәхия саклап кына тота, үзе дә, кесәсенә акча кергән саен, әнкәсе кебек, исле сабын сатып алырга ярата.* Ф.Яруллин. *Минем әле битемә исле сабыннан башка әйбер тидергәнем юк иде.* Л.Ихсанова. *Элекке Казанда «Гөлҗиһан сабыны» исемле исле сабын чыгарылуы билгеле.* Казан утлары

**ИСЛЕ́ ТӘМӘКЕ** *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан, яндырып, төтенен суыру өчен игелә торган әчкелтем исле үлән; *русчасы*: **табак ароматный**. *Мин дымсу әчкелтем исле тәмәке түтәлен ерып узам да, койма башыннан, йомарланып, урамга сикерәм.* М.Галиев

**ИСЛЕ́ ҮЛӘН** *и. бот.* 1) Иренчәчәкләләр семьялыгыннан, тау битләрендә өем-өем булып үсә торган, сыек канәфер төсендәге вак чәчәкле, исле, тәбәнәк, берьеллык үләнчел үсемлек; чабыр; *русчасы*: **чабрец, чабер**. *Таш араларыннан чыккан исле үлән, йөрүче булмагангадыр инде, тәмам котырган, тиздән тиң булып үскән.* М.Хәсәнов

2) Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан, чәчәклегенең читендә вак кына ак таҗсыман үсентеләр булган, уртасы – сары, калкып торган берьеллык дару үләне; аптека ромашкасы; *русчасы*: **ромашка пахучая аптечная**

**ИСЛЯХ** *и. гар. иск. кит. к.* **ислах**

**ИСМЕ ГА́ДӘД** *и. гар. грам. иск.* Сан

**ИСМЕ ЗАТ** *и.гар. грам. иск.* Алмашлык

**ИСНӘК** *и. диал.* Йокы; иснәү. *Иснәү иснәк китерер.* Мәкаль

**ИСНӘНҮ** *ф.* 1) Үзалдына иснәп йөрү; берәр нәрсәнең исен сизәр өчен, иснәп карау. *Төн буе улашып, якында Иснәнеп йөриләр бүреләр.* М.Җәлил. *Өйгә беренче булып кергән мәче мич кырыендагы савыт кырыйларын иснәнде.* Н.Хәсәнов. *Көрәнсу овчарка мәет янында аз гына тынгысызланып иснәнде* ---. М.Маликова

2) *к.* **иснәү** (*2 мәгъ.*). *Шулчак тавышка Исмәгыйльнең хатыны Людмила да ишек янына килде. – Ни бар? Ни булган? – дип сорады ул, иснәнеп.* Ә.Сафиуллин

3) *күч.* Яшерен күзәтеп, сагалап йөрү, берәр нәрсәнең асылына, серенә төшенергә тырышу. *– Мильтон булмый тагын, ярыктан карап иснәнеп йөрүче генә ич бу! – диде тимер тешле шадра егет.* З.Фәтхетдинов. *Тикшерүче беркөн Зәйдән үтенгән иде: Тимәш посёлогына бар, «иснәнеп» йөр, дигән*

*иде.* Х.Камалов. – *Маңка, сиңа ничу иснәнергә, – диде малайның артыннан күзәтүен сизенгән Сибгатулла.* Н.Гыйматдинова // Берәр нәрсәне күтәп, сагалап йөрү. *Әллә каян иснәнеп сизәсең дә, бәйрәм көннәрендә киләсең дә чыгасың.* Т.Гыйззәт

**Иснәнә башлау** Иснәнергә тотыну. *Хатынның мәче баласын идәнгә җибәрүе булды, әнисе Актәпи шундук аның янына килеп иснәнә дә башлады.* Ә.Сафиуллин. *[Кириллов:] Анакай! Таңда килгән биш кеше яңа боерык китерделәр. Миңа Паратскига кайтырга ярамый. Анда большевиклар иснәнә башлаган.* А.Гыйләҗев. – *Безнең һәр чыгыштан соң милиция иснәнә башлый. Шуны оныттыңмы әллә? – дип дәвам итте Мойше.* М.Насыйбуллин

**Иснәнеп алу** Тиз генә, бер кат иснәнү. *Тик Акбәкәл нәзберек иде. Сөткә комсызланып ташланмады. Башта муенын алга сузып иснәнеп ала, аннан гына берәрсенең сөтле шешәсенә танавын төртә иде.* Ф.Яруллин

**Иснәнеп йөрү** Озак вакытлар, туктаусыз иснәнү. *Уралып, иснәнеп йөри торгач, ул бер төркем яшьләрнең елгачы формасы кигән картрак агай белән кызып-кызып сөйләшеп торуларына игътибар итте.* А.Гыйләҗев. *Әндри генә: – Олылар эше инде ул, олылар эше, – дип, ачыкларга теләп, бик иснәнеп йөрсә дә, табышмакка җавап таба алмады.* Р.Бәшәр

**Иснәнеп карау** *күч.* Берәр мәсьәләне ачыкларга тырышу. *Җитди мәсьәлә бу, җитди. Ярар, иснәнеп карарбыз, Валерий Архипович.* Н.Хәсәнов

**Иснәнеп кую** Бер яки берничә тапкыр иснәнү

**Иснәнеп тору** Туктаусыз, берөзлексез иснәнү. – *Бу нәрсәгә син ничек карыйсың? – диде Феликс, шешәгә күрсәтеп. – Мин сиңа компаньон түгел. Тамчысы да ярамый. Капитан иснәнеп кенә тора.* М.Юныс. *Бер-берсенең исен хәтердә калдырырга теләгәндәй, бик озак иснәнеп тордылар.* Г.Гыйльманов

**ИСНӘТҮ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **иснәү**. *Яз! Сөенеч чәчеп эшчән ил эченә, Йомшак җилләр сибеп кичләтеп, Яшь күкрәкне тагын киңәйтәсең, Саф һаваңны безгә иснәтеп.* Ш.Маннур. *Аннары кызның төшеп калган яулыгын бәйдән ычкындырган этләренә иснәтә ---.* Р.Вәлиев. *[Гөлҗамал:] Кая әле, нашатырь спирты иснәтим үзеңә.* Ф.Яруллин

2) *з-сыз ф. к.* **иснәү** (*2 мәгъ.*). *Минем кәеф тә мактанырлык түгел, авыз ачыла да тора, иснәтә.* А.Гыйләҗев. *Таң сызылып килә офыкта... Иртәнге чык төшә үләнгә, Салкын дымы үтә иңнәргә, Калтырата, өшетә, иснәтә, Эх, йокыны ничек җиңәргә?* Х.Камалов

3) *күч. сир. сөйл.* Махсус дару биреп, авыртуны сизмәс хәлгә китерү; анестезия ясау. *Минем бер иптәшкә доктор, иснәтми, авыр бер операция ясаган иде.* Һ.Такташ

**Иснәтә башлау** Иснәтергә тотыну

**Иснәтеп алу** Берникадәр, бераз иснәтү. *Пешекче Васяның озын саплы зур чүмеч кадәр йодрыгын иснәтеп алды тегеңә.* Ш.Маннапов

**Иснәтеп карау** Иснәргә бирү. *Берсеннән өчәр литрлап тутырылган ике банка хушбуй чыкты. Райнур аларны пүнәтәйләргә иснәтеп карады.* К.Кәрами. *Нишләргә? Нашатырь иснәтеп караган иде, сизми дә.* З.Мәхмүди

**Иснәтеп кую** Бер тапкыр иснәтү

**Иснәтеп тору** Туктаусыз иснәтү. *Аңа нашатырный спирт иснәтеп торалар.* Г.Әпсәләмов

**ИСНӘ́Ү** *ф.* 1) Борын аша һава сулап ис сизү. *Атлар, туктап торган арада, борыннарын җиргә төртәләр, танауларны киереп, туфракны исниләр дә --- зур тынгысызлык белән еракларга текәләләр.* Г.Бәширов. *Без май көнне урманнарга чыктык, Яшь чәчәкләр исен иснәдек...* Ш.Маннур. *Беренче стаканны эчкәч, олаучы агай ах-ух килде, ипи иснәде, аны бәләкәй генә итеп кабып та куйды.* М.Әмир

2) Йокы килү һ.б.ш. хәлләрдә ирексездән авызны киң ачып, тирән сулыш алу һәм аны шунда ук кире чыгару. *Ул, җитү чәчле бәләкәй башын артка ташлап, күзләре йомык килеш, очлы борынын түшәмгә төбәп, карават янында рәхәтләнеп иснәде, киерелде.* Р.Кәрами. *Шакир абзый йокысы килгәнен белгертеп озак итеп иснәде.* М.Маликова. *Гапсамат көч-хәл белән генә күзләрен ачты, беркавым миңа сәерсенеп карап торды. Аннары авызын зур ачып иснәде ---.* Ф.Шәфигуллин

3) *күч.* Берәр нәрсәне аңлап, татып, күреп, баштан кичереп белү. *Хабул бераз сәяси исне дә иснәгән.* Г.Нигъмәти. --- *Габдулла – ни әйтсәк тә, гыйлем исе иснәгән, күп китаплар укыган шәкерт.* Ә.Фәйзи

**Иснәп алу** Бер мәртәбә иснәү; тиз генә иснәү. *Мөбиләр йорты янында, машинадан чыкканда, сарык бәтие Рушадның битен тагын бер иснәп алды.* М.Мәһдиев. --- *Җәмилә яныма ук килде дә, сипкелле борынын җыерып, киемемне иснәп алды...* Л.Ихсанова. *Авызын зур ачып, киерелеп, бер йомарлам һава иснәп алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев

**Иснәп карау** Исен тикшерү. *Тик ул икмәкне иснәп карады да читкәрәк китеп басты.* Д.Бүләков. *Боцман, подшкиперскийның фонарьлар саклана торган өлешенә кереп, бер чирек литрлы шешә алып чыкты. Иснәп карады, эченә өрде.* М.Юныс. *Шәүкәт, графинны үрелеп алып, шәрабны иснәп карады.* Р.Бәшәр

**Иснәп кую** Бер тапкыр иснәү. *Шулчак Илүзә тирәсендә генә утырган Зәкия киерелеп иснәп куйды. – А-һ, йокы килә...* А.Вергазов. – *Хуш, углан, сабыр итик, – диде хан һәм иснәп куйды.* М.Хәбибуллин. – *Да-а... – дип суза калын гына икенче бер тавыш һәм шаулатып иснәп куя.* Р.Төхфәтуллин

**Иснәп тору** Сөйләү моментында, әле, хәзер иснәү. *Кыз, сискәнеп, яулыкны йөзенә каплады, иснәп торды.* Р.Мулланурова. *Ул эчемлекне стакан тутырып салды да төбенәчә эчеп бетерде. Артыннан берни капмыйча, беравык җиңен иснәп торды.* А.Вергазов. *Акбай, борын төбендә эленеп калган шул исне хәтердә калдырырга теләгәндәй, озак кына һава иснәп торды.* Р.Бәшәр

**Иснәп чыгу** Һәрберсен, барысын да берәм-берәм иснәү. --- *ул --- өстәл өстенә менә, һәр җиргә борынын тыгып карый, кызыксындырган нәрсәләрне иснәп чыга.* Н.Әхмәдиев

**Исни башлау** Иснәргә тотыну. *Әнием пешергән чәкчәкне, ул кайнаткан кызыл эремчекне тырнак очына алып исни башласалар, җаным рәнҗи, түзә алмыйм мин ул чакта, үләсем килә.* М.Юныс. --- *Верещагин, кинәт күтәрелә төшеп: – Иптәшләр, әллә ялгышам инде, төтен исе килә бит, – диде. Барысы да башларын калкыттылар. Исни башладылар.* Г.Әпсәләмов. *Шакир киерелә, исни башлады.* А.Таһиров

**ИСНӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **иснәү**

2) *күч. сөйл.* Бер-берсе белән кавышу; очрашып, якынаеп китү. *Син гаепле, Диләрә. --- Минем өмет Равилдә иде. Сез аның белән беренче көннәрдә үк иснәштегез.* Н.Гыйматдинова. *Шул гомер өйләнми торып, яшь хатын белән иснәшүгә башы-күзе әйләнгән икән карт юләрнең!* З.Фәйзи

**Иснәшә башлау** Иснәшергә тотыну. *Бозаулар иснәшә башладылар*

**Иснәшеп тору** Бераз, берара, кыска вакыт арасында иснәшү. *Алар койма аша башларын сузып, бераз иснәшеп тордылар.* Г.Сабитов

**ИС-ОС** *җый. и. к.* **ис-кон**

◊ **Исе-осы юк** Бертөрле дә хәбәр ишетелмәү, һаман билгесез булу турында. *Вакыйгаларның барышы һаман үзгәреп тора, әмма җирнең исе-осы да юк.* М.Шабай. **Искә-оска кермәү** Башка, искә, уйга килмәү; бу хакта бөтенләй уйламау. *Ничек шулай, һичкемнең дә исе-осына кермичә, аерылып калганмын – һич аңламыйм.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Искә-оска китермәү** *к.* **искә-оска кермәү**. *Әйе, аларда [танышларыбызда] куна калсам, мине андадыр дип, безнекеләр искә-оска да китермәсләр иде.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Ис-осын җыю** Зиһенне, уй-фикерне туплау, берәр нәрсәне аңлар хәлгә килү. *[Өннәш] Күршесенең йорты ягына күз төшереп алгач, өенә чакырды: – Әйдә, Алимбай күрше, хәзергә үземә кереп тор. Ис-осыңны җыйсаң, соңыннан үзең карасаң.* Я.Зәнкиев. *Азрак ис-осларын җыйгач, сугыш алдындагы тыныч, бәхетле көннәрен искә алдылар.* Я.Зәнкиев. **Истә-оста булмаган** Бөтенләй уйга, башка килмәгән, уйламаган; бөтенләй билгесез. *Ул юри вакытны суза. Чөнки бу һич истә-оста булмаган хәлне аңы белән кабул итеп җиткерә алмый иде.* Х.Камалов. **Истә-оста югында (юк чагында)** Һич көтелмәгәндә, уйламаганда. *Ни чарадан бичара, истә-оста югында, мин Зәйгә барып урнаштым.* А.Гыйләҗев. *Ә быел, истә-оста югында, туган-үскән җирләр дә сагындырды, сезнең якларда эшчеләр дә кирәк икән, дип, Ленинградтан Галия сеңелкәш кайтып төште.* Ф.Шәфигуллин. *Авыл белән ике арада аларны, истә-оста югында, башкорт ягыннан килгән ястык кадәр генә соры болыт куып җитте.* Г.Бәширов. **Истә-оста юк** 1) Искә дә, уйга да килмәгән, башка да килмәгән. *Әле чапылдатып ими суыра торган бәләкәй энекәшенә, әле аңардан тилмереп нидер көтүче әнисенә карангалап ала һәм кинәт истә-оста юк сорау: – Мин дә шулай имә идемме, әни... бәләкәй чагымда?* Ф.Хөсни. *«Аракы» дигән җен исемдә-осымда да юк иде.* Г.Мөхәммәтшин; 2) Моңарчы уйга килмәгән, булуы көтелмәгән; бөтенләй кирәксез. *Истә-оста юк уйларга бирелеп, шәһәр уртасында калып инде сүтелеп бетүгә якынлашкан бистәгә барып җитүен абайламыйча да калды ул.* М.Хуҗин. **Истә-оста юкта (юк чакта)** *к.* **истә-оста югында (юк чагында)**. *– Анисы, кәнишно, хәләл малың, хәзергә үзең хуҗа, Галләм абзый, – дип кушылды Сәүбән... – әмма, истә-оста юкта, бу ниткән ат сату дип карамаслармы?* Ф.Хөсни. *Бер дә бер көнне, кырдан, тракторчылар яныннан кайтып килешли, --- күпердә, һич тә истә-оста юк чакта, Рәдиф очрады миңа.* В.Нуруллин

**ИС-ӨН** *җый. и. к.* **ис-акыл**

◊ **Ис-өн китү** *к.* **ис-акыл китү**. *Бу сүзләргә Рәмиләнең исе-өне китте.* Э.Касыймов

**ИСПАН** *и.* Испаниянең төп халкы һәм шул халыкның бер вәкиле. *– Фашистларны тәмам җиңгәннән соң, мин --- синең исемеңә хатлар язармын әле, Мачадо! – Мин дә сиңа язармын, – ди испан очучысы.* С.Шакир. *Испан телен белсәң иде, рәхәтләнеп сөйләшсәң иде, дип уйлады Рәшидә...* М.Маликова. *Ә вокзалдан электричкага --- Әкълимә белән дәртле, ялкынлы испан биюләрен тыпыр-тыпыр биюче Руфия генә утырды.* А.Хәсәнов

**ИСПА́НИЯЛЕ** *и.* Чыгышы белән Испаниядән булган яки Испаниядә яшәгән кеше. *Җиңнәрен сызганган зур гәүдәле бер испанияле Марины күтәреп ала һәм халыкка карап сөйли башлый.* А.Әхмәт. *Син русмы, --- испаниялеме – телгә аптырамассың, ары-бире кул болгагач, бер-ике минуттан соң синең алдыңа синең телне синнән дә яхшырак белгән мосье килеп чыгар.* Г.Гобәй. *Вакыйга Испаниядә реконкиста чорын – гарәпләр белән испаниялеләр арасында барган сугышларны чагылдыра.* Мәйдан

**ИСПА́НКА** *и. рус* 1) Гриппның беренче мәртәбә Испаниядә күренгән һәм 1918–1919 елларда дөньяның күп илләренә таралган бик авыр формасы

2) *тар.* Солдат пилоткасына охшабрак торган балалар баш киеме (Советлар Союзында пионер формасы). *Кара пиджак, кара чалбар, кара испанка яшүсмерне кечкенә генә солдатка охшатып җибәрде.* Н.Дәүли

**ИСПАНЛЫ** *и. к.* **испан**. *Яшь испанлы атлый шул тауга, Дружиналары шунда, күрәсең.* М.Җәлил. *Башында – испанлылар кия торган чуклы пилотка.* А.Әхмәт. *Испанлы Санчос Педрос яшьли Рәсәйгә китерелеп, советча тәрбия алган, урыс мәктәбендә укыган коммунист баласы иде.* А.Гыйләҗев

**ИСПА́НЧА** *рәв.* Испан телендә. *Экранда кытайча, итальянча, испанча, япунча тапшырулар, кинолар бик еш күрсәтелә.* Р.Батулла. *Чит ил журналы тотып утырганын күрә дә, берәү юлдашыннан сорый: – Испанча беләсезме әллә? – Әллә тагын, алдым гына, укып караганым юк әле!* Ш.Галиев

**ИСПӘРӘК** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан, бармаксыман чукланып торган яфраклы, зәңгәр, күк, миләүшә төсендәге чәчәкле кыргый яки бакча үсемлеге; зәңгәр чәчәк; *русчасы*: **живокость**

**ИСПО́ЛЬЩИК** *и. рус тар.* Арендага алынган җир өчен, аның хуҗасына җиргә аренда бәясен җыеп алган уңышның яртысы белән түләүче арендатор.

*Байлар өчен тирләп, испольщик булып, мәңге шулай газап чигеп, бер генә дә якты көн күрмәбез микәнни?* И.Туктар

**ИСПО́ЛЬЩИНА** *и. рус тар.* Җир хуҗасына бәяне җыеп алган уңышның яртысы белән түләүдән гыйбарәт аренда төре; уртакка эшләү

**ИС-ПОС** *җый. и. к.* **ис-кон**. – *Исәнме, кызым, идән юасыңмыни? – диде [Сәфәргали абзый]. – Юып чыгарыйм дидем әле, Сәфәргали абзый. Төрле испослар да бетәр.* Г.Ахунов

**ИСПРА́ВНИК** *и. рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә өяз полициясе башлыгы. *Исправникны, ат койрыгына тагып, урам буе йөрткәннәр, үләксәсен чиркәү баганасына асып куйганнар.* Ф.Бурнаш. *Алпавытларны яклаучы исправниклардан, урядниклардан, жандармнардан, полицейскийлардан, стражниклардан булган бөтен бер армия тора иде.* М.Җәлил. *Чукындырылганнан соң, Колангы побы Виктор Охотин, мөселман исемен юкка чыгарып, «Герасим» исеме кушып, бабабызны Зөя өязе исправнигы тарафына җибәрә.* Казан утлары

**ИСРАИЛ** *и. гар. иск.* Яһүдләрнең төп бабаларының исеме һәм аннан таралган яһүдләр нәселе; Ягъкуб пәйгамбәр. *Матур йөзле, ягымлы хәзрәтебезның чырае бу вакытта бәни исраил алласы «Яһүвә»нең иң ачулы вакытындагы чыраеннан да ачулырак төскә кергән була.* Ш.Камал

**ИСРАИЛИЯТ** *и. гар.* Яһүди чыганакларыннан алынган һәм яһүдилек, аның гореф-гадәтләре, әүлиялары һ.б.ш.-лар белән бәйле риваятьләр, хикәяләр (кайбер очракларда Коръәннең яки хәдисләрнең тәфсирен эшләгәндә кулланыла). *Исраилияттән алынган кыйсса*

**ИСРАФ** *и. гар.* **1.** Мал-мөлкәтне, акчаны урынсызга, кирәксезгә тотып әрәм-шәрәм итү. *Улы туендагы исрафларның чамасы юк.* Ш.Мөхәммәдев. *Исраф иң хөрмәтле гаиләләрне дә бозар, иң бай өйләрне дә туздырыр, --- иң шөһрәтле фамилияләрне харап һәм фәкыйрь итәр.* Ирек мәйданы

**2.** *с. мәгъ.* Юкка-барга тотылган, әрәм-шәрәм булган. *Исраф мал. Исраф көч*

**ИСРА́Ф БУЛУ** *ф.* Юкка-барга тотылу, әрәм-шәрәм ителү. *Исраф булды юкка малың.* Бәет. *Ул китапка киткән кәгазьнең, исраф булган караның Хода каршында ничек җавабын бирерсең?* Ш.Мөхәммәдев. *Без – сугышта җиңгән ил, әмма җиңелгән илләрдән күпкә ярлы яшибез. Байлык чит илләргә китеп исраф була.* Х.Камалов

**ИСРАФИЛ** *и. гар. дини* Ислам динендә, Җәбраил, Микаил, Газраил белән беррәттән, дүрт олуг фәрештәнең берсе: сурга өреп, Кыямәт көнен хәбәр итәчәк фәрештә (беренче тапкыр өргәч, исән булган барлык җан ияләре үләчәк, икенче тапкыр өргәч, барлык үлеләр тереләчәк һәм Аллаһ каршында хисапка тартылачак). *Исрафилме сурын өргән? Әллә мәхшәр көн килә?* Н.Исәнбәт

◊ **Исрафил суры** Кискен үзгәрешләргә сигнал, хәбәр. **Исрафил сурын өрү** Кискен үзгәрешләргә сигнал, хәбәр килү. *Бер вакытта безнең өстә өрде Исрафил сурын.* М.Гафури

**ИСРА́Ф ИТҮ** *ф.* Әрәм-шәрәм итү, юкка-барга тоту, туздыру, кирәксезгә тоту. *Исраф итмә, кызым, күз яшеңне.* Бәет. *«Сәфәргалин колхоз байлыгын вактөяккә, гел кирәк булмаган нәрсәләргә исраф итә» дип, өч адреска анонимка әзерләп куйган Габдрахманов ---.* А.Гыйләҗев. *Исраф иң хөрмәтле гаиләләрне дә бозар ---. Шуның өчен исраф итүдән бик сакланыгыз һәм һәр эшегездә икътисадлы булыгыз!* Ирек мәйданы

**ИСРА́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **исраф итү**. *Гәрчә син, кәгазьне исраф кылгансың, дисәң дә, янә хат язгансың.* Ш.Мөхәммәдев. *Кызганыч: акыллы кеше укымаса, сәләтле сәләтен файдаланмаса, гомерен юкка зая итсә, саулыгын юкка исраф кылса.* Г.Хөсәенов. *Атасыннан калган мирас янына үзенең туктатусыз торкан сәүдәсеннән кергән табышның кадерен дә белә, теләгәнендә исраф та кыла торган иде.* Ф.Яхин

**ИСРАФЛАНУ** *ф. к.* **исраф булу**. *Бу гыйбадларның югары материяләрдә гаме юк. Тирән фикерләр әйтеп исрафланасы да түгел.* З.Фәтхетдинов

**ИСРАФЛЫК** *и.* Әрәм булу, исраф булу; кирәксезлек. *Янәсе, дүрт-биш тонна ягулыкны әрәм-шәрәм итү бернәрсә түгел ул. Мондый исрафлык Союз күләмендә законлаштырылмаган булса, бер хәл иде дә бит.* Г.Ибраһимов. *Исрафлыкта көн күрүчеләрнең чутчамасы бетте...* Ә.Моталлапов. *Бөтен илдә әрәм-шәрәм, исрафлык.* Ш.Галиев

**ИСРАФЧАН** *с. иск.* Әрәм-шәрәм итүчән, юкка-барга тотучан, сарыф итүчән. *Исрафчан бай ярлы булыр, исрафчан ярлы хәерче булыр.* Мәкаль. *--- яһүд акчаның кадерен белми, исрафчан, «ахмак».* Г.Исхакый

**ИСРАФЧЫ** *и. сир.* Әрәм-шәрәм итүче, юкка сарыф итүче кеше. *Исрафчы хатын елга утыз пот май чыгарып түгәр.* Әйтем. *Саранның чыгымы исрафчыныкы белән бер.* Мәкаль. *Әгәр без – шушындый ваемсыз, алак-шалак, хуҗалыксыз, исрафчы халыклар – нәни утрауларда, әйтик япон утраулары төсле утрауларда яшәсәк, биш-алты елдан бер-беребезне ашарга тотыныр идек.* А.Гыйләҗев

**ИСРАФЧЫЛ** *с. иск. к.* **исрафчан**. *Яшьләр исрафчыл. Кибеткә тәмәкегә дә «Беларусь» белән торып чабалар.* М.Мәһдиев

**ИСРАФЧЫЛЛЫК** *и. иск.* Исрафчыл булу. *Авыл халкының кызык кына гадәте бар: адәм баласына нинди генә исем кушмасыннар – элек-электән аны кыскарта килгәннәр. Бу – бәлки, халыкның үзенә күрә исрафчыллыкка каршы көрәшедер?* М.Мәһдиев. *--- су буе сүз уйнату, ахыр чиктә кешенең вакытын алу, минемчә, әдәбиятта үзенә күрә бер җинаять, сүзгә исрафчыллык – әдәби культура һәм укучыларны ихтирам итү билгесе.* Р.Фәйзуллин

**ИСРАФЧЫЛЫК** *и.* Әрәм-шәрәм, юкка-барга сарыф итүчән, исрафчан булу. *Динебез әрәм-шәрәм, исрафчылык эшләрен катгый тыйды.* Дини календарь. *Рөстәм Миңнеханов ассызыклавынча, исрафчылык матбугатны да читләп узмый.* Мәдәни җомга

**ИСРӘЮ** *ф. сөйл. диал.* Акыл, зиһен чуалу; юләрләнү. – *Сиңа сулга, безгә уңга, энем, – диде кыз, аландагы тамашалардан исрәйгән шофёр егеткә.* Н.Гыйматдинова

**Исрәеп бетү** Тәмам, бөтенләй исрәю

**Исрәеп китү** Кинәт кенә, уйламаганда исрәю

**Исрәя башлау** Исрәю билгеләре сизелү

**ИС-САН** *җый. и.* Хәтер, ихтирам, кадер, хөрмәт

◊ **Искә-санга алу** *сөйл.* 1) Зурлау, хөрмәтләү, санлау, онытмау; 2) Игътибарга, искә алу, телгә алу. *Дәүләтнең һич нигезсез шикләрен искә-санга сугарга Карачуринаның теләге дә, вакыты да, мөмкинлеге дә юк иде.* К.Тимбикова. *Болай иркенләп яза башлагач, күңелдә калмасын, барысын да әйтим инде: син минем бер үзенчәлегемне әллә аңламыйсың, әллә аңлап та искә-санга алмыйсың.* М.Маликова. **Искә-санга кату** *сөйл. к.* **искә-санга алу**. **Искә-санга сугу** *сөйл. к.* **искә-санга алу**. **Истә-санда юкта** *к.* **истә-оста юкта**. *Ул --- кунакларның һич истә-санда юкта китеп баруларын әйтергә тиеш иде.* Г.Шарипова. *Студент чагымда бер җәйне, Иделдәге Маркиз утравына барганда, бер хатынның күзләренә чәч пәкесе белән сызган кесә карагы, анә һич истә-санда юкта, Вахитов колониясендә очрады бит.* Г.Тавлин. *...Хикмәт диген, истә-санда юкта, икенче көнне туй ясап ташладылар.* А.Әхмәтгалиева

**ИССЕЗ** I *с.* 1) Исе I булмаган; *киресе*: **исле**. *Зәйтүнә чәчәкләргә үрелде. Кашкарыйлар иссез була… икән.* М.Маликова. *Сагынып кайткан сандугач та Таный алмады язны. Сайрый-сайрый гөлгә кунды, Гөл иссез, төссез иде.* А.Суфиянов. *Исле гөл янында иссез гөл дә хуш исләнә.* С.Поварисов

2) *күч.* Ямьсез, тупас, күңелгә ятышсыз. *– Сакманов, тыңла игътибар белән. Син җиңелдең! Зөлфияң бездә… – Шул ук төссез, иссез, тәмсез тавыш.* Т.Галиуллин

**ИССЕЗ** II *с. диал.* **1.** 1) Аңсыз, һушсыз, һуштан язган

2) Уйлап, аңлап эшли белми торган. *Гали һаман иссез кеше кебек тора.* М.Фәйзи

**2.** *рәв. мәгъ.* Аңын югалтып, һушсыз хәлдә. *Бала үр астында иссез ята иде. Ул – ташка сугылган, авызы, борыны канаган.* И.Салахов. *Ул, башын күтәрә алмаенча, кай вакыт иссез, хәлсез булып киткәнгә, Сөннәтче бабай, башына җыелган бозык каннарны чыгарыр өчен, кан алмакчы да булды.* Г.Исхакый

**ИССЕ́З ӘРЕМ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, яшь бәбәкләре салат өчен һәм аш тәмләткеч булларак кулланыла торган үләнчел үсемлек («тархун» дип тә атыйлар); *русчасы:* **полынь эстрагоновая**. *Бөтенләйгә ятканнарны --- иссез әрем үскән җиргә күтәреп алып баралар да бер казыган чокырга күмәләр дә китәләр.* Ә.Гаффар

**ИССЕ́З КАЛУ** *ф.* 1) Һуштан язу, аң югалту

2) Кинәттән бик әсәрләнеп, нык тәэсирләнеп, ни әйтергә белми тору. *Егет аңа, өнемме бу, төшемме, дип, иссез калып карап торды да, исенә килгәч, куанычыннан елмай[ды].* Г.Мөхәммәтшин. *Бу тавыш, бу сүзләр, бу ялкындай янган йөз Максимовка «сөям!» дигән сүздән дә катырак тәэсир итте күрәсең, тәмам каушап иссез калды, ---.* Х.Сарьян

**ИССЕЗЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) Зиһен таркалу, фикер чуалу. *Кайгыдан иссезләнү*

2) Һавага таралып юкка чыгу, очу, исе калмау, исе бетү

**Иссезләнеп тору** Берара иссез I (*1 мәгъ.*) хәлендә булу. *Бу күренеш ачлыктан йончыган Гөлҗамалга начар тәэсир итә, ул артта иссезләнеп тора да тавышсыз-нисез, җиңелчә генә урынына авып төшә.* Н.Исәнбәт

**ИССЕЗ-ӨНСЕЗ** *рәв.* Нык аптыраган хәлдә, әйтергә сүз таба алмыйча. *Нәҗип киртә баганасына терәлеп, иссез-өнсез карап калды.* А.Гыйләҗев

**ИССЕ́З-ТЫНСЫЗ** *с.* 1) Аңсыз, сулышы да сизелмәслек хәлдә; бернинди хәрәкәтсез. *Ята Морат. Иссез-тынсыз ул.* Н.Исәнбәт

2) Хәбәрсез, мәгълүматсыз. *Кояш ярты сүәм күтәрелде исә, күзен тырнап килеп җиткән Зиннәт тә иссезтынсыз.* Н.Гыйматдинова

**ИССЕ́З-ТЫНСЫЗ КАЛУ** *ф.* Аңсыз хәлдә калу

**ИСТӘК** *и.* Көнбатыш башкортларның борынгы атамасы. *– Шулай да ни өчен соң әле син гаскәрең белән минем илгә килдең? Истәкләргә Сәмәкә җәйләүләре --- күп мәртәбә якын, – [диде хан].* В.Имамов. *--- чын кышлак кормыйча, истәкләр ыругы гына быел – монда, ярен анда җәйләп-кышлап йөри.* Х.Сарьян

**ИСТӘЛЕК** *и.* 1) Хәтердә, күңелдә, истә сакланып калган вакыйга, күренеш; хатирә. *Энәне ханым истәлек өчен үзенә сорый. Истәлек өчен икән, истәлек өчен, күп уйлап тормастан, Аллаяров энәне бирә.* С.Сөләйманова. *Никадәрле истәлек, вакыйгалар югалып, күмелеп калганнар. Кеше хәтере иләк: коела да бетә!..* А.Гыйләҗев. *Дөресен әйтергә кирәк: бу минутта безнең беребездә дә озын сүзләр, нидидер истәлекләр тыңлау теләге юк иде.* А.Шамов

2) Үлгән (вафат булган) кешенең хатирәсе, ядкәре. *Үз вазифаларына турыдан-туры кагылмаса да, Дания шагыйрь истәлегенә бәйле урыннарда булмый китә алмады.* М.Маликова. *Әмирханның әтисе Нәдерхан исемле, Талкыштан күчкән Нәдерхан бабайның истәлеге итеп кушканнардыр, бәлки, бу исемне.* С.Зыялы. *Бу – яшь хатын алдында каушаумы, аның күңел ярасына кагылудан куркумы, әллә Илфирнең якты истәлеген мәсхәрә итү булмасмы дип шикләнүме – моны Әзһәм анык кына белми иде.* Р.Кәрами

3) Берәр кеше яки нәрсә турында искә төшереп торган, аны хәтерләткән әйбер, ядкәр. *Рөстәм, тиз генә агачка менеп, мөгезне алып төште дә миңа сузды: – Бүләк булсын. Истәлек. Сезне туңдырып үтерә язган теге Мөгезбай истәлеге.* Г.Сабитов. *--- ул миңа үзендә саклана торган бер дәфтәрне бирергә булды. – Истәлек булсын, дип --- миңа тапшырдылар, ә мин ул дәфтәр белән нишли алам?* Ф.Хөсни. *– Трофическая язва, – дип аңлатты баш врач, Давыткага карап. – Сугышта яралануның нәтиҗәсе. – Әйе, Курск дугасының истәлеге, – дип җөпләде карт.* М.Маликова

4) Борынгыдан сакланып калган корылма яки сәнгать әсәре. *Суздальнең табигатен, музейларын, борынгы истәлекләрен кара[рбыз].* М.Галиев. *Нишләргә? Беләзекне Баһадурга кире*

*кайтарып бирергәме?.. Ул чакта тарих өчен бик кыйммәтле истәлекнең бөтенләй юкка чыгуы ихтимал.* Ф.Сафин. *--- әнкәйләр баз казыганда табылган бакыр алка, металл хәнҗәр, --- ише истәлекләр дә борынгы төрки-болгар бабаларыбызга --- бәйләнешле түгелме?* Мирас

5) Борынгы язма әсәр. *Төрки-татар телендәге язма истәлекләр күп сакланмаган.* Казан утлары. *Казан ханлыгы чорында язылган, укылган, шул дәвердән безгә килеп җиткән язма истәлекләр үзләренең табигатьләре белән гаять төрле.* Мирас

6) Үткән көннәрдән истә калган хәлләр, күргән, ишеткән вакыйгалар турында язма хикәя; мемуар. *Тукай хакындагы истәлекләрне җентекләп укып чыктым.* М.Маликова. *Әткәм хакында уйлаганда, аның бала чакларындагы михнәтле тормышлары турында язган истәлекләре күз алдыма килә.* Р.Ишморат. *Иң яратып укыган китапларым бөек кешеләрнең тәрҗемәи хәлләре һәм алар турында язылган истәлекләр иде.* Г.Кутуй

**ИСТӘЛЕ́К ДӘФТӘРЕ** *и.* 1) Шәхси тормышта булган вакыйгаларны теркәп бара торган дәфтәр. *[Конверт] Эченнән шакмаклы дәфтәр бите килеп чыкты. Почмакларына, истәлек дәфтәрендәге төсле иттереп, чәчкәләр төшерелгән ---.* М.Маликова

2) Яшьләр арасында, бер-берсенә истәлеккә дип, җыр, шигырь һ.б.ларны язу өчен махсус дәфтәр

**ИСТӘЛЕКЛЕ** *с.* 1) Нинди дер яклары белән хәтердә яхшы сакланган, истән чыкмаслык; онытылмаслык. *Яңа ел алдыннан, утызынчы декабрьдә очрашу аларның икесе өчен дә хәтердә калырлык, истәлекле булды.* М.Маликова. *Зиннур Абдуллинның мәктәптә дә, колхозда да, фронтта да хөрмәт итәрлек истәлекле эшләре күп булды.* Я.Зәнкиев. *Шушындый истәлекле минутларны сагышланып үткәрәләр димени?* С.Зыялы

2) Тормыштагы әһәмиятле вакыйгага бәйле. *Рушад, күтәрелеп, Ләйләгөл утырган партага күз салды. Истәлекле парта буш калган.* М.Мәһдиев. *Бу – Фәриднең гамьсез яшьлегенең истәлекле урыннары иде.* Я.Зәнкиев. *Алай да истәлекле урынны күреп, таныш кизләүнең салкын суын эчеп, йөрәкнең януын басасы килә иде...* М.Маликова

3) Әһәмиятле вакыйгаларны яки күренекле шәхесләрне искә алуга багышланган. *Истәлекле кичә оештыру* // Берәр атаклы шәхес яки әһәмиятле вакыйга белән бәйле. *Истәлекле бүләкләр бирү*

**ИСТӘЛЕКЛЕ́ ТАКТА** *и. к.* **истәлек язуы**. *Әхәтов --- Покрау чиркәвенең 1703 елда төзелгәнлеге турында язылган истәлекле тактаны укыган булып азаплана ---.* М.Насыйбуллин

**ИСТӘЛЕКЧЕ** *и. сир.* Үткән вакыйгалар турында шәхси истәлекләр формасында әсәр язучы кеше; мемуарлар язучы. *--- истәлекче күпмедер арттырган очракта да, әдип балачагында һәм мәктәп елларында матди кытлык күргән дип әйтә алмыйбыз.* И.Нуруллин. *– Истәлекче! – диде хан. – Утыр, яз.* М.Хәбибуллин

**ИСТӘЛЕ́К ЯЗУЫ** *и.* Берәр даһи шәхеснең яки зур тарихи вакыйганың истәлеген мәңгеләштерү өчен язылган язу; мемориаль такта. *Нәфисә уңып бетә язган бу истәлек язуларын дулкынланып укыды.* Г.Бәширов

**ИСТЕ́РИК** I *с.* Истерияле. *– Юк! Юк! Боже мой, син мине бер генә тамчы да яратмыйсың, – дип, аны бүлдерде истерик хатын-кыз тавышы.* Ш.Хөсәенов. *Син үзең истериягә бирелмәгәнсең, ә тамагыңа истерик спазм булган. Тамак сеңерләрең, кыскарып, --- азык үткәрә торган юлны буган.* А.Шамов

**ИСТЕ́РИК** II *и. рус* Истерия өянәге белән авыручы кеше

**ИСТЕ́РИКА** *и. гр.* Истерия, нерв өянәге. *Дөрес, ул [Бибиҗамал апа] кайбер аналар шикелле истерикага бирелмәде.* Ш.Хөсәенов. *Әмма Җәмил селкенми дә, чөнки йөрәге таш кебек каткан, эрергә уйламый. Моңа ачуы килеп, Мөслимә истерикага бирелә.* Н.Әхмәдиев. *Хатын истерикага бирелә, алан читендәге әкият йортына барып, --- ишек дөбердәтә башлый.* Р.Вәлиев

**ИСТЕ́РИКЛЫК** *и.* Истерик II булу; истерикага бирелү

**ИСТЕРИ́Я** *и. гр.* 1) Үзен-үзе белештермәслек дәрәҗәдә көлү катыш елау, көлү яки бик нык әсәрләнү белән уза торган үзенчәлекле нерв авыруы (неврозның бер төре). *Менә син --- балаларны бик сагынганга, кызганганга, сөтне кулыңа алгач, истериягә бирелгәнсең.* А.Шамов. *Аны ничә көн изеп килгән курку, өметсезлек истериясе шулай тыелмас ярсу булып бәреп чыга икән, чыксын.* Ф.Галиев

2) *күч.* Кайсы да булса берәр өлкәдә ярсулы, кызу эшчәнлек; берәр нәрсәгә ашкынулы, шашкын омтылыш. *Көнбатыштан искән җилләр белән хәзер яңадан сугыш истериясе төтене килә.* Ш.Мөдәррис

**ИСТЕРИ́ЯЛЕ** *с.* Истериягә дучар булган

**ИСТЕРИ́ЯЛЕЛЕК** *и.* Истерияле булу. *Яшәргә ашыгып сусау! Бөтенесенә һәм берниндикөч куймыйча ия булырга омтылу... – мөгаен, истериялелек буенча алда баручы бөтен Россиянең универсаль диагнозыдыр бу.* Татарстан

**ИСТИБДАДИ** *с. гар. иск. кит.* Деспотик, тиранлыкка нигезләнгән; реакцион

**ИСТИБДАТ** *и. гар. иск. кит.* 1) Бер кешенең баш булуына һәм кәефенә корылган идарә, һичбер законга буйсынмаган, чикләнмәгән хакимият; деспотизм, абсолютизм. *Иван Грозный – Россиядә истибдатны иң каты урнаштыручыларның берсе ---.* Г.Гобәйдуллин. *--- төрекнең Аурупада тамыр җәя алмавына сәбәп – солтаннарның истибдаты ---.* Җ.Вәлиди

2) Изүче сыйныфларның революцион хәрәкәтне һәм иҗтимагый прогрессны бастыру юлы белән үзләренең хокукларын һәм сәяси хакимиятен кире кайтару яки саклап калу өчен алып барган көрәш сәясәте; реакция. *Китте җаннар азыгы, һәм кайтты истибдат кире.* Г.Тукай. *Татар музыкасының чәчәк атканын күрү Тукайга насыйп булмады. Тиз вакыт эчендә яңадан истибдат (реакция) кире кайтты, аның канлы тырнаклары астында шомлы сыкрану таралды.* М.Максуд

**ИСТИГАРӘ** *и. гар.* 1) Көтәчәккә, бурычка алып тору

2) Читтән алып куллану

3) *әд. кит.* Сүзне яки тәгъбирне күчмә мәгънәдә куллану; метафора. *Гарәп сүзләрен куллану Бабич өчен бер истигарә генә икәнен һәркем аңлый.* Г.Ибраһимов

**ИСТИГЪДАД** *и. гар. иск. кит.* 1) Бирелүчәнлек; сәләтлелек, булдыклылык. *Истигъдад бездә бар әле.* Г.Тукай

2) Зирәклек, үткенлек

**ИСТИГЪДАДЛЫ** *с. иск. кит.* Сәләтле, булдыклы. --- *Рөстәм дәресләрне яратып укый башлый һәм, озак та үтми, гимназиянең юаш әхлаклы, истигъдадлы шәкертләреннән исәпләнә [башлый] ---.* С.Җәлал

**ИСТИГЪМАЛЬ** *и. гар. иск. кит.* Кулланылыш, кулланыш. *Әгәр [Туйкә иптәш] мондый сүзләрне, мәгънәләрен, истигъмаль рәвешләрен дә язып, турыдан-туры үземә җибәрсә, --- гомуми эшкә бер ярдәмче булыр иде.* Ж.Вәлиди. *Бәйлекләрнең төрле мәгънәләре, төрлечә истигъмальләре хакында монда тәфсыйлатка керелмәде ---.* Ж.Вәлиди

**ИСТИГЪМА́ЛЬ ИТҮ** *ф.* Файдалану, куллану. *Бер «Кодурине» генә тәрҗемә итеп, шуны гына истигъмаль иткән булсалар, никадәр хезмәт, вакыт һәм акча әрәм ителмәгән булыр иде.* Ф.Әмирхан. --- *[дәва] минем кебек картка ярый торган булса, бәлки, истигъмаль итәрмен дә.* Казан утлары

2) Ризык буларак, ашамлык сыйфатында файдалану; эчү, ашау. *Авырудан соң көчсезләнеп калган, гади вакытта исерткеч истигъмаль итми торган Шакирга бу өч рюмка инде гаҗәеп тиз тәэсир итте.* Ф.Әмирхан. *Доктор Рөстәмгә гаҗәпсенеп карый: – Коньякны алай күп истигъмаль итәргә ярамый бит! – ди.* С.Җәлал

**ИСТИГЪМА́ЛЬ КЫЛУ** *ф. к.* **истигъмаль итү**. *Уру, чабу, сугу вә җилгәрү эшләрендә машина истигъмаль кылынмый иде.* Г.Ибраһимов. *Татарларның ашый торган нәрсәләре күбрәк иттән булган, --- кымызның «кара кымыз» дигәннәрен, бик каты әчетеп, исерткеч урынында истигъмаль кылганнар.* Г.Гобәйдуллин

**ИСТИГЪФАР** *и. гар. дини* Алладан гөнаһларны кичерүне, гафу итүне, ярлыкауны сорау; гафу үтенү; «әстәгъфирулла» дию. *Ташла... Бер төрле исповедь та, тәүбә дә, истигъфар да юк... Бары тик күңелне бушатып сөйләшү генә...* Р.Ишморат

**ИСТИГЪФА́Р ИТҮ** *ф.* Тәүбә итү, Алладан гөнаһларны ярлыкауны, кичерүне сорау

**ИСТИГЪФА́Р КЫЛУ** *ф. к.* **истигъфар итү**. *Төшлек салдырган идем, изгеләрдән шул килеп иреште. Пакьләнеп-аруланып, «кылган кара эшемә тәүбә итәм, йа Аллаһы Тәгалә, истигъфар кыл» дип, җитмеш мәртәбә кабатласын --- диделәр.* Н.Гыйматдинова

**ИСТИКАМӘТ** *и. гар. иск. кит.* Дөреслек, намуслылык; Аллаһ кушканнарны тайпылышсыз үтәү; турылык, туры юл, дөрес юнәлеш. *Тик Ходай хәзер урынны сайлый ул азмак өчен, әһле дөньяга тышыннан истикамәт күрсәтә.* Г.Тукай. *Мулла Вахидта сүз бер юк. Гыйлеме бар... Истикамәтендә... Ир вазифасын белә ---.* Г.Исхакый. *Ходай Тәгалә хәзрәтләре хәерле абруйлар, тәүфикъ, истикамәтләр бирсен.* Ш.Камал

**ИСТИКАМӘТЛЕ** *с. иск. кит.* Тугрылыклы, намуслы. *Истикамәтле дус. Истикамәтле хатын*

**ИСТИКЪБАЛЬ** *и. гар. иск. кит.* 1) Киләчәк. *Шәһәрдән ерак түгел генә җирдәге бу авылда хулиганлык әсәренең сизелмәве минем күңелемдә ниндидер бер тыныч өмет вә истикъбальгә ышану уятты.* Ф.Әмирхан. *Төрле уйлар, хыяллар вә мазый вә истикъбальдән төрле ләүхәләр зиһененнән кичкәннән соң, [ул] авыр вә басынкы адымнар белән номерына юнәлде.* Г.Ибраһимов

2) Каршы алу, хөрмәтләп каршылау. *Габделгалләм гадәтенчә, каш астыннан гына карап: «Ярар, әткәй», – диде дә үзе кунаклар истикъбаль итәргә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Дәһханә, шәһәрдән чыгып, шәһәр халкы илә хәзинәне һәм әсирләрне истикъбаль кыл[ды].* Ф.Халиди

**ИСТИКЪЛЯЛЬ** *и. гар. иск. кит.* Бәйсезлек, мөстәкыйльлек, ireклелек, берәүгә дә буйсынмаганлык. --- *болгарларның истикъляльләре кулларыннан киткәнен сөйләгәндә, Мәрҗани моны күбрәк сәяси сәбәпләрдән күрә ---.* Г.Гобәйдуллин. *Кемнән алдык дин фикрендә истикъляльне?* Г.Тукай

**ИСТИЛАХ** *и. гар. иск. кит.* Атама, термин. *Телебездә фәнни истилахлар һәм хәзерге заманның тудырган мәдәни ихтыяҗларын тутырырлык сүз һәм тәгъбирләрнең ясалып, эшләнеп чыгуын --- күтеп торып булмый, --- чөнки мәсьәлә соң дәрәҗәдә мөһим.* Ж.Вәлиди. *Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилах.* Г.Тукай

**ИСТИЛАХЧЫ** *и. иск. кит.* Терминнар өлкәсендә эшләүче белгеч. *Ул безгә ихтилахчы буларак билгеле*

**ИСТИЛЯ** *и. гар. иск. кит.* 1) Берәр җирне басып алу, сугышып алу. *Бер мең биш йөз сәнәдә, илле ике көз дигәндә, мәлгунь Иван Грузнай истиля итте Казанга.* Бәет. --- *Урта Азия дәүләтләре, икътисади вә шуның аркасында сәяси истилядан куркып, рус вә Европа сәүдәгәрләрен кертмә[де] ---.* Г.Гобәйдуллин

2) Җәелү, каплап алу. *Елганың суы, ярыннан чыгып, әтрафны истиля итте.* Х.Чистапули

**ИСТИНАДӘН** *рәв. гар. иск.* Таянып, берәр фактка нигезләнеп. *Шагыйрьнең әсәргә үзе биргән искәрмәсе дә кызыклы: «мин бу “Шүрәле” хикәясен Пушкин вә Лермонтовның шундый авыл җирләрендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуларына истинадән (нигезләнеп) яздым».* И.Нуруллин

**ИСТИНҖА** *и. гар. иск. кит.* Тәрәттән соң пакьләнү. *Яраткан әбием бер сәгать тә урын өстендә ятмаган, тышка чыгып истинҗа алып кергән дә, мин үләм инде, дип, урынына яткан да күзләрен йомган.* Г.Сәгыйров

**ИСТИРАХӘТ** *и. гар. иск. кит.* Ял; рәхәт. *Бәйрәмнәрне истирахәт ясау сезнең үзегездән килә.* Ф.Әмирхан. *Артистларның истирахәт йортында ял итеп ятканда, Айдар Хафиз белән Хәлим Җәләй икесе ике көймә белән Иделгә балык тотарга керәләр.* Р.Батулла. *Анда тутыйлар, шәрәк, куил кебек сайрар кошлар тавышын тыңлап, Алып Бәргән истирахәт алды.* Р.Батулла

**ИСТИРАХӘ́Т ИТҮ** *ф.* Ял итү, рәхәтлек кичерү, ләззәт. *Алып кайткан*

*илче ишан хәзрәткә әйтә: – Тәкъсир, сез инде бүген шушында тәгам җыеп, авыр, озын юлдан соң әйбәт кенә истирахәт итегез...* Ә.Еники. *Автобус эче эссе. Төрекләр истирахәт итә, мин тирләп барам.* Р.Батулла

**ИСТИРАХӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **истирахәт итү**. *Яхшы йокладыгызмы, истирахәт кылдыгызмы?* К.Насыйри. *Хельсинки читендә, урман, гранит таулар эргәсендә аквапаркта истирахәт кылабыз.* М.Галиев. *Кабан күле буенда гадәтемчә истирахәт кылып йөргәнемдә, каршыма бер төссез адәм килмәсенме?* Ф.Яхин

**ИСТИСКА** *и. гар. дини* 1) Корылыктан яңгыр теләү

2) *к.* **истиска намазы**. *Моңарчы ихлас күңелдән яңгыр намазы – «истиска» укып йөргән картлар да дөнья кайгысыннан ваз кичтеләр.* К.Нәҗми

**ИСТИСКА́ НАМАЗЫ** *и. дини* Корылык сәбәпле игеннәргә һәм хайваннарга зарар килү куркынычы булганда, кырга (сахрага) чыгып, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап дога кылу өчен укыла торган намаз. *Укыйсы иде бит истиска намазы, укыйсы иде!* Ш.Камал

**ИСТИСНА** *и. гар. иск. кит.* Чыгарма, искәрмә. *Пушкин вә Лермонтовтан тәрҗемә вә икътибаслары да телләрен истисна белән --- гүзәл чыкканнар.* Ф.Әмирхан. *Хөкемнән хариҗ булуы ихтимал күрелгәннәрне хөкемнең эченә кертүне* (*ягъни истиснаның киресен*) *аңлата.* Җ.Вәлиди

**ИСТИСНА́ ҖӨМЛӘСЕ** *и. иск. лингв. Тик, мәгәр, фәкать* кебек бәйлекләр белән бәйләнгән, мәгънәләре бер-беренә капма-каршы җөмләләрдән торган кушма җөмлә

**ИСТИСНА́ ИТҮ** *ф.* Чыгарма ясау, арадан аерып алу. *Төрек халкының бәйнәлмиләл вазгыяте бу ихтирамны катгый сурәттә истисна итә.* Ф.Әмирхан

**ИСТИСНА́ КЫЛУ** *ф. к.* **истисна итү**. *Хәйләкәр карт мулла тирәяктагы муллаларны берәм-берәм сүгеп чыкты да, ахырдан китереп, Җәләшне истисна кылды.* Г.Ибраһимов

**ИСТИФАДӘ** *и. гар. иск. кит.* Файда

**ИСТИФАДӘ́ ИТҮ** *ф.* Файдалану, куллану, тоту; файда күрү. *Мәхдүмнең яшьлегеннән истифадә итмәкче булды.* З.Һади. *Аяз, матур һавадан истифадә итеп, Болак өстендә көймә белән йөзеп йөрүчеләр дә шактый бар иде.* Ф.Әмирхан. *1902 елда угылым Мөхәммәткямил Әлкаһирәдән кайткач, Габдулла аннан истифадә итәргә башлады.* М.Төхфәтуллин

**ИСТИФАДӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **истифадә итү**. *Җир-судан болай аз истифадә кылуларына аларның көч вә саннарының азлыгы вә табигый сәрвәтнең артык күплеге сәбәп булган ---.* Г.Ибраһимов

**ИСТИХАРӘ** *и. гар. дини* Берәр эшнең ничек булачагын алдан төштә күреп белү өчен, кичтән махсус догалар укып, шуңа ниятләп йокларга яту. *Хәзрәт, истихарәне бөтен шартлары белән кылыр өчен, умывальниктан тәһарәт алмыйча, комганнан тәһарәт алырга карар биргән иде.* Ф.Әмирхан // Шундый догалар укып яткач күрелгән төш. *Ул төш истихара шикелле бернәрсә булды.* Ш.Камал

**ИСТИХАРӘ́ КЫЛУ** *ф.* Төшлек салу, төшлек салдыру, төш юрау. *Без --- истихарә дә кылып карадык.* Г.Ибраһимов. *Ул кичә үзенең ниләр эшләгәнен хәтеренә китерде, истихарә кылганлыгы исенә төшкәч, фикерен җыеп, күргән төшләрен тәртипкә сала башлады.* Ф.Әмирхан

**ИСТИХАРӘЛЕ** *с. иск. дини* Алдагы эшнең нинди булачагын белү өчен төшлек салдырылган. *Аһ шайтан, килеп, тәһарәтемне боздырып чыгып китте бит, нәгъләт! Истихарәле төш күрермен дигән идем.* М.Әмир

**ИСТИХАРӘ́ НАМАЗЫ** *и. дини* Мөһим карарны кабул итәр алдыннан яки берәр олуг эшне башлар алдыннан, шул эшнең хәерле булуын теләп укыла торган нәфел намаз төре. *Әле бүген истихарә намазын укып бетергәннән соң да синең турыда уйладым.* Т.Гыйззәт

**ИСТИХКЯМ** *и. гар. иск. кит.* Хәрби ныгытма. --- *истихкямнар салырга, --- яңа каналлар казырга, рус, --- белән бергә, әллә никадәр татарлар да китәләр иде.* Г.Гобәйдуллин

**ИСТИҺЗА** *и. гар. иск. кит.* Мыскыл, мәсхәрә. *Гадәте я истиһза яки тәхкыйрь; сүз сөйләмәс бирәүне җәрых кылмый.* Акмулла. *Ул минем каушаганымны күреп, ачулы чәһрәсенә бирдән истиһза рәвеш биреп, салкын вә үткен бер көлеш белән --- көлде дә миңа таба борылды.* Ш.Камал

**ИСТИҺЗА́ ИТҮ** *ф.* Мыскыл, мәсхәрә итү; мыскыллап, мәсхәрәләп көлү. *Мөгълифә, һаман да истиһза итеп: «Кем белә, бәлки, алыр да, синең өчен, бәлки, хатыннарын да аерыр», – ди.* Г.Камал

**ИСТИҺЗА́ КЫЛУ** *ф. к.* **истиһза итү**. *Туган җиребездә яшәргә имкян калмаганга, кяфер түрәләрнең истиһза кылуына түзә алмаганга, рәхим-шәфкать сорап, сиңа килдек.* В.Имамов

**ИСТИҺЗАЛЫ** *с. иск. кит.* Мәсхәрәле, мыскыллы. *Җан биргәнгә җүн бирә, диләр. Дөрестән дә бирә; ләкин кайвакыт аның биргәне шундый ачы истиһзалы була ---.* Г.Ибраһимов. *Истиһзалы караш. Истиһзалы көлү*

**И́С ТИЮ** *ф.* 1) Сөрем белән, ис (*2 мәгъ.*) белән агулану. --- *болар икесе бер төндә ис тиюдән һәлак булдылар.* Г.Ибраһимов. *Ата да, кызы да хәрәкәтсез, йөзләре мунчада ис тигән кешеләрнеке кебек сулып, агарып калган.* Я.Зәнкиев. *Утырма кайнар мич каршында. Башыңа ис тияр. Егылырсың.* Р.Мулланурова

2) *куч.* Исерү (*1 мәгъ.*). *Тик фәкать беркөнне «башка ис тигәч», Азрак эчкәч, башка киткәч «пирәш», Кемгәдер ул иске серне итте фаш.* Г.Тукай

**ИСТОРИО́ГРАФ** *и. гр. махс.* Историография белгече. *Императрица Елизавета Петровна вакытында рәсми историограф вазифасы кертелә.* Бөтендөнья тарихы

**ИСТОРИОГРА́ФИК** *с.* Историографиягә караган, историография белән бәйле

**ИСТОРИОГРА́ФИЯ** *и. гр. махс.* 1) Тарих фәненең үсеше һәм тарихи чыганаклар турындагы фән. --- *феодализм иҗтимагый-экономик формациясен гомуми тикшерүдән башка, Г.Гобәйдуллин тагын историография --- өстендә эшли.* С.Алишев. *XVIII гасыр тарихчысы П.Рычков --- рус историографиясендә татарны монголлар*

*белән бутауга каршы көрәшеп караган беренче рус галиме булса кирәк.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *XIX гасырның башында Россия историографиясе (тарихны өйрәнү фәне) алга таба зур адым атлаган.* СССР тарихы

2) Тарихи әдәбиятны өйрәнү. *Историография буенча булган хезмәтләреннән Г.Гобәйдуллинның «Идел буе төрки-татар телендә тарихи әдәбиятның үсеше» дигән әсәрен санарга кирәк.* С.Алишев

3) Нинди дә булса проблеманы өйрәнү тарихы

4) Билгеле бер чорга караган тарихи хезмәтләр җыелмасы

**ИС-ТӨШ** *җый. и.* Зиһен, аң, акыл, хәтер

◊ **Истә-төштә юк (булмау)** Бөтенләй көтмәгәндә, һич уйламаганда. *Кинәт, истә-төштә юк чагында, кемдер иңбашыма кулын китереп салмасынмы!* Г.Шәрәфетдинов

**ИСТРЕБИ́ТЕЛЬ** *и. рус хәрби* Һава сугышларында дошман самолётларын һәм пилотсыз очкычларын юк итү өчен файдаланыла торган, яхшы коралланган, җиңел сугыш самолёты. *Ә һаваны дерелдәтеп очкан куәтле «Су-27» истребительләре бутала да бутала иде. Бомбалар тегә якка да, бу якка да ява.* З.Мәхмүди. *Менә шуңа күрә лейтенант Зәки Нурмыев бүген фашист истребительләре эзәрлекләгән самолётта дошман тылына оча.* З.Фәтхетдинов. *Баш очыбыздан гына истребительләр пулемёттан пуля яңгыры сиптереп узалар.* К.Миңлебаев

**ИСТЫЙРАП** *и. гар. иск. кит.* Борчылу, хафалану, тынычсызлык. *Шул хәлдә Зөләйха өч тәүлек уткәрде, өч көн көндезен авыр бер истыйрапта, төннәрен йокысыз, урам як тәрәзәдән беренең яңагына сөялгән хәлдә, бер үзен онытып, хыял дөньясына югалып, бер елап кичерде.* Г.Ибраһимов. *Кассага якын утырган яшь кыз да, якын урын ишгаль итә алмаганлыктан, шактый истыйрапта күренә иде.* Ф.Әмирхан

**ИСТЫЙРАПКА́ ТӨШҮ** *ф.* Хафага, борчуга төшү, аптыраштa калу, тынычсызлану. *Мин, алдан ук икенче класста бер урын яздырып куйганлыгымнан, бик истыйрапка төшми утыруымда дәвам итә идем.* Ф.Әмирхан

**ИСТЫЙРАПЛЫ** *с. иск. кит.* Борчулы, хафалы, тынычсыз. *Истыйраплы еллар. Истыйраплы көннәр. Истыйраплы уйлар*

**ИС-ТЫН** *җый. и.* Зиһен, аң һәм уй, фикер

◊ **Истә-тында юк чакта** Уйламаганда, көтмәгәндә. *Һәр сүзне энәгә җеп итеп саплаган карчык, истә-тында юк чакта гына, капка дөбердәтә иде.* Н.Гыйматдинова. **Ис-тын алу** *к.* **ис-тын җыю**. *Ә карчык бүген генә ис-тын алып, хәлләнә төште.* Н.Гыйматдинова. **Ис-тын җыю** Зиһенне, уйны, фикерне бер ноктага туплау, берәр нәрсәне аңларлык хәлгә килү. *– Бусы нәстәгә?! – дип үкерде Лотфулла. – Әллә үрдәкләр йөздерәсезме?! – Кукчәчәк ис-тын җыйганда, Сабирҗан карт: – Килен кер чайкый, улым, бакчи, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Монысы нәрсә тагы?! Аптыравымнан авып китә яздым. Азрак ис-тын җыйгач: – Каян чыгып әйтәсез бу сүзләрне? – дим.* Казан утлары

**ИС-УШ** *җый. и. к.* **ис-акыл**

◊ **Истә-ушта югында** Һич уйламаганда, көтмәгәндә. *Кичке очрашуда, --- Байназар истә-ушта югында, --- кыз моңарчы уйларга да курыккан сүзне әйтте.* М.Хуҗин

**ИСҮ** *ф.* Җылы һава белән салкын һаваның аралашуы нәтиҗәсендә, һава агымы хәрәкәткә килү, һава агымы җәелеп өрү. *Исә җилләр, күчә комнар, бетә эз.* Дәрдемәнд. *Көзге салкын җил исә, Атлашкино ягыннан кара болытлар килә.* М.Мәһдиев. *Иңгә-иң терәлешеп, дымлы рәхәтлектән мәһабәт булып үскән өянкеләр өстеннән, --- талгын җил исә.* М.Галиев

**Исә башлау** Исәргә тотыну. *Көн дә сизелерлек салкынайтты, суык җил исә башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Төньяктан дымсу, салкын җил исә башлады.* ---. Н.Фәттах. *Кинәт ярыйсы ук көчле төнге җил исә башлады.* Р.Вәли

**Исеп алу** Берара, кыска вакыт эчендә исү. *Ул арада иң биек агачлар гына сизәрлек талгын җил исеп ала...* М.Мәһдиев

**Исеп җибәрү** Кинәт исә башлау. *Урам ягыннан салкынча төньяк җиле исеп җибәрде.* А.Вергазов

**Исеп китү** 1) Бераз, берникадәр исү. *Байракны аз гына исеп киткән җил җилфер-җилфер китереп тора* ---. С.Җәлал. --- *су өстеннән бераз салкынчарак вә бераз юешрәк һава исеп китте.* Ф.Әмирхан

2) Кинәт исү. --- *яшел алмалы алмагачлар кинәт исеп киткән җилдән калтырап куйгандай булдылар.* Р.Вәлиев

**Исеп кую** Кинәт, аз гына яки бер мәртәбә исү. *Бераздан таң җиле көчлерәк исеп куя.* М.Хәсәнов. *Әнә көнбатыш ягыннан ялкау гына җил исеп куйды, еракта – әллә кайда! – гөрелдәү ишетелеп алды, талгын җилгә камышлар чыштырдашып куйды.* М.Мәһдиев. *Әкрен генә җилләр исеп куя Киң Иделгә тынгы бирмичә.* Ә.Ерикәй

**Исеп тору** Бертуктаусыз исү. *Автовокзалдагы тынчу бөркүлекне күпер төбендә туктаусыз исеп торган салкынча җил алыштырды.* Ф.Сафин. *Җиңелчә генә җил исеп тора иде.* Р.Фәизов

**Исеп узу** Бер очыннан икенче очына кадәр исү. *Гүя, күңелем күле өстеннән кискен җил кинәт кенә исеп узды да тынып калды ул...* Ә.Еники. *Күрәсең, өермәдәй исеп узган баш җитмәс хәлләрдән соң, мин беркадәр әйле-шәйлерәк булып калган идем.* Ә.Еники

**ИС-ХУШ** *җый. и. сөйл.* Берәр нәрсәнең булу билгесе, галәмәте, әсәре

◊ **Ис-хуш булмау** Бөтенләй булмау, күренмәү, ишетелмәү. --- *хәлләрен сорашып, бер-ике авыз сүзлек хат кисәге дә язып салганы юк бит таш йөрәкнең... Хәер, кирәге юк, сабыйларның нарасый күңелендә вакытсыз ачы гамь уятып, ананың болай да китек күңелен телгәләп йөргәнче, исе-хушы да булмавы мең артык!..* Р.Төхфәтуллин

**ИС-ҺУШ** *җый. и. сөйл. к.* **ис-уш**. *«Хәер, акыра» дигән нахак бәла аның тәмам исен-һушын алган* ---. Р.Мулланурова

◊ **Исен-һушын алу** Бик нык гаҗәпләндерү, шаккатыру. *Без хәзер инде ныгыган, тамыр җәйгән иҗтимагый тормышыбыздан адәм баласының исен-һушын алырлык әллә нинди герой-*

*лыклар таба алмыйбыз.* Х.Сарьян. **Истән-һуштан тайдыру** *к.* **истән тайдыру**. *Боларны сөяркәңнән ишетү, гәрчә Фәүрия үз тәртибен акламаса да --- аны хәтта истән-һуштан тайдырды.* М.Хуҗин. **Ис-һуш җыю** *к.* **ис җыю**. *Мөхәммәт әле һаман ис-һушын җыеп өлгермәгән, әле һаман диван почмагында өнсез утыра иде.* З.Хөснияр. **Ис-һуш кайту** Һушка килү, аңга килү. *Адъютантының исе-һушы кайтканчы, атаман үз урынына барып утырды.* З.Фәтхетдинов. **Ис-һуш китү** *к.* **ис китү**. --- *ә хәзер аның кояш кебек якты, чибәр офицерга әверелгәнен күрә торып та, мөгаллимәнең исе-һушы китмәде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИТ** *и.* 1) Ашау өчен суелган яки ауда атып алынган хайванның, кош-кортның түшкәсе. *Ит прилавкалары янына килдек. Бер хатын бөрешеп, тимгелләнеп беткән тавык ите сата.* Ф.Баттал. *Ит чабучы кызы Рамилә күз өстендәге кашка әвереләде.* Р.Мөхәммәдиев. --- *мари авыл хуҗалыгының хәзер кымыз, бүдәнә ите һәм йомыркасы кебек савыктыргыч продукцияләр җитештергәнен дә әйтеп үтү урынлы булыр.* Казан утлары

2) Чалынган йорт хайванының яки ау вакытында атылган хайванның үпкә-бавырдан, эчәкләрдән башка тән тукымасы кисәге, шуның бер өлеше. *Гата да усал, кайдандыр капкын алып кайтып, аңа ит кисеп куйды, ә үзе тыныч кына йокларга ятты.* А.Алиш. *Җыелышны тәмамлап, Сабир өйгә кайтып кергәндә, өйдә аш пешкән, тәмле ит исе чыккан иде.* М.Мәһдиев. *[Хәдичә апа] Өстәлгә табак белән аш, аерым тәлинкәдә бәрәңге белән тавык ите китерде.* М.Маликова

3) Кеше яки хайван тәненең мускуллы урыны; тән тукымасының гади телдә йөри торган атамасы. *Хатынны әйтәм, үзе сары, үзе юка, тәнендә черки тешләр ите дә юк!* М.Маликова. *Студентның күзе Разиянең шәрә беләкләренә, аның кибеп беткән күкрәгенә төште. Кызның тәнендә бер чеметем ит юк иде.* М.Юныс. *Әйрәннең, авыз читләреннән саркыла биреп, ачык изүдән иң башта киң, сум итләре бүселеп торган күкрәгенә --- агып төшүен сизмәде...* А.Хәлим

4) Яфракның тамырчалары арасындагы өлеше. *Яфрак ите*

5) *тарт. форм.* Җиләк-җимеш, яшелчәләрнең, гөмбәнең тышча эчендәге итләч өлеше, йомшагы. *Карбызның ите үскән саен кабыгы да үсә, кабыгы үскән саен ите дә үсә.* А.Расих

6) *куч.* Нигезеннән ертып, кубарып алынган тукыма кисәге. *Кофтаның төймәсе ите белән йолкынган*

◊ **Ит арттыру** *ирон.* Симерү, тазару. *Ял вакытларында Муса тән үстерүне, ит арттыруны кайгыртмый иде, бик күп җәяү йөри иде.* М.Максуд. **Ит басу** *сөйл.* Артык симерү, чамадан тыш тазару. **Ит белән тырнак арасына керү** Бик якын ике яр яки ике дус, ике туган арасына керү. *Кем мине көчли? Сез шул җаваплы минутта да, күзгә карап, иптәш Вахитов өстенә сөйлисезме? Шаяртмагыз, ит белән тырнак арасына керә алмассыз, бик белеп торыгыз: аның теләге – минем теләгем.* Н.Исәнбәт. **Ит бүкәне (кисмәге, мичкәсе, чапчагы)** *гади с. мыск.* Таза, юан, симез кеше. *– Кем котыртты соң сине? – Ленар. – Йөзе кара, ул ит бүкәненең колагын борырмын...* Н.Хәсәнов. *Бу ит бүкәнен нишләтәбез?* Д.Аппакова. *Хатын-кызның бер ишесе, нечкә билле булыйм дип, --- ашамый интегә. Тик барыбер, ит бүкәнеме – ит бүкәне.* Б.Камалов. **Ите белән ертып (аерып, каерып) алу** Нигезе белән (мәс., төймәне үзе тегелгән тукымасы белән) кубарып, аерып алу. **Итен ашау** *гади с.* 1) Берәр кешене юк-бар нәрсәләр белән тинтерәтү; вак-төяк өчен дә тиргәп аптырату. *Минут саен итемне ашады [ул], әле бер эшем килешми, әле икенчесе.* Х.Садри; 2) *к.* **итен чәйнәү**. **Итен чәйнәү** *гади с.* Кешенең гайбәтен сату. *[Себер бае:] Ә адәм ите чәйнәү – көн буе гайбәт сатып утыру – аннан харам түгел?* Г.Камал. **Ите сезгә (сиңа), сөяге безгә (миңа)** *тар.* Ата-аналарның балаларын мәдрәсәгә хәлфәләргә, муллаларга яки берәр һөнәрчегә өйрәнчеклеккә биргәндә әйтә торган сүзләре. *Өстерим дә китерәм тегене Ильясларга, мәгез, минәйтәм, ите сезгә, сөяге миңа.* М.Әмир. *Алпар углын иң оста бизәк төшерүчегә малайлыкка бирде. «Ите сиңа, сөяге миңа, өйрәт, тыңламаса, чыбыгың кулыңда!» – диде.* М.Хәбибуллин. **Ите синеке, сөяге минеке** *к.* **ите сезгә (сиңа), сөяге безгә (миңа)**. *Хәйдәргали туганым, оланның гаебе зур түгел... «Ите синеке, сөяге минеке» дигәндәй, син – әти кеше, үзең белә торгансыңдыр инде.* Р.Мөхәммәдиев. **Ит йогу** *к.* **ит куну**. **Иткә әйләндерү** Кош-кортны, хайваннарны иткә сую. *Ат-сыер күрсә Арыслан, [аларны] иткә тиз әйләндерә.* Г.Тукай. **Ит кибәне (чүмәләсе)** *гади с. мыск.* Зур гәүдәле, бик ямьсез симергән кеше. **Ит корышу** *диал.* 1) *к.* **ит төшү**; 2) Ачу килү. **Ит кундыру** Текстны сурәтләүчагыштыру чаралары белән баету; өстәү, кубәйтү, төзәтү. *Бөре педучилищесында укыган елларында һәвәскәр сукыр артистлар төркеменең администраторы булып йөргән дәверне чагылдырган кызыклы повестеның караламасы эшләнеп беткән диярлек, аңа, мәрхүм үзе әйтмешли, «ит кундырып чыгасы» гына калган иде.* Л.Хәмидуллин. **Ит куну (утыру)** Тазару, тәнгә симерү, ашаган ризыгы тәнгә куну. *[Алимҗанга] Тәрбия җитсә, әле дә көч-егәре ташып торыр иде. Ләкин... үлән ашап, караҗиләк ише вак-төяк чемченеп кенә тәнгә ит кунмый шул.* Р.Кәрами. *Вустлау лагеренда ул [Янгураз] тәмам аякка баса язды: тәненә ит кунды.* Т.Әйди. *Безнең сыйнфый дошманнарыбызның дүртесе дә, нишләптер, үтә арык, үтә зәгыйфь иде. – Кешеләрне күп рәнҗеткәннәр алар, шуңа күрә үзләренә ит кунмый, – дигән нәтиҗә чыгарды Әсгать ---.* М.Кәрим. **Ит күрмәгәнгә (югында) үпкә (дә) тансык** Яхшысы булмаганда начарракка да риза булу, шуның белән канәгатьләнү турында. *Хәер, әлегә Ринаның да чын мөнәсәбәтен чамалау мөмкин түгел ич. Ит юкта үпкә тансык, дигәндәй, бәлки, кызыкай да, тормыш юлында әлегә күзе төшәрлек чын арий каһарманы очрамаганлыктан гына, һуннар онысына илтифат күрсәтәдер.* Т.Әйди. **Ит тә юк, йон**

**да (сөт тә) юк** *мыск.* Булдыксыз, кулыннан эш килмәгән, эш рәтен белми торган, файдасыз кеше турында. *Ул кешедән ит тә юк, сөт тә юк, алыштыр син аны, Мохтар абзый.* Ю.Әминов. **Ит төшү** Ябыгу. *Ә мин көнаралаш печән җыйдырам да арба тарттырам үзеннән. Күрәбез: ите төшеп, җыйнаклана, матурлана башлады бу [Сылугөл].* З.Фәйзи. **Ит урлаган мәче (песи) төсле** Ниндидер гаеп эш эшләгән яки эшләргә җыенучы кешенең үз-үзен табигый булмаган тотышы турында. *[Хәйрулла] Ит урлаган песи төсле, якягына ялт-йолт каранып: «Ә командир үзе ничегрәк соң?» – диде.* К.Тинчурин. **Ит утырту** Тазару. *[Өммегөлсем] Моннан бер ай чамасы элек кенә кызамыктан көч-хәл белән котылган, инде хәзер тәненә ит утыртып, --- үсә башлаган ун айлык Тансыгын --- алып, ерак юлга чыкты.* А.Хәлим. **Ит үсү** Яраланган, киселгән урын төзәлү

**ИТАГАТЬ** *и. гар. иск. кит.* 1) Буйсыну; сүз тыңлау, ихтирам. *Патша хезмәтендә итагатьтән таймасагыз, Хода ташламас.* Ф.Бурнаш

2) Үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; этикет. *Варис коньякка бөтенләй кагылмады. Әтисе һәм район башлыгы алдында итагать саклавы гына түгел иде егетнең.* Б.Камалов. *Кич буе Фәрит белән үзебезне, итагать белмәвебез, --- өчен битәрләп утырдык.* Р.Вәлиев. *Кайда сыю-сыймау итагатен яхшы белә иде Азат.* Казан утлары

**ИТАГА́ТЬ ИТҮ** *ф.* Буйсыну. *Бу чордагы билгеле татар язучыларының зур бер өлеше дин һәм милләт исеменнән халыкны бөек Россия патшасына итагать итәргә чакырдылар.* М.Җәлил. *Вахидның «Әнкәңне тыңла, әнкәңә итагать ит!» дип васыять әйтеп калдырырга да угылы юк...* Г.Исхакый

**ИТАГА́ТЬ КҮРСӘТҮ** *ф. к.* **итагать итү**. *Ул хәзер дингә вә Коръәнгә итагать күрсәтә.* Г.Тукай

**ИТАГА́ТЬ КЫЛУ** *ф. к.* **итагать итү**. --- *Ислам диненә күп хезмәтләр калдырган затлар динебездә һәм мәзһәбебездә һичбер үзгәреш кертмичә, --- бер-берсенә итагать кылып --- яшәгәннәр.* Гөлстан

**ИТАГАТЬЛЕ** *с. иск. кит.* Буйсынучан, сүз тыңлаучан, күндәм; ихтирамлы. *Вера түтәй, --- ишек төбендә басып, итагатьле кыяфәт белән тыңлап тора.* М.Маликова. *Бу төр мәҗлеснe кайбер итагатьле балалар, әти-әниләрен зурлау йөзеннән, аларга багышлап та җибәрәләр.* Ю.Әхмәтҗанов. *Тракторы белән силос базына төшеп Мисбахы үлгәнгә ун ел, ә ул һаман каенатасына тугрылыклы килен булып яши, итагатьле иде.* Н.Әхмәдиев

**ИТАГАТЬ(ЛЕ)ЛЕК** *и. иск. кит.* Буйсынучанлык, ихтирамлылык, сүз тыңлаучанлык, күндәмлек. *Ә егетләре, итагатьлелектәнме, әллә оялчанлык галәмәтеме, чакырмыйлар үзен.* Р.Мөхәммәдиев. *[Хәбриев:] «Рәхмәтләр яусын сезгә үзегезгә», – дип, японнарча итагатьлек белән кулларын кушырып, баш иеп куйган булды.* М.Галиев. – *Кая, башта пальтоңны сал әле. – Җәмил, итагатьлек күрсәтеп, Мөслимәнең пальтосын шифоньерга элеп куйды.* Н.Әхмәдиев

**ИТАГАТЬСЕЗ** *с. иск. кит.* Буйсынмый, сүз тыңламый торган, карышучан; ихтирамсыз. Янәсе, күрегез: безгә итагатьсез кешеләргә карата без ничек рәхимсез була беләбез. Т.Нәбиуллин

**ИТАГАТЬСЕЗЛЕК** *и. иск. кит.* Буйсынмаучанлык, күндәмсезлек; ихтирамсызлык. *Минем Исламны тынычландырасым, теге вакытта үзем дә аңламастан эшләгән итагатьсезлегем өчен гафу үтенәсем килде.* И.Сирматов. *Халык бозылыр иде, син әйткәннәрне эшләсәк! Йортта тәртипсезлек, итагатьсезлек, әдәпсезлек хөкем сөрер иде!* Р.Батулла. *Димәк, киләчәктә төш турында сораулар итагатьсезлек билгесенә әйләнүе бар.* Ирек мәйданы

**ИТАГАТЬЧЕЛ** *с.* Ихтирамлы; буйсынучан, сүз тыңлаучан. – *Падишаһ хәзрәтләренә яхшы хезмәт итегез, аның олуг түрәләренә итагатьчел булыгыз, – диде мулла.* М.Гафури

**ИТА́ЛИЯЛЕ** *и.* Чыгышы белән Италиядән булган яки шунда яшәүче кеше. *Кара диңгез буенда торучы сәүдәгәр италияле вә румнарга елкы саталар ---.* Г.Гобәйдуллин. *Италиялеләр бәйрәм ярата.* М.Юныс. *Циолковский анда рус, американы, француз, немец һәм италияленең 2017 елда, йолдызара очкычка утырып, космоска очуын сурәтли.* Галәмгә юл

**ИТАЛЬЯН** *и.* Италиянең төп халкы, милләт теле һәм шул халыкның, милләтнең бер вәкиле. --- *шуның өстенә дә бу итальяннар белән төрекләр арасында бертуктаусыз низаг вә сугышлар китте: бугазлар аркылы итальян көймәләре йөрмәс булды ---.* Г.Гобәйдуллин. *Син русмы, итальянмы, төрекме, испаниялеме – телгә аптырамассың, ары-бире кул болгагач, бер-ике минуттан соң синең алдыңа синең телне синнән дә яхшырак белгән мосье килеп чыгар.* Г.Гобәй. *Арча госпиталенә Сталинградта әсир төшкәннәр кайта башлады. Нинди генә милләт кешеләре юк анда – немец, итальян, чех, мадьяр.* А.Гыйләҗев

**ИТАЛЬЯ́НЧА** *рәв.* **1.** Итальян телендә. *«...Пушкиннан башлап барлык бөек язучылар бездә булды», – дип яздым. Тәрҗемәче кыз моны итальянчага тәрҗемә итеп бирде.* Г.Ахунов. *Кунакка килгән итальяннар бер авыз русча, без бер авыз итальянча белмибез, шуңа карамастан бер-беребезне аңлыйбыз.* М.Юныс. *Джованни Скиапарелли аларны итальянча «табигый үзән» булган «канали» исеме белән атый.* Кызыклар дөньясында. *Баллада итальянча «бию» дигән мәгънәне аңлата.* Әдәбият

**2.** *с. мәгъ.* Итальян телендәге, итальян телендә булган, итальян телендә язылган. *Китапханәдә итальянча китаплар бик аз*

**ИТӘК** *и.* **1.** 1) Күлмәк, алъяпкыч, плащ, пальто һ.б.ш.ларның билдән түбәнге өлеше, чабу. *[Таштимерованың] Плащ итәге тырпаеп күтәрелгән, астан сызылып ап-ак челтәр күренә. Эчке күлмәк итәге.* М.Маликова. *Мәрзия әби --- алъяпкыч итәге белән битен каплап, үксеп елап җибәрде.* Ә.Сафиуллин. *[Канкаевның] Пинжәк итәкләре җилфер-җилфер килә ---.* Р.Мөхәммәдиев

2) *диал.* Юбка. *Диванга утыргач, [Сиринәнең] болай да кыска итәге тагын да өскәрәк күтәрелде.* З.Хөснияр. *Кыш, әче салкын, ә мин нибары кофта*

*белән итәктән генә, җитмәсә, нинди-дән дип уйлыйсыз?* Р.Вәлиев. *Аягын аяк өстенә атландырып, итәкләрен тарт-калап куйды ул [Асия].* Р.Мөхәммәдиев

3) Кеше киеменең алгы аскы өлеше. *--- [Хәйбүш] кулын игътибарсыз гына сузып, әлеге теге учы тулы акчаны янында басып торучы ачык авызлы малайның итәгенә койды.* Ф.Хөсни. *– Андый кыярлар тәмле булмый ул, – диде, минем итәгемнән коелып, җир-дә яткан эре сары кыярларга төртеп күрсәтте.* М.Әмир. *Теге кеше, алтын-нарны итәгенә җыеп алган да иртә-гәсен үк баеп киткән, имеш.* И.Гази

4) Кешенең тез өсте, ал. *Бала кинәт йөзе белән минем итәгемә капланды ---.* Ф.Хөсни. *Лидка, Настёнаның итәген-дә утырган килеш, аңа сыенып җы-лынып, йокыга оеп китте.* В.Распутин

5) *күч.* Нинди дә булса биеклекнең сөзәкләнеп, җәелеп киткән иң аскы өлеше, чите. *Җир дә ак, итәкләрен җәеп утырган чыршылар да ак, без килеп туктаган алан өсте дә ап-ак.* Л.Ихсанова. *Онытылган исемнәрнең эзе кайда калган? Тау итәгеннән ти-беп чыккан чишмәләр дә, --- бу хакта эндәшми.* С.Зыялы. *Тастымалны алып, пөхтә генә дүрткә бөкләде Сания апа һәм аны бакыр җәймә өстендә түбәй-тәләрен биетеп кайнап утырган сама-выр итәгенә куйды.* Р.Мөхәммәдиев

6) *күч.* Урман, болын һ.б.ш.ларның кырые, офык чите. *Урман итәгендә зәңгәр томан, Яңрый монда күке та-вышы.* Ф.Кәрим. *Ә аннан соң Гөлләр үскән җиргә – Урман итәгенә китәбез.* Ш.Маннур. *Еракта, немецлар тылын-да, нәрсәдер яна булса кирәк: күк итәге кып-кызыл.* И.Гази

7) *күч.* Диңгез, океан, елга яры. *Лена – матур елга, Боргаланып, Соры комга җәйгән итәген.* М.Җәлил. *Бер-ялгызым кызыл яр итәгенә барып утырдым.* Г.Сабитов

8) *күч. мыск.* Хатын-кыз турын-да. *Кызлар кайгысымы хәзер кешедә? Теләсәң, монда андый итәкләрне дис-тәләгәнне табарга була.* Я.Зәнкиев. *Кирәкми Исмәгыйль миңа. Йөзенә дә карый алмыйм! Ябышмаган итәге юк, диләр.* Ә.Сафиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Итәкнең алгы өлеше кадәр (халык телендә үлчәү берәмлеге булып йөри)

◊ **Итәге бөтен, җиңе киң** Дәүләтле, хәлле, иркен, мул тормышлы кеше ту-рында. **Итәге касмаклы** *сөйл.* 1) Яман, әшәке; гаебе зур; 2) Бәйләнчек. *Улым, чынлап әйтәм, каенанаң тирәсендә күп чуалма син. Итәкләре касмаклы халык бит алар.* К.Нәҗми. **Итәгенә ут кабу** Авыр, мәшәкатьле эш, хәл ал-дында калу; һәлакәт купкан кебек йөгерү. *Итәгенә ут капса да кабалан-мый торган хатынның йөрүенә хәтле үзенә бертөрле ---.* Л.Ихсанова. *Ә өй хуҗасы Сөббух, киресенчә, [ирләрне] йөгәнләп-авызлыклап тора: – Итә-гегезгә ут капмаган лабаса, салмаграк маташыгыз ---.* Ф.Баттал. *Кабаланып кына рәтле эш майтарып булмый. Итәккә ут капмаган лабаса, район больницасы бар бит.* М.Маликова. **Итәгеннән җиңе мул (озын)** Чыгымы килереннән артык яки кеременнән чы-гымы күбрәк. **Итәк асты** Яшерен. *[Хәйдәр] Атнасына бер көн авылда булмый, Ясәвиләр белән итәк асты сәүдәсенә йөри.* Т.Гыйззәт. **Итәк асты-на елышу** Яшеренү. *--- Варсанофий атакай монда: кайсыдыр ярыкка кереп поскан. Әле Мусин да аның итәге астына елышкандыр.* З.Фәтхетдинов. **Итәк астына учак ягып, коймак пе-шерү** Алдалау, ялганлау. *Итәк астына учак ягып, коймак пешерә икән бу сер-дәш. Ерткычны күралмыйм, диюләре – чеп-чи ялган!* Н.Гыйматдинова. **Итәк астында балта йөртү** *к.* **итәк астын-нан үрт (ут) йөртү**. *Син нәрсә, Сәрвәр килен, бер читтә генә торасың әле, якынрак кил. Гомер буе итәк астында балта йөртәсең, телеңә төер чыккы-ры.* М.Галиев. **Итәк астында саклау** Яшерү, яшереп саклау. *Катынның яшергәне бар аның, дәҗҗал, итәк ас-тында саклый.* Н.Гыйматдинова. **Итәк астыннан** 1) Бик якыннан, бер-ике адым җирдәге. *Туган илнең өч солда-ты, --- немец часовоеның итәк астын-нан шуышып үтеп, чәнечкеле тимер чыбыклар пәрәвезе арасына кереп югалды.* Ф.Кәрим; 2) Яшерен рәвештә. *Итәк астыннан сата – урман сата.* К.Насыйри. *Кибетләр ябык, алу-сату юк, атнага бер килә торган базар да бик ярлы, агайлар азык-төлекне, ка-чып-посып, итәк астыннан гына сата-лар.* Ә.Еники. *--- Казанда бердәнбер «Яхонт» кибете ишеге төбендә әче таңнан чират. Анда итәк астыннан сатучылар очрый, ләкин алар милиция-дән куркып сак эш итә.* Н.Гыйматди-нова. **Итәк астыннан үрт (ут) йөртү (уйнату)** Астыртын коткы, интрига кору. *Ул арада Рәхимҗан абый теге-[ләрнең] --- картлар аша итәк астын-нан ут йөртүләре, --- төрле уйдырма-лар таратып, --- йөрүләре турында сөйли иде.* М.Хәсәнов. *– Беләм мин син мыштыкыйны! Астыртын гына итәк астыннан ут уйнатканыңны! Кая йөрдең? Дөресен әйт! – диде Мөслимә.* Н.Әхмәдиев. *Әхтәмҗан --- әйтә куй-ды: – Итәк астыннан ут уйнаталар, иптәш Гайсин.* Б.Камалов. **Итәк ас-тыннан үрт (ут) йөртүче (уйнатучы)** Астыртын эш итүче, коткы таратучы кеше. *– Ташлы Тауда обстановка кат-лаулы. Бу егет үз урынында бик ки-рәк, – дип җибәрде райком секретаре. Итәк астыннан ут йөртүчеләр шун-нан файдаланырга тырыштылар.* Л.Ихсанова. *Итәк астыннан ут йөр-түчеләр азмы? Уларының бер-берсенә шикле караш ташлаулары да атаның күз угыннан читтә калмый иде.* Р.Зәй-дулла. **Итәк астыннан эш итүче** *к.* **итәк астыннан үрт (ут) йөртүче (уйнатучы)**. *Бөек Утыз Имәнинең ши-гырьләре бүгенге көндә дә итәк астын-нан эш итүче мәкерле җаннарның – гайбәтчеләрнең – чын йөзен ачып би-рергә ярдәм итә ---.* Мирас. **Итәк белән җитәк** Һәрвакыт бер-берсенә тагылып, җитәкләшеп йөрүчеләр, бер-берсеннән беркайда да аерылмый тор-ган кешеләр турында. *Һаман бергә, итәк белән җитәк, Кушмый бит болай йөрергә китап.* К.Әмири. **Итәк иләп йөрү** Шөгыльсез, эшсез йөрү. *Коры-тай Хафиз кайтып керүгә, бөтен дөнья берьюлы хәрәкәткә килә. Моңа кадәр итәк иләп йөргән хезмәтчеләр, тиз ара үзләренә шөгыль табып, җан-фәрманга эшкә тотыналар.* Ф.Яхин. **Итәк касмагы** *тирг.* Бәйләнчек кешегә

карата әйтелә. *Тәмам итәк касмагы булдың син, Минһаҗ агай!* К.Тинчурин. **Итәккә бастырмау** 1) Сер бирмәү. *Мина нәкъ алар җыелышып утырган урынга төшеп ярылды. --- Ләкин сугышта очкан ядрәне күзләре белән күрергә өйрәнгән егетләр итәкләренә бастырмадылар.* Ф.Кәрим; 2) Артыннан кеше җиткермәү, эштә, ярышта куып җитәргә, үзеннән алга чыгарга мөмкинлек бирмәү. **Итәккә басу** 1) Берәр нәрсәнең килеп җитүе, тыгызлавы. *Өйдә утырырга картайгач та җитешерсең әле. Андый заманнар да итәккә килеп баса ул бер.* С.Рафиков; 2) Ярышта куып җитү, узарга тору; 3) Кемне дә булса гаепле эш өстендә тоту. **Итәккә салып кайту** Никахсыз бала табу. *– Мин белмәдем. Баласы, дисез? Атасы юкмыни соң? – Булгандыр инде, «җилдән» дигәч тә... Итәгенә салып апкайтты шул, бик итагатьле, оялчан гына кыз ие юкса.* Р.Мулланурова. *– Флора – минем кызым ич ул... Кызым... – Перинов күзендәге яшьне сөрткәләп алды. – Үскән саен күбрәк мәшәкать ясады. Итәгенә салып кайтса, бәлки, әйбәтрәк булыр иде.* З.Фәтхетдинов. **Итәккә тагылу** (**ябышып йөрү**) *шелт.* 1) Берәр кеше артыннан калмыйча гел ияреп йөрү. --- *эшләүче – бер үзем. Хатын бик эшләр иде дә, мөмкинлеге юк. Итәгенә берсеннән-берсе кече ике бала ябышкан.* М.Хәсәнов. *[Әлфис] Әнисенә караганда, күбрәк сигез яшьлек апасы Миләүшә итәгенә тагылып, тәтелдәп йөрүче шук малай.* Р.Ишморат. *«Хатын», дигәч тә, аның итәгенә тагылып йөрү мәҗбүри түгел лә.* Н.Әхмәдиев; 2) Мөстәкыйль рәвештә эш яисә тормыш итә алмыйча, өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк кешеләргә салыну. *[Рәимә] --- район больницасында эшләүче Ниса исемле бер танышының итәгенә тагылып, Казанга китеп барды.* М.Хәсәнов; 3) Хатын-кызлар белән мавыгу, хатын-кызлар артыннан күп йөрү (ирләр турында). --- *Әйе, сез [хатыннар] тыштан ялтыраучы артыннан һәр мизгелдә китәргә әзер. Ирләр турында сүз барса, моны «һәр итәккә тагылу» диләр.* М.Хуҗин. --- *ир, гомер буе ресторанда эшләп, шомарып, баеп беткән бер хатынның итәгенә тагылып, --- күчеп китте.* М.Маликов. **Итәккә ут кабу** Эшнең кызу чагы, тыгыз чагы. *Акыл сата, теоретик бәхәсләр корып утыра торган замана түгел. Итәккә ут капкан: әнә Колчак Камага якынлашып килә.* Р.Мөхәммәдиев. *Кабаланып кына рәтле эш майтарып булмый. Итәккә ут капмаган лабаса, район больницасы бар бит.* М.Маликова. **Итәк кисеп җиң ялгау** (**ямау**) 1) Икенче бер кирәкле як, кирәкле әйбергә зарар китерү бәрабәренә берәр төрле эш башкару. *Яшерен-батырын түгел, --- еллык йомгакны түгәрәк итеп күрсәтер өчен, итәк кисеп җиң ялгаган чаклар да булмады түгел.* Ф.Хөсни. *Болыны булган авыллар печәнлекләрен бозып чәчтеләр. Бу инде – итәкне кисеп, җиң ялгау.* Х.Камалов. *– Итәк кисеп җиң ямауны ташлагыз әле, егетләр, колхоз төзүне контр тотудан җиңел дип беләсезме әллә, – дип, райком секретаре тегe кешегә бәйләнүчеләрнең үзләрен шелтәләде.* Л.Ихсанова; 2) Җитмәгәнне тартып-сузып җиткерергә тырышу. **Итәк колы** Хатын-кызларны яратучы; хатын-кызлар белән чуалырга яратучы (ирләргә карата әйтелә). *Гарьләнгән Мирсәлим: «Ул йөз хатын белән чуалган итәк колын сайлаган икән, мин дә аңардан калышмыйм, йөз ир белән йоклаган җилбәзәк Гөлсемне ярәшәм!» – дигән, имеш.* Н.Гыйматдинова. *Элекке мөхәррир итәк колы иде. Сәлимә белән чуалдылар да, абзагыз моны хатлар бүлегенә тыкты.* Н.Гыйматдинова. **Итәк кыска** Мөмкинлек, хәл, җай чамалы булу турында. *– Үткән ел, техниклар китертеп, смета да төзетеп карадык, Нурулла абзый, ә? – Әлеге дә баягы, итәк кыскарак.* Т.Гыйззәт. **Итәкне җыештыру** (**җыйнау, җыю**) *сөйл.* 1) Сак, уяу булу, саклык белән эш итү. *Ирләр алар ни кыланмас, хатын-кыз үзе итәген җыя белергә тиеш.* Г.Әпсәләмов. *Әхтәмов, моның сәбәбен яхшы белгәнгә, аны кырт кисеп туктатты: – Юк нәрсә белән булышма. Итәгеңне җыеп йөр, – диде ул Самойловка.* Р.Кәрами. *– Йөкле мин, әни... – Әй кызым, кызым! – диде Гөлсем, кисәк кенә карлыгып калган тавыш белән әкрен генә, --- итәгеңне җыеп йөр, дип әйтә килдем лабаса мин сиңа!* Ә.Сафиуллин; 2) Гаепле эшне, эшләгән җинаятьне яшерү, сиздермәү. *– Микрорайонны ансамбль буларак та тәнкыйтьләгәннәр булса кирәк. Художество ягын, диюем... Шәхси тормышыңны да искә алганнар. Итәгеңне җыебрак йөр, – [диде Шәфикъ абзый].* М.Маликова. **Итәктән тарту** Ниндидер сәбәпләр аркасында берәр эштән тыелып калу, нәрсә булса да эшләргә кыюлык җитмәү. *Әнвәрнең комсомолга керәсе килә иде. Әмма, тегe – әсирлектә булуын искә алырлар дип шүрли ул. Шул гел итәгеннән тарта.* Х.Камалов. *Тагын әлеге киңәш итәктән тартты, киресенчә эшләргә кушты ---.* Ф.Баттал. **Итәктән тоту** *к.* **итәктән тарту**. *Шулай бер көнне секретарь Диләрә Сәмитованы --- чакырып, авылларда, башлангыч оешмаларда ешрак булырга киңәш итте. – Транспорт итәктән тота, – диде кыз.* Г.Гомәр. *Лениза үзенең элемтәләрен эшкә җиксә, --- мине бер матавыксыз [Әлмәткә] күчерерләр иде. Юк, бер дә борчылмыйлар. Нәрсәдер итәктән тота шикелле.* Х.Камалов. **Итәктән төшү** Үсеп җитеп, мөстәкыйль яши алырлык булу (балалар турында). *Моңарчы күңел җылысын улына биреп килгән Фәйрүзәнең улы итәктән төшеп шау-шулы урам дөньясына чумгач, күңел ялгызлыгы үзәкләрне өзеп өскә калкып чыкты.* Г.Ахунов. **Итәк тулы** Бик күп (балалары булу турында әйтелә). *Киленчәкнең әле итәк тулы бала-чага сибелмәгән ---.* Р.Кәрами. *Әле ярый, итәк тулы бала-чага өелеп калмады, дип куанып йөрисе урында ---.* Г.Бәширов. **Итәк тутырып** Күп итеп (бала табу турында). *Бикә кәзинәккә арба тутырып бирнәсен бирде, бәхет-тәүфыйк теләде, итәк тутырып бала табарга юрады.* М.Хәбибуллин

**ИТӘ́К АСТАРЫ** *и. диал.* Кием итәгенең эчке ягына тегелгән тукыма; инеч

**ИТӘК-ҖИҢ** *җый. и.* Киемнең киңәеп торган төрле өлешләре

◊ **Итәк-җиң бөтәйтү** Кием яңарту, кием юнәтү. **Итәк-җиңне җыю (җы-**

**ештыру, җыйнау**) Саклык чараларын күрү, теләсә нинди көтелмәгән хәлгә әзер булып тору. *Дөрес, Чекушкин аша имеш-мимеш таратуның куркыныч ягы да бар иде. Тегеләрне өркетеп, алдан ук итәк-җиңнәрен җыярга ярдәм итүе дә ихтимал бит.* М.Насыйбуллин. *Ала-ай, менә нимәгә куйганнар икән аны ЧЕКАга! Итәк-җиңне безгә икеләтә җыеп йөрү кирәк ләбаса.* Т.Әйди. *--- яшь бай --- НЭПның вакытлы чара икәнлеген, --- чамалый булыр. Шуннан чыгып, нишләр дип беләсең аны? Әлбәттә, итәк-җиңне җыю, малны червонецларга әйләндерү ягын карар.* Ф.Хөсни. **Итәк-җиңне йомарлау** *к.* **итәк-җиңне җыю (җыештыру, җыйнау)**. *Әмма шундый пәри туе кузгалганда, итәгеңне-җиңеңне йомарлап бер читтә посып калырга мөмкинме соң?* Ф.Хөсни. **Итәк-җиң тулу** Әйбер күп булу

**ИТӘКЛӘНҮ** *ф.* Тау, кыяның түбәнге өлеше тигез җиргә таба сөзәкләнү. *Тау итәкләнгән җирендә Күренә тынган бер авыл.* Н.Исәнбәт. *Кичкә таба, --- тау башына чыксаң, дөнья тагы киңәя, артта итәкләнеп-итәкләнеп, берсе өстенә берсе менеп, берсе янына берсе үсеп, түгәрәк озынча таулар менеп киткәннәр.* Г.Исхакый

**ИТӘКЛӘП** *рәв.* 1) Тау, елга, урман, болын итәге буйлап, кырыйлатып. *Таулар итәкләп, Ярларың буйлап, Ярларың буйлап, Мин чабам һаман Күп уйлар уйлап, Күп уйлар уйлап.* Ш.Маннур

2) Итәкле итеп; итәген тоташтырып, беркетеп. *Аклы ситсы күлмәгемне Үзем тектем итәкләп.* Җыр

**ИТӘКЛЕК** *и.* **1**. Итәк тегү өчен тукыма, итәк тегәргә яраклы (билгеләнгән) тукыма. *Универмагта итәклек саталар*

**2.** *с. мәгъ.* Итәк тегү өчен җитәрлек, итәк тегәргә билгеләнгән. *Итәклек тукыма сатып алу. Итәклек ефәкне тегүчегә илтү*

**ИТӘ́К САЛУ** *ф. к.* **итәк тоту**. *Гайниҗамал киң генә итәк салып тегелгән йон күлмәген киде.* Ф.Әмирхан

**ИТӘ́К ТОТУ** *ф.* 1) Күлмәкнең түбәнге өлешенә бериш яки башка тукымадан бала итәк тегү

2) *күч.* Ялагайлану, ярарга тырышу

**ИТӘК-ЧАБУ** *җый. и. к.* **итәк-җиң**

◊ **Итәк-чабуны җыю (җыештыру, җыйнау)** 1) *к.* **итәкне җыештыру (җыйнау, җыю)**. *Борһан --- әйтә салды: «Кара аны, балдызкай! Син анда итәк-чабуыңны җыебрак йөре. Сак бул».* М.Хәсәнов. *Усал гына түгел, хәйләкәр дә идем мин. Йөргән җиремдә итәк-чабуымны җыеп, эземне адаштырып йөрдем.* М.Кәрим; 2) Тәмамланмаган, эшләми калган эшләрне тәмамлау, эшләп бетерү. *– Йөгермәгез, берни эшләмәгез, ял итегез, итәк-чабуыгызны җыештырыгыз, ичмасам, – [диде Шаһмиран].* Г.Гомәр. *Чишмәбаш мөгаллиме --- Шәпкүлгә шушы арада тикшерүчеләр киләчәк, Морза дус алдын-артын шәйләп, итәк-чабуын җыеп куйсын, дигән.* Г.Мөхәммәтшин. **Итәк-чабуы киң** *Бу җинаятьнең итәк-чабулары без уйлаганнан киңрәк булырга охшый...* М.Насыйбуллин

**ИТӘ́К ЧАБУЫ** *и.* Итәк ачылмасы; *русчасы:* **пола**, **фалда**. *Итәк чабуына тагылып барган карашны тоймый калалармы соң!..* Р.Мөхәммәдиев

**ИТЕК** *и.* 1) Озын кунычы күннән, кирзадан, брезенттан тегелгән, каты табанлы аяк киеме. *Кулына щётка тоткан Саттар тышта итек тазартты ---.* А.Таһиров. *[Булатовның] Ишектән керер-кермәс беренче соравы шул булды: – Нәрсә, Галиулла, баттыңмыни? – Булды ла шул, кадалгыры, – диде Галиулла, резин итеген сала-сала.* А.Алиш. *Агай бер ялтырап торган паркет идәнгә, бер аяк очына карап алды да, иелеп, күн итекләрен сала башлады.* М.Галиев // Күннән тегелгән йомшак аяк киеме, күн итек (борынгы болгарларда)

2) Озын кунычлы, йомшак табанлы, мех эчле күн аяк киеме. *Өстендәге киеменә, аягындагы мех итегенә карaганда, очучы булырга тиеш иде ул.* А.Шамов

3) Йоннан басылган, балтырлы киез аяк киеме. *Ахырда түзмәдем: бер тәнәфес вакытында ул дөмеккере туфлиләрне укытучылар бүлмәсендә салып калдырып, киез итектән йөри башладым ---.* Ф.Хөсни. *Зират капкасы төбендә, хатын-кыз арасында, итек кунычыннан карга баткан хәлдә, ана басып калды.* М.Маликова. *Быел киез итек тә күп булыр, кыска тун да җитәрлек булыр, колакчыны да, башкасы да – бөтенесе булыр, боерган булса.* Г.Бәширов

◊ **Итеген (итек табанын) ялау (үбү)** Үз максатына ирешү өчен, түрәләргә ярамсаклану, аларга түбәнсенеп баш ору; лакейлык, әләк белән көн күрү. *Ул шул максатларына ирешү өчен, теләсә нинди әшәкелеккә барыр, теләсә кемнең итеген ялар.* Ә.Еники. **Итек астында (булу, яшәү)** Кемнең дә булса хакимлеге астында булу, кемгәдер тулысынча буйсынып яшәргә дучар ителү. *Искәндәр, сөйгән Ленинградын, Мәрьяме белән Маратын Гитлер итек астында күз алдына китереп, йөрәге әрнүенә түзә алмыйча, күзләрен йомды.* Г.Гобәй. *Мөхәммәт, аның сүзләрен куәтләгәндәй: – Урыс итеге һәм марҗа итәге астында яшәгән милләт без, – дип кенә куйды ---.* З.Хөснияр. *Фашист ерткычлар итеге астында чыдап яшәр дип уйлыйсыңмы син әллә халыкны?* М.Маликова. **Итек табанына тормау** Берәр кешедән дәрәҗәсе, абруе түбән булу турында. *Насыйров Сәидәне дә тикмәгә күтәрми, шул кисәү агачы белән абруегызны төшермәкче... Югыйсә, ул сезнең итек табаныгызга да тормый!..* А.Каһһар. **Итек туздыру** Файдасызга, бушка йөрү. *Ике ел армиядә итек туздырдым.* З.Фәтхетдинов

**ИТЕ́К БАСУ** *ф.* Йоннан киез аяк киеме ясау. *Кыш буе ирләре итек басуда, хатыннары шәл бәйләп саталар ---.* М.Мәһдиев. *Ә кышларын, бабай, авылдан авылга йөреп, итек баса.* Н.Гыйматдинова. *Мин биргән кортлаган йоннан күпме кешегә итек басып биргәндер әле.* Ф.Яруллин

**ИТЕ́К БАСУЧЫ** *и. к.* **итекче** (*2 мәгъ*). *Юк, кызым, син теге итек басучыларны әйтәсең ---.* Ш.Камал

**ИТЕКЧЕ** *и.* 1) Аяк киемнәре тегүче яисә төзәтүче оста. *Мидхәтнең бабасы – итекче, атасы бер сәүдәгәрдә приказчик була.* Т.Әйди. *Юкка гына Хәкимҗанның әтисе узганда-барганда шушы нигездә утырган итекче Матвей йортына сугылмагандыр.* Н.Хәсәнов. *Фәйзинең әнисе үлгән, әтисе – күн итек, ботинка төзәтү буенча оста*

*(патша вакытында итекче булып хезмәт иткән)* ---. М.Мәһдиев

2) Киездән әвәләп аяк киеме басучы оста. *Итекчеләргә йон күтәреп илтә башлыйлар, төз лапаслар ясала, тәрәзәләр җылытыла.* М.Мәһдиев. *Ә итекче Шәйхулла – бөтенләй башка кеше. Мин аңа ничә тапкыр колхоз складыннан көя кисеп ята торган йоннарны биреп җибәрдем.* Ф.Яруллин

3) *күч. гади с.* Эш җаен белмәгән, белер-белмәс эшләгән кеше турында әйтелә. *Шулай итеп, мең еллык камиллеккә ирешкән, нәфислекнең иң биек ноктасына менгән телебезне итекчеләр теленә алыштырабызмыни?* А.Расих

**ИТЕКЧЕЛЕК** *и.* Итекче булу. *Базарда итекнең кыйммәте бик түбән төшеп, итекчелек һөнәре иң файдасыз һөнәрләрдән санала.* Г.Тукай

**ИТЕК-ЧИТЕК** *җый. и. сөйл.* Итекләр һәм читекләр (гомумән озын кунычлы аяк киемнәре). *XX йөз башында инде «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе берничә катлы өч таш корпусны, ашханә, --- итек-читек, кәвеш төзәтү --- остаханәләре һ.б.ны берләштергән зур бер комплекс тәшкил итә ---.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Җәй үтеп, җиргә салкыннар төшү белән, мондагы халык --- итек-читек каерга тотына.* К.Тимбикова. *Үзле балчык, аягыңа сылашып, итек-читекләреңне суырып алырга да күп сорамый.* Г.Әдһәмова

**ИТЕНЕШ** *и. диал.* Кыланыш, үзүзеңне тоту рәвеше. *Сакалны кырганда борыла-сырыла бөтәрләнеп йөргән парикмахерның итенешләре безгә бик ошады.* Һ.Такташ. *Кияү булып йөргән вакытындагы итенешләре күршеләре өчен айлар буенча рәхәтләнеп көлеп сөйләрлек вакыйга булып калды.* Һ.Такташ

◊ **Итенеше илгә сыймый** Артык кылану, чамадан тыш кыланчыклану

**ИТЕНМЕШ** *и. иск. к.* **итенеш**

◊ **Итенмеше илдән аерым** *к.* **итенеше илгә сыймый**. *Ашады бит колак итемне... Имеш, итенмешең илдән аерым... Гүргә саклыйсыңмыни хәерчелегеңне, ди.* Ф.Бурнаш

**ИТЕНЧӘК** *и. диал. к.* **итенчек**. *Ул үзе бик иркә дә бик иренчәк. Өстәвенә, бик үпкәчән дә бик итенчәк икән.* Н.Исәнбәт

**ИТЕНЧЕК** *с. диал.* Кыланчык, чытлык. *Итенчек кызчык*

**ИТЕНҮ** *ф. кайт. юн.* 1) *иск. к.* **итү** (ярдәмче фигыль функциясендә кулланыла). *Бәхетеннән исергән кеше сыман итенде бичара.* М.Хәсәнов. *Габделбасыйр да мәдрәсә капка төбенә әледән-әле чыгып, Рәүф байлар ягына каранып басып торуны гадәт итенде.* Ф.Әмирхан

2) Берәр эш-хәл башкарган булып күренү, кылану. *Марат, яралының бәләген тотып, пульсын санагандай итенде.* Г.Гобәй. *Шул чак Ногман урынсыз гаепләнүгә тарыган кеше сыман итенде, җене чыкты.* М.Хәсәнов

3) *диал.* Кылану; чытлыклану. *Кара син аларны, карт юләрләрне, тамаклары тугая башлаганга шулай итенәләр алар.* Ф.Бурнаш. *– Оял, абый, болай итенергә! – диде.* Ш.Камал

4) *диал.* Берәр нәрсә эшләмәкче булу, эшләргә омтылыш ясау. *– Үзеңә-үзең артык ышанмыйсыңмы, дустым, – диде хатын, елмаерга итенеп.* Р.Мөхәммәдиев. *Сабый, валчыкларны чүпләп бетергәч, әнисенең киезләнеп киткән чәчләре белән уйнагандай итенде.* Г.Гобәй. *Көндез үк бил, эч тирәләре авыртырга итенә башлаган иде ---.* А.Әхмәтгалиева

**ИТ-ЙОН** *җый. и.* Ит һәм йон. *Нәтиҗәдә ун ел эчендә ит-йон өчен үрчетелә торган нечкә йонлы яңа сарык токымы китереп чыгарылган.* Дарвинизм нигезләре

**ИТКЕЧ** *с. Итү* ярдәмче фигыленнән ясалып, кайбер исемнәрдән соң килеп, шулардан аңлашылган эшне үтәүче мәгънәсендә кулланыла. *Әсир иткеч гүзәллек*

**ИТЛӘНҮ** *ф.* Тәнгә ит куну; тулылану, симерү, тазару

**ИТЛӘҮ** *ф. махс.* Җепне материалның тышына чыгармыйча тегү. *Итек табанын итләү*

**ИТЛӘЧ** *с.* 1) Ите күп булган, итле. *Сәйрин казның итләч түшенә үткен пычак тыга.* М.Юныс

2) *сөйл.* Юан, таза, симез (кеше тәне, тәннең, битнең аерым өлешләре турында). *Гайса кечерәк кенә, ләкин итләч бармакларын миңа сузып исәнләште.* Ф.Әмирхан. *Әхмәтша бабай, --- кульяулыгы белән итләч муенын сөрткәләп, көлеп утырган сельпо председателен күреп алды.* Г.Шәрәфи. *Айдан артык ач йөрергә тәнендә май булган кеше булдыра ала торгандыр, яисә итләч кеше.* М.Юныс // Тыгыз, тулышып торган, таза. *[Елгада] Итләч --- балыклар тулып ята.* С.Рафиков

3) Калын йомшаклы (үсемлекләргә һәм җиләк-җимешләргә карата әйтелә). *Җимешләрнең итләч катлавы бик вак бөртекләрдән тора.* Кызыклар дөньясында. *Йөзьяшәр (алоэ) гөленең сусыл, итләч һәм кырыйлары чәнечкеле яфракларын фикусның киң, каты, калын кабыклы яфраклары белән чагыштырыгыз.* Биология

**ИТЛӘЧЛӘНҮ** *ф.* Калынаю, симерү, итләч булу. *[Миңнисаның] Кашы юк, тик урыны гына итләчләнеп кабарып тора.* М.Шабай

**ИТЛӘШКӘ** *с. сөйл. к.* **итләч** (*2 мәгъ.*)

**ИТЛЕ** *с.* 1) Ит белән пешерелгән, ит кушып әзерләнгән, составында ит булган. *Хәерниса итле токмач янына өстәлгә --- эремчек тә китереп куйды.* Р.Фәизов. *Кичен, Шакир абзый эштән кайтканда, өй ялт иткән, авыздан сулар китереп, итле аш исе аңкый иде.* М.Маликова // Ит салынган, ит булган. *Ихтыяр --- Нурисламга итле табакны китереп тоттырды ---.* Р.Вәлиев

2) Ите булган; симез, таза, көр. *--- [Сәрвәрнең] Чәче дулкынланып ялангач иңнәренә таралып төште. Тыгыз итле ябь-яшь беләкләр, эчке күлмәгенең челтәре астыннан тулы гына күкрәкләре тертәеп тора.* Ф.Хөсни

**ИТЛЕК** *и.* Ит өчен махсус суела торган йорт хайваны. *Ит йөкләмәсен бездән арттырып үтәү өчен, буаз таналарын, менә дигән савым сыерларын итлеккә илтте.* В.Нуруллин

**ИТЛЕ-ТӘНЛЕ** *с.* Симез, таза, көр

**ИТ-МАЙ** *җый. и.* Ит һәм май ризыклары. *Иткә-майга акча чыкмый диярлек.* М.Хәсәнов. *Кәшифә әбинең исе китте, суыткычлар ит-май, кыйммәтле балыклар, --- һәм эчемлекләр бе-*

*лән тулган иде.* З.Фәйзи. *Ит-май бирүләрен белгәч, Мәрьямбикә күккә сикерде ---.* А.Гыйләҗев

◊ **Ите-мае сиңа, сөяге-тиресе миңа** *тар. к.* **ите сезгә** (**сиңа**), **сөяге безгә** (**миңа**). *– Менә Мәхмүт, – диде тимерче, карлыккан тавыш белән, – өлкән улымны китердем; ите-мае сиңа, сөяге-тиресе миңа.* М.Кәрим. **Иттәмайда йөзү** Таза, мул, җитеш тормышта яшәү

**ИТСЕЛ** *с.* 1) Иткә охшаган, ит кебек

2) *к.* **итләч** (*3 мәгъ.*). *Беренче елда кәбестә үсемлекләре эре һәм итсел яфраклар таралгысы белән кыска гына сабак үстерәләр ---.* Яшелчәчелек

**ИТ-СӨТ** *җый. и.* Ит һәм сөт азыклары. *– Кеше җанын аңлыйсыңмы син? Әллә, ит-сөт һәм бүтәнне күбрәк булдыру өчен, мал-туарны кешедән алгарак чыгарасыңмы? – дип, --- куллары алга сузды Газизҗан.* М.Хуҗин. *[Дуся түтәй] Тимошаны иркәли, пенсия акчасына аның өчен ит-сөт сатып ала ---.* М.Маликова. *Кул бассейнында болыннар, көтүлекләр бик күп, монда күп тармаклы авыл хуҗалыгы да нык үскән. Бигрәк тә терлекчелек, ит-сөт җитештерү, сарык асрау алга киткән.* А.Муранов

**ИТ-СӨЯК** *җый. и.* 1) Ит һәм сөякләр

2) Гәүдә, буй-сын. *Зарифа бик начар күрә, ә Марат, сөйләшми торганда, Габелфаяз абыйсына охшаган, әмма ите-сөяге белән генә охшаган шул.* Р.Әбүбакирова

**ИТТАРТКЫЧ** *и.* Ит яки яшелчәне ваклап, тоташ бер массага әйләнгәнче тарттыра торган җайланма. *Шушы яшемә җитеп, иттарткычның ничек итеп итне туравын аңлап җиткерә алмыйм.* М.Маликова. *1 кг керән тамырын --- иттарткычтан чыгаралар. Өстенә 3 л кайнаган салкын су салалар ---.* Сәламәт булыйк! *2 пешкән чөгендер, --- 4 әстерхан чикләвеген иттарткыч аша чыгаралар ---.* Мәдәни җомга

**ИТТИФАК** *и. гар. иск. кит.* 1) Берлек, союз. *Менә шул залим адәмиләрнең кулыннан тәмам котылып, үз праваларымызны үз кулыбызга алып, моннан соң иркенчелектә, рәхәттә яшәр өчен, бер иттифак вә бер союз ясарга хаҗәт иде.* Ш.Мөхәммәдев. --- *Казанда Әстерхан ханнары нәселеннән килә торган ханнар була, һәм шул вакытта Казан белән Әстерхан иттифак ясый[лар] ---.* Г.Гобәйдуллин. *Әнә шундый сөйләшүләрдән соң, аның [Хәмит Ярми] янына әле берәм-берәм «дүртлек» иттифакы әгъзалары барып кайта ---.* М.Мәһдиев

2) Очраклылык, очраклы күренеш. *Соңгы вакытта --- «өсткә чыкканлар» дигән кебек татарча формаларны да --- очратырга мөмкин. Ләкин мондыйлар, күбесенчә, иттифак булып, --- элекке --- кебек үк төрекчәдер.* Җ.Вәлиди

3) *тар.* Татарстан милли азатлык хәрәкәте фиркасының исеме. *Хәзергә кадәр «Иттифак» сайлау вакытларында да бер генә төрле сәяси игътикатлы кешеләрне үз тарафыннан сайлату урынына, кайда нинди кешене сайлату мөмкин булса, шуны үз кандидаты санады.* Ф.Әмирхан

4) *күч.* Кем белән дә булса тулысынча килешеп, бер сүздә, бер киңәштә булу. *Арадан кайсылары, кыз илә әсир бер иттифакта булып качканнар, имеш, диләр иде.* Ш.Мөхәммәдев

**ИТТИФА́К ИТҮ** *ф. иск. кит.* Берләшү; бер фикердә булу. *Бәлки, буйлә мөкатдәс бер көндә бер-беребез илә күрешеп, мәхәббәт итешмәк, сөйләшеп бер фикер алмак, үзебездә булган кимчелекләрне тәфтим кылып, хәлебезне ислах кылырга юл эзләмәк, бер-беребез илә иттифак итмәк вә фикерләрне берләштермәк өчендер.* Ш.Мөхәммәдев

**ИТТИФАККА́ КИЛҮ** *ф. иск. кит.* Килешү; берләшү. *[Болар] Иттифакка килә алмый, үзара сугыша яздылар.* М.Гафури

**ИТТИФАКЛАШУ** *ф.* Берләшү, сүз беркетү, килешү. *Һич оеша алмыйлар, --- Галиулла коданың мәслихәт мәҗлесендә эш инде тәмам булып, иттифаклашырлар, диеп торганнар иде, каһәр суккан Галиәкбәр агай --- мәҗлескә килми калган.* Ш.Мөхәммәдев

**ИТТИФАКЛЫ** *с. иск. кит.* Бердәм, тату, берләшкән. *Бер тарафтан кемнеңдер рояльдә уйнаганы ишетелә вә шул ук вакытта ир вә кызлардан мөрәккән бер хор матур дәртле вә хәятлы бер көйне урта гына вә бик иттифаклы тавыш белән суза иде.* Ф.Әмирхан

**ИТТИФАКЧЫ** *и. тар.* Кайсы да булса бергәлекнең, союзның әгъзасы. --- *Россиядә әүвәлдәгечә боярлар хакимияте куелгач, боярлар үзләренең иттифакчылары --- татар морзаларына каршы хәрәкәт итә башладылар.* Г.Гобәйдуллин. *Аңа кадәрле иттифакчыларны сүгү гадәте кызыл яшьләр эчендә көчле иде.* Г.Ибраһимов

**ИТТИФАКЫЙ** *рәв. гар. иск. кит.* Очраклы рәвештә. *Безнең көйләребезнең, безнең музыкабызның андый булуы иттифакый гына вөҗүткә килгән бер эш түгел, аны тарих агымы тудырган ---.* Г.Ибраһимов. *Бу көнге көн кичәгегә, иртәге берсекөнгә охшаган тормышым иттифакый бер вакыйга берлән бераз үзгәрде.* Г.Исхакый. *Бер көнне шулай икенде намазына барышым, хикмәти хода, иттифакый рәвештә шушы тәрәзәгә күзем төшмәсме.* Т.Гыйззәт

**ИТТИФАКЫЙЛЫК** *и. иск. кит.* Очраклылык. *Тарихның тәҗрибәле каты кулы, бу эше, бу кануны белән мәсьәләләрне иттифакыйлыктан коткарып, аларга туры хөкем чыгара.* К.Тинчурин

**И́ТТРИЙ** *и. гр. хим.* Сирәк очрый торган йомшак көксел металл (атом техникасында һәм авиациядә, металл легирлауда, радиотехникада кулланыла)

**ИТТУРАГЫЧ** *и. к.* **иттарткыч**. *Камырны иттурагычтан чыгарып печенье пешерә беләсез бит.* Э.Шәрифуллина. *Хәзерге сугышта дәһшәтле машиналар адәм балаларының гомерләрен иттурагыч шикелле туктаусыз «эшкәртеп» торалар.* М.Юныс. *Ул егетләрнең барысы да сугыш иттурагычында беттеләр, теге борнай кызлар тол калдылар.* М.Мәһдиев

**ИТҮ** *ф.* **1.** 1) *сөйл.* Нәрсә булса да эшләү, нинди дә булса эш башкару, үтәү. --- *Шәяхмәт энесенең каршысына басты: – Сиңа госпитальдә эш тәкъдим иттеләрме? – Иттеләр.*

Г.Ахунов. – *Иптәш секретарь, – диде ул, --- Борын асты кипмәгән ниндидер мальчишканы тиргәгәндәй итеп, бетереп ташламасагыз да ярый иде бит. --- Варис көлде. – Ярар, Иван Нилович. Бүтән алай итмәбез.* М.Хәсәнов. *--- бүген кызыннан ишеткән хәбәре бигрәк тә үкенечле иде, чөнки «Ит изгелек, көт явызлык» дигән мәкальдәгечә килеп чыкты.* Ә.Сафиуллин

2) *диал.* Берәр нәрсә эшләмәкче булу, берәр нәрсә эшләргә уйлау, теләү, ниятләү. *Сиринә Самуиловнага кушылып көләсе дә иттем.* З.Хөснияр. *Карчык, хәлсез генә кузгалып, һавага чыгып керде, битен-кулын юган итте.* Казан утлары

3) Нәрсә дә булса эшләгән булып кылану. – *Кадрлар әрәм була, – дип күрсенгәндәй итте Ихтыяр.* Р.Вәлиев. *Хан кызы Назлыгөл сискәнеп китте, --- ирен чите белән генә елмайгандай итте ---.* М.Хәбибуллин

4) *эвф. сөйл.* Табигый йомышны үтәү. – *Тышка чыгып йөрмә, балам, --- менә бәләкәй ләгәнгә генә утыр шунда. – Минем алай өйдә иткәнем юк шул, тышка чыгамын мин.* Әкият

5) *диал. к.* **илтү**. *[Мин] Фәрхи җиңгиләргә әйбер итергә чыктым...* Г.Ибраһимов

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Исемнәрдән, хәбәрлекләрдән соң килеп, шул исемнәр белән бәйләнешле эш-хәрәкәтне башкаруны, үтәүне белдерә. *[Халидә] Күңелендә төен булып кына калырга тиешлесен дә ычкындырды: – Минем туемны итәргә бераз соңгарак калдың, әни.* Ф.Хөсни

2) Исем, хәбәрлекләр, сыйфат һәм рәвештән соң килгәндә, берәр хәлгә китерү, бер рәвешкә кертү, әверелдерүне белдерә. *Ике бүлмәле шәһәр фатирында урегеннән мәхрүм ителеп читлеккә ябылган кошчык сыман хис итәргә керешә үзен [Асия].* Р.Мөхәммәдиев. *[Мәдинә]--- әйткән аннары: – Шулай килешсәк, Хәтирәне сөтсез итмәбез, шәт.* Ф.Хөсни

3) Аваз ияртемнәреннән соң килеп, алар белдергән эш-хәрәкәтне аңлата. *Карбид лампасының яктылыгы астында казылмаларның стеналарындагы таш токымнары җем-җем итеп уйнап, ялтырап торалар ---.* Ә.Айдар. *Кызның --- ялтыр-йолтыр килеп торган муенсалары әллә кайдан күзгә ташланып, елык-елык итеп куйгалыйлар...* М.Хәсәнов. *Чапан яңа, көмеш һәм алтын җепләр катыштырып тукылганнамы, җем-җем итә.* М.Хәбибуллин

4) Теге яки бу кешене берәр эшкә урнаштыру, билгеләү; аңа бер вазифа, хезмәт йөкләү. *Ә аның [Мәсрүрә түтинең] исәбе бик кыска һәм бик тә аңлаешлы иде: --- балаларын укытып, инженермы, укытучымы итмәкче ---.* Ф.Хөсни. *Хан үз халкына ышанмый башлады: сарайны читтән яллаган баһадирлардан саклата, килмешәкләрне куштан итә.* М.Хәбибуллин. *Шәвәлиев Сабитовны --- редактор итүдән курка да иде.* Ф.Садриев

5) Исемнәрдән аңлашылган караштa, фикердә, мөнәсәбәттә булуны аңлата. *Бик яхшы, каената итеп килгәнсең икән.* Әкият

**ИТ ЧАПКЫЧЫ** *и.* Итне, яшелчәләрне чапкалап, ваклап турау өчен кулланыла торган озын саплы ярымай яки башка рәвештәге пычак, чапкы. *Симез сыер итен --- ит чапкычы белән чабарга да мөмкин.* Ю.Әхмәтҗанов

**ИТЧӘ** *рәв.* Ит килеш. *Тик торганда, танадай тәкәне егып суюы әллә ничек бит ---. Тиресен тиречә, итен итчә өләшеп бетер, имеш.* Г.Сабитов

**ИТЧЕ** *и.* 1) Ит белән сату итүче кеше. *Акча чыгармасагыз, бер тиенлек тә әйбер бирмибез, дип әйтәләр, ди, итче дә бүген ит бирмичә керткән.* Г.Камал. *Шуннан соң моның хатыны иртәгәсен торган да, күрше авылдагы итчегә барып, бер җамаяк үгез каны алып кайткан.* Т.Гыйззәт. – *Хәзер фатирны саттырмакчы да акчасына Израилендә ит кибете ачмакчы. – Ит кибете? Ул итчемени?* М.Маликова

2) Базарда, кибеттә ит чабып торучы кеше. --- *кибеткә халык тулды. Итчеләр, лимончылар, толчокчылар, йорт-җир сату һәм алу эшендә маклер булып йөрүчеләр – барысы да килде.* С.Җәлал. *Бу – итче Гали абзый йорты. Тук йорт, һәрвакыт итле бәлеш исе килеп торган йорт.* Ә.Еники. *Һәркайсы үз эше белән мәшгуль: итче ит чаба, экспедитор, машина янына басып, йөкчеләр эшен күзәтә.* З.Фәйзи

**ИТЧЕЛ** *с. к.* **итләч**. *Йомырка бирә торган тавыклар да күп төрле. Алар итчел түгел, аның каравы елга 200–300 йомырка салалар.* Ф.Ибраһимова. *Итчел яфрак*

**ИТЧЕЛЕК** *и. сир.* Терлекчелекнең ит җитештерү белән шөгыльләнүче өлкәсе. *Итчелекне күтәрү буенча да шундый бер шаукым булмадымыни: утызынчы елларда ук инде акыллы башлар ит мәсьәләсен хәл итүне куян асраучылыкка кайтарып калдырмадылармыни?* М.Мәһдиев

**ЙТ ШЕШЛӘҮ** *ф. диал.* Тозлап киптерелгән итне утта кыздыру

**ИФАДӘ** *и. гар. иск. кит.* 1) Аңлату, аңлатып бирү, хәбәр итү; сөйләп аңлату; аңлатма. *Сүз һәрникадәр күңелдә булган мәкъсудны ифадә кылмакта васыйта булса да, күзнең ифадәсе кадәр юктыр.* К.Насыйри. *Габдулла әфәнде хәзер үз хиссиятен әүвәлгедән артык тулырак, киңрәк һәм ачыграк әйтеп җиткерә ала; һәм мондагы тәгъбирләр, ифадәләр шигъри вә җанлылар.* Мирас

2) Уй-фикерне, төшенчәне һ.б.ш.-ларны сүз яки форма ярдәмендә белдерү; аңлату; тәгъбирләү. *Шиһаб хәзрәтнең татарча тарыз тәхрире вә өслүп ифадәсе бу көндә һичкем тарафыннан ияреләчәк бернәрсә түгелдер.* Г.Тукай

3) Нинди дә булса мәгънә яки фикер белдергән сүз тезмәсе, сүз әйләнмәсе, әйләнмә. *Бу пәрдәдә Габдулланың мөгаллимәгә каршы сөйләгән җөмләләре арасында безнең өчен шактый гарип ифадә вә кәлимәләр бар.* Г.Кәрам. *Шуның белән бергә авылда булмаган, татарның зыялы катлавы, аның да тынычсыз күңелле төркемнәре арасында гына табыла торган сүз һәм ифадәләр дә бар.* Г.Нигъмәти

**ИФАДӘ ИТҮ** *ф.* 1) Аңлату, сөйләп аңлату. *[Мин ризасызлыгымны] Ифадә итмеш идем.* Г.Тукай

2) Тәгъбир итү. *Әгәр дә без шул ук утыручы мәфһүмен «утырган кеше» дигән тәгъбир белән ифадә итсәк, монда инде «утырган» белән «кеше»нең*

*һәр икесе ике мөстәкыйль бер мәгънәгә малик булганлыклары күренәдер.* Җ.Вәлиди

3) Күрсәтү. *Тел, бердән, күңел тойгыларын тышка чыгарырга тиеш булса, икенче яктан, гакылдан туган гыйлем һәм фәнне ифадә итәргә тиеш.* Җ.Вәлиди

**ИФРАТ** *рәв. гар. кит.* Чамадан тыш, чиктән тыш, кирәгеннән артык, чамасыз, үлчәүсез; гаять, үтә, бик. *Сезнең авылга төшкәндә, пар нарат тирәсеннән ачылган бай күренеш миңа ифрат соклангыч кебек күренде.* Г.Бәширов. *Хәзер менә елмаеп, шат кыяфәт белән әнисен алдавы ифрат авыр Ләйләгә.* М.Маликова. *Бер уйлаганда гади генә күренгән бу күзәтүдә ифрат зур тапкырлык ята.* А.Гыйләҗев

**ИФРА́Т ИТҮ** *ф. иск. кит.* Чамадан, чиктән ашу. *Кычкырырга, тавышын мәдрәсәгә ишеттерергә юл бармы, булса җитте. Болар бит аның моназыйрлыкта ифрат итүен генә күрсәтә.* Г.Ибраһимов

**ИФРАТЛЫК** *и. кит.* Чамадан тыш булу, кирәгеннән артык булу, гаять күп булу. *Ул бит үзе дә һәр тугрыда ифратлыкны эзли.* Г.Ибраһимов

**ИФРАТЧЫ** *и. кит.* Радикализм, кискенлек тарафдары, экстремист

**ИФРАТЧЫЛЫК** *и. кит.* Радикализм; экстремизм

**ИФТАР** *и. гар. дини* 1) Ураза көнне тәмамлап авыз ачу (ризык кабул итү). *Ифтар вакытларында мәчеттә җимеш тотмыйсың.* Т.Гыйззәт

2) Рамазан аенда ураза тотучы мөселманнарны ашка чакырып, бергәләп авыз ачу йоласы; авыз ачу мәҗлесе. *Элек тәравихларда Коръән хәтем итә башлагач, «карый» дип, аны авыз ачарга – ифтарга чакыралар, сәдакалар бирә торганнар иде.* Г.Ибраһимов. *Хөснулланың ифтар мәҗлесе, Садыйк хаҗинең тәкъдиме буенча, бик тар итеп һәм ирләр өчен генә үткәрелгәнгә күрә, Хөснулланың сеңлесе Миңсылу да анда чакырылмаган иде.* Ш.Камал

**ИФТА́Р ИТҮ** *ф.* Ураза тоткан көнне, кояш баегач, авыз ачу. *Икенде-ахшам укыгач, өйгә кайттым да, ифтар итеп, хөрмә ашадым.* З.Һади

**ИФТА́Р КЫЛУ** *ф. к.* **ифтар итү**

**ИФТИРА** *и. гар. иск. кит.* Яла, яла ягу, берәү өстенә нахакка гаеп ташлау; ялган сүз, ялган гаеп. *Сөйләнде өстемә күп ифтира, бөһтан, усал телләр; Сибелде зур хәкарәт берлә хәтта башыма көлләр.* Г.Тукай. *Чыкмый мәйданга хакыйкать ифтира, бөһтан белән ---.* З.Ярмәки

**ИФТИРА́ ИТҮ** *ф.* Яла ягу; ялган сөйләү, ялганлау. *Сез миңа ифтира итәсез, ялганлыйсыз, --- миңа ифтира итәргә, минем йөземне каралтырга гына килгән икәнсез монда!* Г.Тукай

**ИФТИРА́ КЫЛУ** *ф. к.* **ифтира итү**. *Дәһханә әйтте: – Әй Фанис, нә өчен, сән буйлә ифтира кылып, мәне кызым, үзеңез мөселман, мән гарәп, исемем Габделмалик, диярсең?* Ф.Халиди. *Әгәр дә сез ---, Оренбург җәмгыяте исламиясенең собраниесендә председательгә ачу илә – җәмгыятьне ифтира кылып, --- тиешсез хәрәкәттә булсагыз, ул вакытта сез, миннән бигрәк, эшебезгә зарар китерәчәксез.* Ш.Мөхәммәдев

**ИХ**, **И-ИХ** *ы.* Контексттан чыгып, шатлану, әсәрләнү, соклану, кайгыру, ачулану, үкенеч, сагыш, мыскыллау, көчле теләк һ.б.ш. хисләрнең көчлелеген күрсәтү өчен кулланыла («и» авазының сузылып әйтелүе бу хисләрнең аеруча көчле булуына ишарә итә). *Их, явызлар! Их, адәм актыклары! Кеше тырыша-тырмаша кием җиткерде, мескен, ә болар – әзергәбәзер.* Ә.Сафиуллин. *И-их, күк йөзен гел бәхет йолдызлары гына басып китсә...* Э.Шәрифуллина. *И-и-их, билеты-ние белән эләктереп аласы, бөтен сорауларны чишәсе иде дә бит.* М.Насыйбуллин

**ИХАТА** *и. гар. диал.* 1) Йортны, корылмаларны тирәли әйләндереп алган киртә, читән, койма. *Анысына да карамас идек – көлгән кеше көлә бирсен, – крәстиән бит без, тик нигә йортларны ихата белән урап алмаска да урам буйлап арыкмы, торба суымы җибәрмәскә?* Ә.Мохтар. *Кая карама – салам түбә, җимерек каралты-кура, тал чыбыгыннан үреп, балчык белән катырган ихата.* М.Хәсәнов

2) Киртә, койма яки читән белән тирәли әйләндереп алынган урын; ишегалды. *Көтүдән сыер кайтасы бар, дигән уй көндезләрен дә ишегалдын тутырып, ихатаны бөтен итеп тора иде бит.* М.Галиев. *Ул арада сыер да, тук тавышка мөгрәп, авыр тояклары белән җир селкетеп, ихатага кайтып керә.* Г.Галиева. *Сәетҗан абыйларның ихатасы сирәк кенә койма белән аннанмоннан гына әйләндереп алынган иде.* М.Маликова

3) Тирәли күз күреме җирләр

**ИХАТА́ ИТҮ** *ф. иск. кит.* 1) Ишегалдын киртәләп, корылма белән әйләндереп алу; ихаталау. *Биктимер агайның кечкенә салам түбәле ялгыз өенең тирәсе киртә берлә ихата ителеп, --- кишер вә шалкан [утыртылган].* З.Һади

2) Тирәли корып алынган, уратып алынган урын ясау, ихата хасил итү

**ИХАТА-КУРА** *җый. и.* Ихата һәм ихатаның абзарлар һәм келәтләр урнашкан урыны. *Юештән каралган, моңсу ихата-кураларны кысрыклап, болытлы төн иңеп килә.* М.Галиев

**ИХАТА́ КЫЛУ** *ф. иск. кит. к.* **ихата итү**. *Авылның тирәсе кара урманнар берлә ихата кыйлынган иде.* З.Һади

**ИХАТАЛА́У** *ф. диал.* Нинди дә булса урынны койма, читән яки киртә белән тирәли әйләндереп алу. *Бер кулым, бер аягым исән чакта, хет чишмәләрне караштырып калыйм, ичмасам. Барысының да авызларын ихаталап алдым.* А.Хәлим. *Зират тирәсен ихаталау*

**Ихаталап алу** Берәр урынны аерып алып бөтен ягын тоташ ихаталау. *[Мәктәпнең] Артка – ихаталап алынган ишегалдына чыгу юлы да бар иде.* Г.Минский

**Ихаталап кую** Ихаталаган хәлгә китереп калдыру

**Ихаталап чыгу** Йортны, корылмаларны тулысынча койма белән әйләндереп алу; барысын да ихаталау

**Ихаталый башлау** Ихаталарга керешү

**ИХАТАЛЫ** *с. диал.* Ихатасы булган, ихата белән тирәли әйләндереп алынган. *Карт тар гына ихаталы йортның*

*бик тә кысан бер бүлмәсендә яши булып чыкты.* В.Имамов. *Ихаталы бакчаларда тырыш куллар үстергән шомырт, чияләр, алмагачлар шау чәчәктә утыра.* Г.Әпсәләмов

**ИХАХА(Й)** *ы. сөйл. шелт.* **1.** Авызны күтәреп кычкырып, шаркылдап көлүне белдергәндә кулланыла. --- *беркем дә килми, ишекне беркем дә какмый. Көзге җил генә, ваемсыз кешедәй ихахайлап, балкон тәрәзәләренә ышкылып уза.* Ф.Шәфигуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Уйсыз-исәпсезлек, гамьсезлек, ваемсызлык. *Ландышка шул ихахай гына булсын!*

2) Борчуы, мәшәкате, кайгысы булмаган, гамьсез, шаркылдап көлеп йөрүче кеше. *Ул ихахайга өйләнеп, ни кырырсың икән?* Ә.Камал

**ИХАХА(Й) ДА МИХАХА(Й)** *ы. сөйл. шелт. к.* **ихаха(й)**. *Түрфәндә чыркылдап көлеп җибәрде. – Сиңа ихахай да михахай, юма тел үзеңдә, – дип, Фаяз ризалыгын белгертеп кулын селтәде ---.* Х.Камалов. *Камәрия әби, яңгыратып көлгәне, матур итеп киенеп йөргәне өчен булса кирәк, Гөлсем апаны еш тиргәп тора. – Ихахай да михахай ат кебек син. Йөрисең бөтен авылга тутый кош булып! – дип кычкыра.* Р.Фәизов. *Моннан алда танышкан Әминәгә караганда, картрак булуга карамастан, ихахай да михахай гына Миңлегөл: боргалану-сыргалануларын күрсәң, исең китәр!* З.Фәйзи

**ИХАХА(Й) ДА МИХАХА(Й) КИЛҮ** *ф. шелт.* Оялмыйча, тартынмыйча кычкырып шаркылдап көлеп чытлыклану, уенчаклану. *Эштә егетләр белән ихахай-михахай киләсең...* Р.Кәрами. *Яшьләр ихахай да михахай килеп такмак әйтешкәндә, миңа гына күңелле түгел иде бу көнне.* Юлдаш

**ИХАХАЙЛАНУ** *ф. сөйл. шелт. к.* **ихахайлау**. *Акланма, кызый! Ихахайланып Лотфыйның машинасына утырып киткәнеңне укытучылар күргән.* Н.Гыйматдинова

**ИХАХАЙЛА́У** *ф. сөйл. шелт.* **1.** Оялмыйча, шаркылдап көлеп чытлыклану, уенчаклану. *– Бер гөнаһсыз кешене аздырып син йөрдең, айгыр. – Бия ихахайламаса, айгыр михахайламый.* Ф.Яруллин. *Һашиянең ихахайлап көлүе Рәхимҗанны чүт кенә һуштан яздырмады.* Н.Гыйматдинова. *Китте сөйләшү, көлешү, төрттерү, мыскыллау, ихахайлау...* М.Мәһдиев

**2. ихахайлап** *рәв. мәгъ.* Кайгы-хәсрәтсез, рәхәт; типтереп. *Карале, көчсезләрне, юаш, юньсезләрне рәнҗетеп, рәхәтләнеп, ихахайлап яшәп була икән бит бу дөньяда.* М.Мәһдиев

**Ихахайлап җибәрү** Кинәт ихахайлау

**ИХАХАЙЛАУ-МИХАХАЙЛАУ** *ф. сөйл. шелт.* Шаркылдап көлү; кычкырып көлү. *Ашлык сугучы кызларыңа әйт: бәрәңгеләрен ашасыннар да ихахайлап-михахайлап утырмасыннар, өйләренә китсеннәр.* Т.Гыйззәт

**ИХАХАЙ-МИХАХАЙ** *и. сөйл. шелт. к.* **ихаха(й)** (*2 мәгъ.*). *Нишләптер, мин бүген боегып торам. Бу йөзләрчә кызларның шатлыгы белән ихахай-михахайлары миңа мәгънәсез булып тоела ---.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИХАХА́Й ЯБАЛАК** *и. зоол. диал.* Ябалаклар семьялыгына караган, зур күзле, ыргакка охшаган томшыклы, кабарып торган йомшак каурыйлы, күз тирәсендәге йоны диск сыман аерылып торган йомры башлы, тавышы ухылдаган, сызгырган, шаркылдап көлгән тавышка охшаш төнге ерткыч кош; чырайсыз ябалак, мәче башлы ябалак; *русчасы:* **филин**. *Кеше булып шаркылдый, дигәннәр иде аны [байгышны]. Ихахай ябалак, дип, юкка атамыйлардыр.* Г.Хәсәнов

**ИХА-ХА-ХА** *ы.* Кычкырып, шаркылдап көлүне белдергәндә кулланыла

**ИХА-ХА-ХА КИЛҮ** *ф. сөйл. шелт.* 1) Берәр нәрсәдән яки кешедән мыскыллы, мәсхәрәле көлү. *Дошман теле иха-ха-ха --- килә, Пычрак бер сүз йөри күтәреп.* Һ.Такташ

2) *к.* **ихаха(й) да михаха(й) килү**

**ИХИ-МИХИ** *ы. сөйл.* Игътибарны ясалма рәвештә җәлеп итү өчен уенчак булу, чытлык булу; кемгә дә булса ошарга тырышу турында. *Мәхәббәттә бераз ихи-михи дә кирәк, ансыз булмый!* М.Маликова

**И́ХИ-ХИ**, **И́ХИ-ХИ-ХИ** *ы.* 1) Акрын гына мыскыллап көлүне аңлаткан-да кулланыла. *Кызык иткәнсең икән син ул йөремсәк иреңне, ихи-хи-хи!*

2) Көрсенүне, борчылуны, гаҗәпләнүне һ.б.ш.ларны белдерү өчен кулланыла. *Ихи-хи-хи, рәхәтләнеп елый да алмыйм шул мин, балалар бар бит*

**ИХИ-ХИ ДА МИХИ-ХИ** *ы. сөйл. к.* **ихи-михи**. *Зиннур булган җирдә – пляждамы ул, бакчадамы – мәзәк. Ихи-хи да михи-хи.* М.Мәһдиев

**ИХЛАС** *и. гар.* **1.** 1) Күңел чынлыгы, сафлыгы, риясызлыгы; пакь күңеллелек, эчкерсезлек, турылык. *Ул бу китаптагы изгеләр вә аларның тормышлары хакында язылган хикәятләрне чын бер дәрт белән укый, җәннәт рәхәтләрен, җәһәннәм газапларын язган җирләрне ихлас белән күңеленә салып кала иде.* Ф.Әмирхан

2) Нәрсәнедер эшләргә чын теләк; эчкерсез мөнәсәбәт; омтылыш, дәрт. *Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга, Уенга салмаса ихлас – менә бәхте аның шунда.* Г.Тукай. *Аның эшкә ихласы юк*

3) *сөйл.* Кемне дә булса чын күңелдән ошату, хуп күрү; мәхәббәт. *Ничә мәртәбә Гани бай сиңа бирергә әзер торганлыгын, кызның да синдә ихласы зурлыгын сөйләде.* М.Фәйзи

**2.** *кер. сүз мәгъ.* 1) Нәрсәнең дә булса дөреслегенә, хаклыгына ышандырганда әйтелә; чынлап та, чын-чынлап, дөрестән дә. *– Ихлас, әни, мин бер киңәш тә бирә алмыйм бит! – дигән булды.* Г.Бәширов. *Киявең качмас. Минем дачаны күрми китәсе булсаң, үпкәлим. Ихлас, үпкәлим.* К.Тинчурин. *[Мөсфирә] Үзе матур, үзе уңган, үзе өлкәннәргә итагатьле. Ихлас менә.* Җ.Фәйзи

2) Гозерләнеп, ялынып-ялварып сораганда, үтенгәндә кулланыла. *Ул, эчкә баткан күзләре белән үтенеп, Айсылуга карады: «Барсана, Айсылу сеңел, Михаил Павлычка тагын бер сүз салып карасана. Ихлас, авырсынмасаң, кереп чыксана, ә!»* Г.Бәширов

**3.** *с. мәгъ.* Саф күңелле, риясыз, эчкерсез; чын күңелдән эшләнә торган. *Табигать үзенең чын асылында законнарына тугрылыклы һәм ихлас, ә алдау-ялганны, икейөзлелекне кешеләр уйлап чыгарганнар.* М.Маликова. *Егет*

*тә аңлап алды: аның җавабы ихлас булырга тиешле.* Р.Мөхәммәдиев. *Аңлагач, минем ихлас киңәшләремә дә колак салыгыз.* А.Расих

**4.** *рәв. мәгъ.* 1) Чын күңелдән, күңел биреп, бирелеп. *Сөйсәң дә, җаный, сөй ихлас, сөймәсәң дә бәннән каласың.* Г.Тукай. *Аның бу үтенече миңа да ошап куйды: – Ярар, абзый, эзләп карармын! – дидем мин ихлас кына.* Ә.Еники. *Шәрәфи карт үзе өчен дә бу хәлләр чит әйбер түгел икәнлеген ачык сизә һәм бу турыдагы сүзләрне чын ихлас белән кызыксынып тыңлый иде.* Ш.Камал

2) Тырышлык куеп, зур теләк белән. --- *Җомабикә абыстай кайнап торган күп халык арасында, бернәрсә югалткан кебек, бик ихлас илә ашыгып-ашыгып, ары-бире бернәрсә эзләп йөрмәктә иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Син бит – минем кушканнарымны ихлас белән үти торган акыллы малай.* М.Фәйзи

◊ **Ихлас ачылып китү** Эчкерсез сөйләп бирү, күңелдәгесен әйтеп бирү. *Ихлас ачылып китәргә иртәрәк, каршысында басып торучы егетнең кем икәнлеген белми ич әле.* Р.Мөхәммәдиев. **Ихлас белән** Берәр нәрсәгә бөтен күңелне биреп, чын күңелдән; игътибар белән. *Ул, шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә, Бик каты ихлас белән чынлап ябышты дәрсенә.* Г.Тукай. *Фәридә, --- мин сине ихласым белән яраттым ---.* Р.-Н.Гүнтәкин. **Ихлас кайту** Күңел кайту, күңел бизү, теләк бетү, суыну. *– Я Ходай, күрсәләр ни булган? – Күргәннең ихласы кайтуы бар.* И.Рәми. *Син --- Зәйнәпнең ихласы кайтачагын яхшы беләсең шул.* Ф.Әмирхан. *Авыл урамнарында егетләр, көз көне никрутлар яңа кыйбдән тәмам ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар.* Г.Тукай. **Ихлас кую (баглау, салу)** Күңел бирү, бирелү, чын күңелдән кызыксыну. *Без моннан егерме биш ел борын «Тәрҗеман»ны укыдык һәм ихлас багладык.* Г.Тукай. *Гали үзе дә укуга бик ихлас куеп, иҗтиһат кылды.* Ш.Мөхәммәдев. *Иблис әйтә: «Тыңлагыз ихлас куеп. Бак: минем ушбу сакал берлән мыек – Изге әйбер болар, оҗмах гөлем».* Ш.Бабич. **Ихлас күңелдән** Чын күңелдән, эчкерсез, самими рәвештә. *Җыр сүзләрен ихлас күңелдән бирелеп кабатлыйлар иде.* К.Нәҗми. *Руссо, --- «өченче катлауның» иң яхшы кешеләре – гомумкешелек идеалларын чагылдыручылар, дип, ихлас күңелдән ышана.* Ә.Хуҗиәхмәтов. **Ихлас сүнү** Күңел кайту, бизү. *Әмма Фәтхулла хәзрәтнең «хатын-кыз адвокат булсын» дигән сүзне ишетеп, бу кешедән ихласы тәмам сүнгән иде ---.* Ф.Әмирхан. **Ихласың дөрес булу** Чынлап күңел биргән, ышанган, чын күңелдән бирелгән булу. *Ихласың дөрес булса, әтәч салсаң, саваптан коры калмассың! Дошман теле иха-ха-ха... килә, Пычрак бер сүз йөри күтәреп.* Һ.Такташ. **Ихласы юк** Күңеле, дәрте юк, кызыксынмый, теләге юк. *Тугрысын әйткән вакыт: Укуда юк ихласы.* М.Гафури

**ИХЛАСАН** *с. гар. к.* **ихластан**. *Ихласан котлау*

**ИХЛАСИ** *с. гар.* **1.** 1) Риясыз, эчкерсез, саф. *Сөембикә аңа күтәрелеп карады, елмаерга итте, иллә ихласи елмаю килеп чыкмады ---.* М.Хәбибуллин

2) Чын, дөрес. *Беркөнне аңа имам хәзрәтләре: «Сәнең шигъриятеңдәге дөреслек вә хаклык ихласи җисми хаклыктан күп өстен чыккан, Кол Гали», – диде.* М.Хәбибуллин. *Ихласи хезмәт белән үткән ул еллар бүген дә күңел түрендә.* Мәдәни җомга

**2.** *рәв. мәгъ.* Чын күңелдән, бөтен барлыгы белән. --- *Ислам диненә ихласи бирелгән имамнар укыган самими вәгазьләрнең күңелемә тирән тәэсир ясавын әйтәсем килә.* И.Надиров

**ИХЛАСЛАНУ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса бөтен күңелне бирү, ихлас булу; шуның белән артык кызыксынып, бирелеп шөгыльләнү, шуңа бирелеп китү. *– Хәзер тәһарәт яңартам, өсбашыма чиста кием алыштырып киям дә! – дип сөйләнә-сөйләнә, ул никах йоласын үтәргә ихласланып тотынды.* Ш.Янбаев. *Ли бик бирелеп, ихласланып, [спорт] белән шөгыльләнә башлый ---.* Кызыклар дөньясында

2) Эчкерсезләнү, риясызлану. *[Алмаз белән Созыкин] Күп сүзләр сөйләштеләр. Бер-берсенә җаннарын ачтылар. Сәрхүшләнеп алса, Созыкин ихласланырга ярата.* Х.Камалов. *Һәм кулларын авызлыклы ат тоткан күк итеп кысып тотып, ихласланып сөйләп китте.* Д.Галимов. *Хуҗабикә, кунак кызының авыз ачып тыңлавын күреп, тагы да ихласланып сөйләнде.* С.Шәрипов

**Ихласлана бару** Торган саен ныграк ихласлану

**Ихласланып китү** Кинәт ихласлану

**ИХЛАСЛЫ** *с.* **1.** 1) Чын, риясыз, эчкерсез, саф. *– Бу эшләрне сөйләмә, ихласлы милләтпәрвәр инсан анчак сыйбъян укытмак илә канәгатьләнмәсен кәрәк, --- – дип, кисеп әйтте Зурколаков.* М.Акъегетзадә. *Аның ятим калган асрау кыз икәнен белгәч, ихласлы кызгану белән: – И-и, шулаймыни?! – дип гаҗәпләнде.* С.Сабиров. *Аңа ышанасы килеп китте доцентның. Эчкерсез, ихласлы күренә бит.* Т.Галиуллин

2) Күңел бирүчән, кызыксынучан, мавыгучан. *Ислах өчен чын күңелдән ихласлы сез.* Г.Тукай

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **ихластан**. *Монысын алгач, бик ихласлы сөйсен хатыным, дип, һичбер каты сүз әйтеп хафаларга батырчылык итә алмасын.* Г.Тукай

**ИХЛАС(ЛЫ)ЛЫК** *и.* Саф күңеллелек, риясызлык, эчкерсезлек. *Замполит һаман ышанмый, башын як-якка чайкый. Иң авыры – синең ихласлылыкка ышанмаулары.* Х.Камалов. *[Балалар] Керләнмәгән, сизгер күңелләре белән фәкать рәссамнарның тырышлыгын, ихласлыгын, омтылышларын тоялар ---.* М.Маликова. *Ихласлык белән алган иде һәр икесен.* Р.Мөхәммәдиев

**ИХЛАССЫЗЛЫК** *и.* Ихлас булмау. *Ахыргы сүзләрне әйткәндә, Рәшатның күзләре инде әүвәлге ихлассызлык, ялкаулыкларын җуялтып, гадәттәгечә --- хәятлы сикеренә башлаганнар иде.* Ф.Әмирхан. *Ихлассызлык ул – ясалмалык, эшләгән эшләреңә рия кертү, кылану, икейөзләләнү, кеше күрсен өчен генә эшләү.* Ф.Бәйрәмова

**ИХЛАСТАН** *рәв.* Чын күңелдән, җаны-тәне белән, бөтен йөрәктән. *Кайгы пәрдәсе аша сорады моны Җәмилә Закировна. Ләкин сүз өчен генә түгел, чын күңелдән сорады, һәм аңа*

*ихластан җавап бирергә дә кирәк иде.* М.Маликова. --- *Кларапы чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар.* Ә.Еники. *Нажия Әлфредкә күтәрелеп карады. Чибәр егет икән үзе. Сүзләре дә ихластан әйтелә кебек.* Ф.Яруллин

**ИХЛА́СТЫР** *кер. сүз к.* **ихлас** (**2.**). *Көтелмәгән тәкъдимнән Трофимов аптырап калгандай булды: – Юморны аңламый башладым, ахрысы, Вилдан Галиевич. Ихластыр менә, тел төбеңне төшенеп җитмәдем.* М.Насыйбуллин. *Ул да: – И-и, әллә фәрештәләр чынлап та тырышканмы? И-и! Китәсе дә килмәс инде, ихластыр менә, – дип сөйләнде.* Ә.Баянов. *Күрше-күлән кыяр орлыкларын сорап теңкәгә тияләр иде. Ихластыр әгәр!* М.Хәсәнов

**И́ХМА**, **И́Х-МА** *ы.* 1) Рәхәтлек, күтәренке кәеф тойгысын белдерә (сузып әйтелү бу тойгының көченә ишарәли). *Шунда Сөембикә кушучына су алды да эчеп куйды, ахыр: – Ихма, Җаеккаем сулары, йөрәгем ярсулары, – дип җырлап җибәрде.* М.Хәбибуллин. --- *Дамир софага чалкан төште, селкенеп карады. – Их-ма! Кил әле, кил яныма, Фирүзә.* М.Хәбибуллин

2) Үкенү, борчылу, көрсенү тойгысын белдерә. *Утны сүндерә алмадылар. Их-ма, бер-бер артлы өч йорт!* Н.Гыйматдинова

**ИХРАМ** *и. гар. дини* 1) Көндәлек тормыштагы кайбер гамәлләр (мәс., чәч кистерү, үсемлек өзү һ.б.) хаҗ кылу вакытында харам саналып, аннан тыелып тору. *Ихрамнан чыгасы көндә, уяулы-йокылы чагымда --- [изге сүз] колагыма керде.* Г.Камал

2) Хаҗ һәм гомрә вакытында мөселманнар кия торган җөйсез кием. *Гали дәхи ихрам киеп Мәккәгә килде.* К.Насыйри

3) Ау тыелган урын, мәйдан

4) Җәймә, чаршау, япкыч

**ИХСАН** *и. гар. иск. кит.* 1) Кешегә эшләгән изгелек, ярдәм, булышлык, мәрхәмәт; бүләк. *Берәүгә кыйлам дисә ихсан мәүла, Бәхет яры дошманнан кыйлыр шәүлә.* М.Гафури

2) Хөрмәт, ихтирам. *Падишаһ халыкка бик ихсаннар күрсәткәннән соң, Каһтаранны мәмләкәтнең пәһлуаны атап, аны шул бер урынга билгеләде.* Дастан

**ИХСА́Н ИТҮ** *ф.* 1) Бүләкләү, насыйп итү. *Миңа сабый балалар йокысын ихсан ит.* Г.Тукай. --- *Җәгъфәргә өстенлек ихсан ителгән иде.* Г.Тукай

2) Булышлык, ярдәм итү. *Мин дөньяда вакытымда аңар ихсаннар иткән идем.* Г.Тукай

3) *күч.* Бирү. *Аңа шушы сыйфатлар ихсан ителгән: аягы юк, кулы юк, телсез, сукыр ---.* М.Фәйзи

**ИХСА́Н КЫЛУ** *ф. к.* **ихсан итү** (*2 мәгъ.*). *Бәдри, үзенчә бик зур ихсан кылган, бер кешенең рәхәт тормышына сәбәп булган кешеләрчә: «Я Җәмилә, бу көн ирең кая китте?» – диде.* М.Гафури

**ИХСАНЛЫ** *с. иск. кит.* Изгелекле, шәфкатьле, мәрхәмәтле, ярдәмчел. *Шагыйрь әфәнде – ихсанлы кеше, һиммәтле кеше.* Г.Тукай. *Ул ихсанлы кеше кем? Улмы? Ул – мин.* Г.Тукай

**ИХСАНЛЫЛЫК** *и. иск. кит.* Ихсанлы булу. *[Ул] Башкаларның милке илә --- ихсанлылык [күрсәтә].* Г.Тукай

**ИХСАНЧЫ** *и. иск. кит.* Ярдәмчел, изгелекле, шәфкатьле кеше; чын күңелдән яхшылык теләүче кеше. *Әйтсәң – әйт Габделлатиф хаҗины, бер ихсанчы, дип!* Ш.Бабич

**ИХСАС** *и. гар. иск. кит.* Хис, тойгы, кичереш. *Бу тәэсир, бу ихсасларның алышынуы вә төрләнүе Казанның үзгәрүеннән түгел, бәлки, Сәлимнең үзенең үзгәрүеннән иде.* Г.Ибраһимов

**ИХТАР** *и. гар. иск. кит.* 1) Нәрсәне дә булса берәүнең исенә төшерү, хәтерендә яңарту

2) Алдан белдереп кую, искәртү; кисәтү. *Татарчага сарыф, нәху язучыларга ихтар.* Г.Тукай

3) Искәр(т)мә. *Ихтар: әгәр дә шушындый ук хикәя бер-бер мөхәррир вә шагыйрь тарафыннан бизәкләп вә матурлап язылса, инде ул «халык әдәбияты»лыктан чыга.* Г.Тукай

**ИХТИЗАР** *и. гар. иск. кит.* Үлем авыруына дучар булу; үлем алды, соңгы сулыш

**ИХТИЛАЛ** *и. гар. иск. кит.* 1) Баш күтәрү, фетнә, бунт ясау. *Төркия ихтилалы елны Йосыф Акчурин да үзенең «Вакыт»ка язган «Истанбул мәктүбләре» белән шундый матур эш эшләде.* Г.Тукай. *Бу җиһан, бу сугыш, бу канлы вәхшәт – ихтилал, җир, җиһан аст-өскә әйләнмичә, бетмәс ихтимал.* Ш.Бабич. *Бирән түрәләрнең безнең халыкны никадәрле сансызлатуын, истиһза итүен ишеттерик дисәк, без башкорт далаларында купкан ошбу ихтилалны Казан иленә дә күчерергә --- тиешбез.* В.Имамов

2) Чуалыш, башбаштаклык китереп чыгару. *Менә бу протест, бу сугыш бездә дә менә шундый шәкерт ихтилаллары рәвешендә дөньяга бәреп чыга ---.* Г.Ибраһимов. *Алдагы көннәрнең берендә зур ихтилаллар булмый калмас.* М.Гафури

3) Инкыйлап, революция, революцион хәрәкәт. *Россиянең һәр тарафында ихтилал, фәсәд, шикаять вә рәхәтсезлек дәвам итәдер.* Ш.Мөхәммәдев

**ИХТИЛАЛЧЫ** *и. иск. кит.* **1.** Фетнәче, баш күтәрүче кеше. *Рәсемгә дикъкатьлек белән карап, төбендә «Ихтилалчылар Англия халкына падишаһыбыздан шикаятькә баралар» дип, русча язган җөмлә күрдем.* Ф.Әмирхан. *Шул көнне үк иркен үзәнлектән төрле якка ихтилалчылар гаскәре тарала башлады.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* Инкыйлаби; баш күтәрүче. *Ихтилалчы мәмләкәтләр*

**ИХТИЛАЛЧЫЛЫК** *и. иск. кит.* Ихтилалчы булу, инкыйлапчылык. *Аянычка, безнең җәмгыятькә ихтилалчылык (революциончылык) белән мавыгу хас.* Мирас

**ИХТИЛАФ** *и. гар. иск. кит.* 1) Фикер төрлелеге; каршылыклар, үзара килешмәүчелек. *Менә бөтен ихтилаф бетте дә: ышандыралар икән, мин аларча булам; ышандыра алмыйлар икән – дәлилләренә үпкәлиләр.* Ф.Әмирхан

2) Дау, ызгыш, гауга. *Казан халкы арасында зур гауга, бетмәгән, төгәнмәгән ихтилаф икән.* Ф.Әмирхан

**ИХТИЛЯЛЬ** *и. гар. иск. к.* **ихтилал**. *XVII гасырда Россиядә килеп чыккан ихтиляль 1613 ел Земский соборында Романовларны сайлау белән генә бетмәде.* Г.Гобәйдуллин

**ИХТИЛЯЛЬЧЫ** *и. иск. к.* **ихтилалчы**. *Башкорт бунтларында татар муллалары, ислам шигарен тоттырып, ихтиляльчыларның илһамчыларына әйләнделәр.* Г.Гобәйдуллин

**ИХТИМАЛ** *и. гар.* **1.** 1) Теге яки бу эш-хәлнең булуына, тормышка ашуына объектив мөмкинлек, фараз. *Шәмсия карчык өчен бу төнге сәгатьләрдә кызның егеткә ябышып чыгу ихтималыннан бүтән ихтималның дөньяда булуы һич мөмкин түгел иде.* Ф.Хөсни. *Бер дә борчылма, абзый, минем һәр ихтималда үземне үзем сакларлык кына көчем җитәрлек.* Р.Ишморат. *Син абзыеңны сәүдәгәр булмаска үгетләгәндә дә, үзең өчен куркып кына, «сәүдәгәр энесе» исемен күтәрү ихтималыннан шикләнеп кенә үгетлисең.* М.Әмир

2) Фаразый мөмкинлек; фараз (эш яки хәлнең тормышка ашуы икеле, шикле булган очракта әйтелә). *– Александр Вениаминович, мин аны белеп тә бетермим. – Ихтимал. Әле аның безгә кергәненә өч кенә ай, – диде Семагин.* Р.Кәрами // Булуы мөмкин саналган очрак, мөмкин булу. *– Төнлә, без сизмәстән, бик каты явып, вак-төяк йорт нәрсәләрен агызып китү ихтималы бар, – дип, ишегалдыннан суга агып китәрлек нәрсәләрне өйгә кертеп тырды.* М.Гафури. *Һәр ике ихтималда крестьян аны өйрәнергә, төшенергә, аның артыннан күзәтергә тырыша.* Г.Нигъмәти. *Мостафадан дошманның кайсы яктан килүе ихтимал тотылганын һәм пост өчен шушы урын сайлануның сәбәбен сорашты.* Ш.Камал

**2.** *хәб. сүз* Мөмкин. *Мондый җирдә, Алла сакласын, акчаңны талап, үзеңне суеп ташлаулары да ихтимал.* Г.Камал. *– Юк, – дигән булды Кәшифә әби, нидән авырып китүен яшереп. – Кичә җиде сәгатьләп машинада утырып килгәнием, шуннан түгел микән? – Ихтимал, – диде табибә ---.* З.Фәйзи

**3.** *кер. сүз* Теге яки бу эш-хәлнең булу-булмавы ачык хәл ителмәгәндә, икеләнеп фараз иткәндә, кемне якларга белми икеләнгәндә һ.б. очракларда әйтелә; бәлки, мөгаен. *Ихтимал, шул халык арасында иң нечкәргән күңеллесе мин булганмын.* Г.Тукай. *Ихтимал, рус солдатының кулында таяк кына, үзе ялангач, үзе аңгыра, я, шулар белән сугышып йөр инде, дип көлүләре булгандыр.* Ә.Еники. *Башка урында булса, ихтимал, Хәйдәр аны бик коры тоткан булыр иде.* Г.Бәширов

**ИХТИМА́Л ЙӨРТҮ** *ф.* Я тегеләй, я болай булуы бар, булырга мөмкин, дип уйлау; фараз итү. *Әйберләрнең дә табылмавына карап төрле кеше төрле ихтимал йөртсәләр дә, колакка хуш килердәй сүз сөйләүче юк иде.* Ш.Камал

**ИХТИМАЛЛАНУ** *ф. сир.* Нинди дә булса эш яки хәлнең мөмкин булуына, дип уйлау. *«Урталыкта» романының ун, унбиш булуы ихтималланган кисәкләреннән тик берсе генә чыккан.* Г.Ибраһимов

**ИХТИМАЛЛЫК** *и.* Ихтимал булу; мөмкин булу, мөмкинлек. *--- байтак геосәясәтчеләр олы империя (СССР) артыннан кечесенең (РФ) таркалуы ихтималлыгын да фаразлый.* Р.Сафин. *--- бу йорт Рәхимгә ят булса да, күңелендә сизелер-сизелмәс кенә булып, билгесезлектән аерылып, шушы җирлеккә берегеп калу ихтималы улган иде. Хәзер бу ихтималлык югалды.* А.Вергазов. *Әгәр --- шушы ике брошюрага берәр төрле әдәби премия биреп куйсалар? --- Бу – башка да сыярлык хәл түгел һәм, әлбәттә, ул кадәр ахмаклыкка бармаслар, әлбәттә, бирмәсләр. Әмма моның бездә булу ихтималы да бар! Иң хәтәре әнә шул ихтималлыкның яшәвендә!* Ф.Садриев

**ИХТИМАЛЛЫ́К АМПЛИТУДАСЫ** *и. физ.* Системаларның төрле хәлдә булу ихтималлыгын билгели торган параметрларга бәйле физик зурлык; дулкын функциясе

**ИХТИМАЛЛЫ́К ТЕОРИЯСЕ** *и. мат.* Математиканың күп сандагы очраклы күренешләрнең үзара бәйләнешләренә нигезләнгән закончалыкларны өйрәнә торган бүлеге. *Ихтималлык теориясе буенча, син инде бүтәнчәрәк эш итәчәксең, синең тормышың бүтән юлдан китәр.* А.Тимергалин. *Н.И.Лобачевский алгебра, математик анализ, ихтималлыклар теориясе, физика, --- фәннәре буенча да хезмәтләр яза.* Татарстан тарихы. *Тел элементларының яшәеше аларның кабатланып килүе белән характерлы, һәм аны математик статистика һәм ихтималлык теориясе формулалары һәм төшенчәләре белән дә тасвирларга булыр иде.* Тел гыйлеменә кереш

**ИХТИМА́Л ТОТУ** *ф.* Берничә варианттан кайсының да булса берсен күздә тоту. *--- ул кызларның бер эш кылып, дөнья яңгырата алуларын, Җәләл мулланың кызы фәлән эшләр кылган дип, тирә-якта макталып сөйләнерлек бер хәлнең булырын һичбер хәлдә ихтимал тотмый.* Г.Ибраһимов. *--- дәрес китаплары да – һичбер хатаны ихтимал тотмый вә үзгәртми торган нәрсә ---.* Җ.Вәлиди

**ИХТИО́ЗАВР** *ис. гр.-лат.* Мезозой эрасында яшәгән, балык сыман гәүдәле сөйрәлүче ерткыч диңгез хайваны (казылма хәлендә генә табыла). *Ничәмә миллион еллар бу матурлык, бу гүзәллек әрәм яткан. Ихтиозаврлар матурлыкны аңламаганнар.* И.Гази. *Тереклекләрдән Триас чорында --- еланнар, ташбакалар, крокодиллар үрчегән. Аларның кайберләре диңгез ерткычларына, ихтиозаврга, плезиозаврга, мастодонзаврга әйләнгән.* А.Фаткуллин. *Ул вакытларда диңгездә яшәгән «балыккәлтәләр» (ихтиозаврлар) бик гадәти күренеш булган.* Дарвинизм нигезләре

**ИХТИОЛ** *и. гр.-лат.* Балык һәм диңгез хайваннары калдыклары катнашкан казылма тау токымнарын (сланецларны) күкерт кислотасы ярдәмендә эшкәртү юлы белән табылган, куе көрән төстәге майсыман матдә (медицинада эремә, мазь буларак киң кулланыла)

**ИХТИО́ЛОГ** *и. гр.* Ихтиология белгече. *Йорт балыкларын үрчетү һәм үстерү ихтиологлар алдында торган бурычларның берсе генә.* В.Сабунаев. *Шул ноктага җиткәч, ихтиолог та, директор да, күл эшчесе дә сукранып куя.* М.Рафиков. *Кайбер ихтиологлар горбуша кыяфәтенең болай үзгәрүен яшәү шартлары үзгәрүдән килә дип исәплиләр.* Кызыклы ихтиология

**ИХТИОЛО́ГИК** *с.* Ихтиологиягә караган, ихтиологиягә мөнәсәбәтле

**ИХТИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Зоологиянең бөҗра авызлыларны, балыкларны өйрәнә торган бүлеге. *Ихтиология фәненең үсешендә яңа чор Пётр Артедидан башлана.* Юлдаш

**ИХТИОФА́УНА** *и. гр.-лат.* Нинди дә булса сулыкның яки аның бер өлешендә яки Җир шары тарихындагы билгеле бер вакыт арасында яшәгән барлык балыклар. *Татарстанның ихтиофаунасы, ягъни балыклар фаунасы, ул кадәр бай һәм төрле түгел; соңгы мәгълүматлар буенча, безнең сулыкларда балыкларның 52 төрен очратырга мөмкин.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Каспий диңгезе ихтиофаунасы*

**ИХТИРАГ** *и. гар. иск. кит.* Әлегә хәтле күрелмәгән нинди дә булса яңалык, ачыш. *Ишми юләр чыдаша алмый урыныннан сикереп торып: – Бу – кяфер, ихтираг, – диде.* Ф.Әмирхан. --- *дөньядагы ул вакыттагы сәяси хәлләр, фәнни ихтираглар, --- һәммәсе дә бер Европа кешесен искә төшерә торган рух белән язылганнар.* Г.Гобәйдуллин

**ИХТИРА́Г ИТҮ** *ф.* Уйлап табу, уйлап чыгару. *Адәмнәр, «язу» дигән нәрсәләрне ихтираг итү вә хәзерге дәрәҗәсенә җиткерү өчен дә, бик күп тәҗрибәләргә мохтаҗ булганнар.* Ф.Әмирхан

**ИХТИРА́Г КЫЛУ** *ф. к.* **ихтираг итү**

**ИХТИРАЗ** *и. гар. иск. кит.* Сакләну; саклык. *Печән базары беткән тәкъдирдә татар халкының да Җир йөзеннән бетү куркынычы барлыгын буржуазиянең исенә төшереп, милләтнең корама чаршавына бөркәтеп, шәрык фашизмына нигез салырга теләгән фикерләрен «ихтиразларында» күрсәтергә тырыштылар.* К.Тинчурин

**ИХТИРАЗӘН** *рәв. гар.* Саклык белән, сакланып кына; саклык йөзеннән. --- *Мөхәммәтҗан хафизның үзенең тавык алачыгы шикелле йортыннан ихтиразән иске-поскысын чыгарып ятуын күргәч, минем фикерем бер минутка гына янгын фаҗигасеннән бушанып тора.* Ф.Әмирхан

**ИХТИРАМ** *и. гар.* Зурлау, олылау, санлау, хөрмәт. *Инглиз инженерының ихтирамы Алтынчәчнең дәрәҗәсен үстереп җибәрде.* М.Маликова. *Исәр вакыты узгач, тормышында төрлесен татып карагач, [Җәвидә] аңлады: Ленарга ихтирамы вакыт узган саен арта бара иде.* Р.Айзатуллин. *Тукай Исхакыйның бөеклеген, милләт юлында никадәр олуг эшләр башкаруын таныган --- һәм гомере буена аңа ихтирамын, хөрмәтен белдереп килә.* Казан утлары

◊ **Ихтирам йөзеннән** Зурлап, хөрмәт күрсәтеп

**ИХТИРА́М ИТҮ** *ф.* Зурлау, олылау, хөрмәтләү. *Чуар йөрәкле Сөләйман, эшчәнлеге өчен, Сәетзадәне ярата, хәтта ихтирам да итә иде.* К.Тинчурин. *Ак халатлы хатын Гөлсем апаны ихтирам итеп, шул ук вакытта кызганып: – Ах, балагыз юкмыни? – диде.* Г.Гобәй. *Хөсәен --- Зәйтүнәне ---, үз хәсрәтен үзе генә кичереп бетерергә әзер торуы өчен, чын күңелдән ихтирам итә иде.* М.Маликова

**ИХТИРА́М КЫЛУ** *ф. к.* **ихтирам итү**

**ИХТИРАМЛА́У** *ф. сир. к.* **ихтирам итү**. *«Алтынчәч» операсын тыңлаганда, син, Нәҗип Җиһанов белән беррәттән, операның шигъри юллар белән либреттосын язган Муса Җәлилне ихтирамлыйсың.* Җ.Фәйзи

**ИХТИРАМЛЫ** *с.* 1) Хөрмәткә, ихтирамга лаек булган, ихтирам ителә торган. *Югары очтан авылның ихтирамлы карчыгы Камилә әби кайтып килә.* Р.Фәизов. *Бәлки әле, яраланып кайтып, «Ватан сугышы инвалиды» дигән ихтирамлы исем белән яшәр идем.* М.Мәһдиев. --- *бу повестьта исә милиционер булып хезмәт иткән Шәүкәт нечкә күңелле, итагатьле, кеше шәхесенә игътибарлы, ихтирамлы, намуслы егет буларак күз алдына килеп баса.* Мәйдан

2) Хөрмәт итүчән, ихтирам күрсәтүчән. *Әмма сөйләшүнең барышы эшлекле, бер-береңә ихтирамлы иде.* З.Фәтхетдинов. --- *Хәтирә апа --- тездә дә тезде: – Балаларыгыз, кайгыхәсрәтнең нәрсә икәнен белмичә, намуслы, белемле, тәрбияле, кешеләргә ихтирамлы, тимердәй нык ихтыярлы булып үсеннәр.* М.Хәсәнов. *Ихтирамлы дәшмәүдән гайре җавап ала алмадым.* Р.Мостафин

**ИХТИРАМЛЫЛЫК** *и.* Ихтирамлы булу. --- *Каменский балаларда тыйнаклык, тыңлаучанлык, киң күңеллелек, җыйнаклык, пөхтәлек, итагатьлелек, өлкәннәргә ихтирамлылык --- тәрбияләргә киңәш иткән.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИХТИРАМСЫЗЛЫК** *и.* Ихтирам күрсәтмәү, хөрмәт итмәү. *Шул минутта ук бу ихтилафлар, бу ихтирамсызлыклар һәммәсе юк булалар.* Ф.Әмирхан. *Һәр вак-төяктән үземә игътибарсызлык, ихтирамсызлык эзли идем, үземне дә, аны да борчый идем.* М.Маликова. *Председательнең утырган җиреннән кәгазьләрен актарган, телефоннан әллә кемнәр белән сөйләшкән булуыннан егетнең ихтирамсызлыгына хәтере калган сыман бер нәрсә сизелеп тора иде.* Ә.Баян

**ИХТИРАМЧЫЛ** *с.* Һәрвакыт ихтирам итүчән; хөрмәт күрсәтүчән; хөрмәтчел. *Иң ихтирамчыл Россия халкының саулыгын [телик].* Т.Гыйззәт

**ИХТЫЯҖ** *и. гар.* 1) Тормыш-көнкүреш өчен бик кирәкле, мөһим, әһәмиятле, зарур нәрсәләр. *Дисәгә дә Гази белән очрашу, аның янында булу ихтыяҗга, хаҗәткә әверелде.* М.Хәсәнов. *Әтинең укытучылар төсле итеп азрак матур киенәсе, хезмәтенә күрә ашыйсы, рәхәт күрәсе дә килгәндер. Алар бит – адәм баласының иң гади, табигый, бик тыйнак кына ихтыяҗлары ---.* Р.Фәизов. *Балаларга гамәли белем бирү ихтыяҗыннан чыгып, галим яшь буынга фәннең төрле тармакларыннан мәгълүмат бирү, --- мәсьәләсен күтәреп чыга.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Ялыныч; үтенеч. *Ихтыяҗын гарыз итеп килсә теләнче капкаңа, Каты сүзләр белән инсаниятен син таптама.* Г.Тукай

3) Мохтаҗлык; мохтаҗ булу; кирәклек, кирәк булу. *Иске татарларыбыз аяклары белән уйларга өйрәнеп, башларына бөтенләй ихтыяҗлары беткән.* Ф.Әмирхан. *Кешедә акча да җитәрлек. Ихтыяҗ һәм талым да бар.* Р.Мөхәммәдиев. *Иргали Бәһрам җизнәсенең сүзен урта бер җирендә диярлек бүлеп: «Кайтуын кайттым да хәзер нишләрмен икән соң мин?» – дип, үз ихтыяҗын кыстырып куйды.* М.Хәсәнов

4) Теләк

5) Сорау, таләп. *Һәрьяклап халык ихтыяҗын канәгатьләндерү – бүген дәүләтнең иң мөһим бурычы*. Татар иле

**ИХТЫЯҖЛЫК** *и.* Ихтыяҗ булу, кирәклек. *Илдә мәктәп эше тайпылусыз үсүгә капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсеше, халык, бигрәк тә шәһәр халкы саны үсүе, белемгә ихтыяҗлык, --- сәбәп булганнар.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИХТЫЯР** *и. гар.* 1) Кеше психикасының алга куелган максатны, теләкне тормышка ашыруда чагылган сәләте, аңлы омтылышы; рухи көч. *Йөрәкләрне сыкратып, булган ихтыярын да богаулап, [Хәйрүштә] үз-үзен кызгану хисе туды.* М.Хәсәнов. --- *күзләрдән ниндидер көч аңкый. Ул синең ихтыярыңны сындыра, чарасыз итә.* А.Вергазов. *Бер җанына кереп тулган үч катыш гарьлек, ачу катыш кимсенүләр аңар ихтыяр көче өстәде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Теләк, ирек. *[Вәли:] Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә, көчләмим, үзем генә барам.* Г.Камал. *Ирекле көннән үз ихтыяры белән үз башына авыру алган: ниндидер бер сумашедший кеше, барып, безнең идән астына төшкән дә чыкмый тора икән.* Ш.Камал. *[Рәхим:] Качса да, зарар юк, бүген иң якын дустым миндә кунак икән, мин аның ихтыярында.* Р.Ишморат

3) Хакимлек, ирек. *Әнине кызганмаска, аны язмыш ихтыярына ташларга көчем җитмәячәк.* Г.Ибраһимов. *Бу минутта без икебез дә узган көннәр ихтыярында, аның безнең яшь йөрәкләребездә калдырган әрнүле көчләре тәэсирендә идек.* А.Шамов // **ихтыярыгыз, ихтыярың** *тарт. форм.* «Ничек телисез, шулай эшли аласыз, сезнең иркегездә» мәгънәсендә. *[Даниял] Таньшуның әүвәлге көннәрендә кызлар янына Җәмилне дә кысташтырып караган иде, тора-бара: – Ярар, нәчәлник, теләмисең икән, ихтыярың, – дип кул селтәде.* Н.Әхмәдиев. – *Әгәр рөхсәт итсәгез, мин юлымны гадәттәгечә башлар идем. – Ихтыярыгыз.* М.Маликова. – *Әллә сиңа ияреп үзем кайтыйм микән? – диде әнисе. Рөстәм, «ихтыярың» дигәндәй, җилкә сикертеп куйды.* Ф.Яруллин

4) Берәр нәрсә эшләргә шарт, җай, мөмкинлек; мөстәкыйльлек. *Юк өчен тавыш чыгармагыз, бераз сабыр итегез, һәркем үзенең теле илә сөйләшергә ихтыяр икәнен башта ук әйттем бит, бу сөйләүче бүдәнә әфәнде, ят мәмләкәттән килгән сәбәпле, безнең бу җирнең телен белмидер һәм үзенең белгән фарсы теле берлән сөйлидер.* Ш.Мөхәммәдев

5) *иск.* Азатлыкка, бәйсезлеккә омтылыш. *М.Гафури халыкның иреген, ихтыярын басып торучы --- дин-шәригать законнарын фаш итә.* М.Җәлил

6) Көч; түземлек, сабырлык. *Кәримә тешләрен кысты, елап җибәрмәс өчен, бөтен ихтыярын җыйды.* Р.Хафизова. --- *Бикташ белән Сәетҗан абый кайтып кергәндә, Салиха апаның ихтыяры тәмам сынган иде инде. Ул баласын күрүдән дә өмет өзеп өлгергән иде.* М.Маликова

◊ **Ихтыяр бирү** Ирек бирү. *Ура башлаган җирләрне бетерергә түгел, яртылай куелган чүмәләңне очларга да ихтыяр бирмәделәр.* Г.Ибраһимов. – *Куй инде... аны елатма, – дип, Сәлимгә ихтыяр бирмәде.* Д.Юлтый. **Ихтыярга кую** Үз дигәнчә эшләргә мөмкинлек бирү, ирексезләмәү. *Менә Шамил мине, ихтыярыма куймый, монда алып килде.* Н.Исәнбәт. **Ихтыярга салу** *к.* **ихтыярга кую**. *Яшьлегебез сәбәпле, зөфафыбызны үз ихтыярыбызга салдылар.* З.Һади. **Ихтыярың – кыярың, чөгендерең, кишерең** Кайсын сайласаң да, үз иркең. **Ихтыярың – үз кыярың** Ничек теләсәң, шулай эшли аласың. *Вәли, торып, тагын су эчкәннән соң: – Кодалар --- бер-ике шешәне юлга да тыктылар. Әгәр теләсәң, берсен алып киләм, ә? – Юк, кирәкми, – диде Хәкимҗан. – Ихтыярың – үз кыярың.* Н.Хәсәнов. *Кәмран шаркылдап көлеп җибәрде: – Ихтыярың – үз кыярың, дигәндәй, монысына инде катыша алмыйм, – диде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИХТЫЯРИ** *с. гар.* **1.** 1) Ирекле, мәҗбүри түгел. – *Сез улыгызны алып китмәкчеме әллә? – диде табибә. – Ник алып китмәскә? Монда аны мәҗбүрләп тота алмыйлардыр ич? Минем белүемчә, бездә дәвалану ихтыяри ---.* М.Маликова

2) Ихтыярга (*1 мәгъ.*) нигезләнгән. *Министр практик сүзенә ихтыяри кул изәве белән чик куйды.* Ә.Баянов

**2.** *рәв. мәгъ.* Ирекле рәвештә, үзе теләп, үз ихтыяры белән

**3.** *и. мәгъ.* Сугыш вакытында гаскәрләргә үз теләге белән язылган кеше. *Ихтыярилар батальоны шуннан ук вокзалга төшеп, туп-туры фронтка киткән.* Г.Бәширов

**ИХТЫЯРИ-МӘҖБҮРИ** *рәв. гар.* Нигездә, мәҗбүри булып, үтәлеше аңлы рәвештә кешенең үз ихтыярына куелган эш турында әйтелә. *Ирекле көннән бу нужа арбасына җигелергә теләүчеләр булмаганлыктан, мондый эшкә ихтыяри-мәҗбүри кушалар.* Р.Кәрами. – *Күпме алдыйлар, һаман ышанасың. – Ышанмыйча да булмый бит, Рәмисә. Ихтыяри-мәҗбүри, дигәндәй...* Х.Камалов. *Урыс мәдәни мохитендә яшәүче халыклар өчен алар юлы икесе дә яраксыз: беренчесе – ихтыяри-мәҗбүри, икенчесе, мәҗбүри рәвештә, урыс булмаганнарның ассимиляцияләнүенә китерәчәк.* Р.Сафин

**ИХТЫЯ́Р ИТҮ** *ф. иск. кит.* Ике нәрсәнең, ике якның, юлның берсен сайлау, икенең берсен теләү. *Билал, разый Аллаһе ганһенең мевасы астында кубудан калмас өчен, мөәззинлекне ихтыяр иткәнен сөйләде ---.* Г.Исхакый

**ИХТЫЯ́Р КЫЛУ** *ф. иск. кит. к.* **ихтыяр итү**

**ИХТЫЯРЛЫ** *с.* **1.** 1) Ихтыяр көче булган. *Ана түзә... Әмма тормышта зур ихтыярлы, олы йөрәкле аналарны да аяктан егарлык бәхетсезлекләр була, күрәсең.* З.Вәли. --- *нечкә сынына корыч үзәк яшеренгәндәй нык ихтыярлы Луциус гадәти кыз түгел иде, билгеле.* М.Маликова. *Минем дә тимер кебек нык ихтыярлы буласым килә.* А.Шамов

2) Теләгән нәрсәне яки теләгән эшне эшләргә ирекле; тулы хокуклы. *Бу Думада --- җир хуҗаларының вәкилләре бик кирәк булган күп мәсьәләләрне уздырмаска ихтыярлы вә кодрәтле ---.* Ф.Әмирхан

**2.** *рәв. мәгъ.* Үз теләгендә, мәҗбүри түгел. *Безнең спектакльгә килү һәркем өчен ихтыярлы.* М.Әмир

**3**. *и. мәгъ.* Ихтыяр көченә ия зат. *Билгеле, нык ихтыярлылар сугышчан иптәшләре белән дәшми-тынмый гына саубулашып, башларын аска иеп узалар.* Ш.Рәкыйпов

**ИХТЫЯРЛЫ-ИХТЫЯРСЫЗ** *рәв.* Теләккә каршы килеп, теләр-теләмәс. *--- гомерләр ихтыярлы-ихтыярсыз --- гаип уздылар.* Ш.Камал

**ИХТЫЯРЛЫК** *и.* Теләгән нәрсәне эшләргә иреклелек, хокук булу; мөмкинлек. *Тәрбия баланың нык характерын һәм ихтыярлыгын, түземлеген, бурычлары хисен үстерергә тиеш.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ИХТЫЯРЛЫЛЫК** *и.* Ихтыярлы булу, ихтыяр көченә ия булу. *Аның көр тавышында зур ихтыярлылык, үзүзенә бик нык ышану бар иде.* А.Шамов

**ИХТЫЯРСЫЗ** *с.* **1.** 1) Ихтыяр көче булмаган; йомшак характерлы. *Болай нинди бала тәрбияләнә соң? Үз сүзе, --- үз гамәле булмаган, ә читтән боеруны гына көтеп торган ихтыярсыз зат.* А.Вергазов. *Көчсез, ихтыярсыз кешене генә үткәне җиңә.* М.Хәсәнов

2) Теләгән нәрсәне яки теләгән эшне эшләргә ирексез, хокуксыз. *Ибәт абызагайның [ышануында], хатыннар – кәнизәк кеби ихтыярсыз* (*ирексез*) *затлар.* З.Һади

3) Нәрсә булса да эшләргә мәҗбүр. *Сез үзенең эшли торган көчен сатарга ихтыярсыз булган эшчегә карагыз.* РСДРП прокламациясе

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **ихтыярсыздан**. *Чит хатын-кызга әйтергә килешмәгәнен белә торып, «җаным»ны Газизәгә беренче тапкыр ихтыярсыз ычкындырды.* Ш.Камал. *Наҗиянең эчкерсез көлүе Әнвәргә дә тәэсир итте. Ул ихтыярсыз елмайды.* Р.Хафизова. *Бу сүзләр шулкадәр көчле тәэсир итте: ихтыярсыз күзем яшьләнде.* Җ.Фәйзи

**ИХТЫЯРСЫЗДАН** *рәв.*1) Ихтыярдан тыш, теләмәсә дә, ирексездән (күбесенчә кешенең үз ихтыярына буйсынмаган хис-тойгылар турында әйтелә). *Борынгы моңлы җыр-көйләрне тыңлаганда, безнең җаннарыбыз ихтыярсыздан тетрәнеп куя ---.* И.Надиров

2) Үзе дә теләмичә, нәрсә эшләвен үзе дә сизмичә. *Мин --- еш кына «Нигә бу абзый табигый курайда уйнамый икән?» дип, ихтыярсыздан уйлана да идем.* Ә.Еники. *[Картның] Җыерчыклар яргалаган коңгырт көрән йөзе һәм куе ак сакалы, ихтыярсыздан, игътибарны җәлеп итә.* М.Вәлиева. – *Кагылма! Берәрсе алып китсә... базарда балның килосы йөз тәңкә тора, – дип, ихтыярсыздан, кайнарлык белән ычкындырып ташлады амбарчы хатын.* Г.Ахунов

**ИХТЫЯРСЫ́З ИТҮ** *ф.* Буйсындыру, ирексезләү, мәҗбүр итү. *Илсөяр --- чыгып китә алмады: борынга бәреп кергән кайнар кабартма исе, табынга куелган юкә балы аны ихтыярсыз итте.* Ф.Яруллин. *Әмма бервакыт элек бөтенләй таныш булмаган, ә сугышта беренче көннән үк бергә сугышкан сержант Хәкимовка строй алдында беренче сугышчан бүләк тапшырганда, Шатохинның күкрәгендә тагын нәрсәдер көйри башлый, ихтыярсыз итә.* Ф.Галиев

**ИХТЫЯРСЫЗЛАНУ** *ф. сир.* Ихтыяр көчен югалту, икенче берәүнең йогынтысына иярү. *[Аңа] Кулларын туп-туры куярга куштылар. Ул ихтыярсызланды, алар кушканча торды.* М.Гафури

**ИХТЫЯРСЫЗЛА́У** *ф.* Мәҗбүр итү, кемнеңдер ихтыярына буйсындыру. – *Әлбәттә, – диде ул, – тормышка чыгу, бүтән берәү белән тормышыңны бәйләү – йөрәк эше ул, ---. Без моны аңлыйбыз, сине һич ихтыярсызларга теләмибез.* Ә.Еники

**Ихтыярсызлап тору** Гел, һәрвакыт ихтыярсызлау; әледән-әле ихтыярсызлау

**ИХТЫЯРСЫЗЛЫК** *и.* Ихтыярсыз булу. *Бөтен дөньяның асты өскә әйләнеп, үземне --- ихтыярсызлыкка аткан табигый куәт тәэсирендә чагымда, аның --- тавышы [ишетелде].* Г.Ибраһимов. *Кылган хәлдә дә, чарасыз вә ихтыярсызлыктан кылсам кылырмын бу адымым.* М.Хәбибуллин. *Ул [Шәмсир] инде әсирләр лагерена килеп эләккәч үк, адәм баласының бөҗәктән аерылмавын, ихтыярсызлыгын һәм зәгыйфьлеген яхшы төшенде ---.* Т.Әйди

**И́Х-ХА-ХА** *ы.* Шаркылдап көлүне белдерү өчен кулланыла. *Их-ха-ха, Фәтихә! Сыер бии әпипә.* Н.Исәнбәт

**И́Х-ХИ-ХИ** *ы. к.* **ихи-хи**. *Их-хи-хи-хи, убыр кулында никадәр мал әрәм ята бит?!* К.Тинчурин

**ИХЫЛДА́У** *ф. сир. сөйл.* «Их» дип кую, нәрсәгә дә булса үкенеп көрсенү. *Хәбир, эчеп бетергәч, ихылдап тамак кыра-кыра, тирән итеп тын алды ---.* З.Зәйнуллин

**Ихылдап кую** Кинәт, бер тапкыр ихылдау

**ИҺ** *ы. к.* **их**. *Иһ, тынгысыз җан да инде бу председатель, дип уйлады Мидхәт ---.* М.Хәбибуллин. *Койрыгын күрсәтсә... Иһ, әбиең юк. Ул булсамы? Әллә нинди риваять, әкиятләр сөйләр иде.* Р.Мулланурова. *«Иһ, бездәге ак төннәрне күрсәгез сез!» – диләр.* Сөембикә

**И́ҺА-ҺА** *ы.* 1) Ат кешнәгән тавышны белдергәндә кулланыла

2) *күч.* Кычкырып, ямьсез итеп көлүне белдергәндә кулланыла. *Безнең Арча-Саба ягында андый шаярулардан «иһа-һа» килеп кешнәп бер көләләр дә шуның белән бетә.* М.Мәһдиев

**ИҺАҺАЙЛА́У** *ф. к.* **ихахайлау**. *Алар башта мәче тычкан белән уйнагандай уйныйлар, шаяралар да соңыннан иһаһайлап көләләр.* Г.Бәширов. *Су буе шау-гөр килеп, иһаһайлап аны озатып калды.* А.Гыйләҗев. *Янә иһаһайлап көлгән тавыш.* А.Әхмәтгалиева

**ИҺАҺАЙ-МИҺАҺАЙ** *и. сөйл. к.* **ихахай 2.** (*2 мәгъ.*). *Энекәшләре күргән булса, борып кайтарып җибәрерләр иде. Ә теге иһаһай-миһаһайларга нәрсә?..* Э.Касыймов

**И́ҺА-ҺА-ҺАЙ** *ы.* Үзара чакырып эндәшкәндә, адашып кайдалыгыңны белдерергә теләгәндә кычкырып әйтелә торган аваз, өн. *Ерактанмы тавыш ишетәмен: «Иһа-һа-һай!» Бу кем мондый төндә? Әллә салчы суга батканмы?* Ф.Кәрим

**ИҺИ** *ы.* Шаккату, гаҗәпләнү кебек хисләрне белдерә. *«Москвич» машинасы --- чокырга төшкән иде. – Иһи,*

*матурым, мондый ермактан синең белән мин генә сөйрәп чыгара алмабыз моны, – диде Харис.* З.Вәли. *Иһи, безнең якта инде ул шәфталу – телеңне йотарлык.* Р.Вәлиев. *«Иһи! – дип куйдым мин. – Бөтенләй бүтән якка килеп чыкканмын ич: уңгарак алдырганмын, күрәсең», – дип, ялгышуыма гаҗәпләнә-гаҗәпләнә, --- таудан төштем.* И.Тургенев

**ИҺИК** *ы.* Көләсе килмичә кыланып көлүне, балаларның капризланып елавын белдергәндә кулланыла. *– Нинди гаҗәп... Иһик, иһик... – Йотарсың телләреңне...* Н.Исәнбәт

**ИҺИ-МИҺИ** *ы. к.* **иһи**. *Кызлар, иһи-миһи килеп, егетләрнең исемнәрен кычкыралар.* М.Хуҗин

**ИҺИ-ҺИ** *ы. к.* **иһи**. *Иһи-һи, келәмгә күзең төштемени? Алты йөз илле тәңкә тора бит аның шушы аяк астына сала торганы да.* Ф.Баттал. *Иһи-һи, кызым, Газр-раил юлдадыр-р, канатлар-рын җилпидер-р, мин китәр-рмен озакламый.* Н.Гыйматдинова

**ИҺИ-ҺИ-И** *ы.* 1) *к.* **иһи**. *Полковник --- тагын авыр сулады: – Иһи-һи-и, апа... Моның бит берсе инде өч таплкыр унбишәр тәүлек утырып чыккан.* М.Мәһдиев

2) Мыскыллап көлгәнне белдергәндә кулланыла

**И-ҺИ-ҺИ** *ы. к.* **иһи**. *– И-һи-һи... – дип сузды карчык. – Бик кыен икән, балам, хәлләрең, кыен икән.* Х.Сафина. *И-һи-һи, бәйрәмнәрдә өзелгән үзәк!..* Ш.Рәкыйпов

**ИҺ-ҺА-АҺА-ҺА-ҺА** *ы. к.* **иһи**. *Шул чакта чана эчендәге берәр малайның чыдамы бетеп, эчендә туа башлаган очу теләген авазга әйләндереп кычкырып җибәрә: – Иһ-һа-аһа-һа-һа-а-а!* З.Зәйнуллин

**ИҺИЭ** *ы.* Акрын гына, чак ишетелерлек итеп мышкылдап елауны белдерә. *– Әбделбәр... иһиэ, иһиэ... синең... синең... ә... ә... әтиең юк, диде миңа! – дип, көчкә генә әйтеп чыга Габдулла, һәм күз яшьләре аны әүвәлгедән дә ныграк буалар.* Ә.Фәйзи

**ИҺО-ҺО-ҺО** *ы. к.* **иһа-һа** (*1 мәгъ.*). *[Атлар] Күзләре белән күрәме, әллә адымыңнан танымы – син якынаюга, назланып кешнәп җибәрә: – Иһо-һо-һо!* Н.Әхмәдиев

**ИҺРАМ** *и. гар. иск.* Борынгы Мисыр фиргавеннәренең каберләре өстенә төзелгән һәм нигезе дүртпочмактан, ян-яклары бер түбәгә тоташкан өчпочмаклардан торган бик зур таш корылма; пирамида. *Кабышев ул опалубкаларны Египет пирамидаларына – иһрамнарга охшата. Дөрес, алар иһрамнарның меңнәрчә мәртәбә кечерәйтелгән макетларын хәтерләтә: шулай ук өскә таба кечерәйгәннән-кечерәеп менәләр.* Р.Кәрами

**ИЧ** *кис.* 1) Сөйләмнең төп эчтәлегенә раслау төсмере өстәү, хәбәрнең тыңлаучыга мәгълүм булганлыгын яисә мәгълүм булырга тиешлеген аңлату, фикерне көчәйтү яки куәтләү өчен кулланыла. *Андый хәлнең булганы да юк ич.* Ш.Камал

2) Җөмләдә белдерелгән фикергә аеруча басым ясап, ышандырып әйткәндә кулланыла; бит. *Мохтар тагын: «Тукта, дим, батасың ич!» – дип кычкыра.* Ш.Камал. *Гали абый кебек кешеләр монда да бардыр ич!* Г.Әпсәләмов. *Югыйсә, тимерче Әхмәт углы Бәкер – хан кызына өйләнердәй хөрмәткә ия кеше ич.* М.Хәбибуллин

**ИЧМАСА(М)** *кер. сүз* **1.** 1) («Һич булмаса» тезмәсеннән кыскарган). Ахыр чиктә, бер дә булмаса, һич булмаса, шунысы гына булса да. *Кычкырмадың да бит, ичмасам, узып киткән кыр казы сыман.* Г.Рәхим. *Шунда, минем арттан чапканда, трамвай да басмый, ичмаса, үзеңне!* М.Маликова. *Бәгырьләре каткан салкын күзле балаларга ни дә булса төшендерсәм, тормышның ямьле икәнлеген, ичмасам, энә очы хәтле генә күрсәтә алсам да, сабый бала кебек сөенә торган идем.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) Һич югында. *«Ичмасам, күңел өчен генә дә «барып чыгыгыз» дип әйтми бит, мәлгунь!» дип уйлап куйды ул.* Ш.Камал. *Ичмасам, адәм рәтле кешегә дә чыкмаган...* Ф.Бурнаш. *Шушы кар диңгезе уртасында айга карап, Есенин әйткәнчә, көчек булып бер улыйсы килә икән! Ичмасам, бер күңел басылыр иде...* М.Мәһдиев

3) Җитмәсә, җитмәсә тагы; өстәвенә, шуңа өстәп. *Баласы гына да, ичмасам, адәм рәтле булмады!* Ш.Камал. *Якында гына кешесе дә юк, ичмасам.* Р.Ишморат. *– Ичмасам, улларым да кайтып җитмәде ---, – диде карчык ---.* А.Шамов

**2.** *кис. мәгъ.* 1) Күбесенчә *менә* алмашлыгы белән килеп, мактауны, хуплауны, соклануны белдерә. *Менә Гыйлаҗи егет, ичмасам!..* Г.Ибраһимов. *Менә шигырь бу, ичмасам!* М.Җәлил. *Фәтхи моны укыгач: «Менә ичмасам хәбәр!» – дип, шатлыгыннан киң итеп елмаеп куйды.* Ш.Камал

2) Хәтта. *Мәүлиха түтине җибәрмим! Ичмасам, тешеңне дә агартма!* Г.Бәширов

**ИШ** *и.* **1.** 1) Матди, рухи яки башка яктан тиң, пар булырлык кеше, үзе кебек кеше; тиңдәш. *--- кешеләр, туган чакта ук, үзләренә билгеләнгән ишләре белән туалар ---.* Ә.Еники. *– Зөмәрә, син үзеңә тиң иш тап, – диде Фаяз, көлә-көлә.* Х.Камалов. *Нәркиснең яшьтәшләре фронтта кырылып бетләр. Нәркис үзенә иш тапмады ---.* М.Мәһдиев // Теге яки бу яклары белән бер-берсенә охшаган, бер үк төрле характердагы кеше. *Ә ир-ат халкының барысы да бер иш, дигән сүз хак икән ---.* Р.Мөхәммәдиев

2) Кайберәүләр; аерым кешеләр. *Ни өчен --- бер ишләр бай булган да күпчелек ярлылыкта интеккән?* М.Хуҗин. *Түйкә белән килгән егетләрнең бер ише, атларны җыйнап, Бәрсуан буендагы әрәмәлек арасына алып китте.* В.Имамов

3) Бер үк материалдан эшләнгән, бер үк сыйфаттагы, бер үк төрдәге әйбер; нәрсәнең дә булса кайсыдыр ягы (төсе, сыйфаты) белән охшаган тиңе. *Аклы ситсы күлмәгемнең Таба алмадым ишләрен.* Җыр. *[Динә] Күз нурыңны алырлык итеп зәңгәрдән киенгән (күзләре төсенә иш итеп тектергән җиңел затлы күлмәк!), аш-су тирәсендә әвәрәләнгәч, ак алъяпкыч бәйләп җибәргән.* Б.Камалов

4) Дус, иптәш, әшнә. *Ишләре арасында ул, гомумән, замана музыкасын иң әйбәт белүчеләрдән санала...*

А.Сафин. *Биккол сәүдәгәр үз күзләренә үзе ышанмый, артында басып торган ишләренә борылып карады ---.* М.Хәбибуллин. *Ни дип, күрәсен күргән, яшисен яшәгән Чалабайга ияреп, шуңа иш булуына юанып, егет башы белән мәхлук сарыклар артыннан теркелди?* Т.Әйди

5) Нинди дә булса билгеләре белән бердәй булган, бер төр. *Яшь агачлар шаулый кырда Иш булып каеннарга.* Җыр

6) Пар. *Нажия – ялгыз яши алмый торган аккош шикелле ул, аның янында, бер адым читкә китмичә, карап, сагалап торучы ата ише булырга тиеш.* Ә.Еники

7) Өлеш, кисәк. *Ул бодайның бер ишен триер аркылы уздырырга, бер ишесен кояшта җылытырга кушты.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Парлы, бер-берсеннән башка яши алмый торган. *Иш күгәрченнәрдәй гөрләшеп гомер иткән идек тә бит...* М.Хәбибуллин

2) Бер үк материалдан эшләнгән, бер үк сыйфатлы, бер үк төрдәге. *Куе шәмәхә төстәге костюм, ак күлмәк, костюмына иш галстук аңа гаҗәеп килешеп тора.* Б.Камалов. *--- колхоз канцеляриясе --- гел бер иш нарат бүрәнәләрдән салынган, --- урам башы өенә урнашты.* М.Хуҗин

**3. ише** *бәйл. функ. тарт. форм.* 1) Сорты, төре белән икенчесенә якын әйбергә карата әйтелә. *Буш күлгә кәрәкә, чабак, алабуга, чуртан ише әрсез балыклар җибәреп карыйлар, берсе дә үрчеп китми.* А.Муранов. *– Ташладыгыз, димәк? – дидем, бу юлы инде ышанмыйча, чөнки беләм: хатын-кыз алкоголизмы ул ирләрнеке ише генә түгел.* Сөембикә

2) Кебек, шикелле, төсле, сыман. *Аңла, Әскәр, моның серен бары тик минем ише яңа тормыш башлап җибәргән сабырсыз җилкенчәкләр генә аңлый ала.* З.Вәли. *Безнең Закирә, бер түгел, биш баласы булса да, синең ишеләргә алыштыргысыз.* С.Зыялы. *Алтынчәчнең кәефе начар түгел, бер җире дә сызламый. Ә йөрәк кагу, тын бетү ишесе мондый чакта һәркемдә була.* М.Маликова

◊ **Ишәй белән Кушай** Гел бер-беренә тагылып, бер-береннән аерылмый йөрүче кешеләр. *– Мактарлык булмагач, килеп тә йөрмиләр, – дип, алып килгән шешәләрен өстәлгә тукылдатып утыртты ирләрнең өлкәнрәге. – Ишәй белән Кушай кебек парлашып торсыннар.* З.Фәйзи. *Тотындылар болар [Силушкин белән Рудаков], нәкъ Ишәй белән Кушай. Гәүдәгә дә, төскә дә бер чамадарак үзләре.* С.Шәрипов. **Иш белән куш** *к.* **Ишәй белән Кушай**. **Иш ише белән** Сәяси, икътисади, социаль яки рухи яктан бер-беренә охшаган кешеләрнең бердәм булулары, бер-берсен якын күрүләре турында әйтелә. *«Иш ише белән» дигән шикелле, байлар бай белән аралашадыр, абыстай һәм башка бай хатыннары белән танышадыр.* Ш.Мөхәммәдев. **Ишкә куймау** Санламау, санга сукмау, ихтирам итмәү. *Син, Чемберлен агай, карап торам, Безнең ишне ишкә куймыйсың.* Һ.Такташ. **Иш янына куш** Нәрсәгәдер өстәмә кушымта булу, берсе өстенә икенчесе өстәлү. *Шамил кулына кергән биш сумны җиргә ташламады. Чеметеп җыйсаң, учлап ашарсың, ди, аннан – ун тиен, моннан – ун, иш янына куш, дигән сүз.* З.Вәли. *Салкын тию дә шуннан башланды бугай. Апрель җитү белән тәрәзәләрнең эчен-тышын юу иш янына куш булды.* С.Сөләйманова. *Мин алып кайткан салам әллә ни күп булмаса да, барыбер иш янына куш булып тора әле ул.* З.Хөснияр

**ИШАН** *и. фар. дини* 1) Идел буе мөселман халыкларында суфилар остазы; дини яктан абруйлы, дин гыйлемен яхшы белүче мөгаллим. *Ишан – Алла илә бәндә арасында васыйта булып, алдан хәбәр бирүче бер кеше.* Г.Тукай. *Ишан хәзрәтнең мөритләрен һәм башка байларны – барын хисапласаң, дүрт йөзләп кеше булгандыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Шулай, көннәрнең берендә бер мөрит, ишан хәзрәтнең кулын үбеп кайтканда, безгә кунарга туктады.* Т.Гыйззәт

2) Урта Азия мөселман халыкларында чыгышы белән Мөхәммәд пәйгамбәр нәселенә тоташкан кеше

3) *куч.* Дөнья эше белән кызыксынмаучы, бик тәкъва, динле кеше. *Алар башта мине, эчмәгән, тартмаган, карта уйнамаган өчен, бигрәк тә хатын-кызга карамаган өчен, «ишан» дип мыскыл итәләр иде.* Г.Ибраһимов

◊ **Ишанга кул бирү** Ишанның мөрите булу, аңа рухи яктан ияреү. *Гайнулла хаҗи Казанда тәкъвалык, суфилык илә атаклы булып, Казан тирәсендәге бер зур ишанга кул да биргән иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Мондагы халыкларның күбесе – ишанга кул биргән мөритләр.* Ә.Камал. **Ишан хилкасы** Мөритләрнең түгәрәкләнеп, ишанны уртага алып үткәрә торган дини мәҗлесе. *«Мәдрәсә» дип, нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе, Нәкъ эче азган мөрит, [акылдан язган] ишаннар хилкасы.* Г.Тукай

**ИШАНЛЫК** *и.* Ишан булу, ишан дәрәҗәсе. *Ишанлык мәсьәләсе татар матбугатында бик күптәннән бирле язылып кил[ә].* Ф.Әмирхан. *Бу кеше, заманына күрә аңлы булып, яңалык тарафдары, ишанлык һәм суфилыкка каршы иде.* М.Гафури. *Автор, ишанлык кебек, сатира объекты булып калган күренешнең социаль йөзен, --- иҗтимагый табигатен фаш итүне проблема итеп ала.* Казан утлары

**ИШАНЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Ишан булып тору, мөритләр белән җитәкчелек итү. *Монда кайткач инде [ул] Ишанлык итәргә башлаган.* Н.Думави

**ИШАНЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **ишанлык итү**. *[Аның максаты] – Мөдәррис булып, ишанлык кылып, байларны кулга алып, барча муллалар вә мөдәррисләргә өстен булып – гомерен рәхәт кичермәк.* З.Һади

**ИШАРӘ** *и. гар.* 1) Нәрсәнедер сүзсез аңлату өчен, кул, баш, күз ярдәмендә ясалган төрле хәрәкәт, ым. *Актык мәртәбә кергәнемдә, ул мине бармак ишарәсе белән генә чакырып алды ---.* Г.Ибраһимов. *Газизә баш ишарәсе белән генә риза булганлыгын аңлатты.* Ш.Камал. *Чжу карт аның үз авыллары икәнен кул ишарәсе белән аңлатты.* А.Шамов

2) *куч.* Ачыктан-ачык, турыдан-туры әйтмичә, читләтеп кенә сиздерү; киная. *Келәттән чыккач, егетләрнең берсе, үз иткәндәй, минем җилкәмә*

*кулын салды. Бу дуслык ишарәсе миңа бик ошады.* Ә.Еники. *Хәл белешергә кергәләп йөргән күрше-күләннән Кәшифә авыл хәлләрен, һичшиксез, белеп торгандыр. «Теләгән кешеңне сайла» дигән сүз шуңа ишарә иде.* М.Галиев. *Хуҗа хатынның яшерен ишарәсе буенча, кунаклар акрынлап юкка чыктылар.* Р.-Н.Гүнтәкин

3) *күч. к.* **ишарәт** (*4 мәгъ.*). *Егерме чакрымнан артык араны җәяүләп атладылар. Кешеләр дә, кош-корт та, тереклек ишарәсе дә сизелми.* Г.Ахунов

4) *иск.* Билге, тамга. *Нечкәлек ишарәсе*

5) Суфичылыкта: теге яки бу гамәлне кылуга илаһи күрсәтмә, галәмәт

**ИШАРӘ́ БАРМАК** *и. к.* **имән бармак**. *[Күрәзәче] Ханга телен чыгарып, ишарә бармагын куеп, монда җитди кисәтү барын белдерә.* Н.Исәнбәт

**ИШАРӘ́ ИТҮ** *ф.* 1) Баш, йөз, күз, кул хәрәкәте белән нәрсә дә булса эшләргә кушу. *Гатау Гәрәйгә калырга ишарә итә.* М.Фәйзи

2) Ымлау, күрсәтү. *Хәят чәчәкләрне йөзенә якынрак китерде дә күзләре белән Михаилга ишарә итте.* Ф.Әмирхан. *Ул бераз үзенең дә гаебен таныган сыман, чак кына көлемсерәп, башы белән өстәлдәге рәсемгә ишарә итте.* Г.Бәширов

3) *күч.* Ачыктан-ачык, турыдантуры әйтмичә, читләтеп кенә сиздерү

**ИШАРӘ́ КЫЛУ** *ф. к.* **ишарә итү**. *Гали хәлфә кайтып, хәзрәтнең килеп җитүен белдерер өчен, безгә ишарә кылу белән, без һәммәбез дә утырып тып-тын калдык.* М.Гафури. *Бәдигылҗамал аңа төрле ишарәләр кыла, ләкин аны Гөлҗамал күрми.* Г.Камал. *Рәшит бәй әфәнде минем белән французча сөйләште. Сүз арасында минем, әлбәттә, җиңеп чыгачагыма ишарә кылды.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ИШАРӘЛӘҮ** *ф.* 1) Кулны, башны хәрәкәтләндереп, нәрсәгә дә булса күрсәтү, ишарә ясау. – *Әйдә син, Габделхак, бар әле, – диде һәм башы белән ишеккә таба ишарәләде дә кайракны, малайдан алып, үзе әйләндерә башлады.* Г.Гобәй. *[Гарифулла] Аннан куллары белән ишарәләде: – Монда – Уфа, монда – Кинәле!..* А.Хәлим. *Рәмилә тагы Гөлкәйгә төртеп алды, күзләрен уйнатып, ишеккә ишарәләде.* Х.Ширмәт

2) Ым белән нәрсә дә булса эшләргә кушу яки ризалык белдерү; әйтергә теләгәнне ым белән аңлату, ымлау. *Синең белән тәрәзә аркылы аңлашып булмас, дигән сыман, ул кызыйга узарга ишарәләде.* Г.Ибраһимов. *Ишарәләп тоз сорады ул. Тегеләр бик тиз аңладылар.* И.Гази. *Әмир азатларга халыкны тыярга ишарәләде.* М.Хәбибуллин

3) *күч.* Турыдан-туры әйтмичә, читләтеп аңлату; кинаяләп әйтү, нәрсәгәдер фикерне юнәлтү. – *Сезнең эш түгел бу, Аллаяр, тимә минем икмәккә. Морг докторы операциянең файдасыз икәнлегенә ишарәли.* С.Сөләйманова. – *Язмышыгыз авырлыгына ишарәлисез кебек, – дип, Фидаянең дәвам итүен теләдем мин ---.* М.Хуҗин. *[Минем шефлар] Җиңүчеләр озакламый гаугалашып бетәчәк, алман халкы шулчак хәрабә астыннан шытып чыккан гөлдәй тагын аякка басачак, дип ишарәлиләр.* Т.Әйди

**Ишарәләп кую** Бер тапкыр ишарәләү

**Ишарәләп тору** 1) Әле, хәзер нәрсәгәдер ишарәләү

2) Һаман, гел ишарәләү

**ИШАРӘЛЕ** *с.* **1.** Нәрсәгә дә булса ишарә ясаган, кинаяле итеп, читләтеп сиздерелгән, әйтелгән. – *Артта батырланып, «дөреслек» дип тукынасыз, ә дөреслек алга килгәч, шуны якларга куркасыз... – Надир тавышын күтәрде, юка иреннәре ишарәле елмаю белән җәелде.* Х.Камалов. *Нина инде җыен мокытның --- әллә нинди ямьсез ишарәле, мәгънәсез комплимент әйтүләреннән бик туйган иде.* Ә.Еники. *--- кыз кыланчыкланып --- тел очын ирен читеннән чыгарып ала, аның керфек арасыннан нindидер ишарәле ымсындыргыч чаткылар сибелә.* Р.Зәйдулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса ишарә ясаган кебек, кинаяләп, читләтеп. – *Сорап торасың тагы, кем шулай түгел соң? Тартакиевнең --- зәңгәр күзләре кысылыбрак ишарәле карады.* Х.Камалов

**ИШАРӘТ** *и гар.* 1) Кул, баш, күз хәрәкәтләре белән аңлатылган ым, мимика. *Аңлаганга – ишарәт, аңламаганга бишәр әйт.* Мәкаль. *Мулла аңа кулы белән ишарәт итеп, күзләрен йомып торырга куша.* Ш.Камал. *Ул танталы рәвештә сәхнәгә чыгып, халыкка тавыш-тын чыгармаска ишарә итеп, уң кулын югары күтәрде ---.* Ш.Камал

2) Берәр нәрсә эшләнәчәге, эшләнергә тиешлеге турында сигнал, билге. *Бары да – хәерсезлеккә ишарәт.* Г.Тукай. *Кәккүк тавышы, ---, бу – безгә ишарәт. Таралыштык.* Н.Исәнбәт

3) Тамга, билге. *Миңа козгын да кычкырды. Боларны аеру өчен, бу бүлекләрдә миңа озын сызык, кыска сызык, бер нокта кебек ишарәтләр кулланырга туры килде.* М.Фәйзи

4) *күч.* Нинди дә булса эш-хәрәкәтнең, вакыйганың эзе, галәмәте, әсәре. *Кырлыганның көзгедәй якты кыйпылчыклары ай яктысында күзгә күренеп ишәя. Бу – инешнең, авылга таба саегая барып, сазлану һәм сызлану ишарәте.* А.Хәлим

5) *күч.* Үзеннән соң аңа бәйләнеп килгән сүзнең билгесе, галәмәте булырлык, аңа охшаган әйбер, нәрсә

6) *күч.* Нәрсәгә дә булса аз гына охшаган, шуны хәтерләткән әйбер. *Көннәрдән бер көнне инәләре лар төбен себергәләштереп, балтырган шулпасына бер-ике уч он әсәрәсе сибеп, аш ишарәте пешерде.* А.Хәлим

◊ **Ишарәтен китерү** Бөтен таләпләрен төгәл үтәү; җиренә җиткерү, шартын китерү. *Үсентеләрне шул әйткән чүлмәкләргә утырткан идем... Күрәсең, ишарәтен китереп җиткерә алмаганмын, [үлделәр].* Г.Насрый

**ИШАРӘ СӘЛАМЕ** *и.* Кулны күкрәккә куеп яисә башны иеп, яки кулны күтәреп, сүзсез генә сәламләү. *Оҗмах хуры кебек өч кыз бала миңа таба күз сала. Шуннан кулымны күкрәгемә куеп ишарә сәламе бирдем.* Т.Гыйззәт

**ИШАРӘ́Т БАРМАГЫ** *и. к.* **имән бармак**. *Бер карт, иптәшемә таба борылды да, ишарәт бармагын бутап: «Гайнетдингә әйтергә кирәк», – диде.* Ш.Камал

**ИШАРӘ́ ТЕЛЕ** *и. лингв. к.* **ишарәт теле**. *Башка төрле балыклар да «ишарә теле»ннән файдаланалар.*

Кызыклы ихтиология. *Ишарәләр телен чукрак кеше яхшы аңлый.* Кызыклы физиология

**ИШАРӘ́Т ИТҮ** *ф. к.* **ишарә итү**. *Сафый күзе белән Рокыяга ишарәт итә.* Ф.Әмирхан. *Ә кыз көтә. Серле карашы нидер ишарәт итә.* Ф.Фәтхелислам

**ИШАРӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **ишарә итү**

**ИШАРӘ́Т ТЕЛЕ** *и. лингв.* Төрле ишарәләр, хәрәкәтләрдән торган аралашу чарасы

**ИШӘК** *и.* 1) Атлар ыругыннан булган, 1–1,2 метр биеклектәге, гадәттә соргылт төстәге, зур авызлы, озын колаклы, кечерәк гәүдәле, аркасына йөк салып ташу өчен асрала торган хайван; *русчасы:* **осёл**. *Мужикның юаш кына бер ишәге бар иде.* Г.Тукай. *Төрле-төрле телләрдә, шивәләрдә сөйләшүче базаркәннәрнең шау-шуын күмеп, дөяләр кычкыра. Сыерлар мөгри, ишәкләр акыра, атлар кешни...* Ф.Латыйфи. *Урамга чыккач, ишан хәзрәтләрен көмеш иярле, көмеш йөгәнле, --- кечкенә ишәк өстенә күтәреп атландырдылар.* Ә.Еники

2) *күч. гади с.* Аңгыра, ахмак, булдыксыз, кулыннан эш килми торган кеше турында. *«Ишан» исемле ишәкләр күп бит.* Г.Тукай. *Без – Шамраевка ияргән ахмак ишәкләр – кыланып, телләребезне чыгарып, түшәмгә карап акаеп калдык.* В.Нуруллин. *Ә ул, ишәк, кирәкле кешенең акчасын отып, үзенең академиягә әләгү, күтәрелү мөмкинлеген оттырып утыра. Менә бит ул тәрбиясез үскән сала йолкышы!* М.Юныс

3) *күч. гади с.* Кире, үзсүзле, үҗәт, авыр холыклы кеше турында. --- *теге шофёр да ишәк төсле кире адәм булып чыкты.* М.Маликова

◊ **Ишәк сугару (сугарып йөрү)** Вакытны заяга, бушка уздыру, кирәк эш артыннан йөрисе урынга, бер файдасызга, юк-бар белән йөрү. *Бозау! Ачуым да килмәгәе, Лаля белән йөридер, дип, юаныр торсам, ул анда ишәк сугарып йөри.* М.Фәйзи. **Ишәк төчкергәндә туу** Хәерле сәгатьтә туу, бәхетле булып туу турында. *Безгә Алла дәүләтен яудырып кына тора шул. Без, карчык, ишәк төчкергәндә туганбыздыр.* Д.Аппакова

**ИШӘ́К КОЛАГЫ** *и. бот. к.* **испәрәк**

**ИШӘ́К КОЛАК** *и.* 1) *бот.* Кыярчалар семьялыгыннан, дымлы болыннарда, иңкүлекләрдә, яр буйларында үсә торган, каты төкле, зур яфраклы күпьеллык үлән; су кынасы; *русчасы:* **окопник**

2) *күч. гади с. тирг.* Аңгыра, ахмак, тинтәк кеше. *Их, ишәк колак! Тавык тәпиенең ни кирәге бар?* Ш.Камал

**ИШӘКЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Кешегә эшләү, кемнең дә булса файдасына эшләү, хезмәт итү. – *Ташбашларың өчен күп ишәкләндем, җитәр! – диде Даян.* Х.Камалов

**ИШӘКЛЕК** *и.* Кирелек, үҗәтлек, үзсүзлелек. *Ишәк ишәклегенә барыр.* Мәкаль. *Ишәк янына атны бәйләсәң, ишәклеге йогар.* Мәкаль

**ИШӘКЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Киреләнү, үзсүзләнү, үҗәтлек күрсәтү. – *Белəм нахаклыгымны, --- итәм ишәклегемне.* Г.Тукай

**ИШӘ́К МАРУЛЫ** *и. бот.* Кычу үләннәре семьялыгыннан, чәнечкеле озын сабаклы ике яки күпьеллык үсемлекләр ыругы; *русчасы:* **ворсянка**

**ИШӘ́К МИЛӘҮШӘСЕ** *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, кыска сабаклы, чәчәгенең кырыйлары ак, ал яки кызыл, ә уртасы ак булган бер яки күпьеллык бакча үсемлеге; *русчасы:* **маргаритка многолетняя**

**ИШӘЮ** *ф.* Сан ягыннан күбәю, арту; үсү, зураю. *Авылда сүз тиз тарала. Таралган саен, яңа төсмер ала, ишәя.* С.Зыялы. *Су өстендәге дулкыннар ишәйде.* З.Хөснияр. *Сугыштан соң, тегенди-мондый җай табып, аттестат, таныклык алырга йөрүчеләр ишәйгән.* М.Мәһдиев

**Ишәеп китү** Кинәт ишәю. *Семья да бик ишәеп китте.* М.Гали. *Соңгы ун-унбиш елда бакчалар бигрәк ишәеп китте.* С.Шәмси. *Айлар, еллар үтте, --- яланнарны ягы-ягы белән сарут басты, хәтта, авылда күгәрченнәр кимеп, каргалар ишәеп киттеләр.* Ә.Еники

**Ишәеп тору** *к.* **ишәя тору**

**Ишәя бару** Торган саен күбрәк ишәю. *Әчтәгә нәни ялкын теле, корыган каен тузына капкандай, зурая, ишәя баргандай булды.* М.Маликова. *Яңгыр тамчылары вак иде, ләкин алар минут саен ишәя барды.* М.Шәфигуллин. *Әмма күңелне берөзлексез, идән астында кыштырдаган тычкан сыман, нидер борчып, тынгысызлап тора. Торган саен арта, ишәя бара иде бу тынгысызлык.* Р.Мөхәммәдиев

**Ишәя башлау** Ишәергә тотыну. *Бармак белән генә санамалы чын шагыйрьләр янәшәсендә, шигырь чыгаручылар, үзләрен «шагыйрь» дип исәпләүчеләр бик нык ишәя башлады.* Р.Миңнуллин. *Төрле илләрдән килгән сәүдәгәрләр ишәя башлагач, хан аларга кәрвансарай салдырды.* М.Хәбибуллин

**Ишәя килү** Әкренләп ишәя бару. *Хезмәтендә шомара барган саен, [Нәзирнең] кереме дә елдан-ел ишәя килде ---.* Т.Әйди

**Ишәя тору** Бер-бер артлы артып ишәю. --- *оныклар бер-бер артлы ишәя торалар.* Р.Әбүбакирова

**Ишәя төшү** Бераз ишәю, тагын да арту, күбәю. *Баштарак читтән-чатанрак кодрәтләнгән хатын-кызлар, ишәя төшкәч, берьюлы батыраеп --- киттеләр.* Ф.Хөсни. *...Тора-бара «туган көннәр» ишәя төште.* Р.Мөхәммәдиев. *Гаиләсе ишәя төшкәч, ул [Зөһрә ханым] җәмәгать эшләрендә катнашу белән чикләнә башлаган.* И.Нуруллин

**ИШГАЛЬ** *и. гар. иск. кит.* 1) Берәр эш, уй белән мәшгуль булу; шөгыль. --- *Мәрҗанинең тарихи ишгаль вакыты Казанда шәрык галимнәренең бик рәваҗдә вакытына тугры килгән.* Г.Гобәйдуллин

2) Биләү, биләп алу; оккупацияләү

**ИШГА́ЛЬ ИТҮ** *ф. иск. кит.* 1) Нинди дә булса эш яки күренеш күңелне биләп алу, мәшгуль итү. *Ләкин болар берсе дә аны ишгаль итмиләр, күңелен юандырмый иделәр; аның бик эче поша иде.* Ш.Камал

2) Урын алу, урын биләү. --- *анасы, берүзе ике кешелек юлны ишгаль итеп, скамьялардагы кешеләрне дикъкатьләп карый вә нәрсәдер Разиягә сөйли иде.* Ф.Әмирхан

**ИШГА́ЛЬ КЫЛУ** *ф. иск. кит. к.* **ишгаль итү**. --- *XVI–XVII гасырда татарларны Идел буе вә яхшы җир-*

*ләрдән куу аркасында, татарлар начар җирле, коры урыннарны ишгаль кылып утырганнар.* Г.Гобәйдуллин. *Бу соңгы килүендә исә ул бу уйлар, бу өметләр, бу гали хыял вә идеяләрнең һәммәсеннән аерылган; тормышның каты дулкыннары эчендә алар бар да югалып бетеп, урыннарын «мәнафигы шәхсия» фикере тәмам ишгаль кылган иде.* Г.Ибраһимов

**ИШЕГАЛ** *и. сөйл. к.* **ишек алды**. *[Кешеләр] Елмаешып капка ачтылар, йөгәненнән тотып, атны ишегалга алып керделәр.* Н.Фәттах

**ИШЕГАЛДЫ** *и.* Өй янында коймa, каралты-кура стеналары белән әйләндереп алынган җир; терлекләр, хуҗалык әйберләре өчен буш, ачык урын. *Күк «Волга»ны ишегалды уртасына, нәкъ юл өстенә китереп куйганнар.* М.Маликова. *Ишегалдының түрендә, зәңгәр күк читендә, кабара-кабара, кайный-кайный ак болытлар агыла. Хәмдиянең кибәргә элгән керләре ул.* Г.Галиев. *Ишегалдында гамьсез генә чүпләнгән тавыклар, пырхылдашып, як-якка сибелделәр.* М.Галиев

**ИШЕК** *и.* 1) Йорт һ.б. корылманың, эченә кереп-чыгып йөрү өчен, стенасына ясалган уем һәм аңа беркетелгән ачылмалы-ябылмалы каплавыч. *Ишек катындагы чөйдә иске тун белән мескен бүрек эленеп тора.* М.Хәсәнов. *Газзә ишек борысына капланып үкси башлады.* М.Маликова. *Абзар түбәсеннән төшкәндә искәреп алам: өйалды ишеге төбенә хәтле ачып куелган.* М.Галиев

2) *күч. шигъ.* Бәхеткә, рәхәт тормышка, белемгә һ.б.ш.ларга илтә торган яки эчке серләрне белергә мөмкинлек бирә торган юл, ачкыч. *Матур җәннәт ишекләрен үз кулың белән япма!* Г.Коләхмәтов. *Бәхет ишекләре ачыла, диеп Көткән чакта, тагы ябыла.* М.Гафури. *Өметнең ишеге бәләкәй шул, чынбарлык аннан сыеп эчкә үтә алмый...* М.Галиев

3) *күч.* Кешенең эчке, рухи дөньясы. *Әйе, өлкәннәр халкын аңлап бетмәссең: аларның күңел ишекләре, Канәгатьләр ишеге кебек, чыбык белән генә бикләнми.* А.Хәлим

◊ **Ишек артында гына** Бик якында, борын төбендә генә. **Ишек ачу** Кемгә дә булса керү, якыннан катнашып, аралашып йөрү, очрашкалап-күрешкәләп тору турында. *Гайшә инде безнең кебек ялгыз-ябаганың ишеген ачарга теләмәс.* Ф.Бурнаш. **Ишек ачык** 1) Һәрвакыт зур теләк, якты йөз белән кабул итүне аңлатканда кулланыла. – *Син чакырсаң, синдә дә бер төн кунып чыга алам. – Синең өчен ишегем һәрвакыт ачык.* И.Гази; 2) Теләсә кая барырга, керергә, теләсә нәрсә эшләргә мөмкинлек, җай, ирек булуны аңлата. *Һәммә җирдә безгә ишек ачык, «Доклад белән» керү үтенелми.* М.Җәлил; 3) Китәсе килгән кешене көчләп тотмауны белдерә. *Һөрениса – улының, Кифаятхан кызының беркатлылыгына эчләре пошып һәм Сәидәнең керүенә кәефләре китеп, нишләргә белмәделәр. Эчләреннән «Килгән юлың такыр, ишек ачык!» диебрәк сыкрансалар да, тышларына чыгармадылар.* А.Каһһар. **Ишек кагу (шаку)** 1) Берәр кеше янына яисә оешмага йомыш, үтенеч, гозер белән килү. *Тоткын булып үз иленДә Ишек кактың бүгенгә син.* Р.Рахман. *Гали баба бу юлы да иң элек Мәхүбә карчыкның ишеген какты.* Ф.Хөсни; 2) Нәрсә дә булса белергә теләп мөрәҗәгать итү. *Әдәби образлар ничек туалар? Монысы инде язучының иҗат лабораториясенең ишеген кагу була.* Г.Әпсәләмов; 3) Нәрсәнең дә булса якынлашуын, килеп җитүен сиздерү, белдерү. *Көзге салкыннар ишек кага, безнең әле утын да әзерләнмәгән.* Н.Исәнбәт. **Ишеккә бару (килү)** Кемгә дә булса берәр төрле йомыш, үтенеч белән мөрәҗәгать итү; йомыш төшү. *Башка кешегә сатар иде, кирәк вакытта аның ишегенә барып булмас дип курка Сәмигыл карт.* М.Гали. **Ишеккә ишек** Кара-каршы яки янәшә. *[Фәридә белән Гөлгенә] Күршеләр, ишекләре ишеккә орынып кына тора.* Л.Ихсанова. **Ишеккә карап елап, түргә карап көлеп** Икейөзле кешегә карата әйтелә. **Ишеккә күрсәтү** Кемнең дә булса чыгып китүен таләп итү. **Ишекнең кайсы якка ачылганын белү** Кемнең дә булса өендә моңа кадәр дә булганлыкны аңлата. *Ерак юлдан килгән кунакны --- миңа алып килергә кирәк иде. Аллага шөкер, ишекнең кай якка ачылганын беләсең.* А.Шамов. **Ишекнең кай якка ачылуын оныту** Кем белән дә булса йөрешми, аралашмый башлау яки озак бармый, аралашмый тору. *Хәдичә кунакка чыгып китәргә кушты: «Хәзергә, Мисбах дус, минем ишекнең кай якка ачылганын онытып тор».* М.Хәсәнов. **Ишек саен** Күп, исәпсез. *Үзен күзәтүчеләр ишек саен --- булган хәлдә дә ни гомер иплe генә басып тора, кабаланмый, кыбырсынмый.* Р.Мөхәммәдиев. **Ишектән куганда тәрәзәдән (тишектән) керү** 1) Әрсез, басымчак кеше турында әйтелә; 2) Бәла-каза турында. **Ишектән уздырмау** *к.* **ишек төбеннән бору**. *Мин ул гайбәт капчыгын ишектән уздырмыйм.* Н.Исәнбәт. **Ишек төбеннән бору** Йомышны үтәми яисә кунак итми, өйгә кертми кайтарып җибәрү. *[Карт] Өч тапкыр бара, ә алар аны алдалап ишек төбеннән борып җибәрәләр.* Г.Әпсәләмов. **Ишек тупсасын төшерү** Кайда да булса еш булу. *Мин шуннан соң, эш хакын алырга, бухгалтериянең ишек тупсасын төшерә башладым.* Н.Исәнбәт. *[Рәмзия] Аларның ишек тупсаларын төшереп бетерде, әмма бер эш тә чыгара алма[ды].* Г.Гобәй. **Ишек юлыннан аяк өзелмәү** Кереп-чыгып йөрүчеләр күп булу

**ИШЕ́К АЛДЫ** *и. к.* **ишегалды**. *Аучы белән Актырнак, бүрене сөйрәп, ишек алды уртасына керәләр.* А.Алиш. *Хәлим, капканы ачып, тавыклар белән тулган ишек алдына керде ---.* И.Гази. *Тар, кысрык ишек алларында яссы гәүдәле, салынкы корсаклы кара дуңгызлар йөри.* А.Шамов

**ИШЕ́К БАВЫ** *и.* 1) Ишекне тартып ачар өчен кагып куелган ике башы төенле кыска бау; ишек тоткасы. *Кияү ишек бавын тартып җибәрде.* Г.Ибраһимов

2) *этн.* Кыз куенына керергә килгән кияү тарафыннан кыз бүлмәсенең ишеген ачучы кешегә бирелә торган акча. *Кыз янына керәсе кияүне ишек төбендә балалар туктатып акча сорыйлар. Балаларга акча бирмәсәләр,*

*ишек ачылмыйдыр*: --- «*Ишек бавы – бер алтын, Безнең апай – мең алтын*». Г.Тукай

◊ **Ишек бавын басу** *этн. к.* **ишек бавын тоту**. **Ишек бавын тоту** *этн.* Кыз куенына керергә килгән кияүдән акча алу максаты белән, балаларның кыз өе ишеге төбендә саклап басып торулары. *Безнең якларда туй көнне кәләш янына керәсе кияүне --- ишек төбендә җырлап туктаталар. Гадәт буенча, кияү ишек бавын тотучыларга акча өләшергә тиеш була.* Казан утлары

**ИШЕ́К БАШЫ** *и.* Ишек яңакларын өске яктан тоташтырып торган агач. *[Ул] Ишек башына бәрелүдән курыккандай, кирәгеннән артыграк иелә төшеп чыгып китте.* М.Хәсәнов

**ИШЕ́К КАШАГАСЫ** *и.* 1) Ишек өстенә кадакланган бизәкле такта. *Ихтыяр --- стенадагы фотоларга, ишек кашагасы өстендәге шәмаилләргә, --- өйгә нур биреп торган олы ак мичкә карап ятты.* Р.Вәлиев. *Кунак акрын гына ишек кашагасын кубарды.* Сөембикә

2) Ишек башына эленә торган тукыма, пәрдә

**ИШЕКЛЕ-ТҮРЛЕ** *рәв.* Бер ишеккә, бер түргә таба, арлы-бирле. *Профессор, ике кулын артына куеп, кабинет буйлап ишекле-түрле бер узды.* Г.Әпсәләмов. *Гыйльмуллин Харисның диктантын тикшергәч, урыныннан торып, ишекле-түрле йөренде.* Р.Хафизова. *Бая гына имгән тук бәрәннәр, --- сикергәли-сикергәли, ишекле-түрле уйнарга керештеләр.* М.Галиев

**ИШЕКЧӘ** *и.* 1) Ике якка ачыла торган ишекнең берсе. *Ә инде киштәләрнең бәләкәй ишекчәләре ике якка ачылып киттеме, --- хәйран калырлык әшләр күрергә туры килә.* Ш.Камал

2) Мич, плитә авызының кечкенә ишеге. *Карт та плитә ишекчәсе каршындагы бүкән өстеннән ашыкмый гына торды.* Ә.Айдар

**ИШЕКЧЕ** *и. иск.* Швейцар

**ИШЕ́К ЯҢАГЫ** *и.* Ишек уемының ян борысы. *Шушы Ягъфәр бит инде ул вакытта урта өйнең ишек яңагы белән мәш килде.* Сөембикә

**ИШЕЛҮ** I *ф.* **1.** 1) Оешкан, өелгән яки корылган нәрсә таркалып җимерелү, авып таралып китү. *Трактор өстенә балчык өйнең черек салам түбәсе ишелде.* М.Әмир. *Әнә мәктәп ишелгән һәм бүселгән.* Н.Исәнбәт. *Иргали туган нигезен кабат күздән кичерде. Каралтыларның эзе дә калмаган. Базы ишелгән.* М.Хәсәнов

2) *куч.* Өстән аска таба асылынып, салынып тору. *Сәгыйрнең ишелеп төшкән кашлары кинәт өскә чөелде, йөзе яктырып китте.* М.Галиев. *Әнинең иңенә ишелеп төшкән яулыгы, кара чәчләре шул шомны тагын да арттыралар.* Рифә Рахман // Өстән күп булып агып төшү. *Күк капусын ачканнармыни – һавадан су ишелә.* Р.Батулла // Каян булса да күпләп чыгу, таралып китү. *Сүз төгәлләнмәде, кызның туганнары ишегалдына ишелгән, сеңелләрен эзли иде, егет бакча артыннан гына тыкрыкка шылды.* Н.Гыйматдинова

3) *куч.* Алга таба авышу, бөкрәю. *Элек аны атасы, бик ачуы килгәндә: «Тасламаган агач, килбәтсез өрәк», – дип тирги иде. Алга табан ишелеп йөргән гәүдәсе ---, чынлап та, шундый кушаматларга урын калдыра иде.* Г.Толымбай

4) *куч.* Кемгә дә булса бер-бер артлы шатлык яки борчу-мәшәкать, тынгысызлык килү. *Ә взвод командиры җилкәсенә яңа хәсрәт ишелде: Украинаны азат итү сугышларында олы абыйсы Сергейның һәлак булуы турында әнисеннән хат килде.* Ш.Рәкыйпов. *Бу нахак сүзләр яшь укытучыга күтәрә алмаслык бәла булып ишелә.* Мәгърифәт

5) *куч.* Мул булып килү, керү. *Улым, уеңнан кире чиген. Балаларым хәерчелектән арынмас, дип борчылма, аларга байлык көтмәгәндә ишелер.* Н.Гыйматдинова

6) *куч.* Килешсез кабару, бүлтәеп салынып тору. *Айгөлдә тагын икенче кайгы: ишелгән корсак белән кайтып, авылда ничек йөрерсең?* Ә.Моталлапов

7) Кайда булса да аунап яту, тәгәрәү. *Көне урын өстендә ишелеп үтте*

**2. ишелеп**, **ишелеп-ишелеп** *рәв. мәгъ. куч.* 1) Бик яхшы, бик күп, мул, куе булып. *Их, җире җир генә түгел бит аның монда, алтын бит ул, бодай нинди ишелеп уңа бит.* М.Әмир. *Ишелеп үскән иген арасыннан чаба-чаба, Такталачыкның йөк машинасы Аккүз авылына килеп керде.* М.Мәһдиев. *Бу әле сугышка кадәр үк, икмәкләр ишелеп уңган бай елларны кайнатып куйган көмешкә иде.* В.Распутин

2) *куч.* Бик күп булып, берсе өстенә икенчесе өелеп, өсте-өстенә өстәлеп. *Ишелеп-ишелеп дөбердәүләр офыкка буйдан-буйга таралып китте.* Э.Касыймов. *Ул арада шалтыр-шолдыр ишекләр ачылды, --- унлап надзиратель һәм бозау хәтле өч эт ишелеп керде.* И.Салахов. *«Ехал цыган» дип, теге сихерле тавыш башлануга, бөтен халык «плацкарта» бүлмәсенә ишелеп өелә ---.* М.Мәһдиев

3) *куч.* Бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесе. *Ишелеп-ишелеп килгән кыенлыкларны мең газап белән эчемә йотам.* Н.Хәсәнов. *Һич уйламаганда, көтмәгәндә, Нурислам абзыйга ишелеп байлык килде.* Р.Фәизов

4) *куч.* Бик тиз, тиз арада. --- *Аббасов --- авыр башын мендәргә батырды. Арыган күз кабаклары йомылуга, йокы ишелеп кенә төште.* М.Галиев

**Ишелә бару** Торган саен күбрәк ишелү. *Язгы ташкыннардан ишелә барган яр җанымны тынгысызлап, йөрәкне тырмап тора.* Н.Хәсәнов

**Ишелә башлау** Ишелергә тотыну. *Лапас түбәләре ишелә башлаган, болдыр такталары купкан.* А.Гыйләҗев. *--- әллә нинди куркыныч тавыш белән гүләп, күктән су дәрьясы ишелә башлады*. Ф.Бәйрәмова

**Ишелеп бару** Акрынлап-акрынлап арта барып ишелү. *Картлар исә хәрабә яныннан узганда, тирән уйга чумган бакча белән ишелеп бара торган өйгә бер карап алалар ---.* С.Җәлал

**Ишелеп бетү** Тулысы белән, тулысынча ишелү

**Ишелеп китү** Барысы да бердән кинәт ишелү. *Кинәт ул утырган себеркеләр ишелеп китте һәм кыз --- Фидаилнең кочагына авып төште.* Р.Мөхәммәдиев

**Ишелеп тору** Туктаусыз, берөзлексез ишелү. *Текә ярлар, вакыт үткән саен әкренләп ашалып, ишелеп тора.* Мәдәни җомга

**Ишелеп төшү** 1) Өстән аска таба кинәт ишелү. *Өйалдында нидер дөбердәп ишелеп төште.* А.Алиш. *Очлы күз Динис --- түбәсе ишелеп төшкән, күптән инде ташландык хәлгә килгән, --- таш келәт шәйләп ала.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Көтмәгәндә, уйламаганда бәхет, шатлык, кайгы һ.б. шундыйлар килү. *Ярулла абзыйның кызы чытырдап миңа ябышты. Һай күктән кинәт ишелеп төшкән бәхет!* З.Хөснияр. *Искәрмәстән иңенә ишелеп төшкән бу бәхеттән Гөлнисаның аңына зыян-зәрәт килмәсә генә ярар иде.* М.Хәсәнов. --- *аларның башына, көтмәгәндә-уйламаганда, шуның кадәр исәп-хәсрәт, борчу-мәшәкать ишелеп төште* ---. В.Распутин

3) *күч.* Авып китү, егылу. *Шул мәлдә җәлладның аркасына ук кадалды, җәллад капчык кебек бер якка ава башлады. Ниндидер мизгелдә генә югалып калган Сәлим хан ишелеп төшкән җәлладның кулыннан кылычын тартып алды.* М.Хәбибуллин. *Гайсә кызуны өсти торды: – Гүли исертә торган әче бал кирәкме? Чемердәп тора, ишелеп кенә төшәсең, апай.* Ф.Садриев. --- *ишеккә терәлеп торган Нәҗип Нургалиев, мәлҗерәп, аның бүлмә идәненә ишелеп төште.* А.Гыйләҗев

**Ишелеп чыгу** Зур булып салынып, ишелеп торган хәлгә килү. *Шулай да «Гафифәнең корсагы ишелеп чыккан» дигән сүзләр йөрде.* Ә.Моталлапов. *Хуҗаның ачык изүеннән ишелеп чыккан корсагына ышкынып, --- Гөлсинә сикергәләп алды.* Р.Мөхәммәдиев

**ИШЕЛҮ** II *ф. төш. юн.* 1) *к.* **ишү** II. --- *аның күзе почмакта яңа гына суелган сап-сары юкә тасмаларына һәм аның өстендә кашагага кыстырылган берничә яңа гына ишелгән чыбыркыга төште.* Ә.Фәйзи

2) *күч.* Сарылу, елышу; назланып сыену. *Егет кызга кушылды, ефәк булып ишелде.* М.Фәйзи // Бәйләнү, бер-берсенә чорналу. *Чүмәлә дәү җанвардай селкенергә тотынды, ахыр килеп, очып китәргә теләгәндәй, төтенгә ияреп, бер-берсенә ишелә-ишелә, еланнар күккә күтәрелә башлады.* М.Хәбибуллин

**Ишелеп бетү** Тәмам, бик нык бөтерелеп ишелү. *Ул утырып та укыды, чалкан ятып та, капланып та, одеал-мендәрләре чүбеккә әйләнеп, җыерылып, бау кебек ишелеп бетте.* Х.Ширмәт

**ИШЕМ** *и.* Көчле су агымы, су ташкыны. *Агым буйлап йөзгәндә, текә бораылышларда агым ишеме баржаларны ярга китереп бәрә.* Г.Иделле

**ИШЕРӘМ** *и. диал.* 1) Ашлыкны җилгәргән вакытта аерылган кибәк, башак кисәкләре; кылчык катнаш масса

2) Саламны, башакны вак итеп турап, кайнар су һәм он белән болгатып әзерләнә торган хайван азыгы; башак

**ИШЕРЕЛҮ** *ф. диал.* Күп булып, өем-өем булып, бер-бер артлы, берсе өстенә икенчесе өелеп, ташкын булып килү. *Таулар, яланнар, урманнар аша-сыннан шәһәр өстенә таба каты давыллы, җилле яңгырлар ишерелеп киләләр.* Г.Ибраһимов. *Шул арада халык, ишерелеп, егетне кыйнарга һөҗүм кылганнар иде.* Г.Ибраһимов

**ИШЕРҮ** *ф. диал. к.* **ишү** I. *Баздан чыккан да Самат Ярны тибеп ишергән, Җимереп балчык төшергән.* Н.Исәнбәт

**ИШЕТЕЛЕР-ИШЕТЕЛМӘС** *рәв.* **1.** Чак-чак ишетелерлек итеп. *Бу юлы Миңниса җиңги бер сүз дә дәшми почмакка барып утырды һәм, ачу белән кабасыннан сүсне йолка-йолка, сүзе ишетелер-ишетелмәс мыгырданды.* Ә.Фәйзи. – *Озатырмын, – диде Фәрис ишетелер-ишетелмәс итеп.* А.Вергазов. *Шуннан соң Фёдор Иванович миңа тыенкы гына баш иеп, ишетелер-ишетелмәс кенә сәлам бирүдән узмый торган булды.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* Акрын гына, чак ишетелерлек итеп әйтелгән. *Ишетелер-ишетелмәс тавыш белән җавап кайтару*

**ИШЕТЕЛЕШ** *и. махс.* Ишетелү дәрәҗәсе, ишетелү ачыклыгы; ишетелү ачыклыгы берәмлеге

**ИШЕТЕЛҮ** *ф.* 1) Тавыш дулкыннары килеп җитеп, колакка тәэсир итү. *Бер тарафтан кемнеңдер рояльдә уйнаганы ишетелә* ---. Ф.Әмирхан. *Рәмзия тавышында исә, ягымлылык, күңел күрергә тырышудан битәр, үтә җитдилек ишетелде.* Б.Камалов. *Кайдадыр такта яралар, ахрысы, түгәрәк пычкы зырылдавы ишетелә.* Г.Әпсәләмов

2) Берәр эш-хәл яки хәбәр кешеләр аша башка урында мәгълүм булу. *Икенче көнне цехлар буйлап йөргәндә, һәр почмактан: – Генералны тагын үз урынында калдырганнар, --- – кебек сүзләр ишетелде.* Ф.Баттал

**Ишетелә башлау** Ишетелерлек тавышлар барлыкка килү. *Төньякта акрын, ләкин бик тирән гөрләү белән күк күкрәгән тавыш ишетелә башлады.* Ш.Камал. *Керфек какмыйча ята торгач, тәрәзәләргә таң алсулыгы йөгерә, трамвай, машина тавышлары ишетелә башлады.* З.Фәйзуллин. *Каршы ярдан шау-шу, атлар кешнәгән, кешеләр кычкырышкан тавышлар ишетелә башлады.* Т.Нәбиуллин

**Ишетелә тору** Даими, һәрвакыт ишетелү; әледән-әле ишетелү. *Әтинең --- иртән: – Уф Алла! Билем, аркам, – дип сыкранганы ишетелә торган булды.* Г.Ибраһимов

**Ишетелеп алу** 1) Кыска вакыт арасында ишетелү, ишетелгән булу. *Әнә көнбатыш ягыннан ялкау гына җил исеп куйды, еракта, әллә кайда, гөрелдәү ишетелеп алды* ---. М.Мәһдиев. --- *елына ике тапкыр Гаффә карчык йортында да чит тавышлар ишетелеп ала.* С.Шәмси

2) Нәрсә турында булса да ниндидер сүз йөрү, хәбәр булу. *Шахтага китәләр икән, дигән сүз ишетелеп алды*

**Ишетелеп калу** Башка тавышлар арасыннан аерымланып ишетелергә өлгерү. – *Чү, ү! Кирәкми, сабыр итегез! – дигән тавышлар арасыннан бик нечкә һәм әрнеп елаган тавыш ишетелеп калды.* М.Гафури. *Өйдә магнитофонның ирләр тавышы белән чинап җырлаганы гына ишетелеп калды.* М.Маликова. *Тик аргы урамнан кычкырта-кычкырта машиналар үтеп китүе генә ишетелеп кала.* Р.Төхфәтуллин

**Ишетелеп китү** Кинәт ишетелү, анда-санда, өзек-өзек ишетелү. *Минем колагыма паркта уйналган музыка кисәкләре ишетелеп китә.* Ф.Әмирхан. *Якында гына ат аяклары тавышы ишетелеп китте.* И.Гази. *Ара-тирә шау-шу арасыннан өзек-өзек тавышлар ишетелеп китә.* А.Шамов

**Ишетелеп куюю** Кинәт, сирәк кенә ишетелү; әллә нигә бер ишетелү. *Күл ягыннан --- үрдәкләрнең чупылдашканы, чумып уйнаганы ишетелеп куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Хор белән кычкырган әтәчләр концерты төнгә җан кертә --- бу тавышларның һәммәсен җиңеп, аратирә Имәли шакылдавыгы ишетелеп куя иде.* М.Әмир. *Житмәсә, кешенең тавышы да кәҗәнеке кебек бик нечкә, хәлсез генә ишетелеп куйды.* Ф.Садриев

**Ишетелеп тору** 1) Туктаусыз, берөзлексез ишетелү. *Шунда ук бертуктаусыз ниндидер шау-шулы митингларда катнашучыларның «Һайль Һитлер!» дип акырышулары ишетелеп тора.* М.Әмирханов. *Бермәлгә тирән тынлык урнашты: акчалар чыңлаганы гына ишетелеп торды.* И.Тургенев

2) Даими рәвештә, әледән-әле кабатланып ишетелү. *Әллә нигә бер, туптан аткан тавышлар ишетелеп тора.* И.Гази. *Ялгызы яшәсә дә, өе тын һәм үле түгел аның. Анда сөйләшкән, фикер алышкан авазлар ишетелеп тора.* Р.Фәизов

3) Озак вакыт дәвамында ишетелү. *Туп тавышлары шактый вакыт өзлексез ишетелеп торды.* С.Җәлал. *Тик сәкедә Һаҗәрнең акрын гына өзелеп-өзелеп сыкрануы ишетелеп торды.* К.Нәҗми. *Хәер, «шап» иткән тавыш үзе хәйран озак ишетелеп торды ---.* М.Хуҗин

**ИШЕТЕШ** *и.* Музыкаль авазларны дөрес ишетә һәм кабатлый алу сәләте. *Музыкаль ишетеш*

**ИШЕТЕШЛЕ** *с.* Ишетешкә ия булган

**ИШЕТЕШСЕЗ** *с.* Ишетешкә ия булмаган

**ИШЕТКӘН-БЕЛГӘН** *с.* Ишетеп, күреп белгән, күптән билгеле булган; таныш. *Нинди Разин? Нинди алты йөз сум ул? Ишеткән-белгән нәрсәм түгел.* Г.Ибраһимов

**ИШЕТМЕШ** *и. диал.* Шәхсән күреп билгеле булмаган, ишетеп кенә белгән хәбәрдарлык. *– Ничек, махсус буазмы? – дип куйды Шамил. Ул бу хакта ишетмеш буенча гына белә; Фёдор Лукич сөйләгәннәрнең күбесе аның өчен, чыннан да, яңалык иде.* З.Фәтхетдинов

**ИШЕТТЕРҮ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **ишетү**. *Гөрләүнең яңгырашы сүзләребезне бер-беребезгә бөтенләй шыпырт сөйләнгән шикелле итеп ишеттерәләр иде.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Нинди дә булса сүзне яки хәбәрне кеше аркылы җиткерү. *«Начальник халыкны тарата башлады...» – дип, Вариска да ишеттерделәр.* М.Хәсәнов. *Галиябануны Хәлилгә биргәннәр, дип хәбәр чыкканга бер генә тәүлек булса да, миңа төбәп байтак сүз ишеттерделәр.* М.Фәйзи. *Йомагыл, ачуланып, кыз җиңгәләре аркылы кызга ишеттерергә кушып, каты-каты сүзләр әйтеп карады ---.* М.Әмир

**Ишеттерә башлау** Ишеттерергә тотыну. *Татар соңгы ничә гасырдан соң үзен «Дөньяда без дә бар!» дип күтәрелеп чыкты, үз тавышын ишеттерә башлады.* Р.Фәйзуллин

**Ишеттереп алу** Бер тапкыр ишеттерү. *– Хәдичә белән Рабигадан гел хөрмәт күреп торам ---, рәхмәт яугырлары, – дип, тагын бер кат күршеләре үзен ташламаганны, игелек күрсәтеп торганны Илдарга ишеттереп алды карчык.* З.Фәйзи

**Ишеттереп тору** 1) Һәрвакыт, гел нинди дә булса сүз яки хәбәр ишеттерү. *Россиядә милләтчеләр хәрәкәте үзләре турында гел ишеттереп тора ---.* Шәһри Казан

2) Әледән-әле, еш берәр сүз яки хәбәр ишеттерү. *--- керәшеннәр әле яши, үзләренең барлыкларын әледән-әле белгертеп, ишеттереп торалар.* Туганкайлар

**ИШЕТҮ** *ф.* 1) Төрле авазларны, тавышларны колак белән сизү, кабул итү. *Солтания --- соңгы елда колакка катыланган, вакыт-вакыт гел дә начар ишетә иде ул.* М.Галиев. *[Мин] --- Зөһрәнең сулкылдавы аша --- мич артында чикерткә сайравын ишеттем.* М.Маликова. *Баян баһадир аңа хан фәрманын тапшырды, кәтиб Хафиз аны укып чыкты, барысы да ишеттеләр ---.* М.Хәбибуллин

2) Берәр хәбәрне икенче бер кеше аша белү, нидер хакында хәбәр алу. *Бүген мин сезнең турыда бик күп мактау сүзләре ишеттем.* А.Шамов. *--- мин хатын-кызны, аз гына гаебе булса да, үлемгә хөкем иттем. Ханбикәгә бу ошамаган, киленнәре дә дәгъва белән килгәннәр, дип ишеттем.* М.Хәбибуллин. *– Син элек бу мәктәптә укыткан Сулимовның берәр кешесе түгелме? – Улы. Таныш идегезме әллә? – Юк, ишетеп кенә беләм.* М.Мәһдиев // **ишет(егез)** *боер. ф. форм. күч. к.* **ишетсен колагың**

3) *күч.* Тыңлау, игътибарга алу, әһәмият бирү. *Минә ишет әле, Зәки абыең нәрсәләр ди.* Ф. Әмирхан

◊ **Ишетмәсәң ишет** 1) Кешегә ишетү авыр булса да, аңа тиешле сүзне, хәбәрне кисәтеп әйтү; 2) Кеше үзе теләмәгән сүзне, хәбәрне ишеткәндә, «ул нинди сүз тагын?» дигән мәгънәдә, сәерсенеп, үз-үзенә әйтү. *Минә сиңа, ишетмәсәң ишет, ул – нинди сүз? Мин кайчан аларда булган булам?* Н.Исәнбәт. *Күр инде... Ну, Гаяр абый... андый түгел кебек иде бит ул. Минә сиңа, ишетмәсәң ишет...* Г.Кашапов. *– Үтергән икән тәки... – Ишетмәсәң ишет...* М.Хәсәнов. **Ишетсен колагың** Нәрсәне дә булса эшләгәндә игътибарлы булырга, онытмаска кирәклекне искәртеп яки кемгә дә булса кисәтү ясаганда әйтелә. *– Җиләк хакын өеңне сатып түләтәм мин синнән, ишетсен колагың! – дип кисәтте аны бакча хуҗасы.* З.Вәли. *– Кыстасалар да --- анда кунып ятмагыз, төш авышуга кайтырга чыгыгыз, – дип калды әнкәй. – Бәрәңге китмәнлисе бар, ишетсен колагыгыз.* И.Сирматов. *– Ниязулла улым, монда кара әле син. Ходай кушса, иң беренче булып минем бакчама керерсең, ишетсен колагың, – дип, чират алып куйды ялгыз карчык Маһисәрвәр түти.* Р.Фәизов

**Ишетә башлау** 1) Ишетү сәләте барлыкка килү, колак ачылу. *--- егетнең утлы сулышы тигезләнде ---. Күзе ачылып, колагы аермачык ишетә башлады.* А.Гыйләҗев. *Әнвәрнең бер колагы тавыш ишетә башлады.* Х.Камалов

2) Төрле хәбәрләр алу. *Самат та Н. шәһәреннән Казанга күчеп киткәч, Хәмәт турында пошаманга төшерердәй сүзләр ишетә башлады.* М.Вәлиев

**Ишетә бирү** Бернигә карамыйча ишетү; ишетүен тагын да дәвам итү. *Әнә кирпеч өеме янында Григорий бе-*

*ләң бәхәсләшеп торган Соня да бит: – Ишетмәгәе тагын, ишетә бирсен! – дип, бәгырьне телгәләп алды.* З.Вәли

**Ишетеп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә ишетү. *Ул, башын иеп, вакытсыз килүе өчен ачынып торган чакта, каршыдан тәрәзә чиерткән тавыш ишетеп алды.* Ә.Еники. *Җир астындагы әтәч --- канатын кагынып кычкыра. Моны җир өстендәге әтәчләр ишетеп алалар.* М.Мәһдиев. --- *бер мәлне Кәшифә әби аста килене һәм улының, балалары белән бергәләп, урысча гына сөйләшкәнен ишетеп алды.* З.Фәйзи

**Ишетеп бетерү** Күп ишетү. *Әллә нинди ямьсез сүзләр ишетеп бетердем...* Юлдаш

**Ишетеп җиткерү** Нинди дә булса сүзне, фикерне яки берәр хәбәрне ахыргача тыңлау, аңларлык дәрәҗәдә ишетү (күбрәк юклык формасында кулланыла). *Әммә Моназыйрның соңгы сүзләрен Сәрвия белән Рәйсә ишетеп тә җиткермәделәр.* М.Хуҗин. *Сөйләшкәндә, шулай ук игътибар белән тыңламый һәм әледән-әле: – Гафу итегез, ишетеп җиткермәдем, – дип, кайтарып сорый.* Җ.Тәрҗеманов

**Ишетеп калу** Ишетергә өлгерү; очраклы рәвештә ишетү. *Курамшин аларның караңгыда аяк тавышларын гына ишетеп калды.* Ш.Бикчурин. *Тик кичен, Җәгъфәрләрнең сәкесендә йокыга изрәп барганда, Ахияр ишетеп калды: Минһаҗның әнисе чыбылдык артында картына сөйли иде ---.* М.Мәһдиев. *– Тагын кайсы хулиганы тия минем улыма? Үтерәм бит хәзер! – дигән ачы тавышны мин ерактан гына ишетеп калдым...* Р.Төхфәтуллин

**Ишетеп килү** Озак вакытлар дәвамында, даими ишетү. *Менә алтмыш ел буена Җир шарында ерткычлыкның мисалларын мин --- ишетеп киләм.* Ә.Еники

**Ишетеп тору** 1) Берәр сүз яки хәбәрне әледән-әле, еш ишетү. *Жихарев үзе дә яланда үсеп килгән ризасызлык шавын ишетеп торды ---.* В.Имамов. *Өй хәлләрен барыбер ишетеп торды.* Ә.Моталлапов

2) Нәрсәдер хакында хәбәрдар булу, барысын да белеп тору. *Әсхәт, фронтка чыгып киткәнче, вакытын Сара янында үткәрде, --- Зөләйхәттәй боларның барысын да белеп, ишетеп торды.* Л.Ихсанова. *Һаҗәр яшь пәрдәсе каплаган яшькелт күзләрен тутырып Гарифка карады: – Мин инде барын да аңлыйсыңдыр дип уйлаган идем. Күреп, белеп, ишетеп тордың бит, Гариф.* К.Тимбикова

3) Билгеле бер вакыт арасында ишетү; сөйләү моментында ишетү. *Күзләре экранда булса да, күңеле белән Рухиясенең керфек какканына тикле тоеп утыра Равил. Хәтта йөрәк тибешенә кадәр ишетеп тора.* В.Нуруллин. *Ахияр элекке көнне генә капка-коймa аркылы ишетеп торды.* М.Мәһдиев

**Ишетеп яту** *к.* **ишетеп тору**

**И́ШИАС** *и. гр. мед.* Утракса нервлары ялкынсынудан гыйбарәт булган авыру

**И́Ш ИТҮ** *ф.* 1) Тиңләү, тиң итү, тиң итеп карау. *[Туган җирем] Көчле иткән мине, эшле иткән, Көрәш ирләренә иш иткән.* Ә.Ерикәй

2) Якын итү, үз күрү, үз тиңе итеп күрү. *Һәй, һәй, һәй, безнең ишене иш итмәскә, ахры, әле боларның исәпләре!* Г.Гобәй

**ИШ-ИШ** *рәв.* Парлап, пар булып. *Мәйданбаш һәм аның ярдәмчеләре үсмерләрне иш-иш бүлеп чыктылар ---.* М.Хәбибуллин. --- *кубызга курайчылар кушылды, егетләр кызлар белән иш-иш килеп бии башладылар.* М.Хәбибуллин

**ИШКӘГАЯКЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Озынча, орчыксыман гәүдәле, ишкәккә охшаган очлыклы имезүче диңгез хайваннары (мәс., тюлень, морж, су арысланы һ.б.) отряды атамасы; *русчасы:* **ластоногие**. *Ишкәгаяклылар бөтен тән өслеге аша сулый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Диңгез һәм океаннар экосистемасының башында китсыманнар һәм ишкәгаяклылар тора.* Ирек мәйданы

**ИШКӘК** *и.* 1) Суны ишеп, көймәне хәрәкәтләндерү өчен кулланыла торган, бер башы яссы итеп эшләнгән зур калак. *Баскан саен тибрәлеп торган бүрәнәләр арасыннан су ургылып чыга, ишкәкләр ишетелер-ишетелмәс кенә чапылдыйлар ---.* И.Гази. *Кыю сәяхәтче 134 көн эчендә давыллы-шаулы Тын океанны сыңар ишкәк белән кичә.* А.Гыйләҗев. *Ишкәкләр судан күтәрелгәндә, шлюпка очарга талпынган кошка охшап китә иде.* М.Юныс

2) *зоол.* Морж, тюлень, су арысланы кебек диңгез хайваннарының йөзгече. *Сукыр тычканның тәпие җир казырга җайланган, китныкы суда йөзгәндә ишкәк ролен үти ---.* Дарвинизм нигезләре. *Тюленьнәрнең очлыклары ишкәкләргә әйләнү*

3) *бот.* Кузаклылар (күбәләк чәчәкләләр) семьялыгыннан булган үсемлекләрнең ике ян аерчалары (таҗ яфракчыклары). *Борчак чәчәгенең югарыгы таҗ яфракчыгы – «җилкән», бергә тоташып үскән түбәнге ике яфракчык – «көймәчек», ә ян яктагы ике яфракчык «ишкәкләр» дип атала.* Ботаника. *Комлык эспарцетының --- чәчәк төзелеше кузаклылар өчен берникадәр гадәти түгел, җилкән һәм көймәчек яхшы үсеш алган, ә ишкәкләре (канатлары) кыска ---.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ИШКӘККАНАТЛЫЛАР** *и. зоол. күпл.* Шөлдисыманнар отрядыннан кечкенә һәм уртача зурлыктагы диңгез кошларының бер семьялыгы; *русчасы:* **чистиковые**

**ИШКӘКЛЕ** *с.* Ишкәкләре булган, ишә торган. *Алар ишкәкле һәм җилкәнле көймәләрдә Идел буенча сәяхәт итәләр.* Сабантуй. *Ә инде июнь ахырына кадәр без ишкәкле көймәләр каналын ачачакбыз.* Шәһри Казан. *Быелдан башлап гап-гади ишкәкле резина көймә хуҗалары аларны регистрацияләргә һәм техосмотр үткәрергә тиешләр.* Татарстан яшьләре

**ИШКӘКЛЕ́ КАНДАЛАЛАР** *и. зоол. күпл.* Озынлыклары 5–7 мм, арткы тар аяклары йөзәргә җайлашкан, яхшы оча торган кандалаларның бер семьялыгы; *русчасы:* **гребляки**

**ИШКӘКЧЕ** *и.* 1) Ишкәк ишүче кеше. *Кайбер көймәләрнең озынлыгы 12–14 метрга җитә, аларда җилкән һәм уникешәр ишкәкче булган.* Р.Мостафин. *Менә икенче тәүлек инде колаклар, борынгы Греция ишкәкчеләренеке кебек үк, бер ритмга тимер рельсларга*

*бәрелгән көпчәкләр тавышына күнегеп киләләр ---.* Х.Ширмәт. *Пароход китәр алдыннан, карт кына бер ишкәкче розалар бәйләме китереп биргән иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) Көймәче. --- *Камышлы су аркылы көймә белән симәнә чыгарып торырга кирәк. Шулай итеп, Галимулла абзый, ремонт эшләрен ташлап, ишкәкчегә әйләнде.* З.Фәйзи

**ИШКЕЧ** *с.* **1.** Ишү өчен җайлаштырылган. *Йөзгәләкнең --- ишкеч аякларын төкләр каплаган.* Г.Хәсәнов. *Ишкеч тәгәрмәчләр. Ишкеч винт*

**2.** *и. мәгъ.* Машина яки башка берәр нәрсәнең ишү өчен җайлашкан өлеше

**И́Ш КИЛҮ** *ф.* 1) Бер-беренә охшау, бертөсле, бердәй булу; нинди дә булса сыйфаты белән бер-берсенә туры килү. *[Гөлүсәнең] Өстендә йөзенә иш килә торган, эре күзәнәкләп бәйләнгән сыек зәңгәрсу төстәге йон күлмәк.* М.Хәсәнов

2) Бер-берсенә ярашлы булу, бергә бербөтен тәшкил итү

**ИШ-КУШ** *җый. и.* Үз тиңнәре, үз ишләре, үзе кебекләр. *Өченче класстагы сәүдәгәрләр, иш-кушы белән табышып, танышып алгач, беренче эш иттереп чәй эчәргә керешәләр.* И.Рәмиев

**ИШЛӘ́Ү** *ф.* Бер үк төрдәге материя кушу. *Ишләп тегү*

**Ишләп бетерү** Барысын да ишләү

**Ишләп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм, бер-бер артлы ишләү

**Ишли башлау** Ишләргә керешү

**ИШЛЕ** *с.* Сан ягыннан күп булган, күп сандагы. *Ишле кызга кияү табып бетерү ансат эш түгел, хәтта бай кешегә дә...* Ә.Еники. *Казларым быел да ишле, ике ояга – егерме дүрт бәпкә.* М.Хуҗин. *Ул, --- Шәймулла авылындагы ятимә кыз Ләмигага өйләнеп, ишле, төпле гаиләгә нигез сала.* Р.Фәизов

◊ **Ишле кулдан** Мул итеп. *Безне өйгә чакырдылар. Хатыннар, ишле кулдан, табынны әзерләп өлгергәннәр иде.* Ә.Еники

**ИШЛЕ-ИШСЕЗ** *с.* Бөтенлегә бозылган, ишсезләндерелгән, кайсыларының ише калмаган; комплектлары җитәрлек, тулы булмаган. *Ишле-ишсез чәй дирбиясе. Ишле-ишсез запчастьләр комплекты*

**И́ШЛЕ-КУШЛЫ БУЛУ** *ф.* Өйләнү, парлы булу

**ИШЛЕЛЕК** *и.* Ишле булу. *Бала-чаганың ишлелеген күреп, Габдулла тирән һәм авыр итеп көрсенде...* А.Гыйләҗев

**ИШМӘ** *и. бор.* Көмештән эшләнгән нәфис, нечкә чыбыкларны тимер яки бакыр чыбыкка урап ясалган беләзек. *[Мишәр] Кызлары вә хатыннары, гомумән, кулларына беләзек вә ишмә кияләр.* З.Бәшири

**ИШРАК** *и. гар. иск. кит.* Яктырыш, нурланыш

**ИШРА́К НАМАЗЫ** *и. дини* Кояш тәмам чыгып, күтәрелә башлагач укыла торган намаз. *Ул, иртә намаздан соң ишрак намазы уку гадәте булса да, яшь мулла белән күрешер өчен, бергә чыкты вә --- сәлам биреп күреште ---.* Г.Исхакый

**ИШСЕЗ** *с.* Ише, пары булмаган, сыңар. *[Ул] Карсак буйлы булганлыктан, стройга тезелгән саен, иң кырыйга ишсез номер булып бас[а].* К.Нәҗми. *Ялгыз ирләр «ишсез» хатыннарны тиз таптылар.* М.Әхмәтшина

**ИШСЕНҮ** *ф.* Якын күрү, иш күрү, үз тиңе итеп карау

**ИШТӘ** *а. иск. кит.* Менә. *Зыяның ул дөньядан, ул фонарьлы йортлардан җаны вә йөрәге белән чиркануы иштә башлыча шул табигатенең тәэсиреннән иде.* Г.Ибраһимов

**ИШТӘШ** *с.* Бер иштән, бер төрдән булган. *Нәби ага белән табында утыру рәхәт. Яше буенча олпатлыгын онытa белеп, кечелекле, уенчак холкын саклаган хәлдә, ара калдырмыйча, иштәш булып, үзен тигез дәрәҗәдә тота.* М.Галиев. *Җирдә тусаң, Җиргә төшсәң, Йә тәгәрә, йә атла. Иптәшләрең чит булырлар, Иштәш булырлар ятлар.* Х.Хөснуллин

**ИШТӘШЛЕК** *и.* Иштәш булу. *Ул сүз, үз авазларының көче белән каршы яктагы берничә сүзне дә үз рифмасына буйсындырып, --- аваз ымлыгы иштәшлеге (интонацион симметрия) китереп чыгара.* Н.Исәнбәт

**ИШТИРАК** *и. гар. иск. кит.* Катнашу, кушылу, булышлык; бергәләп башкарып чыгу, уртак эшләү. *Мусин җәнаплары беркөнне миңа «Сак-Сок» бәетен язып китерде. Бу иштиракы өчен --- Мусин җәнапларына [рәхмәт].* Г.Тукай

**ИШТИРА́К ИТҮ** *ф.* 1) Катнашу. *Габдулла әфәнде Тукаевның җеназа мәрасимнәрендә «Вакыт» һәм «Шура» идарәләре исеменнән иштирак итүегезне үтенәбез.* Мирас

2) Кушылу, уртаклашу. *Рөстәм тагы тутырып кына берне эчә. Доктор да аңар иштирак итә.* С.Җәлал. *Мин моңа кыйсмән иштирак итәм.* Г.Ибраһимов. *Кадерле шагыйребезнең вакытсыз безне ташлавы кайгысын иштирак итәбез.* Мирас

**ИШТИҺА** *и. гар. иск. кит.* 1) Теләк. *Башка кызларга кияүләрнең килүе бер сәгадәт булып, дәрт вә иштиһа белән көтсәләр дә, Гөлбану бик күңелсез вә кәефсез көтә.* Г.Ибраһимов. *[Ул] Гомеренең нәфес вә иштиһа илә кайнарлык дәвере булганына карамыйча, үзе суфый вә тәкъва иде.* Г.Ибраһимов

2) Ашау-эчү теләге; аппетит. *Бүген хәзрәтнең иштиһасы азрак булырга кирәк: берничә тарелка кабартма бушагач һәм самавырның да суы бетеп, акмый башлаганны күргәч: «Җитәр инде» – [диде].* Ш.Мөхәммәдев. *Әмма аракы вә гайре эчемлек --- тәгамгә иштиһаны бетерәдер.* К.Насыйри

**ИШҮ** I *ф.* **1.** 1) Өелеп, оешып торган яки төзеп-корып куелган нәрсәләрне таркатып җимерү, аудару. *Бала-чагалар тезелешеп йоклаган урын-җир өстенә сандык өстенә өеп куелган юрган, мендәр, ястык, киез ише нәрсәләр дә ишеп төшерелгән.* М.Хәсәнов. *Баш күтәрүчеләрне тәмам буйсындыру нияте белән, Александр бөяне ишеп, суны агызырга куша.* А.Муранов

2) *күч. мыск.* Билгеле бер эшкә тотынып та аны башкарып чыкмау, эшне бозу. *Абрар сүзен очлап үз урынына үткәндә, иптәшләре чәнчештергәләп калдылар аны артыннан: – Ну-у, бирдең дә соң!.. Иштең...* М.Хәсәнов. *«--- анда халык җыелган. Мин күз генә салдым да шунда ук синең янга чаптым...» – «Ишкәнсең, – дим мин, канәгатьсезлегемне белдереп. ---».* Ф.Галиев // Бернәрсә дә эшли алмау, бернинди эш тә чыгара алмау. *Теге ел-*

*ларны авылда калсак, ишәр идең инде.* Р.Төхфәтуллин

3) *күч. гади с.* Кыйнау. *Ничек булса да бер төрмәдән чыксак, --- Семёнов --- Анненковларның кабыргаларын ишәрбез!* И.Туктаров. *Клуб артында --- китте сугыш, китте сугыш... Хәтерлисеңдер инде: иштек сезнең буынны ул көнне!* М.Галиев. – *Маташтырма! Кайнаштырма, ләгыйнь! – дигән дә робот әти кешене чыбык белән туйганчы ишкән.* Мәдәни җомга

4) *күч. гади с.* Көчле, коеп яву. *Самолёт төшәм дигәндә генә, төрекмән бүреге хәтле генә болыт килде дә Эзи өстенә эленмәсме! Коеп яварга тотынмасынмы! Ишә генә!* А.Гыйләҗев. *Март башларында карны иштеләр генә күк кәнсәләрендәгеләр.* Ф.Шәфигуллин

5) *күч. гади с.* Күп итеп алу. *Әнә минем малай Чаллыда ишә генә акчаны.* М.Галиев

6) *күч. гади с.* Нәрсәнедер чамасыз күп итеп башкару. *Канәгать, көне буе ашамый ураза тотуның үчен алып, карыны бүлтәеп чыкканчы иште ул кара ипи белән солы кесәлен. Мөмкин булганда нигә ишмәскә?* А.Хәлим. – *Сөбханалла, елмаясың, кызым, – диде Мәйсәрә. – Мәрхүмә әбием әйтмешли, иштең йокы кибәнен.* Н.Гыйматдинова

7) *күч.* Өстән күп булып таралып төшү. *Аны-моны уйламастан, чәчемне күкрәгемә ишеп төшердем дә түбәнгә тәгәрәдем.* Р.-Н.Гүнтәкин

8) *күч.* Уйлау, фикер йөртү. *Билләһи, дурак түгел син, әй, Дмитрий. Без икебез дә бер юнәлештәрәк ишәбез төсле.* З.Фәтхетдинов

10) Тоташ томалау, каплап алу. *Бу да дөньяларның хәсрәтеннән Ике күзем генәмне кан ишкән.* Җыр

**2. ишеп, ишеп-ишеп** *рәв. мәгъ.* Күп булып, мул итеп. --- *кинәт гарасат купкандай, күкрәп-яшенләп яңгыр килгән, ди, дә, бөтен дөньяны иңләп, ишеп-ишеп яварга да тотынган, ди...* Ә.Еники. *Аннан ишеп-ишеп яңгыр коярга тотынды.* Д.Гайнетдинова. *Урамда ишеп-ишеп кар ява.* Р.Вәлиев

◊ **Ишкәнсең икән** *к.* **ишкәнсең (иштең) ишәк чумарын (ишек бавын)**. – *Ә мин бөтен гомеремне харап иттем, авырга уздым... Фатыйха: – Ишкәнсең икән! – дип, шелтә һәм әр белән бәрелде.* Х.Сафина. **Ишкәнсең икән шул арыш шишарасын** *к.* **ишкәнсең (иштең) ишәк чумарын (ишек бавын)**. **Ишкәнсең (иштең) ишәк чумарын (ишек бавын)** *сөйл.* 1) Күп көч куеп, бик тырышып та эшен яки тапшырылган бурычын үти алмаучыга әйтелә. *Киңәшмәдән чыккач та, Мөнир мине бер кырыйга чакырып алды: – Иштең ишәк чумарын, тәнкыйтьләдең! Бүлек данын саклый, имеш!* З.Вәли. – *Батыр булу кызлар эше түгел, егетләр эше. Һи, иштең ишәк чумарын, – дип, Тәүгиз, кызны ирештергән кебек, иреннәрен чалшайткалап куйды.* Х.Камалов. *Хатын кеше янә элеккеге кыяфәтенә кайтты да куйды: – Нәрсә? Базага, дидеңме? Ишкәнсең икән, алайса, ишәк чумарын.* М.Хәсәнов; 2) Куелган максатның асылын аңламыйча эшләүче кешегә карата әйтелә. – *Иштең ишәк чумарын, Әсгать энем. Юк инде, --- Нерон белән Цезарьны бутый башлагач, булмады бу, – диде Хөрмәтша агай.* Ф.Шәфигуллин. – *Иштең ишәк чумарын, – диде дустым, --- иреннәрен кыйшатып, – «Идегәй» дастаны белән таныш түгелме әллә син?* М.Әмирханов. **Иштең инде арыш салмасын** (**чумарын**) *к.* **ишкәнсең (иштең) ишәк чумарын (ишек бавын)**. *[Гыймади:] Тарт, тарт, карчык (аягыннан читек тарттыра. Читек кинәт чыгып, Гыймади егылып төшә). Иштең инде арыш чумарын!* К.Әмири. *Иштең арыш чумарын! Малай өчен өйгә учитель йөртергәме?* Г.Әпсәләмов. **Иштең йокы кибәнен** Озак йоклау. – *Сөбханалла, елмаясың, кызым, – диде Мәйсәрә. – Мәрхүмә әбием әйтмешли, иштең йокы кибәнен.* Н.Гыйматдинова

**Ишә башлау** Ишәргә тотыну. --- *әрҗәне саклык белән генә «кабергә» төшерде дә, өстенә такталар тезеп, көрәк белән балчыкны ишә башлады.* С.Поварисов

**Ишеп ату** *к.* **ишеп ташлау**. *Ольга торып басты, диңгез җиле аның алтынсу-аксыл чәчләрен печән кибәнедәй ишеп атты ---.* Р.Сибат

**Ишеп бетерү** Тулысынча ишү; барысын да ишү. --- *мал-туарга хуҗа табылмады, көтү чыкса чыга, чыкмаса, сыер-сарыклар уҗымны таптыйлар, печән кибәннәрен ишеп бетерәләр.* А.Гыйләҗев. *Стенаның өске өлешен дә ишеп бетерә иде – көчкә тукаттылар.* М.Галиев

**Ишеп җибәрү** Кинәт ишү. *Чүмәләне ишеп җибәрү*

**Ишеп кую** Алдан ишү; ишелгән хәлгә китереп калдыру. *Капларны ишеп кую*

**Ишеп ташлау** Тиз-тиз ишү; кинәт ишү. *Алтынчәч, тезләрен бөгә төшеп, кайнар комнан таучыклар ясый, аннары аларны ишеп ташлый.* М.Маликова. *Ремонтларга ярамый бу бинаны. Аны ишеп ташларга гына кирәк.* Т.Миңнуллин

**Ишеп тору** Нииндидер вакыт дәвамында ишү; бертуктаусыз ишү

**ИШҮ** II *ф.* Бауны, җепне яки җеп сыман нәрсәне нык булсын өчен берничә катлы итеп үрү. *Әсирлеккә дә эләктем, аркан да ишәм. Станокта аркан ишү миңа таныш иде үзе.* М.Әмирханов. *Йөгереп уйнарга ярамаганлыктан, Рәйхана бәләкәйдән үк өй тирәсендә чуалды: шәл бәйләде, чабата үрде, юкәдән баулар иште.* З.Зәйнуллин. *Шәвәлиевнең куллары калтырый, бармакларын ул кая куярга белми, берберсе белән аралаштыра, бау ишкәндәй ишә, кыса, боргалый иде.* Ф.Садриев

**Ишә башлау** Ишәргә керешү. *Ул арада Сәгыйдулла уклау юанлыгы торбаны бау кебек ишә башлады.* Ф.Баттал

**Ишеп бетерү** Ахырга кадәр ишү. – *Арканыңны кайчан ишеп бетерәсең инде? – дим, энем поша башлагач.* М.Кәрим. *Шушы тойгылар әледән-әле йокыдан уяталар, ул әйләнә-тулгана җәймәсен, одеялын бау кебек ишеп бетерә, бер рәхәтләнеп еласам, җиңеләеп калыр идем, ди, әмма елый алмый.* Ф.Садриев

**Ишеп кую** Алдан ишү

**Ишеп тору** 1) Даими рәвештә ишү

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында ишү. *Кара Йомагылның кысык күзләре кинәт зураеп китте дә ниндидер тылсымлы нур чәчә башлады. Нур тәүдә аның итләч йөзенә таралды, аннан соң ул ишеп торган аркан буйлап йөгерде.* М.Кәрим

**ИШҮ** III *ф.* 1) Көймәне, корабны хәрәкәткә китерү максатыннан ишкәк, тәгәрмәч калаклары белән суны этәрү. *Океан – дөнья йөзендәге иң зур төрмә ул, ялгызак төрмәсе, мин иректе баштан шуның тоткыны идем һәм тәүлегенә унбишәр сәгать ишәргә мәҗбүр ителдем.* А.Гыйләҗев. *[Мәрдән абзый] Көймәсен этеп җибәрде дә, сикереп кереп, тиз генә ишкәкләрен киертте һәм шаулап килгән ак башлы дулкыннарга каршы каерып-каерып ишә башлады.* Г.Гобәй. *Каһир белән Ильяс бер көймәдә йөзәләр. Әнә Каһир Ильяска каршы утырган да җәһәт кенә ишә.* К.Латыйп // Аяк, кул, тәпи яки берәр яссы нәрсә белән суда гәүдәне хәрәкәткә китерү. *[Кариле егете белән] Бәхилләштем дә --- суга кереп киттем. Төенчекне уң кулыма алдым, сулы белән ишәм.* М.Мәһдиев. *Үрдәк бәпкәләре, тәпиләре белән ишеп, ярдан ерагайдылар*

2) *күч.* Тормыш агымы кешене үзе теләмәгән якка алып китү. *Шулай, ләкин кирегә ишсә язмыш, Үлеп китсә хатын, күп тормый яңлыш.* Г.Тукай

**Ишә башлау** Ишәргә тотыну. *Көймәчеләр, алты-җиде кеше алып, теге якка ишә башладылар.* Р.Хәбибуллина. *Вәли эре генә: – Күрерсез әле! – диде дә, артык сөйләшеп тормыйча, елга уртасына таба ишә башлады.* Н.Фәттах. *Прокофьев, ишкәк очы белән этеп, көймәне кузгатты, ишә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Ишә бирү** Бернигә карамыйча ишү; ишүен дәвам итү. *Ильяс кошлар сизмәсен өчен куе камышлыклар арасына яшеренергә дигән фикергә килде һәм иптәшенә ишарә ясады. Каһир ишә бирде.* К.Латыйп

**Ишеп алу** Бераз, аз гына ишү

**Ишеп карау** Ишәргә тырышу. *– Сәгыйть абый, – диде миңа сеңелыбрак Рузалия, – туктатыгыз әле, мин азрак ишеп карыйм. – Буйсындым. Рузалия, кулларын төкреклэп, ишкәккә тотынды ---.* А.Гыйләҗев

**Ишеп җибәрү** Кинәт ишә башлау. *Курыкма син бернидән, Ишеп җибәр кул белән, Аягың күтәр җирдән, Кыю йөзәргә өйрән!* Ш.Маннур

**ЙӨШ ЯСАУ** *ф. к.* **иш итү**. *Төннәрдә тагын да авыррак анысы. Караңгылыкны иш ясап, көчкә таң аттырган чакларың да була.* Н.Гыйматдинова

**ИЮ** I *ф.* Гәүдәнең, агач кәүсәсенең яки үлән сабагының югары өлешен түбәнгә, аска таба сыгылдыру, бөгү (сыйфат фигыль формасы *игән*). *[Сәхип] Башын түбән иеп, җиргә карап үтте.* Ш.Камал. *Ул башын тагы да аскарак иде, кашларын җыерып тынып торды.* А.Расих. *Өлкә комитеты секретаре баш иде, елмайды, күкрәгенә кулын куеп сәламләде ---.* Ф.Садриев

**Иеп кую** Иелгән хәлгә китерү; бер тапкыр ию

**Иеп тору** 1) Һәрберен берәм-берәм ию

2) Әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында игән булу; игән хәлдә тоту. *Йорт баскычы алдында яңа гына кайтып туктаган, койрыгын төйнәп бәйләгән, корсак астына кадәр пычранып --- беткән бер туры ат башын иеп тора.* Ә.Еники

**Ия башлау** Ияргә тотыну

**Ия төшү** Тагын да бераз ию. *Башымны ия төшеп, сыер савучыларга рәхмәтемне белдердем.* Н.Әхмәдиев. *Ректор, башын чак кына ия төшеп, профессор Ильясовага юл бирде.* М.Маликова. *Карыштай башаклар, авыраюдан, башларын җил искән уңайга ия төшкәннәр.* З.Фәйзи

**ИЮ** II *ф.* 1) Махсус эремәдә эшкәртелеп йомшару (тире турында; сыйфат фигыль формасы *иегән*). *Алар сәкегә иске, йоны иегән тиреләр җәеп, өсләренә киеп йөргән иске чикмәннәрен --- ябынып йоклыйлар икән.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Йомшару, нечкәрү. *Күңел ию*

**Иеп бетү** Тулысынча, бөтенләй йомшару. *Студентка череп, иеп беткән --- бер үләксә туный.* Ф.Әсгать. *Бераз арырак, суны ярдан аерган сызыкка тияр-тимәс, иеп беткән эт үләксәсе ята.* Р.Мостафин

**ИЮЛЬ** *и.* Календарь елының җиденче, җәйнең икенче ае. *Июль керде, ул арада яшь торгач тернәкләнеп, карт үзенә шөгыль дә тапты ---.* М.Мәһдиев. *Көн чалт аяз. Кояш бар көченә кыздыра. Унсигезенче елның егерменче июле иде бу.* В.Нуруллин. *Ямьле июль кичләренең берсендә хатын өйгә бик күңелсезләнеп, сөмсере коелып кайтты.* Ф.Шәфигуллин

**И-ЮНЬ** *и.* Рәт, уңай шартлар, мөмкинлек. *Шәһәрдә и-юнь булмагач, авылга кире кайттык*

**ИЮНЬ** *и.* Календарь елының алтынчы, җәйнең беренче ае. *Учаклардан әрфия булып сыек төтеннәр урмәләгәндә, июнь киче урманны серле бер тынлыкка әзерләгәндә, чирәм өстендә шушы өчлек җырлый.* М.Мәһдиев. *Июнь кояшы иртән үк кыздыра, чирәмдәге чыкны киптереп тә куйган.* М.Галиев. *Июнь төненең җиләс җиле, ачык калган тәрәзәләргә кереп, төн сәламен тапшырып чыкты ---.* Х.Ширмәт

**ИЯ** *и.* 1) Берәр нәрсәнең, милекнең хуҗасы. *Менә ул матур күзләрнең иясе, --- кап-кара чәчле --- кыз бакча читәне янына килде.* Ф.Әмирхан. *Ул арада түбән оч ягыннан салмак кына аяк тавышы ишетелде, озак та үтмәде --- көйле тавышның иясе үзе дә калкып чыкты.* Г.Бәширов. *Авылның ике мәхәлләсенең берсендә биш вакыт намазның берсен калдырмый үтәп барган мәчет картларының --- күпчелеге хәзер үзләре гүр ияләре.* М.Хәсәнов

2) Башлык, төп хуҗа; түрә. *– Ләйлә, син өйдә ия бул, чәй көйлә, Бәхтиярне кыста, ятсынып тормагыз, --- [диде Кол Гали].* М.Хәбибуллин

3) Нинди дә булса сыйфатка, дәрәҗәгә, сәләткә һ.б.ларга ирешкән кеше. *Авызларын ачып утырган мужикларның, бу вакыйгадан соң, булачак мулланың зур гыйлем иясе икәнлегенә шикләре калмады.* Ә.Фәйзи. *Бәһрамны бөтен авыл халкы ихтирам итә, гадел, булдыклы, зирәк акыл иясенә саный иде.* М.Хәсәнов. *Сез – талант иясе. Сезнең талант – ул ил, халык байлыгы.* Казан утлары

4) Хөрмәт, игътибар, әһәмият һ.б.ларны яулаган кеше яки әйбер. *Җәләш мулла угылларын да зур мәртәбә иясе, бай, иркен тормышлы, һәммә кеше тарафыннан хөрмәт ителеп яшәүчеләр итеп күрәсе килә.* Г.Нигъмәти. *Оста Әхмәт Кашан каласында хөрмәткә ия кешеләрнең берсе иде.* М.Хәбибуллин. *[Р.Фәхреддиневнең] Матбугатта басылган бик күп китаплары һәм мәкалә-*

*ләреннән тыш, зур фәнни әһәмияткә ия булган 40 том басылмаган --- язмалары [бар].* Казан утлары

5) Берәр эш белән шөгыльләнүче, берәр кәсеп белән яшәүче, көн күрүче кеше. *Белә инде бездә аны Һәрбер хезмәт иясе: Буйсына аңа үзе дә Атом энергиясе!* Ә.Исхак. *Әйе, һөнәр ияләре булуы да бик мөмкин, соңгы вакытта Бөек Калада бу халык аерата ишәеп китте.* М.Хәбибуллин

6) Нәрсә булса да иҗат иткән, уйлап чыгарган зат; автор. *Сүз – иясе белән йөрми.* Мәкаль. --- *ул заманның яңа сыйныф әдип, шагыйрьләре, сәнгать ияләре эчендә дә романтизм тойгыларына бирелүчеләр булгалады.* Г.Нигъмәти. *Гадәттә, без, каләм ияләре, «дөньяның тоткасы – гади халык, хезмәт кешеләре» дигән гыйбарәне алга чыгарып куярга яратабыз.* Р.Фәизов

7) *миф.* Халык ышанулары буенча: суда, урманда, йортта, абзарда һ.б.ш. урыннарда кешегә күренмичә яши торган һәм шуларның хуҗасы саналган мифик зат. *Алтын тәңкәле киемнәрдән, пыяла таягына таянып су иясе килә.* Н.Исәнбәт. *Кыз, чынлап та, баһадир Бачман сеңлесе идеме, аның сурәтенә кергән урман иясе булса?.. Болгар халкы урман иясен «Шүрәле» ди.* М.Хәбибуллин. *Урман күленең үз иясе – Су кызы бар, дип, телдән-телгә тикмәгә генә риваять йөрмидер.* К.Латыйп

8) *миф.* Мәҗүси болгарларда: явыз рух

9) *иск. дини* Тәңре, Аллаһы. *Ясаган иямә шул вакыт ант бирдем ---.* Г.Ибраһимов

10) *лингв.* Җөмләдә бары тик баш килештә килә һәм хәбәр тарафыннан расланган яки аныкланган предметны яки билгене белдерә торган баш (грамматик бәйсез) кисәк. *Ия, башлыча, исемнәр белән бирелә. Исем мәгънәсендә барлык башка төрле сүз төркемнәре дә җөмләдә ия булып килә алалар.* Татар грамматикасы. *Ия төрле мәгънәләр белдерә: билге йөртүче, үтәүче, эш башкаручы, --- эшкә булышучы.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев. *Бер генә сүз белән бирелсә, ия «гади ия» дип йөртелә.* Татар теле морфологиясе

**ИЯ́ ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Баш җөмләдәге алмашлык белән белдерелгән ияне ачыклап килгән яки баш җөмләнең иясе урынына килә торган иярчен җөмлә (мәсәлән: «Кем эшләми, шул ашамый»). *Ия җөмлә баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, --- «ки» теркәгече ярдәмендә бәйләнә.* М.Зәкиев

**ИЯК** *и.* 1) Кеше йөзенең аскы өлешендә аскы теш казналары урнашкан, ашаганда һәм сөйләгәндә хәрәкәтләнә торган ярымтүгәрәк чыгынты. *[Ул] Кечерәк кенә буйлы, чандыр гәүдәле, ач яңаклы, ияк очында сирәк кенә сакаллы, --- салмак кына сүзле кеше иде, мәхрүм.* М.Гафури. *Моңарчы битараф бер чырай белән тыңлап кына утырган Идият абзый кузгалып куйды, сакалсыз ияген сыпырып алды ---.* Ә.Еники. *Карт, көндәгечә, самавыр артында ияген сыпырып кына дәшмичә утыра.* М.Мәһдиев

2) *диал.* Ишек һәм тәрәзә яңагы. *Гафифә аркасы белән ишек иягенә сөялгән, йөзе ак киндер кебек булган, иреннәре күгәргән иде.* Ш.Камал

3) *күч. к.* **итәк** (*5 мәгъ.*). *Маңгаенда тауның – кыя ташлар, Иягендә – зәңгәр урманнар.* Н.Исәнбәт

◊ **Ияк асты (ияге) тишек** *сөйл. шелт.* Сер тотмас кеше турында әйтелә. **Ияк биетү** *сөйл.* Яхшылап, нык-лап ашау. *[Алар энеләрен] Көттеләр, көттеләр дә, казандагы токмачның шулпасы кайнап бетә язгач, тавышсыз-тынсыз гына ияк биетергә керештеләр.* Ш.Рәкыйпов. **Ияк кагу** 1) Исәнләшү, сәламләшү билгесе. *Элек, сәлам биргәч тә, теләр-теләмәс кенә ияк кагып үтүчеләр хәзер ерактан ук кул сузып килүчән булып киттеләр.* Б.Камалов. *Үткән-сүткәннәр аңа игътибар итәләр, таныганнары кычкырып исәнләшәләр. Митрәй агай аларга күтәрелеп карамый, бары тик ияк кага ---.* М.Хәбибуллин. *Ул [Борһанетдин бәй] минем белән ерактан ук ияген кагып нәзакәтле генә исәнләште.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) Раслау, җөпләү, ризалык белдерү билгесе. *Сәмәрхановның йөзенә карасаң, чамалыйсың: әйткәннәрен күз карашы белән раслап бара. Сизелер-сизелмәс кенә ияк тә кага.* Б.Камалов. – *Түләтү генә түгел! – дип, башын күтәреп ияк кагып куйды Габдулла. – Кая керер тишек тапмады баең!* Ә.Фәйзи. *Лаборантка апа, ризалыгын белгертеп, ияк какты.* Э.Касыймов; 3) Ымлау, ымлап, ишарәләп берәр нәрсә эшләргә кушу. *Тышта ниндидер тавышлар ишетелә башлады. Сәлим хан ияк кагып кына ишек янында торган җансакчыларына карап керергә кушты.* М.Хәбибуллин; 4) Сорау ишарәте. *Яшь чекист бүлмәгә әйләнеп кергәч, Шамил, сораулы караш белән, әкрен генә ияк какты: ничек ишетелә, янәсе?* З.Фәтхетдинов. **Ияк кычып йөрү** 1) Берәр нәрсәгә катышасы, нәрсә дә булса әйтәсе килеп йөрү. *Минем бик ияк кычып йөри инде ул персидәтелегезгә, җыелышта эшләрен фаш итеп чыкмыйча булмас.* Н.Исәнбәт; 2) Берәр нәрсәгә нәфес төшү

**ИЯЛӘНҮ** *ф.* 1) Күнегү, гадәтенә кертү, өйрәнеп китү. *Билгеле, Хәмдия өчен бу гаиләдәге кайбер гадәтләргә ияләнү яки аларга иярү бигүк җиңел булмады булуын.* Г.Галиев. *Бер-береңне ирештерүгә ияләнмәгән кеше флотта яши алмый. Әнә Овсюк ияләнде, бичара.* М.Мәһдиев. *Әнисе үлеп киткәч, гел әзергә, чиста-пөхтәгә, кадер-сыйга гына күнеккән егет авыр хәлдә калды. Акрынлап җайлашты, ияләнде тагын.* Р.Фәизов

2) Гел яки еш килеп йөрү, янында күбрәк булырга тырышу. *Килә ява, килә ява, Ияләнде бер болыт.* Җыр. *Бер җәйдә Гөлсем апа янына, кунакка кайткан, нәүбәттәге бер ир-ат ияләнде.* Р.Фәизов

3) *к.* **ияләшү** (*3 мәгъ.*). *Тереклек ияләре кулларында бернинди короллары булмаган, бернинди дошманлык гамәле күрсәтмәгән кешеләргә бик тиз ияләнделәр.* Р.Фәизов. *Ул Закировка бик тиз ияләнде.* Р.Кәрами

◊ **Ияләнде шөпшә көнбагыш чәчкәсенә** Бер ияләнгән җиргә кат-кат килүчегә карата әйтелә. *Сали өенә кереп киткәч, барысы да җиңел сулап куялар. – Ияләнде шөпшә көнбагыш чәчкәсенә, – ди Монтазима, әллә гаепләп, әллә хуплап.* М.Маликова

**Ияләнә башлау** Бераз ияләнү. *Ул минем хакта сөйли башлады ---. Һәм*

*шатланып елмаюдан йөзе ачылып китте, күз төпләренә ияләнә башлаган сызыклар югалдылар.* М.Хуҗин. *Барс та акрынлап хуҗасына ияләнә-күнегә башлады.* З.Хөснияр

**Ияләнә алу** Ияләнергә мөмкинлек табу. *Ул бу саф, матур тормышка бик тиз ияләнә ала.* М.Фәйзи

**Ияләнә бару** Торган саен ныграк ияләнү. *Ул көннән-көн матурлана, шаянлана, җитезләнә, акрынлык белән генә булса да, миңа ияләнә бара иде.* Ф.Әмирхан. *Гомумән, алар бер-беренә көннән-көн ныграк ияләнә баралар.* Р.Кәрами. *Машинаны йөртү бик кыен, шулай булса да, син бу эшкә көннән-көн ияләнә барасың.* Казан утлары

**Ияләнә тору** Әлегә, хәзергә, бераз ияләнү. *Фәрдәнә Сәрвиназ утырасы урындыкка яңа киез салгач, кыз уңайсызланды, әмма каенана буласы кеше: – Сәрвиназ, ияләнә тор, ---, – дип җайлап җибәрде.* Ирек мәйданы

**Ияләнә төшү** Азрак, тагы да бераз ияләнү. *Авыз ияләнә төштеме, моньсының тәме әүвәлгесеннән бераз җиңелрәк тоелды.* Г.Камал. *Көннәр үтеп, бер-берсенә ияләнә төшкәч, Гөлҗиһан сөйкемле киленнең кайбер сәер гадәтләре барын да искәртеп өлгерде ---.* Ф.Сафин. *Шул арада алар бер-берсенә ияләнә төшетеләр.* Ә.Моталлапов

**Ияләнеп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә ияләнү

**Ияләнеп бару** Вакыт үткән саен күбрәк ияләнү, аз-азлап, акрынлап ияләнү. *– Ник --- килдең Казанга? – диде Рамилә, кинәт башын күтәреп. – Ялгызлыгыма ияләнеп бара идем бит инде!* Н.Әхмәдиев

**Ияләнеп бетү** Тәмам, тулысынча ияләнү. *Бәлки, шулай кирәктер, дигән фикергә ияләнеп беттем кебек.* Л.Ихсанова. *Ул --- үзенең балага ияләнеп беткәнен аңлатып язып салды.* Г.Гобәй. *Югыйсә, без гел ит, сөт, икмәк турында гына сөйләшергә ияләнеп беткән.* М.Мәһдиев

**Ияләнеп җитү** Тәмам, тиешенчә ияләнгән булу. *Хәзерге ае биш сумлык ияләнеп җиткән бүлмәдән ае алты сумлык бүлмәгә күчү аңа кирәкмәгән эш шикелле күренде.* Ф.Әмирхан. *Ул --- инде Хәлимнең үзенә тәмам ияләнеп җиткәнен күрде ---.* Г.Гобәй. *Ала сыер соңгы вакытларда йомшак тавышлы бу хатынны иртә-кич күрсә дә, аңа, ничектер, ияләнеп җитмәгән иде әле.* Г.Галиев

**Ияләнеп килү** *к.* **ияләнеп бару**. *Артык пошынмыйча, язасы килгәндә генә язып, үз җаема гына яшәүгә ияләнеп килә идем бугай инде.* Л.Ихсанова. *Хәзер минә Газизнең ата-анасы ---, үзләре дә сизмәстән, улларының үлүенә ияләнеп киләләр.* Г.Бәширов. *Соңгы көннәрдә салкыннар бик еш кабатланганлыктан, балалар моңа инде ияләнеп тә килә ---.* М.Мәһдиев

**Ияләнеп китү** Тора-бара ияләнү, гадәткә керү. *Ул аның шалтыратуына шулхәтле ияләнеп китте ---.* Ә.Сафиуллин. *Сыерлар агач күләгәсенә ял итәргә яткач, без шунда балык каптырырга ияләнеп киттек.* Н.Хәсәнов. *Төнгә остаханәләрнең хуҗалары, гадәттә, өенә кайтып китә, бинаның бу каты бөтенләй буш кала. Шуңа күрә аңа йортсыз-җирсез сәрхушләр ияләнеп киткән иде ---.* М.Маликова

**ИЯЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Кемне дә булса берәр нәрсәгә, эшкә гадәтләндерү, күнектерү. *Салгаларга яраткан Валя тора-бара бу зәхмәткә ирен дә ияләштерде.* Ватаным Татарстан. *Алар 150 яшь кешене наркотикларга ияләштерергә өлгергән.* Шәһри Казан. *Баш астына мендәр куеп йокларга әни айлар буе ияләштерде.* Безнең гәҗит

2) Берәр урынга әледән-әле, еш йөртү, шунда йөрергә гадәтләндерү. *Яхшы күңеле, акыллы Саҗидә аларның хәлләрен аңлап, үзләренә ияләштерде.* М.Галәү. *Бу бичараны үзенә ияләштереп, йортка кертәсе, иптәшле буласы киләдер бәлки.* Идел. *Канат йоннары чыгып, карга-тилгән ала алмаслык булгач, үрдәкләрне «әниләре»ннән аерабыз: берәр атнага тавыкны аерым абзарга бикләп, үрдәкләрне елгага ияләштерәбез.* Ватаным Татарстан

3) Кемгә дә булса буйсындыру, аңа күнектерү, тыңлаучанга әйләндерү. *Алар илендәге сирәк-мирәк елга үзәннәрендә кабан яши ала, ләкин аны күчмә тормышта кулга ияләштереп, ерак җирләргә куып йөртеп булмый.* З.Мифтахов. *Минә нигә борынгылар иң беренче йорт хайваны итеп кәҗәне кулга ияләштергәннәр!* Сабантуй. *Аюны да биергә өйрәтәләр, башка хайваннарны да кулга ияләштерәләр.* Ватаным Татарстан

**Ияләштерә бару** Торган саен ныграк ияләштерү. *«Барс-медиа» компаниясе безне акрын гына ярымшәрә җырчыларга да, биючеләргә дә --- ияләштерә бара.* Татарстан яшьләре

**Ияләштерә башлау** Ияләштерергә керешү. *Галимнәр фикеренчә, тавыкларны якынча 4000 еллар элек Көньяк Көнчыгыш Азиядә --- кулга ияләштерә башлаганнар.* Биология

**Ияләштерә төшү** Тагын да бераз, беркадәр ияләштерү

**Ияләштереп бетерү** Бөтенләй, тулысынча, тәмам ияләштерү. *Казанда шактый еллар яшәгәч, Татарстан климаты үзенә ияләштереп --- бетерде ахры мине.* Казан утлары

**Ияләштереп карау** Ияләштерергә тырышу

**ИЯЛӘШҮ** *ф.* 1) Берәр кешегә, нәрсәгә, эшкә күнегү, өйрәнү, гадәтләнү. *Йокы даруына да ияләшмәү ягын карарга киңәш итәр идем...* Б.Камалов. *Килен шәһәрдән, затлы нәселдән булуына карамастан, --- йортка тиз ияләште ---.* М.Мәһдиев. *Зәйнәп --- сөттә кабартылган тары ярмасын чебиләргә --- салды: – Моннан соң суда бүрттерелгән ярмага ияләшәсегез булыр инде, – дип сөйләнде.* М.Галиев

2) Берәр урынга әледән-әле, еш йөри башлау, аны гадәткә алу. *Карлен әкренләп «Золотой петушок» ресторанына ияләште.* Р.Мирхәйдәров. *Теге яшь каенлыкка тагын берничә оя көртлек ияләшкән...* М.Хәсәнов. *Безнең зур калын толымлы, алсу-ак битле Резедабызга --- Фәршад исемле бер егет ияләште.* Г.Ахунов

3) Кемгә дә булса буйсыну, аннан кыенсынмау, аңа күнегү, үзләшү, тыңлаучанга әйләнү. *Барыбер тормаячак иде ул кыз. Андыйлар, иярләмәгән кыргый тай кебек, кулга ияләшми.* Х.Ширмәт. *Ияләшү – мәхәббәт түгел ул. Әнә эт-мәче дә кешегә ияләшә.*

Р.Габделхакова. *Бөтенләй үк ышанып җитмәсә дә, төлке безгә хәзер шактый иләште.* Н.Әхмәдиев

**Иялэшә алу** Иялэшергә мөмкинлек табу. *Моннан өч ел чамасы элгәре булды бу: яңа фатирга күчеп, зур шәһәрнең икенче бер төбәгенә иялэшә, көнегә алмый йөдәгән көннәр иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Иялэшә бару** Вакыт үткән саен күбрәк иялэшү; аз-азлап, акрынлап иялэшү. *Скрипка торган саен кулга иялэшә бара иде.* Г.Бәширов. *Әкренләп Габделкаюм боларның һәммәсенә дә иялэшә барса да, еш кына өе, --- искә төшеп, ул аларны өзелеп-өзелеп сагына иде.* М.Гафури. *Актәпи көннән-көн йортка да, аның кешеләренә дә ныграк иялэшә барды.* Н.Әхмәдиев

**Иялэшә башлау** Бераз иялэшү. *Башта мина, бомбалар шартлаудан коты очып калган егет әкрен генә бу тәмуг күренешләренә иялэшә башлады.* Р.Сәгъди. *--- торган саен урмандагы агачлар да сирәгәя, һәм шул сәбәпле элеккеге куе урман эченә кояш иялэшә башлады.* З.Хөснияр. *Бераздан соң күзләре караңгыга иялэшә башлады.* Ф.Яруллин

**Иялэшә төшү** Азрак, тагы да бераз иялэшү. *Ә инде тора-бара мәхәббәт сынлы кыз иялэшә төште булса кирәк...* Р.Мирхәйдәров. *--- чәй алдында гына, бер-беребезгә иялэшә төшкәч кенә түбәндәгечә сөйләшүләр китте ---.* Г.Кутуй. *Вакыт үтү белән, Зәйтүнә бу әнисенә дә, әлбәттә, иялэшә төште.* Ф.Хөсни

**Иялэшеп алу** Тиз арада иялэшү. *Ишетүемә караганда, җизнәм бик озак заманнар солдатта кяфер арасында йөреп, иманын югалтып кайткан. Шуның аркасында, гөнаһларын йолмакчы булып, мәчеткә иялэшеп алган.* М.Кәрим. *Бездән кыйгачрак урам аша Каюп агайлар тора. Берзаман мин аларга бик нык иялэшеп алдым.* М.Кәрим

**Иялэшеп бетү** Бөтенләй, тулысынча, тәмам иялэшү. *Яңа тормышка тәмам иялэшеп беттең бугай.* Г.Галиева. *Тора-бара Гатаулла абзыйның теленә авыл халкы иялэшеп тә бетте.* Ә.Хәсәнов. *--- хатын үзенең фаҗигале хәленә күптән иялэшеп беткән иде.* Ә.Еники

**Иялэшеп җитү** Тәмам иялэшү. *– Буламы, Исмәгыйль? Бик арытмыймы? – диде директор. – Зарар юк, Елизавета Сергеевна, иялэшеп җиттем инде, – диде Исмәгыйль.* Ә.Сафиуллин. *Укулар бетеп, ял вакыты килгәч, күңелсезләнә башладым. Иялэшеп җиткән якын дусларым юк.* М.Әмир. *Тәмам иялэшеп, үзләшеп җиткәндә генә: – Иртәгә мин китәм инде, Өлфәт, – диде Сәкинә.* В.Нуруллин

**Иялэшеп килү** Әкренләп, аз-азлап иялэшү. *Даниянең күзләре караңгыга иялэшеп килә иде.* А.Вергазов. *– Заводта хәлләр ничек соң? – Иялэшеп киләм бугай инде әкренләп.* Р.Вәлиев. *Нәзакәтле кыз-кыркын чат ябышып ятучы бу баллы һәм шикәрле тәгамнәрне электән үк өнәмәсә дә, Чәчкә белән йөри башлагач, Айзат та аларга яхшы гына иялэшеп килә иде инде.* Г.Мөхәммәтшин

**Иялэшеп китү** Тора-бара иялэшү. *--- Марат самолёттагы пассажирларга тиз иялэшеп китте.* Г.Гобәй. *Шул рәвешле тормыш ярыйсы гына барганда, Зәбир йомшаклык күрсәтеп аракыга иялэшеп китте.* Н.Хәсәнов. *--- Карлен Мәскәүдә иялэшеп киткән «Баллантайн» вискиен урысларча тутырып салды да каплап та куйды.* Р.Мирхәйдәров

**ИЯЛӘШҮЧӘН** *с.* Кешегә тиз күнегүчән, ияләнүчән. *Яшь аналарга аеруча иялэшүчән була, диләр бит яшенне.* Г.Гыйльманов. *Хатын-кыз кавеме яңалыкка тиз иялэшүчән ---.* Р.Мирхәйдәров. *Ана җәнлекләр йомшак, назлы, кешегә тиз иялэшүчән, шуңа күрә шулай аз калганнар да.* Татарстан яшьләре

**ИЯЛӘШҮЧӘНЛЕК** *и.* Күнегүчән, ияләнүчән булу

**ИЯЛЕ** *с.* 1) Иясе (*1, 6 мәгъ.*) булган. *Бу урын ияле. Әйбер ияле булу*

2) Ире булган, ирле (хатын кеше турында). *Бу хатын инде ияле, синеке түгел.* Мәдәни җомга

3) Җөмләдә ия булып килгән. *[Бу җөмләләрнең] Ияле икәнлекләре исемнәреннән дә аңлашылып тора.* В.Хангилдин

**ИЯЛЕК** *и.* Нәрсәнең дә булса иясе булуны аңлата. *Йортка иялек документы*

**ИЯЛЕ́К КИЛЕШЕ** *и. лингв. Кемнең? Нәрсәнең?* сорауларына җавап бирә, предметның яки затның башка бер предметка яки затка ия булуын белдерә торган килеш. *Баш һәм иялек килешләрне Вил шартлатып әйтеп бирде.* Э.Касыймов. *Иялек килеше предметның (затның) башка бер предметка (затка) ия булуын, --- предметлар арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдерә ---.* Татар грамматикасы. *Сонор тартыкка башланган иялек (-ның/-нең) һәм төшем килеше --- кушымчалары ике вариантта --- килә.* Татар теле морфологиясе

**ИЯР** *и.* 1) Атка яки ишәккә, дөягә атланып утырыр өчен махсус җайланма, утыргыч. *Әнисе ияр өстенә аркылы яткан, чәчләре асылынып төшкән, --- иде.* Г.Бәширов. *Барысы да толпарга сокланып карадылар. Йөгәне, ияре, япмасы, эзәңгесе – гелән алтын-көмештән иде.* М.Хәбибуллин. *Карт авылына ашыккан Сылукайны ияреннән тотып туктатты.* Н.Гыйматдинова

2) *тех.* Утырту, кидерү, саклау яки терәтү өчен кулланыла торган җайланма детальләре исеме

3) Кош түшендә сыртланып торган сөяк

4) *күч. сөйл.* Велосипед, мотоцикл, мотороллер һ.б.ш.ларда утыргыч. *Мотовелосипед бер-ике метр этеп баргач та кабынды. Әбүзәр иярга сикереп тә менде, --- капка аша урамга атылып та чыкты.* А.Тимергалин

5) *күч. сөйл.* Җитәкче, башлык. *Өйгә кайткач, хатыны үртәде: – Даншөһрәтне бик ярата башладың, картаясың ахры? --- Һаман иярдә барырга телисең.* Х.Камалов

◊ **Иярдә тоту** Төрле көтелмәгән хәлгә әзер булып тору, уяулыкны югалтмау. **Ияреннән аву** Җитәкче урыннан, түрәлектән төшерелү. *Безнең баш кеше ияреннән ауды, яңасын ясап атландырып куйдылар.* Н.Исәнбәт. **Ияреннән бәреп төшерү** Җитәкче урыннан, түрәлектән алып ташлау, эшеннән чыгару. *Түрә чагында бик иләсләнгән иде, ияреннән бәреп төшергәннәр егетне.* Н.Исәнбәт

**ИЯ́Р АГАЧЫ** *и.* Ат ияренең агач кысасы

**ИЯ́Р АЕЛЫ** *и.* Ат сыртындагы иярне яки япманы беркетә торган киң каеш

**ИЯ́Р АРЧАГЫ** *и. к.* **ияр агачы**

**ИЯ́Р АСТЫ** *и. к.* **ияр җәймәсе**

**ИЯ́Р БАВЫ** *и. к.* **ияр аелы**. *[Ат] Ияр бавы тартылганда хуҗасының җиңеннән тешләп-тешләп алгалады.* И.Туктар. *Зина атының иярен салдырмаган иде әле. Ул ияр бауларын чиште.* А.Расих. *Ординарец атларны яшел лапас астына алып кереп китте. Кемдер аңа: – Ияр бауларын бушата төш, – дип киңәш бирде.* Г.Әпсәләмов

**ИЯ́Р БУКЧАСЫ** *и. к.* **ияр капчыгы**. *Җаныбәк, --- ияр букчасыннан зур киндер алып, Ярулланың тәне кызып яна башлаганчы, бик ныклап ышкыды.* З.Зәйнуллин

**ИЯРЕШЛЕ** *с. махс.* Бер-берсе белән бәйле булган, үзара бәйләнештә булган; *русчасы:* **сопряжённый**. *Ияршле гиперболалар*

**ИЯ́Р ҖӘЙМӘСЕ** *и.* Атның аркасы суелмасын өчен ияр астына җәелә торган постау яки киез; ыңгырчак киезе. *[Атлы] Атыннан төште, --- бармакларын ияр җәймәсе астына кертте.* Ш.Камал

**ИЯ́Р ҖӘЯСЕ** *и. к.* **ияр кашы**. *Чапкыртайның күзенә яшь бәреп чыкты. Дагалар җиргә тигән саен, күз яшьләре ияр җәясенә тамалар иде.* Р.Батулла

**ИЯ́Р КАНАТЫ** *и.* Иярнең ике ягына өзәңге бавы өстеннән төшеп торган күн

**ИЯ́Р КАПЛАВЫЧЫ** *и.* **ияр канаты**

**ИЯ́Р КАПЧЫГЫ** *и.* Азык-төлек, кирәк-ярак салып, ияр элмәгенә асып йөри торган капчык, букча. *Вәзир килеп ике бармагы белән ханның күз кабакларын төшерде, башны ияр капчыгына салды.* Р.Зәйдулла. *Ә борынгылар бавырсакны, ияр капчыгына салып, сугыш кырына алып китә торган булганнар.* М.Юныс

**ИЯ́Р КАШАГАСЫ** *и. к.* **ияр кашы**. *Дөябай, --- бераз аты өстендә утыргач, кулындагы чукмарын ияр кашагасына элде дә биленә кыстырган камчысын уң кулына алды.* З.Зәйнуллин

**ИЯ́Р КАШЫ** *и.* Иярнең дугаланып торган алгы яки арткы кырые. *Алачын Алау куып килеп җитте. Атына атты. Иярнең арт кашына тиде.* Дастан. *Шыпырт --- озын сөңгесе белән дәрвазага какты да, --- затлы йөгән тезгенен көмеш ияр кашына гына элеп, --- нык бәдәнле гаярь җайдакның күтәрмәле күпергә олугланып якынаюын хәбәр итте.* Р.Зәйдулла. *Әтием, минем ризалыкны көтеп тормый, иңбашымдагы йөгемне иелеп алып, ияр кашына салды.* М.Кәрим

**ИЯ́Р КИЕЗЕ** *и. к.* **ияр кашы**

**ИЯ́Р КОЙРЫКЧАСЫ** *и.* Ияр алга таба шуышмасын өчен ат койрыгына кидерелә торган бөҗралы каеш

**ИЯРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Атның яки ишәкнең сыртына ияр беркетү. *Заһир абый --- миңа: – Ни карап торасың, ияргә Алмачуарны! – дип кычкырды.* М.Маликова. *Акбикә көмеш кыңгыравын чыңлатуга, бусагабаш килеп керде. – Миңа ат иярләгез, туры бияне.* М.Хәбибуллин. *Юныс энем, бар, йөгер Гыйззәткә, хәзер үк ике ат иярләп китерсен!* Ә.Еники

2) *күч.* Атлану, атланып утыру. *Әйдә, җилкәгә иярләп утыр, аякларыңны җәйла.* Ш.Камал. *– Җибббәрр! – дип тырылдады тыңкыш Зәйтүн, яткан җиреннән аркасын дугаландырырга һәм Әнәсне чөеп ыргытырга тырышып. Тик Әнәс аны нык иярләгән иде.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Буйсындыру, кулга алу; баш булу. *Зәринә күкрәгендә бөреләнеп, аның саен зурая, куәтләнә барган тыелгысыз ярсу көчне иярли алырлык халәттә түгел иде ---.* Г.Әдһәмова

4) *күч.* Фәнне, техниканы үзләштерү һәм үз максатларыңа, үз мәнфәгатьләреӊ өчен файдалану. *Без, иярләп техниканы, Үттек норма киртәсен.* Г.Кутуй. *Кемнәр иярләп бетерсен: Техникасы иксез-чиксез; Очкыч, танк, ракеталар – Тора бар да үксез?!* Р.Рахмани

5) *күч.* Нәрсә белән булса да идарә итү, йөртү. --- *ул инде шактый мәртәбәләр руль тоткалады. Машинаны матур гына «иярли» белә.* Ф.Яруллин

6) *күч. хәрби* Елга, тимер юл кебек стратегик әһәмиятле урынны кулга төшереп, шуның тирәсендә ныгу. *Аның взводына --- зур таш юлны иярләргә, чолганыштан котылырга теләгән дошманны үткәрмәскә кирәк иде.* А.Шамов

**Иярләп алу** Тиз генә иярләү

**Иярләп кую** Алдан иярләү, иярләнгән хәлдә тоту. *Атын иярләп куярга боерды.* Т.Миңнуллин

**Иярләп чыгу** Һәрберсен, берәмберәм иярләү

**Иярли башлау** Иярләргә тотыну. *Фәрит Гыйльми дә, Әлмәткә күчкәч, Бикчурин, Рәхимовлар йогынтысына бирелеп, эш атларын иярли башлады түгелме...* Р.Вәлиев

**ИЯРЛЕ** *с.* Иярләнгән, ияре булган. *Арба саен бер ат тотучы икәнен Захаров бик яхшы күрде, бары тик ул иярле атларны караучыларның ничә икәнен генә белә алмады.* А.Шамов. *Өстенә ул чорның үзенә хас киемен – кара күн тужурка, башына күн фуражка киеп, кылыч белән наган таккан атасы, иярле атка менеп, ике йөкнең алдыннан бара.* Г.Бәширов. *Баскыч төбендә көтеп торган ике иярле атның берсенә --- Искәндәрев атлана.* Ә.Еники

**ИЯРЛЕ-ЙӨГӘНЛЕ** *с.* Ияре белән йөгәне булган. *Ир-егетнең эчендә иярле-йөгәнле ат ятар.* Мәкаль. *Ир-егетнең эчендә иярле-йөгәнле ат ятуын исәпләп бетермибез шул кайчак.* Шәһри Казан

**ИЯРЛЕК** *и.* Ат яки ишәк сыртының ияр беркетелә торган урыны. *Гали чиләк белән сумала китерә. Атның иярлеген майлыйлар.* Д.Аппакова

**ИЯРЛЕКЛӘ́Ү** *ф. күч.* Кемне дә булса бик нык кулда тоту, буйсындырып тоту

**Иярлекли бирү** Бернигә дә карамый иярлекләү

**ИЯРМӘ** *с. тех.* 1) Бер-берсенә бәйләнгән, үзара бәйләнештә торган. *Иярмә реакцияләр*

2) Машиналарда: йөртүче деталь тәэсире астында хәрәкәтләнә торган. *Иярмә тәгәрмәч*

**ИЯРМӘЛЕ** *с.* Нәрсәгә дә булса (мәс., кошлар тавышына) ияреп ясалган. *Сирин өчен, сурәт тудырганда, хәрәкәт итү тавышларына иярмәле чаралар куллану хас.* Х.Госман

**ИЯ́Р ТАКТАСЫ** *и. к.* **ияр агачы**

**ИЯРТЕМ** *и. лингв.* Кеше тавышына, хайван һәм кош-корт, бөҗәкләр чыгарган авазларга һәм җансыз предметлар тудырган хәрәкәт, образларга охшатып ясалган сүз; аваз яки образ ияртеме. *Ияртемнәргә чынбарлыкның төрле күренешләрен образлы чагылдыру өчен килгән образ ияртемнәре дә керә.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев. *Тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре белән бергә кеше яки предмет хәрәкәтен, яктылык яки башка билге буенча табигать күренешен «образлы итеп күз алдына китерү өчен» дә төрле ияртемнәр кулланыла.* Татар теле морфологиясе. *Мотивлаштырылган тамгалар хезмәтен үтәү, ягъни аларның яңгырашы белән мәгънәсе арасында турыдан-туры бәйләнеш булу аркасында, аваз ияртемнәре, --- югары экспрессия белән сугарылган булалар ---.* Татар грамматикасы

**ИЯРТМЕШ** *и.* Ияреп эшләнгән эш, охшатып эшләнгән әйбер; имитация

**ИЯРТҮ** *ф.* 1) Каядыр барганда кемне яки нәрсәне дә булса үзе белән бергә алу, бергә йөртү, үзеннән калдырмау. *Режиссёр, эченнән бөтен дөньяны әйләндерә-әйләндерә сүгеп, яшел куллы туташны ияртте дә клубына китте.* Г.Бәширов. *Апанайны тылмач итәр өчен алмады ул, үзе дә урыс телен ару гына сукалый иде. Ул аны башка уй белән ияртте.* М.Хәбибуллин. *Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: Фарукҗан ике дә уйламый иптәшен ияртеп керде дә нәкъ шулар артындагы урынга утырды.* Т.Әйди

2) Үзе белән алып килү, үзеннән калдырмау. *--- тыштан үзенә әллә ни чаклы суыклар, карлар ияртkән ялчы килеп керде ---.* Г.Ибраһимов. *--- барыбер чәчәкләрен ияртеп яз килер, барыбер без тагын ялангач комга ятып, --- кояшка күзебезне кысарбыз.* Һ.Такташ

3) *юкл. форм. сөйл.* Артыннан җиткермәү. *Бер сту[дентны] өч казак атта куа, ә ул, ичмасам, ияртми дә, ди.* Т.Гыйззәт

4) *этн.* Кызны ата-анасы ризалыгыннан башка ябыштырып чыгару, хатынлыкка алу, өйләнү

**Ияртә башлау** Иярергә рөхсәт бирү. *--- бәләкләре бераз ныгый башлау белән, атасы аны урманга, утын алып кайтырга, аны бушатырга, кисәргә, ярырга, үзе белән ияртә башлады.* С.Салах

**ИЯРТҮЛЕ** *с. лингв.* Бер җөмлә кисәгенең (яки җөмләнең) икенче җөмлә кисәгенә (яки җөмләгә) буйсынуына, иярүенә нигезләнгән. *Татар телендә ияртүле бәйләнешне өч төргә бүлү традициясе яшәп килә.* М.Кашапов. *Ияртүле конструкцияләр*

**ИЯРТҮЧЕ** *и. диал.* **1.** 1) Йөртүче, җитәкләп йөртүче; *русчасы:* **поводырь**. *Сукыр кешене ияртүче*

**2.** *с. мәгъ. лингв.* Иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртеп килә торган. *Теркәгеч, шул исәптән ияртүче теркәгеч тә, бары тик бәйләүче чара вазифасын гына үти.* Татар грамматикасы. *Ияртүче теркәгечләргә «чөнки», «ки», «гүя», «гүяки», --- «ягъни» кебек теркәгечләр керә.* Татар теле морфологиясе. *Әгәр аныклагыч уртак ияртүче кисәк белән янәшә урнашса, өтер бер яктан гына куела.* Фән һәм тел

**ИЯРҮ** *ф.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса артыннан калмый бару. *Юлда аларга тагын алты-җиде малай иярде.* Г.Гобәй. *Җәмилә Закировна каталка артыннан иярде.* М.Маликова. *Сәлим хан мәйданның иң күркәм вә калку урынына --- юнәлде, аңа ханбикә Зөбәрҗәт һәм башкалар иярде.* М.Хәбибуллин

2) Берәр кешегә яки нәрсәгә ябышу, тагылу, сырылу, сылану. *Суккан саен, --- тәненнән, чәчрәп һәм чыбыкка ияреп, тасма-тасма тире белән ит кубып чыга иде.* М.Гафури. *Ул бишмәтенә ияргән башак, салам кисәкләрен чүпләп атты ---.* И.Гази. *Хәлим, винтовкасына ияреп, бик тиз генә сикереп торды ---.* А.Шамов

3) Йогу, берәүдән икенчегә күчү (авыру турында)

4) Кемне дә булса җитәкче, башлык дип тану, аңа буйсыну, аның фикеренә кушылу, аның юлыннан бару. *Авыл ярлылары барысы да Ленинга иярәчәк.* К.Нәҗми // Гомумән кушылу. *Кайберәүләр аңа [Газинурга] борылып карады, ләкин күпчелек аңа иярде, һәм берничә секундтан шундый көчле алкышлар давылы күтәрелде ---.* Г.Бәширов

5) Буйсыну. *Минем зиһенем дә алар сүзенә иярде.* С.Зыялы

6) Холык, фигыль, кыланмышлары белән кемгәдер охшарга тырышу, кемнедер кабатлау. *«Яшь йөрәкләр» романы укучыларны --- Сабирга иярергә, Сабирдан үрнәк алырга кирәклек фикере тойгысын тәрбияли.* Г.Нигъмәти. *Билгеле, Хәмдия өчен бу гаиләдәге кайбер гадәтләргә ияләнү яки аларга иярү бигүк җиңел булмады булуын.* Г.Галиев. *Өйләренә бер-бер классташы кереп чыкканда да, шундук аның җиде бабасын, --- тикшерергә өлгерә иде. --- Урам балаларына ирмәсен, янәсе.* Р.Мөхәммәдиев

7) Иҗат эшендә: берәр язучы, рәссам яки халык иҗатының стилен кабатлау, аны өлге итеп алу. *Берәр шагыйрь әсәрләренә ияреп шигырьләр язу – Тукай иҗатының характерлы сыйфатларыннан берсе.* Г.Нигъмәти. *Безнең бит яшь шагыйрьләр бер төрле: бер-берсенә артык ияралар.* Һ.Такташ. *Габәши үз иҗатында борынгы шәрык музыкасына иярсә, Сәйдәш музыкасы үзенең беренче дәверендә күбрәк халык музыкасына, авыл моңына иярде.* М.Җәлил

8) Берәр көйгә яки тавышка мөмкин кадәр дөресрәк, төгәлрәк охшату. *Бу әсәрдә --- авылның реалистик картиналарын --- бирергә омтылу һәм шуның үзенә күрә бер формасы да табылу* (*орчык тавышына иярү, эвфоник алымнар*) *[сизелә].* Н.Исәнбәт

9) *лингв.* Җөмләнең яки җөмлә кисәгенең икенче бер җөмләгә яки җөмлә кисәгенә буйсынуыннан гыйбарәт синтаксик бәйләнеш төре. *Ияртүле бәйләнештә сүзләр һәрвакытта да берсе икенчесенә ияргән, буйсынган булалар.* М.Зәкиев

10) *күч.* Кемнең дә булса сүзен тыңлап, аның фикеренә таянып, нигезләнеп эш итү. *--- иске фикерле фанатик байлар, Галинең сүзенә колак салмаенча, хәзрәтләрнең сүзенә ияреп, мондый эшне һич кабул итмиләр иде, хәзрәтләргә тел тидерә, диеп, Галине дошман күрәләр иде.* Ш.Мөхәммәдев. *Кара фикергә иярмә, дип, мин әйтмим*

*сиңа* ---. Г.Камал. *Җыландай телләремне чыгарып әйттем мин аңа: иярмә шул Надыйр малаена, язылма шул «камсамул» дигән нәмәстәгә, җүнлегә илтмәс, дидем.* М.Хәсәнов

11) *күч.* Бер урыннан икенче урынга китерелү. --- *авылдан ияреп килгән, шәһәр ыгы-зыгысында адашып калырга өлгермәгән беркатлы кыюсызлык әледән-әле чабудан тартып куя* ---. М.Галиев

**Иярә башлау** Иярә торганга әйләнү. *Соңынтын бала, аның артыннан адым да калмыйча, маэмай кебек иярә башлады.* Ә.Баян

**Иярә бирү** Бернигә дә карамыйча ияртү; иярүне дәвам итү. *Мин туктамадым. Иптәшләремә иярә бирдем.* М.Кәрим

**Ияреп йөрү** Һәрвакыт, гел, һаман иярган булу, бертуктаусыз иярү. *Хәтереңдәме: ул, «Рәхилә апай!» дип, артыңнан калмыйча ияреп йөри иде...* Ә.Еники

**ИЯРҮЧЕ** *и.* Кемнән дә булса үрнәк алып, аның юлыннан баручы кеше. *Хәсән Туфанны ал син. Анда, ичмасам, рифма дисәң дә рифма. Иярүчеләре дә шундук табылды.* Ф.Хөсни

**ИЯРЧЕ** *и.* Ияр ясаучы оста

**ИЯРЧЕН** *и.* 1) Кемгә дә булса иярүче, ул сайлаган юлдан баручы кеше. *Өне алынган Ефим* (*Кузьманың иярчене*) --- *аңлатма язарга аяк терәп каршы торды.* М.Хәсәнов. *Галләм хаҗиның алдан әзерләп куйган иярченнәре,* --- *өйләренә чаптылар.* Ф.Хөсни // Нинди дә булса эш башкарганда кемгә дә булса ияреп йөрүче. *Нәҗипкә иярчен булып кына йөргән идем ич. Юк шул, иярчен генә булмаганмын икән.* Г.Нәбиуллин

2) Мөстәкыйль булмаган, кемнәндер яки нәрсәдәндер бәйле әйбер яки кеше. *Империалистик монополияләрнең колониаль иярченнәре*

3) Планета яки йолдыз тирәсендә әйләнә торган күк җисеме. *Ай – ул Җир шары иярчене һәм аннан бик ерак та түгел.* Р.Фәизов. *1975 елның 22 һәм 25 октябрендә «Венера – 9» һәм «Венера – 10» автомат планетара станцияләре Венераның ясалма иярченнәре орбитасына чыктылар.* А.Романов. *Америка галимнәре фикеренчә, Сатурнның иң зур иярчене булган Титанда нефть, газ һәм ташкүмер запаслары Җирдәгедән йөзләрчә тапкырга күбрәк.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Куштан, ялагай, тәлинкә тотучы кеше. *Сыйнфый дошманнар, кулак иярченнәре «диненнән язган большевик Насыйбулла»ның берничә тапкыр башына җитәргә тырышып караганнар.* М.Хәсәнов. *Кичке ашка иярченнәре белән башлык үзе дә килгән иде.* Ф.Фәтхелислам. *Мөдир хатын, «үләм» дип, йөрәген тотып җиргә егылды. Ә хаким иярченнәре белән машинасына ашыкты.* Н.Гыйматдинова

**ИЯРЧЕ́Н БАЛА** *и. диал.* Анасы икенче иргә чыкканда ияреп килгән бала

**ИЯРЧЕ́Н ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Кушма җөмләдә баш җөмләгә ияреп, аны ачыклап килгән һәм аңа ияртүче чаралар ярдәмендә бәйләнгән җөмлә. *Кушма җөмлә нинди була соң әле? Хикәя җөмлә, өндәү җөмлә бар, иярчен җөмлә, тәмамлык җөмлә...* Г.Нәбиуллин. *Мөнәсәбәтле сүзләр – иярчен җөмләләрне алыштырып һәм иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләп килә торган сүзләр.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев. *Иярчен җөмләләр --- баш җөмләнең кайсы да булса бер кисәге функциясен үти.* Татар теле морфологиясе

**ИЯРЧЕ́Н ИЯ ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Кушма җөмләдә баш җөмләнең иясе урынында килә яисә баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән ияне ачыклый торган җөмлә. *Иярчен ия җөмләнең аналитик төре баш җөмләгә [төрле] чаралар ярдәмендә бәйләнә.* Татар грамматикасы

**ИЯРЧЕ́Н КИСӘК** *и. лингв.* Җөмләнең ия яки хәбәренә буйсынып, алар белдергән эчтәлекне ачыклап, тулыландырып килгән кисәк; төгәлләүле һәм аныклаулы мәнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе. *Татар телендә тәмамлык, аергыч, хәл кисәкләре, аныклагыч, модаль кисәкләр (эндәш белән кереш сүзләр) дип аталган иярчен кисәкләр бар.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев. *Соңга таба* --- *иярчен кисәкләрне өчкә генә бүлеп йөртә башлыйлар:* --- *аергыч,* --- *тәмамлык һәм хәл* ---. Татар грамматикасы

**ИЯРЧЕНЛЕ** *с.* Иярчене булган

**ИЯРЧЕНЛЕК** *и.* Иярчен булу. *Тагып сиңа иярченлек [түбәнчелеген], Корал итеп йөретәләр [наданлыгыңны].* Г.Тукай

**ИЯРЧЕНЛЕ́ КУШМА ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Баш җөмләгә иярү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә. *Бер җөмләнең икенчесенә ияреп килүе белән оешкан җөмлә иярченле кушма җөмлә дип атала.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев. *Бәйләнеше төренә карап, кушма җөмләләр «тезмә кушма җөмлә» һәм «иярченле кушма җөмлә» дигән төрләргә бүленәләр.* Татар грамматикасы

**ИЯ́Р ЭЛМӘГЕ** *и.* Ияргә йөк, төен беркетә торган махсус элмәк

**ИЯ́Р ЯСТЫГЫ** *и. к.* **ияр җәймәсе**

**ИЯСЕЗ** *с.* 1) Иясе, хуҗасы булмаган, беркемнеке дә түгел. *«Их, сөйли белсәмме?» – дигәнрәк моңсу карашында этнең иясез һәм беркемгә дә кирәксез җан икәнен аңладым.* М.Әхмәтшина. *Урамнарда иясез маллар кычкырып йөри* ---. Ә.Сафиуллин. *Ул* ---, *күз ачып йомганчы, иясез велосипедка атланып, парк эченә кереп югалды.* А.Вергазов

2) *лингв.* Иясе (*8 мәгъ.*) булмаган. *Беренче җөмлә дә иясез.* М.Җәлил

**ИЯСЕ́З ҖӨМЛӘ** *и. лингв.* Хәбәре генә аерым сүз яки сүзтезмә белән белдерелгән бер составлы җөмлә. *Мондый [бер составлы фигыль] җөмләләрдә баш кисәк булып килгән сүзләр җөмләнең хәбәрен хәтерләтәләр, ә ия булмый. Шуннан чыгып, аларны «иясез җөмлә» дигән термин белән дә атап йөртәләр.* М.Зәкиев. --- *иясез җөмлә дә, исем җөмлә дә,* --- *иярчен кисәкләр кабул итеп, җәенкеләнә алалар.* Татар грамматикасы. *Үтәүченең билгеле булу-булмавына карап, иясез җөмләләр билгеле үтәүчеле һәм билгесез үтәүчеле дигән төрләргә бүленәләр.* Татар теле морфологиясе

**ИЯСЕЗЛЕК** *и.* 1) Гомумән иясе, хуҗасы булмау халәте

2) Эштә таркаулык, шәхси җаваплылык булмау; хуҗасызлык. *Һәр кыз үзенә төшкән өлешен җәй буе үзе карый, үзе үстерә, уңышын да үзе җыеп ала, үзе тапшыра. Болай эшләү һәркемне кызыксындырган, иясезлеккә юл куелмаган.* Фәтхи-Балыкчы

# Й

**ЙОБАНУ** *ф. диал.* 1) Юану

2) Мәшгуль булу, шөгыльләнү, эшләү. *Тапшырдык, кызым. Үзең дә озак йобанма, ял ит. Бу ыгы-зыгыда арыгансыңдыр...* И.Туктар

3) Озак мыштырдау, маташу

**ЙОГ** *и. санскр.* Йога тарафдары. *Хәзер алар һинд йогларын хәтерләтәләр иде.* М.Юныс. *Бер чиләк су эчеп, шуны кире чыгара алучы, йөрәген-үпкәсен туктатып тора алучы йогларны, әлбәттә, күреп булмады.* М.Мәһдиев. *Безнең Гайшә Хәлиловна хакында «ул йоглар системасы белән дәвалана икән» дип сөйлиләр.* А.Гыйләҗев

**ЙО́ГА** *и. санскр.* 1) Һиндстанда: үз-үзеңне танып белү алымнарының аерым бер системасын эшләгән дини фәлсәфи тәгълимат (кешегә үзенең психик һәм физиологик функцияләре белән идарә итү мөмкинлеген ача)

2) Шушы тәгълимат тарафдарлары эшләгән физик күнегүләр һәм чыныгулар системасы. *Билгеле бер курс узганнан соң нәтиҗәләр: сиксән, туксан тугыз проценты, йога белән шөгыльләнгәннән соң, авыруыннан терелгән.* М.Мәһдиев

**ЙОГАЛАНУ** *ф. диал. к.* **йогану**. *Искегә йогаланма, исең китәр.* Мәкаль

**ЙОГАНУ** *ф. диал.* Кагылу, тотыну, тиеп китү. *Казанга йогансаң, карасы йогар.* Мәкаль

**ЙОГУ** ф. 1) Йогышлы авыру эләгү, авыру иярү. *Төрле сихер, зәхмәти чир генә йоккан булса бер хәл иде, бәлки, шифасы да тиеп куяр иде.* М.Хәсәнов

2) Берәр төрле һөнәр оту, отып алу, шул һөнәр белән ныклап мавыгу. *Уникe яшьләр тирәсендә мин китап уку белән аеруча җенләнеп киттем. Тагын киез итеккә олтан салу чире йокты.* Р.Низамиев. *Рәшаттан йоккан сурәт ясау эше исә тормыш юлымда миңа шактый күп ярдәм дә күрсәтте соңыннан.* А.Расих

3) Ис сеңү, буяу яки буяла торган берәр нәрсә ягылу. *Казанга якын барсаң – карасы йогар, яманга якын барсаң – бәласе йогар.* Мәкаль. *Бардан йога, балдан тама.* Мәкаль. *Ике куллап үлән йолкый-йолкый, аның чәнти бармакларына үлән яшеле йога.* К.Кәримов

4) *күч.* Нәрсә дә булса көчле тәэсирен калдыру, берәүдә икенче затның тәэсире сизелү. *Егетнең өс-башына да бераз культура йокты: майка өстеннән күлмәк киеп йөри башлады, пиджак-чалбар үтүкләнгән, чистартылган булды, моңарчы тузгытып йөргән чәчләрен дә матур гына итеп тарап куярга өйрәнде.* Ә.Еники // Берәр кешенең яки нәрсәнең сыйфатлары, гадәтләре һ.б. башка кешедә кабатлану, шулар дәвам итү. *Әллә сиңа да аның чире йоктымы? Ул да һәрбер адәм затыннан, алай гынамы соң, үзеннән дә шикләнеп яши иде.* Н.Гыйматдинова. *Мәрьямнең күп сыйфатлары Кәримгә дә йоккан иде.* М.Юныс. – *Төрмәнең начар гадәте мәңгегә йога икән! – диде, гыжлый-гыжлый ютәлләп.* Р.Сибат // Гомумән кушылу, башкаларга да күчү, йогынты ясау. *Мондый шигырьләрне укыганда, синең күңелгә дә дөньяны сабыйларча ярату хисе йога.* Р.Миңнуллин

5) *күч.* Истә, хәтердә калырлык булып тәэсир итү, шул күңелгә кереп калу. *Малайга һаман да гыйлем йокмады.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Кемдә яки нәрсәдә нинди дә булса төс барлыкка килү, нинди дә булса төскә керү. *Суфия ханым тәмам ябыккан, йөзенә саргылт төс йоккан.* Г.Әпсәләмов

7) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса якынлашу, шуңа ияләшү, үзләшү. *Ел саен диярлек читкә чыгып --- гомер үткәрмәссең, йортка йогарсың.* Ш.Маннур. *Шәһәргә йогу*

8) *күч. гадәттә юкл. форм.* Тоелмау, эләкмәү (телгә, авызга, кулга; гадәттә бик аз булган әйберләргә карата әйтелә). *Кече телгә дә йокмады.* Әйтем. *Улак кимерә башлаган җирәнкәе, әнә, яңа хуҗасының су белән сыйлавына гына риза түгел, көтүчеләр хәзинәсеннән алып чыгып биргән бер сынык пәтернан аның кече теленә дә йокмады, билгеле.* Т.Әйди

**Йога бару** *к.* **йогып бару**

**Йога башлау** Йогарга тотыну. *Әмма Хәмбәлгә карата хөрмәте булмавын һаман сиздереп торды, һәм шул гадәте миңа да йога башлаган иде Илдарның.* Э.Шәрифуллина. *Сәгыйтьнең шат күңеллелеге Гасыймга да йога башлады.* Н.Фәттах

**Йога тору** Әледән-әле, бер-бер артлы йогу. *Яраткан кешеңнең күркәм сыйфатлары, бәлки, сиңа да йога торгандыр?* М.Юныс

**Йога төшү** Беркадәр, өлешчә йогу. *Ата буларак сиңа игътибарым, тәрбиям дә җитеп бетмәгәндер, шуның нәтиҗәсендә урам йогынтысы да йога төшкәндер.* Н.Хәсәнов

**Йогып бару** Аз-азлап, акрынлап, эзлекле рәвештә көчәя барып йогу. *Бүген ул татарларга да йогып бара.* Р.Ишморат

**Йогып бетү** Бик нык, тулысынча йогу

**Йогып калу** Нindidер сәбәп белән яки нинди дә булса вакыйгадан соң йогу, йогарга өлгерү. *Ник дигәндә, күңеленә шул вакыйгадан соң үкенүгә тартым бер хис йогып калса, аннары --- икенче бер хәл пошаманга салды.* Ә.Баянов. *[Зиннәт:] Әллә шуннан соң биеклекне ярату чире йогып калды микән?!* Р.Кәрами. *Учыма йогып калган онны тегенең күз тирәләренә сылап куйдым.* М.Хәсәнов

**Йогып киту** Билгеле бер вакыттан, сәбәптән соң йогу. --- *һәр яктан уйлап,*

*шул персонаж характерына йогып китәрдәй оригиналь исем сайлаганлыкларын беләбез.* Х.Сарьян

**Йогып тору** 1) Һәрвакыт, гел йогу

2) *күч.* Килешле булу, ятышлы булу, ярау; белеп эш итү. *Ничек онытмадың, кулыңа балта-пычкы йогып тора икән бит?* Р.Мөхәммәдиев. *Шулай тынгысыз булгангадыр инде, исеме дә үзенә йогып тора: Чапак морза*. Р.Батулла

**ЙОГЫ** *и. тарт. форм.* Нәрсәнең дә булса кечкенә берәмлеге, бөртеге, эзе

◊ **Йогы калмау** Тәмам, ахырынача бетү; эзе дә калмау. *Инде бүтән ризыкка урын да юктыр, дип чыгарган вак бәлешнең йогы калмады, комагайланып, табында ни бар, бөтенесен ашап бетерделәр.* А.Гыйләҗев. *Еллар буе җыелып, стеналарга утырган тузанның йогы да калмаган, тәрәзәләр көлеп тора, сәке сап-сары.* Р.Мулланурова. **Йогын калдырмау** Тәмам бетерү, эзен дә калдырмау. *Бу җавабым директорның йөзендәге ихлас елмаюның йогын да калдырмады, сүндерде.* Г.Тавлин

**ЙОГЫМ** *и. диал.* Тәэсир, эсәренү хәле

**ЙОГЫМЛЫ** *с. диал.* Йөрәккә ятышлы, ягымлы

**ЙОГЫМЛЫЛЫК** *и. диал.* Йөрәккә ятышлы булу, ягымлылык

**ЙОГЫНТЫ** *и.* 1) Кем яки нәрсәнең нинди дә булса объектка тәэсире, шуның шаукымы. *Аларның [казакларның] хатын-кызлары ислам дине йогынтысына азрак бирелгәннәр*. М.Хәсәнов. *Рөстәм разведчиклар блиндажына килеп әләкте һәм шунда тыңлаган сүзләр йогынтысында немецларга каршы немецлар ягына чыгып көрәшергә карар итте.* Г.Кутуй. *Шәһәр, чыннан да, нык һәм матур салынган, аның кварталларында Европа йогынтысын күрәсең.* В.Юныс

2) Дәрәҗәле, хөрмәт ителә торган, абруйлы кеше(ләр)нең тәэсире. *Уемча, әнигә мәгърифәткә ашкынуда, әдәбиятка мәхәббәт тудыруда аның [Ф.Әмирханның] йогынтысы аз булмаган.* А.Расих. *Зур шагыйрьләрнең йогынтысын аерым юллардан эзләргә кирәкми.* С.Хәким

**ЙОГЫНТЫЛЫ** *с.* 1) Йогынты ясый алырлык, тәэсир итә алырдай (абруйлы, дәрәҗәле кеше, даирә һ.б. турында). *Кунакка күбесе бай, йогынтылы, культуралы, авылча әйтсәк, затлы киенгән кешеләр җыелачак.* Ә.Баянов. *Репрессияләр, иң беренче нәүбәттә, милләтнең, халыкның әнә шул иҗатчыл өлешенә, иҗтимагый фикердә һәм мәдәни хәрәкәттә йогынтылы роль уйнаган хөр карашлы катламына каршы юнәлтелгән була.* Р.Мостафин

2) Тәэсир итәрлек, эз калдырырлык; көчле. *Кешенең әхлагын чистарту, зәвыгын тәрбияләү, аның аңында сафлык-пакьлек, гаделлек, кешелеклелек сыйфатлары салуда иң йогынтылы сәнгать чараларының берсе – ул җыр.* Ф.Яруллин

**ЙОГЫНТЫЛЫЛЫК** *и.* Йогынты ясый алу хәле

**ЙОГЫНУ** *ф. диал.* Кемгә яки нәрсәгә булса да кагылу, орыну, тию, җиңелчә генә бәрелү

**Йогынып алу** Тиз генә йогыну

**ЙОГЫРТ** I *и.* Сөткә махсус гөмбәчекләр салып оетылган һәм төрле тәмләткечләр, җиләк-җимешләр яки аларның суларын өстәп тәмләндерелгән ашамлык. *Йоклар алдыннан кефир, йогырт эчәргә, алма, банан һ.б. ашап куярга мөмкин*. Тәмле киңәшләр

**ЙОГЫРТ** II *и. бот.* Мареначалар семьялыгыннан ак яки сары вак чәчәкле берьеллык яки күпьеллык үләнчел үсемлек (чүп үләне); *русчасы*: **подмаренник**. *Ябышкак йогырт --- – әрсез чүп үлән, саз йогырты --- саз, елга буйлары, дымлы баткак урыннарда күпләп үсә, төньяк йогырты --- урман, болын, куаклыкларда үсә.* Л.Мәүлүдова

**ЙОГЫРТЛЫЛАР** *и. бот.* Ябык орлыклы үсемлекләрнең бер семьялыгы атамасы (йогырт, кофе агачы, хина агачы һ.б.)

**ЙОГЫШ** *и. мед.* Авыру тарата торган микроорганизмнар. *Гасырлар буе шакшылар агызып киленгәнгә, инде узган йөздә үк аның суының йогыш чыганагына әйләнгәнлеге ачыкланган иде.* Ф.Гарипова

**ЙОГЫ́Ш КИЛҮ** *ф.* 1) Килешеп тору, ятышлы, таман булу (кием, өс-баш, бизәнү һ.б. турында). *[Саниянең] Өстендәге карасу зәңгәр костюмы да, яңа гына үтүк астыннан чыккан нәфис ак якасы да, ничектер, аның йөз төсенә һәм җыйнак гәүдәсенә бик йогыш килеп, килешеп тора иде.* М.Әмир

2) Сөйләм бәйләнешле булу, сүз сөрешенә туры килү, эзлекле булу. *Сүзләрем йогыш килеп чыкмый, әйеме? Дулкынланам бугай.* Ә.Баянов

**ЙОГЫШЛАНДЫРУ** *ф.* Тәҗрибә максатыннан яки очраклы рәвештә берәр җан иясенә яисә аның берәр әгъзасына авыру йоктыру

**ЙОГЫШЛАНУ** *ф.* 1) Йогышлы чир эләктереп авыру. *Грипп белән балалар бигрәк тиз йогышланалар*. Азат хатын

2) *күч. сир.* Нәрсәнең дә булса йогынтысына бирелү; шуның белән мавыгу, әсәрләнеп йөрү. *Абстракционизм чире белән бездә аерым художниклар гына йогышланды*. Казан утлары

**ЙОГЫШЛА́У** *ф.* Йогышка дучар итү, йогу. *Авыру олы яшьтәге бал кортларын, күп очракта ябык личинкаларны һәм бер-ике көнлек курчакларны йогышлый.* Татар балы

**ЙОГЫШЛЫ** I *с.* 1) Кемнән яки нәрсәдән дә булса йога торган (авыру, чир турында). *Авылда йогышлы авыру бар. Бая килгән хатынның сыеры түләмәдән үлде.* Т.Гыйззәт. *Бер бала нindидер йогышлы чир белән авырый башлаган икән, шул һәммәсен хафага салган.* Ф.Яруллин. *«Сальмонеллез» дигән йогышлы чир белән авырмыйм дисәгез, ветеринар-санитар тикшерүе үтелмәгән итне кулланмагыз, ит һәм ит әйберләрен суыткычта башка ризыклардан аерым саклагыз.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Йогынты ясый, шундый ук сыйфатлар барлыкка китерә торган; үзенә ияртә торган. *Аһ, бу йогышлы елаулар! Берәүнеке – сәбәпле. Башкаларны бер сәбәпсез ияртергә сәләтле.* Р.Харис. *Әтиләре дә түзмәде, шыркылдап көлә башлады. Көлү йогышлы бит ул. Илгизәр кушылды.* Р.Сәгъди. *Йогышлы итеп көлә торган Надя белән мин беренче тапкыр әнә шулай очраштым*. Р.Төхфәтуллин

**ЙОГЫШЛЫ** II *с.* 1) Күзгә сөйкемле, мөлаем, күркәм булып күренә торган. --- *ерак түгел генә җирдә утырган бер студентның үзенә бик туры, ләкин йогышлы карап торганлыгын күрде.* Ф.Әмирхан

2) Килешле, таман. *Аның төрле-төрле киемнәре булмаса да, өстендәге бер кат киеме һәрвакыт соңгы мода белән тегелгән йогышлы кием була торган иде.* Ф.Әмирхан

**ЙОГЫШЛЫЛАНДЫРУ** *ф. сир.* Йогышлы итү, төс-кыяфәткә ятып тору; матур итеп күрсәтү

**Йогышлыландырып җибәрү** Йогышлылык өстәү, тагы да йогышлы итү. *Биек ак яка аның озынчарак кына муенына бик килешә, хәтта аның өстендәге гадәтчә пиджагын да әллә ничек матурлатып, --- йогышлыландырып җибәрә иде.* Ф.Әмирхан

**ЙОГЫШЛЫЛЫК** I *и.* 1) Йогышлы I булу, йога торган булу. *[Бу авыруларның] Кайберләрендә йогышлылык юк диярлек*. Ш.Камал

2) Йогынты ясый, ияртә торган булу. *Елый кеше һәм бушана: җаныннан юа керне. Елауның йогышлылыгы – кешенең бөек сере!* Р.Харис

**ЙОГЫШЛЫЛЫК** II *и.* Йогышлы II (*1, 2 мәгъ.*) булу, күркәмлелек, килешлелек

**ЙОГЫШСЫЗ** I *с.* 1) Йокмый торган, йогышлы булмаган. *Җир йөзендәге күпчелек үлемнәрнең сәбәбе – рак, диабет, йөрәк һәм үпкә авырулары кебек йогышсыз чирләр.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Йогынтысы булмаган; тәэсир итми торган. *Шул төндә Георгий кенәз, каланы ташлап, пайтәхеткә качты. Яман чирләр йогышсыз булмый калмый.* В.Имамов

**ЙОГЫШСЫЗ** II *с. сир.* **1.** 1) Йогышлы II (*1, 2 мәгъ.*) түгел; сөйкемсез, килбәтсез, килешсез. *Йогышсыз елмаю. Йогышсыз кием*

2) Тәртипсез, гадәти түгел; күңелгә ятышсыз; күнекмәгән, ят. *Күңелгә йогышсыз дорфа музыка тынып, аһәңле вальс яңгырап китүгә, яшьләр парлаша башладылар.* З.Фәйзи

3) Кире хис уята торган. *Симез үрдәкне хәтерләткән бу хатында күңелгә йогышсыз нииндидер бер нәрсә бар иде.* А.Гыйләҗев // Ярамый торган, урынсыз; начар, тупас. *[Солтангәрәй] Белер-белмәс башың белән йогышсыз сүз ычкындырып, аның кайнар йөрәген рәнҗетерсең.* А.Гыйләҗев

4) Тәртипләргә, кагыйдәләргә, табигатенә туры килмәгән. *Шулай итеп, татар теленә йогышсыз хәрефләр татарның телен боза башлый.* Р.Батулла

5) Уңайсыз, кыен, четерекле. *Ул күсәк кебек үрә катып торудан уза алмады. Шулай да мондый йогышсыз хәлдән чыгарга киръәклекне акылы белән сизә иде.* Б.Камалов

6) *диал.* Күңелне болгата торган, әчегән-төчегән. *Хәлил, кайтканнан бирле, тирә-ягындагы йогышсыз исләрдән җәфалана ---*. А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әхлак, тәртип кагыйдәләрен сакламыйча. *Йогышсыз кылану*

2) Ятышсыз, ямьсез. – *Мин кәгазьдән укырга яратмыйм, алай йогышсыз чыга, мин күңелгә ятлап сөйлим, – ди иде.* Г.Бәширов

**ЙОГЫШСЫЗЛАНДЫРУ** *ф. сир.* Йогышсыз итү, йогышлы микробларны бетерү. *Моңа кадәр донор канын махсус фильтрлар ярдәмендә йогышсызландырганнар.* Ватаным Татарстан

**Йогышсызландыра бару** Һәрберсен, булган берсен йогышсызландыру

**Йогышсызландыра төшү** Бераз йогышсызландыру

**Йогышсызландырып бетерү** Барысын да, тулысынча йогышсызландыру

**Йогышсызландырып кую** Алдан йогышсызландыру, йогышсыз итү

**Йогышсызландырып тору** Еш, һәрвакыт, әледән-әле йогышсызландыру

**Йогышсызландырып чыгу** Барысын да бер-бер артлы йогышсызландыру

**ЙОГЫШСЫЗЛАНУ** *ф.* Авыру тарата торган бактерияләрдән арыну, аларны юк итү

**Йогышсызланып бетү** Тәмам, тулысынча йогышсызлану; барысы да йогышсызлану

**Йогышсызланып җитү** Тулысынча йогышсызлану

**Йогышсызланып калу** Нииндидер сәбәптән, вакыттан соң йогышсызлану

**ЙОГЫШСЫЗЛЫК** *и.* Йогышсыз булу. *Фатыймага бирелгән җавабының йогышсызлыгы белән пошынып, Шакир --- бүлмәгә чыкты.* Ф.Әмирхан

**ЙОГЫШУ** *ф. диал.* Кемне яки нәрсәне дә булса якын итү, үз итү; аңа нык ияләшү

**Йогышып бетү** Тәмам, тулысынча йогышу. *[Самат] Унычылар белән ничектер йогышып бетми...* А.Гыйләҗев

**Йогышып җитү** Тулысынча, бөтен күңеле белән йогышу. *[Зарифның] Бу халыкка күңеле йогышып җитми бугай.* Ш.Камал

**ЙОД** *и. гр.* 1) Гадәттә, диңгез суүсемнәреннән алына, медицинада киң кулланыла торган кара көрән төстәге кристаллик матдә. *Йод кристаллары*

2) Шул матдәнең спирттагы эремәсе. *Сергей үзе белән дару-препаратлар, йод, эфир исләреннән торган, --- больница һавасын да алып кергән иде.* Ә.Сәйфетдинов. *Аннары, икенче якка чыгып, тумбочка өстендә торган чирек литрлы шешә белән йод алдым.* Н.Фәттах. *Кулларымны юдырып, ярамны йод сөртеп бәйләгәч, надзирательләр мине бер кешелек гадәти камерага яптылар.* Г.Тавлин

3) Составында шул элемент күп булган эйбер. *Аннан ул безне кич белән диңгез буенда йод сулап утырырга өйрәтте.* М.Мәһдиев

**ЙОДА** *и. сөйл. к.* **йод** (*2 мәгъ.*). *Ул эшен дәвам итте: авыруның кулын яхшылап чистартты, җәрәхәт тирәләренә йода сөртте, бинт белән бәйләде.* Р.Кәрами

**ЙОДАЛЫ** *с. сөйл. к.* **йодлы.** *[Мотаһир] Кыскычны өскә каратып, йодалы таякчыкны өстәлнең икенче кырыена куйды.* Р.Кәрами

**ЙОДЛА́У** *ф.* Йод тидерү, йод сөртү

**ЙОДЛАНУ** *ф.* Йод кушылган булу, йод катнаштырылу; йод белән баетылу. *Тоз эре һәм йодланмаган булырга тиеш.* Ватаным Татарстан

**ЙОДЛЫ** *с.* Составында йод булган, йод катнашкан; йод белән баетылган. *Әкрен генә сүнеп барган көн тынтымызык, инде сүрелеп өлгергән дымлырак һава бик саф, шул йодлы һаваны*

*сулый-сулый йөрүе җиңел, рәхәт.* Ә.Еники. *Сораша торгач, аларның йодлы су үсемлекләрен таратып киптереп йөрүләре аңлашылды.* Каһарман каләме

**ЙОДОФОРМ** *и. фр. махс.* Йодтан эшләнгән, бик көчле исле сары төстәге кристаллар формасындагы, медицинада, бигрәк тә ветеринариядә йогышсызландыру чарасы буларак кулланыла торган препарат. *Күрше бүлмәдән йомшак кына ыңгырашкан тавыш ишетелә, һәм йодоформ исе киләдер иде.* Ш.Камал

**ЙОДРЫК** *и.* 1) Бармаклары уч төбенә кысып йомарланган кул чугы. *Алмагөл уянып торып утырды, йодрыгы белән күзләрен уды, аннан йөгереп әнисе янына килде.* И.Салахов. *Аннары Энҗе, рәсемне урынына куеп, өстәл янына барып утырды да, арык йодрыкларын ияк астына терәп, терсәкләре белән өстәлгә таянган килеш уйга калды.* Г.Тавлин. *Мендәргә йөзтүбән капланган көйгә, кысып йомарланган йодрыклары белән, үз-үзен белешмичә, урын-җирен төяргә керешкән иде кыз.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Корал белән яки физик көч кулланып буйсындыру, куркыту көче турында. *Юләргә йодрык кына акыл кертә ала.* Әйтем. *Сабир председательнең җитәкләү ысулы чыбык-чыбыркы, йодрыктан гыйбарәт икәнен бөтен авыл белә.* Р.Батулла

3) *күч.* Бергә тупланган сугышчан көч. *[Акбирдин:] Антанта – минемчә, дәһшәтле һәм көчле йодрык.* Р.Ишморат

◊ **Йодрык айкау** *к.* **йодрык күрсәтү**. *Аның артыннан әниләре, йодрыгын айкап: – Бар, бар! Күрәсем дә килми!– дип кычкырып калды.* Мирас. **Йодрык алу** *к.* **йодрык ашау**. **Йодрык астында яшәү** Җәбер-золымга буйсынып, кыйналып гомер итү. *Татар халкы революциягә кадәр патшалар йодрыгы астында яшәде.* Н.Исәнбәт. **Йодрык ашау** Кыйналу, сугылу, җәберләнү. *Сибгатулла арттырыбрак җибәргән, йодрык «ашаган» әнкә шыр диванага сабышты әнә.* Н.Гыйматдинова. *Монда инде өзлексез допрослар, резин таяк һәм немец йодрыгы ашаулар бетеп китте.* Ш.Маннур. **Йодрык белән кадак кагу** Үзенең көчле булуы белән халыкны буйсындыру, изү, рәнҗетү һ.б. *[Рухани карт:] Йодрыгы белән кадак какмакчы иде ул малай.* М.Хуҗин. **Йодрык белән уйнау** Бер сәбәпсездән физик көч куллану, җәберләп тору. *Акмал да элекке төсле һәммә нәрсәне гафу итеп торучан авыл мокыты түгел хәзер, йодрык белән уйнауның да кыйммәткә төшүен аңлады бит инде.* Г.Ахунов. **Йодрык булып** Бердәм көч булып. *Татарлар йодрык булып берләшсә, Литва белән Польша да тик ятмас.* Р.Батулла. **Йодрык дискуссиясе** Бәхәсне хәл итүдә физик көч куллану. *Әйдәгез, йодрык дискуссиясе оештырып алыйк әле шул кешегә. Нәрсәгә әле ул «бик беләм»ләнеп китте?* Н.Исәнбәт. **Йодрык иснәтү** *к.* **йодрык күрсәтү**. **Йодрыкка йому** Табышны, байлыкны үзләштерү, беркемгә бирмичә, үз кулында гына тоту. *Үз атасының да, хатынының атасының малын да йодрыгына йомды.* Н.Исәнбәт. **Йодрык кесәдә** *к.* **йодрыкны кесәгә тыгып йөрү**. *Сак бул син ул кешедән, аның йодрык кесәдә.* Н.Исәнбәт. **Йодрык күрсәтү** Янау, куркыту. *Гайфи миңа, Җәгъфаров абыйга сиздерми генә, йодрык күрсәтте.* Г.Тавлин. *«Күрсәтермен мин сезгә алты-бишне!» – дип, авылы ягына шактый ныгыган йодрыгын күрсәтте.* А.Гыйләҗев. **Йодрык күтәрү** 1) Кизәнү, сугарга әзерләнү яки сугу; 2) Бик нык каршы төшү, ризалашмау. *Башта кеше әйткәнне тыңлап бетер, аңа нигә йодрык күтәрәсең?* Н.Исәнбәт. **Йодрыкны җигү** Кизәнү, суга-кыйный башлау. *Андый чакта, билгеле инде, ачудан йодрыкларны шундук эшкә җигәсе килә башлый.* Р.Низамиев. **Йодрыкны җиң очына яшерү** Дошманлыкны эчтә саклау, янап йөрү. *Йодрыкны җиң очына яшергән дә теге аңгыраларны акрынлап көйгә китерә.* М.Фәйзи. **Йодрыкны кесәгә тыгып йөрү** *к.* **йодрыкны кесәдә йөртү**. **Йодрыкны кесәдә йөртү** Үч кайтарырга җай чыкканны көтеп йөрү. **Йодрыкны худка җибәрү** Кул күтәрү, сугу, кыйный башлау. *Күрәмсең, низаг вакытында рядовой Гребенщиков күп уйлап тормаган, боксер йодрыгын худка җибәргән.* Н.Хәсәнов. **Йодрык политикасы** Җәмгыятьнең тоталитар режимга корылган сәясәте турында. *Әмма егерменче еллар ахырында Сталинның «йодрык политикасы» милләт кулыннан халык мәгарифен акрынлап ала башлады.* Р.Ягъфәров. **Йодрык сугышы** 1) Борынгы Грециядә спорт уенының бер төре; бокс. *Әле бокс, йодрык сугышы белән җенләнде.* Ф.Сафин; 2) Сугышта: кул белән сугышу. *Ук-җәя белән генә коралланган, үзе дә сизмәстән иң алдагы сафларда татарлар арасына барып кергән Василий йодрык сугышында бер чарасыз торды да калды.* Ф.Латыйфи; 3) Физик көч кулланып сугышу. *Йодрык сугышы кызып киткән бер мәлдә, һич көтмәгәндә-уйламаганда, чаттан выжылдап милиция машинасы килеп чыкты.* З.Мәхмүди. **Йодрыктан баш чыкмау** Һәрвакыт кыйналып, җәберләнеп яшәү. **Йодрык тарафдары** Сугышырга гына торган кеше. *Ул, бу сүзем өчен тулы җаваплылыкны өстемә алып әйтәм, бугаз һәм йодрык тарафдары.* Б.Камалов. **Йодрыкта тоту** 1) Тыңлатып, буйсындырып, үз карамагында нык тоту. *Бу яңа председатель хуҗалыкны йодрыкта тота, урлашырга бирми.* Н.Исәнбәт; 2) Үз-үзен берәр нәрсә эшләүдән туктату, уй-кичерешләрен, хисләрен тыю. **Йодрык теле** Сугып, кыйнап буйсындыру турында. *Кайберәүләр «йодрык теле»н генә аңлаучан була бит, төшендереп биргәч, төшенгәннәр, кыскасы.* Казан утлары. **Йодрык төйнәп йөрү** *к.* **йодрыкны кесәдә йөртү**. *Сәфәргә йодрык төйнәп йөргән Әхмәдулла гына кичке аш янында: – Кияү булыр ул тиздән, теге дөньяда, – дип, Мөнәвәрәнең күңеленә шом салды.* Н.Гыйматдинова. **Йодрык төю** Йодрык белән каты әйбер өстенә кат-кат сугып алу. *Һи, юньсез картлач! Син дә, берзаман начальник булдым, кешеләргә йодрык төеп өстәл кактым, диген!* Н.Исәнбәт. **Йодрык уйнату** *к.* **йодрык күрсәтү**. *Револь иптәшенең болай кызып ки-*

*түен, нилектән шулай аның борын төбендә йодрыгын уйнатуын аңлап ук бетермәгәнгә күрә, күзләрен мелт-мелт ачып-ябып торды.* Г.Үзиле. *Һәм [таза гына гәүдәле берәү], йодрыкларын уйнатып, озын буйлы әсир янына килеп тә басты.* С.Йосыпов. **Йодрык хокукы** Законсызлык хөкем сөрү, ирексезләп хакимлек итү. **Йодрык чумары пешерү (ашату)** Бик каты кыйнау. **Йодрык эчендә тоту** Көч белән билгеле бер таләпләргә, шартларга буйсынырга мәҗбүр итү. **Йодрык янау** *к.* **йодрык күрсәтү**. *Ярар инде, Сәфәр ил байлыгын сакларга куша, ә бу ач күзе, бу ач күзе бодай өчен йодрык янап ята бит!* Н.Гыйматдинова. *Түрә чайкала-чайкала борылды һәм күзенә күренмәгән дошманнарына йодрык янады, аннан көймә читенә гөрселдәп ауды.* Ж.Рәхимов

**ЙОДРЫК-ЙОДРЫК** *с.* Гадәтидән зур, йодрык кадәрле. *Нәкъ уртада йодрык-йодрык пилмәннәрдән пар күтәрелә.* Р.Сибат. *Аннан да биегрәк агачларда йодрык-йодрык алмалар, безгә буегыз җитми дип, кызарышып көлеп торалар сыман.* Н.Дәүли. *Имеш, урамда, яшен яшьнәп, чиләкләп яңгыр коя. Ул да түгел йодрык-йодрык боз ява башлады.* Ә.Галиев

**ЙОДРЫКЛАНУ** ф. 1) Йодрыкка йомарлану. *Заһид Шәркыйның арык куллары йодрыкланган, киеренкелектән бит мускуллары уйнаклап тора.* Ф.Сафин

2) *күч.* Һөҗүм итәргә әзер булу. *Атомның дәһшәтле көче йодрыкланып тупланган реактор-казаннар Җирнең төрле почмакларында дисטәләгән генә түгел, йөзәрләгән бит хәзер.* Р.Фәйзуллин

**ЙОДРЫКЛА́У** *ф.* 1) Бармакларны уч төбенә кысып йому; йодрык хасил итү. *Нәфисә дә, аңа очып кунарга теләгәндәй, кулларын йодрыклады.* Ф.Садриев

2) *сөйл.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса сугу, кемне яки нәрсәне дә булса кыйнау. *Үзенең чарасызлыгын белгертергә теләп, еламсыраган аваз белән ишекне эчке яктан йодрыклап бераз төйде дә, аяк очларына басып, көннең-көн буена ачык торган балконга юнәлде.* Р.Мөхәммәдиев

3) *күч. сөйл.* Уңай һәм җитешсез якларны аяусыз күрсәтү, тәнкыйтьләү

**Йодрыклап алу** Тиз арада, берничә тапкыр бәргәләп йодрыклау

**Йодрыклап йөрү** Һәрвакыт һәм һәрберсен йодрыклау. *Гәрчә көрәштә әллә күпме еллар мәйдан тотса да, Котлызаман агай, Хөрмәтулла абзый кебек, сабан туе ямен җибәреп сугышучыларны йодрыклап йөрмәс иде.* С.Поварисов

**Йодрыклап ташлау** Кискен, кинәт, чаманы онытып йодрыклау. *Рамил аны кинәт этеп җибәрде дә елый-елый йодрыклап ташлады: – Менә үзеңә рәхәтме?! Рәхәтме үзеңә?! – диде ул, кайда туры килсә шунда тондырып.* М.Кәбиров

**Йодрыклап тору** Һәрвакыт йодрыклау; бертуктаусыз йодрыклау

**Йодрыклый бирү** Йодрыклауны дәвам итү

**ЙОДРЫКЛАШУ** *ф.* Сугышу, кыйнашу. *Аннары егетләр йодрыклашуга күчәләр.* Ф.Садриев

**Йодрыклаша башлау** Йодрыклашырга тотыну

**Йодрыклаша бирү** Һаман да йодрыклашу, йодрыклашуны дәвам итү

**Йодрыклашып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә йодрыклашу

**Йодрыклашып китү** Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәт йодрыклашырга тотыну

**Йодрыклашып тору** Гел, һәрвакыт йодрыклашу

**ЙОДРЫКЧА** *и. тех.* Машина механизмын хәрәкәткә китерә торган детальдәге кечкенә йодрык сыман калкып торган чыгынты. *Шнек приводы механизмы конструкциясендә, төрле әйләнү тизлекләре алу өчен, өстәмә йодрыкчалар каралган.* Урып җыю машиналары. *Йөрәк сыман йодрыкча. Кабатлы йодрыкча*

**ЙОДРЫКЧАЛЫ** *с.* Йодрыкчасы булган. *Ролик белән йодрыкчалы диск кырыйлары арасы СК-5М комбайнында 2–3 мм, ә «Енисей» комбайнында 8–10 мм булырга тиеш.* Урып җыю машиналары

**ЙОЗАК** *и.* 1) Ачкыч белән яки ачкычсыз ачып ябыла торган итеп эшләнгән бикләү җайланмасы. *Әнвар, пациенттан бушап торган арада, кайчандыр калкансыман биз авыруына каршы көрәшү өчен оештырыла башлаган, ләкин күптән ишегенә йозак эленгән лаборатория бүлмәсенә керде.* Ә.Сәйфетдинов. *Ә ул крокодил тиресеннән тегелгән портфеленең көмеш йозагын --- гайрәтле хәрәкәт белән шартлатып ачып, капкачын артка каерып салды.* Ә.Гаффар. *[Хәйдәр] Ашыкмыйча гына ишекне япты, инглиз йозагының бикләгеч телен төшерде.* Г.Үзиле

2) Кайбер ату коралларының затворы

3) *тех.* Агач корылмаларда бүрәнә, борыс башларын эләктереп, тоттырып кую өчен ясалган уем

4) Киемдә тиз ачыла һәм ябыла торган тасмасыман җайланма; молния. *[Серафима] Әүвәл юлда кия торган спорт формасының йозагын төшерә.* З.Хөснияр

5) *күч.* Берәр нәрсәнең алшарты. *Ашлыкның йозагы – салам, акчаның йозагы – саран.* Мәкаль

◊ **Йозак астында саклау** Серне тирәнгә яшереп тоту; серне беркемгә сиздермәү. *Теге ата таракан моны сер итеп мең кат йозак астында саклаcа да, шулай булачагын белдем мин!* З.Хөснияр. **Йозакка әйләнү** Авыз ачып бер сүз әйтмәү, сер сатмау. *Атасының холкын үзләштергән йомышчы кирәк чакта тимер йозакка әйләнә белә иде шул.* Ф.Латыйфи. **Йозак салу** 1) Йозак белән бикләп кую. *Төннәрдән бер төнне Убырлы карчык, нииндидер явызлык эшләргә чыгып киткәндә, ишеккә йозак салырга онытткан, ди.* Әкият. *Күршеңне гаеплəгәнче, ишегеңә йозак сал.* Н.Исәнбәт. *Авылда карак-фәләннең булганы юк, ишеккә йозак салып тормаса да ярар.* Р.Низамиев; 2) Берберсенә беркетелгән металл боҗраларны кулга кидерү. *Шул ук сәгатьтә [ике атлы солдат] Мохтарны тотып алганнар да, кулларына «йозак» салып, каядыр алып киткәннәр.* Н.Дәүли; 3) Үз-үзеңне нәрсә дә булса эшләүдән тыеп калу. *Авызыннан чак кына*

*«җинаятеңнеме...» дигән әшәке сүз төшмәде. Акылы теленә йозак салырга өлгерде.* Т.Галиуллин. **Йозакта тоту** Йозак белән бикләп саклау

**ЙОЗАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **йозаклау**. *Ишекләре бар да йозакланган.* Әкият

2) *күч.* Ябылу, каплану; йомылу

**Йозакланып килү** Кинәт йозаклану. *Йөрәктәге нәни җәрәхәтем агач куышыдай йомылып, йозакланып килде.* Р.Низамиев

**ЙОЗАКЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Йозак белән бикләп кую, йозак салу. *Дөрес, өйнең ишеген йозаклап, тәрәзәләрен кадаклап киткән очракта, ананы улы янында тотып булыр димә.* Ә.Сәйфетдинов

2) Йозак (*3 мәгъ.*) ясау, йозак ую

3) *күч.* Кулны кулга чалыштыру. *Хәбиб абзый, урындык алып, Илфат караваты янәшәсенә утырды. Аның шундый гадәте бар: уң аягын сул тезенә атландыра да, кулларын «йозаклап», кул сырты белән уң тезенә кагыла-кагыла сөйләшә, гүя һәр әйткән фикерен кадаклап бара.* Б.Камалов

4) *күч.* Яшерү, башкаларга белгертмәү. *Яттан йозакла сереңне, Ерак тор юраучыдан...* И.Ибраһимов

**Йозаклап алу** Тиз генә йозаклау. *--- бер тар гына камерага кертеп, өстемнән шалтыр-шолтыр китереп йозаклап алдылар.* С.Рәмиев

**Йозаклап кую** 1) Йозаклаган хәлдә тоту. *[Мөстәкыйм:] Аптырагач, караватбашына чылбыр белән бәйләп, йозаклап куйдым.* Д.Салихов. *--- диварларда сәндерәләр генә. Аларны кичке сәгать унда гына ачалар да иртәнге алтыда кире күтәртеп йозаклап куялар.* И.Сиражи

2) *күч.* Сүз әйтмәслек, сөйләмәслек итү, әйттермәү. *Берни эшләр чара юк, берәүнең дә авызын йозаклап куя алмыйсың.* Р.Низамиев. *Кирәкле сүз аслан килми тел очына. Әйтерсең телләрен йозаклап куйдылар.* С.Поварисов

**Йозаклап тору** 1) Вакытлыча, хәзергә йозаклау

2) Һәрвакыт йозакта тоту

**Йозаклап чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы йозаклау. *Бөтенләй өйләрен йозаклап чыгып, һәммә кешенең дә урамда гомер итүен син дә теләми торгансыңдыр бит?* Г.Камал

**ЙОЗАКЛЫ** *с.* 1) Йозак белән бикләнгән, йозакланган. *Ходай Тәгалә аны җир бүләге – гади дә, җиде йозаклы сандыктай серле дә Зөлфиядән аермасын иде дә бит.* Т.Галиуллин. *--- һәрвакыт үзгәртеп торучан сәясәт буявына төренгән кырыс заман андый иҗат җимешләрен тимер йозаклы подвалларга бикләп куярга мәҗбүр була.* Р.Вәли

2) Йозагы (*1, 4 мәгъ.*) булган. *[Куртка] Шундый матур, шундый шәп: алдында дүрт кесә, җиңендә ике кесә. Кесәләре йозаклы.* М.Юныс

3) *күч.* Тыелган, законнан тыш булган. *Әле яшьлек «җүләрлеген» җуймаган, төпле акыллы, максатлы, зирәк галим-голәмә, «йозаклы» әдәбиятны ачып укыган, тарихи тамырларыбызга төшәргә омтылган язучылар аңа [«Идел» журналына] тартыла иде.* М.Галиев

◊ **Йозаклы тел белән яшәү** Үз сүзен, фикерен ачыктан-ачык әйтә алмау, нинди дә булса серне яшерергә мәҗбүр булу. *Аның шушындый богаулы иректә йозаклы тел белән яшәүгә ачуы килде.* Ш.Маннур

**ЙОЗАКЧЫ** *и.* 1) Йозак ясаучы, йозак төзәтү остасы

2) *хәрби* Артиллериядә тупны корып торучы. *Йозакчы янында снарядлар ята иде. Ул, ярасын бәйләп бетерергә ирек бирмичә, шул снарядларның берсен эләктерде.* Г.Әпсәләмов

**ЙОКЛАР-ЙОКЛАМАС** *рәв.* Ярым йокылы, ярым уяу хәлдә. *Әмма сыер токымының шундый ваемсызлыгы, шулай йоклар-йокламас кына атлавы бераздан ук аларны [шофёр халкын] пошындыра башлый.* Г.Бәширов

**ЙОКЛАТКЫЧ** *с.* 1) Йоклата торган (дару, укол яки берәр үсемлектәге шундый сыйфатка ия матдә). *Миңзаһит базардагы үлән сатучы картка бик озак барып йөрде, әмма ул йоклаткыч нәрсәне бирергә ашыкмады.* Ф.Садриев. *Америка галимнәре ачыклаганча, Е витаминына гаять бай әлеге чикләвектә мелатонин күп, ул йоклаткыч үзлеккә ия.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Эчпошыргыч, ялыктыргыч, тиз туйдыра торган, бертөрле. *Поезд тәгәрмәчләренең йоклаткыч текелдәве тиз тәэсир итте*

3) *күч.* Уяулыкны, саклыкны киметү өчен уйлап табылган, хәйләле. *Шагыйрь Татарстанның төгәл кыяфәт алуына ихластан сөенә, аны бәйсез дәүләтләр арасында күрергә хыяллана. Хәтта йоклаткыч алдавычка ышанып та куя.* Т.Галиуллин

**ЙОКЛАТУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **йоклау** (*1 мәгъ.*). *[Карт:] Мине йоклатып, үзләре генә бәйрәм итә түгелме соң болар?* Аманулла

2) Йоклау өчен урынга салу (гадәттә, балаларга карата әйтелә). *[Ана] Тагын да карыннары ачканчы дип, балаларын тизрәк йоклату ягын карады.* Г.Гобәй. *Аның әнкәсе, энеләрен, сеңелләрен йоклатып, колхозчы улын эзләргә дип чыккан.* Я.Шәфыйков

3) Тән авыртуны тоймыйча йокларга мәҗбүр итү (наркоз, гипноз һ.б. белән). *Хәзер сызлауны баса һәм тынычландырып йоклата торган наркотикларны да көннән-көн азрак бирәләр аңа [Гамирга].* З.Фәйзуллин. *Әнвәрне морфий белән йоклатып тоттылар.* Х.Камалов

4) *күч. эвф.* Берәр төрле агулы әйбер ашатып, эчертеп, иснәтеп яки укол кадап үтерү

5) *күч.* Тиз туйдырудан, ялыктырудан, акрын һәм бертөрле булудан йокы килү. *Фикере булмаса, доклад та йоклата.* Ш.Галиев. *Тыныч музыка аны [яралгыны] йоклата.* А.Низамов

6) *күч.* Уяулыкны, сизгерлекне алу. *Яхшы тел еланны да йоклата.* Мәкаль. *Мактау тәнкыйте сәнгатьченең уяулыгын йоклата.* Р.Батулла

**2. йоклатып** *рәв. мәгъ.* Акрын гына, салмак; бер тизлекне саклап. *Менә хәзер, өстебезгә аэроплан килеп чыккач, [ат] иплән кенә, йоклатып кына барып яткан җиреннән кинәт койрык чәнчеп, юл буендагы чокырга сикерде.* В.Нуруллин

**Йоклата бару** Торган саен ныграк йоклату

**Йоклата башлау** Йоклатырга тотыну. *Караватыбыз янына урындыклар*

*тезеп, шунда улыбыз Фәритне йоклата башладык.* Р.Юсупова

**Йоклата төшү** Тагын да бераз йоклату

**Йоклатып алу** Кемгә дә булса кыска вакытка йокларга мөмкинлек бирү. *Минем Григорийны, операция өстәленә яткырып, кабат йоклатып алганнар.* Н.Дәүли. --- *үз нәүбәтендә Вәгыйзь дә төнге сменада аларга ярдәмгә килә, Һарунны һәм чәчүчеләрне бирәр сәгать йоклатып ала.* Ф.Хатипов

**Йоклатып бетерү** Тәмам йоклату; барысын да йоклату. *Ничек балаларны урнаштырып, йоклатып бетерәсе.* Н.Гариф

**Йоклатып җибәрү** Кемгә дә булса йокыга китәргә ярдәм итү. *Хәния, кечкенә Зөлфияне йоклатып җибәргәнче дип, утны сүндерде дә кызы белән караватка ятты.* Н.Хәсәнов. *Син бит ул чакларда: «Гөләндәм әби шундый җылы, имеш, йомшак, имеш, ятмас борын ук йоклатып җибәрә торган, имеш, урын җәя», – дип сөйли идең.* Совет әдәбияты

**Йоклатып тору** Һәрвакыт, гел, әледән-әле йоклату

**Йоклатып чыгару** Төн кундыру, төнне үткәрергә үзенә алу. *Укытучы апалары аларны биш катлы йортның өске катында яшәүче бер танышларында йоклатып чыгарды.* М.Маликова

**ЙОКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Йокы хәлендә булу. *Ак мамык мендәрнең Эченә күмелеп, Ул йоклый...* М.Җәлил. *Ләкин Хәлим, яңагы астына кулын куеп, авызын бераз ача төшеп, яшь бала шикелле тыныч, рәхәт йоклый иде.* А.Шамов

2) Йокы хәлендәге сыман күз йомып тору. *Менә Будда йоклый – 20 метрлы таш гәүдә.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Төнлә, таң атканда, иртә белән бик тын булу // Хәрәкәтсезлек, җансызлык урнашкан булу. *Зәңгәр ефәккә төренеп, Йоклый кырлар, бакчалар.* М.Җәлил

4) *күч.* Гамьсезлек күрсәтү, бернәрсә дә эшләмичә тик тору; билгеле бер нәтиҗәгә ирешү өчен чара кулланмау, әмәлен күрмәү, бер урында туктап тору

5) *күч.* Тик тору, эшләмәү; дәртсез, сүлпән булу. *Галимнәр исәпләвенчә, без әле баш миенең дә утыз-кырык процентын гына эшләтәбез икән. Фәлән проценты йоклый, ял итә, форсат чыкмый икән, шул килеш дөньядан кичә.* Р.Низамиев. *Җир шарындагы кешеләрнең туксан тугыз проценты бөтен гомерен йоклап үткәрә.* Ф.Садриев

6) *күч.* Вафат булу, үлгән булу. *Бу җирдә туган илебез өчен һәлак булган батырлар йоклый.* Р.Хафизова

**2. йоклаган** *с. мәгъ.* 1) *бот.* Тиешле шартлар булмаганлыктан, вегетация чорында үсемлек яфрак ярмый, чәчәк атмый калган. *Йоклаган бөреләр*

2) *күч. сөйл.* Сүлпән, дәртсез; игътибарсыз, әкрен хәрәкәт иткән. *Йоклаган йөрәкләрне дә уята торган чагың, Бар дөньяны оныттырып, уйната торган чагың.* Ш.Галиев. *Син дә инде, Кадермәт күрше, бигрәк тә йоклаган кеше булып чыктың. Шуны да күрмәдеңмени соң?* М.Әмир

3) *күч. сөйл.* Җебегән, булдыксыз

**3.** *и. мәгъ. шелт.* Ваемсыз, оешмаган, эшкә сәләтсез кеше

**4. йоклап** *рәв. мәгъ.* 1) Тәрәкъкый итмичә, үсмичә. *Дөньяда торудан максатың тыныч кына йоклап яшәү булса, Кара фикергәияр.* Г.Коләхмәтов

2) Салынкыланып, теләр-теләмәс, җиренә җиткермичә (эшләү турында)

3) Уйларга бирелеп, онытылып, кыймшанмыйча

◊ **Йоклаганда да күзе ачык** Бик уяу, сизгер

**Йоклап алу** Бераз вакыт йоклау, черем итү. *Ул одеялга төренеп ятты һәм сәгать ярым чамасы йоклап алды.* Ф.Садриев. *Бар хыялы – ничек тә йоклап алу.* Х.Камалов

**Йоклап бару** Акрынлап йокы хәленә күчү

**Йоклап бетермәү** Туйганчы йоклау мөмкинлеге булмау, теләгән кадәр, җитәрлек йоклый алмау. *[Фәһим Айтуганов] Биш ел буена җан-фәрманга чабып, йоклыйсы йокыларын йоклап бетермичә, иркәлисе оныкларын иркәләргә вакыт тапмыйча, терлек каралтылары салдырды.* Г.Ахунов

**Йоклап бетү** Барысы да йоклау. *Зур чатырда әле кешеләр барысы да йоклап бетмәгәннәр иде.* Н.Фәттах. *Бөтен авыл йоклап беткәч кенә, Әнкәемнең уты сүнгәндер...* Ш.Җиһангирова. *Күңелсез итеп сөйләсәң, студентларың йоклап бетәргә мөмкин.* Г.Кашшаф

**Йоклап йөрү** Һаман, гел кунача калу. *Кызы ишекне үз ачкычы белән ачып керде дә, аяк киемен дә салып тормый, карт йоклап йөргән бүлмәнең ишеген этте.* Ә.Әминев

2) Һәрвакыт йоклаган хәлдә булу. *Йоклап йөри торган гына егет иде ул, бүген, ничектер, ут өертә!* А.Гыйләҗев. *– Малайлар елдам булырга тиеш ул, ә син аяк өсте йоклап йөрисең, – дип үртәде аны кызый.* Л.Гыймадиева

**Йоклап калу** Йоклау сәбәпле нәрсәгә дә булса катнашмау, уздырып җибәрү. *Шау-гөр килеп тормыш читтән узган, Син ояңда йоклап калгансың.* Г.Афзал. *Үз бәхетен ул да йоклап калмас.* Ф.Латыйфи

**Йоклап китү** Йокы халәтенә күчү. *Тәмам хәле бетеп, күзеннән яшь, авызыннан сүз чыкмый башлагач кына тукталып, йоклап китте ул.* В.Нуруллин. *Алмагөл, баланың болай тиз йоклап китүенә кәефсезләнеп, караватт тирәсендә әйләнде дә, --- кире одеял астына кереп ятты.* И.Салахов

**Йоклап тору** 1) Әле, хәзер йоклау

2) *күч. юкл. форм.* Уяу булу, югалып калмау. *Гата да йоклап тормады, поскан җиреннән чыкты да тавык артыннан атлады.* А.Алиш

**Йоклап яту** 1) Билгеле бер вакыт дәвамында йокы хәлендә булу. *Кайтып керсә, ни күрсен: Чикерткә чалмачапанын салып ташлап, мендәрләргә батып, сабыйдай изрәп йоклап ята, имеш.* Ә.Еники. *Әти җир сукалаган, ә мин арбада йоклап ятканмын.* Н.Дәүли

2) *күч.* Яшеренеп, үзен белгертмичә, күренмичә тору. *[Сынчы:] – Карагыз әле, сездә йөз илле ел буена сатирик шагыйрь сәләте йоклап яткан бит! – диде ул, көлеп туйгач.* А.Тимергалин

**Йоклый башлау** Йокларга тотыну.

**Йоклый бирү** Һаман да, әле дә йоклау, бернигә карамый йоклавын дәвам итү. *Ана кеше --- тынычсызлана төшсә дә, икенче кабат төпченергә тотын-*

*мады, «йокласа, әйдә, йоклый бирсен» белән бетерде.* Ф.Хөсни

**Йоклый төшү** Тагы да озаграк йоклау

**ЙОКТЫРУ** *ф.* 1) Эләктерү, алу (йогышлы авыру). *Ачлык елны апам приют балалары белән Себергә киткән җиреннән, тиф чире йоктырып, Томскида үлеп кала.* А.Расих. *Әнә шул эшендә йөргәндә, маллардан тимрәү чире дә йоктырды ул.* Н.Кәримова

2) Берәр нәрсәгә тидереп, үзенә сеңдереп, эзен яки исен үзенә алу

3) *күч.* Нәрсә дә булса күчү, ияrү; нәрсәне дә булса башкалар үзләштерү. *Әгәр исереп прогул ясап ятучыларга әзер урыннан икенче урынга күчеп йөрергә ирек бирсәк, алар бу чирләрен башкаларга да йоктырачак.* З.Фәйзуллин

4) *күч.* Үзеннән икенче берәүгә (нәрсәгә) күчерү, йогынты ясау (һөнәр, гадәт, хис, кәеф һ.б.). *Сугышның очына гына эләгеп, аның тышкы бизәкләрен генә йоктырып кайткан мин, хатын-кызның игътибарын казангач, үземне каһарман итеп хис иттем.* И.Гази. *--- хыялый рухлы, мавыгучан, шул мавыгуларын башкаларга да йоктыра белүче отставкадагы офицер район яшьләре белән шунда ук уртак тел тапты.* Р.Миңнуллин. *--- син минем пакь күңелемә үзеңнең пычрагыңны йоктырдың.* Ф.Яруллин

5) *күч.* Берәүнең гадәтен алу. *«Кемнән йоктырдың әлеге зәхмәтне?» – дип сорасалар, бу адәм өтеген каян табасы икәнен белеп каласы.* Т.Галиуллин. *Әнине яратуымны Сеңлемә дә йоктырам.* Г.Гыйльманов

**Йоктыра башлау** Йоктырырга тотыну. *Әмма, ни хикмәт, Семён Моисеевич үзенең тарих фәнен яратуын аз-азлап кына тыңлаучыларга да йоктыра башлады шикелле.* Р.Кәрами

**Йоктыра язу** Чак кына йоктырмый калу. *Менә шул кешеләр сиңа богемачылыкка кызыгу тойгысын йоктыра яздылар.* Х.Туфан

**Йоктырып алу** 1) Кыска вакыт арасында, бик тиз йоктыру. *[Сафуан абый] Әллә ничә ел күрми торган шикелле, ир-атлар белән кул биреп күрешә, минем дә кулга бензин исе йоктырып ала.* М.Галиев

2) Азга гына, кыска вакытлы гына йоктыру. *Күренекле генә язучы, журналистлар да, шушы сәяси шаукымга бирелеп китеп, гарәп-фарсы, төрки неологизмнар белән мавыгу чирен йоктырып алдылар.* И.Низамов

**Йоктырып тору** Һәрвакыт, гел йоктыру, шул ап-ачык булып күренү, тоелып тору. *Куанды, сөенде, чөнки әнкәсенең кызлар кебек өлгерлеге, җитезлеге, уңганлыгы бөтен өйгә ниндидер сихри бер дәрт һәм көрлек йоктырып тора иде.* Г.Гыйльманов

**ЙОКЫ** *и.* 1) Аң эшчәнлегенең билгеле бер вакыт арасында тукталып торуына бәйле физиологик тынычлык, организмның ял итү халәте. *– Йокы – иң файдалы дару, – дияр иде Камәр карчык, – сырхау адәм изелеп йоклый икән, Ходай терелтә аны.* Н.Гыйматдинова. *Үсмер кызның төн йокыларын калдырып әзерләгән, атналар-айлар буе тиешле кешесенә ничек тапшырырга белми йөдәгән беренче һәм ихлас бүләге...* Р.Мөхәммәдиев

2) Кышын кайбер кыргый хайваннарның тереклек эшчәнлеген киметеп яки туктатып торуы; *русчасы*: **спячка**. *--- керпе гаиләсе шул гөмбәләр тирәсендә чемченеп йөри торгач, шактый ризык табып, симергәнче сыйланыр. Симергәнче: кышкы йокыга җиткәнче.* К.Кәримов

3) *күч.* Гомуми тынлык, хәрәкәтсезлек (табигать күренешләре, җансыз әйберләр турында). *Тып-тын. Әйтерсең лә бөтен дөнья татлы йокыга талган.* Р.Батулла. *Җирне, ахры, төнге йокысыннан Сыерчыклар җыры уята.* Р.Гәрәй. *Караяр авылы тыныч йокыда.* М.Юныс

4) *күч.* Кыш көне табигать эшчәнлегенең сүлпәнләнүе. *Табигатьнең кышкы йокыдан уянып, хәрәкәткә килгән, кат-кат тунын салып бетереп, ашыга-ашыга өстенә яңа яшел киемен киеп торган көннәре иде.* Г.Гобәй

5) *күч.* Үлем, үлгән булу. *Син мәңгелек йокыда идең, балам. --- Сине туган ил һавасы үлемнән йолып алып калды.* Г.Сабитов. *Әле генә дөнья шаулатып яшәгән Асылбикә бүген мәңгелек йокыда!* Гөлшәһидә. *Үлем – йокы. Тирәнлеге мәңгелек.* Ш.Галиев

◊ **Йокы алмау** Йоклый алмау, йоклый алмыйча яту. *Әминәне йокы алмый иде.* Ф.Әмирхан. **Йокы аралаш (ара, арасында)** Ярым йокылы хәлдә. *Йокы аралаш әнкәгезнең, күгәрчендәй гөр-гөр килеп, сезне назлауларын тою ---.* Ф.Яруллин. **Йокы ачылу** Уянгач, яңадан йоклап китә алмау. **Йокы базарына китү** Йоклап китү. **Йокы базы** Күп йокларга яраткан кеше. **Йокы басу** Бик каты йоклыйсы килү, изри башлау. *Сөйләшеп ята торгач, балыкчыларның тавышлары карлыга, телләре авырая башлады, йокы басты үзләрен.* Н.Исәнбәт. **Йокы бүлү** Вакытлы-вакытсыз йокыдан уяту, йокларга бирмәү. *Төн йокысын бүлеп вак кисәккә, Мендәрләрен меңгә бөгәрләп, Уйлыйлардыр һаман шул турыда Башкалар да йөзләп, меңәрләп.* Ш.Маннур. *«Йокысын бүлдем, тагын рәнҗер инде». Рәйханәгә кыен булып китте.* Р.Ишморатова. **Йокы бүсү** Кирәксә дә, кирәкмәсә дә, бик озак итеп йоклау, күп йоклау. *Я, егетләр, нәрсә? Ашыйбыз, эчәбез дә һаман ятып йокы бүсәбезме?* Н.Исәнбәт. **Йокыга бирелү** *к.* **йокыга китү**. **Йокыга китү** 1) Йокы хәленә күчү. *Язидә утын сүндерә дә тынычлап йокыга китә.* Г.Бәширов. *Һәркайсы үз уйларына, үз хыялларына бирелеп, йокыга киттеләр.* А.Шамов; 2) Һушны югалту; 3) Тирән тынлык урнашу, хәрәкәт бетү. **Йокыга куеру** Йокымсырау халәтендә булу, оета башлау; йокыга китәргә әзерләнү. *Җил, яңгыр. Тешләр тешкә тими. Шуңа карамастан, биш-алты тиңентен берәм-берәм йокыга куерып китәбез.* Р.Төхфәтуллин. **Йокыга ою** *к.* **йокыга китү. Йокыга сак булу** Бик сизгер, уяу, берәр хәл булу белән шунда ук уяна торган кешегә карата әйтелә. *Наҗия апаның йокысы сак икән, шундук торып утырды, итәген җыештырды.* А.Гыйләҗев. **Йокыга талу** *к.* **йокыга китү** (*1 мәгъ.*). *Сәкегә утырасың --- һәм искиткеч татлы йокыга таласың.* М.Мәһдиев. *Шыплап мал төягән зур көймә, җилкәннәрен төшереп, Идел*

*уртасында йокыга талган иде.* Ф.Латыйфи. *Табигать ул вакытлыча гына йокыга тала.* Р.Кутуй. **Йокыга түнү** *к.* **йокыга китү**. *Әбүсөгыт бай төшермеш иде, салган-салган – лаякыл исергәнче эчсен иде, ичмасам, йокыга түнәр иде.* М.Хуҗин. **Йокыга чуму** *к.* **йокыга китү**. *Аны абзар эчендәге тирес өеменә илтеп салдылар. Ул мәрткә киткәндәй йокыга чумды.* З.Хәсәнов. *Кыз ике-өч көн буена түшәктән аерылмады, торып ашады-эчте дә кабат йокыга чумды.* М.Кәбиров. *Тик өйгә кайтып, татлы йокыга чумган гына идем, мине иңнәремнән селкеп уяттылар.* Казан утлары. **Йокыдан айный алмау** Йокы хәлендә калу, йокысы ачылмау. *Улын җилтерәтеп торгызды да йокысыннан айный алмаган малаеның пижамасы өстенә җылы тунын кидерә башлады.* Т.Галиуллин. **Йокыдан баш чыкмау** *к.* **йокыдан айный алмау**. **Йокыдан калу** Йоклый алмау, йокысызлык белән интегү. *[Җавапсыз мәхәббәттән] Кеше җафалана, кеше йокыдан кала, кеше үзен һәм башкаларны каргый башлый, кеше елый, нәфрәт кичерә ---.* З.Фәтхетдинов. **Йокыдан кибән кую** Бик озын-озак йоклау, йокыдан туймыйча йоклау. *Мисхаб абзаң өендә йокыдан кибән куя.* Р.Хафизова. **Йокыдан уяну** 1) Сәяси аңлылык үсә башлау, аңлы көрәшкә күтәрелү. *Вакыт үтә. Изелгәннәр йокыдан уяна башлыйлар.* М.Мәхмүтов; 2) Актив эшчәнлек башлап җибәрү. *[Айрат] Үз кул астындагы бюро членнарын йокыларыннан уятты.* Г.Ахунов; 3) Хәрәкәткә килү, җанлану (табигать күренешләре турында). *Табигать кышкы йокыдан уяна.* Ә.Фазылҗанов. **Йокыдан уятып (торгызып) сораганда да (сорасалар да)** «Теләсә кайсы вакытта, теләсә нинди шартларда дөрес итеп җавап бирерлек дәрәҗәдә яхшы белә» мәгънәсендә. **Йокы изрәтү** *к.* **йокы басу**. *Шулай тирбәлә-тирбәлә бераз баргач, йокы баскан, яшьлек йокысы изрәткән.* С.Зыялы. **Йокы изү** *к.* **йокы басу**. *Аны йокы изә: ул күзләрен йома, башы капчык өстенә авып төшә.* Г.Кутуй. **Йокы йөзе күрмәү** Йоклый алмау, тынычлык булмау. **Йокы калдыру** Йоклыйсы вакытын әрәм итү, йокларга ирек бирмәү. *Күршемдә бик юньсез бер хатын бар, шул әлләниләр сөйләп йокымны калдырды.* Г.Исхакый. **Йокы капчыгы** Күп йокларга яратучы кеше. --- *күп йокларга яраткан кешене сурәтләү өчен кулланыла торган «йокы чүлмәге», «йокы капчыгы» дигән метафоралар бар.* Р.Юсупов. **Йокы качу** Йоклыйсы килеп тә, тирән кичерешләр, борчулар һ.б. аркасында йокы югалу. *Ул нихәтле арыган булса да, йокысы качкан иде.* Ш.Камал. *Бабасының тавышын абайлап алгач та, малайның йокысы табан астына качты.* А.Хәлим. *Мирхасның кинәт йокысы качты, ул бусагага торып утырды.* Казан утлары. **Йокы качыру** Йоклау теләген бетерү. **Йокы кермәү** *к.* **йокы алмау**. **Йокы килмәү** *к.* **йокы алмау**. **Йокы китергеч** Ялыктыргыч, эчпошыргыч, күңелсез; бертөрле. *Бир әле шул йокы китергеч романыңны.* Н.Исәнбәт. **Йокы күрмәү** Йоклый алмау, йоклау мөмкинлеге булмау. *[Муса абый:] Төне буе ютәлләп йокы күрмәдем, таң алдыннан гына оеп киткәнмен.* С.Йосыпов. **Йокы мазасы бирмәү** Бик еш борчып яки тавышланып, тынычлап йокларга мөмкинлек калдырмау. *Болай булгач, Сабирәттәйгә дә йокы мазасы бирмибез.* М.Галиев. **Йокы мичкәсе** *к.* **йокы базы**. **Йокыны ачу** Айнытып җибәрү, уйланырга мәҗбүр итү. *Чыңгыз ханның Җаек буена басып керүе бик күпләрнең йокысын ачты.* Н.Фәттах. **Йокыны җую** *к.* **йокыдан калу**. *Ул үзе дә, хәлвәфрушне күргәннән бирле, төн йокыларын җуйган иде.* К.Насыйри. **Йокының нәзере юк** «Йокы – табигый күренеш, озак йокларга, дигән йөкләмәне үз өстеңә алырга ярамый» мәгънәсендә кулланыла. *– Ярар инде, кызым, тор инде. Күпме ятсаң да йокы туймас ул, йокының нәзере юк, – диядия, бүлмәгә килеп керә [әни].* М.Хәбибуллин. **Йокың (йокыгыз) тәмле булсын!** Йокларга ятканда, теләк рәвешендә әйтелә торган сүзләр. **Йокы очу** *к.* **йокы качу. Йокы симертү** *к.* **йокы бүсү.** *Тор, җитте сиңа, йокы симертеп ятма!* М.Хәбибуллин. *Әгәр спортчы күнегүләр ясыйсы урында көне-төне йокы симертсә, аның нинди дә булса җиңүгә ирешүе шикле.* Р.Низамиев. **Йокы сүтү** *к.* **йокыдан кибән кую**. **Йокысы җитү** *к.* **йокы басу**. **Йокысы сандугач йокысы шикелле** Йокысы җиңел, тиз уянучан, кыска йокылы (кеше турында). *Авырайгач, утырган җиреннән ястыкка авышып, сандугач йокысы чаклы гына черем итеп ала.* К.Кәримов. **Йокы таралу** *к.* **йокы ачылу**. **Йокы төсе күрмим** Сөйләүченең: «Сүзем ялган булса, үз-үземне йоклый алмау газабына салам», – дип карганып ант итүе. **Йокы туйдыру** *к.* **йокы бүсү**. **Йокы чүлмәге** *к.* **йокы капчыгы**. **Йокы чырае күрмим** *к.* **йокы төсе күрмим**. **Йокы элену** Йоклыйсы килү, оету. *Карәхмәтнең күзләренә дә йокы элenә башлады.* З.Хөснияр. *Керфекләренә йокы эленеп, инде онытылып китәм дигәндә, баш миендә янә уйлар өермәсе кузгала.* Ф.Сафин. **Йокы югалу** *к.* **йокы качу**. *Ә синең «бишле»ләрең арасына «дүртле» керсә, йокың югала, дөньяңның яме бетә.* М.Юныс

**ЙОКЫ́ БҮЛМӘСЕ** *и.* Фатирда йоклау өчен уңайлаштырылган аерым бүлмә. *Аннары барысы да йокы бүлмәләренә таралдылар.* К.Насыйри. *Якуб каударланып торды, ашыгып, йокы бүлмәсенә керде, ут алды.* М.Хәбибуллин. *Үзе турында сүз сөйләшүне җене сөймәс Гөлзар шунда ук йокы бүлмәсенә кереп бикләнде.* Р.Хисмәтуллин

**ЙОКЫЛЫ** с. 1) Йокы баскан яки йокысы туймаган, йокыдан уянып җитмәгән. *Әйтерсең сүз берләшкәннәр: һәммәсе, йокылы күзләрен тырнап ача-ача, урыннарыннан кузгалып китми тора.* Г.Ибраһимов. *Йокылы тавышлы нindiдер хатын-кыз сыерына, сарыкларына кычкырды.* Н.Фәттах

2) *күч.* Сәяси эшчәнлектә катнашмаган, аңсыз һәм пассив булган. *Үз түбәсендә кара болытның куерганын, яшен ялкыннары уйнавын күргәч, татарның авыр йокылы катламы да сискәнде.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Хәрәкәтсез, җансыз, тынлык урнашкан. *Йокылы урам*

**ЙОКЫЛЫК** *и.* 1) Яшь баланың башында була торган сары төстәге кутыр

2) Кайбер яңа туган балаларның аркасында була торган чәчсыман каты төк

3) *диал.* Савыт-саба стенасына ябышып каткан калдык-постык; кырындык, касмак

**ЙОКЫЛЫ-УЯУЛЫ** *рәв.* **1.** Ярым йоклап, ярым уяу хәлендә булып, йоклар-йокламас. *Төнне йокылы-уяулы уздырган Җәмил, таң атуга, бала тудыру йортына ашыкты.* Н.Әхмәдиев. *Йокылы-уяулы яткан Рухия сискәнеп сикереп торды.* Г.Гыйльманов. *Шулай йокылы-уяулы яттым-яттым да, кешеләр уянып йөри башлагач, палубага чыктым.* Х.Сарьян

**2.** *с. мәгъ.* Йокыдан арынмаган, йоклап китеп барган; йокы белән өнне аера алмаган. *Шулай йокылы-уяулы хәлдә утырганда, кемдер тәрәзәгә чиртте.* К.Нәҗми. *Калган дүрт патронымны йокылы-уяулы кеше сыман аттым.* Г.Тавлин. *Тирә-юньдә шикле авазлар юк, әлегә әтәч тавышлары да ишетелми, тик йокылы-уяулы этләрнең андасанда гына өргәләп алулары колакка чалынгалап куя.* Җ.Рәхимов

◊ **Йокылы-уяулы халәт** Ваемсыз булу, йоклап йөрү. *Алсу кебек язмышны үзгәртергә тырышып бәргәләнә, «соры таш стена»га килеп бәрелеп, тормышка булган өметен җуеп, йокылы-уяулы халәттә, ягъни «психологик кома халәтендә», гомеренең соңгы сәгатьләре сукканны көтеп ята.* А.Шәмсутова

**ЙОКЫМСЫРАТУ** *ф. з.-сыз.* Йокыны китерү, йокыга изрәтү, оету. *Мондый дарулар, йокымсыратып, авырту газапларын бассын өчен эчелә дә!* Р.Вәли. *Бертөслелек – хәтәр нәрсә, кешене ул йокымсырата, чарланасы уй-хисләрен читлектә бикләп тота.* Р.Низами

**Йокымсырата башлау** Йокымсыратырга тотыну. *Аяк табаннары гел басып торып, гел йөреп кызышканнар һәм сызлап гүлиләр иде. Утыру белән мәлҗерәтә, йокымсырата башлады.* А.Гыйләҗев

**Йокымсыратып алу** Кыска вакыт эчендә, бераз йокымсырату. *Башым йомшакка тиюгә, бераз йокымсыратып алды да базарда ишеткәнем, яңадан колак төбемдә яңгырап торган кебек, күңелемне тынгысызларга тотынды.* З.Фәйзи

**Йокымсыратып җибәрү** Кинәт, искәрмәстән йокымсырату. *Балтыйк өстеннән искән әкрен җил белән ниндидер йод исе катыш тозлы --- һава килеп, үзенең татлы җиңеллеге, сәрхуш иткеч рәхәтлеге белән аны йокымсыратып җибәрде.* Ш.Маннур

**ЙОКЫМСЫРА́У** *ф.* **1.** 1) Тынычланып йокыга талу, оею, изрәү; йоклый башлау. *Ә хәзер ул әнә арбада борыны белән төртелә-төртелә йокымсырап бара.* Н.Дәүли. *Моның өчен онытылу ---, йокымсырау фарыз.* И.Низамов. *Бер саташу, утырган җирдән йокымсырап төшләнү генә булды, ахрысы, бу.* Р.Фәизов

2) *күч.* Шау-шу, хәрәкәт басылып, тынып калу; җансызлану, тынычлыкка бирелү (табигать күренешләре турында). *Хәзер менә бөтен тирә-як йокымсыраган кебек күренә.* Г.Бәширов. *Кайчагында очырып алып китәрдәй җил чыга, икенче көнне табигать аны йокымсырап, талыгып кына каршы ала.* Туган тел китабы

**2. йокымсырап** *рәв. мәгъ.* 1) Әкрен генә, ашыкмыйча. *Керосин лампасы һаман бер көе йокымсырап яна.* Ф.Шәфигуллин

2) *күч.* Бернәрсә белән кызыксынмыйча, ваемсызланып; үз эченә бикләнеп. *Ул күп вакытта йокымсырап йөри иде.* Г.Камал

**3. йокымсыраган** *с. мәгъ. күч.* Сүлпән, әкрен, пассив (кеше турында). *Минем карашымда, мондый йокымсыраган, салмак кеше озак яши алмас, хәрәкәт яраткан заманыбыз андый кешеләрне онытыр, дигән фикер туган иде.* Г.Кутуй

**Йокымсырап алу** Кыска вакытка йокымсырау. *Айсылу бассейн янындагы гамакта бераз йокымсырап ала.* Ф.Яруллин

**Йокымсырап бару** Акрынлап, азазлап йокымсырау халәтенә керү

**Йокымсырап йөрү** Һәрвакыт йокымсыраган халәт кичерү. *Бер тынар, басылыр күңел, йокымсырап йөри торган көн килер.* Ш.Галиев

**Йокымсырап калу** Ниндидер сәбәптән, тышкы тәэсирдән, билгеле вакыттан соң йокымсырау. *Бөтен тәнегез рәхәтләнеп, йокымсырап кала, эчке борчуларыгыз бетә.* Н.Хәсәнов

**Йокымсырап китү** Бераз, бернికадәр, искәрмәстән йокымсырау. *Тавыш үзенекен итте, әби утырган җирдән оеп, йокымсырап китте.* Р.Низамиев. *[Дневальный] Хат укыган җиреннән йокымсырап киткән.* М.Юныс

**Йокымсырап тору** Әле, хәзерге вакытта йокымсыраган хәлдә булу. *--- иреннәрен салындырып, берничә ябык ат йокымсырап тора.* Г.Бәширов

**Йокымсырап яту** Берәр урында йокымсыраган халәттә булу. *Моны аңы, акылы түгел, бик тирәндә йокымсырап яткан горурлык хисенә буйсынып эшләде [хатын].* Р.Кәрами

**Йокымсырый башлау** Йокымсыраргa тотыну. *Көндез тимер мич кебек кызган табигать әкрен генә үзенә салкынлык җыя: агачлар йокымсырый башлаганнар, үләннәргә елтыр чык төшкән.* Р.Сибат

**Йокымсырый бирү** Бераз йокымсырау халәтендә булу, шул халәтне дәвам итү. *Гөлчибәр карчык, борынгыча эшләнгән сәке өстенә ашъяулык җәеп, бар булган ризыгын, тәм-томын шунда тезеп, гадәтенчә йокымсырый биреп, аякларын йөзлек буйлап сузган килеш, ашыкмый гына төшке чәен эчә иде.* Д.Бүләков. *[Малай] Ничек оеп утырган булса, шул хәлендә өнсез генә йокымсырый бирде.* Р.Низамиев

**Йокымсырый төшү** Бераз йокымсырау

**ЙОКЫМСЫРАУЛЫ** *с.* 1) Йокымсырау хәлендәге, ярым йокылы, йоклар-йокламас. *Ул [Фатыйх] хатынының йокымсыраулы, аптыраулы йөзенә карап: – Бәлки, сиңа табибка күренергә кирәктер, матурым, – диде.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Җансыз, хәрәкәтсез; табигатьтә яшәеш дәвере тукталган. *[Сәет:] Һиһаять! Йокымсыраулы озын кышлардан соң җиргә яшәү-яшәрү килә, тормышның яме кайта...* Ф.Латыйфи

3) *куч.* Тормышны, яшәешне берьяклы гына сурәтләгән, яхшы якларны гына калку итеп күрсәткән; тыныч, бертөрле. *Аның исемен таныткан беренче повесте ук торгынлык дәверенең йокымсыраулы әдәбиятын сискәндергән яңа сүз дип кабул ителгән, хәтта бәхәсләр кузгаткан иде.* Р.Даутов

**ЙОКЫСЫЗ** *с.* **1.** 1) Аз йоклый торган, йокламый торган. *Мендәремнән башым күтәреп: «Йокы, – димен, – миннән кит әле. Ярты гомер уза йокыда, --- – Мин йокысыз булып яңадан Туар идем, килсә көчемнән».* Д.Сирай

2) Йокламыйча үткәргән; уйланып, газапланып чыккан. *Йокысыз төннәрдә уйлап табылган һәм күңел беркеткән бердәнбер планы, баш китәрлек вакыйгалардан башны саклап калу чарасы шул иде аның.* К.Нәҗми. *Дөрес, ул байтак михнәт чикте, аңа ач та йөрергә, дер-дер калтыранып, йокысыз төннәр дә уздырырга туры килде.* Г.Кутуй

**2.** *рәв. мәгъ.* Йоклый алмыйча яки йокламыйча. *[Ялтадан Моратның үлүе турында хәбәр килгәч] Күпме төннәрне йокысыз үткәрдем, мендәремнән күз яшем кипмәде.* И.Салахов. *Мансурның төннәре әнә шулай йокысыз узды, иҗат газабында узды.* Хәйдәр

**ЙОКЫСЫЗЛЫК** *и.* 1) Аз, начар йоклау, йоклый алмау. *Төннәрен, йокысызлыктан җәфаланып, гел тышта йөренәсең.* Н.Гыйматдинова. *Ул [әби] безгә йокысызлыктан зарланды. Ә без аңа йокы таблеткасын эчерттек.* Д.Салихов

2) Бөтенләй йокламау, йокларга вакыт тапмау. *Туктаусыз чабудан, йокысызлыктан, яңгырдан бер дә кеше төсе калмады.* Г.Ибраһимов. *Йокысызлык белән кичләрен, һәм ул тойды йөрәк төпләрендә яшьлегенең ашкын хисләрен.* Ш.Маннур. *Черек күл буена алып китәләр дә, төне буе аяк өсте тотып, сорау алалар. Атналар буе шул хәл, йокысызлыктан тәмам исереп, аң бетә башлый.* М.Галиев

**ЙОКЫЧАН** *с.* 1) Йокларга ярата торган, күп һәм кат-кат йоклый торган. *Дәртсез егет йокычан булыр.* Мәкаль

2) *куч. к.* **йокылы** (*3 мәгъ.*)

**ЙОКЫЧЫ** *с. сөйл. к.* **йокычан** (*1 мәгъ.*). *– Бу йокычы [аю] безне азыктөлексез калдырып куймасын тагы, – диде Межаков.* И.Хуҗин

**ЙОКЫЧЫЛ** *с. сөйл. сир. к.* **йокычан** (*1 мәгъ.*)

**ЙОКЫ-ЯЛ** *җый. и.* Йокы һәм һәртөрле ял. *Яуда эләккән контузиясен дә, мина кыйпылчыклары кереп тулган сызлаулы аяк-кулларын да санга сукмагандай, бирелеп, йокы-ялын җуеп эшләде.* Ә.Сәйфетдинов. *Төн димәде, көн димәде, йокы-ял белмәде, олы яу кубуын хәбәр итүче чапкындай, алашасын куды да куды.* Җ.Рәхимов

**ЙОЛА** *и.* 1) Халыкның яшәү рәвеше, тормышы, хуҗалык итү үзенчәлеге, дине белән бәйләнешле рәвештә борынгыдан кереп урнашкан тәртипләр, гореф-гадәтләр. *Кайбер халыкларда шундый йола да бар бит: кызлар бертөрле йөртә чәчне, хатыннар икенче төрле...* М.Маликова. *Беләсеңме, кыргызларда «кияү егете эдельвейсләр бүләк иткән кәләш кенә бәхетле була» дигән йола бар икән.* Ә.Мушинский. *Хатын-кызлар Сараның бармакларын онга тыгып, төрле йолалар үтәп маташтылар.* М.Галиев

2) Җәмгыять, коллектив тарафыннан кабул ителгән, гадәткә кереп киткән күренеш, тәртип, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр. *Бу картларның бер дә ялгыштырмыйча үтәп бара торган изге бер йолалары бар иде, ул – туган көн.* М.Мәһдиев. *Бу куштанлык та, тәлинкә тоту да түгел – тантана йоласы шулай куша.* В.Юныс. *Комсомол эшендәге кешеләр арасында язылмаган, әмма мәҗүси кануннар шикелле, мәҗбүри үтелергә тиешле йолалар яши.* Т.Галиуллин

◊ **Йоласына җиткерү** *к.* **йоласын китерү**. *Барысы да йоласына җиткезеп эшләнгән.* Ф.Хөсни. **Йоласын китерү** Гореф-гадәт таләп иткәнчә, йоланың бөтен таләпләрен үтәп башкару. *Хуҗа үзе дә утырып алгач, йоласына китереп, йорт-җиргә иминлек теләп, дога кылдылар.* Җ.Рәхимов. *[Тәзкирә:] Мине сорарга авылга кайтасың. Бөтен йоласын китереп, әтиләрдән сорыйсың.* Р.Кәрами

**ЙОЛАК** *и. иск.* Корбан. *Кымызны кам аз-азлап кына утка сибә: утка йолак бирү йоласын башкара.* Н.Фәттах

**ЙОЛАЛА́У** *ф. сөйл.* Йола буенча эш итү, кабул ителгәнчә, гадәттәгечә башкару. --- *аннан әллә нинди үләннәр, кипкән тамырлар, кош канатлары җыеп кайталар, әле, үзләре генә белгән йоланы йолалап, Санияләрнең капка төпләренә, ишегалларына көл сибеп чыгалар...* Г.Гыйльманов

**ЙОЛАЛЫК** *и. сир.* Йола булу, йолага туры килү. *Безнең көннәрдә аларның [могҗизалы хәрәкәтләрнең] йолалык, магик вазифалары бөтенләй онытылган.* Ф.Урманче

**ЙОЛА́ЧА** *рәв.* Кабул ителгән йола буенча, йола таләп иткәнчә. *Угланның үзләрен олылап, «ил агалары» дип эндәшүе, борынгы йолача тутырып исәнләшүе аларның күңеленә хуш килде.* Ф.Латыйфи. *Әмма Нифа барысын йолача кыландыра. Ишектән кергәндә, аңа калак белән бал каптырды.* Х.Камалов

**ЙОЛАЧЫ** *и.* Йолаларны яхшы белүче, аларны башкаручы; гореф-гадәтләрне саклаучы. *Ак җайдаклар төркеменең башында, озын саплы ал байрагын югары күтәреп, ыруның өлкән йолачысы Ут-таш кам бара иде.* Н.Фәттах

**ЙОЛДЫЗ** *и.* 1) Табигате белән кояшка охшаган, кызган газдан гыйбарәт шар формасындагы, төнлә гади күзгә күктә җемелдәп торган якты нокта рәвешендә күренә торган күк җисеме. *[Йолдызларның] Диңгезгә төшкән шәүләләре диңгезнең төбенә куәтле һәм гаять матур электрик лампаларын меңәрләп яндырып куйган шикелле итеп күзләрне алдый иде.* Ф.Әмирхан. *Ниһаять, бик еракка китеп кояш та бата, дала өстенә бик тиз караңгылык иңә, ә күктә, төнгелеккә бер җиргәрәк җыелган кыргыз малларыдай, бихисап йолдызлар калка.* Ә.Еники. *[Мисырлылар] Нил елгасының ташуы Кояш чыгар алдыннан гына офыкта Сириус йолдызы калкуына туры килгәнлеккә игътибар итәләр.* Астрономия

2) Биш почмаклы очлы башлы чыгынтылары әйләнә буенча бердәй ераклыкта урнашкан геометрик фигура;

шундый фигура формасындагы геометрик җисем

3) Гомумән, шундый формадагы, шуның сурәте төшерелгән предмет. *Соңгы сүзе итеп, каберемә кызыл йолдыз утыртырсың, диде дә белзгемә ятып җан бирде, мескенкәем.* М.Фәйзи

4) Фуражкага, бүреккә һ.б.га беркетелә торган шундый формадагы хәрби значок; кокарда

5) Шундый ук формадагы, хәрби дәрәҗәне күрсәтә торган кечкенә билге. *Погоннарында ике йолдыз ---, күкрәгендә – орденнар.* И.Гази. *Разведрота командиры Ильинга үз вакытында капитан йолдызын бирделәр.* З.Хөснияр

6) *тар.* Совет чорында башлангыч сыйныф укучыларының октябрят булуын белдергән, шундый формадагы аеру билгесе; значок. *Октябрятлар зәңгәр киемнән. Түшләрендә кызыл йолдыз бар.* М.Җәлил

7) Кызыл Йолдыз орденының яки Советлар Союзы героеның махсус билгесе. *Батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз алды.* Г.Ибраһимов. *Пиджак кайтармасында, хәзер инде хәтерләмим, Алтын Йолдыз ничәү иде: берәүме, икәүме?* М.Мәһдиев. *Күкрәгенә бер Кызыл Йолдыз, ике Дан ордены, берничә медаль һәм яралану билгеләре таккан.* А.Шамов

8) Тимернең тимергә, ташның ташка бик каты бәрелүеннән, ышкылуыннан барлыкка килгән ут кисәкләре; очкын. *Аннан [казан астыннан], кечкенә йолдызлар төсле очкын кисәкләре чәчрәтеп, куе төтен бөркелә иде.* К.Нәҗми. *Кискечләр үтмәс, сынык, җитмәсә, гади корычтан ясалган, кайракка тидерү белән аксыл йолдызлар чәчрәтәләр.* А.Расих

9) Мәктәпнең башлангыч сыйныфларда «бишле»гә тиң билге. *Алмагөл бүген мәктәптән кызыл йолдыз алып кайтты бит.* И.Салахов

10) *күч.* Көч, рух, илһам биреп торучы чыганак. *Син [Фирүзә] – алдагы тормышымның ышанычлы йолдызы.* Г.Үзиле. *Рабига, Рабига... Әйе, Әхмәтсафаның күңелен биләп алган йолдыз ул.* Ф.Сафин. *Каләмдәшләребез иҗатындагы кимчелекләрне эзләү белән мавыкмыйча, алар әсәрләрендә җемелдәгән рухият йолдызларын күреп алып, аларның балкып яну мохитен киңәйтик!* Ә.Сәхапов

11) *күч.* Язмыш, бәхет; уңыш чыганагы. *Ерактагы якты йолдызын эзләп чапкан бу батыр егет, хәзер, инде үз «йолдызын» тапкач... аптырады да калды.* Ф.Хөсни. *Ә хәзер, әйдә, үз-үзеңне сайлау, язмышың йолдызын билгеләү турында сөйләшик.* Р.Низамиев

12) *күч.* Берәр өлкәдә зур уңышка ирешкән, күренекле, дан казанган кеше. *Арслан да шул минутта әлеге киноны карыйдыр кебек тоелды аңарга, карыйдыр һәм әлеге кино йолдызына карап авыз суын корытадыр.* Р.Мөхәммәдиев. *Гаспралы – татарның ничә гасыр буе мең газап кичереп көтеп алган якты йолдызы.* Т.Әйди. *Сәнгатебез күгендә кабынган тагын бер йолдыз белән, әйдәгез, якыннанрак танышыйк әле.* Г.Шәйхиева

13) *күч.* Тар даирәнең алдынгысы, яме, горурлыгы (кеше турында). *Иң мактаулы бакчачыга, Колхоздагы йолдызга.* Ф.Кәрим. *Яңа урында яңа йолдызлар булыр, тик барыбер без сезне оныта алмабыз.* И.Гази

14) *күч.* Бик каты итеп башны бәргәч, күз аллары караңгыланып барлыкка килгән нурлы утчыклар

15) *күч.* **йолдызым** *тарт. форм.* Яратып, иркәләп эндәшү сүзе. *Ах җанашларым, йолдызларым!* Ф.Әмирхан. *Газинур, бәгырем, өмет йолдызым, кайт инде тизрәк.* Г.Әпсәләмов. *[Дүшән:] Бәхетең синең укудан булсын, якты йолдызым!* Ч.Айтматов

◊ **Йолдыз атылу** Күк җисеменең үз артыннан якты эз калдырып атмосферадан узуы. *Төн, тынлык, сызылып кына йолдыз атылып китә, әмма кәрванчылардан селкенгән кеше дә булмый.* Ә.Еники. *Атасы уянды, сарай өстенә чыкты. Казага каршы, ул чыккан вакытта күктән йолдыз атылды.* Мәҗмугыл-хикәят. *Аяз төннәрне йолдыз атылу күренеше безнең игътибарны еш җәлеп итә.* Астрономия. **Йолдыз җиле кагылу** Мактану, горурлану, үз-үзеңне күренекле кеше итеп хис итү. *Рәдиф булсын да аңа «йолдыз җиле» кагылмасын имеш.* С.Хәким. **Йолдыз күрсәтү** Уен: берәү идәнгә ятып, җиң аша түшәмгә карый, икенчесе аның йөзенә сиздермичә генә җиң очыннан су коя. **Йолдызлары туры килү** Холкы, характеры белән бер-берсенә тәңгәл булу. **Йолдызлар юкка гына кабынмый** Бер сәбәпсездән теге яки бу мәсьәлә турында сүз кузгатылмый. *Шагыйрь бит әнә, йолдызларны юкка гына кабызмыйлар, дип яза.* Т.Галиуллин. **Йолдызлы булу** Дан казану, уңышка, дәрәҗәгә ирешү; бәхетле булу. **Йолдыз санау** 1) Уен: кичәдә җәза бирелгән егет үзе теләгән кызны сайлап тышка, ишек төбенә алып чыга, шунда аңа әйтәсе сүзен әйтеп, булдыра алса, үбеп тә керә. *Гел гармун тотып утыргач, кызларегетләр бергәләп уйный торган күмәк уеннарда катнашып та, «кәҗә ябарга» яки «йолдыз санарга» чыгып та булмады.* В.Нуруллин; 2) Бер нәрсә турында да кайгырмыйча, гамьсез йөрү, вакытны бушка уздыру. **Йолдыз тоту** Хыялый эш-гамәлләр кору, тормышка ашмый торган нәрсәләр белән хыяллану. **Йолдыз төшү** Теләк тормышка ашу, максатка ирешү. *Бик теләгән кешенең учына йолдыз төшә, диләр. Безнең әти дә, күрәсең, бик теләгәндер инде, аның да учына йолдыз төште!* Ф.Ярullин. **Йолдыз яңгыры** Бик күпләп йолдыз атылу күренеше

**ЙОЛДЫ́ЗАК** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан, ак төстәге таҗчыклары икегә аерылып чәчәк ата торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **звездчатка**. *Йолдызак үләне иртән чәчәкләрен йомса, көндез яңгыр булачак.* А.Девятков, А.Макаревич

**ЙОЛДЫЗАРА** *с.* Йолдызлар арасындагы; йолдызлар арасында була торган. *Бүгенге көндә галимнәр, Кояш һәм планеталар бөтенесе берьюлы йолдызара матдә – тузан һәм газдан барлыкка килгән, дип уйлыйлар.* Табигать белеме

**ЙОЛДЫ́З КАШКА** *и.* Маңгаенда ак тап булган ат. *Яу кырына килгән Уралдан, Йолдыз кашка йөргән иң алдан.* И.Юзеев. *Кайгы баскан башым күтәреп Карадым мин йолдыз кашка атка.* Ф.Кәрим

**ЙОЛДЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Йолдыз формасын алу

2) Яктырып җемелдәү. *Әллә тәрәз уты йолдызлана? Кап-караңгы авыл читендә.* Зөлфәт. *Сәнгать --- салкын клубларның зәңгәр яшькелт боз каткан тәрәзәләрен, йолдызланып торган стеналарын санга сукмый.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Очкынлану, нурлану, нур чәчеп балку. *Нәфрәтләнү, хәтерләүләр, ачынулар белән дөньядан үтәчәк юлым яралы кавышу һәм аерылулар белән йолдызланган.* Г.Тукай

**ЙОЛДЫЗЛА́У** *ф.* **1.** Йолдыз рәвешендә ясау, күп итеп йолдызлар төшерү

**2. йолдызлап** *рәв. мәгъ. физ.* Өч фазалы ток чылбырында статор кәтүкләренең ахыргы очларын генераторның (яки трансформаторның) нуль ноктасы, баш очларын электр челтәре белән тоташтырып. *Йолдызлап тоташтыру*

**ЙОЛДЫЗЛЫ** *с.* 1) Йолдызлар (*1 мәгъ.*) белән капланган, йолдызлар балкып торган. *Икәүдән-икәү генә кыргый үрдәкләрне сискәндереп су коенулары, кочак-кочак төнбоек чәчәкләре, ай нурында сикерешеп уйнаган балыклар, йолдызлы зәп-зәңгәр күк йөзе дисеңме.* Р.Мөхәммәдиев. *Йолдызлы күк йөзе буйлап, бик югарыдан, төнге бомбардировщиклар үтеп китәләр.* Г.Әпсәләмов

2) Йолдыз (*4 мәгъ.*) беркетелгән. *Ул баштанаяк хәрби киемдә: итек, яшькелт чалбар, гимнастёрка; каешының җиз йолдызлы каптырмасы ялт-йолт итә.* И.Салахов. *Данилов аларның ротасында беренче тапкыр килеп күренгәндә, аның өстендә һәйбәт күн пиджак, башында кызыл йолдызлы кара күн фуражка иде.* Г.Бәширов

3) Йолдыз (*4 мәгъ.*) төшерелгән, йолдыз ясалган; йолдыз чигелгән; йолдызлар (*4 мәгъ.*) белән бизәлгән. *Зәңгәр күкне ерып, дошман ягына таба кызыл йолдызлы самолётлар оча.* Р.Мостафин

4) *тех.* Йолдызча формасындагы, төрле ягыннан чыгып торган тигез тешләре булган. *Йолдызлы тәгәрмәч*

5) *спорт* Төрле яктан бер ноктага килә торган. *Йолдызлы йөзеш*

6) *күч. шигъ.* Якты, бәхетле; уңышлы

◊ **Йолдызлы су** Коньяк

**ЙОЛДЫЗЛЫК** *и.* 1) *астр.* Бер исем астына берләштерелгән йолдызлар төркеме. *Сөмбелә йолдызлыгы – җәйнең таҗы.* Җ.Рәхимов. *Күк йөзе 88 йолдызлыкка бүленгән.* Астрономия. *Йолдызлыклар турында төрле халыкларның үз мифлары һәм риваятьләре яшәгән, йолдызлыкларны һәр халык үзенчә атап йөрткән, шул ук вакытта төрле халыкларда йолдызлыкларның саны да төрлечә исәпләнгән.* Астрономия

2) *күч.* Берәр өлкәнең (коллективның) танылган, талантлы һәм мәшһүр затлар төркеме. *Фәрит Фәтхуллин йолдызлыгыннан бишенче герой булган Григорий Коцебаны полк очучылары, бигрәк тә яңарак килгәннәр, Чистяков белән еш бутыйлар.* Р.Ибраһимов. *Ул [Нур Баян] – легендар вә бөек Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуйлар йолдызлыгыннан!* М.Сафин // Үзен шундый бөек затка санау. --- *яшьләр арасында масаю, даһилык, йолдызлык чире шактый еш күренә.* Р.Низами

3) *күч. сир.* Диалект, шивәләр төркеме. *Теләсә нинди телнең үз сөйләмнәре йолдызлыгы бар.* А.Хәлим

**ЙОЛДЫЗНАМӘ** *и.* 1) Чынбарлык күренешләрен йолдызларның торышына карап аңлата торган китап (күрәзәлек итү өчен кулланыла). *Бәхет юрап йолдызнамә ачтыгызмы? Уегызда үткәннәрдән качтыгызмы?* Ф.Мөслимова

2) Йолдызнамәче тарафыннан йолдызлыкларның һәрберсендә туган кешеләргә атап төзелә торган атналык, айлык, еллык фараз; *русчасы:* **гороскоп**. *Аерым бер кешегә йолдызнамә төзү өчен нәрсә кирәк?* Татарстан яшьләре

**ЙОЛДЫЗНАМӘЧЕ** *и. к.* **йолдызчы**. *Йолдызнамәче әллә нинди торбалар аша күк галәме, йолдызлар белән таныштырган.* Г.Хөсәенов

**ЙОЛДЫЗЧА** *и.* 1) *махс.* Чылбырлы тапшыргычта (мәс., танк, трактор чылбырында); тешле тәгәрмәч. *Сырлы, киң буыннардан җыелган авыр чылбырны – гусеницаны хәрәкәткә китерүче арткы тәгәрмәч, яисә, техник термин белән әйткәндә, ияртүче йолдызча, үз урыныннан ычкынып, читкәрәк күченгән булырга тиеш.* Н.Фәттах

2) *бот. к.* **йолдызак**

**ЙОЛДЫЗЧАЛЫ** *с.* Йолдызчасы булган. *Йолдызчалы тәгәрмәч*

**ЙОЛДЫЗЧЫ** *и.* 1) Йолдызларны өйрәнүче белгеч; астроном. *Йолдызчылар ул чорда киң таралган астролябия кебек прибордан файдаланганнар.* Р.Шәймәрдәнов, Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Йолдызларга карап күрәзәлек итүче; астролог. *Йолдызчылар бу хикмәтне Мөхәммәд галәйһис-сәламгә нисбәт иттеләр.* Ф.Яхин. *Мөгаен, йолдызчылар телендә бу көн балык көне булып, малай-шалайга бәхет вә сөенеч килә торган сәгатьтер.* Ф.Яхин

**ЙОЛДЫЗЧЫК** *и.* 1) *кеч. к.* **йолдыз**. *Киек Каз Юлы!.. Ерактан гына шулай томанлы бер тасма кебек күренә ул. Үзендә исә әллә никадәр эреле-ваклы йолдызлар, йолдызчыклар...* А.Гыйләҗев. *«Бишле» алды, йолдыз такты һәр малай һәм һәр кызчык. Пионерда – кызыл галстук, Октябрятта – йолдызчык.* Р.Батталов

2) *махс.* Китапларда, кульязмаларда астөшермә өчен кулланыла торган билге. --- *гарәп-фарсы алынмаларының сүзлекчәсе бернинди ишарәсез, Тукайның үз искәрмәләре һәм төзүчеләрнең кайбер шигъри юлларга аңлатмалары йолдызчык белән күрсәтелә.* З.Мөхәммәтшин

3) *махс.* Текстның төп өлешен йомгаклау фикереннән аеру билгесе

4) *махс.* Катлаулы чыгыр яки йөк күтәрә торган механизм детале; *к.* **йолдызча**. *Комбайн частьлары салынган капчыкны алмаш-тилмәш күтәреп барабыз. Капчыкта – ике кечкенә тәгәрмәч, берничә йолдызчык, шөрепләр, гайкалар.* Р.Хафизова

5) *зоол.* Умырткасызлар классына караган, энәтиреләләр тибындагы, тиресе өске яктан известь энәләр белән капланган, тышкы формасы белән йолдызны хәтерләткән, барлык диңгезләрдә дә очрый, диңгез төбендә шуышып хәрәкәт итә, моллюсклар белән туклана торган диңгез хайваны. *Ашыкмый гына диңгез йолдызчыгы шуыша, һаваланып кына мыеклы лангустлар китеп бара, кырын-кырын гына краб үрмәли ---.* Балачак китабым

6) *тар.* Совет чорында: мәктәптә октябрят оешмасында кечкенә бүлек; звено. *Безнең «йолдызчык» бүләк әзерләү буенча беренче урынга чыгарга сүз бирде.* Г.Мөхәммәтшин

7) Хайваннарның маңгаенда төп төстән аерылып торган ак йон үскән тап; кашка. --- *безнең авыл кешеләре, олысыннан кечесенә кадәр, маңгаенда нәни генә ак йолдызчыгы булганга, Филипсонның яраткан этенә Акмаңгай дип эндәшкәннәр.* Ф.Шәфигуллин. *Циркның ат абзарында колын дөньяга килде. Төсе белән әнисен хәтерләтә иде ул: үзе шоколад төсендә, маңгаенда ак йолдызчыгы бар, ә койрыгы белән ялы кара.* А.Мельников

8) *күч.* Кар бөртекләре (йолдызлар кебек җемелдәп торуына ишарәләп әйтелә). *Акрын гына исеп куйган җил, каралты-кура түбәсендә яткан карны каз канаты белән сыпырып кына алгандай, нәни йолдызчыклар сибә.* Р.Мөхәммәдиев

**ЙОЛДЫРУ** *ф. сир.* Бетерү, юкка чыгару (гаепне, гөнаһны һ.б.). *Үлгән кешенең гөнаһларын йолдыру өчен, өчесе узганчы, гүр сәдакасы бирелә*

**ЙОЛКУ** *ф.* **1.** 1) Үсемлекне, гомумән, үсеп утырган берәр нәрсәне тамыры белән тартып чыгару яки аның яфрагын, чәчәген һ.б. өзеп алу. *Билләр сызлый, үрмәләп йөри-йөри, тез башлары кызарып чыга, тырнак астына үзле каты балчык кереп тула, ә син һичнигә карамыйсың – узыша-узыша чүп үләне йолкуыңны беләсең.* Р.Мөхәммәдиев. *Илбарыс бер чәчкә өзеп ала, һәм алар чәчкә таҗларын йолкый-йолкый язмышларын юрыйлар.* М.Хәбибуллин // Төбе-тамыры белән тартып алу, кубарып ташлау (мәс., агачны, куакны, бағананы һ.б.ны)

2) Чистарту өчен, кош-кортның йонын, төкләрен тартып-тартып алу. *Әнкәләре, тар ушатка җәйләп утырган көе, бик эшлекле кыяфәт белән җиңнәрен сызганып җибәреп, тавык йолкый иде.* Н.Фәттах. *Каз өмәсе, ул --- күмәкләшеп эшләнгән, каз йолку бәйрәм төсен алган.* Ф.Зарипова

3) Кискен хәрәкәт белән тарту, тартып-тартып алу. *Фатыйма, иреннәрен бөрештереп: – Мин сиңа барыбер Сәфәргалине бирмим! – дип ажгырды. – Бирмим! Йөзеңне тырныйм, чәчеңне йолкам, барыбер бирмим! Ул – минеке!* Н.Гыйматдинова. *Бу юлы Миңниса җиңги бер сүз дә дәшми почмакка барып утырды һәм, ачу белән кабасындагы сүсне йолка-йолка, сүзе ишетелер-ишетелмәс мыгырданды.* Ә.Фәйзи. *Моның өчен, саламны йолкып, куыш авызын тирәнәйтергә кирәк иде.* Р.Низамиев

4) Беркетелгән, тегелгән һ.б.ш. нәрсәне тарту, сөйрәү, өзеп чыгару. *Пәрдә бирешмәде, ул тагын тартты, пәрдә тагын ябылмады, ачу белән өченче кат йолыкканда, өске чите ычкынып китеп, бөҗрадан чыкты.* С.Шәмси. *Кызларның колакларыннан ите-ние белән алкаларын йолкыйлар.* Аргамак

5) Тарткалау. --- *ялгыз башың, ник шунда пәйгамбәр булмыйсың, берни майтара алмыйсың. Йә йолкып төшерәләр, йә тибеп очыралар ---.* Р.Мөхәммәдиев

6) Терлекнең, кош-кортның үлән башларын гына ашавы; чемченү. *Таллыклар буенда аяклары тышауланган яки өзәңгеләре бәйләнгән атлар чирәм йолкый.* В.Имамов. *Тирә-якта, бәпкә үләннәрен йолкып, төркем-төркем казлар йөри.* А.Гыйләҗев

7) *күч. сөйл.* Кемнеңдер байлыгын, мал-мөлкәтен көч белән үзләштерү; талау, ирексезләп алу. *Йолкырга дип барды, йолкынып кайтты.* Мәкаль. *Кемнәр йолкый, кемнәр йоклый. Дөнья бу, абзыкаем.* Ш.Галиев // Ансат, җиңел ысул белән файда, табыш алу. *Колхоз рәисен үзе алдында «булдыклы» дип мактаган, «дус» дип ышаныч казанган икенче берәү, баксаң, рәистән ит-май йолку өчен шулай икейөзлеләнә икән...* Х.Сарьян

8) *күч. сөйл.* Төрле сораулар белән аптырату, йончыту, бик еш борчу. *Бүген [Мансурны] газета кешеләре бик йолыктылар, алардан качып йөрмиме икән?* И.Гази

9) *күч.* Авыр хәлдән чыгарга ярдәм итү, саклап калу, йолып калу. *Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?* Г.Тукай

10) *күч.* Юкка чыгару, ахырынача бетерү. *Ачудан шашкан апа килер дә ялган идиллия пәрдәсен бер селтәнү белән һәм бер алама сүз белән йолкып ыргытыр.* Ә.Баянов. *Ул хисләрне йөрәкләрдән Никтер тормыш йолкыды.* Н.Мәдияр

11) *күч.* Төрле якка тарату, туздыру; көчле җилфердәтү. *Нинди давыл бу, җил?.. Чәчләрне тузгыта... Йолка...* Г.Гыйльманов

12) *күч.* Каршы көрәш алып бару, тар-мар итү, юк итү. *Аларга сугышта да бер фронтта булырга туры килде һәм, сугыштан соң тирә-юньдәге помещикларны йолкыганда да, бертигезрәк катнаштылар.* Ш.Камал

13) *күч.* Кеше сүзен, фикерен, әйберен һ.б.ны өзек-өзек үзләштерү, әле тегеннән, әле моннан урлап алу. *Син инде, кайбер чиле-пешле композиторлар шикелле, көйләрнең башын моннан, ахырын тегеннән йолкып, шуларны гына сипләштереп чыгармассың бит!* Г.Бәширов

**2. йолкып** *рәв. мәгъ.* 1) Ашыгып, кабаланып, зур-зур кабып. *Фатыйма шунда ук, ике аягы белән басып, кечкенә тешләре белән йолкып --- ашый башлады.* Г.Гобәй

2) Сүзне сүзгә ялгамыйча, бер фикердән икенчесенә күчеп. *Карт белән бергә аның ике кызы башта, аннан йолкып, моннан йолкып, бер әйбердән икенчегә сикереп, күп нәрсә өстеннән үтеп сөйләштеләр.* Г.Ибраһимов

3) Артык нык тырышып, соң дәрәҗәдә ярсып

**Йолка бирү** Йолкуын дәвам итү, һаман да йолку

**Йолка тору** Бертуктаусыз аннан-моннан йолку, ничек тә булдыру. *Аннан-моннан йолка торгач, кирәк кадәр өй җиһазы да табылды.* И.Гази

**Йолка төшү** Бераз йолку

**Йолкый башлау** Йолкырга тотыну. *Тамагы ачыккан Рәмзия, тәкатьсезләнеп, әнисенең күлмәк итәгеннән йолкый башлады.* Р.Ишморатова

**Йолкый тору** Бер-бер артлы, туктаусыз һәрберсен йолку. *Усаллашты Вакыт, күрдек тагын: Ул әнинең соңрак төсләрен Һәм хисләрен, бәлки, китте*

*урлап, Йолкый торды чәчен, тешләрен.* Ә.Баян

**Йолкып алу** Көтмәгәндә, кинәттән кискен хәрәкәт белән йолку. *Ләкин сабыры бик тиз төкәнде, --- Котбый егетне йолкып алды һәм, аңлашырга дип, тышка алып чыгып китте.* М.Хәбибуллин. *[Бүреләр] Менә-менә артыбыздан куып җитәрләр дә безне, йөк өстеннән йолкып алып, ботарлый башларлар шикелле иде.* В.Нуруллин. *Хикәянең әһәмияте --- авторын, дөнья мәдәнияте шаукымыннан йолкып алып, милли җирлек, милли чынбарлыкка кайтарып бастырган.* Р.Рахмани

**Йолкып ату** *к.* **йолкып ташлау** (*1, 2 мәгъ.*). *Үз фатирыбыз була дигәндә шул якты өметне төбе-тамыры белән йолкып атсыннар әле!* Ә.Сафиуллин. *[Разыя апа] Карт куллары белән бу агулы тамырларны милләт тормышыннан йолкып атарга тели, үзе булдыра алганны эшләп калырга ашыга.* Мәгърифәт

**Йолкып бетерү** Тулысынча, барысын да, тәмамланганчы йолку. *Чәчен йолкып бетерә язганнар. Уң колагын тешләп өзгәннәр.* Р.Батулла

**Йолкып кую** Алдан йолкыган хәлгә китерү

**Йолкып ташлау** 1) Аз вакыт эчендә тиз-тиз йолку

2) *күч.* Тиз арада йолку, юкка чыгару. *Һәр бакчаның чүбе булган кебек, Йолкып ташлый торган кул була. ...Чистка комиссиясе бу чүпләрне Йолкып ташлый торган кул булды.* Һ.Такташ. *Чүп үләнен йолкып ташлау – фашистны йолкып ташлау ул. Ә фашистны йолкып ташлагач, сугыш бетә.* Г.Гобәй. *Шул сәбәпледер, бәлки, Марзияне күңелемнән тиз арада йолкып ташлый алдым.* А.Расих

**Йолкып тору** Һәрберсен, булган берсен һәрвакыт йолку. *Шуннан соң берничә ай дәвамында гөлне, үскән саен, биегрәк итеп таякка бәйләп, --- чәчәкләренең барысын да йолкып торырга кирәк.* Кәеф ничек?

**Йолкып чыгу** Башыннан ахырына кадәр рәттән йолку. *Хатыным көнләшеп бөтенесенең чәчен йолкып чыкты.* Татарстан яшьләре

**ЙОЛКЫЙ-ЙОЛКЫЙ** *рәв.* Йолкып, йолкып торган хәлдә. *Ул, гомумән, тирләп-пешеп, гүр газаплары кичереп, чәчләрен йолкый-йолкый язучыларны аңламый да, яратмый да.* А.Расих. *Казлар, чирәм йолкый-йолкый, ярдан ераклаша.* Р.Батулла

**ЙОЛКЫМ-ЙОЛКЫМ** *с.* Кисәкләрдән торган. *Шәһәр өстен киезләнеп беткән йолкым-йолкым болытлар томалаган.* Ә.Хәммәдишин

**ЙОЛКЫНУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **йолку**. *Офицерларның алтын-көмешле погоннары беррәттән өзелеп җиргә ташланды, маңгайдагы кокардалар йолкынып ыргытылды.* М.Гафури. *[Камалның] Бүген генә кынага манылган җирән сакалыннан --- бер тотам төкләр йолкынды.* К.Нәҗми. *Йөрәктән сагыш йолкынмый, менә шул ябыктыра.* С.Баттал

2) Кидерелгән, эләккән урыннан һ.б.ш. бәйлелектән ычкынырга тырышу. *Соры явыз чылбырда нишләргә белми, табан ялтыратырга ниятләп, ары йолкына, бире йолкына, ләкин юкка изалана, ычкына алмый.* Г.Тавлин

3) Киреләнү, карышу, киеренкелекле көрәш алып бару. *Этнең муенсасыннан алган ике-өч таза егет аны көчкә тыеп торалар: тартыла, йолкына, шашып өрә-өрә җылый иде ул.* М.Галиев. *Имәннең як-якка җәелгән тармаклары салмак кына аккан болытларга тотынып калмакчы була, киселеп бетмәгән үзәге шатыр-шотыр йолкына.* Н.Хәсәнов

4) Рухи кичерешләрдән газаплану, ярсу. *Иптәше төшеп җиткәндә, Гыйммран, тозакка эләккән җәнлек шикелле, акылдан шашып йолкына иде.* М.Юныс. *Кинәт тирән сагыштан, әрнүдән, йолкынудан, әллә ниткән бер сызланулы ләззәттән, билгесез бер сөенечтән хәтта елыйсы килеп китә.* М.Мәһдиев

5) *күч. сөйл.* Бөлү, ярлылану, талану. *Йолкырга дип барды, йолкынып кайтты.* Мәкаль

6) *күч.* Бик нык чыгымлану

**2. йолкынган** *с. мәгъ.* 1) Тузган, таушалган, сәләмә. *Әлеге кешенең йолкынган кыяфәтенә күзе төшү белән, ирексездән, кызның күңелен авыр тойгы басты, кәефе кырылды.* А.Сафин

2) Бөлгән, бөлгенлеккә төшкән, малмөлкәтен югалткан

**3. йолкынып** *рәв. мәгъ.* Кубарылып, кире кайтмаска дип, кире кайтырга урын калдырмыйча. *Себергә китәсе булу, дөресен генә әйткәндә, сөендерде мине. Болай төп-тамыр белән йолкынып киткәч, кабат кайтмабыз инде, җиргә, урманга бай Себердә нигезләнеп калырбыз, дип уйладым.* Ш.Маннур

◊ **Йолкынган каз кебек (төсле)** *к.* **йолкынган тавык кебек (төсле)**. **Йолкынган тавык кебек (төсле)** Тәмам бөлгенлеккә төшкән. **Йолкынып алына торган** Сәүдә тармагында еш сорала, тиз сатыла торган (товар турында). **Йолкырлыгы калмаган** *к.* **йолкырлык мамыгы калмаган**. **Йолкырлык мамыгы калмаган** Байлыгын, мал-мөлкәтен таратып бетергән; ярлыланган

**Йолкынып бетү** Бөтенләй йолкынган булу. *Гап-гади йолкынып беткән төзелеш оешмасының сүгенеп сөйләшә торган бер башлыгы.* Р.Зарипов

**Йолкынып калу** Нindидер вакыйгадан, сәбәптән соң йолкынган хәлгә килү. *Миләүшәнең бер уч чәче теге бәндә кулында йолкынып калды.* Ф.Яруллин

**Йолкынып чыгу** Бөтенләе, төбетамыры белән йолкыну. *Өянкеләр белән бергә Назыймның күкрәгеннән хатирәләр, истәлекләр дә йолкынып чыкты сыман.* Ф.Яруллин

**ЙОЛКЫТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **йолку** (*1 мәгъ.*)

2) Тикторыш хәленнән, урыныннан кузгату, җимерү

**Йолкытып ташлау** Көтмәгәндә, саксыз, аяусыз йолкыту, йолкытып юкка чыгару. *[Бульдозер] --- төбетамыры белән чишмә араларындагы куакларны, яшь агачларны йолкытып ташлый иде.* Г.Бәширов

**Йолкытып яту** Әле, хәзер, шушы моментта йолкыту. *Түбәнең калган ягын --- трактор белән йолкытып яталар иде.* Ә.Гаффар

**ЙОЛКЫШ** *с. гади с.* **1.** 1) *кимс.* Ярлы, хәерче; сәләмә киемле. *Ул,*

*битен умарта корты чаккан, кысык күзле, сипкелле борынлы, чәче машинка белән китәртелгән, кыска чалбарлы йолкыш малайга – миңа – ачу белән --- карап кына куйды.* А.Расих

2) Хәрабә хәлендәге, җимерек, туздан. *Йолкыш биналар*

3) Хәлсез, ябык, зәгыйфьләнгән. *Рәхимсез кышкы төннәрне җылы морҗа эчләрендә, кара мунча төнлекләрендә посып уздырган йолкыш чыпчыклар шул күлдәвекләрдә корымлы канатларын юа.* Г.Сабитов

4) *күч.* Абруйсыз, авторитетсыз, әһәмиятсез. *Юк кына йолкыш малайлар охраналы коттеджларда яши, «Мерседес», «Линкольн», джипларда чаба, иң чибәр кызлар белән үзе теләгән вакытта чит илләрдә, диңгез буйларында кәеф-сафа кора.* Т.Галиуллин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ярлы, фәкыйрь кеше. *Ходайбирде: «Авызын ачса, үпкәсе күренгән йолкышка бирердәй кыз юк миндә», – дигән җавап алып кайтты.* Җ.Рәхимов. *Ул, җыен гладиаторны, җыен колларны, брамат йолкышларны, бөлгән типкеләрне һәм дөньяда торырлык рәте калмаган гына түгел, артык яшәргә өмете дә калмаган җыен мөртәтне җыеп, явызлар бандасы корды.* Н.Исәнбәт

2) Төскә-биткә, буйга-сынга матур булмаган, сөйкемсез кеше. *[Сабит:] «Күр син аны, энекәшне, йолкыш кына дип йөрсәм, хатынның асылын эләктергән икән ләбаса!»* А.Гыйләҗев

**ЙОЛКЫШЛАНУ** *ф. гади с.* 1) Ярлылану, фәкыйрьләнү; бөлү

2) Җимерелү, искерү, таушалу. *Ана бәпкәчен күкрәгенә ныграк кысты, салам өстендә атналар буе аунап шактый йолкышланган төлке туны белән яхшылабрак каплады...* И.Сираҗи

**Йолкышлана бару** Торган саен ныграк йолкышлану

**Йолкышлана төшү** Тагы да йолкышлану

**Йолкышланып калу** Нииндидер сәбәптән, вакыйгадан соң йолкышлану. *Баштарак көязләнеп, кәперәеп, әллә кем булып кыланган милиционерларга ачуы килгән иде Җәмилнең, хәзер аларның суга төшкән тавык кебек йолкышланып калуларын күргәч, егетләрне кызганып куйды.* Н.Әхмәдиев

**Йолкышланып китү** Кинәт йолкышлану

**ЙОЛКЫШЛЫК** *и.* Йолкыш булу

**ЙОЛКЫШТЫРУ** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **йолку**

2) Төрле юллар белән юнәтү, табыштыру. *Аннары килеп, больница кадәр больницаны тегеннән-моннан йолкыштырып, урлаштырып, коры тәвәккәллек белән генә төзеп була микән ул?* М.Маликова

**ЙОЛТ-ЙОЛТ** *рәв.* Зур җитезлек белән, җәһәт кенә. *[Балалар] Тирәюньдәге миләш асылган агачны күрү берлә, мәче балалары кебек берсе артыннан берсе йолт-йолт җиргә сикерде.* Г.Исхакый. *Аптыравы һәм шүрләве як-ягына йолт-йолт күз йөртүеннән сизелә иде.* Х.Камалов

**ЙО́ЛТ-ЙОЛТ ИТҮ** *ф. к.* **йолт-йолт килү**. *Күкләр күкри, тәрәзәләр зыңлый, Йолт-йолт итә яшен утлары...* Д.Гыйсметдин

**ЙО́ЛТ-ЙОЛТ КИЛҮ** *ф.* Елтырау, җем-җем итү; ялт-йолт итү

**ЙОЛУ** *ф.* 1) Хәвефле, бәла-казалы, авыр хәлдән саклап алып калу, коткару, аралау. *Үлемгә юлыктырган да акча, үлемнән йолган да акча.* Мәкаль. *Бер игелек кешене мең бәладән йолыр, ди.* Ф.Латыйфи. *Әмма яулык салу да бәладән йола алмый шул.* Ватаным Татарстан

2) Юкка чыгару, аклау яки яшереп әйтмичә калу, белгертмәү (гаепне, яманатны, гөнаһларны һ.б.ны). *Ялгыз атаң мин идем, Күзем орып чыгардың --- Языгы белән гөнаһсын кайда ла барып йоларсың?* Дастан. *Ышыкланыр җилкәсе – ире – ил-көн гайбәтеннән, ил-көн камчысыннан араламаганны, җиде ят бәндә хурлыклардан йолар, ди, сиңа, көт!* Н.Гыйматдинова

3) Тотыкларны яки сугыш әсирләрен сугышып коткару яисә берәр нәрсә исәбенә яки түләп кире кайтару. *Тик анда куып килүчеләр, аларны әсирлектән йолып алучылар күренмәде.* Т.Нәбиуллин. *Ул Шагали ханны күп акча биреп йолып алдылар вә һәм яңадан ханлыкка утырттылар.* Ф.Урманче

4) Тартып алынган мөлкәтне акча түләп кире кайтару

5) *күч.* Эләктерү

**Йолып алу** 1) Аралау, аерып алу. *[Хөсәен] Арбадан төшүгә, беркемгә дә игътибар итмәстән, төркем арасыннан сеңлесен йолып алып, кочагына кысты.* А.Расих

2) *күч.* Кемне дә булса авыру, бәла-казалы, газаплы, оятлы һ.б.ш. хәлдән коткару, исән калдыру; шундый хәлдән чыгарга ярдәм итү. *Их, кулларыннан килсә, әниләрен газаплы сыкранулардан йолып алмаслар идемени соң?* Ф.Сафин. *Ашыгыч һәм яшертен йомышлар калыкса, алар шартлы сүзләр белән телефоннан хәбәрләшәләр дә очрашалар, --- тимер юллар тирәсендә бер-бер чатак чыкса, Иван Иванович Басыйр Бариевичны һәрчак йолып ала.* А.Гыйләҗев

**Йолып бетерү** Тәмам, бөтенләй, тулысынча йолу. *Китап белән кергән иман шартларын, Коръән образларын сихер-зәхмәт тә йолып бетерә алмагандыр.* Г.Гыйльманов

**Йолып калу** Кемне дә булса авыру, бәла-казалы, газаплы, оятлы һ.б.ш. хәлдә калдырмау, вакытында ярдәм кулы сузу, коткару. *Сине үлем тырнагыннан йолып калды.* Н.Гыйматдинова. *Кайбер вакытларда [Чыңгызга:] «Бәлки, ул кызга ... әйе, әйе, авырлы килеш өйләнергә, аны гомерлек бәладән йолып калып, бәхетле итәргә кирәк булгандыр?» дигән сәер уй да килә иде.* З.Садыйков. *Йөрәкле яшьләрнең каны авыруларны үлем тырнагыннан йолып калуда хезмәт итә.* Шәһри Казан

**Йолып китү** Аз гына, чак-чак кына эләктерү, кагылып, тиеп китү. *Патша кырык аршинлы бер багана утырттыра, элеп куя бер янчык: «Менә шуны кемнең угы йолып китә, алтын шуныкы».* Әкият

**ЙОЛЫК-ЙОЛЫК** *рәв.* Җемелдәп, җем-җем итеп, ялт-йолт

**ЙО́ЛЫК-ЙОЛЫК КИЛҮ** *ф.* Җемелдәү, ялтырау; җем-җем килү, ялт-йолт итү. *Озакламыйча ерактагы биек тау шәүләләре тирәсендә йолык-йолык килеп яшен яшьнәргә керешә.* Я.Хамматов. *Елга ярына ак «Волга» килеп*

*туктады. Әле яңа, буяулары да йолык-йолык килеп тора.* З.Хөснияр

**ЙОЛЫККАЛА́У** ф. 1) Төрле якларга тарткалау. *Ә тыштагы буран кабинаның тәрәзәләренә, кузовка сугылып, машинаны аударырга теләгәндәй, йолыккаларга тотынды.* И.Салахов. *--- бармак араларыннан кырык эз сызып, кып-кызыл кан ага... – Күзеңме, күзеңме? – дип сорыйм, инәләм, йолыккалыйм, ул дәшми, башын гына чайкый....* А.Гыйләҗев. *Гайсәнең чал чәчләрен җил төрле якка йолыккалады, туйганчы туздырды.* Ф.Садриев

2) Сындыру, ботарлау; өзгәләп бетерү. *Җитмәсә, ал аяклары астына кысып, теше белән йолыккалый, авызына кабып пыран-заран китерә, күлмәкнең тетмәсен тетә [Полкан].* Г.Сабитов. --- *янда гына җирне аяусыз йолыккалап, бомбалар ярыла башлады.* Ш.Янбаев

3) *күч.* Төрле сораулар биреп аптырату, йөдәтү

**Йолыккалап бетерү** Тәмам, бөтенләй юкка чыгарып йолыккалау. *Монтескье --- «их, ваклап, төрле яктан йолыккалап бетерерләр бу халык тарихын» дип, үзенең сагаюын белдергәндер шикелле.* М.Галиев

**Йолыккалап тору** Бертуктаусыз йолыккалау. *Нигә син мине йолыккалап кына торасың?* А.Гыйләҗев

**Йолыккалый башлау** Йолыккаларга тотыну. *Кожемякин кашларын җыерып, пиджагының төймәсен йолыккалый башлады.* Ф.Галиев. *Берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе зифа, ап-ак шәмдәй кәүсәле каеннарның кайсысын йолыккалый башларга кыймыйча, аптырап калган егетне старшина: – Курсант Салихов! Лирикага бирелеп торырга вакыт юк, – дип кисәтте.* Г.Кашапов. *Ул арада без Ибрай абзыйны яңадан йолыккалый башлыйбыз: – Ә Шүрәлеңне безгә кайчан күрсәтәсең?* Ш.Маннап

**Йолыккалый бирү** Һаман да йолыккалау, йолыккалавын дәвам итү

**ЙОЛЫМ** и. 1) *иск.* Крестьяннар тарафыннан алпавытка түләнә торган җир акчасы, салым. *[Спартак:] Минем сезгә ике айлык хезмәтем бар. Шуның өчен, сеңлем өчен йолым хакы түләмәкче булам.* Н.Исәнбәт

2) Җиңгән илнең җиңелгән илгә салган салымы; контрибуция. *[Олуг Мөхәммәт] Мәскәүгә яу чаба һәм аны камап тора, мәскәүлеләрдән йолым алганнан соң, кире Сарайга кайтып китә.* А.Әминов

3) Тотыкларны, әсирләрне кире кайтару өчен түләнә торган акча. *Әсирлеккә төшкән гаскәр башлыгы Шереметьев мәгарә төрмәсендә егерме бер ел утырган! Анда бай әсирләрне генә тотканнар, йолым түли ала торганнарны гына.* Л.Гыймадиева. --- *бу орышта Василийның гаскәрләре тар-мар ителә, үзе әсир төшә. Хәер, тоткынлыкта ул озак булмый, ханга вәгъдәләр биреп, йолым түләп котыла.* Б.Хәмидуллин

4) Штраф, гаепне аклый торган бәя. *[Электә] Авыру нинди дә булса ялгышың, хаталарың (гөнаһың) аркасында килеп чыккан, шунлыктан авыруың да шул ялгышың өчен йолым түләвең, дип караганнар.* Н.Исәнбәт. *Әгәр хакимнәр гаепне җиңеләйтә торган берәр нәрсә яисә шартлар табалар икән, шул чакта гаепләнүче гөнаһны каплый ала торган йолым түләргә тиеш булган.* Оҗмахка алып баручы юл

**ЙОМ-** *кис.* «Й» авызына башланган кайбер сыйфат һәм рәвешләргә ялганып һәм басымны һәрвакыт үзенә алып артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәкчә (мәс., *йо́м-йомшак; йо́м-йомры*). *Йомгак кебек йом-йомры чебиләр йөгерешә.* А.Алиш. *Он мамык кебек йом-йомшак.* И.Гази

**ЙОМАК** *и. диал.* 1) Табышмак. *Башкорт табышмагында бу термин нәкъ менә жанр атамасы буларак кулланыла: «Йомып биргән йомакны ачайома кем чишәр? Төреп биргән йомгакны ача-йома кем сүтәр?»* Ф.Урманче

2) *иск.* Гомумән фольклор әсәр. *Әкиятем-йомагым, мич башында кунагым, иртә торып сыйладым, кич утырып кыйнадым.* Такмак

**ЙОМАРЛАВЫК** *и.* Кантар, төер

**ЙОМАРЛАВЫКЛЫ** *с.* Кантарлы, төерле

**ЙОМАРЛАК** *с.* **1.** Йомгак сыман булып укмашкан, укмаштырылган, йомры-йомры. *Ул да булмый дала буйлап йомарлак үләннәр тәгәрәшә башлый.* М.Әмирханов

**2.** 1) *и. мәгъ. к.* **йомарлам**. *Гаҗәп: минем эшем юеш көнне таудан тәгәрәгән кар йомарлагы кук үсә бара.* Г.Тавлин. *Борчак онын төкерек белән төкерә-төкерә юешләп, ике йомарлак ясады.* Ф.Урманче

2) *бот. к.* **дүңгәләк**

**ЙОМАРЛАМ** *и.* **1.** 1) Йомшак яки таралучан берәр әйбернең тыгызланып йомгак сыман укмашкан кисәге. *Бүген исә малайлар Хәлимне кар йомарламнары белән каршы алдылар.* Г.Гобәй. *Йомарламы белән ак май.* А.Гыйләҗев

2) Түгәрәк, йомгак шәкелендә булган берәр нәрсә; төргәк. *Әнә бит, төн карасы аша аксыл томан йомарламнары булып шәйләнгән шомырт агачлары шундый иртәнең килерен хәзердән хәбәр итә сыман.* М.Маликова. *Уртак мәхәббәт җимеше, каннарын кушып яралган нәни йомарламнан да кадерле, аннан да тансык, газиз нәрсә юк иде ул чакларда Гөлйөзем белән Сәеткә.* Ф.Латыйфи

3) *күч.* Җыерылып, куырылып килгән, кечерәеп калган йомгак. *«Беттем!» Бу уе шулкадәр ачык һәм төгәл иде, дәү гәүдәсе куырылып, бер йомарлам булып кына калды. «Үләм, бетәм», – дип кабатлады ул, соңгы көчен җыеп.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Түгәрәк, шарсыман. *Һәр сабакның очында бер йомарлам сары кояш балкый, ап-ак таҗлары исә тасма-тасма ак нур булып ташып чыккан [ромашкалар].* Р.Низамиев

2) *к.* **йомарлак**. *Ишледән базарга килүче берәүсе аңа [Бәдретдингә] әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде.* Ә.Еники. *Авызын зур ачып, киерелеп, бер йомарлам һава иснәп алырга да өлгерде.* Р.Мөхәммәдиев

**ЙОМАРЛАМЛЫ** *с.* Йомарлам ясап, укмаштырып куелган. *Йомарламлы май*

**ЙОМАРЛАН** *и. бот.* Дала һәм чүлдә үсә, орлыгы өлгереп җиткәч, тамырыннан аерылып җил уңаена тәгәрәп

йөри торган куаксыман яки үләнчел үсемлек, дүңгәләк, давыл үләне; *русчасы:* **перекати-поле**

**ЙОМАРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **йомарлау** (*1–3 мәгъ.*). *Байның кызы бай кебек, Өйрәнмәгән тай кебек; Ярлы кызы, җанкисәгем, Йомарланган май кебек.* Ф.Бурнаш

2) Йомры хәлгә килү; йомры кисәкләргә укмашу. *Кара урманга кар ява, йомарлана, бозлана*. Җыр

3) Кул-аякларны җыеп, гәүдәне бөгәрләү. *Маңгаена тирә ике тезен Керпе кебек йомарлана да, Күргән төшем кабатланмасмы дип, Ул күзләрен йома яңадан.* Ф.Кәрим. *Төнге тынлыкны уятмас өчен, койма өстеннән генә йомарланып төшәм.* М.Галиев. *Шул хәвефсез урынга урнашу белән, тетелеп беткән пиджагымны астыма салам, йомарланып йокларга ятам.* А.Расих // Бөгәрләнү, үз-үзенә җыелу. *Гыйльфанованың йомшак тезгән ялагай сүзләрен ишетүгә, Мортазин йодрык сыман кискен әсәренде, йомарланды.* В.Имамов

4) Үсемлекләрдә чәчәк, яфрак бөреләре яки җимшәннән яшь җимешләр барлыкка килү. *Җиләк чәчәккә йомарланган чорда үсемлекләрне --- зарарлый торган филчекләргә, яфрак коңгызына, кисмәннәргә каршы --- эремә сиптерәләр.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

5) *күч. шигъ.* Нәрсә дә булса эшләргә өлгереп җиту, җитлеккән хәлгә килү. *Чәчәк атарга күңел йомарланды.* М.Гафури

**Йомарлана башлау** Йомарланырга тотыну. --- *сикереп төшкән карак әүвәл таудан түбәнгә таба агач әрдәнәсе кебек тәгәрәде-тәгәрәде дә, берзаманны керпе шикелле йомарлана башлады, ә аннары инде тәгәрмәч йә булмаса йомгак рәвешен алды.* В.Имамов

**Йомарлана бирү** Йомарлануын дәвам итү

**Йомарлана төшү** Бераз йомарлану. *Бу авыр гына нәрсә такта сыман юка, дүрткел һәм озынчарак иде. Аннан соң ул бераз гына йомарлана төшкән, бер ягы шома, икенче ягы кытыршы иде.* Н.Фәттах

**Йомарланып бетү** 1) Бик нык йомарлану. *Малай бияләй эченнән йомарланып беткән язулы кәгазь чыгарды.* Ф.Хөсни. --- *кесәсеннән йомарланып беткән унлык чыгарды.* Л.Ибраһим-Вәлиди

2) Барысы да, берсе дә калмастан йомарлану. *Тагын мендәрләр ишелеп төште, тагын бөтен нәрсә йомарланып бетте.* Ф.Яруллин. *Аның [Шәрифҗанның] өсте-башы йомарланып беткән, киеменә салам кисәкләре ябышкан, йокысызлыктан йөзе ямьсезләнгән.* А.Гыйләҗев

**Йомарланып җиту** Тулысынча йомры рәвеш алу

**Йомарланып калу** Нинди дә булса сәбәптән, билгеле бер вакыттан соң йомарланган хәлгә килү. *Бөтен тәне белән ул бер йодрыкка йомарланып калды.* Н.Фәттах. *«Синме бу, югалмадыңмы?» – дип, битләренә, күзләренә йотылып карыйм, ул уңайсызлана, читкә тартыла, каушый, бәләкәйләнеп, йомарланып кала.* Р.Вәлиев

**Йомарланып килү** Кинәт йомарлану. *Аның [әтинең] бите һаман шул коеп куйган төсле, тик ара-тирә йә бармаклары селкенгәләп куя, йә йодрыгы йомарланып килә.* Г.Бәширов

**Йомарланып киту** Бераз йомарланган хәлгә килү

**Йомарланып кую** *к.* **йомарланып килү**. *Урын өстендә ятып калган әнисе, сабыйлары искә төшкәндә, җаны тагын да йомарланып куя Галимәнең.* Борынгы Калатау итәгендә

**Йомарланып тору** Йомарланган хәлдә булу. *Аларның кәбестә шикелле йомарланып торганнары, тәлинкәгә охшап үскәннәре, хәтта люстра кебек тармакланып асылынып торганнары да бар.* М.Юныс

**Йомарланып яту** Йомарланган хәлдә вакыт үткәрү. *Өйдә, йомшак түшәк өстендә, тук әрлән кебек йомарланып ятудан да рәхәтрәк нәрсә бар?* Ә.Фәйзи

**ЙОМАРЛА́У** *ф.* 1) Куллар белән уч төбендә әвәләп укмаштыру, йомры хәлгә китерү. *Апуш тагы балчык йомарлый да, баш өстебездән очып барган торналарга төзәп, һавага очыра.* Г.Ибраһимов. *Йодрык хәтле генә итеп карны йомарлыйсың да шуны тәгәрәтеп китәсең.* А.Алиш. *Гамил, ике-өч сикерүдә, кызыйны яңадан куып җитте, кар йомарлап, аллы-гөлле шарфына төзәде.* Г.Сабитов

2) Нәрсәне дә булса төенчеккә төрү, чорнау. *[Егетләр] Чистарак киемнәрнең --- барысын бер төргәккә йомарладылар.* Н.Фәттах

3) Җыерчыклар барлыкка китереп кысып тоту, бөгәрләү; бөтерү. *Асия әлеге кәгазьне шундук уч төбенә кысып йомарлады.* Р.Мөхәммәдиев. *Аннары ул, фуражкасын йомарлап тотып, халыкка болай диде.* Ә.Гаффар

4) *к.* **йодрыклау** (*1 мәгъ.*). *Икенче арбада исерек әллә ниләр кычкырынды, бакырынды, әллә кемне тиргәде, әллә кемгә ялынды, йодрыгын йомарлап, әллә кемгә янады.* Г.Исхакый. *Дроздов куркуыннан куырылып килде, әмма бу халәте озакка сузылмады, тирән итеп бер сулыш алды да өстәл астында кулын йодрыкка йомарлады.* З.Хөснияр

5) Нәрсәне дә булса уч эченә йомып яшерү. *Акчасын кулына йомарлап сөйләгән кешенең сүзендә куәт бар.* Мәкаль. *Мин чаршау артыннан атылып чыктым да әтиемнең кулыннан шешәне умырып алдым, учыма йомарладым.* Н.Дәүли

6) *күч.* Табышны, байлыкны үзе генә үзләштерү, яшереп алып калу. *[Габдуллаҗан:] Юк инде, Муса әфәнде, алай үзеңә генә бөтен нәрсәне йомарлап тотмыйлар аны.* К.Тинчурин

7) *күч.* Берәр максат белән берләшү, бер урынга җыю яки көчне, фикерне, ихтыярны туплау. *Командир бөтен ихтыярны кулына йомарлаган да эндәшми.* Г.Әпсәләмов

**Йомарлап алу** Тиз генә, җәһәт кенә йомарлау. *Йомарлап алсаң, учка сыярлык кына бер адәм иде ул.* В.Нуруллин

**Йомарлап бетерү** Тулысынча, барысын да йомарлау

**Йомарлап кую** Йомарланган рәвешкә китерү. *Гәрдәншакир карт ирексездән йодрыгын йомарлап куйды да, авыр уйларыннан арынырга теләгәндәй, икенче якка борылды.* М.Кәбиров

**Йомарлап тору** Йомарланган хәлдә тоту. *Бер кул белән якасыннан тотып, икенче йодрыкны йомарлап тордым-*

*тордым да, үзем дә сизмәстән, елап җибәрдем.* Р.Вәлиев

**ЙОМАРЛЫ** *с.* 1) *к.* **йомарлавыклы**

2) Берәр нәрсәгә төреп йомарланган. *Гудок тавышы, йомарлы чүпрәк тыгылган тәрәзә өлгеләрен тетрәтеп, хәлсез гәүдәләргә биш-алты сәгатьлек ял бирергә дә өлгермәгән бистә эшчеләрен --- завод сукмакларына куып чыгара.* К.Нәҗми

**ЙОМАРЛЫК** *и. к.* **йомарлам**. *Мин җүнләп төзәп тә атмадым, беренче йомарлыгым ук дустымның чыраена эләкте.* Г.Тавлин. *Балчыклы туфрак йомарлыгы аз гына кагылганда да таралып торса, --- су сибәргә кирәк дигән сүз.* А.Девятков, А.Макаревич

**ЙОМАРЛЫКЛА́У** *ф. сөйл. к.* **йомарлау**. *Менә Тәкәрлек димә инде аны, миңа атарга кабалана-кабалана кар йомарлыклап маташа бит.* Г.Тавлин

**ЙОМГАК** *и.* 1) Йомры җеп чорнамы. *Әллә нәрсәсе чуала да куя тормышның; йомгагыннан сүтелгән җеп кебек, һич җаен табып бетерә торган түгел.* Ә.Сәйфетдинов. *Галя белән Миләүшә, зур йомгакны икегә аерып, җеп сүтәләр.* Р.Кәрами

2) *күч.* Йомры, шарсыман әйбер. *Карасак, каен төбенең тирән куышында, берсенә берсе уралып, тубал хәтле йомгак булып укмашып беткән исәпсез-сансыз кара елан кайнаша!* Г.Бәширов

3) *күч.* Башкарылган эш, хезмәтнең соңгы нәтиҗәсе; берәр нәрсәнең җыеп туплаган күрсәткече. *Конкурска йомгак ясалып, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырганда, Зөмрәднең кулын кысып котлыйсы килсә дә, Гамирның кыюлыгы җитмәде.* З.Фәйзуллин. *«Атлап үтмәгез, аңлатып үтегез...». Шушы фикер аның кырык елга якын сузылган фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәсе, йомгагы буларак туган диярргә була.* Н.Юзиев. *Кереш сүзеннән соң Василий Михайлович кыска гына итеп быелгы уку елы йомгакларына тукталды.* Н.Фәттах

4) *күч.* Чишелергә, ачыкланырга тиешле буталчык, бәйләнешсез нәрсәләр; яшерен мәгълүмат. *Әминев элек беркайчан да мондый эшләргә катнашмаган, серле йомгакларны сүтүдән ифрат ерак торган бер һөнәр иясе булганлыктан, хезмәткәренең белдеклелегенә гаҗәпләнүен яшермәде.* Т.Әйди. *Сер йомгагы ничек кенә төенләп чорналса да сүтелә икән ---. Күр әнә, гомеренең азагында сүтелде ул йомгак.* Р.Газизов

5) *күч.* Уй-фикернең, гомернең һ.б.ның бару юнәлеше, агышы. *Фикер йомгагы аны һаман-һаман хастаханә ятагына салган фаҗигале хәлләр ярына өстери.* Т.Галиуллин. *Тәгәри китте сүз йомгагым, Хәерле сәфәр! Сабыр, Каләм! Хәбәрләре кичексә әгәр.* Ф.Бәширов. *Ихтыярсыздан, уй йомгагы Кама суларына барып ялганды.* Н.Хәсәнов

◊ **Йомгак итеп** 1) Йомгаклап, нәтиҗә ясап, нәтиҗә чыгарып; 2) Бөтереп, бөгәрләп. *Кыйнап туйгач, йомгак итеп бәйләделәр.* Р.Мөхәммәтҗан. **Йомгакны башыннан сүтү** Ачыкланасы нәрсәне башлангыч моменттан сөйли башлау. *Моны, бәлки, тулырак итеп сөйләргә, йомгакны башыннан сүтәргә кирәктер.* А.Расих. **Йомгакның очы** Мәсьәләнең, эшнең төбе, асылы. *Әмма аннан да кирәгрәге, мөгаен, Шиһабетдиновның Каганнан ары китеп өлгермәгән хатларыдыр: йомгакның очы яки шуңа берәр ишарә менә кайда күренүе мөмкин.* Т.Әйди. **Йомгакның очына чыгу** Мәсьәләнең, эшнең төбен, асылын белү, аңлау, төшенү. **Йомгакның очын тоту** *к.* **йомгакның очына чыгу**. **Йомгакның очын чуалту** Мәсьәләнең, эшнең төбен, асылын белгертмәү, яшереп калдыру; бутау, ялгыш юлга кертү. **Йомгакның очын югалту** *к.* **йомгакның очын чуалту**. **Йомгакның очын яшерү** *к.* **йомгакның очын чуалту**. *Ярар, син монда җиткәч боргаланма, йомгак очын яшереп маташма, ачыктан-ачык сөйләшик.* Н.Исәнбәт. **Йомгакның очы чыгу** Мәсьәләнең, эшнең төбе, асылы билгеле булу, ачыклану. **Йомгакның төене** *к.* **йомгакның очы**. *Озерцовта – йомгакның төене.* Р.Мөхәммәтҗан. **Йомгакны тәгәрәтү** 1) Уй-теләкне куелган максатка юнәлдерү. *Йортка кергән тәкъдирдә, йомгакны кая таба тәгәрәтәсен белер иде ул.* Н.Гыйматдинова; 2) Сүз юнәлешен башлап җибәрү, теманы билгеләү. *Утыр янәшәмә, яшьлек дустым Рабига. Йомгакны кайсыбыз тәгәрәтеп җибәрә?* Н.Гыйматдинова. **Йомгакны чуалту** 1) Бутап бетерү, бозу, тәртибен җибәрү. *Их егетләр, йомгакны чуалтуы ансат, сүтүе кыен икән!* К.Тинчурин; 2) Сүзнең очын югалту. *Башта төрле сораулар биреп сүзен бүлдерделәр, аннан, бара торгач, үзе дә йомгагын чуалтты.* Н.Исәнбәт. **Йомгак сүтелү** 1) Сер билгеле булу, буталчык нәрсәләр ачыклану. *Шул боҗраланып өскә таба күтәрелгән төтенгә ияреп, уй-фикер йомгагы да сүтелә башлады.* М.Хәсәнов; 2) Әзлекле рәвештә, тәртибе белән бару. *Әкрен генә сүтелеп барган спектакль йомгагы актрисага Нәфисәнең холкын киңәйтеп ачып бирергә ярдәм итә.* Мәдәни җомга. **Йомгак тәгәрәп китү** *к.* **йомгак сүтелү**. *– Нәтиҗә бер, – диде әлегә кадәр сүзсез торучы өченче кунак, – телсез шаһиттан да яхшы нәрсә юк. Телгә килсә, йомгакның тәгәрәп китүе бар.* Р.Мөхәммәтҗан

**ЙОМГАК-ЙОМГАК** *с.* Берничә йомгактан торган, йомгаклар сыман. *Трактор торбасыннан йомгак-йомгак аксыл төтен атылды.* М.Хуҗин

**ЙОМГАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **йомгаклау** (*1 мәгъ.*). *Конкурс йомгакланып, бүләкләр тапшырганда, Фарсил аңа сабан туе бүләге – почмагына роза чәчәге чигелгән кульяулык бирде.* З.Фәйзи. *Монда кыска ителеп, йомгакланып язылды.* Х.Туфан

2) Йомры, шарсыман булу; шул шәкелгә килү; йомарлану (*2 мәгъ.*). *Кар йомгаклану*

3) *күч.* Акрынлап барлыкка килү, азазлап туплану, җыелу. *Йомарланган йодрыкларда ачу һәм нәфрәт йомгаклана*

4) *күч.* Тәмамлану, ахырына җитү, төгәлләнү. *Надзирательләр килеп чыкмаса, эш нәрсә белән йомгакланыр иде, билгесез.* Р.Кәрами. *Гадәттә әңгәмә шундый сүзләр белән йомгаклана иде.* Х.Хәйруллин. *Әкият, гадәттәгечә, тантаналы туй белән йомгаклана.* Ф.Урманче

**Йомгаклана башлау** Йомгакланырга тотыну. *Хәлимнең күңелендә юан малайга ачу йомгаклана башлый.* И.Гази

**Йомгакланып бетү** Тулысынча йомгаклану, йомгаклану процессы тәгәлләнү

**Йомгакланып килү** Эзлекле рәвештә, акрынлап йомгаклануга таба якынаю. *«Гомер» дигәннәре йомгакланып килә.* Г.Бәширов. *Ниһаять, әкиятләр дә очланып, йомгакланып килә инде.* Х.Мәхмүтов

**ЙОМГАКЛА́У** *ф.* **1.** 1) Йомгакка чорнау, йомгак ясап урау

2) Бетерү, тәмамлау. *– Наташа кебекләрдән башкалар да җитәрлек диюем генә ... – дип акланып, сүзен йомгаклады Матрёна Евдокимовна.* З.Фәйзи. *Соңыннан Мәхмүтов киңәшмәне йомгаклады.* Р.Кәрами. *– Укуны йомгакладым. Иртәгә китәм, – дип, бар хәлне Җәмил абыйга сөйләп бирдем.* М.Гайнетдинов

3) Нәтиҗә чыгару, гомумиләштерү. *Шулай итеп, йомгаклап әйткәндә, бер яманның яхшы ягы да калкып чыкты.* Р.Рахмани. *Йомгаклап әйткәндә, ул – колхозны, колхоз аны күтәрде.* Т.Нәҗмиев

**2.** *и. мәгъ.* Йомгак (*2 мәгъ.*), нәтиҗә. *Гадәти һәм табигый кабатланулардан соң, йомгаклау көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты.* Ә.Бая. *[Айтуганов] Барысын уйлап, үлчәп, сабыр гына итеп азактан йомгаклау сүзе белән чыкса, кем белә, бәлки, откан да булыр иде.* Г.Ахунов

**Йомгаклап бетерү** 1) Ахырына кадәр, барысын да йомгаклау

2) Йомгаклау өлешен тәгәлләү

**Йомгаклап килү** Акрынлап йомгаклау, йомгаклауга якынаю. *Президиум өстәле артында Мумиев, Буриев, Еланов, Чепчугин һәм Кутлякова. Мумиев нотыгын йомгаклап килә.* Т.Миңнуллин

**Йомгаклап кую** Йомгаклаган рәвешкә китерү

**Йомгаклап тору** Әле, хәзерге вакытта йомгаклау. *Призларны тапшырып, бүләкләрне өләшеп, кичәне йомгаклап торганда, мине чакырып алдылар.* Р.Хәбибуллина

**Йомгаклап чыгу** Башыннан ахырына кадәр йомгаклау; йомгаклауга ирешү

**Йомгаклый төшү** Бераз, берникадәр йомгаклау. *Шушы хәл инде гомерне йомгаклый төшәргә, башкарылган эшләргә нәтиҗә ясарга һәм алардан канәгатьлек тоярга вакыт җиткәч билгеле булыр дип, кем уйлаган, кемнәр генә уйлаган...* Ә.Баян

**ЙОМГАКЛЫ** *с.* Йомгакка чорнаган, йомгаклап торган

**ЙОМГАКЧА** *и. сир.* Кечкенә йомры-йомры төерчек. *Менә бу – чөгендер йомгакчасы, икенче төрле әйткәндә, чөгендер орлыгы.* Г.Галиев

**ЙОМГА́К ЯСАУ** *ф.* Нәтиҗә чыгару, йомгаклау; төгәл фикергә килү. *Ә инде эшкә йомгак ясаганда, иң беренче чәчрәп чыгып, башкалар өстенә тәнкыйть уты яудыручы ул иде.* Ф.Сафин. *К.Насыйри еш кына мәкальләрне әкиятләргә йомгак ясау, мораль чыгару өчен файдалана.* Х.Мәхмүтов. *Төнге эшенә йомгак ясагач, Карлен шундый фикергә килде: Неделинның өйдәге телефоныннан башка тагын нинди элемтә чаралары бар икән, шуларны эзләп табарга кирәк.* Р.Мирхәйдәров

**ЙОМГЫЧ** *с. анат.* Аерым әгъзаларны йому, ябу хәрәкәтен башкару өчен хезмәт иткән. *Йомгыч мускуллар*

**ЙОМДЫРГЫЧ** *с. анат.* Күз кабакларының күтәрелеп, төшеп торуын тәэмин итә торган. *Йомдыргыч яры*

**ЙОМДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **йому** (*1, 2 мәгъ.*)

2) *күч. гади с.* Үтерү. *Алар таң алдыннан Сәфәрне йомдырып, эшен бетереп кайтырлар, син [Гайфәрә] теге көмешкәне өстәлгә куйган бул!* Н.Гыйматдинова. *Бәлки, әнә шул әйтергә тиешле сүз ычкынмасын дип, аны йомдырганнардыр да.* Р.Мөхәммәтҗан

**Йомдырып кую** Йомдырылган хәлгә китереп калдыру. *Малайның ачык калган күз кабакларын йомдырып куйды.* Р.Мулланурова

**ЙОМРАН** *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядының тиеннәр семьялыгына караган, җиргә өн ясап яши һәм игеннәргә зур зыян сала торган җәнлек. *Тау битендә оясыннан башын тыккан йомран мине үртәп сызгырып куя.* М.Галиев. *Йомран шундук, суга чумган күк, юкка чыкты.* Р.Сибат

◊ **Йомран баш** *сөйл.* Алдакчы, ялганчы, хәйләкәр

**ЙОМРА́Н БАЛЧЫК** *и.* Төптән, тирәннән чыккан кызыл балчык, әрлән балчык

**ЙОМРЫ** I *с.* **1.** 1) Түгәрәк, шар формасында булган. *Йомры ипине яңадан урталайга кисеп вакыт әрәм ителсә, бу ипине бер генә кисәргә кирәк.* Н.Сәйяр. *Мәзин «караклар»га үзе тырнак белән дә чиртмәгән, ләкин икесенең дә кулларына бирәр йомры таш тоттырып, бер-берләрен кыйнарга кушкан.* Г.Тавлин. *Такыр итеп кырылган йомры башлар җиргә ятып тыңлый, үрелеп-үрелеп күзәтәләр юлны ---.* Р.Мөхәммәдиев

2) Аркылы кисеме түгәрәк булган озынча әйберләр турында. *Урамга йомры агачлар түшәп, җәяүле йөрү өчен, кырыйларына юллар ясалган иде.* М.Гали

3) Симез, тулы тәнле, юан. *Күрәсең, әнә шулай туйганчы йоклап өйрәнелгәнгәдер инде, теге көнне иртүк, әле көн яктырганчы ук, җиңги үзенең нык, йомры куллары белән беләгемнән эләктереп... [алды].* В.Нуруллин. *Сәке астыннан, күзләрен уа-уа, заправщик – теге, директорга үзенең «почмагын» бүләк иткән, йомры егет чыкты.* И.Салахов. *Биниһая күп кеше арасында кыска итәкле, уттай кызыл күлмәк кигән йомры гәүдәле кыздан да килештереп биегәне булмаганга, егет аңардан күзен ала алмады.* А.Сафин

**2.** *и. мәгъ. к.* **йомарлам**. *Такта алдында Хәлимне чалып еккан, зур кар йомрысы белән битенә бәргән малай --- тора иде.* Г.Гобәй

◊ **Йомры баш(лы)** *сөйл. хуп., ирон., шаяр.* Акыллы, үткен; бик елгыр һәм хәйләкәр. *Егет – йомры баш – тиз генә чамалап ала: бу бикәчкә ияреп байлык та киләчәк бит һәм артык икеләнеп тормыйча гына риза да була.* Ә.Еники. **Йомры җөмлә** Кыска, рифмага салынган төртмәле җөмлә. *--- ваемсыз заманда откан «Тәмәке тартабыз, эчүне ташламыйбыз», «Пычрак эшне ташладык, дегет сата башладык», «Без ипи ашамыйбыз, без эш кешеләре», «Минем 24 сәгать эшлисем килә» кебек йомры җөмләләрне, җае чыкса да, чыкмаса да, кыстыр-*

*мый калмас.* Т.Галиуллин. **Йомры сан** Эшнең күләмен күпкә арттырып күрсәткән зур сан. **Йомры сүз** Көчле тәэсир итәрлек, үткен итеп әйтелгән төртмә сүз яки тупас сүз. *Күренеп тора: Сәйдәштән унике елга алданрак туып, ипине күбрәк ашап өлгергән Тинчурин тел сәхнәсеннән йомры сүзләрне тәгәрәтеп кенә тора, сүзгә кеше кесәсенә керми.* Р.Низами. *Урта Саба авылы янындагы артышлыкта бер-беребезне «мактыйбыз», йомры-йомры сүзләр эзлибез.* Т.Нәҗмиев. *Ә менә Шәриф югында, аерым кешеләр белән сөйләшкән чакларында, аның адресына йомры-йомры сүзләр ычкындыргалый иде.* В.Нуруллин. **Йомры телле** Туры сүзле, уйлаганын әйтеп бирергә сәләтле. *Башын ими, туры карый торган йомры телле Әнвәр абый ул.* Ә.Хәбибуллин. **Йомры телне ясмык итеп җәю** Ясалма ягымлылык белән сөйләшү, төчеләнү. *Хәсрәтең белән килсәң, йомры телләрен ясмык итеп җәяләр, капкаларын арттан өч катлы биккә бикләп калалар.* Г.Ахунов. **Йомры телне яссы итеп** Ясалмалылык белән, ярарга тырышып, ялагайланып. *Йомры телеңне яссы итәрсең, яссы телеңне тасма итәрсең.* Мәкаль. *Йомры телемне яссы итеп ялындым.* Г.Зәйнашева

**ЙОМРЫ** II *и. диал.* Чынаяк чокыры. *Ана, сөйләнә-сөйләнә, сөтне йомрыларга бушатты.* Ә.Сәйфетдинов. *[Хуҗа] Аннан инде бик мөһим эше онытылган кешедәй, кисәк кенә кашыгын ашъяулыкка ташлады, чүлмәктән йомрыларга бал салды.* Җ.Рәхимов. *Алар килеп урнашу белән, картый йомрыларга чәй агыза башлады.* Н.Фәттах

**ЙОМРЫБАШ** *и. зоол.* Кәлтәләр семьялыгыннан, башы йомры, яссы-җәлпәк гәүдәле сөйрәлүче хайван; *русчасы:* **круглоголовка**

**ЙОМРЫБОРЫН** *и.* Металл, калай әйберләр ясаганда, аларны кысып тоту, бөгү өчен кулланыла торган башы йомры эш коралы

**ЙОМРЫК** *и. иск. к.* **йодрык**. *Өченчебез – Гани исемле сәүдәгәр. Соңгы елларда --- йомрык сугышларында катнашып беренчелекне яулаган бик мәһабәт гәүдәле ир ул.* А.Тимергалин

**ЙОМРЫ́ КАРТА** *и.* Имезүче хайваннар ашказанында беренче иң зур бүлек. --- *итче Яхъя бик симез ат суйган, ди, бер биш кадак йомры карта алып кайтырсың.* Т.Гыйззәт

**ЙОМРЫКЛАНУ** *ф. иск. к.* **йодрыклану**

**ЙОМРЫЛАНДЫРУ** *ф.* Йомры итү, түгәрәкләндерү. *Наденька күзләрен йомрыландырып, авызын җыя алмыйча елмаеп, Фирәзәгә карады.* Г.Үзиле

**Йомрыландыра төшү** Тагын да бераз йомрыландыру. *– Ничек инде?.. – диде ул [Вәлидә], күзләрен тагын да йомрыландыра төшеп.* М.Хәсәнов

**ЙОМРЫЛАНУ** *ф.* 1) Йомры формага керү, йомры булу. *Бу агач үсә барган саен йомрылана.* А.Девятков, А.Макаревич. *Мегастробиллар озынча – йомырка сыман, өлгергәндә йомрылана, куе кызыл төскә керә.* Л.Мәүлүдова

2) *күч.* Түгәрәкләнү, тулылану. --- *ул әле гәүдә үсеше белән бөтенләй бала иде. Аның гәүдәсе йомрыланып, тулып җитмәгән.* М.Җәлил

**Йомрылана бару** Торган саен ныграк йомрылану

**Йомрылана башлау** Йомрыланырга тотыну

**Йомрылана төшү** Тагы да, бераз йомрылану

**Йомрыланып бетү** Тәмам, бик нык йомрылану

**Йомрыланып җитү** Тулысынча йомрылану

**Йомрыланып калу** Йомры хәлгә килү. *Ул [Ислам] үзенә яны белән иелеп плитә янында булашкан Мәрьямнең юка күлмәк кигәч тагын да йомрыланып калган сылу гәүдәсенә --- карап торды.* Н.Фәттах

**Йомрыланып килү** Эзлекле рәвештә йомрыланган рәвеш алу

**Йомрыланып китү** Әле, соңгы вакытта йомрыланган рәвешкә керү. *Бер айдан соң Гөлйөземнең битенә элекке матурлыгы кайтты, тәне тыгызланып, гәүдәсе йомрыланып китте.* М.Әмирханов. --- *сиңа [Әхмәтсафа] өч ай дәвамында хезмәт хакы – айлык түләп тордык, ашханәдә тамак туклыгы иттердек, әнә чыраеңа бак: тазарып, матураеп, йомрыланып киттең, күз тимәсен...* Ф.Сафин

**ЙОМРЫЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Йомры хәлгә китерү, йомры итү

2) *күч. сөйл. ирон.* Эшне тулысынча тәмамлау, ахырына кадәр башкарып чыгу; төгәлләү, очлау

**Йомрылап бетерү** Тулысынча, ахырына кадәр йомрылау

**Йомрылап кую** Алдан йомры хәлгә китерү

**Йомрылап тору** Әле, хәзер йомрылау

**Йомрылый төшү** Тагы да бераз йомрылау

**ЙОМРЫЛЫК** *и.* 1) Түгәрәк, шарсыман, йомры булу. *Иңбашларының йомрылыгы*

2) Тулылык, симезлек, юанлык. *Хатын үзенең йомрылыгы белән башкалардан аерылып тора*

**ЙОМРЫ́ ЧАБАК** *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан, елгаларда һәм саф сулы күлләрдә таралган зур булмаган балык; *русчасы:* **елец**

**ЙОМУ** *ф.* 1) Ябу, йомык хәлгә китерү (күзне, авызны). *Егет көтелмәгән дәһшәттән һушын җуйган кызны кулына алып, очкыннар яктылыгына түзәлмичә, күзләрен йома.* Н.Сәйяр. *Карчык, күзләрен яртылаш йомып, еракта калган яшьлек хатирәләре дөньясына чумган.* М.Юныс

2) Бармакларны уч төбенә бөгү

3) Берәр нәрсәне уч төбенә алып яки салып, бармакларны бөгү. *Егет Рәхиләнең кулларын үзенең җылы учларына йомды.* Ф.Сафин. *– Талиягә бирерсең. Миннән бүләк. Югалтмасын, – диде. – Бирермен, – диде Әкълимә, абыйсы биргән бүләкне тиз генә учына йомып.* Н.Фәттах

4) Бетерү, тәмамлау. *План юк иде, сүзне йомарга тырыштым.* М.Мәһдиев. *Ничектер шулай, чәй эчеп утырган чагында, Акмал бер мәртәбә сүз чыгарып караган иде, Шаһислам әңгәмәне тиз йомды.* Г.Ахунов

5) *күч. к.* **йоту** (*13 мәгъ.*). *Алай гына булса, бәлкем, эшне зурга ук җибәрмичә йомарлар иде.* З.Хөснияр

6) *күч.* Сиздермичә, күрсәтмичә үзләштерү, бирмичә алып калу. *Совет*

*тирәсенә елышкан җыен әтрәк-әләм йома малны.* Ф.Сафин

7) *куч. гади с.* Тавыш-тынсыз гына юк итү, үтерү. *[Сәлим хан:] Илче Садакны да йомдыгыз, кем үлтерде?* М.Хәбибуллин

◊ **Йом да борыныңа тык** Бик нәфис, нечкә, затлы материяне мактап әйтү. **Йоммый, түгеп ява** Бик каты елау, күзләрдән туктаусыз яшь агызу (елак бала турында). **Йомып калдыру** Берәр җинаятьне, гаепне һ.б.ш.ны җәмәгатьчелектән яшереп калдыру, эзен югалту. *Димәк, бу фаҗигане шыпырт кына йомып калдырырга мөмкин булмаячак.* Т.Әйди. *[Лилия:] Сатира Гыйззәтовна, юк инде. Өч кызның әйберләре югалды, йомып калдырдыгыз.* Д.Салихов. – *Мин үземне якларга җыенмыйм, ә авариягә китергән кимчелекләрне йомып калдырганга борчылам, – диде ул.* Х.Камалов

**Йома төшү** Җиңелчә, бераз, сизелер-сизелмәс йому. *Шул чакта баядан бирле җыендагы сүзләргә колак салып, ияренә таянып утырган Сатымкол агай, сыңар күзен йома төшеп һәм теш арасыннан гына бер төкереп, әйтеп куйды.* Ч.Айтматов

**Йомып алу** Азга, кыска вакытка йому. *Җәүдәт кара күзләрен тагын бер чытырдатып йомып алды.* Ә.Исхак. *Әхмәдулла абзый кытыршы учлары белән кулымны йомып алды.* Р.Бәшәр

**Йомып бару** *к.* **йотып бару**. *Рәҗәпов әйткән һәр санны авыз эчендә йомып бара иде.* Ф.Сафин

**Йомып бетерү** Тәмам, тулысынча йому. *Тәминдәр сул күзен бертын бөтенләй йомып бетереп карап торды.* М.Галиев. *Хәбир, --- болай да кысынкы күзләрен бөтенләй йомып бетереп, рәхәтләнеп бер көлде дә кинәт җитдиләнеп сүз башлады.* А.Әхмәтгалиева

**Йомып килү** Моңарчы, хәзерге вакытка кадәр йому

**Йомып кую** 1) Кинәт йому. *Карт күзләрен мелт-мелт итеп йомып куйды.* Ш.Камал

2) *куч.* Берәр нәрсәнең әһәмиятен юкка чыгару, каплап китү. *Хыял-уйларны аның үз сүзләре йомып куйды.* М.Хуҗин

**Йомып тору** 1) Билгеле бер вакыт дәвамында йомган хәлдә тоту. *Ишан хәзрәт тагын китапка бөгелә, озак кына селкенә-селкенә укый, тынып күзләрен йомып тора, аннары тагын укый.* Ә.Еники. *[Хөсәен] Бермәл күзләрен йомып торды.* А.Расих. *Зәнфирә, хәтерләргә теләп, ахрысы, күзләрен йомып торды.* Ф.Садриев

2) Әлегә, хәзергә йому, вакытлыча йому. *Юлдашыңның бер күзе сукыр булса, ике күзеңне йомып тор!* Мәкаль

3) Һәрберсен, булган берсен йому. *Үзләре өчен һәр уңайсыз эшне йомып тордылар.* Татарстан яшьләре

**ЙОМШАК** I *с.* **1.** 1) Кул белән тотып, капшап карауга яки тоюга сиземләүгә тыгыз булмаган; *киресе:* **каты**. *Тиз генә, эләктереп, самавырын да куя, --- хәлфә астына йомшак юрган да җәя, таянырга мендәр дә ташлый.* Ә.Еники. *Мамыктай йомшак, сөттән ак кар өстендә калган эзләрен күзәткәндә туган хозурга бер-береңне ярату ышанычы да өстәлде.* Ә.Сәйфетдинов. *Йомшак, затлы тиредән тегелгән чигүле чүәкләрнең башы үләнгә ышкылып ялтыраган.* Ә.Гаффар

2) Күперенке, кабарынкы; симез, майлы. *Ул [Газиз] Мәрьямне коридорда очратты да, котлыйм, дип, тәмам югалып калган кызның маңгаеннан йомшак иреннәре белән үбеп тә алды.* М.Маликова. *Альфредның укырга керүе, Руфинә белән бер төркемдә укыячагы турында ишеткәч, Кәүкәбелҗәннәт аларны берәм-берәм кочып чыкты, ә кызны йомшак, итләч аркасыннан шапылдатып сөйде.* Ф.Садриев

3) Ефәк сыман, нечкә, нәфис (чәч, йон һ.б. турында). *Кунак бабай Илсөярнең йомшак сары чәчләрен сыйпады да, куеныннан алып, аңа тагын бер алма бирде.* Г.Гобәй

4) Бөгелмәле-сыгылмалы, каты булмаган. *Мәрьям җитди әсәрләр, һич булмаса, квартир хуҗасының эшенә бәйле справочниклар табарга өметләнеп, өске киштәләргә үрелер өчен, йомшак креслога менеп басты.* М.Маликова. *Эштән арып-талып кайткач, йомшак кәнәфигә ятып хәл җыярга гадәтләнеп киткән идем.* А.Сафин. *Йомшак утыргычлар өр-яңа кызыл бәрхет белән тышланган.* В.Юныс

5) Сөрү-казуга, эшкәртүгә җиңел бирелүчән, көпшәк. *Төзелеш 5 мең гектар җирдә алып барылачак. Монда уңдырышлы, мамыктай йомшак кара туфраклы басу-кырлар да, хәтта сугарыла торган җирләр дә эләгә.* М.Әмирханов

6) *куч.* Сәламәтлеге кимегән, физик яктан көчсез, хәлсез булган. *Иммунитет йомшак, шуңа күрә төрле лимфатик бизләр, бавыр, баш авыртырга мөмкин.* Мәдәни җомга

7) *куч.* Зәгыйфь, көчсез, начар (ишетү, сизү, игътибар һ.б.ш. турында). *[Бабай:] Кычкырыбрак сөйлә, колагым йомшаграк. Нәрсә дисең?* Г.Гыйльманов. *Күзләре генә бирешкән. Яшьтән үк күзгә йомшак булган, күрәсең.* Б.Камалов

8) *куч.* Чагылыш дәрәҗәсе гадәтидән кимрәк булган, көчсез, әкрен. *Чуар пыялалар белән бизәкләп эшләнгән зур тәрәзәдән кабинеттагы авыр мебельләргә йомшак яктылык сибелә.* К.Нәҗми. *Алда өстәл сәгате текелди. Тавышы йомшак аның, ялыктыргыч.* А.Сафин. *Кайдадыр яңгыр ява булса кирәк: йомшак кына гөлдерәү ишетелеп ала.* М.Мәһдиев

9) *куч.* Тыныч холыклы, тыйнак, күндәм; ихтыярсыз. *Минем улым – йомшак күңелле бала.* А.Гыйләҗев. *Зиннәт абый – йомшак холыклы кеше.* Г.Тавлин. *Әтиемнең характеры үтә йомшак, ул тормышка җитәрлек әзерлек белән кермәгән һәм шуның аркасында заман рөхсәт итмәгән бер хата артыннан икенчесен ясаган.* А.Расих

10) *куч.* Җиңел, җитез хәрәкәтле. *Тагын менә бу югарыга таба күтәрелүне, чиләк авырлыгын, әнинең йомшак адымнарын, артта энекәшнең сызгыргалап баруын тою – барчасы җанга тыныч бер рәхәтлек бирә.* Ә.Гаффар

11) *куч.* Күңелгә ятышлы, ягымлы; сөйкемле, мөлаем. *Туры сүз тимерне тишәр, йомшак сүз кылычны кисәр.* Мәкаль. *Ләкин карт аңа карамады, акрын, йомшак тавыш белән һаман иркәли биреп, аркадан, кабыргадан сыйпады.* Г.Ибраһимов. *Йомшак, назлы музыка кәефне күтәрә.* Т.Галиуллин

12) *күч.* Температурасы чагыштырмача югары булган, җылы; *киресе:* **суык**. *Йомшак, назлы дала җиле исә.* Р.Батулла. *Урта диңгезнең йомшак һавасы гасырлар буена табигый сайлау ясап, кешене камилләштерәме әллә?* В.Юныс. *Ишекне ачуга, йомшак яз җиле назлап чәчләрне сыйпады.* Н.Гыйматдинова

13) *күч.* Тәэсир итү көче аз булган, түбән градуслы (алкоголь, кислота һ.б.). – *Ә нәрсә ул коньяк? – дип соравыма: – Хатын-кызлар гына эчә торган иң йомшак эчемлек, – дип аңлаттылар.* Ф.Чанышева

14) *күч.* Тиешле дәрәҗәдә түгел, начар; әзерлексез, кимчелекле. *Киң танылган язучыларыбызның илһамланып, тирән уйланып иҗат ителгән, бер дигән әсәрләреннән соң ук әлеге авторларның иҗат мөмкинлекләреннән күп түбән, йомшак әсәрләре басылып чыкты.* Ф.Хатипов. *Үзеңдәге көчле һәм йомшак, уңай һәм кимчелекле сыйфатларны, холык-фигылеңдәге үзенчәлекләрне яхшы белү шарт.* Р.Низамиев

15) *күч.* Таләпчәнлек җитмәгән, кырыс, катгый булмаган, гуманлы. *Җинаятьчеләргә закон артык йомшак шул бездә.* З.Фәйзи

16) *күч.* Үз вазифасын начар башкарган, белеме түбән, әзерлеге җитешле булмаган. *Авыр якка, чиргә-бүсергә төрттерде ул, белем ягы сайрак иде шул Габдрахманның, урысчасы да йомшаграк.* Р.Сибат

17) *күч.* Буяуның, карандашның төсе артык ачык, җете булмаган. *Бу хатынның һәр рәвешен тасвирлау өчен, төрле буяулар, төрле стиль таләп ителер кебек. Әйтик, --- чәй янында кызы белән сөйләшкәндә – импрессионистларга хас йомшак акварель һәм нурлы да, томанлы да төсмерләр ---.* М.Маликова. *Илле тугызынчы меридиан белән унберенче параллель очрашкан җирдән бер сантиметр гына читтә йомшак карандаш белән кораб сурәте ясап куйганнар.* М.Юныс

18) *күч.* Составында минераль тозлар аз булган. *Дим елгасы Агыйделдән күпкә тар. Ул йомшак сулы.* С.Поварисов

19) *күч.* Эшләнеше, сыйфаты ягыннан начар булган. *Ашыгып ясаганлыктан, либертиларның корпуслары йомшак чыккан.* М.Юныс

20) *күч.* Кайбер диалектларга хас булганча, сөйләмдә нечкә әйтелә торган (мәс., *к, г* авазлары). *Дәү әнием минем соргылт күзле, йомры гына гәүдәле, күңелле итеп, чистайлыларга хас йомшак мишәр шивәсендә сөйләшә.* А.Расих

21) *күч.* Техник эшләнеше һәм комфортлылыгы ягыннан башкалардан югарырак класслы, уңайлыклары күбрәк булган. --- *очы-очка ялганып җитмәгән икән – «йомшак вагон» дипме, өстәп түләргә туры килде.* Ш.Галиев. *Рөстәм йомшак вагонга кайтып кергәндә, Яков Михайлович купеда ашапэчеп утыра иде.* Г.Кутуй

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Сизелер-сизелмәс, җиңелчә. *Йомшак кына искән җил белән селкенәләр, йөрәкне җилкендерәләр.* А.Алиш. *Мин аның кулы каты дип хәтерли идем, ә бу юлы кыюсыз, йомшак тотынды ул миңа.* М.Маликова

2) Ихтирам белән, ягымлылык күрсәтеп, хөрмәт итеп. *Йомшак сөйли, йомшак мөгамәлә кыла.* Г.Ибраһимов. *Дога тәмам булгач, патша хәзрәтләре ишан хәзрәтләреннән исәнлек-саулыгын, озын сәфәрне ничегрәк кичерүен йомшак кына сораша.* Ә.Еники. *Картының гадәттән тыш йомшак сөйләшүе аны сагайта, ул инде бөтен нәрсәне аңлаган, ләкин һаман да иренең эшен шаяруга алырга тели.* Р.Хәмид

3) Җайлап, ипләп, җиңел хәрәкәт белән. *Песи кебек әкрен, йомшак атлап йөри...* К.Хәмзин. *Абзый, гөрелдәп сөйләнә-сөйләнә, мине бүлмәгә алып керә, йомшак итеп урынга яткыра.* С.Хафизов. *Тикшерүчем телефон трубкасын йомшак кына итеп үз урынына куйды.* Г.Тавлин

4) Әкрен, сүлпән барган (темп, үсеш һ.б.ш. турында). *«Ярыш»тагы кимчелекләрнең башка хуҗалыкларда да күзәтелүен, [беренче секретарь] Шәвәлиев командасының йомшак эшләве нәтиҗәсе икәнлеген әйтте.* Ф.Садриев

**3. йомшагым** *и. мәгъ. тарт. форм.* Ярату, иркәләү хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Бака әйтте: «Матурым!», Керпе әйтте: «Йомшагым!»* Ш.Галиев

◊ **Йомшак авыз** Оештырып сүз әйтә алмаган, булдыксыз, пешмәгән. *Без үзебез дә шул йомшак авыз.* Ш.Камал. *Без үзебез дә шул йомшак авыз, күптән тотып өйләндерәсе генә бар иде.* Г.Камал. **Йомшак алтын** *эфв.* Кыйммәтле мех. *Бабам шунда баш приказчик булып, «йомшак алтын», ягъни затлы мехлар белән сәүдә итә башлый.* А.Хәсәнов. **Йомшак баш(лы)** *гади с.* Ахмак, тинтәк, акылы тулы түгел. **Йомшак җәеп, катыга утырту** 1) Күңелгә ятышлы сүзләр белән юмалап, уңайсыз хәлдә калдыру. – *Минемчә, Фәйзулла да астыртын гына дөнья болгата монда, – диде Тураев, кыза башлап. – Беләм инде аны, йомшак җәеп, катыга утыртырга дисәң, Хуҗаевка гына куш.* Т.Әйди. *[Миңзаһит:] Син, йомшак кына итеп җәеп, катыга утыртмакчы булдың инде, Сабитов, ә?* Ф.Садриев; 2) Каты бәрелмичә, гади сүзләр белән бик үтемле, тиешле нәтиҗә ясарлык итеп әйтү, тәнкыйтьләү. *Әнвәр Сергейның: «Тормыш алга барсын дисәң, көрәшергә өйрәнергә кирәк... Эчке мохиткә күмелеп, дөньяны үзгәртүне көтү – пассивлык», – дип әйткәннәрен исенә төшерде. – Йомшак җәеп, катыга утырту булып чыга бит бу...* Ә.Сәйфетдинов. **Йомшак җир** 1) *эвф.* Арт сан. *[Дүрәнкәсе] Аның аяк-куллары белән тыпырчынуын, кыбырсуын уйлап та бирмичә, йомшак җиренә иплән кенә шапылдата-шапылдата, һаман такмаклавында булды.* Н.Фәттах. *Маңгаена «мөгез» чыгуга да, тез күмәчләренең зәңгәрле-күкле күгәрүенә дә, йомшак җирнең суелып-чиләнеп чыгуына да чыдады рус малае.* Б.Камалов. *«Хәзер ул матур, саллы кулы белән яңакка китереп сылаячак яисә минем йомшак җирдә импортный итегенең эзен калдырачак».* Т.Галиуллин; 2) *к.* **йомшак як** (*1 мәгъ.*). **Йомшакка утыртып, какка аунату** *к.* **йомшак җәеп, катыга утырту**. **Йомшак күлү** *эвф.* Юмор. *Укучым, үзең дә сизәсеңдер инде, бу китаптагы мәзәкләрдә ике канат бар: берсе – тарихи факт, икенчесе – юмор, ягъни*

*йомшак көлү.* Т.Нәҗмиев. **Йомшак куллылык** Таләпчәнлек җитешмәү, катгый була белмәгәнлек, тиз килешүчәнлек. **Йомшак күңелле** Тәэсиргә тиз бирелүчән, әсәрләнүчән, кызганучан. **Йомшак кына итеп әйткәндә** Әдәплелек күрсәтү йөзеннән каты, усал сүзләр әйтүдән тыелып калуны искәрткәндә кулланыла. **Йомшак муен** Җебегән, кеше фикеренә тиз бирелүчән, тиз сынучан. **Йомшак сыйпап, каты егу** *к.* **йомшак җәеп, катыга утырту**. **Йомшак телле** Әдәпле, ягымлы, күңелгә ятышлы итеп сөйләүче. *Сабада практика үткәндә, Зөфәр Харисов, Әлфияне «йомшак телле» дип, бераз арттырып та җибәрде.* Т.Нәҗмиев. *Борчылма син аз гына да, энем, Тимәс сиңа җәбер-золымнар. Чәнечкеле ал гөл түгел, синең Бәрхет үскән йомшак телең бар.* Ә.Исхак. **Йомшак тотып катыга утырту** *к.* **йомшак җәеп катыга утырту**. **Йомшак түшәп, катыга утырту** *к.* **йомшак җәеп, катыга утырту**. **Йомшак урын** *к.* **йомшак җир**. **Йомшак як** 1) Җитешсез як, кимчелек. *Нурлыбикә сөйкемле сөяк Эдикның йомшак якларын белә.* Г.Кашапов. *Ят ирләрнең берсе: – Ну что же, хатын-кызга артык таләпчән килергә ярамый, – дип акыл өйрәтә иде. – Аның йомшак якларын кичерергә тиешбез.* М.Маликова. *Берберебезнең чамасын тарттык, йомшак якларын капшадык.* Ф.Хөсни; 2) Үз принципларына каршы барырга мәҗбүр булу, берәр нәрсәгә юл куючанлык, ирексездән бирелүчәнлек; 3) Бик бирелеп, артык мавыгып, кызыксынып башкарыла торган шөгыль. *Шуңар күрә бер йомшак ягым бар: табигатьне, урман кошларын бик яратам.* Ш.Маннур

**ЙОМШАК** II *и.* 1) *диал.* Калач, бодай икмәге. *Килен йомшакларны пичтән чыгарды гына* // **йомшагы** *тарт. форм.* Икмәкнең эчке өлеше. *– Малайлар үсте, эшкә ярады. Ай саен акча килеп тора, – диде карт, тешсез уртлары белән әкрен генә ипи йомшагын әвәләп.* Н.Фәттах. *Тагы бер мизгелдән кулыма ипи йомшагы тотып, күгәрченне куркытудан сагаеп, иплән кенә балкон ишеген ачтым.* Р.Мөхәммәдиев. *Хәлфә тегe балдакны, кесәсеннән тиз генә чыгарып, ипи йомшагына әйбәтләп төрә дә тәвә кошының алдына иплән кенә ыргыта.* Ә.Еники

2) **йомшагы** *тарт. форм.* Тере организмның тән тукымасы, тәненең итләч, мускуллы урыны

3) **йомшагы** *тарт. форм.* Яшелчәләрнең, җиләк-җимешләрнең тышча эчендәге итләч өлеше. *Алай да эчендәге йомшагы алынган кабак мисалында калмады остазы.* Җ.Рәхимов. *[Штрейфлинг алмаларының] Йомшагы аксыл-сары, кайчакларда алсурак та була.* А.Девятков, А.Макаревич

4) **йомшагы** *тарт. форм.* Баткак, балчыклы урын. *Авыл урамы су эчендә. Урамны иңләп бер комбайн туктаган, алгы корылмалары кара балчыклы юл йомшагына сеңгән.* М.Мәһдиев

**ЙОМШАКЛАНУ** *ф.* 1) Йомшак I **1.** (*2 мәгъ.*) хәлгә килү; йомшару. *Зарарланган җимешләр йомшаклана, чери.* Л.Мәүлүдова

2) *күч.* Йомшаклык күрсәтү, кырыслыгы киму. *Ә бу көнне Сәрия йомшаклана. Ушлырак ирләр шуңардан файдаланалар. Ниндидер четерекле кәгазьләргә кул куйдырырга киләләр.* Х.Камалов

3) *күч.* Салкынлык киму, җылыракка әйләнү, җылытып җибәрү. *Бәхеткә, климат әйбәтләнү, йомшаклану һәм җылыну ягына үзгәрде.* Р.Фәизов

**Йомшаклана бару** Торган саен ныграк йомшаклану

**Йомшаклана төшү** Бераз йомшаклану

**Йомшакланып бетү** Тәмам, бик нык йомшаклану

**Йомшакланып калу** Нинди дә булса вакыттан, вакыйгадан соң йомшаклану. *Тупас телле, каты куллы комсомол башлыгының йомшакланып калуына авылдашлары да игътибар итте.* Рифә Рахман

**ЙОМШАКЛЫК** *и.* 1) Йомшак (I) булу, батучан, тыгыз булмаган халәт; *киресе:* **катылык**

2) *күч.* Юл куючанлык, түзеп торучанлык; *киресе:* **таләпчәнлек**. *Житте туктаусыз эчү белән булашучыларга. Мондыйларга аз күрсәтмәдек йомшаклыкны.* З.Фәйзи. *Ашыгу белән икеләнү, тартышу, алдыңа килеп баскан мәсьәләне тиз генә хәл итә алмау – йомшаклык билгесе.* Р.Низамиев

3) *күч.* Мәрхәмәтлелек, рәхимлелек; *киресе:* **рәхимсезлек**. *[Потапов:] Мәгариф министры, әгәр студентлар арасында чуалыш була калса, йомшаклык күрсәтмәгез, дип, попечительне кисәтеп куйган.* Р.Ишморат

4) *күч.* Ягымлылык; *киресе:* **кырыслык**. *– Гөлгенә бүләге, – диде Әнвәр әнкәсенә генә дигән аерым бер йомшаклык белән.* Ә.Сәйфетдинов. *– Ярар соң, – диде әти, тавышына рәхимлек, йомшаклык билгесе чыгарып.* С.Хафизов

5) *күч.* Җылы булу, җылылык, рәхәтлек. *Көченнән килсә, бу сүзен кояш җылыларына, ай нурларына, су тәмнәренә, җилләр йомшаклыгына кушып әйтер иде.* Ә.Гаффар. *Йокы бүлмәләрендә ниндидер йомшаклык, серлелек [бар].* Ф.Яруллин

6) *күч.* Ихтыярсызлык, үзеңне кысаларда тота алмау. *Иремнең характер йомшаклыгы шунда күренде.* Ф.Галиев

7) *күч.* Тәҗрибә, сәләт җитеп бетмәгәнлек, белмәгәнлек. *Бу мәсьәләне төбеннән куптарып, өлкә оешмасына язмакчы идем, орфография ягы шәп булса да, урынына җиткереп язу ягыннан үземдә йомшаклык сизәм.* Р.Сибат

8) *күч.* Берәр нәрсә белән мавыгучанлык, артык бирелүчәнлек гадәте (еш кына начар, хупланмый торган эш турында). *Мопассан бер герое турында: «Аның иң зур көче һәм йомшаклыгы яхшылык иде», – дигән кызыклы фикер әйтә.* Р.Низамиев

**ЙОМШАКТӘНЛЕЛӘР** *и. зоол.* Йомшак тәнле умырткасыз хайваннар, моллюсклар; *русчасы*: **мягкотелые**. *Моллюсклар, яки йомшактәнлеләр, борынгы күптөкле бөҗралы суалчаннардан башлангыч алган умырткасызларның аерым тибын барлыкка китерәләр*. Биология

**ЙОМШАНУ** *ф. сир. сөйл. к.* **йомшару** (*2 мәгъ.*). *Мускуллар йомшану*

**ЙОМШАРТКЫЧ** *с.* Нәрсәне дә булса йомшарта, йомшак хәлгә китерә

торган. *Кастор мае элек-электән эч йомшарткыч дару итеп кулланыла.* Л.Мәүлүдова

**ЙОМШАРТУ** *ф.* 1) Йомшак хәлгә китерү, йомшак итү. *[Фәрихә карчык] Кунакларын келәткә алып кергәч, җәйгән урынын ятарга уңайлырак итеп йомшартты.* М.Юныс

2) Тырма, көрәк белән җирне көпшәкләндерү. *Муеннарына кызыл галстук таккан балалар, кояш белән торып акчага килеп, яшелчәләрнең төпләрен йомшарттылар, чүп үләннәрен утадылар.* А.Алиш. *[Сөембикә] Агач төпләре йомшарта.* Ф.Садриев. *Игеннәр шытып чыгалмыйча интегәләр иде, тырмага төштеләр, йомшарттылар җирне.* Г.Кашапов

3) Тәнне язу, мускулларның тартышуын, киеренкелеген киметү, хәрәкәтләндерү

4) Тартып, кысып торган берәр нәрсәне бушайтып җибәрү

5) *күч.* Кырыслыгын киметү; күндәмрәк, юашрак итү. *Соклану һәм мактау сүзләре белән, комплиментлар сибеп кенә йомшартасың хатын-кыз күңелен.* Р.Мөхәммәдиев. *Кызның һушны алырлык сылулыгы йомшарта каты бәгырьне.* Н.Сәйяр. *Председатель дә тавышын йомшартты.* Б.Камалов

6) *күч.* Авыртуын баса төшү, әрнүен киметү, җиңеләйтү

7) *күч.* Нәрсәнең дә булса көчен, дәрәҗәсен, халәтен, торышын, вазгыятьнең киеренкелеген киметү. *– Тыңлагыз әле, егетләр, – дидем мин, киеренке хәлне йомшарту теләге белән. – Яхшы чакта китеп югалыгыз.* Р.Сибат. *Хатын исә вазгыятьне үз кулына алып, хәлне бераз йомшартырга тели иде.* Ф.Сафин. *Әнил --- аннан соң бу авыр халәтне йомшартырга теләп: – Димәк, Себергә, этап белән, – дип куйды.* З.Хөснияр

8) *күч.* Эшнең барышын, темпын һ.б. акрынайту, сүлпәнләндерү

9) *күч.* Физик хәлсезләндерү, алҗыту, йончыту

10) *күч.* Җылыту, сындыру. *Кояш җылысы көнне шактый йомшарткан.* А.Вергазов. *Ә инде февраль бөтенләй йомшартты*. М.Хәсәнов

11) *күч.* Нәрсәнең дә булса катылыгын, әчелек көчен азайту, киметү

12) *күч.* Су составындагы тозларны эретү. *Сода суны йомшарта*

◊ **Йомшартып әйтү** Ипләп, җайлап әйтү, кискен сөйләшмәү

**Йомшарта бару** Акрынлап, аз-азлап йомшарту

**Йомшарта башлау** Йомшартырга тотыну. *Кызга ялынырга уйламаган егет, «сүз бетте» дигәнне аңлатып, мендәрен йомшарта башлады.* Р.Гаязетдин

**Йомшарта тору** Әле, хәзерге вакытта йомшарту. *– Яз килгәч, – диде, – боларны чәчәрсең. Туфракларын йомшарта тор!* Г.Ибраһимов

**Йомшарта төшү** Бераз, тагы да йомшарту. *[Давыт] Фәкать тавышын йомшарта төшеп: – Ярый, үзегез генә булдыра алмасагыз, әнә, Гаделша абзый ярдәм итәр, – диде.* М.Маликова. *Наташаның чәч учмасы Сәйдәрнең борын төбеннән үк узып китте һәм Сәйдәрнең болай да йомшарган ихтыярын тагын да йомшарта төште.* Г.Үзиле. *Ихтимал булган җәнҗаллар бәрабәренә минем белән килешергә тырышуың күңелне йомшарта төште.* Ә.Баянов

**Йомшартып алу** Вакытлыча, өлешчә, азга гына йомшарту. *Көн үзәгендә бераз йомшартып ала, чана юлларында елтыр күлләвекләр күренә башлый.* Р.Хафизова. *--- самолёт штурвалын түгел, гомерендә велосипед рулен дә тотып карамаган Иванга бомбардировщик белән идарә итәргә кушам. Бераз буыннарны йомшартып алырга исәп.* Р.Ибраһимов

**Йомшартып бетерү** Тулысынча, ахырына кадәр йомшарту; бөтенләй йомшарту

**Йомшартып җибәрү** Бераз, берникадәр, кинәт йомшарту. *Шундый ук осталык белән [юмор аша] катлаулы гына хәлләрне дә шактый ансат йомшартып җибәрергә мөмкин.* Р.Низамиев

**Йомшартып җиткерү** Тиешенчә йомшак хәлгә китерү. *Бераз яугаласа да, күп вакытка сузылмый һәм аяк астын бөтенләй йомшартып җиткерә алмый.* Х.Мөҗәй

**Йомшартып йөрү** Әле, хәзерге вакытта йомшарту белән мәшгуль булу. *Анда чандыр гына гәүдәле бер карт помидор төбе йомшартып йөри иде.* Г.Гыйльманов

**Йомшартып карау** Йомшартырга тырышу, йомшартырга омтылу. *– Килен, кара әле, – диде, – соң без моны кул тырмалары белән йомшартып карасак, ничек булыр икән, ә?* Г.Бәширов

**Йомшартып кую** Йомшарткан хәлгә китереп калдыру. *Кешегә ачуланып, дөп-дөресен кискен итеп әйтәсең дә, соңыннан шаяртып, бер җөмлә белән йомшартып куясың.* Ш.Галиев. *Мостафа тиз генә сәкегә чоланнан каты киез алып кереп салды, урын җәймәсен җәйде һәм мендәр йомшартып куйды.* Т.Нәбиуллин

**Йомшартып тору** Еш, һәрвакыт яки хәзерге моментта йомшарту. *Саф һава, кояш нурлары --- [трактор] тавышын чистартып, йомшартып тора шикелле.* М.Юныс. *Авыр балчыклы туфракларда крыжовникның рәт араларын еш кына йомшартып тору яхшы.* А.Девятков, А.Макаревич. *Ул тагы да озак кына авыз эчендә әллә тормышның каты почмакларын чәйнәп йомшартып торды, аннары гына әйтеп куйды: – Сиңа яшәү җиңел булмас.* Р.Нуруллина

**Йомшартып чыгу** Башыннан ахырына кадәр, бер-бер артлы йомшарту. *Тукландырганнан соң, рәт араларын йомшартып чыгалар, ә үсемлекләрнең төпләрен өяләр.* А.Девятков, А.Макаревич

**ЙОМШАРУ** *ф.* 1) Йомшакка әйләнү, йомшаграк хәлгә килү

2) Су, дым, җылылык тәэсирендә җебү, изрәү (мәс., юл). *Чөнки боз көпшәкләнгән, йомшарган, ярылырга гына тора.* Ф.Ибраһимова

3) Тән язылу, тәннең берәр әгъзасы хәрәкәтчәнрәккә әйләнү. *Шунда гына келәшчәдәй кыскан бармаклар йомшарды.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. *Тренировкасыз мускуллар йомшара*. М.Юныс

4) *күч.* Кырыслыгы, таләпчәнлеге киму, күндәмләнү, юашлану. *[Мөсафир Бәдретдин абзыйга] «Мин сезне под суд җибәрермен», – дип, авыл*

*халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара әти-әни йомшардылар.* Г.Тукай. *Алай да мин шул сүзләрне әйткәч, ул бераз йомшарды булса кирәк.* А.Әхмәт

5) *күч.* Елау, күңел тулу. *Вакыт-вакыт Күңел йомшара да Дәфтәр бите яшькә чылана...* Х.Туфан

6) *күч.* Басыла төшү, бераз җиңеллек килү. *Таңга таба авыртуы бераз йомшарды*

7) *күч.* Эшнең барышы, темпы һ.б. акрынаю

8) *күч.* Тиешле дәрәҗәдә булмау, көче, киеренкелеге, тәэсир көче кимү. *Ләкин ул кеше [Гали абый] миннән алдарак председатель итеп сайланып куелган, ул эшне тарта алмаганлыктан, дисциплина йомшарган.* Ф.Галиев. *Хәзер тәртип йомшарды.* М.Хуҗин. *Мисаллардагы аерым-аерым җөмлә итеп бирелгән сүзләрне тиңдәш кисәкләргә әверелдерсәк, сөйләмнең тәэсир көче бөтенләй йомшара.* Х.Курбатов

9) *күч.* Физик хәлсезләнү; алҗу, йолчу. *Кинәт Фәхри абыйның тавышы ерагайганнан-ерагая башлый, күз кабакларым авыраеп йомылалар, аякларым йомшара...* А.Гыйләҗев. *Илгиз аңа таба якынлашканда, Фәния әлеге куркынычны аерата сизә иде: аның аяк буыннары йомшара, сулышы ешая, йөрәк каядыр корсак төбенә төшеп тибә башлый...* Р.Зәйдулла

10) *күч.* Салкынлык сизелерлек кимү, җылыту. *Суыклар тәмам йомшарды, матур аяз көннәр башланды.* Ә.Сәйфетдинов

11) *күч.* Нәрсәнең дә булса катылык, әчелек сыйфаты кимү

12) *күч.* Матди як начарлану, акча җитмәү

13) *күч.* Тупаслыгы, кырыслыгы кимү (сүз, тәнкыйть, тавыш һ.б.). *Күзләрендә әүвәлге салкын бозның әсәре дә юк, боз эрегән, карашы йомшарган.* Н.Гыйматдинова. *Кешегә башта каты бәрелә торган гадәте булса да, соңыннан шактый ук йомшара да белә иде.* Ә.Еники

14) *күч.* Исерү. *Яңа ел кичендә ярыйсы гына йомшарып, наян кешенең шаян сүзе итеп, Алмазның телен тарткалап карарга да әзерләнеп килгән иде [Әкълимә].* З.Садыйков. *Карт, аракыдан тәмам йомшарып, хәлсезләнеп төшкән иде.* Р.Мөхәммәтҗан

**Йомшара бару** Торган саен ныграк йомшару, акрынлап йомшару. *Үз халкыннан шүрләп, Мәскәү кальгасында бикләнеп утырган Чулак Зәнки, Бөек Империясендә кодрәте йомшара барганын сизеп, ил өстенә үзенең опричникларын өсләтте.* Т.Мөбарәков. *--- утраклыкка көчләп күчерелгән казаклар, төрекмәннәр, кыргызлар, Кавказдагы нугайлар үзләренең яшәү дәртен, активлыгын югалтып, йомшара баралар.* М.Әхмәтҗанов

**Йомшара башлау** Йомшарырга тотыну. *Бу – каткан бәгырьнең әкренләп йомшара башлавы иде бугай.* М.Хәсәнов

**Йомшара төшү** Бераз йомшару. *Әрнеп әйткәч, егет бераз йомшара төште.* Н.Гыйматдинова. *Картның мөгамәләсе дә торган саен йомшара төште.* Т.Әйди. *Сергей да сабырлана калды, баягы катгыйлык та, таләпчәнлек тә беркадәр йомшара төшкәндәй иде хәзер.* Ә.Сәйфетдинов

**Йомшарып алу** Кыска вакытка йомшару. *Ана күңеленең йомшарып алуын кыз да сизеп алды.* Р.Мөхәммәдиев

**Йомшарып бетү** Тулысынча йомшару, тәмам йомшару. *Бераз суына төшкән егетнең күкрәкләреннән үзенең үбешә-үбешә йомшарып беткән иреннәре белән кытыкларга тотынды.* Ф.Яхин

**Йомшарып җитү** Тиешенчә йомшарган булу

**Йомшарып калу** Ниндидер сәбәптән, тәэсирдән соң йомшару. *Әчтән исә бөтен мускуллары бу кулның матурлыгыннан йомшарып калган сыман иде.* Х.Камалов

**Йомшарып китү** Берәр тәэсирдән соң кинәт йомшару. *Кинәт [тракторчы егетнең] кырыс йөзе йомшарып китте.* Н.Фәттах. *Әхмәтсафаның миһербанлы, игелекле булып, алар өчен борчылуын күреп, [Хәлимә апайның] күңеле йомшарып китте.* Ф.Сафин. *Алтынчәчнең нык гасабиланганын, теләсә нинди тәвәккәллеккә әзер икәнлеген күреп, Резеда Фәритовна аның тупаслыгын үткәреп җибәрде, киресенчә, йомшарып китте.* М.Маликова

**Йомшарып тору** Әле, хәзер йомшарган хәлдә булу. *Әллә ничек, буыннар йомшарып тора.* Г.Гыйльманов

**Йомшарып төшү** Тәмам йомшару. *Танышкан көннәреннән үк, Гаярның көчле куллары үз тәненә килеп тиюгә, Нурлыбикә ирексездән тынып кала, йомшарып төшә, тавыш-тынсыз гына аның көченә буйсына.* Г.Кашапов

**ЙОМШАТУ** *ф. к.* **йомшарту**. *Карлен Татлян шундый сирәк очрый торган кешеләрдән иде: аны спиртлы эчемлекләр йомшатмый, ә киресенчә, эшчәнлеген генә арттыра.* Р.Мирхәйдәров. *Яманлык күреп күңел ката, ә Хәтирә кебекләр каткан күңелләрне йомшата.* Г.Афзал. *Менә аяклар җиргә тиде, Рифкать тез буыннарын йомшатып чүгәләде.* Р.Вәлиев

**Йомшата төшү** *к.* **йомшарта төшү**. *[Алинә] Тавышын йомшата төшеп: – Ашыйсың килгәндер әле синең, – диде дә этнең алдына кәнфит ыргытты.* Н.Каштанов

**Йомшатып җибәрү** *к.* **йомшартып җибәрү**. *Өстәл янына килеп утыруга, әнисенең караңгы белән үк торып аны кайгыртып йөрүе Гайнанның күңелен йомшатып җибәрде.* Г.Бәширов

**ЙОМШÁУ** *ф. сөйл. к.* **йомшару**. *Моңарчы нык торган саннары йомшап, буыннары сыекланып киткәндәй булды.* З.Фәйзи. *Держава эчендә бердәмлек йомшый.* Г.Дәүләтшин. *Безнең ныклы сафны күргәч, йомшады егет, дусларча гына орышкандай итте.* А.Гыйләҗев

**Йомшап бетү** *к.* **йомшарып бетү**. *[Тавыклар йөри торган юлның] Туфрагы йомшап беткән, аны кул белән казып тирәнәйттеләр, як-ягындагы ташларны сак кына кузгатып киңәйттеләр.* М.Галиев

**Йомшап китү** *к.* **йомшарып китү**. *Һәм кинәт кенә Карленның йомшап киткән миеннән бер уй йөгереп үтте, ул шундук айнып китте.* Р.Мирхәйдәров. *Тез буыннары йомшап китте Габделсәлимнең.* Җ.Рәхимов. *Иректәнең таштай каткан күңеле йомшап китте.* Ф.Садриев

**Йомшап төшү** Бирешү, юл кую; куркытуга, кызгандыруга яки мактауга бирелү. *Башта каты торган кебек иде, аннан тагы үзе йомшап төште.* Н.Исәнбәт

**Йомшый бару** Торган саен ныграк йомшау. *Әйтерсең аның бөтен гәүдәсе камыр сыман булып йомшый барды, йомшый барды да, ниһаять, рәхәт кенә сызлатып торган ниндидер татлы бер караңгы эченә иңеп, эреп бетте.* Г.Бәширов. --- *борынгы профессиональ җыручы-чичәннәрнең бетүе һәм башка шундый сәбәпләр аркасында мәкаль иҗатчылыгында бу алымнар, билгеле, кими, йомшый барган.* Н.Исәнбәт. *Кар азая, күзгә күренеп юкара, йомшый бара.* Г.Якупова

**Йомшый башлау** Йомшарга тотыну. *Урманчыларның йомшый башлаган буыннарына хәл керде, йөзләре алсуланды.* Г.Гыйльманов

**Йомшый төшү** *к.* **йомшара төшү**. *Әби калдырган «поминка» аракысыннан поп нык кына йомшый төшкән иде инде.* Р.Сибат. *Асяның аңа карата күңеле йомшый төште.* Х.Камалов. *Шулай да хатның ахырында тагын йомшый төште.* Г.Бәширов

**ЙОМЫК** *с.* **1.** 1) Йомылган, ябык. *Гәүдәләре чайкалып-чайкалып куя, иреннәре йомык. Йомык булсалар да, чык тамчылары кунгандай, елык-елык килә, көлә, елмая сыман үзләре.* Р.Мөхәммәдиев. *[Электр лампасының] Яктысы йомык күзгә дә сизелерлек.* Г.Тавлин

2) Очлары үзара тоташкан, әйләнеп, түгәрәк ясап ялганган. *Кан әйләнеше – бер йомык түгәрәк.* З.Хисамов. *Тимер чаршау гамәлдә булган чорда без СССРның йомык түгәрәге эчендә яшәдек.* Р.Хәкимов. *Электромагнитик индукциянең төп законы: йомык контурда барлыкка килгән индукцион электр йөртү көче зурлыгы буенча контур белән чикләнгән өслек аша узучы магнит агышының үзгәрү тизлегенә тигез.* Магнитик күренешләр физикасы

3) Чыгу юлы булмаган, томаланган, хәрәкәтсез. --- *алардагы фикер сөреше телне аерым шәхес белән генә чикләп, хәтта аңардан да аерып алып, катып калган махсус йомык система итеп карарга, шуның белән аның иҗтимагыйлыгын инкяр итәргә юл калдыра.* И.Низамов. *Йомык күл*

4) Төзәлгән, бөтәшкән. *Ни дип, нәрсәгә өметләнеп сөйләшеп торам, йомык яраны тырныйм?* А.Гыйләҗев

5) *лингв.* Сөйләм органнары арасында йомыклык хасил итеп барлыкка килгән (мәс., *[м], [н], [ң], [п], [б]* һ.б. тартыклар). *Йомык авазларны әйткәндә, сөйләм органнары арасында йомыклык хасил була.* Ф.Сафиуллина. --- *[б] – шаулы, йомык, саф, яңгырау ирен-ирен тартыгы, [п] авазының яңгырау пары.* Н.Максимов

6) *күч. к.* **йомыкый**. *Кара Йомагол йомык кешеләрдән санала, «аның авызыннан сүзне көрәк белән каерып алырга кирәк» диләр.* М.Кәрим. *Йомылды әбием, дип уйлады Аюхан, файдасыз икәнен белгәнгә сүз озайтмады. Юкка гына кушмаганнар инде аның әбисенә «Йомык Һәдия» дигән кушаматны.* Г.Якупова. *Шактый ук йомык, аз сүзле күршесенең гәп сатарга шулкадәр үк сәләте бардыр дип, Газиның башына да килгәне юк иде.* М.Хәсәнов // Аң дәрәҗәсе түбән булган. *Халыкны калада яшәүче культуралыга һәм салада яшәүче йомык авыл кешесенә бүлүнең шактый очраклы, авыл кешесе өчен кимсетүле булуы турында уйлап куйды Габдрахман.* М.Юныс

7) *күч.* Җансыз, тавышсыз, үтә тын. *Мондый авыр, йомык тынлык мәет чыккан өйдә генә була.* М.Юныс

8) *күч.* Караңгы чырайлы. *Соклану-ярату кебек сирәк килгән мизгелнең рәхәтен эчкә яшереп, йомык чырай белән кабул итә алмыйм.* М.Галиев. *Минем белән бер аранга туры килгән эре сөякле, какча гәүдәле, йомык чырайлы кеше утлыклардан куралы печән калдыклары алып килде.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* Ашказаны, карын; авыз, тамак. *Тапканын – тамагына, йотканын – йомыгына.* Әйтем

◊ **Йомык авыз** Кирәк сүзен дә әйтә алмаган, юаш кеше

**ЙОМЫ́К КАЛТЫРАУЛЫ** *с. лингв.* Сөйләм органнарының бер йомылып, бер ачылып, тел очының яисә кече телнең калтырап торган вакытында ясалган (мәс., *[р]* авазы)

**ЙОМЫКЛАНУ** *ф.* Йомык (*2 мәгъ.*) кешегә әйләнү

**Йомыклана төшү** Бераз, бернигадәр йомыклану, тагын да йомыклану. *Бердән, әсирлектә легионерларның күңелләре йомыклана төшкән, күп нәрсәгә ышанмыйлар да бугай.* Г.Әпсәләмов

**Йомыкланып бару** Торган саен йомыклыгы көчәю

**Йомыкланып бетү** Тәмам йомыкыйга әйләнү

**Йомыкланып калу** Нинди дә булса хәлдән, вакыйгадан соң йомыклану

**Йомыкланып китү** Соңгы вакытта, хәзер кемдә дә булса йомык кешегә хас сыйфатлар барлыкка килү

**ЙОМЫКЛЫК** *и.* Йомык (*1, 2 мәгъ.*) булу. *Әйе, әлегәчә йомыклыкта яшәгән татар халкы --- 1905 елгы революция чорында беркадәр ирек ала, иркенрәк сулый башлый.* Л.Хәмидуллин. *Чөнки элекке чорларда, тормыш шартлары никадәр авыр булса да, милләтебез соңгы дәверләрдәге кебек йомыклыкта яисә тик берьяклы гына мөнәсәбәттә яшәмәгән иде.* Мирас

**ЙОМЫ́К ӨРЕЛМӘЛЕ** *с. лингв.* Сөйләм органнарындагы йомыклык ярыкка күчә барганда ясалган (мәс., *[ц], [ч]* һ.б.ш. авазлар). *Бу яктан тартыклар «йомык-өрелмәле», «ярым йомык-калтыраулы» дигән төркемнәргә бүленәләр.* Х.Сәлимов

**ЙОМЫ́К ҮТЕШЛЕ** *с. лингв.* Сөйләм органнары йомылганда, сөйләм каналының бер өлешендә бераз ачыклык калган вакытта ясалган (мәс., *[л], [м], [н], [ц]* һ.б.ш. авазлар). *Кайчак сөйләм органнары йомылганда, сөйләм каналының бер өлешендә бераз ачыклык кала. Бу вакытта катлаулы артикуляциягә ия булган йомык үтешле авазлар ясала.* Ф.Сафиуллина

**ЙОМЫ́К ШАРТЛАУЛЫ** *с. лингв.* Сөйләм органнарының берәр урында йомылуы һәм шул йомылуның шартлап ачылуы нәтиҗәсендә ясала торган (мәс., *[б], [д], [г], [к]* һ.б.ш. авазлар). --- *сөйләм органнары тиз генә ачылалар, һәм шул вакытта авазлар ясала.*

*Аларны «йомык-шартлаулы авазлар» диләр.* Ф.Сафиуллина

**ЙОМЫКЫЙ** *с.* 1) *сөйл.* Аралашмаучан, кешеләрдән аерылып яшәгән, үз эченә бикләнгән. *Кайчандыр тын гына, йомыкый гына күренгән классташың рухи яктан шулкадәр үскән, акыллыланган: сөйләшүенә, үз-үзен тотышына таң каласың.* Р.Низамиев. *Бу якта халык йомыкый. Зур су буенда яшәгән халык белән сөйләштерергә иде сезне. Вәт, сайрап торалар алар.* Ф.Сафин. *[Урманчы] Йомыкый кеше, аралашырга яратмый торган.* Ф.Галиев

2) Аң дәрәҗәсе түбән булган, акыл үсеше артта калган. *Күзе тонганчы чөмерде! Йомыкый!* А.Гыйләҗев. *Тик зерә дә надан Рәсәй кешесе, караңгы, йомыкый.* Г.Бәширов

3) *диал.* Күз кисеме кысынкы булган

◊ **Йомыкый авыз** Артык күп сөйләшми торган, үз-үзенә йомылган кеше турында. *Һи, йомыкый авыз, торасың шунда бер сүз дә әйтә алмыйча.* Н.Исәнбәт

**ЙОМЫКЫЙЛАНУ** *ф.* Йомыкый булу, йомыкыйга әйләнү. *Кеше белән сөйләшми, йомыкыйланган.* Р.Хисмәтуллин

**Йомыкыйлана бару** Акрынлап, көннән-көн йомыла бару, йомыкыйлыгы арту

**Йомыкыйлана төшү** Бераз, тагы да йомыкыйлану. *Туйда Георгий, эчеп алгач, Зинаның сүзсез генә моңаеп утыруына тәкәллефсез җавап кайтара, хәтта рәнҗетә дә. Зина тагын да йомыкыйлана төшә.* Ф.Углов

**Йомыкыйланып китү** Нинди дә булса сәбәп белән йомыкыйлык сыйфатларын алу

**ЙОМЫКЫЙЛЫК** *и.* Йомыкый булу. *Халык язмышы өчен борчылучылар, аны йомыкыйлыктан аерып, йокысыннан тизрәк уятырга ашкынучы алдынгы фикер ияләре көрәш мәйданына күтәрелделәр.* Л.Хәмидуллин. *– И-и, йомыкый да соң син, – диде ул миңа, әле һаман да сүз әйтергә кыймавымны йомыкыйлыкка санады.* М.Хуҗин

**ЙОМЫЛУ** *ф.* **1.** 1) Ябылу, бер-берсенә тию, орыну (иреннәр һәм күз кабаклары турында). --- *маңгаендагы ал постаудан тегелгән дәү кызыл йолдыз астында зәңгәрсу күзләре бер йомыла, бер ачыла.* Г.Бәширов

2) Үсемлекләрнең чәчәк яфракчыклары кире үз-үзенә җыелу. *Төнгә каршы чәчәк үзе дә йомыла.* К.Кәримов. *Нәҗип салкынга эләккән чәчәк кебек һаман йомыла, куырыла бара.* Ф.Яруллин. *Көннәрдән бер көнне чәчәкләр үстерергә яратучы Ләбибә апа Ихсанова дачадагы өеннән минем яныма килде. «Ишеткәнең юкмы, кичен йомылып, иртән ачылучы бер чәчәк бар икән, шуның исемен белмисеңме?» – диде ул.* И.Юзеев

3) Җәрәхәт, яра кибеп төзәлү

4) *к.* **йомарлану** (*3 мәгъ.*). *Бөтен энергиясен бер йодрыкка җыеп, алга сикерергә әзерләнгән барс шикелле йомыла, кечерәя, көч туплый.* Х.Ширмән

5) *күч.* Берәрсе күрмәслек, тапмаслык итеп, нәрсәнең дә булса артына яки эченә кереп яшеренү; ышыклану. *Бүген качарга дип карар кылган өч әсир, --- балчык өемнәре арасыннан кача-поса килделәр дә торба эченә кереп йомылдылар.* М.Галиев

6) *күч.* Бәхәсләшүдән туктау, ризалату, сүз көрәштерми башлау. *Анда да әле кызлар: «Атмаган куянның итеннән Хәйдәргә – бәлеш, тиресеннән – Зәкәриягә тун», – дигәч кенә авызлары йомыла.* Ф.Яруллин

7) *күч.* Кешеләрдән ераклашу, читләшү; үз-үзенә бикләнү. *Әнисе көннән-көн усаллана, телчәнләнә, ә этисе исә үзалдына йомыла, суына бара.* З.Фәйзуллин. *Ул инде тәүге көннәрендәге кебек ачыш-табышларына да куанмый башлады, кешеләрдән читләште, йомылды.* М.Әмирханов. *Нәби көн саен йомыла, ваемсызлана бара.* К.Тимбикова

8) *күч.* Карьерасы үсмичә калу; берәр нәрсә белән чикләнү. *Артистлык карьерасы йомылу*

9) *күч.* Үзеннән-үзе хәл ителү, онытылу, бетү. *Шуның белән Хәлиулла вакыйгасы йомылды.* Н.Гыйматдинова // Төгәлләнү, тәмамлану. *Ни дәлил, ни шаһит юк иде, эш шуның белән йомылды.* Н.Гыйматдинова

10) *күч.* Бер-беренә якын килү, кулга-кул тотышып бердәм үзәккә таба хәрәкәт итү. *Төркем әле кысылып йомыла, әле таралып җәелә.* Ә.Гаффар

11) *күч.* Юкка чыгу, кушылып, эреп югалу. *Әмма, бераз баргач, әлеге эзләр дә юкка чыкты: ком өстендәге тояк эзләре йомылган иде.* Р.Батулла. *Елгалар, исемен җуеп, диңгез кочагында йомыла.* М.Галиев

**2. йомылып** *рәв. мәгъ.* 1) Тынычланып, дөньясын онытып. *Ирең утыра синең каршыңда, Ул сәҗдәгә киткән кебек утыра, Барыннан ваз кичеп, йомылып.* С.Хәким

2) Тырышып, бар булдыклылыгын куеп. *Күр абыеңны: йомылып эшләп йөри. Басымчак, сүз тыңлаучан.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Барлык көчкә, атылып, ыргылып. *Сөн буеның яшь куаклар каплаган сөзәк иңкүлегеннән йомылып чабып, ат көтүе кайта.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Шым гына, сиздермичә, күздән югалырга тырышып. *Ул арада шым гына арт ишек ачылды, Зәйнәп йомылып юк булды.* А.Гыйләҗев

**Йомыла бару** Эзлекле рәвештә, аз-азлап, акрынлап йомылу, йомылуы акрынлап көчәю. *Әмма Маринкин көннән-көн йомыла бара.* Х.Камалов. *Җир җимертеп әлләниләр эшлисе урында, ул үз эченә йомыла бара.* К.Тимбикова. *Ярлары камышлык, яшел суүсем каплаunion йомыла барган күл кебек.* М.Галиев

**Йомыла башлау** Йомылырга тотыну. *Утка карап утыра торгач, ничә төннәр йокы күрмәгән күзләре йомыла башлады.* Н.Хәсәнов

**Йомыла төшү** Бераз, берникадәр йомылу. *[Зөһрәгөл] Бала тапканнан соң бөтен көнен өйдә, ишегалдында бөтерелеп, --- ипи салып, аш пешереп, төтенле учакка таба мүкәләргә тотынган кызларын багып уздыра башлагач, үзеннән-үзе сүрәнләнә, йомыла төште.* Т.Әйди. *Әйе, чак кына тазара төшкән ахры, йөзе түгәрәкләнгән, соргылт күз кабаклары йомыла төшкән.* А.Расих

**Йомыла язу** Аз гына йомылмый калу. *Су читендә уйдык-уйдык су бөтнекләре, кояш нурларында күзләре йо-*

*мыла язган төн миләүшәләре, йөнтәс күрәннәр.* Ф.Шәфигуллин

**Йомылып алу** Кыска вакыт эчендә берничә тапкыр йомылу. *Аның керфексез кызарган күзләре куркынып челт-челт йомылып алды.* М.Юныс. *Карчыкның күзләре челт-челт йомылып алды, ул пышылдап: – Балакаем... – диде.* Г.Бәширов

**Йомылып бару** *к.* **йомыла бару**. *Әнә тагын берсе, күрәсең, ничек йомылып бара.* Ш.Камал. *Ул йомылып барган керфекләре арасыннан Янчуринның ут сүндерергә дип үрелгәнен күреп калды.* Ф.Садриев. *Йомылып бара Яралар да, Сабырлана бара Холыклар.* Л.Шарова

**Йомылып бетү** Тулысынча йомылу, йомылган хәлгә килү. *Көлгәндә дә аның уң күзе ачылыбрак кала, сул күзе бөтенләй йомылып бетә.* М.Галиев. *[Аның] Бер керфеге калмаган күзләре кысылып, йомылып беткән.* Н.Фәттах. *Чәй әзерләп китергән арада күрәм: Гыйлемдарның күзләре үк йомылып беткән.* Х.Сарьян

**Йомылып йөрү** Йомылган хәлдә булу, шулай дәвам итү. *Язучының үзүзенә бикләнеп, йомылып йөрүенә күнегеп бара инде.* Ф.Сафин

**Йомылып калу** 1) Кинәт йомылу. *Ханша әле елмая-көлә, шатлыктан тау чишмәседәй чылтырый башлый, әле елга өстенә төшкән иртәнге томан кебек тынып, йомылып кала.* М.Хәбибуллин. *Ишек тоткасына тотынган Сәмигулла абый ишетелер-ишетелмәс итеп кенә «өч тәңкә» дип кабатлады, ачык ишектән кергән суык пар эчендә йомылып калгандай юкка чыкты.* Н.Кәримова. --- *һәрбер нәрсә белән кызыксына торган, дәртләнеп, ялкынланып сөйли белә торган, үз фикерләрен яклый белә торган егет тынып, йомылып калды.* Н.Фәттах

2) Бөтенләй, тулысынча йомылу; үзеннән-үзе йомылу. *Моны искә алуы да авыр. Иң кара хатирә бу. Калсын, үткән көннәр белән йомылып калсын.* Н.Гыйматдинова. *Чибәркәеваның мәгънәсез үлеме турында курска килгән врачлар арасында да сүз күп булды, мондый сирәк очрый торган вакыйга йомылып каламы соң?!* Г.Әпсәләмов

**Йомылып килү** Акрынлап йомылу, төзәлә башлау. *Йомшак җир өстенә кайчандыр тирән яра булып төшкән көпчәк эзләре дә йомылып киләләр.* М.Рәфыйков

**Йомылып китү** Көтмәгәндә, искәрмәстән йомылу. *Аяк өсте кайтса да, күзләре йомылып-йомылып китәләр.* М.Вәлиев. --- *аның сайраганда бер үрелеп, бер киерелеп һәм бер йомылып киткән тамак астын минем үбәсем килә.* Ш.Әхмәдиев

**Йомылып тору** Билгеле бер вакыт эчендә, вакытлыча гына йомылган булу. *Ваһапов ике учы белән колакларын томалады, эчендә нидер авыртудан күзләре дә йомылып торды.* Х.Камалов. *Әйтерсең лә ул кара күзләр юри генә йомылып торганнар.* М.Әмир

**Йомылып яту** 1) Тиешенчә файдаланылмау, үстерелмәү (белем, тәҗрибә, талант, хис һ.б.ш. турында). *Бәлки әле малайның атасына карата җылы хисләре уянып та җитмәгәндер. Ул әле үзен сиздермичә, күңел түрендә йомылып ятадыр.* Л.Ихсанова

2) Актив эшчәнлек күрсәтмәү, пассив булу. *Аларның сүзләре – Мостафаның йөрәгендә бик тирән йомылып яткан тойгыларны, --- ачулы уйларны --- кабызып җибәрделәр.* К.Нәҗми

**ЙОМЫЛУЧАН** *с.* Йомыла торган. *Андый вакытларда Мотаһир үйхисләренә бирелүчән, үз-үзенә йомылучан булып китә.* Р.Кәрами

**ЙОМЫЛЫР-ЙОМЫЛМАС** *с.* Ярым йомык, ярым ачык; ярым йомылган. *Нәҗипнең, тамак туйгач, йомылыр-йомылмас күзе шардай ачылды.* А.Гыйләҗев

**ЙОМЫРКА** *и.* Кошларда, кайбер җәнлекләрдә (мәс., ташбака, крокодил һ.б.да) озынча түгәрәк формадагы, төрле төстәге кабык белән тышчаланган күкәй күзәнәге. *Әби ак тавыгын бик ярата, аны төрле тәмле җимнәр белән сыйлый, ә йомыркаларын иләккә җыя бара.* А.Алиш. *Аннары атна кичләрен авыл малайлары боларга, сәдака итеп, әз-мәз онын, ярмасын, йомыркасын, сөтен дә китергәлиләр икән.* Ә.Еники. *[Әни] Пешкән йомыркаларны, калын итеп киселгән кызылык кисәкләрен минем алга этәрә.* М.Галиев

◊ **Йомыркадан җөй эзләү** *к.* **йомыркадан сап тапкан**. *Аны күренекле язучы-публицист, бигрәк тә «Чаян» журналындагы мут хикәяләре белән танылган, һәр нәрсәне тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, «йомыркадан җөй эзли» торган Мәгъсүм Гәрәев карап чыккач та, бәйләнер урын таба алмады.* Т.Нәҗмиев. **Йомыркадан сап тапкан** Булмаган гаепне күрүче кеше турында. **Йомыркадан чыкканчы әтәч булган** Тәҗрибә тупламаган килеш, үзеннән акыллылардан, белемлеләрдән өстен булырга омтылучы яшь кеше турында. **Йомырка сарысы кипмәгән** Тәҗрибәсез, яшь. **Йомыркасы бар тавык кебек [әйләнә]** «Урын тапмый, һаман бер тирәдә әйләнгәләп йөри» мәгънәсендә. **Йомырка эчендәге сары кебек** Иркәләнеп, назланып яшәүче кеше турында. **Йомырка эчендәге чебеш** Дөньяның асылын белмәгән, күрмәгән, татымаган: тәҗрибәсез, иркә. *Ул малай нәрсә генә әле? Анасы куеныннан чыкмаган сабый, йомырка эчендәге чебеш.* Н.Исәнбәт

**ЙОМЫРКАЧЫ** *и.* Йомырка җыючы, йомыркалар сатучы. *Бер уен битте, кычкырыну нәүбәте йомыркачыга җитте. Ул егермене «егерме» дип әйтә алмыйча – «ике дистә», унбишне «дистә ярым» дип куя иде.* К.Тинчурин

**ЙОМЫРЫК** *и. сөйл. сир.* 1) *к.* **йодрык**. *Колчак керде Иркутск төрмәсенә, Утырттылар как йомырыкны җилкәсенә.* Н.Хәким

2) Төен. *Фәрдүс Зәбиховның күзләре шарайды, «әһ» итте дә теле төенләнде. Бугазына йомырык килеп тыгылды, һәм күзләре йомылып бетә язды.* М.Хуҗин

**ЙОМЫРЫЛЫП** *рәв. диал. к.* **йомылып** (*3 мәгъ.*). *Миннән биш-алты гына сажин калышып, йомырылып теге дә килә!..* М.Хәсәнов

**ЙОМЫЧКА** *и.* Агачны яки металлны эшкәрткәндә киселеп, чабылып, юнылып чыккан вак, юка кисәкләр. *Пуля кече капканың тактасын тишеп чыкты, Гата карт аяк астына йомычкалар очты.* М.Хәбибуллин. *Мин*

*кулымны суппорт токкасына тидердем. Сак кына бордым һәм үткен корыч кискечнең патрондагы металлны «ашап», төтенле йомычка бөтерә башлавын күрдем.* А.Расих. *[Акмал] Галанка мичкә башта газета кисәкләре йомарлап салды, аннары балта белән бер пүләнне йомычкага ярып, пөхтәләп өйдә дә ут элдерде.* Г.Ахунов

◊ **Йомычканы йомыш итеп** Юк нәрсәне, вак-төяк эшне сәбәп итеп. *Йомычканы йомыш итеп йөрмә.* К.Тимбикова

**ЙОМЫЧКА́ БАЛЫК** *и. зоол.* Сельдь балыклары семьялыгыннан озынча тар һәм вак балык; *русчасы:* **килька**. *Биш-алты тачка йомычка балык, сельдь, унбиш-егермеләп биреш, эре генә өч сазан чыкты.* Ш.Камал

**ЙОМЫЧКАЛА́У** *ф. сир.* 1) Йомычка итеп ваклау, йомычкага әйләндерү. *Баракларын җылытырга үзләре йомычкалап утын ташыйлар.* Н.Фәттах. *Юан бер агач төбен каезлый-каезлый, кулын канатып юна, йомычкалый торгач, үзәгеннән нәзек кенә карандаш ясап куанган шикелле ---.* М.Галиев

2) Йомычка белән чүпләү

**Йомычкалап бетерү** 1) Барысын да йомычкага әйләндерү

2) Тирә-якны йомычкалар белән тутыру (чүпләү)

**Йомычкалап кую** Алдан йомычкага әйләндерү, йомычка әзерләү

**ЙОМЫЧКАЛЫ** *с.* Йомычка белән тулган, чүпләнгән; йомычка салынган

**ЙОМЫШ** *и.* 1) *к.* **йөкләмә** (*1мәгъ.*). *Ул кемнедер шелтәли, кайсыларына йомыш куша.* Р.Батулла

2) Үтенеч, гозер, ялыныч. *Хәзер инде, Кәбир әфәнде, штат исеменнән минем сезгә йомыш: сез безгә шул көннәрдә бер лекция укыгыз.* Н.Исәнбәт. *Апа мине шактый озак көттерде, башка килгән-киткәннәрнең йомышларын үтәде.* М.Маликова. *Кореялы студент Ли Ин Сан ниндидер йомыш белән Мәскәүгә китте.* Г.Тавлин

3) Югары даирә яисә аерым затлар тарафыннан халык өчен дип эшләнгән гамәл. *Ләкин ыругның бик күп йомышларын башкарганга, һәрвакыт иренә илчелек хезмәтләрен үтәгәнгә, үзенең күңелендәгеннән аз гына да тышка чыгармый иде.* Г.Ибраһимов. *Бабайларыбыз, заманында, бик зур миссия белән [Һиндстанга] барганнар, дәүләт күләмендәге йомышлар үтәгәннәр.* М.Мәһдиев

4) Берәрсе кушкан эш. *[Биби:] Үзләре җүнләп йомыш куша белмиләр дә кешене орышалар.* Г.Камал. *Алар янында, йомыш йомышлап, кая кушсалар, шунда йөгереп, җиңел сөякле Миңсылу гына бөтерелде.* М.Хәсәнов. *Хасталарына дәва бирер, мохтаҗларына ихсан кылыр, һәркемнең мөнәсәбенчә йомышын йомышлар.* А.Расих

5) Әйтәсе сүз, киңәш; киңәшләшеп хәл итә торган ниндидә булса эш, мәсьәлә, ихтыяҗ. *Бер көнне ул ниндидер ашыгыч йомыш белән, шакымый-нитми, Постнов бүлмәсенә керә.* З.Фәтхетдинов. *Яңгыр вакытында качып калган, әмма аннан соң кичектергесез йомышлары белән сәяхәткә чыккан чыпчыклар, адәм заты якынлашып килгәнне тоеп, пырхылдашып очыпочып китәләр.* Г.Үзиле

6) Вакытлыча файдалану өчен сорап алына яки бирелә торган нәрсә. *Касыймовлар бирәү белән дә аралашмый, күршегә йомышка керми, үзләре йомыш бирми торган карун кешеләр иде.* Л.Ихсанова. *Безнең өй алардан өчдүрт йорт аша гына, шунлыктан вактөяк йомышка алар безгә, без аларга чабабыз.* Э.Касыймов

7) *куч.* Табигый бушануны үтәүгә туган ихтыяҗ. *Зират яки каберләр янында табигый йомышларны үтәү тыелган.* М.Әхмәтҗанов. *Кече йомышы белән ишегалдында булышкан әнкә карчык, комганын ыргытып, өйгә йөгереп керде.* Н.Гыйматдинова

◊ **Йомыш төшү** Көндәлек тормышта берәр нәрсәгә ихтыяҗ туу, нәрсә булса да кирәк булу. *Көздән бирле, дүрт ай дәвамында, бергә укысалар да, аның артык аралашкан кешесе юк, моңарчы йомыш төшеп берәүгә дә кергәне булмады.* А.Гыйләҗев. *Наилә дөп-дөп типкән йөрәген тынычландырырга тырышты: авылның хуҗасына тәүлекнең һәр сәгатендә кешенең йомышы төшү ихтимал лабаса.* М.Маликова. *Гәрчә шул ук хатыннар, кечкенә генә йомышлары төшсә дә, Мәснәвигә йөгереп киләләр иде.* А.Сафин. **Йомышы юк** Исе китмәү, мәшәкатьләнмәү, кайгыртучанлык күрсәтмәү

**ЙОМЫШЛА́У** *ф.* **1.** 1) Йомышны үтәү, башкару; хәл кылу. *[Учак Сәләх] Нәниләрне бик ярата, бервакытта да каты бәрелми, гел аларның йомышын йомышлый иде.* З.Зәйнуллин. *Таяк ханның тәхетенә сөяләикән – тыныч бул, борчылма, гасабиланма, ханның кәефе күтәренке, йомышың йомышларга ашык.* М.Хәбибуллин

2) *куч.* Табигый бушануга туган ихтыяҗны үтәү. *Әнә ул юлдан читкә борылды, тизләнеп кече йомышын йомышлады.* Х.Хәйруллин

**2. йомышлап** *рәв. мәгъ.* Атап, багышлап, ниятләп. *Мәдинә апа да каядыр барырга йомышлап чыккан бит әнә.* М.Галиев

**Йомышлап бетерү** Йомышларны ахырына кадәр йомышлау, тәмамлау. *Атасының йомышларын йомышлап бетерү ихтималын гел истә тотканлыктан, Фарукҗан саубуллашу ягын карады.* Т.Әйди. *[Равил] Үзеннән алда килгән кешеләр йомышларын йомышлап бетергәч, председательнең янына ук килде.* В.Нуруллин

**Йомышлый килү** Билгеле бер вакытка кадәр эзлекле рәвештә йомышлау; һәрвакыт, гел йомышлау

**ЙОМЫШЛЫ** *с.* **1.** 1) Йомышы булган. *Ханшам, болай ук хөрмәтләп каршы алырсың дип уйламаган идем. Кабул ит, йомышлы кунакка килүем.* М.Хәбибуллин

2) Йомыш язылган, үтенеч белдерелгән. *Муса бабасы бик үтенгәч, атның нинди бәлагә таруы хакында йомышлы кәгазь дә язып бирде.* А.Хәлим

3) *тар.* XV–XVIII йөзләрдә татарлар арасыннан Россия дәүләтенә хезмәткә тартылган катламга караган. *Йомышлы татарлар да, баярлар да бөек кенәзгә нидер әйтергә теләгән иде.* Р.Батулла. *Типтәрләр, «яңа башкортлар», йомышлы татарлар яки мишәрләр, керәшеннәр – кемнәр алар?* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* XV–XVIII йөзләрдә татарлар арасыннан Россия дәүләтенә

хезмәткә тартылган катлам. *Монда [Казанда] ике меңләп укчы, дворяннар, хөкүмәт мобилизациясенә эләккән татар морзалары һәм йомышлыларының берничә алае булган.* Мирас

**ЙОМЫШЛЫ-ЙОМЫШСЫЗ** *рәв.* Йомышы булса да, булмаса да; юк эшне бар итеп

**ЙОМЫШЛЫКЛЫ** *с. диал. к.* **йомышчан**. --- *Җәгъфәр абый тимерче булып эшләде, бик тә йомышлыклы кеше иде, кемне дә кире бормады, шуңа авызы сый-хөрмәттән өзелмәде дип истә калган.* Безнең гәҗит

**ЙОМЫШЧАН** *с.* Сораган үтенечне, кушылган йомышны үтәүчән; тыңлаучан

**ЙОМЫШЧАНЛЫК** *и.* Йомышчан булу

**ЙОМЫШЧЫ** *и.* **1.** 1) Кемнең дә булса йомышын, кушкан эшен үтәүче; йомышка йөрүче кеше. *Моны --- ата-аналары кайчандыр әлеге байларның ышанычлылары, йомышчылары булып йөргән кешеләрнең балалары сөйлиләр.* Л.Хәмидуллин. *Колшәриф остаз Зөннарны Ханмәсҗет йомышчысы итте.* Р.Батулла

2) Хәрби хезмәттә: йомышларны үтәү өчен махсус билгеләнгән кеше. *Вакыйган, бу вакытта башкорт ихтилялчеләре Казан әтрафы хезмәт әһеле белән берләшеп килгән чакларында, хөкүмәт Казан йомышчыларын мобилизовать итеп алып, башкорт вә башка гайре рус кузгалучыларына каршы куеп, аларны җиңгән иде.* Г.Гобәйдуллин. *Йөзен танырлык булмаса да, буе-сыны һәм хәрәкәтләре буенча, Фарукҗан аны хәрби комиссар йомышчысы Рахманколга охшатты.* Т.Әйди

3) Берәр төркемнең йомышы йөкләтелгән һәм шундый эшләр белән йөргән кеше, берәүләрнең мәнфәгатьләрен яклаучы, вәкил. *Чөнки А.Невский – татар патшаларының турылыклы йомышчысы.* Казан утлары

4) *тар.* Чапкын. *Бу хәбәр белән килгән йомышчыны чак кына кыйнап ташламады Кубрат хан.* М.Хәбибуллин

**2.** *с. мәгъ.* Йомышларны йомышлау өчен билгеләнгән; йомышка йөргән. *Клерк минем эшне офиста Ибне Хаддам исемле кеше алып баруы турында белешмә бирде һәм йомышчы малайны шуны чакырырга җибәрде.* В.Юнысов. *Башыма ирексездән аңа карата «йомышчы кыз» дигән кимсетүле уй килде.* Г.Тавлин

**ЙОМЫШЧЫЛ** *с. к.* **йомышчан**

**ЙОМЫШ-ЮЛ** *җый. и.* Һәртөрле йомыш, теләсә нинди эш. *Җитмәсә, тагын нәкъ шундый вакытта әнкәйне дә йомыш-юлга җибәргәннәр.* К.Нәҗми. *Гөлсем апа, Казанга килеп, йомыш-юлларын йөреп чыккач та уенчык магазинына керде.* Г.Гобәй

**ЙОН** *и.* **1.** 1) Хайваннарның чәчсыман куе төкләре. *Адәм дисәң – коны юк, хайван дисәң – йоны юк.* Әйтем. *Имезүчеләрдә йон алышыну яки йон коюю елга ике тапкыр – яз һәм көз көннәре булырга мөмкин.* Биология

2) Кеше тәнендәге төкләр (аеруча ир-атларда). *Борын, ияк асларында сирәк-мирәк кара йон төкләре тибеп, сакал-мыек эзләре беленә башлаган.* З.Фәйзуллин. *Куллары зур, йонлач иде, күлмәк җиңнәре тартылгач, беләкләрен куе йон каплавы күренде.* М.Хуҗин. *Альфред тагын нидер әйтергә авызын гына ачкан иде, зал ишегеннән кар кешесенекедәй бөдрә йон баскан ярым шәрә адәм килеп чыкты.* Ф.Садриев

3) Хайваннардан (мәс., сарыктан, дөядән, кәҗәдән) кыркып яки тарап алына торган чәчсыман йомшак җепселләр. *Сүзне сүзгә тоташтырсаң, ип булыр; йонны йонга тоташтырсаң, җеп булыр.* Әйтем. *[Алар] Икенче көнне йон түкләрен Иделгә ташлап агызганнар.* К.Тинчурин. *Элек бу тарафның кара туфрагында үскән алтын бөртекләре кебек игенне, сарык йонын, төрле хайван тиреләрен, түшкә-түшкә итләрне һәм бәйләм-бәйләм чабаталарны зур баржаларга төяп озатканнар.* З.Зәйнуллин

4) Шундый җепселләрдән эрләнгән җеп

5) Шундый җептән эшләнгән тукыма

6) Кошларның тәнендә һәм каурыйларындагы мамык үсентеләр. *Алар [чыпчыклар] ашауларыннан туктадылар да, йоннарын купшы кабартып, кытыршы тавышлары белән дәррәү чырчу кузгатып җибәрделәр.* З.Фәйзуллин. *Канатның йомшак йоны иренне генә түгел, бөтен гәүдәне кытыклый сыман.* Р.Батулла. *Рәукыя апа тагын бер әтәчне суеп өлгергән, йолкый, йоннарын очырып йолкый.* Я.Зәнкиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Хайваннарның чәчсыман йомшак җепселләреннән эрләнгән. *Моның ишегалдында бер ябыгып беткән кеше туламы, нәрсәдер йон җептән бер нәрсә сугадыр иде.* Г.Гобәйдуллин

2) Шундый җептән бәйләнгән, сугылган яки эшләнгән. *Картның кигән киеме дә әллә нәрсә түгел: сырган тән җылыткыч, чалбары да калын, ботинкасын йон оекбаш белән кигән.* Р.Кутуй. *Аның кулында зур корык. Корыкның очына йон арканнан элмәк бәйләнгән.* И.Салахов. *Яшь бала да шулай: бишегендә ятканда торып утыра да үзен каплаган йон юрганнан нәрсәдер эзли, нәрсәнедер алырга тели.* М.Мәһдиев

3) Шундый тукымадан тегелгән. *Безнең авылның күпме хатын-кызы еллар буена Чуриле урыслары манган йон оек, йон фуфайка, --- киндер әйберсе киеп йөрде.* М.Мәһдиев. *[Рахманкулов] Зәңгәр йон спорт костюмын киеп җибәргәч, ишеккә үрелде.* М.Юныс

◊ **Йон батыр** Чамадан тыш арттырырга яратучы. **Йон да юк, сөт тә юк** Бернинди дә файдасы юк, табыш китерми торган. *Ул кешедән безнең өчен йон да юк, сөт тә юк: дуңгыз кебек.* Н.Исәнбәт. **Йон йөрәк** Бик куркак, кыюсыз. **Йон кабару** Ачу килү, ачу хисе биләп алу. *Әнә шунысына йоны кабарып китә Закирычның.* В.Нуруллин. **Йон куну** Тормыш шартлары рәтләнеп китү, иркен тормышта яши башлау, табышлы булу. *Караклар, хулиганнар куып йөреп, кемгә йон кунганы бар?* Г.Мөхәммәтшин. **Йон-май түгү** Газаплы хисләр кичерү. *Ул Бибкәйне инде әйткән дә юк. Гел бергә иделәр авылда. Киткән чакта көч-хәл белән аерылыштылар, картлар әйтмешли, йон-май түктеләр.* Ф.Сафин. **Йоннан эвәләгән** Җебегән, пешмәгән, булдыксыз. **Йоннан төргән** *к.* **йоннан эвәләгән**. **Йоннан төрмәгән** Ахмак түгел, юләр түгел. **Йонсыз мендәргә яткыру**

Юмалап, хәйләләп алдау. *Я, нихәл синең эш? Йонсыз мендәргә яткырдыларммы? Әйттем мин сиңа.* Н.Исәнбәт. **Йон тубалы** Тәнен куе йон (төк) баскан кеше. *Шуны гына көткән «тәмуг мәчесе», келәшчә кебек куллары белән ике аягымнан эләктереп, мине кисмәккә томырды. «Алдады йон тубалы, мәйтәм, тыпырчынып».* З.Мәхмүди. **Йон уңаена сыпыру** Аныңча эшләү, көенә каршы килмәү, җаена тору. *Үтерүче бер мәлгә югалып калды һәм, йон уңаена сыпырып, астан ут йөртә башлады.* З.Мәхмүди. **Йон урынына өреп очыру** Берәр нәрсәне җиңел генә кире кагу, көчле дәлилләр китереп инкяр итү. **Йоны коелган яман эт** Кешегә яманлык эстәп йөрүче усал, бик явыз кеше. *Син – йоны коелган яман эт.* Г.Ибраһимов. **Йонын кирегә сыпыру** Ачуын китерү, кемнең дә булса теләгенә каршы бару. **Йонын сыйпаштыру** Берәр нәрсә белән юмалап, көенә тору (мәс., бүләкләр биреп, хәйләләп һ.б.). **Йонын тетү** 1) Бик каты шелтә белдерү, тиргәү, сүгү. *[Сабир:] «Пленумнан соң энекәшне ыбыр-чыбырлары белән төяп алып кайтырга да, каракаршы утырып, йонын тетәргә кирәк юньсезнең!»* А.Гыйләҗев; 2) Бик каты кыйнау. **Йонын туздыру** *к.* **йонын тетү**. **Йон ятышына сыпыру** *к.* **йон уңаена сыпыру**. *Үзең ничек йонны ятышына сыпырырга беләсең, ә? Оста син, оста.* Н.Исәнбәт

**ЙОНАШАР** *и. зоол.* Кош каурыйлары һәм имезүче хайваннарның йоннары арасында була торган паразит; мамыкашар; *русчасы:* **пухоед**

**ЙОНКАНАТ** *и. зоол.* Имезүчеләр отрядыннан, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яши торган, озынлыгы 36–43 см, авырлыгы 2 кг чамасы булган, җир өстеннән акрын йөри, салмак кына очып түбәнәергә сәләтле булса да, кошлар кебек оча алмый торган җәнлек; кагуан; *русчасы:* **шерстокрыл**

**ЙОНКОЯР** *и. зоол.* Канәчүчеләр семьялыгыннан, сарыклар йоны арасында яши торган корткыч канатсыз чебен (бөҗәк); *русчасы:* **рунец**

**ЙОНКЫТЫЙК** *и. диал. мыск.* Йолкыш, булдыксыз, пешмәгән. *[Наилә Нәҗип турында:] «Әллә берәр хатын янына иялэштеме бу йонкытыйк?!»* А.Гыйләҗев

**ЙОНЛАНУ** *ф.* 1) Йон чыгу, йон белән каплану

2) Берәр нәрсәгә йон, төкләр ябышу

**Йонланып бетү** Тәмам йонлану, йон басу. *Мондагы эче күгәргән, йонланып беткән әллә ничә чакрымлы торбаларны күз алдына китерсәң...* Ш.Галиев

**Йонланып килү** Акрынлап йонлану

**ЙОНЛАЧ** *с.* 1) Куе озын йонлы, йон баскан (хайваннар, җәнлекләр турында). *Аяк астына сырпаланып йөргән йонлач песиенә тикле сөйкемле, ягымлы бит ул Сания апаның.* Р.Мөхәммәдиев. *Шул чак бая гына юл аша бу якка чыгып җиткән aклы-каралы йонлач мәче, --- ялварулы тавыш белән мияулый-мияулый, аякларына сарыла башлады.* Җ.Юнусов

2) Куе төкле, төкләре күп булган, йон баскан (кешеләр турында). – *У-у-х! – Микола йонлач зур йодрыкларын төйнәде.* Р.Ишморатова. *Ул арада Йомабикә табак белән кайнар су, сабын китереп бирде, Ташкәй бер кулы белән картның ябык, йонлач муенын эләктереп алды, икенче кулы белән битен сабынлады һәм бритвасын уңга-сулга йөртә башлады.* Я.Зәнкиев

3) Йонсыман куе җепселләре булган (үсемлекләр һәм бөҗәкләр турында). *Яфрак ярганчыга кадәр шактый алдан чәчәк ата. Алкалары эре, йонлач, утырма.* Л.Мәүлүдова. *Чәчәк атканда, кабырчыклар ачыла, ә йонлач җимешлек авызчыгы һәм серкәчләр тышка чыгып кала.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

◊ **Йонлач кул(лы)** Кемгә дә булса күтәрелергә, кая да булса урнашырга, нәрсәне дә булса табып бирергә ярдәм итә алырлык кеше. *Башкалар әнә «йонлач кул»га таянып өскә үрмәләсен, Фидаяров бары тик үз көченә, сәләтенә, ихтыярына таянып менәчәк.* Г.Үзиле. *Диңгезчеләр арасында «йонлач куллы» агай-энеләре булган кешеләр азмыни?* М.Юныс. *Ә ул хатын үзе, мөгаен, вакытында башка берәүнең, халык әйтмешли, «йонлач кулы» ярдәмендә күтәрелгәндер.* Ә.Сафиуллин

**ЙОНЛАЧЛАНУ** *ф.* Йон басу, куе йон (төкләр) белән каплану

**Йонлачлана төшү** Бераз йонлачлану

**Йонлачланып бетү** Тулысы белән, бик нык йонлачлану

**ЙОНЛЫ** *с.* 1) Йон белән капланган. *Үзе [эт баласы] чем-кара, ялтыравыклы йонлы, ап-ак муенлы.* А.Алиш. *Чиный-чиный бәргәләнгән шома йонлы кара эт башкаларын инде шашыну дәрәҗәсенә җиткерде.* М.Галиев

2) *к.* **йонлач** (*2 мәгъ.*). *Сәетнең --- йонлы күкрәкле егеткә ачуы чыга башлады.* Т.Галиуллин. *Нурулла сөякчел, йонлы йодрыгы белән күкрәген төйде: – Бөтен хәсрәте менә шушында аның!* А.Гыйләҗев

3) Кыска, тигез чәчсыман җепселләре булган, йомшак төкле (мәс., тукыма)

**ЙОНЛЫБАШ** *и. диал. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, сары чәчәкле, мамык сыман төкле орлыгы аз гына җил исүгә очып китә торган үләнчел үсемлек; тузганак; *русчасы:* **одуванчик**

**ЙОНЛЫ́ КӨПШӘ** *и. бот.* Чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан, каурыйсыман катлаулы яфраклы, вак ак чәчәкле күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **купырь лесной**

**ЙОНМАМЫК** *и.* Төрле җәнлек тиреләренең озын төкләре астында була торган йомшак, нәфис кыска йоннар. *Мех бирүче җәнлекләрне, гадәттә, куе йонмамык үсеп җиткәч, кыш көне суялар.* Зоология

**ЙОН-МАМЫК** *җый. и.* Йон һәм мамык һ.б.ш. йомшак нәрсәләр. *Саз эчендә, кыяклы тумгак өстенә чыбык-чабыклар, йон-мамыклар өеп, үрдәкләр оя ясаганнар.* А.Алиш

**ЙОНТАЧ** *с. сөйл. к.* **йонлач**. *Өстенә җылы күн тужурка, башына зур йонтач малахай кигән Гафур ишекне хуҗаларча киң ачып кайтып керә.* Р.Ишморат

**ЙОНЧА** I *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан, шома озын кыяклы, себеркәч чәчәк төркемле терлек азыгы

үсемлеге; *русчасы:* **мятлик**. *Бу тугай болынына чалгы кермәгән әле. Һәр чәчәк үз урынында. Юасы бар, күгәрчен бүреге, болын йончасы.* М.Рәфыйков. *Саз йончасы. Имәнлек йончасы*

**ЙОНЧА** II *и.* Кайбер тукымаларның уң (өске) ягындагы кыска, тигез, йомшак төкләр; *русчасы:* **ворс**

**ЙОНЧАЛЫ** *с.* Йончасы булган, төкле, төкләре булган. *Озын йончалы. Кыска йончалы. Куе йончалы*

**ЙОНЧУ** *ф.* **1.** 1) Хәлсезләнү, талчыгу, ару. *Аның [бүренең] сөйрәлеп баруыннан яшь хатын аңлады: хәзергә көчләр тигез, чөнки алар икесе дә йончыган.* Н.Гыйматдинова. *Юлга чыгуыгызны әйтеп телеграмма суккан булсагыз, ичмаса, Можгадан җиңел машинада, йончымыйча, рәхәтләнеп кайтыр идегез.* Э.Касыймов. *Ничек инде көнозын эшсез йөреп тә шулай йончырга мөмкин әзмәвердәй ир-ат?..* Р.Мөхәммәдиев

2) Газаплану, борчылу, рухи газаплар кичерү. *Бу арада көрәшкәннәре юк иде, Мөхәммәт абыйсы олыланган, йончыган һәм бик күңелсез кебек тоелды.* Я.Зәнкиев

3) Азаплану, зур мохтаҗлык күрү, нәрсәгә дә булса зар булу

4) Бөлү, ярлылану. *– НЭП елларында совет хуҗалыгы тәмам йончыды, эздән чыкты, – дип сөйли башлады ул.* Ф.Сафин. *Кайчандыр гөрләп көн күргән әртил хуҗалыгы бу соңгы кышта, бөтен икмәк запасы фронтка җибәрелеп беткәнлектән, артык дәрәҗәдә йончып, бик авыр хәлдә калган иде.* Ш.Маннур

5) Тынычсызлау, җәфалау, тынгылык бирмәү, йончыту. *Икенче театрны көтеп ала алмаенча йончыдым.* Г.Исхакый

6) Зәгыйфьләнү, сәламәтлеге кимү, хәле начарлану. *Еллар буе ашлык агулауда катнашып --- ни сулаганын уйламаган Йосыфның организмы агудан тәмам йончыган, үпкәләре эштән чыккан, бронхларына куркыныч матдәләр кереп тулган булып чыкты.* А.Гыйләҗев // Ябыгу, хәлсезләнү (хайваннар турында). *Мескен айгыр гомерендә бер генә тапкыр булса да нәсел калдыру куанычыннан авыз итмәгән хәлдә --- суырылып, ябыгып калды, тәмам йончыды, юашланды.* А.Расих

7) *күч.* Тузу, искерү, сәләмә хәлгә килү. *[Әти-әнисе Нәҗипкә:] Каралты-кура йончыган, аларны рәтләрбез.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Борчулы, тынгысыз. *Әле күзе дә ачылмаган кып-кызыл җан иясенең иреннәре алсу имчәккә тиюе була, ананың аксыл йончу маңгае кинәт балкып, яктырып китә.* М.Кәрим

2) Арык, өшәнгән. *Алда – Шаһи картныкылар, аның атлары бик йончу.* Г.Ибраһимов

**Йончып бетү** Тәмам йончу, бик нык йончу. *Болар көрешеләреннән мәңге уздырырга тырышкан булып, ару-талчыгулардан йөзләре саргаеп, тәннәре кибеп, тәмам йончып беткәннәр.* Р.Хисмәтуллин. *Әмма, карчыкның йончып беткән йөзен күреп, ирен очы белән дә елмаймаслык тәкать таптым үземдә.* Ф.Баттал

**Йончып калу** Нинди дә булса вакыттан, вакыйгадан соң йончыган хәлгә килү. *Сурия шул арада аның озакка сузылган авыр операциядән соң шешенгән күз кабакларын, йончып калган йөзен күзәтеп өлгерде.* Г.Галиев

**Йончып китү** Кинәт, бераз йончу. *Кхм, әйе, йончып китмәгәе, дим, киленне әйтәм.* М.Хәбибуллин. *Көне буе дус-ишләре белән йөреп арыган егет җәйге җылы төн уртасында йончып киткән дә, мастерга да, машинистка да әйтмичә, склад артына чыгып, агач кайрылары өелгән урынга ятып йоклаган.* М.Мәһдиев

**Йончып тору** Әле, хәзерге вакытта йончыган хәлдә булу. *Гәүһәриянең кәефе шәптән түгел иде, талчыгып, йончып тора иде соңгы араларда.* Д.Гайнетдинова

**ЙОНЧУЛЫ** *с.* 1) Арыган, талчыккан, хәлсезләнгән. *[Автобустан төшеп] Җиргә аягы тиюгә, [арык гәүдәле ир-атның] йончулы йөзе язылып китте.* Р.Мулланурова. *Хатынның кыяфәте йончулы, көн эсселегеннән талчыкканлыгы күренеп тора.* Ә.Моталлапов

2) Борчулы, газаплы, мәшәкатьле. *Кояшның чырае авырудан терелеп килгән кешенеке кебек газаплы, сагышлы, йончулы булып күренде аңа.* М.Мәһдиев

**ЙОНЧЫГАН** *с.* Арыган, талган, хәлсезләнгән. *Бик йончыган кыяфәттә бөрешеп кенә утырган «ишан» әкренсүлпән генә --- [әйтеп куя].* Ә.Еники. *Зал инде арыган, йончыган, талчыккан, аңа бернинди сүз дә, бернинди яңа фикер дә тәэсир итми кебек.* Н.Акмалов. *– Беләм, егетләр, беләм, арыгансыздыр, – ди бригадир! Аннан, безнең йончыган йөзләребезгә карамаска тырышып, кыенсынып дәвам итә.* Татарстан яшьләре

**ЙОНЧЫГАНЛЫК** *и.* Йончыган булу, арыганлык, йөдәгәнлек, хәлсезләнгәнлек

**ЙОНЧЫГУ** *ф. к.* **йончылу**. *Хәер, ул вакытта инде биштәрендә дә кызыгырлык әйбере булмый. Ике күмәч тә тишек чабата. Йончыгып, ачыгып, хәлсезләнеп килеп керә ул Казанга.* Н.Кәримова

**Йончыгып бетү** Тәмам, бик нык йончыгу

**Йончыгып китү** Бераз йончыгу

**Йончыгып тору** Әле, хәзер йончыган булу

**ЙОНЧЫЛГАНЛЫК** *и.* Йончылган булу. *Икенче көнне дә йончылганлык үзен сиздерде*

**ЙОНЧЫЛУ** *ф. з.-сыз* Ару, талу, хәлдән таю. *Әнкәй, минем кайтуымны әллә кемнәргә ишеттерергә ашыкма әле. Бераз ял итәсем, сулыш аласым килә. Йончылды...* Ә.Сәйфетдинов. *[Кызлар] Чак-чак кына арыган, йончылган күренәләр, шулай да һәркем шат, көләч.* Н.Фәттах

**ЙОНЧЫТКЫЧ** *с.* Йончыта торган. *Хирургның тормышы да, хезмәте дә, озын-озак йокысыз төннәре, бөтен барлыгын авыру кешеләр мәнфәгатенә багышлавы, йөрәкне туздыра, сәламәтлекне бетерә торган йончыткыч операцияләр – болар шәфкатьлелек үрнәге түгелмени?* Ф.Углов. *Бу гаять авыр, йончыткыч каторга хезмәте була.* Казан утлары

**ЙОНЧЫТУ** *ф.* 1) Хәлсезләндерү, талчыктыру, арыту. *Карамалы үрләре йончытты яшь хатыннарны.*

З.Зәйнуллин. *Елга буенда көннәр буе чемченеп йөргән малларны, саздан да яман баткак ферма утарында ыткырып йончытмас өчен, төнгелеккә дә болында калдыру мәслихәт күрелде.* Ә.Баянов. *Атлар инде өшәнгән, каладан чыкканнан бирле бертуктаусыз иярдә бару җайдакларны йончыткан, бөтен гәүдәләре ял сорый иде.* Т.Әйди

2) Интектерү, җафалау, бик нык борчу. *[Ирем мине] Көне-төне орыша, суга, чиксез-хисапсыз йончыта.* М.Гафури

3) Ялкыту, туйдыру. --- *гел-гел урам һәм рестораннарда йөрү дә туйдыра, йончыта икән ул бер.* Р. Мөхәммәдиев

4) *хәрби* Хәлсезләндерү, көчсезләтү, көчен алу (борынгыларның сугыш ысулы). *Күчмәләрнең, шул исәптән һуннарның да, чигенгән булып, кытай гаскәренең иң яхшы өлешен засадага алдап кертүе, аннан соң аны камап алып юкка чыгаруы, дошманны йончыту тактикасы, күп гасырлар үтеп, 1223 елда Идел болгарларының монголлар белән беренче бәрелешендә дә күренә.* Г.Дәүләтшин

5) Ашалу, тузу. *Көчле җилләр, бозлы яңгырлар, рәхимсез бураннар, берсе җебетеп, берсе туңдырып, кабер ташын да йончытканнар.* Г.Бәширов

6) *күч.* Талау, яшерен ысул белән үзләштерү; бөлгенлеккә төшерү. *Шуннан файдаланып, «старшина» дип аталган козгыннар, «оят» дигәннең барын да белмичә, үз кесәләрен калынайталар. Әнә шулар барысы бергә казнаны шактый йончыткан, бушаткан иде бит.* Җ.Рәхимов

**Йончыта башлау** Йончытырга тотыну. *Күрәсең, юл йончыта башлаган иде: торуы авыр бүген.* З.Зәйнуллин

**Йончытып бетерү** Бөтенләй йончыган хәлгә китерү. *Мондый «җәннәт» балаларны да, тәрбиячеләрне дә йончытып бетерде.* Ф.Сафин. *Теләсә кем җигеп, атымны йончытып бетергәннәрдер.* Ш.Янбаев

**Йончытып җибәрү** Бераз йончыту

**ЙОН-ЯБАГА** *җый. и.* Йон һәм ябага ише нәрсә. *Бу ел тире-яры, йон-ябага бик кыйммәтләнде.* Ш.Мөхәммәдев

**ЙОП-** *кис.* «Й» авазына башланган кайбер сыйфатларга ялганып һәм һәрвакыт басымны үзенә алып артыклык дәрәҗәсе ясый торган индивидуаль алкисәкчә (мәс., *йо́п-йомшак, йо́п-йомры* һ.б.). *Картның куллары йоп-йомшак, мамык кеби, бармагында сөяге юк иде.* З.Һади. *Йоп-йомры, төптән юан чыккан, берсеннән-берсе таза, томырылып торган балалар!* Н.Кәримова. *Искәндәр белән Рөстәмнең йоп-йомшак ипи телемнәрен төелә-төелә ашаганын күреп, Наиләнең күзенә яшь килде.* А.Гыйләҗев

**ЙОРТ** *и.* 1) Яшәү-тору өчен салынган яки төрле оешмалар һ.б. урнашкан корылма, бина; өй. *Иртәгә үк йорт түбәсен капласын!* Һ.Такташ. *Урам яктан ике тәрәзәле, ян-яктан ике тәрәзәле, түбәсе уртадан сыгылып төшкән, кайбер бүрәнәләре череп кыышланган, бераз гына алга сөрлеккән, бераз гына читкә янтайган, тәбәнәк кенә, иске генә йорт --- үзенең якын дусына ерактан ук сөенеп елмайды.* Н.Фәттах. *Шәһәрнең кырмыскадай кайнаган кешеләре, биек йортлары, машина-трамвай шавы белән гөрләп торган таш урамнарыннан соң авыл бик бәләкәй, гади, оялчан кебек тоелды.* Р.Низамиев

2) Өй һәм аның янындагы хуҗалык корылмалары. *Яндырылган йортлар урынында, шомлы булып карачкыллаunion, мичләр, морҗалар тырпаеп торалар.* А.Шамов. *[Хәрбиләр] Йорт хуҗасын акрын киенүдә гаепләп, ашыктыруларын белделәр.* Р.Гыйззәтуллин. *Йортын тартып алып, дәүләт ихтыяҗына файдаланганнар.* Мәдәни җомга

3) Ишегалды. *Миләштән башка да бабайның байлыгы юк түгел иде: аның өй артында канау белән әйләндереп алган, суга кадәр сузылган йорты бар иде.* Г.Исхакый. *Һәммәсе дә, йортка чыгып, кунакларны озатып калдылар.* Ә.Фәйзи. *Йортка да ул [Сара карчык] хәзер таягы белән җитәкләшеп кенә чыга башлады.* С.Лашманчы

4) Бер хуҗалык булып яшәүче бер гаилә кешеләре. *Сәйдә җиңги, минә кайтыр, минә кайтыр, йортка бәхет алып кайтыр дип, һәркөн ирен көтә башлады.* С.Рафиков. *Минем улларымны илебезнең теләсә генә кайсы йортында да кунак итеп каршылыйлар. Керәләр икән, түр башына утыртырлар.* А.Шамов. *Йорт башлыгы кая гына сәүдә итәргә барса да, Гөлҗиһан аңардан матур күлмәкләр дә, энҗемәрҗәннәр дә сорамаган.* Н.Сәйяр // Бер түбә астында яшәгән берничә гаилә кешеләре. *Янгын бик тиз куркыныч төскә керде. Бөтен йорт аякка басты.* Ә.Фәйзи // Хуҗалык. *Җиде йорт бергә оешып, артель төзергә булдык.* Ш.Камал. *Сүз --- йорт башыннан түләнә торган ясакны җан башыннан акчалата бирелә торган салымга күчерү хакында икән.* Җ.Рәхимов

5) Аерым бер максат өчен махсус билгеләнгән бина, корылма (мәс., дәүләт оешмасы урнашкан). *«Уку өе» дип аталган бу зур гына, иркен генә бүлмә клуб йортының бер почмагына урнашкан иде.* Н.Фәттах. *Нурханова сөйләшә-сөйләшә культура йортыннан урамга таба килгән Гаяров белән Әхмәдуллинны күреп алды.* М.Маликова. *Терлек азыгы цехы һәм мал караучылар өчен яңа кирпеч йорт салынды.* Ф.Галиев

6) Ил, дәүләт; туган, яшәгән җир. *Сине йорттан аерган Тур тавы – Фәләстиндәге Синай таулары.* Дастан. *Болгар йорты – минем туган йортым, Матур исемем минем – татар ул.* Ә.Мәхмүди. *Шушы тыныч еллар эчендә Казанда сәүдә гөрләде, йорт ныгыды, казна тулыланды.* Р.Батулла

7) Оешма, учреждение. *Казан шәһәренең зур мактанычы бит бу йорт [университет].* М.Әмир

8) *иск.* Бер нәсел кешеләре, нәселнәсәп

9) *махс.* Кайбер кош-корт, хайван исемнәре белән килеп, *кыр, кыргый* сүзенә капма-каршы мәгънәдә, хуҗалыкта үрчетеп, карап үстерелә торган кош-корт, хайван атамасын ясый. *Ул кәҗәләрне тау кәҗәләренә, кыр кәҗәләренә, йорт кәҗәләренә бүлгәләргә тотынды.* Т.Миңнуллин. *Буада кыр үрдәкләре бик күп: язын алар күзгә-башка чалынмыйлар, мөгаен, йорт үрдәкләре кебек, бала чыгаралардыр.* Хәйдәр

10) Кайбер ашамлык, тукыма, киемсалым атамалары белән килеп, аның махсус производствода түгел, кустарчылык юлы белән әзерләнгән булуын белдерә. *Арча кешеләре тәмле йорт сырасын менә шул салаттан пешерәләр инде.* Г.Бәширов

◊ **Йорт җанлы** Йорт эшләренә җан биргән, хуҗалыкчан, йортлыклы. *Икенче берәү тыйнак, йорт җанлы, кыю, максатчан, шат күңелле --- дип раслый икән.* Р.Низамиев. *Зөлхәбирә сөйләп бетергесез йорт җанлы булып чыкты. Килен булып төшүенә атна да үтмәде, Мөслим старшина салдырып куйган шәрә өйне җәннәт итте дә куйды.* Ж.Рәхимов. **Йорт җылысы** Йортта яшәүчеләрнең бер-берсенә якын, җылы мөнәсәбәте. *Бу ташны йорт җылысын, гаилә бердәмлеген саклый торган изге нәрсә дип тә саныйлар.* Мәдәни җомга. **Йорт итү** Гаилә корып, көндәлек хуҗалык эшләре белән яшәү. *Менә Габрахман тырышып-тырмашып «йорт итә» башлады инде.* Ф.Әмирхан. **Йортка кертү** Кияүгә чыгып, ирне үз йортында калдыру. *Каян табылып тора, диген, әни тагы бер ирне йортка кертте.* Х.Камалов. **Йортка керү** 1) Өйләнеп, хатын йортында калу. *Йортка керү ир-егеткә хурлык санала.* Н.Гыйматдинова. *[Сәмигулла абзый] Ерак китмәде китүен, каршы якта иске өен сипләп торгызды да, хатыны белән бишектәге Байтирәген калдырып, биш-алты өй аша гына яшь хатынга йортка керде.* М.Галиев. *Милләтнең анасын Хәлим әфәндегә кияүгә бирдек. Хәлим әфәнде йортка керде.* М.Галәү; 2) Берәр фатирда вакытлыча акча түләп яшәү, вакытлыча фатирга кертү. *Сугыш алдыннан ул үзеннән ундүрт яшь кече бер егетне йортка кертте.* Г.Тавлин. **Йортка төшү** Йортны талау, йорт басу, әйберләрен урлау максаты белән йортка караклар керү. *Йортка төшү күбәйде.* Н.Исәнбәт. **Йорт көтү** *к.* **йорт итү**. *Ышту безгә йорт көтү дә атаана кайгырту.* М.Фәйзи. **Йортсыз йомран** 1) Гаилә корып, бер урынга төпләнеп яшәмәгән кеше; 2) *ирон.* Командировкаларда бик еш йөргән кеше, йөремсәк. **Йорт токтасы** Хуҗа, башлык, хуҗалыкка җавап бирүче. *[Груша түтәй:] Ярый, ярый, Василич, син миннән күбрәк беләсең. Син бит – бу йортның токтасы.* Г.Ахунов. *Чөнки, ничек кенә димә, малай кеше – йорт токтасы.* Ф.Хөсни. **Йорт тоту** Хуҗалык эшләрен алып бару. *Шунда карт әти, бу киленнең йорт тотуга барыбер дәрте юк, әйдә, үз эшен эшләсен, дип, әнине үз иркенә куя.* А.Расих

**ЙОРТАВАЙ** *и. тар.* Старшина. *Бу хәлгә сөенмәүче бер генә бәндә бар иде монда – ул да булса, йортавай.* Ж.Рәхимов

**ЙО́РТ АЛДЫ** *и. диал.* Ишегалды. *Иң кызыгы: йорт алдына чыгып, Гыйлаҗиның анасын тоткансмын да: «Миңа кызың Гайнияне бир, мин аңа гашыйк булдым...» – дип, ахмаклык сатып беткәнмен.* Г.Ибраһимов

**ЙО́РТ АШЫ** *и. этн.* Яңа йортка, фатирга күчкәч, туган-тумачаларны, таныш-белешләрне чакырып уздырыла торган мәҗлес, өй туе

**ЙОРТБАСАР** *и.* Илне, дәүләтне көч белән яулап, басып алучы кеше. *Казан җиренә басып кереп, мәмләкәтара солых вә язылмаган әхлак кануннарын җимереп, Сура елгасы тамагына рөхсәтсез рәвештә шәһәр корып куйган йортбасар да ул – Иван углы Василий кенәз булды.* Р.Батулла

**ЙОРТ-ҖИР** *җый. и.* 1) Йорты һәм җире булган шәхси хуҗалык. *Ярга менеп җиткәч, Сөнгатулла зират астындагы болын, койма, бәрәңге бакчасы аша йорт-җирен күзләде.* Ә.Гаффар. *Йорт-җир тирәсендә нинди генә кош очмас, ашарга эзли күбесе, тавыкка сипкән бодайга да төшә.* Н.Гыйматдинова

2) Өй эче. *Йортың-җирең карамаган, эшең карамаган, бала-чагаларның өсте-башы рәтләнмәгән, йөрисең адәм мәсхәрәсе булып, ди...* Ф.Бурнаш. *[Камәрия] Мәктәптән дә иртәрәк кайткан, аш-суны да бәйрәмчә хәстәрләгән, йорт-җирне дә җыештырып җиһазлап куйган.* Б.Камалов

◊ **Йорт-җирне учлап тоту** Хуҗалык эшләрен алып бару. *Хатын-кыз заты шундыйдыр инде ул: йорт-җирне учлап тоту, өйдә учакны сүндермәү өчен яралгандыр.* Ж.Рәхимов

**ЙОРТ-ҖИРСЕЗ** *с.* Тору өчен үз урыны булмаган, сыеныр урыны булмаган. *Чүп оясына йорт-җирсез этмәчеләр җыела, китә чинаш, талаш, калдык азык өчен тарткалаш.* Г.Әдһәм. *Акмырза агай, гомере буе Котырыкка эшләп йөреп, хатынсыз һәм йорт-җирсез калган икән, мине һич тә андый хәлгә төшерә алмассыз.* Н.Яһудин. *Беткәнмени йорт-җирсез исерек йолкыш.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ЙОРТ-ҖИҺАЗ** *җый. и.* Йорт өчен кирәк-яраклар. *Закон ришвәтчелек өчен кулга ала, йорт-җиһазны конфискацияли – Васильева моны белә.* Ф.Галиев

**ЙО́РТ ИЯСЕ** *и. миф.* Ышанулар буенча: кеше күзенә күренмичә, йортны кайгыртып яшәгән һәм үзен йортның хуҗасы дип санаган рух; *русчасы:* **домовой**

**ЙОРТ-КАРА** *җый. и.* Өй, хуҗалык корылмалары, йорт кирәк-яраклары. *Берең ике булмасын! Йортың-караң калмасын!* Дастан

**ЙОРТ-КАРАЛТЫ** *җый. и.* Өй һәм аңа караган корылмалар. *Ул җинаять эшен ачып, теге хәвефле көнне тентү үткәргән һәм йорт-каралтыны караган милиционерлар тарафыннан сызылган йорт планын тиз генә эзләп тапкач, Исәнамовка күрсәтте.* Ф.Галиев. *Тик синең йорт-каралтыларың төссез күренә.* М.Хуҗин

**ЙОРТ-КИРТӘ** *и.* Киртәләр белән уратып алынган йорт урыны. *Хак дөресе шул: киләләр болар, йорт-киртә булдыралар, яши башлыйлар.* Л.Хәмидуллин

**ЙОРТ-КУРА** *җый. и. к.* **йорт-каралты**. *Көтүләр кайтып, йорт-кура тирәсендә эшләр беткәч, капка төпләренә чыгып гәп куертып утыручыларны күргәнең бармы бездә?* Ф.Сафин

**ЙОРТ КУЯНЫ** *и. зоол.* Куяннар семьялыгыннан, тиресе, мамыгы һәм ите өчен хуҗалыкта махсус үрчетелә торган җәнлек; *русчасы:* **кролик**. *Йорт куяны итеннән тәмле ашамлык пешерү өчен, аны эшкәртә белергә кирәк.* Татар халык ашлары

**ЙОРТЛАШТЫРУ** *ф. сөйл.* Йортка, кулга ияләштерү (хайваннар, җәнлекләр турында). *Борынгы кешеләр кайбер кыргый җәнлекләрне кулга ияләштергән һәм акрынлап аларны йортлаштыра һәм үз кирәкләре өчен файдалана башлаган.* Ф.Ибраһимова

**ЙОРТЛАШТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **йортлаштыру**. *Йортлаштырылган хайваннар. Йортлаштырылган атлар*

**Йортлаштырылып бетү** Тулысынча, бөтенесе дә йортлаштырылу

**ЙОРТЛАШУ** *ф. сөйл.* Йортка, кулга ияләшү (хайваннар, җәнлекләр турында)

**ЙОРТЛЫ** *с.* Йорты булган; каралты-курасы, хуҗалыгы булган. *Төтенле авыл – морҗалы, ягъни кеше яши торган йортлы авыл.* Г.Гобәй. *Шәһәрчек янында унбиш-егерме йортлы гына хутор да бар икән.* Х.Камалов. *Мәскәү елгасы ярында, шул шәһәргә җитәргә биш чакрым чамасы каларак, унҗиде йортлы гына кечкенә бер урыс авылы бар.* З.Зәйнуллин

**ЙОРТЛЫ-ҖИРЛЕ** *с.* Мөстәкыйль яшәрлек үз йорты һәм үз җире булган, үз йортына һәм үз җиренә үзе хуҗа булган. *Назыйф та, чыгып китсә, күптән йортлы-җирле була иде инде.* В.Гали. *Бүген кемнең генә йортлы-җирле буласы килмәсен?!* Ватаным Татарстан. *Аларны йортлы-җирле итүдә, һөнәр сайлауда, эшкә урнаштыруда булышудан әхлагыбызга зыян килмәс.* Мәдәни җомга

**ЙОРТЛЫКЛЫ** *с.* Йортын кадерләп тотучы, хуҗалыкчан

**ЙО́РТ МАЛАЕ** *и. тар.* Байда тамак ялына бушлай хезмәт итүче яшүсмер. *Башта үсмерләр йорт малае хезмәтен үтәргә, ягъни кибеткә чәй, товар ташырга, идән себерергә, утын ярырга, ат карарга, сыер абзары көрәргә тиеш.* А.Расих

**ЙОРТСЫЗ-ҖИРСЕЗ** *с. к.* **йортҗирсез**. *Якын кардәш дип аталырдай барлык дус-ишләре – һәммәсе дә үзе шикелле үк йортсыз-җирсез кешеләр.* М.Галәү. *Курыкма, ул йортсыз-җирсез бер бәндә түгел, бары бәлагә тарыган кеше.* Р.Мирхәйдәров. *Ватансыз калгач, сөекле анасыннан аерылгач, йортсыз-җирсез Рудольфның бер генә ышанычы бар иде: аяклары, биюе.* Р.Батулла

**ЙОРТСЫЗЛЫК** *и.* Йорты һәм җире, торак урыны булмау. *Моңа гына түзә әле егет, ә менә йортсызлыкны сылтау итеп, сиңа чыкмыйм, дисә, нишләр ул?* Н.Гыйматдинова

**ЙОРТТАШ** *и.* Бер-берсенә карата: бер йортта яшәүчеләр. *Яучыны көтәләр, йортташлар капка төбенә чыгып каршылыйлар иде.* А.Гыйләҗев

**ЙОРТТОТМАС** *и.* **1.** Йорт эшләренә, гаилә белән яшәргә күңел бирми торган кеше; йорт, гаилә эшләренә катнашмаучы кеше. *Таздан ялпакбаш туар, Ялкаудан йорттотмас туар.* Мәкаль

**2.** *с. мәгъ.* Йорт җанлы булмаган, күңелен йортка, гаиләгә беркетмәгән

**ЙО́РТТУМА** *и. к.* **йорт тумасы**. *Баш килде Тимгелкүк, йорттумаларны әллә кайларда калдырып килде.* М.Хуҗин

**ЙО́РТ ТУМАСЫ** *и.* 1) Хуҗалыкта үрчетелгән һәм карап үстерелгән мал. *Йорт тумасы җирән тай хәзер өч айлык булды инде.* Г.Бәширов

2) Үз халкы арасында туып, үсеп күтәрелгән кеше

3) Туган-тумачалар арасында берәр ягы белән аерылып торган яисә гарип, зәгыйфь булган кеше. *Нәсел-ыруда арада бер йорт тумасы да була бит ул.* Н.Исәнбәт

**ЙО́РТ УРЫНЫ** *и.* Өй, хуҗалык корылмалары һәм ихатасы булган, гадәттә, койма белән тирә-ягыннан уратып алынган урын; *русчасы:* **усадьба**. *Житмәсә, ишегалды хуҗасы Зариф Бадамшин йорт урыны өчен болардан елына ун сум акча таләп итә.* А.Расих. *Дәүләтгәрәй абзыйлар Ленин урамының иң кырыена йорт урыны алып, шунда таудай яңа йорт салып чыккач, --- ике арадагы мөнәсәбәтләр дә суына төшкәндәй булды.* Н.Фәттах

**ЙОРТЧЫЛ** *с. сөйл. к.* **йорт җанлы**

**ЙОТ** I *и. сир.* 1) Көтелмәгән зур зыян, бәхетсезлек; афәт (далада яшәп тибендә тукланган мал-туарның җир өсте боз белән капланган көннәрдә, азык таба алмыйча, ачлыктан кырылуын шулай атыйлар). --- *чөнки кышын атлар белән бергә, алар артыннан йөреп, күпсанлы сарыклар, кәҗәләр дә тукланганнар. Менә ни өчен йот – карның бозланып катуы – кайбер төрки телләрдә (казак, каракалпак) «ачлык» мәгънәсен алган.* Р.Әхмәтьянов. *Арттан гүя йот һәм ачлык куа.* Н.Измайлова

2) *күч.* Күп ашарга яраткан кеше, ашауга комсыз кеше

**ЙОТ** II *и. лингв.* Тел уртасы каты аңкауга күтәрелеп, тел һәм аңкау арасында калган ярыктан һава агымы үтеп киткәндә, ышкылудан барлыкка килгән *[й]* авазы. --- *тел һәм аңкау арасында ярык калса, һава агымы үтеп киткәндә, ышкылудан «яшь», «ял», «яблоко» сүзләренең башындагы [й] авазы барлыкка килә. Аны «йот» дип атыйлар.* Ф.Сафиуллина

**ЙОТКАЛА́У** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **йоту**. *«Иләү агасы» дип дан тоткан түрәнең пычрак сүзләреннән җирәнеп, Абдулла чәшкәсен кулына алды, чиркана-чиркана чәй йоткалады.* Җ.Рәхимов

2) Сирәк кенә исерткеч эчемлекләр куллану. *Теше сызлаганда, Иван Иванович, чак кына җылы биреп, затлы коньяк йоткалый иде.* А.Гыйләҗев

**Йоткалый тору** Әле, хәзерге вакытта аз-азлап сирәк-сирәк йоткалау. *Әрле-бирле йөри-йөри, үзалдына мыдыр-мыдыр сөйләнеп, савыттагы сыеклыкны әкренләп йоткалый торды.* Р.Сәгъди

**ЙОТКЫЛЫК** *и.* 1) Авыз куышлыгын үңәч белән тоташтырган, төрлечә үзгәрә алган эластик стеналы әгъза. *Хәбир абыйның мәзәк атлап йөрүләренә, һәр сүз әйткән саен, йоткылыкларына хәтле күрсәтеп авыз еруларына, күңеленә хуш килгән саен, «Во, Хәбир абыең!» дип куюларына хәтле якын, үз тоелды.* Р.Вәлиев. *Хикмәт шунда: итнең ярысы соңгы урт тешнең астан ашалган бер киртенә ычкынмаслык булып эләккән һәм йоткылыкта туктап калган иде.* Ф.Садриев. *Әгъзалардан аскы теш казнасы, муен, муендагы умыртка сөякләре, аңкау, йоткылык, тамак, үңәч аерым игътибарга мохтаҗ.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Мичнең алгы ягындагы ачык өлеше. *[Гафур] Мич йоткылыгына аркылы агач куеп, шунда оекларын элде.* Ә.Баянов

**ЙОТКЫЧ** *и.* Дымны, парны һ.б.ны үзенә сеңдерә, йота торган күзәнәкле матдә. *Күзәнәктә «йоткыч» булуы – аларның [мүкләрнең] тагын бер үзенчәлеге.* Л.Мәүлүдова

**ЙОТКЫШ** *и. диал.* Туймас тамаклы, ашамсак, комсыз кеше

**ЙОТКЫШЛАНУ** *ф. диал.* Туймастай кылану, комсызлану

**ЙОТЛЫГА-ЙОТЛЫГА** *рәв. к.* **йотлыгып**. *Шофёр аны [машинаны], алга-артка селкеткәләп, урыныннан кузгатырга озак азапланды. Мотор йотлыга-йотлыга үкерде.* Г.Тавлин. *[Ул] Эчемлек тулы савытны Юртауылга сузды. Тегесе йотлыга-йотлыга эчеп җибәрде.* Ж.Рәхимов. *Бала, чыннан да, нык сусаган иде. Йотлыга-йотлыга, ике кулы белән чүлмәккә ябышып эчте дә эчте.* З.Зәйнуллин

**ЙОТЛЫГУ** *ф.* **1.** 1) Бик нык ачыгу, сусау. *Бер чишмәнең суын эчеп бетерердәй булып йотлыктым, ирен иренгә ябышты.* Х.Садри

2) Ашаганда, эчкәндә, тын юлына азык яки су китеп тончыгу

3) *күч.* Ашыгу, дулкынлану, каушаудан һ.б.ш.дан тотлыгып сөйләү яки уку // Сөйләгәндә яки укыганда, авазларны яки сүзләрнең ахырын ачык әйтмәү. *Үги әти һаман сөйли, үзе нигәдер йотлыга, иреннәре кайчак калтырап куя.* М.Кәрим

**2. йотлыгып** *рәв. мәгъ.* 1) Туймастай булып (ашау, эчү, һава сулау турында). *Сәет өстәлдә торган графинны алып, стаканны тутыра язып су салды да, тын да алмыйча, йотлыгып эчеп бетерде.* И.Салахов

2) Бик нык бирелеп, игътибар белән. *Алып батырның йотлыгып тыңлаганын күргәч, Саескан тагы да ныграк дәртләнә төшеп сөйләвен дәвам иттерә.* Н.Сәйяр. *Наилә Гөлнараны бүлдермәде, керфек какмады, йотлыгып тыңлады.* А.Гыйләҗев. *Гөлүс газета битләреннән Зур химия төзүчеләре турындагы һәр мәкаләне йотлыгып укып бара иде.* Р.Кәрами

3) Комсызланып, тирән сулыш белән эчкә алып, тончыгып (тәмәке тарту турында). *Хәниф йотлыгып берике суырды да утлы папиросын, бармак очында әвәләп, читкә ташлады.* Н.Фәттах. *Бернычә тапкыр йотлыгып суырганнан соң, Челем Хәмидулланың авызы сүз тотмый башлады.* М.Юныс

4) *күч.* Бик каты ачы һәм өзек-өзек тавышлар чыгарып

**Йотлыгып бетү** Тәмам, бик нык йотлыгу

**ЙОТЛЫГУЛЫ** *с.* Сөйләгәндә сүзләрне ачык әйтеп бетермәгән, ишетелер-ишетелмәс, өзек-өзек чыккан. *Ул вак йотлыгулы тавыш белән пышылдап үтенә: – Туганкайлар!... Туганкайлар!... Кызганыгыз!* Ш.Камал

**ЙОТЛЫК** *и. к.* **йот** I. *Барыс елы – байлык, Сыер елы – туклык. Куй елы – кытлык, Куян елы – йотлык.* Мәкаль

**ЙОТМА** *и. гади с.* Бугаз

**ЙОТУ** *ф.* 1) Тел һәм йоткылык мускулларын хәрәкәтләндереп, ашамлыкны үңәч аша ашказанына үткәрү. *– Юк, юк, – диде ул һәм, кабалана төшеп, авызындагы ризыкны тумылдатып чәйнәргә кереште. Бер-ике тапкыр йотып бушана төшкәч, дорфа гына өстәп тә куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Газдал йоту хәрәкәтләре ясады.* Ф.Садриев

2) Үзенә алу, сеңдерү (мәс., газны, төтенне, исне һ.б.ны). *Кайчандыр аның да иске өлешендәге бакчаларыннан хуш исләр бөркелә иде, ләкин бу хәл озакка бармады, олы төзелеш алып килгән машиналар шау-шуы, күкләргә ашкан ташпулатлар ул исләрне үзенә йотты, сеңдереп алды.* Г.Кашапов. *Папиросын ул юри генә тарта, төтенен бөтенләй йотмый икән, хәйләкәр!* М.Мәһдиев. *[Ноябрина:] Аның үпкәсе болай да таза түгел. Ничә ел шахта тузаны йоткан бит әле ул...* Н.Кәримова

3) Нәрсәнең дә булса төбенә төшеп китү, үз эченә тартып кертү, суырып алу. *Әллә ничә меңнәр, йөз меңнәр минем кеби кабахәт эш эшләгәннәрне күргән, оныткан Кабан күле, минем дә кабахәтлегемне эченә йоткан, минем былчыраклыгымнан да чирканмаган кеби, мине дә эченә йотты.* Г.Исхакый

4) *гади с.* Исерткеч эчемлек эчү

5) *күч.* Бөтен килеш каплап алу, томалау, чолгап күренмәслек итү. *Йолдызларны болыт йотты.* К.Кәримов. *Әкренләп металл диварларны караңгылык йота.* М.Юныс

6) *күч.* Үзенә бик нык җәлеп итү, үзенә тарту

7) *күч.* Басып китү, басу, көчлерәк булу. *Тик ата каз зарлануыннан туктамады, аның калын авазы Булганин сүзләрен йота, һични аңламыйм.* Ә.Гаффар

8) *күч.* Берәр нәрсәне беткәнче тоту, чыгымлану, сарыф итү. *Әнисе биргән акчаны шәһәр тормышы бик тиз йотты*

9) *күч.* Нәрсәне дә булса (мәс., вакыт, көч, чыгым, игътибар һ.б.) үзенә күп таләп итү. *Ләкин тотына алмады, үз иҗатын үстерү һәм татар операсын тизрәк барлыкка китерү кирәклеге аның бөтен вакытын йотты.* Ш.Маннур. *Китаплар, конспектлар, уку заллары Ирекне тәмам йотты.* Ф.Садриев. *Тик ыгы-зыгылы бу тормыш бөтен игътибарымны йота, бик күп матур фикерләр эш белән мәшгульләнгән араларда югалалар.* Мирас

10) *күч.* Күңелдә булганны яшерү, тышка чыгармау, эчтә саклап калу. *Әткәйнең һәр җавабыннан соң, аталы-уллы серләрен тагын да эчкәрәк йотып, иркен сулап куялар иде.* Н.Гыйматдинова

11) *күч.* Басып алу, көчләп буйсындыру (мәс., халыкны, дәүләтне). *Шундый заман килде хәзер: ыру – ыруны, дәүләт дәүләтне йота.* М.Хәбибуллин. *Германиядә фашизм, җиде башлы аждаһага охшап, бөтен дөньяга ут бөрки. Ул инде Чехословакияне йотты.* Р.Хафизова

12) *күч. к.* **ассимиляция**

13) *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне ялган юл белән үзләштерү. *Кеше хакын йоту* // Урлау

14) *күч.* Нәрсәне дә булса (мәс., ачуны, үчне, серне һ.б.ш.ны) тышка чыгармау, белгертмәү, күрсәтмәү, сиздермәү. *Без аны, борчуларын эченә йоткан хәлдә, гел эшләп йөргән җирендә, уңыш өчен тынгысыз көрәштә*

*күрәбез.* Ф.Хөсни. *Ир белән хатын суд бинасыннан чыктылар да, бер-берсенә булган үпкәләрен эчләренә йотып, икесе ике якка китеп бардылар.* А.Сафин. *Василий Михайлович, оятын-хурлыгын йотып, үз-үзен елмаерга мәҗбүр итте.* Н.Фәттах

15) *күч.* Кайгы-хәсрәтне, газапны һ.б.ны күңелдән генә кичерү, зарланмау. *Егет, хәсрәтен йотып, урман буйлап бара да бара.* Н.Сәйяр. *Рөстәм ят чир белән тагын күпмедер вакыт сырхаулар әле, тагын көннәр-төннәр китергән сагышны йота-йота, эчтән сызланыр.* Н.Гыйматдинова. *Ире чирләгәннән бирле, Наиләнең чыраеннан сөенү качкан иде, аның чибәрлеген бетмәс нужа, туя ашамау, курку, икеләнүләр, шик-шөбһәләр йоткан иде.* А.Гыйләҗев

16) *күч.* Юкка чыгару, оныттыру. *Ул белмимени: шәһәр адәм баласының йөрәген, хәтерен үтерә, шәһәр телне, милли гореф-гадәтләрне йота, сындыра, чүпрәккә чыгара.* Ф.Бәширов. *Баягы куркулар, бугаздан ала язган һәлакәт Зур Су уртасында калды, аларның барысын да Зур Су үзенә йотты.* З.Хөснияр. *Колхозлар оештыру, милли политикадагы юнәлешләр җыенны йотты.* Казан утлары

17) *күч.* Бетерү, һәлак итү (сугыш, дошман һ.б. турында). *Ә сугыш аждаһасы сәгать саен меңләгән солдатны йота.* Ш.Маннур

18) *күч.* Тәнкыйтьне һ.б. кабул итү. *Тәнкыйть кәнфит түгел, аны йота белергә дә кирәк.* Р.Батулла

◊ **Йотардай булып** 1) Ачуланып, усалланып; 2) Зур кызыксыну белән. **Йотканны кире костыру** Нәрсәне дә булса кире кайтарырга, кайтарып бирергә мәҗбүр итү. **Йотып алырдай булып** *к.* **йотардай булып**

**Йота бару** Һәрберсен, булган берсен рәттән йоту. *Саимә дә, бугаз төбенә нәрсәдер терәлгән кебек, әйтәсе сүзләрен эчкә йота барды.* К.Нәҗми. *Аңарда комсызлык туды: тел астына гына кыстыру түгел, ул аларны учлап-учлап авызына тутырды һәм чәйнәминитми йота барды.* Г.Кутуй. *Тыңлаучылар Ибраһим авызыннан очып чыккан һәр сүзне йота баралар.* В.Юныс

**Йотып бару** *к.* **йота бару**. *Үз кайгыларына чумган ир белән хатын урамның каршы ягында катып калган сыңар шәүләнең аларның һәр сүзен йотып баруын күрмиләр, бу турыда башларына да китермиләр иде, әлбәттә.* Ф.Латыйфи

**Йотып бетерү** Тулысынча йоту, берсен дә калдырмыйча яки бөтен килеш йоту. *[Фокусчы] Ул арада ярты метрлы шпаганы йотып бетерә.* М.Мәһдиев

**Йотып җибәрү** Кинәт йоту. *Дәшү кая, авызындагы дучмак кисәген тел очы белән әле бер, әле икенче якка этеп-төртеп йөртте дә, ни чарадан бичара калып, чәйнәп тормый гына йотып җибәрергә мәҗбүр булды.* Р.Мөхәммәдиев. *Елак бала йомшак нәрсәне хәзер йотып җибәрә.* Ф.Яруллин

**Йотып калу** Йотарга өлгерү

**Йотып кую** Бер тапкыр йоту хәрәкәте ясау. *Аның шулкадәр ягымлы тавышыннан май яккан күмәч тәме килеп, төкерегемне йотып куйдым.* М.Галиев. *--- дежурный кычкырып укый һәм, алдындагы кружкага күз салып, авыз суларын йотып куя.* Ж.Тәрҗеманов

**Йотып тору** Бертуктаусыз йоту. *[Хуҗа:] Кеше ашаганны йотып тору яхшы кешенең эше түгел.* Н.Исәнбәт. *Метро ишеге көне-төне куе төркемне йотып тора.* М.Юныс

**ЙОТУЧАНЛЫК** *и. махс.* Дым сеңдерүчәнлек. *Туфракның йотучанлык сәләте*

**ЙОТЫГУ** *ф. диал.* 1) Тыгылу, тончыгу, тамакка терәлү. *Нурсия чүт кенә шомырт төшенә йотыкмады.* Н.Гыйматдинова

2) Сөйләгәндә, сүзләрне ачык әйтеп бетермәү, авазларны йоту. *Хәлил агай йотыгып-йотыгып (җаны әрнеп булыр), шуларны хикәя кыла, Мәрфуга түшәмгә караган көе хәрәкәтсез ята.* Ш.Камал

**Йотыга башлау** Йотыгырга тотыну. *Кисәктән Фәттах йотыга башлый.* Т.Гыйззәт

**ЙОТЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **йоту**

2) *күч.* Бирелү, бар игътибары белән берәр нәрсәгә төбәлү, текәлү. *Шул сүзләрне әйтеп, егет бабайның күзләренә йотылды.* Г.Ибраһимов. *Сәяси темаларга язылган әсәрләрне --- йотылып, әкият укыганнан битәр мавыгып укыдык.* М.Әмир

3) *күч.* Артык мавыгудан сизгерлеге кимү. *Уйларына йотылган Җәгъфар койма өстендәге укчыларның тавышсыз гына имән бүрәнәләр ышыгына сыенып посуын да, тупчыларның тыз-быз йөренә башлавын да сизми калган иде.* Ф.Латыйфи

4) *күч.* Билгеле бер урыннанераклашып югалу, берәр нәрсә эченә кереп күренмәс булу. *Дымлы тәрәзәләреннән тонык ут шәүләсе җәйрәгән өйләр, еракка өстерәлеп баручы саллар кебек тирбәнеп, салкын яңгыр эченә йотылдылар.* К.Нәҗми. *Озакламый кошчык кичке караңгылыкта йотылды, ләкин шунда да көмеш тавышы тынып-туктапып калмады.* Н.Хәсәнов

5) *күч.* Чыганактан ераклашып таралу, таралып юкка чыгу. *Күк җисемнәре тараткан күзгә күренә торган нурланышның шактый өлеше Җир атмосферасында йотыла һәм Җир өслегенә үк килеп җитми.* Астрономия. *Галәмнән килгән энергия тиз йотыла.* Мәдәни җомга

6) *күч.* Үз мәдәниятен, телен югалтып, икенче бер халыкка кушылу; ассимиляцияләнү. *Шуның өстенә хәвефле бер караш соңгы вакытларда үзен ачык сиздерә башлады: янәсе, татар теленең киләчәге юк, иртәмесоңмы ул йотылырга тиеш...* Ә.Еники. *Бу халыкның этник йөзен билгеләүче һәм аны саклап калу чаралары булган үзенчәлекләрнең кимүе, аның башка халыклар, аеруча руслар тарафыннан ассимиляцияләнүенә, йотылуына да китерде.* Г.Дәүләтшин

**2. йотылып-йотылып** *рәв. мәгъ.* 1) Бик нык ашыгып, туймастай булып. *Йотылып-йотылып эчтеләр дә, үзләренең кемлекләрен белдерделәр дә алга чаптылар, ди, алар.* А.Алиш

2) *к.* **йотлыгып** (*2 мәгъ.*). *Тамашачылар аны йотылып тыңлау гына түгел, керфек селкетүләренә хәтле игътибар итәләр иде.* З.Фәйзи. *Моны ишеткәч, тоткынның күзләре очкын-*

*лады, йөзе нурланды, якын туганын күргәндәй йотылып карады.* Р.Кәрами

**3. йотылган** *с. мәгъ.* Гырылдаулы, карлыккан, утырган. – *Ниндидер җыен буласы, ахрысы, биредә, Фазыл Артышевич, – диде Сәфәров, юл буе диярлек сөйләшми килүдән йотылган тавышына ирек биреп.* Г.Кашапов

**Йотыла бару** Эзлекле рәвештә, азазлап, акрынлап йотылу. *Мич авызында җемелдәшкән вак-вак очкыннар, бөркелә-бөркелә янып, сүнәргә теләмәгәндәй, төнлек «бугазы»на кереп йотыла баралар.* Н.Хәсәнов

**Йотыла төшү** Бераз йотылу

**Йотылып бару** к. **йотыла бару**. *Бары тик кысыла төшкән күзләре генә аның эчке уйларына йотылып баруын күрсәтә.* Ә.Еники

**Йотылып бетү** Тәмам, тулысынча йотылу. *Шунда Хәлимнең күзләрендә чагылып, фотосурәтләрдә балкып торган кояш нуры, кырт сынып киткәндәй булды да, җилдә сүнгән лампа яктысы кебек, тынлык тарафыннан тәмам йотылып бетте.* Г.Гыйльманов. *Әмма мондый глобаль шартларда вак халыкларның йотылып бетү куркынычы бар.* С.Ибраһимова

**Йотылып калу** Нинди дә булса тәэсирдән соң кинәт йотылу. *[Сәетнең] Әйтеп бирәсе килгәне телендә йотылып калды.* Ф.Латыйфи

**ЙОТЫМ** *и.* **1.** 1) Авыз куышлыгыннан йоткылыкка таба ашамлыкны, эчемлекне, һаваны һ.б.ш.ны йотып җибәргәндә ясалган хәрәкәт. *Соңгы йотымнан соң ул буш касәне Зөннар мирзага сузды.* Р.Батулла. *«Булмас, ахры, бу» дигән шомлы уйдан өметем киселеп барганда, менәтерә вәт, Ходайның рәхмәтле бирмеш көне, колыным беренче йотымын йотмасынмы!* Шәһри Казан

2) Бер тапкыр йотарга мөмкин булган күләм. *Галиев сары брезент белән тышланган савытны иреннәренә тидерде, берничә йотым эчеп куйды.* А.Сафин. *Беренче йотымнардан ук тәненә ут йөгергән Нәҗип икенчесен эчеп куйганын абайламады да…* А.Гыйләҗев. *Рифкатьнең үтенечендә Хәтмулла карт шунда ук җавап бирергә ашыкмады, тәмәкесен кабызып, бер-ике йотым эчкә суырганнан соң гына сүз башлады.* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* Аз күләмдә, аз гына. *«Эх, бер йотым ирек!» – дия-дия, Җаны күпме бәргәләнмәсен, этапларны узган чакларда да Югалтмаган асыл мәгънәсен.* Р.Низами

**ЙОТЫМ-ЙОТЫМ** *рәв.* Вак-вак йотымнар белән; әкренләп, аз-азлап. *Мәкчим, авыр сулап, мич башындагы утлы суны аз гына кружкага койды да --- озаклап йотым-йотым гына эчте.* Р.Сибат

**ЙОТЫМЛАП-ЙОТЫМЛАП** *рәв.* Бер-бер йотымнар ясап. *Чиләкләрне мөлдерәмә тутырганчы, әүвәл Мөнәвәрә йотымлап-йотымлап салкын су эчте.* Н.Гыйматдинова

**ЙОТЫМЛА́У** *ф.* Сыеклыкны йотымнар белән эчү, йоту хәрәкәтен бүләбүлә, тукталыш ясап эчү. *[Ваһимның] Шундый әңгәмәдә хәмер йотымлау теләге куәт биреп җибәрер, дип соравы булган иде аракыны.* М.Хуҗин

**Йотымлап кую** Бер тапкыр йотымлау

**ЙӨГӘН** *и.* 1) Җигеп, атланып йөрү өчен, атның башына кидерелә торган авызлыклы, тезгенле җайланма. *Борын ат алырдан алда йөгәнен әзерләп куярга куша торганнар иде.* Ә.Еники. *Бер читтәрәк кола бия, башын чайкый-чайкый, койрыгы белән чебен-черки куа, аның йөгән тимер-томырлары чылтырап китә.* М.Хәбибуллин. *[Исламгали] Камыт өстенә ыңгырчак утыртты, сул беләгенә дилбегә, йөгән, аркан элде.* М.Юныс

2) *куч.* Берәр нәрсә эшләүдән тыю, тыеп калу көче; тоткарлый торган сәбәп. *Хисләрнең йөгәнен генә бушат, аза да аза, диләр.* Н.Гыйматдинова. *Адәм баласының теленә йөгән кигезеп булмый, бер сөйләмәсә, бер ычкындыра.* М.Маликова. *Бүген эмоцияләрне йөгәндә тотарга, авыр эшләр эшләмәскә, йөрәккә киеренкелек тудырмаска.* Мәдәни җомга

◊ **Йөгәндә тоту** Буйсындырып, тыңлатып яшәтү. **Йөгәннән ычкындыру** Буйсындыра алмау, азындыру, узындыру. *Нишләп сез ул юньсез малайны йөгәннән ычкындырасыз?* Ф.Хөсни. **Йөгәннән ычкыну** Таләпләргә буйсынмау, тыела белмәү, үзе теләгәнчә эш итү. *Менә шулай итеп йөгәннән ычкына язды Хәдичә.* М.Хәсәнов. **Йөгәнне каты тоту** Җитәкчелек эшендә кырыслык күрсәтү, катгый, таләпчән булу. *Хуҗа йөгәнен бик каты тотты шул Сәфәр, бик каты тотты. Хәтта сугышка китәр көнне дә бушатмады.* Н.Гыйматдинова. **Йөгәнне кулдан ычкындыру** Йомшаклык күрсәтү; идарә итү көчен югалту, баш(лык) була алмау

**ЙӨГӘНЛӘ́Ү** *ф.* **1.** 1) Йөгән кидерү. *Акрынлап айгырны йөгәнләделәр.* Г.Ибраһимов

2) *куч.* Билгеле бер таләпкә буйсындыру, берәр нәрсә эшләүдән тыю, чикләү. *Әмма, нишләмәк кирәк, күңелдә айкалып-чайкалып уянган тойгыларны акыл белән йөгәнләми булмый.* Ә.Сәйфетдинов. *[Рөстәм] Тиле хисләрен йөгәнләр: утар ягына ялгыш та күз салмас.* Н.Гыйматдинова. *Бер сүтелә башласа, хәтер йомгагын тиз генә йөгәнләрмен димә.* Р.Гыйззәтуллин

3) *куч.* Үз ихтыярына буйсындыру. *Казансу елгасында кызыл-зәңгәр билге белән чуарланган ак җилкәннәр, аның такта көймәсенә аягүрә баскан каһарман кыяфәтле егетләр, җилне йөгәнләргә тырышып, Ослан ягына таба йөзә.* Р.Низамиев. *Диңгезчеләр алар дулкын кебек: ярга бермәлгә генә сыеналар да кире китеп күздән югалалар. Иярләп тә, йөгәнләп тә яныңда тотып булмый!* М.Маликова

4) *куч.* Нәрсәгә дә булса җитәкчелек итү, эш барышына җавап бирү. *Көннән-көн яңарып торган производствоны алар йөгәнли.* Р.Хисмәтуллин

5) *куч.* Билгеле бер максатларда файдалану, асылына төшенеп, куллanyрга өйрәнү. *Мәшһүр атомчы галим Курчатов 1942–1944 елларда шушы институтта атомны «йөгәнләү» ысулларына өйрәнә.* М.Әмирханов

**2. йөгәнләп** *рәв. мәгъ.* Көчләп, ирексезләп. *[Фәйрүзә Арсланга:] Йөгәнләп алып килмәкче идем сине.* Г.Ахунов

**Йөгәнләп алу** Тиз арада йөгәнләргә өлгерү

**Йөгәнләп бетерү** Барысын да йөгәнләү; тулысынча йөгәнләү

**Йөгәнләп кую** Йөгәнләгән хәлгә китереп тоту

**Йөгәнләп тору** Һәрвакыт, гел йөгәнләгән хәлдә тоту. *Шуннан башлап, мин кайгыларымны Гел йөгәнләп торам...* Ш.Җиһангирова

**ЙӨГӘНЛЕ** *с.* 1) Йөгән кидерелгән, йөгәнләнгән. *Урамга чыккач, ишан хәзрәтләрен көмеш иярле, көмеш йөгәнле, муенына алтын шөлдерек таккан кечкенә ишәк өстенә күтәреп атландыралар.* Ә.Еники. *Анда --- иярсез калган йөгәнле атлар йөренә.* Ж.Рәхимов

2) *күч.* Буйсындырылган, нәрсә дә булса йөкләтелгән. *Йөрәк йөгәнле килеш тә Үзенчә атлый икән.* Н.Сафина

**ЙӨГӘНЛЕКЛӘ́Ү** *ф. сир. к.* **йөгәнләү**

**ЙӨГӘНСЕЗ** *с.* 1) Йөгәне юк, йөгән кидерелмәгән. *Атларга йөгән кидермим, Йөгәнсез атлар оча.* Сөләйман

2) *күч.* Әшәке, начар; әдәпсез, тотнаксыз. *Шуннан бирле ул үзенең йөгәнсез холыклы хәләл җефетенә бүтәнчә каршы килмәс булды.* С.Горский. *Гомумән, узгандагы эшләренә, йөгәнсез тәкәбберлегенә үкенә төсле иде.* Г.Ахунов

3) *күч.* Үзе теләгәнчә яки үзбелдегеннән чыгып эш иткән; законга, тәртипкә буйсынмаган. *Ул йөгәнсез киявегезгә тизлек белән йөгән кигезергә, ике аягын да тышаулап куярга кирәк, ди.* Г.Мөхәммәтшин

4) *күч. шигъ.* Ирекле, бернәрсә белән дә чикләнмәгән. *Дөрес аңлыйсыңдыр, максатым: теләсә ничек һәм йөгәнсез яшәүләргә чакыру түгел, ә бәлки коллык психологиясенең зарарын аңлату.* Р.Низамиев. *[Тимерша:] Улым, омтылуың яшьлегеңнең йөгәнсез кыбырсуы гына түгелме?* М.Хуҗин. *Кызына игътибар иткән Кубрат хан, Чәчкә йөзенә чыккан куанычны күреп: «Яшьлек, – дип уйлады. – Йөгәнсез яшьлек».* М.Хәбибуллин

**ЙӨГӘНСЕЗЛӘНҮ** *ф.* **1.** Йөгәнсезгә әйләнү; азу, әдәпсез кылану, буйсынмау. *Ләкин, «беләм» дигәч тә, ул тикле үк йөгәнсезләнергә ярамый бит инде.* В.Нуруллин. *Элегрәк тә хатыннарның кылларын чиерткәләп йөргән бабаң инде бөтенләй йөгәнсезләнә.* Г.Кашапов. *Кай арада бу тикле йөгәнсезләнергә җитеште соң әле бу малай?* Б.Камалов

**2. йөгәнсезләнеп** *рәв. мәгъ.* Иркенләп, тыелгысыз рәвештә. *Икенче көн инде урамда буран йөгәнсезләнеп котыра*

**Йөгәнсезләнә бару** Акрынлап йөгәнсезләнү, йөгәнсезлек сыйфатлары эзлекле рәвештә арту

**Йөгәнсезләнә башлау** Йөгәнсезләнергә тотыну. *Парторг эше катлауланды. Кешеләр шактый гына йөгәнсезләнә башладылар.* Х.Камалов

**Йөгәнсезләнә төшү** Бераз йөгәнсезләнү

**Йөгәнсезләнеп алу** Ара-тирә яки бик кыска вакыт арасында йөгәнсезләнү

**Йөгәнсезләнеп китү** Йөгәнсезгә әверелә башлау, кинәт шундый кешегә хас сыйфатлар барлыкка килү. *Хак, Йосыф кахан аңа ошады, күңеле кинәт йомшарып, йөгәнсезләнеп китте, ләкин бу хәл шундук үтте.* М.Хәбибуллин

**ЙӨГӘНСЕЗЛЕК** *и.* 1) Әдәпсез, тыйнаксыз булу; азгынлык. *Кыскасы, без Үзбәк белән, аның йөгәнсезлегенә карамастан, уртак тел табабыз, бик күңелле итеп уйныйбыз.* А.Расих. *Юктыр, мәхәббәт түгелдер ул, гашыйклык түгелдер ул; гап-гади йөгәнсезлек, җенси комсызлык бу.* Р.Батулла

2) Башбаштаклык, сансызлык, үзиреклелек. *Билгеле, мондый сансызлык, йөгәнсезлек дин сабакларының дәрәҗәсе төшүдән, --- бары атайлар мәҗбүр иткәнгә күрә генә йөреп маташудан килә иде.* Ә.Еники

**ЙӨГЕНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. сир. к.* **йөгенү**

2) *күч.* Буйсындыру, чүктерү. *Җир шарын яулый, хисапсыз күп халыкларның патшаларын үзенә тез йөгендерә.* Р.Зарипов

3) *күч.* Соңгы көченә калдыру, авыр хәлгә җиткерү, тәмам хәлсезләндерү. *Балтырган шулпасында җан саклаган, ачлыктан шешенә башлаган адәм баласын тәмам йөгендерү өчен эшләнмәде микән ул?* А.Хәлим

**ЙӨГЕНҮ** *ф.* 1) Гәүдәне бераз алга таба ию

2) Чүгү, түбәнчелек күрсәтү. *Сөмбелтай янә тез йөгенде дә: – Башым өстә, йөзем түбән! – дип юкка чыкты.* Р.Батулла. *Алдына килеп бер тезенә йөгенә: «Наилә, минем кәләшем булырга син ризамы?»* Р.Зарипов

3) *күч.* Аптыраган хәлгә килү, гаҗиз булу, хәлсезләнү

**Йөгенә башлау** Йөгенергә тотыну. *Тик, сатып алган атның хакын түли-түли, Сәйфулла йөгенә башлады.* З.Зәйнуллин

**ЙӨГЕРӘ-АТЛЫЙ** *рәв.* Тиз-тиз, ашыгып; бер йөгереп, бер адымлап. *Гамир тиз генә кызларның уенчыкларын җыеп кулларына тоттырды да, икесен ике яктан җитәкләп, йөгерә-атлый аланга ашыкты.* З.Фәйзуллин. *Кыз, җавап көтмәстән, йөгерә-атлый, беренче катка төшеп китте.* Ф.Сафин

**ЙӨГЕРӘ-ЙӨГЕРӘ** *рәв.* Тиз-тиз, ашыгып. --- *барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп биргәч, икесенең дә йөзләре ачылып китте, йөгерә-йөгерә чәй әзерләргә керештеләр.* Г.Галиев

**ЙӨГЕРӘ-ЧАБА** *рәв.* Ашыгып, кабаланып, тиз-тиз. *Саубуллашканда, күңел тулудан куркып, йөгерә-чаба чыгып китте.* М.Юныс. *Класстәшлары йөгерә-чаба таралышты.* М.Хуҗин

**ЙӨГЕРЕК** *с.* **1.** 1) Кызу йөгерә торган; елдам, җитез. *Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар.* Г.Ибраһимов. *Ренат рәсем төшерергә бик ярата. Ул кызылармеецлар ясый, өйләр ясый, йөгерек атлар да эшләп куя.* А.Алиш // Хәрәкәт итү тизлеге көчле булган. *Озакламый җылы яз да үзенең купшы фаэтонында килеп җитәр, тәрәзәләрдән кояш нурлары сибелер, стеналарда ап-ак йөгерек шәүләләр биешә башлар.* А.Расих // Йөгерешеп, куышып уйный торган. *Яшьләр биеп, йөгерек уеннар уйнап арыгач, ял иткәндә әйтешкән иң үткен, иң җор сүзләр – Каимәнеке.* С.Хафизов

2) Тиз ага торган. *Баһаветдин исә аны күрмәде дә: бер чибәркәй белән инеш ярына иңгә-иң утырган да учак яктысы төшкән йөгерек агымга чәчәк таҗларын өзеп ата-ата уйный иде.*

Т.Әйди. *Каерылып үлән үскән тын яткылны урталай ярып аккан йөгерек инеш каядыр кояш баешына ашыга.* Җ.Рәхимов. *Мул сулы, йөгерек елга ярындагы болында көне-төне учаклар дөрли.* Ф.Латыйфи // Тиз исә торган. *Нәкъ шул мәлдә йөгерек таң җиле, яфракларын шыбырдатып, әянкенең сак йокысын ачты.* М.Галиев

3) Хәрәкәтчән, җитез; өлгер, елгыр. *[Галәү] «Әпипә!» – дип кычкырды һәм кулларын югары күтәреп, бармакларын шартлата-шартлата, җиңел, йөгерек адымнар белән түгәрәк әйләнеп биеп китте.* Н.Фәттах. *Аның --- тегү-чигүгә кулы йөгерек.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Уйнаклап торган, ялт-йолт иткән. *Ә йөзгә – ачык чырайлы, күзләре йөгерек, утлы күмер сыман әллә каян балкып көлеп тора.* Р.Мөхәммәдиев. *Миңа эчке бер дошманлык белән йөгерек караш ташлап алды.* Ф.Углов. *Кечкенә кара күзләре борчулы, йөгерек.* Т.Галиуллин

5) *күч.* Өстән-өстән генә булган, эчтәлегенә бик төшенеп тормаган

6) *күч.* Кыска, ашык-пошык; тиз арада булып узган

7) *күч.* Тиз, җиңел һәм күп язган. *[Матушкинның] Йөгерек алтын каләмен редакциянең иң каныгучан кешесе – җаваплы секретарь, күзлекле Хафизов кына туктатса туктата алыр иде.* Ә.Мушинский

8) *күч.* Шома, тиз, җиңел. *[Зөннар] Эштә дә бик җитез, урыс димәссең, теле дә йөгерек.* Р.Батулла. *Ширәмәтовтан алып, кәгазен карыйм: язуы йөгерек, гайрәтле, яшен эзе кук.* Ә.Гаффар. *[«Муса» романы] Ана телендә нәшер ителгәне, калын китап булуга карамастан, отышлырак, милли бизәкләр, тапкыр сүзләр, уңышлы җөмләләр хисабына җиңелрәк, йөгерегрәк укыла.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ. күч.* Тиз-тиз, төртелмичә (мәс., уку). *Бәйрәмхан аны: – Йөгерек укыдың, дөрес укыдың, хәрефне әйбәт танийсың икән, – дип бүлдерде.* М.Хуҗин

**3.** *и. мәгъ.* 1) Чабыш өчен махсус өйрәтелгән ат. *Чын йөгеректә сын булмас, Чын сылуда мин булмас.* Мәкаль

2) *сир. гади с.* Бик тиз йөгерә (чаба) алган кеше. *Кая ул йөгерек артыннан җитү.* Әкият

**4.** *хәб. функ.* Күз алдыннан, яннан тиз үтеп китү турында. *Яшел уйсулыкны, чиста каеннарны күреп рәхәтләнергә өлгермисең, автобус аларны җәһәт үтеп китә – безнең төбәкләрдә дә юллар йөгерек икән.* М.Хужин

◊ **Йөгерек акыллы** *к.* **йөгерек зиһенле**. **Йөгерек зиһенле** Бик үткен, зирәк. *Аягың җитез, зиһенең йөгерек, кулың нык? --- авызың биктә булсын!* Ф.Латыйфи. *Җөдә – йөгерек фикерле бала.* Т.Әйди

**ЙӨГЕРЕ́К КОШЛАР** *и. зоол.* Комлы далаларда һәм чүлләрдә яши торган, очуга караганда йөгерү сәләте көчлерәк булган озын ботлы кошлар төркеме; *русчасы:* **бегунки**

**ЙӨГЕРЕ́К ЭТ** *и. зоол.* Бик тиз йөгерә алган, озынча борынлы, озын һәм нечкә аяклы ау эте; *русчасы:* **борзая**

**ЙӨГЕРЕКЛӘНҮ** *ф.* 1) Хәрәкәт тизлеген арттыру, кызулану

2) Шома һәм тиз булу, җитезләнү. *Сөйләм кырыслана, бу сискәндергеч дөньядан тизрәк чыгу чарасына керешкәндәй йөгерекләнә.* М.Гайнетдин

**Йөгерекләнә төшү** Бераз йөгерекләнү

**Йөгерекләнеп китү** Тагы да йөгерекләнү, нәрсәнең дә булса тәэсире белән хәрәкәт итү тизлеге арту

**ЙӨГЕРЕКЛЕК** *и.* Йөгерек булу. *[Йөгерек:] Мин – сукыр кеше, ди, минем йөгереклектән көнләшеп, агаларым минем ике күземне сукырайттылар да шушы җирләргә китереп калдырып киттеләр, ди.* Әкият. *Аскарак салынган иреннәре белән зур авыз эчендә тезелгән ак, озын тешләр, ут уйнап торган ялкынлы зур күзләр, бигрәк тә ут чыгаргандай каты, үткен, тиз баса торган йомры кечкенә ялтыр тояклар аның бу киң далада бик күп җылкыларга алын бирмәс йөгереклеген күрсәтәләр.* Г.Ибраһимов

**ЙӨГЕРЕКЛӘНДЕРҮ** *ф. сир.* Кызулату, тизләтү. *Бу хәл [азат ителеренә ышаныч] шагыйрьнең каләмен йөгерекләндерә, күңелен илһамландыра.* Ф.Галимуллин

**Йөгерекләндерә бару** Акрынлап йөгереклеген арттыру

**Йөгерекләндерә төшү** Тагын да ныграк йөгерекләндерү. *Бер-ике сүз белән генә булса да җавап бирәсе урында, юри иткән төсле, каләмен тагын да йөгерекләндерә төшеп, кәгазьне тагын да шәфкатьсезрәк кыштырдатырга кереште.* Ш.Камал

**ЙӨГЕРЕНҮ** *ф.* Ары-бире йөгерү, йөгергәләү. *Әгәр дә өйдән ана каз да тавыш бирсә, ул, канатларын җилпеп, ишек тирәсендә арлы-бирле йөгеренә, бөтен ишегалдын яңгыратып каңгылдарга тотына.* Г.Бәширов

**Йөгеренә башлау** Йөгеренергә тотыну. *Хәмит абзый кибеткә кеше килеп керүгә хәрәкәткә килә, кыбырсып йөгеренә башлый иде.* М.Мәһдиев

**ЙӨГЕРЕШ** *и.* 1) Төрлесе төрле якка йөгерү (күпләр турында). *Китте чыр-чу, китте тавыш, йөгереш, кычыш.* Г.Бәширов

2) *спорт* Йөгерү ярышы. *«Эстафета» дигән йомышсыз йөгерешләре ---күңелләрен күтәрәме?* Ә.Баянов. *Шуннан соң Сабантуй уеннарына охшашлы уеннар – ат чабыш, йөгереш һ.б. оештырылган.* Р.Ягъфәров

3) *диал.* Ат чабышы, бәйге

4) Тиз үтеш, тиз агыш. *Олыгайган саен, елларның йөгереше кызулана бара: «чылк» – бер ел узган, «чылк» – икенчесе.* М.Маликова

5) Берәр нәрсәнең тиз-тиз хәрәкәтләнү рәвеше. *[Клавишалар өстеннән] Бармакларның йөгерешен шуның белән генә чагыштыра алыр иде Әхмәтсафа.* Ф.Сафин

**ЙӨГЕРЕШӘ-КУЫША** *рәв.* Берберсе артыннан йөгереп, бер-берсен узарга тырышып. *Бер төркем балалар шаулашып урамга чыкты. Йөгерешәкуыша уйнаша башладылар.* Г.Бәширов

**ЙӨГЕРЕШЛЕ** *с.* Йөгерешү белән бәйләнгән, хәрәкәтчел. *Йөгерешле уеннар*

**ЙӨГЕРЕШҮ** *ф.* 1) Ярышып, узышып йөгерү. *Атлар да чабышты, малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды; шулай итеп, сабан туе да бетте.* Г.Тукай. *Үр артына ышыкланган бу урында алар үз ярышларын оештыралар:*

*йөгерешәләр, таяк тартышалар, көч сынашалар иде.* М.Маликова

2) Су өслегендәге дулкыннар тиз-тиз хәрәкәтләнү. *Каршы яктан салкынча җил исә, болганчык су өстен шадралатып, дулкыннар йөгерешә.* Ф.Садриев. *Чишмә сулары вак-вак шарчыкларга охшап, ташларга бәрелә-сугыла, нечкә моңнар сузып йөгерешә кебек.* Н.Хәсәнов

3) Бер-бер артлы йөгерү. *Озак та үтмәде, автомат тоткан немецлар, этләр ияртеп, зона эченә йөгерешеп керделәр.* С.Йосыпов // Бер-бер артлы берәр нәрсә тирәсендә әйләнеп йөгерү. *Җрецлар, луперклар, корбан ителгән кәҗә тиреләрен ябынып, Палатин калкулыгы тирәли йөгерешкәннәр, теләкләр теләгәннәр.* Мәдәни җомга

4) Бергәләп әле бер, әле икенче юнәлештә йөгерү (күпләр турында). *Табиблар, куркып, минем тирәдә тызбыз йөгерешкән икән.* Н.Гыйматдинова. *Сугышчылар, күнитекләрен дә салып атып, юеш җирдә яланаяк йөгерешеп, үзара шаярышып рәхәтләнә.* Т.Әйди. *Урал таудан агып төшкән гөрләвекләр буенда, кәгазь көймә агызып, малайлар йөгерешә.* Р.Мөхәммәдиев

5) *күч.* Берәр нәрсә өслегеннән тиз-тиз күз йөртү. *[Ибрай] Шкаф ишеген ачты, күзләре төрле-төрле аракылар өстеннән йөгереште.* Н.Хәсәнов

6) Кешедә нинди дә булса хистойгылар күренеше булып алу (мәс., шатлык, сыкрану билгеләре һ.б.ш.). *Мөнәвәрәнең күз төпләре дымланды, күңел күлен тибрәлдереп, хис дулкыннары йөгереште.* Н.Гыйматдинова

**Йөгерешеп йөрү** Төрлесе төрле якка йөгерешү. *Чак кына читтәрәк --- сызгырынып, озын сыйраклы ике тәлләтәвеч йөгерешеп йөри.* М.Хәсәнов. *Әнә бандитлар, котырган этләр шикелле, һаман йорттан йортка йөгерешеп йөриләр.* Н.Дәүли

**Йөгерешеп китү** Кинәт бергәләп йөгерә башлау. *Сукмакка чыгып, йөгерешеп киттек.* М.Юныс. *[Этләр] Борыннарын җиргә сузып иснәнә-иснәнә тагын йөгерешеп китәләр.* Н.Дәүли

**Йөгерешеп узу** Бергәләп берәр нәрсә яныннан яки өстеннән йөгерешү. *Барлык фәннәрне дә су урынына эчә, әйбәт укый, алдынгылардан санала, әмма язуы юк инде: дәфтәр битләре өстеннән бер көтү таракан йөгерешеп узган кебек.* З.Хөснияр

**Йөгерешеп үтү** к. **йөгерешеп узу**. *Аның күз алдыннан моңсуланып калган кырлар, юл читендәге шәрә агачлар ---, каядыр ашыккандай, йөгерешеп кенә үтәләр.* Г.Үзиле

**ЙӨГЕРЕШҮ-ЧАБЫШУ** *ф.* Арлыбирле йөгерү, төрлесе төрле якка йөгерү (күпләр турында). *Хезмәткәрләр үзләре йөгерешә-чабышалар.* Ф.Яруллин

**ЙӨГЕРЕШЧЕ** *и. спорт* Йөгерү спорты белән шөгыльләнүче. *Спорт мастерлары гына да дүртәү бездә. Ике штангачы, берсе городки уены буенча, ә берсе – йөгерешче.* В.Нуруллин // Йөгерү ярышында катнашучы. *Безнең авылда Нуришан картка күбрәк кушаматы белән эндәшәләр иде. Башта аңа «йөгерешче малай», аннары «йөгерешче егет» диләр. «Йөгерешче абый»дан «йөгерешче абзый»га күчә. «Йөгерешче бабай»га әйләнүен безнең буын да хәтерли.* М.Хуҗин. *Атлар чапкан арада, мәйданда йөгерешчеләр ярышы башлана.* Казан утлары

**ЙӨГЕРМӘ** *и. диал.* Вак-вак тиз адымнар. *Ул бик кызу, йөгермә белән йөри, артыннан куып җитә алмадым.* Н.Исәнбәт. *Йөгермә белән өйдән чыгып китә.* Г.Гали

**ЙӨГЕРТМӘ** *и.* Берәр нәрсәнең өслегенә юка гына каплатылган матдә, ялтыравыклы эретмә; *русчасы:* **глазурь**. *Чүлмәкләр ясау, аеруча аларның өслеген бизәү өчен сыек пыяладан гыйбарәт йөгертмәләр җитештерү химиядән белем-күнекмәләрдән тыш була алмаган.* Г.Дәүләтшин

**ЙӨГЕРТМӘЛЕ** *с.* Ялтыравыклы эретмә белән каплатылган; шундый ысул белән эшләнгән. *Йөгертмәле нәфис керамика җитештерү Болгар илендә аеруча XII – XIII йөзләрдә үсеп китә.* Г.Дәүләтшин

**ЙӨГЕРТҮ** I *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн.* к. **йөгерү**

2) Берәр кеше яки нәрсә дә булса артыннан бик тиз әйләнеп кайту шарты белән каядыр җибәрү. *Нәҗип чыгып китте, Ихлас идарә дежурныен завхоз янына йөгертте.* А.Гыйләҗев. *Мине тавык оялырын карап кирәргә йөгертә.* А.Хәсәнов. *Рушанга исә йөгертеп кенә кибеттән шәраб һәм консервалар алу эше ышанып тапшырылды.* Р.Мирхәйдәров

3) Төрле йомыш белән бертуктаусыз әле анда, әле монда җибәрү. *Ул иреннәрен кысып, усал елмаеп дәшми генә утырды, туган-тумачасын, кызы Миләүшәне берөзлексез йөгертте: кунакларның алды буш тора күрмәсен, эчемлек, ризык вакытында килеп торсын һәм башкалар.* М.Мәһдиев

4) Куалау, юырттырып алып бару (ат турында). *Ә бит язмыш Батыйга да бу зур эшне могҗиза дәрәҗәсендә, гүя ат йөгертеп үтеп барышлый гына башкаруны шарт итеп куя.* М.Гайнетдин. *Атларны салмак кына йөгертеп кайткан бер мәлдә, әнә шул Сукыр Сәхаплар турысын үтеп барганда, кинәт тарантасның арткы уң як тәгәрмәче күчәреннән чыгып, бер якка тәгәрәп китте.* Ә.Салах

5) *диал.* Бәйгедә катнашу, ат чаптыру

6) Камчы белән яки төрле авазлар кычкырып куып алып бару (мәс., көтүне). *Мин инде ата каздан курыкмыйча, ояларын чыбык белән туздырып, йөгертеп кенә, су буена куып төшерәм.* Ф.Яхин

7) *күч.* Күзләрне тиз-тиз төрле якка хәрәкәтләндерү, күзләр белән тиз генә тирә-якны карап чыгу. *Җиһангир, каш астыннан күзләрен йөгертеп, соңгы тапкыр тирә-ягына күз сала.* Г.Әпсәләмов

8) *күч.* Нинди дә булса чалымнар чыгару, нindидер билгеләр барлыкка китерү. *Сәйдәшнең җавабыннан соң кинәт кенә калкып, чем-кара мыеклары астыннан елмаю билгеләре йөгертеп, кызык бер хәлне сөйләргә җыенганы сизелде.* Р.Низами. *Әбелгаз абзый тиз генә бирешмәс! Үзенең дәфтәрен актарыр, бер сары битенә тукталып, беркатлы, саф күзләренә килешмәүчәнлек төсмере йөгертеп, җиз тавыш белән үзенекен тәкърарларга керешер.* Т.Галиуллин

**2. йөгертеп** *рәв. мәгъ.* 1) Ашыктырып, тиз-тиз, тиз арада. *Әби моңа,*

*йөгертеп, шәл дә китерә.* Әкият. *Мөнир абыйсы, кызу-кызу атлап, аны йөгертеп диярлек, урам буйлап алып китте.* Ф.Садриев

2) Бик тиз, өстән-өстән генә, җентекләп тормыйча. *Четерекле милли мәсьәләләр чыкканда, өстән йөгертеп кенә үтәргә яратканнар өчен? Миргазиян аганың һәммә нәрсәнең төбенә – җелегенә төшеп карау, ваемсызлыкны уяту үҗәтлеге, метекче холкы күпләргә бик ук ошап та бетмәгәндер.* М.Галиев. *Хәдичә түти, кунак солдатның Гафифәне яңадан телгә алуыннан куркып, аңа йөгертеп кенә авыл хәлләрен, колхозның ничек эшләвен сөйли.* Г.Бәширов

3) Тиз, җаен белеп, җиңел (эшләү)

4) Төртелмичә, шома. *Шулай булмыйча ни, әле кайчан гына татарча «әни» сүзен дә белмәгән балалар инде рәхәтләнеп сөйләшәләр, йөгертеп укыйлар, алай гына түгел, әкият-тамашалар куялар.* Ф.Хәкимова

**Йөгертә тору** Әледән-әле йөгертү. *Яшүсмер Мифтах өй йомышларыннан бушамады, аны әле Фәтхия әби, әле Мәфтуха килен бертуктаусыз йөгертә тордылар.* Г.Ибраһимов

**Йөгертеп алу** Кыска вакыт дәвамында тиз генә йөгертү. *[Кыз] Кая карарга белмичә, күзләрен бераз дымландырып, йөгертеп алганнан соң, аска карап, Чыңгыз тәкъдим иткән йомшак кәнәфигә килеп утырды.* З.Садыйков. *Гөлзиләнең партасына таянып, кинога дәшүен көтте. Кыз, үзе дә сизмәстән, тирә-якка күз йөгертеп алды.* М.Кәбиров

**Йөгертеп җибәрү** 1) Йөгереп китәргә этәргеч бирү, кузгату

2) Аякка бастыру, авырудан терелтү. *Үземнең бәләкәй аптегымны алып барып, [тегермән хуҗасын] тиз генә йөгертеп җибәрергә тырышсам да терелтә алмадым.* М.Фәйзуллин

**Йөгертеп тору** Бертуктаусыз йөгертү

**Йөгертеп үтү** Берәр нәрсә яныннан йөгертү

**Йөгертеп чыгу** Нәрсәне дә булса башыннан алып ахырына кадәр йөгертү. *Экспертиза нәтиҗәләрен ул баштa, кәнәфи кырыена таянган килеш, күзләре белән тиз-тиз йөгертеп чыкты.* Р.Мөхәммәтҗан. *Азат тиз генә залга күз йөгертеп чыкты, йөзеннән ниндидер караңгы күләгә узгандай булды.* Ф.Латыйфи. *– Мин рентген аппараты түгел, дустым, – диде ул, Толикны ыңгыраштырып булса да, бармакларын аның сул аягы буйлап йөгертеп чыккач.* А.Хәсәнов

**ЙӨГЕРТҮ** II *ф.* 1) Берәр әйбернең (мәс., балчык яки фаянс савытларның) өслеген юка гына сыек матдә, ялтыравык белән каплау. *Рәсемдә --- яндырып эшләнгән һәм ялтыравыклы зәңгәр глазурь өстенә алтын йөгертеп бизәк төшерелгән кирпеч кыйпылчыгы.* Ф.Латыйфи. *[Матэ:] Дөрес! Сары чалгы бит бу. Менә сап куя торган җирендә, ике бармак читтәрәк, сары җиз йөгерткән.* З.Зәйнуллин. *[Мәчетнең] Стеналарына чүкеп, алтын-көмеш йөгертеп язылган Коръән сүрәләре, догалар.* Р.Ибраһимов

2) Берәр нәрсәнең тузанын һ.б.ны юып төшерү яки изгеләштерү өчен аңа су бөркү, сибү. *Балыкны вак кисәкләргә бүлгәләп, аларны су белән йөгертеп, инде суы кайнарланып килгән казанга салдылар.* Ә.Салах. *Тереклек суы йөгертеп сынландырылган шушы иксез-чиксез манзараларга шигъри әфсен өреп, яшәү нуры тараткaнга мәдхия җырлар өчен, Раббыбыз кешегә сүз тылсымы биргән.* М.Галиев

**Йөгертә төшү** Бераз, өлешчә йөгертү

**Йөгертеп алу** Тиз генә йөгертү

**Йөгертеп тору** Һәрвакыт, даими рәвештә йөгертү

**Йөгертеп чыгу** Бөтен нәрсәгә йөгертү; берсен дә калдырмастан, барысын да йөгертү. *Гасыйм Мәмәдович без юган җирне шлангтан су сиптереп йөгертеп чыга.* М.Юныс

**ЙӨГЕРТҮ** III *ф.* Каплату, чаптыру (хайваннарны)

**Йөгертеп чыгу** Барысын да йөгертү, берсен дә йөгертмичә калдырмау

**ЙӨГЕРТҮЛЕ** *с. сир. к.* **йөгертмәле**. *Аш-су булмәсендәге табында бизәкле япмасы ачылып куелган алтын йөгертүле савыт-сабалар.* А.Вергазов

**ЙӨГЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Аякларны тиз-тиз алыштырып, җирдән кискен этәреш ясап, билгеле бер юнәлештә хәрәкәтләнү. *Походка таңнан торып китәләр. Марш атлыйлар, йөгерәләр, «түш белән шуышып» йөриләр. Окоплар казыйлар.* Г.Гобәй. *Чәчкә бар көченә йөгерсә дә, яхшы атларга атланган куучылар аның эзенә тиз төшәләр.* Н.Сәйяр. *Көн дә, иртән торуга, рота алты чакрымга кросс йөгерә.* З.Хөснияр

2) Кая да булса ашыгып йөрү, кызу-кызу бару. *Минһаҗ абзый, безнең эш бик матавыклы бит, күп йөгерергә туры килә.* А.Расих. *Асылъяр, җайлы вакыт табып, Сәетгәрәе янына йөгерә.* Н.Сәйяр

3) Зур тизлек белән хәрәкәт итү. *Поезд исә, вак-төяк разъездларны бар дип тә белми, алга йөгерде дә йөгерде.* Т.Әйди. *Төн эчендә поезд йөгерә.* Р.Мингалим

4) Зур тизлек белән таралу, җәелү (төтен, җил, яктылык)

5) Дулкынланып, дулкыннар ясап чайкалу. *Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар...* Ә.Еники. *Артларыннан дулкын-дулкын булып Ак кылганнар йөгерә тавышсыз.* С.Гәрәева. *Дулкын-дулкын йөгерә җиткән иген.* Р.Гатауллин

6) Берәр төрле юнәлештә тизлек белән хәрәкәт итү, исү яки агу. *Дулкыннар ярга йөгереп менәләр дә, вак ташларны өстерәп, шаулап, кире төшеп китәләр.* И.Гази. *Аяк астындагы юеш үләннәрне кабартырга тырышып, җил йөгерә.* А.Гыйләҗев // *Сузылу, буй юнәлештә урнашкан булу. Урман аланнарына кәрә-кәрә, бормаланып сузылган бу таш юл, очы-кырые булмаган мари урманнарын урталай кисеп, алга йөгерә дә йөгерә.* Г.Гыйльманов. *Юлның бер чаты кыр эченә, игеннәр арасына йөгерә ---.* Ә.Баян

7) Юл транспортында барганда, тирә-яктагы күренешләрнең, әйберләрнең (юллар, сукмаклар, телефон чыбыклары һ.б.ның) шул транспорт тизлегенә тиң рәвештә артка чигенеп

калуы. *Тәрәзә янынннан берөзлексез күз агыла: сап-сары ак каеннар, күшегеп бөрешкән ялангач куаклар, агачлык араларыннан күренеп-күренеп киткән тайгак юллар, буш басулар һәм яңадан артка йөгергән агач-куаклар рәте.* А.Сафин. *Тәгәрмәчләр өстендә тәгәри заман, тизлек тәэсиреннән тирә-як табигате сызылып кына кала. Бар да артка йөгерә – хәтер аръягына.* М.Галиев

8) *күч.* Тәнгә, тән әгъзаларына нинди дә булса тәэсир таралу. *Бары Фёдоровны күргәч кенә аның йөзенә элекке ясалма мескенлек йөгерде.* А.Расих. *Сыйпап куйсам ап-ак гөлләр таҗын, Тәннәремә йөгерә җылылык.* Ф.Яруллин

9) *күч.* Кул, күз, мускуллар хәрәкәте җиңел, җитез һәм өлгер булу. *Әтәй [чалгысын] киң алдырып алга бара, кояшта янган ялангач аркасындагы мускуллар нәни бурсыклар сыман берберсенә таба йөгерә иде.* Р.Зәйдулла. *Аның яшькелт күзләре, кая барып сугылырга белмәгәндәй, арлы-бирле йөгерә иде.* А.Вергазов

10) *күч.* Вакытның тиз, сиздермичә үтеп китүе. *Һай, ничек тиз йөгерә бу еллар!* И.Салахов

11) *күч.* Чигеннән ташып, агып чыгу. *Моны һич тә улыннан көтмәгән ананың күзләренә яшь йөгерде.* М.Хәбибуллин

12) *күч.* Язу әсбабы белән ак кәгазь өстенә хәрефләр тезү, язу. *Кар өстеннән яланаяк чапкандай, салкын кәгазь өстеннән кайнар каләм йөгерә!..* Ш.Галиев

13) *күч.* Тиз арада хисләр, тойгылар тәэсире булып алу. *Аның бит очларына оялчан алсулык йөгерде.* Н.Фәттах. *Гөлгенәнең таушала башлаган чибәр йөзенә акыл чаткылары, тирәнлек, олылык һәм горурлык йөгерде.* А.Гыйләҗев. *Минем дәшми торуымны күргәч, аның шат йөзенә гаҗәпләнү билгеләре йөгерде.* А.Расих

14) *күч.* Нинди дә булса төс керү. *Кайбер агачлар яфракларына сары йөгереп төс ташлый башлаган булсалар да, өстән җылы кояш көлеп торганга, парк эче үзенә бертөрле матур иде.* З.Фәйзуллин. *[Голумбаның] Чәче дегет кебек кап-кара, чигәсенә әзрәк чал йөгергән.* М.Галиев

15) *күч.* Берәр нәрсә артыннан йөрү, көч куеп оештырырга, булдырырга тырышу. --- *кич белән төн буе – әллә кайда, әллә нинди лекцияләр, укулар... Муса әфәнде шулар артыннан да җисмани вә рухани көче җиткәнчә йөгерә.* Г.Тукай. *Туй да туй дип, көнетөне йөгерә.* Н.Гаетбай

16) *күч.* Тиз арада күп нәрсә башкарырга, эшләргә өлгерү, җитешү // Ашыгып-ашыгып, нәрсә дә булса эшләү. *Хатын-кыз бертуктаусыз кайный: киенәләр, ясаналар, буяналар, тырт-мырт өйдән-өйгә йөгерәләр.* Г.Ибраһимов. *Бу ау, әлбәттә, чын ау түгел иде. Чынына алдан ук әзерләнәләр аның, орды-бәрде чыгып йөгермиләр.* Н.Гыйматдинова

17) *күч.* Кемгә дә булса барып әйтү, әләкләү. *Швалюк, ә нигә штаб башлыгына йөгерергә?!* З.Хөснияр

18) *күч.* Уй-фикер йөртү. *Дөрес, теле аның фикереннән алданрак йөгерә, әмма бу кимчелектән арыныр ул.* Г.Үзиле. *Уйлары: «Монда мине ниләр көтә?» – дип алга йөгерде.* З.Фәтхетдинов. *Тел төбеңне аңладым, мәзин абзый: димәк ки, сарыгыңны бер явызы урлаган булып чыга. Кемгә йөгерә күңелең? Әйт ярып кына.* С.Поварисов

**2. йөгереп** *рәв. мәгъ.* Бик тиз. *Йокларга яткыргач та, Искәндәр тынычланмады, йөгереп кенә абзарга чыгып, Бүркәнең муеныннан кочып саубуллашып керде.* А.Гыйләҗев

**Йөгерә башлау** Йөгерергә тотыну. *Валерия кулымны кысып тотты да, трамвайга таба йөгерә башладык.* М.Юныс. *Өстәлдән өстәлгә запискалар йөгерә башлады: белмисезме, профессорга ни булган?* Г.Әпсәләмов

**Йөгерә бирү** Йөгерүне дәвам иттерү. *Хатын бик ашыга иде, шуңамы, әллә артык кабалангангамы, абындысөртенде, --- үзалдына сөйләнә-сөйләнә, сулкылдый-сулкылдый йөгерә бирде.* М.Маликова. --- *өе тугайның эчендә иде, ишеге алдында камышлы олуг күл бар иде, шул дәкыйга камышның эченә йөгерә бирде.* Ә.Баһадирхан

**Йөгереп алу** Бераз йөгерү. *Шул чагында түгәрәк ике битенә сыек кына матур алсулык йөгереп ала.* Р.Гарипов

**Йөгереп җитү** Берәр урынга яки нинди дә булса предмет яисә кайсы да булса зат янәшәсенә килеп җитешү, килергә өлгерү

**Йөгереп йөрү** Әле, хәзерге вакытта бертуктаусыз йөгерү. *Моны [сагызны] Академия утырышыннан кайтып баручы профессор да, --- Эйфель башнясы янында фотоаппарат асып йөгереп йөрүче америкалы турист та чәйни.* М.Мәһдиев. *Бер урыннан икенче урынга тик йөгереп йөрим шунда.* Ч.Айтматов. *Автор, кулъязмасын күтәреп, өстәлдән өстәлгә йөгереп йөри.* Р.Батулла

**Йөгереп карау** Куып тотарга омтылып йөгерү. *Без тагын бер тын йөгереп карадык та, [трамвайны] куып җитә алмаячагыбызны аңлагач, тиргәнә-тиргәнә тротуарга чыктык.* М.Юныс

**Йөгереп килү** Бер тапкыр урап чыгып йөгерү. *Әйдә, әнә теге агачтан йөгереп киләбез*

**Йөгереп китү** Кинәт йөгерә башлау. *Менә ул, озын кунычлы резин итекләрен лаштыр-лоштыр китереп, ашыгып, урамга чыкты, биегәйтелгән урта юл буйлап югары очка таба йөгереп китте.* М.Маликова. *Гөлфинур, капыл гына кузгалып, ай нурлары коенган уйсулык буйлап йөгереп китте.* А.Вергазов

**Йөгереп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта йөгерү

2) Кушкан эшне, йомышны тиз-тиз, йөгереп башкару

3) Төрле якка елт-елт хәрәкәтләнү (күзләр турында). *[Патшаның] Төпкә баткан нурсыз күзләре, тынычлык таба алмыйча, әле бер якка, әле икенче якка йөгереп торалар.* С.Горский

**Йөгереп узу** 1) Берәр нәрсә яныннан йөгереп алга китү. *Бабай дөрес әйткән икән: әледән-әле этләр йөгереп уза.* Н.Дәүли. *Кызлар керә, бер бала йөгереп уза.* Т.Гыйззәт

2) Тиз барлыкка килеп, шунда ук бетү, юкка чыгу. *Якындагы куак яфракларын шаулатып, беренче яңгыр*

*йөгереп узды.* Н.Фәттах. *Галияр сулга кайшалып, кулы һавада асылынып торган арада, Сәрвиянең башыннан әнә шундый уйлар җәһәт йөгереп узды.* М.Хуҗин. *Ник күтәрелеп караганына, ник туганына үкенде шул мизгелдә. Аркасыннан салкын дулкын йөгереп узды.* Т.Галиуллин

**Йөгереп үтү** *к.* **йөгереп узу**. *Еллар инде узган, Хәтер офыгыннан Йөгереп үтә яшьлек эзләре.* Р.Акъегет. *Тик дугаланып килгән муеныннан арт сыртына табан бер-бер артлы ике дулкын йөгереп үтте.* З.Зәйнуллин. *Бер мизгел эчендә күпме уй башыннан йөгереп үтте.* Р.Кәрами

**Йөгереп чыгу** Берәр вакыт дәвамында яки ниндидер араның башыннан ахырына кадәр йөгерү. *[Яралы көенчә] --- урамның теге ягына йөгереп чыгарга каян көч тапты икән ул?* В.Нуриев

**ЙӨГЕРҮЧЕ** *и. к.* **йөгерешче**. *Икенче көнне йөгерүче Елена Мигунова бердәнбер алтын медаль алды.* Шәһри Казан. *Чаллыдан йөгерүче Гөлнара Сәмитова-Галкина һәм Түбән Камадан Екатерина Волкова катнашындагы йөгереш 15 августка планлаштырылган.* Туганайлар

**ЙӨДӘТКЕЧ** *и.* Еш борчый торган, кат-кат мөрәҗәгать итеп аптырата торган, тынгылык бирми торган кеше. *Йөдәткечне биздерим дисәң, бурычка бир.* Мәкаль

**ЙӨДӘТҮ** *ф.* 1) Берәр төрле сәбәпләр табып, еш-еш борчу, аптырату. *Әллә тәүфыйкка килде, әллә кара эшләрен майтаруның башка юлларын тапты – ничек кенә булмасын, үзе дә килеп чыкмады, чакыртып та йөдәтмәде.* Җ.Рәхимов // Еш-еш, кат-кат мөрәҗәгать итеп аптырату; нәрсә дә булса сорап, туктаусыз борчып тору. *Минә ул --- янә теләнергә тотынды. Бу юлы инде Абдулла --- комсыз малайга янап алды: – Йөдәтсәң, ташлыйм да китәм үзеңне.* Җ.Рәхимов. *[Әнәс Равилнең] тарих дәресендә укытучы Абдулла Мифтахычны сораулар биреп йөдәтүен [сөйләде].* В.Нуруллин // Кемгә яки нәрсәгә дә булса тынгылык бирмәү. *Баткалак ясадым язын, Тәмәкеләр көйрәттем, Чәчләрен тартып кызларның Дәресләрдә йөдәттем.* Р.Акъегет. *Өстәвенә, еллар дәвамында канына сеңеп беткән гадәтләре --- йөдәтте.* А.Сафин

2) Аптырату, борчу (табигать күренешләре турында). *Болытларга бер күмелеп, бер калкып йөдәткән ай да, йөрүеннән туктап, сары йөзе белән җиргә текәлде.* Н.Гыйматдинова

3) *к.* **йончыту**. *Ул [Габделәвәл абый] сүз белән шулкадәр мавыга, хәтта һәрвакыт томау төшеп йөдәткән борынын сөртергә дә онытa.* А.Расих

4) Рухи газаплау, эчке кичерешләр борчу. *Ул кеше турында миннән дә сорап йөдәттеләр бит.* Г.Тавлин. *– Ялгызлык йөдәтә, – дигән тавыш ишетелде.* Г.Кутуй. *Гыйльметдинне уйлап өзгәләнмәгән чагы юк, йоклап китсә дә, төшләренә кереп йөдәтә.* Ф.Сафин

5) Теләкне тормышка ашырмыйча, үтенеч яки йомышны үтәмичә аптырату, гаҗиз итү. *[Позициясе туры килмәгән кешене] Төрлечә кыса башлыйлар (мәсәлән, язган әйбереңне басмыйча йөдәтәләр).* Ә.Еники

6) Нинди дә булса эш яки процесс үзең теләгәнчә килеп чыкмыйча интектерү, тынычлыкны алу. *Башта гел кабинетта утырып, көн үтми йөдәтте, эш белән күмелгәч, көн җитми башлады.* Ф.Галиев. *Гаделша докторга карап торды, теләктәшлеге өчен рәхмәт укырга теләде, ләкин кирәкле сүзләр теленә килми йөдәтте.* Р.Ишморатова

**Йөдәтә башлау** Йөдәтергә тотыну. *Алар әледән-әле: «Искәндәр абзый, әйт инде, кайчан китәбез?» – дип йөдәтә башладылар.* Г.Үзиле. *Ул: «Мине шигырь язарга өйрәт», – дип йөдәтә башлады.* Ә.Галиев

**Йөдәтеп бетерү** Соңгы чиккә җитеп, нык йөдәтү. *Сатучыларның еш килгәнлекләре безне йөдәтеп бетерде.* Т.Гыйззәт. *Төрле-төрле кешеләр иртән дә килделәр, кичен дә килделәр, академикны йөдәтеп бетерделәр.* А.Алиш. *Колхоз базары янында корыштырылган күчмә циркта мотоцикл белән стенада йөргәннәрен карап утыруларым төшләремә кереп йөдәтеп бетергән иде инде.* В.Нуруллин

**Йөдәтеп йөрү** Озак вакыт дәвамында, һаман кемне дә булса йөдәтү. *Безнең авылларда бер-бер өйгә бер теләнче килеп, шул өйнең хатыны теләнчене: «Кит, кит, бабай, йөдәтеп йөрмә, бар, күземә күренмә!» – кебек сүзләр илә орышса, шуны ишеткән ире үзенең хатынына: «Каты бәрелмә, хатын! Ул карт Хозыр Ильяс булмасын!» – дип тәнбиһ итәдер.* Г.Тукай. *Ә нигә соң бал кортлары килмиләр? Савыт тирәли выжылдап очып, йөдәтеп йөрмиләр?* А.Алиш

**Йөдәтеп килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле системалы йөдәтү. *Күп еллардан бирле урысларны йөдәтеп килгән Казан падишаһлыгын бетерүе белән [җыелган халык] Иванны котлады.* Һ.Атласи

**Йөдәтеп тору** 1) Әле, хәзер йөдәтү

2) Әледән-әле, бертуктаусыз йөдәтү. *Бала үзенең «нигә?», «ни өчен?»нәре белән атлаган саен йөдәтеп тора.* Ф.Яруллин. *Минем Зиттага бернинди дә бирәчәгем-алачагым юк, алайса, нигә ул җанымны йөдәтеп тора?* Х.Камалов

**ЙӨДӘ́Ү** I *ф.* 1) Ару, талчыгу, хәлдән таю. *Барысы да, юл килеп, шундый йөдәгәннәр, юл газабы – гүр газабы, дип, белмичә генә әйтмиләр шул.* Ә.Галиев

2) *к.* **йончу**. *Баш авыртудан йөдәгән сәгатьләре икән моның.* Ф.Баттал. *Кан агудан, ачлыктан, атналар буенча йокламаучылыктан йөдәгән, самсыраган солдатларга: – Әй син, нигә башыңны салындырдың? Күтәр башыңны, солдат бул! – диде.* А.Таһиров

3) Берәр нәрсәне хәл итә, башкара алмыйча аптырау, кыен хәлдә калу. *Фәрман өстенә фәрман чыккач аптырадылар, йөдәделәр, ди, патшаның министрлары.* А.Алиш. *[Фәез] Кунакка нинди исем белән эндәшергә, эндәшкәч нәрсә әйтергә кирәген белмичә йөдәде.* Ә.Баянов

4) Рухи газаплану, бик нык борчылу. *Үсмер кызның төн йокыларын калдырып әзерләгән, атналар-айлар буе тиешле кешесенә ничек тапшырырга белми йөдәгән беренче һәм ихлас бүләге...* Р.Мөхәммәдиев

5) *күч.* Бик озак вакыт кызгану хисе кичерү. *Баштагы мәлләрдә мин сарыкларны кызганып йөдәдем.* С.Хафизов. *Беренче көннәрдә үземне дә түгел, кешеләрне дә түгел, атларны кызганып йөдәдем.* Ф.Хөсни

**Йөдәп бетү** Тәмам, нык йөдәү. *Мин чигешемне алып утырсам да, бизәкләремне ялгыш чигеп, үрнәкләремне бутап, бармакларыма инә чәнчеп йөдәп беттем.* Г.Исхакый. *Без «Мәрфугать» мәйданына җиткәнче йөдәп беттек.* Ш.Камал. *Апасы әтисен төшләрендә күреп йөдәп беткән.* Б.Камалов

**Йөдәп йөрү** Озак вакыт дәвамында йөдәү, нәрсә эшләргә дә белмәү халәте кичерү. *Бер җанына җылы табалмыйча, Илдә йөдәп йөргән чагында, Ул үзе дә килеп чыккан әнә Урыс пайтәхете ягына.* Г.Морат

**Йөдәп чыгу** 1) Билгеле бер вакытның буеннан буена, башыннан ахырына йөдәп үткәрү. *Мин төн буе әллә нинди татлы төшләр күреп йөдәп чыктым.* Г.Исхакый

2) Йөдәүгә дучар ителү. *Мәнә кешелек шунда: әгәр син усаллыкка яхшылык кайтарсаң, ул кеше вөҗданына газапланып, эче пошып йөдәп чыга.* Г.Исхакый. *Үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.* А.Алиш

**Йөди төшү** Бераз, аз гына йөдәү

**ЙӨДӘ́Ү** II *с. диал.* Арык, хәлсез. *Йөдәү атлар*

**ЙӨЗ** I *сан* 1) 100 санын һәм микъдарын белдерә торган сүз. *Батальон кичә йөз километрлык марш үтте, марштан кайтуга, фронтка күчте һәм төн буенча дошманны күзәтте.* И.Салахов. *Шулай итмәгәндә, йөз дә ун тәңкәгә ничек итеп гаилә туендырырга, көн күрергә мөмкин?!* Р.Мөхәммәдиев. *Йөз ел үткәч тә, бу яклардан узып барган юлчы, мөгаен, шушы ук күренешкә тап булыр.* А.Сафин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Гасыр, йөз елны эченә алган вакыт. *Татар әдәбиятында оппозицион суфичылыкның киң таралыш алган вакыты XIV һәм XVII йөзләргә туры килә.* Татар әдәбияты тарихы

2) Йөз яшь. *Миф буенча, елан йөзгә кадәр яшәсә, аждаһа була.* М.Җәлил

**3.** *с. мәгъ.* Бик күп, исәпсез. *Йөз төрле төсе, тәме, мәгънәсе, шуңа өстәп тагын мең төрле нюанслары бар аның [тормышның].* Р.Низамиев

**4.** *рәв. мәгъ.* Күп мәртәбәләр, әллә ничә тапкыр. *Кайтам, дигән кеше йөз урар иде бу сукмакны.* Н.Гыйматдинова

◊ **Йөзгә бер тулмаган** Акылга сай, беркатлы кеше. *Әмма «йөзгә бер тулмаган» бәндәләрнең хәйран акыллы фикерлеләре дә --- була.* Т.Нәҗмиев. **Йөзе белән кайтару** Бик күп арттырып бирү. *Күңел биреп тотынсаң, «җир» дигәнең йөзе белән кайтара ул.* Г.Бәширов. **Йөз яшә** Берәр кешегә теләк теләгәндә, рәхмәт белдергәндә әйтелә торган гыйбарә: «озак яшә, озын гомерле бул» мәгънәсендә. *– Бу – синең үз тәхетең, Сафа Гәрәй хан! – диде халык. – Йөз яшә, Сафа хан!* Р.Батулла. **Йөз яшәгән** Озак яшәгән, карт. **Йөз яшәр** *к.* **йөз яшәгән**. *--- әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөз яшәр Миңлебай карт!* Ә.Еники

**ЙӨЗ** II *и.* 1) Кеше башының алгы өлеше, бит. *Буйга миннән калку ---. Йөзе түгәрәк.* И.Салахов. *Артист өчен йөз мимикасының нинди зур әһәмияткә ия булуын һәркем белә. Ә бит сәхнәдә уйнаган һәр образның үз мимикасы бар.* Казан утлары

2) Кешенең рухи халәтен чагылдырган чалымнары, чырай. *Йөздә – бары мәгърур көлемсерәү, Уйдан ерак дөнья мазасы.* М.Җәлил. *Баян тотып кергән Гамир белән Маратны күрүгә, һәммәсенең йөзе бердәм ачылып китте.* З.Фәйзуллин

3) Кемнең яки нәрсәнең дә булса алгы ягы. *Безнең дивизия йөзе белән көньяк-көнчыгышка карап урнашкан.* Казан утлары

4) Нәрсәнең дә булса өске ягы, өсте. *Аннан [Батырша] аягының йөзен бик нык турайтып, божраны аска шудыртты.* Җ.Рәхимов. *Күрәчәгең булгач, күрми хәл юк: Елга ничек йөзен капласын?* Х.Әюп. *Илсөяр ни дип тә уйларга белмәде: анда әтисе, аяк йөзеннән суда торган хәлдә, офицерны, җитәкләп, көймәгә кертеп маташа иде.* Г.Гобәй. *Ипи йөзе килү*

4) Берәр нәрсәнең җәенке өслеге, киңлеге. *Күк йөзенә түгәрәк ай калыккан.* И.Гази

5) *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса асылы, үзенә генә хас үзенчәлеге, башкалардан аерып торган билгесе, сыйфаты. *Янәсе, Дәүләтьяров кебек сәяси йөзе шикле кешеләрне җитәкчелектә тотып булмый.* И.Гази. *Әгәр кеше яманлык кылса, һичкайчан яхшылык йөзен күрмәс.* Мәҗмугыл-хикәят. *Татар матбугатында дәүләт газеталарының йөзе булып «Ватаным Татарстан» санала.* Ватаным Татарстан

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса үзенә хас тышкы күренеше. *Һәр авылның үз йөзе, үз архитектурасы була.* Мәдәни җомга

7) *күч.* Намус, дәрәҗә, абруй. *Автор сөю хисен кешенең бөтен табигате, әхлак йөзе белән бәйләнештә карый.* Ф.Хатипов. *Кешелек йөзен югалту*

**2.** *бәйл. сүз мәгъ.* 1) **йөзендә** Кемнең дә яки нәрсәнең дә булса эшчәнлегенә, тоткан урынына бәя биргәндә кулланыла; мисалында, үрнәгендә

2) **йөзеннән** Нинди дә булса уй-теләк, максат, ният белән; өчен, максатыннан. *Рөстәмгә үгет-нәсыйхәт йөзеннән булырга кирәк, ул сүз арасында гаять тирән мәгънәле берничә фикер әйтте.* Г.Кутуй. *Шул карарларны үтәү йөзеннән авылларда нинди генә гамәлләр кылынмый да, нинди генә хикмәтләр эшләнми шушы ике ел эчендә.* Ф.Сафин. *Бәхти рәшәткә аша сикереп төште, әдәп саклау йөзеннән булса да рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, --- Рафига белән Иданың икесен дә култыклап алды.* Н.Фәттах

3) Берәр нәрсә билгесе белән, хөрмәтенә. *Бары тик икенче көнне, «рәхмәт йөзеннән» дигән булып, чәчәк белән торт керткәч кенә, Наилә хезмәттәшенә күз кысты.* Сөембикә. *Көнчыгыш Себер, Алтай халыклары тау үткелләрендә, күл һәм елга буйларында чуерташлардан биеклеге ике метр чамасы булган чүмәлә өеп, тау һәм су ияләренә ихтирам йөзеннән, аларның рухына табына, ялвара торган булган.* Гасырлар авазы. *Илүсәр ханымга зур хөрмәт йөзеннән чәчәк бәйләмнәре тапшырылды.* Шәһри Казан

◊ **Йөз аклау** Дәрәҗә саклау, абруйны төшермәү. *Кеше алдында йөзеңне бер пычратсаң, кешелегеңне югалтсаң, яңадан йөзне аклау, югалткан кешелегеңне табу, ышаныч яклау кыен шул.* Ф.Яруллин. **Йөз аклыгы** Дәрәҗә, яхшы исем. *Ул аның йөз аклыгын саклый, күршеләр алдында оятлы итәргә теләмидер*... М.Маликова. **Йөз ачу** *дини* Мөселман хатын-кызларының ират заты булган урында йөзен яшермичә йөрүе. **Йөз ачылу** Кәеф күтәрелү, җанлану, шатлану кебек хисләр чагылу. *Ул минем кулымны тагы бик каты кысты, аның йөзе ачылды.* Г.Исхакый. *Рамиләнең сагаюы шундук юкка чыкты, йөзе ачылды.* М.Маликова. **Йөз бәрү** *тар.* Җиргә тезләнеп, башны иеп, патшаны, солтанны һ.б.ны сәламләү. **Йөз белән** Нинди дә булса мәсьәләгә уңай мөнәсәбәт белдереп. *Ниһаять, Татарстанның рәсми җитәкчелеге дә, андагы татар милли хәрәкәте оешмалары да Башкортстан татарлары проблемаларына йөз белән борыла башлады.* Рифә Рахман. **Йөз белән җир себерү** Бөтен көчен куеп, җанынтәнен биреп ярарга тырышып эшләү, хезмәт итү. **Йөз бирү** 1) Үз итеп кабул итү, уңай мөнәсәбәт күрсәтү, кунакчыл булу; 2) Игътибар итү; 3) Ярдәм итү, уңыш килү. *Бәхет миңа йөз бирсә, дуслар миңа кул бирсә, нигә минем эшем алга бармас икән?* Н.Исәнбәт. **Йөз бозылу** Ачу килү, ризасызлык билгеләре чагылу, кәеф кырылу, күңел күтәренкелеге юкка чыгу. *Берәр кыек сүз әйтсәң дә, ялгыш өйдә кычкырып сөйләшә башласаң да, киреләнеп-карышып торсаң да, җитә кала – шундук йөзе бозыла, тавышы үзгәрә.* Н.Фәттах. *Аның сирәк кашлары бер-берләренә тоташып җыерылды, йөзе бозылып ямьсезләнде.* Г.Тавлин. **Йөз бору** 1) *к.* **йөз тоту** (*1 мәгъ.*). *Йөз бора һаман илебез яктылыкларга таба, Юнәлешне ник алды ул яхшылыкларга таба.* Н.Мадьяров; 2) *к.* **йөз чөерү**. **Йөзгә әйләнеп тә карамау** Күрмәмешкә салышу, мөнәсәбәтләр өзелү, ераклашу. **Йөзгә бәрү (бәреп әйтү, ору)** Тиргәү, шелтәү сүзләрен йөзгә карап тупас әйтү, үз уен хәтер саклап тормыйча белдерү. *[Наҗиянең] Соравын шундый тупас итеп, йөзгә бәреп әйтүе кунак кызына бик үк ошап җитмәсә дә, --- кызарынып басып тик торды.* Н.Фәттах. *Әллә соң тугрылыгың, йөзгә бәреп әйтүең кемгәдер ярамадымы?* Н.Хәсәнов. **Йөзгә кара йөгерү** Ярсу, шашыну хисләре йөзгә бәреп чыгу. *Аның йөзенә кара йөгерде, күзләре пыялаланды, куллары йодрыкка төйнәлде.* Ф.Латыйфи. **Йөзгә кара коелу** Тирән борчылу, кайгыру, хәсрәт хисләре йөзгә чыгу. *Чибәр егетнең йөзе кара коелган, этисенең көтелмәгән үлеме көләчлеген юып алган.* Р.Мирхәйдәров. **Йөзгә кара ягу** Яла ягу, гөнаһсызга рәнҗетү, кеше алдында ялган гаеп ташлау. *Шөкер, кеше алдында йөзгә кара якканнардан да түгел.* Ә.Сәйфетдинов. **Йөзгә кызыллык (оятлык) китерү** *к.* **йөз каралыгы китерү**. *[Василий Михайлович:] Без аңа ышанабыз: киләчәктә ул безнең йөзгә кызыллык китермәс, фән-техниканың теләсә кайсы тармагына да үзеннән лаеклы өлеш кертә алырлык югары квалификацияле белгеч булыр.* Н.Фәттах. *Бабаларым йөзгә кызыллык китерерлек яшәмәгән, гадел һәм тырыш кешеләр булганнар.* Г.Тавлин. *Сез минем йөземә кызыллык китермәдегез, шуның өчен рәхмәт сезгә.* Г.Ахунов. **Йөзгә сары коелу** 1) *к.* **йөз саргаю**; 2) Сагынып саргаю, бик күрәсе килеп, гыйшыктан зарыгып, йөзе сары төс алу. *Алтын балдак кия-кия, Бармакларым уелды; Син җаныйны уйлый-уйлый, йөземә сары коелды.* Җыр. **Йөзгә чыгармау** Кешегә эчтәге халәтне сиздермәү, сер бирмәү; ризасызлык, канәгатьсезлекне бер-береңә күрсәтмәү. *Йөзгә чыгармадык, тату яшәдек, Үпкә тотмадык, шөкер.* Ә.Гаффар. **Йөзгә ыштыр каплаган** *гади с.* Чиктән тыш оятсыз. **Йөздән кан качу** 1) Көтелмәгән хәлдән яки берәр вакыйгадан, кинәт куркудан йөзгә аксыл төс йөгерү. *Сәфәрне курәч, абзасының йөзеннән кан качты.* Н.Гыйматдинова. *Төш вакытында янып-пешеп Заһит килеп керде. Йөзеннән кан качкан, куллары калтырый, күрәсең, кичтән шактый төшергән иде.* М.Әмирханов; 2) Ачу килүдән, ярсудан агару. *Йөзеннән кан качкан Гасыйм сизелер-сизелмәс кенә калтыранган бармаклары белән тумбочка өстендәге папирос кабын капшап алды.* Н.Фәттах. **Йөз дүндерү** Ваз кичү, баш тарту. *Үзеңнән киселгән мәхрәм карендәшеңә тоташ, сиңа яхшылык итмәгән кешегә яхшылык ит, үзеңә золым итүче кешедән йөз дүндер!* Р.Фәхреддин. **Йөзе ак булу** Вөҗдан саф булу, эшләр, гамәлләр әхлак таләпләренә туры килү. *[Фидаяның] Намус каршында йөзе ак, димәк, кеше алдында да йөзе ак.* М.Маликова. **Йөзе алыну** *к.* **йөз бозылу**. **Йөзе алышыну** Йөздә нинди дә булса үзгәреш булу (мәс., шатлану, канәгатьсез булу һ.б.). *Ханша Аппакның йөзе алышынып китүен күзәтеп торган Феофанның эченә җылы йөгерде.* М.Хәбибуллин. *Өлкән тикшерүче күзгә күренеп үзгәрде. Йөзе-күзе алышынды.* М.Хәсәнов. **Йөзе кайту** Берәр кешедән күңел сүрелү, яратмый башлау. *Минем аннан йөзем кайтты.* Г.Минский. **Йөзе кара** 1) Гөнаһы, гаебе булган кеше. *[Хәмзә:] Юк! Боларны болай гына калдырырга ярамый, йөзе караларны!* Г.Камал; 2) Юньсез, явыз, кабахәт. *«Чык моннан, кит, йөзең кара!» – диясем килсә дә әйтә алмадым.* Г.Исхакый. **Йөзе кара яну** *к.* **йөзгә кара йөгерү**. *Патшаның ачудан йөзе кара янып китте.* К.Насыйри. *Әлимгулның мыегы кабарды, йөзе кара янды.* М.Әмир. **Йөзе килү** Камыр ашының өсте кызару (яхшы пешү билгесе). **Йөзен ачу** Дөресен белү, ялганны фаш итү. **Йөзен дә чытмый(ча)** Кыенсынмый(ча), уңайсызланмыйча. ... **йөзен күрмәү** Берәр нәрсәнең озак вакыт булмавы яки кемнән дә булса аерылу, югалту. **Йөзен кызарту** 1) Оялту, берәр эштә үкенергә мәҗбүр итү; 2) Шаяртып, көлеп, уңайсыз хәлдә калдыру. **Йөзең белән йөзтүбән каплан** *гади с., карг.* Кадалып кит, чукын (каргау, тиргәү сүзе). **Йөз ерту** 1) Кемнең дә булса хәтерен калдыру, үпкәләтү, дәрәҗәсе белән санлашмау. *[Кунакка] Буш кул [бару] йөзне ертыр, берәр бүләк эзлим дә ни алырга белмим.* А.Гыйләҗев. *Ләкин [Габделхәй] күңеленә килгән уен сүзгә әйләндерә алмады: олы кеше, хуҗа кеше белән бәхәсләшү,*

*аның йөзен ерту оят эш, хурлыклы эш булып тоелды.* Н.Фәттах. *[Хуҗа:] Өч сум өчен минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы?* Н.Исәнбәт; 2) Бик нык ярсу, бәргәләнү, йолкыну. *Моны ишетү белән, патша башын ташка ора, вәзир чәчләренә туфрак сибә, халык йөзен ерта-ерта елаша.* Г.Исхакый. **Йөз ертып** 1) Түбәнсенеп, гарьләнеп; 2) Әрсезләнеп, үҗәтләнеп, оялып та тормыйча. *Әнә хәзер китеп кара, паспорт сорап, йөз ертып барсаң, кәҗә билеты тоттыралар.* А.Гыйләҗев. **Йөзе сары** Сагышлы. *Читтә яшәгәннең Йөзе сары, Үз җирендә яшәү – Зур шатлык.* Р.Мозаффаров. **Йөзе якты булу** *к.* **йөзе ак булу**. **Йөз җимерү** Канәгатьсезлек, ризасызлыкны йөз чытып белдерү. *Шик корты, тирәнгәрәк үтеп, аның җанын кимерә, ул янә йөзен җимереп, кашларын җыера.* Н.Хәсәнов. **Йөз җыеру** *к.* **йөз җимерү**. **Йөз каралу** *к.* **йөз бозылу**. *Кинәт әтисенең йөзе каралып китте, ул, нәрсәдер исенә төшергәндәй, бакча уртасындагы мунчага йөгерде.* Н.Гыйматдинова. *Аның теге калган басуны да бүген үк урып бетерергә кирәклеге турында сүз башлавын ишеткәч, хәтта Родники комбайнчыларының да йөзләре каралып чыкты.* М.Маликова. **Йөз каралыгы (карасы)** Хурлыклы эш, гөнаһ табы. *Аның йөз каралыгы тиздән бөтен заводка фаш булачак, очрашканда, баш механик аның баш түбәсенә генә түгел, гәүдәсенә текәләчәк.* М.Маликова. **Йөз каралыгы китерү** Намуска тап төшерү, оятлы итү, хурлыкка калдыру. **Йөз караңгылану** *к.* **йөз бозылу**. **Йөз кату** Аптырап, шаккатып калу; куркуга бирелү. **Йөз качу** Каты куркудан, ярсудан, озак, бик каты авырудан йөзнең үз төсе югалу, агарып китү. **Йөз качыру** 1) *дини к.* **йөз яшерү**; 2) Кемнең дә булса күзенә чалынмаска тырышу, читләтеп йөрү, аралашмау. **Йөз күрсәтү** 1) *к.* **йөз бирү**; 2) *к.* **йөз ачу**. **Йөз кызару** Оятлы булу, кемнеңдер каршысында авыр, кыен хәлдә калу. **Йөзне кара болыт сару** *к.* **йөзгә кара коелу**. *Ничә сынадым: йөзеңне гел кара болыт сарган, хет бер елмайсаң иде.* Н.Гыйматдинова. **Йөзне хур итү** *к.* **йөзгә кызыллык китерү**. *Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап: – Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең, – ди.* Г.Ибраһимов. **Йөз ору** *тар. к.* **йөз бәрү**. *Бикәч җәһәт кенә җәяүләнде, Сөен тутайның аягына йөзен орып, Бүзтарланның тезгенен тотып әйтте: – Ярлыка мине... тилергән мин.* Р.Батулла. **Йөз оялу** Кыенсыну, уңайсызлану, тартыну. **Йөз саргаю** Авыр борчылулар, кайгы-хәсрәтләр, сагыш кичерү; йөзе ябыгу, тартылып китү, нурсызлану яки авыру нәтиҗәсендә йөзгә саргылт төс керү. *Алар, үзләре күргән тарихи хәсрәттән, кысу-рәнҗетелүләрдән, кимсетелүләрдән күз яшьләре кибеп, җаннары коргаксылап, йөзләре саргаеп, ул саргаюның тәннәренә дә күчә баруын чамалар иде.* Р.Хисмәтуллин. **Йөз сулу** Ябыгып, төссезләнеп китү. *Йөзе сула төшкән, әмма чибәрлеген әле тамчы да җуймаган иде Сәүдә.* Г.Ахунов. *Азат Гөлчирәгә карады: Гөлчирәнең йөзе сулган.* Г.Әпсәләмов. **Йөз суы** Яхшы исем, абруй, дәрәҗә, намус. **Йөз суын корыту** *к.* **йөз суын түгү** (*2 мәгъ.*). *– Мең бәла белән, – диде Кариев, – столоначальникларның бусагасын таптап, йөз суымны корытып, бөтенләй кешелек сыйфатларымны югалта яздым.* А.Расих. **Йөз суын түгү** 1) Мыскыл итү, кимсетү, түбәнсетү (башка кешене яки үз-үзеңне); 2) Түбәнчелек күрсәтеп сорау, ялыну. *Тагын шул: әлеге дә баягы, рәхимле бәндәгә – Золотиловкага – йөз суын түгеп барып егылды.* Р.Кәрами. *Бусагаларына барып йөз суыңны түккәнче, тыныч вөҗдан белән җан бирүең мең өлеш артык.* К.Нәҗми. **Йөз суыну** *к.* **йөз бозылу**. **Йөз суырылу** *к.* **йөз сулу**. *Оляның йөзе суырылган, күзләре кызарып шешенгән, шәле астыннан таралмаган чәчләре бүселеп чыккан иде.* Г.Тавлин. **Йөз тоту** 1) Эшхәлне нинди дә булса юнәлештә алып бару яки кая да булса юнәлтү. *Аның [Ф.Әмирханның] әсәрләрендә мәгърифәтчеләрнең төп идеяләре – кадимчелеккә каршы көрәш, европачыл культурага йөз тоту, хатын-кыз иреген яклау...* Ф.Бәширов. *Кала халкы да, дала халкы да үләргә йөз тоткан бичара сабыйның савыгып китүен төрлечә юрады.* Р.Батулла. *Баштан ук Алтын Урдага йөз тоткан һәм Урданың тәмам аркадашы булып киткән Александр Невский кенәз, үз чиратында, швед, немес һәм литвалыларның Русия җирләренә басып керүләрен туктатты.* Мәдәни җомга; 2) Билгеләнгән юнәлештә юл алу, шул якка таба китү, юлга чыгу. *[Фазыл] Шул сәгатьтә үк Багдадка йөз тотты.* Мәҗмугыл-хикәят; 3) Барлык омтылышларны теләгән якка юнәлтү турында. *Кайчандыр институтны тәмамлагач та, туган ягына кайтмыйча, медицина фәне кысына, ярына йөз тотуы, үрелүләре юкка гынамы икән?* Ә.Сәйфетдинов; 4) Нәрсәнең дә булса (мәс., яшьнең) билгеле бер чиктән үтүе турында. *Яше дә шул кырыкның аргы ягына йөз тоткан булырга тиеш.* Р.Мөхәммәдиев. *[Саттарның] Яше дә инде шактый гына, иллегә таба йөз тоткан.* Н.Акмалов. **Йөз төбәү** *к.* **йөз тоту**. *Атканда, чапканда, хөрлеккә йөз төбәп, булды мизгелләр: капландык йөзтүбән.* Р.Фәйзуллин. **Йөз чөерү** 1) Кире кагу, кабул итмәү, үз итмәү. *Туганының баласыннан йөз чөерсә, аяз көнне яшен сугар тагы!* Н.Гыйматдинова. *Бәлки, сез миңа Габдулла Тукайдан да йөз борырга тәкъдим итәрсез?* Г.Тавлин. *Кем булсаң да, халкың үткәненнән Йөз чөермә, заман баласы.* Ә.Рәшит; 2) Берәр кемгә яки нәрсәгә карата тискәре караш туу, читләшү, аралашуны өзү. *Шанлы вә гайрәтле Казан дәүләтен талый башладылар, үләксәгә җыелган козгыннар кебек, үз туганнарың йөз чөерә башлады.* М.Хәбибуллин. *Укымышлылыгың да зур, әмма ата-анаңа аяулы түгелсең, мәрхәмәтең юк икән, авылдашларыңның синнән йөз чөерәсен белеп тор.* Б.Камалов; 3) Баш тарту, нәрсә дә булса эшләргә каршы килү, кушылган эшне үтәмәү. *Мәрдәншә агай дөрес әйтә: әз-мәз белеме булды исә, күбесе «кара эш»тән йөз чөерә башлый.* Н.Фәттах. *Әниең дә, колхозда эшләүдән йөз чөереп, Ленинградка сыпырган.* Казан утлары. **Йөз чыту** *к.* **йөз җимерү**. *Ике азамат егет кенәзне ая-*

*гына бастырды, сөңгене алдылар, шаулап кан аккан иңен кысып кенәз Горбатый йөзен чытты.* М.Хәбибуллин. *– Садитесь,– диде ул йөзен чытып һәм тәрәзә кырына күчебрәк утырды.* А.Сафин. *Кәефсез генә, азапланып кына, йөземне чытып кына, мин түбәдән төштем дә бакчага барып утырдым.* Ф.Әмирхан. **Йөз шиңү** *к.* **йөз сулу**. **Йөз яктыру** *к.* **йөз ачылу**. **Йөз яшерү** *дини* 1) Мөселман хатын-кызлары чит ир-атлар янында йөзен пәрәнҗә белән каплап йөрү яисә күз карашын читтә тоту, сөйләшмичә йөрү; 2) Белгертмәү, күрсәтмәү, сиздермичә эшләү. *Дәлил: [җинаятьче] бай йорты тирәсендәге юлларны, хәлләрне яхшы белеп эш иткән һәм казу эшләрендә йөзен яшергән.* З.Фәтхетдинов

**ЙӨЗ** III *и.* Кисә, чаба торган коралларның үткен ягы. *Хуҗа ашыкмыйча гына чалбар кесәсеннән үткен пәкесен чыгара, аның ни дәрәҗәдә үткен булуын белү өчен, баш бармагы белән йөзен капшый.* А.Расих. *Низамый, чалгының йөзенә бармагын тидерде дә, авыз эченнән генә мыгырдап куйды.* Н.Фәттах. *Үткер, дип уйлады ул, балтаның йөзен чамалап.* Ә.Гаффар

◊ **Йөзе кайту** Үткенлеге бетү, үтмәсләнү, тупаслану. **Йөзен чыгару** Тиешле дәрәҗәгә җиткереп үткенләү, кайрау. **Йөз салу** Йөзен ясау, үткен итү

**ЙӨЗӘР** *сан* Һәркемгә (һәрнәрсәгә) йөз, бертигез күләмдә йөз булуны белдергән бүлем саны. *Гомеренә кадаклап икмәк ашаган кешегә йөзәр потлап икмәк бирделәр дә бөтенләй зиһенне чуалттылар да куйдылар.* А.Алиш. *Кайбер көннәрдә сөяге-ние белән бергә йөзәр грамм ит бирәләр.* Р.Мостафин. *Әле пристаньда чакта ук, «җиргә аяк басу хөрмәтенә» дип, безгә янә дә йөзәр грамм өлеш тиде.* Н.Акмал

**ЙӨЗӘРЛӘГӘН** *сан к.* **йөзләгән**. *[Иоан] Кызыл мәйданда берьюлы йөзәрләгән кешенең канын койган.* С.Горский. *Тугайлары белән болыннары йөзәрләгән дисәтинә аның.* В.Имамов. *Димәк, хәзер --- йөзәрләгән артиллерия һәм миномёт бригадаларын коралландыру өчен бездә көч бар!* Казан утлары

**ЙӨЗӘРЛӘП** *рәв.* 1) Йөзәр-йөзәр итеп

2) Бик күпләп, берничә йөздән артык. *Ни өчен бүгенге көндәге дистәләп, йөзәрләп язылган көйләрнең күбесе күңелгә, йөрәккә түгел, хәтта колакка да барып җитми икән?!* Н.Фәттах

**ЙӨЗӘРЛЕ** *с.* Үлчәү, исәпләү, чагыштыру өчен нигез итеп йөз саны яки микъдары алынган. *Йөзәрле үлчәү*

**ЙӨЗӘРЛЕ-ЙӨЗӘРЛЕ** *с.* Һәрберсе йөзәр булган. *Колшәриф имам белән Мөхәммәдьяр остаз гаскәренә тирәяктагы авыллар, даругалардан унарлы, йөзәрле-йөзәрле тупламнар килде.* Р.Батулла

**ЙӨЗӘРЛЕК** *и. к.* **йөзлек**

**ЙӨЗБАШЫ** *и. тар.* Йөз сугышчыдан торган төркем башлыгы. – *Минем янга йөзбашы Җирән килсен, – диде Албуга.* Н.Фәттах. *Гаскәриләр ашыгакабалана үзләренең йөзбашлары янына туплана башладылар.* Җ.Рәхимов

**ЙӨ́З БӘГЕ** *и. иск. тар. к.* **йөзбашы**; *русчасы:* **сотенный**. *Азатлык көрәшенең башында элеккеге ханлыкның Болын ягы хөкемдарларыннан берсе – йөз бәге баһадир Мамыш Бирде тора.* Мирас

**ЙӨЗ-БИТ** *җый. и.* Кешенең йөзе һәм яңак өлешләре. *Йөз-битенә кунган сакал-мыек төкләренә караганда, ул егерме яшьләр чамасында булыр.* Г.Гыйльманов

**ЙӨЗ-БУЙ** *җый. и.* Кыяфәте һәм сыны. *Эһ, сынау да булмаса! Йөз-буйга калса, күбесе сынатмаслар иде дә.* Н.Сәйяр

**ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ** *рәв.* Кара-каршы, күзгә-күз. *Аларның өйләре безнекенә йөзгә-йөз карап тора.* Р.Кутуй. *Асия утырган өстәл шулай урнаштырылган иде: ишектән кергән һәр кеше бу өстәл артында утыручы белән шундук йөзгә-йөз туры килә.* Р.Мөхәммәдиев. *Йөзгә-йөз бәрелеп көч сынашсак, алар безне җиңә.* В.Имамов

**ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ КИЛҮ** *ф.* Капмакаршы якларның берсенә-берсе каракаршы килеп очрашуы. *Тиздән миңа ул бәрәңге борын белән йөзгә-йөз килеп очрашырга --- туры киләчәк бит.* М.Кәрим. *Композицияләрдә туплар гөрелтесе дә «ишетелми», яшәү белән үлемнең йөзгә-йөз килүе дә күренми.* Казан утлары

**ЙӨЗГӘЛӘК** *и. зоол.* Коңгызларның бер семьялыгын барлыкка китергән, арткы аяклары йөзү өчен, алгылары эләктереп алу өчен җайлашкан, әкрен агымлы яки торгын суда яшәүче эре ерткыч коңгыз; *русчасы:* **плавунец**. *Аерчалы йөзгәләк. Каймалы йөзгәләк. Тимгелле йөзгәләк*

**ЙӨЗГӘ-МЕҢГӘ** *рәв.* 1) Йөз яки мең саны арасында

2) Ара-тирә, бик сирәк

**ЙӨЗГЕЧ** *и.* Балыкларда һәм суда яшәүче умырткалы хайваннарда хәрәкәт итү органы. *[Чуртанның] Селкенер-селкенмәс торган йөзгечләре – ипи көрәге кадәр ике.* Р.Сибат. *[Акулаларның] Берсе, арка йөзгече белән су өстен ертып, көймәне урап узды.* М.Юныс

**ЙӨЗДЕРҮ** *ф.* **1.** 1) Тирән суга алып кереп, коендыру, юу (мәс., атларны, этләрне һ.б.ны); аларга тотынып йөзү. *Безнең бабайларымыз, Урал елгасын үтеп, атларын йөздереп, Иделне кичеп, Аурупага аяк басканда, Аурупадагы бөтен халыкларга үзләренең баһадирлыкларын танытканда, алар белән бергә безнең әбиләремез дә бар иде.* Г.Исхакый

2) Кул белән этеп яки берәр нәрсә белән төртеп, су өстендә хәрәкәтләндерү. *Шул бассейнда ата булачак кеше Искәндәр белән кәгазь көймә йөздерде.* Ф.Яруллин. *Соңыннан юан-юан бүрәнәләрне суга тартып төшерәләр дә, сал ясап, Атлантик дәрьяга йөздереп алып төшеп китәләр икән.* Р.Сәгъди

3) *күч.* Нинди дә булса хис-тойгылар дөньясына алып керү. *Менә күр дә тор: ул сине, мәхәббәт дулкынында йөздереп, җылы кочагында эретәчәк.* Н.Хәсәнов

**2. йөздереп** *рәв. мәгъ.* Майны күп итеп салып, май эчендә йөртеп. *Шуларны сары майда йөздереп кенә пешерсәң, сезнең суга болгаткан бәрәңге боламыгы оялып үләр иде.* К.Тимбикова. *Әхмәтьяр бөрчекле-бөрчекле кечкенә коймакны алып, тәлинкәдәге өстәмә майда йөздереп, бик тәмләп йотып*

*җибәрде дә артыннан сөтле чәй капты.* Р.Батулла

**Йөздерә башлау** Йөздерергә тотыну. *Су буена төшеп, көймә йөздерә башладылар.* Г.Гыйльманов

**Йөздереп алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә йөздерү. *Әхмәдулла ялан аякларын көймә төбендәге суда чупырдатып куйды, аннан, ике баш бармагын күтәреп, аякларын йөздереп алды.* Р.Сибат

**Йөздереп җибәрү** Йөздерә башлау, йөзәргә этәргеч бирү. *Менә ул каек төбендәге капчыктан түгәрәк ипи алды һәм, нәрсәдер укынып, аны агым уртасына йөздереп җибәрде.* Ф.Латыйфи

**Йөздереп йөрү** Һаман саен йөздерү. *Агыйделнең суы кибә: әүвәле без ат йөздереп йөргән җирләрдән кичү бирә.* М.Әмир

**Йөздереп чыгу** Бер ярдан икенче ярга кадәр, ашадан-аша йөздерү. *Моратай, атының койрыгына ябышып, Иделне йөздереп чыккан.* Г.Бәширов

**ЙӨЗДЕРТҮ** *ф.* Ияртеп, куалап, елганы йөзеп кичтерү (хайваннар турында). *Ул аркан белән җитәкләгән бозауны аръяк болынга су йөздертеп кенә алып чыкты.* Н.Хәсәнов

**ЙӨЗЕК** *и.* Кыйммәтле таш белән бизәлгән балдак, кашлы балдак. *Илсөяр Матвей Ивановичның мескен күзләренә, аннан бармагындагы йөзек кашына карады.* Г.Гобәй. *Аның чәнчә бармагында кашы йөрәк төсле итеп коелган көмеш йөзек ялтырый иде.* Ф.Хөсни. *Нинди генә йөзекләр, алкалар, беләзекләр, муенсалар, асылташ кашлы бизәнү әйберләре юк иде бирегә.* М.Хәбибуллин

◊ **Йөзек кашы** 1) Төркем арасыннан уңай сыйфаты белән аерылып торган кеше, иң яхшы, булдыклы. *Зәйтүнә – мәктәпнең йөзек кашы, горурлыгы – унны бетерүчеләр арасында берүзе медальгә лаек булды.* Ф.Гыйльми; 2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса аерылып торган үзенчәлеге билгесе. *Сабантуйның йөзек кашы булган татарча көрәшне һәркем яратып карады.* Т.Нәҗмиев. **Йөзек яшерү** Сер бирмәү, ул турыда сөйләмәү, ачыктаначык әйтмичә калдыру

**ЙӨЗЕ́К АЛЫШУ** *ф. этн.* Егет белән кыз һәрвакыт бергә булырга диеп вәгъдәләшкәннән соң, бер-беренә йөзек бүләк итү

**ЙӨЗЕ́К БИРЕШҮ** *ф. этн. к.* **йөзек алышу**

**ЙӨЗЕ́К САЛЫШ** *и. этн.* Яшьләр уены (уенны алып баручы тезелешеп утыручыларның учларына йөзек тоткан кулын тидереп чыгып, сиздермәстән, аны берсенең учына салып калдыра һәм: «Кемдә йөзек, йөгереп чык!» – дип кычкыра; учына йөзек салынган кеше тиз генә урыныннан торып китәргә, ә ике ягында утыручы иптәшләре аны тотып калырга тиешләр; әгәр тотылса, ул «җәза» ала). *[Яшьләр] Тотыналар уйнарга: йөзек салыш, күз бәйләш, «станок», әйлән-бәйлән.* К.Тимбикова. *Ә яшьләр рәхәтләнә аулак өйдә: йөзек салыш, күз бәйләп качышлы уйнау, арка сугыш, тагын әллә нинди уеннар уйнап, тәмам кайнарланып бетәләр.* В.Нуруллин. *Кышкы озын кичләрдә авыл яшьләренең аулак өй мәҗлесләрендә «йөзек салыш» уйнаганда, иң оста итеп ул җырлый торган булып китте.* К.Тимбикова

**ЙӨЗЕК-БЕЛӘЗЕК** *җый. и.* Йөзек һәм беләзек шикелле бизәнү әйберләре. *Рәхмәт, сөеклем! Ләкин мин аның ни машинасына, ни кием-салымына, ни йөзек-беләзекләренә һич кенә дә кызыкмыйм.* Р.Мирхәйдәров

**ЙӨЗЕ-КҮЗЕ** *җый. и.* Бите һәм күз карашы. *Азымбай керүгә, ул урыныннан кузгалмады, баш күтәрмәде, йөзекүзе үз алдындагы бер ноктага текәлгән көенчә калды.* Г.Ибраһимов

◊ **Йөзе-күзе алышыну** Кинәт чырае үзгәрү. *Өлкән тикшерүче күзгә күренеп үзгәрде. Йөзе-күзе алышынды.* М.Хәсәнов

**ЙӨЗЕМ** *и.* 1) Йөземчәләр семьялыгының лианалар төреннән, җылы якларда үсә, тәлгәшле җимешләр бирә торган куак үсемлек (җимешләре ашамлык буларак яисә төрле эчемлекләр ясаганда кулланыла); *русчасы:* **виноград**. *Шадра диңгез өсте, кипарислар, Тезелеп киткән йөзем түтәле --- Мираж төсле күзгә чагылып үтте Иртәнге ак томан үтәли.* М.Җәлил. *Әнием, Котдус тирәсендә гел зәйтүн белән йөзем агачы гына утыртылган, дип яза.* А.Расих. *Ничек итеп автобуска кереп утырганын, диңгезгә беренче тапкыр ничек итеп күз салганын, яр буеннан ук күтәрелеп киткән биек тау түшләрен, --- юл буенда тезелеп калган абхаз авылларын, йөзем агачларын әллә тойды, әллә тоймады [Минзилә].* Н.Акмалов

2) Шул үсемлекнең җимеше

**ЙӨЗЕ́М СУЫ** *и.* Йөзем җимешеннән әзерләнгән исерткеч эчемлек

**ЙӨЗЕМЛЕК** *и.* 1) Йөзем куаклары утыртылган (үскән) урын

2) Йөзем сатып алырга җитәрлек. *Хәленнән килгән вак йомышлар башкарып, бер-ике телем икмәклек, берике уч йөземлек --- акча табып яшәде.* А.Расих

**ЙӨЗЕМЧЕЛЕК** *и.* Йөзем үрчетү, аны карап үстерү белән бәйле авыл хуҗалыгы тармагы

**ЙӨЗЕНЧЕ** *сан* **1.** Рәт, тәртип белән санаганда, йөз урынында килә торган тәртип саны

**2.** *рәв. мәгъ. куч.* Күп тапкыр, бик күп. *Шулай да Зөфәр үзенең күргәннәрен инде йөзенче тапкыр сөйләп бирергә иренмәде.* Г.Гыйльманов

**ЙӨЗЕШ** *и. спорт* Йөзү буенча ярыш. *Чемпионат программасына гамәлдәге спортчылар һәм «Мастерс» категориясендәге спортчылар өчен 2,5 километрлы дистанциягә 2 йөзеш кертелгән иде.* Татарстан яшьләре

**ЙӨЗЗУРЛЫК** *и. мат.* Яссылыкта яки өслектә яткан геометрик фигураларны характерлый торган төп математик зурлыкларның берсе; мәйдан

**ЙӨЗ-КЫЯФӘТ** *җый. и.* Кешенең килеш-килбәте, тышкы кыяфәте. *Үзе зуп-зур гәүдәле булса да, кеп-кечкенә башлы, эчкә баткан борынлы, шар күзле, кыек авызлы, күрсәң котың алынырлык, ди, бу егетнең йөз-кыяфәте.* Н.Сәйяр

**ЙӨЗЛӘГӘН** *сан* **1.** Чама белән берничә йөзгә якын, якынча йөз булуны белдергән чама саны; йөзләп. *Зур башлы, кызыл билле йөзләгән кырмыска берьюлы аяк табаныннан балтырларга үрмәләде.* Н.Гыйматдинова. *Элекке ке-*

*бек йөзләгән кеше белән сафка тезелешеп эшкә йөрисе юк, көнозын диярлек бирүзе.* М.Әмирханов. *Гарәпләр --- үз тарихлары турында ел саен йөзләгән фәнни-популяр китаплар чыгарып торалар.* В.Юныс

**2.** *с. мәгъ. күч.* Бик күп, исәпсез. *Йөзләгән кеше эш көтеп тора.* Ф.Яруллин

**ЙӨЗЛӘНҮ** *ф. иск. к.* **йөз тоту** (*2 мәгъ.*). *Бәһрүз Багдадка китәргә карар кылып, күп нигъмәтләр вә чиксез бүләкләр белән ул кәнизәкне бергә алып, Гыйрак тарафына йөзләнде.* Мәҗмугыл-хикәят

**ЙӨЗЛӘП** *сан к.* **йөзләгән**. *Бу төяләр кәрваныннан бирерәк, күл белән тирмәләр арасында, ничә йөзләп колыннар бәйләүдә тора.* Г.Ибраһимов. *Йөзләп агач казып алдык.* Ф.Галиев. *Харис, ишегалдын тутырып мәш килүче чебешләргә күз ташлап алгач, бер сүзгә дә, төрттерүгә дә исе китмәгәндәй, тагын сорап куйды: – Йөзләп бардыр болар? Бигрәк күп күренәләр...* Ф.Баттал

**ЙӨЗЛӘ́РЧӘ** *сан к.* **йөзләгән**. *Ләкин дистәләрчә академикларның ул дарулары, педагогларның йөзләрчә акыллы китаплары ана сөтенең бер тамчысына тормый.* Ф.Яруллин. *Фанәгүргә көннәрдән бер көнне йөзләрчә коллар белән кораб-кораб бүләкләр төягән грек илчеләре килеп төште.* М.Хәбибуллин

**ЙӨЗЛӘТӘ** *рәв.* 1) Йөз тапкыр, йөз мәртәбә, йөз өлеш артык яки ким итеп, йөз тапкырга арттырып яки киметеп. – *Мин тукыган паласларны патша йортына илтеп сатсагыз, минем башка эшләремнән алган файдадан йөзләтә артык файда алырсыз, – ди моңа патша малае.* Әкият

2) *күч.* Күп тапкырга, бик күпкә. *Зур рәхмәт сезгә. Ходай Тәгалә бу изгелегегезне кире үзегезгә унлата... йөзләтә... миллионлата кайтарып бирер.* М.Сәлим

**ЙӨЗЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тәрәзә, ишек уемына йөзлек утырту (кую)

2) Нәрсәне дә булса таш, металл, мәрмәр һ.б.ш. белән тышлау (каплау)

3) Кисә, турый, чаба, кадый торган әйберләрне үткенләү, кайрау

4) Ертыкка пөхтәләп ямаулык тегү

**ЙӨЗЛЕК** I *и.* 1) 100 дән алып 999 эченә кергән саннарның җыелма исеме. *Тезмә саннар түгәрәк дистәләр, йөзлек, меңлекләр (һәм тагын да зур) арасында ясала торган сүзләрне эченә ала.* Татар грамматикасы

2) Йөз сум бәясендәге кәгазь акча. *Йөзлек кенә икән, әйдә, кассадаваклыйбыз.* Н.Фәттах. --- *саргылт көрән төстәге дүрт төргәк йөзлек һәм тагын дүрт төргәк куе яшькелт илле сумлыклар килеп чыкты.* Г.Үзиле

**ЙӨЗЛЕК** II *и.* Битлек; йөзне каплау өчен махсус эшләнгән әйбер

◊ **Йөзлек белән туу** Бәхетле булып туу

**ЙӨЗЛЕК** III *и.* 1) Тәрәзә, ишек уемы тирәли беркетелә торган, сырлап, кисеп, уеп бизәкләнгән такта. *Авылда кемгә балтасын саплатырга, кемгә тиз генә рам ясатырга, кемгә тәрәзә яки ишек йөзлеге эшләтергә кирәк – аңа киләләр.* Г.Тавлин. *Урам якка зур-зур дүрт тәрәзә карый. Аларның йөзлекләре – агачтан челтәр.* Б.Камалов. *Авыл йортларындагы тәрәзәләргә төсле йөзлекләр куйдылар, ак белән зәңгәргә буядылар.* Г.Ахунов

2) Сәкенең кырыена кадакланган такта. *[Гобәйдулла] Кергәч, сәке йөзлегенә утырып дога кылды да бит-ен яулык чите белән каплап мичкә сөялеп торган хатынга сүз катты.* З.Зәйнуллин. *Су сәке йөзлеген күмгән.* М.Маликова. *Бераздан ул сәке йөзлегенә чүмәшеп, мичтә дөрләп кабынган сары утка карап уйга калды.* Н.Хәсәнов

3) Аяк киемендә аякның йөзен каплап торган өлеш. *Җырлашып Өнсә кызлары Чүәккә йөзлек кайый.* С.Хәким

4) Нәрсәнең дә булса тигез өслеге, яссылык. *Такта йөзлеге*

**ЙӨЗЛЕК** IV *и.* 1) Мичнең кызуын саклау өчен, аның алгы өлешенә өеп калдырылган утлы күмерләр (ипи, гомумән, мич ашы пешергәндә)

2) Мичнең алгы өлеше. *Тимерша, кеше килеп керер дип көтмәгән иде, күрәсең, каушавын сиздермәскә тырышып, баскан урындыгыннан сикереп төште дә, мыскыллы оятсыз карашын Сәмигуллага текәп, балчыклы кулын мич йөзлегенә ышкый башлады.* Н.Каримова. *Гыйльметдин бер-ике адым алга атлады да, мич йөзлеген кытыршы куллары белән сыйпап, авыр гына тын алды.* Ф.Сафин

**ЙӨЗЛЕКЛӘ́Ү** *ф. к.* **йөзләү**

**ЙӨЗМӘ** *с.* 1) Су өстенә салынган, йөзеп йөри торган терәкләргә (көймәләргә, понтоннарга һ.б.) корылган. *Яр буе. Пароходлар туктый торган йөзмә пристаньның бер почмагы күренеп тора.* Д.Салихов. *Дәүран ике аты белән йөзмә күперге җитте, күпер тотучыларга акча түләп, аръякка чыкты.* М.Хәбибуллин

2) Су өстендә үзеннән-үзе йөзеп йөргән. *Бу йөзмә утрауны камышлар, үрелеп беткән агач тамырлары шундый нык кысып, җыеп тоталар ---.* И.Гази. – *Әйе шул, йөзмә утрау ул, – ди Рөстәм, һич исе китмичә. – Җил уңаена күчеп йөри.* Г.Сабитов

**ЙӨЗСЕЗ** *с. сөйл.* 1) Күңелгә ятышсыз, оятсыз, әдәпсез; битсез. *Үзе – йөзсез, сүзе – тозсыз.* Әйтем

2) Нуры булмаган, сөйкемсез; бертөсле, төссез, берсеннән берсен аерып булмый торган. *Иске куртка, таушалган плащ, тузган бишмәт ише нәрсә кигән, такыр башлы һәм бер-берсенә охшаган йөзсез егетләр арасында ул үзен шундый уңайсыз һәм кыен сизгән иде.* А.Сафин

**ЙӨЗСЕЗЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Бик оятсызлану, үзен әдәпсез тоту; битсезләнү

**ЙӨЗСЕЗЛЕК** *и. сөйл. сир.* Үтә оятсызлык, намуссызлык, әдәпсезлек. *Миңа калса, шул ук абзыйларның икейөзлелеген йөзсезлек алмаштырды.* Безнең гәҗит. *Йөзсезлекне авыр кабул итү*

**ЙӨЗТҮБӘН** *рәв.* 1) Гәүдәнең алгы ягы белән, йөз белән аска таба карап; берәр нәрсәгә капланып; *киресе:* **чалкан**. *Мөнәвәрә кулларын җәеп йөзтүбән җиргә капланды.* Н.Гыйматдинова. *Сәгыйть абыйсы янына йөзтүбән сузылып ятты.* Н.Фәттах

2) *күч.* Асты өскә килеп. *Шушы мәлдә, туган җир туфрагына баскач, әллә нәрсә булды. Каршыдагы өянке, урам, өйләр йөзтүбән әйләнеп, керфекләре арасында калтырый башлады.* М.Галиев. *Алтын комлы яр буенда*

*йөзтүбән каплап куйган алюмин көймәләр дулкын кагып чыгарган эре балыклардай ялтырап ята.* Н.Хәсәнов

3) *күч. шигъ.* Яңабаштан. *Гомер – аста, вакыт өстә кала, Вакыт каршысында без түбән. Гомерне дә башлап булса икән Әйләндереп кенә йөзтүбән.* Р.Низами

◊ **Йөзтүбән килү** *гади с.* Үлү, һәлак булу. **Йөзтүбән китү** *гади с.* Юкка чыгу, һәлак булу

**ЙӨЗҮ** *ф.* 1) Су эченнән махсус җайлашкан әгъзалар ярдәмендә өскә һәм аска таба хәрәкәт итү (балыклар һәм суда яшәүче хайваннар турында). *[Күлдә] Сарык тәкәсе кадәр карплар фосфорлы күзләре белән без күрмәгәннәрне күрә-күрә йөзәләр.* М.Мәһдиев. *Ә югыйсә пыяла савыт эчендә матурлыклары белән масаеп тын гына йөзгән балыклардан да көчсез һәм ярдәмчесез җан иясе юктыр бу дөньяда.* А.Сафин

2) Су өстендә яки аның тирән урыннарында кул-аяклар ярдәме белән хәрәкәт итү (кешеләр, җирдә яшәүче хайваннар турында). *Эшләп аргач, чумдык инешкә, чабак төсле йөзеп шаярдык.* М.Җәлил. *Исхакның --- хәйләгә маһирлыгы юк иде, аның йөзә белмәвен бик тиз күреп алдылар.* А.Гыйләҗев. *[Фидая:] – Безнең авылда малайларны, йөзәргә өйрәткәндә, тоталар да суга ыргыталар, – дип җавап бирде.* М.Маликова

3) Су өстеннән махсус йөзгеч корылмада (мәс., судноларда, көймәдә һ.б.да) хәрәкәт итү, йөзгеч корылмада кая да булса бару. *– Менә әби, мин ясыйм зур көймә, тиздән туфан суы калка, шул туфан суында көймәдә йөзәбез без, –* дигән. Әкият

4) Йөзгеч корылмаларның берәр төрендә хезмәт итү

5) Судан җиңелрәк әйбернең, батмыйча, агым уңаена хәрәкәт итүе (мәс., бүрәнә)

6) *күч.* Һавада (мәс., ай, кояш, төтен, болыт һ.б.) салмак кына хәрәкәт итү. *Сөләйманов, бик-бик элек, сабый чакларында болыннарда яткан кебек, үләнгә чалкан сузылып ятты, сирәкмирәк ак болытлар акрын гына йөзгән төпсез зәңгәр күккә күз текәде.* Ф.Галиев. *Ә болыт йөзә челләдә... Күк йөзе – зәңгәр-зәңгәр!* Р.Фәйзуллин. *Ерактагы таулар өстеннән ярыйсы ук күтәрелгән кояш сокландыргыч зәңгәрлектә күк гөмбәзендә йөзә.* Г.Кашапов

7) *күч.* Җиңел хәрәкәтләр белән бию

8) *күч. сир.* Очу (кошлар турында)

9) *күч.* Берәр тармакны оста белү, тирән белемле булу. *Ул исә, инде өченче дистәне куучы сазаган шәкерт, --- үзен гыйлем дәрьясында йөзүгә багышлаган тынгысыз зат.* Ж.Рәхимов

10) *күч.* Уңай шартлар тудырылган, бай, рәхәт тормышта яшәү. *Шулай булгач, ничек алмый түзәрмен? Алам мин: бәлки рәхәттә йөзәрмен.* Г.Тукай. *Син анда балда-майда йөзәсең, диләр...* А.Гыйләҗев. *Тимер ташкын аша тояклар тупылдавын ишетәсе килүдән ул җилкенеп, бөтермә җил иркенә бирелеп, алга каерылды да --- кинәт өстәге ак болытлар, каршыдагы өй тәрәзәләре, чирәмле сукмаклар буталып, баш әйләндергеч рәхәтлектә йөзә башлады.* М.Галиев

11) *күч.* Авыр тормышка буйсынып, газапланып, төрле михнәтләр күреп яшәү. *Көн-төн дигәндәй, муеннан эшкә чумарга, нужада йөзәргә тиешсең һәм йөзәсең.* Ә.Баянов

12) *күч.* Уй, хис-тойгыларга, кичерешләргә бик нык бирелү. *Нәҗип кергәч тә [Наилә] борылып карамады, димәк, уйлары бүтән якта, еракта йөзә булса кирәк.* А.Гыйләҗев. *--- мин яңа гына искә төшерергә азапланган һәм фәкать төшләрдә генә була торган гаҗәеп тойгылар дөньясында йөзә идем.* А.Сафин. *Көпчәкләр юл буйлап тәгәри, ә хатыннарның һәркайсы үз уенда, үз кайгысында йөзә.* З.Зәйнуллин

13) *күч.* Эшне белеп, теләп башкару

14) *күч.*Ниндидер халәттә булу. *Бер ун минутлап Матушкин игътибар үзәгендә йөзде дә, аннары сүз әүвәлге эзенә төште.* Ә.Мушинский. *Ул мәхәббәт диңгезендә йөзде. Гүзәлияне шашып сөйде.* Шәһри Казан

**Йөзә башлау** Йөзәргә тотыну

**Йөзә төшү** Бераз йөзү

**Йөзеп алу** Җиңелчә генә, бераз, кыска вакыт эчендә йөзү

**Йөзеп йөрү** Әле, хәзер, күз алдында йөзү. *Түбә өстендә җиңел ак болытлар йөзеп йөри.* Н.Фәттах. *Якты суның өстендә вәкарь белән генә аккошлар йөзеп йөри.* С.Җәлал. *Елгада кояш йөзеп йөри.* Ф.Яруллин

**Йөзеп килү** Берәр нәрсәне урап кире йөзү

**Йөзеп китү** Берәр урыннан яки моменттан соң кинәт нинди дә булса юнәлештә йөзәргә тотыну. *Сәгыйть, кояшта янган көчле беләкләре белән тыгыз суны каерып ишә-ишә, --- икенче як яр читендәге биек карамаларга таба йөзеп китте.* Н.Фәттах

**Йөзеп тору** 1) Әле, хәзерге вакытта йөзү. *Аннары, офицерга караган хәлдә, бер урында йөзеп тора башлады.* Г.Гобәй

2) Һәрвакыт, даими рәвештә йөзү

**Йөзеп чыгу** Нинди дә булса сулыкның бер ярыннан икенче ярына җиткәнче йөзү. *Әнә бер үрдәк елганы аркылы йөзеп чыкты.* Р.Кәрами

**ЙӨЗҮЧЕ** *и. спорт* Спортның йөзү төре белән шөгыльләнүче

**ЙӨЗҮ́ ЯРЫСЫ** *и.* Суда йөзүче кошларның бармак араларын каплап үскән юка тире катламы

**ЙӨЗЧЕ** *и. тар. к.* **йөзбашы**

**ЙӨЗЬЕЛЛЫК** *и.* **1.** Йөз ел вакыт арасы; гасыр. *--- сүз сәнгатебезнең кимендә бер дистә йөзьеллык тарихы бар.* Ф.Галимуллин. *Татар театрының йөзьеллыгы уңае белән татар һәм рус телендәге вакытлы матбугат битләрендә җитди бәхәсләр башланып китте.* Ә.Закирҗанов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Йөз елга сузылган. *1864 елда император Александр II йөзьеллык сугышта Төньяк Кавказ халыкларын җиңү һәм әлеге җирләрне Россиягә кушу турында Россия империясе манифестын игълан итә.* Я.Шәфыйков. *Ә Нестор атакай шул язмаларның барчасын берләштергән дә өчдүрт йөзьеллык вакыйгаларны сәйләп сыман бергә тезеп чыккан.* В.Имамов

2) Йөз ел үскән, бик карт (үсемлекләргә карата). *Әтисе пычкы сабын аның саен дәртләнебрәк тартуын белә – йөзьеллык имән төбен түгел, ныклыкка үзенең улын сыный шулай.*

Р.Мөхәммәдиев. *Ул йөзьеллык имәннәре елдан елга мәгърурлана, колач җитмәслек кәүсәләре, бүрәнә-бүрәнә ботаклары белән котны алып, җил-давылдан курыкмыйча, һаман үсәләр...* Ф.Яхин

3) Бик озак яшәгән, озын гомерле булган (кешеләргә карата). *Ул [җирдә утырган ак күлмәкле бер егет] шулкадәр чибәр һәм илаһи ки, шуның өчендер бу болынның бер көнлек кенә хуҗалары булган күбәләкләр, аңа йөзьеллык гомер тели-тели, чәчәкләргә кунып үләләр.* Р.Бәшәр

**ЙӨЗЬЯФРАК** *и. бот.* Роза чәчәкләләр семьялыгыннан, хуш исле, катмарлы чәчәк ата торган вак яфраклы бакча гөле; *русчасы:* **столепестка, центифолия**

**ЙӨЗЬЯШӘР** *и.* **1.** *бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан, калын итләч, озынча һәм чәнечкеле яфраклы күпьеллык, тропик үсемлек; алоэ (безнең якларда бүлмә гөлләренең бер төре итеп үстерелә һәм дару ясау өчен файдаланыла); *русчасы:* **столетник**

**2.** *с. мәгъ.* 1) к. **йөзьеллык** (*2 мәгъ.*). *Минем тәрәзәм каршында йөзьяшәр наратлар бөгелә-сыгыла җилгә шаулап язны көтәләр.* М.Мәһдиев. *Бакчасындагы йөзьяшәр агачларның ябалдашлары арасыннан тонык эре йолдызлар җемелди.* Т.Әйди

2) Йөз ел яшәгән, йөз ел гомер иткән, озын гомерле булган (кешеләргә карата), йөзьеллык. *[Хода:] Егылмый тор, йөзьяшәр Мөштәри!* Р.Хәмид. *Әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөзьяшәр Миңлебай карт!* Ә.Еники

**ЙӨК** I *и.* 1) Күтәреп ташый торган авыр әйбер салынган олау. *Аңа көн саен салам төялгән, печән төялгән йөкләр килә.* Г.Ахунов. *Биектә, көлтә төялгән йөк өстендә утырып бару рәхәт тә, куркыныч та.* Н.Фәттах. *Алтысы алты җирдән арбага ябышкан хатыннар, үргә менгән саен, йөк тарткан атның хәлен ачыграк аңлый башладылар.* З.Зәйнуллин

2) Шундый олауга сыешлы әйбернең, авырлыкның микъдары. *Ярый, хуҗа кыз белән егеткә яхшы ат җигеп бирә, биш ат йөге товар төйи, аннан әйтә: «Мин сезнең белән бармыйм, үз вакытым белән барырмын», – дип озатып кала боларны.* Әкият. *Беркөнне урамга чыксак, куанычтан сикерешергә тотындык: авылга, өч-дүрт йөк товар төяп, кызыл малчылар килгән!* Г.Бәширов

3) Юл капчыгы, рюкзак. *[Чегән хатыннары] Шау-шу килеп, рөхсәтфәлән дә сорап тормыйча, аркаларына аскан йөкләрен бушата башладылар.* Н.Акмалов

4) Каян да булса алып кайта яки кая да булса җибәрелә торган әйбер; товар. *Кое бурасы янәшәсенә бик үк биек, зур түгел тирмә тегелгән, аның эргәсендә дәү-дәү капчыклар өеме – тәртипсез бушатылган йөкләр аунап ята иде.* Т.Әйди. *Бераздан алар сөзәк ярдагы чирәмлеккә килеп туктадылар да ат сыртларындагы йөкләрен бушата башладылар.* Җ.Рәхимов. *Солдат гимнастёркасының җиңнәрен, итәген буып капчык ясаганнар, шул авыр йөкне күтәреп керделәр дә «лас» итеп идәнгә куйдылар.* М.Мәһдиев

5) Бурыч; вазифа, йөкләмә. *Рус гаскәрләре берлә, Багдад астында сугышта торган инглиз гаскәре берлә кушылу хәрәкәтендә аның алаена зур йөк йөкләнеләчәк булды.* Г.Исхакый. *Яшь капитанга тәҗрибәлерәк ярдәмче куйыйк, дип, кадрлар бүлегеннән өлкән штурман итеп күп еллар каботажда капитанлык йөген сөйрәгән Вакх Андреевич Сторожевны беркеткәннәр.* М.Юныс. *Ләкин соңгы елларны бригадирлык йөген бик тырышып тартканга һәм җәмәгать эшләренә дә төптән җигелгәнгә күрә, Зөһрә эштә еш тоткарлана башлады.* Р.Кәрами

6) *күч. Дөнья, тормыш* һ.б.ш. исемнәр янында килеп, аның «авырлыгы, кыенлыгы, мәшәкате, борчуы» дигән мәгънәләрне белдерә. *[Малайның] Үзбаш тормыш корасы, дөнья йөген җигелеп тартасы көннәре алда...* Ф.Латыйфи. *Тормышның бөтен йөге әнисе җилкәсенә күчте.* Р.Газизов. *Әйтерсең минем җилкәмнән картлыкның авыр йөген кемдер алып атты да гөнаһсыз балачагыма кайтарды.* Ф.Яруллин

7) *күч.* Нинди дә булса эшнең иң күп көч сорала торган өлеше; четерекле, катлаулы мәсьәлә. *Күрәсең, тәртәне борып, яңабаштан эзләнүләр юлына чыгарга кирәк. Ә йөк бик авыр.* З.Фәтхетдинов

8) *күч.* Мәшәкать, борчу тудыручы кеше. *Ә немецлар өчен сарайда яткан хәлсез ике тоткын артык йөк иде бугай.* М.Галиев

9) *күч.* Авыр, газаплы, бик нык борчый торган хисләр. *Нәрсәнең ап-ачык булганын мин әле үзем дә аңламыйм, шулай да инде авыр йөк – күңел газабы – кире кайтмаслык булып артка ташланды.* Н.Фәттах. *Үткәннәрнең авыр йөге аның тормышын агулый шикелле иде.* Б.Камалов

10) *күч.* Башкарылган эшләр, кылынган гамәлләр. *Мәнә сез тимер юлда вак-төяк нәрсәләрне чәлдерүдән башлаган идегез. Ә иң ахыргы станциягә авыр йөк белән – коточкыч җинаятьләр йөге белән килеп төштегез.* З.Фәтхетдинов

11) *күч.* Эченә салынган мәгънә, эчтәлек. *Әсәрдә үзәк образ никадәр колачлы һәм масштаблы булса, аңа шулкадәр күбрәк «йөк» салып була.* Казан утлары

◊ **Йөге белән**, **йөге-йөге белән** Арттырып, тутырып, күп итеп. *Табигать бит ул – хикмәтле нәрсәкәй, бирәүгә булдыклылыкны йөге-йөге белән бирә, икенче берәүгә гап-гади ягымлылыкны да кызгана.* Г.Ахунов. **Йөге кыйшаган** *гади с.* Исерек кеше турында әйтелә. **Йөгенә кирә алмау** 1) Асылына кирә алмау, җаваплылыкны өскә ала алмау; 2) Кистереп кенә әйтә алмау, чын дөресен белмәү. **Йөгенә керер хәл(ем) юк** «Кешенең гаебен таный алмыйм, үз өстемә җаваплылык алмыйм» дигән мәгънәне белдерә. *Берсе, алдың, ди, икенчесе, алмадым, ди, белмим, кайсы алгандыр, күрмәдем, йөгенә кирә алмыйм.* Г.Толымбай. **Йөген өскә алу** Берәр кешенең нинди дә булса эштә гаепле түгеллеген раслап сүз сөйләү, аңлатма бирү. **Йөк аты** 1) Авыр-авыр эшләрне эшләп баручы кеше; 2) Берәр

өлкәдә берәр нәрсә өчен җаваплы кеше; шул өлкәнең төп көче. *Әнә Павел Лещенко – киләчәктә фәнне һәм фән арбасына төялгән сорыкортларны сөйрәргә әзерләнүче йөк аты.* М.Юныс

**ЙӨК** II *и.* Ана карынындагы бала

◊ **Йөккә калу** *к.* **йөккә узу**. **Йөккә узу** Авырлы булып калу, балага узу. *[Вәзир] әйтте: Фәйрүзәне сакласыннар, әгәр йөккә узу әсәре сизелсә, тәрбия-карауны арттырсыннар.* Мәҗмугыл-хикәят. **Йөктән котылу** Бала табу. *Самирә аның йөктән котылганын белеп, шунда ук Хазан мәлигенә хат язып, үзенә лаек угыл туганлыгы хакында белдерде.* Мәҗмугыл-хикәят

**ЙӨК-ЙӨК** *рәв.* 1) Йөкләргә тутырып, берничә йөк ясап. *[Бибинур апалары] Көз көне, басулар тынып, бушап калгач, йөк-йөк төяп ашлыгын да алып кайтты.* Н.Фәттах

2) Бик күп, зур күләмдә

◊ **Йөк-йөк (белән)** *сир. к.* **йөге белән**. *Болынлыкта йөк-йөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак прәннекләр хисапсыз иде.* Г.Тукай

**ЙӨККҮТӘРҮЧӘНЛЕК** *и. махс.* Транспорт чарасының (мәс., кран, вагон, йөк машинасы һ.б.ның) йөкне берьюлы күтәрә алу мөмкинлеге; *русчасы:* **грузоподъёмность**

**ЙӨ́К ТАРТКЫЧ** *и.* Буксир тагып сөйрәтә торган, зур егәрлекле автомобиль яки трактор; *русчасы:* **тягач**

**ЙӨКЛӘМӘ** *и.* 1) Эш урынында башкарыла торган хезмәт, хезмәт вазифасы. *Тимергалиев эшли башлаган беренче елны Галинур барлык йөкләмәләрен дә үтәп җиткерә алмады: ашлыкны әйбәт тапшырды, бәрәңгесе уңмады.* Г.Ахунов

2) Кемдер тарафыннан йөкләтелгән эш, бурыч. *Аллаһ йөкләмәсе дә даими түгел: сынау үткән саен, ул үзгәрә, югарырак дәрәҗәгә күтәрелә; үтә алмаганда, иске чикләрдә кала.* Р.Сафин

3) Мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш булган җаваплы бурыч. *1699 елда Россия патшасы Пётр I ясак түләүче катлаулардан Хәрби Йөкләмә нигезендә рекрут җыюны кертә.* Борынгы Калатау итәгендә // Ике яки берничә як белән шартнамә төзегәндә рәсмиләштерелгән үзара мөнәсәбәтләр; бурычлар

4) *тар. иск.* Крестьянарның алпавыт яки дәүләт файдасына түләүсез мәҗбүри эшләү вазифасы. *Шуннан инде күршедәге Чишмә авылы крестьяннары Петербургка, идарә итүче сенатка үзләренең хәлләрен язып җибәрәләр: «Ата-бабаларыбыз һәм аларның бабалары алпавыт кулында тормаганнар, аңар салым яки ясак һәм башка йөкләмәләр түләмәгәннәр».* Ж.Рәхимов

5) Билгеле бер вакыт аралыгында үтәлергә тиешле эш күләме. *Без үзебез биргән, быелга алган план, йөкләмәләрне гел үзгәртеп бетергән.* Х.Хәйруллин. *Иртәнге якта «Җиңүче» колхозының ике бригадасында терлекчеләр җыелышы уздырдык, йөкләмәләрнең үтәлешен тикшердек.* Ф.Садриев

**ЙӨКЛӘНЕШ** *и. физ.* Өслек берәмлегенә туры килгән көч; *русчасы:* **нагрузка**

**ЙӨКЛӘНҮ** *ф.* Йөкләмә бирелү, нинди дә булса эш эшләргә кушылу, бурыч(лар) куелу. *[Гамил:] Тудыру йортыннан балалы хатыннарны ташу вазифасы кайчаннан бирле клуб мөдиренә йөкләнде әле?* Ә.Фазылҗанов. *Икенче взводка тимер юлга разведка ясау, поездларның килү-китү вакытларын өйрәнү һәм миналар кую урынын тәгаенләү эше йөкләнде.* Г.Кутуй. *Элекке өй йомышлары өстенә апасының йорт эшләре дә хәзер Габдулла өстенә йөкләнде.* Ә.Фәйзи

**ЙӨКЛӘП** *рәв.* Үзеннән алда килгән сан белән, чама белән шул йөк күләмендә, шул йөккә якын. *Нәфикъ абый, самавырны куйсана, төшергән тал кайрыларым бар, берәр йөкләп булыр, шуны бүген-иртәгә тапшырып, налогны түләрмен, дип тә карый, тик кая ул, Кет-Кет колагына да элми, самавырны эләктереп, өстәлдә яткан кәгазьләре янына юнәлә.* Н.Көбәш

**ЙӨКЛӘТҮ** I *ф.* Йөк салып күтәрү яки тарттыру

**ЙӨКЛӘТҮ** II *ф. йөкл. юн. к.* **йөкләү** II. --- *медицинада бүген ике-өч белгечнең эшен бер кешегә йөкләтү гадәти күренешкә әверелде.* Идел. *Русия Президенты Дмитрий Медведев бу вазифаны Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкил урынбасары Галина Изотовага йөкләтү турындагы боерыкка кул куйды.* Ватаным Татарстан

**ЙӨКЛӘТҮ́ ЮНӘЛЕШЕ** *и. лингв.* Фигыль юнәлешенең бишенче төре (грамматик субъектның эшне башка берәүгә яки башка бер нәрсәгә кушуын, йөкләвен белдерә). *Йөкләтү юнәлеше кушымчалары искиткеч күпсанлы һәм күптөрле.* Татар грамматикасы. *Йөкләтү юнәлеше башка юнәлешләр арасында шактый катлаулы форма булып санала.* Татар теле морфологиясе. *Йөкләтү юнәлешенең иң киң таралган кушымчасы «-дыр, -дер», «-тыр, -тер»: «уйландыру, арттыру, яшелләндерү, әйттерү, алмаштыру» һ.б.* Татар теле

**ЙӨКЛӘ́Ү** I *ф. сир.* 1) Нәрсәне дә булса бер урыннан икенче урынга күчерү өчен, нинди дә булса транспорт чарасына төяү, салу (мәс., җигелгән атның арбасына, машинага һ.б.га)

2) Кая да булса алып бару өчен, йөкне аркага асу яки күтәрү. *Яралыны яралы йөкли.* Мәкаль. *Соры Гыймади да, арканын кабат җилкәсенә йөкләп, капкадан эчкә узды.* Ф.Яхин

**ЙӨКЛӘ́Ү** II *ф.* 1) Кемгә дә булса эш, йомыш һ.б.ш.ны үтәргә кушу. *Прибыльщикларны куып, салымнарны җыюны старшиналарга йөклиләр.* Ж.Рәхимов. *Бик җаваплы бу бурычны әлеге Совет --- Гайсә морза Еникеев белән Закир Рәмиевкә йөкли.* Л.Хәмидуллин

2) Нинди дә булса эш, йомыш башкарып чыгуны үз өстенә алу, аның үтәлешенә җаваплы булу. *Дәү апага иреннән соң бөтен хуҗалыкны үз җилкәсенә йөкләү авырга килде.* Ә.Фәйзи

3) Нинди дә булса һөнәр иясенең вазифасын профессиональ осталык белән башкару

4) *күч.* Уй, теләк-ниятләр белән урталашу; күңелгә кабул итү. *Ул аны улы итмәде, андый адымны күңеленә йөкләмәде.* Б.Камалов

5) *күч.* Нәрсәне дә булса (мәс., гаепне) башка кешегә сылтау, аны башка кешедән күрү. *Шул рәвешчә, халыкка*

*әдәби әсәрләрнең чын кыйммәтен төшендерә алмауда төп гаепне М.Акчурина үзләрен галим-голамә дип санап йөргән хәлфәләргә һәм, гомумән, руханиларга йөкли.* М.Гайнуллин

**Йөкләп бетерү** Ахыргача, тулысынча йөкләү. *Телләрнең яшәеше белән бәйле мәсьәләләрне җәмгать тәртибендәге комитет җилкәсенә генә дә, Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына гына да йөкләп бетереп булмый.* Р.Миңнуллин

**Йөкли бару** Торган саен күбрәк йөкләү. *Г.Апанайлар кебек күренекле кешеләр кулыннан вакытлычамы, бөтенләйгәме төшкән хөррият хәрәкәте байрагын таптатмый саклау эшен яңа шартларга җавап бирерлек һәм яраклы рәвештә дәгъвасыз үз иҗаты өстенә йөкли бара.* М.Гайнетдин

**Йөкли тору** Һаман йөкләү, бертуктаусыз йөкләү. *Менә шулай башланды Өметбай Әпсәләмовның пенсия тормышы. Эштән тугарылса да, тормыш аның иңбашына үзенең беткесез мәшәкатьләрен йөкли тора.* Ш.Янбаев

**ЙӨКЛЕ** I *с.* **1.** Йөк төялгән, йөге булган. *[Мортаза:] Бөтен йөкле арбалар туарылып, пролеткаларга җигелсеннәр!* К.Тинчурин

**2.** *и. мәгъ.* Йөк төялгән берәр нәрсә, йөге булган кеше. *Плотина чакрымнар белән үлчәнә, җәяүлеләр чыга-чыга арып бетә, йөклеләр туктап-туктап хәл алгалый.* Ә.Гаффар

**ЙӨКЛЕ** II *с.* Авырлы, балага узган. *Апасы углына язу язды, әйтте: – Әгәр Фәйрүзәнең йөкле булу әсәре сизелсә, аны тәрбия итегез, саклагыз һәм безгә мәгълүм итегез.* Мәҗмугыл-хикәят. *Кендек әбиләр гасырлар буена изге эш эшләгәннәр: йөкле хатыннарга булышлык күрсәтә килгәннәр.* Н.Фәттах. *Син беләсеңме: әгәр йөкле хатын теләгән нәрсәсен ашый алмаса, шул ризыкның рәсеме туачак баланың тәнендә мәңгегә басылып кала икән.* В.Юнысов

**ЙӨКЛЕЛЕК** *и.* Йөкле (II) булу хәле. *Фатыйманың йөклелегә турында да беркем белми калды.* Ә.Сафиуллин. *[Алтынчәч] Хәзер йөклелекнең соңгы чорында була торган токсикозның авыр формасы белән ята.* М.Маликова

**ЙӨКЧЕ** *и.* Йөк йөртүче, йөк ташучы; олаучы. *Сельпо атына йөкче үзе, Шамил, --- дядя Захар утырдылар.* Я.Зәнкиев. *Елга ягыннан һәрдаим исеп торган салкынча дымлы җилдән бите кәшәләнеп беткән йөкче нык кына сүгенеп куйды.* Ф.Сафин. *[Зөбәйдә:] – Бар, шул йөкчене алып, монда кил! – диде.* Мәҗмугыл-хикәят

**ЙӨНДӘ́Ү** *ф. иск.* Хайваннарның (мәс., сыерның, дөянең һ.б.ның) ябага йонын йолку

**ЙӨННЕКӘЙ** *и. бот.* Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан, яфраклары һәм сабагы ашарга яраклы, шома көпшәле, дымлы урыннарда үсә торган үлән үсемлек; *русчасы:* **дягиль**. *Тизрәк май ае җитсен иде дә, ташландык басуларда кәҗә сакалы, кукы, йөннекәй, чыпчык, күгәрчен күзләре кебек үләннәр калыксын иде.* Р.Хисмәтуллин

**ЙӨНТӘЙ** *с. диал. к.* **йонлач**

**ЙӨНТӘС** *с. к.* **йонлач**. *Директор йөнтәс кашларын җыерып йөри, дәрестән соң укытучылар бүлмәсенә керә, шахмат уйнарга партнёр эзли.* М.Мәһдиев. *Капка төбендә Тарзан кушаматлы кара йөнтәс этләре койрык болгап каршы алды.* Н.Хәсәнов. *Рахманкулов зур йөнтәс сөлге белән сөртенде дә әзерләп куйган майка белән трусикны киде.* М.Юныс

**ЙӨНТӘ́С ГӨМБӘ** *и. бот.* Эшләпәсенең өсте алсу төсле, ян-яклары дулкынлы булган, ашый торган гөмбә; *русчасы:* **волнушка**. *Ул йөнтәс гөмбәләр дисеңме, майлы гөмбәләрме, ак гөмбәләрме – барысы да бар иде.* М.Сафин. *Әйтик, урманда беренче булып волнушка – йөнтәс гөмбә, аннары ак гөмбә, кара җиләк һәм нарат җиләге кебек тәмле ризыклар күренгәли.* Р.Кәрами

**ЙӨНТӘСЛӘНҮ** *ф.* Йөнтәскә әйләнү; куе йон яки төкләр белән каплану. *Олы башың белән Шүрәле кебек йөнтәсләнеп йөрмәсәң!..* Ватаным Татарстан

**Йөнтәсләнеп бетү** Бөтенләй, тулысынча йөнтәсләнү. --- *берсе лапастан ашатырына булмаганлыктан ябыгып, йөнтәсләнеп беткән кәҗәбезне сөйрәп чыкты.* Туганайлар

**Йөнтәсләнеп чыгу** Бик нык йөнтәсләнү, йөнтәсләнгән урыннар барлыкка килү. --- *урыны-урыны белән шома гына барган җирлекнең күбектәй йөнтәсләнеп чыккан урыннары аңа ниндидер өрфиядәй күләм дә бирә.* Шәһри Казан

**ЙӨНТӘСЛӘ́Ү** *ф.* Йонын кабарту, йонлы итү

**ЙӨНТӘСЛЕК** *и.* Йөнтәс булу. *[Зиннур Мәгъсүмов] өстендә – кайры тун, башында – бүре бүрек, аның йөнтәслеге йөзенең ябыклыгын бераз каплап, киметеп тора иде.* Г.Ахунов

**ЙӨНТӘЧ** *с. к.* **йонлач**

**ЙӨРӘК** *и. анат.* 1) Кешенең яки хайваннарның сул күкрәк куышлыгына урнашкан, кан әйләнешен тәэмин итә торган мускуллы капчыксыман әгъза. *Шуннан [Фәридә] йөрәк авырулы хаста булып чыкты, гомере буе мантымады.* А.Гыйләҗев. *Зөһрәдә тумыштан килгән йөрәк авыруы булган икән.* Ф.Хөсни. *Теге юаш, юньле Зөфәр дә йөрәк чиреннән моннан утыз биш еллар элек үлгән иде инде, бичара.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Кешенең һәртөрле хис, тойгы, кичерешләр җыелмасы символы. *Халык йөрәгенә иңгән шушындый җырлары булу шагыйрь өчен олы бәхет түгелмени?!* М.Галиев. *Әйтә торгач үз-үземә: «Түзә белергә кирәк!» Югалтулар җәзасына, Кырыс язмыш ярасына өйрәнә бара йөрәк.* М.Нәзиров // Мәхәббәт хисләрен белдерә торган символ. *Мәхәббәте булмагач соң, Ничек яшәр ул йөрәк? Йөрәккә бит үз дигәне, Үз сөйгәне – син кирәк!* Г.Зәйнашева. *Безнең йөрәкләрдәге сезгә булган мәхәббәт һәрвакыт ялкын кебек кайнар, беренче күз яшебез кебек саф.* Ш.Хөсәенов

3) *күч.* Кешенең эчке дөньясы, күңеле. *Меңләп кешенең шатлыклы йөрәк талпынуы белән атылып чыккан көчле «ура» тавышы бөтен чиркәү эчен яңгыратты.* Ш.Усманов. *Без яшәгән илнең матурлыгын Йөрәк белән кирәк тоярга.* С.Хәким. *Хатирәләр түреннән чыгып, Искәндәрев алдына баскан, аның йөрәген туктаусыз борчып торган сорау шушы иде.* Ә.Еники

4) Интуиция. *Кайдадыр якында гына үлем сагалап йөргәнен йөрәге белән тоеп, бер мизгелгә үкереп җибәрәсе килсә дә, тешләрен кысып тыелып калды.* Р.Мөхәммәтҗан

5) Кайбер сыйфатлар белән килгәндә, кешене билгеләгән эчке табигате, холкы. *Мин сине олы йөрәкле, кыю егет дип йөрсәм, син, Әнвәр, вак җанлы мещан икәнсең.* Р.Ишморат. *Кешелекне күрдем, шәфкатьлене, Миһербанлыларны, гамьсезне. Саф йөрәкне, изге күңеллене, Мәкерлене, шактый мәнсезне.* М.Шиһапов. *Әлеге мыскыллауларга таш йөрәк тә түзмәс иде.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Тәвәккәллек, кыюлык, гайрәтлелек. *[Телефонист:] Әгәр дә егет булсаң, командирыңа төзәп атылган дошман пулясын, күкрәгеңне куеп, килгән юлыннан туктат. Билгеле, моның өчен йөрәк кирәк.* Ф.Кәрим. *--- авыз ачып сүз дәшәргә дә йөрәге җитми.* А.Вергазов

7) *күч.* Күңел; намус, вөҗдан. *Мин кабыздым җырда ялкын итеп йөрәгем һәм хаклык кушканны.* М.Җәлил. *Йөрәк кушканны тыңласаң, Акыл белән эш итсәң, Юлың һәрвакыт уң булыр.* Ә.Хәсәнов

8) *күч.* Нәрсәнең дә булса үзеге. *[Иван] Йөрәгенә чиркәү салып куйган, Сызламасын нигә йөрәгең?!* Х.Әюп. *Сугыш башланып өлгермәде, дошман инде безнең илебезнең йөрәгенә сузыла башлады.* И.Гази

9) **йөрәгем** *тарт. форм. ирк.* Ярату хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *[Мәҗит:] Кал инде, Асиякәем, йөгермә инде, кал инде, йөрәккәем!* З.Зәйнуллин

◊ **Йөрәге боз** Мәрхәмәтсез, хисләргә ярлы, һәрнәрсәгә битараф кеше. **Йөрәген алу** Искәрмәстән куркыту; борчу, кайгы китерү. **Йөрәгенә ия булу** Үзенә карату, кемнең дә булса мәхәббәтенә ирешү. **Йөрәгендә эт үлгән** Битараф, салкын, сүлпән, ваемсыз (кеше). *Йөрәгендә эт үлмәгән булса, авыл кешесе бер генә мизгел дә тик утыра алмый бу чакта.* Җ.Рәхимов. **Йөрәген телеп алу** *к.* **йөрәк итен ашау**. **Йөрәген яралау** Кемгә дә булса борчу, кайгы, рухи газап китерү. **Йөрәге салкын** *к.* **йөрәге боз**. **Йөрәк аксау** Йөрәкнең сәламәтлеге начарлану, еш-еш авыртып тору. *[Фәхри:] Ә менә хәзер сәламәтлек бик какшады, йөрәк аксый, Дамир энем, йөрәк.* Д.Салихов. **Йөрәк алгысу** *к.* **йөрәк җилкенү**. **Йөрәк алыну** Куркуга бирелү. **Йөрәк атылып чыгарга җиту** Дулкынланудан, куркудан һ.б.дан йөрәк еш-еш тибү. **Йөрәк ачыну (ачыту)** *к.* **йөрәк әрнү**. *Бераздан тәмам айныдым, бары тик йөрәк ачытуы гына һаман сизелә иде.* М.Юныс. **Йөрәк ачысы** Баштан узган газап, авыр сынаулардан соң күңелдә сакланган кичерешләр. **Йөрәк аша** Акыл белән тоеп, аңлап, күңелдән кичереп. *Беләсең микән, синең барлык кичерешләреңне, яндырып-яндырып, минем йөрәк аша да узды.* Р.Низамиев. *Үзенең һәм башка тоткыннарның өстенә карагач, хәлләренең мөшкеллеген, мескенлекләрен тагын бер кат йөрәге аша кичереп, язмышына чын рәнҗү белән рәнҗеде Мотаһир.* Р.Кәрами. **Йөрәк ашкыну** *к.* **йөрәк җилкенү**. *Әнә атлар чыдаша алмый, баскан җирендә түзә алмый торалар, гүя йөрәкләре ашкына, гүя әллә кемне тизрәк алып китәргә ашыгалар.* Г.Ибраһимов. **Йөрәк әрнеткеч** *к.* **йөрәк өзгеч**. **Йөрәк әрнү** 1) Бик нык кызгану, аяу. *Безнең арада акыллылыгы белән аерылып торган, әти-әнинең иң яраткан улы булган Искәндәр энемнең хатынын да юлдан яздырды. Хәзер менә шул киленне күргән саен, йөрәгем әрни.* Ф.Галиев; 2) Чиктән тыш борчылу, тынычсызлану, рухи газаплану. *Үпкәләдем шулчак табигатькә, Әрнеп куйды, никтер, йөрәгем. Ошатмадым аның гүзәллеккә Явызлыкны өстәп биргәнен.* Н.Мадияров. *«Өйләнгәч» дигән сүзне болай гына, йөрәк әрнүдән генә әйтәм.* Г.Ибраһимов. **Йөрәк басылу** Тынычланып калу; курку, шикләнү һ.б.ш. хисләрдән арыну. **Йөрәк бәйрәме** Гашыйклар, сөешкән парлар өчен шатлыклы көн. *Ул көн йөрәк бәйрәме иде.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. **Йөрәк бизмәненә салу** Эшнең һәр ягын уйлап, күңелдән кичереп, үлчәп карау. *Моны күреп, һәр әйткәнен йөрәк бизмәненә салып утыруның иренә никадәр газаплы икәнен --- бичара хатын башына да китерә алмый иде шул.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. **Йөрәк бозгыч** Юк-бар белән кәеф кыручы, күңелне кайтаручы. *Беләсең килсә, йөрәк бозгыч кына ул.* З.Хөснияр. **Йөрәк бозлану** Бик нык борчылу, катып калу. *Мин аңардан әллә кайчан киткән булыр идем инде, тик кызым турында уйласам, аңа гомер буе «әтиең юк», яисә «әтиең сезне ташлап киткән», яки «әтиегезне калдырып киткәнсез» дип әйткәннәрен күз алдына китерсәм, йөрәгем бозлана.* Ф.Углов. **Йөрәк бозу** Кәефне кыру, борчу, газаплау. *[Мисбах:] Ярый, хуш, Нуретдин. Сөйләшә башласам, йөрәгем бозыла.* К.Тинчурин. *[Гамил әнисенә:] Ярар, юк өчен йөрәгеңне бозма.* Ә.Фазылҗанов. *Ул алай күп уйланып, юккабарга йөрәк бозып яшәргә күнекмәгән иде.* Н.Фәттах. **Йөрәк бушату** Күңелдәгесен уртаклашу, баштан кичергәннәрне икенче берәүгә сөйләп бирү. **Йөрәк дусты** 1) Сердәш, ахирәт; 2) Яраткан, сөйгән кеше. *Мин калдым аерылып Йөрәгем дустыннан. Ул җиңеп кайтканчы, Мин китмәм шушыннан.* М.Җәлил. **Йөрәк елау** Көчле вөҗдан газабы, үкенү хисләре кичерү. *Күренеп тора ич: йөрәге елый аның... Бик тә, бик тә бәхетсез кеше ул.* Р.Сибат. **Йөрәк «елк» («дерт») итү** Сискәнеп кую, шикле уй йөгереп үтү. *Малайның йөрәге «елк» итеп куйды: Бамбук, чынлап та, аларның нәселеннән микәнни?* А.Хәлим. *Шул чакта әллә ничек кенә йөрәге «дерт» итеп куйды.* Ф.Латыйфи, Р.Якуш. **Йөрәк «жу» итү** Бик каты курку, курку алу. *Шул вакытта минем йөрәгем «жу» итеп алды: таза егет – мин егерме еллар элек, дүртенче класста, антипедагогик алымнар белән җәзалаган ташбаш Сәүбән иде ...* М.Мәһдиев. *Бар тирәне томалаган буран эченнән караеп торучы ялгыз будканың кар сарган ишеген күргәч кенә, Алсу үзенең ни хәлдә калуын аңлап алды, йөрәге «жу» итеп куйды.* А.Сафин. *Сәгыйтьнең йөрәге «жу» итеп китте: кызый әз генә мыштырдаса, аны шундук хедер эләктереп алачак иде.* Н.Фәттах. **Йөрәк җилкенү**

Нәрсәгә дә булса түземсезлек белән омтылу, дулкынлану һ.б.ш. хисләр кичерү. *[Габделхәйнең] Шатлыктан йөрәге җилкенеп куйды.* Н.Фәттах. *Клубта биеп, күңел ачып талчыккан, әмма йөрәкләре җилкенгән, күңелләре очынган яшьләр соң гына өйләренә таралалар.* Ф.Сафин. *Көләч зәңгәр күк, саф диңгез һавасы, чыннан да, тынгысызлыктан арыган күңелгә шифалы ял биреп, йөрәк җилкенүен басарлык иде.* М.Юныс. **Йөрәк җилпенү** *к.* **йөрәк җилкенү**. *Агачлар яфрак яра, кошлар коралар оя. Шулчак йөрәк җилпенеп, күңел ашкына кая?!* Акъегет. **Йөрәк җимешем** Яратып, иркәләп эндәшү сүзе. *Минем янда бердәнберем, йөрәк җимешем – син бар бит әле!* Р.Низамиев. **Йөрәк җиңеләю** Күңелгә, җанга тынычсызлык китергән нәрсәдән арыну; җиңеллек хисе тою. *Шул хәбәрдән аның хәзер йөрәге җиңеләеп, күңеле җылынып китте.* З.Садыйков. **Йөрәк җитү** Нинди дә булса эшне эшләргә батырчылык итү; куркыныч янаса да тәвәккәлләү. *[Мулла:] Ничек тә өркетергә кирәк бу явызны [аюны]. Шуңа йөрәгегез җитәрме, егетләр*? Ж.Рәхимов. *Иелгән башны күтәреп, алга карарга йөрәк җитми – юлның очы тау үренең әллә кайсы төшләренә китеп югала.* З.Зәйнуллин. *Монысына йөрәге җиткән малайлар юк диярлек.* Ә.Баянов. **Йөрәк җылысы** 1) Ярату, хөрмәт итү, якын итү хисләре. *Юккабарга сарыф ителмәгән йөрәк җылысын ул алар өчен саклый, дуслыкка, урнашкан мөнәсәбәтләргә бик сак һәм җаваплы карый иде.* З.Садыйков; 2) Чын күңелдән, бик тырышып, җанын-тәнен биреп (эшләү турында). *Көнкүрештә кулланылган балчык, бакыр һәм көмеш савыт-саба, тормыш кирәк- яракларына, һөнәрчелек әйберләренә – барысына да моннан йөзләрчә еллар элек яшәгән кешеләрнең йөрәк җылысы сеңгән.* Ф.Латыйфи. *Авыр елларда йөрәк җылысын салып, киләчәккә якты өметләр баглап иҗат иткән татар хатын-кызларының тарихи әһәмиятле әсәрләре белән яшь буынны киңрәк таныштыру безнең алда зур бурыч булып кала.* М.Гайнуллин. **Йөрәк итен ашау (талау, телгәләү)** Бертуктаусыз бәйләнеп аптыратып бетерү, интектереп тору, тиешле-тиешсез гаепләп тору. *Кая гына башым куйсам да, Кайгы талый йөрәк итемне.* М.Җәлил. *– Ярар инде, ашамагыз йөрәк итемне, мөдир белән гыйшык тотуыңнан файдаланып, япь-яшь башың белән анаң кебек кешегә тел тидерәсең! – дип әйтеп салмасмы!* Ә.Айдар. *Җиде ел эчендә син минем шактый йөрәк итләремне ашадың.* Г.Камал. **Йөрәк итенә үтү** Нинди дә булса хәлне, вакыйганы авыр кичерү, газаплы тойгыларга дучар булу. **Йөрәк итенә ябышып үсү** Һәрвакыт истә (күңелдә) булу, онытa алмау (сөйгән яр, яраткан кеше турында). **Йөрәк ишеген шаку** Ярату тәкъдим итү. *«Икенче атнада ук капитан Хираҗ Камалиев йөрәк ишегеңне шакыр, чибәркәй, көтеп кенә тор», – дип тә һаваланган иде.* Ф.Сафин. **Йөрәк кагу** *к.* **йөрәк атылып чыгарга җитү**. **Йөрәк кайнарлану** Дәртләнү, хис-кичерешләр белән тулу. *Кайсы татарның, бу моңнарны тыңлаганда, йөрәге кайнарланмас?!* А.Гыйләҗев. **Йөрәк кайнау** 1) Борчулы уй-хисләр эчендә йөрү, хәсрәтләнү; 2) Ачу килү, көчле ярсу, нәфрәт хисе кичерү. *Ул боларның кайдан килүләренә, шулкадәр күплекләренә гаҗәпкә кала, берсеннән-берсенең кызганычлыгына исе китә, шундый әдәпсез малайлар, ирдәүкә кызларның уйнашуларына, сүгешүләренә йөзе кызара, йөрәге кайный, үзен-үзе онытa иде.* Г.Исхакый. **Йөрәк калмау** Куркып бетү, хафага калу. **Йөрәк канау** Бик каты рухи газап кичерү. *Онытгыңмы әллә? Хыянәтең яралады – йөрәк канады.* Р.Әхмәтҗан. **Йөрәк канына манып** Хис һәм акыл аша үткәреп, бөтен сизгерлеген җыеп. *Укыганмы ул асыл патшабикә Батыршаның йөрәк канына манып язган зарлы сүзләрен?* Ж.Рәхимов. **Йөрәккә басу** Күңелнең иң нечкә хисләренә тәэсир итү, дулкынландыру, төрле хисләр уяту (нинди дә булса уен коралында уйнап, җырлап яки биеп). **Йөрәккә басып (килү)** Кемнең дә булса күңелендә курку, шик, шом һ.б.ш хисләр тудырып, күзләренә туп-туры карап, каршысына бару. *[Рухия] Әле һаман бер урында басып торган Равилне күреп, авыз чите белән генә, әмма тирә-якны барыбер балкытып елмаеп куйды һәм ялт итеп борылды да тагын шулай йомшак кына Равилнең йөрәгенә басып, кире килә башлады.* В.Нуруллин. **Йөрәккә боз булып утыру** Күңелдә бик авыр, ямьсез, күңелсез тәэсир калдыру. *Маңгайдан аккан ачы тир Табанга җитсә тоз булыр, Колактан кергән ачы сүз Йөрәккә җитсә боз булыр.* Мәкаль. **Йөрәккә җылы керү (йөгерү)** Өмет уяну, ышаныч барлыкка килү; тынычлану, шикләнү, аптырау хисләре юкка чыгу. *Первушинның йөрәгенә җылы йөгерде: сәгать йөри, димәк, аңа да алга таба хәрәкәтләнергә кирәк!* Г.Паушкин. **Йөрәккә йон (мүк) үсү** Битараф калу, дәртсез булу, салкын карашлы булу. *[Андрей:] Йөрәкләребезгә мүк үскән... Ләмгә кердек тә баттык.* К.Нәҗми. *Украин егетенең шашкынлыгын йөрәгенә мүк үсмәгән һәр солдат төшенә ала.* Р.Ишморатова. **Йөрәккә кабу (кабыну)** Бик авыр, начар тәэсир итү. *Ачудан Җәмиләнең йөрәгенә капты, хәле бетте, ләкин хәзер аның җиңел генә чигенәсе дә килмәде.* Н.Фәттах. **Йөрәккә кадалу** Бик авыр тәэсир ясау, рухи интегүләр тудыру. *Теге чокырда Бакшанов белән ансат кына сөйләшкән сүз хәзер ук шикелле йөрәккә кадала икән!* Ш.Маннур. *Нәрсәсе бигрәк тә йөрәккә кадала: синең яхшылыгыңны пычракка салып таптыйлар.* Г.Бәширов. **Йөрәккә кадау** Авыр, ачы сүзләр белән кимсетү, рәнҗетү. **Йөрәккә (кара) кан саву (саудыру)** Чиктән тыш газаплану, зур кайгы-борчуга дучар булу; зур авырлык, газаплар кичерү. *Янгыннан соң өйсез калып, Тайфә карчыкның тавык кетәге кадәр йортында иза чигүләрен исенә төшереп, йөрәгенә кан сава.* Ф.Сафин. *Хәшәрәт Гитлер белән сугышып, мәхшәри яуда башларын салган ирләрен, бәлки исәндер, менә кайтыр әле диеп көткән күп балалы яшь хатыннар йөрәгендә өмет, шомлы шиккә әйләнеп, йөрәккә кан саудыра.* З.Зәйнуллин. *Ә ул, йөрәгенә кан саудыра-саудыра, саргайтып киптерде Чыңгызны.* З.Садыйков. **Йөрәккә (үтеп)**

**керү (кереп утыру)** 1) Көчле тәэсир итү, онытылмаслык булып истә калу. *Бу сүз Нәгыймәнең йөрәгенә кереп утырды.* Г.Ибраһимов. *Аларның һәр авазы аңлаешлы, йөрәккә үтеп керә.* Ф.Сафин; 2) Кемнең дә булса хөрмәтенә, ышанычына ия булу; симпатия, мәхәббәт яулап алу. *Менә бу кыз йөрәгенә керер, Диләрә урынын алыр шикелле иде.* З.Садыйков. **Йөрәккә көч керү** Үзен көчле итеп хис итү, батыраеп китү. *Тәрәзә ватылып, алдымда ак карлы урам калыккач, йөземә җан иясе кебек тере җил килеп бәрелгәч, йөрәккә көч кергән иде.* С.Хафизов. **Йөрәккә (сары) май (кебек) булып яту** Тынычландыру, борчылуларны басу, күңелгә бик хуш килү, кәеф күтәрелеп китү. *Кәүкәбелҗәннәт ханымның күрешкәндә: – Исәнмесез! – диюе үк Руфинәнең йөрәгенә сары май булып ятты.* Ф.Садриев. *Егетләрнең сүзләре аның йөрәгенә сары май булып ята.* Р.Хәмид. **Йөрәккә май яккандай** *к.* **йөрәккә май булып яту**. *Шул кызның оялчан мөлаемлык белән капыл гына үзенә күз ташлап алуы, йөрәккә май яккандай саф тавышы күңелендә яңарып, күкрәк турысын кытыклап куйды.* А.Вергазов. **Йөрәккә сеңдерү** Ишеткәнне, укыганны һ.б.ны хәтердә калдыру. **Йөрәккә сеңү** Нык истә калу. *Фикер җебе, бер вакыйгадан икенчесенә сузылып, йөрәккә сеңеп калган аерылу минутларына килеп тоташты.* И.Гази. *Яшьлеге юлында тәүге мәхәббәт булып йөрәгенә сеңеп калган Тутыя атлы шул кыз күптән онытылырга тиеш иде ләбаса.* Җ.Рәхимов. **Йөрәккә суык йөгерү** Куркыныч булып китү, шомлану. *Аз гына селкенсәң, күзгә күренмәс җеп тартылып куя, тирә-юнеңдә нindидер шикле хәрәкәт барлыкка килүен сизеп, тын кысыла, йөрәккә суык йөгерә.* Ф.Сафин. **Йөрәккә таш булып утыру (яту)** *к.* **йөрәккә боз утыру**. *Боларны ишетеп, хатынның йөрәгенә таш утырды.* А.Шамов. **Йөрәккә таянып** Хис-тойгыларга бирелеп, күңел кушканча. *[Айтуганов:] Безнең колхозда йөрәккә таянып кына бер нәрсә дә эшләнми, иптәш Сәүбанов.* Г.Ахунов. **Йөрәккә тию** 1) Йөрәк авырта башлау; 2) *к.* **йөрәккә кадалу**. *Гөлсемнең уенын-чынын бергә кушып әйткән сүзләре шундук аның йөрәгенә барып тиде.* Н.Фәттах. **Йөрәккә (йөрәк ярасына) тоз салу (сибү)** Бик нык кәефне җибәрү, ачуландыру (авыр, кайгылы, борчулы һ.б.ш. сүз, хәбәр сөйләп) күңел ярасын яңарту. *Шуңа күрә ул аның ачуын китерү, йөрәгенә тоз салу нияте белән, юри бераз арттырып та җибәрде.* Н.Фәттах. *[Лилия:] Нигә минем йөрәгемә тоз саласың?* Д.Салихов. *Бу – аларның даими рәвештә сызлап аптыраткан йөрәк яраларына тоз сибү.* Ә.Сафиуллин. **Йөрәккә төер төшмәсен** Кайгы-хәсрәт, борчу, газап килмәсен. – *Кул нәрсә ул, йөрәккә төер төшмәсен, – дип, уенга уен белән җавап кайтарды Заһит.* М.Әмирханов. **Йөрәккә төшү** 1) Сабырлыкны, түземлекне бетереп, шул дәрәҗәгә җиткереп интектерү, җәфалау (авырту, каты салкын, ачлык һ.б.ш. турында). *Ярама пычрак кергән ахры, шеште, йөрәккә төшеп сызлый.* Г.Тавлин. *Изүгә кар тула, суыгы йөрәккә төшә, эчәкләргә хәтле шакыраеп ката кебек.* Р.Кәрами. *Итекләрен дә үзе салырга ниятләгән иде дә, ләкин, тарта башлау белән, йөрәгенә төшеп аягы сызларга тотынды.* В.Нуруллин; 2) Бик еш борчу, йөдәтү, тынычлык бирмәү; 3) *к.* **йөрәккә керү**. *Шул Фәридә Кудашеваның чыгып «Ашказар» көенә моңлы җырлавы йөрәгемә төште, күз яшенә бик саран булсам да, җаннарым әллә нишләп, яшьләрем агылып төшкәнен сизми дә калдым.* Н.Исәнбәт. *Бу малайның күз карашы йөрәгемә төште, тавышы, акыллы сүзе бөтенләй хәлемне бетерде.* Г.Ибраһимов. **Йөрәккә тышау салу** Тыелып тору, уйлаган уйдан, теләктән, нияттән баш тарту, хисләргә буйсынмау. *Аның янына кайтырга күпме җыенды, әмма әйтеп аңлата алмаслык нindидер хис аның йөрәгенә тышау салып торды.* Н.Хәсәнов. **Йөрәккә ук булып кадалу** *к.* **йөрәккә кадалу**. *Кәримәнең туган теленең нәрсә икәнен аңламавы Рахманкуловның йөрәгенә ук булып килеп кадалды.* М.Юныс. **Йөрәккә ут кабу** 1) Гашыйк булу; 2) Кайгыру, борчылу, хәсрәт чигү. *Кыскасы, боларны Рабига көлә-көлә сөйләде, әмма егетнең йөрәгенә ут капты.* Ф.Сафин. **Йөрәккә ут салу** 1) Гашыйк итү, мәхәббәт хисе уяту. *Идрис ул чакта теләсә кайсы кызның йөрәгенә ут салырлык егет иде әле.* Н.Фәттах. *Сызылып киткән кара мыек йөрәгемә ут салды. Бер көн озата килде дә әллә кая югалды.* Г.Зәйнашева; 2) Дәртләндереп җибәрү, өмет барлыкка китерү, нәрсәгәдер омтылыш бирү; 3) *к.* **йөрәк яну**. **Йөрәккә үткәреп** Аң-зиһенгә җиткереп, ачык итеп, көчле тәэсир итеп (әйтү, җырлау, язу турында). **Йөрәккә чыдый алмау** Бик нык борчылу, тынгысызлык халәтендә булу. *Шактый түзеп утыра да, йөрәгенә чыдый алмагач, сүз сорап ала ул.* Т.Нәҗмиев. **Йөрәккә шифа булу** *к.* **йөрәккә ял булу**. --- *ирсез хатынга ара-тирә эләккән бәхетле минутлар гына аның китек күңелен төзәтә алмый, йөрәгенә шифа була алмый.* Р.Кәрами. **Йөрәккә шом салу** Күңелгә вәсвәсә салу, курку, шик тудыру. *Сөембикә белә иде: ир-канаты канында күчмә төрки халкының мәңге җуелмас сагышы бар, ул сагыш Сөембикәнең үзендә дә вакыт-вакыт тавыш бирә,* --- *дәшә, йөрәккә шом сала.* М.Хәбибуллин. *Гөлҗамал да кабынып китте: – Бер дә юкка баланың җанын талкып, йөрәгенә шом салып утырма әле, карт!* Ф.Садриев. **Йөрәккә шырпы кадау** Авыр тойгылар уяту. *Ә малайлар* --- *шунда йөрәккә шырпы да кадап алалар: – Нәгыйм абыйлар кибәннәрен очлап килә, безнеке яртысына да җитмәгән.* М.Әмирханов. **Йөрәккә ябышу** *к.* **йөрәккә кадалу**. *Авыз оясыннан сүз кошы чыгып очуга, акылым кушланып, «ник әйттем икән» дигән хәсрәтем йөрәгемә ябышты.* Ф.Яхин. **Йөрәккә якын алу** Чамадан тыш игътибар итү; бик тирән кичерү. **Йөрәккә якын (итү)** Үз итү, үз күрү, хөрмәтләү. *Әмма олыгая барган саен, туган төбәк йөрәккә якынрак була икән.* Б.Камалов. **Йөрәккә ял булу** Кайгы-борчылулар онытылу, тынычланып калу; кәеф күтәрелү. *Ике күреп бер сөйләшсәм, Йөрәгемә ял була.* Җыр. **Йөрәккә ялкын салу** *к.* **йөрәккә ут салу**. **Йөрәккә**

**ярып салу** Катлаулы, авыр нәрсәләр турында үтемле итеп аңлатып бирү. *Ул шундый оста педагог: нинди чуалчык, аңлашылмаган мәсьәләне шундый ачык, җиңел генә итеп йөрәгеңә яра да сала инде.* Г.Газиз. **Йөрәккә яту** 1) Уңай тәэсир калдыру, ошау, теләкләргә туры килү. *Кичәдәге башка нәрсәләр дә, ничектер, халыкның йөрәгенә ятты.* Г.Ибраһимов; 2) Тәм табып ашау, тәмле булу. **Йөрәккә ятышлы** Күңелгә ошаган, канәгатьләндерә торган; ягымлы, күркәм. *Җайлы шундый, сабыр сүзләре йөрәккә ятышлы.* Г.Ахунов. *Йосыпов ачык елмаеп, калын, йөрәккә ятышлы тавыш белән, һәр сүзнең тәмен татыгандай, ашыкмый гына җавап бирде.* М.Маликова. **Йөрәккә яшерү** Серләрне күңел түрендә генә йөртү, башка берәүгә белгертмәү, сиздермәү. **Йөрәк кешесе** Шәфкатьле, аңлаучан, ярдәм итүчән. **Йөрәк киселү** Ачлыктан интегү, бик бетеренү. *Бу эшти белән бер кашык боткадан тәмам йөрәк киселде.* Н.Исәнбәт. **Йөрәк кубу** *к.* **йөрәк алыну**. **Йөрәк кузгалу** Кәеф бозылудан, тирән дулкынлану, борчылудан кинәт йөрәк авырта башлау; йөрәк өянәге башлану. **Йөрәк кушуы** Күңел теләге буенча. *Такташның космополитлыгы мәсьәләсендә дә совет галимнәренә ачу итеп түгел, бәлки, үзенең йөрәк кушуы буенча гына каршы чыккан иде.* И.Нуруллин. **Йөрәк кыллары** Хис-тойгының иң нечкә урыны. *[Җәллад] Моңлы йөрәк кылларына сугып интектергән минем милләтне.* Ф.Яруллин. **Йөрәк кылларын чиртеп карау** Берәүнең хисләрен, тойгыларын, кемгә дә булса мөнәсәбәтен чамалап белү өчен сүз кушу. **Йөрәк кылларын чиртү** Күңелгә нык тәэсир итү, хисләндерү. *Ритм күңелгә шулкадәр тәңгәл килә, әйтерсең гитараны кеше түгел, нурлары белән йөрәк кылларына чиртә-чиртә, Ай үзе уйный.* З.Садыйков. **Йөрәк кымырҗау** *к.* **йөрәк чымырдау**. **Йөрәк кысу** *к.* **йөрәк кысылу**. *Туган ягым – мәңге кояш, Йөрәк кыса сагынудан.* З.Хәким. **Йөрәк кысылу** 1) *к.* **йөрәк чымырдау**. *Толстойның «Воскресенье»сен укыганда, йөрәкләр кысылып, аркада кырмыскалар йөргәндәй була.* М.Гайнуллин; 2) Куркыныч янау, афәт, бәла-каза һ.б.ш. хәбәрләргә карата көчле кызгану хисе барлыкка килү. *Безнең генә бәхетсезлегебезгә явыз ярман сугыш ачкан икән. Йөрәкләрем кысыла.* Т.Гыйззәт. *Ә менә 2002 елның сентябрендә булган вакыйга искә төшсә, йөрәкләр кысылып куя.* Т.Нәҗмиев. **Йөрәк кыткылдау** Бик беләсе яки күрәсе килүдән, дулкынлану, кызыксыну хисеннән кая да булса атлыгып, ашкынып тору. *Иртәгә туйга барасына йөрәк кыткылдап тора.* А.Таһиров. **Йөрәк логикасы** Хис-тойгыларның фикерләү закончалыгы, интуиция. *Тышкы формаль логикадан тыш, күңел сизгерлеге, йөрәк логикасы да бар бит әле.* Р.Рахмани. **Йөрәк маем** *диал.* Яратып, иркәләп әйткәндә кулланыла. **Йөрәк маен суыру** Газаплау, борчып тору. *Шушы хәсрәт көн-төн Абу бабаның йөрәк маен суыра иде.* Б.Сөләйман. **Йөрәк мае сызу (сызылу)** 1) Бик нык сагыну, сагышлану. *Агыйделгә басма салдым, Баскан саен сыгыла; Син җаныйны уйлый-уйлый, Йөрәк маем сызыла.* Җыр; 2) Әрнү, кимсенү, эчке дулкынлану хисләре эчендә булу. *Хатынкыз, ничарадан-бичара, иренең азгынлыгына күнегә, ияләшә, йөрәк маен сыза-сыза, күз яшенә манчылып, кара кайгыга сабышса да түзә.* А.Гыйләҗев. **Йөрәк майларын иму** *к.* **йөрәк маен суыру**. **Йөрәк мәсьәләсе** Мәхәббәт өлкәсе. *Егет йөрәк мәсьәләсендә бөтенләй тәҗрибәсез.* Ф.Сафин. **Йөрәк мүкләнү** *к.* **йөрәккә йон (мүк) үсү**. *Йөрәге мүкләнгән аның, мәңге өйләнәсе юк.* Татар иле. **Йөрәкне авызлыклау** Үз-үзеңне тыю, хис-тойгыларны кулга алу, акылга буйсындыру, нинди дә булса теләктән баш тарту. *Кыз башкача очрамаса, әнә шул аек фикере йөрәген авызлыклаган да булыр иде, бәлки.* Җ.Рәхимов. **Йөрәкне ачу** 1) Эчке серләр белән уртаклашу, кемгә дә булса эч серен сөйләү; 2) Яратуыңны-ошатуыңны белдерү, чын күңелдән сөю хисләре турында әйтү. *Соңыннан исә [Рәгыйдә] бөтенләй, бөтенләй бөек хискә бирелеп, аның янына ихлас күңел белән килеп йөрәген ачты.* Ә.Баянов. **Йөрәкне басу** *к.* **йөрәк басылу**. *Ул кайткач, ике арада җилле сөйләшү булды. Болай итү дә йөрәкне басмады.* Б.Камалов. **Йөрәкне бимазалау** Мәшәкать тудыру, тынычлыкны алу. *Ул Әхмәтовның сорауларына җавап бирә, кая барганын да белә, ләкин миен газаплап, йөрәген бимазалап, күңелгә һаман шул борчулы уйлар килә.* Р.Кәрами. **Йөрәкне җилсетү** Кая да булса әйдәү, талпыну. *Аларның салмак моңсу тавышлары, йөрәкләрне җилсетеп, үзләре белән каядыр еракка чакыра-дәшә кебек.* Ч.Айтматов. **Йөрәкне җылыту** Күңелне тынычландыру; борчылу, газаплану хисләрен юкка чыгару, рәхәтлек хисе кичерү. *Сөмбеләне Нәҗип белән Наиләнең эчкерсез, чын күңеленнән каршылавы аның йөрәген җылытып җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Әмма минем кинәт шул билгесез кешегә елмаеп йөрәгемне җылытуы өчен --- рәхмәт йөзеннән бер яхшылык эшлисем килде.* Ч.Айтматов. **Йөрәкне калтырату** Бик нык куркыту. *Үзәк өзгеч бала тавышы Сискәндереп күлне дулкынлатты, Йөрәген калтыратты аккошның.* Ф.Кәрим. **Йөрәкне кимерү** Тынгысызлап тору, күңелдә борчу хисләре булу; эч пошу. *Шик вә көнчелек корты аның йөрәген кимерә.* Р.Сибат. **Йөрәкне кисеп бирерлек** Бер кеше өчен үләргә дә әзер булу. *Йөрәген кисеп бирерлек дәрәҗәдә яраткан кешеңә шундый вәгъдәсезлек күрсәт инде.* А.Расих. **Йөрәкне кистерерлек итеп** *к.* **йөрәккә үткәреп**. *[Ул көй] адәм балаларының бүгенгә чаклы никадәр азаплансалар да, тел белән аңлата алмаган тойгыларын кемгәдер сөйли, ачы, йөрәкне кистерерлек итеп сөйли.* С.Җәлал. **Йөрәкне кисү** Бик нык куркыту, өзгәләнергә мәҗбүр итү, зур газапка салу. **Йөрәкне кубару** Куркыту, борчу. *Йөзе кара, йөрәкләремне тәмам кубарды.* Г.Камал. **Йөрәкне кытыклау** Нинди дә булса тойгылар уяту. **Йөрәкне өзү** 1) *к.* **йөрәк әрнү** (*1, 2 мәгъ.*). *Печәннең хуш исе аны исертеп җибәрә. Йөрәген өзеп, янә туган авылы исенә төшә Мотаһирның.* Р.Кәрами; 2) *к.* **йөрәк яну** (*2 мәгъ.*). *Шул кызның күз караулары йөрәкнең кай җирендер телеп, өзеп-өзеп ала,*

*хәерсез.* Ш.Камал. **Йөрәкне өшетү** Күңелгә шом салу, начар хисләр уяту. *Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды.* Ә.Еники. **Йөрәкне сызландыру** *к.* **йөрәк сызлау**. *Мондый очрашулардан калган хис атна буе йөрәкне сызландыра, бу сызлану икенче очрашуга кадәр җитә иде.* М.Маликова. **Йөрәкне талау** *к.* **йөрәк итен ашау**. *Гайнавал апасыннан ишеткән төртке сүзләр, әтисенең кызын яклап рәтле-башлы сүз әйтә алмавы, Әмирдән хат-хәбәр юклыгыннан зар-интизар булып тилмерүләр, саный-чутлый китсәң, чүп өстенә чүмәлә булып, йөрәкне талый торалар.* Р.Ишморатова. **Йөрәкне телү (телгәләү)** 1) Каршылыклы хис-тойгылар биләп алу, рухи әрнү кичерү. *Рәшит үзенең моңаеп утырган ватык «Коммунар»ы янына килгәч тә, әле генә йөрәген телгәләгән хәсрәтле уйлардан шундук арынгандай булды.* Н.Фәттах. *Җан көеге генә ул, укыган саен йөрәкне генә телгәли.* М.Әмир; 2) *к.* **йөрәккә (үтеп) керү**, **йөрәккә басу** (*1 мәгъ.*). *Искиткеч моң, йөрәгемне телеп, Тетрәндерде мине – еладым.* С.Гәрәева. **Йөрәкне тетрәтү (тетрәндерү)** Бик нык тәэсир итү; бик нык хисләндерү. *Бер кадр йөрәкне тетрәтте: мәһабәт гәүдәле 59 яшьлек Хөсәенов белән карсак кына 70 яшьлек Солтанаев Шәйдулла кочаклашканнар да елыйлар.* М.Мәһдиев. **Йөрәкне тырнау** *к.* **йөрәкне кимерү**. *Алар сине тынгысызлый, йөрәкне тырный.* М.Юныс. **Йөрәкне урыныннан куптарырлык** Бик көчле тәэсир итә торган. *Мостафаның яраткан җыры иде бу, һәм ул аны, исерек булуына карамастан, нинди туң йөрәкне дә урыныннан куптарырлык моңлы тавыш белән җырлый белә иде.* К.Нәҗми. **Йөрәкне ут алу** Дәрт-гыйшык яки ачы хәсрәт-кайгы белән йөрәк яну. *Гыйшык хәлләре яман, Йөрәгемне ут алган. Яшь вакытта гыйшык тоту Пәйгамбәрләрдән калган.* Жыр. **Йөрәкне учта (уч төбендә) кысып (йомып, тотып)** Куркып, шикләнеп, дулкынланып. **Йөрәкне учлап** Йөрәксенеп, тәвәккәлләп. *Бөтенесен яхшылап сумкасына тутырды да, йөрәген учлап, сәфәргә чыкты.* Ф.Садриев. **Йөрәкне шом басу** Күңел тынычсызлану, борчылу. *Фидая чынбарлык табигыйлегеннән каядыр башка бер мохиткә – аңлаешсыз, зиһен җитми торган, шул ук вакытта күңелне ургыткан хисләр белән бәйле дөньяга күчеп киткәндәй булды, йөрәген шом басты.* М.Маликова. **Йөрәкне чәнчү** *к.* **йөрәккә кадалу**. *Әтинең шелтәле сүзләре йөрәкне чәнчеп-чәнчеп ала.* Н.Фәттах. **Йөрәкне эретү** Кәефне йомшарту, ачуны басу, үпкә хисләрен юкка чыгару. **Йөрәк ою** *к.* **йөрәк кымырҗау**. **Йөрәк өзгәләнү** *к.* **йөрәк ярсу**. **Йөрәк өзгеч** 1) *к.* **йөрәк яргыч**. *Нәкъ шул вакытта якында гына йөрәк әрнеткеч итеп сирена кычкыра башлады.* З.Бәширов; 2) Бик кайгылы, ирексездән шомландыра, куркыта торган. *Хатыны Әлфиянең урман тарафыннан килгән йөрәк өзгеч тавышын шулкадәр ачык ишетте ки, бу тавыш һаман да колагында чыңлый иде.* А.Сафин; 3) Күңелнең иң нечкә хисләренә тәэсир итә алган, үзенә бик нык җәлеп иткән. *Саф, салмак тавыш --- бөтен залны, бөтен күңелләрне гаҗәеп моң белән: йөрәк өзгеч, җан тетрәткеч моң белән тутыра барды.* Н.Фәттах. *Чит-ят җирләрдә, бөтенләй диярлек таныш булмаган кешеләр янында аерылышулар икеләтә моңсу һәм йөрәк өзгеч тоела.* З.Зәйнуллин. **Йөрәк өзелү** *к.* **йөрәк әрнү**. **Йөрәк өшеткеч** Шомга салган, хәвеф-хәтәр хисләрен тудырган. *Алар йөрәк өшеткеч тизлек белән, дага асларыннан кара төерләр чәчрәтеп, айһайлап килеп чыктылар.* К.Нәҗми. **Йөрәк өшү** *к.* **йөрәк әрнү** (*1, 2 мәгъ.*). *Якындагы үткәннәр искә төшсә, йөрәк өшеп куя.* А.Хәлим. *Улы белән киленен --- кырык корама чыбылдыклар белән генә берберсеннән аерылып яшәүче унбишләп семья арасында очраткач, Мәликә апаның йөрәге өшеп киткәндәй булды.* К.Нәҗми. **Йөрәк парәсе** Иң кадерле кеше, бала. *Әй балам, балам – йөрәк парәсе. Күземнең яше, күңелем ярасы.* Ф.Яруллин. *Менә, ниһаять, кошчыкларның йөрәк парәләре кысан күкәйләреннән киң иркен дөньяга чыкты.* Н.Хәсәнов. *Нәнә --- йөрәк парәсе Гөлйөземнең аркасыннан бәпләп, сөйләнә-сөйләнә үзенчә уятырга кереште.* Ф.Латыйфи. **Йөрәк парчалану** *к.* **йөрәк әрнү**. **Йөрәк сере** Кемнең дә булса үзе генә белгән уе, хис-тойгысы. *Гөлйөземнең йөрәк серен уртаклашкан карт нәнә авыр сулап куйды.* Ф.Латыйфи. *Бу аның озак яшереп, саклап йөрткән йөрәк сере иде.* М.Юныс. **Йөрәк серен ачу** Берәрсенә эчке уйларны сөйләү, уй-хыял белән уртаклашу. *Бүгенге сәхифәбездә ялгызлык утында янган егет-кызлар, абый-апалар, әби-бабайлар фикерләре белән уртаклаша, укучылар йөрәк серләрен ача.* Шәһри Казан. **Йөрәк серенә керү** Кемнең дә булса тирән уйларын, хисләрен белү. **Йөрәк сикертү** Гыйшык тоту, мәхәббәт утларында яндыру. *Ә, бәлки, мәхәббәтсез, йөрәк сикертүләрсез, газаплы төннәрсез җиңелрәк һәм яхшырак, гүзәлрәктер тормыш, ә?!* З.Садыйков. **Йөрәк сикерү** *к.* **йөрәк атылып чыгарга җитү**. **Йөрәк сугу** *к.* **йөрәк атылып чыгарга җитү**. *Каным кыза, йөрәгем суга, аякларым үзләреннән-үзләре ашыгалар.* Г.Ибраһимов. *Йөрәгем суга, тәнем бераз калтырый, күкрәгем, никтер, кысып-кысып ала.* Г.Ибраһимов. **Йөрәк сүзе** 1) Чын күңелдән, ихластан әйтелгән сүз, теләк; 2) Хисләргә бай, тирән мәгънәле уй, фикер. **Йөрәк сызлану** Рухи газаплану, әрнү хисләре кичерү. *Артта калган туксан еллык озын юлга борылып караганда, үкенүдән йөрәк сызлана.* Г.Бәширов. **Йөрәк сызлау** *к.* **йөрәк сызлану**. *[Галя] Йөзен бала юрганына каплап, йөрәк сызлавына түзә алмыйча, тавыш-тынсыз гына елый.* Р.Кәрами. *Рөстәм маҗаралары белән мавыгып, тыштан көлеп йөрсәм дә, йөрәгем сызлый минем.* Г.Кутуй. **Йөрәк сыкрау** *к.* **йөрәк сызлану**. *Шул чакларда үземнең дә йөрәгем сыкрый, югалган балаларым исемә төшә, күзләремә яшь килә иде.* М.Әмир. **Йөрәк сызылу** Берәрсе турында борчылу, кайгыру. *Шул арада, никтер, кинәттән аның күз алдына Фәридә килә, аның йөрәге тагы сызылып китә.* С.Җәлал. **Йөрәк тавышы** Эчке тоемлау, сизенү. *Без йөрәк тавы-*

*шына колак салырга өйрәнергә тиешбез.* Ф.Сафин. **Йөрәк тамырына төшү** Бик көчле тәэсир итү, үзәккә үтү. *Бу кайгылы аваз, ничектер, йөрәк тамырларына төшә, арка-үзәкләрдән, аяк буыннарыннан йөреп, күңелгә җыелып тулып килә дә күзләргә яшь китерә.* Г.Ибраһимов. **Йөрәк таш булып кату** 1) Каты күңеллеләнү, кырыслану, усалга әйләнү; 2) Битараф калу; ярату, кызгану һ.б. хисләре юкка чыгу. *Алмачуар җан биргәндә, мин аның баш очында идем. Елый алмадым. Йөрәгем таш булып катты.* Г.Ибраһимов. **Йөрәк ташу** *к.* **йөрәк кайнау**. **Йөрәктән алу** Эчкерсез күңел белән тәкъдим итү, бик теләп эшләү. *Бу, әйбәт куелган спектакль кебек, чыннан да, йөрәктән алырлык күренеш иде.* Ф.Сафин. **Йөрәк тырналу** *к.* **йөрәкне кимерү**. *Менә алты ай, Мәрфугадан бер генә хат алганым юк. Ничек кенә димә, йөрәк тырнала бит, малай.* Ф.Хөсни. **Йөрәктән кан таму** *к.* **йөрәккә кан саву**. *Кара печатьле язуны тотып, үксеп-үксеп елаган яшь-яшь хатыннарны, аларның үрсәләнеп елаган балаларын күреп, йөрәктән каннар тама иде.* Ф.Галиев. *Йортсыз-җирсез калган ятимә солдаткаларның, балаларын ияртеп, урманнар ягына яки тимер юл станцаларына таба юл тотканнарын күргән чакта, аның йөрәгеннән кан тама торган иде.* Г.Ахунов. **Йөрәктән кичерү** Күңелгә якын алу, тирән хис-тойгылар белән үткәрү, артык дулкынлану, борчылу. **Йөрәктән серләшү** Мәхәббәт турында сөйләшү, аңлашу. **Йөрәктән сөйләшү** Чын күңелдән, ачыктан-ачык, бернәрсә яшермичә сөйләшү, аңлашу. **Йөрәктән (өзелеп) төшкән** Үз карыныңда, үз каныңнан барлыкка килгән (бала турында). *[Мәҗит:] Ул да – кемнеңдер йөрәгеннән өзелеп төшкән баласы.* Д.Салихов. **Йөрәктән чыгу** Күңелдә йөрткәннәрне әйтү. *Бәлки, кырык ел буена башын күтәрмәгәндер бу хатын, ә менә хәзер бөтенесе, бөтенесе аның йөрәгеннән тышка атылып, бәреп чыкты.* Ч.Айтматов. **Йөрәктән чыкмау** Һич кенә онытылмау, һәрвакыт истә булу. **Йөрәктә саклау (йөртү, яшәү)** *к.* **йөрәк түрендә йөртү** (*1 мәгъ.*). *Батырша исеме күп еллар буе халык йөрәгендә яшәде.* Ж.Рәхимов. **Йөрәк тоемы белән** *к.* **йөрәк аша**. *[Алсу] Аңа тулысынча ышана иде. Ә, бәлки, ул йөрәк тоемы белән генә әллә кайчаннан бирле бу агайда яхшы кешене таныгандыр.* А.Сафин. **Йөрәк тойгысы (хисе, сагышы) белән** Сагышлану, юксыну, ярату һ.б.ш. хисләр белән. **Йөрәк тоту** Йөрәк өянәге башлану. *Врач бик борчылып хәбәр итте: төнлә авыруның хәле кисәк авыраеп киткән икән, берберартлы ике тапкыр йөрәге тоткан.* Ф.Галиев. **Йөрәк төбеннән** Хис-тойгыларның бик тирәннән барлыкка килүе. *Әйләнә-тирәсен онытып, ул үзенең йөрәк төбеннән кайнашып менгән ачы яшьләренә тулы ирек бирде һәм, иңбашларын бер күтәреп, бер төшереп, бик нык сулкылдый башлады.* Ә.Фәйзи. *Моңарчы һич таныш булмаган нindидер бер яңа хис йөрәгем төбеннән җылы дулкын булып күтәрелде.* Ч.Айтматов. **Йөрәк түре** Күңелнең иң эчке, тирән урыны; хисләр дөньясы, хәтер. *Лариса тирән итеп, йөрәк түре белән көрсенеп куйды.* М.Маликова. *Оляга куркыныч төш кергәндә, йөрәк түремә уеласы тирән ярадан кан саркый башларга күп калмаган: мине кулга алу турындагы ордерга республика прокуроры кул куеп, мөһерен салган булган инде.* Г.Тавлин. *Юк, барыбер аның йөрәк түрендә юшкын.* Р.Кәрами. **Йөрәк түрендә йөртү (саклау)** 1) Үткәндәге вакыйгалар, истәлекләр, шәхесләр һ.б. гел хәтердә булу, онытмау. *Чит кешеләрнең тупас тавышлары, инәсенең йөрәк өзгеч итеп, куркыныч итеп кычкырып җибәрүе, шапылдап ишек-капка ябылуы – барысы да Габделхәйнең исендә, йөрәк түрендә.* Н.Фәттах; 2) Сөйгән ярны истән чыгармау, һаман да якын итеп йөрү, якын итеп тою. *Ул үзенең йөрәк түрендәген аңларга куркып йөргән, ә Каләмгөл барысын да сизгән, белгән икән?* М.Маликова. **Йөрәк тыпырдау** *к.* **йөрәк атылып чыгарга җитү**. *Шулай итеп, йөрәк тыпырдаудан туктады, бүрек эче иркенәеп калды.* Ф.Хөсни. **Йөрәк урыныннан кубу (кузгалу)** Хафалану, тынычлыкны югалту, борчылу хисләре биләп алу. *Йөрәгем урыннан куба торганые инде, [малай] саманнан корыштырган стенага ялгыш килеп бәрелеп, йортны ишеп төшерер, дип.* Ф.Сафин. **Йөрәк урынына утыру** *к.* **йөрәк басылу**. **Йөрәк урынында түгел** Күңелдә көчле борчылу, дулкынлану хисләре кузгалу, берәр нәрсәгә хәвефләнү. **Йөрәк ут булу** *к.* **йөрәк яну**. **Йөрәк уты** Хисләр, тойгылар, сөю теләге. *Бәхетле гаилә тормышының калын өресе астында үзенең эсселеген, кайнарлыгын яшергән, саклаган аның йөрәк уты шул көзге җилнең искәртмәстән исүе берлә пәрдәсез, калкансыз калды.* Г.Исхакый. **Йөрәк үлү** *к.* **йөрәк таш булып кату**. *[Сәрвәр:] Исмәгыйль җаным! Синнән аерылуны уйлаганда, минем дә шулай ук йөрәгем үлә.* К.Тинчурин. **Йөрәк хисе** Эчке кичерешләрне аңлый белү сәләте, сизгерлек. *Көйне моңлы итү, кеше күңелләренә җиткерү өчен, үзенә аерым талант, йөрәк хисе кирәк.* М.Маликова. **Йөрәк чире** *к.* **йөрәк мәсьәләсе**. *[Фазилә] Яшереп-нитеп тормады: күрүгә, үзенең кемлеген, чиренең, тән чиреннән бигрәк, йөрәк чире икәнлеген әйтте.* М.Маликова. **Йөрәк чуарлану** *к.* **йөрәк кыткылдау**. **Йөрәк чымырдау** Күңелсез, шомлы хәл яки хәбәрдән куркынып китү, тынычсызлык тойгысы кичерү. *Хәбәрне ишетүгә, [Батыршаның] йөрәге чымырдап китте.* Ж.Рәхимов. *Бу юлы «кылт» итеп Гөлйөзем исенә төште, йөрәге чымырдап китте, тәнен ашкынулы хис басты.* М.Әмирханов. **Йөрәк якынаю** Ир-егет белән хатын-кызның берберсен үз итүе. *Күңел җепләре кушылып үрелгән саен, йөрәкләр якынайды.* Ф.Сафин. **Йөрәк ялгау** Бераз ашап алу; ачыкканны басарлык капкалау. *Бу тургай, гәрчә мәчене туйдырырлык булмаса да, йөрәк ялгарга ярады.* Г.Тукай. *Кичен арып кайтасың, йөрәк ялгарлык аш та юк өйдә.* К.Нәҗми. **Йөрәк ялкыны** Дәртле, ашкынулы хис. *Әмма анда зур трагедияләр тудырырлык йөрәк ялкыннары юк.* Ж.Вәлиди. *Дәһшәтле сугыш кырында Сөйгән халкымның Мин кояшым итеп йөртәм Йөрәк ялкынын.* Ф.Кәрим. **Йөрәк яну**

1) Кайгы-хәсрәт эчендә булу, хәсрәт чигү. *Әмма исерү йөрәк януын гына арттыра*. М.Маликова. *Кара син аны, әнисе кияүгә чыга, имеш, ә моның йөрәге яна, тамагыннан калган, янәсе.* М.Кәрим; 2) Мәхәббәт хисе уяну, ярату хисе белән газаплану; 3) Берәр кешенең уңышыннан көнчелек уяну, көнләшү, гарьлек хисләре кичерү. **Йөрәк ярасы** 1) Баштан үткән фаҗигале, газаплы вакыйгаларның күңелдә калган эзе. *Соң булса да аңладым йөрәк ярагызны, Кичерегез каргалган балагызны*. И.Юзеев. *Килмәсен ул монда яңадан, болай да иңрәп әрнегән йөрәк ярамны миһербаншәфкате белән тоз сипкәндәгедәй әрнетмәсен...* Г.Тавлин. *Сәкинә, авыр кагылам дип уйлап та тормады, йөрәк ярасына тозны учлап сипте.* Н.Хәсәнов; 2) Ошаткан, күңеле төшкән; ярату хисләре тудырган кеше. **Йөрәк яргыч** Бик көчле, коточкыч. *Мылтык төзәп торган ир-атны күреп, ул йөрәк яргыч тавыш белән кычкырып җибәрде*. З.Фәтхетдинов. *Баскычлары-ниләре белән тәгәрәп төшкән алыпларның әрнүсызлану тавышы йөрәк яргыч булды.* М.Хәбибуллин. **Йөрәк ярсу** Артык дулкынлану, бик нык борчылу. *Аның йөрәге ярсыды, күңел чоңгыллары айкалды-чайкалды*. Р.Кәрами. *Сикерепсикереп агадыр кар суы, Ник басылмый йөрәгем ярсуы?* Җыр. **Йөрәк ярчыгы** *к.* **йөрәк парәсе**. *Ташкәй аның улы иде ич, аның йөрәк ярчыгы, аның каны да!* Я.Зәнкиев. **Йөрәк ярылу** 1) Йөрәк карынчыгы стенасы шартлау (мәс., куркудан, бик нык дулкынланудан, артык шатланудан һ.б.дан); 2) *куч.* Бик каты курку. **Йөрәк ятмау** Күңел тартмау, үз итмәү, ошатмау. *Юк, нигәдер, ул кешегә минем йөрәк ятмый.* Г.Минский

**ЙӨРӘКЛӘНДЕРҮ** *ф.* Кыюландыру, кыюлык өстәү (бирү) (эчемлек турында). *Эчемлек тә йөрәкләндерде, ахры, берничә мәртәбә Лиданың аягына басуын да тоймады.* Т.Әйди

**Йөрәкләндерә бару** Торган саен ныграк йөрәкләндерү

**Йөрәкләндерә төшү** Бераз йөрәкләндерү

**Йөрәкләндереп алу** Аз вакытка йөрәкләндерү

**Йөрәкләндереп җибәрү** Йөрәкләнеп китәргә этәргеч бирү, шул моменттан башлап йөрәкләндерү (кинәтлек төсмере белән)

**Йөрәкләндереп кую** Кинәт йөрәкләндерү

**Йөрәкләндереп тору** Һәрвакыт, гел йөрәкләндерү

**ЙӨРӘКЛӘНҮ** *ф.* Кыюлану, батырлану. *Җәгъфәрнең артык карап торырга түземе җитмәде, тешләрен кысып, йөрәкләнеп, баскычтан иптәшләре – нөгәрләр янына йөгерде*. Ф.Латыйфи

**Йөрәкләнә төшү** Бераз йөрәкләнү

**Йөрәкләнеп алу** Тиз арада, кинәт йөрәкләнү. *[Бия] Казан урамнарында башын салындырып кына йөрсә дә, кайту юлына чыккач, йөрәкләнеп алды һәм «эһ» тә итми җилдертә торды.* Ф.Яхин

**Йөрәкләнеп бару** Әзлекле рәвештә акрынлап йөрәкләнү; батырлык, кыюлык кебек сыйфатлар даими арту

**Йөрәкләнеп китү** Кинәт, берәр нәрсә тәэсирендә яки үзеннән-үзе йөрәкләнү. *Һәм Иргали тәвәккәлләде, йөрәкләнеп китеп, бөтен ихтыярын бергә туплады да җиңелчә генә ишек келәсенә кагылды*. М.Хәсәнов. *Ә инде үсеп җиткәч, Йөрәкләнеп тә киткәч, Гайрәтләнеп тә җиткәч, Уйлаган ул беркөнне, Тыңламыйча беркемне, Азрак уйнап килергә, Зур урманда йөрергә.* Р.Миңнуллин

**ЙӨРӘКЛЕ** *с. куч.* **1.** 1) Кыю, куркусыз, тәвәккәл. *[Усман абый] кыска буйлы, йөрәкле кеше.* Ф.Галиев. *Ярсу йөрәкле батыр егетләр, җилдән җитез атларына менеп, үткен кылыч болгап, дошманга каршы чыкканнар*. М.Маликова

2) Дәртле, ашкынучан. --- *һәр яшь кешегә дә чиксез кызык. Бигрәк тә бар нәрсәне үзе танып белергә, ясап карарга омтылучы кайнар йөрәкле, шашкын хыяллы малайларга!..* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Курыкмыйча, батырланып. *Йөрәкле барабыз сугышка, Сакларга Советлар йөрәген!* М.Җәлил

**ЙӨРӘКЛЕЛЕК** *и.* Кыюлык, тәвәккәллек, батырлык. *Физик тәрбия бирү кыюлык, батырлык, йөрәклелек, тәвәккәллек, каушап калмау, түземлелек, дисциплиналылык, нык торучанлык кебек сыйфатларны үстерүгә ярдәм итә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ЙӨРӘКСЕЗ** *с.* 1) Кыюлыгы җитмәгән, куркак. *Шулай куркак һәм йөрәксез кеше чыпчык канаты тавышын ишетсә дә коты чыга*. К.Насыйри

2) Усал, салкын карашлы, кызгана белмәгән, рәхимсез. *Нинди җансыз, йөрәксез кеше син!* Г.Гыйльманов

**ЙӨРӘКСЕЗЛЕК** *и.* Йөрәксез булу. *Йөрәксезлеккә Түзеп яшәүдән Төзек яшәүгә Багланган өмет.* Р.Гыйззәтуллин

**ЙӨРӘКСЕНДЕРҮ** *ф.* Рухландыру, дәртләндерү, үсендерү

**Йөрәксендереп җибәрү** Кинәт йөрәксендерү

**Йөрәксендереп тору** Әледән-әле яки һәрвакыт йөрәксендерү

**ЙӨРӘКСЕНҮ** *ф.* 1) Батырчылык итү, кыюлык җитү. *Койма аша карап торып тәмам арыган Нәзифә, йөрәге алгысынуына түзә алмыйча, капка келәсенә тотына, тагын кире китә, ишегалдыннан бер урап килә, ике урый, әмма капканы ачып, урамга чыгарга йөрәксенми, тагын туктап кала.* М.Галиев. *Ул арада ханым йөрәксенеп ишеккә килде, аны бәреп ачты һәм Моратовка коридор юлын күрсәтте.* З.Фәтхетдинов

2) Алгысу, омтылу; гайрәтләнү. *[Зөфәр] әз генә дә курыкмый иде. Киресенчә, күренеп торган бәхетенә ашкынгандай, бераздан каударланып, йөрәксенеп алга атлады.* Ә.Галиев. *Шофёр, җен ачулары белән газга басып, кабинасында йөрәксенгәндә, автомашинаны ул арттан этеп азапланды.* Б.Камалов

**Йөрәксенеп китү** Билгеле бер вакыттан башлап, кинәт йөрәксенү. *– Ишеттеңме син мин әйткәнне? – диде Равил, кыз аңа ачуланмаганга куанып һәм йөрәксенеп китеп. – Яратам мин сине, Рухия.* В.Нуруллин

**Йөрәксенеп тору** Әле, хәзерге вакытта йөрәксенү. *Кичтән таза «төшергәнлек» галәмәтеме, әллә йөрәксенеп торуыннанмы, куллары калтырады.* Б.Камалов

**ЙӨРӘКСЕТҮ** *ф. к.* **йөрәксендерү**

**Йөрәксетеп җибәрү** Кинәт йөрәксетү

**Йөрәксетеп тору** Әледән-әле яки даими йөрәксетү

**ЙӨРӘКСҮ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса омтылу, ашкыну

2) Газаплану, әрнү, борчылу хисләре кичерү

**2. йөрәксеп** *рәв. мәгъ.* Ашкынып, дәртләнеп. *Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады, ара-тирә йөрәксеп кычкырып та җибәрә, тик шулай да ул берәүне дә куркытмый.* Ф.Хөсни

**ЙӨРӘ́К ТИБЕШЕ** *и.* Йөрәкнең эшләү ритмы; *русчасы*: **сердцебиение**. *Кызның йомшак чәче Саматның битләрен, борыннарын иркәләде, кызу-кызу типкән йөрәге аның йөрәк тибеше белән кушылды.* Г.Гыйльманов. *Йөрәк тибеше аермачык булып чигәгә бәрә, бармак очларын чәнчеп-чәнчеп ала.* Р.Вәлиев

**ЙӨРӘКЧЕЛ** *с.* Кимсетү, түбәнсетү, хурлану күтәрә алмый торган; йөрәгенә якын алучан, гарьчел. *[Талип] Бик йөрәкчел малай, суга ташлануы-нитүе бар.* Ә.Фәйзи

**ЙӨРГЕЗҮ** *ф. иск. к.* **йөртү**. *Һөнәрле ком өстеннән көймә йөргезә.* Мәкаль. *Астыртын кеше салам астыннан су йөргезә.* Мәкаль

**ЙӨРГЕНЧЕ** *и. тар. к.* **йөрекче**

**ЙӨРГЕСЕЗ** *с.* Йөреп булмаслык, үтмәслек, үтеп йөри алмаслык. *Татар каны мөлдерәп ага, мәетләр аша үтеп йөргесез була.* Ф.Латыйфи. --- *базарларда – ерып йөргесез кеше һәм тауар диңгезе.* М.Галиев

**ЙӨРЕКЧЕ** *и. тар.* Махсус йөкләмә белән патша янына баручы; йомышчы (*3 мәгъ.*). *Казан юлындагы старшина Сөләйман Диваев командасындагы мишәрләр җыелып, --- әлеге «салым» дигәннәреннән коткаруны сорап, патшага бару өчен йөрекчеләр сайлап куялар.* Ж.Рәхимов

**ЙӨРЕМ** *и. сөйл.* Йөреп табылган кирәкле әйбер. *Йөргән аякка йөрем ияр.* Мәкаль. *Йөргәнгә йөрем бирсен, калганга түзем бирсен!* Мәкаль

**ЙӨРЕМЛЕ** *с. сөйл.* Тиз, кызу йөри торган. *Йөремле ат*

**ЙӨРЕМСӘК** *с.* 1) Бер урында гына торырга, яшәргә, эшләргә яратмый торган. *[Каргалыда яшәүче татарлар] Йөремсәк халык, дөньяның кайсы ягына гына җибәрсәң дә, һич курыкмый юлга чыгарга әзерләр, тапкырлар, батырлар.* Ж.Рәхимов

2) Күп йөрүчән, күп йөрергә яраткан. *[Рәшидә:] Йөремсәк җан бит. Урын таба алмый.* А.Гыйләҗев. *Аңа агентлар җитми торгандыр, йөремсәк Тураевны күзәтер өчен генә дә күпме көч кирәк ләбаса.* Т.Әйди. *Ул йөремсәк түгел, тамашаларга баруны җене сөйми.* Ф.Сафин

**ЙӨРЕМСӘКЛЕК** *и.* Йөремсәк булу

**ЙӨРЕМСЕЗ** *с. сөйл. сир.* Йөрү тизлеге акрын, түбән булган. *Ялкауның атын алма, йөремсез булыр.* Әйтем

**ЙӨРЕМТӘЛ** *с. сөйл.* 1) Кызу йөрешле, юл йөрүгә чыдамлы (ат турында). *Кешән – йөремтәл атның өч аягына салынган тышау.* Н.Исәнбәт

2) Бер урында гына торырга яратмый торган, күп йөрүчән

3) *сөйл. к.* **йөремче**

**ЙӨРЕМТЕК** *с.* Һәркемгә билгеле, еш кабатлана торган. *Йөремтек тәгъбирләр*

**ЙӨРЕМЧӘК** *с.* Әле тегендә, әле монда йөрергә яраткан, бер урында гына булмаган; һәрвакыт кайда да булса йөргән (булган). *Шунысы да бар: аның йөремчәк күңеле инде байтактан юл мәшәкате өнәп йөдәтә иде.* Ж.Рәхимов

**ЙӨРЕМЧӘКЛЕК** *и.* Йөремчәк булу. *Нәселдән килгән яраклашу, куштанлык, ялагайлык кебек «һөнәрләрне» үз итсә дә, бабаларының гасырлар буе килгән йөремчәклеген өнәмәде яшь морза, аларның юлда узган гомерләрен кызганды.* Ж.Рәхимов

**ЙӨРЕМЧӘН** *с. к.* **йөремтәл** (*1, 2 мәгъ.*). *Малы беткән кешенең эте өрүчән, аты йөремчән була.* Мәкаль

**ЙӨРЕМЧЕ** *и. сөйл.* Бер урында төпләнмәгән, бер җирдән икенче җиргә йөреп кәсеп итүче; йөрергә, гизәргә яратучан кеше

**ЙӨРЕНҮ** *ф.* Әле бер, әле икенче юнәлештә хәрәкәт итү, туктаусыз арлы-бирле килү. *[Фарукҗан] Шуннан соң кире үз бүлмәсенә әйләнеп кереп, ишекле-түрле йөренә башлады.* Т.Әйди. *Җәй урталары җиткән, --- яшел хәтфә болын буйлап --- йөренгән.* Һ.-Х.Андерсен. *Тасма өстендә гамьсез генә яшел бәдәнле чебеннәр йөренәләр иде.* Ф.Сафин

**Йөренә башлау** Йөренергә тотыну. *Ул, туңмас өчен, төрмә каршында әрле-бирле йөренә башлады.* Р.Кәрами

**Йөренә тору** Әле, хәзерге вакытта бертуктаусыз йөренү. *[Ильяс] Баян тавышын һәм соңгы мәртәбә яңгыраган җырларны тыңлый-тыңлый, бер тирәдә хискә талыбрак йөренә торды.* Ә.Баянов

**Йөренеп алу** Бераз йөренү. *Майор, урыныннан кубып, ишекле-түрле йөренеп алды.* В.Нуруллин. *Әбүзәр абзый урыныннан торды, арлы-бирле йөренеп алды.* Г.Әпсәләмов

**Йөренеп тору** *к.* **йөренә тору**. *Фәләх килеп җиткәндә, ул инде урамга чыккан һәм үзе фатирга кергән йорт каршындагы агач бакча буенда нервланып арлы-бирле йөренеп тора иде.* В.Нуруллин. *Хан өе тирәсендә, кораллар тотып, сакчылар йөренеп торды.* Н.Фәттах

**ЙӨРЕШ** *и.* 1) Кешеләрнең, хайваннарның атлап бару, аякларын, гәүдәләрен төрлечә басып йөрү рәвеше. *Яше җитмешнең югары ягына сикергән булса да, Таһир Идиятуллинның гәүдәсе төз, йөреше тотрыклы, тавышы көр иде.* Б.Камалов. *Кәҗәләрнең йөрешләренә кадәр нindидер мутлык сизелә.* М.Галиев. *[Хатын] Кыяфәтатлауларын үзгәртеп, үч алырга теләгән кешесенең йөрешен килештереп күрсәтә.* З.Зәйнуллин // Нинди дә булса хәрәкәт ясау турында (мәс., йоту хәрәкәте). *Фәрвәйнең йодрык кадәр муен кимерчәгә, «гот-тырт» итеп, ун сантиметрлы йөреш ясап ала.* Ф.Сафин

2) Йөрү, бер урыннан икенче урынга хәрәкәт итү тизлеге. *Поезд йөрешен тизләткәннән-тизләтеп, Зыятдин станциясен артта калдыргач, Фарукҗан --- юлдашыннан сорады.* Т.Әйди. *Бу юлы каршыга үкереп килгән КамАЗ үзбушаткычы, йөрешен кинәт салмагайтып, биш-алты адым кала туктады.* Г.Үзиле

3) Транспорт чарасының бер урыннан икенче урынга йөрү тәртибе. *Бу эшне суднолар йөрешенә комачаулык китермичә, 9–10 көн эчендә башкарырга кирәк...* Казан утлары. *Кемнәрдер транспорт йөрешен элеккечә калдыруны сорый, кемнәргәдер яңа кертелгән маршрутлар ошый.* Ватаным Татарстан

4) Бертөрле механизмнарның эш хәрәкәтләре. *Астрономиядә азимутларны көньяк ноктасыннан сәгать йөреше уңаена (көнбатышка таба) исәплиләр.* Левитан. *[Камил] Күтәрелеп карасa, йөреш валын тоташтырган муфтаның ычкынганлыгын күрде.* Н.Хәсәнов. *Күтәрү краны ярдәмендә бер урыннан икенче урынга күчерелә торган йөкнең хәрәкәте, транспортёр тасмасына салынган әйберләр хәрәкәте йөреш хәрәкәтенә мисал булалар.* Физика

5) Нечкә торбалар, кан тамырлары һ.б.ш. буенча сыеклыкның хәрәкәте, таралуы. *Йөрәге урынына утырды, кан йөреше тигезләнде, күңел ярларын каккан дулкыннар салмакланды.* Г.Гыйльманов

6) Шахмат, домино уеннарында фигуралар белән бер-бер артлы ясалган күчеш. *Шушы кичтә Кубрат хан философ Иоанн Фасианның галәмәт хәйләкәр кеше булуына янә бер инанды: ике йөрештә ханга шах куйды философ.* М.Хәбибуллин. *Әзһәм, йөреш ясагач, үз фикерен белдермәкче иде, Зиннәт алданрак әйтте.* Р.Кәрами

7) Кая да булса барып йөрү, берәр кайда булу. *Аннары мөдир мәктәптәге өлгереш, йөреш процентлары белән җентекләп таныштыы.* Б.Камалов. *Беренче май районының Кара Чишмә авылында зурларны укытуда йөреш түбән.* Г.Тавлин. *Бу [мәдрәсәгә] гади йөреш түгел, балалыктан – олылыкка, бүгеннән киләчәккә батыр бер омтылыш, кыю бер сикереш ясау иде.* Ә.Фәйзи // Кайда да булса йөрү. *Төнге йөрешләреннән соң ул кайтып егыла да йокыга китә.* Р.Батулла

8) Алдан уйлап, логик фикерләп башкарылган эш-гамәл турында. *Син, бәгырькәем, коры исәпләүләр белән генә шөгыльләнәсең һәм алдан бер-ике йөреш кенә күрәсең, ә мин арифметикасыз да, интуиция белән дә ераграк күрәм.* Ә.Мушинский

9) Берәр нәрсәнең бик еш кулланылуы, күпмедер вакыт файдаланууда булуы турында. *Ул мине йөрештә булган чулпы көмешеннән бер кыш кар астында чыккан көмешне аермый дип уйлады микән?* Ә.Гаффар

**ЙӨРЕШ-КИЛБӘТ** *җый. и. к.* **йөреш-торыш**. *Ә бүген, бәла-казадан котылып кайтып барганда, аның йөзе шат, йөреш-килбәте яшьләрчә җиңел.* С.Сабиров

**ЙӨРЕШЛЕ** *с.* 1) Тиз һәм алымлы йөри торган. *Туры атым йөрешле, йөрешләре килешле.* Җыр

2) Кайдан да булса йөри, үтә ала торган (транспорт чаралары турында). *Тоташ озынча итеп салынган ашлык келәтләренең баш-башында – машина кереп йөрешле дәү капкалар.* Р.Низами // Кеше үтә ала торган, кеше йөрерлек. *Ун чакрым ара лабаса. Гел-гел килеп-китеп йөрешле дә түгел.* Ә.Галиев

**ЙӨРЕШ-ТОРЫШ** *җый. и.* Кул-аякларны хәрәкәтләндерү рәвеше. *Гәүдәсен тотуы, йөреш-торышы, күз карашлары белән шулкадәр Фәһимгә охшатып, аны көлке итеп кабатлый иде ки, күзгә күренүгә, бөтен өй эче белән егылышып көлделәр.* Г.Бәширов

**ЙӨРЕШҮ** *ф.* Бер-беренә баргалап тору, әледән-әле бер-берендә очрашу, якыннан аралашып яшәү. *Кунакка чиратлашып йөрешәләр, ике як та үпкәләрлек түгел, бүген Иван Ивановичларда җыелсалар, иртәгә табынның мулы Басыйр Бариевичларда әзерләнә.* А.Гыйләҗев. *Ике туган – Байтирәк һәм Хикмәт абзыйлар – хәзер инде элекке үпкәләрен онытып, бер-берсенә йөрешәләр.* М.Галиев

**Йөрешә башлау** Йөрешергә тотыну. *Балалары апалары белән аралашмый инде, белмиләр дә апалары барлыгын. Олыгайгач кына белешәләр. Йөрешә дә башлыйлар.* Т.Миңнуллин

**Йөрешеп алу** Бераз, берникадәр, кыска вакытлы арада йөрешү. *Яшьлекләрендә хәтәр генә йөрешеп алганнар иде.* Ә.Гаффар

**Йөрешеп китү** Нииндидер сәбәп, вакыйгадан соң йөрешә башлау. *Ике гаилә кайчан йөрешеп киткәннәрдер – ул кадәресен хәтерләмим, ләкин үземнең белә башлаганда, безнең гаиләләр бер-берсенә бик якыннар иде инде.* Ә.Еники

**Йөрешеп тору** Даими рәвештә, гел бер-берсенә йөрешү. *Соңыннан терәлеп торган күршеләр булмасак та, бу якынлык бервакытта да бетмәде, һәрвакыт аралашып, йөрешеп тордык.* Ә.Еники

**ЙӨРТКЕЧ** *и. тех.* Берәр төрле транспорт чарасы яки механизмны хәрәкәткә китерә торган җайланма. *Чылбырлы йөрткеч. Пневматик йөрткеч*

**ЙӨРТҮ** *ф.* **1.** 1) Кемне яки нәрсәне дә булса ярдәм итеп, җитәкләп, озатып яки хәрәкәтенә юнәлеш биреп алып бару, иярту. – *Ә... – дип кул селтәде Пономарев, – кызларны ул [походта] бер атнадан да артык йөртмәде.* Р.Мөхәммәтҗан. *Киресенчә, [Кубрат хан] алай артыннан көтү-көтү ат йөртте.* М.Хәбибуллин

2) Йөрергә ирек бирү, рөхсәт итү. *Милицияләр урамнан йөртмиләр, әллә кайлардан Кабан күлләре аша әйләнеп кайттым.* Т.Гыйззәт

3) Күңел ачу, ял итү урыннарына алып бару, берәр нәрсә күрсәтеп йөрү. *--- машинасына ыбыр-чыбыр балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды.* Ә.Еники

4) Халык алдына алып чыгу, тамаша кылдыру яки гаебен фаш итеп йөрергә мәҗбүр итү (мәс., җәнлекләрне, кешеләрне һ.б.ны)

5) Кемне дә булса җәяү яки транспорт чарасында алып бару, хәрәкәт иттерү. *Кайчагында кичләрен Рөстәм Фәридә белән Кәримәне, көймәгә утыртып, Дим өстендә йөртә.* С.Җәлал. *Мин бит сине бүген көймәдә йөртергә тиеш.* Н.Фәттах

6) Нәрсәгә дә булса күнектерү, өйрәтү һ.б.ш. максат белән йөрү. *Ат йөртергә чыгу*

7) *Үзен, үзен-үзе* сүзләре белән килгәндә, «йөрерлек хәлдә булу» мәгънәсен белдерә

8) Парлы биюдә иптәшеңнең хәрәкәтенә юнәлеш бирү, аны үзеңнең бию хәрәкәтләреңә иярту. *[Бәхтинең] Кыюлыгы, танцыда бик яхшы*

*йөртә белүе, үз-үзенә ышанып, кулбашларын сикертеп сөйләшүе һәм кара мыегы Идага һаман ошый барды.* Н.Фәттах

9) Җитәкләү, берәүнең эш-гамәлләренә юнәлеш биреп тору. *Кыскасын гына әйткәндә, бөтенләй чеп-чи наданнар; шулай була торып та, ирләрен үз әмерләре белән йөртергә тырышалар.* Г.Камал

10) *тех.* Үзенә ияртеп яки берәр төрле ысул белән тәэсир итеп, нәрсәне дә булса хәрәкәткә китерү, эшләтү (механизмнар, энергия чыганаклары турында); берәр төрле транспорт чарасының хәрәкәте белән идарә итү. *Идел өсләрендә пар машиналары йөртәләр.* Т.Гыйззәт. *Капитан Дурашин, манёвр ясап, пароходны әле һаман да бер алга, бер артка йөртә иде.* Х.Садрый

11) Авыр әйбер, товар һ.б.ш. нәрсәләрне бер урыннан икенче урынга алып бару, ташу; тарату. *Кыш көннәре ул почта йөртә торган иде.* Г.Бәширов. *Шофёр, син машинаң белән Ил байлыгын ташып йөртәсең.* И.Юзеев

12) Чакыру, чакырып тору, килергә мәҗбүр итү. *Мәгәр милициягә чакыртып, прокурорга йөртеп, кат-кат судка чакырып теңкәсенә тиделәр.* А.Гыйләҗев

13) Терлекне барлап, күзәтеп, аларның хәрәкәтенә юнәлеш биреп йөрү. *Көтү йөртү*

14) Нәрсәне дә булса кул, бармаклар ярдәмендә хәрәкәт иттерү. *Һилалов --- медиаторны гаҗәп бер осталык, матурлык белән йөртә.* Җ.Фәйзи. *[Нуриман] Язу өстәленә җәеп салган сызымы өстендә карандашын йөртте.* Ә.Мушинский. *Илгиз каләмен ышанычлы йөртә.* Ф.Сафин

15) Әле бер, әле икенче якка хәрәкәт иттерү. *Ят тракторчы очлаеп торган ияген селкетеп, тәмәкесен иренендә шудыртып йөртте.* А.Гыйләҗев. *Ул, ашыкмыйча гына, тәмәкесен авызының әле бер, әле икенче ягына йөртеп, бармаксыз уң кулы белән азаплана-азаплана, атын тугарырга кереште.* Р.Мөхәммәтҗан

16) Нәрсәне дә булса һәрвакыт үзе белән алу, янында тоту. *Янымда акча йөртергә мин җүләр түгел.* Г.Камал. *Аннары тагын шул ук ыштан бөрмәсенә бәйләп, ул иске күн кынында кечкенә үткен пычак та йөртә иде.* Ә.Еники. *[Хәниф абый:] Озак йөрттем мин бу нәнине [авыз гармунын] үзем белән.* Н.Дәүли

17) Үстерү (сакал, мыек, чәч турында)

18) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса күңелдә саклау, онытмау; гел истә тоту. *[Ильяс] Рәгыйдәне еллар буе күңелендә йөрттеме? Йөртте.* Ә.Баянов. *Менә шундый тыелган күкрәү йөртә иде ул күкрәгендә.* З.Садыйков

19) *күч.* Билгеле сыйфатка, үзлеккә ия булу, үзендә бер билге булу. *Без барыбыз да – заман продукциясе. Үзебездә заманның плюсларын һәм минусларын йөртәбез.* Г.Ахунов

20) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса, ишләреннән аеру өчен, өстәмә исем яки кушамат белән атау. *Мәрфуга апа дип, без үзебезнең күрше Габдрахман абзыйның олы кызын йөртәбез.* Ф.Әмирхан. *Әнисен авылда «кибетче Саймә» дип йөртәләр.* Р.Низамиев. *Соңыннан белдем: бер-берсеннән аерылмый йөргәнгә, авылда аларны «өчлек союзы» дип йөртәләр икән.* Р.Сибат // Мактаулы исемгә ия булу. *Күпме еллар күмәк хуҗалык рәисе булып, атказанган хезмәткәр исеме йөртеп, ничек эшләгән соң ул?* З.Дәүләтов. *Бүген безнең гаиләбездә бишебез дә «атказанган» дигән мактаулы исемне йөртә.* Шәһри Казан

21) *күч. Исем, фамилия* сүзләре янында килгәндә, кем исемендә яки фамилиясендә булуны белдерә. *Ул бит әнкәсенең фамилиясен йөртә.* Г.Гыйльманов

22) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса башка бер әйбер белән чагыштырып әйтү, исәпләү, шулай дип уйлау, шундый дип йөрү. *Алар, күрәсең, үз араларындагы бу яшь хатынны сабый чутында йөртәләр иде.* М.Маликова. *Тормышта фәләнчәрәк кешене мин хыялда төгәнчәрәк итеп йөртәмме соң әллә?* Б.Камалов

23) *күч.* Берәр нәрсә аша җибәрү, тапшыру. *Хат йөртү*

24) *күч.* Гайбәт тарату, сүз чыгару. *Гомумән, Нургалиевләр затында сүз йөртү юк та бугай, әнә Югары Авылда тордылар, Мәрьямбикә карчык улкиленнәре, кыз-кияүләре хакында авыз ачып берни сөйләмәде.* А.Гыйләҗев

**2.** *ярд. ф. функ.* Кайбер исемнәр янында килеп, шул исемнәргә бәйләнешле эш-хәрәкәтне алып баруны, шул юнәлештә башкаруны белдерә. *Әләкләрнең бер ише Сәлимгәрәй мөфтигә җибәрелә, шул ук вакытта эшне икенче канал буенча да йөртәләр: губернаторга язалар.* А.Расих

**Йөртә башлау** Йөртергә тотыну. *Сугышка алынган елны ул инде үзе машина йөртә башлаган иде.* Н.Фәттах. *Минем шәкертләрем инде буй үстереп, мыек йөртә башлагандыр.* Н.Дәүли

**Йөртә тору** Озак вакыт берсеннән икенчесенә йөртү. *Аннары минем эш кузгатучылар кирәкле кәгазьләр җыеп бетергәнче, тиешле экспертизалар алганчы һәм эшне бер инстанциядән икенчесенә күчереп йөртә торгач, корольнең үзен алып аттылар.* Р.Мостафин

**Йөртеп алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә йөртү. *Хәлимә карчык кесәсеннән тәсбих чыгарып төймәләрен арлы-бирле йөртеп алды.* Н.Дәүли. *Урта бер җиргә чыгып басып, каршысында диңгез сыман дулкынланып торган халык төркеменә – хәрбиләргә күз йөртеп алды ул.* Р.Мөхәммәдиев

**Йөртеп бетерү** Тулысынча, гел дә, барысын да йөртү. *Баланы гомер буе ата-ана җитәкләп йөртеп бетерә алмый.* Ф.Яруллин

**Йөртеп җибәрү** Йөртә башлау, йөрергә этәргеч бирү. *Мин аңа үзем майтарган эшләр турында хисап бирдем һәм, әүвәлге урынына элеп куелган сәгатькә күрсәтеп: – Йөртеп җибәрү хокукы синеке, – дидем.* А.Тимергалин

**Йөртеп кую** Аз гына, кыска вакытлы, бер тапкыр йөртү. --- *юка, гүзәл затларның битендәге пудра шикелле генә, дип, уң кулын, бармакларын мамык тампоны тоткан кебек җыеп, бите тирәсендә йөртеп куя.* К.Шакиров

**Йөртеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз йөртү. *Әнә бит ул, ычкыну дәрте*

*белән тарткаланып, калкавычны тибрәтә-тибрәтә, үзе дә җепне як-якка йөртеп тора*. Ф.Баттал

**Йөртеп чыгу** 1) Һәрберсен, берсен дә калдырмыйча йөртү

2) Нәрсәне дә булса башыннан алып ахырына кадәр йөртү. *Тикшерүче телеграммага күзләрен йөртеп чыкты: «Иртәгә юлга чыгам. Әзер булып тор»*. Ф.Галиев. *«Исәнме-саумы» юк, тәбәнәк гәүдәлесе калын каш астындагы чепи күзләрен өй эчендә ялт-йолт йөртеп чыкты*. Р.Кәрами

**ЙӨРТҮЧЕ** *и.* **1.** Транспорт чарасы белән идарә итүче; *русчачы:* **водитель**. *[Машина] Йөртүчесенең буе дисәң – негр баскетболчыларың бер якта торсын!* Т.Галиуллин. *Трамвай йөртүченең «Достоевский тукталышы» дигән тавышы Фатыйманы уйларыннан арындырып җибәрде.* Ә.Сафиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Берәр техник чараның нигез өлеше. *Йөртүче ракета. Йөртүче диск*

**ЙӨРҮ** *ф.* **1.** 1) Атлап, аякларны хәрәкәт иттереп, бер урыннан икенче урынга күчү (кеше һәм хайваннар турында).

2) Аякка басу, хәрәкәт итәрлек хәлдә булу (кеше һәм хайван турында). *Бала иртә йөри башлады*

3) Йөзү, йөзеп хәрәкәт итү. *Елгада ташбашлар өерләре белән йөри.* А.Расих

4) Билгеле бер маршрут буенча билгеле бер вакытта хәрәкәт итү (поезд, машина, пароход, самолёт һ.б. турында)

5) Хәрәкәт итеп тору (төрле механизмнарның, техниканың эшләп торуы турында). *Сәгать йөри: келт-келт*. М.Җәлил

6) Берәр максат белән нинди дә булса транспорт төренә утырып хәрәкәт итү (кая да булса бару). *Таштимерова районга гына машина белән килә, авыл арасында ат белән йөри, чыбыркысын кулыннан төшерми, диләр.* М.Маликова

7) Чаңгыда, тимераякта шуу. *Ә көз көннәрендә яңа гына каткан боз өстендә, берсен-берсе куа-куа, тимераякта йөриләр*. С.Җәлал. *Бервакыт дус егет белән шәһәр кырыендагы урманда чаңгыда йөргәндә, атлы чана юлына килеп чыктык.* Татарстан яшьләре

8) Нинди дә булса максат белән даими рәвештә кая да булса бару (төрле юнәлештә даими кабатланып торган хәрәкәт турында). *Көтү яланнан кергәч, көзге һәм кышкы салкыннарда --- шаукымга ияреп кенә түгел, ә чын ихласлык һәм, әйтергә кирәк, кайнар дәрт белән һәвәскәр драма түгәрәгенә йөрде яшь Ильяс.* Ә.Баянов. *Елына ике килә торган гаеттән башка ул үзенең мәчетенә йөрде микән?* Ә.Еники. *Алай да бу шигырь кичәләренә йөрү миңа бик файдалы булды.* И.Салахов

9) Берәрсе янына, берәр җиргә баргалап, килгәләп тору. *Минем йөрүемне бер дә күпсенми тор! Йөресәм, синә йөрмим, --- үземнең туганыма йөрим.* Ш.Камал. *Фатыйма бикә, хөрмәтсезлек булыр дип, матәм көнендә кунакка йөрүне килештермәсә дә, кызы бик ялынып сорагач, туктатырга кыймады, җибәрде.* Г.Ибраһимов

10) Берәр нәрсә аркылы үтү; керү, чыгу. *Урамны кар басты. --- Капкадан йөрергә мөмкин түгел.* Г.Ибраһимов

11) Ял итү, тамаша кылу максаты белән кайда да булса хәрәкәт итү. *Көннәрдән бер көнне бу өч кыз болынлыкка йөрергә дип чыкканнар.* Әкият. *Җылы май кичләренең берсендә, гадәттәгечә, дуслары белән урамда йөрергә чыккан иде.* А.Сафин. *[Ир-егет] Төшендә чибәр кыз белән болын-кырларда йөрде.* Ә.Баянов

12) Бер урыннан икенче урынга күчерү, йөреш ясау (шахмат, шашка уеннарында). *Шаһвәлиев аңа дүрт йөрүдә мат куйды*. Г.Ибраһимов. *Кондырев шахмат фигурасын кулына алып йөрергә әзерләнде* --- Җ.Тәрҗеманов

13) Урыннан урынга күчерелү, хәрәкәттә булу. *Аларның [утын төяп торган кешеләрнең] кулларында метрлы юан агачлар уракчылар кулындагы көлтәләр шикелле җиңел йөрде.* Г.Гобәй. *Ять-яшь кешеләр кирпечләрне тигез, пөхтә түшиләр, мастероклар, оста кулларга буйсынып, күндәм йөриләр.* С.Рафиков

14) Яңа җирләрдә булу, дөнья күрү, сәяхәт итү. *Чит илләрдә йөреп малсыз кайтсаң, Әтиең, әниең, сөйгәнең ят була.* Җыр. *Дөньяны җимерәбез, малай, хәзер чит патша җирләрендә йөрибез.* Г.Ибраһимов. *Шул китүеннән озак еллар йөрергә туры килде аңа.* Э.Касыймов

15) Кайда да булса яки кемнәрдер арасында булу. *Кичә көндез кайда йөрдең? Нурлы йөзең күрмәдем.* Җыр. *«Йөргән таш шомара», – диләр бит. Шулай икән ул, күп йөргәч, дөньяның серенә ныграк төшенәсең икән аны.* Р.Кәрами

16) Нинди дә булса эш башкару, кайда да булса хезмәт итү. *Гасыйм --- хәзер транспорт бригадасында грузчик булып йөрүе турында язган иде.* Н.Фәттах

17) Берәр нәрсәне кайгырту, шуның мәшәкатьләре белән мәшгуль булу. *Булат тагы чәнчеп өстәр: ләкин нык булыгыз, интеллигенциянең бер катлавы, кызарып, «социализм» дип йөри дә, ахырдан барып, мещанлык сазына бата, шунардан сакланыгыз, дияр.* Г.Ибраһимов. *Тапкансыз икән өйләнеп йөрер чак. Мондый маҗара көннәрендә нинди никах ул?* Т.Гыйззәт. *Ул цех артыннан Давытка күп йөрергә туры килде.* М.Маликова

18) Нәрсә белән дә булса шөгыльләнү, шуның белән кәсеп итү. *Шул юлда йөреп, бар дәүләтләреннән аерылып, ахырында адәм мәсхәрәсе булып, хәтта ахырында гомер буенча сәдакага йөреп үлгән кешенең очы-кырые юк.* Г.Камал. *[Мулла Бикчәнтәйгә:] Маймыл, аю биетеп йөрү мөселманлык эше түгел.* Т.Гыйззәт. *Нигә миңа ул маймыл, минем маймыл биетеп йөрер вакытым узган.* Ә.Фәйзи

19) Нинди дә булса киемдә, рәвештә булу. *Бәештә гомер булмаган хәл, ди, мәктәпне җыештыручы безнең күрше апа, кышын да, көязләнеп, юка хром күн итекләрдән йөри.* Г.Тавлин. *Иртәнге чыкта яланаяк йөрү дә кайбер сырхауларга килешә.* Д.Салихов. *Шәкүр --- бик нык рәнҗеде, яше барса да өйләнми йөрде, хатын-кызга ышанычфәлән күрсәтмәде.* Н.Акмалов

20) Нинди дә булса хәлдә яки халәттә булу; кичерешләр, хис-тойгылар

белән яшәү. *Алар икәве, бигрәк тә генерал Корнилов, власть башына менү хыялы белән шашынып йөргәннәр.* И.Гази. *Якты дөньядан караңгы дөньяга кучүенә әби тәки күнегә алмады, өч ай буе әчтән генә сызып йөргәч, гүр иясе булды.* Н.Гыйматдинова. *Мондый көннәрдә әнисе борчулы йөри, юньләп сөйләшми.* Р.Низамиев

21) Сөйләнү, таралу, ишетелү (фикер, сүз, хәбәр һ.б. турында*). Әйе, узган ел «Миңнулладан Мәгъсүмәләргә посылка белән гармун килгән, әмма килендәше аны аларга бирмәгән» дигән имеш-мимешләр йөргән иде авылда.* В.Нуруллин. *Бу турыда авыл халкы арасында да ышын-пышын сүзләр йөрүе Иргали өчен сер түгел иде.* М.Хәсәнов. *Аның хакында мәзәкләр халык арасында да йөри.* Ф.Галиев

22) Кем турында булса да әлегә кадәр башка фикердә булу, ... дип уйлау, ... дип исәпләү, санау. *Кара син аны, йөр син аны «бер надан карчык» дип.* М.Мәһдиев

23) Нинди дә булса эшне эшләргә ниятләнү, исәп итү, уйлау. *Аңгыра, без сезнең шикелле кош тотарга йөрүчеләрнең үзләрен дә яхшы гына капкынга эләктерәбез.* Г.Камал. *Ах, гафу итегез, Николай Иванович, әүвәл менә язам, менә язам дип йөрдем дә, аннан соң сезнең адресыгыз алышынган, дип ишеттем.* Ф.Әмирхан. *[Айбулатовның] Торак йортларны яхшырту, үзгәреш кертү нияте белән йөрүе икән.* Г.Кашапов

24) *куч.* Егет белән кыз мәхәббәт мөнәсәбәтендә очрашу, аралашу, гыйшык тоту. *Ах-вах итми, «сөям» дип вәгъдәләр бирми генә бер-ике ай йөрделәр дә, бер көнне эштән соң Гафурның барактагы бүлмәсенә бергә кайттылар.* Җ.Рәхимов. *Сине «Малтабаров белән йөри» диләр, кызым, шул дөресме? Ул бит – синең әтиең яшендәге кеше!* Азат хатын

25) *күч.* Кемнең дә булса үз-үзен билгеле рәвештә тоту. *Пош-пош килеп, кибәк ашаган сыер шикелле мышкылдап йөри.* Г.Камал. *Килен бит һаман минем күз алдымда: --- бик акыллы, бик әйбәт йөри.* Г.Бәширов. *Хватит миңа шыксыз үрдәк баласы булып йөрергә!* М.Мәһдиев

26) *куч.* Кемнең дә булса киңәшен тоту, аныңча эшләү, яшәү. *Бу эштә син аның [әнкәңнең] сүзен тыңла, атаңча йөр.* Ф.Хөсни. *Синең сүзең белән йөргән мин – җүләр!* М.Мәһдиев

27) *куч.* Яшәү, тору. *Кыз, көнләшүдән үз-үзен кая куярга белмичә, юка күлмәктән килеш чыгып китеп, ике айга якын сукбайлыкта йөрде, дөньяга әйләнеп кайтты.* Ш.Шәйдуллин

28) *куч.* Акча кулланышта, әйләнештә булу. *Акча ул кайберәүләрдә капчыклап йөрде, тик менә аларда гына – Габделхәйләрдә генә – капчыклап та, янчыклап та булмады.* Н.Фәттах

29) *куч.* Законлы яки абруйлы көчкә ия булу (сүз, боерык һ.б.ш. турында)

30) *куч.* Югары авторитетка ия булу. *[Наилә иренә:] Нургалиевләр фамилиясе шактый югары дәрәҗәдә йөри икән монда!* А.Гыйләҗев

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Эш-хәлнең дәвамлы һәм өзлексез булуын, субъект өчен чагыштырмача даими булган эш-хәрәкәтне белдерә. *Ләкин хәтер саклап, әдәп саклап, моңарчы дәшми йөрделәр.* Я.Зәнкиев. *Мондый әсәрләр башта телдән телгә сөйләнеп, җырланып йөриләр.* Туган тел

2) Шушы моментта башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә. *Кара әле, матуркай, нишләп монда лампа тотып чуалып йөрисең?* Ш.Камал. *Станциядә манёвр ясап йөргән паровозның өзек-өзек сызгыртулары ишетелә.* Г.Әпсәләмов

**Йөреп алу** Кыска вакыт арасында, тиз арада йөрү. *Ә авылда төрле хәбәрләр йөреп алды.* М.Хуҗин

**Йөреп китү** Кинәттән берәр урыннан йөри башлау. *Төрле планнар уйлап, без тагы йөреп киттек.* Г.Исхакый. *[Әхмәтсафа] Куллары белән идәнгә таянып, аякларын төп-төз өскә күтәрде һәм, барсын да шаккатырып, кулларында җиңел генә йөреп китте.* Ф.Сафин. *Габбаниның аякка йөреп китә алмавына аптырыйлар иде врачлар.* Ә.Галиев

**Йөреп тору** Бертуктаусыз йөрү. *Ике як та бер-берсен күзәтәләр, төннәрен ут сызыгы аша разведчиклар йөреп тора.* Ә.Галиев. *Кайтырсың әле, машина йөреп тора.* Н.Фәттах. *Кышлагыгыз ул хәтле җиде җир чите түгел, халык гел йөреп тора.* Т.Әйди

**Йөреп чыгу** Һәрберсендә булып бер-бер артлы йөрү. *Әти, дим, мин ул өйләрне йөгереп кенә йөреп чыгам!* М.Хуҗин. *Өч кыш рәттән бөтен илне йөреп чыктым лабаса, чыныгырга вакыт бит инде.* Д.Лондон. *Ул этажларны йөреп чыгуга, ишекләр шапылдап ачыла-ябыла, һәм егетләрнең йокылы-уяулы гәүдәләре коридорда күренә башлады.* Р.Кәрами

**Йөри бару** Һаман да йөрү, торган саен күбрәк йөрү. *Касыйм көннән-көн Фәридә артыннан ныклап йөри бара, аңар ялына, бик усал дәлилләр белән үзенең яратканын аңлатырга азаплана.* С.Җәлал

**Йөри башлау** Йөрергә тотыну. *Баламның тәлгәне булмагач, бөтенләй йолкынган тавык кебек йөри башлады.* Һ.Такташ. *Мин директор булып килгәч, мунчага халык күбрәк йөри башлады.* Р.Батулла

**Йөри бирү** Бернигә карамый йөрүен дәвам итү, һаман йөрү. *Бер көн шулай кабатланган бу, икенче көнне дә, тик сүз әйтмәгән: «ак» димәгән, «кара» димәгән, лач-лоч басып гел йөри биргән.* З.Хөснияр. *Ә үзе көтте, һаман көтте, һаман ялгыз килеш, буйдак килеш йөри бирде.* З.Садыйков. *Картәтәй бик үк риза булмаган, ләкин, ул каршы килгән саен, яшьбабай киреләнеп алдынгылар рәтендә йөри биргән.* Н.Фәттах

**Йөри тору** Даими рәвештә, әледән-әле йөрү. *Апам шулай бире килә-китә йөри торды.* Н.Дәүли

**ЙӨТКЕРЕК** *и. диал. к.* **йөткереш**

**ЙӨТКЕРЕНҮ** *ф. к.* **йөткерү**. *[Залда] утыргыч такталары бәрелгән тавышлар, йөткеренүләр дә тынды.* Г.Үзиле

**Йөткеренеп алу** *к.* **йөткереп алу** (*1 мәгъ.*). *[Наҗия] Бераз гына җырлагандай итте дә, тамагы карлыгып, йөткеренеп алды.* Н.Фәттах

**ЙӨТКЕРЕШ** *и. сир.* Сулыш юлларына салкын тигәннән яисә башка

сәбәптән барлыкка килгән гыжылдаулы, калтыраулы тавыш; ютәл. *Берничә минуттан соң инде аның эчендә ниндидер бер хатынның картлык йөткереше белән йөткерә-йөткерә чыгып килгәнлеге сизелде.* Ф.Әмирхан

**ЙӨТКЕРТҮ** *ф. з.-сыз.* Ютәл тоту, кат-кат ютәлләтү. *[Зәлинәнең] Кинәттән генә температурасы күтәрелеп, бөтенләй хәлсезләнеп калды. Өстәвенә бөтен тамак төбен ертып йөткертә.* Ф.Тарханова

**Йөткертә башлау** Йөткертергә тотыну. *Ишек яңагына элгән халатын танымады Наилә, ятсынып кулына алган иде, аннан болыт булып тузан бөркелеп, борын тишегенә тулып төчкертә, йөткертә башлады.* А.Гыйләҗев

**ЙӨТКЕРҮ** *ф.* Сулыш юллары сәламәт булмау сәбәпле, өзек-өзек, калтыраулы тавыш белән тын чыгару; ютәлләү. *Колакка ат пошкырган, ат кешнәгән, үгез мөгрәгән йә сарыкларның «кәһ-каһ» йөткергән тавышлары ишетелеп китә.* А.Расих. *Кемдер авыр сулап куйды, кемдер учына йөткерде.* Ф.Латыйфи. *[Фәриднең] Күңеленә: «Рөстәм абыйны күрсәм, йөткерүем дә бетәр, ябыкканым да, тагы әүвәлге шикелле шат тора башлармын», – дигән уй килә.* С.Җәлал

**Йөткерә башлау** Йөткерергә тотыну. *Кинәт ул буылып йөткерә башлады. Аның тыны капланды.* Р.Батулла

**Йөткереп алу** 1) Тиз арада кыска гына йөткерү. *Байтирәкләр турына җиткәч, туктады, койма аша үреләп карады да, чемоданын куеп, учына йөткереп алды.* М.Галиев. *Хәмдүнә әби, авызын каплап, әкрен генә йөткереп алды.* Р.Бәшәр

2) *күч.* Өзек-өзек тавышлар чыгару. *Бер көйгә генә тырылдап эшләгән көймә моторы бер-ике мәртәбә йөткереп алды да шым булды.* З.Хөснияр

**Йөткереп бетү** Бик нык йөткерү дәрәҗәсенә җитү. --- *ул кеше үзенең иткән хезмәте, бетергән гайрәте һичбер төрле мәгънәви файдага китмәгәнен күрсә, шөбһәсез, шул идея банкротлыгын күтәрә алмас иде, шөбһәсез, ул кеше янып-көеп үләр иде. Яки аһ-ваһ итеп, йөткереп бетәр иде.* Г.Исхакый

**Йөткереп җибәрү** Кинәт йөткерә башлау. *Шулкадәр тамак кырып бер рәхәтләнеп йөткереп җибәрәсе килә: түзә торган түгел.* В.Нуруллин

**Йөткереп йөрү** Әле, хәзерге вакытта йөткерү. *Кич белән яшелчәләргә су сипкәндә, юри кырык-кырык йөткереп йөри дә, авыл малайлары безнең бакчага борылып та карамыйлар.* Аманулла

**Йөткереп кую** Бер тапкыр йөткерү. *Ара-тирә каты көзге юлда аяк кыштырдаганы ишетелгәли, берәрсе йөткереп куя.* Г.Бәширов. *[Әхмәт Тимер] Тамагын кырды, йөткереп куйды.* С.Йосыпов

**Йөткереп тору** Әле, хәзер йөткерү; бертуктаусыз йөткерү

**Йөткереп чыгу** Күпмедер вакыт дәвамында йөткерү. *Ике бүлмә арасындагы юка дивар аша Фатих Әмирхан шагыйрьнең төннәр буе йөткереп чыкканлыгын ишетеп, борчылып ята торган була.* Л.Хәмидуллин. *Кичләрен, типографиядән кайтканда, салкын җилләр Габдулланың гәүдәсен куырып ала да, аннан ул төн буе йөткереп чыга.* М.Гарипов

**ЙЫРМАЧ** *с. тар.* Алдан барып разведка ясый торган. *Эске кирмәнне Чалбай хан алды, кирмәнне кайтарырга кимендә ун төмән алай җибәрергә иде, ә хан бер төмән йырмач алай җибәрә.* М.Хәбибуллин

## ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21

Справочное издание

**ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ**
**ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**
(на татарском языке)

**Том II**
**(Г–Й)**

Редактор *Н.К. Нотфуллина*
Корректоры: *Н.К. Нотфуллина, Р.К. Сагдиева*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать . .2016.
Формат 84×108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 78,5. Уч.-изд. л. 93,85
Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20